ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ ФӘННӘР АКАДЕМИЯСЕ
Г. ИБРАһИМОВ ИСЕМЕНДӘГЕ ТЕЛ, ӘДӘБИЯТ һӘМ СӘНГАТЬ ИНСТИТУТЫ

ТАТАР ТЕЛЕНЕҢ АҢЛАТМАЛЫ СҮЗЛЕГЕ

IV том

Л–Р

Казан · 2018

УДК 811.512.145'374.3
ББК 81.2Тат-4
Т 23

Татарстан Республикасы Фәннәр академиясе
Г. Ибраһимов исем. Тел, әдәбият һәм сәнгать институтының
Гыйльми советы карары нигезендә басыла

«2014–2020 елларда Татарстан Республикасы дәүләт телләрен һәм Татарстан Республикасындагы башка телләрне саклау, өйрәнү һәм үстерү» дәүләт программасы кысаларында нәшер ителә

Россия Федерациясенең авторлык хокукы һәм эргәдәш хокуклар турындагы законнары белән саклана (РФ ГК, 4 өлеш). Китапны тулысы белән яки өлешчә, төрле, шул исәптән электрон мәгълүмат чыганакларына урнаштыру авторлык хокукына ия юридик затның язма рөхсәтеннән башка катгый тыела

Проект җитәкчесе – А.Ә. Тимерханов

Төзүче авторлар:

Ф.И. Таһирова, Э.И. Сафина, И.И. Сабитова, Ф.Ф. Гаффарова , Р.Т. Сәфәров, О.Н. Галимова, Р.Р. Абдуллина, Г.Р. Сәмирханова, Ф.А. Кушелекова, Г.Г. Саберова

Фәнни редакторлар:

Ф.И. Таһирова, Р.Т. Сәфәров

Бәяләүчеләр:

ТР ФА Татар энциклопедиясе һәм төбәкне өйрәнү институтының Энциклопедистика үзәге (мөдире – Р.В. Шәйдуллин, тарих фәннәре докторы, профессор);
М. Акмулла исем. Башкорт дәүләт педагогика университеты Филологик белем бирү һәм мәдәниятара багланышлар институтының татар теле һәм әдәбияты кафедрасы (мөдире – И.С. Насипов, филология фәннәре докторы, доцент)

Т 23 **Татар теленең аңлатмалы сүзлеге:** IV том: Л – Р. – Казан: ТӘһСИ, 2018. – 760 б.
ISBN 978-5-93091-272-2

Татар теленең күптомлы фундаменталь аңлатмалы сүзлеге – күләме һәм эчтәлеге белән мондый төр сүзлекләрдән иң тулысы. Ул татар тел белеме, тюркология һәм гомуми лексикографиянең ирешкән уңышларын, уңай тәжрибәсен исәпкә алып төзелде.

IV томда барлыгы 10 500 дән артык сүз һәм 1100 гә якын фразеологик берәмлек теркәлде. Төп фигыль оясында мәгънә төсмерләренә ия булган тезмә фигыльләр дә исәпкә алынды. Сүзлек хәзерге татар әдәби теленең киң кулланышта йөргән актуаль лексикасы һәм фразеологиясеннән, төрле фән һәм хуҗалык тармакларына караган термин, атамалардан гыйбарәт. Анда соңгы вакытта татар теленең үз мөмкинлекләре исәбенә ясалып, кулланышка кереп киткән неологизмнар, кабат активлашкан сүзләр, телне баетырдай диалектизмнар, алынмалар да чагылыш тапты.

Сүзлек киң катлау укучыларга, шулай ук төрле фән белгечләренә гамәли кулланма буларак тәкъдим ителә.

ISBN 978-5-93091-272-2

© ТФА Г. Ибраһимов исем. ТӘһСИ, 2018

СҮЗ БАШЫ

Татар теленең күптомлы фундаменталь аңлатмалы сүзлегенең I томына А – В, II томына Г – Й, III томына К хәрефенә башланган сүзләр кертелде. IV том Л – Р хәрефләренә башланган сүзләрдән тора. Сүзлеккә кагылышлы белешмә материаллар тулы шәкелдә I томда бирелде.

Проектның гомуми координаторы һәм җитәкчесе – А.Ә. Тимерханов.

Сүзлекнең IV томын төзүдә түбәндәге хезмәткәрләр катнашты: Ф.И. Таһирова – Л хәрефе (лекарь – ли); М хәрефе (М – михнәт); Э.И. Сафина – М хәрефе (михнәтле – мүкәләп); И.И. Сабитова – П хәрефе (полинезияле – проректор; процентлау – пюпитр); Ф.Ф. Гаффарова – Л хәрефе (лактобациллин – лекальщик); Р хәрефе (тулысынча); Р.Т. Сәфәров – Н хәрефе (тулысынча); Ө хәрефе (өтәләү – өянкелек); О.Н. Галимова – О хәрефе (тулысынча); Р.Р. Абдуллина – Л хәрефе (ладан – лактация; лиана – ләх); Ө хәрефе (өге-җөге – өтәләнү); Г.Р. Сәмирханова – П хәрефе (П – печтек); Ф.А. Кушелекова – П хәрефе (пичәткә – полиневрит; проспект 1 – процентсыз); Г.Г. Саберова – Л хәрефе (Л – лагырт-логырт); П хәрефе (печәнче – пүчтәк).

Сүзлек материалы элекке алфавит тәртибендә бүленде, соңыннан хәзерге алфавитка туры китереп урнаштырылды.

Сүзлекнең IV томын түбәндәге хезмәткәрләр редакцияләде: Ф.И. Таһирова, Р.Т. Сәфәров.

Томны туплау, материалларны берләштереп, алфавитка салу эшен А.Ә. Тимерханов һәм Р.Т. Сәфәров башкардылар.

Авторларның исемнәрен албиттә күрсәтү тәртибе аларның сүзлек төзүгә керткән өлешләрен исәпкә алып билгеләнде.

Хезмәтнең һәр томы электрон форматта http://antat.ru/ru/iyli/publishing/book/ адресы буенча урнаштырылган.

Сүзлекнең эшләнешенә, эчтәлегенә бәйле фикер һәм теләк-тәкъдимнәрегезне түбәндәге адреска юллый аласыз:

420111, Казан шәһ., К. Маркс ур., 12 йорт
ТР ФА Г. Ибраһимов исем. Тел, әдәбият
һәм сәнгать институты.
Электрон адрес: iyali.anrt@mail.ru.

СҮЗЛЕКТӘН ФАЙДАЛАНУЧЫЛАР ӨЧЕН БЕЛЕШМӘ

I. Сүзлеккә сүзләр алу тәртибе

§ 1. Сүзлекнең нигезен хәзерге әдәби тел сүзләре һәм фразеологик берәмлекләре тәшкил итә.

§ 2. Сүзлеккә түбәндәге төркем сүзләр дә кертелде:

а) урта мәктәп һәм югары уку йортлары дәреслекләрендә очраган төп төшенчәләрне белдергән сүзләр (**БА́ЗИС, БАКТЕ́РИЯ, ТИГЕЗЛӘМӘ, ФО́РМУЛА** һ.б.);

ә) газета-журналларда урын алган күпчелек иҗтимагый-сәяси терминнар (**ДОТА́ЦИЯ, ВӘКАЛӘТ, РЕФЕРЕ́НДУМ, РЕЙД** һ.б.);

б) моңа кадәр басылып чыккан лексик минимумнарда һәм терминологик сүзлекләрдә тәкъдим ителгән аерым терминнар яки аларның тәрҗемәләренең шактый күләме (**АСТӨШЕРМӘ, БАШЛАМ, БИЗӘМ, ӨЛГЕ, ТАМГАХАНӘ, ТЕРКӘ́Y** һ.б.);

в) бүгенге көн өчен яңа булган, вазгыятнең үзгәрүе белән килеп кергән, язма әдәбиятның барлык төрләрендә дә очраган Европа телләреннән алынган сүзләр (**БА́ЙКЕР, БАЙТ, БО́НУС, ДИВИДЕНД, ДИ́ЛЕР, ИПОТЕ́КА** һ.б.);

г) дингә, халык ышануларына, мифологиягә, йолаларга, төрле ырымнарга бәйләнешле сүзләр (**БАКЫЙ, БАПТИЗМ, БӘДӘЛ, БӘРМӘНЧЕК, НАРДУГАН, ФАНИ** һ.б.);

д) яңадан кулланышка актив кереп бара торган, телдә кабат торгызылган искергән сүзләр (**БАГАВЫЛ, БАЕК, БАЙСА, БАЛГА** һ.б.);

е) хәзерге чорда активлашкан һәм урта мәктәп, югары уку йортларында өйрәнелә торган борынгы әдәбиятта очраган гарәп һәм фарсы телләреннән кергән шактый алынма сүзләр (**БАБ, БАГБАН, БАЗАРКӘН, ҖӘНҮБ, ИГАНӘ, ИГЪДАДИ, ИГЪТИБА́РӘН** һ.б.);

ж) тарихи фактларны һәм электәге тормыш-көнкүрешне чагылдырган искергән сүзләр (**ӘДЕРНӘ, БАРЫМТА, БАТМАН, БАТРАК, БИЗМӘН, КАБИЛӘ, КАГАН, КАГАНЛЫК, НӨГӘР** һ.б.);

ж) әдәбиятта еш очраган һәм, киң кулланышка кереп, әдәби телне баетырдай дип табылган диалекталь сүзләр (**ӘНӘЧӘ, БАДЪЯН, БАШБАТА, КАБЫГУ, КАЗЫМА, ШАМА** һ.б.);

з) матур әдәбият әсәрләрендә очраган яки хәзерге әдәби телдә еш кулланыла торган гади сөйләм сүзләре (**БӘЛШӘЮ, БӘРГӘЛӘШ, БЕЛӘМӘН** һ.б.);

и) киң кулланышка кергән яңа реалияләрне белдерү өчен, телнең үз җирлегендә ясалган яки мәгънәләре киңәйгән яңа сүзләр (**БАКЫЙЛЫК, БАРЛАМА, БАСМАК, ИГАНӘЧЕ, КОЛАКСА, КЕРТЕМ, ЭШМӘКӘР** һ.б.).

§ 3. Сүзлек берәмлеге итеп барлык грамматик сүз төркемнәренә дә караган сүзләр алынды. Конверсия юлы белән барлыкка килгән сүзләр һәм аларның мәгънәләре төп сүз мәкаләсендә күрсәтелде.

ӘВӘРӘ *и. фар.* **1.** Бик буталчык хәлләр, вакыйгалар. *Аның ул әвәрәгә ничек катнашып китүен һич аңлап та булмый, юкса, иреккә чыгарына да нибары өч ай гына калган булган.* Казан утлары

2. *хәб. сүз мәгъ.* Бер нәрсәгә бирелеп китү, мавыгу. *Нинди эшкә башың әвәрә?* Н.Исәнбәт

§ 4. Мөстәкыйль сүзлек берәмлеге буларак, тамыр сүзләр белән берәттән, барлык сүз төркемнәренә дә караган төрле типтагы ясалма сүзләр дә кертелде. Шул исәптән: а) кушымчалау юлы белән ясалган сүзләр (**ӘЙЛӘНЕШ, ВӘКАРЬЛЕК, ҖӘМӘГАТЬЧЕЛЕК** һ.б.); ә) саф кушма сүзләр (**АМПЕРМЕТР, АРПАБАШ**, **АЯ́ГҮРӘ, БАШКИСӘР** һ.б.); б) кыскартылган кушма сүзләр (**БАТРАЧКОМ, БЕНЗОВОЗ, РАБФАК** һ.б.); в) парлы сүзләр (**АНДА́МОНДА, БАШ-АЯК**, **КҮРШЕ́-КҮЛӘН, САВЫТ-САБА** һ.б.); г) компонентлары аерым язылса да, кушма һәм тезмә сүзләр (**БАКА́ ЕФӘГЕ**, **БАКА́ ЯФРАГЫ**, **БАЛА́Н БАРМАК, БАСЫМЧА́К ИТҮ, ВАСЫЯ́ТЬ КЫЛУ, КЫШТЫР-КЫШТЫР ИТҮ** һ.б.).

§ 5. Киң кулланылышлы һәм продуктив булган алкушымчалар, шулай ук кушма сүзләрнең беренче яки икенче кисәкләре сүзлектә аерым мәкалә итеп бирелде (**АВИА-, АВТО-, АГРО-, -АРА, БИ-, БИО-, НЕО-, -СЫМАННАР** һ.б.).

§ 6. Сүзлектә түбәндәге сүзләр бирелмәде: а) үтә профессиональ сүзләр, ягъни фәннең һәм техниканың тик аерым тармакларында гына белгечләр тарафыннан кулланыла торган сүзләр; ә) әдәби телне баетмый һәм әдәбиятта гомумән очрамый торган җирле сөйләм сүзләре (диалекталь сүзләр); б) тупас сөйләм сүзләре, жаргон сүзләр; в) хәрефләрдән һәм авазлардан торган кыскартылма сүзләр; г) ялгызлык исемнәре.

II. Сүзлекнең төзелеше

§ 7. Сүзлектә баш сүзләр алфавит тәртибендә урнаштырылды, һәм алар үзләренә караган материал (аңлатмалар, мисаллар, фразеологик берәмлекләр) белән бергә сүзлек мәкаләсен тәшкил итә.

§ 8. Баш сүздән соң аның сүз төркемен, чыганак телен, стилистик үзенчәлекләрен сыйфатлый торган билгеләре куелды. Шуннан соң мәгънәгә аңлатма бирелде, иллюстратив материал китерелде. Сүзнең барлык мәгънәләрен дә ачып бетергәннән соң, кызыл юлдан шул сүз белән башланган фразеологик берәмлекләр теркәлде.

§ 9. Башка сүз төркеменә күчеп ясалган сүзләр ноктасы калын, ә аларның мәгънәләре җәяле якты гарәп цифрлары белән аерылды.

ИКМӘК *и.* **1.** 1) Ачытылган камырдан мичтә пешерелгән ризык; ипи. *Һади, ап-ак тешләрен икмәккә батырып: – Тәмле! – диде. Икмәк телеме күз ачып йомганчы юкка чыкты.* А.Гыйләҗев ...

2) Ашлык. *Гектарыннан утыз, кырык центнер алган хуҗалык күп булды. Колхоз ындырларында икмәк таулары ясалды.* М.Мәһдиев ...

3) Кырда үсеп утырган иген. *Болгарларның җирләрендә бодай, арпа, тары һәм башка төрле икмәк тә үскән.* Г.Гобәйдуллин ...

2. *ы. мәгъ. сөйл. к.* **икмәктер**. *Конкурста мин беренче урынны алам, Гөлүсә. Чын, икмәк!* Н.Гыйматдинова ...

§ 10. Һәр мәгънә кызыл юлдан башланып китте. Сүзнең якынрак мәгънә төсмерләре параллель сызыклар (//), ә тагы да якын мәгънәләре ноктасы өтер (;) ярдәмендә аерып күрсәтелде.

ӘДӘП *и. гар.* 1) Җәмгыятьтә гомум кабул ителгән әхлак кагыйдәләре; яхшы гадәтләр ... // Кеше арасында үз-үзеңне әхлак кагыйдәләренә туры китереп тота белү сыйфаты ...

2) Яхшы гадәт, йола ...

АРКАДАШ *и.* **1.** Иптәш, дус; таяныч. *Иске белешләр кебек, мәктәп аркадашлары кебек дуслашканнар иде.* Г.Исхакый ...

§ 11. Тигез хокуклы грамматик һәм фонетик вариантлар мөстәкыйль сүзлек берәмлекләре итеп алындылар, һәм һәркайсы алфавит тәртибендә үз урынында бирелде.

АСТРОЛЯБ *и. гр. сөйл. к.* **астролябия**. *Бер якта астролябка таянган Әбелхарис күренә. --- Әбелхарис астролябын тоткан килеш катып кала*. Н.Исәнбәт

АСТРОЛЯ́БИЯ *и. гр.* Астрономиядә: озынлык һәм киңлекне, шулай ук җир үлчәү эшләрендә горизонталь почмакларны билгели торган почмак үлчәү әсбабы

§ 12. Компонентлары аерым язылган, лексик берәмлек тәшкил иткән кушма һәм тезмә сүзләр дә аерым сүзлек мәкаләсе итеп китерелде, сүзлектә алфавит тәртибендә урнаштырылды һәм аңлатылды.

ӘҖӘ-ГӨҖӘ КИЛҮ *ф.* Озак итеп, дусларча сөйләшү ...

ИГЕ́Н ГӨМБӘСЕ *и. а.х.* Ашлык бөртекләрен, зарарлап, кара тузанга яки кибәккә әйләндерә торган гөмбә авыруы; корымбаш; *русчасы:* **головня**

§ 13. Омонимнар шулай ук һәрберсе аерым мөстәкыйль сүзлек берәмлеге итеп алынды һәм якты рим цифрлары белән күрсәтелде.

БИК I *и.* 1) *иск. кит. к.* **бәк**

2) Морзалар нәселендәге фамилияләрдә һәм кайбер кушма исемнәрдә сакланган компонент: *Биктимер, Бикбулат, Ханбиков*

БИК II *и.* 1) Бикләп кую җайланмасы; йозак, келә, бастырык, бикләвеч. *Сыерның тыныч кына күшәп ятуын ишеткәч, җиңел сулап җибәрә, чолан ишегенең биген тикшерә, өй ишеген «бисмилла» әйтеп яба, аннары түшәген җәеп, ятарга әзерләнә башлый.* И.Гази ...

БИК III *рәв.* **1**. 1) Гаять, көчле дәрәҗәдә, гадәттән тыш, чиктән ашкан, югары дәрәҗәдә, искиткеч, искитмәле. *Шулай бик озак барганнан соң, алда, бик ераста, кыр өстендә аз гына калкып, соры карамчык кына булып, бер авыл күренә башлады.* Г.Бәширов ...

III. Сүзләрнең мәгънәләрен билгеләү һәм аларны аңлату

Мәгънәләрне алу һәм урнаштыру тәртибе

§ 14. Сүзлектә китерелгән һәр тел берәмлегенең хәзерге әдәби телдә кулланылган барлык мәгънәләре дә аерып күрсәтелде.

§ 15. Алынма сүзләрнең бары тик татар телендә кулланылган мәгънәләре генә китерелде.

§ 16. Күп мәгънәле сүзләрне шәрехләгәндә, аның бөтен семантик кыры исәпкә алынып, аерым мәгънәләре билгеле бер тәртиптә урнаштырылды:

а) мәгънәләрнең бирелеш тәртибе, беренче чыратта, аларның хәзерге әдәби телдәге кулланылыш ешлыгыннан чыгып билгеләнде; мәгънәләр логик эзлеклелекне һәм генетик бәйләнешне мөмкин кадәр сакларга тырышып урнаштырылды;

ә) мәгънәләрнең үсеш-үзгәрешендәге тарихи эзлеклелекне хәзерге тел материаллары ачык күрсәтеп торганда, сүзнең мәгънә төзелешен аңлауны җиңеләйтерлек очракларда, беренчел мәгънәләр, искергән булса да, алдан бирелде. Калган барлык очракларда искергән мәгънә, кагыйдә буларак, хәзерге мәгънәләрдән соң гына теркәлде;

б) конкрет мәгънәләр абстракт мәгънәләрдән алдарак урнаштырылды;

в) киң кулланыштагы мәгънәләр аның таррак кулланыштагы (гади сөйләм, диалекталь, терминологик һ.б. өчен хас булган) мәгънәләреннән алдарак китерелде;

г) диалекталь мәгънәләр гомуми һәм махсус кулланыштагы мәгънәләрдән соң теркәлде;

д) күчерелмә мәгънәләр туры мәгънәләрдән соң бирелде;

е) бер үк стилистик төсмергә ия булган мәгънәләрнең куллану ешлыгы югарырак булганы алданрак китерелде;

ж) сүзнең аерым синтаксик позициядә ачылган мәгънәләре төп мәгънәләрдән соң урнаштырылды.

БА́ЙТАК *рәв.* **1.** Шактый, шактый зур, шактый күп. *Кичкә таба өй тәмам туздырылып, аннары тау башындагы күрше авылга ташылып беткәч тә, капка һәм койма баганалары белән байтак изаландык әле без.* М.Вәли-Барҗылы ...

2. *с. мәгъ.* Шактый санда булган, күп. *Инде байтак гомер яшәлгән, байтак һава суланган, су эчелгән, дөнья күрелгән, дигән сүз.* Ф.Латыйфи ...

3. байтагы, байтагысы *и. мәгъ. тартымлы форм.* Зур өлеш, зур кисәк, зур төркем; бөтеннең зуррак өлеше. *Урдәкләрнең байтагысы күл өстендә пыр итеп очтылар да түгәрәк ясап әйләнделәр.* Я.Зәнкиев ...

ж) мөстәкыйль сүзнең ярдәмлек функциясендә кулланылган мәгънәсе (яки мәгънәләре) аның мөстәкыйль мәгънәләреннән соң бирелде.

БӘРАБӘР *с. фар.* **1.** Бердәй дәрәҗәдәге, тиң булган, лаек. *Үзенә бәрабәр ана арыслан белән юлдаш булып, сахрада кунды.* Дастан ...

2. *рәв. мәгъ.* Бердәй, тиң. *Ә бит, чыдамлык белән сабырлык фатихага бәрабәр, дигән китап.* М.Хәсәнов

3. бәрабәренә *бәйл. функ.* Хакына, исәбенә. *Дөрес, без миллионнарның каны, җаны бәрабәренә, кеше гомере белән һич исәпләшеп тормастан, дөньядагы афәтләрнең берсен – фашизмны җиңеп чыктык.* А.Гыйләҗев ...

§ 17. Конверсия юлы белән барлыкка килгән сүзләрдә ачылган мәгънәләр шул ук мәкалә эчендә төп мәгънәдән соң теркәлде.

ЕЛДЫРЫМ *и.* **1.** 1) Җәй көне арыш өлгергән вакытта кичләрен, төннәрен офык читендә күренә торган күкрәүсез яшен чаткысы; ажаган. *Оренбург төбәгенең иркен дала ягы авылларында күк күкрәүсез ул яшен елдырымны никтер «рәшә уйнау» дип атыйлар.* А.Хәмидуллин ...

2) *диал.* Яшен. *--- бөтен тирә-якны сызылып яктырткан елдырым балкышындагы төсле [күзаллады].* Т.Әйди ...

3) Нинди дә булса утлар уйнау чагылышы. *Дөм караңгы төн, туплар гөрселди, офыкта утлар елдырымы чагылып китә, ә җирнең калтырап куйганын аяк табаннары гына сизә.* Х.Камалов ...

4) *күч.* Берәр өлкәдә аз вакыт эчендә эз калдырган күренекле кеше. *Үзе дә әдәбият тарихында якты эз сызып, мәдәниятебез күгендә беренче рәшә, беренче елдырымнардан булган олы әдип Фатих Кәрими шагыйрь турында мондый сүзләр язып калдырган ---.* Л.Хәмидуллин ...

5) *күч.* Көтмәгәндә һәм тиз арада булып алган нинди дә булса физик яки рухи халәт, психик күренеш. *Уттай кайнар елдырым аркасын пешереп узды.* Х.Камалов ...

2. *с. мәгъ. күч.* Елгыр, җитез, өлгер; хәрәкәтчән. *Мин Зөһрә туташ белән сөйләштем. [Гарифҗан:] Сөйләштең? Елдырым егет икән син.* Н.Исәнбәт ...

§ 18. Сүзнең берәр кыек грамматик формасы өчен генә хас булган мәгънә (яки мәгънә төсмере) шул ук мәкалә эчендә әйтелгән грамматик формада гомуми кагыйдәләр нигезендә бирелде.

БАШ *и.* **1.** 1) ...

21) **башында** *күч. тарт. һәм кыек килеш форм.* Төп җитәкче, оештыручы урынында, башлык дәрәҗәсендә. *Ипташлар, хәзер җирле граждан эшләре башында торучы Ногматов ипташкә яшьләрнең регистрацияләре турында хәбәр итү өчен сүз бирелә.* Ф.Бурнаш

БАГУ I *ф.* **1**. 1) *диал.* Карау, күз карашын юнәлтү, күз салу. ...

3. **бак, ба́ксана** *ы. мәгъ.* «Кара син аны», «кара әле» мәгънәсендә, игътибар итәргә кирәклекне, гаҗәпкә калуны белдерә. *Баксана! Бөтен күлем айкала!* Н.Исәнбәт. *Гөлҗамал абыстай, ишеткәнең бармы әле, менә бу кем малаеннан, баксана, аты коргыры, үләме әллә югыйсә...* М.Гали

4. баксаң, бактың исә *кер. сүз мәгъ.* 1) Чын-чынлап уйласаң, игътибар итсәң. *Баксаң, шунда бер матур кыз тынып калган.* Н.Исәнбәт. *Бакты исә, бер дә катлауландырасы юк, барысы да мөмкин икән.* Ф.Хөсни

2) Соңыннан билгеле булганча, чынлыкта, чынбарлыкта. *Баксаң, әле генә китерелгән сан да «соңгы сүз» булмаган икән.* М.Госманов...

§ 19. Алынма сүзләрнең мәгънәләрен бирү тәртибе татар теленда кулланылган мәгънәләренең үзара бәйләнешеннән чыгып билгеләнде.

РАДИА́ТОР *и. лат.* 1) Эчке янулы двигательләрне сыеклык ярдәмендә суыту җайланмасы. *Йөк машинасында йөрүче безнең бер шофёрның радиаторына ябалак бәрелгән булган.* Г.Әпсәләмов

2) Үзәктән ягып җылыту системасында пар яки кайнар су йөри торган торбаларга тоташтырылган җайланма

Мәгънәләргә аңлатма бирү тәртибе

§ 20. Сүзлек берәмлеге итеп алынган барлык гади, кушма һәм тезмә сүзләрнең һәм фразеологик гыйбарәләрнең мәгънәләренә һәм мәгънә төсмерләренә тиешле аңлатма бирелде.

§ 21. Аңлатмалар стилистик яктан нейтраль, туры мәгънәдәге һәм гомуми кулланыштагы сүзләр ярдәмендә генә төзелде. Тар кулланылышлы (гади сөйләмгә караган, поэтик, диалекталь, махсус һ.б.), сирәк очрый торган, искергән сүзләр яки сүзләрнең күчерелмә мәгънәләре, шулай ук бу сүзлеккә кермәгән сүзләр аңлатмаларда файдаланылмады.

§ 22. Сүзлектә, сүзнең мәгънәсен ачыклау өчен, аңлатмаларның өч төрле ысулы кулланылды:

1. Тасвирлаулы аңлатма. Сүзләрнең мәгънәсе һәм мәгънә төсмерләре күпчелек очракта кыскача аңлатма бирү юлы белән ачыкланды.

ҖАМАЯК *и.* Төрле зурлыкта һәм тирәнлектә булган тоткасыз савыт. *Карчыкның кулыннан агач җамаягы төшеп китеп, ат аягы астына тәгәрәде.* М.Галәү ...

2. Синонимик аңлатма, ягъни сүзнең мәгънәсен ачу өчен, аның синонимын (синонимнарын) файдалану. Мондый аңлатмалар бигрәк тә нинди дә булса берәр стилистик төсмере булган (искергән, диалекталь, гади сөйләмгә караган һ.б.) сүзнең яки алынма сүзләрнең мәгънәсен ачу өчен кулланылды.

ӘШТЕ́Р-ӨШТЕР *рәв. сөйл.* Ашыгып, аннан-моннан, өстән-өстән генә ...

3. Башка сүзгә яки аның аерым мәгънәсенә (мәгънәләренә) җибәрү. Бу ысул мәгънәләре охшаш яки бик нык якын булган сүзләрдә (синонимнарда) кулланылды. Төп аңлатма тиңдәшләренә караганда күбрәк кулланыла торган сүз янында бирелде, ә калганнарының мәгънәсе шул сүзгә җибәрү юлы белән аңлатылды.

БАЛАШАР *и. к.* **балимәр**

БАЛИМӘР *и.* Сайрар чыпчыклар семьялыгыннан, тонык көрән яки яшел төстә, тел очында чәчәкләрнең баллы суын суырырга махсус щёткасыман әгъзасы булган кечкенә көньяк кошы; *русчасы:* **медосос**

Күпмәгънәле сүзләргә яки омонимнарга җибәргән очракларда, сүзнең кайсы мәгънәсенә яки кайсы омонимга җибәрелүе күрсәтелде. Искәрмә буларак, сүзлекнең зур күләмле булуын исәпкә алып, икенче сүзнең мәгънәсенә җибәргәндә, ул сүз кергән томның басылып чыккан булу шарты куелды. Бу шартка туры килмәгән очракларда, сүзләр алда күрсәтелгән тәртиптә (нигездә синонимын күрсәтү юлы белән) ачыкланды.

КАЕРЫЛУ *ф.* **1.** 1) *төш. юн. к.* **каеру**. *Урамга караган өч тәрәзәнең дә капкачлары каерылган.* Ә.Еники ...

5) *к.* **каеру** (*5 мәгъ.*). *[Бригадир] Шофёрга читтән, икенче юлдан китәргә боерды, һәм бәйрәмчеләр төялгән машина бара торган юлыннан кырт кына читкә каерылды.* Н.Фәттах

§ 23. Сүзнең мәгънәсен тулырак ачыклау өчен, кайбер аңлатмаларда кулланылган өстәмә чаралар:

1. Әгәр сүзнең мәгънәсе тасвирлау юлы белән генә ачылып бетмәсә, аңлатмага өстәп, шул сүзнең синонимнары да китерелде.

КАЗЫЙ *и. гар. тар.* Шәригать законнарына нигезләнеп хөкем итүче рухани; хәким, судья. *[Хуҗа:] Өч сум өчен, минем йөземне ертып, казый әфәнде алдына килеп, тавыш күтәреп йөрергә оялмыйсыңмы*? Н.Исәнбәт ...

2. Аерым очракларда бирелгән сүзнең аңлатмасы аның капма-каршы мәгънәдәге сүзләре (антонимнары) белән дә тулыландырылды.

ҖИҢЕЛЛЕК *и.* 1) Авырлыгы аз булу; *киресе:* **авырлык**. *Җисми кагылу түгел, Мамык җиңеллеге белән Ачылып китте күгем.* Б.Рәхимова ...

2) Уңайлы, җиңел булу: *киресе:* **авырлык, кыенлык**. *Һәр авырлыкның бер җиңеллеге бар.* Мәкаль ...

3. Сирәк очракларда, бигрәк тә вариантлары күп булган, төрле сүзлекләрдә төрлечә бирелгән атамаларның русчага тәрҗемәләре дә китерелде.

БАКА́ ТӘҢКӘСЕ *и. бот.* Нәрсенчәләр семьялыгыннан вак яфраклы йөзмә су үсемлеге; нәрсен; *русчасы:* **ряска**

4. Капма-каршы мәгънәдәге сүзләр (антонимнар) һәм тәрҗемәләр аңлатма ахырында ноктасы өтер белән аерып бирелделәр.

БАЙЛЫК *и. ...*

2) Җитешлек, муллык, иркенчелек; *киресе*: **ярлылык**, **мохтаҗлык**

§ 24. Сүзнең телдә сирәгрәк кулланылган мәгънәләренә сылтамалар биргәндә, ул мәгънә җәя эчендә күрсәтелде.

ВАФАСЫЗ *с.* **1.** *иск. кит.* Тугрылыксыз, хыянәтчел, былагай (*1 мәгъ.*) ...

§ 25. Сүзләрнең индивидуаль, метафорик, шигъри мәгънәләренә, шулай ук чагыштыруларда очрый торган мәгънәләренә аңлатмалар бирелмәде. Сүзләрдәге мондый мәгънәләр, аерым очракларда, мисалларда гына күрсәтелеп китте.

IV. Иллюстратив материалны бирү тәртибе

§ 26. Сүзләрнең мәгънәләренә аңлатмалар биргәннән соң, аерым очракларны исәпкә алмаганда, иллюстратив материал белән ныгытып барылды.

§ 27. Иллюстрация өчен китерелгән мисаллар, күбесенчә, татар телендә басылган матур әдәбияттан, иҗтимагый-сәяси, публицистик, фәнни-популяр, фольклор әсәрләреннән, дәреслекләрдән һәм вакытлы матбугаттан алынды.

§ 28. Мисалга китерелгән җөмләләр артык озын булган очракта, мәгънәгә зыян китермичә, кыскартулар ясалды. Сүзләр төшеп калган урыннар өч сызыкча (---) белән күрсәтелде:

ӘБИ́-БАБА(Й) *җыйд. и.* 1) ... 2) ...

3) Борынгылар, өлкән буын кешеләре. *Бу китапны укып, мәктәп балалары --- хәтта ике-өч буын әби-бабалары да белмәгән, ишетмәгән вакыйгалар --- дәрьясына чумачаклар.* Р.Әмирхан

§ 29. Китерелгән мисаллардагы алмашлык алыштырган сүз, эш-хәрәкәтнең кем тарафыннан башкарылуы, репликаның кемгә төбәлгән булуы яки кем тарафыннан әйтелүе яисә алдагы җөмләләрдән аңлашылган әйтелми калган сүз квадрат җәяләр эчендә искәрмәләр рәвешендә бирелеп барылды:

БӘЙЛӘВЕЧ *и.* 1) Бербөтеннең очларын, ян-якларын (мәс., изүне, балак очларын һ.б.) тоташтыру, бәйләү өчен кара-каршы тагылган бауларның берсе. *Ул [лейтенант], сөйләшү тәмам, дигән шикелле, папкаларын ябып, бәйләвечләрен бәйли башлады.* Х.Камалов ...

БИКЛЕ *с.* 1) Йозак белән бикләнгән; нәрсә белән дә булса керә алмаслык итеп ябылган, йозакланган. *Капка бикле иде, [Камали] авыр гәүдәсе белән ятып, күпме этәрсә дә ачылмады.* К.Нәҗми ...

ӘЙТЕШҮ *ф.* 1) ...

2) Гаепләшү, тиргәшү, ачуланышу. *Ачуланышмыйлар, әйтешмиләр дә, шул ук вакытта ачылып сөйләшмиләр дә иде [каенана белән килен].* М.Маликова ...

§ 30. Һәр җөмлә янында чыганакның авторы күрсәтелде.

§ 31. Аерым очракларда, мисал итеп, сүз тезмәләре яки кыска җөмләләр дә китерелде:

АБАЙСЫЗ *рәв. сөйл.* Саксызлык, гамьсезлек күрсәтеп, хафасыз; таркау. *Абайсыз бәреп төшерү*

БУР I *и. сөйл.* Ак төстәге йомшак известь. *Балалар бур белән асфальтка рәсем ясый*

V. Алынма сүзләрнең чыганак телен күрсәтү тәртибе

§ 32. Тел хәзинәсендә чит (рус, гарәп, фарсы, фин-угор һ.б.) телләрдән турыдан-туры күчкән алынма сүзләр бар. Алар татар халкының күп гасырлар буена бу халыклар белән якыннан аралашып яшәве нәтиҗәсе булып тора. Борынгы алынмалар, фонетик һәм морфологик үзләшеп, татар теле грамматикасына тулысынча буйсынганнар, аның үз сүзләренә якынайганнар. Хәзерге тел хәлендә бу алынма сүзләрне аерып алу гади кулланучыга мөмкин дә булмас иде.

§ 33. Татар телендә шулай ук европа телләреннән алынган сүзләр дә бар. Алар, нигездә, хәзерге чорда рус теле аша күчкән сүзләр. Сүзлектә мондый сүзләрнең беренчел чыганагы – европа телләре күрсәтелде.

Сүзлек массакүләм белешмәлек булганлыктан, сүз турында мәгълүмат алу өчен, барлык алынма сүзләрнең чыганак телен күрсәтү кирәк дип табылды.

VI. Сүз төркемнәренең бирелеше

§ 34. Сүзлек берәмлеге буларак барлык төр сүз төркемнәре дә алынды. Баш сүзнең кайсы сүз төркеменә каравы грамматик билгеләр белән күрсәтелде: *и.* (исем), *ф.* (фигыль), *с.* (сыйфат), *а.* (алмашлык), *сан* (сан), *рәв.* (рәвеш), *бәйл.* (бәйлек), *терк.* (теркәгеч), *кис.* (кисәкчә), *ы.* (ымлык), *иярт.* (ияртем), *хәб. сүз* (хәбәрлек сүз), *мод. сүз* (модаль сүз).

§ 35. Исемнәр сүзлектә берлек санда, баш килештә китерелде һәм *и.* грамматик билгесе белән аерымланды.

§ 36. Җыйма мәгънәдәге парлы исемнәр сүзлек берәмлеге буларак китерелде һәм *җый. и.* грамматик билгесе белән аерымланды:

АЛЫШ-БИРЕШ *җый. и.* 1) Аласы һәм бирәсе әйбер(ләр); алачак һәм бирәчәк нәрсә(ләр) ...

2) Сәүдә, сату-алу эше, кәсебе ...

ӘЙБЕ́Р-КАРА *җый. и.* Төрле кирәк-яраклар ...

§ 37. Ялгызлык исемнәренең, күмәклек мәгънәсе алып, киң кулланышка кереп киткәннәре сүзлектә китерелде (**А́МПЕР, ӘБҮҖӘҺЕЛ, ГАЗРАИЛ, ГАЙДАМАК, ГАЙДУК, ДӘҖҖӘЛ, ИБЛИС, МА́УЗЕР, ОМ** һ.б.).

§ 38. Урта мәктәп дәреслекләрендә һәм матбугатта еш очрый торган төрле ил халыкларының һәм милләтләренең исемнәре чикләнгән күләмдә китерелде (**АБХАЗ, АВАР, АВСТРА́ЛИЯЛЕ, А́ВСТРИЯЛЕ, АЗӘРБАЙҖАН, АЛБАН, ӘРМӘН, ӘФГАН, БАЛКАР, БАШКОРТ, БОЛГАР** һ.б.).

§ 39. Исемләшкән исем һәм сыйфат фигыльләр (**АВЫРУ, АСРА́У, БЕЛДЕРҮ, ЧӘЧҮ, САТУ, ӘЙДӘҮЧЕ, БИЮЧЕ, ОЕШТЫРУЧЫ, УКУЧЫ** һ.б.), сыйфатлашкан сыйфат фигыль (**ЕЛЛАГАН, ЯРАТКАН** һ.б.), рәвешләшкән хәл фигыльләр (**БАГАНАЛАП, БАЛЛАП, БАТМАНЛАП, ЕЛЛАП, ИПЛӘП** һ.б.) аерым сүзлек мәкаләсе итеп алынды.

§ 40. Алмашлыклар *а.* грамматик билгесе белән аерымланды. Сүзлек мәкаләсендә зат алмашлыкларының һәм *ул, бу, шул* алмашлыкларының кыек килеш формалары да бирелде. Ул баш сүз артыннан гади җәя эчендә күрсәтелде. Сүзнең нигезе үзгәргән очраклар аерым сүзлек мәкаләсе итеп китерелде:

МИН (**минем, миңа, мине, миннән, миндә**) *а.* Сөйләүченең үзен атап күрсәтү өчен кулланыла торган беренче зат алмашлыгы

УЛ II (**аның, аңа, аны, аннан, анда**) *а.* 1) Өченче затны яисә гомумән предметны белдерә …

2) Исемнәрне ачыклаган сүзне алмаштырып килә торган күрсәтү алмашлыгы; *андый, мондый, шундый…*

АҢА *а. Ул* алмашлыгының юнәлеш килеш формасы

§ 41. Фигыльне сүзлектә бирү формасы итеп, төп юнәлештәге (*-у/-ү*) исем фигыль формасы алынды һәм *ф.* грамматик билгесе белән аерымланды: **АЛУ, ӘЙТҮ, ДИМЛӘ́Ү, ЫҢЛА́У, КҮЗӘТҮ, КАЙТУ, КӨЛҮ** һ.б.

§ 42. Грамматик мәгънә белдерә торган фигыльләрнең саф юнәлеш формалары телнең грамматик төзелешенә карый, шунлыктан алар сүзлектә теркәлмәде.

§ 43. Лексик мәгънәгә ия булган фигыльләрнең юнәлеш формалары сүзлектә бирелде. Аларның беренче грамматик мәгънәсе төп формага җибәрү юлы белән күрсәтелде, ә лексик мәгънәсенә (мәгънәләренә) аңлатмалар китерелде:

АШАЛУ *ф.* 1) *төш. юн. к.* **ашау** (*1 мәгъ.*). *Хәзрәтләр – шактый күп алган туй сәдакасыннан, авыл кешеләре – тәмле иттереп ашалган ашлардан, кода-кодагыйлар – яхшы бирнәләрдән, Садыйк абзый, Мәрфуга абыстай мәҗлеснең муллаларча затлы үтүеннән разый калдылар.* Г.Исхакый

2) Кояш, җил, су яки башка нәрсәләр тәэсиреннән бозылу, үзгәрү (йөз-кыяфәт, кием-салым һ.б.ш. турында). *Җил-яңгыр белән калай түбәләренең буяулары ашалган, үзе*

җиргә сеңәргә әзерләнгән күн заводының корпуслары яныннан, култыкланып, Миләүшә елгасы ага. А.Алиш

3) Кыршылу, кырылу, ышкылу, тузу. *Ботинканың ашалган үкчәләрен дә төзәткән иде ул.* А.Шамов

§ 44. Дәрәҗә белдерә торган тезмә фигыльләрнең телдә киң кулланылганнары, төп сүзгә аңлатма бирелгәч, фразеологизмнарны күрсәтеп бетергәннән соң, беренче сүз принцибы белән шул фигыль янында ояда алфавит тәртибендә теркәлде:

БӘЙЛӘ́Ү I *ф.* 1) ...

2) ...

◊ **Бәйләп тоту** Ирексезләү, көчләү

Бәйләп алу Тиз генә бәйләү; бәйләгән булу

Бәйләп ату Аннан-моннан, ничек кирәк шулай бәйләү

Бәйләп бару Эзлекле рәвештә бәйләү; бер-бер артлы бәйләү

Бәйләп бетерү Тулысынча бәйләү; бәйләү эшен төгәлләү

Бәйләп кую 1) Алдан бәйләп әзер итү

2) Бәйләнгән хәлдә калдыру, бәйләнгән хәлдә тоту

Бәйләп ташлау Тиз-тиз генә бәйләү

Бәйләп тору 1) Булган берсен, һәрбersен бәйләү

2) Сөйләү моментында, әле бәйләү белән мәшгуль булу

3) Һәрвакыт, гел бәйле итү

Бәйләп чыгу Һәммәсен бер-бер артлы бәйләү; һәрбersен бәйләү

Бәйли бару Һәммәсен тоташтан яки эзлекле рәвештә бер-бер артлы бәйләү

Бәйли башлау Бәйләргә тотыну

Бәйли төшү Тагын да кысыбрак, тыгызрак бәйләү

§ 45. Сүзлектә тезмә фигыльләр ясый торган түбәндәге модификацияләүче фигыльләр (дәрәҗә фигыльләре) кулланылды: **алу, ату, бару, башлау, бетерү, бетү, бирү, җибәрү, җиткерү, җитү, йөрү, калу, карау, керү, килү, китү, кую, салу, ташлау, тору, төшү, узу, утыру, чыгару, чыгу, язу, яту**

§ 46. Сыйфат фигыль һәм хәл фигыль формалары, грамматик категория буларак, сүзлектә аерым китерелми. Әмма кайбер вакытта алар төп фигыльдән үзгә сыйфат һәм рәвеш мәгънәләрен дә белдерергә мөмкин. Бу очракта төп сүзнең барлык мәгънәләренә дә аңлатма биргәч, нокталы ярымкалын гарәп цифрыннан соң, алар аерым күрсәтелеп теркәлде һәм лексик мәгънәләре аңлатылды:

ВАКЛА́У *ф.* **1.** 1) Вак-вак, кечкенә кисәкләргә, өлешләргә бүлгәләү, вату, тураклау, аеру; вак итү. *Койма буендагы такталарны, кисеп, утынга вакларга кирәк.* М.Мәһдиев

2) Эре акчаны шул ук суммадагы вак акчага алмаштыру. *[Тәзкирә:] Соңгы егерме бишлекне вакларгамы?* А.Гыйләҗев...

2. ваклап *рәв. мәгъ.* 1) Аз-азлап, өлешләп, бүлгәләп. *Фәния кисәк-кисәк ваклап сөйләшә торган теле белән зарланып та алырга өлгерде.* Ф.Яхин

2) Данәләп, берәмләп, берәрләп; килолап, граммлап. *Күгендә-түшәгендә чалкан яткан, ваклап сатучыларның кыланышына өйрәнгән айның да исе китми.* Т.Галиуллин

3) Нечкәлекләренә төшенеп, җентекләп, төпченеп. *Кыздырып барган кояш нуры астында, ваклап, тармаклап, җинаятьнең урынын сыйфатлап язды.* Г.Ибраһимов

§ 47. Татар телендә кайбер мөстәкыйль фигыльләр ярдәмче фигыль функциясендә йөри. Сүзлектә бу күренеш күрсәтелде:

КИТҮ *ф.* **1.** 1) ... ; 2) ... .

2. *ярд. ф. функ.* 1) Юнәлеш килешендәге кайбер исем, сыйфат, рәвешләр белән килеп, шулардан аңлашылган торыш, билге һәм рәвешкә күчүне белдерә. *Эшләр уңайга китте. Талашуга киткәч булмый инде ул*

2) Эш-хәлнең кинәт булуын белдерә. *Балкып китте*

3) Эшнең башка бер эш уңаенда кыска гына аралыкта булуын белдерә. *Таныштырып китү. Искә төшереп китү*

4) Эшнең башлануын һәм дәвам итүен белдерә. *Сөйләп китте. Санап китү*

VII. Сүзнең басымын күрсәтү тәртибе

§ 48. Татар телендә басым, күбесенчә, сүзнең ахыргы иҗегенә төшә. Баш сүз булып килгән мондый очракларга (шул исәптән алынма сүзләргә дә) басым куелмады. Басым башка иҗекләргә төшкән очракларда гына сүзнең басымы күрсәтелде.

БАТЫРЛА́РЧА *рәв. ...*

Ю́ГЫЙСӘ *тер.*

ГИГИЕ́НА *и. ...*

Бу кагыйдә омографларга да карый, әмма басымның кайда булуына карамастан, чагыштыру һәм дөрес уку өчен, басым икесенә дә куелды.

А́РКА *и. лат.* 1) *махс.* Ишек, тәрәзә, мич кебек нәрсәләрнең көймәләп эшләнгән түбәсе (түшәме)

АРКА́ *и.* **1.** 1) Кеше гәүдәсендә муеннан алып оча сөягенә кадәрге арткы як ...

§ 49. Татар телендә *-а / -ә* сузыкларыннан соң килгән *-у / -ү* авазлары сөйләмдә, кыскарып, ирен-ирен *в [w]* сонанты булып әйтелә, ә төзелмә үзе *[aw] / [әw]* тибындагы ялган дифтонг булып ишетелә, шул сәбәптән, басым *-а / -ә* сузыкларына төшә. Бу очрак сүзлектә күрсәтелде.

АБА́У *ы. ...*

АҢКА́У II *и. анат. ...*

БИКЛӘ́Ү I *ф. ...*

ВАКЛА́У *ф. ...*

ДӘ́Ү *с. фар. ...*

ШАРТЛЫ КЫСКАРТЫЛМАЛАР

а. – алмашлык
авиа. – авиация
анат. – анатомия
артык. – артыклык (дәрәҗәсе)
археол. – археология
архит. – архитектура
астр. – астрономия
а.х. – авыл хуҗалыгы
әд. – әдәбият термины
баш. кил. – баш килеш
бәйл. – бәйлек
бәйл. сүз – бәйлек сүз
берл. – берлек сан
биол. – биология
биохим. – биохимия
б-сез. – билгесезлек
бор. – борынгы (сүз)
бот. – ботаника
бүл. саны – бүлем саны
вет. – ветеринария
гади с. – гади сөйләм
геогр. – география
геол. – геология
геом. – геометрия
грам. – грамматика
дәр. – дәрәҗә
диал. – диалекталь сүз
дини – дини сүз
диңгез. – диңгезчелек термины
жарг. – жаргон
җый. и. – җыйма исем
җыр – халык җыры
зоол. – зоология
з.-сыз – затланышсыз (фигыль)
и. – исем
икът. – икътисад
информ. – информатика
ирк. – иркәләү сүзе
ирон. – ироник мәгънәдә
иск. – искергән сүз
ият. кил. – иялек килеше
иярт. – ияртем
йөкл. юн. – йөкләтү юнәлеше
к. – кара
кбт. форм. – кабатлаулы формада
кайт. юн. – кайтым юнәлеше
карг. – каргау (каргыш) сүзе
кер. сүз – кереш сүз
кеч. – кечерәйтү
кил. – килеш (формасында)
ким. – кимлек дәрәҗәсе
кимс. – кимсетеп әйтү
кино – кинематография
кис. – кисәкчә
кит. – китап теле
комп. – компьютер
көч. – көчәйтү
кулин. – кулинария термины
күпл. – күплек санда
күрс. – күрсәтү
күч. – күчерелмә мәгънәдә
лингв. – лингвистика
лог. – логика
мат. – математика
махс. – махсус термин
мәгъ. – мәгънәдә, мәгънәсендә
мәс. – мәсәлән
мед. – медицина
метеор. – метеорология
минер. – минералогия
миф. – мифология
мод. сүз – модаль сүз
мод. ф. – модаль фигыль
мөн. – мөнәсәбәтлек (сүз)
муз. – музыка
мыск. – мыскыллау сүзе
неол. – неологизм
нәфр. – нәфрәтләнү
окказ. – окказионализм
пед. – педагогика
психол. – психология
радио – радиотехника
рәв. – рәвеш
рәсм. – рәсми
ритор. – риторик
с. – сыйфат
сан – сан
сәнг. – сәнгать
сәяси – сәяси термин
сир. – сирәк кулланышта
сөйл. – сөйләм телендә
спорт – физкультура һәм спорт
тар. – тарихи
тарт. форм. – тартымлы формада
тасв. – тасвири сәнгать
тәрт. саны – тәртип саны
театр – театр сәнгатенә караган сүз
терк. – теркәгеч
тех. – техника термины
типогр. – типография термины
тирг. – тиргәү сүзе
төзел. – төзелеш термины
төш. кил. – төшем килеше
төш. юн. – төшем (юнәлеше)
туп. – тупас сүз
тур. – турында
урт. юн. – уртаклык (юнәлеше)
у.-вак. кил. – урын-вакыт килеше
ф. – фигыль
фарм. – фармацевтика
физ. – физика
физиол. – физиология
филос. – философия
финанс. – финанслар
фольк. – фольклор
форм. – формасында
фото. – фотография
функ. – функция
хим. – химия
хуплм. – хупламау
хупл. – хуплау
хурл. – хурлау
хәб. функ. – хәбәр функциясендә
хәб. сүз – хәбәрлек сүз
хәрби – хәрби сүз
чаг. – чагыштыру
чыг. кил. – чыгыш килеше
шаярт. – шаярту сүзе
шелт. – шелтәләү сүзе
шигъ. – шигъри сөйләмдә
ы. – ымлык
эвф. – эвфемизм
энд. – эндәш сүз
электр. – электротехника
эпис. – эпистоляр стиль
этн. – этнография
юг. – югары стиль
юкл. – юклык
юн. – юнәлеш
юн. кил. – юнәлеш килеше
юр. – юридик термин
ялг. – ялгыш куллану варианты
ярд. – ярдәмче (фигыль яки сүз)

Чыганак телләрнең кыскартылмалары

алб. – албан теле
амхар – амхар теле
афр. – Африка телләре
әрм. – әрмән теле
баконго – баконго теле
бурят – бурят теле
венг. – венгр теле
гар. – гарәп теле
герм. – герман телләре
голл. – голланд теле
гр. – грек теле
груз. – грузин теле
гуарани – гуарани теле
инг. – инглиз теле
исланд – исланд теле
исп. – испан теле
ит. – итальян теле
кельт – кельт теле
кечуа – кечуа индеецлары теле
коми – коми теле
кыт. – кытай теле
лат. – латин теле
литв. – литва теле
малай – малай теле
малаял. – малаялам теле
мар. – мари теле
монг. – монгол теле
мордв. – мордва теле
нем. – немец теле
норв. – норвегия теле
пол. – поляк теле
полинез. – полинезия телләре
португ. – португал теле
румын – румын теле
рус – рус теле
саам – саам теле
санскр. – санскрит теле
сканд.– скандинав телләре
слав. – славян телләре
тамил – тамил теле
тат. – татар теле
төрек – төрек теле
төрки – борынгы төрки сүз
тунг. – тунгус теле
тупи – тупи теле
удм. – удмурт теле
уйг. – уйгур теле
укр. – украин теле
үзб. – үзбәк теле
фар. – фарсы теле
фин – фин теле
фин-угор – фин-угор телләре
фр. – француз теле
һинд. – һинди теле
чех. – чех теле
швед – швед теле
эст. – эстон теле
як.– якут теле
яп. – япон теле
яһүд – яһүд теле

ТАТАР АЛФАВИТЫ

Аа	Дд	Зз	Мм	Пп	Үү	Чч	ь
Әә	Ее	Ии	Нн	Рр	Фф	Шш	Ээ
Бб	Ёё	Йй	ң	Сс	Хх	Щщ	Юю
Вв	Жж	Кк	Оо	Тт	Һһ	ъ	Яя
Гг	Җж	Лл	Өө	Уу	Цц	Ыы	

Л

ЛА *кис.* 1) Раслау яки инкяр итү сүзләреннән соң килеп, төп фикерне көчәйтү, аңа басым ясау өчен кулланыла. *Җаның юктыр ла синең?* И.Гази. *[Тәзкирә:] Юк ла инде, --- нишләп үзебез өчен булсын, форма өчен.* Ә.Еники. *Ибрайның борынына озынборын кунды ла, каһәр!* Ә.Гаффар

2) Шарт һәм боерык фигыльдән соң килеп, нинди дә булса теләкне, үтенечне, гозерне һ.б.ш. төсмерләрне белдерүдә катнаша. *Балалар, зинһар, тавышланмыйча гына утырсагыз ла.* Идел

3) Шарт һәм боерык фигыль формалары янында килеп, беркадәр фамильярлык, тәкәллефсезлек төсмере өсти. *[Халисә:] Әй, авызыңнан җил алсын ла!* Г.Гобәй. *Әй, ташлагыз ла!* И.Гази. *[Тархан бабай:] Ай-һай ла. Китче. Бер үк сүзне гелән-гел тукымаслар.* Г.Мөхәммәтшин

4) Хәбәр белдергән сүзләрдән соң килеп, шик яки шөбһә катыш теләкне белдерә. *Юк ла, юкка шикләнәм, бу бит – Улмәс абыстай.* Г.Исхакый. *Ярый ла эш барып чыкса уңайга.* Г.Тукай. *Юл баткак вә лайла, Кул-аяк богауда: Кыймылдап булмый ла!* Ш.Бабич

5) Гадәттә, озын көйле халык җырларында иҗекләр санын көйнең ритмикасына туры китерү өчен кулланыла (кайбер очракларда *да* кисәкчәсен алмаштыра). *Бездә биек таулар бар ла, Тау астында таллар бар…* Җыр. *Кызыл ла гына төлке, урман күрке, урманнарга кереп лә югала. Суларга ла барсаң, бар иртәрәк, соңга ла калсаң, болгана.* Җыр. *Кемнәр генә гашыйк, ай, булмады, Сәлимәкәй, кара ла кашыңа.* Җыр

ЛАБАЗ *и.* 1) Башлыча базарларда ашлык, он, көрпә һ.б.ш. белән сәүдә итә торган өсте каплаулы корылма яки ябык бина. *– Бар, чыгып, әзрәк базарлар карап йөр дә кайтып ял итә торырсың, – дип, егерме сум акча тоттырып, Фатыйх абзый мине ит лабазыннан чыгарып җибәрде.* В.Нуруллин. *Бу вокзал, чиксез зур итеп, көймәләп эшләнеп, башын пыяла белән япкан лабазга охшый.* Г.Гали

2) Берәр нәрсәне саклау, куеп тору өчен, өлешчә яки бөтенләй ябык хуҗалык каралтысы; әвеслек. *Алар лабазга якын ук, диңгез кырыеннан унбишегерме саженьнар гына читтә, бер баракта тора иделәр.* Ш.Камал. *Садыйк ике лабаз арасын бүлеп алган.* Г.Гобәй. *Әнә җитез приказчиклар амбар яки лабаз тирәсендә бозау башы кадәрле йозакларын биклиләр.* Җ.Тәрҗеманов

ЛАБАЗЧЫ *и.* Лабаз хуҗасы яки шунда сату итүче. *Лабазчы булып эшләү*

ЛАБАСА *кис.* 1) Сөйләмдә әйтелгән фикернең эчтәлеген көчәйтә (раслауны, сорауны, инкяр итүне, гөманны һ.б.). *Һәркайчан тик тор, берәр ахмак адәм сүз сөйләсә. Бел: аңа сүз кайтарудан тик тору артык лабаса.* Ш.Бабич

2) Сөйләмнең экспрессивлыгын, хискә тәэсир көчен арттыра. *Хәдичә түти Газиз хәсрәте, тормыш мәшәкате белән миңгерәүләнеп йөргән арада, аның төпчек улы егет булып җитә язган лабаса!* Г.Бәширов. *Шәфәкъ шул якта була димени? Кояш баешында була бит ул шәфәкъ, ә бу ут кыйбла ягында лабаса!* В.Нуруллин

ЛАБИАЛЬ *с. лингв.* Иреннәр катнашы белән әйтелә торган (авазлар тур.). *Лабиаль тартыклар*

ЛАБИАЛЬЛӘШТЕРҮ *ф. лингв.* Иренләштерү, кайбер авазларны әйткәндә, иреннәрне алга таба сузып түгәрәкләү

ЛАБИАЛЬЛӘШҮ *ф.* Авазны әйткәндә, төп артикуляциягә өстәмә рәвештә иреннәрнең түгәрәкләнеп алга таба сузылуы; иренләшү

ЛАБИЛЬЛЕК *и. биол.* Ярсынучан тукымада элементар ярсу цикллары-ның үтү тизлеге; функциональ үзгәрүчәнлек. *Академик Н.Е.Введенский, лабильлек күрсәткече итеп, тукыманың бер секундта ничә тапкыр ярсына алу сәләтен алды.* Биология

ЛАБИО-ДЕНТАЛЬ *с. лингв.* Ирен белән тешләр катнашында ясала торган (тартык авазлар, мәс., [в], [ф] тур.). *Лабио-денталь тартыклар*

ЛАБИРИНТ *и. гр.* 1) Грек мифологиясендә: күп бүлмәләр, буталчык коридорлардан торганлыктан, чыгу юлын табу кыен булган бина, сарай. *Ул, имеш, Крит патшасының сарае лабиринтта яшәгән.* Н.Фәттах. *Борынгы Мисырда һәм Элладада бик күп бүлмәләре, заллары, буталчык коридорлары булган зур бина лабиринт дип аталган.* Мәдәни җомга

2) Паркларда куаклар һ.б.ш. арасында тар сукмаклар калдырып, башваткыч сыман эшләнгән урын. *--- Яшь чакларны искә төшерик әле, яныбыздагы матур шәһәр чыршысы янына басып, бозлы таудан шуарбыз, боз лабиринтында адашып йөрербез.* М.Маликова

3) Коридорлар, галереялар, урамнар яки юлларның буталчык урнашуы турында. *Ярминкә шәһәрчеге тирәли йөзләрчә дисәтинә җирне биләп алган урам, тыкрыклар, аллы-гөлле буяулы челтәрле коймалар лабиринты…* Җ.Тәрҗеманов. *Әллә нинди лабиринтлар аша керә торгач, бер бүлмәгә юлыгабыз.* К.Миңлебаев. *Бу юлы лабиринтлар буйлап озак йөрисе булмады, камера шул бинада беренче катта гына икән.* И.Сиражи

4) *анат.* Кешедә һәм умырткалы хайваннарда ишетү, тигезлек саклау хезмәтен үти торган әгъза, эчке колак; эчке колактагы бормалы куышлыклар. *Тавышның кайсы якtан килүен балыклар лабиринт ярдәмендә түгел, бәлки тән тиресе ярдәмендә беләләр.* Кызыклы ихтиология

5) *күч.* Үтә катлаулы, буталчык нәрсә. *Менә шунда безнең Фәндиләбез*

сәудә дөньясының барлык лабиринтларына кереп чумды. Г.Ахунов. *Кешенең гомер юлы исә Алла сызган серле лабиринтлар аша чиксез Мәңгелек Хакыйкатькә генә илтә аладыр.* И.Вәлиулла

ЛАБИРИНТЛЫ *с.* 1) Лабиринтлардан торган, лабиринты булган

2) *тех.* Лабиринт принцибында эшли торган

3) *биол.* Атмосферадагы кислород белән сулау өчен махсус әгъзасы – лабиринты булган (балыклар тур.)

ЛАБИРИНТЛЫЛАР *и. күпл. зоол.* Алабугасыманнар отрядыннан һавадагы кислород белән суларга мөмкинлек бирә торган лабиринтлы әгъзасы булган балыклар асотряды. *Лабиринтлылар семьялыгында 40 тан артык төр исәпләнә, күбесе Африка һәм Азиянең төче сулыкларында яшиләр.* Биология

ЛАБИРИ́НТСЫМАН *с.* Лабиринтка охшаш, лабиринт кебек

ЛАБОГРЕ́ЙКА *и. а.х. сөйл. к.* **лобогрейка**. *Мостафа, ике япьле кыска сәнәген тоткан килеш, лабогрейка артына сикереп менде.* Ш.Камал. *Бер читтә – тузанга баткан лабогрейка, көлтә-көлтә саламнарны тузгытып чыгарган, авызын карга кебек ачкан.* Н.Хәсәнов

ЛАБОРАНТ *и. лат.* Кайбер предприятие, лаборатория, фәнни тикшеренү учреждениеләрендә эшләүче фәнни-техник хезмәткәр яки техник хезмәткәр. *Аннан соң ул, мунча миче янып беткәнче, ашыгып кына, үзенең иске бер танышына – университетның химия лабораториясендә эшләүче карт лаборант янына китте.* Ф.Хөсни. *Авылда кичке мәктәп ачылгач, мин анда лаборант булып эшли башладым.* Х.Вәлиәхмәтов

ЛАБОРА́НТКА *и. рус* Лаборант хатын-кыз. *Институтның бер кафедрасында лаборантка иде ул.* М.Мәһдиев. *Берникадәр вакыт балык консервлау заводында лаборантка булып эшли.* Ватаным Татарстан. *Яшь кыз Ләбибә лаборантка булып эшли.* Мәдәни җомга

ЛАБОРАНТЛЫК *и.* Лаборант эше (хезмәте), лаборант булып эшләү, лаборант вазифасы. *Бер хатында кыз лаборантлыкка укуы турында язган.* Г.Бәширов. *– Юк андый урын! – дип, Хәсән Хәйри Исәнбәтне лаборантлыкка да алмыйча кире борып җибәрә.* Р.Батулла

ЛАБОРАТОР *с.* Лабораториядә эшләнгән, лабораториядә ясалган, лабораториядә алып барылган. *Уку планнарында термодинамика һәм җылылык алмашу теориясе буенча гамәли һәм лаборатор дәресләр каралган.* Фән һәм тел. *Алар югары математика, сызма геометрия, геодезия, гамәли математика кебек техник фәннәр буенча да татарча лекцияләр укыйлар, гамәли һәм лаборатор дәресләр алып баралар.* Мәдәни җомга

ЛАБОРАТО́РИЯ *и. лат.* 1) Тәжрибәләр үткәрү юлы белән төрле фәнни тикшеренү эшләре алып бара торган учреждение яки аның бер бүлеге. *Криминалистларның күчмә лабораториясе ашыгыч рәвештә шунда чыгып чапты.* Х.Вәлиәхмәтов. *Ул миңа эш урынымны күрсәтеп, --- лаборатория шөгыльләнгән мәсьәләләрне санап күрсәтте.* А.Тимергалин. *Профессор --- мине кабинетында түгел, микробиология лабораториясендә кабул итте.* Казан утлары

2) Шундый учреждение яки бүлек урнашкан бина. *Кыш бит, хәзер күбрәк китаплар өстендә утырырга да лабораториядә генә эшләргә туры килә.* Ә.Еники. *Колхозның нәкъ уртасында лаборатория өе бар.* М.Җәлил

3) Югары уку йорты яки мәктәп каршында кайбер предметларны өйрәнүгә ярдәм итү өчен тиешле җиһазлары һәм кирәк-яраклары булган махсус кабинет. *Икенче көнне мәктәп лабораториясеннән реактивлар алып, төгәл микъдар анализы ясагач, ул чишмә суында саф шикәр барлыгына ышанды.* А.Тимергалин. *Лабораториядә углекислый газ табу өчен, нинди матдәләр алырга кирәк?* Химия

4) *күч.* Берәр иҗат кешесенең иҗади эшчәнлек алымнары, иҗатына хас шәхси үзенчәлекләре. *Бу әсәр, шулай беркадәр эскиз хәлендә булуы белән, безгә Тукайның иҗат лабораториясен, «шигырь кухнясы»н ачарга ныграк ярдәм итә.* Н.Исәнбәт. *Язучының иҗат лабораториясеннән тыш дөньяга карата булган позициясе --- һәр чыгышта фикер алышуда яңгырар дип ышанырга урын бар.* М.Юныс. *Олы шагыйрьнең бу хатлары аның иҗат лабораториясен, халык иҗатына мөнәсәбәтен тирәнрәк аңларга ярдәм итә.* Ф.Урманче

ЛАБРА *и. мар. диал.* **1.** Сыек пычрак. *Яз көне лабра ерып бару*

2. *с. мәгъ.* Җыйнаксыз, таркау; шапшак. *Әй лабра да инде бу хатын, өе дә лабра, киеме дә лабра*

ЛАБРАДОР *и. инг.* 1) *геогр.* Канадада бер ярымутрау; Атлантик океанның шул ярымутрау, Ньюфаундленд утравы һәм Гренландия арасындагы бер өлеше. *Гольфстрим җылы агымы белән салкын Лабрадор агымы бергә кушылган урында температура 10–12° аерма күрсәтә.* Кызыклы география

2) *геол.* Шул ярымутрауда беренче мәртәбә табылган һәм шуның исеме белән аталган, бизәнү әйберләре ясауда һәм декоратив сәнгатьтә файдаланылган минерал, кыр шпатының бер төре

3) Шул ярымутрау исеме белән аталган, сары яки кара төсле кыска йонлы эре ау этләре токымы

ЛАБРАДОРИТ *и. геол.* Кыр шпатлары төркеменнән, гадәттә соры, көрән яки кара төстәге, шомартылгач, төрле төсләр белән ялтырый, декоратив максатларда кулланыла торган магматик тау токымы

ЛАБЫЛЫК *и. диал.* Пычраклык, шапшаклык, җыйнаксызлык. *Лабылык кына бездә, өйгә кермәле түгел*

ЛАБЫНДЫЗ *и. диал.* Көзге айларда ява торган карлы-бозлы яңгыр

ЛАБЫРДАТУ *ф. йөкл. к.* **лабырдау**

ЛАБЫРДА́У *ф. сөйл.* 1) Лабыр-лобыр итү, лабыр-лобыр килү. *Ямал җиңги – лабырдап хәбәрен сөйләп торган алчак күңелле хатын.* Кызыл таң

2) Юк-бар сүз, сафсата сөйләү; теләсә нәрсә лыгырдау. *Мин Ватан сугышының Г.Кашшафка, аның гаиләсенә ничек кагылганын белмим, ләкин ул лабырдаган чакта, Тажи Гыйззәтнең үз ирке белән сугышка киткән 18 яшьлек олы улы танкист Үзбәк һәм бер-*

туган энесе Хаҗиәхмәт сугыш кырларында һәлак булырга өлгерәләр инде, икенче улы да Кызыл Армия сафларына алынып, хәрби училище тәмамлап килә ---. Әдипләр

Лабырдап тору Бертуктаусыз лабырдау

Лабырдап утыру Шактый вакыт бертуктаусыз лабырдау

Лабырдап яту *сөйл. к.* **лабырдап утыру**

Лабырдап йөрү Шактый вакыттан бирле, һәр җирдә лабырдау

ЛАБЫРДАШУ *ф. урт. к.* **лабырдау**

ЛАБЫРДЫК *с. сөйл.* Лыгырдык, күп сөйләүчән, такылдык. *Бу кушымча аваз ияртемнәренә ялгана: лыгырдык, мыгырдык, лабырдык.* Фән һәм тел

ЛАБЫР-ЛОБЫР *иярт. сөйл.* Ашыгып, кайбер авазларны ачык ук әйтмичә, туктаусыз яки берничә кеше бердән сөйләшүне белдерә. *Күрше бүлмәдә лабыр-лобыр сөйләшү һаман бетмәде.* Казан утлары. *Лабыр-лобыр килү*

ЛАВ *и. бор.* Болгарларда мөһер басу өчен кулланыла торган балавыз, сургыч

ЛАВА I *и. лат.* 1) Янартаудан җир өстенә агып чыга торган, нигездә силикатлардан торган кызган сыек масса. *Лава җир өстенә атылып чыккан очракта тау токымнарына әверелә.* Кызыклы физика. *Тавыш көчәя бара, һәм, ниһаять, лава фонтаны 4–6 метрга күтәрелгәч, кызыл тамчылар шаулап якякка сибелә.* Кызыклы география. *Суынган лава төрле төстәге кристаллик гранит, каракучкыл базальт катламнары хасил итә.* Үткән заманга сәяхәт

2) *күч.* Бер юнәлештә бара торган көчле хәрәкәт, агым; ташкын. *Фәнни-техник революция лавалары аларның чыганакларын томаламасын, юлларын бумасын.* М.Әмир

ЛАВА II *и. пол. махс.* Файдалы казылмаларны (мәс., күмерне) чыгарганда җир астында ясалган шактый озын забой. *Синең төсле яшь бер егет, моннан элек тә шулай, ашамыйча-эчмичә акча җыйды-җыйды да, җыелган акчасы – җир өстендә, ә үзе, лава ишелеп, җир астында калды.* Ф.Хөсни

ЛАВА III *и. пол. хәрби* Дошман гаскәрен флангларыннан һәм тылдан уратып алу өчен, атлы сугышчыларның атака вакытындагы сугышчан тәртибе; шундый атака ясау өчен төзелгән отряд

ЛАВАНДА *и. ит. бот.* Иренчәчәкләләр семьялыгыннан күк яки шәмәхә төсле чәчәк ата торган хуш исле мәңгеяшел куак яки сирәк кенә үлән үсемлек (парфюмериядә киң кулланыла). *[Дипломат кыз] Лаванда исе аңкып торган йомшак кулын сузды.* М.Юныс. *Лавандадан эфир мае алына. Лаванда үсемлегенең 25 төре бар, күбесенчә Урта диңгез буенда үсә.* Биология

ЛАВИНА *и. нем.* 1) Тау башларыннан зур көч белән ишелеп төшә торган кар ташкыны яки боз өеме. *Тауларда еш кына лавиналар булып тора.* Кызыклы география. *Гадәттән тыш хәлләр министрлыгы белдерүенә караганда, иң күп матди зыян салган һәлакәтләр буларак, су басулар, җир убу, лавиналар, яр һәм кар ишелүләр, давыллар һәм башка афәтләр теркәлгән.* Мәдәни җомга

2) *күч.* Бер юнәлештә бара торган үтә көчле хәрәкәт, ташкын. *Электр бушануы булганда, ионнар һәм электроннар лавинасы барлыкка килә.* Физика

ЛАВКА *и. рус сөйл.* 1) Товарларны ваклап сату өчен махсус яраклаштырылган кечерәк кибет. *Мин аңа күмәч-мазар алырлык акчам юклыгын әйтәсем килмәде ---. – Лавкага барып киләсем бар, – дидем.* М.Гафури. *Комач лавкалары каршына килеп, озак-озак басып тордык.* М.Кәрим. *Балтач шагыйре миңа элеккеге лавка урыннарын, ат бәйләү урыннарын күрсәтеп йөрде.* М.Мәһдиев

2) *диал.* Ян сәке

ЛАВКАЧЫ *и. сөйл.* Лавка тоткан яки шунда сату иткән кеше. *Бер ай чамасы авылда йөрде дә ул, кара тройка костюмын лавкачы Зәйнушка ярты хакына сатып, кире Урта Азиягә китте.* М.Кәрим

ЛАВР *и. гр. бот.* Дәфнәчәләр семьялыгыннан күбесенчә Урта диңгез ярлары буенда үсә торган хуш исле мәңгеяшел куак үсемлек яки биек агач; дәфнә агачы. *Кырымның көньяк яр буеның көнбатыш өлешендә кипарислар, анар, зәйтүн, серкә агачлары, гүзәл лавр һәм башка агачлар үсә.* Ботаника

ЛАВРА *и. гр.* Православиедә: аерым бер тарихи һәм рухи әһәмияткә ия булган зур ирләр монастыре

ЛАВР ВЕНОГЫ *и.* 1) Антик чорда сугышта, көрәштә җиңүчеләргә бирелә, үтә тантаналы очракларда киелә торган, лавр яфракларыннан үрелгән такыя

2) *күч.* Батырлык, җиңү, дан символы

ЛАВР ТАКЫЯСЫ *к.* **лавр веногы**. *Петрарка [шагыйрь] дан-шөһрәткә ирешә: аңа, Римда иң талантлы шагыйрь буларак, лавр такыясы кидерәләр.* Урта гасырлар тарихы

ЛАВРЧАЛАР *и. күп. бот.* Мәңгеяшел агач һәм куаклар ыругы (лавр, камфара агачы һ.б.) атамасы; дәфнәчәләр. *Лаврчалар күбрәк дымлы тропик урманнарда үсәләр.* Ботаника

ЛАВР ЧИЯСЕ *и. бот.* Гөлчәчәкләләр семьялыгыннан көньякта үсә торган, сусыл каты җимеше чияне хәтерләткән мәңгеяшел куак яки агач; дәфнә чия; *русчасы*: **лавровишня**

ЛАВР ЯФРАГЫ *и.* Лавр (дәфнә) агачының аштәмләткеч буларак кулланыла торган киптерелгән яфрагы. *--- Газизә абыстай бер-ике лавр яфрагы биреп тормас микән, чөнки әнисенең башы тагын авырта башлады, ә кемдер, чәй белән бергә кайнатылган лавр яфрагы авыртуны шундук баса, дигән иде.* Г.Шәрипова. *Качып эчә алу мәртәбәгә әверелде, «аек туй» кунаклары чоланнан чыкмады, киңәшмәләргә керәсе кызыл чырайлар кершән белән акшарланды, тыйнак сөйләшүләрдә лавр яфрагы, әнис, тмин, канәфер кебек тәмләткечләр авыздан төшмәде.* К.Кәримов

ЛАВСАН *и. рус хим.* **1.** 1) Полиэфирларның иң киң таралган төре: үтә күренмәле яки ак төсле, химиядә, приборлар ясауда, эретеп коеп яки тукып төрле эшләнмәләр ясау өчен файдаланыла торган чыдам синтетик матдә

2) Шул матдәдән яки шуны кушып эшләнгән тукыма. *Ул төшендә дә креп-жоржетлар, нейлоннар, перлоннар, лавсаннар гына күрә торгандыр.* Г.Афзал. *Аягында ак оек, чалбары да яңа, килешеп тора, буй-буй соргылт лавсаннан теккән.* А.Гыйләҗев

2. *с. мәгъ.* Шундый җептән тукылган яки шундый материалдан тегелгән. *Ник дисәң, үзең беләсең, минем өстә лавсан костюм, башта менә дигән эшләпә.* Н.Дәүли. *Кызның өстендә кыска җиңле лавсан күлмәк.* Казан утлары

ЛАВСАНЛЫ *с. к.* **лавсан 2.** *Мыштым гына утырган ир затының да теленә сүз килде: – Кибеткә лавсанлы соры костюмнар кайткан, ди.* Э.Касыймов

ЛАВЫЛДА́У *ф. диал.* 1) Озак итеп, сузып өрү

2) *күч.* Көчле яңгыравык тавыш белән, кычкырып сөйләшү

Лавылдап тору Бертуктаусыз лавылдау

ЛАВЫР *и. диал.* Күзгә чыккан арпа. *Күзгә лавыр чыкса, кара җиләк ашарга кирәк*

ЛАВЫ́Р ҖИЛӘГЕ *и. бот. диал. к.* **карга күзе**; *русчасы*: **паслён черный**

ЛАГ I *и. голл. диңг.* Суднолларның йөрү тизлеген һәм үткән ераклыкны үлчәү приборы

ЛАГ II *и. голл. махс.* Идән җәйгәндә, такталар астына салына торган аркылы борыс

ЛА́ГЕРЬ *и. рус* 1) *хәрби* Ачык һавада палаткалар корып, вакытлыча гаскәр урнашкан җир. *Суслонгер лагеренда бер ай агач кистеләр, землянка казыдылар да бер төнне кинәт кенә товар поездына төялеп фронтка чыгып киттеләр.* М.Мәһдиев. *Пугачёв Бөгелмә ягындагы Чатыр тавында лагерь корып яшәгән.* Мирас // Гомумән, вакытлыча яшәгән урын; торак. *Шуңа күрә без, гадәттә дүрт-биш, мөмкин булса, аннан да күбрәк авыллар «көлтәсе» урнашкан бер җиргә, күл яки елга буена лагерь корып тукталабыз.* М.Госманов

2) Ял итү, сәламәтлекне ныгыту һ.б.ш. чаралар үткәрелә торган, вакытлыча яшәү өчен тораклары булган урын. *Бу лагерьның Гәүһәрләр мәктәбе лагере икәнен Әгъзам, әлбәттә, белә иде. Бу лагерь турында Гәүһәр күп сөйләде, шуның өстенә бу лагерьда бер баланың суга бата язуын кичә ронода да әйттеләр.* Г.Әпсәләмов. *Без бит кечкенәдән үк һәммәбез лагерьларда үскән кешеләр. Пионерлар – пионерлагерьда, без хәрбиләр – хәрби лагерьда, авыл кешеләре – колхоз дигән лагерьда, тоткыннар – үз лагерьларында. Безнең бөтен ил – тоташ тимер койма белән әйләндереп алынган лагерь.* Ф.Яруллин. *Туган тел һәм дин сабагы бирер өчен, Суомидагы милләттәшләребез балаларын берәр җәйге лагерьда туплый.* Татарстан

3) Әсирләр, тоткыннар өчен төзелгән торак урын. *Янгураз өчен әнә шул көннән ачлык-ялангачлык, әсирлек лагере вәхшәтләре башланды.* Т.Әйди. *Ерак Колыма, Магадан лагерьлары моңарчы ярап торган, хәзерге шартларда аерата куркыныч саналган тоткыннарны да, күнеккән лагерьларыннан чүпләп-йолкып, мондагы көтүләргә китереп кушканнар.* А.Гыйләҗев. *--- Безне, 30–40 татар-башкортны, туп-туры Берлиннан ерак булмаган Вустрау лагерена алып килделәр, анда Көнчыгыш министрлыкның ачык һәм ябык лагерьлары иде. Ябык лагерьда – төрле милләт вәкилләре, ачык лагерьда урыс генераллары урнашкан иде.* Мәдәни җомга

4) Терлекне һавада тотар өчен, киртә белән уратып алынган урын, гадәттә җәйге терлек утары. *Яз көне буаз таналар кышкы лагерьдан Яңа Авылдагы җәйге лагерьга күчерелә, аннан Теңкәш, Нурвахит, Фролово, Кырлаңгы, Степановка фермаларына таратылалар.* Байрак

5) Бердәй карашта торган, мәсләктәш кешеләр төркеме; иҗтимагый-сәяси агым. *Зөфәр дигән егет аламасы, мөгаен генә, Вәзилә апасын сатып, дошман лагерена чыккан.* А.Гыйләҗев. *Революциядән соң аклар лагере һәм кызыллар лагере барлыкка килде.* Мирас. *Бу ил бер-берсенә каршы торган ике лагерьга бүленде.* Татарстан яшьләре

6) Җәмгыять өчен зарарлы, җинаятьчел, яман гадәтләрдән арындыру, тәрбияләү өчен хезмәт итә торган урын. *Узган ел миңа хезмәт белән төзәтү лагерында шефчы укытучы булырга туры килде.* А.Шамов. *Ике малайның олысы төзәтү лагереннан алдарак кайтты.* М.Мәһдиев. *Икесенә дә террор өчен егерме бишәр ел каты режимлы лагерь биргәннәр...* А.Гыйләҗев

ЛАГМАН *и. кыт.* Урта Азия халыкларында таралган, сарык ите, озын токмач һәм яшелчәдән пешерелә торган милли ризык. *Әмма лагман да, бишбармак та, манты да Гомәр ашказанына төшеп утыра.* Р.Батулла. *Лагман өчен дип әзерләнгән махсус савытка иң башта сөзелгән токмач, аннан итле, яшелчәле шулпа салырга.* Ватаным Татарстан. *Эш көнебез иртәнге алтыда башланса да, лагман токмачын тугызга өлгертү мөмкин түгел.* Кызыл таң

ЛАГУ *и. диал. к.* **ләгү**

ЛАГУН *и. рус сөйл.* 1) Агач чиләк яки кечкенә агач мичкә. *Кырга барганда, суны лагун белән алып бара идек*

2) Арба астына тагылып йөртелә торган дегет чиләге. *Мин алдамадым сине, син үзең дегет лагуны шикелле тагылып килүче. Сиңа соң эт барсынмыни?* Г.Камал. *[Карт:] – Баш исән калса, бер юлын табарбыз, – дип, дегет лагунын, бәрәңге бакчасына чыгарып, түтәлләр арасына яшерде.* К.Тинчурин

ЛАГУ́НА *и. лат. геогр.* Диңгездән ком яки мәрҗән рифларыннан гыйбарәт тар коры җир белән аерылган сай култык яки бухта. *Тыныч лагуна*

ЛАГУ́НАЛЫ *с.* Лагуналары булган; лагуналар формасындагы. *Лагуналы ярлар*

ЛАГУ́Н-ЛАГУН *с.* Лагуннар белән булган, лагун белән исәпләнгән. *Арбалар яныңдагы көлтәләрдән ясаган куышларда лагун-лагун сулар, тырыстырыс катыклар, зур-зур икмәкләр уракчыларның сусауларыны кайтарыр, тамакларыны туйдырыр өчен хәзерләнгән иде.* Г.Исхакый

ЛАГЫ́Р-ЛОГЫР *иярт. сөйл.* **1.** Аш, ботка, су, сөт һ.б.ш. кайнаганда чыккан тавышны белдерә. *Казанда лагыр-логыр аш кайный*

2. *диал. рәв. мәгъ.* Теләсә ничек, аннан-моннан, җыйнаксыз итеп. *Эшне лагыр-логыр эшләү*

ЛАГЫ́РТ-ЛОГЫРТ *иярт.* Берәр авыр, гадәттә арба, чана һ.б.ш. агач әйбер бәрелеп, сугылып, тигезсез хәрәкәт иткәндә чыга торган тавышны белдерә

ЛАД *и. рус муз.* Кыллы музыка уен коралларының грифындагы аркылы

тар кабарынкы сызыкларның һәрберсе; пәрдә. *Гитара ладлары*

ЛА́ДАН *и. гр.* Гарәп ярымутравында һәм Сомалида үскән босвеллия ыруына караган агачлардан табыла, башлыча чиркәүдә гыйбадәт кылганда төтәтер өчен һәм парфюмериядә кулланыла торган саргылт яки кызгылт хуш исле сумала; күнлек. *[Рим папасы] Капиталның дары төтененә Катнаштырып ладан төтенен, Советларга поход ясау өчен Җыймак була дошман төркемен.* М.Гафури. *--- шулай ук черкиләр ладан исенә дә түзмиләр ---.* Якты юл

ЛА́ДАННИК *и. рус. бот.* Ладанниклар семьялыгыннан эфир маена бай күпьеллык куак яки ярымкуакчыл үсемлек

ЛАДЬЯ *и. рус* Шахмат уенында аркылыга һәм буйга йөри ала торган, манарага охшатып ясалган шахмат фигурасы; тура. *Миргалим Харисов ике ладья, ферзь белән Гатаның королен китереп кыскан иде дә, Гата бер йөреш ясагач, хәлләр Миргалим өчен бик мөшкелләнде.* Р.Батулла. *Мин килгәндә, интерактив тактада пешка, ат, фил, ладья, ферзь фигураларының ничек йөргәнлеген кабатлыйлар иде.* Якты юл

ЛАДЬЯН *и. рус бот.* Сәхләбчәләр семьялыгыннан күпьеллык үләнчел үсемлек төре; каекчәчәк

ЛАЕК *с. гар.* **1.** 1) Куелган шартларга, таләпләргә җавап бирерлек, туры килгән, таләп ителгән сыйфатка ия булган. *Шунда, бер әдәби очрашудан кайткач, үземә бирелгән чәчәкләрне: «Бу чәчәкләргә Сездән дә лаек хатын-кыз юк», – дип, Сара апага бүләк иткән идем.* Ә.Рәшит. *Шул ук Горький өлкәсендәге Камка авылында очраклы рәвештә кулга төшкән «Сәкам кыйссасы»ның нөсхәсе дә игътибарга лаек.* М.Госманова. *Димәк, җәмәгатьчелек тарафыннан талантына лаек бәя алган, зур ихтирам казанган шәхес ул.* В.Сәйфуллин

2) Берәр максатка ярашлы, туры килердәй. *Бу кыйммәтле, матур алмаз фәкать ханга лаек малдыр.* М.Гафури. *Үзләренең художество дәрәҗәләре белән моңарчы Тукай премиясенә лаек әсәрләрдән һич тә ким түгелләр, хәтта аларның кайберләреннән өстен дә торалар.* Ә.Еники. *Ярышны үстерүгә бәйле мәсьәләләр игътибарга аеруча лаек.* Г.Ахунов

2. *рәв. мәгъ.* Таләп ителгәнчә, тиешле рәвештә, тиешенчә. *Юк, барысын лаек сурәтләргә Хәямнең да, Шекспирның, Пушкинның да тел кодрәте җитмәс иде.* Ф.Дунай

ЛАЕК БУЛУ *ф.* Нәрсәдер казану, яулау, үзенә хак итү. *Бу җыр ДОСААФ өлкә комитеты тарафыннан үткәрелгән конкурста бүләккә лаек булды.* С.Шакир. *Татар милли опера сәнгатен тудыруга зур көч салуы өчен, Сара ханым шул елларда ук «Татарстанның атказанган артисткасы» дигән мактаулы исемгә лаек булды.* Г.Бәширов. *Лаек булса, булмаса да, кайбер артисткаларга зур исемнәрне ашыга-ашыга биргәндә, Сарага зур исемнәр бирергә, инде композитор булып киткәч тә аны танырга бик ашыкмадылар.* И.Һилалов

ЛАЕКЛЫ *с.* **1.** *к.* **лаек 1.** *Бу инде аның мондагылар арасында ихтирамга иң лаеклы кеше икәнен күрсәтә иде.* А.Шамов. *Анысы шулай, ләкин минем батырларга хас булган холкым өчен лаеклы эш түгел.* Т.Гыйззәт. *Мин тавыш бирдем илемнең лаеклы улларына.* Ә.Ерикәй

2. *рәв. мәгъ.* Тиешле рәвештә, тиешенчә; кирәгенчә. *Ләкин халкыбыз үзенекен итте, күптән инде «Татар сандугачы» дип аңа зур һәм романтик бәя бирелде, бу зур бәя һәм бөек исемне Сара Садыйкова лаеклы рәвештә югары йөртте, иҗатта үткән гомере буена шул исемгә лаеклы булды.* Ә.Айдарская. *Лаеклы бул туган халкыңа.* Г.Хуҗиев

◊ **Лаеклы ял** Пенсия яшенә җитеп, эштән тукталган ара. *Гомерен җәмгыятькә файдалы хезмәттә үткәреп, лаеклы ялга чыгасы, хөрмәт һәм ихтирам сүзләре ишетәсе урынга ләгънәттән башканы ишетми.* Х.Вәлиәхмәтов. *Шуңа күрә ансамбльдән китеп, инде лаеклы ялларга чыгып яшәүчеләр дә аны онытмадылар.* Х.Хәмидуллин

ЛАЕКЛЫК *и. сөйл. к.* **лаеклылык**. *Ходай адәм балаларын тигез итеп яратмаган шул. Бу сүзләрнең төбенә дә «кешеләрнең барысы да зур талантлы булмый, лаеклык та тигез түгел» дигән мәгънә җәелгәнлеген Морза аңламый калмады, әйтер иде бер сүз!* Ф.Баттал

ЛАЕКЛЫ́-ЛАЕКСЫЗ *с.* 1) Берәүгә бик үк тиеш булмаган, берәүнең һичшиксез алу хакы булмаган. *Артык җиңел һәм тиз, шунлыктан Хариснең беркатлы күңеле адаптацияләнеп өлгерәлмәде, лаеклы-лаексыз мактаулардан башы әйләнде.* З.Мурсиев

2) Һәрвакытта да лаеклы булмаган, бик үк лаеклы саналмаган (кеше тур.). *Лаеклы-лаексыз кешеләрне бүләкләү*

ЛАЕКЛЫЛЫК *и.* Куелган таләпкә җавап бирерлек булу, лаеклы булу

ЛАЕКСЫЗ *с. сөйл.* **1.** Тиеш булмаган, куелган таләпкә туры килмәгән, лаек булмаган. *Шуңа күрә, гади һәм игътибарга лаексыз күп кенә нәрсәләр армаган күзгә ачыграк-күперебрәк күренүе бик ихтимал.* Р.Батулла. *Ихтирамга лаексыз кеше*

2. *рәв. мәгъ.* 1) Тиеш булмаган рәвештә, җитәрлек югарылыкка җиткермичә. *Әгәр дә берәр хезмәткәребезнең юлда үзен лаексыз тотуы, мохтаҗларга ярдәм күрсәтмәве турында ишетсәк, аның белән шунда ук хушлашабыз.* Кызыл таң

2) Тиеш булмаган хәлдә, хакы булмый торып. *Аның бер генә бүләге турында да «лаексыз алды» дип әйтергә берәүнең дә теле бармас. Машалла, Туфан!* Р.Батулла

ЛАЕШ *и.* Татарстанда Кама елгасы буенда урнашкан шәһәр исеме

◊ **Лаеш шулпасы эчү** Кыенлыклар күрү, бик зур авырлыклар, кайгы кичерү. *Кыяметдин бабай дөньяның ачысын-төчесен күп татыган, лаеш шулпасын күп эчкән карт иде.* М.Хәсәнов. *– Без үзебез дә лаеш шулпасын аз эчмәдек, беләбез, – диде.* Казан утлары. **Лаеш шулпасы чөмерү** *к.* **Лаеш шулпасы эчү**. *Сугыш буенча укчы полкта хезмәт иткән Зариф лаеш шулпаларын аз чөмермәде.* А.Расих

ЛАЖ I *иярт.* Берәр сыгылмалы нәрсә (чыбык, камчы, чыбыркы һ.б.ш.) белән кисәк селтәнгәндә, сукканда, һавада барлыкка килгән сызгыру сыман

тавышны белдерә. *«Синнән картлар хезмәт итә, ә син, бәдбәхет, ялкау, оялмыйча, монда күләнкәдә рәхәтләнеп утырасың!» – дип, кулындагы кара елан төсле камчы илә бичара әсирнең аркасына лаж иттереп бик каты сукты.* Ш.Мөхәммәдев

ЛАЖ II *и. фр. икът.* 1) Кыйммәтле кәгазьләрнең (акцияләрнең, облигацияләрнең һ.б.ш.) номиналь кыйммәте белән чагыштырганда курсы күтәрелү

2) Кәгазь акчаларның кыйммәте төшкән вакытта, алтын акчаның номиналь кыйммәтенә караганда базар бәясе үсү

ЛАҖЫРАЮ *рәв.* Җәелеп, сузылып (утыру, яту тур.). *--- Руфинә, кулларын баш астына салып, юан ботларын бака шикелле җәеп, лажыраеп, диванда йоклап ята иде.* Ф.Садриев

ЛАЗ *и.* Картвел тел семьясының колх төркеменә караган, башлыча Грузиядә һәм Төркиядә яшәүче халык атамасы; шул халыкның бер кешесе. *Мәскәүдә икмәк пешерүче лазлар әйтеп бетергесез күп.* Социалистик Татарстан

ЛАЗА́НЬЯ *и. ит.* Турыпочмак формасындагы зур булмаган токмач җәймәсе һәм шундый җәймәләрдән төрле эчлек белән аралаштырып әзерләнгән ризык. *Ул арада кәстрүлдә кайнап торган суга лазанья токмачын салып, 8–10 минут пешереп алабыз.* Ватаным Татарстан. *«Кызыл дөя» кафесы Европа кухнясыннан бик күп төрле азык әзерләп алып килгән: берничә төр салат, яшелчә-җимеш, фольгада пешкән тәрәч балыгы, дуңгыз итеннән рулет, лазанья...* Туган як

ЛАЗАРЕТ *и. фр.* Хәрбиләр ятып дәвалана торган кечерәк госпиталь. *Күптән түгел безнең ротага Петроград лазаретыннан бер солдат кайтты.* К.Нәҗми. *Аңыма килгәндә лазаретта идем инде мин.* Г.Гобәй. *Без менә йөргәч күрәбез: мәктәпләр ягылмый, лазаретлар ягылмый.* Ә.Еники. *--- чирләп, кыйналып, таушалып беткәннән соң, сәясиләрне чираттагы җәһәннәм юлы станцасына – Спасск төрмә лазаретына китереп ташлыйлар.* А.Гыйләҗев

ЛАЗЕМ *с. гар.* **1.** Кирәкле, тиешле, мөһим, мәҗбүри, зарур. *Социал демократлар бер комиссия сайлауны иң тиеш вә лазем эш күрәдерләр.* Урал

2. *рәв. мәгъ.* Тиеш дип, кирәк дип. *Ул моны ачыктан-ачык әйтмәсә дә, яшерергә дә лазем күрми иде.* Г.Ибраһимов. *Иң башта өйрәнү лазем булган эшләрне өйрәттеләр.* М.Гафури

3. *мод. сүз* Тиеш, кирәк, кулай. *Фәкать таифәнең теләве лазем дип ышана торган шәкертләр үз хәлләреннән зарланалар.* Ф.Әмирхан. *Бездә революциядәгечә бу эш башланган иде, хәзер совет нигезендә күтәреп чыгу лаземдер.* Г.Ибраһимов

ЛАЗЕМЛЕК *и. иск.* Кирәклек, зарурлык

ЛА́ЗЕР *и. инг. махс.* Көчле һәм бик нечкә генә яктылык юлын барлыкка китерә торган яктылык дулкыннарын нурландыручы генератор. *«Яшен ташы» дигәне чынлыкта хәзерге лазер-пистолет кебек нур ата торган корал булса?* А.Тимергалин. *Бу үзгәрешләрнең тизлеген аңларга мөмкин: атом чоры, космос һәм лазер дәвере нәкъ шундый күз иярмәслек тизлек таләп итә.* Казан утлары. *Япония галимнәре, әле тегеләр кире кайтып киткәнче үк, бу көзгеләргә куәтле лазер нуры җибәрәләр.* Кызыклар дөньясында

ЛА́ЗЕРЛЫ *с.* Эшләү принцибы лазер куллануга нигезләнгән. *Арсеналлар корал белән тулы – Атом төшлесе күп, лазерлысы...* Ф.Дунай. *Лазерлы шоу, фейерверклар, конфетти залплары кулланылачак бәйрәм тамашасына зурдан кубып әзерләнәләр.* Татарстан яшьләре. *Яшьләр лазерлы гравёр, фрезер станок, 3D-принтер һәм 3D-сканер кебек заманча җиһазлар белән танышачак һәм алар белән эшләү алымнарына өйрәнәчәк.* Туган як

ЛА́ЗЕР-ШОУ *и. инг.* Лазер ярдәмендә яктылык нурлары уйнатудан, сурәтләр барлыкка китерүдән гыйбарәт тамаша. *Кем нәрсә белән җим салып чакыра: театральләштерелгән лазер-шоу, танылган кунаклар...* Шәһри Казан. *Оештыручылар фейерверклар һәм лазер-шоу вәгъдә итә.* Безнең гәҗит

ЛАЗУРИТ *и. гар. геол.* Бизәнү һәм декоратив сәнгать әйберләре, ультрамарин минераль буявы ясау һ.б. өчен файдаланылган, зәңгәрсу соры яки яшькелт сорыдан алып куе зәңгәр һәм шәмәхә төсле үтә күренми торган минерал. *Памирда алтын, лазурит, тау хрустале очрый.* СССРның экономик географиясе

ЛАЗУРЬ *и. гар.* 1) Ачык зәңгәр төсле буяу. *Уң якта лазурь белән буялган төсле иксез-чиксез зәңгәр дала – Тын океан җәйрәп ята.* М.Маликова. *Лазурь турында: «Лазурь – лөҗүрд, кыйммәтле күк буяудыр», – ди.* Фән һәм тел

2) *к.* **лазурит**. *Залның дүрт стенасы – яшма һәм лазурь белән, гөмбәзтүшәмнәре – рубин белән, мебельләре алтын һәм көмеш белән зиннәтләнгән.* К.Насыйри

ЛАЗУ́ТЧИК *и. рус иск. сөйл.* 1) Дошман тылына үтеп, мәгълүмат җыеп йөрүче, шпион. – *Ул чакта, безгә – чик сакчыларына – япон лазутчикларыннан шактый кыен күрергә туры килде, – дип искә ала сугыш елларын Госман ага, – шунда байтак иптәшләребезне югалттык*. Ватаным Татарстан

2) *күч.* Берәр җирдәге хәлләр турында хәбәр җиткереп торучы үз кеше; җасус. *Без инде берәр лазутчик иптәшенә шартлы сигнал бирә торгандыр дип уйлыйбыз.* Р.Батулла

ЛАИХӘ *и. гар иск. к.* **ляихә**. *Киләчәктә бу хакта фикеребезне мөфассалән язып, бер лаихә шикелле нәрсә дә гарыз итәчәкбез.* Ф.Әмирхан

ЛАЙ I *и.* 1) Сазда, акмый яки акрын ага торган сулыкларда йөзеп йөри торган яисә төпкә ябышкан суүсемнәр. *Лаеш суы ул шулай: Асты ләм дә өсте лай.* Н.Исәнбәт. *Лайга баткан «Шатур» сазыннан Совет иле 32 мең киловаттлы электрик уты кабызган.* Ф.Кәрим

2) *диал. к.* **ләм** I (*1 мәгъ.*). *Күлләвекләрнең болганчык күзләрен сытып лай чәчеп, аллы-артлы поездга чабалар.* А.Гыйләҗев. *Кыйммәтле дәвалау сыйфатлары булган минераль сулар, лайлар безнең республикада да бар.* Кызыклы география

ЛАЙ II *кис.* Озын җырларда иҗек санын көй тактына туры китерү өчен өстәлә торган сүз. *Кычкырыр лай кәк-*

күк, Сайрар былбыл, Шул чагында ничек түзәрсең. Җыр. *Тубылгы лай агач зур булмас, Арасыннан үтәр юл булмас.* Җыр

ЛА́ЙКА I *и. рус* Башлыча Төньякта һәм Себердә үрчетелгән, ау, йөк ташу, саклау хезмәте өчен файдаланыла торган зур булмаган этләр токымы. *Лайка токымлы этләрнең акылына сокланырга гына кала.* Шәһри Казан. *Ә ярыш вакытында лайка аюга каршы берүзе ун минут каршы тора алса, ягъни аңа бер метр да читкә китәргә ирек бирмәсә, хуҗасын каты өреп чакырса һәм шуның өстенә аю табанының иң авырткан җиреннән тешли дә алса, бу – бик югары балл дигән сүз.* Саба таңнары

ЛА́ЙКА II *и. пол.* **1.** Кәҗә яки сарык бәтиләренең тиресеннән эшләнгән йомшак күн

2. *с. мәгъ.* Шул күннән тегелгән. *Кара лайка перчатка эчендә тагын да нечкәрәк, тагын да кечкенәрәк, нәфисрәк булып күренгән аның сул кулында кечкенә генә сары күн саквояж.* К.Тинчурин

ЛА́ЙКРА *и. инг.* 1) Полиуретан каучуктан ясала торган, нык деформацияләнүчән синтетик җеп

2) Шул җеп кушылып ясалган синтетик тукыма; эластан, спандекс

ЛАЙЛА *и.* 1) Кайбер хайваннардан яки үсемлекләрдән бүленеп чыккан һәм тотканда кул шуа торган куе сыекча. *Махсус күзәнәкләре кандагы тозны эләктереп алалар да аның көчле концентрациясен лайла белән бергә тышка чыгаралар.* Б.Сергеев. *Орлыклары өлгергәч, аның җимешләрендә лайла җыела һәм ул орлыклар белән бергә атылып чыга.* Ботаника

2) Кешенең кайбер органнарыннан бүленеп чыга торган шундый ук сыекча. *[Нуруллин] авызында ниндидер лайла, тәмсез нәрсә барлыгын сизде.* А.Шамов. *Аның эчендә... лайлага күмелеп һәм бик нык көзән җыергандай чөмәшеп, теге каектан юкка чыккан кит аулаучыларның берсе – Джеймс Бартли ята!* Кызыклар дөньясында. *Борын куышлыгы бизләреннән бүлеп чыгарылган лайла бирегә керә торган һавадагы бактерияләрнең тереклек эшчәнлеген киметә.* Анатомия

3) *диал. к.* **ләм** I (*1 мәгъ.*)

ЛАЙЛАЛАНУ *ф.* Лайла бүленеп чыгу; лайла белән каплану, лайла ябышу. *Явымлы көннәрдә [валуй] эшләпәсенең өсте лайлалана.* Робинзон эзләреннән. *Мондый очракларда лайлаланып изелгән солы яки җитен шулпасын, суга изгән крахмал, кесәл, атланмай яки чи йомырка бирергә кирәк.* Мәдәни җомга

Лайлалана башлау Лайла барлыкка килү. *Әйтик, Норвегиядән китерелгән сөләйман балыгы вакытында сатылмыйча исләнә, лайлалана башлады, ди.* Ватаным Татарстан

Лайлалана төшү Беркадәр, бераз лайлалану; тагын да ныграк лайлалану

Лайлаланып бетү Тоташ лайла белән каплану. *Лайлаланып беткән ит сатканнар бит сиңа!* Р.Батулла

Лайлаланып китү Бераз гына лайлалану

Лайлаланып тору Һәрвакыт лайлалы булу

ЛАЙЛАЛЫ *с.* 1) Лайла бүлеп чыгара торган (тышча, катлау). *Тире һәм лайлалы сүрүләр яраланганда, яradан кан китү дә, аңа пычрак белән микроблар керүе дә бик куркынычлы.* Йорт эшләре. *Томау төшкәндә (борын куышлыгының лайлалы тышчасы ялкынсынганда) лайланың күп чыгуы һава белән кергән бактериягә каршы саклану реакциясе була.* Анатомия. *Эвкалипт мае белән фурункулларны, лайлалы тышчаларның эрозияле җәрәхәтләрен, югарыгы сулыш алу органнары катарларын дәвалыйлар, миозитлар һәм радикулитлардан, авыртуларны баса торган дару буларак файдаланалар.* Урман аптекасы

2) Лайла белән капланган, лайла ябышкан, лайлаланган. *Никадәр күп аборт ясалса, аналык стенасында шулкадәр күбрәк җөй кала һәм аның лайлалы катлавы җиңелрәк җәрәхәтләнә.* Йорт эшләре. *Башын эшкәрткәндә, йоннарын чистартып бетергәч, авыз эчендәге лайлалы катлауны кубарып алырга, томшыгын кисеп ташларга кирәк.* Татар халык ашлары

3) *диал.* Ләмле, ләм утырган. *Көн урталарында сазаннар, кырыйга якын килеп, лайлалы балчыкка чумып торалар.* Ш.Камал

ЛАЙЛАЧ *и. зоол.* Кабырчыксыз һәм умырткасыз коры җир моллюскы; *рус часы:* **слизняк**. *Төгәлрәк әйткәндә, күп кенә лайлачларның кабырчыгы тире астында кала һәм тыштан күренми.* Ә.Халидов. *Кыш буе җыеп барган йомырка, суган кабыклары лайлач белән көрәшә, үлән бетләрен, гөмбәләрне кырып сала.* Татарстан яшьләре

ЛАЙЛЫ *с.* 1) Лай I (*1 мәгъ.*) белән катыш, лай ябышкан

2) Лае I (*2 мәгъ.*) күп булган, лай утырган, ләмле. *Бервакытны Җиһангир сул кулының лайлы җиргә тиюен сизде, ләкин күңеле ышанып бетмәде.* Г.Әпсәләмов. *Әле дә ярый аяк табаны астында мәлҗерәп торган лайлы су төбен тойды ул.* М.Хәсәнов

ЛА́ЙНЕР *и. инг.* 1) Океан, диңгезләрдә йөк яки пассажирлар ташый торган зур судно. *Лоцман безне ашыктыра, унбиш минуттан трансатлантик лайнер – Италиянең престиж корабы «Андреа Дориа» кузгалырга тиеш.* М.Юныс. *Чынлап та, өч меңләп кешене бортына алган лайнер кечкенә бер шәһәрне хәтерләтә.* Өмет

2) Регуляр рейслар ясый торган күп урынлы самолёт. *Болгариянең транспорт министры Анатас Костов сүзләренә караганда, Ту-154не башка лайнерга алыштыру мөмкинлеге дә бар.* Ватаным Татарстан

ЛАК I *и.* Таулы Дагстанның башлыча Лак һәм Кули районнарында яшәүче, нах-дагстан төркеменә караган телдә сөйләшүче халык; шул халыкның бер кешесе. *--- Дагстандагы лак театрында «Яшел эшләпә» пьесалары зур уңыш белән бара ---.* Әдипләребез

ЛАК II *и. ит.* 1) Нинди дә булса өслекне бозылудан, тырналудан саклау өчен кулланыла торган, спиртта, скипидарда, үсемлек маенда эретелгән сумала сыекчасыннан гыйбарәт буяу. *Кырсынып торган таза күк айгырны каралы-кызыллы лак белән буялган --- пролёткага җигеп, шәһәр уртасыннан узып китүе үзе нәрсә тора!* Ә.Фәйзи.

Гомәр Садриевич чүкеч, кечкенә балта сапларының җиренә җиткезеп шомартылган, төртке-төртке яндырып орнамент бизәкләр төшерелгән һәм үтә күренмәле лак белән ялтыратылган булуына игътибар итте. Казан утлары. *Өй җиһазларының лак белән капланмаган һәм буялмаган урыннарын елына 1–2 мәртәбә натрий фториды яки кремнийлы натрий эремәсенә манчылган чүпрәк белән сөртергә мөмкин.* Йорт эшләре

2) Әйбер өстен буяганнан соң барлыкка килә торган каты ялтыравык элпә. *Лагы кыршылган булуга карамагыз.* Сәхнә

3) Тырнакны матурлау яки ныгыту өчен кулланыла торган төсле яки үтә күренмәле буяу. *Комод өстендә хатын-кызның бизәнү әйберләре. Иннек, кершән, сөрмә, кына, лак, чәч ныгыткыч, чәч йомшарткыч, чәч бөдрәләткеч* ---. Ф.Шәфигуллин. *Тырнак лагы төсе иннек төсе белән туры килергә яки берберсен тулыландырып торырга тиеш.* Кәеф ничек?

4) Чәчкә билгеле форма биргәч, шул форма саклансын, тузгымасын өчен, өстеннән пошкыртып куела торган ныгыткыч состав

ЛА́К АГАЧЫ *и.* Сумахчалар семьялыгыннан Кытай, Корея һәм Япониядә үсә торган, биеклеге 20 метрга җитә, вак чәчәкләре себеркәчкә җыелган, кайрысыннан лак өчен сумала алына торган агач. *Япон утрауларының көньяк өлешендә --- лак агачлары, бамбук, эре ак чәчәкле магнолия, камелия куаклары үсә.* Дөнья кисәкләре географиясе

ЛАКАН *и.* 1) Һәртөрле юынтык сулар түгү өчен кулланыла торган зур агач чиләк. *Хәлим лакан өстендәге кызыл бакыр комганнан кулларын чылатты.* И.Гази. *Шуннан мин: «Чумсаң чум инде», – дип әйтергә дә өлгермәдем, мөритем башы белән йөзтүбән лап итеп лаканга чумды.* Т.Гыйззәт. *Латыш, литва фамилияләре колакка ят, офицерның белем чамалы, боза, боза да авызын тутырып безнең өскә бер лакан мат чәчә.* А.Гыйләҗев

2) *күч.* Бик зур савыт. *Ялмавызга өч лакан шәраб китерделәр.* Р.Батулла. *Аракының лаканына төшәр иде, әгәренки андый лаканны ишек төбенә китереп куйсалар.* А.Хәлим

ЛАКА́Н ЧИЛӘГЕ *и. к.* **лакан 1.** *Сөт, икмәк калдырды, су кертте, ишек төбенә лакан чиләге куйды.* Г.Гыйльманов. *Әйткән кешенең авызы лакан чиләгенеке кебек ачылып калды.* Ф.Яхин

ЛАКА́У *ф. гади с.* 1) Эт, мәче кебек хайваннарның тел белән ялап сөт һ.б. сыеклыкны эчүләре

2) *күч.* Исерткеч эчемлекләрне артык күп эчү. *Каргалар үләксә ашамаган, ә син лакарга өлгергәнсең.* Ш.Камал

Лакап йөрү Теләсә кайда лакау; күптәннән бирле лакау

Лакап тору Гел лакау; хәзер лакау

Лакый башлау Лакарга керешү

Лакап бетерү Ахырына кадәр лакау

ЛАКЕЙ *и. фр.* 1) *иск.* Бай йортында яки кунакханә, ресторанда хезмәтче, хадим. *Мин сиңа лакей түгел бит, үзең монда кил!* Г.Коләхмәтов. *Лакеең бармы әллә синең, ике кружка су бетердең ич.* Ш.Камал. *Ул, музейдагы балавыз сыннар сыман, үзеннән читтәрәк, бусага төбендә үрә катып басып торган лакейларга таба борылды.* А.Толстой

2) *күч.* Тәлинкә тотучы, яраргa тырышучы, ялагай. *Юк, сез дошманнарга лакей булып йөрисез!* М.Гафури. *Халыкларны шундый хәлгә төшергән дәүләтнең геноцид сәясәтен яклаган галимнәрнең, лакейларның җинаяте Нюрнбергтагы кебек халыкара трибуналларда хөкем ителергә тиеш.* Татар заманы

ЛАКЕЙЛАНУ *ф.* Яраргa тырышу, ялагайлану, тәлинкә тоту

Лакейлана башлау Әкренләп үзен лакейларча тотуга күнегү

Лакейланып йөрү Еш кына үзен лакейларча тоту

ЛАКЕЙЛА́РЧА *рәв.* Яраргa тырышып, колларча, ялагайланып, юмакайланып. *Иреннәрем иркемнән башка кызганыч һәм җирәнгеч бер елмаю белән елмаялар, күзләрем лакейларча карый башлый.* С.Җәлал

ЛАКЕЙЛЫК *и.* 1) *иск.* Лакей булу, лакей хезмәте. *Лакейлык вазифасы*

2) *күч.* Юмакайлык, ялагайлык. *Безнең аристократиябез (әгәр мирзаларны шулай дип атарга яраса) Казан ханлыгының соңгы дәвереннән башлап Мәскәү князьлегенә лакейлык итте.* Ф.Әмирхан. *Бу бик үткен, ачы сатира – эпиграмма иде. Муса аны легионнар оештыруда фашистларга лакейлык иткән ак эмигрантка карата язган.* Р.Мостафин

ЛАКИРО́ВКА *и. рус* 1) Әйберне шомартып, лаклап ялтырату эше

2) Әйбер өстендәге лак катламы. *Өстәлнең лакировкасын бозу*

3) *күч.* Нәрсәнедер матурайта төшеп, уңай яктан гына күрсәтү, чагылдыру. *Дүртенчедән, драматургларның «әйләнә тормышыбыздагы шактый күп каршылыкларны схематик аңлап, аны җиңә алмаулары», шул сәбәпле «лакировкага бирелүләре»* ---. Н.Юзиев

ЛАКИРО́ВКАЛАУ *ф.* 1) *к.* **лаклау**

2) Шомартып, махсус эшкәртеп яки лак сөртеп ялтырату

Лакировкалап алу Ансат кына яки тиз генә лакировкалау

Лакировкалап кую Лаклау эшен алдан ук бетерү

Лакировкалап тору Даими лакировкалау

Лакировкалап жибәрү Яхшы итеп лакировкалау

ЛАКИРО́ВКАЧЫ *и.* 1) *к.* **лаклаучы**

2) Шомартучы, ялтыратучы

ЛАКИРО́ВЩИК *и. рус к.* **лакировкачы**

ЛАКЛАНУ *ф.* 1) *төш. юн. к.* **лаклау**. *Нибарысы өч пар аяк киемем бар иде: кызгылт көрән төстәге яңа башмак, кара төстәге иске башмак һәм менә бу – аягымдагы – лакланган туфли.* К.Дойл. *Өй җиһазларының лакланмаган һәм буялмаган урыннарын елына 1–2 мәртәбә натрий фториды яки кремнийлы натрий эремәсенә манчылган чүпрәк белән сөртергә мөмкин.* Йорт эшләре. *Салкынга чыгаргач, лакланган урыннар агара икән, шуңа лак урынына бронза буявын кулланырга исәбе бар останың.* Ватаным Татарстан

2) Лак белән буярга яраклы булу; лак белән буялу. *Бу агач яхшы лаклана*

ЛАКЛА́У *ф.* 1) Әйбернең өслеген лак белән буяу, лак белән каплау. *Фил сөягеннән һәм агачтан лаклап ясалган*

художестволы эшләнмәләргә чит илләрдә бик югары бәя бирәләр. Чит илләрнең экономик географиясе. *Морилка сөрткәннән соң, әйбер кисәкләрен киптерәләр, аннары балавыз сөртәләр һәм лаклыйлар.* Йорт эшләре

2) Лак сиптерү (чәчкә). *Үзенә бик килешеп торган яңа күлмәге, лаклап кабартылган бөдрә чәчләре аны яшь кызлардай сылу, нәфис иткән.* Д.Каюмова

Лаклап алу Бераз, тиз арада лаклау

Лаклап ату Тиз-тиз, аннан-моннан лаклау

Лаклап бетерү Тулысынча лаклау

Лаклап җибәрү Бераз лаклау. *[Гарифулла] Миңа әйтә: «Әгәр син рөхсәт итсәң, мин моны буяп, лаклап җибәрер идем», – ди.* Ф.Яруллин. *Аны буяп, лаклап та җибәргәч, кибеттә сатыла торганга биргесез иде.* Шәһри Казан

Лаклап кую Алдан ук лаклау; лаклап әзер хәлгә китерү. *Башта шешәгә ак буяу белән грунт ясыйбыз, берәр рәсем я бизәк төшерәбез, аннан төсле буяулар белән буяп, лаклап та куябыз.* Сабантуй. *Өйдәге иске җиһазларны ташлыйсыгыз килмәсә, махсус эремә белән чистартып, лаклап куегыз, аларның үз матурлыгы кайтачак.* Шәһри Казан

Лаклап ташлау Тиз-тиз, аннан-моннан лаклау

Лаклап тору Даими рәвештә лаклау

Лаклап чыгу Бөтен җирен дә, тоташ лаклау; рәттән барысын да лаклау

Лаклый башлау Лакларга керешү

ЛАКЛАУЧЫ *и.* 1) Лак белән буяучы, лаклау эшенең остасы, шул эш белән шөгыльләнүче кеше

2) *күч.* Чынбарлыкны дөрес күрсәтмичә, шомартып, кимчелексез итеп күрсәтүче. *Шигырь яздым Мактап яхшы колхозны, Тәнкыйтьчеләр тик бер карап бактылар, «Лаклаучы» дип «матур исем» тактылар.* Казан утлары

ЛАКЛЫ *с.* 1) Лак белән капланган, лакланган. *Хәлим кара лаклы зур тарантас кузласына утырган.* Г.Гобәй. *Лаклы мебель*

2) Махсус эшкәртеп, шомартып ялтыратылган. *Өендә дуслары белән утыруына карамастан, ул кунак төсле киенгән: галстуктан, лаклы туфлиләрдән иде.* Т.Әйди. *Лаклы итек үкчәсе белән кыз аягындагы сандал каешына баса язуын күреп, тагын да аптырый төште.* К.Нәҗми. *Лаклы аяк киемен, лагы ябышмасын өчен, җәен кәгазьгә төрәләр.* Йорт эшләре

ЛА́КМУС *и. голл. хим.* Лишайниклардан табыла торган табигый буяу матдәсе – кислота-селте индикаторларының иң беренчесе һәм киң таралганы. *Лишайникларның кайбер төреннән буяу һәм химия промышленносте өчен махсус матдә – лакмус алалар.* Биология. *Һәр пробиркага лакмус эремәсе тамызыгыз һәм аның төсе үзгәрүен билгеләгез.* Химия. *Зәңгәр лакмус кәгазен ашказаны сыекчасына чылатсаң, ул кызара.* Анатомия

◊ **Лакмус кәгазе** Берәр нәрсәнең ачык билгесе, шуның галәмәте

ЛАКОНИЗМ *и. гр. кит.* Тирән мәгънәне аз һәм кыска сүз белән аңлату алымы. *Поэзиянең үсеше шигъри фикерләүдә тыгызлыкка, мәгънәлелеккә, сурәтләүдә лаконизмга омтылуда да күренә.* Н.Юзиев

ЛАКО́НИК *с. кит.* **1.** Аз сүзле, кыскалыгы, җыйнаклыгы белән аерылып торган. *Пушкиндагы тыгыз, лаконик шигырь, барыннан да элек, элитар укучыны күздә тота.* Н.Хисамов

2. *рәв. мәгъ.* Артык сүз кулланмыйча, кыска, төгәл һәм аңлаешлы итеп

ЛАКТА́ЦИЯ *и. лат.* Имезүчеләрдә сөт хасил булу, җыелу һәм бүленеп чыгу процессы; сөт бүлеп чыгару дәвам иткән чор. *Күп кенә хайваннарның лактация чорын шактый арттырырга мөмкин.* Б.Сергеев. *Шулай ук лактация һәм һәр беренче бозау анасыннан бер бозау югала.* Терлекчелекне интенсив үстерү

ЛАКТОБАЦИЛЛИН *и. лат. махс.* 1) Дәвалау үзлеге бирү максаты белән сөтне әчетә торган сөт бактерияләренең билгеле ике төр культурасы

2) Шушы гөмбәчекләр ярдәмендә оетылган сөт

ЛАКТО́ЗА *и. лат. махс.* Сөт шикәре, дисахарид; сөт составында була торган шикәр. *Аның составында фруктоза, глюкоза, мальтоза, галактоза, лактоза, триптофан һәм алитам дигән баллаткычлар бар.* Ватаным Татарстан. *Ә андагы сөт шикәре (лактоза), организмда кальцийның үзләштерелүенә ярдәм итеп, сөяк һәм тешләрне ныгыта.* Мәдәни җомга

ЛАКТО́МЕТР *и. лат. махс.* Сөт составындагы су һәм майның процент исәбе белән микъдарын билгеләү өчен шкалалары булган озынча пыяла савыт җайланма, прибор

ЛАКТОСКОП *и. лат.-гр. махс.* Сөтнең куелыгын, майлылыгын үлчи торган прибор, җайланма

ЛАКУ́НА *и. лат.* 1) *физиол.* Аерым әгъзалар яки тукымалар арасындагы бушлык, куыш урын

2) *анат.* Әгъзаның (мәс., бадәмсыман биз, тез капкачы) өслегендә булган уем, чокыр

3) *лингв.* Телдәге башка культура вәкиленә аңлашылмый торган, башка телдә төгәл тәңгәле булмаган сүз, берәмлек

ЛАКУНАР *с.* Лакуна булып торган, лакуна күренешенә караган

ЛАКЫЛДА́У *ф.* 1) *сөйл.* Бертуктаусыз сөйләнү, артык күп сөйләү. *Бертуктаусыз лакылдый да тора: заманнары, заманнары!* А.Шамов. *Көннәр буе лакылдап тәмам җелегемә төштең син минем.* М.Мәһдиев

2) Кирәкмәгәнне, артыгын, теләсә нәрсә сөйләү. *– Лакылдама әле, хәерче! – дип кычкыралар кешеләр.* Р.Батулла. *Бату һаман үзенчә чәрелдәде: – Кара син аны, төрмәдә дә болай лакылдамыйлар, ә ул иректә нәрсәләр сөйли!* Мирас

3) *диал.* Бытылдау (балалар сөйләме тур.). *Кайткан чакта, ындырга тычкан тотарга барган мәче эзенә ияреп кайтулары; өч яшьлек баланың юл буенча өзлексез лакылдавы, күзенә чалынган барлык нәрсә турында энәсеннән җебенә хәтле сорашып баруы хәтердә калган.* И.Гази

Лакылдап тору Гел лакылдау; хәзер лакылдау. *Лакылдап торма анда!* Р.Батулла

Лакылдап йөрү Теләсә кайда теләсә нәрсә лакылдау

Лакылдый башлау Лакылдарга керешү

ЛАКЫЛДЫК *и. сөйл.* Күп сөйләүче, җитди булмаган нәрсәләр сөйләүче

ЛАКЫ́Р-ЛОКЫР *иярт.* Әйбер кайнаганда чыккан тавышны белдерә. *Казанда лакор-локыр аш кайнаганы ишетелә.* И.Гази

ЛАЛӘ *и. фар.* Лаләчәләр семьялыгыннан, эре кыңгырау чәчәкле, суганчалы күпьеллык үсемлек; тюльпан. *Лаләләр Урта Азиядә, Кавказда, Волга буе һәм Кырым далаларында кыргый үсә.* Ботаника. *Лалә чәчәкләләрнең кайберләрен санап үтик. Аларга барыннан да элек чәчәкләре ак, алсу, сары яки кызыл төстәге хуш исле төрле лаләләр, хуш исле ландыш, кызалак керә.* Казан утлары

ЛАЛӘГӨЛ *и. сөйл. к.* **лалә**. *Хәсәнә абыстай әллә күпме гөлләр үстерә: тамчыгөл, рәйхангөл, лаләгөл, сөмбелгөл...* С.Поварисов

ЛАЛӘ́ЧӘЛӘР *и. бот. күп.* Лалә, лилия, юа кебек сыңарорлыклы үлән үсемлекләрне берләштерә торган семьялык

ЛА́МА I *и. исп. зоол.* Көньяк Америкада таралган, хуҗалыкта йөк ташуда кулланыла һәм кыйммәтле йон бирә торган өркәчсез дөя

ЛА́МА II *и. тибет* Тибет буддачылыгында дин остазын хөрмәтләп атау һәм эндәшү сүзе; дин әһелләренең төрле дәрәҗәләрен атаган терминнарның икенче компоненты. *Шулай да фикеремне, максат-ниятемне телсез-нисез укый алган лама монахы миңа булышлык күрсәтергә ризалашты.* Г.Гомәр. *Лама, кагыйдә буларак, барлык монахларны (калмыкларда лама – дин башлыгы) аңлата, ә будда дине башында торучылар «далайлама» дип аталалар.* К.Гыйззәтов

ЛАМАИЗМ *и. фр. ялг.* Будда динең VIII йөздә Тибетта, XVI–XVIII йөзләрдә Монголиядә таралган төре; иң югары баш рухание – далайлама. *Гомумән, Монголия һәм Бурятиядә лама «тере Будда» дип санала. Бу илләрдә ламаизм – киң җәелгән күренеш.* К.Гыйззәтов

ЛАМАИСТ *и. рус ялг.* Ламаизм тарафдары, ламаизм динен тотучы

ЛАМАНТИН *и. фр.* Сиреналар отрядыннан Атлантик океанның Африка һәм Көньяк Америка яр буйларында яшәүче, үлән белән тукланучы, имезүче диңгез хайваны; диңгез сыеры. *Ламантиннар Атлантик океанның Африка һәм Көньяк Америка ярлары буенда, шунда коючы елгаларда төркемләшеп яшиләр.* Биология

ЛАМАРКИЗМ *и. фр.* Француз галиме Ж.-Б.Ламаркның табигатьтәге эволюцион үсеш турындагы тәгълиматы

ЛАМБРЕКЕ́Н *и. фр. махс.* 1) Тәрәзә һәм түбә кырыйларын бизәү өчен агачтан кисеп яки тимердән чүкеп ясалган сырлар

2) Тәрәзә, ишек пәрдәләренең өске ягында горизонталь юнәлештә беркетелгән тукыма, драпировка, телле кайма яки башка төрле бизәк

ЛАМИНА́РИЯ *и. лат. бот.* Башлыча Япон һәм Охот диңгезләрендә үсә торган, кайбер төрләре ашарга яраклы, шулай ук фармокология, косметология, хуҗалык максатларында кулланылган көрән диңгез суүсемнәре ыруы; диңгез кәбестәсе. *Ламинария чагыштырмача артык тирән булмаган, кояш яктысы җитәрлек дәрәҗәдә үтеп керә торган урында яши.* Биология. *[Японнар] Ламинарияне азык итеп бигрәк тә еш кулланалар, алар аны диңгез кәбестәсе дип тә йөртәләр.* Биология

ЛА́МПА *и. нем.* 1) Төрле формадагы һәм төзелештәге яктырту җайланмасы. *Гөлмөнәвәрә карчык белән Нәгыймә, кулларына лампа алып, курка-курка гына өйалдына чыктылар.* М.Галәү. *Тәрәзәләрдә маскировка булганлыктан, өй эче дөм караңгы, мич кырындагы сукыр лампаның каләм очы кадәр генә итеп калдырылган сүнәрсүнмәс ут шәүләсе Марат яткан аралыкка килеп җитми иде.* Г.Гобәй. *Акбикә, шырпы табып шахтёр лампасын кабызды да, тышка чыгып, этне чакыра башлады.* К.Латыйп

2) Пыяла куык эчендәге вольфрам чыбыкны ток белән кыздыру нәтиҗәсендә яктылык бирә торган электр приборы. *Урамга эленгән лампаларның яктысында әкрен генә, аяк очларына басып кына йөргән бер хатын күренә.* Г.Гобәй

ЛАМПА́ДА *и. гр.* Икона алдына яндырып куела торган лампа, тәре лампасы. *Бөтен өй эчен тынгысыз шәүләләр белән тутырып, почмактагы лампада гына җемелди иде.* Ф.Кәрим

ЛА́МПА МАЕ *и. иск. сөйл.* Керосин. *Тәсбихе белән Коръәнен артындагы мендәргә куйды да, мулласына йокларга тынычсызлык итмәсен өчен, әкрен генә торып китте, лампа мае беткәнлекне искә төшереп, май салды, ут кабызды.* Г.Ибраһимов

ЛА́МПАЛЫ *с.* 1) Лампасы яки лампалары булган; лампасы билгеле санда яки билгеле сыйфатта булган. *Без туганда, авыл салам түбәле, сукыр лампалы, чабаталы иде, хәзер газлы-электрлы, компьютерлы-интернетлы.* Татарстан яшьләре

2) Электрон лампалар ярдәмендә эшли торган. *«Беренче буынга лампалы телевизорлар керсә, бишенчесенә – сыек кристаллы индикаторлы яссы телевизорлар керә», – дип аңлатты ул.* Руслан Мөхәммәтшин. *Лампалы радиоалгыч*

ЛАМПАС *и. нем.* 1) Офицер һәм генералларның, шулай ук казакларның һәм суворовчыларның чалбарындагы, ян як җөенә кыстырып яки ян җөй өстеннән тегелгән, Россия армиясендә гадәттә кызыл тасма. *Батыр казак, калды канга батып Чалбарының кызыл лампасы. Кешни-кешни юлсыз далаларда Чабып йөрде юртак кашкасы.* Ш.Маннур. --- *Валентина Юрьевна чалбар киергә яратмый, ә итәккә устав буенча лампас тагарга ярамый.* Татарстан яшьләре

2) *сөйл.* Гомумән, берәр чалбарда, гадәттә спорт киемендә, шундый ук тасма. *Кара трикога ак лампас тегелгән*

ЛАМПАСЛЫ *с.* 1) Лампасы булган, лампас тегелгән. *Кара-кызыл плащлар, киң кызыл лампаслы ялтыравыклы кара чалбарлар киеп, муеннарына кызыл сатин бәйләгән уникe-унөч яшьлек малайлар, йөгерә-йөгерә, өстәлләргә төрле эчемлек ташыйлар.* М.Мәһдиев. *Бераздан ишектә сары лампаслы чалбар кигән швейцар күренә.* Ш.Галиев. *Генералның музейда урын алган погоннары, лампаслы киемнәре кайсы гына малайны кызыктырмас икән?!* Ватаным Татарстан

2) *күч.* Югары дәрәҗәдәге званиесе булган. *Лампаслы кешеләр*

ЛА́МПОЧКА *и. рус* Пыяла куык эченә урнаштырылган вольфрам чыбыкны кыздыру нәтиҗәсендә яктырта торган электр лампасы. *Электр лампочкасы, төбе белән бергә кубып, идәнгә төшеп шартлады.* К.Тинчурин. *Артык кызуга китсә, бу лампочка үзеннән-үзе сүнә.* А.Алиш. *Өй эчендә ялт итеп әллә ничә лампочка яна.* М.Мәһдиев

ЛАНГЕТ *и. фр. махс.* Озынча юка ит кисәге яки шуны кыздырып әзерләгән ашамлык. *Идрис үзенә лангет белән бәрәңге алды.* А.Гыйләҗев. *– Шашлыктан тыш ике лангет, табада кыздырган скумбрия, өч өлеш ботка, – дидем мин.* М.Юныс

ЛАНГУСТ *и. фр. зоол.* Ун аяклы кыслалар отрядына караган, гәүдәсе һәм озын мыеклары чәнечкеләр белән капланган, җылы диңгезләрнең су асты кыяларында яши торган, ите ашарга яраклы, кыскычсыз диңгез кысласы. *Лангустлар омарларга охшаганнар, әмма кыскычлары юк. Төп дошманнары – спрутлар.* Биология

ЛАНДРИН *и. иск.* Суыра торган әчкелтем каты конфет, пыяла конфет (рус фабриканты Фёдор Матвеевич Ландрин исеменнән); монпансье. *Бер тәүлеккә азык нормасы: ярты кадак бал, ике ландрин, 5 мыскал май, өч чирек кадак ипи, бер стакан какао һәм «американский сөт» белән чәй.* К.Нәжми. *Элек бер ландрин алып кайтсаң да урталай бүлеп бирә идең түгелме соң?* Г.Гобәй

ЛАНДРИНЛАНУ *ф. сөйл.* Кыланчыклану, төчеләнү. *Талән итәсе урынга ландринланып маташмагыз.* А.Гыйләҗев

ЛАНДШАФТ *и. нем.* 1) *геогр.* Җир өслегенең үзенә генә хас рельефы, климаты, туфрагы, үсемлекләр һәм хайваннар дөньясы булган бер кисәге. *Сезне чолгап алган ландшафтны җентекләбрәк карагыз.* География

2) *иск.* Нинди дә булса табигый урынның гомуми күренеше

3) *иск.* Шундый күренеш сурәтләнгән рәсем, пейзаж

ЛАНДША́ФТЛЫ *с.* Ландшафт (*1, 2 мәгъ.*) белән бәйле, шуңа караган; билгеле ландшафты булган. *Сарман исә тигезрәк ландшафтлы район, халкының холкы да тынычрак.* Татарстан яшьләре. *Әллә нинди ландшафтлы дизайн белән ясалган түтәлләрдә чәчәкләрнең нинди генә төре юк.* Шәһри Казан

ЛА́НДЫШ *и. рус бот.* Әспечәләр семьялыгына караган, озынча яфраклы, кечкенә генә кыңгыраучыкларга охшаган хуш исле ак чәчәкле, агулы, дару һәм декоратив үлән үсемлек; энҗе чәчәк. *Тирәсе яхшылап чистартылган кабер өсте яңа гына өзелгән язгы ландыш чәчәкләре белән күмелгән иде.* Ф.Хөсни. *Лида аланлыкта ландышлар үсүенә игътибар итте.* А.Гыйләҗев

ЛА́НДЫШ АГАЧЫ *и. бот.* Клетрачалар семьялыгына караган, Мадейра утравында үсә торган һәм ландыш исе килгән ак чәчәкле мәңгеяшел агач

ЛАНОЛИН *и. лат.* Сарык йоныннан махсус ысул белән юып алына һәм сабын, мазь, төрле косметика әйберләре, техникада майлау материалы ясаганда кулланыла торган саргылт төсле май. *Мазь ясау өчен, 50 г балавыз, 50 г нарат сагызы, 50 г бал, 50 г ланолин кирәк.* З.Ганиева

ЛАНОЛИНЛЫ *с.* Составында ланолин булган. *Сөембикә ланолинлы сабын белән озаклап кулын юды.* Ф.Садриев. *Ланолинлы крем*

ЛАНТАН *и. лат. хим.* Һавада оксидлаша, җылытканда янып бетә торган көмеш төсендәге сирәк металл

ЛАНЦЕТ *и. нем. мед.* Хирургиядә кулланыла торган очлы, ике йөзле пычак. *Хирургның: «Ланцет бирегез!» – дигәнен ул ишетеп ятты.* Г.Әпсәләмов

ЛАНЦЕ́ТНИК *и. рус* Хордалыларның баштартмасызлар классына караган, үтә күренмәле ланцетсыман гәүдәле, диңгез төбендә яши, планктон белән туклана торган кечкенә генә хайван. *Ланцетниклар күп вакытларын комга күмелеп үткәрәләр, бары гәүдәсенең авыз урнашкан алгы очы гына тышкы якта кала.* Зоология. *Ланцетникның баш сөяге юк, чөнки аларның баш мие булмый. Шуңа күрә дә аларны башсөяксезләр төркеменә кертәләр.* Биология

ЛАНЦЕ́ТСЫМАН *с.* Озынча, тар, ике башы да очланып торган. *Ланцетсыман яфрак*

ЛАНЬ *и. рус* Боланнар семьялыгына караган, Урта диңгез буйларында, Кече Азия, Европа һәм Америкада яшәүче, нәфис зифа буйлы, үтә йөгерек, ата төрләренең мөгез очы көрәксыман киңәеп торган, ак таплары булган җирән төсле имезүче хайван

ЛАҢГЫРТ *иярт.* Нинди дә булса каты әйбер югарыдан килеп төшкәндә яки ауганда барлыкка килгән тавышны белдерә. *Мич турысында эленеп торган чиләк лаңгырт итеп идәнгә килеп төште*

ЛАОСЛЫ *и.* Лаоста яшәүче төп халык һәм шул халыкның бер вәкиле. *Университетта укучы күп милләтле студентлар арасында лаослылар да бар.* Мәгърифәт. *Роза лаослыга кияүгә чыкты.* Казан утлары

ЛАП *иярт.* 1) Нинди дә булса авыр йомшак әйбер җиргә төшкәндә яки кемдер кинәт егылганда, утырганда, ятканда һ.б.ш. вакытта барлыкка килгән тавышны белдерә. *Нидер лап итеп килеп төште*

2) Нинди дә булса авыр йомшак әйбернең кинәт җиргә төшү яки кемнеңдер җайсыз, ямьсез, кинәт утыру, егылу рәвешен белдерә. *Җиргә лап утыруымны үзем дә сизми калганмын.* М.Госманов

ЛАПАРОСКОП *и. гр. мед.* Тикшерү яки операция ясау өчен, кечкенә тишек аркылы корсак яки оча куышлыгына кертелә торган махсус медицина аппараты

ЛАПАРОСКОПИ́Я *и. гр. мед.* Лапароскоп ярдәмендә эчке органнарны һәм тукымаларны тикшерү ысулы. *Лапароскопия ысулы белән башкарылган оператив дәвалауда исә күкәйлекләрне саклап калу мөмкинлеге бар.* Сөембикә

ЛАПАС *и.* Мал-туар, арба-чана, эш кораллары, утын һ.б.ш.ны тоту өчен бер ягы ачык, өсте ябулы хуҗалык корылмасы; сарай. *Атлы чаналар, берәм-берәм кереп, сыйганнары – бөркәүле лапас эченә, сыймаганнары ачык ишек алдына гына тезеләләр.* М.Галәү. *Бүре бакча буендагы лапас тирәсендә йөргәли дә койма башыннан лапас түбәсенә менеп китә.* А.Алиш. *Малайлардан бушагач, камытын, дилбегәсен,*

ыңгырчагын кертеп элде дә, биясенә салам биреп, лапас баганасына килеп сөялде. И.Гази

ЛАПАЮ *ф. диал.* Артык иркенәеп, ямьсез итеп җәелеп утыру. *Ай Ходаем, җыеп бетерәләр инде. Кара әле нәгъләтне, Хәкимгә, лапаеп утырып алган.* М.Фәйзи

ЛАПИДАР *с. лат.* 1) Кыска, конкрет, ачык аңлаешлы (стиль, сөйләм). *Беренче төргә караган лапидар текст үрнәкләре күпсанлы эпитафияләрдә сакланып калган.* М.Госманов

2) Ташка яки башка каты өслекләргә язылган (язма истәлекләр тур.)

ЛАПИДА́РИЙ *и. лат.* Борынгы ташъязма үрнәкләре, шул исәптән кабер ташлары тупланган экспозиция. *Болгарда ул Төньяк төрбәдә («Монастырь базы») бик яхшы лапидарий (музей – кабер ташлары тупланган урын) эшли.* Яңа тормыш

ЛАПИДАРЛЫК *и. кит.* Кыскалык, ачыклык, конкретлык. *Сәхнә бизәлешенә лапидарлык хас: бөтенләй буш диярлек сәхнә басма белән каймаланган; артта ачык төсле тукыма эленгән; уң кулиса янында пианино тора, сул кулиса янында – урындыклар.* Сәхнә

ЛА́П ИТҮ *ф.* 1) Шундый тавыш чыгару. *Бөтенләй якында гына нәрсәдер лап итеп төште: күрәсең, кайсыдыр өйнеңме, сарайныңмы түбәсен кубарып ташлады.* Г.Әпсәләмов

2) Кинәттән егылу яки утыру. *Бер заман чылбыр очы шартлап китеп, Төште Иблис Җиргә егылып, лап итеп!* Ш.Бабич. *Шуннан мин: «Чумсаң чум инде!» – дип әйтергә дә өлгермәдем, мөритем башы белән йөзтүбән лап итеп лаканга чумды.* Т.Гыйззәт. *Ул, чайкалып китеп, лап итеп урынына утырды һәм нечкә ямьсез тавыш белән җырлый башлады.* Г.Әпсәләмов

ЛАПЛАНД *и. иск.* Саам халкының борынгы атамасы

ЛА́П-ЛАП *иярт. к.* **лап-лоп**. *Ары лап-лап, бире лап-лап, киез каплап, сөңге саплап.* Табышмак. *Ул иң гади, әйтик, лап-лап басып йөргән чын җир кешесен дә бераз һавалырак, җирдән күтәребрәк бирә, китапчарак әйтсәк, үзе дә сизмәстән, образларын романтизм белән сугара.* Р.Батулла. *Кыска, юан аяклары белән аю кебек лап-лап килеп чаба бирә малаең.* Н.Яһудин

ЛА́П-ЛОП *иярт.* 1) Йөгергәндә, авыр итеп атлаганда, әледән-әле авыр әйбер җиргә төшкәндә һ.б.ш. очракларда чыккан тавышны белдерә. *Урман эчендә лап-лоп басып аю йөргәне ишетелә.* М.Галәү. *Урам буйлап кемнеңдер лап-лоп йөгереп килгәне ишетелде.* И.Гази. *Шул вакыт «Газиз катыны»ның яман сүгенү сүзе һәм лап-лоп йөгергәне ишетелде.* М.Мәһдиев

2) Авыр, килешсез итеп йөрү, атлау, хәрәкәтләнү рәвешен белдерә. *Әй төшә Иблис, төшә зыр-зыр килеп, Койрыгы ялт-йолт итә яшен кебек, Куллары лап-лоп итә лачын кебек... Бу кызыктан күктә кеткелдәү китә, Күк йөзендә саф тавышлар ялт итә.* Ш.Бабич

ЛАПТА *и. рус* Ике төркемгә бүленеп, кара-каршы уйный торган туп сугу уены. *Без үскәндәге шикелле, унҗиде яшькә җиткәнче лапта уйнап йөрергә туры килмәячәк сезгә.* Х.Сарьян. *Уеннар программасына җиңел атлетика, волейбол, гер спорты, билбау көрәше кебек гадәти төрләрдән тыш, халык арасында инде онытылып бара торган дартс, городки, лапта, гадәти көймәдә шүү кебек төрләр дә кертелгән.* Татарстан яшьләре

ЛАПТАЛЫ *и. к.* **лапта**. *Җәй көне бер төркем малай-шалай тыкрыкта лапталы уйнадык та өйләргә таралыштык.* Әлмәт таңнары. *Караңгы төшкәнче таудан, көлешә-көлешә, чана-чаңгы шуулар, волейбол, футбол, лапталы уйнаулар --- тагын, тагын балачакның әллә нинди мажаралы уеннары күңелләрдә якты хатирә булып балкый.* Хезмәт даны

ЛАПТЫРДА́У *ф. сөйл.* Җилфердәү, лыштырдау (зур аяк киеме, артык иркен өс киеме һ.б.ш.). *Ул аяк киемнәреңне лаптырдамыйча гына йөреп булмыймы соң?* М.Мәһдиев

Лаптырдап тору Лаптырдарлык дәрәҗәдә киң булу

ЛАПТЫРДЫК *с. сөйл.* Лаптырдап торган. *Хәят тиз-тиз генә тәһарәт алды һәм аякларын юды, өйдәге фәрештәләргә күрсәтмәс өчен, зур бер яулык белән чәчен каплады һәм өйдә киеп йөри торган лаптырдык күлмәгенең җиңнәрен бармак очлары гына күренеп калырлык итеп төшерде дә, аталары күз алдына килеп, намаз укырга тотынды.* Ф.Әмирхан

ЛАПТЫ́Р-ЛАПТЫР *иярт. к.* **лаптыр-лоптыр**

ЛАПТЫ́Р-ЛОПТЫР *иярт.* Зур аяк киеме киеп йөргәндә, зур-зур кабып тиз-тиз ашаганда, нәрсә дә булса бик каты җилфердәгәндә, очып канат какканда чыккан тавышны белдерә. *Идрис җанфәрманга чабып китте, бәйләнмәгән «чабаталары» лаптор-лоптыр килде, ул, чапкан шәпкә иелеп, аларны кулына тотты да бара бирде.* А.Гыйләҗев

ЛАПШЫК *с. диал.* Мускуллары, тәнендәге ите йомшарган, сәлперәйгән, тыгызлыгын югалткан. *Симез ат артык туйса, лапшык булыр.* Мәкаль. *Хатынның битләре лапшык, гәүдәләре бик тулы иде.* Ш.Камал

ЛАПШЫКЛАНУ *ф. диал.* Лапшыкка әйләнү; мускуллар, тән сәлперәю, йомшару, тыгызлыгын югалту

Лапшыклана бару Торган саен лапшыклану

Лапшыклана башлау Лапшыклануга табан үзгәрү

Лапшыклана төшү Тагын да ныграк лапшыклану

Лапшыкланып бетү Тәмам лапшыклану

Лапшыкланып китү Күзгә күренеп лапшыклану

ЛАПШЫРДА́У *ф. сөйл.* Сәлперәю, йомшару, тыгызлыгын, эластиклыгын югалту (мускуллар, тире, тән һ.б.ш. тур.)

Лапшырдап бетү Тәмам лапшырдау

Лапшырдап тору Әле, хәзер лапшырдаган хәлдә булу

Лапшырдый башлау Лапшырдауга табан үзгәрү

ЛАПШЫРДЫК *с. диал.* 1) Тәне сыгылмалылыгын, тиресе, мускулы тыгызлыгын югалткан

2) Буш, зур, салынып торган (кием тур.)

ЛАПЫ *и. рус диал.* Урмандагы җиргә егылган агач

ЛАПЫЛДАТУ *ф. сөйл.* Аякларны авыр итеп атлап, йөгереп, авыр

әйберләрне җиргә төшереп яки бәреп, сугып тавыш чыгару. *Кодрәтеннән килсә, арт ягына лапылдатып тибәр иде Рамазан.* Н.Гыйматдинова. *Урта рәттәге бер парта артында буш урын бар иде, сорап та тормыйча, портфелен лапылдатып шунда китереп салды.* Л.Гыймадиева

Лапылдата башлау Лапылдатырга тотыну

Лапылдата төшү Бераз лапылдату

Лапылдатып тору Әле, хәзер лапылдату; гел лапылдату

ЛАПЫЛДА́У *ф. сөйл.* 1) Атлап, йөгереп, авыр әйберне җиргә төшереп, бәрелеп, сугылып тавыш чыгару. *Галәви, караңгыда аны сизмичә, Нәгыймәне дә тотып буйыйм дип барганда, чикмәннәре белән лапылдап идән астына барып төшә.* М.Гали. *Карчык, уйланып әкрен генә барганда, итәк чабуларына абаланып лапылдап егылды.* А.Гыйләҗев. *Пычракның нәкъ уртасына лапылдап килеп төштем.* Ватаным Татарстан

2) Кинәт, авыр итеп аву, егылу, төшү. *Ильясның аяклары ике якка аерылып китте дә, карга лапылдады.* Ә.Ибраһимова. *Фагыйлә ишекне ябып келәсен элде. Аякларын көч-хәл белән сөйрәп залга чыкты да дивангa лапылдады.* Ф.Садриев

Лапылдап китү Кисәк лапылдау

Лапылдап тору Әле, хәзер лапылдау; гел лапылдау

Лапылдый башлау Лапылдарга тотыну

ЛАПЫЛЫК *и. диал.* Урманның куе урыны, караңгылык, ауган, егылган агачлар күп булган урын

ЛАПЫРДА́У *ф. к.* **ла́пылдау**. *Бабай кыйшая башлады, гармуны лапырдап асфальтка төште ---.* Р.Батулла. *Гүреңдә ләхетең өстеңә лапырдап ишелеп төшсен, итекләрнең рәхәтен күрмә, нәселең төбе-тамыры белән корысын ---.* Ф.Садриев

ЛА́ПЫР-ЛОПЫР *иярт.* **1.** 1) Артык озын яки артык иркен кием яки аяк киеменнән тиз-тиз атлаганда, нәрсә дә булса җилдә җилфердәгәндә чыккан тавышны белдерә. *Ул арада аның су тегермәненекедәй иламсез зур куласасы лапыр-лопыр әйләнә башлады.* Ф.Абдуллин

2) Су кергән аяк киеме белән яки сулы җирдән атлаганда чыккан тавышны белдерә

2. *рәв. мәгъ.* Эре-эре, ямьсез хәрәкәтләр ясап, сакланып, юл сайлап тормыйча. *Кәрәзле балны әллә ничек тылсымлап кисеп торганда, лапыр-лопыр атлап, күнитекләренә балчык төяп, ир-атлар кайтып керде.* А.Гыйләҗев.

ЛА́ПЫР-ЛОПЫР ИТҮ *ф.* Шундый тавыш чыгару

ЛА́ПЫР-ЛОПЫР КИЛҮ *ф. к.* **лапыр-лопыр итү**

ЛАР *и. рус* 1) Өсәк. *Хәрәмнамәне абзардагы ларга кертеп бушаттылар.* З.Мурсиев. *Менә искә төште хәзер: Лариса ипи салырга кереште дә, келәттәге ларның буш икәнлеген күргәч, тиз генә табагын алып, күршеләргә йөгерде.* Туганайлар

2) Тегермәндә тартылган он төшә торган зур әрҗә, улак

ЛАРЁК *и. рус сөйл.* Вак сәүдә ноктасы, кечкенә кибет. *Без станция ларёгыннан әле генә сатып алган бер тәбикмәк, черек бәрәңге күмәчен ашап утырабыз.* М.Мәһдиев. *Тиешле юлны узгач, байракчы старшина ларёкка килә.* Казан утлары. *Ларёк тотучы эшмәкәрләр барлык керемнең 30% ын сыра сатудан ала.* Акчарлак

ЛАРЁКЧЫ *и.* Ларёкта сатучы кеше. *[Кариев] үзе башкара торган «шкафчы» (хәзергечә әйтсәк, ларёкчы) ролен үтәү өчен, Печән базарында Мөхәммәтҗан Хафизны өлге итеп өйрәнде.* И.Рәмиев

ЛАРИНГАЛЬ *с. гр. лингв.* Бугазда тавыш ярыларының йомылуы һәм кисәк ачылып китүе нәтиҗәсендә ясала торган (аваз тур.). *Ларингаль тартыкларны бугаз тартыклары дип тә атыйлар*

ЛАРИНГИТ *и. гр. мед.* Бугаздагы лайлалы катлауның ялкынсынуы белән характерлана торган авыру. – *Ларингит анда, – диде, борылып чыгып, ләгәнне ишек төбенә алып куйгач. – Суык тигән.* М.Маликова. *Көн буена сузылган йөткерү – кискен бронхит, ларингит, трахеит авыруы барлыгын күрсәтә.* Ватаным Татарстан

ЛАРИНГО́ЛОГ *и. гр. мед.* Ларингология белгече, табиб

ЛАРИНГОЛО́ГИЯ *и. гр. мед.* Бугазның анатомиясен, авыруларын һәм дәвалау ысулларын, физиологиясен өйрәнә торган дисциплина, фән тармагы

ЛАРИНГОСКОП *и. гр. мед.* Бугазны тикшерү өчен озын сапка яссы көзге утыртылган җайланма. *Табиблар карамагында хәзер электрокардиограф, гастрофиброскоп, ларингоскоп --- [бар].* Биектау хәбәрләре

ЛАРИНГОСКОПИ́Я *и. гр. мед.* Бугазны авыз куышлыгы аша ларингоскоп ярдәмендә тикшерү ысулы

ЛАРК *иярт.* Нинди дә булса авыр әйберне кинәт ташлаганда, берәр авыр әйбер каты җиргә төшкәндә яки ярылып киткәндә барлыкка килгән тавышны белдерә

ЛА́РК-ЛАРК *иярт.* Рәттән, кабат-кабат ларк иткән тавышны белдерә. *Аркаларына ящиклар күтәргән грузчиклар, пароходка кереп, йөкләрен идәнгә ларк-ларк иттереп салдылар.* И.Гази

ЛА́РК-ЛОРК *иярт. к.* **ларк-ларк**

ЛА́Р-ЛАР *иярт.* Берәзлексез кычкырып сөйләшү рәвешен яисә шундый сөйләшү тавышларын белдерә. *Атаң мәрхүм дә шулай иде, җыен булдымы, лар-лар килеп тавыш күтәрә иде.* Т.Гыйззәт. *[Вәсилә:] Ул Иван кызын җенем сөйми, кәничне. Авызын бер дә япмый, гел лар-лар сөйли.* Н.Гыйматдинова

ЛАР-ЛОР *иярт. к.* **лар-лар**

ЛАРС *иярт.* Нинди дә булса авыр предметның берәр җиргә килеп төшү, кисәк егылу, аву рәвешен һәм шул вакытта барлыкка килгән тавышны белдерә. *Илвир чишенмичә-нитмичә каравat янына килде дә ларс итеп ауды.* М.Шаһимәрдәнов

ЛАРСЫЛДАП *рәв. сөйл.* Ларс итеп. *Карт ларсылдап егылды, тиз сикереп торды, ярсына-ярсына чөйдән мылтыгын алды ---.* М.Шаһимәрдәнов

ЛАРСЫЛДАТУ *ф.* Ларс иткән тавыш чыгару, яңгырату

Ларсылдатып кую Кинәт бер мәртәбә ларсылдату

Ларсыдатып тору Хәзерге моментта яки даими ларсылдату

ЛАРСЫЛДАТЫП *рәв. сөйл.* Ларс иттереп. *Хәерелбанат, Нигъмәткә*

арты белән генә әйләнеп, зур түшәкне ларсылдатып сәкегә салды. К.Нәҗми

ЛАРСЫЛДА́У *ф.* Берәр авыр әйбер югарыдан килеп төшкәндә, кисәк ауганда ларс иткән тавыш чыгару, ларс итү; гомумән, кисәк авып китү, килеп төшү

ЛАРТ *иярт.* Гадәттә зур, авыр гәүдәле кешенең, өзек-өзек, кискен хәрәкәтләр ясау рәвешен һәм шул вакытта барлыкка килгән тавышны белдерә. *Ул су багы янындагы ялгыз урынга ларт итеп утырды.* Р.Батулла

ЛА́РТ-ЛАРТ *иярт. к.* **ларт-лорт**. *– На-а, бахбай! – дип, Саттар чыбык белән атка кизәнде, алаша ларт-ларт юырта башлады.* Р.Батулла

ЛА́РТ-ЛОРТ *иярт.* Каты-каты басып, тиз-тиз йөргәндә барлыкка килгән тавышны һәм өзек-өзек хәрәкәтләр ясау рәвешен белдерә. *Аннан тагын гармунын тарта башлый ул [Пәттери]. Әлбәттә, моң да, көй дә чыкмый, ларт-лорт килеп газапланган аһәң генә иңри-иңри бөтен җиһанга тарала.* Казан утлары

ЛАРЫЛДА́У *ф.* Кычкырып сөйләшү; берөзлексез сөйләшү

Ларылдап йөрү Күптәннән бирле, гел ларылдау

Ларылдап тору Бертуктаусыз ларылдау

Ларылдый башлау Ларылдарга керешү

Ларылдый бирү Ларылдавын дәвам итү, бернигә карамый ларылдау

ЛАРЫЛДЫК *с.* Ларылдарга яратучан, кычкырып сөйләшә торган. *Ларылдык кыз*

ЛАСА *кис. сөйл. к.* **лабаса**. *Һәркайчан тик тор, берәр ахмак адәм сүз сөйләсә. Бел: аңа сүз кайтарудан тик тору артык ласа.* Ш.Бабич

ЛА́С-ЛОС *иярт.* Ашыкмыйча, авыр итеп басып йөрү рәвешен һәм шулай йөргәндә барлыкка килгән тавышны белдерә. *Гөбе юанлыгы аяклары белән лас-лос атлап ничек йөри икән бу бичара.* Г.Мөхәммәтшин

ЛАСПЫЛДА́У *ф.* Суга берәр нәрсә белән бәреп суны чыпырдату; лычтырдау. *--- Димгә батырылган челтәр капчык эчендә агач көрәк киңлеге ике корбан ласпылдап ята иде...* М.Кәрим

ЛАССО *и. исп.* Хайваннарны тоту өчен кулланыла торган, очында шума элмәге булган бау, аркан; корык. *Мустангларны лассо ыргытып кына тотарга туры килде.* В.Имамов. *Туй кунаклары атларда йөргән, җептән төеннәр бәйләгән, лассо ыргыткан ---.* Шәһри Казан

ЛА́СТИК I *и. рус* Гадәттә кием эчлегенә куела торган, уң ягы ялтыравыклы киҗе-мамык тукыма

ЛА́СТИК II *и. рус* 1) Резина, каучук

2) *сөйл.* Язганны бетерү өчен резинка, бетергеч, бозгыч

ЛАСТЫ́Р-ЛОСТЫР *иярт. к.* **лаштыр-лоштыр**

ЛАТ *и. тар.* XIV гасыр ахырыннан алып XVI гасыргача башлыча Европада атлы гаскәринең күкрәген һәм аркасын салкын коралдан саклый торган, эре металл кисәкләреннән чүкеп ясалган кием. *Англия укчылары бөтен Европада дан тоткаННар. Аларның уклары хәтта калын тимер латларны да тишә алган.* Урта гасырлар тарихы

ЛАТА́НИЯ *и. лат.* Пальмалар семьялыгыннан, тропикларда үсә, төньяктарак декоратив максатлар белән дә үстерелә торган җилпәзәсыман киң яфраклы үсемлек

ЛА́ТЕКС *и. ингл. махс.* 1) Каучук бирә торган үсемлекләрнең сөтсыман суты. *--- Һәр агачтан [гевеядан] елга уртача 6 тонна сөтсыман сок алалар. Аны тагын латекс дип тә атыйлар.* Химия

2) Шул матдәгә охшатып ясалган, химия, медицина һ.б. өлкәләрдә, көнкүреш кирәк-яраклары җитештерүдә кулланыла торган синтетик материал. *Аны [подгузникны] хлор белән түгел, кислород белән чистарталар, составында латекс, формальдегид яки фталат юк.* Мәдәни җомга

ЛАТЕРАЛЬ *с. лат. махс.* 1) Янда урнашкан, яндагы, кырыйда урнашкан (мәс., берәр орган)

2) *лингв.* Телнең яныннан үткән һава агынтысы ярдәмендә ясала торган (тартык авазлар, мәс., [л] авазы)

ЛАТИН *и.* 1) Борынгы Италиянең үзәк өлешендә – Лацийда яшәгән кабилә һәм шул кабиләнең бер кешесе

2) *сөйл.* Шул кабиләнең, соңрак барлык Борынгы Рим дәүләтенең теле булган, һинд-европа семьясының италик төркеменә караган борынгы тел. *Патриотизм ул «патер» сүзеннән килеп чыккан икән. Ә «патер» латин телендә «әти» дигән сүз икән.* Т.Миңнуллин

3) Шул телгә караган әлифба, хәреф һ.б.ш. *Латин Америкасы халыклары --- латин хәрефләре белән генә язалар, телләре дә (испан, португал) – дәүләт теле.* М.Мәхмүтов. *Татар теленең имласын камилләштерү, латин графикасы нигезендә кору, ул графикага кире кайтуның ролен аның тарафдарлары да, дошманнары да яхшы аңлый.* Ә.Кәримуллин. *Гарәп, латин әлифбасын өйрәнүнең авырлыгын кайбер язучыларыбыз, «үзәккә үттеләр шуның белән» дип, яшьлек тилмерүләрен яза.* Ватаным Татарстан

4) *иск.* Католик. *Латин чиркәве*

ЛАТИНИЗМ *и.* Латин теленә хас булган, шуннан үтеп кергән сүз, тәгъбир

ЛАТИНИСТ *и.* Латин филологиясе белгече. *Урында һәм үзәктә утырган латинистлар җиңә.* Татарстан яшьләре

ЛАТИ́НИЦА *и. рус* Латин хәрефләренә нигезләнгән әлифба. *«Латиницада язганны бастырмады» дигән яманатны күтәргәнче, [нәшрият] басуны артык күрә.* Р.Вәлиев. *Ә хат авторлары, халыкара кануннарны бозып чыгарылган законга мөнәсәбәтләрен белдермичә, сөйләнә-сөйләнә чәйнәлеп беткән кириллица һәм латиница турында фәлсәфә саталар.* Т.Миңнуллин

ЛАТИНЛАШТЫРУ *ф.* 1) Латин телен һәм мәдәниятен кертү

2) Кайсы да булса алфавитны латин алфавиты белән алыштыру

Латинлаштыра башлау Латинлаштырырга керешү

Латинлаштырып бетерү Тәмам, тулысынча, нык латинлаштыру

ЛАТИНЛАШУ *ф.* Латин теле һәм мәдәнияте тәэсиренә дучар булу, шуның билгеләрен алу

Латинлаша башлау Латинлашу билгеләре күренү

Латинлашып бетү Нык латинлашу

ЛАТИ́НЧА *рәв.* **1.** Латин телендә. *Профессорлар латинча үзара сөйләшеп фикер алыштылар, авыруның йөрәген тыңладылар*. Г.Әпсәләмов

2. *с. мәгъ.* Латин телендә язылган, шул телдәге. *Берничә бите машинкада басылган, калганнары кулдан латинча язылган.* Р.Мостафин

3. *и. мәгъ.* Латин теле. *Үткәннәрне искә төшергәндә Шикоян, латинчага күчеп, сагышлы гына әйтеп куяр иде* ---. М.Галиев

ЛАТИНЧЫ *и.* 1) *к.* **латинист**

2) *тар.* Татар телен латин алфавитына күчерүне яклаган кеше. *Кириллица әлифбасы барлыкка килгәч, ул заманда гы латинчылар шул әлифба белән бастырылган китапларны җыеп яндыра башлыйлар. Тарихи чыганакларда «латинчылар кириллица белән бастырылган китапларны яндыралар» дигән рәсем дә бар*. Ватаным Татарстан

ЛАТИФУ́НДИЯ *и. лат*. Күп мәйданны алып торган эре җир биләмәсе. *Африканың миллионнарча җирләре халыкара латифундияләр кулына киткәч, хәзер анда төп проблема шулай ук – җир проблемасы*. Ватаным Татарстан

ЛАТЛА́У *ф. диал*. Җайга китерү; җайлау, көйләү. *Юлбарыслар – уңга, Шаһи сулга атлый, Ләкин Шаһи үз хәйләсен һаман латлый.* З.Бәшири

ЛАТЫЙФА *и. гар. иск. к.* **ләтыйфә**. *--- Габдулла миңа язган бер хатында: «Биби әби әйтә, я, кызым, яшь вакытта хәзер авырыйсың да хәзер терелəсең», – дип, латыйфа әйтеп, язып та куйган иде* ---. И.Нуруллин

ЛАТЫ́-ПОТЫ *рәв. сөйл.* **1.** Телне начар белеп; вата-җимерә сөйләшеп. *Татарча латы-поты сөйләшү*

2. *с. мәгъ.* Бик шома түгел, канәгатьләнерлек дәрәҗәдә булмаган. *Ләкин минем русчам бик латы-поты: сала агае русчасы гына.* Ф.Әмирхан

ЛАТЫШ *и.* Һинд-европа тел гаиләсенең балт төркеменә караган телдә сөйләшкән, Латвия республикасының төп халкын тәшкил иткән халык атамасы; шул халыкның аерым бер вәкиле. *Латыш шул якка башын боргач, Әнвәр дә караган иде, урман кырыенда кое бурасы күреп алды, ерак түгел генә кызыл чүлмәк түбәләр күзгә чалынды.* Х.Камалов. *Сан ягыннан бездән кечерәк булган грузин, әрмән, латыш, төрекмән кебек халыкларның да кино сәнгате дөньякүләм дәрәҗәдә билгеле.* Р.Вәлиев. *Латышлар бер генә дәүләт теле өчен – латыш теле өчен көрәш алып баралар*. З.Зәйнуллин

ЛАТЫ́ШЧА *рәв.* **1.** Латыш телендә. *--- «Закис» – латышча «куян» дигән сүз.* З.Зәйнуллин. *Ишекне ачуга күрде: бусага янында мылтыклы солдат баскан, идән уртасында гражданский киемендә күзлек кигән икенче бер кеше кулын болгый-болгый латышча нидер сөйләнә*. Х.Камалов

2. *с. мәгъ.* Латыш телендәге, латыш телендә язылган. *Латышча язу. Латышча китап*

ЛА́У КИЛҮ *ф. диал*. Ыгы-зыгы килү; шау-шу күтәрү. *Менә җен халык! Үзләре белән арбаларында буза кайнатып алып килгәннәр! Ире-хатыны бары да лау килә!* Н.Исәнбәт

ЛАУЛА́У *ф. диал.* Ялкын белән, ялкынланып яну, дөрләп яну

Лаулап китү Кинәт лаулау

Лаулый башлау Лауларга тотыну

ЛАУРЕАТ *и. лат*. Фән, сәнгать һ.б.ш. өлкәләрдә зур хезмәт күрсәткән өчен бирелә торган мактаулы исем; шундый исемгә лаек булган кеше. *Гомумән, Тукай премияләре тарихы – үзе бер патетик драма ул. Әгәр кырык дүрт язучы лауреат булса, иң киме тагын шул чама санда башка дәгъвачылар да булган бит әле, арасында лаеклылар да бар.* Р.Фәйзуллин. *Исхакый исемендәге бүләк, аның дипломы һәм медальләре лауреатларга Татарстан язучылар берлеге корылтайларында, әдәби ел йомгакларына багышланган гомуми җыелышларда яки Гаяз Исхакый туган көндә биреләчәк.* Р.Батулла

ЛАФ *и. гар.*1) *иск.* Сүз, сөйләм. *Лаф ахырында әйтү*

2) Буш сүз. *Лаф белән пылау пешмәс*. Мәкаль

◊ **Лаф ору** 1) Юк-бар, буш сүз сөйләү; сафсата сату. *Дию пәрие, башын өзәм дип кылычын кыныннан алып, гайрәт белән лаф орып маташканда, әлеге кызлар чыр-чу килеп моңа ябышканда, егет айнып өлгергән*. Әкият. *Егерменче елларда ук коммунистлар җырын җырлаучылар да, безгә татар теле кирәк түгел, тизрәк урыс теленә күчәргә кирәк, дип лаф ора башладылар*. Ә.Кәримуллин; 2) Мактану, шапырыну. *Хәтта ул узган җомга көнне кибете алдында җыелган яшьләр арасында, кызмача баштан: «Телим икән – Миңсылу минеке и вәссәлам!» – дип лаф орган*. Г.Минский. *Инде ничә елдан бирле инновацион икътисад төзү турында лаф орсалар да, бу сүзләрнең нәтиҗәсе сизелми.* Ватаным Татарстан

ЛАФА *хәб. функ. гар. гади с.* Бик уңай, бик яхшы булган эш яки хәл турында. *Да, туганкай... Хәлең шәптән түгел. Безнең монда лафа, хөррият!* Аманулла

ЛАФЕТ *и. нем.* 1) Артиллерия тубы беркетеп куела торган станок, рама. *Утырдым да пушка лафетына Уйга калдым кичке тынлыкта.* Ф.Кәрим. *Миномётның көпшәсе белән прицелы – егерме, көпшә куела торган тактасы – уналты, көпчәкләре белән лафеты егерме --- кила тарткан мөлкәтне җилкәләрегезгә йөкләгез дә, әйдәгез --- марш-бросокка!*.. А.Хәлим

2) Гомумән, төрле техник җайланмаларның йөрткеч нигезе. *Трактор арбасының авыр лафеты*

ЛАФЕТЛЫ *с.* Лафеты булган, лафетка куелган. *Мөслим уртасында, озын торык-лафетлы машинаның көпчәкләре шартлап, йөген бушатмыйча гына тәгәрмәчләрен алыштыру мөмкин түгеллегеннән гажиз идем*. Ф.Яхин. *«Заветы Ильича» газетының 1958 ел, 9 июль санында лафетлы ургыч машинисты Фәрит Җәләлов мәкаләсе бар.* К.Әбләзова

ЛА́ЦКАН *и. нем*. Пиджак, пәлтә кебек төймәле өске киемнең күкрәк өлешендәге кайтарма якасы. *[Атнабаевның] кулы урындык аркасына эленеп куелган пиджагына сузылып, аның лацканына тагылган орденын капшый*. Ф.Хөсни. *Бүләкләрне аларның пиджакларындагы лацканнарга Ватанны саклаучылар көненә багышланган гомумшәһәр чарасы вакытында тантаналы шартларда беркетеләр*. С.Толмацкий

ЛАЧ I *иярт.* Каты итеп төкергәндә барлыкка килгән тавышны һәм шулай төкерү рәвешен белдерә. *Мәннан тугандаш социалистик илдән килгән «күчтәнәч»кә лач иттереп төкерде дә лифт эченә ташлады*. Аманулла. *Оялмыйча, чәйнәп туйгач, күпләр лач итеп төкереп китә*. Туган як

ЛАЧ II *рәв.* 1) Бөтенләй, манма (юеш булу, чылану тур.). *Тишек итекләрдә лач су булган аякларының әрнүе бүгенгәчә онытылмый.* Казан утлары

2) Юеш, бөтенләй юеш хәлдә; сулы, дымлы. *Салам лач булды*

3) Чи, бөтенләй чи (камыр ашы тур.). *Ипи лач булган, пешмәгән*

ЛАЧИНКА *и. рус сөйл. к.* **носилка**. *Бер сәгать чамасы узуга, дүрт француз солдаты күтәргән лачинканы урыс лагере янында гусар дозорына тапшырдылар.* З.Зәйнуллин. *Бер укол кадап, Нуриевны лачинка белән алып чыгып киттеләр.* Р.Батулла

ЛАЧКЫЛДАТУ *ф. сөйл.* 1) Лач иткән тавыш чыгару. *Сәлимеч өстәлдән сулы графинны алып, стаканга агызып тормыйча гына голт итеп бер йотты, кинәт кенә чыраен сытып, лачкылдатып идәнгә төкерде.* Ф.Имамов

2) Ашаганда авызны чапылдату, лач-лоч китерү. *Эт исә, аларның шаушуына карамыйча, кружкадагы сыраны лачкылдатуында булды*. Ш.Еникеев

3) Җебетү, изрәтү, сыек хәлгә китерү. *Эштән иртәрәк кайттылар, яши торган барак идәннәрен, бер-ике сәгать лачкылдатып җебеткәннән соң, гөжелдәтеп юып чыгардылар* ---. Г.Гыйльманов

Лачкылдата башлау Лачкылдатырга тотыну

Лачкылдатып тору Хәзер лачкылдату

ЛАЧКЫЛДА́У *ф. сөйл.* 1) Баткак яисә пычрак юлдан барганда, лач-лач иткән тавышлар чыгару. *Аның аяк астындагы урындыгы шуып киткән, әмма җиңел сөякле ул кыз пычрак идәнгә лачкылдап барып төшәргә ашыкмый, чая кош төсле һавада бер тын чайкалып тора...* Ф.Хөсни

2) Сыек, үзле, чи хәлгә килү, жебү (пычрак, камыр һ.б.ш. тур.). *Җавапка мондый тупаслык көтмәгән әбинең өстенә үк диярлек тегеләрдән берсенең сасы сары какырыгы лачкылдап килеп төште.* Ф.Яхин

Лачкылдап кую Бер мәртәбә лачкылдау

Лачкылдап тору Хәзер лачкылдау; даими лачкылдаган хәлдә булу

Лачкылдый башлау Лачкылдарга тотыну

ЛАЧКЫЛДЫК *с.* Лачкылдап торган, чи. *Ул балчык шикелле лачкылдык, чи, тәме дә юк*. Халык үзе хөкем итәр

ЛА́Ч-ЛАЧ *иярт. к.* **лач-лоч**. *Ул безнең күрше Мәхүп кызы Әпипә күк әдәпсез түгел инде, Ходай күрсәтмәсен, кичә мин кайткан чакта, капка төбендә лач-лач сагыз чәйнәп, узган-барганга эт күк өреп, дәшми калмый-дыр* ---. Ф.Халиди

ЛА́Ч-ЛОЧ *иярт.* 1) Пычрактан яки баткактан атлап барганда барлыкка килгән тавышны белдерә. *Меңләгән аякларның атлавы гына тынлыкны боза: лач-лоч, лач-лоч...* И.Нуруллин

2) Нәрсәне дә булса ялаганда, чәйнәгәндә, төкергәндә барлыкка килгән тавышны белдерә. *Песи лач-лоч итеп ялый, рәхәтләнде каймакка*. Д.Аппакова. *Эчтә яшь кенә сатучы кыз бертуктамый лач-лоч сагыз чәйни*. Татарстан яшьләре. *Билет алырга дип, кассага килсәм, лач-лоч көнбагыш төкерә-төкерә, бер маржа түтәй кесә телефоныннан ләчтит сатып утыра*. Шәһри Казан

ЛАЧМА *рәв. сөйл. к.* **лычма**. *Анда үсә торган, әлегә баш кына җибәрергә өлгергән бодай үсентеләре арасында лачма су*. Ф.Яхин

ЛАЧТ *иярт. к.* **лач** I. *Үзебез, юкса, читкә лачт итеп төкереп, Бу хайван заттан сакласын дип һәм үтенеп* ---. Ф.Яхин. *Ниндидер, гафу итегез, тавык тизәге төсендәге нәмәрсәне чәйнәп, кеше җирәндереп, шуны лачт итеп җиргә төкерүчеләр дә күренгәли хәзер Апас урамнарында.* Ватаным Татарстан

ЛАЧТЫ́Р-ЛОЧТЫР *иярт. к.* **лаштыр-лоштыр**. *Баҗай, әле миңа, әле Мирсалихка карап, пеләшен кашып торды да: «Һә-әәй!» – дип кулын селтәде, аннары лачтыр-лочтыр атлап учак янына менеп китте...* Ә.Дусайлы

ЛАЧЫН *и. зоол.* **1.** 1) Лачын кошлар семьялыгыннан бик үткен томшыклы, озын тар канатлы, бик тиз оча торган ерткыч кош. *Бу кешенең бөтен йөзендә тирән акыл, бетмәс-төкәнмәс көч белән бергә, арыслан һәм лачынның икесеннән кушылган бер рәхимсезлек күрдем.* Г.Ибраһимов. *--- лачын башка кошларга караганда үткенрәк күзле, сизгер, акыллы, көчле, җитез, тугрылыклы*. Сабантуй

2) *күч. юг*. Кыю һәм үтә дә батыр ир-егет турында. *Сез килегез, якын дус итеп, Күп кайгылар кичкән анага. Күкрәк сөтем имезеп, тирбәтеп, Мин өч лачын илгә үстердем.* М.Җәлил

3) *күч. юг*. Кыю очучылар һәм алар идарә иткән очкычлар турында. *Корыч канатлы яшь лачын Сыкратты фрицларны, Каныкты безнең лачынга Кипкән йөзле, бүре күзле Дошман зенитчиклары*. Ф.Кәрим

2. *с. мәгъ. юг*. Батыр, кыю, үткен. *Ул күрсәтте миңа яшь егетне: бөдрә чәчле, лачын карашлы*. Ш.Маннур

◊ **Лачын сөте** Аракы. *Түрәләр белән сөйләшкәндә батыррак булу өчен, лачын сөтен дә онытма*. Ә.Айдар

ЛАЧЫНЛЫ *с.* 1) Лачыны булган

2) Лачын белән, лачын ярдәмендә башкарыла торган. *Милли образны чагылдырган фольклор – мифологик тема [Садри Ахунның] «Лачынлы аучы», «Далада җыр», «Арыслан белән сугышу» әсәрләрендә гәүдәләндерелә.* Мәдәни җомга

ЛАЧЫ́НСЫМАННАР *и. күпл. зоол.* Көчле һәм нык гәүдә төзелешле, кыска муенлы, кыска аяклы, киң күкрәкле көндезге ерткыч кошлар отряды

ЛАЧЫНЧЫ *и.* Лачын асраучы; лачыннар белән ауга йөрүче; кош чөюче. *Азия лачынчылары ау кошларының кадерен белә*

ЛАШ *иярт. к.* **лышк**. *Миңзифа лаш итеп борынын тартты.* М.Әмир

ЛАШБЫК *с. диал.* Җәенке, җәлпәк. *Лашбык борын*

ЛА́Ш-ЛОШ *иярт. к.* **лас-лос**. *Үләннәргә мул булып чык төшкән, шуңадырмы, төн бик яңгырау: юешләнеп авырайган аяклар лаш-лош атлый, табан астында чыбык сынуы,*

ботинкаларның ташка бәрелүе ишетелеп китә. Х.Камалов

ЛАШМАН *и. тар. к.* 1) *к.* **лашманчылык**. *Лашман эшен нужа диләр аннан кайткан кешеләр ---.* Бәет. *1276 (1859) елларда лашман хезмәте дә, атлысы булсын, җәяүлесе булсын, тәмам юкка чыгарылып, лашманчы казакъстан һәм ясаклыдан бертигез солдат алына башлый.* Ш.Мәрҗани

2) *к.* **лашманчы** (*1 мәгъ.*). *Ясаклы татарлар белән берәттән, лашманнар җан башыннан налог та, башка күп төрле салымнар да түләгәннәр, рекрут биргәннәр.* Казан утлары

3) Беренче бөтендөнья сугышы чорында тыл эшләрен башкару өчен, Төркестан халкыннан оештырылган хезмәт армиясе һәм шунда катнашкан кеше. *Батырхан: Төркестаннан. Монда үтешли генә кердем. Давыт: Кая үтәсез? Батырхан: Фронтка. Лашманнар алып барам.* К.Тинчурин

◊ **Лашман кисү** *к.* **лашман тарту**. **Лашман куу** *к.* **лашман тарту**. *Пётр патша [кораблар] ясаткан, шуңа бөтен ил белән урман кискәннәр. Безнең бабайлар мари урманнарында лашман куганнар.* Г.Әпсәләмов. **Лашман тарту** Лашманда урман кисү, лашманда эшләү. *[Галәк бабай:] Синең туганнарың лашман тарта.* М.Фәйзи

ЛАШМАНЧЫ *и. иск.* 1) XVIII–XIX йөзләрдә, корабльләр төзү өчен, урман кисү эшенә һ.б.ш. эшләргә башлыча Идел буе халыкларыннан җибәрелгән дәүләт крестьяны. *Лашманчылар кайтканда бик биртелеп кайталар. Кара урманда кар эчендә землянкада яталар.* Бәет. *Ишеткәнегез бармы лашманчылар турында?* Г.Әпсәләмов. *1814–1827 елларда лашманчылар арасында зур хәрәкәтләр була.* Татар әдәбияты тарихы

2) Лашман (*3 мәгъ.*) армиясендә хезмәт итүче, лашман гаскәренә алынган кеше. *Ул бичараларны изеп, кол кебек куып йөрергә ялланып, лашманчы булу синең кебек зур укыган, тирә-якның йолдызы булган бер кешегә килешә торган эш түгел, диярмен.* Г.Ибраһимов. *Урлый булган малын-мөлкәтен, Лашманчылар халык җәберли, Авыл янындагы урманнан Качкыннар да тынгылык бирми.* А.Нәҗми

ЛАШМАНЧЫЛЫК *и. тар.* 1) Пётр I чорында оештырылган, крестьяннарны массалы төстә дәүләт файдасына эшләүгә, башлыча урман кисү, юл салу, төзелеш кебек авыр физик эшләргә җәлеп итү системасы. *Татарны чукындыру, дәүләт файдасына эшкә җигү (лашманчылык) – нәкъ менә аның идеясе.* Татарстан яшьләре. *Инде тәкъдире кушып, кайсыдыр чит якларга гаскәр хезмәтенә яисә лашманчылыкка алынса, я күмер кисәргә чыгып китсә, татар кешесе барыбер гаиләсе, сөйгән яры, туган ягы өчен ут йотып сарғайган, күз яшен түккән.* Идел

2) *күч.* Мәҗбүр итеп эшләтү системасы; гомумән авыр эш. *«Социалистик ярыш» дип аталган лашманчылыкны күкләргә чөеп мактау совет чорында татар әдәбиятының магистраль темасы иде.* М.Юныс

ЛАШПЫРДА́У *ф.* Киңәеп сәлперәеп төшү, үз үлчәменә туры килмичә салынып тору, бәлҗерәү, җәелеп китү

Лашпырдап бетү Тәмам, бөтенләй лашпырдаган хәлгә килү

Лашпырдап тору Әле, хәзер зур булып салынып, сәлперәеп тору, зурлыгы килешсез, килбәтсез булу

ЛАШПЫРДЫК *с.* 1) Киңәеп сәлперәеп төшкән, үз үлчәменә туры килмәгәнгә салынып торган. *Иртәнге сигезләр тирәсендә идарәгә тыны-өне беткән Әдәс килеп керде. Янчелгән козырёклы сары кепкадан, сарғылт төстәге солдат бушлаты кигән, лашпырдык чалбарлы.* Х.Камалов

2) Көпшәк, йомшак, шәлперәйгән (тән, тире)

ЛАШТЫРДАТУ *ф.* Лаштыр-лоштыр килгән тавыш чыгарып йөрү. *Алтмышынчы размерлы тирән галошларын лаштырдатып тракторист Сәйяф та килде.* М.Мәһдиев

ЛАШТЫРДА́У *ф.* Лаштыр-лоштыр килгән тавыш чыгару

Лаштырдап тору Әле, хәзер, сөйләү моментында лаштырдаган тавыш чыгару. *Минем оек-чабатам эштән чыгып пычранган, эченә су тулып лаштырдап тора.* Г.Ибраһимов

ЛА́ШТЫР-ЛАШТЫР *иярт. к.* **лаштыр-лоштыр**

ЛА́ШТЫР-ЛОШТЫР *иярт.* Аяк киеме юеш яки зур, аяк асты юеш булганнан, аякны сөйрәп атлаганнан чыккан тавышны белдерә. *Олтаны төшкән ботинкалар лаштыр-лоштыр ботакларга эләгәләр.* К.Нәҗми. *Шулчак ишекне шар ачып, лаштыр-лоштыр атлап, бабай килеп керде.* К.Латыйп

ЛА́ШТЫР-ЛОШТЫР ИТҮ *ф.* Лаштырдау. *--- ун кешенең егерме калошы берьюлы эшкә керешеп лаштыр-лоштыр итүе декабрьнең кичке тынлыгын үзенә махсус тупаслык белән бозып җибәрде.* К.Тинчурин

ЛА́ШТЫР-ЛОШТЫР КИЛҮ *ф. к.* **лаштыр-лоштыр итү**. *[Гали абзыйның] Аягындагы йомшак чүәкләре идәндә лаштыр-лоштыр килде.* Г.Әпсәләмов

ЛАЯКЫЛ *рәв. гар.* Акылын җуйганчы, акылсыз хәлгә килгәнче, дөм (исерү тур.). *Әбүсөгыт бай төшермеш иде, салган-салган – лаякыл исергәнче эчсен иде, ичмасам, йокыга түнәр иде.* М.Хуҗин. *Лаякыл исереп идәнгә ауган да шул килеш йоклаган.* Г.Бәширов. *Донбасс мирзасы лаякыл исерек, җүнсез.* Ә.Галиев

ЛӘ *кис. к.* **ла**. *Бер син генә түгел лә ул Миңа болай караган.* Р.Харис. *Ул мине озата гына килде лә...* Г.Гыйльманов. *Әйтерсең лә аны өстән тартып алдылар.* Ә.Гаффар

ЛӘБАСА *кис. к.* **лабаса**. *Ә үзеңә ничек тә ярый, сатар өчен түгел ләбаса!* М.Госманов. *Җан иясе ләбаса ул, ничек син дигәнчә генә эшләп бетерсен, үз белдеге белән дә йөриселәре килә, эшлиселәре килә аларның.* К.Миңлебаев. *Икмәк тотып ант итү – тәүбәнең дә, вәгъдәнең дә соңгы чиге ләбаса.* Б.Камалов

ЛӘББӘ́ЙКӘ *ы. гар.* 1) «Әү, тыңлыйм, ни боерасыз, боерыгыз, йомышыгызга әзермен, баш өсте» дигән мәгънәне белдерә. *[Җиһанша:] Ләббәйкә, тәкъсир... Сез ни телисәгез, шул булыр.* К.Тинчурин. – *Ләббәйкә, ханбикәм! – Гайфулла балдызының уенын кабул итеп алдына тезләнде.* Ф.Яруллин

2) «Рәхим итегез» дигән мәгънәне белдерә. *«Ләббәйкә» дигән кебек, бер кулын күкрәк өстенә куеп чалкан ятkан [ирең] яшь сабыйлар йокысы белән рәхәтләнеп йоклый булыр.* Ш.Камал. *Тимер капкалар ачыла, караучылар үрә катып честь бирәләр: «Ләббәйкә, Иван Иванович!», «Рәхим итегез, Басыйр Бариевич!»* А.Гыйләҗев

◊ **Ләббәйкә дип тору** Кирәккә дә, кирәкмәгәнгә дә гел ризалык күрсәтү, хуплау. *Вәкил ни әйтсә, шуңа ләббәйкә дип кенә тора.* М.Әмир. *Нәселдән килә торган сыйфатлары шул: һәр әйткәнгә ләббәйкә дип торырга, кеше эзенә басып барырга яратмыйлар.* И.Нуруллин

ЛӘВАЗИМ *и. гар.* 1) Тиешле булган нәрсәләр, кирәк-яраклар, кирәкле эшләр

2) Хезмәт, хезмәт урыны, дәрәҗәсе. *Бер кеше бер лавазимнан төшсә, гомер буе шул лавазимга кермәкне фараз кылып йөридер.* К.Насыйри

ЛӘВӘШ *и.* 1) Эченә ит, тары ярмасы яки йөзем салып пешерелә торган бәлеш. *Аның майлары тулып торган ике симез казы белән симез күркәсе, өстенә каклар, җимешләр сибеп пешерелгән дүрт зур ләвәш күмәче, кечкенә дүрткел тау кебек торган, өсте, читләре кәнфит белән чәчәкләнгән ике бавырсагы, тагы әллә ничаклы остаәзерләнгән аш бүләкләре мәҗлеснең күзләрен уйнаттылар.* Г.Ибраһимов. *Аннары һәр түгәрәк уртасына чистартып кайнар суда юган, шикәр комы һәм сары яки атланмай кушылган йөзем салып чыгалар, түгәрәкләрнең кырыен ябыштырып, пилмән кебек ләвәш ясыйлар.* Татар халык ашлары

2) *диал.* Күзикмәк, юка. *[Хаҗиморат], хәзер генә табадан төшкән коймакларны, ләвәшләрне --- кунаклар алдына таратып, чәй ясый башлады.* Г.Ибраһимов. *Өметгалинең әнисе газиз улына бер төенчек каклаган ит, бер капчык кипкән җимеш, бер тубал ләвәш җибәргән иде.* М.Юныс

3) Катлы паштет

ЛӘГӘН *и. фар.* Калай, эмальләнгән тимер, алюминий һ.б.ш.дан төрле киңлектә, зурлыкта ясалган сай савыт; тас. *Ул калай ләгәндәге яңгыр суы белән чистарынган һәм инде болдыр ишеге төбендә сабырсызланып таптанган ана казын өйалдына – оясына кертте.* Ә.Гаффар. *Ләүкәдәге агач ләгәндә ике төрле себерке пешекләнгән иде.* Н.Гыйматдинова. *Карават янында ләгән белән су, табак, караватта башын, аягын я эчен, күкрәген сөлге, юрган белән төргән, юешләнеп беткән бер хатын ята.* М.Мәһдиев

ЛӘГУ *и. гар. иск.* 1) Буш сүз, юк сүз. *Югыйсә без бу көннәр игъланны туктатабыз вә башсыз чыккан игъланнарны ләгу санап, акчаны суд белән кире сорыйбыз.* Г.Тукай

2) Чынлыкта булмаган эш, юк эш

3) Ялгышу, хаталык

4) Гамәлдән чыгару, бетерү, бозу

ЛӘГЪНӘТ *и. гар.* 1) Каргыш, бик каты гаепләү, көчле нәфрәт; каһәр. *Монда провокатор булган берәүнең халык ләгънәтенә чыдый алмыйча акылдан шашу дәрәҗәсенә барып җитүе тасвирлана.* С.Алишев. *Ул качып кына намаз укый торган урынына сыгылып төште, кыйбласына борылды, бер сәҗдәгә китеп, бер рөкүгъка торып, ләгънәтен кире кайтара башлады.* А.Хәлим. *Бөтенесе аларга нәфрәт, ләгънәт белән чирканып карыйлар.* З.Фәйзи

2) Берәр затны тәнкыйть итеп, тиргәп, хурлап атау яки эндәшү сүзе. *– Мостафага, теге ләгънәтнең башка кулъязмаларын табып, судка барган чакта алып барырга куштым, – диде Һидият.* Ш.Камал. *Курка, ләгънәт, куркып чәчен йолка, Чукмар белән маңгаена суккан этнекедәй күзе акая.* Ф.Кәрим. *[Кыз:] Калтыранасың ич, әллә Сарбай ләгънәт куркыттымы?* Г.Әпсәләмов

◊ **Ләгънәт камыты** 1) Иблисне оҗмахтан куганда, аның кичерелми торган гөнаһ иясе икәнен белдерә торган тамга. *Мәлгунь Иблис, мине инкяр итмә! Ләгънәт камытын тиздән киярсең.* М.Гафури; 2) Авыр, газаплы эш турында. **Ләгънәт (орсын) оргыры** *к.* **ләгънәт төшсен (төшкере)**. *Телен, денен санламаган, Милләт зарын аңламаган Мин идем ул, ләгънәт оргыры.* И.Гыйләҗев. **Ләгънәт ору** Ләгънәтләү. *Күпкә бармас тарлык, сабыр ит, ирек, Ләгънәт орма, бизмә дөньядан.* Н.Думави. **Ләгънәт суккан** *к.* **ләгънәт төшкән**. *Ләгънәт суккан шәһәр тавышын ишетәсеңме? Гөрелди ул, шат ул шәһәр.* С.Сүнчәләй. **Ләгънәт суксын (суккыры)** *к.* **ләгънәт төшсен (төшкере)**. **Ләгънәт төшкән** Бик каты гаепләнә торган, нәфрәт уята торган, каргалган, ләгънәтләнгән. *[Нәгыймә:] Ул бит өйләнмәкче булып йөри. [Галимә:] Әй ләгънәт төшкән нәрсә! --- Кем дигәнне алмакчы була?* Ш.Камал. *[Исәнбай:] Ләгънәт төшкән мәдрәсә гадәте... Һәрбер яңа килгән шәкертне газаплап интектерү гореф-гадәт булып әверелгән.* Т.Гыйззәт. **Ләгънәт төшсен (төшкере)** 1) «Зарар килсен, зыян булсын» дигән мәгънәне белдерә. *[Мавия:] Алланың ләгънәте төшсен авылдашыңа! Син, абзый, авылдаш булсаң, аны азрак акылга өйрәт.* М.Фәйзи; 2) Бик каты ачулануны, нәфрәтләнүне белдерә. *[Хөсәен:] Тукта, юньсез. --- Тукта, ләгънәт төшкере.* Ф.Бурнаш. *Тфү, ләгънәт төшкерләре. Каян юлыма җыен шарлатан очрый.* С.Сүнчәләй. **Ләгънәт төшү** Әйтелгән ләгънәт чынга ашу, шуның зыяны тию. *Анасының каргышы, минем ләгънәтем төште аңа.* Ю.Әминов. **Ләгънәт уку** Ләгънәтләү. *Ләкин ахырдан йөземгә төкереп, ләгънәт укыр иде.* Ф.Халиди. *Алар теләнче фабрикасы булган мәдрәсәләреннән ләгънәт укып чыгып киткәннәрдер.* Г.Тукай. *Үзе пыш-пыш ләгънәт укый. Аның кабердәге бәддогасыннан беркем дә котылалмый, ди әнкәй.* Н.Гыйматдинова

ЛӘГЪНӘТЛӘНҮ *ф. төш. юн. к.* **ләгънәтләү**. *Коръәндә аның Аллаһының әмерен тыңламавы өчен ләгънәтләнүе әйтелә.* Г.Исхакый

ЛӘГЪНӘТЛӘ́Ү *ф.* 1) Каһәрләү, бик каты гаепләп шелтәләү, кемгә дә булса явыз теләк теләү. *Шәмсетдин хәзрәт күз төпләрен сөртә-сөртә --- хатыннарын ләгънәтләгән.* Э.Касыймов. *Булдыксыз Чекко кордашы Дантены да, сөйгәне Биккины да, киявен, бөтен кешеләрне күралмас яман көнчегә әйләнә. Барысын каргап ләгънәтли.* Г.Хөсәенов

2) Бик каты хурлау, тиргәү, тәнкыйтьләү; канәгатьсезлек белдерү.

Менә шулай ләгънәтләде язучы иске кануннарны, иске гадәтләрне һәм диннең, руханиларның алдавын фаш итте. Г.Халит. *Гаделсезлекне, кешелексез законнарны ләгънәтли-ләгънәтли атлаган Сәфәргали абзый, уңны-сулны күрми баручы исерек кебек.* З.Фәйзи

Ләгънәтләп тору Гел, даими ләгънәтләү; хәзерге моментта ләгънәтләү

Ләгънәтли башлау Ләгънәтләргә керешү. *Григорий, ниһаять, бер сәбәпсез үзен, аннан язучыны, аннан бөтен җәмгыятьне талый, ләгънәтли башлады.* А.Хәлим

ЛӘГЪНӘТЛЕ *с.* Ләгънәтләнгән, каргалган, каргыш төшкән; бик каты гаепләнә торган, нәфрәт уята торган. *[Әхтәм:] Менә миндә шул мирзаның ләгънәтле каннары бар дип, [ул] үзен үзе хурлый башлый.* Г.Ибраһимов

ЛӘГЫЙНЬ *с. гар.* **1.** 1) Ләгънәтләнгән, каргалган, яхшылыктан мәхрүм ителгән. *Бер заман иңмәс борын Иблис ләгыйнь, Торды инсан ал да гөл дә, син дә мин.* Ш.Бабич. *[Хажи:] Әйе, Иблис ләгыйньнең атабыз Адәм[не] җәннәттән чыгаруын сөйли.* Ш.Камал. *Мөгаен, Иблис ләгыйнь берәр нәрсә болгата торгандыр, тагын ачыйм әле бер.* Р.Ишморат

2) *күч.* Начар, әшәке, куркыныч, нәфрәт уята торган. *[Кабил:] Гүя миңа ләгыйнь көчләр Ерактан кулларын өстемә төртеп сузалар.* Һ.Такташ

2. *и. мәгъ.* Каргалган, әшәке, каһәрләнгән кеше. *[Әхмәтҗан:] Каһәр сукканнар, бәдбәхетләр, ләгыйньнәр, мәңгелек игелек күрмәгез.* Г.Камал. *Һәм ләгыйнь дә күз тегеп бер ноктага, Китте бик төпсез тәфәккергә таба!..* Ш.Бабич

3. *кер. сүз функ. сөйл.* Җиңелчә шелтәләү, ачулану сүзе. *Күрде батыр, шунда яткан ул ләгыйнь.* Г.Тукай. *Шәһәр Думасына депутатлыкка кандидатлар күрсәтү җыелышында үзенең чын йөзен ачты бит, ләгыйнь.* Мәдәни җомга

ЛӘГЫЛЬ *и. гар.* Ал, кызыл төсле кыйммәтле таш, лал; кызыл якут. *Безнең апай гәүһәрдер, Тәннәре чын мәрмәрдер; Ләгыль, якут, гәүһәрдер, Аузы балдыр, кәүсәрдер.* Җыр. *Йөземнәр көнгә каршы ялтырыйлар ләгыль вә якуттай.* Г.Тукай. *Ләгыль, якут бизи аның түшәмнәрен.* Р.Батулла

ЛӘҖ I *и. рус диал.* Ашлык сукканда көлтәнең сугылмыйча калган тоташ кисәге

ЛӘҖ II *рәв. рус диал.* 1) Сузылып, җәелеп, арка белән, чалкан (яту). *Шул яшькә җиткәннән соң да әле әбиләрнең ашап-эчеп, ләҗ ятып кына тормыйча, кеше төсле бөтенесе белән кызыксынуы аңлашылмый яшьләргә.* Азат хатын

2) *күч.* Гамьсез рәвештә, бернәрсә дә эшләмичә. *Ләҗ яту*

ЛӘҖБӘЮ *ф. диал.* Җәелү, җәелеп утыру яки җәелеп яту

ЛӘҖБЕРӘЮ *ф. диал. к.* **шәлперәю**

Ләҗберәеп бару Тора-бара ләҗберәю

Ләҗберәеп бетү Тәмам ләҗберәю

Ләҗберәеп тору Ләҗберәйгән булып күренү

ЛӘЗЗӘТ *и. гар.* 1) Тәм, тат. *Хәер, өчпочмак белән шашлык бары тик сарык итеннән генә була, хәзер генә ул, милләтләрне бутап бетергән кебек, ризыкны да бутап, милли төсен югалтып ләззәтен алдылар.* М.Мәһдиев

2) Тәмле ризыктан алган канәгатьлек. *Габдулла яхшы өйдә, яхшы зур самавырдан чын кытай чәен дә җизнәләрендә бу кадәр ләззәт белән эчкән чагын хәтерләми.* Ә.Фәйзи. *Табында ниләр генә юк иде: зәңгәр йөзем, күк төсендәге алмалар, куе зәңгәр ширбәтләр белән алар зәүкый ләззәт кичерделәр.* Р.Батулла

3) Рух рәхәтлеге, хозурлык, кәеф. *Китаплар... Кемнәр генә алардан рухи ләззәт алмаган да, кайсы бөек шагыйрь, дәһи философ аларга дан җырламаган!* М.Госманов. *Юаш бозаулар тиз ара усалланалар иде. Аннан алар сөзешүдән ләззәт табалар иде.* Ф.Яруллин

4) Нинди дә булса эшне уңышлы башкарудан алган канәгатьлек хисе. *Милләттәшләр арасындагы аңгәмәдән туган ләззәтнең асылында нәрсә ята икән?* М.Юныс

5) Куанычлы халәт, сөенеч тойгысы. *Ләззәт бирә җаннарыма Шомырт чәчәге исе.* Н.Ибраһимов. *Шундый ләззәттә барган Мәрдиев, урманны чыккач, офыкның каралуын искәреп, дерт итеп китте.* М.Галиев

ЛӘЗЗӘТЛӘНДЕРҮ *ф.* 1) Ләззәт (*1 мәгъ.*), тәм бирү, тагын да тәмле итү

2) Канәгатьлек, рәхәтлек бирү. *[Тукай] табигать тормышының кешелек өчен булган тиңсез, ләззәтләндергеч агышын да җырлый.* Г.Халит. *Әнә бит малай вакытта тавышы белән ләззәтләндергән Марат Фәйрушин, тавыш үзгәрү чорын исән-имин кичеп, классик һәм эстрада җырларын да, халык җырларын да бердәй оста башкарып концертлар бирә.* Сәхнә

Ләззәтләндереп җибәрү Ләззәт өстәү. *Юк, бу – агачларны шаулатып, тәннәрне рәхәт ләззәтләндереп җибәрә торган салкынча талгын җил түгел.* Мәх. Хәсәнов

Ләззәтләндереп кую Бер мәртәбә ләззәт бирү; вакыт-вакыт ләззәтләндерү

Ләззәтләндереп тору Даими рәвештә ләззәтләндерү. *Гарәп язуының могҗиза кебек серле бизәкләре күңелгә, йөрәкнең иң эчке түрендә калган нурлы хисне тәрбиялә, өмет биреп, ләззәтләндереп тора.* Р.Абзалина

ЛӘЗЗӘТЛӘНҮ *ф.* Ләззәт алу, тәм табу, рәхәтлек кичерү. *Әтием дә, әбием дә аның суын эчеп ләззәтләнгәннәр.* Н.Хәсәнов. *Сыйныфташлар бу минутларны ләззәтләнеп кичерергә җыендылар.* Ф.Фәтхелислам. *Гомумән, балачакны искә төшереп ләззәтләнергә, балачак истәлекләреннән зур фәлсәфәләр табып юанырга ярата идем мин.* Р.Вәлиев

Ләззәтләнә башлау Берәр нәрсәдән ләззәт табарга өйрәнү. --- *Тукай «яшьрен мәхәббәт», игълан ителмәгән, ачылмаган, хәтта Мәхбүбәнең үзенә белдереп тә, яңалыгы, сафлыгы югалмаган мәхәббәт берлә ләззәтләнә башлый.* З.Рәсүлева

Ләззәтләнеп алу Бераз гына ләззәтләнү

Ләззәтләнеп тору Даими, гел яки хәзерге вакытта ләззәтләнү. *Шулай, өчәүләп, озак кына кочаклашып, елашып, үз бәхетләренә ләззәтләнеп тордылар.* Г.Гыйльманов

ЛӘЗЗӘТЛЕ *с.* 1) Ләззәте (*1 мәгъ.*) булган, тәмле. *Менә бу чәй никадәр ләззәтле.* М.Гафури. *Ул шундый хуш исле, шундый ләззәтле, шундый да татлы*

иде, гүя су алынган коега я булмаса елгага фәрештәләр канатын тыгып алган. Л.Шәех

2) Рухи рәхәтлек, канәгатьлек бирә торган, сөенеч-куаныч хисләре тудыра торган. *Гәрәйшаны өйнең Петрух мактаган ләззәтле һавасы кочып алды.* М.Хуҗин. *Күңел түреннән, әкрен генә агылган болытлардай, ләззәтле хисләр кичте.* Н.Хәсәнов. *Тән өчен хыял кирәкми, аңа ләззәтле мизгелләр кичереп, ярсуын басарга гына кирәк.* Ф.Яруллин

ЛӘЗЗӘТЛЕЛЕК *и.* 1) Тәмлелек, татлылык. *Бу ризыкның ләззәтлелегенә ис китәрлек*

2) Рәхәтлек, кәефлелек, хозурлык. *Кошлар тавышыннан, һаваның сафлыгыннан, аның хуш ислелегеннән, дөньяның матурлыгыннан, яшәүнең ләззәтлелегеннән исергән идем мин.* А.Шамов

ЛӘЗЗӘТСЕЗ *с.* 1) Тәмсез, тәме булмаган. *[Шакмаклы] шикәр ләззәтсез була, анасы, юлга аны алмам; ваткалы бирерсең.* Ф.Әмирхан

2) *күч.* Ләззәт бирми торган, ләззәте (*3–5 мәгъ.*) булмаган. *Аларның --- тәмсез, ләззәтсез шигырьләрен ник мактамыйлар?!* Г.Тукай

ЛӘЗЗӘТСЕЗЛӘНДЕРҮ *ф.* 1) Ләззәтен бетерү, ләззәтсез итү, тәмен бетерү. *Ризыкны ләззәтсезләндерү*

2) *күч.* Мәгънәсен, кызыгын, ямен җибәрү, бозу. *Һичберәүгә бер генә тиен дә файда итмәгән, бөтен милләтнең тормышын харап итеп ләззәтсезләндергән гадәт-гореф вә искелек булсалар, шуларның күбесе нәкъ әүвәлге килешләрендә үк дәвам иттеләр вә итәләр.* Ф.Әмирхан

Ләззәтсезләндереп җибәрү Кисәк кенә ләззәтен бетерү

ЛӘЗЗӘТСЕЗЛӘНҮ *ф.* 1) Ләззәте, тәме бетү

2) *күч.* Мәгънәсе, кызыгы югалу

Ләззәтсезләнеп бетү Тәмам ләззәте югалу

Ләззәтсезләнеп калу Берәр сәбәптән яки тик торганнан, кинәт ләззәте югалу

ЛӘЗЗӘТСЕЗЛЕК *и.* 1) Тәмсезлек, ләззәтсез булу, ләззәте (*1 мәгъ.*) булмау

2) *күч.* Ямьсезлек, күңелсезлек, хозурсызлык

ЛӘЗИЗ *с. гар.* 1) Тәмле, татлы, ләззәтле. *Бу җиһанның ләзиз нигъмәтләре күптер, вә ләкин һичберсе бу чәйдик юктыр.* Бәет. *Нәрсәдә ләззәт икән? Чөнкем ялан дөньяда кәм – Мин ләзиз шәйләр, вә ли кайсында ләззәт, кайда тәм?* Г.Тукай

2) *күч.* Ямьле, күңелле, рәхәт. *Гомернең иң ләзиз вакты ике чак* ---. З.Бәшири. --- *Тукаевның «әшгаре миллияседер» ки, гаять ләзиз хиссияте милләләр уйгатты.* Әлгасрелҗәдид

ЛӘИМ *и. гар. иск.* **1.** Саран кеше, үзеннән дә кызганучы, түбән җанлы кеше. *Ләимнәрдән ләим – кабахәтләрнең кабахәте.* Г.Чокрый. *Сереңне бирмә, яшер карның агын, Ләимнән интизар итмә мәгашың.* Г.Тукай

2. *с. мәгъ.* Саран. *Ул хәсис, надан, ләим адәм иде.* К.Насыйри

ЛӘИМЛӘНҮ *ф. иск.* Саранлану

ЛӘЙ *кис. к.* **лай** II. *Дус-иш белән бергә эш иткәндә, Теләкләргә тизрәк ләй җитәрбез.* Җыр. *Безнең дә ләй авыл бик зур авыл* ---. Җыр. *Ерактан кайткан атыма Салкын су эчермәгез ләй, Уф дип әйтүләре авыр, Исемә төшермәгез.* Җыр

ЛӘЙЛӘ *с. гар. иск.* Төн. *Сән җаным өчен бән йөримен ләйлә [йокыларымны] калдырып.* Г.Тукай

ЛӘЙСӘН *и. гар.* **1.** Яз көне беренче тапкыр вак кына сибәләп яуган җылы яңгыр. *Җир дымлы, күрәсең, таң алдыннан гына яңгыр явып үткән. Беренче яңгыр. Картлар аны ләйсән – шифалы яңгыр диләр.* И.Салахов

2. *с. мәгъ.* Җылы, язгы (яңгыр). *Мин ләйсән яңгыр идем лә, булдым кар, булдым боз.* Р.Акъегет. *Кайнар кояш булып янсам, Ләйсән яңгыр булып тамсам.* Н.Сафина. *Шифалы ләйсән яңгыр явып үтүе бик һәйбәт булды, кызым!* З.Фәйзи

ЛӘКАБЬ *и. гар. иск.* 1) Кушамат. *Яла ягып ләкабь куштылар.* К.Насыйри. *Шуңадыр инде, шәкертләр аңа «чикерткә» дигән ләкабь тә биргәннәр.* Ә.Еники. *Чишмәләрне сөрдерү, малдан таптатудан туктыйк дип, күп чәпчи торгач, үземә «Чишмә Башы Газиз» дигән ләкабьне дә өстәп чәпәделәр дә куйдылар.* А.Хәлим

2) Фамилия, псевдоним; титул. *Царь язган хатларында үзен төрле ләкабьләр белән атаганда, «Казан патшасы» дигән сүзне арттыра башлады.* Г.Гобәйдуллин. *Уземнең ләкабемә тоталыштырдым.* З.Һади

ЛӘКАТӘ *и. гар. диал.* Табылдык, табылган әйбер

◊ **Ләкатә кычкыру** «Таптым!» дип аваз салу, табылдык турында телдән хәбәр итү, яңгырату. *Урласам, ләкатә кычкырмас идем.* Т.Гыйззәт. – *Кешем, – дип олылады Ханбикә хезмәтчесен, – ләкатә кычкырмасаң да, мин синең аны урламавыңа, ә табуыңа ышаныр идем...* М.Хуҗин

ЛӘКӘН *и. коми диал.* 1) Агачның тамыры белән төбе

2) Йомычка

ЛӘКӘТӘ *и. гар. диал.* Гәп, әңгәмә, сөйләшү. *Һәммәсенең бияләйдәй колак торган, Ләкәтәләр куера төшкән әүвәлгедән.* Ф.Бурнаш

◊ **Ләкәтә сату** Юк-бар сөйләшү; ләчтит сату. *Урамны чыккач та, култык астына калын портфелен кыстырган бер бәндә туктатып, беркавым ләкәтә сатып торды.* М.Хәсәнов. **Ләкәтә сугу** *к.* **ләкәтә сату**

ЛӘКЕЛДӘҮ *ф.* Бытылдау (балалар сөйләве). *Ә улым һаман әле татарча ләкелди минем белән.* М.Мәһдиев

Ләкелдәп алу Бераз гына ләкелдәү

Ләкелдәп тору Өзлексез ләкелдәү

Ләкелди башлау Ләкелдәргә керешү

ЛӘ́КИН *терк. гар.* **1.** 1) Җөмләдәге тиңдәш кисәкләрне бер-беренә каршы куя. *Тырышты, көчәнде, ләкин булдыра алмады*

2) Ике мөстәкыйль җөмләнең икенчесе башында килә һәм андагы фикерне беренче җөмләдә әйтелгән фикергә каршы куя. *Гел юкка да, кайчак, якалашып, Тирән «дошманлык»ка бата идек. Ләкин кичен өйгә кайткан чакта Татулашып инде кайта идек.* Ш.Маннур

3) «Шулай да», «шуңа карамастан» дигән мәгънәне белдерә. *Кайчакта бу – Рифкатьнең ачуын да китерә, ләкин ул моңа күнегеп бара.* Р.Вәлиев

4) Беренче җөмләдәге фикерне чикләү мәгънәсен көчәйтү өчен кулланыла. *[Г.Камалның] кайбер элеккерәк*

язган әсәрләрендә аз-маз гарәп, фарсы һәм госманлы сүзләре күренгәләсә дә, ләкин ул сүзләрнең күпчелеге шул әсәр язылганда халыкның сөйләү теленә кергән сүзләр генә. М.Гали

5) Җөмлә башында алмашлык, теркәгеч яки мөнәсәбәтле сүзләр белән килеп, иярчен җөмләне баш җөмләгә бәйләү өчен кулланыла. *Ләкин никадәр сак һәм йомшак атларга тырышмасыннар, ике авыр кешенең артыннан идән сайгаклары шыгырдап калды.* Н.Фәттах

6) Кайбер каршы куючы теркәгечләр белән бергә килеп, каршы кую мәгънәсен көчәйтә. *[Хөснетдин:] Мин аныcына каршы килмим. Әмма ләкин миңа акча кирәк.* Ш.Камал

7) Ымлыклар, модаль сүзләр белән бергә килеп, аларның мәгънәсен һәм алдагы җөмләләргә каршы куюны көчәйтә. *Ләкин ah! Нинди зур ялган! Ышанмыйм мин моңар бер дә!* Н.Исәнбәт. *Ләкин һәйһат [үкенеч]! Болар бар да төш, бар да буш хыял гына иде.* Ш.Мөхәммәдев

2. *и. мәгъ.* Комачаулык, каршылык; киртә; нәрсәгә дә булса комачаулаган берәр төрле хәл. *[Мавия:] Ул «ләкин»нең аръягын бик яхшы аңлыйм, Бәкер абзый. Ничек тә мин аны хәл итәргә тырышырмын.* М.Фәйзи

ЛӘКЛӘК *и. гар.* Ләкләк кошлар семьялыгыннан озын йонсыз аяклы, озын туры томшыклы, ак яки кара каурыйлы, биек агач яки бина башларына оялый торган күчмә кош. *Оянының хуҗасы – ана ләкләк – ялгызы югары талпынды, хәйран биек, Җалпы тауларыннан ашып күтәрелде ---.* Ә.Гаффар. *Камәреннән алтын зынҗырлы котыйчык асылынган хакимнең башында зур чалма, чалма маңгаенда асылташлы мөштек, мөштеккә кара ләкләк каурые кадалган.* Р.Батулла. *Ә менә сыер һәм йорт кәҗәләре еш кына баскан килеш йоклыйлар, кайбер кошлар, әйтик, ләкләк, очып барган җирдән тәмләп кенә черем итеп ала.* Кызыклар дөньясында

◊ **Ләкләк борын** Озын борын, озын борынлы кеше. *[Ирбулат:] Бая да әле Зәкия «ләкләк борын» дигәч гарьләнеп үлә язды.* Р.Ишморат

ЛӘКЛӘ́КСЫМАННАР *и. күпл. зоол.* Тропик, субтропик һәм урта зоналарда таралган, ачык киңлекләрдә, ешрак су буенда тереклек иткән берничә семьялыкны берләштергән эре кошлар отряды

ЛӘКШӘ *и. диал.* Токмач. *Эткә ләкшә салма, үләксә сал.* Н.Исәнбәт

ЛӘКЪЛӘКА *и. гар. иск.* 1) Ямьсез тавыш, гөрелдәү, шакылдау тавышы

2) Бер мәгънәсез сүзләр. *Гыйсмәтинең күп вакытта мәгънәдән күп ләкъләка.* Ш.Бабич

3) Гайбәт. *Малайларга кузна фарыз булса, безгә әнә шул ләкъләка фарыз инде.* И.Нуруллин

4) Ләкләк тавышы

◊ **Ләкъләка сату** Юк-бар турында сөйләшү; ләчтит сату. *Сәгатьләр буе кызлар белән ләкъләка сатарга син ничек иренмисең?* И.Нуруллин

ЛӘЛӘ *и. фар. сөйл. к.* **лалә**. *Без, --- 200 төрдән артык күз явын алырлык лалә чәчәкләреннән бер читкә китеп, шикәр чөгендере игүдәге тәҗрибә белән танышырга булдык.* Социалистик Татарстан

ЛӘМ I *и.* 1) Елга, буа, күл, диңгез кебек сулыклар төбендәге минераль һәм органик кисәкчәләрдән гыйбарәт утырма, дуен. *Малай азаплана торгач, ләмгә баткан күлмәк-ыштанын салып ыргытты.* Р.Мулланурова. *Аннары тәнемә әллә нинди яфраклар ябып, ләмнәр сылап, юрганга төреп яткыра иде.* Ф.Яруллин. *Гади амёба пычрак сулы буа төпләрендәге ләмдә очрый.* Биология

2) *диал. к.* **лай**. *Менә көймә, аңардан балык, дегет, ләм һәм камыш исе аңкып тора.* М.Хәсәнов. *Карусыз, тырыш иде малайлары, сөт машинасында иртәле-кичле район үзәгенә, кырык чакрым пычрак ләм ярып сөт ташыды.* Р.Мулланурова. *Җәүдәт көннәр буе ләм диңгезендә йөзеп, җеп өзәрлек тә хәле калмаган рәвештә кайтып егыла иде.* А.Хәлим

ЛӘМ II *и. гар.* Гарәп әлифбасында «л» хәрефенең исеме. *[Габделкаюм:] Әби, син мине укырга өйрәткәндә, ләм кисәү агачы шикелле була, дип өйрәткән идең.* М.Гали

ЛӘМКЕ *и. рус сөйл. к.* **лямка**. *[Көй] Идел буенда ләмкә тартучылар зарын зарлый.* И.Рәмиев. *Карт Каспийның сөзәк итәгендә Балыкчылар ләмкә тартканнар. Ләмкә тәнне кискән.* М.Җәлил

◊ **Ләмке сөйрәү** *к.* **ләмке тарту**. *Сәфәргали абзый аның белән тормыш ләмкесен утыз җиде еллап сөйрәде.* З.Фәйзи. **Ләмке тарту** Интегеп авыр эш эшләү, берәр авыр эш белән җәфа чигү, авыр хезмәт белән яшәү

ЛӘМЛӘНҮ *ф.* 1) Ләм I (*1 мәгъ.*) утыру, ләм җыелу (су төбенә). *Елганың төбе ләмләнү*

2) *диал.* Ләм I (*2 мәгъ.*) үсү, ләм белән каплану. *Су ләмләнгән*

Ләмләнә башлау Бераз ләм утыру, ләм барлыкка килү

Ләмләнә төшү Бераз ләмләнү; тагын да ныграк ләмләнү

Ләмләнеп бетү Тәмам ләмләнү

Ләмләнеп калу Берәр сәбәптән ләмләнгән хәлгә килү

Ләмләнеп тору Вакыт-вакыт ләмләнү; ләмләнгән булу

ЛӘМЛЕ *с.* Ләме (*1, 2 мәгъ.*) күп булган, ләм I (*1 мәгъ.*) утырган. *Елганың ләмле төбе*

ЛӘМ-МИМ *и. гар.* **1.** Берәр төрле сүз, берәр нәрсәгә карата теге яки бу мәгълүмат, җавап, реакция. *Айсылу белә́зек турында ләм-мим язмаган, Айрат аша сораганыма әткәйнең җавабы булмады ---.* Б.Камалов. *Ачлар авызыннан хатын-кызның сихри тәне, тылсымлы күкрәкләре, сыгылмалы биллəре, бала бишегедәй тирбәлеп торган йомры-йомры артлары турында ләм-мим ишетә алмассың.* А.Гыйләҗев. *– Кабатлап әйтәм, бу турыда кешегә түгел, өегездә дә ләм-мим сүз ычкындырасы булмагыз! – дип кисәтте.* З.Фәйзи

2. *хәб. функ.* Бер сүз дә булмау. *Минем турыда да ләм-мим.* Х.Вәлиәхмәтов. *Изге дип санаган китапларыбызда ачы суыклар турында ник ләм-мим?* Ф.Фәтхелислам. *Теге ләм-мим, хәтта аз гына да елмаймыйча, барысы берьюлы борылып, минем ятак тирәсен уратып алдылар...* Г.Сәгыйров

ЛӘМ ЯЛЬТӘФИТ *хәб. сүз иск.* Илтифат итмәү, ис китмәү, әйләнеп тә карамау. *Минем хәлне белгән ипташлəр дә миңа күп дарунының исемен әйтеп карадылар. Әмма мин ләм яльтәфит.* Г.Тукай.

Көлделәр: куркыткан әйбер буш икән! Тордылар лəм ялтəфит. Ш.Бабич

ЛӘҢ *и.* Этләрнең өзек-өзек чәңгелдәп өргән авазы. *Урамда гына түгел, ихата эчләрендә дә адəм заты бөтенләй диярлек күренмәсә дə, үз билəмəләре чикләрендə аяк тавышы җанлану белəн, һəр йорт маэмайлар ләңе белəн яңара иде.* А.Хәлим

ЛӘҢГӘ *и.* 1) Махсус воланны мөмкин кадәр озаграк җиргә төшермичә аякта сикертүдән гыйбарәт уен. *Ләңгә башлыча Урта Азия илләрендә таралган*

2) Шул уенда кулланыла торган, кәҗә яки сарык тиресе кисәге эченә түгәрәк кургаш яки башка берәр авыр нәрсә куеп ясалган волан. *Ләңгәгә тире сайлау*

ЛӘҢГӘР *и. фар.* Ыргаклары белән җиргә кадалып, судноларны, йөзмә маяк, калкавычларны бер урында тота торган махсус җайланма; якорь. *Ләңгәр ташлау. Ләңгәр күтәрү*

ЛӘҢГӘЧ *и. диал.* Камыр әчетер өчен агачтан ясалган кисмәк

ЛӘҢГЕЛДӘ́Ү *ф. сөйл.* 1) Нечкә тавыш белән өрү, чәңгелдәү. *Кара [бу этне], ничек ләңгелди.* Р.Батулла

2) *күч. гади с.* Хурлау; гайбәт сату. *Тик, култыклашып, көпə-көндез кинотеатр янына барырга ярамас, --- Луизаны күрсəләр, ләңгелдəп туймаслар.* А.Гыйләҗев

Ләңгелдəп тору Бертуктаусыз яки хәзер ләңгелдәү

Ләңгелди башлау Ләңгелдәргә тотыну

Ләңгелди бирү Бернигә карамастан ләңгелдәү

ЛӘҢГЕЛДЕК *с.* Чәңгелдек, нечкә тавышлы, ләңгелдәп өрә торган. *Бүре басар Алабай ырылдап куркытса, башка вакытта капка астыннан өргән ләңгелдек көчеккə дə сəлам биреп йөрисең, диляр.* А.Гыйләҗев

ЛӘҢКӘ *с. сөйл.* **1.** Гел нечкә тавыш белән ләң-ләң өрә торган (кечкенә эт тур.). *Сөләйман --- наборщик алдында, арыслан янында торган ләңкə көчек төсле, кечкенə һəм зəгыйфь итеп хис итте үзен.* К.Тинчурин

2. *и. мәгъ.* Шулай чәңгелдәп өрә торган кечкенә эт. *Аларны ләң-ләң килеп сыер имчәге чаклы зур имчəкле ана эт озата барды, тора-бара бу ләңкəнең бөтен нəселе иярде һəм колакны вауваугa салды.* А.Хәлим

ЛӘ́Ң-ЛӘҢ *иярт.* Нечкә тавыш белән өргән эт тавышын белдерә. *Авыл этләре безне ләң-ләң өреп озаталар.* М.Госманов. *Өрмə, көчек, ләң дə ләң, сүз əйтергə ирек бир!* Н.Гыйматдинова. *Этендə генə үзгəреш юк, сугышка кадəр дə теләсə кемгə ләң-ләң өрə иде, хəзер дə шулай, хак.* А.Гыйләҗев

ЛӘП *иярт. к.* **ләп-ләп** I. *Аягың ләп итсə, авызың чəп итəр.* Мәкаль

ЛӘПӘК *и. зоол.* Вак чебен; чебен-черки

ЛӘПЕК *и. диал.* Сыек балчык, пычрак. *Туңы куера башлаган ләпектəн итекләрен ул да көчкə-көчкə тартып ала иде.* Ə.Хəсəнов. *Тартучы машина... кара төтеннəр атып озак үкерсə дə, иптəшен бəладəн коткара алмады, аны ләпектəн куптарырга, каты юлга чыгарырга куəте җитмəде.* Казан утлары. *Берəүлəр су төбеннəн алынган кап-кара ләпекне аякта баскан килеш кенə сыласа, икенчеләре ләпек эчендə яртышар сəгать ауный.* Туганайлар

ЛӘПЕКЛЕ *и.* Ләпек катыш; ләпектән торган. *Айзатлар машинасы ләпекле кара суга арт тəгəрмəчләре белəн кереп тə утырды.* Г.Мөхəммəтшин

ЛӘПЕЛДӘТҮ *ф. сөйл.* 1) Иреннәрне бер-берсенә тидереп алу, селкетү; чәпелдәтү

2) Су өслегенә йомшак кына бәрү, чыпылдату. *Мин утырган пароход тəгəрмəчлəрен ләпелдəтə-ләпелдəтə агымга каршы үрмəли.* Р. Батулла

Ләпелдәтеп алу Тиз генә, бераз ләпелдәтү

Ләпелдәтеп кую Үзеннән-үзе, кинәт кенә ләпелдәтү

Ләпелдәтеп тору Еш-еш, һаман да ләпелдәтү

ЛӘПЕЛДӘ́Ү *ф. сөйл.* 1) Берәр йомшак әйбер икенчесенә бәрелеп җиңелчә тавыш чыгару

2) *күч.* Хәрәкәттә булу, берәр эш башкару

Ләпелдәп алу Бераз гына ләпелдәү

Ләпелдәп кую Бер мәртәбә ләпелдәү

Ләпелдәп тору Һәрвакыт, даими ләпелдәү. *Аягың ләпелдəп торса, Авызың чəпелдəп торыр.* Мәкаль

ЛӘПЕРӘ *и. рус* Лепра, махау авыруы. *Аның маңгаенда, ефəк кебек чəчləре арасында күренеп калган кутыр, шиксез, ләперə иде.* Аң

ЛӘПЕС *и. лат. к.* **ляпис**. *Фойеда – кына һəм басма, ләпес һəм перекись белəн буялган чəчлəр.* Ш.Хөсəенов

ЛӘПЕШ *и. диал.* Карны эретә торган җепшек, җылы һава

ЛӘ́П-ЛӘП I *иярт.* Берәр яссы предмет икенче бер предметка җиңелчә бәрелгәндә барлыкка килгән тавышны белдерә. *Самараның ат аягы ләп-ләп итеп кəефне китереп бара торган асфальт урамы белəн вокзалга юнəлдек.* Г.Тукай

ЛӘ́П-ЛӘП II *и. сөйл.* Суган кыягының бер очын ярып, шул ягыннан авызга кабып өргән вакытта бөтерелеп ясалган алка. *Минһаҗ бакчадагы түтəлдəн суган кыягы өзеп алды. Аны авызына кабып, яр буенда «ләп-ләп» ясап йөрде.* М.Шәрифуллин

ЛӘ́П-ЛЕП *иярт. к.* **ләп-ләп** I. *Җимерек-ярыкларга цементлы эремəлəрне ләп тə леп ыргыталар гына.* З.Фәйзи

ЛӘ́П-ЛӨП *иярт. к.* **ләп-ләп** I. *Ләплөп килү*

ЛӘПШӘЮ *ф. диал.* Ямьшәю, җәелү. *[Солдатлар] ләпшəйгəн фуражкаларын күтəреп, башларын кашыйлар.* А.Таһиров

Ләпшәеп бетү Тәмам ләпшәю. *Тиздəн ак чалма урынына ләпшəеп беткəн картуз --- киячəген уйлап [Вахит] калтыранып китте.* М.Гафури. *Ə башына кияргə бөтенləй онытып чыгып киткəн кызулык белəн, ярый əле, Захар ләпшəеп беткəн бер фуражка аламасы бирде.* Ə.Əминев

Ләпшәеп калу Берәр тәэсирдән ләпшәйгән хәлгә килү

Ләпшәеп тору Ләпшәйгән рәвештә булу

Ләпшәя төшү Беркадәр ләпшәю; тагын да ләпшәю

ЛӘПШЕК *с.* 1) Сәлперәйгән. *Ләпшек беләкләр*

2) *диал.* Җәенке, яньчек, киңчә. *Ләпшек борын*

ЛӘПШЕРӘ́Ү *ф. сөйл.* Йомшару, тыгызлыгын югалту, шәлперәю. *Көпчәк шины ләпшерәп төшкән, тәмам бушаган.* А.Шамов

Ләпшерәп бару Акрын-акрын ләпшерәү

Ләпшерәп бетү Тәмам ләпшерәү

Ләпшерәп кую Кинәт ләпшерәү

Ләпшерәп тору Ләпшерәгән хәлдә булу

ЛӘПШЕРӘЮ *ф. к.* **ләпшерәү**. *Өйгә кадәр баллы сызык сызуымны белгәндә, капчык шактый ләпшерәйгән иде инде.* Шәһри Казан

Ләпшерәеп бетү Бөтенләй ләпшерәю. *Карагыз, әнә безнең толыпларыбыз юлда ничек итеп балыкчы туны төсле булып ләпшерәеп беткәннәр.* Әдипләр

ЛӘПШЕРДӘ́Ү *ф. к.* **ләпшерәү**. *Эх син, җүләр! Вадим Ильич! Шундый чакта суга төшкән тавык төсле ләпшердәдең!* Ш.Мөдәррис

Ләпшердәп бетү Тәмам ләпшердәү

Ләпшердәп тору Ләпшердәгән хәлдә булу. *Шатланырга да, кайгырырга да белмим, әрекмән яфрагы төсле ләпшердәп торам.* Казан утлары

ЛӘПШЕРДЕК *с.* Ләпшердәгән, ләпшердәгән хәлгә килгән, үз тыгызлыгын югалткан

ЛӘПШҮ *ф. диал.* 1) Мәлҗерәү, йомшау, жебеп төшү

2) Хәлсезләнү, таркаулану. *[Шәмәк:] Тарт, дим, тарт! [Сафа:] Әйдә, әйдә, ләпшемә, агай-эне!* К.Тинчурин

ЛӘСА *кис. сөйл. к.* **ләбаса**. *Һә-һәй, яңа туган ай ләса бу. Тот та хәзер үк мәчет манарасына менгереп күй.* Р.Вәлиев. *Алмашына башлаган карт сүзенә ышанып утырам ләса, шайтан алгыры!* Г.Гыйльманов. *Без бит Аллаһка «Сез» дип мөрәҗәгать итмибез ләса, ә нигә соң аның колына «Сез» дип дәшәбез?* Әдәби җомга

ЛӘТАФӘТ *и. гар. иск.* Гүзәллек, матурлык, нәфислек, ямьлелек. *Бу ике шигырьдә нинди ләтафәт, нинди нәфасәт, нинди поэзия!* Г.Тукай. *Заман үткән саен, табигать хәле алышына вә борынгы ләтафәт югала барып, хәзер бу җирләр бик ялангач вә төсмерсез булып калган иде.* Ш.Камал

ЛӘТЧӘ *и. рус* **1.** 1) Сусарлар семьялыгыннан гәүдәсе нечкә һәм сыгылмалы булган кечкенә ерткыч җәнлек; *русчасы:* **ласка**. *Пошилар калын тунын кия, куян һәм ләтчәләр киемнәрен акка алыштыра.* Л.Гарипова. *Дөрестән дә, ләтчә кайбер очракларда каралтыкура тирәсендә яши һәм тычкан тота.* Мәдәни җомга. *Ас күсе зурлыгында, ә ләтчәнең гәүдәсе бармак юанлыгында һәм ул тычкан ояларына бик ансат үтеп керә.* Биология

2) *күч. сөйл.* Чытлык яки усал хатын. *[Бәдигыльҗамал:] Ни эшләсәм эшләрмен, Ибраһимнан бу ләтчәсен аерттырырмын.* Г.Камал

2. *с. мәгъ.* Усал. *Ләтчә телле бер ханым әче таңнан газиз ирен таларга, игәргә тотынган.* Р.Гаффар

ЛӘТЧӘЛЕК *и. сөйл.* 1) Чытлыклык

2) Усаллык, бәйләнчеклек. *[Гаҗби:] Шул үзенең ләтчәлеге белән ирен эчәргә сабыштырды инде.* Ф.Сәйфи-Казанлы

ЛӘТЫЙФ *с. гар. иск.* 1) Гүзәл, нәфис, мөлаем. *Кечкенәдән гүзәл нәрсәләр укыган балаларның күңелләре дә назик вә ләтыйф булып, --- мөкаддәс нәрсәләрне генә сөючән буладыр.* Г.Тукай. *Һәр нәүгы гүзәл вә ләтыйф күбәләкләр сахраның гүзәллегене арттырмакта иде.* Ф.Кәрим

2) Йомшак, яхшы. *Ләтыйф җил*

ЛӘТЫЙФӘ I *с. иск. кит.* Искиткеч гүзәл, җанга ятышлы, матур (хатын-кызлар тур.)

ЛӘТЫЙФӘ II *и.* 1) Үткен сүз, матур гыйбарәләр

2) Анекдот; хикәя. *Хуҗа Насретдин ләтыйфәләре*

ЛӘТЫЙФЛЕК *и. иск. к.* **ләтафәт**

ЛӘ́Ү *и. кыт. миф.* 1) Аждаһа, мифологик җан иясе, кәлтәсыман канатлы кош

2) Төрки халыкларда унике еллык циклның бишенче елы исеме. *12 ел исемнәре: тычкан, сыер, барыс, куян, ләү, елан, елкы, куй, мичин, тавык, эт, дуңгыз.* Н.Исәнбәт

ЛӘҮЗ *и. гар.* Миндаль, бадәм чикләвеге

ЛӘҮКӘ *и. рус* Мунчада чабыну өчен биек сәке. *Ләүкәгә менеп утырганын, лепердәп торган себеркене кулына алганын хәтерли.* Р.Мулланурова. *Гыймади тәрәзә пәрдәләрен тартып куйды, фонарьны матчадагы чөйгә элде, себерке пешекләнеп яткан агач тагаракны, комганны ләүкәдән түбән төшерде, шунда ике чүмеч су йөгертте.* Ә.Гаффар. *Мен ләүкәгә, себерке белән чабыну ябыктыра адәмнәрне.* Н.Гыйматдинова

ЛӘҮКӘЛЕК *с.* **1.** Ләүкә ясарга яраклы, шуңа дип билгеләнгән. *Идәнгә үзебездәге такталар да ярар, ләүкәлек, сәкелек яңа такта алырбыз, дим.* М.Фәйзи

2. *и. мәгъ.* Ләүкә ясарга яраклы нәрсә, ләүкә өчен материал

ЛӘҮЛӘ́Ү *ф. к.* **лаулау**

ЛӘҮХӘ *и. гар. кит.* 1) Матур язу белән язылып стенага элеп куйган нәрсә, шәмаил

2) Күренеш, картина, пейзаж. *Тар милли әсәрләр булудан бигрәк, билхасса хезмәт белән көн итүче халык, яшь табәканың чурлы шәраит тәэсирендә кичергән тормышларыннан күзгә чалынырлык ләүхәләр биргән әсәрләр бу дәвердә бик күп очрый.* Ф.Бурнаш. *«Мишәрләр тормышыннан бер ләүхә» очерк-хикәясендә автор үзе бала чакларында күргән бер фаҗигале вакыйганы тасвирлый.* М.Мәһдиев

3) Элмә такта; плакат. *Капка башында яшел ләүхә тора*. Г.Тукай

4) Такта. *Буш вәһемнәр берлә ысланган хыялым ләүхәсе.* Ш.Бабич

ЛӘҮХЕЛМӘХФУЗ *и. гар.* Язмыш китабы (тактасы); кешеләрнең дөньяви тормышы, тәкъдире язылган такта. *Ләүхелмәхфузда безгә кардәш булырга язган булса, аны бозып булмас.* К.Тинчурин. *Кем дә кем Мөхәммәд өммәтеннән берәү ихлас белән «Бисмиллаһир-рахмани-р-рахим» дип әйтсә, аның ләүхелмәхфузына җиде йөз еллык гыйбадәт савабын язармын, дигән.* Ә.Гаффар. *Ләүхелмәхфузда ни язылган булса, шул булыр, аны беркем дә боза алмас.* Р.Мостафин

ЛӘФЫЗ *и. гар. иск.* 1) Сүз. *Тагы боларның [болгарларның] табигатьләрендә әллә нинди сүзгә, ләфызга әһәмият бирү булган*. Г.Исхакый

2) Мәгънәнең тел белән әйтелгән калыбы, сүзнең аваз ягы. *Телим, ташлап*

кирәкмәгән вак сүзләрне, «Сөям, җаным» ләфызларына ошавын. Г.Тукай. *Бу – ләфызны саклап калу өчен мәгънәне оештырырга әзер тору.* Ф.Әмирхан

ЛӘФЫЗПӘРӘСТЛЕК *и. иск. кит.* Хәрефкә ябышып яту, коры формализм

ЛӘХ I *и. иск.* Поляк. *Кырымның иске дусты «Ләх короле» (Польша-Литва короле) белән Мәскәү сугыша башлап, аны берничә мәртәбә җиңде.* Г.Гобәйдуллин. *Әйтик, ләх белән чехка да, француз белән алманга да.* Т.Әйди. *Соңыннан татар авылларын Гарифулла Вильнюс тирәсендә дә, ләх, румын, болгар җирләрендә дә очратты.* А.Хәлим

ЛӘХ II *рәв. рус сөйл.* Лаякыл, бөтенләй, бик каты (исерек булу). *Әйе, ул ләх исерек һәм томан эчендә, бөтенләй икенче дөньяда яшәп утыра иде.* М.Мәһдиев. *Шумбутский ләх исерек хәлдә, гырылдап йоклап ята иде.* М.Насыйбуллин. *Ягур тагын ләх булып кайтты. Сөйләшерлек тә хәле калмаган иде бичараның.* Ф.Баттал

ЛӘ́ХӘҮЛӘ *и. гар.* «Бөтенесе дә Аллаһ кулында, Аллаһ ихтыярында» дигән мәгънәдәге дога сүзе. *Таш йөрәкләр һәм яшен күргәч укыр ләхәүләсен.* Г.Тукай. *Кинәт күк күкрәде, үз уйларыннан үзе каушап төшкән Бибинур тагын ләхәүләсен укыды, идәнгә чүкте.* А.Гыйләҗев. – *Әстәгыфирулла! Ләхәүлә вә лә куәтә... – дияргә генә булдыра алды.* Ә.Гаффар

ЛӘХЕТ *и. гар.* 1) Мәет куяр өчен кабер төбенең бер як кырыеннан эчкә таба казып, чокып ясалган урын, уем. *Ләхетемне мул алырсың, тар булмасын, тын кысылырлык булмасын.* М.Мәһдиев. *Аннан ләхетне алмаштилмәш уйдылар.* А.Хәлим. *Ләхеткә иңдергән чакта, Газиз әнкәң кырына, Аязып китте күк йөзе: Кояш сипте нурын ла!* Ш.Мостафин

2) Гүр; гомумән кабер. *Җәмилә инде тыныч ләхеткә барачак, туфрак Җәмиләне кочагына алып, мәрхәмәтле һәм шәфкатьле аналар кебек кочып саклаячак.* М.Гафури. *Тормышта аерым булсак та, салырбыз башны бер ләхеткә.* И.Җиһангирова

ЛӘХЗА *и. гар. иск.* Күз ачып йомганчы үткән вакыт арасы. *Бу я бер ләхза, бер күз ачып йому, я бөтен бер гасыр, озын, бик озын гомер сөргән бер адәмнең бөтен гомере иде.* Ф.Әмирхан. *Алды тынлык дөньяны, шул ләхзада шылт иткән бер тавыш юк сахрада!* Ш.Бабич

ЛӘ́ХЧӘ *рәв.* 1) Поляк телендә. *Урысча, белорусча, хәтта ләхчә яхшы сөйләшкән, әмма татарча бер сүз белмәгән, шулай да биш вакыт намазларын калдырмаган Сәлмән һәм Мәрьям Якубовичлар соңгы чиккә җиткән ике әсир милләттәшләрен аякка бастыру өчен барысын да эшләделәр.* А.Хәлим

2) Поляклар кебек. *Ләхчә киенү*

ЛӘҺҖӘ *и. гар.* Тел, диалект (шивә). *И мөхәррир, --- Кертмә бер чит ләһҗәдән «хәреф» [грамматик чара] ләһҗәбез тәртибенә.* Дәрдемәнд

ЛӘЧ *рәв. диал. к.* **лач** II

ЛӘЧКЕЛДӘ́Ү *ф. диал. к.* **лычкылдау**

ЛӘЧ-ЛӘЧ *иярт. к.* **лач-лоч**. *Ләчләч сагыз чәйнәп нәүбәт көтеп торучы кызларның, киленнәрнең чәч үргечләренә таккан тәңкәләре бер-берсенә бәрелеп чылтырыйлар.* М.Галәү

ЛӘЧМӘ *рәв. к.* **лычма**. *Дәүләтшин, --- ник килгәненә үкенеп, бата-чума кайтып китә. Өсте ләчмә су була егетнең.* И.Гази

ЛӘЧТӘ *рәв. диал. к.* **лач** II

ЛӘЧТИТ *и. фр. сөйл.* Юк-бар сүз, буш сүзләр, сафсата. – *Андый туфлиләрне без дә алган идек, – ди боцман ләчтиткә кушылып.* М.Юныс

◊ **Ләчтит сату** Юк-бар сүзләр сөйләшү, сафсата сату. *Югыйсә мин, егетләр турында ләчтит сатып, сине сыйлауны онытып та җибәргәнмен.* Т.Әйди. *Галия кайтып төшәргә дә вакыт җитә түгелме? Ә без ләчтит сатабыз.* Р.Мулланурова. --- *Кич белән капка төбендә ләчтит сатып утырганда, тыкрык башында кияү егет күренде.* Н.Гыйматдинова

ЛӘШКӘР *и. фар. иск.* Гаскәр. *Мәхшәр кубып, Килделәр диңгез кебек ләшкәр булып.* Ш.Бабич

ЛӘШПЕРДӘТҮ *с. сөйл.* Өстерәү, лаштыр-лоштыр китерү. *Бала --- яланаякка элгән каталарын ләшпердәтә-ләшпердәтә түбән очка таба йөгерде.* Г.Минский

ЛӘШПЕРДӘ́Ү *ф. сөйл.* 1) Тән сәлперәю, йомшару, эластиклыгын югалту. *Ул ишанның дүрт хатыны булган, ди. Иң өлкәне – инде ләшпердәп төшкән бер карчык, ди.* Г.Ибраһимов

2) Шиңү, пәжү; сулу. *Гөл ләшпердәү*

3) Сыгылмалылыгын югалту; йомшару, бушап калу (мәс., шин, шар һ.б.). *[Автомобильнең] көпшәк шины ләшпердәп төшкән, тәмам бушаган. Җирдә насос, күтәрткеч һәм ачкычлар таралып ята.* А.Шамов

4) Лаштыр-лоштыр килү, сөйрәлеп лашпырдау. *Ләшперди торган аяк киеме*

Ләшпердәп бетү Нык ләшпердәү

Ләшперди башлау Ләшпердәргә тотыну

ЛӘШПЕРДЕК *с. сөйл. к.* **лапшырдык**

ЛӘШТЕРДӘТҮ *ф. к.* **лаштырдату.** *Күп кенә малайлар дәрестән юеш балакларын ләштердәтеп өйләренә кайталар иде.* Ә.Еники

ЛӘШТЕРДӘ́Ү *ф. к.* **лаштырдау**

ЛӘШТЕ́Р-ЛӘШТЕР *иярт. к.* **лаштор-лоштыр**. *[Гәрәй] аягына кигән ямаулы итек башын ләштер-ләштер өстерәп, пароход пристанена таба төшеп китте.* Ф.Сәйфи-Казанлы

ЛӘШТЕ́Р-ЛӨШТЕР *иярт. к.* **лаштор-лоштыр**. *Әниләренең һәм картәниләренең ахирәте Ләйләбәдәр карчык тешсез авызларын ләштер-лөштер китереп сөйләнә иде.* А.Хәлим

ЛӘЯКАТЬ *и. иск. кит.* Лаеклылык, лаеклы булу

ЛӘЯКАТЬЛЕ *с. иск. кит.* Лаеклы, тиешле. *[Бай] кыяфәте, сөйләшкән сүзе илә адәмнән хисап ителсә дә, һәркемгә тигезгән җәбере вә мәлгуньлеге илә иблис --- ләкабен алырга ләякатьле иде.* Ш.Мөхәммәдев

ЛЕБЕРДӘ́Ү *ф.* 1) Бер-берсенә йомшак кына тиеп, кагылып җиңел генә тавыш барлыкка китерү, лепердәү (мәс., салмак җилдә яфраклар, байрак, флаглар чайкалып)

2) Әкрен генә сөйләнү

Лебердәп тору Әле, хәзерге вакытта лебердәү. *[Каеннар] Кырык биш ел эчендә зур булып үстеләр, бөтен әйләнә-тирәгә ямь биреп, үзара*

гәпләшкәндәй, акрын гына лебердәп торалар. С.Сабиров

ЛЕБЕ́Р-ЛЕБЕР *иярт.* Җил, пар һ.б.ш.дан бер-берсенә йомшак кына бәрелешеп торудан яки җиңелчә хәрәкәтләнүдән, акрын гына сөйләүдән чыккан тавышны белдерә. *Өстәл түрендә утырган самавыр байтактан кайнап чыккан иде инде, күтәрелгән парда лебер-лебер җиз түбәтәйләре сикергәләп тора.* Р.Мөхәммәдиев

ЛЕБЁДКА *и. рус* Йөкләр күтәртү, аларны бер урыннан икенче урынга күчерү өчен, канатны яки тросны урап җыя яки сүтә торган барабаны булган җайланма-машина. *Ыжгырган җил-буран тавышына хәрәкәткә килгән лебёдка һәм бер-берсенә ялганган шәмнәрнең күз иярмәслек тизлек белән түбән таба очкан тавышлары да кушылды.* М.Хәсәнов. *Инсаф, буферлар аша сикерә-сикерә, лебёдкадан бушанган тросны сөйрәп алып китте.* Ф.Абдуллин

ЛЕБЁДКАЧЫ *и.* Лебёдка белән идарә итүче

ЛЕВ *и.* Болгариянең рәсми акча берәмлеге

ЛЕВИАФАН *и. яһүд. миф.* Тәүрат риваятендә сурәтләнгән, диңгездә яки күктә яши торган бик зур ерткыч җан иясе; мифик зат. *Ул әкияттә рәхмәт укучы балыкның егетне Левиафан янына алып баруы һәм Левиафанның аңа җитмеш тел, шул җөмләдән хайваннар теле дә өйрәтүе турында әйтелә.* Н.Хисамов

ЛЕВИРАТ *и. лат.* Үлгән бер туганының тол калган хатынына өйләнергә мәҗбүр яки рөхсәт иткән, күп кенә Көнчыгыш халыкларында яшәп килә торган патриархаль йола. *Каһанлык төзелгән чорда анда ыруглык җәмгыяте хөкем сөргән. Ул патриархаль булган, левират тәртибе сакланган, ягъни тол калган хатын үлгән иренең туганына тормышка чыгу хокукына ия була.* Г.Фәйзрахманов. *Төркиләрдә левират та булган.* Р. Сафин

ЛЕВИТА́ЦИЯ *и. лат.* Гравитация көчен җиңеп, бушлыкта эленеп тора алу, күчеп йөрү сәләте һәм шул процессның үзе. *Телепатия, күрәзәлек, левитация, ягъни әйберләрне акыл көче белән генә күчерү дә ярый, теге дөнья белән спиритик контакт, буш кул белән хирургик операция тәкъдим итәргә дә мөмкин, чынлыгы гына хак булсын, ди.* З.Мифтахов

ЛЕВКАС *и. гр. махс.* 1) Урта гасыр рәсем сәнгатендә: акбур нигезендә ясалган грунт. *Моннан тыш, балалар левкас, пигмент, темпера кебек сүзләрнең нәрсә аңлатуын, сурәт ясаганда нинди җилем (клей) кулланылуы турында да белә алачак.* Татарстан яшьләре

2) Агач әйберләрнең өстеннән буяр алдыннан тигезләп грунтлый торган җилем белән алебастр яки акбур катнашмасы; шул катнашма белән грунтлаган өслек, аның җирлеге

ЛЕВКОЙ *и. гр. бот.* Әвернәчәчәкләләр семьялыгыннан төрле төстәге чәчәкле хуш исле бакча гөле; шәббуй. *Левкойлар Татарстанда Кама Тамагы районында, Иделнең уң як ярында гына очрый*

ЛЕВРЕ́ТКА *и. фр.* Гадәттә якты һәм куе көрән яки соры төсле кыска йонлы, кечкенә гәүдәле, бурзай токымыннан булган бүлмә эте

ЛЕГАЛЬ *с. лат.* 1) Законлы, гамәлдәге, закон нигезендә рәсми рөхсәт ителгән. *Ул [«Локаф»] – Кызыл Армиянең сәяси идарәсе тәкъдиме белән төзелгән һәм хәрби темага язучыларны берләштергән легаль иҗади оешма.* Р.Мостафин

2) Ачыктан-ачык эшчәнлек алып баруга нигезләнгән, закон тарафыннан кире кагылмаган. *Татар театры патша заманасында ярым легаль хәлдә яшәп, изелеп килгән бер мәйдан булганга, аның Октябрь идеяләрен үзләштерү процессы җиңел үтте.* Ф.Бурнаш. *Легаль базар. Легаль сәүдә*

ЛЕГАЛЬЛӘШТЕРҮ *ф.* 1) Халыкара хокукта: чит илдә бирелгән документның дөреслеген һәм юридик көчен раслау. *Фирманы Россия консуллыгында легальләштереп, АКШта регистрацияләү*

2) Законлаштыру, гамәлгә кертү, законлы дип табу. *«Бездәге криминаль хәл болай да катлаулы, әгәр дә утлы коралны легальләштерү буенча закон кабул ителсә, авыр җинаятьләр бермә-бер артачак», – диләр алар.* Татарстан яшьләре. *Хосусый милекне легальләштерү*

3) Легаль хәлгә күчерү. *Икенчедән, Мокамайның әрвахын легальләштерергә, лабораториядә аның өчен урын табарга, шул ук вакытта әрвахның Фәтхулла хәзрәт белән психоэнергетик багланышын да җуймаска кирәк булды.* А.Тимергалин. *Ул [Шубарин] бизнесын легальләштергән, законлаштырган, казнага налогларын тәртипле түләп бара ---.* Р.Мирхәйдәров. *Мондый нәтиҗәләргә ирешүгә тормыш сыйфатын яхшырту һәм керемнәрне легальләштерү комиссиясе эшчәнлеге дә ярдәм итте.* Ватаным Татарстан

Легальләштерә бару Эзлекле рәвештә, әкренләп легальләштерү

Легальләштерә башлау Легальләштерүгә күчү

Легальләштереп бетерү Барысын да легальләштерү

ЛЕГАЛЬЛӘШҮ *ф.* Легаль хәлгә күчү. *Өченче дәвердә ачыклык шартларында ул [постмодернизм Россиядә] легальләшә һәм, башка илләрдә төрле агымнар арасында үзенә урын табып, сәнгать өлкәсендә бара торган процесска үзенең өлешен кертә.* К.Гыйззәтов

Легальләшә бару Эзлекле рәвештә, әкренләп легальләшү

Легальләшә башлау Легальләшүгә күчү, легальлеккә йөз тоту

Легальләшеп бетү Барысы да легальләшү

ЛЕГАЛЬЛЕК *и.* Легаль хәлдә булу. *Күп партияләрнең легальлеге*

ЛЕГАТ *и. лат.* 1) Борынгы Римда: сәяси йомышлар үтәүче илче; республика чорында: аерым провинцияләрдә дәүләт кешесе, полководец ярдәмчесе; колбиләүчелек монархиясе чорында: аерым провинцияләргә император тарафыннан билгеләнгән кеше. *Ахеялылар, эшне хәл итү өчен, киңәшмә җыялар, һәм шунда Антиохның легаты аларны кулга корал алмаска чакыра.* Н.Макиавелли

2) Рим папасының чит илгә махсус миссия белән җибәрелгән дипломатик вәкиле

ЛЕГА́ТО *и. ит. муз.* Музыкаль әсәрләрне башкарганда, бер аваздан икенчесенә, өзмичә, салмак күчү күренеше; *киресе:* **стаккато**. --- *аларда [ачык иҗекләрдә] (музыкадагы легато рәвешендә) үзләреннән соң килә торган иҗекләргә тоташу, сарылу, агылу сыйфаты бар*. Х.Туфан

ЛЕГАШ *и. рус сөйл.* Ауланган кошны исеннән эзләп таба ала торган ау этләре төркеме

ЛЕГГОРН *и. инг.л* Йорт тавыгының гадәттә ак каурыйлы, йомырканы иң күп сала торган токымы

ЛЕГЕ́НДА *и. лат.* 1) Прозаик фольклор әсәре: тарихи вакыйга яки шәхес турындагы, еш кына илаһи затлар һәм гайре табигый көчләр катнашкан фантастик хикәя, риваять. *Тукай тагын легенда, уйдырма, әкиятләрдән дә файдалана.* Г.Нигъмәти. *Риваятьләр, легендалар һ.б. фольклор жанрларын этнокультур процесслар мәсьәләләрен хәл итәргә тарту бик уңышлы булып чыкты.* Г.Дәүләтшин. *Көнчыгыш халыкларының борынгыдан килгән легендаларын, язма әсәрләрен, татар укучысына җиткерү өчен, әдәби эшкәртү юлы белән формалаштыра [автор].* Татар әдәбияты тарихы

2) Үткәндәге сокландыргыч вакыйгалар турындагы, кайвакытта героик яки дини төсмерле хикәя. *Гади совет кешесе буыннардан-буыннарга калырлык, телләрдән төшмичә легендалар итеп сөйләрлек, җырларда җырланачак батырлыклар эшли иде.* Г.Әпсәләмов. *Җәмил солдатның бу батырлыгы легенда булып тарала.* Г.Ахунов

3) Реаль вакыйгаларны ник үзгәртеп, чынбарлыктан ерак итеп сурәтләгән хикәя, уйдырма. *Язгы розалар төсле матур-матур уйлар туарлар, бәлки, мәхәббәт турында яңа легенда язылыр.* Ф.Хөсни. *Минем кадерле якташым, зур талант иясе, туганүскән авылы Гөберчәкне үз әсәрләрендә легендага әйләндергән Мөхәммәт Мәһдиев тә якты дөньяда юк.* Г.Ахунов

4) Разведчикның уйлап чыгарылган биографиясе, аның турындагы уйдырма мәгълүмат

5) *махс.* Медаль, тәңкә акча һ.б.ш. әйберләрдәге язулар

6) *махс*. Нинди дә булса картага, планга карата бирелгән шартлы билгеләр һәм аңлатмалар җыелмасы

ЛЕГЕНДАР *с. нем.* 1) Берәр сокландыргыч ягы (батырлыгы, көче һ.б.ш.) белән легендаларга кергән, халыкта дан-шөһрәт казанган. *Фашистлар армиясенең, Дон далаларына зур көчләр туплап, Идел буена, бөтен илнең горурлыгы, легендар шәһәр Сталинградка ыргылулары хәзер беркемгә дә сер түгел иде инде.* Г.Бәширов. *Менә шушындый легендар кешеләрнең төпчек кызы Миңлеасиягә өйләнде Тимерхан.* Г.Ахунов. *Атна-ун көн үтмәгәндер, бик тә итагатьле-инсафлы, эзләнүчән җанлы бу өлкән мөгаллим миңа легендар Кыям Абрамовның балачагы, яшүсмер еллары, көрәш юллары һәм фажигасе турындагы истәлекләрен язып бирде.* Ф.Дунай

2) *күч.* Ышанмастай, хыялый, уйдырма. *Аның әсәрләре конкрет кеше урынына гомумиләштерелгән кешене бирәләр, конкрет тормыш урынына ул легендар тормышны сурәтләндерә.* Г.Нигъмәти

ЛЕГЕРДӘ́Ү *ф.* Эреп агып таралырга тору; койкасыман булу

Легердәп тору Әле хәзер, карап торышка легердәгән хәлдә булу. *Койматклары – легердәп торган май.* Н.Исәнбәт

ЛЕГЕ́Р-ЛЕГЕР *иярт.* Кабатлаулы хәрәкәтләрнең монотон тавышын белдерә. *Тегермән ташлары исә уйсу болыннарга бишек җыры көйләп легер-легер әйләнәләр, улаклардан хуш исле он агызалар.* М.Мәһдиев

ЛЕГЕ́Р-ЛЕГЕР КИЛҮ *ф.* Җиңелчә монотон тавыш чыгарып селкенү. *Ә тегермән йорты легер-легер килеп селкенә, тирбәлә, шул арада синең йокың да килә башлый.* М.Мәһдиев

ЛЕГИОН *и. лат.* 1) Борынгы Рим армиясенең төп тактик оештыру һәм структур формасы булган зур (4–6 мең кешелек) гаскәри берәмлек; баштарак бөтен Рим армиясе шулай аталган. *Колхозның утыз биш еллыгында салдык. Рим легионнарын, Гудериан танкларын чыдата торган күпер.* А.Гыйләҗев. *Көн батышы ягында рум легионнары тезелгән, анда --- көбәләренең күкрәк тимерендә арыслан башы төшерелгән алтын тәңкәләрен ялтыратып, бөркет каурыйлары кадалган өслем кигән легатлар балбал сыннары кебек катып калган...* Р.Зәйдулла

2) Төрле чорда төрле хәрби частьлар исеме. *Легионнан башка, сигезенче Урал полкы, өченче Совет полкы, берләшкән Актүбә отряды һәм атлы беренче совет казак полклары оештырдылар.* Ш.Усманов. *Уразаев легион солдатлары арасында астыртын агымның һаман көчәя баруын --- әйтте.* Ш.Маннур

3) Кайбер илләрдә махсус хәрби частьларның исеме. *Идел-Урал легионы ни дип кан түгәргә тиеш соң?* Т.Әйди. *Төрекмәннәрдән махсус легион төзиләр, ди. Каюм хан җитәкчелегендәге «Төркестан легионы» менә шулай барлыкка килә*. М.Әмирханов

4) *күч.* Бик күпләр, күп кеше. *Һәрвакыт кеше күзендә бит ул. Аның абынганын көтеп торучылар – легион*. Р.Зәйдулла

ЛЕГИОНЕР *и. лат.* 1) Легион сугышчысы, легион солдаты. *Цезарь легионерлары һәм Цезарь халык турында кайгыртты дип, һаман ышанып килгән Рим халкы.* Борынгы заман тарихы

2) *спорт* Икенче клубка, гадәттә чит ил клубына күчеп, шул клуб файдасына уйнаучы спортчы. *Россия легионерлары арасында НХЛда уйнаучы Яшин бомбардирлар бәхәсендә күпкә алда бара.* Мәдәни җомга

ЛЕГИОНЧЫ *и. к.* **легионер** (*1 мәгъ.*). *Сезнең егерме легиончыгыз кырык немец солдаты белән бергә Украина фронтына амуниция эшелоны озатырга җибәрелгән иде.* Ш.Маннур. *Легиончыларны нәрсә хакына аяусыз көрәшкә өндәргә тиеш ул?* Т.Әйди

ЛЕГИРЛАНУ *ф. төш. юн. к.* **легирлау**. *Шуңа күрә аз легирланган корычлар вак бөртекле һәм югары сыйфатлы булалар.* Төзү материаллары

ЛЕГИРЛА́У *ф. махс.* Металлның төп сыйфатларын яхшырту, кирәк якка үзгәртү өчен (мәс., үткәрүчәнлеген арттыру һ.б.ш.), билгеле катнашмалар кушу

ЛЕГИТИМ *с.* Законлы, тулы хокуклы, иҗтимагый танылган. *Әмма бу легитим нәрсә түгел: устав буенча казый урынбасары юк.* Ватаным Татарстан. *Ул чакта оккупантлар тарафыннан оештырылган курчак мәхкәмә бәйсез илнең легитим җитәкчесен хөкем итте.* Мәдәни җомга. *Башкортстан татарлары Конгрессы – легитим оешма, аны Рәхимов үзе оештырган.* Татарстан яшьләре

ЛЕГИТИМА́ЦИЯ *и. лат.* 1) Җәмгыятьнең иҗтимагый-сәяси гамәлләрнең законлылыгын, дөреслеген, аклангалыгын тану процессы

2) Шул законлылыкны, хокукларны раслау, аклау ысуллары һәм алымнары

3) Гражданлык хокукында: гражданнарның нәрсә дә булса эшли алу хокуклары дәлиле

ЛЕГИТИМИЗМ *и. лат.* Көнбатыш Европада, башлыча Франциядә барлыкка килгән, дәүләт төзелешенең төп принципларын хәл итүдә монархик династияләрнең өстенлекле хакын таныган сәяси тәгълимат

ЛЕГИТИМИСТ *и. рус махс.* Легитимизм тарафдары

ЛЕГИТИМЛЫК *и.* Законлылык, законлаштырылган булу, гамәлдә булу, вәкаләтлелек. *Ә безнең Дәүләт Советы легитимлыкны, ягъни законлылыкны төгәл саклый дип әйтеп булмый.* Татарстан. *Яңа органның легитимлыгын тану*

ЛЕ́ДИ *и. англ.* Бөекбританиядә лорд яки баронет хатыны һәм гомумән аристократ даирәдә кияүдә булган хатын; ханым. *Әй син, леди Америка, тотма байга тарелка.* Г.Кутуй. *Тамырларында кайнар ирланд каны аккан әлеге леди [Жаклин Кеннеди] кечкенәдән бию сәнгатенә гашыйк булып үскән, алай гына да түгел, Нью-Йорктагы балет студиясенә йөреп, үзе дә кайбер осталык серләрен үзләштереп өлгергән иде.* Р.Вәли

ЛЕ́ЕР *и. голл. махс.* Корабларда кешеләр борт аша егылмасын өчен, кыек җилкәннәрне беркетеп куя торган ике очы ике якка тарттырып ныгытылган трос

ЛЕ́ЗВИЕ *и. рус* Бер яки ике ягы да үткен бик юка корыч пластинкадан гыйбарәт көнкүреш-гигиена әйбере. *Лезвие, кайчы, пәке ярдәмендә җыйган үлән белән сөтчелек, игенчелекнең язмышын хәл итеп буламы?* М.Мәһдиев. *Әйберләрне багажникка урнаштырганнарын доцент Мәрдиев, пәрдә читен лезвие калынлыгы гына ачып, тәрәзәдән карап торды.* М.Галиев

ЛЕЗГИН *и.* Кавказдагы төп халыкларның берсе – Дагстанның көньяк районнарында һәм шуңа янәшә Азәрбайҗан районнарында яшәүче халык һәм шул халыкның бер вәкиле

ЛЕЗГИ́НКА *и. рус* 1) Лезгин хатыны, лезгин кызы

2) Шул исемдәге Кавказ халыклары биюе

ЛЕЗГИ́НЧА *рәв.* **1.** 1) Лезгин халкына хас булганча

2) Лезгин телендә. *Хатны лезгинча язу*

2. *и. мәгъ.* Лезгин теле. *Лезгинчасы бик әйбәт*

ЛЕЙ *и.* Румыния һәм Молдованың рәсми акча берәмлеге

ЛЕЙБ- *нем.* «Патша сараенда, монархка хезмәт итүче» мәгънәсен белдергән кушма сүзләрнең беренче кисәге; мәс., *лейб-медик, лейб-гусар, лейб-драгун*

ЛЕЙБ-ГВА́РДИЯ *и. нем.* Монархның шәхси гвардиясе буларак барлыкка килгән, соңрак монархия булган дәүләтләрдә сайланма, иң әйбәт хәрби частьлардан торган гвардия. *Финляндия полкы лейб-гвардия подпоручигы А.А.Бурнашев «Төньяк җәмгыят»е составына керә.* Татар әдәбияты тарихы

ЛЕЙБЛ *и. нем.* Чит илдә җитештерелгән товардагы этикетка, ярлык. *Фирма лейблы югары сыйфат гаранты булып исәпләнә*

ЛЕЙБ-МЕ́ДИК *и.* Патша сарае табибы

ЛЕЙБОРИСТ *и. англ.* Бөекбританиядә һәм кайбер башка илләрдә «Эшчеләр партиясе» әгъзасы

ЛЕ́ЙКА I *и. рус* 1) Үсемлекләргә су сибү өчен, тишекле махсус борыны булган бакча чиләге; өйдәге гөлләргә су сибү өчен, шуңа охшаш кечерәк савыт. *Фиркать апасы янында торган лейканы алды да шалканнарга, кыярларга, суганнарга ашыга-ашыга су сибә башлады.* Н.Каштанов

2) Суны сосып түгү өчен җайлаштырылган зур чүмечсыман савыт. *Ул сәләмә пиджак җиңнәрен беләгенә таба җыештырды да чан эченә төшеп китте һәм, электән җайлап куйган такталарга басып, озын саплы лейка белән чалтырата-чалтырата былтырдан калып сасыган селёдка суын ушатка тутыра башлады.* Ш.Камал

ЛЕ́ЙКА II *и. нем.* «Leica» фирмасы чыгарган фотоаппаратларның гомуми атамасы

ЛЕЙКЕМИ́Я *и. лат. мед. к.* **лейкоз**. *Ул шартларда синдә бик тиз ак канга әйләнү башланырга мөмкин, ягъни лейкемия.* Ф.Бәйрәмова

ЛЕЙКОЗ *и. лат. мед.* Кан ясалыш системасына хас, башлангыч чорда сөяк җелегендә барлыкка килгән һәм ак кан тәнчекләренең артып китүе белән бәйле авыруларның гомуми атамасы; ак канлылык. *К. Тинчурин исемендәге Татар драма һәм комедия театрында лейкоз (ак кан) авырулы балалар өчен мәрхәмәтлелек акциясе үткәрелде.* Татарстан реформалар чорында

ЛЕЙКОТОКСИННАР *и. күпл. лат. мед.* Кеше яки хайван организмында барлыкка килә торган яисә микроорганизмнар җитештереп чыгарган, лейкоцитларны агуларга сәләтле булган матдәләр

ЛЕЙКОЦИТ *и. лат.* Организмга үтеп кергән микроорганизмнарны һәм чит тәнчекләрне зарарсызлап, кан зарарлануны тоткарлый торган канның төссез күзәнәге; ак кан тәнчеге. *Абдулла абый, санаторийга путёвка булырга тора, дигәч, минем анализларны ала башладылар. Шунда канда лейкоцитларның бик әз булуы беленде.* Ф.Яруллин. *Канда әле тагы башка төрле күзәнәкләр дә бар – лейкоцитлар. Боларның төсе юк, шуңа күрә аларны канның ак күзәнәкләре дип тә атарга була.* Ф.Бәйрәмова

ЛЕЙКОЦИТАР *с.* Лейкоцитлар белән бәйле, шуларга караган. *Лейкоцитар формула*

ЛЕЙКОЦИТОЗ *и. лат.* Канның күзәнәк составындагы лейкоцитлар күбәеп китүе белән бәйле үзгәреш. *Аякларына, кулларына грелкалар. Дилә-*

фрүз, кардиамин. Хәзер үк лейкоцитоз [га анализ] алсыннар. Г.Әпсәләмов

ЛЕЙКОЦИТУРИ́Я *и. лат.* Бәвелдәге лейкоцитларның нормадан артык булуы

ЛЕЙТЕНАНТ *и. фр.* 1) Күп кенә дәүләтләрнең армияләрендә кече команда составына караган хәрби дәрәҗә, Россия армиясендә кече лейтенанттан югарырак офицер чины. *Бөек Ватан сугышында каһарманнарча көрәшкән рота командиры лейтенант С.Садретдинов турындагы --- очеркларын тирән дулкынлану белән укыйсың.* Казан утлары

2) Эчке эшләр министрлыгы һ.б.ш. махсус оешмаларда хезмәт итүчеләрдә шундый үк дәрәҗә. *Кече лейтенант Баязитовның әйтүе буенча, баш кеше, өйгә кайтучыларга бүләк итеп бирелә торган товардан бер кешелек үлчәм (костюмлык) ала һәм аны биш литр спиртка алыштыра.* М.Яһудин. *Тик милициядән тынычлык булмады, бигрәк тә менә шушы лейтенанттан.* Х.Вәлиәхмәтов

ЛЕЙТМОТИВ *и. нем.* 1) Музыкаль әсәрдә нинди дә булса идеяләрне, геройларга хас булган холык-фигыль үзенчәлекләрен чагылдыру өчен, әсәрнең башыннан ахырына кадәр кабатланып килгән төп мотив

2) Гомумән, иҗатта, сәнгать әсәрендә басым ясап, кабатлап әйтелгән фикер, ассызыклап бирелгән тема, сюжет линиясе. *Бөтен спектакль буенча лейтмотив булып бара торган төп фикер – халыкның киләчәгә нинди булыр?* Р.Фәйзуллин. *Шагыйрь иҗатының лейтмотивы – шәхеснең рухи пакъләге, әхлакый камиллеге мотивы.* Татар әдәбияты тарихы

ЛЕКА́ЛО *и. рус* 1) Кәкре сызыклар сызу өчен кулланыла торган сызым әсбабы

2) Катлаулы профильле әйберләр әзерләү өчен кулланыла торган шаблон, модель, үрнәк деталь

ЛЕКА́ЛЬЩИК *и. рус* Лекалолар (*2 мәгъ.*) әзерләү белгече. – *Эшчеләр күп төрле була: токарь, фрезеровщик, лекальщик, аппаратчы, слесарь, гравёр, штамповщик... Ул тагын әллә нинди профессияләрне санап китә алган булыр иде, ишеккә арты белән утырган абый аны бүлдерде: – Әле ул гравёр булып эшли алмас, лекальщик булуы да бик икеле.* Л.Ихсанова

ЛЕ́КАРЬ *и. рус* 1) *иск. сөйл.* Табиб, врач

2) *шаярт.* Гомумән дәвалау белән шөгыльләнүче теләсә кем

ЛЕКИСТЛАР *и. күпл. әд.* «Күл шагыйрьләре» (*ингл.* lake poets) дип аталган, XVIII гасыр азагы – XIX гасыр башында сентименталь-романтик юнәлештә иҗат итүче инглиз язучылары төркеме

ЛЕКПОМ *и. рус иск.* Лекарь ярдәмчесе, урта медицина белгече. *Бер үк вакыт яралы кызылармеецларны да, тәртип урнаштыра алмаган врачларны, лекпомнарны һәм санитарларны да бик каты ачуланырга тотынды.* А.Шамов

ЛЕКСЕ́МА *и. гр. лингв.* Үзенең барлык формалары һәм мәгънәләре белән бербөтенне тәшкил иткән һәм бер мөстәкыйль эчтәлеккә ия тел берәмлеге буларак сүз. *Алар йогынтысында телнең структур берәмлекләре семантик һәм грамматик яктан үзгәрә, яңалары (лексема, хәбәрләмә, фикерләмә һ.б.) барлыкка килә.* И.Низамов

ЛЕ́КСИК *с.* Сүзгә, сүз байлыгына – лексикага караган, лексикага мөнәсәбәтле. *Чөнки формаль тел-стиль чаралары кебек тышкы күренешләр лексик берәмлек, грамматик форма ише күзгә ачык күренеп, колакка аныклы ишетелеп тора торган, хәтта бармак белән төртеп күрсәтерлек «матди» гәүдәләнеш сыйфатына ия.* М.Госманов. *--- Исмәгыйль сөйләме лексик яктан кызыклы.* В.Әминева. *Лингвистикада лексик абстракция һәм грамматик абстракция дигән төшенчәләр бар.* Татар теле морфологиясе

ЛЕ́КСИКА *и. гр.* 1) Бер телнең, диалектның яки башка катламның сүзлек фонды, байлыгы, телнең барлык сүзләре. *Соңгы елларда диалектальлексиканы махсус өйрәнүләр барышында, сөйләшләрдә бик күп борынгы сүзләр сакланып килүе ачыкланды ---.* Татар халык сөйләшләре. *Симпозиумда татар милләтенең яңарышы һәм үсеше мәсьәләләре, заманча мари һәм мордва телләре лексикасы үсеше, финугорлар һәм ислам --- һ.б. мәсьәләләр күтәрелде.* Казан утлары. *Лексика ягыннан татар тел байлыгы тотрыклы саклана.* Мәдәни җомга

2) Теге яки бу автор теленең яисә аерым әсәрнең сүзлек составы. *Имансызлыктыр ул, денсезлектер, Мәгънәсезлектер ул, мәнсезлек... Бу өзекнең лексикасы исә тагын да кырысрак, киеренкерәк.* Ф.Урманчеев

3) Билгеле эшчәнлек өлкәсендә кулланыла торган барлык сүзләр. *Шәҗәрә тексты лексикасы татар теле орфоэпик таләпләре кысаларында язылган.* М.Әхмәтҗанов. *Футуристлар, үзләренең иҗат җимешләрен критик реализм методы белән язылган әсәрләрдән аерып карарга омтылып, шигырь текстларын вульгар лексика, жаргоннар, бюрократик документлар, плакат, афиша стиленнән кергән сүзләр белән «баеталар».* К.Гыйззәтов

ЛЕ́КСИКАЛАШУ I *ф. лингв.* Телнең аерым элементы (морфема, сүз формасы, сүзтезмә) мөстәкыйль мәгънәгә ия булган лексик берәмлекләр рәтенә күчү, аерым сүз статусы алу; сүзгә әйләнү

ЛЕ́КСИКАЛАШУ II *и. лингв.* Телнең аерым элементы (морфема, сүз формасы, сүзтезмә) мөстәкыйль мәгънәгә ия булган лексик берәмлекләр рәтенә күчү, аерым сүз статусы алу; сүзгә әйләнү күренеше. *Тимерчыбык – бу кушма сүз шулай ук сүзтезмә лексикалашу юлы белән ясалган, компонентлар арасындагы атрибутив мөнәсәбәт югалган (бакыр тимерчыбык, алюмин тимерчыбык һ.б.).* Ф.Хисамова. *Тамыр ясалу юллары түбәндәгеләр: гаплология, конверсия һәм лексикалашу, чит телдән үзләштерү, дублетлашу һәм кабат таркалу.* Фән һәм тел

ЛЕКСИКО́ГРАФ *и.* Лексикография белгече, сүзләр җыю, системалаштыру һәм сүзлекләр төзү белән шөгыльләнүче галим. *Сүзлек төзергә керешкәндә, лексикограф кайбер махсус мәсьәләләрне хәл итәргә тиеш.*

Ф.Сафиуллина. *Сүзләрне җыю, сүзлекләр төзү эше белән лексикографлар шөгыльләнә.* Р.Фәттахова

ЛЕКСИКОГРА́ФИК *с.* Лексикография белән бәйле, сүзлекләр төзү эшенә мөнәсәбәтле. *--- бу сүзлек лексикографик тәҗрибәсе зур булган галимнәр тарафыннан (Ф.Ә.Ганиев, И.А.Абдуллин, М.Г.Мөхәммәдиев, Р.Ә.Юналиева) төзелгән.* Ф.Сафиуллина. *Төзүчеләр лексикографик чыганаклар буларак рус теленең башка сүзлекләреннән, 1977–1981 елларда чыккан өч томлык аңлатмалы сүзлектән, моңа кадәр дөнья күргән --- сүзлекләрдән дә уңышлы файдаланганнар.* Казан утлары

ЛЕКСИКОГРА́ФИЯ *и. гр.* 1) Бер телнең сүзләрен җыю, системага салу һәм сүзлекләр формасында бастырып чыгару эше һәм теориясе. *Телдәге сүзләрне җыю, теркәү, сүзлекләр төзү, сүзлекләрнең төрләрен өйрәнүне лексикография (грек. lexikos – сүз, grafos – язу, тасвирлау) башкара.* Ф.Сафиуллина. *Шул ук вакытта бу проблема аның [Ж.Вәлидинең] татар теленең грамматик төзелешенә, диалектология һәм лексикография өлкәләренә караган хезмәтләрендә дә урын ала.* Ш.Асылгәрәев

2) Сүзлек тибындагы басма хезмәтләрнең барлыгы

ЛЕКСИКО́ЛОГ *и.* Лексикология белгече, телнең сүзлек байлыгын өйрәнүче белгеч. *Атаклы төрки лексикологы Мәхмүт Кашгари язуынча, «Этил – кыпчак илләрендә бер елганың атамасы».* Эзләнүләр. Уйланулар. Табышлар

ЛЕКСИКОЛО́ГИК *с.* Лексикология белән бәйле, лексикологиягә караган. *Лексикологик һәм диалектологик экспедицияләр уздыру дәвам итә*. Татар халык сөйләшләре

ЛЕКСИКОЛО́ГИЯ *и. гр.* Тел белеменең лексиканы тикшерә торган тармагы. *Мин, кирәк булса, синтаксисын да, диалектологиясен дә, тел тарихын да, тарихи грамматикасын да, морфологиясен дә, лексикологиясен дә – барысын да укыта алам...* Х.Сарьян. *Лексикологиянең төп өйрәнү предметы – сүз; ул телебезнең сүзлек составын (сүзләрнең мәгънәләрен, килеп чыгышын, кулланылыш өлкәләрен һ.б.) өйрәнә.* Ф.Хисамова

ЛЕКСИКОН *и. гр.* 1) *иск.* Сүзлек. *Француз язучысы Гюстав Флобернының «Хакыйкать лексиконы» исемле сүзлегендә ат турында болай диелә: «Ат, әгәр дә үзендә күпме көч барын белсә, үзен йөгәнләргә, йөгәндә йөртергә мөмкинлек бирмәс иде».* М.Мәһдиев. *Лексикон төзү*

2) Билгеле даирәнең, катламның яки аерым кешенең сүз запасы, сүз байлыгы, шуңа хас сүзләр. *Вакыйф Җәлал шигырьләрендә чамадан тыш күп чит тел сүзләрен куллана. --- Аның лексиконында шундый сүзләр тулып ята.* С.Сүнчәләй. *ТИУнең эшен исә мин хуплыйм. Шуның эшчәнлеге аркасында гына лексиконыбызга элек каһәрләнгән бик күп сүзләр кайтты, туган телебездә күп газеталар ачылды.* Р.Низами. *Ошбу проектны --- сәяси лексиконга «Барселона процессы» дигән исем астында кергән махсус программаның дәвамы дип тә карарга кирәктер.* Мәдәни җомга

ЛЕКСИК-СЕМА́НТИК *с.* Лексика һәм семантика белән бәйле, сүзнең мәгънәсенә караган. *Телебезнең сүзлек составы, лексик-семантик нормалары еш кына кирәксезгә урыс теле сүзләре кулланы аркасында бозыла.* Р.Юсупов

ЛЕ́КТОР *и. лат.* 1) Лекция укучы, лекция сөйләүче. *Авыл советы председателе, районнан авторитетлы лекторлар чакырып, хорафатлар, ышанулар һәм аларның зарарлары турында өч-дүрт мәртәбә лекцияләр тыңлатып карады...* А.Гыйләҗев. *--- кайбер лекторлар җиңел генә нәрсәне юри катлауландырып, чәбәләндереп бетерәләр.* Ф.Галимуллин. *Йолдызлар турында лекция укып йөрүче бер эчкече лектор, шушы аппараттан чыгуга ук, эчкечелеккә каршы лекция уку өчен, клубка йөгергән, диләр.* Ф.Баттал

2) *күч.* Кеше өйрәтергә, акыл сатарга, гомумән күп сөйләшергә яратучы кеше. *Бүген шундый лектор туры килде. --- иптәшнең күзләр елтырый, бит-муеннар кызыл, сөйләшәсе килә...* М.Мәһдиев

3) Борынгы Римда: китап укып торучы кол

ЛЕКТО́РИЙ *и.* 1) Ачык лекцияләр оештыру белән шөгыльләнә торган оешма. *Биредә автор әдәби-музыкаль лекторий һәм симфоник оркестр эшчәнлегенә карата үз фикерен белдерә.* К.Миңнуллин. *Татарстанның халык артисты Георгий Ибушев лекторийда 1985 елдан бирле эшли.* Мәдәни җомга

2) Халыкка лекцияләр уку өчен махсус бина

ЛЕ́КТОРЛЫК *и.* Лектор эше; лектор осталыгы. *Бу юлы да ул без белгән, без яраткан Мөхәммәт Мәһдиев булып калды. Безгә, яшьрәк буын укытучыларга, лекторлык осталыгы үрнәген бирде.* Ф.Галимуллин. *Аена бер тапкыр часть командирлары өчен уздырыла торган семинарларда да каушап калмый. Кыскасы, аның лекторлык осталыгын күрмәү мөмкин түгел.* С.Шәрипов

ЛЕ́КЦИЯ *и. лат.* 1) Югары уку йортында укытучының предметны телдән сөйләвеннән гыйбарәт булган дәрес һәм шуның язмасы, конспекты. *Илебезнең язмышы кыл өстендә торганда, тыныч аудиторияләрдә лекция тыңлап, бакалар ярып, төннәр буе микроскоп өстендә утыру Дәүләтшинга әллә ничек оят кебек тоела.* И.Гази. *--- профессор Милославский --- галимнәргә генә аңлаешлы итеп лекцияләр укый, Казан нейрогистологлар мәктәбен җитәкләп алып бара.* Г.Ахунов

2) Билгеле темага халык каршында ясалган чыгыш. *Әле кырыгынчы елларда ук бу кеше Кара Чыршыга килеп лекцияләр укып йөргән иде.* М.Мәһдиев. *СПИД турында лекцияләр укып, китаплар таратып, сатучы халкын куркытып бетергәннәр иде табиблар.* Т.Галиуллин. *Әмма мин яхшы беләм: бу лекцияне минем элек ишеткәнем юк, бу аудиториядә дә мин беренче тапкыр.* Кызыклы психология

3) *күч.* Нотык, вәгазь, акыл сату, акыл өйрәтү. *Сезне минем менторларча өйрәтүем һәм бик үк тәртипле булмаган лекциям борчымыймы?* Р.Мирхәйдәров. *Хатын-кыз синең бер сәгатьлек лекцияңне тыңлап торамы соң инде?!* М.Хуҗин

◊ **Лекция уку** Акыл өйрәтү, мораль уку, нотация уку. *--- акыл сатып, кеше*

көлдереп йөрмә. Фәхешханәләргә кереп, оят турында лекция укып, фахишәләрне һәм клиентларны тәрбияләп маташма. Т.Миңнуллин. *Тартучылар булса, аларга тәмәкенең зарары турында сәгатьләр буе лекция укый ала.* Р.Миңнуллин

ЛЕ́ММА *и. гр.* 1) *мат.* Бер теореманы исбатлау өчен кирәк булган икенче бер ярдәмче теорема. *Шуннан ул [Лобачевский], туры почмаклары булган сыныk сызык турындагы яңа леммага таянып, теләсә нинди өчпочмакның почмаклар суммасы ике туры почмакка тигез була, дигән теореманы китереп чыгарды.* Ж.Тәрҗеманов. *Лемманы исбатлаганда, комплекс санның түбәндәге үзлекләре кулланыла* ---. Күпбуыннар

2) *линв.* Лексеманың шартлы рәвештә төп булып саналган, гадәттә сүзлекләрдә теркәлгән формасы

ЛЕ́ММИНГ *и. норв. зоол.* Евразия һәм Төньяк Америка урманнарында һәм тундраларында яшәүче, кыр тычканнары семьялыгыннан кимерүче хайван. *Лишайник, мүк, кәрлә агачлар, кимерүче лемминглар, ак көртлек, ак ябалак, төньяк боланы, ак төлкеләр тундраның табигый бергәлеген тәшкил итә.* Табигать белеме. *Бу [җенси җитлегү] периодның дәвамлылыгы умырткалыларда төрлечә: Норвегия леммингында иң кыскасы (19 тәүлек), гаттерия һәм мөгезборында иң озыны (20 ел).* Биология. Хайваннар

ЛЕМУР *и. лат. зоол.* Приматлар отрядыннан Африка, Мадагаскар, Көньяк-Көнчыгыш Азия урманнарында яши торган, койрыгы һәм арт аяклары шактый озын, үзе зур булмаган имезүче хайван, ярыммаймыл. *Бары тик узган җәйдә генә Парижның зоология бакчасында маймыл-лемурны күргәч, мин канәгатьләнеп үзалдыма әйтеп куйдым: «Менә мин, ниһаять, Ленин күзләренең төсен таптым!»* М.Галиев. *Сайгаклар, йомраннар, лемур, болан, кәҗә һәм филләр шулай туфракны яратып ашый.* Кызыклар дөньясында. *Ярыммаймыллар асотряды лемурлар, озынтабанлылар, тупайяларны берләштерә.* Биология. Хайваннар

ЛЕН I *и. нем. тар.* 1) Көнбатыш Европада феодаллык чорында сеньор тарафыннан вассалына хәрби яки башка төрле хезмәт бәрабәренә бирелә һәм нәселдән нәселгә күчә торган җир биләмәсе һәм билгеле керемнәр

2) Шундый биләмәдән алына торган салым, имана

ЛЕН II *и. швед.* Швециядә административ-территориаль бүленеш берәмлеге

ЛЕНД-ЛИЗ *и. инг.* АКШның Икенче бөтендөнья сугышы чорында (1939–1945) Гитлерга каршы сугышучы коалиция илләренә корал, сугыш кирәк-яраклары, стратегик чимал, азык-төлек һәм башка матди ресурсларны бурычка яки арендага бирү системасы. *Безнең полк сугыш елларында ленд-лиз буенча бирелгән Америка самолёты «бостон»нарда оча иде.* М.Юныс

ЛЕНДЛОРД *и. инг.* Англиядә: җирен фирмаларга арендага биреп, үзе эшмәкәрлек белән шөгыльләнмичә, җир рентасы алып торучы эре җир биләүче

ЛЕНИНИА́НА *и. рус* В.И.Ленинга багышланган сәнгать әсәрләре циклы; шундый әсәрләрнең бөтенесе. *Казан лениниананасының чыганагы күренекле Казан рәссамы Николай Иванович Фешинның 1918 елда ижат иткән «В.И.Ленин портреты» булды.* Казан утлары. *Әгәр лениниананы В.И.Ленин тормышы һәм эшчәнлеге турында әдәбият мәгънәсендә аңлыйбыз икән, «Азат» газетасындагы бу корреспонденция татар матбугатында Ленин исеме яңгыраган беренче мәкалә генә түгел, татар лениниананасының беренче карлыгачы да.* Эзләнүләр. Уйланулар. Табышлар

ЛЕНИНИЗМ *и. рус* Марксизмның империализм шартларыннан чыгып конкретлаштырылган һәм үстерелгән дәвамы булып торган тәгълимат. *Мине ленинизм тәгълиматларын яклаган өчен эзәрлеклиләр, әнкәй. Мин беләм, минем арттан күзәтәләр.* Т.Миңнуллин. *Алты сәгатьлек уку вакытында артистлар, режиссёрлар, театрның техник хезмәткәрләре актёрлык сәнгате теориясе һәм практикасы, татар, рус, чит ил әдәбиятлары, сәхнә теле, ленинизм, матди культура тарихы кебек предметларны өйрәнәләр.* М.Арсланов. *Бу материалларны җентекле өйрәнү революциягә кадәр Ленин әсәрләрен, ленинизм тәгълиматын халык арасында тараткан татар халкының дистәләрчә алдынгы вәкилләре исемнәрен ачар иде.* Эзләнүләр. Уйланулар. Табышлар

ЛЕ́НИНЧА *рәв.* 1) В.И.Ленинга охшарга тырышып, В.И.Ленин шикелле. *Милли республикаларда идеология өлкәсендә эшләүче кешеләрне әзерләүгә бөек Ленинча караш булырга тиеш.* Ә.Мәхмүтов. *Партиянең иң өлкән әгъзаларыннан берсе татар генералы Якуб Чанышев Андроповка: – Без партия җитәкчесенең эшне ленинча алып баруыннан бик канәгать... – дип мөрәҗәгать итә.* Р.Батулла. *Без, проблемага Ленинча килеп, изелүче милләтләрнең милләтчелеге белән изүче милләтләрнең агрессив шовинизмын бер-берсеннән аера белергә тиешбез.* М.Госманов

2) Ленинизм принципларына туры китереп. *Эх, бер тотынгач, Германияне тезләндергәч, --- Франция, Испания, Португалияләрдә совет властен урнаштырып, коммунистик демократия юлына борып, Ленинча яшәтә башларга иде* ---.А.Гыйләҗев

ЛЕ́НИНЧЫ *и.* Ленинизм тарафдары; В.И.Ленин эшен дәвам итүче. *Бериләр илне имгәткәндә, Син куянча читкә шылмадың, ленинчылар дарда тирбәлгәнен Ярык аша карап тормадың...* Х.Туфан. *--- әзмени лаеклы кешеләргә характеристика саклана торган оешмалар киң Советлар илендә?! --- «тотнаклы ленинчы», «үрнәк эшләр иясе» һ.б. һ.б.* А.Гыйләҗев. *Кичәге тугры ленинчыны, Политбюро әгъзасы дияләрлек кешене, орденнар алган кешене партия тарихыннан чыгарып ташламаслар, андый мәгънәсезлекнең булганы юк иде әле.* Р.Мирхәйдәров

ЛЕ́НИНЧЫЛ *с.* Ленинизм тәгълиматына нигезләнгән, шуның принципларын, карашларын үткәргән. *Яшьләр безнең идеологиябездә башка бер этап башланганын сизделәр: ленинчыл нормаларның аякка бастырылуы ту-*

рында ул көннәрдә матбугат күп язды. М.Мәһдиев. *Ул сөйләде – ышандылар. – Алга! – диде. Бардылар... Ленинчыл көрәштәшләрен Төнлә килеп алдылар.* Л.Лерон. *Билгеле ки, фәнни тарихилыкның бөтен методологиясе, тарихи фактларга ихтирам белән карауның ленинчыл принциплары ул фактларга игътибарлы булуны һәм аларны объектив анализлауны таләп итә.* Казан утлары

ЛЕ́ННИК *и. рус тар.* Леннан I файдаланучы һәм шуның өчен сеньоры таләп иткәндә сугышка чыгарга, киңәшмәләрдә катнашырга, акчалата ярдәм күрсәтергә тиешле вассал

ЛЕ́НТА *и. голл.* 1) Тасма; бизәү, бизәнү, кием-салымны матурлау һ.б.ш. өчен кулланыла торган тар озын тукыма. *Карлыгач чәч толымындагы кызыл лентаны бер сүтеп, бер бәйләп торган килеш исәпләргә кереште.* Г.Гобәй. *Аның киемнәре иске, ләкин бик пөхтә. Һәр дәрескә муенына кара лентадан ясалган күбәләк куеп керә.* М.Мәһдиев

2) Бәйрәм, траур, сәяси, революцион, дини карашлар, берәр оешмага мөнәсәбәт һ.б.ш. билгесе итеп баш киемендә, түштә, беләктә йөртелә торган төсле тукыма кисәге. *Военторгта орден, медаль колодкалары өчен лента-лар сатыла.* М.Мәһдиев. *Нәрсәгә ирештем? Булдырдыммы? (Булдыралмау белән тотылдым!) Булдырганнар «көрәшче» күкрәген Орден лентасына тутырды...* А.Хәлим

3) Төрле материаллардан ясала һәм төрле максатларда кулланыла торган тар полоса, буй. *Маннурның --- кичәдә сөйләгән кереш сүзен Казаннан, радиодан килгән корреспондент хәтта магнитофон лентасына язып алды.* М.Хәсәнов. *Мондый конденсаторларны, гадәттә, станиоль һәм парафинланган кәгазь лентaларны тыгыз итеп спираль рәвешендә чорнап ясыйлар.* Физика курсы

4) Киноплёнка, кино тасмасы; шул тасмага төшерелгән фильм. *Кино лентасыннан тәмле ис килә, соңгы рәтләрдә аппарат янында гына мул итеп вазелин яккан, бит урталарын кызарткан кызлар утыра.* М.Мәһдиев

5) Кайбер транспорт җайланмаларының ташыгыч, күчергеч ролен үтәгән, әйләнеп тора торган тасмадан гыйбарәт төп өлеше

6) Пулемёт патроннары тезелгән, беркетелгән тасма. *Пулемёт лентасы таккан... берсе сорады: «Ә безнекеләр нишләп бирешеләр соң?»* Ш.Усманов. *Без пулемёт лентасына патроннар итеп тыгылган.* Ә.Гаффар. *Күмүчеләр таралып бетәр-бетмәстән, Якуб Бураевич киңәше белән, пулемёттагы ярты лентаны һавага атып бетергәннәр иде.* Ш.Шәйдуллин

7) Өзлексез бер буй рәвешендә куелган, тезелгән, өелгән нәрсәләр, тезем. *Тезелеп очкан кыр казларыдай, комбайннар бара – аларның артыннан, тасма булып, салам лентасы кала.* М.Мәһдиев

ЛЕ́НТАЛЫ *с.* 1) Лентасы булган, лента таккан. *Барсам, муенына да пычранып беткән ленталы бер медаль таккан бер мулла утырган.* Г.Тукай. *--- көймәдәге бер кеше ишкәк ишә, күк ленталы бер кызчык койрык тота, яшь кенә хатын-кыз гитара уйный...* Г.Гобәй

2) Лентадан гыйбарәт булган, лента формасындагы. *Учреждение җитәкчесе Сергей Сапурин сүзләренә караганда, элеккеге техника паркы урынында ленталы агач яру цехы ачарга җыеналар.* Н.Михайлов

ЛЕОПАРД *и. лат.* Мәчеләр семьялыгыннан сары яки җирән тиресендә кара таплары булган, куе йонлы эре ерткыч хайван; барс. *Равил Фәйзуллин да егетлек ягыннан Хемингуэйдан ким куймас иде. Йодрык сугышлары оештырыр, үз баркасы белән океанга акула ауларга чыгар, Килиманджарода үзе аткан леопард тиресен стенага элэр ---.* М.Галиев. *– Тәнең тимгелле, леопард нәселеннәнме әллә син? – дип сорады [Тәбрия].* М.Маликова. *Гиена һәм леопард якын килеп кенә карасын, этләр өере аларны хәзер өзгәләп ташлый.* Кызыклар дөньясында

ЛЕПЕЛДӘ́Ү *ф.* 1) *к.* **лепердәү**. *Куркудан йөрәк лепелдәп тибә башлады*

2) *к.* **лепер-лепер итү**

Лепелдәп кую Бер мәртәбә лепелдәү

Лепелдәп тору Бертуктаусыз лепелдәү

Лепелди башлау Лепелдәргә тотыну

ЛЕПЕРДӘ́ТҮ *ф.* Юка, җиңел, кечкенә нәрсәләрне җиңелчә тирбәтү, селкетү, чайкалдыру, вак дулкын җибәрү. *Тимерханның күз алдында ачык тәрәзәнең ак пәрдәләрен лепердәтеп җиләс җил йөри...* Г.Ахунов. *--- талгын гына искән җилнең үләннәрне, тегермән чокырындагы кычыткан, әрем башларын таравын, тупыл яфракларын лепердәткәнен карыйм.* Ә.Гаффар

Лепердәтә башлау Лепердәтергә керешү

Лепердәтә бирү Лепердәтүен дәвам итү

Лепердәтеп алу Бераз гына, берара лепердәтү

Лепердәтеп кую Бер тапкыр лепердәтү. *Кара күбәләк канаты кебек куе кара керфекләрен лепердәтеп куйды.* Г.Сабитов

Лепердәтеп тору Берөзлексез лепердәтү

ЛЕПЕРДӘ́Ү *ф.* 1) Җилдән һ.б.ш.дан җиңелчә кыштырдаган, лепер-лепер иткән тавыш чыгару. *Баш өстенә тарттырылган полиэтилен түбә җәйге урман җиленә лепердәп дулкынлана иде.* М.Мәһдиев. *Тып-тын булып калды. Бакчада яфраклар гына леперди иде.* Р.Төхфәтуллин. *Агачлар талпынып арганнар, Яфраклар лепердәп талганнар. Черем ит, бигрәк тә җайлы: тын.* Ш.Галиев

2) Бик җиңел, матур хәрәкәтләр ясау, очыну. *Авыл яшьләре маржа Наталья апаның күбәләкләр кебек лепердәвен, идәндә ефәк оеклы төз аяклары белән нәкыш чигеп йөзүен авызларын ачып, дөньяларын онытып карап торалар.* Г.Ахунов. *Күбәләкнең тыйнак лепердәвен, Юкәләрнең өнсез дәшүен --- Җырларыма гына теркәрмен.* Р.Низамиев

3) Хәлсез тибү (йөрәк тур.). *Кичә иртән үк, чәй эчкәч, йөрәк бик леперди әле, дип әйткән иде – кичкә таба алмашынып ук китте.* М.Мәһдиев. *Күңеле сизә, нәрсәдер булган. Йөрәге күбәләк урынына леперди, куркыныч.* З.Кадыйрова

Лепердәп алу Бераз лепердәү һәм туктау, кыска вакытлы лепердәү

Лепердәп кую Кинәт лепердәп алу. *Төнге дала җиленә чатыр ефәге лепердәп куя, түр якта утка май салучы кол йокымсырап утыра.* М.Хәбибуллин. *Мирхасның озын керфекләре аптырауданеш-еш лепердәп куйды, шаяра дип белеп, Хәбировка төбәлде*. Х.Камалов

Лепердәп тору Бертуктаусыз лепер-лепер итү. --- *[Альфред] менә сүнәм дип лепердәп торган өмет утын күкрәгенә кысып тоткан хәлдә, таныш ишек каршына килеп басты.* Ф.Садриев

Лепердәп утыру *к.* **лепердәп тору**. *Лепердәп утырган ике катлы тегермән йортына киләсең, арбаңны агач күперданеңгердәтеп тартып өскә алып менәсең.* М.Мәһдиев. *Җилсез вакытта да салмак кына лепердәп утырган усак яфраклары астында йокыга китүе рәхәт.* М.Галиев

ЛЕПЕРДӘШҮ *ф.* Бердән бик күп вак нәрсәләр лепер-лепер килеп селкенү, җилфердәү. *Сукмак кырыйларындагы өрәңгеләрнең яфраклары --- катыланганнар, салкынча җил килеп бәрелгәндә, йомшак кына лепердәшмиләр, калайдан ясалгандай каты бәрелешеп кыштырдыйлар.* М.Маликова. *Җавап булмады. --- Тагын яфраклар гына лепердәшеп җавап бирде.* Р.Төхфәтуллин. *Сигулданың кызыл усаклары лепердәшеп яна җилләрдә!* Р.Әхмәтҗан

Лепердәшә башлау Лепердәшергә тотыну

Лепердәшеп алу Бераз гына, бераралепердәшү. *Куактагы яфраклар җил кузгалткан сыман лепердәшеп алды.* Н.Гыйматдинова

Лепердәшеп кую Бер мәртәбә лепердәп алу. *Шунда, көтмәгәндә, моңарчы тавышсыз-тынсыз торган юкә яфраклары лепердәшеп куйды.* Р.Мөхәммәдиев

Лепердәшеп тору Берөзлексез лепер-лепер итү

ЛЕПЕ́Р-ЛЕПЕР *иярт.* 1) Җиңелчә чайкалган, тирбәлгән вакытта яфраклар чыгарган кыштырдау, лепердәү тавышын һәм рәвешен белдерә. *Куркыттым, ахры, күбәләк лепер-лепер күтәрелде дә читкәрәк очып китте.* М.Галиев. *Яшеллеген җуярга өлгермәгән яфраклар, күреп-сокланып калыгыз дигәндәй, үткән-сүткәнгә лепер-лепер эндәшеп куя.* А.Әхмәтгалиева

2) Бик җиңел, матур хәрәкәтләр ясау, очыну рәвешен белдерә. *Күбә-ләк... Тотып алам диеп сузылган иде дә, күбәләк, аны сулышыннан ук тоеп, лепер-лепер очып та китте.* Н.Каштанов

3) Дулкынлану, курку, куанудан һ.б.ш. йөрәкнең тибешендә җиңелчә калтырау, тизләнү рәвешен белдерә. *Ул [Момаһар] үзендә кипкән усак яфрагыдай җиңеллек тойды. Лепер-лепер, ул инде – залда. Лепер-лепер.* А.Хәлим

ЛЕПЕ́Р-ЛЕПЕР ИТҮ *ф.* Лепердәгән тавыш чыгарып тирбәлү, селкенү, әйләнү һ.б.ш. *Лепер-лепер итеп, керләрнең Җилдә җилфердәвен яратам*. Д.Сирай

ЛЕПЕ́Р-ЛЕПЕР КИЛҮ *ф. к.* **лепер-лепер итү**. *Ә бит бер тапкыр гына карап алды, ә йөрәк лепер-лепер килә башлады.* М.Хәбибуллин. *Күктә якты кояш балкый, лепер-лепер килеп яфраклар серләшә, ботактан ботакка куныпсоры түшле асыл кошлар куаныша.* М.Әмирханов

ЛЕПКӘ *и.* 1) Кечкенә сабый баланың, баш түбәсе сөяге тоташып җитмәгәнлектән, кан тибеше тышка беленеп торган урын. *Лепкә – иң җиңел зарарланучан урын үзе. Ә шушылай булуы кирәк икән.* Ш.Галиев

2) Баш сөяге томаланганнан соң да шул урын, баш түбәсе өлеше. *Дошман минасы лепкәңә төшеп шартламаса, селкенеп өстеңнән туфракны кагасың да бетте-китте.* Ш.Рәкыйпов

ЛЕ́П-ЛЕП *иярт.* 1) Дулкынланудан, куркудан һ.б.ш.дан йөрәк кагу яки кан тамыры тибү рәвешен белдерә. *Баягы утлар җемелдәшкән урынга җитүгә, минем йөрәк леп-леп тибә башлады*. Р.Хафизова. *Юк, аяк тавышлары гына түгел, кызның леп-леп типкән йөрәк тавышы да еракларгаук ишетелми микән?* Р.Төхфәтуллин. *Кар эри башлагач, көзге яңгырларда синең аяк-кулларың йөрмәс була, тыныңбетә, йөрәгең леп-леп тибә башлый иде.* М.Юныс

2) Күбәләкнең канат кагу, еш-еш күзне ачып-йому рәвешен һ.б.ш. белдерә. *Олы малайның күзе шар булды, керфекләре леп-леп бәргәләнде...* А.Гыйләҗев. *[Шәйдулла коданың] Тиктомалга леп-леп күзләре йомылып китә дә башы белән һаваны сөзеп ала.* В.Юныс

ЛЕ́П-ЛЕП ИТҮ *ф.* Лепелдәү, леплеп бәргәләнү, кагу, тибү. *Леп-леп кенә итә яшь йөрәгем, Тынычсызлык чолгый күңелемне.* Җыр

ЛЕ́П-ЛЕП КИЛҮ *ф. к.* **леп-леп итү**. *Йөрәк леп-леп килә, үземнең кызарып-кызарып куюымны сизәм, аякларымны болайрак бассам да, кулларымны тегеләйрәк куйсам да бик килешсез кебек...* Р.Төхфәтуллин

ЛЕ́ПРА *и. лат. мед.* Лепра таякчыклары китереп чыгара торган, тире, периферик нерв системасы, күз һәм кайбер эчке әгъзаларның зарарлануы белән характерлана торган хроник йогышлы авыру; маһау авыруы

ЛЕПРОЗО́РИЙ *и.* Маһау авыруын дәвалау өчен махсус учреждение

ЛЕРКЕЛДӘ́Ү *ф.* Җиңелчә генә чырк итеп ярылу, уалу

Леркелдәп тору Уалырга, изелергә генә тору, чырк итүчән, изелүчән булу. *Аңкауларга, теш казналарына сылашып, уылдыкның йомшак, леркелдәп торган сәйләннәре изелә һәм шундук көч керткәндәй тоела.* А.Хәлим

ЛЕ́РТ-ЛЕРТ *иярт.* Вак кына адымнар белән кызу-кызу атлап яки юыртып бару рәвешен белдерә. *Туры ат лертлерт юырта*. М.Әмир

ЛЕСНИК *и. рус сөйл.* Урманчы, урман каравылчысы, урман хуҗалыгында эшләүче кече хезмәткәр. *Лесник белән килешсәк, әллә ни арада әзерләп печәнле була идек.* А.Гыйләҗев. *Урманчы мин, штатта гап-гади лесник булып саналам*. М.Маликова. *Нишлисең, башка эшкә ярамагач: синнән лесник чыкмый, урманда тиз адашасың, машина төзәтә белмисең, балта эшенә кулың ятып тормый, пич чыгара белмисең. Яз, әйдә, яз* ---. Т.Галиуллин

ЛЕСНИ́ЧЕСТВО *и. рус* Аерым урман участогы белән идарә итә торган учреждение һәм гомумән шул урман участогыннан гыйбарәт хуҗалык; урманчылык. *Лесничествоның үзендә зират юк, православныйларны гадәт буенча күрше рус авылына илтеп күмәсе икән.* М.Мәһдиев. – *Районда дүрт лес-*

ничество, әйдәгез уйлашыйк, кем нәрсә тәкъдим итә? – Шулай дип башлады сүзен директор. Г.Якупова. *Себердә гади урман каравылчысы семьясында туып үскән Аркадий һәм лесничество десятнигы малае Фёдор – икесе дә, мәктәпкә кергәнче үк, урман әлифбасын үзләштергән, табигатьнең урман дигән могҗизасына гашыйк кешеләр булып чыктылар*. Т.Мөбарәков

ЛЕСНИ́ЧИЙ *и. рус* Лесничество мөдире, урман хуҗалыгының җитәкчесе. *Казан тирәсе урманчылыгының лесничие А.Грязнов дигән бер кеше белән очраклы рәвештә танышкан идем алтмышынчы елларда.* М.Мәһдиев. *Үзе, иске танышы лесничий Осипов янына гозер белән барып, урман хуҗалыгына эшкә урнашты: ишле семьяны түйдырып торырга кирәк бит.* Т.Мөбарәков. *Кабинет хезмәткәре буласы килмәде Аюханның, Асанайга лесничий булып кайтты.* Г.Якупова

ЛЕСОВОЗ *и. рус* Агач һәм агач материаллары ташу өчен махсус йөк машинасы яки судно

ЛЕСПРОМХОЗ *и. рус* Урман кисү, агач ташу, аны читкә озату эшләре белән шөгыльләнә торган предприятие, урман җитештерү хуҗалыгы. *Газинур леспромхоздагы хәлләр турында, үзе күреп белгән кеше кебек кызып, дәртләнеп сөйли иде.* Г.Әпсәләмов. *– Урманга барыш әле. Йөрүзән леспромхозына, – диде абый.* Х.Сарьян. *Сугыштан соң монда леспромхоз эшләде, леспромхоз исә ике җирдә кибет, мәктәп, буфет тотты.* М.Мәһдиев

ЛЕСХОЗ *и. рус* Урман үстерү һәм агач әзерләү белән шөгыльләнә торган урман хуҗалыгы. *Колхозны җитәкләвенә ел тулар-тулмаста, юаш кына холыклы Миңлекамал айгыр җигеп лесхозга барырга чыккан.* А.Гыйләҗев. *Кайсы сыерын сата, кайсы күченеп район үзәгенә, лесхозга, шәһәргә, тимер юл станциясенә китә.* М.Мәһдиев. *Кичәге төнне дә шулар аркасында Мари лесхозында уздырырга туры килде әнә...* М.Маликова

ЛЕТАЛЬ *с. лат. мед.* Үлемгә китерә торган, үлемгә китергән. *--- тәҗрибәләр нәтиҗәсендә, даруның уртача үлем (леталь) дозасы һәм уртача дәвалау (эффектлы) дозасы билгеләнә (Disc һәм Deso).* Химик матдәләрнең агулылыгы

ЛЕТАЛЬЛЕК *с. мед.* Билгеле вакыт эчендә бер авыру белән авыручылар санына шул авырудан үлүчеләр санының нисбәтеннән гыйбарәт статистик күрсәткеч. *Летальлек бер яктан авыруның ни дәрәҗәдә куркыныч булуын күрсәтсә, икенче яктан шул авыру белән көрәшүче дәвалау-профилактика учреждениеләре эшенең эффективлыгын күрсәтә*

ЛЕТА́РГИК *с.* Асылы летаргия булган, летаргия белән бәйле. *Әйтерсең лә күптән мәрткә киткән, Летаргик төш күргән монархист Уянган да, погромчылар кебек, Тел тибрәтә: татар-матар... – дип.* Х.Туфан. *--- әй син, тарихка бөек исеме белән кергән татар халкы, летаргик йокыдан уян, заманның уңай якка үзгәрүеннән файдаланып кал ---.* М.Әхмәтҗанов. *Медиклар летаргик йокыны организмның үзенә күрә бер саклану чарасы дип карыйлар.* Могҗизалар энциклопедиясе

ЛЕТАРГИ́Я *и. гр.* 1) Тирән йокыга охшаган, берничә сәгатьтән берничә көнгә кадәр дәвам итә торган, авыр очракларда сулыш алу һәм пульс сизелмәслек дәрәҗәдә булган үзенчәлекле авыру халәт; мәрт. *Табиблар, күпме генә тырышмасыннар, аны бу торгынлыктан (летаргия халәтеннән) йолу чарасын тапмыйлар ---.* А.Тимергалин. *Летаргия һәр очракта да кешенең баш миендәге нерв күзәнәкләре чиктән тыш хәлсезләнгәндә генә барлыкка килә. --- Летаргиянең икенче сәбәбе – минең органик авырулары.* Могҗизалар энциклопедиясе

2) *күч.* Хәрәкәтсезлек, эшлексезлек, сүлпәнлек; мәрт. *Йокламыйча, сакта тора Хыял, Гүя уяулыкка дәшә күңелләрне, Нәфрәт-мәхәббәтне, илләрне, – Летаргия басар кебек Җирне!* Р.Гаташ

ЛЕ́ТКА-ЕНКА *и. фин.* XX гасырның алтмышынчы елларында бик популяр булган, чылбырга тезелеп биелә торган шаян күмәк бию

ЛЕТҮН *и. рус* Бер эш урыныннан икенчесенә күчеп, бер җирдә дә озак эшләмичә, акча артыннан куып йөрүче кеше; очкалак. *Әллә эшче исемен буяучы летун, прогулчы, хатынын кешегә санамаучы бер типмы?* Х.Туфан. *Шунда ук зур хәрефләр белән язып куелган: «Аракы – летуннар, рвачлар дусты...»* М.Мәһдиев. *Авылда рәтләп яшәмичә озак-озак югалып торган кешене каян беләсең. Летун Җамай дип йөртәләр иде аның ирен.* Л.Ихсанова

ЛЕТҮЧКА *и. рус* 1) Эш барышында барлыкка килгән ашыгыч, кичектергесез мәсьәләләрне хәл итү өчен үткәрелә торган кыска гына киңәшмә. *«Казан утлары» редакциясендә летучка бара. Кемнең нәрсәләр эшләгәне турында сөйләшәләр.* Ш.Маннапов. *--- көнаралаш булып торган төрле җыелышларда, киңәшмәләрдә, кирәкле-кирәксез летучкаларда катнашып башы тәмам миңгерәп эштән өенә кайткач, үз өстендә эшләргә, иҗат белән шөгыльләнергә теләге калмый.* Г.Тавлин. *Икенче көнне, дүшәмбе иртәсендә, Татарстан радиосында чираттагы летучка, ягъни атналык эшкә йомгак ясау бара иде.* Ж.Дәрзаман

2) Ашыгыч ярдәм күрсәтү, вак-төяк ремонт һ.б.ш. эшләр башкару өчен махсус бригада яки шул бригаданың махсус җиһазландырылган машинасы. *Самолётлар бик түбән очалар һәм летучка өстенә берничә бомба ташлап китәләр. Летучка каплана.* М.Ибраһимов

3) *иск.* Спектакль, концерт һ.б.ш. турында белдерү басылган листовка, кечкенә афиша. *--- Афиша вә летучкаларда игълан итмәк мөмкин булмаганга, спектакльгә килсәк, халык... бик аз диярлек дәрәҗәдә генә иде.* Г.Тукай

ЛЕЦИТИН *и. гр.* Аксым продукты; бөтен күзәнәкләрдә очрый торган органик матдә, азыкта диспергатор һәм антиоксидант буларак кулланыла, эмульгатор. *Тавык йомыркасындагы лецитин һәм фосфолипид матдәләренең мидәге күпсанлы күзәнәкләр мембранасы өчен әһәмияте зур*. Ватаным Татарстан. *Солы кесәле алыштыргысыз аминокислоталарга (триптофан, лизин, холин, лецитин, метионин) бай.* Мәдәни җомга

ЛЁСС *и. нем. махс.* Уңдырышлы туфрак барлыкка китерә торган, сары төстәге, күзәнәкле, көпшәк, тузансыман вак бөртекле, балчык, карбонатлар һәм башка катнашмалардан торган тау токымы. *Лёсс – туфрак барлыкка китерә торган сары төстәге көпшәк тау токымы.* Х.Туфан

ЛЁТКА *и. рус махс.* Домна мичләрендә металл яки шлакны чыгару өчен махсус тишек

ЛЁТЧИК *и. рус* Очучы, пилот, очкыч аппарат белән идарә итүче. *Ә лётчик... әз генә дә каушамыйча, ләкин бик тә җитди кыяфәткә кереп, рульне әле уңга, әле сулга борды һәм бертуктаусыз тирә-якны күзәтте.* Г.Гобәй. *– Әни, мин мәктәптә укымыйм, мин зур үскәч лётчик булам, – дип ычкындырып ташлады.* Ф.Хөсни. *Менә хәзер лётчик Марат абый үзенең ярапланы белән, теге вакыттагы кебек, безнең Үзәнле өстенә килеп чыкты, ди.* Н.Хәсәнов

ЛЁТЧИКЛЫК *и.* Очучы эше, очучы осталыгы

ЛИ *и. кыт.* 1) Ерак Көнчыгышның төрле илләрендә төрле зурлыкны белдергән озынлык үлчәү берәмлеге. *Аннан да элегрәк, ишетүемчә, аның чикләренең озынлыгы мең лидән артык булмаган.* Н.Фәттах

2) Кытайда якынча 6 м^2, Вьетнамда 0,04 м^2 га тигез булган мәйдан үлчәү берәмлеге

3) 30–40 мг чамасы авырлык берәмлеге

ЛИА́НА *и. фр. бот.* Чагыштырмача нәзек сабаклы үсемлекләрнең башка үсемлекләргә яки биек терәккә мыекчалар, өстәмә тамырлар һ.б.ш.лар ярдәмендә ябышып, үрмәләп тереклек итү формасы; шундый үсемлекләр. *Амозонканың калын урманнарында «яхе» дигән бер төр лиана үсә.* М.Мәһдиев. *Тропик киңлекләрдә лиана булып үсә торган ванильнең кайбер төрләре биргән җимештә дә хуш исле эфир майлары бар...* Мәдәни җомга. *Орлыклы абагалар агач, лианалар һәм үлән үсемлекләр рәвешендә булганнар.* Биология

ЛИБЕРАЛ *и. лат.* 1) Либерализм тарафдары. *Әмма федерация субъектларының хокукларын тигезләүне шул либераллар таләп итә бит инде.* Татар милли календаре

2) Либераллар партиясе әгъзасы. *Ишаннан өмет өзгәч, Урманов либералларга сугылырга уйлап карады.* Г.Ибраһимов. *Әгәр дә либераллар (кадетлар) сәяси власть, сәяси имтиязларны Пуришкевичлар белән бүләргә омтылсалар, ә менә народникларның демократлыгы шунда ки, алар хәзерге вакытта җирбиләүчелектәге бөтен имтиязларны һәм сәясәттәге бөтен имтиязларны бетерергә омтылалар һәм омтылырга тиешләр.* Г.Нигъмәти

3) Хөр фикерле кеше, киң карашлы кеше. *[Әхмәт:] Дөрес, мин либерал: яңаның яхшысын кабул итәм, булмаса – юк.* Г.Камал

4) *күч.* Артык килешүчән, юл куючан кеше. *Артык либерал булырга ярамый*

ЛИБЕРАЛ-ДЕМОКРАТ *и. рус* Либераль-демократик партия әгъзасы. *Россия Президентының кичәге юлламасында, партия җитәкчеләре даими рәвештә алмашынып торырга тиеш, дип искәртүенә каршы либерал-демократлар лидеры бу урыннан китәсен белдерде.* Ватаным Татарстан. *Шәймиев, андый фикерләү либерал-демократлар кебек оппозициядә генә түгел, ә хакимияттәге «Бердәм Русия» депутатларының бер өлешендә дә бар, дип белдерде.* Безнең гәҗит

ЛИБЕРАЛИЗМ *и. лат.* 1) Шәхеснең индивидуаль хокуклары һәм иректенең кагылгысызлыгын яклаган фәлсәфи һәм иҗтимагый-сәяси юнәлеш. *Социализм һәм либерализм юнәлешендәге яшьлек хыялларыңны хәзергә башыңнан чыгарып ташла.* М.Галәү

2) Хөр фикерлелек, киң карашлы булу

3) *күч.* Артык килешүчәнлек, юл куючанлык. *[Сәфәров:] Теләсәгез нәрсә әйтегез, интәшләр, мин моңа либерализм дип карыйм.* Ш.Камал

ЛИБЕРАЛЛАНУ *ф.* 1) *сөйл.* Либералга әйләнү, либералга охшау

2) *сөйл.* Ярамаган эшләргә юл кую, килешүчәнлек күрсәтү; либерал булып күренергә тырышу

Либераллана башлау Либераллык билгеләре сизелү

Либералланып китү Элеккегә караганда либеральрәккә әйләнү

ЛИБЕРАЛЛА́РЧА *рәв.* Либералларга охшатып, либералларга хас рәвештә. *Буржуа либералларча яхшы киенеп, галстук, манжетлар белән ялтырап сәхнәгә күтәрелгән таза гәүдәле бу интәшне күргәч, --- [Солтан] алга таба кысылды.* Г.Ибраһимов

ЛИБЕРАЛЛАШУ *ф.* Либерал булып китү, либералга әйләнү (кеше тур.)

Либераллаша башлау Либераллыкка йөз тоту

Либераллаша бару Тора-бара, торган саен күбрәк либералга әйләнү

Либераллашып китү Бик артык, кирәгеннән дә артык либераллашу

Либераллашып җитү Тәмам либералга әйләнү

ЛИБЕРАЛЛЫК *и.* 1) *к.* **либерализм** (*1 мәгъ.*). *Чехов бервакытта да революционер була алмады, ләкин ул заманның либераллык карашларын (иң яхшы мәгънәсендә алып) үткәрде.* Г.Нигъмәти

2) Юл куючанлык, килешүчәнлек, либерализм. *[Сәфәров:] Ләкин сизгер мөгамәлә күрсәтәм дип, либераллык дәрәҗәсенә үк барып җитәргә ярамый.* Ш.Камал

ЛИБЕРАЛЬ *с.* 1) Либерализм (*1 мәгъ.*) яклы булган, либерализмга нигезләнгән. *Дөрес, Зариф хәзрәтнең иҗтимагый-сәяси иманы моннан күп алга китми, 1905 елгы революциядән соң без аны либераль карашлы мулла итеп күрәбез.* И.Нуруллин. *ТР Дәүләт Советы Рәисе Фәрит Мөхәммәтшин, үз чиратында, республика тарафыннан эшләнгән закон проектының федераль законга караганда либеральрәк икәнлеген белдерде.* Татар заманы. *Либераль идея ул бит гражданнарның хөрлегенә корылган.* Татар милләт календаре

2) Килешүчән, юл куючан

ЛИБЕРАЛЬ-ДЕМОКРА́ТИК *с.* Либерализм һәм демократия принципларына нигезләнгән; шундый карашларда торган. *«Казан мөхбире»нең либераль-демократик басма булуын дәлилләү өчен, аның либеральлек һәм*

демократик сыйфатларын күздән кичерик. Фән һәм тел. *Либераль-демократик партия рәисе Влад Филат сүзләренә караганда, сайлауда берничә ел элек үлгән кешеләр дә «катнашкан», балигъ булмаганнар, күп еллар буе чит илләрдә яшәүчеләр дә «тавыш биргән».* Ватаным Татарстан

ЛИБЕРАЛЬ-КОНСЕРВАТИВ *с.* Консерватизм һәм либерализм принципларына нигезләнгән; шундый карашларда торган. *Хәзер ул либераль-консерватив сәясәт үзәген җитәкли һәм бу өлкәдә бары бер генә яңалык булуын әйтә ---.* Безнең гәҗит

ЛИБЕРАЛЬЛӘШТЕРҮ *ф.* 1) Чикләрне, таләпләрне, кагыйдәләрне һ.б.ш. йомшарту. *С.И.Ожегов «Рус теленең аңлатмалы сүзлеге»ндә либераль-ләштерү дигән сүзнең мәгънәсен «чикләүне бетерү, ирек бирү» дип аңлаткан.* Мәгърифәт. *Министр урынбасары билгеләп үткәнчә, форумда каралган төп темалар сәүдәне һәм инвестицияләрне либераль-ләштерү, азык-төлек куркынычсызлыгы, транспорт системасын үстерү, инновацияләргә ярдәм күрсәтү булды.* Сарман

2) Теләсә нәрсәгә юл кую, артык ирек бирү

Либераль-ләштерә бару Тора-бара, торган саен ныграк либераль-ләштерү

Либераль-ләштерә башлау Либераль-ләштерергә керешү

Либераль-ләштерә төшү Бераз либераль-ләштерү; тагын да ныграк либераль-ләштерү

ЛИБЕРАЛЬЛӘШЕ *ф.* 1) Либераль булып китү, карашлар, сәясәт һ.б.ш. йомшару, кырыслыгы кимү. *Моннан тыш сәяси системаның либераль-ләшүе шартларында оппозиция активлашачак.* Ватаным Татарстан

2) Артык йомшару, таләпчәнлек кимү (карашлар, кагыйдәләр һ.б.ш. тур.). *Бу киңәшләр элеккеге оппозицион идеалларны калдыру, либераль-ләшү, яраклашучылыкка күчү сыман күренә.* Татар әдәбияты тарихы

Либераль-ләшә бару Тора-бара, торган саен ныграк либераль-ләшү

Либераль-ләшә башлау Либераль-леккә йөз тоту

Либераль-ләшә төшү Бераз либераль-ләшү; тагын да ныграк либераль-ләшү

Либераль-ләшеп китү Бик артык, кирәгеннән дә артык либераль-ләшү

Либераль-ләшеп җитү Тәмам либераль-ләшү

ЛИБЕРАЛЬЛЕК *и.* 1) Иркенлек, йомшаклык (сәясәт, кагыйдәләр һ.б.ш. тур.). *Аз гына соңгарак калып, мондый либераль-лек элеккеге совет киңлекләрендә яшәп яткан безләргә дә килеп җитте.* Мәгърифәт

2) Юл куючанлык, артык йомшаклык. *Сыйнфый дошманнарга карата либераль-лек күрсәтә.* М.Җәлил

ЛИБРЕТТИСТ *и. рус* Либретто язучы, либретто авторы. *Бу эш махсус программа белән, либреттистлар өчен кыска сроклы курс-семинар үткәрү, музыка белгечләренең системалы лекцияләрен оештыру төсендә була.* М.Җәлил. *Татарча либретто үрнәкләре булмау, тәҗрибәле либреттистлар булмау, студиягә тартылган язучыларның музыка белән аз танышлыгы – либретто тудыруда зур авырлыклар ясады.* М.Максуд

ЛИБРЕ́ТТО *и. ит.* 1) Опера, оперетта, оратория кебек зур музыкаль әсәрнең әдәби нигезе, сүз белән бирелгән тексты. *Либретто шигырь я ак шигырь, я проза белән, я шулардан катнаш формада язылу мөмкин.* Ф.Бурнаш. *Либреттоны мин ташлап торган идем, әгәр үтә алса, мин аны бөтен көчемне куеп эшләр идем.* Ш.Маннур. *Күрәсең, затлы музыка һәм Әхмәт Фәйзи иҗат иткән мавыктыргыч либретто үз эшен нәтиҗәле башкарган.* Э.Моратова

2) *сөйл.* Операның, пьесаның программада язылган кыскача эчтәлеге

3) Балет яки кинофильмның сюжет планы, сценарий схемасы

ЛИБРЕ́ТТОЧЫ *и. к.* **либреттист**. *Әдәбиятчыдан тиешле рецензияләр алынып, [либретто] студия дирекциясе каршында либретточылар һәм композиторлар киңәшмәсендә тикшерелгән иде.* М.Җәлил. *Опера, оратория, кантата, музыкаль драма я комедия либретточылары да, кызганычка каршы, «Беренче карлыгач»та күренми.* Р.Харисов. *Тиздән үзебезнең опера-балет театрыбыз була, анда җырларлык җырчылар, дирижёр, либретточ-ы, режиссёр булырлык мәгълүмат алып кайтыйк дип, күтәренке рух белән укырга керештек.* Казан утлары

ЛИВА *и. гар. иск.* Әләм, байрак, флаг. *Ф.Әмирханның «Тигезсезләр»е хәзергә кадәр тик князь ливасын тагып тәгассыб бишегендә тирбәлеп килгән татар халкы эчендә яңа тормыш почмаклары төзергә кирәклеген кычкырды.* Ф.Бурнаш. *Тотып милләт ливасын, юлга чыктык: «Бу куллар мәңге, дип, җиргә салынмас».* Г.Тукай

ЛИВАНЛЫ *и.* Ливанда яшәүче төп халык һәм шул халыкның бер кешесе. *«Хизбалла» исә шушы солдатларны Израиль территориясендә тоткынлыкта ятучы ливанлыларга алыштырмакчы булган.* Татарстан яшьләре

ЛИВАТА *и. гар.* Ир-ат арасындагы гомосексуализм, педерастия

ЛИВАТА́ КЫЛУ *ф.* Ике ир кеше җенси мөнәсәбәткә керү

ЛИ́ВЕР *и. ингл.* Суелган хайваннарның үпкә, йөрәк, бавыр кебек ашарга яраклы эчке органнары. *Хәлебез бик яхшы булганда да, 40 тиенлек ливер колбасасыннан уза алмадык без.* С.Шәймиева. *Эчлеген дә төрледән-төрле ясыйлар: бәрәңге, уылган кишер, ливер, джем һәм башкалар.* Сөембикә

ЛИВР *и. фр.* 1) Франциядә 1795 елга кадәр гамәлдә йөргән, 20 су яки 240 деньега тигез булган акча берәмлеге

2) Франциядә 0,5 кг чамасындагы борынгы авырлык үлчәү берәмлеге

ЛИВРЕ́Я *и. фр.* Швейцарлар, лакейлар, кучерлар кия торган укалы махсус форма киеме. *Бая губерна канцеляриясенә килеп кергәч тә, Әкрәм карый күзенә губернатор булып күренгән яшел ливреяле швейцар иде бу.* М.Галәү. *Лакей ливреялары кигән хезмәтчеләр, тантаналы музыка яңгырап торганда, алтын төпсәләргә куелган шәраб кадәхләрен алып чыгалар.* Р.Батулла. *Ул тагын бер стакан шәраб эчте дә, ачыктым диюенә карамастан, ризык китерүче ливреялы лакейны терсәге белән этәрде.* А.Толстой

ЛИ́ГА I *и. лат.* 1) Аерым кешеләрнең, дәүләт, оешмаларның иҗтимагый-сәяси берләшмәсе. *Садри Максудиның оныгы Гөнүл Пултар Гали Акыштан соң Татар Лигасын җитәкли.* Татар заманы. *Анда безне «Татар лигасы»ның җитәкчесе Рамил Агдеев күреп алды һәм Казанга чакырды.* Якты юл

2) *спорт* Спорт командаларын берәр билге (ил, аерым территория, осталык һ.б.ш.) буенча берләштергән бүленеш. *«Ак Барс» командасы «Континенталь хоккей лигасының беренче чемпионы» исемен яулады.* Мәгърифәт. *Димәк, чемпионнар лигасында меңьеллык шәһәребезне танытасы мизгелләр алда әле.* Татарстан яшьләре. *Ниһаять, республикабызның иң яхшы хоккей командасы янә югары лигада чыгыш ясый!* Идел

ЛИ́ГА II *и. ит. муз.* Ноталар өстенә дуга рәвешендә куелып, тоташ уйнарга тиешлекне күрсәтә торган билге

ЛИ́ГА III *и. инг.* Англия һәм Америкада 4828,032 метрга тигез ераклык үлчәү берәмлеге

ЛИГАТУ́РА *и. лат.* 1) Берничә хәрефне кушып ясалган язма билге (мәс., поляк телендә *sz*, *cz*, немец телендә *sch* бер авазны белдерә)

2) *мед.* Хирургиядә кан тамырларын бәйләү өчен кулланылган җеп

3) *муз.* Берничә нотаның берьюлы уйналуын белдергән билге

4) Металлның үзенчәлеген үзгәртү өчен кушыла торган ярдәмче эретмә

ЛИГНИН *и. лат.* 1) *биол.* Үзагачның углеродларга бай матдәсе. *Лигнин – органик матдә.* А.Фәткуллин

2) Җитештерүнең төрле тармакларында һәм медицинада файдаланылган кыйммәтле химик чимал

ЛИГНИТ *и. лат.* Ягулык буларак кулланыла торган файдалы казылма, соры күмер

ЛИГНОФОЛЬ *и. махс. лат.* Юка агач катламы һәм формальдегидлы сумаланы кайнар пресслау юлы белән ясалган катлаулы материал; балинит, дельта-үзагач

ЛИГРОИН *и. фр.* Нефть куганда барлыкка килгән, нефть химиясендә, лак эреткеч җитештерүдә чимал буларак кулланыла торган, сыек углеводородлар катнашмасыннан гыйбарәт продукт

ЛИ́ДЕР *и. инг.* 1) Иҗтимагый-сәяси оешманың яки берәр сәяси партиянең һ.б.ш. җитәкчесе, юлбашчысы. *Кешеләр – академиклар, лидерлар – партия билетларын тапшырганда, шушы вак-төякне язарга каян вакыт таптың?* М.Мәһдиев. *Узенең профсоюз лидеры икәнен дә әйтеп китәргә кирәк булыр.* А.Гыйләҗев. *Аны бер милләт тә үзенең лидеры итеп билгеләмәгән.* Акчарлак

2) Нинди дә булса ярышта беренче булып баручы кеше яки команда. *Лидерга каршы һәр команда икеләтә көч белән уйный.* Социалистик Татарстан. *Гомум турнир таблицасында Минск шәһәренең «Динамо» командасы лидер.* Өмет

3) Нинди дә булса өлкәдә, эшчәнлектә беренче, әйдәп баручы. *Шулай кырыгынчы елларга таба татар әдәбиятында өч жанрда өч лидер барлыкка килде.* М.Мәһдиев. *Эшмәкәрлек сыйфатлары ягыннан чын лидер булып танылган Гөлсинә Галиәхмәтова үз мисалында, --- үзендәге сәләтләрне гаять уңышлы итеп тормышка ашырырга мөмкин икәнлеген раслап күрсәтте.* Сөембикә. *Индонезиянең дә бу әҗәтен үзебезгә үк исәптән чыгарырга туры килсә, чит-ятларның бурычларын кичерү буенча Русия лидерлар сафында калачак.* Мәдәни җомга

4) Стройда беренче булып баручы эскадра миноносецы яисә җиңел крейсерның элекке исеме

ЛИ́ДЕРЛЫК *и.* 1) Нинди дә булса эшчәнлектә беренче булу. *Кави Нәҗми лидерлыкка ярамый, төрмәгә кереп чыкты.* М.Мәһдиев. *Бу кызыклы вә үзенчәлекле конфигурацияне кору максаты – ил президенты алышынган шартларда сәяси хакимиятнең тотрыклылыгын саклау һәм ил халкының югары ышаныч рейтингына ия булган Владимир Путинның сәяси лидерлыгын ныгыту.* Татарстан. *Башкаланың 14 укытучысы арасында иҗат мөмкинлекләре һәм лидерлык сыйфатлары ягыннан иң яхшы сыйныф җитәкчесе дип Казанның 146 нчы мәктәбе мөгаллимәсе Резеда Хәлиуллина танылды.* Мәгърифәт

2) Лидер булу, ярышта беренчелек. *Республика күләмендә лидерлык позициясен саклап калу өчен, яңа, көндәшлеккә сәләтле җитештерү объектлары барлыкка килергә тиеш.* Р.Әбүбәкеров

ЛИ́ЗИНГ *и. инг.* Предприятиеләргә төп фондлар (машина һәм җиһазлар), физик затларга бик кыйммәтле товар алганда күрсәтелә торган финанс хезмәт төре, кредитның бер формасы. *--- механизмнарны лизинг юлы белән яңартырга исәпләп торабыз.* Идел. *Татарстанда лизинг 1990 еллар башыннан авыл хуҗалыгы һәм сәнәгать предприятиеләрен кыйммәтле техника һәм җиһазлар белән тәэмин итү һәм аларның бәяләрен файдаланылуларына карап түләү шарты белән кулланыла.* Мәдәни җомга

ЛИ́ЗИС *и. гр. мед.* 1) Күзәнәкләрнең һәм күзәнәк системаларының, шул исәптән микроорганизмнарның, берәр матдә (мәс., антибиотиклар, ферментлар һ.б.ш.) тәэсирендә эрү күренеше

2) Йогышлы авырулар вакытында күзәтелгән югары температураның акрынлап төшү вакыты

ЛИЗОЦИМ *и. инг. биол.* Бактерияләрнең күзәнәк мембранасын эретеп тарката ала торган фермент

ЛИКБЕЗ *и. рус тар.* 1) Массакүләм рәвештә алып барылган укый-яза белмәүчеләрне грамотага өйрәтү эше

2) *сөйл.* Гадәттә олы яшьтәге грамотасызлар укый торган мәктәп. *Революция булып, авылда ликбез ачылгач, волостьтан килеп укытып киткән Касыйм хәлфәдән белемен арттырды, срогы тулып Касыйм хәлфә кайтып киткәч, Разиянең үзенә ликбезны алып барырга тапшырдылар.* Г.Минский

ЛИКВИДА́ТОР *и. рус* 1) Нинди дә булса эшне туктатучы, нәрсәне дә булса юкка чыгаручы; бетерүче. *Меньшевиклар ликвидаторлар юлына бастылар: «Идән асты оешмалары бетсен!» – дип аңлаталар.* Г.Ибраһимов. *Конкурс управляющийлары һәм бетерү комиссияләре (ликвидаторлар) шәхси состав буенча документларны килешү*

нигезендә тапшырудан баш тарткан очракта --- мәгълүматны прокуратура органнарына бирергә тиеш. Ватаным Татарстан

2) Чернобыль атом электр станциясендәге авария нәтиҗәләрен бетерүдә катнашкан кеше. *Бөтен ил буенча «ликвидатор» исеме һәм мәңге бетмәс, куркыныч атом тамгасы алган кешеләр сибелеп яши.* Безнең гәҗит

ЛИКВИДА́ТОРЛЫК *и.* 1) Сәяси көрәшнең һәм партия эшчәнлегенең бары ачыктан-ачык булуын гына таныган РСДРП эчендәге фракцион агым (1908–1912 еллар)

2) Ликвидатор (*2 мәгъ.*) булу. *Әнинең сеңелесе Зөрәдә кан рагы иде, ул да радиация пычрагын җыюда катнашты, судлар аша йөреп, ликвидаторлык статусы алды.* Ф.Бәйрәмова

ЛИКВИДА́ЦИЯ *и. лат.* 1) Эшчәнлеген туктату, гамәлдән чыгару (мәс., оешманың, эш урынының һ.б.). *Безнең фирманы ликвидациягә биреп киткән ул!* Ф.Яхин. *Оешма ликвидациягә дучар булган очракта, барлык хезмәткәр дә эштән чыгарыла*. Ватаным Татарстан

2) Кемне, нәрсәне дә булса бетерү, юкка чыгару. *Яшерен шифрлы телеграмма буенча аңа хәбәр бирелгән, ликвидация хәзерлегендә бу беренче урынга куелган иде.* Г.Ибраһимов

ЛИКВИДА́ЦИЯЛӘНҮ *ф. төш. юн.* Ликвидациягә дучар ителү. *Мин элек эшләгән оешма ликвидацияләнгән.* Ватаным Татарстан. *Районда бюджет өлкәсендә эшләгән, предприятиеләре ликвидацияләнгән, башка төбәкләрдән күчеп килгән 1350 инвалид бар*. Маяк

Ликвидацияләнеп бетү Барысы да ликвидацияләнү

ЛИКВИДА́ЦИЯЛӘҮ *ф.* Бетерү, юк итү, гамәлдән чыгару. *Аварияне ликвидацияләүгә барлык көчләр эшкә җигелде*. Заман сулышы

Ликвидацияли башлау Ликвидацияләргә керешү

ЛИКВИДЛАР *и. күпл. финанс.* Предприятиенең ансат кына сатып, акчага әйләндереп була торган активы (мәс., акча, кыйммәтле кәгазьләр, алтын һ.б.ш.). *Банкларның акча бөтенлеге (ликвидлар) проблемасы Американ кадагы ипотека-финанс кризисы һәм федераль банк-финанс структураларының аңа соңарыбрак игътибар итүе аркасында килеп чыкты.* Татарстан яшьләре

ЛИКВОР *и. лат.* Арка мие каналындагы, баш мие карынчыкларындагы һәм ми кабыгы арасындагы сыекча

ЛИКЁР *и. фр.* Градусы шактый югары булган татлы исерткеч эчемлек. *Табын бай, француз ликёры мәҗлесне хозур дәвам итәргә тел ачкычы бирә иде.* Т.Әйди

ЛИКПУНКТ *и. рус* Ликбез (*1 мәгъ.*) эше алып барылган урын

ЛИЛЕ́ЙНИК *и. рус бот.* Лаләчәләр семьялыгыннан төер-төер тамырлы күпьеллык үлән үсемлек, чәчәк. *Лилейник – кышка чыдам, аз талымлы үсемлек. --- Лилейникны сукмак буйларында (ике яклап) төркемләп үстерү, шулай ук букетка кисү өчен утырталар.* Йорт эшләре

ЛИЛИПУТ *и. инг.л.* 1) Джонатан Свифтның «Гулливер сәяхәтләре» фантастик романында Лилипутия илендә яшәгән уйдырма кешеләр расасы. *Гадәти гәүдәле кеше, бирегә эләккәч, үзен лилипутлар илендәге чын Гулливер дип хис итәргә мөмкин*. Татарстан яшьләре. *Лилипутлар белән блефускулар*

2) Бүе кыска, балалар кебек кечкенә кеше, кәрлә. *Иван Иванович – баһадир, җилкәсендә өч-дүрт сабыйны «Әпипә»гә биетергә була, --- учларында лилипутлар чабагач белән ашлык сугарлык.* А.Гыйләҗев

3) *күч. сөйл.* Игътибарга лаек булмаган, әһәмиятсез нәрсәләр һәм тоткан урыны буенча бик кечкенә кеше турында. *Сак булыгыз, гамьсез гулливерлар, Лилипутлар килә шигырьгә!* Ш.Маннур. *--- эш сөймәгән, кеше җилкәсендә яшәүче сәләтсез сорыкортлар ни генә кыланмасын, уңышлары лилипут булып калыр.* Кызыл таң

4) *күч.* Кечкенә күләмле әйберләр. *Болар янында алар лилипутлар гына.* А.Гыйләҗев. *Алар каршында җанварлар да, без дә лилипут кына булып калабыз.* Кызыклар дөньясында

ЛИ́ЛИЯ *и. бот. лат.* Лаләчәләр семьялыгыннан, кыңгырау рәвешле эре матур чәчәкле, суганчалы күпьеллык үлән үсемлек; зәнбәкъ. *Ак төс иң яраткан төсем булганлыктан, үземнең туган көнемә әлеге лилияләрне иң кадерле бүләк итеп кабул итәм.* Ватаным Татарстан. *Менә карале, ачылырга да өлгермәгән нинди матур лилияләр бар.* Ялкын

ЛИ́Л-ЛИЛ *и.* Каз яки үрдәк бәпкәләрен чакыру сүзе

ЛИМАН *и. гр.* 1) Елга диңгезгә койган урында, елга тамагында сай сулык, култык. *Күп кенә нематодалар океан, диңгез, елга, лиман һәм башка сулыкларда ирекле тереклек рәвеше алып баралар.* Биология. *Дәреслек авторы аерым бүлектә җирнең сулы өлешенә тукталып китә һәм эч диңгез, тыш диңгез, лиман, ермак, канал, күл кебек терминнарны куллана ---.* Фән һәм тел

2) Порт. *Һава лиманы. Диңгез лиманы*

ЛИМБ *и. лат.* 1) *тех.* Почмак үлчәү коралларының әйләнәсе буенча бүлемнәр төшерелгән яссы металл бөжрадан гыйбарәт детале. *Астрономик, геодезик һәм физик инструментларда лимб бүлемнәрен күрсәтә торган борылмалы деталь, линейка (гарәпчә линейка мәгънәсендәге сүздән)*. Фән һәм тел

2) *астр.* Кояш яки Айның күзгә күренгән диск әйләнәсе, кырые

ЛИМИТ *и. лат.* **1.** Берәр нәрсәне сарыф итү, тоту өчен билгеләнгән чик, норма; берәр нәрсәнең рөхсәт ителгән микъдары. *Ничә бардык районга, лимит куелган дип кире бордылар.* Г.Закирова. *Министрлыклар һәм ведомстволар бу лимитны арттыра алмаячак.* Ватаным Татарстан. *Татарстанда күпфатирлы йортларны капиталь төзекләндерү эшләренә килгәндә, аны финанслау буенча еллык лимит 95 процентка үтәлгән ---.* Зәй офыклары

2. *с. мәгъ.* Рөхсәт ителгән күләмдәге. *Лимит сумма*

ЛИМИТЛА́У *ф.* Лимит кую, лимит билгеләү, лимит белән чикләү

Лимитлап кую Алдан лимит билгеләү

Лимитлап тору Регуляр, даими төстә лимитлау

Лимитлый башлау Лимит кертү

ЛИМИТЛЫ *с.* Лимиты булган, лимит белән чикләнгән; билгеле

лимиттагы. *Лимитлы ягулык хуҗалыкларга чәчүлек мәйданнарының күләменә карап бүленәчәк*. Маяк. *Лимитлы товар*

ЛИМИТСЫЗ *с.* **1.** Лимит белән билгеләнмәгән, лимиты булмаган, лимит белән чикләнмәгән. *Барлык студентларга махсус лимитсыз тариф буенча эшли торган, югары тизлекле Интернеттан файдалану мөмкинлеге тудырылган.* Туган як. *Лимитсыз чыгым*

2. *рәв. мәгъ.* Лимиттан тыш, лимитка карамыйча. *Мәгариф министрлыгы шәһәр һәм район хакимиятләренең мәгариф идарәсе органнары җитәкчеләренә Интернет челтәреннән лимитсыз файдалану механизмын аңлатып хатлар --- җибәрде.* Кызыл таң. *Президентыбыз да халык мәнфәгатен өстен куеп, 12 гыйнварда ук льготалы гражданнарга транспортта лимитсыз йөрү мөмкинлеге тудыру турындагы карарга кул куйды*. Алабуга нуры

ЛИМНО́ЛОГ *и. гр.* Лимнология белгече

ЛИМНОЛО́ГИЯ *и. гр.* Гидрологиянең эчке сулыкларны (күлләрне, буаларны һ.б.ш.) өйрәнә торган тармагы

ЛИМОН *и. фар.* 1) Рутачалар семьялыгына караган, тропик һәм субтропикларда үсә, эре җимеш бирә торган мәңгеяшел цитрус агачы. *Ике елның берендә лимон һәм апельсин агачларын кар күмеп китте, чәй куаклары өшеде, плантацияләрдә йөзем уңышы да бермә-бер кимеде.* А.Тимергалин. *Тагын да арырак әнә лимон үсентеләре*. В.Имамов. *Бүлмәдә үсә торган миңле гөлнең (бегония) кайбер төрләрен, лимонны, узамбар миләүшәсен (сенполияне) яфрак чыбыкчаларыннан үрчетәләр.* Биология

2) Лимон агачының калын сары кабыклы, эче һәм хуш исле озынча йомры җимеше. *Ул арада аларның борын төбеннән генә өлгергән лимон төсендәге сап-сары «Жигули» узып китте...* А.Гыйләҗев. *Бер читтә пирамида итеп лимон өелгән иде, һәр данәсе унбиш тиен, бер дистә алдым, авылда юк бит.* М.Мәһдиев

3) *жарг.* Миллион сум. *Әллә син, Сәмыйк, чыннан да аңгыра, әллә башыңны диванага салып, мине мыскыл итәсең. Лимон ул – бер миллион дигән сүз, ахмак!* М.Галиев. *Йөз лимон тапсам, мин китап чыгармас идем, илле лимонын хатынга биреп, калганына машина алып, авылга китәр идем.* Р.Батулла

4) Төсләрнең аерым төсмерен белдергән тезмәләрдә «шул җимеш төсендәге» мәгънәсен белдергән компонент. *Лимон сары – ышанмау һәм саклану төсе.* Татарстан яшьләре

ЛИМОНАД *и. рус* Лимон яки башка җиләк-җимеш суы кушып ясалган татлы эчемлек. *– Их, бер-ике шешә лимонад алырга иде хәзер, – дигән булам мин улыма.* М.Мәһдиев. *Софи ханым --- кафедан чыкканда шоколад һәм берничә шешә сыра белән лимонад алырга булды.* Т.Әйди. *Ике шешә лимонад алып, дуслар белән утырдылар да, тагын гадәти солдат тормышы башланды.* Р.Вәлиев

ЛИМОНА́РИЙ *и. лат.* Лимон агачлары үстерелә торган питомник, оранжерея. *Хуҗалык шул дәрәҗәдә ныгып китә, хәтта биредә яшелчә теплицалары һәм лимонарий да ясыйлар.* Татарстан яшьләре. *Кавын тәме килеп торган, исе һушларны алырлык папайяны безнең башкалабызда урнашкан лимонарий хезмәткәрләре үстергән һәм... авыз да итеп караган.* Өмет

ЛИМО́Н БӨТНЕГЕ *и. бот.* Баллутчалар семьялыгына караган, эфир мае алына торган хуш исле күпьеллык үсемлек; дару мелиссасы. *Халык медицинасы буенча да дәваланырга була: валериан тамыры, сары мәтрүшкә, ландыш, юкә чәчәге, лимон бөтнеге, ала миләүшә, канлут җыелмасыннан төнәтмә ясыйлар*. Ватаным Татарстан. *Сулыш күнегүләре ясагыз, бигрәк тә бәкам, имбирь, лимон бөтнеге исләрен сулау файдалы*. Мәдәни җомга

ЛИМО́НКА *и. рус* 1) Лимонга охшаган груша төре

2) *сөйл.* Формасы белән лимонга охшаган, калын тышчалы кул гранатасы. *--- постка немец автоматы тоткан бер таза егет баскан иде. – Кайчаннан бирле торасыз? – дип сорады Ковригин. Бил каешына лимонкалар таккан егет: – Ярты сәгать чамасы, инптәш капитан, – дип җавап бирде.* З.Фәтхетдинов. *Противогаз букчасыннан алып кесәләренә ике лимонка тыкты, шинелен салып карга ташлады ---.* З.Зәйнуллин

ЛИМО́Н КИСЛОТАСЫ *и.* Кулинариядә, медицинада, буяу эшендә һ.б. кулланыла торган, лимон җимешеннән һәм кайбер башка үсемлекләрдән алына торган кислота. *Томалап пешергәндә ит тизрәк пешсен өчен, аңа соус, гранат согы яки лимон кислотасы өстәргә кирәк*. Татарстан яшьләре

ЛИМОНЛАП *рәв.* Лимон белән, лимон салып, лимон кушып. *«Сиңа күп сөйләргә ярамый, врачлар кушмый», – дип гел тыйдылар һәм аны юатыр, тынычландырыр өчен, тамчылап даруын эчерделәр, лимонлап чәен китерделәр, тәлинкә тутырып алмасын, чиясен китереп куйдылар.* Ә.Еники. *Рәхәт, һава сафланып киткәндәй кебек, мунча янында урнашкан 3 нче икмәк комбинатыннан чыккан тәмле хуш ис борынны кытыклый, их, лимонлап кайнар чәй эчәсе иде хәзер.* Шәһри Казан

ЛИМОНЛЫ *с.* Лимон кушып ясалган; лимон салынган. *Бүксә киереп, вакытында лимонлы чәйне көмеш калак белән болгатып, берәр министерствода утырам...* Т.Галиуллин. *Грипп йоктырмас өчен, лимонлы май ясап, кара ипигә ягып, көнгә 6–8 тапкыр ашарга кирәк ---*. Мәдәни җомга

ЛИМОНЛЫК *и.* Лимон куаклары үскән җир, лимон бакчасы

ЛИМО́ННИК *и. рус* 1) Лимонникчалар семьялыгына караган, тәме, исе белән лимонга охшаган кызыл җимеш бирә һәм үрмәләп үсә торган куак үсемлек. *Атаклы женьшень (кытайчадан – кеше-тамыр дигән сүз. Уйлансаң, олы хикмәт бар бу чагыштыруда), элеутерококк, лимонник, актиния...* Р.Фәйзуллин. *Лимонник кытай медицинасында моннан мең еллар элек инде «биш төрле тәм җимеше (әчкелтем, ачы, татлы, камаштыргыч, борычлы)» исеме белән билгеле булган.* Бакчачы календаре

2) Бу үсемлекнең тамырыннан, орлыгыннан яки җимешеннән ясалган төнәтмә (медицинада хәл кертә торган

дару буларак кулланыла). *Даруханәдән элеутерококк яки лимонник алып эчү дә файдалы.* Ватаным Татарстан

ЛИМОННИКЧАЛАР *и. күпл.* Башлыча Көньяк-Көнбатышта таралган мәңгеяшел яки яфрак коя торган куакчыл лианалар семьялыгы

ЛИМОНЧЫ *и.* 1) Лимон үстерүче

2) Лимон белән сату итүче. *Итчеләр, лимончылар, толчокчылар, йорт-җир сату һәм алу эшендә маклер булып йөрүчеләр – барысы да килде.* С.Җәлал

ЛИМУЗИН *и. фр.* Каты ябык кузовлы, шофёр белән пассажир салонын аерып торган пыяласы булган озын җиңел автомобиль. *Кармен залда үзе уйлаганга караганда озаграк тоткарланды, начар яктыртылган Тверская урамына килеп чыккач, егетләрнең лимузины әле һаман китмәгәнен, аны көтеп торганын күрде.* Р.Мирхәйдәров. *Чия төсендәге лимузин – тәгәрмәч өстендәге чын сарай.* Мәдәни җомга. *Дөньяда иң озын лимузинны Калифорниянең Бербэнк шәһәрендә Джей Орберг уйлап тапкан һәм эшләгән.* Мәдәни җомга

ЛИ́МФА *и. лат. физиол.* Кеше һәм умырткалы хайваннар гәүдәсенең бөтен тукымаларын, күзәнәкләрен юа һәм кан белән тукыма арасындагы пространствоны тутырып, матдәләр алмашуын тәэмин итә торган төссез сыекча. *Лимфа төеннәре ялкынсынырга, организмда сыеклык алмашы бозылырга мөмкин.* Мәдәни җомга

ЛИМФАДЕНИТ *и. гр. мед.* Лимфатик төеннәрнең ялкынсынуы. *Коры җылы белән җылыту исә лимфаденититан дәвалый, буыннардагы ревматизмны тынычландыра.* Безнең гәҗит

ЛИМФА́ТИК *с.* Лимфага караган, лимфага бәйләнешле. *Лимфатик төерләр ялкынсынуы юкмы?* Сөембикә. *Ак тәнчекләр талакта, лимфатик төеннәрдә һәм сөяк җелегендә бүленү юлы белән үрчиләр.* Анатомия

ЛИМФОЦИТ *и. гр.* Лейкоцитларның бер төре. --- *шулай ук иммун системаның эшкә яраклыгы (ул кандагы лимфоцитлар күләмен, аларның төрләре чагыштырмасын, һәркайсының эшкә яраклылыгын да үз эченә ала) тикшерелгән, кандагы антитәнчекләр микъдары да үлчәнелгән.* Безнең гәҗит

ЛИНГВИ́СТ *и. лат.* Тел галиме, тел белгече, телче. *Антик дөнья лингвистлары фигыльләрне бүтән сүз төркемнәреннән аера торган сигез төрле үзенчәлек санаганнар.* Л.Җәләй. *Француз лингвистлары әйтүенчә, бу закон француз телен чит сүзләр, аеруча инглиз сүзләре белән чүпләнүдән саклау өчен чыгарылган, ди.* Х.Сарьян

ЛИНГВИ́СТИК *с.* Лингвистикага караган, шуңа бәйләнешле. *Борынгы һәм хәзерге лингвистик берәмлекләрне чагыштырып, халык тарихын ачарга тырышу оптылышын XIX гасыр уртасында Швейцария лингвисты А.Пикте ясаган, һәм шул чорда ук бу лингвистик тарих методы лингвистик палеонтология дип аталган.* Фән һәм тел. *Х.Фәезханов бу ядкәрләргә тарихи һәм лингвистик анализ ясый.* Татар әдәбияты тарихы

ЛИНГВИ́СТИКА *и. лат.* Тел белеме. *Татар лингвистикасының һәр тармагы диярлек (фонетика, морфология, лексикология, синтаксис, диалектология, топонимика һ.б.) тарихи яссылыкта, тиешле дәрәҗәдә үсештә булды.* Мәдәни җомга

ЛИНГВОДИДА́КТИКА *и. лат. лингв.* Лингвистиканың тел өйрәтүнең гомуми закончалыкларын, дидактик максатлардан чыгып билгеле телгә өйрәтү ысулларын һәм алымнарын өйрәнә торган тармагы. *Соңгы елларда лингводидактикада компетенция төшенчәсе киң кулланылышка кереп бара.* Фән һәм тел

ЛИНГВОКУЛЬТУ́РА *и. лат. лингв.* Культураның телдә бирелгән һәм тел берәмлекләрендә, тел яки сөйләм процессларында чагылыш тапкан үзенчәлекле билгеләре

ЛИНГВОКУЛЬТУРОЛО́ГИЯ *и. лат. лингв.* Билгеле бер халык культурасының шул халыкның телендә чагылышын өйрәнә торган фән. *Татар лингвокультурологиясе белән дөнья галимнәре дә кызыксына.* Шәһри Казан

ЛИНГВОМЕТОДИСТ *и. рус* Тел өйрәтү методикасы белгече

ЛИНГВОЦИД *и. лат.* Гадәттә борынгыдан бирле билгеле бер төбәктә яшәгән халыкның телен ассимиляция юлы белән бетерүгә юнәлдерелгән административ-сәяси һәм икътисади чаралар комплексы

ЛИНЕ́ЙКА I *и. рус* 1) Туры сызык сызу яки берәр нәрсәнең озынлыгын үлчәү өчен, сантиметрларга, миллиметрларга бүленгән юка озын һәм тар планка. *Юбканы өскә кидереп, итәк очын линейка белән идәннән үлчәп тигезлиләр.* Йорт эшләре

2) *хәрби* Лагерьны кварталларга бүлә торган юлларның берсе

3) Уку яки тәрбия учреждениесендә балаларның тантаналы чара өчен тезелешеп басуы һәм шулай үткәрелгән чара үзе. *Беренче дәрес алдыннан линейкага тезделәр.* М.Мәһдиев. *Ул пионерларны тантаналы линейкага тезелергә чакыра иде.* Р.Хафизова. *Иртәнге линейка, тәрбия сәгатьләре, сәламәтлек сәгатьләре --- барысы да Роза ярдәме белән үтә.* Мәгърифәт

ЛИНЕ́ЙКА II *и. рус иск.* XIX гасырда Россиядә җәмәгать транспорты төре: ике ягына да пассажирлар утыра торган ачык өсле озын экипаж

ЛИ́НЗА *и. нем.* 1) Яктылык нурларын сындыру (үзгәртү) өчен, бер яки ике ягы да кабарынкы итеп ясалган оптик пыяла; ясмык пыяла. *[Гата] физика шкафлары куелган класста унынчы класс укучылары белән көн ятты, төн ятты. Линзалар, амперметр, омметрлар, магнит дугалары ---.* М.Мәһдиев. *Ике ягы да кабарынкы линзаның фокаль яссылыгында яссы көзге урнаштырылган.* Физикадан мәсьәләләр җыентыгы

2) Күрү сәләтен арттыру яки үзгәртү өчен, турыдан-туры күз өстенә ябыштырып куела торган үтә күренмәле йомшак түгәрәктән гыйбарәт күзлек. *Контакт линзаларын урынына утыртып куюга, дөнья ачык булып күренә башлый.* Кәеф ничек?

3) *геол.* Тау токымының чагыштырмача зур булмаган, ясмыксыман формалы ятмасы

ЛИ́НЗАЛЫ *с.* Линзасы булган. *Пуля үткәрми торган пыялага охшаган*

калын линзалы күзлеге артына качып, ул, исе китмичә генә, Ихтыярга урын күрсәтте. Р.Вәлиев

ЛИ́НИЯ *и. лат.* 1) Аралашу юлы (җир өсте, һава, су юллары). *Һава линияләрен төзегәндә төрле изоляторлар, ыргаклар, штырьлар, овал тоташтыргычлар кулланыла.* Авыл хуҗалыгы электригы белешмәсе. *27 ноябрьдә Казанда беренче троллейбус линиясе ачылуга 60 ел тулды.* Татарстан яшьләре

2) Телефон, телеграф элемтәсе һәм электр энергиясен тапшыру корылмалары. *1964 елны Свердловск белән Каменск-Уральск арасында булган шквал электр тапшыру линияләренең металл терәкләрен 90 градуслы почмак ясап бөккән.* Кызыклы география. *Энергетика объектларында мондый янгыннардан бигрәк тә 0,4–10 Кв көчәнешле агач баганалы электр линияләре зыян күрә.* Мәгърифәт

3) Окоп һәм хәрби ныгытмаларның чиге; рубеж

4) Берәр продуктны эшләп чыгару конвейеры. *Безгә әле яңа технологик линия төзеләр.* Ә.Хәбибуллин

5) *күч.* Эш юнәлеше, карашлар юнәлеше; мәсләк. *Бу линияне яклаучылар да булды.* М.Мәһдиев

ЛИ́НИЯЛЕ *с.* 1) Туры сызык шәкелендә булган

2) *мат.* Озынлыгы горизонталь яссылыкта билгеләнә торган

3) *мат.* Графикта туры сызык белән күрсәтелә торган

4) Билгеле сандагы яки үзлектәге юлы булган. *Ике линияле тимер юл*

ЛИНКОР *и. рус тар.* XX гасырның урталарына кадәр файдаланылган, көчле артиллерия һәм күпсанлы экипаж белән коралланган, корпусы броня белән ныгытылган иң зур хәрби кораблар классы. *«Корабльләрне танып бел» дигән баш астында хикмәтле рәсемнәрне күргәч, бөтен мәктәп малайлары дөньяларын оныттылар. Крейсер, линкор, эсминец була икән.* М.Мәһдиев

ЛИНОЛЕ́Н КИСЛОТАСЫ *и. хим.* Алыштыргысыз майлы кислоталарга караган, күп кенә үсемлек майларының составында була торган төссез майлы сыекча. *F витамины --- алыштыргысыз майлы олеин, линоль һәм линолен кислоталары буларак карала.* Урман аптекасы

ЛИНО́ЛЕУМ *и. лат.* Полимер матдәләрдән эшләнгән, идән капламасы буларак файдаланыла торган сыгылмалы материал. *Палубада электрод калдыклары, тимер кыйпылчыклары, майга буялган чүпрәкләр, линолеум кисәкләре аунап ята иде.* М.Юныс. *Кулга, клеёнкага һәм линолеумга тигән кечкенә кара тапларын шырпы башы белән бетерергә мөмкин.* Йорт эшләре. *Бүлмәләре пластик панельләр белән бүленгән, идәннәре – линолеум, түшәмнәре синтетик материалдан ясалган плиткалар белән капланган өйләрдә булганым бар*. Татарстан яшьләре

ЛИНО́ЛЬ КИСЛОТАСЫ *и. хим.* Суда эреми торган, хайван һәм үсемлек мае составында була торган матдә; ачык сары төсле майлы сыекча. *Олеин һәм линоль кислоталары глицериннның катлаулы эфирлары хәлендә үсемлек майлары составына керәләр.* Химия

ЛИНОТИП *и. лат. полигр.* Типографиядә бөтен бер юлны тоташтан коеп җыя торган хәреф җыю машинасы. *Тик әле хәзергә, өстәмә линотип машиналары кайтканчы, ручной наборда эшләп тора икән.* Ф.Хөсни. *Линотип бүлмәләре, литография бүлекләре берәм-берәм ачылдылар.* Г.Гали

ЛИНОТИПИСТ *и. рус к.* **линотипчы**

ЛИНОТИПИ́СТКА *и. рус* Линотипчы хатын-кыз. *Унъеллык мәктәпне бетергәч, полиграфия курслары аша үтеп, линотипистка булып чыккан икән ул.* Ф.Хөсни

ЛИНОТИПЧЫ *и.* Липотипта эшләүче, линотипта хәреф җыючы

ЛИ́НЧЛАУ *ф. кит.* Линч хөкеменә дучар итү, судсыз җәзалау, бернинди тикшерүсез, судсыз җәзалап үтерү

ЛИПАРИТ *и. геол.* Составы белән гранитка охшаган тонык төсле вулканик тау токымы (Липари утравы исеменнән). *Эффузив токымнарга липарит һәм кварцлы порфир керә.* А.Фәткуллин

ЛИПО́ИД *и. гр. махс.* Терек организмнарда һәм үсемлекләрдә була торган майсыман органик матдә. *Майсыман матдәләр яки липоидлар да организмда зур роль уйныйлар.* Биология

ЛИПО́МА *и. гр. мед.* Май тукымасыннан торган зарарсыз шеш; *русчасы:* **жировик**. *Тире астында липома барлыкка килү*

ЛИ́ПСИ *и. нем.* Германиядә иҗат ителгән ирекле композициядәге парлы бию төре

ЛИ́РА I *и. гр.* 1) Борынгы Грециядә барлыкка килгән кыллы музыка коралы. *Тагын бер кырыйда – кара көмештән коелган мәһабәт бер лачын сыны, чын сәдәфтән эшләнгән лира һәм каләм сабы.* Г.Бәширов. *Лира чыңлый, Гомер җырлый эш кешесен зурлап.* Г.Афзал

2) *астр.* Күкнең төньяк ярымшарындагы Киек Каз Юлы буена урнашкан бер йолдызлык исеме. *Безнең Кояш системасы Лира һәм Геркулес йолдызлыклары юнәлешендә 20 км/сек тизлек белән хәрәкәт итә.* Астрономия

3) *күч. шигъ.* Поэзия, поэтик иҗат, шигърият символы; саз. *Мин аңа багышлап шигырьләр язган булам ---, саф йөрәктән булган мәхәббәтем мәсхәрә ителгәч, җансыз лирам сиңа азык була алмас.* Т.Гыйззәт. *Милләтчелек, халыкчанлык лирасын тагып йөрүче егетләр турында.* Ф.Бурнаш

ЛИ́РА II *и. гр.* Ватиканда, Италиядә һәм Төркиядә акча берәмлеге

ЛИ́РАКОЙРЫК *и. зоол.* Чыпчыклар семьялыгыннан көрән соры төсле кош (ата кошның койрыгы лирага охшаган була). *Кошлардан канатсыз тәвә кошы эму һәм лиракойрык тик Австралиядә генә яшиләр.* Дөнья киләкләре географиясе

ЛИРИЗМ *и. гр.* 1) Сәнгать әсәрләрендә нечкә хислелек, шигърилек, эмоциональ төсмер. *Тулаем алганда, XX йөз башы татар әдәбиятындагы психологизмга эмоциональлек һәм лиризм хас...* Г.Халит. *--- мәхшәрле еллардансоң шактый гына вакыт үткәч иҗат ителгән картиналары лиризм белән сугарылган.* Мәдәни җомга

2) Лирик халәт. *Чөнки анда тынгысыз үткен фикер, самими лиризм, хис чынлыгы көчле.* Татар әдәбияты тарихы

ЛИ́РИК I *с.* 1) Лирикага (*1 мәгъ.*) караган, лирикага бәйләнешле. *Мондагы лирик геройны да мин күз алдына китерәм.* М.Мәһдиев

2) Лирик әсәрләр яза торган. *Лирик шагыйрь. Лирик язучы*

3) *сөйл.* Хисләргә бай, лиризм белән сугарылган

4) Музыкада хисле, нәфис аһәңле (тавыш тур.). *Лирик тенор*

ЛИ́РИК II *и.* Лирик I (*1 мәгъ.*) әсәрләр язучы шагыйрь. *Лирикларга йолдыз, Галактика – Иң романтик хисләр сәхрәсе.* Х.Туфан. *Нечкә лирик та ул, трибун да һәм, иң мөһиме, чәнечкеле юмористик шигырьләр остасы да.* Мәгърифәт

ЛИ́РИКА *и. гр.* 1) Эчке кичерешләрне, хис-тойгыларны дулкынландыргыч итеп сурәтли торган, шигъри формадагы әдәби әсәр төре. *Б.Эйхенбаум «Шигырь мелодикасы» дигән әсәрендә лирика әсәрләрен аһәң ягыннан өч типка бүлә.* Г.Нигъмәти

2) Шундый төр әдәби әсәрләр. *Минемчә, фронт лирикасы да, бигрәк тә хәзер, кирәкле һәм мөһим жанр.* М.Җәлил. *Фаил Шәфигуллин лирикасы да – күңелдәге сагыш.* Р.Шәфигуллина

3) Нәфис хис, эчке кичерешләр. *Хисмәтнең дә шулай тормышында, Тирән лирикалар булган күк, Эпос та бар, озын проза да.* Ш.Маннур

ЛИ́РИК-ДРАМАТИК *с.* 1) Лирика һәм драма элементларын үз эченә алган (әдәби әсәрләр тур.). *Лирик-драматик поэма*

2) *муз.* Лирик һәм драматик тавыш арасындагы (җырчы тавышы тур.). *Лирик-драматик сопрано*

ЛИ́РИКЛЫК *и. к.* **лиризм**. --- *биредә фаҗигалелек үскәннән-үсә, курку, борчылу, чарасызлык хисләре артып-алышынып тора, кабатлаулар хикәяләүгә лириклык өсти.* Р.Гали. --- *1908 еллардан соң аның сәнгатьчә фикерләвендә лириклык сизелерлек арта, тирәнәя, мәхәббәт хисләре урын ала.* З.Рәмиев

ЛИРО-Э́ПИК *с.* Лирик һәм эпик элементларны үз эченә алган (әдәби әсәрләр тур.). --- *шәхес һәм милләт язмышына, дингә мөнәсәбәтен зур күләмле лиро-эпик жанрда чагылдыра башлый.* А.Әхмәдуллин. *Мәҗит Гафури лиро-эпик жанрда «Эшче» поэмасын иҗат итте.* Г.Хисмәтуллин

ЛИСАН *и. гар. иск.* Тел. *Студентлар вә гимназисткалар илә үткән ел башында татар лисанында ике уен уйнадык.* Ф.Әмирхан. *Өең, ирең турында шундый бер лисан илә хәбәр итәсең ки...* Ф.Фәтхелислам. *Лисане гарәпнең сарыф-нәхүе вә шул бабта тагы әллә ниләр язды.* Г.Тукай

ЛИСТАЖ *и. рус* Китап ахырында күрсәтелгән басма табаклар санын тираж санына тапкырлаудан килеп чыккан сан-басма табак-оттисклар саны

ЛИСТО́ВКА *и. рус* Сәясәт, пропаганда, реклама һ.б.ш. информацион характердагы басма яки кулдан язылган кәгазь бите. – *Безнең фабрикада урысча листовкалар табылды әле, – диде ул.* Т.Әйди. *Башта галимнәр Көнчыгыш Африка яр буендагы портларда эзләнә торган балыкны тәфсилләп аңлаткан листовка тараталар.* Кызыклы ихтиология

ЛИСТОК *и. рус к.* **листовка**. *Ротада бүген синең турыда чыккан хәрби листокны командир кычкырып укыды.* Р.Вәлиев

ЛИТА́ВРА *и. гр.* Күн яки пластик белән тышланган берничә (җидегә кадәр) ярымшардан гыйбарәт бәрмә уен коралы. *Тромбоннарның куркыныч яңгыраган авазлары, литавралар гүләгән, барабаннар дөбердәгән тавыш белән кушылып, тәмам җиңеп чыкты.* Ш.Хөсәенов

ЛИТА́ВРАЧЫ *и.* Литаврада уйнаучы музыкант

ЛИТВАЛЫ *и.* Башлыча Литвада яшәүче, һинд-аурупа семьясының балтыйк группасына караган телдә сөйләшүче халык һәм шуның бер кешесе. *Күпчелеге бик зур срокларга хөкем ителгән латыш, литва, эстон хатын-кызлары украинкалар төркемен бизәгәннәр, санын арттырганнар.* А.Гыйләҗев. *Аның урынына безгә «Химки»дан берьюлы өчәү – литвалы Паулюс Янкумас белән Робертас Явтокас һәм америкалы Келли Маккарти килә, дигән хәбәрләр йөри.* Татарстан яшьләре

ЛИТВА́ЧА *рәв.* **1.** Литва телендә, литвалылар телендә

2. *с. мәгъ.* Литва телендәге, литва телендә язылган яки сөйләнгән. *Без, Мәдинәкәйдә яшәгәннәр, әле татарча сөйләшәбез, ә исемнәр инде литвача.* З.Зәйнуллин

ЛИ́ТЕР *и. лат.* 1) Поезд һ.б. кайбер транспортта юл йөрү өчен бушлай яки льготалы (аерым бер хәреф – литера белән билгеләнгән) таныклык, документ

2) *сөйл. к.* **литера** (*2 мәгъ.*). *Ул, литерларны коя торган машинадан тыш, хәрефләрне җыю һәм аерым юллар итеп беркетү җаен уйлап таба.* М.Вәлиев

ЛИ́ТЕРА *и. лат.* 1) *иск.* Хәреф

2) *полигр.* Хәреф җыю эшендә кулланыла торган, бер башына кире ягы белән кабарынкы хәреф яки башка бер билге төшерелгән металл, агач яки пластмасса борысчык

ЛИ́ТИЙ *и. гр. хим.* Табигатьтә саф хәлендә очрамый торган, йомшак һәм бик җиңел, көмеш шикелле ак төстәге селтеле металл, химик элемент. *Литий күптән инде психик чирләрне дәвалауда кулланыла. --- Япония хөкүмәте химик психотерапия куллана башларга җыена. Эчә торган суга литий кушачаклар.* Мәдәни җомга

ЛИТО́ГРАФ *и. нем.* Литография белгече, литография цехы яки предприятиесе эшчесе

ЛИТОГРА́ФИК *с.* Литография (*1 мәгъ.*) ысулы белән эшләнгән, бастырылган

ЛИТОГРА́ФИЯ *и. нем.* 1) Яссы таш формадан кәгазьгә рәсем бастырып алу ысулы. *К.Якуб исемендәге китап фабрикасының литография цехында рәсем төшерүче булып эшли башладым.* Гасырлар авазы

2) Шундый ысул ярдәмендә төшерелгән рәсем. *Анда XIX гасыр татарларының киемнәре, алка, беләзекләр, изү каптырмалары, чүлмәкләр, күн мозаикасы, намазлыклар, Коръәннәр, Э.Турнерелли, Э.Турин һ.б. осталарның литографияләре урын алган.* Мәдәни җомга. *Безнең графикларның эшләре күтәрелеш кичерә, алар бик саллы гына эшләп киттеләр, афортлар да,*

литографияләр дә, бик үзенчәлекле рәсемнәр дә ясыйлар. Шәһри Казан

3) Шундый ысул белән рәсем яки язу бастырып ала торган цех яки предприятие. *Исем казанган хаттатлардан Рәхмәт Әмирхан, Мостафа Әлдермеши, Петербург университетының каллиграфия укытучысы Ибнеяминов, М.Чутай, Казан университеты укытучысы Гали Мәхмүдов белән Казан литографиясендә гравёр булып эшләүче Лотфи Өммәти кебекләрне күрсәтергә мөмкин*. И.Рәмиев

ЛИТОСФЕ́РА *и. гр.* Җир шарының геологик төзелешендә җир кабыгыннан һәм мантиясенең өске өлешеннән торган тышкы каты катламы. *Өске каты катлау – литосфера, уртанчы каты катлау – халькосфера һәм Җирнең үзәге – сидеросфера.* А.Фәткуллин. *Литосфера плиталары турындагы тәгълимат Җирнең киләчәген дә күрергә мөмкинлек бирә*. Материклар һәм океаннар географиясе. *Җирнең каты кабыгы – литосфера – төрле тау токымнарыннан тора*. Төзү материаллары

ЛИТР *и. гр.* Күләм һәм сыйдырышлылык үлчәү берәмлеге һәм 1000 куб/сантиметрга тигез булган сыеклык үлчәү берәмлеге; шул үлчәмгә тигез сыеклык микъдары: 1 кг чиста су авырлыгына тигез. *Кичләрен җиделе лампа яктысында, ярты литр керосинга да интегә-интегә, шәл бәйләде.* Н.Хәсәнов. *Станцияләрдә хатын-кыз бер кирпеч ипи белән бер литр сөтне берләштереп пассажирларга сата.* М.Мәһдиев. *Литр, килограмм, пачка, әржә, мичкә, капчык – шушы инде безнең тормыш.* Р.Вәлиев

ЛИТРАЖ *и. фр.* Нинди дә булса савытның литрларда билгеләнгән күләме

ЛИ́ТРЛАП *рәв.* Литр исәбеннән, литрлар белән билгеләнгән күләмдә. *Нургали бирмәс идемени, рәхәтләнеп бирер иде, көн саен литрлап сөтен, атна саен килолап маен, дистәләп йомыркасын өләшер иде, ләкин бит күлеңә күрә чумасың...* Ә.Еники. *Аракыны Яңавылдан мичкәсе белән генә ташыйлар һәм, кәрәчин саткан кебек, литрлап, чүмечләп саталар иде.* Н.Фәттах. *Бәхетне дә литрлап кына үлчисе!* Р.Зәйдулла

ЛИ́ТРЛЫ *с.* 1) Күләме һәм сыйдырышы литрларда исәпләнә торган. *Кемнеңдер парта астындагы сөт салган чирек литрлы шешәсе идәнгә тәгәрәде.* М.Мәһдиев. *Күчтәнәчкә Гайфулла күптән биш литрлы банкага бал тутырып куйган иде.* Ф.Яруллин

2) Сыйдырышлылыгы бер литр сыеклык микъдарына тигез булган. *Литрлы банкаларга салат ясап ябу*

ЛИТФОНД *и. рус* Язучылар берлеге каршында язучыларның матди хәлен яхшырту һәм аларга культура-көнкүреш хезмәте күрсәтү максаты белән төзелгән җәмәгать оешмасы. *Безнең литфондта мобилизованный-ларга билгеле бер күләмдә акчалата пособие бирәләр.* М.Җәлил. *Литфондтан акча сорарга килеп яту иде, Коля.* М.Хәбибуллин

ЛИФ *и. голл.* 1) Хатын-кыз күлмәгенең күкрәк турысы; кыса

2) *сөйл. к.* **лифчик**

ЛИФТ *и. ингл.* Күп катлы биналарда һәм шахталарда кешеләрне яки йөкне күтәрү яки төшерү өчен, кабина формасындагы җайланма. *Нәрсә, әллә лифт эшләмиме, сигезенче катка җәяү менгәнме?* М.Мәһдиев. *Лифт эшләмәү аркасында, салкын бетоннан оекчан килеш, арттан гына тын алып, унберенче катка кадәр күтәреләләр.* А.Хәлим

ЛИФТЁР *и. рус* Лифтны эшләтүче, хезмәт күрсәтүче эшче. *Бервакыт үз йортыннан һава суларга дип чыгып бара иде, аны лифтёр карт тотып алды, баскыч янындагы кечкенә бүлмәсенә алып керде.* М.Галиев

ЛИ́ФТЧЫ *и. к.* **лифтёр**. *Керсә, анда хырхылдап лифтчы йоклап утыра.* Ә.Гадел. *Лифтчы карчыктан сорап, тегенең бишенче каттагы сиксән тугызынчы бүлмәгә килгәнлеген ачыклаган.* М.Насыйбуллин

ЛИ́ФЧИК *и. рус* Хатын-кызның күкрәген каплап, күтәртеп куя торган эчке кием, күкрәкчә, бюстгальтер. *Лифчик уңайлы, күкрәкләрне бик нык кысмый торган булырга тиеш.* Йорт эшләре

ЛИХАЧ *и. рус* 1) *тар.* Яхшы йөгерек атка җигелгән зиннәтле экипаж извозчигы; шул экипаж үзе. *Бай кызларына күренешсез генә, нәсел-нәсәпсез генә кавалер белән лихачка утырып йөрү килешми*. Ф.Әмирхан. *Урамында трамвай, лихач, автомобиль бихисап*. И.Нуруллин

2) *сөйл.* Тизлекне арттырып, юл йөрү кагыйдәләрен бозып транспорт йөртүче. *Кулындагы мәчене машинасының тәрәзеннән эчкә тыкты да дәвам итте теге лихач ханым* ---. Ж.Юныс

ЛИХАЧЛЫК *и. сөйл.* Шофёрның җитезлеген күрсәтер өчен юл йөрү кагыйдәләрен бозуы. *Җайланма тасмасына язылганнарны тикшереп, игътибарсыз яки лихач машина йөртүчеләргә штрафлар да җибәрергә кирәк бит әле*. Яңарыш

ЛИХЕНОЛО́ГИЯ *и. лат.* Лишайникларны өйрәнә торган фән

ЛИ́ХТЕР *и. голл.* Йөк йөртү яисә зур суднолардан йөк бушату, йөк төяү өчен файдаланыла торган яссы төпле, җилкәнле кечкенә судно

ЛИЦЕИСТ *и. рус* Лицейда укучы, лицейда тәрбияләнүче; лицейда белем алган кеше

ЛИЦЕЙ *и. гр.* 1) Россиядә 1917 елга кадәр дворян балалары өчен өстенлекле урта мәктәп яки югары уку йорты

2) Көнбатыш Европа, Латин Америкасы, Африканың күп кенә илләрендә – гомуми урта мәктәп

3) 1989 елдан соң Россиядә үзенең махсус программасы нигезендә укыткан, гомуми яки һөнәри белем бирә торган урта мәктәп. *Ирем үз хәлендә, намуслы бер лицей укытучысы.* Ф.Фәтхелислам. *Илмир, мәсәлән, эретеп ябыштыручылар хәзерләүче лицей тәмамлаган.* Мәдәни җомга

ЛИЦЕ́НЗИЯ *и. лат.* Билгеле эшчәнлек алып бару хокукы, шушы хокукны раслап бирелгән рөхсәт, шул рөхсәтне раслаган документ; рөхсәтнамә. *Шушындый законсыз ысул белән лицензиясе булган башка фирмалар ачыклана башлый.* Мәдәни җомга. *Әлеге карьер лицензиясез һәм җирле хакимиятнең рөхсәтеннән башка эшләгән булган.* Татарстан яшьләре

ЛИЦЕ́НЗИЯЛЕ *с.* 1) Лицензиясе, рәсми рөхсәте булган. *Аракы һәм баш-*

ка төрле алкогольле эчемлекләр махсус лицензияле кибетләрдә генә. Татарстан яшьләре

2) Лицензия белән чыгарылган, лицензия нигезендә җитештелегән. *Аның беркайчан да лицензияле диск алганы булмаган.* Ватаным Татарстан

3) Лицензия таләп ителгән; лицензиягә бәйле. *Закон проекты гамәлгә куелса, таксистлар эшчәнлеге лицензияле булырга тиеш, автомобильнең тышкы кыяфәтенә, машинаның техник торышына һәм шоферның квалификациясенә аерым таләпләр куелачак.* Безнең гәҗит

ЛИЧИ *и. кыт. бот.* 1) Сапиндчалар семьялыгыннан киң ябалдашлы, башлыча Көньяк һәм Көньяк-Көнчыгыш Азиядә таралган мәңгеяшел агач

2) Шул агачның кытыршы кызыл кабыклы татлы җимеше. *Личи компоты. Киптерелгән личи*

ЛИЧИ́НКА I *и. рус* Күпчелек буынтыгаяклыларның, кайбер җирсу хайваннарының билгеле бер үсеш стадиясендә курчак стадиясенә кадәрге чордагы халәте, корт. --- *кырмыска личинкасы ашаучы бөҗәкнең тәне исерткеч бүлеп чыгара. Кырмыскалар шуны ялыйлар да исерәләр.* Х.Камалов. *Италиядән күчерелгән гамбузия балыгы исә бизгәк таратучы озынборын личинкаларын юк итә.* Кызыклы география. *Аннан [он коңгызыннан] авыр ис килеп тора, ә личинкалары тагы да озынрак.* Мәдәни җомга

ЛИЧИ́НКА II *и. рус махс.* Затворның винтовка көпшәсе каналын яба торган кисәге

ЛИША́ЙНИК *и. рус* Җир һәм таш өстендә, агач кайрыларында үсә торган, гөмбә һәм суүсемнән гыйбарәт түбән төзелешле үсемлек. Бакчачы календаре. *Үзләренең тышкы күренешләре һәм төсләре буенча лишайниклар төрле-төрле.* Биология. *Кыя ташларда урыны-урыны белән лишайниклар, чишмә һәм күл тирәләрендә мүк үсә.* Кызыклы география

ЛОБАН *и. зоол. рус* Кефальләр семьялыгына керә торган ашарга яраклы диңгез балыгы, кушбашның бер төре. *Ул үз күзенә үзе ышанмый тора: түбәдә һәм йорт тирәсендә зур-зур океан балыклары – лобаннар ята.* Кызыклар дөньясында

ЛО́ББИ *җыйм. и. ингл.* 1) Лоббизм белән шөгыльләнүчеләр төркеме, берләшмәсе, лоббистлар. *Бүгенге Россиядә хәмер лоббие көчен барыбыз да яхшы аңлыйбыз.* Ватаным Татарстан. *Чөнки лобби булу, ягъни кайсыдыр катламнарның мәнфәгатьләрен яклаган кануннар өчен тавыш бирү кесәләргә таба ришвәт чишмәсенең агуы аша тормышка ашырыла иде.* Татарстан яшьләре

2) *к.* **лоббизм**. *Аңа Россиянең һәр эре шәһәрендә үзләренең мегакибетләрен булдырган олигархларның депутат дуслары лобби ясый, ягъни этәрәдер инде.* Ватаным Татарстан

3) *к.* **лоббист**. *Эчкечелеккә каршы көрәш кайберәүләрнең бизнесына аяк чала, аларның лоббилары үзен нык сиздерәчәк, дәүләт казнасына да «шайтан суы» сатудан күп акча керә.* Ватаным Татарстан. *Сәнәгать-финанс лоббилары уртак базарда көндәшләре белән ярышта җиңелүдән куркалар.* Шәһри Казан

ЛОББИЗМ *и. ингл.* Парламентта берәр канун проектын кабул иттерү яки иттермәү яклы карар чыгарту өчен, депутатларга төрле ысуллар белән басым ясау күренеше; гомумән, сәясәттә аерым шәхесләрнең яки берләшмәләрнең мәнфәгатьләрен үткәрү институты. *Безнең хөкүмәт лоббизм белән дә көрәшә алмаслык көчсезгә әйләндеме, әллә моны теләмиме?* Ватаным Татарстан. *Безнең эш-гамәлләребездә конъюнктура яки лоббизм чалымнарын күрергә теләүчеләрнең хаклы булмаячагын ассызыклап үтәсем килә.* Татарстан яшьләре

ЛОББИСТ *и. ингл.* Лоббизм белән шөгыльләнүче. *АКШ конгрессына һәм хөкүмәтенә монополияләр лоббистлар ярдәмендә дә басым ясыйлар.* Иң яңа тарих. *Биотехнологик корпорацияләр лоббистлары трансген продуктларга каршы чыгыш ясаучыларга аяк чалырга маташалар.* Татарстан яшьләре

ЛОББИСТЛЫК *и.* Лоббизм. *Русиягә килгәндә исә, безнең халык мәнфәгатьләренә тел, мәдәният җәһәтеннән лоббистлык җитми.* Мәдәни җомга

ЛО́БЗИК *и. нем.* Агач әйберләрне сырлап кисү өчен кулланыла торган бик нечкә пычкы. *Кискән вакытта лобзик белән яхшы эшли белү бик әһәмиятле.* Йорт эшләре

ЛОБОГРЕ́ЙКА *и. рус* Урылган ашлыкны платформасыннан кулдан ташлап калдыра бара торган, ат белән эшләргә җайланган гади ургыч машина. *Лобогрейка актык үзәнне кыркып чыкканда, чүмәлә салучыларның эшләре дә бетеп килә иде инде.* Ш.Камал. *Бер читтә – тузанга баткан лобогрейка, көлтә-көлтә саламнарны тузгытып чыгарган авызын карга кебек ачкан.* Н.Хәсәнов. *Бергә булсак, лобогрейка, трактор алырбыз, дим.* Мәдәни җомга

ЛОВЕЛАС *и. ингл.* Хатын-кызлар артыннан йөрергә яратучы ир кеше, хатын-кызларны алдалаучы сөйрәлчек ир. *Ул, чынлап та, бик купшынәзакәтле киенгән, үзен йомшак-ягымлы тота, донжуан һәм ловелас.* Р.Мирхәйдәров

ЛОГАРИФМ *и. гр. мат.* Билгеле бер санны табу өчен, нигез санын шул дәрәҗәгә күтәрүне билгеләгән дәрәҗә күрсәткече. *Дәрәҗә һәм нигез бирелгәндә, дәрәҗә күрсәткечен табу гамәле бирелгән нигез буенча бирелгән санның логорифмын табу дип атала.* Алгебра

ЛОГАРИ́ФМИК *с. мат.* Логарифмнарга караган, логарифмны исәпләү өчен хезмәт итә торган

ЛОГАРИФМИК ЛИНЕЙКА *к.* **логарифм линейкасы**. *Исәпләгәндә таблицалардан һәм логарифмик линейкадан файдаланырга тәкъдим ителә.* Геометрия. *Терсәгенә кадәр сызганган кулларына логарифмик линейка тоткан.* Ә.Галиев

ЛОГАРИ́ФМЛАУ *ф. мат.* Бирелгән санның логарифмын табу

ЛОГАРИ́ФМ ЛИНЕЙКАСЫ *и.* Төрле исәпләүләр өчен хезмәт итә торган әсбап, исәпләү линейкасы. *Кичкә таба талчыгу сизеп, кулындагы логарифм линейкасын өстәл почмагына шудырды да торып басты.* Н.Хәсәнов

ЛО́ГИК I *и. гр.* Логиканы белүче кеше, логика белгече

ЛО́ГИК II *с.* 1) Логикага караган, логикага бәйләнешле. *Логик категорияләр*

2) Логика законнарына ярашлы, логика законнарына нигезләнгән. *Аның логик фикер йөртүе, төрле категория кешеләренең психологиясен нечкәләп белүе күп кенә хезмәттәшләрен сокландыра.* Х.Вәлиәхмәтов. *Аның фикеренчә, барча атлар логик фикер йөртә алмаса да, кайберләре бу сәләткә ия, ә Ганс исә бигрәк тә.* Кызыклар дөньясында. *Ул уеннар ялыктырса, логик фикер йөртүгә корылган башваткычлар, кызыклы мәсьәләләр чиштерә.* Татарстан яшьләре

3) Берәр нәрсәнең үзенчәлеге, эчке закончалыгы белән бәйле; закончалыклы. *Либреттода вакыйгалар уңышлы итеп, логик эзлеклелек белән үстерелә.* М.Җәлил. *Логик басым төшкән сүз*

ЛО́ГИКА *и. гр.* 1) Фикер йөртү формалары һәм аның законнары турындагы фән; мантыйк. *Кайбер галимнәр синтаксиста да логика терминнарын кулланалар: ия урынына – субъект, хәбәр урынына – предикат, тәмамык урынына объект дип язалар.* М.Зәкиев

2) Табигать һәм җәмгыять күренешләре турында фикер йөртү тәртибе, шул күренешләргә хас эчке закончалык. *Әйтәсе фикерең --- укучы күңелендә тиешле яңгырау алсын өчен, шигырьдә эзлеклелек, корычтай ныклы логика булырга тиеш.* Казан утлары. *Аның өчен вакыйгалар чылбырының үзелмичә дәвам итүе, аның эчке логикасы – психологиясе сакланууы мөһимрәктер.* С.Шәмси

3) *сөйл.* Фикер йөртү юнәлеше, берәр нәрсәгә караш. *Шундый гаҗәеп бер логика белән Нургали эшкә тотынмакчы була, аңарда дәрт, энергия, ачу һәм ярсу – барысы бергә кайный.* Ә.Еники. *Әле кояш кыздыра иде, зур залда берүзем утыру әллә ничек логикага сыеп бетми иде, ләкин кая барыйм, студентларым сәхнә артында, янында мәш киләләр.* М.Мәһдиев. *Логиканы институтта – бер ел дәвамында, ә хатын-кыз логикасын гомер буе өйрәнергә кирәк.* Мәдәни җомга

ЛО́ГИКАЛЫ *с.* 1) Логик законнарга нигезләнгән, логика законнарына туры килгән. *Логикалы җавап*

2) Эзлекле фикер йөртә торган. *Логикалы кеше*

ЛО́ГИКАЛЫЛЫК *и.* Логикага нигезләнгәнлек, логикалы булу. *Җаваплларның логикалылыгы*

ЛО́ГИКАСЫЗ *с.* Эзлекле булмаган, каршылыклы, логикасы булмаган. *Логикасыз җавап*

ЛО́ГИКАСЫЗЛЫК *и.* Логикасыз булу, логика җитмәү; эзлексезлек. *[Г.Камал типларында] сабыйларча логикасызлык, акылсызлык та гәүдәләнә.* Г.Кашшаф. *Бәлки, Л.Янсуар докладында, ахырга кадәр тыңласак, кайбер яшь калямдәшләренең, көчле абстракцияләргә нигезләнгән, дип мактанган шигырьләрендә логикасызлык күренеше өстенлек итүне әйткән булыр иде.* Шәһри Казан

ЛОГИН *и. ингл. информ.* Компьютер системасында кулланучының теркәлү язуының (аккаунтының) шартлы исеме. *Һәр ата-анага аерым логин, пароль биреләчәк.* Татарстан яшьләре

ЛОГОГРИФ *и. гр.* Шигырь язганда аерым иҗекләрне, хәрефләрне төшереп калдырудан яки урыннарын алмаштырудан гыйбарәт поэтик һәм стилистик алым; шул алым белән эшләнгән башваткыч

ЛОГОПАТ *и. лат. мед.* Сөйләм кимчелеге булган кеше

ЛОГОПА́ТИЯ *и. гр. мед.* Дисфазия, дизартрия һәм дистомия кебек сөйләм кимчелекләренең гомуми атамасы

ЛОГОПЕД *и. лат.* Логопедия белгече. *--- татар балалар бакчаларын югары белемле, татар телен камил белгән белгечләр, тәрбия һәм белем бирү буенча мөдир урынбасарлары, психологлар, логопедлар белән тәэмин итү өстендә эшләргә ---.* Фән һәм тел. *Балага һичшиксез белгеч ярдәме кирәк, ләкин авыл җирләрендә логопедлар юк.* Ватаным Татарстан. *Биредә кызны физиотерапия чаралары, массаж, электр белән дәвалыйлар, бала белән дефектолог, логопед шөгыльләнә.* Мәдәни җомга

ЛОГОПЕ́ДИК *с.* Логопедия белән бәйле. *--- Яңа ел хәйрия ярминкәсендә җыелган акчасына Гәүһәргә логопедик тренажёр алыначак ---.* М.Низаметдинова. *Әлеге концерт ЮНЕСКОның «Сөйләм теле һәм ишетү сәләте бозылган балаларга һәм үсмерләргә логопедик ярдәм» дип аталган халыкара проекты кысаларында оештырыла.* Кызыл таң

ЛОГОПЕ́ДИЯ *и. гр.* Педагогика фәненең сөйләмдәге сакаулык, тотлыгып сөйләү һ.б. кимчелекләрне һәм аларны дәвалау ысулларын өйрәнә торган бер бүлеге. *Көндәлек өй эшләреннән башка логопедия дәресләрендә өйрәнгән сөйләм күнегүләре бик тиз онытыла, шуңа күрә эти-әни бу уңайдан бердәм эш алып барырга тиеш.* Байрак

ЛОГОТИП *и. гр.* 1) Типография шрифтының ике яки өч хәрефтән торган берләшмәсе; лигатура

2) Предприятие, фирма, физик зат, төрле берләшмә һ.б.ш. тарафыннан үзен халык арасында таныту, хәтердә калдыру, реклама кебек максатлар белән файдаланылган, бары тик үзенә генә хас график билге, эмблема яки символ; теркәлгән сәүдә маркасы. *Танышлыгыбызның истәлеге итеп, үзегезгә «Ягуар» логотибы төшерелгән берничә әйбер сайлагыз: галстуктыр, каештыр, шарфтыр ишеләрдән; алар сезгә миннән бүләк булыр.* Р.Мирхәйдәров. *Бейсболканың төрле формада эшләнгәннәре бар. Аны логотип белән яисә үзеңнең исемеңне язып бизәп тә була.* Сак бул!

ЛО́ДЖИЯ *и. ит.* 1) Тышкы стенасы парапет яки рәшәткәдән ясалган һәм колонналары булган бина

2) Йортның алгы ягында озын һәм бик эчкә кертеп ясалган, балкон урынына файдаланыла торган уентык. *Һәр йортка алты бүлмә, алты лоджия арта, дигән сүз бар.* М.Маликова

ЛО́ЖА I *и. фр.* Тамаша залындагы партер һәм ярусларның ян стеналары буенча берничә кеше утырырлык итеп ясалган аерым бүлеме. *Партер ишеге төбенә аягүрә басып тыгылган халыкны ерып-этәреп, кысыла-кысыла фойега чыкты да Гәүһәрләр утырган ложага таба борылды.* Г.Ибраһимов. *Шул чакта мин ложа ишеге төбендәрәк бер*

төркем яшьләрнең кемнедер уратып алуларына игътибар иттем. Ә.Еники. *Ире белән ложада утырган Солтанияне каршы якта теге «биш көнлек командировка»ның үзенә төбәлгән бинокле куырып киптергән шикелле итте.* Ә.Гаффар

ЛО́ЖА II *и. рус* Мылтык, винтовка яки автоматның түтәсе һәм көпшә беркетелгән агач өлеше, кундак

ЛО́ЖА III *и. фр. иск.* Масон оешмасының бүлеге һәм җыелышлар үздыру урыны

ЛО́ЗУНГ *и. нем.* 1) Сәяси, дини һ.б. өлкәләрдә кулланылган, төп идеяне яки таләпне, бурычны белдерә торган кыска мөрәҗәгать; кыска өндәмә; шигарь. *Трибунадан яңгыраган лозунгларга бер дә туры килми ич болар!* А.Гыйләҗев. *Без лозунглар кычкырдык, барабан актык.* М.Мәһдиев. *Декабристларның кыю лозунглары барлык милләтләрнең солдат һәм крестьян массаларына зур йогынты ясый.* Татар әдәбияты тарихы

2) Шундый мөрәҗәгать, өндәмә язылган плакат. *Ул, башта берни эндәшми, стенадагы лозунгларга күз салды, аннан, туп-туры витрина янына килеп, үрелеп-үрелеп аны укый башлады.* Р.Хафизова. *Дин сөреме белән агуланган көйле вәгазьләр, сыйфатсыз рифмалы лозунглар да җитәрлек.* М.Госманов

ЛОКАЛИЗА́ЦИЯ *и.* 1) Локальләшү күренеше; локальләштерү күренеше. *--- хәзер инде биредәге локализация 95 процентка җиткән, ягъни детальләрнең шулкадәр өлеше «камминз Кама»ның үзендә җитештерелә.* Г.Газиз

2) *информ.* Компьютер программаларын берәр илнең культурасына яраклаштыру процессы. *Альберт Фазлый – Android системасына татарча локализация, ягъни интерфейсына тәрҗемә ясаган Hij azz In с. ширкәтенең директоры ---.* Татар заманы

ЛОКАЛИЗА́ЦИЯЛӘНҮ *ф. кит. к.* **локальләшү**

ЛОКАЛИЗА́ЦИЯЛӘҮ *ф. кит. к.* **локальләштерү**

ЛОКАЛЬ *с.* Аерым бер урынга гына хас, билгеле бер чиктән чыкмаган; урынчыл, җирле. *Дөньяда һәлакәтләр күбәеп китте... Төрле җирләрдә локаль сугышлар кабынып китә, --- тоталитар режимнар егыла.* С.Шәмси. *Күк йөзенең төрле почмагында локаль шартлау күренешләре дә булгалый.* Ф.Хәкимов

ЛОКАЛЬЛӘШТЕРҮ *ф.* Чикләү, билгеле бер чикләрдән чыгармау. *Эпидемияне локальләштерү*

Локальләштереп җиткерү Тәмам локальләштерү

ЛОКАЛЬЛӘШҮ *ф.* Билгеле чикләр эчендә туплану, җыелу, шул чикләрдән чыкмау. *Ул түгәрәк, димәк, шул урында гына локальләшкән.* Кызыл таң

Локальләшә башлау Локальләшүгә табан бару

Локальләшә төшү Беркадәр локальләшү

Локальләшә бару Акрынлап локальләшү

Локальләшеп бетү Тәмам локальләшү

Локальләшеп җитү Тәмам, тулысынча локальләшү

ЛОКА́ТОР *и. лат. махс.* Берәр нәрсәнең урынын аңардан килгән тавыш һәм радиодулкыннар ярдәмендә билгели торган аппарат. *Керү белән лоцман елмайды, барыбыз белән дә баш иеп исәнләште һәм, исәнләшүен дәвам иткәндәй итеп, рубка эчендәге приборларны, штурвалны, локаторны, компас репетиторын – бар нәрсәне күзәтеп, барлап чыкты.* М.Юныс. *Ярканатларның кайтаваз тота торган локаторлары аларга һавада очкан бик вак бөҗәкләрне дә табарга һәм шул вакытта бер-берсенә дә бәрелмәскә ничек ярдәм итә.* Мәдәни җомга

ЛОКА́УТ *и. ингл.* Эш бирүче тарафыннан эшчеләргә басым ясау максаты белән акча түләмичә тору, предприятиене вакытлыча ябу, эшләп чыгару күләмен киметү кебекләрдән гыйбарәт чара. *Менә бер заман локаут!* Г.Тукай. *Бу заводның локаут ясап, яшенә-картына, иренә-хатынына карамаенча, урамнарга чыгарып, эшчеләрне газаплаганы мәгълүмдер.* Урал. *Локаут нәтиҗәсендә бихисап хоккейчы вакытлыча эшсез калды.* Кызыл таң

ЛОКА́ЦИЯ *и. лат. махс.* Объекттан килгән яки аннан чагылган сигналларны танып, аның урнашкан урынын билгеләү

ЛОКМА *и. гар.* Бер кисәк, бер кабым ашамлык. *Симез локмаларны бармак арасына кыстырып авызга сузуларын, чәйнәүләрен, бөтен тәме белән үзе кичерә барды.* Г.Ибраһимов. *Әрсез үрдәк, тавыкка ысылдап тора торгач, үзенең бер локма авыз итмичә ач калган чаклары да булгалый, әмма барыбер комсызланып лаканга беренче булып капланмый.* Р.Мулланурова

ЛОКОМОБИЛЬ *и. фр.-лат.* Төрле машиналарны хәрәкәткә китерә торган пар двигателе. *Локомобиль төре*

ЛОКОМОБИЛЬЧЕ *и.* Локомобильдә эшләүче

ЛОКОМОТИВ *и. фр.-лат.* Үзенә тагылган вагоннарны рельс буйлап йөртә торган паровоз, тепловоз, электровоз һ.б. *Локомотив ул синең кеби кабан дуңгызларын түгел, төяләрне дә изеп, яньчеп китәдер.* Г.Тукай. *Үзйөрешле вагонны локомотив дип атыйлар. Беренче локомотивны 200 ел элек төзегәннәр.* Татар теле

ЛОМ *и. рус* Боз, таш, цемент һ.б.ш. каты нәрсәләрне вату, тишү өчен, бер яки ике башы да очлы итеп авыр тимердән ясалган таяктан гыйбарәт эш коралы. *Бу рәсми сүздән соң Фәйзуллин табылдыгын Туфан учыннан тиз генә суырып алды да, кулъяулыкка төреп, эчке кесәсенә салды, чокырга төшеп, бишләтә көч белән ломга тотынды.* М.Галиев. *Җәй уртасы. Урман аланы. Төп кубарып йөри кешеләр. Кайсы көрәк, кайсы лом тоткан, алны-ялны белми эшлиләр.* Ф.Яруллин. *Берсендә мин ломны тартып чыгарган итенеп тартып караган идем дә, кая ул – селкенми дә!* Ә.Галиев

ЛОМБАРД *и. фр.* Залогка әйбер алып, шуның өчен кыска вакытка бурычка акча биреп тора торган кредит учреждениесе. *Мин дә бер пальтомны ултәм, әйдә, дус, ломбардка бар.* Г.Тукай. *Мәскәү белгечләре үткәргән тикшерү нәтиҗәләреннән күренгәнчә, бүген ломбардлар күбесенчә сату белән генә шөгыльләнә икән.* Ватаным Татарстан

ЛОМОВОЙ *и. рус тар. к.* **ломовой извозчик**. *Аннан базардагы агайэнеләргә, чаттагы извозчикларга, кибеттәге приказчикларга, биржадагы подрядчикларга, хәрчәүнидәге половойларга, йөк ташучы ломовойларга күз-колак булырга куштым.* Т.Гыйззәт. *Ломовой арбаларына салынган пулемётларны, утын төсле әрдәнәләп төялгән винтовкаларны каядыр күчерәләр.* К.Тинчурин. *Урамнарда даңгыр-доңгыр узган ломовойлар, тротуар буйларында сала агайларының ат арбалары, кыскасы, нэп тудырган чын базар, чын сәүдә оясы!* Ә.Еники

ЛОМОВО́Й ИЗВО́ЗЧИК *и. рус тар.* Ат белән йөк ташучы, кеше йөртүче һәм шуның арбасы яки чанасы. *Шәрәфи карт ломовой извозчик белән җеназа ящигы алып килде.* Ш.Камал

ЛОМОНОС *и. рус бот.* Казаякчалар семьялыгыннан үрелеп үсә торган күпьеллык үлән яки куак үсемлек. *[Тропикта] һәрбер агач колмак үләне кебек лиана, ломонос, виноград үсемлекләре белән үтә алмаслык хәлдә чорналган.* А.Фәткуллин

ЛОНГЕТ *и. фр. мед.* Сынган сөяк селкенмәслек итеп беркетелә торган гипс бәйләвеч. *Лонгет салу*

ЛО́НЖА *и. фр.* 1) Атны манеж буйлап йөртергә өйрәткәндә кулланыла торган озын йөгән бавы, корда

2) Акробатлык сәнгатендә аеруча катлаулы номерлар күрсәткәндә артистларны имгәнүдән саклап өчен кулланыла торган бау

ЛОНЖЕРОН *и. фр. тех.* Автомобиль рамында, самолёт канатында яки корпусында, кайбер көймәләрдә һ.б. төп буй борыс

ЛО́П-ЛОП *иярт.* Әледән-әле, бербер артлы авыр әйберләр төшкәндә, бәрелгәндә, авыр адымнар белән барганда һ.б.ш.да чыккан тавышны белдерә. *[Песи балалары] лоп-лоп итеп идәнгә егылып төшәләр һәм сәке артына себертәләр.* Һ.Такташ

ЛОПТЫРДА́У *ф. сөйл.* Зур аяк киеме киеп йөргәндә, берәр нәрсәне каты җилфердәткәндә үзенә бер төрле тавыш чыгару. *Баш өстеннән лоптырдап ярканат очып китте.* Г.Ахунов

ЛОПЫРДА́У *ф.* 1) Җилдә җилфердәгән калын, авыр тукыма кисәге чыгарган тавыш барлыкка килү

2) Артык иркен булып, асылынып тору. *Өстенә [Газиз] лопырдап торган озын чикмән кигән.* М.Галәү

ЛОРД *и. инг л.* Бөекбританиядә дворян титулы һәм шул титулга ия булган кеше. *Һәм менә Адмиралтейство лордлары галимнең бу тәкъдиме турында уйланырга керешәләр һәм... 5 ел буена уйлап утыралар.* Кызыклар дөньясында. *--- өстенә лордның халатын кигән, авызында лордның сигарасы.* Татарстан яшьләре

ЛОРД-КА́НЦЛЕР *и. инг л.* Бөекбританиядә монарх тарафыннан билгеләнә торган иң югары дәрәҗәдәге дәүләт чиновнигы

ЛОРДЛЫК *и.* Лорд дәрәҗәсе, лорд титулы

ЛОРД-МЭР *и. инг л.* Англиянең кайбер шәһәрләрендә муниципалитет башлыгы

ЛОРНЕТ *и. фр.* 1) Кысалы монокль төре

2) Колакларга эләктерелми торган, сапка утыртылган тоткалы күзлек

ЛОРХ *и.* Россия селекционеры А.Г.Лорх чыгарган һәм аның исеме белән аталган бәрәңге сорты. *Әмирхан бәрәңге бетте, аның урынына ниндидер мәгънәсез лорх сорты гына калды.* М.Мәһдиев

ЛОСИ́НЫ *и. рус* 1) *тар.* XVIII–XX гасыр башларында рус һәм башка Көнбатыш армияләрендә, хәрби кием буларак тупас замштан тегелгән тар ыштан

2) Эластик материалдан тәнгә сыланып тора торган итеп тегелгән ыштан

ЛОСЬОН *и. фр.* Тирегә һәм чәчкә сибә торган махсус хуш исле сыеклык. *--- Наилә озаклап көзге каршысында бөтерелә, тәненең төрле җирләренә ислемайлар, кремнар, лосьоннар сөртә.* А.Гыйләҗев. *Мондый лосьон тирене чистарта, төрле ялкынсынуларны бетерә.* Мәдәни җомга

ЛОТ I *и. голл.* Гидрографиядә һәм навигациядә кулланыла торган сулык тирәнлеген үлчәү приборы. *Капитан салчыларга лотларны күтәрергә боерды.* С.Сабиров

ЛОТ II *и. нем.* 12,8 грамм микъдарында авырлык үлчәү берәмлеге

ЛОТ III *и. инг л.* Аукционда яки биржада сатуга куелган товар

ЛОТЕРЕ́Я *и. ит.* 1) Билетларга акча һәм әйбер отышлары уйнату. *Мөстәкыйль Татарстан җөмһүриятендә беренче тапкыр акча-әйбер лотереясы үткәрелде.* Казан утлары. *Алманиядә 70 яшьлек карт лотереяга 4 миллион доллар акча откан һәм отыштан баш тарткан.* Мәдәни җомга. *Лотереялар уйнатып кына газетаны яраттырып булмый.* Татарстан яшьләре

2) *сөйл.* Тормышта, эш-гамәлдә нәрсәнең дә булса хәл ителүендәге очраклылык, уңышның яки уңышсызлыкның очраклы булуы. *Югалган буын түгел без, кыйналган буын гына. Тормыш лотереялары уйналган буын гына.* Ф.Яруллин

ЛОТО *и. фр.* Уенда катнашучыларның махсус картадагы рәсем яки цифрларны беренче булып каплап чыгуыннан гыйбарәт отышлы уен. *Җәдитчеләр тарафыннан оештырылган клуб күренешләрендә иң зур культура эше булып лото, домино уйнау күрсәтелә.* М.Гали

ЛОТОК *и. рус сөйл.* 1) *тар.* Элекке вакытларда тартмачыларга урамда йөреп сату итәр өчен, ачык тартма рәвешендә ясалып, җилкәгә каеш белән асылган такта

2) Урамда сату итәр өчен махсус ясалган өстәл

ЛОТОКЧЫ *и. сөйл.* Лотокта сату итүче, кырыктартмачы

ЛО́ТОС *и. гр. бот.* Төнбоекчалар семьялыгыннан орлыклары ашарга яраклы, эре чәчәк ата торган көньяк су үсемлеге. *Иң кыска гомерле чәчәк Амазониядә үсә, ул – Амазонка лотосы.* Кызыклы география

ЛО́ЦИЯ *и. голл.* 1) Корабль йөртү турындагы фәннең йөзү шартларын өйрәнә торган тармагы

2) Елгачы һәм диңгезчеләр өчен гидрологик, метеорология һ.б. кирәкле мәгълүматлар язылган кулланма-белешмә. *[Иван Кириллович:] Дөрес, лоциясе дә, навигациясе дә, компасы да, локаторы да кирәк.* С.Сабиров

ЛО́ЦМАН *и. голл.* 1) Аерым урыннарда йөзү шартларын яхшы белүче һәм фарватердан чыкмыйча диңгез яки елга судноларын үткәрүче белгеч. *Лоцман шул ноктаны тапты, барып басты, сумкасын ачып бинокль чыгарды, блокнот, каләм алып тәрәзә төбенә куйды һәм тагын елмайды.* М.Юныс

2) *зоол.* Ставридалар семьялыгыннан акула һ.б.ш. эре балыклардан калган азык өчен ерак араларны йөзеп үтә торган кечерәк балык. *Бары тик лоцман балыклары гына калган.* Р.Батулла

ЛО́ЦМАНЛЫК *и.* Лоцман вазифасы, лоцман эше. *Лоцманлыкка өйрәнү*

ЛОЯЛЬ *с.* 1) Дәүләт хакимиятенә, органнарына һәм аның гамәлдәге кануннарына, карарларына карата тугрылыклы булган. *Дөрес, безнең илдә руханиларның күбесе лояль, битараф карашта торалар.* Социалистик Татарстан

2) Тугрылыкны күрсәтә, белдерә торган

2) *сөйл.* Яхшы мөнәсәбәттә булган, кемгә, нәрсәгә дә булса яхшы мөнәсәбәт күрсәткән. *Лояль кеше*

ЛОЯЛЬЛЕК *и.* Лояль булу, лояль мөнәсәбәттә булу. *1947 елда Трумэн дәүләт хезмәткәрләренең лояльлеген тикшерү турындагы приказга кул куйды.* Иң яңа тарих. *Хәтта әлеге мәсьәләдә лояльлек күрсәтү йөзеннән, коллегия һәм башка сөйләшүләрне оештыручылар көн тәртибенә берәр галимнең чыгышын кертмичә калмыйлар*. Ватаным Татарстан

ЛӨГАТЬ *и. гар. иск.* 1) Сүз, кәлимә. *«Чеңләшә» кәлимәсе безнең иске лөгатебез булырга кирәк.* Г.Тукай

2) Сүзлек. *Габделвәли үзенә аерым русча-төрекчә лөгать дәфтәре ясады һәм Габдулладан русча өйрәнергә тотынды.* Ә.Фәйзи

ЛӨГАТЬЛЕК *и.* Сүзлектә аңлатма бирелә яки тәрҗемә ителә торган барлык баш сүзләр тупланмасы; шул сүзләрнең исемлеге. *Энциклопедик басмаларны әзерләү барышында лөгатьлек – булачак хезмәтнең бик күп үзенчәлекләре, төзелеше чагылган проспект, басманың тулаем системасын һәм регламентын билгеләүче документ дип әйтергә мөмкин.* Милли нәшрият һәм китап редакторы. *Башта сүзлекнең лөгатьлеген туплау*

ЛӨГАТЬЧЕ *и. иск.* 1) Сүзлекләр төзүче, лексикограф

2) Сүзлекләр бастырып чыгаручы

ЛӨҖ *и. гар. иск.* Чоңгыл, тоба, тирәнлек

ЛӨЗҮМ *и. гар.* Кирәклек, тиешлек. *Шуның өчен алар --- җәмгыять хәйрия ясау лөзүмен күптән хис итмәктә иде.* Г.Тукай. *Рус лисаны илә бәрабәр мәмләкәтемезнең низам вә каванина ашнә улмак лөзүме дә һәммәбезгә мәгълүмдер.* Г.Ибраһимов

◊ **Лөзүм күрү** Тиеш дип табу, кирәк дип санау. *Хәмидә тыныч вакытында каенагасыннан кача торган иде. Мондый [гадәттән тыш] эшләр булып киткәч, яшереneп торырга лөзүм күрмәде.* М.Гафури. *Ул турыда сөйләргә лөзүм күрмичә, фәкать хәтергә килгән берникадәр [фикерләрне] генә язам.* Ф.Әмирхан. **Лөзүм табу** *к.* **лөзүм күрү**

ЛӨЗҮМЛЕ *с. иск.* Кирәкле, тиешле, зарур. *Лөзүмле тәнкыйть*

ЛӨЗҮМЛЕЛЕК *и. иск.* Кирәклек, тиешлек, зарурлык. *Бу берләшмәкнең никадәр кирәклеген, никадәр лөзүмлеген аңлату өчен, мин ушбу мисалны китерәм.* Г.Тукай

ЛӨКАТА *и. гар. иск. к.* **ләкатә.** *[Вәли:] Лөката таптым, лөката, --- урласам, лөката кычкырмас идем.* Т.Гыйззәт

ЛӨФХӘТӘН *рәв. гар. иск. кит.* Бөтенләй, тулысынча. *Лөфхәтән ияру*

ЛӨЭЛӨЭ *и. гар. иск. кит.* Энҗе. *Шул миңа сер чишмәсеннән лөэлөэ вә мәрҗән бирә.* Ш.Бабич

ЛУБОК *и. рус* 1) Өстенә чокып сурәт ясалган юкә такта

2) Шундый тактадан бастырып алынган рәсем; халыкчан рәсем. *Рус лубогы*

ЛУ́ЗА *и. пол.* Бильярд өстәле кырыйларында һәм почмакларында, шар төшерү өчен, астына челтәрле кечкенә капчык беркетеп куелган тишек. *Исе китмичә, артык селтәнмәгән кебек кенә таякны шудырып алуга, гаҗәп көчле шартлап сибелгән пирамидадан ике шар яшен аткан кебек лузага сикерде.* М.Галиев. *Кургашын шарларны шалтыратып лузага салучылар да юк түгел иде.* Ә.Әхмәт

ЛУНА-ПАРК *и. нем.* Бер урынга җыелган төрле-төрле күңел ачу, тамаша, аттракционнар

ЛУНАТИЗМ *и. рус* Йоклаганда, урыннан торып, үз-үзен белештермичә эш-хәрәкәтләр башкарудан гыйбарәт авыру; сомнамбулизм. *Элек аны ай тәэсире белән бәйләгәннәр һәм шуңа күрә лунатизм дип атаганнар.* Кызыклы психология

ЛУНА́ТИК *и. рус* Лунатизм белән авыручы кеше. *[Мостафа:] Нәрсә сез, лунатиклар кебек, төн йокыгызны калдырып, Идел буенда кайнаша идегез?* Г.Гобәй

ЛУ́ННИК *и. рус* Айга ракета ярдәмендә җибәрелгән фәнни станция. *Советлар Союзы җибәргән лунникларның очышы белән Айны һәм Ай тирәсе киңлекләрен өйрәнүдә яңа сәхифә ачылды.* Социалистик Татарстан

ЛУНОХОД *и. рус* Ай өслегендә үзе хәрәкәт итә торган автомат аппарат. *Авырлыгы йөз килограмм булган луноходны кытайлар Чанъэ илаһының мифик куяны хөрмәтенә Юйту дип атаганнар.* Шәһри Казан

ЛУПА *и. фр.* Кысага утыртылган бер яки берничә кабарынкы линзадан гыйбарәт җайланма; зурайткыч пыяла. *Лупа сыман калын пыялалы күзлеге танавының очына ук шуып төшкән, читтән караганда, үзенә күрә түгел, ярыйсы гына укымышлы дама күренә.* А.Хәлим. *Лупа ярдәмендә без предметны 2–25 тапкыр зурайтылган хәлдә күрәбез.* Биология. *Медицина атласын ачып, йөрәк фотослайдын кулдагы лупа белән караштыргалыйм.* Шәһри Казан

ЛУ́РТ-ЛУРТ *иярт. к.* **лүрт-лүрт**

ЛУ́С-ЛУС *иярт. к.* **лүс-лүс**. *Шулай тирән уйга чумып утырганда, лус-лус басып, коридор буйлап Исхак Еникеев килә.* Ф.Балыкчы

ЛУЩИ́ЛКА *и. рус сөйл. к.* **лущильник**. *Күрше станциядән дүрт лущилка алып кайтканнар.* Ф.Сәйфи-Казанлы

ЛУЩИ́ЛЬНИК *и. рус* Туфракны көпшәкләндерә, йомшарта, чүп

үләннәрен тапап уза торган авыл хуҗалыгы машинасы. *Участокны ЛД-10 маркалы дисклы лущильниклар ярдәмендә дүрт эздән эшкәрттек.* Социалистик Татарстан

ЛҮРТ-ЛҮРТ *иярт.* Вак адымнар белән юыртып атлауны белдерә. *Теге бүлмәдә тыныч кына яткан эт, бу тавышка лүрт-лүрт йөгереп кереп, Алевтина Петровнаның бот араларында урала башлады.* А.Хәлим

ЛҮС-ЛҮС *иярт.* Вак адымнар белән салмак кына йөгереп яки юыртып баруны белдерә

ЛЫБЫ *и. мар. диал.* Юкәдән үрелгән кәрзин

ЛЫБЫРДАВЫК *и. сөйл.* Бик күп, артык күп сөйләшүче

ЛЫБЫРДАТУ *ф.* 1) Берәр нәрсәне кайнатып, болгатып, гөбердәгән, лепердәгән тавыш чыгару

2) Сүзләрнең әйтелешен бозу, ачык итеп сөйләмәү. *Сүзләрне бик үк ачык әйтми, авыз эчендә лыбырдатыбрак сөйли.* Н.Фәттах

ЛЫБЫРДА́У *ф.* 1) Әкрен генә лепердәү, гөбердәү. *Аш күңелле генә лыбырдап кайный башлагач, үзенең бик хәтерле, үтә тырыш булуын тагын күрсәтеп өлгерде.* Ф.Баттал

2) Басынкы тавыш белән ишетелер-ишетелмәс, аңлаешсыз сөйләшү

3) Әһәмиятсез, җиңел нәрсәләр турында, уен-көлке белән сөйләшү. *Үзебезнең озын, амбар кенәгәсе хәтле ян кесәләр ябыштырылган язгы-көзге драп пальтоларны киеп, лыбырдап, Амур затонына төштек, тактага төрелгән кызганыч су асты көймәләре белән саубуллаштык.* М.Мәһдиев

4) Артык күп сөйләшү, такылдау; кирәкмәгәнне, урынсыз, саксыз сөйләү. *Тик син бу хакта теләсә кайда, бигрәк тә блоклейтер улы Паул алдында лыбырдама.* Т.Әйди

Лыбырдап алу Берара, бераз гына лыбырдау

Лыбырдап йөрү Теләсә кайда лыбырдау

Лыбырдап тору Бертуктаусыз лыбырдау

Лыбырдый башлау Лыбырдарга керешү

ЛЫБЫРДЫК *и. сөйл. к.* **лыгырдык**

ЛЫБЫ́Р-ЛЫБЫР *иярт.* Әкрен тавыш белән өзлексез сөйләшү тавышын белдерә. *Тик ул тиктомалдан үзалдына һаваланып китеп, минсенергә тотынган: «Мин башкалар ише генә түгел, мин алар белән тиң түгел», – дип, лыбыр-лыбыр сөйләнергә керешкән...* Х.Мәхмүтов

ЛЫГЫР *рәв. диал.* 1) *к.* **лычма**

2) Бөтенләй, артык дәрәҗәдә. *Эләктергәч, кешенең лыгыр исерек килеш, өстәвенә шушы гап-гади сәпидтә тиз чаба алуын белеп, барысы да шакката.* Татарстан яшьләре. *Лыгыр исерек ир төн уртасында өенә кайтып керә дә бусагадан ук хатынына кычкыра.* Акчарлак

ЛЫГЫРДАВЫК *и. сөйл. к.* **лыгырдык**. *[Р.Ильясның] Галиеве типик «намуслы лыгырдавык» булган да чыккан.* М.Җәлил

ЛЫГЫРДА́У *ф.* 1) Белер-белмәс берәр нәрсә турында сөйләү, кирәкмәгәнне, сөйләргә ярамаганны сөйләү. *[Кыз:] Мәхәббәтсез! Лыгырдый шунда җукны.* Г.Тукай. *Я, нәрсә лыгырдый бу юләр тел?!* Н.Гыйматдинова. *Менә шулай юк-бар лыгырдап ансат кына котылмакчы булды Сушков.* Х.Вәлиәхмәтов

2) Артык күп сөйләү, әһәмиятсез, җитди булмаган сүз яисә гайбәт сөйләү; сафсата сату. *Тегермән кебек күп лыгырдыйсың.* Г.Толымбай. *Лыгырда инде, лыгырда, дип, җүләр кеше сыман авыз ерып утырдым.* Г.Мөхәммәтшин. *Ул әйткәнне кире кагу, киресен исбатлау юкка лыгырдау, тәмам буталып бетү булыр иде.* М.Галиев

Лыгырдап алу Берара, бераз лыгырдау

Лыгырдап йөрү Теләсә кайсы җирдә, теләсә кайсы вакытта лыгырдау. *Әле син монда сасытып утырасыңмы? Көн буе өй борынча лыгырдап йөреп армадыңмыни?* Ф.Бурнаш. *Тикшерүче барысын да белә. --- Күрәсең, Гапониныгыз, исереп, үзе лыгырдап йөргән...* М.Насыйбуллин

Лыгырдап ташлау Ялгышлык белән, үзе дә теләмәстән кирәкмәгәнне лыгырдау. *Әйе, мин сине алып китәм, дидем, артыгын лыгырдап ташладым.* Н.Гыйматдинова

Лыгырдап тору Бертуктаусыз лыгырдау; хәзерге моментта лыгырдау

Лыгырдап яту *сөйл. к.* **лыгырдап тору**. *Юкны лыгырдап ятмале яңа-баштан!* Ә.Хәсәнов

Лыгырдый башлау Лыгырдарга тотыну. *Таяк белән тәрәзәнең карындыгына төртеп: – Ни эшләп ятасыз тагы! Әллә төш җиткәнен көтәсезме? – дип лыгырдый башлыйлар.* Г.Ибраһимов

Лыгырдый бирү Бернигә карамый лыгырдау. *«Әйдә, лыгырдый бирсеннәр», – дип уйлады Хәлим һәм авылдан чыкканчы башын төшермәде: янәсе, бик исем китә минем сезгә.* И.Гази

ЛЫГЫРДЫК *и. сөйл.* **1.** Һәрвакыт лыгырдаучы, күп һәм буш сүз сөйләүче, сафсата сатучы кеше, тел бистәсе. *Аннары миңа әйтте: «Мондый лыгырдыкларны бер-ике ай фронт гарасатында газап чиктерәсе иде!» – диде.* Т.Әйди. *Ә мин бөтенләй түземем беткән кеше кебек кыланам, беркетмәне, каләмемне ташлап әйтәм моңа: – Җитте, лыгырдык! Сиңа вакыт әрәм итеп тормыйм мин.* Ф.Галиев. *Мин власть башына килүгә үк лыгырдыкларны куып чыгарачакмын, ди.* Т.Миңнуллин

2. *с. мәгъ.* Күп һәм буш сүз сөйли торган. *Уф, бу лыгырдык авызыңны япмасаң, машинагыздан сикереп төшеп калам инде.* Ф.Яруллин. *Авызыңда ничек тату яши лыгырдык тел белән акыл теше.* Б.Рафиков. *Әти йөгереп барып бер себеркене эләктереп алган да теге лыгырдык Жалатурин кешесенең кирәген бирә башлаган.* Мәдәни җомга

ЛЫГЫ́Р-ЛЫГЫР *иярт.* 1) Су, ботка һ.б.ш. нәрсәләр кайнаганда чыккан тавышны белдерә. *Самавыр кайный, лыгыр-лыгыр килә.* М.Әмир

2) Өзлексез, бертуктаусыз сөйләшү тавышы һәм рәвеше. *Халык, фельдшерга чират көтеп, Сәвилә ягында утыра башлады. --- лыгыр-лыгыр сөйләшәләр, чирдән зарланалар.* Н.Гыйматдинова

ЛЫҖБЫРДА́У *ф. диал.* Артык йомшаклык, булдыксызлык күрсәтү, мәлҗерәү, җебү

ЛЫҖЫРДА́У *ф. сөйл.* Җебеп изрәү, эреп пычрак барлыкка килү. *Лыҗырдаган бакча аларны аяктан суырып алып калды микәнни?* Ә.Хәсәнов

Лыҗырдап тору Лыҗырдаган хәлдә булу

ЛЫК *рәв.* 1) Кинәт, тиз генә. *Ләкин теге үзенекен эшләде: сабыйлар, хатыннарны сытып эчкә узды һәм тәрәзә янындагы урынга лык итеп утырды.* М.Мәһдиев. *Лык итеп күтенә утырды да, күзләрен челт-челт йомып, муеннарын боргалап калды.* Ә.Хәбибуллин. *Өлкән яшьтәге тоткын чиләккә капланып су эчәргә керешкән иде, артына лык иттереп китереп типтеләр.* А.Гыйләҗев

2) Чигенә кадәр, авызына кадәр, шыгрым. *Күр әле син бу байлыкны – сумкам лык тулы – нинди генә ризык юк монда!* Т.Әйди

ЛЫКМА *рәв. диал.* 1) Шыгрым, туп-тулы, чигенә кадәр

2) *к.* **лычма**. *Әз генә шуышуга бөтен өстебез лыкма су булды.* Р.Хафизова

ЛЫКЫЛДАВЫК *с. к.* **лыкылдык**

ЛЫКЫЛДА́У *ф.* 1) *сөйл.* Туктаусыз сөйләү, сөйләп тору. *Утырып сез бозаулар берлә бергә, Лыкылдыйсыз иҗекне бергә-бергә.* Г.Тукай. *Сәер кеше икәнсең, мин һаман лыкылдыйм, ә синең сыңар сүз әйткәнең юк.* М.Хуҗин

2) Кирәкле-кирәксез нәрсә сөйләү, тиешле-тиешсез вакытта, ялгыш сөйләү. *Ниткән Айсин турында лыкылдыйсың син, кода-а-а?* А.Хәлим

3) *диал.* Бытылдау, яшь балаларның төрле авазлар чыгарып сөйләшкәндәй итүе. *Мохтар аның сүзләренә күбесенчә мәгънәсез балалар лыкылдавы шикеллерәк карый.* Ш.Камал. *Урам баласы төсле лыкылдарга керештегез.* Г.Тукай

Лыкылдап алу Бераз лыкылдау

Лыкылдап тору Гел, бертуктаусыз лыкылдау, хәзергә моментта лыкылдау

Лыкылдап утыру Озак, дәвамлы лыкылдау

Лыкылдый бирү Бернигә дә карамый тик үзенчә лыкылдау

ЛЫКЫЛДЫК *с. сөйл.* Туктаусыз һәм күп сөйләүче, сөйләргә яратучы, ләчтит сатучы

ЛЫКЫ́-ЛЫКЫ *иярт.* Туктаусыз сөйләп, сөйләшеп тору рәвешен белдерә. *Лыкы-лыкы килү*

ЛЫКЫНДЫРУ *ф. йөкл. юн. к.* **лыкыну**. *Келәт тулы бодай, баз тулы чөгендер, ник шуны иртән дә, кич тә лыкындырмыйсың!* Н.Гыйматдинова

Лыкындырып тору Берөзлексез лыкындыру

ЛЫКЫНУ *ф. сөйл.* Бик күп ашау, эчү, артык күп, комсызланып ашау, эчү. *Дуңгыз булганчы лыкынмасаң ярамас идемени.* Х.Вәлиәхмәтов. *«Кибет ачылмас борын лыкынып өлгергән», – дип уйлады инспектор...* Ф.Баттал

Лыкынып тору Гел лыкыну; хәзер лыкыну

Лыкынып утыру Озаклап лыкыну. *Аңлый алмыйм мин: ничек инде ул «Кысла» хәрчәүнәсендә көне-төне сыра лыкынып утырырга була?* Р.Гаффар

ЛЫКЫР *с. гади с.* Пычрак, юеш. *Кичә яуган яңгырдан юл лыкыр*

ЛЫКЫРДАТУ *ф. гади с.* Пычрату, пычракка буяу; юешләтү

Лыкырдатып бетерү Тәмам лыкырдату; хәзер лыкырдату

ЛЫКЫРДА́У I *ф. гади с.* Пычрану, пычракка буялу; юешләнү. *Бала пычракта лыкырдый*

Лыкырдап бетү Тәмам лыкырдау; хәзер лыкырдау

ЛЫКЫРДА́У II *ф. гади с.* Юк-бар сөйләү; артык күп сөйләү

Лыкырдап тору Гел, бертуктаусыз лыкырдау; хәзер лыкырдау

ЛЫКЫРДЫК *и. гади с.* Шапшак, пычрак, буялып беткән кеше

ЛЫП *иярт.* **1.** Кинәт утырганда, авыр йомшак әйбер төшеп киткәндә, бәрелгәндә барлыкка килгән тавышны һәм шуның рәвешен белдерә. *Башына кинәттән генә әллә кайдан килеп кергән бу сораулардан аптырашта калыпмы, лып итеп утырды.* Р.Мирхәйдәров. *Лып итеп җиргә килеп төштем.* Ф.Фәтхелислам. *Бохар песиенең лып итеп идәнгә сикерүе ишетелде.* Р.Хафизова

2. *рәв. мәгъ.* Кинәт, капыл. *Янып торган утлы күмер – көлгә салсаң, лып сүнәр.* Мәкаль. *– Ничек яңа кәҗә? – дип гажәпләнде Анна Афанасьевна һәм, хәле бетеп, янындагы ташка лып утырды.* А.Хәлим

ЛЫ́П-ЛЫП *иярт.* 1) Җилдә тукыма җилфердәгәндә барлыкка килгән тавышны белдерә

2) Әледән-әле берәр җиңел нәрсә бәрелгәндә, шартлаганда чыккан тавышны белдерә. *Сөләйманов сизми дә бара икән, баш өстендә үк зенитка снарядлары лып-лып ярылалар, имеш.* И.Гази

ЛЫПТЫРДА́У *ф.* 1) Зур аяк киемен сөйрәп барып, калын тукыма җилфердәп лып-лып иткән тавыш чыгару

2) Йомшак нәрсәгә җиңелчә бәреп лып-лып иткән тавыш чыгару. *Бары пароход көпчәкләренең лыптырдавы белән пароход борынының Идел суын шаулатып барганы гына ишетелә.* Г.Рәхим

Лыптырдап кую Кинәт, аз гына лыптырдау

Лыптырдап тору Гел лыптырдау

ЛЫПТЫ́Р-ЛЫПТЫР *иярт.* Артык иркен аяк киемен өстерәп барганда чыккан тавышны белдерә. *Галош лыптыр-лыптыр килү*

ЛЫПТЫРМА *рәв. диал.* Бөтенләй. *Аяк асты лыптырма кар.* Х.Сарьян

ЛЫПШЫРДА́У *ф.* Сәлперәю, йомшару. *Аның лыпшырдаган симез гәүдәсе хәрәкәтсез; якасыннан ашып, бүртенеп торган муены кып-кызыл.* А.Расих

ЛЫПШЫРДЫК *с.* Буш, асылынып торган, сәлперәйгән. *Ә аның улы Мөрем лыпшырдык зур киемнәрдән, чырадай ябык кыяфәте белән мескен һәм кызганыч булып күренә иде.* А.Расих. *Бераз тыңкыш, өлкән яшьләрдәге, лыпшырдык гәүдәле бу урыс йөзләгән җырны яттан белә...* А.Гыйләҗев

ЛЫПЫЛДАТУ *ф. к.* **лыпырдату**. *Мичтә һаман коры утыннар дөрләп яна, җил чатыр брезентын лыпылдата.* Г.Әпсәләмов

Лыпырдата башлау Лыпылдатырга тотыну

Лыпырдатып кую Бер мәртәбә, кисәк лыпылдату

Лыпырдатып тору Бертуктаусыз лыпылдату

ЛЫПЫЛДА́У *ф.* Лып итү. *Кинәт... «болытлар» лыпылдап җиргә килеп төште!* Татарстан яшьләре

Лыпылдап кую Кинәт лыпылдау

Лыпылдап тору Гел лыпылдау, хәзер лыпылдау

ЛЫПЫН *рәв. диал.* Яссы ягы белән, бөтен өслегенә яткырып, тидереп. *Тактаны лыпын кую*

ЛЫПЫРДАТУ *ф.* 1) Асылынып торган берәр җиңел әйберне, киемне җилфердәтеп үзенә бер тавыш чыгару. *Сукно тышлы кара мех бүрек, киез итекне сыдырып ката ясап бетергән дә чалбар балакларын лыпырдатып рәхәтләнгән.* М.Мәһдиев

2) Асылындырып төшерү, буш, иркен итеп кую. *Клуб эчендә аяк басарлык урын юк, мамык шәлләрен муенга төшереп өйгән яланбаш кызлар, ак киез итекләренең кунычын сыдырып, киң чалбар балакларын лыпырдаткан, сырма кигән егетләр түгәрәк уен уйныйлар иде.* М.Мәһдиев

Лыпырдата башлау Лыпырдатырга тотыну

Лыпырдатып тору Гел, бертуктаусыз лыпырдату

ЛЫПЫРДА́У *ф.* Җил исеп берәр әйберне җилфердәткәндә, озын кием киеп йөргәндә, шулай ук нинди дә булса предмет берәр нәрсәгә җиңелчә бәрелгәндә һ.б.ш. очракларда үзенә бер төрле тавыш чыгу. *Озын күлмәк лыпырдый.* Г.Тукай. *Ботинкаларга авыр балчык сыланды, шинель итәкләре авыраеп, аяк арасында лыпырдап йөдәтте.* Г.Бәширов

Лыпырдап алу Бераз гына лыпырдау

Лыпырдап кую Кисәк кенә лыпырдау

Лыпырдап тору Һәрвакыт, даими лыпырдау

ЛЫПЫ́Р-ЛЫПЫР *иярт.* Җил исеп әйбер җилфердәгәндә, яфраклар селкенгәндә һ.б.ш. вакытларда барлыкка килгән җиңелчә тавышны белдерә. *Әлеге карт тирәк яфраклары да лыпыр-лыпыр килеп әкрен генә шаулыйлар иде.* Г.Галиев

ЛЫПЫРТ *иярт.* Саз, ләм, су кебекләргә кисәк килеп төшкәндә чыккан тавышны белдерә. *Әнвәр кулларын җәеп лыпырт түбәнгә!.. Бот төбеннән бата бу.* Э.Касыймов

ЛЫ́РТ-ЛЫРТ *иярт. к.* **лүрт-лүрт**. *[Ялчы хатын], һәр көн кояш белән бергә кузгалып, көн буенча лырт-лырт йөри.* Г.Ибраһимов. *Бүртә алаша лырт-лырт юырта.* Х.Кәрим

ЛЫРЫ́К-ЛЫРЫК *иярт. к.* **лырт-лырт**. *[Җирән кашка] лырык-лырык юыртып киткән була да озакламый тагын адымлауга күчә.* И.Гази. *Акташтау башыннан лырык-лырык атлап җигүле ат төшеп килә.* Р.Мулланурова

ЛЫ́С-ЛЫС *иярт. диал. к.* **лүс-лүс**

ЛЫСТЫР *с. диал.* Искергән, эленкесалынкы торган. *Лыстыр күлмәк*

ЛЫСТЫ́Р-ЛЫСТЫР *иярт.* Өстерәлеп лыштырдый торган, лычкылачкы килгән тавышны белдерә. *Юл пычрак, лыстыр-лыстыр ат тарта.* Н.Фәттах

ЛЫЧ *рәв. диал.* Бөтенләй, тоташ. *Ашый торган түгел, лыч май*

ЛЫ́ЧКА *и. рус* Кече командир погоннарында тар гына аркылы тасма; җияк. *Сөйгәнең янына погоныңа зурдан я аркылы лычка, я буйга лычка тагып кайтасың.* С.Шәрипов. *Син сугышасың, кан түгәсең, ә орден-медальләр, лычкалар бүтәннәргә элә́гә.* Ф.Галиев. *Ике көн погонсыз йөргәч, төнге унбердә Әхәтне старшина уятты да погоннарына ашыгыч төстә лычка тагып куярга кушты.* Казан утлары

ЛЫЧКЫ *с. диал.* Лычкылдаган, чи, сулы, пешеп җитмәгән. *Лычкы ипи*

ЛЫЧКЫ́-ЛАЧКЫ *иярт.* Пычрак яисә су ерып барганда барлыкка килгән тавышны белдерә. *Лычкы-лачкы. Каяндыр ерактан шундый тавыш ишетелә. Әнә ул чокырга якынлашты.* Ф.Кәрим

ЛЫЧКЫЛДАТУ *ф. сөйл.* 1) Юеш җирдән барганда яки юеш аяк киеме белән йөргәндә һ.б.ш. вакытларда үзенә бертөрле тавыш чыгару; чапырдату

2) Яңгырның, юеш карның явуы нәтиҗәсендә җирне юешләтү

3) Чәпелдәтү

Лычкылдата башлау Лычкылдатырга тотыну

Лычкылдатып алу Бераз гына лычкылдату

Лычкылдатып тору Вакыт-вакыт яки гел, туктаусыз лычкылдату. *Сыер су эчеп бетергәч, урыныннан кузгалмый, эч пошырып, авызын лычкылдатып тора бирә.* М.Әмир

ЛЫЧКЫЛДА́У *ф. сөйл.* 1) Юеш аяк киеме белән йөргәндә, юеш җирдән барганда, гомумән берәр юеш әйбер белән эш иткәндә, үзенә бертөрле тавыш барлыкка китерү, чапырдау; чаптыр-чоптыр (чапыр-чопыр, лачлоч) итү. *Идән такталары астында баскан саен су лычкылдый.* Г.Әпсәләмов. *Баскан җирдә җир лычкылдады.* А.Хәлим

2) Артык юешләнү. *Җылы, кояшлы көннәрдә бөтен дала чыланып, лычкылдап ятты, һәм бөтен тирә-якка җиңелчә дым, юеш исе таралды.* Н.Фәттах

3) Камырдан пешерелгән ашамлыкның чи булуын белдерә. *Ачлык елларда халык барда алып кайтып, шуңа көрпә кушып ипи пешерә, ул ипи ачы була, лычкылдап тора иде.* М.Мәһдиев

Лычкылдап бетү Тәмам, тоташ лычкылдау

Лычкылдап кую Бер мәртәбә лычкылдау. *Аяк бармаклары лычкылдап куйды.* А.Хәлим

Лычкылдап тору Лычкылдаган хәлдә булу. *[Мәликә:] Әхмәтләргә ашка барган идем, үрдәк бөккәннәре бер дә пешмәгән, бөтенләй лычкылдап тора.* Г.Камал

Лычкылдый башлау Лычкылдарга тотыну. *Габитнең чабатасы да лычкылдый башлады.* Ф.Кәрим

ЛЫЧКЫЛДЫК *с.* 1) Җебегән, юеш, сылана, ябыша торган (җир һ.б.ш. тур.). *Көн яктысын тагын да сүрәнәйтеп, иртәдән үк ниндидер кара канатлы, лычкылдык кар яуды.* А.Хәлим

2) Пешеп җитмәгән, кабармаган, чи (ипи тур.)

ЛЫЧМА *рәв.* **1.** Бөтенләй, манма, тулысы белән (юешләнү, чылану). *Аяккуллары урманга барып җиткәнче үк лычма су булды.* А.Хәким. *– Аны хәзер абзарына алып китәләр! – диде, лычма су өс киемнәрен сыпыргалап.* Ә.Галиев

2. *с. мәгъ.* Тоташ юеш, манма су булып юешләнгән. *Портрет эленгән стенаның обойлары лычма.* Ф.Яруллин

ЛЫЧТЫРДА́У *ф. сөйл.* Су белән маташу, чыпылдау. *[Ул] кер уа, лычтырдый, су чәчрәтә.* М.Әмир

ЛЫЧТЫРТ *иярт.* Юеш җиргә кисәк китереп бәргәндә, сикереп төшкәндә чыккан тавышны белдерә. *Җиргә лычтырт итеп сикереп төшкәндә, ул әнисенең капкадан чыгып килүен искәреп алды.* М.Галиев

ЛЫЧЫ́К-ЛЫЧЫК *иярт.* Юеш балчык яисә башка төрле сыеклыкка ни белән дә булса кагылганда чыккан тавышны белдерә. *Лычык-лычык итеп балчык изү*

ЛЫШ *рәв. диал.* Тоташ. *Уф, аяк асты лыш измә, итекне суыра.* Н.Гыйматдинова

ЛЫШК *иярт.* Борын тартып куйганда барлыкка килгән тавышны белдерә. *Малай лышк иттереп борынын тартты.* А.Гыйләҗев

ЛЫШКЫЛДАТУ *ф.* Борынны тартып-тартып алу. *Әбисенең: «Ә акылын үлчәмәделәрме?» – дип төпченүенә әлеге малай, борынын лышкылдатып: «Юк, анысын үлчәмәделәр», – дип җавап күндергән.* Татарстан яшьләре

Лышкылдата башлау Лышкылдатырга керешү. *Разия: «Монавы кадәр һәйбәт черек бәрәңгене чыгарып түгә диме кеше», – дип, борынын лышкылдата башлады.* А.Хәлим

Лышкылдатып алу Бераз гына лышкылдату. *– Ярыйсы гына номер килеп чыкты бугай. – Флегонт янә борынын лышкылдатып алды.* З.Фәтхетдинов

Лышкылдатып йөрү Гел лышкылдату

Лышкылдатып кую Тиз генә, бер мәртәбә лышкылдату. *– Тәк, – дип, менә болайрак борынын лышкылдатып куйды ул.* Ф.Шәфигуллин

Лышкылдатып тору Туктаусыз лышкылдату

ЛЫШКЫЛДА́У *ф.* Сулкылдап елау, борын тарта-тарта елау, лышык-лышык елау; елаудан борын йомшару. *Залдан ишетелә торган кәеф-сафа тавышлары, шау-шулар хәзрәтнең бу лышкылдавын әллә ничек җиңел һәм көлке итеп ишеттерәләр иде.* Ф.Әмирхан. *Ир лышкылдаган борынын җиң очына сеңгерде.* Н.Гыйматдинова

Лышкылдап алу Бераз гына вакыт лышкылдау

Лышкылдап кую Кинәт лышкылдау

Лышкылдап тору Берөзлексез лышкылдау

ЛЫШКЫЛДЫК *с.* Лыштырдаган, гел лыш-лыш итеп торган

ЛЫ́Ш-ЛЫШ *иярт. к.* **лышык-лышык**. *Иңбашларының җиңелчә дерелдәвеннән, лыш-лыш борын тартуыннан Хәбир аның елавын аңлады.* Ш.Хөсәенов

ЛЫШПЫРДА́У *ф.* Үзенә таман булмаганга эленке-салынкы тору, дөрес тормау, артык иркен, зур булу

Лышпырдап тору Зур булып күренү

ЛЫШПЫРДЫК *с. сөйл.* Зур, эленке-салынкы торган, лышпырдап торган (кием тур.). *Рәхим өстендәге лышпырдык зәңгәр халатка күз ташлады да үзалдына әрнеп елмаеп куйды.* А.Расих

ЛЫ́ШТ-ЛЫШТ *иярт.* Борын тартканда чыккан тавышны белдерә. *Мин мондый вакытларда, гаепле булып күренү кирәктер дип, лышт-лышт борын тартып --- ашка кайта торган идем.* Г.Минский

ЛЫШТЫ́К-ЛЫШТЫК *иярт. к.* **лыштыр-лыштыр**. *Чүәкләр лыштык-лыштык сөйрәлеп киләләр.* Ф.Хөсни

ЛЫШТЫР *с.* Лыштырдап торган, өстерәлә торган, зур (аяк киеме тур.). *Аякларында [егетнең] олы-олы лыштыр галошлар.* Р.Төхфәтуллин

ЛЫШТЫРДАТУ *ф.* Аяк киемен дөрес яки ахырынача кимичә, зурракны киеп сөйрәү, шудырып атлау. *Бабайның иске кәвешен лыштырдатып узып китүен инде онытып бетердек.* Г.Бәширов

ЛЫШТЫРДА́У *ф.* Аяк киеме юеш яки зур булганлыктан, өстерәп йөргәндә үзенә бертөрле тавыш чыгу. *Галошлар лыштырдый*

Лыштырдап тору Лыштырдарлык дәрәҗәдә иркен булу

Лыштырдап кую Кинәт лыштырдау

ЛЫШТЫРДЫК *с. сөйл.* Лыштырдый торган. *Лыштырдык аяк киеме*

ЛЫШТЫ́Р-ЛЫШТЫР *иярт. к.* **лаштыр-лоштыр**. *Авыр атлап Сәйяф та лыштыр-лыштыр китеп барды.* М.Мәһдиев. *Мин, адымнарымның тагын да ныграк авырайганын сизеп, лыштыр-лыштыр Миңҗамал түти артыннан теркелдим.* А.Гыйләҗев. *Дерелдәп, тешем тешкә тимәстәй булып, өйгә лыштыр-лыштыр кайтып кергән идем.* Н.Хәсәнов

ЛЫШЫ́К-ЛЫШЫК *иярт.* Сулкылдап елаганда яки борынны еш-еш тартканда барлыкка килгән тавышны белдерә. *Без, идәнгә караган килеш, лышык-лышык борын тартып тик торабыз.* Р.Хафизова. *Теге юньсез борынын лышык-лышык тартып тора да: – Өскә, – ди.* Р.Зарипов. *Син исә каласың, лышык-лышык танавыңны тартып!* А.Хәлим

ЛЬГОТА *и. рус* Куелган таләпләрне, кагыйдәләрне үтәүдән тулысынча яки өлешчә азат итү яки аларны үтәү шартларын җиңеләйтү; ташлама. *Солдат семьяларына льгота, дип сөйләгәннәр иде.* М.Мәһдиев. *Безнең ишеләргә дә льгота, җиңеллекләр бар икән: шәһәр тирәсе автобуслары һәм электр поездларында бушлай йөрү, квартирга, телефонга, даруларга яртылаш кына түләү хокукларым бар.* М.Зарипов. *– Озакламый сезнең өчен яңа льготалар барлыкка киләчәк, пенсияләр артачак, – дип, пенсионерларның башын әйләндерә.* Татарстан яшьләре

ЛЬГО́ТАЛЫ *с.* 1) Льгота бирә торган; льготасы булган, ташламалы. *Инде быел бирелә торган льготалы урынга йөз чакрымнан үк үкереп-дулап килгән, җиле белән үк башкаларны егып салачак претендентлар да юк иде.* Х.Сарьян. *Гражданнар нормадан чыкмаган очракта льготалы тариф буенча, ә инде электрны артык кулланганда икътисади нигезләнгән яңа тариф буенча түләячәкләр.* Татарстан яшьләре

2) Льготага хакы булган, льготадан файдаланган. *2009 елдан алып Башкортстан Республикасында гражданнарның барлык льготалы категорияләренә торак һәм коммуналь хезмәтләр өчен түләү буенча льготалар айлык акчалата компенсацияләр белән алыштырылды.* Өмет

ЛЬЕ *и. фр.* Франциядә чама белән 4,5 км га тигез булган борынгы

озынлык үлчәү берәмлеге. *«Париждан өч мең льө ераклыкта үземнең соңгы резервымны куркыныч астына куя алмыйм», – тарихта билгеле шушы сүзләрне әйтеп, Наполеон китеп бара.* Кызыл таң

ЛЮ́ВЕРС *и. голл.* 1) Җилкән беркетә торган бауны үткәрү өчен, җилкәндә ясалган түгәрәк тишек

2) Гомумән күн, тукыма, кәгазь әйбердә (пәрдә, кием-салым һ.б.ш.) бау, шнур кебек нәрсәләр кертү өчен тишек тишеп, аның кырыйларын ныгыту өчен куела торган тимер яки пластик втулка

ЛЮИЗИТ *и. хим.* Америка химигы Уинфорд Ли Льюис исеме белән аталган, химик корал буларак кулланылган, куе көрән төсле сыекча формасындагы агулы матдә. *Люизиттан зарарлану*

ЛЮК *и. голл.* 1) Түбәнгә төшү, эчкә үтү өчен, капкач белән ябыла торган тишек. *Танкистлар люкларын ябып танкларына утыралар.* Г.Әпсәләмов. *Фрицлар һаман машинаның бронясын төяләр, рус солдатларына тизрәк люктан чыгып, пленга бирелергә тәкъдим итәләр.* Р.Хафизова. *Каршында – ачык люк.* Р.Вәлиев

2) Нинди дә булса механизм яки корылманың берәр җирендә билгеле максат белән – күзәтү, чистарту, төяү-бушату һ.б.ш. өчен калдырылган тишек, уем. *Самолёт түшәмендәге люкта пулемёт янында пулемётчы юк.* Г.Гобәй

ЛЮКС I *и. лат. физ.* Яктылык чыганагыннан алынган яктыртылу дәрәҗәсен үлчәү берәмлеге. *Ә ябалак исә төнлә 0,00002 люкс яктылыкта да хәрәкәтсез утырган тычканны күрә ала. --- без яшәгән киңлекләрдә чалт аяз көнне төш вакытында кояш җир өстенә 100 мең люкслы яктылык чәчә.* Р.Фәизов

ЛЮКС II *и. фр.* Кунакханә номерлары, купе, каюта кебекләрнең җиһазлану, хезмәт күрсәтү һ.б.ш. ягыннан иң югары сыйфатлы классы. *Төнне без юбилей делегаты Марсель Галиев белән Туфан Миңнуллинның люксында уздырдык.* М.Мәһдиев

ЛЮ́ЛЬКА *и. рус* 1) Кеше яки материалларны югарыга күтәрә торган асылмалы читлек яки басма. *Әллә, мәйтәм, кешеләрне подъезддан түгел, урамнан гына, теге малярлар люлькасы кебек нәмәрсәләр белән күтәрә башларгамы?* Д.Гыйсметдин

2) Мотоцикл бишеге

ЛЮ́ЛЬКАЛЫ *с.* Люлькасы (*2 мәгъ.*) булган. *--- Мин йортка авыл советы председателен чакырттым, ул инде барысын да белә, участковыйга да хәбәр итеп өлгергән икән, люлькалы мотоциклына утырып, анысы да килеп җитте.* М.Мәһдиев. *Берәү иренең люлькалы матаена утырып, югарыга таба җилдерде.* Кәеф ничек?

ЛЮ́МЕН *и. лат. физ.* Яктылык агымын үлчәү берәмлеге. *Әгәр бер люмен яктылык агышы бер берәмлек зурлыгындагы мәйдан өстенә тигез төшсә, ул мәйданның яктыртылуы бер берәмлеккә тигез була.* Физика

ЛЮМИНЕСЦЕ́НТ *с. физ.* Люминесценциягә нигезләнгән. *Иң әүвәле ул балчыгы кубып, саргаеп беткән түшәмне, чебеннәр һәм озынборыннар сарып алган люминесцент лампаны күрде.* З.Мәхмүди. *Чардакларга ящерелгән люминесцент лампалары күзләрне талдырмый торган тигез яктылык бирәчәкләр.* Социалистик Татарстан

ЛЮМИНЕСЦЕ́НЦИЯ *и. физ. лат.* Газ, сыеклык яки каты җисемнең, җылылык нурлары чыгармыйча, салкын яктылык нурларын чәчү күренеше. *Люминесценция күренешләре*

ЛЮМИНОФО́Р *и. лат.* Сеңдергән энергияне яктылык нурланышына әверелдерү үзлегенә ия матдә

ЛЮ́МПЕН *и. нем.* Бернинди мөлкәте, даими эше булмаган, бернинди социаль катламга карамаган, сукбай, хәерче, җинаятьче һ.б.ш. кеше. *Ни өчен соң [Җәгъфәр] шундый өтек люмпен кыяфәтендә?* А.Расих. *Без, янәсе, – люмпен, плебей!..* Р.Батулла

ЛЮМПЕНЛАШУ *ф. кит.* Люмпенга әйләнү. *Ул Дмитрий Медведев башлаган модернизацияләүнең барып чыкмавын халыкның битарафлыгыннан, актив булмавыннан һәм түбән профессиональлегеннән, люмпенлашуыннан һәм дебиллашуыннан күрә.* Ватаным Татарстан

Люмпенлашып бетү Тәмам люмпенлашу

ЛЮ́МПЕН-ПРОЛЕТАРИАТ *җый. и. нем.* Пролетариатның иң түбән, юксыл катлавы. *Капитализмга хас булган конкуренция нәтиҗәсендә буржуа сыйныфының бер өлеше банкротлыкка чыга, бөлгенлеккә төшә һәм люмпен-пролетариатка әверелә.* М.Абдрахманов

ЛЮНЕТ *и. фр.* 1) *иск.* XVII гасырдан XX гасыр башына кадәр ясалган, арт ягы ачык, зур булмаган хәрби ныгытма

2) *махс.* Гөмбәз эчендә, ишек яки тәрәзә өстендә дугасыман уем, архитектур бизәлеш детале

ЛЮПИН *и. лат.* Кузаклылар семьялыгыннан терлек азыгы итеп файдаланыла һәм декоратив үсемлек буларак үстерелә торган үлән үсемлек; бүре борчагы. *Люпинның куагы бик зур булып үсә, шуңа күрә аның орлыкларын 50–60 сантиметр ара калдырып чәчергә кирәк.* Йорт эшләре. *Люпин, хризантема, канәфер, ландыш чәчәкләре кар эреп бетү белән чыгалар.* Татарстан яшьләре

ЛЮ́СТРА *и. фр.* Элек – күп шәм, соңгы вакытта күп лампочка куелган асылмалы яктырту лампасы. *Минем әле запаста тагын бер җөмләлек ясалма тавышым бар иде, һәм мин бөтен конференц-залның люстралары селкенерлек итеп ярдым.* М.Мәһдиев. *Җыелышып төштек тә трюмга люстра астык.* М.Юныс. *Радиотелевидение дикторлары теле белән әйткәндә, корбаннар һәм җимерелүләр әлегә юк, Аллага шөкер, әмма квартирларда люстралар чайкалып, шкафлардагы савыт-сабалар шалтыраулар булгалап тора.* М.Зарипов

ЛЮСТРИН *и. фр.* Ялтырап тора торган юка йон яки мамык катнаш йон тукыма

ЛЮТЕРАН *и. нем.* Лютеранлык динен тоткан кеше. *Үзгәртеп кору шартлары гамәлгә аша барган бер чорда, 1991 елда, Казанда немец-лютераннар җәмгыяте (рәисе В.Диц) оешып, аңа Карл Фукс исеме бирелде.* Мәдәни җомга. *Яһүдләр җәмгыятенә – синагога,*

лютераннарга кирха кайтарып бирелде, чиратта католиклар җәмгыяте тора. М.Шәймиев

ЛЮТЕРАНЛЫК *и.* Протестант диненең XVI йөздә Мартин Лютер өйрәтмәсе нигезендә барлыкка килгән бер тармагы. *Лютеранлык – протестантлыкның сан ягыннан иң зур юнәлеше.* Мәдәни җомга. *Без немец культурасын лютеранлыкны тергезү аша кайтару ягында*. Ватаным Татарстан

ЛЮФА *и. лат. бот.* 1) Кабакчалар семьялыгыннан җимешләре зур кыярга охшаган, тропик һәм субтропикларда үсә торган үрмәле үсемлек. *Моңа мисал итеп мунчала урынына кулланыла торган люфа җимешен күрсәтергә мөмкин.* Робинзон эзләреннән. *Люфа дигәне – Африкада үсә торган үсемлек*. Шәһри Казан

2) Шул үсемлекнең җепселле җимешеннән киптереп хәзерләнгән болыт мунчала. *Кайбер сабыннарга бал, каһвә бөртекләре, диңгез тозы, коңгырт шикәр --- яки люфа кушам*. Шәһри Казан

ЛЮФТ-КЛОЗЕТ *и. нем.-фр.* Гомуми канализация челтәренә тоташтырылмаган йортларда гади җылы бәдрәф. *Әгәр андый бәдрәфләр булмаса, өйгә терәп салынган кечкенә бинада яки турыдан-туры өй алдында җылы люфт-клозет ясау яхшы.* Йорт эшләре

ЛЮЦЕ́РНА *и. лат.* Кузаклылар семьялыгыннан терлек азыгы итеп игелә торган үлән үсемлек. *Биек-биек шомабаш сенаж башняларында җылы җил уйный, алар да Язкилде болыннарының печәнен, кырларының люцернасын, кукурузын, борчак саламын көтеп, дүртәүләшеп балкып утыралар.* А.Гыйләҗев. *--- билдән булып үскән озын сабаклы люцерна чабучылар да, җәйләүдәге көтүчеләр дә – барысы да кайнар аш белән салкын компот китерүче Хәмдияне көтәләр.* Г.Галиев. *Сыер асраган колхозчыга ындыр артыннан бер гектар җир бирергә һәм люцерна, клевер чәчтерергә, шуңа өйрәтергә кирәк.* М.Мәһдиев

ЛЯ *и. муз. ит.* Музыка гаммасының «до»дан башлаганда алтынчы авазы һәм аны белдергән нота исеме. *Ля нотасы*

ЛЯҖҮРД *и. гар. к.* **лазурь**. *Лазурь турында: «Лазурь – ляҗүрд, кыйммәтле күк буяудыр», – ди.* Фән һәм тел

ЛЯЗИМ *с. гар. к.* **лазем**. *Бер кемсәнә уяулыкны үзенә лязим итсә, дошманнан тәләф булмактан әмин булыр...* К.Насыйри. *Күңелең төшенке чакта мунчага керү лязим.* Р.Мулланурова. *Яшьлек дустын, тагын да дөресрәк әйтсәк, аның гаиләсен, инде, соңгы чиктә, тәмам котылгысыз, лязим дөреслек белән әйтсәк, үзенең утыз ел күрешә алмаган хәрби хезмәттәше Сабирны, әлбәттә, аның гаиләсен күрү өчен, ерак Чаллыдан Сабантуйга кайтып төште.* А.Хәлим

ЛЯИХӘ *и. гар.* 1) Проект

2) Берәр эш яки закон өчен төрле яктан карап, тикшереп әзерләнгән тәкъдим. *Дөресен әйткәндә, бу ляихә алдан ук хәзерләнеп килде.* Г.Гобәйдуллин

ЛЯ́МКА *и. рус* 1) Авыр йөкне тартып алып бару яки күтәреп ташу өчен, иңбашына салына яисә киелә торган күн я башка ныклы тукымадан ясалган киң тасма, каеш. *Култык аслары-ннан тарттырып камыт сыман әйбер белән лямка кигән --- бер төркем кешеләрнең бөгелә-сыгыла ниндидер авыр нәрсә тартып барганлыклары күренде.* М.Гали. *Хәйрулла белән Сафа лабаздан лямкалар алып килгәндә, көймәдән арканны кырыйга ыргыткан иделәр инде.* Ш.Камал

2) Сарафан, бюстгальтер, эчке күлмәк кебек киемнәрне күтәртеп тору өчен иңбаш аша төшкән тасма

ЛЯ́ПИС *и. лат. хим.* Медицинада вак җәрәхәтләрне яндыру өчен кулланыла торган төссез кристаллар формасындагы көмеш нитраты. *Яраны ляпис белән эшкәртү*

ЛЯПИС-ЛАЗУРЬ *и. лат.-фар.* 1) *к.* **лазурит**

2) Лазурит минералыннан төеп ясалган натураль пигмент, буяу; ультрамарин

ЛЯ́ПСУС *и. лат. кит.* Ялгыш әйтелгән сүз, ярамаган сүз; тупас, мәгънәсез хата. *Ляпсус җибәрү*

ЛЯХ *и.* 1) *иск. к.* **ләх** I. *Анатолий кычкырып «Тарас Бульба»ны укый. --- Татарларны бик мәсхәрәләп телгә алган җирләрне Натолька сикертеп уза я, татар диясе урынга, лях (поляк) дип укып китә.* И.Гази

2) Силезиянең бер өлешендә һәм Моравиянең төньяк-көнчыгышында яши торган чех халкының бер этнографик төркеме

М

МАВЗОЛЕЙ *и. гр.* Үлгән кешенең, гадәттә зур дәүләт яки сәясәт эшлеклесенең гәүдәсен кую өчен махсус камерасы, кайвакытта искә алу залы булган зур монументаль корылма; төрбә. *Күкрәге киерелеп алга чыккан. Башы югары күтәрелгән: парадта мавзолей яныннан узамыни!* И.Салахов. *Бохарада Саманитлар мавзолеен салганда гына, кирпечкә төгәл форма бирү өстендә ныклап уйлана башлаганнар.* Ф.Баттал. *Казан ханлыгы чорында шушы борынгы мәчет янында, аңа терәлеп диярлек, ак таштан салынган мавзолейлар – төрбәләр торган.* Ф.Хуҗин

МАВР *и. гр. тар.* 1) Борынгы римлыларда Көнбатыш Җәзаир һәм Көньяк Марокко халкының гомуми атамасы; Урта гасырларда Пиренеи ярымутравында һәм Төньяк Африкада яшәгән мөселманнарның европача атамасы. *Безнең каршыда XIII гасырда маврлар тарафыннан салынган готика стилендәге карачкыл замок тора иде, пляжга арт белән борылдык та шул замокны фотога төшерергә тотындык.* М.Мәһдиев. *Кинәт Сивилья, Гранада калаларының гарәпләре – маврлар чоры күз алдына килеп баса.* М.Юныс. *--- Беренче дөньяви университет VIII гасырда маврлар (гарәпләр) тарафыннан Испаниянең Кордова хәлифәтендә ачыла.* М.Әхмәтҗанов

2) Башлыча хәзерге Мавританиядә, шулай ук Сахара Көнбатышы, Мали, Нигер һ.б.ш. илләрдә яшәүче, гарәп теленең хәсәния диалектында сөйләшүче гарәп-бәрбәр халкы

МАВРИТАН *с.* Мавритания (Төньяк-Көнбатыш Африкада, хәзерге Көнбатыш Җәзаир һәм Көнчыгыш Марокко территориясендә, тарихи өлкә) белән бәйле, Мавританиядә барлыкка килгән. *Мавритан стилендә корылган бу бина тыштан ук бик күркәм күренә.* Ж.Фәйзи. *Парктан чыгышлый, без «Мавритан беседкасы» аша үттек.* Ә.Еники. *Мин шәһәр үзәгенә – чынаяк җәйгән урамнар, чынаяк оялар эчендә үсеп утырган пальмалар, мавритан ысулындагы офислар тупланган мәхәллә гә юл тотам.* М.Юныс

МАВЫГУ I *ф.* 1) Берәр нәрсә белән бик кызыксыну, барлык игътибарны шуңа юнәлдерү, тулысынча бирелү. *Гыйлаҗ бабай истәлекләре белән мавыгып, вакыт узганын да сизми калдык.* М.Шабай. *Бер яклы яшибез: аерым проблема белән мавыгып, иң мөһиме шул дип, бүтәннәрен онытабыз.* Ш.Галиев. *Китапны укып бетергән чакта, ул инде ташлар турындагы фән белән тәмам мавыккан иде.* Дөньяда ниләр бар

2) Тәмен табу, юану, онытылу. *Икесенә дә нидер эшләргә, ничек булса да мавыгып онытылырга, туган якка ясалган сәфәрнең авыр хатирәләрен онытып торырга кирәк иде.* А.Гыйләҗев. *Улы башта, утау чорында, тургай сайраганны тыңлап ята иде. Урак өстендә исә башак шавы, иген арасыннан пырхылдап очып чыккан бүдәнәләр белән мавыкты. Әллә еламады да инде?* Ж.Рәхимов. *Авто белән мавыгып, Борис аракысын ташлар, шофёр булып эшкә урнашыр, дип алынган нәрсә.* М.Насыйбуллин

3) Артык ышану, өмет баглау; кирәгеннән артык куллану, чамасын югалту. *Ханәфинең иң зур хатасы, әлеге шул аракы белән артык мавыгып, эшенә тиешенчә әһәмият бирмәүдә --- булды.* В.Нуруллин. *Һәр төштән шпион эзләү белән мавыкмаска кирәк, аныcы. Әмма бу юлы сез эзләгән юнәлеш тә кызыклы.* З.Фәтхетдинов. *Без сугыш еллары шигъриятенең, бизәк өчен генә матур сүзләр белән мавыкмыйча, нинди ачы булса да, дөреслекне күзгә карап әйтергә омтылуын беләбез.* С.Маннапов

4) Бер нәрсә белән бирелеп шөгыльләнү, шуның белән генә мәшгуль булу, бөтен игътибарны шуңа гына юнәлтү. *Гомумән, сез шигърият законнарын белеп бетермисез, рифмалар белән мавыгып, шигырьнең иң әһәмиятле компоненты ритмга игътибар бирмисез.* Ж.Фәйзи. *Берәр эшкә тотынса, ихлас бирелә, мавыгып эшли, дуслыкка да бервакытта да хыянәт итми.* М.Насыйбуллин. *Дәртләнеп, дөньясын онытып мавыккан кеше алдында үзеңнең битарафлыгыңны күрсәтү яхшы түгел.* Р.Мөхәммәдиев

5) Мәшгуль булу, шөгыльләнү, эшләү. *Бар да эшли, тырыша, яши, мавыга бертуктамый ---.* С.Сүнчәләй. *--- Иаков турында: «Епархиясендәге попларның Советка каршы вәгазьләрен хуплый, ул гына да түгел, үзе шундый эшләр белән мавыга», – дигән сүзләр хак булырга охшый.* З.Фәтхетдинов. *--- Фәрит Яруллин турында китап язганда, киңәшкә килгәч, Нәкый ага миңа, нибары берәр сәгатьтән артык мавыкмаска тырыш, дигән фикерен белдергән иде.* Р.Низамиев

6) *күч.* Кемгә дә булса гашыйк булу; берәүнең йогынтысына эләгү. *Мин аның белән мавыктым, мин аңа сокланып карый башладым. Ул – мактаулы егет.* Ә.Еники. *Минем һәрчак бер мавыккан кешем була. Берсеннән бизәм, икенчесенә күчәм...* Ш.Галиев

Мавыга бару Торган саен күбрәк мавыгу. *Миңсылу белән торган саен ныграк мавыга баруын тойды ул.* М.Хәсәнов

Мавыга башлау Мавыгу сизелү. *Аннары әкренләп мавыга башлады, тизрәк, кызыксыныбрак укырга тотынды.* Г.Әпсәләмов. *Ә соңгы вакытта, үзем дә сизмәстән, ямансу, сагышлы шигырьләр белән мавыга башлаганмын.* С.Сабиров

Мавыга төшү Күбрәк, тирәнтенрәк кызыксына башлау. *--- чигенүләр,*

хаталар белән генә мавыга төшү күзгә ташлангандай була. С.Маннапов

Мавыгып алу Билгеле вакыт аралыгында мавыгып, кызыксынып, яңадан сүрелү. *Абстракция дигәннән, моннан 10 ел чамасы элек яшь татар рәссамнары аның белән бик нык мавыгып алган иде.* Мәдәни җомга

Мавыгып йөрү Хәзерге моментта яки күпмедер вакыт дәвамында мавыгу. *Яшьләр уен белән мавыгып йөргән арада, бакчага берничә хатын-кыз килеп җитте.* Ф.Яруллин

Мавыгып китү Берәр шөгыльне башлаганнан соң, аңа бирелү, кызыксыну арту. *Берәр эш белән чын-чынлап мавыгып китсә, кеше дөньядагы мәшәкатьләрне оныткандай була.* М.Насыйбуллин. *Үзенең хикәяте белән мавыгып киткән икән Мурашкинцев, бая чиркәүгә кертеп җибәргән егетнең кай арададыр ишегалды аша уткәнен күрми дә калган.* З.Фәтхетдинов. *Мавыгып китеп, ут турында да оныткан бервакыт.* Г.Гыйльманов

МАВЫГУ II *и.* 1) Гыйшык. *Розаның җан атулары нәрсә – мәхәббәтме, бер мавыгу гынамы?* Ш.Рәкыйпов. *Бәлки, вакытлыча гына Мавыгудыр бу җилкенү?! Минем өчен бәйрәм була Сине бер күрү, сине бер күрү.* Г.Зәйнашева. *Ә ник кала алмыйм синең янда: Яшьлегеңдә – биеклектә, язда?! – Ястык кадәр булсын, язгы бозга – Мавыгуга! – куркам таянырга!..* Р.Гаташ

2) Яраткан шөгыль, хобби; хирыслык. *Маштаковның тагын бер мәзәк мавыгуы бар. Ул кайсы ашамлыкта күпме калория, күпме витамин һәм никадәр файдалы матдә булуын өйрәнә.* М.Юныс. *Әйтегез әле, пароход йөртүчегә кирәге бармы аның? Әллә һичнинди максатсыз, тиктән тик мавыгу гынамы?* Казан утлары. *Вакытлыча булган мавыгулар үтә, ә чын сәнгать чорлар сынавына бирешми шул ул.* Сөембикә

МАВЫГУЧАН *с.* Еш һәм бик тиз мавыгып китә торган, төрле нәрсәләр белән кызыксынучан; һәвәсләнеп, бик нык бирелеп китүчән. *Гомумән, кайнар, мавыгучан кеше генә коллекционер була ала – анысы күптән билгеле.* М.Юныс. *Карлыгач инде Таңсылуга караганда күбрәкне кичергән, мавыгучан җанлы әнисенең бик күп хәйләләрен аңларга өйрәнә төшкән, шуңа күрә бу юлы артык каушамады ---.* Г.Кашапов. *Нурулла – күпкырлы белемле, кызыксынучан, мавыгучан кеше, үтә дә өлгер егет.* Р.Галләм

МАВЫГУЧАНЛЫК *и.* Тиз мавыгып китү үзлеге. *Габдулланы тагын К.Мотыйгыйның яңалыкка омтылуы, кайнап торган энергиясе һәм мавыгучанлыгы үзенә тарткан.* И.Нуруллин

МАВЫГЫРЛЫК *с.* Җәлеп итәрлек, кызыксындырырлык, мавыктырырга сәләтле. *Бөтен дөньяны онытып мавыгырлык дәвамлы шөгыль. Балыкка йөрисезме?* А.Гыйләҗев

МАВЫКЛАНУ *ф. сир. к.* **мавыгу**. *Уен бар җирдә фальшь бар, хәйлә бар. Беренче мавыклануларыннан соң ук китә иде Сәгадәт.* Г.Гыйльманов

МАВЫКТЫРГЫЧ *с.* **1.** 1) Кызыксыну уята, игътибарны нык җәлеп итә торган. *Тик лекциянең эчтәлеге шундый мавыктыргыч булды ки, көнче «Шейх» онытылып китте*. К.Тимбикова. *Китапханә техникумын тәмамлаган яшь әдәбият сөюченең әңгәмәләре, мөгаен, бик үк мавыктыргыч, тирән эчтәлекле булмагандыр.* Т.Әйди. *Химиянең киләчәге белән кызыксынган кешене мавыктыргыч эшләр көтә.* Химиянең киләчәге

2) Ымсындыргыч, кызыктыргыч, үзенә тарта торган. *Алларымда якты йолдыз төсле Мавыктыргыч утлар яналар; Юллар, юллар, борма-борма юллар Шул утларга таба баралар.* Ә.Ерикәй. *Пьеса, театр, иҗат – тормышның үзе кебек үк кызыклы һәм мавыктыргыч.* Мәдәни җомга

2. *и. мәгъ. махс.* Балалар фольклорының бер жанры. *Балаларны бармаклары, куллары яки башка нәрсәләр белән мавыктырганда әйтелә торган такмазалар мавыктыргычлар дип атала.* Н.Исәнбәт

3. *рәв. мәгъ.* Мавыктырырлык итеп, җәлеп итәрлек рәвештә. *Мавыктыргыч язылган булса, Шакир абый аны гына укып чыгарлык вакыт тапкан булыр иде.* Ж.Фәйзи. *Менә Ибраһимов искиткеч мавыктыргыч итеп өчпочмаклар турында сөйли.* Ж.Тәрҗеманов

МАВЫКТЫРГЫЧЛЫ *с. сир. к.* **мавыктыргыч**

МАВЫКТЫРГЫЧЛЫК *и. сир.* Мавыктыру үзлеге, кызыксындыра алу сәләте. *Драматург [К.Тинчурин] уйлап чыгарган әкиятләрнең күплегенә, мавыктыргычлыгына һәм әкиятченең хәтеренә иң якын иптәшләре дә хәйран калган.* Ф.Ибраһимов. *Химиклар эшенең мавыктыргычлыгы, химиянең романтикасы күзгә алай ук ташланып тормый.* Химиянең киләчәге

МАВЫКТЫРУ *ф.* 1) Кызыксындыру, берәр шөгыльгә кызыксыну уяту, шөгыльләндерергә тырышу. *Бу төр фольклор, бишек җырлары, киресенчә, баланы йоклату өчен булмыйча, аны кузгату, хәрәкәтләндерү, активландыру һәм мавыктыру өчен хезмәт итә.* Н.Исәнбәт. *Баланы мавыктыра белергә кирәк.* Ш.Галиев. *Ул ниндидер механизмга, ниндидер автоматка әверелде, һәм мондый автоматик тормыш аны һич тә кызыктыра да, мавыктыра да алмады.* Н.Фәттах

2) Ошау, күңелгә яту, кызыксындыру. *Әсәр башыннан ук үзенә җәлеп итә, мавыктыра, һәм андагы вакыйгаларга, әдәби геройларның мөнәсәбәтләренә ышанып, бу сәгатьтә укучы шулар белән яши.* Ф.Миңнуллин. *Тамаша итеп торучыларның кызыксынулары Миңлегалигә дә күчте, аны да мавыктырды.* Р.Мөхәммәдиев. *Кемнәрнеңдер һаман мазутка батып, пычранып йөрисе килми, кайберәүләрен ата-бабадан калган игенчелек хезмәте мавыктыра.* Казан утлары

3) Үзенә карату, тарту, игътибарны нык җәлеп итү; буйсындыру, әсир итү. *Гыйлем Камай: – Егетләр, вакыт әрәм үтмәсен, мин фән дөньясыннан берике кызыклы мисал китерим, – дип, химия яңалыклары белән мавыктыра, онытылып тыңлыйбыз.* И.Салахов. *Егетләр серлерәк, тәкәбберрәк кызларга тартыла төшә, беркатлы ачык авызлар ул кадәр мавыктырмый.* М.Маликова

Мавыктыра бару Торган саен ныграк мавыктыру. *Фольклор җыю мине*

торган саен ныграк мавыктыра барды. Г.Бәширов

Мавыктыра башлау Мавыгу, кызыксыну хисе уяту. *Укучылар көче белән чыгарыла торган кулъязма журнал мине мавыктыра башлады.* М.Әмир

Мавыктыра төшү Тагын да күбрәк мавыктыру

Мавыктырып алу Билгеле бер вакыт арасы мавыктыру. *Ильясның үзйөрешле комбайн ясау турындагы хыяллары аны бик нык мавыктырып алды, ул үзе дә уйлап табу бизгәге белән яна башлады.* Г.Әпсәләмов

Мавыктырып җибәрү Бераз мавыктыру; билгеле моментта мавыгуга сәбәпче булу. *--- бу эш аны сунарчы эт кебек җилкендереп, мавыктырып та җибәрде хәзер.* З.Биишева

Мавыктырып китү Билгеле бер моменттан башлап мавыктыру. *Эшкә керешкәндә, үзеңне кызыктыра белергә кирәк. Аннары эш сине үзе мавыктырып китәр!* Ш.Галиев

Мавыктырып тору һәрвакыт, гел мавыктыру. *Сер һәрчак үзенә ымсындырып һәм мавыктырып тора.* Г.Хөсәенов

МАВЫКТЫРЫР *с. к.* **мавыктырырдай**. *Күңел юанычы эзләп, ниләр уйлап тапмый адәм баласы. Үзен мавыктырыр уен кора, кәрт суга, ауга чыга.* Г.Хөсәенов

МАВЫКТЫРЫ́РДАЙ *с.* **1.** Мавыктыргыч; кызыксындыра алырлык, җәлеп итәргә сәләтле. *Аерым әсәр өчен язучы шуның нинди дә булса бер ягын, игътибарны җәлеп итәрдәй, мавыктырырдай, дулкынландырырдай бер күренешен, кисәген аралап ала.* Ф.Хатипов

2. *рәв. мәгъ.* Мавыктырып, мавыгырлык итеп

МАВЫКТЫРЫРЛЫК *с.* **1.** *к.* **мавыктырырдай** *(1 мәгъ.). Әмма анда мине мавыктырырлык нәрсә юк иде инде.* Р.Гарипов

2. *к.* **мавыктырырдай** *(2 мәгъ.). Ә шулай да апа, теләсә, мавыктырырлык итеп сөйли ала.* Ф.Яруллин

МАГ *и. гр.* 1) Борынгы Көнчыгыш илләрендә һәртөрле гыйбадәтләрне, дини йолаларны үтәү һәм күрәзәлек итү белән шөгыльләнүче дин башлыгы; жрец. *– Кояш баешында Мәхәббәт дигән ил бар, анда Мәгыя дип аталучы кавем яши. Фарсыча – маглар, һәрберсе – тылсымчы, – дип сөйли Госам канбаба.* Б.Рафиков. *Дин руханилары Мәдиядә (Мидия) яшәгән борынгы иран кабиләсе атамасы буенча маг дип аталган.* Т.Нәбиуллин

2) Сихерче, тылсымчы. *--- Йоклама сын вөҗдан гырылдап – Булдыралсаң әгәр, Эмиль Кио, Син – бөек маг, Шундый ырым тап!* М.Шабай

МАГАЗИН *и. гар.* 1) Кибет. *Әти үлгәннән бирле, абыйга мануфактура магазиныбызны да караргa туры килә.* Ф.Әмирхан. *Магазиннарда (авыл кибетләрендә) ит, сөт, май, шикәр, кәнфит – берсе дә юк.* Г.Ахунов. *Бу күңелсезлекне әнием магазинга чыкканда ишетеп кайтты.* Л-Х.Таналин. *Аптекаларда һәм азык-төлек магазиннарында сатыла торган канәфер – вак кадакларга охшаган чәчәкләрнең бөреләре ул.* Робинзон эзләреннән

2) Аппарат, прибор, ату коралларында детальләрнең, өстәмә кирәк-яракларның бер комплектын тутыру өчен хезмәт итә торган җайланма (тартма, диск, көпшә һ.б.ш.). *Нинди дә булса бер чөйне яки берничә чөйне чыгарып алып, магазиндагы кәтүкләрнең каршылыкларына карап, без магазин ярдәмендә чылбырга төрле зурлыкта каршылык кертә алабыз.* Физика курсы

МАГАЗИНЛЫ *с.* Магазины (*2 мәгъ.*) булган; шуның белән эшли торган. *Магазинлы өскуйма файдалану түбәндәге өстенлекләрне бирә ---.* Татар балы

МАГАЗЫ *и. гар. тар.* Казан ханлыгы чорында һәм соңрак җәмәгать милке сакланган склад, амбар

МАГАРА́ҖА *и. санскр. к.* **mahaраҗа**

МАГИЗМ *и. гр. кит.* 1) Сихрилек, тылсым көче. *Магизм (грекча mageia – сихер, ырым) – аерым сүз яки гыйбарәләрнең, эш-хәрәкәт яки йолаларның кодрәтенә ышану, шулар ярдәмендә тирәлеккә, табигатькә һәм табигатьтән өстен көчләргә таэсир итеп, теләгән нәтиҗәләргә ирешергә тырышу.* М.Бакиров

2) *күч.* Үзенә тарту көче, җәлеп итә, әсир итә торган сыйфат

МА́ГИК *с.* 1) Магиягә караган, нигезендә магия яткан; магияле. *Магик формулаларның аеруча үзенчәлекле үрнәкләре кешегә ниндидер куркыныч, афәт янаганда әйтелә.* Ф.Урманчеев. *Татарның магик көче күпме милләт галимнәрен яшәтә, ялган легенда-мифлар тудыруга илһам бирә.* М.Галиев. *Чәчәк ул – магик фал, серле ым, илаһи ишарә, ниһаять, язмыш...* Г.Гыйльманов

2) *күч.* Үзенә тарту көче булган, нык җәлеп итә торган. *Шул магик сүзгә әллә нинди исерткеч мәгънә салынган кебек иде бит: Сталин...* М.Галиев. *Ул хикәя водородтан да, нейтроннан да, атомнан да куәтлерәк икәнен сизәсезме? Анда магик көч бар.* Р.Батулла. *Бу сүз көчле тәэсир итте, магик көч бар иде бу сүздә.* Р.Зәйдулла

МА́ГИК КВАДРАТ *и.* һәр юлы, һәр баганасы һәм ике зур диагональ буенча суммада бер үк сан биргән, цифрлы бүлемнәрдән торган квадрат; башваткычның бер төре

МАГИСТР *и. лат.* 1) Кайбер илләрдә университет тәмамлаган һәм магистрлык диссертациясе яклаган кешегә бирелә торган, бакалавр һәм доктор арасындагы гыйльми дәрәҗә исеме; шул дәрәҗәгә ия булган кеше. *Үзенең сөекле улы Виллиның – фәннәр магистры Вильгельм Краузеның кем тарафыннан «гефанген» булуын (әсирлеккә төшүен) ишетсә, әлбәттә, атылып үләчәк...* М.Мәһдиев

2) *тар.* Борынгы Римда һәм Византиядә югары титул

3) *тар.* Урта гасырларда руханирыцарьлар ордены башлыгы, гроссмейстер. *Рыцарьлар орденының магистры үзенең кельясыннан атлы гаскәрнең замокка кергәнен карап тора.* М.Мәһдиев. *Бу бинада кайчандыр Мальта орденының Бөек Магистры, аннан соң инглиз губернаторы яшәгән.* М.Юныс

МАГИСТРАЛЬ *и. лат.* **1.** 1) Берәр челтәр системасында (мәс., тимер юл,

су, электр һ.б.) икенчел тармаклардан аермалы буларак, төп, үзәк, генераль линия. *Башлыча Идел елгасы белән бәйле булса да, әлеге халыкара сәүдә магистрале төньякта Балтыйк буе һәм Скандинавия илләренә, көньякта Каспий диңгезе аша Иранга һәм Гыйракка кадәр сузылган.* Ф.Хуҗин. *Көч цилиндрының икесе дә трактор кысасы терәкләренә беретелгән һәм, бербер артлы итеп, туендыру көпшәсе – майкудыргыч – бак магистрале белән тоташтырылган.* Тракторлар һәм автомобильләр. *Байкал – Амур магистрале районында байтак еллардан бирле төзүчеләр белән бергә төрле белгечлектәге галимнәр, шул исәптән географлар эшләп килә.* Физик география

2) Шәһәрдә транспорт хәрәкәте бик зур булган киң һәм туры үзәк урам. *Тик үзәк магистральләрдән, олы юллардан читтәрәк булу ягын карагыз. Карательләр дә, эсэчылар, патрульләр дә озак көттермәсләр.* М.Хәсәнов. *Дөньяда мин эштә таптым дуслар, Рәхмәт ул туганлык илчесенә. Металл кырдым, магистральләр салдым, Мендем буровойлар сөңгесенә.* И.Әхсәнов

2. *с. мәгъ.* 1) Магистраль (*1, 2 мәгъ.*) булып торган; төп, үзәк, әһәмиятле. *Районнан килеп төшкән элемтәчеләр бригадасы багана урыннарын күрсәтеләр һәм магистраль линия белән Гәр Хутор арасында алты-җиде җирдә ут яктылар.* М.Мәһдиев. *Сессия залыннан чыгып барганда, Шәмәрдән магистраль газүткәргечләрнең линия-производство идарәсе начальнигы Ришат Нурисламов кулымны кысты.* Т.Нәҗмиев. *Магистраль линиядән электр приборларына ток китерү өчен сузылган эчке үткәргечләрдә көчәнешнең кимүе, билгеләнгән техник норма буенча, яктырту челтәрендә 2% тан --- артмаска тиеш.* Физика курсы

2) *күч.* Төп, үзәк, әһәмиятле. *«Социалистик ярыш» дип аталган лашманчылыкны күкләргә чөеп мактау совет чорында татар әдәбиятының магистраль темасы иде.* М.Юныс

МАГИСТРА́ЛЬЛЕ *с.* Магистрале булган, билгеле сандагы магистральдән торган. *--- хәзергә без ике генә нәрсәне күрәбез: табигатьнең искиткеч матур киңлекләре буйлап сузылган ике магистральле, беренче класслы автомобиль юлы.* М.Мәһдиев

МАГИСТРА́НТ *и. лат.* Магистрлык дәрәҗәсе алырга әзерләнүче кеше. *Хәзер без атна саен фәнни семинарларга җыелышабыз – фәнни җитәкчебез, ике магистрант һәм бер аспирант.* Татарстан яшьләре. *--- Башкортстан дәүләт аграр университеты биология-технология факультетының алтынчы курсы магистранты Азамат Салихов лауреат дипломы һәм икенче дәрәҗә диплом белән бүләкләнде.* Кызыл таң

МАГИСТРА́Т *и. лат.* 1) Кайбер Көнбатыш Европа илләрендә шәһәр идарәсе; муниципалитет. *Магистрат куркуыннан буйсынырга мәҗбүр була һәм яңа идарә кертә, ә Оливер Оттоны шәһәр хөкемдары дип игълан итә.* Н.Макиавелли. *1518 нче елны Бонн магистраты яңа юл белән алып кайтылган борычны ашаудан тыя.* Робинзон эзләреннән

2) Россиядә, Пётр I тарафыннан кертелеп, 1864 елга кадәр эшләп килгән һәм суд-идарә, салым җыю эшләре алып барган сайлаулы шәһәр идарәсе

3) *тар.* Борынгы Римда диктатор, децемвир, консул кебек югары яки халык трибуны, эдил, квестор һ.б.ш. кебек гади дәүләт хезмәте вазифасы; шул хезмәтне башкаручы кеше

МАГИСТРАТУ́РА *и. лат. тар.* 1) Суд ведомстволары системасы; судьялар корпусы

2) Югары һөнәри белем системасында бакалавриаттан соң килгән, белгечлекне күбрәк теоретик үзләштерүгә юнәлтелгән баскыч. *Шуңа күрә бездә педагогик, психологик юнәлеш буенча бакалавриат һәм магистратура программалары эшләнә.* Ватаным Татарстан. *Моннан тыш ике баскычлы (бакалавриат һәм магистратура) белем бирү системасы булмау да тәгәрмәчкә таяк тыга.* Кәеф ничек?

МАГИ́СТРЛЫК *и.* 1) Магистр (*1 мәгъ.*) дәрәҗәсе. *Ул да бит әнә бүген магистрлыкка кандидат дигән исемне алды.* Ж.Тәрҗеманов. *1905 елда [А.Е.Арбузов] «Фосфат кислотасының һәм аның чыгарылмаларының төзелеше турында» дигән темага магистрлык диссертациясе яклый.* Казан химиклары. *Ул [В.Логинов] Казан ветеринария институтын бик уңышлы тәмамлаган, соңыннан магистрлык имтиханнарын тапшырган, 1917 елда институтның гистология кафедрасы буенча ординар профессор булып сайланган.* Татар балы

2) Магистр (*2 мәгъ.*) власте, магистр идарәсе

МА́ГИЯ *и. гр.* 1) Кешенең (сихерченең, тылсымчының) табигать күренешләренә яки кешеләргә гайре табигый көч белән тәэсир итү сәләтенә ышануга нигезләнгән йолалар; сихер. *Н.Гыйматдинова сер, тылсым, халык йолалары, юраулары, магия һ.б. төрле күренешләрнең яшерен катламнарына үтеп кереп, гаҗәп мавыктыргыч, һич көтелмәгәнчә тасвирлап бирә алуы белән җәлеп итә.* Х.Бадыйков

2) *күч.* Кемгә дә булса көчле тәэсир итә, йогынты ясый торган гадәттән тыш көч

МА́ГИЯЛЕ *с.* 1) Магиягә, тылсым көчләренә ышануга нигезләнгән. *--- Беренче карашка мәгънәсез сүзләр корамасы кебек күренгән бу фольклор әсәре чыгышы буенча шактый борынгы чорлар һәм магияле дөньяга карашлар белән бәйләнгән ---.* Н.Исәнбәт

2) Сихер, магия алымнарыннан торган, магиядән файдаланган

МА́ГИЯЧЕЛЕК *и.* Магиягә ышану, магиягә нигезләнгән дөньяга караш. *Бу әсәрләр эчендә без сыйнфый җәмгыятькәчә булганнарын очраткан кебек (дөньяга мифик караш һәм магиячелекне чагылдырган – кояшка эндәшү һ.б.), төрле сыйнфый җәмгыять чорларын чагылдырганнарны да очратабыз.* Н.Исәнбәт. *--- аларның башка өстәмә вазифалары да бар. Мәсәлән, шул ук мәкальгә, бәяләү, өйрәтүдән тыш, күрәзәлек кылу, магиячелек тә, сөйләмне бизәү, күркәмләү дә чит түгел.* Х.Мәхмүтов

МА́ГМА *и. гр. геол.* Җир шарының мантиясе астында яткан, нигездә силикатлардан торган, газларга бай, уттай кызган үзле-сыек масса (җир

өстенә чыгып, суынып каткан вакытта, вулканик тау токымнары хасил итә). *Һәртөрле тау токымнары да, үсемлекләрнең яшел массасы да, җир куенындагы магма да, атмосферадагы төрле газлар да аның [химия] өчен чимал булып хезмәт итәчәк.* Химиянең киләчәге. *Әгәр кызган магма җир кабыгын тишеп чыга икән, вулкан атылу башлана.* Дөньяда ниләр бар. *Җир өстенә агып чыккан магманы лава диләр.* Табигать белеме

МА́ГМАЛЫ *с.* Магма чыгып торган, магма чыганагы булган. *Җир кабыгында, матдәләр күчеңгәндә, тирәнтирән ярыклар барлыкка килә, аларда басым кинәт төшә, һәм магмалы учаклар хасил була.* Галәм. Җир. Кеше

МАГМА́ТИК *с.* 1) Барлыкка килеше магма белән бәйле; вулканик. *Магматик тау токымнары Җир шарының геологик үткәнен чагылдыра торган көзге генә түгел, кыйммәтле казылма байлыкларына юл күрсәтә торган маяк та.* Казан утлары. *Риголит үзе магматик токым кыйпылчыкларыннан, шлаксыман кисәкчекләрдән һәм эрегән магма тамчыларыннан тора.* Галәм. Җир. Кеше

2) Магма хәлендәге; кызып эрегән, сыек. *Токымның магматик хәле*

МАГНАТ *и. лат.* 1) *тар.* Бай һәм нәселле аксөякләр вәкиле; кайбер Европа илләрендә (бигрәк тә Польшада һәм Венгриядә) эре җирбиләүче, алпавыт. --- *кайбер яклары белән Мәскәүнең Үзәк әдәбият йортын хәтерләткән бу бинада (миңа аны, буржуаз Латвиядә газета-журналлар магнаты булган Бенянинь ханымнан калган йорт, дип әйттеләр) Язучылар союзының эшчәнлеге өчен бөтен шартлар бар.* Р.Фәйзуллин

2) Эре сәнәга яки финанс капиталы вәкиле. *Ни әйтсәң дә, коллегалары арасында «нефть магнаты» дигән аты чыккан атаклы Шәңгәрәевнең газиз кияве ул хәзер.* М.Хәсәнов. *Ә магнатлар акча чөеш уйный: Ватанын да сала уртага... Барыннан да әйбәт уйный заман: алышына төслөр картада!* Р.Әхмәтҗан. --- *ул бервакытта да ярдәмче, киңәшче, сәяси амбицияләрдән азат финанс магнаты роленә риза булмаячак, ул үз вакытын көтә* ---. Р.Мирхәйдәров

МАГНЕЗИТ *и. лат. хим.* 1) Карбонатлар классыннан ак яки саргылт соры төстәге минерал. *Магнезитта магний карбонатының масса өлешен (% ларда), CO_2 нең микъдарын һәм күләмен (н. ш.) табыгыз.* Гомуми химия: Мәсьәләләр һәм күнегүләр

2) Башлыча магнезит минералыннан торган утырма кристаллик тау токымы

3) 1–10 % катнашмалары булган магний оксидыннан гыйбарәт утка чыдам материал. *Сез [мичтән] бер яктан корычны алып бетерүгә, алар икенче яктан магнезит сибеп тутыра да башладылар.* Н.Исәнбәт

МАГНЕЗИТЛЫ *с.* Составында магнезит булган, тулысынча яки өлешчә магнезиттан торган

МАГНЕ́ЗИЯ *и. гр.* Магний оксидыннан гыйбарәт булган, медицинада кулланыла торган җиңел ак порошок. *Кирәк булса, гипноз сеанслары алырсыз. Веналарга магнезия уколлары кадарбыз.* А.Гыйләҗев. *Бүгеннән башлап шәфкать туташы сезгә магнезия белән витамин кадый башлар.* З.Мәхмүди. *Ксилит, сорбит, магнезия, тавык йомыркасының сарысы, карабодай ярмасының вакланганы белән тюбаж ясарга була.* Ватаным Татарстан

МАГНЕ́ЗИЯЛЕ *с.* Составында магнезия булган, магнезия кушылган

МАГНЕТИЗМ *и. гр.* 1) Кайбер магнитлы яки электр корылмасы булган җисемнәрнең үзара тәэсир итешү, үзләреңә тарту яки үзләреннән читкә этәрү күренеше. *Кояш һава хәленә, Җир магнетизмы кебек табигый процессларга шактый йогынты гына ясап калмый, бәлки биосферага – Җирнең хайваннар һәм үсемлекләр дөньясына – һәм шулай ук кешегә дә шактый тәэсир итә.* Галәм. Җир. Кеше. *Нинаять, магнетизм гасырлар һәм меңнәрчә еллар буена балчык савытларда һәм төзелеш кирпечләрендә сакланып кала.* Могҗизалар энциклопедиясе. *Электромагнитик күренешләр турындагы тәгълиматның үсешендә зур роль уйнаган мангнетизм табигате турындагы гипотезаны да Ампер тудырган.* Физика курсы

2) Физика фәненең әлеге күренешне өйрәнә торган тармагы

3) *күч.* Кешенең үзенә җәлеп итү сәләте, харизма

МАГНЕ́ТИК I *и. гр.* Магнит үзлекләренә ия булган матдә (ферромагнетиклар, парамагнетиклар һ.б.ш.). --- *һәр җисем магнетик, ягъни магнит кыры тәэсирендә ул магнитик момент ала (магнитлана).* Магнитик күренешләр физикасы

МАГНЕ́ТИК II *с.* Магнетизмга мөнәсәбәте булган. *«Магнетик көчне үстерү һәм хәтерне көчәйтү», «Ихтыяр гимнастикасы», «Үз-үзеңә баш була белү мәктәбе» --- мондый кулланмалар узган гасырда да һәм аннан элек тә чыгып килгән, ә хәзер, табигый, алар тагын да күбрәк басыла.* В.Леви

МАГНЕТИТ *и. нем.* Составында тимер булган һәм магнитка хас үзлекләргә ия каты кара минерал; магнитлы тимерташ; ферромагнетик. --- *магнетит – Fe_3O_4 – шулай ук ярымүткәргеч, әмма FeO --- аша металл белән кислород ионнарының хәрәкәте бик нык чикләнгән.* Коррозия һәм металларны саклау

МАГНЕ́ТО *и. ингл. тех.* Эчке янулы двигательләрдә шәмнәрнең электродлары арасында очкын барлыкка китереп, ягулыкны кабызып җибәрә торган алмаш ток магнитоэлектрик генераторы. *Егетләр, малайлар арасында кәлинвал, карбюратор, эсвичә, магнето, радиатор дигән нәкъ биш сүз Кәшфи истәлеге буларак отып калынды.* М.Мәһдиев. *Шәм очкыны тудыру өчен кирәкле ток аккумуляторда, генераторда яки магнетода барлыкка килә.* Тракторлар һәм автомобильләр

МА́ГНИЙ *и.* Бик җиңел һәм чыдам, чүкүгә тиз бирелүчән, порошогы һәм чүбе көчле ак ялкын белән яна торган көмешсыман ак металл. *Әгәр сезнең магний тасмагыз булса, сез кызыклы һәм гыйбрәтле бер тәҗрибә ясый аласыз. Янып торган магний йомычкаларын су белән сүндерүнең файдасыз гына булмыйча, гаять куркыныч та икәне моннан ачык күренә.*

Күзгә күренми торган матдәләр турында хикәяләр. *Бу җиләкләрдә [саз җиләге] глюкоза, фруктоза, каротин, пектин, --- магний, калий, кальций, натрий, хром, бакыр, алюминий, кремний, башка матдәләр һәм элементлар бар.* Урман аптекасы. *Хәзерге вакытта алюминий һәм бакырдан башка, электр тогы ярдәмендә күп кенә бүтән металларны, мәсәлән, магний, натрий, калий, кальций һәм башкаларны табалар.* Физика курсы

МА́ГНИЙЛЫ *с.* Магний катнашкан, составында магний булган. *Түбәндәге матдәләрнең магнийлы кушылмаларына углерод (IV) оксиды белән тәэсир итеп, нинди кислоталар табарга мөмкин ---.* Органик химия: Күнегүләр һәм мәсьәләләр. *Соңгы елларда яшелчәчелектә магнийлы ашламалар һәм микроашламалар кулланыла башлады.* Яшелчәчелек

МАГНИТ *и. гр. физ.* **1.** 1) Тимер һәм корыч предметларны үзенә тарту яки читкә этәрү үзлегенә ия булган тимер рудасы кисәге; магнит кыры хасил итә торган җисем яки җайланма. *Йолдызлар юклыгы һәм әйдәүче магнит дулкыннарының бозылуы юнәлешне дөрес тотарга комачаулый иде.* Ә.Гаффар. *Китапның үзенә тарту, күңелне арбау, сихерләү һәм шаукымландыру сәләте ризыктан, акчадан һәм магниттан көчлерәк.* А.Хәлим. *Электр һәм магнит күренешләренең берберенә бәйләнешен аңлата торган беренче теорияне ул [А.Ампер] эшләгән.* Физика курсы

2) Кайбер физика терминнарының Җирнең магнит кыры белән бәйле күренешләрне белдергән компоненты. *Кызыйның --- үрелмәгән куе чәче, бөтен аркасына таралып, бил батынкылыгын каплаган; ул чәчләр, хәрәкәт итеп, әйләнә-тирәгә электр тогы чәчәләр, магнит кыры ясыйлардыр кебек иде.* М.Мәһдиев. *– Эфирда магнит давылы. Пеленгның минимумы юк, – диде икенче штурман.* М.Юныс. *Моннан шактый ук элек Колумб та Җир шарының төрле урыннарында магнит авышуының төрле зурлыкта булуын белгән.* Физика курсы

3) *күч.* Үзенә җәлеп итә, игътибарны тарта торган җанлы яки җансыз объект, кызыксыну предметы. *Гармуны да үзе кебек – Бар сәер гадәтләре: Кызлар күңелен җилкетеп, Ялтырап балкып тора. Эчендә магниты бардыр: Үзенә тартып тора.* Г.Зәйнашева. *Күңелемдә нинди өермә купканны тасвирлау читен. Куәтле магнитка эләккән идем.* Б.Камалов. *Туган җир – магнит: Гел бергә җыя, Залга сыймас җыр Йөрәккә сыя.* Ш.Галиев

4) *күч.* Үзенә карату, җәлеп итү сәләте. *– Кермәгез, монда эзегез булмасын, дисәгез дә керәм мин сезнең бүлмәгә. Магниты бар аның, хәерсез, шул тарта, – дип, ишектән гадәтенчә шаулап Мин ага керде.* Г.Тавлин. *Сәхнә уртасындагы малай күренмәс магниты белән күзне, колакны үзенә тартып, яңа төр бәете белән күңелләрне билән алды.* С.Лашманчы

2. *с. мәгъ. к.* **магнитлы**. *Хәзер шул магнит тасмаларны тыңлыйм да хәтер сандыгында казынам.* Н.Нәҗми. *Ул бу уенчык эчендә тавыш яздыруга көйләнгән магнит тасма барлыгын төшенеп алган иде инде.* Г.Гыйльманов

МАГНИ́ТИК *с.* Магнит күренеше белән бәйле, магнит күренешенә нигезләнгән. *Магнитик үзлекләрен бик тиз үзгәртә алучы кристаллик магнитлар – ферритлар – радиотехниканың киләчәктәге үсешен тәэмин итәрләр.* Серле кристаллар. *--- океаннарда магнитик рәсемгә алулар бу сыртларның битләүләрендә уңай һәм тискәре аномалияләр, чиратлашкан параллель полосалар булуын күрсәтте ---.* Галәм. Җир. Кеше. *Монда шуны искә алып китәргә кирәк: электр тогы нинди генә (катымы, сыекмы, газсыманмы) үткәргеч аша узса да, һәрвакыт токның магнитик тәэсире була.* Физика курсы

МАГНИТЛАНДЫРУ *ф. к.* **магнитлау** (*1 мәгъ.*). *Чорнау урамалары буйлап алмаш ток ага һәм кендек корычын магнитландырып, анда алмашына торган магнитик агыш тудыра ---.* Физика курсы

МАГНИТЛАНУ *ф.* Магнит үзлекләре алу, үзендә магнит үзлекләре барлыкка килү, магнитка әйләнү. *Карашлары булсын, куллары булсын, магнитланган сыман бер-берләреннән аерыла алмый торды.* Р.Мөхәммәдиев. *Магнитлана торган тирәлек булмаса, магнитик агышның зурлыгы кырның көчәнешлегенә карый.* Физика курсы

Магнитлана башлау Магнитланырга тотыну

Магнитлана төшү Бераз магнитлану; тагын да ныграк магнитлану

Магнитланып бетү Нык магнитлану

Магнитланып җитү Җитәрлек дәрәҗәдә магнитлану. *--- ток зурлыгы бер билгеле чиккә җиткәч, тимер кендек тулысынча магнитланып җитә; шуннан соң ток зурлыгын арттыру кәтүкнең генә магнит кырын көчәйтә.* Физика курсы

МАГНИТЛАНУЧАНЛЫК *и. махс.* Магнит тәэсиренә бирелү үзлеге

МАГНИТЛАНЫШ *и. махс.* Магнитлану дәрәҗәсе

МАГНИТЛА́У *ф.* 1) Берәр җисемгә магнит үзлекләре бирү, аны үзен магнитка әйләндерү. *Магнитлы йомшак материалларның кабат магнитлауга югалтулары зур булмый.* Авыл хуҗалыгы электригы белешмәсе. *Шактый авыр тимер стаканның уртасындагы күчәренә магнитлаучы кәтүк уралган.* Физика курсы

2) *күч.* Кызыктырып үзенә тарту, җәлеп итү

Магнитлап бетерү Тулысынча магнитлау

Магнитлап бирү Башка берәү өчен магнитлау. *--- банкага су тутырырга һәм миңа алып килергә. Мин аны магнитлап бирермен.* Ватаным Татарстан

Магнитлап кую Магнитланган, магнитлы итү

Магнитлап тору Даими рәвештә, әледән-әле яки хәзерге моментта магнитлау. *Үзеңне бел, сине дә хатының үз ягына магнитлап кына тора.* Х.Камалов

Магнитлый башлау Магнитларга тотыну

Магнитлый төшү Бераз магнитлау; тагын да ныграк магнитлау

МАГНИТЛЫ *с.* 1) Магнит үзлекләренә ия булган, магнитланган. *Яки магнитлы миналар булса? Бензин*

цистернасына ябыштырып киттең – эше бетте!.. Ш.Рәкыйпов. *Тимер рудасы, мәсәлән, магнитлы тимерташ, гадәттә окисьлашкан металлдан, ягъни кислород белән кушылган металлдан гыйбарәт.* Күзгә күренми торган матдәләр турында хикәяләр. *Магнитлы йомшак материалларның кабат магнитлауга югалтулары зур булмый.* Авыл хуҗалыгы электригы белешмәсе

2) Магнит күренешенә нигезләнгән; төп эшләтү элементы магнит булган. *Әгәр инде космодромда магнитлы җибәргечләрнең тавыш тоннары кинәт кенә үзгәрә калса, --- таныш көйдәге ялгыш нотаны Королёв шундук тотып ала – моның өчен аңа бернинди прибор да кирәк түгел.* Галәмгә юл

3) *күч.* Үзенә җәлеп итеп торган. *Театр! Гажәеп көчле, тылсымлы, магнитлы сүз.* Р.Низамиев

МАГНИТЛЫЛЫК *и.* Магнит үзлегенә ия булу яки магнитланган булу хәле. *--- логарифмнарны аңлатырга кереште. Шуның белән бергә ул метеорологик күзәтүләр алып барды, җирнең магнитлылыгын өйрәнде.* Ж.Тәрҗеманов

МАГНИТЛЫ ТИМЕРТАШ *и. минер. к.* **магнетит**. *Домна мичендә магнитлы тимерташны эреткәндә, $Fe_3O_4 + CO = 3FeO + CO_2$ реакциясе үтә.* Г.Хисамиев

МАГНИ́ТО- Кушма сүзләрдә «магнит күренеше белән бәйле», «магнитлы» мәгънәләрен белдерә торган беренче кисәк (мәс., *магнитосфера, магнитопауза, магнитострикция*)

МАГНИТОБИОЛО́ГИЯ *и. гр.* Биофизиканың тышкы магнит кырларының тере организмнарга тәэсирен, шулай ук организмда (мидә, нервта һ.б.) барлыкка килгән магнит кырларын өйрәнә торган тармагы

МАГНИТО́ГРАФ *и. гр.* Җирнең магнит кыры үзгәрешләрен эзлекле рәвештә берөзлексез язып, теркәп бара торган прибор

МАГНИТО́ЛА *и. рус* Конструктив яктан радиоалгычны һәм магнитофонны берләштергән җайланма. *Аның күңеле булсын дип, Тәслимә кыйбатлы магнитола да алып куйган иде.* М.Маликова. *– --- биеп алабыз, Радик Хафизович! Юкса болай гына кан таралмас... – диде Сабира, магнитоланы җибәреп.* З.Фәйзи. *Фаягөлнең әниләре калдырган кечкенә генә искерәк магнитоласы бар иде, аны радиодулкынга көйләп куйгач, бүлмә җанланып китте.* Х.Ширмән

МАГНИТО́МЕТР *и. гр. махс.* Магнит кырының һәм физик объектларның күрсәткечләрен үлчи торган прибор

МАГНИТОСФЕ́РА *и. гр.* Җирнең яки башка планеталарның физик үзенчәлекләре аларның магнит кыры һәм космостан килгән корылган кисәкчекләр белән тәэсир итешүенә бәйле булган планета тирәсендәге киңлек. *Юпитерның зур магнитосферасы һәм радиация пояслары ачылды, алар Җирнең радиацион поясларын хәтерләтәләр, ләкин аларга караганда күп тапкырлар зуррак.* Галәм. Җир. Кеше. *--- Җирне магнитосферасыз – Кояш җиленнән һәм космик нурланыштан саклаучы табигый киртәсез калдырсак, бу – җан ияләре өчен һәлакәт булачак.* Мәдәни җомга

МАГНИТОФО́Н *и. гр.* Магнит тасмага тавышны язып алу һәм аны яңадан сөйләтү, ишеттерү җайланмасы. *Магнитофонга язып аласы иде дә серен өйрәнәсе иде шушы гадәти сөйләмнең, музыка сыман кабат-кабат тыңлыйсы иде.* Ш.Галиев. *Ул магнитофонны сүндерде, свитерын, күлмәген салып, аркасын кояшка куеп утырды.* Ә.Гаффар. *Магнитофон уйлап табучыга рәхмәтем аеруча зур. Һәркемгә мәгълүм, бу аппарат якын-тирәдәге тавышны түкми-чәчми язып бара.* Ф.Баттал

МАГНИТОЭЛЕ́КТРИК *с. гр. махс.* Даими магнит кыры белән үткәргечләрнең магнит кыры арасындагы тәэсир итешү күренешенә нигезләнгән. *Мәктәп физика лабораторияләрендә, күбесенчә, ике системадагы электр үлчәү приборлары – магнитоэлектрик приборлар һәм электромагнитлы приборлар кулланыла.* Физика курсы. *Магнитоэлектрик һәм электромагнитик система приборларының эшләү принцибы һәм кыскача характеристикалары.* Даими ток законнары

МАГНИТСЫЗ *с.* **1.** Магнит көче булмаган; магнитланмаган. *Теплоход алдан бара, корпусы магнитсыз булганга, аңа мина куркыныч түгел.* С.Сабиров

2. *рәв. мәгъ.* Магнит кулланмыйча

МАГНИТСЫЗЛАНДЫРУ *ф.* Магнит кырын нейтральләштерү, тарту көчен бетерү

Магнитсызландырып бетерү Тулысынча магнитсызландыру, барысын да магнитсызландыру

МАГНИТСЫЗЛАНУ *ф.* Магнит үзлекләрен югалту. *Кире юнәлештә тышкы магнит кыры тудырганда, доменнар ориентациясе үзгәрә, ягъни җисем магнитсызлана.* Магнитик күренешләр физикасы

Магнитсызланып бетү Тулысынча магнитсызлану

МАГНО́ЛИЯ *и. фр. бот.* Магнолиячәләр семьялыгыннан Көнчыгыш һәм Көньяк-Көнчыгыш Азиядә үсә торган, хуш исле ак яки ал төстәге эре чәчәкле һәм эре яфраклы, еш кына декоратив үсемлек буларак үстерелә торган мәңгеяшел агач яки куак. *[Евпаторидә] Агачлардан кипарислар, сәрви куаклары, магнолияләр күп очрый.* Г.Тавлин. *Магнолияләр баш ия Кошлар җырына монда, Чиксез ярлары хыялның Гүзәл Кырымда гына.* Ә.Синугыл. *Мин, Иделнең шомырт чәчәкләрен, Фирганәнең утлы мәкләрен, Кавказның ак магнолияләрен, Россиянең зәңгәр умырзаяларын, Кырымның ак розаларын Бергә җыеп, букет ясадым.* Н.Хисамов

МАГНО́ЛИЯЧӘЛӘР *и. күпл. бот.* Икеөлешле үсемлекләр классының күбесенчә Төньяк ярымшарның субтропик зонасында үсә торган 220–230 төрне берләштергән агач яки куаклар семьялыгы. *Ләкин кайбер семьялыкларда (магнолиячәләр – Magnoliaceae, бадьянчалар – Illiciaceae һ.б.) таҗ яфракчыклары вегетатив яфраклардан барлыкка килә.* Л.Мәүлүдова. *Гидрохинонның метил һәм этил эфирлары --- магнолиячәләрдән йолдызлы әнис (анис звёздчатый) төрләрендә табылганнар.* Агулы үсемлекләр

МАГУЛ *и.* 1) *к.* **могол**. *Канлы бәрелешләр ешая, берсендә магулларның*

гаскәр башы Кечек бәк хәтта әсирлеккә дә төшә. С.Шәмси

2) *к.* **монгол**. *Төрекләргә якын торган башка кавемнәр – якутлар, чуашлар, магул (монгол), манҗур, фин, венгр-мажарлардыр.* К.Насыйри. *Таярга кирәк моннан исән чагында, Гали! Китик далага. Магул качты, дала үзебезгә калды.* Н.Фәттах. *Магул явы чапты өстебезгә, Тапмап үтте изге җиребезне. Ул камады шәһре Биләрне дә – Ялкын ялмап алды бу каланы.* Р.Шиһапов

МАДАМ *и. фр.* 1) Франциядә һәм француз телле илләрдә хатын кешегә мөрәҗәгать итү сүзе (гадәттә исем яки фамилиягә кушып әйтелә); ханым. *Бер фаэтон тоттык та, мадам белән янәшә утырып, пристаньга таба юлга чыктык.* Г.Баттал-Таймас. *Ипле генә сөйләшеп торган җиреннән кинәт кабаланып куйды мадам һәм кулындагы сәгатенә күз төшереп алды.* Р.Мөхәммәдиев. *Дөресендә бу яктан беренчелек мадам Помпадурга бирелергә тиеш.* Кызыклар дөньясында

2) Гомумән хатын-кызга, еш кына шаярту яки ирония төсмере белән эндәшү сүзе. *Мин сине танымадым. Киноларда гына күренә торган мадамга әйләнгәнсең.* З.Хәким. *Стюард килеп эндәште. Я Раббым, нәрсә ди икән, бер сүзен – «мадам» дигәнен генә аңладым.* Сөембикә. *--- ул, кулындагы чәчкәләрне аптыраган Наиләгә сузып: – Менә, мадам! Сезгә бирергә куштылар, – диде.* Мәдәни җомга

3) *иск.* Фахишә. *Госман карт әйтә: – Мадам дип әйткән сүз безнеңчә абыстай дигән сүз була. – Габделхәй аңар авыз ачарга да бирми: – Мадам – фахишә ул! – ди.* Ш.Камал. *Рамазанда байбәтчәләр «Ожегов»ка төшәләр, Яннарына мадам алып, Мадейр, коньяк эчәләр.* Ш.Таһири-Көлтәси

МАДДӘ *и. гар. иск. к.* **матдә**. *Сәбәпләре ушбу маддәдә бәян кылыныр.* К.Насыйри

МА́ДДӘТӘН *рәв. гар. иск.* Материаль яктан, матди буларак. *Әдәбият ахшамы әһәли өчен дә, яшь интеллигентлар өчен дә маддәтән вә мәгънән файдалы булган, әдәбият ахшамын күреп, күзләре нурланган.* Г.Тукай

МАДЕМУАЗЕЛЬ *и. фр.* 1) Франциядә һәм француз телле илләрдә кыз кешегә мөрәҗәгать итү яки аны атау сүзе (гадәттә фамилия яки исем белән әйтелә); туташ. *Мадемуазель Бәхтиярова булмаска соң! Шәүкәт ничә тапкырлар үз күзе белән күрде.* А.Хәсәнов. *Мәсәлән, Көнбатыш илләрендә яшәүче халыклар тормышы сурәтләнгән татарча әсәрләрдә мәр, лорд, сенатор, леди, мадам, синьор, мадемуазель кебек сүзләр очрый.* Р.Юсупов

2) Гомумән кызларга мөрәҗәгать формасы. *[Зөфәр:] Күлмәгегезне пычратмагыз, мадемуазель.* Ф.Яруллин. *Ә мин, мадемуазель, ахмак кеше түгел идем. Син генә акылдан яздырдың мине.* Т.Миңнуллин

МАДЕ́РА *и. португ.* Йөземнең ак һәм алсу сортларыннан сосла яки төчлегәнне әчетеп, соңыннан спирт өстәп әзерләнгән куәтле шәраб. *Петербург матросларына, солдатларга, верфь эшчеләренә, йөкчеләргә, төзүчеләргә көн саен түләүсез берәр чәркә аракы бирергә боера [Пётр].* *--- Халык аны «патша мадерасы» дип атаган.* Р.Зәйдулла

МАДИХ *и. гар. иск.* Мактаучы, дан җырлаучы; ода, мәдхия язучы

МАДМУАЗЕЛЬ *и. к.* **мадемуазель**

МАДО́ННА *и. ит.* 1) Борынгы Италиядә хатын-кызга мөрәҗәгать итү сүзе

2) Изге ананың (Мәрьям ананың) итальянча атамасы; шулай ук аның скульптур сыны яки рәсеме. *«Сикстин мадоннасы» исемле мәшһүр картинаның Германиядәге Дрезден шәһәренең галереясында саклануын [Чунтонов] әйтеп бирде.* Ш.Рәкыйпов. *Рафаэльнең Сикстин мадоннасы – Валентина белән чагыштырганда чүп кенә ул.* Н.Әхмәдиев. *Германия төсле. Дрезденда шыплап тулган китаплар яна. Галерея. Сикстин мадоннасы – баласына иелгән Ана...* Р.Әхмәтҗан

3) *күч.* Хатын-кыз идеалы, матурлык, сафлык, тыйнаклык үрнәге булган хатын-кыз. *– Җүләр, син анда ялгыз бармыйсың, – секретарь хәйләле елмаеп күз кысты, – биофакның мадоннасы Зәйтүнә белән...* И.Салахов. *Шул вакытта һәрчак минем күз алдыма үзебезнең авылның мадоннасы – Зәһир хатыны килеп баса ---.* И.Юзеев. *И, кайда сез, Рафаэльчә – сабыйларын Күкрәгенә кыскан гүзәл мадонналар?!* Ә.Рәшит

МАДРИГАЛ *и. фр.* 1) *әд.* Пасторальмәхәббәт эчтәлекле кыска шигырь; соңрак – берәр ханымга багышланган шаян эчтәлекле шигъри комплимент

2) *иск.* Ялагайлы мактау сүзләре, комплимент

МАДЬЯР *и.* Венгрларның үзатамасы. *Мадьяр орнитологы Секе тургай тавышын магнитофонга язып алган һәм язмаларны нык акрынайтып тыңлап караган.* А.Гыйләҗев. *Күршедә генә яшәгән күчмә мадьярлар аларга [болгарларга] иген игүдә комачауламыйлар: яңа хуҗалар үстергән икмәктән аларга да өлеш тия.* М.Мәхмүтов. *«Шәмдәлләрдә генә утлар яна»ны, Равельның «Болеро»сын, Брамсның «Мадьяр биюләре»н тыңлаганда, шушылай тетрәнәм мин.* М.Юныс

МАДЬЯ́РЧА *рәв.* Мадьяр (венгр) телендә. *Заманы өчен бик белемле кеше: дүрт телдә – татарча, урысча, немецча, мадьярча яхшы сөйләшкән.* Кызыл таң

МАЕМЛАТУ *ф. з-сыз. сөйл.* Артык күп ашалган майлы, баллы нәрсәләр ашказанында дискомфорт тудыру, күңелне болгату. *Майлы булсын, майсыз булсын – Барыбер күңел кайта; Көн дә ботка ашап булмый: Туйдыра, маемлата.* Л.Лерон

МАЕМЛА́У *ф. сөйл.* 1) Артык күп яки артык майлы, баллы нәрсәләр ашап, ашказаны эшчәнлеген бозу; күңел болгану; үтләү. *Фома гына тагын кабак төше ашап маемлаган...* Сөембикә

2) *күч.* Күңел кайту, бизү, тую

3) *күч.* Азу, узыну, кадерен белмәү. *Ул хуҗалар байлыктан маемлап кына шулай котырынып йөриләр.* М.Маликова

Маемлап бетү Тәмам маемлау; бөтенләй бизү. *Әни: – Конфеттан бернинди зарар да юк. Ашыйсыңмы тагын берне, Инсаф? – ди. Мин инде маемлап беткән булам, конфет-шикәрне күрәсем дә килми.* Г.Мөхәммәтшин

Маемлап китү Билгеле дәрәҗәгә җиткәннән соң маемлау. *Шулай*

көйләнеп китә Мостафинның эчке тормышы. Рәхәтләнә бир, маемлап кына китмә! Ә. Еники

МАЕМСЫР *с. сөйл.* Бик нык керләнеп, каешланып беткән; майлаган кебек ялтырап торган

МАЕМСЫРА́У *ф. сөйл.* Керләнеп, каешланып, майлагандай ялтырап тору

МАЕМСЫРАУЛЫ *с. к.* **маемсыр**

МАЕРУ *ф. иск.* Бору, әйләндерү, кыйшайту, чалшайту. *Как сөяген каерып, Куйдай итеп маерып, Ир Капланны өреп, Туктамыш хан кашына Саугатка алып китерде.* Дастан

МАЕРЫК *с. диал.* **1.** 1) Кәкре, чалыш (аяк тур.)

2) Ябык, хәлсез. *Икесе дә [кызыл-армеецлар] юка гәүдәле, эчкә баткан күкрәкле, маерык кыяфәтләр иде.* Х.Камалов

3) Зәгыйфь, авыру (мал-туар тур.)

2. *рәв. мәгъ.* Кыек итеп, чалыш (басу, атлау тур.)

МАЕРЫЛУ *ф. иск.* Кыйшаю, чалшаю, борылу. *--- Аяклары аерылган, Тояклары маерылган, Өер атка иярә алмый Бара торган ябага – Аңа нукта кидерде.* Дастан

МАЕШУ *ф. иск. к.* **маерылу**. *Аван икән Ир Каплан: Кармак булып каешып, Җиз бармагы маешып, Кыпчак бигә елышып, Туң чукмарын бер орды.* Дастан

МАЁВКА *и. рус тар.* Революциягә кадәр Россиядә революцион карашлы эшчеләрнең Беренче Май көнне үткәрә торган яшерен җыелышлары. *Бу алан – Уральск эшчеләренең 1906 елда беренче маёвка үткәргән һәм атлы казаклар белән очрашкан урыны*. З.Рәсүлева. *Тукайга турыдан-туры кагылышы булган маёвка урынын чистартып, истәлек билгесе кую турында да хыяллаланар*. Ватаным Татарстан

МАЁВКАЧЫ *и. тар.* Маевкада катнашучы

МАЖОР *и. фр. муз.* **1.** 1) Нигезендә зур һәм кече терцияле аккорд барлыкка китерә торган өч тавыш яткан, дәртле, күтәренке төсмер белән характерланган музыкаль лад; *киресе:* **минор**. *Делиб әнә шул ышаныч белән мажор тонда операсын тәмамлаган.* М.Мәһдиев. *Музыкада мажордан минорга күчкән кебек, Фәрит үзе тормышның бер халәтеннән икенчесенә атлап керде.* Р.Низамиев

2) *күч.* Күтәренке күңел, кәеф

2. *с. мәгъ.* Уңай тәэсир итә торган, кәефне күтәрә торган, шат рухтагы. *Мажор ладка корылган өч кисәкле бу җыр безнең совет чынбарлыгында гына үзенең икенче яңа тормышын тапты ---.* Ж.Фәйзи. *«Яфраклар коелганда» дип аталганы, киресенчә, мажор тонда язылган; биредә гаҗәеп дәрәҗәдә оста сайланган төсләр гармониясен күреп сокланасың.* К.Миңлебаев. *Аннан инде, йола үтәлгәчтен, Мажор тонга күчеп тагын бер, Үткәннәрнең әйбәт көннәрен дә Хәтерләргә форсат табылыр.* Ә.Рәшит

МАЖОРДОМ *и. лат.* 1) *тар.* V–VIII гасырларда Франк дәүләтендә югары вазифадагы кеше

2) Зур йортта барлык хуҗалык, тәэмин итү һ.б.ш. эшләр белән идарә итүче; дворецкий

МАЖОРИТАР *с. махс.* Бер мандатлы сайлау округында тавыш бирү нәтиҗәләрен билгеләүдә күпчелек тавыш алган кандидатны сайланган дип исәпләүгә нигезләнгән. *Мажоритар система*

МАЖОРЛЫ *с.* Нигезендә мажор лады яткан, мажорда иҗат ителгән. *Мажорлы гамма*

МАҖАР *и. к.* **мадьяр**. *Алмас ханның онығы Арпат, мажарлар кавемен җитәкләп, көнбатышка таба юнәлә.* М.Хәбибуллин. *Будапешт урамында, мажарлар арасында бер җырладык төнозын «Олы юлның тузаны»н...* Р.Бохараев. *Самолётта бер тапкыр комплексны ризыклар бирәләр бит инде. Мажарларның күз явын алырлык зиннәтле тартмаларында тартма эчендә тартма икән.* Т.Нәҗмиев

МАҖАРА *и. гар.* 1) Бер кешенең башыннан үткән кызыклы, гадәти булмаган хәл, көтелмәгән вакыйгалар чылбыры. *Теге яки бу күршеләренең төнге кәсептә йөргәндә башыннан кичергән мажараларын турында ачыктан-ачык сөйлиләр.* М.Әмир. *Бу җаваплы эшемдә кечкенә генә мажаралар да булмады түгел.* Ж.Фәйзи. *Рафисның эш киеме киюе үзе бер мажараға әверелде. Келәттә аңа яраклысы юк иде ---.* Н.Әхмәдиев

2) Уңышлы булуы икеле, шикле гамәл, хәвефле хәл, куркыныч вакыйга. *Акылга утырырга вакыт җиткән булса да, эчтән ниндидер шайтан котыртып, яңа мажараларга этәреп тора иде.* М.Насыйбуллин. *1935 елны мажаралар яратучы француз коммерсанты Август Рабо Көньяк Америкага крокодиллар ауларга китә.* Кызыклы ихтиология

3) Гомумән, очрак, хәл. *Өйдә базар мажарасын сөйләп тә бетерә алмады, Әхмәт шундый итеп берне китереп кундырды: Бибисаракай чәчрәп идәнгә барып төште.* Ф.Мансуров

4) Мавыктыргыч формада язылган, гадәттә ерак илләр, сәяхәтләр, күрелмәгән хәлләр сурәтләнгән әдәби әсәрләр жанры. *Безнең әдәбиятта мажара жанры туып-формалашып килә.* Ф.Миңнуллин. *Ул шул минутта үзен тиз генә кулга алып, кызы өчен мавыктыргыч мажара уйлап чыгарды.* Г.Гыйльманов

◊ **Мажара эзләү** Җитди уйламыйча, кирәкмәгән, шикле, куркыныч эшләргә катышу. *Егет яшь, каны уйнап торган чак: кичә шактый чөмерелгән, төне буе мажара эзләп йөрелгән, инде «атам» дисәләр дә йокыдан бүленәсе килми.* З.Фәтхетдинов. *Ацтеклар һәм инклар яшергән хәзинәләр комсызларга гына түгел, мажара эзләүчеләргә дә тынгы бирми.* М.Юныс

МАҖАРАЛЫ *с.* **1.** 1) Төрле кызыклы вакыйгаларга, мажараларга бай. *Илүсә, мажаралы кино караган кебек, бу йола туен авызын ачып, шаклар катып карап торды.* Г.Гыйльманов

2) *әд.* Чагыштырмача гади эчтәлекле, башлыча төрле мажаралар тасвир итүгә нигезләнгән, җиңел укыла торган (әдәби әсәрләр). *Билгесез даһиларыбыз иҗат иткән --- мәзәк һәм мажаралы романнар, җырлар һәм дастаннар, энҗе-җәүһәрләргә тиң әдәбиятыбыз, гыйльми әсәрләребез гасырлар буе җыйналып килә-килә бай хәзинәгә әверелгән.* Т.Әйди. *Мажаралы*

романнар язучыларның үз робинзоннарын тропик илләргә төшереп калдырырга яратулары очраклы хәл түгел. Робинзон эзләреннән. *Документаль һәм мажаралы повестьларның һәммәсе диярлек шәһәр материалы җирлегендә язылган.* Ф.Миңнуллин

2. *рәв. мәгъ.* Тынгысыз рәвештә, төрле мәшәкатьләр белән. *Ул көнне төн бик мажаралы узды: Гыйззәтуллин ике тапкыр кычкырып уянды, Зарифуллин төшләнеп көлде.* М.Мәһдиев

МАҖАРАЛЫЛЫК *и.* Мажаралы булу үзенчәлеге; мажаралы булу дәрәҗәсе. *Балалар әдәбияты мажаралылыгы белән кызыктырып торырга тиеш*

МАЗА *и. гар.* 1) Тынычлык; тыныч тормыш, иминлек. *Суның мазасы боз белән, ашның тәме тоз белән.* Мәкаль. *Бай белән кода булсаң, назланып мазаңны алыр, ярлы белән кода булсаң, теләнеп мазаңны алыр.* Мәкаль. *--- Башына тынгы кунган йорт, Тынычлык, мазаң алдырдым, Әл-аман бул миннән соң!* Дастан. *Илнең мазасы киткән. Яу артыннан яу.* М.Госманов

2) Гамь, дөнья мәшәкате, борчу. *--- мәхәббәт бар! Кемдәдер ул хис йокымсырап ятадыр, дөнья мазасы белән тупаслангандыр, уятырга кирәк аны, заманга, тормышка яраклаштырып уятырга кирәк...* А.Гыйләҗев. *Бик күп булды мазасы – Шул мөртәтнең казасы. Аш итмәде ашымны, Каз ашады башымны.* Ш.Галиев. *Шәһәрләрнең кайсына эләксәң дә, аларда бертөслерәк тормыш хәзер. Сугыш мазасы һәркайсына үзенең тамгасын суккан...* Р.Низамиев

3) *күч.* Уй, хәстәр, кайгыртучанлык. *Яшьләр – яңа өйләнешкәннәр, боларда сыер-сарык мазасы юк, мич ягасылары да килми, әзергә-бәзер, үз бәхетләренә үзләре чумып, каладагыча яшәргә омтылалар.* А.Гыйләҗев

4) Файда, мәгънә. *Айдар абзый, сүз озайтуда маза юк. Каһарманны чыгарасызмы, юкмы?* Т.Гыйззәт

МАЗАЛАНУ *ф.* Мәшәкатьләнү, интегү. *Иң яраткан күперегез булып, аны нык мазаланып, зур авырлыклар белән салгансыз, ди.* Р.Мирхәйдәров. *Хәербарга артыгы кирәкми иде, ул урталай сыгылып, һава сулый алмый мазаланган егетнең җирдә яткан мылтыгын алды да кайтыр якка атлады.* З.Мурсиев

Мазаланып тору Шактый вакыт мазалану

Мазаланып утыру *к.* **мазаланып тор**у. *--- самолёттан чыгарга чакыру көтеп, мазаланып утырган юлчылардан аңа игътибар итүче булмады.* Р.Мирхәйдәров

МАЗАЛАУ *ф. к.* **мазасызлау**. *Бабай бервакытта да сүгенми, ачуланмый иде. Берәребез аны бик артык мазалый башласа гына: --- Кит әле моннан!.. – дип куя торган иде.* Г.Гали. *Без, һәрвакыт салынып төшеп мазалый торган киндер ыштаннарны күтәрә-күтәрә, бер-беребезне узышып, тау астына тәгәрәдек.* Г.Бәширов. *Бал кортлары мескен атны мазалыйлар. «Быз-быз» килеп, минем дә якага, балакка, җиң эченә сырыштылар.* Г.Вәлиева

Мазалап тору Гел, еш кына яки шушы моментта борчу, мазалау

Мазалап йөрү Тирә-юньдәгеләрне шактый тынычсызлау, борчу. *Шундый зур кешене мазалап йөрүемә кыенсынып, оялып куйдым ---.* Ә.Моталлапов

МАЗАЛЫ *с.* 1) Тыныч, имин; мәшәкатьсез

2) Мәшәкатьле, борчулы. *Кәүсәрия дә директордан ял сорагач, җыенырга ук керештеләр. Анысы бик мазалы булып чыкты: тегесен дә, монысын да аласы килә, ләкин ярамый.* З.Мурсиев

МАЗАР I *и. гар. иск.* 1) Кабер өстендә торгызылган зиннәтле корылма яки үле гәүдә куела торган төрбә. *Үлегенә карап мазары, товарына карап базары.* Мәкаль

2) Кабер. *Базарыбыз белән бергә Мазарыбыз да бер җирдә.* Ә.Синугыл-Куганаклы. *Өметсез кеше мазар эзләр.* Мәкаль

3) *к.* **мазарлык**. *Балалы өй – базар, баласыз өй – мазар.* Мәкаль

МАЗАР II *и. гар. диал.* 1) Әллә кайсы җир, билгесез бер урын, ниндидер бер юнәлеш. *Кай мазарыма киткәндер. Кай мазарыма куйганнардыр, һич таба алмыйм*

2) Әллә ни, ниндидер бер әйбер, әллә нәрсә. *Әй әни, күрсәң иде [аның] кармакларын: шундый шәпләр, аның калкавычлары да агачтан түгел, әллә ни бер мазар шунда.* З.Бәшири

МАЗАР III *кис. гар.* Парлы исемнәрнең (сирәк кенә фигыльләрнең) икенче компоненты булып, «кебек, ише» мәгънәсен белдерә. *--- ул явыз катын сине сыйдырмый икән, мин сыйдырырмын, үзебездә торырсың, эштән кайтуга, кием-салымыңны, китапмазарыңны алып кил ---.* Г.Ахунов. *Авыл халкыннан берәрсенә белешмәмазар кирәк булмый калган көннәр, айһай, ел тәүлегенә ничәү генә була икән?* В.Нуруллин. *Әнә бит тирә-якта бер эз дә юк. Кеше-мазар йөргән җир түгел бу...* Г.Гыйльманов

МАЗАРЛЫК *и.* Каберлек, зират. *Менә кинәт киселделәр саз кыллары, Өзелеп көе, тынып калды гармуннары, – Мазарлыктай тынга калды табыннары.* Ф.Бурнаш. *Үзебезчә бер сүз әйт әле син! – Тәкрарлап бер җырлар язарлык. Онытылган, үлгән, корыган тел... Бер сүз калган – мазар. Мазарлык...* Р.Зәйдулла

МАЗАРСТАН *и. к.* **мазарлык**. *Чиготай зираты кечерәк калкулыкта урнашкан һәм, шәһәр йортлары килеп терәлгәнче, бик күп еллар элек үк мазарстан булып торган.* Р.Мирхәйдәров

МАЗАСЫЗ *с.* 1) Тынычлыгы, тотрыклылыгы бозылган, тынычсыз, болгавыр, хәвефле, чуалышлы. *Габидулла бистәдәге мазасыз хәлләр өчен шәһәр түрәләренең борчылуын әйтеп сүз башлады.* Г.Минский. *Мазасыз заманнан шешә артына качып булмый.* Ш.Галиев

2) Тыныч, гамьсез, кайгысыз, борчусыз, мәшәкатьсез. *Һай бу яшь күңелне, тынгысыз һәм мазасыз бу дәртле йөрәкне!* Г.Бәширов

МАЗАСЫЗЛАНУ *ф.* 1) Тынычлыгы бозылу, уңайсызлыклар күрү, мәшәкатьләнү

2) *күч.* Борчылу, пошыну, тынычсызлану. *Шамил генә аларның шау-гөр килүенә битараф калды. «Нәрсәгә әле шулкадәр мазасызланам?» – дип уйлады ул.* З.Фәтхетдинов. *Хәзер инде кайсы тарафка очарга белми мазасызланамы [сыерчык]?* С.Поварисов

Мазасызланып тору Шактый вакыт мазасыз булу яки хәзерге моментта мазасызлану

Мазасызланып яту *к.* **мазасызланып тору**. *Шулай мазасызланып ятып, өч сәгатьләр узгандыр, бер мәлне, чыбылдыкны сак кына ачып, Таҗинур карчык керде.* З.Фәйзи

МАЗАСЫЗЛА́У *ф.* Борчу, тынычлыгын бозу, уңайсызлык тудыру, мәшәкатьләү. *Узган елгы Сылугөл кебек, мазасызлап, эш арттырып йөрүче булмасын тагы.* З.Фәйзи. *Гадәттә исә Королёв белгечләр эшенә тыкшынмый: алай эшләү кешеләрне мазасызлый гына.* Галәмгә юл

Мазасызлап тору Шактый вакыт мазасызлау; гел мазасызлау; хәзерге моментта мазасызлау. *Моннан соң күбә артыннан күбә, бал корты шикелле мазасызлап, кибән өстенә ябырылып кына торды.* З.Биишева

МАЗАСЫЗЛЫК *и.* Тынычлык җитмәү, тынгылык булмау хәле; мәшәкатьле, борчулы булу

МАЗЛУМ *с. гар. иск.* **1.** Кыерсытылган, изелгән, җәберләнгән. *Ярлы авыл, мазлум җир эшчесе, Урагыңны ал да син, әйдә, Көтә сине анда иркен бәхет, Күп көттермә, батыр йөр, әйдә!* М.Җәлил

2. *и. мәгъ.* Золым ителгән, кыерсытылган, изелгән, җәберләнгән, кимсетелгән кеше. *Кылыч күтәрсенме шагыйрь, Җаннарны кыеп? Шигырен кылыч итә ул, Уйларын уеп. Һәм изге антын яңартып Йөрәге аша, Мазлумнарның башын сыйпап, Яшәүгә дәшә.* Ә.Рәшит

МАЗЛУМӘ *и. гар. иск.* Мазлум хатын-кыз

МАЗОК *и. рус мед.* Кешенең яки хайванның сәламәтлеген тикшерү, бигрәк тә йогышлы авырулар булу-булмавын билгеләү өчен, берәр лайлалы тышчасыннан алына торган сыекча

МАЗОХИСТ *и. лат.* **1.** Үзенең күңел газапларыннан канәгатьләнә торган, үзен-үзе җәберләүче кеше (Л.Захер-Мазох исеменнән). *Соңгы вакытта нишләптер гел үземә зыянга эшлим... Мин инде мазохистка әйләнеп беттем, хәерле булсын...* М.Юныс. *Хәер, без барыбыз да – мазохистлар. Безне изәләр – безгә рәхәт.* Т.Миңнуллин

2. *с. мәгъ.* Газапта канәгатьлек таба, кимсетүгә, җәберләүгә артык түзә торган. *Гаҗәп бит: үз-үзен кечерәйтүдән, үз-үзен мыскыллап изүдән тәм таба алган мазохист милләт тагын бар микән дөньяда?* М.Гали

МАЗУ́РКА *и. пол.* 1) Атамасы Польшаның Мазовия өлкәсе белән бәйле, XIX гасырда Европада бал биюе буларак таралган, өч өлешле тактлы поляк халык биюе. *--- ул авыр хәсрәтләр полька һәм мазуркага бии-бии вальс әйләнгән бу кешеләр өстенә дә капланыр микән соң ---?* Р.Низамиев

2) Шул үлчәмдә язылган инструменталь пьеса. *--- композитор Валлдемоссада вакытта үзенең мәшһүр мазуркасын, ике соната һәм «24 прелюд»ын яза.* М.Мәһдиев

МАЗУТ *и. төрки* Нефтьтән яки аның икенчел продуктларыннан керосинлы, бензинлы, газойльле фракцияләрне аерып алганнан соң калган, сыек ягулык буларак яки майлау материаллары, битум, кокс җитештерү өчен чимал буларак кулланылган куе сыекча. *Элегрәк --- балыклар уйнар иде. Бу юлы күрмәдем. Бөтен елганы иңләп, мазут элпәсе ага...* М.Хәсәнов. *--- шундый зур корабль бер алып чыккан мазут запасы белән айдан артык йөзә ала.* Дөньяда ниләр бар. *Кемнәрнеңдер һаман мазутка батып, пычранып йөрисе килми, кайберәүләрен ата-бабадан калган игенчелек хезмәте мавыктыра.* Казан утлары

МАЗУТЛА́У *ф.* 1) Мазут сылау, мазут ягу, сеңдерү

2) Мазут белән пычрату; мазут таплары калдыру

Мазутлап бетерү Бөтен җирен мазутлау

Мазутлап кую Махсус мазутлау, мазут сылап, сеңдереп әзерләү

Мазутлап ташлау Бик тиз арада мазутлау

МАЗУТЛЫ *с.* 1) Мазут белән пычранган, мазутка буялган. *Салкын җил исә, күрәсең, сука суыгы җиткәндер, төньяк җиле вокзал лабазы артында җыелып торган мазутлы суларны шадраландыра, сабакташым Мансур белән минем ач үзәкне өзеп, муеннан кереп балактан чыга торган шәфкатьсез җил исә.* М.Мәһдиев. *Хәрби трибунал белән янаган кеше түзми: безне мазутлы бик зур кулы белән ишкәк эскәмиясеннән кош мамыгыдай гына очырып җибәрә ---.* Т.Нурмөхәммәтов

2) Мазут салынган, мазут тутырылган. *Мазутлы канистр*

МАЗЫЙ *и. гар. иск.* Үткән заман, үткәннәр. *Әле һич күрмәгән сезләрне мазый.* Г.Тукай. *--- боларның һәммәсе бетте, һәммәсе килде дә кичте. Инде алар, мазыйның караңгы пәрдәсе артына кереп, мәңгегә югалдылар.* Г.Ибраһимов

МАЗЬ *и. рус сөйл.* 1) Дәвалау матдәләрен майга кушып, тәнгә сөртү өчен әзерләнгән дару формасы; *к.* **май** (*9 мәгъ.*). *Фармацевтика промышленносте борыч бөтнеге мае, ментол (спирттагы эремәләрен), борыч бөтнеге төнәтмәләре, эфкамон мазе, бөтнек суы, анестезол, олиметин, энатин шәмнәре һәм башка препаратлар эшләп чыгара.* Урман аптекасы

2) Төрле әйберләрне майлау өчен махсус техник состав; *к.* **май** (*6 мәгъ.*). *Чаңгы мазе*

МАИЛ *с. гар. иск.* 1) Берәр нәрсәгә һәвәслеге, сәләте булган, хирыс, оста, маһир. *Ләйлә вә Кайсның матурлыгына багып, бер дилбәр зиба ул дәхи бик җан илә Кайскә маил булып, борчылыр булды.* Дастан

2) *иск. диал.* Берәр нәрсәгә охшаган, охшаш, тартым, кебек. *Күрең япон әһалисен нәя маил, имеш, анлар.* Г.Тукай

МАИС *и. исп.* Кукуруз

МАЙ I *и.* 1) Савым хайваннарының, башлыча сыерның, сөтеннән сыеклыкны аертканнан соң кала торган кыйммәтле туклыклы матдә; *русчасы:* **масло**. *Малчы кулы майда булыр.* Мәкаль. *Зәйнәп җиңги ике тәлинкә белән майга чыжылдаган коймак чыгарып утыртты.* М.Мәһдиев. *Җиде басуда үскән бодайның оны, җиде чишмәнең суы, ун сыерның мае һәм дә йөз илле күкәй салынган булыр ул ипекәйнең камырына.* Ш.Рәкыйпов

2) Тере организмнарның күзәнәкләре һәм тукымаларының төп компоненты булган органик кушылма, суда

эреми торган матдә; *русчасы:* **жиры**. *Без төрле кушылмаларны – антибиотиклар һәм витаминнар, углеводлар, аксымнар һәм майлар, үстерү стимуляторларын күп итеп синтезлау эшен җайга салырбыз* ---. Химиянең киләчәге. *Алар [мономерлар] исәбенә --- шулай ук глюкоза – тереклек эшчәнлеге өчен кирәкле энергия чыганагы, майлар – күзәнәктә мембраналар төзү өчен китә торган һәм энергия туплаучы структур материал керә.* Галәм. Җир. Кеше. *Мәсәлән, майлар рәтендәге чикле углеводородларның молекулалары бик актив матдәләр белән дә реакциягә керми.* Химия фаш итә

3) Кеше тәненең тоташтыргыч тукымалары арасында тупланган әлеге органик кушылмалар катламы; *русчасы:* **жир**. *Гашыйк хәле бигрәк яман икән, Май кундырмый, бәгырем, йөрәккә.* Җыр. *Тәндә бер чеметем май юк. Мускул, сеңер, сөяк.* М.Юныс. *Тире асты май катламы җылылыкны начар үткәрә, бу хәл тән температурасын даими сакларга ярдәм итә.* Биология

4) Шул матдәнең хайван тәнендәге – мускуллар белән тире арасындагы тупланмасы; *русчасы:* **сало**. *Шәһәр базарында халык мал таный: гел майдан гына торган ит арасыннан моны тиз танып алдылар.* М.Мәһдиев. *Әйе! Чын каракучкар иде. Курдүгеннән генә дә пот ярым май чыкты.* Р.Мирхәйдәров. *Тимерчыбыкка яки чи таякка кидереп учак өстендә кыздырылган ит һәм ит маеның кисәкләреннән аучылар шашлыгы хәзерләрсез.* Робинзон эзләреннән

5) Хайван маеннан (*4 мәгъ.*) эретелгән һәм ризык, чимал буларак яки башка төрле техник һәм хуҗалык максатларында файдаланыла торган матдә; *русчасы:* **смалец**. *[Солдат], хатынына карабодай я ясмык коймагы пешертеп, шуны каз мае белән майлап, яңа сауган сөт белән чәй эчәр иде.* М.Гали. *Кайсыдыр бер бәндәнең әйтүенә ышанып, Кариев җылкы мае эчә башлый. Җылкы мае аны савыктырмый, эчке әгъзаларын, бавырын тәмам эштән чыгара.* Р.Батулла. *Үтерелгән тур түшкәсеннән җиде мичкә май эретеп алырга була, шуның өстенә тагын йөз ушат итте дә була икән әле.* Дөньяда ниләр бар

6) *анат.* Кешеләрдә, имезүче хайваннарда тышкы секреция бизләре тире өстенә бүлеп чыгарган, аның дымлылыгын һәм сыгылмалылыгын тәэмин итә торган матдә. *Май бизләре*

7) Үсемлекләрнең, гадәттә махсус игелгән техник культураларның, орлыгыннан сыгып алына, ризык, чимал, майлау материалы һ.б. буларак кулланыла һәм суда эреми торган куе сыекча; үсемлек мае. *Май сыгу производстволары безнең терлекчелегебезгә ел саен, ай саен, көн саен аксымга бай булган түп биреп тора.* А.Расих. *Көнбагыш, мамык һәм башка күп кенә үсемлекләрнең орлыклары исә майга аеруча бай.* Биология. *Урман чикләвеге төшләреннән алынган май аеруча кыйммәт бәяләнә. Үзлекләре буенча ул бадәм маеннан калышмый.* Урман аптекасы

8) Төрле табигый яки синтетик чималдан җитештерелгән яки табигатьтә табыла торган сыек, ярым сыек яки куе ягулык, техник майлау материалларының сөйләмдәге гомуми атамасы. *Өс-баш киемнәрендә май таплары беленеп торган, зур кирза итекле, торнадай озын сыйраклы ефрейтор теләр-теләмәс кенә кулларын күтәрде.* Ш.Рәкыйпов. *Шул урыннарда аның [елганың] су агышы гына түгел, ә сулышы да байтак тукталып торды, өстенә май җәелде, чүпләр тулды.* Ә.Гаффар. *Канифоль лаклар, сургуч, тәгәрмәч мае ясауга, кәгазь җилемләүгә, сабынга китә.* Робинзон эзләреннән

9) Хуш ис бирү, тирене йомшарту, дәвалау кебек максатлар белән сөртелә торган крем, эссенция кебекләрнең сөйләмдәге гади атамасы. *Кашыңны кара йөртәсең, Нинди майлар сөртәсең? «Сөям» сүзләреңне әйтеп, Җанымны эретәсең.* Җыр. *Борынгы Шәрыкта җәрияләр, төн җиткәндә, үзләренең тәннәренә иң затлы чәчәк майлары сөрткәннәр.* М.Мәһдиев

10) Керосин. *Җиделе лампа якты яна, эчендә мае булса.* Җыр. *Мин язам, шунда күрәм: лампам эчендә май кими.* Г.Тукай. *Кайсын корымнан чистартты, кайсының насосын төзәтеп, май өстәп, керогазларны яндырып җибәрде [Мәгариф].* Х.Камалов

11) Бензин. --- *икенче цилиндрның газы ачыла. Аннан карбюратор аркылы тагын газга әйләнгән май бөркелә.* М.Мәһдиев

12) Авырткан урынны тыштан дәвалау өчен, тирегә сылап сеңдерелә яки ярага сөртелә торган дарулы куе катнашма; *русчасы:* **мазь**. *Иң әйбәте – балавызлы май. Шул килешә минем кулга.* М.Юныс. *Дию борычының тамыры төче авыруына (золотухага) каршы кулланыла торган май (мазь) һәм настойка составына керә.* Робинзон эзләреннән. *[Терлектә] җәрәхәтләнгән урыннарны бөҗәкләрдән саклау өчен, йодоформ, нафталин, креолин һәм башка төрле майлар сөртәләр.* Сөт терлекчелеге турында кыскача белешмә

13) *күч.* Затлы, туклыклы, тәмле ризык

14) *күч.* Туклыклы матдәләр, җим. *Өстәлләрдә икмәк арткан саен, җирнең мае кими басуларда.* Р.Низамиев

15) *күч.* Физик һәм рухи көчләр, яшәү дәрте. *Кешеләр ябыктылар, хәлсезләнделәр. Йөрәкләрдә май бетте. Сугыш алҗытты.* М.Мәһдиев

16) *күч.* Матди мөмкинлекләр, физик көч, куәт, егәрлек. *Мае җитәрлек әле егетнең*

17) *диал.* **маем, май гынам**. Якын итеп, яратып яки жәлләп эндәшү яки атау сүзе. *Кирәк түгел, су сипмә, май гынам, Икәү бергә яныек, алтыным, канатым!* Җыр. *Нещадим, маем, үз-үзен аямады шул. Туп янында япа-ялгыз калып, атуын дәвам итте.* Ш.Рәкыйпов

◊ **Мае котыру** *к.* **маена чыдый алмау**. *Бер төрле дә җәза бирмәгәнгә, шулай майлары котыра.* Ш.Рәкыйпов. **Маена сыешмау** *к.* **маена чыдый алмау**. **Маена сыймау** *к.* **маена чыдый алмау**. **Маена түзә алмау** *к.* **маена чыдый алмау**. **Маена чыдый алмау** Мул, тыныч, рәхәт тормышның кадерен белмичә азу, бозылу, узыну. --- *бу шакмакка [Рубик кубигы] чират торган халыкны мин кызганмадым. Әйдә, торыгыз, маегызга чыдый алмыйсыз икән, торыгыз, дидем.* М.Мәһдиев.

--- ир уртасына җиткәч, яшьләр күк, аерылабыз, дип дулый. Маена чыдый алмый, пәрие котырта үзен. Г.Тавлин. *Иртән, спорт костюмы киеп, урам буйлап йөгергән өлкән кешене күреп, Күлле халкы: «Эшсезлектән маена чыдый алмый», – дияр иде.* Р.Мирхәйдәров. **Маена чыдаша алмау** *к.* **маена чыдый алмау**. *Тыныша алмадым... Зоотехник белән. Тылда утырып, маена чыдаша алмый башлаган бюрократ шунда.* А.Расих. **Маен чыгару** 1) Файдасын күрү, мөмкин кадәр тулырак файдалану, булдыра алган кадәр файда чыгару; 2) Бик нык тәфсилләү, җиренә җиткерү, җентекләп эшләү. *Нәҗибәнең – бәхете, ул мондый спектакльләрдә рәхәтләнеп уйный, «йөзә», рольнең тәмам маен чыгарып, тамашачыга шуның ләззәтен татытып бирә.* К.Тимбикова. **Мае чыгу** Берәр эш-гамәлнең, сөйләшүнең мәгънәсе, кирәге булу, шуннан файда, нәтиҗә булу. *Чүбек чәйнәп май чыкмады, чыкмаячак.* Г.Камал. *– Сөйләсәң, сүзнең мае чыга, үзем барып сөйләшим әле, – диде Гарәфи абзый.* Г.Әпсәләмов. **Май ашаган** Сугым ите бик симез булу турында әйтелә. **Май ашаган мәче кебек (төсле)** Кемнең дә булса берәр шуклык, мутлык яисә гаеп эш эшләгән кебек кыяфәте, кыланышы, үз-үзен тотышы турында. *Синең дә аны күрү белән күзләрең май ашаган мәче кебек ялтырап-ялтырап китә.* Х.Мөдәррисова. **Май басу** 1) Артык симерү, май катламы белән каплану. *Май баскан күзләрен чекрәйтеп, озак кына Галимҗанга карап торды [хуҗа].* С.Поварисов; 2) Рухи яктан ялкаулану, тирән уйламаучан, ваемсыз кешегә әйләнү. *Алар --- кичәге кебек ырылдаша, талаша башладылар, бераздан икесе дә тыелып, май баскан хәтерләрендә нидер уянып, сүзсез калдылар.* А.Гыйләҗев. *Ләкин Лютыйның күзләрен май баскан, ул бернине дә алдан исәпләп тормый иде инде.* Р.Мирхәйдәров. **Май булып** Үтә уңай кабул ителү, күңелгә бик тә хуш килү турында. *--- башка берни кирәкми, җанга сары май булып утыра ул яңалык.* Р.Мөхәммәдиев. *Ә большевиклар исә, шул ук шовинист булсалар да, форсаттан нык файдаланалар, халык күңеленә май булып ягыла торган лозунгларны «сибәләр» генә.* М.Әхмәтҗанов. *Бу юллар Фәридун абзыйның җанына май булып тама.* В.Юныс. **Майга китү** Майга (*3 мәгъ.*) әйләнү, май (*3 мәгъ.*) булып туплану, симертү. *Май майга китә, шулпа гына кая китә.* Әйтем. **Майга ут төртү** Берәр бәрелеш, низаг башланып китүгә сәбәпче булу, конфликтка этәрү, коткы салу. **Майда йөздерү** Кемгә дә булса бай, мул, җитеш тормыш тәэмин итү, кадерләү, рәхәт күрсәтү. **Майда йөзү** Һәрьяктан җитеш тормышта, рәхәттә, байлыкта, муллыкта яшәү, кыенлык күрмәү. *Шулай итеп, аның майда гына йөзеп яшәрмен дигән хыяллары җилгә очты.* З.Фәйзи. **Май җыю** 1) Симерү, май туплау; 2) Ял итү; 3) Эшләмичә, ялкауланып яту. **Май канаты** Камыр ризыклары пешергәндә, табаны яки ашларның йөзен майлау өчен, каз яки үрдәк каурыйларыннан ясалган бәйләм. **Майдай итү** Уңай фикергә китерү, күндерү, ризалату; күңелен күрү, җайлау, көйләү. **Майдай эрү** *к.* **май кебек эрү**. *Җиңгиләрнең өйләре җылы, тәрәзәләренә хәтле эрү иде, мин дә, аш ашагач, майдай эреп кенә киткәнмен һәм шунда йоклап та калганмын.* Х.Сарьян. **Май кап «**Артыгын сөйләшмә, кешегә белгертмә, башкаларга сөйләмә, үзең генә бел» дип, сүзнең, хәлнең сер икәнлеге турында кисәтү. *Сул кулы яраланган, дияргә дә – вәссәлам. Кайда, кайчан – моны-сы турында май кап...* Ш.Рәкыйпов. *– Казанга кунаклар киләсен белмисеңме әллә, әби? Бу югарыдан бирелгән фәрман буенча эшләнә бит, май кап! – дип кеткелдәп алды [бер ир].* З.Фәйзи. **Май каплау** *к.* **май басу**. *Бу кешенең күзләрен дә май каплаган хәтта.* С.Поварисов. *Җил-давылсыз тыныч-лыкта яшәгәндә, теләкләрне, омтылышларны май каплый башлый.* М.Юныс. **Май кебек** 1) Өй, кием, көн, су һ.б.ш.ның бик җылы булуы, тәнгә рәхәт булуы турында. *«Төнлә керергә кирәк суга, су монда төнлә бик җылы була, май кебек», – диде [Саттар].* Н.Акмал; 2) «Барысы да тәртиптә, эшләр уңышлы, тиешенчә бара, хәлләр әйбәт» мәгънәсендә. *Хәзергә һәммәсе дә май кебек.* Ф.Бурнаш; 3) Кешегә карата бик ягымлы, йомшак мөгамәләле, мөлаем; 4) Тәрбияле, әдәпле, тыңлаучан, тәртипле. *Балалар аның яныннан май кебек булып кайталар.* А.Шамов; 5) Бик ягымлы, күңелгә хуш килә торган, күңелгә ятышлы (сөйләшү, сүз һ.б.ш. тур.). **Май кебек эретү** 1) Күңелне йомшарту, күңелгә хуш килү, җанга рәхәт, ләззәт, канәгатьлек бирү; 2) Бик тиз тирән йокыга талдыру, рәхәт йокыга җибәрү. *Нинди хикмәтедер, әби түшәгән шул урын мине май кебек эретә дә җибәрә торган иде.* Г.Гали. **Май кебек эрү** 1) Күңеле йомшау, куану, рәхәтләнү, ләззәтләнү, бик канәгать булу. *Ханым бөтенләй май булып эреп елмая.* В.Юныс; 2) Яту белән тирән йокыга талу, рәхәтләнеп, изрәп йоклап китү. **Май кебек ягылу** Артык ягымлы булып күренергә, ошарга тырышу, ялагайлану. **Май тибү** *к.* **маена чыдый алмау**. *[Зәһидулла мулла никахлы өч хатыны өстенә ике сөяркә тоткан.] Шуңа ни әйтәсең инде? Төшем күп, эш юк. Май тибә, нишлисең?* Ш.Камал. **Май төшерү** Ябыгу, тәндәге артык майдан котылу, аны киметү, бетерү. *[Курортта], физкультура залындагы кебек, кешеләрне үрмәләтеп, майларын төшерәләр икән.* Г.Әпсәләмов. **Май төшү** Каймакны туглау нәтиҗәсендә, мае әйрәненнән аерылу. *Су язып май төшми.* Мәкаль. **Май урлаган мәче кебек (төсле, шикелле)** *к.* **май ашаган мәче кебек (төсле)**. *Безнең күршедә генә берсе, май урлаган мәче кебек, әмма күзләрен елтыратып йөри дә соң!* Ф.Хөсни. *Бикташны тагын урамда калдырып, ашыгып азык-төлек кибетенең арткы ишегеннән кереп китә дә, озак та тормый, кызарынып, күзләрен май урлаган мәче шикелле елтыратып килеп тә чыга [Сәетҗан абый].* М.Маликова. **Май төсле** *к.* **май кебек**. **Май шикелле** *к.* **май кебек**. *Тавышы матур, үзе батыр, Май шикелле сүзләре.* Ә.Ерикәй. *Май шикелле диңгез суы Ят кебек, салкын сымак, Авылымның кеп-кечкенә Буасы якын сымак.* Атнабай

МАЙ II *и. лат.* 1) Календарь елның бишенче ае, борынгы итальяннарның җир алиһәсе исеме белән аталган, дип фаразлана. *Ай күзе белән тыныч дөньяга караган зәңгәрсу май төне иде.* Ә.Гаффар. *[Имән] Апрель ахырында, май башларында чәчәк ата, җимешләре сентябрьдә, октябрь башларында өлгерә.* Урман аптекасы. *Җылы майлар нишләп салкын миңа, ямьсез уйлар нишләп бәйләнә?* Ә.Дусайлы

2) *күч.* Май аендагы кебек җылы вакыт, матур, ямьле, рәхәт чор

3) *күч.* Яшь чак. --- *баланы да вакытында үстерү кирәк. Яшь, дәртле-дәрманлы чагында – гомереңнең маендa!* Ш.Галиев

◊ **Май бәйрәме** 1) *тар.* Беренче май көнне билгеләнгән хезмәт ияләренең халыкара бердәмлеге бәйрәме. *Яз җиткәнен сизми дә калдык. Май бәйрәмен дә уздырдык.* Ж.Фәйзи. *Май бәйрәме – алар өчен үтә кадерле, үтә төшемле бәйрәм.* А.Гыйләҗев. *Бервакыт шулай, Май бәйрәме алдыннан, аның янына алтынчы класс пионерлары килде.* Ж.Тәрҗеманов; 2) Яз һәм хезмәт бәйрәме. **Май бәйрәмнәре** 1 май һәм 9 май – Җиңү бәйрәме турында. *Гаиләсенең күченеп килүе дә май бәйрәмнәренә кадәр сузылды.* Р.Мирхәйдәров. **Май кояшыдай** Ачык-шат, бик канәгать кыяфәт, чырай белән. --- *Подностагы чынаякларын шалтыратып, май кояшыдай елмайган Гөлкәй килеп керде.* Х.Ширмән. *Тәһир ишеккә таба борылды, күтәрмәдә басып торган әтисе белән әнисен күреп, май кояшыдай елмаеп, колачын җәйде* ---. З.Кадыйрова. **Май кояшы кебек** *к.* **май кояшыдай**. *Бәйрәмгали, җилкәсенә пинҗәген элеп, ишегалдына чыгып китте. Машинасын кабызды. Ул да түгел, аның артыннан ук, май кояшы кебек балкып, Миләүшәсе күренде.* Р.Мөхәммәдиев

МА́Й АШЫ *и. диал.* Бодай онынан йомыркага изелгән камырны вак-вак турап, кайнап торган майда пешерелгән ашамлык; бавырсак. *Әби-бабай, аманмысыз? Аш-тәгамнар салганмысыз? Майашлар әзер, туганнар, Утырыгыз, оланнар*. Җыр. *Иртән китсәң дә ярамыймы соң, улым? Юлга азрак май ашы да пешерер идем.* Р.Ишморат

МА́Й ӘБИ *и. этн. диал.* Әбисенең яки бабасының әнисе

МАЙБАЛЫК *и. зоол.* Карплар семьялыгыннан Кара һәм Азак диңгезләре бассейнында гына таралган сирәк балык; *русчасы:* **шемая**

МА́ЙКА *и. рус* Юка трикотаждан җиңсез, якасыз итеп тегелгән, эчке кием, кайвакытта спорт киеме буларак та файдаланыла торган кыска күлмәк. *Күлмәк белән берәттән эчтән кигән майкасы да умырылып төшкән иде.* Аманулла. *Егете гитара тоткан, әллә нинди сурәтле майкадан, кызын кочаклап төшеп килә.* М.Галиев. *Аларның уң ягындагы ихатада шундый ук киртләч түтәлләргә кызыл майка кигән бер малай су сибеп йөри.* М.Маликова

МАЙ-КАЙМАК *җый. и.* Төрле сөт ашлары, гомумән, сый. *Сыер асрар хәлләре булганнар авылда калмады, алар май-каймак ашарга калаларга күченеп бетте.* А.Гыйләҗев

МАЙКАНАТ *и.* Камыр ризыклары пешергәндә табаны яки мичтән чыккан ашларны майлау өчен җыеп бәйләнгән эре каурыйлардан (гадәттә, казныкыннан) гыйбарәт пумала; майлавыч

МАЙ-КОЙМАК *җый. и.* Төрле таба ашлары, гомумән, сый. --- *килгән бер илче май-коймак ашый да --- кире китә.* М.Гафури

МА́Й КОҢГЫЗЫ *и. зоол.* Җәенке мыеклылар семьялыгыннан, урман һәм авыл хуҗалыгы корткычы булган, җитлеккән кортлары май аенда оча башлый торган кызгылт көрән төстәге коңгыз. *Шинель итәкләре ике якка ачылып, май коңгызының канат элпәләрен хәтерләткән ак халат, кечерәя барып, төн куенына кереп сеңде.* Ш.Рәкыйпов. *Чуар май коңгызы личинкасы турында да әйтеп китәргә кирәк: ул умарта кортын чәчәк таҗларында сагалап тора да, азык җыючы умарта кортына кадалып ябышып, аның белән бергә умартага керә.* Умарта кортлары. *Татарстанда иң күп санлы коңгызлар – бызылдавыклар (306 төр), филчекләр (163 төр), май коңгызлары (106 төр), шыртлавык коңгызлар (80 төр) һ.б.* Татарстанның үсемлекләр һәм хайваннар дөньясы

МАЙЛАВЫЧ *и.* Күчәр, тәгәрмәч кебекләрне тышкы яктан майлау өчен кулланыла торган, гадәттә кылдан эшләнгән пумала

МАЙЛАГЫЧ *и.* Төрле механизмнарның тар урыннарын майлау өчен махсус нечкә көпшәсе булган, эченә солидол, май кебекләр тутырылган ярдәмче техник әсбап. *Тешләр тоташтырылган урыннарны майлагыч аша майлыйлар.* Тракторлар һәм автомобильләр

МАЙЛАНДЫРУ *ф.* Майлы, сыланучан әйберләргә буяу, пычрату. *Бияләйләрне майландырып бетерү*

МАЙЛАНУ *ф.* 1) *төш. юн. к.* **майлау**. *Төп тапшыргыч – чәчрәтеп, әборылу планетар механизмы майлау челтәре торбалары --- аша майлана*. Тракторлар һәм автомобильләр. *Углекислый газлы һава бирегә керә алмый, чөнки калпак кырыйлары вазелин белән майланган һәм пыялага нык итеп капланган.* Биология. --- *әгәр дә бушаган күзәнәкләр хәзерләнмәгән, эчке яктан майланмаган һәм ялт итеп торырлык дәрәҗәгә китереп тел белән яланмаган булсалар, корт анасы аларга күкәй салмый.* Умарта кортлары

2) Май сеңү, май белән таплану, майга буялу. *Авыз тирәсе майланган, --- сагызлы чәчле малаеның, кулына кабартма кисәге тотып, урамга чыккынына тап булган әти кеше болай гына, бәхете ташыганнан гына, әлеге сагызлы башка берне биреп ала: ризыкның кадерен бел!* М.Мәһдиев

3) Гомумән керләнү, пычрану. *Мондагы халыкның һәммәсе дә диярлек соры шинельле солдат, майланган куртказы эшчеләрдән гыйбарәт булып, бик күбесенең йөзләре, төсләре тирән мәсьәлә чишүгә юнәлдерелгән уйлаучылык, җитдилек аңгарта иде.* Ш.Камал. *Пластинканың кәгазе бөтенләй майланып капланган.* М.Мәһдиев. *Чәче тузган, күзләре әллә нинди тонык карашлы, өстендә майланып беткән сырма куртка.* Л-Х.Таналин

4) Майлы булып күренү, ялтырап тору

5) *күч.* Кызу, кызыгу, ымсыну. *Кайчан карама – капка төпләрендә җигүле ат торыр, ә Сәмигулланың күзе майланган, эше җайланган булыр.* Ф.Яруллин. *Йөзләре чөгендердәй кып-кызыл, күзләре майланган, таза беләкле куәт иясе кешеләр.* Р.Мирхәйдәров. *Хатыннарга күз салуга, күзләре майланып ялтырый башлыйлар кебек.* З.Фәйзи

Майланып бетү Бик нык майлану; майга яки шуңа охшаш нәрсәгә тәмам пычрану. *Алар каршысында гимнастёркасы һәм сырган чалбары майланып беткән, кыска буйлы, ялваручан карашлы авыл малае басып тора.* Г.Ахунов. *Колхоз җитәкчеләре әлеге кара егетләр белән байтак сөйләшеләр, тагылма сукаларны көйләшкәндә, үзләре дә майланып беттеләр ---.* М.Мәһдиев. *Бикташ майланып, керләнеп беткән тимер саплы җыелмалы пәкене бик кадерле нәрсә сыман сакланып кына кулына алды.* М.Маликова

Майланып тору Майлы булып күренү, май сөрткән кебек тору. *Безнең өйгә битләре майланып торган юан бер абзый биш-алты сандык, бер унлап ястык кертеп куйды.* Ж.Фәйзи

МАЙЛАП *рәв.* Май белән, май кушып, май ягып (ашау, эчү тур.). *Чәй эчәргә утырганнар. Майлап, баллап чәй эчәләр икән болар.* Ш.Маннапов

МАЙЛА́П-ҖАЙЛАП *рәв.* 1) Эшнең рәтен белеп. *--- күп һөнәр иясе Анатолий кайсының да булса пианиносын сәгать урынына сүтеп ташлый да аннары инде майлап-җайлап ремонтлый.* Р.Низамиев

2) Мең дә бер хәйлә белән, оста итеп хәйләләп. *Хатын укыгач аңладым: бу хәйләкәр иптәш минем адресны, майлап-җайлап, энемнән алган икән.* Р.Габделхакова

3) Күндерер, ризалатыр өчен, бар тырышлыгын куеп, юмалап, ышандырырлык итеп. *Шулай да Камәриягә дөресен әйтү хәтәр икәнен истә тотып, майлап-җайлап җибәрүне хуп күрде: – Менә иптәш Гаделшина үрнәгендә эшләрсең.* М.Маликова. *Подполковник Салих Гаяров белән сөйләшеп, тегене майлап-җайлап, мәсьәләне зурга җибәрмәде, вакытында яптырды.* Т.Галиуллин

МАЙЛАТУ *ф.* 1) *йөкл. юн. к.* **майлау**. *Закир, егет-җилән шаярмасын дип, зур көймәне үзе карап майлатты, өч атны үзе карап-катнашып, үз күз алдында җиктерде.* Г.Ибраһимов. *Бригадир хәзер арбаларны кырда гына майлата.* Г.Рәхим

2) Ялгыш майга буяу, берәр майлы нәрсә белән пычрату. *Ә баш киеме, бигрәк тә түбәтәй, чәчкә сыландырып, басылып киелә. Аңлашыла ки, алай кигәндә чәч аны бик тиз майлата, керләндерә ---.* Б.Рәхимова

МАЙЛА́У *ф.* 1) Ризыкны тәмләтү, туклыклырак итү өчен, аны әзерләгәндә яки ашар алдыннан май (*1–3 мәгъ.*) кушу, салу, ягу. *Коймак-кабартманы [Камәр] мул итеп майларга ярата. Әгәр арпа коймагы пешерсә: – Әйдә, майлап аша, арпа чыкны ярата ул, – дип кыстый.* М.Мәһдиев. *Язмыш димә инде: менә шундый төгәл, пөхтә, җыйнак, һәрьяктан оешкан иргә ---, янып торган мичне бутаганда, алъяпкычына күмер очыртмый, кабартма майлаганда, түшенә май тамызмый калмас хатын туры килгән.* Т.Галиуллин

2) Пешергәндә, камыр табага ябышмасын өчен, табага май сөртү, май салу. *Бу майларның барысы да тәмле түгел, ләкин аларны кабартма пешергәндә, таба майлау, итек майлау, яндыру өчен, бик уңышлы файдаланырга мөмкин.* Робинзон эзләреннән. *Битне пешерә, Тиргә төшерә, Бик майласаң – үтләтә.* Табышмак

3) Төрле косметик максатларда (мәс., матурлау, ялтырату, шомарту өчен) махсус май, крем һ.б.ш. сөртү. *Борынгы Грециядә тәнне һәм чәчне майлау өчен кулланылган хуш исле майларны да ясап була.* Робинзон эзләреннән. *--- кимсетергә тырышып сүз башлады озын буйлы, бите бетчәле, бөдрә чәчләре майлап таралган, камердинер булса кирәк, берәү ---.* И.С.Тургенев

4) Төрле механизмнарның өлешләренә, хуҗалык кирәк-ярагына, ышкылып, кырылып таушалмасын, тутыкмасын өчен, шома, җиңел хәрәкәт иттсен, әйләнсен өчен, май (*7 мәгъ.*) салу, сылау. *Зур сәфәргә юлга чыксаң әгәр, Мулдан майла арбаңның күчәрен ---.* Ә.Синугыл-Куганаклы. *Моннан тыш, нефть майлау материаллары һәм төрле ягулыклар табу өчен дә хезмәт итә.* Химия фаш итә. *Чистарткаңнан соң, алар техник майга әвереләләр. Бу май каешлар майлауга китә.* Күзгә күренми торган матдәләр турында хикәяләр

5) Авырткан җиргә дәвалый торган сыеклык, мазь, май һ.б.ш. сөртү, ягу, сылау. *Авыл миченең җылы кирпеченә терәлеп торган кешегә бернинди дару, уу, майлау кирәк түгел билне.* М.Мәһдиев. *Хатын яраны бер кат майлады да яңа яшел бинт белән бәйләде.* Х.Камалов. *Ангинадан авызны чайкау һәм кан саркып торган уртларны майлау өчен, [төз тәпичәнең] спирттагы настойкасын файдаланалар.* Урман аптекасы

6) Гомумән, нәрсә дә булса сөртү, тидерү, ягу. *Аннан инде табага урнаштырып, --- мичкә тыгар алдыннан гына, каз каурыеннан ясалган таба канатын йомыркага манып, пәрәмәчнең өстен майлыйсы.* М.Мәһдиев. *Коймакны эретелгән сыр белән майлагыз һәм рулет итеп төрегез.* Сөембикә

7) *күч.* Буяу, сөрмә, керше һ.б.ш. сөртү. *Завод күргән кызлар безнең авылда бераз борнайрак була иде. Алар битләрен башка кызларга караганда мулрак итеп майлыйлар ---.* М.Мәһдиев

8) *күч.* Йомыш төшкән кешенең күңелен күрү, җайлау, сыйлау, ришвәт бирү. *--- иң әүвәл рәиснең күңелен күрергә, авызын майларга кирәк. Ә күп вакыт майлау-җайлауның да файдасы тими.* Ш.Маннапов. *Һәммәсен табарга, юнәтергә, җайларга, майларга, --- күз буярга, ялган гуаһлык итәргә туры килә иде. Акча кирәк, акча!* А.Гыйләҗев. *– Ну, син молодец, әйбәт майлыйсың, – диде ул аңа пышылдап кына.* Р.Мирхәйдәров

9) *күч.* Аралашу вакытында барлыкка килгән киренкелекне бетерү, кыен хәлдән чыгу, ялгышны төзәтү

10) *күч. жарг.* Аракы яки гомумән исерткеч эчемлек эчү

Майлап җибәрү Бер мәртәбә, билгеле бер моментта, тиз генә майлау;

бераз гына майлау. – *Эшләр барамы? – Майлап җибәрсәң, бара. Әллә маең бармы?* Г.Гыйльманов. *Әмма, майлап җибәргәч, эш җайланды: Рәйсәнең дә тавышы йомшарды, йөк ташучылар да табылды, аскы катка – суыткычка төшерә торган лифт та хәрәкәткә килде*. М.Маликова

Майлап йөрү Майлау эше белән мәшгуль булу. --- *Мөхипкә бер акаеп карасаң, чырый-чырый елап, өйләренә кереп кача торган иде, ә бүген район нәчәлникләрен майлап йөри* ---. И.Гази. *Ит исе чыккан тәбәнәк өйгә килеп кергәч, хәзрәтнең күзе, чыбылдык артынарак посып, бәлеш майлап йөргән яшь киленгә төште.* М.Мәһдиев

Майлап кую Алдан майлау хәстәрен күрү. *Майлап куелган авыр кара капка аның алдында тавыш-тынсыз гына ачылып ябылды.* З.Биишева

Майлап тору Бертуктаусыз яки регуляр төстә, һәрвакыт, даими майлау. *Кошлар аларны [каурыйларны] томшыклары ярдәмендә койрык бизе бүлеп чыгарган майсыман матдә белән периодик рәвештә майлап торалар, шуңа күрә аларның каурыйлары чыланмый.* Биология. Хайваннар

Майлап яту Шушы мизгелдә майлау эшендә булу. --- *әни кеше таба майлап ята, бу инде – бик тә матур күренеш, таба теге алтынсыман күмер өстенә куела, чыжлый башлый* ---. М.Мәһдиев

◊ **Майлагандай бару** *к.* **майлаган кебек бару**. *Зариф мулланың да тормышы майлагандай гына бармаган. Күңелсезлекләр дә чыккалаган, бәлагә дә юлыккан.* И.Нуруллин. *Банданың кәефе шәптән: эшләре майлагандай бара, бер җирдә дә каршылык күрсәтмиләр, ызгыш-бәхәс юк, салымны тавыш-тынсыз түлиләр, дәүләткә түләгәндә дә андый тәртип һәм ашыгу булмый.* Р.Мирхәйдәров. **Майлагандай булу** Тәртибе, кыланышы әйбәтләнү, әдәпләлөнү, тәртипләнү. *Стенгазетада аның рәсеме, фәнни бюллетеньдә аның рәсеме. Ипташең майлагандай була.* М.Мәһдиев. **Майлагандай тәгәрәү** *к.* **майлаган кебек бару**. *Күпләр беренче җиңүдән исерде, хәзер инде калганы көч түкмичә дә майлагандай тәгәрәр, дип ышана башлады. Бәйсезлекне нығыту юлларын ачык кына күз алдына китермәделәр.* Т.Әйди. **Майлаган кебек** Үзен тотышында бик ягымлы, йомшак, тыныч, җайлы. **Майлаган кебек бару** Эшләр бик җайлы, артык хезмәт сарыф итмичә бару, яхшы, җиңел, тоткарлыксыз эшләнү турында. *Башкалар зарлана, ә боларның тавышы да ишетелми, татулар, эшләре дә майлаган кебек бара.* Т.Әйди. *Инде монысы майлаган кебек барадыр, дип уйлаган идем, алай булып чыкмады.* Мәдәни җомга. **Майлаган шикелле** *к.* **майлаган кебек. Майлаган шикелле бару** *к.* **майлаган кебек бару**. **Майлап куйган кебек булу** *к.* **майлагандай булу**. **Майлап ташласаң, эт ашамас** Бер матур сыйфаты да, сокланырлык ягы да булмаган; әшәке, начар, гадәтсез (кешегә карата)

МАЙЛАЧ *с. диал.* Таза, симез

МАЙЛЫ *с.* **1.** 1) Составына май (*1, 5, 7 мәгъ.*) кушылган, май өстәлгән, эченә май салынган; май ягылган; майда пешерелгән. *Малайларга коймак та, майлы бәрәңге телемнәре дә, Сөмбелә апаларының җылы карашы, татлы теле дә ифрат ошады* ---. А.Гыйләҗев. *Кыз-кыркын ашыгыч рәвештә ак оекбашлар бәйләде, һавада майлы күмәч исе аңкыды.* М.Мәһдиев. *Суган белән сарымсак майлы һәм итле азыкларның бик яхшы үзләштерелүенә ярдәм итәләр.* Робинзон эзләреннән

2) Симез, шактый өлеше майдан (*4 мәгъ.*) торган (ит һәм ит ризыклары). *Сарысымбай, акрын, сабыр сайлап, кулына биш турам майлы ит алды.* Г.Ибраһимов. *Майлырак сарык ите күрсәтсәң, чәен, шикәрен дә каяндыр капшап чыгара [шәһәр кешесе].* Н.Дәүли

3) Төшләре, орлыклары майга бай булып, шулардан май алу өчен махсус игелә торган; *русчасы:* **масличный**. *Көнбагыш, мамык, җитен, киндер, арахис, соя һәм башка майлы культураларны май алу өчен игәләр.* Биология. *Майлы культуралар институты тәҗрибәләре мәгълүматларына караганда, каплам арпа җиренә кертелгән тирес арпага да, люцерна-арышбаш катнашмасы печәне уңышына да яхшы тәэсир итте.* Күпьеллык үләннәр. *Шепкән һәм ярут дигән чүп үләннәр бездә майлы культура буларак игелә башлады.* Робинзон эзләреннән

4) Өстенә май бүленеп чыккан, үзенең мае белән майланган; гомумән, составында мае күп булган. *Дару чималына плауннның спораларын хәзерлиләр. Алар бик вак, капшап карауга майлы, саргылт порошоктан гыйбарәт* ---. Урман аптекасы. *Җимешләре бик майлы булганлыктан, «сыер-агач» дип аталган авокадо агачын белүчеләр күп түгел.* Күпьеллык үләннәр. *Майлы тире өчен глицерин белән ясалган крем куллану яхшы.* Йорт ашлары

5) Төзелеше һәм химик составы белән майга (*2 мәгъ.*) караган, шуның нигезендәге. *F витамины, гадәттә, бигрәк тә җитен һәм көнбагыш кебек үсемлек майларында була торган туенмаган алыштыргысыз майлы олеин, линоль һәм линолен кислоталары буларак карала.* Урман аптекасы

6) Майда изеп ясалган, иң мөһим бер компоненты май булган. *Әлфинурның бу почмакны беренче күрүе иде. Майлы буяу исе аның борынын кытыклап алды.* З.Фәйзи. *Бу – Голландия корымы – кара буяу. Әгәр дә шуңа кайнатылган май (олифа) кушсак, майлы кара буяу барлыкка килә.* Робинзон эзләреннән. *Стеналарны, кайчыларны, сиртмәләрне, шпросларны һәрвакыт майлы ак буяу белән буярга кирәк.* Яшелчәчелек

7) Хуш ис тарату, дәвалау һ.б.ш. максатлардан май (*6, 8 мәгъ.*) кушылган, составында май булган. *Майны көнгә 2–3 тапкыр берәр чәй кашыгы эчәләр, ә югарыгы сулыш алу юллары авыруларыннан майлы ингаляцияләр ясыйлар.* Урман аптекасы

8) Майга буялган, майлы таплары булган; май сеңгән. *Узган гасырның ахырында, бакыр колчеданыннан бушаган майлы капчыкларны юган вакытта, колчедан бөртекләренең сабын күбеге белән өскә калкып чыкканын күргәннәр.* Кызыклы физика

9) Мазут, дегет, солидол һ.б.ш. ягулык-майлау әйберләре белән пычранган.

Рульдә тракторчы-фәлән иде бугай. Комбинезоны бик майлы иде. К.Тимбикова. *--- өч кара егет, чиратлап, кара җир өстенә утырып, майлы кулларын белән кайнар ит сыпырттылар, сөяк кимерделәр, калын күмәч телемен умырып, сөт ашадылар.* М.Мәһдиев. *Мәҗит, --- каен төбендәге майлы сумкада актарынгач, яңадан машина астына иелгән иде, тукталып калды ---.* Р.Төхфәтуллин

10) *тех.* Майда эшли торган, май биреп тору исәбенә үз функцияләрен башкара торган. *Майлы реостатларда майны алыштыру яки аны чистарту.* Авыл хуҗалыгы электригы белешмәсе

11) *күч.* Ит, май кебек затлы нәрсәләрдән пешерелгән, туклыклы, җимле. *– Әйттем бит инде, безнең эчкә майлы аш килешми, дип... – Иң әүвәл бәрәңге ашарга өйрәнергә кирәк...* С.Поварисов

12) *күч.* Оятсыз, дәртле, азгын хисләр, теләкләр чагылдырган (күзләр, караш һ.б.ш.). *[Әпипәнең] майлы күзләре мутланып ялтырыйлар.* Г.Бәширов. *Дәү абыйсының майлы күзләренә карый да малай, ярар инде, калып тор, дигән шәйне аңлап ала.* К.Кәримов. *Зуфирә аларның майлы күзләренә, чиксез сокланууны, кызыгуны чагылдырган йөзләренә карап, эчтән генә көлемсерәп куйды ---.* М.Маликова

13) *күч.* Хәйләкәр, комсыз. *Ала күздә акыл булмый, майлы күздә ягым булмый.* Мәкаль. *Майлы күзле майор бу сыйдан Кәефләнде, тәмам исерде.* М.Җәлил

14) *күч.* Шактый зур, әһәмиятле, саллы. *Эшләргә, ничек кенә булса да эшләргә! Шәхси карточкага язып, шелтәнең «майлысы»н чәпәсәләр чәпәрләр.* Казан утлары

2. *рәв. мәгъ.* Оятсыз рәвештә, әдәпсез. *Сестра [палатадан] чыгып киткәч, Хасият, майлы гына елмаеп, телен шартлатып куйды.* А.Шамов. *Яртыны гына сорагач, Җәмилә дигәннәре, майлы елмаеп, Әдрәнгә карады.* Х.Сарьян

◊ **Майлы ботка ашау түгел** Бик катлаулы, җиңел түгел, авыр, кыен. *Аксар бригадасына җитәкчелек итү майлы ботка ашау түгел.* С.Рафиков. *Мамык җыю майлы ботка ашау түгел шул. Августтан декабрьгә кадәр каторга хезмәте бит ---.* Р.Мирхәйдәров. **Майлы ботка түгел** *к.* **майлы ботка ашау түгел**. *– Анда бик авыр бит, туганкай! – Эшнең майлы ботка түгеллеген беләбез, анысы.* С.Поварисов. **Майлы калҗа** 1) Бик зур табыш, зур файда. *Кайчан --- кайберәүләр майлы калҗа гына эләктерергә тырышалар, шулай бит, мадам?* А.Яһудин; 2) Бик зур ымсыну, кызыксыну, омтылу объекты. *Хәзер бу майлы калҗаны Малик үз кулына эләктермәкче була.* И.Гази. *Җирле славян кабиләләре белән иңгә-иң басып, болгарлар куәтле Византия империясенә каршы торалар, аның майлы калҗа эзләп сузылган кулларын «кыскарталар».* М.Мәхмүтов. *Безнең яклар бүген – майлы калҗа ул. Дөрес, Мәскәүдә дә акча капчыклары аз түгел, Кавказда да җитәрлек, Азәрбайҗанны әйтәсе дә юк.* Р.Мирхәйдәров. **Майлы урын** Артык тырышлык куймыйча шәхси файда алу мөмкинлеге булган, табышлы урын

МАЙЛЫ́ ГӨМБӘ *и. бот.* Башлыча нарат урманнарында үсә торган, шоколад көрән яки соры сары төстәге эшләпәсе лайлалы юка элпә белән капланган, аскы ягы көпшәле ашарга яраклы гөмбә; *русчасы:* **маслёнок**. *Кайбер гөмбаларнең, мәсәлән, ак гөмбә, каен гөмбәсе, майлы гөмбә (маслята) эшләпәләренең аскы катламы күп санлы нечкә көпшәләрдән тора.* Биология. *Сез нарат агачы төбендә – җирән гөмбә белән майлы гөмбәне, усак агачы төбендә – кызыл усак гөмбәсен, каен агачы төбендә – каен гөмбәсен, яшь чыршылыкта һәм имәнлектә гөрәҗдәләрне табасыз.* Робинзон эзләреннән. *Базидиомицетларга гадәти ашарга яраклы гөмбәләр – әтәч гөмбәсе, каен гөмбәсе, майлы гөмбә, җирән гөмбә, баллы гөмбә, болын һәм көтүлекләрдә еш очрый торган яңгыр гөмбәләре дә керә.* Татарстанның үсемлекләр һәм хайваннар дөньясы

МАЙЛЫЛЫК *и.* Берәр матдәдә майның гомуми күләменә карата нисбәте, майга туенганлык дәрәҗәсе. *--- сөтнең майлылыгы түбән булу сәбәпле, тапшырыла торган сөт, кагыйдә буларак, киметеп языла.* М.Хәсәнов. *Тау үгезе белән әлеге сыер «кушылуыннан» туган бозаулар үсеп җитәчәкләр дә майлылыгы югары булган чиләк-чиләк сөт бирәчәкләр, имеш.* М.Әхмәтҗанов. *Хайваннарның кайбер индивидуаль билгеләре дә нәселдәнлек билгесе булып тора, мәсәлән, имезүчеләрнең йон төсе һәм сөт майлылыгы.* Биология. Хайваннар

МАЙМАК *с. иск.* Йомшак һәм янякка аеры. *Төя аягы маймак, түрә аягы тайгак.* Мәкаль

МАЙМЫЛ *и. гар.* 1) Иерархик системалы төркемнәргә оешып, күбесенчә агач башларында тереклек итүче, катнаш азык белән тукланучы, кешесыман приматлар асотрядына караган имезүче хайван. *Дарвин әфәнде! Кешене маймыл дәвамы диеп, Бик зур ялгыш ясавыңны Искәртәм, башым иеп...* Г.Рәхим. *--- Рим дәүләтендә ата-анага күл күтәрү коточкыч җинаять саналган. Андый бәдбәхетне, камчы белән ярганнан соң, тере эт, әтәч, елан, маймыллар белән бергә күн капчыкка салып, суга батыра торган булганнар.* М.Насыйбуллин. *--- кешесыман маймыллар күптән инде үзләренең кешегә охшашлыклары белән игътибарны җәлеп иткәннәр, һәм еш кына аларны «урман кешеләре» дип атап йөрткәннәр.* Галәм. Җир. Кеше

2) *күч.* Кыланышлары гадәттә җитди булмаган, төптән уйлап түгел, башкаларга ияреп эшләүчән, кыланырга яратучан кеше

3) *күч.* Кыланышлары һәм тышкы кыяфәте бик ямьсез кеше. *Көнчелек аркасында гына шушы ике маймылны тончыктырсаң – атаман каршына ничек кайтырсың?* З.Фәтхетдинов. *Мин Васяның кабыргасына төрттем: «Нигә интегеп зоопаркка йөрергә? Кара әле, маймыл каршыбызда утыра».* М.Юныс

МАЙМЫ́Л АГАЧЫ *и.* Бомбаксчалар семьялыгыннан Африка саванналарында үсә, биеклеге 20 м, юанлыгы 4–10 метрга җитә торган агач; баобаб

МАЙМЫЛ-КЕШЕ *и.* Кешелек дөньясының беренче вәкилләре дип фараз ителгән, казылмалар вакытында

табылган борынгы кешеләрнең гомуми атамасы; *к.* **питекантроп**. *Хезмәт маймылны маймыл-кешегә әверелдергән. Тормыш акрынлап аңардан акыллы зат китереп чыгарган* ---. Химиянең киләчәге. *Геккель, кеше шәҗәрәсендә маймыл-кеше булган, дип игълан итте һәм аны питекантроп дип атады.* Галәм. Җир. Кеше

МАЙМЫЛЛАНУ *ф.* Башка берәүнең кыланышларын кабатлау, иярү, шуңа охшарга тырышып кылану. *Миңа икейөзлеләнергә кушасыз? Алдашырга, маймылланырга?* Н.Исәнбәт. *Теге, Мәлик Рәхимов дигәне генә: «Минем доклад барыбер яхшырак иде, беренче урынны, ялагайланып, Казан студентларына бирделәр, беренче диплом үзебездә – Чаллыда калырга тиеш иде», – дип маймылланган булды.* Т.Галиуллин. *– Кая мендең? – ди Ирек янә, күз алдында маймылланып*. С.Лашманчы

Маймыллана башлау Маймылланырга тотыну

Маймылланып йөрү Шактый вакыт маймыллану; теләсә кайчан, теләсә кайда маймыллану. *Беренче апрель түгел маймылланып йөрергә!* З.Мәхмүди. *Өч көн нәрсәдер кыланып, маймылланып йөргән кешеләр Татарстанның фәлән исемнәренә лаек була*. Тамаша

Маймылланып тору Гел, даими яки хәзерге моментта маймыллану. *Гел төчеләнеп, һаман маймылланып тору да түйдыра*. Татарстан яшьләре

Маймылланып утыру *к.* **маймылланып тору**. *– Маймылланып утырмагыз! – дип кисәтте генерал кунагын. – Үзегезне җитди тотыгыз!* Ф.Бәллүр

МАЙМЫЛЛЫК *и.* Маймылланы күренеше, артык иркен яки сәер кыланыш

МАЙМЫЧ *и.* 1) Күптән түгел генә уылдыктан яки личинкадан чыккан вак балык яки моллюск. *Инештә кәрәкәләр, маймычлар, кызылканат. Малайлар белән таңнан кармак салырга йөрерсез.* А.Гыйләҗев. *Йөзгәләк коңгызлар һәм аларның личинкалары, су чаяны, энә карагы личинкалары маймычларны бик күп һәлак итәләр икән.* Кызыклы ихтиология. *Степанның аяк астында ташлар чыгырдады, ваграклары, зур балыктан курыккан маймычлар сыман, алга очкалады.* Ә.Гаффар

2) *күч.* Бала, малай. *Бүтән вакытта безнең ише вак маймычларны чутка да кертмәгән кеше, Шүрәле турында әйткәч, хәтта көлеп җибәрде.* Р.Зәйдулла

МА́ЙНА I *ы. ит.* Моряклар теләндә барлыкка килгән, соңрак порт йөкчеләре, такелажчылар, төзүчеләр, кранчылар теленә таралган «түбәнгә!», «түбән төшер!» мәгънәсен белдерә торган команда; *киресе:* **вира**. *Кранчыга, баш бармакны аска күрсәтеп, «майна!» кычкырырга туры килә.* Ш.Маннур

МА́ЙНА II *и. зоол.* Каурыйлары кара күгелҗем яки коңгырт сары, томшыгы һәм аяклары сары төстәге уртача зурлыктагы кош; һинд сыерчыгы. *Мәсәлән, майна, сыерчыклар гаиләсеннән булса да, теләсә кайсы тутый коштан әйбәтрәк сөйләшә белә.* Мәдәни җомга

МАЙО́ЛИКА *и. ит.* 1) Эре күзәнәкле балчыктан эшләнгән, яндырылган һәм ялтыравык глазурь белән капланган керамика төре, шундый эшләнмәләр. *[Павильонның] ян як ишекләренә дә матур төстәге майолика белән милли орнаментлар ясалган.* Казан утлары

2) Шундый эшләнмәләр ясау ысулы, техникасы, сәнгате. *Майолика белән шөгыльләну. Майолика остасы*

МАЙОНЕЗ *и. фр.* 1) Үсемлек мае, йомырка сарысы, серкә һ.б.ш. аш тәмләткечләр катнашмасыннан торган куе соус. *Салат ул, әни, – пешкән бәрәңге, чөгендер, колбаса, суган, яшел борчак кушып әзерләнгән ризык. Шуларны барысын бергә кушалар да бер-ике кашык майонез салып болгаталар.* М.Юныс. *--- кеше, тиз-тиз укыганда, аны чамаламаска да мөмкин, «майонез» диелмәгән, ашарга була* ---. Н.Измайлова

2) Кош итенә яки балыкка, зәйтүн маена йомырка сарысы һәм тәмләткечләр кушып әзерләнгән соус коелган салкын ризык

МАЙОР *и. лат.* Күп дәүләтләрнең, шул исәптән Россиянең, хәрби көчләрендә, полиция һ.б.ш.да капитаннан өстен, подполковниктан түбән офицер дәрәҗәсе; шул дәрәҗәгә ия зат. *Майор В.И.Перевозчиков җитәкчелегендәге сугышчылар биредә җиде йөзләп картина табалар.* Ш.Рәкыйпов. *Шик тудырмас өчен, майор турыдан-туры үзенә кирәкле номерны атап сорамады.* М.Насыйбуллин

МАЙОРАН *и. лат. бот.* Иренчәчәклеләр семьялыгыннан хуш исле, бал бирә торган күпьеллык үлән яки ярымкуак үсемлек (медицина, парфюмерия һәм кулинариядә кулланыла). *Суган, сарымсак, дәфнә агачы яфрагы, сельдерей, чабыр, зәгъфран, тмин, майоран, тимьян, базилик – борынгы заманнардан билгеле үсемлекләр.* Робинзон эзләреннән. *Шулай ук барысын бергә алганда 1 центнер кыярга 200 грамм майоран, кориандр һәм лавр яфрагы, чабыр, барлыгы 300 граммга кадәр сельдерей һәм петрушка яфрак-сабаклары өстәргә мөмкин.* Яшелчәчелек

МАЙОРАТ *и. лат. кит.* 1) Граждан хокукында күчемсез милекнең, беренче чиратта җир биләмәләренең, мирас итеп, варисларның иң олысына тулысынча күчүеннән гыйбарәт мирас формасы. *Аның [Е.М.Мелетинский] карашынча, майорат, ягъни мираснының олы туганга күчү тәртибе, кече туганны өлештән мәхрүм иткән, һәм шуңа күрә әкиятләрдә кече туган идеаллаштырылган* ---. Ф.Әхмәтова

2) Әлеге хокук нигезендә мирас итеп алу мөмкин булган милек

МАЙСЫЗ *с.* **1.** Мае бик аз, җитәрлек түгел яки бөтенләй булмаган. *Майлы булсын, майсыз булсын – Барыбер күңел кайта; Көн дә ботка ашап булмый: Туйдыра, маемлата*. Л.Лерон. *Ләлә ботка ашамый: Ботка аңа ошамый. Әллә майсыз булганмы? Өстәл җайсыз булганмы?* М.Газизов. *Майсыз дуңгыз итенә ихтыяҗның артуы селекционерлар алдына --- дуңгызларның ит сыйфатларын яхшыртуның яңа методларын булдыру бурычын куйды.* Татарстанда терлекчелек

2. *рәв. мәгъ.* Май салмыйча, май кулланмыйча. *Ризыкны майсыз әзерләү*

◊ **Майсыз табада куыру** Берәүгә карата үзен артык кырыс, таләпчән тоту, һәр теләгәнен, кушканын каршылыксыз үтәп торырга мәҗбүр итү.

Майсыз табада сикертү *к.* **майсыз табада куыру**

МАЙСЫЗЛАНДЫРУ *ф.* Берәр өслекне май элпәсеннән, май катламыннан чистарту өчен махсус рәвештә механик яки химик чаралар белән эшкәртү. *Спирт белән майсызландыру*

Майсызландыра башлау Майсызландырырга тотыну

Майсызландырып кую Тулысынча майсызландырып әзер хәлгә китерү

Майсызландырып тору Даими рәвештә, әледән-әле яки хәзерге моментта майсызландыру

Майсызландырып чыгу Баштан ахыргача майсызландыру

МАЙСЫККЫЧ *и.* Майлы культураларның бөртегенннән сыгып маен чыгару өчен махсус җайланма

МАЙСЫЛ *с.* Майлы кебек күренгән; бераз май сеңгән, майга охшаш нәрсә белән капланган. *Чәчелеп китте вак-вак кына майсыл Яфраклардай сары кәгазьләр.* Х.Камалов

МАЙСЫМАН *с.* Майга охшаш, майныкы кебек үзлекләргә ия булган. *Кошлар аларны [каурыйларны] томшыклары ярдәмендә койрык бизе бүлеп чыгарган майсыман матдә белән периодик рәвештә майлап торалар, шуңа күрә аларның каурыйлары чыланмый.* Биология. Хайваннар

МАЙТАРУ *ф. ирон.* 1) Эшләү, башкару, булдыру. «*Ниләр генә майтарып булыр микән бу багаж белән?*» *дигән уйлар башыннан үтсә дә, Зәйнулла төшенкелеккә бирелмәде.* М.Насыйбуллин. *Кем тәм таба койрык болгап йөреп, Мактанып һәм ялган мактылып. Кем тәм таба күкрәк көче белән Тау кадәрле эшләр майтарып.* Ә.Синугыл-Куганаклы. *Эшләп майтарганы чүп булса да, Гайбәтчедә сөйләр сүзләр күп.* Ф.Гыйззәтуллина

2) Берәр эшне тиз-тиз, аннанмоннан, түбән сыйфатлы итеп башкару, эшләү, маташтыру. *Эшебезне тиз-тиз майтарабыз да атларыбызда яңадан урманга сызабыз.* Г.Тавлин. *Кай яклардан җил ташлады, пенсионер абзый? Ниләр кырып, ниләр майтардыгыз инде?..* Р.Мөхәммәдиев

3) Махинацияләр, афералар белән шөгыльләнү, гаделсез юл белән эш йөртү. *Гафифә махсус килгән, аның ялгыз калуын белгән. Ниндидер юньсезлек майтарырга йөрүедер, мөгаен...* Ә.Моталлапов

4) Бәла чыгару, берәр куркыныч эш кузгату. *Ул малай, чынлап та, мөгез чыгарып куймасын тагын. Югыйсә майтарасын майтарыр да китеп барыр, кырган-җимергәнен төзәтергә, җавабын бирергә безгә калыр.* Ж.Дәрзаман. *Сылу шыңшып Шаманның өстенә капланды: – Тагын нәрсәләр генә майтардың?* Р.Зәйдулла

Майтарып алу *к.* **майтарып ташлау**. *Алай теләгең булгач, берәр көнне икәүләп майтарып алырбыз.* З.Фәйзи

Майтарып йөрү Берәр нәрсә, гадәттә әһәмиятсез эш белән мәшгуль булу, эшлекле кыяфәт чыгарып, ыгы-зыгы килү. *Инде бер башлагач, ул арада ниләр майтарып йөргәнегезне дә сөйләп бирерсез дип уйлыйм.* М.Насыйбуллин

Майтарып ташлау Тиз арада күзгә күренердәй зур эш эшләү. *Барысын колачлыйсы, хәзер үк ташланып, шушы дәрт-дәрман белән майтарып ташлыйсы килә.* Ш.Галиев. *Кияүне әйтәм, Бәйрәмханны, дип уйлады ул, кояш күтәрелмәстән ат җитәкләп урам йөри, тагын ни әкәмәт кылмакчы икән, ат көтүен туктаттыруга үзенчә баш күтәрүедер, кирәкмәсне майтарып ташлавы ихтимал кызыш җанның ---.* М.Хуҗин. *Күр әле син, дистә ярым ел эчендә нәрсәләр майтарып ташладык! Гектарыннан уртача 47,6 центнер уңыш алдык бит!* Казан утлары

Майтарып яту Шушы вакытта майтару. *Кифая чыгып киткән арада, ишегалларын, бакчаларны карап-тикшереп чыктым. Ниләр майтарып ята икән бу монда?* Р.Габделхакова

МА́ЙҮЛЧӘГЕЧ *и. махс.* Сөтнең майлылыгын үлчәү өчен кулланыла торган прибор. *Сөтнең майлылыгын кислота белән майүлчәгеч (бутирометр) ярдәмендә билгелиләр ---.* Сөт терлекчелеге турында кыскача белешмә

МА́Й ЧАБУ *и. этн.* Татарларда мәҗүсилек чорыннан калган, март аенда соңгы карларда чаналарда узышудан гыйбарәт кышны озату йоласы. *--- махсус мәҗлесләр уздырылган. Ул Болгар-Казанда ел башы саналган нәүрүз (март) аенда, май чабу вакытларында, нардуган кичәләренең берсендә ясалган.* Н.Исәнбәт. *Кышны озату һәр милләтнең үзенчәлекле бер бәйрәменә әверелде. Безнең керәшен халкында аны Май чабу дип атыйлар. Кайбер авылларда Чуман озату, Май базары дип тә йөртәләр.* А.Усачёва

МА́Й ЧӘЧӘГЕ *и. бот.* Лаләчәләр семьялыгыннан ак чәчәк ата, чыршы урманнарында үсә торган күләгә яратучан үлән үсемлек. *Чыршының юлдашлары – кымызлык, май чәчәге – озак вакыт кояш нурлары астында үссәләр, һәлак булалар.* Биология. *Май чәчәгенең җиләкләре кеше өчен агулы, ә кайбер кошлар аларны чүпләсә дә зыян күрми.* Татарстанның үсемлекләр һәм хайваннар дөньясы

МАЙЧӘЧӘК *и. бот. к.* **май чәчәге**

МАЙЧЫ *и. иск.* Май сату эше белән шөгыльләнүче вак сәүдәгәр. *Залда инә төшәрлек тә урын калмады. Урта сафларда вак сәүдәгәрләр, кибетчеләр, тиречеләр, майчылар.* Г.Минский

МА́ЙЯ I *и.* Мексика, Гватемала һәм Белизда яшәүче индеец халкы, Америкадагы иң борынгы цивилизацияләрне тудырган халыкның варислары. *--- ул [Ә.Кәримуллин] Мексикада яшәүче майя кабиләсенең телендә төрки сүзләр барлыгын исбатлый һәм кырыкка якын сүзне чагыштырып китерә.* М.Әхмәтҗанов. *Зәйтүнә --- «Вокруг света» дигән журналның урта битләрен ачты. Анда борынгы майя һәм инк халыкларының гаҗәеп сәнгать әсәрләре, калалары, пирамидалары турында язылган, аларның рәсемнәре урнаштырылган иде.* М.Маликова. *Мексикада да туристларга бик кызык булмас шикелле: Акапулько һәм борынгы майя яшәгән урыннарда наркотрафикка каршы сугыш бара.* Мәгърифәт

МА́ЙЯ II *и. гр.* Җиңел киҗе-мамык тукыма төре

МАКА́КА *и. португ. зоол.* Тарборынлылар семьялыгыннан Көньяк һәм Көнчыгыш Азиядә, Африкада һәм Гибралтарда яши торган,

төркемнәрендә мимика, аваз, ишарә белән аралашу һәм иерархия көчле булган, кайбер төрләре Кызыл китапка кертелгән маймыллар ыруы. *Бер галимнең әйтүенчә, макака дигән ата маймылның үз хатынын ничек бизәгәнен, аның маңгаеннан артык озын чәчләрен теше белән өзеп алганын, шул ук юл белән кашларын да тигезләгәнен үз күзләре белән күргән.* Кызыклар дөньясында. *Бу асотрядка --- тарборынлылар (мартышкалар, макакалар, павианнар, мандриллар); кешесыман маймыллар (гориллалар, орангутаннар, шимпанзелар) керә.* Биология. Хайваннар

МАКАРОН *и. ит.* Бодай онынан, баштарак озын нечкә көпшә рәвешендә, соңрак күп төрле: дулкынлы, кәкре, яссы, куыш һ.б. формаларда киптереп әзерләнгән токмач. *--- пар плитәсе бар, Америкада алар 6 гына диделәр, хак булса, анда бөтен нәрсәне дә – ярмаларны да, макароннарны да коп-коры килеш тыгасың да куясың: һәрберсе үзенә тиешле суны алып, кнопкасына басылган минутка пешеп чыга.* Н.Измайлова. *Калачлар һәм кабартмалар, печенье һәм макаронга яраклы шәп бодайны көньякта үстерәләр.* Казан утлары. *Бодайның югары сыйфатлы икмәк, макарон, ярма һәм башка азык әйберләре әзерләү өчен файдаланыла торган кыйммәтле сортларының уңышын һәм сыйфатын күтәрүгә, урып җыю чорында һәм ашлыкны саклаганда югалтуларга юл куймауга аеруча игътибар бирелә.* Биология

МАКАРОНЛЫ *с.* Макароннан әзерләнгән, макарон салып пешерелгән, макарон белән бирелгән. *Якшәмбе көнне безгә макаронлы аш бирделәр.* Казан утлары

МАКЕТ *и. фр.* 1) Архитектурада проектлана торган яки әзер корылманың, ансамбльнең кечерәйтелгән күләмле күренеше. *Микрорайонның эшен нигездә төгәлләдем, дип исәпли иде ул. --- Ни гомер, интегеп, макетын гына ясап утырды*. М.Маликова. *Булачак һәйкәлнең макетын кайда, кайчан күрергә мөмкин булуын ачыкларга куштылар.* Казан утлары

2) Театрда куелачак спектакльнең пространство һәм декорация эшләнешен билгели торган моделе

3) Гомумән берәр нәрсәнең кечерәйтеп ясалган моделе; үрнәк. *Без противогазлар астык, мылтык макетларын күтәреп, кырга тактик дәресләргә чыктык, атакага бардык...* М.Мәһдиев. *Ә Колмаерда – фәннилеккә, тулылыкка дәгъва, сурәтлелеккә омтылу. Макетлар, кош-корт, хайван карачкылары ---.* Т.Әйди. *Курчакны космик корабларның макетларына, төрле капсулаларга төрлечә утыртып карыйлар*. Кызыклар дөньясында

4) *махс.* Нәшер итү эшендә: басылып чыгарга тиешле китап, газета, журнал кебекләрнең тиражны әзерләүгә кадәр төзелгән, текстның барлык элементларын, иллюстрацияләрне урынларына куеп караган сынау экземпляры. *Макет буенча алдан билгеләнгән материаллар һәрвакытта да юлга юл килеп, үз урынына сыеп кына тормый.* М.Әмир. *--- безгә чыгасы номерның макетын баштанаяк үзгәртергә туры килде.* Г.Тавлин. *Киләсе санда чыгасы бер мәкалә урынына үз фельетонын макетка салды.* Ж.Дәрзаман

МАКИНТОШ I *и.* Шотландия химигы Макинтош уйлап тапкан, каучук эремәсе белән ябыштырылган ике катлы материядән, соңрак гомумән су үткәрми торган тыгыз тукымадан тегелгән плащ. *Горький бит бу! Өстендә озын макинтош, башында бохар кәләпүше, борын астында --- кырау төшә башлаган мыек.* Ж.Фәйзи. *Идел өстеннән искән салкынча җил аның җилфердәвек чабулы макинтошын куптарып алып китмәкче булып дуылдый*. К.Тимбикова. *Соңгы мода белән тегелгән, ятып-килешеп торган костюм, иң өстә җилбәгәй җибәрелгән җиңел макинтош.* М.Хәсәнов

МАКИНТОШ II *и. информ.* Apple Computer фирмасы компьютеры

МАКИЯЖ *и. фр.* Төрле косметика кулланып, битне бизәү, грим салу осталыгы һәм әлеге грим үзе. *Ул төрле өлкәләргә караган мәгълүматларны үзенә җыйган: гади һәм аңлаешлы тел белән сәламәтлек, гигиена, макияж, маникюр, стиль, табын әзерләү, хобби, мәхәббәт мәсьәләләре хакында сөйли ---.* Матур буласың килсә… *Макияжда иң мөһиме – битнең тигез тоны.* Сөембикә

МА́КЛЕР *и. нем.* Сәүдә һәм биржа килешүләре төзүдә сатучы белән алучы арасында эш йөртүче, клиентлар исеменнән һәм алар исәбеннән эш итеп, килешү суммасыннан процентлар алучы профессиональ арадашчы. *Карт хаҗиның ризыгын урлап ашаган маклерларны ирештерәләр...* А.Таһиров. *Һәркем, әле базар юлында шомарып өлгермәгән сатучылар гына түгел, --- урта кул эшем ияләре, кесә караклары, маклерлар --- да бик ерактан иелеп-бөгелеп аңа сәлам бирәләр.* А.Гыйләҗев. *Инспекторның сүзләре эчемне әчеттереп җибәрде. Аның сөйләшүе сатыласы атын мактаган маклерны хәтерләтә иде.* М.Юныс

МА́КЛЕРЛЫК *и.* Маклер эшчәнлеге, арадашчылык. *Ә маклерлык? Маклер кешегә кайсы власть булса да начар түгел бит.* М.Мәһдиев

МАКЛЕ́Я *и. лат. бот.* Мәкчәчәкләләр семьялыгыннан берьеллык агулы үлән үсемлек. *Мәкчәчәкләләрдән (маковые) вак җимешле маклея (маклея мелкоплодная) үләненең барлык органнарында күп күләмдә --- алколоидлар булып, нигездә алар протопин, криптопин, аллокриптопин, хелеритрин һәм санвинарин (0,8 % ка кадәр) алколоидларыннан тора.* Агулы үсемлекләр

МАКМАЛ *и. гар. иск.* **1.** Бәрхет

2. *с. мәгъ.* Бәрхеттән тегелгән, бәрхет белән тышланган. *Яхшы атаның баласы – макмал тунның якасы.* Мәкаль

МАКМЫР *и. гар. сөйл. к.* **махмыр**. *Макмырдан газапланган ирне сүгеп игә китерергә азапланган хатын андый иртәләрдә ир күзенә аждаһа, җиде башлы дию булып күренгәнен беләме икән?* А.Гыйләҗев. *Зәбир, машинадагы аракыны урлап, кичтән голкынганчы эчкән, иртәдән бирле макмырдан интегә.* М.Маликова

МАКМЫРЛА́У *ф. сөйл. к.* **махмырлау**

МАКМЫРЛЫ *с. к.* **махмырлы**. *Макмырлы баштан*

МАКРЕЛЬ *и. голл. зоол.* Алабугасыманнар отрядыннан, зурлыгы 50 см кадәр җиткән, әһәмиятле промысел объекты булып торган диңгез балыгы, скумбрия. *Гадәттә аларны [оча торган балыкларны] алдавыч итеп кармакка элэктерәләр һәм зуррак диңгез балыкларын – укбалык, тунец, макрель балыкларын тоту өчен файдаланалар.* Кызыклы ихтиология

МА́КРО- *гр.* Эре берәмлекләргә, зурлыкларга караган төшенчәләрне белдергән кушма сүзләрдә «зур», «озын» мәгънәләрен белдерә торган беренче кисәк (мәс., *макромолекула*)

МАКРОДӨНЬЯ *и.* Гади кеше күзе белән күзәтелерлек күренешләр һәм процесслар дөньясы, гадәти зурлыклар белән эш ителә торган дөнья. *Химик энергия тереклекнең макро- һәм микродөньясында да хәрәкәт барлыкка китерә.* Химиянең киләчәге. *Квант механикасы, микродөньядагы, ягъни атомнар һәм молекулалар дөньясындагы күренешләрнең закончалыклары, без турыдан-туры күзәтә ала торган әйберләр дөньясындагы (макродөньядагы) закончалыкларга караганда башкача булуын күрсәтте.* Физика курсы

МАКРОКЛИ́МАТ *и. махс.* Атмосфераның бер үк төрле циркуляцияләве белән аерылып торган бик зур территорияләрнең (мәс., материкның, океанның) климаты

МАКРОКО́СМ *и. гр. кит.* Кешедән кала барлык дөнья, галәм. *Г.Тукайның «Өзелгән өмид» шигырендә һәм объектив пространство, һәм субъектив кабул ителүче макрокосм бирелеше күзәтелә.* В.Әминева

МАКРОПОД *и. гр. зоол.* Лабиринтлылар асотрядына караган, кайбер төрләре аквариумнарда үрчетелә торган балык ыруы. *Иректә дә яши, аквариумнарда да үрчетелә торган макропод дигән балык бар.* Кызыклар дөньясында

МАКРОСКО́ПИК *с. махс.* 1) Зур күләмле, гади күз белән, ягъни микроскопсыз күзәтү мөмкин булган; *киресе:* **микроскопик**. --- *микродөньяда барган күренешләрдән макроскопик вакыйгаларга күчәргә туры килә.* Химиянең киләчәге

2) Гади күз белән, ягъни микроскопсыз үтәлә торган. *Макроскопик күзәтүләр*

МАКРОСТРУКТУ́РА *и. махс.* Металл, эремә, бетон, керамика кебек каты материалларның гади күз белән яки гади зурайту приборы ярдәмендә күреп булган төзелеше; *киресе:* **микроструктура**

МАКРОЭКОНО́МИКА *и. гр.* Халык хуҗалыгын тәшкил иткән төрле юнәлешләрнең: милли байлык, милли доход, җитештерелгән продукт, әйләнештәге акча күләме, инвестицияләр, дәүләт секторы, шәхси сектор эшчәнлеге һ.б. барлыгы; аларны берлектә өйрәнә торган икътисад фәненең бер тармагы

МАКРОЭТНО́НИМ *и. гр.* Берничә халык өчен уртак атама, генетик уртаклыгы булган халыкларның гомуми атамасы. *Шул ук вакытта нигез этнонимнарга М.А.Членов макроэтнонимнарны да, ягъни югарырак этник гомумилекне белдерә торган атамалар да кертә (мәсәлән, славяннар, төркиләр, германнар һ.б.).* Ә.Кәримуллин

МАКСАТ *и. гар.* 1) Киләчәктә ирешү, булдыру өчен билгеләнгән бурыч; омтылган нәрсә. *Максатың булсын да, хөрлегең булсын! Сөйгәнең булсын да, ирлегең булсын!* Р.Фәйзуллин. *Алда әле заман имтиханы, Күп сынаулар әле үтәсе; Максатларга әле ирешәсе, Хыялларны чынлык итәсе!* Ш.Галиев. *Туа өмет: гомер буе барган Максатыма гүя бер атлам.* Р.Әхмәтҗан

2) Күздә тотылган, уйланылган ният, теләк, уй, исәп. *1986 елның кышында мин бер төркем язучылар белән Чепья авылына барып чыктым. Максатыбыз бу авылдагы уникаль музей белән танышу иде.* М.Мәһдиев. *Илһамлы булды гомерләр, Еллары юртак булды, Йөзләр кызармаслык булды, Максатлар уртак булды.* Ш.Галиев. *Дәвалау максатында аморфаның яфракларын, яшь ботакларын, орлыкларын һәм җимешләрен файдаланалар.* Урман аптекасы

МАКСАТЛЫ *с.* **1.** 1) Билгеле максаты, теләге, омтылышы булган; гомумән, максатчан. *Яшәвенең мәгънәсе булган максатлы кеше бәхетле.* Ш.Галиев. *Ләкин тотрыксызлык тиз генә бетмәс әле, аныk-ачык фикерле, максатлы инсаннар әлегә күренми.* Р.Мирхәйдәров

2) Төгәл бер максатка дип билгеләнгән, шуңа хезмәт итә торган, аерым максатка юнәлтелгән. *Минем юлым – авыр, ләкин максатлы юл.* Г.Коләхмәтов. *Рух – милләтнең фидаи җаны, максатлы омтылышы, үзеннән югарырак сикерә алу мөмкинлеге.* М.Галиев. *Милләт капма-каршы мәнфәгатьле, максатлы төркемнәргә, фиркаләргә бүленде – милли хәрәкәт шул рәвешле тукталу чорына керде.* Х.Әшрәфҗанов

2. *рәв. мәгъ.* Билгеле максатка, максатчан рәвештә, махсус рәвештә. *Сорау туа: хөкүмәт тарафыннан бүленгән бу акчалар максатлы файдаланыламы?* Өмет

МАКСАТЛЫЛЫК *и.* 1) *к.* **максатчанлык**. *Халык тормышын тирәнтен тою нәтиҗәсендә, Х.Туфан белән С.Хәким иң гүзәл әсәрләрендә иҗат юлларын милләт язмышы белән кушу бәхетенә ирештеләр, үзләреннән соң килүчеләр өчен максатлылык үрнәге булып калдылар.* Әдәбият

2) Төгәл билгеле максатка юнәлдерелгән булу күренеше. *Матди ярдәмнең максатлылыгы. Бюджет акчасының максатлылыгы*

МАКСАТ-МӘСЛӘК *җыйд. и.* Яшәү принциплары, дөньяга караш, тормышта тоткан кыйбла. *Ялгышмасам, бүгенге иң көчле әр дә сезнең өчен авторитет түгел, алар кызыктырмый бугай, сезнең максат-мәсләгегездә аларга урын юк.* Р.Мирхәйдәров

МАКСАТСЫЗ *с.* **1.** Бер максаты да булмаган, аерым бер максатка юнәлдерелмәгән, билгеле максат күздә тотмаган. *Максатсыз кеше үз юлын күрмәс, ник яшәгәнен белмәс.* Мәкаль. *Әле кайчан гына без прозаикларыбызны артык озын итеп язуда, максатсыз тасвирлаулар белән мавыгуда гаепли идек.* Ф.Миңнуллин. *Максатсыз кеше ничек яши? Тормышында ни кызыгы бар?* Ш.Галиев

2. *рәв. мәгъ.* Билгеле максат куймыйча, болай гына. *Үзең чит илдә бул, үзең бер максатсыз урамда йөр әле. Менә кайда кешенең рухы, дөньясы кителә икән...* М.Мәһдиев. *Ары сугылып, бире*

кагылып, максатсыз-мәсләксез йөри торгач, Айсылу күңелендә дә, парктагыча, кырыкмаса кырык төс хасил булды. Б.Камалов. *Бер генә спектакль дә максатсыз куелмый.* Сәхнә

МАКСА́ТЧА *рәв. иск.* Максатка туры китереп, максатны күздә тотып, максатка яраклы рәвештә. --- *организмнар төзелешенең һәм аларның бөтен эшчәнлегенең максатча булуы боларның ниндидер акыллы һәм кодрәтле көч тарафыннан яратылганлыгын күрсәтә.* Дарвинизм һәм дин

МАКСА́ТЧАЛЫК *и. иск.* Максатка ярашлылык, максатка җавап бирү. *Үсемлек һәм хайваннар систематикасында класслар, отрядлар, ыруглар һәм төрләрне аеруны билгеләп, К.Линней бу категорияләрне куллануның максатчалыгын башка фәннәрдән мисаллар китереп аңлаткан.* Биология

МАКСАТЧАН *с.* **1.** 1) Үзенә максат куеп, шуңа ирешү өчен, эзлекле эш итүчән, тырышучан, максатына тугры. *Гыйззәт – максатчан, кыю, саф күңелле шәхес, уңай герой.* Х.Бәдигый. *Максатчан, һәр адымын мәгънәле итүчән, төп бурычны икенчел дәрәҗәдәгеләреннән аерып караучан шәхесләрнең хезмәт нәтиҗәләре бөтенләй башка була.* Ф.Галимуллин

2) *к.* **максатлы 1.** (*2 мәгъ.*). *Түләүле бу курсларга ел саен максатчан юллама белән бюджетка да алты кеше алабыз.* Сөембикә. *Барлык бу шартлар күп мең еллар дәвамында бөтен кешелек җәмгыятенең максатчан эшчәнлеге белән барлыкка китерелгән.* Биология

2. *рәв. мәгъ.* Максат куеп, шул максатка яраклаштырып, махсус шул максат өчен. --- *бүгенге тәнкыйть үтемлерәк, максатчанрак, объективрак эш итә, анда профессиональ осталык һәм затлылык та күтәрелә бара.* Казан утлары. *Әгәр Дарвин, эволюция теориясен эшләгәндә, селекционерлар тәҗрибәсен өйрәнгән булса: фәнни теория белән коралланган селекционерлар яңа сортларны шактый тизрәк һәм максатчан рәвештә чыгарырга өйрәнделәр.* Галәм. Җир. Кеше. --- *РФ төбәкләреннән килгән сәләтле татар балаларын Татарстан вузларына максатчан кабул итү буенча махсус программаның үтәлеше мисал итеп китерелде.* Татарстан

МАКСАТЧАНЛЫК *и.* Максатка юнәлгәнлек, максатка омтылучанлык, бер максатка тугрылык. *[Хафиз Гайнуллинның] ихтыяр ныклыгы һәм максатчанлыгы тагын да көчәйгән.* Г.Әпсәләмов. --- *бу төр затларны максатчанлык, алынган эшен җиренә җиткерә белү һәм үзенчә фикерләү бизи.* Т.Галиуллин. *Кеше табигый тереклекнең саклануы өчен, анда башкарыла торган үзгәрешләрнең максатчанлыгы өчен җаваплы.* Биология

МАКСАТЧЫЛ *с. к.* **максатлы**. *Халыкның ихтыяҗы белән исәпләшмәү, куштанлык, икейөзлелек максатчыл бер зарурилыкка әйләнә.* М.Юныс. *Күп санлы культуралаштырылган үсемлекләр һәм йорт хайваннары килеп чыгуы кайнозой эрасында иң күренекле вакыйга булган. Алар барысы да – максатчыл эшчәнлеккә сәләтле акыл иясе булган кеше иҗаты нәтиҗәсе.* Галәм. Җир. Кеше

МАКСИМАЛИЗМ *и. лат.* 1) Нинди дә булса карашларда, таләпләрдә чиктән тыш позицияләрдә тору. *Г.Рәхим – әдәбиятка тормыш һәм иҗат максимализмы белән килгән буын вәкиле.* С.Маннапов

2) *тар.* Эсерлардан аерылып чыккан үтә сул, ярым анархистик-террористик агым

МАКСИМАЛИСТ *и.* 1) Максимализм (*1 мәгъ.*) карашларында торучы кеше, һәр нәрсәнең идеаль булуын теләүче. *Безнең студент халкына ярап буламы соң (бөтенесе максималистлар!): каләмдәшебезнең беренче тәҗрибәләре белән танышкач, авторның тетмәсен теттек.* Ә.Рәшит. *Юк, сугышып-талашып яшәмәдек. Тик... яшьләр идек бит әле, максималистлар идек.* Идел. *Күрәсең, рус мәдәнияте йогынтысында Солтангалиев социалистик идеянең дөреслегенә ышанган. Әлбәттә, яшьлек максимализмын да исәпкә алырга кирәк.* Чын мирас

2) *тар.* Ярым анархистик-террористик эсерлар группасы әгъзасы. --- *халык арасында без төрле партияләр – кадетлар, социалист-революционерлар, социал-демократлар, максималистлар бар икәнен аңладык.* М.Укмасый

МАКСИМАЛЬ *с.* **1.** Билгеле яки мөмкин булган сыйфатлар, күрсәткечләр рәтендә иң югары, иң зур; соң чиккә җиткән. --- *беренче җөмлә фәлсәфи-лирик эчтәлеге белән генә түгел, ә бәлки аваз төзелеше, сүз тәртибе, ритмик яңгырашы белән дә максималь дәрәҗәдә эшләнгән, камиллеккә омтылган булырга тиеш.* Казан утлары. *Бер фазалы счётчикның щитында номиналь һәм максималь токларны, номиналь көчәнешне һәм тапшыру (күчерү) санын күрсәтәләр.* Авыл хуҗалыгы электригы белешмәсе. *Һәрбер үлчәү приборын билгеле бер максималь ток зурлыгына чыдарлык итеп эшлиләр.* Физика курсы

2. *рәв. мәгъ.* Мөмкин булган иң зур күләмдә, тулысынча, иң югары дәрәҗәдә. *Минемчә, чын шигырь, һәр төр иҗаттагы кебек, җанның максималь киеренке чагында, --- илаһи гаҗизләнү минутларында туа.* Р.Фәйзуллин. *Умарта кортының һавада очып уздырган гомере бик кыска, очышның һәрбер минуты семьяга кыйбатка төшә, шунлыктан умарта кортлары очу вакытыннан максималь файдаланалар ---.* Умарта кортлары

МА́КСИМУМ *и. лат.* **1.** Барлык күрсәткечләр арасында иң зурысы, мөмкин булган кадәр зур микъдар; *киресе:* **минимум**. *Кояшның күзгә күренми торган нурланышы циклларының максимумнары бергә туры килгән елларны иң зур интенсивлыкка ирешә.* Галәм. Җир. Кеше. *Конденсатор корылып беткәндә, ток нульгә тигез була, ә конденсаторның көчәнеше максимумына җитә.* Физика курсы. *Бер үк функциянең берничә максимумы һәм берничә минимумы булырга мөмкин.* Югары математика нигезләре

2. *с. мәгъ.* Иң зур, иң югары дәрәҗәгә җиткерелгән. *Җүнле эш тапса, билгеле, һәркем ул эштән максимум акча чыгарырга тырыша.* Җ.Фәйзи. *Монда бөтенесе гади, аңлаешлы һәм максимум файда китерә торган итеп көйләнгән.* З.Фәйзи. *Максимум һәм ми-*

нимум тирбәнү амплитудаларының болай чиратлашып торулары картинасы интерференцион картина дип атала. Физика курсы

3. *рәв. мәгъ.* Иң күбе(се); иң зуры(сы); күп дигәндә

МАКСУД *и. гар. иск. кит. к.* **максат**. *Максудым Одессадан әүвәл Болгариягә, аннан Истанбулга китү иде исә дә, муафикъ була алмадым.* Г.Камал. *Үтеп китте гомерләр, бер дә кабул булмады максуд.* М.Иманколый. *Борын заманда адәм балалары үзләренең максудларын бүтән кешеләргә болай, безнең кебек, кәгазьләргә сызгалап аңлата белмәгән.* Г.Алпаров

МАКСУТ *и. гар. иск. кит. к.* **максат**. --- *ул изгеләрне вә аларның тормышларын иң зур максут итеп күрә, «явызлар» вә аларның эшләреннән бик курка торган булды.* Ф.Әмирхан. *[Егет] бу ишарәте белән үзенең максутын аңлатмакчы була иде.* М.Гафури

МАКСЫМ *и. гар. диал. к.* **максыма**

МАКСЫМА *и. гар. диал.* Өйдә әзерләнгән сыра. *Менә шушы бер йомры максыманы бушатып куйсаң, аңлашылмас нәрсә калмас.* Ә.Баян. --- *аерым гаиләләр, самавырлар куеп, чәй эчеп утырган, я булмаса, күмәк табын корып, кунакларын үзләре ясаган максыма дигән сыра яки ачы бал белән сыйлаган.* М.Бакиров

МАКТАЛУ *ф. төш. юн. к.* **мактау**. *Заманында күккә чөеп макталган автоэчергечләр һәм асылмалы юллар, багана һәм утлыклар – барысы да алып ташланган.* М.Хәсәнов. *Н.В.Гоголь тарафыннан макталган Диканька янындагы хуторның умартачысы Рудый Панько әнә шундый тәмам өлгереп җиткән бал турында болай дип әйтә алды да: «Ант итеп әйтәм, хуторларда моннан да яхшыракны эзләп тә таба алмассыз ---».* Умарта кортлары. *Орхидея матурлыгы һәм чәчәкләренең үзенә бертөрле булуы белән генә макталмый.* Робинзон эзләреннән

МАКТАНУ *ф.* 1) Үз-үзеңә яки берәр эшеңә уңай бәя бирү, яхшы яктан күрсәтү, мактап сөйләү. *Бар мактанса – табылыр, Юк мактанса – чабылыр.* Дастан. *Кичләрен су буенда яшьләр уены, бөтен фронтовик егет монда велосипед белән килә, без велосипед саклыйбыз, утырып йөрибез, мактанабыз.* М.Мәһдиев. *Мактанырлык уңышың бар икән, авыз тутырып сөйләргә дә, күкрәк кагып мактанырга да хакың бар.* М.Хәсәнов

2) Горурлану, горурлык хисе тою. *Мин хатынга гел мактанам, ул үзе Кукмара ягыннан, журналда-фәләндә сезнең исем күренсә, әйтәм: менә, дим, безнең авылныкы.* М.Мәһдиев. *Ышанычың арта, рухың ныгый, Сөенечләр белән сафлансаң; Мактану да гаеп түгел бит ул – Туган ягың белән мактансаң!* Ш.Галиев. --- *аның угы иң биек чыршыдан да югарырак очкан кошны куып җитә. Шуның белән мактана да.* М.Әмирханов

3) Эреләнү, масаю, шапырыну, урынсызга үз-үзеңне мактау. *Шунысы мөһим – аның сөекле оныгы Фәрит: «Минем бабам – Советлар Союзы Герое!» – дип мактанмаган.* Ш.Рәкыйпов. *Бераз эчтеме, мактана, шапырына башлар иде [Сәлимов].* М.Хәсәнов. *Якуб би хан оныгының мактануын килештереп бетермәде, алай да дәшмәде: әйдә, мактана бирсен, аның кебек чакта кем бераз һаваланмаган да эреләнмәгән.* М.Хәбибуллин

4) Булмаган эш турында алдан шапырынып, мин-минләнеп сөйләү. *Ул, үзенең буе җитмәслеге күренеп торуына карамастан: «Фәлән агайның авызына менеп төштем әле, фәлән кешенең баш түбәсен төйдем әле», – дип мактана иде.* Ф.Әмирхан. *Мактану, шау-шулардан Ераксың, димәк, син – Тормышта бик кирәк, Бик кирәк бизәк син.* И.Юзеев. *Кем тәм таба койрык болгап йөреп, Мактанып һәм ялган макталып.* Ә.Сынугыл-Куганаклы

Мактана төшү Бераз мактанган кебек булу; тагын да ныграк мактану. *– Үземнең, әткәй белән әнкәйнең, әбинең исемнәрен яза беләм, – диде Габделкаюм, мактана төшеп.* М.Гали

Мактанып алу Бераз гына мактану, кыска гына ара мактану. *Ерак юлдан кайткач аның белән күрешү, сөйләшеп алу үзе бик рәхәт иде. Аның чынаяк чокырына салып биргән шифалы эчемлеге, «эчегез, сездә юк ул» дип мактанып алуы* --- М.Мәһдиев. *Платон Платонович тешен елтыратып мактанып алгач, озак кына сөйләп ташлады: «Эшләргә өлгерербез! Көн озын! ---».* А.Гыйләҗев. *Заманында Әнәс Камал үзенең язучы гына түгел, рәссам да булуын әйтеп, күз хәтеренең шәплеге белән мактанып алырга ярата иде.* Ш.Маннапов

Мактанып бетү Мактанып өлгерү; төрлечә мактану, ничек кенә мактанмау. *Буаз дигәч, мин инде аның булачак колынын, әлбәттә, алмачуар дип башыма да утырткан, бөтен иптәшләремә мактанып беткән идем.* Г.Ибраһимов

Мактанып җибәрү Ялгышлык белән, кирәгеннән артыграк яки кирәкмәгән моментта мактану. *Нәселен акыллы санауда мактанып җибәрүе булса да, хак иде бу, нәселгә бирелгән «Акыллы» кушаматы Шәйхетдиннең бабасыннан ук килә иде.* М.Хуҗин

Мактанып йөрү Теләсә кайда мактану, һәрвакыт мактану. *Галләмнең эш өзелеп бетмәс борын ук мактанып йөрүенә кем гаепле?* М.Фәйзи. --- *Касыймҗан малае Бәләбәйдә хезмәт итеп кайтты. Барыбер солдатта булган исемен күтәреп йөрде. Атна буена, өйдән өйгә кереп, мактанып йөрде кайткач.* Ф.Сафин. *Мактанып йөрсә дә тавык Үзенең кирәклегенә, Күтәрелә алмый барыбер Бөркет биеклегенә.* И.Әширов

Мактанып калу Мактанырга өлгерү. *Мин, моменттан файдаланып, мактанып калырга ашыктым.* Д.Галимов

Мактанып кую Бераз гына мактанган кебек булу, бер мәртәбә генә мактану. *Кичә газетада шигыреңне күргәч, мактанып куйдым әле. Коллегаларга әйттем, бу шагыйрь белән таныш мин, дидем.* Т.Миңнуллин. *Кушаматы белән мактанып куярга яратса да, һәм кияве аңардан ун яшькә кечерәк булса да, Шәйхетдин Бәйрәмханны үзеннән акыллырак саный, шушы көчне тануы ук аның акылы ныклыгын сөйли.* М.Хуҗин

Мактанып ташлау Кисәк, берьюлы артыграк мактану, ялгышлык белән кирәкмәгән моментта мактану. *Чулпан, күрәсең, артыграк мактанып*

ташлавын сизде, шуңа сүзне икенчегә борырга теләп, тавышын үзгәртә-үзгәртә, мәзәк сөйләргә кереште ---. Х.Ширмән

Мактанып тору Мактану белән мәшгуль булу, хәзерге вакытта мактану.

Мактанып утыру *к.* **мактанып тору**. *Без дә барган булыр идек. Алайса, үзе генә барган да хәзер мактанып утыра.* Х.Ширмән

◊ **Мактану булмасын** Җитди, чынлап, дөресен сөйләнгән сүзләр мактану, коры сүз генә дип кабул ителмәсен өчен искәртү. *Мактану булмасын, нибучь, маршал Рокоссовскийның үзен күргән кеше мин!..* Р.Низамиев. **Мактанудан булмасын** *к.* **мактану булмасын**. *Инде Садыйкның үзенә килсәк, әтисенең әйтүенчә, ул исем туры, эчкерсез дигәнне аңлата икән. Мактану булмасын, шундый ул, шундый.* Ш.Рәкыйпов. **Мактанудан түгел** *к.* **мактану булмасын**. *Мактанудан түгел, Гарәфи бит – Уралын да, Себерен дә, Кырымын да күргән кеше.* Г.Әпсәләмов. **Мактанып әйтүем түгел** *к.* **мактану булмасын**. *Мактанып әйтүем түгел, кулымда корал булганда, куркаклыкны белми идем мин.* А.Шамов. *Мактанып әйтүем түгел, әлегәчә чирнең нәрсә икәнен, хастаханә ишегенең кайсы якка ачылганын белмәдем диярлек.* Т.Галиуллин. **Мактанып туймау** Бик еш, бик теләп, озаклап мактану; гел, һәрвакыт мактану. *Үз атлары белән мактанып туймаган, үз атларын мактаганны сәгатьләр буена да тыңлап торырга әзер булган рәискә шул җитә калды.* Р.Мөхәммәдиев. *Теге ялагаең Халтаев мактанып туя алмый, беркемдә дә андый яңа нәрсә юк, имеш.* Р.Мирхәйдәров

МАКТАНЧЫК *с.* **1.** 1) Еш мактанучы, гомумән, характерында мактану, шапырыну, масаю гадәте булган. *Җилбикә мактанчык аучының борынына шалт берне!* М.Әмирханов. *Ул – вакчыл, көнчел, мактанчык, даһилык чире белән интегә.* Р.Низамиев. – *Ә мин оча алам, – дигән мактанчык песи баласы.* В.Бирюков

2) Мактануны белдергән, мактану билгеләрен чагылдырган. *Мактанчык кыланышлар. Мактанчык тон белән сөйләү*

2. *и. мәгъ.* Мактанырга яратучы кеше, мактану гадәте булган кеше. *Әллә, ветеринарга укучы буларак, латинча такылдап маташа инде, мактанчык?* Р.Төхфәтуллин. – *Ялгыш аягым тайды, шуңа гына егылдым, югыйсә менә дигән итеп сикергән булыр идем, – дип җавап кайтарган мактанчык.* В.Бирюков. *Ниең калды сиңа урамда? Алачыктан туеп качтың дамыни? Мактанчык!* Ф.Мансуров

МАКТАНЧЫКЛЫК *и.* Мактанырга ярату үзлеге, еш мактану күренеше, масаючанлык. *Мактанчыклыгы хур итә язды Жанны.* Ш.Рәкыйпов. *Атлар чапты... Колга башларына Менеп җитте кичә Кыюлык; Хаклык батыр калды. Мактанчыклык Капчык тигәч төште егылып.* Х.Әюп. *Роберт Әхмәтҗанов турында күп яздылар. Мактап яздылар, әмма... бу мактаулар аның холкына мактанчыклык, хөсетлек --- алып килмәде.* Р.Рахман

МАКТАНЫРЛЫК *с.* **1.** Мактану өчен нигез булырлык, мактану хакы бирә торган, горурланырлык. *Зәкиулла абзый гына, өлкән кешеләр алдында мактанырлык акча әмәллән, өс-башын карап кайта алмавыннан кыенсынып-тырмы, күбрәк бала-чага белән аралаша.* М.Юныс. *Урамнан узган кеше хәйран калырлык булыр. Кем өе дигәндә, Нәҗипнеке дип мактанырлык, менә күрерсең...* Р.Мөхәммәдиев. *Мактанырлык уңышың бар икән, авыз тутырып сөйләргә дә, күкрәк кагып мактанырга да хакың бар.* М.Хәсәнов

2. *и. мәгъ.* Мактану хакы, мактану өчен нигез, горурлану өчен мөмкинлек. *Мактанырлыгы бар, арада аңа җиткән мәргәннәр юк.* М.Әмирханов

МАКТАНЫЧ *и.* Мактану өчен нигез булырлык сәбәп, мактану хакы бирә торган кем яки нәрсә; горурлык. *Урысларның мактанычы булган «Слово о полку Игореве»ның чордашы бит югыйсә [«Кыйссаи Йосыф»]... Күпме янгыннардан, сугыш-кырылышлардан исән калган...* М.Гали. *Алар кем дә, син кем? Алар – бөек математик, акыл иясе. Россиянең мактанычы Николай Лобачевский. Гигант Лев Толстой.* М.Мәһдиев. *Җиһандагы һәр татарның Кыйбласы ул, кәгъбәсе. Берәүләрнең – мактанычы, Берәүләрнең – дәгъвасы.* Л.Шагыйрьҗан

МАКТАНЫЧЛЫ *с. сир.* Берәүнең горурлыгы, мактанычы булган. *Нәселнең һәр кешесенә шушы кушамат тагыла бара: Акыллы Шәйхетдине, Акыллы Хуриясе; Шәйхетдиннең хатыны һәм балалары да шушы кушаматны йөртәләр, боерган булса, балаларының балалары да мактанычлы кушаматтан йөз чөермәсләр.* М.Хуҗин

МАКТАНЫШ *и.* Мактану күренеше, мактанулы кыланыш. *Әй, җәгетләр!.. Булмасын бу мактаныштан: Бик күп шагыйрь чыккан безнең Актаныштан.* Л.Лерон

МАКТАНЫШУ *ф.* Күп яки берничә кеше бер-берсе алдында мактану. *Тараканнар очрашып мактаныша: «Телевизор янында шундый җылы!»* Ш.Галиев. *Алласын да, мулласын да Ташладык та пыр туздырып, Мактаныштык, күкрәк какты, Бер-беребезне уздырып.* И.Әширов

Мактаныша башлау Мактанышырга тотыну. *Безнең Актырнакны әллә ничә эт уратып ала, ә мине урыс малайлары төрле яктан тикшереп чыгалар да, берсен-берсе уздырып, уенчыклары белән мактаныша башлыйлар.* Ә.Гаффар

Мактанышып алу Бераз гына мактанышу. – *Көн кызуында ял итсәләр дә, төнлә алар [алабайлар] күз йоммый, һәрчак сакта, – дип, бер-берен бүлдерә-бүлдерә мактанышып алды хуҗалар.* Р.Мөхәммәдиев

Мактанышып тору Хәзерге моментта мактану; шактый вакыт мактану

Мактанышып утыру *к.* **мактанышып тору**. *Космоска чыгу, генетика серләрен ачу заманында мактанышып утыру килешми.* Т.Галиуллин

МАКТАРЛЫК *с.* Мактауга лаек, шәп. *Мактарлык эше бар икән – курыкмагыз, мактагыз.* Х.Сарьян. *Бик ук мактарлык түгел мондагы хәлләр дип, Фәйзулла Хаҗиевич тулай тораклының тәрәзәләренә күтәрелеп бакты.* Ш.Рәкыйпов. *Шундый ук гади генә тормышта яши. Артык кайгысы да,*

үтереп мактарлык шатлыгы да юк. Г.Гыйльманов

МАКТА́У I *ф.* 1) Берәр кешенең яки әйбернең яхшы, күркәм, файдалы ягын хуплау, яхшы яктан күрсәтү, уңай бәя биреп сөйләү; *киресе:* **яманлау**. *--- ат караучының колхозда ни дәрәҗәсе, ни исеме юк. Хәзер бит колхозда механизатор белән сыер савучыны гына күралар, шуларны гына мактыйлар.* М.Мәһдиев. *Яшь нарат һәм эрбет агачларыннан җыеп алынган ботак очларын безнең Себердә промышленниклар һәм диңгез сәяхәтчеләре, зәңгеләргә каршы кулланыла торган бик яхшы бәлзәмле дару, дип мактыйлар.* Робинзон эзләреннән

2) Хуплау, дөрес санау, яхшы дип табу; хуп күрү. *Тимерхан башлаган эшләрне мактыйлар, гел аның күңелен үсендереп торалар иде.* Г.Ахунов. *Берсе дә мондый эшне мактамаган иде.* Э.Касыймов

3) Данлыклау, дан җырлау. *Сезне мактап күпме җырладылар, Сезнең хакта күпме яздылар?!* Х.Әюп. *Мактама да куштанланып, Хурлама да дерелдәп. Әйтсәң әйт ярып турысын, Тавышың чыксын гөрелдәп.* Л.Шагыйрьҗан. *Гоголь мактаган Запорожье сечындагы Югары Хортица авылында хәзергә кадәр 700 яшьлек имән сакланган.* Робинзон эзләреннән

Мактап алу Бераз гына, берара, күп сүз белән мавыкмыйча мактау. *Сүз арасында, үзе ялкын, кулы алтын, дип, Мәдинәне дә мактап алды Ногман абзый.* М.Хәсәнов. *Илһам аны [мәкаләне] бик яратты, әле кулъязма хәлендә укып чыккач та: «Бу үзенә бер диссертация шикелле булган», – дип мактап та алган иде.* Л.Шагыйрьҗан. *– И-их, әйттерә дә соң безнең Мәрьям түтекәй, – дип, кемдер җыр арасында аны мактап алырга да өлгерде.* Р.Мөхәммәдиев

Мактап бетерү Төрле яклап мактау, бик нык мактау. *Трубкасын куйгач, [Сабит] әле генә мактап бетергән Нәҗипкә сыңар күз салмыйча, аны бетереп, үз өстенлегеген раслап, тәрәзә аша төнгә карап утырды.* А.Гыйләҗев

Мактап җибәрү 1) Мактый башлау, мактарга керешү. *– Сугышта да сынатмагансың икән, менә монысы шуның өчен. Рәхмәт, агай-эне! – дип мактап та җибәрде әле.* В.Нуруллин

2) Артыграк мактау, чамасыннан артык мактау. *Гаҗәеп матур шигырьләр яза иде ул. Мактап җибәрдек без моны. Шушы мактау сүзләре аңа килешмәгән.* И.Юзеев. *Алай да артык мактап җибәрмим, дигән сыман, тагын кырысланды: кара аны, Митрий, юлда шаяра күрмә.* З.Фәтхетдинов

Мактап йөрү һәр очракта, һәр җирдә мактау. *Аның улы турында моңарчы берәү дә колакка ятышсыз сүз әйтмәде бит. Укытучысы да дүрт ел буе мактап йөрде.* М.Насыйбуллин

Мактап кую Бер мәртәбә мактау. *Торбаны китергәч, Гайнан: – Булдырдың, егет! – дип мактап куйды.* Н.Әхмәдиев. *Хәмит абый акбур белән хәрефләрнең тиешле сызыкларын калынайтып чыккач, аны тагын да мактап куйды ---.* Ә.Баян. *Полицейский хуплап мактаган була, Ранутны да мактап куя: «Син – бик яхшы дус!» – ди, тегесенең авызы колагына җитә.* Н.Измайлова

Мактап тору 1) һәрвакыт мактау, гел мактау. *Редакторым башта бик яратты: «Кыю! Кыю!» – дип мактап кына торды.* К.Тимбикова. *Башкалар да гел мактап тора иде бу сестраны, ләкин, минем ышануымча, ул бары тик миңа гына шулай назлы, иркә итеп орына иде шикелле.* М.Маликова. *Әтием мактап торса да, Абый колакны борса да... Физзарядка ясасам да, Үсәм, кишер ашасам да!* А.Нигъмәтуллин

2) Шушы моментта мактау. *Мин аны мактап торам әле, бәһадир. Хәтта әнә үзенә кылычым бүләк иттем.* М.Хәбибуллин

Мактый башлау Мактарга керешү. *Ул сугышмый минем белән, киресенчә, кочаклап ала да сөя, мактый башлый.* В.Юныс

◊ **Мактап бетерә алмау** Бик ошату, һәр яктан риза булу, чын күңелдән мактау. *Спектакльнең эчтәлеге һич кенә дә башка керми, уйда гел бүрек: әнә бит күрше мәктәп завучы ничек сокланды, мактап бетерә алмады.* Т.Галиуллин. *– Күрче, Ходаем, күрче генә, йорт эшенә кулы тәмам сусаган булган икән балакаемның, – дип, әбием аны [Элеонораны] мактап бетерә алмый.* А.Хәсәнов. **Мактап йөрисең (икән)** Өйдәгеләр ашап-эчеп утырганда килеп кергән кешегә ачык чырай күрсәтеп, «бик вакытлы килгәнсең, табынга рәхим ит» мәгънәсендә әйтелә. *– Мактап йөрисең, Сабир туган, әйдә, утыр табынга, – диде Лотфулла абзый әтигә, үз янында урын күрсәтеп.* Г.Тавлин. *Мактап кына йөри икән, рәхмәт яугыры, самавырым кайнап кына чыкканые.* Г.Ахунов. *Әйдә, рәхим ит, Радик Хафизович! Өстәл әзерләгәндә генә килеп кердең, мактап йөрисең икән. Әйдә, уз!* З.Фәйзи. **Мактап туймау** *к.* **мактап бетерә алмау**. *[Вәлидә] Вазих абыен: «Менә, ичмаса, кеше!» – дип мактап туя алмый.* М.Хәсәнов. *Дүрт хатын шәлнең дүрт почмагыннан тотып, иң элек аның зурлыгына сокландылар, аннан, кулларына алып, җиңеллеген, йомшаклыгын мактап туймадылар.* Р.Мөхәммәдиев

МАКТА́У II *и.* Хуплау, тану, күңел күтәрүне белдергән сүзләр һәм гамәлләр. *Шулхәтле батырлык күрсәткәч, Асылгәрәй, бәлки, мактау сүзләре көткәндер.* М.Шабай. *Дәрәҗәдән, мактаулардан ардым; Ә күңелдә – канәгатьсезлек хисе: Аз тырыштым, аз эшләдем төсле.* Г.Афзал. *Табигый ки, бөтен игътибар Шәфикада иде, барча мактау аңа эләкте, һәммә чәчәк аның кочагына тулды.* М.Маликова

МАКТА́У ГРАМОТАСЫ *и.* Эштә, спортта һ.б.ш. өлкәдә зур уңышка ирешкән кешегә, аның тырышлыгын танып, хуплап, зурлап, хөрмәт итеп бирелә торган рәсми язма таныклык. *Идарә исеменнән Нургали картка да, Фәрдиевкә дә мактау грамотасы һәм иллешәр сумлык сәгать биргәннәр, халык кул чапкан, пионерлар чыгып, геройларны котлаган.* М.Мәһдиев. *Менә Феликсның мактау грамоталары, бусы – унынчыны бетергәндә бирелгән алтын медале.* М.Юныс

МАКТА́У ҖЫРЫ *и.* Фольклорда йола җырларының бер төре; *русчасы*: **хвалебные песни**. *Тылсымлы гомнарның нәфис тавышлары үзләре*

ышыклана торган чәчәкләргә мактау җырлары җырлыйлар. Робинзон эзләреннән

МАКТА́У КӘГАЗЕ *и. сөйл. к.* **мактау грамотасы**. *Кеше вафат булгач, киемнәрен, әйберләрен чүплеккә чыгаралар: мактау кәгазьләре, фотолар, хатлар, адреслар, блокнотлар, төрле язмалар.* Ш.Галиев. *Орден-медаль түгел, сыңар мактау кәгазе дә алганы юк үз гомерендә [Фатыйма].* Р.Мөхәммәдиев

МАКТАУЛЫ *с.* **1.** 1) Мактауны, хуплауны эченә алган, уңай бәя белдерә торган. *Шунда эшләгәндә, «Татарстан Республикасының атказанган авыл хуҗалыгы хезмәткәре» дигән мактаулы исемгә лаек булды.* К.Тимбикова. *Колхозның уңышлары, кешеләре турында сөйләделәр, иң мактаулы сүзләр белән механизатор Кәшфине телгә алдылар.* М.Мәһдиев. *--- Мәскәүдә яшәгән Камаловның агропромышленность берләшмәсенең уңышлары турында ишетүе икеле, үзәк матбугатта басылып чыккан мактаулы мәкаләләрне дә укымаска мөмкин ---.* Р.Мирхәйдәров

2) Мактау, дан, хөрмәт китерә торган, һәркем тарафыннан хуплана торган. *Иң соңгы мактаулы эше шул булды: Түбән очта, Ташлыяр кинәт кенә тарайган урында, елганы будыртты.* А.Гыйләҗев. *Дөрес булса да, сөйләүдән тыелу – бәндәләрдәге мактаулы сыйфат.* Р.Фәхретдин. *Алда аны шул ук мактаулы эш – авыл тамашачыларына культура хезмәте күрсәтү эше көтә.* М.Шиһапов

3) Иң күп макталган, мактауга лаеклы булган, уңай яктан гына танылган. *1992 елның 20 июлендә Казанның Актёрлар йортында республикабызның иң мактаулы, иң тырыш, иң актив һәм иң гүзәл хатын-кызлары җыйналды.* Л.Шагыйрьҗан. *Мактаулы исеме булган балта остасы иде аның әтисе.* Р.Мөхәммәдиев. *Мактаулы очучы, өлкән лейтенант Черепнинның куркак икәнлеген син белмисең икән.* М.Юныс

2. *рәв. мәгъ.* Уңышлы рәвештә, мактарлык дәрәҗәдә. *Югары уку йортларын бик мактаулы бетергән белгечләр генә түгел болар, өстәвенә махсус хәрби белем алган офицерлар.* Г.Ахунов

МАКТАУ ТАКТАСЫ *и.* Хезмәттә, җәмәгать эшчәнлегендә яки башка өлкәдә уңышка ирешкән кешеләрнең рәсемнәре һәм исемнәре язып куелган такта (витрина). *Икесенең дә рәсемнәре район Мактау тактасында. Һич икеләнми яз шулар турында.* Г.Тавлин. *--- капка челтәрләп-бизәкләп эшләнгән. Аның бер ягында Мактау тактасы, икенче ягында «Маяк» колхозының перспектив планы.* М.Хәсәнов. *Ярты ел дигәндә, Рәхмәтулланың фотосурәте мактау тактасына куелды.* Б.Камалов

МАКТАШ *и.* Мактау күренеше, мактау гамәле

МАКТАШУ *ф.* 1) *урт. юн. к.* **мактау**

2) Бер-береңә игътибар, илтифат күрсәтү, исәпләшү, уңай мөнәсәбәттә булу

Макташып тору Хәзер макташу, гел макташу. *Ә еллары макташып тора торган заман түгел иде.* М.Мәһдиев

Макташып утыру Озаклап макташу. *Дөнья хәлләрен сөйләшеп, үзара макташып утырган җирдән хуҗа кеше капылт кына сорап куйды ---.* Р.Мөхәммәдиев. *Теге кәккүк белән әтәч сыман бер-берегезне макташып утырасыз.* Идел

МАКУЛАТУ́РА *и. лат.* 1) Бер мәртәбә файдаланылганнан соң, яңадан эшкәртүгә җибәрелә торган кәгазь. *--- халык үзенең күз алмасы кебек саклларга тырышкан борынгы кулъязмаларны аннан талап алып яндырдылар, макулатурага тапшырдылар, юкка чыгардылар...* Ә.Кәримуллин. *Макулатураны әйткән дә юк инде, – өй борынча тотылган кәгазь эзләп йөрүләр...* А.Гыймадиев. *60 кг кәгазь әзерләү өчен, бер зур агачны кисәргә туры килә. Менә шуңа күрә кәгазьне саклау, макулатура җыю – урманны саклау дигән сүз ул.* Биология

2) *күч.* Әдәби, сәнгатьчә һәм иҗтимагый әһәмияте ягыннан бик түбән сыйфатлы матбугат чаралары һәм китаплар, әсәрләр. *Хәзер, ниһаять, мәгълүм булды: юк, бу әсәрләр ялган, --- милләтебезнең бәһасен төшерә торган макулатура икәне ачыкланды.* Р.Зәйдулла

МАЛ *и.* 1) Терлек-туар, ит, сөт һ.б.ш. өчен үрчетелә торган йорт хайваннары. *Мал карау, кар көрәү, утын кертү, моржа ачу, көл түгү, тирес чыгару кебек эшләр – карт кулында.* М.Мәһдиев. *Моңарчы район җирендә яшәгәч, Хәнәфинең үз терлекләре юк, барысы да колхоз маллары иде алар.* В.Нуруллин. *Мал куарга чыккан апалар, ярты гомер күрешмәгән кешеләр сыман, бер-берсе белән бик тәмләп гәпләшергә, хәл-әхвәл белешергә кереште.* Р.Мөхәммәдиев

2) Материаль байлык, милек, мөлкәт. *Эх, бөтен дөнья малына алыштыргысыз күпме ирләрне вакытсыз күмдек бит без ул көннәрдә!* Ш.Рәкыйпов. *Өеңә карак керсә, бер әйбереңне урлый, нигезеңә ут төшсә – бөтен малыңны ялмый, дип, белми әйтмәгәннәр.* З.Фәтхетдинов. *Бер ташка ике абынма, Малга, акчага табынма.* Ә.Синугыл-Куганаклы

3) Файда, табыш, керем. *Эзләгән егет кулына мал төшмиме, Нәҗип туганым?!* А.Гыйләҗев. *Тылсымлы тавышлар дөньясында мал, файда, өстенлек шикелле теләкләргә урын юк иде.* М.Юныс. *Хәлә мал, әни! Эшләп, маңгай тиремне түгеп алдым!* К.Кәримов. *Эзләгән корт бал табар, эшләгән кул мал табар.* Мәкаль // Акча. *Атаң кара кеше иде, Мал биргәннең колы иде ---.* Дастан

4) Көнкүреш кирәк-яраклары, хуҗалыкта файдаланыла торган әйберләр; кыйммәтле дип саналган нәрсәләр. *Малны юкка сарыф итмәде, ипинең чын кадерен белде...* Ш.Рәкыйпов. *Гомерем буе кеше малына кул тидермәдем. Башкалар байлыгын талауга бәрабәр сакланган баш белән ничек яшәмәк кирәк?!* К.Тимбикова. *Әледән-әле ялчыларың килеп, бар булдырган малыбызны, хезмәт белән, тир белән тапкан милкебезне талап алып бетерә тордылар.* М.Маликова

5) Сатуга чыгарылган әйберләр; сәүдә объекты, товар. *--- райпотребсоюзда галантерея маллары буенча товаровед булып эшләүче Мария Петровна белән почта мөдире Мәрьямне күздән үткәрде.* Р.Мирхәйдәров.

Ефәк – асыл мал! Мондый товар белән хан сараена да, Казаннан көнбатыштагы башка мәмләкәтләргә дә үтеп кереп була! Кирәкле мал! Ф.Латыйфи. *Базарда мал табыла ул, баш кына табылмый!* Ф.Баттал

6) Тукыма. *Әтисе карт, авылдан авылга күчеп, кубыздан алып аршинлы малга хәтле вак-төяк сатып йөри торган кеше – кырыктартмачы булган.* М.Хафизов

7) *күч. гади с.* Берәр кешегә язылган, насыйп булган, билгеләп куелган кем яки нәрсә. *[Сирай, Ярулланың Мавиягә якынлашканын күреп:] Әй, син минем малга якын юллама! – Синең кебек аксакларга кул мал түгел ул.* М.Фәйзи

◊ **Мал артыннан куу** Матди байлыклар тупларга омтылу, байлык җыюга артык әһәмият бирү. *Кешеләр күпне өмет итеп мал артыннан кумый иде ул чакта, бернинди сугыш юк елларда бер-берсен үтерми иде, дөнья малы – дуңгыз каны өчен җанын сатмый иде.* Г.Ахунов. *Мал артыннан куу, күреп торам, безне әкренләп рухсызлануга таба сөйри.* М.Юныс. *Куа күпләр дан я мал артыннан – Арыганын белми, ял итми. Малга комсызларга мал бер җитә, Данга комсызларга дан җитми.* Ф.Яруллин. **Мал булу** Үсеп, эшкә ярар дәрәҗәгә җитү, кеше булу. *Камбәр үсеп мал булган, укыган. Киек тә болан атарга урманга йөргән.* Дастан. **Мал җанлы** Байлык, акча җыюга бирелгән, яратучы, байлык өчен тырышучы. *Син яшьтән үк тынычсыз, мал җанлы идең.* Т.Гыйззәт. *Йорт җанлы, мал җанлы булырга охшый иде улыгыз.* Х.Вәлиәхмәтов. **Мал итү** Кулланырлык, файдаланырлык яки сатарлык хәлгә китерү, эшкә яраклы итү. *Авызымнан өзеп алып ашатып мал иттем мин аларны [сыерларны].* М.Хәсәнов. **Мал табу** Көн күрү, тормыш итү өчен акча эшләү. *Атадан бала яшьләй калса, Күкрәк көчләре белән, абау, бәгырем, мал таба.* Җыр

МАЛА *и. иск.* Тырма, җир себеркесе. *--- Колаклары калкандай, Куллары бер җобадай, Аяклары маладай [Кара Тиен Алыпның] ---.* Дастан

МАЛАДИС *ы. рус сөйл. к.* **молодец**. *Күпме газапланып аңлата алмый йөдәгән сүзләремне әйттең дә салдың. Маладис, Айдар!* Р.Мөхәммәдиев. *Маладис, иптәш Нурисламов ---. Сугышта да сынатмагансың икән ---.* В.Нуруллин. *– Ай-да маладис, чын спортсменка менә нинди сыйфатларга ия булырга тиеш, – дип, аны усендереп җибәрергә дә күп сорамый иде.* Ф.Сафин

МАЛАЙ I *и.* **1.** 1) Яңа туган яки кече яшьтәге, яшүсмер ир бала. *--- малай чагында җиләк җыйган урман аланнарын, балан белән миләшкә, шомыртка, карлыганга, кыргый чиягә, чикләвеккә йөргән урыннарын караганнар иде.* Г.Ахунов. *Тәнәфестә өлкән класс малайлары без кечкенәләрне ил-умач итеп кыйнап ташлаганда, Рафка кул күтәрүче юк.* М.Мәһдиев

2) Ата-анага мөнәсәбәттә: ул, ир бала. *Һәрбер хуҗа бары тик үзе генә яки компаньоны белән генә сату итә, ә базар көннәрендә исә хатынын һәм малаен эшкә җигә.* Ә.Еники. *Аларның бер малайлары Норильскида яши, төпчек кызлары шушы авылда кияүдә иде...* М.Мәһдиев. *Башка командирлар кебек тырт-тыртланмыйча, егет белән иплән, малае белән фикерләшкән кебек сөйләште күрше батальон хуҗасы.* Т.Галиуллин

3) Гомумән сөйләүчедән яшьрәк булган ир кеше. *Шулай да бер көнне малай кухняга уза алды һәм, дәү әнисе күрмәгәндә генә, шырпы кабы эләктерде.* М.Мәһдиев

4) Туган як, милләт турында сүз барганда: шунда туган, шуңа караган кеше. *--- зонтик астында бер доцент бара, татар малае, Африка илләрендә француз телендә физика укыта, әле ялга гына кайткан ---.* М.Мәһдиев

5) *сөйл.* Дәрәҗәсе яки эш тәҗрибәсе белән түбән яки җитди булмаган, беркатлы кеше турында. *Мин, үземнең исемемне әллә нинди малайлардан таптатмас өчен, һәртөрле юлга керергә хәзер.* М.Фәйзи

6) *иск.* Хезмәтче. *Малай! Кая, миңа бер стакан чәй, ике сумса китер әле.* Г.Камал. *Аның, шулай итеп, самавырчы малайдан Казанның, Казан тирәсенең иң зур бае булуы өчен гакылның иң зур роль уйнавында шөбһәгезме бар?* Г.Исхакый. *Мактанмасын байлар, әй, мал белән – Бар да яшь малайлар хезмәте.* Җыр

7) *иск.* Оста, тәҗрибәле һөнәрче янында ярдәмче, һөнәргә өйрәнүче, өйрәнчек. *Атасы аны бер кибеткә малай итеп бирде.* К.Тинчурин. *Сату-алу кызган чакта, йомышчы малайлар күп йөри.* Ф.Латыйфи

8) *диал.* Хайван баласы; чага. *Казанга терәлеп торган орденлы совхозларның берсендә, куе сыер сөте эчертеп кенә, биш данә чучка малаен симертә башладылар.* А.Гыйләҗев. *Елгаларны тап урталай бүлеп, Чикләр сызу нигә ул тикле? Төймә кадәр маймыч малае да Көнгә кырык боза бу чикне!* Г.Гыйльманов

9) *сөйл.* Бер-береңә (шул исәптән хатын-кызларга да) тәкәллефсез һәм дусларча мөрәҗәгать итү сүзе. *Кәшифә, сәлам, малай!* К.Тимбикова. *Малай, дачамдагы гөрләп үсеп утырган бәрәңге сабаклары күз алдында диярлек шиңеп төште...* Ш.Маннапов. *Баш бетте дип торам, малай. Күздән утлар күренде.* Ф.Баттал. *Ну-у, Хәдичә малай! Зур шатлык китердем бит әле үзеңә!* М.Хәсәнов

2. *ы. мәгъ.* **малай, малайкаем, малакаем**. Гаҗәпләнү, соклану, үкенү һ.б.ш. төрле эмоциональ төсмерләрне белдерә торган сүз. *И-и-и, малайкаем, килешүен генә күр әле, йөзләреңне балкытып җибәрә бит.* Р.Мөхәммәдиев. *Малакаем, син андагы файдалы витаминнарның күплеген белсәң!* Т.Галиуллин. *Тамак тәмугка кертә, ди, хактыр, малай, Булмагандыр сугыш вакытында да алай...* Л.Шагыйрьҗан

◊ **Малай актыгы** Гадәттә малайларны, егетләрне, яшьрәк ирләрне шелтәләгәндә, тиргәгәндә кулланыла. *Әй, малай актыгы, нишлисең анда! Кил әле!* М.Маликова. *Суйды, чалкан яткырды бу малай актыгы!* Н.Әхмәдиев. *Кинәт күз каршыма Гөлфия апа килеп басты: «Малай актыгы, шулай йөрсәң, барып чыгасың син, кара аны ---».* Л.Шәех

МАЛАЙ II *и.* Малайзия, Индонезия, Сингапурда яшәгән халык һәм шул халыкның бер вәкиле. *Малай теле*

МАЛАЙЛАНУ *ф.* Үзен малайларга хас булганча тоту, малайлар кебек кылану

Малайлана башлау Малайланырга тотыну

Малайланып кую Көтмәгәндә малайлану

Малайланып тору Даими рәвештә, әледән-әле яки хәзерге моментта малайлану

МАЛАЙЛА́РЧА *рәв.* 1) Малайларга I хас булганча, малайлар кебек. *Тешләренә кысып «катись» сүзен, Малайларча кашын киерер; Һәм кызларча итеп, үз егетен – үз «җүнсез»ен исенә китерер...* Х.Туфан. *Ул, малайларча, айга тел чыгарып күрсәтте дә ашыга-ашыга язарга тотынды.* Р.Вәлиев. *Һәм Таһир, малайларча шатланып сикерә-сикерә, кулларын болгый-болгый, яр читенә таба чапты ---.* Н.Акмал

2) *күч.* Төптән уйламыйча, җиңелчә генә. *Дипломсыз да җирдә яшәп була, «Җитди» булмаса да кылган эш; Малайларча булсын ләкин хыял, Шагыйрьләрчә булсын кыланыш.* Ә.Рәшит. *Ул чактагы эзләнүләрем, турысын гына әйткәндә, бигрәк малайларча булган икән минем.* Р.Төхфәтуллин. *--- Гөлфирәнең күз алдына теге вакыттагы Гаяр: басма төбендә кочагына ап-ак шомырт чәчәкләре күтәреп, күзләрен ялтыратып торган, аннары малайларча кызуланып басма такталарыннан үчен алучы егет килеп баса.* Г.Кашапов

МАЛАЙЛЫК *и.* 1) Кечкенә малай (I) булган вакыт, малай чак. *Малайлык дәверендәге хәлләр еллар томанына төренеп тоныкланды.* Б.Камалов. *Малайлыктан уздык бугай инде, Булмасак та әле ир-ага.* Г.Рәхим. *Малайлыктан чыгар-чыкмас борын Чырайларга кунды кырыслык...* Ә.Рәшит

2) Берәүнең малае булып тору, берәүгә ул булу. *Җибәрелгән тикшерүче хастаханәдә калдырылган баланың Гафифә тарафыннан малайлыкка алынуы хакындагы документларның күчермәсен алып кайткан.* Ә.Моталлапов

3) Малайларга, яшьләргә хас билгеләр; малайларча кыяфәт, үз-үзен тоту. *Әсәрдә малайлык шуклыгы да, кызлар нәзбереклеге дә, авыл атмосферасы да, мәктәптә пионер оешмасы эше дә бик җанлы итеп тасвирланган.* Р.Вәлиев. *Яшен уты кабынып сүнәрлек вакыт узды микән, аның күзләрендәге малайлык сүнеп юкка чыкты, һәм алардан тагын бакыр салкынлыгы сирпелә башлады.* З.Хөснияр

4) *күч.* Җитди булмаган кыланыш, җавапсызлык, тирән уйлап җиткермәү күренеше. *Малайлык күрсәтүемә соңыннан үкендем үкенүен. Соң, нишлисең бит, характер, имеш.* Ж.Фәйзи. *Тиз генә кубып чыгып китү дә малайлык булыр сыман, кул кушырып басып тору да әллә ни егетлек түгел.* М.Гали. *--- аның [Рәхминең] төпле уй-фикере юк иде, аның акылы ныклы эзгә төшәргә өлгермәгән, малайлыктан чыгып өлгермәгән иде әле ул.* М.Хуҗин

5) Хезмәтче эше, шөгыле. *Зариф хәзрәттә малайлыкта торган Шаһбаз, күрше авылга барып, карт чувашка дуңгыз көтәргә яллана.* Г.Нигъмәти. *Мортаза берәүне дә үзенә малайлыкка ялламый.* Ә.Фәйзи

6) Һөнәргә өйрәнү өчен, оста янында ярдәмче, өйрәнчек эше. *--- Алпар шушы көннән соң тагын да канатланып яши башлады. Углын иң оста бизәк төшерүчегә малайлыкка бирде.* М.Хәбибуллин. *[Заһидулланы] Малайлыкка бирер идең, әлегә эшкә яраклык түгел, буыны сыек.* Р.Низамиев

МАЛАЙ-САЛАЙ *җыл. и. к.* **малай-шалай**. – *Әллә нинди ата-бабада булмаган, мең метрлы җылым бәйләтеп азаплыйлар, эш белмәгән малай-салай баш, ахрысы, колхоз таралыр, – ди.* М.Җәлил. *– Бу да ярар, йөгерешә торган малай-салайның берәрсенә бирербез, – дип, аны [янчыкны] сәрпинкә яулыкның почмагына бавыннан бәйләп куйды.* Ә.Фәйзи. *Чыккан саен куян ату ул бит малай-салайны да түйдыра.* Фән һәм тел

МАЛАЙСЫТУ *ф.* 1) Кечкенә балаларга күрсәткән мөнәсәбәт күрсәтү, малай дип, яшь дип санау. *Иң элек [минем янга больницага] Алёша белән капитан килде. Бигрәк малайсытканнар: шоколадлар, печеньелар, конфетлар төяп килгәннәр.* Р.Төхфәтуллин

2) Яшәртү, малайларга хас төс бирү, артык яшь күрсәтү. *Хәлимнән берничә яшькә өлкәнрәк булса да, нәзек йөз чалымнары аны малайсытыбрак күрсәтә иде.* Ф.Яхин

3) Исәпләшмәү, кимсетү, тәҗрибәсез дип карау, беркатлыга санау. *[Мусага] ипташләренең хәтере калды. Бигрәк малайсыта инде. Ләкин эчләренә йоттылар.* Ш.Маннур. *Туктале, син нигә мине малайсытасың, Ася?* Х.Камалов. *Кайбер артистлар, Марсельне малайсытып, репетицияләргә соңлап килә башлыйлар, аның әйткәннәрен дә сангә сукмаучылар табыла ---.* Сәхнә

Малайсытып җибәрү Бераз малайсыту. *Нишләптер солдат гимнастёркасыннан иде ул, һәм бу аны яшәртеп, бөтенләй малайсытып җибәрә иде.* М.Маликова

МАЛА́ЙЧА *рәв.* Малай (II) телендә

МАЛА́ЙЧАК *и.* Балачак, кечкенә малай булган чор, малайлык еллары. *Малайчак карап торды да Сарылды иңгә – Әллә нинди бер гажәп хәл башланды миндә ---.* С.Мулла Гали. *Нигъмәтләр тулы табында, Үзара дәшми бер сүз, Малайчак белән икәүләп, Чәй эчеп утырабыз.* Ә.Рәшит. *Җирән кашка дугаларын күмеп, Ак тын бөркеп җитез юырта. Ә чанада, толып аша карап, Кырын яткан малайчак кайта.* М.Галиев

МАЛАЙ-ШАЛАЙ *и. җыл. сөйл.* Малайлар, бала-чага, балигъ булмаган яшүсмерләр. *Болар тавышына мәйдан читендәге туармыйча бәйләп куелган сабантуй атларының шөлдер, кыңгырау тавышлары, малай-шалайның чыр-чу килеп куышып йөрүләре --- – бөтенесе бергә кушылып, баш әйләндергеч сихри бер оркестр тәшкил итә иде.* М.Мәһдиев. *Боз өстен тутырып, малай-шалай хоккей уйный иде.* Ж.Мостафин. *Авылга килеп чыккан сәер юлчыны танырга теләгәндәй, тәрәзәләргә капланып калган хатын-кызда да, үзе артыннан иярген малай-шалайда да гаме юк иде аның.* Р.Мөхәммәдиев

2) Җитди кешеләр исәбенә кермәгән, хөрмәт ителмәгән, исәпләшмәслек, әһәмиятсез кешеләр. *Күзгә яшь тула,*

кайнар яшь. Тир әчеттерүдән генәдер лә монысы... Болай ук йомшарырга малай-шалай түгел лә инде. Ш.Рәкыйпов. *Әүвәл юк-барны сөйләп йөри торган малай-шалай түгел иде ул.* М.Насыйбуллин. *Кайсына карама, синең җиленнән аварга тора. Җыенысы малай-шалай.* Казан утлары

МАЛАЙ-ШАЛАЙЛЫК *и.* Кешенең үз-үзен тотуында, кыланышында, эшендә җитдилек җитмәү күренеше, төптән уйламау, ваемсызлык. *Үзеңне тиңсенмәгәннәргә күз алартып йөрисең дә юк, бөтен дөньяга күсәк күтәрүең инде, гафу ит, акылсызлык, малай-шалайлык...* Т.Әйди. *Малай-шалайлыктан чыгып җитмәгән абыйларыбызның 2 ел эчендә чын ирләргә әйләнеп кайтуын күреп, хыял йолдызыбыз тагын да яктырак яна башлый иде.* Татарстан яшьләре

МАЛАХАЙ *и.* **1.** Күректән колакчынлы һәм артлы итеп тегелгән бүрек. *Каяндыр лапас астыннан кичәге агач аяк күренде, иске малахаен салып сәлам бирде.* А.Гыйләҗев. *Монда каракүл бүрек кигән татар зыялылары да, малахай кигәннәр дә, фуражкалы кызылавызлар да, картуз кигәннәр дә бар.* Р.Батулла

2. *с. мәгъ.* Шундый фасонда тегелгән. *Кием-салымы да аның тазарак: башында эче-тышы мех малахай бүрек, өстендә калын тышлы, сырган эчле, каракүл якалы пальто, аягында зур соры киез итек ---.* Ә.Еники. *Миңнурый карт, иске сары тунын киеп, малахай бүрегенең колакларын тырпайтып, мич янында тын гына утыра.* А.Шамов. *Абдулланың юка иреннәре җәелеп китте, кашлары биеп алды, олы бияләй кигән кулы малахай бүрекне баш артына сыпырды.* Э.Касыймов

МАЛАХИТ *и. гр.* **1.** Карбонатлар классына караган, гадәттә ачык яшел төстәге, ювелир һәм декоратив сәнгать әйберләре эшләү яки буяу алу өчен чимал буларак файдаланыла торган минерал. *Янәшәдә үк могҗиза тудырып укмашкан куе яшел төстәге малахит ята.* Ж.Тәрҗеманов. *Бары тик стенадагы шәрә кыз сурәте төшкән календарь, өстәл өстендәге яшел малахиттан ясалган уткабызгыч, шкафтагы бәллүр рюмкалар гына монда яңа кеше яшәвен сиздереп тора.* М.Юныс. *Сезнең, бәлки, таркалу реакциясен өйрәнгәндә, малахит порошогыннан файдаланганыгыз да булгандыр.* Күзгә күренми торган матдәләр турында хикәяләр

2. *с. мәгъ.* 1) Әлеге таштан ясалган; составы белән шул минералдан торган. *Татар җырында Идел карамаларыннан алып малахит Урал сыртлары аша Себер карагайларына кадәрге киңлектә дәрья булып шаулаган кара урманнарның гөнаһсыз-шомлы тирәнлеге бар!* М.Галиев

2) Әлеге минерал төсенә охшаган яшел төстәге. *[Һади абзый] --- малахит яшел күзләре белән елмаеп, туп-туры карап торды, кул бирде.* Н.Исәнбәт

МАЛБАГАР *и.* Мал багучы. *«Бераздан соң, кем әйтмешли, карьера усеше китте, мөстәкыйль рәвештә малбагар булып эшли башладым», – дип көлә шук телле Илдус Рәфгать улы.* Ютазы таңы

МА́Л БАГУЧЫ *и.* Терлекче, маллар үстерү, симертү белән шөгыльләнүче, аларга азык бирү, абзарларын чистарту кебек эшләрне башкаручы. *Мал багучымы, игенчеме, аларга хезмәт күрсәтүче сәүдәгәрме – барысының да максаты, мәнфәгате уртак ---.* Т.Әйди. *Мал багучы Гыйсьмине эшкә җиккәндә, җәйге базарга бәлки дә бер дигән товар булачак!* Ф.Яхин

МА́Л ВРАЧЫ *и.* Ветеринар. *Инженерлары, мал врачлары да җитәрлек. Яшь булсалар да, эшне әйбәт оештыралар.* Т.Әйди. *Үзем дә шул көннән башлап мал врачы булырга хыяллана башладым.* Мәдәни җомга

МАЛДАР *с. иск.* Бай, малы күп булган; мал җанлы. *Синең хуҗаң – малдар кеше, сездән күп сорарга да мөмкин, ләкин мин бу эшләрне савап өчен эшлим.* З.Бигиев

МА́Л ДОКТОРЫ *и. к.* **мал врачы**. *Андый чакта мин үзем дә, Наил дә, югары белемле мал докторы Хәбир Кәлимуллин дә кулга сәнәк яки көрәк алудан чирканмыйбыз.* Т.Әйди

МАЛИК *и. гар. иск.* Берәр әйбернең яки гомумән милекнең иясе, хуҗасы. *Ук җәядән атылып китсә, атучы аңа малик түгел.* К.Насыйри. *Әгәр миңа җырлар ярдәм итмәсә, туган телебезне сөймәк кеби бер олуг нигъмәткә малик була алыр идеммени?* Г.Тукай

МАЛИКИ *и. гар. дини* 1) Ислам динендә дүрт сөнни мәзһәбтән берсе. *Сөнниләр янә дүрт мәзһәбкә: хәнбәли, хәнәфи, шафигый, маликигә бүленә.* Ватаным Татарстан

2) Шул мәзһәбтән булган кеше. *Маликиләр дә намазларны күбрәк хәнәфиләргә ияреп укыйлар.* Ислам – татарлар һәм мөселманнар

МАЛИКИЛЕК *и. дини* Малики мәзһәбе. *Маликилекнең башка мәзһәбләрдән аермасы*

МА́ЛИЦА *и. ненец.* Төньякта яшәүче халыкларда: болан тиресеннән, йонын эчкә калдырып, башлыклы, бияләйле итеп тоташтан тегелгән тышкы кием

МАЛИЯ *и. гар. иск.* Финанс. *Бюроның малия ягында комиссия менә нинди фикергә килде.* Г.Исхакый

МА́Л ЙОРТЫ *и. к.* **мал өе**. *--- еласаң ела шунда дип, остабикәне өеннән мал йортына куып чыгаручыларның да берсе ул иде.* Ә.Баян

МАЛКАЙ *и.* **1.** Ат, сыер кебек хайван, аларны яратып атау сүзе. *Атын юырттырып, елга буена төште, малкайны эчерде.* М.Хәбибуллин. *Малкай, черки-кигәвен бимазалагандагы кебек тыпырчынып, баш бирмичә маташты.* М.Хәсәнов. *Малкай, чыннан да, сулга таба каерылды, үзе белән бер төпкә җигелгән юртакны да әйдәде.* З.Фәтхетдинов. *Бөтен ягыннан да бик өметле күренә. Бу малкайдан әле менә дигән шәп айгыр чыгачак.* Ф.Латыйфи

2. *ы. мәгъ.* Ат, сыер кебек хайванны яратып әйдәү яки куу сүзе. *На-а, малкай!.. Бераздан привал ясап алырбыз.* Ш.Рәкыйпов. *--- [Мәйсәрә] арба үрәчәсенә егетләрчә җиңел генә сикереп менеп утырды да: «На-а, малкай!..» – дип, атын юырттырып, ерак болынга таба китеп тә барды.* М.Хәсәнов. *– Эх, ат заводына җибәрәсе иде сезне, малкайлар, – дип уфтангалый иде. – Хәзер, малкаем, хәзер... Кояшка чыгарырмын үзеңне...* Казан утлары

МА́Л КАРАУЧЫ *и. к.* **мал багучы**. *Врачларны, мал караучыларны Казан врачлары белән Мәскәүдән килгән профессор кат-кат тикшерде ---.* А.Гыйләҗев. *Папау фермасындагы кызыл почмакны, Урәндәге терлекчеләр ашханәсен, мал караучыларның ял бүлмәләрен күреп, сокланмый мөмкин түгел.* Т.Әйди

МАЛКУАР *и.* 1) Эшкуар, бизнесмен. *Малкуарлар, эшкуарлар, кәсәбәчеләр пәйда булды.* Ә.Салах

2) *кимс.* Һәрнәрсәдән үзенә табыш, файда эзләп йөрүче; байлык артыннан куучы

МАЛКУРА *и. диал.* Мал ябу өчен тышкы абзар, киртә абзар; утар

МАЛЛЫ *с.* 1) Малга (*1 мәгъ.*) бай, малы күп булган. *Фермаң маллы булса, эшең җайлы булыр.* Н.Исәнбәт

2) Мул тормышлы, бай; малы (*2 мәгъ.*) күп булган; барлыклы, хәлле. *Берәү сөя маллыны, Берәү сөя данлыны. Асыл кеше сөя – бары Җаны гүзәл җанлыны.* Х.Туфан. *--- бу сандык, чынлап та, бик бай – акчалы һәм маллы булырга тиеш.* А.Хәлим. *Синең монда ничек килеп эләгүең, ничек яшәвең миңа караңгы. Әмма күрәм: яхшы ук дәрәҗәле, маллы, хәлле кеше булгансың.* Ф.Латыйфи

МАЛЛЫК *с.* **1.** Махсус малга (*1 мәгъ.*) дип әзерләнгән, малга билгеләнгән, мал өчен, малга җитәрлек

2. *и. мәгъ.* Мал (*1, 2 мәгъ.*) буларак файдалылык, әһәмиятлелек дәрәҗәсе. *Кәҗәнең маллыгы юк.* Мәкаль

◊ **Маллыктан чыгару** Бозу, товарлыгын алу, рәтен җибәрү, сатуга яки файдалануга яраксыз хәлгә китерү. *Печәнне мал итим дип, Халикъ чабар, маллыктан чыгарыйм дип, Малик чабар.* Мәкаль

МАЛ-МИЛЕК *җый. и. сир. к.* **мал-мөлкәт**. *Моңа кадәрге фетнәчеләрнең башына, әлеге дә баягы, мал-милек, ваемсызлык җитте.* М.Әмирханов

МАЛ-МӨЛКӘТ *җый. и.* Бер хуҗаның барлык төр милкеннән, хуҗалыгыннан, тормыш кирәк-яракларыннан һ.б.ш.дан торган байлыгы. *Гомер бакый җыйган мал-мөлкәтемне калдырсам да, берни кыра алмассың.* Ф.Хөсни. *Утар сугыш аркасында шактый бөлгән, таркалган, калдык-постык җирләр сатылып беткән, арендага таратылган, мал-мөлкәт җилгә очкан тузан ише генә калган.* Ә.Гаффар. *Шулай итеп, бай сәүдәгәр Кекин бабайның мал-мөлкәте, мирас буларак, әле дә халыкка хезмәт итә.* Л.Шагыйрьҗан

МАЛ-МӨЛКӘТЛЕ *с.* Матди яктан хәлле, мул, җитеш тормышлы, бай. *Мал-мөлкәтле кешеләрнең барысы да диярлек дачаларга сыздылар.* К.Нәҗми. *Син теләнчегә шундый мал-мөлкәтле хатын түгел, хәтта урамда теләнеп йөри торган убырлы карчык та чыкмаячак.* А.Шамов. *Шушы көнгә кадәр ни башлы-күзле, ни мал-мөлкәтле булганы юк.* Җ.Тәрҗеманов

МА́Л ӨЕ *и.* Җылытылган, кышын терлекне ябып тоту өчен яраклы абзар. *Мулла абзыйлар янында чәй эчте дә минем янга, мал өенә, йокларга керде.* Т.Гыйззәт. *Мал өенең җитәрлек ягылмавы --- аркасында күгәреп, бәсәреп беткән стеналарны, түшәм такталарын тараканнар, кырыгаяклар тәмам сарып алган иде.* З.Биишева

МАЛСЫЗ *с.* Материаль байлыгы, малы (*2 мәгъ.*) аз булган яки бөтенләй булмаган, юксыл. *Болай да малсыз, милексез калдырылган, таланган колхоз бөтенләй бетте.* Җ.Юнусов. *Без бөтенләй малсыз, җирсез – насыйп ризыклардан да мәхрүм калдык.* Ф.Мансуров

МАЛСЫЗЛЫК *и. сир.* Малга мохтаҗлык, мал җитмәү хәле; ярлылык, фәкыйрьлек. *[Солдатларны] илләрендә авыр тормыш, җирсезлек, малсызлык, төрле яктан җитешсезлек каршы алырга көтеп торгандай күренде.* М.Гафури

МАЛТАБАР *и. к.* **малкуар**. *Җирдә яшәп киткән шагыйрьләргә Шаһит булып күктә ай кала: Дәшми-тынмый һәм күзен дә йоммый, Һәрбер шигырь юлын күзәтә... Шагыйрь китабыннан көлә-көлә, Малтабарлар башын төзәтә...* Л.Шагыйрьҗан. *Баксаң, Казан сәүдәгәрләренең үз кануннары, кагыйдәләре, бөтен дөнья малтабарларыннан аерым үз берлекләре бар икән.* Ф.Латыйфи. *Хуш, рәхмәт малтабарларга, кулларыннан килгәч, акча янчыклары мөмкинлек биргәч, төзетсеннәр.* Мәдәни җомга

МАЛ-ТУАР *җый. и.* Авыл хуҗалыгында ит, май һ.б.ш.ны алу өчен үрчетелә торган йорт хайваннары, терлек. *Чәчүдән туктап тордылар. Мал-туар абзарлардан чыкмады. Кошлар тынды.* Ә.Гаффар. *--- нәрсәгә тотынма, шул җитми. Мал-туарга азыгым гына да юк, ичмасам.* Ш.Маннапов. *Бераздан, бер-бер артлы капкалар ачылып, урамга төркем-төркем мал-туар чыга башлады.* Р.Мөхәммәдиев

МАЛ-ТУАРЛЫ *с.* Мал-туары, терлеге булган; җитеш тормышлы. *Тәмам тынычланып өлгергән Иргали абый киләчәк турында, халыкны йортлы-җирле итеп кенә калмыйча, һәр гаиләне мал-туарлы итү өчен дәүләттән ярдәм соравы турында да --- сөйләп китте.* М.Хәсәнов

МАЛЧЫ *и.* 1) Мал караучы. *Колхозчыларның ел буена акча алганнары юк ---. Малчылар эш хакын мал белән ала ---.* З.Кадыйрова. *Әткәй, малчылар: «Метри дәдәң шикелле ветврач булырсың, мәктәпне тәмамлагач, шәһәргә укырга китәрсең, синдә өмет бар», – диеште.* Мәдәни җомга

2) Гомумән, мал асраган кеше. *Малчы мал карар, балчы бал карар.* Мәкаль

МАЛЧЫЛЫК *и. иск.* Терлекчелек. *Тематик яктан ырымнар байтак төркемнәргә бүленәләр. Шулар арасында иң борынгы мифологик карашлар белән нисбәтләләре, игенчелек, малчылык, умартачылык һ.б. белән бәйләнгәннәре бар.* Ф.Урманчеев. *Авылда яшәүче татарлар җир эшкәртүчәннәр, умартачылык һәм малчылык белән шөгыльләнгәннәр, комач тукыма сукканнар.* Эзләнүләр. Уйланулар. Табышлар

МА́ЛЬВА *и. бот.* Мальвачалар семьялыгыннан төньяк ярымшарда таралган, кайбер төрләре ашарга яраклы, терлек азыгы, дару һәм декоратив үлән буларак файдаланылган үсемлек; эт борчагы. *Талак зурайганда, 200 г мальва, 150 шәр г ромашка, солы һәм гади әремнән ванна ясыйлар.* Урман аптекасы

МА́ЛЬВАЧАЛАР *и. күпл. бот.* Киң таралган, күпчелек төрләре субтропикларда үсә торган үлән яки куак үсемлекләрнең 80 ыругын берләштергән үсемлекләр (мәс., *мамык, бамия, гибискус, мальва* һ.б.ш.) семьялыгы

МАЛЯР *и. нем.* 1) Төзелеш эшләреннән бина эчендәге шомарту, буяу, агарту кебек декоратив эшләрне башкаручы эшче. *Бер-ике атна үтүгә түбә ябыла, коммуникацияләр үткәрелә, штукатурлар, малярлар эшкә тотына.* Г.Тавлин. *– Тагын нәрсәләр кирәк? – диде Вафин, чыгырыннан чыга башлап. – Я инде, шунда барып малярлар белән ызгышып йөрү ник кирәк булды сиңа, ә?* М.Маликова

2) *сөйл. кимс.* Осталыгы җитмәгән башлаучы яки гомумән талантсыз рәссам. *[Вәсилә язучыга:] Сез малярлар ясап куйган тоташ бәхетне авыр аякларым белән ерып, ничә еллар буена мин аны эзләп йөрдем.* Ф.Хөсни

МАЛЯРИ́Я *и. ит.* Бизгәк плазмодияләре китереп чыгара, малярия озынборыны тарата, өшетү һәм анемия белән характерлана торган инвазив авыру. *Ул үзен балачагында малярия белән чирләп, бизгәк тоткандагы кебек хис итте.* З.Фәтхетдинов. *Малярия белән көрәшү өчен, бу балыкны [гуппиларны] XIX йөз ахырларында Европага китерделәр.* Кызыклы ихтиология. *Будра төнәтмәсен аппетитны ачу өчен, теш уртлары сызлаганда, подаградан, маляриядән кулланалар.* Урман аптекасы

МАЛЯРЛЫК *и.* Маляр эше, маляр һөнәре

МАМАЛЫ́ГА *и. рум.* Кукуруз онынан пешерелгән куе ботка, боламык. *Биредә кукуруз оны боламыгы – мамалыга, чучка итеннән шашлык, парланып пешкән форель һәм өй шартларында ясалган шәраблар һәм коньяклар белән сыйлыйлар икән.* Татарстан яшьләре

МАМЗЕЛЬ *и. сөйл.* 1) *Мадемуазель* сүзен кыскартып әйтүдән барлыкка килгән яшь хатын-кызга мөрәҗәгать итү сүзе. *Шәрифҗан атын туп-туры [буржуйкалар] өстенә борды: – Мадамнар, мамзельләр, юл бир!* И.Гази

2) *ирон.* Җилбәзәк хатын-кызга мөрәҗәгать итү яки аны атау сүзе. *Леонид Абрамович, мыскыл катыш елмаеп, Нюраның күзләренә карады: – Эшләр ничек, мамзель?* Р.Ильяс

МА́МОНТ *и. фин-у.* Филләр семьялыгыннан плейстоцен чорында Евразия һәм Төньяк Америкада яшәгән, климат үзгәрү һәм ау нәтиҗәсендә юкка чыккан, йонлы эре гәүдәле, озын казык тешле хайван. *Күтәрелә елга төпләреннән Эре сөякләре мамонтларның, Калыккандай чорлар төпкеленнән Сынмас рухы кыю халыкларның...* Х.Әюп. *Музей оештырып, борынгылык тәменнән исереп йөри иде [Н.Гамбәр]. Чабагачлар, булат кылычлар, хәситәләр, күкрәгенә патша сурәте төшкән самавырлар, мамонт тешләре – кыскасы, ни генә җыймаган!* М.Гали. *Җирдә кайчандыр яшәгән гигант кәлтәләр, мамонтлар һәм мастодонтлар турында без хәзер яхшы хәбәрдар икән, моның өчен беренче чиратта без Жорж Кювьега бурычлы.* Галәм. Җир. Кеше

МА́МОНТ АГАЧЫ *и.* Таксодиячәләр семьялыгыннан Төньяк Америкада үсә торган кыйммәтле үзагачлы мәңгеяшел ылыслы агач; гигант секвойя, веллингтония. *Менә бер бик биек, төп-төз, ботакларын түбән салындырып үскән агач янына туктадык. «Мамонт агачы» дип атала икән үзе...* Ә.Еники. *Иң зур үсемлек – «мамонт агачы»ның биеклеге 150 м, диаметры 12 м га җитә.* Дарвинизм нигезләре

МАМЫГАШАР *и. зоол.* Гадәттә кошларда тереклек итүче, ләкин имезүче хайваннарда да очрый торган канатсыз паразит бөҗәк; *русчасы:* **пухоед**

МАМЫК *и.* **1.** 1) Тырнакгөлчәләр (мальвачалар) семьялыгыннан тропикларда һәм субтропикларда үсә, кайбер төрләре техник культура буларак игелә торган куак яки үлән үсемлек; *русчасы*: **хлопчатник**. *Аларны [калий һәм фосфорны] туфракка керткәндә, бөртеклеләр, яшелчә, мамык уңышы бик нык арта.* Галәм. Җир. Кеше. *--- ашламалар башаклы ашлыкларда аксымны һәм бөртекнең натурасын (күләм авырлыгын) арттыралар, шикәр чөгендеренең шикәрлелеген, мамыкта һәм җитендә беренче сорт сүс чыгышын, бәрәңгедә крахмалны күбәйтәләр.* Күпьеллык үләннәр. *Мамык үсемлеге җылыны һәм суны ярата.* Дөньяда ниләр бар

2) Әлеге үсемлекнең орлыгын каплап торган, озынрагы җеп, тукымалар, трикотаж һ.б. җитештерү өчен, вагы химия сәнәгатендә кулланыла торган җепселләр, сүс; *русчасы*: **хлопок-сырец**. *Бары тик узган гасырның җитмешенче елларында гына Рус пароходчылык ширкәтенең суднолары Россиягә Һиндстан мамыгының беренче партиясен алып кайталар һәм шул ук судноларга Һиндстан өчен Россия товарларын төяп җибәрәләр.* М.Мәһдиев. *--- ул заманнарда кәгазь папирус, мамык, киндер шикелле кыйммәтле чималлардан ясалган, шунлыктан гади кешеләр китап, дәфтәр сатып ала, газета-журналлар укый алмаганнар.* Кызыклар дөньясында. *Чистартылган мамыкны зур-зур төргәкләргә төрәләр дә фабрикага озаталар. Анда мамыктан тукыма эшләнә.* Дөньяда ниләр бар

3) Җепселле үсемлекләрнең сүсеннән махсус эшкәртеп ясалган, медицинада, көнкүрештә кулланыла торган нәфис йомшак масса; *русчасы*: **вата**. *Аның [сфагнумның] дымны суыру сәләте гигроскопик мамыкныкыннан 4 тапкырга артып китә.* Урман аптекасы. *Яралы кызылармеецлар күп була. Ләкин мамык та, бинт та, йод та булмый.* Робинзон эзләреннән. *Табылдыкны саклык белән генә мамыкка төрәбез һәм бөтенебез шатланышып, чыр-чу килеп, өйгә чабабыз.* Дөньяда ниләр бар

4) Кайбер хайваннарда өске эре йон, кыл катламы астында була һәм җылылык саклау ролен үти торган бик йомшак, нәфис йон; *русчасы:* **пух**. *[Кызның] өстендә куян мамыгыннан калын итеп, күпертеп бәйләнгән, җылы һәм йомшак икәнлеге әллә кайдан күренеп торган ап-ак кофта иде.* М.Әмир. *[Ярминкә көннәрендә] хатын-кыз кәҗә мамыгыннан бәйләнгән шәлен, биш билле яңа сатин тышлы бишмәтен кия.* А.Расих. *Баланың башына ак кәҗә мамыгыннан бәйләнгән*

йомшак, йөнтәс башлык, өстенә бик зур ике кара төймә белән каптырылган кыска гына сырма кидерелгән ---. Н.Фәттах

5) Кошларның эре каурыйлары астындагы вак, нәфис, йомшак йон. *Һаваларда очкан аккошлардан Коела җиргә мамык тузаны. Туган илдә сөйгән дуслар белән Сизелми лә гомер узганы.* Җыр. *Күрше-күлән аны чәйгә йөртте, күчтәнәчләр китерделәр, Гайнелвафа аңа бер мендәрлек каз мамыгы бирде.* М.Мәһдиев. *[Тәвә кошының] Баш, муен һәм аякларында каурыйлары юк, алар бары тик кыска мамык белән генә капланган.* Биология. Хайваннар

6) Кайбер үләннәрнең һәм агачларның орлыкларында була, аларның җил белән таратылуын җиңеләйтә торган нәфис төкләр, җепселләр. *Тал мамыгын күтәрү дә авыр, мәхрүм калсаң туган нигезеңнән.* М.Галиев. *Очырды, мамык очырды Талларым, камышларым.* Ф.Гыйззәтуллина. *Яшьләр газетасындагы «Тупыл мамык очыра» хикәясенең төп герое – ялгыз яшәүче шәһәр кызы Зарифә.* М.Вәлиев

7) *күч.* Чиста, ап-ак яки яңа гына яуган йомшак кар. *Җир өстендә ак мамык.* Табышмак. *Таңнан башланган кар туктамады, яуды да яуды. Агачларның ботаклары яңа йомшак ак мамыкларга төренделәр.* Г.Ибраһимов. *Хәзер дә бер, эх, кайтасы килә! Әнә мамык түши юлларны... Кактырасы иде әнкәемнән Чәчләремә кунган ак карны...* Г.Гыйльманов

8) *күч.* Җылылык, йомшаклык, жанлылык, ягымлылык (тел, сөйләм, сүз һ.б.ш. тур.). *Җидееллыкны русча укып тәмамлаган язучылар, шагыйрьләр бар. Телнең мамыгын ник төймыйлар болар, ник тәрҗемә сыман яңгырый әсәрләре, дисәм, сәбәбе шул икән.* Ш.Галиев

2. 1) *с. мәгъ.* Махсус игелгән мамык (*1 мәгъ.*) үсемлегенең сүсеннән эрләнгән; шундый җептән тукылган, бәйләнгән. *Мамык җептән яки кургашынланган тимерчыбыктан 3–4 миллиметр зурлыкта тишекле итеп ясалган иләкләр яхшырак була.* Яшелчәчелек

2) Хайваннарның нәфис җылы йонынннан, мамыктан (*4 мәгъ.*) эрләнгән яки шундый җептән бәйләгән. *Оренбурдан мамык шәл алдым, Алтын тәңкә бирдем жәлләми.* Җыр. *Оренбур шәлләре мамык, Оренбур шәле дебет. Мәхәббәтем алда кебек – Өзелми әле өмет.* С.Хәким. *Бит алмалары комач кызыл, мамык шәл кырыйларына, сытылып чыккан чәч бөртекләренә мул булып кунган бәс кыйммәтле ташлар кебек җем-җем итә.* М.Хәсәнов

3) Кошларның вак нәфис йонын, мамыгын (*5 мәгъ.*) тутырып ясалган. *Мамык мендәрләргә төренеп, килен төшә бүген авылга.* Р.Миңнуллин. *Тәүлеккә якын поездда килеп, ял-фәлән күрмичә әлеге хәлләрне кичергәннән соң, авыр һавалы вокзалның каты эскәмиясе дә мамык ястык кебек тоелып, йоклап та киттеләр.* З.Фәйзи. *Баш астыңда мамык мендәр, Өстеңдә мамык юрган. Тыныч йокы теләп сиңа Бар дөнья тынган.* Э.Мөэминова

4) Мамык (*3 мәгъ.*) кебек йомшак яки мамык кебек ап-ак. *Һе, көнне әйтәм, әле генә чалт аяз иде, инде күктә мамык болытлар да купкан...* Э.Касыймов. *Тымызык кына мамык карлар яуган чакта, Ул тын гына, сабыр гына мине көтәр...* Р.Вәлиева. *Ул чактагы мамык карлар ап-ак һәм хуш исле иде.* Р.Низамиев

5) *күч.* Ягымлы, җылы, йомшак (мөгамәлә, холык, кеше тур.). *Тышы мамык, эче кабык икәнлеген белгәч кенә, Нәзирдән җаны бизә башлады...* Т.Әйди

МАМЫКБАШ *и. бот.* 1) Күрәнчәләр семьялыгыннан башлыча тундра һәм урман зонасында үсә торган, чәчәге, соңрак орлыклары тирәсендә шактый озын ак яки җирән төкчәләре булган күпьеллык үлән үсемлек; *русчасы*: **пушица**. *Пумаланы нинди дә булса оешма чәчәкле үсемлекнең яки мамыкбашның чәчәкләр төркеменнән бәйләп ясавы бер дә авыр түгел.* Робинзон эзләреннән. *Сазлыкта һәркайда тимгел-тимгел булып ак мамыкбаш үсемлеге күренә.* Дөньяда ниләр бар. *Мамыкбаш шуның белән үзенчәлекле: ул торфлы сазлык үсемлекләре арасында беренче булып чәчәк ата.* Татарстанның үсемлекләр һәм хайваннар дөньясы

2) Мамыкбашчалар семьялыгыннан, көньякта үскән кайбер төрләре сүс, техник май алу өчен игелә торган үлән үсемлек; карлыгач койрыгы; *русчасы:* **ластовень**. --- *дала мамыкбашы --- күбесенчә Кама аръягында очрый, ә дарулы мамыкбаш --- Татарстанның барлык төбәкләрендә дә үсә.* Агулы үсемлекләр

МАМЫКБА́ШЧАЛАР *и. күпл. бот.* Суккулентлар, сүс бирә торган, декоратив һ.б. 2000 төр үсемлекләрне берләштергән куак, ярымкуак яки үлән үсемлекләр семьялыгы. *Мамыкбашчалардан (ластовневые) дарулы мамыкбашта --- сөтсыман матдә составында винцетоксин ($C_{50}H_{82}O_{20}$) йөрәк гликозиды бар.* Агулы үсемлекләр

МАМЫК БЕТЕ *и. к.* **мамыгашар**

МАМЫК-ҖЕП *җыйд. и.* **1.** Киҗе-мамык. *Мамык-җеп нигезендәге лактукымаларның электрик ныклыгы 35–50 кВ/мм га тигез.* Авыл хуҗалыгы электригы белешмәсе. *«Чикләвекчә» – мамык-җеп производствосы калдыгы.* Яшелчәчелек

2. *с. мәгъ.* Кижеле

МАМЫКЛАНДЫРУ *ф.* Вак төкләрен, сүсен йомшартып, мамык хәленә китерү; мамыгын кабарту. *[Каты сүс бауны, таратып], мамыкландырганчы тетәбез.* Г.Гобәй

МАМЫКЛАНУ *ф.* 1) Мамык, йон үсү, мамык белән каплану (кошлар, кайбер хайваннар, үсемлекләр тур.). *Куяннар әрсезләнеп үрчеделәр, зурлары торган саен итләчләнә, мамыкланып һаман кабара бардылар.* М.Шабай. *Көзен исә кылган, мамыкланып, чал төскә керә, һәм дала кар белән капланган төсле тоела.* Казан утлары

2) Йомшару, бик йомшак, мамык сыман хәлгә килү. *Кабарып, мамыкланып торган ярым бөдрә чәчләре тегелә дә ачык, сөйкемле, гел көлемсерәүле йөзенә тагын да күркәмлек бирәләр иде.* З.Бәшири

3) Мамыкка (*2 – 4 мәгъ.*) буялу, мамык сару (кием тур.)

4) *күч.* Матди яктан аякка басу, хәлләнү, манту, җитешле тормыш белән яши башлау. *Икәүләп эшләп,*

мамыклана башлагач кына, [Мәрьям үлеп китте]. Ә.Еники

5) *күч. диал.* Җылы төшү, җылыну. *Мич җылы итеп ягылган, пирог исе чыккан, өй мамыклы (Казан артында өй җылынса – «мамыкланган», «мамык кергән» диләр) ---.* М.Мәһдиев

6) *күч.* Мөгамәләдә, кешенең үзен тотышында ягымлылык, йомшаклык барлыкка килү. *Ул, оныгын кочаклап, аркасыннан букчасын салдырды, үзе --- күз алдында үзгәреп китте, әллә ничек йомшакланды, мамыкланды, яхшыланды, күзләрендә тормышка өмет калыкты.* Р.Мирхәйдәров

Мамыклана башлау Мамыклануга табан үзгәрү. *Бер тәүлек эчендә кайсы ипи әчи, кайсы күгәреп чыга, кайсы мамыклана ук башлый.* Татарстан яшьләре

Мамыкланып бетү Бөтен җире мамыкка буялу, мамык сару

Мамыкланып тору Мамык беләнкапланган булу, мамыгы күренеп тору. *Бу тәбәнәк үсемлекнең башы мамыкланып, көмештәй ялтырап тора.* Дөньяда ниләр бар

МАМЫКЛЫ *с.* 1) Мамык (*4 мәгъ.*) бирә торган. *Әллә каян мамыклы кәзә алып кайткан булган. Мамыклы кәзә сыердан җакшы, дип сөйләп йөргән.* Т.Миңнуллин

2) Мамыкка (*1, 2 мәгъ.*) бай, мамык күп булган. *Мамыклы Төрекмәнстан*

3) Мамык (*2–4 мәгъ.*) тутырылган, эченә мамык салып сырылган һ.б. *Кулы юк – күлмәк кия, Кош түгел – мамыклы. Мамыгы эчтә, Кирәк була кичкә.* Табышмак

4) Мамык төкләре ябышкан, мамыкка буялган. *Өс-башы мамыклы*

5) Мамыкланып, кабарып торган. *Беренче булып төлке сайлый койрыкны: – Миңа менә шунысын, мамыклысын, йонлысын, – ди.* А.Алиш

6) Мамыгы (*6 мәгъ.*) булган. *Шушы җимеш-тартмачык дүрт якка ачылып китә, һәм аның эченнән мамыклы орлыклар очып чыгалар.* Робинзон эзләреннән

7) *диал. күч.* Җылы, матур, каралган, җыештырылган (торак тур.). *Беркөнне ишек ачып керүгә, борынга тәмле мич ризыгы исе килеп бәрелде, өй эче мамыклы-рәхәт җылы иде.* Р.Төхфәтуллин

8) *күч.* Тәнгә рәхәт бирә торган, җылы. *Хәле җиңелрәк чак булса, мөгаен, ул да, улы ясаган кечкенә урындыгын тышка алып чыгып, кояшның мамыклы җылысында иркәләнер иде.* С.Зыя

9) *күч.* Күңелгә хуш килә торган, ягымлы

МАМЫКСЫЗ *с.* 1) Мамыгы булмаган. *Ә директор – дөнья явызы! Мамыксыз торна!* М.Мәһдиев

2) *күч.* Шыксыз, салкын, каралмаган, ямьсез, күңелгә ятмый торган. *Ленар өйдән дә бер әйләнеп чыкты: өй эчендә хатын-кыз булмаган йортларга гына хас мич, кирпеч исе таралган, гөл яфраклары саргайган, мамыксыз, шыксыз иде.* М.Мәһдиев

3) *күч.* Кешеләр белән мөгамәләдә коры, кырыс холыклы

МАМЫ́КСЫМАН *с.* Мамыкка (*3, 5 мәгъ.*) охшаш, мамык кебек. *Тирәкнең мамыксыман төкчәләр белән капланган орлыкларын җил бик еракларгаочыртып алып китә.* Биология. *Күктә, биектә мамыксыман болыт кисәкләре күренә башлады.* Дөньяда ниләр бар. *Мукор ыругы гөмбәләре целлофан пакетларда озак сакланган икмәктә ак мамыксыман күгәрек барлыкка китереп үрчи башлый.* Татарстанның үсемлекләр һәм хайваннар дөньясы

МАМЫ́КТАЙ *с.* Йомшаклыгы, төсе һ.б.ш. белән мамыкка охшаган. *Әнә шундый ак мамыктай җиңел болытларның берсе янып тезелешеп кыр казлары очып бара...* М.Хәсәнов. *Тибрәнә җилләрдә Мамыктай чәчләре. Күзләрдә кургаштай авыр күз яшьләре...* Р.Вәлиева. *[Инҗирнең] Яфраклары түгәрәк, 3 – 7 канатлы, сирәк кенә бөтен читле, каты, кытыршы, аскы яктан соргылт, мамыктай йомшак, озын-озын юан саплы.* Урман аптекасы

МАМЫ́К ҮЛӘН(Е) *и. бот.* Кыяклылар семьялыгыннан себеркәч чәчәкле күпьеллык үлән үсемлек; *русчасы:* **бескильница**

МАМЫКЧЫ *и.* Мамыкчылык тармагында эшләүче кеше. *Таң атып, офыклар аллана, Мамыкчы басуга юл ала.* Ә.Синугыл-Куганаклы. *Бу – төсле мамык, аны совет мамыкчылары үстерде.* Дөньяда ниләр бар

МАМЫКЧЫЛЫК *и.* Авыл хуҗалыгының мамык үстерү белән шөгыльләнә торган тармагы. *Мишәр сәүдәгәрләре, --- тере куйлар җыеп, аларны көтү-көтү итеп, мамыкчылык белән көн күрә торган Фирганә тарафына җибәрәләр.* З.Бәшири

МАНАРА *и. гар.* 1) Мәчет түбәсендә яки аның янында гадәттә түгәрәк, дүрт яисә күпкырлы тар конус рәвешендә эшләнгән биек корылма. *Ике мәчет үзләренең яшел түбәләре һәм нечкә очлы манаралары белән Мәләвезнең зур авыл икәнлеген белдереп торалар.* А.Таһиров. *Күл ярыннан аз гына читтә, Өч кыз тавы алдында биек, кызыл гранит манара.* И.Салахов. *Алдыбызда мәчетләрнең Манарасы төште авып, Без, динсезләр, карап тордык, куркып түгел, ә кул чабып.* Ф.Гомәров

2) Чиркәү түбәсендә яки аның янында чаңнар элү өчен, гадәттә цилиндрик яки кырлы формада төзелгән тар биек корылма. *Ул [чиркәү] биш гөмбәзле, чаң манарасы гөмбәзләрдән калкурак.* Ә.Гаффар. *Күз алдына китерегез: иске таш корылма. Түбәсен кыңгырау манарасы очлый.* Ш.Әхмәдуллин

3) Гомумән шундый формадарак эшләнгән һәртөрле тар биек корылма; башня, вышка. *– Хезмәт кешесен, әйтик, шул ук нефтьчене, буровой манарасы янына бастырып полотнога төшерү әлләни авыр түгел, – ди Виктор Иванович, – тик ул «портрет» бирәуне дә дулкынландырмаячак.* Г.Ахунов. *Галиҗәнап ныгытмасына беренче бәреп кергән нугай полыгы тупчысы капка манарасы башыннан Бохара мәхәлләләренә, Регистан мәйданына күз ташлады ---.* Т.Әйди. *Сенажны манараларга тутырып саклау ысулын өйрәнеп җиткәнебез юк.* Казан утлары

МАНАРАЛЫ *с.* 1) Манарасы яки манаралары булган. *Касба – мөселман Көнчыгышының күп бизәкләрен үзенә туплаган район. Монда очлы манаралы мәчетләр, каһвәханәләр, вак товар сатучылар...* М.Мәһдиев. *Без ике манаралы мәчет каршында басып торабыз.*

М.Юныс. *Болгарлар борынгы крепостька яңадан җан өреп җибәрәләр, таштан дүрт манаралы мәчет торгызып куялар.* Ф.Хуҗин

2) Манаралап эшләнгән. *Болгаргача заманнарда ук калын-калын стеналы һәм манаралы хәрби ныгытмалар торгызыла.* Казан утлары

МАНГАЛ *и. гар.* Утлы күмер салып, шуның өстендә ризык кыздыру өчен кулланыла торган тимер савыт. *Әкрәм Галиевич, мангалны көйләп, шашлык кыздырган арада, Наталья Сергеевна верандада табын әзерләде.* Р.Мирхәйдәров. *Иртәнге сәгать алтыдан инде һәркайсы үз урынында: ит чабучылар ит түшкәләре янында, пешекчеләрнең бер ише мангалларына ут ягып җибәргән, кайнар күмер төшерергә ашыгалар...* Казан утлары

МА́НГО *и. малай. бот.* 1) Сумахчалар семьялыгыннан Көньяк Азия тропик урманнарында үсә торган, кайбер төрләренең сусыл җимешләре ашарга яраклы мәңгеяшел агач ыруы. *Андагы халыклар банан, кокос пальмасы, икмәк агачы, манго һәм авокадо җимешләре белән тукланалар.* Биология. *Манго агачының җимешләре бик тәмле булса да, чәчәкләренең исе, үсемлекнең сыекчасы һәм кабыгы бик күпләрдә көчле аллергия тудыра.* Агулы үсемлекләр

2) Шул агачның каты төшле, сары-гылт яшел яки кызыл төсле, хуш исле әчкелт эре җимеше

МА́НГОЛЬД *и. нем. бот.* Кайбер илләрдә яшелчә буларак яки декоратив максатлар белән үстерелә торган үсемлек; яфрак чөгендер. *Мангольд – яфрак чөгендер – юан, итләч сабаклы сусыл яфраклар үстерә, һәм шуларны ашамлык итеп файдаланалар.* Яшелчәчелек

МА́НГРЛАР *и. ингл. күпл. бот.* Тропикларның ләмле ярларында, су күтәрелү-чигенү зонасында үскән, күпчелеге ризофорлар семьялыгына караган, мәңгеяшел агач һәм куаклардан торган урман. *Ул [сикерүче ләм балыгы] су кайтканда (кимегәндә) коры җиргә әйләнә торган урында, мангр үсемлекләре арасында яшәргә ярата.* Кызыклы ихтиология

МАНГУСТ *и. португ. зоол.* Виверрачалар семьялыгыннан Африкада, Кече, Алгы һәм Көньяк Азиядә яшәүче, башлыча кимерүчеләр һәм елаННар белән туклана торган имезүче хайван. *--- мангуст белән кобраны сугыштырып күрсәтәләр. Мангустның, бичараның, авыз-борыны канап бетә...* М.Мәһдиев. *Күселәр һәм тычканнар өчен хәзер иң уңайлы яшәү урыны – кеше тораклары. Мангустлардан котылу өчен, алар идән асларына, чормаларга кереп тулалар.* Кызыклар дөньясында

МАНГЫТ *и. монг.* Чыңгыз хан яуларында катнашып, киң территориядә таралып, Урта Азия һәм Себердә яшәгән төрки халыкларның этник составына кушылып киткән монгол ыруы. *Туктамыш хан анда әйтте: – Һай син татар, һай татар, Мангыттан азган чал татар!* Дастан. *Диван бәге кул чабуга, алар каршында мангыт ыруының атаклы җырчысы Әсән пәйда булды.* Р.Зәйдулла

МАНДАЛИН *и. сөйл. к.* **мандолина**. *Җырлады, елады Мандалин кыллары... Шул көннән яңадан күрешеп булмады.* Р.Әхмәтҗан

МАНДАРИН I *и. фр. бот.* 1) Рутчалар семьялыгының цитрус ыругыннан тропик һәм субтропик районнарда үстерелә торган мәңгеяшел культуралы җимеш агачы. *Төз буйлы кипарислар белән чорналган әфлисун бакчалары, зәйтүн плантацияләре, җимешләре өлгереп килә торган йөзем, мандарин, лимон, анар, инҗир агачлары – болары Кипрның гүзәл табигате.* И.Иксанова. *Субтропик районнарда үсемлекләрне (мандарин, әфлисун, гранат, зәйтүн, әстерхан чикләвеген) ашарга яраклы җимешләре өчен үстерәләр.* Биология. *Ботаклардан алтынсыман җимешләр асылынып тора. Бу – мандарин урманы.* Дөньяда ниләр бар

2) Шул агачның шикәрләргә, С витаминына, лимон кислотасына бай, кабыгында эфир мае булган хуш исле татлы җимеше. *Шунда әлеге кызчык, килеп, сумкасыннан мандарин алып бирә.* Ш.Галиев. *Анда өрек, йөзем, мандарин һәм банан гына түгел, Кәшифә әбинең гомерендә бер генә дә күргәне, кулына тотып караганы да булмаган ананас, арахис һәм кивиларга кадәр бар иде.* З.Фәйзи

МАНДАРИН II *и. португ.* Борынгы Кытайда португаллар тарафыннан зур дәүләт чиновникларына бирелгән атама. *Диалектлардан иң зурысы булып Кытайдагы мандарин шивәсе санала.* Кызыклар дөньясында

МАНДАТ *и. лат.* 1) Күрсәтүченең билгеле хокуклары булуын яки берәр эшкә вәкаләтле булуын раслый торган таныклык. *Нинди генә җилләр иссә дә лә, Нинди генә еллар килсә дә, Бер гомерлек озын постта торам, Бер гомерлек мандат кесәдә.* Г.Афзал. *Измайлов --- бу адәмне бер адым чигенергә мәҗбүр итте дә чекист мандатын чыгарды.* З.Фәтхетдинов. *Сайлыйбыз: кем кемгә якын, Кемдә кемнәр кайгысы? Бер мандатка – күпме кеше, Яклар безне кайсысы?* И.Әширов

2) Вәкаләт, хокук, йөкләмә. *Имеш, тиздән зур сайлаулар була, Һәрбер балык, бака, ондатра Үзен кандидат дип күрсәтә ала, Җиңсә, кандидатлык мандаты.* Аманулла. *--- ул [мәкалә] Генераль прокуратура мандаты белән килгәннәргә генә кагылып калмыйча, партия, хокук саклау органнарында һәм башка югары урыннарда утыручыларның уй-фикерләрен аныклау өчен дә язылды ---.* Р.Мирхәйдәров. *БМО Куркынычсызлык Шурасы резолюциясе буенча, Гыйрактагы коалицион көчләр мандаты узган елның 31 декабрендә төгәлләнде.* Мәдәни җомга

МАНДАТЛЫ *с.* 1) Билгеле хокуклар бирә торган мандаты, вәкаләте булган. *Мандатлы делегат. Мандатлы территорияләр*

2) Алда килгән сүздә белдерелгән үзенчәлекле мандатка ия булган. *Метшин шәһәр Думасына сайлауларда партия исемлеге буенча да, бер мандатлы округ буенча да катнашып, һәр ике очракта да җиңде.* Татарстан

МАНДОЛИ́НА *и. ит.* XVII гасырда Италиядә барлыкка килгән, гадәттә дүрт пар кыллы, плектр белән чиертеп уйнала торган музыка коралы. *Миләүшә белән Вилдан туй сәяхәтенә*

чыктылар, хәзер берсе гитара, берсе мандолина чиертә торгандыр. Г.Әпсәләмов. *Чәйдән соң, Сәрвәр мандолинада уйнады.* А.Таһиров. *Әй син, иске мандолинам!.. Моннан күп еллар элек Чирткән идем кылларыңны, Көй чыгачагын белеп...* Л.Шагыйрьҗан

МАНДОЛИ́НАЧЫ *и. к.* Мандолинада уйнаучы музыкант. *Мандолиначылардан оештырылган кечкенә генә оркестрга да җитәкчелек иттем.* Ж.Фәйзи. *Мандолиначы Миңнулла, сукыр скрипкачы Ибенәмин, шулар уртасында зәңгәрсу-кара күзлек кигән гармунчы Заһидулла утыра.* Р.Низамиев. *Мандолиначы димәктән, шагыйрьләр Муса Җәлил, Хәсән Туфанны, хәтта композитор Җәүдәт Фәйзине дә мандолина чиртергә Бабич өйрәткән булган.* Мәдәни җомга

МАНДОЛИНЧЫ *и. сөйл. к.* **мандолиначы**. *Бу вакытта инде Исмәгыйль Һилалов зур осталыкка ирешкән атаклы мандолинчы булып таныла.* Ж.Фәйзи

МАНЕЖ *и. фр.* 1) Атка атланып йөрү, ат өстендә күнегүләр башкару өчен шартлары булган махсус мәйданчык яки бина. *Ташбай башкалар белән атлар тазартырга бара, ат өстендә йөри, манежда чаба иде.* Ә.Айдар

2) Цирк аренасы. *Тамашачылар кереп утыргач, тынычлангач, манежга, кап-кара костюм киеп, мин чыгам.* З.Фәтхетдинов. *Бер куплет шигырь язылуга, цирк манежындагы җәнлекләрне ымсындырган кебек, чикләвек алып, үз-үземне сыйлап куям.* М.Гали. *Дуров манежга үзенең бер дуңгызын яшелгә манып чыгарган.* М.Маликова

3) Ветеринария учреждениеләрендә авыру хайваннарны карау, ярдәм күрсәтү, дәвалау процедуралары үткәрү өчен махсус җиһазланган мәйданчык. *Рәхим ветеринария шифаханәсенә килеп җитте. Үз бүлмәсенә кереп, халатын киде һәм манежга чыкты.* А.Расих. *Амбулаториядә манеж, дәвалау процедуралары үткәрү бүлеге, аптека, дезинфекцияләү средстволары өчен склад була.* Татарстанда терлекчелек

МАНЕКЕН *и. голл.* 1) Кибетләрдә, витриналарда кием үрнәкләрен кигезеп кую, шулай итеп күрсәтү, реклама ясау өчен, кеше зурлыгында ясалган курчак. *--- Маратның одеколон сиптермәячәген белгәч, [мастер] аны бөтенләй онытты, манекен белән эш иткәндәй, сүзсез генә кырды, промкомбинат шофёры белән генә ара-тирә уен-көлке сөйләшкәләп алды.* М.Мәһдиев. *Наташа исә витринага куйган манекен янына тукталырга ярата.* М.Юныс. *Тузан суыртырга тиешле минитрактор пыр туздырып үтеп киткәндә, халык төркеме манекенга әверелеп кала...* К.Кәримов

2) Тегү эшендә киемне кигезеп кую, үлчәү, тарттыру һ.б.ш. өчен кеше гәүдәсенә охшатып ясалган калып, фигура

3) *махс.* Рәссамнар кешенең гәүдә торышын төрле хәлдә рәсемгә төшерү өчен файдаланган, кул-аяклары хәрәкәтләнә торган агач курчак

4) Гомумән, зурлыгы, авырлыгы, тыгызлыгы һ.б.ш. кеше гәүдәсенә охшатып эшләнгән, спорт, медицина, янгын сүндерү, милиция эшендә өйрәнү, төрле күнегүләр, экспериментлар ясаганда кулланыла торган курчак. *--- Камалов --- шәһәрнең угрозыск начальнигын бер читкә чакырып алды һәм спортзалда көрәшчеләр, самбистлар куллана торган манекеннар бармы икәнлеген белеште.* Р.Мирхәйдәров. *Мәсәлән, без самавырлар, приказчик манекены торган бүлмәдә сәүдәгәр Лисенков тормышы белән танышканнан соң, кинәт кенә скафандр, ложементлар урнаштырылган «ябык космос»ка килеп керәбез...* Идел

МАНЕКЕНЧЫ *и.* 1) Манекеннар ясаучы

2) Махсус оештырылган күргәзмәләрдә модалы кием киеп күрсәтүче кеше. *Аларның берсе – яшьрәге, озын буйлы, үгез муенлысы – ишек төбендә тора, калганнары, бер-берсен бүлдереп, көлешә-көлешә, стенадагы япон гейшалары, ымсындыргыч позадагы манекенчы кызлар төшерелгән япон календарен карый иде.* Р.Мирхәйдәров

МАНЕР *и. сөйл. к.* **манера**. *Сөйләм теленнән беркадәр аермалы булган бу күренешләрне халыкның җырны беркадәр шигъри музыкальлеккә күтәрү, аны әдәби стильләштерү манеры дип карарга кирәк.* Н.Исәнбәт. *Кем белә, бәлки, рус-украин солдатлары белән аралашкан татар солдаты, аларның нинди дә булса көен отып алып, туган якларына кайткач, аны үз «манерына» җырлый башлагандыр.* Ж.Фәйзи. *--- ул мине инглиз манеры белән хәзерләнгән иртәнге ашны ашатмыйча җибәрергә теләмәде һәм кабинетына алып кереп китте.* И.Тургенев

МАНЕ́РА *и. фр.* 1) Үз-үзеңне тоту рәвеше, үз-үзеңне тотудагы үзенчәлек, кыланыш, гадәт. *[Хөснетдин] ике-өч ел гына элек солдатта булган икән. Әле дә аның кайсыбер кыланышларында андагы манералар күренгәли.* Ш.Камал. *Мин бары тышкы манералар һәм ялтыравыклар белән кызыксынганмын.* М.Шабай. *Затлы нәселдән булсаң да, затлы манераларга өйрәнмәгән килеш, ничек итеп патша кызына өйләнмәкче буласың син, ә?* Р.Корбан

2) **манералар** *күпл.* Тәрбиялелек, әдәплелек, яхшы гадәтләр. *Манералары, киенү рәвеше, тышкы кыяфәте, йөреше аның башка «даирә» кешесе икәнен күрсәтәләр, мондыйлар өчен хәтта классификация дә юк, чөнки алар кешеләр дигән төркемгә керми, бик-бик сирәк очрый торган сирәк экземплярлардан санала.* Р.Мирхәйдәров. *«Әйбәт бул!» Бу – әдәп, манера саклауны аңлата.* Н.Измайлова

3) Билгеле кешегә генә хас булган берәр төрле үзенчәлек. *Профессорлар Толстой һәм Сыромятников сөйләү манералары белән генә түгел, тышкы кыяфәтләре белән дә башка укытучыларыбыздан аерылалар.* Ж.Фәйзи. *Беренчедән, Рәшит Баһапов җырларның үзенә, башкару манерасына килешеп торганнарын гына сайлап ала белә; икенчедән, кабатланмас башкаруы белән аны бары тик үзенеке генә итә ала.* Казан утлары

4) Бер авторга хас нюанслар, характерлы алымнар, иҗади үзенчәлекләр җыелмасы. *Журналның бөтен күтәренкеэстетик пафосы, әдәбият белән сәнгатьнең консолидациясенә омтылышы Г.Ибраһимовның шул еллардагы*

иҗат манерасына туры килә. М.Мәһдиев. *Шушы ике хикәя үк әдипнең [Г.Исхакыйның] әсәрләренең тематикасына һәм язылыш рәвешенә (өслүбенә, манерасына) бик игътибарлы булуын раслый, безнеңчә.* М.Хуҗин. *Әлеге җыентыклары белән ул [Л.Шагыйрьҗан] үзен романтик рухлы, нечкә күңелле, хатын-кызларга гына хас үз язу манерасы, шигъри йөзе булган талантлы каләм иясе итеп таныта.* Хәзерге татар әдәбияты

МАНЕ́РАЛЫ *с.* Тәрбияле, әдәпле, яхшы манераларга өйрәтелгән. *Мутин үзе дә зыялы алпавыт баласы, белемле, манералы кеше була.* Р.Батулла

МАНЁВР *и. лат.* 1) *хәрби* Сугышчан хәрәкәтләр барышында хәрби көчләрнең стратегик, оператив яки тактик максатларда оешкан төстә яңа юнәлешкә, районга күчүе. *Хәзер Днепрны кичеп, Жлобинга таба кузгалырга кирәк. Паника тудырырга! Манёвр ясый-ясый гел алга барырга!* Ш.Рәкыйпов. *Инде манёврга киткән батальоннар да күптән күренмәс булды, аяклар кайнар суга тыккан шикелле кызышты, бөтен тәннән пар күтәрелә башлады.* Р.Вәлиев

2) **манёврлар** *күпл.* Гаскәрнең яки флотның сугыш шартларына якынлаштырылган обстановкада тактик өйрәнүләре. *Капитан кая барырга икәнне яхшы белә: сугыш алды елларында шушы җирләрдә манёврларда катнашкан икән.* З.Зәйнуллин. *Дөрес, манёврлар уен кебек, ләкин алар – Зур җиңүгә бару юллары.* Һ.Такташ. *Манёвр сугышында фронт сызыгы йөгерек ат тизлеге белән үзгәртелгәнлектән, тирәяктан күзне алмыйча карап торабыз.* Ш.Усманов

3) *махс.* Тимер юл станциясендә, поездлар төзү өчен, вагоннарны юлдан юлга күчереп йөртү. *Ераста салмак төстә завод гүли, манёврда йөргән паровоз кычкырта.* Ш.Рәкыйпов. *Биек таш койма артында, тау-тау товарлар арасында, манёвр ясаучы паровозлар чабыша.* М.Юныс. *Шул манёвр аркасында ул 36 вагонны үз поездына һичбер зарарсыз китереп орындырган.* Кызыклы физика

4) Хәрәкәт юнәлешенең үзгәреше, курс алмашыну (корабль, самолёт һ.б. тур.). *Шунысы да күзгә ташланды: әйтерсең ул [лоцман] бу корабны берничә ел күзәткән, аның гадәтләрен, мөмкинлекләрен, манёвр ясау параметрларын – барысын да ныклап алдан өйрәнгән.* М.Юныс. *Кайсысы яхшырак: төшүне планлаштырып, шуның үтәлүе яхшыракмы, --- манёвр ясап карау яхшыракмы – монысын әйтүе кыен әле.* Галәмгә юл

5) *күч.* Оста хәрәкәт. *Зоология-анатомия белгечләре канатлар хәрәкәте механизмын, мускул двигателе механизмын һәм очучы умарта кортының манёвр ясавын тәэмин итә торган җиһазның детальләрен тулысы белән язып күрсәттеләр һәм аңа анализ ясадылар ---.* Урман аптекасы. *--- рульдәге кеше нигәдер бик сак кылана, хәтта машинасы ясаган шушы манёврга да ниндидер зур факт итеп карый, үзенчә борчылу-кайгырту күрсәтә иде.* Р.Мирхәйдәров

6) *күч.* Хәйлә; хәйләләү, алдау максаты белән кулланылган алым. *Искәндәрнең бу манёврын барысы да беләләр. Бу аның актив арасындагы оппортунизм җәясен тартып карау манёвры иде.* Ф. Сәйфи-Казанлы. *Ләкин сугышчан манёврны бөтен нечкәлекләренә кадәр алдан ук уйлап килгән шома егет --- кызга аңына килергә ирек бирмәгән.* М.Маликова. *Аннары җайлап манёврга күчтем: – Әти, дим, әти, авылга кайчан кайтабыз?* Д.Галимов

МАНЁВРЛАУ *ф.* Хәрәкәт юнәлешен үзгәртү, манёврлар (*4 мәгъ.*) ясау

МАНЁВРЧАН *с.* 1) Актив рәвештә манёврлар (*1 мәгъ.*) ясап алып барыла торган; *киресе:* **позицион**. *Манёврчан сугыш. Манёврчан оборона*

2) Хәрәкәт юнәлеше тиз генә, җиңел, гади ысуллар белән үзгәртелә ала торган; хәрәкәтчән. *Манёврчан танк*

МАНЁВРЧАНЛЫК *и.* Манёврчан булу үзлеге. *Техниканың манёврчанлык күрсәткечләре*

МАНЖЕТ *и. фр.* Күлмәк, куртка кебек киемнең җиң очы, җиң очы кайтармасы. *Ул зыялыдыр, беләмсез: мәгърифәт, хикмәт сата; Манжет алган ун тиенгә, биш тиенгә – ак яка.* Г.Тукай. *1903 елга таба ул, мәдрәсәдән тыштагы мәдәни мәҗлесләрдә катнашу өчен, костюм, ак яка, манжетлар, галстук, бант, штиблет булдыра ---.* И.Нуруллин. *Ак манжет, яка һәм галстук – болар [кадимчеләр] өчен кирәксез бер муенчак.* Р.Низамиев

МАНЖЕТЛЫ *с.* Манжеты булган. *Сүзне җитү чәчле, ак якалы, манжетлы яшь егеткә бирделәр.* А.Расих

МАНЗАРА *и. гар.* 1) Билгеле ноктадан күз алдында ачыла торган панорама, табигать күренеше, пейзаж. *--- Бәлки, син дә елыйсыңдыр читтә Охшаш манзаралар күзәтеп...* Ф.Гыйззәтуллина. *Урман аша чыгып, биек тау башына баскач та шундый манзара ачыла!* И.Иксанова. *Хәлим, үзен-үзе белештермичә, җәһәт кенә сикереп торды һәм... алдындагы сәер манзараны күреп, тәмам телсез калды...* Г.Гыйльманов

2) Берәр очрак, хәл, күренеш, вакыйга. *Капитан Курбатов --- сораулары тыңлап торучыларга «тыныч булыгыз, гомеремдә минем моннан да көчле томаннар күргәнем бар, моннан күпкә катлаулы манзараларга юлыкканым бар, озакламый яктылыкка чыгабыз» дигән юату булып яңгырый.* М.Юныс. *Су читендә калган туристлар да хәйран калып күзәтә иде бу манзараны.* Р.Мөхәммәдиев

3) Берәр эш-хәлнең, вакыйганың асылы, тулы картинасы. *--- кечерәк кысага утырту гына зур манзараның асылын үзгәртә алмас, дип ышанасы килә.* З.Фәтхетдинов. *Манзара тагын да аныклана төшсен өчен, Болгар иленең монгол яулары алдыннан нинди җирләрне үз эченә алуын искә төшереп китик.* Ф.Хуҗин

4) *иск.* Спектакльдә пәрдәнең чагыштырмача мөстәкыйль, логик яктан төгәлләнгән аерым бер кисәге, картинасы; гомумән, әсәрдәге бер эпизод, күренеш. *Үзенең укыган нәрсәләрен уйларга, үзенең театрларда күргән манзараларын күз алдына китерергә тотынды, анда да искитәрлек бернәрсә дә таба алмады.* Г.Исхакый. *Төп персонажларның берсе --- вагоннан*

сикереп гомерен чикли. Шәхси мин үзем, әлеге манзараны уйлап, авторның гомумиләштерү көчен күрәм. Б.Камалов

МАНЗАРА́ КЫЛУ *ф.* Карап тору, күзәтү. *Ф.Гыйззәтуллина дөньяны энә күзе аша күзәтсә, Хәниф Хөснуллин аны теодолит күзләре белән манзара кыла.* Р.Вәлиев

МАНИАКАЛЬ *с. псих.* Мания дәрәҗәсендәге, мания билгеләре булган. *Хөрмәтле доктор! Сезнең «Мин һәм без» дигән китабыгызны укыганда, үземдә маниакаль психоз һәм өч өндәү билгесе дәрәҗәсендәге шизофрения барлыгын белдем.* В.Леви

МАНИГЪ *и. гар. иск.* Киртә, кыенлык, каршылык, тоткарлык, комачау. *Вакытында үз фикерләремне язарга әллә нинди манигълар булды.* Г.Тукай. *Хыялның чәчәкләнүенә манигъ булганга, аны сүндердем.* Г.Ибраһимов. *Юлдагы манигъларны тибеп аударырмый торып, теләккә ирешеп булмый.* М.Фәйзи

МАНИГЪСЫЗ *с. иск.* **1.** Тоткарлыксыз, каршылыксыз

2. *рәв. мәгъ.* Тоткарлыксыз рәвештә, бернигә карамастан. *Тәмам 20 нче октябрь көне җиткәнче, --- шушы хаксызлыкларның булганына вә һичбер манигъсыз вакыйг булачагына канәгать итеп вә бөтенләй ышанып тордым.* Г.Тукай

МАНИКЮР *и. фр.* 1) Кулларга махсус ванналар, массажлар ясау, кремнар сөртү, тырнакларны чистарту, шомарту, лак белән буяу һ.б.ш. процедуралар. *--- [кыз] кечкенә сумкасыннан тегүчеләр үлчәве белән маникюр кайчысын чыгарды.* Ж.Фәйзи. *Чүпли башласаң [тигәнәкне], бармак битләрен калдырмый инде бу, маникюрны ды бозып бетерер.* Р.Төхфәтуллин. *Чәчтараш-ханәдән кайтып тормады, матурлык салоннарында маникюр, педикюр ясаты ---.* Сөембикә

2) Тырнакларны буяу, матурлау, ялтырату, озайту һ.б.ш. өчен кулланыла торган материалларның гомуми исеме. *Гадәттәгедән озын куллар һәм бармаклар... Маникюр каплаган тырнаклары ул бармакларны тагы да озынайта иде төсле.* Ә.Гадел

МАНИКЮРЛА́У *ф.* Тырнакларны махсус чистарту һәм маникюр (*2 мәгъ.*) белән каплау. *[Кыз] тырнакларын бик оста маникюрлаган, килешле ак халат кигән.* А.Шамов

МАНИКЮРЛЫ *с.* 1) Маникюр (*1 мәгъ.*) ясалган. *Аның булганлыгына, чибәрлегенә сокланып торам. Тырнаклары да маникюрлы икән.* Ж.Фәйзи. *Рәмзия ханым өстәлдән күз явын алырлык китапны күтәрде, маникюрлы нәфис бармаклары белән актара-актара, әле бер, әле икенче сурәтне аңлатырга кереште ---.* Ф.Баттал

2) Маникюр (*2 мәгъ.*) белән капланган. *Аның пешкән чия төсендәге маникюрлы бармаклары пыяла савыттагы йолдызларга кушылып китте.* М.Вәлиев

МАНИКЮРЧЫ *и.* Маникюр (*1 мәгъ.*) ясаучы белгеч

МАНИКЮ́РША *и. сөйл. к.* **маникюрчы**. *Әнисәнең унынчыны бетергәч ике ел колхозда эшләп, куллары бирчәеп беткән иде, маникюрша, аның тырнакларын бизәгәндә, шактый озак маташты.* М.Мәһдиев

МАНИ́ЛОВЧЫЛЫК *и.* Җәмгыять өчен файдалы, реаль эшләр эшләмичә, тормышка ашмаслык проектлар кору, коры хыялга бирелү күренеше

МАНИОК *и. тупи бот.* Сөтлегәннәр семьялыгыннан Америка тропикларында таралган, ашарга яраклы кассава төре бүлбеләреннән он, ярма алу өчен игелә торган үлән яки куак үсемлек

МАНИПУЛЯ́ТОР *и. фр.* 1) Кулындагы төрле гади әйберләр белән оста манипуляция ясаучы цирк артисты, фокусчы, иллюзионист

2) *махс.* Авыр яки куркыныч шартларда кешене алмаштыру өчен файдаланыла, оператор идарәсе белән яки автомат рәвештә программалаштырылган хәрәкәтләрне үти торган механизм. *Ул [астроном] безне чолгап алган миллиардларча яктырткычлардан бер дистәдән дә кимрәк объектларга гына космик аппаратларның манипуляторлары белән орына һәм телекамера «күзләре» аша күзәтә ала.* Галәм. Җир. Кеше

3) Аферист, хәйлә остасы

МАНИПУЛЯ́ЦИЯ *и. лат.* 1) Катлаулы эш эшләгәндә, кул белән ясалган хәрәкәт, кул эшендә катлаулы алым

2) Оста алдау алымы, махинация, хәйлә. *Кызганычка каршы, күп кенә авторлар макро- һәм микроэтнонимнар белән манипуляция ясарга биреләләр, һәм күп кенә буталчыклар, хаталану һәм саташулар шулардан килеп чыга.* Ә.Кәримуллин

МАНИФЕСТ *и. лат.* 1) Дәүләт җитәкчесенең яки югары власть органының гадәттән тыш әһәмиятле вакыйга уңаеннан халыкка мөрәҗәгать итеп чыгарган акты. *Забастовка, митинг, демонстрацияләр ешая. 17 октябрь манифесты да бу дулкынны туктата алмый.* И.Нуруллин. *--- патша манифестыннан соң (анда вәҗдан иреге турында маддә була) яңа керәшеннәр күпләп-күпләп ислам диненә кайта башлыйлар.* Р.Зәйдулла. *Падишаһ хәзрәтләренең манифесты илә иреккә җибәрелүенә карамый, үз артыннан һәр көн эзәрлеклә йөргәннәрен күргәч, [Г.Исхакый] Казаннан китәргә мәҗбүр булган.* Вакыт

2) Сәяси партиянең яки иҗтимагый оешманың эшчәнлегендә йөз тоткан юнәлеше, торган платформасы, төп принциплары һ.б.ш. турындагы мөрәҗәгате, декларациясе, программ документы. *Коммунистлар партиясе манифесты*

3) Әдәбиятта, сәнгатьтә берәр юнәлешнең, язучылар яки рәссамнар төркеменең иҗат принципларын чагылдырган, аларны аңлаткан белдерүе, игъланы; шул юнәлешнең үрнәге булып исәпләнерлек әсәр. *Шигырь бәйрәмнәрендә колачын җәеп, яшьләрнең җан манифесты булырлык романтик шигырьләрен мәйдан өстенә очырды [Р.Гаташ].* Н.Хисамов

МАНИФЕСТАНТ *и. кит.* Манифестациядә катнаша торган кеше. *Ул арада урамны буып алган манифестантлар тагы да катырак кычкырырга, сызгырырга тотындылар.* А.Расих

МАНИФЕСТА́ЦИЯ *и. лат.* Билгеле таләпләрне хуплап, теләктәшлек яки протест белдереп үткәрелә торган ачык, күпсанлы халык катнашындагы

чыгыш, демонстрация. *Берничә кеше сөйләгәч, «Интернационал» җырланып, манифестация тарала башлады.* М.Гафури. *Ә бу юлы без шәһәр читенә манифестациягә барыр өчен җыелдык.* Ж.Фәйзи

МАНИФОЛЬД *и. ингл. тех.* Нефть яки газ табуда файдаланыла торган, бер нигезгә үзенчәлекле итеп беркетелгән берничә үткәргеч торбадан гыйбарәт җайланма. *Мастерларның да еш әйтә торган «күрсәтмәләре» шуңа кайтып кала: манифольдны туңдырмагыз, насосны еш эшләтегез!* Ә.Салах

МА́НИЯ *и. гр.* 1) Психиканың күтәренке кәеф, артык хәрәкәтчәнлек, күп сүзлелек белән характерланган авыру халәте. *Әхмәтнең рухында яңадан бер маниягә юл ачылган иде: ул [үзен] үтерүләреннән курка башлаган иде.* Г.Газиз

2) *күч.* Гадәттән тыш көчле омтылу, теләк. *Хакимияткә менгән кешеләр арасында сату-сатылу, ялагайлык – гадәти хәл. Шул юл белән алар үзләренә байлык туплый, шөһрәт казана. Шуннан үзләрендә бөеклек, хакимдарлык маниясе башлана.* З.Фәйзи

3) *күч.* Берәр шөгыль белән артык мавыгу, нәрсәгә дә булса чиктән тыш һәвәслек, бирелгәнлек

МАНКОРТ *и.* 1) Ч.Айтматовның «Бер көн – бер гомер» романында китерелгән, үз әнисен танымаган легенда герое. *Халык үзенең тамырыннан, тарихыннан, әдәп-әхлак, тәрбия эшенең нигезе булган әдәбияттан аерыла. --- Чыңгыз Айтматов әйткән манкортка әверелә.* Т.Галиуллин

2) *күч.* Телен, динен онытканы, милләтен санламаган, бары үз мәнфәгатьләре өчен генә яши торган кеше. *Милли манкортларга көн юк «Идегәй»ләр кайтканда!* Р.Фәйзуллин. *Бетәсе түгел шымчың да, зобани вә манкортларың, Төшләргә кереп алалар рәкетирларың котларым.* Ә.Синугыл-Куганаклы. *Манкортларга Әйләндекме әллә инде без? – Төбәбрәк бер карагыз әле Көзгеләргә, Булса көзгегез!..* Х.Әюп

МАНКОРТЛАНУ *ф. к.* **манкортлашу**. *Айлы манаралар елап ауды, Сыкрап сүнде иман нурлары, Ана телен «белмес» дәрәҗәдә Манкортланды милләт уллары.* Атнабай

МАНКОРТЛАШТЫРУ *ф.* Мәҗбүри рәвештә үз милләтеннән биздерү, милләтен онытты ру. *--- хутор булып яшәү Балтыйк буе республикаларының кешеләрен колхозлаштырып манкортлаштырудан коткарып калды.* М.Юныс

МАНКОРТЛАШУ *ф.* Миллилекне, гомумән, милләтне оныту, манкортка әйләнү. *Гасырлардан җәрәхәтле минем дә, Милләт, тәнем, Манкортлашкан милләттәшнең кайсына бирим телем?!* Ә.Синугыл-Куганаклы

МАНКОРТЛЫК *и.* Үз милләтен танымау, санламауга корылган карашлар һәм яшәү рәвеше, милләтсезлек. *--- милли мәктәпләр саны артмый. Моңа халыкта таралган милли нигилизм, манкортлык – төп сәбәп.* Р.Ягъфәров

МАНМА *с.* **1.** Нык чыланган, юеш. *Балаклары чыктан манма булган чалбарымны ботакка элеп, инде урынга авам дигәндә генә, кулыма сабаклы җиләк бәйләме тиеп китә.* М.Галиев. *Өсте манма булган, битендә тамчылар ялтыраган Бикташны күреп елмайды [Әхсән].* М.Маликова

2. *рәв. мәгъ.* Юп-юеш булганчы, суга манган кебек. *Репетиция вакытында балет артистларының кулларындагы сөлгеләр манма чыланган була.* М.Маликова. *Тагын шулай манма чыланып, андый ташу сулары аша берничә тапкыр чыгарга туры килде.* М.Хафизов

◊ **Манма су** Бик нык, суга тыгып алган кебек юешләнгән, чыланган. *Көн саен явып, бөтен киемнәрне манма суга әйләндергән яңгыр кичкә таба туктады.* Казан утлары. *Садыйкка бу ышыклыкта хәл җыярга да мөмкин үзе. Аның өсте манма су, тешләре тешкә бәрелә.* Ш.Рәкыйпов. *Чокырдан көчкә чыгып, өс-башымны капшадым – манма су.* Г.Тавлин. **Манма су булу** Бик нык, суга тыгып алган кебек юешләнү, чылану. *Манма су булган киемнәрне киптерергә мунча ягып җибәрдек.* А.Хәсәнов. *--- [Билал] барыбер манма су булды, тик моңа тамчы да уфтанмады, чөнки барыбер көне җылы, матур иде!* М.Вәлиев. *Ул да манма су булды. Теше тешкә тими.* С.Поварисов. **Манма суга бату** *к.* **манма су булу**. *Уянганда, Зыя манма суга баткан, ... йөрәге бөтен тәнен дерелдәтә иде.* Г.Ибраһимов. *[Җәүһәрия белән Харис] Икәүләшеп егылдылар, манма суга баттылар*. М.Маликова. **Манма суга төшү** *к.* **манма су булу**. *Яңгыр астында манма суга төшкән ана, аяк астындагы пычракны да абайламыйча, кызының тавышы килгән якка йөгерде.* Г.Тавлин. **Манма тир булу** Бик каты тирләү. *Йөгереп, манма тир булганнар иде, хәзер менә тән буйлап салкын тәпиле бөҗәкләр чабыша башлады, аннары тешләр тешкә тиеп калтыратырга ук тотынды.* Р.Вәлиев. **Манма тиргә бату** *к.* **манма тир булу**. *Без манма тиргә батып чәйләп утырган арада, эңгер-меңгер булып куя.* А.Хәсәнов. *[Сәфәргали] манма тиргә баткан айгырда, тарантас түренә кырын ята биреп, авыз эченнән нидер җырлагандай итеп кайтып [керде].* Ф.Хөсни. *Үзе манма тиргә баткан, тәненнән кайнар пар бөркелә [пошиныңа].* Р.Мөхәммәдиев. *Шулай манма тиргә батып, саташып уянып китте ул.* Г.Гыйльманов. **Манма тиргә төшү** *к.* **манма тир булу**. *Бер җирдән икенче җиргә атылып йөргән Степан инде үзе дә манма тиргә төшкән.* М.Шабай. *Аның аяклары көчкә сөйрәлде, алҗудан күз алдында утлы бөҗралар биеде, манма тиргә төште.* Г.Тавлин

МАНМАЛЫ *с. диал.* Берәр төскә манылган яки нәрсә дә булса (мәс., алтын, көмеш) йөгертелгән. *Чәч кенәләремнең көдрәсенә Манмалы тәңкәләр үрермен. Минем җан гынаем тынмаса, Җиңгәкәем, синнән күрермен.* Җыр

МА́ННА *и. яһүд* 1) Леканорчалар семьялыгыннан Урта диңгез буйларының коры районнарында үсә торган, формасы белән вак ярманы хәтерләткән һәм җил белән бик җиңел күчереп йөртелә торган лишайниклар төре

2) Кайбер үсемлекләрнең (мәс., тамариск, корычагачның кайбер төрләреннән) саркып чыккан һәм катып калган суты

МАННЫЙ *и. рус* **1.** Бодай бөртегенең үзәгеннән генә ясала һәм туклыклылыгы ягыннан иң кыйммәтле санала торган, сөт төсендәге бик вак бөртекле ярма. --- *бүлектә беркем дә ашый алмый иде, уйлап карагыз инде: салкын манный, аны Нью-Йорктагы махсус компаниядән сатып алалар әле, кайчан ясалганын беркем дә белми.* Н.Измайлова. *Иртән бакчада манный боткасы бирделәр.* Ш.Галиев. *Ул, баласын итәгенә алып, манный боткасы ашата башлады* ---. Р.Зәйдулла

2. *с. мәгъ.* Шундый ярмадан әзерләнгән. *Балага манный ботка пешергән идем, шуны ашатып алыйм әле.* Т.Гыйззәт

МАНО́МЕТР *и. гр.* Сыеклыкларның яки газның басымын үлчәү өчен махсус прибор. --- *көчәнә торгач, пар басымын тиешле атмосферага күтәрдем. Манометр угы кызыл сызыкка җиткәч, көчкә сөйрәлеп, ком тартмасы янына килдем.* М.Юныс. *Двигательнең һәм электр җиһазларының эше турында манометр, термометр, амперметр, ягулыкның күләмен күрсәткеч мәгълүмат бирә.* Тракторлар һәм автомобильләр. – *Профессор, – дип куркынып кычкырып җибәрә Самохвалов кинәт кенә, – минем кислород баллонымда басым кими! Манометрга карагыз әле.* Күзгә күренми торган матдәләр турында хикәяләр

МАНОМЕ́ТРИК *с.* Манометр ярдәмендә башкарыла торган. *Манометрик үлчәү*

МАНПАСИ *и. сөйл. к.* **монпансье**. *Бер бау криндел, манпаси, өч йөз грамм мәк хәлвәсе, ярты кило кара җимеш сатып алдылар – күчтәнәчләре шуннан артмады.* А.Гыйләҗев

МАНСА́РДА *и. фр.* Француз архитекторы фамилиясе белән аталган, чарлакта авыш түбәле итеп эшләнгән торак бүлмә. *Ул, ялгыз үзе генә, Арча кырындагы бер мансардада тора иде.* А.Расих

МА́НСИ *и.* Угро-фин телләре группасыннан Ханты-Манси автоном округында яшәүче халык һәм шул халыкның бер кешесе. *Уб елгасы буйлап ирле-хатынлы мансилар бара икән.* Т.Әйди. *Биредә, Конда елгасы буендагы аланда, әүвәл җиде-сигез йортлы гына манси авылы була.* Ф.Мансуров. --- *бу каберлектә X гасыр ахырында ерак Урал якларыннан Кама елгасы буйлап күчеп килгән угор телле халыкларның бер вәкиле күмелгән (угор телле халыкларга хантлар, мансилар һәм венгр-мажарлар керә).* Ф.Хуҗин

МА́НТА *и. лат. зоол.* Скатлар отрядына караган, киң яссы гәүдәле, ачык океан киңлекләрендә яши торган эре диңгез балыгы. *Отрядның иң эре вәкиле – киң шайтаннар семьялыгына кергән манта, аның массасы 2,5 тонна чамасы.* Биология. Хайваннар

МАНТИ́ЛЬЯ *и. исп.* < *лат.* 1) Испан хатын-кызлары кия торган, башны һәм арканы капларлык озынлыктагы ак, кара яки кызыл төсле челтәр япма. *Серенада җырлаучы егетләр, мантилья салган кызлар, кызыллы-каралы плащлар кигән тореадорлар причалда юк иде.* М.Мәһдиев

2) Җиңсез кыска япма рәвешендәге хатын-кыз өс киеме

МА́НТИЯ *и. гр.* 1) Патшалар, чиркәү әһелләре, кайбер илләрдә судья, адвокат, академия яки гыйльми җәмгыять әгъзасы кебекләр кия торган киң озын плащ сыман тантаналы кием. *[Профессорларның] Башларында киң читле кәләпүш сыман кара атлас ермолка. Өсләрендә озын итәкле, киң җиңле кара мантия.* Ж.Фәйзи. *Беренчеләре, имән кафедра артындагы чем кара мантиягә төренгән мацитайска ияреп, Лютерның катехизисларын укый.* Ж.Тәрҗеманов. *Ат өстенә сенатор мантиясе ябып, ул [Калигула] аны сенатка алып килгән, һәм тегесе Римның атаклы патрицийлары белән бергә яңа законнарны «тикшергән».* Кызыклар дөньясында

2) *зоол.* Кайбер умырткасыз хайваннарда: моллюскларның h.б.ш.да бөтен гәүдәсен яки бер әгъзасын каплаган тире катлавы, ябынча. *Моллюскларның характерлы органнары – мантия һәм аяк.* Зоология. *Су өстенә күтәрелеп, әкәм-төкәм тәненең ян-ягында урнашкан сулыш тишемен ача һәм стенкалары мантиядән ясалган киң үпкә куышлыгына һава ала.* Татарстанның үсемлекләр һәм хайваннар дөньясы. *Кабырчык матдәсен тиренең арка җыерчыгыннан ясалган мантия күзәнәкләре бүлеп чыгара.* Биология

3) *геол.* Җир шары күләменең 83 % ын алып торган, Җир кабыгы һәм Җирнең төше арасында урнашкан катлау. --- *вакытлар үтү белән, бу таулар да акрынлап таркалган, җир тәненә, мантиягә бата барган.* Кызыклар дөньясында. *Кабык астында мантия – Җирнең бик тыгыз һәм нык кызган өлеше урнашкан.* Галәм. Җир. Кеше. *Чагыштырмача күптән түгел генә Җир кабыгы һәм аның астындагы мантиянең иң өстәге каты катламы тоташ түгел, ә аерым кисәкләрдән торганлыгы билгеле булды.* Табигать белеме

МАНТО *и. лат.* Иркен, гадәттә мех, хатын-кыз пальтосы. *Секретарь исә мантосын бик саклык белән генә, эч ягын әйләндереп элеп куйганнан соң, вак-вак кына атлап, директор кабинетына кереп китте.* М.Хәсәнов. *Әйтергә кирәк, кеш тиресеннән хатын-кыз туннары һәм мантоларын бик сирәк тегәләр. Җитмәсә, җиңгән дә назланыбрак тора соңгы вакытта. Манто сорады* ---. Ф.Баттал. *Мин саксон фарфорлары белән ас мехыннан тегелгән манто кебек әйберләргә алданучы арзанлы мещанка түгел.* Ш.Хөсәенов

МАНТУ I *ф. сөйл.* 1) Физик яктан сәламәтләнү, савыгу, тазару, рәтләнү, хәлләнү. *Ил, мантырга теләмәсә, халкыннан дошман эзләр.* Р.Фәйзуллин. *Имәннәр суыктан шартлап ярылды, яз буе мантый алмыйча, җәй башында гына яфрак ярдылар.* К.Тәхау. *Гөлүсә үзенең әтисен белми. Сугышта алган яраларыннан мантый алмыйча, ул бишектә вакытта ук үлеп киткән.* Г.Сабитов

2) Тиенү, үзеңдә булдыру, җиткерү. *Әүвәл заманнарда шикәргә, чәйгә мантымый газап чиктеләр.* Р.Мөхәммәдиев

3) Яңа урынын ошату, яраклашу, әйбәт кенә үрчеп китү. *Мәләкәстән кайткан бу асыл сөяк сыерның нәселе, ни хикмәттер, безнең Яу тирмәдә мантый алмый, икенче, өченче буыннан ук*

акрынлап ваклана башлый. Ә.Еники. *Саксавыл нинди әрсез агач инде югыйсә, ул булып ул да рәтләп мантый алмый Мангышлакның өстәл кебек тигез күкрәгендә.* Г.Тавлин. *Суер беткәч, төклетура үрчи башлады. Ә төклетура бал кортын ашый. Суер булмагач, умарта асравы кыенлашты. Корт мантымый.* М.Юныс

4) Эш, тормыш уңай якка үзгәрү; уңу, оту, уңышка ирешү. *Ашыккан кыз кияүгә барса да мантымас.* Мәкаль. *Моңарчы әле Шәйморат абзагыз белән дошман булып берәүнең дә мантыганы юк.* Р.Төхфәтуллин. *Хәзер зимагур Хәйдәр кызганыч бер бәндә иде аның өчен. Бичара, шәһәр арты шәһәр алыштырып та әллә ни мантымаган икән.* Идел

5) Матди яктан хәлләнү, аякка басу, баеп китү. *Һич мантымады кесәләр, Тулып тормады бер дә; Шунда кереп уйнамаса, Урын беткәндер җилгә!* Х.Әюп. *Тулай торакгагы бөтен буш шешәләрне миңа калдыралар.* --- *Ләкин аның белән генә мантып буламыни?* М.Маликова. --- *ниндидер яңа юридик затлар оешып, салым органнарында теркәлгәннән соң, үз эшчәнлекләрен башлап җибәрә, ә кайсылары, мантый алмыйча, банкротлыкка чыга, ягъни тарала.* Мәдәни җомга

Мантып китү Билгеле бер моменттан алып хәлләнә, байый башлау. *Аннан соң кинәт мантып китте, хәзер кызымның буе җитәрлек түгел инде...* М.Маликова

МАНТУ II *и. мед.* Тире астына туберкулин кертеп, кешедә туберкулёз авыруы булу-булмавын тикшерү

МАНТЫЙ *и. кыт.* Токмач камырына охшаш камыр эченә ит һәм суган (кайвакытта бәрәңге) салып әзерләнә һәм парда пешерелә торган ризык. --- *быел да бәрәңге пәрәмәче ашарга кайтмассың, ахрысы. Әллә чиннарның мантыйсы татар пәрәмәченнән тәмлерәкме?* Г.Бәширов. *Биш минут та үтмәде, Мәүлидә мантый салынган кечкенә табак алып керде.* Р.Мирхәйдәров

МАНТЫЙК *и. гар.* 1) Логика; дәлилләү һәм инкяр итү ысуллары турындагы фән. *Төп чыганагы Платон һәм Аристотель әсәрләренә кайтып кала торган бик борынгы бу мантыйк китабын Фәтхулла хәзрәт кенә түгел, Фатихның бабасы һәм әтисе дә тырышып «кимергәннәр» иде.* И.Нуруллин. *Мансур Ибраһимович быел тагы алар төркемендә укыта икән... Бу юлы логика – мантыйк – фәненнән керә.* Х.Ширмән

2) Фикер йөртүдәге эзлеклелек. *Укучыларның иншаларында мантыйк эзлеклелеге бозылу – иң еш очрый торган җитешсезлек.* Л.Гыйлажева

3) *иск.* Схоластика. *Ул күптән мәдрәсәләрнең мантыйк оясы булуыннан зарлана.* Ф.Әмирхан. *Мәдрәсәдә мантыйк укуга каршы забастовкаларда катнаштым.* Г.Алпаров. *Мин мәдрәсәдә укыганда, мантыйк буенча дәрес бирүче хәлфә теңкәмә тиеп җәфалаган ие.* Р.Вәлиев

◊ **Мантыйкка сыймау** Мантыйксыз булу, мантыйк кагыйдәләренә туры килмәү. *Батый ханның башта шәһәрне юкка чыгарып, аннан соң шул ук урында үзенең ставкасын төзү турындагы карары һичнинди мантыйкка сыймый, минемчә.* Ф.Хуҗин

МАНТЫЙКЛЫ *с.* Билгеле мантыйгы, логикасы булган, гомумән мантыйкка нигезләнгән

МАНТЫЙКЛЫЛЫК *и.* Мантыйклы булу үзенчәлеге; мантыйклы булу дәрәҗәсе. --- *татар әдәбиятында, нихаять, чын мәгънәсендәге постмодерн әсәре туган, дип тә белдереп булмый, чөнки авторының мантыйклылыкка омтылышы сизелеп тора – ул аңа бары тик ирешә генә алмаган.* Идел

МАНТЫЙКСЫЗ *с.* **1.** Мантыйгы булмаган; мантыйкка нигезләнеп эшләнмәгән. *Нәрсә бу: кыланумы, әллә кыз баланың әхлакый этикеты белән хистойгыларының үзара көрәшеме? Әллә алогизмга корылган логикамы, ягъни, үзебезнең телдә әйтсәк, мантыйксыз мантыйкмы?* Н.Әхмәдиев. *Димәк, әсәр авторы үзара бәйләнешсез, эчке мантыйксыз нәрсәләрнең һәммәсен бергә тутырган.* Х.Миңнегулов

2. *рәв. мәгъ.* Мантыйкка нигезләнмичә, мантыйкка буйсынмыйча

МАНТЫЙКЧЫ *и.* Мантыйк белгече, логик. *Мантыйкчылар искәрткәнчә, акылның берьяклы эшчәнлеге иҗатта бертөрлелеккә китерә.* З.Мансуров

МАНТЫЙКЫЙ *с. гар. иск. к.* **мантыйклы**. *Сарыф-нәһүләрне төзүдә саф мантыйкый җиһатне генә игътибарга алып эш итү ярамаганлыгы инде ачык исбат ителде, аңлашылды булса кирәк.* Г.Алпаров. *Кайбер мәгълүмат кинәт кенә бөтенләй икенче ягы белән ачылып китә, мантыйкый вариантларын да чутлап чыгарасың.* Р.Мирхәйдәров. *Бу тарихи елъязманы анализласаң, берничә мантыйкый нәтиҗә ясарга мөмкин.* Татар милли календаре

МАНТЫТУ *ф. йөкл. юн. к.* **мантy** I. *Колониаль система үзенең җинаятьләрен искә алучыларны мантытмый. Ул аларны гел юкка чыгарып тора...* М.Юныс

МАНУ *ф.* 1) Сыек яки порошоксыман матдәгә тидерү яки батыру. *Бер-береңә эчтән янап, ананас, тавык ашап, Балеар утрауларында ясалган мәшһүр шәраблар эчеп утырырга мөмкин; бер-береңә ихтирамың ташыган хәлдә хозур кылып, тозга манып мич бәрәңгесе ашап, такталы кытай чәе эчеп утырырга мөмкин...* М.Мәһдиев. *Кунак ипине сул кулы белән бер кабарлык сындырып, тозга манып бер уртлады.* Г.Тавлин. *Һәр алманы карамельгә манып алып, карамельнең артыгы агып төшкәнен көтәбез.* Сөембикә

2) Юешләү, чылату. *Аннан инде табага урнаштырып, --- мичкә тыгар алдыннан гына, каз каурыеннан ясалган таба канатын йомыркага манып, пәрәмәчнең өстен майлыйсы.* М.Мәһдиев. *Каурыйлары каләм икән, Манар карам – йөрәк каным.* Рәшит Әхмәтҗанов. *Пәкене суга манығыз да яфрак, сабак, тамыр, чәчәк, җимеш, орлык кисәкләреннән юка гына катлау кисеп алыгыз.* Робинзон эзләреннән

3) Буяу; әйберне берәр төскә кертү өчен, аны төс бирә торган матдәгә батырып тору, аңа буяу сеңдерү. *Карага манган киндер күлмәк, шуның өстеннән кызгылтрак чикмән кигән бу.* З.Зәйнуллин. *Күрәсең, кәнизәкләр көне буе шәл манганнар, өйдән буяу исе таралып бетмәгән әле.* Р.Зәйдулла. *Шомырт агачының кабыгы белән*

тукымаларны яшел яки кызыл көрән төскә маналар. --- Наратбашка ачуташ кушып, йонны соры төскә маналар. Робинзон эзләреннән

4) *к.* **йөгертү** II (*1 мәгъ.*). *Заһид беләгендәге алтынга манган сәгатькә карады.* А.Расих. *--- Сакаллы реставраторлар буясын кыйммәтле буяуларга чиркәү ташларын, мансыннар гөмбәзләрен алтынга!..* Р.Фәйзуллин

5) *күч. шигъ.* Берәр төс өстәү, шул төскә кертү, шул төс белән өртү. *Зәңгәрсу эңгергә төренә башлаган бакчага, наратларның очын алсулыкка манган шәфәкъ нурларына карады.* М.Маликова. *Офык йөзен нурга манып ал таң атачак.* Ә.Синугыл-Куганаклы. *1954 нче елның көзе дөньяны алтын төсләргә манып маташкан көннәрнең берсендә --- никах укыттылар.* З.Хәким

6) *күч. шигъ.* Билгеле рух белән сугару, төсмер бирү, нюанс бирү, өртү. *Кайбер әсәрләрдә --- юмористик хикәяләргә генә нигез булырдай вакыйгаларны чын драматик буяуларга манып сурәтли бирдек.* Л.Ихсанова. *Дан димә син, мал димә син, Төкереп бир барына. Тынмасын саз, җырларың яз, Манып йөрәк каныңа.* Р.Вәлиева. *«Укучы арымасмы?» – дип, хакыйкатьне тагын иннек-кершәнгә манып күрсәтә башлыйкмы?* Р.Низамиев. *Гомернең таңында ук мандык Хыялны алсуга... Ә дөнья – Утларда... Янганга без яздык!* Р.Гатауллин

7) *күч.* Бик каты сугу; берне бирү, сылау, кундыру. *Ак әфисәр кинәт ап-ак булды, Нидер ырылдады һәм, кизәнеп, Йодрык белән манды әсиргә.* Ә.Рәшит

Манып алу Кыска вакытка гына, тиз генә, бер тапкыр ману. *Эссе. Бөркү, һава җитми. Швабраны сабынлы суга манып алам да палубаны ышкыйм.* М.Юныс. *Походка чыгар алдыннан, шырпыларны берәм-берәм эретелгән балавызга яки парафинга манып алырга һәм, алар кипкәч, тимер гильзага яки калын пыялалы кечкенә генә банкага тутырып, бөке белән ябып куярга мөмкин.* Робинзон эзләреннән. *Һәр кискән саен пычакны (үсемлекнең сәламәт яки авыру булуына карамастан) сыек формалин эремәсенә манып алалар.* Яшелчәчелек

Манып кую Бер тапкыр ману; алдан ук манып әзерләү

Манып чыгу Рәттән барысын да ману

МАНУЛ *и. монг. зоол.* Мәчеләр семьялыгыннан Кавказ аръягында, Алтайда, Байкал аръягында, Урта һәм Үзәк Азия далаларында һәм чүлләрендә яши торган, куе озын йонлы сирәк ерткыч хайван; дала мәчесе

МАНУСКРИПТ *и. лат. кит.* Башлыча антик яки Урта гасыр Көнбатыш Европадагы кулъязма китапларның атамасы; кулъязма. *Манускрипт һәм табышмак бер үк кулдан нәсех белән язылган.* Н.Исәнбәт. *Ул манускрипт кулъязмалар бүлегенең иң борынгы киштәсендә ята иде.* Ялкын

МАНУФАКТУР 1. *с.* Мануфактура (*1 мәгъ.*) формасында оештырылган. *Мануфактур хезмәт бүленеше. Капитализмның мануфактур чоры*

2. *и. сөйл. к.* **мануфактура** (*3 мәгъ.*). *Шәһәр базарларында ак күмәч, ит, шикәр, май, мануфактур тулып ята, дигән булалар, чынмы икән?* К.Тинчурин. *Биек тауның башында Мануфактур кибете; Кайдагы, дип сорасагыз, Без – Оренбур егете.* Җыр

МАНУФАКТУ́РА *и. лат.* 1) XVI йөздә Көнбатыш Европада барлыкка килгән, хезмәт бүленешенә һәм һөнәрчелектәге кебек кул техникасына нигезләнгән капиталистик җитештерүнең эре машина индустриясенә кадәрге формасы. *Гади кооперация белән чагыштырганда мануфактураның өстенлекләре хезмәт бүленешеннән гыйбарәт.* Политэкономия. *Капитализмның мануфактура чоры*

2) Текстиль эшләнмәләр җитештерә торган фабрика

3) *иск.* Текстиль эшләнмәләр, төрле тукымалар, кызыл мал. *--- Вәсимәдән ул үлеп тә көнләште: аның кебек чытыр ак халат киеп, мануфактура кибетендә сатучы булып эшләргә иде менә.* Г.Ахунов. *Бер байның мануфактура кибетендә приказчик ярдәмчесе булып эшләсә дә, аның [Һ.Такташ] күңелен матурлык һәм илаһилык күрке – әдәбият, шигърият үзенә тарта.* Т.Галиуллин. *Хезмәтче егет тә йөз солдат белән ике йөз метр мануфактура, күп итеп азык-төлек алып юлга чыгып китә.* Әкият

МАНУФАКТУ́РАЧЫ *и.* 1) Мануфактура (*2 мәгъ.*) хуҗасы

2) Төрле тукымалар, кызыл мал белән сәүдә итүче. *Мин мануфактурачы Насретдин Тинишевларда приказчик булып эшли идем.* Казан утлары

МАНЧЕ́СТЕР *и.* **1.** Киже-мамык тукыманың бер төре (Англиядәге шәһәр исеме белән аталган). *Менә безнең Хезмәт артистлары: Күлмәк кызыл, Чалбар – манчестер.* М.Крыймов

2. *с. мәгъ.* Әлеге тукымадан тегелгән. *[Фәхрелисламның карчыгы] туй бүләге итеп, Халыкъка кура җиләге төсендә бик әйбәт утыз тиенлек манчестер кәләпүш --- алып бирде.* Ш.Камал

МАНЧУ *ф.* 1) *к.* **ману** (*1 мәгъ.*). *Мондагы баш әйләндергеч исләр, әйтерсең мич алдында әниең пешергән кайнар коймакны эретелгән атланмайга манчып ашыйсың!* М.Мәһдиев. *--- шашлык өчен туралган суганын, яшь сарык ите телемнәрен шәраб серкәсенә манчыды, шашлык кыздыру өчен, мангалны һәм шампурларны барлап күйды, шулай да вакыт бик акрын узды.* Р.Мирхәйдәров. *Карт, укытучы сүзен ишетмәгәндәй, эчкән чәенә өрә-өрә, шакмаклы шикәрне чәенә манчып, авызында җебетте.* Х.Ширмән

2) *күч. шигъ. к.* **ману** (*3 мәгъ.*). *--- Казлар кайта, казлар китә, Болытларга канат манчып, Казлар нидер яза күккә.* Х.Әюп. *Нарат пумаласы омтыла да өскә, Күк капусын ясый манчып яшел төскә.* Р.Зәйдулла. *Кояш офыктан дүрт бармак биеклеге генә өстәрәк, әледән-әле биек йортлар, агачлар артында югалып тора да тагы күзгә күренеп ала, ерактагы урман башларын алтынсу төскә манчый ---.* Х.Ширмән

3) *күч. шигъ. к.* **ману** (*5 мәгъ.*). *Бүген исә социализм «шиненнән» чыккан байтак бәндәләр аны эт итеп сүгә, карага манчый.* Р.Низамиев

4) *күч.* Үтерү, дөмектерү. *Барысын рәттән дер селкетәләр, абруйга,*

дәрәҗәгә карап тору бетте, караклыкның изге кануннарын, тәртип-кагыйдәләрен бар дип тә белмиләр. Ул гынамы, үз иптәшләрен тотып манчыйлар. Р.Мирхәйдәров

5) *күч.* Эчү, җибәрү, салу. *– Давай, манчы, – диде Гайфи, тустаганны Сөнгатькә таба этеп.* Аманулла

Манчып алу Бер мәртәбә генә, кыска вакытка гына манчу. *Ал кояшның соңгы нурларында Коенып йөзә болыт төркеме, Шәфәкъ шәүләсеннән кызарганга, Канга манчып алган шикелле...* М.Җәлил. *Утыртыр алдыннан, 4–6 бөрегә кадәр [розаның] очын кыскарталар һәм тамырын кызыл балчык һәм сыер тизәгеннән ясалган сыекчага манчып алалар.* Юлдаш

МАНЧЫЛУ *ф.* 1) *кайт. юн. к.* **манчу**. *Төне буе чиккән кулъяулыгы күз яшенә манчылган.* М.Галиев. *[Яшь хуҗабикәнең] Озын керфекләре яшькә манчылдылар ---.* Ш.Рәкыйпов

2) *төш. юн. к.* **манчу**. *Һушына килгәндә, олырак яшьтәгесе пистолетын биленә тыккан һәм аның борын төбендә нашатыр спиртына манчылган мамык тотып тора иде.* Р.Мирхәйдәров. *Яшькелт, сары, аксыл мәрмәрдән салынган, алтынга манчылган һәйкәлләр, чәчәккә күмелеп утырган парклар үзенә бер иланһи дөнья тудыра.* Т.Галиуллин. *--- әгәр кәгазь урынына спиртка манчылган мамык куйсаң, ул озаграк яна һәм һаваны күбрәк җылыта ---.* Кызыклы физика

3) Тузан, балчык, лай, кан һ.б.ш.га баштан аяккача буялу, пычрану, бату. *Ярты лаш лайга манчылган, номерлары гына түгел, ишек тоткалары да күренмәскә әйләнгән машина – яньчелгән канатлы «Запорожец» булып чыкты.* А.Гыйләҗев. *Юл буенда тузанга манчылган күкбашлар гына чагылып калгалый.* М.Хәсәнов

4) Берәр төскә керү. *Әллә инде шулай таң беленеп килә иде, әллә инде күзләрен баскан кан пәрдәсе аша бөтен тирә-юнь кызыл кара төскә манчылып күренде.* З.Фәтхетдинов. *Кызгылт сары төскә Манчылды җир-һава: Әллә нинди шомлы Ләззәт тула җанга.* Л.Шагыйрьҗан. *Тал песиләре дә алтынга манчылган, серкәчләре озынча һәм неп-нечкә.* К.Тәхау

5) *күч.* Өртелү, берәр төсмер, кәеф, яңгыраш алу. *Ап-ак теләк телиселәр килә Сез дусларның бары-барына. Күңелкәйләр манчылгандыр, ахры, Аккош күле аклыкларына.* Г.Рәхим. *Тормышчанлык, мәхәббәт һәм нәфрәт, романтикага манчылган кайнар хисле фәлсәфә... Әгәр менә шушы яклары, шушы сыйфатлары белән күңелдә калган.* Р.Низамиев. *Рим үз хыялында туган, ал төсләргә манчылган романтик дөньяда яшәде.* Т.Галиуллин

Манчылып бетү Бик каты манчылу; тулысынча манчылу. *Ике дус кайтып бара. Балаклары балчыкка манчылып беткәне: – Әләгә инде! – ди.* Ш.Галиев

Манчылып яту Манчылган хәлдә булу. *Без тауга бераз мендек тә аксыл нурга манчылып яткан тигез алан үзәгеннән сулга борылдык.* Х.Сарьян

МАНЫЛУ *ф.* 1) *төш. юн. к.* **ману**. *Гарнитур стенкасындагы алтынга манылган бәллүр белән савыт-саба гына да миллионнар торырлык монда!* З.Фәйзи. *Манылды күңел күкләре Шәфәкъләр кызылына. Искитми генә әсәрәм Дөньяның кызыгына.* М.Галиев. *Газиз, Мәрьямгә карый-карый, кара буяуга манылган пумала белән киндергә сызгалый.* М.Маликова

2) Буялу, пычрану. *Тагы шунысы күзгә ташланды: вискига манылган күлмәген алыштырып өлгергән иде [Ирфан].* Р.Мөхәммәдиев

МАНЬЧЖУР *и.* Хәзерге Кытай Халык Республикасының төньяк-көнчыгышында яшәүче төп халыкның атамасы һәм шул халыкның бер кешесе. *Мәсәлән, бер Урал-Алтай тамырыннан чыгып, төрле үзгәрешләр нәтиҗәсендә төрек, монгол, маньчжур, фин, самоед телләре туган.* Г.Алпаров

МАНЬЯК *и. гр.* 1) Маниягә (*1 мәгъ.*) бирелгән кеше

2) Авыр ысуллар белән кеше җәзалаудан яки үтерүдән ләззәт тапкан явыз зат. *Бичара әнисе кайда? Маньяк этисе кайда?* Г.Гыйльманов. *И Алла, канга батып аңсыз яткан кешене мыскыл итәр өчен, бөтенләй җансыз-кансыз булырга кирәктер. Чит ил видикларын карый-карый, үзе дә маньякка әйләнгәнме әллә ул?* Р.Габделхакова

3) *күч.* Нәрсәгә дә булса нормаль булмаган тартылыш, үзен-үзе белештермәс авыру дәрәҗәсенә җиткән һәвәслек тоючы кеше. *Әйтергә кирәк, заманча сатып алу системасы – кредит карточкаларыннан файдалану – товар белән мавыгып китүне арттыра гына: акча янчыгы бушаганны «маньяк» абайламыйча да кала.* Мәгариф

МАНЬЯКЛА́РЧА *с.* **1.** Маньякларга хас. *Маньякларча караш*

2. *рәв. мәгъ.* 1) Маньяклар кебек, маньякларга хас рәвештә

2) *күч.* Бик бирелеп, чын күңелдән мавыгып, фанатикларча. *Монда, бер яктан, китап җыюга маньякларча ябышкан тип, аның хәйләләре ачылса, икенче яктан, акча-мал бәрабәренә саф мәхәббәтне дә пычрак итек белән тап-тап узу фаш ителә.* Б.Камалов

МАҢ *и. кыт.* 1) Киемнең күлмәк изүен матурлау, төймә тишекләре, чалбарның бил тирәсе яки балак очы кебек кайбер өлешләрен ныгыту өчен, эчке ягыннан куелган тар астар; әдеп. *Маңның очын, төп тукымадан һәм маңнан ясалган киртләчләрне бөтенесен бергә машинада кайыйлар.* Йорт эшләре

2) Тукымадан тегелгән әйберләрнең кырыйларын бөрү өчен бөкләп тегелгән урын, бөрмә. *Җитез идем, җил идем, Җиде көндә бер ыштан тектем: Бавы бар да маңы бар, Җиде көнлек тагы бар.* Такмаза

МАҢГАЙ *и.* 1) Йөзнең күздән югарыгы өлеше. *Еллар эзе кайда димсең? Алары – маңгаемда...* Р.Фәйзуллин. *Маңгаендагы, борын тирәсендәге сырлар, күз төпләрендә салына башлаган көрәнсу капчыклар – бөтенесе аның вакытыннан алда картайганын күрсәтеп тора.* З.Фәйзуллин. *Ул маңгаена төшкән чал чәчләрен сыпырып куйды, графиннан агызып су эчте һәм арыган, хәлсез тавыш белән чыгышын дәвам итте...* Ф.Садриев // Хайваннар башының алгы, күздән югары өлеше. *Менә тагын Микәй белән маңгайны маңгайга терәп шаярышып, сөзешле уйнап торганда, ул килеп кысылды.* Р.Мөхәммәдиев

2) Баш киеменең алгы өлгесе, башның өске алгы өлешенә туры килә торган детале. *Доктор баш очымдагы браны яндырып, маңгаена беркетелгән түгәрәк көзгенең утын күз алмама төшереп, нәрсәдер тикшерә башлады.* М.Юныс

3) Калкулыкның, тауның алгы, чыгыбрак торган, иң биек, текә урыны, кашы. *Озакламый җилнең канаты салынды, көн суытты, кояш Кашка тау маңгаен каплаган куе нарат урманының эзмәнкәле очын сыпырып үтте* ---. А.Гыйләҗев. *Тау маңгаенда – гомеремнең иң биек ноктасыннан әз генә түбәндәрәк басып торам.* Ә.Гаффар. *Маңгае гарип куаклар белән капланган гажәп текә яр өстенә менеп җиткәч, олы урам шавына күнеккән колаклар гадәттән тыш тынлыкка ияләшә алмыйча торды.* М.Галиев

4) Транспорт чараларының өске алгы өлеше. *Маңгай утларын ялтыратып әледән-әле үтеп киткән поездлардан бу як – Әнисә абыстайның җәйкөз каз көтә торган иркен биләмәләре бөтенләй күренми*. А.Гыйләҗев. *Чылбырыннан ике яклап кар сиптереп килгән чуар машинаның нәкъ «маңгае»на эләкте.* Ш.Рәкыйпов. --- *маңгае 200 миллиметр калынлыктагы бу танкны бәреп ватар өчен, бездә яңа гаубицалар, үзйөрешле орудиеләр эшләнә башлый.* Р.Низамиев

5) Гаскәрнең сугышчан тәртибендә ике флангның уртасында һәм алардан алдарак торган позиция; шушы позицияне алып торган хәрби подразделение. *Келәү беткәч, аның янына маңгай чирүе башлыгы Илбакты килеп йөгенде.* Р.Зәйдулла

◊ **Маңгаена тай типмәгән** Мондый зур ялгышлык эшләве мөмкин түгел, аек акыллы. *Сабирның кем икәнлеген үтәдән-үтә күрмәсәм, мондый эшне тапшыраммыни мин. Маңгаема тай типмәгән минем.* М.Әмир. **Маңгаена язулы булмый** *к.* **маңгаена язылмаган**. *Эчке дошманнарның: «Бу – дошман», – дип, Булмый маңгаена язулы.* М.Гафури. **Маңгаена язылган** Язмышы алдан билгеле. *Маңгаена язылганны җую мөмкинме?* Г.Ибраһимов. **Маңгаена язылмаган** Беренче карашка ук күренеп тормый, тышкы кыяфәтеннән кем булганы билгеле түгел. *Ә кешенең саф намуслымы, астыртын дошманмы икәнлеге маңгаена язылмаган, белә алмыйсың.* Г.Тавлин. **Маңгай астыннан карау** 1) Күз кырые белән генә, сиздермәскә тырышып, уңайсызланып кына карау. *Ул килеп утыргач, маңгай астыннан гына аңар тагы да күз йөртеп алдым. Кызкай сокланырлык иде.* Л-Х.Таналин; 2) Башны аска иеп, ачу белән, усал итеп карау; каш астыннан карау. *Сөзәргә җыенган үгез кебек маңгай астыннан гына карап, сүзләрен теш арасыннан кысып, сайлап кына чыгарып әйтә салды: «Мәдинә янына үзең барасың. Үзең сөйләшәсең. Менә шул!..»* М.Хәсәнов. *Һәдия аңа маңгай астыннан сөзеп кенә карады да арба читенә килеп утырды.* М.Галиев. **Маңгай аша күзәтү** *к.* **маңгай астыннан карау**. *Малайлар шыпырт кына көлешеп һәм качынып кына маңгай аша Габдулланы күзәтә башладылар.* Ә.Фәйзи. **Маңгай белән таш (стена) вату** Булмаячагы алдан ук билгеле булган эшкә керешү. *Маңгаем белән таш стенаны ватармын, ә Вәсимәне кешегә бирмәм.* Ф.Хөсни. **Маңгай белән таш тишү** *к.* **маңгай белән таш (стена) вату**. **Маңгай белән таш яру** *к.* **маңгай белән таш (стена) вату**. **Маңгайга бәреп әйтү** *к.* **маңгайга бәрү**. *Юкка түгелдер: маңгайга бәреп әйтелгән агит сүзләр челтәре аша булса да, аның әсәрләрендә революциядән соңгы авыл кешесенең реалистик образлары шактый ачык күренә иде.* М.Әмир. *Рәсәй, гомумән, гомер-гомергә, Ельцин кебек дорфарак, сүзен маңгайга бәреп әйтүчән каты куллы патшаларны яраткан.* Р.Зәйдулла. **Маңгайга бәрү** 1) *к.* **йөзгә бәрү**. *Ркаил Зәйдулла – заман һәм җәмгыять, милләт һәм кешеләр турында усал итеп, әрнеп, ләкин аңларга тырышып түгел, ачыктаначык гаеплән, «маңгайга бәреп» сөйләшүче шагыйрь.* Д.Заһидуллина. *Төслəр артык ачык, күзне ерта. Автор кешеләрне маңгайларына бәреп шакатырырга тырышкан.* М.Маликова; 2) Алгы ягыннан, туп-туры каршысыннан, фронтыннан һөҗүм итү. *Маңгайга бәреп рәт чыкмаслыгына инанган фашистлар, тукталып, барлык төр кораллардан атарга керештеләр.* Ш.Рәкыйпов. **Маңгайга язу** 1) Алдан билгеләү. *Маңгаеңа язып куйган хак язмышың Җуеп кына алып булмый кул белән...* Җыр; 2) Аңларлык, акылына сеңдерерлек, истә калдырырлык итеп әйтү, сөйләү, аңлату; ныклап кисәтү. *Минем маңгайга язып җибәрделәр. Без Вәли этне беләбез. Андый ерткычларга якты кояш астында көн булмасын, дип әйтергә куштылар.* Г.Ибраһимов. **Маңгайга язылу** 1) Алдан билгеләнгән булу. *Маңгаена, бәлки, шулай язылгандыр, ләкин моңа ризалашмаячак аның таш маңгае.* С.Поварисов. *Нәкъ мәктәптәге кебек, студентларның киләчәктә кем буласы «маңгаена язылып куелган» иде шул.* М.Әхмәтҗанов. *Шулай инде, маңгаеңа язылган булса, син күрәсең бүтәннәр күрмәс, дигән борынгылар.* Р.Зәйдулла; 2) Бик ачык күренеп тору, беренче карашка ук билгеле булу, җиңел аңлашылу. *Сүзләр русча әйтелде, тик авылда үскән егетнең татар икәнлеге маңгаена язылган гына түгел, теленә мәңге бетмәслек итеп уелган иде.* М.Маликова. – *Минем маңгайга нәрсәләр язылган соң? – дип төпченде Хәбир. – Намуслы кеше булуың.* Н.Акмал. **Маңгайдан бәрү** *к.* **маңгайга бәрү** (*2 мәгъ.*). *Шулчак ракета кабынды, алдан киткән батальоннар «дошман»ның тылына төшкәннәр иде, ә Рифкатьләр батальоны «маңгайдан» китереп бәрде.* Р.Вәлиев. **Маңгай ору** *иск.* Түбәнчелек белән баш иеп, тирән ихтирам белдерү, олылау. *Барысы да Камышлы мәчет мулласына садака бирергә, кулын үбеп, маңгай орырга, догасын алырга ашыкты.* Г.Минский. **Маңгай тире** Хәләл хезмәт, тырышлык. *Маңгай тирең сибеп эшләсәң дә, Һич тә ярап булмый ятларга.* Җыр. **Маңгай тире агызу** *к.* **маңгай тире түгү**. *Маңгай тире агызып эшләгән халыкның күңелен күтәрәсе, «алтын куллар»ның дәртен, куәтен арттырасы бар аның, шуңа ашыга ул* ---. Э.Касыймов. **Маңгай**

тире сеңү *к.* **маңгай тире таму**. *Алпавыт малы синең малың түгел, ә халыкныкы! Аңар безнең атабабаларыбызның маңгай тире сеңгән.* И.Гази. **Маңгай тире таму** Бик күп тырышлык һәм хезмәт куелу, көч сарыф ителү. **Маңгай тире түгү** Бик күп тырышлык кую, зур физик көч түгү. *Колхозчыларның көн дими, төн дими маңгай тирләрен түгеп тапкан хәләл акчаларын урлагансыз. Моның өчен судка бирү генә дә аз...* М.Хәсәнов. *Хәләл мал, әни! Эшләп, маңгай тиремне түгеп алдым!* К.Кәримов. **Маңгай тире чыгару** *к.* **маңгай тире түгү**. *Ипекәй дигәнең безнең өйгә үз аягы белән тәпиләп кайтмый шул. Аны менә шулай, маңгай тирен чыгарып эшләп алырга кирәк.* Г.Бәширов

МАҢГАЙГА́-МАҢГАЙ *рәв.* Каракаршы килеп, каршысыннан туп-туры килеп. *Монда менә чып-чын дөнья белән маңгайга-маңгай килеп бәрелдем мин. Аермасы шактый икән ич!* К.Тимбикова. *Манёвр паровозлары вагоннарны төн ката арлы-бирле сөйри, --- буферлар маңгайга-маңгай килеп, очкын һәм тәмуг авазлары тараталар.* А.Гыйләҗев. *Идәнгә чәчелгән кәгазьләрне җыярга иелгәндә, тагын бер мәртәбә маңгайга-маңгай чәкәштеләр...* Г.Гыйльманов

◊ **Маңгайга-маңгай бәрелештерү** Бер-берсенә каршы төшәргә мәҗбүр итү, капма-каршы кую, берсен икенчесенә каршы котырту. *--- никадәр неформаль берләшмә яралды, кайчагында программаларында революцион орлыклар да күрәм, аларның иң яхшыларын үземә җыя барам, алга таба исә иң амбициоз идеологларны маңгайга-маңгай бәрелештерәчәкмен ---.* Р.Мирхәйдәров. **Маңгайга-маңгай бәрелешү** Ачыктаначык бәрелешү, бик каты бәхәскә керү, кара-каршы сугышу яки көрәшү, талашу. *Бу сугышта бик күп язмышлар бергә үрелде, Вахит Хазиахметович. Маңгайга-маңгай бәрелешкән кешеләр дә байтак.* С.Лашманчы. *Бәлки, безгә тегеләр белән маңгайга-маңгай бәрелешергә туры килер.* Р.Мирхәйдәров

МАҢГАЙЧА *и.* 1) Йөгәннең маңгай турысындагы каешы

2) *этн.* Яулык өстеннән киелә торган, алгы ягы энҗе яки тәңкә белән бизәлгән хатын-кыз баш киеме, такыя

МАҢГЫРА́У *ф. иск.* 1) Бәэлдәү

2) Ахылдау, көрсенү, авыр сулау. *Ялгыз башы каңгырап, Куйдай булып маңгырап, Чүл далада тинтерәп, Дуадактай хан калыр.* Дастан

МАҢКА *и.* 1) Борынның эчке лайлалы тышчасын саклый торган, салкын, көчле ис кебек тышкы ярсыткычларга реакция буларак борыннан бүленеп чыга башлый торган сыекча. *Минем кебек булмаса, минем кебек булырга тырышсын. Була алмаса, ыратам дип, маңкасын агызып йөрмәсен.* Т.Миңнуллин

2) *күч. гади с.* Гадәттә үзеннән яшьрәк, тәҗрибәсез, уңмаган кешегә аны кимсетеп, мыскыллап әйтелә. *Әрсез алабай, минем кисеп ташлаган тырнагыма тормаслык маңка, мине мыскыллап сөйләшсен, имеш!* Г.Ахунов. *Шигърият дөньясында Ул – олы бер хан хәзер. Аның янында без, Рафис, Малай-шалай, маңка бер!* Г.Гыйльманов. *Әйттем мин сиңа! Шул маңканы да шпионлыкка өйрәтеп куйганнар инде.* М.Маликова

3) *к.* **маңка авыруы**. *Башны балта бозар, Елкыны маңка бозар.* Мәкаль

◊ **Маңка борын** *к.* **маңка малай**. **Маңка малай** *гади с.* Үзеннән яшьрәк кешегә, ешрак бала-чагага, аның белән санлашмауны, түбәнсетүне, кимсетүне белдереп әйтелә торган сүз. *Алтын чылбыр булып сузылган шушы рухи җеп, телен онытkан бер маңка малайга килеп җиткәч, өзелә дә куя.* Ш.Галиев. *Сабыем шуңа рәнҗегәндер: Ниндидер бер маңка малай анда, Үзен өстен күрсәтмәкче булып: «Әй, кәләпүш... татар...» – дигән аңа.* Ә.Рәшит. *Фәниснең зәңгәр күзләреннән яшьләр тамганын күргәч, Фәнисә тагын да ярсып: – Армиядан кайткан егет булсаң да, маңка малайлар кебек елап торасың. Кит, күземә күренәсе булма! – дип кычкырды.* Р.Ахунова. **Маңка сарык** *гади с.* Кеше белән санлашмыйча, аның дәрәҗәсен төшереп, кимсетеп, мыскыллап әйтелә торган гыйбарә. *Йоклаган урыннары ханнарныкы кебек, ашаган ризыкларын сөйләп, мактап бетерермен димә, ә алар, маңка сарыклар... «Кайчан моннан китәбез?!» имеш...* А.Гыйләҗев. **Маңкасы кипмәгән** *гади с.* Тәҗрибәсез, дөнья күрмәгән, яшь. *--- тол хатынның тормышы да бал түгел – һәркайсы кыерсытырга гына тора: маңкасы кипмәгән малайлар да, итәк-чабуын җыя белмәгән көнчел хатыннар да яннарыннан узганда тешләп калырга тырыша.* З.Кадыйрова. **Маңка танау** *к.* **маңка малай. Маңка тәре** *гади с. к.* **маңка сарык**. *Мыскыл итә бит, маңка тәре! Заһит абзасының алырлыгы бармы икән, дип икеләнә, имеш.* Җ.Юныс. – *Әйдә, алдыңа кара, маңка тәре, түбәңә кундырганчы! – ди бу миңа.* Аманулла

МАҢКА́ АВЫРУЫ *и.* Атларда һәм башка тактояклы хайваннарда була торган йогышлы авыру; *русчасы:* **сап**. *Авыру тудыручы бактерияләр тиф, --- ангина, сап (атларда һәм башка тояклы хайваннарда маңка авыруы), түләмә, бруцеллёз авыруларын китереп чыгаралар.* Биология. *Аларның [авыруларның] иң куркынычлары түләмә, чума, рожа, маңка авыруы (сап), котыру авыруы булган.* Татарстанда терлекчелек

МАҢКАЛАНУ *ф.* 1) Җебеп яки куерып, консистенциясе белән маңкага охшаш хәлгә килү

2) Маңкага яки шуңа охшаш нәрсәгә буялу. *Ни күрим, мөгезле һәм олы колаклы, кызыл күзле, хәшәрәт рәвештә маңкаланган кара йонлач тәнле, әле яңа гына, юлда Гарәфи сөйләгән шайтан миңа таба килеп маташа иде.* Ф.Яхин

Маңкалана башлау Маңкалануга табан үзгәрү

Маңкаланып бетү Тулысынча маңкалану

Маңкаланып тору Маңкага охшаш булып күренү

МАҢКАЛА́У *ф. сөйл.* 1) Салкын тию, аллергия кебекләрдән борын кушылыгы ярсыганда, туктаусыз маңка килеп тору

2) Маңка авыруы белән авыру, маңка авыруы йоктыру

Маңкалап бетү Нык маңкалау

Маңкалап тору Әледән-әле яки хәзер маңкалау

Маңкалый башлау Маңкаларга тотыну

МАҢКАЛЫ *с.* Борыныннан туктаусыз маңка агып торган, гомумән, еш кына авырый торган, күрер күзгә сәламәт күренмәгән. *Юкса маңкалы борын белән йөрү егетләргә килешми, кызлар сөймәс үзеңне, Илсур*. Т.Миңнуллин. *Маһирәләр яшәгән озын коридорлы, алты ишекле дәү квартирага ишле гаиләле ярлы-ябагай, җылак балалар, маңкалы кызлар, эт һәм песиләр кереп тулган*. А.Гыйләҗев

МАҢЛАЙ *и. иск.* 1) *к.* **маңгай** (*1 мәгъ.*). *--- Берәве аның олы угыл, Маңлае чыкык, гүзәл булыр, Батыр булыр шул угыл ---*. Дастан

2) *к.* **маңгай** (*5 мәгъ.*). *Уң кулында – Ир Каплан, Сул кулында – Кыйгырчак, Маңлай башы – Идегәй, Кыргын юлга юнәлде [Шаһ Тимер чирүе]*. Дастан

МАҢЛА́У *ф. диал.* Маң тегеп кую, тар әдеп салу

Маңлап кую Маңлаган итү

Маңлап тору Әледән-әле яки хәзер маңлау

Маңлый башлау Маңларга тотыну

МАҢРА́У *ф. диал. к.* **маңгырау**

МА́ОРИ *и.* Австронезия телләр семьялыгының полинезия төркемчәсенең маори телендә сөйләшкән, Яңа Зеландия һәм Кук утрауларының җирле халкы һәм шуның бер вәкиле. *Хәзерге вакытта Яңа Зеландия утрауларында маори дигән җирле халык яши.* А.Кәримуллин. *--- маорилар күз алдына китергәнчә, күкне җирдән үсемлек алласы Тане аера, ул үзенең ботаклары белән күкне терәтеп тора.* Галәм. Җир. Кеше

МАРАБУ *и. гар. зоол.* Ләкләк кошлар семьялыгыннан Африкада, Көньяк-Көнчыгыш Азиядә сулыклар буенда һәм сазлыкларда яши, башлыча үләксә белән туклана торган, массив томшыклы зур кош. *Марабу кошы таркалып баручы хайван үләксәләре белән туклана.* Биология. Хайваннар

МАРАЗМ *и. гр.* 1) *мед.* Баш мие кабыгы атрофиясе нәтиҗәсендә кешенең психик эшчәнлеге бөтенләй диярлек туктау, әкренләп организмның барлык яшәү процесслары сүнү күренеше. *Яза алмавыма, хәтерем начарлыгына бик пошынган идем, әллә соң склероз башландымы, картлык маразмы килдеме, дип борчылдым.* Т.Миңнуллин

2) *күч.* Әхлакый, рухи, ижтимагый яки идеологик яктан деградация, артка китеш; таркалыш, җимерелү күренеше. *Әгәр сез эшли-эшли хәлдән таеп егыласыз икән һәм миегезнең бер җыерчыгын да җигә алмыйча, башыгыз авыртканчы телевизор каршында утырасыз икән, бу инде ял түгел, бәлки хайвани омтылу һәм маразм.* В.Леви

МАРАЗМА́ТИК I *и. рус* 1) Маразм авырулы кеше

2) *хурл.* Ахмак, тинтәк. *Неужели сез, вакытыгызны әрәм итеп, шушы бездельник, маразматиклар янына барып йөрисез?* М.Мәһдиев

МАРАЗМА́ТИК II *с.* Маразм авыруына хас, шуның белән бәйле

МАРАЛ *и. төрки зоол.* Боланнар семьялыгыннан затлы боланның географик расасы булган, Алтайда һәм Тянь-Шаньда яши, мөгезеннән дару алу өчен питомникларда махсус үрчетелә торган партояклы хайван. *--- тау елгаларында балык тоту, ак башлы, текә кыялы олы тауларның тирән тарлавыкларында, калын урманнарында тау тәкәләре, архарлар, мараллар аулау, чын мәгънәсендәге саф табигать кочагында иркен-имин хозур итүләр бәхете миңа мул эләкте...* М.Госманов. *Атларның берсенең сыртына Себер боланы – марал аркылы салынган.* М.Хәсәнов

МАРАФЕТ *и. гар.* 1) Тәртип, тышкы пөхтәлек. *Хәзер марафет ясыйбыз, аннан трассага [чыгабыз]*. Р.Мирхәйдәров

2) Бизәнү. *Төс-кыяфәтен үзгәртеп, әзрәк үзенә марафет ясатса, туйда аңардан да чибәр, күркәм хатын-кыз булмас кебек*. Х.Ибраһим

3) *жарг.* Наркотик

МАРАФО́Н *и. гр. спорт* 1) 42 км 195 м ераклыкка йөгерү ярышы, җиңел атлетика ярышларының бер төре. *Хәзер инде берәү дә хатын-кызның стайер булуына гаҗәпләнми. Алар бүген хәтта марафонга барып җитте.* Сөембикә

2) Гомумән, бик озакка сузылган берәр чара, кампания, гадәттә шоу, спорт, күңел ачу һ.б.ш. чарасы. *Моңарчы да күпме күпер киҗтең, Тик аерма бүген бары шунда: Сират күпере – инде соңгы күпер Тарих дигән озын марафонда.* Н.Акмал. *Сайлау алды марафоны*

МАРАФО́НЧЫ *и. спорт* 1) 42 км 195 м ераклыкка йөгерүдә махсуслашкан ярышчы. *42 километр 195 метр араны үтү өчен, никадәр ихтыяр көче, түземлелек кирәк икәнен марафончылар яхшы белә*. А.Гафиятов

2) Гомумән, ерак дистанциягә йөгерә яки йөзә торган спортчы. *Исрафил моннан егерме еллар элек йөгерә башлаган иде. Элегрәк кыска араларга гына йөгерде, соңыннан һаман саен тыны ачыла баргач, марафончылар сафына басты*. Ф.Яруллин

МА́РГАНЕЦ *и. нем. хим.* Периодик системаның VII группасына караган химик элемент, әкрен эри, металлургиядә эретмәләр составында кулланыла торган уалучан көмешсыман ак металл. *«Чолман» Поти белән Мариуполь арасында күмер һәм марганец мәгъдәне ташучы штрафниклар пароходы иде.* М.Юныс. *Аңа [кешегә] аз гына булса да иод, марганец, кобальт һәм башка бик күп элементлар кирәк.* Химиянең киләчәге. *[Күк җиләк] җиләкләрендә --- лимон кислотасы, алма һәм кузгалак кислоталары, пектин, дуплау һәм буяучы матдәләр, тимер, бакыр, марганец һәм кобальт бар.* Урман аптекасы

МАРГАНЦО́ВКА *и. рус сөйл.* Медицинада зарарсызландыру өчен кулланыла торган марганец сульфаты кристалларының яки эремәсенең сөйләмдәге атамасы. *Дистиллятор – зур колба, астына спиртовка куеп, шуның эчендә су кайнатасың. Тизрәк кайнасын өчен, аңа калий перманганаты, ягъни марганцовка да өстиләр*. М.Маликова. *[Розаны] Утыртканчы ком сибәләр һәм туфракны марганцовка эремәсе белән яхшылап эшкәртәләр.* Юлдаш. *Куыкларны сытарга, пешкән урынга үсемлек майлары, яндырып ала торган матдәләр (марганцовка, спирт, йод) сөртергә ярамый, чөнки алар пешүне, авыртуны көчәйтәләр,*

җәрәхәтнең төзәлүен акрынайталар. Биология

МАРГАРИН *и. гр.* Туң май, үсемлек мае, сөт, тоз, шикәр, хуш ис бирә торган матдәләр һ.б.ш.лардан әзерләнгән ашамлык май. *Кичке чәйгә һәрберебез алдына өстенә маргарин ягылган берәр (!) телем ипи куела.* К.Тимбикова. *Әллә кайчаннан бирле инде алар өендә атланмайның булганы юк. Маргарины гына керсә дә – зур сөенеч.* М.Маликова. *Көнбагыш мае азык итеп кулланыла; маргарин, лак әзерләү һәм сабын кайнату өчен файдаланыла, аның орлыгыннан хәлвә ясыйлар.* Биология

МАРГАРИ́ТКА *и. рус бот.* Оешмачәчәклеләр семьялыгыннан Европа һәм Кече Азиядә үсә торган күпьеллык, культуралы сортлары башлыча икееллык, вак алсу, ак, кызыл чәчәк ата торган үлән үсемлек; мәрвәрит чәчәге. *[Газондагы] назлы бегония һәм маргариткалар Заһидны сәламләп каршыладылар.* А.Расих

МАРГИНАЛ *и. лат.* Милли тамырларыннан аерылган, әмма яңа җәмгыятькә яраклаша алмаган кеше. *Без маргиналлар түгел. Әгәр дә бүген дөнья йөзендә җиде миллионлап татар яши икән, милләт шәҗәрәсен тәшкил иткән кардәшләрне исәпләргә саннар җитмәс иде.* З.Мансуров

МАРЕ́НА *и. рус бот.* Мареначалар семьялыгыннан, кайбер төрләре тамырыннан буяу алу һәм дәвалау өчен файдаланыла торган күпьеллык куак яки үлән үсемлекләр ыруы. *Марена тамырчаларын август башыннан алып (җимешләре өлгергәндә) кыраулар төшкәнче һәм яз көне марттан башлап апрель урталарына кадәр хәзерлиләр.* Урман аптекасы. *--- кызыл буяуны (крапп) Персиядә үсә торган марена исемле үсемлекнең тамырыннан алганнар.* Робинзон эзләреннән. *--- буяу маренасы (марена красильная) тамырларында табылган кыйммәтле табигый буяу – ализаринны (антрахинон чыгыш матдәне) атарга була.* Агулы үсемлекләр

МАРЕ́НАЧАЛАР *и. бот.* Киң таралган, башлыча тропикларда һәм субтропикларда үсә торган, ашамлык (кофе агачы), дәвалау (хин агачы), декоратив (гардения) максатлардан файдаланыла торган икеөлешле агач, куак һәм үлән үсемлекләр семьялыгы. *Мареначалардан (мареновые) ипекакуана үсемлегенең тамырларында 3 % ка кадәр алколоидлар бар.* Агулы үсемлекләр

МАРЕ́НГО *и. ит.* 1) Ак аркау җепле кара тукыма (Италиядәге авыл исеменнән)

2) Соргылт кара төс

МАРЕОГРА́Ф *и. лат.-гр. махс.* Диңгездә су югарылыгының үзгәрешләрен өзлексез рәвештә теркәп бара, башлыча калкавычның торышындагы үзгәрешләр язу җайланмасына тапшырылу нигезендә эшли торган прибор

МАРҖА *и. сөйл.* 1) *Мария* исемен татарча гадиләштереп әйтүдән алынган, соңрак гомумән сөйләмдә рус хатын-кызларын атау өчен кулланыла башлаган сүз. *Станцияләреннән үткәндә, сөт сатучы марҗалар миңа көлеп калдылар.* Г.Исхакый. *Марҗа апайның туны күзнең явын алып тора. Шуны-сын белергә иде: күпмерәк каермак була икән?* А.Хәсәнов. *Мәгәр шәп әби булып чыкты бу карт марҗа.* С.Поварисов

2) *гади с.* Хатын-кызны сүгеп, кимсетеп атау яки эндәшү сүзе. *Чык, хәерче марҗа, өемнән, күземә күренмә!* Г.Камал. – *Күрсәтермен әле мин күрмәгәннәрегезне, сатлык марҗалар! – дип, өстенә бара башлады.* Ж.Фәйзи. *Гадәтсез марҗа! Кашын-күзен җимереп кычкырудан бүтәнне белмәс шул!* М.Маликова

МАРҖА́ БАШМАГЫ *и. бот.* Сыраҗчалар семьялыгыннан сары, шәмәхә һ.б.ш. чәчәкле, кайбер төрләре декоратив максатлар белән үстерелә торган күпьеллык үлән үсемлек; *русчасы:* **льнянка**

МАРҖА́ БАШЫ *и. этногр. диал.* Урылган һәм көлтәгә бәйләнгән ашлыкны киптерү өчен, 6–10 көлтәне башакларын югары каратып, бер-берсенә сөяп утыртып, өстән бер көлтә белән ябылган өем

МАРИ *и.* Угро-фин халыкларының Идел буе группасыннан Мари Республикасында яшәүче төп халыкның атамасы (элекке атамасы: чирмеш) һәм шул халыкның бер кешесе. *Бу вакытта Федосеев түгәрәкләре зурая барды. Түгәрәкчеләр инде татар, мари яши торган төбәкләргә дә барып чыккаладылар.* Г.Әпсәләмов. *Атлашкино тирәсендә яшәүче бер мари. Балыкчы ул, Иделдә очрашабыз.* М.Насыйбуллин. *[Корылтай] эшендә --- Урта Идел төбәгендә яшәүче мөселман булмаган башка халыклардан – мари, удмурт, чуваш, мордвалардан – барысы 150 делегат катнаша.* Казан утлары

МАРИНА *и. лат.* 1) Яхталар туктату өчен махсус яраклаштырылган урын, стоянка

2) Диңгез манзарасы, диңгез сугышы яки диңгездәге башка күренешләрне сурәтләгән рәсем, пейзаж төре. *Мариналар коллекциясе*

МАРИНАД *и. фр.* 1) Серкә, тәмләткечләр һ.б.ш.дан торган сыек соус. *[Хатыннарның] Прилавка эчендәгесе [балыкны] томалап пешерүне һәм кишердән маринад ясап, шуның белән ашауны мактый.* М.Юныс

2) Шундый соус салып яшелчә, гөмбә, балык кебекләрдән әзерләнгән ашамлык. *Дарчин – кулинариядә, маринадлар әзерләгәндә, кондитер, ликер-аракы сәнәгатендә хуш исле тәмләткеч буларак кулланыла торган мәңгеяшел тропик дарчин агачларының киптерелгән кайрысы.* Товар турында мәгълүмат укыйбыз

МАРИНАДЛА́У *ф.* Җимеш, яшелчә, балык кебек нәрсәләрне маринад салып әзерләү. *Җикәнбашның тамырчаларын һәм яшь ботакларын маринадлыйлар, ә тамырчаларын пешереп тә ашыйлар.* Урман аптекасы. *Тузганакның чәчәк бөреләрен маринадлыйлар һәм алар белән солянкага һәм винегретка сала торган тәмләткечләрне алыштыралар.* Робинзон эзләреннән. *Кәбестәне азык итеп күп төрләрдә файдаланалар: аны чиләй, пешереп, тозлап (әчетеп) һәм маринадлап кулланырга була.* Яшелчәчелек

МАРИНАДЛЫ *с.* Маринадланган, маринадлау ысулы белән әзерләнгән

МАРИНИСТ *и. ит.* 1) Диңгез күренешләрен рәсемгә төшерүче рәссам.

Иң атаклы маринист Айвазовскийның әсәрләре

2) Диңгез һәм диңгезчелек турындагы әдәби әсәрләр авторы. *Яшь чагында пиратлык белән шөгыльләнеп, акыл утыртканнан соң күренекле галим һәм әдип (маринист) булып киткән Дампирның «Җир шары әйләнәсенә яңа сәяхәт» исемле китабы да искиткеч бай мәгълүматлы.* М.Юныс. *Экзотик лексиканың матур үрнәкләрен без бөтен Җир шарын гизеп йөргән маринист язучы Миргазиян Юнысның күпсанлы язмаларында очратабыз.* Ф.Сафиуллина

МАРИНИ́СТИКА *и. рус* 1) Рәсем сәнгатенең диңгез күренешләрен ясауга багышланган жанры һәм шул жанрга караган барлык әсәрләр. *Маринистиканың үсеше*

2) Диңгез һәм диңгезчелек турындагы әдәби әсәрләр жанры. *Менә ул [М.Мәһдиев] маринистика һәм сәяхәтнамә өлкәсенә кергән.* М.Юныс

МАРИОНЕ́ТИК *с. кит.* Үз сәясәтен үткәрүдә мөстәкыйльлеге булмаган, башка субъектларның мәнфәгатьләрен яклау өчен махсус оештырылган. *Марионетик хөкүмәт*

МАРИОНЕ́ТКА *и. фр.* 1) Курчак театрында: курчакчы артист кулындагы җепләр ярдәмендә хәрәкәтләндерелә торган курчак төре. *Болар һәркайсы – курчаклар яхут маскалар театрындагы марионеткалар.* М.Җәлил. *Бу ике туганнар республикаларның галимнәре һәм язучылары арасында бәхәс барса да, берлекнең җитәкчеләре, марионетка курчак шикелле, бер җепкә беркетелгән булалар.* М.Юныс

2) *күч.* Мөстәкыйль рәвештә карар кабул итеп, үзе теләгәнчә эш итә алмаган, башкаларның кушуын үтәгән, башка берәүнең кулында сукыр корал булган кеше, дәүләт һ.б.ш. *Үзара җепкә беркетелгән шикелле, юлбашчылар теләгән йөз процентка раслап, марионеткалар кул күтәрә иделәр.* М.Юныс. *Марионетка Курчак түгел, Марионетка Кол була. Уйнатучылары аның Сабый түгел – Кул була...* Л.Шагыйрьҗан

МАРИХУА́НА *и. исп.* Һинд киндере орлыгыннан алына торган наркотик матдә. *АКШта наркомания киң таралган. Армиядә солдатларның 85 % ы марихуана тарта, ә мәктәп, колледжларда укучыларның 80 % ы героин белән таныш.* Сәламәт яшәү нигезләре

МАРИ́ЧА *рәв.* **1.** 1) Мари телендә. *--- Нәҗипнең әзер квартирдан баш тартуын белгәннән соң, шартлар дәрәҗәгә җитеп очрашуны көткән Сабит ярты сәгать тоташтан русча, татарча, чувашча, марича сүгенде.* А.Гыйләҗев. *Әгәр аның башында беләме бар икән, русча укыганмы ул, татарча укыганмы ул, марича укыганмы ул – барыбер рус балалары белән бергә үк укырга керә ала.* В.Нуруллин. *Газетаны русча, чувашча, марича да чыгарырга иде. Кушымта төсендә генә булса да.* Казан утлары

2) Марилар рәвешле, мариларга охшатып

2. *с. мәгъ.* Мари халкына хас булган, шуңа караган. *Русча, татарча, марича җыр-биюләр чиратлаша башлый, ярыш-тамаша бергә кушылып мәйданга таба юл тота.* А.Вергазов

МА́РКА I *и. нем.* 1) Берәр сурәт төшерелгән һәм бәясе күрсәтелгән, гадәттә, дүртпочмаклы кәгазь формасындагы почта яки башка төрле рәсми җыемнарны түләү билгесе. *Марка да җыймыйсыз инде, шырпы каплары да... Чаңгы да шумыйсыз?* А.Гыйләҗев. *Маркада сурәтләнгән бүгенге Дрезден галереясын Витяның да бик-бик күрәсе килә.* Ш.Рәкыйпов. *Берәүләр өчен хәзинә – сирәк очрый торган китап, икенчеләр өчен – фотоаппарат, ә филателист өчен – нинди дә булса таушалып беткән бер марка.* Робинзон эзләреннән

2) Товарда аның эшләп чыгаручысын күрсәткән штамп, фирма билгесе, келәймә. *Гармонь ничектер таныш кебек. Кая соң моның маркасы? Дусларым! Бу бит – безнең фабрика эше.* А.Расих. *Пакет эченнән --- кофта чыкты. Маркасын карадылар. Читят телдә «Made in China» дип язылган иде.* М.Мәһдиев

3) Бер үк билгеләнешле әйберләрнең, товарларның сорты, чыдамлыгы, егәре һ.б.ш. сыйфатларына карап бүленгән төре. *Чыбык яки кабельнең маркасы бинаның характерына карап сайлана.* Авыл хуҗалыгы электригы белешмәсе. *Клеверны сукканнан һәм махсус клевер угычларда уганнан соң, орлыкларны төрле маркадагы сортировкаларда, җилгәргечләрдә һәм җилгәргеч-сортировкаларда чистарталар.* Күпьеллык үләннәр

4) Товарның, ешрак транспорт чаралары, электроника кебекләрнең, җитештерүченең товар билгесе яки атамасы белән йөртелгән төре. *Машинаның шәп кай маркасы да: «Мерседес», «Волга», «Тойота»сы да.* Ә.Сынгыл-Куганаклы. *Тракторны, комбайнны, автомашинаның барлык маркаларын күз йомып йөртәм.* В.Нуруллин. *Станоклар гүли, димәк, эш бара. Тирә-юньдә – төрле маркадагы тракторлар, грейдерлар.* С.Шәрипов

5) *күч.* Авторитет, абруй, дан. *Без бит – фронтовиклар. Маркаңны төшермәскә иде...* М.Мәһдиев. *Жора тагын стаканына үрелде дә аның буш икәнлеген күргәч, ялварып сорады: – Төшермә маркаңны, Габдрахман, тагын ике йөз грамм ал.* М.Юныс. *--- моңа кадәр Колун кулыннан бер генә тоткынның да үз гаебен «танымыйча» чыкканы юк иде. Колун үз маркасын тотып, шуның белән горурланучы палач иде. Һәм үз маркасының дәрәҗәсен төшерергә теләми иде.* З.Зәйнуллин

6) *күч.* Кешегә, аның холкына, эшчәнлегенә карата мөнәсәбәтне чагылдырган, гадәттә тискәре характердагы бәяләмә; кушамат, ярлык. *--- безнең тикшерүебез фольклор материалларының һәрберсенә «дворянчылык» яки «капиталистлык» маркалары ябыштырып утыру булырга тиеш түгел ---.* Н.Исәнбәт

МА́РКА II *и. нем.* Евро әйләнешкә кергәнче Германиядә 100 пфеннигка, Финляндиядә 100 пеннига тигез акча берәмлеге. *Гитлер әйткән, ди, әллә ничә тапкыр: Мәскәүдән – Левитанны, Беренче Украина фронтыннан Ягудинны тотып китерегез, һәр икесенең башына йөзәр мең марка акча түлим, дип әйтеп әйткән, ди.* М.Мәһдиев. *Өй сатып алудан калган акчаларны соңгы*

маркасына чаклы кайтарып бирүе тагын?! Ш.Рәкыйпов

МА́РКА III *и. нем. тар.* 1) Урта гасырларда кайбер Көнбатыш Европа илләрендә крестьян общинасы

2) Франк дәүләтендә (VIII–IX йөзләрдә) һәм Германиядә Урта гасырларда маркграф җитәкләгән чик буе өлкәсе

МА́РКАЛАУ *ф.* Товарга марка I (*2 мәгъ.*) сугу, марка кую

МА́РКАЛЫ *с.* 1) Марка I (*1, 2 мәгъ.*) ябыштырылган, марка сугылган, маркасы булган. *Низамый, өстәл өстендә яткан «Сафо» маркалы саргылт тартманы ачып, безгә папирос тәкъдим итте.* М.Әмир. *Маркалы конверт*

2) Билгеле маркадагы I (*4 мәгъ.*), билгеле җитештерүченеке. *«Рекорд» маркалы иске телевизоры да аннан калган иске телевизор иде.* В.Нуруллин. *Төрле-төрле маркалы дистәләгән машиналар үзләре тирәсендәге кешеләр төркемен төяп, төрлесен төрле якка алып китеп бетерә.* Э.Мөэминова. *ДДН-30 маркалы озын агынтылы яңгырлау машинасы трактор белән эшли.* Яшелчәчелек

3) Югары сортлы. *Төрле маркалы кайбер төсле металларның кирәкле дәрәҗәдә җитмәве сәбәпле, графикны үти алмавыбыз тыныч лыкны ала иде.* Казан утлары. *Маркалы шәраб*

МА́РКАСЫЗ *с.* Маркасы булмаган, марка ябыштырылмаган. *Разия [Рәхимгә] маркасыз конверт тоттырды.* А.Расих

МА́РКЕР *м. ингл.* Текстта гы кирәкле урыннарны билгеләп кую өчен кулланыла торган төсле фломастер. *Стеналарга кара маркер белән язылган сүзләр дә таныш иде аңа.* М.Кәбиров

МА́РКЕРЛАУ *ф. махс.* 1) Келәймә сугу, маркировка ясау. *Маркерлаганнан соң мичкәләрне бозга урнаштыралар.* Яшелчәчелек

2) Маркер белән сызу, буразналар ерy. *Маркерлаганда һәм утыртканда буй һәм аркылы рәтләрнең туры сызыклы булуын һәм рәт араларының билгеләнгән киңлектә булуын нык күзәтергә кирәк.* Яшелчәчелек

МА́РКЕТ *и. ингл.* Кибет, магазин. *Бөтен кибетләр маркетка әйләнеп беттe. Маркет та маркет!.. Маркет та маркет! Акчаң булмаса, бар, кит! Бар, кит!..* Г.Зәйнашева

МАРКЕ́ТИНГ *и. ингл.* 1) Продукцияне җитештерү һәм сату мәсьәләләре белән шөгыльләнә торган икътисади дисциплина

2) Предприятиеләрнең эше белән идарә итү, продукцияне җитештерү һәм сатуны базар таләпләренә туры китереп оештыру эшчәнлеге. *Юкка гына хәзер чат саен менеджмент, маркетинг дип тел чарламыйлардыр шул.* Р.Зәйдулла. *Маркетинг эшләре дә Зөмәйрә Харисовна кулында хәзер.* К.Кәримов

МАРКЕТО́ЛОГ *и. ингл.-гр.* Маркетология белгече; маркетинг эшләре белән шөгыльләнүче хезмәткәр. *Икенче каттагы үзәк офиста исә компания президенты Мацэу әфәнде белән маркетолог Иваки арасында мондыйрак сөйләшү бара ---.* А.Гыймадиев. *Бу җәйнең бик матур көннәренең берсендә Дилә Нигъмәтуллина маркетолог белгечлеге буенча дипломлы булды.* Ватаным Татарстан

МАРКЕТОЛО́ГИЯ *и. ингл.-гр.* Маркетингны фәнни өйрәнү юнәлеше

МАРКЁР I *и. фр.* Бильярд уенында уенчыларга ярдәм итеп, исәпне алып баручы кеше. *Караңгы чырайлы, күз төпләре күгәргән чахоткалы маркёр: – Утыз һәм беркемгә дә! – дип акырды.* И.Тургенев

МАРКЁР II *и. фр. махс.* 1) Үсемлекләрне кулдан утырту яки чәчү алдыннан буразна сызу, рәт урынын билгеләү өчен эш коралы. *Әти бәрәңге тутырылган капчыкларны ташый, маркёр белән тигез-тигез итеп рәтләр сыза, ә без, оя ясап, чиләктәге бәрәңгеләрне шуларга салабыз да күмә барабыз.* Илһам Канатында. *Кулдан утыртканда, басуны башта буйга һәм аркылыга маркёр (билгеләгеч) белән билгеләп чыгалар һәм сызыклар очрашкан чатлыкларга рассада утырталар.* Яшелчәчелек

2) Чәчү агрегатына беркетелгән, чәчелгән җирнең чиген күрсәтеп, эз калдырып бара торган диск һәм штангадан торган җайланма

МАРКИЗ *и. фр.* Франция, Англия, Италия һәм Испаниядә дәрәҗәсе белән граф һәм герцог арасында торган дворян титулы; шул титул иясе. *Бездән түгел, граф, маркизлардан Туган кебек эре, тәкәбберләр, Кабинетларына шакып кергәч, алар безгә, белмим, ни әйтерләр?..* Р.Юныс. *Казанлылар аны Маркиз утравы дип тә йөртәләр, чөнки ул – ниндидер килмешәк маркиз биләмәсе.* М.Маликова

МАРКИ́ЗА I *и. фр.* Маркиз хатыны яки кызы

МАРКИ́ЗА II *и. фр.* 1) Тәрәзәгә яки балконга кояш төшмәсен өчен, аның турысына тышкы яктан беркетелгән тукыма япма

2) Өйгә керә торган ишек яки терраса өстендәге тукыма, тимер яки пыяладан ясалган түбә

МАРКИЗЕТ *и. фр.* **1.** Бик нечкә һәм бик чирак итеп катылган җептән тукылган үтәкүренмәле киҗе-мамык яки ефәк тукыма. *Рәшидә моңа бик куанды, күктәй ачык зәңгәр маркизетны кат-кат тотып та, сүтеп тә, өстенә каплап та карады.* Ә.Еники

2. *с. мәгъ.* Шундый тукымадан тегелгән. *Катя зәңгәр маркизет күлмәктән, ак панамадан, күбәләк шикелле җилфердәп, шәһәргә чыгып китте.* И.Гази. *Каюта тәрәзәсен ачып, рәшәткәне төшерде дә тиз генә юынып алды, аннары чәчен тарады, үтүкләнгән җиңел маркизет күлмәген киде.* Г.Әпсәләмов. *Чәчәкле маркизет күлмәге, ияк астыннан ук түгәрәкләнеп, муенын каплаган.* М.Мәһдиев

МАРКИРО́ВКА *и. нем.* 1) Товарга яки аның аерым кисәкләренә, ярлыкларга, төргәкләргә куела торган, хәреф, цифр, сызыкча кебекләрдән гыйбарәт билгеләр. *Озакламыйча машиналар килеп җитәргә тиеш, барлык әзер бүрәнәләргә маркировка ясап бетерергә кирәк.* Г.Әпсәләмов

2) Шундый билгеләр салу эше. *Ике ай буе Карп Васильевич яшь кенә бер егетне маркировкага – тамга салырга өйрәтте.* Г.Әпсәләмов

МАРКИРО́ВКАЛАУ *ф.* Маркировка ясау, маркировка үткәрү. *Азык-төлек продуктларын ирекле маркировкалау тәртибе һәм рөхсәт бирү шартлары турында положение, «Башкортстан*

продукты» билгесенең тасвиры Башкортстан Республикасы Хөкүмәте тарафыннан раслана. Г.Бахшиева

Маркировкалап бару Рәттән маркировкалау

Маркировкалап бетерү Барысын да маркировкалау

Маркировкалап кую Алдан яки тиз арада маркировкалау

Маркировкалап чыгу Баштан ахыргача маркировкалау

Маркировкалый башлау Маркировкаларга керешү

МАРКИРО́ВЩИК *и. рус* Маркировка эшен башкаручы хезмәткәр. *Беренче өйрәнчеге маркировщик эшен ошатмыйча ташлап киткәннән соң, Карп Васильевич яңасын бик төпченеп сайлады.* Г.Әпсәләмов. *Язмышым кушкандыр инде, сугыш башланган вакытта, Харьков шәһәрендәге заводларның берсендә маркировщик (эрегән металга сан куеп торучы) булып эшли идем.* Яңарыш

МАРКИТАНТ *и. ит. тар.* 1) Күп кенә Европа армияләрендә Борынгы Рим чорыннан XX йөзгә кадәр булган, поход шартларында азык-төлек әйберләре, эчемлекләр, гигиена кирәк-яраклары һ.б.ш. белән сату итүче вак сәүдәгәр

2) Алыпсатар. *Маркитантлар басты бар җир йөзен, Юнь итәргә башкача юнь дә юк...* Ә.Синугыл-Куганаклы

3) *ирон.* Сату-алуга хирыс кеше; җиңел һәм тиз баю ягын караучы кеше

4) *диал.* Җилкуар, сукбай

МАРКИТА́НТКА *и. рус* Маркитант хатын-кыз. *Яшь маркитантка да шунда үтерелгән.* Н.Абдулкәримова

МАРКСИЗМ *и. нем.* К.Маркс һәм Ф.Энгельс тарафыннан классик немец фәлсәфәсен, инглиз политэкономиясен һәм француз социализмын өйрәнеп нигез салынган фәлсәфи, икътисади һәм сәяси тәгълимат. *Учительская школа укучылары арасында марксизм идеяләре белән кызыксынучылар килеп чыга.* И.Нуруллин. *Марксизм тәгълиматы үзенең аяусыз сыйнфый көрәш идеясе белән миллионнарның күңеленкальбен пычратты ---.* Ә.Бөрһанов. *Марксизм тәгълиматына таянып фикер йөртсәк, тарихка Бөек Октябрь социалистик революциясе дип кергән олы вакыйга Россиядә булмаска тиеш иде.* М.Әхмәтҗанов

МАРКСИЗМ-ЛЕНИНИЗМ *и. рус* Марксизмның XX гасыр башында социал-демократик хәрәкәтнең идеологик нигезе булып хезмәт иткән һәм 1917 елдан соң Россиядә рәсми дәүләт идеологиясе дәрәҗәсенә җиткән догмалаштырылган варианты. *Татар шигыренең олы белгече профессор Хатип Госман марксизм-ленинизм тәгълиматына табынган, хакимияткә турылыклы шәхесләрнең берсе булып, шәкертләреннән дә шуны таләп итте.* Т.Галиуллин. *1934 елда Татарстан Мәгариф Халык Комиссариаты чакыруы буенча ул [Г.Гобәйдуллин] Казанга, университетта һәм марксизм-ленинизм фәнни тикшеренү институтында эшләргә кайта.* С.Алишев. *Марксизм-ленинизм тәгълиматының нигез ташларыннан берсе – пролетар революцияне баштан ук законлы рәвештә коммунистик революция итеп күзаллау.* Ә.Бөрһанов

МАРКСИСТ *и. нем.* Марксизм тарафдары. *Андый тарихның марксистлардан башка кемгә кирәге бар?* Ә.Бөрһанов. *Марксистлардан беренче буларак ул [М.Солтангалиев] теоретик һәм практик яктан бик тә мөһим әлеге мәсьәләне көн тәртибенә куя.* М.Әхмәтҗанов. *И.Терегулов һәм Ш.Тәһиров марксист революционерлар түгел, әмма алар бөтен гомерләрен һәм энергияләрен татар яшьләренә алдынгы фәнни белемнәр бирүгә багышлыйлар ---.* Казан утлары

МАРКСИ́СТИК *с.* Марксизм принципларына нигезләнгән, марксизм рухындагы, марксизм идеяләрен чагылдыра торган. *Социал-демократлар белән аралашу, марксистик идеяләр белән танышу Фатихның соңгы маягы сүнеп, алдында яңа маяк кабынуга гына китерде.* И.Нуруллин. *Татарстанда марксистик тарих фәненең үсеше Г.Гобәйдуллин исеме белән тыгыз бәйләнгән.* С.Алишев

МАРКСИ́СТИК-ЛЕ́НИНЧЫЛ *с.* Марксизм-ленинизмга хас; марксизм-ленинизм принципларына нигезләнгән, шуларны чагылдыра торган. *Дөньяны бутап бетергән, юл башына һәрчак канәчкеч тиран менеп утырырлык сукмак, мөмкинлекләр калдырган --- бу марксистик-ленинчыл тәгълиматта кешелек сыйфатлары, шәфкать, мәрхәмәт дигән зарурияттар бер дә юктыр шул!* А.Гыйләҗев. *Бай әдәбиятыбызга бүгенге көндә – үзгәреш чорында – марксистик-ленинчыл эстетика биеклегеннән торып --- дөрес бәя бирергә тиешбез ---.* Ә.Мәхмүтов. *Марксистик-ленинчыл философия күрсәтүенчә, очраклылык һәм зарурлык абсолют капма-каршы факторлар түгел, очраклылык үзара бәйләнешнең тик бер полюсы гына, аның икенче полюсы – зарурлык.* Дарвинизм һәм дин

МАРКСИ́СТЧА *рәв.* Марксизм таләп иткәнчә, марксизм принципларына нигезләнеп. *К.Нәҗми марксистча язылган классик хезмәт сыйфатында Г.Ибраһимовның «Кара маяклар һәм ак әдәбиятлар» --- исемле китабын саный ---.* Ф.Галимуллин

МАРКШЕ́ЙДЕР *и. нем.* Тау эшләре инженеры яки технигы, маркшейдерия белгече. *Болай да минем өчен маркшейдер эшен Габбас үтәп йөри икән.* Ә.Галиев. *Чунай таш карьерында өлкән яшьтәге маркшейдер бар иде.* Р.Кәрами

МАРКШЕЙДЕРИ́Я *и. нем.* Тау фәненең файдалы казылмаларның җир астында яткан катламнарының формасын, структурасын, зурлыгын өйрәнә торган бер тармагы

МА́РЛЯ *и. фр.* **1.** 1) Сирәк итеп тукылган, тегүчелектә, полиграфиядә, медицинада кулланылган юка киҗемамык тукыма. *Әнием миңа, мәктәптә укыганда, сәхнәдә биер, җырлар өчен, марля яки ситсыдан шундыйрак күлмәкләр тегеп бирә иде.* Л.Шагыйрьҗән. *Ул үзе дә, ефәк кисеядән (марлядан) ясалган кечкенә ятьмәне суга төшереп, бик кечкенә диңгез хайваннарын аулый.* Диңгез тирәнлегендә. *[Ландыш] Үләнен әледән-әле әйләндергәләп торалар, ә чәчәк төркемнәренә марля ябалар һәм, коелмасыннар өчен, аларны әйләндереп тормыйлар.* Урман аптекасы

2) Шундый тукымадан тар буй итеп кисеп ясалган, башлыча яраларны бәйләү өчен кулланыла торган материал; бинт. *Кулының буган урыны күгәреп шешкән. Бауны бушатырга туры килде. Марля кып-кызыл канга буялды.* Ж.Фәйзи. *Көннәр үтте... Солдат ярасыннан Ак марлялар инде алынды. Илнең ярасына ак марлядай Ап-ак йортлар, юллар салынды.* Ш.Галиев. *Әллә ничә кат марляны үтеп, [Перкунаснының] аягыннан кан саркый башлады.* А.Хәсәнов

2. *с. мәгъ.* Шундый тукымадан эшләнгән. *Медицина практикасында гадәттә мүкне стерилизацияләр, аны марля янчыкларга төеп тутыралар һәм яраларга ябалар.* Урман аптекасы. *Без палаткалар куябыз, черкидән саклану өчен, марля чыбылдык корабыз.* Дөньяда ниләр бар

МАРМЕЛАД *и. порт.* Җиләк-җимеш суына яки измәсенә шикәр һәм патока яки агар-агар кушып әзерләнгән кондитер эшләнмә төре. *Кара карлыган җиләкләрен шул килеш тә ашыйлар, алардан варенье кайнаталар, павидло, желе, джем, как, мармелад, --- кесәлләр ясау өчен дә файдаланалар.* Урман аптекасы. *Әрекмәннән кайнаткан павидло белән чәй эчәләр. Аңардан мармелад та эшлиләр.* Робинзон эзләреннән. *Аннан [ревеньнән] кесәл, варенье, шулай ук мармелад, цукат һәм башка кондитер әйберләре әзерләп була.* Яшелчәчелек

МАРОДЁР *и. фр.* **1.** 1) Сугыш кырында яралы һәм үлгән сугышчыларны талаучы яки сугыш хәрәкәтләре, табигый бәла-казалар яки башка экстремаль хәлләр булган җирдә халыкны талаучы кеше. *Кичерүемне сорыйсың? Сезнең кебек мародёрларны бездә менә шулай кичерәләр...* Т.Гыйззәт. *– Мародёрлар, сволочьлар! – дип сүгенде старшина. --- Курку адәм баласын ерткычка әйләндерә...* Х.Камалов. *Миннән барсын алдың. Мародёрларның күзе төшмәгән үлек кулындагы сәгать кебек, ялгыз калдым...* Р.Фәйзуллин

2) *күч.* Халыкның авыр хәленнән файдаланып, үзенә файда, табыш эшләүче кеше. *Сез нәрсә, мине үзегез ише мародёр дип беләсезме әллә? Карак дип, бандит дипме?* Ә.Баян

2. *с. мәгъ.* Талау белән шөгыльләнгән, мародёрлык иткән. *Теге мародёр полковник ничек искәрмәде икән боларны [атларны]? Әллә искәреп тә урларга курыкканмы?* Р.Зәйдулла

МАРОДЁРЛЫК *и.* Мародёр гамәлләре, шөгыле, гадәте. *Мародёрлык итү*

МАРОКЕН *и. фр.* **1.** Ясалма ефәктән тукылган тыгыз тукыма төре

2. *с. мәгъ.* Шундый тукымадан тегелгән

МАРС *и. голл. диңг.* Корабльнең мачта очында прожекторлар, навигация приборлары һ.б.ш. урнаштыру, офыкны күзәтү, паруслы корабларда парусларны бору, күтәрү-төшерү эшләре өчен ясалган кечкенә мәйданчык

МАРСЕЛЬЕ́ЗА *и. фр.* 1792 елда Бөек Француз революциясе вакытында чыгарылган, Парижга Марсель волонтёрлары алып килгән (исеме шуннан алынган), соңыннан Франциянең милли гимны булып киткән революцион җыр

МАРСИАН *и.* Марс планетасында яшәве ихтимал дип фараз ителгән тереклек иясе. *Марска киттек без! Марсианнар безгә каршы сугыш ачкан, ди. Шунда барабыз!* Аманулла. *Марсианнар һәм Венерадагы бай үсемлекләр дөньясы турындагы хыяллары-быз белән саубуллашырга туры килде.* Химиянең киләчәге. *Хосусан, ямананы чыккан Марс каналлары марсианнарның гидротехник корылмалары түгел, бәлки кечкенә кратерлар яки рельефтагы башка вак нәрсәләр тезмәсе булып чыкты.* Галәм. Җир. Кеше

МА́РСЛЫ *и. к.* **марсиан**. *Анда [Г.Уэллс романында] безнең Җир шарына килеп, атлап йөри торган каланчаларына утырып, кешеләрне аулап йөргән марслылар сурәтләнә.* Кызыклар дөньясында

МАРСЫК *и. диал.* 1) Эчендәге тукымалары борылып, ишелеп үскән, бик тыгыз, каты агач төбе. *Марсыкның төтене төнгә җитәр*. Әйтем. *Марсык яна белмәс, янса, сүнә белмәс, дия иде минем әти.* М.Хуҗин

2) *күч.* Үзсүзле, кире, тискәре холыклы кеше. *Урманлы якларда яшәүче күмер яндыручы татарлар тискәре, кире кешене «марсык» дип атыйлар.* К.Нәҗми

МАРТ *и. лат.* Календарь елның өченче, борынгы римлыларның сугыш илаһы Марс исеме белән аталган, 31 көннән торган ае. *Цементтан коелган кәкре баскыч янындагы эскәмиягә килеп утырган теге кызлар март чыпчыкларыдай чыркылдашалар.* Ш.Рәкыйпов. *Күк йөзе нинди зәп-зәңгәр, Һавалар нинди аяз! Март ае бүген урамда, Тәрәзәгә чиртә яз.* И.Әширов. *2009 елның 16 мартында Казанның боз сараенда аншлаг иде.* Мәдәни җомга

МАРТЕН *и.* Француз металлургы Мартен фамилиясе белән аталган, чуеннан һәм корыч калдыкларыннан корыч эретү, кою өчен махсус мич. *Берәүләре ут эчендә сугыша, икенчеләре кызу мартеннарда корыч кайната, өченчеләре җир астында, бик тирәндә, күмер чаба ---.* Г.Әпсәләмов. *Мартен миче Балкып, гөжләп тора: – Була, – дигәндәй.* Х.Туфан. *--- танкларны яртылаш диярлек тутык ашап бетергән. Нигә аларны, җыеп алып, мартен мичләренә озатмыйлар икән?* М.Юныс

МАРТЕНЧЫ *и.* Мартен мичен эшләтүче белгеч

МАРТЫ́ШКА *и. зоол.* 1) Мартышкачалар семьялыгына караган, озын арт аяклы, озын койрыклы һәм кыска борынлы үтә хәрәкәтчән маймыл. *Маймыллар дөньясы төрле һәм кызыклы. Без, мәсәлән, гориллалар, орангутан, шимпанзе, мартышкалар турында беләбез.* Кызыклар дөньясында. *Маймыллар дөньясы төрле һәм кызыклы. Бу асотрядка --- тар борынлылар (мартышкалар, макакалар, павианнар, мандриллар); кешесыман маймыллар (гориллалар, орангутаннар, шимпанзелар) керә.* Биология. *Кошлар, кимерүчеләр һәм бөҗәкләрдән тыш, агач башларында күп санлы маймыллар – мартышка, шимпанзе һ.б. яши.* Материклар һәм океаннар географиясе

2) *сөйл.* Гомумән маймыл

3) *күч.* Кыланырга, маймылланырга яратучы кеше

МАРТЫ́ШКАЧАЛАР *и. күпл. зоол.* Африка, Азия һәм Европада таралган, 140 лап төрне берләштергән тар борынлы маймыллар семьялыгы

МАРУЛ *и. бот.* Оешмачәчәклеләр семьялыгыннан, сөтсыман матдәләргә бай үрген тамырлы, ялангач сабаклы күпьеллык үлән үсемлек. *Марул --- безнең якларда басу-кырларда, ташландык җирләрдә үсә торган, тирән үзәк тамырлы, корыга чыдам чүп үләне ---.* Агулы үсемлекләр

МАРШ *и. фр.* **1.** 1) Сафта төп-төгәл ритм саклап, тигез атлап йөрү ысулы. *Попечительгә һәм укытучыларга чак кына башын иеп алгач, ул, маршка атлаган төсле ник басып, залның икенче ягына барып басты.* Ж.Тәрҗеманов

2) Хәрби частьләрнең оешкан төстә, транспорт чараларында яки җәяүле сафта бер урыннан башка бер билгеләнгән районга күчүе; поход. *Бу нинди хикмәт, бер дә бу агымны тыярлык көч юк микәнни?! Марш белән алга баралар бит!* Х.Камалов. *Дошман сугышларда сирәгәйгән дивизияләрен тулыландырып торды, йөзләрчә танклар, бронетранспортёрларга утырган марш батальоннары белән көчәйтте.* Казан утлары. *--- фронтка илтеп җиткерер юл буйлап атлап киттек. Ике сәгать «марш» бирдек.* Идел

3) Дәртле, кискен ритмлы, төп-төгәл атлап бару темпына яраклаштырылган үлчәүле музыкаль әсәр, башлыча хәрби музыка төре. *Бик авыр материаль шартларда яшәвенә карамастан ---, ул [С.Сәйдәшев] матур-матур җырлар, маршлар, башка музыкаль әсәрләр иҗат итә.* Р.Мостафин. *Баш очымнан, бик югарыдан Бөек Тукай маршы ишетелә. Бу кадәрле моңлы, назлы көйне Тыңламыйча калыр кемең генә?* Ф.Гыйззәтуллина. *Һ.Такташның «Камил», Г.Кутуйның «Күк күгәрчен» --- В.Киршонның «Җилләр шәһәре» пьесаларында җыр һәм маршлар аеруча киң урын ала, эчтәлекне ачыкларга ярдәм итә.* Казан утлары

2. *ы. мәгъ.* 1) Хәрбиләр телендә хәрәкәтне башлап җибәрү командасы. *Капитан Логиновның тавышы корычтай яңырады: – Кем разведкага тели, дүрт адым алга, марш!* З.Зәйнуллин. *Мондагы сержант кызылармеецларны алачык тирәли траншея казырга --- приказ биреп куарга тотынды: – Марш! Марш! Көрәкләр, балталар, хозвзводка, тизрәк, тизрәк!* Х.Камалов

2) Катгый рәвештә берәр урыннан китәргә таләп итү, кая да булса керергә яки чыгарга боеру сүзе. *– Я, инструментларыңны ал да марш конторага, живо! – дип кычкырып куйды [мастер].* Ш.Усманов. *Теге абый мине аякка бастырды да: – Карбыз ашыйсың килсә, үземә кил. --- Ә хәзер – марш өеңә! – дип артыма сукты.* Ж.Фәйзи. *Барыгыз, марш өегезгә! Кемнең эшлисе килми? Я?* М.Мәһдиев

◊ **Марш атлау (атлап йөрү)** Дулкынланганда, түземсезләнгәндә, бертуктаусыз арлы-бирле йөренү. *Юрист исә марш атлап йөргән җиреннән бер аягына басып, икенчесен атларга күтәргән көе каткан да телсез калган иде.* М.Мәһдиев. *Каршы дәшүче булмагач, [Коһл] кемгә барып бәйләнергә белмичә, марш атлап ишекле-түрле йөрде дә чыгып китте.* Ә.Галиев

МА́РШАЛ *и. фр.* 1) Кайбер дәүләтләрнең армияләрендә һәм авиацияләрендә иң югары хәрби дәрәҗә исеме; шундый дәрәҗәдәге кеше. *Китапханәдәге хәрби мемуарларны су урынына эчәм. Маршал Жуковның «Уйланулар һәм истәлекләр»енә чират җитте.* Ш.Рәкыйпов. *Әгәр инде маршал Тимошенко үзе рөхсәт иткән икән, Гәр Хутор егете Кәшфи Габделбарыев әлегә үзенең корыч айгыры белән илгә икмәк җитештереп торсын --- дигән икән, димәк, Кәшфи монда кирәк.* М.Мәһдиев. *Советлар Союзы маршаллары Тухачевский һәм Егоров халык дошманнары булгач, нигә ниндидер Шамил Усмановның дошман булмавына шикләнә икән ул?* Г.Тавлин

2) Кайбер дәүләтләрдә хөкүмәт, суд һ.б.ш. рәсми урыннарда эшләүчеләрнең чины; шундый вазифа башкаручы кеше

МАРШ-БРОСОК *и. рус* Хәрби частьнең бер сугышчан бурычны үтәү яки өйрәнү максаты белән бик кыска вакыт эчендә дислокациясен үзгәртүе, икенче урынга күчүе. *Марш-бросок белән тагын бер ыргым ясап, төн урталарында тиешле квадратка барып җиттеләр.* Х.Камалов. *--- нәрсәләргә генә өйрәтмәделәр аларны. --- Окоп эчендә сапёр көрәге белән кул сугышы оештыру, тревога белән чыгып йөгерү, төн уткәнче кырык-илле чакрым араны марш-бросок белән үтү...* З.Зәйнуллин

МА́РШАЛЛЫК *и.* Маршал дәрәҗәсе, маршал исеме

МАРШИРО́ВКА *и.* Марш (*1 мәгъ.*) белән йөрү, саф-саф булып үтү. *Беренче җыелуда тарих факультеты алда иде. Икенчесендә, маршировка вакытында, ректор минем планны бозды да ташлады.* И.Салахов. *Гимназистларны маршировкага һәм мылтык белән эш итәргә өйрәтә башладылар.* Ж.Тәрҗеманов

МАРШРУТ *и. фр.* 1) Үтеләчәк пунктлары алдан ук билгеләнеп куелган юл, төп юнәлеш. *Мин сиңа хат язармын. Маршрутыгыз билгеле бит.* М.Маликова. *Маршрут буенча алга барабыз, укучым.* Т.Нәҗмиев. *Театрның гастроль маршрутлары Урал шәһәрләреннән алып Казахстан далаларындагы чирәм җирләргә кадәр барып җитә.* М.Шиһапов

2) Шәһәрдә автобус, трамвай һ.б.ш. ның йөрү схемасы, юлы һәм шул схема белән йөргән аерым бер җәмәгать транспорты. *--- Одесса халкына мондый трамвай кулай тоелган, ахры, башка маршрут трамвайларын күптән яңага алыштырсалар да, унсигезенче трамвайны һаман саклый килгәннәр.* М.Юныс. *--- Айсылу --- трамвай вагонына сикереп менде, ничәнче маршрут трамвай икәнен дә карап торырлык хәлдә түгел иде. Алтынчы маршрутныкы булып чыкты.* Б.Камалов. *Көтеп-көтеп тә трамвай килмәгәч, маршрут таксие белән тулай торакка кайттым.* Л.Шәех

МАРШРУТЛЫ *с.* Маршруты төгәл билгеле булган. *Мин дә шәһәрнең бердәнбер маршрутлы троллейбусына утырырга ниятлим инде...* М.Вәлиев. *Ә чыбыклы телефон гел өеңдә уяу тора, фатирыңны, малыңны саклый,*

килгән хәбәрләрне язып бара, төшеп югалмый, маршрутлы таксиларда урланмый ---. К.Кәримов. *Син үзең дә бер генә юлдан йөрүче «маршрутлы трамвай» булмадың кебек?..* Н.Гамбәр

МАСАЕШУ *ф. урт. юн. к.* **масаю**

МАСАЙТУ *ф.* Масаерга (*1 мәгъ.*) сәбәп, нигез булу; масаерга ирек бирү, эре кыланышына юл кую, узындыру. *--- кешене үз күз алдында ул тиклем күккә чөргә ярамый, чөнки мактау бәгъзе берәүләрне масайта, боза, тәкәбберләтә.* С.Поварисов. *«Чистай чалмалысы» Каргали әтәче кебек масайта моны, күрәмсең, мәйтәм.* Х.Вәлиәхмәтов

Масайтып җибәрү Бераз масайту

МАСАЮ *ф.* 1) Тәкәбберләнү, үзен башкалардан өстен кую, артык эре кылану, эреләнү, һавалану; мактану. *Милләт өчен эш кырмаса да тиенлек, Масаеп түш киереп алар йөрерлек.* Ә.Синугыл-Куганаклы. *Ә масаю дигәнең тора-бара мин-минлеккә күчеп, кешенең кешелеклелеген тәмам бетерә, адәми затка охшаган бер җанварга әверелдерә.* З.Фәтхетдинов. *Масайдың, хатын, әй масайдың. Борын күтәрә башладың. Ни өчен икәнен дә беләм, беләм.* Х.Ибраһим

2) Горурлану, хаклы рәвештә мактану. *Мактау сүзләрен дә күп ишетте, әмма масаймады*. М.Насыйбуллин

Масаеп алу Бераз гына мактанган, масайган кебек булу

Масаеп йөрү Һәрвакыт яки еш кына масаю; һәр җирдә, һәркем алдында масаю. *«Мин инженер, мин кара эш эшләргә тиеш түгел», – дип кенә җибәрә. Үзенең югары белеме белән масаеп йөри.* М.Юныс. *--- ул Хлебодаровкада масаебрак йөри башлады, элек үземне бик түбәнсетеп, кирәгеннән артык тыйнак һәм күзгә ташланмый гына яшәгәнмен икән, дип уйлады.* Р.Мирхәйдәров. *Шулай дигәч, мин үземне Зур диеп белгән идем, Устем инде хәзер, диеп Масаеп йөргән идем.* Ә.Бикчәнтәева

Масаеп китү Билгеле моменттан башлап масая башлау, холкында масаю билгеләре барлыкка килү. *Госман Гомәр дигән өметле каләм иясе бар бездә. Аңа уңышлар телик. Тик масаеп китә күрмәсен.* Б.Камалов

Масаеп тору Берара, күпмедер вакыт масаю. *Йортларның берсе генә дә: «Мин монда – иң зур, иң матур йорт, чөнки минем хуҗам башка хуҗалардан баерак та, акыллырак та», – дип масаеп тормый.* М.Юныс

МАСАЮЛЫ *с.* Масаюны чагылдырган, эре кыяфәтле, тәкәббер. *Күз алдыма хыялый, уенчак, үзенең чибәрлегеннән бераз масаюлы да кыз килеп баса.* Г.Ахунов. *Суднонының һәр иллюминаторы, һәр винты, мин – пароходчылыкның флагман корабы дигәндәй, масаюлы горурлык белән күзгә бәрелеп китә.* М.Юныс. *[Майор] Корт чаккандай кинәт талпынып алды да, масаюлы биеклектән торып, усал итеп Таһировка текәлде ---.* М.Хафизов

МАСАЮЧАН *с.* 1) Һәрвакыт мактана, эреләнә торган, тәкәббер, һавалы. *Адәм еш кына масаючан, мактанучан җан шул.* Г.Хәсәнов. *– Син, Идмас, куык очырма әле. – Әнис масаючан кешеләрне яратмый иде.* Ә.Хәсәнов. *Мөгаен, бу яңа рухани, һәрбер яшь кеше шикелле, зур планнар корадыр, ә бәлки, хәтта масаючан, дан сөючәндер ---.* Р.Мирхәйдәров

2) Масаюны чагылдырган, масаю белән эшләнгән. *Шундук як-ягына масаючан караш ташлап өстәде: – Үзең әйтмешли, ул кадәр хафаланырлык сүз әйтмәдем ич.* М.Хәсәнов

МАСАЮЧАНЛЫК *и.* Кешегә хас булган тәкәбберлек, эреләнү, үзен кешедән өстен кую кебек сыйфатлар, шундый характер үзенчәлеге. *Урыс кешесенең, аеруча аның интеллигенция дип аталган өлешенең, бөекдержавачылык масаючанлыгы рус халкының үз өстенә күсәк булып төшәчәген алар аңламадылар һәм әле дә аңлап бетерә алмыйлар.* Т.Миңнуллин. *Масаючанлык, тәкәбберлек исламда да хупланмый.* Ш.Җәләлиев. *Ул әтине масаючанлыкта гаепләү белән генә чикләнми, аны иҗат принципларының дөрес булмавында да гаепли башлый.* Тажи Гыйззәт: истәлекләр, мәкаләләр

МА́С БУЛУ *ф. иск.* Масаю, эреләнү, тәкәбберләнү. *Такка менгәч мас булган Туйгужа улы Туктамыш Әзәлдән сиңа яу икән, Әзәлдән миңа яу булды ---.* Дастан

МАСДАР *и. гар. лингв.* Исем фигыль. *Татар телебездә әдат масдар ошбу ике төрледер ки, кәлимәнең хоруф тәткибиясенә карап, калын яки нечкә әйтеләдер.* К.Насыйри. *Масдар теркәгеч тә, теркәлмеш тә булырга мөмкин. Мәсәлән: укуның ләззәте, йөрү вакыты, ашамакның әдәбе, аның укуы ---.* Ж.Вәлиди. *[Г. Ибраһимов тарафыннан] Фигыльләр алты төргә бүленә: боерыклар, хәбәр фигыльләре (хикәя фигыльгә туры килә), төрдәшләр (сыйфат фигыль), шарт фигыльләре, хәл фигыльләре, масдар (инфинитив һәм исем фигыль).* Б.Хәкимов

МА́СКА *и. лат.* 1) Битне каплый торган, күзләр өчен кечкенә тишекләре булган, кайберләре кеше йөзе яки хайван башы формасында эшләнгән, борынгырак заманнарда дини йолаларда, соңрак театрда яки маскарадларда кулланылган япма, бәйләвеч. *Битенә маска кигән кешенең кулы бөтен экран зурлыгында булып йодрыклана да, көт тә тор, үтереш башлана.* Ж.Фәйзи. *Курчак театрында бик үзенчәлекле артист. Маскасын салгач та күрдем – «ачтым» мин аны үзем өчен. Үз йөзе кызыклы икән!* Ш.Галиев. *Узен тануларына гаять тә кәефе кырылган малай авыр сулап бүре ягына карап куйды һәм маскасын салды.* А.Гыймадиев

2) Армиянең яки полициянең кайбер махсус частьләрендә махсус киемнең, форманың бер предметы булган битлек. *Йокыга киткәнемне көтеп кенә торганнармы, төн уртасында, өченче каттагы тәрәзәне ватып, маскалар кигән, муеннарына автоматлар аскан «омон» киемендәге җиде-сигез әзмәвердәй ир-ат бәреп кермәсенме яныма!* Р.Мөхәммәдиев

3) Җинаятьче, үзен кеше танымасын өчен, йөзенә кия торган каплавыч. *Сәфәрче йөзеннән берни укып булмый, маска кигән фатир талаучы диярсең.* Т.Галиуллин. *--- тартма тартып чыгарды. Анда теге карабин иде. Элек әзерләп куелган, чаңгыда йөри торган баш киеменнән ясалган масканы да*

сумкага салдылар. Р.Сәгъди. *Мәлсның йөзе җитдиләнеп китте: – Маскадан талаучылар, бандитлар, шамакайлар гына йөри.* Ф.Садриев

4) Үлгән кеше йөзеннән алына торган, күп кенә борынгы халыкларда аның каберенә куелган, төрле материаллардан, хәтта алтыннан, соңгы чорларда күбрәк гипстан коелган күчермә. *--- критлыларның фреска, ваза һәм статуэткалардагы сурәтләренә һәм, бигрәк тә, төрбәләрдәге алтын маскаларга игътибар итик, – дип яза И.А.Резанов.* Ә.Кәримуллин. *Ул институтның китапханәсендә Ф.Әмирханның бит маскасы булуы, аны кемдер төшереп ватуы турында да борчылып сөйли иде.* Ф.Ибраһимова

5) Медицинада төрле максатларда кулланыла, авыз-борынны каплап киелә торган бәйләвеч. *Сәгать унда ул инде резин перчаткалар кигән кулларын терсәктән бөккән, авызына маска бәйләткән килеш, бер минут кичекмичә, операция өстәле янына килеп басты.* Г.Әпсәләмов. *Таныдым мин аны. Иң кызыгы шунда: беренче тапкыр күргәндә дә ул марля маскада иде сыман.* М.Хәсәнов. *Стерилизацияләү чаралары Көнбатыш стандартларына туры килә, тик бер ассистентның гына маскасы борынын бөтенләй капламаган.* Я.Шәфыйков

6) *махс.* Кайбер спорт төрләрендә йөзне травмалардан саклау өчен киелә торган битлек

7) Төрле тармакларда сулыш юлларын саклау, ясалма сулыш алдыру, кислород белән тәэмин итү һ.б.ш. җайланмаларның борын һәм авызга киелә торган өлеше. *Миргазиян ага – заманында, акваланг маскасы киеп, диңгез төпләренә төшкән --- егет...* М.Галиев. *Маска киеп, авызга көпшә кабып чумарга өйрәнсәң шәп инде, әлбәттә.* А.Тимергалин. *Берсе «газ!» дип, яман кычкыра, Сигнал бирә ракета чөеп. Кайсы ава, кайсы йөгерә, Башларына маскалар киеп.* Р.Фәйзуллин

8) Косметикада дәвалау, тирене йомшарту һ.б.ш. максатлардан биткә, муенга сылана торган крем, дәвалау катнашмасы катламы. *Дымландыргыч маска*

9) *күч.* Кешенең башкалардан үзенең чын асылын яшерү, алдау яки яхшырак күренү өчен кабул иткән тышкы кыланышы, ясалма күренеше, эшчәнлеге. *Узенә кагылдыңмы, дуслык маскасы да, мәхәббәт кабыгы да төшә, инстинкт буенча үзен генә кайгырта кеше.* Ш.Галиев. *Барысы да Америкача: мактаулар, рәхмәтләр, кычкырып-кычкырып көлүләр, бәхетле маскалар, тик иң кирәк нәрсә юк: җан юк.* Н.Измайлова. *Кайвакытларда барлык бу фикерләрне бик читләтеп кенә, маска астына яшереп кенә сөйләделәр ---.* Умарта кортлары

◊ **Маска кию** Ясалма кыяфәт чыгару, үзенең чын йөзен, асылын яшерү, икейөзлеләнү. *Хакыйкать маскасы кигән ялган булмасын...* Ш.Галиев. *Гафу итү өчен кешечә хисләр кирәк, ә миндә ул юк! Тагы икейөзләнергә, маска кияргәме? Юк!* Х.Камалов. *Шул рәвешле, маска киюнең сәбәбе – гади бер усаллык түгел, ә чын мәхәббәткә ирешү.* Р.Гали. **Масканы салу** Үзеңнең кемлегеңне яшерми башлау, икейөзлеләнүдән туктап, гадәти кыланышыңа кайту, чын йөзеңне ачу. *Мин маскаңы салам... Ах, сагындым, Кайтыйм инде, җитәр, үземә.* Р.Аймәт. **Маскасын салдыру** Фаш итү, чын асылын күрсәтү

МАСКАРАД *и. ит.* 1) Катнашучылар билгеле әкият персонажларын, әдәби әсәр геройларын хәтерләткән үзенчәлекле маскалар һәм махсус костюмнар кигән күңел ачу кичәсе, бал. *Дөньякүләм маскарадтан соң, Салып ташлап иске җиләнен, Иске ел көлә: – Мин исән!* Р.Әхмәтҗан. *Халык тамашалары, маскарад, мәйдан театры корулар шәһәр мәдәнияте белән бәйле.* Р.Ягъфәров. *Илшат, бик бирелеп, Яңа ел маскарадында үзенең «Ну погоди»дагы бүре булып киенәчәге турында сөйли башлаган иде ---.* А.Гыймадиев

2) *күч.* Шаярту яки ялгыш фикер тудыру максатыннан күрсәтелгән ясалмалык, ялган кыланыш. *Аңламый торам. Нигә бу вакытсыз маскарад?* А.Гыйләҗев. *Бары антрополог кына аны [кроманьон кешесен] танып алыр, маскарадны шунда ук фаш итәр, чөнки аның һөнәре – кеше турындагы фән.* Химиянең киләчәге

МАСКИРО́ВКА *и. фр.* 1) Маска һәм башка чаралар ярдәмендә тышкы кыяфәтне үзгәртү. *Мин әйтәм: – Арсланов, нишләп Сократныкыдай киң һәм биек маңгаеңны чәч төшереп әрәм итәсең? – Маскировка, – дигән була.* Р.Зарипов

2) Үз гаскәрләреңне яки тыл объектларын дошман күзәтүеннән коткару яки дошманны алдау максаты белән, аларны яшерүгә юнәлтелгән төрле чаралар комплексы. *Лейтенант белән икесе, маскировка складына барып, язгы табигать үз канаты астына яшерә ала торган төстәге маскхалатлар киеп юлга чыктылар.* Ф.Кәрим. *Алар икесе дә маскировка өчен зур-зур агач ботаклары белән капланганнар.* Ә.Галиев. *Маскировканы махсус карап йөрүчеләр билгеләнгән: бер чеметем яктылык шәйләп алсалар, тәрәзәңне ватарлык шакып, әрләп-сүгеп китәләр.* Г.Сәгыйров

3) Маскировкалый торган нәрсә, маскировкалау чарасы. *Тәрәзәләрдә маскировка булганлыктан, өй эче дөм караңгы --- иде.* Г.Гобәй. *Баракларда төннәрен ут яндыру һәм тәмәке тарту катгый рәвештә тыела иде. Шуңа күрәдерме, тәрәзәләрдә бертөрле дә маскировка юк иде.* Ә.Галиев. *--- шофёрның муенындагы кызыл шарфы белән машинаның яшел «күзе» шосседан күренеп тормаслык итеп тәмам томаладык без. Чып-чын маскировка булды!* М.Вәлиев

4) Тереклек ияләренең, төсе, формасы һ.б.ш. белән тирә-якстан аерылып, күзгә бәрелеп тормас өчен, үзе яшәгән мохиткә яраклашуы. *Күп кенә елаННарның саклагыч төсе әйләнә-тирәлек төсе белән яраша. Бу ау вакытында маскировка өчен кирәк.* Т.Шакирова. *--- балыклардан күп нәрсәгә өйрәнергә мөмкин. Алар иң камил маскировканы беләләр.* Кызыклы ихтиология

5) *күч.* Кешенең үзенең чын фикерен, эшен, гамәлләрен башкаларга белгертмәскә тырышуы, чын йөзен күрсәтмәве. *Башта ук без Булатовның тупас, сөйкемсез бәндә икәнен күрәбез.*

Аның бертөрле хәйләсе, маскировкасы да юк. М.Җәлил. *--- битарафлык ул – теләк белән чынбарлык арасында кискен контраст килеп чыкмасын, алда булачак күңелсез хәлләр турында күп уйламас өчен корылган маскировка гына...* В.Леви

МАСКИРО́ВКАЛАУ *ф.* 1) Тышкы күзәтүне мөмкин кадәр кыенлаштыру өчен, күзгә бәрелеп тормаслык, күренмәслек, сизелмәслек итеп ышыклау, буяу, каплау кебек чаралар күрү. *Алар өчен бу соңгы окоп буласын малайлар белмиләр иде әле, шуңа күрә брустверларын бик тырышып ясадылар, чирәм һәм яшел ботаклар белән маскировкаладылар.* Галәмгә юл

2) Маскировка (*3 мәгъ.*) ролен үтәү, маскировка чарасы булып тору. *Төсләре төрле-төрле һәм үрмәкүчне яшәү тирәлегендә еш кына маскировкалый.* Биология. Хайваннар

3) *күч.* Тиешенчә аңларга комачаулау, әһәмиятен бәяләргә мөмкинлек бирмәү. *Күч аеручылык төшенчәсен характерлый торган хисапсыз күп фактлар эчендә ялгызлык һәм аерымлык тереклек ияләре табигатенең гомуми законнары тәэсиренең монда чагылуын яшерә һәм маскировкалый.* Умарта кортлары

МАСКХАЛАТ *и. рус* Маскировка (*2 мәгъ.*) өчен кием өстеннән киелә торган, төсе әйләнә-тирә белән бердәй булган махсус халат яки комбинезон. *Аларның битләреннән тир ага, икесе дә гыжлап беткән, маскхалатлары ерткаланган.* Г.Әпсәләмов. *Алар совет солдатларыннан сакланып йөрми, маскхалатлар да кими, иелеп-бөгелеп тә узмый.* Г.Ахунов. *Әрекмән яфрагы күләгәсенә, солдатның маскхалаты төсендәге сыртын судан чыгарып, бер бака йөзеп килде.* Т.Миңнуллин

МАСЛЁНКА *и. рус сөйл. к.* **майлагыч**. *--- [Буханько] бик тыныч кына үзенең маслёнкасы белән чүкечен җирдән алды да читкә атлады.* Х.Камалов

МАСОН *и. фр.* Масонлык тарафдары. *--- партия байлары безнең масоннар белән тигезләшүебез өчен үпкәләргә мөмкиннәр, шайтан алгыры.* Р.Мирхәйдәров. *Ул Сабит Садыйкович авызыннан үз гомерендә беренче мәртәбә «масон» дигән ят сүз ишетте.* З.Хөсният. *--- дөнья белән кем идарә итә, дигән сорауга җавап эзли-эзли, масоннар белән дә нык кызыксынган, үзе әйткәнчә, әдипләр белән дә аралашкан, татарның чын тарихын яхшы белгән Мөхәммәт аны барыбер аңлый алмый.* Р.Шәрәфиев

МАСОНЛЫК *и.* XVIII йөз башында Англиядә барлыкка килгән, Россиядә XIX йөз башында укымышлы дворяннар арасында таралган, барлык кешелекне берләштерү идеяләренә нигезләнгән әхлакый-дини агым. *Халыкара масонлык оешмасын да, гангстерлыкны да мафиядән аерып карап булмый.* Р.Фәйзуллин. *Яңүд халкындагы бердәмлек, үзара ярдәмләшү күренеше, автор фикеренчә, аларның үз вакытында масонлык оешмаларына берләшүендә.* Ә.Закиржанов

МА́ССА *и. лат.* 1) Материянең төп физик билгеләреннән берсе булган һәм аның инерцион һәм гравитацион күрсәткечләрен билгели торган үзлек

2) Бер җисемнең микъдары, күләме. *Электроннарның массалары да, корылма микъдарлары да үзара тигез булганлыктан, электроннарның күчеп йөрүеннән ярымүткәргечнең структурасы үзгәрми.* Серле кристаллар. *--- аның [Айның] аркылысы Җир диаметрының чиреге чамасы, ә массасы Җир массасыннан 81 тапкыр кимрәк.* Галәм. Җир. Кеше. *Атом физикасында атом төшләренең массалары чагыштырмача берәмлекләр белән күрсәтелә ---.* Физика курсы

3) Формасыз матдә. *Трюмнарда сарык. Куркудан, үзара укмашып, алар тоташ соргылт массага әйләнгәннәр.* М.Юныс. *Клеверны тик яхшы киптерелгән килеш кенә сугалар, чөнки коры массаны сукканда, орлыклар яхшы коела.* Күпьеллык үләннәр

4) Гадәттә эшкәртелеп бетмәгән, камыр сыман сыек яки ярым сыек катнашма. *Һәртөрле тау токымнары да, үсемлекләрнең яшел массасы да --- аның [химия] өчен чимал булып хезмәт итәчәк.* Химиянең киләчәге. *Нефтьтән – шушы каракучкыл куе массадан – меңләгән продуктлар ясыйлар.* Дөньяда ниләр бар. *Бу күренеш тә инерция аркасында була: чи йомырка эчендәге сыек масса каты кабык туктаганнан соң да әйләнеп тора ---.* Кызыклы физика

5) Хисапсыз күп санда булган кешеләр яки бик зур күләмдә җансыз нәрсәләр. *Барыгыз да бер калып белән язасыз? Кая масса өчен язылган җырлар?* Ж.Фәйзи. *Такташ, үтә дә җитди фикерләрне укучылар массасына җиткерү өчен, шигырьгә нәни шаярту элементлары керткәнне күпме генә аңлатырга тырышса да, тәнкыйтьчеләрнең күпчелеге үз сүзендә кала.* И.Юзеев. *Шулай шул. Үзеңне сәләтсез халык массасы арасында итеп сизү кыен...* М.Маликова

6) *тех.* Бер үткәргечле электр челтәренә тоташтырылган төрле механизмнарда машинаның икенче үткәргеч булып хезмәт иткән барлык металл өлешләре. *--- берни дә барып чыкмый. Я камера янып тишелә, я клапан ката, --- я кислород краны ага башлый, я соплолар һәм тышлык янып чыга. Я шәм массага тоташа...* Галәмгә юл

7) **массалар** *күп.* Халыкның киң катлаулары; бик күп кешеләрне эченә алган бергәлек. *Ләкин, юлына корылган барлык киртәләрне җимереп, дарвинизм үз ягына яңадан-яңа массаларны яулап ала.* Дарвинизм һәм дин. *Конвейер, модага, ихтыяҗга яраклашырга өлгерсә дә, аерым кешене түгел, массаларны күздә тотып хәрәкәт итә.* Казан утлары

МАССАГЕТ *и. гр.* Каспий аръягы һәм Арал буенда күчмә яки ярымкүчмә яшәү рәвеше алып барган кайбер кабиләләрнең антик тарихчылар кулланган җыйма исеме. *Вавилоннарны буйсындыргач, мидәннәр шаһы Бөек Кир массагетларны яуларга уйлады.* М.Хәбибуллин. *V гасырда яшәгән массагетлар турында Геродот: «Алар хөрмәт иткән бердәнбер алла ул – Кояш. Кояшка алар ат корбан итеп бирәләр», – ди.* Н.Фәттах

МАССАЖ *и. фр.* Дәвалау яки косметик максат белән гәүдәнең аерым урыннарына механик тәэсир итү (ышку, уу,

сылау, бәргәләү һ.б.ш.) ысулларының системасы. *Гөлнур сава башлаганчы ничегрәк итеп массаж ясау, ничә төр массаж куллану, аның әһәмияте турында сөйли.* М.Хәсәнов. *Без бит масажны сөяк шыгырдату, ачык җиргә шап-шоп бәрү, көтмәгәндә авырттырып чеметеп алу, соңыннан «тәмле» иттереп сыйпаштырып кую дип кенә күз алдына китерәбез.* Т.Галиуллин. *Яңа дәвалау йортында иң файдалы процедуралар җайга салынды: --- массаж, физик күнегүләр, диетик тукланы – барысы да кеше гомерен озайтуга хезмәт итә.* Казан утлары

МАССАЖИСТ *и. рус к.* **массажчы**. *Иртәнге чәйдән соң палатага озын буйлы, чәчсез йомры башлы, зур, көчле куллы массажист килеп керә торган булды.* Т.Галиуллин. *И-и, әйбәт массажист икәнсез! Булды! Җитте! Их! Рәхәтләнеп киттем!..* Г.Зәйнашева. *Укуны тәмамлап, массажист булып эшкә урнаштым.* Н.Әхмәдиев

МАССАЖЛА́У *ф.* Массаж ясау, сылау. *--- анда [сыерларны] бозаулатуга әзерлиләр: җиленнәрен массажлыйлар һәм башка зооветеринария чаралары үткәрәләр.* Татарстанда терлекчелек

Массажлап алу Аз гына, тиз генә массажлау. *Сыер ашаган арада, робот зур, тимер кулын сузып, җиленне әзерли: аны юа, массажлап ала, беренче сөт агымын идәнгә саркыта.* Татарстан яшьләре

Массажлап җибәрү Берара массажлау; җиңелчә генә массажлау

Массажлап тору Даими рәвештә, регуляр төстә массажлау

Массажлап чыгу Бер-бер артлы барысын да массажлау. *Муенның арткы өске өлешеннән башлап, әйләнмәле хәрәкәтләр белән башның бөтен өлешләрен дә массажлап чыгыгыз.* Безнең гәҗит

Массажлый башлау Массажларга керешү. *--- елаган авазлар йөрәкне тагы да ныграк бимазалый, кисә... Без, үзебез дә сизмәстән, учларыбыз белән йөрәк турын уа, массажлый башлаганбыз.* Х.Камалов

МАССАЖЧЫ *и.* Массаж ясаучы, массаж алымнарын һәм ысулларын кулланып дәвалаучы белгеч. *--- тәне авыртудан җыерыла-куырыла башлаган бала, массажчының тылсымына буйсынгандай, бөтенләй таралып урынга сеңә.* Г.Афзал. *Шәһәрнең мәшһүр массажчысы, Кавказдан махсус чакыртылган әрмән Григорьян көне буе алар белән мәшгуль була.* А.Гыйләҗев. *Сезгә йөзләгән кешеләр – сакчылар, шофёрлар, --- мунчада арка чабучылар, массажчылар һәм башкалар хезмәт күрсәтер.* Ф.Баттал

МА́ССАКҮЛӘМ *с.* **1.** 1) Зур халык массалары, бик күп кешеләр катнашында башкарыла торган. *Мондый күченүләр, шул исәптән массакүләм күченүләр дә, бик борынгы заманнарда да булган, дип уйларга кирәк.* Ә.Кәримуллин. *Халык шундый массакүләм хәрәкәткә җәлеп ителгән көннәрдә татар феодализмының нигезенә дә балта чабыла ---.* М.Гайнетдинов. *Ул арада чуалышлар татарлар арасында да массакүләм төс ала.* Ватаныбыз тарихы

2) Гомуми алып барыла, глобаль күләмдә башкарыла торган. *Хикмәт шунда ки, Сталинның бөтен бөек эшләре массакүләм террор белән бергә үрелеп барды.* Ә.Еники. *Ареалдан куылуның төп сәбәбе – төрнең саны массакүләм арту периодында азык җитмәү.* Биология. Хайваннар

3) Халыкның киң катлауларына исәпләнгән, массалар өчен билгеләнгән. *--- ул вакытларда телевидение, компьютер, Интернет кебек массакүләм мәгълүмат чаралары турында әкияттән дә укып белми идек.* Р.Миңнуллин

4) Массалы рәвештә җитештерелә торган, бик күп күләмдә эшләнә торган. *Массакүләм җитештерү*

2. *рәв. мәгъ.* Күп итеп; гомуми рәвештә, массалы төстә. *Ләкин хазарларда VIII гасырда ук башланган акча сугу эше мөстәкыйль, ягъни үз акчаларын массакүләм чыгаруга китерми.* Ә.Мөхәммәдиев. *Ташбакаларны массакүләм тоту һәм аларның күкәйләрен браконьерларча җыю яшел ташбакаларның санын сизелерлек киметте.* Биология. Хайваннар

МА́ССАЛАШТЫРУ *ф.* Киң халык катламнарына җиткерү, массалар арасында тарату, популярлаштыру. *Революция һәммә гыйлемнәрне массалаштыруга бара, массаның тәҗрибәләрен гыйлем дөньясына бирә икән, тюркология съезды бу хакта, бу мәсьәләләрдә беренче тәҗрибә булды.* Г.Ибраһимов

МА́ССАЛАШУ *ф.* Популярлашу, киң халык массалары арасында таралу, күпләр тарафыннан үзләштерелү. *Ясалган сүзләрнең барлыгы да телнең сүзлек составына урнашып китми; күп яңа сүзләр авторлары телендә генә чагылып кала, массалашмый.* Ш.Рамазанов

Массалашып бетү Бөтенләй массалашу

Массалашып җитү Тәмам массалы төс алу

МА́ССАЧЫЛ *с.* Массалы төстә, киң масса, бик күп кешеләр катнашында башкарыла, үткәрелә торган. *Ортега карашынча, хәзерге заман кешеләренә массачыл төс ала бару («омассовление»), «уртача»га («усреднённость») әверелү, индивид буларак шәхес сыйфатларын югалта бару хас.* К.Гыйззәтов. *Драмада матур, психологик яктан бай күренешләр – дуэтлар да, массачыл хәрәкәтләр дә урын алган.* В.Әминева. *Мондый эш патша хөкүмәте тарафыннан татарлар яшәгән барлык үзәкләрдә дә үткәрелеп, 1910–1914 елларда массачыл күренешкә әйләнгән.* Ф.Җәүһәрева

МАССИВ I *и. фр.* 1) Килеп чыгышы һәм геологик төзелеше ягыннан бердәй, озынлыгы һәм киңлеге чагыштырмача тигез булган тау калкулыгы. *Килиманджароны – мәңгелек кар каплаган 19710 фут биеклегендәге тау массивын – Африканың иң биек ноктасы, диләр...* М.Мәһдиев. *Мәсәлән, Макквелл тау массивы өлкәсендә, иң биек тау башында, 100 километрлы иңкүлек бар, мөгаен, ул вулканик чыгышлы булыр.* Галәм. Җир. Кеше

2) Кайбер билгеләре буенча бердәй булган күп объектларның барлыгы, шуларны берләштергән зур киңлекләр, пространство, катлам. *Бездә авыл хуҗалыгы өчен үзләштерелгән территорияләр массивы үсеп барган саен, кыргый хәлдә тереклек итүче*

серкәләндерүчеләрнең саны кими ---. Умарта кортлары. *Зур массивларда тракторлы түтәл ясагычларны һәм түтәл чәчкечләрне файдаланырга кирәк.* Робинзон эзләреннән. *Селәүсен, башлыча, төньяк тайга өлешенең зур урман массивларында һәм Татарстанның көньяк-көнчыгышында сакланып калган.* Татарстанның үсемлекләр һәм хайваннар дөньясы

МАССИВ II *с.* 1) Бик зур, авыр, күләмле. *--- Прибытков кабинеты. Бик зур ишекләр, массив канделябрлар, барокко стилендәге җиһаз – барысы да үтә зиннәтле, үтә тантаналы, тәэсир итә торган.* И.Илялова. *Белгечләр исәпләвенчә, бу кратер Тефиянең бик массив җисем белән бәрелешүеннән барлыкка килгән булырга тиеш.* Галәм. Җир. Кеше. *[Үрмәкүчнең] Тәне ике бүлектән – башкүкрәк һәм массив корсак өлешеннән тора.* Татарстанның үсемлекләр һәм хайваннар дөньясы

2) *геол.* Җир кабыгында эрегән магмадан барлыкка килгән тоташ, бер төрле магматик (тау токымнары)

МАСС-МЕ́ДИА *и. публ.* Массакүләм мәгълүмат чаралары

МАССОВИК *и. рус сөйл.* Коллективтагы кешеләрне культура белән мавыктыру, күңел ачу чаралары оештыру белән шөгыльләнүче белгеч яки җәмәгатьчелек тәртибендә эш алып баручы кеше. *--- Культура сараен өлгертеп яталар. Яңа штатлар бирелде, Сөембикә директор булды, ул баянист штатымы дисең, массовикмы дисең...* М.Мәһдиев

МАССО́ВКА *и. рус* 1) *тар.* Октябрь революциясенә кадәрге Россиядә: революцион пропаганда һәм агитация алып барылган, гадәттә яшерен җыелыш, митинг

2) Спектакльдә, фильмда аерым рольләре булмаган, зур халык төркемнәрен уйнаган, гадәттә профессионал булмаган артистлар. *«Галиябану»ны куеп яталар. Массовкага кешеләре җитми.* Б.Камалов. *Рәсим Сәләхов, Ирек Баһмановлар белән сабакташ булып, Камал театрына массовкаларга йөгерә башлаганын сизми дә кала кыз [Н.Гәрәева].* Сәхнә

3) *иск.* Ял итү, күңел ачу өчен, җыйнаулашып табигатькә чыгу, күп кеше катнашкан экскурсия

4) *күч.* Җәмәгатьчелек арасында шактый киң резонанс алган сәяси чыгышлар. *Иҗтимагый күренешләрнең күзенә туры карый белергә өйрәнгән һәм үзе дә драматик «массовкалар»да катнашкан шагыйрь буларак, Әхмәт Рәшитнең язганнарында заманның кискен каршылыклары, кешенең җанрух сызланулары шактый тулы чагыла.* З.Мансуров

МА́СТЕР *и. ингл.* 1) *сөйл.* Үз һөнәрендә, эшендә зур осталыкка ирешкән кеше, югары квалификацияле һөнәрче, һөнәр остасы. *Фаик абый – адвокат, Камил бер артельдә сабын кайнатучы мастер булып эшлиләр.* Ж.Фәйзи. *МТФ каршында саву мастерлары әзерләү курсы ачылды.* М.Хәсәнов. *Урта гасырларда Италиянең кәгазь ясаучылары бик оста мастерлар булып исәпләнгәннәр.* Робинзон эзләреннән

2) Җитештерү өлкәсендә зур булмаган структур берәмлекне җитәкләгән белгеч. *Гармонь фабрикасында мастер булып эшләвемне кунаклар аңлау белән, миңа үтенеч белдерделәр.* А.Расих. *Рафисларның төшкелектән килүен өлкән мастер Газизов көтеп тора иде.* Н.Әхмәдиев. *Тау эшләре мастеры Токмашевның әнисен больницага салдылар.* Ә.Галиев

3) Спортта югары күрсәткечләргә ирешкән, спортны һәм физик культураны үстерү өлкәсенә зур өлеш керткән кешеләргә бирелә торган исем; әлеге исеме булган кеше. *--- шахмат буенча спорт мастеры Азамат бу уенга бөтен дусларын да гашыйк итте.* М.Кәбиров. *Атлар, нәсел эше, ярышлар, спорт төрләре турында яратып, тәфсиллә, бик озак сөйләде әле спорт мастеры.* Ф.Латыйфи. *Министр Әсгать Сәфәров атказанган спорт мастерын министрлык исеменнән ике бүлмәле фатир белән бүләкләде.* Сөембикә

4) Сәнгать остасы. *Бу елда [Г.Кашшафның] берьюлы өч китабы чыккан: «Каләм мастерлары», «Шәриф Камал», «Чүл буенда».* Казан утлары. *Шул ук вакытта ул [М.Сәлимҗанов] югары сәнгать мастерларының тулы бер йолдызлыгын кабызды.* Шәһри Казан

5) *күч.* Аферист, махинацияләр остасы. *Ариповның миллионнары, потлаган алтыннары, пычрак эшләр буенча мастерлары нигә аңа?* Р.Мирхәйдәров

6) *күч.* Кулыннан эш килмәгән, булдыксыз кеше

МА́СТЕР-КЛАСС *и. ингл.* Яңа методика, алым, технология һ.б.ш.га өйрәтү өчен, гадәттә шуның авторы үзе үткәргән, алымның турыдан-туры гамәлдә кулланылышын күрсәткән укыту-өйрәтү формасы. *Сүз уңаеннан мастер-классларның быел да бик җанлы төстә булуын әйтергә кирәк.* Сөембикә

МА́СТЕРЛАРЧА *рәв.* Сыйфатлы итеп, чын осталарда гына була торган һөнәр югарылыгында, зур осталык белән

МА́СТЕРЛЫК *и.* 1) Мастер (*2 мәгъ.*) хезмәте, мастер вазифасы

2) Мастер (*3 мәгъ.*) дәрәҗәсе, мастер исеме. *Аннары минем үземә дә быел мастерлык нормасын үтәргә кирәк.* Х.Сарьян

3) Һөнәрлелек, булдыклылык, кулдан эш килү, эшкә кул яту; берәр эштә зур осталык, югары сәнгатьлелек. *Хисам Камал үзенең әсәрләрендә геройларының эчке дөньясын, күңел байлыгын сугыш гарасатларына, вәхшилеккә каршы куя. Бу – мастерлык. Бу – без күптән көткән осталык.* Г.Ахунов

4) *сөйл. ирон.* Һәвәслек, хирыслык, берәр нәрсә белән артык мавыгу күренеше

МА́СТЕР-НАЛА́ДЧИК *и. рус* Төрле станок, механизм, җайланмаларны эшләтүче, көйләп җибәрүче белгеч. *Нәкъ менә шул вакытта килеп чыкты да инде мастер-наладчик Садри.* М.Хәсәнов

МАСТЕРОВОЙ *и. рус иск.* Кул һөнәре белән шөгыльләнүче кеше, оста, гомумән, вак кәсәбә яки заводфабрика эшчесе. *Василий Петрович, егерме биш елдан артык эшләгән карт мастеровой, әле күптән түгел генә герман фронтыннан, газ белән агуланып, бөтенләйгә гаскәрдән котылып кайткан ---.* Ш.Усманов

МАСТЕРОК *и. рус* Штукатурларның, ташчыларның измәне кирпеч араларына яки бетон, кирпеч стенага сылау өчен куллана торган махсус калагы

МАСТЕРСКОЙ *и. рус* 1) Гадәттә заказга вак-төяк көнкүреш әйберләре ясау яки төзәтү белән шөгыльләнә торган зур булмаган кәсәбә; һөнәрханә, кярханә. – *Итек мастерскоенда мастер булып эшлим, – диде ул үзе турында.* А.Шамов. *Ишегалдында гончарлык мастерское, шунда ук диңгез атчыгы, чүлмәкләр, савыт-саба ясыйлар.* М.Мәһдиев. *Галимнәр һәм җил техникасы инженерлары җилне тирән коелардан су чыгарырга, ---, мастерскойларда станокларны һәм машиналарны хәрәкәткә китерергә, электр тогы бирергә өйрәттеләр.* Дөньяда ниләр бар

2) Цехның, завод яки фабриканың, авыл хуҗалыгы предприятиесенең башлыча техниканы төзәтү белән шөгыльләнә торган бер бүлеге. – *Механика мастерскоенда идем, – диде. – Без әле монда механиклар белән бер эксперимент ясап карарга җыенабыз...* М.Хәсәнов. *Көннәрдән бер көнне, колхозның ремонт мастерскоеннан кайтып барышлый, кибет каршында җыелып торган ирләрне күреп, Микәй алар янында да тукталып алды.* Р.Мөхәммәдиев. *Варис белән Вәсилә механика мастерское янына күтәрелә башладылар.* М.Хәсәнов

3) Рәссам, скульптор, архитектор кебек иҗат кешеләренең эш бүлмәсе, остаханәсе. *Репетиция скульптор мастерскоенда балчыклардан сәнгать әсәре тудыру процессы булса, спектакль шул балчыкларның талантлы сәнгать әсәренә әверелүе икән.* Ж.Фәйзи. *Мастерскойдагы барча инженерларны, конструкторларны эшкә җиккән [Морат].* М.Маликова. *Ау йортының проектын --- берәр атаклы төзелеш фирмасы яисә архитектура мастерское каталогыннан алганнардыр, дип фикер йөртте ул.* Р.Мирхәйдәров

4) Режиссёр, актёр, рәссам кебек иҗади һөнәр ияләренең яшьләрне һөнәр осталыгына өйрәтү, үз тәжрибәсе белән уртаклашу, үзенә генә хас иҗат алымында, стилендә тәрбияләү өчен оештырган курсы. *Ләкин бу вакытта инде анда реализм нигезендә торучы рәссамнарны оештырган мастерскойлар да шактый нык позиция яулап алган булалар.* М.Әмир. *Лев Додин мастерское. Пётр Фоменко мастерское*

МАСТИ́КА *и. гр.* 1) Битум, резина, дегет, полимерлар кебек үзле матдә һәм порошоксыман өстәмәләр катнашмасыннан гыйбарәт, төзелештә гидроизоляция, ябыштыру, җыелма конструкцияләрне герметиклаштыру, агач әйберләрне эшкәртү һ.б.ш. өчен кулланыла торган куе масса. *[Казармада] Караңгы төстәге мастикага буялган идәннәр.* Ж.Дәрзаман. *Кислотага чыдам бетон, измә һәм мастикалар төрле концентрациядәге кислота --- тәэсиреннән саклау өчен кулланыла.* Төзү материаллары

2) *кулин.* Тортларны бизәү, төрле бизәкләр ясау өчен кулланыла торган ашарга яраклы камырсыман эластик матдә. *Мастика массасы*

МАСТИ́КА АГАЧЫ *и. бот.* Аккадиячәләр семьялыгының пестә ыруыннан Урта диңгез буенда үсә торган һәм культуралы сортлары да булган, лаклар эшләп чыгару өчен файдаланылган хуш исле сумала – мастика бирә торган мәңгеяшел агач үсемлек; сагыз агачы. *Ямәндә хуш исле сәрви агачы, мирра, мастика агачы, банан, хөрмә һәм цитрус агачлары үсә.* Совет әдәбияты

МАСТИТ *и. гр. мед.* Сөт бизенең ялкынсынуы. *Мин дә саву аппараты сатып алырмын дигән идем, ләкин ул имчәкләрдә мастит авыруы барлыкка китерә, диделәр.* Э.Сәлахова. *Күкрәктә мастит булганда, авырткан урынга телемләп киселгән чәй гөмбәсе куялар, өстенә марля каплап, кәгазь ябалар.* Ватаным Татарстан

МАСТИХИН *и. ит. сәнг.* Рәсем ясауда буяу изү, палитра чистарту һ.б.ш. өчен кулланыла торган кечкенә сыгылмалы металл калак яки пычак формасындагы әсбап. *Киндер өстенә буяуларын пумала белән ышкып-җәеп тә тормыйлар. Кайберләре хәтта пумала да кулланмый, мастихины белән генә чәпи.* М.Әмир

МАСТОДОНТ *и. гр.* Хортумлылар отрядыннан олигоцен чорында барлыкка килеп бөтен дөньяга диярлек таралган, голоцен чорында үлеп беткән имезүче хайваннар семьялыгы. *Моннан берәр миллион еллар чамасы элегрәк Кара диңгез буйларында, Көнбатыш Себердә страус, газель, дөя, жираф, носорог, мастодонт һәм башка шундый төрле хайваннар яшәгән.* Җир һәм туфрак

МАСТЬ *и. рус* Уен карталары колодасының очколарының төсе һәм формасы буенча аерылып торган дүрт өлешенең берсе. *Буби масте. Черви масте*

МАСШТАБ *и. нем.* 1) Картадагы, сызымдагы сызык озынлыгының чынбарлыктагы озынлыкка карата нисбәте. *Урынның планы буенча ераклыкларны билгеләргә мөмкин булсын өчен, аның аскы өлешендә масштаб күрсәтелә.* Физик география. *--- вертикаль сызыклар А пыяласында горизонталь сызыклардан зуррак масштабта килеп чыгарлар: сурәт вертикаль юнәлештә сузылгандай булыр.* Кызыклы физика. *Үлчәү нәтиҗәсендә килеп чыга торган сан үлчәү берәмлеге итеп алынган берәмлеккә яки масштабка бәйле була.* Югары математика нигезләре

2) *күч.* Киңлек, колач, эшчәнлек аренасының зурлыгы. *Әлеге дә баягы, тәрбия эшен генә дә нинди масштабта оештырган идек бит.* Ф.Баттал. *Зуррак масштабта күтәрелгән мәсьәлә булса, бу, билгеле, укучы балалар кулыннан гына килә торган эш булмас иде.* Л.Ихсанова. *Теләсә нинди масштабтагы мәсьәләләрне якындагы берничә ел, якындагы ун ел эчендә хәл итәрлек көчебез, мораль һәм материаль мөмкинлекләребез бар.* Серле кристаллар

МАСШТАБЛЫ *с.* **1.** 1) Билгеле масштаб (*1 мәгъ.*) нигезендә эшләнгән, башкарылган, масштабы (*1 мәгъ.*) күрсәтелгән. *Һәр исәп системасында ара ераклыгы һәм вакыт арасы бу системада тик торучы масштаблы линейка һәм сәгать ярдәмендә үлчәнергә тиеш.* Физика

2) *күч.* Зур күләмле, киң колачлы, иңле, әтрафлы. *Аның [С.Хәкимнең] гомер маршрутлары бик киң масштаблы,*

бик гыйбрәтле. Л.Шагыйрьҗан. *Зур осталык һәм бай тәҗрибә, масштаблы фикер һәм колач киңлеге сорый торган роман жанрында безнең прозаның, шул исәптән урта буынның да уңышлары күп дип булмый.* Ф.Миңнуллин. *Шулай да әле генә күз алдыбызда нинди масштаблы һәлакәт булып узганлыгын аңларлык хәлдә түгел идек әле без.* Р.Мөхәммәдиев

2. *рәв. мәгъ.* Күләмле, колачлы итеп, киң җәелдереп, зур масштабта. *Комплекслы итеп, масштаблы башлап җибәрү эшне тизләтә, төзелеш арзанга да төшә.* А.Гыйләҗев. *Татарстанда гына түгел, бөтен Россиядә һәм чит илләрдә дә югары дәрәҗәдә һәм масштаблы үтте ул тантаналар.* Р.Фәйзуллин

МАСШТАБЛЫЛЫК *и.* Эшчәнлектә, фикер йөртүдә һ.б.ш.да күзаллау киңлеге, күләмлелек, киң колачлылык, зурлык. *--- роман-повестьларда тормышчан һәм ышандырырлык гадәти геройлар, бер уку белән истә кала торган тормыш күренешләре күп. Әмма олы характерлар, эпик киңлек һәм масштаблылык җитеп бетми.* Ф.Миңнуллин. *Мәдинә Маликова иҗатына колачлылык, масштаблылык, киң планлылык хас.* М.Әхмәтҗанов. *Тарихи-психологик романнарда психологик тирәнлек эпик масштаблылык, күп планлылык һәм тарихилык --- белән тыгыз бәйләнештә тора ---.* Х.Әшрәфҗанов

МАТ I *и. гар.* 1) Шахмат уенында каршы як короленә кайтаралмаслык итеп куелган шах, партияне оту. *– Йөрүен йөрдем... Тик барыбер, дүрт йөрештән соң миңа – мат, – диде...* Ж.Фәйзи. *Кондырев шахмат фигурасын кулына алып йөрергә хәзерләнде һәм гажәпләнеп кычкырып җибәрде: – Миңа мат ич!.. Авыз ачып калганмын, их...* Ж.Тәрҗеманов. *– Хәзер бетә, маэстро, – диде малай һәм каршы якка мат игълан итте.* А.Тимергалин

2) *күч.* Мәсьәләнең чишелешен таба алмау, катлаулы ситуация, бик кыен хәл, авыр вазгыять. *Кулларда флагчыклар. --- Кучерәләр шахмат уйнагандай: – Европага – мат! Фрау Россия, инде сиңа чират!..* Р.Әхмәтҗан

◊ **Мат алу** Оттыру, җиңелү. *Цейтноттан чыкмый кайберәүләр, Бертуктаусыз гел «мат» алалар.* Ә.Синугыл-Куганаклы. **Мат бирү** *к.* **мат кую**. *Шахматта өч йөрештә бирелә торган матны киндер, ягъни балалар маты дип йөртәләр иде.* А.Әхмәт. *Камил Шәрипыч! Мин сезгә дә мат бирә алам! Гомумән, мине әле шахматта берәүнең дә...* М.Шаһимәрдәнов. **Мат булу** *иск.* Үлү. *Тай ат булганчы, иясе мат була.* Мәкаль. **Мат итү** *диал.* Азаплау, изалау, аптыратып бетерү, туйдыру. *Картлык, сине кая итим, әйтер сүзгә мат иттең.* Мәкаль. **Мат кую** Шахмат уенында җиңү, партияне оту. *Утыз беренче декабрьдә мин сиңа меңенче тапкыр мат куячакмын.* Р.Вәлиев. *Матбугат йортында шахмат тотып караган бөтен егетләребезгә дә берәр мат куеп чыккан иде Гата.* Р.Миңнуллин. *Валентин Макарович шахмат уйный иде. Без дәрескә кергәндә, бер студентка мат куйды.* К.Сатиев

МАТ II *и. голл.* 1) Тупас җәймә, чыпта

2) Спортчыны егылган яки сикергән вакытларда бәрелеп имгәнүдән саклау өчен, матрас сыман йомшак калын җәймә

3) Салам, камыш кебек материалдан ясалган, парниктагы үсентеләрне салкыннан саклау һ.б.ш. өчен кулланыла торган япма. *Менә узган яз көне, салкынайткач та, без умарталарны саламнан үрелгән матлар белән төрдек.* Умарта кортлары. *Рассадалы әрҗәләрне кырга илткәч, кояш һәм җил тимәсен өчен, чыпта яки матлар белән каплыйлар.* Яшелчәчелек

4) Минераль яки пыяла мамыктан торган, җылы саклау, изоляцияләү һ.б.ш. максатларда файдаланылган эшләнмә

МАТА I *и. гар. иск.* Киҗе-мамык тукыманың бер төре. *Мәкаль – сүзнең атасы, Мата – бүзнең атасы.* Мәкаль

МАТА II *и. иск. к.* **мат** II. *Бәрәңге астына салам маталар яки чыпталар җәяләр, шулай ук ян-яктан һәм өстән дә ябалар.* Яшелчәчелек

МАТАВЫК *и. диал.* 1) Мәшәкать, һәртөрле вак-төяк көнкүреш эшләре. *Матавык арасында эш табылгач, биана да, килен дә бер мәлгә җиңеләеп калдылар.* А.Гыйләҗев. *Шул иртәнге сафлыкта рухланып каптырган балыкларны күтәреп өйгә кайтуга, романтикасы бетә: балык чистарту кебек баналь көнкүреш матавыгына батасың бит.* И.Иксанова. *Карчык үзе дә моңа риза иде: белмәгән кешеләр арасында калганчы, юл матавыкларын бергә күргән карт белән сөйләшеп утыруны тыныч-ка санады ---.* М.Хуҗин

2) Киртә, кыенлык, комачау; һәртөрле проблемалар, борчулар. *Сезгә бәйләнешле матавыкларны хәтерлим мин, яхшы хәтерлим.* Г.Тавлин. *Ә бүгенгене аңлау, бүгенге дөнья матавыкларыннан сөземтә чыгару – шактый катлаулы нәрсә.* Р.Вәлиев. *Хәреф алмаштыру матавыгы артыннан йөреп, янә бер аем үтте.* Мәдәни җомга

3) Ыгы-зыгы, тыз-быз килү; шаушу, чыр-чу. *Бу матавык миңа нигәдер көлке тоелды. Мин бу хәлгә, әйдә, телә-сә нишләсеннәр, дип карадым.* Г.Тавлин

МАТАВЫКЛАНУ *ф. диал.* 1) Шушы моментта бер эш белән шөгыльләнү, шуның белән мәшгуль булу. *Мин аның турында [З.Насыйбуллин] күптәннән язарга тиеш идем инде. Дөнья мәшәкатьләре белән матавыкланып, ничектер кул җитмәгән.* Ә.Рәшит. *Әле, шөкер, кабинет – ындыр табагыдай, ара – хәтсез, синең ни белән матавыкланганыңны бинокльсез абайларлык түгел.* Р.Зарипов. *– --- кәгазькаләмең җитәрлекме соң? – Матавыкланма, бәк, олуг кенәз Василий Иванович Мәскәүдән бер олау язу-сызу әсбаплары җибәргән.* М.Әмирханов

2) Маташу, азаплану, тырышу. *Нинаять, без кышкы суыкта көне буе авызыбызга бер бөртек ризык капмыйча матавыклангач, кичкырын мәрхүмне кечкенә автобуста Киров районының 1 нче мәктәбе янындагы зиратка җирләргә алып бардык.* Г.Тавлин. *Кодагый ут кабыза алмыйча матавыкланды.* М.Мәһдиев. *Коридорда шәльяулык япкан әбиләрнең күренеп китүендә ниндидер зур эш белән матавыклану, кабалану, ашыкканлык сизелә.* Р.Низамиев

МАТАВЫКЛА́У *ф. диал.* Борчу, тынычсызлау, комачаулау, мәшәкатьләү.

Балалар болай да инде мич тирәсендә әшер-өшер киләләр, кул астына керәләр, әни кеше әнә шул кызу, аяк арасына кыл сыймаган бер вакытта матавыклап йөргән балаларына инде чын күңелдән, ләкин йомшак кына итеп биргәләп тә алган ---. М.Мәһдиев

Матавыклап бетерү Бик күп мәшәкать тудыру, өстәмә эш ясап, комачаулап, тынычсызлап, тәмам туйдыру. *Аю балалары аш өендә эшләүчеләргә матавыклап йөдәтеп бетерәләр иде.* Ак юл

МАТАВЫКЛЫ *с. диал.* 1) Мәшәкатьле, борчулы, катлаулы, кыенлыклары булган. *Бу – хәзерге матавыклы көннәрдә кадрлар сәясәтенә башбаштаклык кертү булыр иде.* Р.Мирхәйдәров

2) Тынгысыз, тынычсыз, ыгы-зыгылы, шау-шулы. *Бик матавыклы, шау-шулы тормыш монда.* А.Расих

МАТАДОР *и. исп.* Испаниядә үгезләр белән традицион көрәштә төп катнашучы, үгезгә шпага кадаучы; тореадор. *Менә Порто-Кристо ресторaны алдындагы кибетләр. Матадор костюмнары, рапиралар, кастаньетлар.* М.Мәһдиев. --- *матадорлар алтын чигешле камзуллары, ыспай сыннары белән ерактан ук аерылып торалар. Хәер, гажәпләнерлек тә түгел, шулай булырга тиеш: матадорлар бүгенге уенның, бүгенге мәйданның корольләре ләбаса!* Р.Фәйзуллин. *Испаниядәге искиткеч кыю матадорларның бичара үгезне кызыл чүпрәк күрсәтеп ярсытулары борынгы заманнан кереп калган гадәтне куу гына*. Кызыклар дөньясында

МАТАЙ *и. сөйл. к.* **мотоцикл**. *Ярулла абзыйның матае зәһәр икән, газын боруга йолкып алып та китте*. З.Хөсния р. *Матайны Гайнаннан алып тордым. Вакытлыча йөреп торырга.* Х.Ибраһим. *Җәлт кенә матайны этеп кабыздык та киттек кузгалып.* Аманулла

МАТАЛАНУ *ф. диал.* 1) Азаплану, маташу, тырышу, мәшәкатьләнү

2) *күч.* Бер кешегә ярарга омтылып ялагайлану, яхшы булып күренергә тырышу. *Бераздан әткәй килде, хәлемне карап белде. Әткәйгә, маталанып, бай абзый бүләк бирде.* Бәет

МАТА́У *ф. диал.* Комачаулык итү, тоткарлау, борчу, уңайсызлау. *Кеше монда, җан тиргә батып, яңа чыккан көйне өйрәнергә тырыша, ә син аңа матыйсың.* Т.Гыйззәт

МАТАШТЫРУ *ф. сөйл.* 1) Берәр нәрсә эшләргә тырышу, омтылу, азаплану, эшләп карау. *Менә бу бетон свайларны да иплəп-иплəп лом белəн генə шудырып маташтырам.* Ф.Яруллин

2) Эш-процессны белдергән фигыльләр урынында кулланылып, шул эшне аз-маз булдыруны, кыенлык белән генә башкаруны белдерә. *Ярар безгә мандолинада уйный белгәч, скрипканы маташтыргач.* Ж.Фәйзи. – *Китап укырга яратасың, яттан шигырьләр сөйлисең, диләр. Пьесалар да язасың икән. Шәт, бии дә белəсеңдер? – Анысын да маташтырам.* Х.Сарьян. *Кем ничектер инде, мин үзем гает көнне бер укыйм да корбан бәйрәмендә бер маташтырам...* А.Гыйләҗев

3) Берәр нәрсәгә кирәксезгә кагылып, казынып бозу, зыян итү, ялгышлык китереп чыгару. – *[Сәгатебез] бик дөрес йөри иде, – дип аптырады Камилнең әнисе, – син маташтырмагансыңдыр бит, улым?* А.Әхмәт

4) Әтмәләү, аннан-моннан гына, гадәттә түбән сыйфатлы итеп эшләп кую. *Ул чирләп яткан арада, өлкә түрәләре минем астан ут йөртә башлады, китеп өлгермәгән булсам, hичшиксез, берәр ялган «эш» маташтырып башыма җитәчәкләр иде.* Р.Мирхәйдәров

5) *күч.* Ялгыш юлга кертү, ялгыштыру, бутау, алдалау. *[Гәрәй, Насрины күреп] Эhм... Менә кем маташтырган, пьяница... сволочь!* Ш.Камал. *Баксаң, икесенең дə паспорт-фəлəне булмагач, «алдап-йолдап фатир алгансыз» дип, ниндидер бер томана түрə кисəгə шулай маташтыра икəн.* Марс Шабаев

6) *күч.* Шаярту, юри кылану; ирештерү, үртәү, аптырату. *Син моны чынлап әйтәсеңме, авылдаш, әллә маташтырган буласыңмы?* Ф.Хөсни. – *Мәйсәрә, ахирәт, сөенеч, сөенеч, сөенеч! – Я, әйт инде, Заһирә, маташтырма.* К.Тинчурин

Маташтыра башлау Маташтырырга тотыну

Маташтырып карау Маташтырырга тырышу. *«Сүзләрен маташтырып карыйбыз аның», – дип, кәгазь-карандаш алып, язу өстәле янына утырды.* Ж.Фәйзи. --- *төзәтердәй нәрсә дә түгел, җен алгыры. --- Белмим әле... Бераз маташтырып карыйм әле* ---. Э.Касыймов

Маташтырып тору Даими маташтыру яки хәзерге моментта маташтыру

◊ **Маташтырып бетерү** Бөтенләй бутау, бозу, ялгыштыру. *Халыкны агартам, дигән булып, яшьләрне маташтырып бетердең.* М.Фәйзи

МАТАШУ *ф. сөйл.* 1) Билгеле эш белән шөгыльләнү, шуның белән мәшгуль булу; әлеге моментта шул эшне үтәүдә булу. *Корабларны талау белән алар күптән маташалар икән.* И.Хуҗин. --- *Казан тирәсендә озаграк маташырга мәҗбүр булсам, кулга төшүем бик мөмкин иде.* Г.Баттал-Таймас. *Әгәр дә инде кабырчык буш булса, кысла аның белән озак маташа: аны әйләндерә-әйләндерә карый, аны үз гәүдәсенә үлчәгәндәй итә.* Диңгез тирәнлегендә

2) Эшләргә җыенган эшен әллә ни булдыра алмау, акрын, кыенлык белән яки өстән-өстән генә башкару. *Рояль янына барып утырдым. Импровизация ясап маташтым.* Ж.Фәйзи. *Карт, бар ишегалдын тутырып, кышның-кыш буена шактый коргаксыган көймәсен сумалалап буяп маташа иде.* М.Хәсәнов

3) Берәр эшне башкарырга тырышу, омтылу. *Миңа балалайкада өйрәнүе бик авыр булды. Маташтым, маташтым, барыбер рәт чыкмады.* Ж.Фәйзи. *Урта гасырларда алхимиклар канлы үләннең сары тамырын һәм сары суын башка металлардан алтын алу өчен файдаланырга маташып караганнар.* Робинзон эзләреннән

4) Азаплану, көчәнү. – *Маташма, булдыра алмаганда, – дип торып киттe [Шәүкәт].* Ж.Фәйзи. *Безне милләтчелектә, экстремизмда гаепләргә маташтылар.* Казан утлары. *Кыланып маташмагыз, Николай Еремеич. Нәрсә әйтергә теләгәнемне бик шәп аңлыйсыз.* И.Тургенев

5) Үзен яхшырак яктан күрсәтергә тырышу, берәр роль уйнарга омтылу, кылану. *Күрсә, бигрәк тә сүзеннән*

бүленә калса, бетте баш: мондый чакта Нестор Иваныч «демократия» уйнап маташмый. З.Фәтхетдинов. *Шулай, туган, ничек кенә хәйләләп маташма, берни барып чыкмас: беткән баш беткән.* И.Тургенев

Маташып йөрү Күпмедер вакыт берәр нәрсә белән мәшгуль булу. *Менә хәзер дә костюмнар белән маташып йөри икән [Шамильский].* Ж.Фәйзи

Маташып тору Хәзерге вакытта берәр нәрсә белән маташу; артык озак маташу

Маташып яту *сөйл.* Шактый вакыт маташу. *Һаман шулай оятсызлык әрсезлеген акларга маташып яткач, түзмәдем* ---. З.Фәйзи

МАТӘМ *и. кит.* Кеше үлү яки берәр иҗтимагый фаҗига булу сәбәпле кичерелә торган, гадәттә төрле гомуми кабул ителгән билгеләрдә – махсус киемдә, бәйрәм-күңел ачу чараларыннан баш тартуда һ.б.ш. чагылган зур кайгы, хәсрәт. *Ул бәләнд җан безне кыйлды Мәңгегә мәхрүм, ятим. Зур матәм, бик зур матәм! Зур – Милләтнең хәсрәте!* С.Сүнчәләй. *Безнең тормышлар шавында, Безнең богаулар тавышы ул, Безнең матәмнәр маршы ул.* Х.Туфан. *Илдә бер атналык матәм көннәре игълан ителә.* Ә.Еники

◊ **Матәм тоту** Берәр фаҗига булу сәбәпле, тирән кайгы кичерү, траур саклау, уен-көлке, күңел ачулардан тыелып тору. *Поляк милләте --- зур бер матәм тотарга мәҗбүр булды: Польшаның иң шөһрәтле вә гаять зур мәхәббәт казанган мөхәррире Генрих Сенкевич вафат булды.* Ф.Әмирхан. *Мин үзем дә матәм тотып йөрим, Мин үзем дә – йөрәге ятим.* Х.Туфан

МАТӘМЛЕ *с.* Матәмне белдерә торган, кайгылы. *Мәҗүсилек чорында, йола башкарыр алдыннан, аеруча тәэсирле сүзләрне шушындый матәмле тавыш белән укый торган булганнар.* М.Юныс

МАТБАГА *и. гар.* 1) Типография, басмаханә. *Ахырда чын матбага эшләре белән танышкач, мин матбагаларыбызда хәреф күплегеннән килгән зарарларны аңладым.* Г.Алпаров. *Бу матбага әле яңа, бу архивта бүтән редакцияләрдә эшләп килгән журналистлар да шактый.* Ш.Галиев. *Печән урамы Кәримовлар матбагасы белән дә атаклы.* Р.Низамиев

2) Полиграфия эше. *Нәчөн бу бәдбәхетләр матбага өстендә эш рәтли?* Г.Тукай. *Матбага эше гөрләп тормаса, көчле әдәбият каян килер иде?* Р.Фәйзуллин. *Минемчә, матбага әһелләре укучылар катламын тулырак иңләү өчен тырышканда, боларны истә тотарга тиешле.* М.Вәлиев

МАТБАГАЧЫ *и. иск.* 1) Полиграфия эшендә хезмәт итүче кеше, типография эшчесе

2) Типография хуҗасы, нәшер итүче. *Матбагачы – матбугат эшен [бакалея] кибетенә әйләндереп файда күрүче.* Г.Тукай

МАТБАГАЧЫЛЫК *и. иск.* Нәшер итү эшләре, басма әдәбият чыгару эше, типография эшләре. *Алманияле Жан Гутенбург тарафыннан матбагачылык сәнгате ачылганнан бирле биш йөз еллар вакыт кичсә дә, Русиядә безнең мөселманнарның бу һөнәрдән шәхсән файдалана башлаулары күптән түгелдер.* М.Әхмәтҗанов

МАТБУГАТ *и. гар.* 1) Басылып чыккан барлык газета-журналлар, периодик әдәбият, вакытлы басмалар. *Мөмкин булган кадәр Мәскәү матбугатын карап барырга тырышам.* М.Әхмәтҗанов. *Илһам абый гомер буе татар вакытлы матбугатын күплән алдырып, укып барды.* Л.Шагыйрьҗан. *Татар матбугатында Ф.Туйкинның беренче шигырьләре 1906–1907 елларда Уральск шәһәрендә чыккан «Фикер» газетасында дөнья күрә.* Казан утлары

2) Гомумән, басылып чыккан һәртөрле әдәбият

3) Басма әдәбият чыгару эше; нәшер итү һәм типография эше. *Революцион көрәш нәтиҗәсендә азмы-күпме әдәбият һәм матбугат иркенчелегенә ирешелде.* М.Гали

МАТБУГАТЧЫ *и.* Матбугат өлкәсендә хезмәт итүче кеше

МАТДӘ *и. гар.* 1) *филос. к.* **материя** **1.** *Вакыт мәңгелек саналса, Тере матдә булса – җан, Гомер кардиограммасына Һәрбер эзең салынган.* Р.Фәйзуллин

2) Материянең төрле сыйфат һәм формалардагы реаль гәүдәләнеше; физик җисемнәрне тәшкил иткән нәрсә. *Фторның агалтын белән кушылмаларын өйрәнгәндә, химиклар очраклы рәвештә яңа матдә табалар.* Химиянең киләчәге. *Тимер иң күп таралган һәм иң файдалы матдәләрнең берсе булып санала.* Дөньяда ниләр бар. *Фитотерапияне киң куллануга әле һаман да үсемлекләрдәге тәэсир итүче (биологик актив) матдәләрнең хәзерге биохимик методлар ярдәмендә җитәрлек өйрәнелмәве комачаулый.* Урман аптекасы

3) Конституция, кодекс кебек күп бүлек һәм бүлекчәле катлаулы текстлар бүленешендә аерым параграф һәм пунктлардан торган бер статья. *70 ел элек, ягъни Язучылар оешмасы төзелгәч кабул ителгән Уставта да төп матдә итеп язып куелган ул.* Р.Фәйзуллин. – *Соңга калган өчен саботаж дигән матдә белән төрмәгә озатуга яисә хезмәт срогыңны бер елга озайтуга ничегрәк карыйсың, матрос иптәш? – диде капитан, ваемсыз гына* ---. Т.Галиуллин

МАТДИ *с. гар.* 1) *к.* **материаль** (*1 мәгъ.*). *Монда бары тик мөселман Көнчыгышына гына хас контрастлык, матди чынбарлык белән рухи фантазия арасындагы котычкыч аерма сизелә иде.* М.Мәһдиев. *Ибне Фадлан, Әбү Хәмид кебек мәшһүр сәяхәтчеләрнең Бөек Болгар турындагы кадерле истәлекләре матди төс ала башлый.* К.Тимбикова

2) Милек, акча өлкәсенә караган, яшәү шартлары, эш хакы һ.б.ш. белән бәйле; материаль (*3 мәгъ.*). *Ләкин, истәлекче күпмедер арттырган очракта да, әдип балачагында һәм мәктәп елларында матди кытлык күргән, дип әйтә алмыйбыз.* И.Нуруллин. *Ул елларда авыл халкы матди яктан инде шактый тернәкләнгән, тамак өчен дип кенә яшәми, йорт-җир яңарту артыннан да йөри башлаганнар иде.* В.Нуруллин. *Аларның гаиләсе матди авырлыкта көн күрсә дә, үзара тату, бердәм яши.* Мәдәни җомга

◊ **Матди егылу** *иск.* Зур мохтаҗлык, материаль кыенлыклар кичерү, акча ягы бик начар булу, бөлү, банкрот

чыгу. *Иптәшләрем күңелсезләнергә бирмәсәләр, башкалар матди егылудан саклап калдылар*. Г.Кутуй

МАТДИЛӘШТЕРҮ *ф.* Матди предметка әверелдерү, материальләштерү; тормышка ашыру. *Кайчан да булса җирлеләр дә фикерне матдиләштерү серләрен ачачаклар.* З.Мәхмүди

МАТДИЛӘШҮ *ф.* Материальләшү, реаль әйбергә әйләнү, конкрет предмет рәвеше алу. *Рәссам яки әдип дөньяда булмаган затны (җенне, аждаһаны) ясаса, ул кайдадыр матдиләшәчәк яки ул инде матдиләшкән чорда яшәгән.* Р.Батулла. *Шулайдыр, чөнки уй сүзләр аша матдиләшә*. Р.Габделхакова

Матдиләшә башлау Матдиләшүгә табан бару

МАТДИЛЕК *и.* Материягә (*1 мәгъ.*) хас билгеләргә ия булу хәле, материаль (*1 мәгъ.*), матди (*2 мәгъ.*) булу үзлеге. *--- дөньяда хәрәкәт яшәп килә, һәм бу – аның матдилегенә хас, аңардан аерып алу мөмкин булмаган сыйфаты, дип расларга хакыбыз бар.* Ж.Тәрҗеманов. *Киртәнең бу ягына [зиратка] үтү белән матдилекнең, өстенлекләрнең кирәге юкка чыкты.* М.Юныс

МАТДИ-ТЕ́ХНИК *с. к.* **материаль-техник**. *Дәүләтебез 1946–1950 елларда авыл хуҗалыгының матди-техник базасын ныгытуга зур средстволар бүлде*. Борынгы Калатау итәгендә. *Чыннан да, соңгы елларда республикабызда югары технологияле медицина үзәкләре булдыру һәм аларны матди-техник яктан ныгытуга зур игътибар күрсәтелә.* Татарстан

МАТЕМА́ТИК I *и. гр.* 1) Математика фәне белән шөгыльләнүче белгеч. *Алар кем дә, син кем? Алар – бөек математик, акыл иясе. Россиянең мактанычы Николай Лобачевский. Гигант Лев Толстой.* М.Мәһдиев. *Борынгы грек математигы Пифагор (б.э.к. VI гасыр) – озак сәяхәтләрдә йөргән кеше – Җирнең шар формасында булуы турындагы фикерне беренче булып кузгата.* Галәм. Җир. Кеше. *О.Ю.Шмидт күренекле математик, географ, астроном була.* Табигать белеме

2) *сөйл.* Уку йортында математика фәнен укыткан педагог. *Дәрестә Мөкәррәмә апаның күзләре яшьләнә: аның ире – искиткеч әйбәт укытучы, математик Григорий Герасимович – фронтта хәбәрсез югалды.* М.Мәһдиев. *Математик Роза Сәләховна, Ничек тапкан диген җай-юлын, Төшендерә иде җиңел генә Күп буынлы Ньютон биномын.* Ә.Рәшит. *Бер авылда мин Азнакай мәктәбендәге укытучым, математик Әхсән ага Туйкинның туганы белән таныштым.* М.Гали

МАТЕМА́ТИК II *с.* 1) Математикага караган, математика кагыйдәләре нигезендә эшләнгән. *Математик анализның нәрсә икәнен белсәләр дә, фәлсәфә анализының нәрсә икәнен кем белгән...* Х.Ширмән. *--- сызымнардан файдаланганнар. Андагы математик, геометрик бәйләнешләрне төзеләсе бина үлчәмнәренә күчереп, аны төгәл, матур, мәһабәт итәргә теләгәннәр.* Татарстан тарихыннан хикәяләр. *Мөхәммәтшакир яшьтән үк Коръәнне яттан белә, математик гамәлләр башкара, счёт салырга өйрәнә.* Казан утлары

2) *күч.* Математикадагы кебек төгәл, җыйнак, ачык, эзлекле. *--- табышмак коры зиһен эшләтү, коры логик яки математик фикер йөртү яки корыга хыяллану да түгел, ул – --- синкретик шигъри әсәр.* Н.Исәнбәт. *Математик төгәллек белән әйтелгән бу фикер чын гражданлык хисен купшы сүзләргә төренгән ясалма хисләрдән аера белү җәһәтеннән игътибарга лаек.* Р.Низами

МАТЕМА́ТИКА *и. гр.* Чынбарлыктагы микъдарча мөнәсәбәтләрне һәм пространстводагы формаларны өйрәнә торган фән. *Ә институт аның математикага һәм рәсемгә булган мәхәббәтен берләштерде*. М.Маликова. *--- ул [Уатт] немец телен өйрәнә, французча өйрәнеп, математика, астрономия һәм хәтта философиягә кереп китә.* Кызыклар дөньясында

МАТЕМАТИКАЛАШТЫРУ *ф.* Математика алымнарын куллану, математика принциплары нигезенә күчерү. *Химияне математикалаштыру башлана гына, һәм математиканың ярдәме без теләгән кебек үк зур түгел әле.* Химиянең киләчәге

МАТЕРИАЛ *и. лат.* 1) Берәр нәрсә эшләп чыгару, җитештерү, хәзерләү, ясау өчен файдаланыла торган предметлар, матдәләр; чимал. *Мин яшисе бүлмәмне күзәттем. Түшәм юк, түбә – саргылт пальма яфрагыннан, стеналар шул ук материалдан – матылардан тора, аларны җил селкетә.* М.Мәһдиев. *Ачыклаучы исем баш килештә килсә, предметлар арасында урынга, вакытка, материалга --- һ.б. төшенчәләргә карата булган мөнәсәбәтен белдерә ---*. Татар грамматикасы

2) Берәр мәсьәләне ачыклау, тикшерү, шул турыда фикер йөртү, иҗат итү һ.б.ш. өчен нигез булырлык чыганак, белешмәләр, фактлар. *--- шагыйрь икән, авыл темасына яза торган поэмасына материал туплап йөри ---*. М.Мәһдиев

3) Билгеле бер темага, мәсьәләгә, эшкә караган һәртөрле документлар, язмалар, кәгазьләр җыелмасы. *Узара киңәшкәннән соң, сезнең материалларны судка тапшырмаска булдык*. М.Юныс. *Аларның [конференцияләрнең] материаллары фәнни җыентыклар, буклетлар, белешмәлекләр итеп бастырыла*. Л.Җамалетдинов

4) Әйбер тегү өчен файдаланыла торган тукылган, трикотаж яки синтетик эшләнмә, тукыма, материя (*4 мәгъ.*). *Ничек һәм нәрсә белән материалны үлчәп кисүгә килгәч, югалып калдык.* Ж.Фәйзи. *--- малай әнисе белән универмагка, чыгарылыш кичәсенә костюм өчен материал сайларга киткән иде ---*. М.Мәһдиев. *Миңа Австрия, Югославия костюмын кию бәхете тиде. Хакы да безнекеннән әллә ни кыйммәт түгел, ә материалы, тегелеше бик яхшы!* М.Әхмәтҗанов

МАТЕРИАЛИЗМ *и. лат.* 1) Фәлсәфәдә идеализмга капма-каршы, аң белән чагыштырганда материя беренчел, дигән карашка нигезләнгән, объектив чынбарлыкның аңга, фикерләүгә бәйсез рәвештә яшәвен таный торган тәгълимат. *Югарыда саналган хезмәтләре Г.Гобәйдуллинны марксизм-ленинизм методологиясе, тарихи материализм нигезендә эшләүче тарихчы итеп күрсәтәләр.* С.Алишев. *Кешеләр диалектик материализм дигән бөек*

фәнне белеп җиткермиләр. Р.Низамиев. *Диалектик материализмга нигез салучылар кешене хайваннар дөньясыннан һәрвакыт иҗтимагый эшчәнлек булган җитештерү аерып торганлыгын беренче тапкыр аермачык итеп әйтеп бирделәр.* Галәм. Җир. Кеше

2) Һәрнәрсәне файдалылыгы ягыннан гына бәяләү, үтә практик карашларда тору; прагматизм

3) Шәхси файда принцибыннан чыгып эш итү; меркантилизм

МАТЕРИАЛИСТ *и.* **1.** 1) Фәлсәфәдә материализм тәгълиматын алга сөрүче, материализм карашларында торучы галим. *Саумы син, дөньядагы беренче материалист Демокрит һәм гигант акыл ияләре Сократ, Платон, Аристотель Ватаны!* М.Мәһдиев. *--- кеше үзенә нык рухи ышаныч, рухи азык эзли. Ә бу исә дингә кайтып кала. Моны хәтта материалистлар да танырга мәҗбүр.* М.Әхмәтҗанов. *Аны [Л.Бербанкны], материалист, дарвинчы һәм шуның белән бергә алласыз кеше дип, күралмаганнар.* Робинзон эзләреннән

2) Прагматик карашлы кеше, һәрнәрсәне практик яктан бәяләп, һәрнәрсәгә үтә тар, коры акыл күзлегеннән генә караучы, югары максат, этика, әхлак мәсьәләләрен исәпкә алмаучы кеше. *Мин материалист идем, дөньяда булган нәрсәләрне төрле матур буяуларга буямыйча гына, туры хакыйкать көенчә генә күрергә ярата идем.* Г.Рәхим

3) Беренче урынга үзенең шәхси мәнфәгатьләрен куеп, бары тик материаль файданы күздә тотып эш итүче кеше

2. *с. мәгъ.* Материализм карашларына нигезләнгән. *Материалист философлар, борынгы гасырларда ук инде, дөнья үзенең асылы буенча материаль, ул беркайчан да яратылмаган --- дигән фикер белдергәннәр.* Дарвинизм һәм дин. *Генетика фәне барлыкка килгәнче, әлеге теорияне яклаучы материалист галимнәр үз позицияләрендә нык тора иде әле.* Татарстан яшьләре

МАТЕРИАЛИ́СТИК *с.* **1.** Материализм принципларына нигезләнгән, шул тәгълиматны чагылдыра торган, асылы шуңа бәйле булган. *Ул, төгәл фәннәр буенча әзерлекле кеше, әлеге беренче карашка идеалистик булып күренгән «туган туфрак» төшенчәсенә материалистик аңлатма бирә.* М.Мәһдиев. *Физика үсешенең соңгы унъеллыклары матдә турындагы тәгълиматта дөньяны материалистик аңлатуның чәчәк ату чоры булды.* Галәм. Җир. Кеше. *Тимирязев Ч.Дарвинның терек табигатьнең тарихи үсеше турындагы материалистик тәгълиматын армый-талмый яклаучы булды.* Дарвинизм нигезләре

2. *рәв. мәгъ.* Материализм принципларын истә тотып, шуларга таянып, шулар нигезендә. *Феодализм эпохасында дөньяны фәнни, материалистик аңлатырга тырышкан күп галимнәрне утта яндырганнар һәм инквизиция төрмәләрендә газаплап үтергәннәр.* Дарвинизм һәм дин. *Табигатьне дөрес итеп, материалистик аңлауның көче гаять зур.* Умарта кортлары

МАТЕРИАЛИСТЛА́РЧА *рәв.* Материализм күзлегеннән, материализм таләп иткәнчә, материалист позициясеннән. *Син бит комсомолец, Рифгать, һәр мәсьәләгә материалистларча карарга тиеш.* М.Әмир

МАТЕРИАЛЬ *с.* 1) Материянең (*1 мәгъ.*) реаль бер формасында, объектив рәвештә, ягъни аң, фикерләү белән бәйсез рәвештә яши торган; материягә караган; физик, матди. *Дөрес, авыл – гармунчысыз, урман – сандугачсыз, материаль дөнья шагыйрьсез дә яши алыр иде... Ә кешеләр?..* И.Юзеев. *Норвегияле Лейле Рыжийның Америкага үтеп кереп, анда колонияләр төзи башлаганлыгы материаль фактлар белән расланды.* Ә.Кәримуллин. *Иң элек, күкләрнең дә Җирдәге шикелле ук материаль объектлардан торуы беленде: Айда таулар, «диңгезләр» һәм үзәнлекләр булуы, ә илаһи сафлыкның символы булган Кояшта таплар булуы ачыкланды ---.* Галәм. Җир. Кеше

2) Җитештерү чаралары, җиһазлар, чимал һ.б.ш. белән бәйле, шуларга мөнәсәбәте булган. *Теләсә нинди масштабтагы мәсьәләләрне якындагы берничә ел, якындагы ун ел эчендә хәл итәрлек көчебез, материаль һәм материаль мөмкинлекләребез бар.* Серле кристаллар

3) Акча, милек һ.б.ш. формадагы, финанс мәсьәләсенә караган, эш хакы, табыш, яшәү дәрәҗәсе белән бәйле; матди (*1 мәгъ.*). *Кирәкми, Габдрәшитов абый, мин сезгә материаль ярдәм сорап кермәдем.* Г.Тавлин. *Җинаять-челәрне фаш итеп, аларны хөкемгә тарту белән генә эш бетми, урланган, таланган әйберләрне табып хуҗаларына кайтарырга, кешеләргә салган материаль һәм мораль зыян өчен караклар тулысынча җавап бирергә дә тиешләр.* Х.Вәлиәхмәтов. *Чыннан да, эчке кыйммәтләр дә тышкы – материаль кыйммәтләр кебек үк үлчәнә: аларны да эквивалентлар белән чагыштырып карыйлар («сәламәтлек акчадан кыйммәтрәк», «ирек тормыштан кыйммәтрәк») ---.* В.Леви

МАТЕРИАЛЬЛӘШТЕРҮ I *ф. кит.* Чынга ашыру, реальләштерү, сизем-ләнә торган конкрет формаларда гәүдәләндерү

МАТЕРИАЛЬЛӘШТЕРҮ II *и. кит.* Чынга ашыру, реальләштерү, сизем-ләнә торган конкрет формаларда гәүдәләндерү процессы; шуның белән бәйле эшләр

МАТЕРИАЛЬЛӘШҮ *ф. кит.* Реаль әйбергә әйләнү, сизем-ләнә торган конкрет формалар алу, гәүдәләнү. *Уйларның, сүзләрнең материальләшү мөмкинлеге турында белә иде бит, юкса.* И.Иксанова

МАТЕРИАЛЬЛЕК *и.* Матдилек, реальлек, объектив чынбарлыкта булу. *«Реальлек» – «материальлек» түгел, ул чиксез, (Маритен карашынча) «киңрәк», үзенең колачына рухи дөньяны да сыйдыра.* К.Гыйззәтов

МАТЕРИАЛЬ-ТЕ́ХНИК *с.* Эшчәнлекнең берәр тармагында төрле кораллар, техник кирәк-ярак, җиһазлар, транспорт кебек җитештерү чараларына мөнәсәбәтле, шулар белән бәйле. *Хезмәт хакын башкача күтәреп булмый иде: материаль-техник база мөмкинлек бирми – Ленар сыер савучыларның эш нормаларын арттырды.* М.Мәһдиев. *Материаль-техник базаны киңәйтү, механикалаштырылган эре комплекслар төзү буенча чаралар билгеләнде, һәм алар терлекчелекне*

хәзерге заман индустриаль рельсларына күчүне тизләтәчәк. Татарстанда терлекчелек

МАТЕРИК *и. рус* 1) Дөнья океаны йөзеннән калкып торган, кырыйлары су астында урнашкан бик зур мәйданлы коры җир массивы; континент. *Галимнәр кайчандыр гаять зур бер генә материк – Пангея гына булган дип уйлыйлар.* Кызыклар дөньясында. *--- һәркемгә мәгълүм глобус. Материклар һәм океаннар, тау сыртлары, зур күлләр һәм елгалар анда яхшы күренә.* Галәм. Җир. Кеше. *Европа материгында бер генә вулкан – Везувий вулканы гына бар.* Дөньяда ниләр бар

2) Диңгезчеләр телендә судан аермалы буларак коры җир

3) Геологлар, промыселчылар һ.б. телендә утрауга, цивилизациядән бик ерак урнашкан җирләргә карата континент территориясе, олы җир, халык күп яшәгән үзәкләр

МАТЕ́РИЯ *и. лат.* 1) *филос.* Төрле типтагы объектлар рәвешендә (элементар кисәкчекләрдән алып биологик һәм социаль оешмаларга кадәр), кеше аңыннан тыш һәм аңа бәйсез рәвештә яши торган объектив чынбарлык. *Материя мин, җаным, Аның бары Сөйли, җырлый, сагына торганы.* Х.Туфан. *Башта һаман теге тирән уйлар. Вакыт, пространство, материя, температура турында. Галәм төзелеше, атом-молекуляр структуралар турында.* Ж.Юныс. *Мәңгелек материя күзлегеннән караганда, Мона Лиза чүпрәккә сыланган бер-ике кашык буяу гына бит!* М.Маликова

2) Теләсә кайсы физик җисемне тәшкил итә торган нигез, субстрат; матдә. *Чыннан да, җансыз материядән торган безнең планеталарны кем шулкадәр сәгать механизмы кебек көйләгән икән?* М.Әхмәтҗанов. *Атом һәм молекулалар төзелеше өлкәсендәге иң соңгы ачышлар фән горизонтларын киңәйтеп җибәрделәр, материя структурасының иң серле якларын үзләштерергә һәм --- күп төрле процессларны аңлатырга мөмкинлек бирделәр.* Химия фаш итә. *Ньютонның классик физикасына алмашка килгән яңа физика үзе белән материя төзелеше турында өр-яңа фикерләр алып килде.* Галәм. Җир. Кеше

3) *сөйл.* Материал, тукыма. *Ике тәрәзә арасындагы кызыл материя өстенә чын урак белән чын чүкеч беркетелеп, чын ашлык башаклары белән бизәкләп куелган.* М.Фәйзи. *Менә бер яшь ир сөйли: затлы пиджак, килешле галстук, пиджакның түш кесәсеннән аз гына күренеп торган, пиджак белән галстукны ачып җибәрү өчен куелган бер материя кисәге ---.* М.Мәһдиев. *Табутларны яхшы сыйфатлы күн һәм ефәк материя белән тышлаганнар, көмеш кадаклар һәм фигуралы калайлар белән матур итеп бизәгәннәр.* Ф.Хуҗин

4) *күч.* Абстракт төшенчәләр, аң, фикерләү, рух, әхлак кебек категорияләр. *Бу гыйбадларның югары материяләрдә гаме юк. Тирән фикерләр әйтеп исрафланасы да түгел.* З.Фәтхетдинов. *Без зур материяләр хакында язарга өйрәнгән кеше түгел югыйсә.* Р.Зәйдулла. *Тик шунысы бар: югары материяләр, ил күләмендәге карарлар, политик тәгълиматлар хакында сөйләве тыңлаучыларына барып җитәме, юкмы – бу хакта әллә ни уйланмый.* С.Шәрипов

МАТЛУБ *с. гар. иск.* **1.** Тиеш булган, таләп ителгән, кирәкле

2. *хәб. функ.* Тиеш, таләп ителә, кирәк. *Бюро әгъзалары, фракциядәге депутатларымыз берләп бергә утырышып, закон проектлар хәзерләү дәрәҗәдә мәгълүмат, тәҗрибә сахибләре булырга тиеш (юристлар булуы матлуб).* Г.Исхакый

МАТРАС *и. гар.* Караватка яки башка каты каркаслы ятакка салу өчен, сырып эшләнгән йомшак калын җәймә; көрпә. *Егетләр күлмәкләрен юып элделәр, чалбарларын үтүкләп, матрас астындагы фанер такта арасына кыстырып куйдылар.* М.Юныс. *Җиһаз-мазар юк, бары бер почмакта матрас, юрган һәм ак тышлы мендәр ята.* М.Маликова

МАТРАСЛЫК *с. сөйл.* **1.** Матраска дип билгеләнгән, шуңа әзерләп куелган; матраска яраклык, бер матраска җитәрлек. *Матраслык мамык*

2. *и. мәгъ.* Матрас ясау өчен әзерләнгән мамык, тукыма кебек материаллар

МАТРА́У *ф. диал.* 1) Уңайсыз утырып, ятып, хәрәкәтсез торып кан йөрәше әкренәю аркасында кул яки аяк ою

2) Әле генә бик каты эшләп яки чабып кайткан атны кызган, тирләгән килеш эчерү аркасында, атның аягы аксау. *Хәйретдин карт аяклары матраган бияне, яхшы тәрбияләү белән бергә, ныклап дәваларга да тырышты.* Ш.Камал

МАТРАЦ *и. к.* **матрас**. *Караватка пружиналы матрац урынына куелган тимерчыбык ятьмә ни өчен ятарга каты түгел?* Кызыклы физика. *Артында берничә матрацка уңайлап салынган Биҗан ара-тирә авыр ыңгыраша-ты.* Г.Тавлин

МАТРЁШКА *и. рус* Эче куыш ярымовал формасында агачтан кырып ясалган, берсе эченә икенчесе куела торган традицион рус курчагы. *Иртәгә тамашада катнашачак һәрбер артистка кечкенә генә сувенир бирелә. Матрёшкалар!* Х.Ибраһим

МАТРИАРХАЛЬ *с.* Матриархат принципларына нигезләнгән, асылы матриархаттан гыйбарәт булган. *--- убырлы карчык персонажы үзенең үсешендә ике этап кичергән: башта ул, йолага аваздаш рәвештә, кешеләргә ярдәм итүче, бүләк бирүче буларак гәүдәләнсә, соңрак, матриархаль тәртипләр беткәннән соң, явыз итеп сурәтләнә башлаган.* Л.Җамалетдинов

МАТРИАРХАТ *и. лат.-гр.* Борынгы ыруглык җәмгыяте үсешенең патриархатка кадәр булган, гаиләдә, көнкүрештә һәм җәмәгать тормышында хатыннар (ана) җитәкче рольне уйнаган чор. *Каршыңда – мин. Матриархатның үзе теләп әсир төшкән бер тоткыны.* Р.Фәйзуллин. *Су анасы, Урман анасы, Бик анасы... Борынгы грекларда аллалар булса, мәҗүси бабайларда аналар булган. Матриархат чорыннан ук киләдер.* Ш.Галиев. *Матриархат чорында да үзләренең нәфислекләрен саклап кала алганнар [хатыннар].* Р.Вәлиев

МА́ТРИЦА *и. лат.* 1) Металл эшкәртүдә пресслау, штамплау, сузу кебек эшләрдә кулланыла торган үтәли тишекле яки уемлы инструмент

2) *полиграф. иск.* Типографик литерлар кою өчен файдаланылган, хәреф яки билгенең туры сурәте төшерелгән тимер кисәге. *Сенат типографиясендәге гарәп хәрефе белән коелган матрицалар --- Казанга күчерелә.* И.Рәмиев. *Хәрефне корыч таякчык очыннан йомшак пластинкага басып төшергәч, литерлар кою өчен нигез – матрица хасил булган. Хәреф-литерны матрицага утта эретелгән металл коеп ясаганнар.* М.Вәлиев

3) *полиграф. иск.* Басма калыпның стереотиплар кою өчен файдаланыла торган тискәре (батынкы), пластик материалдан эшләнгән копиясе. *Әхмәт Симаев [яшерен хатларны] тиз арада синтетик матрицага төшереп бирде.* Ш.Маннур

4) *полиграф.* Басып бизәк төшерүдә файдаланыла торган штампның сырлы копиясе

5) Фотоаппарат, видеокамера, компьютер дисплее кебек цифрлы техниканың бик вак фотоэлектрик әверелдергечләрдән торган төзелмәдән гыйбарәт бер состав өлеше

6) *мат.* Алгебраик һәм дифференциаль тигезләмә системаларын җыйнак язу ысулы булган, башлыча турыпочмак формасындагы таблица. *Яңа мисал өтеп, М – икенче тәртиптәге, элементлары реаль саннар булган квадрат матрицалар күплеге, дип фараз итик ---.* Күпбуынлар. *Тигезләмәләр системасының сул ягы коэффициентларын цемент катылыгы матрицасы тәшкил итә.* Материаллар һәм конструкцияләр механикасы

7) *күч.* Гомумән, үрнәк, калып, беренчел вариант. *Әгәр бу негативтагы сурәтне оригиналның төгәл күчермәсенә әйләндерергә кирәк булса, хәзерләнгән матрицаның күчермәсен алырга туры килә ---.* Физика курсы. *Нәсел информациясен саклау һәм аны гамәлгә ашыру өчен күзәнәктә иң элек нуклеин кислоталары җавап бирә: алар үзенә бертөрле матрицалар (калыплар) булып хезмәт итәләр, тереклекнең күпләгән күчермәләре шулардан алына.* Галәм. Җир. Кеше

МА́ТРИЦАЛАУ *ф. к.* Оригиналдан матрица ясау

МАТРОС *и. голл.* Хәрби диңгез флотында кече, гаскәрнең башка төрләрендә солдатка туры килә торган хәрби звание, шулай ук сәүдә флотында судно командасы составындагы хезмәткәр; диңгезче. *Күпне күргән адәмдәй кырыс, эре кыяфәт белән уң аягын алгарак куеп баскан яшь кенә матрос трапны алырга әзерләнгән иде инде.* М.Маликова. *Матрослар җылы дулкыннарга сикерешеп төшәләр дә колач салып йөзәләр.* М.Мәһдиев. *Бу ике матрос белән вахтада торучы штурман – чибәр Лохмачев та иркен каютасында рәхәтләнеп ял итә.* М.Юныс

МАТРО́СКА *и. рус сөйл.* 1) Матросларның форма киеме – зур туры кайтарма якалы иркен блуза

2) Шундый ук яки охшаш тегелешле балалар яки хатын-кызлар блузасы. *[Рөстәмнең] өстендә өр-яңа ак матроска белән кыска ак чалбар иде.* А.Шамов

МАТРОСЛА́РЧА *рәв.* Матрослар гадәте буенча, матросларга хас булган рәвешле, матросларга охшатып. *Ул [Х.Ярми], матросларча бераз алгарак йөгенеп, кулларын болгый-болгый тиз-тиз атлап, каядыр ашыга иде.* Г.Бәширов. *Диңгез флоты көннәрендә матросларча киенеп йөрергә яратса да, корабта хезмәт итмәгәнгә охшый.* М.Юныс

МАТРОСЛЫК *и.* Матрос хезмәте. *Мин ике улымны да матрослыкка урнаштырдым.* М.Юныс. *--- Пётр патшаның 1722 ел, 19 гыйнвар фәрманы нигезендә, татарларның 10–12 яшьлек балаларын рекрутлыкка алалар. Аларның өчтән бере денщиклыкка, матрослыкка бирелә.* Р.Зәйдулла

МАТУР *с.* **1.** 1) Тышкы күренеше гармонияле, күзгә ятышлы, күркәм; төсләрнең, бизәкләрнең, сызыкларның нәфислеге, йомшаклыгы белән аерылып торган. *Алар Кара диңгез буена – Җир шарының иң гүзәл почмакларының берсенә, оҗмахтан да матуррак бер җиренә киләләр ич.* Н.Дәүли

2) Чибәр (кеше тур.). *Шулай да, үзем дә белмим, Арча җирләрендә кызлар ни өчендер матуррак кебек тоела миңа.* Н.Дәүли. *Матур буласы килми соң Дөньяда кайсы кызның? Чибәр күренәсе килми, әйтегез, кайсыгызның?* Ш.Галиев. *Кичен, йокыга ятар алдыннан сөйләгәннәр иде: шәһәрдән бик матур бер кыз кайткан, ак «Жигули»га утырып кайткан.* М.Мәһдиев

3) Гомумән, йөз чалымнары игътибарны җәлеп итә торган, ягымлы булган. *Бабай бик күп яшь яшәгән, карт ул үзе. Ләкин һаман сәламәт ул, матур йөзе.* Г.Тукай. *Ул үзенең ал күлмәге, матур чырае белән бик зур гөл чәчәгенә охшый, ифрат та сөйкемле.* Ш.Камал

4) Хәрәкәтләре җиңел, йомшак, килешле, нәфис, сыгылмалы булган. *Шәрәф озак, матур фигуралар ясап, төрле сүзләр ычкындырып, дәртләнеп бии.* М.Фәйзи. *Матур йөреш*

5) Аһәңле, гармонияле яңгырашлы, колакка ятышлы, нәфис. *Ул кылларны думбрага тартып куялар да чиртә-чиртә көй уйныйлар. Матур, бик моңлы җыр килеп чыга.* Н.Дәүли. *Кеше тавышы нинди матур, ягымлы икән!* Х.Камалов. *Матур җырдан туймыйсың, сөйгән ярдан бизмисең.* Ш.Галиев

6) Хыялда, теләктә күз алдына китерелгән кебек, идеаль. *Сугыштан соң тормыш матур булачак.* Х.Камалов

7) Уңай, күркәм сыйфатларга ия булган, харизмалы, гармоник табигатьле, ипле холыклы (кеше тур.). *Дөньядагы барлык гүзәл нәрсәләрне шигыремә килә кертәсем. Тирәмдәге бөтен матур кешеләрне, табын җәеп, килә кунак итәсем.* Л.Шагыйрьҗан

8) *сөйл.* Гомум кабул ителгән, җәмәгатьчелек тарафыннан хуплана, мактала, хуш күрелә торган, уңай, күркәм. *– Аның яхшылыкларын белми генә калганбыз икән. – Кара, нинди матур йола икән! – дип, кет-кет көлеп куйды бер яшь кенә хатын-кыз врач Анна Сергеевна.* Х.Камалов. *Һәркөнне аның бер матур сыйфаты ачыла бара.* К.Тимбикова

9) Күңелгә хуш килә торган, җанга рәхәт бирә торган, рухи канәгатьләнү, ләззәт бирә торган. *Үзәк өзгеч матур картина булып күз алдыма килде.* М.Әмир. *Макаров матур теләкләр, яхшы киңәшләр әйтеп балалар белән саубуллашты.* Ж.Фәйзи. *Безнең татар халкында кешене бәяләгәндә әйтелә*

торган бик матур бер сүз бар: «Дөнья күргән, ил-җир күргән кеше», – диләр. М.Мәһдиев

10) Сәнгатькә караган, нәфис. *Матур әдәбият миңа гаделсезлекне кичерергә ярдәм итә иде, мин киләчәккә гел якты өметләр белән яшәдем.* М.Мәһдиев

11) *күч. ирон.* Буш, мәгънәсез, кыйммәтсез, ышанычсыз, тышкы эффект тудыру өчен генә әйтелгән, эшләнгән. *Матур сүзләрен кызганмыйлар, теллә-реннән бал тама.* К.Тимбикова

2. *рәв. мәгъ.* Килешле, әйбәт, күңелле итеп; күңелгә ятышлы рәвештә. *Яз аенда матур ага Шул Каманың бозлары; Эшкә оста, сүзгә кыска Безнең Бондюг кызлары.* Җыр. *Шулай иткәндә, ихтимал, Ханәфи абзаң бу көнгә калмас: саутаза булыр, матур гына яшәп, әйбәт кенә эшләп йөрер иде...* В.Нуруллин. *Матур китү турында уйлану берәүгә дә иртә түгел.* Р.Фәйзуллин

3. *и. мәгъ.* 1) Чибәр кеше, гадәттә хатын-кыз. *Суда балык йөзәдер лә, Су салкынын сизәдер шул, сизәдер; Авылыбызда бер матур бар, Үзәгемне өзәдер шул, өзәдер.* Җыр. *Бәйрәмнәр күп... Сабантуйга җитә сирәге! Матурлар күп... Ә күңелгә – Син иң кирәге!* Р.Фәйзуллин. *Матурлар арасында ямьсез булып йөргәнче, ямьсезләр арасында матур булып яшәвең мең артык!* Г.Рәхим

2) *тарт. форм.* **матурым, матуркай(ым)**. Үз итеп, яратып, иркәләп, якын итеп атау, эндәшү, мөрәҗәгать итү сүзе. *Хәбиб ачуланып үпкәләп йөри башласа, көтмәгәндә генә аңа «матурым» дип дәшеп куя иде.* М.Мәһдиев. *– Әлфирә, матурым, зинһар, борчылма, – дип, ашыга-ашыга, өзелгән сүзен ялгап китте Зәвил.* Ф.Шәфигуллин

МАТУРАЙТУ *ф.* Матур итү, матурлык бирү, матурлык өстәү; бизәү. *Урамны, авылны матурайту ихтыяҗы йөртми шул аларны.* Р.Мөхәммәдиев. *Осталыкның югары бер ноктасында иҗат башлана. Шул илһамландыра адәм баласын, шул матурайта, яшәртә.* М.Юныс

Матурайтып җибәрү Бераз матурайту, өстәмә рәвештә матурайту. *Тәрәзә-көзге аның йөзен баягыдан да матурайтып, чибәрләндереп җибәргән.* Н.Хәсәнов. *--- Эмиль һәм Ранисларның җырлап килеп керүләре тагын да җанлылык өстәп, бәйрәмне матурайтып җибәрде.* Туган як

МАТУРАЮ *ф.* 1) Тышкы матурлыгы сизелерлек арту, гүзәлләнү, ямьләнү, матуррак булып күренә башлау. *Иң элек, саргылт ямаулыкларга охшап, ут чәчәге утраучыклары барлыкка килер. Алар янына башка төрле чәчәкләр дә өстәлгәч, болын чуарланыр, тагын да матураер...* М.Хәсәнов. *Гөлниса тагы да матурайды, күзне камаштырырлык гүзәл булып җитеште.* Л-Х.Таналин

2) *диал.* Матур булып күренергә тырышу, бизәнү-ясану. *[Кече кызлары] Әнкәсенә чәч буявы алган. Янәсе, яшәртмәкче булган. Нишлисең, заманы шундый. Шәһәр әбиләренә генә матураерга димәгән ич.* Н.Дәүли

Матураеп китү Билгеле вакыт аралыгында матурлыгы сизелерлек арту. *– Сөбханалла, улым, матураеп, яшәреп киткәнсең бит. Шулай гына бул. Әллә берәр сылуга гашыйк булдыңмы? – дип төпченде Тәклимә түти.* Х.Сарьян. *Бала тапкач, җитмәсә угыл да булгач, Туйбикә тагын да түгәрәкләнеп, матураеп китте.* М.Хәбибуллин. *Ул бераз яшьләрә төшкән, әмма моңарчы беребез дә белмәгәнчә матураеп киткән иде.* Р.Ахунова

Матурая бару Торган саен матурлыгы арту, элеккегедән матуррак хәлгә килү. *Торган саен үсә һәм матурая барган моңлы тавыш тәэсиренә бирелгән халык оеп тыңлый иде.* М.Шабай. *Торган саен матурая бара балачакта күргән төш кенә.* Р.Фәйзуллин. *--- бертын тирә-юньне күзәтеп торды. Дөнья һаман саен матурая гына бара иде.* Р.Мөхәммәдиев

МАТУРЛАНДЫРУ *ф. к.* **матурлау**. *Көнчыгыштан искән йомшак кына җил диңгезнең өс катын азрак җыерчыкландырып бизи, матурландыра ---.* Ш.Камал

МАТУРЛАНУ *ф.* 1) *к.* **матураю** (*1 мәгъ.*). *Чәчәк ата туган илем, Матурлана көн саен.* Җыр. *Яз матурлана, Җәй ышыклый, Көз ашата, Кышын җылыта.* Табышмак. *Үткәннәрем, зәңгәр хыял булып, Йөрәгемдә һаман саклана: Гомер үткән саен матурлана, Кадерләнә бара, сафлана...* Х.Туфан

2) Тышкы кыяфәте, буй-сыны тулылану, тазару, үсү, камилләшү, төс керү (гадәттә хатын-кыз һәм яшьләр тур.). *Кичә бер ай срок белән Берлиннан Гариф Галиев кайтып төште. Шундый матурланып, мутланып кайтты.* Г.Бәширов. *И-и-и, күз нурым! Син Сәфәргали малае бит. Ничек матурлангансың. Танырлык та түгел.* М.Юныс. *– Гөлкәй җаным! Үзгәргәнсең диимме соң? Әллә тагы да матурлангансың инде? – дип, тагы Гөлкәйнең кочагына ташланды [Гөлүсә].* Х.Ширмән

3) Җайлану, уңай якка үзгәрү, көйгә салыну, яхшыру, рәхәт, тыныч тормыш өчен мөмкинлекләр барлыкка килү. *--- башка берәр колхозга кушкан булсалар да, колхозның үзәге Куралыкта булыр, һәм ул менә шушылай үчүгә бармас, киресенчә, зурайган, матурланган булыр иде.* В.Нуруллин. *Хәзер безнең башкалабыз күп тапкырлар зурайды, баеды һәм матурланды ---.* Дөньяда ниләр бар

4) Тышкы кыяфәтне, киемне тәртипкә китерү, ыспайлану, матур күренү өчен бизәнү-ясану. *Киендем, хәл кадәре матурландым.* М.Гафури. *Чәчәкләр дә күбәләкне җәлеп итү, ымсындыру өчен – нәсел калдыру өчен матурлана, бизәнә.* Ш.Галиев

Матурлана бару Торган саен матурлыгы арту, яхшыру, чибәрләнү. *Якынайган саен тылсымлы сурәт зурая, матурлана бара.* Ф.Латыйфи

Матурлана башлау Матурлануга табан үзгәрү. *Шулай атна-унбиш көн диетада утыргач, Җирәннең тагын тавышы көрәйде, тиресе матурлана башлады, гайрәт керде.* М.Мәһдиев

Матурлана төшү Бераз матурлану, матурлыгы сизелерлек арту; тагын да матурлану. *Әлфинур чәчәкләр арасына кергәч, гөлбакча тагын да матурлана төште.* З.Фәйзи. *Асылбикәнең бите тагын да матурлана төшкән, ирен кырыендагы җыерчыклары язылган иде.* Гөлшәһидә

Матурланып җитү Бик матур кыяфәт алу, тәмам матурлану. *Моның берсе иң төпчек кыз – нәзек торна*

аяклы, зур авызлы, әлегә матурланып җитмәгән Тәслимә иде ---. М.Мәһдиев. *Өстәвенә, юатып: – Тора-бара тәмам матурланып җитә ул! – диделәр.* З.Фәйзи

Матурланып калу Берәр хәлдән соң матурлану, матур булып күренү. *Үзе ура, үзе суга, Үзе капчыкка сала, Ул гөрләп эшләгән чакта, Кыр матурланып кала.* Табышмак

Матурланып килү *к.* Матурлана башлау. *Бездә, мистер, эшләр әйбәт хәзер, Матурланып килә һавалар.* Һ.Такташ

Матурланып китү Билгеле бер моменттан алып сизелерлек матурлану ягына үзгәрү. *Ул, атасы-анасы берлә сөйләшмәсә дә, пароходның башына чыгып утырып, рәхәтләнеп карап килде. Хәтта аның йөзе дә матурланып киткән кеби булды.* Г.Исхакый. *Руфинә тазарып, матурланып китте, юккабарга чәүчәләкләнүләре, көйсезләнүләре кими барды, басынкы кызга әверелде.* Ф.Садриев. *Баш сызлау көннәре – өянәге узганнан соң, Әлфинурның рухы күтәрелеп, күзгә күренеп җанланып киткәндәй була. Йөзенә яңадан нур иңә, матурланып китә.* З.Фәйзи

МАТУРЛАП *рәв.* Матур, пөхтә итеп. *Туры аткан өчен алган знакны бик матурлап күкрәккә кададым.* Г.Исхакый. *Шул арада матурлап эшләнгән тимер рәшәткәле койманың теге ягында биек-биек ике таш йорт өлгерткәннәр.* Ш.Рәкыйпов. *Бригададагы ун кешенең һәркайсы биш мең кирпечне матурлап өйдеме – көнлек норма үтәлде дигән сүз.* Ф.Баттал

МАТУРЛАТУ *ф. к.* **матурайту**. *Дөньяны матурлатырга, рәхәт-шатлык татырга, бәхетле көн итәргә туа бит адәм баласы бу җир йөзенә!* Ә.Рәшит

Матурлатып җибәрү Бераз матурлату

Матурлатып кую Алдан матурлату. *Хәтимә өйне тагын да матурлатып куйган. Кәгазьдән бизәкләп кисеп, яңа тәрәзә пәрдәләре элгән, идәнне ап-ак итеп кырып юган.* Ж.Фәйзи

МАТУРЛА́У *ф.* 1) Тышкы матурлык бирү, бизәү, кемне-нәрсәне төрле чаралар белән матур төскә кертү, ямь өстәү, яхшы күренеш бирү. *Парикмахер җаным, Матурла син мине, Теләсәң ничек итеп матурла: Тик бер генә кабат сөйләсеннәр Минем матурлыгым хакында...* Һ.Такташ. *«Туган тел» шигырен шәмаилгә язганнар. Шуны матурлап, бизәп, мәктәпләрдә кую өчен, плакат итеп чыгарасы иде.* Ш.Галиев. *Матурлап, чистартып, агартып Үтәләр гел шулай көннәрең.* Ф.Яруллин

2) Камилләштерү, сәнгатьлелек дәрәҗәсен арттыру, стилистик бизәкләр өстәү, шомарту, купшырак, үтемлерәк, тәэсирлерәк итү (сөйләмне, стильне һ.б.ш.ны). *Фаил Шәфигуллинның хикәя һәм повестьларына кергән табигать күренешләре – әсәрләргә лирик тон бирү яки аның канвасын матурлау өчен генә алынган бизәк түгел.* Л.Ихсанова

3) Матурлык бирә, ямьләндерә торган элемент булу, бизәк ролен үтәү. *Тын бакчада кошлар сайрый, Сибелә айның нурлары; Көмеш төсле ай нурлары Матурлыйлар дөньяны.* Җыр. *Иң элек түбә күзгә ташлана, түбә матурлый, түбә яшәү өчен уңайлыклар тудыра, түбә корылманы җил-яңгырдан, черүдән саклый.* М.Юныс. *Егетләрнең шашкын моң-җырлары Матурлады кырыс елларны.* Рәшит Әхмәтҗанов

4) *күч.* Эчтәлеген тулыландыру, баету, җанлылык өстәү, рухи яктан үстерү, яхшы якка үзгәртү. *Әдәбият-сәнгать кешене матурлый. Беренче чиратта – иҗатчысын.* Ш.Галиев. *Аллаһы Тәгалә безнең үзебезгә бирелгән ареалда яшәргә, аны сакларга, матурларга, кадерен белергә кушкан.* М.Юныс

Матурлап тору 1) Матурлык бирү, матур төс кертү, матурлык өстәү. *Уз өен генә түгел, бөтен урамны матурлап, авылга нур, яктылык һәм ямь өстәп торсын ул ясаган тәрәзә йөзлекләре.* Р.Мөхәммәдиев. *Хәтта почмактагы кечкенә генә миче дә өйне матурлап тора.* Ф.Яруллин

2) *к.* **матурлап утыру**

Матурлап утыру Матурларга, бизәргә тырышып җентекләү, тәфсилләү. *Анда һаман шул план куу, матурлап утырырга вакытлары юк.* Ф.Яруллин

МАТУРЛЫК *и.* 1) Хозурлык, камиллек, гармония; эстетик ләззәт бирә торган сыйфатларның барлыгы. *Безнең буын байлыктан дошманлык, карунлык, мещанлык, күремсезлек түгел, нәкъ шуларның киресен – туганлык һәм матурлык тойгылары тәрбияләү юлын эзләп табарга тиеш.* А.Гыйләҗев. *Баталов матурлыкка гашыйк җан иде. Матурлыкны күрә, бәяли белә иде.* Ш.Рәкыйпов. *Матурлык табигатькә ширбәт сыман таралган, бал корты кебек тырышып җыярга кирәк аны.* Ш.Галиев

2) Күзгә ятышлы, матур, сокланырлык урыннар, гүзәл манзара. *Дөньяда безнең авылның урманга таба җәелеп яткан басуында борчак кузаклангән кояшлы көннәре кадәр ямьле вакыт, рухи күтәренкелек, хөрлек, матурлык тагын кайда була икән?!* М.Мәһдиев. *Мин күрмәгән җирләрдә әллә нинди матурлыклар, шатлыклы кичерешләр бардыр кебек тоела.* М.Юныс. *Әйе, тормыш һәм табигать, тирә-юнебез бетмәс-төкәнмәс матурлыклар һәм могҗизалар белән уратып алынган.* Р.Низамиев

3) Йөз чалымнарындагы нечкәлек, гармониялелек; гомумән, матур, ягымлы, сөйкемле, үзенә җәлеп итә торган тышкы кыяфәт; гүзәллек, чибәрлек. *Төскә син ямьсез, матурлык синдә юк, тик вөҗданың Пакь синең, күңлең ару, нечкә, беләм, ямьле җаның.* С.Сүнчәләй. *Әйе, хатын-кызга табигать нәфислек белән матурлыкны жәлләмәгән.* З.Фәйзи. *Ә менә йөзе? Матурлыгын җуймаган да шикелле, әмма таушалган* ---. М.Әмирханов

4) Кешене бизи торган, аның уңай образын тудыра торган, уңай тәэсир калдыра торган характер үзенчәлекләренең, сыйфатларының барлыгы. *Мин яратып карыйм, берәү дә күрмәгән матурлыгын күрәм.* Ш.Галиев. *Сине мин беренче булып ачтым: Синең кыргый матурлыкны күрдем.* Р.Гаташ

МАТУР-МАТУР *с.* Берсеннәнберсе матуррак булган. *Бик еш кына, үз янына утыртып, [әбием] миннән матур-матур теләкләр теләтте, синең кылган догаларың Ходай күңеленә тизрәк барып җитәр, ди иде.*

А.Хәсәнов. *Җилкәләренә ак сөлгеләр салган яшь егетләр, матур-матур хәрәкәтләр ясап, шул савытларга шампанский салып чыктылар.* М.Мәһдиев

МАТЧ *и. инг.л.* Ике яки берничә спортчы яисә команда арасында үткәрелә торган спорт ярышы. *Матч дәвамында алар безнең капкага 7 һөҗүм генә ясый алды.* Мәдәни җомга. *Федераль каналлар Универсиада ярышларын хоккей матчлары кыза төшкәч кенә күрсәтә башлады.* Ватаным Татарстан

МАТЧА *и. рус* Агач биналарда түшәм такталарын тотып тора торган төп аркылы борыс, өрлек. *Матчаларга элгән бишек – Әлли-бәлли, әлли-бәлли... Сабый җанга ни кирәген Син кайлардан сиздең әле?* Х.Әюп. *Бар иде, аның түшәм матчасына кыстырып куйган, шыгырдап торган унтугыз тәңкәсе бар иде.* А.Гыйләҗев. *--- түшәмнең сапсары нарат матчасы, тәрәзә кашагалары, ишек яңаклары кара бизәк белән тоташ чуарланган ---.* М.Маликова

МАТЧАЛЫК *и.* **1.** Матчага дип билгеләнгән агач, бүрәнә. *Кара урман! Көндез Печән чабып, төндә ат чабып, Палищщиктан урлап, синнән генә Шарт аудара идек матчалык.* А.Хәлим

2. *с. мәгъ.* Матча итеп куярлык, матча булып хезмәт итәрлек, шуңа дип билгеләнгән. *«Әхмәтне Табай авылында күрдем, «Рамай»ны җырлый-җырлый, матчалык бүрәнә юна иде», – дип сөйләгән ---.* Т.Миңнуллин

МАТЫ *и. к.* **мат** II. *Моның стенасы да, түбәсе дә пальма яфракларыннан, стена хезмәтен үтәүче матыларны җил селкетеп тора, баш очында пальмалар шаулый, берничә метр читтә океан үкерә иде.* М.Мәһдиев

МАТЭ *и. кечуа бот.* 1) Падубчалар семьялыгына караган, башлыча Көньяк Америкада таралган, яфракларында һәм яшь сабакларында кофеин булган мәңгеяшел агач үсемлек. *Мәсәлән, кофеин алколоиды --- падубчалардан (падубовые) матэ (парагвайский чай) һәм кош өрәңгесе (падуб) яфракларында --- табылган.* Агулы үсемлекләр

2) Үләннәр һәм әлеге агач яфракларын пешереп ясалган, тонус бирә торган эчемлек; парагвай чәе. *Матэны калебаса дип аталган махсус савыттан эчәләр*

3) Шундый эчемлек өчен әзерләнгән үлән чәе. *Матэнының төрле сорты сатыла*

МА́УЗЕР *и.* Винтовка, пистолет һ.б.ш. утлы коралның немец конструкторлары Вильһельм һәм Пауль Маузерлар уйлап чыгарган системасы. *Танкетка янында, ике кулына ике маузер тотып, бер полковник басып тора.* Ә.Галиев. *Кара чәч, кара сакал, өстендәге кара кием, кулындагы зур кара маузер аны шулай дәһшәтле итеп күрсәтә, кара акай күзләре ялт-йолт килеп бөтен тирә-юньне айкый иде.* З.Фәтхетдинов. *Бил каешында уңда – инглиз маузеры, сулда төрле асылташлар белән бизәкле кәкре Бохара кылычы аскан үтә сугышчан кыяфәтле кешене күргәч, бүлмәдә утырган киң маңгайлы чекист урынынан сикереп торды.* Т.Әйди

МАФИОЗ *с.* Мафиягә караган, мафия оештырган, мафиядән гыйбарәт. *Газета-журналларда мафиоз оешмалар турында яза башладылар.* М.Юныс

МАФИО́ЗИ *и. ит. к.* **мафияче**. *Телевизор карый Рәсәй. Инде ничә кат карый: Сицилия... Мафиози... Һәм комиссар Каттани.* Л.Лерон. *Мондый җитди әзерлеккә итальян мафиозилары да көнләшерлек иде.* Р.Мирхәйдәров

МАФИО́ЗНИК *и. рус сөйл. к.* **мафияче**. *Тынычланыгыз, әфәнделәр, тынычлан! Сез мафиозниклар түгел бит, көч белән аңлашырга...* З.Фәйзи. *Юлга чыгып бер сызгырсам, бай, надан мафиозник малайлар мине әрсез көзге чебеннәр кебек сырып алачак, акчага күмәчәк.* Т.Галиуллин

МА́ФИЯ *и. ит.* 1) XVIII йөздә Сицилиядә барлыкка килгән, көчле, тармаклы яшерен җинаятьчел оешма. *Атышулар, үтерүләр, Дары исе, кан исе... Мафияне эзәрлекли Курку белмәс комиссар.* Л.Лерон

2) Гомумән, оештырылган җинаятьчелек. *Ул бөгелә, ул сыгыла, Ул иелә, баш ия. Марионетканы биетә Я фирка, я мафия.* Л.Шагыйрьҗан. *Тиздән яшь һәм талантлы оста белән җирле мафия кызыксына.* Кызыклар дөньясында. *--- ул [Т.Галиуллин] --- нәкъ менә бүгенге тормышның иң кайнар һәм хәтәр ягын – әле формалашып кына килүче милли мафиянең йөзен ачып бирә.* Казан утлары

3) *күч.* Гомуми мәнфәгатьләр белән берләштерелгән, бер сүздә булган кешеләр төркеме яки катламы. *Сталин чорында безнең әдәбият культка хезмәт итте, торгынлык елларында – җитәкчеләр мафиясенә.* М.Юныс

МА́ФИЯЧЕ *и.* Мафия әгъзасы, мафиядә катнашучы. *Болай дигәндә, мин милиция майоры Александр Алаевны – мафиячеләр башлыгы Шамил Бакаевның шымчысын күздә тотам.* Б.Камалов

МА́ФИЯЧЕЛ *с.* Мафиоз эчтәлекле, җинаятьчел. *Монда тасвир кылынган мафиячел төркемнәрнең башында Дәү абзый (Әмир Шаһназаров) тора.* Б.Камалов

МАХАОН *и. гр. зоол.* Җилкәнканатлылар семьялыгыннан, личинкалары чатырчәчәклеләрдә һәм рутачаларда яши, канат колачы 90 мм га җитә торган күбәләк төре. *--- Балачакта мин кара махаон тоту һәм кургашын ташы табу хыялы белән яна идем ---.* Дөньяда ниләр бар. *Безнең республикабызның иң эре һәм матур күбәләкләре – җилкәнканатлылар. Махаон, аполлон, мнемозина, подалирий безгә яхшы таныш.* Татарстанның үсемлекләр һәм хайваннар дөньясы

МАХАРА́ДЖА *и. санск. к.* **махаража**. *Тот та сәхнәгә чыгар: Отелло булсын, Махараджаны уйнасын, Брут булсын.* М.Мәһдиев

МАХА́У *и.* Озын инкубация чоры белән аерылып торган, тирене, бугазны, эчке органнарны зарарлый торган йогышлы авыр хроник авыру, лепра; *русчасы:* **проказа**. *Әйтерсең алар тозланган, каешланган гимнастёркалары астында махау чире йөртәләр: ул бичараларны якын җибәрмиләр.* М.Хафизов

МАХАУЛЫ *с.* Махау авыруы белән зарарланган (әгъза), махау белән авырган (кеше)

МА́Х БИРҮ *ф. сир. к.* **махы бирү**. *Хәкимем түргә – почётлы кунаклар*

янына китеп барды, ә мин... мин шунда гына үземнең нинди мах биргәнемне абайлап алдым. С.Сабиров

МАХИЗМ *и. нем. филос*. XIX йөз ахырында Э.Мах һәм Р.Авенариус җитәкләгән, реаль матди дөньяның барлыгын инкяр итеп, аны аң күренешләренә һәм тоемлауга кайтарып калдырган субъектив-идеалистик философик агым; эмпириокритицизм. *Махизм философиясе, бигрәк тә алла төзүчелек, политикада реакция белән бергә кушыла иде*. КПСС тарихы

МАХИНА́ТОР *и. лат. сөйл.* Махинацияләр остасы, аферист. *Әхлаксыз махинаторлар властька тулып, тормышны таяк тыгып актарган кырмыска оясы кебек ясагач, заводта эшнең рәте-чираты бетеп, яман чир безнең гаиләгә дә китереп сукты.* З.Фәйзи

МАХИНА́ЦИЯ *и. лат.* Кабул ителгән законнарны, гадәтләрне читләтеп, ялган, хәйлә белән башкарылган эш; эш итүдә гадел булмаган ысул, юл. *Сез кем?.. Җитәкчеләрме, әллә Остап Бендер кебек төрле махинация белән шөгыльләнүче «комбинаторлар»мы?* М.Хәсәнов. *--- хезмәт урыныннан файдаланып, ниндидер махинацияләр юлы белән шыпырт кына, яшертен генә еллар дәвамында байлык туплап яткан адәм затлары очраштыра ич кайда да ---*. Р.Мөхәммәдиев. *Ә бүген исә властьта кайсы – парламентны тупка тотып, кайсы – сайлаучыларны акчага сатып алып, кайсы сайлау вакытында махинация ясап күтәрелгән карьеристлар утыра.* З.Фәйзи

МАХИСТ *и. нем.* Махизм карашларында торучы фәлсәфәче

МАХМЫР *и. гар. сөйл.* 1) Артык күп исерткеч эчемлекләр эчеп химик агулану белән бәйле сиптомнар: хәлсезлек, бик каты баш авырту, үзеңне бик начар хис итү хәле; аракы чире. *– Кичә дустым көмешкә белән шундый сыйлады – үлә яздым! – ди бу. – Ә бүген иртән махмырдан баш төзәттердеме соң?* Ш.Маннапов. *Сал тизрәк. Махмырдан үләм дип торам, ә кесәдә җил уйный.* Р.Зәйдулла. *--- Сара апа, берәр әче-мөчең юкмы, махмыр бит, коткар!..* С.Лашманчы

2) Алкогольле эчемлекләрнең эшкәртелү калдыгы булган сивуха майлары исе. *Йөзеннән, үзен тотышыннан, теленнән күренеп, эчкеченең авызыннан бәреп торган махмыр исе шикелле аңкып тора бит аның нинди нәселдән икәне.* Т.Галиуллин. *Үзебез йоклаганда да курку-сагаюыбыз уяу. --- «зур дәрәҗәләр биләүче» адәмнән тирәякка авыр махмыр исе тарала иде.* Р.Мирхәйдәров

3) *күч.* Артык күп күргән, кичергән нәрсәләрнең күңелсез нәтиҗәсе, ачы тәҗрибә. *Юк, борынгыдан килгән инстинкт кына түгел бу, ямanаты чыккан еллардан сеңеп калган, шуның махмыры.* Ш.Галиев. *Ә сез – йолкыш! Махмыр йокысында, Кузгаталмас оран, әмер дә...* Р.Зәйдулла

МАХМЫРЛА́У *ф. сөйл.* 1) Күп исерткеч эчкәннән соң авыру, махмыр халәте кичерү. *Махмырлаудан иза чигүе, башының түзә алмаслык булып чатнавы йөзенә чыккан иде аның.* М.Хәсәнов. *Үзе исерек булмаса да, аракы исе әллә кайдан бөркелеп тора, куллары калтырап-калтырап куя. Күрәсең, кичә эчкәнлектән махмырлый иде*. В.Нуруллин

2) *күч.* Махмырны бастыра торган исерткеч яки башка эчемлек эчеп, авыру халәтне бетерү, баш авыртуын басу

3) *диал.* Гадәттә бер төрле ризыкны бердән күп ашап, яки гомумән күп ашаудан авыру; үтләү. *Син, Нурлыбикә кызым, үз тормышын үзе ашап махмырлаган кеше икән...* Г.Кашапов

4) *күч.* Артык күп күргән, кичергән һ.б.ш. нәрсәдән тую, гайрәт чигү. *Хәзер Флюра нишләргә белми: ирем миннән туйды, махмырлады дип, күз яше агыза*. Х.Камалов

Махмырлап бетү Нык махмырлау

Махмырлап йөрү Шактый вакыт, еш кына махмырлау. *Шуннан соң күпме вакыт узгандыр, мин аның эчкән чагын да, махмырлап йөргән чагын да күрмәдем*. Казан утлары

Махмырлап тору Хәзерге моментта махмырлаган хәлдә булу

Махмырлап яту *сөйл. к.* **махмырлап тору**. *Якуб Колмый артык эчеп, бик каты махмырлап ята икән. Шешә күрсә дә укшый, стакан күрсә дә укшый, интегә икән, бичара*. Р.Батулла

Махмырлый язу Аздан гына махмырламый калу

МАХМЫРЛАУСЫЗ *с.* Махмырлау очраклары булмаган. *Бүгенге өстәл шешәсез... Гаилә тормышы гаугасыз, махмырлаусыз...* М.Юныс

МАХМЫРЛЫ *с.* Айнып җитмәгән, махмыр хәлендәге; исәнгерәгән, бик нык авырткан. *Инспекторның сөйләшер рәте юклыгы махмырлы чыраеннан, шешенке күз кабакларыннан күренеп тора*. Х.Камалов. *Әле исә, кичә фахишә хатында дөм булганчы эчеп-аунап кайтып, бүген махмырлы баштан мастерскойда көч-хәл белән эшләп көнен уздырып кайтуы иде Саматның.* З.Фәйзи

МАХНОЧЫ *и. тар.* Анархист Н.Махно тарафдары һәм аның гаскәрендә сугышучы кеше. *Мәхшәр эчендә калган качаклар махночылар өчен корбан тәкәсенә әверелде.* З.Фәтхетдинов

МАХОВИК *и. рус тех*. Валның тигез итеп әйләнүен тәэмин итү өчен, аңа беркетелгән авыр тугымлы тәгәрмәч. *Маховик терсәкле валны тигез әйләндерү һәм кривошип-шатун механизмын тынлык хәленнән уздыру өчен хезмәт итә.* Тракторлар һәм автомобильләр. *Кояш нуры гигант пар машинасының гаять зур маховигын да, художникның кечкенә генә пумаласын да, шагыйрьнең каләмен дә хәрәкәткә китерә.* Дарвинизм нигезләре

МАХО́РКА *и. рус сөйл.* 1) *бот.* Паслёнчалар семьялыгының тәмәке ыруына караган, Польша, Венгрия, Һиндстанда техник культура буларак игелә торган берьеллык үлән үсемлек. *Махорка тәмәкесенең яфракларында агулы матдәләр бик күп. Никотин аеруча агулы*. Биология. *Тәмәке сыгынтысы хәзерләү өчен, 400 грамм тәмәке тузаны яки махорка алалар, 4 литр суда 2 тәүлек тоталар яки 2–3 сәгать кайнаталар, аннары сөзәләр һәм 10 литрга кадәр су кушып сыеклыйлар*. Яшелчәчелек

2) Әлеге үсемлекнең сабакларын вак кына турап ясалган түбән сортлы тәмәке. *Кесәсеннән юеш махорка*

чыгарды да суга атып бәрде [егет]. Ж.Фәйзи. *Маңгай тирләремне сөртеп алдым да, урындыкка утырып, махорка төрә башладым.* Ш.Усманов. *Ул тумбочкасыннан бер буханка ипи, ике пачка махорка алып гәҗиткә төрде дә өченче баракка китте.* З.Хәким

МАХРА *и. гади с.* 1) *к.* **махорка** (*2 мәгъ.*). *Инде берне төрми булмый, – махра сала янчыгыннан, – Монысы батыр калган өчен бүләк иде карчыгымнан ---.* Р.Әхмәтҗанов. *--- [Шапырай карт] ашыкмыйча гына як-ягына авышкалап, кесәләрен капшап куйган була. Тәмәке эзли, янәсе. Ләкин махра янчыгын чыгармый.* М.Хәсәнов. *Балта остасы аның бу беркатлылыгыннан рәхәтләнеп көлә, балтасын бүрәнәгә чабып, кесәсеннән махра янчыгы чыгара.* Н.Акмал

2) Махорка салып кулдан төрелгән тәмәке. *Чулпылары чыңлап торган озын толымнар урынына ирләрчә кыркылган чәч, биленда киң солдат каешы, кулында, ике бармак арасында, карандаш озынлыгы итеп төрелгән махра төтенли.* Р.Төхфәтуллин. *Әй сөйлиләр, әй сөйлиләр, сөйлиләр... Син тыңлыйсың махра-мазар көйрәтеп.* Л.Лерон. *--- Тәкый, тәмәке янчыгын алып, махра төрә башлады.* Ф.Сафин

МАХСУС *с. гар.* **1.** 1) Аерым бер кеше өчен яки билгеле бер максат өчен тәгаенләнгән. *Махсус пластиктан космик корабль кабинасының тышчасын ясарга һәм космонавт өчен «ябышкак» аяк киеме әзерләргә мөмкин.* Химиянең киләчәге. *Җитен сабакларын орлык тартмачыкларыннан махсус тараклар белән арындыралар.* Дөньяда ниләр бар. *Мае булгач, аңардан олифа, буяулар да ясарга тотынганнар, махсус цех җиткезеп куйганнар.* Казан утлары

2) Гадәттән тыш вакыйга яки максат белән бәйле рәвештә оештырылган, ашыгыч, җитди, кичектергесез; гадәттән тыш хокуклары булган. *Су басудан зарар күргән кешеләргә ярдәм күрсәтү өчен, махсус комиссияләр оештырылган.* Ж.Фәйзи. *Синең бу эштә калукалмавың турында мин хәзергә берни дә әйтә алмыйм. Махсус органнар белән сөйләшергә кирәк.* М. Мәһдиев

3) Фән, техника, һөнәр, сәнгать һ.б.ш.ның бер өлкәсенә генә караган, аерым белгечлеккә караган. *Хәрби һава көчләре майоры Владимир Шаталов Хәрби һава көчләренең махсус мәктәбен --- һәм Хәрби һава академиясен отличного тәмамлап өлгергән иде инде ул чагында.* Галәмгә юл. *Опера – сәнгатьнең махсус әзерлек таләп итә торган төре.* Сөембикә

4) Үзенчәлекле, үзгә, үзенә бер төрле, үзенә башка. *Шәһәр белән авыл бер-беренә үзенә махсус җеп белән бәйләнгән.* Г.Нигъмәти. *Губерна шәһәрендә, өязләрдә, волостьларда махсус милли оешмалар төзелә икән.* И.Гази

5) Аерым бер кешегә яки бер нәрсәгә генә хас булган. *Һәркемнең үзенә махсус ләззәт тапкан нәрсәсе буладыр.* Ш.Мөхәммәдев. *Абайлап карагыз әле шул Әхмәтләрен. Анда әллә нинди, авылга гына махсус матурлыклар бар.* М.Фәйзи

2. *рәв. мәгъ.* Билгеле бер максат белән, бер максатны күздә тотып; атап. *--- аларга беренче тапкыр махсус ясатылган «Сабантуй батыры» медале белән яшел бәрхеттән тегелгән янчыкапчыкка салынган акчалата бүләкне тапшырулары тантанага үзенчәлекле ямь өстәде.* Т.Нәҗмиев. *Тышта махсус безне алырга килгән йомышчы хатын көтә.* Р.Зәйдулла. *«Очраклы хәлме бу? Әллә бөтенесе алдан сөйләшеп, махсус оештырылганмы?» – дип уйланып алды күңеленә шомлы шик төшкән Венера.* З.Фәйзи

МАХСУСЛАП *рәв. сөйл.* Махсус рәвештә, атап. *Болай кемне генә махсуслап чакыралар дисең? Ильясны чакыралар менә.* Ә.Баян

МАХСУСЛАШТЫРУ *ф. йөкл. к.* **махсуслашу**. *Без бу институтны махсуслаштыру һәм аңа һөнәри юнәлеш бирү юлыннан барачакбыз.* Кызыл таң

Махсуслаштыра башлау Махсуслаштырырга керешү. *Без студентларыбызны телевизион журналистика буенча махсуслаштыра башладык, соңгы ике елда хәтта аерым төркемнәр тупладык.* Мәдәни җомга. *Бер төркем студентларны журналистика буенча махсуслаштыра башлыйлар.* Безнең гәҗит

МАХСУСЛАШУ *ф.* Аерым, махсус функцияләр башкаруга күчү, билгеләнеше, файдаланышы тараю, специальләшү

МАХЫ́ БИРҮ *ф.* Алдату, сынату, ялгышлык җибәрү, форсаттан файдалана алмый калу, уңганлык-җитезлек күрсәтә алмау. *Хәер, яшьрәк чакта без дә махы бирми торган идек...* М.Хәсәнов. *Дөрес булса, Габдрахманны, соңгы вакытта махы биргән, дип сөйләделәр.* М.Юныс. *Дәминов махы бирмәс! Дәминов күрсәтер аларга кәмит!* Х.Ибраһим

МАҺ *ы.* Эт чакыру өчен әйтелә торган сүз. *– Маһ-маһ, кил әле монда, кил! – дип, кыяр-кыймас тагын бер адым ясамакчы иде абзый, усал ырылдау туктатты аны.* Н.Әхмәдиев. *– Кашкар, маһ, маһ! – дип чакырды аны Иштуган. Байгилде агай да чакырып карады. Эт иярмәде.* З.Биишева. *Чакырабыз Акбайны: Маһ-маһ-маһ!.. Маһ-маһ-маһ!..* Уен

МАҺАРА́ҖА *и. санскр.* Һиндстан феодаль дәүләтендә иң югары хөкемдар титулы – бөек ража; шул титулга ия булган зат

МАҺИР *с. гар.* **1.** Оста, сәләтле, берәр һөнәргә булдыклылыгы, осталыгы булган. *Җиде диңгез артыннан китерелгән төрле җан ияләрен карап йөрергә маһир малайлар гына бер-ике тапкыр Башкорт янына килеп, аның сәләмәгә төренгән гәүдәсенә карап тордылар ---.* Р.Зәйдулла

2. *хәб. функ.* Оста булу. *Керәшеннәр «борчак чәчәргә» – берне биш итеп сөйләргә маһир.* Г.Тавлин. *Ибраһим бахшы, яшь булуына да карамастан, арада акыл иясе зат иде. Язу-сызуга бик маһир.* М.Әмирханов. *Шәүкәт Галиев шаян, төрткеле, көтелмәгән юморны чәпәргә маһир.* Р.Низамиев

3. *рәв. мәгъ.* Оста итеп, осталык белән. *[Ам] Кура җиләгедәй бөрчекле иреннәрен маһир кыймылдатып, кулдан торт кисәкләрен дә берәм-берәм ялмап куйды.* С.Лашманчы

4. *и. мәгъ.* Үз эшенең остасы, мастер; һөнәр иясе. *Сезнең прокурорларча*

карашыгыздан ук минем кәрт уены маһиры, катала икәнлегемне сизгәнегезне аңладым инде. Р.Мирхәйдәров

МАҺИ́РАНӘ *рәв. фар. иск. кит.* Зур осталык белән, чын осталарча, осталыкның югары дәрәҗәсендә. *Гади тормышта була торган трагедияләр икенче планда калып, рухани трагедияләрне маһиранә тасвир итү тиеш дип санала.* Г.Исхакый. *Нәгыймә карчык ролендә Баязидскийдан башка бер уенчы, белмим, бу кадәр маһиранә уйный алыр микән.* Камал театры

МАҺИРЛАНУ *ф.* Остару, шомару, бер эшкә өйрәнеп җитү, тәҗрибә туплау. *Алкин шулхәтле маһирланган бу сөйләшүгә. Аерым хәбәрләрне тапшыру белән генә канәгатьләнми ---.* И.Салахов. *Жәлләдем: төзәлер, эшкә күнегер, дип уйладым. Ә син, эшне җигелеп тартасы урында, яшерен җепләр үрергә маһирландың...* Х.Камалов

Маһирлана төшү Маһирлыгы арту

Маһирланып бетү Тәмам маһирлану

МАҺИРЛА́РЧА *рәв. к.* **маһиранә**. *--- соңгы елларда зур түрәләрнең яраткан шөгыленә әйләнгән кәрт уенында да алар маһирларча эш итәләр, үзләренә икърар итмәсәләр дә, шактый оста шулерга әйләнгәннәр иде инде.* Р.Мирхәйдәров

МАҺИРЛЫК *и. кит.* 1) Берәр эшкә кул яту, һәвәслек тою, осталык, сәләтлелек. *Сүзгә Шәрыкның --- җирдә ожмах бакчалары үстерә белү маһирлыгы, тәхет биеклегеннән торып, чәчәннәрнең тел осталыгына баш ия белүе – бар да Сүзгә, өрфия, нәзберек тажлы Сүзгә сыйган.* М.Галиев. *Менә шундый сәерлекләре-маһирлыклары бар иде Зөбәер абыегызның...* М.Хуҗин. *Лирик композиция төзү маһирлыгына алардан [Г.Хәйям, Г.Тукай] өйрәнүен яшерми [Х.Туфан].* Т.Галиуллин

2) *күч.* Гадәт. *--- иптәшләре өстеннән төрле даирәләргә имзасыз шикаять һәм башка төрдәге хатлар оештыруга керешә. Ә олы шагыйрь аның мондый маһирлыгын белмичә яши бирә.* Т.Галиуллин. *Кимсену гадәте барлыгын, көнләшергә маһирлыгын да белә [Сәнифә Вәсимнең].* Ә.Моталлапов

МАҺИЯТ *и. гар. кит.* 1) Берәр нәрсәнең, вакыйганың, күренешнең асылы, табигый хәле, табигый сыйфаты. *--- гыйльме хәйванат вә гыйльме вәзаифел-әгъзаның әсасы вә хакыйкый бер фән хәленә килүе, тавышның маһияте, нәүгы вә хосусиятләре хакында тәҗрибәгә бина кылынган канунарның кәшеф ителүе телнең табигатен тикшерүгә киң юл ачты.* Җ.Вәлиди

2) Берәр күренешнең, вакыйганың, эш-хәлнең төп эчтәлеге, чыны, үзлеге, асылы. *--- казанлы «милли» коммунистлар, тагын шул ук маһияттә булган кырымлылардан Исмәгыйль Фирдәвес, Осман Деренарлы һәм коммунист булмаган язучы Әхмәд Өзәнбашлы да бу «рус Гвинеясына» яки «большевистик Сахалинга», каторга әсире буларак, нәкъ шул вакытларда җибәрелгәннәр иде.* Г.Баттал-Таймас

МАЧ *и. сөйл. к.* **масть**. *Кәрте, кәрте нинди Уңай төшеп тора, Һәр мач сиңа бәхет Төенен чишеп тора.* Ә.Фәйзи

◊ **Мач бирү** Карта яки домино уенында ялгышлык белән яки иректән каршы як өчен уңайлы йөреш ясау. *[Домино уйнаучыларның берсе:] Я, чык. Әйдә. Мин сиңа мач бирдем. Яса алты да алты.* Г.Камал. **Мач булу** *к.* **мач килү**. *Бусы [снаряд тию] да бик мач булды, ахры, немец танкысының мотор тавышы кинәт тынып калды.* Х.Камал. *Ифрат та мач булып чыкты бу киңәш.* А.Хәлим. **Мач килү** 1) Уңышлы килеп чыгу, әйбәт, отышлы булу. *Менә сиңа мә! Уен мач килеп барганда гына тартып чыгардың, сезнең белән ни табарымны юньләп белмим, мәгәр биш кисәк минем яннан шуып очты...* Р.Мирхәйдәров. *Хәзерге яңа байларга мач килде инде, үстереп тә бирәләр баласын.* Р.Мулланурова; 2) Туры килү, ярау, ошау. *Сайлап киссәң дә, андый өрлекләр таба алмассың инде менә. Мач килеп торуын күр әле син аның, ә!* М.Хәсәнов. *Быел хатынның туган көне Сабан туена мач килүе шәп булды бит әле, әй...* Р.Гаффар. **Мач китерү** Туры китерү, яраштыру. *--- шагыйрь нәкъ шул тезмә табышмак әйтешүдә һәм җаваплары тизлек белән мач китереп кайтарып әйтә белүдә сынала.* Н.Исәнбәт. *Алыш-бирешне ясау өчен урынны да мач китерәләр: ришвәтне базар мөнәсәбәтләре кайный торган Колхоз базарында төртәләр.* Н.Вахитов. **Мач төшү** *к.* **мач килү**. **Мач чыгу** *к.* **мач килү**. *Поляковның аягы җиңел, аңа һәрчак мач чыга, дип сөйләнделәр.* Х.Камалов

МАЧЕ́ТЕ *и. исп.* Латин Америкасында куе урманда юл ачып бару һәм шикәр камышы кисү өчен файдаланыла торган озын пычак; пычакбалта. *Моннан соң экспедициядә катнашучылар, әйберләрен җилкәләренә асып, дымлы тропик урманнарын үткен мачете белән ерып үтәләр.* Кызыклы ихтиология

МАЧИН *и. иск.* 1) Себер татарлары мифологиясендә маймыл кыяфәтле явыз рух

2) Көнчыгыш ел исәбендә унике еллык циклның бер елына туры килгән хайванның – маймылның атамасы

МА́ЧТА *и. голл.* 1) Судноның диаметраль яссылыгында вертикаль урнаштырылган, җилкән беркетү, югарыдан торып күзәтү, сигнал бирү һ.б. өчен хезмәт иткән биек агач яки металл корылма. *Палуба ялт иткән, мачтада дәүләт флагы җилферди, ап-ак киемле чибәр егетләр – болар барысы да пакьлек, пөхтәлек, сафлыкны күрсәтеп торалар иде.* М.Мәһдиев. *Мачтадагы сигнал флаглары, корабны тизрәк кузгалырга кыстап ашыктыргандай, ярсып җилфердиләр.* М.Юныс. *1681 елда июль яңгырында инглиз корабле «Куин»ны шундый итеп яшен суга ки, барлык мачта һәм җиһазларын юк итеп ташлый.* Кызыклар дөньясында

2) *тех.* Вертикаль баганадан һәм аны тарттырып торган ян трослардан гыйбарәт, радио яки телевизион антенналар ныгыту, сигналлар бирү һ.б.ш. элемтә максатлары өчен файдаланылган биек корылма. *Иң авыры түбәгә мачта ныгытып, антенна тарттыру булды.* Җ.Фәйзи. *Телевизор мачталары Язкилде авылы өстеннән узган болытларның итәкләреннән тартып алырлык.* А.Гыйләҗев

МА́ЧТАЛЫ *с.* 1) Мачтасы яки мачталары булган. *Өч мачталы француз*

кораблендә батыр капитан де Клие Париждан хәзинә алып китеп бара. Робинзон эзләреннән. *Капитанның канатлы хыялы мине өч мачталы иске баркка китереп бәйләде.* М.Юныс

2) Мачта формасында эшләнгән. *Кулланучыларда 10/0,4 кВт көчәнешле түбәнәйтүче трансформатор подстанцияләрен конструктив яктан ачык һәм ябык мачталы типта итеп ясыйлар.* Авыл хуҗалыгы электригы белешмәсе

МАШ I *и. рус сир*. Башня, манара, мачтага охшаш биек корылма. *Шәһәр читендәге пристаньда да урман кебек торган сәүдә көймәләренең машларына флаглар тагылган, аларны төрле төсләр илә чуарлап бетергән иде...* Н.Думави. *Кырык метрлар чамасы биеклектә салынган вышкаларны бездә маш дип йөртәләр.* М.Мәһдиев

МАШ II *и. фар. бот.* Фасоль ыруына караган, Һиндстан, Кытай, Индонезия, Урта Азиядә игелә торган берьеллык үлән үсемлек һәм аның борчагы. *Машны баш итеп күрү.* Әйтем. *Күчтәнәч май, борыч белән бергә сөт һәм тоз да салып әзерләнгән чәй (ширчәй), мамык мае тәме килгән маш боткасы һәм бодай, кукуруз ярмаларыннан пешерелгән өйрә чабаннарның тукланыш шактый төрләндереп җибәрде.* Т.Әйди

МА́ШАЛЛА *ы. гар.* Сокланыу, хуплауны, гаҗәпләнүне белдерә. *Ихлас куандым. Машалла, дидем, безнең гвардия сынатмый*... Г.Минский. *Марсель Галиевнең «Догалы еллар» китабын укып баккач, әдәби мохит бердәм аһ итте. «Афәрин!», «Машалла!» дигән сүз иде бу.* Н.Гамбәр

МАШИНА *и. лат.* 1) Бер төр энергияне икенче төр энергиягә әверелдерү өчен (йөрткеч машиналар), төрле хезмәт предметларын үзгәртү өчен (корал машиналары, хезмәт машиналары) кирәкле гамәлләр үти торган, мәгълүмат җыю, эшкәртү һәм тапшыру өчен (исәпләү машиналары) файдаланыла торган механизм яки механизмнар җыелмасы. *--- хәзер компьютер-роботлар катлаулы математик мәсьәләне чишә, шахмат та уйный ала, әмма мондый «акыллы» машиналар беркайчан да әдәби әсәр яза алмаячаклар.* Р.Низамиев. *1930 ел уңышын чәчеп, урып җыйганда, колхозда 35 баш эш аты, 10 сабан, 1 ашлык сугу машинасы, 6 пар тимер тырма бар иде.* Э.Мөэминова. *Ике дә уйлап тормыйча, Рафис тегү машинасына ябышты: бөкте, кыскартты, тарайтты – ничек итсә итте ---, оялмыйча киярлек хәлгә килде.* Н.Әхмәдиев

2) *сөйл.* Берәр транспорт чарасын, гадәттә автомобильне сөйләмдә атау сүзе. *Дүрт-биш еллар элек, министр урынбасары булып эшләгән чагында, Тимерхан Борһанов Вәрәшбашка машина белән кайткан иде.* Г.Ахунов. *Машинаның шәп кай маркасы да: «Мерседес», «Волга», «Тойота»сы да.* Ә.Синугыл-Куганаклы. *Юллардагы машиналар кебек Еллар басып килә үкчәгә... Кеше гомере үрдән-үргә узган адымнары белән үлчәнә.* Ф.Гыйззәтуллина

3) *күч.* Эшне җайга салынган механизм шикелле тоткарлыксыз һәм төгәл алып бара торган оешма турында

4) *күч.* Эш-процессларның, күренеш-вакыйгаларның үзлегеннән, котылгысыз рәвештә баруы турында. *Кайгы машинасы шундый вата кешене: җаны изелеп кала.* Ш.Галиев. *Организмның биохимик машинасы безне яшәргә мәҗбүр итә һәм яшәвебезне аңлау мөмкинлеге тудыра ---.* В.Леви

◊ **Машина каны** Нефть. *Без машиналар каны – кара алтын аккан диңгез ярларында булдык!* Һ.Такташ

МАШИНАЛАШТЫРУ *ф.* Механикалаштыру, кешенең физик көче урынына җитештерүдә машиналар һәм агрегатлар куллана башлау. *Иптәшләр, «Кызыл йолдыз» колхозын машиналаштыру, электрлаштыру өчен көрәшне башлыйбыз!* К.Тинчурин

МАШИНАЛЫ *с.* Машиналаштырылган, хезмәт процесслары машиналар белән башкарыла торган. *Машиналы хуҗалык. Машиналы индустрия*

МАШИНАЛЫК *с.* **1.** Машина алырга җитәрлек, машина бәясе торырлык; машина алырга дип билгеләнгән. *Миңа хәзер бер клиент килә, без Екатерина Максимовна белән яхшы гына бер машиналык килешү төзибез.* З.Кадыйрова

2. *и. мәгъ.* Машина алырга дип билгеләнгән акча

МАШИНАЛЬ *с.* **1.** Махсус уйлап түгел, аңсыз рәвештә, ирексездән, рефлекс дәрәҗәсендә, гадәтләнгән хәрәкәт белән эшләнгән, механик. *Ханның «Двин» запасы калмаган микәнни дип, машиналь рәвештә генә уйлап алды ул ---.* Р.Мирхәйдәров

2. *рәв. мәгъ.* Уйлап тормастан, аңсыз рәвештә, гадәтләнгән хәрәкәт белән, механик рәвештә. *Нуриев, иелеп, аның кулын үпкәндә, Мария машиналь рәвештә сул кулы белән Нуриевның чәчен сыйпап узды*. Р.Батулла. *Дәһидиның тавышы кискен, таләпчән иде. Дәһиди эндәшүгә, ул машиналь рәвештә сумкасын ачып күрсәтте ---.* Х.Ибраһим

МАШИНА́ЧА *рәв.* 1) Машина кебек җитез, тиз, төгәл, ритмик хәрәкәтләр белән. *Бар да, иелгән, бөгелгән килеш, капчык-мазар бәйләп, төйнәп торалар. Куллар машинача эшли, ашыгыч хәрәкәт.* Н.Исәнбәт

2) Уйлап-нитеп тормастан, хискә бирелмичә, салкын кан белән

МАШИНАЧЫ *и. сир. к.* **машинист**. *Машиначы сыбызгы каешын тотты. Хәзер, хәзер... туу... шып булды.* А.Таһиров. *Бездән китә барган кара көннәр Әзме аның Көчен ашаган. Шулай да ул – Җиңү корабында Машиначы, Матрос, Кочегар!* Х.Туфан

МАШИНИСТ *и. лат.* 1) Берәр транспорт чарасы яки башка үзйөрешле машина, яки гомумән катлаулы механик агрегат, җайланма белән идарә итүче механик. *Машина бүлеге вахтасыннан алышынган икенче механик Русаков, аның белән торучы машинист Миша Шмаков, кочегар Сукач һәм кочегар Емельянов та рәхәтләнеп ял итәләр.* М.Юныс. *Бу хатны Хәдичә квартирына бала-чагалары белән күчеп килгән завод машинистының хатыны тоттырды.* М.Хәсәнов. *Җыелышта чыгыш ясадылар: --- язучы М.Мәһдиев, «Органик синтез» производство берләшмәсе машинисты Н.П.Никишин ---.* Казан утлары

2) Поезд йөртүче, локомотив белән идарә итүче тимер юлчы. *Якындагы*

борылыштан үкереп килеп чыккан поездны машинист, теләсә дә, барыбер туктата алмаячак. М.Хәсәнов. *Поезд машинистлары шунда тагын бер кешене күреп калганнар, тик аның кем булуын гына ачыклый алмадылар.* Х.Ибраһим. *Тапкыр машинист бу куркынычны күреп алган да үзенең поездын туктаткан, артка чигерә башлаган ---.* Кызыклы физика

МАШИНИ́СТКА *и. рус сөйл.* Кулдан язылган әзер текстны яки әйтеп барганнарны язу машинкасында яки компьютерда басучы хатын-кыз. *Машинистка Елизавета Сергеевна Люшина нәшриятта күндәмлеге, эшен тиз башкаруы, хатасыз һәм искиткеч чиста басуы белән дан тота иде.* Г.Тавлин. *Имеш, алдан анда машинистка булгансың да, хәзер сине редакция чакыртып ала.* К.Тимбикова. *Котлов шәп почерк белән, машинисткалар таныр-лык итеп кулдан яза, ә мин алфавитны яхшы белəм инде: педучилищеда укыдым бит!* М.Мәһдиев

МАШИ́НКА *и. рус* 1) Көнкүрештә берәр төрле эш башкару өчен кулланыла торган, зур булмаган, гадәттә механик прибор. --- *Исламгали агайның өендә инде телевизор, күкеле сәгать, кырыну машинкасы, электр чәйнеге, зур көзге ватылган ---.* М.Мәһдиев. *Смена тәмамланып, сатудан кергән акчаны санап чыкканнан соң, туры киләме дип, санау машинкасындагы санга караган иде – исе китеп коелды да төште.* З.Фәйзи. *Кунак җайлап утыргач, авылыбызның бердәнбер чәчтарашы булган күршем, эшкә керешергә җыенып, машинканы «келт-келт» иттереп алды.* Ш.Абдуллин

2) *сөйл.* Кәгазьдә кулдан текст, таблица, санлы мәгълүматлар басу өчен махсус клавиатурасы булган җайланма, язу машинасы. *Ул әдәбиятка вә сәнгатькә кагылышлы материалларны эшкәртә-редакцияли, машинкада бастырып ала ---.* Ш.Маннапов. *Хәзерге урынга тиенгәнче сигез ел машинкада утырдым, хәреф чүпләп, кеше фикерен кәгазьгә төшереп.* К.Тимбикова. *Әнсар әле үзенең кабинетына кермәгән, кабул итү бүлмәсендә секретарь кыз машинкада басылган кәгазьләрне укып тора иде.* З.Хәким

МАЭМАЙ *и. сөйл.* 1) Балалар телендә, шаяртулы сөйләмдә этне атау өчен кулланылган сүз. *Бер сүзем юк, маэмай булып йөрсәң дә, койрык чәнчеп «hay-hay» диеп өрсәң дә...* Л.Лерон. *Бер кулына кара дипломат, икенчесенә сары маэмай күтәргән ак костюмлы Револ елга портының троллейбус тукталышында әрле-бирле йөренә иде.* М.Маликова. *Малай татлы уйларыннан бүленде, чөнки күрше балкондагы йөнтәс койрыклы аклы-каралы маэмай кереп киткән иде инде.* А.Гыймадиев

2) *күч. кимс.* Үз аңы белән эш итмәгән, кушканны башкарып йөрүче, әһәмиятсез, авторитетсыз кеше. *Ярый ла чека абзарына ниндидер аңгыра маэмай килеп эләкмәгән булса.* З.Фәтхетдинов

МАЭ́СТРО *и. ит.* 1) Композитор, рәссам, дирижёр кебек төрле сәнгать өлкәсендәге атаклы кешеләрне олылап атау һәм эндәшү сүзе. *Ул – чын маэстро, чын артист! Мин аның [У.Әлмиев] турындагы һәр тапшыруны игътибар белән тыңлап барам ---.* Л.Шагыйрьҗан. *Маэстро [Ф.Мансуров] белән болай концертларына килгәндә, төрле очрашуларда күл бирешеп исәнләшеп йөрибез.* Г.Гомәр. *Җырчы [З.Сөнгатуллина] маэстро [Н.Даутов] җитәкчелегендә 25 образ иҗат итә, халыкка таныла.* Сөембикә

2) *күч. ирон.* Берәр кирәкмәгән эшкә хирыс кеше, усаллык, әшәкелек, интригалар остасы. *Аппарат уеннарының остасы маэстро Р.Беляев ялгыша бу юлы.* Т.Галиуллин

МАЯ *и. фар.* **1.** 1) Акча фонды, капитал. *Тик онытма: күргән файдаңның, тапкан малыңның уннан бере – Казанйорт казнасына, тагын бер өлешенең яртысы уртак маяга күчә барыр.* Ф.Латыйфи. *Балык күп булып, мач килсә, шактый гына мая туплап кайтырбыз.* Р.Сибат. *Байрак, гимн – гавам өчен, Милке – байлар маясында...* М.Мирза

2) Саклыкка куелган, җыелган акча, тупланган запас. *Василий моторлы көймәгә ия. Аны нинди маяга алганы, кайда тотканы мәгълүм түгел.* М.Насыйбуллин. *Кара көнгә дип акча-мая җыймадык, уңга-сулга карамый, җан теләгәнчә яшәдек.* Ш.Галиев. --- *Назыйм кеше әйберенә кызыкмады, гомумән, әйбер колы булмады, өендә иң кирәкле нәрсәләрне генә тотты, хатынының еш кына кабатлауларына карамастан, мая өстенә мая өймәде ---.* М.Хуҗин

3) Тавык йомырканы бер урынга гына салсын өчен, ояда калдырыла торган йомырка. *Тавык, иш янына куш булсын дип, йомыркасын маяга кушып сала, ди.* Н.Исәнбәт. *Каралтыда оя бар, Ояда бер мая бар... Йоклаганда мәчеләр, Йомырканы күселәр Чәлдереп китмәкчеләр.* Ш.Галиев. *Гөлҗиһан әби күкәй салган казын аерып ашатып чыгаруын, ояда мая гына калдырып, яңа салган күкәйләрне иске бүреккә җыя баруын да сөйли.* Э.Шәрифуллина

4) *күч.* Берәр нәрсәне үрчетү, арттыру һ.б.ш. өчен башлангыч, нигез; гомумән, запас. *Су Иясе белән Шүрәлене таламасам да, тамак туйдырырлык маям бар әле минем, анысы...* Р.Батулла. *Шул көннәрдә, стратегик һөҗүмгә мая туплар өчен, совет гаскәрләре озак вакытлы оборонага күчә.* Р.Низамиев. *Рөстәм чәнчә бармак кадәрле генә балык тартып чыгарды: – Әһә, мая бар.* Г.Сабитов

5) *күч.* Осталык, тәҗрибә. *Моңарчы да яраткан рәссамнарымның берсе булган, сәнгатьнең бу өлкәсендә ярыйсы ук мая туплаган, ә инде китап ясауда тиңен белмәгән оста хакында үз фикеремне язарга утырдым.* К.Миңлебаев. *Җир асты елгасы буйлап сәяхәт иткәндә, автор үзенең геройларын төрле кыен хәллəр белән очраштыра, бары тик бала хыялына гына сыярлык могҗизалар сурәтли, укучының белем маясын ишәйтә.* Р.Вәлиев. *Рухи маяга ия булган шагыйрь, билгеле, иҗатта үзен чагыштырмача ирекле тота.* Ә.Рәшит

2. *с. мәгъ.* Запастагы, запас итеп тотылган. *Чатыр артында Кубрат ханның азмы-күпме мая алае бар. Ул аны һәм Көбер ханны соңгы мәлдә генә чыгарачак.* М.Хәбибуллин

◊ **Мая мал** Төп фонд, нигез булырлык мал, сәрмая. **Маяга калдыру**

Запаска калдыру; үрчемлеккә, ыруга дип аерып кую. *Төп гаскәрләр каты бәрелеш алып барганда, калмыклар маяга калдырган алайларын да сугышка ташларга уйлаганнар икән.* Т.Нәбиуллин. **Мая салу** Берәр эшне башлап җибәрер өчен нигез әзерләү, җирлек булдыру. *Сүз башларга мая салынган.* А.Таһиров

МАЯК *и.* 1) Диңгез ярларында, утрауларда, елга тамагында урнашкан, сигнал уты яки махсус сирена белән судноларга юл күрсәтү өчен хезмәт иткән биек корылма, манара. *Ул маякларның төрлесен күрде. Балтыйк диңгезендә дә, Ла-Маншы узганда да, ниһаять, Дарданелл белән Босфорны үтеп, үзебезнең Одессага якынайгач та.* Г.Бәширов. *Кырмыскадай тырыш, көчле буксир зур корабны пирслар арасыннан порт уртасына тартып чыгарды да борынын ак маяк ягына каратып борып куйды.* М.Юныс. *Электр дугасы проекцион аппаратларда, кинокартиналар төшергәндә, прожекторларда, маякларда һәм төрле төзелешләрдә яктылык чишмәсе итеп кулланыла.* Физика курсы

2) Сай сулыкларда судноларга фарватерны һәм сай, куркынычлы урыннарны күрсәтү өчен куелган йөзмә билге; бакен. *Идел ага. Без агабыз. Артта маяк, саллар кала.* Р.Фәйзуллин. *Су уртасында кызыл маяк юл күрсәтеп калды.* Р.Кәрами

3) Түшәлмәгән, күтәрелмәгән гади грунт юлның ике ягына кышын адашмас өчен утыртылган агачлар. *Маяктан маякка ат җитәкләп йөрде, яшь ат юл катысын таба белмәде. Озак җәфалангач, маяк төбенә утырды да, тезгенне кулында тоткан килеш, үкереп-үкереп елады.* М.Мәһдиев

4) Гомумән, юлны, юнәлешне билгеләү өчен ярдәм иткән теләсә нинди билге, ориентир. *Таң йолдызы, маяк бул син Юлда иркәмә; Нурларың белән аны син Назлап иркәлә!* М.Ногман. *Сандугач, соңгы маягыннан тайчанмас өчен, бер һава агымыннан икенчесенә күчә-күчә, төрле якка талпынып оча башлады ---.* Ә.Гаффар. *Әгәр дә нектарга бай чәчәкләрнең бер дә исе булмаса яки табыш хуш исе булмаган җимлектән алынса, умарта кортлары --- азык алына торган урынга үз исләрен сеңдереп, табыш урынында үзләренең хуш исле маякларын калдыралар.* Умарта кортлары

5) Берәр процессның, үсешнең асылын чагылдырган төп билгеләр, иң мөһим моментлар. *--- барлык кыенлыкларга карамастан, фән инде кешенең хайваннар дөньясыннан формалашуындагы төп маякларны ачыклап бетерде.* Галәм. Җир. Кеше

6) Гомумән, башкаларга үрнәк биргән, шуңа охшарга тырышылган шәхес, авторитет, идеал. *Егерменче гасыр – язмышыбыз. Хафалан, тик өмет өзмә, туган: Халкым рухы маяклары булып Бер башында яна сүнмәс Тукай, Бер башында яна сынмас Туфан!* Ш.Галиев. *Бүгенге шагыйрьләребез, үз әдәби мирасыбызны маяк итеп алу белән бергә, дөнья поэзиясе казанышларына да таяналар икән, бу – бик табигый.* И.Юзеев. *Әйе, без аны [С.Хәкимне] үзебезгә бер эталон, үрнәк итеп саный идек. --- Ә яшь чакта шундый маякларың булу бик кирәк икән.* Л.Шагыйрьҗан

7) *күч.* Эштә башкаларга үрнәк булырлык хезмәт алдынгысы. *Син – колхозыбызның маягы. Адым саен маяк алыштырып тормыйлар.* А.Гыйләҗев. *Бу өч шагыйрь Тукайны әдәбиятыбыз үткәненнән, халкыбыз тарихыннан гына эзләмиләр, алар Тукайны киләчәктән, алдагы көнебездән эзләп табалар, аңа халкыбызның мәңгелек символы, киләчәк юлындагы маягы итеп карыйлар.* Р.Вәлиев

8) *күч.* Берәр эшчәнлектә яки гомумән тормышта йөз тотылган кыйбла, күздә тотылган төп юнәлеш, максат. *Нәсел типкән Идел-йортта Сүнә гомер маяклары.* Ф.Гыйззәтуллина. *Республиканың туган көне алдагы тормышыбызда яңа маяклар билгели, милләтләр арасындагы тигезлеккә һәм интернационализмга юл ача.* Р.Низамиев. *Кечкенә Фуат күңеленә татар моңнары, татар көйләре, чын татарлык хисләре әнә шулай чит-ят җирләрдә сеңә, мәңге сүнмәс гомер маягына әйләнә.* Мәдәни җомга

МАЯКЛА́У *ф.* Маяклар белән билгеләү, маяклар кую. *Юлларны маяклау*

МАЯКЛЫ *с.* Маягы яки маяклары булган. *--- төштән соң кояш, җәяүле буранна талчыгып, маяклы юл артына – җир белән күк тоташкан кар дәрьясына кереп югала ---.* М.Мәһдиев

МАЯКСЫЗ *с.* 1) Маягы (*1–3 мәгъ.*) булмаган

2) *күч.* Максатсыз, идеалсыз, кыйбласыз. *Минем аңнан сорау китми һаман, Ә җавабын бирми бу тормыш... Юл чуалган, юл маяксыз калган, Чакрым саен җиде борылыш.* К.Булатова. *--- тарихны дөрес язмау --- – яңа буынларны маяксыз калдыру, аларны үткән еллар, үткән гасырлар тәҗрибәсеннән оятсызларча аеру, чорлар арасында, еллар һәм юллар чатында күзләре бәйләнгән хәлдә адаштырып калдыру ул.* Н.Акмал

МАЯКЧЫ *и.* Маякта (*1 мәгъ.*) эшләүче, маякны (*1 мәгъ.*) яки маякларны (*2 мәгъ.*) карап торучы хезмәткәр. *Барысы да артка калып, инде маякчы турына якынлашканда, әллә кайдан гына яр өстенә Җәзилә калкып чыкты.* Х.Сарьян. *Тоткынлыкта бер мин генә түгел, бик күпләр тормышка ашмас шундый хыяллардан тәм табып, иреккә чыккач, --- я берәр зур елгада маякчы, я бакчачы булырга, фани дөньядан мөмкин кадәр ераклашырга, кешеләр белән бик сирәк алыш-биреш итәргә хыяллана иде.* Г.Тавлин. *--- үзем өлкән маякчы буларак, тралчыларга мина төшкән урынны күрсәтергә киттем.* С.Сабиров

МАЯЛ *и.* Чынаяк әйберләр өстен каплаган пыяласыман каты ялтыравык катлау; глазурь

МАЯЛЛА́У *и.* Чынаяк әйберләр өстен глазурь белән каплау; глазурьлау

МАЯЛЫ *с.* Акчалы, сәрмаяле; барлыклы, бай

МАЯЛЫК *и.* **1.** Башлангыч капитал, берәр мөстәкыйль эш, бизнес башлап җибәрү өчен нигез булып торган фонд

2. *с. мәгъ.* Маяга дип (*2 мәгъ.*) калдырылган. *Миңленисаның чуар тавыгы йомырка салмады, --- печән түшәп әзерләнгән оя буш та буш, маялык акбур йомыркасы да гел ялгыз.* Г.Минский

МА́ЯТНИК *и. рус* 1) Авырлык үзәге аскы – атынып, тирбәнеп торган башында урнашкан, икенче башы хәрәкәтсез ноктага беркетелгән таяк. *Егетем көтә, әти-әнием көтә – бар да көтә, ә мин, селкенүдән туктаган маятник шикелле, ни ары, ни бире!* Ә.Еники. *Әгәр башына калын бакыр пластинка беркетелгән таяктан гыйбарәт авыр маятникны көчле электромагнитның магнит кырында тирбәтеп җибәрсәк, ул үзенең тирбәнүеннән бик тиз туктала.* Физика курсы. *Корабль тирбәлеп куйды, маятник кебек кыйшайды, яңадан элекке хәленә кайтты.* Галәмгә юл

2) Механик сәгатьләрдә, үз күчәрендә төрле якка хәрәкәт итеп, сәгатьнең ритмлы йөрешен тәэмин итә торган тәгәрмәч. *Тере табигатьтәге барлык тигезләнешләрне ныклы нигезгә утырган үлчәү белән чагыштырып булмый-дыр, ул төрле сорт һәм төрле зурлыктагы сәгатьләр белән тулган бүлмәне хәтерләтә төшә, бу сәгатьләрнең маятниклары тирбәнү колачларын үзгәртәләр ---.* Галәм. Җир. Кеше

3) *күч.* Гомумән ниндидер күрсәткечләрнең периодик, ритмик рәвештә үзгәреп торуы. *--- нәкъ менә ике маятник – тонус һәм кәеф маятниклары – тыгыз бәйләнгәннәр, берсенең инерциясе икенчесенә тәэсир итә ---.* В.Леви

МА́ЯТНИКЛЫ *с.* Эшләү, хәрәкәт итү механизмы маятник принцибына нигезләнгән; маятнигы булган. *Маятниклы сәгать*

МАЯ́У *ф. иск.* Коеп ясала торган әйберләрнең өлешләрен эретеп ялгау. *Чың-чың иткән чынаяк фабрикта маямый эшләнер.* Н.Исәнбәт

МӘ I *хәб. сүз* 1) Кемгә дә булса нәрсәдер биргәндә, тәкъдим иткәндә «ал, кулыңа ал, тот» мәгънәсендә кулланыла. *Яны белән генә торып, миңа көмеш кәгазьгә төрелгән бер нәрсә суздыз: – Мә!* Г.Бәширов. *Мә сиңа акча, шушы акчага син Булатны ресторанга алып кер.* Р.Батулла. *Капкадан чыкканда, аның кулында пыяла шешә белән сөт иде. – Мә, әле генә саудым, – диде хуҗабикә.* Н.Гыйматдинова

2) Нәрсәгә дә булса ирек, рөхсәт бирү сүзе буларак кулланыла. *Үлмәс борын кабер казыдылар алар миңа! Мә, ашагыз, мә!* А.Гыйләҗев. *Каклаган каз «мә, мине дә ал!» дигән кебек, дыңк итеп башына бәрелеп калды.* Г.Сабитов. *Гел шулай ач кеше икмәккә тилмереп карагандай ымсынып утырасың, мә, күр, кинән, дип уйладымы?* С.Поварисов

3) Кыйнаганда, сукканда, әйберләр атып-атып бәргәндә әйтелә. *[Гәрәй:] Мә күзеңә! Мә борыныңа! Мә авызыңа!* М.Фәйзи. *Нерв җепселләрем коточкыч киерелеп тартылган иде, шунда эчемдә нәрсәдер өзелде, нәрсәдер шартлады, көзгегә кадалып утырган җиремнән сикереп тордым да, Гамилне диварга терәп, уңлы-суллы яңакларга керештем: – Мә сиңа, мә!* Н.Гыйматдинова

◊ **Мә сиңа** Көтелмәгән хәлдән аптырап, югалып калуны белдерә. *[Мирвәли:] Шаяртмачы, Шәмсегаян! Ничек була инде бу, үлмим, үлмим, дип кайт та, мә сиңа.* А.Гыйләҗев. **Мә сиңа кирәк булса** *к.* **мә сиңа**. *Мә сиңа кирәк булса, [Хәйрүш] велосипед алган!* М.Җәлил

МӘ II *иярт.* Кәҗә кычкырган тавышны белдерә (гадәттә сузып яки кабатлап әйтелә). *Бу карт аю сукыр икән, өйгә килеп керүгә, кәҗә мә-ә-ә дип, мөгезе белән аюның корсагын сөзеп тишкән.* Әкият

МӘГАРӘ *и. гар.* 1) Тау куышы. *Җил-давылдан саклый торган мәрмәр кыялар, кышын – туңдырмый, җәен эсселәтми торган тау куышлары, мәгарәләр...* Ф.Бәйрәмова. *Шул чакта кеше яныл торган ботакны алган да, үзен кабат уттан «тешләтмәскә» тырыша-тырыша, аны мәгарәсенә алып кайткандыр.* Күзгә күренми торган матдәләр турында хикәяләр. *1856 елны монда карьер ысулы белән известьташ чыгара башлыйлар һәм шул чакны бер мәгарәгә тап булалар.* Галәм. Җир. Кеше

2) *күч.* Бик зур булмаган караңгы яки юеш урын, торак. *Чынлыкта бу мәгарә аю өне икән.* Г.Гыйльманов

3) *күч.* Теләсә кем кереп йөри алмый торган, ябулы урын // Аулак урын; куыш. *Фәтхи шундагы «мәгарә»дә эшли иде. Тимер ишекләр артындагы сирәк кулъязмалар бүлеген ул шулай атый иде.* Р.Батулла. *Сагыш тулы зәңгәр күзләр тиз генә «мәгарә»гә бәя бирделәр, битараф майорның игътибарын җәлеп итү өчен, хатын салмак кына тамагын кырып куярга мәҗбүр булды.* Ф.Бәллүр. *Чыннан да, мәчет ул читкә тибәрелгәннәр җыелып утыра торган мәгарә түгел.* Ватаным Татарстан

4) *күч.* «Зур, күләмле, тирән, чиксез» дигән мәгънәдә (төрле әйберләр тур.). *Ник шомлана күңел мәгарәсе, Сизенәме тетрәү буласын.* М.Галиев. *--- күз ачып йомганчы --- ризыкларны ашказаны дигән туемсыз мәгарәгә озаттым.* Р.Сибат. *Шигъри мәгарәгә кереп барам, Әйди мине сере галәмнең.* Л.Кәшфи

МӘГАРИФ *и. гар.* 1) Гыйлем, белем, аң-белем, мәгърифәт. *Мәгариф ул гомумкешелек культурасының бер тармагы гына түгел.* В.Гайфуллин

2) Уку-укыту, белем бирү гамәле һәм шуның тулы системасы. *Ул [Тимерхан], озын-озак уйлап тормастан, тотты да Мөслимгә, мәгариф бүлегенә китте.* Г.Ахунов. *Бирегә аны илнең мәгариф вәкилләре һәм милләттәшләре дә чакырган була.* Х.Миңнегулов. *Хәзрәтләребез рухи идеологлар да, еш кына үлемнең күзенә карап, чукындыруга каршы торуны оештыручылар да, мәгариф системасын коручылар һәм мөгаллимнәр дә булганнар.* Р.Юныс

МӘГӘР *терк. фар.* 1) Тик, ләкин, әмма, хәлбуки. *Фетнә тынды, кискәләнде елан, Кисәкләре мәгәр боргаланып ята.* Ә.Баян. *Мәгәр дөнья бит бу, алай гына булалмый.* Ж.Мостафин. *Мәгәр биек үрләрне яулаганчы, иң тәүдә кечерәкләрен буйсындырып, тауларның «холкына» ияләшү шарт.* Мәдәни җомга

2) Шулай, шулай да, шулай итеп. *Мәгәр кырык дүртенче елның язындагы ачлыкның шыр сөяк кулы адәм балаларының бугазыннан буып алды.* Б.Камалов. *Мәгәр карт көтүче үзе артык картайгач, үзе урынына көтү көтәргә ике кызын җибәрә башлаган.* Г.Гали

МӘГӘ́РЕНКИ *терк. сөйл. к.* **мәгәр**. *Сүрән ут яктысында ялтырап торган*

карашыннан нигә килгәнлеген тоярлык түгел иде, мәгәренки нидер сорап кермәгәне ап-ачык. Р.Рахман

МӘГӘРИЧ *и. гар. сөйл.* Берәр эш барып чыккан, уңышлы үтәлгән очракта, сөенечне уртаклашучы кешегә бирелә торган (яисә аны сыйлый торган) күчтәнәч (гадәттә, исерткеч эчемлек). *[Зөлфәт:] Менә миннән нәни генә мәгәрич.* А.Гыйләҗев. *Хәвеф-хәтәрсез генә барып чыкса – капчыгын тотып, мәгәрич бүлешергә киләсен көт тә тор.* З.Фәтхетдинов. *– Сиңнән мәгәрич, – дип шаркылдады кызмача Фәйзрахман.* Ф.Садриев

МӘГӘРИЧЛЕК *и.* Мәгәрич алырлык, мәгәричкә җитәрлек. *Мәгәричлек акча*

МӘГӘ́РКИ *терк. иск. сөйл. к.* ***мәгәр***. *Мәгәрки Әбүгалисинаның гыйльме ихфада, вә гыйльме кимиядә, вә гыйльме симиядә шөһрәте җәелеп, вә халык арасында хикмәте сөйләшмәктә иде*. К.Насыйри

МӘГЪДӘН *и. гар.* 1) Казылма байлык, руда, металл. *Карт сибиряклар соңыннан миңа аңлаттылар: Себер тауларында пыяласыман утәкүренмәле мәгъдәннәр – слюдалар бар икән.* Г.Әпсәләмов. *Тимер мәгъдәнендә (рудасында) тимернең массача өлеше 0,5 булганда, ул баетылган мәгъдәннәр рәтенә керә.* Гомуми химия. *Әмма сүз алтын табу турында бара, һәм мәгъдән учагы хуҗаларын бернинди куркыныч та туктата алмый.* Мәдәни җомга

2) Рудник, шахта. *Шушы якты дөньяны күргәнче, җир астының мәңгелек караңгысында нинди генә тауташлар, мәгарәләр, мәгъдәннәр арасыннан узмаган --- алар [чишмәләр]!* Г.Бәширов. *Күмер беткәч, мәгъдәннәр ябыла – шахтёрлар язмыш кочагында онытылып кала икән*. М.Хуҗин

МӘГЪҖҮН *и. гар. иск.* 1) Дару, шифалы катнашма. *Аннан соң мәгъҗүн бир. Вә җәһед ит ки, үләннәр бирмәктә җөрьәт итмәгәйсең.* К.Насыйри. *Тагы бездә мәгъҗүн бар. Бохара әмире үзе дарулана торган мәгъҗүн, бик файдалы, бик!* Г.Исхакый

2) Мәк орлыгын һәм башка шуның кебекләрне катнаштырып ясалган, миңгерәүләтә торган наркотик әйбер. *Әле аның тагы икенче төрлесе – мәгъҗүн дигәне бар. Ансын ишан хәзрәт үзе җитмеш җиде төрле шифалы нәрсәләрдән ясата.* Г.Камал. *--- баягы мәгъҗүн дип соратып алдырган нәрсәңез урынына мин эч авырттыра торган пилюль ясап бирдем*. Ф.Әмирхан

МӘГЪЗҮР *с. гар. иск.* **1.** 1) Үтенүле; гозерле, гозере булган. *Тагы рәхмәт күгеңнән мәхрүм итмә, Онытмачы, гасый, мәгъзүр энеңне...* М.Җәлил. *Нә белсен ул гавам бичара, мәгъзүр.* Татар әдипләре

2) Ниндидер гафу итәрлек сәбәпләр аркасында берәр эшне, йомышны үти алмаган. *Әллә, хакыйкатән, милли көчемез җитәрлек булмаганга, без бу эштә мәгъзүр идекме?* Г.Исхакый

2. *хәб. мәгъ.* «Гаеп итмә, гафу ит» дигән мәгънәдә. *[Шәйхезаман:] Башка сүз юк, мәгъзүр!* Т.Гыйззәт

◊ **Бары белән мәгъзүр** «Булганына канәгать» дигән мәгънәдә. *Бары белән мәгъзүр, Башы белән бака да зур.* Мәкаль. *Бары белән мәгъзүр, Югына Ходай хәзер.* Мәкаль. **Мәгъзүр күрү** *к.* **мәгъзүр тоту**. *Дөрест, фәнни бер журналның сыйрыф фәнни бер мәкаләсендә боны мәгъзүр күрү мөмкин булыр иде.* Г.Ибраһимов. *Ачуланма миңа, җаным, мине мәгъзүр күр.* М.Фәйзи. **Мәгъзүр тоту** *иск.* Гафу итү, кичерү, гозерен кабул итү. *Муса галәйһиссәлам әйтте: «Мәгъзүр тот, хәтеремнән чыкты»*. К.Насыйри

МӘГЪКУЛЬ *с. гар. кит.* **1.** Лаек, лаеклы; акылга ярашлы. *Акылсыз баштан мәгъкуль сүз чыкмас.* Мәкаль. *Әмма нәкъ менә бүген җыелуыбыз – бик тә мәгъкуль бер эш.* Р.Миңнуллин. *Я, әйтегез, бу чуваш балаларын үз авылларында укыту мәгъкульрәк түгелме икән?* Ф.Галимуллин

2. *рәв. мәгъ.* Кулай, отышлы, дөрес; акылга сыярлык рәвештә, ышанырлык, аңлаешлы итеп. *Чегәннәрнең исемлеген төзегәндә, адресларын, фамилияләрен, исемнәрен һәм аталарының исемнәрен күрсәтүегез мәгъкуль күренә.* Ш.Рәкыйпов. *Шуңа күрә ул – Галимҗан – ялгыз торнадай аерым яшәүне мәгъкуль күрә.* С.Поварисов. *--- Хуҗа әйләнеп кайткачы, Салихҗанның уйнавын тыңлауны мәгъкуль күрделәр.* Р.Низамиев

3. *хәб. функ.* Ризалыкны, хуплауны белдерә; яхшы, хуп. *Мәгъкуль, җаным, бик мәгъкуль, бәрәкалла, машалла, фаразан.* Ш.Камал. *– Әйе, әйе, бик мәгъкуль, фаразан, ханнан узу килешеп бетмәс, – дип хупладылар бахшыны карачылар.* М.Әмирханов. *[Тимер:] Хуш, Гайшәбикә! Синең минем яннан китеп торуың мәгъкуль.* Р.Батулла

МӘГЪЛҮМ *с. гар.* **1.** Билгеле, билгеле булган; гадәттәге, таныш. *Такташның мәгълүм сүзләренә таянып әйтсәк, Сәйдәштә дә ике «мин» яши...* Р.Низамиев

2. *хәб. функ.* Билгеле, таныш. *Хәнәфинең төрле даирә кешеләре белән аралашканы мәгълүм, мондый очракта кая барырга, кемгә сугылырга икәнен яхшы беләдер*. М.Маликова. *Прокурор булмаган кешенең күзенә дә мондый муллыкның кайдан килүе мәгълүм ләбаса.* Р.Мирхәйдәров. *Чөнки салам мәсьәләсе, мал азыгы проблемасы һәркемгә мәгълүм.* Р.Миңнуллин

3. мәгълүмең, мәгълүмегез *и. мәгъ.* Танышыгыз, белгән кешегез

◊ **Мәгълүм ки** Билгеле булганча. *Мәгълүм ки, революция вакыйгаларында аерым шәхесләрнең роле аеруча көчәя, моның мисалларын тарихтан күп табарга була*. Ә.Еники. *Мәгълүм ки, югарырак менгән саен, һава басымы да көчәя, нәтиҗәдә, сулыш алу авырлаша, кан басымы уйный --- башлый.* Р.Габделхакова

МӘГЪЛҮМАТ *и. гар.* 1) Аң-белем, фәһем, гыйлем. *Ул башкалар кебек җитәрлек мәгълүмат, иҗтимагый тәрбия дә алмаган*. Г.Нигъмәти. *Мәдрәсәдә уналты яшенә кадәр укыган булса да, аның мәгълүматы бик сай иде.* Ш.Мөхәммәдев

2) Хәбәр, материал, информация. *Күрешү, хәл белешү, дөнья хәлләре турында мәгълүмат алу, бәхәс, кәмит урыны да ул.* М.Әмирханов. *Ә.Кәримуллин мондый хәбәрне игътибарсыз калдыра алмый, шундук төрле дәверләрдә һәм илләрдә яшәгән галимнәрнең, сәяхәтчеләрнең әлеге темага*

мөнәсәбәтле мәгълүматларын эзли башлый. И.Хуҗин. *Ярый әле бүген куен дәфтәренә яңа мәгълүматларны теркәп куйган иде [Каюм].* М.Хуҗин

3) Белешмә. *Археологик истәлекләр турында да бераз мәгълүмат бирик.* Ф.Хуҗин. *Алынган мәгълүмат буенча геройны Мәскәүдә Ленин китапханәсендә эзләп таптым.* Р.Ибраһимов. *Аның [«Азатлык» радиосының] чит илләрдә һәм Россия төбәкләрендә 25 хәбәрчесе, Казанда үз мәгълүмат бюросы бар.* Казан утлары

МӘГЪЛҮМАТЛАШТЫРУ I *ф.* Җәмгыять тормышының төрле тармакларына мәгълүмат технологияләрен кертү, җәелдерү

Мәгълүматлаштыра башлау Мәгълүматлаштырырга тотыну

Мәгълүматлаштырып бетерү Мәгълүматлаштыруны төгәлләү; барысын да мәгълүматлаштыру. *Мәктәпләрне мәгълүматлаштырып бетерү*

Мәгълүматлаштырып тору Һәрдаим мәгълүматлаштыру; әледән-әле мәгълүматлаштыру. *Вакытында мәгълүматлаштырып тору шарт*

МӘГЪЛҮМАТЛАШТЫРУ II *и.* Җәмгыять тормышының төрле тармакларына мәгълүмат технологияләрен кертү, җәелдерү процессы; шуның белән бәйле эшләр. *Халыкара мәгълүматлаштыру академиясенең төп үзенчәлекле билгесе: ул барлык фәннәр тоташкан җирдә урнашкан.* Я.Шәфыйков. *Президент --- мәгълүматлаштыруны арттыруны, Россия мәктәпләрен Интернет челтәренә тоташтыруны мондый авыр шартларда зур җиңү дип саный.* Шәһри Казан. *Мәктәпләрне мәгълүматлаштыру белем бирүдә уңайлыклар тудырса да, әлегә укытучының хезмәтен җиңеләйтте дип әйтеп булмый.* Ватаным Татарстан

МӘГЪЛҮМАТЛАШУ *ф.* 1) Хәбәрләшү. *Татарлар аз чыгымнар тотып, чикләрсез, административ киртәләрсез мәгълүматлашу чарасына ия булдылар.* Р.Хәким

2) Мәгълүмат технологияләре керү, җәелү

Мәгълүматлаша башлау Мәгълүматлашырга тотыну

Мәгълүматлашып бетү Барысы да мәгълүматлашу

Мәгълүматлашып тору Һәрдаим мәгълүматлашу; әледән-әле мәгълүматлашу

МӘГЪЛҮМАТЛЫ *с.* 1) Белемле, күп белә торган, күп укыган. *Батальон инженерлык хезмәтләре өчен билгеләнгән булганлыктан, офицерларның барысы да зур мәгълүматлы, --- сызымнарны, карта белән эш итүне бик яхшы белиләр ---.* Г.Ахунов. *Анда бик кызыклы кешеләр килгән иде. Һәммәсе югары белемле, бик мәгълүматлы...* М.Маликова. *Ж.Фәйзи безнең күңелләрдә һаман да киң эрудицияле, зур мәгълүматлы, барлык вакыйгалардан хәбәрдар, халыкның ихтирамына лаек олы композиторыбыз булып сакланыр.* Казан утлары

2) Нәрсәдән дә булса хәбәрдар; аерым өлкә яисә мәсьәлә буенча мәгълүматы булган. *Мәгълүматлы сарай әһеленең фикере үзгә иде.* М.Әмирханов. *Бу төбәктә үземне республика прокуроры, хәтта эчке эшләр министрына караганда да мәгълүматлырак дип санарга батырчылыгым җитә.* Р.Мирхәйдәров

МӘГЪЛҮМАТЛЫЛЫК *и.* Мәгълүматлы булу дәрәҗәсе

МӘГЪЛҮ́М БУЛУ *ф.* Ачыклану, билгеле булу. *Соңрак аның [Мисхәтнең] төрекләшкән осетин икәнлеге мәгълүм булды.* Т.Галиуллин. *Миңа шунысы мәгълүм булды: нинди олы шагыйрь булса да, Х.Туфан кайбер шигырьләрен дүрт, биш, хәтта алты тапкыр эшкәрткән.* Т.Нәҗмиев

МӘГЪЛҮ́М ИТҮ *ф.* Белдерү, ачып салу, хәбәр итү. *Аннан соң кайтып, бу хәлне ул падишаһка мәгълүм итте.* К.Насыйри. *[Айсылу:] Шатморатның армиядән килгән хатын да мәгълүм итте, сәлам-әманәтен тапшырды.* Г.Якупова

МӘГЪМҮР *с. гар. иск.* Төзек, төзекләндерелгән, тәртипкә китерелгән. *Мәгъмүр Болгар шәһәрләре, Болгар авыллары бер дә булмаган төсле кырылдылар да беттеләр, эзләре дә калмады.* Г.Тукай. *Инде өченче Рамазан гаетен дөньяның иң мәгъмүр мәмләкәтләре өстенә ут, тимер яуган вакытта үткәрәмез.* Г.Исхакый. *--- шимальдан килгән гаскәрләр, Урал тавы артынннан чыккан күчмәләрнең һөҗүмнәрен сөйләп, бу мәгъмүр шәһәрне шуларның уклары көл иткәнен --- сөйләде.* М.Хәбибуллин

МӘГЪНӘ *и. гар.* 1) Кемгә дә булса әйтергә, җиткерергә теләгән фикер; нәрсәнеңдер асылына, төбенә салынган фикер. *Тел төбеннән, сүзләренә шаян мәгънә салып әйтүеннән шул аңлашыла.* Р.Кәрами. *Тик мәгънәсе башкача: тол калган әниеңне кияүгә алып китсәләр, калымга сыер бирергә мөмкиннәр, ди...* Ф.Җамалетдинова. *Сәлахов телеграммаңы тагын бер мәртәбә укып чыкты. Аның мәгънәсе әле һаман да аның башына барып җитми иде.* Ф.Садриев

2) Сүзнең, атаманың, фикернең һ.б.ш. эчтәлеге. *Мөнирҗанның аңына килүенә сөенешкән шәфкать туташлары телен көчкә генә әйләндереп әйтелгән бу сүзнең мәгънәсен аңларга тырышып баш ватты.* Н.Әхмәдиев. *– Күбәләк! – диде Илгизә туган телдә. Һәм әлеге сүзнең мәгънәсе хакында уйланды.* Ф.Җамалетдинова. *Латинчадан тәрҗемә иткәндә, «прокурор» сүзе «кайгыртучы» дигән мәгънәне аңлата.* Р.Вәлиев

3) Мөһимлек, әһәмият. *Мәгънә биреп бөтен тормышыма, Үз йөрәгем тибә сулкылдап.* С.Гәрәева. *– Ә аларны җанлы итеп күрү безгә кирәк, бик кирәк, ансыз тормышның мәгънәсе югала, – дип дәвам итте Нигъмәтҗан.* М.Маликова. *Нәфес түгел, Намус икән яшәүнең төп мәгънәсе...* Л.Шагыйрьҗан

4) Файда. *Минемчә, кирәк булмас, чөнки укытып маташудан барыбер мәгънә чыкмаячак.* Ә.Еники. *Инде кире кузгалып торудан мәгънә юк: караңгыда барыбер күрмәбез.* И.Хуҗин. *Аның монда элгүенә сөенеп туялмаган Бикхуҗаевларның тегермәненә су коеп, шушы эшкә ябышып ятудан ни мәгънә?* Р.Мирхәйдәров

5) *сөйл.* Рәт, җай. *Мәгънәсен белгән, эшен дә эшләр.* Мәкаль. *Бу – башка. Кешесе дә, мәгънәсе дә башка.* Ә.Еники. *Шуңа күрә исән чакларыңда Яшәү кирәк мәгънә, мән белеп.* Н.Әхмәдиев

◊ **Мәгънә бирү** Асылына төшенү, нәрсәдер дип уйлау, аңлау; берәр хәлгә юрау. *Аның бу эшләренә бернинди мәгънә биреп булмый.* Ш.Хөсәенов

МӘГЪНӘВИ *с. гар. кит.* 1) Мәгънәгә караган. *Әсәрнең һәр сүзе, һәр җөмләсе һәм һәр мәгънәви фикере ачык, аңлаешлы булырга тиеш ---.* Р.Батулла

2) Рухи, эчке. *Менә мин шул үземнең мәгънәви атамның сәламәтлегенә, тагы минем кебек йөзләр, меңнәрне тудыруына кадәх күтәрәм.* Г.Исхакый. *Шунда үсте ул [Гасыйм Сәләхович], шунда шактый зур дәрәҗәгә иреште һәм тормышын тәэмин итәрлек матди җирлекне дә, үзенә кирәк мәгънәви азыкны да шунда тапты.* Ә.Еники. *– Үзең киеп йөре, – ди Заһидә ханым. – Эстафета булыр, аның мәгънәви мирасы синдә калды.* Р.Батулла

МӘГЪНӘДӘШ *с.* **1.** Бердәй мәгънә белдерә торган, синонимик. *Ләкин бүген инде без «ана теле» һәм «туган тел» сүзләрен тулысынча мәгънәдәш дип карыйбыз.* А.Тимергалин. *«Райкомда эшләүчеләр», «район җитәкчеләре» бу өзектә мәгънәдәш тезмәләр буларак кулланылалар.* Г.Галиуллина. *Бу очракта намус белән иман синонимлаша, яки мәгънәдәш сүзләргә әверелә.* Кызыл таң

2. *и. мәгъ.* Синоним; бер үк төрле мәгънә белдерә торган сүз, термин, мәкаль һ.б. *Тураган теләгәнен кабар, ашаган биргәнне кабар [мәкаленең] мәгънәдәше: кемнең кулында, шуның авызында.* Н.Исәнбәт

МӘГЪНӘДӘШЛЕК *и.* Мәгънәдәш булу, синоним булу. *--- боларның мәгънәдәшлек төсмерләрен тоемлау әллә ни кыен түгел.* И.Низамов

МӘГЪНӘЛЕ *с.* **1.** 1) Эчтәлекле; билгеле бер мәгънә салынган. *Тирән мәгънәле җырлар сагындыра башлады хәзер халыкны.* Мәдәни җомга. *Аерым өлкәләрдә генә җырлана торган, бик мәгънәле, тәмле сүзле, тыңлагач эсселе-суыклы булып китә торган җырлар бар.* Кызыл таң

2) *лингв.* Билгеле мәгънә белдерә торган. *--- китап сүзе лексикада мөстәкыйль мәгънәле, алынма (гарәптән кергән) бер мәгънәле сүз буларак аңлатылса, шул ук китап сүзе морфологиядә исем сүз төркеменә караган тамыр сүз булуы, килеш, тартым, сан белән төрләнә алуы ягыннан характерлана.* Татар теле морфологиясе. *Бер мәгънәле сүз. Абстракт мәгънәле исем*

3) Акыллы, эшлекле, файдалы. *Минем белән очрашкан саен, Кәшшафетдин абый нинди дә булса кызыклы хәл (бабай андый хәлләрне «мәгънәле гыйбарәләр» ди) турында сөйләп өлгерде.* М.Хуҗин. *Ипи салу... Дөньяда иң игелекле, мәгънәле, иҗади бер эш ул.* М.Мәһдиев. *Менә бу урында якташыбыз Габдерәхим Утыз Имәнигә һәйкәл булса, нинди мәгънәле булыр иде.* Р.Зәйдулла

4) Күп нәрсә аңлата торган, серле. *Зәйнулла аңа мәгънәле караш ташлады. «Күрдеңме, эзләгәнне табабыз бит, болай булгач» дигән ишарә иде бу.* М.Насыйбуллин. *Бәләкәйдән үк атның шатланганда кешнәп көлүен, кайгырганда яшь чыгарып елавын, зур күзләрендә чагылган мәгънәле моңны тоеп үсә идең.* Ш.Галиев. *Савымчы кызлар мәгънәле генә елмаешып алдылар.* Ф.Тарханова

5) Килешле; уйланылган. *Һәр хәрәкәтең салмак, мәгънәле булырга тиеш.* М.Маликова. *Бу ерткыч зирәк акыллы, аның үз-үзен тотышы мәгънәле, бик сак.* Кызыклар дөньясында

6) Тулы; вакыйгаларга бай. *Аның [Хәйринең] мәгънәле тормышы сызып атылган иде.* Ф.Садриев. *Бу – иң нәтиҗәле хәрәкәттә булу, чынбарлык үсеш-үзгәрешләренә үзеңнән өлеш кертә-кертә замана белән бергә атлап, тулы канлы, мәгънәле тормыш белән яшәү.* Т.Әйди

2. *рәв. мәгъ.* Күп нәрсә аңлата торган итеп; серле итеп. *Интизар мәгънәле итеп елмайды да урынына утырды.* Р.Вәлиев. *– Үзе тапкан фасон, – дип җавап бирде Наргизә һәм мәгънәле генә елмаеп куйды.* М.Маликова

МӘГЪНӘЛЕЛЕК *и.* Билгеле мәгънәгә ия булу; мәгънәле булу сыйфаты. *Безнең урманның матурлыгын, мәгънәлелеген, акылын беләсегез килсә, аның эченә көзге вак яңгыр яуганда керегез.* М.Мәһдиев. *Бу төр әсәрләрдә юмор һәм сатирик сызыклар мәгънәлелек белән, заманының актуаль мәсьәләләре белән бер бөтен тәшкил итәләр.* А.Әхмәдуллин. *Әле күптән түгел генә аңы томаланган кешеләрнең хәрәкәтләре мәгънәлелек төсмере алды.* И.Хуҗин

МӘГЪНӘСЕЗ *с.* **1.** 1) Мәгънә салынмаган; билгеле мәгънәсе булмаган; бернәрсә дә белдерми торган. *Сүзләр урынына мәгънәсез хәрефләр теземе генә чыга башлый.* А.Гыйләҗев. *Сәлперәеп төшкән яңаклар, мәгънәсез күз карашы, акыл загыйфьлеге, вакытыннан элек картаю – болар бар да исерткеч эчемлекләрне еш куллану нәтиҗәсе.* Биология

2) Килешмәгән; урынсыз. *Ачуга ачу белән җавап кайтару – төшемсез, мәгънәсез эш.* Х.Камалов. *Башта Бибинурның тәкъдиме шундый кызык, шундый мәгънәсез, хәтта ки мыскыл итү булып тоелган иде.* А.Гыйләҗев. *Ул чәнти бармагыннан алтын балдагын салып, чәчкә белән янәшә куйды һәм аларны чагыштыруның никадәр мәгънәсез икәнлеген аңлады, көлеп җибәрде.* М.Маликова

3) Буш, кызыксыз, эчтәлексез. *Кемнеңдер трибунадан сөйләгән мәгънәсез яки ялган сүзен тыңлап утырам да түзә алмыйм, чәчрәп чыгып кычкырынырга тотынам.* Т.Миңнуллин. *Бигрәк тә минеке шикелле һөнәр иясенә бу тормыш мәгънәсез.* Р.Кәрами. *Бүгенге табын яныңдагы сүзе телевидение һәм радиодан туктаусыз яңгырап торган мәгънәсез, үзе әйтүенчә, тозсыз җыр сүзләре --- турында иде.* Ә.Сафиуллин

4) Файдасыз. *Хәзер инде бу авыруның озакка сузылачагы ачыкланды: кул көче җитенкерәми, планнар үтәлми, кайбер хуҗалыкларның яшәве – мәгънәсез бер күренеш.* В.Шугаев

5) Буталчык, аңлаешсыз. *Ул әллә нинди мәгънәсез төшләр күреп саташып чыкты.* Ш.Камал. *Нигә кирәк булды бу су кызларын, урман егетләрен уч төбе кадәр мәйданга менгереп, мәгънәсез сикерүләр, бил бөгүләр, баш чөюләр, кул болгаулар, йөзгә, меңгә сыгылулар аша табигатьне кабатларга тырышып тамаша куеп азапланырга?* Р.Вәлиев. *Кемнең мәгънәсез*

законы белән таныштырасың син? Н.Гыйматдинова

6) Акылсыз, аңгыра. *Мәгънәсез баш никадәр булса да зур – Уты-суы булмаган бер дала-кыр.* Г.Камал

7) Мәнсез, мән (II), мәгънә (*4 мәгъ.*) белми торган. *Юк, бу тормыш була алмас, ахры, Мәгънәсез һәм мәнсез адәмсез.* М.Шиһапов. *Мәскәүдән, Казаннан килгән мәгънәсез тәнкыйтьчеләр кайчакларда фидакяр артистларның ачуын кабарта ---.* Р.Батулла. *Мәгънәсез бәндә, сүз алып, мәгънәсез сүзләр сөйләде.* Г.Зәйнашева

2. *рәв. мәгъ.* Буш, эчтәлексез. *Торабара бу мәҗлес кызыксыз һәм мәгънәсез тоела башлады, карын туйды.* А.Гыйләҗев

МӘГЪНӘСЕЗЛӘНҮ *ф.* Мәгънәсезгә әйләнү. *Ул [А.Фәтхи] Ходайның киң дөньясын тарайтырга тырышып, бүтәннәрне кояш яктысыннан мәхрүм итәргә омтылып мәгънәсезләнмәде.* Р.Мәрданов. *Мөселман егетеннән шикләнмичә, эчендәгесен бушатты: – Бигрәк мәгънәсезләнде бу халык, – диде ул, тавышына ачулы үртәлү чаткысы чыгарып.* Ә.Моталлапов. *Студент халкы шундый инде ул: юктан гына да мәгънәсезләнеп көлке таба.* Ф.Яхин

Мәгънәсезләнә башлау Мәгънәсезлек билгеләре күренү

Мәгънәсезләнеп бетү Тәмам мәгънәсезләнү. *Телевизорны ачсаң, карарга әйбер юк, тапшырулары да мәгънәсезләнеп бетте.* Кызыл таң

Мәгънәсезләнеп йөрү Озак вакыт дәвамында мәгънәсезләнү

Мәгънәсезләнеп тору Туктаусыз, даими мәгънәсезләнү; сөйләгән моментта мәгънәсезләнү

Мәгънәсезләнеп утыру *к.* **мәгънәсезләнеп тору**

МӘГЪНӘСЕЗЛЕК *и.* 1) Мәгънәсез булу сыйфаты. *Габдулла укыды, башка авторның тозсызлыгыннан, мәгънәсезлегеннән көлде, журналны атып бәрде.* А.Расих. *Тәрбиясенә баксаң – анда да мәсләксезлек, мәгънәсезлек; үз башында да зиһен чамалы булды Ядигәр ханның.* Р.Батулла. *Юк, бу елау түгел, бу – тилерү, бу – акылдан шашу, бу – мәгънәсезлек.* А.Әхмәтгалиева

2) Акылсызлык. *Шулай ук Рәшит участогын ике өлешкә бүлеп, бер өлешенә – уракчыларны, икенчесенә комбайнны кушу да мәгънәсезлек булыр иде.* Н.Фәттах. *Гаепләү дәлилләре мине ышандыра, шуңа күрә карышып маташу мәгънәсезлек дип уйлыйм.* Ф.Сафин. *– Бүгенге көндә аларга каршы көрәшү – мәгънәсезлек! – Көрәшчеләр эзләргә кирәк, Буртас! – дип кабатлады ханзадә.* Р.Батулла

МӘГЪРИБ *и. гар. кит.* 1) Көнбатыш. *[Зөләйха абыстай:] Балаларымның берсе мәшрикътә, берсе мәгърибтә.* С.Җәлал. *Әнсар, күлын каш өстенә куеп, кояшны үзенә алган мәгъриб ягына карап торганнан соң, салмак кына адымнар белән әрәмәлек буендагы сукмактан авылга таба атлады.* З.Хәким. *Җил исә төрлечә: Мәшрикътән, мәгърибтән...* Ф.Мөслимова

2) *тар.* Төньяк Африкадагы Мисырның көнбатыш ягында урнашкан (Җәзаир, Марокко, Тунис һәм Ливия) гарәп илләре

◊ **Мәгъриб диюе** Искиткеч зур гәүдәле кеше турында. *Ишек уемын тутырып, мәгъриб диюе кебек кап-кара әзмәвер пәйда булды.* З.Фәтхетдинов

МӘГЪРИФӘТ *и. гар.* Гыйлем, аңбелем, культура. *Менә мәгърифәт кешене ни эшләтә.* Г.Камал. *Шигырьләре белән мәгърифәт сараен кем салды?* Р.Батулла. *Мәгърифәткә тартылган яшьләрнең Тукайны укып шашкан, канатланган чорлары.* Р.Миңнуллин

МӘГЪРИФӘТЛЕ *с. кит.* **1.** 1) Белемле, акыллы, укыган (кеше тур.). *Синең кулда: теләрсең, мәгърифәтле бул, бәхетсез бул ---.* Г.Тукай. *Менә шул сөйләшүдән соң озак та үтми, безнең мәгърифәтле җизнәбез, ничектер туры китереп, бер тотылганрак рояль дә сатып ала.* Ә.Еники

2) Алга киткән, культуралы, мәдәниятле (халык һ.б.ш.). *Менә күрерсез, барлы-юклы бер ел эчендә тоташ укый-яза белүче мәгърифәтле авыл иттерәбез дә куябыз Килдебәкне!* Г.Бәширов

2. *рәв. мәгъ.* Мәгърифәтле булып; мәгърифәт күреп

МӘГЪРИФӘТСЕЗ *с.* **1.** Мәгърифәт күрмәгән, белеме булмаган, томана. *Менә шуннан татарны мәгърифәтсез халык дип кем әйтә алыр?* Татарстан яшьләре

2. *рәв. мәгъ.* Мәгърифәттән башка; мәгърифәтле булмый торып. *«Гыйлем вә мәгърифәтсез дә гомер итә белә-без», – дип, Әбүзәр бәктән көлделәр.* М.Акъегет

МӘГЪРИФӘТЧЕ *и. кит.* **1.** 1) Гыйлем иясе, галим; мәгърифәт таратучы

2) Мәгърифәтчелек (*2 мәгъ.*) тарафдары. *Ә Ибраһим Терегулов – культура тарихыбызда мәгълүм кеше – мәгърифәтче, педагог, җәмәгать эшлеклесе...* Ә.Еники. *Әгәр шушы гади нәрсәләрне аңламасак, татар мәгърифәтчеләре исемен күтәреп йөрү – мәгънәсезлек.* И.Әмирханов. *Мин – мәгърифәтче, тел сакчысы.* Н.Кәримова

2. *с. мәгъ.* Белемле, мәгърифәтле. *Җәелеп ята минем каршыда Мәгърифәтче татар баласын Якын иткән казах даласы.* Н.Хисамов. *Шунысын да онытмыйк: күп кенә дин әһелләре иң алдынгы карашлы, ачык фикерле, мәгърифәтче кешеләр булганнар.* Т.Миңнуллин

МӘГЪРИФӘТЧЕЛЕК *и. кит.* 1) Мәгърифәт, уку-укыту өлкәсендә эшчәнлек. *Бу елларда Габдрәшит Ибраһимов мәгърифәтчелек, дәреслекләр язу һәм бастыру белән дә актив шөгыльләнә.* Татар әдипләре. *Кеше турында тәгълимат теләсә нинди мәгърифәтчелекнең үзәген тәшкил итә.* Казан утлары

2) *тар.* XVIII–XIX йөзләрдә алдынгы рус һәм славян җәмәгатьчелегенең иҗтимагый фикер хәрәкәте; XIX–XX йөзләрдә татар җәмәгатьчелегенең иҗтимагый һәм мәдәни хәрәкәте. *Шушы Татар бистәсендә башта мәгърифәтчелек, соңрак җәдитчелек хәрәкәте туа.* Ә.Еники. *Шуңа күрә аны азатлык көрәше дип атаучылар да, мәгърифәтчелек яки буржуаз хәрәкәт буларак бәяләүчеләр дә бар.* Р.Сафин. *Мәгърифәтчелек идеологлары үзләренең иҗади эшчәнлекләрен дини караңгылыкка гына түгел, бәлки абсолют монархия тудырган социаль тәртипләргә дә каршы юнәлдерәләр.* К.Гыйззәтов

МӘГЪРУР *с. гар. кит.* **1.** 1) Үзүзенә ышанган, көчле рухлы; горур.

Бер урында ул [Такташның романтик герое] юлында очраган каршылыкларны тар-мар китереп барган мәгърур кеше буларак ачылса, --- чынбарлыкны тарихи катлаулылыгында һәм конкретлыгында аңлый алмавы өчен сыкрана-әрни башлый... Т.Галиуллин. *Үз җиренең мәгърур йөрәкле бер баласы иде бу Зөһрә сылу.* А.Хәлим. *Габдулла Кариев ярлы булса да мәгърур кеше булган, дип сөйлиләр.* Р.Батулла

2) Масайган, тәкәббер, эре. *Ул – бик мәгърур кеше, дөньяда мин генә дәһи кеше, дип уйлаучы иде.* Г.Бәширов. *Әнсарның зәп-зәңгәр күзләре чамадан тыш майланган, килеп җитәрәк, ул мәгърур кыяфәт белән авызын чалышайтты.* З.Хәким. *Нефтьчеләрнең йөреш-торыш бөтенләй башка: мәгърурлар! Фыртлар! Моңа ничек түзеп тормак кирәк!* Казан утлары

3) Данлыклы, бөек; мәһабәт. *Таяныч ноктасы, горурлык чыганагы буларак мәгърур Идел елгасы алыну табигый.* Т.Галиуллин. *Кап-кара чуеннан коелган, бинуһая зур, мәгърур һәйкәл иде ул.* Р.Фәизов. *Әдип үзен бөек илнең – Советлар Союзының мәгърур улы дип санады.* Р.Сверигин

2. *рәв. мәгъ.* 1) Горурлык белән, горурланып. *Ә ул мәгърур гына баш изәп саубуллаша да тагын шигырьләренә чума.* К.Кәримов. *Юлаучының үзен артык мәгърур тотуына гаҗәпләнсә, соңра, баш игәндә, артык ялагайларча төче елмаюы Ананы шиккә калдырды.* Тарих эчләрендә ниләр бар?

2) Эреләнеп, тәкәббер рәвештә. *Ул бик кәпрәергә ярата булса кирәк, үзен бик эре тота, һәрвакыт мәгърур басып тора ---.* Г.Әпсәләмов. *Борыннарын чөйгән кызлар, хәерчегә баккандай, мәгърур басып, Алып Бәргәнне күзәтә.* Р.Батулла. *--- ул кыя тыштан караганда гына шулай мәгърур күренә, эчтән күптән инде сагыш сулары юган, ялгызлык хәсрәтләре көйдергән иде аны.* М.Маликова

МӘГЪРУ́РАНӘ *рәв.* **1.** 1) Горурланып, горурлык белән. *– Күрәсеңме безне, менә без ништәдек?! – дигән төсле, мәгъруранә кукраеп утыралар иде.* Н.Думави. *– Мин сезгә тагын да матуррагын китерермен әле, --- – дип, мәгъруранә үз көчемә ышанганлыгымны белдердем.* Г.Кутуй. *Җиңел арбада чибәр ир-егет мәгъруранә утыра.* Р.Батулла

2) Вәкарь белән, эреләнеп, тәкәбберләнеп. *Ишекне ача да өйгә мәгъруранә кереп китә.* Ә.Баян. *Һәм... мәгъруранә үтеп баручы маэмаем өстенә ярсып ыргылган овчарка белән тавыш-тынсыз гына сугышып, үз горурлыгын саклый белүенә шаклар катам.* Р.Юсупова

2. *с. мәгъ.* Горур; эре, тәкәббер. *Ул менә өстәлдә шундый мәгъруранә кыяфәттә бөгәрләнеп ята ки: «Ә мин сиңа менә хат алып кайттым», – ди ул.* Х.Туфан. *Күз карашы мәгъруранә, шул ук вакытта аңарда безгә – җир кешеләренә аңлашылмый торган тагын нәрсәдер бар кебек.* Г.Әпсәләмов. *Аның белән янәшә пионер галстугы таккан мәгъруранә Сонька, җиңенә кызыл бәйләгән физкультура укытучысы Чумак басып торалар.* А.Тимергалин

МӘГЪРУРЛАНУ *ф.* Эреләнү, тәкәбберләнү, масаю. *Мин шул «үзе биргән» алманы, урлаган алманы ашап торган малайлар алдында: «Менә үзе бирде!» – дип, мәгърурланып ашыйдыр идем.* Г.Тукай. *Ул йөзьеллык имәннәре елдан-елга мәгърурлана, колач җитмәслек кәүсәләре, бүрәнә-бүрәнә ботаклары белән котны алып, җилдавылдан курыкмыйча, һаман үсәләр дә үсәләр, ныгыйлар да ныгыйлар.* Ф.Яхин

Мәгърурланып тору Берникадәр яки әледән-әле мәгърурлану. *Гаюр тәңре үз дәһшәтен үзе күреп Мәгърурланып торгач әзрәк гаршесендә, Ачты серен кулындагы колларына.* М.Җәлил

МӘГЪРУРЛЫК *и.* Горур булу; үз-үзенә ышанганлык. *Аның [Сарьян абыйның] йөзендә эчке мәгърурлыгын чак тыеп торган канәгатьлек һәм шул ук вакытта үзе генә белгән ризасызлык та чагыла.* М.Галиев. *Әнсар, әкрен генә борылып, мәгърурлык белән җавап бирде: – Исәнмесез!* З.Хәким. *Манаралар саклый мәгърурлыгын, Шәһри Болгар – минем Элладам.* Н.Хисамов

МӘГЪСУМ *с. гар. иск.* Гөнаһсыз, саф, керсез күңелле. *Фәкыйрь үзе, ләкин шулай да ул Көләч; Йөзе мәгъсум, шат һаман.* М.Җәлил. *Инде аның [Фәридәнең] мәгъсум рухы бу газап урыны булган җирне ташлап, мәңгелек бәхет, мәңгелек сәгадәт урыны – күккә, үзе шикелле мәгъсум фәрештәләр янына оча.* С.Җәлал

МӘГЪСУ́МАНӘ *рәв. фар. кит. иск.* Саф, гөнаһсыз, керсез күңел белән; чын күңелдән. *Төшә искә сабый чакларым: Мәгъсуманә йөгереп уйнап йөргән, Зар-хәсрәттән хали чакларым.* М.Фәйзи. *Бу матур мәгъсуманә көлү Искәндәргә яңадан-яңа җан кертте.* К.Тинчурин

МӘГЪСУМЛӘНҮ *ф. иск.* Сафлану, гөнаһлардан арыну. *Җиңелләнәм, мәгъсумләнәм мин шул чакта, Рәхмәт әйтәм укыганым шул китапка.* Г.Тукай. *Конкурска килгән язмаларны укып, Бөек Тукаебызга булган халык мәхәббәтенең ихласлыгына ---, шагыйрьнең «җиңелләнәм, мәгъсумләнәм мин шул чакта, рәхмәт әйтәм укыганым шул китапка» дигән сүзләрнең хаклыгына янәдән бер кат инандык.* Шәһри Казан

МӘГЪСУМЛЕК *и. иск. кит.* Гөнаһсызлык, сафлык, чиста күңел

МӘГЪФИРӘТ *и. гар.* Ярлыкау, кичерү, гафу итү. *Башына гафу вә мәгъфирәт кидерде.* К.Насыйри. *Тагын бер хәдистә Пәйгамбәребез (с. г. в.) әйтә: «Рамазан аеның беренче ун көне – рәхмәт, икенче ун көне – мәгъфирәт, өченче ун көне – җәһәннәмнән котылу: кем бу айда үзенең малын сарыф итсә, Аллаһ аны уттан саклар».* Дин вә мәгыйшәт. *Күп гөнаһ эшләгән кеше, «Раббымның йөзенә карарлык хәлем калмады» дип, гөнаһка батмасын, шунда ук үкенеп сәҗдә кылсын, гафу һәм мәгъфирәт сорасын.* Дога китабы

МӘГЪФИРӘ́Т ИТҮ *ф.* Кемне дә булса ярлыкау, гафу итү (Аллаһы Тәгалә тур.)

МӘГЪФИРӘ́Т КЫЛУ *ф. к.* **мәгъфирәт итү**. *Я Аллаһ, миңа биргән тәгамнәреңне бәрәкәтле ит вә хуҗаларга мәгъфирәт һәм рәхмәт кыл.* Ватаным Татарстан

МӘГЪШУК *и. гар. кит.* Сөйгән яр. *«Мәхәббәт сукыр, ул мәгъшугының чын йөзен күрми», – дигән бер акыл иясе.* М.Маликова. *Ике мәгъшук, иркендә*

калгач, үзләре генә аңлап, шырык-шырык көләләр иде. А.Хәлим. *Мөхәммәдәмин хәтта берара тәҗрибәсез яшь мәгъшуктай югалып калды.* М.Әмирханов

МӘГЪШУКА *и. гар. кит.* Сөйгән хатын-кыз. *Казанда минем мәгъшукам, сөйгән ярым калды.* Ф.Латыйфи. *Бу сүзләре белән ул [Камил] мәгъшукасының никадәр иркә, өф-төф итеп кенә үстерелгәнлеген әйтергә теләде булса кирәк.* Р.Мирхәйдәров. *Марат Әмирхановның «Тояк эзе» дигән әсәрендә Кәшшаф үз мәгъшукасына мәхәббәт хаты яза ---.* Ф.Хатипов

МӘГЫЙШӘТ *и. гар. кит.* Яшәеш, тормыш, көнкүреш, тереклек итү. *Монда инде сәясәт аңкый: әйтерсең җөмһүрияттә татар дигән зур халык, аның мәгыйшәте юк.* С.Хафизов. *Көе киткән мәгыйшәтнең бәясе сукыр бер тиен.* Л.Шагыйрьҗан. *Мөселман мәгыйшәтендә генә түгел, кяфер мәгыйшәтендә дә күрелмәгән вәсвәсә бу!* А.Хәлим

МӘГЫЙШӘ́Т ИТҮ *ф.* Яшәү, тормыш итү. *Балыклар суда мәгыйшәт итәләр.* Г.Тукай

МӘГЫЙШӘ́Т КЫЛУ *ф. к.* **мәгыйшәт итү**. *Мәгәр бу да миңа мәгълүм: инсанга лаек мәгыйшәт кылып яшәр өчен, авыл кешеләренә мәдәният җитешми.* Т.Мөбарәков

МӘДӘНИ *с. гар. кит.* 1) Мәдәнияткә бәйле, мәдәнияткә кагылышлы. *Байлыкка ияреп, татарның рухи һәм мәдәни тормышы да бик кызу тәрәккый итә башлый.* Ә.Еники. *Каршылыклы тагын бер сорау туа: гасыр башында татарның матди һәм мәдәни хәле ничегрәк булган?* Р.Фәйзуллин. *Егерме еллык көрәшендә татар театры якты бер мәдәни коралга әверелде.* Р.Низамиев

2) Культуралы, алдынгы. *Мәдәни ул безнең авыл. Өйләремдә Фән нигезендә тукылыр, ди, чабата да.* М.Җәлил. *Ни әйтсәң дә, Норлат – мәдәнирәк, затлырак, алдынгырак авыл.* Ә.Рәшит. *Боларның һәр икесе дә мәдәни кеше гамәленә сыя торган нәрсәләр түгел иде.* Ф.Садриев

МӘДӘНИЛӘШТЕРҮ *ф.* Мәдәниятле итү, культуралаштыру. *Аларны тәрбияләү, мәдәниләштерү яки кулга ияләштереп маташу мөмкин нәрсә түгел.* А.Тимергалин. *Әллә без илебезне басып алырга килгән илбасарларга, кочагыбызны ачып: «Безне мәдәниләштерү өчен килдегез, хуш килдегез!» – дип әйтергә тиеш идекмени?* Инсан һәм дин

Мәдәниләштерә башлау Мәдәниләштерергә керешү

Мәдәниләштерә төшү Бераз мәдәниләштерү; тагын да мәдәниләштерү

Мәдәниләштереп бетерү Барысын да мәдәниләштерү

МӘДӘНИЛӘШҮ *ф.* Культуралашу, мәдәни булып китү. *XIX гасырның ахырларында бездә дә капитализм мөнәсәбәтләре нигу һәм шуның нәтиҗәсендә европача мәдәниләшү башлану белән иске идеология акрынлап җимерелгән кебек, аның телендә дә яңару, үзенә күрә динчелектән милләтчелеккә таба авышу башлана.* Ж.Вәлиди. *Башка милләтләрнең тәрәккый вә мәдәниләшү юлына керү ысулларын үзебезнең милләткә яраклаштырырга теләп йөрде [Ш.Рәмиев].* Ф.Ибраһимова

Мәдәниләшә башлау Мәдәнилек билгеләре сизелү. *Халык мәдәниләшә башлады*

Мәдәниләшә төшү Тагын да мәдәниләшү

Мәдәниләшеп бару Вакыт үткән саен ныграк мәдәниләшү. *Мәдәниләшеп бара торган милләтләр, Әхсән әфәнде, үлчәми-нитми тәкълит итмәскә тиешләр.* И.Нуруллин

Мәдәниләшеп бетү Тәмам мәдәниләшү

Мәдәниләшеп җитү Тиешле дәрәҗәдә мәдәниләшү

Мәдәниләшеп килү Мәдәниләшә башлау; бераз мәдәниләшү

МӘДӘНИЛЕК *и.* Культуралылык, алдынгылык. *Ризык җыю, мәҗлес, табын мәдәнилеге – бу тормышның кадере хакында уйланганнар өчен зур фал.* М.Гали. *Мәдәнилек, тәрбия турында язылган акыллы сүзләр, дәфтәрләрне чыгарып ташлаганнар.* Ш.Галиев. *XIX гасыр ахырларында үзеңнең тугран сурәтләнгән шәхси мөһерең булу мәдәнилек билгесе саналган.* Н.Гамбәр

МӘДӘНИЯТ *и. гар.* 1) Җәмгыятьнең аерым бер үсеш этабында матди булмаган казанышларның, материаль һәм рухи кыйммәтләрнең кешеләр тормышында һәм үзара мөнәсәбәтләрдә иҗади чагылышы; культура. *Сәйдәш үзенең күп кенә замандашлары белән мәдәният урамының зурысыннан – кызылыннан атлады.* Р.Низамиев. *Әгәр язучы үзенең әсәрендә алман тоткынлыгында әсир булып яткан татар шагыйрен тасвирлый икән, ул бу милләтнең әдәбиятына, тарихына, мәдәниятенә мөрәҗәгать итмичә булдыра алмый.* Л.Шәех

2) Аерым халыкларның, милләтләрнең материаль һәм рухи кыйммәтләре. *Тургай абый – безнең мәдәният йорты директоры.* Ф.Яруллин. *Кичәдән соң мин, җәлт кенә чыгып, мәдәният сараеның юан колонналары арасына постым.* М.Галиев. *Кичке якта мәдәният йортында халык белән очрашу буласы.* Р.Батулла

3) Мәдәнилек, укыганлык, гыйлемлелек. *Әнием минем заманына күрә алдынгы карашлы, мәдәнияткә омтылучы хатын иде.* Ә.Еники

МӘДӘНИЯТЛЕ *с.* **1.** 1) Культуралы, укымышлы. *– Ханым әфәнделәргә мәдәниятле ирләр беренче булып урын тәкъдим итәләр, – диде ул ярым шелтә белән.* Г.Әпсәләмов. *Мәдәниятле халыкларда талантлы шәхесләргә аеруча зур хөрмәт, ихтирам белән карыйлар.* Т.Миңнуллин. *Бу бит татарны дөньяга тагын бер кат олы милләт, акыллы, мәдәниятле милләт итеп таныту булыр иде.* Р.Вәлиев

2) Алдынгы, цивилизацияле. *Халкыбыз элек-электән шәһәр мәдәниятле милләт булган, Болгар, Биләр, Сарай, Казан калалары, андагы мәдәният, фән, сәнгать үсеше татарларны бөтен дөньяга таныткан.* Татар, уян!

2. *рәв. мәгъ.* Мәдәният белән; мәдәнияткә нигезләнгән

МӘДӘНИЯТСЕЗ *с.* **1.** Цивилизация, мәдәният үсешендә артка калган. *Китапсыз халыклар – тарихсыз халыклар, тарихсыз халыклар – мәдәниятсез халыклар.* Ф.Яхин. *Анда татар-монголлар, электән килгән*

гадәт буенча, вәхши, ахмак, мәдәниятсез кавем буларак тасвирланган. Мәдәни җомга

2. *рәв. мәгъ.* Мәдәнияттән башка, мәдәният булмый торып. *Тарихсыз, мәдәниятсез, милли мәгарифсез генә төрки телләрне саклап калып буламы?*

МӘДӘТ *и. гар.* Ярдәм. *Менә-менә калтыраган кул түбә астына кыстырып куйган арба кендеген эләктерде, тыны буылган карт уч төпләренә төкерде дә аякларын киң җәеп басты. – Я Ходa, мәдәт бир!* М.Мәһдиев. *Я Ходаем, ярлыкый күр, бир мәдәт!..* Ф.Яхин. *Яңабаштан исән калу өчен, Мәдәт бир син безгә, Киләчәк!* Р.Низамиев

МӘДӘ́Ү *ф. диал.* 1) Уңайсыз, гадәттә артка табан авып китү, мәтәлү; тора алмаслык итеп егылу (хайваннар тур.)

2) *күч.* Утырган яки баскан җиреннән ялгыш артка табан егылып төшү (кеше тур.)

МӘДЕХ *и. гар. иск.* Мактау. *Аның Җан Баевичны мактап әйткән сүзләре – мәдех стихиясенә бирелеп китүнең классик үрнәге.* Х.Миңнегулов. *--- ә Миргазыймның мең кат ләгънәтләнгән һәм мең кат мәдех ишеткән әл-Куһел (алкоголь) тәэсирендә ялгыша язган чаклары гына булды.* А.Тимергалин

◊ **Мәдех әйтү** *к.* **мәдех итү**. *--- Олуг затлар белән ул Аллага күп-күп мәдех әйтте.* М.Җәлил. *Аны кире кагып, Тәңребезгә табыну, сыену, Аңа гозерләнү, ялвару, Аны олылау, мәдех әйтүгә бәйләнгән дини йолаларны үзең аңламаган ят телдә башкару гадәте ахирәткә әзерләнү өчен түгел, фани дөнья ихтыяҗыннан чыгып кертелгән.* Р.Сафин

МӘДЕ́Х ИТҮ *ф.* Мактау, зурлау. *Яздырды хат, Мәдех итте Ходаны башта кат-кат.* Фирдәүси. *--- сине халык һөнәрмәнд вә яхшы эшли дип мәдех итсеннәр.* К.Насыйри

МӘДЕ́Х КЫЛУ *к.* **мәдех итү**. *Бер гакыйль кемсәнә әйтте: «Мине мәдех кыйлсалар да, зәм кыйлсалар да бәйләнмимен, мәдех, зәм миңа бәрабәрдер», – диде.* К.Насыйри. *Пәйгамбәребез җыр һәм шигырьгә ул кадәр каршы булмаган, Рәсүлулланың шигырьне хурлау сүзләре генә түгел, мәдех кылган сүзләре дә бар бит югыйсә.* А.Тимергалин. *Ләкин бит аның [Мәсгуд абыйның] башка мәдех кылынырлык эшләре дә күп.* Р.Кадыйров

МӘДЕХЛӘ́Ү *ф.* Мактау, зурлау; мәдех итү. *Әмма Фәридетдин Гаттар һәм Хисам Кятиб әсәрләреннән үзгә буларак, «Кисекбаш китабы»нда дөньявилык, җир тормышын мәдехләү көчле.* Х.Миңнегулов. *Кеше гүзәллегенә битараф булмау, мәдехләү осталыгы исә аның күпсанлы --- натюрморт-тасвирламаларында чагылыш таба.* Р.Шаһиева

Мәдехли башлау Мәдехләргә керешү

Мәдехләп тору Гел, даими мәдехләү

МӘДЕХЛЕ *с.* Мактаулы. *Әүвәл башта мәдехле вә мактаулы булып та, соңыннан хилафы заһир булган хосуста зарбе мәсәл кыйлыныр.* К.Насыйри. *Ул заманнарда иң мәдәниятле, гыйлемһөнәрдә бөтен дөньяда иң шөһрәтле, шәрык вә гареп халыклары эчендә мәдехле, иң яхшы вә тугры халыклар безнең бабаларыбыз болгарлар булган.* Гасырлар кайтавазы

МӘДРӘСӘ *и. гар.* Мөселманнарда урта белем бирә торган мәктәп; дин әһелләре, мөгаллимнәр әзерләп чыгара торган урта яки югары уку йорты. *Мәдрәсә бинасы кечерәк тә, искереп тә килә.* Г.Галиева. *Безнең Югары Колмаер авылында «Мөхәммәдия» мәдрәсәсен тәмамлаган яшь егет имам вазифасын башкара.* С.Шәрипов. *Салихны «Мөхәммәдия» мәдрәсәсенә биргәннәр иде, ул бик тырышып шунда белем эстәде.* Р.Низамиев

МӘДХИЯ *и. гар.* 1) Мактау сүзе. *Фәйзи ага, Галия утырган өстәл почмагын сыпыргалап, аңа мәдхия яудыра: «Пылау өстендәге йөзем инде, валлаһи!»* Г.Гомәр. *Үзен тәкәбберлек дәрәҗәсендә горур тотуы, кемгәдер ялагайлану, мәдхия яудыру юлына төшмәве, дөресе – булдыра алмавы, Мәһдиевнең тормышын кыенлаштыра.* Т.Галиуллин. *Мәхәббәтнең мәңгелеге иксез-чиксез тормыш тантанасына мәдхия булып ишетелә.* Р.Сверигин

2) *әд.* Кемнең дә булса шәхесен, аның эш-гамәлләрен, яшәешен мактау яки нинди дә булса тантана уңае белән иҗат ителә торган лирика жанры; ода. *Ш.Маннур күмәкләшүдән соң язып ташлаган «Гайҗан бабай» кебек чат кызыл мәдхиянең (һәм аның дәвамының!) бу мәҗмугага да, шигырь антологияләренә дә керергә хакы юк, әлбәттә.* А.Тимергалин. *Якуб аганың алтмыш еллык бәйрәменә багышланган әдәби кичәдә шәкертләреннән берсе --- остазына карата ихлас ярату хисе белән сугарылган мәдхиясен укыган иде.* М.Госманов. *Аның [Акмулланың] Шиһабетдин Мәрҗани һәм башка бик күп затларга багышланган шигырь-касыйдә, мәдхия, мәрсияләрен --- замандаш-ватандашлары яттан белгән ---.* Р.Әхмәт

◊ **Мәдхия җырлау** *к.* **мәдхия уку**. *Аннары бу Китап кемгә дә булса мәдхия җырлау белән дә шөгыльләнми.* А.Тимергалин. *Сүз дә юк, бөек шагыйрь, әмма бит ул шаһларны гына данлаган. Аларга мәдхия җырлау өчен гомеренең өчтән берен биргән.* Ж.Ильясов. **Мәдхия уку** Чамасыз мактау, күкләргә күтәрү. *Менә хәзер ул кеше бизәнү бүлмәсенең ишеген шакыр. Керәкерешкә үк концертка мәдхия укыр, иң яраткан җырчым – Сез, дип, кулын үбәр.* К.Кәримов. *Ә бит чынлыкта, эшләпәләр сатучы менә шушы кибеткә кирәк иде мәдхия уку!* М.Вәли-Барҗылы

МӘДХИЯЧЕ *и.* 1) Мактап сөйләүче; мәдхия укучы. *Тәнкыйтьчегә караганда мәдхияче куркынычрак.* Р.Батулла. *Ә былбылга – мәдхияче иткәч, Җырларына рөхсәт биргәч җиткән!* Р.Рахман

2) Ода, мәдхия (*2 мәгъ.*) язучы. *Мәдхияче шагыйрь халыкның караңгылыгыннан, наданлыгыннан зарлана.* С.Алишев. *Сатирик язучы белән мәдхияче шагыйрь бер йортта тора.* Р.Батулла

МӘДХИЯЧЕЛЕК *и.* Мактау, мәдхияләр белән мавыгу күренеше. *Бер яклы бәяләүнең, мәдхиячелекнең нык тамыр җибәрүе турында күп язылa ---.* Т.Галиуллин. *Авторның бу темаңы шулай аеруча калкытуы бу очракта*

мәдхиячелек белән артык мавыгуы да, башкалардан арттырып җибәрергә омтылуы да түгел. М.Гайнетдин

МӘЕЛ *и. гар.* **1.** 1) Нәрсәгә дә булса тартылу, күңел яту, күңел кую

2) Нәрсәдер уйлап яки нәрсә белән дә булса килешеп, билгеле бер нәтиҗәгә, фикергә килү яки күчү процессы; авышу

3) Омтылыш, теләк, кызыксыну. *--- шундый әдәби парчалар анда матур вә ләтыйф хисләр вә мәелләр уятып, нигъәять, әдәбиятның үзенә мәхәббәт вә мәел куәтләндерүгә сәбәп улдыгы һәркемгә мәгълүмдер.* Г.Ибраһимов. *Сез, алайса, адәмнең рухында яхшылыкка, икенче кешеләргә яхшылык теләүгә мәел барлыгын инкяр итәсез икән?* Г.Рәхим. *Авиациягә аны табигый мәел түгел, ә бәлки яшьлек романтикасы тарткан, дигән тәэсир бар иде ул чакта миндә.* Р.Батулла

2. *бәйл. функ.* Нәрсәгәдер охшаш, тартым. *[Йолдыз] үзенең карага мәел чәче, ак, нәфис һәм балкып торган йөзе --- белән бөтен авылның кешеләрен гаҗәпкә калдыра.* Ш.Әхмәдиев

3. *кис. функ., тарт. форм.* **мәйле**. «Ихтыяры, үз ирке, теләгәненчә эшләсен» дигән мәгънәдә кулланыла. *Иртән Мирали әкәгә әйткән идем, ул: «Хуп, мәйле!» – ди.* Н.Әхмәдиев. *Барыгызның да теләге шундый икән, хуп, мәйле, шунда күмегез алайса.* Ф.Баттал. *Хуп, мәйле, Иван Степанович!* Ф.Абдуллин

МӘЕ́Л ИТҮ *ф.* Күңел белән нәрсәгә дә булса тартылу, омтылу; нәрсәгә дә булса авышу; бирелү. *Күңелен шул кызга мәел итте ул.* К.Насыйри. *Хәзрәт, бераз уңга таба мәел итеп, ике аршын озынлыгындагы көмеш башлы кызыл камыш таягыны ярты адым кадәр алга куеп, алга таба атлый башлап, өенә таба хәрәкәткә хәзерләндегене мөсафирга белдерде.* Г.Камал. *Вә хәрам мал җыярга мәел итмә.* М.Гайнетдин

МӘЕ́Л КЫЛУ *ф. к.* **мәел итү**

МӘЕЛЛЕ *с.* 1) Берәр шөгыльгә теләге, кызыксынуы, маһирлыгы, кул ятышлыгы булган

2) Берәр кемгә яки нәрсәгә уңай карашта, мөнәсәбәттә булган

МӘЕТ *и. гар.* Үлек, үлгән кеше гәүдәсе. *Мәет өстенә ефәк материя ябылган.* Г.Әпсәләмов. *Иртәгәсен зиратта Әсма карчыкның кабере янәшәсенә ике улының да мәетен ләхеткә иңдерделәр.* Н.Әхмәдиев. *Апам шунда [моргта] ятканда, мәетләрне китерүләрен үз күзләрем белән күреп тордым.* В.Нуриев

◊ **Мәет чыккан йорт кебек (төсле, шикелле)**. Күңелсез, шомлы тынлык турында. *Бөтен авыл мәет чыккан йорт кебек кайгыга чумды.* Г.Бәширов. *Авыл урамы мәет чыккан йорт кебек буп-буш.* Г.Сабитов. *Мәктәп мәет чыккан йорт кебек иде.* Р.Батулла. **Мәет чыккан йорттай** *к.* **мәет чыккан йорт кебек (төсле, шикелле)**. *Авыл мәет чыккан йорттай тын калды.* М.Мәһдиев. *Көлешеп алган зал, җитди хәбәр көтеп, мәет чыккан йорттай тынып калды.* А.Хәлим. **Мәет чыккан өй кебек** *к.* **мәет чыккан йорт кебек (төсле, шикелле)**. *Сөембикә белән Үтәмеш ханны бәйләп коллыкка озаткач, Казан мәет чыккан өй кебек бушап, җансызланып, шомланып калды.* Р.Батулла. **Мәет чыккан шикелле (төсле)** *к.* **мәет чыккан йорт кебек (төсле, шикелле)**. *Син булмагач, өйдә дә күңелсез, мәет чыккан шикелле.* Г.Бәширов

МӘҖӘЛ *и. гар. иск.* Чара. *Әҗәл, әҗәлгә юк мәҗәл.* Мәкаль. *Шулай булгач, Искәндәр ахунның үз мәхәлләсендәге татарлар белән хисаплашмыйча һич мәҗәле юк.* Ә.Еники

МӘҖБҮР *с. гар.* **1.** 1) Иректезләнгән, җәберләнгән. *Нигә соң син мескен, мәҗбүр мужикларны Талавыңда белә алмыйсың хәт-чикләрне.* Г.Тукай

2) Берәр эш-гамәлне башкарырга тиеш булган. *Иң элек мине ашатырга тиешле әни, аннан соңрак матур итеп киендерергә мәҗбүр әни, аннан да соңрак, мин теләсә нишләп йөрсәм дә, кисәтеп миңа сүз әйтергә хакы юк әни.* Т.Миңнуллин. *--- кунак кына булып калачакбыз! Үзебез өчен даими һәм ышанычлы яшәү җирлеге таба алмыйча, каяндыр килгән һәм кире китәргә мәҗбүр затлар булып кына!* М.Вәли-Баржылы

2. *хәб. сүз* Ниндидер сәбәпләр аркасында яисә иректездән берәр эш эшләргә, башкарырга тиешлек турында. *Гаян, машинасын туктатып, аны [тавыкны] кararга мәҗбүр.* М.Хуҗин. *Хәер, режим сиңа ошыймы-ошамыймы, килешергә мәҗбүрсең.* В.Нуриев. *Озатышырга килгән Әхмәт Фәйзи, шул квитанция белән кассага барып, «багаж» бәясен түләргә мәҗбүр.* Р.Низамиев

МӘҖБҮ́РӘН *рәв. гар.* Мәҗбүр булып, иректезләнеп рәвештә. *--- мәҗбүрән эшемне бүлмәс идем, әмма ерак җирдән махсус кешеләр җибәреп, --- безне үзенең солтанатлы хозурына чакырган падишаһе әгъзам хәзрәтләреңең утенечен кире кагарга җөрьәт итә алмыйм.* Ә.Еники. *Димәк, Тукай заяга килгән һәм монда, башкалада, мәҗбүрән, ничарадан бичара гына Муса Биги өендә кунак булырга, ягъни кеше мәшәкатьләре өстендә тик ятарга тиеш була.* Р.Батулла

МӘҖБҮ́Р БУЛУ *ф.* Иректездән нәрсә дә булса эшләргә тиеш булу. *Меңгазап белән аякка басарга, юктан бар итәргә мәҗбүр булган алар [мөһаҗирләр].* И.Нуруллин. *Сафия дублёр булып кына кала; ә дублёрлар белән режиссёр гадәттә ныклап эшләргә җитешә алмый, алар, беренче составның репетицияләрен күзәтеп, шуннан өйрәнеп кенә утырырга мәҗбүр булалар.* М.Маликова. *Шуннан соң ул балаларның исемнәрен Сәлим белән Сәлимәгә алыштырырга мәҗбүр булды.* Р.Батулла

МӘҖБҮРИ *с.* **1.** 1) Берсүзсез, каршылыксыз, һичшиксез үтәлергә, эшләнергә, башкарылырга тиешле. *Фатирга кайткач, уңышлы яки уңышсыз сәүдәне юу – мәҗбүри хәл.* Ә.Баян. *Безгә чыбык «ашату» әти өчен дә мәҗбүри нәрсә түгел.* Т.Галиуллин. *Әсәргә партия җитәкчесен, өлкән туганның уңай вәкилен кертү мәҗбүри бер шартка әйләнде.* Ф.Хатипов

2) Кануннар таләп итә торган. *Бу әсәрләрдә колхозларның мәҗбүри хәрәкәт буларак оешуы, законсызлыкның көчәюе, әхлак дәрәҗәсенең түбәнәюе, кешенең кадере кимүе, хакимият тарафыннан яклау таба алмавы хикәя ителде.* Ф.Хатипов

3) Булырга тиешле, зарури; үзеннән-үзе эшләнә торган, булмыйча кала алмый торган. *[Рафаэль:] Аның өчен яннарына бару мәҗбүри түгел, гүзәлем, су читендә – дымлы урыннарда үсә ул*

агачлар. Р.Мөхәммәдиев. *Чын шигъриятkә тугры хезмәт итүнең мәҗбүри бер шартын үтәп, туктаусыз яңалыкка омтылучы, бик кыю һәм үзенчәлекле шагыйрь Газинур Морат.* Р.Фәизов. *Рус теле бит ул – Советлар Союзының бердәнбер дәүләт теле, димәк, барлык республикалар өчен дә мәҗбүри уртак тел.* Ә.Еники

4) Үз ихтыярыңнан, теләгеңнән башка, ирексездән эшләргә тиеш булган. *Торасың килмәгән чакта мәҗбүри торудан да әшәкерәк җәбер юктыр адәм баласы өчен.* Ф.Садриев. *Әмма әдип монда авыл хуҗалыгын мәҗбүри, тоташ күмәкләштерү турында сүз алып бармый* ---. Ф.Хатипов

2. *рәв. мәгъ.* 1) Ирексез рәвештә, теләмичә, мәҗбүрән. *Ләкин менә мәҗбүри ябылып ятарга кем риза икән?* М.Маликова. *Элек кешеләр әтиәниләренең хәлен белеп, бәрәңге казып, утын ярып килер өчен, өстәмә эш сәгатьләре алып эшләсәләр, хәзер исә ялны мәҗбүри бирәләр.* Г.Бәйрәмова. *Ләкин бу мәҗбүри ясалган туй фажига белән төгәлләнә.* Н.Мөхибуллин

2) Зарури рәвештә, булмыйча кала алмый торган итеп. *Хәзер исә бу мәҗбүри диярлек: көннәрдән бер көнне бөтен класс – бер класс кына түгел, ә бөтен Советлар Союзында барлык шәһәрләрдәге барча мәктәпләрнең фәләненче класслары һәммәсе пионер булып китә.* А.Тимергалин

3. *хәб. сүз* Һичшиксез кирәк, үтәлергә, эшләнергә тиешле булу турында. *[Мисбах:] Эчмәсәң эчмә, ашау мәҗбүри.* Н.Әхмәдиев. *Иң элек төпле, бөтен ижатын күзәтеп бәя биргән кереш сүз мәҗбүри.* Р.Мостафин. *Муеныңа галстук – мәҗбүри.* Ә.Хәсәнов

МӘҖБҮРИЛӘТҮ *ф. к.* **мәҗбүриләү**. *Ялгызы гына гомер итүенең нилектән икәнен һаман саен беләсе килсә дә, әбекәйне мәҗбүриләтеп сөйләтәсе килми аның, холкы шундый* ---. И.Вәлиуллина

МӘҖБҮРИЛӘ́Ү *ф.* Кемнедер үз теләгеннән, ихтыярыннан башка нәрсәдер эшләргә этәрү, мәҗбүр итү. *Мәҗбүриләп битен юдырта икән ана кеше дүрт яшьлек малаеның.* Т.Нәҗмиев. *– Юк, Әхнәф, мәҗбүриләмә, – диде Ирек, аның кулын иңбашыннан алып.* Ф.Садриев. *Тәһир кызны мәҗбүриләп капкадан кертеп җибәрде* ---. М.Кәбиров

Мәҗбүрили башлау Мәҗбүриләү билгеләре сизелү. *Бу – миграция хезмәткәрләренә ошамый, Эмзарга психологик басым ясап, Русиядән китәргә мәҗбүрили башлыйлар.* Өмет

Мәҗбүриләп тору Күпмедер вакыт мәҗбүриләү

МӘҖБҮРИЛЕК *и.* Ирексезлек, чарасызлык; кирәклек, тиешлек. *Газаплы уйлар кемне күбрәк җәфалагандыр: Александр Невскийнымы, Даниил Галицкийнымы – әйтүе кыен, әмма бу вазгыятьнең фажигасе ике явызлыктан берсен сайлау мәҗбүрилегеннән гыйбарәт.* Р.Хәким. *Аннан соң, мәҗбүрилек белән эшләнгән эшнең ахыры хәерле бетәр дип, кем гарантия бирә ала?* Р.Кәрами. *Ул мәҗбүрилекнең безнең өчен уңай нәтиҗәләре дә булгалады.* Л.Хәмидуллин

МӘҖБҮ́Р ИТҮ *ф.* Ирексезләп эшләтү, башкарту; нәрсәгәдер этәрү. *Бу хәл уйланырга мәҗбүр итте: туктале, ул Харитоновны узып йөри түгелме соң?* Г.Ахунов. *Аның [Рашатның] сүзләрендә боеру, мәҗбүр итү яңгыраса да, Ирек нишләптер китапны алды.* Ф.Садриев. *Ул залдагы йөзләгән халыкның үз гамьнәрен оныттырды, сәхнәдә вакыйгалар арасында яшәргә мәҗбүр итте.* М.Маликова

МӘҖБҮРИЯТ *и. гар. к.* **мәҗбүрилек**. *Менә курорттан кайтып барам, тазалык Аллага шөкер, бернинди эш, вазифа, мәҗбүрият белән бәйләнмәгәнмен: үземә үзем хуҗа!* Ә.Еники. *Хәер, айнык акыл белән уйлап карасаң, бу кыланышларда әллә ни зур җинаять булмаган кебек, аларның әхлак җәһәтеннән ярамаган алым, шул ук вакытта мәҗбүрияттән туган садә тәвәккәллек икәнлеген дә аңлавы читен түгел.* М.Госманов. *Димәк, һәр мәсьәләне безгә кечкенә генә дә ялгышусыз хәл итү мәҗбүрияте туды.* М.Хуҗин

МӘҖБҮРЛӘ́Ү *ф. к.* **мәҗбүриләү**. *НКВД тарафыннан кулга алынган Кави Нәҗмине кыйнап, җәзалап, контрреволюцион оешмага Фатих Кәримне җәлеп итүен танырга мәҗбүрләгәннәр.* Р.Вәли

МӘҖЛЕС *и. гар.* 1) Җыелыш, утырыш. *Шундый бер вакыйга хәтеремдә калган: без съездга оппозициядә тора торган берничә яшь-җилбәзәкләр --- бюро мәҗлесләренең бер-икесендә үзебезнең ноктаи назарларын әйтеп калырга теләдек.* Ф.Әмирхан. *Җөмләдән, галимнәр мәҗлесендә Рәшит Сюняев, Роберт Нигъмәтуллин һәм башка дөньякүләм танылган галимнәр бар иде.* Казан утлары

2) Берәр ижтимагый, сәяси, милли һ.б.ш. берләшмәнең корылтае, съезд. *Шул ук елның 20 ноябрендә Уфада Милли мәҗлес җыелып, күренекле шәхесебез Садри Максуди җитәкчелегендә эшен башлап та җибәрә.* И.Таһиров

3) Парламент

4) Кунак ашы. *Минем хөрмәткә оештырылган мәҗлес булып чыкты бу.* И.Нуруллин. *Пар чыгып торган ярым ачык ишектән өйдәге мәҗлеснең тавышы ишетелде.* М.Мәһдиев. *Шундый чәй мәҗлесләренең берсендә Салих өчен язмышын тамырдан үзгәрткән искитмәле хәл булды.* Р.Низамиев

5) *иск.* Пьесада пәрдә яки күренеш. *Бишенче мәҗлес. Соңгы мәҗлес*

МӘҖЛЕСТӘШ *и.* Кем белән дә булса бергә бер мәҗлестә утыручы. *– Амин, солтаным, хәерле сәгатьтә!.. – диде моңсуланып Иркен ага. – Берәрне кунар идеңез лә!.. – Ул мәҗлестәшләренә күз салды.* А.Хәлим. *Мәҗлестәшләр, гафу, сездән исә Мин беркадәр киттем читкәрәк.* Г.Бәйрәмова. *Мәҗлестәшләр, Мөхәммәт һәм аның ике улының сөйләшүләрен ишетмәсәләр дә, болар арасында ниндидер бәхәс бара бугай диеп, бераз сагаеп калдылар.* Р.Сибат

МӘҖМУГА *и. гар.* 1) Җыентык, сайланма әсәрләр. *Монда яңа әдәбияттан ике-өч роман, дүрт-биш шигырьләр мәҗмугасы, --- фарсы телендә берничә дәреслек бар иде.* Ә.Еники. *«Гомер фасыллары» дип, гажәеп бер тыйнаклык һәм гамәли бер аныклык белән исемләнгән бу китапны --- хикмәтле бер мәҗмуга дип атарга*

мөмкиндер. А.Хәлим. *Кәнәфигә сеңгән иләмәннең куенында затлы мәҗмуга.* З.Мансуров

2) Журнал, альманах. *Әдәби, фәнни һәм сәяси эчтәлекле «Шура» мәҗмугасы 1917 елның 31 декабренә кадәр айга ике мәртәбә нәшер ителеп, барлыгы 240 саны дөнья күрә.* Р.Исламов. *К.Насыйри --- аерым бер мәҗмуга – журнал чыгару теләге белән янып йөргән.* Фән һәм тел

МӘҖНҮН *и. гар.* **1.** 1) Акылдан язган, дивана, җенләнгән кеше. *Мин шул булмасын, дим, аның үзен мәҗнүн кебек күрсәтүе Алланың әмере берлә булмасын, дим.* Г.Исхакый. *Мәҗнүн микән, мәхлук микән мин.* Р.Закиров

2) Гыйшык утында газап чиккән кеше. *Минем Гранит абый да гашыйк мәҗнүнгә әйләнде әле.* Ф.Яхин. *Бәлки, алай итәргә кирәк булмагандыр: беренче генә тапкыр шундый өмет белән ышанып талпынган йөрәкне бер күрүдән гашыйк булган мәҗнүн кыяфәтенә кереп ымсындыру ярамагандыр.* Ш.Янбаев. – *Мәҗнүн син бүген! – диде Фатих, Мәхмүткә китәргә ишарә ясады.* Р.Батулла

2. *с. мәгъ.* Тилергән кебек, юләрләргә хас сыйфатларга ия булган. *Ышандым мин: сөю ул – могҗиза, Мәҗнүн карашларың исертте.* А.Бикмуллина. *[Хаким:] И мәҗнүн хатын! Әле һаман да шул буш хыяллар белән юанып яшисеңмени?* М.Маликова

МӘҖРУХ *с. гар. кит.* **1.** Яралы, җәрәхәтле. *Кичәдән җыелган бөтен акча, ишеткәнемчә, мәҗрух кызыл гаскәриләр файдасына китәчәк.* Ә.Еники. *Әйе, аларның күңелләре китек булган, мәҗрух.* А.Тимергалин. *Күптән түгел арабыздан киткән Мөдәррис Әгъләмнең соңгы шигырьләреннән берсе, сизгәнегезчә, үзенә күрә шигъри васыять булырлык мәҗрух җан авазы шикелле яңгырый.* З.Мансуров

2. *и. мәгъ.* Яраланган, җәрәхәт алган кеше. *Хастаханәләрдә мәҗрухлар азайды.* Г.Камал. *Мөслимәләр җәмгыяте мәҗрухларны карау эшен үз өстенә ала.* К.Тинчурин

МӘҖРУ́Х БУЛУ *ф.* Яралану, җәрәхәтләнү. *«Сугышка бармаган килеш мәҗрух булгансың икән», – дигән була, көлә [Арзу].* А.Гыйләҗев

МӘҖҮС *и. гар. иск.* **1.** 1) Мәҗүсилек. *[Балтамар:] Мәҗүс колы! Әнә бакыр пәриең табын!* Ә.Баян

2) Мәҗүси ышанулар белән яшәгән кеше; мәҗүси. *Мәдрәсә хәзер рәсүл алдында калтыранып торган мәҗүс хәлендә калды.* С.Поварисов

2. *с. мәгъ.* Мәҗүсилеккә хас, мәҗүсилеккә караган. *Бу урында бер нәрсә хәтергә килә: безнең халык җырларында халкыбызның мәҗүс заманнарында җырлаган җырлары дип хөкем итәрлек бер җыр да сизелми.* Г.Тукай

МӘҖҮСИ *с.* **1.** Мәҗүсилеккә бәйләнешле; мәҗүсилеккә хас йола-гадәтләрне тоткан; мәҗүсилек өстенлек иткән. *Эш шунда ки, борынгы мәҗүси чорларда Көнчыгыш халыклары табигатьтәге бердәнбер, мәңгелек, җир тормышының төп чыганагы булган кояшка табынганнар.* Г.Рәхим. *Юк, иманга өндәми Мәҗүси имче сүзе. Күрәзәсе һәр өйнең – «Аятелкөрси» үзе.* Г.Садә. *Нәстә түти, буш өй күреп, «ай-вай» килә башлады, төрле мәҗүси догалар пышылдап, түргә узды, кечкенә агач сандыктан Орман потын алды, ике уч арасына куеп ышкый башлады.* Г.Гыйльманов

2. *и. мәгъ.* Мәҗүсилек ышанулары белән яшәгән, мәҗүсилек йолаларын тоткан кеше. *Мәккә юлында аларны христиан да, мәҗүси дә түгел, ә нәкъ менә мөселманнар – чүл гарәпләре талаган.* М.Мәһдиев. *Мәҗүсиләр тартылгандай утка, Мин ымсынып сиңа төбәләм.* Р.Зәйдулла. *Славян кенәзләре, мәҗүсиләр гадәте буенча, зур биналар салырга керешкәнче, иртәннән үк юлга кешеләр чыгарып җибәргәннәр.* Кызыклар дөньясында

МӘҖҮСИЛӘ́РЧӘ *рәв.* Мәҗүсиләргә хас булганча, мәҗүсиләр кебек. *Ул яши-яши акыл җыйган авыл карты кебек тирән уйга чума, мәҗүсиләрчә матурлыкка табына, тын сагышка бата, шуңадырмы, аның шигырьләрендә әүлиялык чаткылары да чагылып киткәндәй була ---.* Н.Гамбәр. *Сүземнең башында ук, куеныбызга карандаш-дәфтәр кыстырып, Тарбели тавына күтәрелүебез, табигатькә мәҗүсиләрчә мөкиббән китеп, шигырь дөньясына чумуыбыз хакында язган идем бит.* Р.Әхмәтҗан. *Кояш чыгышы ягында калган авылы, карт нараттлары шаулаган зират, өянке янында озатып калган Нәзифә – күз карасыдай кечерәеп, йөрәгенә сыйган шушы күренешкә ул мәҗүсиләрчә табына.* М.Галиев

МӘҖҮСИЛЕК *и.* Айга, кояшка, утка, потка һ.б. табынудан гыйбарәт, бер илаһлы диннәргә кадәрге инану төре. *Бу ишанлыклар-фәләнләр – бер мәҗүсилек, имеш.* Г.Тукай. *Безнең бабаларыбызның мәҗүсилек заманында бүре культына табынган булу ихтималын фольклорчылар еш әйтәләр.* М.Мәһдиев. *Калканның бизәлеше бик сәер – ислам һәм мәҗүсилек билгеләре бергә кушылган, дигән фикер калды.* Ф.Бәйрәмова

МӘҖҮСИЯТ *и. гар.* Мәҗүсилек. *Табышмакларны да мәкальләр кебек мәҗүсият дәверенә һәм тормыш тугрында сөйләнгәннәргә аерырга мөмкиндер.* Ф.Сәйфи. *Иске төрек дине турысында Зәки әфәнде берничә җирдә «мәгънәсез мәҗүсият» дигән сүзне куллана.* Р.Вәлиев

МӘЗ *с. фар. диал.* Барыннан да риза, канәгать булган

◊ **Мәз бетү** Мөкиббән китү, сокланү; мөкиббән булу. *Ахирием мәз бетеп тел шартлата-шартлата әйтте ---.* З.Мәхмүди. *Мин беләмен, сез йөрисез мәз бетеп.* М.Фәйзи. **Мәз булу** Ләззәтләнү. *Сәлим илә Зәйнәп, чыкка чыланып агарган, йомшарган аякларына карашып, мәз булып, аталары артыннан баралар иде.* А.Таһиров. **Мәз китү** *к.* **мәз бетү**

МӘЗӘК *и. гар.* **1.** 1) Шаярып, уйнап әйтелгән сүз, уенчак сүз. *--- Җиһангирның сүзен уен-көлке, мәзәк дип кенә кабул иткән кешеләр аны шунда ук онытмадылар да...* А.Гыйләҗев. *Сөйләгәне исә гел мәзәк булды.* М.Мәһдиев

2) Анекдот. *Тәлгать Нәҗмиев, «Саба мәзәкләре», «Тагын... Саба мәзәкләре» дип аталган китаплар чыгарып, изге эш башкарды.* Т.Миңнуллин. *«Төчкерек мәзәкләр» язып, Күпме*

кәгазь «ашады» [Марсель Гали]! Л.Лерон. *Иртәнге чәйне эчкәндә дә, төрле мәзәкләр сөйләп, сеңлесен көлдереп бетерде.* Х.Ширмән

3) Кызык; көлке; күңел күтәрә торган шаянлык һ.б. *Шуның өчен алар, үзара төрле шуклыклар, мәзәкләр уйлап, күңелләрен күтәрергә тырышалар.* Р.Батулла. *Шуннан үзләренә мәзәк табалар. Рәхәтләнеп бер көлешеп алалар.* С.Поварисов. *Габделхакка ышаныч юк, аннан да мәзәк табарга булдыра ул, ләкин бу юлы мин эшләгәннәрне кабатлады, монысы өчен рәхмәт аңа.* Г.Госман

2. *с. мәгъ.* 1) Көлдерә торган, кызык, шаян. *Борын белән бәйле хәйран гына мәзәк хәлләр дә сөйләнелә, төрттерүләр дә була.* Т.Нәҗмиев. *Ул [Искәндәр] --- һәркемгә карата кыска, үткер һәм мәзәк шигырьләрен әйтеп көлдереп тә ала.* Р.Фәизов. *Ипташләре белән сөйләшкәндә генә түгел, сафта йөргәндә дә, мәзәк сүзләр кыстырып куярга ярата [Шәрип].* Р.Кәрами

2) Кызык, үзенчәлекле, сәер. *Безнең капка төбенә җыелган күршетирәләр аның бу мәзәк гадәтенә каш җыерып та, көлеп тә карап утыралар.* М.Галиев. *Безнең ише читтән карап торган кешегә мәзәгрәк тә инде үзе.* М.Маликова. *Бу мәзәк кошлар [балтабарлар] үзләре оя ясамый, ә йомыркаларын, безнең күке кебек, бүтән кошлар оясына сала.* Кызыклы физиология

3. *рәв. мәгъ.* Сәер рәвештә, кызык. *Әйбәтрәк өйле, сыерлы, сарыклы кешеләр, кайгырышсалар да, артык аһ ормыйча гына торганда, Маһисәрвәр апаның шушылай үрле-кырлы сикеренүе, бер караганда, шактый мәзәк тоела иде, әлбәттә.* В.Нуруллин. *Бу хәлләр ул чакта мәзәк тоелса да, мин озак вакытлар, олы кешеләрне рәнҗеттем бит, дип борчылып йөрдем.* Ә.Хәсәнов

4. *хәб. функ.* Кызык, сәер. *Бөкре җилкәле кешенең ярсып өстәл астына кереп китүе дә мәзәк кайберәүләр өчен, диван өстендә селтәнеп маташуы да көлке!* А.Гыйләҗев. *Шунысы гына мәзәк: салкын көннәр җиттеме, кое шакырдап туңа да кызганыч дәрәҗәдә сәрсез булып кала.* Ә.Баян

◊ **Мәзәк итү** *к.* **мәзәккә алу**. *Идрснең төнге икедә япа-ялгыз су коенуын мәзәк иткән укучылар, шукланып биибии, һаман җырлашып тордылар.* А.Гыйләҗев. **Мәзәккә алу** Көлү; кем яки нәрсә турындадыр көлеп сөйләү, җитди кабул итмәү. *Бу гайре табигый хәл иде мөселман сугышчылары өчен, шуңа аларны кайтып-кайтып мәзәккә алып та сөйләделәр.* Р.Мөхәммәдиев. **Мәзәк ясау** Кызык ясау, шаяру, күңел ачу. *Бәхтияровның аңлы рәвештә шундый уйдырма хәбәр таратуы каракларны өркетеп мәзәк ясау өчен генә түгел иде, әлбәттә.* М.Насыйбуллин. *Сиңа кешедән көлү, мәзәк ясау булсын.* Т.Галиуллин

МӘЗӘКЛЕ *с.* Шаян, көлке, кызыклы, уенчак. *Һәр әсәр мәзәкле булсын димибез, мәзәк мәгънәле булган кебек, җитди сүз дә тапкыр булсын.* Ш.Галиев. *Ә сериалның мәзәкле урыннарында ул авызын ачып көлеп җибәрә торган иде...* Р.Сабиров

МӘЗӘКЛЕК *и.* Мәзәк хәл; кызык нәрсә. *Бичара, өйләнмәгән, сөкәт кадәр гәүдә белән мәзәкләкләр эшләп йөргән.* М.Мәһдиев. *Аларны балалар авызыннан ишеткәндә, бигрәк тә күңелгә хуш килә икән, бу күренештә уш китәрлек мәзәклек тә бар.* Б.Рәхимова. *«Бер кирпеч, ике кирпеч...» көнкүреш комедиясендә мәзәклек, балаганлык өстенлек итә.* Ә.Закиржанов

МӘЗӘКСЕНҮ *ф.* Гаҗәпләнү, сәерсенү, сәер нәрсә дип кабул итү. *Малай мут елмаеп торган картка мәзәксенеп текәлде.* М.Галиев. *Аның бу сүзләре миңа бик сәер тоелды: – Нинди тылсымлы кәгазь ул, кайдан таптыгыз, кем бирде аны? – дип мәзәксенеп сорадым.* С.Сабиров

Мәзәксенеп калу Аптыраган, сәерсенгән хәлгә килү. *Бухгалтерлары, ни әйтергә белмичә, мәзәксенеп калдылар.* С.Рафиков

Мәзәксенеп тору Гаҗәпләнгән хәлдә булу

МӘЗӘКЧӘН *с.* Мәзәк, кызык нәрсәләр сөйләргә яратучан, шаян, шук. *Җор телле, мәзәкчән, бинаһая талантлы иде халык композиторы ---.* Г.Гомәр. *Әнә әтинең дә күзләре дымланган, һәрвакыт көләч, мәзәкчән булса да, бу юлы чыраена мин аңламастай сагыш кунган.* Ә.Рәшит. *--- Сәйфулла һәрвакыт шат, мәзәкчән, җор теленнән рәхәтләнеп көлдерә торган уен-көлкеле сүзләр коелып кына тора.* Сәхнә

МӘЗӘКЧӘНЛЕК *и.* Мәзәкчән булу. *Миңлеасиясе әле һаман җор табигатьле, әле һаман зифа гәүдәле, чыраенда әле һаман уенчак-мутлык, мәзәкчәнлек...* Г.Ахунов

МӘЗӘКЧЕ *и.* 1) Мәзәкләр сөйләргә яратучы һәм шуларны оста сөйләүче кеше. *Ул [Рим Кәримов] – артист, диктор, тәнкыйтьче, оештыручы, оста мәзәкче, тагын әллә кемнәр...* Т.Галиуллин. *Мәсәлән, Мефистофель белән йөрүче ике мәзәкченең тозсыз мәзәкләре аша явызлыкның фәкать әшәке күңелле җаннар өчен генә көлке булып тоелуы аңлашыла.* Л.Шәех. *Моннан Дюреның беркайчан да мамыкны күрмәгән, фантазёрлар яки мәзәкчеләр сүзеннән генә чыгып язган икәне ачык күренә.* Робинзон эзләреннән

2) Цирктә: комик. *Мәзәкчеләр шаркылдап көләләр дә югалалар.* И.Юзеев

МӘЗӘКЧЕЛ *с. к.* **мәзәкчән**. *Равил Габделхәевич та – бик мәзәкчел кеше.* Т.Нәҗмиев. *Вакыты белән кискен, вакыты белән мәзәкчел, ә тулаем алганда, тирән мәгънәле фәлсәфи фикер алышуны без, Алла бирсә, телевизорлардан тыңларбыз.* Р.Харис. *Үзе дә мәзәкчел кеше булганга, ул бу эшне бик мавыгып башкара, хәтта кайчагында артыгы белән.* И.Хәйруллин

МӘЗӘКЧЕЛЕК *и.* Мәзәкче кешегә хас сыйфатлар. *Ротада мәзәкчелеге белән танылган яшь солдат Андрей Гаврилов шаян күзләрен солдатлар өстеннән йөгертте.* И.Туктар

МӘЗИН *и. гар. сөйл.* Мәәззин, азанчы. *Мулла белән мәзин килеп җитте.* Г.Бәширов. *Мәҗлесләрдә дә, бүтән муллалар шикелле, үзе башлап акыл сатарга яратмый, бары сорауларга җавап кына биреп утыра, Коръәнне дә күбрәк мәзиннән укыта --- иде [Искәндәр ахун].* Ә.Еники. *Агай бик теләп ризалаштыр, «ярты сәгать тә узмас, укымышлы мәзин өеңдә булыр» дип ышандырды.* Р.Мөхәммәдиев

МӘЗКҮР *с. гар.* Югарыда әйтелгән, әйтеп үтелгән, телгә алынган. *Шөкер булсын, хәзер алдымда бер нурлы хәят инде, Теге мәзкүр пот алдында табынганнан оят инде.* Г.Тукай. *«Шәкертләр» имзасы белән басылган бу хәбәр: «Без, шәкертләр, югарыда исемнәре мәзкүр адәмнәргә игълане нәфрәт кыламыз», – дигән сүзләр белән тәмамлана.* Г.Исхакый. *Мәзкүр хатын Сәлим илә Зәйнәпне үз өйләренә алып чыгып китте*. А.Таһиров

МӘЗЛУМ *с. гар.* **1.** Кыерсытылган, кимсетелгән, золым күргән. *Гасырлар буенча изелгән мәзлум милләтләргә тулы азатлык килде.* Ә.Еники. *Мәзлум халык хокук, ирек даулый, Тәрәккый да була төрлечә*. Г.Афзал

2. *и. мәгъ.* Кыерсытылган кеше. *Мәзлумнарга якты, нурлы көннәр килде, – Азатлыкның кояшы тугды имди.* Г.Тукай. *[Хәмдия:] Түгел! Түгел! Мин көтүче яры түгел. Мин – мәзлумнарны яклаучы саф күңелле кыз.* М.Фәйзи. *1912 елның язында бик ярлы кеше вафатыннан соң Коръән укыгач, алга куелган бик күрексез, шикле ризыктан (мәзлумнарны кимсетмәү өчен) яхшысынмый гына авыз итә [Мирзаян мулла]*. Ә.Баян

МӘЗЛУМӘ *и. гар.* Кыерсытылган хатын-кыз. *Син ела: күр дә кешелек дөньясы тапталганын, Мәзлумә, толлар, ятимнәрнең елап ач калганын*. М.Җәлил. *Бәетләрдә көчләп кияүгә бирелгән кызларның, мәсхәрәләү һәм авыр эштән иза чиккән киленнәрнең язмышын чагылдырган шушындый трагик мотивлар күп очрый: андый мәзлумәләрнең күбесе елга яки күл төбенә ташланып кына котылу таба.* Казан утлары

МӘЗҺӘБ *и. гар.* 1) Ислам дине фикъһын төрлечә аңлау һәм аңлатудагы аермалар сәбәпле барлыкка килгән тармакларның һәрбере. *Әле бит шунысы да бар: күпчелек Кавказ мөфтиятләре Әбү Хәнифә мәзһәбенә түгел, шафигый мәзһәбенә карый.* Ватаным Татарстан

2) Гыйлемдә, фәлсәфәдә, дөньяга карашта тоткан юл, юнәлеш; мәсләк. *Алардан бераз соңрак яшәгән Ш.Мәрҗани да бу турыда: «Мин үземне һичкемнең фикер һәм мәзһәбенә иярергә мәҗбүр дип белмим», – дип белдергән.* Г.Ибраһимов. *Бөтен нәрсә төгәл генә дөрес булсын, иманга хилафлык килмәсен. Менә шушындый мәзһәб.* Ә.Баян. *Әллә кайчан үз «мәзһәбен» тудырган, Ул какшамас кәнәфигә утырган.* Р.Низамиев

МӘЗҺӘБЛЕ *с.* 1) Мәзһәбе (*1 мәгъ.*) булган, мәзһәбләрне кабул иткән

2) Мәсләкле, үзенең тоткан юлы булган. *Мин мәсләкле, мин мәзһәбле, мин эшлекле.* Г.Тукай

МӘЗҺӘБСЕЗ *с.* 1) Мәзһәбе (*1 мәгъ.*) булмаган, мәзһәбләргә каршы булган. *Бүген вәһһаби, сәләфи, тәймияче атамалары белән билгеләнеп йөрүчеләргә мәзһәбсезләр дигән сүзне куллану дөресрәк.* Шәһри Казан

2) Мәсләксез, кыйбласыз

МӘЗҺӘБСЕЗЛЕК *и.* Мәзһәбләрне кабул итмәү позициясе. *Мәзһәбсезлектә һәркем үзен мөҗтәһид буларак саный*. Безнең гәҗит

МӘЗҺӘБТӘШ *и.* Кем белән дә булса бер үк мәзһәбтән булган кеше. *Иске йоланы саклаучы мәзһәбтәшләре Рәсәйдәге кысынкылыктан соң монда ныклап тамыр җибәрергә, баерга комарлана, күчмә казахларның терлек көтүеннән кырларын-бакчаларын саклар өчен, алар ширкәт сыман бер нәрсә төзегән, нәүбәтләшеп биләмәләрен каравыллый иде.* Т.Әйди

МӘЗҺӘБЧЕ *и. иск.* Мәзһәб (*1 мәгъ.*) яклы, мәзһәбләр тарафдары булган кеше

МӘЗҺӘБЧЕЛЕК *и.* Мәзһәбләрне кабул итү позициясе. *Мәзһәбчелек кирәкме?*

МӘЙ *и. фар. сөйл.* Аракы, исерткеч. *Чәй кирәк, чәй янына мәй кирәк.* Мәкаль. *Маша! Чәй керт, мәй керт.* Т.Галиуллин. *Чәй эчеп тә, мәй эчеп тә тормыйм.* Л.Лерон

МӘЙДАН *и. гар*. 1) Шәһәр яки авыл эчендә биналар, корылмалар булмаган ачык, буш урын. *Өчәүләп вокзал каршындагы мәйданга чыктылар.* А.Хәсәнов. *Манара тирәсендә иркен мәйданны койма белән әйләндереп алганнар да турникет куйганнар ---.* М.Маликова. *Һәр иртәдә чираты килеп җиткән гаилә кешеләре, читтән көтү көтәргә дип махсус кайткан туган-тумачасын алып, үзәк мәйданга барып баса.* Г.Гыйльманов

2) Берәр нәрсә биләп торган урын, җир; киңлек, территория. *Кайберләренең, бигрәк тә болгар шәһәрлекләренең, мәйданы берничә йөз гектарга җитә бит.* Ф.Хуҗин. *Бу храмның мәйданы 40 мең квадрат метрга җиткән заллары бар!..* М.Мәһдиев. *Карагай безнең ил урманнарында башка агачларга караганда иң зур мәйданны алып тора*. Ботаника

3) Күмәк төстә күңел ачу уеннары һ.б.ш. була торган урын. *Алар һәр җирдә – танцы мәйданнарында булсын, концерт залларында булсын, күңелле прогулкаларда булсын – һәрвакыт бергә күренә башладылар.* И.Гази. *Мәйданда уеннар күп – кайсына өлгермәк кирәк*. М.Хуҗин

4) Шундый урында үткәрелә торган уеннар. *Бу авылның мин җыен, мәйдан, сабаны туйларын Язмыймын, куркып, ераклarга китәр, дип уйларым...* Г.Тукай

5) Сабантуй үткәрелә торган урын. *Юаш күренгән малайдан Мәйданда батыр чыгар.* Ш.Галиев. *Көрәш кыза мәйдан уртасында, дулкынлана халык: кем җиңәр?* Х.Әюп. *Инде мәйдан тирәли ыспай киенеп, култыклашып йөргән Кәүсәрия белән Әлтәфне күргән авыл халкы исә шаклар катты.* И.Хәйруллин

6) Волейбол, футбол һ.б. спорт уеннары өчен махсус урын. *Инде спорт мәйданы да ясап бирергәме?* Х.Сарьян. *Таш-бетон панельләрдән җыеп салынган терлек абзарының волейбол мәйданы чаклы ишекләрен ачып керүгә, төче силос, әче сидек исе белән тулган җылымса һава борынга бәрелде*. А.Вергазов

7) *мат.* Яссылыкта, өлектә яткан геометрик фигураларны характерлый торган математик зурлыкларның берсе. *Озынлык белән киңлек билгеле булганда, мәйданны исәпләргә авыр түгел*. Яшь натуралистларга

8) Нинди дә булса хәл, вакыйга булган урын. *Абага чәчәге турында*

хыялланып йөри-йөри, Рөстәм үзен фронтта, сугыш мәйданында хис итте һәм язны көтте. Г.Кутуй

9) *күч*. Нинди дә булса эшчәнлек өлкәсе. *Нишлисең, иҗат мәйданы шулай булырга тиеш тәдер.* Р.Фәйзуллин. *Әмма бу очракта инде тикшерү мәйданы тагы да киңәя төшә, аның юнәлешләре арта, бер юрамага икенчесе өстәлә.* М.Насыйбуллин. *Кайда гына күз төшермә, Күз салма кая гына – Әдәби мәйданга яки Азатлык мәйданына – --- Һәркайда да ул булыр [Рабит Батулла]*. Л.Лерон

10) *күч*. Нәрсәнең дә булса барлыкка килүе, гамәлгә ашуы, яшәве өчен мөмкинлекләр, юл. *Әдәби әсәрдә сүзгә кысан булса булсын, фикергә киң, иркен мәйдан булсын.* Х.Бәдигый. *Прозаикка әдәби портрет та, образның эчке һәм тышкы сурәте дә бу очракта җиңелрәк бирелә, иҗади хыялга да мәйдан киң була.* Р.Фәтхрахманов. *Югыйсә моңа С.Габәшинең рух һәм белем мөмкинлекләре дә киң мәйдан бирә, чөнки ул – татар һәм, гомумән, ислами Көнчыгыш мәдәниятен якыннан белә, ярата.* Милли моңнар

11) *күч.* Берәр урында җыелган халык; кешеләр төркеме. *Син дә, мин дә сүзсез калдык, Мәйдан да тынды төсле.* Р.Гарифуллина. *Кинәт искән җилдән шадраланган тыныч күл шикелле, мәйдан бердәм хәрәкәткә килде*. М.Ибраһимов. *Мәйдан көләр иде, биер иде, Әй очыныр иде шатлыктан!* Н.Сафина

12) *күч*. Берәр нәрсәнең таралыш, кулланылыш киңлеге. *Татар иле язмышы, тел язмышы кыл өстендә торганда, халкыбызның дәрәҗәсен халыкара мәйданга чыгару өчен галим булып җитешергә этәргеч биргәндер.* Ә.Халитов. *Милли мохитебезнең мәйданы әнә нинди зур икән, моңа кадәр күреп кенә җиткерә алмаганбыз*. Р.Шәрәфиев

◊ **Мәйданга килү** 1) Барлыкка килү, туу. *Шунлыктан күп санлы дидактик рухлы үгет-нәсыйхәткә нигезләнгән әсәрләр мәйданга килде.* Ә.Хуҗиәхмәтов. *Яңа заман әдәбияты мәйданга килә.* Ә.Закиржанов; 2) Басылып чыгу; дөньяга чыгу, матбугатта чыгу. *«Габделбасыйр гыйшкы», «Тигезсезләр», «Сүнгән гыйшык» кебек матур һәм тирән эчтәлекле әсәрләр бер-бер артлы мәйданга килеп торалар.* Ф.Әмирхан турында истәлекләр; 3) Халыкка ачылу, билгеле булу. **Мәйданга чыгу** *к.* **мәйданга килү**. *Кайчан да булса гомум тарихыбыз мәйданга чыгармы?* Р.Вәлиев. *Үз вакытында Мирсәетнең ярдәме белән мәйданга чыккан Салих Атнагуловның «Эшче» газетасындагы мәкаләләрен уку аеруча авыр була.* Р.Мөхәммәдиев. *Тамырларның киселүе, традицияләрнең бетерелүе, милли деградациянең мәйданга чыгуы...* А.Хәлим. **Мәйдан тоту** Ярышта җиңү; өстен чыгу; өстен булу. *Шоңкар юкта ябалак мәйдан тотар.* Мәкаль. *Бабайларым мәйдан тоткан, Әтием дә бил алышкан…* Л.Лерон. *1951 нең февраль ахырында 17–18 яшьләкләр арасында «Хезмәт резервлары» спорт җәмгыяте беренчелегенә оештырылган бәйгедә 67 килограммга кадәрге урта үлчәүдә мәйдан тотты [Сафин]*. Казан утлары

МӘЙДАНБАШ *и.* Сабан туе мәйданында төп кеше, җитәкчелек итүче. *Иһаять, кулына озын колга тоткан, аңа төрле төстәге чигүле сөлгеләр аскан мәйданбаш күренде.* М.Хәбибуллин. *Ингел Фәткуллин бүген хезмәт ветераны санала, пенсионер инде, әмма сабан туйлары булдымы – Ингелебез алмашсыз мәйданбаш.* Гасырлар кайтавазы

МӘЙДАНДАШ *и.* Бер мәйданда булган, катнашкан һ.б. кешеләр. *Мин сезнең арадагы кайбер кешеләрнең вак эгоистлыгына хәйран калам ---. Мәйдандашын батыру исәбенә үзенең персонасын расларга омтылалар алар.* А.Расих

МӘЙДАНЧЫК *и*. 1) Билгеле бер максат белән файдаланырлык итеп әзерләнгән урын; тигез җир, зур булмаган мәйдан. *Шуннан соң мин аны икенче көнне, кичке ашка керер алдыннан, шушы кечкенә мәйданчыкта күрдем.* Ә.Еники. *Элеккеге киң ишегалдында балалар уйнар өчен мәйданчык.* М.Хәсәнов. *Карт аңа мәйданчыкта җилдәй җилдергән чандыр гына малайны күрсәтте.* М.Насыйбуллин

2) Нинди дә булса эш башкара торган урын. *Табылдыкларны һәр квадраттан аерым-аерым өемнәр белән янәшәдә генә җиһазландырылган мәйданчыкта эшләүче лаборант кызларга илтеп тапшырабыз.* Ф.Хуҗин. *Көтүчеләргә малларны күзәтү өчен, күтәренке итеп такта түшәп ясалган мәйданчык иде ул элек.* Казан утлары

МӘЙЛӘ́Ү *ф.* Мәй эчү, мәй белән сыйлану. *Монда гел башка тамаша, Монда гел бүтән хәлләр: Мәйләүдән чәйләүгә күчкән Әҗәл белән Әлмәндәр.* Г.Морат. *Әгәр бу хәл дөрес булса, алар кабат аракы юллап, Фаизларның әбисендә мәйләп утырыр идемени?* Безнең гәҗит

Мәйләп алу Бераз, аз гына мәйләү. *[Кәбир:] Шаянрак тон белән: – Әйдә, чәйгә хәтле башта печтик кенә мәйләп алыйк әле, – диде.* Г.Бәширов. *Хәтта Бәширов кияве булса да, үзен бик гади тотты, студентлар белән чәйләп, мәйләп алудан да баш тартмады [М.Мәһдиев]*. Т.Галиуллин

Мәйләп тору Сөйләү моментында яки әледән-әле мәйләү

МӘЙМҮН I *и. гар. иск.* Маймыл. *Барча әгъзасы адәм шикелле, әмма мәймүн кебек бер койрыгы бар иде*. К.Насыйри. *Мәймүн булдың тәки*. З.Мәхмүди. *Китапны арткы ягыннан ачып, бабай пышылдап укый башлады: – Мәймүн елында Сараш баба туган...* Р.Батулла

МӘЙМҮН II *с. гар. иск*. Шат, бәхетле

МӘЙМҮНЛӘШҮ *ф*. Маймыллашу, маймылга әверелү. *Без үзебез дә мәймүнләшеп һәм роботлашып бетәрбез дә, тарих башлангыч ноктасына әйләнеп кайтыр микәнни?* А.Тимергалин

МӘЙТӘМ *кер. сүз. сөйл.* Мин әйтәм, дим. *Әллә, мәйтәм, хисап эшенә, сәүдәгә өйрәтсәк, дөресрәк булмасмы...* Р.Низамиев. *Табибларга, мәйтәм, барырсың, Байкап чыксаң тәхет тарихын ---*. Р.Идиятуллин. *Мәйтәм, айны да учлап тотар идең дә, буең кыскарак.* Н.Гыйматдинова

МӘЙХАНӘ *и. фар.* 1) Исерткеч эчемлекләр сатыла һәм кулланыла торган йорт. *Мәйханәләр вә кабаклар кимесә, үлем аз булыр иде вә авырусырхау аз булыр иде.* К.Насыйри. *Кич белән күрше мәйханәгә кереп, тиречеләр, итчеләр, извозчиклар, жуликлар белән катышам.* Г.Тукай. *Тамашачылар, кәефе кырылып, мәйханәгә киткәли башладылар.* Х.Туфан

2) *күч.* Ыгы-зыгы, шау-шу, буталыш. *Танышасың, өметләнәсең, әллә нинди мәйханәләр килеп чыга...* Г.Зәйнашева

◊ **Мәйханә килү** Ыгы-зыгы килү, буталу. *Тәрәзәгә тагын бер күләгә төшә: эчтә дә бер «милиционер» мәйханә килә, ахрысы...* З.Фәтхетдинов. *Заһит чүмәлә тарттыручы малайларның мәйханә килүләрен күзәтеп, абайламыйча да калган: кыз-кыркын, егет-җилкенчәк кибән тирәсенә җыелган икән.* М.Әмирханов. *Әйе, пәрдә ачылганга кадәр әле фойеда тамашачылар кырмыска урынына кайнаша, аларның бер ише буфет тирәсендә мәйханә килә.* Р.Низамиев

МӘК *и. рус бот.* 1) Мәкчәчәкләләр семьялыгыннан матур эре чәчәкле, эченә вак орлык тулган тартмачыклар формасында җимеш бирә торган үлән үсемлек. *Әлегә тюльпаннар белән янып торган кызыл чәчәкле вак мәкләрдән башкалары чәчәк атмаган, әмма чәчәк атканнары да күз явын алып, әллә каян ук балкып утыра.* Р.Вәлиева. *Мәк чәчәк атканда төсе-исе белән исертә, орлыгы өлгереп, күп ашасаң, орлыгы белән тилертә.* Г.Хөсәенов. *Мәк, кыяр, борчак һәм кайбер башка үсемлекләрнең җимешендә бер генә орлык түгел, ә бик күп орлык үсә.* Ботаника

2) Шул үсемлекнең орлыгы. *Өстенә мәк сибеп клиндер, булки пешергән [Фёдор Алексеевич].* Ш.Рәкыйпов

МӘКАЛӘ *и. гар.* Журналда, җыентыкта яки газетада фәнни яисә публицистик стильдә язылган кечерәк күләмле инша. *Мин беркатлылык белән аның үзен һәм иҗатын мактап мәкаләләр яздым, ә ул нәкъ киресен эшләде.* Г.Бәширов. *Шулай бервакытны «Яшь ленинчы»да бөтенләй көтмәгәндә минем бер кеп-кечкенә мәкалә, дөресрәге, гап-гади бер хәбәр басылды.* Н.Фәттах. *Мәкаләдә борынгы рун язмаларының башкорт язмалары булуы хәбәр ителгән иде.* Т.Миңнуллин

МӘКАЛЬ *и. гар.* Җәмгыять тарафыннан үз ителеп уртак кулланылышта йөргән кыска һәм тирән мәгънәле, гадәттә нәсыйхәт бирә торган калыплашкан тәгъбир, тапкыр сүз. *А.Яхин халык җырларын, табышмакларын, мәкальләрен һәм мәзәкләрен системалы тикшереп, татар фольклорының традицион жанрларына яңача карый алды.* Т.Галиуллин. *Шуның өстенә «Йөз сум акчаң булганчы, йөз дустың булсын» дигән мәкальне дә беләбез.* Т.Миңнуллин

МӘКА́ЛЬ-ӘЙТЕМ *җыйд. и.* Халык уйлап чыгарган тотрыклы гыйбарәләр. *Әтисе сүз мәгънәсен мәкаль-әйтемнәр белән тирәнәйтергә ярата иде.* С.Поварисов. *Алар [казахлар] мәкаль-әйтемнәрне катнаштырып сөйләргә яраталар.* Х.Миңнегулов. *Мин мәкаль-әйтемнәрне үткәннәрдән килгән телеграмма дип кабул итәм.* Ш.Галиев

МӘКАЛЬЛӘШҮ *ф.* Мәкаль булып кулланыла башлау. *Мәкальләшкән җөмләләр*

Мәкальләшеп бетү Тәмам мәкальгә әйләнү

Мәкальләшеп китү Мәкальгә әйләнү

МӘКАЛЬЧЕ *и.* Мәкальләр җыючы, шуларны өйрәнүче. *Н.Исәнбәт кебек мәкальчеләр һәр халыкта булмый да әле ул.* Казан утлары

МӘКАМ *и. гар. кит.* 1) Дәрәҗә, тоткан урын. *Бәс, шәех Хәбибулла әйтте: «Сезнең кебек түрәләрнең мәкаме бу түгелдер».* К.Насыйри. *Аңа [Ш.Галиевка] мөнбәр, шөһрәт, мәкам, дәрәҗәләр кирәк түгел.* Т.Галиуллин

2) Көйле тавыш, көйле тон. *– Исәнме, мәгърур Кояш! – диде ул [Сәетҗан бабай] тантаналы итеп, ниндидер бер моңлы мәкам белән.* Р.Фәизов. *Хәтеренә төште: «Мөхәммәдия» мәдрәсәсендә укыган чакта, коръәнхафиз мөгаллимнәре Вәли кари да Коръән сүрәләрен әнә шундый затлы мәкам белән, күңелеңне эретердәй итеп укый торган иде...* Р.Низамиев. *Сабыр мәкам белән изге китап Көен көйләр иде [әнкәй].* Х.Әюп

МӘКАМЛӘ́Ү *ф.* Мәкамгә салып, көйләп башкару. *Кыз Коръәнне дә тавышына әллә нинди бормалар сала-сала мәкамләп укый, ашап-эчеп алгач, остабикәләр үтенече буенча рәхәтләнеп җырлый да икән.* К.Тимбикова

МӘКӘ *и. бот.* Чатырчәчәклеләр семьялыгыннан вак кына ак чәчәкле күпьеллык үлән үсемлек; *русчасы:* **бедренец**

МӘКӘЙ *и. диал.* Ылыслы агачларның тәңкәчекләр белән капланган озынча формадагы орлык чәкәне (кәшәнкәсе). *Бу вакытта тиен, чыршы мәкәйләре уңмаган урыннан, шушы елда алар җитәрлек булган урынга күчә.* Хайваннар турында очерклар

МӘКЕР *и. гар.* Астыртын явызлык, астыртын усаллык; астыртын явыз эш яки уй. *Бу җиһанда бер кеше дә Йөрмәсен мәкер уйлап.* Н.Сафина. *--- Минем оҗмах – керсез җаннар өчен, Урын булмас анда мәкергә.* Н.Хисамов. *Юкса һәр кешедә кызыл кан ага, ә нигә мәкер кара була икән?* Р.Низамиев

МӘКЕРЛЕ *с.* 1) Эчкерле, астыртын усал, астыртын явыз (кеше). *Дошман никадәр генә мәкерле булмасын, нинди генә каршылыклар күрсәтмәсен, ул хәзер актык сулышын сулый, аның актык минутлары җитте.* Г.Бәширов

2) Мәкергә корылган (уй, ният һ.б.ш.). *Еракка төбәлгән бик мәкерле исәп иде бу.* Г.Әпсәләмов. *Хәйләкәр зат синнән яшерергә теләгән мәкерле уй-фикерләрен барыбер яшерәчәк.* А.Хәсәнов

МӘКЕРЛЕК *и.* Астыртынлык, астыртын усаллык, астыртын явызлык, эчкерлелек. *Мәгълүм булганча, зур сәясәткә мәкерлек тә, хыянәт тә, җинаять тә хас нәрсәләр ---.* Ә.Еники. *Ләлә һич мәкерлек көтмичә, кулларын җиң эченә тыгып, сабыр гына басып торган һаҗәрне йомшак кар көртенә кинәт этеп җибәрде дә үзе дә кар эченә ташланды.* Г.Әпсәләмов. *Комбат баш иде һәм, империализмның мәкерлеген үз күзләрең белән күреп кайт, алайса, дигәндәй, шәһәргә чыгарга рөхсәт кәгазе язып бирде.* Ш.Рәкыйпов

МӘКЕРЛЕ́К ИТҮ *ф.* Кемгә дә булса астыртын явызлык эшләү. *Шушы төп темага параллель рәвештә әсәрдә Булат белән Рәйханәнең мәхәббәте һәм алпавыт управляющие Аблайның арага кереп мәкерлек итүе бирелгән.* М.Җәлил

МӘКЕРЛЕЛӘНҮ *ф.* Мәкерле булып китү; эчкерлеләнү

Мәкерлеләнә башлау Мәкерлеләнүгә таба үзгәрү

Мәкерлеләнеп бетү Тәмам мәкерлеләнү

Мәкерлеләнеп китү Сизелерлек мәкерлеләнү

МӘКЕРЛЕЛЕК *и.* Мәкерле булу; эчкерлелек, астыртынлык. *Әле озак вакытлар ул [Тимерхан] Гайфулланың фажигале үлемен, японнарның мәкерлелеген оныта алмыйча, кара кайгыга калып йөрде.* Г.Ахунов. *Уземнең уйнавым белән кешеләрдәге мәкерлелекне, астыртынлыкны фаш итәргә тырыштым, кешеләрне уяу булырга өндәдем.* Ф.Ильская. *Мәкерлелек бетерә, һәлакәткә китерә.* К.Латыйп

МӘКЕРСЕЗ *с.* **1.** Чиста күңелле, яхшы ниятле, беркатлы, мәкер белмәгән. *Табигать хәйләләми, мәкерсез ул.* Х.Камалов. *Эдуард Мостафин – тумыштан моңлы шагыйрь, мәкерсез, күңеле бай, үзе фәкыйрь шәхес*. Р.Батулла

2. *рәв. мәгъ.* Мәкердән башка, хәйләләмичә. *Аяныч хәлендә дә Хәлил хәйлә һәм мәкерсез булдыра алмый*. Т.Галиуллин

МӘКИНӘ *и. рус сөйл.* Кибәк. *Тик кул сузып бер талпынсаң, буш хыяллар мәкинә кебек җилгә оча.* Р.Мулланурова. *Өлкәнрәкләр мәкинә чүмәлесе өстенә брезент җәеп утырды, яшьләр, көрәкләргә таянып, артка басты.* К.Кәримов

◊ **Мәкинә баш** *к.* **кибәк баш**. *Син, мәкинә баш, башыңа кибәк тутырылган, шул диварны аударышып йөрисең!* Р.Камал. *Нәрсә сез анда, мәкинә башлар, юлдан адашмаслык та акылыгыз калмадымы әллә?* М.Әмирханов

МӘККӘ БОДАЕ *и. бот*. Кукуруз, маис, Кәгъбә бодае, Мисыр бодае

МӘКЛӘ́Ү *ф*. Мәк катнаштыру, мәк салу, мәк сибү. *Камырны мәкләү*

МӘКЛЕ *с*. **1.** Мәк катнаштырылган, мәк салынган, мәк сибелгән. *– --- торт белән чикләвек пирогын һәм кош теле белән мәкле конфетны өйдә үзем генә пешерермен, – диде хатын ---*. Г.Мөхәммәтшин. *--- акмай яктым мәкле күмәч телеменә*. Г.Сәлим

2. Мәкер белән, хәйләләп. *– Юктыр, ал да гөл түгелдер, – ди, авызын мәкерле чалшайтып.* Ватаным Татарстан

МӘКРУҺ *с. гар.* **1.** Ярамаган, тыелган, дин тарафыннан хупланмый торган. *Мәкруһ гамәлләр: отыш уеннар уйнау, әдәпсез җырлар җырлау, кеше алдында, кунакта әдәпсез кылану; нәфескә бирелү ---*. И.Әмирханов. *Кайбер фикыһ китапларында күгәрчен асрау да мәкруһ, ягъни ярамаган эш булуы турында языла.* Татар мөселман календаре

2. *и. мәгъ.* 1) *дини* Харам дәрәҗәсендә катгый тыелмаса да, шәригатьтә эшләнүе хупланмаган, кабул ителмәгән, кире кагылган гамәл. *Ашыгу – шайтаннан, бәгъзе эшләрдә ашыгу мәкруһ булса да, җиткән кызны тапшыруда ашыгу – савап*. Г.Камал. *Берәүләре аны [музыканы] мәкруһ дисә (бу гамәлне эшләсәң, газап юк, тыелсаң – савап бар), икенчеләре мөбах ди (бу гамәлне эшләсәң, савап та, газап та юк).* Мәдәни җомга

2) XVIII–XIX гасырларда көчләп чукындырылганнан соң кабат мөселманлыкка кайткан татар, элекке керәшен. *Бу хәл Янгилде татарларының мөселман диненә кайтуын, мәкруһларның попны санга сукмавын күрсәтә иде.* Т.Вафин. *Мәкруһлар – көчләп чукындырылган һәм бөтен рәсми кәгазьләрдә урыс исемнәре астында йөргән саф мөселман татарларыбыз.* Казан утлары

МӘКТӘП *и. гар*. 1) Балаларга гомуми белем һәм тәрбия бирә торган уку йорты. *Мәктәптә укулар башланды, бу чынлап та көз җитте дигән хәбәр иде.* А.Гыйләҗев. *Мәктәптә җиде ел укып, аның бер генә мәртәбә дә кызлар белән җырлы уен уйнаганы булмагандыр*. М.Мәһдиев. *Бик беләсең килсә, мәктәптә укыганда да, шул сине яратканга, синнән калышмаска, сиңа ошарга теләгәнгә отличник булырга тырыштым бит мин!* В.Нуруллин

2) Шул оешма урнашкан бина. *Моннан өч ел элек мин сезне мәктәп ишегалдында күрдем*. Р.Юсупова. *Мәктәптән авылга алты чакрым чамасы ара.* Д.Гайнетдинова. *Теле кисеп алынган, чырык-чырык, чорны мактап, Чыпчыклар оя кора; Күзләре чокып алынган Карт кебек, мәктәп тора*. Р.Мингалим

3) Берәр белгечлек буенча махсус уку йорты. *Хәрби мәктәпне тәмамлагач, сержант Рой Гатауллин Сталинградны азат итүдә катнаша, зур батырлыклар кыла*. М.Әхмәтҗанов. *Россиядә исә иң беренче бию мәктәбе 1738 елда – ил белән патшабикә Анна Иоанновна идарә иткәндә оештырыла.* Р.Вәли

4) Уку-укыту учреждениеләре, уку-укыту системасы. *Нәрсәдер, татар мәктәпләрендә киңлек җитми, бөтендөнья әдәбияты күзлегеннән чыгып балаларны өйрәтү җитми*. Г.Бәширов

5) Тәжрибә туплау; тупланган тәҗрибә, алган белем. *Ул [Ж.Мостафин] – зур тормыш мәктәбен, авыр сынаулар үткән кеше.* Ә.Гаффар. *Үзләре исә монда барыбер колхоз эшендә катнаштылар һәм шулай күмәк тормыш мәктәбе уздылар булса кирәк.* Ә.Баян

6) Шундый тәжрибәне, шундый белемне бирә торган нәрсә. *Һәрбер чын язучы, нинди генә «мәктәп» узмасын, ахыр чиктә бары үзенчә, үзе аңлаганча иҗат итә*. Ә.Еники. *Мәскәү – мәктәп ул. Барган саен, нидер иярәп кайта, кешеләр белән күбрәк аралашкан саен, ничектер ачыла һәм «шомара» барасың.* Г.Бәширов. *Ә.Еники безнең прозада үзенә бертөрле мәктәп тудырды.* Ф.Хатипов

7) Нәрсәне дә булса өйрәнү, башкару һ.б.ш. өчен практик алымнар системасы; метод. *Алар [формаль методлар] арасында структураль метод (мәктәп) аерым урын алып тора.* Ә.Закирҗанов

8) Әдәбият, сәнгать, фән, иҗтимагый-сәяси фикер өлкәсендәге юнәлеш, агым. *И.Н.Березин, В.В.Радлов, А.Н.Самойлович мәктәпләрен узу аңа [С.Вахидига] тарихи истәлекләрне өйрәнүгә Европа ориенталистлары кулланган алдынгы гыйльми тикшерену*

методикасын үзләштерергә ярдәм итә. М.Госманов. *Бигрәк тә Көнбатыш Европада һәм Америкада сүз сәнгате өлкәсендә алып барылган һәм аеруча әдәби мәктәпләр, әдәби концепцияләр, әдәби методлар өлкәсендәге эзләнүләр әдәбият белеменең барлык тармаклары турындагы карашларыбызны киңәйтеп җибәрде.* Ә.Закиржанов

9) Ял итү белән бергә фәннең нинди дә булса өлкәсе актив өйрәнелә торган лагерь төре. *Хәзер татар балалары өчен җәйге мәктәп эшли.* Р.Батулла

МӘКТӘП-ГИМНА́ЗИЯ *җыйм.* Урта белем бирү йортлары. *Аның [А.Әхмәдуллинның] эшчәнлегенең киң бер тармагы мәктәп-гимназияләр өчен программалар һәм дәреслекләр төзү белән бәйле.* Ә.Закиржанов. *Бары хәзер генә кайбер мәктәп-гимназияләрдә, югары уку йортларында (филология һәм тарих бүлекләрендә) гарәп язуы өйрәтелә.* Татар халык педагогикасы

МӘКТӘПКӘ́ЧӘ *с.* Мәктәпкә кадәрге. *Безнең авылда мәктәпкәчә яшьтәге малайларны җиңүнең, куркыту, тәрбияләүнең иң куәтле чарасы «Масра бабай» иде...* М.Мәһдиев. *Милли тәрбия, милли үзаң һәм идентификация балага мәктәпкәчә яшендә бирелә башлый.* Р.Вәлиев. *Мәктәпкәчә яшьтәге чор 3 яшьтән 6 яшькә кадәр.* Биология

МӘКТӘП-МӘДРӘСӘ *җыйм.* 1) Дини уку йортлары. *Әмма бу уңай белән шунысын да искә төшерик: татарга, гәрчә ул дәүләткә коточкыч күп салымнар түләсә дә, балаларын укытыр, мәктәп-мәдрәсәләрен тотар өчен, хөкүмәт бер тиен дә акча бирми.* Х.Миңнегулов

2) Гомумән уку йортлары. *Әлбәттә, мәктәп-мәдрәсә һәм шәхси китапханәләр генә елдан-ел арта барган китап ташкынын сыйдыра алмый.* М.Галиев. *Балаңны, оныгыңны татар мәктәбендә укытсаң, үзеңнең мал-мөлкәтеңнән мохтаҗ кардәшеңә, ятим балаларга, картларга, мәктәп-мәдрәсәгә хәлеңчә өлеш чыгара белсәң, милли хәрәкәт шушы була инде.* Р.Вәлиев

МӘКТҮП *и. гар.* Хат, намә. *[Балтамар:] Менә мәктүб: «Кояш тирәсендә Жир әйләнә» дигән.* Ә.Баян. *[Тукай:] Нинди мәктүп икән ул? Шаять, кызлар хаты түгелдер, анысын мин сезгә күрсәттем.* А.Расих. *Әти әнә, патшага каршы мәктүп язарга да ярамый, ди.* Р.Мөхәммәдиев

МӘКЧӘ *и. бот.* Мәкчәчәкләләр семьялыгыннан басуларда, ачык сөзәкләкләрдә, юл буйларында үсә һәм сары, кызыл эре чәчәк ата торган үләнчел үсемлек; мәк үләне; *русчасы:* **мачок**. *Юл буенда үскән сары мәкчәләрне фотога төшереп алдым.* Сөембикә

МӘ́КЧӘЧӘКЛЕЛӘР *и. күпл. бот.* Икеөлешле үсемлекләр классыннан үлән, куак, тәбәнәк агачлар һәм аларны берләштергән семьялык. *Канлут, сәрдәнә – мәкчәчәкләләр семьялыгыннан.* Биология

МӘКЪБҮЛ *с. гар.* 1) Кабул ителгән. *Алла Тәгалә хәзрәтеннән дога мәкъбүл була торган урыннарда вә мәхсус вакытларда сәне сорадым.* Г.Камал

2) Хуш күрелгән, охшаган, яхшы табылган

МӘЛ *а. гар. сөйл.* 1) Чак, вакыт. *Сихерли дә куя бакчалары – Кызык та соң шушы көз мәле.* Х.Әюп. *Кырык икедә, шомырт чәчәк аткан гүзәл мәлдә, госпитальдән ялга дип аларның бердәнбер уллары кайтып төште.* А.Гыйләҗев

2) Момент, мизгел. *Сөю назларында үзгәреп, хис-тойгылары үткенләнгән мәлдә, хатын-кызлар йөрәк астында яңа җан яралуын сиземлиләр, диләр.* М.Кәбиров. *Сәет ишеккә якынрак килгән мәлдә, Зөлфия кискен нотага күчте.* Т.Галиуллин. *Нәкъ шушы мәлдә тәкъдирең гомер дисбесенең тагын бер төймәсен артка таба шудырып куяр.* М.Галиев

МӘЛӘК *и. гар. кит.* 1) Фәрештә. *Ул [күк алласы] киң күген үзенә биек сарай итте, --- Вәзирләре – фәрештәләр, мәләкләргә Яшәр өчен мәңгелеккә уңгай итте.* М.Җәлил. *Әллә исмең гали, җисмең бер нур – Хакның җиргә иңгән мәләге.* М.Фәйзи

2) *шигъ.* Чибәр кыз, сөйгән яр. *Ярлыка, мәүлам, мине, мин инде көнче күбәләк, Ибне адәмме түзәр, җирдә әгәр күрсә мәләк?!* Г.Тукай. *Мең мәләк – мең җен миңа, син бер мәләгем булмагач.* М.Җәлил

МӘЛГУНЬ *с. гар.* **1.** 1) Ләгънәтләнгән, каһәрләнгән. *Юк, ул ялгыз түгел иде: аһ, мәлгунь күрше бүлмә...* Ш.Камал. *Һай, бу муены астына килгере мәлгунь Гитлер дөньяны ничек болгатты.* Г.Әпсәләмов

2) Теңкәгә тигән һәм ачу китерә торган. *Канатларыбыз каерылган, сынган, үзем сугыш кырларында корычкургаш бураннарында йөргән чакта, туган якларга мәлгунь дошман кергән.* Ә.Гадел. *– Ике кулсыз, ике аяксыз иттте, мәлгунь карчык! – дип, хәсрәтләнепкөрсенеп сүз башлады.* Р.Мулланурова. *Килеп җитә йөгереп теге мәлгунь җәен.* Кызыклар дөньясында

2. *и. мәгъ.*1) *дини* Ләгънәтләнгән, Аллаһның рәхмәтеннән читтә калдырылган кеше һ.б.ш. *Эченә Иблис мәлгунь кереп оялаган диярсең.* Г.Гыйльманов

2) Начар, юньсез, нәфрәт ителгән кеше. *Көннәрнең берендә әлеге шул мәлгунь белән бәйләнешкән [Флора].* З.Фәтхетдинов

3) Зур ризасызлыкны белдерә торган ачулану, тиргәү, сукрану сүзе. *[Хәнәфи агай:] Аягы нишләгәнен онытты-мыни, мәлгунь?* Ж.Мостафин. *Тешләрен кысып: «Туктa, мәлгунь, килер бер көн, без дә сиңа кем икәнлегебезне күрсәтербез», – дип әйтә торган булган [Алиш].* Р.Мостафин. *Ә ул, ава-түнә, абына-сөртенә барып, бөтен көчләрен суыра, мәлгунь.* З.Фәйзи

МӘЛГУНЬЛЕК *и.* Мәлгунь кешегә хас сыйфатлар; мәлгунь булу. *Мәлгуньлек беркемне дә бизәми*

МӘЛЕМ *и. иск.* **1.** 1) *к.* **манул**

2) Шул хайванның күреге

2. *с. мәгъ.* Шул хайванның күрегеннән тегелгән. *Мәлем тун*

МӘЛҖЕРӘТҮ *ф.* 1) Җебетү, йомшарту

2) Хәлсезләндерү, әлсерәтү. *Саф, салкынча һава, тиз-тиз йөреп керү аның аракы мәлҗерәткән тәнен җиңеләйтте, ул барган уңайга елбыр чәчләрен тарады, ак күлмәгенең бүселгән итәкләрен сыерып чалбарына тутырды...* А.Гыйләҗев. *Бу әңгәмә мине тәмам мәлҗерәттe, дулкынланулымнан очкылык тота башладым.* М.Әмирханов

Мәлҗерәтә башлау Мәлҗерәтергә тотыну

Мәлҗерәтеп җибәрү Кинәт мәлҗерәтү. *Майда чыжылдап утырган ит кисәкләренең тәмле исе мине тәмам мәлҗерәтеп җибәрде, башым әйләнеп китте.* Г.Галиев

МӘЛҖЕРӘ́Ү *ф.* 1) Артык куркып, аптырап, югалып калу. – *Шул Әмиржанымны авылда иң юаш, иң мәлҗерәгән кеше иттеләр, – дип, чынаякларын җыештыра башлады Сәхәрия.* М.Хуҗин. *Тотарсың айгырны! Яз көне түгел, мәлҗерәгәнне кыш көне дә каплап кына калдыра ул.* Ә.Галиев

2) Төрле сәбәпләр аркасында бик хәлсезләнү, әлсерәү, буыннарны тота алмас хәлгә килү. *Ул иректән шул агачка борылып карады һәм тәне эсселе-суыклы булып, бер мәлгә җаны мәлҗерәп, күзләре шар ачылып, сургылт йөзенә үлем агы йөгерде, чөнки каенның таза ботагына аларның моннан бер атна элек югалган чая разведчиклары --- асылган иде.* Р.Сибат

Мәлҗерәп калу Ниндидер тәэсирдән соң мәлҗерәгән хәлгә килү. *Мәлҗерәп калганнарны өнәмәде, өнәми [Рәхимулла].* Б.Камалов. *Әмма мәлҗерәп калырга, сер сынатырга ярамый иде.* Д.Гайнетдинова

Мәлҗерәп тору Мәлҗерәгән хәл кичерү, шундый хәлдә булу. *Мәлҗерәп торуларын бер читкә куеп, таныклыгын кош тоткан кебек эләктерә дә мәктәбенә йөгерә: – Үзгәртегез минем фамилиямне!* Т.Нәҗмиев

Мәлҗерәп төшү Тәмам мәлҗерәгән хәлгә килү. *Байтирәк бу турыда башына да китермәгән иде, кинәт аптырауга калды, ләкин карчыгы каршында болай чарасыз мәлҗерәп төшүгә күнекмәгән акылы хәйләне тиз тапты ---.* М.Галиев. – *Мәлҗерәп төшмәс өчен! – Әсфәндияр күңелле көлеп җибәрде дә тирмәгә кереп китте.* Б.Рафиков

Мәлҗерәп утыру Озак вакыт дәвамында мәлҗерәү. – *Иртәгә эштә мәлҗерәп утырырмын микән инде... – Нинди иртәгә? Бүген, диген!* Л.Лерон

Мәлҗери башлау Мәлҗерәү билгеләре күренү

МӘЛҖЕРӘЮ *ф. к.* **мәлҗерәү**

Мәлҗерәя бару Торган саен ныграк мәлҗерәю. *Ә Мисбах ашыкмый. Хәзер инде ул эчми, йотып-йотып кына куя һәм күзгә күренеп мәлҗерәя бара.* Н.Әхмәдиев

Мәлҗерәя башлау Мәлҗерәү билгеләре сизелү

Мәлҗерәеп тору Мәлҗерәйгән хәлдә булу

МӘЛҖЕРЕК *с.* 1) Мәлҗерәгән, хәлсезләнгән. *Төнлә исерек, көндез мәлҗерек.* Әйтем. – *Син ул – мин, мин ул – син, – дип пышылдады аның ни әйткәнен үзләре дә аңламаган кайнар, мәлҗерек иреннәре.* Л.Лерон. *Аңзиһенен җыя алмый җәфаланган малайның күңеле һаман әле өн белән төш арасында бәргәләнеп йөри, ахры, Сәүбән торгызып утыртканчы, ул шул мәлҗерек хәлендә калды.* Г.Гыйльманов

2) Салынкы, сүрән. *Яратам шундый көзге мәлҗерек көннәрне.* Р.Зәйдулла

МӘЛҖҮ *ф. к.* **мәлҗерәү**. *Мәлҗеп озаграк та утырган икән, хәерсез.* Ә.Еники. *[Ибраһимов:] Сәламәт булсагыз, ник саклану турында уйланмыйсыз, ваемсыз гына, «дөрес, өстемә алам» дип, мәлҗегән мокыттай мыгырдап утырасыз?* М.Насыйбуллин. *Яшәү түгел бу! Йокымсырау. Мәлҗү. Мәмрәү. Гарьлек. Дөньяны шулай матурлап буламы?* С.Поварисов

Мәлҗеп җитү Тәмам мәлҗү. *Ахры, мәлҗеп җиткәнмен: Кинәт йоклап киткәнмен.* Н.Мадъяров

Мәлҗеп калу Ниндидер вакыйгадан соң мәлҗү. *Шулай да колхоздан «Семеновод» совхозына күчү уе белән йөргәнгә бик үк мәлҗеп калмады.* Х.Камалов

Мәлҗеп төшү Тәмам мәлҗү. *Ничек инде мин алкаш булыйм, Минһаҗ туган, ди, алкаш бит ул илле грамм эчүгә үк мәлҗеп төшә, ә мин әле бүген дә, Алланың биргәненә шөкер, үзең күреп торасың, ди.* Т.Миңнуллин. *Егетнең күңеле болганды, болай да тотрыгын югалткан буыннары мәлҗеп төште.* Т.Галиуллин. *Шуннан соң кайберәүләр өйләренә кайтып китте, кемнәрдер чирәм өстенә авып гырлый башлады, ә мәлҗеп төшмәгәннәр – яшьрәкләр – Фәтхулның үнәрләрен карарга кереште.* М.Шаһимәрдәнов

Мәлҗи башлау Мәлҗү билгеләре сизелү

МӘЛИК *и. гар.* Патша, хөкемдар, ил башы. *Бервакыт [Йосыф] Мисыр мәлиге-патшасы була.* С.Поварисов. *Язма чыганакларга караганда, Болгар һәм Казан идарәчеләрен мәлик, солтан, әмир, падишаһ дип атаганнар.* Г.Мөгътәсимова. *Башлаган һәрбер эшен җиренә җиткереп үтәүне үзенә гадәт итеп алган Сәлахетдин кыска вакыт эчендә югары мәртәбәләргә ия була һәм мәлик титулын ала.* Инсан һәм дин

МӘЛИКӘ *и. гар.* Хатын-кыз патша. *Саба мәликәсе Бәлкыйс*

МӘЛЛӘ *кис. сөйл. к.* **әллә**

МӘЛЛЕ *рәв. диал.* Соңга калмыйча, вакытында, нәкъ моментына. *Мәлле килеп җитү*

МӘЛСЕЗ *рәв.* Вакытсыз, вакыты җитмичә. *Мәлсез чәчәк яралмас.* Мәкаль

МӘМӘЙ *и. к.* **мәми**. – *Яле, кызым, тор әле. Менә нинди мәмәй алып кайттым үзеңә, – диде ул, аның битеннән үбеп, чәченнән сыйпый-сыйпый.* Р.Вәлиева. --- *Зөһрә әби кәҗәсен саварга баскычтан төшеп килә икән: бер кулында литрлы банка, бер кулында кәҗәсенә «мәмәй» (ул үзе шулай ди) – ике телем ипи.* Р.Сибат. *Уен кызык бәбәйгә, Кирәк ләкин мәмәй дә.* Н.Әхмәдиев

◊ **Мәмәй авыз** *кимс. к.* **мәми авыз**. *Шакиржәны мәмәй авыз булды.* С.Поварисов. *Һәркемнең дә үз үлчәве була: Явызларны таный явызлар, Изгелекне гаеп итеп сөйли Кайчагында мәмәй авызлар.* В.Галиев. *Гомеремдә әйтерсең кызлар чырае күрмәгән бер мәмәй авыз, боламык.* Н.Әхмәдиев

МӘМӘЧ *и. диал.* Агач кайрысы астындагы сыекча, су

МӘМИ *и.* **1.** 1) Балалар телендә яки шаяртып әйткәндә күчтәнәч, тәмле азык; гомумән ашамлык. *Хафиз улым, әтиең сиңа тәмле мәмиләр җибәргән.* Г.Галиева. *Бала бит конфет булмаганда аны уйлап та карамый, ә инде матур кәгазьгә төрелгән конфет күрсә, тәкатьсезләнеп, әти-әнисеннән шул мәмине сорый.* Ф.Яруллин. *Әйтерсең лә карынында этләр улый, Галиҗәнап бертуктаусыз мәми сорый.* Г.Афзал

2) *күч. кимс.* Булдыксыз, җебегән, пешмәгән кешегә карата. *Мәми булмаса, ирен тартып алмаслар иде!* Ә.Хәсәнов. *Ә син, күрше, җебегән, мәми!* Х.Ибраһим

2. *с. мәгъ.* Җебегән, пешмәгән. *Мин дә элекке Васия түгел, син белгән мәми Васия түгел.* М.Хуҗин

◊ **Мәми авыз** Җебегән, булдыксыз кеше. *Ул чор балалары хәзергеләр шикелле мәми авыз түгелләр һәм ике йөз илле-өч йөз илле сум хезмәт хакы өчен әти-әниләренең таңнан төнгәчә бил бөккәннәрен күреп үсәләр* ---. Р.Мирхәйдәров. *Чура морза Апай угланны мәми авызга чыгарды.* М.Әмирханов. *Мәми авыз булма син.* Р.Батулла. **Мәми авызлану** Булдыксызлану, оеп тору. *Мин шәһәрдә туып үскән булсам, синең шикелле мәми авызланып йөрмәс идем.* Р.Вәлиев. **Мәми авызлык** Булдыксызлык

МӘМИЛӘНҮ *ф. сөйл.* 1) Булдыксызлану; кыюлыгы җитмәү. *Сөйләшергә яратса да, арзанлы юморны кабул итеп, мәмиләнеп, изрәп төшә торганнардан түгел икән Лениза туташ.* Т.Галиуллин. *Әптерахман да пионер, Ләкин куркак куян бер: Кеше белән мәмиләнеп, Борынын тартып сөйләшә...* М.Җәлил

2) Капризлану

Мәмиләнә башлау Мәмиләнергә тотыну

Мәмиләнеп бетү Тәмам мәмиләнү

МӘМИЛЕК *и. кимс.* Булдыксызлык, кыюсызлык. *Минем пешмәгәнлек, мәмилек инде бу!!!* Я. Гарипова-Абдрәхимова

МӘМЛӘКӘТ *и. гар.* Ил, дәүләт. *Тетри җирләр, мәмләкәтләр!* Н.Арсланов. *Төркия – зур мәмләкәт, аның мин күрергә теләгән төбәкләре бик күп.* Т.Әйди. *Заманында бөек Тукаебез «хөр мәмләкәт, хөр Русия» дип язган.* Х.Миңнегулов

МӘМЛҮК *и. гар.* 1) *иск.* Кол. *Мәмлүк язмышы*

2) Урта гасырлардагы Мисырда төрки (кыпчак) һәм кавказ чыгышлы кол егетләрдән торган хәрби сословие һәм шул сословиеның бер вәкиле. *VII гасырда аны (Сурияне) – гарәпләр, XVII–XVIII гасырларда бер өлешен – тәре йөртүчеләр, алардан соң Мисыр мәмлүкләре басып ала.* М.Мәһдиев. *Мисалга, Мисыр тәхетенә төрки гаскәриләр – мәмлүкләр ия булган 1250–1547 елларда шәһәрләрдә бик күп архитектура һәйкәлләре корылуына ничек игътибар итмисең, ди?* Т.Әйди. *Мәмлүкләр династиясе Гарәбстанда 300 ел дәвамында хакимлек итә.* Мәдәни җомга

МӘММӘМ *и. сөйл.* Балалар телендә яки балаларга һәм балалар турында сөйләгәндә «ризык, ашамлык» дигәнне аңлата. *Бәби белән бәпкә, шул рәвешчә, Берен бере «авыз иткәчтен», Нәтиҗәгә килә икесе дә: «Син бит мәммәм түгел икәнсең».* Х.Туфан. *Башкалар шикелле үк тәпи-тәпи атлап китте, теле ачылды, әннә-әттә, диде, мәммәм, диде, курчак уйнады һәм башкалар, һәм башкалар.* Т.Миңнуллин. *Чатыр эчендә баланың тәпиен тотты, киемнәрен алыштырды, аннан соң аны җылыга – куенына алды, мәммәм бирде.* Н.Фәттах

МӘМНҮН *хәб. гар.* Канәгать, риза. *Үзе үк башлап: – Ә, Салих туган! – дип дәште. – Уеныгыздан бик мәмнүн булдык, рәхмәт сезгә!..* Ә.Еники. *Акчура җаваптан бигүк мәмнүн түгел иде булса кирәк.* Р.Мөхәммәдиев. *Бу сүзләре белән артист дусларын да, тамашачыларны да мәмнүн итте [Сәйдәш].* Р.Низамиев

МӘМРӘ́Ү *ф.* 1) Йомшарганчы, бик нык пешү, өлгерү. *Ачык урыннарда, аулак кашлакларда мәмрәп кызарып, чыпчык башы-чыпчык башы каен җиләкләре озатып калдылар.* А.Гыйләҗев. *Газдал иттән курка иде, ул «ит ашыйсы килми» дип, фарфор чәйнек кадәр тәмам мәмрәгән бер помидорны алды.* Ф.Садриев. *Эчтәге агачларда чиясе дә калган, бисмилла әйтеп, берике чия дә капты: мәмрәгән, баллы, авызда эриләр.* Р.Кәрами

2) *күч.* Йомшару, хәлсезләнү. *Сөякләре мәмрәп, гәүдәсен талгын бер көчсезлек биләгәч кенә, судан чыкты [Идрис].* А.Гыйләҗев

3) *күч.* Югалып калу, йомшаклык күрсәтү. *Дөрес, халык бу очракта да мәмрәп югалып калмый; ярлы тәкәббер, горур икәнлеген дә онытмый.* С.Поварисов. *Сабый балалардай мәмрәп, кайгысыз һәм канәгать бер кыяфәттә ашарга китерүләрен көтеп утыра иде.* Н.Фәттах

Мәмрәп тору Тәмам мәмрәгән хәлдә булу. *Җәй буена без аның урманында мәмрәп торган җиләкле аланнарыннан чыга алмыйбыз* ---. Ф.Җамалетдинова. *Аның да бүртмәч авызы бер якка мәмрәп тора.* М.Галиев. *Әгәр син тагын мәмрәп торсаң, мин аны алып кереп, менә хәзер шушында күз алдыңда турап бәям.* Ф.Садриев

Мәмрәп төшү Тәмам мәмрәү. *Үзенең тышкы кыяфәтенә күз карашларыннан, сыгылып торган билләрдән, тирбәлеп-дулкынланып торган күкрәкләрдән әллә нинди вәгъдәләр сизгәндә дә эреп-мәмрәп төшмәде ул.* А.Гыйләҗев

МӘН I *и. гар. иск.* Берәү; зат, шәхес, кеше. *– «Сөбханалла» диеп әйтү тиеш, – диде, – Бер мән яңа гына туган айны күрсә.* Г.Тукай. *Бер мән төшендә үзенең министр яки губернатор булганын күрсә, гомере кыска булгай.* Ш.Мөхәммәдев

МӘН II *и. гар. сөйл.* 1) Мәгънә, рәт, җай. *Күңелемнең көрлеге, Дөньямның мәне син.* Г.Латыйп. *Өй котламый калмабыз, анысына гына мәнебез җитәр.* А.Гыйләҗев. *Бир, Тәңрем, безгә саум, Мантыр борынгы кавем, Кайтыр таралган зиһен, Мән-мәгънә иңгән саен.* Җ.Сөләйман

2) Мәгънәлелек; мәгънә, акыл, затлылык. --- *Ми киштәңә кунмый калмас иде, шаять, Мәсләгеңә мән салырлык Бер хакыйкать.* Ж.Сөләйман. *Ниндидер эчке мән, эчке гамь-сагыш бәреп чыккан иде аның йөзенә.* Г.Гыйльманов. *Бер мән калмады дөньясында.* Т.Галиуллин

МӘН III *и. гар. дини* Тәүратта һәм Коръәндә хәбәр ителгәнчә: чүлдә йөргән яһүдиләргә күктән индерелгән ашамлык; кодрәт хәлвәсе

МӘНДИ *и.* Татар халык мәзәкләрендә очрый торган персонаж; үзенең наданлыгы, үтә беркатлылыгы белән танылган мәзәк герое

◊ **Мәнди анасы да белә** «Һәркем белә, һәркемгә билгеле» мәгънәсендә.

Моны инде Мәнди анасы да белә. Х.Камалов. *Мылтыксыз сугышып булмаганны Мәнди анасы да белә бит!* Г.Бәширов

МӘНЗИЛ *и. гар. иск.* 1) Сәфәр вакытында ял итәр өчен туктый торган урын, тукталыш. *Хәтта кайбер мәнзилләрдә аның сораган нәрсәсене башкача аңгарып, алып килгән нәрсәсене кабул итмәвеҗдән аз гына гауга чыкмады.* Г.Тукай

2) Шундый ике тукталыш арасы; күчем, мәрхәлә

МӘНЗУМ *с. гар. иск.* Тезмә, тезмәле, үлчәүле; көйле. *[«Мин үләм» дигән шигырендәге] юллар, шөбһәсез, шигырь мәнзумгә мисал булырлыклардандыр.* Г.Ибраһимов

МӘНЗУМӘ *и. гар. иск. к.* **назым**. *«Әсәр шигырь түгел, бәлки нәзым вә мәнзумә генә, һәм безгә шигырь белән нәзымны аерырга күптән вакыт инде» дип яза Ибраһимов: «нәзым вә мәнзумә» сүзләрен «көйле проза», ягъни «такмак» мәгънәсендә куллана булса кирәк.* Р.Батулла

МӘНИ *и. гар.* Ир-атларның һәм ата хайваннарның җенес бизләреннән бүленеп чыга торган җенес күзәнәкле орлык сыекчасы; сперма. *Әйдәгез, карыйк, адәми затны яралдыру Коръәндә болай язылган: иң башта хатын-кызның нәсел орлыгы (фаллопий көпшәсендә) ир кешенең мәние белән аталана да сидек юлы буенча агып китә, шуңа күрә ул «затсыз, чирканыч».* Р.Батулла. *Серкә инфекцион гепатитны, мәни бизен дәвалауда да кулланыла.* Татар балы. *--- Ир хатынын яки бер хатын-кыз ирен үбеп, ир кешедән мәни килсә, хатын-кызда исә юешләнү беленсә, боларның уразалары бозылыр.* Инсан һәм дин

МӘНЛЕ *с.* Мән (II) белә торган; тәртипле, рәтле. *--- Әсмабикә әйтә: «Хәмидә ул – бик булган, бик мәнле кеше, Алла боерса, кеше арасында битебезгә оят китермәс әле», – ди.* Г.Камал. *Әйбәт, мәнле егет, кичә сугышка китәр алдыннан кереп саубуллашып чыкты.* С.Сабиров. *Мәнле ул авыл кешесе!* Р.Мулланурова

МӘНЛЕЛЕК *и.* Кеше характерына хас булган мәнле булу, мән (II) белү сыйфаты. *Мәнлелек дигән нәрсәне белә-мени ул?* И.Нуруллин. *Намус, мәнлелек, затлылык буенча да Раиса Тимофеевага тиңнәр булмады...* Туганайлар

МӘНСЕЗ *с. сөйл.* Мәгънәсез, юньсез, мән (II), мәгънә белми торган. *Рабига да, йодрыкларын төйнәп, моңа җикеренде: – Мәнсез! Тагын кошлар каргышын кая куярсың?!* Г.Бәширов. *Андый мәнсез сүзне әни әйтергә тиеш түгел иде.* С.Сабиров. *Без – бәгырьсез, мәнсез бер халыкмы, Ким халыкмы кимсетелсәк тә?* Ә.Синугыл-Куганаклы

МӘНСЕЗЛЕК *и.* Төптән уйлап эш итмәүчәнлек, җиңел караш, мәгънәсезлек. *Малайлар һәр заманда да шул берүк малайлар инде: мәнсезлек тә, шуклык та, ызгыш та, рәнҗеш тә җитәрлек булган.* Ә.Еники. *Я, нинди гайре табигый хәл соң бу?! Нинди мәнсезлек?!* А.Тимергалин. *Битарафлыктан – мәнсезлеккә, мәнсезлектән – миһербансызлыкка, миһербансызлыктан бәхетсезлеккә берәр адым гына лабаса.* Э.Шәрифуллина

МӘНФӘГАТЬ *и. гар.* Берәүнең файдасы, ихтыяҗы, теләгенә туры килә торган, җавап бирә торган һәрнәрсә. *Шул кичтә крестьян Шәяхмәт, ак җәймә өстенә утырып, гомере буе халык мәнфәгате өчен көрәшергә, бу юлда актык тамчы канын кызганмаска ант итте.* М.Мәһдиев. *Шулай затлы төшенчәләр пәрдәсенә Төренүчән аның иң вак мәнфәгате.* Н.Хисамов. *Вак үпкә, шәхси мәнфәгать Ватан мәнфәгатеннән өстен булса, ил мөстәкыйльлек яулый алмый.* Н.Гамбәр

МӘНФӘГАТЬЧЕЛЕК *и.* Үзен генә кайгырту гадәте. *Хөсетлек, көнчелек, вак мәнфәгатьчелектән өстен торыйк!* Татар милләт календаре. *Чәчәктән аның җимешенә хас сыйфатлар дәгъва итү – мәнфәгатьчелек, ягъни сәнгать әсәренә файда-зыян позициясеннән карау.* Шәһри Казан

МӘҢГЕ *рәв.* 1) Һәрвакыт, берөзлексез, һаман, чиксез. *Ул да мәңге яшәмәс, үләр бит, үлгәч, аны ничек күмәрләр?* Г.Галиев. *Борынгы һәм мәңге яшь шигърият турында, жанр буларак аның асыл сыйфатлары турында нинди-дидер яңа сүз әйтү, ихтимал, мөмкин дә түгелдер.* Р.Фәйзуллин

2) Һич тә, беркайчан. *Мәңге сүнмәс безнең мондый дуслык. Мәңге бетмәс бөек туганлык.* Ә.Исхак. *Тел дәрьясының аргы ярына берәүнең дә мәңге җитә алмаячагын белгән нәүмизлек иңне баса.* М.Галиев. *Манарага айны беркеткәндә, якташларының өмет белән күккә баккан утлы карашын шагыйрь мәңге онытмас.* Р.Вәлиев

3) Бик күптән, күптәннән, озак вакыт, күп еллар буена. *Мин сине мәңге беләм кебек.* Н.Баян. *Чиратлашып мәңге алмашына Кышкы көртләр, җәйге чәчәкләр.* И.Сабиров

4) Гомергә, гомер буена, бөтенләйгә. *Авыл кызыгы белән генә рухланып, анда мәңге торып кала да алмыйм.* М.Фәйзи. *Илдар, серне мәңге саклау турында әйтеп, дәфтәр битенә ант язды һәм кул куйды.* Г.Гобәй

МӘҢГЕГӘ *рәв.* Гомергә, һәрвакытка. *[Янчурин:] Мин сезнең каршыда мәңгегә бурычлы булып калам.* Ф.Садриев. *Дәһшәтле сугыш күренешләрен хәтерендә яңарта, мәңгегә ятып калган полкташларын искә төшерә [Михаил Максимыч].* Ш.Рәкыйпов. *Җаны, бөтен барлыгы чагылган төсмерләрне гүя мәңгегә хәтерендә сеңдереп калырга тели.* Н.Хәсәнов

◊ **Мәңгегә күз йому** Үлү. *Ә аңарчы гомерлек юлдашы, сөекле хатыны Әлфирә, өч улын әтисенә калдырып, мәңгегә күзләрен йома.* Р.Камал. *Нинаять, Габдрахман бабай мәңгегә күзен йомды.* Я.Шәфыйков

МӘҢГЕЛӘШТЕРҮ *ф.* Гомергә онытылмаслык итү, киләчәк буыннар өчен истәлек итү. *Казан Кремлендә башкалабызның 1000 еллык юбилеена әзерлек көннәрендә ачылган мәһабәт мәчет олуг шәхесебезнең исемен мәңгеләштерде, аны бүгенге яшәешебезнең аерылмас өлешенә әверелдерде.* Ф.Хуҗин. *Кавказ халыкларын патша Русиясенә каршы азатлык көрәшенә күтәргән имам Шамил үз исемен мәңгеләштерде.* Р.Батулла. *Күренекле җәмәгать эшлеклесе, мәгърифәтче, педагог Сөләйман Колчак улы яшәгән урамга исемен биреп, йортына*

мемориаль такта куеп, авыл халкы, киң җәмәгатьчелек аның исемен мәңгеләштерде. Яңарыш

Мәңгеләштерә башлау Мәңгеләштерү эшенә керешү. *Җәлилчеләрнең исемнәрен мәңгеләштерә башласак кына да, унлап урамга исем кушарга кирәк.* З.Мәхмүди

Мәңгеләштереп кую Мәңгеләштерү эшен башкарып чыгу. *Минин, байрак тукымасына үзенең һәм дүрт көрәштәшенең исемен язып, мәңгеләштереп куя.* Я.Шәфыйков

Мәңгеләштереп йөрү Билгеле бер вакыт дәвамында мәңгеләштерү эше белән мәшгуль булу. *Бу арада Гариф абый бабасының исемен мәңгеләштереп йөри әле.* Казан утлары

МӘҢГЕЛӘШҮ *ф.* Тарихка керү, мәңгегә халык хәтерендә калу. *Оста салган йорт шикелле көннән-көн кирпечләп күтәрелде, көннән-көн бәхетле минутларның мәңгеләшүен якынайта иде ул.* Ж.Дәрзаман. *Аның исеме тарихта мәңгеләшергә тиеш дип уйлыйм.* Р.Батулла

Мәңгеләшеп китү Әкренләп мәңгеләшү

Мәңгеләшә башлау Мәңгеләшүгә табан бару

Мәңгеләшеп калу Мәңгеләшергә өлгерү. *--- бу якларга Уразайлар, Чурай, Сорнай исемнәре ияләре белән бергә килделәрме икән, мәңгелеккә киткәннәрнең исемнәре шулай, чишмәсуларга тотынып, мәңгеләшеп калдылармы икән?* Т.Нәҗмиев

МӘҢГЕЛЕК *и.* **1.** 1) Бер дә тәмамланмый торган, башы да, ахыры да булмаган вакыт агышы. *Бу көн дә бәхетле, бу көн дә мәңгелек булып тоелды...* Р.Мөхәммәдиев. *Аңла син шуны: без үләчәкбез, юкка чыгачакбыз, мәңгелек белән чагыштырганда безнең проектларның гомере – бер мизгел!* М.Маликова

2) *дини* Вакытка бәйле булмау, вакыттан тыш яши алу, вакытка бәйле рәвештә үзгәрмәүчәнлек хәле. *Изгелек мәңгелек, бакый кыйммәт дәрәҗәсенә күтәрелә.* Д.Заһидуллина

2. *с. мәгъ.* 1) Күптәннән булган, күптәнге, әллә кайчангы. *Бу ярлы өйнең һавасында ук ниндидер бер авыр сагышлы моң – мәңгелек моң йөзә кебек иде.* Ә.Еники

2) Беркайчан да бетми торган, гомерлек. *– Баегач, мәңгелек итеп, тоташ бетоннан коярбыз буаны, – диде ул [Җиһангир] аларга карап.* А.Гыйләҗев. *Баррикадалардан килә торган Азатлыкның төсе – мәңгелек!* Р.Низамиев. *Инде терелеп аякка басса, мәңгелек сабак булыр, яңадан урлашмас, диделәр.* Ф.Яруллин

◊ **Мәңгелек йокыга талу** Үлү. *Берәү мәңгелек йокыга тала, икенчесенә яшәү килә.* Ф.Садриев

МӘҢГЕЛЕККӘ *рәв. к.* **мәңгегә**. *Инде менә бергә булдык, без кавыштык, язмышларны мәңгелеккә бергә куштык.* Ф.Яруллин. *Күп тә үтми, мәңгелеккә дөнья яктысын күрүдән мәхрүм кала.* Т.Биктимерова. *Беребез дә мәңгелеккә килмәгән.* Д.Салихов

МӘҢГЕЯШЕЛ *с. бот.* Кышынҗәен үсүеннән туктамый, яфрак коймый торган. *Азалия – мәңгеяшел куак.* Ботаника

МӘРАСИМ *и. гар.* Нинди дә булса чара, йола һ.б.ш.ларның рәсмиләшкән, гадәттә тантаналы итеп уздыру тәртибе. *Монда янә бер мәртәбә олылау мәрасиме булды.* Ш.Мостафин. *Мәрасим вакытында «тәне бик йомшак, тагын мәет булмагае» дип шомланучылар да күп булды.* Ф.Садриев. *Иң әүвәл Г.Тукайның бакыйлыкка күчкән көнендә Казанның Яңа Татар бистәсе зиратында хәтер яңарту мәрасиме булды.* Мәдәни җомга

МӘРӘ *и.* 1) *и.* Берәр нинди уен өчен өлеккә, җиргә һ.б.ш. сызыла торган әйләнә. *[Хажи], көлемсерәп, ике имән бармагы белән ашъяулык өстендә алга таба ярым түгәрәк мәрә сызды.* Ш.Камал

2) *к.* **мәрәй**. *Тезелешеп яткан укчыларның барысы да атып бетергәч, команда бирелгәч кенә, кар ерып, мәрәләргә таба атладылар.* Р.Кәрами. *Газапланмыйча, озак тинтерәмичә үләсең килсә, коралыңа иң яхшы мәрә – чигә.* Т.Әйди

◊ **Мәрәгә тию** *к.* **мәрәйгә тию**. *С.Күруглы да, бүтәннәр дә «сорау алу» барышын, бигрәк тә җавапларымның мәрәгә төгәл тиюен тыштан тыныч, эчтән исә кәефләнеп күзәтеп утырдылар.* Т.Әйди

МӘРӘЙ *и.* 1) Мишень. *Инһаять, сине гел мәрәй итүче снайперлары, айнымас офицерлары, карак, наркоман, мародёр, гаскәригә караганда күбрәк бандитка охшаган яллы солдат-контрактчылары белән Чечен иле артта калды.* И.Сиражи

2) Төрле уеннар өчен гадәттә җирдә ясала торган әйләнә яисә батынкы урын

3) Уен мәйданы, уен түгәрәге. *Ныклап карап баксак, бу сүз татар телендә дә бар ич: татарча мәрә, мәрәү яки мәрәй – «аткы; ату мәйданы (гомумән, уен мәйданы, уен түгәрәге)», мәрәләү, мәрәүләү – «аткыны төзәгәндәге шикелле әкрен, сак һәм җентекләп эшләү яки хәрәкәт итү».* Р.Әхмәтьянов

◊ **Мәрәйгә тию** Максатка ирешү

МӘРӘКӘ *и. гар.* **1.** Уен-көлке, шаяру; күңел ачу тамашасы. *Беренче хезмәт хакы алганчы савылып эшкә йөриләр, акча кулга кергәч, башлана мәрәкә!..* А.Гыйләҗев. *Искәндәрнең үтә җитди кыяфәте үзе бер мәрәкә иде.* М.Кәбиров

2. *с. мәгъ.* Кызык, көлке уята торган. *Кара әле, бик кызык, бик мәрәкә икән бу кыз-кыркын халкы!* А.Хәлим

МӘРӘКӘЧЕ *и.* Шамакай, комедиант

МӘРВӘР *и. фар. к.* **мәрвәрит**

МӘРВӘ́Р АГАЧЫ *и. бот. к.* **мәржән агачы**. *Безнең якларда аны мәрвәр агачы дип йөртәләр.* Сөембикә

МӘРВӘРИТ *и. фар.* 1) Энҗе бөртеге

2) *к.* **мәрвәрит чәчәге**. *Мәрвәрит чәчәк аткан*

МӘРВӘРИ́Т ЧӘЧӘГЕ *и. бот.* Оешмачәчәклеләр семьялыгыннан ак, кызыл, ал чәчәк ата торган бер яки күпьеллык үсемлек; *русчасы*: **маргаритка**

МӘРГӘН *и.* 1) Төз атучы. *Кулы озын – мәргән булыр.* Мәкаль. *– Ишләреңнән каласың ич инде, мәргән, – диде кыз, кайгыртучанлык күрсәтеп.* М.Хәбибуллин. *Ел саен була торган бу ауны бәкләр, мәргәннәр, сунарчылар көтәләр иде.* Т.Нәбиуллин

2) *неол.* Снайпер

МӘРГӘНЛЕК *и.* Мәргән булу. *Тапкырлык, тәвәккәллек, елгырлык, мәргәнлек, ир-егетне чын ир иткән гайрәтле ау сынавы сугыш сәнгатен өйрәнү өчен хәтәр уен алымы булган.* М.Галиев. *Кинәт пәйда булган һәм мәргәнлек белән уңышка ирешкән дошманнар үзләре дә төзәтеп булмаслык хата эшләп ташлыйлар.* Т.Галиуллин

МӘРҖӘН *и. гар.* 1) *зоол.* Эчәкуышлылар тибыннан диңгездә хәрәкәтсез төркемнәр булып укмашып яши торган диңгез хайваны. *Шундый бер балыкчык мәрҗәннәр тирәсендә йөзеп йөрде.* Диңгез тирәнлегендә

2) Әлеге хайваннарның скелетын эшкәртеп бизәнү әйбере буларак кулланыла торган ачык кызыл яки алсу, ак һ.б. төстәге таш. *Күзләре бриллиант, мәрҗән, зөбәрҗәт, гранат, ахак кебек бик күп төрле ташлардан ясалган.* Р.Сәгъди. *Безнең әниләр заманында башта аршын ярымлы ак калфак иде, өстә үзләре эшләгән күлмәк иде, камзуллары бөтенләй көмеш тәңкә, мәрҗән белән каелып беткән иде, ул читек-кәвешнең исеме дә юк иде.* Г.Исхакый. *Иң төп эш – су төбеннән энҗе һәм мәрҗән җыю, аларны эшкәртү...* И.Хуҗин

3) Шул таштан, шулай ук башка нинди дә булса материалдан ясалган, гадәттә йомры вак бөртекләрдән тезелгән, муенга тагыла торган бизәнү әйбере, муенса. *Өстәл өсләрендә ак мәрҗәннәр, Алып бәйлә, бәгърем, муеныңа.* Җыр. *Ап-ак энҗем, ал мәрҗәнем – Каралтмамын һичберсен дә.* Л.Шагыйрьҗан

МӘРҖӘ́Н АГАЧЫ *и. бот. диал.* Зелпечәләр семьялыгыннан яшькелт сары чәчәк атып, миләшкә охшаш кызыл җимеш бирә торган декоратив куак үсемлек; мәрвәр агачы; *русчасы*: **бузина красная**. *Җимеш бакчасына аяк бастырырга ярамаган мәрҗән агачы да каралтыларга якынрак рәшәткә буенда рәхәтләнеп үсеп утыра иде.* Ә.Еники

МӘРҖӘНЛЕ *с.* Мәрҗәне булган; мәрҗән белән бизәлгән. *Кызыл мәрҗәнле ак муенына Чап-чал сакал чар булган...* Р.Харис. *Мин бу мәрҗәнле калфакны әбием истәлеге итеп саклыйм.* Сөембикә. *Кара күлмәге өстеннән мәрҗәнле яка киеп сәхнәгә чыккач, бөтенләй икенче кешегә әйләнә Әлфия.* Мәйдан

МӘРКӘЗ *и. гар. кит.* **1.** 1) Нәрсәнең дә булса уртасы, үзәге. *Шәһәрнең мәркәзе Манхэттен утравына салынган йөз-йөз ун катлы йортлардан тора.* Р.Батулла

2) Административ идарә үзәге; башкала. *Мәркәз белән бәйләнеш юлын нинди генә бәһа белән булса да сакларга карар бирелгән.* Ш.Усманов. *Мәркәзебезнең кыл уртасында – «Татарстан» кунакханәсендә торган чагыбыз.* Т.Нәҗмиев. *И мәркәзем, халкым тажы – Казан! Якты синең Ирек мәйданың!* С.Гәрәева

3) Берәр эшчәнлек төре белән шөгыльләнә торган оешма, учреждение; шуның бинасы. *Без мәдәният мәркәзендә Исхакыйга багышланган күргәзмәдә очрашкан идек.* Р.Батулла

4) *күч.* Нинди дә булса өлкәдә әһәмиятле урын, шуның үзәге. *Безнең малай чактагы уеннарыбызның мәркәзе Чүлмәк тау да элеккеге соклангыч кыяфәтеннән бөтенләй мәхрүм калган.* Г.Тавлин. *Ә безнең төп мәркәзебез барыбер Бауман урамындагы 19 нчы йорт булды.* Р.Әхмәтҗанов. *Казан – гыйлем мәркәзе.* Р.Мөхәммәдиев

2. *с. мәгъ.* Нәрсәнең дә булса уртасы, үзәге булган. *Аннары Мәскәү, Петербург, Киев кебек мәркәз шәһәрләргә китеп эшләүчеләр, шулай ук зур сәүдә алып баручылар да аз булмаган.* Ә.Еники. *Көннәрен эшләп арып кайткан халык күңелен ача, Кичләрен мәркәз урамнар шат халык берлән таша...* Г.Сөнгати

МӘРКӘЗЛӘШТЕРҮ *ф. кит.* Үзәкләштерү; берләштерү. *[«Тирән тамырлар»ның] сюжеты катлаулы һәм композициясе бер ноктага җыю, мәркәзләштерү нигезендә төзелгән.* Г.Нигъмәти

Мәркәзләштерә башлау Мәркәзләштерергә керешү

Мәркәзләштереп бетерү Барысын да мәркәзләштерү; тулысынча мәркәзләштерү

МӘРКӘЗЛӘШҮ *ф. кит.* Үзәкләшү

Мәркәзләшә башлау Мәркәзләшү билгеләре күренү

Мәркәзләшеп бетү Тәмам мәркәзләшү

МӘРМӘР *и. гар.* **1.** Скульптура һәм архитектурада кулланыла торган матур бизәкле каты тау токымы. *Юк, баскычлары ак мәрмәр икән, баскыч култыксалары да салкын мәрмәр, әменә стеналар, идән, түшәм елкылдап торган сары такта белән тышланган, алтын белән капланган диярсең.* Ф.Бәйрәмова. *Затлы мәрмәрдән эшләнгән киң баскыч буйлап икенче катка күтәрелде Мирсәет һәм ишек шакыды.* Р.Мөхәммәдиев. *Чыннан да, Илдус сүзендә торды: берничә көннән татар зираты янындагы мастерскойга төшеп, мәрмәр кисәкләре кушып, цементтан кабер ташы койдырырга теләге барлыгын белдерде.* Ә.Сафиуллин

2. *с. мәгъ.* 1) Шундый таштан эшләнгән. *Сөйли иде безгә [Рөстәм] төрле хәлләр: Яуда алышканын, Солдат булып киләчәккә мәрмәр Сарай салышканын.* Н.Арсланов. *Моңа кадәр мәрмәр сындай хәрәкәтсез утырган кызның сыңар керфеге селкенеп куйды.* Ф.Яруллин

2) *күч.* Төсе, катылыгы яки башка берәр сыйфаты белән шул ташка охшаган. *Җәйнең кояшлы иртәсендә күл уртасына йөзеп кергән яшь аккош шулай бер мәлгә туктап кала: мәрмәр муенын көяз генә бөгеп, су өстенә карый, үзенең күләгәсенә соклана.* М.Мәһдиев. *Юк, шалкан яки мәрмәр тәнле иркә бикәч түгел ул!* А.Тимергалин

МӘРМӘРЛӘ́Ү *ф.* Махсус буяулар ярдәмендә берәр өслеккә мәрмәрнең табигый бизәкләренә охшаган бизәкләр төшерү

МӘРМӘРЧЕ *и. махс.* 1) Мәрмәр эшкәртү остасы. *Бу мәрмәрче Казан өчен милли китапханә проектын ясаган иде.* Б.Тимерова

2) Мәрмәрләү сәнгатенең остасы

МӘРСИН *и. гр.* 1) *зоол.* Мәрсинчәләр семьялыгыннан кара уылдык бирә торган кыйммәтле балык; **осётр**. *Аларны [суалчаннарны] укбаш һәм мәрсин кебек кыйммәтле балыклар бик ратып ашый башладылар һәм бик әйбәт үсеп киттеләр.* Кызыклар дөньясында. *Мәрсин балыгына мәрсин гипофизын*

керткәч, уылдыкның берничә ай урынына тәүлек ярым вакыт эчендә өлгерүе билгеле була. Кызыклы ихтиология

2) *бот. к.* **мирт**

МӘРСИН АГАЧЫ *и. к.* **мәрсин** (*2 мәгъ.*)

МӘРСИ́НСЫМАННАР *и. күпл. зоол.* Ганоид балыклар төркеменә караган төньяк ярымшарда төче суларда яшәүче балыклар отряды

МӘРСИЯ *и. гар. әд.* Үлгән кешеләргә багышлап, аларның яхшы сыйфатларын күрсәтеп язылган элегик әсәр. *Шушы кыска гына вакыт эчендә остазы-укытучысы Яруллин «Тукай хатирәсе» дигән мәрсия җырын да язып өлгерткән икән.* Р.Низамиев. *Багышламалар рус әдәбиятында XVIII гасырда рус классицизмы вакытында ук күзәтелә, ә татар әдәбиятында багышламалар, мәдхия һәм мәрсия формасында булып, XIX гасырда күпләп языла башлый.* Ф.Хәсәнова. *XIX гасырның икенче яртысында яшәгән Габделвәли исемле кеше үзенең хатыны Хәбибә бәнат Әхмәдулла үлгәч язган мәрсиясен нәкъ менә Утыз Имәни мәрсияләре формасында һәм калыбында иҗат иткән.* Казан утлары

МӘРТ *и. фар.* Тышкы тәэсирләргә бернинди реакция булмау һәм тулы хәрәкәтсезлек белән характерлана торган йокыга охшаш авыру хәл; летаргия. *--- Тирән мәрттән уятырлык, сүнгәнне дә тергезерлек, үлгәнне дә торгызырлык – Бөек бер Хәбәр кирәк...* Л.Шагыйрьҗан. *Мәрт йокысы белән йоклаган картын Фатыйма карчык килеп карап китте, үрелеп, колагын куеп, аның тын-сулышын тыңлап торды*. Г.Гыйльманов. *Ул [Нагаев] мәрттән уянгандай башын чайкап куйды*. Р.Зәйдулла

◊ **Мәрткә китү** Берни күрмәсә-ишетмәс дәрәҗәдә онытылу. *[Печән базарында] --- хуҗасыз этләр, карак мәчеләр, иреннәрен салындырып мәрткә киткән ябык, җигүле атлар...* А.Расих. *Сыерлар да муеннарын сузып, күзләрен йомып, авызларындагы ризыкларын күшәргә онытып мәрткә китеп торалар...* А.Гыйләҗев

МӘРТӘБӘ *и. гар.* 1) Дәрәҗә, исем, абруй. *Безнең ханнар шигъри телдә хәтта Ак бүрегә сәлам юллаган! Шушы йола чордан чорга китеп Мәртәбәгә чөйгән Ил данын...* Ф.Гыйззәтуллина. *Әмма Туфан беркайчан да көндәшләрен терсәк белән төртеп өскә күтәрелмәде; ул бары тик үз михнәте, үз сәләте аркасында мәртәбәләргә иреште ---*. Т.Нәҗмиев

2) Кемнең яки нәрсәнең дә булса хәле, халәтенең интенсивлыгы; хәл, дәрәҗә. *Милләтнең, милли рухның җилгә аумас, суга батмас, утка янмас мәртәбәдә куәт алуы һәм дә мәдәни бер калыпта корычка әйләнүе өчен, ул үзенең сәнаигы нәфисәсенә мохтаҗ.* М.Вәлиев

3) Кат, тапкыр, кәррә, дәфга. *Тимерхан Борһанов, байтак еллар узгач, ул түтине кызганып, аларга тагын бер мәртәбә барды.* Г.Ахунов. *--- Бусагага күтәрелгәнче, тупылның җыерчыклы каралҗым кәүсәсен яктыртып торган сыерчык оясына тагын бер мәртәбә күз салды [Сабирулла].* З.Хөснияр

◊ **Мәртәбәгә күтәрү** Зурлау, олылау. *Дистә еллар эшләгәч, ниһаять, безне дә мәртәбәгә күтәрделәр.* И.Нуруллин. **Мәртәбәгә менү** Югары дәрәҗәгә ирешү. **Мәртәбә иясе** Абруйлы кеше, бик хөрмәт ителә торган кеше. *Канәгатьле бул. --- җиһанда олуг мәртәбә иясе булырсың*. К.Насыйри

МӘРТӘБӘЛЕ *с.* 1) Дәрәҗәле, хөрмәткә лаек, абруйлы. *Түгәрәк табынның түре булмас, кайда утырса да, һәркем үзен мәртәбәле итеп саный ала.* М.Галиев. *Каршысында көтүдәге иң мәртәбәле, иң хөрмәтле айгыр торуына да кармастан, кола тай үзенең кыерсытучысына ташланды.* Ж.Мостафин. *Хуҗаның ризалыгын алганнан соң, мәртәбәле кунаклар биһуш булдылар*. Р.Низамиев

2) Мәртәбә китерә торган. *Туфан Миңнуллин җитәкчелек иткән чорда, «халык шагыйре», «халык язучысы» дигән мәртәбәле исем булдырылды.* Р.Фәйзуллин. *Әдипләрнең хыялын җилкетерлек мәртәбәле бәя – Тукай бүләге*. Н.Хисамов. *Мәртәбәле бүләк алу уңаеннан, аны хөрмәтләү әдәбият бәйрәме программасына махсус рәвештә кертелгән иде.* Казан утлары

3) Рухи яктан бөек, югары, гали. *Әйе, без укучыны китаптан аермаска тырышабыз. Бу – безнең мәртәбәле һәм изге бурычыбыз.* Х.Әюпов. *Әлбәттә, аныкы гына түгел, шушы мәртәбәле җыенга килгән һәрбер кешене милли хис һәм тойгы чорнап алган була*. И.Таһиров

МӘРХӘБА *ы. гар.* «Хуш килдегез» мәгънәсендәге сәламләү сүзе. *Һа, мәрхәба, дустым, рәхим итсеннәр!* Г.Ильяси. *– Мәрхәба, изге ният белән килгәнсез икән, – ди хәлфә торып*. Ә.Еники

МӘРХӘЛӘ *и. гар.* 1) Бер көн эчендә туктамыйча үтелә торган юл арасы, бер көнлек юл, күчем

2) Юлчылар туктый торган урын. *Юл буендагы мәрхәлә*

МӘРХӘМӘТ *и. гар*. Кемнең дә булса хәсрәтенә, начар хәленә карата кичерелгән кызгану, аяу хисе, шәфкать. *Мәхәббәт ул, беләсегез килсә, мәрхәмәттән башлана.* М.Маликова. *Мәрхәмәтебез белән без Булыйк мәһабәтрәк.* Ф.Яруллин. *Калын кашлары кушылып үскән тулы битле көньяк баласы – беркатлы бәндә – һаман боларга ышана, мәрхәмәт яки теләктәшлек көтеп, сорауларына дөрес җавап бирер тора.* Р.Кәрами

МӘРХӘМӘ́Т ИТҮ *ф.* Кызгану, аяу; ярдәм кулы сузу, мәрхәмәтле булу. *И каләм, безгә һәрдаим ярдәм һәм мәрхәмәт ит.* Г.Тукай. *[Гыйсмәт:] Зинһар, Мөршидәм, мәрхәмәт ит!* М.Фәйзи

МӘРХӘМӘ́Т КЫЛУ *ф. к.* **мәрхәмәт итү**. *Халкыңны күр, хәленә кер, Мәрхәмәт кыл, суз кулың.* Р.Вәлиева

МӘРХӘМӘТЛЕ *с.* Шәфкатьле, кызганучан, мәрхәмәт иткән. *Тузмас иде [йөрәк], бер-беребезгә Булсак мәрхәмәтлерәк.* Ф.Яруллин. *Әмма шунысын яхшы белә [Гайнан]: язмыш аңа бик үк мәрхәмәтле булмаган.* М.Насыйбуллин

МӘРХӘМӘТЛЕК *и. ялг. к.* **мәрхәмәт**. *Тормыш аңа иң риясыз, гөнаһсыз ягы белән борылган, мәрхәмәтлек күрсәтеп, ничә ел төшкә кереп изалаган иң гүзәл кочагын ачып елмайган кебек тоелды.* Ә.Гаффар. *Әллә соң без, уенчык фигуралар гына булгач, уйнаучы тарихтан мәрхәмәтлек сорап,*

аклар һәм каралар уенын уен башланганчы ук һәрвакыт ничьяга төгәлләвен үтеникме? Т.Миңнуллин. – *Тор, сөйлә, улым, ни булды, ни кирәк? – диде ул, ниһаять, улаһи бер мәрхәмәтлек белән.* Н.Фәттах

МӘРХӘМӘТЛЕЛӘНҮ *ф.* Шәфкатьле, мәрхәмәтле булып китү, йомшак күңеллеләнү

Мәрхәмәтлеләнә башлау Мәрхәмәтлегә әйләнү

МӘРХӘМӘТЛЕЛЕК *и.* Мәрхәмәтле кешегә хас сыйфатлар. *Төркем башлыгының мәрхәмәтлелеге хәтта беразга авыруын да оныттырган.* Ф.Яруллин. *Ханның бу мәрхәмәтлелеге бик ошады, төрле яктан канәгать авазлар яңгырады: – Авызыңа бал да май, хан!* М.Әмирханов. – *Миңа калса, мондагы диварлардан да шәфкатьлелек, мәрхәмәтлелек бөркелеп тора, – диде ул хастаханәнең баш табибына.* Р.Мирхәйдәров

МӘРХӘМӘТСЕЗ *с.* **1**. 1) Кызганмый торган, аяусыз, шәфкатьсез, каты холыклы, кансыз (кеше тур.). *Төп хикмәт шунда: халыкны кыруда мәрхәмәтсез, рәхимсез булсалар да, мондый бәндәләр үз җинаятьләре өчен җавап бирер вакыт җиткәч дер калтырыйлар.* Ф.Баттал. *Мәрхәмәтсез булгандыр шул: әти аны гел рәнҗеп искә ала иде.* А.Гыйләҗев

2) Шундый характерны яки шундый тойгыны белдерә торган. *Мәрхәмәтсез күзләр*

3) Түзә алмаслык авыр. *Иң яманы: мәрхәмәтсез сугышның һаман дәвам итүе иде әле.* М.Хәсәнов

4) *күч.* Рәхимсез, яман, куркыныч. *Бүген буран, суык, мәрхәмәтсез буран...* Ә.Еники. *Бигрәк мәрхәмәтсез шул картлык дигәннәре.* А.Әхмәтгалиева. *Алга таба да шулай дәвам итсә, солдатларның йөрер рәте калмаячак, мәрхәмәтсез гөмбәчек чире полкны аяктан егачак иде.* Ф.Латыйфи

2. *рәв. мәгъ.* Җәлләмичә, аяусыз рәвештә

3. *и. мәгъ.* Рәхимсез кеше. *Бу мәрхәмәтсез белән бәйләнеп, кайсыбызның артыгын хезмәт итәсе килсен.* Р.Кәрами

МӘРХӘМӘТСЕЗЛЕК *и.* Рәхимсезлек, шәфкатьсезлек. *Мәрхәмәтсезлек, шәфкатьсезлекне дә кичерде [Бибинур].* А.Гыйләҗев

МӘРХҮМ *и. гар.* **1.** Үлгән кеше (гадәттә, ир-ат). *Әткәй мәрхүм капка төбенә бер чыкты, ике чыкты, өйдә читтән кайткан кунаклар да бар, ул да түзмәде, «барып кайт, улым» диде бу.* А.Гыйләҗев

2. *хәб. мәгъ.* Үлгән булу. *Әти-әни – мәрхүмнәр.* В.Нуриев

МӘРХҮМӘ *и.* Үлгән хатын-кыз. *Әнисе, мәрхүмә, газиз баласы белән соңгы тапкыр күрешүен сизенде, ахрысы, күзләреннән кан-яшь агызып, тыела алмыйча, сулыгып-сулыгып елап калган иде.* М.Хәсәнов. *Мәрхүмә 25 ел буена Гайсәсеннән килгән акчаны яңа өй салырга җыеп барган икән.* Р.Шәфигуллин. *Шатлык, нур бөркелеп тора, биллаһи! Мәрхүмә әнкәй шулай дия торган иде.* Ш.Рәкыйпов

МӘСӘЛ *и. гар.* Хайваннар, кошлар яки җансыз предметлар турында сөйләп, читләтеп әйтүгә, кинаягә корылган һәм гадәттә үгет-нәсыйхәт белән тәмамлана торган кыска шигъри хикәя. *Безнең кебек гади халыкның моңарчы үз тавышы юк иде. Үз шатлыгыбыз һәм кайгыбызны башкалар уйлап чыгарган мәсәлләрдә, җырларда һәм догаларда гына белдерә ала идек.* Ж.Ильясов. *Шулай да, Мирза бишьюллыкларының, гәрчә кинаясе булса да, мәсәл жанры белән уртаклыгы шул бер «әхлак» өлешендә генә.* Казан утлары

МӘ́СӘЛӘН *кер. сүз. гар.* Җөмләдә берәр сүзне, тезисны аңлатканда, нәрсәне дә булса санаганда «мисал итеп», «мисал өчен», «мисалга алсак» дигән мәгънәдә кулланыла. *Мәсәлән, Руми: «Сез үлчәнешле дөньяга карыйсыз, ләкин сез бернинди үлчәү булмаган урыннан килгәнсез», – ди.* А.Тимергалин. – *Кайсы яктан карыйсың бит! – дип куйды Ансар. – Мин, мәсәлән, Мозаффарның картинасын җырлый алмыйм...* М.Маликова. *Безнең якларда, мәсәлән, өлкән агалар, башлы-күзле булуга, тизрәк башка чыгып китү җаен карый.* Г.Морат

МӘСӘЛЧЕ *и.* Мәсәл язучы; мәсәл сөйләүче. *Юл уңаенда шуны да искәртәсе килә: нәкъ менә Җаек чорында Тукай бөек мәсәлче Крыловның бик күп әсәрен тезмә белән тәрҗемә итә.* Т.Галиуллин. *С.В.Михалков күренекле балалар шагыйре генә түгел, ул – мәсәлче дә, драматург та, киносценарист та, педагог та, җәмәгать эшлеклесе дә.* Р.Миңнуллин. *Сугыштан соң Әхмәт Исхак юмор-сатира остасы, мәсәлче һәм тәрҗемәче буларак танылу ала.* Казан утлары

МӘСЕХ *и. гар.* Тәһарәт алганда, чылатылган кул белән башны һәм читекне сыпыру хәрәкәте. *Тубыктан югары тишек булса яки бөтенләй балтырсыз читек булса зарар юк, мәсех дөрес булыр, мәсехнең мөтдәте мокыймга бер тәүлек, мөсафирга өч тәүлектер.* Ислам – татарлар һәм мөселманнар

◊ **Мәсех тарту** Мәсех кылу

МӘСЕ́Х ИТҮ *ф.* **мәсех кылу**

МӘСЕ́Х КЫЛУ *ф.* Тәһарәт алганда, чылатылган кул белән башны һәм читекне сыпыру. *Кәҗүл читеккә мәсех кыласың.* Г.Исхакый. *Муенны су белән чылатып алуны да мәсех кылуга кертеп була.* Ватаным Татарстан

МӘСҖЕД *и. гар. кит.* Мәчет. *Хәзерге көндә укыту тарафында булганнар яңа мәсҗед салырга вә мәктәп бинасына рөхсәт алдылар, бәлки, тиздән мәкъсудларына ирешерләр...* Г.Камал. – *Аннан ары мәсҗед алдына китереп суктыралар; мулла абзый үзе суктыра, – диделәр.* Г.Исхакый

МӘСИХ *с. гар.* 1) Сыйпалган, сыпырылган, өстенә май сөртелгән

2) Гайсә галәйһиссәламгә бирелгән исемнәрнең берсе. *Әйтелгәнне төгәлрәк аңлату максаты белән Мәсих нәсыйхәтләреннән бер өзек китерик.* Р.Сафин. *Шул ук вакытта Мәсих (г.с.) – Аллаһның улаһи чагылышларыннан насыйбын алган олуг пәйгамбәр.* Мәңгелек нур

МӘСЛӘК *и. гар.* Принцип, максат; тоткан юл, юнәлеш. *[Каюм:] --- Һич әүлиялык сатмыйм, мәсләгем шул: эчмәү, тартмау һәм башка начарлыклар кылмау.* Г.Исхакый. *Хәерле булсын, дидем, бу – минем мәсләгемә каршы*

килү килүен, тик хуҗаның сүзенә риза булмый ярамый. А.Расих. *Мәслә кләре белән адашканнар – Юлларында буран я кардыр.* Ә.Халитов

МӘСЛӘКЛЕ *с.* Билгеле рухи кыйбласы булган; бер идеягә, принципка ышанган, шуңа таянып яшәгән, шуңа тугры булган. *Тукай үзе исә Беренче рус революциясе елларында Россиядә тарихи мәйданга чыккан күп санлы һәм капма-каршы мәслә кле партияләргә карашын тынычрак итеп белдерә...* Р.Фәтхрахманов. *Югары мәслә кле, төпле әзерлекле галим буларак, Г. Әхмәров типтәр сүзенең килеп чыгышын иҗтимагый-тарихи факт буларак эзләргә кирәклеген абайлый.* Фән һәм тел

МӘСЛӘКСЕЗ *с.* Билгеле бер рухи кыйбласы, ышанган идеясе булмаган, принципсыз, аумакай. *Әгәр язучы аны объектив күзәтче булып, шул ялангач килеш гәүдәләндерсә, әсәрнең идея юнәлешен билгели торган үз фикерен чагылдырмаса, бу идеясез, мәслә ксез әсәр була.* М.Җәлил. *Эшлексез, буынсыз, мәслә ксез, зиһенсез бер адәм иде [Җан Гали хан].* Р.Батулла

МӘСЛӘКТӘШ *и.* Карашы, максаты башка берәү белән уртак булган кеше. *Ул [Суфия] бит Гафурның сеңлесе генә түгел, сердәше һәм мәслә ктәше дә.* А.Расих. *1918 елны акларның үлем эшелонынан качып котылган Ф.Бурнаш мәслә ктәшләре кулыннан ычкына алмый: 1940 елны нахакка гаепләнеп, 1942 елны атып үтерелә.* М.Вәлиев. *Аның [хезмәтнең] аерым бүлекләре белән санаулы гына кешеләр – язмыш уртаклыгы якынайткан мәслә ктәшләр таныш.* Р.Мөхәммәдиев

МӘСЛИХӘТ *и. гар.* **1.** Киңәш. *Кешенең күплеге эшкә ярар, мәслихәткә ярамас.* Мәкаль. *Ни булса да булсын, мин Сәйдәш бабайга гәзитәсенә дәһри, динсез, хәтта мөртәт дигән сүзләрне язарга ашыкмаска мәслихәт бирәм.* Г.Тукай. *Без бер иптәшем белән китәргә дә үйлашкан идек, ләкин өченче – карт иптәшебез мәслихәт бирмәде.* Ш.Камал

2. *с. мәгъ.* Акылга сыярлык, урынлы, кабул итәрлек. *Нәселгә ят, чит затларны кертү дә мәслихәт гамәлләрдән түгел.* А.Хәсәнов. *– Мин, – диде ул, иреннәрен чүп-чүп китереп, – хәрби мәнфәгатьләргә акча арттыруны ифрат та мәслихәт эш дип саныйм.* М.Әмирханов

3. *хәб. функ.* Яхшы дип табу, урынлы дип санау, хуплау турында. *Шулай да хәрәкәтләнү мәслихәт, сөйләшү җиңеләйтми Нәгыймнең күңелен.* З.Хәким

◊ **Мәслихәт җыелышы** *к.* **мәслихәт мәҗлесе**. *Мыек Шәмсетдин үзе кузгалган икән, бу инде килде-китте утырыш кына түгел, зур мәслихәт җыелышы булырга охшый.* Г.Бәширов. **Мәслихәт күрү** Яхшы дип табу, хуп күрү, нәрсә турында булса да килешү. *[Ибраһим:] Кеше язганны укуны гына мәслихәт күрәм.* Ф.Садриев. *Г.Ибраһимов әсәрен каршылыклар төвене рәвешендә төзүне мәслихәт күргән.* Ф.Хатипов. **Мәслихәт мәҗлесе** *иск. кит.* Киңәшмә. **Мәслихәт табу** *к.* **мәслихәт күрү**. *Әмма күпчелек укучы психологиясе аларны югары бәяләми. Ул ачык, төзек сюжетны мәслихәт таба.* Ф.Хатипов

МӘСЛИХӘ́Т БУЛУ *ф.* Яхшы булу, уңышлы булу, урынлы булу. *Тик аны китәр көнегез алдыннан гына, күрше-күләнгә бик сиздермичә башкару мәслихәтрәк булыр.* Г.Галиева. *Аларга хәерле юл теләп, ачкычны кайсы күршедә калдыру мәслихәт булуын аңлатып, ишеккә юнәлдем.* Р.Юсупова

МӘСЛИХӘ́Т ИТҮ *ф.* Киңәш итү. *Ялкауга мәслихәт итсәң, Дөнья хәтле эш өйрәтер.* Мәкаль

МӘСЛИХӘ́Т КЫЛУ *ф. к.* **мәслихәт итү**

МӘСЛИХӘТЛӘШҮ *ф.* Киңәшү, киңәшләшү, уртага салып сөйләшү. *Әфганлылар хакында алар [Рәхимулла белән Айрат] икесе дә ирексездән телгә алдылар, югыйсә бер сүз дә сөйләшмәскә мәслихәтләшкән килешүләре дә бар аларның күңелендә.* Б.Камалов. *Мунча вакыйгасын ишеткәч, Хөршит абыстай белән мәслихәтләштек тә гармун алырга булдык.* Н.Әхмәдиев

Мәслихәтләшеп алу Тиз арада мәслихәтләшү. *Идарә утырышына куйганчы үзара аңлашып, мәслихәтләшеп алырга кирәк иде.* А.Гыйләҗев

Мәслихәтләшеп тору Даими мәслихәтләшү

МӘСЛИХӘТЛЕ *с. кит.* Киңәшле, киңәшеп эшләнгән. *Мәслихәтле эш төпле булыр.* Мәкаль. *Мәскәү Кремле ягыннан җылы җилләр исте һәм миллионнарча кешеләрнең бинихая мөһим мәнфәгатьләренә җавап бирүче мәслихәтле милли проектлар турында хәбәр җиткерде.* Татарстан яшьләре

МӘСЛИХӘТЧЕ *и. иск.* Киңәшче, киңәш бирүче. *Көннәрдән бер көнне ни сәбәптәндер Оракул саташкан: бер мәслихәтче килсә, яңлыш мәслихәт бирә, икенче берсенә ап-ачык ялганлый....* Г.Тукай

МӘСНӘВИ *и. гар. әд.* Шигырь юллары бердәй үлчәмле, үзара рифмалашкан, интонацион һәм мәгънәви яктан чагыштырмача бөтен һәм мөстәкыйль бәет. *Әсәр үзара рифмалашучы икеюллык строфалар – бәетләр (мәснәви) белән язылган.* Х.Миңнегулов. *Мондый бәетләр мәснәви, касыйдә, газәл һәм башка шигъри жанрларның нигезен тәшкил итә.* Г.Макаров

МӘСХӘРӘ *и. гар.* Хурлык, мыскыл. *Хөсәен Оренбургта Тимерша Соловьёв чыгара торган журналның Тукайга өзлексез мәсхәрә яудыруы турында искә төшереп алды.* А.Расих. *Кысрыклауга, мәсхәрәгә түзәсең, телем.* Р.Мөхиярова. *Иртәгә үк бөтен авылга яман хәбәр таралачак бит. Бу мәсхәрәне ничекләр күтәрермен?!* Р.Габделхакова

МӘСХӘРӘ́ БУЛУ *ф.* Хурлыкка калу. *Мөниржан, кабат мунча алдына кереп, күрше карчыгының капкадан чыгып киткәнен көтеп торды. Шулай итеп ул кеше алдында мәсхәрә булудан котылды һәм бу хакта берәүгә дә, хәтта Фазыл дустына да сөйләмәде.* Н.Әхмәдиев

◊ **Мәсхәрәгә алу** 1) Мыскыллау дип аңлау; 2) Мыскыллау. *Ул сүзләрне мин мәсхәрәгә алдым инде, әлбәттә.* Казан утлары. **Мәсхәрәгә калу** Хурлыкка калу, мәсхәрә булу. *Ни булды миңа, ни булды?! Мәсхәрәгә калдым...* Р.Габделхакова. *Миңа нишләргә кирәк иде, ничек итеп аның йөзенә күренергә кирәк иде соң? Шундый мәсхәрәгә калып...* Ә.Хәсәнов. **Мәсхәрәгә төшү** *к.* **мәсхәрәгә калу**. *Ачлык кешене нинди*

генә мәсхәрәгә төшерми дә, нинди генә этлек ясарга әтәрми икән. Г.Шакиров

МӘСХӘРӘ́ ИТҮ *ф.* 1) Көчләп алу, көчләү. *Шулай да борын-борыннан килгән йола – егетләр һәм кызларның аулак өйләрдә куну гадәте, анда чишенмичә генә йоклау, кызларны мәсхәрә итүгә, алдауга юл куелмавы – әлеге дәлилләргә каршы үзенә күрә көчле аргументлар.* Р.Кәрами

2) Мыскыл итү, мыскыл итеп көлү, хурлау. *Минем укытучымны шулай башка язучылар алдында мәсхәрә итүләренә әрнедем.* Л.Бадыйкшан. *Ул иблисләрдә бернинди иман юк: иң изге әйберләрне дә мәсхәрә итә алар.* Ш.Рәкыйпов

МӘСХӘРӘ́ КЫЛУ *ф. к.* **мәсхәрә итү**. *Сөйгән кызын мәсхәрә кылса, ул шундый хат язар иде микән?* Ә.Хәсәнов

МӘСХӘРӘЛӘ́Ү *ф.* 1) Көчләп алу, көчләү. *– Сез, сабыр ит, дисез. – Идмас йөзен җыерды. – Ә кем аңа йөргән кызын мәсхәрәләргә ирек биргән?* Ә.Хәсәнов

2) Хурлау, хур итү. *Язмышның ничек ачы итеп мәсхәрәләвен кара инде син, ә?* В.Имамов. *Сөембикәнең аны [Янчуринны] әллә ничекләр итеп мәсхәрәлисе килде, әмма тыелып калды.* Ф.Садриев

3) Кимсетү, мыскыллап көлү. *Шул көннән алып өч ай буе туктамастан сорау алулар, кыйнаулар, типкәләүләр, мәсхәрәләүләр китте.* З.Зәйнуллин. *Бу заманда курс эшләрен, дипломын үз кулы белән язган кешеләргә карата мәсхәрәләү ярылып ята иде аларда!* М.Маликова

Мәсхәрәләп ату *к.* **мәсхәрәләп ташлау**. *Башта теләсә нинди начар сүзләр белән мәсхәрәләп атса, тора-бара күл күтәрә башлады*. Шәһри Казан

Мәсхәрәләп бетерү Нык мәсхәрәләү. *Ул хатын-кызларны мәсхәрәләп бетерделәр.* Р.Батулла. *Иң «үтергәне» – соңыннан шушы текстны үз белдекләре буенча төзәтеп, аны мәсхәрәләп бетерүләре.* Өмет

Мәсхәрәләп йөрү Озак вакыт дәвамында мәсхәрәләү. *Атасы халык өстеннән көлеп, сугыш елларында солдатка хатыннарны мәсхәрәләп йөргән бер адәм актыгы иде* ---. Ш.Алпар. *Хокук сакчылары Казанның Арча зиратында каберләрне мәсхәрәләп йөргән 20 һәм 21 яшьлек беркайда да эшләмәүче бәндәләрне тотканнар, һәм аларга каршы җинаять эше кузгатылган*. Татарстан яшьләре. *Иреңә хыянәт итеп, аны мәсхәрәләп йөрмә*. Мәдәни җомга

Мәсхәрәләп килү Күптәннән мәсхәрәләү. *Элеккеге заманнардан ук хатыннарны сангa сукмаганнар, мәсхәрәләп килгәннәр.* Ватаным Татарстан

Мәсхәрәләп ташлау Бөтенләй, тәмам мәсхәрәләү. *Син анда, үзеңнең куркаклыгыңны аклар өчен, «мәсхәрәләп ташласалар да ала идем» дидең.* Ф.Яруллин. *Мәскәү бүләгеннән баш тарткан Вахтанг Кикабидзены әнә ничек мәсхәрәләп ташлаганнар бит!* Ватаным Татарстан

Мәсхәрәләп тору Сөйләү моментында мәсхәрәләү; даими мәсхәрәләү. *Эштән кайтышлый сатучыга, кичә бер килограмм дип саткан алмаң өйдә үлчәп карагач җиде йөз илле грамм гына килде, диюгә, теге күкерт кебек кабынып: «Мине – честный кешене – бөтен халык алдында мәсхәрәләп торасың, абзый, әкият сатма, өеңдәге үлчәгечең дөрес түгел синең», – ди.* Ф.Дәүләтбаев. *Тол хатыннарны мыскыл итеп, ятим балаларны мәсхәрәләп тордылар.* Безнең гәҗит

МӘСХӘРӘЛЕ *с.* **1.** 1) Хурлыклы, мыскылланган, кимсетелгән. *Аның үзе, хатыны Сәрвәр һәм ун яшьлек улы Тансык өчен караңгы көннәр, куркыныч төннәр, мәсхәрәле тормыш башлана...* З.Зәйнуллин. *Мәсхәрәле язмыш белән Саклап кара Иманны...* Э.Шәрифуллина. *Минем милициягә эшкә кергәнемә берничә ай гына, ә үземне инде ничә тапкыр тинтәк булып, көлкеле, мәсхәрәле халәттә калуымны тоям.* З.Хәким

2) Мәсхәрәләү белдерә торган, мыскыллы. *Идмасның йөзе үзгәреп китте. Ирен почмакларына мәсхәрәле елмаю кунды.* Ә.Хәсәнов. *Сөембикә аңа мәсхәрәле караш ташлады.* Ф.Садриев. *Чөнки аңа беркайчан да мондый мәсхәрәле рәвештә китереп органнары юк иде*. М.Маликова

2. *рәв. мәгъ.* Мыскыллап, кимсетеп. *Бүлмә хуҗасы мәсхәрәле елмайды.* Г.Тавлин. *Яңадан рәхәтләнеп, мәсхәрәле көлемсерим.* З.Зәйнуллин. *Ул алар янына тәкәллефсез генә якынайды да, мәсхәрәле елмаеп, катгый гына аңлата башлады: – Сез, иптәшләр, – диде ул, – бер бик мөһим сүзне ишетми калдыгыз бугай.* Р.Мирхәйдәров

МӘСХӘРӘЛЕК *и.* Хурлыкка, мәсхәрәгә калдыра, шуңа сәбәп була торган нәрсә. *Бу бит – мәсхәрәлек. Бу – кешенең дәрәҗәсеннән, мәгълүматыннан көлү була.* К.Тинчурин. *Бу – мирзалар токымының берәрсендә булып күргән эшме? Оят! Хурлык! Мәсхәрәлек!..* М.Фәйзи

МӘСЬӘЛӘ *и. гар*. 1) Хәл ителергә тиешле нәрсә; проблема. *Бибинурның чыраена салкын елмаю таралды, ул шундук мәсьәләне аңлап алды.* А.Гыйләҗев. *Йодрык белән хәл ителә торган мәсьәлә түгел бу сиңа!* М.Маликова. *Димәк, яңа хуҗалары аның ярдәменә, элемтәләренә исәп тота, юмартлыклары да, торак мәсьәләсен тиз хәл итүләре дә тизрәк үз эшләренә тартып кертү максатыннан.* Р.Мирхәйдәров

2) Тикшерелергә, игътибар ителергә тиешле эш-хәл. *Монда мәсьәлә, бәлкем, курку-курыкмауга гына да кайтып калмыйдыр.* Р.Юныс. *Гөлкәйнең яшерен мәхәббәте дә, тәнәфесләрдә аңа караучы Зиннур исемле малай да минем өчен вак мәсьәлә иде.* Р.Габделхакова. *Шулай итеп, көнүзәк мәсьәләне тавышка куйдылар.* Г.Морат

3) *мат*. Кагыйдә буенча билгеле шартлар, юллар белән чишелеп, җавап табылырга тиешле математик характердагы бирем. *Мәсьәләне ике юл белән чишегез*. Математика. *Дәреснең максаты: укучыларны мәсьәлә белән таныштыру һәм аны дөрес чишәргә өйрәтү.* Мәгариф

МӘСЬҮЛ *с. гар. иск.* **1.** 1) Соралган, сораган

2) Җаваплы. *Кеше үзенә үзе хуҗа, һәрбер эше өчен үзе мәсьүл.* Г.Ибраһимов. *Хәлил ул вакытта мәсьүл бер урында эшләп паёк алган.* Һ.Такташ

2. *хәб. функ.* Җаваплы булу. *[Сәгыйть хәзрәт:] --- Кыямәт көнне безнең алар өчен мәсьүл булуымыз бар*. Г.Исхакый

МӘСЬҮЛИЯТ *и. гар. иск.* Җаваплылык. *Җаббаров иске гадәт кулланыу өчен мәсьүлияткә тартылды.* Ф.Бурнаш. *Наширнең мәсьүлияте кечкенә булганга, хөкүмәт аның өчен бер шарт та куймый.* Г.Исхакый. *Аның үзенә дә җиңел түгелдер: бик зур мәсьүлият ала ич ул өстенә!..* Ә.Еники

МӘСЬҮЛИЯТЛЕ *с. иск.* Җаваплы; мөһим. *Коммунистлар позициясендә торып тәнкыйть итә белгәндә, көлә белгәндә нинди генә мәсьүлиятле теманы алсаң да, бүгенгегә кирәкле сатира тудырып була.* Һ.Такташ. *Фуад бу эшләрнең эчендә булып килде һәм дә иң мәсьүлиятле (җаваплы) эшләрне алып барды.* Х.Миңнегулов

МӘТӘКЛӘ́Ү *ф. диал.* Мәтәлчек ату. *Яшел чирәмдә бала-чага мәтәкли ---.* С.Җәлал

МӘТӘЛӘ́-КАДАЛА *рәв.* 1) Абына-сөртенә, егыла-тора

2) Нык ашыгып, кабаланып, ашык-пошык. *Бер әби мәтәлә-кадала каядыр чаба.* В.Нуриев

МӘТӘЛДЕРҮ *ф.* 1) Этеп, аяк чалып, төртеп һ.б.ш. егу; нәрсәне дә булса аудару, төшереп җибәрү. *Ул дәррәү бар көченә селтәнеп, мине юл кырыена мәтәлдерде.* Г.Галиев. *Ибрайны чалбар каешыннан тартып мәтәлдердем һәм бөтен урман авызын яңгыратып аваз салдым: – Тимәгез! Үтермәгез!* Ф.Шәфигуллин

2) *күч.* Бәреп төшерү, юк итү. *Нинди оста итеп мәтәлдерде! Димәк, гитлерчыларны үкертеп-үкертеп кыйнап була!* Г.Әпсәләмов. *Тик ул гамәлгә ашыру өчен түгел, Идел-Урал проектын мәтәлдерү өчен дөнья күргән бер уен гына булып чыга.* Казан утлары

Мәтәлдереп җибәрү Кисәк мәтәлдерү. *Ә менә үзенә каршы ничә кеше – ике яисә егерме көндәше чыкса да, барысын да мәтәлдереп кенә җибәрә торган бер сугышчының экраннарда килеп чыгуы ажиотаж куптара.* Кызыклар дөньясында

Мәтәлдереп ташлау Тиз генә мәтәлдерү

МӘТӘЛЕШҮ *ф. урт. юн.* Бер-бер артлы күбәүләп мәтәлү. *Хәтерлим: бу хәйләне белеп алгач, бер дефиледа чебешләр кебек бер-бер артлы берничә кыз мәтәлешкән иде.* Шәһри Казан

Мәтәлешә башлау Мәтәлешергә тотыну

Мәтәлешеп бетү Барысы да мәтәлешү. *Әгәр җир әйләнә торган булса, кешеләр йөри алмаслар, мәтәлешеп бетәрләр иде.* М.Әмирханов

МӘТӘЛҮ *ф.* Абынып, сөртенеп егылып китү; егылу. *Каргаларның берсе җиргә мәтәлде, икенчесе яман ачы аваз белән каргылдап кире борылды, дәү, алама канатларын җил-җил кагарга кереште.* А.Гыйләҗев. *Анда [солдатларның] берсе, мәтәлеп, аягын сындырды бугай.* Р.Кәрами. *--- каплап куелган табакка абынып мәтәлде дигәндә, кер бавына эләгеп кенә калды [Руфинә], тик бау шартлап өзелгән иде инде.* Ф.Садриев

Мәтәлеп бару Мәтәлү алдында тору. *[Моназыйр:] Телеңне тый, дим! Чалуга мәтәлеп барасың бит!* М.Хуҗин

Мәтәлеп китү Кисәк мәтәлү. *Безнең халык, буш дигәндә, мәтәлеп китә бит инде ул.* Т.Нәҗмиев. *Сәере шул булды: өскә бик тиз үрмәләсә дә, түбән төшүләре яман булды, бер-ике тапкыр чак кына аяклары ычкынып, мәтәлеп китмәде.* М.Хәбибуллин

Мәтәлеп тору Рәттән, бер-бер артлы мәтәлү. *Икәү әрчергә керештеләр, Мөзәкирнең бәрәңге кабыклары алкаланып-алкаланып чиләк эченә мәтәлеп тордылар.* А.Гыйләҗев

МӘТӘЛЧЕК *и.* Кулларга таянып һәм аякларны югары күтәреп, баш аркылы икенче якка әйләнү; баш аркылы әйләнү. *Ул хәзергә мәтәлчекне генә булдыра алмады: башын җиргә кадап, аякларын күтәрә башлауга, яны белән лап итеп авып төште.* Г.Гобәй. *Килер бер вакыт, телевидениедән хоккей, футбол белән берәттән авыл малайларының көзге кыска көндә эскерт өстеннән мәтәлчек атып уйнаганнарын күрсәтерләр.* М.Мәһдиев

◊ **Мәтәлчек ату** Баш аркылы икенче якка әйләнеп төшү, мәтәлчек ясап тәгәрәү. *Бер мәтәлчек атам чирәмендә, Авыртса да аяк-кулларым.* Ш.Камалов. *Мич каршында өлгән саламда мәче малайлары, сарык бәрәннәре белән әүмәкләшеп уйныйбыз, мәтәлчек атабыз, ялкын телләренең талпына-талпына җилпенүен күреп, ләззәт кичерәбез.* Ә.Баян. **Мәтәлчек атыну** *к.* **мәтәлчек ату**. *Кошлар да уйнарга бик оста. Алар һавада мәтәлчек атына, төрле таяклар, ботаклар, ташлар һәм яфраклар җыя.* Кызыклар дөньясында

МӘТӘЛЧЕКЛӘ́Ү *ф.* Мәтәлчек ату. *Шул шамакай мәтәлчекли-мәтәлчекли: «Рифма – чуар: сонет бу!» – мәзәк сөйли.* Х.Туфан. *Әҗәле килгән бу шөкәтсез зат астында сытылып калмас өчен, Алып Бәргән, мәтәлчекли-мәтәлчекли тәгәрәп, урман авызына чаклы барды.* Р.Батулла

МӘТӘШТЕРҮ *ф. сөйл. к.* **маташтыру**. *Дөрес, үз көчләре белән ел саен 3–4 квартир мәтәштерәләр, ара-тирә яшь гаиләләрне бәхетле итәләр, читтән килгәннәрне дә совхозга теләп кабул итәләр.* А.Гыйләҗев. *«Бәхетләр»е, җиңелчә яраланып, өенә кайтып киткән, ә «бәхетсезләр»ен – кеше ышанырлык итеп мәтәштерә белмәгәннәрен – шундук атып үтергәннәр яки штраф батальоннарына озаткаННар.* Р.Кәрами. *Бер сүз белән әйткәндә, хуҗалары ничек таләп итсә һәм үзе ничек эшләргә күнеккән булса, шулай «мәтәштергән» икән [яһүд].* Р.Мирхәйдәров

МӘТЕ *и.* Юеш балчык. *Монда тирән түгел, хәтәр чоңгыллар да юк, әмма төбе бик алама: тубыктан батарлык мәте генә...* Ә.Еники. *Без казан төбендәге мәтедән төрле уенчыклар әвәләргә, балык тотарга ярата идек.* Ж.Дәрзаман

МӘТЕН *и. гар.* 1) *иск.* Текст. *«Шәмсия» мәтенен бер кышта тәмам хифаз кыйлып бетергә мөмкин.* К.Насыйри

2) Хәдиснең эчтәлеген тәшкил иткән, хәбәр ителәсе мәгълүматны җиткергән төп өлеше. *Мәтене бик озын хәдис*

МӘТРҮШКӘ *и. рус бот.* Иренчәкләләр семьялыгыннан хуш исле сыек шәмәхә чәчәк ата, медицина һәм парфюмериядә файдаланыла торган күпьеллык урман үләне; *русчасы*: **душица**. *Мәтрүшкәне алтын путаллы касәләргә агызып, сөйләшмичә генә эчтек.* Ш.Рәкыйпов. *Өйдә, чормада*

мәтрүшкә кыстырып бәйләнгән каен себеркесе көтә! Г.Гыйльманов

МӘТРҮШКӘЛӘП *рәв.* Мәтрүшкә салып, мәтрүшкә белән. *Танкны каенмы, имәнме себеркесе белән ничек чабындырмак кирәк? Бигрәк тә мәтрүшкәләп.* Ә.Гаффар. *Ә хәзер, әйдә, сөтләп, мәтрүшкәләп бер чәй эчеп алыйк.* Ш.Фәрхетдинов. *Каты авырып ята, әле мәтрүшкәләп чәй эчереп карадым.* Д.Бүләков

МӘТРҮШКӘЛЕ *с.* Мәтрүшкә салынган, мәтрүшкә кушылган. *Гандәлифә, термостан агызып, икесенә дә мәтрүшкәле кайнар чәй алып килде.* Ф.Садриев

МӘТРҮШКӘЛЕК *и.* Мәтрүшкә күп үсә торган урын. *Ул мине үзе белгән һәрнәрсә белән: гөмбәлек, мәтрүшкәлек, кузгалаклык, каен җиләклек, чикләвеклек, тагын әллә күпме тылсымлы урыннар белән таныштырды.* Н.Сафина

МӘҮҖҮБ *с. гар. иск.* Әмер ителгән, кушылган. *«Ясыйм, – ди ул, – шундый нәрсә, ул күп булсын, Бик күп булсын, хәрәкәте мәүҗүб булсын».* М.Җәлил

МӘҮҖҮД *с. гар.* **1.** Булган; тормышта бар, реаль

2. *хәб. функ.* Бар. *Хәйрулла мулла: Әлбәттә, мәүҗүд булырга кирәк... Чөнки [заман] мәүҗүд булмаса, мәгъдүм булыр.* Г.Исхакый

МӘҮЗУГ *и. гар.* Тема, проблема. *Ә чын иректән башка язучы да, сәяси мәүзугка алынган фән кешесе дә ихлас була алмый.* Ф.Галимуллин. *Көтелмәгән нәтиҗә – Г.Зәйнашеваның яратқан мәүзугы.* Т.Галиуллин. *Драматург сәхнәгә моңа кадәр яңгырамаган, моңа кадәр сәнгатькә күтәрелмәгән мәүзуг алып килә.* Р.Батулла

МӘҮЛА *и. гар.* 1) Ия, хуҗа, әфәнде. *Бер мизгелдә дөнья мәүласыннан Әверелдем гүя тоткынга.* С.Әхмәтҗанова

2) *дини* Аллаһы Тәгалә. *– Күп шөкер, – ди, – бу җимешне бирде мәүла! – дип куя.* Г.Тукай. *Туганмын мин дөнья-зиндан бишегендә, Мәүла колы булып яши кеше монда ---.* И.Юзеев. *Аннары тәмам аптыраган, исе киткән кешедәй ихтыярсыздан сорап куя: – Ничек сине җир йотмый, ә? Я кадир, я мәүла!..* Ә.Еники

МӘҮЛЕТ *и. сөйл. к.* **мәүлид**. *Кичен без мәүлет бәйрәме мәҗлесенә бардык.* Т.Әйди. *Изге китап сүзе генә өйдә, Гайбәт йөрми мәүлет кичендә.* Х.Әюп. *Иртән мәүлет көне, иртүк торып, Мунча кереп, юынып кайтырсың.* Х.Мөҗәй

МӘҮЛИД *и. гар. дини* 1) Мөхәммәд пәйгамбәрнең туган көне һәм шул көнне үткәрелә торган бәйрәм. *1911 елның 27 гыйнварында Казанның Галиев мәчетендә (Г.Баруди имамлык иткән мәчет) Мөхәммәд галәйһиссәламнең туу көне (мәүлид) уңае белән намаз укыла.* Р.Әмирхан. *Дүртенче бәйрәм – Мәүлид кичәсе, «мәүлид ән-нәби», ягъни «пәйгамбәрнең туган көне» дигәнне аңлата.* Татар милли педагогикасы. *Бу касыйдә Мәүлид кичәләрендә, ягъни рәбигыльәүвәл аеның уникенче көнендә уздырылган бәйрәмнәрдә, Мөхәммәд пәйгамбәрнең туган көне хөрмәтенә башкарылган.* Милли моңнар

2) Мөхәммәд пәйгамбәрнең тууы, тормыш юлы турындагы дини текст. *Мәүлид уку*

3) Шундый текстлар укыла торган йола

4) Пәйгамбәр туган рәбигыльәүвәл аеның халык телендәге атамасы. *Я булмаса, мәүлид айларында Коръән укылгач, ашлар ашалгач, тәгамгә дога кылынгач, абыстай кайтып киткәч, мөнәҗәтләр әйтә башлый.* Р.Батулла

МӘҮСИМ *и. гар. кит.* Сезон. *Көтсәләр дә гаҗәп түгел, чөнки кыш – гаҗәеп мәүсим ул.* Г.Тукай. *Узган ел хаҗ мәүсиме килер алдыннан Төркия вә Италия мәхарәбәсе башланган иде, азрак булуга шул сәбәп булган булса кирәк.* Г.Камал. *Бу мәүсимдә [«Зөләйха» драмасы] өченче мәртәбә сәхнәдә уйнала.* Л.Гайнанова

МӘФТҮН *с. гар.* 1) Сокланырлык. *Толымнары мәфтүн кара иде [укытучы апаның], Чәчен инде еллар уңдырган.* Ә.Синугыл-Куганаклы

2) Мөкиббән; үз-үзен онытып сокланган. *Мин үзем Нәҗип Җиһановның музыкасына мәфтүн түгел, һәрхәлдә, ул татар музыкасында зур урын тота һәм тотачак!* Р.Батулла

МӘФТҮН БУЛУ *ф.* Үз-үзен онытып соклану. *Ул һәрбер матурлыкка мәфтүн булган кеби, һәрбер матурлык каршысында тез чүгәргә, аның тудырган хиссиятен зур сәгадәт итеп алырга һәрвакыт хәзердер.* Г.Ибраһимов

МӘФТҮН ИТҮ *ф.* Сокландыру, әсир итү; сихерләү. *Чын сихергә мәфтүн итте бер матурга күз ату...* М.Җәлил. *Бу яшел төс бөтенләй мине мәфтүн итә.* Г.Рәхим

МӘХӘББӘТ *и. гар.* 1) Кемне яки нәрсәне дә булса бик нык якын күрү, кемгә яки нәрсәгә дә булса чын күңелдән бирелгәнлек хисе. *Тик аның әсәрләрендә илгә булган мәхәббәт, җирне олылау хисе күзгә ташланып, чекерәеп тормый.* И.Нуруллин. *Безнең дошманнарыбызда була алмый торган иң көчле, иң җиңелмәс коралыбыз да шул: туган илгә чиксез мәхәббәт, көрәштә тиңе булмаган фидакярлек!* Г.Бәширов

2) Кемгә яки нәрсәгә дә булса хөрмәт, симпатия кебек үз итү, якын итү хисе. *Әмма егетнең күңелендә әдәбият-сәнгатькә дә мәхәббәт бөрелә.* Л.Җамалетдинов. *Яраткан язучысының шундый вакытсыз үлеме дә бик күпләрнең күңелендә Кутуйга карата инде булган мәхәббәт өстенә әрнү, яңа сагыну, табыну хисләре уятты шикелле.* Р.Фәйзуллин

3) Башка җенестән булган бер кешегә карата кайнар йөрәк хисе; ярату, сөю, гыйшык. *Бу дөньяда ир белән хатын арасындагы мәхәббәттән өстенрәк нәрсәләр дә бар*. М.Маликова. *Мәхәббәткә лаек йөрәк һаман яши, тибә, эзләнә икән...* А.Гыйләҗев. *Бу мәхәббәт түгел, ияләшү генә булган.* Р.Габделхакова

4) Шундый хис, гыйшык төшкән объект турында. *Үкенечле яшьлек мәхәббәтем... Ничек итеп онытыйм мин аны?* И.Юзеев. *Беренче мәхәббәте Миңниса...* А.Фәлах. *Ул минем беренче һәм соңгы мәхәббәтем иде.* Г.Гыйльманов

5) Нәрсә белән дә булса кызыксыну, нәрсәгә дә булса омтылыш, теләк, һәвәслек. *[Кариев:] Афәрин, Габдуллажан, син үзеңнең лекцияң белән публиканың халкыбызга булган мәхәббәтен тагы да арттырдың, әйткәннәреңә бик*

дөрес, халык ул – дәһи ул! А.Расих. *Чөнки аның [Сәйдәшнең] кайчандыр үзе хезмәт иткән Кызыл Армиягә, кызыл йолдызга мәхәббәте беркайчан да сүнмәслек иде.* Р.Низамиев

МӘХӘББӘТЛЕ *с.* 1) Сөйкемле, үзенә тарта, җәлеп итә торган. *Кеше гомере еллар белән түгел, мәхәббәтле күңеле белән үлчәнергә тиештер, чын яшәве шунда бит.* Ш.Галиев. – *Минем исемем Айдар, – диде ул, мәхәббәтле караш ташлап.* Ф.Садриев

2) Мәхәббәт белән сугарылган; якты, бәхетле. *Алда аларны – сөйләшеп, куанып, сөешеп туя алмаячак әнис алмаларын – киң кочагын җәеп гүзәл Казан, мәхәббәтле, бәхетле-сәгадәтле тормыш көтә иде.* Ә.Хәсәнов. *Шуңа күрә без аналарга мәхәббәтле, игътибарлы һәм ихтирамлы булырга тиешбез.* Р.Миңнуллин. *Елмайсак, куллар кысышсак, Йөрешсәк әгәр күбрәк, Булыр иде бу дөньялар Тагы да мәхәббәтлерәк...* Ф.Яруллин

МӘХӘББӘТЛЕЛЕК *и.* Мәхәббәтле булу сыйфаты; сөйкемлелек. *Хәзер менә күп җырчыга мәхәббәтлелек җитми.* Р.Батулла. *Ямьсез булса да, аның йөзендә ниндидер мәхәббәтлелек, горурлык, җитдилек чаткылары бар иде.* С.Поварисов. *Андагы [Гаделиядәге] мәхәббәтлелек, сылулык!* М.Мәһдиев

МӘХӘББӘТСЕЗ *с.* 1) Ямьсез, шыксыз, сөйкемсез. *Халык каршында иң мәхәббәтсез кеше – мәҗлестә үз-үзен олы күрүчедер.* Р.Фәхретдин. *Өстәвенә Шәүкәткә дә ул хатын мәхәббәтсез, күңел кайтаргыч түгелдер, мөгаен; әнә бит алар ничек матур итеп, икесе бер адымнан атлап баралар.* М.Маликова. *Күземә бар нәрсә шыксыз, мәхәббәтсез булып күренә иде.* Л.Гыймадиева

2) Ачуланып яки шаяртып, үпкәләгән сыман итеп әйтелә. *[Мәгъри:] Һи, йөзе кара нәрсә, мәхәббәтсез!* Г.Камал. *[Исмай:] Минем мәхәббәтемә кысылма, мәхәббәтсез!* И.Юзеев. *«Вөҗдансыз, имансыз, мәхәббәтсез» – минем өчен соңгы чиктәге сүгенү сүзенә әйләнер.* А.Хәлим

МӘХӘЛЛӘ *и. гар.* 1) Шәһәр яки зур авылның билгеле территория белән чикләнгән өлеше; квартал. *Килмешәк этне җиде мәхәлләдән куалар, аларга иркенлек бирсәң ни буласын бүгенге хәлебездән чамала инде.* Ф.Сафин. *Әмма стенадагы картадан шәһәр мәхәлләләрен күздән кичергәндә, Фарукҗан бөтенләй башка нәрсәләр турында уйлады.* Т.Әйди. *Шул нәселдән килгән Мәмәт, хәзерге Татарстанның Мамадыш ягындагы Саба авылын салып, үзенә бер мәхәллә төзеткән.* М.Әхмәтҗанов

2) Шунда яшәгән кешеләр. *Безнең тавык күкәй салганны бөтен мәхәллә ишетә, күршенең байталы колынласа да, һич тавыш чыкмый.* Әйтем

3) Шәһәр яки зур авылның бер мәчеткә караган өлеше. *Мине сәнга сукмыйсың икән, ичмасам, мәхәллә халкының ышанычын җуймаска иде.* Т.Гыйзәт. *Имам кешегә һаман-һаман мәхәллә ташлап йөрү читен.* Ә.Фәйзи. *Атнасына бер мәртәбә мәхәллә халкы, бер төбәккә җыелып, кирәкле ихтыяҗларын хәл итүдә үзара киңәшеп, якынлыкны даими саклап торган.* М.Галиев

4) Шәһәрнең яки авылның бер мәчете тирәсендә берләшкән җәмәгать. *Боларына да түзә мәхәллә.* А.Тимергалин. *Япон җирендә дә бирешмәгәнсез, зур мәхәллә булып оешып яшисез икән, ярхәмикалла.* В.Имамов

МӘХБҮБ *и. гар. иск.* **1.** Сөелгән, яратылган ир-егет; сөйкемле ир-егет; сөйгән яр. *Я сакалым, сән юк идең, бән хуб идем, Кызларның каршысында мәхбүб идем.* Г.Кандалый

2. *с. мәгъ.* Сөйкемле, күңелгә якын, сөекле. *Солтан Мәхмүд Газнавиның ун данә мәхбүб коллары бар иде.* К.Насыйри. *Хак Тәгалә хәзрәтләре аңа бер сәвекле вә мәхбүб угыл бирде.* М.Гайнетдин

МӘХБҮБӘ *и. гар. иск.* Сөйгән кыз. *Бирмәде Ләйлә кеби мәхбүбәгә дөнья бәһа, Ул болай бер кыз гына, каршында Мәҗнүн булмаса.* Г.Тукай. *Гайни – Закирның мәхбүбәсе, кара кашлы, уртача буйлы.* Г.Камал. *Я, нинди ул сезнең яшьлеккә – Гаташ? Сөйләрсеңме шулай син «мәхбүбәм» дә?!* Р.Гаташ

МӘХБҮС *и. гар. иск. кит.* **1.** Тоткын, кулга алынган кеше. *Бары тик өч айдан, мәктәп мөдәррисе Кормаши китергән ышанычнамә кәгазеннән соң гына азат иттеләр мәхбүсләрне.* А.Хәлим. *Әгәр тел сау-сәламәт икән, ул телдә җәмгыятьнең бөтен катламнары сөйләшә: ил башы да, бомж да, сырхау кеше дә, мәхбүс тә, шагыйрь дә...* Р.Фәйзуллин. *Чөнки ир-ат һәм хатын-кыз мәхбүсләрне аерым төрмәләрдә саклаганнар.* Р.Мирхәйдәров

2. *с. мәгъ.* Тоткындагы, иректсез. *Мәхбүс шагыйрьгә, ерактагы сөйгәне турында уйланганда, таң ату вакытында кар зәңгәр күренә.* Г.Әпсәләмов. *Йөргән чакта мәхбүс Туфаныбыз Себер җилләрендә каңгырап, Кем күзенә карап ышык тапкан, Ялгыз калгач көзге яңгырда?* Ә.Рәшит

МӘХБҮСЛЕК *и. иск.* Тоткынлык; төрмәдә утыру; төрмәдә үткәрелгән вакыт. *Белмисеңме син: читен мәхбүслек ул, Булса да алтын, һаман да читлек ул.* Г.Тукай. *Хәсән ага үзенең лагерь тормышын, мәхбүслек газапларын шактый күп сөйләде безгә.* Р.Әхмәтҗан. *Үрбәт үзенең мәхбүслек язмышы белән килешкән иде инде.* М.Әмирханов

МӘХДҮМ *и. гар.* 1) Хөрмәткә лаек ир кеше, хөрмәтле кеше

2) Мулла улы. *Берәр хәзрәтнең мәхдүме, зур байның улы, әллә учитель баласымы?* Ә.Еники. *Ләкин, өстәвенә кара болыт килеп, яшен яшьнәгәч, бер гаепсез хәзрәтне дә, остабикә белән мәхдүмнәрне дә яклап кала алмадылар.* Н.Әхмәдиев. *Ир туганнар башлы-күзле булганнан соң да үзара тату гына яшәп яткандә, төпчек мәхдүм кайтып төшкәч, аны моңарчы хәзрәтнең төсе итеп саклап торган почмак бүлмәгә урнаштыруны кулай күрделәр.* Г.Бәширов

МӘХДҮМӘ *и. гар.* 1) Хөрмәткә лаек хатын-кыз

2) Мулла кызы. *Гайшә абыстай үз тирә-якларында шөһрәтле бер мөдәррис кызы улдыгы хәлдә, ни өчендер мәхдүм вә мәхдүмәләр табигатенә тәмам башка бер табигатьтә вә анлар гадәтеннән башка бер гадәттә иде.* Р.Фәхретдин. *Мәхдүмәләрнең берсенә никахланып алсаң, муллалык ләвазиме дә, дәүләт байлыгы да, шөһрәт-абруе да табыла.* Т.Гыйззәт. *Остабикәсе дә шуннан соң күп тормаган, мәхдүм белән мәхдүмәләр, йорт-каралтыны*

сатып, кайсы кая таралышып беткәннәр икән. А.Тимергалин

МӘХДҮМЛЕК *и.* Мәхдүм булу. *Рәсүлевләр шәҗәрәсендәге ике мәхдүмлек Атилла Расихның алдагы тормышында һәм иҗатында гел чагылыш таба.* К.Кәримов. *Туган көненнән алып өлкән яшькә җиткәнче «ишан оныгы», «мулла малае» дигән ярлыктан котыла алмаган язучы фани гомеренең соңгы биш-алты елын гына булса да мәхдүмлеге белән горурланып яшәп калгандыр [А.Расих].* Казан утлары

МӘХЗҮМ *и. гар. к.* **мәхдүм**. *Камил мәхзүм җырлап җөри борнын түбәнгә салып ---.* Г.Тукай. *Намаз бүлмәсенең йомшак киезенә тезләнеп, зур түгәрәк ясап утырган килеш, карт хәзрәтнең үзеннән һәм аның чатан мәхзүменнән сабаклар алдык.* Ә.Еники. *Бу сүздән соң Зыя мәхзүм көлемсерәде.* Г. Садри

МӘХЗҮМӘ *и. гар. к.* **мәхдүмә**. *Аннары килеп, Дәүләкән үзе һәм аның мәчете утка янса да, Гайшәбикә мәхзүмә кала бит әле, ул бар бит әле.* Ә.Еники

МӘХКӘМӘ *и. гар. кит.* 1) Дәүләтнең гражданнар арасындагы низагны һәм җинаять эшләрен хәл итүче хөкем органы; суд. *Шуңа күрә мәхкәмә карары безгә билгеле түгел.* Р.Мостафин. *Мәхкәмә утырышы ачык булды, тик чын-чынлап төбенә төшә башласаң, аның ачык үткәрелүенең үз тарихы бар.* Р.Мирхәйдәров

2) Шул хөкем органында эшне тикшерү утырышы. *Бу бәладан котылыр өчен инде, бер генә түгел, мең мәхкәмәгә керергә дә разый инде, Әсма апа!* Г.Исхакый. *Моннан йөз, иң кимендә егерме алты ел элек булган вакыйгаларга батып, ул үзенең эше каралачак мәхкәмә турында да онытып җибәргән ләбаса!..* А.Хәлим. *Мәхкәмә барышында судья, сораулар биреп, аның фикерен үзенә кирәк яккарак юнәлтергә тырыша: «Сезнең бит мамык шәлегез булмый калмагандыр?»* С.Ибраһимова

3) Хөкем йорты; суд йорты. *Бу хәлләрнең ахыры мәхкәмә залында тәмамланды.* Д.Гыйсметдин. *Монысы – гомере буе мәхкәмә залларында күп еллар буе хезмәт иткән, меңнәрчә язмышларны үзгәрткән күптәнге таныш, хәтта сердәшем.* Ф.Баттал. *Адвокатлар яллап, мәхкәмә бусагаларын таптап, кассацион тәртиптә ата-ул төрмәгә ябылудан котылып калсалар да, Камил өчен иң яманы наширлек һәм мөхәррирлек хокукларыннан бөтенләйгә мәхрүм ителү була.* Әдипләребез

МӘХКҮМ *с. гар.* **1.** Хөкем ителгән, гаеп ителгән, җәзага тартылган. *Болардан бигрәк ул мәхкүм бер халыкның киң, акты бер дөньяга чыгу юлындагы тарихи идеалының тәмсалы мөҗәссәме.* Татар әдәбияты

2. *хәб. мәгъ.* Мәҗбүр; хөкем ителгән. *Болардагы мәхлуклар чын ихлас белән тик торырга мәхкүмнәр.* М.Гафури. *Мәгърифәт бетсә, милләт үзе дә иртәме-соңмы, Тукай әйткәнчә, бетәргә мәхкүм иде.* Ә.Еники. *Үз эчендәге бөтен мөмкинлекләрен сарыф иткәннән соң гына халык үләргә мәхкүм.* Р.Батулла

МӘХКҮМ ИТҮ *ф.* Суд карары чыгару; хөкем итү. *Торсын баба шул баланы үлемгә мәхкүм итәргә тиеш.* Р.Батулла

МӘХЛУК *и. гар.* **1.** 1) Җан иясе, барлык. *Кычкырган көенә тәгәрәп тә төште, соңгы көчен салгандыр инде мәхлук үзенең дөньяви мөһим бурычын үтәүгә.* Г.Якупова. *Тик Рөстәм бит дуңгыз да, башка мәхлук та түгел.* М.Кәбиров. *Әсәрдә хан түгел, мескен бер мәхлук сурәтләнгән кебек тоела.* Казан утлары

2) Кешегә яки хайванга карата кызганып яки кимсетеп әйтелә. *Һәнүз йокыдан торгалаганчы, ул мәхлук (кәҗә) ишегалдына кайтып та керә.* Ф.Яруллин. *Ишегалдына чыккач, Азатларның сыеры мөгрәп тавыш бирде бугай, ләкин мин әле һаман айнып җитә алмаган идем, көтүгә куылмый калган мәхлук турында мәктәптә генә уйлап куйдым һәм шундук «ә Музгарка?» дигән сорау миемне бораулый башлады.* А.Тимергалин. *– Тыпырчынма, мәхлук! – дип ысылдады Әнсар. – Болынга син хуҗа түгелдер бит?* З.Хәким

2. *с. мәгъ.* Мескен, бичара. *Ә менә болай: йөгән сабагыннан (тезгене дип тә әйтәләр) тотасы да мәхлук атны тәртә арасына кертәсе.* М.Мәһдиев. *– Хач таккач, үзен татардан өстен куя, ахрысы, мәхлук җан, – дип эчтән генә уйлап куйды Мәүлетдин.* З.Зәйнуллин. *Машина, кисәк кенә борылып, мәхлук кошларны эзәрлекләвен дәвам итте, инде куып тотам дигәндә генә, шып туктап калды.* А.Гыймадиев

МӘХЛУКАТ *җыйн. и. гар.* Җан ияләре, мәхлуклар, бөтен барлыклар. *Әнә инде кошлар да кайтканнар: бар да үзләренең матур тавышлары белән язны, табигатьне өзелеп-өзелеп мактыйлар, бөтен мәхлукатны тормышка, шатлыкка өндиләр.* С.Җәлал. *Төн караңгыланып, мәхлукат тирән йокыга киткән, тукмак тавышлары берсе дә ишетелми, авылның югары урамында «чәң-чәң» килеп салмак кына өргән бер эт тавышыннан башка тавыш юк иде.* А.Таһиров. *--- Адәмне һәм башка мәхлукатны Аллаһ бер мизгелдә эволюция юлы белән яраткан, дип әйтә алабыз.* А.Тимергалин

МӘХРӘМ *и. гар.* **1.** Якын туган булганнары өчен шәригать буенча никахлашу рөхсәт ителмәгән ир-егет белән хатын-кыз (бер-берсенә карата). *Шуңа күрә кызның берәр якыны – мәхрәме булу шарт.* Безнең гәҗит

2. *с. мәгъ.* Якын туган, туган тиешле; никахлашырга ярамаган (ир-егет яки хатын-кыз тур.). *Мәхрәм карендәшләргә тоташуның ризык киңәюгә сәбәпче икәнлеге хакында да хәдисләр бар.* Р.Фәхретдин

МӘХРӘМЛЕК *и.* Мәхрәм булу. *Чыннан да, никадәр якын карендәш булса да, әгәр киселеп торылса, якынлык һәм мәхрәмлек булмас һәм никадәр ерак карендәш булса да, әгәр күрешеп торылса, ераклык калмас.* Р.Фәхретдин

МӘХРҮМ *с. гар.* **1.** Берәр нәрсәсе булмаган, өлешсез, буш калган. *Хәтта Алласын яшьлегендә үк җуйган, шәригать кушканча түгәрәк сакалмыек йөртүдән мәхрүм картлар да бәйләнмиләр үзенә...* М.Галиев. *Әмма тумыштан ишетү сәләтеннән мәхрүм кешедән композитор чыгуын минем ишеткәнем юк.* Т.Миңнуллин. *Аның каравы шушы иң кыйммәтле сыйфатыннан мәхрүм кешеләр югары бәяләнде.* Ф.Галимуллин

2. *рәв. мәгъ.* Нәрсәседер булмаган хәлдә. *Әти-әни җылысыннан мәхрүм үскән бала бит ул.* Т.Миңнуллин

3. *хәб. мәгъ.* Теге яки бу хиснең, әйбернең һ.б. булмавы турында. *Тегеләр юмор хисеннән гел дә мәхрүм түгелләр икән.* Р.Низамиев. *Чөнки ул бичаралар куркудан мәхрүм.* Ә.Гаффар. *Әмма ул инде элекке кебек уйлау сәләтеннән дә мәхрүм иде.* Г.Гыйльманов

◊ **Мәхрүм калу** 1) Нәрсәне дә булса ала алмый калу, үзенеке итә алмый калу. *Бар җылыдан мәхрүм калып, Ялгызлыкта туңган җан Әрнеп, сызлап үлде, сулды, Иясен кызганмыйча.* Н.Хисамов. *Булмаган үгезне көтеп, бозаудан мәхрүм калма.* Әйтем; 2) Югалту; берәр нәрсәдән колак кагу. *Ләкин, ни хикмәттер, көзнең җитәсе барыбер искә төшә һәм бу матурлыклардан бер көн килеп мәхрүм каласың акылыңа барып ирешә.* Ш.Рәкыйпов. *Ә безнең казлар нефть базына төшкән иде, ул елны мәхрүм калдык.* Р.Кәрами

МӘХРҮ́М БУЛУ *ф.* Кемнеңдер нәрсәсе дә булса булмау турында. *Бу бәхеттән мәхрүм булган Гадел белән Ардуан артыбыздан каерыла-каерыла, тилмереп карап калдылар.* В.Нуриев

МӘХРҮ́М ИТҮ *ф.* Кемнең дә булса берәр нәрсәсен алу, кемне дә булса берәр нәрсәсез, өлешсез калдыру. *Авылыбызны килер буыннардан Бөтенләйгә мәхрүм иткәнбез лә!* Х.Әюп. *Гөнаһ булган нәсел-ыруыңны Мәхрүм итү бәби туеннан...* Ф.Гыйззәтуллина. *Әмма Сталин хакимияте урнашкач, татар халкы Г.Исхакый әсәрләрен укудан мәхрүм ителде, әдип исеме бары кара буяулар белән генә телгә алына башлады.* Х.Миңнегулов

МӘХРҮМЛЕК *и.* Мәхрүм булу. *Срогы да минеке төсле – «бер катушка, биш тагылма» – ун ел төрмә, биш ел мәхрүмлек.* И.Салахов. *Картлык ул – мәхәббәт тою бәхетеннән мәхрүмлек дигән сүз.* Ш.Галиев. *Өзгәләнеп тормый үзиреккә – канга сеңеп калган мәхрүмлек.* З.Мансуров

МӘХҮ *и. гар. иск.* Югалу, юкка чыгу, бетү күренеше

МӘХҮ́ БУЛУ *ф. иск.* Югалу, юкка чыгу, бетү

МӘХҮ́ ИТҮ *ф. иск.* Юкка чыгару, бетерү. *Качып чыгуымның төп сәбәпләреннән берсе --- улебезне харап иткән, милләтебезне мәхү иткән коммунистлардан үч алырга чакыру иде.* Г.Исхакый. *Бу риясыз бер генә кат сүзләремне ит гафу, Китсә кәйфең, янда йөртмә, ташла утка, ит мәхү!* Р.Батулла

МӘХШӘР *и. гар.* 1) *к.* **Мәхшәр көне**. *Бил алышып, чат ябышып, Мәхшәргәчә барасы ---.* Р.Сафин. *[Алсылу:] Мәхшәрдә дә, тәмугта да ут йотыгыз.* Ә.Баян

2) *күч.* Ыгы-зыгы, мәш килү; шау-шу, тынычсызлык, буталыш. *Тору булмады, мәхшәр булды инде ул.* А.Хәсәнов. *Капкадан базар эченә керделәр, монда да мәхшәр: койма тирәли әйбер сатучылар тора ---.* Р.Кәрами. *Тагын ыгы-зыгы. Тагын мәхшәр...* В.Нуриев

3) *күч.* Зур фаҗига, афәт. *Николай нигәдер тетрәнеп китте. Онытырга мөмкинме икән соң җиргә фашизм китергән мәхшәрләрне?!* Ш.Рәкыйпов. *Яшәү хакына мин кемнәрнеңдер башына җиткәнмен икән, хәзер шул турыда дөреслекне сөйләп, сугыш дигән мәхшәрдән исән-сау кайткан башны тәмугка илтеп тыгасым юк.* Р.Сибат. *Барча мәхшәр, һәммә кан коюлар шушы каһәр суккан Киевтагы тәхет аркасында гына килеп чыккан.* В.Имамов

◊ **Мәхшәр көне** 1) Кешеләрнең, үлгәннән соң, Аллаһ катында хисап тотар өчен җыеласы көн; Кыямәт көне. *Мәхшәр көне – кешелек дөньясының җирдә яшәүдән туктау көне, бөтен буын кешеләренең очрашу көне.* Мөнәҗәтләр. *Шушылай була икән ул мәхшәр көне, я Алла!* Г.Афзал. *Мәхшәр көне турындагы дини риваятьләр менә шуннан килеп чыккан, «денсезләрне» күктән иңәчәк коточкыч җәзалар белән куркытканда, борынгы пәйгамбәрләр Җир тарихындагы менә шундый фактлардан файдаланганнар.* Галәм. Җир. Кеше; 2) Ыгы-зыгылы көн. *Тирә-як авылларда мәхшәр көне башлана.* Ф.Бәйрәмова. *Әйтерсең лә мәхшәр көне: Мәш килә халык Казанда.* Ф.Әһлия. **Мәхшәр кубу** Шау-шу, ыгы-зыгы, тавыш башлану. *Әрле-бирле әнә шулай чаба торгач, ал таң аткан, кояш чыккан. Һәм шәһәрдә әллә нинди мәхшәр купкан.* Ф.Яруллин. *Шул хәлне ачыклау-бәяләү өчен, иртәгесен авылда мәхшәр купты.* Ш.Шәйдуллин

МӘХШӘ́Р МӘЙДАНЫ *и. дини* Кыямәт көнендә кешеләрнең каберләреннән терелеп җыеласы урын

МӘҺАБӘТ *с. гар.* 1) Сокланырлык, матур, күркәм. *Диңгездән килгән җылы һава, тын, мәһабәт каштан бакчасы, ак фураҗкалар, көмеш трубаларның сихерле тонык аһәңе ---.* М.Мәһдиев. *Болар һәммәсе халык күңелендә язучының матур, мәһабәт образын тудырды.* Р.Фәйзуллин. *Әгәр дә шушы минутта Кадимбикәне Исмегөлдән дә мәһабәтрәк, тирәнрәк итеп уйнап булса, ул чакта, бәлки...* М.Маликова

2) Зур, төз гәүдәле, озын буйлы (кеше тур.). *Эре сөякле, озын буйлы бу кеше кайчандыр бик мәһабәт-таза булганга охшый ---.* Ә.Еники. *Алар арасында Булат абыйларының мәһабәт гәүдәсе әллә каян аерылып тора.* Ф.Яруллин. *Әйләнә уртасында таза гәүдәле мәһабәт бер ир-ат басып тора иде.* Р.Мөхәммәдиев

3) Зур, биек; сокланырлык, таң калырлык. *Меңләгән тонналы мәһабәт тау янында йөрүче кешеләр кырмыска гына булып күренәләр.* М.Мәһдиев. *Монда йортлар аграк, агачлар – бездә дә үсә торган нарат-чыршы, каенимәннәр – тагын да зуррак, биегрәк, мәһабәтрәк булып үсә икән.* М.Маликова. *Мәһабәт нарат һәм чыршы урманнары өстендәге зәңгәр күктә һәрвакыт кояш елмаеп торсын, дөньялар имин булсын.* М.Хәсәнов

4) Матур һәм көчле (тавыш тур.). *--- аларның [пароходларның] берсе кычкыртып җибәрде дә бөтен Идел өстен яңгыратты; икенчесе кычкыртты да калын, куәтле һәм мәһабәт тавышы белән тауларны, урманнарны тотты ---.* Ф.Әмирхан. *Менә якыннан ишетелгән көчле тупның мәһабәт тавышы, юеш, караңгы урманның тынычлыгын бозып, урман буйлап шаулап китте.* К.Тинчурин. *– Шөкер әле, Нургали туган! – диде ул гаять көр, мәһабәт тавыш белән.* Ә.Еники

МӘҺАБӘТЛЕ *с.* 1) Матур, сокланырлык; зур, бөек. *Мәһабәтле, озын буйлы Мөхәммәдьярыбыз бардыр.* Г.Тукай. *Тау башында тезелеп гаскәр тора, Мәһабәтле йөзен балкытып.* М.Җәлил

2) Көчле, олуг, сокланырлык. *Мәһабәтле ул гаскәр Тора таулар башында!* М.Җәлил. *Ата кеше үзенең ишле балалары белән бергә булганда аерата горур һәм мәһабәтле күренгән кебек, иҗатчы да үз «балалары» – әсәрләре – исән-имин бер ышанычлы төштә тупланган очракта көчлерәк.* Р.Фәйзуллин

МӘҺАБӘТЛЕК *и.* Мәһабәт булу. *Әмма дулкынланганда чын ул диңгез – нинди мәһабәтлек, бөек олылык аңарда!* Ш.Галиев. *Минем шул вакыт, шатлыктанмы, әллә бу мәһабәтлекне кабул итеп бетерә алмауданмы, сулышым кысылды, йөрәгем еш-еш типте.* М.Мәһдиев. *Чын-чынлап гашыйк булу өчен, мәһабәтлек, чибәрлек кенә дә җитми бит әле ул.* М.Әмирханов

МӘҺАРӘТ *и. гар.* Осталык, маһирлык. *Аучы мәһарәт белән шома гына ау астыннан чыкты.* Әкият. *Фәкать шунысы бар: аның чын көче, чын мәһарәте «Кызганыч бала»да Шәфыйка ролендә, «Бәхетсез егет»тә Гайни ролендә ---.* Г.Тукай. *Пьесаны бу юлда артистлар шундый бер иттифак вә шундый бер мәһарәт белән уйнадылар ки, караучыларга җуелмаслык авыр, ләкин дөрес тәэсир калдырдылар.* Ф.Әмирхан

МӘҺӘР *и. гар.* **1.** Мөселман халкында, никахлашканда, кияү тарафыннан кызга бирелә яисә билгеле бер вакыттан соң бирелергә вәгъдә ителә торган акча, мал яки башка нинди дә булса милек. *Мәһәр ике йөз сум булырга, Мәрфуга әбинең сыеры эчендәге чуар тана язылырга, Садыйк абзыйның алачагы читек-кәвеш, камзул, түшәкястык белән йөз илле сумы тәмам, илле сумы мөәҗҗәл булырга сүз беркетелде.* Г.Исхакый. *Мөхафизә артыннан мәһәр булып килгән ике йөз баш һәм үзләре ишәйткән өч йөз баш сарык бу чорда өч мең башка җитеп ишәя.* А.Хәлим

2. *с. мәгъ.* Мәһәргә бирелгән. *[Хөснелхәят әбинең] Беләгендәге беләзегенә җитмеш биш ел. Тәһир бабайның мәһәр бүләге...* А.Хәлим

МӘҺӘРЛЕК *и.* 1) Мәһәргә бирелә торган акча, мал яки башка бер милек. *Кызга мәһәрлек – туена чәй-шикәрлек.* Мәкаль

2) Мәһәргә җитәрлек. *Өйләнә торырга, сәүдә эшенең җаен караштырырга бик мөмкин, өйләнмәгән егеткә мәһәрлек мая да тупларга кирәк ич!* Т.Әйди

МӘЧЕ *и.* Мәчесыманнар семьялыгыннан күсе һәм тычканнар тота торган йорт хайваны; песи. *Сабира карчыкның яраткан мәчесе Каракай да, хуҗасы җирләнгәч, читкә китеп югалды...* Р.Шәфигуллин. *Мәче юкка гына сырпаланмый ул.* Т.Миңнуллин. *Балык ашаган мәче баласын күзәтәм, – кем өйрәткән дисең, белеп туган бу!* Ш.Галиев

◊ **Мәче ашаган** Эзсез югалган

МӘЧЕ́ БАШЛЫ ЯБАЛАК *и. зоол.* Ябалаклар семьялыгыннан зур күзле, ыргак сыман томшыклы, йомры башлы ерткыч кош; өке; *русчасы*: **филин**. *Шушы караңгы тынлыкка түзә алмагандай, зарланган тавыш белән кайсыныңдыр әвенендә мәче башлы ябалак иңрәп алды.* Г.Бәширов. *Камның түшендә балык тешләре, тире сырмасына төрле ялтыравык ташлар такканган, сул иңендә ике елан эленеп тора, уң иңендә мәче башлы ябалак утыра.* М.Хәбибуллин. *Балыкчылар янында мәче башлы ябалактан да сагаясы юк.* М.Рафиков

МӘЧЕ́ БОРЧАГЫ *и. бот.* Кузаклылар семьялыгыннан күпьеллык, сирәк кенә берьеллык үсемлекләр ыругы; песи гөле, дөя сеңере; *русчасы*: **астрагал**. *Бу үлән безнең ишегалдында – баскыч төбендә үсә, исеме – мәче борчагы.* М.Мәһдиев. *Тагын да соңрак, май ахырларында, яңа урамдагы Әлфия апа бакчасында, бөтнек чәчә торып, мәче борчагы басып алган?!* З.Хөснияр

МӘЧЕ́ БӨТНЕГЕ *и. бот.* Иренчәчәклеләр семьялыгыннан өчпочмаксыман яфраклы, вак чәчәкле күпьеллык үлән үсемлек; песи койрыгы; *русчасы*: **котовник кошачий**. *Мәче бөтнегенең исен мәчеләр ярата һәм алар аның яфракларын бик теләп ашыйлар.* Татарстанның үсемлекләр һәм хайваннар дөньясы

МӘЧЕ́ КОЙРЫГЫ *и. бот.* Ташгөлчәләр семьялыгыннан берьеллык чүп үлән; песи койрыгы, елкылдык; *русчасы*: **подсвекольник**

МӘЧЕ́СЫМАННАР *җый. и.* Ерткыч хайваннар отрядыннан йомры башлы, озын койрыклы төрле зурлыктагы хайваннарны (мәс., песи, арыслан) берләштергән имезүчеләр семьялыгы. *Мәчесыманнар йөргән чакта тырнакларын эчкә тарта ала, бу аларга тавышсыз гына табышына якынаерга мөмкинлек бирә.* Биология. *Юлбарысны мәчесыманнар семьялыгыннан дип уйласак, киләсе елда ни көтәдер, белгән юк.* Шәһри Казан. *Мәчесыманнар янына ашкынып бардым, чөнки биредә күптәнге танышым – җәнварлар патшасы Дик атлы арыслан бар.* Татарстан яшьләре

МӘЧЕТ *и. гар.* Мөселманнар җыелып намаз укый, гыйбадәт кыла торган, гадәттә манаралы һәм михраблы корылма. *Бераздан ярым караңгыда мәһабәт булып калкып торган зур мәчет янына килеп чыктылар.* Г.Бәширов. *Ишегалды мәчет эче кебек тын, караңгы.* М.Әмир. *Хәер, мәчет катында кечкенә мәдрәсә булган, әмма ләкин электр да, клуб та булмаган.* Ә.Еники

◊ **Мәчет карты** Дин тота торган, мәчеткә йөри торган карт. *Ләкин Закиров бераздан, үзенең кайда икәнен дә онытыр дәрәҗәгә җитеп, сәҗдәгә киткән мәчет карты кебек талгын бер рәхәтлеккә чумды.* Р.Кәрами. *Менә шул кеше, хәзер инде мәчет карты, миңа урыс теленнән ныклы нигез салып калдырды.* Т.Галиуллин

МӘЧЕТЛЕ *с.* Мәчете булган. *Мәчетле авыл – бәхетле авыл ул.* Р.Миңнуллин. *Тирә-юнь авыллары халкы Олы Елганы Мәчетле авыл дип тә атап йөрткән.* Ф.Гарипова. *Мәчетле авыл, мин монда дигәндәй, ерактан ук күренеп тора, мәчет манарасы маяк сыман сиңа юл күрсәтә, мәчетле авыл янынан үтеп китүе җанга тынычлык бирә.* Т.Миңнуллин

МӘЧЕТ-МӘДРӘСӘ *җый. и.* 1) Гыйбадәт кылу һәм дин сабаклары алу урыннары. *Болгар дәүләтендә, алар килгәнче үк инде, ислам дине*

таралган, мәчет-мәдрәсәләр, имам-хатиблар һәм мөәзиннәр күп булган. Р.Фәхретдин. *Татар байлары булган һәр шәһәрдә мәчет-мәдрәсәләр салына.* Ә.Еники. *Мәчет-мәдрәсәләр дә күп түгел икән.* З.Зәйнуллин

2) Эчендә яки янәшәсендә мәдрәсәсе булган мәчет. *Төп урамның уртарак бер төшендә, мәчет-мәдрәсәгә дә якын, базардан да ерак түгел, каршыда гына тимер юлга чыга торган кыскарак тагын бер урам башлана.* Ә.Еники. *Элекеге мәчет-мәдрәсәгә урнаштырдылар.* Р.Батулла. *Авыл белән җыелышып мәчет-мәдрәсә салырга ният иткәч тә, иң беренче булып һәр җирдә ул башлап йөргән* ---. Р.Вәлиев

МӘЧЕ́ ҮЛӘНЕ *и. бот.* Валериана-чалар семьялыгыннан вак, исле чәчәкле, тамыры дарулар ясаганда кулланыла торган күпьеллык үлән үсемлек; *русчасы*: **валерьяна**

МӘЧКӘЙ *и. миф.* 1) Убырлы карчык. *Мәчкәй – тәңренең убыры.* Әйтем. *Мәчкәйнең эчендә еланы бар.* Әкият

2) *күч.* Явыз, комсыз, начар күңелле кеше. *Дөрес, хатыны мәчкәй инде, сараннның сараны.* Х.Камалов

МӘШӘКАТЬ *и. гар.* 1) Һәртөрле эш, шөгыль, ыгы-зыгы; тынычсызлык. *Балкондагы кар бер көн эчендә җәбеп тама башлады, балкон чистарту дигән яз мәшәкате туды.* М.Мәһдиев. *Шундый мәшәкатьләр белән көннәр уза торды.* Ф.Яруллин. *Өйдәгеләре онытканнар димме, әллә хатыны йорт мәшәкатьләреннән бушап өлгермиме?* К.Кәримов

2) Газап, авырлык, кыенлык; борчу, тынгысызлык. *Мал мәшәкать тудыра.* Мәкаль. *Гомер буенча шундый хурлыкта, шундый рисвайлыкта, шундый газапта мәшәкать чиккәнче, үлүең меңмең өлеш артык!* Г.Камал. *Әнием, шул бер таба уалманы пешереп җибәрер өчен, нихәтле мәшәкать кичергәндер әле.* Л.Ихсанова

◊ **Мәшәкатькә бату** Вак-төяк эшләре, борчулары, мәшәкатьләре күп булу. *Һәм без гомер кичерәбез мең мәшәкатькә батып, Буйсынып үзебез сүккән законнар, указларга, Үзебез үк рөхсәт биреп шундыйларны язарга...* Р.Харис. **Мәшәкатькә күмелү** *к.* **мәшәкатькә бату**. *Барысын күңеленнән себереп ташлап, эшкә, мәшәкатькә күмелде.* Х.Камалов. **Мәшәкатькә салу** Кемгәдер кыенлык тудыру, борчу. **Мәшәкатькә чуму** *к.* **мәшәкатькә бату**. *Әни болай да башы-аягы белән мәшәкатькә чумган, минем өчен дә күз яше түкмәсен дип кенә мәктәпне тәмамлап чыгарга вәгъдә бирдем.* К.Миңлебаев. **Мәшәкать чигү** Мәшәкатьләнү, нужалану, зәхмәт чигү. *Мәшәкать чиктем, эзләдем, таптым [кызны].* Г.Исхакый. *Ятарга да йокларга кирәк иде, болай да кып-кыска төндә мәшәкать чигәргә әллә.* М.Әмир

МӘШӘКАТЬЛӘНДЕРҮ *ф. к.* **мәшәкатьләү**. *[Сорур:] Зинһар бул, Кәрим җаным, мине болай мәшәкатьләндермә!* Г.Исхакый

МӘШӘКАТЬЛӘНҮ *ф.* Интегү, борчылу, азаплану; эшләү, тик тормау. *Төшендә ул [Гайшәтти] бик озаклап, мәшәкатьләнеп ит ашаган, һәм шул көнне үк кәефсезләнде.* М.Мәһдиев. *Ул чакта инде бәрәңге ашап мәшәкатьләнмәячәкбез, шул Колорадо кортларын үрчетү өчен генә утыртсак инде...* М.Галиев. *Шофёр агайлар аяк киемнәрен алмаштырып мәшәкатьләнмиләр, урам тузанын рәхәтләнеп ташыйлар, юып кына өлгер.* Р.Габделхакова

Мәшәкатьләнеп алу Кыска вакыт аралыгында мәшәкатьләнү; бераз мәшәкатьләнү. *[Кәрим:] Синең артыңнан йөреп мәшәкатьләнеп алам.* Г.Исхакый

Мәшәкатьләнеп йөрү Озак вакыт дәвамында мәшәкатьләнү; һәрдаим мәшәкатьләнү. *[Хәдичә:] Рәхмәт мәшәкатьләнеп йөрүеңә, Таифә әби.* А.Гыйләҗев

Мәшәкатьләнеп тору Әледән-әле, еш мәшәкатьләнү; хәзер мәшәкатьләнү. *--- ә сез ул нәрсә белән мәшәкатьләнеп тормагыз, Сидор Андреевич, безнең арада эчә торган кеше юк!* В.Нуруллин. *Күмеп мәшәкатьләнеп тормадылар, аны авыл халкына калдырдылар.* З.Зәйнуллин. *Әллә чынлап әйтә, әллә үзенең артык мәшәкатьләнеп торасы килми.* Сөембикә

МӘШӘКАТЬЛӘ́Ү *ф.* Борчу, тынычсызлау. *[Артист:] Гафу итегез, туташ... Тән җылынып киттем дә сезне мәшәкатьләмим дидем...* Г.Исхакый. *[Нина Михайловна:] Кеше мәшәкатьләп йөрмик инде...* А.Гыйләҗев

Мәшәкатьләп тору Мәшәкать тудыру. *Бу юлы без әтине мәшәкатьләп тормадык – баянда абый белән үзлегебездән өйрәнә башладык.* Р.Вәлиев. *И-и, шулай мәшәкатьләп торабызмы?* Ф.Мөслимова. – *Сергейны мәшәкатьләп тормыйм инде, туры аэропортка китәм, – диде ир.* Д.Булатова

МӘШӘКАТЬЛЕ *с.* 1) Борчулы; ыгы-зыгылы. *Беренче тапкыр йомышы төшкән кеше эшнең иң тыгыз, мәшәкатьле чагына туры килә.* Ш.Галиев. *Аның кайгы-хәсрәтле, уйлы-моңлы, моннан тыш өстенә бүлек җитәкчесе вазифаларын кабул итеп алган мәшәкатьле көннәре иде.* Ә.Сәлах. *Шәһәр тормышы шулай мәшәкатьле ул.* М.Юныс

2) Зур эш белән мәшгуль булган. *«Хуҗа»ның бүген бик мәшәкатьле көне иде.* Р.Мөхәммәдиев. *Яз башы – авыл халкы өчен аеруча үзенчәлекле, мәшәкатьле вакыт.* Д.Гайнетдинова. *Май ае – мәшәкатьле ай, Еш ялгыз калгансыңдыр.* Р.Камалетдинова

3) Авыр, катлаулы, кыен; газаплы. *Мәшәкатьле һәм авыр походка чыгып киттек.* М.Җәлил. *Берьюлы тугыз йорт, аның өстенә каралты-кура яңарту бик кыен, мәшәкатьле булачак иде.* А.Гыйләҗев. *Чөнки яңа фикерне реальләштерергә кирәк була, ә ул мәшәкатьле.* М.Мәһдиев

МӘШӘКАТЬЛЕЛЕК *и.* Мәшәкатьле булу хәле. *Аны авылның мәшәкатьлелеге куркытты бугай.* Казан утлары

МӘШӘКАТЬСЕЗ *с.* **1.** 1) Борчусыз, ыгы-зыгысыз. *Мәшәкатьсез, тыныч балалар, сүз дә юк.* Л.Ихсанова. *Китсә дә гаепләүче булмас: хәзерге яшьләрне дөнья малы ымсындыра, мәшәкатьсез тормыш кызыктыра...* А.Әхмәтгалиева

2) Җиңел; катлаулы булмаган, авырлык китермәгән. *Менә монысы мәшәкатьсез үлемгә охшаган.* З.Мәхмүди. *Кышкы юл – сазлыклар арасында урнашкан Себер татар авыллары өчен иң мәшәкатьсез юл.* Н.Алан

2. *рәв. мәгъ.* Җиңел итеп, җайлы гына, мәшәкать күрмичә. *Без мәшәкатьсез*

генә яшәргә яратабыз. Н.Әхмәдиев. *Язучы дигән абруйлы исемгә тиз генә, мәшәкатьсез генә ирешеп, беренче каты тәнкыйть сүзе ишетүгә кире чигенүчеләр, язучылык эшен бөтенләй ташлаучылар була; әдәбият тарихы мондыйларны да хәтерли: йөрәк кушуы буенча килмәгәннәр алар әдәбиятка.* Н.Фәттах

МӘШӘЛӘНҮ *ф. диал.* Көч куеп, куелган максатка, берәр нәрсәгә ирешергә тырышу; маташу. *Мәшәләнә торгач, әйләнеп менеп утырды.* Ф.Кәрим. *Карасак, балалар күл буенда мәшәләнәләр.* А.Гыйләҗев. *Фәрдәнә дә бүтән каршы сүз катмады, аш ягына чыгып, нәрсәдер эшләп мәшәләндә.* Х.Камалов

Мәшәләнеп тору Сөйләү моментында мәшәләнү. *Шушы эшләр белән мәшәләнеп торганда, алар янына тагы Сөенчалин килде һәм боларның кулына кирәкле кәгазьләр тоттырды.* Х.Камалов

МӘШГУЛЬ *хәб. сүз. гар.* Нинди дә булса эш белән шөгыльләнү, нидер эшләү. *Ул үзенең куенына әле генә килеп кергән бер улын йоклату белән мәшгуль.* М.Мәһдиев. *Үзе тыз-быз эш белән мәшгуль: казларга, тавыкларга җим сибеп, казан астына ягып җибәрде, күп итеп чыра телеп, кучкарга матурлап өйде.* Р.Батулла. *Тукай көнозын кымызчы казакълар янында яки үз бүлмәсендә язу-сызу, газета-журналлар уку белән мәшгуль.* С.Сабиров

МӘШГУ́ЛЬ БУЛУ *ф.* Ни белән дә булса шөгыльләнү. *Шешә ачу белән мәшгуль булса да, Мисбах моны күреп алды һәм исе китмичә генә: – Аша, аша, кыенсынма! – диде.* Н.Әхмәдиев. *Шуңа күрә мулла абзый үз эшләре белән мәшгуль булды: ат карады, абзар тазартты, малларга печән салды, кар көрәде...* С.Поварисов. *Күрәсең, аягы таеп, чокырга туры килде, һәрберсе үз эше белән мәшгуль булганга, сүз-фәлән әйтүче булмады, көлүче дә күренмәде.* Р.Мулланурова

МӘШГУЛЬЛЕК *и.* Мәшгуль булу. *Һич тә яшермим, хәтта шагыйрьләрнең дә мондый халәткә күтәрелгән минутлары сирәк була, алар, күбрәк үз кемлекләре хакында мәшгульлекләре аркасында, анда ук ирешә алмый калалар.* Ф.Яхин. *Безнең елмаймау мәшгульлек кенә түгел.* Ш.Галиев

МӘШКӘ *и. диал.* Гөмбә

МӘШКӘК *и. диал.* 1) Куык гөмбә, саңгырау гөмбә; русчасы: **гриб-дождевик**

2) Агач эчендәге черек. *Яфрак гөмбәчеге үзагачны тишеп чыга торган гөмбәлектән (мицелий) һәм агач кайрысы өстендә сузынкы-цилиндрсыман яки тояксыман утырма эшләпәләр булып киткән мәшкәктән тора*. Урман аптекасы

МӘ́Ш КИЛҮ *ф.* Ыгы-зыгы килү, нәрсә белән дә булса бик мәшгуль булу. *Мәчет янындагы чирәмдә атларын тугарып, тәртәләрен югары күтәреп бәйләгәннәр дә мәш килеп арбаларын чишеп маташалар.* Г.Бәширов. *Шулар белән мәш килеп йөргәндә, күзе бүлмә ишегенә төште.* Ф.Яруллин. *Оркестр чокыры да тик тормый, анда музыкантлар үзләренчә мәш килә.* Р.Низамиев

МӘШРИКЪ *и. гар. кит.* Көнчыгыш. *Атына мәшрикътә атланып, мәгърибкә – Карпат тауларына барып җиткән.* Ә.Баян. *Иртәне ул түземсезләнеп көтеп алды, мәшрикъ ягы аллана башлауга, болдырга чыкты ---.* А.Гыйләҗев. *Үзе үк әйтмешли, кояш мәгърибтән чыгып мәшрикътә батса да шалтыратмаячак.* А.Әхмәтгалиева

МӘШРУГ *с. гар.* Шәригать рөхсәт иткән, шәригатькә каршы килми торган. *Даим хатыннар белән шөгыльләнмәк, бертоташ нәфес арзусына хезмәт итмәк мәшруг булырмы икән?* К.Насыйри

МӘШҺҮР *с. гар.* **1.** Танылган, атаклы, атказанган, шөһрәт казанган, данлыклы. *Кыскасы, тирә-якта шактый мәшһүр авыл булган ул.* Ә.Еники. *Киемнәре шәп булгач (ак нейлон күлмәк, кара фрак – нәкъ менә халык артисты, мәшһүр дирижёр инде), мин аны юньле заттыр дип уйлаган идем.* М.Мәһдиев. *Ә бит мәшһүр уллары, җитәкчеләре турында халыкның күбрәк беләсе килә...* Р.Вәлиев

2. *хәб. мәгъ.* Танылган булу. *Шәһәрдә бит инде әллә кайчан ул Хәбиб Фәһмиевич дип мәшһүр.* М.Мәһдиев

МӘШҺҮРЛЕК *и.* Мәшһүр булу. *Заманында ислам дөньясында мәшһүрлек казанган татар галимнәре байтак булган.* Р.Батулла. *Ул кинофильмнардан ишеткән теләсә нинди җырыңны отып алыр да, зур мәшһүрлек казанган тенорларың сыман, тәмам җиренә җиткереп башкарыр иде.* К.Миңлебав. *Шушы амплуа аңа мәшһүрлек китерә.* А.Арсланов

МӘЭЛДӘ́Ү *ф. Мә-ә, мәэ* сыман тавышлар чыгарып кычкыру. *Кысылганмы, читәнне мөгезе белән аралап чыгарга азапланамы, кызганыч итеп мәэлди: иреккә чыгарсана, ди кебек.* Р.Батулла. *Тыштан ара-тирә сыер мөгрәгән, сарык мәэлдәгән тавышлар ишетелеп куя.* Ә.Моталлапов. *Аның сүзен җөпләгәндәй, Саматлар абзарыннан сөенечле мәэлдәү ишетелде.* А.Гыймадиев

Мәэлдәп алу Бераз гына мәэлдәү

Мәэлдәп җибәрү Кинәт кенә мәэлдәгән тавышлар чыгару. *Менә-менә мәэлдәп җибәрер төсле кызганыч тавыш белән.* Өмет

Мәэлдәп йөрү Әле, хәзерге вакытта яки еш мәэлдәү

Мәэлдәп кую Бер тапкыр мәэлдәгән тавыш чыгару. *Бәти ишетелер-ишетелмәс кенә мәэлдәп куйды.* Р.Батулла

Мәэлдәп тору Бертуктаусыз мәэлдәү. *Арт капкадан да, урам капкасыннан да күренмәгәч, бердәнбер кәҗәсе дә, көтүдән кайтып, капка төбендә ике-өч көн мәэлдәп торгач, Ярмөхәммәт койма өсләтеп ишегалдына төште.* Р.Батулла. *Караван янындагы яртылай ачык тәрәзә каршында ак кәҗә мәэлдәп тора.* С.Сабиров. *Ике бозавы, сарыклары, Зоя исемле кәҗәсе бәтиләре белән мәэлдәп торалар.* Татарстан яшьләре

Мәэлди бирү Бернигә дә карамастан мәэлдәүне дәвам итү

МӘЭЛДӘШҮ *ф. урт. юн. к.* **мәэлдәү**. *Китте мөгрәү, китте мәэлдәшү...* Н.Әхмәдиев. *Алар берсен икенчесе уздырышып мәэлдәшә: җиңүчене мактый, җиңүче тирәсендә көязләнеп боргаланырга тотынды.* Р.Мөхәммәдиев

МӘЭЮС *с. гар.* **1**. Өметсез; боек. *Алар, сыер күзләре төсле, һәрвакыт*

кайгылы, хәсрәтле, мәэюс иделәр. Т.Галиуллин

2. *рәв. мәгъ.* Өметсезләнеп; берни дә өмет итмичә; боегып. *Хыялымда, хастаханә тәрәзәсеннән урамда аккан ташу суларына мәэюс кенә карап, үткәндәге матур вә күңелсез мизгелләрне хәтерендә яңарткан илаһи да, мәҗнүни дә артистка язмышын гәүдәләндерергә җыенган идем.* Ә.Рәшит. *Көтәрмен мин шулай мәэюс әҗәлемне.* Р.Батулла. *Чыгуын күргәч, мафиячеләр тагын да читкәрәк тайпылдылар да, нүжәли котылырбыз икән бу бәладән дигәндәй, мәэюс кенә күз текәп тора башладылар.* Ф.Баттал

МӘЭЮСЛӘНҮ *ф.* Өметсезләнү, өметсезлеккә төшү. *Шактый озак сөйләшеп утырды ул кичне яңа табылган, рухы төшкән, өметсезләнгән, тәмам мәэюсләнгән энесе белән Казан мафиясе башлыкларының берсе.* Т.Галиуллин

Мәэюсләнә бару Торган саен ныграк мәэюсләнү

Мәэюсләнеп тору Беркадәр вакыт мәэюсләнгән булу. *Шулай мәэюсләнеп торганда, борыныма тәмәке исе килеп бәрелде.* З.Мәхмүди

МӘЭЮСЛЕК *и.* Өметсезлек. *Сине юатырлык, сине мәэюслек хәленнән чыгарырлык, әбиемнең исән булуына өмет уятырлык бер кешең булса иде яныңда.* В.Нуриев

МЕ́БЕЛЬ *и. лат.* Кеше яши һәм эшли торган биналарда утыру, яту, әйбер саклау һ.б.ш. өчен билгеләнгән җиһаз. *Бәргәләнә торгач, анда-монда сугылып тәмам сөмсере коелган Нәҗип мебель кибетенә грузчик булып эшкә керде.* А.Гыйләҗев. *Тиле наратның матур кызгылт төстәге үзагачы соңга табарак кыйммәтле мебель эшләүдә киң кулланылган.* Дөньяда ниләр бар. *Синтетикадан үтәкүренмәле оранжерея түбәләре, обсерватория гөмбәзләре, уңайлы мебель һәм күп кенә башка көнкүреш әйберләре ясыйлар.* Химиянең киләчәге

МЕ́БЕЛЬЧЕ *и. сөйл.* 1) Мебель, төрле өй җиһазлары ясау остасы

2) Өй җиһазлары ташу, сату һ.б.ш. хезмәттә эшләүче кеше. *Дөрес, ире эшләде: кирәгендә мебельче грузчик булды, йөз чөермәде – кулына себерке тотты, авыр чүкеч белән тимер чүкеде ---.* А.Гыйләҗев

МЕ́ГА- *гр.* 1) Кушма сүзләрдә «бик зур, гигант күләмле» мәгънәсен белдерә торган беренче кисәк (мәс., *мегаполис*)

2) Физика берәмлекләренең атамаларында «миллион тапкыр зуррак» мәгънәсен белдерә торган беренче кисәк (мәс., *мегабар, мегагерц*)

МЕГАБАЙТ *и. ингл. информ.* Электрон исәпләү техникасында миллион байтны тәшкил иткән мәгълүмат үлчәү берәмлеге

МЕГАВАТТ *и. физ.* Миллион ватт. *Мәсәлән, Германиядә җил көче белән 505 мегаватт, Һиндстанда 375 мегаватт электр энергиясе җитештерелә.* Казан утлары

МЕГАГЕРЦ *и. физ.* Бер миллион герцны тәшкил иткән тирбәлеш ешлыгын үлчәү берәмлеге. *Ай өстендәге станция белән радиоэлемтә тотрыклы. Тапшыру 183, 538 мегагерц ешлыкта алып барыла.* Социалистик Татарстан

МЕГАПО́ЛИС *и. гр.* Берничә шәһәр һәм торак пунктларның үсеп кушылуы нәтиҗәсендә барлыкка килгән гигант шәһәр. *Хәзер дөньяның иң эре мегаполисы булып Токио санала, анда 34,2 миллион кеше яши.* Мәдәни җомга

МЕГАТО́ННА *и. гр.-фр.* Миллион тонна. *Очыш мәйданында, күкләргә ыргылып, ничә мегатонна тора ярсып...* Р.Әхмәтҗан

МЕГАФЕ́РМА *и. гр.-ингл.* Бик зур, гадәттә берничә юнәлешне берләштергән терлекчелек хуҗалыгы. *Авыл халкын эш белән тәэмин итәрлек мегафермалар төзелде.* Ватаным Татарстан. *2000 елдан монда Европада иң зурлардан саналган сөт мегафермалары барлыкка килде.* Идел

МЕГАФО́Н *и. гр.* Сөйләүченең тавыш көчен арттыру өчен, сөйләгәндә авыз турысына куела торган чагыштырмача гади төзелешле җайланма, рупор. *Урам уртасына мегафон тотып милиционер баскан, тәртип бозганны кисәтә ---.* Ш.Галиев. *Зур катердан, инглизчәләтеп, мегафон тавышы ишетелде: – Әй, «Меконг»тагылар! Бөтенләй туктагыз!* И.Хуҗин

МЕГЕ́РА *и. гр.* 1) Борынгы грек мифологиясендә үч алучы алиһәләрнең – эринияләрнең – башында чәч урынына еланнар булган ямьсез карчык итеп күзалланган берсе

2) Бик усал, явыз, талашучан хатын. *Ярдәмчел, киң күңелле, беркатлы, эчкерсез булып күренгән Оляның асылда мегера – миһербансыз зат булуы башыма да килмәде бит.* Г.Тавлин

МЕД- Кушма сүзләрдә «медицина» сүзеннән кыскартылган компонент, (мәс.: *медпункт, медсанбат, медэкспертиза*). *[Мидхәт абый] --- медфакка хәзерләү курсларында да укый.* Ж.Фәйзи. *Ахырда медтехникумга керде [Туфайлов]. Табиблык юлы шулай башланды.* Х.Камалов

МЕДАЛИСТ *и.* Медале (*2 мәгъ.*) булган, медальга лаек булган зат. *Тимер капка, капка төбендә үк ике эт, берсе – медалист, доберман пинчер, икенчесе – овчарка.* А.Гыйләҗев

МЕДАЛЬ *и. лат.* 1) Хезмәттә ирешкән зур уңышлар өчен яки сугышта күрсәткән батырлыклар өчен бирелә, түшкә яки муенга тагып йөртелә торган, өстенә рәсем, язу төшерелгән махсус билгесе булган дәүләт бүләге. *Җинаятьләрнең барысын да ачкансыз, дип мактарлар. Йөз процент! Медаль биреп куюлары да бар.* М.Насыйбуллин. *Кырык дүртенче елдан алып соңгы көненә кадәр сугышта булган, өч медаль, бер орден тагып, лейтенант чины алып кайткан егет иде ул.* В.Нуруллин. *Медальләрен тага бүген бөтен ирләр... Кайберләрен бүген пуля түгел, – ега кургашындай хәтерләр!..* Р.Әхмәтҗан

2) Мәктәпне иң югары билгеләргә тәмамлаган укучыларга, олимпиада, чемпионат кебек спорт ярышлары җиңүчеләренә һ.б.ш. бирелә торган махсус билге. *--- китабына ябышкан, укый да укый, белемне су урынына эчә, алтын я көмеш медальгә тартмагае.* Ф.Садриев. *--- аларга беренче тапкыр махсус ясатылган «Сабантуй батыры» медале белән яшел бәрхеттән тегелгән янчык-капчыкка салынган акчалата бүләкне тапшырулары тантанага үзенчәлекле ямь өстәде.* Т.Нәҗмиев. *Израильдә нәфис гимнастика*

буенча узган халыкара турнирдан Татарстан кызлары Лиана Семёнова – өч алтын, Камилла Гатиатуллина – алтын һәм ике көмеш, Эллина Солтанова алтын һәм ике бронза медаль алып кайттылар. Сөембикә

3) Зур тарихи яки мөһим иҗтимагый вакыйгага, күренекле шәхескә багышлап чыгарылган истәлекле билге. *Галимнәрнең Лондон Король җәмгыяте Пристлины зур алтын медаль белән бүләкли һәм аны олылап тантаналы җыелыш үткәрә.* Робинзон эзләреннән

4) *иск. сөйл.* 1917 ел революциясенә кадәрге Россиядә авыл старостасы йөртә торган калай жетон. *Ул арада, комган төбе чаклы җиз медален тагып, кулына таягын тотып, зур кара сакаллы, тупас битле староста да килеп җитте.* М.Гали

◊ **Медальнең икенче ягы** Берәр күренешнең кирәкле, уңай сыйфаты белән берәттән бик үк кирәкмәгән яки бөтенләй тискәре ягы булу турында

МЕДАЛЬОН *и. фр.* Муенга тагып йөртелә торган, еш кына эченә истәлек итеп рәсем яки башка нәрсә куелган, түгәрәк яки озынча түгәрәк тартмачык рәвешендәге ювелир әйбере. *Синең бер рәсемең миндә саклана, паспортка төшкәнсең, мин аны медальон эченә салдым.* М.Мәһдиев. *Моисеева тикшергән саен, җилгә очкан әйберләрнең исемлеге арта бара: көмеш тартма, аның эчендәге өч алтын йөзек, дүрт чылбыр, медальон, фирәзә кашлы алка – барысы да алтын.* М.Насыйбуллин. *Анысының да муенындагы, колак һәм бармакларындагы асылташлы балдаклар, алкалар һәм медальоннар әллә кайдан күренеп, балкып тора.* З.Фәйзи

МЕДЕ́Р-МЕДЕР *иярт.* Аңлашылыр-аңлашылмас кына, басынкы тавыш белән, әкрен генә, ишетелер-ишетелмәс. *Медер-медер килеп нидер укынып алды, аның соңгы сүзләре генә ишетелеп калды* ---. Г.Гыйльманов

МЕ́ДИА- *ингл.* Кушма сүзләрдә «массакүләм мәгълүмат чараларына караган» дигән мәгънәне белдерә торган беренче кисәк

МЕДИАБАЗАР *и.* Экономик эшчәнлек өлкәсе буларак массакүләм мәгълүмат чаралары тармагы. – *Әмма кризис республика медиабазарына барыбер йогынты ясамыйча калмас, – диде М.Мораторов. – Чөнки рекламадан кергән табыш кимүгә бара.* Мәдәни җомга

МЕДИАМАГНАТ *и.* Массакүләм мәгълүмат чаралары тармагында зур байлыкка һәм йогынты көченә ия кеше. *Медиамагнатлар экраннарда кемне әйләндерсә, тамашачы шуларны көтте.* К.Кәримов

МЕДИА́НА *и. лат. мат.* Өчпочмакның түбәсен каршы яткан кырның уртасы белән тоташтыра торган туры сызык. *Өчпочмакның медианалары кисешкән нокта аның авырлык үзәге булып хезмәт итә.* Югары математика нигезләре

МЕДИА́ТОР *и. лат.* Мандолина, гитара һ.б. кайбер кыллы музыка кораллларында уйнаганда кулланыла торган юка сөяк, пластик яки металл пластинка кисәге; чиерткеч, плектр. *Галия медиаторны --- мандолинаның кыллары арасына кыстырып куйган.* А.Расих. *Скрипкада уйнавы мандолинадагы кебек үк икән. Медиатор урынына уң кулың белән смычок кына сызасың.* Ж.Фәйзи. *Аның медиаторы бервакытта да сөртенми, һәрвакыт тигез тавыш чыгарып тора. Шуның белән бергә ул мандолина грифының теләсә кайсы җирендә уйный* ---. Г.Ахунов

МЕ́ДИК I *и. лат.* Медицина белгечләренең барысын да, махсус белемен һәм дәрәҗәсен исәпкә алмыйча, гомуми атау сүзе. *Хәзер әнә медиклар язган була, тук карын белән йоклау зарарлы, «кичке ашыңны дошманыңа бир» дигән булалар...* М.Мәһдиев. *Кара җиләк – дару үләне. Аның яфраклары һәм җиләкләренең файдалы үзлекләрен медиклар һаман ачып торалар.* Татарстанның үсемлекләр һәм хайваннар дөньясы. *Күп илләрнең медиклары һәм җәмәгать эшлеклеләре тәмәке тартуга каршы көрәштә үзләренең тырышлыкларын берләштерәләр.* Биология: кеше һәм аның сәламәтлеге

МЕ́ДИК II *с.* Медицинага караган, медицина белән бәйле. --- *озакка сузылган дәвамлы очышның кеше организмына тәэсирен өйрәнү буенча киң медик һәм биологик тикшеренүләр үткәрелде.* Галәмгә юл

МЕДИКАМЕНТ *и. лат.* Теләсә кайсы формадагы дәвалау чарасының, даруның гомуми атамасы. *Ни белән файда китерә алам мин сезгә? Медикаментлар кирәкме?* Ш.Рәкыйпов. *Дошман авиациясе һөҗүмнәре, азык-төлек һәм медикаментларга кытлык, тәүлек буйларына дежур торулар...* Эзләнүләр. Уйланулар. Табышлар. *Мөселманнарга составында дуңгыз компонентлары булган медикаментлар куллану да тыела.* Мәдәни җомга

МЕДИК-БИОЛО́ГИК *с.* Медицинага һәм биологиягә караган, бер үк вакытта медицина белән дә, биология белән дә бәйле. *Космик очыш факторларының кеше организмына һәм эшчәнлегенә тәэсирен өйрәнү буенча медик-биологик тикшеренүләр ясадылар.* Галәмгә юл

МЕДИНСТИТУТ *и. рус* Медицина институты. *Ләкин егет укуны бездән алда тәмамлады да, һич көтмәгәндә мединститутта укыган бер кызга өйләнеп, башка шәһәргә китеп барды.* М.Маликова. *Әкрәмхуҗаев нәрсәнедер хәл иткәндәй йодрыкларын төйнәде, эшкә бармаска булды һәм иске мединститут ягына юл алды.* Р.Мирхәйдәров

МЕДИТА́ЦИЯ *и. лат.* Физик киренкелектән тулысынча бушанган, тышкы дөньядан вакытлыча читләшкән, шул ук вакытта игътибарны соң чиккә кадәр бер максатка юнәлткән акыл эшчәнлеге һәм шул хәләт. *Нәкъ менә риторик эндәш, өндәү һәм сораулар шигырьдәге көйләүне үзүче моментлар булып тора, тыныч медитацияне чарасызлык чигенә җиткән кичереш ноктасына ташлый, укучыга тәэсир итү алымына әйләнә.* В.Эминева

МЕДИТА́ЦИЯЛӘҮ *ф.* Медитация халәтендә булу

Медитацияләп алу Бераз медитацияләү

Медитацияләп тору Хәзерге вакытта медитацияләү

МЕ́ДИУМ I *и. лат.* 1) Спиритларның күзаллавынча, Рухлар дөньясы белән элемтәгә керә алу сәләте бар, дип

күзалланган кеше, ике дөньяга арадашлык итүче зат

2) Парапсихологиядә сизү органнарыннан тыш та үтә сизгерлеккә ия булган кеше

МЕ́ДИУМ II *и. лат. муз.* Җырчы хатын-кызларда урта регистрдагы тавыш

МЕДИЦИ́НА *и. лат.* Кешенең сәламәтлеген саклау һәм ныгытуга, гомерен озайтуга, авыруларны кисәтү һәм дәвалауга юнәлдерелгән фәннәр системасы һәм гамәли эшчәнлек. *Медицина училищесын тәмамлагач, Хәлисә шәһәрнең бишенче хастаханәсендә эшли башлады.* Ә.Гадел. *Медицина раслаганча, кимендә йөз илле яшькә кадәр яши алырлар иде.* Химиянең киләчәге. *Медицинада алколоидлар шома мускулларны ярсыту, кан басымын, физик һәм акыл эшчәнлеген күтәрү өчен файдаланыла.* Урман аптекасы. *Улы Камил Әхмәров Татарстан травматология институтында нейрохирург булып эшли. Медицина фәннәре докторы.* Мәдәни җомга

МЕДИ́ЧКА *и. рус сөйл.* Медик хатын-кыз; медсестра. *Бөтен клуб работникларын, медичкаларны, мәктәп педагогларын җәфалап бетердек.* Ф.Баттал. *--- үзе сәнгать белгече. --- Хатыны – медичка.* З.Фәйзи

МЕДКОМИ́ССИЯ *и. рус* Билгеле эшчәнлек алып бару максаты белән әзерлек, билгеле яшәү шартлары һ.б.ш. күзлегеннән кешенең сәламәтлеген бәяләү өчен, төрле белгечлектәге табиблардан төзелгән комиссия. *Ленинградта төзелгән яңа танкерга утырырга тиеш идем, медкомиссия үтә алмадым.* М.Юныс. *Медкомиссия карарын аның тәгәрмәчкә таяк тыгу дип кабул иткәнлеге сизелде.* Х.Камалов. *Күптән түгел генә малайларны медкомиссия үткәрделәр.* З.Кадыйрова

МЕДОСМОТР *и. рус сөйл.* Төрле медицина белгечләренә күренү, медкомиссия үтү. *Медосмотр үтәргә дип кенә барган иде югыйсә... Менә өченче ай инде «тикшерәләр»...* Г.Гыйльманов

МЕДПУНКТ *и. рус* Медицина ярдәме күрсәтү өчен, берәр сәнәга предприятиесе, оешма һ.б.ш. каршындагы, авылдагы амбулатор пункт. *Сөләй дус, әйдә, медпунктка барыйк, анда күзеңне дарулап бәйләрләр, бәлки, төзәлер күзең, ә?..* Г.Тавлин. *Ә мин сезне беләм. Медпунктка килгән яңа фельдшер буласыз. Шулай бит?* Ф.Сафин. *Быел ул, үзе башлап йөреп, медпунктны ремонтлатырга кереште.* Сөембикә

МЕДСАНБАТ *и. рус* Медицина-санитария батальоны; хәрәкәттәге армиядә, сугышның алгы сызыгы шартларында медицина ярдәме күрсәтүче хәрби часть һәм шул ярдәмне күрсәтү урыны. *Ул [Зәкия Туишева] сугышчылар алдында җыр-бию белән генә чыгыш ясамый, шул ук вакытта медсанбатта санитарка булып та эшли.* Сөембикә. *Сүз минем әти хакында. Аны медсанбатка илтеп җиткергәннәр, ә аннан Молотов (хәзерге Пермь) өлкәсендәге Усолье шәһәре госпиталенә озатканнар.* Идел

МЕДСАНЧАСТЬ *и. рус* Зур сәнәга предприятиесе, оешма, хәрби часть һ.б.ш. каршындагы хастаханә. *Головинны да өлкә больницасына озата киттеләр. Ул хастаханәнең бер башында хәрби медсанчасть та урнашкан иде.* Б.Камалов. *– Аңлагыз, без аны төнгә калдыра алмыйбыз, ул – җинаятьче, ул сак астында булырга тиеш, – дип үзенекен тәкрарлады МВД медсанчастеннән килгән табиб.* Р.Мирхәйдәров

МЕДСЕСТРА *и. рус* Махсус урта белемле медицина белгече, дәвалау учреждениеләрендә урта звено хезмәткәре. *--- врачлар укол арты укол кададылар, анда да тынычландыра алмагач, Нәҗипләрнең кысан фатирында медсестра саклап калгалады.* А.Гыйләҗев. *Аңыма килгән мизгелдә сине күрәм дип, саташам икән дип уйладым. Медсестра икән...* Җ.Тәрҗеманов. *– Ничек инде ул алай, үтә дип, – диде Ләйсән. – Ичмасам, медсестраны чакырып килим.* М.Маликова

МЕДУ́ЗА *и. гр. зоол.* Эчәккуышлылар отрядына караган, зонт яки кыңгырау формасындагы койкасыман тәнендә озын кармавычлары булган диңгез хайваны. *Диңгездә бүген медузалар бинисә күп күренде.* К.Миңлебаев. *Галимнәр, медуза «барометры»ннан күчереп, давыл якынлашуын хәбәр итә торган аппарат конструкцияләделәр инде.* Кызыклы ихтиология. *Планктон диңгезне шәмәхә төскә керткән иде. Яр читендә үк көмеш медузалар күренде.* Ә.Гаффар. *Балыкчыклар очкан шикелле йөзәләр, ә нәфис медузалар кечкенә генә һава шарына охшаганнар иде.* Диңгез тирәнлегендә

МЕДУЧИ́ЛИЩЕ *и. рус* Махсус урта медицина белеме бирә торган уку йорты. *Исеме Раузамы, Розалияме, әллә Розамы – хәтерләмим. Медучилищеның соңгы курсында укый икән.* Җ.Тәрҗеманов

МЕЖА *и. рус к.* **ызан**. *Бригадир бер йөк озын таяклар китереп межага салды.* М.Мәһдиев. *Башкалар өчен ул – койма кебек межа, үтеп керергә ярамый, йоласы кушмый.* К.Кәримов. *--- һава хәле аз гына үзгәреп, җил чыгу белән, умарта кортларының һәммәсе дә карабодайга әйләнеч юл белән – урман юлы буйлап һәм урман межасы буйлап оча башлыйлар иде.* Умарта кортлары

МЕЖАЛАНУ *ф. кайт. юн. к.* **межалау**. *Безнең җир межаланган бит инде.* Э.Фатыйхова. *Шул ук сурәттә аларның мунчасы да безнең бакча уртасында утыра иде, ләкин әле ул межаланмагач, без аны суд аша бакчабыздан алдырта алдык.* Безнең гәҗит

Межалана башлау Межалану эше тотыну

Межаланып бетү Барысы да межалану; межалану эше тәмамлану. *2015 ел ахырына 11 катлы яңа йортлар төзеләсе әлеге җирләр межаланып бетәргә тиеш.* Ватаным Татарстан

МЕЖАЛА́У *ф.* Межалар сызу, межалар белән аерып, бүлеп чыгу; ызанлау. *XVIII йөздә авыллар арасында җир низаглары күбәя, бер авыл җире белән икенче авыл җире арасындагы межалар билгеләнмәгән була. Хөкүмәт, бу низагны бетерү өчен, 1757 елда «межалау инструкциясе» чыгара.* Казан утлары

Межалап бетерү Барысын да межалау; межалауны төгәллә. *Икенче елга төзелеш башланасы җирләрне межалап бетерделәр генә әле.* Сөембикә

Межалап килү Үз чираты белән барысын да межалау; бер-бер артлы межалау

Межалап кую Тиз арада яки алдан межалау

Межалап тору Әле, сөйләү моментында межалау. *Без килгәндә һаман шул элеккеге җирләрне межалап торалар иде әле.* Р.Вәлиева

Межалап чыгу Барысын да башыннан ахыргача межалау

МЕЖАЛЫ *с.* Межалары булган, межаланган, межалар белән аерылган; ызанлы. *Авылга сугыш башлану турында хәбәр килеп җитә. Кешеләр, изге тирләре тамган межалы басуларын ташлап, авылга ашыгалар.* Казан утлары

МЕҖЕЛДӘҮ *ф. к.* **меж-меж итү** (*1 мәгъ.*). *[Бибиҗамал апа], яулык почмагы белән авыз-борынын каплап, йөзен читкә борды һәм меҗелдәп елап җибәрде.* Ш.Хөсәенов

МЕҖЕЛДӘШҮ *ф.* Үзара меҗелдәү

МЕҖӘ́-МЕҖЕ *рәв.* Меж-меж итеп, авыз эченнән генә (сөйләшү тур.). *Клара керә, меҗе-меҗерәк сөйләшә.* А.Гыйләҗев

МЕҖӘ́-МЕҖЕ КИЛҮ *ф. к.* **меж-меж килү** (*1 мәгъ.*). *Кайбер каләм осталары, шундый шәп язучы булуларына карамастан, үз фикерләрен җыеп әйтә алмыйча, меҗе-меҗе килеп аптырап бетәләр. Ә Аяз абый [Гыйләҗев] – оратор!* Н.Дунаев

МЕҖӘ́Р-МЕҖЕР *иярт.* Берәр сыеклыкның талгын утта әкрен генә кайнау рәвешен һәм тавышын белдерә

МЕҖӘ́Р-МЕҖЕР ИТҮ *ф.* Межер-меҗер килгән тавыш чыгару. *Балык ул тыныч утта ярты сәгать кайнасын. Межер-межер итеп, талгын гына.* Г.Мөхәммәтшин

МЕҖӘ́Р-МЕҖЕР КИЛҮ *ф. к.* **межер-межер итү**

МЕ́Ж-МЕЖ *иярт.* Авыз эченнән генә ишетелер-ишетелмәс сөйләнгәндә чыккан тавышны белдерә. *Татар агайэне сызып кына ачылган иреннәре ирек биргән чаклы меж-меж меҗелдәшә дә кет-кет кеткелдәп көлә.* И.Рәмиев

МЕ́Ж-МЕЖ ИТҮ *ф.* 1) Аңлашылыр-аңлашылмас, ишетелер-ишетелмәс әкрен тавыш чыгарып сөйләнү, метердәү

2) Чымырдау. *Уянып-уянып китәсең, рәхимсез асфальтта йөреп коргаксыган аяк сеңерләре меж-меж итеп сыкрап алалар, аның саен йоклыйсы, ыңгыраша-ыңгыраша, хөкүмәт мендәрендә авызыңнан селәгәйләр агызып йоклыйсы килә.* М.Мәһдиев

МЕ́Ж-МЕЖ КИЛҮ *ф.* 1) Сөйләгәндә, фикерне төгәл, аңлаешлы итеп әйтә алмау, кыю итеп, өздереп әйтмәү. *Меж-меж килеп сөйли татар, Булса да сүзе хаклы: Ана сөте аша килә Биш йөз еллык куркаклык...* Р.Харис

2) Ашаганда сайланып, чемченеп, ашар-ашамас утыру

3) Тәвәккәлли алмау, икеләнү, җебегәнлек күрсәтү. *Нәрсә эшләргә икәнен мин үзем беләм, Барсуков. Меж-меж килмә, аңладыңмы? Бу – сугыш. Сугыш мәетсез булмый. Я без, я алар, аңладыңмы?* Р.Сәгъди. *--- халык, амбарларны ачып, ашлыкны талап алып бетерде, озаклап, меж-меж килеп, сорау-җавап кичәсе үткәреп утырсак, монда да килеп җитәр алар.* Ф.Сафин. *[Нәсимә:] Нәрсә, татар кызы җансыз булырга тиешмени? Меж-меж килеп торырга тиешмени? [Әнвәр:] Кыю булырга тиеш.* Т.Миңнуллин

МЕҖМЕЛДӘҮ *ф. к.* **меж-меж килү**. *Менә шулай ашарга кирәк сиңа да. Болай меҗмелдәп утырсаң, үсми калырсың әле!* М.Маликова

МЕЗГА *и. рус махс.* Бәрәңге, чөгендер, виноград һ.б.ш. яшелчә яки җиләк-җимешне эшкәрткәннән соң калган, гадәттә терлек азыгы буларак файдаланылган йомшак сыгынты. *Олы терлекне силос, бәрәңге, барда, мезга, бөртекле ашлык калдыклары һәм катнаш азык (тупас, сусыл, концентрат азыклар) ашатып симертәләр.* Сөт терлекчелеге турында кыскача белешмә

МЕЗДРА *и. рус махс.* 1) Эшкәртелмәгән тиренең эчке ягындагы тире асты клетчаткасы катламы. *Аскы катта мездра машинасы зырылдарга, барабаннар үкерергә тотындылар.* А.Алиш

2) Гомумән күннең яки тиренең эчке ягы

МЕЗОЗОЙ *и. гр. геол.* Җирнең геологик тарихында палеозойдан соң, кайнозойга кадәр килә торган дүртенче эра һәм тау токымнарының шуңа туры килә торган катламы. *Мезозой чорында әнә язучылар үтә дә тыйнак булганнар. Тау куышында рәхәтләнеп яшәгәннәр.* М.Галиев. *Мезозой эрасында Җирнең хайваннар һәм үсемлекләр дөньясы тагы да тизрәк тәрәккый иткән.* Галәм. Җир. Кеше

МЕЗОН *и. гр. физ.* Тотрыксыз, үзлегеннән таркалучан, массалары лептон массасыннан артыграк, нуклон массасыннан кимрәк булган элементар кисәкчекләрнең гомуми атамасы. *Вакытның релятивистик акрынаюы мюоннар (μ – мезоннар) таркалуы күренешендә расланды.* Физика

МЕЗОНИН *и. ит.* Торак йортның урта өлешендә, югары катның өстенә ясалган, гадәттә бер бүлмәлек кечкенә корылма, чарлак. *Җәй өчен [йортның] тагы бер уңай ягы бар икән: чормаларына мезонин сыман бер бүлмә ясап куелган.* Э.Касыймов

МЕЗОНИНЛЫ *с.* Мезонины булган, мезонин белән эшләнгән. *Мезонинлы яңа дача. Бакча. Аскы якта Фәритнең верандалы квартирасы.* Ә.Фәйзи

МЕКЕРДӘНҮ *ф.* Үзалдына мекердәү

Мекердәнеп алу Бераз мекердәнү

Мекердәнеп йөрү Бертуктаусыз мекердәнү. *[Редактор] һич кирәкмәгән әңгәмә корып җибәрде, нәкъ менә кәҗәнең ишегалдында үзлексез мекердәнеп йөрүе кебек.* К.Тимбикова

Мекердәнеп тору Күпмедер вакыт мекердәнү

МЕКЕРДӘ́Ү *ф.* Мекер-мекер иткән тавыш чыгару. *[Илдар] уйнаклап йөргән колынының, аңар җавап итеп, матур мекердәп, әнисе янына йөгереп килүе турында сөйли.* Г.Гобәй

Мекердәп йөрү Гел мекердәү, үзлексез мекердәү

Мекердәп кую Бер мәртәбә мекердәү. *Ә кичен, талчыккан гәүдәмне ястыкка таратып ташлауга, күз алдымнан болытлар булып сарык көтүе үтәр әле, мекердәп куйган бәрән тавышлары колагымда кабат-кабат яңгырар әле ---.* М.Галиев

Мекердәп тору Хәзерге моментта мекердәү, бер вакыт аралыгы мекердәү

МЕКЕРДӘШҮ *ф. урт. юн. к.* **мекердәү**. *Аннан соң, үз дәрәҗәләрен төшермичә генә, тәкәббер башларын югары тотып, вак-вак атлап, безнең атаман Иблис җитәкчелегендәге кәҗә командасы басу капкасыннан үзара мекердәшеп килеп керде.* Ялкын

МЕКЕ́Р-МЕКЕР *иярт.* Кәҗә яки бәрәннең әкрен генә, йомшак кына тавыш бирү рәвешен белдерә. *Юеш танаулы сарыкларның мекер-мекер печән уртлавы... Гөнҗәлә койрыклы әтәчнең, күрше тавыкларын койма ярыгыннан күзәтеп, баскан урынында тәкатьсез тыпырдавы...* М.Гали

МЕКЕ́Р-МЕКЕР КИЛҮ *ф.* Мекердәү. *Шайтан бәләкәй хуҗасына эттән болай тугры, мекер-мекер килеп, гел Гаделгә каныккан: ияреп йөри.* Р.Гаффар. *Бәтиләсә, назлы тавыш белән мекер-мекер килеп, бәтиләренә дәшә инде ул кәҗә.* Ф.Шәфигуллин

МЕЛАНЖ *и. фр.* **1.** 1) Төрле төскә буялган сүсләрдән эрләнгән җеп һәм шундый җепләрдән тукылган тукыма. *Әни соравы буенча 800 г меланж һәм ике метр марля сатып алдым.* Ялкын

2) Йомырка агы белән йомырка сарысы катнашмасы. *Меланжны печенье пешергәндә кулланалар*

2. *с. мәгъ.* Төрле төскә буялган сүсләрдән эрләнгән; берничә төсле. *Меланж җептән бәйләнгән ул кофтаны мин бик озак кидем.* Р.Вәлиева. *Әлеге кофтаны бәйләр өчен 500 г меланж җеп (яки 5 төрле төстәге җепләр) кирәк.* Сөембикә

МЕЛАНХО́ЛИК I *и. гр.* 1) Меланхолия (*1 мәгъ.*) белән авыручы кеше

2) Гомумән, тиз төшенкелеккә бирелүчән; боегучан, боек күңелле кеше. *Сез тумыштан меланхолик, князь. Бүгенге мәҗлестә, минемчә, шат булырга сәбәп бар.* Т.Миңнуллин

3) Эмоциональ кичерешләренең акрын башлануы, ләкин тирән һәм дәвамлы булуы белән характерлана торган темпераментлы кеше. *Меланхолик акрын хәрәкәтле, ләкин эчке дөньясы холерикныкын хәтерләтә.* М.Әхмәтҗанов. *Мәсәлән, елгада тавык батып үлгән, ди. Меланхолик өчен бу – зур фаҗига, сангвиникка бу хәл кызык кына, флегматикның исә аңа исе дә китмәстер, мөгаен.* З.Хөснияр. *Каршыгызда сулышын тирән һәм еш алып акрын гына чыгаручы кеше торса, бусы – өметсез меланхолик.* В.Леви

МЕЛАНХО́ЛИК II *с.* 1) Боек, күңелсез, кәефсез. *Аннары зифа сынлы меланхолик туташ чыгыш ясады, ул дару эчүдән һәм ашказаны эшләмәүдән килеп чыга торган сәер төссезлеге белән аерыла.* М.Твен

2) Меланхолия белән сугарылган, моңсу эчтәлекле. *Шулай иткәндә [кыскартканда] шигырьләр җыйнаклана гына түгел, аларның темпераменты, тәэсир итү көче бермә-бер арта, меланхолик шигырьләр дәртле, импульслы әсәрләргә әверелә.* Р.Харис

МЕЛАНХО́ЛИЯ *и. гр.* 1) Депрессия, сәбәпсез күңел төшенкелегенә бирелү, кайвакытта саташу дәрәҗәсенә җитү белән характерланган психик авыру. *--- ул кичтә эчкән шәрабыңның пары миеңнән чыкмый торып, сабух эчсәң, аның махмыры дәхи катышып, икесеннән меланхолия хасил булыр ки, диваналыктан бер нәүгъдыр.* К.Насыйри

2) Күңел төшенкелеге, моңсулану, ямансулы рухи халәт, боеклык. *Эч поша, йөрәк яна, күңелдә меланхолия, башта философия, шайтан алгыры!* Ә.Еники. *Күл өстеннән көймә килә... Юк, көймә түгел, Григның галибанә-талантлы, әле сокланырлык нечкә меланхолия, әле балаларча самимилек белән сугарылган «Сольвейг»ы килә.* М.Мәһдиев

МЕЛА́ССА *и. фр. махс.* Чөгендердән шикәр җитештерү калдыгы булган, кара кызыл төстәге куе ширбәт сыман, үзенчәлекле исле, терлек азыгы буларак файдаланыла торган сыекча. *Азык промышленносте калдыклары – барда, меласса – терлек азыкларын тулыландыруның әһәмиятле чыганагы була алалар.* Социалистик Татарстан

МЕЛИ́ЗМНАР *и. күпл. гр. муз.* Музыкада орнаментиканың бер төре, зур булмаган, форма ягыннан тотрыклы мелодик бизәкләр (группето, форшлаг, трель, мордент). *Безнең татар-башкорт көйләрендәге традицион бормаларны, мелизмнарны моң дип атаучылар да бар.* М.Гали. *Шәүкәт Галиев шигыре белән җырлана торган бу көй үзенең мелизмнарга бай булуы, ритмик төрлелеге, настроениесенең дәртле булуы белән иске көйләр традициясен дәвам иттерә.* Ж.Фәйзи

МЕЛИОРАТИВ *с.* Мелиорациягә караган, мелиорация максатларыннан башкарылган. *1970–1971 елларда «Татмелководстрой» трестының механикалаштырылган күчмә колоннасы сазлы җирләрне киптерү һәм куаклыкларны бетерү буенча комплексны чаралар үткәрде, башка мелиоратив һәм культура-техник эшләр башкарылды.* Татарстанда терлекчелек

МЕЛИОРА́ТОР *и. лат.* Мелиорация белгече, мелиорация тармагында хезмәт итүче кеше. *Хәрбиләр, мелиораторлар белән бергәләшеп, эш системаларының ышанычлы булуын сынар өчен, җир асты шартлавы үткәрделәр.* Ә.Гаффар. *Каладан килгән... мелиоратор... Зөһрәнең атасы шул иде бит инде...* Х.Ибраһим. *--- мактаулы исемнәр дә төшеп калды. Атказанган ветеринар табиблар, үйлап табучылар һәм рационализаторлар, мелиораторлар, чик сакчылары да булмаячак.* Мәдәни җомга

МЕЛИОРА́ЦИЯ *и. лат. а.х.* Җирне авыл хуҗалыгында файдалану өчен яраклы хәлгә китерүгә һәм уңдырышлылыгын арттыруга юнәлдерелгән оештыру, хуҗалык һәм техник чаралар системасы: коры җирләрне сугару, сазлыклы урыннарны киптерү һ.б.ш. *Бабай мелиорация станциясендә яшәгән, улы белән килене фронтка киткәннәр.* Г.Нәбиуллин. *Ләкләкләрнең саны кимүнең төп сәбәпләре – --- сазлыклы болыннарны киптерү, мелиорация ярдәмендә аларны авыл хуҗалыгы җирләренә әйләндерү нәтиҗәсендә азык базасы кискен кимүе тора.* Биология. Хайваннар. *Шул ук вакытта җирләрдә мелиорация эшләре башкарып, җимергеч ташкыннар юлында плотиналар төзеп, ясалма диңгезләр барлыкка китереп, кеше табигатьне үзгәртеп кора.* Биология: кеше һәм аның сәламәтлеге

МЕЛИОРА́ЦИЯЛӘҮ *ф. а.х.* Мелиорация эшләре алып бару. *Мелиорацияләү нәтиҗәсендә сары төнбоек*

запаслары акрынлап кими бара. Урман аптекасы

МЕЛИ́ССА *и. гр. бот.* Иренчәчәкләләр семьялыгыннан, 1 м га кадәр биеклектәге, тәмле лимон исе булган, эфир мае азык-төлек һәм парфюмерия җитештерүдә файдаланыла торган күпьеллык үлән үсемлек; лимон бөтнеге. *Мелисса суы көзән җыеруга каршы микстуралар составына керә, мае нерв системасын тынычландыра, яфраклары бактерияләргә каршы тәэсир итә.* Урман аптекасы. *Бакчаларда үсә торган мәче бөтнеген еш кына лимон исле бөтнек яки, ялгышып, мелисса дип атыйлар. Бу ике төр үсемлек арасында аерма шунда: мелиссаның чәчәк төркемнәре – куентыкта, ә мәче бөтнегенең очта урнашкан.* Татарстанның үсемлекләр һәм хайваннар дөньясы

МЕЛЛА *и. гар. иск.* 1) Укымышлы, галим кешене атау һәм аңа ихтирам белән эндәшү сүзе. *– Тагы бер сәгать! Тагы бер сәгать, мелла Сәгыйть! – диди сәгать өчләргә кадәр утыргач, – Кая кайтасың инде? – дип, мине туктата иде [Г.Тукай].* С.Сүнчәләй. *Ишекне ачып керүгә, аңа таба мулла кузгалды: – Я Алла, Мөхәммәд рәсүлулла, Булат бәк. Котылдың?.. – Котылдык, котылдык, меллам.* М.Хәбибуллин

2) Гомумән, кешене хөрмәт итеп, олылап эндәшү сүзе. *Кара әле, мелла Закир, мин болай кунак булырга килмәгән идем бит.* Ф.Әмирхан

МЕЛОДЕКЛАМА́ЦИЯ *и. гр.-лат.* 1) Россиядә XIX йөзнең 70 нче елларыннан тарала башлаган, музыкага ияреп шигырь яки проза әсәрен сәнгатьле итеп укудан гыйбарәт жанр. *Икенче (әдәби-музыкаль) бүлектә исә С. Габәши татар музыкасы өчен яңа жанрда – Ә. Тангатаровның «Ни ул?» дигән шигыренә мелодекламация белән чыгыш ясый.* К.Миңнуллин

2) Музыка белән сөйләмнең әле бер үк вакытта, әле чиратлашып килүенә нигезләнгән әсәр (сәхнә әсәре булганда мелодрама дип атала). *Алга таба композиторның репертуарында мелодекламация жанры ныклап урнаша.* К.Миңнуллин

МЕЛО́ДИК *с.* 1) Мелодия өлкәсенә караган, мелодиягә кагылышлы. *Аның [Р.Бәһәповның] югары художестволы, катлаулы һәм музыкаль яктан югары, мелодик яктан мөкәммәл җырлары классик үрнәктәге сәнгать әсәрләре булып калдылар.* Казан утлары

2) Моңлы, көйле, музыкалы, гомумән, матур яңгырашлы. *Лаборатория почмагында акрын гына мелодик безелдәү тавышы җәй буе тынмый.* Умарта кортлары

МЕЛО́ДИКА *и. гр. сәнг.* 1) Мелодия турындагы өйрәтмә

2) Аерым музыкаль әсәрнең, композиторның, халык иҗатының барлык мелодик чараларының системасы, музыкаль төзелеше. *Ул стильгә кискен интонацион күчешләр, «сикерешләр» характерлы түгел, аларга орнаментлы мелодика, йомшаклык, пластика, берсеннән берсенә ялганып бара торган бизәүләр хас.* К.Гыйззәтов

МЕЛО́ДИЯ *и. гр.* Матур яңгырашлы, тәэсирле музыкаль бердәмлек хасил итә торган, билгеле бер югарылык, озынлык һәм көчлелектәге авазлар эзлеклелеге, көй. *Бу мелодияләрдә гүзәл испан кызларының зәңгәр кичләрдә лимон агачлары арасында сөйләгән гыйшык сүзләре --- ишетелгән сыман иде.* М.Мәһдиев. *«Кара урманны» ул [М.Расторопович] болай дип искә ала: «Сүзләрен аңламасам да, гажәеп тирән мелодиясе аша җырның ни турында икәнен тойдым мин ---».* М.Гали. *Уң яктан киртләч таулар, сул яктан юан урманлы озын утрау белән кысыкланган ургыл сулы тармак тамагына җитәрәк, һавада гадәти булмаган илһамлы мелодия ишетелә башлый.* Казан утлары

МЕЛОДРА́МА *и. гр.* 1) XVIII гасыр азагында Франциядә барлыкка килгән, кискен интрига, күпертелгән эмоцияләр, үгет-нәсыйхәткә юнәлгәнлек кебек үзенчәлекләр белән аерылып торган драматургия жанры. *Мелодрамалар, комедияләр, әкиятләр сафын тыгызлап килеп кергән «Җир уллары» (Һади Такташ) театр дөньясын җитди уйланырга мәҗбүр иткән иде.* Сәхнә

2) Монологлар һәм диалоглар җыр һәм музыка белән аралашып барган драма жанрындагы әсәр. *Аның 1926 елда язылган «Зәңгәр шәл» мелодрамасы – бик күп халык көйләрен туплаган әсәр.* Ж.Фәйзи. *Безнең тамашачы мелодраманы бик тә ярата.* Р.Батулла

3) Гомумән, шундый стильдәге теләсә нинди сәнгать әсәре. *Радж Капурның студиясен нәрсә дип белдегез? Аның бит гел мелодрама. Менә соңгы фильмын карагыз әле.* М.Мәһдиев

4) *күч.* Ясалма хисләр, гадәти булмаган кыланышлар, урынсыз трагизм, ясалмалык белән аерылып торган вакыйга, хәл, ситуация. *Бу күренештә бернинди чамасыз хискә бирелү дә юк, бернинди мелодрама да юк, ләкин дулкынланудан тын кысыла.* И.Илялова

МЕЛОДРАМАТИЗМ *и. рус кит.* Хис-кичерешләрне сурәтләүдә ясалмалылык, артык киеренкелек, күпертелгәнлек. *--- салкын канлы, шактый дәрәҗәдә акылга нигезләнгән сүз сәнгате рус укучысын канәгатьләндереп бетермәгән кебек, аңа Шәрыкның нәзберек романтизмы – мелодраматизм да хас түгел.* Ф.Галимуллин

МЕЛОДРАМА́ТИК *с.* 1) Әдәби үзенчәлекләре, стиле белән мелодрама жанрына караган; мелодрамага хас. *Теле, стиле, --- фәлсәфәсе, кыскасы, барлык яклары белән «Язгы аҗаган» – безнең укучы бик тә ярата торган мелодраматик әсәр.* Ф.Миңнуллин. *Соңгы елларда дөнья күргән әсәрләрдә ул, җыр-музыка белән кушылып, мелодраматик төсмерләргә тагын да байый.* Ә.Закиржанов

2) Мелодрамалардагы кебек ясалма, артык күпертелгән. *Спектакльләрдә җыр-бию, мелодраматик коллизияләр, шау-шулы эпизодлар, аһылдау-уһылдау хуплана.* К.Гыйззәтов. *Җитди теманы хәл итүне автор ахырга кадәр бер югарылыкта алып барып чыга алмаган, кайбер җиңелчә алымнарга, мелодраматик чараларга мөрәҗәгать итеп, арзанлы эффектка исәп тоткан ситуацияләр китереп керткән.* А.Әхмәдуллин

МЕЛОМАН *и. гр. кит.* Музыкага мөкиббән киткән, җыр-көйне бик яраткан кеше. *Башкалада туып үскән кыз, меломан, театрал, өченче ел инде*

электрсыз урман посёлогында, тупас урман эшчеләре арасында яши, кирза итектән язгы-көзге пычракны ерып, зарлану, зарыгу, уфтану галәмәтләре күрсәтмичә, дүрт километр җиргә җәяүләп эшкә йөри. Т.Мөбарәков

МЕЛОМАНЛЫК *и.* Меломан булу. *Яшьләр арасында меломанлык нык үсеш алган.* Т.Галиуллин

МЕЛТЕК *с. диал.* Тәбәнәк, карсак, кыска буйлы. *Өченче иптәшем – Вәли дигән татар малае. Монысы – безнең Муллагали кебек бер мелтек кенә нәрсә.* А.Расих

МЕЛТЕРӘ́Ү *ф. сөйл. к.* **мелт-мелт итү**

Мелтерәп китү Кисәк мелтери башлау. *[Сәлим бабайның] иреннәре мелтерәп китте.* Н.Исәнбәт

Мелтерәп тору Бертуктаусыз мелтерәү

МЕ́ЛТ-МЕЛТ *иярт.* 1) Күз кабакларының яки иреннәрнең иректән еш-еш ачылып йомылу рәвешен белдерә. *Ак керфекле күзләрен мелт-мелт йомгалады да чәркәсен югары күтәрде.* К.Тимбикова. *Белеше, керфекләрен мелт-мелт сикертеп: «Төрмә сине төзәтмәгән икән!» – диде.* А.Гыйләҗев. *Бермәлне мине төп башына утыртып куялар, ә мин күзләремне мелт-мелт йомып дәшми калам.* М.Юныс

2) Утның бер кабынып, бер сүнеп, өзек-өзек, зәгыйфь яктылык чыгарып яну рәвешен белдерә

МЕ́ЛТ-МЕЛТ ИТҮ *ф.* 1) Йомылып-ачылып алу (иреннәр, күзләр тур.). *--- кыз аңа авызларын мелт-мелт итеп бераз карап торды да кычкырып елап җибәрде.* Ә.Баян. *Әнвәр күзләрен мелт-мелт итеп аңа карап торды, нигә куганлыгын аңламый иде ул.* Х.Камалов

2) Кисәк-кисәк кабынып-сүнеп алу (ут тур.). *Матчадагы кадакка эленгән керосин лампасы гына әледән-әле куык эчендә мелт-мелт итеп җан биреп ала.* Р.Мөхәммәдиев. *Лампочкалар мелт-мелт итә, һәм Тимержан бизгәк тоткан бозау кебек калтырый башлый.* Р.Батулла

3) Вак-вак, өзек-өзек хәрәкәтләр ясау. *Менә шушы ачык зәңгәр күктән, шушы көне буе туктаусыз аккан көмеш тәңкәләрдән тыш, мин мелт-мелт итеп утырган кармак җепләрен генә күрәм.* А.Гыйләҗев

МЕ́ЛТ-МЕЛТ КИЛҮ *ф. к.* **мелт-мелт итү**. *Кызыл сакалның иңбашлары калтыранды, зәңгәр күзләре мелт-мелт килде, ул тавышсыз гына җылый иде...* А.Гыйләҗев

МЕЛЬХИОР *и. фр.* **1.** Башлыча никель белән бакыр катнашмасыннан торган, сирәгрәк тимер яки марганец кушылган, каррозиягә чыдамлы, диңгез судноларын төзүдә, акча, савыт-саба, медицина инструментлары ясауда файдаланыла торган коелма

2. *с. мәгъ.* Шундый коелмадан ясалган. *--- дачаны басканнар. Транзистор юк, бер-ике свитер, самавыр, мельхиор кашыклар, пычаклар.* М.Мәһдиев. *Буйдак хуҗалыгында хатын-кыз кулы юклыгы сизелә: чынаяклар чәйдән саргайган, мельхиор калаклар күгәргән, тәрәзә төбендә катканипи сыныклары ята.* М.Маликова

МЕМБРА́НА *и. лат.* 1) Тере организмның теләсә кайсы әгъзасын, күзәнәкләрен, күзәнәк эчендәге аерым куык яки каналчыкларны аерып торган нечкә яры, элпә. *Әгәр этнең борынынан тоемлау мембраналарын чыгарып җәеп салсаң, аның мәйданы этнең гәүдәсе зурлыгыннан да артып китә.* Кызыклар дөньясында. *Умырткалары булган югары төзелешле хайваннар тавышны ишетү аппараты – тышкы колак яфрагы, колак тишеге, бормача һәм мембрана ярдәмендә ишетәләр.* Кызыклы ихтиология. *Күзәнәкнең төп өлешләре – тышкы мембрана, цитоплазма һәм төш.* Табигать белеме

2) *физ., тех.* һава тирбәнешләрен яки басымын кабул итеп, аны механик хәрәкәткә яки, киресенчә, механик тирбәнешләрне һава тирбәнешләренә әверелдерә торган киерелгән яры яки сыгылма материалдан эшләнгән юка пластинка. *Ток тәэсире астында тоз кисәкчекләре ионлаша, мембрана аларны сортларга аера, ә ионнарны кире нейтральләштерүе кыен түгел.* Химиянең киләчәге. *Микрофонның мембранасы – юка гына корыч пластинка яки пресс белән кыстырып ясалган күмер пластинка.* Физика курсы

МЕМБРА́НАЛЫ *с.* 1) Мембранасы булган. *Панцирь тишеге аша мембраналы куык чыга, аңа бала күзәнәкләр агып керәләр, камчылар үстерәләр һәм, куыктан чыгып, ирекле яши башлыйлар. Шуннан соң һәр күзәнәк үзенә панцирь кора.* Ботаника: суүсемнәр, гөмбәләр һәм лишайниклар систематикасы

2) Мембрана ярдәмендә эшли торган. *Мембраналы реле*

МЕМОРА́НДУМ *и. лат. рәс.* Берәр мәсьәләнең фактик, юридик яки документтагы хәлен ача һәм гадәттә нотага өстәп бирелә торган дипломатик документ. *Татарстан Республикасы Дәүләт Советы һәм АКШның Нью-Йорк штаты арасында үзара аңлашу, фикерләр уртаклыгы турында меморандум әзерләнүен, аңа кул куелуын Ф.Мөхәммәтшин тарихи вакыйга буларак бәяләде.* Мәдәни җомга

МЕМОРИАЛ *и. лат.* 1) Күренекле спортсменнар истәлегенә багышланган ярышлар. *Бертуган Знаменскийлар мемориалы*

2) Берәр күренекле шәхеснең яки тарихи вакыйганың истәлеген мәңгеләштерү максаты белән торгызылган архитектура корылмасы. *Әлбәттә, монда мәһабәт Ленин мемориалы булыр дип уйламадык ул чакта.* Ж.Фәйзи. *Минемчә, Фазыл, килер шундый бер вакыт: без Казанның тарихи үзәген саклаган килеш, аның барлык матур сыйфатларын чагылдырган мемориал булдырырбыз әле.* Г.Кашапов

МЕМОРИАЛЬ *с.* Берәр тарихи вакыйгага яки атаклы кешегә багышланган, шуның истәлеген мәңгеләштерә торган. *Патриотлар истәлеген мәңгеләштереп, Барановичи шәһәренең М.Горький урамындагы 10 нчы йортка мемориаль такта куелган.* Ш.Рәкыйпов. *Зәңгәр капкачлы тәрәзәләр, мемориаль такта сыман, йорт хуҗасының истәлеген саклыйлар.* М.Юныс. *Әбекәй, туп-туры барып, таш һәйкәл каршына туктады. Аңа бераз карап торгач, читкәрәк тайпылып, сугышта үлеп калганнарның исемнәре уеп язылган мемориаль стена янына килде.* Г.Гыйльманов

МЕМУАР *и. фр.* **1.** Автобиографик характердагы язмалар, истәлекләр; авторның үзенә кагылышлы вакыйгалар турында, үзенең шәхси тәэсирләренә һәм хатирәләренә нигезләнеп язылган әдәби әсәр. *Укырга тотындым. Китапханәдәге хәрби мемуарларны су урынына эчәм.* Ш.Рәкыйпов. *Хы, кызык заман китте: хәзер генераллар отставкага чыкса – мемуар язарга тотына ---.* Ф.Яруллин. *Кем чыгарса ел саен калын китаплар, Мемуарлар... эчетышы гел «ак таплар».* Ә.Синугыл-Куганаклы

2. *с. мәгъ.* Мемуар жанрында язылган. *Мемуар әдәбият – иҗат эшенең үзенчәлекле тармагы.* М.Мәһдиев

МЕМУАРЧЫ *и.* Мемуарлар авторы, башлыча мемуар жанрында иҗат иткән язучы

МЕ́НӘ *а.* **1.** 1) Игътибарны күз алдындагы, якындагы объектка юнәлдерү, кемгә яки нәрсәгә, берәр хәл-күренешкә күрсәтү өчен кулланыла. *Менә тыкрык. Борылу белән Мәдинәнең өе.* М.Хәсәнов. *Эзләгәнем, менә күрәсең, борын төбемдә үк яткан.* Г.Тавлин

2) Якындагы предмет-күренеш турында сөйләгәндә, күрсәтү хәрәкәте белән бергә әйтелә. *– Менә ул эшне туктатты, – дип, Хатип абый Сәлим бабайга күрсәтте.* Г.Тавлин. *– Ә менә бу нәрсә? – Кемдер стенадагы графикка төртеп күрсәтте.* М.Хәсәнов. *– Бар андый чәчәк. Менә ул, – Самат иң түрдә балкып утырган ак лилияләр гөлләмәсенә ишарәләде.* Г.Гыйльманов

3) Эш-процессларның эзлеклелеген, күренешләрнең бер-бер артлы баруын тасвир итү өчен кулланыла (тиңдәш кисәкләр алдыннан кабатланып килүе мөмкин). *Менә звонок булды. Барысы да тынып калдылар. Сәхнәдә чын репетиция башланды.* Ж.Фәйзи. *Менә дулкынланып көткән сәгатьләр килеп тә җитте.* М.Шабай. *Менә тагын язлар җитә... Син дә янымда булсаң соң!* М.Хәсәнов

4) Конкрет урынга, вакытка, сәбәпкә күрсәтү өчен, ешрак мөнәсәбәтлек һәм күрсәтү алмашлыклары белән килеп, аларның мәгънәсен ачыклый, көчәйтә. *Эх, Борһанны алып киләсе иде дә, борыны белән төртеп: «Менә күр, күр! Эшне аны менә болай да куеп була икән ләбаса!» – дип дөмбәслисе иде.* М.Хәсәнов. *Менә шунда, язу өстәле артында, күзгә күренмәгән эчке көрәш башлана да инде.* Р.Низамиев. *Менә бүген вакыт табып чыктым Кырларыма... Нинди тугайлар!..* Г.Гыйльманов

5) Гомумиләштерүче сүзләр янында йомгак, нәтиҗә ясауны белдерү өчен кулланыла. *Тәрбия эшен көчәйтергә, сафларыбызны ныгытырга – менә безнең алда торган бурыч!* Ж.Фәйзи. *Әхлак пычраклыгы, шапшак вәҗданнар – менә нәрсәдән арынасы бар безгә.* М.Юныс

6) Аерым сүзләргә логик басым ясау, ассызыклау өчен шулар алдыннан килә. *Бу ап-ак халатлы кызда Хәнияне тану кыен түгел иде. Ә менә Хәния аны таныды микән?* Г.Гыйльманов. *Ни өчен башка берәүгә түгел, нәкъ менә миңа сүз катарга кирәк тапкан?* Р.Мөхәммәдиев

7) Тыңлаучының, әңгәмәдәшнең игътибарын җәлеп итү өчен, гадәттә эндәш сүз янында кулланыла. *Менә, Фирдәвес, кара. Сыерны, гадәттә, тәбәнәк эскәмиягә утырып, уң ягыннан савалар.* М.Хәсәнов. *Озак та тормам, күңелем күрсәткән җирдән табып та алып кайтырмын үзен, менә күрерсең...* Г.Гыйльманов

8) Тойгылы җөмләләрдә аларның экспрессивлыгын көчәйтү өчен кулланыла. *Менә кемнәрдә икән әхлак, менә кемнәрдә икән намус-вөҗдан, менә кемнәрдә икән ул сафлык...* Г.Ахунов. *Менә кайда ул илнең бар юридик вузларында өйрәнелергә тиешле документ!* Р.Мирхәйдәров. *Кырымның аяз көзе җиткәч, менә кайда күп булачак ул җирән гөмбәләр!* Дөньяда ниләр бар

9) *Инде* сүзе белән килеп, «хәзер» мәгънәсен барлыкка китерә. *Инде менә яшь йөрәкләр бирә бездән калган иске сорауны.* Л.Шагыйрьҗан. *Инде менә аның күңел дәфтәре – җан серләре тупланмасы безнең кулда. Кайсы яклары белән кызыктыра соң безне Наиснең шигырьләре?* Зөлфәт. *Инде менә җиде ел мин үземнең җаныма тынычлык таба алмыйм.* Х.Ибраһим

10) *күч. к.* **менә дигән**. *Сөнгать абый бит ул, берәүләр түгел. Егете – менә!* М.Фәйзи

11) *сөйл.* Кыйнаганда, сукканда, үч итеп берәр нәрсә эшләгәндә әйтелә. *Нәгъләт төшкерләре, югалыгыз күземнән! Менә, менә, менә, күп сугышып йөрсәгез!* Ә.Фәйзи

2. 1) *кис. функ.* Җөмлә ахырында килеп, «бит», «ич», «инде» мәгънәсен өстәп, алдагы сүзнең мәгънәсен көчәйтә. *Бүрәнәләрне күрдем. Сайлап киссәң дә, андый өрлекләр таба алмассың инде менә.* М.Хәсәнов. *Сез булмасагыз, мин керә алмас идем, чын менә!* Г.Гыйльманов. *Яшьли канатсыз үссәң дә, югалып калмагансың, тырышып, кеше булгансың менә.* З.Фәйзи

2) *Бит*, *ичмаса*, *инде* һ.б.ш. кисәкчәләр белән килеп, сөйләмнең экспрессивлыгын арттыра. *Менә ичмаса кеше иде! Кеше түгел, алтын иде.* М.Хәсәнов. *«Менә бу кыз, ичмасам! Суыр да йотып җибәр!» – дип куйды ул.* З.Фәйзи. *Менә бит нинди гүзәл туташ белән очрашырга насыйп булды...* Г.Гыйльманов

3. *рәв. функ.* Бер үк яки синоним фигыльләр белән кабатланып кулланылганда, «хәзер», «тиз арада» мәгънәсен белдерә. *Көзгә кадәр идән тактасының берсен алыштырасы бар, череп беткән, менә сынам, менә сынам дип, сыгылып кына тора.* А.Гыйләҗев. *Авыруы болайга үк барып җитәр дип башта ул уена да китермәде. Менә бетәр, менә үтәр дип ышанып йөрде.* В.Нуруллин. *Менә авам, менә җимереләм дип торган салам түбәле иске каралтыны хәтерләткән гәүдәне бары кулындагы таяк кына тотып тора сыман.* Р.Мөхәммәдиев

4. *мод. сүз функ.* Әйе. *– Менә, менә, Хәдичә!.. – дип элеп алды секретарь. – Нәкъ менә шундый мисаллар кирәк булачак та инде...* М.Хәсәнов. *Менә, менә! Рома-а-а-нтика... Казан купецының алтын тәңкәләре, хикмәтле план – болар чын-чынлап романтика...* З.Фәтхетдинов. *Менә, менә, аралашуның файдасы тигәнлеге күренеп тора.* Т.Әйди

◊ **Менә генә** 1) Янда гына, бик якын, күз алдында, каршыда гына. *Хәзер менә*

ул аның каршысында... Менә генә ул. Г.Бәширов; 2) Күптән түгел генә, әле генә, хәзер генә. **Менә дигән** Сокландыргыч, югары бәягә лаек булган, һәр яктан килгән, чынлап та бик яхшы; шәп. *Соң, бар җирегез җитеш. Өй дисәң – менә дигән, ашарга бар.* Р.Мөхәммәдиев. --- *Динәнең абзарында йомычка тау булып өелә. Кабызгылыкка, коймак, көлчә пешерергә менә дигән вак утын бу.* К.Кәримов. *Нурания апа белән ире Фәргать абый менә дигән умартачылар да бит әле.* Сөембикә. **Менә мин сине (сезне)** Ачулану, янау, куркытуны белдерә. *Сания, Маратны яклап, Илдарга ташланды. – Нигә тиясең син аңа, ә? Әнигә әйтим әле менә мин сине!* Г.Гобәй. **Менә ничек!** Гаҗәпләнүне белдерә. *Менә ничек икән! Шәһәрдә квартираларны кеше санына карап бирәләр икән, димәк.* М.Маликова. **Менә син**! *к.* **менә ничек!** *Менә син, ә!.. Нинди җаваплы эшкә шундый юньсез нәмәрсәне утыртып куйганнар бит!* Г.Гобәй. **Менә сиңа!** 1) Бу – сиңа тиешле җәза. *Менә сиңа, менә, йөзең кара! Менә сиңа, муеның сынгыры!* һ.Такташ. --- *өлкән класс малайлары (унбишләп булыр) мине көтеп торалар иде, килеп керүемә сугып ектылар да ил-умач итеп кыйнадылар, изделәр. – Менә сиңа, менә сиңа, әләкче тәре! – дип, озак кыйнадылар.* Р.Низамиев; 2) Тискәре мөнәсәбәт белдереп, түбәнсетеп, кимсетеп әйтелә. *Менәтерәк сиңа терлекчелектә югары культуралы колхоз! Менә сиңа районның күчмә Кызыл Байрагы!* М.Хәсәнов; 3) Үтәлмичә калган яки бөтенләй башкача, көтелмәгән нәтиҗәгә китергән эш-хәл турында әйтелә. *Ул тыңлый, дәшми ---. Менә сиңа, рәнҗүе микән?* Ш.Галиев. **Менә (сиңа) кирәк булса!** Көтелмәгән хәлгә, берәүнең аңлашылмаган кыланышына һ.б.ш.га гаҗәпләнүне, сәерсенүне белдерә. *– Менә сиңа кирәк булса! – диде бу хәлгә аптырап калган ата.* Г.Тавлин. **Менә сиңа мә!** *к.* **менә сиңа кирәк булса**. *Менә сиңа мә! Менә сиңа әкәмәт! Безнең күптәнге танышлар ласа болар!* Г.Гыйльманов. *– Менә сиңа мә!.. – дип уйлана башлады Даниял, өйдән чыгуга. – Кичә, кызым белән кияүемдә сөйләшкәндә, барысы да ачык, аңлаешлы иде. Ә бүген бөтенесе чуалып китте.* З.Фәйзи. *Слюда башта капкара иде, хәзер алтынсыман сары төскә кергән. – Менә сиңа мә!* Дөньяда ниләр бар. **Менә тагы(н)** Әңгәмәдәшнең фикеренә карата ризасызлык, гаҗәпләнү, килешмәү мөнәсәбәтен белдерә. *Балаларны куркытып, шулай кычкырырга, менә тагы, тапканнар.* Ә.Баян. **Менә шул шул** Әңгәмәдәшенең фикерен хуплап, җөпләп куюны, аның белән тулысынча килешүне белдерә. *Менә шул шул... Икенче хәбәрем нәкъ шул хакта.* Г.Гыйльманов. *Менә шул шул, бөтен хикмәт тә шунда.* Х.Ибраһим

МЕНӘЗ *и.* Образ. *[М.Мәһдиев] --- эчке бәйсезлеге, буйсынмас, баш бирмәс менәзе белән урысның бөек язучысы Иван Бунинны хәтерләтте.* Т.Галиуллин

МЕ́НӘ-МЕНӘ *рәв.* Хәзер үк, тиз арада. *Инде була, менә-менә чиертә кармакка дип торганда, кинәт кенә бөтен өмет-ышанычны юкка чыгара да куя!..* В.Нуруллин. *Ничә еллар инде, керфек какмый, Алмыйсың син миннән күзеңне; Менә-менә әйтеп бирерсең күк Әйталмыйча калган сүзеңне...* Ш.Галиев. *Башта ул Алсу утырган чананы менә-менә куып җитәм дип йөгерде.* Р.Мөхәммәдиев

МЕ́НӘТЕРӘ *ы.* Көтелмәгән хәлгә карата гаҗәпләнүне, зарлануны, сокланууны һ.б.ш. эмоцияләрне белдерә. *Әллә нәрсә булды бит менәтерә. Күз аллары караңгыланып китте, йөрәк кыскыч белән эләктергәндәй чәнчеп куйды.* Ш.Рәкыйпов. *Менәтерә, бажасы ласа бу, Мансур!* Г.Гыйльманов

МЕ́НӘТЕРӘК *ы. к.* **менәтерә**. *Менә элек Гомәр хатыны Мөһәлилә тегә иде карчыкларга күлмәкне! Сылап кына куя иде менәтерәк!..* А.Гыйләҗев. *Менәтерәк, тел галимнәре арасында Алтай теориясе һәм угро-фин теориясе яши.* М.Мәһдиев. *Менәтерәк сиңа терлекчелектә югары культуралы колхоз! Менә сиңа районның күчмә Кызыл Байрагы!* М.Хәсәнов

МЕНГӘШТЕРҮ *ф. диал.* Атка атланган кеше үз янына тагын бер кешене атландыру. *Мин аларга хәлне аңлаткач, аларның берсе мине, үзенең атына менгәштереп, теге якка алып чыкты.* М.Гафури

МЕНГӘШҮ *ф. диал.* Бер атка берьюлы ике кеше атлану. *Менгәшмә, менгәштеңме, артың авыртса да эндәшмә.* Әйтем

МЕНГЕ *с.* **1.** Җигү, йөк ташу кебек эшләргә тотылмый торган, атланып йөрүгә генә өйрәтелгән. *Кинәт ул тимерлек каршында менге атлар бәйли торган куш өянке төбенә туктады да, өянкене кочаклап, үксеп елап җибәрде: – Әти!.. Әти!..* А.Хәлим. *Сабан туйлары гөрләп уза монда, ат бәйгеләренә тирә-яктан иң җитез, иң елгыр, каннары уйнап торган шәпле чаптарлар, менге атлар, нәселле юртаклар, канатлы аргамаклар җыела.* Ф.Латыйфи. *Уклы җәя бир дә менге ат бир, – Ир канаты була җитез ат!* Н.Гамбәр

2. *и. мәгъ. к.* **менем**. *Бераздан мин Каракошны ярауландыру эшенә керештем. Җикмәдем, менгегә генә тотарга булдым.* М.Хәсәнов

МЕНГЕЗҮ *ф. к.* **мендерү**. *Шуңа күрә эшләп чыгару нормасын ике йөз дә биш процентка менгезде.* Ф.Сәйфи-Казанлы. *Кичен өйгә кайткач, --- әнкәсе аны мич башына менгезеп, кайнар кирпечләр өстенә яткыза, үзе умач уарга керешә...* И.Гази. *Илледә – акыл иясе, алтмышта хаким сизеп, Кеше һаман куяр үзен гел биеккә менгезеп.* Р.Фәйзуллин

Менгезеп ату Тиз-тиз генә менгезү

Менгезеп кую Бер мәртәбә менгезү, алдан менгезү. *Керләрне чайкап бетергәч, Габдулла аларны, кәрзингә тутырып, ярга менгезеп куйган.* Ә.Фәйзи

Менгезеп тору Хәзерге моментта менгезү; менгезү эшен башкарып тору

МЕНГЕРҮ *ф. к.* **мендерү**. *Менә хәзер дә, гөнаһысына һич катышмый, бер чиләк бәрәңге тутырып менгердем.* А.Хәсәнов. *Әнә башка аталар малайларын эскәмиягә менгереп яткырганнар, шау күбеккә батырып, кычкыртып, мунчала белән ышкыйлар.* Ф.Латыйф. *Хәзер «яңарып» яткан Рәсәйнең сәяси сәхнәсенә патша заманындагы Думаны өстерәп менгерделәр.* Р.Низамиев

Менгереп ату Тиз-тиз генә менгерү

Менгереп бирү Икенче кеше өчен менгерү. *Әй, минекеләр дә, болыннан берәр чүмәлә печән менгереп бирә алмаслармы, белеш әле, дигәннәр иде*. Н.Әхмәдиев. *Йөкне тиешле урынына илткәч, бишенче я дүртенче катка менгереп тә биргәлиләр*. М.Маликова

Менгереп җибәрү Тиз генә менәргә ярдәм итү; менәргә кушу. *Кайдандыр килеп җиткән Галләм аларны аркан буйлап өскә – печән өстенә менгереп җибәрде.* Р.Зәйдулла. --- *сырхау Гөлзәлифә олы кызы Гайшәне югары очка менгереп җибәрә: бар, белеш, әтиегездән бер-бер хәбәр юкмы, янәсе.* Р.Низамиев

Менгереп кую Бер мәртәбә менгерү, алдан менгереп эшен бетерү. *Илдус... Илдус, дим. Әйт берәрсенә, тәрәзә йөзлекләрен хәзер үк миңа менгереп куйсыннар.* Р.Мөхәммәдиев. *Яңа хисләр, яңа назлар Миләүшәне бәхетнең җиденче катына менгереп куйды.* Шәһри Казан

Менгереп ташлау Тиз генә менгереп кую, бер җиргә менгереп шунда калдыру. – *Самолёт, тарттырып, күккә менгереп ташлый да, шуннан соң планер үзе оча, белдеңме! – Зәбир боларны күптән белгән, үзе очып караган сыман ук сөйли башлады.* М.Галиев

Менгереп тору Хәзерге моментта менгерү; менгерү эшен башкаруда булу; шактый вакыт менгерү белән шөгыльләнү

МЕНДӘР *и.* 1) Баш астына салу, сөялеп яки аска куеп утыру өчен, мамык, йон яки шуларга охшаш ясалма материал тутырып эшләнгән йомшак әйбер. *[Кыз] сәке өстенә түшәк җәеп, мендәрләрне кабарта-кабарта, урын әзерләргә кереште.* К.Тинчурин. *Йомшак мендәрдә йокла, йом күзең, Рәхәтләнеп ял ит, төн озын.* М.Хөсәен. *Ап-ак челтәр корылган бүлмәдәге ап-ак карават өстендә каз мендәренә күмелеп, калын юрган белән төренеп, Гөлфия ята иде.* Л.Шәех

2) Иярнең каты кысасы белән ат аркасына тиеп торган өлеше арасында урнашкан йомшак катлам. *Алтын ияр, атлас мендәр Килешә җирән кашкага.* Җыр. *Алтын иде иярем, Ыштуф иде мендәрем...* Җыр

3) *тех.* Төрле корылмаларның, механизмнарның һ.б.ш. йөртүче каркасы, нигезе, терәге

4) Арбаның ал күчәре өстенә аны күчәр белән тоташтырып тору һәм тотрыклылык бирү өчен куелган агач терәк. *Арба мендәре*

5) Табигатьтә шактый күп булып җыелган бертөрле матдәләр яки организмнар катламы. *Гипнум хәтта коры болыннарда тыгыз мүк мендәрләре хасил итеп үсәргә мөмкин.* Татарстанның үсемлекләр һәм хайваннар дөньясы. *Кашалотның башында балавызсыман матдә – спермацет булган эре май мендәре урнашкан.* Биология. Хайваннар

6) Авыруларга ашыгыч ярдәм күрсәткәндә, сулыш алдыру өчен, кислородка бай һава тутырылган резин капчык; һава капчыгы. *Бу чаралар, милли тойгыны уятыр өчен, авыру, бетерелүгә дучар ителгән милләтне үлемнән коткарып калу өчен, кислород мендәреннән тын алдыру белән бер.* Н.Нәҗми. *Больницаларда авыру кешеләр өчен һәрвакыт кислород тоталар. Яман әле, яман безнең эшләр. Кайбер көнне резин мендәрдән кислород сулатып кына саклап калалар.* Г.Сабитов. *Кислород корыч баллоннарда һәм резина мендәрләрдә саклана.* Күзгә күренми торган матдәләр турында хикәяләр

7) *тех.* Транспорт чараларында кулланылган пассив куркынычсызлык чарасы: куркыныч туган очракта һава белән тула торган эластик сүрү. *Җитмәсә, битенә панельдән чәчрәгән куркынычсызлык мендәре китереп бәргәч, бөтенләй миңгерәүләнеп киткәндәй булды.* Х.Ширмән

◊ **Мендәр астына җыю** Яшерү, астыртын байлык туплау. --- *тик ятудан тәмам симергән, миңгерәүләнгән сорыкортлар да байлыкларын мендәр астына җыярга ашыгалар.* З.Фәтхетдинов. **Мендәргә бастыру** Яшь килен беренче мәртәбә кайнана өенә кергәндә, аның аяк астына мендәр салу. *Кияү йортына беренче мәртәбә керүендә яшь киленне мендәргә бастыралар.* М.Юныс. **Мендәр җылыту** Йоклап алу. **Мендәр салу** Бик кадерле кунакка зур хөрмәт күрсәтү. *Нәрсә, сукмагыңа мендәр салып көтүче бар дип белдеңме?.. Тот капчыгыңны...* Р.Мөхәммәдиев. **Мендәр тыңлау** Ятып йоклау. *Хәзер инде мөсафирханәгә кайтып мендәр тыңлаудан да шәбе булмас.* З.Фәтхетдинов. **Мендәр чылату** Елау (гадәттә хатын-кыз тур.). *Төн буе мендәр чылаткан Нурсөя иртән кое янында шомырт юган сердәшен күрде* ---. Н.Гыйматдинова

МЕНДӘ́Р-ТҮШӘК *җый. и.* Мендәр, түшәк һәм башка шундый урын-җир кирәк-яраклары. *[Нәфисә] --- мендәр-түшәген кыйный-кыйный, хәлдән тайганчы чәбәләнде.* Г.Гыйльманов

МЕНДӘРЧЕК *и.* 1) Формасы белән мендәргә охшатып эшләнгән, әмма башка максатларда файдаланылган кечкенә әсбап. *Процессия алдыннан кызыл мендәрчекләр тоткан кешеләр атлый. Мендәрчекләрдә Ленин премиясе һәм дәүләт премияләре лауреаты медальләре, Социалистик Хезмәт Герое йолдызлары...* Галәмгә юл

2) *зоол.* Бармакларның очындагы иң йомшак, иң сизгер урын

3) *зоол.* Берәр әгъза эчендәге махсус куышлык, капсула. *Монда капилляр тишемнәр системасы күзәнәкле мендәрчекләр белән тәмамлана. --- Кәлтәнең ике мендәрчеге бар.* Кызыклы физиология

4) *тех.* Ике деталь арасына аммортизация максатлары белән куелган ара деталь; прокладка. *Ияртүче тәлинкә иярүче тәлинкә белән резин мендәрчекләр аша тоташа.* Тракторлар һәм автомобильләр

МЕНДӘ́Р-ЯСТЫК *җый. и. к.* **мендәр-түшәк**. --- *язгы кояш астында җылынып, мендәр-ястык кебек кабарып яткан түтәлләр арасында, әле генә башларын төртеп чыгып, күзгә күренеп үскән яшелчә үсентеләренә карап сокланып йөрисе килә.* М.Хәсәнов

МЕНДЕРТҮ *ф. йөкл. юн. к.* **мендерү**. *Куштан ул белә хак түләтә: Сарайлар салдырта бүләккә. Эзләрен чәчәккә күмдертә, Укалы тәхеткә мендертә.* Ф.Гыйззәтуллина

МЕНДЕРҮ *ф.* 1) Өскә күтәрү, югары урынга күтәреп кую, урнаштыру.

Габделхакның бөтен тәнен катырып, башын бер урындыкка, аякларын икенчесенә куеп, төз яткан гәүдәсенә берәр бала мендереп бастыра идем. Ж.Фәйзи

2) Югарыдарак урнашкан җиргә күтәреп илтү яки берәр төрле транспортта ташу. *Дөньяда мал җыймак – олы ташны биек тауга мендермәк.* Мәкаль. *Ул яшь чагында грузчик булган: Тәтеш ярлары өстенә тонна-тонна йөкләр мендергән.* М.Әмир

3) Өскә күтәрү, югарырак урынга урнаштыру, күчереп кую. *Хәлим белән бабай калган агачларны, паровозның тендерына мендереп, бер читкә әрдәнәләп өеп куйдылар.* Г.Гобәй. *Бу көнне өеңә керергә ашыкма, абзар артына чык та түбә итәгенә кадәр мендереп өйгән карга басып кырны тыңла.* М.Мәһдиев. *Моннан әллә ничә еллар элек чормага мендереп бәпкә артына кыстырган урагын алып төште, тузанын сөртеп, бармак бите белән тешләрен барлады* ---. Ж.Рәхимов

4) Югарырак урынга менәргә, менеп утырырга ярдәм итү. *Куркаклык баганага мендерә, Кыюлык йолдызларга мендерә.* Мәкаль. *Сакчыларны алып, өскә мендерделәр*. И.Хуҗин

5) Атка атланырга ярдәм итү яки ирек бирү, рөхсәт итү, мөмкинлек бирү. *Дусым утын сүндермәм, Дошманым утын яндырмам! Үзем димәс намартка Ап-ак бүз ат мендермәм!* Дастан. *Атка мендереп кара – менә аламы?* М.Галиев

6) *сир.* Арттыру, ишәйтү, үстерү, берәр чиккә җиткерү (эш хаклары, бәяләр, керемнәр һ.б.ш. тур.). *Бер миллионлы байның [теләге] – акчасын ике миллионга җиткерү (йөз меңленеке – ике-өч йөз меңгә мендерү).* Г.Тукай

7) *күч.* Властька килергә, югарырак иҗтимагый дәрәҗәгә ирешергә, яхшы эш урынына урнашырга, эшендә уңышлы карьера ясарга ярдәм итү. *Мангыт бәге шаркылдап көлеп җибәрде: – Чыңгыз нәселеннән дип, теләсә нинди көтүчене тәхеткә мендерергә була.* Р.Зәйдулла

8) *күч.* Зурлау, олылау. *Садыйкка төрлечә кыйммәт куйдылар, Садыйкның фикердәшләре, иптәшләре, әлбәттә, бу эше өчен Садыйкны каһарман (герой) дәрәҗәсенә мендерделәр.* Г.Исхакый

9) *күч.* Үзенең эшчәнлек өлкәсендә оста буларак таныту, дәрәҗәсен күтәрү

10) Сәхнәләштерү, спектакль итеп кую, тамашачылар алдына чыгару. *Балетны [«Шүрәле»] сәхнәгә мендерү алдыннан Ватан сугышы башлана, һәм Фәрит [Яруллин], премьераны күрә алмыйча, фронтка китә.* И.Юзеев

Мендереп ату Тиз-тиз генә мендерү

Мендереп бирү Икенче кеше өчен мендерү

Мендереп җибәрү Тиз генә менәргә ярдәм итү; менәргә кушу

Менгереп кую Бер мәртәбә мендерү, алдан мендереп эшен бетерү

Мендереп ташлау Тиз генә мендереп кую, бер җиргә мендереп, шунда калдыру

Мендереп ташлау Бик тиз арада, бик җиңел генә мендерү. *Бу да язмышмы? Ярый ла язмыш җиле, котырынып исеп, балык җәтмәседәй урап алып, таулар түбәсенә мендереп ташласа.* С.Поварисов

Мендереп тору Хәзерге моментта мендерү; мендерү эшен башкаруда булу; шактый вакыт мендерү белән шөгыльләнү

МЕ́НЕДЖЕР *и. англ.* Предприятие, банк, компания яки шуның бер бүлеге белән профессиональ идарә итүче кеше. --- *Киңәшчем булырсыз, хәзергечә әйтсәк – менеджер*... Г.Гыйльманов. *Мин аны ике ел буена юкка гына эшкә өйрәтмәдем, бер дигән менеджер ул, беләсең килсә.* З.Кадыйрова

МЕ́НЕДЖМЕНТ *и. англ.* Товар җитештерү һәм аны реализацияләү белән идарә итү, аның нәтиҗәлелеген күтәрү һәм табышны арттыруга юнәлдерелгән теория һәм гамәл. --- *Тәлгатьтәге бер сәләткә – аның тумыштан оештыру эшенә (менеджмент) сәләтле булуына ак көнләшү белән карыйм мин.* М.Юныс. *Авылдагы теге белдекле бәндә дөрес исәпләгән икән: Камай сәүдә менеджменты бүлегенә кергән.* Ж.Юныс

МЕНЕМ *и. диал.* Атка атланып йөрү, атны менге ат буларак файдалану. *Айгырым сыналмаган түгел. Өченче яшенә чыккач та менемгә өйрәттек.* Г.Ибраһимов

МЕНЕСТРЕЛЬ *и. фр.* Урта гасырларда һәм Яңарыш чорында Европада музыкант-шагыйрьләрнең гомуми атамасы. *Сугыш һәм җимерүләр белән мавыккан рыцарьлар «Роланд турында җыр» дигән героик поэма, «Тристан һәм Изольда» дигән роман, менестрельләр, трубадурлар һәм миннезингерлар поэзиясен тудыралар.* Урта гасырлар тарихы

МЕНЕШЛИ *рәв.* Менгәндә, менү юлында, менеп барган уңайга. *Юлда туган шигырен ул [М.Ногман], баскычтан менешли, гарәп имлясы белән тиз генә язып куйган була, безнең алда күн папкасыннан ачып ала* ---. М.Гали

МЕНЗУ́РКА *и. лат.* Лабораторияләрдә, даруханәләрдә сыекчаларның чагыштырмача кечкенә күләмнәрен үлчәү өчен, бүлемнәре, шкаласы булган пыяла савыт. *Аның кечерәк кенә эш бүлмәсендә һәрчак ут яна. Өстәлләрдә, шүрлекләрдә төрле пробиркалар, мензуркалар, спиртовкалар, пыяла банкаларда төрле-төрле препаратлар.* А.Хәсәнов

МЕНИНГИТ *и. гр. мед.* Баш һәм (яки) арка мие тышчаларының ялкынсынуыннан гыйбарәт авыру. --- *Һади Такташ вафат булган. Башта тиф, аннары менингит белән ул нибары 13 көн генә авырган.* Ж.Фәйзи. *Иң гади төзелешләләр китереп чыгара торган кеше авыруларыннан амёба дизентериясе, амёба менингиты, токсоплазмоз, йокы авыруы, «Көнчыгыш язвасы» кебекләре куркыныч.* Биология. Хайваннар

МЕНЛА *и. гар. иск. к.* **мелла**. *Хисаметдин менла үзенең милләтене, ягъни татарларны бик сөюче адәм иде.* М.Акъегет

МЕНМӘ *и. к.* **менем**. *Менмәгә бирсәң җәбә бир: Тибенгедән тир чыкмас* ---. Дастан

МЕНСТРУА́ЦИЯ *и. лат.* Бала табу яшендә булган хатын-кызларда овуляция белән бәйле рәвештә ай саен аналыктан кан килү күренеше; күрем, айлык. *Кычыткан экстракты овариаль циклны нормальләштерә, нәтиҗәдә*

менструация көннәренең саны кыскара. Урман аптекасы. *Яшүсмер кызларда менструация циклы регуляр булмый, кайчагында берничә айга тукталып тора.* Биология

МЕНТАЛИТЕТ *и. фр.* Халыкка яки аерым шәхескә хас булган дөньяга карашлар җыелмасы, фикер йөртү рәвеше, психология. *Ата-ана еш кулланa торган бәетләр, кыйссалар, мәкальләр, әкиятләрне башка телгә күчерсәң, югала да кала. Безнең бит менталитетыбыз да башка.* М.Әхмәтҗанов. *Кешенең физик эштән читләшүе, шулай итеп, җәмгыятьнең язылган һәм язылмаган кануннарыннан, тормыш рәвешеннән, халык менталитетыннан да килеп чыга.* Н.Измайлова. *Карадан киенү дә ямьсез димәс идем. Бары тик без башка менталитетта тәрбияләнгәнгә генә сәер тоела ---.* Татарстан

МЕНТАЛЬ *с.* **1.** 1) Менталитетка караган, менталитет дәрәҗәсендәге. *--- теге яки бу халык театры дигәндә, аның асылын, йөзен --- милләтнең үзенә генә хас яшәү рәвешен, менталь сыйфатларын, тарихи язмышын, әхлакый кыйммәтләрен сәхнәдә тулы итеп ачу, шуларга нигезләнү билгели.* А.Әхмәдуллин. *Концептларны өйрәнүчеләрнең барысы да аларның менталь табигатен билгеләп үтә.* Фән һәм тел

2) Акыл эшчәнлеге, акыл сәләте, зиһен белән бәйле булган. *Менталь арифметика*

2. *рәв. мәгъ.* Менталитет белән бәйле рәвештә, менталитет дәрәҗәсендә

МЕНТОЛ *и. лат.* Япон һәм борыч бөтнегенең эфир майларыннан алына торган, үтәкүренмәле кристалл формасындагы көчле исле органик матдә (медицинада, парфюмериядә һәм кондитер әйберләре хәзерләүдә кулланыла). *Медицина практикасында ментол аеруча киң файдаланыла. Ментол маен бавыр һәм үт куыгы авыруларыннан кулланалар.* Урман аптекасы. *Бөтнекләрнең хуш исе аларда үзенә бер төрле матдә – ментол булуга бәйле; борыч бөтнегендә ментол шактый күбрәк.* Татарстанның үсемлекләр һәм хайваннар дөньясы

МЕ́НТОР *и. гр. кит.* 1) *иск.* Остаз, өйрәтүче, тәрбия бирүче

2) *күч.* Өйрәтеп торырга, кирәксә-кирәкмәсә киңәш бирергә яратучы кеше

МЕНУЭТ *и. фр.* Хәрәкәтләре күбрәк иелү һәм реверанслардан гыйбарәт булган, салмак кына биелә торган борынгы француз бал биюе. *Анда ул салмак менуэт белән катлаулы контрдансны тиз үзләштерде һәм җитез полька-кадрильне дә җиңел биергә өйрәнде.* Җ.Тәрҗеманов. *--- полонез, менуэт, вальс көйләренә ләззәтләнеп, уеннарда я фал ачуларда катнашып вакыт үткәрәсегез килсә, 26 һәм 27 декабрь яки 4 һәм 6 гыйнвар көннәрендә музейга килегез.* Сөембикә

МЕНҮ *ф.* 1) Биеклеккә күтәрелү, югарыга, өскә табан хәрәкәт итү. *Киң офыкка менгәч кояш, Алтын нурлар кунгач тауга, Ишкәкләрен кулга тотып, Балыкчылар чыкты ауга.* Р.Әхмәтҗанов. *Узган елны ак тауларга менеп, Бер җыр язган идем ак ташка.* Ф.Гыйззәтуллина. *Биек тауга менә идек, Җитәкләргә мин теләдем сине.* Р.Гаташ

2) Үрмәләп, нәрсәгә дә булса тотынып, асылып, биек урынга, берәр нәрсәнең өстенә, түбәсенә күтәрелү. *Шәйхи хәлфә, больницага киткән карчыгының озак торуына эче пошып, Ташлытау юлын күзәтергә манарага менгән иде.* М.Мәһдиев. *Мин утар янындагы койма киртәсенең иң өскесенә мендем дә тирә-якны күзәтергә тотындым.* Л.Шәех. *Без, малайлар, йөзәр ел яшәгән наратлар буйлап үрмәләргә бик ярата идек. Аларның очларына кадәр менә идек.* Дөньяда ниләр бар

3) Урнашу, берәр югарырак урынга басу яки утыру. *Бабай, әлеге бер квадрат метрлы сәкегә менеп, аягын бөкләп утырды.* М.Мәһдиев. *Әйтәсе фикерең бар икән, рәхим ит: трибуна артына менеп бас та сөйлә.* М.Хәсәнов. *Ә Иван сәүдәгәр чыгарга ашыкмады, үз өендәге хуҗа шикелле таралып, түр башына менеп утырды.* Ф.Латыйфи

4) Кая да булса бару өчен, автомобиль, вагон, теплоход һ.б. транспорт чарасында урын алу, кереп утыру. *Мин тиз генә ханымның кулларын кысып саубуллаштым да пароходка мендем һәм иптәшем И.Ар. гаиләсенә кушылдым.* Г.Баттал-Таймас. *Көймәгә беренче Хуҗа сикереп менде, аның артыннан ярдәмчесе үрмәләде, аннан соң Мөхәммәтләр урнашты.* З.Хөсният. *--- артымнан ияреп бер үк вагонга менсә, поезд кузгалгач, мин бу адәм хурын тамбурдан тотып тондыруым җөдә ихтимал.* Т.Әйди

5) Һавага ашу, очып, җилпенеп югарыга күтәрелү. *Без очкычлар уйлап тапкан булдык, Ракеталар менде галәмгә, Тик металлга сеңгән энергия Бик аз ярдәм итте адәмгә.* Ә.Рәшит. *Мин эзләдем сине күпме таудан, Хәтта кошлар менмәс биекләрдән!* Зөлфәт. *Һава шары атмосферада гондоланы югары күтәреп менгән кебек, һава куыкчыгы да үзенә асылынган кисәкчекне өскә калкытып чыгара.* Кызыклы физика

6) Елга агымына каршы хәрәкәт итү, йөзеп бару. *Халык белән шыгрым тулы пароходта Кама буйлап өскә таба тәүлек ярым мендек.* А.Хәсәнов. *Пароход сиздермичә генә дебаркадердан аерылып китте, бер йөз метр чамасы үргә менде дә, бик зур әйләнгеч ясап, түбәнгә таба борылды.* Н.Фәттах. *Бу вакытта ерактарак түбәннән менеп килгән зур гына пароход күренде.* Р.Гали

7) Тирә-яктагы урыннардан чагыштырмача югарырак урнашкан берәр җиргә бару, килү. *Әллә --- күп үтелгән шушы таныш юл белән институтка менеп китәргәме?* Э.Касыймов. *Пароходтан мин иң соңгы пассажир булып чыктым. Җиргә аяк баскач, өскә – вокзал бинасына мендем.* Н.Фәттах. *– Ярар, күп теленә салынма, – диде Гүзәл үртәшеп, – кара моны, мәктәптә тавышы чыкмый, клубка менгәч әтәч булган!* А.Гыймадиев

8) Аскы каттан югарыдагысына күтәрелеп, берәр кеше янына керү. *Хуҗа кеше балаханәгә менмәде – төннe шул кунагы белән серләшеп уздырды.* Т.Әйди. *Тамак ялгагыз да, син минем янга – өске катка мен.* В.Имамов. *«Нинди йомышың булса да мен, фатирым сезнең өстә генә ---», – дип көйләгән Дуся түти белән, чынлап та, бик тиз дуслашып та киттек.* Сөембикә

9) Астагы корылмадан, каттан өске катка үтеп керү, таралу (һава, төтен, ис, пар һ.б.ш. тур.). *Моржадан Күк*

төтеннәр Күкне бораулагандай Бөтерелеп менәләр дә Шым гына тараладар... Ш.Галиев. *Һава җитми. Тыны кысыла. Күрәсең, ул кунаклаган өске катка сасы һава гына менә.* М.Хафизов

10) Югарыга табан таралу, яңгырау (тавыш, җыр тур.). *Җыр тавышы Чаукалык тавына менеп китә, ә Чаукалык тавы бу тавышка күнеккән һәм аны көлемсерәп тыңлый кебек...* В.Юныс

11) Ашу, ирешү, килү, җитү. *Котылдым дияр идем, шунда ук икенче кайгы менде башка: әйткән нәзеремне ничек гамәлгә ашырырга?* М.Әмир. *Шигырь техникасы, шигырьдә образлылык чәчәк ата, әмма фикер орбитасы гына чикләнгән дә, күңелләргә менеп ирешергә хис җитенкерәми...* Ш.Галиев. *--- һәрьяктан мөкәммәл әсәрләр – халык теленә менгән әсәрләребез бармы?* Р.Әхмәтҗанов

12) Тән буенча астан өскә табан җәелү, күтәрелү (авырту, исерү һ.б.ш. халәт тур.). *Кинәт тыны тамагына менеп, иркенләп сулыш алырга комачаулый башлады.* М.Хәсәнов. *Башка менми, иңгә оешса кан. Иңдә камчы эзе, йөк эзе...* Р.Зәйдулла. *Ә йөрәк каядыр бугаз тирәсенә менгән. Тынны кысып каты-каты тибә.* И.Иксанова

13) Атлану, атланып утыру. *Атка менеп юыртып китеп бару турындагы уй башына да килеп карамады малайның.* Р.Мөхәммәдиев. *Ул атка менеп урам буйлап чабып узганда, кем генә сокланып карап калмады икән!* М.Маликова. *Аягына басканнан алып авылның бик күп атларын, атаклы айгырларын сырт менеп йөрергә өйрәткән Җәүдәт монда да югалып калмады.* З.Зәйнуллин // Атланып йөрү. *Тарханнар һәм илчеләр алардан олау һәм менү атлары алмасыннар.* Казан утлары

14) Су горизонты күтәрелү, су биеклеге арту. *Кил, диңгез! Тезләремә мен дә сөйлә әле, Хәлләреңне синең белербез.* Р.Зәйдулла. *Дулкын палубага менеп, корылмага килеп сугылганда, су тамчылары рубка тәрәзәләренә бәрелә.* М.Юныс

15) Температура күтәрелү турында. *Хәтирә [докторга] әнисенең температурасы язылган кәгазьне суздым. – Уһу, 39,1. Кая, карап карыйк әле, хәзер ничәгә менде икән?* Г.Минский

16) Калкып өскә чыгу (сыеклык эчендә батмый торган әйберләр тур.)

17) *күч.* Властька күтәрелү, эш урынында, гомумән, җәмгыятьтә дәрәҗә яулау, уңышлы карьера ясау. *Әгәр син көч кулланырга, корал белән властька менәргә, кан коярга чакырмыйсың икән, синең теләсәң нинди партия политикасын яклап чыгарга хокукың булырга тиеш.* В.Юныс. *--- минем өчен изгеләр дәрәҗәсенә менгән малайны рәнҗетәсем килмәде.* Г.Гыйльманов. *Моннан ике ел элек, ул Парижда чакта, Сухроб Ак йортка үрмәләгән, аның дусты Миршаб Югары судта дәрәҗәле кәнәфигә менеп утырган.* Р.Мирхәйдәров

18) *күч.* Осталык югарылыгына күтәрелү, югары сыйфатлы әсәр тудыру дәрәҗәсенә ирешү. *Поэзиябезнең киләчәктә Тукай, Җәлил менгән биеклекләргә күтәрелүе бәхәссез!* И.Юзеев. *Вакландык дип юкка оялабыз, Биеклеккә менгән кеше генә Азатлыкның җилен, тәмен татыр, Һәркайсыбыз, бәлки, Алып Батыр?!* М.Галиев

19) *күч.* Үсү, арту, күтәрелү (эш хакы, бәяләр тур.). *Әйбер бәяләре котырынып үсә. Бер көн – бер хак, икенче көн инде аның ике бәясенә менгән.* Ш.Камал. *Эшкә өйрәнеп, инде үзең чынчын мастер булып киткәч, [эш хакың] йөзгә дә, артыкка да менәр.* Ф.Әмирхан. *Ул акчаны кайтарган көнне бер долларның кимәле дүрт меңгә менгән иде.* Т.Галиуллин

20) *күч. сир.* Артып бару, үсү (яшь тур.). *Белем ягы да бик сай инде минем, яшем дә алты дистәнең өске ягына менеп бара.* Г.Бәширов

21) *күч.* Җырлау, бию һ.б. өчен сәхнәгә күтәрелү, тамашачылар алдына чыгу. *Сәхнә буш кала. Буш калган сәхнәгә дилетантлар, конъюнктурщиклар менә.* Р.Низамиев. *Балалар йортында яшәгәндә дә, студент елларында да сәхнәгә күп тапкырлар менәргә туры килде.* Ә.Моталлапов. *Ниһаять, сәхнәгә себер татары теле, җыры, бию менде!* Сөембикә

22) Куелу. *Анда [табынга] төрле ризык-нигъмәтләр, тәм-томнар урта-сына, кукраеп, бер шешә әрмән коньягы менеп утырды.* Г.Тавлин. *Басынкы ул: халыкара конгресслар, Парламентлар ачып йөрми, Акча, чеклар битенә менми.* Р.Фәйзуллин. *Түрдә торган тәбәнәк өстәл булмә уртасына чыгарып куелды, суыткычтан иң затлы ризыклар, тәм-томнар алынды, иң ахырдан өстәл түренә күзне камаштырырлык шәраб шешәсе менеп кунаклады.* Г.Гыйльманов

◊ **Менеп төшү** *гади с.* Сугып җибәрү, кундыру, манчу. *--- тыңлап торучылар арасында булган Хуҗа абзый бу эшкә нокта куйган: Курай Назыймның колак төбенә менеп төшкән.* Р.Мөхәммәдиев. *Арлы-бирле юыртырга әллә син мине лакей дип белдеңме? Ычкын моннан, яңак төбеңә менеп төшкәнче!* Ш.Абдуллин. *Их, торып басып, туктатып, кабинасыннан өстерәп төшереп, колак төбенә бер менеп төшәсе дә ---.* Ж.Юныс

Менә башлау Менәргә тотыну. *--- полковник үзенең әсирләренә: «Минем арттан!» – дип җикерде дә, машинадан сикереп төшеп, биек баскычтан менә башлады.* И.Хуҗин. *Азамат зур һәм тиз адымнар белән йолдызлык тавына менә башлады.* Р.Ахунова

Менә тору Башка эш-гамәл барышында менү; һаман менү. *– Син, әби, үз җаең белән генә менә тор, – дидем мин, кузгалып.* Н.Фәттах. *Дошман күп иде, таш басмалар буйлап киң дивар өстенә алар менә торды, менә торды.* З.Мурсиев

Менеп бару Сөйләү моментында менү хәлендә булу, өскә, югарыга таба хәрәкәт итеп ераклашу. *Үрдән-үргә менеп барганда, Офыкларга торам орынып. Үрсәләнеп карыйм борылып ---.* Ш.Галиев. *Габделхак улы Гыйлемхан үзенең туган нигезенә тәрәзә йөзлекләре куярга менеп бара, күрәсезме?!* Р.Мөхәммәдиев. *Ул инде үргә менеп бара. Олы юл өстендә эленеп тора тузан.* Роб.Әхмәтҗанов

Менеп җитү Кирәк булган, күздә тотылган урынга кадәр күтәрелү, менү, билгеле чиккә ирешү. *Төн. Ай күк гөмбәзенең түбәсенә менеп җиткән.* М.Хуҗин. *Атлар чапты... Колга башларына Менеп җитте кичә Кыюлык;*

Хаклык батыр калды. Мактанчыклык Капчык тигәч төште егылып. Х.Әюп. *Соңгы борылышка да менеп җиттем: ул-бу күренми дә, ишетелми дә кебек.* Р.Мөхәммәдиев

Менеп килү Астан өскә таба хәрәкәт итеп якынлашу, югарыга күтәрелү хәлендә булу. *Түбән яктан зур бер пароход менеп килә.* Г.Бәширов. *Әнә Геннадий Китайгородский үзенең матросын иәртеп рубкага менеп килә.* М.Юныс. *Дөбер-шатыр кемдер чормага менеп килә иде.* Аманулла

Менеп китү Өскә табан, үрге якка, югары катка юнәлү, югарыга таба күтәрелә башлау. *Олькеницкий үзенең егетләренә, уяурак торыгыз, дигәндәй бер ым кагып, икенче катка менеп китте.* З.Фәтхетдинов. *Розаның иң матурын сайлап алдым да алман дәресенә менеп киттем.* Л.Шәех. *Кайчандыр сазлыклы тайгаларга кереп, беренче тимер юллар салган бабалары кебек, беренче иреклеләр, иңнәренә төзү кораблләрен салып, Айга менеп китәр.* Кызыклар дөньясында

Менеп тору Даими, регуляр рәвештә менү, берөзлексез менү; шушы моментта менү. *Астан, йөкләр причалыннан, берөзлексез диярлек машиналар менеп тора.* Э.Касыймов

Менеп төшү Югарыга, берәр нәрсә башына, өстенә яки өске катка күтәрелеп, яңадан төшү; тизгә генә, гадәттә якын җиргә барып кайту. *Үз урынын эзләү сылтавы белән [Әхмәт] залны да йөреп чыкты, югары катка, балконга да менеп төште. Рабига юк иде.* Г.Минский. *Билал үзе генә торып, юынып, киенеп, иң югары каттагы кафега менеп төште.* М.Вәлиев. *Капотны ачтырды, кузовка менеп төште, хәтта утыргыч асларына хәтле тикшерде [сержант].* А.Гыймадиев

МЕНҮЛЕ *с.* Атлы, атка менеп хәрәкәт иткән, атка атланган. *Ат менүле немецлар, полицайларга җим буласылары килми иде.* Х.Камалов

МЕНҮ-ТӨШҮ *ф.* Менү һәм төшү, менеп-төшеп йөрү. *Менеп-төшеп йөрергә бик уңайлы: ындыр артына гына чыгасың да койма башына үрмәлисең.* Н.Акмал

МЕНЬШЕВИЗМ *и. рус тар.* Россия социал-демократик эшчеләр партиясенең большевиклар тармагына каршы булган, шул партиядән аерылып чыккан сәяси агым. *[Фәйзи] меньшевиклар казанында кайный. Бөтен типография, бөтен союзлары меньшевизм авыруы белән чирлиләр.* Ш.Камал. *Меньшевизм – көрәш сафларының Үпкәсенә поскан авыру ул. «Лидер»ларның бите ачылуда Ул микробның ачы даруы.* Х.Туфан

МЕНЬШЕВИК *и. рус тар.* Меньшевизм тарафдары, шул агым әгъзасы. *Арбадан халык өстенә «анархист», «монархист», «большевик», «меньшевик», «эсер», «хөррият» дигән яңа сәер сүзләр сибелә башлый. Сөйләүчеләрнең һәркайсының үз сүзе, үз иманы бар ---.* Г.Бәширов. *Корылтайда катнашучыларның күпчелеген социалистлар, уң эсерлар, меньшевиклар, кадетлар тәшкил итә, ә утыз делегаттан гыйбарәт большевиклар азчылыкта кала.* Казан утлары

МЕНЬШЕВИКЛА́РЧА *рәв.* Меньшевизм күзлегеннән, меньшевиклар позициясеннән торып. *Ничек итеп, Мохтар, икәү бергә торып, [Фәйзине] бераз рәткә китерә алмыйсың? Нәкъ меньшевикларча уйлый бит.* Ш.Камал

МЕНЬШЕВИ́СТИК *с.* Меньшевизм карашларына нигезләнгән, шул карашларны чагылдырган; меньшевизм һәм меньшевиклар белән бәйле. *Меньшевистик фракция*

МЕНЮ *и. фр.* 1) Иртәнге, көндезге һ.б. ашау вакытына әзерләнгән ашамлык төрләре һәм ашханәдә, ресторанда, кафеда шуларны күрсәткән исемлек. *Руфинә менюны елмая-елмая карап чыкканнан соң, аңа [Альфредка] суздыы.* Ф.Садриев. *--- Сез сораган ризыклар юк, – дигән кыз. – Меню кәгазегездә бар дип язылган лабаса.* Ш.Маннапов. *Менюны караштырган кунагым: – Мин монда рус ашлары бүлегендә пилмән күрмим, – диде.* М.Гали

2) *информ.* Компьютерда кереп эшләү өчен тәкъдим ителгән программалар һәм функцияләр исемлеге

МЕҢ *сан* **1.** 1) 1000 санын һәм микъдарын белдергән сүз. *Хәзергесе көндә банкыда ун мең тәңкә акчабыз бар.* Т.Миңнуллин. *Ун мең, йөз мең, хәтта миллион кешегә бер генә шагыйрь туа, бер-ике генә...* Р.Батулла. *Ашамлык итеп кишер инде дүрт мең ел кулланыла.* Дөньяда ниләр бар

2) *күч.* Бик күп, исәпсез, бихисап. *Мең кайгыңа мең җырым Әзер сиңа, күз нурым.* Ф.Сафин. *Бу – көздер бу... Көз халәте Меңгә төрләнгән чаклар.* Л.Лерон. *Кондызлы күл буенда булган хәлне Мөбахис мәзин малае Бәкержән, гайбәтче алама хатын-кызларга охшап, мең өлеш арттырып, күпертеп сөйләп йөргән.* С.Поварисов

2. *рәв. мәгъ.* 1) *күч.* Әллә ничә тапкыр, бик күп мәртәбә. *Матурлар арасында ямьсез булып йөргәнче, ямьсезләр арасында матур булып яшәвең мең артык!* Г.Рәхим. *Мең янды да йөрәк, мең суынды, Мең кат үлеп, мең кат терелде ---.* Г.Мөхәммәтшин

2) **мең-мең** *каб. форм.* Бик күп, күп төрле, меңнәрчә. *Ләкин дөньяда меңмең очракка бер тапкырдыр, мөгаен, һичкем ышанмаслык могҗизалар да булгалый икән.* Ш.Рәкыйпов. *Без диңгезгә карап сокланабыз, Бигрәк матур суның өсләре – Бардыр монда гәүһәр, зөбәрҗәтнең Уйнап торган мең-мең төсләре!* Ш.Галиев. *Рәхмәт сезне юлга чыгаручыга, рәхмәт кичү күрсәтүчегә, мең-мең рәхмәт ат тотучыңа.* М.Хәбибуллин

3. *и. мәгъ.* **меңнәр** *күпл.* 1) Халык, массалар, меңнәрчә кешеләр. *Меңнәр барып үлмәсә, җиңеп кайтучылар булмас иде.* Ш.Галиев. *Кайгыра да алмый ана – Исән дип куана: Меңнәр бүген кул-аяксыз, Берәү сукыр булганга.* Р.Юныс

2) Әллә ничә мең тәшкил иткән акча, зур байлык. *Меңнәргә ия дип әйтәләр аны*

◊ **Мең бәла** Зур бәла, зур проблема. *Киштәләрдә калын китап – «Рух»мы, «Рухнамә» микән? Рухың булып, намәң бетсә, Яшәү мең бәла икән.* Г.Мөхәммәтшин. **Мең бәла белән** Авырлык белән генә, бик зур кыенлыкларны җиңеп. *Бикмуш бабай --- тимерне коры имән утынннан төшкән кызу күмергә салып кыздырды. Мең бәла белән бөкте аны.* Г.Гобәй. **Мең газап белән**

к. **мең бәла белән**. *Ярар, мең газаплар белән барып та җитсеннәр, ди. Анда аларны кем көтеп тора?* А.Хәсәнов. *Мең дә бер газап белән язылган хатны алып укыгач, Рәхимулланың күңел җәрәхәтенә янә учлап тоз сипкән төсле булды.* Б.Камалов. *Мең газап белән булса да әлеге, бөтенесен дер селкеткән, бик тә куркытып торган тикшерү дә узып китте.* М.Вәлиев. **Мең дә бер тапкыр (кат)** Кабат-кабат, әллә ничә тапкыр, бик күп мәртәбәләр. *Җәләл кәнәфигә кырын ята да мең дә беренче катка янәдән сорый башлый.* Г.Ибраһимов. **Мең дә берне белү** Бик күп белү, кирәкне-кирәкмәгәнне белү (гадәттә төрле хәйлә, алдау ысулларын белүче кеше тур.). *Бик инде күпне, мең дә берне белә торган нәрсә [бу Маннур].* М.Хәсәнов. **Мең яшә!** Озын гомер теләү гыйбарәсе. *Безгә патшалар сые әзерләгәнсең – мең яшә!* М.Юныс. **Мең рәхмәт!** Чын күңелдән рәхмәт әйтү, чиктән тыш канәгатьлек хисен белдерү сүзләре. *Күнмәдең, ярашмадың син Урталык юлларына. Мең дә бер рәхмәт, йөрәгем, Битараф булмавыңа.* Х.Туфан. *Аш талымлап тору гомумән юк, өстәлгә ни куйсалар, шуңа мең рәхмәт.* А.Хәсәнов. *Шатлыклы хәбәр алып килгәнең өчен мең рәхмәт, Сабир туган.* Г.Тавлин. **Мең төрле** Бик күп, бихисап, төрледән-төрле. *Минем кебек бичара хәлдәге кешеләрне яклый торган мең төрле законны актарып чыгарды.* К.Тимбикова. *--- Озаталар берәм-берәм, Мең төрле бәла-казадан Йолачак дога белән.* Х.Әюп. *Бер көн эчендә аның башына мең төрле бәла төште.* М.Хәбибуллин. **Мең шөкер** Үтә канәгать, бик риза булуны белдерү гыйбарәсе. *Күз тигәндер, диеп эчтем тәң суын, авыз иттем, мең шөкер, зәмзәм суын...* Л.Шагыйрьҗан. **Мең яшәрле(к)** Бик озак еллар яшәгән яки яши алырлык, бик озын гомерле. *Борын-борын заманда яшәгәннәр бу тауда йөз башлы аждаһалар, Мең яшәрле юхалар.* М.Җәлил. *Үзе үлсә дә, «мең яшәрлек имән булып», яшьлегенә «һәйкәл булып» эше калды, эзе калды.* Казан утлары

МЕҢ АГАСЫ *и. тар. к.* **мең башы**

МЕҢАЯК *и. зоол.* Күбаяклылар классыннан аз хәрәкәт итә һәм таш аслары, агач төпләренең кабык асты кебек тыныч урыннарда яши торган умырткасыз хайван; *русчасы*: **кивсяк**. *Яфрак ашап торган меңаякларны тоту бик ансат: ачык пробирканы яфрак астына якын китереп тотасың да күбаякны шунда җиңелчә генә төртеп төшерәсең ---.* Ә.Халидов. *Күбаяклыларның тагын бер төре – меңаяк (кивсяк), ул сапрофаг, ягъни органик матдәләргә бай үсемлек калдыклары белән туклана, икенчеләрен фитофаглар дип тә атап була.* Яшь натуралистларга

МЕҢӘР *сан* 1) һәркемгә, һәрнәрсәгә мең, бертигез күләмдәге мең нәрсә туры килүен белдергән бүлү саны. *Меңәр ваттлы миллион лампочкаларны берьюлы кабыздылар диярсең.* А.Хәсәнов. *Дүрт кешегә меңәр сум түләргә кирәк булыр.* Ф.Сафин

2) *к.* **меңнәрчә**. *Меңәр чакрымнарга сузылган иген кырлары, урманнар, дәрьялар, диңгезләр ---.* Г.Бәширов. *Тирә-юньдә меңәр чакрымга сузылган ком чүле.* Р.Вәлиев

МЕҢӘРЛӘГӘН *сан к.* **меңләгән**. *Буран дулый, Җанны кыйный, Бәргәләнәм, дивана! Кызыктырып, офыкларда Меңәрләгән ут яна.* Р.Зәйдулла. *Ахыр чиктә дистәләгән кешеләр моңарчы күрмәгәнчә баеды, меңәрләгән эшчеләр исә бернәрсәсез, хәтта эшсез калып, урамга чыгарып җибәрелде.* М.Маликова. *Меңәрләгән яшен берьюлы яшьнәгәндәй итеп күкләр күкри.* Р.Низамиев

МЕҢӘРЛӘП *сан* **1.** *к.* **меңләп 1.** (*2 мәгъ.*). *Падишаһларга адәм балаларын меңәрләп кыру гына аз. Бәндәләрнең күңелен изеп, рухын таптап кинәнү кирәк.* М.Маликова. *Мин синнән куәтлерәк батырларны да меңәрләп дөмектердем!* Р.Батулла

2. *рәв. мәгъ.* 1) Мең-мең итеп, меңнәргә бүлеп. *«Үз теләкләре белән минем эшемә ярдәм итүчеләрне, – дип яза Бербанк үзенең хатларында, – меңәрләп санарга мөмкин ---».* Робинзон эзләреннән

2) Бик күпләп, исәпсез-хисапсыз. *Әйе, безгә милләт җанлы кешеләр берән-сәрән генә түгел, йөзәрләп, меңәрләп кирәк.* Т.Миңнуллин. *Ә үзләре полякларны төрмәләрдә черетәләр, меңәрләп-меңәрләп Себер сөрәләр.* М.Хафизов. *Рига шәһәре янында зур концлагерь булган, шунда бернинди гаебе юк латышларны, хатын-кызларны меңәрләп кырганнар.* Х.Камалов

МЕҢӘ́Р-МЕҢӘР *рәв.* Меңәрләп, меңләп; бик күп, бихисап. *Алар уйлап таба тора, заводлар меңәр-меңәр тонна эшләп чыгара, поездлар ил буйлап тарата.* М.Маликова. *Әтилдә кенәзләрдән качып киткән урыслар бик күп икән. Алар хәзер пайтәхеттә меңәр-меңәр исәпләнә, диләр.* В.Имамов

МЕҢӘ́Y *сан* **1.** Барлыгы бергә мең берәмлек булуны белдергән җыю саны. *Берәү бар – меңгә торыр, меңәү бар – бергә тормас.* Мәкаль. *Куйсалар белән сайласалар арасында аерма бар, энекәш. Куйганда берәү куя; сайлаганда меңәү сайлый.* Т.Миңнуллин

2. *рәв. мәгъ.* 1) Мең кеше берьюлы

2) Бик күп, бихисап. *Сөю хисе меңәү икән, Ә мин үзем берәү икән. Акыл моны белә кебек, Ә соң йөрәк белә микән?* Р.Фәйзуллин

МЕҢБАШ *и. тар. к.* **мең башы**. *Ул арада сарай йортына меңбаш баһадир Баян килеп керде.* М.Хәбибуллин. *Нуретдин бәк, яуны син әйдисең! Мин чирудә меңбаш булып барам.* В.Имамов

МЕҢБА́Ш ҮЛӘН *и. бот.* Канәферчәләр семьялыгыннан сабан ашлыгы арасында чүп үләне буларак үскән, кайбер төрләре декоратив максатларда үстерелгән берьеллык үлән үсемлек; *русчасы:* **тысячеголов**

МЕ́Ң БАШЫ *и. тар.* Борынгы заманда мең кешелек гаскәр башлыгы. *Яуны кара качырыр, җиңгән исеме мең башына калыр.* Мәкаль. *Мең башыннан йөз башы, Йөз башыннан ун башы --- – Бар да атлады каладан.* Дастан. *--- Емельян Пугачёв гаскәренә полковник Бәхтияр Канкаев, мең башы Муса Мостафин, полковник Мәсәгут Гомәров кебек кыю егетләр җитәкчелегендә 85 мең татар килеп кушыла ---.* М.Мәхмүтов

МЕҢГЕ́Р-МЕҢГЕР *иярт. к.* **медермедер**. *Ул, чынлап та, башкалар кебек*

меңгер-меңгер дәрес ятлап баш ватмый. Г.Ибраһимов

МЕҢЕНЧЕ *сан* 1) Рәт, тәртип буенча мең урынында килүне белдергән тәртип саны. *Инде очраклы рәвештә тере карп сатканны күргәнсең икән, меңенче кеше булып чиратка басарга көчең җитәме?* М.Әмир. *Мең яшә, меңьяшәр Казаным! Меңенче языңа керсәң дә, Иң гүзәл шәһәр син дөньяда!* Р.Сәлах

2) *күч.* Әллә ничәнче. *Утыз беренче декабрьдә мин сиңа меңенче тапкыр мат куячакмын.* Р.Вәлиев

МЕҢЛӘГӘН *сан* Әллә ничә мең; меңнәрчә, бихисап. *--- Усемлек дөньясы меңләгән төрдән тора.* М.Насыйбуллин. *Безнең эзләргә басып, җир йөзеннән меңләгән буыннар узар.* М.Юныс. *Ялгышлыкка меңләгән юллар илтсә дә, дөреслеккә исә берәү генә алып бара, диләр.* Т.Галиуллин

МЕҢЛӘП *сан* **1.** 1) Мең чамасы. *Җир йөзендә өч меңләп тел бар. Һәрберсенең үз тамыры.* С.Поварисов. *Гөлнисә белән кара көнгә дип унҗиде меңләп акча җыйган идек.* З.Фәйзи. *--- әгәр саклык белән генә салсаң, аңа [сулы бокалга] меңләп булавка сыйдырырга мөмкин ---.* Кызыклы физика

2) Бик күп. *Ачылмаган меңләп сере белән Озатып калыр мине Сүрия.* Р.Сәлах

2. *рәв мәгъ.* 1) Меңнәргә бүлеп, мең-мең итеп, меңнәр белән. *Шуны да әйтеп үтик: югарыда санап кителгән табылдыклар йөзләп, хәтта меңләп исәпләнә.* Ф.Хуҗин

2) Бик күпләп. *Пётр I урыс халкын меңләп кыра, кеше җәзалаганны карап торып, шуннан тәм таба, аны бөек реформатор дип мактаналар урыслар.* Т.Миңнуллин

МЕҢЛӘ́П-МЕҢЛӘП *рәв.* Меңәр данә яки меңәр кеше итеп; меңнәр белән исәпләп. *Меңләп-меңләп баланы мөселман авылларына, мөселман шәһәрләренә йирләштерә алыр идек.* Г.Исхакый. *--- алар, лагерьларга ябылып, шунда ачлыктан, төрле йогышлы авырулардан меңләп-меңләп кырылганнар.* Р.Мостафин

МЕҢЛӘТӘ *рәв.* 1) Мең тапкыр, мең кабат

2) Күп мәртәбәләр, әллә ничә тапкыр. *Без немец җирендә. Безгә хәзер меңләтә уяу булырга һәм дошманга без рәхимлек күрсәтмәскә тиешбез ---.* А.Кутуй. *Аллаһы Тәгалә сезнең бу сваплы эшегезнең әҗерен меңләтә кайтарыр.* Г.Афзал. *Тау кадәр михнәт-газапларга исләре китмәгән кешеләрнең тормышка бәйләнеп ятулары гүя меңләтә арткан-көчәйгән кебек.* Ә.Еники

МЕҢЛЕ *с. к.* **меңлек**. *Бер заман --- шәһәрдә йөз меңле гаскәр тупланган булган.* Ж.Тәрҗеманов. *Сез – алка эчендә... Сезне ун меңле немец гаскәре камап алган!* Н.Нотфуллина. *Алты йөз лир түләп галереяда утыручыларның өстендә кара смокинг, утыз меңле билет белән ложаларда утыручыларның иске свитер һәм таушалып беткән джинсыдан булулары аеруча хәтергә сеңеп калган.* М.Юныс

МЕҢЛЕК *с.* **1.** 1) Билгеле мең микъдарындагы, билгеле мең берәмлекне эченә алган. *Ханнар катып торганда, Яулар посып торганда, Анда тузан ачылып, илле төрле ту белән, Илле меңлек яу белән Җитеп килде Идегәй.* Дастан. *Вятка ягыннан Владимир Азин командалыгында ярты меңлек отряд килде инде.* Д.Галимов

2) Билгеле мең күләмендәге

3) Билгеле мең сум бәясендәге. *Җиде меңлек телефон*

2. *и. мәгъ.* Бер мең сумлык банкнота. *Меңлекне кибеттә ваклау*

МЕҢНӘ́РЧӘ *сан* Меңләгән сандагы, әллә ничә мең. *Тау-ташлы, канлы, меңнәрчә аналарның, аталарның, сөйгән ярларның, балаларның котын алып торган --- Әфганстан сугышыннан әйләнеп кайтуның ул елларда да, соңрак та әллә ни абруе, даны юк иде.* Ә.Гаффар. *Планетада ел саен меңнәрчә үсемлек төре юкка чыга.* М.Әхмәтҗанов. *Җир йөзендәге иң борынгы халык – төрки бабаларыбыз – меңнәрчә еллар буена күпме сүзләр тудырган, чарлаган, шомарткан, көмешен – көмешкә, мәрҗәнен – мәрҗәнгә, бакырын бакырга аерып куйган.* М.Галиев

МЕҢЧЕ *и. тар.* 1) Эш планын ун тапкыр арттырып яки аннан артык үти торган алдынгы эшче. *Меңчеләр ярышы*

2) Спортта, ешрак аның техник төрләрендә, билгеле күрсәткече бер меңгә тулган спортчы (мәс., парашют белән мең тапкыр сикергән кеше)

3) *тар.* Гаскәрдә мең сугышчыдан торган хәрби берәмлек башлыгы; мең башы

МЕ́ҢЬЕЛЛЫК *и.* **1.** Бер мең елдан торган вакыт аралыгы. *Бу хезмәт халыкның тарихы, аның күп меңьеллык иҗаты белән бәйләнгән.* Х.Госман. *--- төньяк-көнбатыш Европага финугор кабиләләре безнең эрага кадәр III меңьеллыкта килеп чыккан, дип уйлый.* Ә.Кәримуллин. *Өченче меңьеллыкка аяк бастык.* Н.Гариф

2. *с. мәгъ.* Бер мең елдан торган, мең ел тәшкил иткән. *Аның [Рәсәйнең] соңгы меңьеллык тарихында сигез йөз елы сугышта үткән...* М.Юныс

МЕҢЬЯФРАК *и. бот.* Оешмачәчәклеләр семьялыгыннан калкансыман чәчәк төркеме хасил иткән ак чәчәкле, тар озынча киртләч-киртләч вак яфраклы, бик исле күпьеллык үлән үсемлек; ак мәтрүшкә; *русчасы:* **тысячелистник**. *Әгәр кырларда меңьяфрак дигән үлән яхшы уңса, кыш йомшак булыр.* Х.Мәхмүтов. *Меңьяфракның яңа сыгылган соңгы бетчәләрне бетерү өчен биткә сөртәләр.* Урман аптекасы. *Меңьяфракның чәчәк төркеме катлаулы: вак чәчәкләрдән җыелган калкансыман чәчәк төркеме, вак чәчәкләр үзләре дә аерым бер генә чәчәк түгел, ә кәрзиннәр.* Татарстанның үсемлекләр һәм хайваннар дөньясы

МЕҢЬЯШӘР *с.* Мең ел яши торган; мең ел яшәрлек; бик карт. *Меңьяшәр имәннәрнең үсенте чагын күргәндәй инде бу. Боларның өлгерү чаклары килер гасыр офыгының аръягында.* Ш.Галиев. *Мең яшә, меңьяшәр Казаным! Меңенче языңа керсәң дә, Иң гүзәл шәһәр син дөньяда!* Р.Сәлах

МЕ́РГЕЛЬ *и. нем.* Вак бөртекле кальциттан, доломит һәм кызыл балчыклы минераллар катнашмасыннан торган, цементлар җитештерү өчен файдаланылган утырма тау токымы. *Тизрәк, тизрәк бу күңелне тырный торган мергель бетсен иде. Ләкин мергель катлавы тиз генә җиңелергә*

уйламады, ахры. Р.Ильяс. *Мәсәлән, әгәр туфрак катламы асты ташлы булса, яки катлам өстенә якында мергель, көпшәк известьташ ятса, мондый участокта алмагач (һәм кара карлыган да) утыртырга кирәкми, аның каравы монда чия ярыйсы гына үсәчәк.* Бакчачы белешмәсе

МЕРЕ́ЖКА *и. рус махс.* Тукыманың буй җепләре буйлап тар юл кебек итеп эшләнгән үтәли чигү, челтәрнең бер төре. *Мережка ясау өчен, тукыманың берничә җебен суырып алалар.* Йорт эшләре

МЕРЕ́ЖКАЛАУ *ф. махс.* Мережка ысулы белән, челтәрләп-юллап чигү. *Төсле җеп белән мережкалау. Әйбернең читен мережкалау*

МЕРИДИАН *и. лат. геогр.* Ике полюс аша үткән яссылык Җир шарының өслеген кискәндә барлыкка килгән уйланма йомык сызык. *Мин, аның белән ерак меридианнарда күрешкәч, кырыгынчы-илленче еллар интонациясе белән сүз башлаган идем, ул, елмаеп, йөзенә мине кызганган кыяфәт чыгарды ---.* М.Мәһдиев. *Бер океаннан алып икенче океанга кадәрге кыйтганың кайсы меридианында яшисең син, вакыт көзгесенә килеп асылыңа кара да кан кычкыруын тыңла ---.* М.Галиев. *Меридиан белән 50 бугай, Минутларын белмим тәгаен. Широтасы бөтенләй онытылган, Координатлар ялгыш, мөгаен.* Аманулла

МЕРИДИОНАЛЬ *с. геогр., астр.* Меридиан буенча сузылган, меридиан юнәлешендә, төньяктан көньякка барган. *Меридиональ юнәлеш*

МЕРИНОС *и. исп.* **1.** Бик йомшак һәм бик нечкә йонлы сарык токымы. *Ә әнә теге зур ферма белән янәшә – сарык бәрәннәре өчен ясле биналары. Меринос бәрәннәре өчен махсус.* Ә.Фәйзи. *Алты-җиде адым алга сөрлегеп барып төштем, күтәрелеп карасам, теге нәсел тәкәсе меринос икән.* М.Мәһдиев. *Алтай мериносы Әгерҗе, Актаныш, Минзәлә, Мөслим районнарында --- районлаштырылган.* Татарстанда терлекчелек

2. *с. мәгъ.* Шундый токымга караган. *– Чи тире-илтер – 25 мең, даланыкы, – ди Кузмич, башын күтәрми генә. --- – Меринос сарык тиресе – 30 мең.* Х.Камалов. *Самолёт ангары кебек иркен ындыр табагына без меринос сарыкларын ташып торабыз.* Ә.Хәсәнов. *Ә мех юнәлешендәгеләрдән каракүл, романов, меринос сарыклары – иң кыйммәтлеләр.* Биология. Хайваннар

МЕРКАНТИЛИЗМ *и. лат. кит.* 1) *икът.* XVI–XVIII йөзләрдә Көнбатыш Европада таралган, керем сәүдә өлкәсендә барлыкка килә, илнең байлыгы акчадан гыйбарәт һәм акча капиталын туплауга дәүләт кушуы белән ирешергә мөмкин, дигән фикерләргә нигезләнгән экономик тәгълимат һәм сәясәт

2) *күч.* Һәрбер эш-гамәлнең шәхси матди файда алуга буйсынган булуы, һәрбер нәрсәдән файда алырга тырышу; үтә вакчыллык

МЕРКАНТИЛИСТ *и. лат. кит.* Меркантилизм (*1 мәгъ.*) тарафдары. *Меркантилистлар феодализм эчендә үсеп чыккан тышкы сәүдәне үстерү, колониаль талаулар, сәүдә сугышлары һәм артта калган халыкларны коллыкка төшерү юлы белән алтын һәм көмеш формасында байлык тупларга омтылган буржуазия интересларын гәүдәләндерәләр.* Политэкономия

МЕРКАНТИЛИ́СТИК *и.* Меркантилизмга (*1 мәгъ.*) нигезләнгән, шул карашлардан чыгып эшләнгән. *Меркантилистик карашлар*

МЕРКАНТИЛЬ *с. кит.* 1) Сәүдә, коммерция, акча өлкәсенә караган. *--- нишлисең: язучы кеше өчен «меркантиль» бу мәсьәлә шулай ук зур әһәмияткә ия.* Р.Фәйзуллин. *– Ләкин мәсьәләнең меркантиль ягы да бар, – диде Нургалиев.* М.Мәһдиев

2) Вакчыл, шәхси файда алуны күздә тоткан, вак матди мәнфәгатьләрне кайгыртып эшләнгән. *Дөрестән дә, тәбәнәк буйлы, йомры-юан гәүдәле Фатыйх ага Дон-Кихотны борчыган проблемаларга меркантиль мөнәсәбәттәге кешегә охшаган.* М.Гайнетдинов. *Нидә хикмәт: ваемсызлыктамы, әллә вак меркантиль исәп-хисаптамы?* Аккош күле – илһам аланы

МЕРКАНТИЛЬЛЕК *и.* Кеше характерында һәр нәрсәдән файда алуга омтылу, матди мәнфәгатьләрне беренче урынга кую сыйфаты. *--- бәя биргәндә, шунысын да онытырга ярамый: бу принцип сәнгать өлкәсендә меркантильлек тенденциясенең көчәеп китүенә үзенчәлекле реакция дип тә кабул ителә.* К.Гыйззәтов. *--- алар шәхсиэгоистик мәнфәгатьләрнең өстенлеген, җиңел табыш алуны, конкурентын бастыру, меркантильлеккә һәм аның әхлактан өстен торуына омтылуны алга сөрә.* Ә.Хуҗиәхмәтов

МЕРОПРИ́ЯТИЕ *и. рус* 1) Билгеле эшчәнлек өлкәсендә, билгеле шартларда конкрет максатлардан чыгып оештырылган чара, эш-гамәл. *Терлекләрегезне фермаларга кайтару белән, сезнең колхозда семинар формасында зур гына бер мероприятие үткәреп алуны планлаштырдык.* М.Хәсәнов. *Балалар лагерьларында педикулёз авыруына каршы профилактик мероприятиеләр үткәрелде.* Ватаным Татарстан. *Эвакуацион мероприятиеләр*

2) Гадәттә бәйрәм, тантана уңаеннан уздырылган ял итү, күңел ачу чарасы. *Ул бер киноны да болай гына уздырмый, кино алдыннан берәр төрле мероприятие оештыра.* Х.Камалов

МЕРЧЕНДА́ЙЗЕР *и. инг.л.* Мерчендайзинг белгече. *Редактор, билгеле, махсус белеме-эшчәнлеге буенча менеджер, мерчендайзер, логист, экономист яки юрист вазифасын башкаручы хезмәткәрләрнең «өлеше»нә керергә җыенмый.* М.Вәлиев. *Аларда эшсезлектән тилмереп, көннәр буе якякларына каранып басып торган сакчылар һәм, син килеп керешкә, яныңа өтәләнеп килеп җитүче сатучы-консультантлар, әллә ниткән мерчендайзер, супервайзерлар сатып алучыларга караганда да күбрәк.* Татарстан яшьләре

МЕРЧЕНДА́ЙЗИНГ *и. инг.л.* Сәүдәнең нәтиҗәлелеген арттыру, сатып алучыларны җәлеп итү алымнары h.б.ш.дан торган сәүдә осталыгы; сәүдә бинасын, витриналарны бизәү, товарны рекламалап тору, сатып алучыларга мәгълүмат бирү h.б.ш. ваклап сәүдә итүдәге чаралар системасы. *Нәшриятның махсус сәүдә ноктасы*

булган тәкъдирдә, аның эшендә якыннан катнашу – мерчендайзинг, ягъни сәүдәне оста оештыруда ---, бәя куйганда кирәкле киңәш бирү, укучыларны кызыксындыру юлларын эзләшү --- редакторның эшен җайлырак, мәгънәлерәк, үзен абруйлырак итә. М.Вәлиев

МЕСКЕН *с. гар.* **1.** 1) Фәкыйрь, ярлы. *Синең алда бер сыныk ризык сорап кул сузган мескен хәерче ---.* Э.Халидов

2) Бәхете булмаган, бәхетсез язмышлы, куаныч-шатлыктан мәхрүм; бичара. *Ир-ат мескен нишләсен, колак итен ашап торсалар, буйсынмый да булмый...* Р.Мөхәммәдиев. *Ниләр язган икән мескен кыз балага ул кеше кулларыннан күрергә?* М.Маликова

3) Аяныч хәлдәге, зур бәлагә тарыган, бәхетсезлеккә дучар булган; зур кайгысы булган. *Мескен бичара гаскәрләр гарешкә күзләрен тикте.* Бәет. *Хәзер менә мескен гарип суд юллары буйлап законнан яклау эзләп йөри иде.* М.Маликова

4) Газап, кайгы билгеләре булган, авыр рухи кичерешләрне чагылдырган. *Әмма елмаю галәмәте аның чыраен тартыштырып, авызын кыйшайтып, тәмам мескен хәлгә кертте.* М.Маликова. *Нигә соң аның бармаклары җиңелчә дерелди, йөзендә мескен елмаю талпына?* Р.Зәйдулла

5) Үзен җәлләтә торган, кызганыч кыяфәтле, тышкы күренеше белән кызгану хисе уята торган. *Ташландык авыл йортыдай шомлы минем дә йөрәк: Каршылыйм мескен картлыкны Буранга арка терәп.* Ф.Гыйззәтуллина. *Бикташка әтисен мондый мескен хәлдә күрү кыен иде, шуңа күрә ул артkарак чигенде*. М.Маликова

6) Ярлылык, мохтаҗлык, искелек билгеләре булган, берәр фаҗига, афәт эзләре күренеп торган (җансыз әйберләр тур.). --- *талгын җил исә, җил яз исе, башлары кыркылган мескен тупыллар ягыннан кайры һәм үксезлек исе китерә иде.* А.Гыйләҗев. *Мескен күпер, авыр йөк күтәргән карт шикелле, әледән-әле ыңгырашып куя.* Ф.Мансуров. *Кечкенә тимер мич бу мескен алачыкны җылыта алырмы?* Казан утлары

7) Бик кечкенә, көчсез, хәлсез. *Миллиард сорау – үзе Галактика. Җавап – тузан, мескен бер бөҗәк!..* Х.Туфан. *Мескен кошчык бүлмә бетереп бәргәләнә караңгыда, Тыпырчына, чыгу юлын табалмыйча.* Р.Фәйзуллин

8) Рухи яктан ярлы, көчсез, әһәмиятсез, нәтиҗәсез. *Уйдан авыраеп иелгән баш мескен түгел. Мескен уйлы горур баш мескен.* Ш.Галиев. *Моңарчы башкарган нәрсәләр чүп кенә, вак-төяк, мескен омтылышлар...* Р.Мирхәйдәров

2. *и. мәгъ.* 1) Бик ярлы, фәкыйрь кеше. *Мескеннәр сөт-майның тәмен түгел, төсен дә күрмичә интегәләр...* Н.Дәүли

2) Бичара, бәхетсез кеше, кызганыч хәлдәге кеше. *Ике атна эчендә саз чәчәгедәй сулды мескен.* С.Поварисов. *Аннан күрерсез, кем мескен, кем могҗиза иясе икәнен! Акбүрене алса, үлсә дә үкенмәс кебек.* Р.Батулла

3) *ирк. форм.* Кешене җәлләп, аңа теләктәшлек белдереп, хәленә кереп атау, эндәшү сүзе. *Мескенем, сине кыйнаганнар, ахры?* Т.Гыйззәт. *Ул да шул, мескенкәй, сагынадыр кошкаен – Иң матур, иң якын, җан өзгеч дускаен, дускаен.* Ә.Ерикәй. *Әллә ни генә булды инде мескенемә, гел нигәдер кабаланды, гел нигәдер ашыкты ---.* Ф.Шәфигуллин

3. *рәв. мәгъ.* Кешедән ким булып, үзен җәлләтеп, бичара кыяфәт белән. *Болар чит кеше булса кирәк: эшләпәләрен тез башларына гына куеп, мескен генә утыралар.* Х.Сарьян. *Берзаман син урамда калдың, үги ана кулында мескен булып торырга теләмәдең.* Г.Ахунов. *Борыныңны да бик күтәрмә, Йөрмә мескен булып та. Әйтерләр кем икәненне Кешеләр үзең юкта...* Л.Шагыйрьҗан

МЕСКЕНӘЙТҮ *ф.* Мескен хәлгә кую, мескен итеп күрсәтү; кимсетү, түбәнсетү. *Көтеп тору кешене мескенәйтә.* М.Юныс. *Гасырлар дәвамында изелү безне бик нык мескенәйтте.* Р.Зәйдулла

Мескенәйтә бару Торган саен ныграк мескенәйтү. *Чын башкорт кадрлары аякка ныграк баса барган саен, андыйларның [башкорт булып язылган татарларның] исемнәрен мескенәйтә барачаклар*. М.Галиев

Мескенәйтә төшү Бераз мескенәйтү; тагын да мескенәйтү

Мескенәйтеп бетерү Тәмам мескенәйтү

Мескенәйтеп җибәрү Бераз мескенәйтү

Мескенәйтеп тору Мескен итеп күрсәтү

МЕСКЕНӘЮ *ф. к.* **мескенләнү**. *Яшь хуҗабикә, --- гаебе бар кешедәй мескенәеп, почмакка утырды.* Ш.Рәкыйпов. *Кыш көне дисәң, ул [инеш] бөтенләй юк шикелле, үзәннәр белән тигезләнә, мескенәя.* Ә.Баян

Мескенәеп бетү Бөтенләй мескенәю

Мескенәеп калу Берәр тәэсирдән соң мескенәю. *Шуны җилкәсендә татыган сыеграк буынлы бер ише кешеләр тәмам боегып, мескенәеп калды.* Ш.Рәкыйпов. --- *[Сөмбел] башын алга иеп, кулы белән йөзен каплады, гәүдәсе шундук кечерәеп, мескенәеп калды.* Ә.Гаффар

Мескенәеп китү Элеккегедән мескенрәк хәлдә булу, элеккегә караганда шактый мескен күренү

Мескенәеп тору Мескен күренү. *Каршыда түбәсе кыйшайган лапас мескенәеп тора*. Р.Зәйдулла

Мескенәя башлау Мескенлеккә йөз тоту

Мескенәя төшү Бераз мескенәю; тагын да мескенәю

МЕСКЕ́Н БҮРЕК *и. тар.* Күрексез, тукымадан, постаудан сырып эшләнгән бүрек. *Әмма, ни кылсам да, эшем Пешеп бетмәде кебек. Гомер буе мескен бүрек Баштан төшмәде кебек.* Н.Нәҗми. *Әле ул кыска бишмәт өстеннән киндер алъяпкыч киеп алган. Кижеле ыштаннан. Башында мескен бүрек.* С.Поварисов

МЕСКЕНЛӘНҮ *ф.* 1) Мескен хәлгә төшү, кызганыч хәлгә килү. *Моңарчы белгән мәгърур Шәүрәнең – тәкәббер Шәүрәнең – ул беркайчан да, хәтта сөйгән егете алдында да мескенләнүен теләми иде.* Г.Бәширов. *Бердәм бергәлек булмаса, Олы ил дә таркала. Бүгенгесе мескенләнә, Киләчәге тар кала...* Ш.Галиев. *Ул [бүре баласы], мескенләнеп, койрыгын кысып, картка карый.* Дөньяда ниләр бар

2) Мескен булып күренү. *Нигә дип очраган һәр кеше алдында мескенләнәм, теләсә кемгә отчёт бирәм мин?* Г.Тавлин. *Ал, син бит башкалардан ким түгел. Акчам юк, дип мескенләнмә, ал.* М.Юныс. *Ә бит син, авырлыклардан куркып, яшәүдән ваз кичүең белән үк мескенләндең, түбәнлеккә төштең...* Г.Гыйльманов

3) Мескенгә салышу, мескен кыяфәте чыгару, мескен булып кылану. *Мескенләнмә, бакый гомер килгән Тел байлыгын итмә кадерсез. Бер уйласаң, иланһи бит, изге – Кеше әйткән аваз, һәрбер сүз!* Р.Фәйзуллин. *Айсылу, машинасын кертеп куяр өчен, ишегенә тотынуга, Рәхилә белән Альберт, мескенләнеп, аның каршына килеп баса.* Ф.Яруллин. *Мескенләнергә аслан яратмый ул.* С.Поварисов

Мескенләнә бару Торган саен тагын да мескенләнү. *Ул агай-энеләренә, авылдашларына, танышларына чын күңелдән рәнҗи, үзен санламауларын күреп, аның болай да сынык күңеле тагын да сүрәнләнә, мескенләнә бара иде...* А.Гыйләҗев. *Гаебең булмаса да, гаебеңне танырга мәҗбүр буласың, аның каршында кечерәя, бөрешә, мескенләнә барганыңны тоясың.* Т.Миңнуллин

Мескенләнә башлау Мескенлек күренү, мескенлеккә йөз тоту; мескен булып кыланырга керешү. *[Тимергазин:] Мескен? Кайчаннан башлап шундый инде мин? [Дамирә:] Мескенләнә башлаган көннән башлап.* Т.Миңнуллин. *Һай икән, Шәгаетов абзаң мескенләнә үк башлады, кызганыгызчы үзен...* М.Хуҗин

Мескенләнә төшү Бераз мескенләнү; тагын да ныграк мескенләнү

Мескенләнеп бетү Тәмам мескенләнү

Мескенләнеп йөрү Шактый вакыт дәвамында мескенләнү. *Михневич бу минутта көчле иде. Мескенләнеп, авыруга сабышып йөрүләренең эзе дә юк.* Х.Камалов. *– Әнә кунакханә төзүне җайлап, ашханә ачтыр, Мисыр хәерчесе кебек йөрмәгез мескенләнеп, – дип кырт кисте.* Ш.Янбаев

Мескенләнеп калу Билгеле бер хәлдән соң мескенләнү. *Үзе өчен түгел, Микәйне кызганудан шулай бөрешеп, мескенләнеп калган иде булса кирәк Шомырткара.* Р.Мөхәммәдиев. *Бусагаңнан кергәндә мәңге иелмәс кебек тоелган горур башлар, чыгып киткәндә, кечерәеп, мескенләнеп кала.* Ф.Яруллин. *Ихтыяр элек гаҗәеп мәһабәт һәм усал булып күренгән укытучысының кечерәеп, хәтта боегып һәм мескенләнеп калганын тойды.* Р.Вәлиев

Мескенләнеп карау Берәр максат белән мескенгә сабышу. *Мисбах ялынып та, янап та, хәтта мескенләнеп тә карады, әмма Гәүһәр үз сүзендә нык торды.* Ф.Яруллин

Мескенләнеп китү Билгеле бер моменттан алып мескенләнү. *--- Янәшәңдә утырган картлар сыман, син дә үзеңне нинди дә булса гөнаһың бардыр кебегрәк хис итәсең дә ничектер мескенләнеп китәсең.* Г.Бәширов. *Ихата кечерәеп, каралып, мескенләнеп китте.* Р.Рахман

Мескенләнеп кую Бер мизгелгә мескенлек күрсәтү. *– Һәммәсен дә белдегезме инде? Менә шундый гөнаһлы бәндәләр бит без, – дип мескенләнеп куйды хуҗам.* Б.Камалов

Мескенләнеп тору Хәзерге моментта мескенләнү; даими, гел мескенләнү. *Хәлфә соравына җавап биргәндә, бәгъзе бер йомшак бәдәнле шәкерт шикелле, аркасында чыбык чыжлаудан куркып, мескенләнеп-калтыранып тормады.* С.Поварисов. *--- Салих аны-моны сиздермәде, киресенчә, юату сүзләре әйткән булды: – Алай мескенләнеп торма, Галия. Кычкырыбрак җырла икенче.* Ф.Әһлия

Мескенләнеп утыру *сөйл. к.* **мескенләнеп тору**. *Күрдегезме ничек... Үзе, мин – ир хатыны, дип мескенләнеп утырган була.* Т.Миңнуллин. *– Туганнарың бармы? – Шушы яшькә җиткәч, мин ятим, дип мескенләнеп утырасым килми.* К.Кәримов

Мескенләнеп яту *сөйл. к.* **мескенләнеп тору**. *Ул, Миләүшәнең битеннән сыйпап: – Синең кебек кыз алдында мескенләнеп яту оят, валлаһи, – дип, туфракта коенганнан соң өстендәге чүпне кояр өчен кагынып алган коштай, кагынгалап алды ---.* Ф.Яруллин. *Тамырыма балта төшкән чакта, Мескенләнеп елап ятыймммы?* С.Якупова

МЕСКЕНЛЕК *и.* 1) Мескен булу хәле, кызганыч халәт; чарасызлык, көчсезлек. *И-и-и-их! Шушындый мескенлеккә калырмын дип уйлаган кеше идемени ул?* В.Нуруллин. *Гомер буе шигырь сукмагында, Дәгъва кылмый һичбер өстенлеккә, Җылы сүзе белән каршы торган Тәкәбберлек илә мескенлеккә.* Л.Шагыйрьҗан. *Әнсарның күңелендә шатлык елтырап алгандай булды: көндәшенең мескенлеген күреп, сөенеч хисе тойды шикелле.* З.Хәким

2) Ярлылык, юксыллык, фәкыйрьлек. *Бүген, ике баласын җитәкләп, чирле ире егылмасын дип борчылып кайткач, аны-моны уйлап тормады, фәкыйрьлек, мескенлек аларның гаиләсенә төс кебек тоелды.* А.Гыйләҗев. *Аның артыннан ярдәмчесе дә кабинетны күзе белән сөреп чыкты, әмма кимсетә торган мескенлек күрмәде.* Р.Мирхәйдәров

МЕСКЕННӘ́РЧӘ *рәв.* **1.** Мескен рәвештә, түбәнсенеп, кызганыч кыяфәт белән, мескен кешеләрчә. *--- Түрәкараның төче сүзләрен тыңлап, баш иеп: «Әйе шул, шулай шул», – дип, мескеннәрчә яшәүгә ник риза булды соң ул?* Г.Ахунов. *Гадәттә, аларның барысы да үзен мескеннәрчә тота.* М.Кәбиров

2. *с. мәгъ.* Мескенлек, түбәнсенү чагылдырган; кызганыч кыяфәтле, кызганыч яңгырашлы. *--- Бераз төртмәлерәк тон да ясарга мөмкин, тик сүзләр ышанып әйтелергә тиеш, ә мескеннәрчә тон һич тә ярамый.* В.Леви

МЕСКЕНЧӘК *и.* Жәлләп, кызганып, якын итеп эндәшү сүзе. *Мескенчәк, бу вакыйганы күреп, тәңрегә тилмереп вә зарилык кылып җанындан өмет өзеп килә торганда, Ак елан очрады.* Әкият. *Аптыраган, мескенчәк...* Г.Камал

МЕСКЕНЧЕК *и. к.* **мескенчәк**. *Анда бер юл очрады. Юлга чыгып, юл буенча егълый-егълый бара, мескенчек.* К.Насыйри. *Мескенчегем, син дә хәзер, минем бервакыттагы кебек, әллә нинди хыяллар белән әвәрә була торгансыңдыр.* Ш.Камал

МЕСЛӘ́Ү *ф. диал.* Йоклау, черем итү. *--- ерак кодасы белән кодагые*

килгән икән, ашап-эчеп утыралар. Оныкта бишегендә месләп йоклап ята. Мәдәни җомга

Месләп алу Аз гына месләү

Месләп китү Месли башлау

Месләп яту Хәзерге вакытта месләү. *Атка менеп, бер җилдереп кайтыр идем. Тирә-яктагы кызларның йокысы качар иде. Ә хәзер өчесе тиң месләп яталар. Бармы дөньяда Марат, юкмы – аларга барыбер...* А.Гыйләҗев

МЕС-МЕС *иярт.* Бик тыныч йоклау, черем итү рәвешен белдерә. *Тышта чатнама салкын, буран, ә ул җылы өйдә, ак җәймәдә ята, мес-мес кечкенә кояшы йоклый ---.* З.Кадыйрова

МЕСНӘ́Y *ф. диал. к.* **месләү**. *Кәрам аның борын сызгырта-сызгырта меснәвенә карап алды.* Казан утлары

МЕ́ССА *и. лат.* 1) Рим католик динендә чиркәүдә уздырыла торган догалы һәм музыкалы гыйбадәт. *Якшәмбе көнне сый әзерләп, шәраб утыртып месса тыңларга чакыралар икән. Ачка шулкадәр интексәләр дә, чиркәүгә баручы булмаган.* М.Юныс

2) Әлеге гыйбадәтнең төп өлешләрен берләштергән, аның барышында башкарыла торган тантаналы музыка; мөстәкыйль музыка әсәре буларак та языла һәм башкарыла. *Радиоланы кабызалар. Анда Бахның орган өчен язган «Месса»сы.* Т.Миңнуллин. *Әле хәзер генә Нотр-Дамнан чыктым месса тыңлап... Гажәп матур икән собор, чынлап!* Р.Гаташ. *Итальян халык музыкасы күп кенә опера, балет әсәрләренә нигез булып хезмәт итә. Ул чиркәүдә башкарыла торган мессаны да сугара алган.* К.Гыйззәтов

МЕССИАНЛЫК *и. кит.* Мессия турындагы тәгълимат, шуңа нигезләнгән идеология. *Мессианлык – Израильдә борынгы яһүдләрдән килгән теория.* К.Гыйззәтов

МЕССИ́Я *и. яһүд кит.* 1) Бөтен кешелекне коткару һәм җирдә идеаль җәмгыять төзү өчен, күкләр тарафыннан сайлап алынган патша яки пәйгамбәр, мәсих. *Урысларны ул [Соловьёв] Алла тарафыннан сайланган (богоизбранный) халык, мессия дип саный.* К.Гыйззәтов. *Безнең заманга кадәр бик күп тәкәббер, үҗәт һәм башбирмәс затлар, шайтанның уенында алданып, үз-үзләрен әүлия, мәһди (мессия) санаган, күпме ялганчы үзен пәйгамбәр дип игълан иткән, ничә фиргавен үзен илаһи затка тиңләштергән ---.* Инсан һәм дин

2) *күч.* Барлык проблемаларны хәл итүче, күптән көтелгән коткаручы

МЕСТКОМ *и. рус* Профсоюз оешмасының иң кечкенә берәмлеге – җирле комитеты. *– Ни әйтсәң дә, мин местком члены да әле, – дип, көлә-көлә, кулына кашык алып өстәлгә сугып куйды [Иван Палыч]. Мәрьям местком председателе Ирина Сергеевна янына кереп китте.* М.Маликова. *--- «Крутушка» санаториена бер путёвка бар иде. Местком утырышында сиңа бирергә тәкъдим иттем.* З.Фәйзи. *Гаризаңны местком утырышында карадык.* Г.Сабитов

МЕТАБОЛИЗМ *и. гр. биол.* Тере организмнарда матдәләр алмашу процесслары. *Шулай итеп, биологик ритмнар формалашуда төрле механизмнар – генетик, метаболизм (матдәләр алмашы), нерв, эндокрин системалары катнаша.* Сәламәт яшәү нигезләре

МЕТАГАЛА́КТИКА *и.* Җиһанның хәзерге астрономик ысуллар белән тикшерү мөмкин булган, берничә миллиард галактикадан торган өлеше. *«Күзәтелә торган галәмдә», ягъни хәзерге заман астрономик тикшерүләрнең «кулы җиткән» өлкәдә, миллиардлаган галактика исәпләнә. Аларның барысын бергә галимнәр метагалактика дип атыйлар.* Галәм. Җир. Кеше

МЕТАЛЛ *и. гр.* **1.** 1) Югары электр һәм җылылык үткәрүчәнлек, чүкелүчәнлек, үзенчәлекле ялтыравык кебек сыйфатлар хас булган гади химик матдә яки коелма. *Диңгездә металл тиз тутыга. Металлны диңгез тозы ашый.* М.Юныс. *Самшит үзагачы гадәттән тыш каты һәм, әйберләр ясаганда, еш кына металлны алмаштыра ала.* Дөньяда ниләр бар. *Астероидларның кайберләре тоташтан диярлек тимердән һәм бөтен металлардан тора.* Кызыклар дөньясында

2) *күч.* 1970 елларда башлыча Англия һәм АКШта формалашкан музыка жанры – рок музыкасының бер төре. *Бөтен халык авыз ачып Шуларны тыңлый хәзер. «Әпипә»ләр урынына Металлар чыңлый хәзер.* Г.Рәхим. *Ак хыялларда балкытсын ихлас җанын, әйтегез! Шау-шулы металл музыка, роклардан моңны яклап, «Биек тауга менәмсең» дип, еш җырласын, әйтегез!* Р.Гаташ

2. *с. мәгъ.* Металлдан (*1 мәгъ.*) торган, шундый материалдан ясалган. *Предприятие исеменә алынган моторлар, металл көймәләр, катерлар, балык тоту әсбаплары белән эш иткәннәр.* М.Әмир. *Гөсләнең өске өлешенә төрле озынлыктагы һәм төрле калынлыктагы барысы унике металл кыл тарттырыла ---.* Казан утлары. *Әгәр электрометрның металл таягына электрланган бер әйбер белән орынсаң, корылмаларның беркадәресе металл таякка күчәр, һәм күрсәткеч ук металл таяктан беркадәр почмак ясап кыйшаер.* Физика курсы

МЕТА́ЛЛИК *с.* 1) Металл формасында булган; металл үзлекләренә ия булган. *Металлик рутений һәм осмий кислоталарга һәм аларның катнашмаларына чыдам була.* Г.Хисамиев. *Кисәкчекләр (атомнар, ионнар, молекулалар) арасындагы тәэсир итешү көчләренә бәйле рәвештә, кристаллар биш типка – ионлы, атомлы, металлик, молекуляр, водородлы бәйләнешле кристалларга бүленәләр.* Физика

2) Металлдан торган; металл (*2 мәгъ.*). *Металлик детальләр*

МЕТАЛЛИСТ *и.* 1) Металл детальләр эшкәртүче эшче. *Бик нечкә эш башкаручы металлистның эш урыны яктыртылуы норма буенча 75 лк булырга тиеш.* Физика курсы

2) *күч.* Яшьләр культурасында 80 нче еллар азагында – 90 нчы еллар башында формалашкан, рок музыкасы белән кызыксыну, киемнәрен бик күп тимер элементлар белән бизәүдән гыйбарәт формаль булмаган юнәлеш вәкиле. *[Шәйхулла карт үз-үзенә:] Нәрсә ди, мин металлист түгел, диме?* Д.Салихов

3) Металлик рок музыкасын яратучы

МЕТАЛЛОГРА́ФИК *с.* Металлография фәненә караган, шул өлкәгә

мөнәсәбәте булган. *Металлографик тикшеренүләр*

МЕТАЛЛОГРА́ФИЯ *и. гр.-гр.* Металларның һәм коелмаларның макро- һәм микроструктурасын, атом-кристалл төзелешен, шуларга бәйле механик, электрик, магнитик һ.б. үзенчәлекләрен өйрәнә торган фән. *Тимер һәм шлак кисәкләрен яңа ысуллар (металлография, спектраль анализ һ.б.) кулланып өйрәнү өчен, коллекция-безгә алдык, тәртип белән тартмаларга тутырып куйдык.* Ф.Хуҗин

МЕТАЛЛО́ИД *и. хим. иск.* **1.** Металл булмаган химик матдәләрнең искергән атамасы. *Бу вакыт кремний дигән металлоид (металл булмаган матдә) зәһәр натр белән реакциягә керә.* Күзгә күренми торган матдәләр турында хикәяләр. *Мондый төен ирекле электронны эләктереп алып, үзендә тотарга тырыша. Чөнки кристалл төененнән киткән тискәре коргылы металлоид ионының җитешмәвен капларга кирәк.* Физика

2. *с. мәгъ.* Әлеге металлоидлар (*1 мәгъ.*) группасына караган. *Металлоид элементлар*

МЕТАЛЛОЛОМ *и. рус* Икенче тапкыр куллану өчен җыелган металл калдыклары; тимер-томыр. *Иске авыл шулай итеп металлоломга китте.* М.Мәһдиев. *Ә ул колхозның машина-трактор паркындагы һәммә ни бар, шуны өч кешесе белән актлап «списать» итте дә, ике ел буе көн дә тонналап-тонналап ташытып, металлоломга тапшырды.* Ф.Яхин. *Моның өстенә, план төшергәннәр: алдагы кварталда зур гына күләмдә металлолом – сүтелгән заводның тимерләрен тапшырасы.* Р.Мирхәйдәров

МЕТАЛЛОФОН *и. гр.-гр.* 1) Чаң, гонг, виброфон кебек, металлдан коелган һәм махсус чүкеччекләр, таякчыклар, бәргечләр (телләр) белән сугып уйнала торган музыка коралларының гомуми исеме. *Күңелле көй тыңлап, шатлык хисләре уяту, баланың игътибарын металлофон яңгырашына юнәлдерү.* Чәбәк-чәбәк итә ул

2) Ксилофоннан аермалы буларак, пластинкалары металлдан булган бәрмә музыка коралы. *Ул [Кәлимулла Билалов] сезгә Баламишкин көен уйнап күрсәтер, ә балалар аңа кушылып оркестрда уйнарлар (шөлдер, металлофон, баракас, өчпочмак).* Могҗизалы мәктәп сәхнәсе

МЕТА́ЛЛСЫМАН *с.* Ниндидер сыйфаты белән металлга охшаган, металлга якын торган. *Ул [тимер] углерод, кремний, азот, бор, фосфор, водород белән – каты эремәләр, металлсыман кушылмалар (Fe_3C, Fe_3Si, Fe_3P, Fe_4N, Fe_2N), тозлар яки тозсыман кушылмалар хасил итә.* Г.Хисамиев

МЕТАЛЛУРГ *и.* Металлургия белгече, металлургия тармагында эшләүче кеше. *Су һәркемгә кирәк: төзүчеләр, химиклар, металлурглар, авыл халкы, ипи пешерүчеләр дисеңме – бер генә көн дә сусыз яши алмый.* Казан утлары. *Безнең илебездә беренче тапкыр буларак кислородка баетылган өрдерү кулланылды. Бу исә корыч кою процессын бик нык тизләтте, һәм хәзер металлурглар илебезгә шул ук мичләрдә элеккегә караганда шактый күп микъдарда югары сыйфатлы корыч бирәләр.* Күзгә күренми торган матдәләр турында хикәяләр

МЕТАЛЛУ́РГИК *с.* Металлургия тармагына караган, металлургиядә кулланылган. *Металлурглар, плазма бик зур металлургик агрегатларны кирәксезгә чыгарыр, ә металлургияне, шул исәптән металл коюны да, тулысынча автоматлаштырырга мөмкинлек бирер, дип хыялланалар.* Химиянең киләчәге

МЕТАЛЛУРГИ́Я *и. гр.* Фәннең, техниканың һәм җитештерүнең рудалардан һәм башка материаллардан металл алу, металл коелмаларның химик составын, сыйфатларын үзгәртү, төрле формаларга кертү процесслары белән шөгыльләнә торган тармагы. *Шул вакыт эчендә электротехника җиһазлары сатып алу – 22 тапкырга, металлургия җиһазлары – 19 тапкырга, ә авыл хуҗалыгы машиналары сатып алу 154 тапкырга артты.* М.Хәсәнов. *Шри-Ланкада Советлар Союзының ярдәме белән шин заводы, металлургия заводының прокат цехы, элеватор һ.б. объектлар төзелгән.* М.Мәһдиев. *Металлургиянең бурычы – тимерне химик «тоткынлык»тан азат итү.* Күзгә күренми торган матдәләр турында хикәяләр

МЕТАЛЛЧЫ *и.* 1) Металлургия тармагында эшләүче белгеч; металлург. *Көтүче малае да түгел Хисмәт, Шахтёр малае да булмаган. Металлчы да түгел, тиреченең дә, Кулак йортында да тумаган.* Ш.Маннур

2) *к.* **металлист** (*2–3 мәгъ.*)

МЕТАЛЛЫ *с.* 1) Металл рудасы ятмалары булган. *Металлы катлам. Металлы токым*

2) Металлдан ясалган; металл өлешләре булган. *Җиһазның металлы җирләрен нашатырь спирты, акбур яки теш чистарту порошогы, су катнашмасы белән ялтыратырга була.* Ватаным Татарстан

МЕТАМОРФИЗМ *и. гр. геол.* Температура, басым һәм бик тирәндә яткан эремәләрнең химик активлыгы аркасында тау токымнарының төзелеше, текстурасы һәм минераль составы үзгәрү күренеше. *Тау токымнары метаморфизмы*

МЕТАМОРФОЗ *и. гр. биол.* Бер үсемлекнең үсеше процессында аның төп органнарының (мәс., тамыр, сабак, яфрак) функцияләре үзгәрү белән бергә формасы һәм төзелеше үзгәрү; шулай ук бер үсеш стадиясеннән икенчесенә күчкән хайваннарның тышкы кыяфәте һәм тереклек итү рәвеше үзгәрү күренеше. *Метаморфоз кайбер хайваннарның, мәсәлән күбәләкләрнең, личинка белән чагыштырганда олы хайваннарының туклану характеры алмашуга китерә.* Биология. *Кайчак чукмарбашлар метаморфозны төгәлләргә өлгерми һәм сулыкта кышларга мөмкин.* Татарстанның үсемлекләр һәм хайваннар дөньясы

МЕТАМОРФО́ЗА *и. гр.* 1) *к.* **метаморфоз**. *Җәй уртасында метаморфозадан соң бака балалары коры җиргә чыга.* Татарстанның үсемлекләр һәм хайваннар дөньясы. *Төнбоек чәчәген шул рәвешчә күзәтү атаклы шагыйрь Вольфганг Гётене үсемлек яфракларының үзгәрүе яки метаморфозасы*

турындагы ботаник законны ачуга китергән. Робинзон эзләреннән

2) *кит.* Кемдә яки нәрсәдә дә булса күзгә ташланып торган, асылын алмаштырган зур үзгәреш. --- *аның [сүзнең] нинди метаморфозалар кичереп, бер телгә ни хәлдә килеп керүе әһәмиятле.* Ж.Вәлиди. *Чынлап, ышанып та куярсың, үткән йөз елдагы үзгәреш-метаморфозалар шаккатарлык!* Р.Фәйзуллин. --- *«пролетариат диктатурасы» дигәне сүздә генә кала, асылда ул хакимият башында утыручы коммунист юлбашчылар диктатурасына әверелә. Милли сәясәттә дә шундый ук метаморфоза – кискен үзгәреш килеп чыга.* Ә.Бөрһанов

МЕТАН *и. гр. хим.* Углерод белән водород кушылмасыннан гыйбарәт, нефть, рудник һәм саз газларының төп өлешен тәшкил иткән, һавада шартлаучан кушылма хасил итә торган төссез газ. *Бер төрле бассейннарда, шакшы суны ачытканда, углекислый газ, икенчеләрендә исә янучан газ – метан хасил була.* Күзгә күренми торган матдәләр турында хикәяләр. *Гигант планеталарның атмосфераларында аммиак һәм метан бар.* Химиянең киләчәге. *Җир группасы планеталары өлкәсендә температура шактый югарырак булганга, барлык очучан матдәләр (шул исәптән метан һәм аммиак) газ хәлендә калганнар һәм, димәк, планеталар составына кермәгәннәр.* Галәм. Җир. Кеше

МЕТАСТАЗ *и. гр. мед.* Авыруның беренчел чыганагыннан кан яки лимфа агымы белән күчү нәтиҗәсендә барлыкка килгән икенчел патология учагы. *Метастаз, яки беренчел шеш күзәнәкләренең тәннең башка өлешләренә күчүе, рактан үлү очракларының 90 процентын тәшкил итә.* Мәдәни җомга

МЕТАТЕ́ЗА *и. гр. лингв.* Ассимиляция яки диссимиляция нигезендә сүзләрдә ике авазның яки иҗекнең үзара урыннары алмашу күренеше (мәс., *абзар – азбар, кырмыска – кымырыска*). *Төрле комбинацияләрдә килгәндә, авазларның бер-берсенә тәэсир итешүе нәтиҗәсендә барлыкка килә торган аваз үзгәрешләре (ассимиляция, диссимиляция, аккомодация, метатеза, гаплология һ.б.).* Х.Сәлимов. *Метатеза вакытында хәтта иҗекләр дә урынарын алыштырырга мөмкин: ведмедь сүзе, заманнар үтү белән, медведь формасына күчкән.* Ф.Сафиуллина. *Терминнар бер (метатеза, вектор, нурланыш) яисә берничә өлкәдә (прогрессивлык, ассимиляция, инкубация, басым) кулланыла алалар.* Г.Галиуллина

МЕТАТЕ́ЗАЛАШУ *ф.* Метатеза процессы кичерү. *Сүздәге янәшә иҗекләр метатезалашырга мөмкин*

МЕТАФИ́ЗИК I *с.* 1) Асылын, нигезен метафизика (*1 мәгъ.*) тәшкил иткән, метафизикага караган. *Нәтиҗәдә, XVII гасыр ахырында ук инде механистик корпускуляр теорияләр метафизик төс алдылар.* Химия фаш итә. *Алар [соңгы унъеллыклар] физика өлкәсендә метафизик, механистик материализмның, Ньютон материализмының, Кельвин һ.б.лар материализмының чикләнгәнлеген тулысынча ачып салдылар.* Галәм. Җир. Кеше. *Үсешне, ягъни нинди дә булса яңалыкның килеп чыгуын инкяр иткән мондый фикер йөртү ысулы метафизик ысул дип атала.* Дарвинизм нигезләре

2) *күч.* Сәер, аңлашылмый торган, читләтеп кенә белдерелгән, аңлатмасы булмаган (фикер, караш һ.б.ш.лар тур.). --- *әдәбиятны өйрәнүче галимнәребез бармак белән генә санарлык, яшьләрне фәнгә авырлык белән алып кергән чорда «кем беренчел» кебек метафизик бәхәсләргә кереп чумсак, бу хәл безнең инкыйразны якынайтуга бер адым гына булыр иде.* Т.Галиуллин. *Игътибарга лаеклысы шунда: ахыр чиктә тугызынчы бүлектәге бу шигъри әсәр ахырында да кеше күңеленең метафизик азатлыкка омтылуы ачык күренеп китә.* И.Вәлиуллин

МЕТАФИ́ЗИК II *и. гр.* Фәлсәфәдә метафизика (*1 мәгъ.*) карашларында торган галим. *Метафизиклар хәрәкәтне, дөнья үсешен, шулай ук дөнья-ны тәшкил иткән әйберләр һәм күренешләр арасында яшәп килгән бәйләнеш һәм мөнәсәбәтләрне танымый-лар яисә бозып күрсәтәләр.* Дарвинизм һәм дин

МЕТАФИ́ЗИКА *и. гр. филос.* 1) Тәҗрибә белән бәйле булмаган яшәеш нигезләре (Алла, җан, рух һ.б.ш.) турындагы философик өйрәтмә. *«Метафизика» терминын Аристотельнең шәкертләре керткән. Алар аны «философия» мәгънәсендә кулланып эш иткәннәр.* К.Гыйззәтов. *Борынгы грек философы һәм галиме Аристотель үзенең «Поэтика», «Метафизика» китапларын драматик жанрларга багышлаган.* М.Җәләлиева

2) Марксизмда: диалектикага капма-каршы, күренешләрнең бер-берсенә бәйлелеген, каршылыгын, үсеш-үзгәрешен исәпкә алмый торган танып белү методы. *Философиядә диалектика дигән нәрсә бар, метафизика дигән нәрсә бар. Метафизика ул – тик тору дигән сүз, ә диалектика дигәндә, без һәрвакытта да туктаусыз алга баруны күздә тотабыз.* Т.Миңнуллин. *Хатип Госман Язучылар союзындагы теоретик семинарда доклад укыды. Ул, метафизика үз заманында прогрессив булган, диде.* Р.Нуруллина

3) Кайбер философия мәктәпләрендә: онтология, ягъни яшәешнең гомуми нигезләре, принциплары, төзелеше һәм закончалыклары турындагы тәгълимат. *Көнбатышның кайбер фәлсәфәләреннән аермалы буларак ---, Көнчыгыш метафизикасы, ислам суфичылыгы кеше «мин»енең чынбарлыкта, билгеле бер вакытта күзәтелгән фаҗигале халәтен абсолютлаштырып карамый ---.* И.Вәлиуллин

4) *күч.* Артык гомуми, абстракт, аз аңлаешлы, томанлы нәрсә (гипотеза, фикер тур.)

МЕТА́ФОРА *и. гр. әд.* Күренешләрнең охшашлыгына, аналогиясенә яки каршылыгына, сүз белән аталмаган чагыштыруга нигезләнеп, сүзне, тәгъбирне күчерелмә мәгънәдә куллану; тропларның берсе. *Сәнгатьчә аерымлыкларына килгәндә, табышмакларда тагы метафора, аллегория, синекдоха, гипербола, омоним, охшату --- һәм башкаларның тоткан урыннарын күрсәтергә мөмкин.* Н.Исәнбәт. *Һәр образ, метафора, сурәт, эпитет, илаһи код, символ кебек, укучы күңеленең иң*

ерак, иң тирән почмакларына барып җитәргә тиеш ---. Г.Гыйльманов. *Метафора белән канатланган шигырьнең үтемлелек дәрәҗәсе күп мәртәбә артып китә.* Мәдәни җомга

МЕТА́ФОРАЛАШТЫРУ *ф. сир.* Метафора белән белдерү, күчмә мәгънәдә бирү. *Шагыйрь яз образын Бөек Октябрь вакыйгалары аша метафораларштырды, нәтиҗәдә язның һәрбер күренешенә иҗтимагый-политик һәм сугышчан мәгънә бирде.* Х.Госман

МЕТА́ФОРАЛЫ *с.* Метафоралар кулланган, метафораларга бай булган. *Татар әдәбияты аксакалының --- саллы җөмләсе белән Мәһдиевнең йөгерек метафоралы, шаян, шук, җор һәм шул ук вакытта итагатьле стилен бутау мөмкин түгел иде.* Т.Галиуллин. *Баллада жанрыннан килә торган метафоралы, масштаблы образларга һәм бизәкле, пластик этюд сурәтләренә карап, гадәттә, Зөлфәтне романтик шагыйрь дип йөртәләр.* М.Гайнетдинов

МЕТА́ФОРАСЫЗ *с.* Метафоралар аз кулланган, метафораларга ярлы. *Татар поэзиясенең нигез тамырына балта 30 нчы елларда һәм сугыштан соңгы бишьеллыклар дәверендә (озын-озын поэмалар, мәҗбүри вакыйгалы сюжетлы, төссез, йөзсез, метафорасыз шигырьләр чоры) һәм торгынлык (Ленин һәм партиягә багышланган шигырь-поэмалар) дип аталган чорларда чабылды.* Т.Галиуллин. *Мәхмудовның шигырьләре метафорасыз булса да, күз алдына гажәеп төсләр дөньясын, кайвакыт әкияти, ә кайвакыт кырыс реалистик күренешләрне бик ачык китереп бастыралар.* Р.Харисов

МЕТАФО́РИК I *с.* 1) Күчерелмә мәгънәле, читләтеп әйтелгән. *Ә.Фәйзи, --- ихтыяҗ-хаҗәт булганда, лиризмның үзенчәлекле алымнарына, романтик тасвир чараларына, метафорик, аллегорик образларга өстенлек бирүдә дә «көферлек» күрми.* Т.Галиуллин. *Роберт Әхмәтҗановның күңел дөньясын, аның иҗади принципларын, рухи эзләнүләрен, эстетик карашларын, ахыр чиктә поэтик идеалларын шушы метафорик образдан да төгәлрәк әйтеп бирергә мөмкинме соң?* Н.Гамбәр. *--- бер шагыйрьләр метафорик, символик иҗат алымнарына өстенлек бирсә, икенчеләр лирик-фәлсәфи канатны алга үстерде.* Г.Гыйльманов

2) Метафоралар кулланып язылган, метафоралар белән баетылган. *Мондый әсәрләргә гадәттән тыш арттыру, трагифарска хас сурәтләр, фантастик һәм метафорик күренешләр хас.* Ә.Закирҗанов. *Тинчурин үз теләгенә ирешә. Ә менә Вәлиев-Сульва, П.Сперанскийның заманча сәхнә бизәлеше, спектакльнең метафорик теле һәм бербөтенлеге, алда әйтелгән капмакаршылыкның «юылуы», югалуы аркасында, тамашачы белән багланыш таба алмый.* Камал театры

МЕТАФО́РИК II *с. геол.* Магмалы һәм утырма тау токымнарыннан бик югары температура, газлар һәм басым тәэсирендә минералларның составы үзгәрү нәтиҗәсендә ясалган (тау токымнары тур.). *Метафорик тау токымнары (мәрмәр, кварцит, гнейс һәм башкалар) югары температура һәм басым тәэсиренә элэккән магмалы һәм утырма тау токымнарыннан ясалалар.* Табигать белеме

МЕТАФО́РИКА *и. әд.* Бер әсәрдә яки бер язучы иҗатында кулланылган метафоралар җыелмасы. *Иң беренче үзенчәлек шунда: драматурглар сәхнә сәнгатендә лирик-шигъри бизәкләр, метафорика, тирән мәгънәле детальләр һәм шартлылык зур роль уйнавын искә алып иҗат итүгә йөз белән борыла башлыйлар.* А.Әхмәдуллин

МЕТЕКЛӘ́Ү *ф. сир.* **1.** Ваклап эшләү, җентекләү, тәфсилләү. *Шактый авыр тел белән метекләп язылган бу дастаннарны укып чыгарга гаять зур түземлелек, тәндә йөгергән кан тибешенең сабырлануы, акыл утыруы, атлы гасырларны юксынырлык олыгаю кирәктер, ахрысы.* М.Гали. *Хәсән Сарьян, үзе әйткәнчә, «утырып яуган яңгыр кебек» тел белән ашыкмыйча, ипле итеп, һәр күренешнең күләгәсенә кадәр метекләп, нечкә җеп белән үрә-үрә яза белә иде.* М.Галиев

2. метекләп *рәв. мәгъ.* 1) Җентекле итеп, ваклап, тәфсилләп. *Кичен Хәсән абзый идарәдән кайтып килүче Мәгыйзь белән исәнләшкәч әйтә куйды: – Иллә дә метекләп сорашты инде. Җон төбенә төшмичә туктый торган кеше түгел икән...* М.Мәһдиев

2) Әкренләп, аз-азлап. *Ул йөкне элеккечә метекләп түгел, эре адымнар белән сөйри башлады.* А.Хәлим

Метекләп тору Шактый озак метекләү

Метекләп утыру Артык метекләү, бик озак метекләү

МЕ́ТЕО- *гр.* Кушма сүзләрдә «метеорологик» мәгънәсендәге беренче кисәк (мәс.: *метеобелешмә, метеопатия, метеостанция* һ.б.)

МЕТЕОР *и. гр. астр.* 1) Планетаара киңлектән Җир атмосферасына үтеп кергән, дистәләрчә км/с тизлектә хәрәкәт иткән космик җисем; атылган йолдыз. *Метеор сыман янамын, Үй катламына үтеп. Дөнья эшләреннән бизеп, Чат Уйдар булып бетеп...* Л.Шагыйрьҗан. *Кап-караңгы күк йөзен сызып, йолдыз атылган шикелле була. Болар – метеорлар* ---. Табигать белеме. *Ай бассейннарын тутырган лавага килгәндә исә, ул Айның эчке катлауларыннан чыккан, ягъни метеорлар бәрелү нәтиҗәсендә барлыкка килмәгән.* Галәм. Җир. Кеше

2) Су транспортының пассажирлар йөртү өчен файдаланыла торган, чагыштырмача кечкенә тизйөрешле төре. *Кайдандыр ерактан якынлашып килгән метеорныңмы, ракетаныңмы тавышы ишетелә, ул узып киткәч, бераздан үзйөрешле баржа тавышы су буйларын яңгырата.* Г.Әпсәләмов. *Метеорга да, автобуска да билетлар җитәрлек: рәхим ит, ал да җилдерт, дүрт ягың кыйбла!* М.Насыйбуллин. *--- пароходлар инде күренми. Аның каравы сине татар мәркәзенә автобус яисә метеор хәзер дүрт-биш сәгатьтә җилтерәтеп китереп җиткерә.* Т.Галиуллин

МЕТЕОРИЗМ *и. гр. мед.* Ашказанында яки эчәклектә артык газлар җыелу күренеше. *Чистартылган каен дегете препараты – карболен – ашказаны метеоризмы, чәнчешүләр вакытында, ашказаны сыекчасының ачылыгы күтәрелгәндә һәм бигрәк тә агулар һәм*

бактерия токсиннары белән агуланганда, адсорбент буларак файдаланыла. Урман аптекасы. *Ютәлне, тавыш карлыгуны, метеоризмны, бөер ташы авыруын дәвалауда карагач кулланыла.* Мәдәни җомга

МЕТЕО́РИК *с. астр.* Килеп чыгышы метеор (*1 мәгъ.*) белән бәйле, метеорларга мөнәсәбәте булган. *Метеорик күренеш*

МЕТЕОРИТ *и. гр. астр.* Атмосфераның өске катламнарында бөтенләй янып бетмичә җиргә төшкән метеор җисем. *Ерак галактикаларны, шулай ук метеоритларны да, фотоплёнкада чагылып калган эзләре буенча табалар.* Ш.Галиев. *Миллиард еллар буена метеоритлар төшеп, Ай өстен 10 метр тирәнлеккә кадәр йомшартып бетергәннәр.* Кызыклар дөньясында. *Хикмәт шунда: борынгы мисырлылар Нил үзәнендә бик сирәк очрый торган тимерне беренче тапкыр метеоритлардан тапканнар.* Галәм. Җир. Кеше

МЕТЕОРО́ГРАФ *и. гр.* Өзлексез режимда берничә метеорологик билгене берьюлы – һаваның җылылыгын, басымын, дымлылыгын автомат рәвештә язып бара торган прибор

МЕТЕОРО́ЛОГ *и. гр.-гр.* Метеорология өлкәсендәге белгеч. *Зәйтүнә шушы темага язылган фәнни хезмәтләрне табып укырга, авыру тарихларын өйрәнергә, метеорологлар белән элемтәгә кереп, алардан күп еллык күзәтүләрне алырга булды.* М.Маликова. *Космонавтлар геолог, метеоролог, гидролог һәм башка белгечләргә Җир өслеген өйрәнү, файдалы казылмаларны табу һәм бүтән әһәмиятле мәсьәләләрне хәл итүдә әллә никадәр ярдәм күрсәтәләр инде.* Кызыклар дөньясында. *Метеорологлар җилнең көчен баллар белән билгелиләр.* Дөньяда ниләр бар

МЕТЕОРОЛО́ГИК *с.* 1) Метеорология фәненә мөнәсәбәте булган. *Әлбәттә, хәзерге вакытта, көндәлек һәм айлык прогнозларны билгеләүдә куәтле һәм бай техника, шул исәптән метеорологик спутниклар киң файдаланылганда, халык сынамышлары бу өлкәдә төп рольне уйнамый.* Х.Мәхмүтов. *Әгәр гадәти метеорологик станциядәге күзәтүләр һава хәлен «бер ноктада» регистрацияләгән булсалар, хәзерге заман иярчене бер тәүлек эчендә бөтен җирдәге метеорологик шартларны күздән кичерә.* Галәм. Җир. Кеше

2) Һава торышы белән бәйле. *Әлеге полоса [радиоактив зарарлану полосасы] шартлауның куәтенә, төренә, җил тизлегенә, метеорологик шартларга һәм урынның рельефына бәйле.* Г.Шакиров. *Бина эчендә температураны, дымлылыкны, һаваның хәрәкәтен һәм газ составын --- тышкы метеорологик шартларга, шулай ук терлекләрнең җылылык, дым һәм газ бүлеп чыгарулары на карап,--- норма чикләрендә тоталар.* Авыл хуҗалыгы электригы белешмәсе

МЕТЕОРОЛО́ГИЯ *и. гр.* Җир атмосферасын, аның төзелешен, үзлекләрен һәм анда барган физик процессларны өйрәнә торган фән. *--- Һиндстан спутнигы беренче чиратта метеорология службасына, геологик разведкага, сулыклар, каналлар өчен оптималь мәйданнар сайлап алу максатына хезмәт итәчәк.* М.Мәһдиев. *--- метеорологиядә сыкы дип, бәстән бөтенләй аерылып торган күренешне атыйлар.* Дөньяда ниләр бар. *Хәзерге вакытта һава торышын төрле илләрнең метеорология хезмәте күзәтә.* Табигать белеме

МЕТЕОСТА́НЦИЯ *и. гр.-лат.* Метеорологик станция, һава торышын даими рәвештә күзәтеп торган фәнни учреждение. *Алты почмаклы йортның бер башында алар яши, икенче башында метеостанция конторасы урнашкан.* Р.Хәбибуллина

МЕТЕР *с. диал.* Үтә вакчыл характерлы. *--- Кайчагында, юкны эзли-эзли, Әвереләм метер карчыкка.* Ф.Мөслимова

МЕТЕ́Р-МЕТЕР *иярт.* 1) Әкрен генә, өзек-өзек тавыш чыгарып сөйләнү, көлү һ.б.ш. рәвеше турында. *Әйе, ул кәҗә көлүе төсле метер-метер көлми, киң күңелле, ихлас кешеләрчә дөнья шаулатып көлә.* Г.Ахунов

2) Вак-вак хәрәкәтләр ясау, әкрен генә селкенгәләү рәвеше турында. *Әгәр инде калкавыч метер-метер генә селкенеп, суга акрын гына батып китсә, монысы инде эре чабак була.* Р.Фәизов. *Пошынмас Рафисның битенә егылып төшмәсме дип, каты гына өргән идем, ул [чебен] гөл чәчәгенә килеп кунды да, борынын метер-метер китереп, Сәлимә апага текәлде.* Р.Рахман

МЕТИЛ *и. гр. хим.* Бервалентлы CH_3 органик радикалы, күп кенә кушылмалар составына кергән, бер атом углерод һәм өч атом водородтан торган группа. *--- каравылчысыз торган ул цистернадан шактый кеше спирт эчә, һәм... шул ук көнне берничәсе үлә, ә калганнары сукыраялар. Ул метил спирты булып чыга.* З.Зәйнуллин. *Метил йодидының электронлы формуласы түбәндәгечә булачак ---.* Органик химия. *[Тубылгы тамырында] --- эфир мае (аның составына салицил альдегиды һәм синиль кислотасы керә), салицил кислотасының метил эфиры, ванилин, терпеннар, С витамины һәм сары буяу матдәсе бар.* Урман аптекасы

МЕТИЛОРАНЖ *и. гр. хим.* Аналитик химиядә кулланылган, азобуявычлар төркеменә караган органик буявыч матдә. *Суда эрүчән нигезләрнең судагы эремәләрендә (нигезләрнең ионнарга таркалуы сәбәпле) лакмус – зәңгәр, метилоранж – сары, фенолфталеин кура җилләге төсенә керә.* Гомуми химия

МЕТИС *и. фр.* 1) Индеецлар белән европеоид раса кешеләре никахлашудан туган буын. *Биредә ак тәнлеләр белән берәттән кызгылт мулат, метис, негр балалары да бар.* Р.Ибраһимов

2) Гомумән төрле раса кешеләре өйләнешүдән туган буын. *Таптаган каткан киездә Гарепне Батый тезе. Ничәмә миллион метиста Әле дә яши төсе.* Р.Зәйдулла

3) *биол. иск.* Селекциядә: токымара яки сортара кушылдырудан килеп чыккан буын. *--- Ә миләш, Валдай миләше, Бер гибрид, метис миләш: – Минемчә яшә, Тимер! – дип, Бирмәкче миңа киңәш...* Х.Туфан. *Мотор испродромнарда тәрбияләп үстергән метис түгел, туган як болыннары тудырган, шунда үскән чын рысак иде.* А.Хәсәнов

МЕТИСЛАШТЫРУ *ф. иск.* Токымын яхшырту өчен, төрле токым хайваннарны кушылдыру

МЕТМЕЛДӘТҮ *ф. сөйл.* Күзләрне яки иреннәрне еш-еш ачып йомгалау, сүз әйтергә яки еларга теләгәндәй кыймылдату

Метмелдәтеп алу Кыска вакыт арасында метмелдәтү

Метмелдәтеп кую Бераз гына яки бер мәртәбә метмелдәтү

Метмелдәтеп тору Билгеле вакыт дәвамында, шушы моментта яки гел метмелдәтү. *Кеше сүзен тыңлаганда, ул ни өчендер авызын метмелдәтеп тора.* М.Мәһдиев

МЕТМЕЛДӘҮ *ф.* Дерелдәү, калтырау, кыймылдау (ирен, күз кабагы тур.). *Хәлиулла әле бирешми, шулай да күзләр инде кызара, иреннәре дә метмелди башлый*. М.Мәһдиев

Метмелдәп алу Бераз метмелдәп туктау

Метмелдәп тору Билгеле вакыт дәвамында, хәзерге моментта яки гел метмелдәү

Метмелди башлау Метмелдәргә керешү

МЕ́Т-МЕТ *иярт.* **1.** Еш-еш селкенү, дерелдәү, калтырау, ачылып-йомылу рәвешен белдерә

2. *рәв. мәгъ.* Еш-еш ачып-ябып, кыймылдатып (күзләр, иреннәр тур.). *Камалиның мет-мет йомылган күзләренә әйтерсең лә кояш чаткысы чәчрәп төште.* К.Нәҗми

МЕ́ТОД *и. гр.* 1) Табигать күренешләрен һәм иҗтимагый тормышны танып белү, тикшерү ысулы. *Диалектик метод*

2) Билгеле бер эшчәнлек өлкәсендә кулланыла торган ысуллар һәм алымнар системасы. *Безнең илдә беренчеләрдән булып ул чит телләргә тиз арада өйрәтү методларын үзләштерде, зур галим булып үсеп җитте, кафедра җитәкчесе дәрәҗәсенә иреште*. М.Маликова. *Язучыга, бәлки, төрле иҗат методларыннан читтә тору, аларны белмәү хәерлерәктер.* Р.Низамиев. *Җир кабыгында табылган иң карт минералларның яше 4 миллиард ел чамасы булуы радиоактив метод белән билгеләнгән.* Галәм. Җир. Кеше

МЕТО́ДИК *с.* 1) Методика белән бәйле, методикага караган. *Сәламәтлеге, холкы уку-укыту бүлеге мөдире булырлыкмы аның? --- укымышлы, методик ярдәмгә сәләтле, сабыр табигатьле һәм үз өстендә эшли ала торган кеше кирәк ул эшкә.* Г.Тавлин. *Дипломлы укытучылар Татарстаннан килсен иде. Икенче кыенлыгыбыз – дәреслекләр, методик әдәбият, күргәзмә әсбаплар.* Т.Әйди. *Хәзер күрше өлкәләрдәге милләттәшләрдән үтенечләр килә: татар теленә өйрәтүче кадрлар, методик кулланмалар сорыйлар.* Казан утлары

2) Максатчан рәвештә, эзлекле, даими, регуляр төстә эшләнә, башкарыла торган. *Әгәр сез методик эзлеклелек белән үзегезгә таләпләрне акрынлап арттыра барсагыз, бөтенесе дә бик әйбәт булачак.* В.Леви

МЕТО́ДИКА *и. гр.* 1) Билгеле эшне алып баруда, башкаруда максатка ярашлы һәм кирәкле алымнар, ысуллар җыелмасы. *Анда каралган мәсьәләләр бер гыйльми нигезгә яки бер методикага корылган булса, бер хәл иде.* Ж.Фәйзи. *Археология методикасының бөтен шартларына җавап бирерлек дәрәҗәдә оештырылган казу эшләре Кремль территориясендә беренче мәртәбә 1953–1954 елларда гына үткәрелә.* Ф.Хуҗин. *Операцияне билгеле методиканы төгәл үтәп, тыныч күңел белән дәвам итәргә була иде*. М.Маликова

2) Билгеле бер фәнне укытуда кулланыла торган методлар турындагы өйрәтмә. *Математиканы, физиканы, химияне оныткан бу егетләр кичләрен клубларда кызлар янында дәрес бирүнең методикасы турында тәмләп сөйлиләр.* М.Мәһдиев

МЕТОДИСТ *и. гр.* Бер фәнне укыту методикасы белгече. – *Миһербану Хөснуллина яки методист Фарук Галимовны тыңлап, артык тынычлана күрмә, – диде ул миңа.* Т.Әйди. *Галимҗан Ибраһимов – язучы, тарихчы, әдәбият галиме, публицист, методист, педагог, тел галиме, тәнкыйтьче, революционер...* С.Поварисов. *Методист Сания Исмәгыйлева Акмулла шигыреннән өзек укып җибәрде ---.* Т.Галиуллин

МЕТОДОЛО́ГИК *с.* Методологиягә караган, методология белән бәйле. *Ә әдәбият һәм әдәби хәрәкәт исә җәмгыятьнең үзгәреш юлларын чагылдыра, үзе дә эчтәлек һәм форма җәһәтендә сәнгати, методологик һәм әхлакый-рухи үсеш кичерә.* Х.Әхмәтҗанов. *Конкрет әсәрләрне күзәтүгә күчкәнче, тагын берничә методологик мәсьәләне яктыртып үтү сорала*. Ф.Урманчеев. *--- бу концепция методологик кимчелеккә ия. Ул төрле субъектив фараз итүләргә юл куя ---*. К.Гыйззәтов

МЕТОДОЛО́ГИЯ *и. гр. кит.* 1) Танып белүнең фәнни методы турындагы өйрәтмә. *Югарыда саналган хезмәтләре Г.Гобәйдуллинны марксизм-ленинизм методологиясе, тарихи материализм нигезендә эшләүче тарихчы итеп күрсәтәләр.* С.Алишев. *--- дөнья үзгәрә, тикшеренүләр заман таләп иткән методологиягә нигезләнеп алып барыла.* М.Әхмәтҗанов. *1983 елда --- аның [Й.Нигъмәтуллинаның] рус телендә «Әдәби иҗатны өйрәнүнең комплексы методологиясе» исемле китабы дөнья күргән иде.* Казан утлары

2) Аерым бер авторда, чорда, фәндә һ.б.ш. кулланыла торган алымнарның барысы. *Философия кешеләрнең дөньяга карашын чагылдырган күренеш кенә түгел, ул әле билгеле бер теоретик «калып», методология дә.* К.Гыйззәтов. *Аның методологиясендә төп урынны дөнья әдәбиятындагы уртаклыклар һәм аларның милли әдәбият сыйфатлары белән баюы алып тора.* Ә.Закирҗанов

МЕТОНИ́МИК *с.* Метонимия алымы белән оештырылган, метонимия кулланып язылган. *Метонимик эпитет логик эпитеттан үзен аерым гына алып караганда метонимия булуы белән аерыла.* Х.Курбатов

МЕТОНИ́МИЯ *и. гр. әд.* Тропның бер төре: бер сүзне мәгънәсе ягыннан аның белән тыгыз бәйләнештә булган икенче сүз белән алмаштыру алымы (мәс., *«эшләпәле кеше әйтә»* урынына *«эшләпә әйтә»*); образлы итеп кулланылган шундый сүз яки гыйбарә. *Шәхес кичерешләре, күңел көзгесе – рухи дөнья турында уйланганда, Туфан сурәтне тарайта бара (метонимия алымы) һәм турыдан-туры йөрәк*

белән серләшеп китә ---. Т.Галиуллин. *[Сүзнең] Туры яки күчерелмә мәгънәдә булуы күрсәтелә (күчерелмә мәгънәдә булса, төре билгеләнә: метафора, метонимия, синекдоха, вазифа буенча күчеш).* Р.Шәмсетдинова

МЕТР I *и. гр.* 1) Халыкара берәмлекләр системасында озынлык үлчәүнең төп берәмлеге: элек Париж меридианының ун миллионнан бере буларак билгеләнгән, хәзерге вакытта яктылыкның вакуумда секундның 1/299 792 458 өлешендә үткән юлын тәшкил итә. *Көтүче абый, сыерларын елга буена туплауга китергәч, аш әзерләү өчен, ике йөз метр чамасы ераклыктагы чишмәгә су алырга китә.* Ә.Баян. *Инде немец траншеясына егерме-утыз метр чамасы гына калды.* Х.Камалов

2) Шундый озынлыктагы, сантиметр бүлемнәре булган, берәр нәрсә үлчәү өчен хезмәт итә торган линейка. *Гайнан чемоданнан берәм-берәм алып, фотоаппарат, йомшак метр, төсле порошок, ябыштыргыч кәгазь, башка кирәк-яракларны өстәлгә бушата башлады.* М.Насыйбуллин. *Улым! Балта, пычкыны ал әле. Метрны да онытма.* Н.Хәсәнов. *Нотыкчы зур мәгънәле кыяфәттә, әле бармакка, әле тамаша залына карап, куен дәфтәренә нидер яза бара. Метр алып, ниләрдер үлчи.* Р.Батулла

МЕТР II *и. гр.* 1) *әд.* Шигырьдә басымлы һәм басымсыз иҗекләр чиратлашуның билгеләнгән схемасы, шигырь үлчәме. *Гаруз, төрки телләрдәге поэзиядә гасырларча хакимлек итүче метр буларак, соңыннан бу телләрдән тизлек белән төшеп калды.* Х.Госман

2) *муз.* Такттагы көчле һәм көчсез өлешләр чиратлашуындагы тигезлек. *Бу чор язмаларында метр (вәзен), ритм (икаг), мелизматика үзенчәлекләренең реаль яңгырашлары күп очракта дөрес язылышта бирелмәгән.* Г.Макаров

МЕТР III *и. гр.* Остаз. *Р. Харисның «Кайтаваз» (1969) китабына кереш сүз язып, метр [Сибгат Хәким] үзенең фатихасын бирә.* Т.Галиуллин

-МЕТР *гр.* 1) Кушма сүзләрдә «беренче сүздә күрсәтелгән озынлыкта, күләмдә» мәгънәсен белдерә торган икенче кисәк (мәс., *сантиметр, миллиметр* һ.б.). *Норма буенча эшчеләр андый туң җирне берәр кубометр эшләргә тиешләр.* А.Алиш. *Кичә мин бер метр да кырык сантиметрны сикердем. Син ярты метрны да сикереп чыга алмадың.* Т.Миңнуллин

2) Беренче компонентта белдерелгән билгене үлчәү өчен кулланыла торган прибор (мәс., *омметр, барометр* һ.б.). *Вольтметр белән көчәнеш үлчәү чиген арттыру өчен, аңа бер-бер артлы тоташтырыла торган өстәмә каршылыктан файдаланалар.* Даими ток законнары

МЕТРАЖ *и. фр.* 1) Нәрсәнең дә булса метрларда белдерелгән озынлыгы. *Метражы буенча минем өй биегрәк килеп чыга.* М.Галиев. *Бүген язылган шигырьләрне метражга салып карасаң, чакрымнар пәйда булыр иде!* Р.Әхмәтҗанов

2) Берәр нәрсәнең квадрат метрлар белән бирелгән мәйданы. *Алгы бүлмәнең метражы*

МЕТРАЖЛЫ *с.* Билгеле метраждагы. *Килегез, текстлар язарсыз, тулы метражлы урысча фильмнарны татарчага тәрҗемә итәрсез. --- нәфис фильмнар төшерә башлау күздә тотыла. Башта, әлбәттә, кыска метражлы фильмнар эшләнер.* Г.Тавлин. *Быел фестивальнең сайлап алу комиссиясенә 67 илдән 400 фильм (168 – нәфис, 138 – документаль һәм 94 кыска метражлы фильм) кабул ителде.* Казан утлары

МЕТРАНПАЖ *и. фр. махс. тар.* Типографиядә набор җыю эшен күзәтеп торучы өлкән наборщик, наборны полосага яки биткә салучы. *Җыелган материалларны биткә салып чыгару эшендә метранпажга күрсәтмәләр биреп торучы да мин.* М.Әмир. *--- линотипистлар, кизү корректорлар, метранпажлар чыгаручы, курьер, җаваплы секретарь урынбасары, газета басучылар һәм «сафбаш» бергә әвәрә килеп, төн уртасына кадәр аяк өстендә булалар.* Г.Тавлин

МЕТРДОТЕЛЬ *и. фр.* 1) Баш официант, ресторанда җаваплы оештыручы. *Шул вакыт бүлмәгә метрдотель керде: «Кайнар ашны кайчан китерәсе?» – дип сорады.* З.Фәтхетдинов. *Метрдотель капитанны ишек төбендә үк каршы алып, баш иеп, түрдәге өстәл янына озатты: «Рәхим итегез, сезнең урын менә биредә».* М.Маликова. *--- метрдотельнең борчылуын кул белән алып ташладылармыни, ул күз ачып йомганчы тынычланып калды.* Р.Мирхәйдәров

2) Зур йортларда һәм отельләрдә табын өчен җаваплы һәм барлык хезмәтчеләрнең эшен оештыручы кеше

МЕ́ТРИК *с.* 1) *физ. тех.* Метрика (I) белән бәйле, метрика үзенчәлекләренә караган. *Халыкның метрик һәм хисап системасы – рухи мәдәниятнең гамәли эшчәнлеккә иң якын торган өлкәсе.* Г.Дәүләтшин

2) *әд.* Метрика (II) белән бәйле, метрика үзенчәлекләренә караган. *Башка очракларда, катлаулы метроритм эффектын бетерү теләге барлыкка килгәндә, С.Габәши, киресенчә, метрик берәмлек итеп сигезле нота урынына чирекле нота алган* ---. Милли моңнар. *Шигырьнең метрик төзелеше*

МЕ́ТРИКА I *и. гр.* Физик зурлыкларны үлчәүнең халыкара системасы. *Юлий Цезарьның буе 7 стадий чамасы гына булган, хәзерге метрика белән бу 162 см тирәсе тарта; Наполеон, Франко – карсаклар.* Т.Мөбарәков

МЕ́ТРИКА II *и. гр. әд.* 1) Шигырь үлчәүләре турындагы өйрәтмә. *Гарәп-фарсы метрикасына корылган көйләп укыла торган шигырьләр урынына интонацион сөйләүгә нигезләнгән шигырьләр барлыкка килә.* Ә.Исхак

2) Шигырьнең, гомумән поэзиянең үлчәве белән бәйле үзенчәлекләре. *Төрки «Шаһнамә»нең жанр һәм композиция, метрика һәм рифма бирелеше күпсанлы мисалларда ачыкланып, әсәрнең Урта гасырлар шигъриятендәге урыны тагы да тулырак күз алдына килеп баса.* Ә.Закирҗанов. *Р.Вәлиев – нигездә, традицион метрика калыбындагы, җитди эчтәлекле, яшәү мәгънәсе һәм тормыш фәлсәфәсенә кагылышлы уй-фикерләр белән сугарылган романтик рухлы лирик поэзия тарафдары.* Хәзерге татар әдәбияты

3) Шигырь язуда файдаланылган барлык үлчәм төрләре

4) *муз.* Такттагы метр үзенчәлекләре турындагы өйрәтмә

МЕ́ТРИКА III *и. лат.* 1) Туу турында метрика кенәгәсендә ясалган махсус язуга нигезләнеп төзелгән документ; туу турында таныклык. *Бабайның үз хәтеренә ышанып кына, соңрак метрика язып биргәннәр.* Г.Сабитов. *--- ниндидер хорафатка ышанып, метрика бозу – ахмаклык, Сара Кыямовна.* С.Лашманчы

2) *иск. к.* **метрика дәфтәре**. – *Сиңа әйтәм, – диде Галимулла, – без аны яңа елсыз метрикага кертми торырбыз, бер елга булса да, солдатка соңрак алыныр.* И.Гази

МЕ́ТРИКА ДӘФТӘРЕ *и. тар.* Туу, үлү, өйләнешү очраклары рәсми рәвештә теркәлеп бара торган төп кенәгә, гражданлык актларын теркәү кенәгәсе. *1905 елның 20 маенда Чистай ишаны Мөхәммәтзакир кызы Әсмаигалия белән Ростов-Дон мулласы Муса Җарулла улы Бигиевнең никахлары метрика дәфтәренә теркәлә һәм зурдан кубып туй үткәрелә.* И.Нуруллин. *Риф Якупов беренче буларак шагыйрьнең иҗатын һәм тормышын өйрәнүдә гаять әһәмиятле --- метрика дәфтәрләрендәге хәбәрләрне фәнни әйләнешкә кертсә, Зәкия Рәсүлева исә беренче булып Тукайның нәсел шәҗәрәсен төзү тәжрибәсен ясады.* Эзләнүләр. Уйланулар. Табышлар

МЕ́ТРИКА КӘГАЗЕ *и. к.* **метрика** III (*1 мәгъ.*). *Хәйбүш яшь чакта авыллары янган, метрика кәгазьләре сакланмаган.* Г.Әпсәләмов

МЕ́ТРИКА КЕНӘГӘСЕ *и. к.* **метрика дәфтәре**. *Дөрес, Күктау авылының метрика кенәгәләрендә исем-фамилиям теркәлмәгән теркәлүен, әмма бу як минем өчен, чынлап та, кадерле.* М.Зарипов

МЕ́ТРЛАП *рәв.* 1) Озынлыгын берәр метр итеп. *Имәнне метрлап турады. Бүкәннәрне сигезгә ярып күләгәдә --- киптерде.* А.Гыйләҗев. *Метрлап-метрлап җир тишә торгач, кое бораулаучы абзагыз кабер тирәнлегендәге туфрак җылысының ни дәрәҗәдә булуын чамалый бераз.* К.Кәримов

2) Метрлар белән үлчәп. – *Мин сыраны литрлап түгел, метрлап эчәм, – дигән драматург.* Р.Батулла. *Квадрат метрлап исәпләгәндә, Казанда иң күп техника бездә.* Татарстан яшьләре

3) Микъдар санында белдерелгән метр чамасы. *Ике метрлап биеклектәге яр кисентесеннән үк сөзәк үр күтәрелә, ә анда – ташландык рус зираты.* Ә.Гаффар. – *Менә шушындый, – дип, кулларын ярты метрлап җәеп күрсәтте ул, – бау аласың да яр буена утырасың.* М.Маликова. *Бумеранг биш метрлап очып барып, салмак кына борылыр ---.* Кызыклы физика

МЕ́ТРЛЫ *с.* 1) Озынлыгы бер метрга тигез булган; бер як үлчәме бер метр тәшкил иткән. *Район вәкиле, үрелеп, метрлы линейка белән форточканы ачып җибәрде.* М.Мәһдиев. *Инде безнең көннәрдә ул байлыкны эзләргә омтылышлар да булды, ләкин күл төбенең күп метрлы ләме бүгенге эзләнүчеләр өчен ерып чыккысыз кыенлыклар тудыра.* Ф.Гарипова

2) Билгеле метр үлчәмендәге. *Түбә ябучылар белән эретеп ябыштыручылар бергәләп эшләделәр, чөнки озынлыгы ундүртәр метрлы, эре сырлы калын түбә калаен эретеп кенә кисеп була иде.* М.Маликова. *Узен королева кебек хис иткән хатын ничек, алты квадрат метрлы тараканлы кухняга кереп, тозлаган кәбестәдән исерек ире өчен аш пешерсен?!* Д.Гыйсметдин. *Җир астында тоз гадәттә егерме биш утыз метрлы калын катлам булып ята.* Дөньяда ниләр бар

МЕ́ТРЛЫК *и.* **1.** Җыелмалы метр. *Метрлыгын гел кесәсендә йөртә*

2. *с. мәгъ. к.* **метрлы**. *Өй халкы, көлеп, «мастерской» дип йөрткән дүрт метрлык кечкенә бүлмәдә Галим әнисенең керосинкасын төзәтеп утыра иде.* Г.Әпсәләмов. *Башкаланың Авиатөзелеш районында яшәүче Гаяз Сабиров 5 кешелек гаиләсе белән 21 кв. метрлык бүлмәдә яши.* Ватаным Татарстан. *Ышансагыз – ышанығыз, ышанмасагыз – юк: ләкин иртүк, мин барганда, «Җиңү проспекты» станциясенең керү ишеге ягында дүрт-биш метрлык чират иде.* Шәһри Казан

МЕТРО *и. фр. к.* **метрополитен**. *Шулай да кесәләрдән егерме тиенләп акча кырыштырып алдылар, анысы метрога кирәк булды.* М.Мәһдиев. *Алар көндезге сәгать икедә тимер юл вокзалы янындагы метро станциясендә очрашырга килештеләр.* М.Маликова. *Сокольникида трамвайдан төшеп, метро станциясенә кердек.* М.Юныс

МЕТРО́ВКА *и. рус сөйл. к.* 1) **метрлык** (*1 мәгъ.*)

2) Ике таяктан «А» хәрефенә охшатып эшләнгән, колачы гадәттә ике метрга тигез булган җир үлчәү әсбабы. *Тимери Нәфисәнең, метровкасын атлатып, эшләгән җирне үлчәп килүен сакалын аралаштыргалап карап торды.* Г.Бәширов

МЕТРО́ЛОГ *и.* Метрология тармагында белгеч. *Өченчедән, һәр бүлек үз оешмасыннан посылка ала (мин метрология бүлегендә өлкән техник-метролог булып эшләдем).* Татарстан яшьләре. *Ул шулай ук Татарстанда метрология хезмәте күрсәтә торган предприятиеләрнең һәм Метрологлар советының алдагы бурычлары белән таныштырды ---.* Шәһри Казан

МЕТРОЛО́ГИК *с.* Метрология фәненә һәм эшенә караган, шуның белән бәйле. *Җәмгыятьнең үсеш югарылыгы аның метрологик культурасының ни дәрәҗәдә үсүе белән билгеләнә, дисәк тә әллә ни арттыру булмас.* Г.Дәүләтшин. *Ул --- Метрологлар советының алдагы бурычлары: кулланучының мәнфәгатьләрен дөрес булмаган үлчәү һәм аның нәтиҗәләреннән яклау; метрологик хезмәт күрсәтүче оешмаларның көчләрен берләштерү --- белән таныштырды.* Шәһри Казан

МЕТРОЛО́ГИЯ *и. гр.* Үлчәү гамәлләре һәм берәмлекләре, аларның дөреслеге һәм төгәллеге турындагы фән. *Безнең белән пароходчылыкның метрология (приборлар төгәллеген тикшереп тору) лабораториясеннән ике хатын диңгезгә чыкканнар иде.* М.Юныс. *Халык метрологиясе фәнни белемнәр, аеруча математика, астрономия гыйлемнәре белән дә тыгыз бәйләнештә.* Г.Дәүләтшин. *2004 елда биредә ике катлы заманча бинада химия*

һәм метрология лабораториясе һәм медицина-санитария бүлеге ачылды. Т.Нәҗмиев

МЕТРОНОМ *и. гр.* Музыка башкарганда һ.б.ш. очракларда темпны билгеләү өчен кулланыла торган, сугу тавышы белән кыска вакыт арасын билгели торган маятниклы прибор. *Күке берәмләп кенә саный. Табигатьнең метрономы сыман тавыш салмак кына кабатлана.* Ш.Галиев. *Метрономнар шакып биргән шәп-шәрә темпоритмнар аркылы актёрларны билгеле бер халәткә кертеп, шуның белән бергә катлам-катлам кичерешләрне «уятырга» мөмкин булды.* В.Леви. *«Якуп көе» (№ 18) язмасында, мәсәлән, «Акрын» ремаркасы куелган. «Әлифба» (№ 92) көенә тизлек билгесе метроном буенча гына куелган (М = 108).* Милли моңнар

МЕТРОПОЛИТЕН *и. фр.* Зур шәһәрләрдә җир астыннан, җир өсте буйлап яки махсус эстакадалар белән җир өслегеннән күтәреп үткәрелгән, электрлаштырылган тимер юл. *Метрополитен төзүчеләрнең беренче газеталары татар телендә чыга.* М.Юныс. *--- метрополитен шау-шуын киметү өчен, вагоннарны махсус конструкцияле итеп ясарга һәм туннельләрне тавыш йотучы материаллар белән тышларга була.* Кызыклы физика. *Казан шәһәр метрополитенының беренче линиясен – 2013 елга сафка басачак «Декабристлар», «Мәскәү», «Завод» станцияләрен төзеп бетерү өчен, 17 млрд сум акча килүе көтелә.* Шәһри Казан

МЕТРОПО́ЛИЯ *и. гр. тар.* Үзенең колонияләренә, икътисади яктан үзенә бәйле территорияләргә яки илләргә карата үзәк дәүләт. *Колониаль администрация метрополиягә күпме байлык озатылганын бик җентекләп теркәп барган.* М.Юныс. *Инде изүче халыкларга килгәндә, алар – метрополиядә яшәүчеләр, чөнки колониаль халыклардан талап алынган байлыкның бер өлеше метрополия кешеләренең һәммәсенә дә тия.* М.Әхмәтҗанов. *--- бу илләрдә колонияләрнең бетерелүе элекке метрополияләрдә эшчеләр сыйныфының күтәрелешен барлыкка китермәде һәм китерми.* Казан утлары

МЕТРОРИ́ТМИК *с.* Метрика һәм ритмика белән бәйле. *Бу көйне революциягә кадәр үк чыккан, диләр. Тик ул гражданнар сугышы чорында гына үзенең марш характерындагы метроритмик төзелешен тапты һәм революцион җырга әйләнде.* Җ.Фәйзи. *[Көйнең] Беренче өлеше бормалы озын көйләргә хас ямблы метроритмик формулага корылган ---.* Милли моңнар. Төрки-татар көйләре

МЕТРОСТРОЙ *и. рус* Метро төзү эше һәм шул төзелеш үзе. *Урамнан егетләрне җыеп кердем, араларында метрострой егетләре дә бар иде.* Г.Ахунов. *Әлеге башлыкларны һәм «КамАЗ», «Татнефть», «Метрострой» предприятиеләре җитәкчеләрен «Пирамида» сәхнәсенә укытучыларны тәбрикләргә чакырганнар иде.* Ватаным Татарстан

МЕТРОСТРОЙЧЫ *и.* Метрополитен төзү белгече яки шуны төзүдә катнашучы эшче

МЕТРОЧЫ *и.* 1) *к.* **метростройчы**. *Озакламый метрога забойщик булып эшкә керде. Аннары метрочылар өчен чыга торган күптиражлы газетага журналист булып күчте.* Г.Әпсәләмов

2) Метрополитенда хезмәт итүче кеше

МЕ́ТЧИК *и. рус* Металл эшендә эчке резьбалар кисү инструменты. *Киндер чолгаулар арасыннан, тык-тык тавыш чыгарып, цемент идәнгә корыч метчиклар, пружиналар коелдылар.* А.Алиш. *Метчик эчке сырларны (резьбаларны) ясау өчен кулланыла. Метчик – киселгән туры яки винт канавы булган инструмент ул.* Әзерләнмәле бораулау станокларында эшкәртү

МЕХ I *и. рус* **1.** 1) Имезүче хайваннарның тәнен каплап торган йомшак куе йон япмасы. *Адәм заты аны [асны] бөтен дөньяда шул мехы өчен кыра. Ә үзенчә ул мехын алыштырып саклана.* М.Рәфыйков. *Матурлыгы, күпшылыгы һәм ефәктәй елкылдап, кулга тоткач агып торуы белән кешенең кышкы мехына бу дөньяда тиңнәр юк.* Кызыклар дөньясында

2) Шундый йомшак япмасын саклап эшкәртелгән хайван тиресе; күрек. *Ул эш киемнәрен инде салып аткан, өстенә кара постау пәлтә, башына кара сарык мехыннан теккән зәңгәр бәрхет түбәле кубанка, кулына язгы сарык йоныннан кызлар бәйләп биргән юка ак перчатка киеп алган ---.* Г.Ахунов. *Безнең Татарстаныбыз затлы мехлары белән бөтен дөньяда дан тота.* М.Маликова. *Мехка ышкыганда, сумала (яки каучук) таякта хасил булган корылманы исә тискәре корылма дип атаганнар.* Физика курсы

2. *с. мәгъ.* Күректән тегелгән. *Өстенә мех якалы җылы куртка кигән урта яшьләрдәге ир: – Сул якта бу урамга параллель өченче урам – Фрунзе урамы, – дип, кулын сул якка изәде...* Г.Тавлин. *--- безгә театрда Ильскаяныкы төсле мех пальто бирделәр, бушлай бирделәр, хәзер кәпрәеп манто киеп йөрим, буржуйка кебек.* Р.Батулла. *Биредәге товарлар – күн, тире, мех киемнәр, модельле туфлилар, итекләр, джинсы, ягъни безгә алып кайтып сатыла торган әйберләр – башка төрек базарларындагыдан аерылалар.* Т.Нәҗмиев

МЕХ II *и. рус* Төрле механизмнарда һава өрдерү өчен, сырлы торба рәвешендәге махсус җайланма, күрек. *Суын, утынын ташыдым, йомышына йөрдем. Аннан бушаган сәгатьләрдә мастерскойда чуен кырдым, мех өрдерттем, чүкеч суктым.* Ш.Усманов. *--- гармунны тартып карыйм. Я Алла! Эче буп-буш! Мехы тишкәләнеп беткән.* Ә.Баян. *Мехлары аллы-гөлле, бизәкләре гел җиздән [тальянның].* Г.Ахунов

МЕХ- I Кушма сүзләрдә «мех эшкәртү, мех җитештерү белән бәйле» мәгънәсендәге беренче кисәк. *Мин менә шул мехбазаның каракүлләр цехына өйрәнчек булып барырга тиешмен.* Ә.Еники. *Умартачы булам дигән авыл кызы мехкомбинатка эшкә килә.* Ш.Галиев

МЕХ- II 1) Кушма сүзләрдә «механикага караган, механикага бәйләнешле» мәгънәләрен белдерә торган беренче кисәк (мәс., *мехмат*)

2) Кушма сүзләрдә «механикалаштырылган» мәгънәсен белдерә торган беренче кисәк (мәс., *мехколонна*)

МЕХАНИЗА́ТОР *и.* 1) Төрле эш процессларын механикалаштыру

белгече. *Механизаторлар, пилорам куярга дип, вал яраштырып йөриләр, күп техник терминнар телдә русча.* Ш.Галиев

2) Машина, механизмнарга хезмәт күрсәтүче, шулар белән эш итүче, шуларны йөртүче белгеч. *Хәзер бит колхозда механизатор белән сыер савучыны гына күрәләр, шуларны гына мактыйлар.* М.Мәһдиев. *Ә бай тормышлы колхозлар урып җыю вакытында, механизаторларны һәм кыр эшендә эшләүчеләрне ашатырга, ике көн саен бер сыер яки тана суеп торалар.* В.Нуруллин. *Ул елларны, яшелчәче, механизатор таныклыгы биреп, укучыларны колхозда калдырырга тырышалар иде.* Шәһри Казан

МЕХАНИЗА́ЦИЯ *и.* Механик энергия, механик көч куллануга күчү, кул хезмәтен өлешчә яки тулысынча машиналар, механизмнар белән алмаштыру эше; машиналар һәм механизмнар белән тәэмин итү эше. *Бу курска механизациягә катнашы булмаган кешеләр дә йөрде.* М.Хәсәнов. *Механизация, механизация дип, бөтен дөньяны тимер-томыр белән тутырдык, һаваны корымладык, чирәмне ертып, җирне чокыр-чакырга әйләндердек.* А.Вергазов. *Арышбашны, рәт араларын эшкәртүдә механизация кулланууны исәпкә алып, киң рәтле итеп чәчәләр.* Күпьеллык үләннәр

МЕХАНИЗА́ЦИЯЛӘҮ *ф. к.* **механикалаштыру**. *Атом шартлавы өлешчә көйдергән Брянск өлкәсенә без «Татсельстрой»ның төзелешне механизацияләү идарәсе коллективы белән килдек.* Х.Вәлиәхмәтов. *1960–1964 елларда Бәләбәй авыл хуҗалыгын механизацияләү һәм электрлаштыру техникумын тәмамлап чыга.* Д.Бүләков

МЕХАНИЗМ *и. гр.* 1) Машинаның, аппаратның яки приборның аны хәрәкәткә китерә торган эчке төзелеше, аны тәшкил иткән төп узеллары системасы. *Бар иде заманалар: ферма эчләре ялт итеп тора, производство процессы сәгать механизмы кебек төгәл эшли, барысы да үз урынын белә.* Ж.Юныс. *Эчке янулы двигательләрнең төп механизмы булып кривошип-шатун механизмы санала.* Тракторлар һәм автомобильләр. --- *электр моторларның егәрлеге бик кечкенә булырга мөмкин. Мәсәлән, сәгать механизмнарын эшләтә торган электр двигательләренең егәрлеге бары 3 милливатт кына була.* Физика курсы

2) Аерым бер эш процессын үтәү өчен ясалган махсус агрегат, җайланма. *Дөрес, бу механизм утын ярырга да ярамый.* Н.Дәүли. *Шәһәрләрне камау, ташлар һәм уклар ыргыту механизмнарын ул [Архимед] үзенең туган шәһәрен римлылардан саклау вакытында гамәлгә керткән.* М.Мәһдиев. *Шулай өч сәгать йөзеп, корабның механизмнарын сынаганнан соң, портка кереп, йөк төйи башларга тиешбез.* М.Юныс

3) *күч.* Берәр өлкәдәге эшчәнлекнең эш тәртибен, эзлеклелеген китереп чыгарган, шуны билгеләгән система. *Хәбәрне язып алу белән, дежурный «тревога» сигналына басты, шул минутта ук тикшерү механизмы хәрәкәткә килде.* Д.Галимов. *Эш итү механизмнары үзгәрде. Моннан ун ел элек нәтиҗәле булган чаралар бүгенге көндә көтелгәннәрне бирә алмый.* Татарстан. *Тормыш планлаштыруны гына түгел, бөтен хуҗалык механизмын үзгәртеп коруны --- мәгънәле, нәтиҗәле эш алымнары таләп итә.* Казан утлары

4) *күч.* Нинди дә булса күренешне яки гамәлне барлыкка китерә торган хәл һәм процессларның эзлекле чылбыры. *Без белмәгән биологик механизмнар бар. Кайсы беренчел, кайсы икенчелдер әле?* Ш.Галиев. *Химик әверелешләр механизмын өйрәнүдә радиохимик ысулларның әһәмияте бик нык үсте.* Химия фаш итә. *Химик реакцияләрнең, химик бәйләнеш механизмнарының һәм молекулалар, атомнар, атом группалары, ионнар, электроннар белән була торган күренешләрнең серләре ачыла бара.* Химиянең киләчәге

МЕХА́НИК I *и. гр.* 1) Механика (*1 мәгъ.*) белгече. *Без әле монда механиклар белән бер эксперимент ясап карарга җыенабыз...* М.Хәсәнов. *Механик һөнәре сайлау белән Уатт, зур тырышлык вә түземлек куеп, үзлегеннән гыйлем туплауга керешә.* Кызыклар дөньясында

2) Механизм, машиналарның дөрес эшләвен тәэмин итеп, күзәтеп торучы белгеч; аларны эксплуатацияләү белән җитәкчелек итүче инженер. *Гүзәл кыз Мәйсәрәнең язмышы бик фаҗигале булды. Аны авылга кино куярга килгән механик урлап китә.* Г.Ахунов. *Механик тегене-моны алмаштырып көйләгәнче, гадәттә, ирләр ишек яңагына сөялеп, аякның берсен клуб эченнән алмыйча гына көйрәтеп торалар.* М.Мәһдиев

3) Предприятиедә махсус бүлек, цех башлыгы булган урта звено җитәкчесе. *Мастерскойның башлыгы – механик – мине, ни өчендер, бер карауда ук дошман күрде.* Ш.Усманов. *Нәркис Нәгыймович Бадамшин зур кеше бүген, баш механик.* М.Маликова

МЕХА́НИК II *с.* 1) Механизмнар башкара торган процессларга, күренешләргә мөнәсәбәте булган. *Механик энергияне электр энергиясенә әверелдерә торган машиналар генератор дип атала.* Физика курсы. *Химик энергияне турыдан-туры механик энергиягә әверелдерү ысулларын табу (мускуллар эшләгән вакыттагы кебек) мавыктыргыч түгелмени?* Химиянең киләчәге

2) Механизмнар, автоматик җайланмалар ярдәмендә эшләнә, башкарыла торган. *Баштарак, механик савуга күчү белән, сыерлар сөтләрен киметтеләр.* М.Хәсәнов. *Механик эшкәртү белән бер үк вакытта рәтләрдә туфракны китмән белән йомшарталар һәм чүп үләннәрен утыйлар.* Яшелчәчелек. *Күл белән саву күп хезмәт таләп иткәнгә, сыерларны механик юл белән савуга күчү үзеннән-үзе сорала.* Сөт терлекчелеге турында кыскача белешмә

3) *биол.* Үсемлекнең, күзәнәкнең, тере организмның тышкы тәэсирләргә карата ныклыгын тәэмин итә торган. *Яфракларда механик тукымаларның күзәнәкләре еш кына үткәргеч тукыма күзәнәкләре тирәсенә урнашалар һәм аның белән бергә яфрак сеңерчәләрен формалаштыралар.* Биология. *Күзәнәкләр күзәнәкара матдәдә*

урнашкан, ул матдә күзәнәкнең механик ныклыгын, тукланыуын һәм сулавын тәэмин итә. Биология: кеше һәм аның сәламәтлеге

4) *физ.* Җисемнең физик составына, составында булган катнашмаларга, тышкы ныклыгына бәйле. *Электротехник кәгазьләрне һәм катыргыларны механик яктан нык һәм югары температура тәэсиренә бирешмәүчән сульфатлы целлюлозадан ясыйлар.* Авыл хуҗалыгы электригы белешмәсе. *Туфракларның үзлекләре, аларның механик составы һәм физик төзелеше, бигрәк тә туфракның реакциясе үләннәрнең үсешенә бик нык йогынты ясый.* Күпьеллык үләннәр. *Түгәрәк фильтрда кала торган механик катышмаларга карап, сөтнең чисталыгын белергә мөмкин.* Сөт терлекчелеге турында кыскача белешмә

5) *к.* **механистик**. *Механик материализм*

6) *күч.* Формаль яки гадәти, эшнең асылын, үзенчәлекләрен исәпкә алмаган; берьяклы. *Син мәсьәләне механик рәвештә чишәсең.* Ш.Камал. *Гамьсез куллар белән механик рәвештә язылган һәм язылачак мондый характеристикалар архивларда сакланыр, һәм миңа шул характеристикалар буенча бәя биреп ялгышырлар.* Т.Миңнуллин

7) *күч.* Уйлап тормастан, автоматик рәвештә башкарылган. *«Тагын нинди хаталарыгыз булды?» – дигән сорауга --- [С.Атнагулов] тәрҗемә иткәндә сүзгә-сүз, механик рәвештә тәрҗемә итүен, татар телен рус сүзләре белән чуарлап, аны бозуын күрсәтә.* Р.Мостафин. *Беркем дә ата-бабалары кылганны механик рәвештә кабатлап кына яшәргә риза түгел, гәрчә ата-бабалардан кадерле мирас калган очракта да!* А.Гыйләҗев. *Материалны кат-кат укып кына булса да үзалдына телдән кабатлау механик кабатлаугa караганда һәрвакыт нәтиҗәлерәк.* Биология: кеше һәм аның сәламәтлеге

МЕХА́НИКА *и. гр.* 1) Физиканың пространствода хәрәкәт итү законнарын һәм хәрәкәтне китереп чыгара торган көчләрне өйрәнә торган тармагы. *Александриянең тарихы механикага нигез салган галим Архимед исеме белән дә бәйле.* М.Мәһдиев. *Механика буенча хезмәтләрне үзләштерү өчен, ул [Уатт] немец телен өйрәнә ---.* Кызыклар дөньясында. *Физикада, мәсәлән, теоретик механика, молекуляр физика, төш физикасы, плазма физикасы һ.б. кебек бүлекләр аерылып чыкты.* Галәм. Җир. Кеше. *Электр чылбырларындагы үзиндукция күренешләрен механикадагы инертлык күренеше белән чагыштырырга мөмкин.* Физика курсы

2) Техниканың хәрәкәт һәм көчләр турындагы тәгълиматны гамәлдә куллануны өйрәнә торган тармагы. *МТСтан әллә ниткән списанный моторлар, движоклар ташып, бөтен мәктәпне механика цехына әйләндерделәр бит инде.* М.Мәһдиев. *Озын-озак уйламады, тотты да нәни генә механика заводының тимерчелегенә чүкеч сугучы булып керде.* А.Гыйләҗев. *Биремнәр механика белгечлеген үзләштерүче студентлар өчен төзелгән.* Сызма геометрия

3) Берәр җайланманың механик өлеше

4) *күч.* Берәр эшнең сере, асылы, катлаулы ысуллары, методикасы, башкарылу механизмы

МЕХА́НИКАЛАШТЫРУ *ф.* Билгеле бер тармакта эш процессларын механизмнар ярдәмендә үтәүгә күчү, кул хезмәтен машиналар һәм механизмнар эше белән алмаштыру. *Алар пилорамаларның конструкцияләрен бераз үзгәрттеләр: каяндыр тасма транспортёр табып, аның катокларын файдаланып, пилорамалар астына бүрәнәләр бирүне механикалаштырдылар.* М.Хәсәнов. *Нишләтәсең, агай-эне, бөтен нәрсәне механикалаштырып була, ә көтү көтүне...* Т.Миңнуллин. *Хуҗалыкта терлекче хезмәтен җиңеләйтү, механикалаштыру өлкәсендә шактый чаралар күрелә.* Борынгы Калатау итәгендә. *Бу ысул эшләрне күбрәк механикалаштырырга мөмкинлек бирә һәм туфрактан дымның парга әверелүен шактый киметә.* Яшелчәчелек

Механикалаштыра башлау Механикалаштыру эшенә керешү

Механикалаштырып бетерү Тулысынча механикалаштыру, барысын да механикалаштыру. *[Иҗат кешесе дигәнебез] Бик четерекле дигән җирләрне механикалаштырып бетерә язды.* Ә.Баян

Механикалаштырып бирү Башка берәү өчен механикалаштыру. *Мин сезнең фермаларны механикалаштырып бирермен.* Т.Миңнуллин

МЕХА́НИКАЛАШТЫРЫЛУ *ф. кайт. юн. к.* **механикалаштыру**. *Фермада тирес түгү, азык өләшү, сугару механикалаштырылган.* Т.Әйди. *Хәзерге вакытта, кәрәз күзәнәкләрендәге чыршынны алу өчен, тулысынча механикалаштырылган технологияләр һәм машиналар системасы эшләнелгән.* Татар балы. *Күп кенә хуҗалыкларда хезмәт процесслары тулысынча диярлек механикалаштырылган ---.* Татарстанда терлекчелек

МЕХА́НИКЛЫК *и.* Механик *(1 мәгъ.)* хезмәте, шөгыле

МЕХАНИ́СТ *и. гр. филос.* Механицизм тарафдары

МЕХАНИ́СТИК *с.* Механицизм карашларына нигезләнгән, механицизм принципларыннан чыгып эшләнгән. *--- тирән белем кирәк. Ул булмаса, язучы сукыр кала; тормыш фактларына беркатлы, схематик, механистик караш белән килә.* М.Җәлил. *Т.һоббс теориясе – механистик материализм.* К.Гыйззәтов. *Алар [соңгы унъеллыклар] физика өлкәсендә метафизик, механистик материализмның, Ньютон материализмының, Кельвин һ.б.лар материализмының чиклэнгәнлеген тулысынча ачып салдылар.* Галәм. Җир. Кеше

МЕХАНИСТЛА́РЧА *рәв.* Механистларга хас булганча, механистлар кебек, механицизм күзлегеннән. *Иске материализмның «тормыш аңны билгели» дигән карашын алып та, шул ук вакытта диалектик материализмның аң үзе дә тормышка тәэсир ясый, дигән карашын онытсак, мәсьәләгә берьяклы – механистларча караган булыр идек.* Г.Нигъмәти

МЕХАНИЦИЗМ *и. гр.* XVII–XVIII гасырларда: табигать һәм җәмгыять үсешен гади механика законнары белән генә, дөньяның төрлелеген бердәй материя кисәкчекләренең механик

хәрәкәте дип кенә аңлаткан философик юнәлеш. *Күрәсез, Маркс һәм Энгельс безне бу мәсьәләдә механицизм һәм педантизмга бирелүдән сакларга тырыштылар, сәнгатьнең үз спецификасы барлыгын һәм моннан аша атлап үтәргә ярамый икәнен әйтә килделәр* ---. Н.Исәнбәт. *Механицизм – әнә шушы антидиалектик фикер йөртүнең чагылышы ул.* К.Гыйззәтов

МЕХАНОТЕРАПИ́Я *и. гр.-гр.* Буыннар, хәрәкәтләнү аппараты авыруларын махсус механик җайланмаларда үтәлгән физик күнегүләр белән дәвалау ысулы

МЕХКОМБИНАТ *и. рус* 1) Хайван тиреләрен эшкәртеп, күрек чыгара торган зур эшханә. *Өченче үткен кыз бик һәйбәтләп кенә мехкомбинатта тире юу цехында өч сменага күчә-күчә эшли һәм --- җитмеш ике тәңкәдән дә ары ала алганы юк* ---. М.Мәһдиев. *Җил мехкомбинат ягыннан иде. Казан күген кара җилпәзә февраль болытлары каплаган* ---. А.Гыйләҗев

2) Күрек эшләнмәләр, гадәттә киемсалым тегә торган эшханә. --- *фатирга күченеп Казан кешесе булып киткәч, кичке эшче яшьләр мәктәбе укытучылары һәм укучылары, җитен комбинаты, мехкомбинат кызлары Фәнистән [Ф.Яруллин] өзелмәделәр.* Марс Шабаев

МЕХЛЫ *с.* 1) Мехы (*1 мәгъ.*) булган. *Син бер-ике айдан кара борынлы, җылы мехлы, җелтер күзле бала табар идең...* М.Мәһдиев. *Биредә мамык басуларыннан елына биш йөз мең тонна «ак алтын» җыеп алына, җимеш бакчалары мул уңыш бирә, Арал диңгезендә балык тотыла, затлы мехлы җәнлекләр үрчетелә, дөнья базарында дан алган каракүл бирүче куйлар асрала.* Р.Вәлиев. *Тиеннәр куе ефәксыман мехлары өчен кыйммәт бәяләнә, кыйммәтле мехлы җәнлек буларак алар әле ау объекты да.* Биология

2) Мех (*2 мәгъ.*) белән җылытылган, мех белән бизәлгән, мех тотылган. *Мехлы кышкы кием*

МЕХСЫЗ *с.* Мехы булмаган, мех куймыйча эшләнгән, мех тотылмаган. *Гадәти дип, үзгә фасон белән тегелгән демисезон пальтосы һәм мехсыз бүреге дә Азатны безнең кебек провинциаллардан аерып тора иде.* А.Тимергалин

МЕХЧЫ *и.* 1) Мех эшләнмәләр, гадәттә кием белән сәүдә итүче. *Атам мехчы булганлыктан, мине мех сәүдәгәре ясамакчы булалар. Аңа да риза түгел.* Г.Камал

2) Мех эшкәртү предприятиесендә эшләүче, мех эшкәртү белгече. *Мәскәүдән ярдәмгә чакырылган профессорга мехчылар исеменнән кайры тун бүләк иттеләр.* А.Гыйләҗев. *Яңа төзелгән Мехчылар клубы опера һәм балет театры карамагына тапшырылган, репетицияләрнең күбесе шунда уза.* Р.Низамиев

МЕЦЕНАТ *и. лат.* Иганә кылучы, химаялек итүче, фән, сәнгать, мәдәният үсешенә финанс ярдәм күрсәтеп яклаучы кеше. *И батырдык инде үзебезнең меценатларны... Шуннан соң безнең хакыбыз бармы инде «безне рус агай кимсетә» дип әйтергә?* М.Мәһдиев. *Татар меценатлары арасында татар типографиясе ачу уе белән янып йөрүчеләр шактый була.* М.Әхмәтҗанов. *Мәхәлләнең меценаты – мәдрәсә хуҗасы Ибраһим Юнысов (Озын Ибрай) белән дә шулай булган.* С.Алишев

МЕЦЕНАТЛЫК *и.* Меценат булу, иганәчелек. *Хосусый кулларда булса да, бу капиталның шактый өлешен милли байлык дип тә әйтергә мөмкин. Моңа бер дәлил – меценатлык.* Р.Фәйзуллин

МЕЦЦО-СОПРА́НО *и. ит. муз.* 1) Вокал сәнгатендә: югарылыгы буенча сопрано белән контральто арасында торган хатын-кыз тавышы. *Тиешле югарылыктагы җыр культурасы булмау сәбәпле, аның өчен ялгыш тавыш булган меццо-сопрано белән җырлаган Кайбицкая Мәскәү дәүләт консерваториясе профессорлары ярдәме белән лирик колоратур сопранога күчерелде.* Х.Туфан. *Зур театрда төп сопрано партияләрен башкара иде [С.И.Друзякина]. Тавышы матур тембрлы булып, лирико-драматик һәм меццо-сопрано партияләрне дә җырлый.* У.Әлмиев. *Тавышыгыз менә дигән меццо-сопрано икән. Нәкъ хорның үзәгенә кирәкле тавыш!* З.Фәйзи

2) Шундый тавышлы җырчы

МЕЩАН *и. рус* **1.** 1) 1917 елга кадәр Россиядә җан башыннан салым түләү, рекрут йөкләмәләре кебек бурычлары булган, вак сәүдәгәрләрдән, һөнәрчеләрдән, хезмәткәрләрдән һ.б.ш. торган катлау вәкиле. *Татар мәгърифәтенә азмы-күпме өлеш керткән кешеләр – укытучылар, нәшриятчылар, галимнәр! Алар арасында мещаннар, сәүдәгәрләр юк.* Ж.Фәйзи. *Татар купецлары, мещаннар трактирга күңел ачарга киләләр, сыра эчәләр, чөгә балыгыннан пешерелгән солянка яраталар, ди ул [К.Фукс].* М.Гали. *Ә мещаннар һәм гади шәһәр халкы исә иң аскы рәтләрдә көнбагыш чиртеп утыра.* Р.Ибраһимов

2) *күч.* Рухи таләпләре булмаган, матди муллыкны өстен куеп, шәхси мәнфәгатьләрен генә уйлап яшәүче кеше. *Авыл руслары белән гөрләшеп, серләшеп яшәп була безгә, әмма Казан мещаннары, обывательләренең бик күбесенең эче чиста түгел шул әле.* М.Мәһдиев. *Бу – мещаннар логикасы. Һәрхәлдә, ижат кешесе өчен бу логика ят булырга тиеш.* Т.Миңнуллин. *Халыкта исә аның гаме юк, ул мещан сазлыгына тулаем баткан, мещаннарча яши һәм фикер йөртә.* Л.Гыйззәтуллина

2. *с. мәгъ.* Тар карашлы, рухи идеалларсыз, көндәлек рухы белән сугарылган. *Төкер черек мещан тормышка, Төкер шуңа, Сәрвәр, Төкер шуңа, Сәрвәр, Көл, Сәрвәр!* М.Җәлил. *Мещан җанның фәлсәфәсе – Кадими фәлсәфә: «Ничек яшәсәң дә яшә, тик Тук һәм рәхәт яшә!»* Р.Фәйзуллин. --- *хисләренең югары булуы сатирикны башка ваемсыз мещан язучыдан аерып тора.* Р.Батулла

МЕЩА́НКА *и. рус* Мещан хатын-кыз. *Ә мин – юлэр, сине үткән көнне, Ал бизәкле күлмәк кигән өчен, «Мещанка» дип көлеп йөдәдем.* М.Җәлил. --- *кызлар аны мещанка дип, ирләр исә аристократка дип йөртәләр.* Ж.Фәйзи. *Нәрсәкәй? Ни дидең? Ни сүз ул мещанка?* Т.Миңнуллин

МЕЩАНЛАНУ *ф.* Әкренләп мещанга әйләнү, вак-тәяк көндәлек мәшәкатькә бату, рухи ярлылану

Мещанланып бару Аз-азлап мещанлану

Мещанлана башлау Мещанлануга табан йөз тоту

Мещанланып китү Кыска вакыт арасында сизелерлек мещанлану

МЕЩАНЛАШУ *ф. к.* **мещанлану**. *Мин – крестьян кызы, үземнең аз гына булса да мещанлаша башлавымны да белəм*. Г.Кутуй

Мещанлашып бару Аз-азлап мещанлашу, торган саен мещанлашу. *Җомагыл, син көннән-көн мещанлашып барасың.* Ф.Сәйфи-Казанлы

Мещанлаша башлау Мещанлашуга табан йөз тоту. *Китап минем бəгыремə үтеп кереп, күңелемне били, тупаслана, мещанлаша башлаган хисларне кузгата.* Т.Миңнуллин

Мещанлашып китү Кыска вакыт эчендə, соңгы вакытта мещанлашу

МЕЩАНЛЫК *и.* Фикер йөртүдə, үз-үзен тотуда, эш итүдə мещаннарга хас психология, карашлар, мещаннарча кыланыш. *Əсəрдə иске карашлар, мещанлык пычраклыклары бик ачык күренə.* Ж.Фəйзи. *--- ул җырда һич тə «төкердем мин бөтен дөньясына, минем үз илем яхшы» дигəн мещанлык фəлсəфəсе юк.* М.Мəһдиев. *Безне ул артта калуда, мещанлык сазлыгына батып, сөрсеп ятуда гаепləдe, чын ир-егетлəрне Алабугада гына табуы хакында кызып-кызып, йөренə-йөренə сөйлəдe.* Т.Галиуллин

МЕЩАННА́РЧА *рəв.* Мещан күзлегеннəн, мещан позициясеннəн, мещаннар кебек. *Əүвəл бик сəлəтле булган кызының мещаннарча яшəү юлына басу җирлекləрен ул гаилəдəн дə, мəктəптəн дə эзлəп карый, ləкин нигезле сəбəпləрен таба алмый.* А.Расих. *Үзең турында гына уйласаң, үзеңне генə кайгыртсаң, ул вакытта, бəлки, җиңел булыр иде, алай гына яшəве – мещаннарча яшəү.* Г.Бəширов. *Тормышны мещаннарча тарайтып һəм ялгыш аңлау фəлсəфəсе ышандырырлык төстə кире кагыла. Бу – Юныс Əминев иҗатының бер юнəлеше* ---. А.Əхмəдуллин

МИ I *и.* 1) Кешедə һəм башка умырткалыларда үзәк нерв системасының баш сөяге куышлыгында һəм умырткада урнашкан бүлеге. *Кешенең баш мие сырлардан тора – алай күбрәк сыя!* Ш.Галиев. *Егетлəр синең миең селкенгəн дип сөйлиләр, дөресме?* М.Юныс. *Баш миендə организмдагы барлык нерв күзəнəкляренең дүрттəн өч өлеше тупланган.* Кызыклар дөньясында

2) Кешенең фикерләү, танып белү, аңлау чарасы буларак əлеге əгъзаның башта урнашкан өлеше

3) *сөйл.* Фикерләү сəлəте, акыл; аң. *Менə шушы михнəт-хəсрəтле оялар Минем мигə тəмле хыяллар коялар.* С.Сүнчəлəй. *Чəмəт кинəт, баш миендəге бер шөребе бушап китеп, урындык өстенə ыргып менде.* Х.Сарьян. *Тел күтəреп əйтер сүзем юк иде. Аның каравы миемне билəп алган уйлар бихисап.* Б.Камалов

◊ **Ми əйлəнү** *к.* **ми кабару**. *Уф-ф!.. Мием əйлəнде... Харап булдык!.. Харап булдык!..* Г.Ибраһимов. **Мигə йөгерү** Башка китү, ми эшчəнлегенə тəэсир итү (гадəттə исерткеч эчемлек тур.). *Кымызның кəефе мигə йөгерде.* Г.Ибраһимов. **Мигə сеңдерү** Отып алу, ныгытып истə калдыру. *Дөрес сөйлиме ул, хаталанамы – яшьлəр барыбер аның сүзен генə ишетə, ул сөйлəгəнне миенə сеңдерə*. М.Маликова. **Мигə сеңү** Онытылмаслык булып истə калу, хəтердə бик нык саклану. **Мие кибү** Аңлау, фикер йөртү, яңалыкны кабул итү сəлəте зəгыйфьлəнү. *Мие кипкəн, күрəсең [Халикъның]. Башы эшləми нəгъləтнең!* Ш.Камал. **Мие күгəрү** *к.* **мие кибү**. *Сезнең миләрегез күгəргəн, Сезгə сугыш сөреме сырышкан.* Ə.Ерикəй. **Миен томалау** Ялган яки ялгыш мəгълүмат белəн фикерне башка якка бору; фикер йөртү сəлəтен бетерү. *Дəүлəт, кешеləрнең миләрен томалау өчен, пропаганда көчləрен тота.* М.Юныс. **Мие сыекланy** *к.* **мие кибү**. *Эх, бу башны, эчə-эчə миләре сыекланып беткəн шул, ни генə бирə алыр икəн бу чибəр хатынга?* З.Кадыйрова. **Мие черегән** Аңгыра, миңгерәү. *Мисез шул, мисез! Мие черемəгəн булса, атаанасының бераз кадерен белгəн булыр иде.* Г.Камал. **Ми кабару** Тавыш, эссе, күп уку, уйлау һ.б.ш.дан ару, нервлар артык киеренкеләнү; миңгерәүлəнү. **Ми кайнау** *к.* **ми кабару**. *Əлифə коелып төште. Теле бəйлəнде, мие кайнады.* М.Маликова. **Ми кату** 1) Уйлау гадəте булмау, уйлау сəлəтен югалту. *Безнең бəхет шунда – миләр таш булып каткалаганчы, фикер йөртə торган заман килде.* Ш.Галиев; 2) Ыгы-зыгы, тавыш, эш күп булу кебекləрдəн ару, баш кату. *Тукта əле, мин аны нигə, кыстый-кыстый, Лəлə янына җибəрəм соң... Эшне отыры боза гына бит инде ул. Ми дə катып бетте инде болар белəн.* М.Фəйзи. *Дөреслекне эзлəп күзлəр тонды, Мием катып бетте, баш катты...* Л.Лерон. **Ми күперү** *к.* **ми кабару**. *Бу бер елда баштан кичкəннəрдəн Ми күперде, йөрəк кабарды.* М.Җəлил. **Ми кызу** *к.* **ми кабару**. *Көтелмəгəн бу күренештəн егетнең мие кызды, башы шаулады.* К.Тинчурин. **Ми төшү** *к.* **ми кузгалу**. **Ми түнү** Аңлау сəлəтен югалту, аңгы-миңге хəлгə килү. *Мие түнде, күз кабаклары салынды, буыннар йомшап камырга əйлəнде.* А.Гыйлəҗев. *Əхлак кодексын кабул иттек. Ə үзебез, ресторанга кереп, ми түнгəнче салабыз.* М.Юныс. *Əлифə: – Мием түнгəн, кеше əйткəн колагыма керə, зиһенемə барып җитми, – дип куйды*. М.Маликова. **Ми черетү** 1) Файдасыз нəрсəлəр укуга, өйрəнүгə вакыт һəм акыл эшчəнлеге сарыф итү. *Флүн китап өстендə күз талдырып, ми черетеп утыра торганнардан түгел, үзе утырган тормыш арбасын такыр юлдан шома гына тəгəрəтү җаен белə* ---. М.Маликова. *Ялкау, əлифне таяк дип белмəүче надан, ləкин бай студентларга «ми черетеп» торуның хаҗəте калмады*. Н.Вахитов; 2) Кирəкмəгəн, буш, мəгънəсез сүз, бəхəсləр белəн туйдыру, җəфалау. *Мəгърифə: – Бигрəк əйбəт, иртə-кич акыл сатып, миеңне черетмəс*. М.Маликова. **Ми черү** Ялыктыргыч, бертөрле шөгыльдəн интегү, тую, баш катып бетү. *– Күпме кешенең мие черегəн инде бу саннар белəн!.. – диде Харис*. М.Маликова

МИ II *и. ит. муз.* Язуда *Е* латин хəрефе белəн билгеләнгəн, төп диатоник до-мажор авазлар рəтенең өченче баскычы булган музыкаль авазларның берсе; шул авазны белдерə торган нота

МИВӘ *и. фар. иск.* Җимеш, җиләк-җимеш. *Ул нəдер кем, зəррə-зəррəкань*

ирер; Зәррә тохым, мивәсе чәндан ирер; Агызы бер, теле ике, җаны юк, Аны белмәгән кешенең наны юк. Табышмак. *Кырымнан, Төркестаннан, чит мәмләкәтләрдән мөселман сәүдәгәрләре әллә никадәр мивә китертәләр.* Г.Исхакый. *Бик тәмле ризыклардыр инде ул мивәләр.* Г.Бәширов

МИГРАНТ *и. лат.* Күчеп киткән (килгән) кеше. *Америкага килгән мигрантка иң беренче итеп инглиз телен өйрәнү шарты куела.* М.Юныс. *Бөек акыл иясе Лев Гумилёв журналист Вл.Суворов белән әңгәмәсендә болай дигән иде: «Мигрантлар, ягъни читтән килгән кешеләр өчен урындагы ландшафтлар һәрвакыт ят була, аларның йөрәгенә якын була алмый ---».* М.Мәһдиев. *Русиядә мигрантлар кылган җинаятьләр барлык хокук бозуларның 3,5 процентын тәшкил итә, аларның да өчтән бере ялган документлар куллануга бәйле.* Мәдәни җомга

МИГРА́ЦИОН *с.* Миграция мәсьәләләре белән бәйле, миграциягә караган. *Бу цикллар матдәләрнең һәм аларда тупланган энергиянең берберсенә күчешле (миграцион) процессларыннан тора.* К.Гыйззәтов. *Татар милләтенең берләшүенә Идел-Урал төбәге татарларының миграцион активлыгы зур йогынты ясый.* Татар милли календаре

МИГРА́ЦИЯ *и. лат. кит.* 1) Халыкның бөтенләйгә, вакытлыча яки сезон белән бәйле рәвештә өлкәдән өлкәгә яки илдән илгә яшәргә күчүе; күчеш, күченеп йөрү. *Авыл җирендәге эшсезлек аркасында шәһәрдә «квалификациясез эшсезләр» катлавы үсә. Бу миграцияне ничек туктатырга?* М.Мәһдиев. *Әлеге миграция хәрәкәтләрендә татарлар актив катнашалар.* Д.Исхаков. *Федераль миграция хезмәте мәгълүматларыннан күренгәнчә, 2010 елда Русия Федерациясенә барлыгы 13,6 миллион кеше күчеп килгән ---.* Мәдәни җомга

2) *биол.* Хайваннар дөньясында тереклек шартлары үзгәрү яки билгеле бер үсеш циклы үтү сәбәпле, терек организмнарның регуляр төстә яки очраклы хәлдә (янгын, ачлык һ.б.ш. белән бәйле) бер урыннан икенче урынга күчү күренеше. *– Курс турысында – эре кошлар. --- истребитель очучысы үзалдына: – Миграция вакыты, шайтан! Җитмәсә, бу яшенле давылы... – дип сукранды.* Ә.Гаффар. *Сөләйман балыкларның миграциясен өйрәнгәндә, бик кызыклы сорауларга туа. Миграциянең мәгънәсе нәрсәдә?* Кызыклы ихтиология. *Миграцияне өйрәнү күп биологик сорауларга җавап бирергә ярдәм итте.* Биология. Хайваннар

3) Бер организмда нинди дә булса күзәнәкләрнең, әгъзаларның бер урыннан икенче урынга күчү күренеше

МИГРА́ЦИЯЛӘҮ *ф. кит.* Күчү, күчеп йөрү; миграция ясау. *Камбалалар туклану өчен генә күчеп йөрмиләр, бәлки уылдык чәчү өчен дә миграциялиләр.* Кызыклы ихтиология

МИГРЕНЬ *и. фр.* Башның бер як яртысында әледән-әле көчле авырту барлыкка килүдән гыйбарәт, сәбәпләре ачыкланып бетмәгән авыру; баш өянәге. *Аның [буквица үләне] белән бавыр һәм бөер авыруларын,--- ревматизмны, подаграны, эпилепсияне, параличларны, мигреньне, баш әйләнүләрне, неврозларны, гипертонияне һәм вируслы гепатитны дәвалыйлар.* Урман аптекасы. *Яшүсмерләрдә травматизм, аденоидлар, гайморит, дерматит, мигрень еш очрый.* Сәламәт яшәү нигезләре

МИГЪМАР *и. гар.* Архитектор. *Иртәгесен мигъмарлар иртә белән чыгып кала корырга тотынгач та күрделәр: ханның үз углы килә.* К.Насыйри. *И олуг хан, син яңа йортлар кордырыр өчен Казан казнасындагы соңгы алтынны түләп, Мәскәүдән мигъмарлар, мөһәндисләр чакырттың.* Р.Батулла

МИГЪМАРИЯТ *и. гар.* Архитектура, мигъмарлык. *Бераздан чират Казанның иң гүзәл мигъмарият корылмаларыннан һәм гыйбадәт йортларыннан булган Кол Шәриф җамигъ мәчетенә дә килеп җитте.* Гасырлар авазы

МИГЪМАРЛЫК *и.* 1) Мигъмар һөнәре, эше; мигъмар булу

2) Архитектура. *Яңарыш чоры мигъмарлыгы*

МИГЪРАҖ *и. гар. дини* Ислам динендә Мөхәммәд пәйгамбәрнең күккә ашу вакыйгасы. *Ник, рәхим Раббым, яраттың ай кебек ямьле мине? Ник минем күзләр матур соң – нәкъ газиз Мигъраҗ төне?* С.Сүнчәләй. *Мигъраҗ көнендә хәзрәти Рәсүл галләйһиссәлам Каф тавының артында бу кошны [Фениксны] күреп сорады.* Х.Мәхмүдов. *Шагыйрьнең «Ана догасы», «Кадер кич», «Мигъраҗ» шигырьләре дә кечкенә укучы күңеленә иман нуры чәчә.* Ф.Ибраһимова

МИ́ДИЯ *и. лат. зоол.* Диңгезнең яр буе зонасында су асты объектларына ябышып зур тупланмалар хасил итә, җимне судан фильтрлап ала торган ике кабырчыклы моллюск. *Бүген Ксения Фёдоровна дөге катнаштырып мидия пешергән булырга тиеш.* М.Юныс. *[Ике капкачлы моллюскларның] Күбесе – промысел объектлары, азык буларак файдаланыла, мәсәлән, устрица, мидия, диңгез тараклыклары.* Татарстанның үсемлекләр һәм хайваннар дөньясы. *Кайбер моллюсклар, мәсәлән, устрица һәм мидияләр, банкалар дип аталган бик эре тупланмалар хасил итәләр.* Биология. Хайваннар

МИЕЛИТ *и. гр. мед.* Нерв күзәнәкләренең үлүе сәбәпле сизүчәнлек кимү яки паралич белән характерлана торган арка мие ялкынсынуы

МИЖАН *с. диал.* Дымлы, чи. *Кулымдагы мижан көлтә бавын Бора-бора уйда югалам.* Ш.Маннур. *Мижан юкә*

МИЗАН *и. гар.* 1) Үлчәү, бизмән. *Иң әүвәл мизанга салып карыйк.* Г.Тукай. *--- гамәл дәфтәрләрен үлчәүче мизан янында өммәтем өчен шәфкать һәм мәрхәмәт таләбендә булырмын.* Ф.Яхин

2) *күч.* Берәр нәрсәгә карата бәяләүле мөнәсәбәт, критерий. *Гомумән, теләсә нинди бер телнең имлясының начар яки яхшы булуы нинди мизан белән үлчәнеп беленә?* Г.Ибраһимов. *Глобаль мизаннан караганда, язмыш адәм баласын өч рәвештә Ватанлы итә: беренчесе – туып үскән Ватан.* А.Хәлим. *Бәллүрдәй саф, чишмә суыдай чиста, йомшак җилдәй ягымлы бу тавышны бәяләргә җир йөзендә мизаннар табылмас.* Сәхнә

МИЗАНСЦЕ́НА *и. фр. театр* Спектакльнең теге яки бу моментында

артистларның, сәхнә җиһазларының урыны, урнашу тәртибе. *Яңа фильм өчен бернинди өстәмә мизансцена да, аһәңнәр дә кирәкми.* А.Хәлим. *Декадага алып барасы репертуар бай, коллектив ныгыганнан-ныгый, мизансценалар ясаганда сәхнә кытлыгы үзен һаман саен ныграк сиздерә.* Р.Низамиев. *Аның спектакльләрендә мизансценалар аз санлы һәм алар монументаль, мәһабәт.* М.Арсланов

МИЗАНТРОП *и. гр. кит.* Кешеләрне яратмый, кешеләрдән читләшә, аралашмый торган кеше

МИЗАНТРО́ПИК *с. кит.* Мизантропиягә нигезләнгән, мизантропия карашларын чагылдырган. *Мизантропик характер*

МИЗАНТРО́ПИЯ *и. гр. кит.* Характерда, дөньяга карашта чагылган, кешеләргә карата тискәре мөнәсәбәт, кешеләрне күралмау, аларга нәфрәт белән карау, читләшү

МИЗАР *и. гар.* Каберлек. *Мизарымнан мин сорармын: Татар бармы? Ала алмасам яхшы җавап, Ах, җылармын!* М.Ниязи

МИЗГЕЛ *и. гар.* 1) Берәр эш-хәл булып үтә, башкарыла торган билгеле вакыт, нәрсәнеңдер үз вакыты. *Мизгел җитсә, боз ятмас.* Әйтем. *Печән өсте! Беренче мәхәббәтем төслерәк гажәеп мизгел!* Ә.Баян

2) *иск.* Елның билгеле чоры; фасыл. *Һәр җимешнең үз мизгеле бар.* Мәкаль. *Яз мизгеле. Көз мизгеле*

3) Бик кыска вакыт арасы, минут, момент. *Кайчак язмышларны озын юллар, еллар түгел, мизгел хәл итә.* Р.Фәйзуллин. *Гомер тирәгемнең һәр яфрагы Вакыт узуларга бик сизгер. Мизгелләре кайчак – тулы гасыр, Гасырлары – тулмас бер мизгел!..* Р.Әхмәтҗан. *Энә генә дип йөргән гамәлнең мизгел эчендә дөягә әверелүе дә ихтимал.* М.Әмирханов

4) Вакыйга, очрак, хәл. *Тынлык өсләренә сузып куйган Үзәк өзгеч нечкә җепләрен Хәтердәге газиз мизгелләрнең Сагыну белән кайый читләрен.* Х.Әюп. *Очрашуның кыска мизгелендә Аерылышу көтмәдем мин, Хәтта үпмәдем мин.* Р.Гаташ. *Тантанада катнашучылар язучының иҗатын, тормыш юлын, турникта кояш ясаганда гомерлек имгәнү алган аянычлы мизгелләрне чагылдырган «Фәнис Яруллин очышлары» дигән фильмның премьерасын карау бәхетенә дә иреште.* Мәгърифәт

5) *диал.* Гадәт. *Мизгел китмәс, чир китәр.* Әйтем

МИЗГЕЛЛӘП *рәв.* Мизгелләр белән, аерым мизгелләргә аерып. *Мизгеллә тә, Тамчылап та җыям, Иң кирәге – рухи туганлык; Ул – күңелең сусаганда кирәк, Ул гына бит иң кодрәтле терәк, Мәхшәрләрдән алып чыгарлык.* М.Әгъләмов. *Синең тарих, синең гомер Исәпләнә мизгеллә. Сине сөрә алмый илдән һичбер нинди каһәр дә...* Р.Зәйдулла

МИЗГЕЛЛЕК *с.* **1.** 1) Бик кыска, бер мизгел генә дәвам иткән. *Мизгеллек тынлыкта иреннәре кипшенеп-катып киттеләр, сүзләре чыкмады.* Ф.Җамалетдинова. *Бер мизгеллек арада артистканың күз карашы, йөз рәвеше, кул-бармаклары, гәүдә торышы – бөтен вөҗүде уйный.* М.Галиев. *Бу кинәт кәефе бозылуы аның мизгеллек кенә «ычкынып алуы» иде, шуңа күрә икенче минутта ул әбекәйгә әле сокланып, әле яратып карый иде инде.* Р.Сибат

2) *күч.* Вакытлыча, кыска гомерле, тиз үтүчән. *Әгәр җиңүне мизгеллек ләззәт итеп кенә карамасаң, вакыт яссылыгындагы көрәш ул җиңелеп җиңә белү кебек фәлсәфи отышлардан да тора...* М.Гали

2. *и. мәгъ.* Фанилык, һәрнәрсәнең вакытлыча булуы. *Аны яшәү белән үлем, мизгеллек белән мәңгелек, яктылык белән караңгылык, вакыт сурәтләре кебек мәңгелек проблемалар борчый...* Г.Бәширов. *Мәңгелек Йортта йөрим... Ялгызлык. Мәгърурлык. Билгесезлек. Чарасызлык. Мизгеллек...* Р.Фәйзуллин

МИЗГЕЛСЕЗ *рәв.* **1.** Вакытлы-вакытсыз, вакыт сайлап тормастан, теләсә кайчан. *Торлаксыз үскән коланмын, Мизгелсез юшап уртлармын, Яралыштан асаумын, Бугалак салсаң, туктамам!* Дастан

2. *с. мәгъ. диал.* Әдәпсез; чаманы белми торган. *Мизгелсез кеше*

МИЗГЕЛСЕЗЛӘНҮ *ф. диал.* Мизгелсезгә (*2 мәгъ.*) әйләнү; тыйнаксызлык, әдәпсезлек күрсәтү. *Азма, энекәш! Биредә алай мизгелсезләнергә ярамый.* Н.Исәнбәт

МИКА́ДО *и. яп.* Япония императорының титулы; әлеге титул иясе. *--- Күп башлы кара елан. Әле дә илләр юлына Мәкерләр корып тора. Бер зур башы аның – Гитлер, Бер башы – Муссолини. Чемберлены бар, Даладье, Бар Микадо япуни.* Х.Туфан

МИКАТ *и. гар.* Дөньяның һәр тарафыннан Мәккәгә хаҗга килүчеләр ихрам хәленә кермичә үтә алмаган территориянең чикләрен белдерә торган махсус урыннарның һәрбере. *Хаҗилар, Мәккәи Мөкәррәмә шәһәренә барып җиткәнче, микат дип атала торган җирләрнең берсендә туктап, мыекларын кыскарталар, тырнакларын кисәләр, тәннәрендәге артык төкләрен кыралар, гадәттәге киемнәрен салалар, аннары госел коенып, ихрам киемнәрен кияләр.* Ә.Максуди

МИКӘН *кис.* Сорау мәгънәсен белдерә. *Кемнәр икән соң без, Ни кылабыз, ничек хәлебез? Ата-бабаларның изге исемен Онытмадык микән әле без?* Х.Әюп. *Әллә ул каз җуйды микән Бергә очкан парын, Без яшьлектә җуйган кебек Җанның газиз ярын?* Н.Акмал. *Чистайны узгач микән, пароходка кулыннан кечкенә генә кыз җитәкләгән бер сукыр утырды.* А.Хәсәнов

МИКӘННИ *кис. сөйл.* «Чынлап та шулаймы икән?» мәгънәсен белдерә. *Козгын дошман кошы микәнни соң: Йөзе кара, бәгъре таштай каты?!* Ф.Гыйзәтуллина. *Таң алдыннан йокы кача – Ул төн кошы микәнни?* Ш.Галиев. *Аңына килә алмас микәнни?! Бөтенләй китте микәнни инде? Ясалма сулыш алдырырга кирәк...* М.Маликова

МИКИ-КИ *иярт.* Кәҗә мекердәвен белдерә. *Кәҗә балаларына дәшкән, ди: – Мики-ки-ки, мики-ки-ки, балакайларым, шырпы кая? Ут төртегез, янсын Бүре, йөзе кара!* Әкият. *Шулчак тагын да гажәпләндерерлек хәл булды, Кәҗә бәтие телгә килде: – Мики-ки, мики-ки, мин синеки, хуҗабикәм, мин синеки-и!* Н.Каштанов

МИКОЗ *и. гр. мед.* Организмга паразит гөмбәләр үтеп кергәнгә барлыкка

килә торган йогышлы тире авыруы. *--- авыру кузгатучы чүпрә гөмбәләре дә бар, мәсәлән, Кандида ыругы гөмбәләре тиредә һәм органнарның лайлалы тышчасында микоз авыруын китереп чыгара.* Татарстанның үсемлекләр һәм хайваннар дөньясы

МИКОЛО́ГИЯ *и. гр. биол.* Гөмбәләрне өйрәнә торган фән. *Суусемнәрне өйрәнә торган фән – альгология, мүкләрне өйрәнә торган фән бриология дип атала. Гөмбәләрне – микология, лишайникларны лихенология өйрәнә.* Татарстанның үсемлекләр һәм хайваннар дөньясы

МИКОРИ́ЗА *и. гр. бот.* Гөмбәлекләрнең югары төзелешле үсемлекләр тамыры белән симбиозы, кушылып үсү күренеше. *Күбесе, [гөмбәләрнең] агач тамырлары белән симбиозга кереп, микориза хасил итәләр.* Ботаника

МИ́КРО- *гр.* 1) Кушма сүзләрдә берәр нәрсәнең бик кечкенә һәм үтә кечкенә күләмен, зурлыгын белдерә торган беренче кисәк (мәс., *микроашлама, микродөнья, микрометеорит*)

2) Кушма сүзләрдә бик вак предметларны, зурлыкларны тикшерү, өйрәнү, үлчәү яки җитештерүгә мөнәсәбәтле булуын белдерә торган беренче кисәк (мәс.: *микроанализ, микроэлектроника, микромодуль*)

3) Сүзнең икенче кисәге булып килгән физик күрсәткечләрне белдергән төп үлчәү берәмлегенең миллионнан бер өлеше (мәс., *микрометр*)

МИКРОАВТО́БУС *и. рус* Аз санлы юлчыларны якын араларга йөртү өчен билгеләнгән зур булмаган автобус. *Эченә ун кешене сыйдырган микроавтобус, Киевтан чыгып, трасса буйлап төньякка таба җилдертә.* Р.Фәйзуллин. *Һава аланыннан килгән микроавтобус безне Андаман диңгезенең чираттагы бер җыйнак бухтасына, ягъни култыгына урнашкан Камал шәһәрчеге читендәге кунакханә ишегалдына китереп куйды.* Р.Мөхәммәдиев. *Шул вакыт зәңгәр төстәге микроавтобус, тузан туздырып, Сөләйләр капка төбендә тукталып калды.* Н.Хәсәнов

МИКРОАШЛАМА *и.* Составында үсемлекләр үзләштерә алырлык формадагы микроэлементлар булган ашлама. *Микроашлама сыйфатында бакыр купоросы $CuSO_4$ $5H_2O$ кулланыла.* Г.Хисамиев. *Микроашламаларда бор, бакыр һәм марганец була, ә туфракта бу матдәләрнең булмавы кайбер яшелчә-үсемлекләрнең торышына начар йогынты ясый.* Яшелчәчелек

МИКРОБ *и. гр.* 1) *к.* **микроорганизм**. *Шартлар авыр, әмма меңнәрчә күгәрек үрнәкләре өйрәнелгән, аларның төрле микробларга каршы активлыгы җентекләп тикшерелгән.* Ш.Рәкыйпов. *Антибиотикларны микроблар һәм микроорганизмнар эшләп чыгара.* Химия фаш итә. *Микроблар белән китларны, секвойя белән бактерияне, умарта кортлары белән диңгез болытларын чагыштырып карагыз!* Химиянең киләчәге

2) *күч.* Начар үрнәк булырлык күренеш, яман гадәт. *Комсызлык кешене сукырайта. Комсызлык микробларын эләктергән бәндә тыела алмый башлый.* М.Юныс. *Иман бар. Кәтрә дә агу белән агуланмаган, әче тоз, бирәнлек ашламасы, мин-минлек микробыннан затсызланмаган саф чишмәләр, якты алкынлы агымсулар, уңдырышлы чемкара туфраклар бар.* А.Хәлим. *Хәзер инде рухи «крепостное право» юридик яктан юкка чыгарылса да, куркаклар канында элекке коллык микроблары мыжлап яши бирә.* В.Юныс

МИКРОБИО́ЛОГ *и.* Микробиология белгече. *Мин – микробиолог, геннар инженерлыгын барлыкка китерүчеләрнең берсе.* Ә.Баян. *Мәгълүм ки, пенициллинны инглиз микробиологы Александр Флеминг (1881–1955) уйлап тапкан.* Кызыклар дөньясында. *1928 елда инглиз микробиологы А.Флеминг беренче булып пенициллның бактерияләр үсешен тоткарларга сәләтле матдә бүлеп чыгаруына игътибар итә һәм бу матдәне пенициллин дип атый.* Татарстанның үсемлекләр һәм хайваннар дөньясы

МИКРОБИОЛО́ГИК *с.* Микробиологиягә караган, микробиология закончалыкларына нигезләнгән. *Узган елдан бирле шактый кыю рәвештә химик өстәмәләр, микробиологик һәм ферментлы кушылмалар файдаланыла башлады.* М.Хәсәнов. *--- эрозия процесслары --- туфрактагы микроорганизмнарның кимүен көчәйтәләр, шуның белән туфракларның микробиологик эшчәнлеген һәм аларның уңдырышлылыгын бик нык түбәнәйтәләр ---.* Күпьеллык үләннәр. *[Эрбет чикләвегенең] Орлыкларыннан алынган май микробиологик тикшеренүләрдә кулланыла.* Татарстанның үсемлекләр һәм хайваннар дөньясы

МИКРОБИОЛО́ГИЯ *и.* Биологиянең бактерия, вирус, суусем, чүпрә, күгәрек гөмбәләре кебек микроорганизмнарны өйрәнә торган бүлеге. *Аның өчен генетика, селекция, биофизика, микробиология фәннәрен үзләштерергә генә кирәк.* Т.Гыйззәт. *Әйе, сөйләү түгел, бу хакта уйланырга да вакыт күп калмаган: барча хыяллар белән бергә, бөтен зиһенен фән – микробиология, микродөнья биләп алган да үз эчендә биләп тоткан икән.* Ә.Баян. *Ботаника – үсемлекләр дөньясын, зоология – хайваннар дөньясын, микробиология гади күз белән генә күреп булмый торган микроскопик хайваннар дөньясын --- өйрәнә.* Дарвинизм нигезләре

МИКРОБЛЫ *с.* 1) Микроблары булган, микроблар белән зарарланган. *Пенсионерны җәйлап кына җибәреп, микроблы кәгазьләр тоткан кулын өч тапкыр сабынлап юып, әле генә кабинетына кергән иде баш редактор, менә сиңа тагын берәү...* М.Галиев

2) Микроблар тарафыннан кузгатыла торган. *Микроблы инфекция*

МИКРОГРА́ФИЯ *и. гр.* Микрофильмга төшерү. *Ул [Р.Гук] үзенең 1667 нче елны чыккан «Микрография, яки Кечкенә предметларны тасвирлау» исемле китабында бу хәлне түбәндәгечә сурәтли ---.* Робинзон эзләреннән

МИКРОДӨНЬЯ *и.* Гади кеше күзе белән күзәтү мөмкин булмаган күренешләр һәм процесслар дөньясы, гадәттән тыш кечкенә зурлыклар белән эш ителә торган дөнья. *Микродөньяның химиклар элек күз салмаган иң тирән катлауларына үтеп керергә туры килде.* Химиянең киләчәге. *Хәзерге табигать белемененең иң мөһим бурычларыннан*

берсе – фундаменталь физик теорияләрне алга таба үстерү, аерым алганда микродөнья күренешләре белән космик процесслар арасындагы бәйләнешләрны ачыклау. Галәм. Җир. Кеше. *Квант механикасы, микродөньядагы, ягъни атомнар һәм молекулалар дөньясындагы күренешләрнең закончалыклары, без турыдан-туры күзәтә ала торган әйберләр дөньясындагы (макродөньядагы) закончалыкларга караганда башкача булуын күрсәтте.* Физика курсы

МИКРОДУЛКЫН *и. физ.* Миллиметрлы, сантиметрлы яки дециметрлы диапазондагы электромагнит дулкын. *Өлкән механик микродулкын белән эшли торган мич кочаклаган.* М.Юныс

МИКРОДУЛКЫНЛЫ *с.* Электромагнит дулкыннар энергиясеннән файдалану нигезендә эшли торган. *Мин моны телевизордан күрсәтелә торган микродулкынлы мичтер дип уйладым.* Г.Афзал. *Беркөнне Җәүһәрнең микродулкынлы мичтә ә дигәнче кабартмалар пешереп алуын күреп, ачуыннан шартлар дәрәҗәгә җитте.* Ф.Яруллин. *Катнашманы эченә май сөртелгән чынаякка күчерәбез һәм максималь көченә (1000 Ватт) көйләнгән микродулкынлы мичкә өч минутка куябыз.* Сөембикә

МИКРОКИСӘКЧӘ *и. физ.* Үтә кечкенә авырлыкка ия кисәкчә (элементар кисәкчә, атом төше, атомнар һ.б.ш). *Физика фәнендә XIX гасыр азагына хәтле «атом – бүленми торган микрокисәкчә» дигән фикер яшәп килә.* К.Гыйззәтов

МИКРОКЛИ́МАТ *и. гр.-гр.* 1) Зур булмаган территориядә (урман чите, кыр һ.б.да) һаваның җир өслегенә якын катламындагы климат. *Микроклимат – әйләнә-тирәдәге һаваның тере организмнарга комплексы йогынты ясый торган төп физик һәм химик факторлары (температура, дымлылык, һаваның химик составы, аның хәрәкәт тизлеге, тузанлылык, ионлашу дәрәҗәсе һ.б.).* Авыл хуҗалыгы электригы белешмәсе. *Үсемлекләр мохиткә, микроклиматка зур йогынты ясый, туфрак ясалуда катнаша, су әйләнешен тәэмин итә.* Биология. *Бу кечкенә пластмасса камерада автоматик рәвештә микроклимат һәм ясалма яктылык булдырыла.* Химиянең киләчәге. --- *караңгы чыршы урманына килеп керсәң, шунда ук салкынча дымлы һаваны сизәсең. Мондагы микроклимат ачыклык микроклиматыннан аерыла.* Татарстанның үсемлекләр һәм хайваннар дөньясы

2) Ябык биналарда яшәү, эшләү өчен комфорт тудыру, тышкы тискәре шартлардан саклау өчен, ясалма рәвештә тәэмин ителә торган климатик шартлар. *Бал корты торагында оптималь микроклимат булдыру – гаиләнең интенсив үсешенең әһәмиятле шарты.* Татар балы

3) *күч.* Бергә яшәгән, эшләгән, тыгыз аралашкан кешеләр даирәсендә урнашкан үзара мөнәсәбәтләр. *Ул – җитәкче кеше, аңа карап микроклимат барлыкка килә.* Ш.Рәкыйпов. *Кеше характеры үз тирәсендә микроклимат тудыра.* Ш.Галиев. --- *гаиләдәге микроклимат, үзара мөнәсәбәт – сәламәтләндерү системасының әһәмиятле элементы.* А.Хаҗиәхмәтов

МИКРОКЛИМА́ТИК *с.* Микроклиматка бәйле булган. *Бинаның микроклиматик үзенчәлекләре*

МИКРОКЛИ́МАТЛЫ *с.* Үзенең аерым микроклиматы булган. *Ә бездән соң килүчеләр тау токымнары арасындагы туңлыкларны эретеп, ул каналларны су белән тутырыр. Алар өстенә үтәкүренмәле түбәләр киереп куяр, микроклиматлы оазислар ясар.* Р.Фәизов

МИКРОКОНФЛИКТ *и. гр.-лат. кит.* Вак конфликт

МИКРОКОНФЛИ́КТЛЫ *с.* Вак конфликтлардан торган; вак-төяк конфликтлар китереп чыгарган. *Конфликтлы, аеруча микроконфликтлы ситуацияләргә юл куймау (кирәк чакта конфликтка керә алу сәләте кебек үк) – мәхәббәтнең психологик культурасында төп нигез ташы.* Тигез гомер итегез!

МИКРОКОСМ *и. гр. кит.* 1) Макрокосмның, җиһанның чагылышы, кечкенә бер үрнәге, символы буларак кеше; кешенең шәхси дөньясы, күңеле, күзаллаулары. *Борынгы грек философиясе вәкиле Демокрит кешене микрогаләм (микрокосм) дип бәяли.* К.Гыйззәтов. *Еш кына инсанның үзен кечкенә бер дөнья – микрокосм рәвешендә күзаллыйлар.* Х.Миңнегулов

2) Микрокисәкчәләр (элементар кисәкчә, атом төше, атомнар һ.б.ш.) дөньясы

МИКРОМЕТЕОРИТ *и.* Бик кечкенә метеорит. *Микрометеоритларга килгәндә исә, 20–25 сантиметр радиуслы мәйданчыкта ике ел вакыт эчендә бер генә кисәкчек тә төшеп утырмавы билгеле.* Галәм. Җир. Кеше

МИКРО́МЕТР *и. гр.-гр. махс.* 1) Төз өслекләрдәге бик кечкенә озынлыкларны контактлы ысул белән үлчәү өчен үтә төгәл корал. *Заводта үзе токарь булып эшләгәч, төгәллекне ярата, ирен дә микрометр белән яшәргә өйрәтеп бетерде инде. Юк, вакчыл, саран димим, төгәллек-пөхтәлек ягыннан әйтәм.* Г.Госман. *Эшне башкару өчен, аналитик үлчәү, микрометр, 0,10 °С бүлемле термометр кулланыла.* Химия технологиясенең процесслары һәм аппаратлары. *Приборлар һәм җиһазлар: аскуймага беркетелгән пыяла цилиндр, микрометр, секундомер, миллиметрлы линейка, шарчыклар.* Газларда һәм сыеклыкларда күчерү күренешләре

2) *физ.* 10^{-6} м.га тигез булган озынлык үлчәү берәмлеге

МИКРОМЕ́ТРИК *с.* Микрометрия ысулы белән башкарылган, шуңа бәйле. *Микрометрик винт төгәл үлчәү приборларында (микрометр, микроскопларда) кулланыла.* Газларда һәм сыеклыкларда күчерү күренешләре

МИКРОМЕТРИ́Я *и. гр.-гр.* Микроскопик җисемнәрнең зурлыкларын лаборатория шартларында махсус окулярлы микрометр ярдәмендә төгәл билгеләү ысулы

МИКРОМОХИТ *и.* Кешенең шәхси тормышы белән бәйле кешеләр, аның якыннары, тар аралашу даирәсе. *Булачак галимнең нинди микромохиттә шәхес булып формалашуын да күзалларга буладыр.* М.Әхмәтҗанов. --- *дуслык һәм ярдәмләшү мөнәсәбәтләре, югары идея – сәяси һәм әхлак*

принциплары – һәр кешегә турыдантуры тәэсир итә торган «микромохит» ул. Ә.Хуҗиәхмәтов

МИКРОН *и. гр.* 1) *иск.* Микрометрның йөздән бер өлешенә тигез озынлык үлчәү берәмлеге. *Заводта энә очы хәтле генә бәләкәй деталь ясаучыларның остарып китә алучылары микронны бармак очлары белән тоярга өйрәнәләр икән.* Б.Рәхимова. *Югары ешлыклы токларны көчәйтүче триодларның нигезе бигрәк тә юка (берничә микрон чамасы гына) була.* Серле кристаллар. *Гадәттә, базаның калынлыгын бик кечкенә итеп ясыйлар. Ул берничә дистә микрон, ягъни тишемнәрнең диффузия юлы озынлыгы белән бер чама була.* Физика

2) *күч.* Бик аз күләм, бер бөртек. *Һәм шунысы хәйран калдыра: шагыйрь чынбарлыктан бер генә микронга тайпылмыйча тудыра шушы шигъри хәзинәләрне.* М.Юныс

МИКРОНЛАП *рәв.* Микроннарга бүлеп, микроннар исәбе белән. *Миллион чакрымлап мин үтәр юл Микронлап алдан салынган.* С.Баттал

МИКРООРГАНИ́ЗМНАР *и. күпл. гр.-лат.* Гади күз белән күреп булмый торган, бактерияләр, зәңгәрсу яшел суүсемнәр, беркүзәнәклеләр кебек бик вак тереклек ияләре. *Химикатлар туфракның биологик активлыгын киметә, кирәкле микроорганизмнарны юк итә, бал кортларын, сайрар кошларны, файдалы бөҗәкләрне, суалчаннарны кыра ---.* М.Хәсәнов. *Меңнәрчә төрле химик реакцияләрне безнең өчен хәзергә микроорганизмнар башкара, әмма киләчәктә алар эше белән идарә итәргә, юнәлеш биреп торырга өйрәнәчәкбез.* Химиянең киләчәге. *--- иң чиста кулларның да һәр квадрат сантиметрында 100 әр микроорганизм торып кала.* Кызыклар дөньясында

МИКРОПРОЦЕСС *и. гр.-лат.* Микрокосмда барган процесс. *Фән һәм атом дөньясына, микропроцесслар дөньясына үтеп кергәч, ул күп санлы «сәер», «әкәмәт» күренешләр белән очрашты.* Галәм. Җир. Кеше

МИКРОПРОЦЕ́ССОР *и. гр.-лат.* Бер микросхемадан яки берничә махсус микросхема комплектыннан гыйбарәт процессор. *– Кем син, сүз синтезаторы, ничек сөйләшәсең әле? – Микропроцессор, микро-ЭВМ ярдәмендә...* Г.Хәсәнов

МИКРОРАЙОН *и. гр.-фр.* Шәһәр районының торак йортлар комплексыннан һәм якында урнашкан көндәлек куллану, хезмәт күрсәтү, мәдәният объектларыннан торган берәмлеге. *Кала чите. Яңа микрорайон. Телефоннан дәштең – килдем монда.* Л.Лерон. *Институтка унике мең кешелек микрорайонның проектын төзү эшен тапшырдылар.* М.Маликова. *Хәтта карагларны «җәлеп итәрлек» микрорайоннар да, андагы якынча маршрутлар да күзәтү астына алынды.* Х.Вәлиәхмәтов

МИКРОСКОП *и. гр.-гр.* Гади күзгә күренмәслек вак әйберләрне һәм аларның элементларын зурайтып күрсәтә торган линзалар системасыннан гыйбарәт прибор. *Беренче микроскопны да голландияле уйлап тапкан. Аның исеме – Антони Левенгук.* Кызыклар дөньясында. *Астрономиягә – телескоп, биологиягә микроскоп никадәр зур җиңеллек китерсә, кешелек тарихының серләрен чишүдә археология дә шундый ук роль уйный.* К.Тимбикова. *Микроскопның объективы да, окуляры да берничә линзадан төзелгән катлаулы системадан гыйбарәт; аларның хезмәте – бик яхшы сыйфатлы сурәт булдыру.* Физика курсы

◊ **Микроскоп астына алу** Күзәтү астына алу, тикшерү, кызыксыну. *Бәлки, республика прокуроры минем яшәү рәвешемне микроскоп астына алыр ---.* Р.Мирхәйдәров. **Микроскоп аша карау** Бик җентекләп өйрәнү, ныклап тикшерү. *Безнең сабакташлар арасыннан, Микроскоп аша карасаң да, Табалмассың юньсез кешене.* Ә.Рәшит

МИКРОСКО́ПИК *с.* 1) Микроскоп ярдәмендә башкарыла торган; үтә вак объектларны күзәтү белән бәйле. *Хәзерге көндә галимнәр кулында --- махсус институтлар һәм лабораторияләр, умартачылыкка якын торган гомуми һәм хосусый фәннәрнең биргән мәгълүматлары, камил микроскопик техника, бик нечкә химик анализ ысуллары бар...* Умарта кортлары

2) Үтә вак, бик кечкенә, микроскоп аша гына күрү мөмкин булган. *Витаминнар, гормоннар һәм ферментлар кебек куәтле серле матдәләрне табигать --- тере организмнарга тотып булмаслык микроскопик кечкенә өлешләр белән генә саранланып тараткан.* Химиянең киләчәге. *XVII гасырда голландияле Антони ван Левенгук микроскопик организмнар дөньясын күрү һәм өйрәнә башлау мөмкинлеген биргән микроскоп ясаган.* Биология. Хайваннар. *Ләкин микроскопик яктылык дулкыннарының да төшкән һәр әйбергә басым ясауларына ышану кыен ---.* Кызыклы физика

МИКРОСКОПИ́Я *и.* 1) Гади күзгә күренми торган бик вак һәм үтә вак объектларны микроскоп аркылы күзәтү алымнарының гомуми атамасы

2) Микроскопның төзелеше, аны куллану һәм микроскопик препаратлар хәзерләү турындагы гамәли фән

МИКРОСТРУКТУ́РА *и. тех. гр.-лат.* Каты җисемнәрнең микроскоп аша күренә торган төзелеше. *Корычның микроструктурасы*

МИКРОТОПО́НИМ *и. гр.-гр. лингв.* Топонимнарның бер төре булган, гадәттә болын, урман, кое, көтүлек кебек вак объектны белдергән, шул тирәдә яшәүче җирле халыкка гына билгеле атама. *Ялгызлык исеменең төренә карап, антропоним, топоним, гидроним, ороним, ойконим, микротопоним, зооним, космоним һ.б. аерыла.* Г.Галиуллина. *Идел болыны, Идел тугае, Идел урамы һ.б. – микротопонимнар.* Эзләнүләр. Уйланулар. Табышлар

МИКРОТОПОНИ́МИКА *и. лингв.* Топонимиканың микротопонимнарны өйрәнә торган бүлеге. *Микротопонимика теге яки бу төбәктәге урам, тыкрык, чокыр, тау, болын һ.б. төшенчәләрнең атамаларын өйрәнә.* Ф.Сафиуллина

МИКРОТОПОНИ́МИЯ *и. лингв.* Билгеле территориягә караган микротопонимнар. *Мин профессор Гомәр Фәиз улы Саттаров җитәкчелегендә*

«Саба районы авылларының микротопонимиясе» дигән теманы сайладым. Т.Нәҗмиев. *Әлеге фәнни хезмәтнең татар микротопонимиясен дөнья мәйданында таныту өчен зур бер адым булачагына иманым камил.* Шәһри Казан

МИКРОФЛО́РА *и. гр. биол.* Табигый мохиттә (суда, туфракта, һавада, кеше яки хайван организмында һ.б.) тереклек иткән һәртөрле микроорганизмнар. *Туфрактагы микрофлораның югары биологик активлыгы күп кенә туклыклы матдәләрнең туфрак эремәсенә күчүенә ярдәм итә.* Күпьеллык үләннәр

МИКРОФОН *и. гр. тех.* Тавыш тирбәнешләрен электрик тирбәнешләргә әверелдереп, көчәйтеп, билгеле ераклыкка тапшыру өчен хезмәт итә торган прибор. *Аның кулындагы микрофон ниндидер стандарт бер ритм белән дерелди сыман иде.* М.Мәһдиев. *Төрле уеннар, көрәш дәвам итә. Алып баручы микрофоннан чираттагы бәйге башлануын игълан итә ---.* Т.Нәҗмиев. *Көчәнмәгез, зинһар, микрофоннар! Өркеп качып бетте инде сездән изге моңнар...* Л.Шагыйрьҗан

МИКРОФОТОГРА́ФИЯ *и. гр.-гр.* 1) Микроскоп ярдәмендә зурайтылган объектларны фоторәсемгә төшерү

2) Микроскоп ярдәмендә төшереп алынган объектның зурайтылган сурәте

МИКРОХӘРӘКӘТ *и.* Бик кечкенә амплитудалы хәрәкәт, күзгә күренер-күренмәс хәрәкәт. *Бер ноктага текәлгән күзләрдә микрохәрәкәт ясалмыйча калмый.* В.Леви

МИКРОЭЛЕМЕНТЛАР *и. күпл. биол.* Терек организмнарда бик аз микъдарда гына була торган, әмма организм өчен бик кирәк булган химик матдәләр. *Без хәзер үк инде химик ашламалардан файдаланабыз, туфракка микроэлементлар кертәбез, үсемлекләргә үсеш тизләткечләре бирәбез ---.* Химиянең киләчәге. *Ризык белән организм үзенә аксым, май, углевод, биологик актив булган матдәләр – витаминнар һәм микроэлементлар ала.* Малайларга-кызларга: «тәмле» киңәшләр. *Бутонларның чәчәк атмыйча калуы минераль ашлама һәм микроэлементларның җитәрлек булмавыннан һәм яктылык җитмәүдән булырга мөмкин.* Юлдаш

МИ́КСЕР *и. ингл.* 1) *тех.* Домна миченнән агып чыккан сыек чуенны кабул итү сыемы

2) Төзелештә кулланыла торган бетон измәсен болгату җайланмасы; шушы җайланма белән җиһазланган йөк машинасы. *– Мин Чернобыльдә бетон болгаткычта эшләдем ---. Ул «миксер» дип атала, – диде Никитин, тавышын күтәрә төшеп.* Ә.Салах

3) Аш-су әзерләгәндә, төрле сыеклыкларны болгату, туглау, күбеккә күпертү өчен хезмәт итә торган көнкүреш электр приборы. *Чикләвек, он, тоз өстибез, миксер я кашык белән әйбәтләп туглыйбыз.* Малайларга-кызларга: «тәмле» киңәшләр. *Йомырка агын миксер ярдәмендә куе итеп күперт, аз-азлап шикәр комы сала-сала янә күпертеп ал.* Матур буласың килсә…

МИКСТУ́РА *и. лат.* Төрле сыеклыкларны (эремә, төнәтмә һ.б.) кушып яки берәр сыеклыкта берничә каты матдәне эретеп әзерләнгән дару формасы. *[Сары умырзая] үләне төнәтмәсен Бехтерев микстурасын хәзерләүдә файдаланалар.* Урман аптекасы. *Хикәянең геройлары фантастик микстура эчәләр, ул дарунының нерв системасына ясаган тәэсире нәтиҗәсендә, тою органнары бик тиз арада булып алган күренешләрне дә аерым-аерым күрә башлый.* Кызыклы физика

МИКЪДАР *и. гар.* **1.** 1) Нәрсәнең дә булса үлчәнә, санала, азаеп күбәя ала торган үзлеге; үлчәм. *Матди кыйммәтләр беренче дәрәҗәдәге әһәмияткә ия булган чакта, байлык шул кыйммәтләр микъдары белән үлчәнә.* Ә.Баян. *Үсемлек яфраклары бүлеп чыгарган суның микъдарын да билгеләргә мөмкин.* Биология. *Биологик актив матдәләр микъдарына үсемлекнең үсеш стадиясе, аның яше һәм күп кенә башка факторлар зур йогынты ясый.* Урман аптекасы

2) *филос.* Сан, күләм күрсәткече. *Фәлсәфи әдәбиятта, бигрәк тә аерым дәреслекләрдә, үзенчәлелек категориясен микъдарга, санга бәйләнгән аспектта карарга омтылалар.* К.Гыйззәтов. *Микъдар һәм сыйфат үзгәрешләре үзара тыгыз бәйләнгәннәр һәм алар бер-берсен китереп чыгаралар.* Галәм. Җир. Кеше

3) *лингв.* Предметның төгәл санын белдерү белән бәйле категория. *Микъдар саннары контекстта исемләшеп киләләр һәм исемнәр кебек төрләнәләр ---.* Ф.Хисамова. *Микъдар саны урынына җыю саны куллану очраклары еш күзәтелә ---.* Татар халык сөйләшләре

4) *иск.* Күренешнең, вакыйганың гомуми күләме, колач, масштаб. *Бу эш әле, гомум Россия микъдарында алганда да, тиз вакытта гына кирәгенчә күелып җитә алмаячактыр.* Ф.Әмирхан

2. *бәйл. иск.* Хәтле, чаклы, кадәр, тирәсе, чамасы. *Ләкин бу вакытта Әсма тиф хәстәлегенә дучар улып, өч ай микъдары агыр ятты.* Р.Фәхретдин. *– Башкаебызга тегермән ташы микъдар кайгы төште бит – Мирзабызга хулиганнар чәнечкән!.. – диде [Анифә апа].* Х.Сарьян

МИКЪДАРИ *с. гар. иск. кит. к.* **микъдарлы**. *Микъдари үсеш*

МИКЪДАРЛА́П-МИКЪДАРЛАП *рәв.* Аз-азлап, бөртекләп, тамчылап. *Миргазиян ага гомере буе, тәненнән микъдарлап-микъдарлап «исергәплеген» чыгарып, аурупалашырга тырышты.* М.Галиев

МИКЪДАРЛЫ *с.* 1) Берәр нәрсәнең микъдары (*3 мәгъ.*) белән бәйле; санлы күрсәткечләрдә белдерелгән, микъдары күрсәтелгән. *Микъдарлы үзгәрешләр*

2) Билгеле микъдарда булган

МИКЫЛДА́У *ф. диал.* Нык симерү

Микылдап тору Бик симез, таза булып күренү. *Камиләнең кабарган күкрәкләренә, өрелеп торган таза беләкләренә карыйлар да: – Камиләгә кияүгә бару килеште, микылдап тора! – диләр әүвәлге таныш-белешләре.* М.Әмир

МИЛАДИ *и. гар.* Җирнең Кояш тирәли әйләнү циклына нигезләнгән, беренче тапкыр Рим папасы Григорий XIII тарафыннан кертелгән һәм бүгенге көндә бөтен дөньяда кабул ителгән ел исәбе. *Һиҗри белән 573 елда, милади белән 1177 елда җәйнең иң ямьле аенда Казан дәрьясы Олуг Иделгә койган төбәктә Болгар ханы Сәлим моңа*

кадәр ише булмаган Кирмән Кала салырга фәрман бирде. М.Хәбибуллин. *Төркиләрнең бер-берсенә кылыч күтәрергә баш тартуын тарих шулай хәтерли. Шуңа күрә бу гайре табигый вакыйганың төгәл елы да билгеле – милади белән 1183 санә.* Р.Зәйдулла

МИЛӘҮШӘ *и. фар. бот.* **1.** 1) Миләүшәчәләр семьялыгыннан башлыча Төньяк ярымшарның уртача поясында таралган шәмәхә, сирәгрәк – сары яки төрле төсләрдәге чәчәкле күпьеллык үлән яки куак үсемлек. *Өй түрендәге чәчәкнең Аты миләүшә икән шул; Сандугач сайрый дип торам, Дустым сөйләшә икән.* Җыр. *Әле нәни генә күбәләкчекләрне хәтерләткән миләүшәләргә карады, әле ачык тәрәзәгә текәлде кыз.* Р.Мөхәммәдиев. *Кызыл ләлә, зәңгәр ирис, алсу зәңгәр миләүшәләр чәчәк ата.* Дөньяда ниләр бар

2) Кызгылт зәңгәр яки шәмәхә төс. *Төсләр спектрының башка нурлары әфлисун төсле, сары, яшел, күк, зәңгәр һәм миләүшә төсле дугасыман сызыклар хасил итәләр.* Дөньяда ниләр бар

2. *с. мәгъ.* Шәмәхә төстәге. *Анда таулар, комлы сахралар аша Якты кояшның миләүшә нурына Таш каланың стенасы күмелә.* М.Җәлил. *Гаяр больницага барышлый кызгылт, миләүшә һәм ак төстәге өч данә роза чәчәге сатып алган иде, Гөлфирә бүлмәсенә шуларны тотып, елмаеп килеп керде.* Г.Кашапов. *Әйбер ап-ак булып кызганда без, кызыл төстән башлап, миләүшә төскә кадәр тоташ спектр күрәбез.* Физика курсы

МИЛӘҮШӘ́ ГӨЛ *и. бот. к.* **миләүшә** (*1 мәгъ.*). *Урманда үткән елгы яфраклар астыннан миләүшә гөленең тәмле исле кечкенә генә чәчәкләре башларын калкытып киләләр.* С.Җәлал

МИЛӘҮШӘ́СЫМАН *с.* Шәмәхә. *Андый [юеш] урыннарда кәбестәнең яфраклары миләүшәсыман төскә керә, ваклана, баш йомарлау туктала.* Яшелчәчелек

МИЛӘҮШӘ́ЧӘЛӘР *и. күпл.* Бөтен Җир буенча таралган, 900 ләп төрне берләштергән үлән яки куак үсемлекләр семьялыгы. *Миләүшәчәләр семьялыгына (Violaceae) 18 ыруг һәм 850–900 төр керә, алар Җир шарының барлык өлешләрендә, бигрәк тә тропик һәм субтропик өлкәләрендә таралган.* Л.Мәүлүдова. *Салицил кислотасының метил эфиры миләүшәчәләрдән (фиалковые) ала миләүшә (фиалка трёхцветная), каенчалардан (берёзовые) каен (берёза) төрләрендә һәм башка кайбер үсемлекләрнең эфир майлары составында табылган.* Агулы үсемлекләр

МИЛӘШ *и. фин-угор* 1) Гөлчәчәкләләр семьялыгыннан, Төньяк ярымшарның уртача полосасында таралган, аерчалы яки парсыз каурыйсыман яфраклы агач яки биек булып үсә торган куак. *Урманның бер агачы сап-сары, монысы – усак, икенчесе кып-кызыл, анысы – миләш.* М.Мәһдиев. *Өзгәләнмә, миләш, – Булчы якын сердәш Мәхәббәтен көткән кызларга!* Х.Әюп. *Каршыдагы бакчада шомырт һәм миләш агачларында чыпчыклар чыркылдаша* ---. Р.Кәрами

2) Әлеге агачның тәлгәшләр рәвешендә була торган саргылт кызыл төстәге җимешләре. --- *көзнең соңгы күрке булган миләш тәлгәшләре, шушы салкыннарда да ут кебек янып, тирәякка ниндидер бер моңсулык сирпеп торалар.* М.Шабай. *Аннары менә кичә генә укыдым. Миләшнең, шомыртның, баланның файдасын язган.* М.Мәһдиев. --- *Фәрхиягә бирермен, чәчәк урынына булыр, бу агачның миләше аерата тәмле, инде пешкән.* М.Хуҗин. --- *малай чагында җиләк җыйган урман аланнарын, балан белән миләшкә, шомыртка, карлыганга, кыргый чиягә, чикләвеккә йөргән урыннарын караганнар иде.* Г.Ахунов

МИЛӘ́Ш КУАГЫ *и. бот.* Гөлчәчәклеләр семьялыгыннан, пирамида формасындагы себеркәчтәге ак яки ал төсле вак чәчәкле, җимеше татлы куак үсемлек; *русчасы:* **рябинник**

МИЛӘШЛЕ *с.* 1) Миләш агачлары булган, миләш үсеп утырган. *Алардан соң шомыртлы, баланлы, миләшле урман тугае, әрәмәлекләр җәелеп китә.* С.Поварисов. --- *мәче, авызына тычкан капкан көе, тын урамга гажәпләнеп бераз карап торгач, канау аша сикереп, рәшәткә ярыгыннан миләшле бакчага чумды.* Р.Бәшәр

2) Миләш җимеше булган, шуңа бай

МИЛӘШЛЕК *и.* Миләш күп үсә торган урын. *Агыйдел ярлары гөлҗимеш, миләшлек. Дулкыннар ярларга торалар гел дәшеп.* М.Мирза. *Әрсез миләшлек тора-бара авылның мөһере, туграсы булып китте.* Т.Нәбиуллин

МИЛӘШ ТӨСЕ *и.* Саргылт кызыл төс. *Су буендагы әрәмәләр белән урманнар башта саргайды, урыны-урыны белән кызарды, миләш төсенә керде.* Г.Бәширов

МИЛӘШ ЧЫПЧЫГЫ *и. зоол.* Чыпчыксыманнар отрядыннан уртача 25 см зурлыгындагы, Евразия урманнарында тереклек итә торган кош; *русчасы:* **дрозд-рябинник**. *Миләш чыпчыгы! Безнең Җиләкне ник ашыйсың? Түтәлдәге җиләкне Нигә читкә ташыйсың?* Р.Миңнуллин. *Боланның төлке белән, тиеннәрнең кыр куяннары, ә куяннарның миләш чыпчыгы белән уйнаганын күзәткәннәр.* Кызыклар дөньясында. *Миләш чыпчыклары җиләкне бөтен килеш йота, кошның ашказанында аның орлыклары кайнатылмый һәм, шул рәвешле, урман буенча тарала.* Татарстанның үсемлекләр һәм хайваннар дөньясы

МИЛЕК *и. гар.* 1) Бер иянеке булып исәпләнгән һәм тулысынча аның карамагында булган мал-мөлкәт, әйберләр. *Мин кызыкмыйм һич кешенең малы, милке, бәхтенә.* Г.Тукай. *Әледән-әле ялчыларың килеп, бар булдырган малыбызны, хезмәт белән, тир белән тапкан милкебезне талап алып бетерә тордылар.* М.Маликова. *Шәхси милек – шәхесне сынарга лакмус кәгазе.* Ш.Галиев

2) Гомумән байлык, мал-мөлкәт. *Берәүләрне симерткән дә – милек-милек! Берәүне кан төкерткән дә, исерткән дә – милек-милек!* Сирин. *Ә җирдә дөнья яралганнан бирле бөтен тарткалаш милек өчен. Дөнья белән милек идарә итә* ---. Ф.Садриев. *Берәүне дә баетмыйча тик торган милек – үле милек.* Р.Хәкимов

МИЛЕКЛЕ *с.* Байлыгы, мал-мөлкәте булган, хәлле. *Шуның өстенә*

эре җир биләүчеләргә, һөнәр остаханәсе тотучыларга, сәүдәгәрләргә, зур милекле затларга, мал-мөлкәтләреннән чыгып, өстәмә салым төшерелә. М.Әмирханов. *Халыкның бераз гына булса да милли хисләре уянудан, мөстәкыйль дәүләт төзү, милекле булу омтылышыннан файдаланып, һәр акыллы баш үз мәнфәгатен кайгырта, үз урынын ныгытып калырга ашыга.* Р.Шәрәфиев

МИЛЕК-МӨЛКӘТ *җыйм. и.* Төрле мал-мөлкәт. *Инвентарь кенәгәсе буенча мәктәпнең милек-мөлкәтен барлап, тапшыру һәм кабул итү акты төзеделәр.* М.Ибраһимов

МИЛЕКСЕЗ *с.* **1.** Милке, мал-мөлкәте, байлыгы булмаган

2. *рәв. мәгъ.* Мал-мөлкәтсез хәлдә. *Әмма ни хикмәт: хезмәт кешесе тагын милексез калды.* С.Зыялы. *--- алар --- башка илләр һәм регионнарда сугышлар алып бардылар, миллионлаган кешеләрне үтерделәр, имгәттеләр, тораксыз, милексез калдырдылар, үксез балаларны рәнҗеттеләр.* К.Гыйззәтов

МИЛЕКТӘШ *и.* Кем белән дә булса бер үк милеккә ия булган зат; уртак. *«Нәфис» ширкәтләр төркеменең милектәше Ирек Богуславский билгеләп үткәнчә, гомуми мәйданы ике га булган күңел ачу мәйданчыгы күпләп шуу һәм балалар командалары арасында ярышлар үткәрү зоналарына бүленгән.* Шәһри Казан

МИЛЕКЧЕ *и.* 1) Нинди дә булса милеккә ия булган зат; хосусый милек хуҗасы. *Татарстанның һәр кешесе милекче булырга тиеш.* М.Галиев. *300 меңнән артык милекче, үзләренең конституцион хокукыннан файдаланып, үз җирләрен арендага бирү турында договорлар төзеде һ.б.* Я.Шәфыйков. *Шулай ук якын араларда идарәче компанияләр җитәкчеләренең торак милекчеләре белән очрашулары да узачак.* Шәһри Казан

2) *күч.* Милек булдыру, байлык җыюга артык бирелгән кеше, мал җанлы кеше

МИЛЕКЧЕЛЕК *и.* 1) Милеккә ия булу һәм шуннан тулы файдалану хокукы. *Һавага, суга шәхси милекчелек була алмый.* Ш.Галиев. *Фихте милекчелек проблемасын да үзенчә аңлый.* Т.Гыйззәтов

2) *күч.* Кеше характерында мал җыю хирыслыгы, милек булдыруга артык бирелгәнлек; саранлык. *Элекке авыл агаенда хосусый милекчелек хисе тирән тамыр җәйгән, кирелек белән йомыклык та җитәрлек.* Г.Бәширов. *Эш нәкъ менә шунда – милекчелектә! Һәм моны бер дә оялмыйча әйтергә кирәк.* Х.Әшрәфҗанов. *Ниндидер бер акыл иясе: «Адәм баласының күңелендә хосусый милекчелек хисен дөрләтим дисәң, аңа ашъяулык кадәр генә булса да җир бирергә кирәк», – дигән, имеш.* Ш.Маннапов

МИЛИТАР *с. к.* **милитаристик**. *Рәсәй әкренләп сугыш бәрабәренә көн күрүче, ганимәт ашап яшәүче милитар дәүләткә әверелә.* М.Юныс. *Бәлкем, бу – кемнәрнеңдер милитар менталитеты, яшәү мәгънәседер, ләкин без үзебез ни эшләр кылабыз, бу сугыш афәтләрен үткән изге җаннар рухы өчен ниләр эшлибез соң ---?* Ватаным Татарстан

МИЛИТАРИЗА́ЦИЯ *и. лат.* Дәүләтнең икътисади һәм иҗтимагый тормышын сугышка әзерләнү максатларына буйсындыру һәм нәтиҗәдә хәрби оештыру алымнарын тыныч хуҗалык мөнәсәбәтләре өлкәсенә күчерү күренеше. *Империя ул – теләсә нинди очракта да дошман эзләү, кораллану, милитаризация дигән сүз.* Ватаным Татарстан

МИЛИТАРИЗА́ЦИЯЛӘҮ *ф.* Милитаризация сәясәте үткәрү, милитаризмга йөз тоту. *Ил икътисадын янә милитаризацияләү белән берраттан, идарә итү тезгенен хокук саклау органнары кулына тоттыру дәүләт тарихындагы алтмыш-җитмеш еллык вакыйгаларны хәтерләтә.* Кызыл таң. *Дәүләтне милитаризацияләү*

МИЛИТАРИЗМ *и. лат.* Дәүләтнең хакимияттәге даирәләре тарафыннан илнең хәрби куәтен арттыру өчен үткәрелә торган сәяси, икътисади һәм идеологик чаралар системасы. *Милитаризм һәм сугыш көчләрен авызлыклау, ныклы тынычлык һәм ышанычлы иминлек тәэмин итү – хәзерге заманның төп проблемасы.* Казан утлары

МИЛИТАРИСТ *и. лат.* Милитаризм яклы кеше, милитаризм сәясәтен үткәрүче. *Финляндия чигендә хәрби провокация оештыручы Англия һәм Франция милитаристларына карата (бу турыда һәр рәсми хәбәргә ышану шөбһәсез иде) йодрыклар йомарлана, кайнар нәфрәт сүзләре әйтелә.* Т.Гыйззәт. *Япон милитаристлары белән сугыш озакка бармады, әмма ул тиз һәм аяусыз булды.* Г.Ахунов. *--- милитаристларның бик котырынган чорында яшибез. Колагыңны зирәк тотмасаңмы? Һи-и-и...* М.Мәһдиев

МИЛИТАРИ́СТИК *с.* Милитаризм сәясәтенә нигезләнгән, милитаризм карашларын чагылдырган. *СССРның --- дөньякүләм мәйдан тоткан, табигать байлыкларын, бигрәк тә нефтьне ифрат күп чыгарып, нигездә шуның хисабына милитаристик державага әверелгән чагы.* Р.Фәйзуллин. *Чечен сугышында инде менә биш гасыр гамәлгә ашырылып килгән милитаристик сәясәт пыяла линза аша үткән кояш нурларыдай бер ноктага тупланган.* М.Юныс. *Бөек Октябрь социалистик революциясен шатланып каршы ала, Германия хакимнәренең милитаристик позицияләрен тәнкыйтьләгән өчен, төрмәгә утыртыла [Ф.Меринг].* К.Гыйззәтов

МИЛИТАРЛАШТЫРУ *ф. к.* **милитаризацияләү**. *Экономиканы милитарлаштыру капиталистик монополияләргә бик зур табыш бирә.* Политэкономия

МИЛИЦИОНЕР *и. лат.* Милиция хезмәткәре. *Милиционер сүз катмады, учак тирәсендә утырган һәммәбезне дә каш астыннан берәм-берәм күздән кичерде.* Г.Тавлин. *Директор абый бүлмәсендә, бәлки, милиционер да көтеп утырадыр.* Г.Нәбиуллин. *Милиционерларның берсе – ач яңаклысы, куе кара кашлы, югары бөтерелгән очлы мыеклысы – каккан казык булып, ишек катына басты.* Ә.Гаффар

МИЛИЦИОНЕРЛЫК *и.* Милиционер хезмәте, вазифасы. *Нигә? Милиционерлык – кечкенә эшмени? Шәһәр җирендә халыкның рәхәт яшәве, дөресен әйткәндә, милиция кулында.* М.Әмир

МИЛИ́ЦИЯ *и. лат. тар.* 1) СССРда һәм 2011 елга кадәр Россия Федерациясендә иҗтимагый тәртип саклау һәм җинаятьчелек белән көрәшү вазифасын башкара торган административ орган. *Халык милициясе оештырыла башлый. Милициягә, эшчеләрдән кала, студентлар, гимназия укучылары һәм күпмедер санда шәкертләр языла.* И.Нуруллин. *Милициядә эшләүче егетләр арасында керәшен егетләре байтак кына – азанның кайчан әйтеләсен алар белми иде.* М.Мәһдиев

2) *сөйл.* Милиционер; милиция (*1 мәгъ.*) хезмәткәре. *Арча врачлары, милицияләре ниндидер бер тагын да мөһимрәк эш белән Кенәр якларына китеп барганнар икән.* М.Мәһдиев. *Милиция фуражкасын өскәрәк күтәреп куйды. Чәч бөдрәләре җилдә тирбәлеште.* Р.Бәшәр. *Начальницаның як-ягына кобура таккан ике милиция баскан иде.* Я.Шәфыйков

МИЛЛӘТ *и. гар.* 1) Тарихи рәвештә уртак әдәби тел, этник үзенчәлекләр, территория, мәдәният, икътисад формалашып, шуның нигезендә уртак үзаң һәм җәмгыять структурасы барлыкка китереп яшәгән зур тотрыклы бергәлек буларак халык; *русчасы:* **нация**. *Милләтемнең кайгыларын кайгырып, Шатлыгына шатланып җырлап калам ---.* С.Сүнчәләй. *Һәр милләт баласында үз халкы, үз милләте өчен горурлык хисе булырга тиеш.* Ш.Галиев. *--- җир катламнары кебек үк, милләт тә тарихи яктан төрле этник, рухи, мәдәни катламнардан тора.* И.Әмирханов

2) Шәхеснең әлеге берләшмә әгъзасы булуы, шушы халыкка каравы; *русчасы:* **национальность**. *Әйе, кол – интернациональ төшенчә: колның милләте булмый.* Г.Моратов. *Гүзәл кызларның татарлыгы йөзенә үк чыккан. Монда инде, милләтең кем, дип сорап торасы юк.* Ф.Әһлиуллина. *Исеме – Рубен, милләте – испан, Сугышкан ярсып, арыслан кебек. Үзенең туган каласын яклап, Рус егете дошманны кырган.* Ш.Самат

3) Дәүләт, ил. *Берләшкән милләтләр оешмасы. Милләтләр лигасы*

4) Кешеләр, халык. *Милләт йоклый, дип, авыз эченнән мыгырданамыгырдана, Фәрит янына барып аудым.* Р.Вәлиев

5) *күч.* Бер тармакка караган, бер өлкәдә эшчәнлек алып барган кешеләр. *Маржәмыдыр анда, яһүдә... Шагыйрь милләтеннән булгач, барыбер – Барыбер каләм бүген үксеп яшь түгә...* Л.Шагыйрьҗан

МИЛЛӘ́ТАРА *с.* Милләтләр арасындагы мөнәсәбәтләргә караган; төрле милләтләргә карый торган. *Язмыш Татарстаныбызны милләтара сугыштан үзе сакласын.* М.Мәһдиев. *Өлкә советы башкарма комитетының милләтара мөнәсәбәтләр комиссиясе рәисе Дамир Шәрипов белән очрашу да байтак мәсьәләләрне ачыкларга мөмкинлек бирде.* Т.Әйди. *Икетеллелек мәсьәләләрен хәл итүдә, милләтара рус телен өйрәнүне җиңеләйтүдә һәм тизләтүдә тәрҗемәле сүзлекләр бигрәк тә әһәмияткә ия.* Казан утлары

МИЛЛӘТКӘ́ЧӘ *с.* Милләтләр барлыкка килгәнче булган, шул чорга караган. *Милләткәчә әдәби тел*

МИЛЛӘТПӘРВӘР *с. фар.* **1.** Милләтен яратучы, үз милләте өчен тырышучы. *Ләкин җиде йөз меңнән артык әгъзасы булган Латвия халык фронты үзенең милләтпәрвәр фикердәшен кыерсытырга юл куймый: имзалар җыеп, хәрби министр Язовка делегацияләр җибәреп, аны бәла-казалардан йолып кала.* Р.Даутов. *Ә мин – милләтпәрвәр затлардан, Дмитрий. Тарихтагы барлык империяләрнең җимерелү сәбәбе бер дип беләм: ул – милләтләр язмышына битарафлык.* З.Фәтхетдинов. *Хәбибрахман ага үзе дә күренекле мәгърифәтче һәм мөгаллим гаиләсендә туып үскән, атаклы әдипләр, артистлар, җәмәгать эшлеклеләре белән аралашып яшәгән--- милләтпәрвәр зыялы иде.* Казан утлары

2. *и. мәгъ.* Үз милләтен яратучы кеше, үз милләтенә хезмәт итүче шәхес. *Шул көннән башлап Ирек мәйданына милләтпәрвәрләр белән бер рәткә Садыйк Сираевичның пациентлары да басты.* З.Хөснияр. *Шулай да бүген чын милләтпәрвәр булу өчен мөмкинлекләр бар, дидек.* М.Ибраһимов. *Чын йөрәктән милләт дип сызланган, фидакярләрчә халыкка хезмәт иткән милләтпәрвәр, асылзат, бердәнбер – беренче һәм соңгы казый Мөхлисә Бубыйның тууына быел 140 ел тулды.* Сөембикә

МИЛЛӘТПӘРВӘРЛЕК *и.* Милләткә карата фидакярлек, үз милләтенә хезмәт итү. *Зыялыларның дүртенче сыйфаты – милләтпәрвәрлек.* Ф.Яруллин. *Бу беркетмәләрдә Исхакыйның милләтпәрвәрлеге ап-ачык күренә.* Р.Батулла. *Әдипнең [А.Хәлимнең] төбәгенә һәм якташларына багышланган «Минем Түгәрәк Имәнем» (1999), халык санын алу уңае белән язылган «Яңа сагыш» (2002) кебек китаплары да шул ук көрәш рухы, гаделлекне яклау, милләтпәрвәрлек идеяләре белән сугарылганнар.* Хәзерге татар әдәбияты

МИЛЛӘТСЕЗ *с.* 1) Милли хисләре, милли үзаңы булмаган, миллилеген югалткан. *Балаларын чукындырып, аларга тузга язмаган исемнәр биреп яшәүче милләтсез, җирсез, хәтерсез манкортлар күпме?..* А.Гыйләҗев. *Әдип бюрократлардан, үз телен, борынгы культурасын оныткан милләтсез бәндәләрдән --- ачы көлә, хәзер дә актуаль булып яңыраган фикерләрне кыю итеп әйтә.* Р.Мостафин

2) Бернинди милли үзенчәлеге булмаган; бер милләткә дә карамаган. *Татар дөньясын бүген «уйнаштан туган», милләтсез көйләр, компьютер-композиторлар язган бер көнлек җырлар басып китте.* Р.Вәлиев

МИЛЛӘТСЕЗЛЕК *и.* Милли билгеләре, милли үзенчәлекләре бетү, милли үзаңы булмау күренеше. *Әлбәттә, бүгенге яшьләребезгә заманның төссезлек, нәселсезлек, ырусызлык, милләтсезлек, космополитизм чире йога бара.* Т.Миңнуллин. *Чыннан да, милләтне һәм туган телне юкка чыгаручы иң беренче куркыныч – катнаш никахлар. Алар – татарны милләтсезлеккә һәм телсезлеккә өстерәүче тамгалар.* И.Таһиров. *Туган телем миңа нәкъ анам күк, Тарихларда эзле халкым атам кебек, Туган телсез калу – милләтсезлек, Ә милләтсез калу үлгән Ватан кебек.* Р.Шиһапов

МИЛЛӘТТӘШ *и.* Сөйләм субъекты белән бер милләттән булган

кеше. *Күпме милләттәшләр, чит илгә китмичә, Татарстанның үзендә яшәп тә чит телдә югалганнар.* Ш.Галиев. *Мин, кая гына барсам да, үз милләттәшләремне елдам-кайнар күз карашыннан, тавыш тембрыннан танып алам.* М.Галиев. *Милләттәшләр арасындагы аңгәмәдән туган ләззәтнең асылында нәрсә ята икән?* М.Юныс

МИЛЛӘТЧЕ *и.* **1.** 1) Милләтчелек (*1 мәгъ.*) тарафдары. *Аның артык милләтче булып китүендә әнә шушы ялгышы ятмыймы икән, соңга таба ул – милләт өчен хакыйкать эзләп, УКларга барып, кыйналып кайткан кеше.* Р.Батулла

2) *иск.* Милли азатлык хәрәкәтендә катнашучы, милли бәйсезлекне яклап сугышучы. *Безнең арада чын ихласлы милләтчеләр тиз генә туачак та түгел. Чөнки без – барыбыз да кол, дәрвиш!* Ф.Сәйфи-Казанлы. *Төрек милләтчеләре үзләренең бүгенге юлларын Россия Советлар власте юлы белән бергә күрәләр.* Ф.Әмирхан

3) Милләтпәрвәр, үз милләтен яратучы, патриот. *--- чын милләтче булмасаң, милли дуслык дип йөрүнең бәясе – сукыр бер тиен!* Л.Шагыйрьҗан. *Ул – милләтче түгел, ләкин милләт өчен җан атар.* Р.Низамиев

2. *с. мәгъ.* Милләтчел (*1 мәгъ.*), милләтчелеккә (*1 мәгъ.*) нигезләнгән, милләтчелек сәясәтен алып барган. *Лагерьларда легионнарга туплау эшен эмигрантларның милләтче комитетлары алып барган.* Р.Мостафин

МИЛЛӘТЧЕЛ *с.* **1.** Милләтчелек (*1 мәгъ.*) рухындагы. *Гасырларга сузылган милләтчел сәясәт эзсез калмаган, күрәсең.* Ф.Зариф

2. *рәв. мәгъ.* Милләтчелеккә (*1 мәгъ.*) таянып, милләтчелек (*1 мәгъ.*) күзлегеннән чыгып; милләтчеләргә хас булганча. *Бу да шулай ук милли тел мәсьәләсен буржуача, милләтчел аңлау булып, милли форма сылтавы белән прогрессив эчтәлекне инкяр итүдән гыйбарәт иде.* Г.Халит

МИЛЛӘТЧЕЛЕК *и.* 1) Бер милләтнең башка милләттән өстен була алуын раслый торган тәгълимат һәм идеология. *Әгәр дә без әле идеология томаныннан арынабыз икән, нигә әле милли тойгыны милләтчелеккә әйләндерергә ашыгабыз һәм гаепләп барабыз?* Н.Нәҗми. *--- әгәр җыелыш урысча барганда, без ташлап чыгып китсәк, безгә милләтчелек мөһере сугарлар иде. Аларның бездән аерылып китүләре интернационалистлык санала...* М.Юныс. *Солтангалиевне бер үк вакытта милләтчелектә, пантюркизмда һәм панисламизмда гаепләргә маташу – бөтенләй сафсата.* Казан утлары

2) *иск.* Милли бәйсезлек өчен көрәш хәрәкәте. *Мостафа Кәмал паша хәрәкәте --- чын милли, чын халык хәрәкәтедер. Менә шул хәрәкәт, менә шул төрек милләтчелеге бүген Россия Советлар властена дуслык, кардәшлек кулын суза.* Ф.Әмирхан

МИЛЛЕК *и. диал.* Мунча себеркесе, мунча яфрагы. *Түзә алган хәтле каен миллеге белән сыйпап-сыйпап чабынырга кушканнар.* Х.Сарьян. *Мунча ягуның эчке тәртибен, нечкәлекләрен, миллекләрнең шифасын, хасиятләрен бөтен ваклыкларына тиклем белә ---.* А.Гыйләҗев. *Юл өстендә теге пар каенның сыңары кубарылып, сузылып ята. --- Бер-ике көннән аның миллеген алып бетерделәр ---.* М.Мәһдиев

МИЛЛИ *с. гар.* 1) Милләткә, милләтләргә караган, шуның белән бәйле. *Милли аңны, милли тойгыны уяту бездә бик авыр.* Н.Нәҗми. *Татар һәм башкорт халкы арасында бернинди милли, социаль каршылык юк.* А.Хәлим

2) Аерым бер милләткә генә хас, шуның төп характерлы үзенчәлекләрен чагылдыра торган; шул милләткә караган. *Гореф-гадәтне, милли бәйрәмнәрне сакларга кирәк. Сабантуйларны да матуррак, күңеллерәк уздырырга мөмкин.* Т.Әйди. *Грекларның милли киемнәре бераз гына безнең чуваш халкының милли костюмнарына охшаган.* М.Мәһдиев. *Татарныкын гына түгел, рус һәм украин халкының да традицион милли орнаментларын өйрәнергә туры килде аңар.* Р.Мөхәммәдиев

3) Гомумдәүләт, илкүләм. *Кеш Россиянең милли байлыгы булып исәпләнә.* Кызыклар дөньясында

4) Халыкның милләтен исәпкә алып бүленгән, билгеләнгән, төзелгән, оештырылган. *Милли автономия*

МИ́ЛЛИ- *лат.* Кушма сүзләрнең икенче компонентында аталган төп үлчәү берәмлегенең меңнән бер өлешен белдергән беренче кисәк (мәс., *миллилитр, миллиметр*)

МИЛЛИАМПЕР *и. физ.* Амперның миллионнан бер өлешенә тигез электр агымының көчен үлчәү берәмлеге. *Амперның миллионнан бер өлеше миллиампер (ма) дип атала.* Физика курсы

МИЛЛИАРД *сан фр.* **1.** 1) 1 000 000 000 ның сан һәм микъдар атамасы. *Дүрт ярым миллиард кеше яшәгән планетада ир белән хатын япа-ялгыз иделәр.* М.Юныс. *Дөньяда су юлы белән елына ике миллиард тоннадан артык нефть ташыла.* Казан утлары. *Ә баш мие хәзерге заманның иң яхшы кибернетик машиналарыннан да өстенрәк, аның эчендәге унбиш миллиардка якын нерв күзәнәкләре үтә төгәл җайлашып, иң нәфис эшләрне башкаралар.* Химиянең киләчәге

2) Чиксез күп, бихисап. *Миллиард сорау – үзе Галактика. Җавап – тузан, мескен бер бөҗәк!..* Х.Туфан. *Диңгезнең кургаш суын миллиард бөртеккә әйләндереп, кара сыртын шәфкатьсез рәвештә елтыратып килгән үлем машинасы торпеданы күргән иде.* М.Мәһдиев

2. *и. мәгъ. күпл. сөйл.* **миллиардлар**. Бик зур финанс агымнары, бик зур акча суммалары, зур байлык. *Калач урлап тотылганнар – зинданнарда. Миллиардлар урлаганнар – йөзә данда*. Р.Фәйзуллин. *– Вакланмыйк, җәмәгать. Тиеннәр бүлешмибез ич, сүз миллиардлар хакында бара, – дип тынычландырды үзләрен депутат.* Р.Мөхәммәдиев. *Милләтләрнең язмышын бүгенге көндә биржаларда уйнаучы брокерларның миллиардлары хәл итәчәк.* М.Юныс

МИЛЛИАРДЕР *и. фр.* Акчалата исәпләгәндә бер миллиард һәм аннан да күбрәк акчага, шуңа тиң байлыкка, милеккә ия булган кеше. *Эшкуар да, җилкуар да түгел, Хәерче дә түгел, мескен дә... Миллиардерлар,*

минем хәлдә булса, Яши алмас иде өч көн дә. И.Юзеев. *[Америкада] Миллиардер хәерче каршында уңайсызлык тоймый. Миллиардерның кеременнән муниципаль кирәк-яракка, штат һәм федераль бюджетка кирәк кадәр салым басып калалар.* М.Юныс. *Шунысы гына гаҗәпләндерә: яхшылап тикшермичә, төрле фаразларга таянып кына, аларны [террор актларын] мөселман динендәге гарәп кешеләре оештырган, башында миллиардер Усәммә бән Ләдин тора, дип, АКШ президенты Джордж Буш игълан итте.* М.Әхмәтҗанов

МИЛЛИАРДЛАГАН *сан* Берничә яки әллә ничә миллиард; бихисап, бик күп санда. *Сәүдә флотының күп көче, вакыты, аны эшләтү өчен тотылган акчаның зур өлеше Кораллы Көчләргә эшләүгә --- китеп торды. Миллиардлаган акча!* М.Юныс

МИЛЛИАРДЛАП *сан* **1.** 1) Миллиард чамасы. *Кешелек тарихында 15 меңләп зур сугыш булган. Теркәлгәне генә, диләр тарихчылар. Шуларда 4 миллиардлап кеше һәлак булган*. Г.Хәсәнов

2) Бихисап, чиксез күп

2. *рәв мәгъ*. Миллиардларга бүлеп, миллиард-миллиард итеп, миллиардлар белән. *Кытай кебек, халкы миллиардлап исәпләнгән илләр хасил булды*. Р.Фәйзуллин

МИЛЛИАРДЛА́РЧА *сан* Миллиардлар белән исәпләнгән, әллә ничә миллиард; чиксез күп. *Җир шарында миллиардларча кешеләр алмашынып беткән булыр.* Ш.Галиев

МИЛЛИАРДЛЫ *с.* 1) Миллиард берәмлектән торган, миллиардны үз эченә алган. *Ә Кытайда татар – миллиардлы халык арасында бер бөртек.* Татарстан яшьләре

2) Миллиардлар белән исәпләнә торган; бәясе миллиард сум, доллар яки башка шундый акча берәмлеге тәшкил иткән. *Бу – аның проекты һәм миллионлы, хәтта миллиардлы табыш китерергә тиеш иде.* Ф.Яхин. *Югыйсә миллиардлы акчалар түгеп үткәрелгән кампаниянең әһәмияте өч тиенлек кенә булачак...* Кызыл таң. *Рөстәм Миңнеханов Тәһранда миллиардлы килешү төзеде.* Безнең гәҗит

3) Миллиард сум табыш алып эшли торган. *Утыз ел эчендә миллиардлы зур фирманың җитәкчесе дәрәҗәсенә күтәрелгән кеше ул!* Р.Вәлиев

МИЛЛИВАТТ *и. лат.-ингл. физ.* Ваттның меңнән бер өлешен белдергән үлчәү берәмлеге. *--- электр моторларының егәрлеге бик кечкенә булырга мөмкин. Мәсәлән, сәгать механизмнарын эшләтә торган электр двигательләренең егәрлеге бары 3 милливатт кына була.* Физика курсы

МИЛЛИГРАММ *и. лат.-гр.* Граммның меңнән бер өлешен белдергән авырлык үлчәү берәмлеге. *Бер литр суда 0,01–0,1 миллиграмм нефть булса, ул инде эчәргә яраксыз, аннан чәй дә кайната, аш та пешерә алмыйсың.* М.Зарипов. *Бер чәчәктә 25 миллиграммга кадәр нектар бар, ә бер гектар кырыгган кырында 40 миллионга кадәр чәчәк була.* Робинзон эзләреннән

МИЛЛИГРАММЛАП *рәв.* 1) Миллиграмм исәбе белән; миллиграммнарга бүлеп. *Миллиграммлап кына арту*

2) Бик ваклап, зур төгәллек белән. *Миллиграммлап бүлү*

МИЛЛИГРАММЛЫ *с.* Бер миллиграмм авырлыгындагы; миллиграммнар белән белдерелгән. *Миллиграммлы шкала*

МИЛЛИЛӘШТЕРҮ *ф.* Нәрсәгә дә булса милли төс бирү, милли колорит тудыру; миллилеген арттыру; милли элементлар кертү. *Татар шагыйре В.В.Князев шигырендәге мотивны, үзе әйтмешли, шактый миллиләштерә.* Х.Миңнегулов. *Телебез тәүге асылын җуйган, һәм аның даими кулланучылары кимеп бара, замана белән бергә яңа сүзләр барлыкка килми, үсми, керәшен алфавитында укый-язабыз, динне миллиләштермибез.* Безнең гәҗит

Миллиләштерә башлау Миллиләштерергә керешү

Миллиләштерә төшү Бераз миллиләштерү

Миллиләштереп бетерү Ныклап миллиләштерү

МИЛЛИЛӘШҮ *ф*. Милли булып китү, милли характер алу; миллилек сыйфатлары алу. *Шулай ук шура составы да яңарды яки, шартлы рәвештә әйтсәк, миллиләште.* И.Фәйзрахманов. *Халыкның бер төркеме дөньядагы сәясәтне белмичә, «лидерларның» миллиләшкән уеннарында катнашмыйча, милли тормышта дөнья көтә.* Татар заманы

Миллиләшә бару Торган саен ныграк миллиләшү. *Артык сиздерергә теләмәсәк тә, без дә – әкрен генә миллиләшә бара торган татар баласы, һәм бездә дә милли терәк-таянычларга ихтыяҗ зур лабаса.* Шәһри Казан

Миллиләшә башлау Миллиләшү билгеләре сизелү; миллиләшүгә табан бару. *Ислам университетының миллиләшә башлавын барыбыз да күрәбез.* Безнең гәҗит

Миллиләшеп китү Ниндидер сәбәпләр аркасында, нәрсәдер тәэсирендә миллиләшү, тиз миллиләшү. *Бу исем латышларда да очрый, Балтыйк буе республикалары хәзер бөтенләй миллиләшеп китеп, һәрбер исем-фамилиягә «С» хәрефе өстиләр – Артурс, мәсәлән.* Шәһри Казан

МИЛЛИЛЕК *и.* 1) Кемгә яки нәрсәгә дә булса хас милли үзенчәлек, милли төсмер. *Егерменче гасыр башы әдәби хәрәкәтен өйрәнүдә тарихилык һәм миллилек принципларына таянды [М.Мәһдиев]*. Т.Галиуллин. *Бу – кылкаләм остасының картиналарына зыялылык һәм миллилек хас.* Мәдәни җомга

2) Үз милләтеңне ярату, аның белән горурлану хисе, милли хис, милләтчелек (*1 мәгъ.*). *--- һәр йөз татарның җитмеш-сиксәненең чын миллилек, ягъни чын интернациональлекнең нигезен тәшкил иткән миллилектән «батырларча» арына барып, үзе турында да манкортларча уйларга онытуы – бу система алып килгән иң зур бәлаләрнең берсе.* А.Хәлим

МИЛЛИМЕТР *и.* Метрның меңнән бер өлешенә тигез озынлык үлчәү берәмлеге. *Кавказ таулары елына 12 миллиметр үсә икән.* Ш.Галиев. *Техникада үткәргечнең озынлыгын метрлар белән, аркылы кисем мәйданын квадрат миллиметрлар белән үлчиләр.* Физика курсы

МИЛЛИМЕТРЛАП *рәв.* 1) Миллиметрларга бүлеп, миллиметр үлчәме белән. --- *Бикчәнтәев актёрларга сәхнәдә шулкадәр күп ирек бирә, шул ук вакытта мыскалына кадәр үлчәнгән дөрес мизансценалар кора һәм рольнең һәр адымы миллиметрлап исәпләнгән «рәсемен» ясый.* Сәхнә. *Миллиметрлап үлчәп эш итәргә кирәк, хата җибәрергә ярамый.* Ирек мәйданы

2) Миллиметр чамасы. *Унбиш миллиметрлап ара калдыру*

3) *күч.* Аз-азлап, бик аз итеп. *Сүгү мильләп булса, баштан сыйпау – миллиметрлап.* Х.Туфан

4) *күч.* Бик акрын. *Аннары чират нейрохирургларга җитә: болары берничә сәгать дәвамында, миллиметрлап, кызларның баш мие тукымасын аералар*. Татарстан яшьләре. *Миллиметрлап кына алга бару*

МИЛЛИМЕ́ТРЛЫ *с.* 1) Бер үлчәме билгеле миллиметрга тигез булган, билгеле миллиметр тәшкил иткән. *Шул окруженнедән чыккач, йөз илле ике миллиметрлы тупка төзәүче итеп куйдылар мине.* Ф.Сафин. *1943 елдан Ә.Кәримуллин солдат-автоматчы, разведчик һәм сиксән ике миллиметрлы миномёт наводчигы сыйфатында Ватан сугышы фронтлары буйлап сугышчан юл уза* ---. Казан утлары. --- *черки, үзенең өчәр миллиметрлы кечкенә генә ике антеннасына җылылык бер үк микъдарда килә башлаганчы, гәүдәсенең торышын үзгәртә.* Кызыклы физиология

2) Миллиметрларга бүленгән. *Приборлар һәм җиһазлар – аскуймага беркетелгән пыяла цилиндр, микрометр, секундомер, миллиметрлы линейка, шарчыклар*. Газларда һәм сыеклыкларда күчерү күренешләре

МИЛЛИМЕТРО́ВКА *и. рус сөйл.* Сызымнар сызу өчен, бер квадрат миллиметрга тигез шакмакларга бүленгән кәгазь

МИЛЛИОН *сан фр.* **1.** 1) 1000 000 санын һәм микъдарын белдергән сүз. *Миллион автомашина! Уйлый китсәң хәйран калырлык бит: искән җил кебек уза икән гомер дигән нәрсә!* М.Хәсәнов. *Безгә шул кырык ике миллионны күчереп куйсагыз, сентябрьдә яхшы табыш алачаксыз.* М.Маликова. *Һавада азот шулкадәрле күп, Җир өстенең һәр гектарына ул утыз миллион тонна чамасы туры килә!* Химиянең киләчәге

2) *күч.* Бихисап, чиксез күп; миллионнарча. *Гафу итегез, йөз, мең, миллион кат гафу итегез!* К.Тинчурин. *Кем белә бит алай буласын, мондый очрак миллионга бер туры килә.* М.Маликова. *Хәлим бу тавышны мең, миллион тавыш арасыннан танып алыр иде!* Г.Гыйльманов

2. *и. мәгъ.* **миллионнар**. 1) Зур байлык, бик күп акча. *Мәскәүгә, Петербургка барамы, чит мәмләкәтләргә чыгамы, мескенләнеп мең тәңкә телә-нүче түгел, миллионнар белән эш итүчеләр кирәк.* Т.Миңнуллин. *Инде, ниһаять, уңга-сулга карамыйча, иркенләп сөйләшә, миллионнарны үзләре телә-гәнчә бүлешә алалар.* Р.Мөхәммәдиев. *Хуҗасының кереме миллионнардан торуын белгән хәлдә, үзе ун мең хезмәт хакы алган түрәдә эчке протестның барлыкка килүе табигый.* Татарстан

2) Зур халык массалары, халыкның киң катламнары. --- *командир һәм шагыйрь Хәйретдин Мөҗәйнең героик образы миллионнарның күңелен җылытып, каһарманлыкка чакырып, җыр булып яшәр.* И.Юзеев. *Ул күңеленең алсу чәчәкләрен Миллионнарга өзеп таратты, Ул үзенең илен һәм җырларын Чын ярату белән яратты.* Х.Рахман. *Фашизм, миллионнарның гомерен өзү белән бергә, Фәрит Яруллинның язылмый калган өр-яңа симфонияләрен дә үтерде.* Р.Низамиев

МИЛЛИОНЕР *и. фр.* 1) Байлыгы, милке акчалата исәпләгәндә миллион һәм аннан да күбрәк акча берәмлегенә тигез булган зат. *Революциягә кадәрге Камада пароходлар, баржалар йөрткән миллионер Стахеевлар кешесенең дачасы булган ул.* Җ.Фәйзи. --- *империянең кесәсе дип йөртелгән бу ярминкәгә [Мәкәрҗәгә] һәр елның августында миллионерлардан башлап шәкертләргә чаклы әллә никадәр мөселман килеп тула.* И.Нуруллин. *Кәефе шәп иде миллионерның. Егерме җиде яшьтә үз эшең, үз фирмаң, үз миллионың булу алай ук начар түгел икән.* Г.Гыйльманов

2) Берәр эшчәнлек өлкәсендә югары күрсәткечкә ирешкән: миллион сум табыш алган, миллион тонна күмер чыгарган, очышлары миллион километрга тулган һ.б.ш. зат. *Әйе, бар андый миллионер колхозлар. Минем дә аларда булганым бар* ---. Р.Зәйдулла

МИЛЛИОНЕРЛЫК *и.* Миллионер булу хәле, миллионер дәрәҗәсе. *Хасиятулла бабай --- [үз] колхозын СССР күләмендә иң алдынгы колхозлар сафына, миллионерлык дәрәҗәсенә җиткерү турында уйланып ләззәтләнә иде.* Ш.Камал

МИЛЛИОНЛАГАН *сан* Берничә миллион; миллионнар; чиксез күп сандагы. *Көньякның куе кара күге астындагы кара җир миллионлаган лампа яктысы белән чигелгән иде...* М.Мәһдиев. *Инде хәтсездән көйләнгән мондый багланышлар өзелгәч исә, --- әмирлектә сатып алучысын тапмаган миллионлаган пот мамык, йон, миллионлаган данә каракүл тупланды.* Т.Әйди. --- *социализмның астын өскә әйләндергәч, башка миллионлаган пенсионерлар кебек, карчыгы белән Сәфәргали абзыйның да хәле мөшкелгә әйләнде.* З.Фәйзи

МИЛЛИОНЛАП *сан* **1.** 1) Миллион чамасы. *Язучылар союзы органы саналган «Новый мир» кебек журналлар заманында миллионлап тираж белән чыкса, бүген берничә меңнән артмый...* М.Әхмәтҗанов. – *Егетләр! Быел гына миллионлап акча эшләдек. Болай барса, ел ахырына тагын шулкадәр үк эшли алабыз, – дип, Кабан кушаматлысы әшнәләренә фикерен җиткерде.* И.Сәйфуллин. *Хәзер безнең сафларда, кара исәп белән генә дә, миллионлап кеше санала.* Казан утлары

2) *күч.* Бихисап, чиксез күп. *Чечен, ингуш, татар, карачайлар – «Антихристлар алар», янәсе! – Ә миллионлап сабый, әниләрнең Сиңа дошман иде нәрсәсе?* Х.Туфан. *Миллионлап йолдызлар балкыды, Яктыга иреште күрәчәк...* Ф.Гыйззәтуллина. *Бигрәк тә бездә бүгенге капитализм хәерчеләрне миллионлап тудырып тора.* Т.Миңнуллин

2. *рәв мәгъ.* Миллионнарга бүлеп, миллион-миллион итеп, миллионнар

белән. *Гади халыкны бер капчык бәрәңге урлаган өчен төрмәгә тыгалар, ә миллионлап урлаган түрәләр, шартлы рәвештә берничә елга ирекләреннән мәхрүм ителеп, өлкә губернаторы итеп сайлана.* З.Мәхмүди. *Миллионлап киткән адәм башы: Кем хәбәрсез, Кемдер табылган...* И.Иксанова. *Миллионлап урлаган директорның җәзасызлыгы, ике куян аркасында олыгайган көнендә баланда чөмерүче агайның гаҗизлеге нык тәэсир итте аңа.* И.Сиражи

МИЛЛИОНЛЫ *с.* 1) Миллион берәмлектән торган, миллионны үз эченә алган. *Ил иҗаты күкләренә Йолдыз булып калыктың, Чын улы син, Хәмит ага, Биш миллионлы халыкның.* Х.Туфан. *Без – җиде миллионлы халык, дибез. Кайберәүләре аны егерме миллионга да җиткерә. Бу бит – миф.* А.Гыйләҗев

2) Бәясе миллион сум, доллар яки башка шундый акча берәмлеге тәшкил иткән. *--- бөек рәссамнарның картиналары була. Аларның һәрберсе бик кыйммәт, ә инде барысын бергә санасаң, күп миллионлы хәзинә тәшкил итә.* М.Юныс

3) Миллион сум табыш алып эшли торган. *Аның атасы – авылдан самавырчы малай булып килеп --- егермеутыз ел эчендә миллионлы чәй фирмасының хуҗасы булган Борһанетдин абзый түгелме соң?* Г.Исхакый

4) Миллион кеше яши торган. *Миллионлы шәһәрдә син – миллионнан берем. Юк-юк, бердәнберем!* Ш.Галиев

МИЛЛИОНЛЫК *с.* Миллионга җитәрлек; миллион сумлык. *Эшне тиешенчә оештырсаң, алтын һәм асылташларны көрәп алырга мөмкин – бер генә миллионлык булмас.* З.Фәтхетдинов. *Сафуан кулында 70 миллионлык нефть чыгару корылмалары һәр көнне өч мең тонна нефть бирә.* Х.Туфан. *--- Болгар һәм Биләргә каршы монгол татарларының җавабы кырыс булган, алар, ярты миллионлык гаскәр белән килеп, Болгар һәм Биләрне тезләндергәннәр.* Ф.Бәйрәмова

МИЛЛИО́Н-МИЛЛИОН *сан* **1.** Күп миллионнар. *Миллион-миллион яфрак теле белән Урман җырлый минем җырларым.* Н.Сафина

2. *к.* **миллионлап** (*2 мәгъ.*)

МИЛЛИОННА́РЧА *сан* Миллионнар, әллә ничә миллион; чиксез күп. *Күрәсең, миллионнарча балалар ятим, миллионнарча хатыннар тол калып бәргәләнә-сугыла елады дип, дөньяның асты өскә килмәде, тормыш үз җаена дәвам итте.* М.Хәсәнов. *Күр инде, Татарстан илгә миллионнарча тонна нефть бирә.* А.Гыйләҗев. *Монда миллионнарча комбинацияләр ясарга, исәпсез-хисапсыз вариантлар китереп чыгарырга мөмкин.* Химиянең киләчәге

МИЛЛИОНЫНЧЫ *сан* Тәртибе, чираты буенча миллион урынында булган. *Синең яшьтәшләрең теге дөньяда әллә кайчан инде миллионынчы төшен күреп ята.* Ә.Хәсәнов. *Без дала балаларына Казанда юллар тармы? Белмим, белмим... Мин – Мәскәүнең Миллионынчы татары...* Р.Вәлиев

МИЛЛИЯТ *и. гар.* Миллилек, милли үзенчәлек. *Милли ямь, милли шигырь, җыр, милли моң, милли уен Күп заман яктыртмадылар безгә миллият алар. Бикләнеп сакландылар байтак күңелләрдә алар, Күрми тордык без шуңар шатлык, бәхет, тормыш юлын.* С.Сүнчәләй. *Минем фикеремчә, татар милләтен, татар яшьләрен иламият, миллият юлына чыгару өчен, дөньякүләм илами күтәрелеш кирәк.* И.Әмирханов

МИЛЬ *и. лат.* Аерым илләрнең метрик системаларында төрле күрсәткечкә тигез булган, башлыча диңгез-челектә кулланыла торган ераклык үлчәү берәмлеге. *--- хәтәрле Бискай култыгы артта калды. Без инде Урта диңгезнең дә соңгы мильләрен үтеп барабыз.* М.Юныс. *Элладаның яр буйлары бездән ярты миль ераклыкта гына.* М.Мәһдиев. *Һәм менә без Америка Кушма Штатларыннан бары тик 140 миль ераклыкта гына урнашкан Азатлык утравы Кубада.* Р.Ибраһимов

МИЛЬЛӘП *рәв.* 1) Миль исәбе белән. *Мильләп исәпләү*

2) Микъдар санында белдерелгән миль чамасы

3) *күч.* Күпләп. *Сүгү мильләп булса, баштан сыйпау – миллиметрлап.* Х.Туфан

МИМ I *и. гар.* Гарәп алфавитындагы егерме дүртенче хәрефнең исеме. *Әлифне күрсә, таяк дир, мимне күрсә, чукмар дир.* Әйтем

МИМ II *и. гр.* Пантомима күрсәтүче актёр. *Сәхнәдә – мим, хәрәкәт кенә күрәбез, мим үзе ләм-мим, ә «сүзе» аңлашыла!* Ш.Галиев

МИ́МИК *с.* Мимика белән чагылдырылган, мимикада күренгән, мимика чаралары белән башкарылган. *Йөзгә төрле мимик җыерчыклар җыела башлаган вакыт шул яшькә туры килә.* Э.Фатыйхова

МИ́МИКА *и. гр.* 1) Кешенең күңел кичерешләрен, рухи халәтен чагылдыру формасы булган йөз мускуллары хәрәкәте. *Ана теле шул телдә сөйләшүче милләт кешесенең йөзкыяфәтендәге мимиканы, күз карашын, тавыш үзенчәлеген, җыр-моңын билгели.* М.Галиев. *Ул Муафикъның мимикасыннан берни аңламаган иде...* Р.Зәйдулла. *Мәрьям ошатмады булса кирәк, чибәр йөзенең кырыс мимикасы белән моны бик тиз сиздерде.* М.Вәлиев

2) Хисләрне, рухи халәтне йөз мускуллары хәрәкәте белән чагылдыру сәнгате, актёрлык сәнгатенең мөһим бер өлеше. *Күзләр акайган, кашларга тикле җимерелгән (мимика да эштә, димәк!), куллар да хәрәкәттә.* Ә.Сафиуллин. *Ике партиягә бүленеп, шундый сүзсез, мимика белән генә уйнала торган күренешләрне уйнап карагыз: бер партия уйный, ә икенчесе карап, беренчесенең нәрсә уйнаганын әйтеп тора.* Робинзон эзләреннән

МИМИКРИ́Я *и. англ. биол.* 1) Кайбер хайваннарның һәм үсемлекләрнең, төсе яки формалары белән табигать чолганышыннан аерылып тормас өчен, башка хайваннарга һәм үсемлекләргә охшау күренеше. *Табигатьтә организмнарның тереклек шартларына бик күп төрле җайланмалары була. --- Аларга саклагыч төс һәм мимикрия күренешләре керә.* Биология. *Хәрби киемнең нанобуяу ярдәмендә тирәлеккә охшап калуын (биология фәнендә ул*

мимикрия дип атала) күз алдына китерегез. Ватаным Татарстан

2) *күч.* Тормышта теләсә нинди шартларга яраклашу, ят карашларга, таләпләргә җайлашу күренеше, принципсызлык. *Аңарда [Зөфәрдә] мимикрия, хамелеонлык сыйфатлары бик көчле.* Ф.Хатипов, Р.Сверигин

МИМО́ЗА *и. гр. бот.* 1) Кузаклылар семьялыгына караган, Америка, Азия һәм Африка тропикларында таралган үлән, куак яки агач үсемлек; кайбер төрләренең яфраклары аз гына кагылу белән йомарланып китә. *Химик механизм мускулда гына очрамый. Мимоза чәчәгенең яфраклары бер ачыла, бер ябыла, ерткыч үсемлекләрнең тозаклары ачылып ябыла.* Химиянең киләчәге. *Канлы үләннең мимозаныкы шикелле үзенчәлекләре бар.* Робинзон эзләреннән

2) Сары төстәге себеркәч чәчәкле мәңгеяшел акация төре; кыр кынасы. *Бервакыт, 1984 елның 23 февралендә (Бакый аганың туган көне), мин, язның беренче чәчәкләре – мимоза бәйләме тотып, Бакый агаларга килеп кердем.* Л.Шагыйрьҗан

МИМЫЛДАТУ *ф. сөйл.* 1) Җиңелчә селкетү, хәрәкәтләндерү (тән мускуллары тур.). *Мунча иясе әллә кем түгел, ләүкә астында чуар түшен мимылдатып, арт аякларына чүмәшеп утырган сәйләп күзле бака булган икән лә!* М.Галиев

2) Бер ачып, бер йомып хәрәкәтләндерү, селкетеп тору, метмелдәтү (иреннәр, күзләр тур.). --- *Такмак әйтә апасы ла, Әттә-гидер дүттә-тә. Авызын-күзен мимылдатып Карап утыра әбкәсе.* Җыр. *Фәндилә, иреннәрен мимылдатып, сүзен әйтә алмыйча, беркавым басып торгач, елый-елый такмакларга кереште* ---. Г.Ахунов. *Нурзаһит, дустына күзләрен кысып, кашларын уйнатып, иреннәрен мимылдатып карады, кызма, артыгын бәйләнмә, эшне генә бозасың, янәсе*. М.Маликова

Мимылдатып тору Бераз вакыт дәвамында, даими рәвештә яки шушы моментта мимылдату

МИМЫЛДА́У *ф. сөйл.* 1) Селкенеп, хәрәкәтләнеп тору. *Кысыла төшкән күзләре эчендә йөргән кара алмаларыннан да, вакыт-вакыт мимылдап куйган юка күгелҗем иреннәреннән дә авыр уйларыннан котыласы килгәнлеге әллә кайдан аңлашылса да, сүзне Нурисә башлады: – Районда ни әйткәннәрен дә сорашмыйсың инде, алайса?* Р.Рахман

2) Метмелдәү, бер ачылып, бер йомылып, селкенеп, хәрәкәтләнеп тору (иреннәр, күзләр тур.). *Шул мизгелдә аның көлү, елмаю, җырлау, җылау белми торган калын иреннәре мимылдап селкенеп куя.* Т.Галиуллин

Мимылдап кую Бер мәртәбә яки кисәк кенә мимылдау. *Шулчак Гаяр елмаеп җибәрә, теле кычыткандай, иреннәре мимылдап куя.* Ф.Баттал. *Көлгәндә Валяның өч ияге берьюлы мимылдап селкенеп куя.* Татарстан яшьләре

Мимылдап тору Бераз вакыт дәвамында яки шушы моментта мимылдау. *Рәния, бөтен гәүдәсен катырган тыелгысыз көчнең ташуыннан үз-үзен белештермичә, Минәтнең мимылдап торган көпшәк яңагына сугып җибәрде*. А.Вергазов

МИМЫЛДЫК *с.* Мимылдап (*1 мәгъ.*) торган. *Сәрбиҗамал ирләр күзе төшәрлек мимылдык йомры гәүдәле, ике бите янып, сәламәтлеге ташып торган, җитез һәм кыю хәрәкәтле егерме биш-утыз яшьләр чамасындагы хатын иде.* З.Биишева

МИН (минем, миңа, мине, миннән, миндә) *а.* 1) Беренче затны, ягъни сөйләүченең үзен күрсәтү өчен кулланыла. *...Акчаның ни икәнлеген бик яхшы аңлыйм мин.* Т.Миңнуллин. *Мин ераkта, бик ераkта синнән, Киткән дуслык – кипкән елгадыр.* Ф.Гыйззәтуллина

2) Индивидуумның үз-үзен шәхес буларак билгеләү, атау, шулай ук философик мәгънәдә субъектны белдерү өчен кулланыла. *Кешедә «минеке» дигән тойгы тумыштандыр. Шулай булмый ни, бу дөньяга «мин»ен раслап туган ла ул!* Ш.Галиев. *Кайсыдыр акыл иясе кеше күңелендә ике «мин»нең сугышуы турында әйтеп калдырган бит әле.* Р.Низамиев. *Сүз үзеңнең «мин»ең белән мөнәсәбәттәге иң гади алымнар, үзеңне идарә итүдәге иң төп этәргечләр турында бара.* В.Леви

◊ **Мин сиңа әйтим** *к.* **минсиңайтим**. *Берзаман, мин сиңа әйтим, сыерлар бозаулый, сарыклар бәрәнли башлады, хәйран-тамаша.* М.Хәсәнов. *Кызлар үз иткән егет болай да бер башка үсә ул, мин сиңа әйтим.* Ф.Сафин. **Миннән киткәнче, иясенә житкәнче** Җиренә җиткереп түгел, ә аннан-моннан, өстән-өстән генә, сыйфатсыз гына эшләү турында. **Миңа димәгәе** Үпкәләп, ачуланып, берәр эшкә, хәлгә катнашудан баш тарту, битарафлык мөнәсәбәте белдерү өчен кулланыла. *Ничә көнгә? Ике-өч атнага? Миңа димәгәе, хет ике-өч ел торсын.* М.Насыйбуллин. *Тик кыланып йөрсен шунда. Миңа димәгәе...* Л.Гыймадиева. *Кемем соң ул минем? Теләсә нәрсә сөйләнсен шунда! Миңа димәгәе... Класстагы бер хулиганның сүзләренә исем китте, ди...* А.Гыймадиев. **Миңа дисә** *к.* **миңа димәгәе**. *Ачлыктан үлмәгәе, миңа дисә, шунда бөтенләй кадалып китсен, ди....* Г.Камал. *Ярый, ярый, миңа дисә, бүген үк туй итәргә мин разый... Теләсәгез кайчан булсын.* К.Тинчурин. **Миңа калса** Минем фикеремчә, минем уйлавымча, минемчә. *Миңа калса, баһадир, бүген кичкә таба кирмәнгә кешеләр җибәрергә кирәктер.* М.Хәбибуллин. *Актанаштан ишетеп кайткан әлеге канатлы сүз, миңа калса, тирән мәгънәгә ия.* Р.Миңнуллин

МИ́НА I *и. фр.* 1) Җир өстенә яки тирәнгәрәк күмеп, суга батырып, берәр нәрсәгә ябыштырып куела һәм, билгеле тәэсирдән соң (бәрелү, басым, җылылык, радиосигнал һ.б.ш.), корылган механизмы хәрәкәткә килеп шартлый торган снаряд. *Минага ләккән дә юк, Үлемгә дәшкән дә юк. Баш исән, йөрәк исән, Башкасын әйткән дә юк.* Х.Туфан. *Алар гаскәрләргә юл ярып баралар, елга-инешләрдән сугышчыларны чыгаралар, дошманның мина яшергән кырларын чистарталар.* Г.Ахунов. *Безнең корабль фашист минасына эләкте. Без баттык. Круглар белән котылдык.* М.Мәһдиев

2) Миномёт тубы, миномёттан ату өчен махсус снаряд. *Ул тирәгә миналар сирәк төште. Кыз исән, менә Миша гына...* Ш.Рәкыйпов. *Икебезгә*

тиде берьюлы Бер минаның ике ярчыгы. Берсе калды сержант Фоминда, Икенчесе – минем тәнемдә. М.Кәрим. *Снаряд һәм миналар кыю взвод өстенә дә, шаулы Днепр өстенә дә, безнең төп көчләр тупланган сул як ярга да мул ява.* Г.Тавлин

3) *к.* **торпеда**. *Корабның борынын мина җимереп ташлаганда, егермеләп матрос гигант су тавы астында калды.* М.Мәһдиев

МИ́НА II *и. гр.* Греция, Бабил кебек борынгы дәүләтләрдә авырлык һәм акча берәмлеге. *Борынгы Афинада исә мондый исәп булган: 1 талант 60 минадан, 1 мина 100 драхмадан, 1 драхма 6 оболдан, 1 обол 8 халктан торган*. Ә.Мөхәммәдиев

МИ́НАЛАНУ *ф. төш. юн. к.* **миналау**. *Ялкын сулап торган күк йөзе, төтеннәргә уралган офыклар, тоташтан миналанган кырлар, ут көлтәләре чәчкән мина шартлаулары, сугышчан иптәшләреңнең кыелган җаннары*. Г.Ахунов. *Миналанган җир шикелле шәһәрләр дә: Кайда шартлар?.. Кайчан шартлар?..* Ш.Галиев. *Хата һәм иллюзияләр монда миналанган кырдагы кебек сагалап кына тора, моны бер генә минутка да истән чыгарырга ярамый.* Р.Мирхәйдәров

МИ́НАЛАУ *ф.* Шартлату өчен, мина кору, мина урнаштыру. *Кыю подпольщиклар бер ел эчендә дошманга байтак зарар сала: хәрби эшелоннарны шартлату, күперләрне миналау, немец гаскәрләренең көче һәм хәрәкәте турында партизаннарга хәбәр итү, партизан отряды сафларын тулыландыру һ.б.* Р.Низамиев

Миналап бетерү Тулысынча миналау, миналау эшен төгәлләү

Миналап тору Хәзерге моментта миналау эше белән шөгыльләнү

Миналап чыгу Башыннан ахырынача, бер ягыннан икенче ягына кадәр миналау

МИ́НАЛЫ *с.* Миналанган, миналар куелган. *Дары җиле искән, вәхшәт тулы, Әҗәл көткән ачы сәгатьле, Шигъриятнең Муса үткән юлы – Миналы кыр кебек дәһшәтле.* Г.Афзал. *Теге группа, җиңү дәрте белән алга ыргылып, миналы кырга барып кергән.* М.Мәһдиев

МИ́НАСЫЗ *с.* Миналар куелмаган, миналанмаган

МИ́НАСЫЗЛАНДЫРУ *ф. к.* **минасызлау**

МИ́НАСЫЗЛАУ *ф.* Корылган миналарны зарарсызландырып, җыеп алу, миналанган урынны миналардан арындыру

Минасызлап бетерү Тулысынча минасызлау, минасызлау эшен төгәлләү

Минасызлап тору Хәзерге моментта минасызлау эше белән шөгыльләнү

Минасызлап чыгу Башыннан ахырынача, бер ягыннан икенче ягына кадәр минасызлау

МИ́НА ЧӘЧӘГЕ *и. бот.* Миначәчәклеләр семьялыгыннан культуралы төрләре канәфернекенә охшаш хуш исле чәчәкле үлән яки ярымкуак үсемлек. *Аларның микъдары барыннан да күбрәк әремдә, баллы чәчәктә, яушанда, бабасыр утында, мина чәчәгендә, тузганакта һәм алтынбашта була.* Урман аптекасы. *Мәк, гөлҗимеш, роза (гөлчәчәк), мина чәчәге (вербена), цикорий һәм башка утыз биш төрле сорттагы һәм төрдәге үсемлекләрнең чәчәкләренә умарта кортлары килүне күзәтү әнә шуны күрсәтте.* Умарта кортлары

МИ́НАЧЫ *и.* Миналар куеп, дошманның төрле объектларын шартлату яки миналардан арындыру эшләрен башкаручы белгеч. *Алар [хәрби этләр] санитар булып та, элемтәче булып та, миначы булып та эшлиләр.* Дөньяда ниләр бар

МИНБЕЛӘМЛЕК *и. сөйл. ирон.* Кешенең холкындагы үзенә, үзенең белеменә артык ышанучанлык, кеше фикере белән исәпләшмәү сыйфаты. *Аз белгәндә, минбеләмлек күбрәк була.* Ш.Галиев. *Татарның холкына хас таркаулык, минбеләмлек галәмәтләре дә өскә бәреп чыкты.* М.Галиев

МИНДАЛЬ *и. гр.* **1.** 1) Бадәм куагы. *Әйе, диңгез порты янындагы искиткеч отельләр, чәчәккә күмелгән күпкатлы торак йортлар, миндаль агачлары эчендә утырган виллалар, беренче класслы ресторанлар урнашкан урамнан соң Касбага кергәч югалып каласың.* М.Мәһдиев

2) Бадәм җимеше – чикләвеге. *Миндаль татарча «бадәм» дип әйтелә. Әллә кайдагы җимешләрнең үзебездә исемнәре булган.* Ш.Галиев. *Тырнаклары миндаль чикләвеге рәвешенә китерелеп, кызылга манылган...* М.Маликова. *Чикләвек мае ачык сары төстә, югары сыйфатлы була. Тәм ягыннан ул миндаль маен хәтерләтә.* Робинзон эзләреннән

2. *с. мәгъ.* Бадәм чикләвеге кебек озынча формадагы (күзләр тур.). *Ә менә хәзер, инде күп еллар узгач, ул абыйсы турында бөтенесен дә белә, хәтта чибәр шәфталу йөзле, миндаль күзле бухгалтершаның да язмышы билгеле, ул аны «мадам Баттерфляй» дип тә атаган иде әле.* Р.Мирхәйдәров

МИНДАЛЬЛЕ *с.* Бадәм чикләвеге кушып, шуның нигезендә әзерләнгән. *Миндальле печенье*

МИНДА́ЛЬСЫМАН *с.* Тышкы формасы белән бадәм чикләвегенә охшаш. *Лимфатик төеннәр суалчансыман үсентедә (аппендикста) аеруча күп, аны эчәкнең миндальсыман бизе дип атыйлар.* Биология

МИНЕКЕ *тарт. а.* **1.** Кемнең яки нәрсәнеңдер сөйләүчегә караган булуын белдерә. *Ул арада ике егет көдрәеп кара-каршы килеп басты. – Кыз минеке! – диде Сак.* Р.Батулла. *Кешедә «минеке» дигән тойгы тумыштандыр. Шулай булмый ни, бу дөньяга «мин»ен раслап туган ла ул!* Ш.Галиев

2. *и. мәгъ. сөйл. эвф.* 1) Ирен яки хатынын, сөйгән ярын үз итеп атау сүзе

2) *күпл.* **минекеләр**. Сөйләүченең гаиләсе, балалары, якыннары, туганнары. *– Минекеләр килеп җиттеме анда? – ди.* Т.Миңнуллин

МИНЕ́МЧӘ *рәв.* **1.** 1) Мин әйткәнчә, мин уйлаганча, мин теләгәнчә. *Беренче эш итеп, Тукайны ачып, әлеге шигырьне карадык. Ура! Нәкъ минемчә икән.* Р.Гаташ

2) Мин күрсәткәнчә, мин кушканча, мин өйрәткәнчә; мин эшләгән рәвешле. *Минемчә дә эшлиселәре килми, миннән дә котыла алмыйлар.* Т.Миңнуллин

2. *кер. сүз. функ.* Сөйләүченең үз фикерен, үз мөнәсәбәтен белдереп, үз

тәжрибәсенә таянып сөйләвен белдерә. *Минемчә, каракның юлы, һичшиксез, аэропорт аша узар...* М.Насыйбуллин. *Минемчә, Фазыл, килер шундый бер вакыт, без Казанның тарихи үзәген саклаган килеш, аның барлык матур сыйфатларын чагылдырган мемориал булдырырбыз әле.* Г.Кашапов. *Минемчә, адәм баласын әйдәп баручы көч – аның күңелендә, йөрәгендә кайнаган ялкын, хис.* М.Маликова

МИНЕРАЛ *и. лат.* Җир кабыгы составында булган һәм гадәттә файдалы казылмалар буларак чыгарыла торган, табигый органик булмаган химик матдә. *Музейны 1817 нче елда профессор Броннер оештырып җибәргән, аның минераллар коллекциясе музейга нигез ташы булып яткан иде.* Ж.Тәрҗеманов. *Минералларны һәм кыйммәтле ташларны тикшереп караган галимнәр аларга төсне биниһая вак металл кисәкләре бируен ачтылар.* Кызыклар дөньясында. *Юлда малайлар – бик яхшы минераллар коллекциясе, кызлар кызыклы үсемлекләр гербарие төзиләр.* Робинзон эзләреннән

МИНЕРАЛЛА́У *ф.* Минералларга баету, минераль тозлар белән туендыру. *Туфракны минераллау*

МИНЕРАЛЛАШУ *ф.* Органик матдәләр минералларга әверелү, минераль кушылмалар барлыкка килү. *Уле органик матдәнең биосферадагы биологик әйләнештә катнашмаган бу минераллашу продуктлары тау токымнарына килеп кушыла.* Галәм. Җир. Кеше. *Микроорганизмнар атмосфера азотының органик кушылмаларга әверелүен, туфракта органик матдәләрнең минераллашуын, үсемлек калдыкларыннан туфракның структурасын булдыра торган кушылмаларның барлыкка килүен тәэмин итәләр.* Күпьеллык үләннәр

МИНЕРАЛЛЫ *с.* Составында минераллар булган. *Әгәр төче су запасы Пермь катламнарының өске өлешендә урнашса, аның урта һәм аскырак өлешендә җиңелчә минераллы дәва сулары очрый.* Ватаным Татарстан. *Күргәзмәгә дарулар, минераллы-витаминлы комплекслар, парафармацевтика продукциясе, протез-ортопедия эшләнмәләре, санитария, гигиена, дезинфекция, стерильләштерү кирәк-ярагы, медицина кием-салымы, компрессион бәйләм әйберләр куелган.* Кызыл таң

МИНЕРАЛОГ *и.* Минералогия белгече

МИНЕРАЛО́ГИК *с.* Минералогиягә караган, минералогия белән бәйле. *Балчукларның гранулометрик составы минералогик состав белән тыгыз бәйләнгән.* Төзү материаллары. *Минералогик лаборатория. Минералогик коллекция*

МИНЕРАЛО́ГИЯ *и.* Минералларны өйрәнә торган фән. --- *Ялгышмасам, кристалларны минералогия фәне өйрәнә шикелле. --- Математиканың монда ни катнашы бар?* Ж.Тәрҗеманов. *Борынгы ыруг общинасы вәкилләре туган җирләренең үзенчәлекләре һәм байлыклары турында шактый мәгълуматка, ягъни практик география, ботаника, зоология, минералогия, метеорология һәм табигать турындагы башка белемнәргә ия булганнар.* Галәм. Җир. Кеше. *Саф тимерне Мәскәүдә – СССР Фәннәр академиясенең Минералогия музеенда гына күрергә була.* Дөньяда ниләр бар

МИНЕРАЛЬ *с.* 1) Минераллардан торган. *Сазлы туфракларда клевердагы минераль составның гомуми түбәнәюе күзәтелә.* Күпьеллык үләннәр. *Әгәр промышленность предприятиеләре җир, су, урман, минераль ресурслардан файдаланган өчен түләргә тиеш булсалар, халык байлыгын шул тикле кадерсезләмәсләр иде.* М.Хәсәнов. *Үз җисемнәрен төзү өчен, яшел үсемлекләр углекислый газдан, судан һәм минераль тозлардан төрле-төрле органик матдәләр синтезлыйлар.* Урман аптекасы

2) Минерал(лар) кушылган, составында минерал(лар) булган. *Авыру тигәндә кыргый җанварлар төрле минераль су чыганакларын эзләп табалар һәм эчәләр.* Кызыклар дөньясында

МИНЕРАЛЬЛӘШҮ *ф.* Минераль тозлар белән туену. *Суның гомуми һәм карбонатлы катылыгы билгеләнә, минеральләшү дәрәҗәсе хлоридлар буенча аерым, сульфатлар буенча аерым үлчәнә.* Казан утлары. *Шул ук вакытта әлеге елга суының минеральләшкән булуы да мәгълүм.* Ватаным Татарстан

МИНЁР *и. фр.* 1) *к.* **миначы**. *Немец минёрларыннан үзләре куйган миналарны казытып алыгыз. Безнең гаскәрләргә, танкларга юл ачылсын.* С.Баттал. *Язылмаган законнар буенча беренче булып минёрлар бара.* Г.Ахунов. *Аның белән өч ай буе бер землянкада яшәгән Самойлов минёрлар батальонына җибәрелә.* Р.Низамиев

2) Хәрби корабта торпеда тупларына хезмәт күрсәтүче хәрби белгеч. *Яшьләр сөйли иде, кырык бернең июль-август айларында, диңгез пехотасының минёрлар курсында укыганда сөйлиләр иде.* М.Мәһдиев

МИНЁРЛЫК *и.* Миналар кую һәм аларны зарарсызландыру эше. --- *1701 елның әнә шул көнендә патша Пётр I Указы белән беренче Инженерлык мәктәбе оештырылган, ә аны тәмамлаучылар ул чагындагы Россия армиясенең беренче минёрлык подразделениеләрендә хезмәт итә башлаган.* Туган як. *Минёрлыкка өйрәнү*

МИ́НИ *с. фр.* **1.** Кыска. *Тар балаклы чалбар киеп алдык; Кызлар белән (мини юбкалылар!) Бераз гына твист биеп алдык, Кереп-кереп чыктык ресторанга...* Х.Әюп

2. *и. мәгъ.* Кыска итәк

МИ́НИ- *лат.* Кушма сүзләрдә «кыска» һәм «кечкенә» мәгънәләрендә кулланылган беренче компонент. *Җаннан җанга күчә, куәт ала Минисугыш, минишартлаулар.* Р.Юныс

МИНИАТЮР *с.* 1) Миниатюра (*1, 2 мәгъ.*) сәнгатенә караган. *Ирекле шигырьнең миниатюр бер төренә караган менә бу ике җөмләлек парчада да һичнинди образлы сүз кулланылмаган.* Х.Курбатов. *Гарәп сәнгатендә нәкыш жанры белән бергә төрле миниатюр әйберләр ясау үсеш ала.* К.Гыйззәтов. *«Мәк чәчәге», «Бер генә сәгатькә», «Кем җырлады?», «Без дә солдатлар идек» әсәрләре – сугыш темасын чагылдыруда миниатюр үрнәкләр, диярлек кирәк.* М.Җәләлиева

2) Бик кечкенә зурлыктагы, кечкенә форматлы. *Тәгъзимә Яббаровна ак*

миниатюр ридикюлен ачып, шыртлатып япты, колагындагы алтын алкаларын балкытып баш селкеп алгач, янында басып торган кибет директорына ысылдады ---. Г.Ахунов. *Уылдык чәчәргә барырга җыенган сөләйман балыгын диңгездә тотып алып, сыртына миниатюр ультратавыш генераторы куярга мөмкин.* Кызыклы ихтиология. *Зурлык ягыннан щитлы приборлар миниатюр (иң кечкенә), кече габаритлы, уртача һәм зур габаритлы приборларга бүленәләр.* Авыл хуҗалыгы электригы белешмәсе

3) Кечкенә һәм бик матур, бик нәфис. *Бу бик җыйнак, миниатюр шәһәрдә немец бароннары соңгы вакытларга чаклы аерым дәүләт булып яшәгән, диләр.* Х.Камалов

МИНИАТЮ́РА *и. лат.* 1) *тар.* Китапны яки кулъязманы җанландыру өчен ясалган вак бизәкле төсле рәсем яки бизәкләп язылган баш хәреф. *Мәсәлән, мәшһүр рәссам А.Матисс һәм аның фарсы миниатюраларыннан рухланып иҗат ителгән «Гаилә портреты», «Гарәп кафеханәсе» картиналары шундый үрнәкләрдән.* Мәдәни җомга

2) Кечкенә күләмле, бик нәфис итеп сөяк, ефәк, металл һ.б.ш. өслеккә төшерелгән рәсем

3) Зур булмаган күләмдәге әдәбият, музыка яки театр әсәре. --- *Ерак Көнчыгыш сүз осталарының өч-дүрт юллык миниатюралары... Кешелекнең дөнья кадәр байлыклары бит алар!* Р.Фәйзуллин. *Миниатюралар, монологлар әзерләдем дә «Барс-медиа» компаниясе уздыра торган кастингка бардым.* И.Иксанова. *Бездә хәзер шигырьнең ике юллык миниатюрадан алып романга кадәр төрләре бар.* И.Юзеев

4) *күч.* Нәрсәнең дә булса кечерәйтелгән копиясе; шуның үрнәге, мисалы. *Каршыдагы стенада матур кысалы Репин рәсеме эленгән. Болардан башка тагын миниатюрада бирелгән табигать күренешләре дә күп кенә иде.* Г.Бәширов. *Дәүләтләр күләмендә дипломатия, разведка – хәйләдә, чаялыкта, осталыкта ярышу бара. Кайчакта аерым кешеләр мөнәсәбәтендә шуны миниатюрада күреп торасың.* Ш.Галиев

МИНИАТЮ́РАЧЫ *и.* Миниатюралар ясаучы рәссам яки башка сәнгать остасы

МИНИ-БАР *и. лат.-ингл.* Эчемлекләр кую өчен махсус кечкенә шкаф яки зур шкафның аерым бүлеге. *Сәбилә урынныннан сикереп торды да, стенадагы мини-барны ачып, шампанский шешәсе алды.* Р.Вәлиев. *Өч йолдызлы: номерлар көн дә юыла, һәр номерда да санузел, телевизор, мини-бар яки суыткыч, кунакханә территориясендә бассейн, тренажёр залы, бизнес-үзәк һәм иртәнге аш өчен ашханәсе бар.* Шәһри Казан

МИНИМАЛИЗМ *и. лат.* 1) Модада, архитектурада артык бизәкләрдән, купшылыктан качу стиле, бары тик функциональ структурадан гына тору күренеше. --- *Актёрлар йорты – совет минимализмы стилендәге пыяла һәм бетоннан ясалган аквариум.* Идел. *Шулай ук хәзер интерьерда киң таралган минимализм күренеше дә пәрдәләргә йогынты ясый.* Кәеф ничек?

2) Яшәү рәвешендә, характерда тыйнаклык, таләпләрне иң түбән чиккә төшерү, минимумга калдыру. *Минимализм һәм гадилек яратам.* Идел

МИНИМАЛИСТ *и. лат.* Минимализм тарафдары

МИНИМАЛИ́СТИК *с.* Минимализмга нигезләнгән; минимализм өчен характерлы булган, шуны күрсәтеп торган. *Аның минималистик сәяси стиле гомумилеккә дәгъва итми.* Кызыл таң. *Минималистик интерьер*

МИНИМАЛЬ *с.* Охшаш зурлыклар рәтендә иң азы, иң кечкенәсе; *киресе:* **максималь**. *Минималь хезмәт хакы белән пенсияләр кемнәрнеңдер бер әбәтенә дә тормый бит хәзер.* З.Фәйзи. **---** *электролитлардагы ионнарның корылмалары билгеле бер минималь корылманың бөтен сан тапкыр кабатланышы булалар.* Физика курсы. *Терек организмнарга витаминнар минималь дозаларда гына кирәк.* Робинзон эзләреннән

МИНИМА́РКЕТ *и. лат.-ингл.* Иң кирәкле киң куллану товарлары сатыла торган кечкенә кибет. *Супермаркет, бутик, минимаркет, Субконтинент... Тагын әллә ни... Көнбатыштан кайчан кереп тулды, Чиркандыра, тфү, валлаһи.* Ә.Хәсәнов. *Чумара акчасына яңа минимаркет ачкач, аракы эчүен ташлап, «үлән» иснәргә тотынды.* Х.Ибраһимов

МИ́НИМУМ *и. лат.* **1.** 1) Нәрсәнең дә булса иң кечкенә күрсәткече, иң кечкенә күләм, микъдар; *киресе:* **максимум**. *Дулкыннар когерент булсалар, максимумнар һәм минимумнарның чиратлашу картинасы тотрыклы була.* Физика курсы. *Бер үк функциянең берничә максимумы һәм берничә минимумы булырга мөмкин.* Югары математика нигезләре. --- *фәзада яктылык агымының яңа бүленеше барлыкка килә, һәм нәтиҗәдә бер ноктада – интенсивлыкның максимумы, ә икенче ноктада минимумы була. Бу күренеш дулкыннар интерференциясе дип атала.* Физика

2) Билгеле максатка ирешү өчен үтәлүе тиеш булган иң кирәкле эшләр планы яки төп белемнәр җыелмасы. *Ул шушы институтта укыган, шунда ук эшкә калган, Камил килгәндә, кандидатлык минимумнарын тапшырып бетергән, диссертация язып ята иде.* Х.Сарьян. *Аларның һәркайсы уналтыдан узган инде, так что, устав буенча минимумны тутырырга тиешләр.* Л.Гыйззәтуллина

2. *с. мәгъ.* Иң кечкенә, иң ким. *Аутотренингка багышланган вакыт берәмлегенә алдыгызга минимум бурыч куегыз, шул вакыт арасында куелгаңнан артыгын эшләргә тырышмагыз: монда сездән беркем дә план үтәүне талап итми.* В.Леви. --- *хәрәкәт активлыгының минимум дәрәҗәсе организмны сәламәтлек чигендә генә тота, аңа тренировка эффекты ясамый.* Сәламәтлек нигезләре

3. *рәв. мәгъ.* Иң азы, ким дигәндә. – *Күпме кирәк була инде дисез? – Ике миллион – минимум.* Т.Галиуллин. *Киләсе дәрескә кадәр һәрберегез, ким дигәндә, минимум бер кыз белән танышырга тиеш!* Р.Вәлиев

МИНИСТЕ́РСТВО *и. рус к.* **министрлык**. *Менә министерстводан багаж киләсе, имеш.* М.Мәһдиев. *Мин министерстводан вәкилләр чакырырмын.* Р.Батулла

МИНИСТР *и. фр.* Дәүләт яки регион хөкүмәтендә хезмәт вазифасы башкарган, гадәттә министрлык белән җитәкчелек иткән дәүләт эшлеклесе. *Шундый абруй-дәрәҗәле министр иде Салих Япеев! Аларны сагынырга гына кала...* Марс Шабаев. *Дүрт-биш еллар элек, министр урынбасары булып эшләгән чагында, Тимерхан Борһанов Вәрәшбашка машина белән кайткан иде.* Г.Ахунов. *Бу хатын Петербург зыялылары нәселеннән: элекке патша министры Макаров кызы икән.* З.Фәтхетдинов

МИНИ́СТРЛАРЧА *рәв. сөйл. ирон.* Эре, тәкәббер кыяфәт белән

МИНИ́СТРЛЫК *и.* 1) Дәүләттә аерым эшчәнлек өлкәсе белән җитәкчелек итә торган үзәк идарә органы; шул учреждение урнашкан бина. *Капитан телефон янына килде, кирәкле санны җыеп, министрлыкка хәбәр итте.* М.Насыйбуллин. *Мин яңа кафедра ачуны күздә тоткан идем, министрлыктан җавап алдык: ул эш барып чыкмаслыгын хәбәр иттеләр. Кызганыч.* А.Гыйлаҗев. *Моннан бер ел элек Авыл хуҗалыгы министрлыгында, министр ярдәмчесенә керергә чират көтеп утырганда, өлкән яшьтәге бер карт интеллигент белән танышып китте ул.* М.Мәһдиев

2) Министр вазифасы, хезмәте; министр дәрәҗәсе. *Министрлыкка ирешү*

МИНИ-ТРАКТОР *и. лат.-инг.л.* Кечкенә җир мәйданнарында печән чабу, ашлама кертү, культивацияләү кебек авыл хуҗалыгы яки кар чистарту, урам себерү кебек төрле коммуналь һ.б.ш. эшләр башкара ала торган күп функцияле универсаль машина. *Тузан суыртырга тиешле мини-трактор пыр туздырып үтеп киткәндә, халык төркеме манекенга әверелеп кала...* К.Кәримов. *Йорт янына бер көтү техника куып китерделәр – эвакуаторлар, мини-тракторлар, гадәти тракторлар, грейдерлар, самосваллар...* Татарстан яшьләре

МИНИ-ФУТБОЛ *и. лат.-инг.л.* Гадәти футбол кырыннан кечерәк махсус мәйданчыкта уйнала торган футбол уены. *КДУ факультетлары арасында кызлар мини-футболы буенча турнирларда катнашабыз.* Ватаным Татарстан. *Мини-футболдан башка махсус спартакиада программасына өстәл теннисы һәм армрестлинг буенча ярышлар кертелде.* Яңа тормыш

МИНИ-ЮБКА *и. лат.-фр.* Бик кыска итәк. *Мини-юбка кигән макси чикләнгән кыз.* Ш.Галиев

МИНЛЕК *и. к.* **мин-минлек** (*3 мәгъ.*). *--- кешенең минлегенә, үзенә биргән бәясенә берәр төрле зыян килү куркынычы янаса ---.* В.Леви

МИН-МИНЛӘНҮ *ф.* 1) Мактану, масаю; үз-үзен эре, һавалы тоту, тәкәбберләнү. *Дәүли үзе дә һәрвакыт үзен-үзе күрсәтергә, мин-минләнергә, үзеннән башканы кешегә санамаска бик ярата.* Н.Гали

2) Үз көчен, сәләтен тиешеннән артык бәяләү, үз-үзенә артык ышану. *Мин-минләнгән егетне яу килгәндә күрербез.* Мәкаль

МИН-МИНЛЕ *с.* Мактанчык, масаючан; һавалы, тәкәббер. *Мин-минле автор язудан туктаса, донос жанрына күчә.* К.Кәримов. *Укытучы – шактый тәкәббер, мин-минле ханым – ялгышканын аңласа да, бирешергә теләмичә: «Йомырка тавыкны өйрәтми!» – дип әйтеп ташлады.* Татарстан яшьләре. *«Бик һавалы, мин-минле кыз икән бу, әңгәмә корып булмас инде», – дип уйладым.* Ялкын

МИН-МИНЛЕК *и.* 1) Мактанчыклык, масаючанлык; һавалылык, тәкәбберлек. *Чит кеше булса, аз сүзле Бәхтияровны дөрес аңламас, мин-минлек чире йоккан бәндә, дип уйлар иде.* М.Насыйбуллин. *Мин-минлек түгел һич ирлек, мин-минлек – кешегә кимлек.* Ә.Сынугыл-Куганаклы. *Ә масаю дигәнең тора-бара мин-минлеккә күчеп, кешенең кешелеклелеген тәмам бетерә, адәми затка охшаган бер җанварга әверелдерә.* З.Фәтхетдинов

2) Үзеңне, үз көчеңне, сәләтеңне артык югары бәяләү, үз-үзенә артык ышанучанлык. *Атлаган саен сокланучыларны очратып тору андый кызларның күбесенең мин-минлеген арттыра, акылларын тирәнәйтергә ирек бирми.* М.Юныс. *Хуҗа кешенең теленә салынырга яратуын Гыйлемхан чамалап алган иде инде. Әмма әлегә төшенә алмый газапланды: мин-минлеге, үртәргә маташуымы?* Р.Мөхәммәдиев. *Игорь белән Ларисаның тагын бер кагыйдәсе – мин-минлегеңне җиңүгә эчке әзерлек һәм үзеңнең хаксызлыгыңны таный белү ---.* Тигез гомер итегез!

3) Үз-үзеңне хөрмәт итү, үзеңә карата хөрмәт, үз дәрәҗәңне белү, горурлык. *Алай да тәмам ачылып китәргә мин-минлек ирек бирми әле.* М.Маликова. *Бүтәннәрдә булган мин-минлек анда да бар. Ул да үзе җитәкләгән колхозның алда баруын тели.* В.Нуруллин. *Әллә минем бер дә горурлыгым, мин-минлегем юкмы? Әллә мин бары җәйга җәйлашып кына яши ала торган сәер затмы?* Х.Камалов

МИН-МИНЛЕКЛЕ *с.* 1) Артык масаючан, мактанчык; һавалы, тәкәббер. *Абыйсы белән әнисеннән ул мин-минлекле, комсыз булмавы белән дә аерылып тора иде.* М.Галәү. *Югарырак күтәрелгән саен, болытлар сыегая, дигәндәй, акыллылар да азая бара, аларны тираннар һәм мин-минлекле хуҗалар алыштыра.* Ф.Яхин

2) Үзбелдекле, үз көченә, мөмкинлегенә артык ышанучан. *Нинди горур, нинди мин-минлекле, нинди матур хыяллар белән яшәгән чаклар да булган икән.* З.Мәхмүди. *Көчле мускуллы, мин-минлекле америкалылар җиңелергә мәҗбүр булалар.* Яңа тормыш

МИН-МИНСЕНҮ *ф. сир. к.* **мин-минләнү**. *Ажгырган айгырның өерен күр, мин-минсенгән егетнең өен күр.* Мәкаль

МИН-МИНЧЕЛ *с. к.* **мин-минлекле** (*1 мәгъ.*).

МИННӘТ *и. гар. кит.* 1) Күрсәткән яхшылыгы, ярдәме турында гел искә төшереп тору, шуның өчен нәрсәдер таләп итү, шуның белән битәрләү. *Кешенең миннәтен җигәнче, үзеңнең хезмәтеңне җи.* Мәкаль. *Падишаһ дәхи мең төрле миннәт белән рөхсәт бирде.* К.Насыйри. *Әгәрчә зәррә мыскал һиммәте бар, Аның артында тау-тау миннәте бар.* Г.Тукай

2) Берәү алдында бурычлы булу. *Агачтыр аты, Тимердән каты, Ил*

өстендә миннәте, Су өстендә кодрәте. Табышмак

3) Иткән яхшылыкны тану, рәхмәтле була белү, яхшылыкка каршы яхшылык белән җавап бирү. *Һәр һиммәтнең миннәте бар.* Мәкаль

МИННӘТДАР *с. фар. кит. к.* **миннәтле**. *Бәс, бу хезмәтләрең тәмам булгач, мосафирга вә кунакка миннәт йөкләмә. Бәлки син аларга миннәтдар бул.* К.Насыйри. *Шуңгар күрә үзләрен тоткынлыктан азат итү юлында көрәшүче каһарман артистларга каршы татар хатыны миннәтдар.* Г.Исхакый. *Солтаннарның затлы киемнәре, хатын-кызларның асылташлы калфаклары, чулпылар, борынгы китапларны күреп, мин чиксез миннәтдар булдым.* Р.Батулла

МИННӘТДАРЛЫК *и. кит.* Рәхмәт әйтү, канәгатьлек белдерү гадәте. *Татар дип тә мондагы егет-җиләнгә бик үк миннәтдарлык булыну тиеш түгеллеген аңлатыр өчен, бу сүзне әйттем [карчык кызына].* Ш.Камал

МИННӘ́Т ИТҮ *ф.* Эшләгән яхшылыгы белән битәрләү, каршы яхшылык таләп итү. *Сәүдәгәр бер тиенлек хөрмәт итәр, ун тиенлек миннәт итәр.* Мәкаль. *Син, мулла кем, син инде алай миннәт итеп, үзеңнең нигъмәтеңнең әҗерен җуйма.* Г.Камал. *Аз мал биреп байның кызын алсаң, Куеныңда бер яткынын миннәт итәр.* Н.Исәнбәт

МИННӘ́Т КЫЛУ *ф. к.* **миннәт итү**. *Зур эшкә дә санамыйм, миннәт тә кылмыйм, әмма мин синең төсле бөтен авырлыктан, мәсьүлияттән качып котыла торган җиңел юл да сайламыйм, Габдуллажан кордаш.* Ә.Фәйзи

МИННӘТЛЕ *с. кит.* Рәхмәтле, кешедән күргән яхшылык яки ярдәмне танып, шуның өчен рәхмәт әйтә белгән; яхшылыкның, ярдәмнең кадерен белгән

МИННӘТЛЕК *и. кит. к.* **миннәт** (*1 мәгъ.*). *Һиммәтле кешедә миннәтлек юк.* Мәкаль

МИННӘТЛЕЛЕК *и. кит.* Миннәтле булу үзлеге; миннәтле булу сыйфаты

МИННӘТСЕЗ *с. кит.* **1.** Миннәт (*1 мәгъ.*) белдермәгән, миннәткә корылмаган. *Без бу дөньяда шундый дус булдык: эчебез керсез, сый-хөрмәтебез миннәтсез булды.* З.Бәшири

2. *рәв. мәгъ.* Миннәт белдермичә яки миннәт ишетмичә. *Миннәт белән коймак ашаудан миннәтсез таяк ашау яхшырак.* Мәкаль

МИННӘТЧЕЛ *с. кит.* Күрсәткән ярдәме, яхшылыгы өчен гел нидер таләп итүчән. *Мин сезнең миннәтчел кешеләр түгел икәнлегегезгә бик нык ышанам.* С.Кудаш

МИНО́ГА *и. нем. зоол.* Бөжрә-авызлылар классында бердәнбер булган, миногалар семьялыгына караган, шәрә елан сыман гәүдәле төче су балыгы. *Миногалар, омарлар, краблар, елан балыклар алырга вәкилләр Балтыйк буена, Калининградка ашыкты.* А.Гыйләҗев. *Балыкларның иң якын кардәшләре булган миногалар паразитлар кебек яшиләр*. Кызыклы ихтиология. *Түбән төзелешле хордалылар – ланцетник, миного, миксин – тәннәренең арка өлешендә баштан койрыкка кадәр сузылган нык эластик аркан сыман хордага ия*. Биология. Хайваннар

МИНОМЁТ *и. рус* Миналар ата, ышыкланган цельләргә тидерү максаты белән текә траекторияле ут алып бару өчен файдаланыла торган туп. *Гарьлегеннән шартларга җитешкән генераларның безнең окопларны артиллериядән һәм миномётлардан ничә рәт утка тотуын сөйләп тә тормыйм.* Ш.Рәкыйпов. *Дошман, үзенекеләренә тидерү куркынычы барын чамалап, миномётлардан атуны сирәгәйтте.* Х.Камалов. *Фашистларның уң як ярдагы тимер-бетон ныгытмаларын йөзләгән туплар, миномётлар, самолётлар дәһшәтле утка тоталар.* Г.Тавлин

МИНОМЁТЧЫ *и.* Миномёт частенда хезмәт итүче; миномёттан атучы. *Үзе миномётчы бит инде, сугышның иң кызуында йөрибез, атналар буе передовойдан чыккан юк, дигән бер хаты гына килде*. Л.Ихсанова. *Баштарак ул, тиешле хәрби әзерлекне үткәч, миномётчы сыйфатында Сталинград янындагы җитди сугышларда катнаша, фашист гаскәрләренең куәтле зур көчләрен тар-мар итүдә үзеннән лаеклы өлеш кертә.* Ш.Мостафин

МИНОНО́СЕЦ *и. рус* Нигездә торпедалар белән коралланган кечерәк хәрби диңгез корабле. *Кая алар, минем беренче килүемдә күргән крейсерлар, миноносецлар, торпеда катерлары һәм су асты көймәләре?* М.Юныс. *Ак диңгездә (Урта диңгез) Төркия диңгез флоты Грециянең иң шәп, тизйөрешле «Аваров» исемле сугыш корабларын сафтан чыгаруы, бер миноносецларын кулга төшерүләре хәбәре төрекләрнең җиңүгә ышанычларын арттыра.* Ә.Алиева

МИНОР *и. лат. муз.* Тавышлары кече терцияле аккорд барлыкка китерә, моңсу, төшенке тавыш төсмерләре белән характерлана торган музыкаль лад; киресе: **мажор**. *Натураль минор ладка корылган интонация алымнары, ноталар белән иҗек арасындагы төгәл мөнәсәбәт --- – болар барысы да җырның татар музыкаль поэтик иҗатында яңа бер үрнәк булуы турында сөйли.* Ж.Фәйзи. *Ныграк төшенә барган саен, шатлану-соклану аваз-лары минор тоннар белән аралашты.* Ф.Миңнуллин. *Музыкада мажордан минорга күчкән кебек, Фәрит үзе тормышның бер халәтеннән икенчесенә атлап керде.* Р.Низамиев

МИНОРЛЫ *с.* Минор тональлегендәге. *Минорлы гамма. Минорлы аккорд*

МИНСЕНҮ *ф. сир. к.* **минминләнү**. *Минсенгән – мин, мин дип күкрәк каккан.* Мәкаль. *Ул ни өчендер, тиктомалдан үзалдына һаваланып китеп, минсенергә тотынган.* Н.Исәнбәт

МИНСИҢАЙТИМ *ы.* Сөйләмгә экспрессивлык төсмере бирү, аның эмоциональлеген арттыру, тыңлаучының игътибарын шуңа юнәлтү өчен кулланыла. *Юк кына бит, минсиңайтим, чыдамый гына терәтеп куйган чыбык, шартлап сына.* Н.Әхмәдиев. *Шундый итеп, арт саннарын дерелдәтеп көлеп җибәрде, минсиңайтим, көлгәндә чибәрләнеп тә китә икән үзе.* Г.Галиева

МИНТАЙ *и. вьет.* Тәрәчсыманнар семьялыгыннан Тын океанның төньягында таралган, салкын су сөючән, промысел объекты булган диңгез балыгы. *Пешкән минтай иде безнең «сөйгән» балык. Чират торып ашый иде*

шуны халык. Л.Шагыйрьжан. *Ә анда кибеттә көн саен яңалык: я яңа исемле пачкалы аш кайткан, я балык паштеты, я минтай сырты, инде дә килеп, көмешсыман хек та кайтса!* М.Мәһдиев

МИ́НУС *и. лат. мат.* 1) Математикада алу гамәлен яки кире зурлыкны белдерә торган билгенең атамасы (–).

2) Алу гамәленең үзен белдергән сүз. *Егерме минус биш ничәгә тигез була?*

3) Кире зурлык. *Ә бит «плюс» белән «минус»тан башка электр тогы юк һәм була да алмый.* Г.Тавлин. *Табигать-анабыз нишләргә кирәген үзе белә: тискәре янына уңайны, плюс янына минусны китереп утырта, тын гына саркып яткан инеш янында утын яндыра.* Т.Галиуллин

4) Нульдән түбән булган температура. *Температура минус ике йөз җитмеш өч градус.* Галәмгә юл. *Мәсәлән, Согуд Гарәбстанында бу көннәрдә температура минус 8 градуска кадәр төшкән, кайбер районнарында хәтта кар яуган.* Татарстан яшьләре

5) Берәр эшчәнлектә тискәре нәтиҗә; файда алу урынына зыян күрү. *Күпме чыгымнар, күпме көч, күпме нервы түгеп, 20 сәгатьлек телемарафон үткәрдек, ахыр чиктә безнең Фонд минуста калды.* Татарстан яшьләре

6) *күч.* Җитешсезлек, кимчелек, тискәре сыйфат. *--- кыланчык дигәннәрен ишеткән юк иде әле. --- Анысы минем минустыр инде.* Х.Сарьян. *--- прокурор үзеннән-үзе Аксайга баруын анализлауга күчте. Бу дөньяда, соңгы чиктә, плюс белән минуслар, табу белән югалтулар үзара кушылып, тигезләнә торалар.* М.Юныс. *Монда плюслар да, минуслар да күзгә күренеп тора.* Р.Мирхәйдәров

МИ́НУСЛЫ *с.* Нульдән түбән (һава температурасы тур.). *Бу якларда гомер-гомергә күрелмәгән минуслы температураның иң күп корбаннары Перуда.* Татарстан яшьләре

МИНУТ *и. лат.* 1) Сәгатьнең 1/60 өлешенә тигез булган, 60 секундтан торган вакыт үлчәү берәмлеге. *Өстемдәге күлмәгемне Ничек киеп туздырыйм? Минуты – ай, сәгате – ел, Ничек кенә уздырыйм?* Җыр

2) Бик кыска вакыт арасы, мизгел. *Туган якка табынудан Минутка да туктаган юк.* Ф.Гыйззәтуллина

3) Билгеле момент, мизгел. *Нәкъ шул минутта скрипкалар чыңлап куйды да, контрданс башланып китте.* Ж.Тәрҗеманов. *Шул минутта нәрсәдән башларга, ни диярга белми генә сүзсез калды ул.* Р.Мөхәммәдиев. *Яшь чагыбызда бергә булган рәхәт минутларны бөтенләй үк онытырга кирәкмәс иде сиңа.* В.Нуруллин

4) *махс.* Градусның 1/60 өлешенә тигез булган һәм язуда цифрның өске уң ягында махсус билге (′ билгесе) белән күрсәтелә торган почмак яки дуга үлчәү берәмлеге. *Курсның берничә минутка, хәтта ярты, бер градуска үзгәрүен аңлап була.* М.Юныс. *Меридиан белән 50 бугай, Минутларын белмим тәгаен. Широтасы бөтенләй онытылган, Координатлар ялгыш, мөгаен.* Аманулла

5) Ситуация, очрак, хәл. *Ах, бу бала белсә иде әнисенең хәзер нинди кыен минутлар кичергәнен...* М.Мәһдиев. *Авыр минутларда упкынга ташлап киткән бәндәнең миңа ни хаҗәте бар?* Б.Камалов. *Дусларны белеп сайласаң, нык ул дуслык җепләре. Авыр минутта сынала Дусларның кемлекләре*. Ә.Синугыл-Куганаклы

6) Нәрсәнең дә булса билгеле, гадәтләнелгән вакыты. *Синең тормышың график буенча бара. Иртән вакытында уяну, юыну, ашау, эш сәгате, кичке аштан соң китап уку, минуты җиткәч йоклау – һәр көн шулай. Артыгы юк.* Т.Миңнуллин

◊ **Минутка минут** Бик төгәл, нәкъ билгеләнгән вакытта. **Минутлар белән яшәү** Бүгенге көн белән генә яшәү, алдагыны уйламау, кайгыртмау. **Минуты белән** Кичекмичә, шундук. *--- хисләренең чынлыгына ул шулкадәр тирәнтен инанды ки, бу изге тойгылары минуты белән әнисе күңеленә барып керәчәгенә ул ихлас ышанды ---.* Г.Бәширов. *--- [балыкның] тешләре тимер кискеч кебек! Сөзгечеңне өзеп, минуты белән чыгып шылачак!* Ж.Дәрзаман. **Минуты-сәгате белән** Әйткән вакытында ук, шундук, бик тиз арада; бик төгәл. *--- кемгә никах укылу хакындагы хәбәр сәгате-минуты белән бөтен якын-тирәгә таралачак.* Г.Бәширов. *Прокурорның гаепләнүчеләргә нинди җәзалар бирергә тиешлеге турындагы сүзләре минуты-сәгате белән каланың урамнарына, мәйданнарына, зур, кечкенә өйләренә таралып өлгергән иде инде.* Р.Гайфуллина. **Минуты-секунды белән** *к.* **минуты-сәгате белән**

МИНУТЛАП *рәв.* 1) Берәр минут итеп, минутларга бүлеп; минут исәбе белән. *Тамчылар тамар чаклар, Ташулар агар чаклар – Кадерен белгән кешегә Минутлап санар чаклар.* Ш.Галиев. *--- аның көненең һәр сәгате минутлап бүленгән, сезнең белән очрашу өчен башкача мөмкинлек күренми.* Р.Мирхәйдәров

2) Үзеннән алда килгән микъдар саннарындагы минут чамасы. *Чакырылган психиатр тоткын белән ун минутлап утыруга ук, аның үз акылында икәнлеген белдерде.* Р.Мирхәйдәров. *Берәр минутлап икебез дә эндәшмәдек.* И.Тургенев

МИНУТЛЫ *с. к.* **минутлык** (*3 мәгъ.*). *Минутлы күренеш*

МИНУТЛЫК *с.* 1) Билгеле минут дәвам иткән, минут эчендә башкарылган. *– Бер минутлык шигырьдә дә бик күпне әйтеп була, – дип, Айдар сәхнәгә менде ---.* Ж.Фәйзи. *Торган җиребезгә «Татар ашлары йорты»ннан биш кенә минутлык юл.* Г.Ахунов. *Атнага бер чыга торган 40 минутлык тапшыру иде ул.* Сөембикә

2) *күч.* Бик тиз, кыска вакыт эчендә үтәлә, башкарыла, була торган. *Башсызлыкмы, әллә исәп белән эшләнгән эшме бу? Минутлык куркуга бирелеп, йомшап, аңын, ихтыярын җуюмы?* Х.Камалов. *Коста тынычланды, үзенең минутлык йомшаклыгына читенсенгәндәй итте һәм яткан мендәрен төзәтүен үтенде.* Р.Мирхәйдәров

3) *күч.* Тиз үтүчән, бер мизгеллек, вакытлы гына булган. *Кешеләр язмышы да менә шулай кемнеңдер минутлык кәефенә бәйле.* Ш.Галиев. *Көрәшсәң, яшәү – мәңгелек, Үлем – минутлык*. Ф.Гыйззәтуллина

МИНУТЫНДА *рәв.* 1) Шул ук минутта, шул ук мизгелдә. *Җиһангир*

Биктаһиров Сафиядәге бу үзгәрешне минутында күреп алды һәм киренке дикъкать белән аңа текәлде ---. М.Маликова. *[Әминә] Тынычсызлана башлагач, шалтыраткан идем. Минутында килеп алып киттеләр.* Р.Вәлиев

2) *күч.* Вакытлы, үз вакытында, кирәк моментта

МИНЧЕЛ *с. к.* **мин-минчел**. *Көнчел кеше – минчел кеше.* Мәкаль

МИНЧЕЛЕК *и. к.* **мин-минлек**. *Электән килгәннең бөтенесен тоташтан җимерү, социалистик революциянең ижади асылын күреп җиткермәү, барлык нәрсәгә аермасыз гыйсъян итү, минчелек – вак буржуаз революционлык тәэсире күбрәк әнә шуларда гәүдәләнде.* Х.Госман

МИҢ *и.* Тәндә тумыштан була яки соңрак барлыкка килә торган тап. *Сул күзенең кабагы өстендәге тары ярмасы хәтле генә мәхәббәт миңенә күзем төшкәч кенә танырдым.* Ш.Рәкыйпов. *Аның чем-кара чәчләре иңбашларына таралып төшкән, калын кашлары, озын керфекләре, уң як яңагындагы кечкенә миңе йөзенә сөйкемлелек биреп тора.* Ф.Садриев. *Маңгаем агындагы миңем генә кара минем...* А.Хәлим

МИҢГЕРӘЙТҮ *ф. к.* **миңгерәүләтү**. *Милләтне миңгерәйтү бара, энем.* Ф.Сафин. *Олылардан калтырап тору, куркытып миңгерәйтү хакында сүз бармый, билгеле, «писарь» Галиулла балалары аныкарашлы, юлдан тайпылмаслык мөстәкыйль фикерле булып җитешкәннәр.* Р.Шәрәфиев. *Кыздан ишеткән бу сүзләр, әти-әниләренең тарихы Камилне тәмам миңгерәйтеп, хәлен алган иде.* Ф.Бәйрәмова

Миңгерәйтә башлау Бераз миңгерәйтү

Миңгерәйтеп бетерү Тәмам миңгерәйтү. *Баланы миңгерәйтеп бетерәбез инде.* Г.Афзал

Миңгерәйтеп җибәрү Кинәт миңгерәйтү. *Бу хәл аны бер мәлгә миңгерәйтеп җибәргәндәй булды.* М.Хәсәнов

Миңгерәйтеп килү Озак вакытлар миңгерәйтү. *Ул бездә иске ишанлык культы һәм аның гасырлар буе халыкның миен миңгерәйтеп килгән булуы, соңгы якта исә шәхес культы һәм бигрәк тә маррчылык догмалары белән дә бәйләнгән.* Н.Исәнбәт

МИҢГЕРӘТКЕЧ *с. сөйл.* **1.** Зиһеннe томалый, аңгы-миңге итә, миңгерәүләтә торган. *Халыкның Җилкуардар дигән бер каверне чит илский сагызлар һәм «Актаныш таңнары» дигән астматик тәмәке вә миңгерәткеч хәмер сатып баер.* Л.Лерон. *Баш миңгерәткеч уйлары каядыр ераккa-ераккa, караңгы бушлыкка таба агылалар һәм бераздан бөтенләй таралышып юкка чыгалар...* К.Кәрами

2. *и. мәгъ. бот.* Паслёнчалар семьялыгына керә торган сары чәчәкле агулы үсемлек; *русчасы*: **жёлтый паслён**. *Чүплектә үскән миңгерәткеч белән тилебәрән орлыгын күргәч, оныгын тагын кисәтте Сәхипҗамал әби: – Бу үләннәрнең дә тартмачыктагы орлыклары бик агулы.* К.Закирова. *Тилебәрән, миңгерәткеч, белладонна кебек агулы үсемлекләр дә паслёнчалар семьялыгына керә.* Ботаника

МИҢГЕРӘТҮ *ф. к.* **миңгерәүләтү**. *Коточкыч шартлау тавышы һәм зур тизлектә барган танкның кинәт туктап калуы Мөниржанны миңгерәттe.* Н.Әхмәдиев. *– Тискәре бала, качып миңгерәтүең җитмәгән, сүз тыңламыйча да җанга тиясең! – диде әни.* Р.Габделхакова. *Ә Айвазны, тренировкадан кайтканда, төнлә урамда кемнәрдер кыйнап миңгерәткән, ул аңсыз егылган.* Ф.Зыятдинов

Миңгерәтә башлау Бераз миңгерәтү

Миңгерәтә тору Бераз миңгерәтү. Әледән-әле миңгерәтү. *Ялгызлык барыннан да усалрак иде, зиһенне гел миңгерәтә торды.* Ә.Баян

Миңгерәтеп бетерү Тәмам миңгерәтү. *Югыйсә тагын әллә ниләр кыланып, Ханәфинең башын бөтенләй дә миңгерәтеп бетерер иде.* В.Нуруллин

Миңгерәтеп җибәрү Кинәт кенә миңгерәтү. *Килгән кешенең соңгы җөмләсе егетләрне миңгерәтеп җибәрде.* С.Зыялы. *«Микрофон – гранат»ның бетон плитәгә килеп төшкән мизгелендә... «берничә снарядның берьюлы шартлаган тавышы»... йөзләгән кешене миңгерәтеп җибәрде: колаклары, күзләре тонды, Берлинны алу операциясе шулайрак булгандыр кебек тоелды.* М.Садыйков

Миңгерәтеп ташлау Тиз арада миңгерәтү. *Нинди генә көчле булсаң да, мондый хәсрәт кешене аягыннан ега, миңгерәтеп ташлый, бу минутта ни эшләргә кирәген дә оныттырып җибәрә икән.* Г.Сәгыйров

Миңгерәтеп тору Озак вакыт дәвамында миңгерәтү

МИҢГЕРӘ́Ү I *ф.* 1) *к.* **миңгерәүләнү**. *Шул сүзе белән гүя болай да миңгерәгән башыма китереп сукты [сеңлем].* Р.Габделхакова. *– Берүзең буш квартирада миңгерәп ятмассың, кил, – дип чакырды Лида.* А.Гыйләҗев

2) Кинәт баш тону; зиһен таралу. *Кинәт миңгерәү*

Миңгерәп бетү Тәмам миңгерәү. *Юлда селкенеп миңгерәп беткән бораулаучылар, автобустан төшкәч, башта моңа артык игътибар итмәгәннәр иде.* Ш.Бикчурин. *Башлар миңгерәп беткәнче, Тукран шикелле тукыйбыз.* Ш.Галиев

Миңгерәп йөрү Миңгерәйгән хәлдә булу; һәрдаим миңгерәү. *Ахмак булма, миңгерәп йөрмә, вакытын ычкындырма, ди [Ләйсән].* М.Маликова

Миңгерәп калу Ниндидер вакыйгадан, тәэсирдән соң миңгерәгән хәлгә килү. *[Апаларның] Күзләрендә тамчы яшь юк, ә үзләре шундый кызганыч улыйлар, без, ниишләргә белмичә, миңгерәп калдык.* Ә.Баян. *Әти район начальнигы янына кереп киткәннән соң, кинәт зиһене чуалган кешедәй, каютада миңгерәп калдым.* С.Сабиров. *Бу кадәр көтелмәгән хәбәрдән миңгерәп калдым.* Р.Габделхакова

Миңгерәп китү Кинәттән миңгерәү. *Башыма гөрзи белән китереп ордылармыни, миңгерәп киттем хәтта.* Ж.Дәрзаман. *Көтелмәгән сорауданюгалып, миңгерәп киттем.* Р.Габделхакова

Миңгерәп төшү Беркадәр миңгерәү. *Болар барысы да аның [әбинең] каушап калуыннан, башына күсәк белән суккандай миңгерәп төшүеннән генә әйтелгән сүзләр булгандыр инде.* А.Хәсәнов

Миңгерәп тору Миңгерәгән хәлдә булу. *Ишекне ябып тышка чыккач та,*

кая бәрелергә, ни кылырга белмәгәндәй, күпме вакыт миңгерәп торды. Р.Мулланурова

Миңгерәп чыгу Тәмам, тулысынча миңгерәү. *Тирләп бетте, миңгерәп чыкты Фәхри.* Ә.Исхак

Миңгери бару Вакыт үткән саен, тагын да ныграк миңгерәү

Миңгери башлау Миңгерәү билгеләре күренү

МИҢГЕРӘ́Ү II *с. сөйл.* **1.** Башсыз, акылсыз, аңгы-миңге (кеше, җан иясе һ.б.). *Миңгерәү тавык булса да, җан иясе бит, ипташ булыр*. Н.Әхмәдиев. *--- Яман хәбәр ишетеп, маңгаена электр тогы бәргән мескен сыер кебек, дөньяны бер кавем онытып, кешеләрнең дә кагылуын тоймыйча, миңгерәү кыяфәт белән гажиз хәлдә басып тордым.* Р.Сибат. *Мин әйткәнчә булмаса, бөтенләй җырламыйм мин, аңладыңмы шуны миңгерәү башың белән!* И.Сабиров

2. *и. мәгъ.* Аңгыра, тулы акыллы булмаган, аңгы-миңге кеше. *Мөрти агай: «Бу нинди миңгерәү?» – дигән төсле гажәпләнеп, азрак кызганып, күбрәк ачу белән, миңа бераз карап торды.* Ә.Еники

◊ **Миңгерәү баш** Аңсыз, аңгыра; «шуны да аңламый» дигән мәгънәдә әйтелә. *[Бикмулла:] Ә-ә... Сез әнә нәрсә турында сорыйсыз икән! Вәт миңгерәү баш, сизми торам.* Ә.Еники

МИҢГЕРӘҮЛӘНҮ *ф.* Зиһен таралу; аңгыралану, аңгы-миңгеләнү. *Өстеңә шундый бәхет аугач ни, миңгерәүләнерсең дә шул!* Ә.Еники. *Су өстендә кыегаеп һәм хәлсез, миңгерәүләнгән шикелле йөзгән зур бер корбан балыгы күренде дә бу теләгемне юкка чыгарды*. Ә.Гаффар. *Болай да сирәкләнеп калган көтү бөтенләй чыгудан туктады, ярым җимерек ферма абзарлары биклән куелды, ике-өч скотник, эчкә ябылып, арык малларны карап, начар көмешкәдән миңгерәүләнеп, көнетөне шунда яттылар...* Г.Гыйльманов

Миңгерәүләнә бару Торган саен ныграк миңгерәүләнү. *Жан миңгерәүләнә барган зиһенен җыярга тырышты, ләкин ни эшләргә дә белмәде.* Ш.Рәкыйпов

Миңгерәүләнә башлау Миңгерәүләнүгә таба бару. *Хаксызлык синең башыңа олы күсәге белән бер тондыра, ике тондыра, аннары кеше үзеннән-үзе миңгерәүләнә башлый.* Г.Афзал. *Майя урман зәхмәте шаукымыннан шактый айнып өлгергән, ә Хәлим, киресенчә, ару-талудан бераз миңгерәүләнә башлаган иде*. Г.Гыйльманов

Миңгерәүләнеп бетү Бөтенләй миңгерәүләнү. *Өстәгеләр идеология белән тәмам миңгерәүләнеп беткәннәр.* Х.Камалов. *Авылда яшәп, бөтенләй миңгерәүләнеп беткәнсез инде.* Ф.Яруллин

Миңгерәүләнеп йөрү Күптәннән бирле миңгерәүләнгән хәлдә булу

Миңгерәүләнеп калу Ниндидер тәэсирдән соң миңгерәүләнү. *Ул күзләрдә ниндидер хәйран калу, ис китү, хәтта бераз миңгерәүләнеп калу да сизелә кебек...* Ә.Еники. *Әмма икенче көнне үк тормыш күсәге аның башына китереп тондырды, ул [егет] миңгерәүләнеп калды.* З.Хөснияр. *[Габделнурның] Башы ничектер миңгерәүләнеп калды бугай*. Р.Кәрами

Миңгерәүләнеп килү Миңгерәүгә әйләнә бару. *Миңгерәүләнеп килгән Хәйретдин агайны чукый-чукый озаттылар.* А.Гыйләҗев

Миңгерәүләнеп китү Кинәт миңгерәүләнү. *Матурлык алдында егетнең зирәге дә миңгерәүләнеп киткәндәй була.* М.Юныс. *Мин бу куркыныч хәбәрне башта бермәл аңыма сыйдыра алмый тордым, кинәт миңгерәүләнеп киттем.* С.Сабиров. *Шунысы гажәп: икенче аен яшәгәндә үк, һәркайсы миңгерәүләнеп киткәндәй була.* Ф.Баттал

Миңгерәүләнеп тору Сөйләү моментында миңгерәүләнгән булу. *Миңгерәүләнеп торам. Ни дип җавап бирергә белгән юк.* Ф.Сафин

МИҢГЕРӘҮЛӘТҮ *ф. йөкл. юн.* 1) Берәр куркыныч хәл, очрак яисә көтелмәгән вакыйга, сүз һ.б. зиһенне томалап, башны эшләмәс хәлгә җиткерү; аңгыралату, аңгы-миңге итү. *Һава дулкыны агачларны аударды, арттагы машиналарга утырып килгән автоматчыларны миңгерәүләтте.* Ш.Рәкыйпов. *Бу – кешене миңгерәүләтү, куркыту, чиргә сабыштыру, аның психикасын үзгәртү өчен махсус эшләнә торган үзенә күрә бер идеология түгел микән?* Р.Миңнуллин. *Башта Артурның башын миңгерәүләтеп ышанычка керде.* Х.Камалов

2) Нинди дә булса физик көч яисә башка төрле сәбәпләр нәтиҗәсендә, тәэсирендә көчсезләнү, хәлсезләнү. *Кораб астыннан винт миңгерәүләткән балыкларны чүпләп килүче акчарлаклар Кара диңгез, Урта диңгез акчарлакларыннан ваграк*. М.Юныс

Миңгерәүләтеп бетерү Бик нык миңгерәүләтү

Миңгерәүләтеп җибәрү Тиз арада миңгерәүләтү. *Һава аларның башны миңгерәүләтеп җибәрә торган төче исләре белән тулы.* Г.Әпсәләмов

МИҢГЕРӘҮЛЕК *и.* Миңгерәү (II) булу хәле. *Сагынган булсаң, әнә генә ул миңгерәүлек томаны эчендәге көннәрең.* Ф.Садриев. *Без сыйнфый миңгерәүлек күрсәтергә тиеш түгел*. Ф.Сафин

МИҢГЕРӘЮ *ф. к.* **миңгерәүләнү**. *Өстәгеләрнең ә дигәненә җә дип, астагыларның башына тибеп яшәгән чиновниклар, капкачын бәреп пары атылган казан янында берара миңгерәеп, аптырап, каушап калдылар шикелле*. Р.Зәйдулла. *Кемнәрдер кереп, аны [Рафилне] өстери башлады, ул алар белән сугышты, карышты, ахырында миңгерәеп, каядыр очты...* А.Галиева. *Бу әрсез һәм ябышкак караштан котылырга теләп чәбәләнүдән Рәфиснең башы миңгерәйде, авызы кипте.* А.Вергазов

Миңгерәя башлау Миңгерәю билгеләре сизелү

Миңгерәя бару Торган саен ныграк миңгерәю

Миңгерәеп бетү Бөтенләй миңгерәйгән хәлгә килү. *Әллә тагы, сезнең белән миңгерәеп бетәрсең.* Казан утлары

Миңгерәеп калу Ниндидер тәэсирдән соң миңгерәю. *Мәскәү, Чиләбедән килгән телевизорчылар, зыр-зыр әйләнеп, миңгерәеп калган халыкны төшерүләрен дәвам иттеләр*. Ф.Бәйрәмова. *Хатның эчтәлеге аңына барып җитү белән, Мансур Ибраһимович нишләргә белми миңгерәеп калды*. Х.Ширмән

Миңгерәеп китү Кинәт, тиз арада миңгерәйгән хәлгә килү

Миңгерәеп тору Миңгерәйгән халәт кичерү, шундый халәттә булу. *Тоткан нурым кулым өтеп ала, Миңгерәеп торам мин берара.* Н.Сафина. *Уйларыннан аралана алмыйча миңгерәеп торганда, Рәниянең каршына килеп баскынын ул сизми дә калды.* А.Вергазов

Миңгерәеп йөрү Озак вакыт миңгерәйгән хәлдә булу. *Сыер савучылар, һушларына килә алмагандай, беркавым миңгерәеп йөрделәр.* М.Хәсәнов. *Әллә нишләп миңгерәеп йөрдем шунда.* М.Маликова

МИҢКҮ *ф. диал.* Хәл китү, әлсерәү, көчсезләнү. *Тазарак яралылар, миңкеп, үз-үзләрен белештерми кычкырыша, ыңгыраша башладылар.* Х.Камалов. *Көзге яңгыр астында минут саен үлем көтеп миңкеп ятуны «дөнья» дип атап булса, әйе, дөньяда әле Сәфәргали дигән кеше дә бар иде.* Ф.Хөсни

Миңкеп бетү Тәмам миңкү

Миңкеп китү Кисәк, көтмәгәндә миңкү

Миңкеп тору Миңкегән халәттә булу

МИҢЛЕ *с.* Миңе булган. *Миңле кызлар күп, ә менә сөйкемле тамчысы яңак уртасындагы чокырга тамганы... Дөньяда андый тагын берәр бар микән?* М.Маликова. *Әнисе: «Миңле бала бәхетле була, шуңа күрә сиңа бу исемне куштык», – дигән иде.* Ф.Зариф

МИҢЛЕГӨЛ *и. бот.* Бегониячәләр семьялыгыннан күп төрләре һәм гибридлары декоратив үсемлек буларак үстерелә торган үлән үсемлек; карабодай гөле, бака гөле; *русчасы*: **бегония**. *Гөл чүлмәгенә дымлы комга нинди дә булса бер үсемлек – миңлегөл, узамбар миләүшәсе яки глоксиния яфрагын утыртып тамырландырыгыз.* Биология

МИҢРӘ́Ү I *ф.* Аңгыралану, аңгыми ңгеләнү. *Ул бөтенләй миңри, Күз алдында Бөтерелә кара ноктала р, Сулышы буыла, гүя аның Бугазыннан кысып тоталар.* Ф.Кәрим. *Чөнки суд юлында йөргән кеше мораль яктан миңри, сәламәтлеген югалта.* Э.Шәрифуллина

Миңрәп бетү Бөтенләй миңрәгән хәлгә килү. *Югалган улын уйлый-уйлый миңрәп бетә Әминә әби.* Шәһри Казан

Миңрәп калу Ниндидер тәэсирдән соң миңрәү, курку, аптырау. *Егет, сөт чүлмәген җиргә төшереп ваткан кыз бала төсле, миңрәп калды.* К.Тинчурин

МИҢРӘ́Ү II *с. к.* **миңгерәү** II. *Әй-й, Мәрвәр җаным, оныта да язганмын лабаса, миңрәү түгел диген инде син мине!..* Ә.Еники. *– Күземнән югал, миңрәү хайван! – дип кычкырган түрә.* Р.Батулла

◊ **Миңрәү баш** *к.* **миңгерәү баш**. *Күпме уйланып та белә алмаганмын шуны, миңрәү баш!* Ә.Еники

МИОКА́РД *и. гр. мед.* Йөрәкнең мускуллардан торган тышчасы. *Инде безнең көннәрдә Ленинград тикшеренүчесе Б.Рывкин, күпсанлы фактларны анализлап, Кояш активлыгы күтәренке булган көннәрне миокард инфаркты авырулары санының шактый артуын раслады.* Галәм. Җир. Кеше. --- *доцент Латфуллин 1981 елда йөрәк миокардына багышланган докторлык диссертациясе язып бетерә.* М.Әхмәтҗанов

МИОКАРДИ́Т *и. нем. мед.* Йөрәк мускулының ялкынсынуы. --- *кардионевроз, миокардит, кыскасы, күкрәк бакасы стенокардиягә бер адым калган булган.* А.Гыйләҗев. *Үлән [сукыр кычыткан] төнәтмәсен һәм экстрактларын, тыныч ландыра торган дару буларак, йөрәк-кан тамырлары невроз ларыннан, гипертониядән, стенокардиядән, кардиосклероздан, миокардиттан, кардионевроздан, йөрәк зәгыйфьлегеннән һәм баш мие контузияләреннән кулланалар.* Урман аптекасы

МИР *и. рус сөйл.* 1) Авыл; авыл халкы. *Тик мир көтүен көтүче, кайсы авылдан килеп урнашканы мәгълүм булмаган, акылы шактый сәеррәк утыз-кырык яшьләрендәге сирәк сакаллы Мөбарәкша гына кешеләрдән көлде.* М.Мәһдиев. *Кара, кабахәт, мир алдында нәрсә сөйләп тора!* Ә.Моталлапов. *Көче-кодрәте дә Аллага шөкер икән, мең мирдән торган камераны бер йодрыкта тота белә [Малько].* М.Хафизов

2) Җәмәгатьчелек, халык, кешеләр. *Аннары мир күзенә ничек карарсың? Ирдән-иргә йөрүчеләрне кешемен дигән кешеләрнең хуплаганы юк бит әле.* Б.Камалов. *Авыздагы сүз синеке, авыздан чыкса – мирнеке.* Ә.Синугыл-Куганаклы. *Миргә килгән җыен бәлаказа, Илдә купкан дәһшәт-давыллар – Һәммәсенә түзеп, сабыр гына Кичергәннәр тыйнак авыллар.* Л.Шагыйрьҗан

МИРАБЕЛЬ *и. гр. бот.* 1) Вак сары җимеш бирә торган көньяк агачы, сливаның бер төре

2) Шул агачның җимеше

МИРАЖ *и. фр.* 1) Атмосфераның тыгызлыгы һәм температурасы белән нык аерылып торган катлаулары чигендә яктылык нурлары сынудан гыйбарәт оптик күренеш (бу вакытта горизонт артындагы күренми торган әйберләр һавада чагылып күренәләр); сагым. *Шадра диңгез өсте, Кипарислар, Тезелеп киткән йөзем түтәле – Мираж төсле күзгә чагылып үтте Иртәнге ак томан үтәли.* М.Җәлил. *Канат изи астан акчарлаклар, ә офыкта – тагын ап-ак нокта!.. Пәйда булган көтеп алган кораб – Мираж күк чыкмаса ярый юкка...* Л.Шагыйрьҗан. *Күп кенә яктылык күренешләре, мәсәлән, кояш яктысында су тамчыларының ялтырап күренүләре, --- миражлар яктылыкның тулы кайтарылышы аркасында хасил булалар.* Физика курсы

2) *күч.* Ялган ориентир, ялгыш максат, алдавыч. *Имансызлык белән сыный дөнья, Миражлары юлдан яздыра: Тәмнәр-тәннәр белән ымсындырып, Рәхәт биреп алдап аздыра.* Ш.Галиев. *Офыклар артындагы киңлек, андагы хөрлек – мираж гына ул.* М.Юныс. *Чалыш көзгеләр илендәме мин: Бии каршымда мираж-алдавыч.* Р.Низамиев

3) *күч.* Чынлыкта булмаган, уйдырма нәрсә; буш хыял, тормышка ашмас уйлар, теләкләр, өметләр. *Барган саен ерагайды Хыялдагы миражлар. Алда тормыш сиратлары Мине көтеп торганнар.* Ш.Маннапов. *Мираж, мираж – Ерак сөю илем. Мираж, мираж – Яшьлегем минем.* Л.Лерон

МИРАЖЛАНУ *ф. сир.* Мираж кебек кенә күренү. *Небит-Дагым минем, Аму-Дәрьям, Ни бар бездә – гүзәл шунысы: Миражланып яткан тыныч сахра, Каспиемның дымлы сулышы.* Ш.Мөдәррис

МИРАС *и. гар.* 1) Иясе үлгәннән соң башка кешегә күчә торган мал-мөлкәт һәм шуның белән бәйле милек хокуклары һәм йөкләмәләре. *Мирас булып күчкән байлыгы да, ил, халык ихтирамын казанып яуланган хокукы да булмаган бу бәндәләр ничек болай түргә үк узганнар соң?* Ш.Рәкыйпов. *Алтын җыйма, йортлар куйма, Мираска дип балаңа, Иң кадерле мирас итеп Туган телен бир аңа.* Р.Вәлиева

2) Мәдәнияттә, көнкүрештә һ.б.ш. элекке буыннардан, үткән чордан калган нәрсә, күренеш, гадәт. *Һәр нигезнең, һәр авылның, һәр каланың үткәне бар... Гыйбрәт алырлык мирасның калганы бар, киткәне бар...* Р.Фәйзуллин

3) *сөйл.* Алда эшләп киткән кешедән калган әйбер, шуның бүләге. *Ал, яшь егет, үткер кылычымны. Миннән сиңа изге мирас ул!..* М.Гафури

4) *күч.* Элеккедән, алдагы буыннан калган тискәре сыйфат яки күренеш. *Яхшы ата баласы дигән мактаулы исемнән дә кадерлерәк нинди мирас кирәк сиңа?!* Р.Ишморат. *Бу элекке буржуа җәмгыятенең әшәке мирасы безнең пролетар язучылары арасында юкка чыгарылырга тиеш!* Җ.Фәйзи. *Китмән белән җир эшкәртү, аркадагы капчыкка бала салып йөртү, хәер сорашу, фәкыйрьлек, пычраклык, авырулар – колонизаторлардан калган мирас әнә шул.* М.Мәһдиев

МИРАСНАМӘ *и.* Язма васыять. *Исән чакта мираснамәңне яз, Оныкларга тәти сатып ал, Кәфен-мазар хәстәрләүне уйла, Җәсәдеңә урын алып кал.* Г.Рәхим

МИРАСЧЫ *и.* 1) Мирас алучы; мирас алырга хакы булган кеше; варис. *Сөмбел авырга узып малай таба калса, Сәгыйтьнең фамилиясен дәвам иттерүче һәм тора-бара эшен үз кулына алып, аның мирасчысы булыр иде.* Ф.Яруллин. *– Так! Тәхет мирасчысының исеме кем? – Царевич Алексей.* З.Зәйнуллин

2) *күч.* Берәр шәхеснең эшчәнлеген дәвам иттерүче; билгеле ижади юнәлеш, традиция, сәясәт һ.б.ш.ның дәвамчысы. *Нинди бай һәм борынгы шигъриятнең мирасчылары без, иңнәребездә, йөрәкләребездә – никадәр җаваплы миссия!* И.Юзеев. *Ханнар, чыгышлары белән Атын Урда мирасчылары буларак, чыңгызыйлар нәселеннән сайлап куелган.* Н.Гариф

МИРАСХАНӘ *и.* Мәдәни, тарихи һ.б.ш. әһәмияткә ия булган кулъязмалар, китаплар кебек нәрсәләрне саклау урыны. *Бу эшләрне башлап җибәрү алдыннан, без, гадәттәгечә, мирасханәләрдә, фәнни китапханәләрдә «казындык», безгә кадәр үткәрелгән казылмалар, табылдыклар турында кызыклы мәгълүматлар тупладык.* Ф.Хуҗин

МИРАСЧЫЛЫК *и.* Элгәрнең мирасчысы (*2 мәгъ.*), дәвамчысы булу, алдагы буыннар белән эзлекле бәйләнеш. *Бу тарихи мирасчылык археологик ядкарьләр аша да күзәтелә.* Н.Гариф

МИРЗА *и. фар. тар.* 1) Кайбер төрки халыкларда өстен катлау вәкиленең титулы һәм шул титулга ия булган кеше. *Гәрәй мирзаның улы Җәлмәт, «бәхет эзләп» булса кирәк, Сембер ягыннан Чистай төбәгенә килеп чыга һәм Чирүле Шонталы авылына туктала.* И.Нуруллин. *Әбкәм ай-яй гаярь кеше иде. Азнакай ягыннан мирза кызы, бай нәселдән, диләр иде аны.* Ф.Яхин. *--- коллар, чуралар, мирзалар, казыйлар! Вә дәхи бөтен эчке вә тышкы даруга бәкләренә мәгълүм булсын ---.* Р.Батулла

2) Кайбер төрки халыкларда югары дәрәҗәдәге чиновник яки галимнең шәрәфле исеме, шуңа эндәшү сүзе

МИРЗАЛЫК *и.* 1) Мирза (*1 мәгъ.*) дәрәҗәсе. *Менә шуңа күрә дә татарның ул мирзалык катлавы берничә йөз еллар буенча үзләренең урыслашу фикерләрен саклап, гамәлдә урыслашып, сүздә бу хәлне урыс мәдәниятенең югарылыгы белән аңлатып, бер дәрәҗәгә хәтле көчле яшәп килделәр.* Г.Ибраһимов

2) Үзен тотыштагы, кыяфәттәге, кыланыштагы аристократлык. *Гөлсемнең мирзалык, аксөяклек каны сеңгән апасы (тутакай) Пашаны татарлыкта, затсызлыкта гаепли.* Х.Миңнегулов

МИРИА́ДА *и. гр. кит.* Чиксез күплек. *Сүзләр мириадасы... Хәтер ятьмәсенә эләккән кайбер асылташтай сүзләрне үзалдыма кабат-кабат әйтеп карыйм: борынгы заманнар кайтавазы яңгырап ишетелә.* М.Галиев

МИРОВОЙ *с. рус* **1.** Кайбер илләрдә кешеләр арасындагы төрле бәхәсләрне һәм вак җинаять эшләрен тикшереп хәл итүче гомуми юрисдикциядәге суд системасына караган. *--- казна урманыннан бүрәнә урлап тотылгач, мировой суд бер ай ятарга, унбиш сум штраф түләргә ясаган.* К.Тинчурин. *1889–1890 елларда ул, губернаторга, мировой судьяга, Казан психбольницасының директорларына һәм башка хакимият әгъзаларына төрле тупас сүзләр әйткән өчен, башта ике айга, аннан соң дүрт айга хөкем ителә.* Р.Вәлиев. *– Соң ул гараж өчен Хафизовлар мировой судьяга барып җиттеләр бит ---, – дип тәтелдәде сатучы.* Р.Ахунова

2. *и. мәгъ. сөйл.* Мировой судья. *[Мәрәк Фәсхи:] Табып китер миңа үз җиремдәге кызыл балчыкны, кәҗәсакалны. Югыйсә хәзер мировойга барам.* Ф.Хөсни

МИ́РРА *и. гр.* Бурзер семьялыгының коммифора ыругына караган тропик агачларның кайрысыннан алына, парфюмериядә һәм медицинада файдаланыла торган хуш исле сумала

МИРТ *и. гр. бот.* Миртлылар (мәрсидчәләр) семьялыгына караган, яфракларыннан эфир мае алына, җимешләре тәмләткеч буларак файдаланыла торган мәңге яшел агач яки куак. *Шушы ук ассемьялыктан сфагнум сазлыкларында күп яфраклы акчыл (Andromeda polifolia), гади саз мирты (Chamaedaphne calicu-lata), шулай ук гади талкан уты яки аю җиләге (Arctostaphylosuva-ursi) сирәк кенә очрый.* Л.Мәүлүдова. *Мирт дигән гөл микробларга каршы көрәшә һәм иммунитетны күтәрә торган матдәләр бүлеп чыгара.* Шәһри Казан

МИ́РТА *и. к.* **мирт**

МИ́РТЛЫЛАР *и. күпл.* Башлыча тропик һәм субтропик өлкәләрдә таралган, 3000 төр мәңге яшел куак һәм агачны берләштергән үсемлек семьялыгы. *Гаять зур агач – эвкалипт кебек үк, канәфер дә миртлылар семьялыгына керә.* Робинзон эзләреннән

МИС *и. фар. к.* **миски**. *Тавык кына түгел, сарык пеште Пот ярымлы мистә.* Ф.Гыйззәтуллина

МИСАЛ *и. гар.* 1) Башка кешеләр үрнәк алырлык зат яки охшарга, иярергә яраган эш-гамәл, күренеш. *Бүтән чакта Ленинны мисал итәсез, ә хәзер нигә аның әмерен онытасыз?* М.Хуҗин. *Гази Кашшафның дүрт дистә ел дәвамында әдәбиятка күрсәткән хезмәте – киң күңелле һәм кешелекле яшәешнең иң дәлилле мисалы.* Казан утлары

2) Берәр күренешнең ачык үрнәге, билгесе, чагылышы. *Мисалга ерак барасы түгел, әнә Чирмешән авылын гына ал.* В.Нуруллин. *Дәүләтнең финанс системасын җимерү мисаллары шулкадәрле дә күп иде ки, берзаман ул аларны билгеле бер системага кертеп язып бара башлады.* Р.Мирхәйдәров. *Минем редакторлык тәҗрибәсендә дә гыйбрәтле мисаллар җитәрлек иде.* Р.Низамиев

3) Кемгә яки нәрсәгәдер тиңләрлек башка бер объект, шуңа охшаш, иш нәрсә. *Уртада басып торасың, Әйләнмиме башларың? Карлыгачка мисал икән Синең кара кашларың.* Җыр. *Нуретдиннең йөзендә мисалы күренмәгән бер шатлык иде.* Г.Тукай. *[Рәис:] Без, иптәшләр, менә бүгенге кебек мәдрәсә яшьләре тормышының тарихында мисалы булмаган бер вакытка килдек.* Г.Ибраһимов

4) Билгеле фикер, караш һ.б.ш.ны аңлату, исбатлау, раслау өчен китерелә торган берәр факт, дәлил, аргумент. *Белеп тор: мин явыз түгел, әмма усал, Бөтен гомерем булыр шуңа ачык мисал!* Л.Шагыйрьҗан

5) Берәр фикергә дәлил итеп китерелгән үрнәк, сүз, цитата һ.б.ш. иллюстратив материал. *Ясалма, тәмсез, пешмәгән җырларга --- 2–3 мисал китереп була.* М.Җәлил

6) Математик гамәлләрне үзләштерү өчен бирелә торган мәсьәлә. *Без бит әле ул чак, тик сүз тыңлап, Мисал чишкән, шигырь ятлаган.* Ә.Рәшит. *Ә без мәктәптә телләребез арып беткәнче дәрес сөйлибез... Бары тик математикада гына рәхәт: мәсьәлә һәм мисалларны чишәсең дә чишәсең.* Ф.Яхин

7) Нәрсәне дә булса өйрәнүгә ярдәм итә торган күнегү. *Катя аңа һәр мисалны иренмичә, аерата зур түземлелек белән аңлата һәм, русча сөйләгәндә, татарчаны онытып торырга куша иде.* Г.Әпсәләмов

МИСАЛЛЫ 1. *с.* Мисалы булган, мисал белән бирелгән; мисал булып торган, мисал хезмәтен үтәгән. *--- мәкальләр --- үзләренең күп мәгънәле һәм мисаллы булулары белән яки трибунлык һәм тәрбияви-әхлакый карашлары белән безгә тормышны да үзебезчә эшкәртергә, төзергә, үзгәртергә корал булып хезмәт итеп киләләр һәм киләчәкләр.* Н.Исәнбәт. *--- бер генә мисаллы ыбыр-чыбыр арасына (андыйлар 3б) Дәрдемәнд, Бабич, Ф.Әсгать, М.Галәү, М.Максуд, Ш.Усманов, Н.Баян кебекләр элеккән.* Х.Сарьян

2. *бәйл. функ. иск.* Кебек, шикелле. *Заман явызлар заманы булса, адәмнәре бүре мисаллы булырлар.* Мәкаль. *Ул – сүзгә оста кеше, фараз итәр дә җавап бирер; бәлки, артыграк ышандырыр өчен, өч бармагын бергә оештырып (төрекләр мисаллы) күзгә төртеп тә сөйләр ---.* Г.Тукай. *Май кеби йомшак, сандугач сайравы мисаллы моңлы вә мөлаем тавышлары таң йиле рәвешендә җанымны рәхәтләндерә иде.* Р.Фәхретдин

МИСВӘК *и. гар.* Хуш исле үзагачлы агачтан бер очы пумала итеп ясалган таякчык рәвешендәге, гадәттә Гарәбстаннан алып кайтылган теш чистарткыч. *Бу хатларны мин бик матурлап, төсле карандашлар белән мәчет, комган, тәсбих, мисвәк сурәтләре төшереп, шигырь белән яза идем.* Т.Гыйззәт. *Ниләр генә булмый аның кырык тартмасында! Бадъян, дарчин, мисвәк, канәфер, инә, уймак, кармак, сәдәпләр, төймәләр, эскәк, поташ... тагын әллә нәрсәләр.* Г.Бәширов

МИСЕЗ *с.* **1.** *кимс.* Аңгыра, тиле, тинтәк, миңгерәү. *Син, әйтсәм әйтим инде, шундый бозау, мисез бер ир белән теләсәң ничек уйнар өчен, безнең монда булуыбызны теләмисең.* Г.Камал. *Мисез Гитлер белми башка телне, Кан һәм сөрем – теле төбендә. Сөйләшергә калды аның белән Хәзер бары туплар телендә.* М.Җәлил. *Бу мисез башларга җентекләп аңлаттым бит инде. Ничек итеп мондый эштә даими элемтә кирәклеген аңламаска?* М.Юныс

2. *и. мәгъ.* Мидән башка, ми булмаган очракта. *«Мин» ди кеше үзен. Шушы сүзнең эче тулы ми. Мисез «мин» булмаска тиеш...* Ш.Галиев

МИСЕЗЛЕК *и.* Аңгыралык, акылсызлык. *Партия куштаннары үзләренең мисезлеге белән данлыклы иделәр.* М.Юныс

МИСК *и. фар.* Кайбер хайваннарның (мәс., ата кабарганың) бизләреннән яки үсемлекләрдән (шома көпшә тамыры, гибискус орлыгы) алына, парфюмериядә киң кулланыла торган көчле исле матдә, мускус

МИСКИ *и. рус сөйл.* 1) Кәстрүл. *Шуннан читтәрәк, кырын яткан әрҗә эчендә миски һәм савыт-сабалар.* З.Фәйзи. *Пешка тиз арада кешегә ияләшә, аларның артларыннан йөри башлый, борыны белән мискигә яисә чиләккә килеп тыгыла, үзенә игътибар итмәсәләр, тояклары белән тибенә.* Дөньяда ниләр бар. *Кайчакларны, тәмам дөньясын онытып, алдында яткан миски белән футбол уйнарга керешә [Актырнак].* Мәгърифәт

2) Табак, тәлинкә. – *Ачтан үләсең килмәсә, күнегерсең әле, – диде Миша, кургаш миски төбен тыкырдатып.* Җ.Тәрҗеманов. *Күбесе, кулы пешеп, мискине җиргә төшереп җибәрә.* Ә.Галиев. *Өстәл артына утырып, иптәшләре порциянең яртысын да ашарга өлгерми, ул [Белобородов] инде миски тотып «амбразура»ны каплый.* Р.Кәрами. – *Мискиеңә аш салырга калдырмагансың ич, яньчеп бетергәнсең бит, – дим.* Мәгърифәт

МИСКИ-ТӘЛИНКӘ *җыйл. и.* Эреле-ваклы савытлар. *--- шул ук Гөлбикә, Хөппениса, Миңниса түтәйләр пешерүен дә пешерә, миски-тәлинкәләргә салып та бирә иде.* Ф.Баттал

МИ́СЛЕ *бәйл. гар. иск.* **1.** Кебек, күк, рәвешле, шикелле, төсле, сыман. *Тәмам ундүрткә җиткәнендә Хөсрәү,*

Гыйлем кунды аңарга мисле Сәмрәү. Котб. *Тынычландык, мисле алаша без, Хөкүмәтне эчтән эттәй сүгеп, Хатын белән тәмләп талашабыз.* Н.Әхмәдиев. *Аралашуыбыз, чукраклар мисле, тегендә төртеп, монда күрсәтеп.* Т.Галиуллин

2. *и. мәгъ.* Нәрсәнең дә булса мисалы, үрнәге, очрагы. --- *мин моны яздым, бу – гыйшкым миследер; Чөнки гыйшкым нәкъ минем шул төследер.* Г.Тукай. *Бөтен илне каплап алган, тарихта мисле булмаган бу золмәт бик тиз Сталинның үзенә дә, тоткан юлына да ышанмау, килешә алмау, җан газабы, хәтта яшерен нәфрәт тә тудырды.* Ә.Еники

МИСРАГ *и. гар. кит.* Шигъри юл. *Соңгы мисрагны алар Солдат белән икәү күтәргән иделәр, Гариф та кычкырып җибәрде ---.* Ш.Камал. *Инде бу саналган ритмик берәмлекләрнең ни дәрәҗәдә бай һәм төрле шигъри юллар, алымнар, мисраглар тудырырга мөмкинлек бирүләренә тукталу әһәмиятле.* Н.Исәнбәт. *Әсәр [«Кисекбаш китабы»] күләм ягыннан 300 мисрагтан артмый.* Х.Миңнегулов

МИСС *и. инг л.* 1) Инглиз телле илләрдә кияүгә чыкмаган хатын-кызны атау һәм аңа эндәшү сүзе. *Кинотеатрда «Мисс Менд» исемле мажаралы фильм бара иде.* Ф.Хөсни. *Мисс Сафия? --- Беренче сандагы язманы күрсәтүегезне үтенәм.* И.Юзеев. *Мисс Селли куркуыннан баскан урынында катып кала.* Р.Мөхәммәдиев

2) Патша Россиясендә: югары катлау гаиләләрендә балалар тәрбиячесе булып эшләгән инглиз хатын-кызы, гувернантка

3) Чибәрлек конкурсында җиңгән кыз. --- *без «Мисс Калькутта – 1974» дигән мактаулы исемгә дәгъва кылучы Маринаның биюен күрдек.* М.Мәһдиев. *Хәзер чибәрләр конкурсы уздырабыз. Мисс класс!* Аманулла. *Әгәр мин ике-өч көн элек «Мисс – 2005» дигән фотокүргәзмәгә кермәгән булсам, Мәхүбеч белән икебезнең арадан җил дә үтәсе түгел иде.* Ф.Баттал

МИССИОНЕР *и.* 1) Дингә ышанмаучыларны яки башка диндәге кешеләрне үз диненә җәлеп итүче кеше. --- *патша хөкүмәте һәм аның христиан миссионерлары телнең хәзинәсе, сакчысы булган милли китапка каршы көрәштеләр.* Ә.Кәримуллин. *Без, җылый-җылый, бәетләр укыйбыз: имеш, Иван патшаның миссионерлары татар халкын елга буйларына этеп китереп, мәҗбүри чукындырган, христиан диненә керткән, кан кою, елашыңгыраш булган.* Р.Низамиев. *Сүзлек --- татар телен белүче миссионерлар әзерләү максатын күздә тотып төзелгән.* Мәгариф

2) *күч.* Берәр мөһим фикер үткәрү, җаваплы бурыч башкару өчен сайланган, билгеләнгән кеше. *Автор сагаерга тиеш ---. Димәк, ул (драматург) мөһим фикер уздыручы миссионердан тамашачыга хезмәт күрсәтүчегә әверелеп бара.* Ә.Зарипов

МИССИОНЕРЛЫК *и.* Миссионер эшчәнлеге. *Монда революциягә кадәр христиан миссионерлыгы үзәге һәм шул ук вакытта аң-белем учагы да булган церковно-приходская школа эшләгән.* Х.Мәхмүтов. *Чукындыру контуры ябылгач та, Димитрий Сеченов миссионерлык эшен дәвам итә, аны камилләштерү өчен төзелгән махсус комиссия җитәкчесе була ---.* Ф.Ислаев. *Патша Россиясендәге миссионерлык хәрәкәте татар телен белүне талән итә.* Мәгариф

МИ́ССИС *и. инг л.* Инглиз телле илләрдә кияүдәге хатынны атау һәм аңа мөрәҗәгать итү сүзе. *Бер тапкыр шундый «кунак»ка барганда, тышына «Миссис Мансурова» дип язылган папканы үзе алып укыган Ләйлә.* М.Маликова. *Зур шәһәр туйдыргач, ул әлеге «миссис» белән икесенә махсус самолёт алып, Балеар утрауларына ял итәргә китә.* Р.Низамиев. *Үзегезнең эшегезне төгәлләгәннән соң, үзегез я, булмаса, миссис Пигденның аска төшеп регистрация үтүен сорар идем.* Д.Салихов

МИ́ССИЯ *и. лат.* 1) Йөкләмә, йомыш, тапшырылган эш. *Дәү-дәү саллы тартмаларны --- Иван Иванович квартирына кертеп урнаштырдылар. Йөкчеләрнең миссиясе шуның белән тәмамланды.* А.Гыйләҗев. *Миссиям бик җаваплы. Соңгы араларда урамга түгел, капка төбенә дә бик сирәк кенә үз аягы белән чыга алган әбиемне, культыгыннан тотып, түбән очка – Әкбәр бабайларга кунакка алып төшү.* Р.Мөхәммәдиев. --- *иптәшләр, шушы җаваплы һәм мактаулы миссияне өстегезгә алу белән тәбриклим.* М.Юныс

2) *юг.* Берәр шәхеснең, катламның һ.б.ш.ның тарих, җәмгыять, үз милләте алдындагы зур, катлаулы һәм җаваплы бурычы. *Хәрбиләрнең кызу эш өстендә авыл хуҗалыгына ярдәм итүе безнең кораллы көчләрнең бик гуманистик миссияләреннән берсе инде ул.* М.Мәһдиев. *Бәхеткә каршы, урта буын үз өстенә төшкән миссиянең нихәтле җаваплы булуын тиз аңлады: төпкә җигелеп, безнең прозаны алга тарта башлады.* Ф.Миңнуллин. *Аның бу җыры гади генә җыр түгел кебек, дөресрәге, ул үзе гади генә, кешечә генә җырламый, ниндидер мөһим, хәтта илаһи бер эш башкарган кебек, хәлиткеч миссия үтәгән кебек җырлый ---.* Г.Гыйльманов

3) Бер дәүләтнең икенче илдәге илче яки вәкил җитәкчелегендәге даими дипломатик вәкиллеге. --- *Ю.В.Андропов ярдәм кулы суза, ул [Камалов] Вашингтонга, АКШтагы совет миссиясенең куркынычсызлык хезмәтен җитәкләргә җибәрелә.* Р.Мирхәйдәров

4) Икенче илгә билгеле бер эш белән җибәрелгән вәкиллек, делегация. *Бабайларыбыз заманында бик зур миссия белән барганнар, дәүләт күләмендәге йомышлар үтәгәннәр.* М.Мәһдиев. *Сәүдә миссиясе. Хәрби миссия*

МИ́СТЕР *и. инг л.* Инглиз телле илләрдә ир-атка, гадәттә олырак кешегә мөрәҗәгать итү сүзе. *Шанхай каласының баш хөкемдары мистер Джордж Джеймсон, бик телә п, минем тәүге язмаларымны карап, төзәтеп чыкты һәм китапны бастырганда да күз уңында тотты.* М.Хәбибуллин. *Сез, өегезгә кайтып җиталырмын дип, үз көчегезгә ышанасызмы, мистер Пигден?* Д.Салихов. *Лупа булмаганда, утны «Серле утрау»дагы мистер Сайрес Смит ысулы буенча, өстенә су салынган ике сәгать пыяласын бергә куеп табарга мөмкин.* Робинзон эзләреннән

МИ́СТИК I *и. гр.* Мистицизм карашларында торган кеше. *Мин үземне мистик түгел, реалист дип уйлыйм.* Б.Урманче. – *Сез – хыял кешесе, мистик! – Шулайрак шул. Мистик. Мин – сезнең янга киләчәктән килгән кеше.* Р.Батулла. *Шәмсе Тәбризи – XII гасыр ахыры – XIII гасырның беренче яртысында яшәгән суфи шагыйрь, мистик Шәмсетдин Мөхәммәд Тәбризи. Җәлалетдин Руминың якын дусты һәм остазы.* Кол Шәриф һәм аның заманы

МИ́СТИК II *с.* Мистикага нигезләгән; мистицизм белән бәйле. *Бердән, мистик, икенчедән, фантастик бу әсәргә ышанмаска да була.* Ә.Еники. *Әмма бу тема [күк темасы] ниндидер катып калган, абстракт яисә мистик тема да түгел.* Р.Зәйдулла. *Фәнни ачышларның бик тиз таралуы, аларны производствога кертү, иҗтимагый җитештерү һәм идарә итүдә хезмәт ияләренең аңлы төстә катнашулары дөнья турында мистик карашларның кире кайтаргысыз булып артта калуына, безне чолгап алган табигать күренешләре турында башка сыймаслык хыялый күзаллауларның юкка чыгуына китерә.* Галәм. Җир. Кеше

МИ́СТИКА *и. гр.* Илаһи көчләр белән турыдан-туры бәйләнеш урнаштыру өчен башкарылган махсус дини гамәлләр һәм моны мөмкин дип раслаган теологик һәм фәлсәфи доктриналарның барлыгы. --- *мистика юк монда. Мин үземне мистик түгел, реалист дип уйлыйм.* Б.Урманче. *Көләсең? Мистика дисең? Баштагы тыныч көннәремдә үзем дә шулай дидем.* К.Тимбикова. *Андагы метафораларның үзенчәлеге, алардагы сыйфат, андагы сүз музыкасы, моң, тылсым, мистика – нәрсә генә тапмыйсың бу [Р.Әхмәтҗан] иҗатта.* М.Юныс

МИСТИФИКА́ТОР *и. лат. кит.* Мистификацияләр яратучы, мистификация остасы; уйдырма сөйләүче, ялганчы

МИСТИФИКА́ЦИЯ *и. гр. кит.* Теге яки бу максат белән алдау, ялгыш фикер тудыру; саташтыру, бутау. *Бу, әлбәттә, бернинди мистификация түгел, мистика юк монда.* Б.Урманче. *Мистификация остасы да әле ул [Л.Лерон].* Р.Зәйдулла

МИСТИЦИЗМ *и. фр. кит.* Чынбарлыкны акыл белән түгел, мистика аркылы гына аңлап һәм аңлатып була, дигән карашларга нигезләнгән фикер йөртү рәвеше. --- *бик күпләрдә, шул исәптән Европаның үзәгендә торган француз әдәбиятында да, хәтсез генә мистицизм үрнәкләрен табарга мөмкин.* Ф.Галимуллин. *Хәтта аның бик кыю, уткен әйтелгән тостлары да дини мистицизм белән өртелгән була башлаган иде.* Р.Мирхәйдәров

МИСТРАЛЬ *и. фр. геогр.* Көньяк Франциядә таулардан искән көчле салкын төньяк яки төньяк-көнбатыш җил. *Ә планетада пассат, муссон җилләре, әфганлы, харара, сәмум, мистраль, трамонтана, тайфун, торнадолар... Аларның туктарга исәпләре юк әле.* М.Юныс

МИСЫ́Р БОДАЕ *и. иск.* Кукуруз

МИСЫ́Р КҮГӘРЧЕНЕ *и. зоол.* Күгәрчен кошлар семьялыгының яшел күгәрченнәр ыругына караган яшькелт сары төстәге кечкенә кош. *Мисыр күгәрчене кебек гөрләп, Бәдәр балаларны янбакчага алып чыкты, һаман бер сүзне тугылады.* А.Гыйләҗев. *Ни барына ризалык итеп тукланганыннан соң, Мисыр күгәрченнәредәй гөрләшеп өстәл башында утырган теге яшьләрнең үзләрен генә калдырып, аштан соң зиһенгә файдасы тияр, дигән уй белән һавага чыкты.* Ф.Яхин. *Зөлфәт. Ни бар ул хәтле сөенерлек? Гөлчирә. Бер кош очып килде. Зөлфәт. Нинди кош? Сабира. Асыл кош. Мисыр күгәрчене.* Г.Сабитов

МИСЫРЛЫ *и.* Мисырда туып үскән яки шунда яшәүче кеше. *Шул чак үзара бәйләнеш тоту һәм суның җимергеч көченнән саклану өчен, борынгы мисырлылар дамбалар һәм буалар төзергә мәҗбүр булганнар.* Ж.Тәрҗеманов. *Борынгы фарсылар, шумерлар – таш һәм балчык таблицаларга, греклар, римлылар – балавызлы такталарга, мисырлылар – папируска, славяннар – тузга, кайбер башка халыклар пергаментка һ.б. язганнар.* Ф.Сафиуллина. *Сөннәрнең үлгәннән соң яшәүне күзаллавында һәм күмү йолаларында мисырлылар белән уртаклык бар. Шулай да, һичшиксез, сөннәрнең күмү йоласы Мисырныкына караганда күпкә тыйнарак була.* Г.Фәйзрахманов

МИСЫ́Р ТАВЫГЫ *и. зоол.* Мисыр тавыклары семьялыгына караган, соры төстәге, башында мөгезсыман үсентесе булган, тавыктан зуррак йорт кошы; *русчасы*: **цесарка**

МИСЫ́Р ТАВЫКЛАРЫ *и. күпл. зоол.* Тавыксыманнар отрядыннан Африка һәм Мадагаскарда таралган кошлар семьялыгы

МИСЫ́Р ТАРЫСЫ *и. бот.* Кыяклылар семьялыгыннан, тропиклардан алып урта поясларга кадәр таралган, культуралы игелгән төрләреннән шикәр, он, буяу һ.б. алына торган кукурузга охшаш үлән үсемлек; *русчасы:* **сорго**

МИ́ТИНГ *и. инг.* Нинди дә булса мөһим, гадәттә сәяси мәсьәләгә бәйле җыелган халык җыены, массалы төстә узган зур җыелыш. *[Дим буенда] уен-көлке күләгәсе астында митинг – маёвка башлана.* Х.Садрый. *Ул [Ә.Афзалова] халык мәхәббәтен, митингтан митингка чабып, кызыл сүзләр кычкырып түгел, ә авылдан авылга, шәһәрдән шәһәргә ерак юллар гизеп, туган халкын моң белән сугарып яулап алды.* Л.Шагыйрьҗан. *Бездә сәяси митингны еш кына тамашага әйләндерәләр.* Р.Низамиев

МИТКАЛЬ *и. фар.* **1.** Эшкәртелеп бетмәгән, шуның нигезендә ситсы, муслин һ.б.ш. тукымалар эшләнә торган тупасрак юка киже-мамык материал

2. *с. мәгъ.* Шул тукымадан тегелгән. --- *бер уч кәнфит, прәннек белән читенә ак мишура ука тоткан чуклы яшел миткальдән эшләнгән, башка чап итеп ябышып ята торган бер яшел миткаль кәләпүш миңа да эләкте.* Ш.Камал

МИТОХО́НДРИЯЛӘР *и. гр. күпл. биол.* Күзәнәкләрне энергия белән тәэмин итә торган оксидлашу-кайтару реакцияләре барган органоидлар. *Эукариотларның күзәнәкләрендә аларга хас булган барлык органоидлар да бар: эндоплазматик челтәр, диктиосома, рибосома, лизосома, митохондрия, диктиосома, берничә вак яки үзәк вакуоль.* Л.Мәүлүдова. *Күзәнәктәге*

ферментларның күпчелеге митохондрияләргә – бер-берләреннән бүлгеләр белән аерылган махсус тәнчекләргә тупланган булып чыкты. Химиянең киләчәге. *Мәсәлән, рибосома дип аталган органоидта аксымнар хасил була, митохондрияләрдә энергия чыганагы булып хезмәт иткән матдәләр эшләнә.* Биология: кеше һәм аның сәламәтлеге

МИТРОПОЛИТ *и. гр.* Православиедә һәм католицизмда архиерейләрнең иң югары дәрәҗәсе һәм шул дәрәҗәгә ия булган кеше. *Сул кулда митрополит өе: зәп-зәңгәр күк гөмбәзе астында аның ак сыны күзне чагылдыра.* З.Фәтхетдинов. *Казан алыну хөрмәтенә уздырылган «изге» җыенда Иван Грозный митрополит Макарий каршында ясаган чыгышында үзенең күп хәрби җитәкчеләрен (воеводаларын) татар шәһәрләре һәм җирләрендә урнаштырып калдыруы турында сөйли.* Н.Гариф. *Митрополит Макарий кулыннан бер генә мөселманның да чукынмыйча исән калганы юк әле.* Р.Зәйдулла

МИТРОПО́ЛИЯ *и. гр.* Чиркәүнең митрополит идарәсенә караган административ берәмлеге. *Текстны төзүче һәр кулай очракта митрополия кафедрасы биләмәләрен искә ала ---.* Б.Хәмидуллин. *Киев митрополиясе*

МИФ *и. гр.* 1) Борынгы халыкларның дөньяның барлыкка килүе, табигать күренешләре, илаһлар, легендар батырлар һ.б.ш. турындагы риваятьләре. *Әнә борынгы греклар заманындагы фаҗигале бер миф берничә йолдызлыкка сыеп беткән.* М.Юныс. *Бер борынгы грек мифында аконит, тәмуг капкасын саклаучы Цербер дигән этне Геркулес упкыннан сөйрәгән чакта, этнең авызыннан тамган күбектән үскән, дип сөйләнелә.* Галәм. Җир. Кеше. *Антик мифларда кешеләр ташлап киткән һәм кыргый җанварлар тарафыннан тәрбияләп үстерелгән игезәкләр дә очрый.* Кызыклар дөньясында

2) *күч.* Уйдырма, чынбарлыкка туры килми торган фикер, караш, теория. *Мифларны яратабыз без. Дөреслекне миф белән сыеклагач кына мәсьәләне әзрәк аңлый башлыйбыз, һәм җаныбыз тынычланып китә.* М.Юныс

МИ́ФИК *с.* 1) Мифка нигезләнгән, мифтан алынган. *Әлеге кабиләнең тотемы, ягъни мифик бабалары, нәсел башы, күрәсең, каз булгандыр, ди Һ.Йосыпов, чөнки борынгы кабиләләр кошкортларны (мәсәлән, торна, аккош, каз һ.б.), төрле хайваннарны (бүре, барс, аю, поши һ.б.) еш кына үзләренең тотем-бабалары итеп санаган.* Ф.Хуҗин. *Бүгенге әдипләребез мифик Фениксның легендар-әкияти асылына да, кучерелмә мәгънәсенә дә тирән тарихи, иҗтимагый, фәлсәфи мәсьәләләрне масштаблы итеп күтәргәндә мөрәҗәгать итәләр.* Х.Мәхмүдов

2) *күч.* Әкияттәге, мифтагы кебек. *--- тракторның мифик куәте турындагы легенда утызынчы елларда, ул машина әле авылда үзе күренгәнче үк килеп җитте.* М.Мәһдиев

3) *күч.* Бернинди реаль нигезе булмаган, чынбарлыкка туры килмәгән, уйлап чыгарылган, уйдырма. *Җитмеш елга сузылган большевистик режим шартларында халыкларның (200 милләт, этносның) менталитеты бөтенләй инкяр ителде, тәрбиячеләр ниндидер мифик «коммунистик җәмгыять» шәхесе формалаштыру белән «шөгыльләнде» ---.* М.Әхмәтҗанов. *Урта Идел, Әстерхан, Кырым, Себер һ.б. регионнарда яшәүче хәзерге татарларның этник нигезен монголлар белән, хәтта аңа кадәр үк килгән мифик татарлар белән бәйләү фәнни яктан исбатланмаган.* Ф.Хуҗин. *Без битараф, салкын канлы булгач, Телебезне хәтта кисәләр. Түзәрбезме, мифик дәүләт теле – Татар теле – юк ул, дисәләр?* Ә.Хәсәнов

МИФО́ЛОГ *и. гр.* Мифология (*2 мәгъ.*) белгече

МИФОЛОГЕ́МА *и. гр. фольк.* Дөнья халыкларының культурасында киң таралган, үзләренең гомумилеге, универсальлеге, хәтта глобальлеге белән аерылып торган мифологик сюжет, вакыйга, образ кебекләрнең гомуми атамасы. *Шигырьнең беренче строфасында шагыйрь бу мифологемаңы аксиома итеп алып, икенче строфада аны димифологемага әверелдерә.* А.Шәмсутова

МИФОЛО́ГИК *с.* Мифологиягә мөнәсәбәте булган, мифологиягә караган // Эчтәлеген, асылын миф тәшкил иткән, мифка нигезләнгән. *Мифологик сюжетлар, символлар дәвере узып, әдәбият гадәти ярларына кайтып төшә, тышкы киеренкелекне, куе хиссилекне эзлеклелек алыштыра.* Т.Галиуллин. *Китап күренекле рәссам, мифологик образлар иҗат итү остасы Әхсән Фәтхетдиновның гаҗәеп серле рәсемнәре белән бизәлгән.* Мәдәни җомга

МИФОЛО́ГИЯ *и. гр.* 1) Билгеле бер чорга, дингә яки халыкка караган мифлар (*1 мәгъ.*) җыелмасы, мифлар системасы. *Безнең теплоход борынгы грек мифологиясенең туган якларына – Мәрмәр, Эгей диңгезләренә таба юл тотты.* М.Мәһдиев. *Шунысы кызык: грек мифологиясендә кеше язмышы эрләнгән җеп сурәтендә бирелә.* М.Юныс. *Борынгы римлылар мифологиясендә Венера – матурлык белән мәхәббәт алиһәсе.* З.Фәйзи

2) Фольклор фәненең мифларны (*1 мәгъ.*) өйрәнә торган тармагы. *Аның шигырьләре, иҗтимагый актуальлеккә ия булган күп санлы поэмалары әхлак, этнопсихология, мифология, милли характер һәм милли үзаң, халык педагогикасы мәсьәләләре белән кызыксынган галимнәр өчен дә кызыклы.* Р.Харис

МИХӘФФӘ *и. гар*. Дөя, фил яки башка хайваннарның аркасына куела торган өсте (кайчакта һәр ягы) бөркәүле носилка яки утыргыч; паланкин. *Вә Кайсны михәффәгә куеп, Кәгъбәгә рәван улдылар*. Дастан

МИХНӘТ *и. гар.* 1) Тормыш-көнкүрештәге мохтаҗлык, тарлык, шул сәбәпле туган газаплар, авырлыклар, кыенлыклар. *Узар юлларыма бер карасам, Йөз кат хисап бирәм узганыма. Узган көннең күргән рәхәте дә, Авыр михнәте дә кызгандыра.* Ф.Гыйззәтуллина. *Сугыш елларын зур михнәт, югалтулар белән үткәргән, йончыган авылда күңелсез караңгылык.* З.Зәйнуллин. *Киндер сөлге ирләр беләгендә – Михнәтләрне сала әйләндереп.* Х.Әюп

2) Юксыллык, ярлылык, хәерчелек, фәкыйрьлек, мохтаҗлык. *Сөямдерме авылны, әллә халкымны яратаммы?*

Я әллә ярлылык, михнәтләреме тарталар җанны?! С.Сүнчәләй. *Иделгә йөреп баржа бушатты, укудан соң төзелештә кирпеч ташыды, кыскасы, михнәт дигән котсыз нәрсәне хәләл көче, тырышлыгы белән җиңде [Гайнан].* М.Насыйбуллин

3) Гомумән, яшәештә, көнкүрештә кеше кичергән авырлык, кыенлык, газап, мәшәкать. *Адәм баласы михнәткә түзә, рәхәткә түзми.* Мәкаль. *Өстеңә бомба явып торганда, Хайфон рейдында баржага снаряд ташуның тәмен, АКШ крейсерларының сиңа снаряд төкерергә торган көпшәләре астыннан узып, Кубага ракета ташу михнәтен дә белә торгандыр ул, бәлки?* М.Юныс

◊ **Михнәт күрү** Гомере җиңел булмау, кыенлыклар күп кичерү. *Сөйләп бетергесез михнәтләр күреп, инде тәмам өметне өздек дигәндә, алар җиргә килеп җиткәннәр.* М.Маликова. **Михнәт чигү** *к.* **михнәт күрү**. *Ташламаган, ваз кичмәгән өчен, Азмыни сез михнәт чиккәнсез...* Х.Туфан. *Сугышның, аннан соңгы елларның бар михнәтен чиккән өлкән яшьтәге бу ханымнарның иңнәренә затлы тун салдылар.* Мәдәни җомга

МИХНӘТЛӘНҮ *ф.* Интегү, җәфалану; газап чигү, михнәт күрү. *Утызынчы елларда качып киттегезме, шунда михнәтләнегез, диләр!..* А.Хәлим. *И-и, үзләре алар [Исламия һәм Хәлил Мәхмүтовлар] балаларны бик михнәтләнеп үстергәннәр иде.* Сәхнә

Михнәтләнеп йөрү Озак вакытлар михнәтләнү. *Шул кәгазьләрне җыям дип, ай буе михнәтләнеп йөргән бит...* Сөембикә

МИХНӘТЛЕ *с.* Авырлыклары, кыенлыклары күп булган. *Кап-кара икмәк кисәге – нигъмәтең, Иң авыр, михнәтле – белгән хезмәтең.* С.Сүнчәләй. *Диңгез-океаннарда йөзгәндә, һавада очканда, гел җир, андагы михнәтле авыр һәм газиз тормыш, җирдә калган якын кешеләреңә турында уйлыйсың.* М.Юныс

МИХНӘТСЕЗ *с.* **1.** Җиңел, җайлы; мәшәкатьле, кыен булмаган. *Михнәтсез юл истә калмый торган була шул ул.* Р.Вәлиева

2. *рәв. мәгъ.* Борчу-мәшәкатьсез, җиңел генә; җайлы гына; бик күп физик һ.б. көч түкмичә. *Михнәтсез кергән мал исәпсез китәр.* Мәкаль. *Ләкин олы эшләр михнәтсез генә бармый икән шул: адәмнең бакчасына корт төшкән, бар җимешне шулар ашап бетерә икән.* З.Мурсиев. *Кеше, бер яктан, авырлыклар сез, михнәтсез, тыныч кына яшәмәкче була, ә икенче яктан, авыр кичерешләрсез, михнәт чикми яши алмый, хәтта аларны үзе эзли дә.* Фән һәм тел

МИХНӘТТӘШ *с. сир.* Бердәй михнәт күрүче; бергә кыенлык, газап кичерүчеләрнең берсе. *Муса аны һаман да бары тик һәйбәт, акыллы кыз итеп, якташ һәм михнәттәш дус итеп ярата иде.* Ш.Маннур. *Исән түгел микән аның михнәттәше Талип Сибгатуллин?* А.Хәлим

МИХРАБ *и. гар. дини* 1) Мәчетнең кыйбла ягындагы диварында булган һәм имам өчен билгеләнгән уем яки керентеле урын. *Тиз үк михраб ягыннан тамак кырган тавыш ишетелде.* Г.Бәширов. *Азан тәмамлангач та, башка вакыттагы кебек михрабына ашыкмады хәзрәт: әйтелмәгән сүзе кала бит!* И.Сиражи. *Мәчетнең михрабы сәхнә төслерәк итеп ясалган да, анда әле хәзрәтләр вәгазь сөйли, әле фәс кигән ирләр мөнәҗәт әйтә.* Мәдәни җомга

2) *күч.* Иң мөһим, әһәмиятле урын; түр; изге урын. *Ипташең шагыйрь генә бассын аяк михрабыңа.* Г.Тукай. *Ватанның михрабы буш тора, Юк анда Алла да, Иблис тә.* Г.Афзал

МИһАһАЙ *иярт.* 1) Ат кешнәгән тавышны белдерә. *Сабый әйтә: – Muhahай! – Mhay! Mhay! – ди бахбай...* Л.Лерон

2) Ат кешнәвенә охшаш тавышны белдерә. *Хатын-кызның шул инде, бервакытта да алар сиңа сөям, яратам дип әйтмәс, һаман боргаланырсыргаланыр, uhahай да muhahай килер.* Т.Гыйззәт. *Чаптырып агач атта, Карамыйча як-якка, «Muhahай!» – дип шатланып, Энем килә атланып.* Р.Шәехова

МИһАһАЙЛА́У *ф.* 1) Кешнәү. *Айгыр кинәт muhahайлап кешнәп җибәрде, һәм бераздан инде ул киң ботакларын җәеп утырган карт карама агачы күләгәсенә кереп туктады.* М.Хәсәнов. *Ат ал аяклары белән тибенеп алды, muhahайлап кычкырды һәм салмак кына тирбәлә-тирбәлә һавага күтәрелде.* Р.Хафизова

2) Ат кешнәвенә охшаган, muhahай иткән авазлар чыгарып кычкыру яки ямьсез көлү. *Ашыгыч эш белән барып ишеген ачсам, ат кебек muhahайлап идәндә дүрт аякланып йөри, өч баласы менеп атланган...* Ш.Галиев

Muhahайлап җибәрү Кинәт muhahайлау. *Шулвакыт, без чыкканны гына көткәндәй, кара айгыр muhahайлап җибәрде.* А.Гыйләҗев

Muhahайлап кую Бер тапкыр гына muhahайлау. *Мине күргәч, Карлыгач muhahайлап куйды.* Ялкын

Muhahайлап тору Сөйләү моментында muhahайлау. *Muhahайлап торган атка таба карый да елмая, карый да елмая, бар шатлыгы шул гына диярсең ---.* Азат хатын

МИһЕРБАН *и. фар.* Йомшак күңел, мәрхәмәт, рәхим-шәфкать, кешелеклелек. *Ата-бабадан калган миһербан үзе шулай куша.* Ә.Баян. *Даладан миһербан көтеп булмый, иң башлап ипле мөнәсәбәт кирәк аңа...* М.Хуҗин. *Карап торам, күзеңдә мыскал да миһербан әсәре юк бит син шайтанның...* А.Хәсәнов

◊ **Миһербан иясе** Рәхимле, шәфкатьле, яхшы күңелле кеше турында. *Режиссёрларның уңышына сөенә, ямanына көенә торган киң күңелле, миһербан иясе була ул [К.Тинчурин].* Р.Батулла. **Миһербаны килү** Күңел йомшару, шәфкатьлеләнү. *Әтинең миһербаны килде, соң булса да, үз хатасын тануын әйтте.* Г.Галиева

МИһЕРБАНЛЫ *с.* 1) Шәфкатьле, мәрхәмәтле, кешелекле, яхшы күңелле. *Ни генә димә, хатын-кыз заты ир-атка караганда миһербанлырак.* Г.Ахунов. *Рабигадай нечкә күңелле, сизгер, саф, миһербанлы йөрәкләр генә риваятьләргә кереп калырлык итеп ярата ала.* М.Маликова

2) Шәфкать, мәрхәмәт белдергән. *Аның карашы миһербанлы, изгелек нурлары чәчә аның күзләре.* М.Хуҗин

3) *күч.* Рәхимле, шәфкатьле; җайлы, мәшәкатьсез, уңай. *Шулчак Заһидә туташ сүзгә катнаша: – Ничек инде иң миһербанлы дин католиклар дине булсын?! – ди яшь кыз.* Р.Батулла. *Еллар миңа миһербанлы булды.* Казан утлары

МИһЕРБАНЛЫК *и. ялг. к.* **миһербанлылык**. *Ниндидер күзгә күренмәс көчләрме, әллә өлкән кешенең миһербанлыгы, зирәклеге булдымы, язмыш дигәнең бу юлы да имәннең гомерен һәлакәттән йолып калды.* Р.Низамиев. *Шушы олпат җиһангирның оныгы – Алтын Урда дәүләтен бар иткән Бату хан да зирәклеге, тәвәккәллеге, миһербанлыгы белән дан тоткан.* М.Әмирханов. *Урталарына бер уч көнбагыш килеп төшкәч, җим исен сизеп, тыныч кына миһербанлык көтеп йөргән күк күгәрченнәр гаиләсендә этеш-төртеш башланды, әтәчләре чукышырга тотынды.* К.Кәримов

МИһЕРБАНЛЫ́К ИТҮ *ф.* Шәфкать, мәрхәмәт күрсәтү; яхшылык кылу. *Хәдичә түти, калтыранган куллары белән эзләнеп, киленең сузылды, гүя анага миһербанлык иткән кебек, күзләрендә беренче тапкыр яше күренде.* Г.Бәширов

МИһЕРБАНЛЫ́К КЫЛУ *ф. к.* **миһербанлык итү**. *Алайса, миһербанлык кылу хурлык эш санала хәзер, ә?* Н.Гыйматдинова. *Шулай да «Онытылмас еллар» әсәрендә Курманаев, Дәүләтъяров кебек кешеләрнең Хәлимдәй ятим татар балаларына миһербанлык кылырга омтылышларын күрсәтеп алды.* Т.Галиуллин

МИһЕРБАНЛЫЛЫК *и.* Шәфкатьлелек, мәрхәмәт, яхшы күңеллелек. *Бер якта – шыксыз чынбарлык, җан өшеткеч ятимлек, әхлаксыз бәндәләрнең чиркангыч гамәлләре, икенче якта – сабыйлар язмышын үз җаннары аша уздырырга сәләтле мәрхәмәтле затлар, игелекле ниятләр, шәфкатьлелек, миһербанлылык...* Ф.Бәшир. *Мондый үзара миһербанлылык куяннар арасында шактый киң таралган.* Кызыклар дөньясында. *Гаиләдә эшкә мөкиббәнлек, татулык, миһербанлылык хөкем сөрә икән, димәк, яшь буын шуны кабатлячак.* Мәдәни җомга

МИһЕРБАНСЫЗ *с.* Шәфкатьсез, рәхимсез, каты күңелле. *[Балтамар:] Мине миһербансыз диеп ялгышмагыз.* Ә.Баян. *Тыпырчына миһербансыз кулда, Бәргәләнә җаны авылымның ---.* Х.Әюп. *Ник син адәм балаларына шулкадәр миһербансыз да, шулкадәр игелекле дә [язмыш]?* Ф.Садриев

МИһЕРБАНСЫЗЛАНУ *ф.* Миһербанлылык сыйфатларын югалту; миһербансызга әйләнү. *Бигрәкләр дә пычранганбыз, гөнаһка батканбыз, миһербансызланганбыз, йөзебезне үк югалта барабыз икән бит.* Р.Шәрәфиев

Миһербансызлана бару Торган саен ныграк миһербансызлану. *Отыры миһербансызлана барган яшәешебез авыру яисә имгәнгән балалар, аларның якыннары аша тагын да җәтерәк ачыла икән шул.* Казан утлары

Миһербансызлана башлау Миһербансызлык билгеләре сизелү. *Яшьләр миһербансызлана башлады*

Миһербансызланып бетү Тәмам миһербансызга әйләнү

Миһербансызланып килү Әкренләп миһербансызлану

МИһЕРБАНСЫЗЛЫК *и.* Шәфкатьсезлек, явызлык, рәхимсезлек. *Миһербансызлык, саранлык, вөҗдансызлык, ялганчылык гадәткә әйләнеп бара.* А.Юнысова. *Шунысы кызганыч: бүгенге көндә миһербансызлык, эгоизм тәрбияләүче, тарихи, әхлакый тамырларыбызга балта чабучы, кеше мәнфәгатен, рухи халәтен шаблонга салучы арзан мәдәният киң тарала бара.* Казан утлары

МИһЕРЛЕ *с.* Миһербанлы, шәфкатьле, рәхимле, кызганучан. *Мәулам, дим, мөҗәһидне миһерле ит!* Г.Сәлим

МИһМАН *и. фар. сир.* Кунак. *Әмма сез, әй, ул Мөхәммәднең шәкерт миһманнары! Санлаңыз пәйгамбәремне: сез аның угланнары.* С.Сүнчәләй. *Сакманов – түйда иң кадерле миһман.* Т.Галиуллин. *Син мең биш йөз дә унынчы ел кышында әниең Нурсолтан ханбикә белән, сараема килеп, айлар буе миһман булган идең.* В.Имамов

МИЦЕ́ЛИЙ *и. гр. биол.* Вак һәм тармакланучан гөмбә җепселләреннән гыйбарәт булган гөмбәлек, гөмбәнең вегетатив өлеше. *Яфрак гөмбәчеге үзагачны тишеп чыга торган гөмбәлектән (мицелий) һәм агач кайрысы өстендә сузынкы-цилиндрсыман яки тояксыман утырма эшләпәләр булып киткән мәшкәктән тора.* Урман аптекасы. *Лишайниклар – симбиотик организмнар төркеме, аларның катламаларының нигезен гөмбә мицелие барлыкка китерә.* Татарстанның үсемлекләр һәм хайваннар дөньясы

МИЧ *и. рус* 1) Бинаны җылыту, аш-су пешерү өчен, кирпеч яки тимердән эшләнеп, утын, күмер, газ һ.б.ш. белән ягыла торган җайланма. *– Минем бу йортка кергән расхут инде, – диде ул, эш бетереп, мичкә ягып, осталарны һәм моржачыны сыйлаган көнне, кулына стакан тотып.* М.Мәһдиев. *Калтыранган куллары белән мичтәге утыннарны тергезеп җибәргәнче, шактый гомер үтте.* З.Хөснияр

2) Газ, электр, яисә микродулкыннар ярдәмендә эшли торган аш-су пешерү өчен көнкүреш техникасы. *Өлкән механик микродулкын белән эшли торган мич кочаклаган.* М.Юныс. *Табага майланган кәгазь җәеп, өстенә бисквит камырын агызалар да газ мичендә пешерәләр.* Мәдәни җомга

3) Технологик процесслар вакытында материалларны эретү, кыздырып эшкәртү өчен хезмәт итә торган корылма. *Бер ел буе газда эшләгәндә, Җитез булганмыдыр эшендә. Хәзергесе көндә Сары Хисмәт Чуен эретә домна мичендә.* Ш.Маннур. *Реторта эчендә дә металл рудаларын күмер ярдәмендә металлга әверелдерә торган исәпсез-хисапсыз металл эретү мичләрендә мең еллар буена булып килгән хәл кабатланган.* Күзгә күренми торган матдәләр турында хикәяләр

4) Җылылык энергиясеннән файдалана торган механизмнарның ягулык бирелә торган өлеше. *Каршыда, астарак, паровоз мичендә кып-кызыл булып күмер яна.* Н.Фәттах. *Ә паровоз мичен чистартырга күпме көч кирәк?* Р.Мирхәйдәров

◊ **Мич башына менәр вакыт җитү** Картаю. *Мич башына менәр вакыт тиз җитә икән ул, оланнар ---.* Сөембикә. **Мич башыннан төшмәгән** Дөнья күрмәгән, тәҗрибәсез. *Мич башыннан төшмәгән башың белән сөйләнеп торма әле, дип төртеп кенә җибәрде аны агасы.* А.Шамов. **Мич башына менү** Ялкаулыкка сабышып, эштән, хезмәттән читләшү, качу. *Менмәмен мин, Ходай кушса, мич башына.* Г.Тукай. **Мич башында таракан санап яту** *к.* **мич башында яту**. **Мич башында яту** Эшләми яту, ялкаулану. *Андый салкын көндә акыллы кеше мич башында гына ята, ә без тинтәкләр базарда йөрибез.* И.Гази. **Мич тарту** Мич узгач, күмерен алу, моржасын ябу. *Моны (таба ипиен) мич тартыр алдыннан, күмер төшкәч пешерәләр.* М.Мәһдиев. *Мичтә йодрык кадәр алтынсу күмерләр ялкын бәрә, мичне тартыр алдыннан гына күәс чиләге дә инде ташырга әзерләнә (димәк, камыр уңган!), аны учлап алып «әпәләп» ясарга, бадьянга урнаштырырга кирәк, ләкин шул арада әле таба ипие пешереп алырга кирәк.* М.Мәһдиев. **Мич томалау** Утын янып беткәч яисә газ ягулыгы килүне туктаткач, мичне ябу. *--- Өйгә әллә бүрәнәләрдән, әллә тәрәзә пәрдәләреннән алсу нур тулган, әни мич томалап йөри, ә өстәлдә алсу тышлы дәфтәр.* М.Мәһдиев. **Мич уздыру** Мичкә бәйле эшләрне төгәлләү; мунча мичен өлгертеп, томалап кую. *Ул табын хәзерләште, мичне уздырып, тәрәзәдәге такталарны алды.* К.Нәжми. *Мунча мичен уздырдым, озаклама-гыз, дип калды әниләре.* Казан утлары. **Мич үрләтү** Мичкә ягып җибәрү; мичне кабызып җибәрү. *Мич үрләтеп маташкан әнисенә сокланып карап торды ул.* Казан утлары

МИ́Ч АВЫЗЫ *и.* Мич эченә утын, ташкүмер һ.б. ягулык салу, таба-чүлмәкләр кую өчен зур тишек. *Коры утын гөмбәзгә сыймыйча аңа таба ыргылды, ул [Бибинур], утның мәңгелеге алдында сихерләнеп, керфек тә какмыйча байтак карап утырды: мич авызындагы корымга ут капты.* А.Гыйләҗев. *Аннары ул бишмәтен ишек катындагы чөйгә элде дә сөякләренә кадәр туңган гәүдәсен мич авызына ук китереп җылынырга кереште.* З.Хөсният. *Ләкин тимер рәшәткәле тәрәзә уемы утсыз мич авызы кебек караеп торуында булды.* З.Фәтхетдинов

МИ́Ч АЛДЫ *и.* 1) Мичнең авызы урнашкан ягы. – *Хатының кайда соң? – Кемнеңдер мич алдында күмер ашый, – диде Алексей ---.* Х.Камалов

2) Идәннең мич авызы турысындагы өлеше. *Озакламый балалар да чыгып китте, мич алдына, идәнгә утыртылган самавыр гөрләргә тотынды.* Н.Фәттах

3) *сөйл.* Өйнең кухня итеп файдаланыла һәм аш-су пешерелә торган өлеше. *Алсу тышлы дәфтәр миңа әле дә март аеның кояшта җемелдәгән кар диңгезен, мич алдында ризык әзерләп йөргән әнинең нурлы йөзен хәтерләтә.* М.Мәһдиев. *Йокыдан торып, мич алдында әнкәй калдырган ризыкны ашагач та шул эшләргә керешәм.* Ә.Баян

МИ́Ч АРТЫ *и.* Мич белән стена арасындагы урын. *Ни генә әйтмәсеннәр, мин, борынгы киленнәр кебек, мич артына гына сыя алмыйм.* Г.Бәширов. *Әнисе чәй хәстәрләп йөргән чакта, ачык ишектән түр якның мич артына кереп, чаршау артыннан өлкәннәрнең сөйләшүен шыпырт кына качып тыңлап торган Мирсәетнең йөрәге кысып-кысып куйды шул чагында.* Р.Мөхәммәдиев. *Ахырдан әнисенең киленлек чаршавы белән «мич арты» кебек бер нәрсә булеп аласы.* Р.Рахман

МИЧӘ́Ү I *и.* 1) Ике яки өч атны бергә җиккәндә кулланыла торган каеш перәшкә; *русчасы*: **постромки.** *Ул да булмый, төпкә озын яллы кара ат, мичәүгә тимер күк җиккән тарантас ишегалдына бик кызу гына килеп тә керде.* Ә.Еники. *Танкистлар танкларын бер-бер артлы, мичәүгә җигелгән атлар шикелле алып барганнар ---.* Г.Әпсәләмов. *Мичәүдә, авызлыгын чәйнәп, башын кырыйга каерганнары – татар һәм монгол атлары.* М.Галиев

2) *күч.* Ярдәмче, булышчы. *Өй эчендә ничәүсең – бер-береңә мичәүсең.* Мәкаль

3) *күч.* Тагылма, койрык, иярчен. *Тинчуриннның хатыны Шаһбазгәрәй Әхмәров кызы Заһидә шәхесе сезне кызыксындырмый бит, так себя, Тинчурин шәхесенә мичәү буларак кына кирәк мин сезгә...* Р.Батулла

◊ **Мичәү аты** Ярдәмче көч. *Ә хуш күңеллелек – буш күңеллелекнең мичәү аты.* Татар әдипләре. **Мичәүгә җигү** Үзенә бәйле итү; берәр эштә, хезмәттә ярдәмче итеп файдалану. *[Тимери] Нәфисәнең картлар янында салам кыстыруын ишеткәч: «Кара безнең киленне, картларны ничек итеп мичәүгә җигеп куйды!» – дип, мыек астыннан көлеп утырды.* Г.Бәширов. – *Мичәүгә җигәргә уйламыйсыңдыр бит? – Редактор урыны буш.* Ф.Садриев. **Мичәүдә бару** Нинди дә булса эштә ярдәмче көч булу. *Мичәүдә барганнар кайвакыт күренмичә дә кала торган була шул...* Казан утлары. **Мичәүдә баручы** Ярдәмче; өстәмә көч. *Без монда төп көч түгел – мичәүдә баручылар гына.* Г.Әпсәләмов. **Мичәүдә тарту** Башкаларның эшен эшләү, кирәкмәгән эшкә ярдәм итү. *Аның [әтинең] җыен-җыентык, тәмам яраксызга әйләнеп беткәннәр белән бер тәртәгә керәсе, әтрәк-әләмне мичәүдә тартып барасы килмәде.* Ә.Гаффар

МИЧӘ́Ү II *ф.* Төп тартып баручы ат янына перәшкәле өстәмә, ярдәмче ат җигү, мичәүләү. *Минем рысакны төпкә, ике яшь айгырны перәшкәгә мичәп, резин көпчәкне җиксеннәр.* Т.Гыйззәт. *Чанага мичәп җиккән кечерәк кенә ике туры ат ишегалды уртасына килеп туктаганнар иде.* М.Гали

МИЧӘҮЛӘ́Ү *ф.* Мичәп җигү; мичәүгә, янга җигү. *Һәйбәт артлы, бөркүле чаналарга парлап та, мичәүләп тә җигелгән атлар очраштырга-лый.* М.Хәсәнов. *Сарай ишегалдында күпсанлы олаулар, мичәүләп җигелгән бер ишләр.* М.Хәбибуллин. *Бу дүртәр сажинлы агачларның авырлыгы егерме-егерме биш потлап булганга күрә, бер чанага мичәүләп ике ат җигелә һәм аны ике йөкче илтә иде.* Т.Нәбиуллин

Мичәүләп кую Мичәүләнгән хәлгә китерү. *Атларны мичәүләп куйды да тәмәкесен кабызды әти.* Казан утлары

Мичәүләп тору Даими мичәүләү; хәзер мичәүләү. *Ишегалдында атларын мичәүләп торган абыең мин кергәнне күрми дә калды ---.* А.Нуруллин

МИЧӘҮЛЕ *с.* 1) Мичәүләп җигелгән (ат). *Икенче көнне кыңгыраулар таккан мичәүле атларга утырып, становой пристав үзе килеп төште.* Г.Бәширов. *Мичәүле атларның дулап китүләрен күреп, Җик Мәргән атын тыя төште һәм дулаган атлар җитүгә, алдагы атларның тезгенен эләктерде ---.* М.Хәбибуллин

2) Мичәү аты җигелгән. *Янгын сүндерүче агай мичәүле арбасындагы олы мичкәле суны сиптереп бетергән.* Г.Якупова

МИ́Ч БАШЫ *и.* Әйберләр киптерү яки йоклау өчен ясалган мич өстендәге махсус мәйданчык. *Мич башында шалкан пешми.* Мәкаль. *Мичкә якмады, ашарга пешермәде, киез катасын аягына элеп, почмактагы чапчактан бакыр чүмеч тутырып суык су эчте дә, иске тунын ябынып, һаман мич башында ятты [Бибинур].* А.Гыйләҗев. *Кайчандыр Зарифа бу баскычлардан үзе генә дә бик иркенләп төшә, комган тотып ишегалдына чыга һәм, намазлыкта дога кылып алганнан соң, тавыш-тынсыз гына мич башына үрмәли иде.* Р.Әбүбәкерова

МИЧКӘ *и. рус* 1) Тимердән, агачтан һ.б. материалдан цилиндр формасында яки кабарынкы корсаклы, ике башы да яссы төпле итеп эшләнгән зур савыт, чәпчәк. *Бер чакрымга якын җирне әллә нәрсәләр белән тутырганнар: калай мичкәләр, зур пыяла балоннар; тау-тау өелгән тоз, тагын әллә ниткән ташлар, мәгъдәннәр.* Ш.Камал. *Әрҗәләр, мичкәләр, урам һәм мунча себеркеләре, йөзләрчә тонна ылыс оны [ясыйлар].* М.Хәсәнов. *Теләгәннәр шәраб эчкән мичкәсеннән, теләгәннәр ит кимергән түшкәсеннән.* Ф.Яруллин

2) *сөйл.* Сыеклык үлчәү берәмлеге (кырык чиләк сыеклык күләменә тәңгәл)

◊ **Мичкә кебек** Бик зур, юан. *Кая танысын, еллар адәм баласын үзгәртә, әнә миннән – нечкә билле кыздан – мичкә кебек юан хатын ясады.* Н.Гыйматдинова. **Мичкә корсак** 1) Юан корсаклы кеше. *Күрче, бай – мичкә корсак! – эш итә миллион белән, Сәүдәсе һәр җир белән, куйлар, тире һәм йон белән.* М.Фәйзуллин. *Беләсеңме, мичкә корсак, Хуҗа сине ник ярата?* Ф.Яруллин; 2) Эчкече

МИЧКӘЛӘП *рәв.* 1) Мичкә белән; мичкәләр исәбе белән. *Кирәк чакта капчыклап, кирәк чакта мичкәләп дигәндәй, балыкны ташып торды.* Ф.Яруллин. *Суны ике чакрым арадан, Габдерәшит бабай күрсәткән күлдән, мичкәләп ташымаганнардыр лабаса!* А.Тимергалин

2) *күч.* Бик күп. *Кара болыт та ашыга, мичкәләп коя-коя!..* Р.Фәйзуллин

МИЧКӘЛЕ *с.* 1) Мичкәгә салынган. *Янгын сүндерүче агай мичәүле арбасындагы олы мичкәле суны сиптереп бетергән.* Г.Якупова

2) Мичкә беркетелгән; мичкә утыртылган. *Тугаш карт, Тәбрик оныгының нечкә күңелен рәнҗетмәс өчен, трактор чылардан мичкәле арба сорарга мәҗбүр.* Ә.Баян. *1907 елдан исә мичкәле арбаларны машиналар алыштыра башлый, каланчалар төзелә.* Р.Кәрами

МИЧКӘЧЕ *и.* Мичкә ясаучы. *Әтием оста мичкәче минем.* И.Нуруллин. *Бездә мичкәче Сабир бабай бар иде.* Казан утлары

МИЧКӘЧЕЛЕК *и.* Мичкә ясау һөнәре, шөгыле. *Сезнең якта мичкәчелек бик алга киткән бит ---.* А.Галиева. *Мондый эшләрне генә белмәскә, мичкәчелек белән дан тоткан авылда тудым бит мин.* Сөембикә

МИ́Ч КУЫШЫ *и.* Оек, биялә, итек һ.б.ш. кую, киптерү өчен, мичнең тышкы стенасына махсус ясалган кечкенә генә куыш урын. *Хәлим, кайтырга кирәк инде дип, мич куышыннан аякчуларын алып чолгарга тотынганда, капка әкрен генә, бер дә шыгырдамыйча гына ачылып китте.* Г.Гобәй

МИЧЛЕК *с.* **1.** 1) Мич салырга җитәрлек; мич чыгарырга әзерләнгән. *Мичлек кирпеч сугарга иде исәп.* М.Галәү

2) Мичкә ягарга җитәрлек; мичкә ягарга әзерләнгән. *Утын сараенда мичлек утын әзерләгәндә, Мөби кыскача гына хәлне аңлатты.* М.Мәһдиев. *Менә сез җыйган ботаклардан күп булса ике мичлек утын чыга.* Авыл офыклары

2. *и. мәгъ.* Мич салырга, мич чыгарырга дип әзерләнгән, шуңа билгеләнгән материал. *Мичлекне аерым өяргә кирәк*

МИ́ЧМАН *и. ингл.* 1) Хәрби диңгез флотында хәрби хезмәт вакыты тәмамланганнан соң да, үз теләге белән хезмәттә калучыларга бирелгән дәрәҗә һәм шул дәрәҗәне алган кеше (офицер ярдәмчесе). *Халык чуар: тоташ кара киемле булсалар да, коры җирдә хезмәт итәргә мәҗбүр, кайчандыр күбесе хәрби-диңгез училищеларын тәмамлаган көяз офицерлар һәм төрле сәбәпләр аркасында үзләре телә п хәрби хезмәтне дәвам итүче мичманнар, яшькелт төстәге армия формасы кигән лейтенантлар һәм старшиналар ---.* Р.Кәрами

2) Беренче офицер дәрәҗәсе һәм шул дәрәҗәдәге офицер (рус һәм башка кайбер флотларда). *Карт мичман нәкъ шул вакытта кубрикка керә, утыра һәм, янчыгын чыгарып, тәмәке төрә.* М.Мәһдиев. *Өлкән мичман капитанның ышанычлы кешесе, таянычларының берсе икән ләбаса...* К.Кәримов

МИ́ЧМАНКА *и.* 1) Флотта: хәрбиләр кия торган фуражка. *Парк тулы хәрбиләр, диңгез портының бизәге – аллеяда, бию мәйданында ак түбәле фуражка (мичманка), бескозырка чайкала.* М.Мәһдиев

2) Шуңа охшаш фуражка. *Мичманка алып кияргә дә онытмаска кирәк әле.* М.Юныс

МИ́ЧМАНЛЫК *и.* Мичман дәрәҗәсе. *Ринат абый мичманлыкка күптән кызыгып йөргән иде инде.* Сөембикә

МИЧ-МОРҖА *җыйд. и.* Мич һәм аның барлык өлешләре. *Мич-морҗаны шомырт чәчәге төсенә кертеп агарта, җиз самавырны ачы катык, ком белән агартып, кояш көнләшерлек итеп ялтырата.* А.Гыйләҗев

МИ́Ч ТӨБЕ *и.* Мичнең көймәсе астындагы утын, күмер ягыла, камыр ашлары пешергәндә, табалар куела торган түбәнге аркылы өлеше. *Ипи*

көрәге – юкә агачыннан ясалган почмаксыз көрәк. Моны бары тик мич төбенә ипи камыры утырту өчен генә кулланалар. М.Мәһдиев. *Аннан пумала белән калган күмерләрне җыя, мич төбе тәмам күмер тузаныннан арынгач, түгәрәк камырларны агач көрәк белән мич төбенә тезеп чыга ---.* Д.Гайнетдинова

МИЧУ́РИНЧЫ *и.* Биология һәм авыл хуҗалыгында И.В. Мичурин тәгълиматы тарафдары. *Министрлык мичуринчылар турында бер китап бастырып чыгарырга әзерләнә.* Т.Гыйззәт. *Әтинең бакчасын Мичурин бакчасы дип йөртәләр, бөтен мичуринчылар белән диярлек хатлар алыша иде.* А.Арсланов

МИЧЧЕ *и.* 1) Мич чыгаручы, мич салучы. *Көннәр көзгә авышканлыктан, нәселләре белән укымышлы дин әһелләре һәм алтын куллы миччеләр вәкиле булган Вәли хәзрәт Фәтхуллинга дилбегә буе чират иде.* Т.Нәҗмиев. *Миннән, билгеле, чын балта остасы да, чын ташчы да, мичче дә, калайчы да чыкмады.* Н.Фәттах. *«Харис кебек миччеләр тирәякта бармак белән генә санарлык, ул чыгарган мичнең җылысы әле икенче көнне дә суынмаган була», – дип сөйләрләр иде аның турында.* Г.Бәйрәмова

2) Мич янында эшләүче, мичкә ягып торучы; *русчасы*: **истопник**. *Миччедигәч, хатын-кыз затыннан булса да, олы гәүдәле кеше күз алдына килә.* Татарстан яшьләре

МИЧЧЕЛЕК *и.* Мичче булу; мич чыгару һөнәре, эше. *Әмиржан үзлегеннән миччелек һөнәрен үзләштерә.* Безнең гәҗит

МИШӘ *и. сир.* 1) Имәнлек; имән үскән җир. *Куе мишә*

2) *диал.* Кечкенә урман; яфраклы урман. *Мишәдән җыелган җиләк*

МИШӘР *и.* Татар теленең көнбатыш диалектында сөйләшә торган этник төркем һәм аның бер кешесе. *Ә мишәрләр, дөресен әйткәндә, сөйләргә дә, эшләргә дә маһир.* Г.Ахунов. *Шулай ук аңа бу эшендә милләтнең берләшүенә комачаулый торган «типтәр», «мишәр», «керәшен» кебек этнонимнарның һәм җирле атамаларның татарлар арасында киң таралуы да тәэсир итә.* А.Юзиев. *Шулай да алар – Хөрмәт, Сергач мишәре Атаулла, Ырынбур егете Шәрип, Габделнур һәм тагын берничә татар егете – көн саен спортзалда көрәш оештыралар.* Р.Кәрами

МИШӘРЛӘШҮ *ф. сөйл.* Мишәрләргә хас сыйфатлар барлыкка килү, шуның тәэсиренә бирелү. *Шуңа күрә монда мишәрләшү акрынлабрак башлана һәм мишәрләргә якын татарларда шактый мишәрлек сизелә.* Ж.Вәлиди

Мишәрләшә бару Торган саен ныграк мишәрләшү. *Мишәрләшә баруымны үзем дә сизмәдем мин ---.* А.Нуруллин

Мишәрләшә башлау Мишәрлек билгеләре сизелү

Мишәрләшеп бетү Тәмам, бик нык мишәрләшү. *Авылда яшәгәндә, мин бөтенләй мишәрләшеп беттем, кызым, --- сөйләшүемнән дә сизгәнсеңдер.* Сөембикә

МИШӘРЛЕК *и.* Мишәр булу. *Ләкин бу мишәрлек аның [Лотфрахманның] телендә бөтенләй дә чагылмый диярлек.* А.Хәлим. *Мишәрлек аның бөтен кыяфәтенә, холкына чыккан.* Г.Гыйльманов. *Авылның исеменнән үк күренгәнчә, биредә төп халык татарлар яши, әмма аларның сөйләмнәрендә мишәрлек чатнап тора.* Ф.Бәйрәмова

МИШӘРСТАН *и. шаярт.* Көнбатыш диалект вәкилләре яши торган өлкә, район. *Егерменче гасыр башы иҗтимагый тормышыбызның бер мөһим үзенчәлеге төрле җирләрдә, чит өлкәләрдә яшәүче татарларның Казанга тартылуында иде. Әйтик, башкорт якларыннан Галимҗан Ибраһимов, Мирхәйдәр Фәйзи, Себердән Габдерәшит Ибраһимов, безнең мишәрстаннан Заһир Бигиев, Шәриф Камал, Һади Такташ, Фәхрелислам Агиев, Кәрим Тинчурин, ниһаять, Гадел Кутуй, Кави Нәҗмиләр…* М.Госманов. *«Мишәрстан башкаласы»нда яшәп тә, безнеңчә «сүләшмичә», әдәби телдә аралашуына күрә, шул хакта ачыкламакчы булып сүз катам.* Ватаным Татарстан

МИШӘ́РЧӘ *рәв.* **1.** 1) Мишәр диалектында. *Ул гармунчы мишәр дә Тукайның капельмейстерлыгы тәхтендә без җырлаган сәхнәгә менеп, гармунны әйттерә, үзе уйнаганда, хатыннар тавышы берлә мишәрчә әллә нинди урам җырлары җырлый башлады.* И.Газиев. *Матур кызның телне ватып мишәрчә сөйләшмәве тагын да табигый хәл сыман кабул ителде.* Ф.Яхин

2) Мишәрләргә хас булганча. *Беренче җыентыгында тупланган шигырьләрендә Фәниснең гаделлек сөюче каләм иясе булуы да, шактый төртмәлечәнечкеле тел иясе икәнлеге дә, мишәрчә үҗәтлеге, горурлыгы да абайлана.* Шәһри Казан

2. *с. мәгъ.* Мишәр диалектына караган. *Тора-бара күнектек тагын: үзебез дә мишәрчә сүзләр кыстырып сөйләшә башладык.* Ә.Рәшит. *Төрле йолалар турында сөйләгәндә, җыр-такмазалардан мисаллар китерә, аларны көлкелерәк итәр өчен, мишәрчә әйтелештә яңгырата [Якуб ага].* М.Госманов

МИШӘРЧӘЛӘП *рәв.* Мишәр акценты белән, мишәр диалектында. *Илсөясе дә, Камиләсе дә болай ярыйсы икәннәр, мишәрчәләп әйтмешли, «ничавалар», әмма дә Нәфисәгә җитмиләр шул.* Ф.Яхин. *Кыенсыну, ятсынуның тамчысы да юк бу балада, җырла дигәнне дә көтмичә, кычкырып мишәрчәләп җырлап та җибәрде...* Казан утлары. *– Ниндирәк кеше иде ул? – дигән соравыма каршы Фәйзи ага җыелыбрак утырды, күкрәгенә сулыш җыеп, Туишев роленә керде, мишәрчәләп сөйли башлады ---.* Татарстан яшьләре

МИШЕНЬ *и. фар.* **1.** 1) *махс.* Ату күнегүләре ясаганда, төбәү ноктасы билгеләнгән махсус предмет, сурәт; мәрәй, һәдәф. *Габделнур, сул күзен йомып, ераста күренгән мишеньгә – мәрәгә төбәп, командирлар өйрәткәнчә атып җибәрде.* Р.Кәрами. *Аның [атның] шушы күркәм сыйфатлары --- чабып барган шәпкә ат өстендә «кайчы» ясап, артка борылырга һәм мишеньгә төбәп мылтыктан атарга мөмкинлек бирде.* Р.Сафин

2) Ату объекты. *Һәммә үк та мишеньгә тими.* Мәкаль. *– Болай син ак таракан күк. Тере мишень! – диде Дәгъвә.* Ш.Рәкыйпов. *Солдат тиз*

генә аңга килеп, юан каен артына сузылып ятты, ул үзенең немец өчен иң кулай мишень икәнен аңлаган иде. Казан утлары

3) *күч.* Мәсхәрәләү, тәнкыйтьләү, җәфалау объекты; бар авырлыкны үзенә алучы. *Теткәләнә, туза бик тиз: Мишень бит безнең йөрәк*. Ф.Яруллин. *Оһо, АКШ армиясе! Бу инде рус шпионнары өчен әкәмәт кызыктыргыч мишень була ала!* Р.Вәли

2. *с. мәгъ.* 1) Ату объекты булган

2) *күч.* Авырлыкны, җаваплылыкны үзенә алучы. *Такташны мишень итә, дип ачынып яза автор.* Т.Галиуллин. *Гормоннарның беришеләре билгеле бер органнар системасына күбрәк тәэсир итәләр. Андый органнарны мишень органнар дип атыйлар*. Биология

МИШУРА *и. гар.* 1) Тегү эшендә кулланыла торган алтын яки көмеш йөгертелгән юка металл җеп; алтын яки көмеш төсле юка тасма. *Һәм ул чыннан да шулай булды: бер уч кәнфит, прәннек белән читенә ак мишура ука тоткан чуклы яшел миткальдән эшләнгән, башка чап итеп ябышып ята торган бер яшел миткаль кәләпүш миңа да эләкте.* Г.Камал. *Калфакны да мишура белән түгел, ә энҗе белән бизәгәннәр.* Б.Рәхимова

2) Төрле төсле ялтыравык тасмалар һәм шулардан эшләнгән чыршы бизәү әйберләре. *Мишура һәм яңгыр сыман гирляндалар турында да онытмагыз.* Сабантуй. *Сәйләннән үреп ясалган, түбәсенә кызыл йолдызчык куелган һәм вак төймәләрдән ясалган мишура белән бизәлгән чыршы күргәзмә дәвамында күпсанлы халыкны үзенә җәлеп итеп торды*. Ватаным Татарстан

3) *күч.* Алдый торган, ясалма, ялтыравык матурлык. *Башкалары фон өчен, коллегиальность дигән мишура өчен генә ---.* Т.Мөбарәков. *Аерым башкаручыларның табигый таланты таныган хәлдә дә, «Татар моңы» конкурсының иң зур хатасы нәкъ шунда – моң дигән идеяне мишура (татарчасын тиз генә таба алмыйм) чүбенә батыруда*. Ватаным Татарстан

МИЯ́У *иярт.* Мәче кычкырган яисә мәче тавышына охшаш авазны белдерә. *Әгәр бу мәҗлестә минем шикелле берничә яшьләр булса, ахун сөйләгәндә, һәммәсе беравыздан мырау-мырау, мияу кычкырып, мәче музыкасы уйнаячаклар иде.* Г.Тукай. *Медицина училищесына имтиханнар тапшырып, бүлмәмдә ямансулап ята идем, берсе, ишекне сыза гына ачып, мияу, диде.* Н.Гыйматдинова

МИЯУБИКӘ *и. сөйл*. Ана песи, ана мәче (гадәттә, балалар телендә). *Иң шаяны – Мияубикә, Ошый аңа уйнау бик тә!* Р.Миңнуллин. *Мияубикә урындык аякларына килеп сырпалана-сырпалана да, дустының бик мөһим эш белән утыруын чамалап, мич буена китеп бара*. Р.Низамиев

МИЯУЛА́У *ф.* Мияу-мияу дигән яки шуңа охшаш авазлар чыгару. *Сабира карчык нигезендәге бердәнбер җан иясе – мәчесе Каракайның ишекне тырный-тырный миялаганына уянып китте.* Р.Шәфигуллин. *Ул [Габделнур] аны өзек-өзек чыгара, тавыш исә сызгыруга түгел, ә нәкъ мәче мияулаганга тартым иде.* Р.Кәрами. *Шулвакыт якында гына мәче мияулаган тавыш ишетелде.* М.Әмирханов

Мияулап алу Бераз мияулау. *Иске мәчет урынында парлашып утырганнар [эт белән мәче]: берсе кызганыч тавыш белән мияулап алса, икенчесе аны юатырга теләгәндәй шыңшып-шыңшып өреп куя.* Р.Галиев. *Әтәч кычкырып, эт өреп куя, трактор-фәлән тавышы ишетелә, бәлки, мәче мияулап аладыр, бала-чага көлгәне яңгырыйдыр; кыскасы, авыл иртәсе*. Ә.Гаффар

Мияулап җибәрү Кинәт мияулый башлау. *Шулчак песием мияулап җибәрмәсенме!* Сабантуй

Мияулап кую Бер тапкыр мияулау. *Кичке салкынча һава үзен караңгылык белән уравын тоеп, ул кызганыч итеп мияулап куйды.* Н.Каштанов. *Гайфи шаярып мәче булып мияулап куя, Суфия куркып китә, мәче бар дип, өстәл асларын карый*. Г.Зәйнашева

Мияулап йөрү Анда-санда мияулау

Мияулап тору Бертуктаусыз мияулау; сөйләү моментында мияулау. *--- балалаган кыргый мәче биш баласын урманнан боларның ишеге төбенә ташыган да өйгә, ягъни балаларын җылыга кертүне үтенеп, ишек төбендә мияулап тора, ди.* Г.Бәширов. *Тимерхан өстәл астында мияулап торган песигә калҗа бирде*. Р.Вәлиев

Мияулый башлау Мияуларга тотыну. *Мине күрүгә мияулый башлый Йомшаккай.* Ялкын

Мияулый бирү Бернигә карамыйча, озак вакыт дәвамында мияулау. *Сөт тә салдым, кибеттән алган ризыгын да бирдем, барыбер мияулый бирә бит җүнсез песи.* А.Галиева

МНЕМО́НИК *с.* Мнемоникага бәйле булган. *Яңа бер теория буенча, коллектив аң характеры аерым төркемнәрдә кулланылган мнемоник код төренә бәйле.* Ватаным Татарстан

МНЕМО́НИКА *и. гр.* Мәмкин кадәр күбрәк фактларны, мәгълүматны истә калдырырга, хәтерне яхшыртырга ярдәм итә торган алымнар һәм кагыйдәләр җыелмасы. *Борынгы Грециядә безнең эрага кадәр үк махсус фән булган – мнемоника (грекча – «хәтердә калдыру сәнгате»).* Ялкын

МНЕМОТЕ́ХНИКА *и. гр. к.* **мнемоника**. *Ә 4 нче класста укучыларга «мнемотехника» дигән – аңлы рәвештә башкарыла торган күнегүләр җыелмасы тәкъдим ителә.* Мәгариф. *«Сәләт-Прага»да катнашучылар шулай ук инглиз теле күнекмәләрен камилләштерәчәк, психология, мнемотехника (кирәкле мәгълүматларны истә калдырырга ярдәм итә торган алымнар һәм кагыйдәләрне үз эченә алган өлкә) һәм журналистика буенча дәресләр алачак, профессиональ рәвештә видео төшерергә өйрәнәчәк.* Ватаным Татарстан

МОБИЛИЗАЦИОН *с.* Мобилизациягә караган, мобилизация белән бәйле. *Яңа ел алдыннан гына Русия президенты (ул – Кораллы Көчләр баш командующие да) В.Путин 2004 елда мобилизацион әзерлек хакындагы фәрманга кул куйган иде.* Татарстан яшьләре. *Бу – бүгенге көндә мобилизацион кадрлар әзерләүнең бердәнбер үтемле чарасы*. Шәһри Казан

МОБИЛИЗА́ЦИЯ *и. фр.* 1) Хәрби хезмәткә яраклы кешеләрне солдат хезмәтенә алу. *Башта 1905–*

1918 елгыларга мобилизация игълан ителде. Г.Якупова. *Шактый авыл кешеләре мобилизациядән качып котылса да, юаш Гариф (аны шулай дип йөртәләр) андый юлга бармый.* М.Әхмәтҗанов

2) Кораллы көчләрне сугышчан хәлгә күчерү. *Алай-болай мобилизация башланса, офицерлар ике дивизиягә җитәрлек, ә солдатлар, сержантлар запастан чакырыласы икән.* Р.Кәрами. *Кызыл Армияне мобилизация юлы белән тулыландыруга күчү, интервентларга һәм акгвардиячеләргә каршы көрәшүче совет гаскәрләренә җитәкчелекне үзәкләштерү өчен, Көнчыгыш фронт оештыру һәм бу фронтны мөмкин кадәр көчәйтү --- һәм башкалар – шундыйлардан.* Казан утлары

3) Халык хуҗалыгының барлык тармакларын сугыш максатларына җавап бирерлек хәлгә күчерү

4) *күч.* Барлык көчне, кешеләрне нинди дә булса ашыгыч эш башкару, мөһим бурыч үтәү өчен туплау, оештыру эше. *Мобилизация игълан ителде. Дошман тылына яшерен агитаторлар җибәрергә карар кылынды.* Р.Мөхәммәдиев. *Безнең партия, минем кебек крестьян арасыннан килеп чыккан членнарга мобилизация үткәреп, авылларга чыгарды.* Т.Гыйззәт

МОБИЛИЗА́ЦИЯЛӘҮ *ф.* 1) Мобилизация үткәрелү

2) Мобилизация буенча җибәрелү, мобилизациягә тартылу. *Әти-әнисе репрессияләнгәч, ятим үсә, мобилизацияләнгәч, [Г.Тавлин] туп-туры Казанга кайта һәм пединститутның татар бүлегенә укырга керә.* М.Әхмәтҗанов. *Безнең полктан да Кировоград тирәсендәге авыллардан мобилизацияләнгән кешеләр берәм-берәм качып беттеләр.* Ә.Галиев. *Ул [Суфия] рәсми рәвештә мобилизацияләнмәсә дә, үз ирке белән шәфкать туташы сыйфатында холера баракларының берсендә эшләргә теләк белдерде.* А.Расих

Мобилизацияләнеп бетү Барысы да мобилизацияләү, тулысынча мобилизацияләү

Мобилизацияләнеп тору Хәзер мобилизацияләү; әледән-әле мобилизацияләү

МОБИЛИЗАЦИЯЛӘҮ *ф.* 1) Мобилизация үткәрү. *Армияне мобилизацияләү турындагы хәбәрне ишеткәч, ни уйларга да белмәдек.* Казан утлары

2) Оештыру; берәр чара үткәрү өчен, бөтен көчне туплау. *Казанда Шәһәр идарәсе барлык медицина хезмәткәрләрен ваба белән көрәшкә мобилизацияләде.* А.Расих. *Съезд безне яңа фидакярлекләргә мобилизацияли.* Ш.Рәкыйпов. *Аның [О.Артёменко] фикеренчә, милли телләрдә укыту гомумроссия үзаңын тәрбияләми, гомум бердәмлекне какшата ---, мәктәп яшьләрне этник мобилизацияләү институты буларак файдаланыла.* Казан утлары

3) *күч.* Теләсә нинди эшне башкару яки сынауны үтеп чыгу өчен, барлык көчне туплау. *Димәк, ул куркыныч хәлләр туган очракта үзен мобилизацияли ала, дигән сүз.* Безнең гәҗит. *Авырлыклар адәми затны булсын, гаиләне булсын, мобилизацияли, күпмедер ныгыта, берләштерә дә.* Ватаным Татарстан

Мобилизацияләп бетерү Тулысынча мобилизацияләү. *Без барлык көчләрне мобилизацияләп бетергәч кенә бу адымга бара алачакбыз.* Казан утлары

Мобилизацияләп тору Даими мобилизацияләү

Мобилизацияли башлау Мобилизацияләргә керешү. *Шуңа күрә район башлыгы Альберт Хәбибуллин, язгы чәчү кампаниясен вакытында башлап җибәрү өчен, бүгеннән ук барлык көчләрне мобилизацияли башларга, дигән күрсәтмә бирде.* Байрак

МОБИЛЬ *с.* 1) Тиз хәрәкәт итү, эш башкару өчен, махсус җиһазландырылган һәм шуңа билгеләнгән. *Кама – Чирмешән аралыгындагы районнарга отставкадагы һәм запастагы драгуннар күчереп утыртыла. Алар мобиль, хәрәкәтчән ландмилиция отрядларына берләштерелә.* М.Гайнетдин. *Мобиль бригада*

2) Өлгер. *Кадрлар мобиль булырга тиеш.* Р.Вәлиев. *Тирән үзгәрешләр барган хәзерге заманда тынгысыз, һөнәри яктан мобиль кешеләр күбрәк уңышка ирешә.* С.Ибраһимова

3) Кесәдә йөртелә торган. *Фукс бакчасы янына кайтып җиткәч, хәзрәтнең мобиль телефоны шалтырады.* А.Тимергалин. *Мобиль телефоны хитлар, роклар – Бары да сайрый шул ук сәгатьтә!* С.Гәрәева

МОБИЛЬЛЕК *и.* Хәрәкәтчәнлек, оперативлык, өлгерлек. *XXI гасырны мобильлек гасыры диләр.* С.Ибраһимова. *Алар арасында белгечләр әзерләүнең сыйфатын халыкара стандартларга, хезмәт базары таләпләренә туры китерү һәм ике баскычлы укыту системасында кадрлар әзерләү шартларында профессиональ мобильлек булдыру бурычлары аеруча әһәмиятле.* Фән һәм тел. *Болонья процессы шулай ук университетара багланышларның һәм студентлар белән укытучыларның мобильлеге артуына булышлык итә.* Мәдәни җомга

МОБИ́ЛЬНИК *и. рус сөйл.* Кесә телефоны, мобиль телефон. *Шундый зур ыгы-зыгы тудыра алуына чиксез шатланган малай, дулкынланудан, абыйсыннан чәлеп торган мобильникны да парта астында онытып калдырган иде хәтта.* И.Сәйфуллин. *Иномарка хуҗалары – яңа урыс белән яңа татар – билләреннән мобильникларын тартып чыгарып, кай тарафларгадыр шылтырата башладылар.* Д.Гыйсметдин

МОГҖИЗА *и. гар.* 1) *дини* Аллаһның рөхсәте һәм әмере белән пәйгамбәрләр генә күрсәтә алган гайре табигый эш, хәрәкәт, хәл. *Пәйгамбәрнең вафатыннан соң асла могҗиза булмас: Ярылмас ай икегә, һәм кара таштан дөя тугмас.* Г.Тукай. *Иһаять, Муса галәйһиссәламнең могҗизасы белән Нил суының канга әйләнүен, бөтен җирне һәртөрле бөҗәк-хәшәрәтләр тутыруын --- күргән Фиргавен бәни Исраилгә Мисырдан чыгарга рөхсәт бирергә мәҗбүр була.* Г.Исхакый. *Алар үз диннәрен пәйгамбәрләрнең могҗизалары белән куәтләргә тырышалар.* И.Әмирхан

2) Кешене шаккаттыра, хәйран калдыра торган ышанып булмаслык гайре табигый вакыйга, нәрсә. *Әгәр могҗиза булып, мин аякка бассам, мин аны җирдән атлатмыйча, күтәреп кенә йөрер идем...* Р.Юсупова. *Бу бит*

могҗиза! Төштә, әкияттә генә була торган хәл! Г.Гыйльманов

3) Кеше акылы кабул итә алмаслык хәл, күренеш. *«Полуторка» дип, хәзерге заманда ирен читен кыйшайтып кына әйтелә торган үзе бәләкәй, үзе көчсез бер нәмәстәкәй булгандыр инде ул [машина], әмма утызынчы елларда ул Вәрәшбаш кешеләренә могҗиза булып күренде*. Г.Ахунов

4) Гаҗәпләнерлек, сокланырлык, искитәрлек, гадәти булмаган әйбер, күренеш. *Табигатьнең могҗизалары турында газиз балалары белән ничә тапкырлар сөенеп сөйләшмәгән ул [Бибинур]: «Хәтимә кызым, кара! Салават күпере!» «Улым Сабир, күрче, ләйсән яңгыр ява!» «Нәҗибем, бәләкәчем, синең иптәшләрең – сыерчыклар килгән!»* А.Гыйләҗев

◊ **Могҗиза белән** Аңлатып булмаслык, гаҗәеп рәвештә. *Могҗиза белән исән калган татарлар тауларга качалар.* Ф.Бәйрәмова. *Әгәр дә вагон эчендәге кыз могҗиза белән Зәлия булып чыкса, Ихтияр аны күрү белән кочаклап алыр да шушы мәхшәрле көнне өйләренә кадәр күтәреп кайтыр, моннан соң беркая да җибәрмәс, һәрчак үзе янында гына тотар кебек иде.* Р.Вәлиев. *Ниндидер могҗиза белән аның очын кисеп алып, өстен тигезләп, «сыпырып» куйганнар диярсең...* Г.Гыйльманов

МОГҖИЗАВИ *с. гар.* Могҗиза дәрәҗәсендәге; искитәрлек, гадәттән тыш сыйфатларга ия булган. *Киң күкрәкле, шома маңгайлы, маңгаена хәрефләре кыеп, матур итеп «ЗИЛ» дип язылган --- бу могҗизави машиналардан әллә нинди чит дөнья, шәһәр исләре, тузанлы иген, урак кайнары белән бергә ят бензин, ягулык-май исләре аңкып тора.* А.Хәлим. *Бәлки, хәерлегә булгандыр, әнә бит Сиринәнең тәне-җанында нинди могҗизави үзгәрешләр башланды...* Р.Низамиев. *Сугыш – җәмгыятьнең авыру халәте, дип әйтсәләр дә, мин аны яшәеш рәвешен, тормыш принципларын чагылдыручы бер могҗизави индикаторга тиңләр идем*. Ә.Рәшит

МОГҖИЗАЛЫ *с.* 1) Гаҗәп, искитәрлек, шаккатырлык. *Әлеге могҗизалы универсаль уен коралының исеме – тел!* Ф.Дунай. *Алар гына да җитмәгәч, түземсез тамашачылар Нуриевның могҗизалы биюен хәтта аягүрә баскан килеш тә кararга ризалаштылар.* Р.Вәли

2) Серле; кызык, үзенчәлекле. *Рафаэль өчен яңа, моңарчы күрелмәгән бер дөнья бит бу. Үзе күпме көтеп, күпме хыялланып тапкан яңа һәм искиткеч могҗизалы дөнья*. Р.Мөхәммәдиев. *Ирекkә могҗизалы бер төш кенә күрәдер кебек тә тоела, аннары тагын моның чынлыгына ышана.* Ф.Садриев. *Менә шушы могҗизалы су минем сәламәтлегемне уңай якка хәл итте дә инде.* Казан утлары

3) Гайре табигый, чынбарлыкта була алмый торган. *Мич башында яткanda, түшәмдәге ботакларны, алар тирәсендәге сызык-эзләрне дә могҗизалы «шайтаннар», «җанварлар» итеп күрә булачак сынчы*. Т.Нәҗмиев

МОГИКАН *и.* Төньяк Америкада яшәгән һәм үлеп беткән индеецлар кабиләсенең атамасы һәм шул кабиләнең аерым бер кешесе. *Безнең балалар Чингачгукның кем икәнен, индеецларның делавар яки могикан кабиләләре турында шундук сөйләп бирәчәкләр, ә менә океан аръягында түгел, элек үзенең газиз Татарстанындагы Актаныш районында яшәгән найман яисә кирәет кабиләләре турында берни дә белмиләр*. Р.Хәким

◊ **Соңгы могикан** Бетеп бара, югалу алдында торган нәрсәнең дә булса соңгы вәкиле. *Аннары Сахалинда теркәлгән бердәнбер айн кешесе. Исхакыйның соңгы болгары. Соңгы могиканнар...* А.Тимергалин. *Олылардан соңгы могиканны, Илләр буйлап, зурлап йөртерләр. Нинди бөек халык булган, диеп, Дөнья аңа карап фикерләр*. М.Галиев. *Чыннан да, әгәр без – Сәйдәш заманының соңгы могиканнары – дәшми калабыз, татар халкының бөек улы-композиторы, аның тормышы һәм иҗаты турындагы драманы сөйләп калмыйбыз икән, мәдәният тарихындагы байтак сәхифәләр килер буыннар өчен күләгәдә торып калачак*. С.Шамов

МОГОЛ *и.* 1) 1526–1858 елларда Һиндстанда идарә иткән династия. *Гарәпләр Һиндстанда Бөек Могол дәүләтенә нигез салалар.* М.Әхмәтҗанов. *Моти Мәсҗеде артында гына могол бакчасы.* Ә.Халидов. *Моголларның хәрби һәм оештыру терминнары барысы да төркинеке – уннар, йөзләргә бүлүдән башлап.* Татар милләт календаре

2) Монголлар токымыннан булган һәм хәзергесе вакытта Әфганстан территориясендә яшәүче азсанлы халык; шуның бер вәкиле

МОГТӘБӘР *с. гар. кит.* Хөрмәтле; абруйлы, югары дәрәҗәле, күренекле. *Авылның могтәбәр кешеләре капкасы турысыннан узганда, җыр өзелеп тора*. М.Мәһдиев. *Бу ике могтәбәр шәхес, заманалар үзгәреп, мәчет салу мөмкинлеге тугач, авылдашлары Әюп абый Вәлиуллин һәм Җәүдәт Миннәхмәтов белән бу изге эшне башлап йөрүчеләр булдылар*. Т.Нәҗмиев

МО́ДА *и. фр.* 1) Билгеле бер җәмгыятьтә ниндидер бер вакыт аралыгында кием-салымга, тормыш кирәкъяракларына һ.б. бәйле рәвештә зәвыклар өстенлеге. *– Төпчек малай җибәрә, – диде түшен тагын да киереп Галикәй. – Мода үзгәргән саен, бишалты посылка чүпрәк сала!* А.Гыйләҗев. *Ул [әнием] Мәскәүдә яшәгән. Кистергән чәчле, шул заман модасында, бик затлы киемнәрдән*. А.Хәсәнов. *Тукаемны, Такташымны сөйми, Имеш, алар – авыл җырчысы. Мода өчен затлы китап җыя, Тик опера, имеш, «моңлы»сы.* Р.Зәкуан

2) Заман һәм сезон таләпләренә бәйле рәвештә, кешеләрнең зәвыгына туры килерлек кием үрнәкләре. *Интизар торып баскач, аның гәүдәсенә сыланып торган соңгы мода белән тегелгән костюмына, кардай ак күлмәгенә, якасына килеп кунган кара күбәләгенә, бармагындагы имән чикләвеге кадәр кашлы йөзегенә карап, мәҗлестәге барча кыз өнсез калды.* Р.Вәлиев. *Төсле-ялтыравык мода журналларында ир-атлар өлгесе итеп бирелә торган фотосурәтләрең бер читтә торсын, чынлаптыр менә...* Р.Низамиев. *Мода белән кызыксынучыларның сорауларына модельерлар, дизайнерлар һәм башка белгечләр җавап бирде*. Өмет

3) *сөйл.* Аерым бер чорда, җәмгыятьтә, бер төркем кешеләр арасында уңай дип кабул ителгән яисә өстенлек алган күренеш, эшчәнлек, киң таралган гадәт, фикер, юнәлеш һ.б. *Зәйнуллина апа үзе татар мәктәбендә укытса да, Луиза русча укыды. Ул елларда мода шулай иде.* Н.Фәттах. *Гомумән, ул елларда русча әйбәт белү, чатнатып нәкъ русларча сөйли белү хакында сүз куертулар модада иде.* М.Госманов. *Мәркәзебезнең унике клубына һәм дүрт сарайга (театр биналарында концерт кую модасы юк иде) шау-гөр килеп халык җыела, җыр белән шигырь, музыка белән юмор үрелеп бәйрәмгә әверелә иде.* К.Кәримов

◊ **Модага керү** 1) Модалы булып китү. *Төркиядә кызыл төстәге, чуклы фәсләр XIX гасырның беренче яртысында модага кергән.* А.Тимергалин. *Хәзер ниндидер формасыз, абстракт дип әйтерлек рәсемнәр модага кереп китте.* И.Сиражи; 2) Гадәткә керү, җәмгыятьтә кабул ителә, кулланыла башлау. *80 нче еллар ахыры – 90 нчы еллар башында бездә диссидентлык модага кергән иде.* Р.Фәтхерахманов. *Ул елларда эшмәкәрлек модага кереп киткән иде, кем гәзит-журнал чыгара, кем – китап, дигәндәй...* Р.Миңнуллин; 3) Киң таралу; игътибар үзәгендә булу, кызыксыну уяту. *Хатыннары яраткач, аларның кодрәтле икенче яртылары да соңгы елларда аеруча җанланып, аеруча модага кереп киткән балет сәнгатен ошатырга тиеш булып чыга бит инде!* Р.Вәли. *Мине бер тенденция сагайта: тарихи романнар язу модага керде түгелме?* Казан утлары. **Модага ияргү** Заман таләпләренә буйсыну; башкалардан күреп эшләү. *Күптән түгел Лас-Вегаста (Казанныкыннан зуррак), Парижда (Казанныкыннан кечерәк) шулай ук пирамидалар төзелде, ләкин алар – барыннан да бигрәк модага ияргү һәм архитектура стиле.* С.Гарифуллин. *Чөнки бу вакытта киң таралган модага иярәп, егетләрнең күбесе матросларныкына охшаш киң балаклы чалбарлар кисә, Рудольфныкы урта буйлы гәүдәсенә артык сыланган, артык тар булуы белән әллә кайдан күзгә ташланып тора иде.* Р.Вәли. **Модадан артта калу** Киенү, яшәү рәвеше һ.б. белән мода таләпләренә туры килмәү. *Үзең модадан артта калган син, акыл өйрәткән буласың ---.* А.Нуруллин. **Модадан чыгу** Төсе, формасы, тегелеше һ.б.ш. белән модалы булмау (кием тур.); модасы (*3 мәгъ.*) искерү. *Шәһәрдә нинди кием модадан чыкканын беләсең килсә, аңа [Галикәйгә] гына бар.* А.Гыйләҗев. *Диссидентлык модадан чыкты, сайлауларда җиңүне хакимият белән әшнәлек һәм капитал тәэмин итә башлады.* Р.Фәтхерахманов. **Модадан төшү** *к.* **модадан чыгу**. *[Әбинең] Өстендә инде модадан әллә кайчан төшеп калган хәтфә тышлы жакет, башындагы бинһая киң береты астыннан ак чәчләре күренеп тора.* Р.Фәизов. **Модасы чыгу** *к.* **модадан чыгу**. *Ул адәм Ташкент өчен сәеррәк киенгән – ялык-йолык килгән күнитекләрдән, эссе булса да, үзенә зуррак булган кыйммәтле, инде күптән модасы чыккан яңа костюмнан иде.* Р.Мирхәйдәров

МОДАЛЫ *с.* 1) Мода таләпләренә туры килә торган. – *Ярый. Керегез, – диде министр ханым, үзе, модалы кыска күлмәгенең итәген тарткалап куйгач, кабинетына алдан кереп китте.* Г.Ахунов. *Кырык еллардан соң бу туның дөньяда иң модалы киемгә әйләнгәнлеге әлбәттә гаҗәп.* М.Мәһдиев. *Ә аның [Сафый Насыйбуллинның] улы өстендә иң модалы кием булса да, башында, һәрвакыттагыча, кәләпүш.* Р.Солтанова

2) Билгеле бер җәмгыятьтә кабул ителгән, киң таралган, актив кулланылышта булган. *Республикабыз матбугатының дистәләрчә еллар буена тупланган матур традицияләре бар. Төрле-төрле модалы агымнарга кушылып, ул традицияләрне югалтмаска, саклап калырга кирәк.* Казан утлары

МОДАЛЬ *с. лингв.* Модальлекне белдерә торган. *Бу очракта бар, юк, түгел сүзләре урынында була, булмый сүзләре үзләре генә кулланылырга, ә модаль сүзләр янында алар өстәлеп килергә тиеш.* Р.Юсупов. *Чөнки безнең исем, сыйфат, фигыль, модаль сүзләребезнең һәркайсында ясалмышында ук күплек идеясе бар.* Х.Сарьян. *Модаль сүзләр сөйләмдә модальлек белдерүнең лексик чарасы буларак билгеләнә. Кереш сүзләр – синтаксик категория, аларны модаль сүзләр белән тиңләштерергә ярамый.* Татар теле морфологиясе

МОДАЛЬЛЕК *и. лингв.* Сөйләүченең сөйләм эчтәлегенә, сөйләмнең чынбарлыкка мөнәсәбәтен билгели һәм аны кереш сүзләр, интонация, фигыль төркемчәләре, хәбәрлек сүзләр һ.б. аша белдерә торган грамматик категория. *5 нче сыйныф укучысы татар телендәге кушымчаларның (аларның санын күз алдына китереп карагыз) сүз ясагычларга, модальлек белдерә торганнарга, бәйләгечләргә бүленешен яттан белергә тиеш!* Х.Ширмән. *Белгәнебезчә, модальлек – киң мәгънәдә сөйләмнең чынбарлыкка төрле-төрле мөнәсәбәтен белдерү дигән сүз, һәм ул күп төрле тел чаралары – морфологик, синтаксик, фонетик һәм лексик чаралар ярдәмендә башкарыла.* Татар теле морфологиясе

МОДЕЛИЗМ *и. тех.* Машина (самолёт, судно һ.б.ш.) механизмнарын һәм корылмаларын ясау, конструкцияләү, сынап карау эшләре. *Уңышлы яклардан мәктәпләрдә һәм зурлар арасында физкультура-спорт эшенә игътибарның артуы, бигрәк тә спортның мылтыктан ату, парашют белән сикерү, моделизм төрләрен атарга була.* Шәһри Казан

МОДЕЛЬ *и. фр.* 1) Үрнәк, өлге өчен эшләнгән әйбер. *Без әле генә кереп чыккан җир өй ул – бер модель генә, бу тирәдә яшәгән берәр кавемнең кайсыдыр чорда яшәп киткән куышы...* Ф.Бәйрәмова. *Иң элек эскиз – модель рәсеме эшләнә.* Татарстан яшьләре. *[Н.Әюпова:] Мин модельләремдә нигездә натураль ефәк кулланам.* Сәхнә

2) Форма, ысул, калып. *Ләкин ул модель без күз алдына китергән өлгегә туры килми, әлбәттә.* Ә.Баян. *Әле бит һәр язучы жанрның яңа моделен тудырырга омтыла.* Т.Галиуллин. *Болар сөйләр өчен кызыклы булсалар да, кешеләрне туктаусыз низагта яшәмәскә чакырсалар да, реаль*

тормышта модель була алмыйлардыр шул. Т.Миңнуллин

3) *тех.* Берәр нәрсәнең кечерәйтеп ясалган үрнәге яки схемасы. *Галәмне өйрәнә барып, астрономнар күзәтүләр нигезендә торган саен катлаулырак һәм төгәлрәк модельләр төзиләр, бу модельләр торган саен күбрәк космик күренешләрне аңлатып бирә алалар.* Галәм. Җир. Кеше. *[Укучыларның] кайсы очкыч, кайсы көймә модельләре ясый, классик бию түгәрәкләрендә, сынлы сәнгать студияләрендә иҗат серләрен үзләштерсә, кайберләре журналистикада, шигъриятта каләм тибрәтү күнекмәләрен ала.* Мәгърифәт

4) Төрле машина, конструкция, механизм һ.б. тибы. *Аларны аңларга иң соңгы модель электрон-хисаплау машиналарының да башы җитмәс.* А.Хәсәнов. *Телевизорны алганда, ничек сөенгән иде ул! Плазма экранлы, соңгы модель дип, дусларына да мактанды бит әле!* А.Галиева. *Җайланма кесә телефоннарының теләсә кайсы моделенә тоташтырыла ала.* Мәдәни җомга

5) *тех.* Эретеп кою эшендә кулланыла торган калып, өлге

6) Хакимияттә, идарә итүдә билгеле бер юнәлеш, алым, ысул. *Яңа идеяләрне үстереп, дөньяга яңа үсеш модельләре тәкъдим итә алганда, бу гаделсезлеккә каршы торырга, дөньядагы көчләр торышын яхшыга үзгәртә башларга мөмкин.* Р.Минһаҗ. *Гадәттә кешеләр үз фикерләрен башкаларга тагарга омтыла, ә кулында хакимият тә булса, ул аларны бөтен җәмгыятькә тагарга тырыша.* Р.Хәким. *Танылган сәясәт белгече Дмитрий Бадовский да әнә: «Хакимиятнең яңа моделе – Медведев һәм Путин тандемы туды», – дип исәпли.* Шәһри Казан

7) Үрнәк, өлге итеп тегелгән төрле фасондагы индивидуаль киемнәрне подиумнан, сәхнәдән халыкка тәкъдим итүче кеше. *Әйтик, татар фамилияле модель Ирина Шәйхелисламова белән гаилә корырга җыенган футболчы Криштиан Роналду 38 миллионлык хезмәт хакы белән җиденче урынга урнашкан.* Ватаным Татарстан. *Төрле илләрдән җыелган абруйлы жюри фикеренә караганда, татарстанлы дөньяда иң яхшы модель дип танылды.* Шәһри Казан

8) Рәсемле журналлар, реклама плакатлары һ.б.ш. өчен фотосурәткә төшү белән шөгыльләнүче кеше. *Модельләргә килсәк, мин беренче төшергән модель – татар егете Эмиль Шига.* Ватаным Татарстан

9) Портрет ясаганда, карап ясар өчен, рәссам алдында торучы кеше. *--- картинаны эшләгәндә, артистка Нәфыйга Арапова модель булган, хәзер каберләре янәшә ---.* Э.Шәрифуллина. *Нишләсен, кызның образын тулысынча нәфис итеп күрәсе килгән рәссам, эш кулларга барып җиткәч, икенче модель чакырырга мәҗбүр була.* Шәһри Казан

МОДЕЛЬЕР *и. фр.* Яңа кием фасоннары, модельләр (*1 мәгъ.*) уйлап табу, тегү белгече. *Әллә кай арада яңалыкны эзләп таба [Венера], һәр ачышка башкалардан алдан барып өлгерә, кем әйтмешли, соңгы җөйне төенләп бетергәнен дә көтмичә, модельерларның кулыннан тартып алып, өр-яңа үрнәкләргә төренеп, сәхнәгә дә чыгып өлгерә.* К.Кәримов. *Мода дөньясында танылган модельер Вячеслав Зайцев безнең дизайнерлар белән хезмәттәшлек итәргә ризалык белдерде.* Шәһри Казан

МОДЕЛЬЛӘШТЕРҮ *ф.* Төзү, оештыру; калыплаштыру. *Бу әдәбият чынбарлыкны кабат тергезү максаты белән түгел, бәлки яңа чынбарлык төзү, модельләштерү өчен языла.* Д.Заһидуллина. *Иң камил приборлар һәм методлар ярдәмендә тере организм матдә яралуның аерым этаплары модельләштерелә һәм өйрәнелә.* Галәм. Җир. Кеше

Модельләштерә башлау Модельләштерергә керешү

Модельләштереп тору Сөйләү моментында модельләштерү; даими рәвештә модельләштерү

МОДЕЛЬЛЕ *с.* 1) Билгеле модельдәге, типтагы. *Шубаринны исә үлемнән могҗиза белән Нәргиз саклап калды: хатын-кызга хас эчке тоем белән ул җиденче модельле кызыл «Жигули»ның бина артыннан, караңгыдан шуып чыгуында ниндидер хәтәр-хәвеф барлыгын сизеп алган иде.* Р.Мирхәйдәров. *АКШта цифрлы тапшыруларны кабул итми торган модельле телевизорларны яңа мөмкинлекле плазма, сыек кристаллыларына алыштыралар икән.* Татарстан яшьләре

2) Иң соңгы мода буенча эшләнгән, модалы, үзенчәлекле, эксклюзив. *Куртка сүтеп, дублёнка тегүдән эш башлаган «Йомшак Алтын» бүген 60 төр модельле чүәкләр җитештерә.* Татарстан яшьләре

МОДЕЛЬЧЕ *и. махс.* Модель (*2 мәгъ.*) ясаучы, модельер. *Ф3Өдә кызның сәләтле булуын бик тиз күреп алалар һәм Гөләндәмнән югары квалификацияле кием кисүче-модельче әзерлиләр.* А.Тимергалин

МОДЕМ *и. ингл.* Челтәр аша компьютерара мәгълүмат тапшыру җайланмасы. *Кереп, шул мең биш йөз студентка бер компьютер, модем сорый алмыйлармы?!* Татарстан яшьләре. *Кәрәзле телефон, төрле мобиль җайланмалар, модем өчен кирәкле SIM карталарның элемтә салоннарында гына сатылмавын барыбыз да яхшы белә.* Шәһри Казан

МОДЕРА́ТОР *и. лат.* 1) *муз.* Музыкаль инструментларның тавышын кимәтә, әкренәйтә торган җайланма

2) *тех.* Машиналарның тизлеген көйләү җайланмасы

3) Интернеттагы теге яки бу сайтта, аралашу мәйданында җаваплы кеше; төркем җитәкчесе. *Бераз соңрак бу игълан модератор тарафыннан юкка чыгарылган.* Шәһри Казан. *Модератор тикшергәннән соң, хәбәр сайтта пәйда булачак.* Казан утлары. *Модератор билгеләп узганча, әлеге форумга шундый зур әһәмият бирелүе Татарстан җитәкчелегенең интеллектуаль милек үсешенә җитди игътибар юнәлтүен дәлилли.* Ватаным Татарстан

4) Нинди дә булса өлкәдә, юнәлештә җаваплы кеше. *Татарстан Президентына республика авыл территорияләрен комплексы үстерү буенча яңа проектны модератор, «Агропарк-менеджмент» идарәче компаниясе җитәкчесе Юрий Шевченко тәкъдим итте.* Ватаным Татарстан. *Ике көнгә*

генә килгәндә, модератор безнең илдәге көнкүреш мәшәкатьләренә төшенергә өлгермәгән, билгеле. Шәһри Казан

МОДЕРН *и. фр. махс.* XIX йөз ахыры – XX йөз башы архитектура һәм гамәли сәнгатендәге стиль юнәлеше. *– Модерн! – Бервакыт, Кулларын һавада уйнатып, Шулай дип кычкырды берәү Һәм йөгереп килде Киерелгән киндер каршына.* Н.Хисамов. *Икенче бөтендөнья сугышы чорында җимерелгән бина урынына салынган Термини вокзалы бу тирәдәге бердәнбер модерн ысулындагы бина иде.* М.Юныс. *Газинур Морат – модерн шагыйрь, киң күңелле кеше, әмма, шигыреннән башка, мохтаҗларга таратырлык маясы юк.* Р.Батулла

МОДЕРНИЗА́ЦИЯ *и.* 1) Нәрсәне дә булса заман таләпләренә яраклаштырып үзгәртү, яңарту эше. *Без бит хәзер модернизация, яңа технологияләр заманында яшибез.* Г.Гыйльманов. *Гамәлдәге система нигезендә болайрак килеп чыга: реформа, модернизация, яңалык кертү, дибез дә, аны-моны үйламыйча, эшне башлыйбыз.* Р.Вәлиев

2) Элек кулланылышта булган яисә искерәк әйберләрне үзгәрешләр кертеп камилләштерү, яңарту, башка шартларда куллану өчен җайлаштыру. *Бүген биредә модернизация – производстволы яңа автомат линияләр белән җиһазландыру бара*. Ватаным Татарстан. *Соңгы дүрт елда гына да биредә 800 Т-150, 200 К-700А тракторларын, 40 «Дон-1500» комбайнын яңартып, модернизация үткәреп, тагын берничә ел ремонтсыз эшләрлек хәлгә җиткергәннәр.* Татарстан яшьләре

МОДЕРНИЗА́ЦИЯЛӘҮ *ф*. Модернизация ясау; яңарту. *[Машиналарны арттыру проблемасын] күбрәк иске станокларны модернизацияләү исәбенә хәл итәргә туры килер*. Г.Әпсәләмов. *Шулай ук әзерләү, төпләү, басу цехларында зур күләмле модернизацияләү эшләре башкарыла*. Ватаным Татарстан

Модернизацияләп бетерү Барысын да модернизацияләү. *Әгәр без тарифларны арттыру хисабына бу акчаларны янга калдырсак һәм аны шушы тармактагы реформаларга тотсак, тагын сигез елдан әлеге системаны тулысынча модернизацияләп бетереп, ТКХны бу өлкәгә бизнесменнарның инвестицияләрен җәлеп итәр дәрәҗәгә күтәрер идек.* Татарстан яшьләре

Модернизацияләп килү Билгеле бер вакыттан башлап модернизацияләү

Модернизацияләп тору Даими яки регуляр рәвештә модернизацияләү. *Бүгенге көндә исә әлеге авиакомпания тәҗрибәле топ-менеджмент, алгарышлы үсеш стратегиясенә ия һәм һава флоты паркын актив рәвештә модернизацияләп тора*. Ватаным Татарстан

Модернизацияләп чыгу Һәрбер сән, барысын да, тулысынча модернизацияләү

Модернизацияли башлау Модернизацияләргә тотыну

МОДЕРНИЗМ *и. фр.* XIX йөз ахыры – XX йөз башында барлыкка килеп, әдәбият һәм сәнгать өлкәсендә яңа эстетик принципларга омтылган, реализмнан баш тартып, кубизм, сюрреализм, футуризм һ.б.ш агымнарны берләштергән юнәлеш. *Мәсьәләнең болай куелышы элегрәк әдәбиятта гел саф реализмның чагылышы дип саналган романның әдип иҗаты буенча дәвам итеп килгән яңа романтизм яисә модернизм күренешләре белән ниндидер бәйләнеше һәм уртаклыгы бар дигән яңа кыю карашларны да бөтенләй үк инкяр итми.* Р.Сверигин. *Бәлки, «яңа теоретик концепция», «авангардизм», «модернизм» дигәннәребез борынгы сүз сәнгатенең кабатланышы, дәвам итүедер?* Казан утлары

МОДЕРНИСТ *и. фр.* Әдәбият һәм сәнгатьтә модернизм алымнары кулланып иҗат итүче автор. *Модернист имам әлеге исемдә бернинди гөнаһ та күрми.* Р.Зәйдулла. *Бит модернист ул – үтә чыккан индивидуалист.* Р.Фәйзуллин. *XX йөз башындагы татар модернист авторларының традицияләрен үстереп, яшәештәге төп кануннарны аерып чыгару омтылышы ясый ул [Ф.Бәйрәмова].* Д.Заһидуллина

МОДЕРНИ́СТИК *с.* Модернизмга нигезләнгән; модернизмга яки модернистка хас булган. *Т.Галиуллин моңа кадәр әдәбият белемендә тискәре бәяләнеп килгән, ләкин күп кенә әдипләр иҗатына зур йогынты ясаган динимифологик катламның, модернистик һәм шәкли эзләнүләрнең махсус тикшеренүләр объекты булырга тиешлеген дәлилли.* Д.Заһидуллина. *Әсәрдә Яшәү һәм Үлем фәлсәфәсе модернистик әсәрләрдәгечә хәл ителә.* Фән һәм тел. *Бәлки, акыл, зиһен, күңел саташуларына корылган шигъриятне, чыннан да, модернистик әдәбият дип билгеләргә кирәктер?* Казан утлары

МОДИ́СТКА *и. фр. иск.* 1) Хатын-кыз эшләпәләре тегү остасы. *[Фәйзулланың] Хатыны Франциядә танылган модистка булган, --- ул теккән эшләпәләр әле дә музейларда саклана, диләр.* Сөембикә

2) Хатын-кыз киемнәре тегүче. *Бөтен дөньяга мәшһүр модалар уйлап табучы модисткалар Парижда яшиләр.* Г.Гали. *Мәхәббәтне үлчәүгә куялармыни, сөйгәнеңнең югары белемле яисә талантлы модистка булуы мөһиммени?* Р.Мирхәйдәров

МОДИФИКА́ТОР *и. лат.* 1) *тех*. Төрле машиналарның хәрәкәтен, эшчәнлеген үзгәртү җайланмасы

2) *хим*., *биол*. Катнашмаларның үзлекләрен үзгәртү өчен кулланыла торган матдә. *Углеродлы тимер эретмәләре кристаллашканда һәм кабатлана торган җылыту – суыту вакытында фаза әверелешләре кичерәләр, термомеханик, химик тәэсирләр һәм модификатор – кушылмалар керткәндә структураларын һәм үзлекләрен үзгәртәләр.* Төзү материаллары

3) Генетика: төп геннының тәэсирен киметә яки көчәйтә торган ген

4) *лингв*. Башка сүзләрнең мәгънәсен үзгәртә торган сүзләр, сүз төркемнәре; модификацияләүче сүзләр. *Бер төркем тел семьялыкларында --- модификатор (актионсарт) фигыльләр кулланыла һәм аларның мәгънәләре беришле, мәсәлән, китү мәгънәсендәге фигыльләр модификатор буларак кинәт башлануны (балкып китү, ярсып китү), чыгу мәгънәсендәге фигыльләр тәмамлау, һәммәсен эченә алуны (укып чыгу, карап чыгу) белдерә һ.б.* Фән һәм тел

МОДИФИКА́ТОРЧЫ *и.* Модификаторлар цехында эшләүче. *Модификаторчыларның еллык планы артыгы белән үтәлгән булып чыкты.* Шәһри Казан

МОДИФИКА́ЦИЯ *и. кит.* 1) Нәрсәнең дә булса үзгәрүе, башка төргә әйләнүе

2) Нәрсәне дә булса үзгәртү, башка төргә әйләндерү. *Соңгысына килгәндә, бүген күпләрне генетик модификация ярдәмендә үстерелгән яшелчә һәм җиләк-җимеш, алардан ясалган ашамлыклар проблемасы борчый.* Ватаным Татарстан. *Безнең өчен балаларга сәламәт, модификация үтмәгән, витаминга бай ризык ашату мөһим.* Шәһри Казан

3) Нәрсәнеңдер үзгәртелгән төре. *Күргәзмәдә --- раритет гитаралар, төрле модификациядәге мандолиналар урын алган иде.* Мәдәни җомга. *Бу модификация тагын да югарырак техник характеристика белән аерылып торачак.* Ватаным Татарстан

МОДИФИКА́ЦИЯЛӘҮ *ф. кит.* Нәрсәгә дә булса модификация ясау; үзгәртү, башка төргә әйләндерү. *– Наркотик чараларны модификацияләү, ягъни психоактив матдәләрнең күп төрен алдан ук дәүләт контроленә күчерү, киләчәктә бу хәлнең кичектерелүенә китерер иде, – дип белдерә ТР Министрлар Кабинетының наркотикларга каршы көрәш бүлеге башлыгы.* Шәһри Казан. *– Алдагы 15 елда тармакта заказлар тотрыклы булачак, чөнки Русиядә берничә атом станциясен модификацияләү көтелә, – диде Президент.* Ватаным Татарстан

Модификацияли башлау Модификацияләргә керешү. *Иске станцияләрне модификацияли башларга әмер бирелде.* И.Нуруллин

Модификацияләп бетерү Барысын да модификацияләү. *Дәүләт заказы системасын модификацияләп бетергәч, дәүләт чыгымнарын оптимальләштерү башланачак.* Ватаным Татарстан

Модификацияләп кую Модификацияләнгән хәлгә китерү

Модификацияләп чыгу Бер-бер артлы һәммәсен дә модификацияләү

МО́ДНИЦА *и. рус сөйл.* Яңа мода белән яисә заманча, зәвыклы киенә торган хатын-кыз. *[Геннадий Мәрфуга турында:] Модница дип сөйләгән идең, шул кызмы?* Г.Ахунов. *Хатыны искиткеч модница булган.* Х.Камалов. *Әнием аркасында «модница» булып, матур киенеп йөрдем дә инде мин.* Сөембикә

МО́ДУЛЬ *и. лат.* **1.** 1) *физ.* Төгәл фәннәрдә кайбер коэффициентлар атамасы. *Эластиклык модуле. Кысылыш модуле. Каршылык модуле*

2) *мат.* Билгеле бер система логарифмын табу өчен, башка система логарифмын тапкырларга кирәк булган сан

3) Космик корабльнең мөстәкыйль оча ала торган аерым бер өлеше. *Америка Кушма Штатларының ике астронавты Нейл Армстронг һәм Эдвин Олдрин Ай өстенә аяк бастылар. Алар анда төшү һәм күтәрелү модуленә утырып төштеләр.* Кызыклар дөньясында. *Кеше яшәрлек 8,5 тонна авырлыгындагы «Небесный дворец – 1» модуле Җир тирәсе орбитасына 2010–2011 елларда чыгарга тиеш.* Мәдәни җомга

4) Форма, модель; калып, өлге. *Аттестатлар компьютерда махсус модуль ярдәмендә рус телендә тутырылачак.* Шәһри Казан

5) Берәр конструкциянең, корылманың чагыштырмача мөстәкыйль кулланыла ала торган, кирәк вакытта бераз җыеп куела ала торган өлеше. *Мебель модульләре*

6) *пед.* Укыту системасында, белемнәрне ешрак тикшереп, балл кую мөмкинлеге булсын өчен, укытылырга тиешле программаның аерым бер өлеше һәм шул өлешне үзләштергәннән соң тапшырылган зачёт, имтихан һ.б. *Билгеле инде, модуль, имтихан, зачётларны кат-кат тапшыралар.* Мәгариф. *Һәр модуль тәмам булганнан соң, тыңлаучылар имтихан тапшыра, һәм аларга белемнәренә тиңдәшле дипломнар (сертификатлар) бирелә.* Ватаным Татарстан

2. *с. мәгъ.* Модульләрдән торган. *Модуль бәдрәфне ясау һәм җиһазлау 550 мең сумга төште.* Шәһри Казан. *Бу авылда фельдшер-акушерлык пункты өчен модуль бина төзеләчәк.* Татарстан яшьләре

МОДУЛЯ́ТОР *и. лат. тех.* Радиотапшыргыч, кино төшерү аппаратлары, телемеханикада һ.б.ш.да тирбәнешләрнең модуляция процессын башкара торган җайланма. *Модулятор, бутагыч кебек аналог схемаларда күп кенә линияле булмаган эффектлар кулланылса да, аналог схемалар линияле схемалар дип атала.* Татарстан яшьләре. *Аннан җиһазлар һәм, «Шевроле» машинасының тәрәзәсен ватып, видеорегистратор, FM модулятор, флешкарта һәм башка кирәк-яраклар урлый.* Ирек мәйданы

МОДУЛЯ́ЦИЯ *и. лат.* 1) *муз.* Бер тональлектән икенче тональлеккә күчү; тавыш югарылыгы үзгәрү. *Бу нисбәттән немец философы Ф.Ницше болай дигән: «Телдә сүзгә караганда да мәкам, шул сүзләрне әйткән энергия, модуляция, темп әһәмиятлерәк».* Р.Зәһидуллина

2) *физ., тех.* Түбән ешлыклы тирбәнешләр тәэсирендә югары ешлыклы тирбәнешләрдә барлыкка килгән үзгәреш

МОДУЛЯ́ЦИЯЛӘҮ *ф.* 1) *муз.* Бер тональлектән икенче тональлеккә күчү (музыкаль авазлар тур.)

2) Модуляция барлыкка китерү

МО́ДУС *и. лат. кит.* Төр; ысул, алым (юриспруденция, фәлсәфә, логикада кулланыла). *«Ак эт», «Шүрәле» кебек хикәяләрдә ироник модус алга чыга ---.* Д.Зәһидуллина. *Аныңча, гүзәллек, Абсолютның модусы буларак, табигатькә дә, җәмгыятькә дә хас объектив көч.* Философия. *Шигъри модус белән эш итү осталыгын Х.Туфанның «Иртәләр җитте исә» шигыре ачык аңларга ярдәм итә.* Казан утлары

МОЗА́ИК *с.* 1) Мозаикага охшаш, аерым элементлардан торган. *Моңа инде мең ярым ел вакыт үткән булса да, әле мозаик эшләрнең бик күбесе сакланган.* Х.Миңнегулов. *Соңрак Глория, ничектер, Рушанга, Яшьләр йортының яңа бинасындагы фойеның зур диварын «Мотоциклчылар» дигән мозаик панно бизәп торсын иде, дигән теләк белдерде.* Р.Мирхәйдәров

2) Мозаика рәвешендәге, мозаика техникасында эшләнгән. *Күзгә*

кереп торган метафоралар, капмакаршылыклы – кычкырып торган логик фикерләр аңарда юк диярлек, ул мозаик штрихлардан җыелган микросурәтләр белән рәсем ясый. Р.Миңнуллин. *Бу – шулай ук шагыйрь дә булган прозаик әдип Марсель Галинең «Догалы еллар» исемле портрет-эсселардан гыйбарәт мозаик бер романыдыр.* Р.Гаташ. *Еткыч, гәүдәсен агач кәүсәсенә ныклы терәп ботак өстендә ятканда, тропик агачларның күләгәле яфраклары аркылы төшә торган кояш леопардның мозаик төсен әйләнә-тирә төсенә куша һәм аның тирәсендәге бөҗралар, таплары белән катнаша.* Хайваннар турында очерклар

МОЗА́ИКА *и. фр.* 1) *сәнг.* Нинди дә булса өслеккә төрле төстәге вак пыяла, таш, эмаль, мәрмәр һ.б. материаллардан тезеп ясалган бизәк, сурәт. *Әллә сез минем портретны мозаика итеп ясап, берәр кибет стенасына элмәкче буласызмы?* М.Маликова. *Христиан һәм ислам диннәре сәнгатен иксез-чиксез алтын-көмеш мозаикалар белән чагылдырган дөньядагы бердәнбер корылма бу, диләр төрек дуслар күпне күргән Айя-Софья мәчете турында.* Т.Нәҗмиев. *[Рифкать Вахитовка] Ташкентның «Динамо» стадионында керамик плиткадан төзелгән мозаикасы һәм «Ташкент – 2» аэропорты фойесының бизәлеше уңыш китерә.* Р.Солтанова

2) *җый. мәгъ.* Шундый бизәк ясау өчен файдаланыла торган пыяла, мәрмәр, төсле таш һ.б. материал кисәкләре. *Сарайның үзәк өлешен каплап торган гөмбәзе ак-зәңгәр төстәге мозаика белән капланган булган, түбәнең уртасында 90 кг чамасындагы алтын ай торган.* Татар халкы һәм Татарстан тарихы

3) Төсле ташлар, тонык пыяла, мех, күн һ.б. материаллардан бизәк ясаудан гыйбарәт монументаль нәкыш сәнгате

4) Төрле төстәге һәм формадагы кисәкчекләрдән, вак предметлардан бизәк, рәсем җыюдан гыйбарәт балалар уенчыгы. *Мин инде кактус турындагы легенданы тыңламас өчен мозаика төзеп утырырга да әзер идем.* А.Гыймадиев. *Шакмак урынына төймәләр, мозаика һәм башка вак уенчыклар да кулланырга мөмкин.* Ф.Харрасова

5) *күч.* Күп төрле элементлардан, өлешләрдән, компонентлардан торган әйбер. *Яфрак мозаикасы да үсемлекләрнең яктылык яхшырак төшүгә җайланышы булып тора.* Ботаника. *Белем исемле мозаиканы күз алдыгызга китерегез, ә сез – аның һәр кисәге.* Илһам канатында

6) *күч.* Төрлелек; төрле әйберләр (предметлар, әсәрләр, карашлар, фикерләр, вакыйгалар һ.б.) бергәлеге, катнашмасы. *Шагыйрь Зөлфәт исә К.Латыйпның ирекле шигырьдәге уңышларын, үзенчәлекле ритмикасы китергән яңалыкны билгеләп, болай язды: «Тормышның үзенчәлекле мозаикасы, панорамасы күз алдына килә...»* Р.Гатауллин. *Шәһәр – калейдоскоп, шәһәр – мозаика.* М.Мәһдиев. *Хәзерге заман сурәтле әсәрләр мозаикасында А.Хисамов хезмәтләре төсләр палитрасының куе буяулары һәм кояш яктысының муллыгы белән аерылып тора.* Мәдәни җомга

МОЗА́ИКАЧЫ *и.* Мозаика белән эш итүче; мозаика остасы

МО́ЙВА *и. фин* Корюшкачалар семьялыгыннан вак тәңкәле кечкенә диңгез балыгы. *Авылча гына киенгән бер апа безнең янга килде дә әрҗәдәге туңдырылган мойва балыгын бармагы белән төрткәли башлады.* М.Мәһдиев. *Өч бармаклы акчарлаклар төньяк балыклары булган мойвалар көтүе артыннан башкаларга караганда ешрак очалар.* Хайваннар турында очерклар. *Алар өчен шәһәрдән атна саен туңдырылган минтай балыгы, өебез өстәленә 4 – 5 айга бер генә менеп кунаклаган тәмле мойва балыгы, эре һәм майлы булып үссеннәр өчен, балык мае кайтарыла иде.* Татарстан яшьләре

МОКАСИН *и. ингл.* 1) Төньяк Америка индеецларының күннән эшләнгән, оекка охшаш йомшак табанлы аяк киеме. *Индеецлар ак тәнлеләр белән сугышканда йомшак табанлы мокасиннар киеп йөргәннәр.* Робинзон эзләреннән

2) Йомшак табанлы, үкчәсез аяк киеме. *Нейлон күлмәкләр, твид тройка костюмнар, вельвет пинҗәкләр, мамык кытай полуверлары, очлы башлы мокасиннар, калын платформа табанлы туфлиләр, төрле фасондагы эшләпәләр, туза белмәс габардин һәм бостон костюмнар, киң каптыргычлар һәм галстук булавкалары... Болар игътибарлы кешегә кием хуҗаларының язмышы турында бик күп нәрсәләр сөйли иде.* Р.Мирхәйдәров. *Студентның өстендә ательеда тегелгән кыйммәтле костюм иде. Аягында затлы мокасин.* М.Юныс

МО́КО *и. фр.* Вак орлыклы кыйммәтле каһвә сорты һәм шуннан ясалган эчемлек. *--- шоколадка рус хәрефләре белән «Моко» дип язылган.* А.Тимергалин

МОКТӘДИР *с. гар.* Көчле, кодрәтле. *Каләм тотмая вә язмая мокътәдир улмаян исәгез...* З.Бигиев. *Әгәр дә мокътәдир мотәрҗимнәр тарафыннан тәрҗемә ителгән булса, бәлки, кыйммәте бераз арткан булыр иде.* Г.Камал. *--- бөтен барлыкны яратырга мокътәдир булган Зат ихсан итә.* Инсан һәм дин

МОКЫТ *с.* Аңсыз, мәнсез; үз фикере булмаган; йомшак холыклы, жебегән. *[Ибраһимов:] Сәламәт булсагыз, ник саклану турында уйланмыйсыз, ваемсыз гына: «Дөрес, өстемә алам», – дип, мәлҗегән мокыттай мыгырдап утырасыз?* М.Насыйбуллин. *Җиде-сигез ел хезмәт иткән, сугыш узган бу егетләрне алыштыру өчен, мондәй мокытларга сафка басарга кирәк иде...* М.Мәһдиев. *Без – авыл мокытлары – таяк, йодрыкны гына аңлый идек шул.* Р.Батулла

МОКЫТЛАНУ *ф.* 1) Аңгыралану, мәнсезләнү. *Мокытланып, ишек төбенә чүмәшеп, түрдәгеләр ыргыткан сөяккә ризалашып утыру безгә килешми.* Т.Миңнуллин

2) Үзеңне мокыт шикелле тоту. *Үз хатыныңтурында «минем хатын» дип мокытланып сөйләшәсе түгел.* М.Мәһдиев

Мокытлана бару Көннән-көн ныграк мокытлану. *Картая барган саен мокытлана барабыз.* Сөембикә

Мокытлана башлау Мокытлану билгеләре сизелү

Мокытлана төшү Беркадәр мокытлану

Мокытланып бетү Бөтенләй мокытлану. *Кайда Айрат Арсланов мәктәбе? Әллә инде бүгенге яшьләр яисә уртарак буын мокытланып беткәнме, шашканмы, белемсез-тәрбиясезме?* Р.Сибат

Мокытланып калу Берәр вакыйгадан, тәэсирдән соң мокытка әйләнү

Мокытланып китү Кисәк, көтмәгәндә мокытлану

МОКЫТЛЫК *и.* Мокыт булу. *Әлбәттә, «кала шәкерте» була торып, миңа мокытлык, җәбегәнлек күрсәтергә һич ярамый иде.* Ә.Еники. *Мин үземнең мокытлыгымны аңладым: Сабантуйга кул селтәп түгел, әнә шулай палас җәеп утырырлык итеп барасы.* М.Мәһдиев. *Мине иң куандырганы һәм сокландырганы: аңарда (Әмирхан Еникидә) мокытлыкның эзе дә юк.* Т.Миңнуллин

МОЛ *и. лат.* Порт акваториясен көчле дулкыннардан саклау өчен хезмәт итә торган биек, бер кырые диңгезгә тоташкан гидротехник корылма. *Дулкыннар, күкрәкләрен алга терәп, молга каршы килеп бәрелделәр һәм үлек булып кире кайттылар.* Г.Коләхмәтов

МОЛДАВАН *и.* Роман телләренең берсендә сөйләшкән, Молдавиядә яшәгән төп халык һәм шул халыкның бер кешесе. *Ул көннәрдә әле гагаузларның гына түгел, алардан күпкә өстен торган --- молдаваннарның да милли аңы уяну хәрәкәте болай дөрләп кабыныр дип фараз итү бик кыен иде.* Т.Әйди. *Молдаваннар, дисең, күрмиләрме Изгәнлеген «урыс теллеләр»нең?!* Ә.Синугыл-Куганаклы. *Олы юлдан авылга таба борылуга, безне милли киемдәге молдаван дуслар чигүле сөлгегә куелган ипи-тоз белән каршыладылар.* Ш.Мостафин

МОЛЕ́КУЛА *и. лат.* Матдәнең төп химик үзенчәлекләренә ия булган иң кечкенә кисәге. *Аксымнарның күптөрле булуы 20 дән артык аминокислотаның, бер-берсе белән кушылып, төрле төзелешле аксым молекулаларын хасил итә алулары белән аңлатыла.* Биология. *Молекула үзе атомнар дип аталган тагын да ваграк кисәкчекләрдән тора.* Диңгез тирәнлегендә. *Бутлеровның идеясе шуннан гыйбарәт: молекуланың нинди химик әверелешләргә сәләтле булуын өйрәнсәң, молекуланың эчке төзелешен бик төгәл итеп күрсәтергә мөмкин.* Химия фаш итә

МОЛЕКУЛЯР *с.* Молекулага мөнәсәбәтле. *Туфракның молекуляр структурасы кайда да бер инде аның.* Аманулла. *Сәмихләр (чәер) – пентозлардан һәм гексозлардан торган югары молекуляр полисахаридлар.* Урман аптекасы. *Шулай итеп, төшнең магнитик релаксациясен өйрәнеп, матдәдәге молекуляр хәрәкәтләр турында бай һәм төгәл информация алып булуы ачык күренә.* Фән һәм тел

МОЛЕСКИН *и. ингл.* **1**. Эш киемнәре, спорт костюмнары һ.б.ш. тегү өчен кулланыла торган калын һәм ник мамык тукыма

2. *с. мәгъ.* Шундый тукымадан тегелгән, эшләнгән. *Молескин пиджак*

МОЛИБДЕН *и. гр. хим.* Көмешсыман ак, ялтыравык каты металл; тереклек өчен кирәкле булган микроэлемент. *Гөлҗимештә С, В2, Р, К витаминнары, шикәр, кислоталар, пектин һәм буягыч матдәләр, бакыр, хром, молибден, кобальт микроэлементлары бар.* Ватаным Татарстан. *Җир җиләге С, Е, В витаминнарына, марганец, калий, бакыр, кальций, кобальт, молибден, йодка бай.* Мәдәни җомга. *Составында молибден булган минераль ашлама исә бик кыйммәт тора.* Шәһри Казан

МОЛЛЮ́СКЛАР *и. лат. зоол.* Гадәттә кабырчык белән капланган умырткасыз, йомшак тәнле хайван. *Күл, урманнар, басу, хәтта тропик балыклар, яшел суүсемнәр һәм моллюсклар яши торган акварИум – болар барысы да экологик системалар.* Галәм. Җир. Кеше. *Монда акчарлаклар чокырларга кереп калган балыкларны җыялар, диңгез керпеләренең кабыкларын ачалар, лайдан суалчаннар һәм моллюсклар эзлиләр.* Хайваннар турында очерклар. *Төче сулыкларда (күбесенчә чиста салкын тау чишмәләрендә һәм елгаларында) һәм диңгезләрдә ташларга, үсемлекләргә, моллюсклар кабырчыгына берегеп, төрле төстәге куык яки таплар хасил итеп яшиләр.* Ботаника

МО́ЛНИЯ *и. рус* 1) *махс.* Ашыгыч телеграмма. *[Фәнис:] Ике атналык эшне биш көндә! Молния белән бүген үк редакциягә хәбәр итәм.* Г.Минский

2) Даими һәм оператив рәвештә көндәлек тормыштагы иң мөһим вакыйга, хәлләрне яктыртып бара торган стена газетасы

3) Аяк һәм өс киемнәре, сумка һ.б.ш.ларда төймә, каптырма, шнур урынына кулланылган, тиз ачыла-ябыла торган тасмасыман җайланма. *Чын тукымадан тегелгәнлеге сизелеп торган банан чалбар, илле кесәле, җитмеш җиде молнияле авангард модалы куртка кигән [М.Юныс], аягында «Пума» кроссовкасы.* М.Галиев. *Манар алдыннан киемнәрдәге төймәләрне, каптырмаларны, молния каптыргычларын сүтеп алырга, кесәләрен әйбәтләп әйләндереп, щётка белән чистартырга кирәк.* Файдалы киңәшләр

МОЛОДЕЦ *хәб. сүз рус сөйл.* **1.** Мактау, хуплау, соклануны белдерү өчен кулланыла. *Үзең дә молодец инде: сүзне тыңлый белдең.* Г.Ахунов. *[Әбләлимов:] Молодец! Колыннар үстерәсең икән анда? Ишеттерделәр.* А.Гыйләҗев. *– Молодец! – диде Рашат һәм шапылдатып кул чапкандай итеп куйды.* Ф.Садриев

2. *с. мәгъ.* Булган; мактауга лаек. *– Минемчә дә молодец кыз ул, – диде лейтенант Павлова һәм кабатлап әйтеп куйды: – Молодец кыз!* А.Шамов

МОЛОТИ́ЛКА *и. рус а.х. сөйл.* Суккыч, ашлык сугу машинасы. *Молотилка, усал ерткыч төсле, ярсып үкерә.* М.Җәлил. *Молотилкада көлтә суккандай, дисәм, әнә күшәп яткан сыерны чебен зурлыгына калдырган кебек, киметкән булырмын.* Ш.Рәкыйпов. *Рушад, Хәкимҗан молотилкада эшләделәр, көлтә эскертләделәр, вика чаптылар.* М.Мәһдиев

МОЛЬ *и. лат.* Халыкара берәмлекләр системасында матдә микъдары берәмлеге. *1971 елда XIV Үлчәмнәр һәм авырлык үлчәүләр буенча генераль конференция СИга үзгәрешләр керткән, атап әйткәндә, матдә микъдары берәмлеге (моль) өстәлгән.* Казан утлары

МОЛЬБЕРТ *и. нем.* Рәсем ясаганда, киндерле рамны бастырып кую өчен кулланыла торган өчаяк. *Һиһаять, ул эшеннән аерыла, үзенең укытучы икәнен исенә төшерә, яңадан балаларның мольбертлары тирәсендә йөри.* Г.Әпсәләмов. *Мольберт янында рәсем ясаучы ханым – янып торган, истә кала торган образ.* Шәһри Казан

МОМЕНТ *и. лат.* **1.** 1) Нинди дә булса эш, күренеш, хәрәкәт башкарыла, үтәлә торган бик кыска вакыт арасы; мизгел. *[Рашат:] Шушы моментта мин Ленин мавзолее каршындагы бер йорттан шалтыратам.* Ф.Садриев. *Димәк, Мәрьям Вәсилевна әле пристаньда ук каты яраланган булуына карамастан, коточкыч авыртуга бирешмичә, хәвефле моментта үз постында торуын дәвам иттергән һәм, пароходны һәлакәттән алып чыгып, тәмам хәлдән тайгач кына аяктан егылган икән.* С.Сабиров

2) Нәрсәнең дә булса үсешендә билгеле бер этап, чор. *Кысылу нәтиҗәсендә массаның концентрациясе артканнан-арта, һәм, һиһаять, шундый бер момент килеп җитә ки, аның өстендәге гравитация көче шулкадәр зурая, аны җиңү өчен, яктылык тизлегеннән дә зуррак тизлек кирәк булыр иде.* Галәм. Җир. Кеше

3) *сөйл.* Нинди дә булса күренешнең, хәлнең һ.б.ш. аерым бер ягы. *Ләкин бөеклек өчен әле тагын бер момент зур әһәмияткә ия.* М.Вәлиев. *Монда җитди бер психологик момент бар.* М.Маликова. *Монда тәрбияви момент та бар: хорафатлык шаукымын кертмичә генә, табигатькә, әйләнә-тирә мохиткә мәхәббәт тәрбияләү.* Шәһри Казан

4) Уңай очрак, җайлы вакыт. *Аның өчен иң тантаналы момент шул иде, ул вак акчаны эчкә, кибетче аяк астына терсәге белән сыпырып төшерә һәм мыскыллы караш белән әйтә иде: – Миңа ыздача нәрсәгә?* М.Мәһдиев. *Ул миңа сыйрагымны чеметеп җавап кайтарырга булган, ахрысы, тик моментның файдалырагын сайлаган, күрәсең: бер хатын әче итеп кычкырып җибәрде.* Ә.Гаффар

5) *сөйл.* Фактор, факт. *Районыбыздагы барлык дәрәҗәдәге җитәкчеләрнең көн үзәгендә булган барлык проблемаларны да хәл итәргә әзер торуларын һәм демократиялелеген безнең өчен уңай һәм бик кирәк момент дип кабул итәргә кирәк.* Байрак

6) Әдәби әсәрләрдә ниндидер бер аерым вакыйга, хәл һ.б.ш.ны тасвирлаган эпизод, күренеш. *Зөлфия сөйләгән әкиятләрдә әллә ниткән куркыныч моментлар була иде, һәм һәр кичне берничә бала, шул куркыныч моментны сөйләгәндә, дерелдәп урыныннан сикереп тора да йомылып өенә йөгерә иде.* М.Мәһдиев. *Либреттода очраклы хәлләр фабуланы төзүче хәлиткеч момент булып торалар.* М.Җәлил

2. *рәв. мәгъ. сөйл.* Бик тиз, хәзер үк. *Көпә-көндез төш күрә башласаң, немец момент әсир итеп урлап китәр, Ходай сакласын!* Ш.Рәкыйпов. *Ул үзе дә кеше белән момент дуслаша торган малай булып чыкты.* Х.Сарьян. *Фирүзәттәй, черек капка баганаң аварга тора. --- без аны момент утыртып куярбыз!* М.Галиев

МОНА́ДА *и. гр. филос.* Яшәеш нигезендә ята торган принцип. *Бу галимнәрнең аңлавынча, дөньядагы барлык нәрсәләрнең нигезен махсус кисәкчәләр – «монадалар» (грекча «монос» – бердәнбер мәгънәсендә) тәшкил итә.* Химия фаш итә

МОНАЗАРА *и. гар. иск.* Бәхәс, сүз көрәштерү, диспут. *Вакыты буш булганда, ул [Рөстәм] үзенчә яхшы дип белгән студентлар янына барып утыра, сүзгә катышмый гына, аларның үзара моназара кылышканнарын тыңлый: ара-тирә аларның җиңел генә эчке мәҗлесләренә дә катышкалый.* С.Җәлал. *Ул [Гаспринский] партия низаглары белән чыккан моназараларда, үзенең кызу табигатенә, чандыр буе күрсәтә торган гасабилегенә капма-каршы буларак, гажәп бер салкын канлылык саклый ала, вә бу аңар бик килешә, аның ул низаглардан өстен торганлыгын ачык күрсәтә иде.* Ф.Әмирхан

МОНАЗАРАЧЫ *и. к.* **моназыйр**. *Шул сәбәптән булса кирәк, мәҗлес таралган чагында, Мортаза бай карый белән әлеге ач калган моназарачы мулланы үзендә бер кич кунак булырга чакырды.* М.Галәү. *[Абелкарип:] Без моназарачылар түгел, моназарада нишләп йөрик.* Т.Гыйззәт. *Тукай үткен каләмле публицист, ялкынлы һәм аяусыз моназарачы, нечкә тәнкыйтьче һәм сабыр, акыллы тәрбияче булган.* Ватаным Татарстан

МОНАЗЫЙР *и. гар. иск. кит.* Бәхәсләшүче, сүз көрәштерүче, дискуссиядә оппонент. *Моназыйр Җиһанша исеме белән мәшһүр булды.* З.Һади. *Бу елларда Зыя мәдрәсәнең пишкадәмнәреннән булган бер моназыйр илә бик чынлап якынлашты.* Г.Ибраһимов. *Бу кеше Нижегород губернасыннан булып, бервакытлар Касыйм каласында үзалдына гөжләгән бер мәдрәсәдән уртакул бер «моназыйр», «тәүфикъле» гына бер хәлфә булып чыккан ---.* Ш.Камал

МОНАР *и.* Куерып, зәңгәрләнеп торган һава; томан. *Биек тауның үләне – Башын монар алганы.* Н.Исәнбәт. *Нәрсә син утырасың! Бу – монар!.. Бу – мираж!..* Р.Батулла. *Шундый дымык, боек иртәләрдә Ослан өсләрендә күкшел монар, Яна йөрәк – юк бер чара моңар.* Н.Гамбәр

МОНАРЛАНУ *ф.* Һаваның куерып, ерактан болыт төсле булып күренеп һәм зәңгәрләнеп торуы. *Кызды һава монарланып, Кыр белән дала чобарланып.* Дәрдемәнд. *Монарланган һаваларның, күкнең төсе Күзләреңә керә, килә җир, дым исе.* Р.Гаташ. *Сары алтын – сагышлары, борчулары – сары сыман һәм кызара бара сыман, кыза, монарлана сыман ---.* Р.Миргалимов

Монарлана бару Торган саен ныграк монарлану

Монарланып китү Кинәттән монарлану

Монарланып тору Монарланган хәлдә булу, монарланып күренү. *Һава монарланып тора*

МОНАРЛЫ *с.* Монар белән капланган. *Монарлы таулар*

МОНАРХ *и. гр.* Монархия башлыгы (патша, король, император, солтан һ.б.). *Халыкларга андый монархларны күрергә язмасын!* М.Мәһдиев. *Я, кайсы*

монарх шулай вакланып, барысын да белеп эшләргә сәләтле булган?! Кызыклар дөньясында. *Татар халкының (рус булмаган башка халыкларның да) аерым милли мәнфәгатьләренә килгәндә, монархлар сүздә үзләрен татарларны яклаучылар итеп күрсәтергә тырышсалар да, бу мәнфәгатьләр игътибарсыз калып килә.* Ватаныбыз тарихы

МОНАРХИЗМ *и. нем.* 1) Монархияне дәүләт хакимиятенең бердәнбер формасы итеп санаган сәяси юнәлеш. *Демократиядә яшәргә өйрәнмәгән, монархизм, тоталитаризм, тирания, деспотизм рухында гасырлар буена тәрбияләнгән Русия халкы коллыктан арынырга теләмичә тартышты, Ельцинны кабул итә алмады.* Хезмәт даны

2) *к.* **монархия**. *[Француз] монархизмына каршы либераль буржуа фикерләр (кафеларда оешкан беренче ячейкаларда) үскән.* Г.Гали. *Монархизм чорында урыс булмаган халыкларны чукындырып руслаштыру булса, СССР чорында бу сәясәт ялган «интернационализм», «халыклар дуслыгы» шигарендә үткәрелде.* Безнең гәҗит

МОНАРХИСТ *и. рус к.* **монархияче**. *Әйтерсең лә күптән мәрткә киткән, Летаргик төш күргән монархист ...* Х.Туфан. *Арбадан халык өстенә «анархист», «монархист», «большевик», «меньшевик», «эсер», «хәррият» дигән яңа сәер сүзләр сибелә башлый.* Г.Бәширов

МОНАРХИ́СТИК *с.* Монархизмга, монархиягә мөнәсәбәтле; монархизм белән сугарылган. *Аларга тик ирек бир генә, Монархистик темалар чәйнәп, Гайбәт сата алар шигырьдә.* Х.Туфан. *Ул – Дәүләт думалары депутаты, анда монархистик рухтагы нотыклары белән танылган кеше*. Ватаным Татарстан. *Аннан соң, сугышның глобаль нәтиҗәләре дә, инде алда әйтеп кителгәнчә, бер генә дә бу сугышта җиңгән дип исәпләнгән монархистик режимнар, шул исәптән Россия файдасына түгел.* Татар, уян!

МОНА́РХИЯ *и. гр.* 1) Югары дәүләт хакимияте бердәнбер хөкемдар – монарх кулында булган идарә итү формасы. *Монархия җимерелде, хәррият килде, телләр чишелде, һәм бик табигый рәвештә безнең җәмәгатьчелектә татарның киләчәге турында кызу бәхәсләр башланды.* Ә.Еники. *Янә дә демократия дия-дия властька килгән Дәүләт Думасы депутатлары, империя, монархия идеяләрен яклап, милләтләрнең халыкара үзбилгеләнү хокукын аяк астына салып таптарга җыеналар*. Т.Миңнуллин. *Монархия – бер кеше хакимияте дигән сүз.* Философия

2) Шундый идарәле дәүләт. *Казан ханлыгы монарх эшчәнлегенә феодаль курия һәм феодаллар съездлары ярдәмендә юнәлеш бирелгән феодаль монархия була.* Ә.Хәмидуллин

МОНА́РХИЯЧЕ *и.* Монархизм тарафдары, монархия яклы кеше

МОНАСТЫРЬ *и. гр.* Үзенең җире, милке, гыйбадәт кылу һәм яшәү урыннары булган, бердәм хуҗалык алып бара торган монах яки монашкалар оешмасы. *Хәйран калмалы: соңгы елларын монастырьларда уздырган монахлар тарафыннан язылган бәяннарның күбесе бары тик XVIII – XIX гасырларда гына аякланып китә.* М.Хәбибуллин. *Монастырьның музее бик бай.* М.Мәһдиев. *Илсур абый авыру хатыны белән сабые арасында озак бәргәләнә алмый, һәм Нурия апаны --- хатын-кызлар монастырена илтеп салалар.* Татарстан яшьләре

МОНА́У *алм. диал.* Бу; менә бу. *Шул ук көннеме, соңракмы, минем артта утырган икенче бер кыз көтмәгәндә, барыбыз да тырышып тактага апа язган сүзләрне күчергәндә, бөтен классны яңгыратмасынмы: – Апа, карале, монау малай гел басма хәрефләр белән яза!* Ә.Баян. *Монау якта ана урманыбыз бар, шунда эшлибез.* Ә.Гаффар. *– Анысын монау кәндигә тезегез, – дип, хуҗа хатын юлдашыма ак тастымалга төргән бер яссы әйбер сузды*. Н.Гыйматдинова

МОНАФИКЪ *и. гар.* **1.** Сөйләгәне белән күңелендәгесе бер үк булмаган, эчкерле кеше. *Бәс, карт әйтте: «Мин Нәҗедтән килдем. Күп эшләрне тәҗрибә кыйлдым. Мин һич монафикъ түгелмен», – диде.* К.Насыйри. *[Мулла:] Әүвәл бит пәйгамбәребез заманасында да монафикълар булган.* Г.Исхакый. *Кыйтгалардан тавыш кайтарыла, чын-хак җавап төсле: «Монафикъ!»* З.Мансуров

2. *с. мәгъ. иск.* Икейөзле, эчкерле. *Җәмгыять икейөзле, аңарда монафикъ сыйфатлар җитәрлек.* Р.Низамиев. *Кальбеңне генә керләмә, монафикъ булма*. М.Әмирханов. *Партиягә ышанмаган килеш, Аллага ышанган килеш, партиягә керсәм, «мин коммунист» дип нәгьрә орсам, мин икейөзле – монафикъ булыр идем.* Р.Батулла

МОНАФИКЪЛЫК *и.* Икейөзлелек, эчкерлелек. *Исламда мөэминлек һәм монафикълык дигән төшенчәләр бар.* Инсан һәм дин. *Спектакльнең башланып китү мизгелләреннән үк тамашачы сату-алу, катгый, салкын исәп-хисап, икейөзлелек, монафикълык мохитенә килеп эләгә.* Татар театры. *Әгәр сүз белән гамәл аерыла икән, моны икейөзлелек – монафикълык дип бәяләргә була.* Безнең гәҗит

МОНАХ *и. гр.* Үзенең гомерен Ходайга хезмәт итүгә багышлаган, гадәттә монастырьда яшәүче һәм чиркәү кагыйдәләре таләп иткән тормыш алып баручы ир-ат. *Караңгы чырайлы монахлар власть вәкилләренең кемнедер эзләп килүен инде аңлап алганнар иде.* З.Фәтхетдинов. *Диңгез буендагы бу храмда бертуган дүрт монах яши.* М.Мәһдиев. *Данила, җимерек каланы урап чатырына кайтканда, берничә монахны очратты*. Т.Миңнуллин

МОНАХЛЫК *и.* Монах булу; монах тормышы. *Протестантларда изгеләр сурәтенә (иконаларга), әүлияларның сөякләренә табыну, монахлык юк.* Философия. *--- үз акчасына ул Уралда күп кенә чиркәүләр салдырды, монастырьлар тотты, картлык көненда үзе дә монахлыкка китеп, күптән түгел шунда вафат булды.* Ф.Бәйрәмова

МОНА́ШКА *и. рус* Монах тормышы алып баручы хатын-кыз. *Табутны монашкалар урап алган.* Г.Әпсәләмов. *Басыйр бабайларга бик ерактан – Тинкәү дигән җирдән – туганнары белән Анна исемле монашка килә икән.* Ә.Баян. *Монашка дигәннән, алар һич тә без күз алдына китергән, фани*

дөньядан ваз кичкән ак чырайлы төссез хатыннар түгел. М.Мәһдиев

МОНГОЛ *и.* Урал-алтай төркеменә караган телдә сөйләшүче, Монголиядә һәм Кытайның Эчке Монголиясендә яшәүче төп халык; шул халыкның бер вәкиле. *Харәзем шаһы Олуг Мөхәммәт монгол илчеләрен яклап чыккан өчен, олуг шәех Пәһлеван Мәхмүтнең башын кистертә.* М.Хәбибуллин. *Монголлар да, беләсез ич, капитализмны сикереп үтеп, социализм төзи башлаганнар.* Ф.Хуҗин. *Аның берсе монголны хәтерләтә, икенчесе Ирекка иконалардан таныш булган Гайсә пәйгамбәргә тартым булып күренә*. Ф.Садриев

МОНГОЛИ́СТИКА *и. рус* Монголларның телләрен, әдәбиятын, тарихын, матди һәм рухи мәдәниятен өйрәнә торган фән тармагы. *Студент чагында ук Шәрыкны өйрәнү семинарында үзе дә [Әхмәт Тимер] дәресләр биргән. Белгечлеге – тюркология һәм монголистика*. И.Нуруллин. *Дөньякүләм танылган тюрколог, монголистика белгече, профессор Әхмәт Тимерне фән дөньясында белмәгән кеше юк, ләкин үлеменә инде 8 ел булса да, бу гомер эчендә Төркиядә «Тукай» мәдәният һәм мәгърифәт үзәгеннән тыш, аны бернинди татар җәмгыятьләренең искә алганы булмады*. Татар әдипләре

МОНГОЛЛАШТЫРУ *ф. йөкл. юн. к.* **монголлашу**

МОНГОЛЛАШУ *ф*. Монголларның телен, гореф-гадәтләрен һ.б.ш. яхшы белү, үз итү, кабул итү. *Монголлашкан татар*

Монголлаша башлау Монголлашу билгеләре сизелү

Монголлашып бетү Тәмам монголлашу. *Коллыкка төшкән татарларны Темучин гаскәренә кушалар, һәм алар монголлашып бетәләр, ләкин исемнәре таралып кала.* Татарстан тарихыннан хикәяләр

Монголлашып калу Ниндидер сәбәпләр аркасында монголлашу. *Ә монголларда татар каны булуы турында дөрес әйттең, чөнки Чыңгыз башлаган суешган соң исән калган татарлар монгол кабиләләренә сатылып монголлашып калдылар*. Безнең гәҗит

МОНГОЛО́ИД *с.* **1.** Кешелекнең төп расасының берсенә хас булган сыйфатларны үз эченә алган: кара туры чәч, кысык күз, сары тән, җәенке борын; шундый кыяфәттәге. *Себердәге, Урал артындагы, Әстерхан өлкәсендәге татарларның чырае монголоид*. Р.Батулла. *Көнбатыш Украинада, мәсәлән, бер авыз сүз татарча әйтмәсәк тә, урамда монголоид йөзле дип таш атып калганнары булды.* Ватаным Татарстан. *Монда, Катмандуда, буддистлар да (монголоид йөзле), һиндиләр дә яши.* Кызыл тан

2. *и. мәгъ.* Шул раса вәкиле. *Халыклар арасында монголоидлар да, европеоидлар да бар.* Н.Фәттах. *Монголоид дип, сарғылт тәнле, кара кыл чәчле, сирәк сакал-мыеклы, җәлпәк битле, почык борынлы, калку яңаклы, кысык күзле кешегә әйтелә.* Р.Фәхретдинов

МОНГО́ЛЧА *рәв*. **1.** 1) Монгол телендә. *Камыр әчетү төркиләргә, гомумән, әллә кайчан билгеле: борынгы төрки – эгэрчэ, татарча – әгерҗе, игәрче, алтай, хакас телләрендә – аарчы, тувача – ааржы, монголча – аарца, агарча – әче камырны, катык оеткысын белдерә.* Р.Әхмәтьянов. *Мәсәлән, бүгенге көндәге алтайлылар телендә «җиз» – ку-улы дип, монголча «күл» – ну-ур дип атала.* Н.Фәттах. *Бу темага режиссёр Л.Эрдэнебулганның чиста монголча, инглиз режиссёры Эдвард Базалдеттның Чыңгызханның яулап алулары турындагы, тагын японча, кытайча фильмнар булганда, күпләрдә, тагын бер фильм кирәкме икән, дигән сорау туганды*р. Ватаным Татарстан

2) Монголларга хас булганча

2. *с. мәгъ.* Монголларга хас; монгол телендә булган, монголларга караган. *Солтаннары да парча кафтаннардан, кыргыз бүрегеннән иде; бөтенесе дә бик күркәм, монголчарак йөзле, гадәттән тыш ирләрчә мәгънәле кыяфәттә иделәр*. М.Галиев. *Алар хәтта күчмәләрнең тышкы кыяфәтләрен дә өнәмичә сурәтләгәннәр, европалыларга һәм иранлыларга аларның монголча йөзләре бер дә ошамаган.* Р.Фәхретдинов

МОНГОЛЬФЬЕР *и. фр*. һава шары. *Бер айдан соң исә монгольфьер беренче кешене һавага күтәргән.* Күзгә күренми торган матдәләр турында хикәяләр

МОНДА *а.* **1.** «Бу» алмашлыгының урын-вакыт килеш формасы. *Үзләре исә монда барыбер колхоз эшендә катнаштылар һәм шулай күмәк тормыш мәктәбе уздылар булса кирәк*. Ә.Баян. *Болгар заманында монда Олы Кыр дигән авыл булган икән.* М.Мәһдиев

2. *рәв. мәгъ.* 1) Бу урында, биредә. *Монда тирән түгел, хәтәр чоңгыллар да юк, әмма төбе бик алама: тубыктан батарлык мәте генә...* Ә.Еники. *Капкадан базар эченә керделәр, монда да мәхшәр: койма тирәли әйбер сатучылар тора ---.* Р.Кәрами. *Тып-тын дала. Монда сугыш үткән.* Р.Вәлиева

2) Бу очракта; бу мәсьәләдә, бу моментта. *Монда мәсьәлә, бәлкем, куркукурыкмауга гына да кайтып калмыйдыр.* Р.Юныс. *Монда инде сәясәт аңкый: әйтерсең җөмһүрияттә татар дигән зур халык, аның мәгыйшәте юк*. С.Хафизов

МОНДАГЫ *а.* 1) Бу урындагы, биредәге, шушындагы. *Җимеш бакчалары күзгә күп чалынмый, юл буйлары шәрә, мондагы басулардан иген-тару әллә кайчан җыйнап алынган.* Т.Әйди. *Мондагылар монда калырга тиеш*. Ф.Яруллин. *Мондагы һәр укымышлы, зыялы белән бергәләп, милләт өчен күп эшләр башкарган адәм булам.* Ф.Сафин

2) Бу урында туып-үскән, озак яшәгән яки яши торган. *Чынлап, абзый, аңлый алмадым; мин бит, абзый, мондагы кеше түгел.* Г.Камал. *Келәүлекне биек койма белән әйләндереп алгач, мондагы кешеләр аллаларга зекер әйтеп, иркенләп, тынычлап яши башлаганнар.* Н.Фәттах

МО́НДЫЙ *а.* 1) Нәрсәнең дә булса сыйфатына, дәрәҗәсенә, үзгәлегенә ишарә итеп, аны башкалардан аерып күрсәтү өчен кулланыла. *Балалар, мондый тәмле балык ашаганыбыз юк иде әле, диделәр*. Г.Әпсәләмов. *Мондый чакта һич өйдә утырасы килми.* Ф.Яруллин. *Болай гына арттырып җибәрү мондый көнне табигый иде*. М.Маликова

2) Гомумиләштерүче сүз буларак кулланыла. *Әбүзәр абзый мондый*

дәһшәтне госпитальдә үләселәрен белгән яралы сугышчыларның күзләрендә күп күргән иде. Г.Әпсәләмов. *Мондый теләк күптән туса да, мин аны төрле сәбәпләр аркасында үти алмыйча йөрдем.* Ә.Еники. *Икенче капка өчен мондый уңайлы куак юк иде, кырыска түмгәкләреннән файдаландылар.* Ф.Яруллин

МОНИЗМ *и. гр. филос.* Дуализмның капма-каршысы буларак, дөньяның яисә андагы күренешләрнең нигезе итеп бары бер генә башлангычны (рух яисә материяне) таный торган фәлсәфи агым. *Беренчесе – борынгы юнан һәм рум фәлсәфәсе: җан һәм тән берлеге хакындагы өйрәтү – берлек, ягъни монизм.* Д.Заһидуллина. *Шуннан чыгып, философия фәнендә монизм һәм дуализм дигән терминнар, төшенчәләр барлыкка килгән.* Философия

МОНИСТ *и. гр. филос.* Монизм тарафдары

МОНИ́СТИК *с. филос.* Монизмга мөнәсәбәтле. *Философлар яшәү белән үлемне теоретик планда эшкәртүдә монистик алшартларны истә тотып гамәл итәләр.* Философия

МОНИТОР *и. лат.* 1) Компьютер, телевизор һ.б.ш. техник җайланмалардагы мәгълүматны күрсәтә торган экран, дисплей. *Ул тагын клавишка басты, һәм инде меңенче кабат мониторда теге күренеш пәйда булды.* М.Кәбиров. *Шулай ук, теләгән кеше «Галия» мәдрәсәсе тарихына кагылышлы материаллар, фоторәсемнәр, иллюстрацияләр, документлар, башка тарихи мәгълүматлар белән компьютер мониторында әйләнеп торган хәрәкәттәге экспозиция аша да танышты.* Казан утлары

2) *махс.* Яр буендагы һәм ярга якын урнашкан объектларны, дошман кораблъләрен җимерү өчен файдаланыла торган, эре калибрлы артиллерия белән коралланган хәрби корабль. *Тральщик, охотник, монитор, сторожевой катер, торпедный катер була икән...* М.Мәһдиев

3) *махс.* Җир катламнарын һәм тау токымнарын көчле су агымы белән юдырып эшкәртә торган җайланма

МОНИТО́РИНГ *и. ингл.* 1) Биосфера һәм аның аерым өлешләренең хәлен күзәтү һәм аларның киләчәктә нинди булачагын алдан әйтү өчен төзелгән комплексы тикшерү системасы. *Һава атмосферасын, су, туфрак байлыкларын саклау, калдыклар белән эш итү, идарә, мониторинг системаларын камилләштерү һ.б. чаралар экологик сәясәтне тормышка ашыруның төп өлешләре булып тора.* Ватаным Татарстан. *Татарстан Республикасының гидрометеорология һәм әйләнә-тирә мохиткә мониторинг буенча идарәсе җитәкчесе Сергей Захаров сүзләренә караганда, Арча, Әтнә, Балтач, Кукмара, Саба һәм Теләче районнарында урманнарның янгын хәвефлелеге иң югары чиккә җиткән.* Шәһри Казан

2) Үсеш, үзгәрешне контрольдә тоту; теге яки бу процессның динамикасын өйрәнү, беренчел һәм соңгы нәтиҗәләрен даими чагыштыру, күзәтү, прогноз ясау. *Икенче яктан, телебезгә мониторинг, кластер кебек «гөнаһсыз» сүзләр генә түгел, бигрәк тә мәгълүматлаштыру һәм икътисад өлкәсенә караган чит тел терминнары ургылып керә.* М.Вәлиев. *Нинди генә шәхес, сыйныф, группа булмасын, аларны компетентлы рәвештә диагностика, мониторинг аша үткәрмичә, шуннан соң тиешле төзәтүләр ясамыйча, бу мәсьәләдә уңышларга ирешү мөмкин түгел.* Ф.Харисов. *Дәвалау оешмаларында исә, авыруның төрен ачыклау өчен, мониторинг үткәрү гадәткә керде.* Ватаным Татарстан

МОННАН *а.* **1.** «Бу» алмашлыгының чыгыш килеш формасы. – *Моның атасы юктыр, ятимдер, моннан ни файда булыр?! – диделәр.* К.Насыйри. *Моннан да усал иде, химиядән укытты берәү.* М.Мәһдиев

2. *рәв. мәгъ.* 1) Бу урыннан, биредән. *Тизрәк, тизрәк качарга моннан!* М.Хәсәнов. *Чулман өсте дә, ерактагы урманнар, калкулыклар да моннан уч төбендәгедәй күренә.* Н.Фәттах. *Ишегалдындагы тротуар моннан уч төбендәгедәй күренеп ята.* Ф.Бүләков

2) Бу хәлдән, бу вакыйгадан, бу мәсьәләдән, бу очрактан. *Минем өчен моннан да зуррак сюрприз юк.* Р.Вәлиев. *Хатын өчен моннан да зуррак бәхет бармыни дөньяда!* Н.Гыйматдинова

3) Вакытны белдергән сүзләр белән килгәндә, күрсәтелгән вакыттан (сәгатьтән, көннән һ.б.), шул моменттан башлап. *Моннан 5–6 ел элек килүендә ул Аны күрә торган була.* Г.Рәхим. *Моннан өч ел элек мин сезне мәктәп ишегалдында күрдем.* Р.Юсупова

МО́НО- *гр.* Кушма сүзләрдә «бер» мәгънәсендәге беренче кисәк (мәс., *моногамия, монотеизм, монокультура* һ.б.)

МОНОГА́МИЯ *и. гр.* 1) Үрчү сезонында бер ата организмның бер генә ана организм белән кушылуы (кошларда, кайбер имезүчеләрдә һәм бөҗәкләрдә)

2) Бары тик бер хатын (ир) белән яшәү; берникахлылык. *Әлеге бәйрәмнең моногамия урнашканчы формалашканлыгын фаразларга нигез бар.* Р.Сафин. *Икенче яктан, шул моногамия (берхатынлылык) белән без ирләрыбызның хакын шуның кадәр кыстык, ул бичара, хатын рөхсәтеннән башка, мунчага да барып кайта алмый.* Татарстан яшьләре. *Монда, үзегез күрәсез, моногамия, ягъни бер кешегә: иргә яки хатынга тугрылык турында сүз дә бармый.* Ватаным Татарстан

МОНОГРА́ММА *и. гр.* 1) Ике яки берничә хәрефнең үргән сыман итеп, бер-берсенә бәйләп, бизәкләп язылган, чигелгән һ.б. сурәте. *Вензель – исем белән фамилиянең яки ике исемнең бер-берсенә нәфис итеп уратып язылган баш хәрефләре (монограмма).* М.Вәлиев

2) Шундый ысул белән язылган хәрефләр, сүзләр яки инициаллар, шартлы билгеләр. *Әйе, капитан әфәнде, хатын-кыз кулъяулыгы. Монограммасы да бар.* Т.Гыйззәт. *Кешенең исеме, атасының исеме, нәсәбатыннан (фамилиясеннән) торган монограмманы да төрле сурәтләр рәвешендә язып була.* Н.Гамбәр. *Һәр чәнечкенең сабында бизәкләп язылган монограмма.* М.Юныс

МОНОГРА́ФИК *с.* Монография формасындагы, монография рәвешендәге; монографиягә бәйле, монографиягә мөнәсәбәтле. *Ә бер аспирантыма*

С.Хәлфинның фәндә инде шактый тикшерелгән сүзлегенә монографик планда тарихи-лингвистик анализ ясау бурычы куелды ---. Ф.Саттарова. *Монографик темалар тормышны, тарихи чорны киңрәк иңләп алып күрсәтүгә бер язучы иҗаты ярдәмендә ирешергә мөмкинлек бирә.* А.Әхмәдуллин. *Профессор Сафиуллина – өч йөздән артык фәнни, методик хезмәтләр авторы, шуларның җитмештән артыгы – монографик характердагы хезмәтләр.* Ватаным Татарстан

МОНОГРА́ФИЯ *и. гр.* Аерым бер мәсьәлә, темага кагылышлы тикшеренүләр һәм ачышларны яктырткан фәнни хезмәт, китап. *Әгәр С.Вахиди саклап калган истәлекләрнең эченә кереп, аларның узгандагы реаль фәнни дәрәҗәбезне, әдәби фикер һәм халык иҗаты өлкәләрендәге казаныш һәм югалтуларыбызны өйрәнү өчен нәрсәләр бирә алуын барлый башласак та, катлаулы монография хасил булыр иде.* М.Госманов. *Кайбер галимнәрнең коры сүздән торган калын монографияләрен укып, тәмам тын кысылып беткән булган.* М.Мәһдиев

МОНОКЛЬ *и. фр.* Элек күзлек яки пенсне урынына кулланылган һәм бер күзнең чокырына куяр өчен эшләнгән түгәрәк формалы оптик пыяла. *Тагын карап алам үзеңә: Килеш-килбәтең дә әйбәт бугай, Монокль дә килешә күзеңә ---.* Һ.Такташ. *Монокль кигән, зәһәрлегеннән иреннәре чалшайган Чемберлен карикатурасына бер эшче агай бармагы белән күрсәтеп тора: ул гаепле.* И.Гази

МОНОКУЛЬТУ́РА *и. а.х.* 1) Берничә ел рәттән бер кырда игелгән бер үк иген яисә үсемлек культурасы

2) Берәр ил яисә җирлекнең авыл хуҗалыгында өстенлек иткән иген яисә үсемлек культурасы

МОНОЛИТ *и. гр. кит.* **1.** 1) Бербөтен зур таш һәм шундый таштан ясалган предмет. *Җөйләре булмаган бетон, монолит кирәк шул аларга.* Ш.Галиев. *Аның түбәсен кыя монолитыннан эшләнгән 18 метр биеклектәге колонналар тотып торганнар...* Кызыклар дөньясында. *Аларның «Командор» машинасы ташны коеп бара һәм монолит итеп ясый.* Татарстан яшьләре

2) Каты материалларны кушу, берләштерү, коеп ясау нәтиҗәсендә хасил булган массив. *20 нче еллар ахырында монолит һәм җыелма тимер-бетон да киң кулланыла башлый.* М.Мәһдиев

2. *с. мәгъ.* 1) Җөйсез, тоташ. *Халыкта монолит йортлар турында төрле имеш-мимешләр йөрде.* И.Нуруллин. *Ул заманнарда тактадан кормаштырган әрҗәләргә коела торган монолит бетон бик хутта булды.* Р.Мирхәйдәров

2) *күч.* Бердәм, таркалмаслык; нык, көчле. *Һәм шундый нәтиҗә ясала: кыскасы, монолит милли бер тел юк. Милли телне монолит бер тел итеп уйлау ул, асылда, сыйнфый аермаларны күрәсе килмәгән буржуа милләтчеләрнең фикере генә.* Г.Алпаров. *Патриотик, бердәм, монолит хис, Накаллы хис һәрбер йөрәктә.* Х.Туфан

МОНОЛИТЛЫК *и.* Монолит булу. *Тау токымының монолитлыгы*

МОНОЛОГ *и. гр.* 1) Әдәби әсәрләрдә персонажның үз-үзенә, башка персонажларга яки тамашачыларга мөрәҗәгать итеп сөйләгән сүзләре. *Ф.Бурнаш романтизмның сыналган алымнарын эшкә җигә: вакыйганы һәм геройны калкытыбрак, чынбарлыктан өскәрәк күтәреп сурәтли, --- диалог һәм монолог алымнарына күп таяна.* Т.Галиуллин. *Бу хәлне, мондый монологны, әлеге финалны башларына да китермәгән «коллегалар», ни әйтергә дә белми, аптырашта тора бирделәр.* А.Хәсәнов

2) Кемнең дә булса башкаларга яисә үз-үзенә сөйләгән сүзләре (сөйләмә). *[Г.Хафизова:] Уземнең яраткан монологым Ч.Айтматовның «Анам кыры» әсәреннән... Бик яратып, вакытлар узган саен, үзем өчен генә дә укый торган монолог ул.* Сәхнә

МОНОЛО́ГИК *с.* Монолог формасындагы. *Хикәяләү, тасвирлау еш кына диалогик һәм монологик сөйләм белән үрелеп бара.* Х.Миңнегулов. *Ә менә демократиягә юл ачыла башлаган елларда матбугат монологик формадан диалогик формага күчү юнәлеше алгач, аның укучы белән ихлас аралашу ихтыяҗы көчәйгәч, жанрларның да үзгәрүе сизелә.* И.Низамов. *Эш шунда: шәкерт монологик хикәяләвендә үзе хакында гына түгел, бәлки үзе кебек «меңләр-меңләр егетләремезнең» аянычлы язмышы турында сүз алып бара.* Ф.Гыйбадуллина

МОНОМЕР *и. гр.* Полимер синтезлаганда төп материал булып кулланыла торган түбән молекулалы кушылма. *Промышленность күләмендә үткәрелә торган күп кенә реакцияләр, мәсәлән, полимерлашу процесслары, чылбыр механизмы буенча уза, ягъни реакция өчен алынган гади молекулалардан – мономерлардан югары полимер материалларның зур молекулалары хасил була.* Химия фаш итә. *Беренчел ферментларның эшчәнлеге нәтиҗәсендә иң әһәмиятле органик кушылмалардан нуклеин кислоталары, катлаулы полимер (ягъни күпләгән блоклардан – мономерлардан торган) матдәләр хасил булган.* Галәм. Җир. Кеше

МОНОМЕТАЛЛИЗМ *и. лат.* Акча әйләнеше нигезендә бары бер төрле металл (алтын яки көмеш) гына йөртелә торган акча системасы

МОНОПЛАН *и. гр.-рус* Бер пар канатлы аэроплан (самолёт). *Моннан туксан еллар элек, очкычларның әле канат ярып маташкан чорында, француз авиаторы Луи Блерио үзенең монопланында утыз бер миль киңлегендәге шушы бугазны утыз җиде минут вакыт эчендә очып үтә ---.* Р.Ибраһимов. *Синең монопланда очуың хакында кем генә белми инде хәзер...* Сөембикә

МОНОПОЛИЗМ *и. ингл.* Җитештерүнең нигездә монополияләргә тупланган булуы. *Бар җирдә дә монополизм, тендерларда җиңүчеләр алдан ук билгеле һәм анда катнашып торуның файдасы да юклыгын әйтә.* А.Галиева. *Игорь Артемьев республикада монополизм күренешләренә каршы күрелә торган чараларны югары бәяләде.* М.Сәфәров

МОНОПОЛИСТ *и.* 1) Нинди дә булса өлкәдә монополиядән файдаланучы кеше яки оешма. *Башкортстан, Казакстанда, бер дәрәҗәгә кадәр Урта Азиядә татар сәүдә капиталы кайбер заманнарда монополист ролен*

уйнап, халыкны бик нык талады. Г.Ибраһимов. *Көньяк-көнчыгыш Азия илләрендәге урманнар да мәрхәмәтсез рәвештә киселәләр, кырылалар, комсыз монополистлар тарафыннан вәхшиләрчә таланалар.* М.Хәсәнов

2) Эре капиталист, монополистик капитал иясе. *Без беләбез: һәрбер империалист, Монополист – ата шовинист ---*. Х.Туфан

МОНОПОЛИ́СТИК *с.* 1) Монополия принципларына нигезләнгән; монополиядән файдаланган. *Ул [Дж. Кейнс], башка галимнәрдән аермалы буларак, монополистик капитализм белән дәүләт идарә итәргә тиеш, дип исбатлый.* Философия. *XIX гасырның соңгы утыз елында ирекле конкуренцияне чикли торган монополистик капитализм формалаша.* Политология. *Бүген көндәшлекне яклау проблемасы, аның үсеше өчен уңай шартлар булдыру һәм тискәре монополистик күренешләргә каршы көрәш актуаль булып тора*. Ватаным Татарстан

2) Монополия формасында булган. *Монополистик оешма*

МОНОПО́ЛИЯ *и. гр.* 1) Нәрсәне дә булса җитештерү яки сату бер эре предприятие яки дәүләт кулында гына булудан, конкуренция булмаудан гыйбарәт система; шундый эре предприятие. *Борынгыча – бабайларча эш йөртеп килгән татар сәүдә капиталы чәй монополиясен кулдан ычкындыра.* И.Рәмиев. *Илдә урнаштырылган пролетариат диктатурасы басма сүзнең массалар өчен көрәштә куәтле корал икәнлеген искә алып, аңа дәүләт монополиясе игълан итә*. Казан утлары

2) Берәр нәрсәдән файдалану хокукы; нинди дә булса өлкәдә тулы хокуклы, өстенлекле булу. *Әлеге вакытта республикада ТР монополия хезмәте бәяләрнең артуы нигезләме, юкмы икәнен тикшерү белән мәшгуль*. Ватаным Татарстан. *Шулай булуга да карамастан, монополия белән көрәш идарәсенә «Росгосстрах»тан зарланып мөрәҗәгать итүчеләрнең саны кимемәгән.* Татарстан яшьләре

3) *күч.* Нәрсәнең дә булса тулы хуҗасы булу. *Авыл кешесенең бердәнбер яшерен биләмәсе – күңел сере генә кала, күңел серең булса, ул – синең бердәнбер кеше кулы тимәс монополияң.* А.Гыйләҗев

МОНОПО́ЛИЯЛӘШТЕРҮ *ф.* Берәр нәрсәгә монополия урнаштыру. *Наркотиклар базарын монополияләштерү, наркобизнесның оешкан формаларының ныгуы һәм үсүе, халыкара җинаятьчел төркемнәрнең Россиядә урнашырга омтылуына бәйле процесслар сизелерлек активлашты*. Ватаным Татарстан. *Эчкечелек, тәмәке тарту кебек социаль проблемалар белән дә көрәшнең юлы шул ук – акцизларны монополияләштерү һәм бәяләрне чүпрә урынына кабарту.* Татарстан яшьләре

Монополияләштерә башлау Монополияләштерергә керешү

Монополияләштереп бетерү Тәмам, тулысынча монополияләштерү

Монополияләштереп кую Монополия хәленә китерү; тиз арада монополияләштерү

МОНОПО́ЛИЯЛӘШҮ *ф.* Нәрсәгә дә булса монополия урнашу. *Кавказ халкы эшләргә һәм шәхси бизнес белән шөгыльләнергә тели, ләкин алар авыл хуҗалыгы товарлары җитештерүчеләр белән сәүдә структуралары арасындагы арадашлыкның начар үсүе һәм бу тармакның монополияләшүе нәтиҗәсендә үз продукцияләрен сата алмый.* Кызыл таң

Монополияләшеп бетү Тулысынча монополияләшү

Монополияләшеп килү Монополияләшү юлына басу, монополиягә әйләнә бару

МОНОПО́ЛИЯЛЕ *с.* 1) *к.* **монополистик**. *Юрий Лужковның экспрессив сүзенең асылы түбәндәгедән гыйбарәт: «Бердәм Россия» сул партия түгел, шуңа күрә ул хакимияттә монополиягә һәм монополияле икътисадка омтылмый*. Ватаным Татарстан. *– Без шушы хезмәттәшлеккә нигезләнеп, алдагы елларда Россиядә сөт җитештерү буенча монополияле үзәккә әйләнергә тиешбез, – ди министр*. Татарстан яшьләре

2) Нинди дә булса өлкәдә монополия яулап алган. *[Виктор:] Шәһәрдә без антенналар кую эшенең монополияле белгечләре идек.* Р.Төхфәтуллин

МОНОПО́ЛИЯЧЕ *и. к.* **монополист**. *Аерым алганда, локаль монополияче телефон канализациясендә урын арендалау, телефон канализациясендә кабельгә техник хезмәт күрсәтү, оптик кабельне арендага бирү һәм аңа техник хезмәт күрсәтү өчен тарифларны нигезсез күтәрүдә гаепләнә*. Ватаным Татарстан

МОНОПО́ЛЬ *с. к.* **монополистик** (*1 мәгъ.*) *Янәсе, алар астыртын рәвештә үзара килешеп, ясалма төстә дефицит тудырганнар һәм шул рәвешле монополь төстә бәяләрне күтәрергә омтылалар икән*. Ватаным Татарстан. *Алыпсатарлар күп кенә төбәкләр һәм муниципалитетларда монополь рәвештә эш итә.* Безнең гәҗит

МОНОПСО́НИЯ *и. гр. икът.* Базарда бер генә алучы һәм бик күп сатучы булган вазгыять. *Монопсония турында мәкалә*

МОНОРЕ́ЛЬС *и. гр.-ингл.* Рельслы транспорт төре; бер рельслы тимер юл. *Метро һәм монорельс линияләре көн саен 420 мең кеше ташый.* А.Нуруллин. *Эшмәкәрләр Татарстан ягына вокзалны метро станциясе белән тоташтырачак монорельс проектын тәкъдим итте*. Шәһри Казан

МОНОСАХАРИД *и. гр.* Организмда төп энергия чыганагы булган гади шикәр (мәс., глюкоза, фруктоза). *Полисахаридлар – берничә (икедән алып берничә меңгә кадәр) моносахарид яки аларның чыгарылма калдыкларыннан торган углеводлар алар.* Урман аптекасы

МОНОСПЕКТАКЛЬ *и. гр.-лат.* Бер актёр катнашындагы спектакль. *Мәсәлән, «Яр» спектаклендәге нигезен югалткан кеше образын гәүдәләндереп, ул аны чын мәгънәсендә моноспектакль дәрәҗәсенә күтәрә*. Д.Гыймранова. *Соңгысы аның композитор Солтан Габәшигә багышланган моноспектакль иде.* Ю.Сафиуллин

МОНОТЕИЗМ *и. гр.* Бер генә илаһны таный торган дин, берилаһлык. *Диннең хәзергә иң югары формасы – бераллалык (монотеизм), ул бердәнбер*

һәм иң югары илаһи затка табыну белән бәйләнгән. Ф.Урманчеев. *Караларны җиңгән Рама нәселе, шул исәптән борынгы бабаларыбыз туранлылар өчен төп илаһи принцип – триада; ариларда (Йәфәс токымы) монотеизм һәм септет таныла.* Р.Сафин

МОНОТЕИСТ I *и. гр.* Монотеизм тарафдары; бер илаһка ышанган кеше

МОНОТЕИСТ II *с. к.* **монотеистик**. *Дунай буе Болгарының мәҗүси чорына караган грек телле язуларына нигезләнеп, ышанулары монотеист булганына килергә мөмкин, чөнки Болгар монархлары үзләрен «Ходай билгеләгән җитәкче» дип атаган, Ходайны исә барны белүче һәм гадел дип тасвирлыйлар.* Фән һәм тел

МОНОТЕ́ИСТИК *с*. Бер илаһка табынудан гыйбарәт. *Монотеистик дин*

МОНОТИП *и. гр. полигр.* Юлларны аерым басма билгеләр коеп җыя торган полиграфик машина. *Тольберт Ланстон хәреф коя торган монотип машинасын уйлап таба.* М.Вәлиев

МОНОТИ́ПИЯ *и. гр.* Рәсемне металл пластинага төсле буяулар белән кулдан төшерүдән гыйбарәт бастыру алымы. *Ә менә темпера, монотипия, офорт дигән төшенчәләрне мин әле китаплардан укып кына белә идем*. Гөлшаһидә

МОНОТОН *с.* 1) Тоны, югарылыгы һәм интонациясе бер генә төрле. *Экран артындагы диктор монотон тавыш белән нидер аңлата.* Безнең гәҗит

2) Үзгәрешсез, ялыктыргыч, эчпошыргыч. *Шушы сәбәпле тел аксый, сөйләмнәр бертөрлегә әйләнә, монотон кыяфәт ала.* Кызыл таң

МОНОТОНЛЫ *с. ялг. к.* **монотон**. *Алыштырсаң алыштырмасаң да, барыбер монотонлы бер көй агыла сыман.* Ә.Мушинский

МОНОТОНЛЫК Монотон булу сыйфаты

МОНОТОНЛЫЛЫК *и. ялг. к.* **монотонлык**

МОНОФТОНГ *и. гр. лингв.* Ике элементка бүленми торган сузык аваз. *Өй дифтонгына у монофтонгы туры килү Урал төбәгендә таралган татар сөйләшләренә хас.* Ф.Баязитова. *Дифтонглар урынына аларның төрле вариантлары (дифтонглар, дифтонгоидлар, монофтонглар) әйтелә.* Д.Рамазанова

МОНОФТОНГЛАШУ *ф*. Монофтонгка әйләнү. *Темников сөйләшендә, башка мишәр сөйләшләрендәге кебек үк, дифтонглар монофтонглаша.* Татар халык сөйләшләре

МОНПАНСЬЕ *и. фр.* Суыра торган конфет төре. *Төсле-төсле монпансье*

МОНПАСИ *и. сөйл. к.* **монпансье**. *Чәкчәкне монпаси яки төрле борчак конфет белән бизәргә мөмкин*. Сөембикә. *Ачык йөзле бу апа кечкенә Раилә-гә бер савыт монпаси тоттыра.* Ватаным Татарстан

МОНПАСЬЕ *и. фр. к.* **монпансье**. *Таймас сыңар куллы алиһәне һәм фарфор кыйпылчыклары салынган монпасье савытын келәттән көн яктысына алып чыкты.* А.Тимергалин. *Көнбагыш, кабак төше, эрбет чикләвеге ашагыз, монпасье суырыгыз ---.* Г.Мөхәммәтшин

МОНСТЕ́РА *и. лат.* Ароидчалар семьялыгыннан дымлы тропик урманнарда үсә һәм вак чәчәк ата торган үсемлек һәм шуның декоратив бүлмә гөле буларак үстерелә торган төре. *Мәсәлән, сансевьера, хлорофитум, үрмәле гөл, филодендрон, диффенбахия, монстера, маранта, антуриум күп күләмдә кислород бүлеп чыгара, һавадагы агулы матдәләрне йота.* Юлдаш. *Кактуслар өйдә ызгыш чыгара, үрмәгөл (плющ) ир затын өйдән куа, ә монстера һәм киперис төннәрен кешеләрнең энергиясен суыра, имеш.* Ватаным Татарстан

МОНТАЖ *и. фр.* 1) *тех*. Машина, корылма, композиция һ.б.ш.ларны билгеле бер план һәм сызым буенча җыю, кору эше. *Турбиннарга фундаментлар инде күптән әзер, аларга монтаж ясап, вак бүлекләрдән торган машинаны җыеп ходка җибәрәсе генә калды*. А.Алиш. *[Михаил Николаевич:] Урынын тагы бер тапкыр күзәтеп, монтаж эшләрен башларга.* З.Дәүләтов. *Әйе, эксперименталь цехта монтаж эшләрен башлап җибәрделәр*. Д.Бүләков

2) Төрле әдәби, музыкаль, фото, видео материалларны кушу, ялгау ысулы белән ясалган фильм, сурәт, әдәби әсәр һ.б. *Тагын кайтып, мин фильмдагы профессиональ режиссура вә кинооператорлык сәнгате турында әйтмәкче булам. Бу монтаж эшләрендә бигрәк тә ачык күренә*. Р.Батулла. *Ул бит – монтаж, фотомонтаж. Аны теләсә нинди фотосалонда ясатырга була*. Х.Ибраһим

3) Аерым бер темага багышланган, шигырь, җыр һ.б.ш.лардан төзелгән әдәби-музыкаль чара. *[Укучылар] «Җиңеп кайт, әти!» дигән әдәби монтаж төзеделәр.* Г.Гобәй. *Балалар бакчаларында төрле кичәләр, очрашулар, бәйрәмнәр оештырганда файдалану өчен, әдәби-музыкаль композицияләр, монтажлар, бәйгеләр, математик уеннар, викториналар тупланды.* Ф.Зарипова. *Бакчага йөрүче балалар белән тәрбияче апалары Фәридә Гарифуллина, Гөлүсә Әхмәтшина, Сәрия Гыйләҗиевалар әдәби-музыкаль монтаж әзерләгәннәр.* Борынгы Калатау итәгендә

МОНТА́ЖКА *и. рус тех. сөйл.* Кечкенә лом шикелле, монтажлау эшендә кулланыла торган инструмент; монтировка. *Фазыл кулына монтажка тотып чыкты*. К.Кәримов. *Аларны (ботинкаларны) киеп, мин монтажка белән сүчинкәләрне «шикәрле гипс»тан азат итәргә маташа башладым*. Х.Вәлиәхмәтов

МОНТАЖЛА́У *ф*. Монтаж (*1 – 3 мәгъ*.) эшләрен алып бару. *Әсир төшәргә теләгән бу немец сапёр частьта хезмәт иткәнлектән, әлеге корылмаларны монтажлауга катнашкан икән.* Ш.Рәкыйпов. *--- Тирес чыгару транспортёрлары урнаштыра, азык кухняларын монтажлый, кыскасы, нинди авыр һәм пычрак эш бар, моны аның бригадасы башкара.* Т.Нәҗмиев. *Аның [Диләрәнең] көне сизелмичә дә үтеп китә: лекцияләр, гамәли дәресләр, танылган кешеләр белән очрашулар, яңа сценарийлар төзү, монтажлау эшләре*. Идел

Монтажлап алу Тиз генә монтажланган хәлгә китерү

Монтажлап бару Рәттән барысын да монтажлау

Монтажлап бетерү Монтажлауны төгәлләү. *Озакка түгел бит, цехны*

монтажлап бетергәч үк, элекке урынарына кире кайтачаклар алар. Д.Бүләков. *Төзүчеләр комплексны 1 ноябрьгә кадәр монтажлап бетерергә исәплиләр.* Татарстан яшьләре

Монтажлап кую Тиз арада монтажланган хәлгә китерү. *Озакламый монтажлап та куялар.* Ә.Рәшит. *Ярык плитәне урынында тапмагач, Рафаэль туп-туры катка менде һәм, аның инде монтажлап та куелганын күреп, ачу белән бригадир Салаватка дәште: – Мин бу плитәне монтажламаска кушкан идем.* Ә.Сафиуллин

Монтажлый башлау Монтажларга керешү. *Инде ИП-6 мичләрен монтажлый башладык.* Шәһри Казан

МОНТАЖЛАУЧЫ *и. к.* **монтажчы**. *Радиоэлектроника аппаратуралары монтажлаучы булып эшләүче Натальяның хәлен аңлаган мәрхәмәтле җитәкче станокны өенә алып кайтып эшләргә рөхсәт биргән.* Кызыл таң. *Искәндәр «Казлифтсервис»та хезмәт юлын гади монтажлаучы һөнәреннән башлап, мастер, прораб вазифаларында тәҗрибә туплап, хәзер монтажлау участогы башлыгы булып эшли.* Шәһри Казан. *Ул «Яңа Гасыр» телерадиокомпаниясендә монтажлаучы булып эшли.* Сөембикә

МОНТАЖЧЫ *и. махс.* 1) Монтаж (*1, 2 мәгъ.*) эшен башкаручы. *Үзе [яңа министр] әле цехтан, монтажчы дигән белгечлектән.* Г.Ахунов. *Беренче монтажчылар бригадасын Саша Кислов, икенчене Зөлфәт Зәйнуллин, өченчесен – штукатурчы-буяучыларны – Гөлфирә Шәйхетдинова җитәкләде.* Г.Кашапов. *Шулай да объектларга бер барганда күрде: аптырагач, котлованга төшеп-менеп йөрергә монтажчылар үзләре, җир чокып, киртләч баскыч ясап куйганнар иде куюын.* Ф.Абдуллин

2) Әдәби, музыкаль, видео һ.б. материалларны эшкәртү, монтажлау белгече. *Багратның сценарие буенча кино куйган режиссёр хөрмәтенә кул чаптык, ура кычкырдык. Аннан соң оператор, артистлар, рәссам, монтажчылар, костюм тегүчеләр, декорация ясаучылар бер-бер артлы тезелеп китте.* М.Юныс. *Фильмның директоры Нурания Җамали, операторы Хәйдәр Миндубаев, рәссамы Линар Гыйльметдинов, монтажчысы Зөфәр Хәйретдинов.* Мәдәни җомга

МОНТАЗАМ *с. гар. иск.* Тәртипкә салынган, низамлы, тәртипле. *Монтазам булсынмыни соң гаскәрең, алгач үрнәккә Бохара гаскәрен.* Г.Тукай. *Мондый язучылар бухгалтерия ысулынча монтазам дәфтәрләр йөртеп, һәр айда баланс ясап, хуҗаларның эше ни дәрәҗәдә бара, --- дәфтәрләрдә хата юкмы, һәммәсен белеп вә күреп баралар.* Ш.Мөхәммәдев. *Мөфти Риза хәзрәтнең аермасы шундадыр ки, ул бу дәрәҗәгә, монтазам мәктәп күрә алмаенча, үз тырышлыгы, үз казынуы берлә генә ирешкәндер.* Х.Миңнегулов

МОНТАР *и. иск.* Киртә, каршылык. *Аккан суга монтар юк.* Мәкаль

МОНТЕКРИ́СТО *и. фр.* Вак калибрлы мылтык һәм пистолетлар системасы; шул системадагы мылтык, пистолетларның гомуми исеме

МОНТЁР *и. фр.* 1) Электр үткәрү, ремонтлау эшләре белгече; электромонтёр. *Мин вальцовщик түгел, монтёр түгел, Корыч дәрт һәм утлы җыр белән Бер ударник итеп станокка Алыгыз, дуслар, менә мине дә!..* М.Җәлил. *Алдагы елда Сәфәргалин зират коймасының баганаларын бетон белән алмаштырды, урам чатларына лампочкалар элдертте, утлар кич саен янып тормаса, монтёрга бик әләгә иде: «Ильич лампалары булыр алар, исеңдә тот шуны!» – дип кисәтә иде ул тыңлаусыз монтёрларны.* А.Гыйләҗев. *Бер заман мин монтёрдыр дип уйлаган баягы ир-ат бүлмәгә башын тыгып: – Ни йомыш? Мин ул Кара Чобан! – димәсенме.* Т.Әйди

2) Машина, механизмнар җыючы, коручы, төзәтүче белгеч; монтажлаучы. *Механик-монтёр*

МОНТЁРЛЫК *и.* Монтёр эше, һөнәре. *Әнәс монтёрлыкка укырга карар кылды.* И.Нуруллин

МОНТИРО́ВКА *и. рус тех.* Бер башы бераз бөгелеп тора торган монтажлау инструменты, кечерәк лом. *Берни аңламыйча, буш кул белән йөгереп килгән эшчеләрне күн курткалылар кастет, тимер ыргак, монтировка һәм газлы уенчыклар белән каршы алалар.* Т.Галиуллин. *Полициягә шалтыратасы урынга, әбекәй бишенче катта көн күреп ятучы торак хуҗасының номерын җыйды, олы яшьтәге пар санаулы секундлар эчендә монтировка күтәреп менеп тә җиткте.* Ф.Бәллүр

МОНУМЕНТ *и. лат. кит.* **1.** 1) Зур тарихи вакыйга яки бөек шәхесләр хөрмәтенә салынган архитектура яки скульптура корылмасы; һәйкәл. *Менә без Солтан Әхмәт мәйданында. Византиянең ипподромыннан калган ике монумент бар икән монда.* И.Нуруллин. *Алда Виктор Эммануэль II гә куелган монумент күренде.* М.Юныс. *Мәйдан уртасындагы бу мәһабәт монумент янында һәрвакыт халык.* М.Мәһдиев

2) Үлгән кеше турында истәлек буларак кабер өстенә гранит, мәрмәр һ.б. ташлардан куелган язулы корылма. *Татар хәрбиләренә монумент куелу Польшаның беренче Президенты Юзеф Пилсудскийның илдә яшәүче азсанлы милләтләргә дә толерантлык күрсәтүен раслый.* Татарстан яшьләре. *1921 елда ачлыктан үлгән авылдашларыбыз җирләнгән урынга монумент куелып, ул җир койма белән тотып алынды.* Туганайлар

2. *с. мәгъ. к.* **монументаль**. *--- Явыз Иван гаскәрләренә каршы көрәшкән каһарманнар истәлегенә узган ел монумент һәйкәл дә калыкты.* Борынгы Калатау итәгендә

МОНУМЕНТАЛИСТ *и. рус* Монументаль сәнгать белән шөгыльләнүче рәссам; монументлар ясаучы скульптор. *Талантлы кеше булса, административ эштә утырмас, үз юлын табар иде. Ә ул – монументалист та, скульптор да, рәссам да, сәнгать белгече дә.* М.Маликова. *Төрле жанрларда сынап карый рәссам үз көчен. Ул – монументалист та.* Сөләйман. *Татарстанның халык рәссамы, график, монументалист Рөстәм Килдебәков 1934 елда Казанда туа.* Казан утлары

МОНУМЕНТАЛЬ *с.* 1) Бик зур, мәһабәт яисә затлы булуы белән аерылып тора торган. *XIX гасырда мондый*

монументаль мәчетләр саны тагы да арта. Татарстан тарихы. *Анда – киселгән кош канаты рәвешендәге зур монументаль һәйкәл.* Р.Фәйзуллин

2) *күч.* Күләмле, җитди, тирән эчтәлекле. *Бу чор поэзиясендә романтизм төрле формаларда яши (монументаль, лирик-тәэссири һ.б.).* Т.Галиуллин. *Без яшь язучыларны кабартылган-күпертелгән ашыгыч повестьлар язуга түгел, рус һәм дөнья классикасы, алдынгы язучыларның иң яхшы әсәрләре үрнәгендә монументаль проза иҗат итүгә юнәлтергә тиешбез.* Г.Ахунов

МОНУМЕНТАЛЬЛӘШҮ *ф.* Монументаль (*2 мәгъ.*) хәлгә килү

Монументальләшә бару Торган саен монументальлеге арту. *Образ күзгә күренеп зурая, монументальләшә бара.* Ф.Миңнуллин

МОНУМЕНТАЛЬЛЕК *и.* Монументаль булу. *Чыннан да, аның әсәрләрендәге зур шәхесләр, киң масштаблылык, күп чагында күзгә үк бәрелә торган монументальлек, вакыйгаларның киң агымы һәм тирәнлеге кайсыбер стиляга-стилистларга ошап та җитмәскә мөмкин.* М.Вәли-Баржылы. *Соңгы елларда төбәк зиратларында кара һәм кызыл граниттан эшләнгән, монументальлек белән баетылган эпитафик истәлекләр куела башлаган, ләкин алар типиклык тәшкил итмиләр.* Ташлардагы татар тарихы

МОНЫ *а.* «Бу» алмашлыгының төшем килеше формасы. *Ләкин философ моны илдән куу дип уйламасын иде, акыллы кешеләр Византиягә дә кирәк.* М.Хәбибуллин. *Моны башына төшкән кеше генә белә.* М.Әмирханов

МОНЫКЫ *а.* Берәр кешегә яки предметка караган, аңа мөнәсәбәтле булуны белдергән тартым алмашлыгы. *Бүтәннәр яра өстенә гипсны йомшак итеп, эчкә һава керерлек итеп салалар, ә моныкы, ни хикмәттер, авыртыра торган булып чыга.* Х.Камалов. *Барыбызның аталышлары яки Бүре, я Куян, яисә Тавык булса, моныкы ни җитте генә түгел.* Ф.Яхин

МОНЫҢ *а.* «Бу» алмашлыгының иялек килеше формасы. *Әмма моның, һичшиксез, реаль җирлеге дә бар.* Ә.Еники. *Ләкин моның белән Гайнетдин абзый һәм Фатыйма абыстай истәлегенә тузан кадәр дә күләгә төшерәсем килми.* Г.Бәширов. *Җаен белеп, елмаебрак сөйләшсәң, хәзерге председательләр, моның ише гадәти әйберләрне генә түгел, күгәрчен сөте дә табып бирә.* В.Нуруллин

МОҢ *и.* **1.** 1) Көй, музыка яисә җырның эчке үзенчәлеге, аһәңе; төрле халыкларның, кешеләрнең күңелләрендәге хисләр җыелмасын чагылдырган үзенчәлекле аһәң, көй. *Горефгадәтләребез, телебез, моңыбызны киләчәк буыннарга җиткерергә бурычлы без.* Х.Миңнегулов. *Безнең телебез дә, йөзебез һәм моңыбыз да үзебезчә калган.* Х.Сарьян. *Музыка өлкәсендә эшләүчеләр татар моңын сакларга, күтәрергә бурычлылар.* Шәһри Казан

2) Кайгы, хәсрәт, борчу; ah-зар. *Бай малын сөйләр, Ярлы моңын сөйләр.* Мәкаль. *Хәер, күңеле тулы иде шул аның [Сафияның], уйларын-моңнарын урамда очраган баганага сөйләргә әзер иде, күзгә-күз терәшеп, рәхәтләнеп сөйләшер кешесе юк иде бит.* М.Маликова. *Бары тик авыз гармунына гына йөрәге әрнүләрен, сагышын, моңын ышанып тапшыра [егет]...* Казан утлары

3) Сагыш; моңсулык. *Шомырт кара чокырдай зур күзләре моң тулы.* Ә.Гадел. *Күңелдән моңнар түгелгән чаклар!..* Н.Арсланов. *Тезелеп кала моңга чумган каеннар, Уйга талган зифа усаклар.* Н.Хисамов

4) *диал.* Кимчелек, җитешсезлек. *Җирнең моңы юк, җир начар түгел, без үзебез начар.* Г.Бәширов

2. *с. мәгъ.* Моңлы, моңсу. *Аның өзелеп чыккан моң тавышыннан Бөтен хәсрәтләрем таратам.* Ф.Бурнаш. *Моң көзләрдән шат язларга дәшә-дәшә, Яшә, сөю, яшә яшьнәп, мәңге яшә!* Р.Вәлиева

3. *рәв. мәгъ.* 1) Моңсу; тирән сагыш катнаш моңсулык белән. *Ул моң гына карап тора.* Ә.Баян. *Тәнзиләнең моң гына сузып бер җырлап җибәрәсе килеп китте.* Р.Төхфәтуллин. *Ак каеным, Яшел шәл ябынып, рәхәтләнеп утыра моң гына.* Х.Камалов

2) Сагышландыра, моңландыра торган бер әкренлек белән. *Ә ул сүзен дәвам итә моң гына ---.* Р.Вәлиева. *Гитарасын ала да улының баш очына килеп утыра, тын гына чиртә, моң гына нидер шыңшый...* А.Гыйләҗев

МОҢА *а.* «Бу» алмашлыгының юнәлеш килеш формасы. *Патшаның исе китә моңа.* Әкият. *Әмма директор абый Хәсәншин, моңа һич игътибар итмәстән, укытучыны мактый: – Былтыр гына үзебезнең мәктәпне отличного тәмамлап чыкты абыегыз.* Ә.Баян. *Хатын моңа тотынганчы, йорт хуҗасы ир абзар-кураны бер әйләнеп керергә тиеш, бала-чага, сәкедә байтак сугышып алгач, «биз памяч» йокыга тәгәрәргә тиеш.* М.Мәһдиев

МОҢАЙТУ *ф.* 1) Кайгыга салу, хәсрәтләндерү, кәефен җибәрү. *Моңаеп кына килдеңме? Моңайтып килдеңме син? Моңлыга сыена торган моңлы бер кеше иң мин.* К.Сибгатуллин. *Бик карадым мин аны, Моңайтып утыртмадым.* Р.Вәлиева. *Безне, ахры, Кайта алмаганнар һәм кайталмас Абыйларның җыры моңайта ---.* Р.Ягъфәров

2) *з.-сыз* Күңелгә моң (*1 мәгъ.*), сагыш төшү турында. *Уйлата да шулай, моңайта, Уйлый торгач, сызылып таң ата.* Ә.Баян. *Хисләндерә, күңелне һәм җанны чистарта, шатландыра, кайгырта һәм моңайта...* А.Әхмәдуллин

Моңайтып тору Озак вакыт дәвамында, даими моңайту. *Җырлары колак төбемдә бүгенгедәй рәхәтләндереп, моңайтып торалар!* Г.Бәширов

Моңайтып бетерү Тәмам моңайту

МОҢАР *а. сөйл. к.* **моңа**. *Бу нишләп кайткан? Моңар ни булган?!* Г.Исхакый. *Фәхрелниса моңар бик кызыга.* Г.Камал. *– Башкалар, хәтта политбюро әгъзалары да җөрьәт итмәс моңар, – диде ул.* Р.Мөхәммәдиев

МОҢА́РЧЫ *рәв.* 1) Бу көнгә кадәр, бу вакытка кадәр. *Аларны [Асия белән Тимерханны] котладылар, моңарчы ишетмәгән матур сүзләргә төреп, озын, бәхетле, тигез гомер теләделәр.* Г.Ахунов. *Егет уңган, телгә беткән җилбәзәк түгел, моңарчы кызлар кулы тотканы юк, ипле ---.* А.Гыйләҗев. *Кыйбла турында әтрафлы сөйләшүне әле хәзер генә башласак та, моңарчы да студентларыбызны кыйблалы*

итүдә шактый тырышлык куелган лабаса. Мәдәни җомга

2) Бу хәлгә, вакыйгага кадәр. *Беренче мәртәбә ату, гәрчә моңарчы вак калибрлы мылтыктан атканы булса да, Габделнурны нигәдер дулкынландыра.* Р.Кәрами. *Моңарчы беркайчан да бу хәтле дулкынланганы юк иде Тәбрикнең...* Ә.Баян. *Моңарчы әле аның беркайчан да Иданың үзен генә озатып куйганы да, хәтта аның белән култыклашканы да юк иде.* Н.Фәттах

МОҢА́ЧА *рәв. к.* **моңарчы**. *Моңача мине берәүнең дә болай сүккәне юк иде...* А.Шамов. *Бүген син күргән шәхес – моңача кылган барлык гамәлләреннән берәр кирпечләп салынган манара.* Ш.Галиев. *Әгәренки Гыйрфан мулланың өенә моңача һич таныш булмаган бер адәм заты мохтаҗлык илә килеп керсә, буш кул белән чыгарып җибәрер идемени?* С.Поварисов

МОҢАЮ *ф.* 1) Кайгыру, хәсрәтләнү, борчылу. *Балалары булмаганга моңаеп, кимсенеп йөрсә дә, хатыныныңяз башында шундый хәбәр әйтүе Сабирулланы артык шатландырмады.* З.Хөснияр. *Ул моңаймый, кем моңайсын – әтисез үскән бала.* Л.Лерон. *Киемсезе, күшеккән тавыкка охшап, өй эчендә моңаеп утыра бирә.* С.Поварисов

2) Сагышлану; боегу, күңелсезләнү; уйга бату. *Сабый чаклар карап тора аннан, Бер моңая сыман, бер көлә...* Х.Әюп. *Бишектә чакта ук сандугачларга кушылып җырлаган, урман шавын тыңлап моңайган, сихри күккә карап уйланган.* Ф.Яруллин. *Аннары болай диде [күке]: «Ничек инде мин моңаймыйм?! Эчем тулы сагыш бит минем».* Ф.Яруллин

3) Уйланып, хисләргә бирелеп утыру. *Әмма татлы бу моңаю.* Ш.Галиев. *Карты ятып йоклады, ә Хәдичә апа суынган самавыры янында моңаеп утырып калды.* М.Маликова

4) Моңлы итеп көйләү, җырлау. *Ярты төнгә тикле җырлап, моңаеп, тамбурда уздырды.* Г.Бәширов. *Сараннардан эзлим юмартлыклар, Моңсызлардан – бер җыр, моңаю.* Г.Афзал

Моңаеп алу Беразга гына моңаю

Моңаеп йөрү Шактыйдан бирле моңаю. *Көзге урманнарга сызгырып кер, Моңаеп йөр шәрә урманнарда.* Г.Афзал

Моңаеп калу Берәр вакыйгадан соң моңаю, моңлыга әйләнү. *Әллә егет моңаеп калмасын дип юри шаярта, әллә фаҗигане аңлап җиткерми бу бала.* Ә.Баян. *Күзе томаланып, ул алга таба атлады һәм күркәләрен коеп, моңаеп калган нарат кәүсәсенә килеп төртелде.* Р.Рахман

Моңаеп китү Кинәт, тиз арада моңайган хәлгә килү. *--- хәзер инде ул, артыграк моңаеп китсә дә, җырлап чыккач, түгелеп бер елап ала иде.* Х.Сарьян

Моңаеп тору Сөйләү моментында моңаю; гел, һәрвакыт моңайган хәлдә булу. *Урман юлына борылганда, ялгыз карама бар бит, шуның янына баскан да моңаеп тора.* А.Гыйләҗев

МОҢДАШ *и.* Кемнең дә булса кайгы-хәсрәтен, борчуын, сагышын уртаклашучы. *Ахмак юлдаш булмас, ятлар моңдаш булмас.* Мәкаль. *Юаш кына димә, Юлдаш булдык менә, Моңдаш икәнбез дип, И агыла җәяуле буран, Мондый чакта кырга чык, туган...* М.Галиев. *1982 елда оештырылган зур күргәзмәсенең каталогына менә нилләр язып биргән иде ул: «Газиз дустым, моңдашым, олуг әдип, намус иясе Әмирхан мирза Яники җәнапларына – там самимият белән Габделбакый».* Ә.Еники

МОҢ-ЗАР *җыйм. и.* Моң һәм зар, кайгы-хәсрәт; аһ-зар. *Кабатлады үзе [егет:] Моң-зар түгел, Иген күкрәр монда һәр елны!* Х.Әюп. *Болар барысы да юлда кайтканда, аннары әле генә өйдә туган икеле-микеле моң-зарларны алып киттеләр, ул залдагылар янына чыкканда, баш әйләндергеч киеренкелектән арынган, ял иткән иде.* А.Гыйләҗев

МОҢ-КАЙГЫ *җыйм. и.* Һәртөрле борчу-хәсрәтләр. *Чамасынча бирепнигъмәт вә михнәт, Күрәсең, тиз алыр моң-кайгыны, шәт.* Котб. *Табигать белән бер булу аңа [Бибинурга] бик күп четерекле хәлләрне җиңәргә, моң-кайгыга баш бирмәскә ярдәм итте.* А.Гыйләҗев

МОҢЛАНДЫРУ *ф.* 1) Күңелгә моң салу, хисләрне көчәйтү. *Тамашачы кабат театрга кайтыр, чөнки театр фикер бирә, уйландыра, моңландыра, тәрбияли.* Р.Таҗетдинов. *Җанда сүз ярала... шомландырып, Моңландырып ул сүз ярала, Әйтерсең лә атом төше үзе Таркала бу җанда, тарала!* Зөлфәт

2) Сагышландыру, боектыру. *Мондый хәлгә түзәр микән җаным, моңландырды дөнья болай да.* З.Мансуров. *Минем вазифам кешеләрне моңландыру дип, үз кадерен белеп кенә кешеләр җырын тыңлыймы Ай, чиксез кодрәте белән кешеләрне үзе җырлатамы Ай...* М.Хуҗин

3) Моңлы итү, моңын көчәйтү (җыр, көй, тавышны). *Гүяки [Газизә] шушы такмакларны тагын да моңландырыбрак җырлап йөри, имеш.* Ш.Камал

Моңландырып алу Кыска вакыт аралыгында моңландыру. *Ә менә бүген, киресенчә, дөньяның шушылай матурлыгы аның болай да моңлы, болай да борлыккан күңелен тагын да моңландырып җибәрде ---.* В.Нуруллин

Моңландырып бетерү Тәмам моңландыру; бик нык моңландыру

МОҢЛАНУ *ф.* 1) Кайгыру, хәсрәтләнү, борчылу. *Мартуктан ул [Володя] елап китеп барды, монысын Рушан да раслый ала, теге яктан килгән беренче хатлары да Россияне сагынып моңлану белән тулы булды – Рушан аларны үзе укыды.* Р.Мирхәйдәров

2) Сагышлану. *Ул мескен бичарага карап күңелем тула да моңланам.* Д.Аппакова. *Тавыш тора-тора көчәйде, киңәйде, әйтерсең лә таш диварлар да кызга кушылып моңлана, сагышлана иде.* М.Маликова. *Ханзадәләр тартып курай уйнаган, Курай көен тыңлап кошлар моңланган.* Ә.Синугыл-Куганаклы

3) Моңлы итеп җырлау, көйләү, уен коралларында уйнау. *Гаеп булмаса да, җырлау, моңлану йортка бәхетсезлек китерә, дигән бабайлар.* Т.Гыйззәт

4) Хисләргә бирелү; җыр-моң аша хисләргә ирек биреп юаныч табу, сагыш-борчулардан арыну. *Кыен чакларымда да җырлыйм, алай гына да түгел, кычкырып җырлап җибәрәм һәм борчуларның үтеп киткәнен сизми дә калам, моңланып юаныч табам.* Мәдәни җомга

5) Уйчанлану, моңсулану, уйга бату. *Ул гаҗәеп күзләр әллә ничек иркәләнеп, кадерләнеп моңланалар.* Ф.Әмирхан

6) *күч.* Моңлы яңгырау (уен кораллары көе турында). *Чыңлады гармун, моңланды гармун, Айлы кичләрдә тынмады гармун. Үз итеп кенә сөйләде безгә Шул моңга кушып шатлыгын, зарын.* Х.Әюп

7) *күч.* Кошлар сайрау. *Күке дә анда кунып моңлана.* М.Галиев. *Сабан тургаедыр, ниндидер кош, зәңгәр хозурлыктагы бишектә тибрәнә-тибрәнә моңланырга, үзәкне өзәргә кереште.* Р.Мөхәммәдиев. *Урманның барча кошлары эчләренә сыймаган шатлыкларын тирә-юньгә җыр итеп тараткан чакта, ни өчен күке болай моңлана икән?* Ф.Яруллин

8) *күч.* Моңлы булып, моңланган кебек булып күренү (табигать тур.). *Төн тыныч, күк балкый иренеп, ай яна, ай моңлана.* Н.Исәнбәт. *Көннәр һаман җилли дә давыллый, Урман шаулый, Идел моңлана...* Х.Туфан

Моңлана башлау Моңланырга тотыну. *--- Бөтен кыяфәтенә, ижатына көләчлек, шаянлык чыккан шагыйрьләр дә, мин генә калмыйм дигәндәй, кирәгеннән артык моңлана башлады.* Л.Лерон

Моңлана төшү Бераз моңлану

Моңланып алу Кисәк кенә моңлану, моңланган хәлгә килү. *Юк, җырламадың. Шулай да ике-өч мәртәбә моңланып алдың.* Ә.Салах. *Табигатьнең тын почмагында ялгызың аулакта уйланып-моңланып алу – җаныңа ял ул.* Ш.Галиев

Моңланып йөрү Озак вакыт моңланган хәлдә булу, шундый хәл кичерү. *Тагын бер нәрсә бик нык исемдә саклана: Маратны ничә генә очратмыйм, ул һәрвакыт карлыккан бер тавыш белән шыңшып, үзенчә моңланып йөри иде; соңрак, Марат үсә төшкәч, «Бродяга» кинофильмыннан соң таралып киткән җырны авызыннан төшерми йөртте.* Х.Сарьян. *Моңланып йөрим һаман Синдә откан бер көйгә!* Р.Миңнуллин

Моңланып калу Ниндидер тәэсирдән соң моңлану, моңлыга әйләнү. *Бер минут эчендә ай караңгыланып өлгергән: әүвәлге шат балкуын, шаян җалкылдавын җуялтып, моңланып калган.* Казан утлары

Моңланып китү Тиз арада моңлану, кинәттән моңлану. *Нигәдер күңелем моңланып китте.* Г.Бәширов

Моңланып тору Моңланган хәлдә булу. *Мин сагындым, ахры, сине, – Күңел моңланып тора.* Г.Гыйльманов

МОҢЛА́У *ф. диал.* 1) Моңлану, уйга бату

2) Моңлы итеп көйләү, җырлау. *Күлнең артында берәү моңлап көйли ---.* Г.Тукай. *Судагы бакаларга кадәр үзләренчә моңлап гөрләшә...* Т.Гыйззәт

Моңлап тору Сөйләү моментында моңлау

МОҢЛЫ *с.* **1.** 1) Аһәңле, колакка ятышлы, музыкаль (аваз, тавыш тур.). *Шундый моңлы Дилиянең тавышы!..* Г.Гыйльманов

2) Музыкасы булган; җырлы, мелодияле. *Татарлар – моңлы халык*

3) Кайгылы, хәсрәтле, борчулы. *Уфадан озатып калгандагы моңлы карашы белән һаман күз алдында басып тора.* Х.Туфан. *Бер без генәмени, Бу дөньяга үги, уксез моңлы җаннар меңләгән.* Л.Шагыйрьҗан 2) Сагышлы, уйчан, сагыш тулы, моңсу. *Кем белә, бәлкем, шагыйрь халкына моңлы булу килешәдер.* Ф.Сафин. *Күл буенда үскән чәчәкләр, аларның канат җилпүеннән әкрен генә тирбәлешеп, үзара ниндидер моңлы җыр сузганнар.* Ф.Яруллин. *Иртән йөрәкне моңлы азан тавышлары ярсыта.* С.Поварисов

4) Тирән хисле. *Ләкин Гәрәй Рәхим – моңлы шагыйрь, моңнар шагыйре.* Р.Миңнуллин. *Җыр моңлы иде, хатынларның берничә тавышка (Сафия санап бетермәде, һәрхәлдә өчтән дә ким түгел иде тавышлары) сузган көе дәртле дә иде шул ук вакытта.* М.Маликова

5) Моң сала торган, ямансулата, моңландыра торган (табигать күренешләре тур.). *Рәсемдәге төсле матур, әкияттәге төсле серле, җырдагы төсле моңлы елга ул Агыйдел.* М.Әмир. *«Торыйк-торыйк!» – дип китәләр Көзге моңлы һаваларда.* Н.Нәҗми. *Бу бакчаның сөйләшүе ник шомлы? Чинарларның чайкалуы ник моңлы?* К.Сибгатуллин

2. *рәв. мәгъ.* 1) Күңелгә моң салып. *Кошлар моңлы сайрый бүген, Кояш көлеп карый бүген.* Р.Вәлиева. *--- азат итүчесенә моңлы сайрап, гүя аңа дога кылган Кошчык.* Ф.Ибраһимова. *--- Празат Исәнбәт әйтер: – Бурнаш кебек матур, моңлы җырлаган кешене ишеткәнем булмады! – дияр.* Р.Батулла

2) Тирән хис белән, моңлы итеп; моң белән. *Моңлы җырлаган бәхетсез була.* Әйтем. *Бигрәк тә моңлы җырлый инде, җаныкаем.* Т.Мөбарәков. *Әйе, ул ялгышмаган: Сандра бик моңлы җырлый икән бит.* Ә.Сәлах

3. *и. мәгъ.* Моңы, кайгысы бар кеше, кайгы-хәсрәтле, зарлы кеше. *Моңлы моңын сөйләгәндә, моңсызның башы авырта.* Мәкаль

МОҢЛЫ́-ЗАРЛЫ *с.* Кайгылы, хәсрәтле, сагышлы; сагыш тулы. *Барысы да парлы-парлы, Без генә моңлы-зарлы.* Мәкаль. *Кемнәр алар: баймы, ярлымы? Күңелләре моңлы-зарлымы?* Р.Закиров

МОҢЛЫК *и.* 1) *к.* **моңлылык** (*1 мәгъ.*). *Ни булса да, Сәгадәтнең тавышындагы моңлык үткәндәге хәсрәттән хәбәр бирү булмаса, киләчәктәге кайгыларга хәзерләнү иде.* Г.Исхакый. *Упкыннарың берни түгел, Батырма тик моңлыкка...* Х.Туфан. *Күңелне ниндидер бер моңлык, сагыш биләп алды.* Г.Галиева

2) Күңелгә моң сала, ямансулата торган тынычлык. *Болытлар, башка төшәм дигән кеби, түбәннән генә акыртын гына агып, матур күк күкне, ялтыраган кояшны каплап, бөтен дөньяга моңлык, ялкаулык йоктыралар.* Г.Исхакый. *Бу тавыш [Коръән тавышы] белән бергә моңлык бөтен тамырларга тарала.* Г.Рәхим

3) *иск.* Моңлы көй, җыр. *Өлкәннәрнең рөхсәте буенча аның бер моңлык әйтүгә исәбе юк түгел иде.* Г.Ибраһимов

МОҢЛЫЛЫК *и.* 1) Ямансулык. *Аз гына элек Гарифны кара хатирәләр, тупас өметсезлекләр белән газапланган шушы билгесез моңлылык гүя аны юата, иркәли, шатланырга, шатланып, үзе белән бергә еларга куша...* Ш.Камал

2) Моң, сагыш, хислелек. *Моңлылык ул – хислелек, кичерешләр дөньясында яшәү.* Ш.Галиев. *Итальян халык*

музыкасына моңлылык хас. К.Гыйззәтов. *Җырларыбызга моңлылык хас булган кебек, телебезгә дә моңлылык хас*. Сәхнә

3) Моң, сагыш тулы булу (җыр, тавыш һ.б.да). *Һиндстанда яшәүче милләтләрнең көйләре моңлылык ягыннан безнекеләрне күпкә уздырсалар да, шуңа таянып, аларны да зарлы милләт дияргә хакыбыз бар.* М.Фәйзи. *Яшьләр аның тавышының моңлылыгына сокланды, картлар денсезлектә гаепләде.* Ф.Яруллин. *Җырлаучылар арасында Һидаяның тавышы нәфислеге, моңлылыгы белән аерылып тора иде*. Ә.Моталлапов

МОҢСАР *с.* Моңлы, сагышлы. *Яшь коючы моңсар таллар кебек, Күтәрми шул Сөю җәберләр...* Ә.Синугыл-Куганаклы. *Әллә ошбу моңсар кошлар, Ватан сугышы елларында һәлак булганнарның якты истәлекләрен, изге рухларын кадерләп, аларга үзләренең кабатланмас сихри моңнарын багышлап, мәңгелек сакка басканмы?* Ш.Мостафин. *Марсель ул тыштан гына батыраеп, кукыраеп йөри, ә эчтән... Эчтән моңсар күңелле, ярларына сыеша алмыйча тулышып түгелергә дә күп сорап тормый.* Н.Гамбәр

МОҢСУ *с.* **1.** 1) Берникадәр моңлы, сагышлы; моң, сагыш чагылып торган. *Гөлүсәнең сылу йөзенә, күзгә күренеп диярлек, янә моңсу күләгә кунды*. М.Хәсәнов. *Нияз китапны ябып күкрәгенә кысты да моңсу күзләрен бер ноктага төбәп уйга калды.* В.Нуриев. *Моңсу каеннар аларга хәерле юл теләп, тымызык җилдә тирбәлгән озын чукларын чайкалдырып озатып калдылар.* Р.Кәрами

2) Ямансу, күңелсез. *Әллә ничек бик моңсу иде аның [Шәфиканың] кыяфәте.* М.Маликова. *Бигрәк озын, бигрәк моңсу көннәре вә төннәре.* Р.Сүлти

2. *рәв. мәгъ*. Моңланып, ямансулап, моңлы итеп. *– Әйе, бәхет миңа чыкты, – диде ул моңсу гына, яңакларын батырып, тәмәкесен суырды.* Х.Камалов. *Заһидә каенсеңлесенә тутырып карады да моңсу гына елмайды*. М.Маликова

МОҢСУЛАНУ *ф.* 1) Ямансулау, моңлану. *Байтал үзенең яныннан җилеп үткән җилбәзәк кырыкмышларга моңсуланып карый.* А.Хәлим. *Кинәт моңсуланып, нидер көтеп текәлгән ирен кызыклы берәр вакыйга сөйләп, читләтеп кенә юата белде [Нәзифә].* М.Галиев. *Карт эт Аю киткән юлга моңсуланып озак кына карап торган.* Ф.Яруллин

2) Моң чагылу, моңлылану, уйчанлану. *Каңгылдашып узды кыр казлары, – Моңсуланган чагың микәнни?* Х.Әюп. *Аның турында сөйләгәндә, әфганчының күзләре тагын да моңсулана.* Н.Гыйматдинова

Моңсулана башлау Моңсуланырга тотыну. *Аның ашыйсы килеп, җылы өен сагынып, күңеле моңсулана башлаганда гына, өстә – колак төбендә генә Караборынның: «Һау-һау-һау!» – дигән тавышы ишетелә.* Н.Каштанов. *Үзе туктаусыз шул зарурият турында такылдап торса да, иренең китәр вакыты җиткәч, кәефсезләнә, моңсулана башлады.* Т.Галиуллин

Моңсулана бару Торган саен ныграк моңсулану. *Торган саен моңсулана бара җәен кошлар тынган чаклар, айның ундүртләре узган көннәр, үткән поездларның борылмада югалулары...* Р.Фәйзуллин. *Ә шулай да җәйләр үткән саен Моңсулана бара күзләрем.* Ф.Әһлия

Моңсуланып бетү Тәмам моңсулану

Моңсуланып калу Берәр вакыйгадан соң моңсулану. *Югыйсә абзыебыз, кулына курай алу белән, һәрчак моңсуланып кала.* Г.Гомәр. *Кияү моңсуланып калды.* Н.Гыйматдинова

Моңсуланып китү Кинәт моңсулану. *Зәйтүнә чәченнән тарагын ала, көзгесенә карый, моңсуланып китә.* Н.Кәримова

Моңсуланып тору Хәзерге моментта моңсуланган хәлдә булу; әледән-әле, һәрвакыт моңсулану

Моңсуланып йөрү Күпмедер вакыт дәвамында моңсулану. *Сабираттинең әйтүенә караганда, кичкә кергәч, балаларга сынап-сынап карап, моңсуланып йөргәнмен, имеш.* Э.Шәрифуллина

МОҢСУЛАТУ *ф. йөкл. юн.* 1) *к.* **моңайту**

2) Моңсу итү. *Уйландыра күкләр зәңгәрлеге, Моңсулата шәфәкъ балкышы.* Р.Низамиев

3) Күңелгә моң салу. *Агымсулар моңсулата, Туган илләргә агып.* Р.Ягъфәров

МОҢСУЛЫК *и.* 1) Күңелсезлек, ямансулык, моңлылык. *Кызларның йөзенә алсу бер моңсулык йөгерде, күзләргә сагыш тулды ---*. Г.Ахунов. *Күзеңнән моңсулык сирпелә, Чәчеңдә кыраулар, ахрысы.* Х.Әюп. *Әй мәхәббәт, зинһар, безне моңсулыктан арала!* Л.Лерон

2) Моңсу тынычлык турында. *Кырларга, урманнарга көзге моңсулык тула, их, шушы җилгә ияреп кырлар буйлап бер исәргә иде...* М.Мәһдиев. *Һәр яфрагы саубуллашып уза, Моңсулыкка чумган бу алан...* Х.Әюп

МОҢСЫЗ *с.* **1.** 1) Музыкасы булмаган; җырсыз, мелодиясез. *Ә менә музыкасыз, моңсыз, көйсез милләт була ала микән?* Мәдәни җомга

2) Җырлау сәләте булмаган, көйсез, тавышсыз. *Күңелгә ятмый: моңсыз адәм җыр башласа; сәләте булмаган иҗатка тотынса; сәнәге булмаган чүплектә казынса; акылы булмаган акыл таратса*. Г.Хөсәенов. *Моңсыз егет түгел үзе болай, нәкъ Салават абыйсы кебек җырлый, шуып кына бара*. Ватаным Татарстан

3) Аһәңсез, яңгырашсыз, колакка ятмый торган. *Тавышы тонык, җыры моңсыз булган аның.* Ф.Яруллин. *Югыйсә әллә нинди моңсыз, сыек, төссез тавышлы җырчылар да җитәрлек ләбаса.* Р.Миңнуллин. *Көйләрне җиңел отса да, тавышы ямьсез, моңсыз булуын үзе белмәде, аңламады*. Ф.Яхин

4) Бернинди хис тә чагылдырмаган, рухи яктан буш булган, күңелгә ятмаган. *Без, бу җыр моңлы, монысы моңсыз, дип әйтәбез*. Р.Вәлиев. *Юк, аның Фирәвиясе мондый әче, моңсыз көйләрне белми, таң көен ярата ул*. М.Хуҗин

5) Ваемсыз, гамьсез; борчумәшәкатьсез. *Моңсыз, ваемсыз адәмнән дә рухи бахыр бәндә юк.* Г.Хөсәенов. *Тормышны хәзер бигрәк тә дәртсез, моңсыз адәмнәр басты*. Р.Низамиев. *Иң гаҗәбе шул: аның моңсыз, җансыз күзләрендә мөлдерәмә яшь*. Г.Гыйльманов

2. *рәв. мәгъ*. 1) Көйсез итеп, музыканың, мелодиянең үзенчәлекләрен бирә алмыйча. *Шундый да моңсыз итеп җырлый бу җырны Илһам, гомерендә*

җырлап карамаган кеше диярсең. Т.Миңнуллин. *Ул опера ариясе яки җырмы – татар музыкасын җырлаган чакта моңсыз җырларга ярамый.* Н.Алан

2) Моңнан башка. *Моңсыз, җырсыз яшәгәнче, үлем мең өлеш артык!* Р.Батулла. *Ахыр чиктә халык моңсыз яшәп булмаганлыгын аңлый, моңны юксына һәм Мөкатдәс табылгач, аннан гафу үтенеп, зур бәйрәм ясый...* Безнең гәҗит

3) Гамьсез рәвештә, ваемсыз төстә; кайгырмыйча, борчылмыйча

МОҢЧАН *с.* Еш моңланучан, хисле, нечкә күңелле; моңлы, сагышлы. *Искәндәрнең су шикелле саф, акыллы, моңчан коңгырт күзләре өстендә шәркый рәвештәге кара нечкә кашлары, озынчарак яңаклар арасындагы алсу бит урталары һәм чия шикелле кызыл, шактый калын иреннәреннән яшьлек, тазалык җиле исеп торадыр иде.* Ш.Камал. *Исән чагында дөнья рәхәте күрмичә, ачлы-туклы яшәп, утызга да җитмичә кара туфрак астына күмелгән ул моңчан егетне без нәрсәсе өчен зурлыйбыз соң?* Сөембикә

МОҢЧЫ *и.* Моң (*3 мәгъ.*) таратучы; моң чыганагы. *Алтын куллы, көмеш телле Авылда гармунчылар, Туган яктан аерылгач, Һәммәбез дә моңчылар.* Ш.Галиев. *Һәм менә бөек моңчы, тагын бер «яралы юлбарыс», чынлап ук китеп барды.* Р.Шәрәфиев

МОҢЫ́НЧА *рәв. сөйл. к.* **моңарчы**. *Әйе, мин моңынча хатыным берлә тартышып, бабайлар, әбиләр берлә тартышып гомеремне әрәм иттем.* Г.Исхакый

МОҢЫ́НЧЫ *рәв. сөйл. к.* **моңынча**. *--- Моңынчы умарталыкка бабаң сукмагыннан менелә иде.* Г.Бәширов. *– Моңынчы килмәгәч, аның килмәве инде, алайса, – дигән ач бүре.* Ф.Яруллин. *Хөрмәтле дуслар, әле моңынчы бер тапкыр да үбелмәгән егетләр һәм шул үбелмәгән егетләрне бер генә тапкыр булса да үбәргә өметләнеп йөргән яшь ханымнар!* Ж.Дәрзаман

МОПЕД *и. нем.* Мотор ярдәмендә хәрәкәт итә торган велосипед төре. *Менә монысы әти-әнисеннән акча сорап, велосипед, мопед, мотоцикл, «Жигули», «Волга» – шул сызык буенча үсүче егет.* М.Мәһдиев. *Болайга киткәч, әтисе улына гармун белән мопедны алып бирә инде!..* М.Шәймәрданов. *Мин хәтта аның мопеды тырылдавын ишетәм, ул да булмый, такси машинасының сигналыннан читкә тайпылып калам.* Гөлшаһидә

МОПС *и. нем.* Зур түгәрәк башлы, яньчек борынлы, кыска куе йонлы бүлмә эте. *Быел гына алты мең сумга сатып алган мопс токымлы эт хуҗасы Евгений исә ике ай ярымлык көчеге белән укол кадатырга килгән.* Шәһри Казан

МОРАД *и. гар. кит. к.* **максат**. *Яхшы белән юлдаш булсаң, җитәрсең морадка, яман белән юлдаш булсаң, калырсың оятка.* Мәкаль. *Могҗизалы, нурлы шул күренеш Морадыма мине ирештерә, Күрәчәгем белән күрештерә.* Ф.Гыйззәтуллина. *Әгәр мине Ходай ташламаса, Беләм авыр чаклар үтәсен. Чарасызлыктан чара табып, Морадыма бер чак җитәсем.* Ш.Җиһангирова

МОРАЛЬ *и. лат.* **1.** 1) Җәмгыятьтәге әхлак, әдәп нормалары. *Ярар, мораль белән яшәп кара, дип янадылар аңа.* Х.Камалов. *Сүз, иптәшләр, коммунистик мораль турында, әйе, коммунистик мораль – чын мораль, чын әхлак турында бара!* Н.Фәттах. *Ике төрле мораль белән яшәүче җәмгыять үзенең идеалларын, үзе дә сизмәстән, аяк астына салып таптады.* Р.Низамиев

2) Гыйбрәт, гыйбрәтле нәтиҗә. *Гадәттә, һәр мәсәлнең була морале.* Г.Минский. *Бу мәсәлдән моральне Эзләп тә торма хәтта: Нинди мораль булсын, ди, тагы Ялагай белән Бюрократта?* Ә.Исхак

3) Үгет-нәсыйхәт. *Маратым авызын чалышайтты: – Бер килмәсә килми икән! Кая барсам да – мораль!* Х.Сарьян. *[Лариса:] Тагын мораль уку башландымы?* Э.Яһудин. *Җитәкче халык хәтерен Саклауны күздә тотып, Бик каты тәнкыйть ясама, Объектив мораль укып.* Г.Афзал

2. *с. мәгъ.* 1) Әхлакый; әдәп-әхлакка мөнәсәбәтле. *Ф.Шәфигуллинның укуга һәм хезмәткә мәхәббәт тәрбияләгән, баланың мораль йөзе турында кайгыртып язган әсәрләреннән «Ярдәмче», «Хыянәт», «Сугышчан бурыч» һ.б. хикәяләрен аерып карарга мөмкин.* Р.Кукушкин. *Ырымнар төбендә мораль кагыйдәләр ята, алар да әдәби әсәрдәге гыйбрәт ролен башкара.* Ш.Галиев

2) Рухи; рухи яктан. *Бусына да коллективтагы мораль климат гаеплеме?* Р.Вәлиев. *Чөнки соңгы ел ярымда кыйнаудан, мәсхәрәләүдән, мыскыл итүдән, физик һәм мораль изүдән башканы күрмичә, мин кешеләрдә була торган кешелек сыйфатларын югалтып бетерә яздым инде.* З.Зәйнуллин. *Материаль яктан да, мораль яктан да булышты алар безнең гаиләгә.* Э.Шәрифуллина

МОРАЛЬЛЕК *и.* Үгет-нәсыйхәт. *[Тәнкыйтьче әфәнде] «Гафура укырга, әхлакка өнди» дип, шигырьне шул коры моральлек җәһәтеннән тәкърир итә (бәяли).* Ф.Әмирхан

МОРАЛЬ-СӘЯСИ *с.* Нәрсәнең дә булса әхлакый һәм сәяси нигезен тәшкил иткән. *Россия – Татарстан килешүләренең гамәлдәге комплексы зур тарихи, мораль-сәяси һәм юридик әһәмияткә ия.* Ватаным Татарстан. *Китап рухыбызны ничек тәрбияләргә, характерыбызны ничек чыныктырырга, мораль-сәяси сыйфатларны ничек булдырырга өйрәтә.* Шәһри Казан

МОРАЛЬ-ЭТИК *с.* Нәрсәнең дә булса мораль һәм этик нигезен тәшкил иткән. *Бүгенге мораль-этик хәлләрнең авылларыбызда да чигенә җитеп начарланганын күз алдында тотсак, фольклор клублары оештыру көнүзәк мәсьәләгә әйләнгән икән.* Б.Рәхимова. *Димәк, иң беренче чиратта, балаларда әхлак сыйфатларына эмоциональ мөнәсәбәт булдыру, мораль-этик бәяләү үзенчәлекләрен бергәләп өйрәнү, аларны алга таба тәрбия процессында үстерү өчен, махсус биремнәр кирәк.* Әдәпле булып үсәбез

МОРАТО́РИЙ *и. лат.* 1) Хөкүмәтнең яисә теге яки бу оешманың һ.б. рәсми белдерүе нигезендә нинди дә булса йөкләмәләрне үтәүнең кичектерелүе яки туктатылуы. *Бу юллар турыдан-туры теллар турындагы Законга мораторий игълан итәргә чакыру түгелме?* Р.Миңнуллин. *Чөнки 90 нчы*

елларда уткәрелгән хосусыйлаштыру чорында без мораторий игълан иттек. Р.Фәйзуллин. *«Чаллы икмәге» ЯАҖ Директорлар советы 2009 елның беренче яртысында компания җитештерә торган төп продукциягә – барыннан да элек икмәк-күмәч әйберләренә бәяләрне арттыруга мораторий кертү турында карар чыгарды*. Ватаным Татарстан

2) Халыкара хокукта: дәүләт арасындагы килешүләрнең үтәлешен кичектерү, туктатып тору. *Узган ел, мәсәлән, азык-төлек мәсьәләләре белгече Джин Зиглер БМО Генераль ассамблеясының 62 нче сессиясендә чыгыш ясаганда, биоягулык җитештерүгә биш еллык мораторий кертергә тәкъдим итте һәм «дөньяда 845 миллион ач кеше булганда азык-төлекне ягулыкка әйләндерү – кешелеккә карата җинаять» дип атады.* Ватаным Татарстан

МОРГ *и. фр*. Мәетләр вакытлыча саклана торган махсус бүлмә яки бина. *Юлны белмәгәч, моргның эшләмәгәнен каян белә ул?!* В.Нуриев. *Морг ябылырга инде ярты гына сәгать калып бара.* З.Мәхмүди. *Морг коточкыч урын кебек*. Ш.Галиев

МОРДАР *и. фар.* **1.** 1) *иск*. Үләксә. *Кассап күп булса, хайван мордар китәр.* Мәкаль

2) Үз-үзенә кул салган кеше, китиленәфес. *Белмим, бәлки, шуңа күрәдер авылымда сәрхушлек чәчәк ата, елдан-ел мордарлар саны арта.* Р.Вәлиев

3) *күч*. Кара эчле, хыянәтчел, кабахәт кеше. *Мал хакына иман белән бергә Халкын сатса бик күп мордарлар ---*. Ә.Синугыл-Куганаклы. *[Оранчы:] Әй кала халкы, колакларыгызны торгызыгыз! Мордарларны яндырабыз! Мордарларны утка атабыз!* Р.Батулла

2. *с. мәгъ.* 1) Шәригать кушканча суелмаган, мөселманнарга ашарга ярамаган. *Мордар ит*

2) Начар күңелле, эшәке, кабахәт, шакшы. *Үз гөнаһын башкалар өстенә аудару – иң мордар, иң эшәке кешеләрнең эше.* Дәрдемәнд. *Ул Ягъкуб Галиев – бик мордар кеше.* З.Бигиев. *Мордар Камай кеби, ике яклы Ядегәр кеби, бер маржа хатын, Мәскәү артындагы ике катлы бер йорт өчен кяфер китикме?* Р.Батулла

◊ **Мордар актыгы** Начар, эшәке кеше, хыянәтче турында. *Әллә берәр хыянәтче мордар актыгы Үз ояңнан сине тышка йолкып аттымы?* Ә.Синугыл-Куганаклы. **Мордар китү** *дини* Шәригать тыйган юл белән гомерен өзү, үз-үзенә кул салу. *Мордар китү гомер-гомергә гаеп, хурлык саналган.* Р.Кәрами. *Мөселман бәндәгә мордар китү гөнаһ эш санала, шуны беләсеңме?* Р.Низамиев

МОРДАРЛЫК *и.* 1) Мордар булу. *Үзегезгә кул салып, тынычлык табармын дип уйлыйсызмы? Мордарлык – иң зур гөнаһ бит ул.* Р.Габделхакова. *Нинди иләмсез йөкләрне тараткмый буып тора алган аркан адәм муенын гына кысарлык иде. Юк, мордарлыкның гөнаһы зур! Ярамас!* Ф.Яхин

2) *күч*. Кабахәтлек, пычраклык, начарлык. *Ул нинди генә эшкә, нинди генә мәслихәткә катышмасын, һәрвакыт – уйлаганы җәбер-золым, эшләгәне бозыклык, мордарлык иде*. Ш.Мөхәммәдев. *Мордарлыкка баткан мирзаларым, нәрсә җене сезгә кагылган?* З.Мансуров

МОРДВА *и.* Мордовия Республикасында, Урта Иделнең башка төбәкләрендә яшәүче мукшы һәм эрзя субэтносларына бүленгән фин-угор халкы һәм шул халыкның бер вәкиле. *Мордва халкының бер тармагын эрзя дип йөртәләр бит, шуны алган [псевдоним итеп].* Р.Кәрами. *Ул урамда элек чуваш, мари (чирмеш), мордва (мукшы) халыклары яшәгән.* Ф.Гарипова. *Республиканың төп халкын татарлар, чуашлар, руслар, марилар, удмуртлар, мордвалар һ.б. тәшкил итә.* Р.Вәлиев

МОРДВА́ЧА *рәв*. Мордва телендә; мордвалар кебек. *[Габделнур:] – Ә мин мордвача җырлый беләм, – диде.* Р.Кәрами. *Безгә күрше халыкларда да «тиен» сүзе бер үк вакытта җәнлекне һәм акча берәмлеген белдерә (мәс., марича – «игур», мордвача – «ур» сүзләре)*. А.Тимергалин

МОРЕ́НА *и. фр. геол.* Бозлыклар белән шуышып төшкән гравий, ком, балчык катыш тау токымнары, зур-зур таш өемнәре. *Мондый бозлык утырмалары морена дип атала.* Башлангыч география курсы. *Тау тирәсендәге мореналар ерактан бик күренмәскә дә мөмкин*. География

МОРЖ *и. зоол.* 1) Моржлар ыругыннан кыска куе йонлы, ишкәк аяклы, зур казык тешле, озын мыеклы, авыр гәүдәле имезүче диңгез хайваны. *Моржның божралар аша сикерүен, саксофонда «уйнавын» сокланып карадык.* Р.Вәлиев. *Моржлар – күрер күзгә иләмсез дәү, авыр гәүдәле, соң дәрәҗәдә тупас, уйсыз-хиссез җир-су хайваннары.* Кызыклар дөньясында

2) *күч*. Кыш көне ачык сулыкта, бәкедә коенырга яратучы кеше. *Арада моржлар булса, кайнар ләүкәдән төшеп, бассейнга чумарга була.* А.Хәсәнов. *Кыш көне ир-атлар белән, бәке чабып, коенырга йөргәнен беләм, морж дип йөртәләр хәзер аларны.* А.Гыйләҗев. *Морж диләр абыйны: Ул бәкедә коена.* Ш.Галиев

МОРЖЛАР *и. күпл. зоол.* Хәзер бердәнбер төрне (моржны) үз эченә алган, калган төрләре үлеп беткән имезүче диңгез хайваннары ыругы

МОРЖА *и.* 1) Мичнең, түшәм аша өй түбәсеннән өскә таба күтәрелеп, төтенне тышка чыгара торган өлеше. *Моржаларын сузган зур заводлар Күз алдына килеп тезелде...* М.Җәлил. *Бөтен моржалардан туры төтен күтәрелә, дөньяга тозлы гөмбә, балык пирогы исе чыккан*. М.Мәһдиев. *Капкалар җырлап кына ачыла, моржалардан хуш ис кенә тарала, яшь кызларның сулышлары, адымнары үзгәрә*. А.Гыйләҗев

2) Пароход, паровоз кебек транспорт чараларының төтен чыга торган җайланмасы. *Басуында зур моржалы тракторлар Томан белән күз алдында чуалдылар.* М.Җәлил

3) *диал*. Самавыр торбасы. *Аның манзарасы гаять күңелсез: тәрәзәләр такта белән томаланган, түбәсендәге калайлар, буяулары күптән уңып, яңгырдан күгәренеп, самавыр моржасы төсле челтәр-челтәр булып беткәннәр*. С.Җәлал

4) *диал*. Лампа пыяласы, лампа куыгы. *Лампаның моржасы челтер-*

челтер килә, Хәдичә әледән-әле уф дип авыр сулап куя иде. Г.Бәширов

5) *диал*. Мич. *Кәҗә сакаллы бабай, таягын кочаклап, моржага аркасын сөйгән дә, тешсез аңкауларын метмелдәтеп, бертуктаусыз нәрсәдер чәйни*. М.Мәһдиев

◊ **Моржадан очу** Бөлгенлеккә төшү, банкротлыкка калу. *Ирләрегез моржадан очкач, фирманы исемегезгә күчерергә мәҗбүрме?!* М.Фәйзи. **Моржадан төтен чыгару** Башкалар кебек үк тормыш алып бару, башкалардан калышмыйча гомер итү. *Кыярыңны каравылла да моржаңнан төтен чыгар.* А.Шамов

МОРЖА́ КАПКАЧЫ *и.* Моржадан җылы чыгып тормасын өчен, төтен юлын ябып куя торган җайланма

МОРЖАЛЫ *с*. 1) Моржасы булган. *Басуыңда зур моржалы тракторлар.* М.Җәлил. *Төтенле авыл – моржалы, ягъни кеше яши торган йортлы авыл.* Г.Гобәй

2) *күч.* Билгеле сандагы йорты, хуҗалыгы булган. *Авыз чалшайтырга ашыкмагыз, мең моржалы авылга ике юлар күп түгел ул*. К.Кәримов

МОРЖАЧЫ *и.* 1) Мич чыгаручы, миче. *Бер башы Мөрәле дигән авылга – кара сазлыклы урамнары белән, гомер буе урманда, күлдә мунчала төшереп, еланнан чагылып яшәүче, бүретөлкедән җәфа чигүче, әллә ниткән корыс холыклы, әмма каты куллы моржачы, мунчала чыгаручылардан торган авылга таба бара.* М.Мәһдиев

2) Мичнең төтен юлларын чистартучы кеше. *Малайның кыяфәтен күргәч, Хөршидәттәй сукранган шикелле итте: – И бала, моржачы гыйфрит булгансың лабаса!* А.Тимергалин

МОРЗА *и. фар.* 1) *тар*. Төркитатарларда өстен катлау вәкиле титулы; рус дворяннарына тиңләштерелгән феодаль аксөяк вәкилләре дәрәҗәсе. *Берничә хатыны бар өстенә ул җарияләрне дә теләгән кадәр алыштырып торды, морза-бәкләрнең матуррак бичәләренә күз кыздырудан, сүз катудан да тартынмады.* Ф.Бәйрәмова. *Бу урында сорау туа: әлеге илчеләрне Кырымга кем җибәргән? Казанның Мәскәүгә каршы булган түрә-морзаларымы?* Р.Вәлиев. *Хезмәтебездә Ырынбур губернаторы И.И.Неплюев истәкләре, чукынган татар морзасы Тәфкилев материаллары да кулланылды.* Ф.Ислаев

2) Татарлар яшәгән кайбер районнарда һәм казак халкында түбәнчелек белән мөрәҗәгать итү формасы

МОРЗАЛЫК *и.* Морза дәрәҗәсе; морза булу. *Хуш, ә безгә – Еникеевләргә һәм Терегуловларга – морзалык кайдан килгән соң?* Ә.Еники. *Бу җирләрдә яшәгән чабаталы морзалар белән бергә дин алыштыру бәрабәренә морзалыгын саклаган кенәзләр – Йосыповлар, Тенишевлар, Бикләмишевләр, Урусовлар, Кугушевлар – Петербург кебек шәһәрләрдә зур сарайлар корып, рус дворяннарының йөзләгән фамилияләрен башлап китәләр*. А.Юнысова. *Әби патша вакытында инде чукынмаган татарларга да морзалык кире кайтарыла*. Р.Миңнуллин

МО́РЗЕ АППАРАТЫ *и.* Морзе әлифбасы буенча сигналлар тапшыру өчен эшләнгән иң гади төзелешле телеграф аппараты. *Морзе аппараты янында бер яшь егет утырган*. Ш.Усманов. *Морзе аппараты дер-дер килә: нокта да сызык, сызык та нокта эфирга очалар гына.* Ә.Гадел. *Әйтерсең лә Морзе аппаратында телеграмма бирә*. И.Салахов

МО́РЗЕ ӘЛИФБАСЫ *и.* Телеграф буенча хәреф һәм саннарны тапшыру өчен шартлы билгеләр системасы. *Морзе әлифбасы өйрәттеләр, Сөйләштек без тукран телендә.* Р.Харис. *Монысын да күрше камерага тыгарга унбиш тәүлеккә. Морзе әлифбасы белән серләшеп ятсыннар шунда*. Т.Галиуллин. *Морзе әлифбасында нокта һәм сызыклар теләсә нинди хәбәрне тапшыра алган шикелле, нуклеотидларның чиратлашуы да нәселдәнлек информациясенең үзенчәлекләрен билгели.* Галәм. Җир. Кеше

МОРИ́ЛКА *и. рус* Үзагачка төс кертү, ныклык бирү һ.б.ш. максатларда кулланыла торган махсус сыеклык

МОРО́ЖЕНОЕ *и. рус сөйл*. Туңдырма. *Монда теләгәнчә мороженое ашарга мөмкин.* М.Мәһдиев. *Ләкин розалар матурлык ягыннан гына түгел, практик яктан да әһәмиятле: аларның таҗ яфракчыкларыннан хуш исле май алалар, ислемай һәм варенье ясыйлар, алардан ликёр, мороженое эшләгәндә файдаланалар.* Робинзон эзләреннән

МОРО́ЖНЫЙ *и. рус сөйл. к.* **мороженое**. – *Мин кичә әни белән Бөгелмәгә бардым, морожный ашадым, – ди югары оч малае.* М.Галиев. *Кинога барырга, морожный алырга акча кирәк булганда, себерке тоткан әниең яныңа чыгарга хурлана идең.* А.Гыйләҗев. *[Гүзәл:] Әйдә, морожный алып ашыйбыз, Гыйльфан?* Т.Миңнуллин

МОРО́ШКА *и. рус бот. к.* **мырак**. *Кайчакта биек үлән арасында төньякның җир җиләге – морошка очрый иде.* Г.Әпсәләмов. *Менә бер вакыт урманны яшел үлән каплый, кырмыска оясы җанлана, саз җиләкләре булган кара бөрлегән, күк җиләк, морошка өлгерә.* Хайваннар турында очерклар

МОРС *и. нем*. Суга шикәр һәм җиләк-җимеш суы яки кайнатма кушып ясалган салкын эчемлек. *Шулай да өстәлләргә графиннар белән морс дигән су куйганнар, чәйгә караганда бу кызгылт суның мәшәкате азрактыр, күрәсең*. Ә.Еники. *Симаков тегендәмонда чабып йөргән арада, Коля белән Хәсип берничә морожный ашап, туйганчы морс эчәргә өлгерделәр*. Р.Сәгъди. *Җимеш-җиләкләрен яңа җыелган килеш ашыйлар, алардан варенье кайналар, повидло, джем, квас, компот, сироп, морс ясыйлар*. Урман аптекасы

МОРТИР *и. голл. иск. к.* **мортира**. *[Булат:] Мортирлары җиздән коелган, Көпшәләре тирән уелган.* Ә.Фәйзи

МОРТИ́РА *и. голл.* Кыска көпшәле артиллерия тубы. *Ул юл кырыенда бер тәгәрмәче ватылган мортира өстенә барып утырды.* Г.Әпсәләмов

МОРФЕ́МА *и. гр. лингв.* Сүзнең лексик яки грамматик мәгънәгә ия иң кечкенә кисәге. *Шуны истә тотарга кирәк: мәгънәле кисәкләр (морфемалар) тамырга бик төгәл эзлеклелек белән ялгана.* Н.Максимов. *Морфема – иң кечкенә (минималь) берәмлек, ә морфология өйрәнә торган, зурлыгы буенча*

иң чик берәмлек ул – сүзформа. Татар теле морфологиясе

МОРФЕ́МИКА *и. гр. лингв*. Сүзнең мәгънәле кисәге булган морфемалар җыелмасы; морфемаларның гомуми үзенчәлекләре турындагы фән. *Хәзерге вакытта морфема морфемика фәнендә өйрәнелә*. Ф.Сафиуллина. *Соңгы вакытта татар тел белемендә сүз төзелеше (морфемика), морфология бүлегеннән аерылып, сүз ясалышына бәйле рәвештә генә өйрәнелә башлады*. Татар теле морфологиясе

МО́РФИЙ *и. гр. фарм.* Әфьюн мәгеннән ясалган, авыртуны баса, йоклата һәм билгеләнгән дозадан артык кабул иткәндә агулый торган наркотик матдә. *Нитроглицириннан һәм морфий, атропин, камфара уколларыннан соң йөрәк авыртулары басылган*. Г.Әпсәләмов. *Яралыларга салган морфий уколының көче беткән, шуңа уянып, тавышлана башлаганнар иде.* Х.Камалов. *Морфий сүзе чыккач, Гөлнара Тузга карап куйды. Туз, аның карашын сизеп: – Сез гаҗәпләнмәгез, мин үзем дә медик кеше, – диде.* Ф.Яруллин

МО́РФИЙЧЫ *и*. Морфинизмга бирелгән кеше; наркоман

МОРФИН *и. гр. к.* **морфий**. *Больницада аңа ашыгыч медицина ярдәме күрсәткәннәр: кабат морфин, атропин, кардиамин уколлары ясаганнар, кислород сулатканнар.* Г.Әпсәләмов. *Өлгермәгән тартмачыкларның сыекчасында төрле алкалоидлар туплана, алар арасында морфин һәм кофеин медицинада киң кулланыла.* Ботаника. *Ул [суперанальгетик] авыртуны морфинга караганда 10 мең тапкырга тизрәк баса, кешегә тәэсире инде бер микрограммнан башлана*. Мәдәни җомга

МОРФИНИЗМ *и. гр. мед.* Наркоманиянең бер төре: морфий куллану белән мавыгудан гыйбарәт авыру. *Ул вакытта «солдат авыруы» – морфинизм чире киң тарала.* Кызыл таң

МОРФИНИСТ *и. гр. к.* **морфийчы**

МОРФО́ЛОГ *и. гр.* Морфология белгече. *Татар теле белеме белән дә эш шулай, анда да специализация бар: фонетикачы, морфолог, дериватолог, лексиколог, лексикограф һ.б.* Фән һәм тел

МОРФОЛО́ГИК *с.* Морфологиягә мөнәсәбәтле булган. *Аның, мәсәлән, сүз төркемнәрен эчке һәм тышкы яклардан карап классификацияләве, сүзләр ясалышын фонетик, морфологик, синтаксик төрләргә бүлеп каравы нәкъ әнә шул принципка корылган*. Г.Алпаров. *Кайбер морфологик формалар, күчерелмә мәгънәдә кулланылганда, шаян төсмер бирә.* Х.Курбатов. *Морфологик органнар барлыкка килү үсемлекләр дөньясы эволюциясендә зур вакыйга булып тора.* Ботаника

МОРФОЛОГИСТ *и. гр. к.* **морфолог**. *Күренекле морфологист галим Д.Г.Тумашева үзенең татар телендә фигыльгә хас темпоральлек, персональлек, модальлек функциональ-семантик категорияләрен яктырта.* Татар теле морфологиясе

МОРФОЛО́ГИЯ *и. гр.* 1) Туфрак төзелешен, үсемлек һәм хайван организмнарының формасын, төзелешен, функцияләрен өйрәнә торган фән. *Эксперименталь морфология*

2) Организмнар, органнар һәм туфрак төзелеше. *Үзенең «Организмнарның генераль морфологиясе, органик формаларга карата төрләрнең килеп чыгуы турында Чарлз Дарвин тарафыннан реформацияләнгән теория белән механик нигезләнгән фәннең гомуми принциплары» дигән зур хезмәтендә немец табигать тикшеренүчесе имезүче хайваннарның шәҗәрәсен реконструкцияләп бирде*. Галәм. Җир. Кеше

3) *лингв.* Сүзләрнең үзгәреш формалары системасы; грамматиканың сүзләрнең төзелешен, төрләнешен, сүз төркемнәрен һәм аларга хас грамматик категорияләрне өйрәнә торган бүлеге. *[Хәлил Ишмаев] мең дә беренче тапкыр аудиториягә керде, мең дә беренче тапкыр татар теленең морфологиясе турында лекциясен укып чыкты.* Ә.Еники

МОРФОНОЛО́ГИЯ *и. нем.* Тел белеменең төрле типтагы морфемаларның фонологик төзелешен, морфологик процесслар вакытында сүзнең фонетик төзелешендә бара торган үзгәрешләрне, ягъни морфонологик күренешләрне өйрәнә торган тармагы

МОРЯК *и. рус сөйл.* 1) *хәрби* Диңгез флотында хезмәт итүче кеше; диңгезче. *Акчарлаклар елый, Ә моряк еламый беркайчан.* М.Җәлил. *Ул [егет] флотта чыннан да булган, моряк чактагы фотосын күрсәтте*. Г.Ахунов. *Аннан соңгы диңгез алышлары – дистәләгән, морякларның ул орышларда күрсәткән батырлыгы – тиңдәшсез*. Р.Кәрами

2) Диңгездә хезмәт иткән кеше; диңгезче. *Ә авыл җирендә моряклар һәм очучыларга аеруча хөрмәт бар иде.* Т.Миңнуллин. *Рәт-рәт булып моряклар, солдатлар, алар артыннан дин әһелләре атлады, укучы балалар да бәйрәмчә иделәр...* Ф.Җамалетдинова. *– Ул Татиздатта минем ике китабымны бастырып чыгарды, – диде Мостафа ага. Моряк иде ул*. Р.Харис

3) Диңгезне бик яхшы белүче; диңгез эшендә тәҗрибәсе булган кеше; диңгезче. *Разведка начальнигы Микита – карт моряк – алдан бара*. Г.Гобәй

МОСКИТ *и. исп. зоол.* Бик әче тешли торган канечкеч вак бөҗәк. *Биредәге москит дигән бәләкәй-вак чебеннәр тәнеңне тешли*. Р.Низамиев. *Жыерчыклы тире кәркәдәннәрне москитлардан һәм башка бөҗәкләрдән саклый.* Хайваннар турында очерклар. *Хәзер исә галим лазерны озынборын һәм москитлардан саклану чарасы буларак кулланырга җыена*. Мәдәни җомга

МО́СТИК *и. рус* 1) *махс*. Ясалма тешләр беркетелә торган өслек

2) *спорт* Гәүдәне артка каерып, күкрәкне һәм корсакны өскә таба күтәргән килеш аяк-куллар белән җиргә таянып торудан гыйбарәт гимнастик фигура. *Болай булса, мостик кына түгел, әллә нишләтерләр!* Аманулла. *Кай арада өйрәндең, дим, мостик төшәргә?* Сөембикә

3) Суднолларда капитан басып торыр өчен, кайбер машиналарда күзәтү, командалык итү өчен ясала торган махсус күтәренке урын яки каланча; капитан күперчеге. *Пароходның кызыл путалы кара моржәсы, мостикка чыгып баскан ак кительле, ак фуражкалы юан капитаны күренә*. И.Гази. *Мондагы шау-гөр килеп көлешүне югарыда да ишеткәннәр булса кирәк, аннан капитан*

мостик читенә килеп, юри ачуланган кыяфәт белән: – Әй, бала-чага, бик каты кешнәмәгез, урманда аюларны өркетәсез! – дип кычкырды. С.Сабиров

МОСТОВОЙ *и. рус иск. сөйл.* Урамның таш түшәлгән яки асфальт җәелгән, гадәттә транспорт йөри торган өлеше; асфальт юл. *Урамда таш мостовойдан чапылдап үткән ат дагаларының тавышлары сирәкләнгәннән-сирәкләнә бара иде.* Ш.Камал

МОСЬЕ *и. фр.* Французларда ир кешегә хөрмәтләп мөрәҗәгать итү сүзе. *Ә, мосье, беләсеңме син, Парижда тагын нәрсә модада?* Р.Батулла

МОТАЛӘГА *и. гар. иск.* **1.** Уку, өйрәнү; эшне, берәр мәсьәләне төрле яктан тикшереп хөкем чыгару. *[Сәгыйть хәзрәт:] --- Алар хакында «Мохтәсарел-викая» кирәк. Моталәгасы авыр инде дә, ул кирәк.* Г.Исхакый

2. *с. мәгъ.* Гыйлемле, фикерле. *Китапларны моталәгалерәк шәкертләрә вирсә кирәк.* М.Акъегет

МОТАЛӘГА́ КЫЛУ *ф. иск.* Уку-өйрәнү, эшне-мәсьәләне төрле яклап өйрәнү, хөкем чыгару. *Шуннан соң әйтә [хәлфә] Чикерткәгә: – Тәкъсир, синең эшең – менә шушы өстәл янында башыңны бөгеп, изге китап моталәгә кылып утыру...* Ә.Еники

МОТЕЛЬ *и. инг.* Олы юл өстендә урнашкан, юлчыларга ашау, юыну, төн кунып чыгу мөмкинлекләре булган кечкенә һәм башкаларга караганда арзанлырак кунакханә. *Шулай ук мотель, кунакханә, шәхси фатирларда торырга, вакытлыча эшкә урнашырга теләк белдерергә, шәһәр оешма-учреждениеләрен карап йөрергә мөмкиннәр.* Шәһри Казан. *«Диверсант»лар арендага автотранспорт алып торырга, кунакханә, мотель, вакытлыча алып торылган фатирларда яшәргә, эшче мигрантлар сыйфатында эшкә урнашырга, төрле сәбәпләр белән туристлык фирмаларына, агентлыкларга, учреждениеләргә керергә мөмкин.* Хезмәт даны

МОТИВ *и. фр.* 1) Нинди дә булса эш-хәлнең сәбәбе, нигезе, алшарты. – *Хатның язылу мотивы, болай булгач, безгә мәгълүм, – диделәр.* Г.Ахунов. *[Дунаев әлеге ике кешегә:] – Сез кичке заседаниегә килегез, шунда үзегезнең мотивларыгызны әйтерсез, – диде.* Ш.Камал

2) Сәнгать әсәре сюжетының бер элементы; билгеле бер автор иҗатының (гомумән иҗади әсәрләрнең) төп темасы (тематикасы). *Очрашу, аерылышу, кавышу, өмет, сагынып моңаю – Ә.Ерикәй поэзиясенең төп мотивлары.* Т.Галиуллин. *Үз халкыңа тугрылыклы булырга өндәү, азатлык өчен көрәш мотивлары бигрәк тә «Габделмән» поэмасында ачык куелган.* А.Әхмәдуллин. *Көчле кеше фаҗигасен күрсәтү мотивы язучының башка эпик әсәрләрендә дә лейтмотив булып сузылып бара.* Д.Заһидуллина

3) Нәрсәнең дә булса нигезенә алынган үрнәк, сюжет. *Яулар кичкән зур тарихлы халык без – биюдә башка мотив вә темалар табарга әллә кайчан вакыт.* Э.Сиражи. *Айдар [Хисамов] лирик мотивларны сурәттә чагылдырганда беренче планны нечкәләп эшләүчән, андый чакта аның буяулары йомшак һәм нәфис була.* Мәдәни җомга

МОТИВЛАШТЫРУ *ф.* Нәрсәнең дә булса мотивларын китерү, нигезләү, дәлилләү. *Хәзер әсәрдәге мотивлаштыру, ягъни «хикәянең җаны» җитенкерәмәүгә берничә мисал китерик.* М.Хәсәнов. *Ошбу карар әсәрдә юридик яктан да, сәнгатьлелек җәһәтеннән дә мотивлаштырылмаган, димәк, укучы моны кабул итә алмый.* Ф.Хатипов

Мотивлаштырып бетерү Тулысынча мотивлаштыру. *Автор үзен оста психолог итеп танытса да, геройларның үз-үзен тотышы, сөйләмнәре һәрвакыт та мотивлаштырып бетерелми.* Ә.Закиржанов

Мотивлаштырып җиткерү Тиешле дәрәҗәдә мотивлаштыру

МОТИВЛАШТЫРЫЛУ *ф.* Мотивлары китерелгән, нигезләнгән, дәлилләнгән булу. *Димәк, «Илчегә үлем юк» романында Сәлим ханның үз оныгын үтерергә фәрман бирүе аның ерткыч характеры белән мотивлаштырылмый булып чыга.* Ф.Хатипов

МОТЛАК I *с. гар.* **1.** Бернинди шарт белән дә чикләнмәгән, бернигә дә бәйле булмаган, абсолют. *Чыгарылучы яшь белгечләр өчен зур предприятиеләрдә мотлак квоталар кертү кирәк.* Өмет

2. *и. мәгъ. филос.* Абсолют. *Ләкин аң-белем үсешенең үзенчәлеге шундый ки, ул мәҗүси потка һәм түбән дәрәҗәле дини хорафатларга табынудан арына барып, мотлакка – югары рухка таба баруны китереп чыгара.* Казан утлары

МО́ТЛАК II *рәв. гар. к.* **мотлака**. *Хөсәен Тукайның искиткеч сизгер кеше икәнлеген һәм мотлак үзен озата чыгачагын алдан ук уйлаган иде – ялгышмады.* А.Расих. *Ә алар башкорт булгач, мәктәпләрдә мотлак башкортча гына укырга тиеш, дип таләп ителә башлады.* Мәдәни җомга

МО́ТЛАКА *рәв. гар.* Һичшиксез, һичсүзсез; бернигә карамастан. – *Дөрес эшлисез! – диде әдип ваемсыз гына, аннары миңа туры гына карап әйтте: – Салих әфәнде сезнең хакта мотлака белеп әйтәдер дип уйлыйм.* Ә.Еники. *[Исмәгыйль:] Өлкән казый буларак мин моңа мотлака каршы.* Ю.Сафиуллин

МО́ТЛАКАН *рәв. гар. к.* **мотлака**. *Ә инде бераз үткен теллеләнгәннән соң, Габдулла җитди рәвештә: «Мин ул түгәрәккә йөреячәкмен, мотлакан йөреячәкмен, – диде, – тик лектор сыйфатында түгел, ә гади тыңлаучы сыйфатында».* А.Расих. *Хәтерли, күңеленнән, яттан хәтерли [Иркен ага] Исхакыйның оранын: «Алардан качмаска кирәк! --- Милләтемезне инкыйраздан коткарасымыз килсә, мотлакан урыс мәктәпләрендә уку тиеш!»* А.Хәлим

МО́ТО- *лат.* Кушма сүзләрдә түбәндәге мәгънәләрне белдерә торган беренче кисәк: 1) Моторлы (мәс., *мототехника, мотобот, мотодрезина, мотокаток*)

2) Моторлаштырылган, моторлы машиналар белән тәэмин ителгән (мәс., *мотодивизия, мотоколонна*). *Аларга [машиналарга] яңа төзелгән мотобригада сугышчылары утырган.* М.Хуҗин. *Әүвәл бу часть штрафной батальон иде, хәзер техника өстәделәр дә мотомеханизм хәрби частена әверелде.* Р.Кадыйров

3) Мотоциклларда, мотоциклетларда үткәрелә торган (мәс., *мотоузыш, мотоспорт*)

МОТОР *и. лат.* 1) Һәртөрле энергияне механик көчкә әйләндерә торган җайланма; двигатель. *Ул [Нурислам Хәсәнов] 1959 елда Казанга килә, техник училищеда слесарь-ремонтчы һөнәренә өйрәнә һәм Казан моторлар төзү берләшмәсендә эшли башлый.* И.Нуруллин. *Элек аларда көчле дизельләр дөп-дөп эшләп утыралар иде. Хәзер – электр моторлары.* Р.Кәрами

2) Транспорт чараларын хәрәкәткә китерә торган двигатель. *Бары трассадан чапкан автобусның мотор гүләве генә ишетелә иде.* Л.Шәех. *Самолёт моторы күңелле генә гүли башлады.* М.Насыйбуллин. *Хәзерге иң куәтле тракторлар һәм «КамАЗ» кебек автомашиналарда дизель моторлары тора. Арзанлы һәм талымсыз моторлар.* Кызыклар дөньясында

3) *сөйл.* Автомашина, такси. *Гадәттә, шушы кибет каршында күп кеше мотор тота.* Безнең гәҗит

МОТОРИ́КША *и. лат.-яп.* Кешеләр утыртып йөрү өчен өсте ябулы өч көпчәкле мотоцикл. *Урамнарында моторикшалар күреп тә гаҗәпләнмәдек.* М.Мәһдиев

МОТОРИСТ *и. рус к.* **моторчы**. *Джинсылы ике егет кырынмаган, майлы бушлат, берет кигән, кыяфәтеннән моторист икәне күренеп торган ыратка иярде дә, түземсезләнеп, трюмга таба юл алды.* Ә.Гаффар. *Бер кружка чәй эчкән арада, без моторист Пётр Петрович белән уртак тел табып, бер-беребезне ярата ук башладык.* М.Юныс

МОТО́РКА *и. рус сөйл.* Моторлы көймә. *Искәндәр моторка яллап Ладога күленә килде.* Г.Гобәй. *[Идел өстендә] кечкенә моторкалар чабып йөри.* Ф.Сәйфи-Казанлы. *Җыр шушы урынга җиткәндә, моторка минем турыдан үтеп бара иде инде.* С.Сабиров

МОТОРЛАШТЫРУ *ф.* 1) Эш коралларын һ.б.ш.ны мотор белән эшли торган итеп ясау, көйләү

2) *хәрби* Моторлы машиналар белән тәэмин итү. *Ул 1939 елда Сталин исемен йөртә торган «Кызыл Армияне механизацияләү һәм моторлаштыру» Хәрби Академиясен тәмамлый.* Акъегет авылы тарихы

Моторлаштыра бару Аз-азлап, акрынлап моторлаштыру

Моторлаштырып бетерү Тулысынча, барысын да моторлаштыру

Моторлаштырып чыгу Һәрберсен аерым-аерым моторлаштыру

МОТОРЛЫ *с.* Моторы булган; мотор ярдәмендә хәрәкәткә китерелә торган. *Коймага моторлы велосипед һәм тәкә мөгезе сыман кәкрәеп килгән рульле спорт велосипеды сөялгән булыр.* М.Галиев. *Ян тәрәзәләрдән баксаң – язны көтеп кара шәүлә булып калган өнсез урман ишарәсе, арткы тәрәзәгә борылсаң, «Газель» уты күзгә төшә, алга карап барсаң, соры юлда фара нурларының туктаусыз эзләнүе машинаны агымга каршы ашкынган моторлы көймә кебек итә, башка каба.* К.Кәримов. *Яшь егеткә моторлы пычкы белән яки трактордa, автомашинада эшләве әйбәтрәк.* Г.Әпсәләмов

МОТОРО́ЛЛЕР *и. нем.* Мотоцикл төре. *Мотороллер яисә йөк машиналарыннан яшелчә, он, ярма кебек әйберләр тәкъдим итеп аваз салучыларны да ишеткәләдем.* И.Нуруллин

МОТОРЧЫ *и.* Моторларны, двигательләрне ремонтлаучы, караучы, сүтеп җыючы эшче. *Алар, ирләре янында булу өчен, кайсы матрос, кайсы моторчы булып эшләүчеләр яки җәйге ялларын якыннары янында үткәрергә килүчеләр, үзара гына әйткәндә, Нәзифәдән бераз көнләшәләр дә.* С.Сабиров. *Көймәдә бары тик өч кеше – капитан, моторчы һәм матрос кына эшли.* Г.Галәметдин. *Тәжрибәле механизатор үзлектән моторчы һөнәрен дә үзләштергән, хәзер трактор двигательләренә җан өрә.* Кызыл таң

МОТОСПОРТ *и. лат.-ингл. спорт* Төрле шартларда мотоцикл белән иң яхшы идарә итүчене билгеләүдән гыйбарәт ярыш; мотоцикллар узышы. *Воткинск шәһәреннән кечкенәдән мотоспорт белән кызыксынган, әмма техника алырга мөмкинлеге булмаган, инде үзләре эшләп мотоцикл алып, хәзер ярышларга килгән егетләрне дә очраттык.* Х.Гайфуллина. *Башкортстанның халык, Русиянең һәм Татарстанның атказанган артисткасы Нәзифә Кадыйрова бик дулкынланды: «Бүген мотоспорт ветераннарына ярдәм артык булмас иде», – диде ул.* Г.Нәбиева

МОТОЦИКЛ *и. фр.* Эчке янулы двигатель ярдәмендә хәрәкәткә китерелә торган, велосипедка охшаш ике яки өч тәгәрмәчле транспорт чарасы. *Идарә яныннан арба таккан «Беларусь»лар, автомашиналар, мотоциклар кузгалды.* М.Мәһдиев. *--- Читтәрәк бер-ике машина, мотоцикл күренә.* Р.Кәрами. *Фәһмә аның хәлләрен сорады, кич килеп утырырга чакырды, мотоцикл белән район үзәгенә танцыга барырбыз, диде.* Ф.Садриев

МОТОЦИКЛЕТ *и. фр.* Җиңел мотицикл. *Илбашы мотоциклет узышларында катнашучы спортчылар белән аралашты.* Ватаным Татарстан

МОТОЦИКЛИСТ *и. фр. к.* **мотоциклчы**. *Бер генә мотоциклист та, бер генә «Жигули» хуҗасы да ул «мендәр»дән алган канәгатьлек хисен кичерә алмыйдыр...* М.Мәһдиев. *Бер яшүсмер мотоциклистны эзәрлекләгәндә, тәгәрмәченә атам дип, аягына тидергән.* З.Мәхмүди. *Безнең дәвердә, әле күптән түгел генә Таллинда булып узган мотоциклистлар ярышында да җиңүчеләрнең муеннарына имән ботаклары бәйләме кидерделәр.* Робинзон эзләреннән

МОТОЦИ́КЛЧЫ *и.* Мотоцикл йөртүче. *Без абайлап өлгергәнче, чаттан борылган мотоциклчы юл аша тартылган җебебезне үзеп тә китә.* М.Галиев. *Юл йөрү кагыйдәләрен бозган өчен, сигез җәяүле бала, ун велосипедчы, өч мотоциклчы туктатып кисәтелде.* Ватаным Татарстан. *Хикмәт шунда: мототехника үтә тиз хәрәкәт итүчән, мотоциклчы, пассажир өчен саклану чаралары каралмаган диярлек.* Шәһри Казан

МОТЫЙГ *с. гар. иск.* Буйсынучы; итагать итүче; баш июче. *Синең исән чагыңда мотыйг идек әмереңә, Бүген булдык җанлы үлек, алсана, җаным, кабереңә.* Бәет. *Падишаһка әйтсен:*

«Инде без сиңа мотыйг булдык, синең хөкемеңнән һич баш тартмасмыз», – дисен. К.Насыйри

МОХЕР *и. инг л.* **1.** Ангора кәҗәсенең мамыгы. *Очсыздан гына мохер саттылар.* Ватаным Татарстан

2. *с. мәгъ.* Шундый мамыктан, йоннан эшләнгән. *[Гөлшат:] Мин сиңа менә дигән мохер шарф таптым.* А.Хәсәнов. *Мохер беретканы кыңгырайтып куям да, әфлисун төсендәге курткам белән бөтен вагонның күз явын алып, ишеккә юнәләм.* Р.Рахман. *Җилкәдә мохер шарф, аякта фин яисә югослав сапожкилары, --- өстә дә кыйммәтле кием ---.* Р.Зәйдулла

МОХИТ *и. гар.* 1) Тышкы тирәлек; тирә-юнь. *«Җир бер генә ул...» Тирә-юнь мохитне саклау буенча Халыкара хезмәттәшлекнең девизы шундый.* М.Хәсәнов. *Тәүге кар соры мохитне акшарлап куйгач, Балантауның исеме җисеменә тач туры килде, авылдагы һәр куак, тал-тирәк балан агачына әверелеп чәчәк атты диярсең...* К.Кәримов

2) Кеше яшәгән әйләнә-тирә; социаль тирәлек. *Ләкин һәр ирекле үлем хөкем сөргән мохиткә, чордашларына, фикердәшләренә протест ул ---.* А.Гыйләҗев. *Аны [кешене] чолгап алган мохит тар, кешеләр – санаулы.* Р.Кәрами

3) Һөнәр, яшь, белем, кызыксыну һ.б. яклары уртак булган җәмгыять, кешеләр төркеме (коллектив, тирәлек). *Республика китапханәсенә директор булырга ризалашуын ул болай аңлатты: – Язучылар мохитеннән арынып, укучылар даирәсенә якынаерга уйладым.* Р.Зәйдулла. *Әдәби мохиттә генә түгел, «Аккош күле»ндә дә ызандаш булган язучыларның, холык-фигыль ягыннан һәм иҗат дәрәҗәсе белән нык аерылган тәкъдирдә дә, бер-берсен ныграк аңлавы, үз-якын итешүләре гаҗәпмени!* М.Вәлиев

4) Билгеле бер җәмгыяттә аерым кешеләр, аларга хас сыйфатлар һәм берберсенә мөнәсәбәтләре һ.б. тәэсирендә барлыкка килә торган «эчке сулыш», торыш, атмосфера. *Табигый, мондый мохит эчендә үскән кызларыбызга безнең шикелле кара эшчеләр ошамый; алар безне тупас, рухсыз диләр.* С.Җәлал. *Әмма бина нинди генә гүзәл һәм мәһабәт булмасын, әгәр дә эчендә иҗат дәрте кайнамаса, чын артистлар, режиссёрлар һәм сәхнәдә үзенә бер мохит булдыра торган күп төрле һөнәр ияләре илһамланып эшләмәсә, ул театр булмый әле.* М.Маликова. *Хикмәте Хода, бүлниснең һавасын, мохитен үзгәртеп җибәрде бит әле бу Утлыкүз.* В.Нуриев

5) Яшәү, тормыш шартлары. *Шүрлектә Кытайда эшләнгән борынгы ташаяк савыт-саба, кувшинга охшаш савытлар... Мохит ярлы.* Р.Батулла. *Бу рәссам күңелсез, ямансу мохиттә үзе өчен ямьле, җанны җылыта торган почмак булдырган.* М.Маликова

МОХИ́Т ДИҢГЕЗЕ *и. иск.* Океан. *Сез арысланнарны тудырган аналар, тәрбия кылып үстергән аталар, сезнең җир кырына – мохит диңгезе янына сугышка киткәнегезне күреп, никадәр шатлансалар да, хаклары бардыр.* Ш.Мөхәммәдев

МОХТАҖ *с. гар.* **1.** 1) Нәрсәгә дә булса ихтыяҗ, кирәклек тойган, кирәксенгән. *Ләкин мохтаҗ заман өчен икенче ягын да онытырга ярамый фатир кертүнең: ат аунаган җирдә төге калган кебек, бу хезмәтләре өчен куныпчыгучылар да буш итми, колхоздан да тама.* Н.Әхмәдиев. *--- Шәфика үзен янә бик кечкенә, ярдәмгә мохтаҗ җан ияседәй хис итте ---.* М.Маликова. *Иң авыр, мохтаҗ көннәрендә дә Гөлкәй миңа берни хәбәр итмәгән, ярдәм сорамаган.* Р.Габделхакова

2) Тормыш шартлары канәгатьләнерлек, кереме җитәрлек дәрәҗәдә булмаган; ярлы, фәкыйрь, юксыл (кеше тур.)

2. *и. мәгъ.* Ярлы, фәкыйрь, нәрсәгә дә булса ихтыяҗы булган кеше. *Киелгән киемнәрне җыябыз да, тәртипкә китереп, бик арзан хакка, аяк ялы бәрабәренә дигәндәй, мохтаҗларга бирәбез.* М.Маликова. *Мохтаҗларга ярдәм итте, Кайгы тулы диңгез кичте [Гөлсем].* М.Жумабаев. Ул *[Галишир Нәваи] үз дәүләтендә мәчетләр, мәдрәсәләр салдыра, мохтаҗлар өчен хәйрия вәкыфлары оештыра.* Р.Зәйдулла

МОХТАҖЛЫК *и.* 1) Мохтаҗ (*1 мәгъ.*) булу. *Ялкаулык – мохтаҗлыкның ачкычы.* Мәкаль. *Мохтаҗлыкның ни икәнен китап аша түгел, үз башыннан кичергәнгә күрә белә [Гайнан].* М.Насыйбуллин. *Менә нефтьне генә алыйк. Аны сатудан кергән акчаны һәр кешегә тигез итеп бүлеп бирсәк, безнең халык мохтаҗлыкның ни икәнен дә белмәс иде.* Р.Габделхакова

2) Ярлылык, фәкыйрьлек

3) Аерым бер мәсьәләдә, өлкәдә, юнәлештә нәрсәгә дә булса ихтыяҗ. *Кемгә кирәк алтмыш биш яшьлек картның казынулары? Гомумән, татар әдәбиятына мохтаҗлык калдымыни?..* А.Гыйләҗев. *Иҗтимагый-сәяси мәсьәләләрнең чишелеше шәригатьтә әйтелгән, һәм аларны яңача күзаллауга мохтаҗлык юк.* А.Юзиев

МОХТАРИЯТ *и. гар. к.* Автономия. *Омскида башта «Ватан» татар иҗтимагый оешмасы (1992 ел), ә инде 1998 елда өлкә татарларының милли мәдәни мохтарияте эшли башлый.* Ф.Бәйрәмова. *Төрле өлкә һәм республикалардан килгән милли-мәдәни мохтарият рәисләре башкарган эшләренә хисап тотып кына калмады, бергәләп хәл итәсе мәсьәләләрне дә күтәреп чыкты.* Р.Вәлиев. *Казанда Татар федераль милли-мәдәни мохтариятенең III Бөтенроссия җыены булып узды.* Казан утлары

МОЧЕВИ́НА *и. рус к.* **бәвелчә**. *Сыер ул – гаҗәеп биотехнологик комбайн: ул сиңа сөт-каймак, ит-май гына бирепторгай, көн саен илле килограмм чамасы тирес тә бирә; аның уртача көндәлек нормасы болай: ике чиләк сөт, ике чиләк куе сидек – мочевина һәм ике пот чамасы коймак-коймак тизәк.* М.Зарипов. *Азотлы ашламалардан – мочевина, аммоний сульфаты һәм селитра, фосфорлылардан – суперфосфат, калийлылардан калий хлориды киң таралган.* Ботаника

МОШЕ́ННИК *и. рус* 1) Үз мәнфәгате өчен башкаларны алдаучы намуссыз кеше, алдакчы. *Һәм еш кына әнә шундыйлар беренче очраган ришвәтче, алдакчы яки мошенникның корбанына әйләнәләр.* Ф.Латыйфи. *[Исрафилов:] Кара син аларны, мошенникларны!* Г.Ахунов. *Югыйсә башкаларга*

бөтенләй ышаныч юк: мошенник өстендә мошенник... А.Хәлим

2) *тирг.* Тәртип бозучы, ниндидер канәгатьсезлек китерә торган эш эшләүче кеше. – *Ник монда чәчәкләр өзеп йөрисең, мошенник малай! – дип, колагымны борып куып җибәрде [бай абзый]*. М.Гафури. *Ул мошенник каракларны Казематка ябарбыз*. Т.Гыйззәт. *Мошенник булып чыкты бит Безнең саклык кассасы.* Т.Миңнуллин

МОШЕННИКЛЫК *и.* Мошенник булу; мошенник (*1 мәгъ.*) гамәле; алдакчылык. --- *морзалар, опричниклар, сатраплар – бу мошенниклык мастерлары – халыкларны дошманлаштырып маташалар.* Х.Туфан. *Халык суды, Т.Куликованы мошенниклык өчен дүрт елга иреген мәхрүм итәргә, дигән карар чыгарды.* Ф.Латыйпов

МОШКЫ *и. диал. к.* **киндер**. *Мошкы сугу*

МОШТЫМ *и. фар.* Нинди дә булса танылган затның яшерен җансакчысы, кирәк чакта явызлык эшли алырлык зур физик көчкә ия кеше. *Мафия моштымнары*

МӨӘҖҖӘЛ *хәб. сүз. гар.* Кичектерелгән, соңга калдырылган. *[Хәлил:] Биш йөзе тәмам, биш йөзе мөәҗҗәл!* Г.Исхакый

МӨӘЗЗИН *и. гар.* Намаз вакытларын белдерер өчен азан укучы дин әһеле, азанчы. *Мин шул, шул мөәззинне күрәсем килми.* Г.Исхакый. *Утны яндырмыйча гына мөәззин бабай дәдәйне ислам өммәте кешесе иткән.* М.Әхмәтҗанов. *Мөәззиннәр азан әйтә. Җомга бүген. Манаралар, зиһен җыеп, битен юа...* Ч.Зариф

МӨӘННӘС *и. гар.* **1.** 1) *иск.* Хатын-кыз җенесе. *Кешедән кайчагында шундый бала туа: ул мөзәккәр дә булмый, мөәннәс тә булмый.* Җ.Зәйнуллин. *Борчыла: шушындый түм-түгәрәк чибәр бала әнисе ишегеннән якты дөньяга аяклап килде дә мөәннәс затыннан туа торган башка нәниләр кебек яхшылап елап та тормады.* Р.Сибат

2) *лингв.* Кайбер телләрдә исемнәрнең хатын-кыз җенесенә нисбәт ителеп, төрләнештә аерым парадигма белән характерлана торган грамматик җенес төре

2. *с. мәгъ.* Шул грамматик җенес төренә караган. *Гарәп телендәге мөәннәс исемнәр*

МӨБАРӘК *с. гар.* 1) Кадерле, хөрмәтле; бәрәкәтле. *Мөбарәк рамазан ае якынлаша.* Ш.Камал. *Әй Раббым! Мине мөбарәк урынга урнаштыр. Син бит – урнаштыручыларның иң хәерлесе.* Р.Низамиев

2) Бәхетле; хәерле, котлы. *Син баш бухгалтер янына мөбарәк тәпиләреңә белән үзең менеп әйт әле, ул безгә акча җибәрсен, күп җибәрсен, ул секретарь кешенең сүзен тыңлар, бәлки.* Г.Афзал. *Әй мөбарәк бүген бәйрәмебез, Түптүгәрәк безнең җыеныбыз!..* Р.Миңнуллин. *Бәйрәмнәр – Мөбарәк, Түгәләр – Түгәрәк!* Р.Мәннан

3) Изге, мөкатдәс. *Ухуд сугышында кәферләр мөбарәк йөзен җәрәхәтләп, тешен сындыргач* ---. Ш.Шәрәф. *Тегеләрнең һәркайсы керә дә лып итеп тезләнә, мүкәйләп кенә барып, ишанның мөбарәк кулына авызын тидереп ала, акчасын чыгарып сала һәм, ишанга ияреп дога кыла да, артын-артын гына ишеккә таба чигенә.* Ә.Еники

◊ **Мөбарәк булсын** Котлы булсын. *Кайтуыгыз мөбарәк булсын, танышыйк, алайса. Минем исемем Мурат.* Н.Әхмәдиев. *Елмаюлар балкып торсын, Бәйрәм мөбарәк булсын!* Ш.Галиев

МӨБТӘЛЯ *с. гар. иск.* Дучар булучы, бәхетсезлеккә эләккән. --- *Зур мөхәррирнең бу әсәре, хөррият хәрәкәтләре вакытындарак язылган бер әсәр булганлыктан, соңгы бишенче пәрдәсендә беркадәр бер тарафлылыкка мөбтәлядер.* Г.Исхакый

МӨБТӘЛӘ́ БУЛУ *ф. иск.* Дучар булу. *Бара торгач Мансур мулланың үзенә һәм бәддога төшеп, ахыр гомерендә зина вә хәмер белән мөбтәля булып, бәгъзе эшләр өчен хибескә кереп, шунда һәлак булгандыр.* К.Насыйри

МӨГӘЕН *мод. сүз. гар.* Нәрсә турында булса чамалап, фараз итеп сөйләгәндә кулланыла: ахрысы, булса кирәк, шулайрак кебек күренә. *Мөгаен, энҗе җыючыларны алып кайталардыр.* И.Хуҗин. *Ә менә айга менә торган баскычны кайчан да бер уйлап табарлар, мөгаен.* Р.Низамиев. *Сезнең хөрмәткә лаеклы кеше икәнегезне, мөгаен, югары урындагылар да беләдер, ә шулай да иң кирәк чакта сезне ялгыз калдырдылар.* Р.Мирхәйдәров

МӨГАЛЛИМ *и. гар.* Укытучы; гыйлем бирүче. *Очрашуның көтмәгәндә генә шундый нәтиҗә белән тәмамлануыннан күңеле нечкәргән мөгаллимнәр, оялган карашларын идәнгә юнәлтеп, яшьләрен сөрттеләр.* А.Хәлим. *Җиңел сөякле, җитеш кеше булып чыкты яңа мөгаллим.* Т.Мөбарәков. *Буадан Казанга кайтып төшү белән, Шиһаб атлы мөгаллим «Болгар» номерларының берсенә урнаша.* Р.Низамиев

МӨГАЛЛИМӘ *и. гар.* Хатын-кыз мөгаллим. *Айсылу, мөгаен, мөгаллимә булыр.* Г.Якупова. *Гөлҗиһан мөгаллимә көндез дәресләр бирү белән генә чикләнмәгән.* М.Әхмәтҗанов. *Мин – яшь мөгаллимә, яңа гына педучилище тәмамлап, Мамадыш шәһәрендә эшлим.* Э.Шәрифуллина

МӨГАЛЛИМӘЛЕК *и.* Мөгаллимә булу, мөгаллимә вазифасы, хезмәте. *Өч еллык мөгаллимәлек тормышымда сезнең кебек мөгаллимне мин беренче күрәм!* Г.Исхакый. *Аның әбисенең әнисе – карт әбисе – узган гасыр башында Урта Азиягә мөгаллимәләккә чыгып киткән яшь татар кызы – шунда бер үзбәккә кияүгә чыгып төпләнеп калган Казан арты татары.* З.Хөсният. *Остабикәсендә мөгаллимәлек шөһрәте күренеп үк тора.* С.Поварисов

МӨГАЛЛИМЛЕК *и.* Мөгаллим булу; мөгаллим вазифасы, хезмәте. *Себердә мин мәктәп ачмасам, минем мөгаллимлегемә сигез ел тулмаса, минем бертөрле кыйммәтем булмас идемени?..* Г.Исхакый. *Ниһаять, әтисенең Мөгаллим дигән исемен аклап, мөгаллимлек итүгә күбрәк вакытын сарыф итү, үз шәкертләрен тәрбияләү, яшь галимнәрне үстерү мөмкинлеге, кыскасы, фәнгә һәм фикер алгарышына хезмәт итү мөмкинлеге артты...* М.Вәлиев. *Бай фәнни һәм педагогик тәҗрибә туплаган галим [Р.Фәхретдин] үзенең мөгаллимлек һөнәрен яңартып җибәрә* ---. Ә.Хәйри

МӨГАМӘЛӘ *и. гар.* 1) Халык белән эш күрү, башкаларга карата үз-үзен

тоту. *Анасын да, атасын да, араларындагы мөгамәлә вә мөнәсәбәтне дә яхшы аңлый.* Г.Ибраһимов. *Ярый әле бәхетемә күрә авылда туып-үскәнмен, шуңа күрә өлкән яшьтәге кешеләрнең сөйләшүен, хәрәкәтен, үзара мөгамәләсен каныма сеңдергән булганмын.* Ә.Шакиров

2) Кешеләрнең бер-берсенә карата мөнәсәбәте; бер-берсе белән аралашуы. *Театрда мөгамәлә гаиләдәгедәй искиткеч җылы.* Д.Гыймранова. *Нәсимәгә карата да авыл халкының мөгамәләсе чак кына салкынайды, моны ул әлегә үзе генә сизә, әмма укытучы башың белән андый карашны тою бик читен.* З.Хәким

МӨГӘРИЧ *и. сөйл. к.* **мәгәрич**. *Майор, тикшерүчегә икенче бер кәгазьне тоттырып, гадәтенчә шаяртып алды: – Мөгәричен дә онытмассың дип уйлыйм.* М.Насыйбуллин. *Давай, чыгар мөгәричне, мин сиңа Миңнулла булганың өчен ат бирмәдем, Фәнәви өчен...* И.Юзеев. *Ярый, Зәки дус, мөгәриче булса, эчешергә кеше табарбыз.* Т.Миңнуллин

МӨГӘРИЧЛЕК *и. сөйл. к.* **мәгәричлек**. *Күрше авылгача ияреп килгән кылычлы атлы казак Сәмигулла, аңардан тәки бер мөгәричлек акча кысып, төн авызына кереп югалды.* Ф.Яхин

МӨГЕЗ *и.* **1.** 1) Кайбер хайваннарның башында була торган сөякчел каты үсенте. *Ул аның каршына башын сузып килгән сыерның мөгез астын кашыды.* Ә.Еники. *Ләкин Ходай сөзгәк сыерга мөгез бирми интектерә.* Н.Әхмәдиев. *Мөгезе күлмәк эченә кереп калып, ычкындыра алмый, җиргә шап-шап сугып, сыер әнине урам буйлап өстерәп алып китә.* Н.Мөхибуллин

2) Кайбер кош, бөҗәк һ.б.ш.ларның башларында тырпаеп торган үсенте. *Безнең тугай күлләренә кыр үрдәкләре килә, сазлыклырак түмгәкле урыннарга тәкәрлекләр килә – ефәк «мөгезле», нечкә тәпиле бик нәфис кош.* Ә.Еники

3) Хайваннар башындагы сөякчел каты үсентеләрнең көнкүреш кирәк-яраклары яки сәнгать әсәрләре ясаганда кулланыла торган төрләре

4) *муз.* Очы киңәебрәк килгән кәкре торба формасындагы музыка уен кораллы яки сигнал бирә торган җайланма; *русчасы:* **рожок**. *Аны җентекләп өйрәнүче галим В.Радлов сорнай, мөгез, бырсы, нәкара, кубыз, тумбыр кебек инструментларга аңлатма бирә.* И.Гафаров. *Егет кулындагы мөгезне авызына куеп: «Тыңлагыз, тыңлагыз, табигать патшасының фәрманы бар!» – ди.* Ф.Зарипова. *Мәсәлән, көпшә курай, нугай курай, куш курай, күч курай, камыл курай, сорнай, көтүче сорнае, мөгез, музикән, таш сыбызгы, бырсы, кыңгырау, дөмбри һ.б. уен кораллары булган.* М.Макаров

5) *күч.* Мөгезгә (*1 мәгъ.*) охшаш, мөгезне хәтерләтә торган әйбер. *Ләкин шул чак тукталышка, озын мөгезләрен тырпайтып, бер ялкау троллейбус килеп туктады һәм, егетебезне үз куенына тартып алып, ыңгыраша-ыңгыраша күздән югалды.* Р.Габделхакова. – *Синең китәсеңне ишеттем дә олы юлга очтым гына, – диде егет, кыр якка мөгезен тырпайтып торган мотоциклына ымлап.* Ф.Җамалетдинова. *Үзара ызгышып-янашып күпмедер тартышканнан соң, ниһаять, патрон тутырылган өч «мөгезе» белән бер автомат һәм илле мең сум акчага килешеп, юлны ачарга булдылар.* Р.Мирхәйдәров

6) *күч.* Бәрелү, сугылудан маңгайга, башка чыккан шеш. *Гәрәй абзый икенче мөгезен дә уып куйды...* А.Фәлах

7) *күч.* Берәр кыек эш-гамәлнең көтелмәгән нәтиҗәсе. *Бу «мөгез» соңрак аның тормышында зур үзгәрешләр китереп чыгарырга сәбәпче булды.* Р.Сәгъди. *Үзе чыгарган мөгез.* З.Дәүләтов

2. *с. мәгъ.* 1) Тере организмнарда: яклау функциясен үти торган сөякчел тукымадан гыйбарәт (өлеш, әгъза тур). *Кәлтәнең тиресе мөгез катлау белән капланган.* Зоология

2) Хайваннарның башында була торган каты сөякчел үсентедән эшләнгән. *Куеныннан мөгез бокал алып, Чиста спирт сала туп-тулы, Печән төйи атка ике Батыр, Онытыла аяк юклыгы.* Р.Батталов. *Дары һәм пулялар махсус мөгез савытта – сеңрәндә йөртелгән.* Р.Әхмәтьянов

◊ **Мөгезен сындыру** Кемне дә булса тынычландыру, ярсуын басу яки кимсетеп буйсындыру. **Мөгез кую** Хыянәт итү; ир яки хатын өстеннән йөрү. *Кайтып чишенде дә әнигә: – Син миңа тагын бер мөгез куйдың, әйеме? – диде.* Э.Шәрифуллина. *Фәлән ханым иренә мөгез куймыймы?* Г.Әпсәләмов. **Мөгез үсмәс** Берни булмас, түзәр. *Балыкка бармый калганнан гына иптәшләреңнең дә маңгаена мөгез үсмәс.* В.Нуруллин. **Мөгез чыгару** Юк-бар нәрсәләр уйлап чыгару яки кирәкмәгән нәрсә эшләп ташлау. – *Хаҗиәхмәт бакчасы бик ерак, умарталарың быелга иске урында торсын, – диде әти. – Гел мөгез чыгарырга гына йөрисең.* Ф.Яруллин. *Адым саен бер мөгез чыгара иде ул.* Г.Гыйльманов. **Мөгез чыгу** 1) Бәрелеп, сугылып, егылып яки башка сәбәптән маңгай шешеп чыгу; 2) *шаярт.* Зур дәрәҗәгә ирешү; 3) Ниндидер кызык, үзенчәлекле хәл булу. *Марсель катнашкан җирдә мәзәк булмаса да, мөгез чыкмый калмас.* Т.Галиуллин. *Мин юкта берәр мөгез чыгып куймаса ярый инде...* В.Нуруллин

МӨГЕЗБАЙ *и. зоол. к.* **мөгезләч**

МӨГЕЗБОРЫН *и. зоол.* 1) Тактояклылар семьялыгыннан Африка һәм Көньяк-Көнчыгыш Азиядә яши торган, танавы өстендә бер яки ике мөгезе булган коры җир хайваны; кәркәдән; *русчасы*: **носорог**. *Маңгаенда мөгезборын сөзгән җәрәхәт эзе ярылып ята икән.* Р.Сәгъди. *Алар ул мәгарәгә йонлач мамонтлар, мөгезборын, кыргый ат, хәтта озын кеше рәсемнәре дә ясап калдырганнар...* Ф.Бәйрәмова. *Мөгезенә, Мөгезборын Борынына Килеп кунган Озынборын.* Р.Миңнуллин

2) Пластинкамыеклылар семьялыгыннан коңгырт-көрән төстәге, ата затларның маңгаенда артка бөгелгән озын мөгезе, аркасының алгы өлешендә өч тешле аркылы калкулыгы булган коңгыз; *русчасы*: **жук-носорог**

3) Мөгезборын кошлар семьялыгыннан аска таба бөгелеп торган озын томшыклы, Африканың дымлы тропик урманнарында, Тын һәм Һинд океан утрауларында яшәүче зур кош

МӨГЕЗКОЙРЫК *и. зоол.* Элпәканатлылар семьялыгыннан ана затларның корсагы астында койрыкны

хәтерләткән зур һәм бик каты күкәйсалгычы булган бөҗәк

МӨГЕЗЛӘНҮ *ф.* 1) Мөгезгә әйләнү, мөгезсыман тәңкәләр белән капланып, кату

2) Мөгезгә охшап тору

Мөгезләнә башлау Мөгезләнү билгеләре күренү

МӨГЕЗЛӘЧ *и. зоол.* 1) Мөгезле коңгызлар семьялыгыннан гәүдәсе кара, өске канатлары һәм казналары көрән төстәге, ата затларның өске казналары болан мөгезенә охшаган иң эре коңгыз; болан коңгыз; *русчасы*: **жук-олень, рогач**

2) *бот.* Әвернәчәчәклеләр семьялыгыннан ачык тау битләрендә үсә торган ачык сары чәчәкле ике һәм күпьеллык үсемлек

МӨГЕЗЛЕ *с.* 1) Мөгезе булган. *– Ә монысы – мөгезле әкәм-төкәм, безнең бакча артындагы яссы таш тирәсенә җыела алар нишләптер, – дип, сүзне бик тиз ялгап китте Мәдинә.* Г.Якупова. *Ун миллионнарча куй, мөгезле эре хайван асраган Казахстанның башкаласы Алма-Ата кибетләрендә ит юк, аның өчен казах дуслар да Мәскәүгә оча икән...* М.Әхмәтҗанов. *Кәҗә – мөгезле хайван. Алар дәррәү килеп, мөгезләрен терәп, түгәрәкләнеп басалар.* М.Хәбибуллин

2) *күч.* Гадәти булмаган, үзенчәлекле, аерылып торган. *Кискәнгә карап «мөгез»леләр үсми тормый.* Ш.Галиев. *Офицерлыкка мөгезле кешеләр генә укыймыни?* Ф.Яруллин. *Фәнзия дә җавапсыз калмады: – Һе, сиңа ничек ир табасың, тегенди-мондый гына ярамый, сиңа бит мөгезле булсын.* Казан утлары

3) *күч.* Хатыны хыянәт иткән, хатыны тарафыннан алданган (ир кеше тур.). *Һәр ир-ат гомерендә бер булса да мөгезле була торгандыр.* Т.Галиуллин. *Бозау түгел, ә мөгезле ир!* Р.Камал

◊ **Мөгезле түгел** Башкалар кебек үк, артык җире юк, әллә кем түгел. *Бу фани дөньяда берәү дә мөгезле түгел.* М.Мәһдиев. *Мөгезле кешеләр түгел инде, менә синең белән минем кебек кешеләр ала.* Г.Афзал. *Мөгезле түгел икәнен үз күзләре белән күргәч, күңелләре төшкәндәй булды. Язучы дигәннәре гап-гади икән: елмая, шаяра, сөйләшә ---.* К.Латыйп

МӨГЕЗЛЕ́ ОРЛЫК *и. бот.* Казаякчалар семьялыгыннан вак кына сары чәчәк ата торган үләнчел үсемлек; *русчасы*: **рогоглавник**

МӨГЕЗСЕЗ *с.* 1) Мөгезе булмаган. *Читтәрәк кечерәк гәүдәле мөгезсез ана поши бу көрәшнең ни белән тәмамлануын көтә.* И.Хуҗин // Мүкләк. *Борын-борын заманда, кәҗәләр сакалсыз, песиләр мыексыз, үгезләр мөгезсез, маэмайлар койрыксыз чакта яшәгән, ди, бер карт белән карчык.* Ф.Яруллин. *Туры юлдан көтүлеккә ашыкканда, читтәге көзлеккә тайпылган мөгезсез сыерларның артыннан йөгерми Нотфулла, аларны өрәңге саплы, алтыдан үрелгән, кыл койрыклы, биш колачлы чыбыркы куып тота, тәнгә тигән җирендә шартлый.* К.Кәримов

2) *күч.* Бернәрсәне дә абайламыйча йөрүче, тупас, тәртипсез хәрәкәтле, саксыз кыланучы, тыйнаксыз кешегә карата әйтелә. *Иртәгесен моның бүлмәсенә килеп керсәм, ул мөгезсез шофёрга чара күрергә кирәклеге турында телефоннан район эчке эшләр бүлеге начальнигы полковник Равил Гыйльмановка күрсәтмә биреп ята.* Т.Нәҗмиев

◊ **Мөгезсез сыер кебек** 1) Юлдагы кешеләрне, әйберләрне абайламыйча, игътибарга алмыйча, бәрелеп-сугылып баручы кешегә карата әйтелә. *Теге чатта чак кына «Вольво»га бәрелми калдың, монысында мөгезсез сыер шикелле кызыл утка килеп кердең.* Ә.Сафиуллин. *Вак атласа да, бик җәһәт барган Бибинурның итәгенә тагылганнар да мөгезсез сыер кебек баралар да баралар.* А.Гыйләҗев; 2) Гомумән әрсез, мәгънәсез, әдәпсез кешегә карата кимсетеп әйтелә. *Мөгезсез сыерлар сыман, медицина институтына барып кермәкче булдылар.* Р.Мулланурова. **Мөгезсез тәкә кебек** *к.* **мөгезсез сыер кебек**. *Оятсыз егет мөгезсез тәкә кебек.* Әйтем

МӨГЕЗТЕШ *и. зоол.* Мөгезтешле балыклар семьялыгыннан саңаклары белән дә, үпкәсе белән дә сулый торган җирәнсу көрән яки күксел соры төсле эре төче су балыгы; *русчасы*: **рогозуб**

МӨГЕЗЧЕК *и.* Кайбер бөҗәк, җирсу хайваны һ.б.ларның төрле җирләрендә була торган үсенте. *Кичке күбәләкләрнең гусеницалары төксез, һәм еш кына тәненең арткы очында мөгезчек була, ә күпчелек көндезге күбәләкләр гусеницаларының тәне куе төк белән капланган.* Татарстанның үсемлекләр һәм хайваннар дөньясы. *Панцирьда ареолалардан башка төрле үсентеләр барлыкка килә: энәләр, мөгезчекләр.* Ботаника

МӨГЕЗЧЕЛ *с.* Мөгезсыман, сыйфатлары мөгезнеке кебек булган. *Кәлтәнең тиресе өске яктан мөгезчел тәңкәләр, чәнечкеләр һәм калканнар белән капланган.* Хайваннар дөньясы. *Африка тәвә кошының күкрәгендә мөгезчел сөяле бар.* Кошлар

МӨГЕЗЬЯФРАК *и. бот.* Мөгезьяфракчалар семьялыгыннан вак чәчәкле, тамырсыз, су өстендә йөзеп йөри торган күпьеллык үләнчел үсемлек; су кычытканы; **роголистник**

МӨГЕЗЬЯФРА́КЧАЛАР *и. күпл. бот.* Сәнәксыман аерчалы, каты чәнечкеле тешле яфраклы, куентыкка берләшкән чәчәкле, чикләвекчектән гыйбарәт җимешле икеөлешле үсемлекләрне берләштерә торган семьялык

МӨГЕРДӘ́Ү *ф. к.* **мөгрәү**. *Шәл астыннан малайның сыкрап мөгердәгәне генә ишетелде.* А.Гыйләҗев. *[Галимә:] Әбәү! Кәҗә тәкәсе төсле мөгерди.* Ш.Камал

МӨГРӘ́Ү *ф.* 1) Сыер, буйвол, сарык кебек хайваннар кычкыруы турында. *Елга буеннан исә балыкчы картның ишкәк чупылдатканы, авылдан чыгып барган сыер-сарыкларның мөгрәү авазлары ишетелә...* Р.Низамиев. *Кайдадыр этләр өрде, сыерлар мөгрәде, дөнья тәшвишле, хәвефле авазлар белән тулды.* А.Гыйләҗев

2) *күч. кимс.* Сузып-сузып, аңлаешсыз авазлар чыгарып калын тавыш белән сөйләү. *Мин әйтергә икеләнеп торганда, Фәтхи: – Здоров, – дип мөгрәде.* А.Таһиров. *– Ыһы!.. – дип мөгрәде Бөкерле рәисе.* Ф.Баттал

Мөгрәп алу Аз гына мөгрәү. *Кисәк Маратның беләгеннән эләктереп алды да итләч иреннәрен битенә терәп*

диярлек мөгрәп алды: – Кем таныштырды соң сезләрне? Ф.Сафин. *--- шәрә Леонның муенына кунган миннек яфрагын алып ташлап, «Туган авылым», «Күбәләк» җырларын мөгрәп ала иде [Радмир].* Х.Мөдәррисова

Мөгрәп җибәрү Мөгри башлау. *Авылга килеп керүгә бозау бар көченә мөгрәп җибәргән.* Әкият

Мөгрәп йөрү Озак вакыт дәвамында мөгрәү

Мөгрәп кую Бер тапкыр мөгрәү. *Монда һәммә җан иясе үз гамендә... Көр сыерның мөгрәп куюы...* М.Гали. *Ни гажәп, аларга барча этләр кушылды, абзарда сыер мөгрәп куйды, саташкан әтәч кычкырып җибәрде.* М.Әмирханов. *Аңарга [чыбыркы тавышына] җавап итеп, «нигә рәнҗетәсең инде» дигәндәй, сузып-сузып, кемнеңдер сыеры мөгрәп куйды.* Р.Мөхәммәдиев

Мөгрәп тору Озак вакыт дәвамында мөгрәү. *Ә сыерларыңны ашаттым. Юклыгыңны белгертеп мөгрәп тормасыннар...* Ф.Җамалетдинова

Мөгри башлау Мөгрәргә тотыну

МӨДАФӘГА *и. гар. иск.* Саклану, каршылык, каршы тору. *Шуның белән съезддагы тудыру көчен һәрвакыт мөдафәга хәлендә булдырырга муафикъ булдылар.* Г.Исхакый

МӨДАФӘГА́ КЫЛУ *ф. иск.* Саклану, каршылык күрсәтү, үзен үзе саклау. *Бүре килә, Үгез кыйла мөдафәга, Бүрене сөзә һаман, читкә кага.* М.Гафури

МӨДӘРРИС *и. гар.* Мәдрәсәдә өлкән укытучы. *Шул заманның дин галимнәре һәм мөдәррисләр дини мәсьәләләрне чишкәндә фәнни белемне инкяр итсәләр, ул [Мәрҗани] дин белән фәннең тыныч янәшә яши алуын исбатларга омтыла.* А.Юзиев. *[Садретдин] 1885 елда имам хатыйб, мөдәррис дәрәҗәсе алып, Петербург мәчетендә эшли башлый.* Т.Биктимерова. *Мәгълүм булганча, Г.Баруди атаклы Мөхәммәдия мәдрәсәсен оештырып, шунда 35 елга якын мөдәррис булган*. Казан утлары

МӨДӘРРИСЛЕК *и.* Мөдәррис булу; мөдәррис вазифасы, хезмәте. *Шулай да Мөбахис мәзингә тыкшынырга аның хакы бар, Троицк мәдрәсәсендә мөдәррислек вазифасын башкарган чагыннан бирле белә ул аны.* С.Поварисов. *Әмма Бохара гыйлеменә ия, киң карашлы Хөсәен хәзрәт имамлык вә мөдәррислек белән генә канәгатьләнмәгән.* Р.Әмирханов. *– Өргәнечтә шаһ мәдрәсәсендә мөдәррислек итә [Гали угълан], – диде әмир Хажи һаман бер ноктага караган рәвештә.* М.Хәбибуллин

МӨДДӘТ *и. гар. кит.* Вакыт, срок, ара; вакыт аралыгы. *Шул мөддәт эчендә ул милли-мәдәни мохтарият органнарының гамәли эшчәнлегенә караган бөтен мәсьәләләр буенча карарлар кабул итә.* Г.Исхакый. *Ватан сугышы башлану сәбәпле, Ә.Маликовның гаскәри хезмәт мөддәте җиде елга сузыла.* Әдипләребез

МӨДДӘТЛЕ *с. кит.* Мөддәте билгеләнгән; ниндидер срок белән чикләнгән; сроклы. *Мөддәтле эшнең шундый яклары бар инде аның, нишләтеп тә булмый*. Казан утлары. *Безгә гадел һәм озын мөддәтле солых кирәк.* Ватаным Татарстан

МӨДДӘТСЕЗ *с. кит.* Вакыты чикләнмәгән; мөддәте күрсәтелмәгән, сроксыз. *Ул мине мөддәтсез бер асрау бала итеп өенә алып кайткан.* Г.Тукай

МӨДИР *и. гар.* Нинди дә булса оешма, учреждение, бүлек белән идарә итүче. *Ферма мөдире аксак Хәйри кырыс булса да, хатын-кызның иртәкичен яртышар литр сөт алып кайтуына каршы килмәде.* Р.Шәфигуллин. *Мөдир алдында абруе зур булу өстенә, соклангыч чибәрлегенә дә аркалана булыр*. Х.Камалов. *Ә бит тавыш бирәнитә калса, кафедра мөдире, үз ягы теләгән сан ким чыкса да, гаепне махсус рәвештә Рафиягә ташлаган булыр иде*. Р.Рахман

МӨДИРЛЕК *и.* Мөдир булу, мөдир вазифасы. *Ләкин мөдирлеккә генә һич риза түгел, ишегенә бик затлы итеп «Директор Гибралтар Мансурович Кәшәфетдинов» дип яздырган.* Ф.Баттал. *Зифага мөдирлек өчен – йөз, дәресләр өчен биш йөз тәңкә тирәсе түли башладылар.* В.Имамов. *Мөдирлек кулыңнан ычкынгач, синең нәрсәдер җимерәсеңне, тар-мар итәсеңне көтә идем.* А.Гыйләҗев

МӨЕШ *и. диал.* Почмак. *Дүрт мөеш, ике теш, Түр башыннан төш.* Табышмак. *Нишләп шул чаклы сурәт асрыйлар? Җитмәсә кыйбла мөешенә куйганнар үзләрен.* К.Нәҗми. *Шундый уйлар белән ул урамнар мөешендә утырган почтамтны килеп тапты.* А.Хәлим

МӨҖАВИР *и. гар.* 1) Берәр изгенең, әүлияның төрбәсен яки каберен карап, тәртиптә тотып, шуның янындагы хөҗрәдә яки мәчеттә яшәүче кеше. *Ягъни бу мөҗавир бер байдан Екатерина патшабикә бастырган йөзлек акча өмет итеп, бары тик егерме бишне генә ала алган икән дә, шуңа канәгатьсез булып, садака бирүчене хурлап йөри икән*. Р.Батулла. *Берара аның каберендә шагыйрь Мөхәммәдьяр да мөҗавир булып тора.* Х.Миңнегулов

2) Туган җиреннән, йортыннан ваз кичеп, вакытын Мәккә һәм Мәдинә шәһәрләрендә гыйбадәт белән үткәрүче

МӨҖАҺИД *и. гар.* Җиһадта катнашучы; изге җирләр өчен сугышучы кеше. *Мөҗаһидләр урам-базарлар буйлап арлы-бирле йөреп тора, дип чамалыйлардыр.* Безнең гәҗит

МӨЗАКӘРӘ *и. гар. иск.* Киңәш; фикер алышу. *--- «Сәмруг кош» системасында зур һава пароходлары йөртү турысында кызу-кызу мөзакәрәләр бара иде...* Ш.Камал. *Хатыннар мәсьәләсе мөзакәрәгә куелгач, миңа кадәр сөйләгән әфәнделәрнең барысы да диярлек бу мәсьәләгә шәригать ноктаи назарыннан карарга керештеләр.* А.Мәхмүтова

МӨЗАКӘРӘ́ ИТҮ *ф.* Фикер алышу, киңәшү. *Думага кемне сайлаячаклары вә кемне сайларга тиеш идекене мөзакәрә итәләр иде.* Г.Камал

МӨЗАКӘРӘ́ КЫЛУ *ф. к.* **мөзакәрә итү**. *Моның хакында мөзакәрә кылышырга кирәк.* Г.Исхакый. *Атаклы Мөхәммәдьяр, Казан тикле Казан ханнарын әсәрләре белән хисләндергән Мөхәммәдьяр, ни өчен дуадак бер үсмер белән шулай мөзакәрә кыла?* Р.Батулла

МӨЗӘККӘР *и. гар.* **1.** 1) Ир-ат җенесе

2) *лингв.* Кайбер телләрдә исемнәрнең ир-ат җенесенә нисбәт ителеп, төрләнештә аерым парадигма белән характерлана торган грамматик җенес төре

2. *с. мәгъ.* Шул грамматик җенес төренә караган. *Мөзәккәр сүзләр*

МӨКАДДИМӘ *и. гар.* Әсәрнең кереш сүзе, сүз башы. *Шунысын да искәртик: элеккеге әсәрләрнең күпчелегеннән аермалы буларак, «Котадгу белек»нең кереше (мөкаддимәсе), төп өлеше һәм бетеме (хатимәсе) шартлы рәвештә генә бер-берсеннән аерыла.* Х.Миңнегулов. *Әлеге истәлекләргә язган кереш сүзендә (мөкаддимәдә) ул болай ди ---.* Ф.Галимуллин

МӨКАТДӘС *с. гар.* Изге; хөрмәт ителгән, мөһим; кагылгысыз булган. *Ә Күк ул – Раббыбыз галәмнәр белән идарә итә торган бөек һәм серле, илаһи һәм мөкатдәс көч.* Т.Галиуллин. *Я, шушы мөкатдәс сүзләр, әткәңәнкәңне зурлаган бу юлларның кемгә ни зыяны булды икән?* Р.Низамиев. *Үткензирәк каләме очыннан тамган мөкатдәс фикерле Миргазыян Юныснының сугa эчкерсез табынуы әрсез күзләрдән тирән яшерелгән мәҗүси горурлыгы иде.* М.Галиев

МӨКАТДӘСЛЕК *и.* Изгелек. *Аларның бер-берсеннән яшерергә гамәлләре юк кебек, алар беренче һәм соңгы мәхәббәтләре турында бер-берсенә авырлык – күңел китеклеге китермәячәген аңлап сөйләделәр. Мөкатдәслек иде монысы!* М.Хуҗин

МӨКӘЛЛӘФ *и. гар.* Нәрсәне дә булса эшләргә, үтәргә мәҗбүр булган; җаваплы, вазифалы. *Рәсүлүллаһ хәзрәтләре бөтен әһле ислам арасында гыйлем таралуны тели һәм һәрбер мөкәлләф үз кирәген үзе белергә тиеш икәнлеген аңлата иде.* Р.Фәхретдин

МӨКӘММӘЛ *с. гар. кит.* **1.** Камил, тулы; кимчелексез. *Җилкәсенә ташып төшкән куе кара чәчле, буйсыны, бите-йөзе белән мөкәммәл чибәр туташ Зәйнәб – Казан дәүләт университетының медицина факультеты студенты.* Р.Низамиев. *Ханбикәнең күркәм килеш-килбәте дә, мөкәммәл буй-сыны да, чибәрлеге дә күзенә чалынмады.* М.Әмирханов

2. *рәв. мәгъ.* Тулы итеп, камил рәвештә. *Матур иренле кечкенә авызына ялтырап торган ап-ак тешләрен, алсу тырнаклы килешле бармакларын – барысын да тигез, мөкәммәл итеп биргән иде Санияга табигать.* А.Гыйләҗев. *Әниебез аның мөкәммәл рәвештә инглиз, немец, гарәп һәм фарсы телләрен белүен ассызыклый торган иде.* Шәһри Казан

3. *хәб. сүз.* Камил, җитешкән, тулы булу турында. *Ашамак, эчмәк – мөкәммәл, малы бик күп.* Г.Исхакый. *Бибиҗамал апаның күңеле хуш, кәефе мөкәммәл иде.* Ш.Хөсәенов

МӨКӘММӘЛЛӘШТЕРҮ *ф.* Камилләштерү. *Әмма үлеме шушы чиксезлекне тагын да мөкәммәлләштерә.* Ф.Яхин. *Бар яктан да мөкәммәлләштереп булмыйдыр ул кешеләрне, дип уфтанды Нурулла.* Казан утлары

МӨКӘММӘЛЛӘШҮ *ф.* Камилләшү. *Соңгы басмалар ярыйсы ук мөкәммәлләшкән, дигән фикер кала.* Мирас

Мөкәммәлләшә бару Торган саен ныграк мөкәммәлләшү

Мөкәммәлләшә башлау Мөкәммәллек билгеләре күренү, сизелү

МӨКӘММӘЛЛЕК *и.* Мөкәммәл булу, камил булу, тулылык. *Тагын да кызыгы, рәхәте: аннары инде башны яктайта төшеп, көзгедән үз-үзеңә карап, төс-кыяфәтеңне баялисең, тышкы мөкәммәллегеңә күңелдә эчке бер ышаныч ныгытасың.* Р.Низамиев. *Олуг фикер, мөкәммәллек җиңел тумыйдыр шул!* Р.Әхмәтҗан

МӨКЕ́РТ-МӨКЕРТ *иярт.* Ашыкмыйча гына нәрсә дә булса чәйнәгәндә, бер ритмга кимергәндә ишетелә торган тавышны белдерә (гадәттә хайваннар тур.); кетер-кетер. *Ята торгач, аранан ап-ачык булып атның башак ашавы колакка чалынды: «Мөкерт-мөкерт, мөкерт-мөкерт...»* Г.Бәширов. *Ләкин бердәнбер транспорт – ат – туарулы, знай, чирәм кимерә, мөкерт-мөкерт китерә, башында йөгәне дә юк, янына килергә куркырсың.* М.Мәһдиев

МӨКИББӘН *рәв. гар.* **1.** Чиксез, тулаем, чамасыз артык бирелеп, оныгылып, сукырларча (мавыгу, табыну, ияртү, бирелү тур.). *Аннары өстәп куйды: – Синең мөкиббән тыңлап утыруыңны карап тору бик күңелле булды миңа...* Ф.Баттал. *Мөкиббән елмаюы, күз карашларының ягымлылыгы, сүзләренең татлылыгы аны күркәм сыйфатлы бөек ана итеп таныта иде.* С.Поварисов

2. *хәб. сүз.* Кемгә яки нәрсәгәдер артык бирелгән, кем яки нәрсә беләндер чиксез мавыккан булу турында. *Бигрәк тә әти мөкиббән булган инде минем тууымнан.* Ә.Рәшит. *Шагыйрь үзе дә авылга бик тә мөкиббән һәм бик тә рәхмәтле.* Р.Миңнуллин. *Маржа чибәрләренә мөкиббән иде ул.* Р.Әмирханов

◊ **Мөкиббән китү** Берәр эшкә яки кешегә чиксез бирелү, шулар белән бик мавыгу. *Фәйзиев – театрал я футбол җанатарлары кебек туйларга мөкиббән китүчеләрдән, шуңа да тирә-яктагы бер генә туйны да калдырмый иде.* Р.Мирхәйдәров. *Күпне күргән, инде искерә төшкән пианиногa, андагы шәмдәлгә, яшел бәрхет өстендә яткан дирижёр таякчыгына мөкиббән китеп карады.* Р.Низамиев. *Әткәсе, бер хәбәрсез, комиссар Усмановка мөкиббән китеп, һаман ул сөйләгәннәрне тыңлап тора микән мәчет янында?..* Ф.Сафин

МӨЛАЕМ *с. гар.* Ягымлы, күркәм, сөйкемле. *Хәер, аның әнкәсе шундый мөлаем кеше, ул һәрвакыт елмайган төсле.* З.Хәким. *Өстәл башында чәчәкле халаттан китап укып утыручы, кара чәч толымнарын иңбашына үреп салган мөлаем, сөйкемле кызны күргәч, яучы әби аһ итте.* С.Шәрипов

МӨЛАЕМЛАНУ *ф.* Ягымлылану, сөйкемләнү. *Ул хисләнгән иде һәм шул сәбәпле тагын да мөлаемланып, күркәмләнеп киткәндәй тоелды.* Н.Әхмәдиев. *[Хәдичәнең] күзләре очкынланды, йөзе мөлаемланды.* М.Хәсәнов

Мөлаемлана бару Торган саен ныграк мөлаемлану. *Бала тапкан саен юаная, калыная барды, аның саен холкы әйбәтләнә, мөлаемлана барды.* М.Мәһдиев

Мөлаемланып китү Тагын да бераз мөлаемлану. *Егет эре ак тешләрен күрсәтеп елмайды, аның гарәпләргә охшаган каракучкыл озынча йөзе бердәм яктырып, мөлаемланып китте.* М.Маликова

МӨЛАЕМЛЫК *и.* Мөлаем булу. *Карашыннан сылу мөлаемлык бөркелеп*

торган бу кыз-хатын, ак халат киеп куйса да, шәфкать туташы түгел иде. Э.Шәрифуллина. *Тагын шунысы да бар: Габдулла абыйның тышкы кыяфәте Ленинныкына бик якын: зур баш, җәйнак гәүдә, кысылыбрак торган күзләр, борыны, эчтән бәреп торган мөлаемлыгы аны Ленин роленда кабул итәргә бик нык ярдәм итә.* Ә.Шакир. *Елмайганда, ниндидер мөлаемлык биреп, ошбу алтын теш тә елмая.* А.Хәлим

МӨЛӘММӘ́ГЪ *и. гар.* Шәрык мөселман халыкларында шигъри юллар яки аерым очракларда мисраглар төрле телләр катнашында (гарәп, фарсы, татар һ.б.) иҗат ителгән шигырь

МӨЛДЕРӘМӘ *с.* **1.** Бик нык тулган, ташып китәрлек булып тулган. *Мөлдерәмә андый мәхәббәт Сәйдәшнең күңеленнән җыр, моң, музыка булып таша иде.* Р.Низамиев. *Күңелем тулы мөлдерәмә сагыш килеш мин Казанга китеп бардым.* Р.Габделхакова. *Сынтимер кәрәздәге мөлдерәмә балны, балкашык очына гына алып, иреннәренә яга.* Г.Якупова

2. *рәв. мәгъ.* Бик нык, ташырлык булып. *[Сажидә] Иренә текәлеп: – Өнемдәге хыялларым матур төш булып кереп, куанычым күңелем касәсеннән мөлдерәмә ташып торган чакта, ничек әле син, җаныкаем, таралып йоклап ятасың? – дип пышылдады.* Г.Галиева. *Кызның шундук күзләре яшь белән мөлдерәмә булды.* И.Хуҗин. *Шуның ише хәлләр өчен балчыктан өеп ясалган саклагыч мөлдерәмә тулган!* Казан утлары

МӨЛДЕРӘТЕП *рәв.* Мөлдерәмә итеп, тутырып. *Өйдәге җиде бала, ач күзләребезне мөлдерәтеп, әнә шуларны алып чыгып киткәннәрен карап калуларыбыз гомергә онытыласы түгел.* Г.Мөхәммәтшин. *Сөембикә, «Сез боларны миңа нигә сөйлисез?» дигәндәй, аңа мөлдерәтеп карап куйды.* Ф.Садриев. *Кешеләр җиләккә кояш чыгып көянтә буе күтәрелгәч китәләр, Мәрфугатти исә, кояш чыкканчы, кызу-кызу атлап китеп бара һәм, төш җиткәнче, зур су чиләген мөлдерәтеп кура җиләге алып кайта иде.* М.Мәһдиев

МӨЛДЕРӘ́Ү *ф.* 1) Тулып ташырга, түгелергә, чәчелергә, тамарга тору. *Ул сулкылдап куйды тагын, авыр сулап, Күз яшьләре мөлдерәде йөзе буйлап...* Р.Вәлиева. *Мөлдери чыклар гөлләрдә: җир елый ятимсерәп.* Р.Назаров. *Курку яше мөлдери күзләрендә, Авыз ачып әйталмый сүзләрен дә.* Ә.Фирдәүси

2) *күч.* Тулып ташырга тору (хистойгы тур.). *Тиһран аны түзем генә тыңлап торды, миендә бөрҗөннәрнең фарсыларга булган ачуын файдалану мөмкинлеге хакында уй мөлдери башлады шикелле.* Б.Рафиков

◊ **Мөлдерәп карау** *к.* **мөлдерәтеп карау**. *Өске чукларындагы сыек яшел нәфис яфракчыклар көл-күмер, корым баскан ихатага сабыйларча гажәпләнеп, «Ник болай булды соң әле бу?» дигәндәй мөлдерәп карый кебек.* Д.Булатова. **Мөлдерәп китү** Тулып, ташып, читкә агып китү. *Карт күңел түзмәде, күзләрдән берәр бөртек яшь чал сакал буенча мөлдерәп китте.* Г.Ибраһимов. **Мөлдерәп тулу** Ташырдай, түгелердәй булып тулу. *Ике куллап алды ул мөлдерәп тулган тәлинкәне һәм әкрен генә үз алдына китереп куйды.* Г.Гобәй

Мөлдерәп тору Һәрвакыт мөлдерәгән булу; мөлдерәгән хәлдә булу. *Аларда иман нуры, мәрхәмәт мөлдерәп тора, акыл көче чагыла...* Ф.Бәйрәмова. *Мөлдерәп торган сулы чиләкләрен иңнәрендә биетә-биетә, чишмә сукмагыннан үтәләр.* Д.Гайнетдинова

МӨЛДЕ́Р-МӨЛДЕР *иярт.* Тулып, мөлдерәп тору турында. *Үзенең [Низаметдинның] күзләреннән мөлдер-мөлдер яшьләр тәгәри иде.* Ә.Сафиуллин. *Керфекләреннән өзлексез Мөлдер-мөлдер яшь тама, Шул сылуның аһ-зарыннан Моңга тулгандай һава.* Р.Вәлиева. *Сарытүшнең бу җырын ишеткән кошларның күзләреннән мөлдер-мөлдер яшьләр тәгәрәгән.* Ф.Яруллин

МӨЛКӘТ *и. гар.* Милек, байлык. *Җир-су өчен, әзер мөлкәт өчен Ашамаган кемнәр кем башын?* Ф.Гыйззәтуллина. *Байлар күбәеп, сыйнфый көрәшләр көчәйгән саен, фатир ремонтлау, өй алмаштыру, җиһаз яңарту кебек мөлкәт ярышлары кискенләшә.* К.Кәримов. *– Чит ил җирләре, мөлкәте, байлыгы сезнең өчен кеше гомереннән югарыракмыни? – дип сорады юлбашчы.* И.Хуҗин

МӨЛКӘТЛЕ *с.* Бай, хәлле; малмөлкәте булган. *Әмма гамәлдә кайбер мөлкәтле кешеләр тарафыннан бу җиренә җиткереп үтәлмәгән, гошер садакасының бирелгән кадәресе белән гадәттә намуссызрак мулла-мунтагай туенган.* Г.Тукай. *Сүз дә юк, татар бай, мөлкәтле булырга тиеш.* Р.Миңнуллин. *Безнең милләтне дәүләтле һәм мөлкәтле итү, ирекле һәм хөр күңелле итү өчен, бүген нинди юллар бар?* Р.Вәлиев

МӨЛКӘТЛЕЛЕК *и.* Бай булу; мөлкәтле булу

МӨЛКӘТСЕЗ *с.* **1.** Мөлкәте булмаган; ярлы. *Мөлкәтсез кеше бит үзенең түрәләрен тәнкыйть итә алмый.* М.Мәһдиев

2. *рәв. мәгъ.* Мөлкәте булмыйча, мөлкәте булмаган хәлдә. *--- Чөнки сугыш байтак халыкны йорт-җирсез калдырып, мөлкәтсез итте, гарип-гораба ясады.* М.Котлыгалләмов

МӨМКИН *мод. сүз. гар.* 1) «Нәрсәне дә булса эшләп, башкарып була, аның өчен шарт-җай бар» мәгънәсендә. *Ә менә күрмәмешкә салышып тыныч кына эшли бирү мөмкин.* Р.Юныс. *Мөмкин булса укып күрсәтегез әле.* Л.Ихсанова. *Гомәр абый, мөмкин булса, миңа «Халык мәкальләре» дигән китапны табып җибәрсә идегез.* Казан утлары

2) Нәрсәне дә булса эшләргә рөхсәт ителә; ярый. *Әгәр моны яшереп калдырырга мөмкин булса, бераз газапланып йөрер иде дә онытыр иде.* Ф.Яруллин. *Тик мондый портретны барыбер дә ачыктан-ачык күрсәтү мөмкин булмаган, шунлыктан рәссам аны ике катлы рамга куеп саклаган...* М.Маликова

3) Нинди дә булса эш-хәл турында «булуы бар, булуы ихтимал» мәгънәсендә. *– Бик мөмкин, – диде Дамир, күзләрен ялтырата-ялтырата елмаеп.* М.Госманов. *Кечкенә ялган да олы хыянәткә илтергә мөмкин.* Г.Гыйльманов

◊ **Мөмкин кадәр** Булдыра алганча, хәлдән килгәнчә. *Һиһаять, аңарда Иркен ага белән сөйләшү, эч серләрен мөмкин кадәр генә ача биреп, хиссияти*

якынаерга теләү тойгысы җиңде... А.Хәлим. **Мөмкин хәтле** *к.* **мөмкин кадәр**. *Юлда үземне мөмкин хәтле иркен тотарга булдым.* Г.Кутуй. *Бу хакта фән болай дип әйтә: сөтле сыер үстерәсең килсә, бозауга яшь чагында мөмкин хәтле күп итеп куе сөт эчерт, ди.* Ә.Еники

МӨМКИНЛЕК *и.* 1) Берәр эшхәлнең булу-булмавын тәэмин итә торган хәл, шарт, жай. *Ләкин чигенү инде Ельцин вакытында ук, ни гаҗәп, безгә зур мөмкинлекләр биргән Шартнамәгә кул куелу белән диярлек башланган иде.* Р.Юныс. *Сәйдәш үзендә иге-чиге булмаган иҗат мөмкинлекләре сизә!* Р.Низамиев. *Кире борылса, Мозаффар турында нәрсә дә булса белү мөмкинлеге кулдан ычкыначак...* М.Маликова

2) Мөмкин булу, ихтималы булу, ихтималлык

МӨМТАЗ *с. гар. иск.* **1.** Кайсы ягы белән булса да башкалардан аерылып торган, үзгә, югары, өстен. *Әтисе Нурмөхәммәт имам әйтүенчә, ул башкалардан зиһенлелеге белән мөмтаз, имеш.* С.Поварисов. *Һәрнәрсәдә аерым бер ләтафәт, мөмтаз бер матурлык.* Г.Ибраһимов

2. *рәв. мәгъ.* Берәр ягы белән башкалардан аерылып тора торган итеп. *Җәләп капканы тәмам шәһәр рәвешендә зур, чибәр, мөмтаз ясатып, башын төрле төскә буяп тимер белән яптырган.* Г.Нигъмәти

МӨНӘҖӘТ *и. гар.* 1) *иск. дини* Дога кылып, нәрсә дә булса сорап Аллаһка ялвару

2) Шәрык әдәбиятында һәм халык авыз иҗатында эчтәлеге Аллаһка мөрәҗәгать аша гөнаһлардан арынуга омтылу, үз-үзең белән сөйләшү, моңзарларны сөйләүдән гыйбарәт лирик жанр. *Сәкесенә арты белән утырып мөнәҗәт иткән әбекәй чынлап та колакка шулкадәр каты иде ки, ул хәтта керүен дә шәйләмәде.* А.Хәлим. *Татарның да үткәненә, фаҗигасенә сизгер, шуңа бәйле рәвештә хәлахвәлләргә мөнәсәбәтен белдергән бәет белән мөнәҗәт жанрлары яши.* Т.Галиуллин. *Мәчеткә кереп мөнәҗәтләр укыган Нәсимә абыстайның сүзләре дә мәчет диварына оран шикеллерәк килеп кагылды.* Р.Низамиев

МӨНӘҖӘТЧЕ *и.* Мөнәҗәт (*2 мәгъ.*) әйтүче, мөнәҗәт чыгаручы. *Өч көн вә өч төн дәвам иткән бәйрәм. Менә, ниһаять, мөнәҗәтче Сөмбеләнең нәүбәте җиткән.* К.Кәримов. *Нинди дер мөнәҗәтче бәндә Миннән көлсен, имеш...* И.Юзеев. *Барысыннан да бигрәк мөнәҗәтче Аллаһыдан сабырлык сорый, чөнки сабыр итеп кенә авырлыкларга түзеп була.* Сөембикә

МӨНӘСӘБӘТ *и. гар.* 1) Кемгә яки нәрсәгә дә булса караш; берәр кешенең кемгә яки нәрсәгә карата үзен тотышы. *Әгәр шушындый мөнәсәбәт киләчәктә дә дәвам итсә, без видео-аудиокино-архивсыз калачакбыз.* Р.Миңнуллин. *Тормыш тоткасы булган хатын-кызга карата тиешенчә мөнәсәбәт юк дигән сүз инде бу.* С.Ибраһимова. *Ә кара халык белән чуалган кешеләргә карата мөнәсәбәт бер дә яхшы түгел инде.* З.Кадыйрова

2) Кешеләр арасында берәр сәбәп белән яки үзара аралашу нигезендә туа торган бәйләнеш. *Минемчә, сезнең белән безнең ике арада гел рәсми мөнәсәбәт кенә булды.* М.Мәһдиев. *Фәрит Усманович дип сөйләшүеннән үк алар арасындагы дустанә-эшлекле мөнәсәбәт барлыгы сизелеп тора.* Т.Миңнуллин. *Шәвәлиев белән урнашкан яшерен мөнәсәбәт аны башкалардан өстен итеп тойдырды.* Ф.Садриев

3) Нәрсәгә дә булса бәйләнеш, катнашлык. *Никтер, бу эшләр белән Мәрьям туташ арасында бик аз гына да мөнәсәбәт юк төсле тоела.* Г.Ибраһимов

4) Чынбарлыктагы предметлар, күренешләр арасында үзара бәйләнеш. *– Тәнәкә галиҗәнаплары, бу никахның ханлык вазифаларына нинди мөнәсәбәте бар соң? – дип белеште Сафагәрәй.* М.Әмирханов. *Аңның яшәешкә мөнәсәбәте*

5) *иск.* Сәбәп, йомыш. *Берәр мөнәсәбәт чыкса, [яшьләр белән] барып танышырга карар биргән идем.* Ф.Әмирхан

МӨНӘСӘБӘТЛЕ *с.* Мөнәсәбәте булган. *Димче сүзен дәвам итте: – Син, ханбикә, бөек нәселгә мөнәсәбәтле.* М.Әмирханов. *Ник дисәң, мәхбүслектән котылып котыптан кайтуга, сугышка, фронтка, тоткынлыкка мөнәсәбәтле бөтен хатларын, язусызуларын утка яккан иде.* М.Әмирханов. *Бүген дә Сез республикабызда барган вакыйгаларга мөнәсәбәтле саллысаллы мәкаләләр язасыз.* Р.Миңнуллин

МӨНӘСӘБӘТЛЕК *и. лингв. к.* **мөнәсәбәтле сүз**. *Ул хәзерге грамматикаларыбыздагы кисәкчә һәм мөнәсәбәтлек, хәтта рәвеш дигән терминнар астында күрсәтелә торган сүзләрне үзенең эченә алган.* Ж.Вәлиди. *Кыскасы, предметны аңлаткан ук сүзен һәм мөнәсәбәтлек төшенчәләрен белдергән ук берәмлекләрен әһәмиятләре ягыннан һич тә югары яисә түбән дип бәяләргә ярамый, һәркайсы үз урынында мөстәкыйль.* И.Низамов

МӨНӘСӘБӘТЛЕ СҮЗ *и. лингв.* Ике сүз арасындагы ачыклаулы һәм хәбәрлекле мөнәсәбәткә буйсына, иярчен җөмләне баш җөмләгә бәйләп килә, тулы җөмләне алыштыра ала торган аналитик бәйләүче чара. *Мөнәсәбәтле сүзләр, теркәгечләр кебек, җөмләнең тиңдәш кисәкләрен һәм кушма җөмлә өлешләрен үзара бәйлиләр.* Д.Тумашева. *Кем алмашлыгы шул, шунда кебек күрсәтү алмашлыклары белән иярчен җөмләләрне баш җөмләгә бәйли торган чара (мөнәсәбәтле сүз) буларак та телдә актив кулланыла.* Ф.Хисамова

МӨНБӘР *и. гар.* 1) Җамигъ мәчет михрабының гадәттә уң ягында урнаштырыла, хөтбә һәм вәгазь уку өчен хезмәт итә торган, култыксалы, баскычлары намаз залына таба төшкән имам хатыйпның чыгыш ясау урыны. *Халик агай мәчет картларын һәм әбиләрне сәламләгәч, мөнбәр кырына басып, Диния нәзарәтенең фәрманын укыгач, улы Мөхәммәт мөнбәргә басты.* С.Шәрипов. *Менә ханлыкның Диния нәзарәте җитәкчесе, мөфти Бураш сәед мөнбәр алдына килеп басты.* М.Әмирханов

2) Үз фикереңне, сүзеңне киң җәмәгатьчелеккә ачыктан-ачык җиткерү чарасы; трибуна. *Халыкларның җилкәсенә басып Үрмәлибез өскә – мөнбәргә.* Ф.Яруллин. *Аның исемен, мөнбәр*

һәм экраннардан ярсып чыгыш ясау гадәтләрен, татар театрының рухын һәм мәсләген билгеләүгә керткән иҗатын белмәгән кеше сирәктер. Римзил Вәлиев. *Шагыйрь буларак, мәйданнарда Акъегет әллә ни күренми дә, ягъни ул үзен үзе алга куймый, башка мөнбәр шагыйрьләре кебек, сикереп сәхнәгә менеп, үз шигырьләрен укымый, тыйнак кына иҗат итә.* Р.Батулла

3) *күч.* Вакытлы матбугат мәйданы; газет-журнал битләре. *Менә шуннан соң Ф.Мөсәгыйт матбугат мөнбәреннән бер дә төшмәячәк.* Р.Батулла

МӨНДӘРИҖӘ *и. гар. иск.* Эчтәлек. *Ләкин Суворин, «Новое время»ның мөндәриҗәсе ягыннан да яхшы булуына бик зур әһәмият биреп, бик күп акча, гайрәт сарыф иткән.* Г.Исхакый. *Газетаның мөндәриҗәсе күбрәк авыл хуҗалыгы хакында, аның мөхәррире Хәсән Мәликов та – гали дәрәҗә мәгълүматлы агроном.* Ж.Вәлиди. *Болар арасында аеруча мөһимнәре – татар сүз сәнгате тарихының чорларга бүленеше, аның мөндәриҗәсен, чикләрен билгеләү.* Х.Миңнегулов

МӨҢГЕРӘҮ *ф. диал. к.* **мөгрәү**. *Сөт аз бирә торган сыер күп мөңгери.* Мәкаль. *Авызыннан әллә нинди ләззәтле мөңгерәү авазлары хасил итеп, ашыкмый-пошыкмый, ниндидер бер йолага әзерләнгәндәй әзерләнде...* А.Хәлим

МӨҢРӘҮ *ф. диал. к.* **мөгрәү**. *Күзләре яшь берлә тулган, мөңри, тилмереп карый.* Г.Шәрәфи

Мөңрәп алу Аз гына мөңрәү

Мөңрәп җибәрү Кинәт кенә, көтмәгәндә мөңрәү. *Кызыл сыер, аларның туп-туры үзенә таба килүләрен күргәч, моңлы тавыш белән мөңрәп җибәрде.* М.Гафури

Мөңрәп йөрү Озак вакыт дәвамында мөңрәү

Мөңрәп кую Бер тапкыр мөңрәү. *Киек җәнлекне изеп, агач төбенә терәгән мөгезләрен бушатмаса да, без аның янына килеп туктагач, безгә табан күзләрен әйләндереп, нидер әйтергә теләгәндәй мөңрәп куйды.* Л.-Х.Таналин

Мөңрәп тору Озак вакыт дәвамында мөңрәү

Мөңри башлау Мөңрәргә тотыну

МӨРӘББӘГЬ *и. гар.* Шәрык классик поэзиясендәге лирик шигырьнең строфик формасы

МӨРӘҖӘГАТЬ *и. гар.* Сүзеңне кемгәдер юнәлдерү, адреслау. *Ул телевидение аша сайлаучыларга мөрәҗәгать белән чыкты.* И.Таһиров. *Моның өчен дөньяда яшәүче барлык татарлар исеменнән Дәүләт Думасына мөрәҗәгать юлларга кирәктер.* Г.Морат. *Бу хакта язучыларыбыз матбугатта мөрәҗәгать белән дә чыгып карадылар.* Казан утлары

МӨРӘҖӘГА́ТЬ ИТҮ *ф.* 1) Дәшү, эндәшү, сүз кушу. *Көй тәмамлануга, гармунчы, серле елмаеп, залга мөрәҗәгать итә: – Иптәшләр, гаеп итмәгез инде, болардан кечкенә ике гармунымны онытып килгәнмен.* Р.Гобәй. *– Ә сез кем буласыз? – дип мөрәҗәгать итте аңа класс җитәкчесе.* З.Хәким

2) Берәр йомыш, теләк, гозер белән бару. *Тик кая гына мөрәҗәгать итмәсен, һәркайда я ягымлы, я салкын гына кире бордылар, югыйсә тәҗрибәле юристлар кирәклеге мәгълүм иде.* Р.Мирхәйдәров

3) Нәрсә белән дә булса эш итү, шөгыльләнү, тикшеренү. *Р. Низами поэма жанрына сирәк мөрәҗәгать итсә дә, «Ике мөһаҗир» әсәре лиро-эпик төрдә дә аның мөмкинлекләре җитди икәнлекне раслады.* Т.Галиуллин. *Россиядә яшәүче күпсанлы халыкларның канлы ярасына әверелгән чечен сугышы темасына татар әдәбиятында беренчеләрдән булып Ю.Сафиуллин мөрәҗәгать итә.* Казан утлары

МӨРӘҖӘГАТЬНАМӘ *и. гар.-фар.* Язма мөрәҗәгать; мөрәҗәгать язуы. *Бу хакта Баттал үзе болай дип искә ала: --- Язучылар берлегеннән машинада икәү килделәр дә, «Мөрәҗәгатьнамә»нең кулъязмасын алып, юлга җыенырга куштылар.* Р.Мостафин

МӨРӘҮВӘТ *и. гар. кит.* 1) Югары әхлакый сыйфатлар белән аерылып тору, киң күңеллелек. *--- бер кеше мөрәүвәт вә изгелек иясе бер адәмгә үзенең бер зарур хаҗәте өчен килеп, хаҗәт сорарга оялып, берәр сәгать хаҗәтен әйтмәй торды.* К.Насыйри

2) Ирлек, егетлек, гайрәтлелек, йөрәклелек

3) Кешелеклелек, мәрхәмәтлелек, гуманлылык

МӨРӘҮВӘТЛЕ *с. кит.* Югары әхлакый сыйфатлары белән аерылып торган, кешелекле, киң күңелле, олы йөрәкле. *Аның элек кем булуын искә төшерү, минемчә, бик үк мөрәүвәтле эш түгелдер.* Г.Бәширов. *Бу күренеш бары тик турысын әйтүче, мөрәүвәтле зыялылар гаиләсендә генә була икән.* Р.Батулла. *Була бит шундый тыйнак, сабыр, мөрәүвәтле кеше: һәркемне тигез күреп мөгамәлә корыр, итагатьле итеп, әдәпле генә елмаеп сөйләшер, уен-көлке кушып гәпләшүдән дә качмас.* Ватаным Татарстан

МӨРӘҮВӘТСЕЗ *с. кит.* Мәнсез, мәгънәсез, эшен төптән уйлап эшли белмәгән; кешелексез, юньсез. *Җитмәсә, ул үрдәкне сөйгәненә 8 март бүләге итеп тәкъдим иткәнме икән ул мөрәүвәтсез.* Г.Хөсәенов. *Тәрбиясез! Мөрәүвәтсез! Әниең белән бер яшьтәге олы кешегә «сез» дип дәшәргә кирәк, бик беләсең килсә!* Н.Әхмәдиев. *Беркөнне мөрәүвәтсез күршене бүлнискә озаттык.* Н.Гыйматдинова

МӨРИД *и. гар.* 1) *дини* Нинди дә булса тарикать шәехенә, ишанга ияреп суфичылыкның юлларын өйрәнүче, аның җитәкчелегендә үзен камиллеккә ирештерүче кеше. *Шулай көннәрнең берендә бер мөрид, ишан хәзрәтнең кулын үбеп кайтканда, безгә кунарга туктады.* Т.Гыйззәт. *Без кергәндә, өйнең залында мөридләр түгәрәкләнеп утырганнар.* Г.Макаров

2) Гомумән суфи кеше, дәрвиш. *Дөреслектән читтә йөргән мөридләр хакыйкать бик ерак дип уйлыйлар, ә хакыйкать бер дә ерак түгел, муен тамырыннан да якынрак.* Р.Батулла

3) *күч.* Кемгә дә булса турылыклы хезмәт итүче. *Кем өчендер син дә ханбикәдер, Кем өчендер мин дә кол, мөрид...* Г.Морат

МӨРИДЛЕК *и.* Мөрид булу. *Куштанлыкның чишмәсе – коллар хуҗалыгы, крепостнойлык тәртипләре, Шәрыкта сарай хезмәте, ишанга*

мөридлек, колонизаторларга яраклы булу мәҗбүрлеге... Р.Вәлиев

МӨРТӘТ *и. гар.* 1) *дини* Үз диненә хыянәт иткән, башка дингә күчкән, үз диненнән ваз кичкән кеше

2) *сөйл.* Хыянәтче, сатлыкҗан. *Оят: һаман чикләвекне Юкәдән эзләгәнмен. Икейөзле мөртәт белән Араны өзмәгәнмен.* Ф.Габдерәхим. *Әмма ни-нәрсә генә уйлама, ни-нәрсә генә эшләмә – шул мөртәтнең «эшчәнлегенә» барып төртелә, аны һич читләтеп үтеп булмый...* Р.Мирхәйдәров

3) Сүгү, кимсетеп әйтү сүзе. *– Ана-дан күлмәкле килеш тугандыр ул мөртәт, – дип тузынды Чура Нарык, – алашасы да колынлыйдыр, валлаһи...* М.Әмирханов. *Яббар базынып йодрыгын төйнәде: – Телеңне тый, мөртәт!* З.Хәким. *Мәчет хуҗасының күмердәй чем кара кашлары ачудан шундук өчпочмакланып килде: – Син нәрсә, ахмак, телең белән һава кыйныйсың, мөртәт! Аллаһ йортына тел-теш тидерергә ни хакың бар?* Р.Низамиев

МӨРТӘТЛЕК *и.* Мөртәт булу. *Кайдан бу мөртәтлек, икейөзлелек, ниһаять, куркаклык?* Ә.Еники. *Кызганыч, очраша алмадык, диндарлык, кәферлек, мөртәтлек турында сөйләшкән булыр идек.* Т.Миңнуллин. *Әмма көферлек, мөртәтлек, дәһрилек ныгыган саен, тышкы сыйфатлар эчкә күчә барган.* И.Әмирханов

МӨРШИД *и. гар. дини* Нинди дә булса тарикать шәехе, мөридләргә юл күрсәтүче остаз; ишан, пир. *Сине мөрид, үзен мөршид итеп, сиңа садака алыр өчен кул сузган адәмне үзеңә мөршид итмә!..* Р.Фәхретдин. *Акыллы мөршид үз мөриндә йоклап яткан хиссияти тойгысын уятырга тиеш, ягъни үзендә генә түгел, укучысы күңелендә йоклап яткан рухи тойгыны уятырга һәм аны Аллаһыга йөз тоткан хакыйкатькә якынайтырга.* М.Хәбибуллин

МӨСАФИР *и. гар.* Юлчы, узгынчы; кунак. *Шайтан каласына килгән мөсафирның кулында хан ярлыгы булырга тиеш.* М.Хәбибуллин. *Бетерде, харап итте дигәндә генә, күктән төшкәндәй таяклы юлчы пәйда була. Ап-ак сакаллы, сәләмә киемле мөсафир.* М.Әмирханов. *Төн эчендә кичәге көннең утлы тузаны басылган, сирәк-саяк кына очраган ишәкле, Иркеннәр кебек атлы-дөяле мөсафирларны санамаганда, хәрәкәт сүлпән, бөтенләй дә юк диярлек.* А.Хәлим

МӨСАФИРЛЫК *и.* Мөсафир булу хәле. *Урысларда мөсафирлык психологиясе өстенлек итә, алар хәрәкәтчән, үзләре яшәгән авыллардан яки шәһәрләрдән җиңел күчеп китәләр, яңа урыннарга да җиңел җайлашалар.* Р.Хәкимов

МӨСАФИРХАНӘ *и. гар.-фар. кит.* Юлчылар туктый торган кунакханә. *Кирәкле белешмәләр алганнан соң, мунчадан чыгып, мөсафирханә урамына барырга дип торганда, хатыннар мунчасыннан дөньяда тиңе юк бер гүзәл хатын чыкканы шаһзадәнең күзенә чагылды.* К.Насыйри. *Аннары пересылкадан яман авырулы кешеләрне мәңгелеккә озата торган онкология хастаханәсе – «рак корпусы» ясадылар. Аның борынгы мөсафирханә (кәрвансарай) кебек шәкеле дә, шакмаклы ишегалды да, тимер капкасы да «исән» калды...* А.Тимергалин

МӨСЕЛМАН *и. фар.* 1) Ислам динендәге кеше, ислам динен тотучы; мөслим, мөэмин. *[Карт:] Ни булсын, күмдек, түбән очтагы мөселманнар зиратына.* М.Хәбибуллин. *Аннан шунысы да бар бит әле, Хәйдәргали: патша мөселман түгел, артык хафаланма.* Р.Мөхәммәдиев

2) *сөйл.* Татар; татар кешесе. *Үз шәһәреңдә, үз мөселманыңның шундый бер газеты булсын да, синең шуннан хәбәрең булмасын, имеш!* Г.Камал

МӨСЕЛМАНЛЫК *и.* 1) Мөселман булу. *Иманга килим дисәң, мөселманлык кына җитмәгәнен, мөэмин-мөселман булу кирәклеген дә аныкладык сыман.* Р.Сафин. *Үзенең мөселманлык бурычын үтәгәннән соң, юлда каты авырый һәм вафат була.* Р.Вәлиев

2) Ислам; мөселманнар дине. *Ул ел-ларда түбәтәй кию рәсми даирәләр тарафыннан милләтчелек, мөселманлык билгесе дип бәяләнгәнлектән, моны мин аның шаблон карашларга, рәсми идеологиягә җайлап кына төрттерүе булгандыр дип уйладым.* Ф.Садриев. *Авылның яртысы мөселманлыкта кала.* Н.Гариф. *Казан губернасының Зөя өязенә кергән бу Татар Әҗәлесе белән Карашәм, кешеләренең шактый өлеше мөселманлыкка кайткан булсалар да, шул көнгә кадәр мәкруһ авыллар булып саналалар.* Т.Вафин

3) Ислам диненә хас сыйфатлар, гадәтләр, йолалар. *Аларда төркилек тә, мөселманлык та, шәрыклык тә ярылып ята.* Р.Миңнуллин

МӨСЕЛМА́НЧА *рәв.* 1) Мөселманга хас булганча. *Алтай-Саян төбәкләрендә берничә ай яшәп кайткан рәссам Надир Әлмиевнең, тауларга чыккач, мөселманча сарык суюы турында сөйләгәне бар.* М.Гали. *Егетләр башларын селкегәч, инглиз теленә күчте: – Хәерле көн, әфәнделәр! Өйгә рәхим итегез! Бусаганы үткәч, Идрис мөселманча сәлам бирде: – Әссәламегаләйкем!* И.Хуҗин

2) *сөйл.* Татарча. *Күрше җиденче номердан мөселманча сөйләшү ишетеп, мин номер хадимен чакырып, аңардан: «Бу җиденче номерда нинди кешеләр торалар?» – дип сорадым.* З.Бигиев. *Ләкин әйтәсен әйтеп киттеләр: – Паркта очрашырбыз әле, шунда бер мөселманча сөйләшербез, – диделәр.* М.Мәһдиев

МӨСЛИМ *и. гар.* Мөселман, мөэмин. *Каргап каргыш төшмәстәй, янап нәфрәт төкәнмәстәй бу хаиннәр, әхлакның аргы ягына чыгып, адәми зат, мөслим икәнлекләрен онытырдай сәрхушка әверелгән бәндәләр иде.* Р.Батулла

МӨСЛИМӘ *и. гар.* Мөселман хатын-кыз. *Бу дөньядан мөслимә булып китәсем килә.* И.Диндаров

МӨСТӘКЫЙЛЬ *с. гар.* **1.** 1) Беркемгә дә буйсынмаган, бәйсез, башкалардан аерылып чыккан; аерым; бәйсезлеккә ия булган. *Сәнгать – мөстәкыйль, ул ашказаны, корсак фәлсәфәсеннән югары.* М.Мәһдиев. *Уфа – Казан арасындагы саф татар өязләрен кертегез дә мөстәкыйль Татарстан игълан итегез.* Р.Мөхәммәдиев

2) Башкалар булышлыгыннан тыш эшләүгә, фикерләүгә сәләтле; үзбашка,

җитәкчелектән башка; бәйсез. *Мәктәп белән хушлашкан бала үзен бәйсез, мөстәкыйль, балигъ дип саный башлый.* Т.Галиуллин. *Ә мин Әстерханда үземне җитлеккән ир, мөстәкыйль кеше итеп сизә идем.* Ф.Зариф. *Иң гаҗәбе: шушы ундүрт ел эчендә бер мәртәбә дә мөстәкыйль карар кабул иткәне булмады.* М.Әмирханов

3) Чит йогынтылардан башка, чит ярдәмнән башка эшләнгән; оригиналь. *Үзеңә, мөстәкыйль эш өчен, өчдүрт көнгә Солтангалиев һәм Сәгыйдуллинны ал.* Р.Мөхәммәдиев. *Мөстәкыйль эш белемемне сынар өчен менә дигән мөмкинлек булды.* Ялкын

2. *рәв. мәгъ.* Кешеләр ярдәменнән, киңәшеннән башка; үзе теләк белдереп, үз көче белән; чит йогынтылардан башка. *Димәк, сез мөстәкыйль фикер йөртәсез, мөстәкыйль карарлар кабул итәргә сәләтле кеше.* Р.Мөхәммәдиев. *Ләйлә балалыгыннан чыккан инде, мөстәкыйль уйлый.* Н.Гыйматдинова. *Ләкин, миңа калса, ипташ Зайцевка балалар белән мөстәкыйль шөгыльләнү җитеп бетми кебек.* В.Имамов

МӨСТӘКЫЙЛЬЛЕК *и.* 1) Мөстәкыйль булу. *Билгеле инде, моңа бары тик чын мөстәкыйльлек һәм бәйсезлек шартларында гына ирешергә мөмкин.* Ә.Еники. *Мөстәкыйльлек һәрвакыт диярлек үз көненә үзең күрә белүгә кайтып кала.* И.Таһиров. *Мөстәкыйльлек турында сүз чыкканда, мин һәрвакыт үземнең туган авылымны искә төшерәм.* Р.Миңнуллин

2) Мөстәкыйль булу хокукы. *Ә Татарстанда гасырлар дәвамында кабатланып килгән милли күтәрелеш кабат кузгалды, милли лидерлар пәйда булды, Татарстан халкы мөстәкыйльлек даулап мөнбәрләргә менде, ташкын булып, калалар урамнарына ургылды.* Ж.Дәрзаман. *Республикабызга мөстәкыйльлек даулаган көннәрне генә искә төшерик.* Т.Миңнуллин. *Ул баш иеп, мескен кеше булып, һәрнәрсә белән килешеп яшәргә теләми, аның гыйсъян йөрәге, тынгысыз җаны ирек, мөстәкыйльлек талап итә.* Т.Галиуллин

МӨТӘВӘЛЛИ *и. гар.* 1) Нинди дә булса оешмада, вәкыйфта мал-мөлкәт эшләре белән шөгыльләнүче кеше. *Хезмәттәшләрем Рәфикъ Юныс белән Харрас Әюп (хәзер инде танылган шагыйрьләр) кинаяле елмаялар: – Шеф, әнә, синең мөтәвәлли тагын килгән, – диләр.* Г.Гомәр. *Мәктәптә укыту өчен, «Гакаид» белән «Җәмәгать» китаплары Өммегөлсем абыстай Корбангали тарафыннан, «Тәһарәт» белән «Намаз» китаплары Мәгъфурә ханым Мостафа тарафыннан язылганнан соң, мәктәп эшләренең сәркатибе, мөтәвәлли Хуҗа Әхмәт әфәнде Баһаб каравы белән мимеографта бастырып чыгарылды.* Гасырлар авазы

2) Мөтәвәллият әгъзасы. *Габдрәшит ахун вафатыннан соң, углы Ибраһим бай мәсҗедкә мөтәвәлли (мәчет, мәдрәсә эшләрен башкаручы кеше) булган, бу кеше – безнең дәү әтиебез, хәзерге фамилиябез бу кешедән бирелгәндер.* Ф.Бәйрәмова. *Яшь егетнең дөньяга карашы формалашуда гомеренең егерме елын Мәрҗани мәчетендә мөтәвәлли булып хезмәт иткән дәү әтисе Галәветдин Булатов, дәү әнисе Сажидә Булатова, бабасының әтисе Кәрим Хәкимов, Разыя, Рауза, Сажидә, Зөбәйдә абыстайлар аеруча зур роль уйныйлар.* Фән һәм тел

МӨТӘВӘЛЛИЯТ *и. гар.* Составына имам, мөәззин, мәхәллә халкыннан вәкилләр һ.б. керә алган, мәчет-мәдрәсә мөлкәте, вәкыф маллары белән бәйле эшләрнең башкарылышын тәэмин итә торган совет, комиссия; попечительләр советы. *Хәзрәт үзе гел дин, мәчет, мәдрәсә, мөтәвәллият мәшәкатьләренә чумганлыктан, ширкәт эшләре белән күбрәк Әхмәтҗан бай шөгыльләнә икән.* С.Сабиров. *Шундыйларның берсе – мәчет төзүгә зур өлеш керткән, хәзерге вакытта мөтәвәллият рәисе вазифаларын башкаручы Зиннур Нуретдин улы Шәйхетдинов һәм аның гаиләсе.* Татарстан яшьләре. *Ниятемне мөтәвәллият тә хуплады.* Ислам – татарлар һәм мөселманнар

МӨФӘССИР *и. гар.* Коръәнне аңлатучы; тәфсир язучы; тәфсир авторы. *Бу галимнәрнең үзләре мөнәсәбәтле булган гыйлемнәренә нисбәтле ләкаб-титуллары да булып, мөфәссир (тәфсир галиме), мөхәддис (хәдис галиме), лөгави (тел галиме), сарфи (морфология галиме), нәхүви (синтаксис галиме), фәкыйһ (фикъһ галиме), мөтәкәллим (кәлам галиме), табиб, фәйләсүф, тарихчы, мантыйкый, мөһәндис (инженер) кебек хөрмәтле исемнәр белән бер-береннән аерылып торганнар.* Гасырлар авазы

МӨФӘССИРЛЕК *и.* Мөфәссир булу

МӨФТИ *и. гар. дини* Зур административ территориядә (өлкә, республика һ.б.ш.) мөселманнарның дин эшләрен җитәкләгән, фәтва чыгару хокукына ия булган дин әһеле. *Кем дә кем төшендә мөселманнарга мөфти булып, елга өч мең жалованье алып, мөселманнар файдасына ике тиенлек эш кылмаса, хәвефледер.* Ш.Мөхәммәдев. *Җитмәсә, күзен дә йоммый Шәмгунхан сараена кереп оялаган: мөфти булып киткән, мөфти – бөтен имамнарга имам, муллаларга мулла.* М.Хәбибуллин. *Мин мөфти Госман хәзрәткә барып карарга булдым.* Ф.Яруллин

МӨФТИЛЕК *и.* Мөфти булу; мөфти вазифасы. *1911 елның февралендә мөфти Мөхәммәдьяр Солтановның егерме биш ел мөфтилек кылуының юбилеен билгеләп үтәләр.* Г.Камал. *Мөслими дә үз әсәрендә ислам динен, мөфтилек оештырып, аны Россиядә Эчке эшләр министрлыгы органына әйләндерүгә протест белдереп яза.* Гасырлар авазы

МӨФТИЯТ *и. гар.* Башында мөфти торган дини оешма, диния нәзарәте; шул оешма урнашкан бина. *Кичкә таба аны тагын бер җаваплы эш – әле генә казна хисабына ремонтланган яңа мөфтият бинасын кабул итеп хуҗаларына тапшыру тантанасы көтә.* А.Тимергалин. *Мөфтият тә әби патша заманында ук нәкъ шушы максатта оешкан иде.* И.Әмирхан. *Баксаң, Уфадагы мөфтият тарафыннан имамнарга юнәлтелгән мөрәҗәгать икән.* Ф.Хәбибуллин

МӨХАЛЬ *с. гар. иск.* Мөмкин булмаган, тормышка ашырдай булмаган. *Китсә җәһан вилаятене ташлап Һомай, Байгыш күләткәсенә кеше*

килмәке мөхаль. С.Сараи. *Шуның өчен кавышу мөхаль булган Ярга язган хатлар шикелле.* М.Җәлил

МӨХӘДДИС *и. гар.* Хәдис гыйлеме белән шөгыльләнүче мөселман галиме. *Хәдисне ишетеп аны тапшыручы гына әле мөхәддис була алмый, бәлки мөхәддис ул – хәдисне исбатлау юлларын, тапшыручыларны җәрх һәм тәгъдил кылу юлларын да белүче.* Ислам – татарлар һәм мөселманнар. *Албани 10 хәдиснең иснадын китерә алмаса да, Ибн Баз аны «дөньяда иң гыйлемле мөхәддис» дип һәм «гасыр мөхәддисе» дип йөрткән.* Татар заманы

МӨХӘДДИСЛЕК *и.* Мөхәддис булу

МӨХӘРРӘМ *и. гар.* Һиҗри календарьдә беренче аның исеме. *Гашурә исә, имам Хөсәен һәм аның тарафдарларының үлеменә багышланган матәм көннәре буларак, шигырьларда мөхәррәм аеның береннән унына кадәр дәвам итә.* А.Тимергалин. *17 декабрь (пәнҗешәмбе) – 1431 ел, яңа мөселман елы һәм мөхәррәм ае башланган көн.* Казан утлары

МӨХӘРРИР *и. гар.* 1) Редактор. *Һәм, гомумән, Татарстанда матбугат иреге чикләнүгә иң әүвәл үзүзләренә туктаусыз бармак изәп торган журналистлар һәм бигрәк тә баш мөхәррирләр гаепле түгел микән, дигән шигем бар.* Р.Юныс. – *Зур дим бит. Бүген Хамматов (гәзит мөхәррире, журналистлар берлеге рәисе) аны синең янга алып барачак, расларга, – ди шагыйрь.* Г.Гомәр. *Аны район газетасына баш мөхәррир итеп кире куегыз инде, яме.* З.Хәким

2) *иск.* Язучы, журналист

МӨХӘРРИРЛЕК *и.* Мөхәррир эше һәм вазифасы. *Габделҗәббар Кандалыйның соңгы утыз-кырык ел дәвамында табылган, җыелган әсәрләреннән тупланган күләмле җыентыгын әзерләп бетергәч, аны нәшриятка тәкъдим иткән чакта, мин директордан мөхәррирлеккә Рәис Даутовны билгеләвен сорадым.* М.Госманов. *Мөхәррирлеккә ни өчен Фатих Кәрими сайланган? Беренчедән, ул – инде танылып килүче язучы, өч-дүрт китап авторы.* Казан утлары

МӨХБИР *и. гар.* 1) Хәбәрче, хәбәр китерүче

2) Газета хәбәрчесе, корреспондент. *Әйе, мужиктан бер мулла, муллադан бер хәлфә, хәлфәдән бер газета мөхбире, мөхбирдән газета конторщигы, конторщиктан көтепханә назиры, назирдан бер урам каравылчысы урлаган ярлык.* К.Тинчурин. *Моны, Америкадан килгән гәзит мөхбире, диделәр.* М.Мәһдиев

МӨХБИР ӘГЪЗА *и.* Фәннәр академиясенең хакыйкый әгъзалары иерархиясендә академиктан бер баскыч түбән дәрәҗә һәм шул дәрәҗәгә ия булган кеше. *Вакытсыз арабыздан киткән Татарстан Фәннәр академиясенең мөхбир әгъзасы Нил Юзиев үзенең соңгы хезмәтләре, бигрәк тә «Әдәбият белеме чыганаклары» исемле китабы белән әлегә йомшак өйрәнелгән өлкәгә җитди өлеш кертте.* А.Әхмәдуллин. *Р.Мөхәммәдиев Татарстанның (1986) һәм Россиянең (2010) атказанган мәдәният хезмәткәре, Россия Гуманитар фәннәр академиясенең мөхбир әгъзасы (1997), Америка биографик үзәге тарафыннан 1994 елның атаклы кешеләре исемлегенә теркәлә.* Заман

МӨХБИРЛЕК *и.* Мөхбир булу; мөхбир хезмәте һәм вазифасы. *Мөхбирлеккә тәкъдим итү*

МӨХТӘРӘМ *с. гар. кит.* Хөрмәтле, хөрмәткә лаеклы. *Шәһәр, район комитетындагылар – сезнең өчен мөхтәрәм, ә минем өчен алар – караклар, әле ниндиләре!* Р.Мирхәйдәров. *Шушындый мөхтәрәм кунаклар барында үзеңне зур кеше шикеллерәк хис итми кара син!* Р.Низамиев. *Шунда мөселман җәмгыятенең бер бик мөхтәрәм кешесенең кызын үземә хәләл җефет иттем.* И.Хуҗин

МӨХТӘСИБ *и. гар. дини* Мөхтәсибәт башлыгы. *Мөхтәсиб һәм имамнарны кабаттан аттестацияләү мәсьәләсе дә күтәрелде.* Ф.Гыйләҗев. *«Имам белән мөхтәсиб арасындагы бәхәсле вазгыятьне дә казый җайга сала», – ди Җәлил хәзрәт Фазлыев.* Г.Газиз

МӨХТӘСИБӘТ *и. гар. дини* Дания нәзарәтенең билгеле бер төбәктәге, шәһәрдәге мәхәлләләрне берләштерә тораган административ берәмлеге. *Бу чорда җәмгыятебездә вәҗдан иреген киң юл ачылып, авылларда актив төстә мәчетләр төзелеше җәелгәч, алар белән җитәкчелек итү, мөхтәсибәтләр оештыру зарурлыгы да алга килеп баса.* Ватаным Татарстан

МӨҺАҖИР *и. гар.* 1) Сәяси, икътисади яки башка сәбәпләр аркасында мәҗбүри яки ирекле рәвештә туган җиреннән чит илгә күченеп киткән кеше; эмигрант. *Мин чит илгә сөргенгә китүне, мөһаҗир булуны сайладым.* И.Юзеев. *Якташлар гына түгел, туган яктан искән җилләренә кадәр кадерле мөһаҗир кешегә.* Н.Әхмәдиев. --- *татар өчен җан аткан, Идел-Уралны өзелеп сөйгән Исхакый Ватанынnан читкә китәргә – мөһаҗир булып яшәргә мәҗбүр ителә.* Х.Миңнегулов

2) Мөхәммәд пәйгамбәргә ияреп Мәккәдән Мәдинәгә күчеп киткән мөселман. *Мәккәдән күчеп килгән мөһаҗирләр үрнәгендә Мәдинә әнсарлары да ислам динен кабул итә.* Кызыл таң

МӨҺАҖИРЛЕК *и.* 1) Мөһаҗир статусы, мөһаҗир булу күренеше; эмигрантлык. *Исхакыйның хәлен күз алдына китерегез! Өстәвенә – картлык, хасталык, мөһаҗирлек, фәкыйрьлек, Истанбул кебек берничә миллион халыклы шәһәрдә ялгызлык.* Х.Миңнегулов

2) Туган илдән еракта яшәгән урын һәм вакыт; эмиграция. *Мөһаҗирлектә яшәгән милләттәшем шушы кәләпүш бизәкләрендә туган ягыбызның сулышын, әнисенең кул җылысын, туган туфрак исен тойгандай булгандыр.* Шәһри Казан. *Мөһаҗирлектә гомер сөргән әтисе Хәмит абыйның сагыну, җирсү хисеме икән әллә?* Ватаным Татарстан

МӨҺӘНДИС *и. гар.* Инженер. *Укыган кешегә ихтыяҗ бик зур: адвокаты кирәк булган шикелле, мөселманнан табибы да кирәк, мөһәндисе дә кирәк, архитекторы да кирәк, агрономы да кирәк, байтары да, учителе дә вә гайреләре дә кирәк.* Г.Камал

МӨҺЕЛДӘҮ *ф.* Әкрен генә кешнәү (ат тур.)

Мөһелдәп алу Бер тапкыр гына мөһелдәү

Мөһелдәп жибәрү Кинәт, көтмәгәндә мөһелдәү

Мөһелдәп тору Сөйләү моментында мөһелдәү; озак вакыт дәвамында мөһелдәү. *Хөснулла, атның мөһелдәп торуына карамастан, тиз арада атны җикте дә чыгып китте.* Ш.Камал

МӨҺЕР *и. фар.* 1) Кире ягы белән уеп төшерелгән сурәтнең (язу, рәсем, имза кебекләрнең) оттискын ала торган әсбап; пичәт, штемпель. *Аның жилет кесәсеннән зур гына мөһер асылыныр тора.* Н.Кәримова. *Коридорда сөйләшә торган сүз түгел бу, әйдәгез, мөһер кабинетта!* Ә.Зарипов. *Акчалар түштамгалар, кием һәм мөһерләргә тотылган.* Безнең гәҗит

2) Шул әсбап ярдәмендә нинди дә булса документны раслау өчен яки башка максатлар белән сугыла торган билге, пичәт. *Ярлыкларга, аерата мөһим эш кәгазьләренә, бүгеннән башлап Мөхәммәдәмин ханның мөһере сугылачак.* М.Әмирханов. *Безнең татарларда туграны XIX гасыр урталарыннан башлап укымышлы кешеләр, муллалар, сәүдәгәрләр үзләренең шәхси мөһерләре, китап билгеләре рәвешендә куллана башлаганнар.* Р.Ягъфәров. *Ике «документ»ның да имзалары янына түгәрәк мөһер сугылган.* З.Зәйнуллин

3) Ярлык, марка. *Иң яхшы калай төргәкләренә Һиндстан, Куба, Корея, Вьетнам кебек илләрнең мөһерләре сугылган була.* Р.Фәизов. *– Андыйларга элек эксплуататорлар дип мөһер сугалар иде бит, – дигән булып сүз кыстырдым.* Ф.Баттал

◊ **Мөһер сугу** 1) Исем тагу, кушамат бирү. *Менә бит, кайбер тити башлар аның иҗатына «мәгарә җыры» дип мөһер сукканда, таныш түгел шушы кызның бер рәхмәте ун бәягә торырлык булды!* Р.Низамиев. *Бу йортта миңа «әти-әни» дигән мөһер сугылып бирәр эш йөкләнә икән, ул үтәлергә тиеш.* Г.Галиева; 2) *к.* **пичәт сугу**. *Бер күзенә моннан ун ел элек үк ак төшкән иде инде аның, ләкин барыбер, нинди дә булса да мәсьәләгә катгый каршы чыгып мөһер сугасы булса, ул гел шулай ди: «Ике күзем чыкса чыксын», янәмәсе...* З.Хөснияр

МӨҺЕРЛӘНҮ *ф.* Мөһер сугылу; пичәт сугылу. *Аерылышу вакыйгалары – тыелган тема, аңа «табу» коткысы мөһерләнгән иде.* Ф.Яхин. *«Совершенно секретно. Лично» дип мөһерләнгән, ике яклап шыплап язып тутырылган унөч битлек бу белешмә «О движении панисламизма» дип атала.* Безнең гәҗит. *Кешелекнең иң бөек императорына тәгаенләп язылган бу хат мөһерләнеп (пичәт сугылып), сургучланып, аны тапшыру, патшалар патшасы белән сөйләшүләр алып бару өчен, экспедициягә махсус куелган илче кулына тапшырыла.* Татар, уян!

МӨҺЕРЛӘҮ *ф.* 1) Мөһер сугу. *Әмма бу хәл – акчаларны мөһерләү – тарих фәне өчен дә искиткеч әһәмиятле.* Р.Әхмәтьянов. *Бер бабам патша хезмәтендә вакытында гербовой печать чәлгән булган икән, шуның белән үзе генә мөһерләде.* Р.Рахман. *Ишекне мөһерләп ябып куйганнар, һәм... эш янә туктаган.* Шәһри Казан

2) *күч.* Ярлык тагу, исем кушу. *Мәгълүм ки, быел март аенда да Октябрьск шәһәрендә берничә кеше кулга алынгач, аларны да үтә исламчылар дип мөһерләгәннәр иде.* Ф.Фәтхи

Мөһерләп кую Мөһерләнгән хәлгә китерү. *Тикшерүчеләр килеп сизмәсеннәр дип, идән асты ишеген биклән, мөһерләп тә куйган.* Безнең гәҗит

Мөһерләп тору Сөйләү моментында мөһерләү эшен башкару

МӨҺИМ *с. гар.* 1) Әһәмиятле, җаваплы, җитди. *Чөнки Рашат белән ачылып сөйләшкәнче, ул [Нурзифа] бик тә мөһим, четерекле, күптән уйлап йөреп тә моңа кадәр тәвәккәлли алмаган бер эшне башкарырга тиеш иде.* М.Маликова. *[Җангали:] Минем өчен иң мөһиме, синең, туачак баланың иминлеген тәэмин итү.* М.Әмирханов. *Туздырырга дучар ителгән харам акча хисабына кабынган өмет тынгы бирми, ниндидер иң мөһим теләк гамәлгә ашмый калды.* К.Кәримов

2) Актуаль, бик кирәкле. *Һәм хәзер шул органнарның эшчәнлеген фәнни тикшерүне тәмамлау аның тормышында иң мөһим эшкә әйләнде.* Р.Мирхәйдәров. *Сугышка керәчәк солдатларның рухын күтәрү, алар арасында сәяси-агарту эшләре алып бару, артистлар труппасы төзү бик мөһим.* Р.Низамиев

МӨҺИМЛЕК *и.* Мөһим булу. *Мөһимлек ягыннан караганда, алай булырга тиеш түгел кебек, югыйсә.* Ә.Баян. *Чыраенда һәрчак хәстәрле мөһимлек, корылык билгеләре чагыла.* Х.Камалов. *Ярату ул – йөрәк хисләренә аеруча бер мөһимлек, мәгънә һәм максат бирергә теләү...* Г.Гыйльманов

МӨШКӘ I *и.* 1) Тегермәндә: он төшә торган улаксыман җайланма. *– Ярар, – дигән сатучы карт, шүрлектән бер зур табак алып мөшкә астына китереп куйган да тегермәннең колагына нидер бер сүз пышылдап: «Әйлән, тегермән, тарт, пешер шуны!» – дип кушуы булган, шул уңайга тылсымлы тегермән зырылдап әйләнә дә башлаган.* Әкият. *Ул арада, тартасы арышны тегермәнгә кертеп мөшкә янына менгергәләгәнче, җил басыла төште, тегермән канатлары торган саен акрынрак әйләнә башлады.* Г.Бәширов. *Җайлап кына мөшкәдән аккан онны бәләкәй көрәк белән капчыгыма тутыра башладым.* И.Шакиров

2) *сөйл.* Комбайнда: бункер. *Бер мөшкә ашлык*

◊ **Мөшкә башында булу** Нинди дә булса эшнең башында тору, җаваплы булу. *Белгәнеңчә, мөшкә башында без торабыз бит әле.* М.Хәсәнов. **Мөшкә башында тору** *к.* **мөшкә башында булу**

МӨШКӘ II *и. фр. сөйл. к.* **мушка**. *Белмим, бу идиллия әле күпме дәвам итәр иде, һич көтмәгәндә битләренә маска кигән кораллы өч бәндә атылып килеп кереп, студия кунакларын мөшкәгә алды.* Р.Зарипов

МӨШКӘТ *и. гар.* Ябыгорлыклылар семьялыгыннан мәңгеяшел тропик Азия агачы һәм аның парфюмериядә, медицинада, аш-су әзерләгәндә кулланыла торган хуш исле чикләвеге; мускат. *Бөтнек, мөшкәт, дарчин исе тынычландыра.* Мәдәни җомга. *Теләгән кешеләр өч чәй кашыгы лимон кабыгы яки бер чәй кашыгы төелгән кардамон, 0,5 чәй кашыгы мөшкәт чикләвеге,*

өч-дүрт чәй кашыгы ванилинлы шикәр комы, 25 грамм коньяк сала ала. Хезмәт даны

МӨШКЕЛ *с. гар.* Авыр, кыен; начар. *Ул көнне остаханәдән чыкканда, Хәнәфинең хәле бик мөшкел иде.* М.Маликова. *– Сугыш башлангач, хәлләр мөшкел инде ул, – диде Нәгыйм, бу яңалыкның чынлыгына әле барыбер тәгаен ук ышанасы килмичә.* З.Хәким. *Иҗат белән җитештерү тармагын бер шартларга кую, рухияттән матди керем өмет итү әдәбият-сәнгатьне бөтенләй дә мөшкел хәлгә төшерә.* Г.Морат

МӨШКЕЛЛӘНҮ *ф.* Авырлашу, кыенлашу, начарлану (эш-хәл тур.). *Шулай ук Шаһгалигә тәлинкә тотып, әлеге ташка үлчим ханның юк абруен сакларга тырышып йөргән «олы морза» һәм, хәле мөшкелләнгәч, аңа Казаннан качып китәргә ярдәм иткән «зур сәяси фигура» да – ул.* М.Бакиров. *Хәле мөшкеллә нсә, абзыйның күзлеге тирли башлый.* З.Зәйнуллин. *Күп итеп эчәләр дә, хәлләре мөшкеллә нә.* Ф.Җамалетдинова

Мөшкеллә нә бару Торган саен мөшкеллә нү. *Хәленең мөшкеллә нә баруын тоеп, Василий ашыгыч рәвештә Мәскәүгә васыятьнамә артыннан чапкыннар җибәрә.* М.Әмирханов. *Әмма вазгыять тискәре якка шулкадәр тиз үзгәрә, авыл һәм игенче тормышының отары мөшкеллә нә баруын бик игелекле Татарстан вәзире дә туктата алмый кебек инде.* М.Әхмәтҗанов

Мөшкеллә нә башлау Мөшкеллә нү билгеләре күренү, сизелү. *Чөнки аның хәле тагы да мөшкеллә нә башлады: башы әйлә нә, күз аллары караңгыла на, косасы килә.* С.Поварисов

Мөшкеллә нә төшү Тагын да мөшкеллә нү; бераз мөшкеллә нү. *Колхоз төзелгәч, халыкның хәле тагын да мөшкеллә нә төшкән.* М.Әхмәтҗанов

Мөшкеллә неп бару Вакыт үткән саен ныграк мөшкеллә нү. *Баксаң, бүген зур сәүдә үзәкләрендә дә хәлләр шактый мөшкеллә неп бара икән*. Татарстан яшьләре

Мөшкеллә неп калу Ниндидер сәбәпләр аркасында мөшкеллә нү, мөшкел хәлгә килү. *Агач, урман бетсә, үзебезнең хәлләр дә мөшкеллә неп калмасмы?* Г.Хөсәенов

Мөшкеллә неп китү Кинәттән мөшкеллә нү. *Драма театры белән хастаханәне генә төзеп бетерергә өлгерә алмыйча калдылар: рудникның хәлләре мөшкеллә неп китү сәбәпле, төзелешкә акча салуны кырт кисеп туктаттылар.* Р.Мирхәйдәров. *Иван Васильевичның хәле көзгә таба тагын да мөшкеллә небрәк китте.* М.Әмирханов

МӨШКЕЛЛЕК *и.* Авырлык, кыенлык, читенлек; авыр, кыен булу. *Тыйнак, сабыр, ярдәмчел дустым минем хәлләрнең мөшкеллеген аңлый – үзе ашаганда миңа да өлеш чыгара иде.* Ә.Рәшит. *Токиода мөселман мәктәбе ачылган вакытта иң зур мөшкеллек дәрес китаплары булмау иде.* Гасырлар авазы

МӨШМӘЛӘ *и. гр. бот*. Гөлчәчәкләләр семьялыгыннан җылы якта үсә һәм кызгылт көрән төсле әчкелт җимеш бирә торган кечерәк кенә агач; *русчасы*: **мушмула**. *Без яшәгән җирдә гади мөшмәлә күп үсә.* Казан утлары

МӨШТӘРИ *и. гар*. 1) Газета-журналларга язылучы, газета-журналлар алдыручы. *«Нашир вә мөхәррирене нең әмере илә туктатылган «Азат» газетасының мөштәриләренә мөддәтләре тулганчыга кадәр ошбу «Азат халык» газетасы күндереләчәктер».* Р.Әмирхан. *Ф.Әмирханның әйтүенә караганда, «ул җитәрлек мөштәриләр җыя алмый».* Ф.Ибраһимова

2) Клиент. *Урам буйлап барганда, берәрсе каршыңа чыгып: – Кызлар кирәк түгелме? – диеп эндәшсә, аптырарга кирәкми, бу адәм түләүле кызларга мөштәри эзли чыккан.* Р.Батулла

МӨШТЕК *и. нем*. Тартканда, сигарет кыстырыла торган җайланма; мундштук. *Гәпләшә-гәпләшә кофе эчкәннән соң, Нәҗмиев, райком заманнарындагы таныш мөштеген чыгарып, сигарет кабызды һәм, ике-өч мәртәбә тирән итеп сулыш алганнан соң, төтен эчендә элеккечә куәтле, усал зат булып гәүдәләнде*. Ф.Садриев. *Шул бертуктаусыз мөштек суырып йөргән ала күзле Дуга Диасның сүзен нигә өстен чыгарды?* Э.Шәрифуллина. *Коллекция бик сәер иде: папиростар, сигаретлар, төрле портсигарлар, эреле-ваклы трубкалар, кыска, озын мөштекләр, янчыклар, тимер шырпы каплары, зажигалкалар һәм бүтән тәмәке әйберләре белән шкаф бөтенләй тулган иде.* Г.Мөхәммәтшин

МӨЭМИН *с. гар. дини* **1.** Иман иткән, ышанган. *Әлхәмдүлилләһи, без үзебез мөэмин мөселманбыз һәм мөселман булып шәһит китәрбез!* Р.Батулла. *«Вә араларыннан берсе залимнәрдән хаксыз җәберләнсә, бергәләшеп ярдәм итеп, ул мөэмин кардәшләрен коткарырлар», – диелә 42 нче сүрәнең 39 нчы аятендә.* Х.Галәвиев

2. *и. мәгъ.* Мөселман. *Мөэмин булсаң, чын мөэмин бул, намазыңны калдырма ---*. Г.Тукай. *Әгәр дә без пакь калебле мөэминнәр булсак, безгә фәрештәләр: «Әй Аллаһының намаз ияләре! Сезгә Аллаһының рәхмәте булсын, киләсе намазга кадәр без Аллаһыдан сезнең гөнаһларыгызны истигъфар кылуын сорарбыз», – диеп шатланып калырлар, дия иде*. З.Хөсния р

МУАР *и. фр.* **1.** 1) Ефәк яки ефәксыман тыгыз тукыма. *Күлмәклек муар*

2) Өслегенә бизәк төшерелгән кәгазь. *Муардан ясалган котлау кәгазе*

2. *с. мәгъ.* Шундый материалдан эшләнгән. *[Валяның] артка җыеп куйган чәче өстендә ялтыравык муар бант, ул ачык бизәкле эре тропик күбәләккә охшап тора*. Р.Мирхәйдәров

МУАФИКЪ *с. гар.* Лаек, тиешле; яраклы; туры килгән. *Эшләгән эшең әхлакка муафикъ булсын, кешелеккә тугры килсен!* Г.Исхакый. *Мин ничек акылга муафикъ булмаган кешенең гамәлләре өчен җавап бирим?* Ф.Садриев. *Бүген – шулай ук алга карап планнар кора торган, максатыбызга муафикъ нинди эшләр башкарырга кирәк дип, үз-үзебезгә сораулар да бирә торган көн.* Р.Миңнуллин

МУАФИКЪЛЫК *и.* Муафикъ булу. *Бу китергәнем дәлилләр белән мин исемнең җисемгә муафикълыгы мәмдух вә матлуб икәнлегеен исбат иттем бугай.* Г.Тукай. *Һәр иҗат төренең үз премиясе булса, ул, әлбәттә, гакылга муафикълыгыннан, гаҗәпләнү тойгысы тудырмас иде.* Шәһри Казан

МУАФФӘКЫЯТЬ *и. гар. иск.* Уңыш. *Ләкин ул [Ш.Усманов] гадиихлас кына итеп өстәде: – Туташ, мин сезгә бүгенге концертта зур муаффәкыять телим --- !* Ә.Еники. *Без аңа хәерхаһ, Алла муаффәкыять бирсен.* Ш.Әхмәдиев. *Бу мишәр безгә караганда да ун өлеш артык муаффәкыять казанды.* И.Газиев

МУЕЛ *и. монг. диал.* Шомырт. *Каршыбызда күп муеллар, Муелларга кунган былбыллар.* Җыр. *Муел кыр ягына башын борган, Тыңлагандай һәрбер тавышны...* С.Шакиров. *Юл буена чыгып көтәр инде Әнкәм сыман боек муел да ---.* И.Юзеев

МУЕН *и.* **1.** 1) Кешедә, корыда яшәүче умырткалы хайваннарда гәүдә белән баш арасындагы нечкәреп килгән өлеш. *Габдуллажан чиста күлмәкыштаннан, муенына ак сөлге салып, сәке йөзлегендә сабыр гына утырып торды.* А.Гыйләҗев. *Колыннар яллары чак сизелерлек тотнаксыз муеннарындагы тупыйк борынлы башларын күтәреп, дөньяга гаҗәпсенүле карашларын юнәлттеләр.* Ж.Мостафин. *Муеннарын салып муеннарга, Тук бияләр бергә серләшә.* С.Гәрәева

2) Шешә, кувшин кебек әйберләрнең нечкәреп киткән урыны. *Картның андый-мондыйга алып куйган бер кызылы белән бер агы да бар иде, муеннарыннан гына тотып, аларны да чоланнан алып керде*. А.Гыйләҗев. *Аның чалбар кесәсеннән, тырпаеп, шешә муены күренеп тора иде*. Шәһри Казан

3) Чалгының сапка бөжралап беркетелгән урыны. *Ул чормадан чалгыны алып карады да, төзәттерәсе җирләре бар, муены бик йомшак, яңа бөжра кирәк булыр дип, тимерлеккә китмәк булды*. Г.Ибраһимов

4) *геогр*. Диңгез яки океан эчендәге коры җир кисәкләрен тоташтырган тар җир; муентык

2. муеннан *рәв. мәгъ.* 1) Муенга кадәр, бөтен гәүдә белән диярлек. *Шушы салкында муеннан суга чумды бит ул!* Ш.Камал. *– Безнең чишмәләрнең суы чыпчыкка муеннан, каргага тездән! – дип кычкырдылар залдан.* Г.Әпсәләмов

2) *күч.* Бик күп. *Чөнки Әмир абыйның бүгенгә билгеләнгән эшләре муеннан.* М.Хуҗин. *Эшләп үскән кешегә эш муеннан.* Г.Ахунов

3) *күч.* Бик нык, каты. *Ә Клара Сент – шул Ромеоны муеннан гашыйк итә алган Джульетта!* Р.Вәли. *– Муеннан гашыйк булган бит бу миңа, – дип уйлап куйдым*. Н.Шәрифуллин

◊ **Муен белән күтәрү** Эшләгән эшләр, гамәлләр өчен җавап бирү. *Кулы белән кылганын муены белән күтәрер.* Мәкаль. *[Акмулла:] Исукаев – кулы белән эшләгәнне муены белән күтәрергә тиешле ерткыч адәм!* Ю.Сафиуллин. **Муен бөгү** Баш ию, буйсыну. *Аның ачуы чыкканда, иң яхшысы – авызга су кабып тору... Башны иеп, муен бөгеп...* Р.Зәйдулла. **Муенга алу** 1) Гаебен тану, үз гаебен өстенә алу. *[Исмәгыйль:] Мин бу эшне эшләвемә үкенеп, гаебемне муеныма алам.* М.Фәйзи; 2) Үз өстенә эш, йөкләмә алу. **Муенга асылыну** 1) Кемне дә булса үзенә каратырга, үзеңнеке итәргә тырышу; башлап кемнеңдер артыннан йөрү. *Ник дисәң, шәһәрнең азгын, җай чыгуга әрсезләнеп муеныңа асылынырга торган маржасы түгел бит ул.* Н.Әхмәдиев. *[Гөлчирә:] Кайчан минем ирләрнең муенына асылынганым бар, ә?* Т.Миңнуллин; 2) Йөк булып тагылу, бәйләнү, йөдәтү. **Муенга атландыру** Башка кешегә үзеңнән файдаланырга юл кую, мөмкинлек бирү. *Шулай булгач, мин, ни пычагыма дип, авызын ачса – үпкәсе күренеп торган, тире белән сөяккә калган, бетләп, корчаңгылап беткән колхозны саклап ятарга, аны муенына атландырырга тиеш әле?!* Н.Әхмәдиев. **Муенга атлану** Башкалар хисабына көн күрү; башкалар өлешенә тию; кемнән дә булса файдалану. *Ул инде болай да күптән пенсиядә. Утырмасын безнең муенга атланып!* Р.Фәизов. **Муенга бау (җеп, элмәк) салу** Асылыну, асылынып үлү. *Агу эчәләр, имеш, теге хатын да шуның ачуыннан үз муенына җеп салган, имеш.* Ш.Камал. **Муенга йөкләү** *к.* **муенга алу**. **Муенга камыт кидерү** Эш, җаваплылык йөкләү; мәшәкатьләндерү. *Бу алып калулар вакытлыча гына булды. Теләсә кайсы көнне муеныма камыт кидерергә мөмкиннәр минем.* Ф.Яруллин. **Муенга камыт кию** Җаваплылык алу турында. *Яшьлекне дә бераз күрергә кирәк, өйләнгәч, муенга камыт киелә, дөнья баса башлый.* Г.Әпсәләмов. **Муенга тагылган таш** Авырлык; мәшәкать, кыенлык тудыручы әйбер, кеше. *Муенга тагылган таш булдың.* Әйтем. *Бурыч – адәм баласының муенына тагылган таш ул.* А.Гыйләҗев. **Муенга тагылган таш кебек** Кемдер, нәрсәдер аркасында барлыкка килгән мәшәкать, авырлык. **Муенга тагылу** 1) *к.* **муенга менеп атлану**. *[Нурия:] Быел да шулай өчәүләп минем муенга тагылмакчы буласызмы әллә?* К.Нәҗми; 2) Кемгә дә булса авыр йөк булу. **Муеннан ашу** Бик күп булу, кирәгеннән артып китү. *Эше дә, мәшәкате дә муеннан ашкан.* Ватаным Татарстан. **Муенны кисү** Максатка, теләккә ирешүдә нинди дә булса киртә, каршылык, комачау турында. *Акча юклык кисә лә муенны ---.* А.Нуруллин. **Муен тамыры бүртү (кабару)** Ачу кабару, кызып китү. **Муен сындыру** Имгәтү; сәламәтлеккә зыян китерү. *[Рашат:] Күп сораштыра башласаң, муеныңны сындыруы бар.* Ф.Садриев. **Муенын бору** Шелтәләү, ачулану, җәза бирү. **Муены астына килсен (килгере)** *к.* **муены сынсын**. *Ах, мин әйтәм, муеның аска килгере!* И.Гази. **Муены сынсын (сынгыры)**. «Бетсен», «дөмексен» дигәнне аңлаткан сүгү, ачулану сүзе. *Муены сынсын инде бу таркаулыкның!* М.Юныс. *Тик явыз дошманның тизрәк муены сынсын иде дә, балалар кайтып күзгә күренсеннәр иде – көн-төн ялварып теләгән, өмет иткән нәрсә шул гына инде, шул гына.* Ә.Еники. **Муены сыну** Юкка чыгу, һәлак булу; теләгенә ирешә алмау. *Дусның күңеле калганчы, дошманның муены сынсын*. Мәкаль

МУЕНСА *и.* 1) Таш, пыяла, агач һ.б. материалдан төрле формада һәм зурлыкта эшләнгән төймәләрне җепкә тезеп муенга тагу өчен ясалган бизәнү әйбере. *Борынгы көмеш беләзек белән гәрәбә муенса да Габделнурга кечкенәдән таныш*. Р.Кәрами. *Гәрәбә нурыдай хәтер Яктырта күңелемне: Гәрәбә*

муенса таккан Әнкәм ачты телемне! Э.Шәрифуллина. *Муенса шунысы белән аерылып тора: аның биш рәт тезелгән энҗеләре кыл уртадан бик тә матур зур зөбәрҗәткә тупланган иделәр*. Р.Мирхәйдәров

2) Муенга элү өчен алтын, көмештән ясалган бизәнү әйбере; чылбыр. *Заһит бик тиз генә акчаларны йомарлап кесәсенә тыкты, ә үзенең күзләре тартмадагы алтын муенсага төште*. Ф.Яруллин. *Илгизә янә көмеш муенса – чылбырына тагылган «Корт» догасын учына кысты.* Ф.Җамалетдинова. *Хәер, аңа хәзер эш кирәк тә түгел иде: хатынның алтын-көмеш муенсалардан, алкалардан, беләзек-йөзекләрдән торган тулы бер хәзинәсе барлыкка килде* ---. Х.Ширмән

3) *к.* **муенчак**. *Эт муенсасына элә-ктергән каешын тарткан килеш, Касьянов та Памир артыннан йөгереп төште.* М.Насыйбуллин. *[Әйдүк] Караборынның муенындагы муенсасын алды да муенса эченә төрелгән берничә кәгазь чыгарды*. Һ.Такташ

МУЕНСЫЗ *с.* 1) Муены булмаган; муены беленмәслек дәрәҗәдә булган. *Шул китүеннән үзе шикелле үк тәбәнәк, дәү чуен башлы, муенсыз рус егетенә кияүгә чыгып, бергә җайсыз кысылышып төшкән сап-сары фотоларын аналары Зөләйха күрсәтеп йөргән шул*. Д.Салихов. *– Бүгеннән мин – Күмер Тау главасы, – дип, Калын ирен гөл чүлмәген хәтерләткән йомры башын горур гына өскә чөймәкче иде, муенсыз баш селкенмәде, оясындагы күзләр генә төпкә тәгәрәде.* Н.Гыйматдинова

2) *күч.* Йомшак холыклы, принципсыз. *Муенсыз ирләр белән хатын-кызлар идарә итә.* Сөембикә

МУЕНСЫЗЛАНУ *ф. сөйл.* Йомшак холыклы булу, принципсызлык күрсәтү. *Муенсызланып яшәгәннәр телә-кләренә дә тизрәк ирешә түгелме әле?!* Шәһри Казан

Муенсызланып кую Бер тапкыр яки тиз арада муенсызлану. *Закир болай әйбәт егет үзе, ләкин кайбер вакыт бик беркатлылана, анасы сүзенә ятып, муенсызланып та куйгалый*. Г.Ибраһимов

Муенсызланып тору Гел, һәрвакыт муенсызланган хәлдә булу. *Муенсызланып торсаң, өстеңә менеп атланырлар.* Казан утлары

МУЕНТЫК *и.* 1) Нәрсәнең дә булса тараеп киткән урыны. *Утыртыр алдыннан, полиэтилен савытның бер ягын әз генә кисәсең дә, туфрагын таратмыйча салдырып аласың һәм үсентене, оячыкларга утыртып, туфрак белән күмәсең, тамыр муентыгы янына әзрәк яңа туфрак өстисең дә муентык яныннан бераз туфрак белән кысып куясың*. Безнең гәҗит. *Агачны исә казыкның төньягына тамыр муентыгы җирдән 4–5 см югарырак булырлык итеп урнаштыралар.* Без гөлләр яратабыз

2) *геогр*. Коры җирнең ике зур өлешен (мәс., ике материкны) яки материк белән ярымутрауны тоташтыра торган бер буй җир; *русчасы:* **перешеек**

3) *анат*. Нинди дә булса органның муенга охшаган өлеше. *Ун процентлы прополис мае томау төшкәндә, пешкәндә, өшегәндә, геморрой булганда, аналык һәм аналык муентыгы ялкынсынганда булыша.* Мәдәни җомга. *Аналык тәнчеге белән аналык җиңсәсе арасында урнашкан муентык исә әлеге ике органны тоташтыручы канал сыйфатын үти.* Сөембикә

МУЕНЧАК *и.* 1) Хайван муены-на кидерү яки бәйләү өчен махсус эшләнгән каеш яки юка бау. *Эт муены-на энҗе муенчак такмыйлар*. Мәкаль. *Муенчак белән бәйләнгән бозау төсле, Мөҗәһит ул кичтә Хәлимәне озата ук китте.* В.Имамов. *Зәбир аның [бозауның] тамак астын кашып тора, мин муенчагын ычкындырам*. М.Галиев

2) *сөйл.* Матурлык өчен, модага ияреп яисә башка максат белән муенга бәйләнгән, тагылган әйбер. *Ә муенына стиляга булып муенчак тагып кайткан (Барый малае).* А.Хәсәнов. *Иркен ага эндәшергә өлгермәде, аннан, гадәтенчә, майланып беткән калын постау костюмын һәр сәдәфенә кадәр каптырган, ак күлмәктән, муенына һаман да шул кызгылт муенчагын чалшайтып бәйләгән Лотфрахман күренде*. А.Хәлим. *Ә мин, улымның ачуын чыгарып тормасын әле дип, бу малайга сүз катырга булдым: – Нинди муенчак асып йөрисең син?* В.Нуриев

3) *күч*. Дар агачы элмәге. *Сатлык җаннарның язмышы һәркайчан я муенчак, я пуля астында тәмамлана.* Казан утлары

4) *күч*. Бәйлелек, ирекле булмау. *Чылбыр буенча шул рәвешчә китсәң, барлык әсирләрне дә муенчактан азат итү мөмкин.* В.Имамов

◊ **Муенчак кию** Кешенең үз өстенә җаваплылык алып ниндидер дәрәҗәдә ирегеннән мәхрүм булуы. *Без шул дөньяда бөтен галәмне күз алдында тотып яшәргә хаклы, ә бәйләнгән хәлдә, муенчак кигән хәлдә түгел.* Ә.Баян. *Ирек, азатлык, имеш, Муенчак кигән килеш...* Г.Морат. **Муенчак салу** 1) Асу. *Ябу гына түгел, синең кебекләргә муенчак салырга да кыйбат алмыйбыз.* Т.Гыйззәт; 2) Ирексезләү, көчләү, куркытып мәҗбүр итү. *[Гыйм-ран:] Муеныма муенчак салсагыз да өйләнмәм.* Т.Гыйззәт; 3) Тыю, теләкләренә комачаулау

МУЕНЧАКЛА́У *ф.* **1.** 1) Муенчак салу, кидерү. *Бозау комиссиясендәгеләр өй борынча кереп, муенчаклап, бозауларны алып чыга башладылар*. Р.Батулла

2) *күч. к.* **муенчак салу** (*1, 2 мәгъ.*). *Аны киткән җиреннән муенчаклап кына кайтарып булыр*! Ф.Бурнаш

2. муенчаклап *рәв. мәгъ.* 1) Муенчак белән. *Баулар табып китерүгә, бозауларны муенчаклап чыгара башладылар.* З.Фәйзуллин. *Бозауны муенчаклап алып чыгып китәләр.* Г.Бәширов

2) *күч*. Ирексезләп, мәҗбүр итеп. *Ул сизде: өч бала анасын елата-елата, муенчаклап дигәндәй, яңа йортка өстерәп илтү хәерлегә булмаячак, әлбәттә*. Ә.Еники

МУЖИК *и. рус сөйл.* 1) Крестьян. *Ачлыктан кем интегә? Иң түбән катлау вәкилләре – авыл мужигы, картлар һәм сабыйлар...* Р.Мөхәммәдиев. *[Ким:] Әгәр дә син Ленин булсаң, патшалар, олигархлар белән көрәш. Ленин бабаң шулар белән алышкан, мужикка акыл сатып маташмаган.* Т.Миңнуллин

2) Түбән катлам, гади халык вәкиле. *Бездә әүвәл халык «мулла», «мужик»*

исеме белән фәкать икегә генә бүленә иде. Ж.Вәлиди. *Бер урыс мужигы әйтмешли, кулың башка эшкә ятмагач, нишлисең инде.* Т.Нәҗмиев. *Ул үзен гадәти бер кесә карагы – дөньяның кая таба барганын бигүк аңлап бетерми торган мужик итеп күрсәтергә тырышты.* З.Фәтхетдинов

3) Ир-егет. *Урамда бер малай белән басып торалар икән, күрше йорттан мужик чыккан да боларны сугышырга котырткан.* В.Нуриев. *Ничек инде чалгы тапый белмәскә мөмкин? Мужик башың белән!* А.Хәсәнов

4) Хатын ире. *Мужигы бик усал*

МУЖИКЛЫК *и. сөйл.* Мужик булу. *Әтисенең күңелендә үзенең мужиклыгыннан, ягъни чыгышыннан ниндидер бер кимсенү яши иде кебек.* Р.Мөхәммәдиев. *Беренчедән, идәнгә ит кисәге ташлау – мужиклык, икенчедән, әгәр башың булса, кафе мәчесенең ач түгеллеген син белергә тиеш.* Т.Миңнуллин. *Киез эшләпә ул – мужиклык билгесе.* Р.Батулла

МУ́ЗА *и. гр.* 1) Грек мифологиясендә: фән һәм сәнгатьне яклаучы тугыз алиһәнең берсе

2) *күч.* Иҗат дәрте, иҗат көче, илһам. *--- Шәрифнең җитмеш беренче елда сиңа – бердәнбер музасына! – салкынлык күрсәтүен мин, мәсәлән, шулайрак аңлыйм.* Р.Юсупова. *Ишетәсеңме, Пушкин, музаң синең – «Азатлык байрагы»м күптән минем.* Ә.Синугыл-Куганаклы. *Монда кошлар җыела, монда шигърият дөньясы, монда шагыйрь патшалыгы, музалар шаукымы.* Казан утлары

МУЗЕЙ *и. гр.* Тарихи, табигый, техник һ.б. экспонатларны, сәнгать әсәрләрен җыя, туплый, саклый һәм күргәзмәгә куеп халык хозурына тәкъдим итә торган махсус оешма һәм әлеге экспонатлар тупланган урын, бүлмә, бина. *--- Тимерхан абзый соңгы ике елда үзе төзегән музейга барып килмәкче иде, хат ташучы хатын аңа бер зур конвертта хат кертеп бирде.* Г.Ахунов. *Музейда иске күн бүрек, кыршылып, буялып беткән пальто кигән, кулына чүкеч тоткан ач яңаклы бер ир-атка очрадым.* Т.Әйди. *Күгәрә башлаган чаң кыңгыравын Хәйретдин агай мәктәп музееннан барып алды.* А.Гыйләҗев

МУЗЕЙ-ЙОРТ *и.* Билгеле бер шәхеснең үзе яшәгән йортта (бүлмәдә, квартирда) оештырылган музее. *Гадел Кутуйның туган авылы Татар Кынадысында аның музей-йорты барлыгын һәм анда укытучы Талия Хәбибуллинаның тырышлыгы белән бик яхшы экспозиция эшләп куелганлыгын ишетеп сөендек.* А.Юнысова. *Авылда С.Хәкимнең музей-йорты бар.* Ф.Гарипова

МУЗЕЙЛАШТЫРУ *ф.* Музей итү, музей ясау; музей статусы бирү. *Болгар шәһәрендә 24 тарихи һәйкәлне ачыклап, музейлаштыру ниятләнә.* Туган як. *Минтимер Шәймиев объектларны музейлаштыру буенча тагын аерым җыелып сөйләшергә тәкъдим итте.* Ватаным Татарстан. *Музейлаштыру эшләрен төгәлләгән музей-тыюлыкка карата җитди хилафлыклар булмаса да, Зилә Вәлиеваның яңа урынга килүе аңа яңа үрләр яуларга мөмкинлек бирәчәк, дип саный премьер-министр.* Шәһри Казан

МУЗЕЙ-САКЛАУЛЫК *и.* Күчемсез истәлекләр, тарихи-мәдәни объектлар урынында ачык һавада оештырылган гадәттә берничә музей. *Конференция кунакларын «Казан Кремле» тарих-архитектура һәм сәнгать музей-саклаулыгы белән таныштыру каралган иде.* Казан утлары. *Бүгенге киңәшмәдә бистә территориясендә музей-саклаулык булдыру варианты каралды.* Ватаным Татарстан

МУЗЕЙ-ТЫЮЛЫК *и.* Экспозицияләрдән тыш, сакланырга тиешле архитектур, тарихи һәм табигый һәйкәлләрне дә үз эченә алган ачык һавадагы музей төре. *Агымдагы елда музей-тыюлык периметры буенча видеокүзәтү камералары куелды.* Мәдәни җомга. *Болгар дәүләт тарих, архитектура музей-тыюлыгына федераль әһәмияткә ия тарихи һәм мәдәни мирас объектлары керә.* Гасырлар авазы

МУЗЕЙЧЫ *и.* Музей хезмәткәре; музей белгече. *Музейчыларыбызның үткән ел башкарган эшләре аеруча мактаулы. «Татар халкы һәм Татарстан дәүләтчелеге тарихы» музее ачылу гына да ни тора!* Р.Фәйзуллин. *Ярый, без бу хурлыкка түздек. Илшат та түзде (ул музейчылар командасының өченче әгъзасы иде).* Н.Гамбәр. *Музейчылар фондларның куркынычсызлыгын тәэмин итү, яңа төр күргәзмәләр булдыру, халыкны төрле чараларга җәлеп итү юллары, төрле белем бирү программаларын кертү, туристлык эшен җәелдерү буенча фикер алышачак.* Мәдәни җомга

МУЗИКӘН *и. рус иск.* Гармун. *Кулларында музикән, Шул музикән уйнаганда Ишми ничек түзәйкән?* Г.Тукай

МУ́ЗЫКА *и. гр.* 1) Чынбарлыкны көйле сәнгать образлары аша тасвирлый торган сәнгать төре. *Әйтерсең күз алдымда бер мәлгә ак мәрмәрдән терелеп килгән җанлы сын пәйда булды, әйтерсең колагыма гаҗәеп бер нәфис музыка чагылып узды.* Ә.Еники. *Ядкәр магнитофонны тәрәзә төбенә куеп музыка җибәрә.* И.Юзеев. *Музыка өлкәсендә эшләүчеләр татар моңын сакларга, күтәрергә бурычлылар.* Шәһри Казан

2) Шундый төр сәнгать әсәре яки әсәрләр җыелмасы. *Музыка тавышын бүлергә теләп, кешеләрнең кайгыга уралгач авырайган сүзләрен йотарга ашкынып, туктаусыз шаулый иде буа арыгы...* А.Гыйләҗев. *Төрле утлар белән балкып торган ярымкараңгы залда кызлар, егетләр кыргый музыкага дөньяларын онытып бииләр.* Ф.Садриев. *Рульдә утырган Миршаб магнитофоннан агылган музыка тавышына башын селкеп утыра: ул бию көйләрен үлеп ярата иде.* Р.Мирхәйдәров

3) Көй; җыр. *Күрәсең, музыка, гомумән сәнгать кешене яшәртә торгандыр.* Г.Бәширов. *Гөлшат апа үз гомерендә шактый күп пьесалар – драмалар, комедияләр иҗат итте. Аларның күбесенә композиторларыбыз музыка язды.* Казан утлары

4) *күч.* Әйләнә-тирәдәге, табигать-тәге һәртөрле тавышларда авазлар аһәңлелеге, гармониялелеге; колакка ятышлы булган авазлар тезмәсе. *Туплар музыкасы ул вакытта батыр көрәшчегә дәрт бирде.* М.Җәлил. *--- Басу музыкасын тыңларга, Гудок*

җиңешләрен сөйләргә Барыгыз сез дә безнең кырларга!.. М.Җәлил. *Әмма бу шыңгырдау яшь ана торналар өчен ягымлы музыкадай яңгырый.* Кызыклар дөньясында

МУ́ЗЫКАЛАШТЫРУ *ф.* 1) Музыкага салу. *Студия елларына кадәр драма әсәрләрен музыкалаштыру өлкәсендә иң күп эшләүче композитор Салих Сәйдәшев булды.* М.Җәлил

2) Музыка (*3 мәгъ.*) катнаштыру, музыкаль бизәлеш кертү. *Салих Сәйдәшев белән бергә бу елларда шулай ук сәхнә әсәрләрен музыкалаштыру, халык җырларын гармонияләштерү, шагыйрьләрнең текстларына җырлар язу буенча М.Мозаффаров, А.Ключарёв, Ж.Фәйзи һ.б. эшләп килделәр*. М.Җәлил

Музыкалаштырып бетерү Музыкалаштыруны төгәлләү

Музыкалаштырып чыгу Барысын да музыкалаштыру; һәрберсен аерым-аерым музыкалаштыру

МУ́ЗЫКАЛЫ *с.* 1) Көйле, җырлы; көйгә, җырга салынган. *Очрашу программасында язылганча, алар шаяншук музыкалы «Дон Кихот» балетыннан вариацияләр башкарырга тиеш иделәр.* Р.Вәли. *Бу әсәр – музыкалы, җырлы, уенлы тамаша.* Р.Батулла

2) *к.* **музыкаль** (*3 мәгъ.*). *Хәерниса элекке матур, уенчак, җиңел музыкалы тавышын да югалтты, элекке шаян сөю җырлары аның теленә, ничектер, килми башладылар.* Г.Ибраһимов

МУЗЫКАЛЬ *с.* 1) Музыкага мөнәсәбәтле. *Музыкаль редакциядә Татарстанның халык артисты, күренекле җырчыбыз Рафаэль Ильясов кул астында эшләү, --- музыкаль тапшырулар әзерләү, ул тапшыруларны радио тыңлаучыларга эфир аша җиткереп бару, әлбәттә, эзсез югалмый*. Р.Миңнуллин. *[Х.Бадыйков] Хәзерге вакытта Казан дәүләт консерваториясе доценты, шул ук вакытта әдәби-гыйльми, музыкаль иҗат белән дә шөгыльләнә.* Казан утлары

2) Музыка чаралары белән белдерелә торган. *Фуат Мансуровның дөньякүләм мәшһүр музыкаль әсәрләрне --- үз репертуарында сакларга омтылышы һәм аларны яңача шәрехләве ул җитәкләгән оркестрның музыка сөючеләр алдында ифрат уңыш казануына китерде.* Р.Халитов. *400 еллык музыкаль әсәрләрнең, бүгенге нотага күчерелеп, беренче мәртәбә әлеге чарада яңгыравы тамашачыларга да, премия ияләренә дә зур бүләк булды*. Мәдәни җомга

3) Колакка ятышлы, матур яңгырашлы. *Аның [Г.Ибраһимовның] җөмләләре философлар телендәгечә тирән мәгънәле, шул ук вакытта образлы, музыкаль яңгырашлы, халыкчан булалар ---*. Г.Бәширов. *Яңгырап тора торган аһәңле, музыкаль атама ул Сарман*. Ф.Гарипова. *Данлы иҗатыннан башка, аның [С.Сәйдәшевның] бит әле исеме дә ничек музыкаль яңгырый!* С.Шамов

4) Музыка белән башкарыла, музыка белән үрелеп бара торган. *Аерым алганда, бу чорда чынбарлык белән тыгыз бәйле конфликтлар алга чыга, музыкаль драма җитди үсеш кичерә, яңа жанр формалары пәйда була һ.б.* Ә.Закиржанов. *Татар тамашачысы ул – аерым халык, ул музыкаль әсәрләргә битараф түгел, дип кенә әйтү аз.* Д.Гыймранова. *1961 елда Ш.Бикчурин үзенең «Тальян моңы» исемле музыкаль комедиясен яза, һәм бу әсәр шул ук елны Әлмәт театрында, ә бераз соңрак Татар дәүләт опера һәм балет театры сәхнәсендә куела*. Казан утлары

5) Музыкага мөкиббән; җырмузыканы аңлаучы, тоючы; хисле. *Карлен үзе дә, музыкаль гаиләдә үскәнлектән, гитарада менә дигән уйный, фортепьяноны да чит итми, студентлык елларында яшьләр төркемендә җырлап та йөрде.* Р.Мирхәйдәров. *Әмма шундук аның хәрәкәтләреннән бу кешенең искиткеч дәрәҗәдә музыкаль кеше икәнлеген күреп сокланып калдык.* Г.Бәширов

6) Музыка яңгырату өчен билгеләнгән, шуның белән бәйле (диск, кассета һ.б.ш.). *Бүлмәсендә музыкаль үзәк урынына ниндидер кара төстәге иске радио тора*. А.Галиева. *Шулай диюе булды, үзләре бүләккә дип алып килгән музыкаль үзәкнең төймәсенә басты*. Ф.Баттал

МУЗЫКАЛЬЛЕК *и.* Музыкаль булу; аһәңле, матур яңгырашлы булу. *«Бабич шигырьнең музыкальлегенә аеруча игътибар итә иде», – дип язды Туфан*. Г.Гыйльманов. *Шул укуда үзенә бер музыкальлек, көйлелек бар иде.* Г.Бәширов. *Сезнең сөйләмдә ниндидер үзенчәлекле яңгыраш, музыкальлек бар, дип әйтимме...* Н.Әхмәдиев

МУЗЫКАНТ *и. пол*. 1) Музыка белгече. *Музыкант! Пианист! Быел консерватория бетерә.* М.Маликова. *Боларның өенә шагыйрьләр, музыкантлар, рәссамнар җыела, һәм, еш кына әдәби-музыкаль салон оештырып, яшьләр күңел ача*. Р.Батулла. *Ильяс Ислам улының шәкертләре арасында хәзерге вакытта танылган музыкант һәм педагоглар шактый.* М.Макаров

2) *к.* **музыкачы** (*2 мәгъ.*). *Кичләрен сукыр лампа яктысында Тукайның ятимлеге турында елый-елый укып утырулар, сукыр музыкантларның бәхетсез язмышларын җиңеп чыгуларын белү Тимерханның китек күңеленә дәва булып, җанында өмет уты кабыза торган иде.* Г.Ахунов. *Сафия музыкантларның, биючеләрнең, җырчыларның һәркөнне күп сәгатьләргә сузыла торган ялыктыргыч репетицияләрен күз алдына китерде.* М.Маликова

МУЗЫКАНТЛЫК *и.* Музыкант булу; музыкант һөнәре. *Сиңа Ходай музыкантлык сәләтен дә биргән шул!* Г.Ахунов. *Мирсәет абый, Сезнең композиторлык, музыкантлык юлыгыз кышкы урамнардан буранлар туздырып узган чаналардагы сәяхәттән башлана да бугай инде.* Р.Вәлиев. *Хикәяләүче герой иптәшенең табигатьне яратуына, аның «моңнарын өзелеп тыңлавына» малай чактан ук гадәтләнгән, шуңа күрә Фәтхинең музыкантлык юлын сайлавы аңа табигый күренә.* Р.Рахман

МУ́ЗЫКАЧЫ *и.* 1) Музыка белгече. *Шулай ук музыкалы «Башмагым» опереттасы да азмы-күпме уңыш тапты, һәм, Казанда дәүләт татар театрында бу әсәрләрне уйнаган чагында, Салих Сәйдәшев дигән яшь музыкачы үзенең дирижёрлыгы белән танылды.* Татар театры

2) Музыка коралларында уйнаучы. *Төрле җирдән тупланган уенчы, җырчы, музыкачы төркемнәребезне берләштереп, бер милли төркем ясау эше шактый авыр булды.* Г.Исхакый

МУКСУН *и. лат. зоол.* Сөләйман балыклар семьялыгыннан төче сулыкларда тереклек итә торган кыйммәтле промысел балыгы. *Соңрак без аны сайлап – нельма, сирак, муксун, керкә ишеләрен генә ашый торган идек.* М.Хәсәнов. *Муксун ул – Себер елгаларында гына үсә торган балык.* Р.Батулла

МУКШЫ *и.* Мордва халкының ике этник төркеменнән берсе. *Хәер, мордва ике халыктан тора: эрзя һәм мукшы.* Р.Кәрами. *Аларга шушы тормыш бәхетле, шушы кешеләр – ана сөте белән кергән телдә сөйләшүче авылдашлар, күршедәге чувашлар, урманның теге ягындагы урыслар, алардан да тегендәрәк урнашкан мукшылар белән сабан туйларындагы бәйге-ярышлар, көрәш-алышлардан да бүтән тормыш, шуннан гайре башкача бәхет юк иде.* Г.Кашапов. *Шулай итеп, әйләнә-тирәбездә балалар өшкерүче бер әбекәй дә калмагандыр. Чувашы, мукшысы, маржасы, татары!* А.Хәсәнов

МУКШЫ́ЧА *рәв.* **1.** 1) Мукшы телендә. *Марва бит бик кулай белгеч: рус телен дә, татар телен дә белә, чувашча, мукшыча аңлаша ала.* Ә.Баян. *Тик ни русча, ни мукшыча бер авыз сүз белмәгән ике яшьлек балага бер дә җиңел булмады.* С.Арсланова

2) Мукшыларга охшашлы итеп, мукшыларга хас булганча. *Мукшыча бию*

2. *с. мәгъ.* Мукшы телендә булган, мукшыларга караган. *Ичмаса бер генә булса да мукшыча сүз булсын иде дә бит – юк инде ...* Римзил Вәлиев

МУЛ *с.* **1.** 1) Бик күп, шактый. *Әйе, әйе, гомерләре озын булсын, бала-чагалары мул, абзар тулы мал, авызлары бал да май булсын!* Г.Бәширов. *Күрәсең, иртәгә ятим каласы балаларын уйлагандыр, ә аның балалары – кыздан-малайдан нәкъ алты баш иде, безнең авыл хатыннары гомумән баланы мул табарга яраталар.* М.Мәһдиев. *Казлар симергән, тулләре мул, шаярасылары килә.* А.Гыйләҗев

2) Бай. *[Балтамар:] Мул тормышта яши торгач, безнең дәвам булыр юлбарыстай.* Ә.Баян. *Инде мул табыныбызда хуш ис бөркеп торган ак күмәчне күкрәккә терәп кискәндә, безнең буын шул елларны да кабат искә төшерә.* Р.Әхмәтҗанов. *Хәзер мул тормышта яши, кунакка йөри, мәҗлесҗыя.* М.Мәһдиев

3) Иркен, киң, зур (күләме белән). *Татар китабы, гомумән татар матбугаты, империянең дистәләгән регионнарында мул күләмдә, күп санда нәшер ителгән.* Р.Фәйзуллин. *Өйалды ишеге тагын күгәненнән кубарлык булып ачыла, Сабирәттәй, мул күкрәген киереп, тагын чәлдер-чөлдер.* М.Галиев. *Төсе уңган кофтасы ярыйсы ук мул, бәлки, анасыныкы булгандыр.* Ш.Рәкыйпов

2. *рәв. мәгъ.* Күп, җитәрлек. *Көн – сайлап куйган кебек: кояшы да мул булды, яңгыры да таманча гына явып китте, җитмәсә күк гөмбәзе аша бөтен төсләрен уйнатып салават күпере дә пәйда булды...* Г.Гыйльманов. *Җиргә рәхмәт: байлыкны мул бирә.* М.Зарипов. *Кыз Фәрахның ак күлмәгенә мул аккан күз яшьләрен ышкып сөртте.* М.Хуҗин

◊ **Мулы белән** Артыгы белән

МУЛАТ *и. исп.* Кара тәнле белән ак тәнле халык вәкилләреннән туган кеше (нәсел, буын). *Биредә ак тәнлеләр белән берәттән кызгылт, мулат, метис, негр балалары да бар.* Р.Ибраһимов. *Негрлар белән ак тәнле кешеләрдән, гадәттә, мулатлар туа.* Генетикадан лаборатор практикум һәм мәсьәләләр

МУЛАЮ *ф.* 1) Күбәю, арту. *– Уңышлар елдан-ел мулайсын, артсын өчен, сезнең тырышлык кирәк, – диде районнан килгән вәкил.* Татарстан яшьләре

2) Зураю (кием-салым тур.). *Мулайган кофта*

Мулаеп китү Соңгы вакытта мулаю. *Соңгы елларда шактый мулаеп киткән байлыгы өчен дер калдырап утыра хәзер ---.* Казан утлары

Мулая башлау Муллык билгеләре сизелү. *Дәрәҗә зураю сәбәпле, керәчәк хосуллар да мулая башлаган иде.* Г.Ибраһимов

МУЛДАН *рәв.* Күп итеп, артыгы белән. *Зур сәфәргә юлга чыксаң әгәр, Мулдан майла арбаңның күчәрен.* Ә.Синугыл-Куганаклы. *– И, безнең Степан кияү дә шулай, – диде карчык. – Эш хакын мулдан ала, Ходайга шөкер.* М.Насыйбуллин. *Булгач-булгач мулдан булсын, өч җептән катар җебен, май эчендә йөрсен әле егетнең кулы.* Р.Төхфәтуллин

◊ **Мулдан булу** Күпкә өметләнү, күпне көтү (өмет, исәп, планнар тур.). **Мулдан кылану** 1) Бай булуын, булдыра алуын күрсәтергә тырышу; 2) Байлыкны, акчаны юкка әрәм-шәрәм итү, күпләп тоту, тарату. *Күңелдән ул [Хисмәт] акчаларын санап мәш килә һәм унбиш меңенә нәрсә генә алачагын уйлап баш вата, Сабир кебек мулдан кылана алмаячагына уфтана иде.* Ф.Яхин. **Мулдан кубару** *к.* **мулдан кылану. Мулдан ычкындыру** *к.* **мулдан кылану**

МУЛИНЕ *и. фр.* Чигү җебенең бер төре. *Венера мулине җепләр белән чигелгән ак йон бияләенә саф сулышын өрде.* К.Кәримов. *Чигү өчен төрле материаллар – үзләре суккан һәм сатып алынган тукымалар, йон һәм ефәк җепләр, мулине, кәнитил, сәйләнфайдаланганнар.* Гомер агачы. *Әле дә күз алдында: тукыманы зур киергә тарттырып, төсле мулине җепләр белән чигә торган иде.* Шәһри Казан

МУЛЛА *и. гар.* 1) Имам, мөәззин, казый һ.б.ш. дин әһелләренең гомуми исеме; мәхәлләдә дин башлыгы. *Гафу итәрлек дәрәҗәдә генә кичеген, Гыйният мулла килеп җитте.* М.Әмир. *Әткәй белән әнкәйне беләсең, ярлы булсалар да, дингә ышаналар, муллаларны олылыйлар иде.* А.Гыйләҗев. *Мулла вазифаларын башкаручы Миңлегәрәй: – Әйдә, әйт, улым, нинди васыять бар иде? – дип сорады.* Ф.Садриев

2) *иск.* Мәдрәсә шәкерте һәм шул шәкерткә хөрмәт белән мөрәҗәгать итү сүзе. *Чү, мулла Әхмәтҗан, алай каты әйтмә.* Г.Камал. *Шәкертләр салкын һәйбәт су белән юынып, ап-ак сөлгеләр белән сөртенеп бетү белән, хәзрәт:*

– Әйдәңез, әйдәңез, әйдә! Хуш, мулла Галим! Әйдәңез, сез кунак. Г.Исхакый

МУЛЛАБИКӘ *и.* Мулла хатыны. *Муллабикәләр мәҗлестән бик канәгать булып таралыштылар.* Казан утлары

МУЛЛАЛЫК *и.* Мулла вазифасы; мулла булу дәрәҗәсе. *Ләкин әти муллалыгын ташламады.* М.Хуҗин. *Шуңа да бит ул, ике ел моннан элек муллалыгын ташлап, үзенең туган-үскән авылы Уразайга кайтып, гади игенче һәм балыкчы булып көн күрә башлады.* Р.Ишморат. *Укуыңны дәвам итеп, бәлки, муллалыктан баш тарткач, нинди дә булса бүтән төрле укымышлы кеше булыр идең.* Ә.Баян

МУЛЛА-МӘЗИН *җыйый. и. к.* **мулла-мөәззин**. *--- һаман бер үк кул эшеннән алҗып, уйлау сәләтләрен югалткан вак һөнәрчеләр, кендек әбиләре, сөннәтче бабайлар, яучы карчыклар, имче-багучылар, мулламәзиннәр Габдулланы болай да туйдырган иде инде.* А.Расих

МУЛЛА-МӨӘЗЗИН *җыйый. и.* Муллалар һәм башка дин әһелләре. *Без мулла-мөәззин кайгыртмасак, диннe кем кайгыртыр инде!* Г.Исхакый. *Мулла-мөәззин берни дәшмәде, бугазларда төер – таш иде.* И.Ибраһимов

МУЛЛА-МӨӘЗИН *җыйый. и. к.* **мулла-мөәззин**. *--- Мулла-мөәзиннәрнең дә бар мал-мөлкәтен алып чыгып китәләр.* Ф.Гарипова. *Инде мулламөәзиннәрне дә сыйнфый дошманнар исәбенә кертеп, сөргенгә озатырга керешәләр.* К.Кәримов

МУЛЛА-МУНТАГАЙ *җыйый. и. кимс.* Муллалар һәм төрле дәрәҗәдәге дин әһелләре. *[Мөрти агай:] Кайткач, бернинди мәчетнең җыламаганын, бары контр мулла-мунтагайлар чыгарган бер провокацион уйдырма булуын әче итеп язып бирерсең.* Ә.Еники. *Сөннәт бабалары да, мулла-мунтагай да, хәреф таныткан хәлфә дә авылдан я куылды, я, берни янамаса да, үзләре үк чыгып качты.* Р.Рахман

МУЛЛАНУ *ф.* Баю, күбәю, арту. *Кызык, тормыш матди җәһәттән муллanган саен, авылларда алмагачлар кими.* Ә.Гаффар

МУЛЛЫК *и.* 1) Байлык; җитеш тормыш. *Тормышның тынычлыгы, муллыгы һәркайдан сизелеп тора.* М.Маликова. *Муллыкны, табынны-рыбызның ямен --- беренче чиратта көтүләрнең куәте хәл итә.* М.Зарипов. *Шушы муллыкка, шушы бәхеткә карап сөенешер кешесе юк иде Бибинурның.* А.Гыйләҗев

2) Киңлек, колач, тулылык. *Ә.Ерикәй кеше хисләрен бөтен муллыгында чагылдырырга мөмкинлек биргән халыкчан интонацияле, лирик аһәңле, формасы белән халык җырларына якын композицияле шигырьне үстерүгә зур көч куя.* Т.Галиуллин

МУ́ЛЬТИ- *и. лат.* Кушма сүзләрнең «күплек», «күп тапкыр» дигәнне аңлата торган беренче компоненты (мәс., *мультивакцина, мультиварка, мультипликация, мультимедиа, мультикарта* һ.б.ш.). *Ул да – шундый ук мультикультуралы, күпмилләтле шәһәр.* Сөембикә. *Семинар барышында Разил Вәлиевның тормыш һәм иҗат юлына багышланган мультимедиа басмасы да тәкъдим ителде.* Шәһри Казан

МУЛЬТИВИТАМИНЛЫ *с.* Төрле витаминнар катнашкан. *Нәкъ инде менә яхшы каралып, сусыл азыклар һәм мультивитаминлы органик өстәмәләр ашап, көненә өч тапкыр чистартыла торган җылы фермада үскән тананың югары сыйфатлы сыерга әйләнүе кебек...* Ж.Юныс. *Җиләк-җимеш, мультивитаминлы сыекчалар, бал, сыра чүпрәсе, солы боткасы һәм балык мае – чебеннең иң яраткан ашамлыклары.* Кызыклар дөньясында

МУ́ЛЬТИК *и. рус сөйл. к.* **мультфильм**. *Әллә инде татар халык әкиятен дә үз телебездә төшерә алмыйбызмы? Рус мультиклары болай да дөнья тулы, ник аңа акча әрәм итәргә иде?* И.Сиражи. *Чакыралар уйнарга, Әле мультик карарга, Әле чана шуарга – Эшне кая куярга?* Р.Шәрәфиев. *Хәзер безнең очта берничә бала бар икән... Алары да урамга бик борын күрсәтми, телевизордан мультик карап утыра.* Р.Зәйдулла

МУЛЬТИМЕ́ДИА *и. лат.* Төрле форматтагы мәгълүматны экранга чыгара торган интерактив җайланма. *Укытучылар һәм укучылар өчен ярдәмлек, методик әсбап – Ф.Яруллин иҗатына багышланган мультимедиа проекты әзерләнгән.* Мәгърифәт. *Күргәзмәне классик ысул белән төзүдән тыш, мультимедиа технологияләре дә кулланылган.* Казан утлары

МУЛЬТИПЛИКАЦИОН *с.* Мультипликациягә мөнәсәбәтле; мультипликация кулланып эшләнгән. *«Анимация» номинациясенә исә Татарстанда төшерелгән биш мультипликацион картина сайлап алына.* Ватаным Татарстан. *Фильмнар документаль, нәфис һәм мультипликацион төрләргә бүленгән.* Татарстан яшьләре

МУЛЬТИПЛИКА́ЦИЯ *и. лат. махс.* 1) Хәрәкәтнең эзлекле фазалары сурәтләнерлек итеп, аерым рәсемнәрне яки күләмле фигураларны кинога төшерү. *Укытучы фильмда мультипликация кадрлары түгел, ә тере тукымадан төшереп алынган тере күзәнәкләр күрсәтеләчәген дә белдерә.* З.Хисамов. *«Татармультфильм» берләшмәсе җитәкчесе Марат Ганиев мультипликация үрнәгендә дәүләт-хосусый хезмәттәшлекнең Татарстан мәдәниятен саклау һәм үстерүдәге файдасын искәртеп узды.* Шәһри Казан

2) Мультипликация ысулы белән төшерелгән фильм. *Проектның төп максаты – балаларда кечкенә яшьтән үк татар теле һәм әдәбиятына кызыксыну уяту, төрле рәсемнәр, тавышлар, мультипликация чаралары ярдәмендә дәресләрне күңелле итү, шул рәвешле укучыларны татар телен өйрәнүгә өндәү.* Мәгариф

МУЛЬТФИЛЬМ *и. рус* Мультипликация ысулы белән төшерелгән фильм. *Мәскәүдән кызыграк кино, мультфильм яисә сәламәтлек турында берәр тапшыру буласы була, Казан тапшыруына көн калмый.* Ф.Латыйфи. *Мультфильм башланса, бөтен эшебезне ташлап, телевизор карыйбыз.* Р.Миңнуллин. *Тел өйрәнүдә мультфильмнарның шундый көчкә ия икәнен уйлап та караган юк иде.* И.Сиражи

МУ́ЛЬЧА *и. рус а.х.* Мульчалау өчен файдаланыла торган материал.

Ә балансны саклар өчен, 5 см калынлыгындагы мульча ярдәм итә. Шәһри Казан. *Әлеге чаралар чүп үләннәрен юк итәргә һәм туфракта мульча барлыкка килүгә булыша.* Бакча серләре

МУ́ЛЬЧАЛАУ *ф. а.х.* Җылылык һәм дым саклансын өчен, туфрак өстен кәгазь, торф, салам һ.б.ш. нәрсәләр белән каплау. *--- туфрак йомшарту, коры үсентеләрне җыю, мульчалау эшләрен башларга иң кулай вакыт.* Бакчачылык. *Берьеллык үсентеләрне мульчалау өчен пычкы чүбе бик әйбәт икән.* Юлдаш

Мульчалап бетерү Мульчалауны төгәлләү

Мульчалый башлау Мульчаларга керешү

МУЛЯЖ *и. фр.* Төрле предметларның формасын төгәл кабатлый торган итеп, гипс, балавыз, парафин һ.б. материаллардан ясалган күчермә. *Төрле кошлар, җәнлекләр утыртылган читлекләргә, балыклы аквариумнарга, чәчәк, муляж, гербарийларга кызыксынып карап йөрде [Гәүһәр].* Г.Әпсәләмов

МУМ *и. гар. иск.* Балавыз; шәм

МУМИЁ *и. гар.* Кыя ярыкларыннан бүленеп чыга торган катлаулы составлы органик матдә; тау сумаласы, тау бәлзәме (эшкәртелгәннән соң, дәвалау максаты белән кулланыла). *Кичә Сафуан абый килгән иде, 10 гр мумиё биреп китте.* Ф.Яруллин. *Пародонтоз вакытында суга мумиё (тау бәлзәме) салып эретеп, шуның белән иртән һәм кичен авызны чайкыйлар, аннан соң йоталар.* Мәдәни җомга

МУ́МИЯ I *и. гар.* 1) Бәлзәмләү нәтиҗәсендә черемичә саклана торган мәет. *Берничә мең еллык тарихы булган пирамидалар, сфинкс, мумияләр арасында йөрү хисләрне кузгаткан иде – юлда беркем дә сөйләшмәде, һәркем чүлгә таба күзләрен текәп уйланып кайтты.* М.Мәһдиев. *Суган белән сарымсакны моннан алты мең ел элек төзелгән Мисыр пирамидаларындагы мумияләр салынган таш табутлардан тапканнар.* Робинзон эзләреннән

2) Табигый шартларда кипкән мәет. *Анда финикиялеләрдән калган мумияләр, кош чучелолары һәм башка бик күп нәрсәләр бар.* А.Расих. *Мәскәүдә бер тәүлек эчендә коточкыч ике мәеткә юлыкканнар: өч ел элек үлгән хатын-кызның һәм бер ел тирәсе элек гомере өзелгән ирнең мумия булып кипкән гәүдәләрен тапканнар.* Татарстан яшьләре

3) *зоол.* Май аенда тут агачының ботакларына ябыша торган кабарынкы, кипкән корткычлар

4) *кимс.* Ябык, әкрен хәрәкәтләнүчән, битараф, пассив кеше турында. *Син курыкма, курыкма... Ул хәзер берни дә эшли алмый, ул беткән... Әкренләп мине дә бетерә баручы мумия ул.* Ф.Хөсни. *Шул рәвешле нәрсәдер аңлатырга тырышам, хатын һаман – мумия.* Кызыл таң

МУ́МИЯ II *и. гар.* Ачык кызыл һәм кызгылт көрән төстәге, майланып һәм үзенә генә хас ис аңкытып тора торган, балавызга охшаш минераль буяу

МУ́МИЯЛӘҮ *ф.* Мумиягә I (*1 мәгъ.*) әйләнү. *Ул төшенчәгә теге иптәшнең бөтен атрибутлары кереп бетә. Аның ялтыравыклы маңгае да, каләмен тотып берөзлексез нәрсәдер язып утырган шома кулы да, нурсыз, мумияләнгән балавыз йөзе дә.* М.Мәһдиев

МУ́МИЯЛӘҮ *ф.* Бәлзәмләү; мумиягә I (*1 мәгъ.*) әйләндерү. *Фиргавеннең тәнен мумияләп, Саклаганнар, күр, дип, тыйб көчен.* Ш.Маннапов

Мумияли башлау Мумияләргә керешү

Мумияләп бетерү Мумияләү эшен төгәлләү

Мумияләп кую Мумияләнгән хәлгә китерү

МУМЛА́У *ф. иск.* Балавызлау

МУНДИАЛЬ *и. исп.* Иң мөһим халыкара футбол ярышы; ФИФА кубогына чемпионат. *Казан – Универсиада хуҗасы, мундиаль шәһәрләренең берсе икәнен искә алганда, аны ничек эзләп таптыгыз?* Ватаным Татарстан. *Аның берсе мундиаль белән бәйле инфраструктураны үстерү булса, икенчесе – дөнья чемпионаты турында федераль закон кабул итү.* Шәһри Казан

МУНДИР *и. лат.* Хәрбиләр яисә тимер юл, элемтә хезмәткәрләре һ.б.ш.ның махсус форма киеме. *«Аклар» – пальто, бүрек, костюм, мундир, тужурка, «каралар» толып, тун, тире чалбар, бишмәт тегәләр иде.* М.Мәһдиев. *Үзенә ятышлы мундир кигән чибәр подполковник дәррәү урынныннан торып чыгып китте.* А.Расих. *Лицей мундирының төймәләре чишеп җибәрелгән, уң кулы белән бөдрә чәчле башына таянган...* Ш.Рәкыйпов

МУНДШТУК *и. нем. кит.* 1) Трубка яки папиросның, тәмәке тартканда, авызга каба торган өлеше; мөштек. *Эшкә бара алмаган хәлсез әсирләр, утырган җирдән генә булса да, алюмин кисәгеннән матур итеп бизәклән, сырлап-шәрехләп портсигар, теш тазарта торган таушалган щётка сапларыннан – төрле төстәге тәмәке мундштугы --- ише әйберләр ясыйлар.* Р.Мостафин. *Гадәттә, аштан соң ул үзенең пемзадан эшләнгән кыска мундштуклы зур трубкасын тартып җибәрә, алдына пары чыгып тора торган пуншлы стаканын куя да хикәятләрен сөйли башлый иде.* С.Макеев

2) Өреп уйнала торган музыка коралларының авызга каба яки иренгә якын куя торган өлеше

МУНИЦИПАЛИЗА́ЦИЯ *и. лат.* Хосусый милекнең дәүләт хакимияте тарафыннан җирле үзидарә органнарына тапшырылуы. *Бу шаукымның икенче сериясе булган муниципализация дигәне моңа кадәр дә исән калган авылларның тамырларын корытуга юнәлтелгән булып чыкты.* Ватаным Татарстан. *Ә менә узган елда өлкәгә үтеп кергән муниципализация һәм оптимизация дип аталган кануннар турында да мактау сүзләре ишетелмәде.* Шәһри Казан

МУНИЦИПАЛИТЕ́Т *и. лат.* Җирле үзидарә оешмасы һәм шуның бинасы. *Узучылар аңа сокланып карап: «Депутат Шөкри әфәнде муниципалитет утырышына китте», – дип пышылдашып калалар.* Ә.Исхак. *Без муниципалитет бинасында тагын бер кат булдык әле.* Р.Фәйзуллин. *Даниядә, мәсәлән, йортлар төзү эшендә хатын-кызлар оешмалары да катнаша, аларның хөкүмәт составында, парламентта, муниципалитетта үз урыннары бар икән.* С.Ибраһимова

МУНИЦИПАЛЬ *с. лат.* Муниципалитетка караган. *Парламент ел дәвамында закон чыгаручылар эше белән танышырга килгән 1300 кешене: муниципаль органнар, иҗтимагый оешмалар вәкилләрен, студентларны, укучыларны кабул иткән.* Мәдәни җомга. *Хәзер шәһәрләргә дә, раойннарга да муниципаль дигән – тел әйләнми торган койрыкмы, иярченме уйлап чыгардылар.* Татарстан яшьләре

МУНИЦИПАЛЬЛӘШТЕРҮ *ф.* Хосусый милекне җирле үзидарә органнарына тапшыру; муниципализация ясау

Муниципальләштерә башлау Муниципальләштерергә тотыну

Муниципальләштереп бетерү Барысын да муниципальләштерү, тулысынча муниципальләштерү

Муниципальләштереп кую Тиз арада муниципальләштерү

МУНЧА *и. рус* Парлану, юынучабыну өчен корылган махсус бина. *Һай, парлы яшәүләргә ни җитә: кичләрен мунча чабынып, чиста күлмәк киеп кайтыр идең дә, самавырны екканчы чәй эчкәч, караватта җәйрәп яткан тәмле исле йомшак карчыгыңа: «Кая, мине дә сыйдырасыңмы?..» – дип, касыгына берне төртеп куяр идең...* А.Гыйләҗев. *Мунча керү – солдатлар өчен иң шатлыклы, бәйрәмгә тартым көн.* Р.Кәрами

◊ **Мунча аракысы** Өй шартларында җитештерелгән исерткеч эчемлек; самогон. *– Моның янына мунча аракысы да булса, – диде Атаулла уфтанып. – Анысы нәрсә тагын? – дип сорады Габделнур. – Нәстә булсын, самогон! – дип көлде Атаулла, шуны да белмәскә, дигән сыман.* Р.Кәрами. **Мунча кадәр** Бик кечкенә (корылма тур.). *Гомерен рәхәттә уздырган хатын --- кинофәлән барганда, мунча кадәр клубның экран төбенә килеп баса да урам буенча кушаматларны тезеп китә: – Ышстансыз Гали, Күпер асты Лотфулла, Кыяр буры Марзыя...* Р.Рахман. **Мунча кебек** 1) Бик эссе, бөркү (бүлмә, өй тур.). *[Хәдичә:] Уф! Чыдар әмәлләр юк бу эссегә!.. Мунча кебек... перәме!* Л.Лерон; 2) *к.* **мунча кадәр**. **Мунча керту** Бик каты шелтәләү, сүгү, ачулану, тәнкыйтьләү. *Кыскасы, Фәләх министрлыктан (начальство телендә аны «келәмнән кайту», «мунча кертү» дип атыйлар) берничек тә аклана алмыйча, шунлыктан каны бик нык кызып кайткан иде.* В.Нуруллин. **Мунча керү** Каты шелтә алу, тәнкыйтьләнү. **Мунча тараканы** *кимс.* Ямьсез, сөйкемсез. *Кешене кимсетеп әйткәндә, мунча тараканы, мунча фәрештәсе яки мунча пәрие диләр.* Ф.Урманчеев. **Мунча ташы** Хәйләкәр, зирәк, усал, әрсез кеше. *[Гыйльметдин:] Миңни кызы – мунча ташы!* Ф.Бурнаш. **Мунча пәрие** *кимс.* Ямьсез, сөйкемсез, килбәтсез кеше. *Килешә-килешми дип тормыйча, Гөлкәйнең йөзенә бәреп әйттем ул чакта: – Кайдан таптың бу мунча пәриен? – дидем.* Р.Габделхакова. *Юри генә Гыймайның юлында очраган булды, юри генә: «Нихәл, мунча пәрие?» – дип чытлыкланып алды.* Ф.Яруллин. **Мунча фәрештәсе** *кимс.* Ямьсез, сөйкемсез, килбәтсез (хатын-кыз)

МУНЧАК *и. к.* **муенчак**. *Тишек мунчак җирдә ятмас.* Мәкаль. *Ирек мунчакны үзенә алды да бозауны алга өстери башлады.* Х.Камалов. *Без бәләкәй чакта аны «бозау мунчагы» дип көлүчеләр бар иде.* Ш.Галиев

МУНЧАКЛАП *рәв. сөйл. к.* **муенчаклап**. *[Нигъмәтулла:] --- Хәзерге яшьләрне беләсең, үзләре бер-берсен табалар. Мунчаклап китереп булмый.* Ә.Еники. *Бозау комиссиясендәгеләр өй борынча кереп, мунчаклап, бозауларны алып чыга башладылар.* Р.Батулла. *Эткә сөяк ыргыткандай калҗа ташлап, муенчаклап йөртү лазем эш түгел...* Р.Низамиев

МУНЧАЛА *и. рус* **1.** 1) Юкә кайрысын суда озак җебеткәннән соң хасил булган киң җепселләр. *Киндер күлмәкле ярлы балалары бөкрәеп мунчала аерып утырганда, бай балалары, яз алып киләчәк рәхәтлекләрне уйлап, җылы юрган астында хыялланып яталар.* М.Галәү. *Шушы йортта торучы кеше мунчаладан намаз укый торган палас тукыган һәм шуны сатып көн күргән.* Ф.Гарипова. *Җеннең озынлыгы җитмәгәч, тагын өч чебешне мунчала белән аерым бәйләп җибәрдем.* Гасырлар авазы

2) Тәнне һәм савыт-саба, идән һ.б.ш. юу өчен, юкә кайрысы, люффа кебек җепселле натураль материаллардан яисә берничә катлы синтетик җептән ясала торган әйбер. *Дөрес, мари халкы юкә үстерергә ярата. Кирәк ул аларга: мунчала ясап саталар, чыпта үрәләр, себерке ясыйлар.* З.Хөснияр. *Ә шифалы парлы мунчаның тәмле исе, юкә мунчала, бөтнек, карлыган сабагы, җиләк яфраклары кушып бәйләнгән себерке еллар буе тән һәм җан күзәнәкләренә шыплап тулган нәфрәт-ачу, ачынурәнҗешләрне әйтерсең эретә, юып төшерә, куа.* Р.Мулланурова. *Төрледәнтөрле бизәкләр кулланып носки, бияләйләр, ыргак энә белән мунчала, киезләр һәм башка хуҗалык кирәкяраклары бәйли ул.* Безнең гәҗит

3) *күч.* Йомшак, җебегән кеше. *Мунчала булма! Катырак тор! Бозау булма!* М.Мәһдиев. *--- ул мәхшәрдә ихтыярыңнан тыш, үзең дә сизмәстән, мунчала булып калуың ихтимал бит.* Х.Камалов

2. *с. мәгъ.* Мунчаладан ясалган. *Менә шундый ләззәтле куркулар өчен, таудан шуганда, «Чаңгы?» дисәң «Әү!» диярлек чаңгы шәләмәтен аягыбызга мунчала бау белән бәйләп ныгыта идек.* К.Шакиров. *Атның сыртында киез ияр, мунчала дирбия, тезгене дә тузып, чачакланып беткән.* Р.Батулла

◊ **Мунчала баш** Тузган чәчле, таралмаган чәчле. *Ачуым килгән чакларда: «Мунчала баш! Мунчала!» – дип үртим.* З.Хөснетдинов. **Мунчала булып уралу** Кемгә яки нәрсәгә дә булса комачаулау. **Мунчалага әйләнү** Тузу; эштән чыгу; телгәләнеп, тузып бетү. *Йомыркадан чыгуга, ай үсәсен көн үстерү өчен, чебиләрне төрле препаратлар, ясалма ризыклар белән туйдыралар. Бавыр, табигый булмаган бу коточкыч йөкне күтәрә алмыйча, тузып, мунчалага әйләнә.* Ф.Садриев. **Мунчала кебек булу** Тузу, таушалу. *Минем нервылар бик тузган, мунчала кебек булган ---.* Х.Камалов. **Мунчала төшерү** Җебетелгән юкә кайрысыннан җепселле катлавын аеру. *Үсмер малай уникe*

яшеннән урманда юкә каезлап, мунчала төшерергә, чыпта сугарга өйрәнә. Якты юл. *Юкә күле дип аталган күлдә юкә кабыгы эзебетеп, аннан мунчала төшергәннәр*. Ислам – татарлар һәм мөселманнар. **Мунчала чәйнәү** Буш сүз сөйләү. *Күрше өстәлдәге матрос урыныннан күтәрелергә маташа, әмма, биленә авыр таш бәйләп куйган кебек, кузгала алмый, бөтен гәүдәсе белән алга таба авыша гына. – Яле, туктатыгыз мунчала чәйнәүне!* З.Фәтхетдинов. *Кыз ярты сүзендә егетне кискен бүлде: – Нинди очрактан соң?! Нинди мунчала чәйнисез сез?!* З.Дәүләтов

МУНЧАЛА БАЛЫК *и. диал. к.* **жумба**. *Әйтик, жумба (бездә аны мунчала балык, налим диләр) бары төнлә белән генә туклана.* Кызыклар дөньясында

МУНЧАЛАЛАНУ *ф.* 1) Юкә кайрысында мунчала (*1 мәгъ.*) хасил булу

2) *күч.* Тузып бетү, теткәләнү. *Сезнең коллективны хәтта Арканов та сөйри алмыйча, мунчалаланып туктады*. Р.Зарипов

Мунчалалана башлау Мунчалага охшый башлау

Мунчалалана төшү Тагын да бераз мунчалалану

Мунчалаланып бетү Тәмам мунчалалану. *Карасана, күзләре тоныкланган, чәчләре мунчалаланып беткән, үзе шәлперәеп төшкән.* И.Хәйруллин. *Егетнең өстәлендә кат-кат укудан мунчалаланып беткән телеграмма ауный иде.* А.Гыйләҗев

Мунчалаланып калу Нәрсәдер тәэсиреннән соң мунчалалану. *Берничә көннән карасаң, ачылып беткән дә җәелеп, мунчалаланып калган [роза чәчәге]*. Ш.Галиев

МУНЧАЛАЛА́У *ф.* Мунчалага (*2 мәгъ.*) әйләндерү; мунчала кебек итү

Мунчалалап бетерү Мунчалалауны төгәлләү

МУНЧАЛАЛЫК *и.* Мунчала ясау өчен әзерләнгән юкә кайрысы. *Алар себеркеләр бәйлиләр, бастырмалыклар юналар, елгага мунчалалыклар салалар.* Г.Галиев

МУНЧАЛА-САБЫН *җый. и.* Мунчада юыну кирәк-яраклары. *Шуны гына көтеп торган малай иплән кенә күлмәген, майкасын, бераз мыштырданып алгач, чалбарын салды, әнисе әзерләп биргән төргәктән мунчала-сабын чыгарды.* Ф.Латыйф

МУНЧАЧЫ *и.* Мунчада эшләүче кеше. *Билетын мунчачы өстәлендәге тимер әрҗәнең тар тишегенә төшереп җибәрде дә малайны эзләп якягына каранды [Искәндәр]*. Ф.Латыйф. *Шушыныңчы мунчачы булып эшли иде [Зөлкарнәй]. Кичә азат иттеләр.* Ә.Гаффар. *Мунчачы, башка якын хезмәтчеләре кулга алынды, һәммәсе тиешле җәзасын алыр*. М.Әмирханов

МУР *и. рус сөйл.* Үләт, эпидемия. *Тугыз мурдан үткән*. Әйтем. *[Карадәрвиш:] Афәт килә, ә сез кеше яндырганга куанасыз! Чума мурыннан Кытай ягында ундүрт миллион кеше кырылды*. Р.Батулла

◊ **Мур кыргыры** Орышу, әрләү сүзе. *И куамын карганы: – Кит, карак, мур кыргыры!* Йолдыз. *Минем янда калдыруың зыянга гына булган икән: күз алдымда ук эләктерде, бер чарасыз икәнемне мәче дә сизә, мур кыргыры.* Ә.Вергазов. **Мур кыру** Эпидемиядән, каты авырудан күпләп үлү, кырылу. *Мур кыра елкыларны, мур кыра куйларны, мур кыра дөяләрне, кешеләрне мур кыра.* Р.Батулла. *– Зинһар, ташлап китә күрмәгез, – диде [кыз]. – Әллә инде безнең тирәдәге бар халыкны мур кырган*. А.Хәсәнов

МУРДА *и. фин-угор* Берсе эченә икенчесе кертеп беркетелгән ике конус формасындагы тал чыбыгыннан яки камыштан үреп эшләнгән балык аулау җайланмасы. *Яз көне тал чылбыктан мурда үрә.* Д.Каюмова. *Ботаклар сындырып, мурда үрдем.* Өмет. *Ятьмә, елым, сөкә, мурда, тозак, ау кебек балык тоту кораллары күпләргә таныш.* Фән һәм тел

МУРДАЛЫК *и.* Мурда үрергә яраклы талчыбык

МУРЕ́НА *и. лат. к.* **еланбалык**. *Кыя тишегеннән агулы еланбалык – мурена карап тора иде.* М.Юныс. *Мурена – куркынычлы дошман, һәм аңа тибү – начар шаяру: балыкның бик ныктешләве мөмкин*. Диңгез тирәнлегендә

МУРТ *с.* 1) Йомшак, көпшәк (агач). *Зирек утын мурт була, Җиңгә хатын мут була.* Мәкаль. *Дулкын чыгарып ташлаган агач төпләренең исәбе-хисабы юк. Мурт тамырларын сузып, комда әлсерәгән сигезаяклар кебек яталар.* М.Рафиков. *Салкын су ләгәннәре, мурт сөяннән ясалган кисмәкләр.* Р.Батулла

2) Иске; искергән. *Мурт йорт*

МУРТАЮ *ф.* 1) Чери башлау; череп уалу, ваклану, таралу; үзлеген югалту (агач, салам, тире һ.б. тур.). *Нигезгә яткан юан-юан бүрәнәләр череп муртайган, басылып бер-беренә иңгәннәр*. А.Гыйләҗев. *Аларның йортлары каршында урам ямь-яшел чирәм иде, һәм урамның урта бер җирендә диярлек карт, муртайган каен, чуптарларын асылындырып, ничектер бөтен урамга моң, сагыш таратып утыра иде.* М.Мәһдиев. *Әнә берсеннән, пырхылдап, тавык килеп чыкты да муртайган саламда тибенә башлады*. М.Галиев

2) Искерү. *Алдынгы һәм хөрмәтле совет хуҗалык җитәкчеләре безнең системаның савыгуына ышана алмыйлар иде! Системаның эчендә болганып, алар аның тамыры һәм бөтен кәүсәсе муртаеп черегәнен аермачык белгәннәр...* А.Тимергалин

3) Хәлсезләнү (кеше тур.). *Татарстанда авыл халкы әче таңнан торып кара төнгә чаклы печән әзерли, кышлык утын кисә, җир сөрә, карап торган сыерын көчкә асрый, чөгендер каторгасында эшләп муртая, сыер сава, тупаслана, ямьсезләнә, нәфислеген, гүзәллеген сакларга вакыты юк*. Р.Батулла. *--- әле генә ап-аек күренгән Псих Сәлимгәрәевич инде минем алдымда күзгә күренеп җепши, муртая, исерә иде.* А.Хәлим

4) *күч.* Бозылу; тупаслану (холык, кешелек сыйфатлары тур.). *Иртә макталып бар муртайганнар, Артык макталып та бар туңганнар.* Ә.Синугыл-Куганаклы. *Ә олыгая төшкәч, күңелләре тупаслана, муртая, дуслык хисләре кими, шәхси омтылышлары өстенлек итә башлый булса кирәк*. В.Нуруллин

Муртая башлау Муртаю билгеләре барлыкка килү. *Кәүсәсе муртая*

башлаган ялгыз каенның ябалдашлары арасыннан чиксез күк гөмбәзендә бер йолдыз шәйләнә. С.Зыялы

Муртая бару Акрынлык белән, азазлап муртаю

Муртая төшү Тагы да ныграк муртаю; бераз муртаю

Муртаеп бетү Тәмам муртаю. *Зупзур стадионның муртаеп беткән такта утыргычларында, җәйге кичтә телефон чыбыкларына тезелешкән карлыгачлар кебек, байтак кеше утырышкан.* А.Гыйләҗев. *Ярмөхәммәтнең муртаеп беткән бармакларына карап, Дилаева дәшмәде.* Р.Батулла

МУСКАТ *и. фр.* 1) *к.* **мөшкәт**. *Рашат кружканы тутыра язып төнәтмә салды. --- – Күптән тора иде. Мускат чикләвеге салынган аңа...* Ф.Садриев. *Урта гасырларда, бигрәк тә XV, XVI, XVIII гасырларда, Көнчыгыштан китерелә торган хуш исле үләннәр: борыч, канәфер, имбир, дарчин, кардамон, мускат чикләвеге иң кыйммәтле әйберләр булып саналганнар.* Робинзон эзләреннән

2) Виноградның хуш исле сорты һәм шуны киптереп әзерләгән йөзем җимеше. *Ул үстергән алма, йөзем, чавыш, мускат, армут, ильямус җимешләрен тирә-як авыл һәм кала базарларында яхшы белгәннәр.* З.Зәйнуллин

3) Ак, алсу, кара төстәге хуш исле виноградтан ясалган югары сыйфатлы шәраб. *Белгечләр, «Tropicana» натураль согы, «Мускат» шәрабы, «Аморе» джин-тоникы, «Пенное серебро» сырасы кебек эчемлекләргә бик ышанмаска киңәш итә.* Безнең гәҗит. *Быел 90 нан 220 сумга кадәр 16 дегустация үрнәген сатып алганнар, шул исәптән иң популяр 8 ярымбаллы, 4 мускат һәм 4 төр брют – шикәр күләме бик аз булган шампан шәрабын.* Ватаным Татарстан

МУ́СКУЛ *и. лат.* Кешеләрдә һәм хайваннарда кыскару үзлеге булган итләч тукыма. *Аның [Искәндәрнең] көче, шыгырдап торган мускуллары ндагы гайрәт кемгәдер кирәк икән бит ---.* Ф.Латыйфи. *Гадәттә, тире ләре астында тыгыз туплар кебек теләр-теләмәс кенә кыймылдаган мускуллары киерелгәндә, аларның [аттарның] яшь тәннәре җылына, йөрәк тибешләре кызулана, каннары күз аллары тоныкланганчы кайнарлана иде...* Ж.Мостафин. *Нейроннарның икенчеләре – хәрәкәт нейроннары – импульсларны арка һәм баш миеннән мускулларга һәм эчке органнарга тапшыралар.* Биология

МУСКУЛАТУ́РА *җыйн. и. рус* Мускуллар. *Икенче шартны күкрәк өлешендә тупланган һәм күкрәк сөягенә – кильгә береккән ныкмускулатура тәэмин итә.* И.Рәхимов. *Очып баручы бал кортының тән температурасы, югары матдәләр алмашы һәм күкрәк мускулатурасының интенсив эшчәнлеге нәтиҗәсендә, әйләнә-тирәлек температурасыннан 6–20 °С ка югарырак була.* Татар балы. *Күпләр, хәрәкәт бары яхшы гәүдә тотышы һәм матур мускулатура формалаштыру өчен генә кирәк, дип уйлый.* Сәламәтлек нигезләре

МУ́СКУЛЛЫ *с.* Мускуллары булган. *Теге таза мускуллы таза егет тә әйбәтрәк булып күренә башлый.* М.Мәһдиев. *Ул шулкадәр көчле, башта мускуллы гәүдәсе белән корбанын буып үтерә, аннары ғына ашый.* Т.Шакирова. *Кәүсәсе бик юан, ботаклары, таза мускуллы куллар сыман, борылмалы һәм юан; яфраклары ныкуемтыклы.* Р.Кәбирова

МУ́СКУС *и. лат. к.* **миск**. *Аңа кадәр медикаментлар – хинин тамыры, рәвәҗ, камфара, мускус, канәфер, миндаль һәм башкалар чит илләрдән кайтарыла.* Ватаным Татарстан

МУСЛИН *и. фр. махс.* **1.** Бик юка, җиңел, йомшак киҗе-мамык тукыма. *Йөреп тегүчеләр, өязгә чыгып тегүчеләр, парча, комач, ситсы, басма, бурлат, бүз, муслин, миткальның күп төрлесен алып кайталар иде.* Сөембикә

2. *с. мәгъ.* Шул тукымадан тегелгән, эшләнгән. *Франциядә XVIII йөз ахырында бик популяр булган муслин күлмәкләргә карап сокландык.* Казан утлары

МУСС *и. фр.* 1) Җиләк-җимеш суына желатин һ.б.ш. кушып, күпертеп әзерләнгән татлы ашамлык. *Концентратлардан төрле кесәлләр, мусслар, желе, кремнар, татлы пудинглар әзерләргә мөмкин.* Файдалы киңәшләр. *Кесәллəр, мусс, желе һəм компотлар өчен җиләк-җимештән бер өлеш сок сыгып алырга (бер порциягә – бер чәй кашыгы) һəм аны әзер ризыкка өстәргә кирәк.* Тәмлетамак

2) Чәчләрне ябыштыра һәм кирәк формада тоту өчен кулланыла торган күбек. *Кайвакыт кызлар, чәчләрен формада тоту өчен, гель, мусс, лак куллана.* А.Галиева. *Тәҗрибә объектына әйләнәсе чәчләр жюри тарафыннан алдан тикшерелә: алар туп-туры итеп таралган, чиста, бернинди мусс яисә лак белән эшкәртелмәгән булырга тиеш.* Ватаным Татарстан

МУССОН *и. фр. геогр.* Юнәлешен үзгәртеп, җәен – диңгездән, кышын коры җирдән исә торган җил. *Кайнар һәм салкын муссоннар үтеп кермәгән үзәнлекләрдә мәңге яшел субтропик табигать чәчкә атып утырса, бераз ғына тауларга күтәрелсәң, анда нәкъ Татарстандагы кебек яфракларын коя торган агачларга тап буласың.* А.Хәлим. *Совет климатологы Б.П.Алисов классификациясе буенча, Җир шарында җиде климатик зона бар: экваториаль зона, тропик муссоннар зонасы, пассат зонасы, субтропик, урта, субполяр һәм поляр зоналар.* Галәм. Җир. Кеше

МУСТАНГ *и. инг л.* Төньяк Америка прерияләрендәге кыргыйлашкан йорт аты. *Иреген саклап, Мустанглар хәтта Биек кыялардан сикерә.* Р.Шиһапов. *Мустанглар – бик матур, сылу атлар.* Ф.Ибраһимова. *Безнең көннәрдә Көньяк Америкада кыргыйлашкан атлар яши. Аларны мустанглар дип атыйлар.* Табигать бизәкләре

МУТ *с. рус* **1.** 1) Үткен, зирәк; артык хәйләкәр. *Тышы ут, эче мут.* Мәкаль. *Әгәр дә Зайцевның утыз тугызынчы яшь белән баручы гаилә башлыгы, ике бала атасы икәнен белмәсә, аны, һичшиксез, егерме җиде яшьләрдәге бер мут егет дип фараз кылган булыр иде капитан.* М.Насыйбуллин

2) Шаян, шук, азгын. *Бигрәк тә шушы арада ғына өченче иреннән аерылып кайткан мут күзле Җәүһәрия өметләнеп йөрде [Сабируллага].* З.Хөсният. *Әлеге пәри затмы, адәми*

затмы – яшел мут күзләрен тутырып аңа карап-карап куя, бүлмәдә тыны кысылгандай, тирән-тирән сулыш ала ---. З.Фәтхетдинов

2. *рәв. мәгъ.* Шукланып, шаянланып, кыланып; азгынланып. *Кияү. Сукно пальто. Кып-кызыл таза бит, кышкы җил ашаган борын, ияк. Күзләре мут елтырый.* М.Мәһдиев

МУТАГЕН *и. лат.-гр.* **1.** Мутация барлыкка китерә торган физик һәм химик фактор. *Өстәвенә канцероген (рак китереп чыгаручы матдә) гына түгел, мутаген (ректан тыш, күзәнәкләрнең генетик аппаратын җимереп, башка төрле авыруларга да китерә) буларак та әле.* Ватаным Татарстан

2. *с. мәгъ.* Мутация барлыкка китерә торган. *Болар илдә эчәк инфекциясе һәм гепатит чирләре кискен артуга, ә тора-бара кеше организмына канцероген һәм мутаген факторлар тәэсиренең үсүенә китерергә мөмкин*. Татарстан яшьләре. *Моннан тыш, тәмәке тартканда, төтен белән бергә һавага чыккан зарарлы матдәләр мутаген һәм канцероген үзлекләргә ия булып тораллар*. Туган як

МУТАНТ *и. лат.* **1.** Мутация нәтиҗәсендә нәселдәнлеге үзгәргән организм. *Ә Әхнәф үзе? Аны да кемнәрдер ясады, кояш итеп күтәрде түгелме соң? Мутантлар, клоннар, тагын әллә ниләр...* Ф.Садриев

2. *с. мәгъ.* Мутацияләнгән; мутантка әйләнгән. *Әйтик, Америкада мутант бозау дөньяга килә: аның ике йөзе, өч рәт теше, ике аскы казналыгы, ике теле һәм бер авызы бар.* Мәдәни җомга

МУТАЦИОН *с.* Мутациягә бәйле. *Ләкин мутацияләр теориясе үзе дә яңа проблемалар, хосусан, мутацион үзгәрешләрнең сәбәбе турындагы проблеманы тудырды*. Галәм. Җир. Кеше. *Хәдисләрдә вәгъдә ителгән мутацион үзгәрешләр якынлашып килүче Кыямәт көненең билгеләре булып тораллар.* Б.Хаков

МУТА́ЦИЯ *и. лат.* 1) Буыннан буынга күчә торган нәселдәнлек билгеләрендә мутаген факторлар тәэсирендә яисә кинәт үзеннән-үзе барлыкка килгән үзгәреш. *Голландия галиме Хуго Де Фриз нәселдәнлекнең кинәт үзгәрүе турындагы мутация теориясен тәкъдим итте.* Галәм. Җир. Кеше. *Мондый генетик мутация бик сирәк күзәтелә (миллионга бер), әмма нәкъ менә бу очракны аңлатып була: кызлар ясалма аталандыру юлы белән яралган.* Мәдәни җомга

2) Җитлегү чорында яшүсмерләрнең тавышларында барлыкка килә торган үзгәреш. *Җитмәсә, сугыш елларының нәтиҗәседер инде, тавыш мутациясе дә әлегә узылмаган.* М.Мәһдиев. *Ләкин унөч яшемдә, мутация чоры башланып, минем тавыш кинәт сынды.* Татар заманы

МУТА́ЦИЯЛӘНҮ *ф.* Мутация нәтиҗәсендә үзгәреш кичерү. *Казансуга барып, пычрак суларда мутацияләнгән өч күзле балыкларны тотып кайтырга кирәк.* Д.Вәлиев. *Нәтиҗәдә, бу үзгәртелгән, ягъни мутацияләнгән культура сәламәт булганнарын кысрыклап чыгара.* Э.Фатыйхова. *Вирус берничә көн эчендә мутацияләнә һәм инде кешедән кешегә йога башлый.* Татарстан яшьләре

Мутацияләнә бару Торган саен күбрәк мутацияләнү. --- *вируска вакцина да уйлап табылмаган, чөнки ул мутацияләнә бара.* Ватаным Татарстан

Мутацияләнә башлау Мутация билгеләре сизелү, күренү. *Соңгы елларда бөтен җәмгыятьтәге кебек ана һәм бала мөнәсәбәтләре дә мутацияләнә башлады бугай*. Татарстан яшьләре. *Соңгы вакытта тирә-яктагы хайваннар да мутацияләнә башлады.* Безнең гәҗит

Мутацияләнеп бетү Тәмам мутацияләнү

Мутацияләнеп тору Мутацияләнүен дәвам итү. *Ник дигәндә, грипп даими мутацияләнеп тору аркасында, аңа каршы чыгарылган даруларның файдасы тими башлаган.* Татарстан яшьләре

МУТЛАНДЫРУ *ф. йөкл. юн. к.* **мутлану**. *Теге, бүгенге доцент, лекциягә кергәч и күзләрен мутландырып берәр матур кызга карап алган була, и үзе, эффект ясадым, дип ышанып сөйләгән була.* М.Мәһдиев. *Бу юлы да яшькелт күзләрен мутландырып: – Бигрәк тә кайсыбызның исәнлеге кирәк инде, ягъни мәсәлән, – дип авыз ерды.* Л.Ихсанова

Мутландырып тору Гел мутландыру; хәзерге моментта мутландырган булу

МУТЛАНУ *ф.* 1) Шаянлану, кыланы, шуклану; азгынлану. *Аның [Галикәйнең] күз алмалары мутланып тәгәриләр, ирене мылт-мылт килә, ул озын, ябык муенын төрле якка боргалап, бөтен авылның, бөтен урамның, бөтен кешеләрнең игътибарын үзенә генә җәлеп итәргә тырыша.* А.Гыйләҗев. *[Искәндәр] кесәсеннән ике өч тиенлекне эзләп тапты, берсен автомат ярыгына төшереп җибәргәч, ширбәт агып бетүгә, стаканны читкә алып торды һәм, малайларча мутланып, Азатка күз кысты, икенче бакырны ташлады.* Ф.Латыйфи. *Ул [ата үрдәк] мутланып һәм дәртләнеп, теләсә кайсы ана үрдәк артыннан ташлана, аны куып җитәргә һәм үзенеке итәргә омтыла*. Кызыклар дөньясында

2) Хәйләкәрләнү. *Кайчагында артель башлыгы аз-маз гына мутлана икән, шуның өчен дә башлык бит ул.* Ф.Хөсни

Мутлана бару Торган саен ныграк мутлану

Мутлана төшү Берникадәр мутлану; бераз мутлану. *Сабирның да күңеле эреп китте, ул, бераз мутлана төшеп: – Тырышкан булабыз, – диде дә кинәт: – Бакый абый, бокс ярата-сыңмы? – дип сорады*. Г.Әпсәләмов

Мутланып алу Аз гына мутлану; кыска вакыт аралыгында мутлану. *Шунда ук мутланып алырга булды әле генә «чыжлап торган майлы табадан төшкән» полковник иптәш.* Т.Галиуллин. *– Берсен урталай бүләбез, – дип мутланып алды Фәрсия*. М.Әхмәтшина

Мутланып бетү Тәмам мутлану

Мутланып йөрү Мутлану хәлендә булу. *Моның кебек зур җирдә аның үзенә кирәк «суны» да эзләп, мутланып йөрүе бар.* Ә.Еники

Мутланып китү Мутлану юлына басу; соңгы арада мутлану. *Гөлзифа бер мәлгә мутланып киткән ирене ни әйтергә белми югалып калды.* М.Хәбибуллин. *Шуңа күрә син бик мутланып китмә әле.* Г.Әпсәләмов

Мутланып ташлау Уйламыйча мутлану; үзе дә сизмичә артык мутлану. *Шулай бервакыт карлыгач күбрәк мутланып ташлый, караңгы төшкәнче оясына кайтып җитә алмый.* С.Сәүбәнова

Мутланып тору Сөйләү моментында мутлану; мутланган хәлдә булу. *Бая монда су эчәргә кергән сары мыеклы яшь офицер белән бик мутланып торучы син түгел идеңме соң?* С.Сабиров

МУТЛЫК *и.* Артык шуклык, шаянлык, хәйләкәрлек; усаллык, азгынлык. *Дөрес, яшьлек шаярулары, мутлыклары, кайчакта хаталары да булгандыр.* М.Мәһдиев. *Ул [кәҗә] нинди генә мутлык эшләсә дә, минем аңа кулым күтәрелми (сакаллы бит ул!).* М.Галиев

МУТОН *и. фр.* **1.** Сарык тиресеннән махсус эшкәртелгән мех. *Мутон, киез, фетр, җитен, күннән эшләнгән башмак, намазлык, кәзәки, башлык, бияләй һ.б.ны җәй уртасында кырып-себереп алдылар.* М.Мәһдиев. *Хәзерге чорда бик популяр булган мутон тиресен булдырганы өчен, М. Гаркавига Сталин премиясе бирелә.* Р.Ибраһимов

2. *с. мәгъ.* Шул мехтан тегелгән. *Соңгы стакан чәен йонлач бүрекле, салынкы мыеклы агайга эчерткәч, буфетчы кыз да, өстенә мутон тунын киеп, ишеккә юнәлде.* Ф.Шәфигуллин. *Көннәр җылынуга да карамастан, өстенә арка җылысы, сырган чалбар кигән, башын арзанлы мутон бүрек белән каплаган абзый Хәләфне яткан урыныннан тартып торгызды.* Х.Ибраһим. *Аның дебет шәленә, мутон якалы зәңгәр пәлтәсенә ярма-ярма кар бөртекләре кунган иде.* Ф.Җамалетдинова

МУФЛОН *и. фр. зоол.* Куышмөгезлеләр семьялыгыннан Көньяк Европада тереклек итә торган кыргый тәкә. *Корбаннар арасында муфлон (кыргый тәкә), боланнар, кыр кәҗәләре бар икән.* Татарстан яшьләре

МУ́ФТА *и. нем.* 1) Кулларны җылыту өчен, гадәттә мехтан кечкенә капчык сыман итеп, ике башы ачык калдырып тегелгән әйбер. --- *перчаткалы туңган кулларын күкрәк турысындагы муфтасына яшергән, тиен тунлы булганлыктан, Рушанга кайчандыр өлкән сыйныф укучысы гына булып күренгән хатыны да инде пенсиядә* ---. Р.Мирхәйдәров. *Дус кызына туй бүләге итеп хәтта муфта да теккән.* Сөембикә

2) *тех.* Машиналарның, механизмнарның цилиндрик өлешләрен тоташтыру, ялгау яки торбаларны, канатларны, кабельләрне һ.б.ш. озынайту өчен кулланыла торган җайланма. *Вакыт-вакыт эшчеләр килеп муфта куялар һәм башка объектка китәләр.* И.Нуруллин. *Аннан-моннан торбалар юнәттек, ә менә вентиль, задвижка, отвод, муфта, басым үлчәгеч кебек нәрсәләрен бер җирдә дә бирмиләр.* Т.Миңнуллин. *Ярмөхәммәт, тиз генә машинасының муфта тәбәлдерегенә басып, кул тормозын ычкындырды.* Р.Батулла

МУ́ШКА *и. фр.* 1) Ату коралларының көпшәсендәге аткан вакытта туры төзәргә ярдәм итә торган махсус чыгынты. *Без бик яшьли корыч мушка аша Дошман күзәтергә остардык.* М.Җәлил. *Димәк, мушка, төзәгеч һәм чакма белән мавыгып, ул [Габделнур] карабинның тимер кадакланган авыр түтәсе барын исеннән чыгарган икән.* Р.Кәрами

2) *сөйл.* Кемне яки нәрсәне дә булса кызыктыру, алдау өчен кулланыла торган әйбер. *Балыкны чебен, кигәвен, ат кылы, әтәч каурые һәм хәтта кеше сакалы йонын кармакка төреп тә тоталар. Болар барысы да бергә «мушка»-га тоту дип атала.* Кызыклар дөньясында. *Әлбәттә инде, мушка – алдау. Әмма бичара балыкларны тагын да намуссызрак рәвештә алдалап тоту юллары бар.* Кызыклар дөньясында

◊ **Мушкага алу** *сөйл.* Кемне яки нәрсәне дә булса күзәтү объекты итү. *Өстән генә өстерәп бармакчы иде берәү – шундук мушкага алдылар.* М.Мәһдиев. *Тагы танкны мушкага алды, аңа гына ышанмыйча, бинокленнән карады.* Х.Камалов. **Мушкага утырту** *к.* **мушкага алу**. *Чыгып китәргә теләүчеләрне без мушкага утыртып торабыз.* Ф.Яруллин. *Кузгалуы булды тегенең, Шәйхи аны мушкага да утыртты.* Әдипләр

МУШКЕТ *и. фр. тар.* Эре калибрлы борынгы ату коралы, мылтык төре. *Ике солдат ут ягып җибәрде, ә башкалары вак-вак төркемнәргә бүленеп, мушкет һәм башка коралларын әзер тотып, тирә-юньгә таралдылар.* И.Хуҗин. *Робинзон корабльгә икенче тапкыр бара һәм яңадан «өч тимер лом, ике мичкә мылтык пулясы, җиде мушкет, тагын бер ау мылтыгы һәм бераз дары» алып кайта.* Робинзон эзләреннән

МУШКЕТЁР *и. фр.* Мушкет белән коралланган солдат. – *Чукындырылган татарлардан, – дип әйтергә теләгән иде, ләкин нигәдер тынып калды. – Яхшы мушкетёр, – диде ул ахырда.* И.Хуҗин. *Татар егете мушкетёр булган.* А.Гыйләҗев. *Мушкетёр кызлар салган юл бик тә уңышлы була: Казандагы фехтование мәктәбе зур уңышларга ирешә.* А.Гафиятов

МУШКЕТЧЫ *и. к.* **мушкетёр**. *Аны, татар малае диюдән битәр, француз язучысы Дюма романнарының каһарманы – Урта гасыр мушкетчысы дип атарга булыр иде.* А.Расих

МУШТРА *и. пол.* 1) Каты дисциплинага нигезләнгән хәрби өйрәтү методы һәм шундый юл белән өйрәнү эше. *Читтә, илдән аерылып, авыр муштра солдат хезмәтендә егетнең күңелендә Хәбирәсенә мәхәббәте туган туфракны сагыну һәм ярату хисләре белән бергә тагын да үсте, ныгыды.* Ф.Яхин

2) *күч.* Тәрбияләүнең артык кырыс, аңларга, уйларга өйрәтмичә, мәҗбүр итүгә корылган алымы. *Мондый муштра балаларда иҗади сәләт үстерә алмый, билгеле.* Кызыл таң

МҮК *и. рус* Куе булып җиргә ябышып үсә торган, тамырсыз һәм чәчәксез, споралы үсемлек. *Менә бу, әле ул исемен-атын бөтенләй белмәгән абзыйның бүрәнә араларына салып калдырган мүкләре, Төркестан Кизләвендәге Галирахман абзыйның йорт бүрәнәләре арасына салып калдырылган кондырак үләнгә никадәр охшаган бит!* А.Хәлим. *Нәкъ шул вакытта туачак бәпкәләренең көтүчесе Фазылның тавышын танып, мүк арасыннан урамга муенын сузган ала каз, бөтен Шәлене яңгыратып: «Кыйгак! Кыйгак!» – дип кычкырып җибәрмәсенме?!* Х.Бәдигый. *Капма-каршы юнәлештә*

барганмын икән, монысын урманчыкка җиткәч агач кәүсәләрендәге мүкне капшап белдем, болыт арасында күренеп алган ай да шуны раслады. К.Шакиров

МҮКӘЛӘП *рәв.* Мүкәләгән килеш. *[Парторг:] Җәмәгать! Шушындый бөркүдә, ахшам намазына җыелган кебек, мүкәләп утырмыйк әле. Әйдәгез, урамга күченәбез.* К.Кәримов. *Мүкәләп кулыңа таянган килеш көйгән иренеңне, тамагыңны сулыга-сулыга салкын чишмәдә чылатканда, Җир куеныннан килгән тирәнтен су агымын сизми ятмыйсың.* Ә.Гаффар

МҮКӘЛӘ́Ү *ф.* Дүрт аяклап, тезләр һәм куллар ярдәмендә йөрү. *Мүкәли-мүкәли, яктылык бөркелгән якка урмәләдем.* Р.Сафин. *Күзендәге яшьләрен паласка тамыза-тамыза, ул әкрен генә мүкәләде.* С.Зыялы

МҮКЕЛДӘТҮ *ф. сөйл.* Яратып, аппетит белән ашау турында. *Сафа абый, алдына гына карап утырган килеш, бик тырышып, коры ипи мүкелдәтә.* Г.Бәширов

МҮ́К ҖИЛӘГЕ *и. бот.* 1) Арчанчалар семьялыгыннан мүкле, сазлыклы урыннарда үсә һәм җимеш бирә торган куак үсемлек; *русчасы*: **клюква**. *Кар астыннан нарат һәм мүк җиләге яфраклары күренә.* Д.Шакирова. *Мүк җиләге, бик тәбәнәк булып үсүенә карамастан, үләнчел үсемлек түгел, ә куакчыл.* Татарстанның үсемлекләр һәм хайваннар дөньясы

2) Шул куакның әчкелтем кызыл җиләге. *Мүк җиләге ерактан кызыл чәчәкләргә, якыннан кан тамчыларына охшый.* И.Туктар. *Шуннан, малай, шуны ипи белән, тоз белән ашап җибәрәсең дә ишек катындагы кисмәктән бер чүмеч мүк җиләге суын тондырасың.* М.Мәһдиев. *Туганнан алып үлгәнчегә кадәр гел кызыл мүк җиләге ашыйбыз.* А.Хәсәнов

МҮКЛӘГЕЧ *и. махс.* Төзелештә: мүк кыстырганда файдаланыла торган махсус җайланма

МҮКЛӘК *с.* 1) Мөгезсез. *Мүкләк дигәннән, мүкләк кәҗә дә ярата иркәләүне, энем.* Ф.Баттал. *[Кияүгә] иртәсен-кичен җылы сөт эчерәсе булыр, дип әйтеп, узган яз мүкләк кенә булса да бер кәҗә дә алдылар.* Г.Бәширов. *Аклы-каралы мүкләк сыер, алгы кыска аякларын тери-тери текә калкулыктан төшкәндә, ишелеп торган олы гәүдәсен авыр чайкалдырып, арт аякларын җайсыз гына читкә күчереп куя.* А.Вергазов

2) *күч.* Елгыр, тыкшынучан, шома; үҗәт, үзсүзле (кеше тур.)

3) *күч.* Йомшак характерлы, җебегән, булдыксыз, принципсыз. *Мүкләк Әнәсе үзе яшь, үзе чибәр кызга өйләнде дә куйды.* Р.Шәрипов. *Ярый әле бу ирләр – мүкләк халык, хатын-кызның хәйлә-мәкерен аңламый.* Ф.Баттал. *Мүкләк диген, бөтенесен белеп тора түгелме соң бу?* А.Әхмәтгалиева

МҮКЛӘНҮ *ф.* 1) Нәрсәнең дә булса өстенә мүк үсү, мүк белән каплану. *Кемдер корган чишмә улаклары Чүпләнерләр, мүкләнерләр инде.* Ч.Мусин. *Бу үзенчәлекнең эпиграфика фәне өчен аянычлы икенче бер ягы бар: мондый кабер ташлары озак сакланмый, мүкләнә, ашала, сына-ватыла, язулары да тиз уала.* Р.Мәрданов

2) *төш. юн. к.* **мүкләү**

3) *күч.* Рухи яктан артта калу, үсмәү, торгынлыкта булу; бер нәрсә белән дә кызыксынмау. *Чыгып китим ерак сәфәрләргә, өйдә ятып, җаннар мүкләнде.* Л.Шагыйрьҗан. *Ул бит сазаган кыз түгел, җиләк кебек яшь гомерен өйдә генә уздырмас, йөрәге мүкләнмәсә.* Н.Әхмәдиев. *Шулай булгач, нишләп мин авылга китеп мүкләнергә тиеш?* Н.Фәттах

Мүкләнә бару Торган саен күбрәк мүкләнү. *Коедан су алмый торсаң, саега, кибә кое, Мүкләнә бара бурасы, саргая кое суы.* Җ.Сөләйман

Мүкләнә башлау Нәрсәдәдер мүкләр барлыкка килү. *Без мүкләнә башлаганбыз.* Т.Миңнуллин. *Асларын күптән инде саф сулар юмаган, шунлыктан мүкләнә башлаган авыр ташларым җиңеләйгән кебек булып китте, инде төклетуралар, күбәләкләр кунмый башлаган чәчәкләремә сут йөгерде...* Р.Харис

Мүкләнә төшү Бераз мүкләнү, берникадәр мүкләнгән хәлгә килү

Мүкләнеп бетү Бөтенләй мүкләнү; тоташ мүк белән каплану. *Минем туган җиремдәге агачларның да, җиләкләрнең дә, яңгырда тишкәләнеп, мүкләнеп беткән ташларның да, керәшәләре тыз-быз очып йөргән --- елганың да милләте юк.* Р.Бәшәр. *Агачлык белән күл арасында такта түбәсе мүкләнеп беткән тәбәнәк бер йорт тора, бер тәрәзәсеннән кала һәммәсенең дә капкачлары ябык.* Ә.Гаффар

Мүкләнеп килү *к.* **мүкләнә башлау**

Мүкләнеп яту Озак вакыт дәвамында мүкләнгән хәлдә булу. *--- бик күп шәкертләр, сакаллары агарганчы, муллалыкка урын чыкканны көтеп, шул мәдрәсәләрдә мүкләнеп яталар иде.* Ф.Әмирхан. *Мүкләнеп яткан таш кына кыймылдамый ---.* Р.Фәйзуллин

МҮКЛӘ́Ү *ф.* 1) Мүк кыстыру (бура бүрәнәсе арасына, ярыкка). *Борыслардан мүкләп күтәрелгән тоташ стенаны калын фанер белән тышлап акка буяганнар, нәкъ дәфтәр бите кебек кызыктырып тора...* К.Кәримов. *Озын-озакка сузмыйча, мунчаны мүкләп, чутлап, күтәреп тә куйдылар.* Р.Мулланурова. *Ни әйтсәң дә, бер бүлмәсен мүкләп, җылы итеп эшлисең...* Н.Хәсәнов

2) Нәрсә белән булса да каплау, томалау һ.б. *Оясының кайбер төшләрен, үзеннән йолкып алган мамык белән мүкләп, тагын да җылыта төшә.* Г.Бәширов. *Ике яшүсмер малай (берсе хуҗабикәнең кулларын артка каерган, икенчесе аның авызына чүпрәк мүкләп маташа) чит кеше кергәнен шундук сизделәр, һәм берсе ишеккә таба атылды.* З.Хөснияр

Мүкләп алу Кыска вакыт аралыгында мүкләү

Мүкләп бетерү Барысын да мүкләү

Мүкләп кую Тиз арада яки алдан мүкләү. *Бүрәнәләрен инде китергәннәр, рәшәткә янына таслап өйгәннәр, форсат чыкканны гына көтәләр, эһ дигәнче бурап, күтәреп, мүкләп куячаклар.* Т.Миңнуллин

Мүкләп тору Сөйләү моментында мүкләү

МҮКЛӘҮЧЕ *и.* Мүкләү эшен башкаручы. *Мүкләүче бабай*

МҮКЛЕ *с.* 1) Мүк үскән, мүк белән капланган. *Авылга якын гына*

Мүкле күл бар. Ф.Гарипова. *Менә ни өчен ул Аязны дошман күргән һәм аны «җитлекми туган күзлекле ахмак», «тар күңелле кеше», «йөрәк урынына мүкле таш яткан адәм актыгы» дип атаган.* Р.Мостафин

2) *күч.* Рухи яктан чикләнгән; салкын, хиссез. *Онытма, берәүләрдәге тышкы һәм эчке матурлык икенче берәүләрнең мүкле җанында көнчелек корты уята...* Р.Низамиев

МҮКЛЕК *и.* Мүк күп булып үскән урын

МҮКСЫМАННАР *и. күпл. бот.* Мүкләрнең үзләрен һәм аларга охшаган башка организмнарны эченә алган югары төзелешле үсемлекләр җыелмасы. *Мүксыманнар – гадәттә тәбәнәк күпьеллык үсемлекләр, аларның зурлыгы миллиметрдан алып берничә сантиметрга җитә.* Биология

МЫГЫРДАВЫК *и. к.* **мыгырдык**

МЫГЫРДАНУ *ф. к.* **мыгырдау**. *Байның олы улы Балтабай, явыз мыгырданып, нидер әйтеп куйды.* А.Расих. *– Шәһәргә киләләр дә әллә кем булалар, – дип мыгырданды соңгы айларда бик сирәк айнык күренгән Марат, идәндә яткан хатны алып, Наиләгә сузганда.* М.Әхмәтшина. *– Абау-абау норсыз, – дип мыгырданды карчык, – син нәрсә, әллә кешегә җүнләп сүз ката белмисеңме?* М.Мәһдиев

Мыгырдана башлау Мыгырданырга керешү. *--- Карт лоҗман үзе дә бик тиз тынычлана һәм, урынсызга каударлануы өчен уңайсызлангандай, мыек астыннан үзалдына нидер мыгырдана башлый.* С.Сабиров. *[Фәтхулла хәзрәт:] – Менә ысул җәдитнең ахыры нигә барып чыкты! – дип мыгырдана башлады.* Ф.Әмирхан

Мыгырдана бирү Бернигә карамастан мыгырдану; мыгырдануны дәвам итү

Мыгырданып алу Бераз гына мыгырдану. *Вагон ишеген саклык белән генә ачып керде, икенче бүлмәдә кочаклашып йоклап ятучы Карлыгач белән Таңсылуның йокы аралаш нәрсәдер мыгырданып алуларын ишетеп, иреккездән елмаеп куйды [Сәфәров].* Г.Кашапов. *Шыгырдап торган тимер ишекне ябар алдыннан гына үзалдына мыгырданып алды: – Кисеп-суеп бетермәгәнәр шунда үзегезне...* Р.Мөхәммәдиев

Мыгырданып йөрү Әледән-әле мыгырдану. *Үзегез уйлаганча, сандугачым дип эчегездән мыгырданып йөрсәгез, әллә нихәтле җыр килеп чыга.* Т.Миңнуллин

Мыгырданып кую *к.* **мыгырданып алу**. *--- Гаепле елмаеп килде дә, калтыранган кулларын як-якка җәеп: «Менә шулай килеп чыкты, туган, син гафу ит инде...» – дип мыгырданып кына куйды [Камил].* Р.Мирхәйдәров. *Грузин акценты белән мыегы астыннан мыгырданып куйды [Сталин]: – Барны юк итеп була ул. Юкны бар итеп булмый...* Р.Мөхәммәдиев. *Шуларны уйлый да үзалдына гына мыгырданып куя: – Эрләмәгән-сукмаган, Шаһи, сиңа ыштанлык, була инде бу, – ди.* М.Мәһдиев

Мыгырданып тору Сөйләү моментында мыгырдану. *Тавыкларга карап, таягын әле бер, әле икенче якка йөртеп, мыгырданып торды [күрәзәче].* К.Җәмитев. *Ни дип җавап бирергә белмичә мыгырданып торам: – Классный баянист, – мәйтәм.* А.Хәмзин

МЫГЫРДА́У *ф.* 1) Аңлаешсыз һәм ишетелер-ишетелмәс итеп ниләрдер әйтү, үзалдына сөйләнү. *Рәмзи аңа [Шәфикага] мыек аша мыгырдап кына сәлам бирде дә, түшәм астыннан сузылган тоткага ныклы белән ябышып, яны белән борылды.* М.Маликова. *Немец әзрәк «кәефләнеп» алган, борын төбеннән нәрсәдер мыгырдап, җырлаган сыман кылана.* Р.Мостафин. *Ә инде мыгырдау, сүз кайнату дигәндә, аңа тиңнәр юк.* Ә.Гадел

2) Сукрану, нәрсәдән дә булса ризасызлык, канәгатьсезлек белдерү. *Бибинур җавап урынына нидер мыгырдады.* А.Гыйләҗев

Мыгырдап алу Кыска вакыт эчендә, аз гына мыгырдау. *Шул ук Якуб агадан бер мәлне, Хатип ага нинди тема буенча диссертация яза, дип сорагач, ул сүрән генә: «Нәрсә булсын, шул социалистик реализм инде», – дип мыгырдап алган иде.* М.Госманов. *Секретарь хатынның төртмә сүзе Мәгънәвигә ошамаса да, җавап сүзен тиз генә таба алмады, авыз эченнән генә нидер мыгырдап алды.* Р.Рахман

Мыгырдап йөрү Әледән-әле мыгырдау. *Чөнки, әкиятне, мәзәкне хәтерендә тотарга, сөйләргә маһирлыгы булмаса да, мәкаль-әйтемне, тапкыр сүзне кулланмаса да, ниндидер берәр куанычлы я хәсрәтле хәлләр белән күңеленә сеңеп калган җыр сүзен, көен үзе өчен генә булса да «мыгырдап» йөрмәгән, хозурланмаган кеше юктыр.* Т.Галиуллин. *Тик Вәлүк кенә нәрсәдер мыгырдап йөрде.* А.Алиш

Мыгырдап кую Бер тапкыр мыгырдау. *Коста кинәт кенә сүрән тавыш белән: «Амин», – дип мыгырдап куйды, кулы белән мәгънәле генә хәрәкәт ясап алды: мөселманнар мәетне соңгы юлына шулай озаталар.* Р.Мирхәйдәров. *Ни әйтергә дә белмичә, мин нидер мыгырдап куйдым.* Р.Зәйдулла. *Бәхтияр, бу шаяртуны өнәмәгәндәй: – Ә абыйсы синнән күзен алмады, нинди генә ширбәтле сүзләр әйтмәде, – дип, борын астыннан мыгырдап куйды.* С.Сабиров

Мыгырдап тору Туктаусыз мыгырдау. *Эчне пошырып мыгырдап торасың шунда.* Ш.Камал. *Хатыны да мыгырдап кына торды.* А.Таһиров. *Ярар, ярар, мыгырдап торма, мин – кечкенә кеше.* Н.Әхмәдиев

Мыгырдап утыру *к.* **мыгырдап тору**. *[Ибраһимов:] Сәламәт булсагыз, ник саклану турында уйланмыйсыз, ваемсыз гына, дөрес, өстемә алам дип, мәлҗәгән мокыттай мыгырдап утырасыз?* М.Насыйбуллин

Мыгырдый башлау Мыгырдарга керешү

МЫГЫРДАУЛЫ *с.* Мыгырдауга охшаган. *Мыгырдаулы тавышың башкаларга ошый дип уйлыйсыңмы?* Казан утлары

МЫГЫРДЫК *и.* **1.** 1) Аңлаешсыз итеп, мыгырдап сөйләүче кеше

2) Зарланырга, сукранырга яратучы кеше; мыжгак. *Мыгырдык иргә – лыгырдык хатын.* Мәкаль. *Тылсымы белән бөтен нәрсәне үз файдасына хәл итүче мыгырдык та, башкалар да тылсымның вакытлы булуын аңлауга киләләр.* Ә.Закиржанов

2. *с. мәгъ.* Мыгырдап сөйләшә торган. *Мыгырдык хатын Гыйлемханның больницага эләгүен кайдан ишетеп калган?* Р.Камал. *Шәүлә өстәлдәге бер сум көмешне барып алды да, бер дә исе китмичә генә, янә Габдулланың учына текәлде һәм, үзалдына сөйләнгәндәй, салмак, мыгырдык тавыш илә әйтте: – Базардагылар әйтә, имеш, син сорап кергәнгә соңгы тиенеңне биреп чыгарасың.* Р.Батулла

МЫГЫ́Р-МЫГЫР *иярт.* Ишетелер-ишетелмәс, аңлаешсыз итеп сөйләнү яисә нәрсәдән дә булса ризасызлык белдереп сукрану, зарлануны белдергән авазлар җыелмасы. *Әгәр бу ял йортына килеп, иртән иртүк берәүне таш сукмак беткән җирдә очратсагыз, аның мыгыр-мыгыр кемнедер тиргәвен ишетеп гажәпләнмәгез: Максимыч булыр ул.* Ш.Рәкыйпов. *Халык мыгыр-мыгыр сөйләнеп таралды.* Н.Гыйматдинова. *Тегеләр бүлмә аркылы утырганга, мыгыр-мыгыр иткән тавышларыннан башка бернәрсә дә ишетә алмады*. Р.Гали

МЫДЫРДА́У *ф.* Берөзлексез сөйләү. *Бүлмә тактасы аша бу мыдырдау безгә дә ишетелде.* М.Мәһдиев. *Тик караңгыдан тагын ат пошкырган һәм мыдырдап акрын гына сөйләшкән тавышлар ишетелде.* З.Зәйнуллин

Мыдырдап алу Бераз мыдырдау

Мыдырдап кую Кинәт кенә яки бер мәртәбә мыдырдау. *Аның ара-тирә нидер мыдырдап куюы да аермачык ишетелә хәтта*. Туган як

Мыдырдап йөрү Өзлексез мыдырдау

Мыдырдап тору Туктаусыз мыдырдау; хәзерге моментта мыдырдау

Мыдырдап утыру Озак вакыт дәвамында мыдырдау. *[Телефонист егет:] Шушында, өстәл артында мыдырдап утырырга беттеме икәнни берәр кыз?* Ф.Кәрим

Мыдырдый башлау Мыдырдарга керешү. *Ул, газапланып, авыз эченнән генә нидер пышылдый, мыдырдый башлады.* Ф.Бәйрәмова

МЫДЫ́Р-МЫДЫР *иярт.* Кемнең дә булса үзалдына сөйләнеп йөрүе яисә берничә кешенең үзара шыпырт кына сөйләшүләре нәтиҗәсендә башкаларга аңлашылып җитми торган авазлар җыелмасы. *Ул [Сөембикә] иртүк әнисе белән әбисенең мыдыр-мыдыр сөйләшкән тавышына күзләрен ачты.* Ф.Садриев. *Кичке тынлыкта Хәкимулланың мыдыр-мыдыр сөйләшкәне ишетелә иде.* М.Мәһдиев. *Аяк өсте генә йокымсыраган ана каз мыдыр-мыдыр сөйләшеп ала: йоклагыз, йокла, бибиләрем, без монда әткәгез белән икәү уяу торабыз, дип юатамы ул?..* А.Гыйләҗев

МЫЕК *и.* 1) Ир-атларның өске ирен өстендә куе булып үскән төкләр. *Иргали ак киндер тышлы биләве белән шул арада бүрек колакчыннарын, шинель якасын, мыегын сарып өлгергән бәсне сыпырып төшерде.* М.Хәсәнов. *Хәтта борын астындагы матур итеп нечкә генә калдырылган мыегы да ялтырый.* Ф.Садриев. *Хәмит абзый үзе бик культуралы киенә, борын астында нәкъ рафинад шикәр шакмагы зурлыгында мыек йөртә ---.* М.Мәһдиев

2) Кайбер хайваннарның (кошларның, бөҗәкләрнең, балыкларның һ.б.) өске ирен кырыйларында (томшык астында, авыз кырыенда һ.б.) үсә торган кылсыман каты төкләр. *Сакал кәҗәдә дә бар, мыек мәчедә дә бар.* Мәкаль. *Мыеклы песнәкне беренче тапкыр күрүем.* Ялкын. *Дөнья, кызым, зур диңгез, диңгез өстендә – зур балык, балык мыегында – зур үгез, үгез мөгезендә җир тора.* Т.Гыйззәт. *Кысланың колагы алгы мыеклары төбендә.* Кызыклар дөньясында

3) *бот.* Мыекка охшаган үсенте, мыекча. *Игеннәр серкәләнер чак җиткәч, алар доктор кайчысы белән бодайның мыекларын кыркып йөри торган булдылар.* Г.Бәширов. *Кабак, кыяр, кавында да мыек була*. Биология

◊ **Мыек астыннан** Әкренрәк тавыш белән; ишетелер-ишетелмәс итеп. *Серадов ак көяз кулларын чәбәкләп, мыек астыннан гына такмаклап алды: «Ах, кызлар-йолдызлар, судагы кондызлар...»* З.Фәтхетдинов. **Мыек астыннан елмаю** Тыйнак елмаю. *Даян мыек астыннан кыенсынып елмая, кулын кыскан кешеләргә баш иеп рәхмәт әйтә.* М.Маликова. *Ул Нисаның кысыр болыт кебек күкрәп маташуын мыек астыннан гына елмаеп тыңлады һәм сүзнең бик тиз бетәчәгенә шикләнми дә кебек иде.* А.Гыйләҗев. **Мыек астыннан көлү** Астыртын көлү. *Баядан бирле читтән мыек астыннан гына көлеп торган Газдал капканы ачты да машина янына килеп ярып салды: – Дүрт ягың кыйбла!* Ф.Садриев. **Мыек бору** Юк эш белән шөгыльләнү; берни дә эшләмәү. *Әмма Үзәк мыек та бормый, чөнки башкорт түрәләренең явыз эше аның сәясәтенә бик нык туры килә.* М.Әхмәтҗанов. *Үзгәрү һәм яңару чорында Җилкә кашып, мыек борабыз, Ничек итеп үзгәртеп корырга Күрсәтмәләр көтеп торабыз...* Г.Афзал. **Мыек кабарту** 1) Ачулану, ярсу, канәгатьсезлек белдерү. *Ата үзенең кыскартылган мыекларын кабартты, [ачулы итеп кычкырды].* Ф.Әмирхан. *Мыек кабартырлык вакыйга түгел инде, ләкин кечкенә адым да – хәрәкәт*. Кызыл таң; 2) Мактанып, һаваланып йөрү. **Мыекка чолгау** *к.* **мыекка чорнау**. *Минай егетләре, халыктан сорашты рып, кайда нәрсә барлыгын мыекка чолгый йөриләр.* Ш.Рәкыйпов. **Мыекка чорнау** Истә калдыру, хәтергә салу. *Мыегыма чорнап мин утырам, Ничек язмыйм, язарга тотынам!* Ә.Синугыл-Куганаклы. *Ләкин аның [Тукайның] әдәбият турындагы һәр сүзе гадел, әйтелергә һәм мыекка чорналырга тиешле сүз иде.* А.Расих. **Мыекка урау** *к.* **мыекка чорнау**. **Мыек күпертү** *к.* **мыек кабарту**. *Габделбәр, мыекларын хәтәр күпертеп, эре генә чиерттерә чиерттерүен.* М.Шабай. **Мыек очы да селкенмәү** Ис китмәү, битараф булу. *Ә машина – класс, кәртчеләр Икрамга капчык-капчык акча тәкъдим итәләр, тегенең мыек очы да селкенми.* Р.Мирхәйдәров. **Мыек та селкенмәү** Ис китмәү. *Һәркемнең дә үз күзе, үз колагы, ничек күрә, шулай күрсен, ни ишетә, шуны ишетсен, моңа мыегым да селкенми.* М.Насыйбуллин. **Мыек та селкетмәү** Бернигә дә ис китмәү. *Арытырсың Сәлим абзыйны, мыегын да селкетми ул.* Ш.Камал. **Мыек тибү** Мыек чыга башлау. *Менә сиңа мә! Ничек сөйләшә яңа мыек тибә*

башлаган үсмер Азат. М.Хәбибуллин. *Союзниклар бик сыек. Бала-чага. Әмалайлар – күбесенә инде мыек тибә башлаган.* М.Мәһдиев. **Мыек төртү** 1) Яше җитү, балигъ булу. *Шуларның тәүгесе – бала чакта мәдрәсәдә яхшы укып, хәлфәләрнең сөеклесенә әверелеп, кытыгын китергән, инде мыек төрткәч, Сабантуйларында бил бирмәгән, атасының байлыгын тагын да ишәйтеп җибәргән, дөньяны аркылыгабуйга гизеп, бар нәрсәдән хәбәрдар Җиһанша иде.* Р.Рахман; 2) Күренә башлау (үләннәр тур.). *Сыртларда яшел үләннәр мыек төртте.* Н.Фәттах. **Мыек читеннән елмаю** Серле елмаю; астыртын елмаю. *– Үз ишләре санап чиртә алар [балыклар] сиңа, – дип, мыек читеннән генә елмаеп куйды командир.* Р.Мөхәммәдиев. **Мыек чуалту** Эч пошырып, ачу китереп, буталып, комачаулап йөрү. *Дөрес, ул һич нигезе булмаган гайбәт кенә, ләкин әнә Нургали абыеңның мыегын чуалтыр өчен җитә калган.* Ә.Еники. **Мыек чуалу** 1) Кәефсезләнү. *Начальникның мыегы чуалган көн икәнен белепме, башкалар аның күзенә чалынмаска тырыштылар.* А.Гыйлаҗев; 2) Эш көйсезләнү, эшнең рәте китү. **Мыек чыгу** 1) Яше җитү, балигъ булу. *Себер төрмәләренә әле мыек та чыкмаган яшүсмерләр булып китеп, аннан чаларган ир-атлар булып исән-сау кайта алганнары ничек яшәп яталар икән хәзер?* Р.Мирхәйдәров; 2) Тузу. *Ул мыеклары чыккан чабата кигән иде.* М.Гафури. **Мыек чылату** Берәр эчемлек кабып кую. *[Корпухин:] Мунирчик, син кая качтың? Очрашу хөрмәтенә мыек чылатмый ярамый ич.* Н.Әхмәдиев

МЫЕКБАЙ *и. сөйл.* Мыеклы ират. *Чөнки Минзәлә ирләре дә, җир йөзендәге бөтен ирләр кебек үк, чит хатыннар янына йөрергә яратсалар да, үз хатыннарының бүтән мыекбайлар куенында ятуын күз алдына да китерергә теләмиләр.* Ф.Баттал. *Менә ул мыекбай: Талиб Солтанов, 1953 елгы, ике мәртәбә хөкемгә тартылган законлы карак.* Р.Мирхәйдәров

МЫЕКЛАЧ *и.* **1.** 1) *сөйл.* Зур мыеклы кеше

2) *зоол. к.* **мыеклы балык**. *Соңгы елларда үсемлек белән тукланучы балыклар (амур, юанбаш балык) һәм аларның гибридларын (лабео, мыеклач, катлея, циррина) үрчетә башладылар.* Хайваннар дөньясы

2. *с. мәгъ.* Мыеклы. *Яфракларны гусеницалар, кисмән һәм яфрагашар личинкалары, коңгызлар, мыеклач коңгызлар, филчекләр кимерә.* Яшь натуралистларга

МЫЕКЛЫ *с.* Мыегы булган. *Тукайның Уральск шәһәрендә кулына газета тотып төшкән рәсеме булырга тиеш, ди Гатият абзый – укый-яза белми торган, мәһабәт гәүдәле, мыеклы карт.* М.Мәһдиев. *Мич аралыгында төннәр буена мыеклы көрән чикерткәләр сайрашып чыга иде.* Ә.Гаффар. *Хикмәт аның зифа буйлы, күркәм йөзле, кара мыеклы ыспай егет булуында гына түгел, бәлки әнисе «Сөннән алып кайткан» биш баланың берсе булуында да иде.* Л.Җамалетдинов

МЫЕКЛЫ́ БАЛЫК *и. зоол.* Карплар семьялыгыннан булган елга балыгы; *русчасы*: **усач**. *Өйалдыңда кәрзин тулы балыкны күреп, һәммәсе ләззәтле минут кичерде... Ә Шакирҗан исемнәрен әйтергә тотынды: – Корбан балык... кызыл балык... мыеклы балык... табан балык...* С.Поварисов. *Камбала, чуртан балыклары, мыеклы балык һәм елан балыгы да нәкъ шулай ук пешерелә.* Йорт эшләре

МЫЕКСЫЗ *с.* 1) Мыегы булмаган. *Әгәр мыеклы булмаса, Мыексыз булыр иде, Гармунын алып кулына Берне сыздырыр иде!* Р.Корбан. *Без мыексыз яшь егетләр идек, Юк иде әле кызлар кочканыбыз...* Г.Афзал

2) *күч.* Яшь, балигъ булмаган. *Гүяки аның каршында мыексыз яшь командир түгел, зур соры күзле, акыллы карашлы Гайнулласы басып тора иде.* А.Әхмәт. *Аланбашның Григорий Иваныч өендә «Чулпан»нар тальяны да әйттерә, арысландай ирләреннән башлап мыексыз малайларга, буй җиткән кызларга хәтле, --- әле «Әпипә»гә, әле «Барыня»га басып, бөтен Аланбашны ду китерәләр иде.* Г.Бәширов. *Улы бит аның кыюсыз, Мыексыз егет иде; Сугыштан шуны лабаса Каршылар кебек иде.* Х.Туфан

МЫЕКЧА *и.* Мыекка охшаган үсентеләр. *Безнең урманнарда үсә торган каен җиләге кебек шуышма сабаклы үсемлекләр, мәсәлән, мыекчалардан үрчи.* Ботаника. *Каен җиләге – күпьеллык үлән үсемлек; горизонталь яки кыек тамырчалы, алардан озынча, шуышма тармаклар (мыекчалар) китә.* Урман аптекасы. *Кабачкиның, патиссонның сабаклары кыска, мыекчасыз була һәм куакланып үсә.* Яшелчәчелек

МЫЕКЧАН *с. сөйл. к.* **мыеклы**. *Адрес була кыекчан. Егет була мыекчан.* Жыр. *Туны мамыктан, Үзе мыекчан, Йөри оекчан*. Табышмак

МЫЕКЧЫЛ *и. зоол. к.* **мыеклы балык**

МЫ́Ж *иярт.* **1.** Чиксез күп, бик ишле булуны аңлата. *Кичә үк карап куйган кечкенә генә күлем бар иде. Анда һәр елны язгы су белән кергән чуртан мыж була.* Р.Сибат. *«Бүредән, төлкедән сакланыгыз!» дип тәрҗемә кылгач, яшен тизлеге белән якын-тирә авылларда шомлы хәбәр таралды: Шәрдән урманында мыж аю, бүре, төлке, ди, урманга кермәскә кушып, багана башларына язу язып элгәннәр, ди.* Т.Мөбарәков

2. *хәб. мәгъ.* Күп булуны, мыжлап торуны аңлата. *Бала-чаганы әйткән дә юк – мыж*. К.Тимбикова. *Кызган асфальт исе килеп торган тротуарда халык мыж.* А.Гыйлаҗев

◊ **Мыж кайнау** Мыжлап тору, күп булу. *Моңа кадәр партизан отрядлары белән мыж кайнаган урманнарда хәзер мылтык аткан тавышлар да яңгырамый, миналар да шартламый ---.* А.Расих. *Халык монда кырмыска оясыдай мыж кайный: утырып торырга да урын юк.* Г.Кутуй

МЫЖГАК *с. диал.* **1.** 1) Пычрак, яңгырлы. *– Мондый мыжгак көндә син генә йөрерсең инде, – дип елмаеп каршы алды мине Сабир бабай.* Казан утлары

2) Бертуктаусыз сукранып, ачуланып, канәгатьсезлек белгертеп тора торган; мыжык. *Шулай итмәсәң, үзеңне үк заманнан артта калган, мыжгак кеше дип уйлаячаклар.* Татарстан

яшьләре. *«Озын гомерле кешеләр белән эшли башлагач, без, болар – зарланырга яратучы мыжгак, мескен кешеләрдер дип уйлаган идек, ләкин алар бик көр күңелле, тыныч холыклы, шул ук вакытта бик актив кешеләр булып чыктылар», – дигәннәр галимнәр.* Татарстан яшьләре

2. *и. мәгъ.* Зарланырга, сукранырга ярата торган кеше. *Дөнья мыжгаклар белән тулды.* Н.Сафина

МЫЖГАКЛЫК *и.* Мыжгак булу. *Өлкәнрәк буын кешеләренең: «Элек аракы да рәхәтрәк исертә иде, казылык та тәмлерәк иде, сөт тә куерак иде», – дигәненә, яшьләр, гадәттә, ничектер, картлар мыжгаклыгы, дип кенә карый.* Татарстан яшьләре

МЫЖГУ *ф.* 1) Мыж итү; мыж килү. *Гасыйм Сәләхович сәгатенә карап алды – унике тулган икән инде. Халыкның нәкъ мыжгыган чагы...* Ә.Еники. *Ул [Хәниф] алан кырыендагы бер умартаны ача һәм рамнар арасыннан вазелин сөрткән металл поднос ала. Өсте – мыжгыган бөҗәк.* М.Мәһдиев

2) Сукрану, сукранып тору; ишетелер-ишетелмәс яки аңлаешсыз итеп сөйләнү. *Йөремчәк мәчене тавышын-тынын чыгармыйча гына куенга тыгарга да каланың читенә үк илтеп адаштырып калдырырга уйлаган иде Рәсүл, яшь бичәсенең мыжгуыннан шулай гына котылмакчы булган иде.* Ш.Янбаев. *Абзарга чыксаң, алган әйбереңне урынына куя белмисең, дип, әти мыжгый.* Л.Гыймадиева. *Соңыннан, минем мыжгуымнан тәмам гарык булды бугай [әти], [мичне] сүтәргә ризалык бирде.* Татарстан яшьләре

3) Нәрсәнең дә булса чамасыз күп булуы. *Әнә ич, Миргали абзыйларның бакчасында алабута, билчән, эт эчәгесе мыжгыган.* Н.Әхмәдиев. *Кабык күпер өсте дигән җирдә җир җиләге мыжгып үсә.* Н.Хәсәнов

Мыжгый башлау Мыжгырга тотыну. *Идәндәге паласларны җыйганда, ирем мыжгый башласа, аны бик тиз тынычландырыр идем.* М.Сәлим. *Ә хәзер исә бөтенләй башкача: иртә-кичен аның урамнары кешеләр белән тулып, кояш күтәрелгәндә үк мыжгый башлый, машиналар кайнашырга-чабышырга тотыналар.* Ф.Яхин

Мыжгып тору Бик күп булган нәрсәләрнең мыжгыган хәлдә булуы. *Айсылу миендә сораулар мыжгып торды.* Б.Камалов. *Күлнең ләмле чокырында мыжгып тора корт кына.* З.Мансуров. *Мөртәт җанлы шымчылары белән Мыжгып торган бөтен ил эче.* Р.Гәрәй

Мыжгып яту *к.* **мыжгып тору**. *Кешелек – бер-берсен ашап көн күрә торган һәм әз генә дә акылы булмаган микроблар, мыжгып яткан хәшәрәтләр мохите сыман.* Ф.Баттал

МЫЖГЫЛДА́У *ф. к.* **мыжлау**. *Ишек төбендәге чебен өере, Шәлвәдән куркып, мыжгылдап һавага күтәрелде.* Р.Батулла. *Болындай зур бүлмәләрдә, таракан кебек мыжгылдап, шырдый-бырдыйлар гына калды.* А.Гыйләҗев. *Алдыңда – ашың, кулыңда кашыгың булса, мыжгылдама.* Т.Миңнуллин

Мыжгылдап йөрү Һәрдаим мыжгылдау. *Хосусән шуның кассасында акча булганда, тирә-юнендә мыжгылдап йөрүче «иттифакчы»ларның актыккы күздән балны алып бетергәч тә бердән югалулары «Иттифак»ның мәгънәви кыйммәтен төшерә иде.* Г.Исхакый

Мыжгылдап тору Бертуктаусыз мыжгылдау; даими мыжгылдау. *Өстәлдәге юылмаган табак-савыт өстендә чебеннәр болыты мыжгылдап тора.* Р.Батулла

Мыжгылдап яту Нәрсәнең дә булса бик күп булып, шау-шу килеп торуы турында. *Кулларым белән капшап карасам, пычрак дигәнем пычрак түгел, мыжгылдап яткан вак кына суалчаннар икән.* Г.Рәхим

Мыжгылдый башлау Мыжгылдарга тотыну

МЫЖГЫЛДЫК *и. сөйл.* **1.** Зарланып яки бертуктаусыз сукранып, ачуланып торучы кеше

2. *с. мәгъ.* Бертуктаусыз сукранып, ачуланып торучан. *Әмма Сәҗидә бу мыжгылдык каенана кулында уенчык булырга теләмәде.* М.Галәү

МЫ́Ж ИТҮ *ф. к.* **мыж килү**. *Һәм урман баһадирлары кырмыскалар гына, һични белән исәпләшмичә, ыгы-зыгы килеп йөгерешәләр, мыж итеп торган өйләренә кирәк-ярак ташыйлар.* Ш.Рәкыйпов

МЫ́Ж КИЛҮ *ф.* Артык күп булып, ыгы-зыгы килеп тору, тиз һәм җитез хәрәкәтләнү. *Базарларда итчеләр, киезчеләр, күнчеләр, хәлвәчеләр, җәүһәрчеләр, вак-төяк сатучылар мыж килеп торырлар иде.* Р.Батулла. *Куе таллыклар, камышлар белән капланган яр буйларында, елга үзәннәрендә, беркемнән, бернидән курыкмыйча киекләр, ерткычлар яши, суларда – күлнең үзендә, елгаларда – балыклар мыж килә.* Н.Фәттах

МЫЖЛА́У *ф.* 1) Мыж итү, мыжгып тору; бик күп булу. *Имештер, Пекинга барганмын. Халык мыжлаган.* Д.Гыйсметдин. *Нәни генә бер ноктасында без – кешеләре – кырмыскадай мыжлап яшәп яткан, Кояш, Ай һәм йолдызлар белән гаҗәеп тә серле булган Галәм ул нинди?* Кызыклар дөньясында

2) «Мыж-мыж, мыж-ж-ж»га охшаш авазлар чыгарып яисә бик тиз хәрәкәтләнү. *Тукта әле, ошбу юкәдә нидер бар түгелме? Бу агач янында кортлар ник мыжлап оча?* Кызыклар дөньясында. *Шул ук урынга иртә белән иртүк килсәгез, монда ташбакалар, кәлтәләр, еланнар, фаланга үрмәкүчләре, коңгызлар мыжлавын күрер идегез: алар мондагы салкын ком өстендә хәрәкәтләнеп, гаҗәп төрле формадагы эзләр калдыралар.* Хайваннар турында очерклар

3) *к.* **мыжылдау**. *Аның [Игнатның] болай чын картларча үзалдына мыжлап йөрү гадәте дә Сафиягә таныш түгел иде.* М.Маликова

Мыжлап тору Бертуктаусыз мыжлау. *Ростов тирәсендә гаскәр мыжлап тора.* Ә.Галиев. *[Нури:] Мөнирә әйтә, безнең елгада балык мыжлап тора, ди.* Т.Миңнуллин

Мыжлап яту Бик озак вакыт мыжлау. *Идәндә теткәләнгән линолеум, чебен сарган, мыжлап яталар...* Ш.Галиев. *Шуның өстенә, ул замандагы биек һәм куе үлән арасында мыжлап яткан беренче кәлтәләргә, дошманнардан саклану яисә үзең һөҗүм итү максатында, башны гел югары тотарга туры килгән.* Кызыклар дөньясында

Мыжлый башлау Мыжларга тотыну

МЫ́Ж-МЫЖ *иярт.* Ишетелер-ишетелмәс яңгыраган яисә аңлаешсыз булган авазлар җыелмасын белдерә

◊ **Мыж-мыж килү** 1) Мыжгу; ыгы-зыгы килү. *Әби калды мыж-мыж килеп.* Туганайлар; 2) Берөзлексез, бертуктаусыз сөйләнү яки берөзлексез сукрану. *--- берәүләр башкаларның дәрәҗәсен кысу исәбенә үз абруйларын күтәрергә омтылган җирдә, хәтта яхшы ук тупланган күпмилләтле коллективларда да кайчак мыж-мыж килә башлыйлар.* Казан утлары. **Мыж-мыж сөйләнү** Күңел кайтарырлык, эчпошыргыч итеп бертуктаусыз сөйләнү яки сукрану. *Мыж-мыж сөйләнгән хатыннан өмет өз.* Мәкаль

МЫЖУ *ф. диал.* Көйсезләнү, тынычсызлану. *Ә шулай да күңел мыжый: «Без дә бит тере кеше!»* К.Фатыйхова. *Нигә шулай мыжый әле бу карт?* Н.Мусин. *Җитмәсә, кечесе Ригать көн дә: «Әни кайчан кайта?» – дип мыжый.* Кызыл таң

МЫЖЫЙ *с. сөйл.* Әкрен, сүлпән; пошмас. *Тынлыкның шундый сизгер чагы, әгәр Сөмбелә капка келәсенә ялгыш ныграк орынса, абзардагы ишле каз: «Как? Как?» – дип, русчалатып сорау алыр, казлар авазына сагаеп, күрше Җамалыйларның мыжый эте: «Ah! Ah!» – дип өреп куяр.* К.Кәримов

МЫЖЫК *с.* **1.** Зарланучан, сукрануч-ан, вакчыл. *Юкса мин сукранып, зарланып, ах та ух килеп йөрүче, бәйләнчек, мыжык, теңкәгә корытучы, саруыңны кайнатучы, җаныңны өтүче, гайрәтеңне чигерүче, кәефеңне кыручы, җелегеңә төшүче, үзәгеңә үтүче бер карчыкка әйләнеп беткән булыр идем инде.* Ә.Гаффар. *Аннары, ун ел буе мыжык язучылар көен көйләп йөреп, Ринат та арыгандыр инде.* Г.Морат

2. *и. мәгъ.* Зарлануч-ан, сукрануч-ан, вакчыл кеше. *Безнең публицистика бүген ике өлештән тора: аның унунбиш проценты – гамәли публицистика, калган сиксән-туксан проценты – «кирәк-кирәк» дип чәпчүдән, үзебезне мактау һәм макташудан узмаган мыжыклар публицистикасы.* А.Хәлим

МЫЖЫЛДА́У *ф.* 1) Мыж килү. *--- ялгыз гына утырырга яратмый, ишеген ачык калдырса, янында сөйләшеп утыручы булмаса да, ачык ишектән учреждениедәге хезмәткәрләрнең мыжылдауларын карап тору күңелле була.* Һ.Такташ. *Кешеләр шулай аһ итеп торгач, сыраның дәрәҗәсе бермә-бер күтәрелде, аны чырай сыта-сыта йоткалап тордылар, тирә-якта халык мыжылдады, арада таныш йөзләр берән-сәрән чагылып китте, әмма бу минутларда алар үз кайгыларын гына кайгырталар иде.* А.Гыйләҗев. *У-у, яр тирәсендә халык мыжылдый.* Н.Гыйматдинова

2) Сукрану. *Аңа бу карчыкның юкбар турында мыжылдаулары хәзер бик кечкенә нәрсә булып калганга охшый.* Г.Бәширов

Мыжылдап алу Кыска вакыт арасында, аз гына мыжылдау

Мыжылдап йөрү Озак вакыт дәвамында мыжылдау. *Оптимист кеше һәм реалист буларак мин, әлбәттә, төшенкелеккә бирелеп, мыжылдап йөрмәдем.* Т.Миңнуллин

Мыжылдап тору Бертуктаусыз мыжылдау, даими мыжылдау. *Кыскасы, керпе мыжылдап торган йөзләрчә кечкенә еланчыклар белән чорналып алынган булып күренә иде.* Диңгез тирәнлегендә

Мыжылдап утыру Озак вакыт дәвамында мыжылдау

Мыжылдый башлау Мыжылдарга тотыну. *Хәзер алар белән ярышу да кызык түгел, җитмәсә, Ишбирде арып мыжылдый башлый, комачаулап кына йөри.* Г.Якупова

МЫҖЫРДА́У *ф.* Әчеп, күпереп утыру (бал, компот, кайнатма, квас һ.б.ш. тур.). *Былтыргы чия кайнатмасы мыжырдаган ---.* Казан утлары

МЫҖ́ЫР-МЫҖЫР *иярт.* Нәрсәнең дә булса әчеп, күпереп, куыклар чыгарып мыжырдаган тавышын белдерә; чымыр-чымыр. *Кыяр банкасы ачкан идем дә, салкынга куярга онытканмын бит, әнә – мыжыр-мыжыр.* Юлдаш

◊ **Мыжыр-мыжыр килү** *к.* **мыжырдау**. *Кайнатмагыз мыжыр-мыжыр килеп утыра икән, шикәр комы өстәп, яңадан кайнатып алыгыз.* Файдалы киңәшләр

МЫЗЫЛДА́У *ф. к.* **бызылдау**. *Черки бар җирдә күп булдым, аның мызылдаганына карап йокламый да калмадым.* Ш.Мөхәммәдев

Мызылдап алу Кыска вакыт арасында, аз гына мызылдау

Мызылдап йөрү Озак вакыт дәвамында мызылдау

Мызылдап тору Озак вакыт дәвамында мызылдау; бертуктаусыз мызылдау

Мызылдый башлау Мызылдарга керешү

МЫЙК *иярт.* Кеше егылганда яки нәрсәдер төшкәндә һ.б.ш. очракларда ишетелгән тавышны белдерә. *Чыйк итмәгәй мыйк ит, барыбер гөрәнкәгә кергәнсең.* Мәкаль. *Трубкада өй түбәсеннән ташка мыйк итеп егылып төшкән тычкан тавышы ишетелә, аннары бераз тынлыктан соң аңга килү сизелә: – Ничек сез?..* М.Галиев. *Каты төште, ахрысы, мыйк иткән тавыш чыгарды да тынып калды.* М.Кәбиров

МЫ́ЙК-МЫЙК *иярт.* Нәрсәдер эшләгәндә (мәс., хәрәкәтләнгәндә, егылганда, ашаганда һ.б.ш.) ишетелгән тавышны белдерә. *Әби коймак чыш-пыш, ә мин тәмләп кенә мыйк-мыйк, голт-голт, шопыр-шопыр бал белән.* Р.Батулла

МЫЙКЫЛДА́У *ф. к.* **мыймылдау**. *Озак күргәнем юк иде, артык ныкъ тазарган икән шул ул, бар җире мыйкылдый.* Казан утлары

Мыйкылдап кую Кинәт кенә яки бер мәртәбә мыйкылдау

Мыйкылдап тору Һәрвакыт мыйкылдау; мыйкылдаган хәлдә булу. *Гәүдәм мыйкылдап тора дими, һаман ашауны гына белә.* Кызыл таң

МЫЙКЫЛДЫК *с. диал.* Симез. *Диңгез яр буе мыйкылдык гәүдәләр белән генә тулган диярсең.* Ватаным Татарстан

МЫЙКЫ́Л-МЫЙКЫЛ ИТҮ *ф. к.* **мыймылдау**. *Мыйкыл-мыйкыл итеп тора аяклары, куллары ---.* Мәдәни җомга

МЫЙМЫЛДАТУ *ф.* Селкетү, хәрәкәтләндерү; ишарәләү. *Хәйдәров ике йодрыгын күкрәгенә терәп, авызборынын мыймылдатып, малайга*

тыелырга куша иде. А.Гыйләҗев. *– Бүген – билгесезлеккә! – диде ул каш сикертеп, авызын мыймылдатып.* А.Гыйләҗев. *--- аның чыгышы тавышының шәп булуы белән генә түгел, сәхнә пространствосын оригинал файдалануы, бот мыймылдатучыларның күренмәве белән дә отышлы булды.* Мәдәни җомга

МЫЙМЫЛДА́У *ф.* 1) Селкенеп тору (артык таза кешенең һәм бик симез хайваннарның итләч урыннары тур.). *Янәшәмдә яшь бичә, Ятсынуы тоелмый. Юеш күлмәк аркылы Бар нимәсе мыймылдый.* Ш.Гаделша

2) *иск.* Хәрәкәтләнү. *Сынадым [исәп] уеңны. Авызың дәхи былбылдай. Зифа буең, төсең-битең Ки хур кызыча мыймылдый.* Г.Кандалый

Мыймылдап тору Бертуктаусыз мыймылдау; сөйләү моментында мыймылдау. *Тиздән мыймылдап торган йомшак гәүдәле, кабартмадай симез битле Бәдернисаны куеныма кертәчәкмен, дип куанды Хәсән үзе дә.* М.Әмирханов

МЫЙМЫЛДЫК *с.* **1.** 1) Симез; мыймыл-мыймыл килеп торган. *Кичә килсә, Нәҗип мыймылдык хатынның сүзенә ышанып, кара сарык сыман башын иеп, гафу үтенеп чыгып китәр иде: обкомда тек обкомда!* А.Гыйләҗев. *Әмма Нәҗия бик ямьсезләнгән, балан бәлеше кебек җәелеп, бер мыймылдык хатынга әйләнгән, дигән оятсыз сүзләрен ишеткәч, түзмәде.* Ватаным Татарстан

2) Бертуктамый селкенеп тору. *Таҗсылуга нәрсә: авыз мыймылдык, күзкаш тирәләре каймаланып бизәлгән, колак алкалары болыт арасында уйнаган яшендәй елык-ялык килә.* А.Гыйләҗев

2. *и. мәгъ.* Симез кеше

МЫЙМЫ́Л-МЫЙМЫЛ ИТҮ *ф. к.* **мыймылдау**

МЫЛТ *иярт.* Нәрсәдер суга төшкәндә, сикергәндә һ.б.ш. очракта чыккан тавышны белдерә. *Төнбоек яфрагына турылап сикергән бака таеп китә дә, чалкан әйләнеп, эчке күлмәкыштанын ялтыратып, мылт итеп төпкә китә.* М.Галиев

МЫ́ЛТ-МЫЛТ *иярт.* Нәрсәнең дә булса селкенеп торуы, дерелдәве, калтыравы; күзләрнең еш йомылуы турында. *Аның [Галикәйнең] күз алмалары мутланып тәгәриләр, ирене мылтмылт килә, ул, озын, ябык муенын төрле якка боргалап, бөтен авылның, бөтен урамның, бөтен кешеләрнең игътибарын үзенә генә җәлеп итәргә тырыша.* А.Гыйләҗев. *Һәм ул, мылтмылт итеп, керфекләрен кагып куйды.* Безнең гәҗит

МЫЛТЫК *и.* Озын көпшәле ату коралы. *Шатыр-шотыр китереп мылтык затворлары тартылды.* З.Фәтхетдинов. *Кулында мылтыгы булмаган кешедән төлке курыкмый.* Кызыклар дөньясында

МЫЛТЫКЛЫ *с.* Мылтыгы булган; мылтык белән коралланган. *Клуб, гадәттәгечә, суык, ишек төбендә солдат киеменнән мылтыклы бер кеше басып тора иде.* Г.Ахунов. *Ике мылтыклы кешенең Әхмәдулласын арбага утыртып алып китүләре, ә үзенең, Олы күпернең бер бүрәнәсендә чукаеп торган орыга эләгеп егылып, аягын каймыктыруы, атлый алмагач, мәчет ягына тиклем үрмәләп баруы хакында дәү әнисе, мең булмаганда да, йөз сөйләде ләса аңа.* Г.Якупова. *Бу оешма шактый зур көч – 50 мең мылтыклы кешене туплый.* Р.Мостафин

МЫЛТЫКЧЫ *и.* 1) Мылтык ясаучы оста

2) Мылтык белән коралланган сугышчы. *Бу хәлгә җен ачулары чыккан Иван Дүртенче мылтыкчыларына халыкка атарга боера.* М.Хәбибуллин. *Урыс мылтыкчылары туктаусыз ату сәбәпле, җәячеләр, баш калкыта алмыйча, таш диварга сыенып ята бирде.* Р.Батулла

МЫНГУ *ф. диал.* Юешләнү, дымлану. *Бибинур филтәне бераз гына калкытты, Габдуллажанга чишенергә булышты, мынгыган күн итекләрен мичкә терәп куеп, дымлы аякчуларын кайнар мич төбенә тараттты.* А.Гыйләҗев

МЫНГЫЛАНУ *ф. диал. к.* **мынгу**. *Плащларга төренгән, мынгыланган газеталар ябынган бу халык арасыннан Мөнирнең үзен ничек табарга?* А.Гыйләҗев

МЫҢГЫРДА́У *ф. диал. к.* **мыгырдау**. *Аның күрә карау күзе белән борын эченнән мыңгырдап укуын тыңлап торып, Идриснең калак сөякләре сызлый...* А.Гыйләҗев

Мыңгырдап алу Кыска вакыт эчендә, тиз генә мыңгырдау. *Альберт, диваннан башын калкытып, әтисенең кулындагы талбишеккә тутырып карады да, авызын чалшайтып, нидер мыңгырдап алды.* Ф.Сафин

Мыңгырдап кую Бер тапкыр мыңгырдау. *Сәлим, абыйсының сүзенә җавап итеп, мыңгырдап куйды.* Казан утлары

Мыңгырдап йөрү Озак вакыт дәвамында, һәрдаим мыңгырдау. *Көн буе мыңгырдап йөрде ул шулай.* Ф.Сафин

Мыңгырдап тору Сөйләү моментында мыңгырдау. *Закир һаман шулай мыңгырдап торуын белде.* Безнең гәҗит

Мыңгырдый башлау Мыңгырдарга тотыну

МЫҢГЫ́Р-МЫҢГЫР *иярт. к.* **мыгыр-мыгыр**. *Бәхтияр мыңгыр-мыңгыр шигырь ятлый.* Р.Батулла. *Тик автобус йокысы йокымыни – селкенү, кешеләрнең мыңгыр-мыңгыр сөйләшүе, яңа көн тууы – барысы да: «Тор, шәкерт, уян, җиттек Казанга!» – дигән кебек.* Өмет

◊ **Мыңгыр-мыңгыр килү** *ф.* Мыгырдау. *Авыл советы рәисе Башбармак Хәсәннең колагына киртләпләр әйткәне исендә, тегесе исерек иде, баш кагып, мыңгыр-мыңгыр килеп утырды, язып куймаган икән, йөзе кара.* Ф.Сафин. *Башын иеп мыңгыр-мыңгыр килә: – Белә́без, бик белә́без ул язучыны...* Ф.Баттал

МЫР *иярт.* Песи мыраулаган тавышны белдерә. *Тычкан халкы үтә сак бит ул. – Мияу! Мыр-р-р! – диде Тычкан баласы.* Әкият. *Юк исә мыраулармын һаман: мыр-р-р! мыр-р-р!* Г.Камал. *Ул да булмый, нәрсәдер: – Мыр-рр мияу! – дип кычкырып, Думпасның борынын тырнап төшерә дә ишектән атылып чыгып китә.* Р.Батулла

МЫРАК *и. манси бот.* Гөлчәчәкләләр семьялыгыннан тундрада, сазлыкларда үсә, ак чәчәк ата торган күпьеллык үләнчел үсемлек һәм шуның җиләге; саз җиләге

МЫРА́У *иярт.* **1.** Мәче кычкырган калын тавышны белдерә. *--- күсе*

чыга торган тишек янына утырдым. Менә мияулыйм, менә мыраулыйм! – Мияу, мырау, мәау, морррау! Г.Тукай. *Мырау-а-у тавышыннан лейтенант та сискәнеп куйды, кобурасыннан пистолетын тартып чыгарып, әбидән дә борынгырак – ике йөз яшьлек агачка төбәде.* Р.Сәгъди. *[Тәмлетамак:] Мырау-мырау – мырлый белән, Мияу-мияу – җырлый белән.* Т.Миңнуллин

2. *и. мәгъ.* Песи, мәче дигәнне белдерә торган гомуми кушамат. *Кем урлады чебине, Мырау шуны белмиме?* Р.Вәлиева. *Ул да булмый, тәрәзәдән башта Мырау сикереп чыга, аның артыннан – Чәпәләй, Тәпәләй.* Л.Лерон

МЫРАУЛА́У *ф.* Мырау-мырау итү, калын тавыш белән кычкыру (мәче тур.). *Эт кемгә өрә, мәче шуңарга мыраулый.* Мәкаль. *Эт өрә, мәче мыраулый, бар көченә тавык кытаклый.* Ф.Яруллин. *Кухнядан мыраулап зур йөнтәс койрыклы себер песие килеп чыкты, картның протез аягына килеп сырпаланды, җылы тапмагач, исән аягы ягына күчте.* А.Гыйләҗев

Мыраулап алу Бер тапкыр мыраулау. *Җә, нәрсә күзләрегезне акайттыгыз, дигәндәй мыраулап алды да килгән ягына элдертте [мәче].* М.Әмирханов

Мыраулап җибәрү Кисәк мыраулау. *Аяк астында буталып йөргәндә, кайсыдыр аның койрыгына китереп басты, ахрысы, мәче бик яман тавыш белән мыраулап җибәрүгә, барысы да сискәнеп, тынып калдылар.* Л.Ихсанова

Мыраулап йөрү Озак вакыт дәвамында мыраулау. *Аяк арасына сырпаланып, Мыраулап йөри песи.* Р.Шәрипова. – *Ул Песине әле бая гына күрдек, күзләре дә бик исән, мыраулап йөридер иде, – диделәр [сыерчыклар].* А.Алиш

Мыраулап кую Бер тапкыр мыраулау. *Агач башындагы мәче генә, хуҗасының кереп китүенә үпкәләп, моңсу гына мыраулап куйды.* Р.Сәгъди. *Вакыт-вакыт, бу сәер тынлыкны бүлеп, мич башындагы песи генә мыраулап куйды.* А.Әхмәтгалиева

Мыраулап тору Туктаусыз мырылдау; әледән-әле мырылдау. – *Кит әле, мыраулап торма янымда, – дип, яраткан песиен дә куып җибәрде ул.* Сабантуй

Мыраулап чыгу Ниндидер вакыт аралыгын туктаусыз мыраулап үткәрү. *Мәче төн буе мыраулап чыкты*

Мыраулый башлау Мырауларга керешү. *Әби чыгып китүгә, песи мыраулый башлый иде.* Сөембикә

МЫРА́У-МЫРАУ *иярт.* Мәче кычкырган калын тавышны белдерә. *Килеп җитүгә, иткә ташлана да «мырау-мырау» дип ашый башлый бу.* Әкият. *Әгәр бу мәҗлестә минем шикелле берничә яшьләр булса, ахун сөйләгәндә, һәммәсе беравыздан «мырау-мырау», «мияу» кычкырып, мәче музыкасы уйнаячаклар иде.* Г.Тукай

МЫ́РК-МЫРК *к.* **мырык-мырык**

МЫРКЫЛДА́У *ф.* 1) Мырык-мырык килү, мырык-мырык итү. *Шунда, тегермән белән абзар арасында мыркылдап, өч тиен акча зурлыгындагы түгәрәк танауларын җиргә төртеп йөргән ак керфекле йомры дуңгыз балаларына да Пауалныкы булган өчен генә бөтен кеше яратып карый иде.* М.Мәһдиев. *Дөрес, аларга кадәр дә һәр урыс ишегалдында чучка мыркылдый иде, әмма дуңгыз ыслау җайланмаларын немецлар гына булдырды, кешеләр ысланган казылыкның исен-тәмен татыдылар.* Р.Мирхәйдәров. *Хәтта мыркылдыйлар, каркылдыйлар һәм чупылдыйлар [балыклар].* Кызыклар дөньясында

2) *кимс.* Өзлексез сукрану, ачуланып сөйләнү турында. *Әркәшә акрын гына чишенә. Мыркылдап сүгенә.* М.Мәһдиев

Мыркылдап алу Кыска вакыт эчендә мыркылдау

Мыркылдап җибәрү Кисәк мыркылдый башлау. *Ләкин болар тиешле килбәтне алгач, гөнаһ шомлыгына каршы (урыс авылы!), көтмәгәнә дуңгыз мыркылдап җибәрмәсенме!* Р.Әмирханов

Мыркылдап йөрү Өзлексез мыркылдау

Мыркылдап кую Бер тапкыр мыркылдау. – *Ай-яй, малай, таш кебек каты бу нәмә. Маңгаем шундук шешеп чыкты, – дип мыркылдап куйды ул.* Р.Сәгъди. – *Гөнаһсыз кешеләрне тутырасың төрмәгә! – дигән идем, шундук мыркылдап куйды: «Какая разница?! Кемне атып, кемнәрне утыртсаң да, барыбер воздух чище будет!»* Ф.Баттал

Мыркылдап тору Берөзлексез, даими рәвештә мыркылдау. *Чучкалары зәһәр, мыркылдап торалар.* Р.Зарипов. *Янымда мыркылдап кына торалар [чучкалар].* Р.Миңнуллин. *Горефгадәтне югалтырга ярамый, салалар батырның җилкәсенә мыркылдап торган дуңгызны, батыр да тук, дуңгыз да юк!* И.Юзеев

Мыркылдый башлау Мыркылдарга тотыну. *Тик соңгы елларда чәйгә бик кинәндермиләр, халыкның да авызы бозылды, элек такта чәй кунак сые иде, хәзер салып кара такта чәйне – балачагасына хәтле: «Бу нинди чүп тутырдыгыз, ачы тузаны авызга керә!» – дип мыркылдый башлый.* А.Гыйләҗев. *Кешегә, син – дуңгыз, дип кабатлап торсаң, бераз вакыттан соң ул дуңгыз булып мыркылдый башлый, диләр.* Татарстан яшьләре

МЫРКЫЛДЫК *и. сөйл.* Дуңгыз. *Дуңгызны җенем сөймәсә дә, алып кайттым авылдан бер мыркылдыкны.* Т.Миңнуллин. --- *эшләп яткан һәм төзәләчәк гыйбадәтханәләрдә чукындыра торган алтынлы кургашын, тимертомыр, чурт-чураман декорация, тәреле штандартлар, укалы чиркәү байраклары һәм мыркылдык мае, шәмнәр төялгән авыр йөкне ул [хәзрәт] кымшата да алмый.* А.Хәлим

МЫРЛА́У *ф.* 1) Мыр-мыр иткән авазлар чыгару; мыраулау (кайбер җәнлекләр, хайваннар тур.). *Иң ялкавы – Мырау да, Зур эш аңа мырлау да!* Р.Миңнуллин. *Әмма өйгә алып кайтмакчы булып авылга борылуга, усал итеп бер мырлады да тун эченнән сикереп төшеп чапты [мәче].* М.Хуҗин. *Аю үз баласын утырып имезә, бу вакытта аю балалары нәкъ нәни мотор тавышы чыгарып мырлыйлар.* Кызыклар дөньясында

2) Өзлексез сукрану, ачуланып сөйләнү. *Гаражда өйрәнчек слесарь булып йөргән Мөнир печәнгә күчүенә бер дә риза түгел, ул үзен түбәнсетеләр,*

кимсеттеләр дип саный, юынганда да һаман мырлавында була: – Бетмәгән печән булды инде... Йокы күрә алмассың хәзер!.. А.Гыйләҗев

3) Авыз эчендә көйләгән, җырлаган сыман итү. *[Давыт] җиңел көйгә мырлый-мырлый, урам буйлап китеп тә бара.* А.Гыйләҗев

Мырлап алу Кыска вакыт эчендә яки тиз генә мырлау

Мырлап йөрү Берөзлексез мырлау. *Мырлап кына йөриләр бит, Җырлап кына йөриләр. Яшермәсәң, сөт, каймакны Урлап кына йөриләр*. С.Рәхмәтулла. *Хәзер мин шәһәрдә авыру картлар шикелле мырлап йөрим: проигрывательләрен бөтен көченә акыртып форточкага элаләр яки балконда акырталар.* М.Мәһдиев. *Мондый түгел идең ләбаса син, Кәүсәрия?! Картаймыш көнеңдә шушылай мырлап йөрергә калыр идең микәнни?* Ә.Гаффар

Мырлап тору Озак вакыт мырлау; сөйләм моментында мырлау

Мырлый башлау Мырларга тотыну. *Ул менә хәзер, колак артын кашыткан мәче кебек, ләззәтле мырлый башлар иде сыман.* М.Галиев

МЫ́Р-МЫР *иярт.* 1) Мәче мыраулаган тавышны белдерә. *Өстәл лампасын кабызсам, Мәче менә өстәлгә, Кәгазьләр кыштырдавына Мыр-мыр тавышы өстәлә*. Ф.Мөслимова. *Иң наяны – Мырауҗан, Туймый мыр-мыр җырлаудан!* Р.Миңнуллин

2) Шыпырт яисә әкрен сөйләгәндә, үзалдына җырлаганда ишетелә торган тавышны белдерә. *Бөтен вагон мыр-мыр сөйләшә.* М.Мәһдиев

3) Канәгатьсезлек белдереп сөйләнүне белдерә. *Хатын мыр-мыр эшкә җыена, вакыт бик акрын бара, тизрәк чыгып китсен иде бит канә!* З.Хөснияр

◊ **Мыр-мыр килү** 1) Мырылдау. *Тик хуҗа гына, төнлә Хуҗабикә янында мыр-мыр килеп йокласа, аягы белән генә себереп төшерә.* Н.Каштанов. *Калай түбәгә ботаклар тиеп кыштырдавын, тәрәзә пыяласына яңгыр тамчылары бәргәнен, сандык өстендәге мәченең рәхәтләнеп мыр-мыр килүен, ишегалдындагы казларның ара-тирә тынычсызланып каңгылдашып куюларын, су юллыгыннан сүс бау буенча туктаусыз аккан су шыбырдавын тыңлап яттым.* Мәдәни җомга; 2) Сукрану, канәгатьсезлек белдерү. *Кайчакларны: «Бу яңа туфлиемне карабрак ки, үкчәсенә баса күрмә!» – дип тә мыр-мыр килеп ала [Николай].* А.Хәсәнов. *Халык мыр-мыр килеп таралды.* Т.Миңнуллин

МЫ́Р-МЫР ИТҮ *ф.* Мырылдау. *Тиктормас йомшак бәрхет тавышы белән мыр-р, мыр-р, мыр-р итә, Әсфәннең иягенә сыйпалана*. Г.Сабитов. *Мыр-мыр итеп кенә укып куя.* З.Хәким. *Аның мыр-мыр иткән тавышы ачуымны китерде, песине идәнгә төртеп төшердем; бу хәлгә аптыраган песием, идән уртасына утырды да, елаган тавыш белән мияу дип куйды.* З.Хөснияр

МЫРЫ́К-МЫРЫК *иярт.* Дуңгыз кычкырган тавышны белдерә. *Янәшәдә генә кабан мырык-мырык килә, фыш-фыш сулый.* Ә.Галиев

МЫРЫЛДА́У *ф.* 1) Мыр-мыр килү; мырлау. *Мәче кабыргасы белән Рифгатьнең аякларына ышкыла-ышкыла мырылдарга тотынды.* М.Әмир. *Күзгә күренмәгән ниндидер зур җәнлек тешен шыкырдаткан сыман булды, кайсыдыр калын тавыш белән мырылдый, гыжылдый башлады.* Г.Бәширов. *[Фәрит:] Мин мәчебезнең тычкан тоткынын карадым. Ата мәче Мырый мыр-мыр мырылдый.* Р.Батулла

2) *сөйл.* Борын астыннан сөйләнү. *Асрау мырылдап төшеп китә.* Г.Исхакый. *Кайбер авангардчылар бер-ике мотивны мырылдый ала, ә оранжировканы аларга башкалар эшләп бирә, чөнки үзләре ноталарны да белмиләр.* К.Гыйззәтов

3) Сукрану, сукранган сыман итү. *Ул [матрос] беркемне дә танымый, төрле якка бәргәләнә, аңлаешсыз сүзләр мырылдый.* Кызыклар дөньясында

Мырылдап җибәрү Кисәк мырылдый башлау. *Хәтта нәкъ йорт мәчесе кебек дустанә мырылдап та җибәрде.* Р.Фәизов

Мырылдап йөрү Анда-монда яки әледән-әле мырылдау

Мырылдап тору Туктаусыз мырылдау

Мырылдап утыру Озак вакыт дәвамында мырылдау

МЫСКАЛ *и. гар.* Метрик үлчәү системасы кертелгәнгә кадәр якынча 4,26 граммга тигез булган авырлык үлчәү берәмлеге (кадакның 1/98 өлеше). *Моннан соң Хәдичә Мәйсәрәне азат кыйлды вә мең мыскал көмеш биреп җибәрде.* К.Насыйри. *Кияүгә дигән кәләпүшне мыскалы егерме бишәр тәңкәлек кырык мыскал энҗедән эшләтәчәкләр, ди.* Г.Камал

◊ **Мыскалга салу** 1) Һәр ягын уйлап, исәпләп сөйләү яисә эшләү турында. *Акыллы кеше сүзне үлчәп, мыскалга салып сөйли торган була.* Р.Ишморат. *Чыңгыз ханның һәр хәрәкәтне җиде кат үлчәп, мыскалга салып башкарганлыгын исәпкә алыйк ---.* М.Гайнетдин; 2) Ваклашу, вакчыллык күрсәтү. **Мыскал да** *к.* **мыскалы да**. *Матур икән табигате, Кодрак илханга бәйләнүенә мыскал да үкенмәде Илбарыс.* М.Хәбибуллин. *Кыйныйлар иде безнең мәктәптә, кешелегеңне кимсетүдән бер мыскал да тайчанмыйлар иде.* Ә.Рәшит. **Мыскалы да** Бик азы гына да, бөртек кадәре дә. *Хәйлә дигән нәрсәнең мыскалы да юк аларның милләрендә.* А.Хәсәнов. *Бәлки, ул чынлап та ихластан сөйләгәндер, аның фикер йөртүендә дә логика бар, тик аңа прокурорның бу эш буенча белгәннәренең мыскалы да таныш түгел иде.* Р.Мирхәйдәров

МЫСКАЛЛА́У *ф.* **1.** 1) Мыскаллар белән үлчәү; мыскалларда исәпләү. *Кызлар – мыскалламаган ефәк.* Мәкаль. *Мин әйтәм тегеңә, мыскалламаган ефәк кебек балага пычрак атырга ничек телең корымый, дим.* М.Маликова

2) *күч.* Аз-азлап, берәмтекләп, ваклап, бөртекләп җыю, эшләү һ.б.ш. *Күңелне чиркандыра торган мондый нәрсәләрне тәрәҗемә итә-итә, мин үземнең бал корты кебек мыскаллап җыйган әдәби тел нектарын харап итмәмме?* М.Галиев

3) *күч.* Саранлану, артык ваклану

2. мыскаллап *рәв. мәгъ.* 1) Мыскал белән. *Мыскаллап үлчәү*

2) Бик акрын, аз-азлап. *Авыру килә потлап, Китә мыскаллап.* Мәкаль.

--- Дәрдемәнднең шигырьләрен Вакыт Җыйган юллап, җыйган мыскаллап. С.Хәким. *Ике оешмага да акчаны, мыскаллап кына булса да, Татарстан хөкүмәте бүлеп бирә иде.* Л.Хәмидуллин

МЫСКЫЛ *и. гар.* 1) Мәсхәрә, мәсхәрәләп көлү. *Әрнү катыш мыскыл ялкынланды, Мин җиңелү сиздем үземдә.* М.Җәлил. *Соңгы сүзен әйткәндә, хәтта Хәнифнеке кебек көлемсерәү, өйрәтү, мыскыл тоны сизелеп китте.* Н.Фәттах. *Юк, бу пародия була алмый. Бу мыскыл була.* Р.Батулла

2) Кимсетү, хур итү. *Ә Шакирга үч һәм мыскыл белән Янагандай булды бу сүзләр.* М.Җәлил. *– Инде хәзер башкаларның мотоциклларына кара, – диде судья, иреннәренә эленгән мыскылны яшерә алмыйча.* Ф.Баттал

◊ **Мыскылга калдыру** Хурлыкка калдыру. *«Сәмруг кош» хикәясендә үтә европалашкан, «дөнья цивилизациясен» мыскылга калдырган милләт каһарманнарыннан көленә.* Ш.Камал

МЫСКЫ́Л ИТҮ *ф.* 1) Мәсхәрәләп көлү, мәсхәрәгә калдыру. *Әгәр әйткән булса, кайсылары бармак төртә-төртә көләрләр, мыскыл итәрләр иде.* Ф.Садриев. *Башта Бибинурның тәкъдиме шундый кызык, шундый мәгънәсез, хәтта ки мыскыл итү булып тоелган иде.* А.Гыйләҗев

2) Мәсхәрәләү, хурлау. *Ул кабат «картлач»ларны үзенчә мыскыл итеп, команда бирде.* Р.Кәрами. *[Әмир:] Мөсәвир бабай, мине мыскыл ук итә башладың түгелме соң син?* М.Хуҗин. *Икенче вакыт мине мыскыл итеп маташа райпо рәисе.* Т.Нәҗмиев

3) Кызларга карата: көчләү, хур итү. *[Гәрәй Фәхриягә:] Теге жуликтан саклан, ул сине мыскыл итәргә азаплана.* Ш.Камал. *Ә бу, хайван, аның утыз елга сузылган шушы пакьлеген, сабыйларча сафлыгын күрә торып мыскыл иткән.* Г.Бәширов

МЫСКЫЛЛА́У I *ф.* 1) Мәсхәрәләү, мәсхәрәләп көлү, мыскыл итү. *Ә карт-ларны, сөя белмиләр, дип Мыскыллыйбыз, кайчак тиргибез.* М.Җәлил. *– Сез тәмәке төтәтеп, сыра чөмереп йөрүчеләрдән юньле хатын чыкмаячак, – дип мыскыллады кызны.* З.Фәйзи. *– Юләр сүз сөйлисез! – дип мыскыллады аны хуҗа.* Ф.Яхин

2) Көчләү, алдау. *[Ул крестьян] махноченың хәрби кием кигән ниндидер бер кызны Днепр буенда хур иткәнен, мыскыллаганнан соң суга ташлаганын күргән.* А.Шамов. *Үзен 14 яшендә мыскыллаган, кияүгә чыгарга мәҗбүр иткән ирдән хатын шулай үч ала.* Ә.Закиржанов. *Ярый, анысына да түзәр идең әле. Ә үтерсә? Көчләп мыскыллап ташласа?* М.Кәбиров

Мыскыллап алу Аз гына мыскыллау. *– Ул син мактаган кыз мин күргән адәм янында чүп булып калачак, – дип, теге пәрине мыскыллап алды.* К.Насыйри. *Валя анда да үзенең элекке дустын мыскыллап алырга онытмады: – Бу – безнең кадерле Эммочкабыз, йокысына көрсенеп, икенче ягына әйләнеп ятты... – диде.* Р.Мирхәйдәров

Мыскыллап йөрү Озак вакыт дәвамында мыскыллау. *Туктаусыз сәяхәт кылып, укучылары (күбрәк авыл кешеләре, яшьләр) белән очрашып, аралашып яшәгән шагыйрь «өлкән» милләт кешеләре генә түгел, үзебезнең манкорт түрәләр дә «Татария» дип мыскыллап йөргән өлкәнең ни дәрәҗәдә ирекле, нефть сатудан килгән акчаларның күпмесе гади татар кешесенең кесәсен «ертып» керүен, игенченең матди хәлен сизми, күрми калмагандыр...* Т.Галиуллин

Мыскыллап тору Даими мыскыллау; сөйләү моментында мыскыллау. *--- үзе исә Идегәй хәтле Идегәй морзаны ничекләр мыскыллап торган була.* Р.Вәлиев. *Монда мине мыскыллап тормагыз, югары белемле, авырулар начальнигы дигәч тә!* Р.Камал. *Әллә кайчан мәрхүм булган Фазылны мыскыллап торма!* Г.Зәйнашева

Мыскыллый бару Тагын да ныграк мыскыллау. *Ул һаман да шаярта торды, мыскыллый барды.* Ф.Яхин

Мыскыллый башлау Мыскылларга керешү. *Әти-әниләре, туганнары, бераздан үзе дә «татарка» дип мыскыллый башладылар...* Г.Зәйнашева. *Зөфәр мактанчыкның авызы колагына җитәр, борыныңны чөеп йөргән идең, синнән дә әллә кем чыкмады, дип, тагын мыскыллый башлар.* Гөлшаһидә

МЫСКЫЛЛА́У II *и.* Мыскыл; мыскыл итә торган сүзләр. *Фашистларның мыскыллауларына түзә алмыйча, Алиш кичләрен барак буйлап читлектәге кош сыман арлы-бирле йөри торган булган.* Р.Мостафин. *Оренбургта чыга торган бу көлке журналы Тукайга карата нинди генә мыскыллаулар язып бастырмады инде.* А.Расих. *Бу елмаю да, мыскыллау да түгел, әллә нинди яшерен бер уйны чагылдыра иде.* Ф.Садриев

МЫСКЫЛЛАУЛЫ *с. к.* **мыскыллы**. *– Әйләнәсең! – диде Нәфисә, мыскыллаулы тавыш белән.* Ф.Садриев. *Памфлетларда һәм сатирик тасвирлы мәкаләләрдә исә ачы сүзләр, мыскыллаулы әйтелмәләр (хәтта тупас мәгънәле гади сөйләм сүзләренә кадәр) кулланылып, теге яки бу күренешкә турыдан-туры бәя бирелә.* Х.Курбатов

МЫСКЫЛЛЫ *с.* **1.** Мыскыл итә торган, мыскыллауны белдерә торган, мәсхәрәле. *Аның өчен иң тантаналы момент шул иде, ул вак акчаны эчкә, кибетче аяк астына терсәге белән сыпырып төшерә һәм мыскыллы караш белән әйтә иде: – Миңа ыздача нәрсәгә?* М.Мәһдиев. *Ләкин ир кешегә бу мыскыллы көлү булып тоелды.* Н.Фәттах. *«Нигә җүләрләнәсең, килешми болай», – дигән шикелле, мыскыллы күзләрен төбәгән [кәҗә].* М.Галиев

2. *рәв. мәгъ.* Рашат, иреннәрен кыегайтып, мыскыллы елмайды. Ф.Садриев. *Менә әле дә син мыскыллы елмаеп торасың.* М.Хәбибуллин. *Комендант мыскыллы елмайды һәм гадәти көлемсерәве белән янындагыларга немецча нидер әйтте.* Р.Сибат

МЫТЫРДЫК *с.* Бертуктаусыз сөйләнә торган. *Абыстай мытырдык, ә Сүрия апа чәүчәләк булса да, алар белән миңа рәхәт иде.* Н.Гыйматдинова

МЫТЫ́Р-МЫТЫР *иярт.* Берөзлексез аңлаешсыз яки әкрен генә сөйләнгән, укыган һ.б.ш. чакларда ишетелә торган авазлар җыелмасын белдерә. *Түрдәге караватта ак чәчле карт мытыр-мытыр китап укый иде.* Н.Гыйматдинова. *Аннан Миңсылу*

карчык мытыр-мытыр гына мич башына үрмәләде: – Шәһәрский фатирны күрше Зөлхәбирә иллә дә хурлап калган иде. Р.Рахман

МЫЧКЫЛДА́У *ф.* Чымырдау, чымыр-чымыр килү. *Ул арада ир дә киерелә-киерелә йокысыннан тора, җылы су белән әйбәтләп юына (юынмаган көе ипи, он, камыр янына килергә ярамый), мычкылдап утырган күгәрченә ала да сәкегә китереп куя: ипи басасы бар.* М.Мәһдиев

МЫШАЯК *и. рус хим.* 1) Кайбер минераллар составына керә торган химик элемент, көчле агулы матдә. *Кальян төтенендә организм өчен зарарлы булган мышаяк, хром, кара кургаш элементлары күп.* Шәһри Казан. *1941 нче елда Гыйлем Камай фосфор һәм мышаяк кушылмалары турында докторлык диссертациясе яклый.* Казан утлары

2) Шул матдәдән ясалган һәм медицина, техника һ.б. өлкәләрдә кулланыла торган препарат. *Мышаяк белән агулап чыксаң гына инде?* В.Шугаев. *Ул кеше кичен, солы салырга керәм дип, атка мышаяк каптырган, ди.* Ш.Әхмәдиев. *Аз гына мышаяк катнашмалы бер дару бар.* Х.Камалов

МЫШАЯКЛЫ *с.* Составында мышаяк булган. *Мәрхүмне гүреннән чыгарып ярып карагач, күкрәгендә мышаяклы 36 ядрә табалар.* Н.Мөхибуллин. *Мышаяклы порошокны ак майга изергә һәм шуны ярага сөртергә, ә?* Х.Камалов

МЫШКЫЛДА́У *ф.* 1) Берәр төрле физик эш башкарганда, тиз йөргәндә, йөгергәндә еш-еш сулап, мышмыш авазлары чыгару. *Өченче дәрес башланып килә иде, мин, мышкылдап йөгереп, класска кереп утырдым.* М.Мәһдиев. *Шул дүрт-биш ел дәвамында «Князь»ның авызы тулы черек тешләреннән килеп торган сасы искә түзәргә, аның кыргый мышкылдавына буйсынып яшәргә мәҗбүр була кыз.* Р.Мөхәммәдиев

2) Йоклаганда мыш-мыш кебегрәк авазлар чыгару. *Ул әле мышкылдый, әле тончыккандай гыр-гыр килә иде.* З.Хөснияр. *Яшь ананың куллары арасында… май йомарламыдай сабый мышкылдый.* К.Тимбикова. *Габдулла мышкылдый, гырылдап ала.* Р.Сибат

3) Елау; елаган сыман итү; мышык-мышык итү. *Хатынының мышкылдаганын ишеткәч кенә, Гайфулла каш астыннан аңа караш ташлады.* Ф.Яруллин. *Малай борынын мышкылдатты да куркып кына: – Берүзем, – диде.* А.Гыйләҗев. *Аяк очында кызы Сабираның мышкылдап елаганы гына ишетелә иде.* Ф.Бәйрәмова

4) Көч кую, көч сарыф итү, көчәнү. *Дию, сулуы кабып, мышкылдап бара иде.* К.Насыйри. *Малайны чокырдан чыгару өчен, Сәфәргалигә күп кенә мышкылдарга туры килде.* Ф.Хөсни

Мышкылдап алу Бераз гына мышкылдау. *Хатынның борыны мышкылдап алды.* Р.Зәйдулла

Мышкылдап бетү Нык мышкылдау; мышкылдау дәрәҗәсенә җитү. – *Узем эзлим, – диде ул, чума-чума мышкылдап беткән җизнәсенә карап.* Ф.Яруллин. *Аннары, туктап, мышкылдап беткән Рамазанны көтеп ала.* Л.Гыймадиева. *Әй киттек, малай, киттек, Арып, мышкылдап беттек.* Р.Вәлиева

Мышкылдап йөрү Һәрдаим мышкылдау; озак вакыт дәвамында мышкылдау. *Пош-пош килеп, кибәк ашаган сыер шикелле мышкылдап йөри (ир).* Г.Камал

Мышкылдап кую Бер тапкыр мышкылдау. *Эльвира борын аша мышкылдап куйды.* М.Маликова. *Ара-тирә мышкылдап куйганы гына ишетелә.* Ф.Сафин. *Әле анда, әле монда борын тартып мышкылдап куйган тавышлар ишетелеп киткәләде.* Р.Сәгъди

Мышкылдап тору Озак вакыт яки әледән-әле мышкылдау. *Менә сиңа борын тартып, мышкылдап торган малай.* Ә.Баян. *Дөньясына рәнҗеп елаган баланы күкрәгеңә кысып, яшьләрен сөртсәң, бераз мышкылдап тора да тына.* Г.Афзал. *Атам авылыннан Актанышка кайткач, ике ятимә кыз ишек төбендә мышкылдап тора-быз.* Р.Батулла

Мышкылдап утыру *к.* **мышкылдап тору**. – *Мышкылдап утырма әле, яме! – дип, Әнил аңа җиңелчә генә төртеп алды.* З.Хөснияр

Мышкылдап чыгу Мышкылдарлык хәлгә килү. *Эчтән киенмәсәң… хәзер мышкылдап чыгасың…* Г.Гыйльманов

Мышкылдый башлау Мышкылдарга тотыну. *Карчык көрсенә, уфылдый, мышкылдый башлый.* И.Гази. *Чөнки егет шактый арып мышкылдый башлаган, йөреше дә авырайган иде.* А.Вергазов. – *Сагындым, – диде Рөстәм һәм мышкылдый да башлады.* Ф.Яруллин

МЫШКЫЛДЫК *и. сөйл.* Әкрен кыймылдый торган кеше. *Кая инде ул мышкылдыкка безне куып җитү.* Г.Бәширов. *Симез кешеләргә тагын да аяусызрак элгә! «--- Мышкылдык. Черек печән кибәне. Метер баганасы...» – ди тазаларга Фирүзәнең әнкәсе.* А.Гыйләҗев

МЫ́Ш-МЫШ *иярт.* 1) Тиз хәрәкәтләнгән, авыр физик эш башкарган һ.б.ш. вакытта еш сулыш алу нәтиҗәсендә барлыкка килгән авазларны белдерә. *Мыш-мыш сулавыннан ук куркып качарлык оятсызның.* Р.Мөхәммәдиев. *Күрдеңме инде, күрәсеңме дигәндәй, терсәк очы белән янәшәмдә мыш-мыш сулап торган Барыйның колагына төртеп алдым.* З.Хөснетдинов. *Яңгырда җебегән авыл мыш-мыш сулап йокымсырап ята иде.* Р.Зәйдулла

2) Йоклаганда, тыныч сулыш алганда һ.б.ш. чакта ишетелгән тонык авазлар. *Әнә бит ул Миңлеасияң, ике кулын яңагына куеп, мыш-мыш йоклап ята.* Г.Ахунов. *Мыш-мыш сулап тыныч кына кайтып кергән сыер, Руфинә турына җиткәч, кинәт колакларын шомайтты, күзләрен акайтты, борын тишекләрен киңәйтте дә мөгезен сөзәргә җайлап аның өстенә килә башлады.* Ф.Садриев. *Ләйләсе мыш-мыш йоклап ята.* Ф.Яруллин

3) *к.* **мышык-мышык**. *Күрше бүлмәдә берәүнең мыш-мыш елаган тавышы килә шикелле булды.* Ф.Әмирхан

◊ **Мыш-мыш килү** *к.* **мышнау**. *Шулхәтле симергән, суырга салган сыер кебек интегеп мыш-мыш килә.* Ф.Баттал. *Хәзрәт, юл бирергә теләп, уңга тарта, әмма мыш-мыш килеп, чак кына тын алган аты язгы-көзге*

ташуларда чит-читләрендә чокырлар хасил булган юлдан читкә чыгып борыла да, юл да бирә алмыйча, туктап кала. А.Хәлим. *Ул ашыга-кабалана, мыш-мыш килеп авыр сулап, кабер өстен җир белән тигезләгәнче күмде.* Р.Сибат

МЫШНАВЫК *с.* Еш кына мышный торган. *Мышнавык кеше*

МЫШНА́У *ф.* **1.** Мышкылдау, мыш-мыш итеп тын алу. *Гәрәй уйлый; мышный, борын тарта; яна, борчыла.* М.Җәлил. *«Ярар болай да!» – диде үз-үзенә һәм, ишеккә колагын куеп, хатынының мышнап йоклавын тыңлап торды [Гайфулла].* Ф.Яруллин. *Печәнлектә, бөтен фани дөньяның мәшәкатен онытып, сабый балалар йокысы белән ике яшь егет мышныйлар.* М.Мәһдиев

2. мышный-мышный *рәв. мәгъ.* Еш сулыш алып, мыш-мыш килеп. *Мич башына, мышный-мышный, Маратның биш яшьлек кызы үрмәләп менде, ялтырап торган күзләре белән озаклап әбисенә карап торды.* Р.Әбүбәкерова. *Мышный-мышный алма агачы төбенә килеп җиттем.* Р.Вәлиев. *Мышный-мышный абыйны куып җиттем.* Ф.Шәфигуллин

Мышнап алу Кыска гына бер ара мышнау. *Йортларның ишекләре шыгырдап ачыла, кешеләр абзар-кураны бер әйләнеп керәләр, абзарда сыер авыр гына мышнап ала, фонарь яктысында сарыкларның күзе гәрәбә булып яна, алар куркышып, тыбырдашып, берсен-берсе бәреп, абзар стенасына сарышалар.* М.Мәһдиев

Мышнап бетү Тәмам мышнау; нык мышнау. *Егылсалар, бергә егылалар, торсалар – бергә торалар, мышнап бетәләр.* Ф.Яруллин. *Йөгерә-йөгерә мышнап беткәч кенә адымнарга күчтеләр алар.* Ф.Бүләков

Мышнап кую Бер мәртәбә мышнау. *Шундый әдәби итеп аңлатып бируенә куанып, Хәкимҗан тирән генә мышнап куйды, Нәркис тә нәрсәдер аңларга тырышып уйга калды.* М.Мәһдиев

Мышнап тору Сөйләү моментында яки озын-озак мышнау. *Автобус тукталышларда озак мышнап тормасын, җәһәт туктап, җәһәт китсен.* В.Нуриев

Мышнап төшү *к.* **мышнап чыгу**. *Бара торгач, Зиннур мышнап төште.* Ф.Яруллин. *Җиңел генә этеп җибәрмәкче иде дә, көймә шактый ныкутырган булып чыкты. Мышнап төште.* М.Әмир

Мышнап чыгу Бик ныкмышнау. *Тора-бара агачлар эреләнде, юл начарланды: Птенцов тирләп, мышнап чыкты.* С.Шәрипов. *--- Рәфиснең аягы тайды, ул, куаклыкларга чытырдатып ябышып, түбәнгә шуып төшмәскә тырышты, хәлдән таеп мышнап чыкты, аркасына салкын һәм ябышкак тир бәрде.* А.Вергазов

Мышный башлау Мышнарга тотыну. *Ул, ахры, йокыга талды, тын алуы тигезләнде, тәмле итеп мышный башлады.* Х.Камалов. *Сәлим ачуланып мышный башлады.* Г.Әпсәләмов

МЫШТЫБЫЙ *с.* **1.** Сүзсез, күп сөйләргә яратмый торган (кеше); астыртын

2. *и. мәгъ.* Аз сөйләүчән кеше. *Уйладым: бер Шамраевлар гына явызлыкны тормышка ашырмый икән, әнә шундый Аюкиндай ыспайлар, тел яшергән мыштыбыйлар да кан эчәргә ярата торган була.* А.Гыйләҗев. *Мыштыр-мыштыр мыштыбый Пешергән, ди, кыстыбый. Мыштырдаган мыштыбый, Кыштырдаган мыштыбый.* В.Хәйруллина

3. *рәв. мәгъ.* Сөйләшмичә; акрын гына, сиздермичә, белдермичә генә. *Моңарчы мыштыбый гына йөргән Вася, Жаденко аерылып калганнан бирле, әллә ничек ачылып китте.* А.Гыйләҗев

МЫШТЫМ *с.* **1.** 1) Астыртын; күп сөйләшми торган. *Кычкырган адәм – буш куык, Мыштым адәмнән син курык.* Ә.Синугыл-Куганаклы. *– Үзең дә бер мыштым икәнсең, – диде Фазыл, тыңлап бетергәч. – Менә дус дип йөр инде сине.* Н.Әхмәдиев

2) Тыныч, салмак, акрын кеше турында. *Газинур, мыштым Газзән кебек, авызына су капкандай дәшмитынмый гына эшләүне яратмый иде.* Г.Әпсәләмов. *Түзмичә елап җибәрде Шунда мыштым Фәйрүзә: «Ялгыз килеш картаюлар Бигрәк үзәкне өзә...»* Л.Шагыйрьҗан. *Бер вакытта да мескен, елак, мыштым түгелләр, шыңшымыйлар.* Д.Гыймранова

2. *и. мәгъ.* Күп сөйләшергә, аралашырга яратмый торган кеше; астыртын. *Тыңлап утыручылар арасында дегетче Хәйдәршаның уртанчы улы да бар иде. Кем уйлаган бит шул мыштымның эчендә агу кайнаганын.* Х.Садрый. *Фәрит холкының тагын бер чалымы ачыкланууга куанып, Камил үзенә үзе күз кысты. «Мыштым!» Менә кем ул Фәрит!* Г.Бәширов

3. *рәв. мәгъ.* Тыныч; ашыкмыйча, үз җаена. *Төшендә ул [Бибинур] мыштым гына агып яткан урман елгасы өстеннән оча башлады.* А.Гыйләҗев. *Дөнья мәшәкатьләрен куганнарга да, минем кебек мыштым яшәгәннәргә дә бер үк сукмак, бер үк язмыш.* Д.Гыйсметдин. *Дөньялык мыштым калды, шулай да ишеге артында кемдер бар сыман, гүяки сулышына кадәр ишетелгәндәй тоелды.* Ф.Яхин

МЫШТЫМЛАНУ *ф.* Тынып калу, аз сүзлеләнү. *Ирек авыр-авыр атлап тагын мыштымланды.* А.Гыйләҗев

МЫШТЫР *с.* **1.** Акрын кыймылдый, озак җыена торган (кеше). *Мыштыр кеше иртә дә мыштыр, кич тә мыштыр.* Мәкаль. *[Галәви:] Бик мыштыр икәнсең. Кайчаннан бирле шуны да өлгертә алмагансың.* Т.Гыйззәт

2. *рәв. мәгъ.* Акрын, ашыкмыйча. *Без инде карт агачлар... кештер-кештер, мыштыр-мыштыр йөрештерербез.* Н.Фәттах

МЫШТЫРДА́У *ф.* 1) Акрын кыймылдау, нәрсәне дә булса бик акрын, озак эшләү турында. *Алар мыштырдап барып җиткәндә, алачык тагын да иңгән, ялтыр-йолтыр җемелдәшкән вак күмерләр яткан ат хәтле генә өемгә әйләнгәннәр иде.* А.Гыйләҗев. *Йокысыннан уянып җитмәгән аю кебек мыштырдыйсың.* Ф.Яруллин

2) Ни беләндер шөгыльләнү, берәр төрле эш башкару. *Вәзилә кече якта бик озак мыштырдады, урындык аркасына башын куйган әби өзлексез ahылдады, Җәмил, түземлеге бетеп, Вәзилә янына чыкты һәм, сәгатен күрсәтеп: «Безнең бүген бик җаваплы*

очрашу, ашыгам!» – дип пышылдады. А.Гыйләҗев. *Вакыты булганы хуҗалыгында мыштырдый.* Ф.Сафин

Мыштырдап алу Кыска вакыт, бераз гына мыштырдау

Мыштырдап йөрү һәрвакыт мыштырдау. *Ашыгу белән җитезлек икесе ике нәрсә булса да, җитешә алмый мыштырдап йөргәннәрне күрсәм, ачуым чыга.* Ирек мәйданы

Мыштырдап тору Гел мыштырдау; сөйләү моментында мыштырдау

Мыштырдап утыру Күптәннән мыштырдау; озак вакыт дәвамында мыштырдау

Мыштырдап яту Озак вакыт дәвамында мыштырдау, һәрвакыт мыштырдау. *Үзем бер көе генә мыштырдап ятам.* Н.Нәҗми

МЫШТЫРДЫК *с.* **1.** Озак маташу, мыштырдау гадәте булган; акрын кыймылдаучан. *--- берсе дә калмыйча китеп тә беттe диярлек (урын алып калырга кирәк), бүлмәдә тик мәңге мыштырдык Фәйзәви генә һаман мыштырдый иде.* Х.Сарьян. *Әллә ничәгә төрләнә: әле җитез, әле уйчан-моңсу, әле салмак ул, бер эшкә дә кулы бармый торган мыштырдык, әле шартлый...* Сөембикә

2. *и. мәгъ.* Шундый гадәтле кеше, акрын кыймылдый торган кеше. *И-и, мыштырдыксың да инде, Әнисәнең киткәненә биш былтыр лабаса!* Р.Рысаев

МЫШТЫРЛЫК *и.* Мыштыр булу. *Ә материал чыкмый калды. Минем мыштырлык инде!* М.Рафиков

МЫШЫ́К-МЫШЫК *иярт.* Елганда яисә еш борын тартканда барлыкка килгән тавышны белдерә. *Кыз, тәрәзә буендагы ак япмалы диванга менеп, аякларын бөкләп утырган да мышык-мышык елый иде.* К.Тимбикова. *Ул [Тәһир] мышык-мышык борынын тарта, уң як яңагында кып-кызыл яра эзе ярылып ята иде.* Ф.Садриев. *Зәйтүн һаман мышык-мышык елый иде.* А.Гыйләҗев

МЭР *и. фр.* Муниципалитет идарәсе башлыгы (гадәттә шәһәр башлыгы). *Нишләсен Басыйр Бариевич, хәләле җылыткан ятактан торып, Иван Ивановичны эчтән сүгә-сүгә киенеп, кабаланып, төче елмаеп, мэр янына барып җитте.* А.Гыйләҗев. *Аңа дүрт ел элек пенсиягә чыгу сәбәпле эшеннән азат ителгән мэр шалтырата иде.* З.Дәүләтов. *Мэр, ирешелгән уңышлар белән бергә, җитешсезлекләр һәм эшләнәсе эшләргә дә туктaлды.* Шәһри Казан

МЭ́РИЯ *и. фр.* Муниципалитет идарәсе; шул идарә урнашкан бина. *Күчмәс өчен, мэрия белән бәхәскә кергән йортлар арасында Мәрьям әбинең ак кәҗәләре чемченеп йөри.* К.Кәримов. *Чирек сәгатьтән шәһәр башлыгы биш минутлык киңәшмә үткәреп ала да, мэрия гадәти ыгы-зыгылы эшкә чума.* А.Тимергалин. *Казан шәһәре мэриясе, Василий Аксёновка 76 яшь тулу уңаеннан, язучының балачак еллары үткән агач йортны аңа бүләк итәргә карар кылган.* Казан утлары

МЭТР *и. фр.* 1) Укытучы, остаз. *Багдасарян минем иҗади эшләремне тыңлагач, кулымнан тотып, мэтр янына алып барды.* Өмет

2) Үз өлкәсендә зур уңышларга, камиллеккә ирешкән кеше. *Әмма аларның [шагыйрьләрнең] берсе дә эффектлы кызыл муен яулыклы, мэтр кебек данлыклы түгел һәм портвейнга чиратта да гомуми нигездә басып торалар иде.* Р.Мирхәйдәров. *Ул – мэтр, җырларны югары дәрәҗәдә башкара.* Идел. *Туфан Миңнуллин – театр дөньясында мэтр инде ул.* Ватаным Татарстан

МЮ́ЗИКЛ *и. инг.* Оперетта, балет, опера һәм эстрада элементларын кулланып башкарыла торган музыкаль сәхнә әсәре. *Бер ай эчендә үк куям, мюзикл жанрында, әмма син гади тәрҗемә эше белән генә шөгыльләнмәссең, әсәргә бик иҗади килүең сорала.* Ю.Сафиуллин. *Театрның репертуар сәясәте сыгылмалы булырга тиеш: анда интеллектуаль драма да, сатира да, мюзикл да үз урынын табарга тиеш.* М.Сәлимҗанов. *Шул ук вакытта АКШта оперетта белән берникадәр бәйле яңа форма – мюзикл барлыкка килә.* Нәфасәт

МЮ́ЗИК-ХОЛЛ *и. инг.* Эстрада театры. *Зур-зур чуар афишаларда Париж «Мюзик-холл»ы артистларының көләч йөзләре балкып тора.* А.Гыйләҗев. *Калган сүзләрен Булат эченнән генә әйтте: «Сезгә бит мюзик-холл ише әйберләр кирәк, шундыйлар күбрәк ошый бит сезгә...»* М.Вәли-Барҗылы. *Англиядә ул [оперетта] мюзик-холл белән якыная, Франциядә музыкалы фарсларга күчә.* Нәфасәт

Н

НА *ы.* Ат куганда әйтелә торган сүз; чу. *Заһриның аты «тпру» дигәндә чабарга, «на» дигәндә туктарга өйрәтелгән булган.* М.Мәһдиев. *Ул айгырга очып менде дә чабата үкчәләре белән ике яктыгын да төя башлады: «На, на, на!»* А.Гыйләҗев. *– Кем малай-шалай, минме? – дип, Хафиз Җәмиләгә усал гына карап куйды да, көр тавыш белән: «Әйдә, малкай, на-а!» – диюенә, Чаптар дәртләнеп кузгалып китте.* Г.Галиева

НАБАБ *и. гар.* Көнчыгыш Һиндстанда кайбер провинция башлыкларының титулы һәм шул титулга ия булган кеше

НАБАТ *и. гар.* 1) Чаң кагып бирелә торган ашыгыч һәм шомлы хәбәр (янгын, дошман һөҗүме һ.б.ш.) сигналы. *Төн. Набат тавышы. Тавышлар: – Набат, набат, набат! – Сугыгыз! – Мең кабат!* Һ.Такташ. *Киләчәк һәм үткән арасында Яңрап тора Набат шикелле, Набат шикелле...* Х.Туфан

2) Шундый сигнал бирелә торган чаң үзе. *Зур набатның көчле тавышы Җир шарында соңгы кат Канлы гыйсъян билгесе булсын! Набат, набат, набат!..* Һ.Такташ

◊ **Набат кагу** *к.* **Набат сугу**. **Набат сугу** 1) Халыкны тиз тупларга кирәк чакта, тимер белән тимергә сугып сигнал бирү, чаң кагу. *Чиркәүдә набат сугыла башлый.* Г.Исхакый; 2) Нинди дә булса куркыныч нәтиҗәгә китерәчәк гамәлгә игътибарны көчәйтергә чакырып, куркыту, шомландыру. *Тиздән Көннәрне елларга бәреп Набат сугарбыз җир йөзенә!..* Х.Туфан. *Трумэн җиң сызганып набат кага, Атом бомбасына баш орып.* Ә.Ерикәй. *Таулар булып суга алар набат, Россиядән ирек даулап кабат.* Ю.Сафиуллин

НАБО́ЙКА *и. рус* Аяк киеме үкчәсенә сугыла торган күн, резин яки металл кисәге. *Кичә генә кактырган набойкаларым килеп төште, хәзер тагын шуларны суктырып алырга кирәк.* Казан утлары

НАБОР *и. рус* 1) *махс.* Басмаханәдә нинди дә булса текстны басар өчен җыелган хәрефләр. *Баш ягының бик күп оригиналы Юылып, наборлары сибелгән.* М.Гафури. *Ләкин [Тукай], икенче көнне үк килеп җитеп, [сатираның] наборын тараттырган.* И.Нуруллин. *Наборга төшерелгән газетаны кире алып менделәр.* А.Гыйләҗев

2) Нинди дә булса текстның хәрефләрен һәм билгеләрен компьютерда, машинкада һ.б.ш.да җыю. *Китапны тиз арада наборга бирергә кирәк.* Казан утлары

3) Хәрби хезмәткә кабул итү, армиягә алу, призыв. *Ак билет белән калучыларны яңадан наборга чакыралар.* Г.Тукай. *Җиденче ел иде, көз көнендә Ул наборга кайтты керергә.* С.Хәким. *– Мин... армиядә. --- Хәзер десантниклар әзерлим... Менә сезнең шәһәргә яңа набор алырга килдем...* Г.Гыйльманов

4) Бербөтен хасил итә торган әйберләр җыелмасы. *[Рузинә:] Чәч киптергеч феннар наборы алам әле.* Р.Мөхсинова. *Узган ел мин, йөреп-йөреп тә кулга рәтле нәрсә төшерә алмагач, гастрономнан бүләк наборы алып кайттым.* Г.Мөхәммәтшин

НАБОРЧЫ *и. к.* **наборщик**

НАБО́РЩИК *и. рус махс.* Басмаханәдә хәреф җыючы эшче; наборчы, мөрәттип. *Безнең заман үзе яңа, кәгазе яңа, хәтта шул китапны җыйган наборщикның сакалы яңа.* Г.Тукай. *Җырлыйм Зөбәйдәнең наборщикка Булган көчле гыйшкы турында.* Һ.Такташ. *К.Мотыйгый, күрәсең, расход тотып читтә өйрәтүгә караганда, әзер наборщиклар чакыру дөресрәк булыр дигән фикергә килгән.* И.Нуруллин

НАБО́РЩИКЛЫК *и. махс.* Наборщик һөнәре, наборщик эше. *Хаттан күренгәнчә, Камил инде типография, татарча хәрефләр булдыру, берничә шәкертне, наборщиклык һөнәренә өйрәтү өчен, берәр якка җибәрү турында уйлый башлаган.* И.Нуруллин

НАВА́ГА *и. саам зоол.* Тәрәч балыклар семьялыгыннан ашарга яраклы диңгез балыгы; шим балыгы. *Бу урыннарда планктон хасил була, төптә суүсемнәр үсә, балыклар (тәрәч, навага, палтус) йөзә.* Материклар һәм океаннар географиясе

НАВИГА́ТОР *и. лат. махс.* 1) Навигация (*1 мәгъ.*) белгече, штурман

2) Дисплейда компьютер челтәрендә булган мәгълүматны карарга мөмкинлек бирә торган мәгълүматлар базасындагы программа, алгоритм яки язулар эзләү алгоритмнары җыелмасы

3) Шундый программа куелган махсус электрон җайланма. *Иярченле навигаторлар исә автомобиль йөртүченең йозакны ватарга тырышуын тиз арада диспетчерга хәбәр итә.* Ватаным Татарстан

НАВИГА́ЦИЯ *и. лат. махс.* 1) Судноларны һәм төрле очкычлар йөртү һәм юл сайлау ысулларын өйрәнә торган фән. *«Менә бу якта Кассиопея, штурманнар өчен бик кирәкле навигация йолдызы», – дип аңлатып бара [Якуб абый].* А.Гыйләҗев. *Навигация мәктәбе. Планетаара навигация*

2) Зур сулыкларда, табигать шартларыннан чыгып, елның судноларны йөри ала торган вакыты. *Марат, завхоз буларак, аларны, навигация ябылып торган чакларда, гел шкаф тартмасында саклады.* Г.Гобәй. *Июнь башларында, навигация ачылгач, боларга баржа белән азык-төлек, шул җөмләдән эчемлекләр дә китерәләр икән.* А.Гыйләҗев. *Навигация чоры*

3) Судноларны йөрешe, судночылык. *Диңгез навигациясе. Елга навигациясе. Елга навигация өчен яраклы түгел*

НАГАЙБӘК *и.* Татарларның дин (христианлык), сословие (хәрби хезмәт) һ.б. үзенчәлекләр белән аерылып торган этник төркеме һәм шул төркемнең бер вәкиле. *Нагайбәкләрнең традицион мәдәнияте үсешендә курайның тарихи роле зур булган.* Г.Макаров. *Ә менә керәшеннәрнең дә, нагайбәкләрнең дә, татарларның да нигездә татар булып язылганына эче пошканын да яшереп тормый Тишков әфәнде.* Татарстан яшьләре

НАГА́ЙКА *и. рус* Каештан үрелгән кыска камчы, нугай камчысы. *Недоносковны чолгап алган бер кисәк халык, нагайка бик каты эләктерә башлагач, Недоносков берлә бергә Общество трезвости чәйханәсенә качып керделәр.* Г.Тукай

НАГАН *и.* Махсус системадагы әйләнмә барабанлы револьвер (бельгияле конструктор L.Nagant фамилиясеннән). *Халык тынды, минем билдәге наганны күргәч, беразы, куркып, икегә аерылды.* Г.Ибраһимов. *Нинди егет ул наган тагып, сөйгән кызы янында шарт та шорт атып йөргән? Наган бит – куркыныч нәрсә.* М.Мәһдиев. *Эссәт әкә, карга капланып, куеныннан наганын чыгарды һәм гөрселдәтеп атып җибәрде.* Я.Зәнкиев

НАГАЧ *и. диал. иск. к.* **нагачы**

НАГАЧЫ *и. диал. иск.* Ана ягыннан туган тиешле кеше. *Җир агачсыз булмас, адәм нагачсыз булмас.* Мәкаль

НА́ГЕЛЬ *и. нем. тех.* Агач конструкцияләрне бер-берсенә беркетер өчен кулланыла торган агач яки металл кадак

НАГРУ́ЗКА *и. рус* 1) Йөкләмә. *Ә минем еллык нагрузка үтәлгән инде.* Э.Касыймов

2) *күч.* Нәрсәнең дә булса идея эчтәлеге. *--- һәр җөмләсе уйланган, һәр сүзе гыйльми бер нагрузкага ия...* М.Мәһдиев

НАДАН *с. фар.* **1.** 1) Укый-яза белмәүче, өмми. *Үзләре шыр надан инде, бичаралар, әлифне таяк дип тә белмиләр.* А.Гыйләҗев. *– Язу таныймый торган шул наданнарның арт күмәчләрен пешереп алырга исәп! – диде ул [Әбүзәр].* А.Тимергалин

2) Аз белемле, мәдәниятсез; хаталар белән сөйләүче яки язучы. *Ай уңмаган, юләр сарык, надан сарык, Моннан зуррак бүре башын китер табып!* Г.Тукай. *Балаларың командир да инженер булгач, надан калу ничектер килешми.* Г.Кутуй. *Әшәке холыклы, надан, эчкече Фәтхетдиннән котылып, укымышлы һәм кешелекле Сираҗетдин хәлфәгә күчү дә аның [Тукайның] күңелен күтәрми калмаган.* И.Нуруллин

3) Нинди дә булса өлкәдән тулы хәбәрдар булмаган, үз белгечлеген түбән дәрәҗәдә, начар белүче, җаһил, томана. *Наданлыкның да чиге, чамасы бар: сез надан, мин надан, анысы дөрес. Ну да ләкин сезнең белән чагыштырганда, мин – профессор.* М.Мәһдиев. *--- нинди өлкәне адәм баласы белмәсә, ул шул яктан надан, ягъни аптыраулы була, шул мәсьәләләргә килеп төртелгәнендә, җаны боз сыйфатына керә...* Ф.Яхин. *Надан кеше – бәхетсез кеше.* Татарстан яшьләре

2. *и. мәгъ.* Укый-яза белмәүче, мәдәниятсез, белемсез яки аз белемле, караңгы кеше. *Табиблар дәваламас авыруын наданның, Дәвала белем белән наданлыгын аның.* Й.Баласагуни. *Өч наданга алмашынмас бер язу белгән кеше.* Г.Тукай. *Мин докторлар белән утырырга яратам. Аларда бер сыйфат була: наданмы ул, галимме – сөйләшкәндә ышаныч белән, җирдә үз урынын ныктоеп сөйләшәләр.* М.Мәһдиев

НАДАНЛАНУ *ф.* Наданга әйләнү

Наданлана бару Торган саен ныграк наданлану. *Наданлана бара адәм баласы. Белсә, шул бер-ике балык, өчдүрт үсемлек, биш-алты кош исемен беләдер инде.* З.Мәхмүди

НАДАНЛЫК *и.* 1) Надан булу, белемсезлек, мәдәниятсезлек; җаһиллек. *Син гыйлем тупла, наданлыктан уян, Ахирәт көнне надан – эттән яман.* Г.Утыз-Имәни. *Наданлык түбәнлегендә бик күп йөрдек...* Г.Тукай. *Галимнәр наданлыкка бер дә түзмәс, Ходаның рәхмәтеннән өмит өзмәс.* Ж.Абызгилдин

2) Билгеле бер өлкәне, тармакны белмәү. *Исламгали агай хатны кат-кат укыды һәм укыган саен үзенең наданлыгын ныграк сизә барды.* М.Мәһдиев. *Абзый чын күңелдән Әстерханны Мәккә дип кабул иткән. Наданлык гөнаһ түгелдер, бәлки.* Т.Галиуллин

НАДЗИРА́ТЕЛЬ *и. рус* Төрмәдә һ.б.ш. урыннарда тоткыннарны күзәтеп, тикшереп торучы, тәртип тәэмин итүче хезмәткәр. *Караңгы чырайлы дежур надзиратель яңа тоткыннарны китерүче конвоир биргән кәгазьне алып укыды ---.* М.Галәү. *Эрнст Беренгард – партия заданиесе буенча надзиратель булып эшләүче коммунист.* А.Алиш. *Төрмә надзирателе әтинең күлмәкчалбарын чыгарып биргәч, әни шундук аңын югалтып егыла.* Сөембикә

НАДЗИРА́ТЕЛЬЛЕК *и.* Надзиратель вазифасы яки хезмәте

НАДЗОР *и. рус* Дәүләт органнарының закон үтәлешен тәэмин итү буенча күзәтчелек эшчәнлеге. *Беренчедән, читенсендем, ни дисәң дә, прокуратура – надзор ясаучы инстанция.* Р.Мирхәйдәров

НАДИР *с. гар. иск. кит.* Аз, сирәк очрый торган, сирәк. *Мөгаллимә илә мөгаллим гыйлем, мәгърифәт, гүзәл холык, тәкъвалык тугърысында бер-беренә шулкадәр бәрабәр килмешләр иде ки, буйлә рәвештә бер-беренә бәрабәр килгән ир илә хатыннарга дөньяда надир тәсадеф иделенер (очрашылыр)...* Р.Фәхретдин

НАДСМО́ТРЩИК *и. рус* Күзәтеп торып эшләтүче, контрольдә тотучы, назыйр. *Төрмә надсмотрщигы*

НАДУЛАП *и. рус иск.* Агач тротуар

НАЁМЩИК *и. рус иск. сөйл.* Башка кеше өчен ялланып хәрби хезмәткә киткән кеше. *Ызбам арты тал гына, булмады ла үземә, Наёмщиклар яллар идем, булмады ла мал гына.* Бәет. *Наёмщик дигән начар исемне ишетмәгән кеше юктыр. Элек заманда башка берәү өчен ялланып солдатка китүчеләргә бирелгән бу яман ат әшәкелек, усаллык, адәм түгеллекне аңлатадыр.* Г.Тукай. *Билгеле булганча, Салих ага Сәйдәшев үзенең көйләре (музыкаль драмаларга язган) арасында «иң камиле һәм профессиональ яктан иң югары дәрәҗәдә иҗат ителгәне»*

дип, Таҗи Гыйззәтнең «Наёмщик» әсәренә язган музыкаларын санаган. Ватаным Татарстан

НАЖДАК *и.* Пыяла, таш, металл, агач кебек материаллардан эшләнгән әйберләрне шомарту һәм чистарту өчен кулланыла торган минерал; комкайрак, кайрак комы. *Без үзебез дә – участковыйның наждак алмый торган тиресеннән ясалган малайлар.* Т.Галиуллин. *Яңа язмадагы хатын-кызның төксе, «колхозный» тавышы колак ярысын наждак белән ышкыгандай итә.* Татарстан яшьләре

НАЖДА́К КӘГАЗЕ *и.* Наждак комы ябыштырылган тыгыз кәгазь; кытыршы кәгазь. *Наждак кәгазен теләгән урыннан кисү өчен, арткы ягыннан очлы кадак белән сызарга кирәк.* Хезмәт. *Тимәскә дә мөмкин, автоподставщиклар, сез сизмәгән арада, кузовка бәрәңге атып, бәрелгән тавыш чыгара яки кузовны наждак кәгазе белән сыдырып ала.* Ватаным Татарстан

НАЖДАКЛЫ *с.* Наждагы булган, наждак табылган. *Наждаклы казылмалар*

НАЗ *и. фар.* 1) Йомшак, ягымлы мөнәсәбәт, нечкә хис, иркәлек, иркәләү. *Сыйлый кыз һәм сөя, һәртөрле назлар күрсәтә ханга.* Г.Тукай. *Хатын ниләр генә кыланмады. Ирен орышып та бакты, елап та карады, сөю хисләрендә исерсен дип, бар булган назын эшкә җикте, тик алар бер-берсеннән һаман ерагая гына бардылар.* Я.Зәнкиев. *Күңелемдә сагыш-моңнарым бар, Чәчәкләрдән җыйган назларым бар Идел күрке – шушы калага.* Р.Ханнанов

2) Көйсезлек, назлылык, кирелек. *Даһханә ничә мең наз илә боргаланып, фәйтунга утырып уен бакчасына китте.* Ф.Халиди. *Углан мең төрле наз белән разый булды.* К.Насыйри

3) *иск. фольк.* Үзеңне сөйдерү максаты белән җырланган гыйшык җыры. *Гыйшыктан бака да наз җырлый, ди.* Мәкаль. *Гыйраклылар кебек сузып хуш аваз, Гыйракый көй белән әйттерде ул наз.* Котб

4) *күч.* Мәшәкать, борчу

НАЗАЛИЗА́ЦИЯ *и. фр. лингв.* Авазның борын аша чыгуы, нәтиҗәдә авазда борын тембры барлыкка килү; борынлашу

НАЗАЛЬ *с. фр. лингв.* Аваз турында: борын аша чыккан (мәс., *[м], [н], [ң]*)

НАЗАР *и. гар. иск. кит. к.* **нәзар**. *Гомумиятлә төрекләрнең татарларга назарлары соң вакытларда бик күп үзгәргән.* Ф.Кәрими

НА́ЗАРАН *рәв. гар. иск. к.* **нәзаран**

НАЗАРИ *с. гар. иск. кит. к.* **нәзари**

НАЗАРИЯ *и. гар. иск. кит. к.* **нәзария**

НАЗАРИЯТ *и. гар. иск. кит. к.* **нәзария**

НАЗИК *с. фар.* 1) Башкаларга карата бик ягымлы, илтифатлы; нәзакәтле. *Мәрьям хәзер әүвәлгедән дә артык назик һәм хыялый күренә.* Г.Ибраһимов

2) Нәфис, нечкә, игътибар таләп итә торган. *--- ләкин хис ягыннан, бәлки, [Сәгыйть Рәмиев] Тукаевтан да назиктер.* Г.Исхакый. *Ватанлык хисе – самими, назик тойгы, ул бернинди сабак укытуларга мохтаҗ түгел.* Р.Зәйдулла. *Аһ, ул назик ис – затлы хушбуйлы ул, әллә чит илдән кайтартылган ислемаймы, гатыршамы, җофар маемы?* Р.Батулла

НАЗИ́КАНӘ *рәв. фар. иск.* Нечкәлек, нәфислек белән, килешле итеп, тупас, дорфа түгел. *Әфәндем, ул төрекләр бик шундый фәсыйх, шундый назиканә язалар, укыйсың килгәннән-килеп тора.* Г.Толымбай

НАЗИКЛЕК *и.* Нәфислек, сылулык, гүзәллек. *Ул, анасына тартымрак булып, озынрак буйлы, нечкәрәк гәүдәле; бөтен әгъзаларында хатыннарга махсус назиклек сизелә.* Г.Ибраһимов

НАЗИЛ *и. гар.* Югарыдан төшүче, иңүче

НАЗИ́Л БУЛУ *ф.* Төшү, иңү (гадәттә Коръән аятьләре тур.). *Җәбраил галәйһиссәлам назил булды, тәкый бу сүрәне пәйгамбәргә китерде.* М.Болгари. *Гайса (галәйһиссәлам) назил булса да (күктән иңсә дә), әле ул кыямәт алдыннан гына назил булачак.* М.Гафури. *Бу сүрә Мәккәдә назил булган*

НА́З ИТҮ *ф. иск. к.* **назлану**. *Наз итәр кемнәргә гөл, каршында былбыл булмаса?* Г.Тукай

НАЗЛАНДЫРУ *ф. йөкл. юн.* 1) Назлануга юл кую; назлы итеп тәрбияләү. *Кызларын назландыралар*

2) *к.* **назлану**. *Я, сөйлә инде, назландырма.* М.Җәлил. *Мәрьям назландырмый гына җыр башлады, башкалар аңа кушылды.* Н.Яһудин. *Хәдичә назландырып иренә карышкан булды.* Р.Гаязетдин

Назландыра башлау Назландырырга тотыну. *Бала бала инде: Бакый үзе дә үсенеп китте хәтта, бераз гына көйләтә, назландыра башлады.* Г.Гыйльманов

Назландырып тору Гел назландыру; озак назландыру. *Бер дә назландырып тормыйлар тагы үзләре: председатель әйтә тора, тегеләр оркестр уйнаганга тыз-тыз басып һәм күкрәкне мич капкачыдай киереп, президиум өстәле каршына чыга торалар...* Ф.Хөсни. *Әтиләр Гапсамат турында кабат сүз кузгаткач, әллә ни назландырып тормадым.* З.Гыйниятова

НАЗЛАНУ *ф.* **1.** 1) Иркәләнү. *Алар бергә ашыйлар-эчәләр, назланалар.* Г.Гыйльманов. *Әй кызым, килче, бер назлыйм әле үзеңне.* Ә.Баянов. *--- Оныталды назланыр вакытлар, Шәһәрләр, авыллар читендә Ишәйде дотлар һәм окоплар.* Ә.Рәшит. *Вакытлар үтә, моңарчы ефәк кебек назланган хатыны тагын чыгырыннан чыга башлый.* Ф.Яхин

2) *сөйл.* Кылану, көйләттерү, боргалану. *Казанлыларның кунак сыйларга, назланып, ялындырып кына сыйлатырга яратуы мәгъриптә дә, мәшрикъта да билгеле.* Ф.Латыйфи

3) Нинди дә булса эшне үтәргә ашыкмау, көттерү, ялындыру. *Сөйлә инде, ни хәбәр бар, иптәшем, назланмачы.* Г.Тукай

2. *и. мәгъ.* Иркәлек, наз. *Кайнар тән җылысы, назлану сиздергән йокылы тавыш белән, куркып: – Ни булды? Ә? – диде [яшь кияү].* Н.Фәттах

Назлана бару Торган саен иркәләргә арту

Назлана башлау Соңгы арада назлану галәмәтләре күрсәтү; назланырга тотыну

Назлана төшү Бераз назлану. *Рәния, назлана төшеп, чыркылдап көлеп җибәрде...* А.Вергазов

Назланып алу Бераз назлану. *[Зөһрә] Чишенеп, әнисе тирәсендә иркәләнеп-назланып алгач, үз бүлмәсенә барып, өстәле артына утырды.* Г.Гыйльманов. *Хәлен белергә килгәнгә рәхмәт әйтүе булгандыр инде, җилкәмә башын куеп, [аргамак] назланып алды.* Мәдәни җомга

Назланып бетү Тәмам иркәләнү, иркә затка әйләнү

Назланып китү Хәзер, соңгы вакытта назлану

Назланып тору Әледән-әле, һаман, гел назлану. **–** *Әй егетләр, кунакларны бүген үк эшләтергә килешми дә инде... Ну, тот әйдә, мәгъзум, назланып торма! – диде [солдат].* Ш.Камал. *Без назланып тормадык, капчык белән икмәк һәм чәйнекне шунда калдырдык та, бабай белән бергә, теге семьялы кешеләр тора торган казармага барып кердек.* М.Гафури. *Күңелләр күтәренке иде, көлешеп чәкәштеләр, кыстатып, назланып торучы булмады.* А.Гыйләҗев

Назланып утыру *к.* **назланып тору**. *Андый кеше гомергә шулай була ул, ашамыйча борнайланып, назланып утыра да соңыннан каткан икмәк кимереп йөри...* А.Гыйләҗев

Назланып яту Озак назлану. *Хатын куенында дүрт ел назланып яттың, җитәр!* А.Гыйләҗев

НАЗЛАНУЧАН *с.* Иркәләнергә, назланырга ярата торган

НАЗЛАНЫШУ *ф. урт. юн. к.* **назлану**. *Һәр күрешүне бәйрәм итеп кабул итеп, иркәләшеп, назланышып яшәүгә ни җитә.* Т.Галиуллин. *Ләкин бернинди дә этәрешсез назланышырга бу егет белән кызны табигый тыйнаклыклары тыеп калды.* Т.Нәбиуллин. *Очрашканда, бер-беренә каршы йөгереп килеп, кочаклашып күрешәләр, озаклап сөйләшәләр, назланышалар...* Г.Гыйльманов

НАЗЛАТУ *ф. йөкл. юн. к.* **назлау**. *Ул, анасы назлаткан бала төсле, үкереп-үкереп елый башлады.* Ш.Камал. *Ул бит Михаил тарафыннан сөелер өчен, назлатыр өчен генә туган җан иясе!* Н.Әхмәдиев. *Нәфисә Хәлимне үз җанына гына түгел, тәненә дә якын җибәрәчәк, назлатачак, үзе дә аны назга күмәчәк...* Г.Гыйльманов

НАЗЛА́У *ф.* Иркәләү, кадерләү. *Сеңлем чыгып киткәч кенә, Назлый идем мин аны; Терелеп китә иде чәчәк, Булгандыр ул да җанлы.* Ф.Яруллин. *Җырланасы җырымны мин иртәнге һава җилләрендә назладым, кояш нурларында җылыттым.* Г.Кутуй. *Йосыф үзенең балачагын, әнкәсенең туктаусыз назлавын исенә төшерде...* Я.Зәнкиев

Назлап тору Гел, һәрвакыт, һаман назлау. *Аңа гына сыенып, аны гына назлап тора торган чәчәктәй нәфис Наҗиясе белән ул [Шакир] кешеләр алдында горур һәм бәхетле булыр кебек ---.* Ә.Еники. *Ул нурлар озак кына әле яңгырдан соң сизелер-сизелмәс кенә күтәрелгән ефәктәй йомшак җир парларын, күлләвекләрне, үлән, гөл, чәчәкләрне назлап торды.* С.Поварисов. *Дүртебез генә кич утырган чакларда, Нургалинең мине тоташка назлап торуыннан Сажидә бераз көнләшеп тә куя иде шикелле.* Г.Галиева

Назлап чыгу Баштан-аягына кадәр сокланып карап алу. *Камил --- күз карашы белән кала кунагын назлап чыкты.* Г.Әдһәмова

НАЗЛЫ 1. *с.* 1) Иркә, ягымлы; йомшак. *Назлы җил, салмак җил китерә Чәчәкле болынның исләрен.* М.Шиһапов. *«...Син [Атилла] үзеңнең йокы бүлмәңдә искиткеч гүзәл хатынның назлы кочагында үләчәксең», – диләр [юраучылар].* Ф.Дан. *Бер вәзир, ни сәбәп илләр, назлы киемнәрдән, мамык түшәкләрдән, татлы ашлардан аерылып, кортлар, еланнар патшалык сөрә торган мәмләкәткә китте.* Г.Тукай

2) Иркәләүне, назлануны, ягымлылыкны чагылдырган (караш, сүз, мөрәҗәгать һ.б.ш. тур.). *Назлы карашларың белән, Зинһар, сөеп карама.* Х.Фәрхи. *Назлы сүзләр көтмә миннән, Үбәргә ашык. Мәхәббәт сүзләр яратмый, Мин – тиле гашыйк.* З.Мәхмүди. *Аның талчыбыктай зифа буе, озын кара чәче, назлы күз карашы һәм сүзләре, тагын да әллә нәрсәләре, әллә нинди гүзәллекләре мине таң-хәйран калдырып кына түгел, хәтта һушсыз итәләр.* Ф.Яхин

3) Нәзберек, талымчан

4) Назланырга, кыстатырга, ялындырырга яратучан. *Кызлы кеше – назлы кеше, уллы кеше – юллы кеше.* Мәкаль. *Әле килгәненә ничә ай гына булды, менә шул арада да, ди, назлы яшь кәләш булып, матурланып, чытлыкланып, куштанланып, ирне кулга алып бетерде, ди.* Г.Ибраһимов. *Төн буе каравылда йөргән карт!.. Кояш нуры астында йоклый алмаган назлы хатын!.. Берберсенә капма-каршы булган бу ике төрле тормыш күңелне болгандырып җибәрә.* М.Гафури

2. *рәв. мәгъ.* Наз белән, йомшак; назланып, иркәләнеп. *Әмма шалтыратучы чыннан да ул иде, сөйләшүе ягымлы, артык назлы яңгырый иде ---.* Р.Мирхәйдәров. *Туйны зурдан кубып үткәрделәр, һәм, ниһаять, ике яшьнең йолдызлы кичләр, айлы төннәр, шаярубәхәсләшүләр, кызып китү һәм чак кына үпкәләшүләр белән тулы гомере, ике чишмәдәй бергә кушылып, тирән елгадай тын гына, назлы гына ага башлады.* М.Шаһимәрдәнов

◊ **Назлы кияү** Аш-су, кунак-сый иркәсе. *Башындагы бүркен дә үзе салмый, кәләшеннән салдыра! Тәмам назлы кияү булдың инде.* К.Тинчурин

НАЗЛЫЛАНУ *ф.* Назлыга әйләнү; нәфисләнү, сылулану. *Марфа диңгездән тагы да сылуланып, тагы да назланып кайткан иде.* М.Мәһдиев

Назлылана бару Торган саен назлылану

Назлылана төшү Тагын бераз назлылану

НАЗЛЫЛЫК *и.* Иркәлек, назлы булу. *Ниндидер иркәлек, назлылык бар бу тавышта.* Г.Гыйльманов. *Кырмыскалар өредәй кайдадыр ашыгучы төркемнән тыйнак назлылыгы белән карашларын суырып алыр затның җанга якын чалымнарын көтте.* М.Кәбиров. *Кызның йөзеннән иркәлек, назлылык бөркелеп тора.* Сөембикә

НАЗ-НИГЪМӘТ *җыйд. и.* 1) Төрле рәхәтлекләр, һәртөрле нигъмәт. *Дидем: «И хәзрәти бәүвабы җәннәт, Нидән ләкте миңа бу назы-нигъмәт?»*

Г.Тукай. *Бер кеше наз-нигъмәт эчрә, бер кеше тапмый тәгам! Һәрберсе булсын тигез дип, ачуларым басмак булам.* М.Гафури

2) Сый-хөрмәт, һәртөрле тәмледәнтәмле азык-төлек

НАЗЫЙМ *и. гар. иск. к.* **назымчы**. *Шулай ук һичбер назыйм бер юл ахырын «сукмак» дип туктаткач та, өйалдына чыгып, «тукмак» эзләргә бурычлы түгелдер.* Г.Тукай. *Назыймны сорасаңыз, әй яр, мәкяне хар [урыны чәнечке], эчендә – нар [ут].* Р.Фәхретдин

НАЗЫЙР *и. гар. иск.* 1) Элекке татар мәдрәсәләрендә шәкертләрне күзәтеп, тикшереп торырга билгеләнгән кеше. *Ул иң элек Гали хәзрәтне, назыйрны, барлык мөгаллимнәрне канцелярия бүлмәсенә кертеп яба да ишек төбенә кораллы солдат куя.* Г.Ибраһимов. --- *мәдрәсәи Мотыйгыя әдибе Габдулла Тукаевның шул мәҗлестә, бик зур муаффәкыять белән, мәдрәсәбезнең яңа назыйры Вәлиулла Хәмидуллин турында укыган бер шигырен язу белән канәгатьләнәбез.* И.Нуруллин

2) Министр, вәзир, мөдир, идарәдә җитәкчелек итүче. *Әзергә хәзер, хәзергә назыйр.* Әйтем. *1920 елның сентябреннән Бохара халык Совет Республикасының хәрби назыйры (министры) була.* С.Шакир. *Соңыннан гадлия назыйры Җәүдәт паша белән күрештем.* Ш.Мәрҗани. *Күзләренә Аллаһы Тәгаләнең, үзенә генә махсус сыйфаты илә, кыямәттә хаким вә назыйр булып торуы, фәрештәләрнең саф баглап торулары тәмам күренгән шикелле була.* Г.Тукай

НАЗЫЙРӘ *и. гар. әд.* Башка бер авторның ниндидер әсәре тәэсирендә туган һәм аңа охшатып язылган яңа әсәр. *[Тукайның] Кайсы шигыреңә назыйрә икәне әйтелмәгән.* К.Шамил. *Аның «Татар әдәбиятында имажинизм бетерелүе» турындагы манифесты исә чынлап та зур кыюлык булып, заманасында аннан көлделәр, аңа каратып көлкеле пародияләр (назыйрәләр) яздылар.* Г.Нигъмәти. *Бәлки, шул газаплы ләтыйф истә мин, бәхет мөмкин булып та, бәхетсез уздырган яшьлегемнең назыйрәсен табармын.* Ф.Әмирхан

НАЗЫЙРӘЧЕ *и.* Назыйрәләр язучы, назыйрәләр авторы. *Оста назыйрәче*

НАЗЫМ *и. гар. әд.* 1) Шигъри төзелеш, шигырь белән язылган хикәя. *Берсе Габдулла Тукаев җәнаплары тарафыннан назым белән язылган «Алтын әтәч» нам бер хикәядер.* Г.Камал. *Әдәбиятта назым яки нәсер рәвешләре дә әкрен генә бер-берсенә якынлашып, яңа бер форма төзү юлында тәрәкъкый итәләр...* К.Нәҗми. *Күфи һәм сөлес язулары белән язучы осталарыбыз бар; бәгъзе назым белән язучы шагыйрьләребез бар.* Г.Гобәйдуллин

2) Коры рифмага гына корылган, эстетик кыйммәте булмаган шигырь; мәнзумә. *Безгә шигырь белән назымны аера белергә күптән вакыт инде. Бу әсәр [«Мияубикә»] – шигырь түгел, бәлки назым вә мәнзумә генә.* Г.Ибраһимов

НАЗЫМЛЫ *с.* Назым итеп язылган, шигырь белән язылган, рифмалы. *Назымлы шигырь вәзен вә кафияләре белән – нәсергә, нәсер исә үз нәүбәтендә назымга якынлашып, халәте рухия композициясе белән сугарылган шигырьнең яңа бер формасын тудыралар...* К.Нәҗми

НАЗЫМЧЫ *и. әд.* Назым, мәнзумә, рифмалы әсәр язучы. *Язма телнең халыклаша баруына да бу даирә назымчы әдипләр мәгълүм дәрәҗәдә хезмәт күрсәтәләр.* Ф.Фәсиев. *«Биш мужик» – унынчы елларда күпсанлы шигырьләр язган назымчы Гариф Гайнуллин әсәре.* М.Мәһдиев

НАИБ *и. гар. тар.* 1) Ярдәмче, урынбасар. *Анда Үзбәк хан заманында Сарайчык шәһәрендә Үзбәк ханның ике наибе, ягъни баскагы булуы һәм аларның Амәт һәм Самат исемле булулары языла.* М.Әхмәтҗанов. *Сәгать уннар чамасында аларны консулның мәхкәмәсендә консул үзе, аның наибе, кятибе вә тәрҗеманы бергә булганнары хәлдә каршы алдылар* ---. Г.Монасыйп. *Гаскәрләрен карау, дошманнарга каршы тору һәм халык эшләрен күзәтү өчен үзенең [рус хөкемдарының] бер наибе була.* Р.Фәхретдин

2) Иярүче, дәвамчы

НАИХӘ *и. гар. иск.* Мәет күмгәндә такмаклап елау, матәм җыры башкару өчен ялланыла торган оста елаучы хатын-кыз, сыгыт әйтүче. *Бер галим сазәндә [сазчы] бер галимә наихәгә никахланды.* К.Насыйри

НАЙ *и. фар. муз.* Көнчыгыш илләрендә таралган камыш курай төре. *Тумра чиртеп, най тарткан Әшүвәтле [данлы] көннәр узгай ла!* Дастан. *Думбра, най тавышлары ишетелә.* А.Нәҗми

НАЙЗА *и. фар. к.* **нәйзә**. *Карагай найза таянып, Тукмак яллы турыны Актачыдан тоттырып, Туктамыш хан менгәндә, Хан ханәше Йәникә Тезгенгә килеп асылды...* Дастан. *Касмак бик батыр, куәтле кылыч оргучы, найза тотучы, ук атучы кеше икән, ди.* Риваять

НАЙЧЫ *и.* Найда уйнаучы. *Оста найчы*

НАКАЗ *и. рус сөйл.* Теләкләр һәм таләпләр; шуларны белдереп язылган документ. *Сезгә шуның өчен наказ: алдагы көндә дә бригада исеменә тап төшермәскә.* Х.Вахит. *Сайлаучылар авыл белән район үзәге арасындагы юлны асфальтларга наказ бирәчәкләр инде.* Ш.Алпар. *«Наказ» сүзен ишеткәндә, әле ерак китеп өлгермәгән социализм заманнары искә төшә.* Идел

НАКАЛ *и. рус сөйл.* Соң дәрәҗәдә ярсу, әсәрләнү, зур киеренкелек. *Хыялыбызга да китермәдек Талантыңның легендарлыгын, Сизмәгәнбез синең тыйнак җанда Нинди бөек накал барлыгын.* Х.Туфан. *Күрәсең, шагыйрьләге, шигъри накалы яшьтән үк ныклы булгандыр.* Р.Миңнуллин

НАКАЛЛАНУ *ф. сөйл.* Соң дәрәҗәдә ярсып чыгу, тәэсирләнү. *Шагыйрь икәнсең, әйтми калырга мөмкин булмаган халәткә дулкынлану, яну, накаллану белән ирешергә кирәк.* Х.Туфан

НАКАЛЛЫ *с. сөйл.* Киеренке, кайнар, дәртле. *Патриотик, бердәм, монолит хис, Накаллы хис һәрбер йөрәктә.* Х.Туфан

НАКАТ *и. рус* Махсус җайланма ярдәмендә нәрсәнең дә булса өслегенә төшерелгән сурәт. *Гади генә ванна бүлмәсе дә, стеналардагы сыек*

яшел фонга йөгертелгән алтын накат та – барысы-барысы аңа тынычлык бирәләр. А.Расих. *Стенага төшерелгән накатларның төсе уңды, яңадан төшерергә кирәк.* Г.Газиз. *Сафирә туташ белгән маляр хатынны чакырып, накат белән диварларны акшарлатты.* М.Шаһимәрдәнов

НАКАТЛЫ *с.* Накат төшерелгән, накаты булган. *Соңгы вакытларда кибетләрдә накатлы тукымалар сата башладылар.* М.Фәйзи. *Накатлы дивар*

НАКЛАДНОЙ *и. рус махс.* Нинди дә булса йөкне яисә товарны кая булса илтеп тапшырганда, шул йөк яки товар турында мәгълүмат теркәлгән кәгазь, документ. *Үзем юлга чыктым, ә накладнойларымны алырга онытканмын.* Г.Бәширов. *Йөкләр санын без Фәһимә белән исәплибез, накладнойлар язабыз.* Ә.Баянов

НАКЛОНЕ́НИЕ *и. рус лингв.* Эшхәлнең чынбарлыкка мөнәсәбәтен белдергән фигыль формалары системасы (парадигмасы); тәгъбирлек. *Боеру наклонениесе. Теләк наклонениесе*

НАЛА́ДЧИК *и. рус сөйл.* Көйләүче, төзәтүче белгеч. *[Цехта] автоматчиклар – материал, ә наладчиклар корал кабул итеп тыз-быз йөриләр иде инде.* М.Шәрифуллин. *[Кәбир] колхозның машина паркында мастер-наладчик булып эшли икән.* А.Гыйләҗев

НАЛА́ДЧИКЛЫК *и. сөйл.* Наладчик булу. *Наладчиклыкта эшләргә, диләр.* Б.Камалов

НАЛОГ *и. рус* Дәүләт тарафыннан билгеләнеп, юридик һәм физик затлар тарафыннан түләнелә торган акчалата мәҗбүри җыем; салым. *Җиденче класс укучысы Хәбриев (аның әтисе налог җыючы булып эшли иде) үзенең дәфтәр тышыннан бер хәтәр сүз тапкан.* М.Мәһдиев. *Кортканың җилкапкасы төбенә утырып, килеп-китүчеләргә налог салган: «Мин – әбинең сиклитәре, кергән өчен ун тәңкә түләгез», – дип әйтә икән.* Р.Зәйдулла. *Шкаф өсләрендә төргәк-төргәк Налог кәгазьләре саклана...* Ш.Галиев. *Бер көнне, налог полициясеннән килеп, сараен пыр туздырып, штраф салып киттеләр.* Г.Гыйльманов

НАМ *и. фар. иск.* **1.** 1) Исем, ат. *Ата-баба рухын аяк астына салып таптау, гүр ияләренең исемен, намын, хатирәсен пычрату, тынычлыгын бозу – бу бит явыз илбасарлар эше.* А.Гыйләҗев

2) Данлы исем, яхшы ат; шөһрәт, шан. *Сәнең дә йөксәлер бер көн мәкамең, Язылыр, ихтимал, алтынлә намың.* Г.Тукай. *Ансыз [идеясез] нә нам, нә ихтирам...* Г.Ибраһимов. *Хәвефсез мәсләкемдә сабит улмак Каһарман намыны алганнан артык.* М.Гафури

2. *с. мәгъ.* Исемле, дип аталган. *Габдулла Гыйсьмәти әфәнде үзенең «Ана теле» нам кыйраәт китабында балаларга мисал өчен «кылт итеп исемә төште» дигән сүзне язмаган булса...* Г.Тукай

3. намына *бәйл. мәгъ.* Хакына, хөрмәтенә, өчен. *Милли азатлык намына чехка, милли идарәгә, Колчакка тагылдык.* Г.Ибраһимов. *Авыл кешеләренең дошманны җиңү намына эшләгән тиңдәшсез батырлыклары һәрвакыт күз алдында торып, күңелне кузгалтты.* Г.Бәширов

◊ **Нам казану** *иск.* Исем-шөһрәт казану, танылу. **Нам чыгару** *иск.* Дан, шөһрәт, исем казану

НАМАЗ *и. фар. дини* Исламның биш шартыннан берсе булып, мөселманнарга билгеләнгән вакытларда көненә биш мәртәбә үтәлергә тиешле гыйбадәт, салят. *Моннан ике ай элек миңа гүя бөтен халык бердән «намаз!» дип кычкырган, мин исә сикереп торганмын да, ястүме, ахшаммы – тикшермичә, бернәрсә укыганмын.* Г.Тукай. *Әле иртә иде, Казан мәчетләре өстендә мөэмин-мөселманны намазга чакырган азан тавышлары да тынып өлгермәгән иде.* Ф.Латыйфи. *Шул ятудан җомга намазын да, капчык һәм он хәсрәтен дә онытып, байтак кына гырлап, борыны белән бүрәнә тарттырып алды.* Ф.Хөсни

◊ **Намазга басу** Дин юлына кереп, тиешле сүрә һәм догаларны өйрәнеп, биш вакыт намаз укый башлау. *Ә безнең заманда нәрсә күзәтелә? Берәү намазга басса, әти-әнисенә, хатынына яки иренә, туганнарына катгый итеп шартын куя: әгәр намаз укымыйсыз икән, мин сезнең белән араны өзәм!* Р.Юныс. *Киресенчә, хөрмәтем генә артты дип, хәтта намазга басуымны да хуплады.* Ф.Яхин. *Элек әби-бабайлар 40 яшьтән бөтен дөнья мәшәкатен балаларына тапшырып, ахирәт дөньясына хәзерләнә башлаганнар, намазга басканнар, аларны киендерү, туендыру балалар җилкәсендә булган, диләр.* Татарстан яшьләре

НАМАЗҖӘЙ *и. диал. к.* **намазлык**

НАМА́З ИЯСЕ *и.* Биш вакыт намазын калдырмыйча укып баручы, диндар кеше. *Яшьрәкләр яланның хуш исле үләненә сузылып ятты, өлкәнрәкләр, кулларындагы уклауларын, чиләкләрен куеп, белгән догаларын укырга кереште, намаз ияләре намазга басты...* Г.Гыйльманов. *Ул үзе [Сөнгатулла абый] намаз иясе, халыкка да белгәнен җиткерә, хәтем мәҗлесләрендә Коръән укый, җеназаларны оештыра, үлгәннәрнең исемлеген алып бара.* Ф.Бәйрәмова

НАМА́З КЫЛУ *ф. к.* **намаз уку**. *Түләк торды, ясигъ намазын кылды, мәхкәм китерде, башын сәҗдәгә куеп әйтте: «Иләһым, барча авыр эшләр сиңа җиңел бирелә ---».* Г.Гыйльманов. *Сәхәрдә мәсҗедкә барып намаз кылганнан соң, йокысыз төн уздырган кунаклар кайтыр юлга кузгалдылар.* Ф.Яхин

НАМАЗЛЫ *с.* Намазларын калдырмыйча укып барган, намазчыл. *Егет аулаган кыз киемнең итәксезен кия, намазлы әби яулык һәм озын итәкле күлмәк белән йөри.* Ф.Яхин

НАМАЗЛЫК *и. дини* Өстендә намаз укыла торган махсус пакь җәймә яки келәм. *Мәгыйшәт алдына намазлыгын җәеп, намазына кереште.* Г.Тукай. *Артык диндар кеше түгел ул, әмма намазлык өстендә дисбе тартып утыруның үз рәхәте, җанга тынычлык бирүче үз хасияте бар.* Ф.Латыйфи. *Бөтен көнен намазлык өстендә үткәргән бу изге карчыкның беренче уе тәкъдир хакында булды.* Г.Гыйльманов

◊ **Намазлык өстендә утырган** Гамәл-гыйбадәтләрен тиешенчә үтәп барган, диндар. *Намазлык өстендә*

утырган карчык турында шулай әйтергә ничек телең әйләнә? Ә.Еники

НАМАЗ-НИЯЗ *җыйм. и. сөйл. дини* Намаз, дога һ.б.ш. гыйбадәтләр. *Аңар [улына] акчаның кадерен бик белеп тотарга өйрәтеп, намаз-нияз белер кадәре генә мөселманча укытып, адрес язарлык, телеграм укырлык кадәр генә русча укытып, аны аякка бастырды [Галим абзый].* Г.Исхакый. *Ул намаз-ниязның нәрсә икәнен белмәгәндер.* М.Мәһдиев. *Күрше апабыз намаз-ниязга бик бирелеп китте.* Татарстан яшьләре

НАМАЗСЫЗ *с.* Намаз укымый торган, иманга, дингә ваемсыз. *Болай Хода юлында йөргән намуслы фәкыйрьләр булган шикелле, әлеге авылда мордар һәм намазсыз фәкыйрьләр дә аз түгел.* З.Бигиев

НАМА́З УКУ *ф.* Мәгълүм хәрәкәтләрне (кыям, рөкүгъ, сәҗдә һ.б.ны) билгеләнгән тәртип буенча бер-бер артлы үтәп, шул ук вакытта махсус Коръән аятьләре, зикерләр укып гыйбадәт кылу. *Намаз укыр ул ахирәт хатыны, Ах итәр, күккә чыгадыр төтене.* Г.Тукай. *Намаз укырга кирәкме – кырык эше кырылып ятса да, кичекмичә, ул үзенең намазын укый, ашар чак җиттеме, шулай ук, бернигә карамыйча, тамак ялгау ягын карый иде.* Н.Фәттах. *Чөнки аның әтисе – танылган көрәшче, мөселман: намаз укый, мәчеткә йөри!* М.Шәһимәрдәнов

НАМАЗЧЫЛ *с. дини* Гыйбадәтләрен җиренә җиткереп үтәп, намазларын вакытында укып баручы. *Гали Баһабовның хатыны Мәрьям абыстай да, яхшы ата баласы булып, алтмыш яшьләренә җитеп килгән суфи һәм намазчыл бер хатын иде.* З.Бигиев. *Әбием бик дини, намазчыл иде минем.* Татарстан яшьләре. *Тирә-юнебездә намазчыл кешеләр арта бара.* Татарстан яшьләре

НАМӘ *и. фар. иск.* 1) Хат, мәктүп, язу. *Без, ошбу намәгә кул куючылар – Казан вилаяте, Казан нахиясе, Мәүла Колый карьясе мөселманнары – олуг падишаһыбызның мәрхәмәтле вә тугрылыклы түрәләренә шуны таныклыйбыз ---.* М.Галәү. *Ахыр барча бикләр ул падишаһтан йөз дүндереп, бу падишаһка бер намә язып күндерделәр.* К.Насыйри. *И җәнымның җәне, ике күземнең нуры, сине бер күрергә зар вә интизар булып, бер кош теледәй намә яздым.* Г.Исхакый

2) Кушма сүзләрдә «язу» (*3 мәгъ.*), «язулы кәгазь» мәгънәсендәге икенче кисәк (мәс., *бәяннамә, дәгъвәтнамә, низамнамә, сәяхәтнамә, шәһадәтнамә*). *Ул [Галимҗан Ибраһимов] әле Сталинга хитапнамә язачак.* С.Поварисов // Кушма сүзләрдә китап яки әсәр исемен билгеләгәндә кулланыла (мәс., *«Шаһнамә», «Мәхәббәтнамә», «Хаҗнамә»*). *Мондый балкыш хакында борынгы төрки язмаларның берсе булган «Чыңгызнамә»дә дә искә алына икән.* С.Поварисов

НАМӘГЪЛҮМ *с. фар.-гар. кит.* Билгеле булмаган, мәгълүм түгел, билгесез. *Былтыр Һади әфәнде Италия-Төркия сугышының безгә намәгълүм бер сәбәбен ачты.* Г.Тукай. *Сүзне кем нәрсәдән башлап җибәргәндер – анысы намәгълүм.* Ә.Еники. – *Хикмәт шунда тагы, – дип өстәде Гафур, – аның кулында бер хат табылган, анда нидидер намәгълүм кеше аңа, сине агулап үтерәчәкләр, сине хатының агулап үтерәчәк, дип язган.* А.Расих

НАМӘХРӘМ *и. фар.-гар.* **1.** Якын туганлык бәйләнешләре булмаганга һәм шәригать буенча бер-берсенә никахлашырга рөхсәт ителгәнгә күрә, бер-берсенә күренергә ярамаган иргет белән хатын-кыз (бер-берсенә карата). *Бик яратышсагыз да, сез хәзергә бер-берегезгә намәхрәм әле.* Г.Бәширов. *Намәхрәмгә карау дөрес түгел, дия игътираз итмәгез, бәлки без алу ниятe илә карайбыз ---.* Ф.Кәрими. – *Юләр, мәзәк итеп әйткән сүзгә, мәсәлән, ышанды бит, чынлап ук намәхрәм белән биер, дип уйлады, ахрысы... – диде [хәзрәт] ---.* Ф.Әмирхан

2. *с. мәгъ.* Чит, ят, күренергә ярамаган. *Әле сиңа, кач, монда намәхрәм кеше бар, дип әйтергә уйлап кына торадыр идем.* Ф.Әмирхан

НАМӘХРӘМЛЕК *и.* Намәхрәм булу. *Бу эшем – бер алдашу, искедән калган намәхрәмлек тойгысын муллаларча итеп көчсезләндерергә азапланы... Һәм бу турыда үземне акларга маташу иде.* М.Галәү

НАМЕ́СТНИК *и. рус тар.* 1) Россиядә XVIII–XX гасыр башында җирле идарә башлыгы, XVIII гасыр ахырында бер яки берничә губерна башлыгы, XIX–XX гасыр башында чик буе өлкәләрендә югары дәүләт хокуклары булган, хөкүмәт башлыгы исеменнән идарә итүче кеше. *Ул Шаһгалидән рус наместнигына шәһәргә керергә рәсми төстә ризалык бирүне һәм шәһәрне аның кулына тапшыруны таләп итә.* Р.Фәхретдинов. *Кавказның идарәсе аерымча булганга, Кавказ наместнигы азәрбайҗанча гәзитә чыгарырга рөхсәт иткәләгән.* Г.Исхакый. *Провинцияләр белән наместниклар идарә иткән.* Борынгы заман тарихы

2) Монастырь башлыгы ярдәмчесе. – *Мине Синод 2005 ел ахырында бирегә [Свияжски монастырена] наместник итеп билгеләде, – ди Силуан атакай.* Татарстан

НАМЕ́СТНИКЛЫК *и. тар.* 1) Наместник булу, наместник вазифасы, хезмәте

2) XVIII гасыр башы – XX гасырларда Россиядә административ-территориаль берәмлек; вилаять. *Казан губернасы 1745 елдан соң бер «наместниклык» булып кала.* М.Әхмәтҗанов

НАМЗӘТ *и. фар. иск.* Кандидат. *Әрмән патриархларының ачыктан-ачык хөкүмәткә хилаф дашнаксутюн фиркасенең намзәде булуы --- Төркия хөкүмәтенең дә гайре мөслим табгысының рухани эшләренә никадәр иркенлек бирүенә зур дәлил түгелме?* Г.Исхакый

НАМУС *и. гар.* 1) Кылган гамәленне, тәртибеңне, үз-үзеңне тотышыңны, үзеңне бәяләү хисе, тойгысы. – *Ул кешеләрдә намус вә вөҗдан юкмыни? – дип игътиразлар итә.* Г.Тукай. *Монда ахырзаман, этеш-төртеш, ачы итеп, җиде катлы итеп сүгенү, ә син, бабай, ниндидер намус турында сөйлисең.* Р.Зәйдулла. *Оят, намус төшенчәләре бөтенләй бетте хәзер сатучыларда.* Татарстан яшьләре

2) Яхшы исем, абруй, дан. *И аягың коргыры! Намусыбызны таптадың.*

Г.Тукай. *Аның Җәмилә белән сөйләшеп утырасы килде, әмма кыз үз намусы өчен борчыла иде.* Ф.Яхин. *Ватанның намусы өчен күпме кешеләр башларын салдылар.* Сөембикә

3) Гыйффәт, сафлык, кызлык. *Кызлык намусын, мәхәббәтен югалткан кызның киләчәге була аламы?* Г.Шакирова

◊ **Намус белән** 1) Чын күңелдән, күңел биреп, тырышып. *Абдулла үз тормышында әллә ни үзгәрешләр көтмичә, хезмәтен әүвәлгечә намус белән үтәүдә булды.* Э.Касыймов. *Тик бер шарт намус белән үтәлергә тиеш: теге «правокатор»ларга һәркем берәр кушуч борчак кузагы бирергә тиеш.* М.Мәһдиев. *Очрашуда катнашучыларны Эчке эшләр министры Әсгать Сәфәров намус белән хезмәт итәргә, милициядә эшләүләре белән горурланырга чакырды.* Мәгърифәт; 2) Тиешенчә, ничек кирәк шулай. *Мин үземнең кечкенә тормышымны намус белән үттем, намус белән үләм дә.* Г.Кутуй. *Галимнәр, картлар, яшь балалар, аналар вә кызлар кала эченнән чыгарылсын, аларның һәлакәте өчен юкса Йосыф хан намусы белән җавап бирәчәк икән.* Ф.Яхин. *Иманлы үтсен көнегез, Яктылык сипсен йөзегез, Намус белән гомер итегез.* Г.Юнысова. **Намус белү** Уңайсызлану, оялу, кыенсыну. *Син, кайчаннан бирле эшләмичә, әти-әниең өстендә ятасың. Бераз намус белергә кирәк.* Казан утлары. **Намус кушу** Әхлакый нормалар һичшиксез үтәлергә тиешле язылмаган канун таләп итү. *Аннары кешеләрнең үзләренчә, үз намуслары кушканча уйлый белүләре дә гаять мөһим, куанычлы бер хәл бит әле...* Ә.Еники. *Үз эшен намусы кушканча эшли, нәрсәдән курыксын?* С.Сөләйманова. *Бакча-сарайга кайтып сезнең күзегезгә күренергә намусым кушмый.* З.Бигиев. *[Габдулла:] Мин моны сездән яшерә алмыйм, Гәрәй Мингалиевич. Намусым кушмый.* Ф.Яруллин. **Намус саклау (сатмау)** Горурлыкны, үз-үзеңне югалтмау, исемеңә, дәрәҗәңә тап төшермәү. *Мин монда намус саклап эндәшми утырдым. Булды, җитте. Түзәр хәлем калмады.* Ш.Камал. *[Галимов:] Оятсызлар, вөҗдансызлар, намусыгызны саткан нәрсәләр, тунеядецлар сез, сорыкортлар, менә кемнәр.* С.Поварисов. **Намус эше** Кемнең дә булса иң югары әхлакый принциплары чагылган сүзләр, гамәлләр. *Картада ул [Гәрәй] зурдан кубып, бөтен җаны-тәне белән бирелеп уйный һәм уен кагыйдәләрен тиешенчә үтәүне намус эше дип саный иде.* М.Галәү. *Ә инде яңа йортка килгәндә, анысы – колхоз рәисенең намус эше, вәгъдә биргән, үтәсен!..* Г.Гыйльманов. *Аның район алдында ике бурычы бар: беренчесе – кара язда, рәис булып эшли башлаганының тәүге атналарында ук, башка күмхуҗларга тиешле фуражны ул үзләренә юллап алып кайтты, ә икенче бурычы – коммунист сүзе, намус эше – биргән сүзне үтәп, ышанычны аклау иде.* Ф.Яхин. **Намуска көч килү** Кыенсыну, оялу, намуссыну. *Ни кылганын аңлап алдымы, намусына көч килдеме, әллә минем өчен куркып киттеме?* Ә.Еники. *Язганнарым башыннан ахырына кадәр хакыйкатьтән генә торганлыктан, намусыма да көч килерлек булмады.* Ф.Яхин. **Намуска тию** Кемнең дә булса тугрылыгыннан шикләнү, кимсетү, абруена тап тидерү. *Күрәсең, Тукайның Аллага ышануын исләренә төшерүне алар үз вөҗданнарына кагылу, намусларына тукыну шикеллерәк кабул иттеләр.* Ә.Еники. **Намуска тукыну** *к.* **намуска тию**. **Намусы килү** *к.* **намуска көч килү**. – *Әй, синең шөребең бушаган, юкка мәшәкатьләнмә! – дигән сүзгә аның намусы килде бугай.* М.Гафури. **Намусы кузгалу** *к.* **намуска көч килү**. *Әй җаным, теге бәндәнең намусы кузгалган бит. Алып торган акчаларын китерде.* Г.Гобәй

НАМУСЛАНУ *ф.* 1) Нинди дә булса эш-гамәлне башкарырга күңел бармау, намус каршы килү. *Аннан акча сорап торырга намусландым, йөрәгем җитмәде.* Казан утлары

2) Оялу, уңайсызлану, кыенсыну. *Мин хәзер сине «сөеклем» дип хитап кылырга намусланамын.* М.Гафури. *Ә миңа калса, өлкәнәя төшкәч, бу хикәяне ишеткән саен отыры ояла, намуслана идем.* М.Кәрим

Намусланып тору Хәзерге моментта намуслану; гел, һәрвакыт намуслану

Намусланып йөрү Күптәннән бирле, шактый вакыт намуслану

НАМУСЛЫ *с.* **1.** 1) Намусы, ояты булган; гадел. *Шушы авариядән соң ике ел үткәч, намуслы галим үз-үзенә күл салды.* Р.Зәйдулла. *Без карак түгел, без намуслы, димәкчеләр.* М.Мәһдиев. *Ә бит биредә яшәргә ярамаганлыгын әле теге елларда да курыкмыйча әйтә алган намуслы галимнәр булган!* Ф.Бәйрәмова

2) Кемнең дә булса үз вазифасына, эшенә һ.б.ш.га намус белән карауга нигезләнгән. *Тик намуслы хезмәт Шат тормышлы итә кешене.* Ф.Кәрим

2. *и. мәгъ.* Намусы, ояты, вөҗданы булган кеше. *Сүгәргә мин тиеш идем ул чак, Намуслылар еларлык итеп.* Х.Туфан

3. *рәв. мәгъ.* Намус белән, тиешенчә. *Бөек Ватан сугышы чорында халкыбыз намуслы эшләде, арысланнарча сугышты.* Татарстан яшьләре. *Әгәр дә укуга намуслы карап, күңел биреп шөгыльләнсәң, бездән бик яхшы артист чыгарга мөмкин.* Мәгърифәт

НАМУСЛЫЛЫК *и.* Намуслы булу. *Хезмәт сөю һәм намуслылык кына кешене гүзәл итә.* Ф.Кәрими. *Намуслылык – татар халкының гасырлар кичеп, безнең көннәргә килеп җиткән иң күркәм сыйфаты.* М.Галиев. *Чорыбыз өчен намуслылык, гаделлек дигән төшенчәләр югала, кими бара.* Казан утлары

НАМУССЫЗ 1. *с.* Ояты, намусы булмаган; вөҗдансыз, оятсыз. *Мин – намуссыз сугышчымыни инде?* М.Мәһдиев. *Әнә Толстой бай булган, граф, ә кем аны намуссыз, вөҗдансыз дип әйтә ала?* Р.Зәйдулла. – *Әйе, – дидем мин, – әгәр дә намуссыз кешене очратсагыз, бер дә аптырамагыз, ул кешенең акылы да, гыйлеме дә булмас. Акыл һәм аң намуссыз адәмдә тормыйлар!* Ф.Яхин

2. *и. мәгъ.* Намусы булмаган, вөҗдансыз, оятсыз кеше. – *Укы, балам, – дияр иде әнием. – Әгәренки Гыйльми*

Салихы ише намуссызларга баш бирергә теләмәсәң, укы. Тырыш! А.Гыйләҗев. *Кара төннең күзе юк, Намуссызның йөзе юк.* Р.Фәйзуллин. *Алыпсатарлар, спекулянтлар, --- сараннар вә комсызлар, намуссызлар, каруннар --- көннән-көн артсын!* Р.Мирхәйдәров

НАМУССЫЗЛАНУ *ф.* 1) Намусны, оятны югалту, намуссызга әйләнү

2) Кемгә дә булса намуссызлык эшләү, гаделсезлек күрсәтү. *Син, дустым, намуссызланма! Бер дә килешми.* М.Мәһдиев

Намуссызлана бару Торган саен намуссызлыгы арту. *Син, җаным, торган саен намуссызлана барасың түгелме соң?* М.Мәһдиев. *Торган саен күршем оятсызлана, намуссызлана гына бара.* Казан утлары

НАМУССЫЗЛЫК *и.* 1) Намуссыз булу; оятсызлык. *Ул адәм халык арасында үзенең намуссызлыгы белән билгеле.* М.Мәһдиев. *Оятсызлыктан, намуссызлыктан куркырга кирәк, балам.* Ә.Еники

2) Намуссыз кыланыш, гаеп эш. *Баксаң, янәшәсендә хәерчеләр, йолкышлар җан асраганда, аның җитеш яшәве намуссызлык шикелле бит...* Р.Зәйдулла. *Андый усал хәйләгә һәм намуссызлыкка барырга ул [Сөләйманов] бик яшь әле.* Ә.Еники

НАМУССЫНУ *ф. сөйл.* Оялу, кыенсыну, читенсенү, кыймау. *Шунлыктан яңадан өенә кайтып керергә дә намуссынды.* З.Мәхмүди. *Кыш уртасына эшчеләр бушаган иде дә, мең мәшәкать арасында Давыт йортка нигез салдырырга онытканын булып чыкты, туңган җирне актарттырырга исә намуссынды.* М.Маликова

НАН *и. фар.* Тандырда пешерелә торган зур көлчә; гомумән икмәк, ипи. *Якыныңа җаныңны бир, ата-анаңа наныңны бир.* Мәкаль. *Ул кем иде? Соңгы сынык нанын сиңа биреп, Ач калса да, «балам» диюче?* Һ.Такташ. *Бәргәләнә бәгырь, бәргәләнә, якты сорый җаным, нан сорый, рухи уразадан чыга алмый, үзен-үзе көчкә асрый.* Ә.Дусайлы. *Мөхәррирләр язу эшен сөйләгәндә, Күмәччеләр сөйләр күпме салган нанын.* В.Җәлал

НАНАЙ *и.* Амур елгасының түбән агымында, Уссуриның уң кушылдыклары ярларында яшәүче халык һәм шул халыкның бер кешесе. *Майбәдәрнең ире, бала-чагасын төяп, ерак Камчаткага укүченеп китте, балыкка урнашты, башта аз-маз хатлар язгаласа да, нанай маржасына өйләнеп тора башлагач, хат та язмас булды.* А.Гыйләҗев

НАНА́ЙЧА *рәв.* **1.** Нанай телендә. *Нанайча сөйләшү*

2. *с. мәгъ.* Нанай телендә булган. *Нанайча сүз*

НА́НДУ *и. исп. зоол.* Көньяк Америкада тереклек итүче эре, оча алмый, ләкин яхшы йөгерә һәм йөзә торган өч бармаклы кош, Америка тәвә кошы. *Тиз йөгергән вакытта нанду бер канатын җилкән кебек өскә күтәрә*

НА́НО- *гр.* Кушма сүзләрдәге «берәмлекнең миллиардтан бер өлешенә тигез» мәгънәсен белдерә торган беренче кисәк: *нанокисәкчә, наноматериал, нанодиапазон, наносекунд* һ.б.ш.

НАНЫЙ *и.* Балаларга, яшүсмерләргә, яшьләргә иркәләп эндәшү, мөрәҗәгать итү сүзе. *И наный, сиңа сөйләр сүзләрем бик күп минем.* М.Мәһдиев. *Монысы, биллә́hи дип әйтәм, соңгысы, наный.* В.Нуруллин. *Дөрес булмаска соң, наным, шаяртып сөйли торган сүз түгел лә.* Р.Мөхәммәдиев. *Каушама, наным, борчылма берүк, бик әйбәт яшәрсең бездә...* Р.Зәйдулла

НАНЫМ *и. к.* **наный**. *Син дә хафаланма, наным Равил.* В.Нуруллин. *Их наным, элеккеге гайрәтле чакларым кире кайтса...* Р.Сәгъди. *Сиңа әйтер сүзем бар, наным.* Р.Миңнуллин

НАП- *к.* **нәп-**. *Нап-начар*

НАПАЛМ *и. ингл. хәрби* Яндыргыч бомбалар, огнемётлар һ.б.ш.да кулланылган, составында желесыман бензин булган махсус катнашма

НАПА́ЛМЛЫ *с.* Напалм тутырылган, салынган. *Напалмлы бомба*

НАПРАВЛЕ́НИЕ *и. рус сөйл.* Кемгә яисә кая да булса җибәрелү турында рәсми кәгазь, юллама. *Мин Казан больницасына бару өчен направление алдым.* С.Сөләйманова. *[Фәимә]: Кадрия, больницага направление яз.* М.Хәсәнов. *Быел менә Нефтекама каласында яңа интернат ачыла, малаең шунда барсын, дигән. Направление дә тоттырып җибәргән.* Р.Миңнуллин

НАР I *и. нем. сөйл.* 1) Күп кеше яши торган казарма, барак, төрмә кебекләрдә такталардан ясалган ятак, такта сәке. *Хәтереңдәме, теге икәү нарда йоклаган чаклар.* Һ.Такташ. *Абушахман урыныннан сикереп тора һәм нарда ятучыларга шундый ачу катыш шелтәле караш ташлый, тегеләр, телләрен тешләгән кебек, берьюлы тынып калалар.* Г.Әпсәләмов. *Тоткыннарны нарларда йоклаталар иде.* Р.Мостафин

2) *күч.* Төрмә. *Нарда яту*

НАР II *и. гар. иск.* 1) Ут, ялкын, атәш. *Әмма артыннан ияреп хур итә – Дәҗҗәл кеби, Тирә-якны чорнап алган кып-кызу бер нар кеби.* З.Бәшири. *Фәкать Мостафаны каршысында күрү илә бит алмалары кып-кызыл булып, --- Фатыйманың кальбенең дә гыйшык вә мәхәббәт нары илә тулы булдыгына дәлиллек итмәктә иде.* Ф.Кәрими

2) Җәһәннәм, тәмуг

НАР III *и. фар. к.* **анар**. *Һәр кичә ризкы аның [Заһиднең] бер нар иде, Уңында нурдан кандил янар иде ---.* Кол Гали. *Гәми [авылы], иң әүвәл, өрек һәм нар агачларына күмелеп утырган урамнары, якты тәрәзәле очсыз-кырыйсыз йөзем бакчалары белән җәлеп итә.* Р.Мөхәммәдиев

НАР IV *и.* Ике өркәчле дөя белән бер өркәчле дөядән туган бик чыдам һәм көчле кушылгак (аркасындагы ике зур булмаган өркәче бер булып кушылып үсә). *Йөк авырын нар күтәрер.* Мәкаль. *Егылсаң нардан, әҗәлең әллә кайдан.* Мәкаль. *Туктамыштай олы хан Киң Җанбайга анда әйтте: «Садагын кырык нарга тарттырган Солтанатын Улда белән Вылдадан арттырган Хан алдында ат тоткан, Тамагына алты хат тыккан – Кәмалның улы Киң Җанбай, Киңәшең артык би Җанбай».* Дастан. *Сары Үзәктә көче-гайрәте, тиз йөрүе белән аңа [Каранарга] тиң нар, мөгаен, юктыр.* Ч.Айтматов

НАРАЗЫЙ *с. фар.-гар. иск.* Риза булмаган, риза түгел. *Чөнки мондагы наразый гөруһлар һәммәсе дә үзләренең*

әмәлләрен, үзләренең хыялларын мәйданга чыгармакчы булалар. Г.Исхакый

НАРАЗЫЙЛЫК *и. иск.* Ризасызлык, канәгатьсезлек. *Шуның өчен үзенең муллаларда сәгадәтлегеннән тотынып уйларга тотына иде дә, ул Сәгадәтнең фахишәлегенә барып бәрелеп, аның күңеленә әллә никадәр наразыйлык фикере уятканга, аны ташларга тели иде.* Г.Исхакый. *Авыру карауның бөтен җәфасын күтәрү өстенә, ул әле сиңа бернинди наразыйлык-фәлән дә сиздерми.* Ә.Еники

НАРАСИДӘ *с. фар. иск. к.* **нарасый**. *И нарасидә бала!* Г.Тукай. *Абзыкаем, рәхим итсәнә, нарасидә балам ач.* Г.Исхакый

НАРАСЫЙ *и. фар.* **1.** 1) Бала, нәни бала, сабый. *«Я Аллам, үзең кичер. Бу нарасыйга ярдәм ит, түземлек бир!» – дип, сыкрап теләк теләде.* Я.Зәнкиев. *Ике нарасыйның пар йөрәге бер булып тибә башлаган мәл иде бу.* Г.Гыйльманов. *Нарасыйның эчке дөньясын, аның нәрсәгә күңеле ятуын, һәвәслеген, төрле эшчәнлек төрләрен, көчен һәм мөмкинлекләрен өйрәнергә кирәк.* Мәгърифәт

2) *күч.* Кечкенә бала кебек ярдәмчесез, көчсез кеше турында. *Ул «нарасый»ның гүя бу эшкә катнашы юк: кәләшенә якын килергә куркып, кул кушырып утыра бирә.* С.Сөләйманова

2. *с. мәгъ.* Кечкенә, бәләкәй, нәни, сабый, бик яшь. *Ул – синең нарасый балалар уйнаган кузна кеби матур борыннарың!* Г.Тукай. *Күптән түгел генә чикәтаулар белән ана капландай сугышкан кыз атасын күрүгә нарасый балага әйләнгән иде.* И.Хуҗин. *Ул нарасый балаларның өсләрендә юка гына киемнәр.* Татарстан яшьләре

НАРАТ *и. монг. бот.* **1.** 1) Озын ылыслы, йомры күркәле мәңгеяшел агач. *Ишек алдым яшел нарат, бәйләп куйдым пар сары ат.* Г.Тукай. *Үр маңгаендагы нарат башлары күренә.* Ә.Гаффар. *Кинәт җил исте, биек нарат, эре яңгыр тамчыларын җиргә коеп, салмак кына башын чайкады.* Ә.Еники. *Ябалак канатларын кагып нарат башына очып менә дә миңа карап кычкыра: – Уһу-һуу, – ди.* М.Мәһдиев

2) Төзү материалы буларак шул агач. *Бу инде мин кунган кара өйгә охшамый, стеналары сап-сары нараттан.* Г.Тукай. *Манара үзәгенә дигән агач ботаксыз кара чыршы, я булмаса төз нарат булсын, ди.* М.Мәһдиев

2. *с. мәгъ.* Шул агачтан эшләнгән, ясалган. *Ишанның өе янында зур нарат капка бар.* Г.Тукай. *Моннан бер ел элек кенә хуҗаларыннан бушаган бу таза нарат өйгә казённый төс кермәгән дә кебек әле ---.* Ә.Еники. *Улым белән без җиләк исле печәнгә сузылып яттык, мунча алдында каен миллеге, нарат тактасы исенә җир җиләкле печән исе кушылган.* М.Мәһдиев

◊ **Нарат сагызы (чәере) булу** һаман бәйләнеп йөдәтү, әрсезләнеп, кабат-кабат мөрәҗәгать итү

НАРАТБАШ *и. бот.* Споралы үләнчел үсемлекләрнең югары төзелешле төре; нарат үләне, ат койрыгы; *русчасы:* **хвощ**. *Наратбашлар кечкенә генә яшел чыршы рәвешендә булалар. Аларның сабаклары вертикаль рәвештә югарыга таба үсә.* Ботаника. *Наратбашның үсемлек өлешен сидек кудыру, кан туктату һәм ялкынсынганда ярдәм итү өчен кулланалар.* Ватаным Татарстан

НАРАТБА́ШЧАЛАР *и. бот.* Наратбашларның төрле төрләрен берләштергән югары төзелешле споралы үләнчел үсемлекләр семьялыгы. *[Кыр наратбашы –] Наратбашчалар семьялыгыннан.* Урман аптекасы

НАРА́Т ГӨМБӘСЕ *и. бот.* Аксыл яки куе коңгырт төстәге эчкә баткан киң эшләпәле, калын саплы гөмбә; *русчасы:* **боровик**. *Нарат гөмбәсе бер ялгызы гына булмый, көтүе белән үсә.* Г.Хәсәнов. *Майлы гөмбә һәм нарат гөмбәсе чыршы астында була, каен гөмбәсе каен астында инде.* Шәһри Казан

НАРА́Т ҖИЛӘГЕ *и. бот.* Мәңгеяшел яфраклы, аксыл ал төсле чәчәк ата, җәелеп үсә торган куак; вак кына җиләге ачык кызыл төстә, ашарга яраклы; кызыл көртмәлек, саз чиясе; *русчасы:* **брусника**. *--- иксез-чиксез сазлыкларда бу айда кара җиләк, нарат җиләге --- өлгерә.* Э.Касыймов. *Бу арада халык нарат җиләге җыю белән мәшгуль булды.* Я.Зәнкиев. *Нарат җиләген кыздырылган ит янына кушымта (гарнир) итеп тә бирергә була.* Татар халык ашлары

НАРАТЛЫ *с.* Наратлар үсеп утырган, нарат агачлары булган. *Матур кызлар чыга җомга көнендә Наратлы тауга, авылыбыз янына.* С.Сүнчәләй

НАРАТЛЫК *и.* Нарат урманы, күпләп нарат үсә торган урын. *Юлыбыз наратлык аша үтә.* М.Мәһдиев. *Наратлыкта мансардалы коттеджлар тезелеп киткән.* М.Галиев. *Ул [Хәлимә] инде ихатадан чыгып йөри, якындагы наратлык буеннан күркәләр җыеп кайта яисә Ак бабай янына – ат абзарына барып, картның ат чистартканын карап тора.* Г.Гыйльманов

НАРА́Т ҮЛӘНЕ *и. бот. к.* **нарат-баш**. *Берәр аш кашыгы каз үләне, нарат үләне, турак уты яфрагы, укроп орлыгы алып, барысын бергә болгаталар.* Ватаным Татарстан

НАРА́ТЧАЛАР *и. бот.* Мәңгеяшел ылыслы (кайбер төрләре – ылысын коючан) үсемлекләрнең рәте һәм аларның бердәнбер семьялыгы. *Наратны чын мәгънәсендә «ылыслар башлыгы» дип атап булыр иде, чөнки ылыслы агачлар төркемен нарат исеме белән «наратчалар семьялыгы» дип йөртәләр.* Р.Ягъфәрова. *Медицина максатларында наратчалар семьялыгының башка вәкилләре ылысы һәм сумалалары да шундый ук тәртиптә файдаланыла.* Урман аптекасы

НАРА́Т ЧЫПЧЫГЫ *и. зоол.* Чыпчыклар отрядыннан, коңгырт-яшел каурыйлы, җирдә оя кора торган кечкенә сайрар кош; *русчасы:* **пеночка**

НАРВАЛ *и. фр. зоол.* Дельфиннар семьялыгыннан, өске казналыгында озын казык теше үсеп чыккан, сирәк очрый торган имезүче диңгез хайваны; сыңармөгез

НАРГИЛӘ *и. фар.* Төтенен су аркылы үткәрә торган тәмәке тарту әсбабы; кальян, хурхур. *Сарган, теткәләнеп беткән камыш келәмнәр җәелгән шул утыргычларның берсендә, аякларын бөкләп, бер төрек карты наргилә тартып утыра.* М.Галәү. *Кая карама урамнарда кәһвәханә, эскәмияләрне урамнарга чыгарганнар, кызыл фәсле*

агайлар хозурланып кофе эчәләр, комган сыман савыт аша гыр-гыр китереп наргилә тарталар. А.Расих

НАРДУГАН *и. фар. этн.* 1) Елның иң кыска яки иң озын көннәре; кояш торгынлыгы көннәре (*җәйгесе 21–22 июньдә, кышкысы 21–22 декабрьдә була*). *Бүген... Бүген иң озын төн бит... Нардуган бүген!* Г.Гыйльманов. *Кышкы нардуган. Җәйге нардуган*

2) *тар.* Төрки-татарларда яшьләрнең һәм бала-чаганың төрле уеннар уйнап, кеше танымаслык итеп киенеп өйдән-өйгә йөреп, елның иң кыска көнен билгеләп үтү бәйрәме

3) Керәшен татарларында Раштуа белән Хач ману арасындагы бәйрәм көннәре; *русчасы:* **святки**. *Ул [Рыбаков] мондый флейталарда нардуган тамашаларында егетләр уйнаганы турында яза һәм аны чибузга атамасы белән фонетик яктан бераз дөрес булмаган транскрипция аша бирә.* Г.Макаров

4) *диал.* Яңа ел бәйрәме

НАРДУГА́Н ҖЫРЛАРЫ *и. этн.* Нардуган (*3 мәгъ.*) көннәрендә җырлана торган бәйрәм җырлары

НАРДУГА́Н КӨЙЛӘРЕ *и. этн. к.* **нардуган җырлары**. *Нардуганым нар булсын, Эче тулы нур булсын. Нардуган көен кем көйләсә, Шул дәүләтле, бай булсын.* Җыр

НАРДУГА́Н ЧАБУ *и. этн.* Нардуган (*3 мәгъ.*) көннәрендә үткәрелә торган уеннар

НАРЗАН *и. [кабардинча «нартсанэ» (нартлар эчемлеге, батырлар эчемлеге) сүзеннән].* Дәвалану өчен һәм аш-су әзерләүдә кулланыла торган табигый углерод диоксидына бай минераль су. *Карт ел саен нарзан эчәргә, дәваланырга бара.* Ш.Хөсәенов. *Менә шушы нарзан чишмәсеннән генә дә көн саен егерме миллион литр чамасы су агызалар.* Г.Мөхәммәтшин. *Фатих Әмирхан аңа нарзаннан да өстенрәк икенче бер шифа тәкъдим итә.* С.Поварисов

НАРКОБИ́ЗНЕС *и. рус* Законсыз наркотиклар сату итүдән табыш китерә торган шөгыль. *Гәрчә балалар сатуның корал белән сәүдә итү, наркобизнес кебек төшемле гамәлләр рәтендә булуы ачык...* Р.Зәйдулла. *Миңа калса, бу кризис башында мафия, наркобизнес белән шөгыльләнүчеләр тора.* Безнең гәҗит

НАРКОЗ *и. гр. мед.* 1) Махсус дару ярдәмендә кайсы да булса әгъзаның тою сәләтен, сиземләвен ясалма рәвештә туктату яки кешене бернәрсә дә сизмәслек хәлгә китереп йоклату. *Күрше палатада ятучы танышыма операцияне наркозсыз гына ясаганнар.* С.Сөләйманова. *Нинди галәмәт бу: наркоз шаукымы бетмәгәнме, ниндидер зәхмәт яисә сихерме?* Г.Гыйльманов. *– Мин наркоздан уяна алмасам? – ди кыз, ак халатлы апасына кат-кат бер үк сорауларны биреп.* Сөембикә

2) Авыртуны басу яки йоклату өчен кулланыла торган дару. *Аны башта чалбарына чаклы калдырып чишендерделәр, беләгенә наркоз уколы кадап йоклаттылар, кулын бәйләделәр.* Г.Ахунов. *Наркозны кызганып кына бирделәр бугай, чөнки операция озакка сузылды, авыруның күп наркозны күтәрә алмау куркынычы бар.* С.Сөләйманова. *Аннан наркоз бирделәр, и һәм дә мин аңны җуйдым.* М.Мәһдиев

НАРКОЗЛЫ *с.* Составында наркоз булган; наркоз салынган. *Баягы наркозлы укол галәмәтеме икән, сызлануы да басыла төшкән кебек булды, зиһене ачылды.* С.Шәрипов. *Тикшерү күрсәткәнчә, балада наркозлы препаратлар кадагач үлемгә китерә торган чир булган икән.* Татарстан яшьләре

НАРКОЗЧЫ *и. сөйл.* Анестезиолог, наркоз бирүче табиб

НАРКО́ЛОГ *и. мед.* Табиб, наркология белгече

НАРКОЛО́ГИК *с. мед.* Наркологиягә караган. *Наркологик күзәтү. Наркологик диспансер*

НАРКОЛО́ГИЯ *и. нем. мед.* Наркотиклар куллану нәтиҗәләрен өйрәнү һәм наркоманнарны дәвалау белән шөгыльләнә торган медицина тармагы

НАРКОМ *и. рус тар.* Халык комиссары. *Бу эшләрнең барысын да нарком хәл итте.* Һ.Такташ. *Безнең обком секретарьлары, наркомнар – барысы да шунда.* И.Салахов. *Нарком булырлык кеше ул [Нәҗип]!* Ә.Еники

НАРКОМАН *и. гр. мед.* Наркотиклар кулланучы, наркомания белән авыручы кеше. *Сабак, имеш, төрле җинаятьчеләр, наркоманнар арасындамы?* Р.Зәйдулла. *Якын көннәрдә Казанда наркоманнар өчен «Ислам» тернәкләндерү үзәге ачарга җыеналар.* Татарстан яшьләре. *Сугыш чыга калса, Русия армиясенә гарипләр, алкашлар һәм наркоманнар да алыначак, дигән хәбәрләргә «АиФ» гәзите аңлатма биргән.* Мәдәни җомга

НАРКОМА́НИЯ *и. гр. мед. к.* **наркоманлык** (*2 мәгъ.*). *Танышымның улы наркоманиядән җәфалана.* Татарстан яшьләре. *Наркоманиягә каршы көрәшне яшьләр арасында даими алып барырга кирәк.* Татарстан яшьләре. *Наркоманиядән соңгы елларда гына да меңләгән яшьләребез кырылды.* Татарстан яшьләре

НАРКОМАНЛЫК *и.* 1) Наркоман булу

2) Гел наркотиклар кулланырга теләк уята һәм организмның функцияләрен боза торган авыру, чир. *Без инде республика, ил буенча сукбай балалар, рәшәткә артына керүчеләр, наркоманлык афәтенә юлыкканнар санын әйткәндә, колакны торгызырлык статистика килеп чыгар иде.* Мәгърифәт. *Шәһәргә күченгән яшь татар гаиләсе 1–2 бала үстереп, аларны безнең чорга хас эчкечелек, наркоманлык, рухи азу кебек афәтләрдән саклый алмый башлый.* Безнең юл

НАРКОМАТ *и. рус тар.* Халык комиссариаты

НАРКОПРИТОН *и. рус* Наркоманнар җыела торган урын. *Россиядә наркопритон оештыручыларга һәм аларны сыендыручыларга карата киләчәктә катгый чаралар күреләчәк.* Мәдәни җомга

НАРКО́ТИК *и. гр.* **1.** 1) *мед.* Көчле тәэсирле, үсемлекләрдән яки синтетик юл белән ясала торган, вакытлыча йоклата, төрле авыртуларны вакытлыча баса торган исерткеч дарулар төркеме (мәс., *морфий, хлороформ, эфир, әфьюн* һ.б.)

2) *сөйл.* Наркоманнар куллана һәм һәрвакыт куллануга ияләштерә торган

матдәләр (мәс., *нәшә, әфьюн, марихуана* һ.б.). *Наркотиклар куллана башлады Равил.* Х.Мөдәррисова. *Наркотик ише тыелган товарлар белән сәүдә итү дә – миллион туплауда төп чыганакларның берсе.* С.Сөләйманова. *Әлеге исемсез наркотикны студентлар синтез ысулы белән ясаган.* Татарстан яшьләре. *Ләкин онытмыйк: озак вакытлар наркотик кулланганнарга сәламәтлекләрен тулысынча кире кайтару мөмкин эш түгел.* Татарстан яшьләре

2. *с. мәгъ.* 1) Наркотик булган; составыннан наркотиклар алына торган. *Наркотик үләннәр*

2) Наркотикларга мөнәсәбәтле; наркотиклар тәэсире белән барлыкка килгән. *Бу егетләр наркотик матдә ясауда һәм аны куллануда гаепләнеп, җаваплылыкка тартылдылар.* Мәгърифәт. *Наркотик матдәләр ирләр белән хатын-кызларның генетик кодына, аларның организмындагы үзенчәлекләргә бәйле булу сәбәпле, ир-атларга һәм хатын-кызларга төрле дәрәҗәдә зарарлы тәэсир итә.* Мәгариф

НАРКӨМЕШ *и. фар. иск.* 1) Атларны һәм дөяләрне корчаңгыдан дәвалый торган агулы матдә; сүләмә

2) Мышаяк

НАРО́ДНИК *и. рус тар.* Народниклык тарафдары. *Рус народниклары шикелле безнең татар «халыкчы»сы да бу авыл халкының гамәләгә әйләнүе белә тагы бер мөшкел мәсьәләгә барып терәлә.* Г.Газиз

НАРО́ДНИКЛЫК *и. тар.* XIX гасырның икенче яртысында Россиядә: крестьяннар демократиясе идеяләре һәм Россиянең социализмга крестьяннар җәмгыяте аркылы күчүе өчен көрәш алып барган ижтимагый-сәяси хәрәкәт. *Аңла шуны: народниклык һәм социалистик идеяләр белән саташулар синең белән миңа һич килешә торган эш түгел. --- Ә чынлыкта ул нәрсәләр, ягъни народниклык, социализм турындагы мәсьәләләр шактый катлаулы бит.* М.Галәү. *Мине тагын шул рәнҗәттә: синең ата-бабаң ягында урнашып калырга теләвеңне ул, елмаеп, «народниклык» дип атады.* М.Мәһдиев

НА́РТА *и. эвенк* Төньякта болан яки этләр җигеп йөрү өчен махсус ясалган озынча тар чана. *Тауларны төшкәндә, егет, нартаңны тота төш, ул сиңа чана түгел, аның тәртәләре юк бит.* И.Хуҗин. *Бер-ике елдан нарталар җайладылар, эт үрчеттеләр.* Я.Зәнкиев. *Ишек төбенә пар болан җиккән нарта килеп туктады.* Казан утлары

НАРЫНҖ *и. фар. бот.* Цитруслар ыругыннан бер агач һәм шул агачның ашарга яраклы саргылт кызыл кабыклы әчкелт җимеше; әче әфлисун, померанец. *Нарынҗ мае. Нарынҗ чәчәге*

НАРЫНҖИ *и. фар. иск.* Саргылт кызыл, әфлисун төсле, кишер сары

НАРЯД *и. рус* 1) Нинди дә булса эшне үтәр өчен, язмача яки телдән бирелгән боерык, күрсәтмә. *Инде көн саен бригадирларга кырдан кар баскан салам кибәннәрен ташырга наряд тоттыра башлыйлар.* Ә.Еники. *Мин бүген наряд алырга тагын соңга калдым.* Г.Бәширов. *[Секретарь] председательнең юлына аркылы төшеп, наряд бирүгә борынын тыкмасын.* М.Мәһдиев

2) Эшнең төре, күләме күрсәтелгән, эш хакы түләү өчен нигез булып хезмәт итә торган документ. *Анда әзер мехларны сортларга аералар, кләймә суга лар, сорты-сорты белән бәйләп, ящикларга салып, алдан килгән наряд буенча төрле шәһәрләргә озаталар.* Ә.Еники

3) *хәрби* Хәрбиләр үти торган нинди дә булса эш, йомыш; кизү тору. *Лагерьда командалык иткән старшина-сержантлар аларны, эшкә нарядлар биреп, тиз бастылар.* З.Зәйнуллин. *«Ожмах!» диләр иде андагы нарядта булган солдатлар.* Ф.Баттал

4) *хәрби* Нинди дә булса эшне башкаручы хәрби хезмәткәрләр төркеме яки подразделениесе

НАРЯДЧЫ *и.* Эшне оештыручы, кешеләрне эшкә билгеләүче. *Нарядчылар күп, эшләүчеләр генә азаеп бара.* Казан утлары

НАС *и. к.* **насвай**

НАСАРА *и. гар. кит. к.* **нәсара**. *Без насара диюче бер җәмәгатьне мөселманнарга дусрак – күңелләре белән якынрак табарсың, алар арасында галимнәр, габитләр булганы өчен, әлбәттә, алар Коръән сүзләрен ишеткәндә һич тәкәбберләнмәсләр.* Ногмани

НАСАРИ *и. гар. к.* **нәсари**. *Әлбәттә, миңа башта насари диненнән аерылуы кыен булды.* Идел

НАСБАЙ *и. к.* **насвай**. *[Көтүче казакъ егете] тагын бер рәт насбай салып алганнан соң йокларга ятты.* М.Гафури. *Менә шул табасында ул чыршы ылысын һәм үзе генә белгән тагын ниндидер үләннәрне тәмәке белән бергә бутап көйдерә дә, шуннан насбай сыман кара яшькелт бер нәрсә килеп чыга.* Ә.Еники. *--- Фатих хәлфә борынына яшькелт вак насбай салды, рәттән ике тапкыр бик каты төчкерде ---.* Г.Ахунов

НАСБАЙЧЫ *и. к.* **насвайчы**. *Тәмәкече килсә – төкерер, насбайчы килсә – төчкерер.* Мәкаль

НАСВАЙ *и.* Тел астына сала торган тәмәке (гадәттә Урта Азия төбәкләрендә кулланыла)

НАСВАЙЧЫ *и.* 1) Насвай кулланучы. *Менә шундый «тәмле ризык»ны тел астына «яшереп» кәефләнүдән нурсыз, тонык күзләрен һавадагы әллә нинди ноктага юнәлдергән насвайчыларны күргәнем бар.* Заман сулышы

2) Насвай сатучы

НАСОС *и. рус* Сыеклык һәм газларны суырту, кудыру өчен кулланыла торган җайланма; суыргыч. *--- күрше авылдан күренгән төтенне күзәтәләр, шуннан ук кычкырып: «Фәлән авыл яна, тизрәк насос куелган арба җигегез!» – дип хәбәр салалар.* М.Мәһдиев. *Тәндәге авыру пожарын Автомат насос кебек Басарга тырыша бу йөрәк ---.* Х.Туфан. *Двигательләрдә диафрагмалы яки пешкәкле ярдәмче насослар кулланыла.* Тракторлар һәм автомобильләр

НАСОСЛЫ *с.* Насосы булган, насос белән тәэмин ителгән. *Ләкин бу ике башлы таяк булып чыкты: хәзер насослы йортларга су килә, ә калганнарга (күбесенчә пенсионерлар) – юк.* Татарстан яшьләре

НАСТРОЕ́НИЕ *и. рус сөйл.* 1) Кәеф, хәзерге моменттагы рухи халәт. *Кыскасы, мин сөйгән ярым белән урамда йөргәндә дә, хәтта аны*

кочагыма алып сөйгәндә дә, настроениегә карап дигәндәй, шигъри юлларның төрлесеннән әз-әзләп кенә аның нәни колакларына әйткәли торган идем. Ә.Еники. *Бүген көне буе настроение булмады, эч пошты.* Казан утлары

2) Кемгә яки нәрсәгә дә булса мөнәсәбәт, гомуми караш. *Җәмәгатьчелек настроениесе*

3) Кешенең фикере, уй-фикернең юнәлеше; омтылыш, теләк. *Күңел ачарга настроение булмау*

НАСТУ́РЦИЯ *и. лат. бот.* Кызгылт сары төстәге эре чәчәк ата торган декоратив үләнчел үсемлек; капуцин, латин чәчәге. *Мәктәп укучылары да, кибеткә килүчеләр дә куш йодрык зурлык ак, алсу, зәңгәр бөдрә астралардан, чагу төстәге үрмә гөлләрдән, куе сары бәрхетчә һәм настурцияләрдән күзләрен ала алмый.* Кызыл таң

НАСЫЙП *и. гар.* **1.** 1) Язмыш, күрәчәк, тәкъдир. *Гомереңдә хатын чырае күрмә, насыйбың салкын түшәк булсын!* А.Гыйләҗев. *Кешегә насыйбы килми калмый, имеш.* Ф.Яхин // *дини* Аллаһ Тәгалә язган өлеш. *Ходай насыйп итмәгәч, безгә бергә яшәргә язмаган.* Г.Тукай

2) Пар, кәләш яки кияү. *Иртә исләремдә, кич төшемдә – насыйпмы әллә югыйсә.* Г.Тукай. *Әй балам, үз насыйбыңны табып, парлы гомер кичерсәң иде.* Казан утлары. *Әй җаным, син минем насыйбымдыр инде.* Казан утлары

3) Мөмкинлек, җай чыгу, туры килү. *Насыйп чыкса, күрешербез*

2. *хәб. сүз функ.* Язган булу, мөмкин булу. *Әйттеләр: Син юкка ашкынма, Насыйпсың бары үз тиңеңә.* М.Вәлиев

3. *с. функ.* Язган, мөмкин булган, өлешенә төшкән. *Насыйп яр*

◊ **Насыйп әйләсен** Теләк сүзе буларак кулланыла: Аллаһы Тәгалә язсын, туры килсен, тормышка ашсын. – *Һай хуҗа абзый, гафу, исемеңне белмим, әмма дә чын кеше булгансың икән! Мәңгелек җәннәтләр насыйп әйләсен үзеңә! – дип, хак күңелдән дога укып, «Әлхәм»не кушып җибәрдем.* Р.Яхин. **Насыйп кылсын** *к.* **насыйп әйләсен**. **Насыйп чыгу** Дин буенча Аллаһы Тәгалә язган әйбернең кулыңа керүе яки кем белән дә булса тормышыңны бәйләү турында. *Насыйбым чыкса, өйләнермен. Юк икән, аһ орудан мәгънә юк.* Казан утлары

НАСЫ́ЙП БУЛУ *ф.* Туры килү, нәрсәгә дә булса ирешү, нәрсәне дә булса тормышка ашыру. *Ярый әле насыйп булган Елау Башны салып еллар иңенә, Насыйп булган көлү бәхет тоеп, Йолдыз яралганда күңелдә.* Зөлфәт. *Тавыкларга һичбер вакытта да болытларга җитү насыйп булмыйдыр!* Г.Тукай. *--- машина төзелешен дә, аны идарәләү алымнарын да бик ныклап өйрәнгән идем. Әмма «права» дип атала торган таныклык алу насыйп булмады.* Идел

◊ **Насыйп булса** Язган булса, Ходай язса, Алла боерса; боерган булса (теләк теләгәндә, нәрсә дә булса өмет иткәндә яки нәрсә дә булса эшләргә җыенганда, планлаштырганда әйтелә). *Насыйп булса икән менә шушындый хан булу.* Г.Тукай. *Насыйп булса икән миңа кояш булу.* Г.Тукай. *Насыйп булса, синең белән очрашырбыз әле без.* Казан утлары

НАСЫ́ЙП ИТҮ *ф. к.* **насыйп булу**. *--- авыл кешеләрен тәмле ризык белән сыйларга күнеккән Хәйриягә үз улының туена аш-су әзерләргә насыйп итмәде.* М.Хуҗин. *Үзен күрергә насыйп итмәсә дә, хатыны Илзия, кызы Мәрьямне күрдек.* Татарстан яшьләре

◊ **Насыйп итсә** *к.* **насыйп булса**. **Насыйп итсен** *к.* **насыйп әйләсен**. *Тыныч картлык насыйп итсен Ходаем.* Г.Тукай. *Читтә яшәп, ялгыз картаерга Беркемгә дә насыйп итмәсен.* Р.Байтимеров

НАТР *и. гр. хим.* Натрий окисенең гидраты. *Бу вакыт кремний дигән металлоид (металл булмаган матдә) зәһәр натр белән реакциягә керә.* Күзгә күренми торган матдәләр турында хикәяләр

НА́ТРИЙ *и. гр. хим.* Ак төстәге актив, йомшак, җиңел селтеле металл. *Мәсәлән, Җирдә күп очрый торган водород, углерод, кислород, азот, натрий ... һәм башка элементлар бүтән йолдызларда да очрый.* А.Фәткуллин

НАТУ́РА *и. лат. махс.* 1) Рәсемнәр, картиналар ясау, кинога төшерү, скульптур әйберләр ясау, әсәр язу һ.б. өчен табигый үрнәк. *Натурадан карап ясау*

2) Холык-фигыль, табигать, характер. *Аның натурасы шундый: ул алдамыйча түзә алмый.* Татарстан яшьләре

НАТУ́РАЛАТА *рәв.* Акча урынына товар, азык-төлек һ.б.ш. белән (түләү, алу һ.б.). *Эш хакы да күп вакыт натуралата, ягъни икмәк, печән белән түләнә, чөнки бирергә акча юк.* Татарстан яшьләре. *Чиркәүләрдәге чаңнарны салдырып 300 туп коела, Пётр бай кенәзләр һәм монастырьларның кайсыннан ялварып, кайсыннан талап диярлек акча җыя, крестьяннардан да элеккеге натуралата салымнар урынына хәзер инде акчалата салым түләү тәртибе кертелә.* Тарих

НАТУРАЛИЗМ *и. фр.* 1) XIX гасырның 60 нчы елларында барлыкка килгән, тормышның бөтен ваклыгын, нечкәлеген, бигрәк тә тискәре ягын күрсәтеп, иҗтимагый үсеш законнары белән кызыксынмаган әдәбият һәм сәнгать агымы. *Мин натурализмга каршы. Тормыш кисәкләрен шул көенчә фотографияләп дөньяга ташлау юлы белән төзелгән әсәрләрнең кыйммәте юк.* Г.Ибраһимов

2) Хәзерге цивилизация казанышларыннан баш тартып, табигатькә якын тереклек итү идеяләрен таратучы хәрәкәт

НАТУРАЛИСТ *и. лат.* 1) Табигатьне, табигать мохитен өйрәнү белән шөгыльләнүче кеше. *1800 нче елда немец натуралисты Ветцель эт, мәче һәм тавыкларның телләрен өйрәнеп махсус «Сүзлек» төзегән.* А.Гыйләҗев. *Мәктәптә «Яшь натуралистлар» түгәрәге оешты.* Мәгърифәт

2) Натурализм тарафдары

НАТУРАЛИ́СТИК *с.* 1) Натурализмга мөнәсәбәтле, натурализмга караган

2) Көнкүреш ваклыкларына игътибар итүдән гыйбарәт; чынбарлыкны тасвирлау, күрсәтү, сурәтләүдә гомумиләштерү булмаган. *Шуңа күрә ул ире Атлины коточкыч җәзага тарта: үзенең Атлидан туган ике баласын үтереп, итләрен кыздырып иренә*

ашата (бик борынгыдан килгән натуралистик гомумэпик мотив!). Ф.Урманче. *Һәм, киресенчә, мужик белән торуның авырлыгын, ямьсезлеген натуралистик детальләр ярдәмендә күрсәтә.* И.Нуруллин. *Рәссам һәм режиссёр, хәтта кайбер натуралистик детальләр кулланудан да курыкмыйча, революциягә кадәрге татар авылының шигъри образын иҗат итәләр, аның табигатенең гүзәллеген, шул гүзәллек фонындагы социаль тигезсезлекне күрсәтәләр.* Г.Арсланов

НАТУРАЛЬ *с. лат.* 1) Чын, табигый; *киресе:* **ясалма**. *Апабыз натураль ризыклар, натураль тукымадан тегелгән киемнәр генә кияргә ярата*. Казан утлары

2) Акча кулланмыйча башкарыла торган; шундый ысулга нигезләнгән. *Ул чорда, табигый, хуҗалык натураль булган, һәм бөтен авыл халкы диярлек эрләү, туку, тире эшкәртү белән шөгыльләнгән.* Р.Фәхретдин. *Натураль салым*

3) Чынбарлыкка туры килә торган. *Әллә кайда түгел, Чехов базарында, помидор-кишер алып торган җирендә һәм, әйтергә кирәк, бик тә натураль хәлендә очратты [ул аны].* Ф.Хөсни

4) *мат.* Уңай бөтен саннар күплегенә карый торган. *Гадәти фонда ун чыгынты: алар бер, ике, өч, дүрт чыгынтылы төркемнәр булып урнашканнар. Ягъни натураль саннар рәтенең үзе инде.* А.Тимергалин

5) Натурализм (*1 мәгъ.*) агымына караган, шуңа нигезләнгән. *Рус әдәбияты тарихында «физиологик очерклар» жанры «натураль мәктәп» – реализм юнәлеше җиңүенә өлеш керткән кебек, Ш.Мөхәммәдевнең шул жанрга тартым әсәрләре безнең әдәбиятта шундый ук роль уйный.* М.Гайнуллин, М.Гайнетдинов

НАТУРФИЛО́СОФ *и. нем. махс.* Натурфилософия тарафдары, шул тәгълиматны яклаучы галим

НАТУРФИЛОСО́ФИЯ *и. нем.* Табигатьне аңлатканда, тәҗрибә юлы белән алынган мәгълүматларга түгел, фәкать коры фикерләүгә нигезләнгән шартларга таянып карый торган метафизик тәгълимат

НАТУ́РЩИК *и. рус* Рәссам сурәт яки скульптур сын ясаганда, аның каршында күчергеч, модель булып торучы кеше. *Ә менә үзенең миңа натурщик булып утырырга бер генә дә буш вакыты булмады.* Х.Якупов. *Ләкин моның өчен натурщигы юк иде. Дөресрәге, натурщигы да табылыр иде, әмма түләр өчен акчаны каян аласың...* Ф.Әhлиуллина. *Шулай итеп, туганчы ук, әти картиналары өчен натурщик булганмын.* Ватаным Татарстан

НАТУ́РЩИЦА *и. рус* Хатын-кыз натурщик

НАТЮРМОРТ *и. фр.* Төрле җансыз предметлар җыелмасын эре планда сурәтләгән картина яки рәсем. *Кайбер рәссамнарыңның натюрморты бер якта торсын!..* Ю.Әхмәтҗанов. *Мин кабат аның янында, уннарча портретлар, натюрмортлар, плакатлар белән тулы мастерскойда идем.* К.Тимбикова. *Рәссам миңа үзе ясаган натюрмортны бүләк итте.* Идел

НАУ́ШНИК *и. рус сөйл.* Радио, телефон, компьютер һ.б.ш. аппаратларда тыңлау өчен, колакка киелә яки куела торган махсус җайланма; колакчын. *Ә залда утыручы депутатлар тәрҗемәне наушник – колак микрофоныннан тыңлыйлар.* Б.Рәхимова. *Депутатларның күбесе наушник белән тыңлый, чөнки татар телен белү дәрәҗәләре шактый түбән.* Татарстан яшьләре. *Зөбәржәт һәрвакыт, наушникларын киеп, музыка тыңлап утыра.* Мәгърифәт

НАФИЛӘ *рәв. гар. иск.* Бушка, кирәксезгә, әрәмгә. *Нафилә, бушка давылланма, тынычлап йокласын!* З.Бәшири. *Тырышма нафилә җиргә вакты гажәзеңне икърарга.* Г.Тукай

НАФТАЛИН *и. гр.* Ташкүмер сумаласыннан куу юлы белән ясалып, йон тукымаларны һәм мехларны көядән саклау өчен, шулай ук техникада һәм медицинада кулланыла торган көчле исле ак кристалл матдә. *Шуның өстенә исләр: ат исе, камыт күне, яңа чапкан печән, нафталин исе сеңгән күлмәк, ефәк шәл исе*. М.Мәһдиев. *Бу җирдәге һава көне-төне кызган май, сабын исләре белән аралаш нафталин исенә тынчып тора.* К.Тинчурин. --- *Хатыннар, нафталин исе җилли торсын дип, сандыктан күлмәкләрен алып бакчага чыгарып элделәр.* Шәһри Казан

НАФТАЛИНЛА́У *ф.* Көядән саклау өчен, йон яки башка төр тукымаларга нафталин сибү яисә кую. *Шуның өстенә исләр: ат исе, камыт күне, яңа чапкан печән, кыш буе сандыкта нафталинлап яткырылган күлмәк, ефәк шәл исе --- – болар барысы, музыка, ис, чуар төсләр кешене табигый халәтеннән күпмегәдер аерып ала, һәм кеше исәрләнә...* М.Мәһдиев

Нафталинлап кую Озакка нафталинлау. *Радиогыздан нафталин исе килә, диючеләргә: «Кадерле, яхшы әйберне генә нафталинлап куялар, иң мөһиме, фәхешханә, сыраханә исе килмәсен», – дияр идем.* Безнең гәҗит

Нафталинлап тору Әледән-әле нафталинлау

НАФТАЛИНЛЫ *с.* 1) Составында нафталин булган, нафталин кушылган. *Хәер, ападан бер ишетеп калган идем: базарда, имеш, чи тиреләрдән селкеп җыйган нафталинлы тоз саталар, дип...* Ә.Еники

2) *күч.* Күптән үткән, искергән. *Иң аянычы: татар матбагачыларының күпчелегендә бүген сәяси аң бик түбән, алар һаман толерантлык әкиятенә ышанып, катнаш никахларга мәдхия җырлап, авыл карчыкларының «сугыш кына булмасын» дигән сүзләренә таянып, нафталинлы иске заманнарны сагынып, туган авыл, җыр-бию темалары арасында «иҗат» итәләр.* Ф.Бәйрәмова // Искергән, актуальлеген югалткан (идеяләр, фикерләр һ.б.ш.). *[Моратов үзенең] Әллә кайчангы нафталинлы фикерләре белән халыкны ялыктыра, йөдәтә, интектерә, тинтерәтә, башын катыра.* А.Гыйләҗев

НАХАК *с.* **1.** 1) Сәбәпсез, нигезсез, дәлилләнмәгән. *Тик күңел нахак сүзгә бик нык рәнҗегән иде ---.* М.Мәһдиев. *Әгәр бит аның шиге нахак булса, мин үземне нишләтмәс идем.* Ә.Еники. *Нахак сүз – арттан атылган агулы ук.* М.Мирза. *Кеше гомере өзелү, --- гаиләсенә гомерлек итеп ябышкан нахак бәла аркасында кичерелгән*

кимсетү-җәберләүләр өчен җавабын кем бирер? Сөембикә

2) Законсыз, законга каршы; хокуксыз. *Чакырып алдылар да нахак юллар белән җыйган сәрмаясын дәүләткә кайтарып бирүен таләп иттеләр ---.* Р.Мирхәйдәров

2. *рәв. мәгъ.* Хаксызга, урынсызга. *Зарлану булып чыкмасын дип, ул [Шәйхи абзый] Нургалинең нахак әйткән сүзләрен --- мөмкин кадәр йомшартып сөйләргә тырышты ---.* Ә.Еники. *Нигә ул нахак сөйләп үз башына гөнаһ ала икән?* Сөембикә

3. *хәб. сүз* Дөрес түгел, ялган, яла. *[Җанбай:] Нахак, олуг хан, ышанма дошман сүзенә.* Ю.Сафиуллин. *– Нахак! – дидем мин. – Тулай торакка барып сорашыгыз.* Р.Зәйдулла

НАХАККА *рәв. к.* **нахак 2.** *Димәк, ул миңа үзе дә ышанмаган гаепне таккан, мине нахакка политик җинаятьче ясап, эштән кудырган ---.* Ә.Еники. *Нахакка рәнҗетелгән күңел җылыныр урын эзли, кемнән дә булса яклау өмет итә.* Казан утлары. *Русия чиновниклары үзләрен хәерче һәм нахакка рәнҗетелгән дип саныйлар*. Татарстан яшьләре

НАХАКЛЫК *и.* Хаксызлык, гаделсезлек. *Нахаклык безне чолгап алачак, бик нык көчәеп китәчәк һәм безнең үзебезгә китереп сугачак бит!* Х.Камалов

НАХАКТАН *рәв. к.* **нахак 2.** *Сезнең ялган язуыгыз аркасында Муса әфәнде нахактан ун еллык каторга хезмәтенә җибәреләчәк.* З.Бигиев

НАХАЛ *и. рус сөйл.* Чиктән тыш оятсыз, әхлакый кагыйдәләргә буйсынмаучы кеше. *Нәкъ җәядәй тартыла да Киерелә дә кашларың, Һәр нахалны телсез итә Бер сүз әйтеп ташлавың.* Х.Туфан. *Чөнки ул үзе – колхоз осталарыннан, капка гына түгел, өй салдырып кергән кеше, һәм теге нахалның, шуны белеп, аның йөзенә мыскыллы көлеп каравы бар.* Ә.Еники. *[Хәмзәт:] Әнә теге нахал кебек танышырга кыюлыгым җитмәде.* Э.Яһудин

НАХАЛЛАНУ *ф.* Нахалга әйләнү; нахалларча кылану, нахаллык күрсәтү. *Кичә, нахалланып, Гайнан шушы тракторчы табынган фәрештәгә үрелергә йөргән булып чыкты.* Г.Бәширов

Нахаллана бару Торган саен нахаллану

Нахаллана башлау Нахалланырга тотыну яки соңгы арада нахаллану

Нахаллана төшү Тагын да ныграк нахаллану

НАХАЛЛЫК *и.* Нахал булу, оятсызлык, әрсезлек. *Бу нахаллыкка хәйран калып, Гайнан сискәнеп китте.* Г.Бәширов. *Анда [Эннда] хәйләкәрлек, теләсә нинди хәлдән чыга белү, намуссызлык һәм нахаллык кебек сыйфатлар юк иде шул.* Ватаным Татарстан

НАХИМОВЧЫ *и.* Нахимов хәрби диңгез училищесында укучы, тәрбияләнүче. *Ул, дежурный рапортын тыңлап бетергәч, түргә узды да, безгә карап, ачык яңыраган тавышы белән: – Исәнмесез, нахимовчы иптәшләр! – диде.* С.Сабиров

НАХИЯ *и. гар. иск.* Административ бүленештә: өлкә, төбәк, район, өяз, провинция. *Олуг мәрхәмәт вә мәртәбә иясе, газаматлу падишаһу әгъзам Икенче Николай бине Александр хәзрәтләренә вә аның ханәданы гаиләләренә безки садыйк тәбәгаләрегез – Казан вилаяте, Казан нахиясе, Чәүкәле булысы, Мәүла Колый карьясе мөселманнарыннан.* М.Галәү. *Казан нахиясендә аның сөфрәсеннән нигъмәт ашамаган адәмнәр бик аздыр.* К.Насыйри. *Шуны бөтен ифраде милләт аңлаганга, бөтен шәһәрләремез, авылларымыз, вилаятьләремез, нахияләремез оешмалар белән тулды.* Г.Исхакый

НАЦИЗМ *и. нем. сәяси* 1933–1945 елларда Германиядә хакимлек итүнең тоталитар террор ысулларын һәм бөтен милләтләрне «сыйфат» буенча аеруны рәсми рәвештә пропагандалаган режим идеологиясе. *Германиянең «Хәтер, җаваплылык һәм киләчәк» фонды нацизм корбаннарына ярдәм итү өчен ике миллион евродан артык акча бүлеп биргән.* Ватаным Татарстан

НАЦИОНАЛИЗА́ЦИЯ *и. фр. сәяси* Җир, сәнәгать, транспорт, элемтә, банклар һ.б.ш.ның хосусый милектән дәүләт милкенә күчерелүе. *Шул ук Америкада, кризис башында ук, аптырагач, олы-олы банкларны дәүләт карамагына алдылар, ягъни национализация ясадылар.* Ватаным Татарстан

НАЦИОНАЛИЗА́ЦИЯЛӘҮ *ф.* Национализация үткәрү, национализация ясау

НАЦИСТ *и. нем. сәяси* Нацизм тарафдары; нацист партиясе әгъзасы. *Бу кан өчен нацист кына түгел, Черчиллең дә мәсьүл, Көнбатыш!* Х.Туфан. *Нацистларга таяну һәм ышану зур хата булганлыгы да аңлашыла, чөнки хыянәтчел режим үзе дә башка халык вәкилләрендә вакытлыча юлдаш, бары тик үз планнарын үтәүдә инструмент кына күргән.* И.Гыйләҗев. *Русиядә күпләр әле дә, совет гаскәрләре Польшага нацистлар һөҗүменә каршы торуда ярдәм итү өчен кергән дигән, совет чорында уйлап чыгарылган аңлатма белән яши.* Безнең гәҗит

НАЧА́ЛЬНИК *и. рус* Эш башында торучы кеше; башлык; рәсми җитәкче. *Шул ук вакытта мине цех начальнигының ярдәмчесе итеп тә билгеләделәр ---.* Ә.Еники. *Бу – эшелон начальнигы, карчыга борынлы, юан гәүдәле, ак чәчле, алтын йолдыз таккан полковник иде.* М.Мәһдиев. *Тик әле мин белә-белгәннән бирле юл төзүче оешмада начальниклар гына алышына!* А.Гыйләҗев

НАЧА́ЛЬНИКЛЫК *и.* Начальник булу, начальник вазифасы

НАЧА́ЛЬСТВО *и. сөйл.* 1) *җый.* Җитәкчелек, башлыклар, идарә итүчеләр, эш башында торучылар. *Начальство белән ызгыша башласаң, ашарсың әпәйне, тот!..* А.Гыйләҗев. *Начальство директорлыкка димләде. Риза булдым.* Л.-Х.Таналин. *[Эльфа:] Безнең бар икәнлекне начальство да күптән онытkан инде.* И.Зәйниев

2) Җитәкче, хуҗа, начальник. *Ул чакларда бит авылга начальство гел читтән килә иде дә авыл халкын дер калтыратып тора иде.* Безнең гәҗит

НАЧАР *с. фар.* **1.** 1) Уңай сыйфатлары яки үзлекләре булмаган; түбән сыйфатлы; түбән бәя бирелә торган; *киресе:* **яхшы**. *Яхшы атка бер камчы, начар атка мең камчы.* Мәкаль. *Биш министр да бүленеп, барысы да*

начар киемнәр киенеп, үзләре белән унар солдат алып таралдылар, ди, илнең төрле ягына. А.Алиш. *Начар эшгамәлләр үзеңә начарлык булып кайта.* Ф.Яруллин

2) Куелган таләпләргә туры килми торган, актуаль түгел, оста башкарылмаган, уңышлы чыкмаган (әдәбият, сәнгать әсәрләре тур.). *Мин синең хатыңны начар спектакльдә сөйләнгән монологның язма варианты дияр идем.* Г.Минский. *Олпат актёрларыбызның иң югары дәрәҗәдәге рольләре бар – начар фильмда уйнаулары белән тәбриклисе килми.* С.Гаффарова. *Әдәби сәләте «Сагыну» дигән, мәхәббәт турындагы начар хикәядән ары уза алмаган карт бу кешенең икейөзлелеге аны тәмам чыгырдан чыгара язды.* М.Шаһимәрдәнов

3) Күңелсез, әйбәт булмаган, көтелмәгән. – *Төгәл, без тикшердек инде, хата юк, бу – татар теле, – дип пышылдады ярдәмче, шефына шундый начар яңалык әйткәненә үзе дә шат түгел иде инде.* В.Исламетдин. *Ни өчендер бездә бер начар фикер йөри: әгәр кеше бай икән яки югары постта утыра икән, димәк, аның бәгыре – таш, күңелендә – бозлар...* Ф.Яруллин

4) Һава, ел фасыллары турында сөйләгәндә: бик салкын я бик эссе, рәхәт булмаган, күңелгә ятышсыз. *Ул, шәһәргә аяк баскан көннән башлап эштән башын күтәрмәгәнгә, Алла биргән көнне тук уздыру, урынсыз калу кайгыларыннан бушанмаганга, начар һава, яхшы һава дигән тәклифләрне тикшерергә дә аның вакыты юк иде.* К.Тинчурин

5) Үз эшендә тәжрибәсе аз булган, оста булмаган, булдыксыз, квалификациясез (нинди дә булса эшне башкаручы тур.). *Начар останың коралы үтми.* Мәкаль. *Мин начар көтүче түгел идем, таралган көтүне минут эчендә туплый идем...* А.Алиш. *Фатирга керүгә үк, елаудан шешенеп беткән әнисе, ике нәни йодрыгын күтәреп, начар актрисалар кебек иреннәрен җәеп, Гайнанның өстенә килде.* Р.Зәйдулла

6) Түбән әхлаклы, уңай сыйфатлары аз булган. *Начар кеше кеше кулы белән елан тотарга ярата.* Мәкаль. *Фәсих яманат чыгарган егет түгел, мәгәр Сәфәр дә начар кеше түгел иде.* М.Шаһимәрдәнов

7) Үз-үзен тотышы, зәвыгы һ.б. ягыннан тупас, оятсыз, вульгар. *Начар холык өчен акыллыны юләр диләр.* Мәкаль. *Бүтән малайларга иярмә. Начар малайлар да бар бит, кара аны...* Г.Гыйльманов. *Мәрхүмнең үз хатыны белән начар мөгамәләдә яшәүләрен яхшы белгән участок милиционеры тикшерүчеләргә дөрес юнәлеш бирә.* Шәһри Казан

8) Авыр йогынты ясый торган; күңелсез тәэсир итә торган (кәеф, төш һ.б.). *Кич белән кәеф начар иде, һәм әрнетеп эч пошты.* Ә.Еники. *Җәй айлары турында начар кәеф белән язып булмый.* Т.Миңнуллин. *[Камил] Начар төш күрде, саташып бетте, бастырылды...* Г.Гыйльманов

9) Әдәпсез, әшәке; кемнедер гаепли торган (сүзләр тур.). --- *Мин Сөләймановтан сезнең хакта андый начар сүз ишеткәнем юк.* Ә.Еники. *Күсәкләр, юан баулар күтәргән кешеләр, Сәлимнең әтисен начар сүзләр белән тирги-тирги, кайдадыр йөгерәләр иде.* Г.Гобәй. *Ниндидер начар сүз белән зәһәр итеп әйтмәкче иде дә Сабир, сабыр канатларын төзәтеп тынычланды.* Ф.Яхин // Уңай булмаган, тискәре (җавап, сүз һ.б.). *Җитте! Менә нәрсә, Марат, син беркайчан да кешегә сөйгәне турында начар сүз әйтмә, аңладыңмы? Хәтта дөрес сүз булса да.* Р.Шәрипов

10) Авыруның хәле өметсез булу турында. *Шул ук көнне доктор да: «Авыруның хәле начар, озак торса, өч көн торыр, алайга да бармас, сез инде аны ташламагыз, дуслары җыелышып, бер тәртип илә һәрвакыт берегез янында булыгыз», – диде.* Ш.Әхмәров

11) Сан, күләм ягыннан җитәрлек булмаган; аз, түбән. *Начар хезмәт хакы*

12) *махс.* Түбән (билге, бәяләмә). *Безнең тирән ышануыбызча, укытучы бары тик укучыны тотар, батырыр, икеле (ул заманнарда – «начар») билгесе куяр өчен генә дөньяга килгән иде.* М.Мәһдиев. *Мәктәптән начар билгеләр алып кайткаңы өчен, ун яшьлек кыз баланы ата-анасы ач тотып, кыйнап торган.* Ватаным Татарстан

2. *рәв. мәгъ.* Тиешенчә, кирәгенчә, таләп ителгәнчә түгел. *Юкса начар семья аркасында тормышлар ватыла, кешеләр биртелә, гарип тойгылар җәмәгать эшенә начар тәэсир итә.* Г.Кутуй. *Чирмешәндә беренче секретарь булып начар эшләмәде бит [Мостафин].* Ә.Еники. *[Илдус:] Кара, чыннан да, начар күрәм түгелме соң?* К.Ситдыйков

3. *хәб. мәгъ.* 1) Яхшы түгел; күңелсез; күңелгә ятышсыз; тискәре сыйфатлы. *[Зөләйха:] Бүген хәлем бигрәк начар. Бөтен йирдән тәнем бердән, --- сөякләрем аерым-аерым сызлый.* Г.Исхакый. *Билгеле, аның кәефе начар, күңеле төшенке, ул ярлы, кирәкле әйберен алалмый, йортын төзәтәлми.* М.Миначев. *Әхәт Гаффарның хикәясендә тел һич тә начар түгел, бу язучы хикәяли белә, бөтен язучылар да «аның каравы» дип хата язганда, Гаффар дөрес итеп «аның каруы» дип яза.* Татарстан яшьләре

2) Аз, җитәрлек түгел. *Үләннең үсүе начар. Тамак ягы начар*

4. *и. мәгъ.* Яхшы, уңай булмаган, тискәре, күңелсез нәрсә, хәл, вакыйга һ.б.ш. *Начарны күрмәгән яхшының кадерен белмәс.* Мәкаль

◊ **Начар юлга басу** *к.* **начар юлдан китү**. – *Минем кече малай начар юлга басты бит, – дип, янында торган егетнең җиңеннән тотты [Шәяхмәт].* М.Мәһдиев. **Начар юлдан китү** Закон, әхлак һ.б.ш. кагыйдәләрне бозу, бозыклыкка бирелү. *Ипташләре дә җыен башкисәр булды. Күпме әйтеп, үгетләп карадым – колакка алмады. Шуларга иярәп начар юлга кереп китте.* Ватаным Татарстан

НАЧАРАЙТУ *ф. к.* **начарлату**. *Халыкның хуҗалык эшчәнлеге илнең табигатен бик нык үзгәртә, аның торышын начарайта.* Материклар һәм океаннар географиясе

НАЧАРАЮ *ф. сөйл. к.* **начарлану**. – *Әлхәмделилләһи раббилгаләмин, әлегә сәламәтбез, тик менә эшләребез генә бераз начарайды, – дип җавап*

бирде Нигъмәтулла әфәнде. З.Бигиев. *Дөрестән дә, соңгы елда Явыз Иванның сәламәтлеге күзгә күренеп начарайды, ул шешенә башлады, һәм тәненнән яман ис таралды.* Ф.Бәйрәмова

Начарая бару Торган саен начараю. *55 яшькә җиткәндә, организмдагы су тоткарлануы һаман начарая бара.* Шәһри Казан

Начарая башлау Соңгы арада начараю ягына үзгәрү. *Башта хәлләре стабиль булды, ләкин палаталарга озатуга начарая башлады.* В.Исламетдин. *Вәсимәнең күзләре көннән-көн начарая башлагач кына, табибларга мөрәҗәгать итеп карарга уйлады ул.* Безнең гәҗит

Начарая төшү Тагын бераз начараю. *Окоп казырга баргач эләктереп калган салкын тиюдән ул берничек тә арына алмады: аның хәле көннән-көн начарая төште.* Ш.Алпар

Начараеп китү Соңгы вакытта начар якка үзгәрү. *Октябрь бәйрәменнән соң көннәр начараеп киткән иде.* Б.Ислам

НАЧАРЛАНДЫРУ *ф. йөкл. юн. к.* **начарлану**. *Җәй көннәрдә һәртөрле черек нәрсәләрдән чыккан зарарлы газлар һаваны бигрәк тә начарландырадыр.* Г.Камал

НАЧАРЛАНУ *ф.* 1) Начар хәлгә килү, бозылу. *Теш начарланса, иң беренче чиратта ашказаны, аннан йөрәк эштән чыгуы мөмкин.* М.Мәһдиев. *Һава шартлары начарланды*

2) Нәрсәнең дә булса элеккегә, баштагыга караганда начар якка үзгәрүе. *Фронтта хәлләр яхшырды, эш җиңүгә таба китте, әмма... тылның хәле бик начарланды.* Ә.Еники. *Тавышымнан да танымыйсыңмы? Карале, хәтер начарланган икән синең.* Т.Миңнуллин

3) Сәламәтлеге бик авыр хәлгә җитү, үлем хәленә җитү (авыру тур.). *Февраль ахырына таба Тукайның саулыгы тәмам начарлана.* И.Нуруллин. *Бөтен тәнен бетчә басты, коса башлады, сәламәтлеге бөтенләй начарланды.* Безнең гәҗит

Начарлана бару Торган саен начарлану. *Аякның хәле көннән-көн начарлана барды, бара-тора агачка әйләнде.* К.Тинчурин. *Башта торып китәрмен дигән өмет белән яттым, күршеләрнең, калага улларына хәбәр итик, дигән сүзләрен дә кире какты, әмма ләкин хәле аның [Акъәбинең] отыры начарлана барды.* Ә.Еники. *Әнә Фәхрениса абызтай никадәр сөлек салдырды, никадәр мөгез утыртты, үзе һаман начарлана гына барды.* Г.Исхакый

Начарлана башлау Начарлану ягына үзгәрү. *Күзенең берсе күрми, хәзер икенчесе дә начарлана башлаган.* Безнең гәҗит

Начарлана төшү Тагын да ныграк начарлану. *Төнлә белән олуг кенәзнең хәле тагы да начарлана төште, тәне кызышты, сулышы кайнарланды.* М.Хәбибуллин

Начарланып китү Алдагыга, элеккегә караганда начар якка үзгәрә башлау. *– Хәкимулланың хәле начарланып китте, авызыннан ак күбек килә, – диде Шәяхмәт, читкә карап кына.* М.Мәһдиев. *Соңгы көннәрдә карчыкның хәле бөтенләй начарланып китте.* Ә.Еники. *[Маннапов:] Йөрәк дигәннән... Ул синең бик начарланып киткән икән, ә?* С.Поварисов

НАЧАРЛАТУ *ф.* 1) Нәрсәне дә булса элеккегә караганда киметү. *Барлыкка килгән көчле төтен күз күремен начарлатты.* Ватаным Татарстан

2) Начар якка үзгәртү, бозу, рәтен җибәрү (мәс., мөнәсәбәтләрне)

НАЧАРЛЫК *и.* 1) Начар, яман, яраксыз булу. *Башкалар эш шартларының начарлыгыннан зарланганда да, Тәнзилә катнашмады.* А.Гыйләҗев

2) Кемгә дә булса эшләнгән явызлык, әшәкелек, усаллык, яманлык. *Аларның [күп кенә кешеләрнең] күзләре күрми, колаклары хакны ишетүдән саңгырау, йөрәкләре һәртөрле начарлыктан тыйлмый.* Р.Юныс. *Күршеләрнең дә шаяртуларында начарлык юк кебек* ---. Ф.Яхин

3) Әдәпсезлек, яман гамәл, хупланмый торган эш. *[Садыйк:] Мин, алтмышка кадәр яшем җитеп, андый начарлык эшләгәнем юк иде, хәзер чәчем агаргач кына, ул эшкә тотынмам.* Г.Исхакый. *Китабыны пычратмас, начарлыкны яратмас, Ялкау балалар кебек уйнап-көлеп тик ятмас.* М.Гафури

4) Сыйфатсызлык, хасияте тиешле дәрәҗәдә булмаган. *Чүпрәнең начарлыгы аркасында, камыр кабармады*

НАЧА́Р-НОЧАР *с.* **1.** Эшкә яраксыз, түбән сыйфатлы, хөрти. *Начар-ночар, иске-москы киемнәр*

2. *рәв. мәгъ.* Тиешенчә түгел, җиңелчә генә. *Су юл алган инде, өстән агып ята, начар-ночар гына буылган бугай ул.* А.Гыйләҗев

НАШАТЫР *и. сөйл. к.* **нашатырь**. *Ошбу кеше азот селтесе, хлор терекөмеше, нашатыр табу серләрен өйрәтте.* М.Хәбибуллин

НАШАТЫРЬ *и. гар. хим.* 1) Техникада һәм медицинада кулланыла торган ак кристаллик матдә, аммоний хлориды, нишатыр. *Ни әйтсә – зәһәр чыга, ни сөйләсә – ярага нашатырь сибә [Васфикамал].* М.Мәһдиев. *Алтын ясау турында хыялланган Апанаевның берәр җирдә нашатырь кебек матдәсе дә бардыр, бәлки...* А.Тимергалин

2) *сөйл. к.* **нашатырь спирты**. *Көек исеннән парламентлар, илләр исергән – кояшка да берсе таш атыр... Тизрәк, тизрәк, тизрәк – нашатырь!* Р.Харис

◊ **Нашатырь (нишатыр) кыстыргандай (кебек, шикелле)** 1) Тик-тормас, тынгысыз, кыбырсык кешегә карата; 2) Бик тиз, бик кызу. *Тамбурда үтәли туңган бичаралар, посттан бушау белән, нашатырь кыстыргандай, тизрәк вагонга чабалар.* Ә.Еники. *Баксаң, «җен эшергән» Хәсән тыкрыгы чатында Кәлимулласының каршына Габдрахманның сары тракторы арт ягына нашатырь кыстырган Хуҗа Насретдин ишәге шикелле килеп чыккан да өстенә саз сулары чәчрәтеп узган.* М.Шаһимәрдәнов

НАШАТЫРЬЛЫ *с.* Составында нашатырь булган; нашатырь кушылган. *Нашатырьлы салфеткалар*

НАШАТЫ́РЬ СПИРТЫ *и. хим.* Суда эретелгән аммиак, төссез, үтә күренмәле, зәһәр исле очучан сыеклык. *Зөһрәгә шкафтан нашатырь спирты алырга куштым.* Н.Фәттах. *Төрткәләп уятып карадылар, башына дәү чүмеч тутырып сап-салкын су сиптеләр, куш йодрык сыярлык борын тишекләренә нашатырь спирты бөркеделәр, җилпуч*

хәтле колакларын удылар – уянмады Кирам. А.Гыйләҗев. *Һушына килгәндә, олырак яшьтәгесе пистолетын биленә тыккан һәм аның борын төбендә нашатырь спиртына манчыган мамык тотып тора иде.* Р.Мирхәйдәров

НАШӘРГЫЙ *с. фар.-гар.* Шәригать кушмаган, шәригать кагыйдәләренә туры килми торган. *Ягъкубтан кала, бу нашәргый хәмел (балага узу) хакында беркем дә белми иде.* З.Бигиев

НАШИ́ВКА *и. рус хәрби* Хәрби званиеләрне аеру өчен якага, җиңгә һ.б.ш.га тегеп куела торган махсус билге // Яраланган яки билгеләнгән срок тан тыш хезмәт иткән өчен, хәрбиләргә бирелә торган өстенлек билгесе. *Арада фронтта алган җәрәхәтләре өчен бирелгән сары-кызыл нашивкалылары да күп иде.* З.Зәйнуллин

НАШИР *и. гар.* Матбугат әсәрләрен бастырып чыгаручы, нәшрият хуҗасы. *Наширләр бер-бер артлы Тукай китапларының яңа басмаларын чыгара башлыйлар.* И.Нуруллин. *--- революциягә кадәр бу бакчаның хуҗасы берәр тиенлек кенә китаплар бастырып сатучы бер нашир булган, ди.* Ә.Еники. *XIX йөзнең ахыры – XX йөзнең башында кыйсса китапларын бастырып тарату бигрәк тә борадәран Кәримовлар, Хөсәенов варислары, китапчы Кәтиевләр, Кадыйров, Минһаҗетдинов, Бәкеров кебек наширләр активлык күрсәтәләр.* Ф.Урманче

НАШИРЛЕК *и.* Нашир шөгыле; бастырып чыгару эшчәнлеге. *--- К.Мотыйгыйның язучылык һәм наширлек эшчәнлегенә күчик.* И.Нуруллин. *Тәрҗемә һәм, гомумән, наширлек эше табыш китерми.* И.Ибраһимов

НАШМАК *и.* 1) *иск. этн.* Туй көнне кәләшнең күзләрен генә ачык калдырып маңгаен һәм йөзен каплый торган киң шарф яки шәл формасындагы баш киеме

2) *к.* **яшмак**

НАЯ́ДА *и. гр.* 1) Борынгы грек мифологиясендә: елга, инеш, чишмә нимфасы

2) *бот.* Субуярчалар семьялыгыннан берьеллык, тиз сынучан каты сабаклы су үсемлеге

НАЯН *с.* **1.** 1) Шаян, шук, уенчак. *Нургали бик наян булды.* М.Мәһдиев. *Пәрдә артында уйнап торган наян нурлар бүлмәгә кереп тулды.* А.Гыйләҗев. *Күп кошларны җылы якка куып, Урам буйлап наян көз йөри.* Г.Рәхим

2) Шаянлыкны белдергән. *Алма агачыннан ерак тәгәрәми, тәгәрәсә дә шул агачныкы булып кала, күп очракта бу наян сүз үтә рас килә, ул – атага, кыз анага охшый.* А.Гыйләҗев

3) Хәйләкәр, мут

2. *рәв. мәгъ.* Шаяртып; кыланыбрак. *Эльмира наян елмаеп әтисенең галстугын төзәтеп куйды.* Р.Зәйдулла

3. *и. мәгъ.* Шаян, шук кеше. *Хәзрәткә шулар булышканнар булса кирәк, наяннар.* К.Тинчурин. – *Синең белешләрең арасында да наяннар бар икән! – диде Луиза, яратмыйча.* А.Гыйләҗев

НАЯНЛАНУ *ф.* 1) Шаяру, шуклану. *Ник, бала бит инде ул, аның нәкъ уйный-наянлана торган вакыты лабаса.* Безнең гәҗит

2) *сөйл.* Хәйләләү, мутлану, кылану

Наянлана бару Торган саен наянлану

Наянлана башлау Наянланырга тотыну. *Авылга кайтып җитәрәк, ул тагын наянлана башлады.* Г.Бәширов

Наянлана төшү Тагын бераз наянлану

НАЯНЛЫК *и.* 1) Шуклык, уенчаклык, шаянлык. *Монда Дилбәрнең йөгәнсез наянлыгы, уйламыйча әйтелә торган беркатлы шаян сүзләре көчсез иде.* К.Тимбикова. *Алсу класста үзенең наянлыгы белән аерылып тора.* Мәгърифәт

2) Кыланчыклык, хәйләкәрлек, хәйлә, мутлык. *Шуннан ул [Тычкан] бер наянлык уйлап: – Болай талаштан берни дә чыкмас, без елның килгәнен карап-күзәтеп торыйк, кайсыбыз алдан күрсә, шул ел башы булыр! – дип чыйкылдый.* Әкият. *Рәшитне уятып маташмадылар, шуңа күрә әлегә аның бу соңгы наянлыгы кайчан һәм ничек эшләнгәнлеге ачыкланмый калды.* А.Тимергалин

НӘ *а. терк. иск. к.* **ни**. *Нә дәүләт калды да нә шан, Һич калмады шаннан нишан!* Г.Тукай. *Нә кибет, нә магазин, нә кәрвансарай, нә йорт, нә сарай калган.* Г.Исхакый. *Нә әдәбиятта, нә матбугатта татарны юри урыска каршы кую кебек тенденция булмады шикелле, һәрхәлдә, мин андый нәрсәне хәтерләмим.* Ә.Еники

НӘБАТ *и. гар. иск. кит.* Үсемлек. *Йиде йыл күкдән йагмур һич йагмади, һәм дәхи йирдән нәбат һич үнмәди.* Кол Гали. *Кыш көнендә үләнләр(е) йирдә черер, Яз булдисә, нәбат нигъмәт үсә торыр.* Мәүла Колый. *Башка орлыкларның корып, кибеп калуы дөньяга нәбат чыгармый.* Г.Ибраһимов

НӘБӘВИ *с. гар.* Нәби белән бәйле, пәйгамбәргә караган. *Нәбәви хәдис. Нәбәви нәсыйхәтләр*

НӘБИ *и. гар. дини* Илче, пәйгамбәр. *Миңа кол анда бар җәнвар: арыслан, хәтта капланнар Нәбиләргә тимәслекнең мөкатдәс гаһден алганнар.* Г.Тукай. *Биек агач дигәнең – Ягъкуб нәби, Унбер углы аталарына хезмәт итә имди.* Кол Гали. *Гыйлемлек күктин иңде галимләрә, Илче, нәби, әүлия тәмамләрә.* Мәүла Колый

НӘБИЗ *и. гар.* Җиләк-җимештән, гадәттә хөрмә яки йөземнән кайнатып ясала торган буза кебек җиңелчә исерткеч эчемлек. *Аннары икешәр тустаган тутырып нәбиз күтәрделәр.* А.Тимергалин

НӘБИРӘ *и. фар. иск.* Онык. *Шумшурный Гали дигән вә һәм Шайтан Шәриф дигән адәмнәр шул Гайса бабаның нәбирәләреннән икән.* К.Насыйри. *Диде буны гасырда остазы көлл Габдессәлам Хәзрәти ахун нәбирәседин бер голләм.* Ә.Каргалый

НӘВЕМ *и. гар. иск.* Йокы

◊ **Нәвем базарына китү** Йокыга талу, йоклап китү. – *Әй, төн сакчысы, мин киттем! – Кая? – Нәвем базарына.* Г.Бәширов. *Коньяк, нуһаять, аларның икесен дә изрәтә, алар, татлы йокының көмеш канатларында тирбәлеп, нәвем базарына китәләр...* А.Гыйләҗев

НӘГӘР *и. монг.* 1) *тар. к.* **нөгәр**. *Менә син бозык нәгәргә иярт малайны!* Н.Исәнбәт

2) *этн.* Туйда кияүне саклап, озатып баручы кеше, кияү егете, кияүнәгәр

НӘГЪЛӘТ *и. гар. сөйл. к.* **ләгънәт**. *– Бер нәгъләт суккыры коены томалап куйган әле менә, ни ачуы булгандыр, – диде [Мәүлиха апа].* А.Гыйләҗев. *– Бу нәгъләткә ышанырга ярамый, иптәш: исеңдәдер, теге Марфа Петровна ничек кабартмалар белән сыйлый иде үзен, – диде [солдат].* Ш.Камал. *[Асрау кыз (күзләрен зурайтып):] Нәгъләт яуган икән! Тагы кемне әрәм итә икән?* Г.Исхакый

НӘГЪМӘ *и. гар. иск. кит.* Көй, җыр, моң. *Падишаһ карады, күрде: ул сахра бер башыннан икенче башына ча бөтенләй баг булып, эчендә сулар агып, төрле җимешләр пешеп, төрле чәчәкләр атып, тутый, вә былбыл, вә сандугачлар нәгъмәләр тезеп сайрап торыр.* К.Насыйри. *Ачыл, гөлзаре әхрар! Нәгъмә саз улсын бәлабилең.* Г.Тукай. *Моңсу урман, киң яшел болынларда Меңләп нәгъмә белән сайрар былбыллар.* Ш.Камал

НӘГЪРӘ *и. гар. иск. кит.* Ачы, каты тавыш; акырыш-бакырыш. *Нәгърәләр белән Диюне уята; Һич уянмый йокысыннан, ул ята.* Г.Тукай. *Иртә намазы укылып, кояш чыга башлаган вакытта көньяк-көнчыгыш тарафыннан да, төньяк-көнбатыштан да сугыш бырғыларының нәгърәсе кызыл шәфәкъ балкышына асылынып калды.* Ф.Яхин. *Сезнең тормышыгыз нәгърәдән гыйбарәт.* М.Хуҗин

◊ **Нәгърә ору** 1) Акырыну; акыру, бакыру; кычкыру. *Иске низам котырып, җан бирә нәгърә орып, шашадыр торып-торып каргалганын белдея.* М.Гали. *Хуҗа хатын сәхнәдән торып залга нәгърәләр орды.* М.Мәһдиев. *Ермакның бу сүзеннән соң казаклар, рухланып китеп, нәгърәләр орырга тотындылар.* Ф.Бәйрәмова; 2) Бик каты ачулану, җикеренү. *Ул [М.Әгъләмов] биегәеп китә, мәһабәт каһарман кыяфәтенә керә, тавышы бөреннән чыга башлый, ул гайрәт белән гаделсезлеккә каршы нәгърә ора.* Р.Батулла

НӘГЪРӘЛЕ *с.* Киеренке; гаугалы. *Көзгедән карамасам да белеп торам – сезнең нәгърәле яшәешегезне күргәч, күзләрем яшьсезләнә минем!* М.Хуҗин. *[Лирик геройның] авазы нәгърәле гөрелте булып яңгырый.* Х.Госман

НӘГЫЗЬ *с. гар. иск.* Яхшы, гүзәл, әйбәт, шәп. *--- әмма дә мал инде, ефәктән бер дә генә ким түгел, үзе нәгызь, үзе арзан, моны бөркәнеп чыксаң, сөйдергеч догаларың да кирәкми!* Ә.Фәйзи. *[Зариф:] Сөйләп бирдем ич инде: кыз – мировой, үзе шундый нәгызь!..* Ә.Еники. *Әйткән идем бит, нәгызь хатын, дип!* А.Гыйләҗев

НӘГЫШЬ *и. гар. иск.* Табут; табутта яткан мәет. *Тик мин үлгәчтен, карагыз, типмәсеннәр нәгъшемә.* Г.Тукай

НӘДЕРБАШ *и. бот.* Иренчәчәкләр семьялыгыннан күпьеллык, сирәгрәк берьеллык үләнчел үсемлекләр яки ярымкуаклар төре; күркә борыны, күзлут чәчәге

НӘДИМ *и. гар. иск.* Табындаш, мәҗлестәш, әңгәмәдәш. *Наданга нәдим булма.* Әйтем

НӘҖАСӘТ *и. гар.* Пычраклык, нәҗес, пычрак (әшәке) әйбер, шакшы нәрсә. *Фәкать акча җыю белән ләззәтләнмәк нәҗасәт вә үләксә белән ләззәтләнүче эт кебектер.* К.Насыйри. *Спиртның яна торганына да, ага торганына да нәҗасәт түгәргә фәрман бирелде.* М.Галәү. *--- романның төп герое Мотаһар --- үлгәндә, кулына пумала һәм чиста сулы чиләк тотып, Кремльнең сәяси нәҗасәттән, татардан көлү нәҗасәтеннән, Иван Грозный басып алгач, каннан пычранган диварларын юдыра башлый.* Р.Вәлиев

НӘҖАТ *и. гар. иск. кит.* Котылу, исән калу, авырлыктан чыгу. *Бер бетү чокрында мин, юктыр нәҗат ---.* Г.Тукай. *Файдасыз түгелмәктә улан каннарыны идарәи мөстәбидә золымыннан нәҗат юлында түксеннәр.* Г.Исхакый. *Нәҗат биреп бер галәмнән башка бер галәмгә, ул Атлатып тиз-тиз адымнар чыгарып куяр кеби.* З.Бәшири

НӘҖАШИ *и. гар.* Эфиопия императоры титулы һәм шул титулга ия кеше; негус. *Тәңре рәсуле Мөхәммәд пәйгамбәргә Нәҗашидин сәлам.* М.әл-Болгари. *Фарсы патшасына – кисра, Рум патшаларына – кайсар, Хәбәш патшаларына – нәҗаши дип әйтелгән кебек, Мисыр патшаларыннан һәрбер патшага фиргавен дип әйтелә.* Ш.Хәмиди

НӘҖӘГАЙ *и. фар. диал. к.* **аҗаган**. *Урманлы үрләр өстендә Нәҗәгай уйный төннәрдә.* Г.Афзал. *Кичләрен утлы камчысы белән нәҗәгай уйный.* З.Хәким. *XIX гасырда нәҗәгай шикеллерәк Европа өстендә уйнаган коммуна очкыны, XX йөзнең башларында Рәсәй империясенә сикереп, Октябрь түнтәрелешенең гигант ялкынын кабызды.* Т.Шәрәфетдинов

НӘҖЕС *с. гар.* **1.** 1) Шакшы, пычрак. *Алдына китереп капкачын ачып куйгач, кул тиермәстән әүвәл, ике тычкан түбәләшеп югарыдан савытның эченә төштеләр, тәгам нәҗес булды.* К.Насыйри. *Зәки мәхдүм кергән өйнең мәнзарасы менә шул рәвештә иде: ишек төбендә һәртөрле чүпләр вә нәҗес нәрсәләр өелгән, бер сулы таз ---.* Г.Ибраһимов. *Колчак гаскәрен нәҗес пумала белән Япон диңгезенә себереп төшергәч, Солтанга анда эш калмаган.* Г.Ахунов

2) *күч.* Җирәнү, чиркану хисләре уята торган. *Язучыларның киңәйтелгән гомуми җыелышы, искиткеч бердәм рәвештә, бу мәкаләдәге нәҗес ялаларны кире каккан иде.* Х.Туфан. *Карышсаң, җаена тормасаң, нәҗес эшләр кылсаң, утлы кисәү белән тукмап, әллә кая упкынга да китереп сала икән ул.* С.Поварисов

2. *и. мәгъ.* 1) Пычрак, шакшы, әшәке нәрсә. *Саф алтынны нәҗескә буяу илән Нәҗес китәр, алтынның заты китмәс!* Акмулла. *Тышкы яктан «слав» сыман да ул [Ярослав Смеляков], Җан, күрәсең, нәҗес тәпәне: Ваклый, мана кара фикерләргә Шигырь дигән алтын тәңкәне.* Х.Туфан

2) Ачулану, тиргәү сүзе. *[Бикморза:] Кит, нәҗес, якын киләсе булма!* Ф.Бурнаш. *[Закир:] Сез нәҗесләрнең шомлыгы аркасында мондый бәхетсезлекләргә очрадым.* Г.Камал

НӘҖЕСЛӘНДЕРҮ *ф. к.* **нәҗеслә**. *Халык үзе яшәгән җирне нәҗеслә ндерергә тәмам күнекте, моны гадәти бер эшкә саный башлады.* Безнең гәҗит

НӘҖЕСЛӘНҮ *ф.* Шакшылану, пычрану

Нәҗесләнеп бетү Тәмам нәҗесләнү

Нәҗесләнеп тору Гел, һәрвакыт нәҗесләнү

НӘҖЕСЛӘ́Ү *ф.* Шакшылау, пычрату, нәҗес, эшкә яраксыз итү. *Көчкә хәзерләп китерделәр [шулпаны], тычкан төшеп нәҗесләде – ашап булмады.* К.Насыйри. *Буржуазия кибет ачып, --- идеология дөньясын да үзенең пычрак фикерләре белән нәҗесләмәк була.* Г.Ибраһимов. *Үз оясын пычратмады кошлар, Үз дөньясын бәндә нәҗесләде.* Ә.Баян

Нәҗесләп тору Гел, һәрдаим нәҗесләү

Нәҗесләп бетерү Тәмам нәҗесләү

НӘҖЕСЛЕК *и.* Нәҗес, кабахәтлек. *Унар-унбишәр елга Себер җибәрелгәннәрне, төрмәгә дыңгычлап тутырылганнарны, чыннан да, «халык дошманы», «хаин», «ил хыянәтчесе», «нәҗеслек кылучы» дип атады ул.* С.Поварисов

НӘЗАКӘТ *и. фар.* 1) Нәфислек, матурлык (тышкы кыяфәттә, хәрәкәтләрдә). *Газизем, булма такмакчы; Матур гөлләргә бул былбыл, Нәзакәт багына сакчы!* Дәрдемәнд. *Мин үзем әдәп, Үзем нәзакәт! Дөнья үземә Итсен итагать!* Ш.Бабич. *--- аның һәр хәрәкәтендә инде шактый тәэҗрибәле ханымнарда гына була торган нәзакәт сизелеп тора иде...* Р.Зәйдулла

2) Әдәплелек, тыйнаклык, нечкәлек (мөгамәләдә һ.б.ш.да). *Хатын-кызны бизәктән дә бигрәк әдәп-нәзакәт бизи.* Мәкаль

◊ **Нәзакәт сату** Шаблон комплиментлар әйтеп тәкәллефләнү, төчеләнү. *Ярар, безнең алда бик нәзакәт сатма. Без байбәтчәләр түгел.* И.Богданов

НӘЗАКӘТЛӘНҮ *ф.* Бик әдәпле, нәзакәтле булып китү яки шундый булып кылану

Нәзакәтләнә бару Торган саен тагын да нәзакәтләнү

Нәзакәтләнеп китү Соңгы вакытта нәзакәтләнү; чамадан тыш нәзакәтләнү. *Моннан соң үтә нәзакәтләнеп киткән Әсфан, Гөлчирәнең кулыннан помидор, кыяр тутырылган сеткасын да алып, базарга ни өчен килгәнлеген исеннән үк чыгарган хәлдә, ханымны озата китте.* Ф.Хөсни

Нәзакәтләнеп тору Нәзакәтле булып күренергә тырышу, шундый булып кылану

Нәзакәтләнеп утыру *к. сөйл.* **нәзакәтләнеп тору**

НӘЗАКӘТЛЕ *с.* **1.** 1) Нәфис, матур; грацияле. *Хәрәкәтләре шулкадәр дә нәзакәтле иде аның...* Р.Зәйдулла // Нечкә. *Сәйдәшевнең нечкә лирик вә нәзакәтле музыкасы ямь өстенә ямь биреп, спектакльне тагын да тулыландыра, зур уңыштан канатланган композитор яңа көйләр, ариялар яза.* М.Сәлимҗанов. *Шәһәр баласы татар теленең нәзакәтле матурлыгын, аһәңен Тукай аша тоя.* Сөембикә

2) Әдәпле, игътибарлы, кечелекле. *Матур кыз зур ыспайлык белән урындыкка утыргач, егеткә ихтирам күрсәтеп нәзакәтле кыяфәт белән: – Вакытсыз борчуым өчен гафу итегез!.. – диде.* К.Тинчурин. *Аннары бу яңа кунак үз-үзен тотышы белән дә тегеләрдән нык кына аерыла: мөгамәләсе һәрвакытта нәзакәтле, ә ашау-эчүгә килгәндә шактый талымлы.* Ә.Еники. *Эльмира – шәһәр кызы, нәзакәтле, сөйләшүе дә интеллектуаль, кинодан кайтканда, ул күбрәк Камю, Кафка, Зигмунд Фрейд турында сөйли.* Р.Зәйдулла

2. *рәв. мәгъ.* Әдәпле итеп, әдәп белән, тыйнак кына. *Салих әфәнде үзен бик әдәпле һәм нәзакәтле тотты ич.* Ә.Еники. *Ул [Бикчәнтәев] хәзер аеруча җыйнак, пөхтә, хәтта нәзакәтле елмаеп кына сөйли һәм «сез» дип кенә эндәшә.* И.Салахов

НӘЗАКӘТЛЕК *и. ялг. к.* **нәзакәтлелек**. *«Дәһшәтле» комиссарның мондый нәзакәтлек күрсәтүе миңа, билгеле, бик сәер тоелды.* Ә.Еники. *Таймасның нәүмиз күңелен, сагышхәсрәтләрен, сагынуларын ул яхшы аңлый, ә табигый нәзакәтлеге аңа, саксыз сүз ычкындырып, малайны рәнҗетмәскә куша иде.* А.Тимергалин

НӘЗАКӘТЛЕЛЕК *и.* 1) Нәзакәтле, әдәпле булу үзлеге. *Хәтта ул [Гөлчирә] кунагын кисәтүне яки, артык нәзакәтлелек күрсәтеп, нинди дә булса ясалма төчелекләр әйтеп торуны да кирәк тапмады.* Ф.Хөсни. *Дөрес, үзара мөнәсәбәтләрдә берничә нәзакәтлелек юк, ләкин бер-берләрен яхшы аңлыйлар булса кирәк – «алыш-бирәш», гомумән, гаугасыз, тыныч-шома гына бара.* Ә.Еники. *Башта әле ул [очрашу] нәзакәтлелек белән, әдәп кагыйдәләре чикләрендә бара.* М.Гайнетдинов

2) *к.* **нәзакәт** (*1 мәгъ.*). *Урбәт үзенә бер нәзакәтлелек белән йөзен ачыбрак куйды да иренә ике кулын суздыр.* М.Әмирханов. *«Сезне фәлән кеше фәлән дип әйттем», – дип, куштан хатыннарча авызын бишкә бөреп, тәмләп-тәмләп, сүз ләззәтен югалтмаска тырышкандай, үзенчә бер нәзакәтлелек белән сөйләргә керешә.* С.Поварисов

НӘЗАР *и. гар. кит.* 1) Караш, игътибар, илтифат, күз салу. *Әмма мөфәнкыятьле чыктымы-юкмы, ансы тәнкыйтьчеләр нәзарына калдырылды.* Г.Тукай. *Болгар киеменә аның нәзары ул кадәре түгел иде.* Г.Исхакый. *Әмма аңардан катгый нәзар: без, татар җәмәгатьчелеге, «татар мәсьәләсе»н, ниһаять, хәл итүгә, ягъни Татарстанга союздаш статусын алуга юнәлдерелгән хәрәкәтне, әлбәттә, дәвам иттерергә тиешбез.* Ә.Еники

2) Субъектив фикер, шәхси караш (гадәттә иялек аффиксы белән). *Кем белер, бәлки, карчыклар нәзарында егетләр илә кызларны күрештерү саваплы эш санала торгандыр.* Ф.Кәрими. *Нәзарымда син ялгышасың*

◊ **Нәзар ноктасы** Караш ноктасы, ноктаи назар, теге яки бу фактка билгеле позициядән карау. **Нәзарга алу** Игътибарга алу, исәпкә алу

НӘ́ЗАРАН *рәв. гар. иск.* Караганда, карап, ... күрә; ... белән чагыштырганда. *Бу мохтәсарлар куянның шулпасының шулпасы дигән кеби генә бит Коръәнгә нәзаран!* Г.Ибраһимов. *Газета хәбәрләренә нәзаран*

НӘЗАРӘТ *и. гар.* 1) *иск. кит.* Күзәтү, карау. *Ул өйдә булгач, безнең өстәге гадәттән тыш авыр булган нәзарәт тә йомшый төште.* М.Гафури

2) Идарә; министрлык. *Тугрысы, кырымлыларның шул әсаслары мәгариф нәзарәтендә материал булып, мәктәп-мәдрәсә хакында закон эшләнгәндә, мөселман фикеренең нәмунәсе булып торачактыр.* Г.Исхакый. *– Дахилия нәзарәтенә барыгыз, анда сезгә бөтенесен аңлатып бирерләр, – дип кырт кисте Сөләйман.* М.Галәү. *Дәүләттә диния нәзарәте башлыгы мөфти хәзрәтләре ханнан кала икенче зат санала икән, бу – табигый хәл.* М.Әмиров

НӘЗАРӘТЕНДӘ *бәйл. иск.* Карамагында. *Ул министрлар --- Думаның нәзарәтендә түгел итеп ясап куйганнар иде.* Г.Исхакый

НӘЗАРӘ́Т ИТҮ *ф. иск.* Күзәтү, карап тору. *Икенче тарафта түбәләре күккә кадәр күтәрелгән ташлы таулар --- үзләренең итәкләренә бина ителмеш авылларга һәм дачаларга --- нәзарәт итеп торалар.* Ф.Кәрими

НӘЗАРИ *с. гар. кит.* Теоретик. *Бу – мәсьәләнең нәзари ягы.* Г.Исхакый. *--- нәзари белемеңне гамәли яктан сынап карарга бөтен мөмкинлекләр бар.* С.Поварисов. *--- икенче яктан, әдәби-нәзари фикернең яшәү рәвеше, үсү үзенчәлекләре төсендә бәяләнергә тиеш.* Г.Сабиржанова

НӘЗАРИЯ *и. гар. иск. кит.* Теория, доктрина. *Монда коры фән иясе, ачы нәзарияләр белә баш вата торган бер галәмнән бигрәк, бу мәсьәләне тасвирны сизгер кальбле --- кешеләрнең халәте рухиясен үзенә төшереп алырга булдыра торган рухлы сәнгате нәфисә әһелләреннән көтә аламыз.* Г.Исхакый. *Ул [Сәлим], тар «милләтчелек» даирәсеннән чыгып, «инсаният» даирәсенә күчкән; милләтчелекне ташлап, инсаниятче булган; «милләтем... татарым...»ны ташлап, «ватаным – бөтен җир йөзе... милләтем – бөтен бәни бәшәр» нәзариясенә иман китергән иде.* Г.Ибраһимов

НӘЗАРИЯТ *и. гар. иск. кит. к.* **нәзария**. *Соңгы вакытларда докторлык һәм кандидатлык диссертацияләре яклаган яки якларга җыенган галимнәребез дә нәзариять һәм методология мәсьәләләрен өйрәнүгә һәм ачыклауга тиешле игътибар бирәләр.* А.Әхмәдуллин

НӘЗА́Р КЫЛУ *ф. иск.* Күз салу, карау; игътибар бирү. *Кыз шундай һәйбәтлек берлән торадыр, һичкемгә нәзар кылмас, һичкемдин хәрәҗ теләмәс иде.* Ә.Курмаши. *Шул кешеләр зәһәре берлән милләтемезнең күп кешеләре бөтен нәрсә хакында ялган уй берлән торып, дөнья вә ахирәткә үзләренә бертөрле нәзар кылып, хәтта үлеп тә китәләр иде.* Г.Исхакый

НӘЗАФӘТ *и. гар. иск. кит.* Чисталык, пакьлек, гигиена. *Кирәк мунча, кирәк пакьлек, нәзафәт.* Н.Исәнбәт. *Мәдрәсә пакь улсын, һәр мәкамдә нәзафәт, тәртип улсын.* К.Тинчурин

НӘЗАФӘТЛЕК *и. гар. иск. кит.* Чисталык, пакьлек, пөхтәлек

НӘЗБЕРЕК *с. фар.* 1) Аш-суны бик сайлаучан, талымчан, кылтамак. *Сыер – шундый нәзберек ул.* М.Мәһдиев. *Тыйнак кына тормышлы сәүдәгәр гаиләсендә үскән бу кыз (җитмәсә, ризыкка да бик нәзберек була, ипи дә ашамый), зур авырлыклар кичереп, татар кызлар мәктәбен тәмамлый.* Р.Әмирхан. *Мондагы ризык иң нәзберек гурманнарны да канәгатьләндерерлек иде, минемчә.* А.Тимергалин

2) Көйсез, назлы, игътибар таләп итә торган. *Уйлап карасак, адәм баласы да табигатьнең бик нәзберек, бик сизгер бер үсентесе лабаса!* М.Вәлиев. *Бәлки, дала белән урман зонасы арасында булганлыктандыр, мондагы табигать чиктән тыш нәзберек икән.* М.Юныс. *Гаиләдән дә нечкә, нәзберек ни бар икән тагын?!* Сөембикә

3) *күч.* Тигезлек белән генә эшләми, ватылгалап, эштән чыгып тора торган. *Әмма элемтә – иң көйсез, иң нәзберек система.* М.Мәһдиев. *Комбайн. Бик нәзберек машина бит.* М.Мәһдиев

НӘЗБЕРЕКЛӘНҮ *ф. сөйл.* 1) Аш-суны бик сайлаучан, талымчан булып китү. *Үзем куркам. Салкын тимәгәе. Әмма нәзберекләнеп эчәргә сабырым юк...* Безнең гәҗит

2) *күч.* Артык сайлануучан, таләпчән булу. *Чөнки аның [кешенең] таләпләре, яшәү кагыйдәләре шулай нечкәргән була, кеше нәзберекләнә, күңелен канәгатьләндерерлек кеше очрамый башлый.* А.Гыйләҗев

Нәзберекләнә бару Торган саен нәзберекkә әйләнү

Нәзберекләнә башлау *к.* **нәзберекләнеп китү**

Нәзберекләнеп китү Соңгы вакытта нәзберекләнү; артык нәзбереклек күрсәтү. *Зәйнәп Әмирхания ул заман күпчелек татар кызларының төшенә дә кермәгән төпле белемгә ия була. Һәм, әлбәттә, үзенә гомерлек яр сайлауда бик нәзберекләнеп китә.* Р.Әмирхан

Нәзберекләнеп тору Хәзерге моментта нәзберекләнү; гел нәзберек булу. *Кая җибәрсәләр, шунда бара, ни туры килсә, шуны ашый, берсен дә талымлап, нәзберекләнеп тормый иде [Гәрәй].* А.Гыйләҗев. *Башка чакта нәзберекләнеп торган авыл агайлары да «вакланмый»: ниндиен һәм күпмегә бирсәләр, шуңа риза.* Ватаным Татарстан

НӘЗБЕРЕКЛЕК *и.* Нәзберек булу үзлеге. *Ризык мәсьәләсендә һичкайчан нәзбереклек күрсәтмәгән, тәгамне талымламый торган шәкерткә еш кына «Кышкар салмасы» дигән сый белән канәгатьләнергә туры килгән.* Р.Әмирхан. *Атаклы Йосыф бәк кызы, борынгы аксөякләр нәселеннән, нәсел башы Алтын Урда ханнарына барып төртеләдер, ханбикәгә затлылык, гыйффәтлек, нәзбереклек, сөйкемлелек вә мөлаемлык хастыр.* М.Хәбибуллин

НӘЗЕГӘЙТҮ *ф. йөкл. юн. к.* **нәзегәю**. *[Тоннель] Рельс юлларын нәзегәйтеп-тарайтып йота сымак та, киресенчә, зур дөньяга мыек сымак тырпайтып җибәргән төсле.* С.Шәрипов

НӘЗЕГӘЮ *ф.* 1) Нечкәрү; юкару. *Кәүсәдән өскә күтәрелгән, ботаклар нәзегәйгән саен, кабык шомара бара, ачык кызгылт-көрән төскә керә.* Әтнә таңы. *Ләкин сугыш җиңә алмаса да, еллар чүктергән агайны: адымнары вак, колаклары ишетми, нәзегәйгән тән тиресе салкынга бөтенләй чыдамсыз.* Байрак

2) Ябыгу, чандырлану

Нәзегәеп калу Берәр вакыйгадан соң нәзегәю, нәзегәйгән хәлгә килү. *Энә күзеннән үткәндә капкорсаклар да нәзегәеп кала.* С.Поварисов. *--- пен-*

сионер абзый, кабинадан асылынган килеш, келәшчә саплары сыман нәзегәеп калган аяк чәлтерләрен үрсәләндереп ялвара. А.Хәлим

Нәзегәеп килү Күзгә күренеп, әкренләп нәзегәю. *Скрипканың булачак формасы, аның нәзегәеп килгән билләре, каз муены сыман озын муеннары, тырпаеп торган колаклары аның күз алдына килеп басалар.* Ә.Фәйзи

Нәзегәеп китү Соңгы арада нәзегәю

Нәзегәя төшү Тагын да бераз нәзегәю

НӘЗЕК *с. фар. к.* **нечкә**. *Салих, моннан да күчеп, нәзек тавыш белән сөйләмәкче булган иде дә, Хәят рөхсәт итмәгәч, --- баритонга күчте.* Ф.Әмирхан. *Ничә еллар агълагансың, Син – нәзек җанлы хатын!* С.Сүнчәләй. *Куелыкта чакта нәзек агачны да җил сындыра алмый.* А.Гыйләҗев. *Ябыграк йөзле, нәзек, озын муенлы бу кызның да теленә елан төкергән диярсең.* Э.Касыймов

◊ **Нәзек сыйрак** Физик яктан йомшак, нечкә озын ботлы кеше турында, салам сыйрак. *Килен нинди заттан булыр бит әле, килен!.. Саз тәкәрлеге кебек, бәләкәй генә болытка да чыелдап-чыелдап кычкыручы нәзек сыйрак эләксә нишләрсең?* А.Гыйләҗев. **Нәзек җиргә энә белән төртү** Болай да кыен хәлне белә торып тагын да кыенлаштыра төшү. *Табылмасын белеп, юри шулай нәзек җиргә энә белән төртә бит ул [Сибгатулла].* Н.Гыйматдинова

НӘЗЕКЛӘНҮ *ф. сөйл. к.* **нәзегәю**. *Яңагы тартылды егетнең, муены нәзекләнде, корсагы җыерылып эчкә керде.* А.Гыйләҗев

НӘЗЕКЛЕК *и. сөйл. к.* **нечкәлек**. *Нечкә оеклар, нечкә нәфис ак башмаклар аңар әллә никадәр нәзеклек, зифалык бирделәр.* Г.Исхакый

НӘЗЕР *и. гар. дини* Дини карашлардан чыгып, үз өстенә үзе алган эш, шартлы вәгъдә; адарыну. *Күптәнге нәзерен үтәп, әнисенә оренбур шәл, сеңлесе Тәнзиләгә күлмәклек ефәк җибәрде.* А.Гыйләҗев. *Кайткач бу нәзерен [Кәшфи] әти-әнисенә сөйләгән.* М.Мәһдиев. *Сугыштан исән-сау кайта алсам, барлык алып кайтканымны эчеп бетерәчәкмен, дигән нәзере булган икән аның.* З.Зәйнуллин

◊ **Нәзер әйтү** Берәр эш башкару алдыннан, ул эш уңышлы барып чыкса, кемгә дә булса берәр нәрсә бирергә яки берәр йөкләмә үтәргә үз күңелеңнән вәгъдә бирү; адарыну. *Кәшфи шунда җир һәм күкнең ут белән тоташканын күреп, ниндидер мизгелдә куркудан аңын югалтып алган һәм нәзер әйтеп ташлаган.* М.Мәһдиев. *--- авырлык белән исәпләшеп тормадылар, егетле кунакларны бәлеш салып, мунча ягып ашка алдылар; нәзер әйтеп, корбан бәйрәме саен тояклы мал суйдылар, хәер-сәдакаларны кызганмадылар.* А.Гыйләҗев. *Сөяксез Гайшә кушаматы алган карчык бертуктаусыз укынуын белде, Алладан ярдәм сорады, нәзерләр әйтте, ятимнәргә, гарип-горабага хәер-садакалар өләшергә сүзләр бирде.* З.Зәйнуллин. **Нәзер бирү** Нәзер әйтеп, ул уңышлы барып чыгу очрагында, үзең вәгъдә иткән нәрсәне бирү (яки өстеңә алган йөкләмәне үтәү). *Падишаһ Хак юлына даим корбаннар вә нәзерләр бирер иде.* К.Насыйри. **Нәзер тоту** Нәзер әйтеп тә, вәгъдәсен үтәмәү сәбәпле, кешегә нинди дә булса бәла килү. *Ләкин Шәмсениса түти, диндар кеше, каты торды, [сыерның] бозавы кала, бер-ике елга түзәрбез, баланы нәзере тотарга мөмкин, диде.* М.Мәһдиев. *Әллә юкса нәзер тоту дигәннәре бар нәрсәме?* Г.Сабитов

НӘЗЕ́Р ИТҮ *ф. к.* **нәзер әйтү**. *Бабайның карчыгы изге карчык икән, күңеле сизгән дә иртә белән мулланы чакырырга, бабай исән-сау кайтса, корбан чалырга нәзер иткән.* Әкият

НӘЗЕР-НИЯЗ *җыл. и. иск. кит.* һәртөрле нәзер. *[Мулла:] Тизрәк тәүбә-истигъфар итегез, --- нәзер-ниязларыгыз, садакаларыгыз булса, тизрәк биреп калыгыз.* Г.Камал

НӘЗЫМ *и. гар. к.* **назым** (*1 мәгъ.*). *Бу нәзымның кадрен ары ахмак белмәс, Гакыллылар тыңлар, аңлар, белер имди.* Кол Гали

НӘЙ *и. фар. муз. к.* **най**

НӘЙЗӘ *и. фар.* Сөңге. *Бүген кичә бер төш күрдем, Нәйзә белән чәнчеде.* Дастан

НӘКӘС *с. фар. сөйл.* Ялкау, иренчәк, сөрхәнтәй. *И ахмак, нәкәс, синең дә кем икәнең мәгълүм булды.* К.Насыйри. *[Газиз] ике сүзнең берендә шәкертләрне, абзасы төсле, «нәкәсләр» дип сүгүме дисең, һәммә этлекне эшли.* Ш.Камал

НӘКӘСЛЕК *и.* 1) Нәкәс булу; ялкаулык

2) Кешелексезлек. *Алар бит – тоткыннарның арт ягына тибәргә, ачуы кабарса, мылтык түтәсе белән дөмбәсләргә, әллә нинди нәкәслекләр эшләргә ярата торган кемсәләр.* С.Поварисов

НӘКЪ *кис. гар.* 1) Вакытны, урынны, күләмне, микъдарны белдергән сүзләрдән алда килеп, «төп-төгәл» дигән мәгънәне аңлата. *Әлеге дустын Ким моннан нәкъ бер ел элек тапты.* Н.Акмал. *Нәкъ тыкрык уртасында Таһир Җеннең, Күчер Латыйф бабайның капкалары.* З.Зәйнуллин. *Тәүлекне бераз башларына киткән кешеләрдәй иләс-миләс уздырганнан соң, нәкъ шул бер үк вакытта алар икенче көнне дә очраштылар.* Г.Бәширов

2) Исем, алмашлык һәм рәвешләр янында килеп, охшатуны тагын да көчәйтә төшә. *Яулыгын, нәкъ татар кызлары кебек, алкаларын күрсәтеп, колак артына чөеп бәйләгән иде.* Г.Бәширов. *«Бар иде лә атларым, җигеп йөргән чакларым» диләрме әле, ничек соң җырлыйлар?.. Нәкъ шулай җырларга гына калды инде...* Г.Толымбай. *--- милли киемдәге гарәпләр туристларга юлны сүзсез генә күрсәтәләр. Нәкъ телсезләр кебек.* С.Сөләйманова

◊ **Нәкъ өстенә басу** Төп-төгәл әйтү яки күрсәтү. *Айдар: Нәкъ өстенә бастың – бандит мин.* Г.Гыйльманов. **Нәкъ эзенә басу** *к.* **нәкъ өстенә басу**. *– Ә болар сарматларга кызлар сораргә килделәрме, җансакчыларың, дим? – Нәкъ эзенә бастың, унбаш. Кызлар сораргә килүем, тик синең каршыңа түгел, бәк каршына.* М.Хәбибуллин

НӘКЫЛЬ *и. гар. иск.* Күчерү, урынын алмаштыру

НӘКЫ́ЛЬ ИТҮ *ф. иск.* Сүз, хәбәр җиткерү, тапшыру, әйтү; риваять итү. *Ул итсә дә хәдис, аятьне күп нәкыль,*

Булып бетми аның гаклы нәкыльгә кол. Г.Тукай

НӘКЫС *с. гар. кит.* 1) Аз, җитәрлек түгел, ким. *Сүзгә нәкысрак Кәбир хатынының акылына хәйран калып, җүпләп, ияк кагып утырды...* А.Гыйләҗев

2) Ким, бәләкәй; тыгыз. – *Миңа дип алып кайтканнар иде дә, кечерәк булып чыкты, күкрәк турысы кыса, сезгә дә нәкыс булыр, – диде ул, чөнки кунакның күзләре яна башлаганны ачык күргән иде.* Р.Мирхәйдәров

НӘКЫШ *и. гар.* 1) Агач, сөяк кебек нәрсәләргә кисеп, уеп, сырлап яки чокып ясалган бизәк, орнамент. *Бу нәкышьләр бар да сиңа охшаганнар.* Кол Гали. *Боларны эшләүдә сәнгатьнең нәкышь, кою, бөртекләү, каралту, кырлау, басма, алтын-көмеш йөгертү, асылташлар белән бизәү, каю, чигү һәм башка бай алымнары кулланыла.* Р.Фәхретдинов

2) Чигү, чигеш. *Җиңги чәнчә, мин тартам, мин дә нәкышь беләмен.* Әйтем

НӘКЫ́ШЬ ИТҮ *ф. к.* **нәкышьләү**. *Мән, әҗәл җитеп хаста булгач, барча гыйлемлекләремне көмеш тактага алтын илә нәкышь итеп язып, ошбу Мәрмәр диңгезенең астына сандыклар илә китереп куйдым.* Ф.Халиди

НӘКЫШЬЛӘНҮ *ф. төш. юн. к.* **нәкышьләү**. *Сарае зур, нәкышьләнгән, энҗеләнгән; Кискен нурлар сибелеп тора энҗеләрдән.* Һ.Такташ. *Сарайның дивар бүрәнәләре тигез итеп шомартылган, тәрәзә тирәләре нәкышьләнгән.* М.Хәбибуллин. *Менә ни өчен нәсел фамилиясе җиде буын кәүсәсенә Коръән сүрәсе аятьләредәй нәкышьләнде.* С.Поварисов

НӘКЫШЬЛӘТҮ *ф. йөкл. юн. к.* **нәкышьләү**. *Гомумән, бөек атын алган Константин үзенең булачак башкаласын төрле ярым сыннар, могҗизаи бизәкләр белән нәкышьләтә.* М.Хәбибуллин

НӘКЫШЬЛӘ́Ү *ф.* Уеп, сырлап яки чокып бизәкләр төшерү, бизәү. *Куйма юкка хур кызларың, җәннәтләрең, Зур сәнгатең белән нәкышьләп, каршыма!* Һ.Такташ. *Аларны биредә көнтөн эшкәрттеләр, шомарттылар, нәкышьләделәр һәм һәр ташны берберсенә кыл сыймаслык итеп салдылар.* М.Хәбибуллин

Нәкышьләп тору Гел, һәрвакыт нәкышьләү

Нәкышьләп чыгу Тулысынча нәкышьләү

НӘКЫШЬЛЕ *с.* Нәкышьләп бизәлгән. *Каршы яктагы ике катлы йортның нәкышьле кәрнизләрендә кояш нуры уйный, шул нурлар Нуриягә рәхәт җылы булып тоелалар.* Г.Ахунов. *Бүгенге София храмындагы багаиалар, төрле нәкышьле ташлар, бизәлгән сурәтләр Мисырның Изида һәм Осирис, Кояш һәм Ай, Афина һәм Аполлон храмнарыннан сүтеп алындылар.* М.Хәбибуллин

НӘКЫШЬЧЕ *и.* Нәкышь ясау остасы. *Вәзир барып бер нәкышьче останы табып китерде.* К.Насыйри

НӘЛӘТ *и. гар. сөйл. к.* **ләгънәт**. *Кинәт Мирвәлинең колак төбендә генә кемдер пышылдады: «Ә син, Мирвәли, оныттыңмы Карачураны?!» – Тпру! Туктал, нәләт!* А.Гыйләҗев. *Һәм сизенәм: аңа кызгану кирәкми, Гитлер башына нәләт яудыру да кирәкми, чөнки болар – сүз, бары сүз генә!* Ә.Еники. *Һәй, атаңа нәләт нугай урыс!* М.Галәү

◊ **Нәләт камыты** *к.* **ләгънәт камыты**. **Нәләт орган** *к.* **ләгънәт төшкән**. *Башка вакытларда аның күгәрчендәй гөрләп, күңелләрне рәхәт кенә йокымсырата торган бәрхет тавышына әлеге нәләт орган чирнең кортлары төшкән иде.* Р.Сәлим. **Нәләт суккан** *к.* **ләгънәт төшкән**. *Инде туктыйм, ак күңелемнән шул нәләт суккан көнче күбәләкләрнең исемнәрен мәңгегә онытам, хәтеремне сафлыйм, дип уйлап кына өлгерәм, тагын берсе караңгы почмактан чәчрәп чыга да былчырак ата.* А.Гыйләҗев. **Нәләт төшкән** *к.* **ләгънәт төшкән**. *Сайра безгә шушы нәләт төшкән Койма аша гына булса да.* М.Җәлил. **Нәләт төшкере (төшсен, суккыры)** *к.* **ләгънәт төшкере**. *Нәләт төшсен сезгә, нәләт төшсен! Әй урманнар, кырлар, далалар!* Һ.Такташ. *Иске көнгә, нәләт төшкерегә, Ни дисәң дә аңа аз сыман.* Х.Туфан. *– Нәләт төшкерләре, бугазларына көйдерге чыккыры! – Гыйлемдар ага ачулана-сүгенә ашыгып төргәкләрен миңа ыргытты да, тиз генә чүгеп, кар өстеннән шуышып ярдан түбән төшеп тә китте.* И.Салахов

НӘЛӘТЛӘ́Ү *ф.* Ләгънәт уку, каргау. *Шул ук вакытта бөтен илләрнең халыклары җылап, сыкрап, сугышны нәләтли-нәләтли сугышалар...* Ә.Еники

НӘЛТИ *и. диал.* Кузналы уенда: эрерәк, авыррак кузна; сага. *Тик бер генә нәрсәне искә төшерәсем килә: кузнаның бит әле бәрә торганы була. Бездә аны нәлти диләр.* Ә.Еники

НӘМАЕШ *и. фар. иск.* Демонстрация, парад. *Ул гына да түгел, Казандагы хөррият көннәрендә карагруһларның «Хөррият кирәкми» дигән нәмаешларына катнашудан мөселман голямасы алып кала алмады ---.* Г.Исхакый. *Октябрь нәмаешларыннан соң авызлыкланган шәкертләргә Мәскәүдәге декабрь вакыйгалары коргак елдагы беренче яңгыр төсле булып тоелдылар.* К.Тинчурин. *Нәмаештан кайтканда барысы да арыган, әлсерәгән иде.* Г.Тукай

НӘМӘ *и. сөйл. к.* **нәрсә**. – *Тавыгым әтәч булып кычкырып үз башына җитте, нәләт... --- Тагын кайбер нәмәләр белән танышырсың, хи-хи...* А.Гыйләҗев. *Әллә нинди ышпиундыр әле. Хәерсез нәмә. Дилбегә тота белсә, болай адәм мәсхәрәсенә калмас иде.* С.Поварисов

НӘМӘКӘЙ *и. сөйл. кимс. к.* **нәмәстә**. *Их син, җон тәпи! Әллә нәмәкәйләргә ышанасың!* Г.Бәширов

НӘМӘРСӘ(КӘЙ) *и. сөйл. кимс. к.* **нәмәстә**. *Тагын берәр нәмәрсәкәй эшләмәгәйләре дип, ул төнне бөтенләй йокысыз уздырырга булган идем дә, күпкә түзәлмәгәнмен, кабат йоклаганмын.* М.Галәү. *[Сәрбиназ:] Синең ише, майлап бирсәң эт ашамас нәмәрсәләргә кем койрык таксын?!* Ф.Яруллин. *Төргәген сүтте, аннан Канәгать гомерендә күрмәгән кара нәмәрсә китереп чыгарып, тактага куйды ---.* А.Хәлим

НӘМӘСТӘ(КӘЙ) *и. сөйл. кимс.* Игътибарга, хөрмәткә лаек булмаган

зат яки әһәмияте, кыйммәте булмаган берәр нәрсә. *СНГ дигән нәмәстәкәй бик таркау, бик булдыксыз булып чыкты.* Ә.Еники. *[Кара Гобәй:] Бу сугыш дигән нәмәстә алда гына бетмәскә охшый.* З.Зәйнуллин. *[Карчык:] Әкрәм дигән нәмәстәне эзлим.* Р.Зәйдулла

НӘМУНӘ *и. фар. иск. кит.* Үрнәк, өлге. *Татар матбугатының шулкадәр зәгыйфь вакытында ---, һич курыкмаенча, шул мөкатдәс мәсләктә дәвам итеп, бабаларымызга нәмунә улырдай хезмәттә булдыңыз!* Г.Исхакый

НӘНӘ *и. диал.* 1) Әби, ата-ананың анасы

2) Әни. *Әтинең нәнәсе бөер рагыннан үлде.* Ф.Бәйрәмова. *Миңа алты ай булганда, нәнә әтиемнең төп йортыннан сатып алган йортка күчеп чыга. Нәнәнең әнисе Бибигайшә әбием бер бөтен ипи, бер чырагач алып килә.* Ватаным Татарстан

3) *тарт. форм.* **нәнәм**. Үзеннән кечеләргә иркәләп дәшү сүзе. *«Хуш, Җиһангир балам, хуш, асыл затым, хуш, нәнәм! Мәңгегә хуш!» – дип, байтак үрсәләнде Бибинур.* А.Гыйләҗев

НӘНИ *с.* **1.** Кечкенә; бәләкәй. *Төштә миңа нәни кызым килде, Чәчләремне сыйпап тарады.* М.Җәлил. *Нәни эшне кире какмаучы Зур эшне дә оста башкара.* М.Хөсәен. *Нәни генә кырмыска Ямьнәр өсти тормышка.* Ф.Әмәк

2. *и. мәгъ.* Кечкенә бала, сабый. *Ашый торган нәрсә түгел микән Менә шушы ниең, нәнием?* Х.Туфан. *Керпе, нәниләрен сыйлар өчен, йөгерә-йөгерә гөмбә җыйды.* Ж.Тәрҗеманов. *Нәниләрне бик ярата, бервакытта да каты бәрелми, гел аларның йомышын йомышлый иде ул.* З.Зәйнуллин

3. *рәв. мәгъ. диал.* Аз. *Нәни генә күгәргән ис тә килә түгелме икән әле...* Г.Бәширов. *Багананың җиргә күмеләсе башын нәни генә җандырганда җәкшы булырые.* Н.Фәттах. *Нәни генә тырналуның зыяны юк, киресенчә, ул иммун системасын формалаштырырга ярдәм итә.* Ватаным Татарстан

НӘНКӘ I *и. рус сөйл. к.* **няня**. *Мең нәнкә дә бер әнкәне алыштыра алмас.* Мәкаль. *--- безгә кул кешеләр түгелләр алар, әллә ничә горничный нәнкә шикелле ашаталар, нәнкә шикелле эчертәләр, нәнкә шикелле йоклаталар, үзең теләгәнчә йокларга ирек тә юк.* Г.Камал. *Шәңгәрәй, хезмәтчеләрнең тышкы кыяфәтләренә карап, «бусы нәнкә», «бусы сестра» дип чамалап утырды.* И.Гази. *Кечесе, узган ел шәһәрдәге туганнарына киткәне, бала карап, нәнкә булып торганы, быел паспортлы булган инде, заводта эшли, ди, икешәр йөз ала, ди.* Н.Көбәш

НӘНКӘ II *и. иск. [Кытайдагы Нанкин шәһәре исеменнән]* Ныклы ефәк тукыма

НӘП- *кис.* Кайбер сыйфатлар белән килеп, аның артыклык дәрәҗәсен ясый торган кисәкчә. *Ул нәп-нәзек, алсу бармакларын тырпайтып, сакау-татлы теле белән «әттәм, без, без!» дип яныма килә башлады.* А.Гыйләҗев

НӘРӘТ *и. рус сөйл. к.* **наряд**. *Ә син ни дип бәбәкләреңне терәп, нәрәт алган солдат төсле миңа карап шаккаттың?* К.Тинчурин. *– Юлар, – диде әзмәвер. – Безгә буарга кушылган. Эш нәрәт белән эшләнә.* А.Гыйләҗев. *Ул килеп кергәндә, председатель, кәгазьләр эченә күмелеп, нәрәт яза иде.* Н.Гыйматдинова

НӘРӘТӘ *и. фин.-угор.* Авызы бүрәнкә сыман итеп, тар озын кәрзин формасында талчыбыктан үреп эшләнгән балык тоту коралы; мурда, сөкә. *Без барган вакытта, безнең сөвекле бабай нәрәтәләрен элеп киптерә, өзелгән урыннарын рәтләп, бәйләштереп тора иде.* М.Гафури. *--- Тимербай картның шундагы күлләрдә, тар гына бүрәнә каекка утырып, сыңар ишкәге белән камышларны ера-ера нәрәтә куеп йөргәнен гел күрә торган идек.* Ә.Еники

НӘРГИЗ *и. фар. к.* **нәркис**. *Үзе – гел наз, күзе – нәргиз, йөзе – гүзәллек шаһы, Исеменә җисемнәрен тиң яраткан улаһы.* Г.Кандалый

НӘРД *и. гар.* Икегә бүленгән махсус тактада 15 ак, 15 кара таш (шашка һ.б.ш.) белән уйнала торган ике кешелек өстәл уены. *Югыйсә шаһ иде гадел, тыйнак зат. Фәкыйрь һәм бай белән йөрде уйнап нәрд.* Котб. *Бер кемсәнә нәрд, ягъни харита уйнаса, гүяки ул кеше кулын дуңгыз канына батырды.* К.Насыйри

НӘРЕН *и. фар. бот. к.* **бака тәңкәсе**

НӘРКӘМӘС *и. диал. бот.* Әрем

НӘРКӘС *и. фар. к.* **нәркис**. *Нәркәс кара күзләрең, тулгай ай тик йөзләрең, Һич күңлемдин китмәйдер балшикәр тик сүзләрең.* Габдессәлам. *Бакча чәчәкләреннән иң киң таралганы – дәлия, кашкарый, алтын чәчәк, чалма чәчәк, ала миләүшә, гөлчәчәк. Нәркәс, ирис чәчәкләре сирәгрәк очрый.* Ф.Габдуллина

НӘРКИЗ *и. фар. к.* **нәркис**. *Матур кызлар суга бара, Челтери чиләкләре; Берсе сирень, берсе нәркиз, Берсе гөлнең зәңгәре.* Ә.Ерикәй. *Чалмабашлар, зәңгәр кыңгыраулар, Кызыл мәкләр, нәфис нәркизләр.* Л.Шагыйрьҗан. *Нәркиз – тәкәбберлек һәм горурлык, хәтта мәгърурлык билгесе. --- Борынгылар яуда җиңү яулап кайткан батырларны нәркиз чәчәкләре белән каршылаганнар.* Г.Гыйльманов

НӘРКИС *и. фар.* 1) *бот.* Амараллисчалар семьялыгыннан хуш исле, ак яки сары чәчәкле, суганчалы декоратив үсемлек. *Нәркиснең исе аны илһамландыра һәм күңелсез уйлардан арындыра.* Ватаным Татарстан

2) *күч. иск. кит.* Гүзәл кызның күзләре. *Йөзе – кояш, чигәсе – ай, чәче – төн, Күзе – нәркис, иңе гөл – бизи күркен.* Котб

НӘРСӘ I *а.* **1.** 1) Нинди дә булса предмет, күренеш, процесс һ.б. турында сорауны белдерә. *Барып, зиндан ишекләрен ачып керде, Нәрсә күрде?!* Һ.Такташ. *Берише кешенең безнең кулыбыздагы әлеге кечкенә чемодан белән кызыксынуы мөмкин: янәсе, нәрсә алдылар болар үзләре белән?* Ф.Хөсни. *Бусы нәрсә була икән тагын, дип аптырап торганда, тагын да шул Песи Хәнифе: – Абый, пулный выкладны аңлатыгыз әле? – дип сорап куймасынмы!* А.Хәлим

2) «Ни өчен, нишләп, ни сәбәпле» мәгънәсендә кулланыла. *Төш арбадан, нәрсә утырасың җәлеп...* З.Зәйнуллин

3) Инкярны белдергән риторик җөмләләрдә «башка бернәрсә дә түгел»

дигән мәгънәне аңлата. *[Дильяр:] Минемчә, гап-гади, тормышта була торган хәл инде ул – безнең Гөлназ белән очрашуыбыз! Нәрсәсе бар инде аның?!* Р.Сабыр

4) Әйтелгән сүзне яңадан кабатларга кирәклеген белдергәндә һәм гомуми сорауны аңлатканда, сүз-җөмлә булып кулланыла. *– Нәрсә? – диде аңа ул сержант.* Ф.Яхин

5) Риторик сорау һәм юклык формасындагы өндәү җөмләләрдә «бик күп, бернәрсә дә калдырмыйча, барысын да» кебек мәгънәләрне белдерә. *Нәрсә турында гына сөйләшмәделәр алар!*

6) *Менә* күрсәтү алмашлыгы янында: басым ясап күрсәтү яки санап китү алдыннан (яисә аңардан соң) гомумиләштерүче функциясендә кулланыла. *Рәхәтен рәхәт тә, шулай да кем соң без монда? Менә нәрсә эчтән кимерә мине.* Ф.Хөсни. *[Кара Гобәй:] Менә нәрсә, кызым. Бүген соң инде. Иртәгә иртүк мин ат җигеп килермен. Безгә күченерсез.* З.Зәйнуллин

2. *кис. мәгъ.* Сорау җөмләнең башында сорау интонациясен тагын да куәтләү, көчәйтү өчен кулланыла. *[Айбулат:] Нәрсә, башлыйбызмы сөйләшүне?* Р.Сабыр. *Нәрсә, шушы атнада әллә минем дә бер җон-ябаганы коясым килмиме?* М.Мәһдиев. *[Әнисе:] Нәрсә, атасы, эшеңдә берәр күңелсез хәл булмагандыр бит?* Ф.Яруллин

НӘРСӘ II *и.* **1.** 1) Әйбер, предмет. *Ярма аралаш кар кебек нәрсә сибәләп киткәнлектән, мәдрәсәнең ишек алды тегермән идәнен хәтерләтсә дә, Бahay кибетенә икмәк төшмәү аркасында, шәкертләр өйлә чәендә икмәксез калдылар.* К.Тинчурин. *Төн караңгы, берни күренми, мин, аягым белән капшанып, берәр агач-бүрәнә кебек нәрсә эзләргә тотындым.* Ә.Еники. *Кешеләр бит матур нәрсә күрсәләр, аңа якынаерга тырышалар, матур нәрсәне үзенеке итәргә омтылалар.* З.Хәким. *Күктә якты кояш балкый, ә тирә-якта давыл ярга чыгарып ташлаган нәрсәләр аунап ята.* И.Хуҗин

2) Чынбарлык күренеше, факт; нинди дә булса эшчәнлекнең чагылышы, нәтиҗәсе; эш, гамәл. *Хәят портретны бик озаклап, бик нечкәләп карады, иң вак нәрсәләрне дә күзеннән төшереп калдырмаска тырышты.* Ф.Әмирхан. *Хәдичәне аптыратып калдырган нәрсә бөтенләй икенче: ничек торыр мескен Котбый ул хатын белән?* Ф.Хөсни. *Аеруча бер нәрсәгә укучы игътибар итмичә калмас, мөгаен: дүрт елдан артык дәвам иткән сугыштан солдатлар тәмам туйды, гарык булды...* Ә.Еники

3) Сөйләмнең, әдәбият, сәнгать, фән әсәре, китап һ.б.ш.ларның объекты турында гомумиләштереп әйткәндә кулланыла. *Әллә нинди гыйбрәтле нәрсәләр язу*

4) *сөйл.* Кеше, зат. *[Алинә:] Тышкы кыяфәтемне ошаткансың, бәлки, мин чынында бер киребеткән нәрсәдер?* Э.Яһудин // Берәр кеше яки әйбер турында бик үк яратмыйча, ошатып бетермичә әйткәндә кулланыла**.** *Быел килмәгән, авылында калган, инде әнисе аның урынында. Начар, әллә нинди төмсә нәрсә. Әх, теге чибәр кеше иде.* Ш.Камал. *Тәбәнәк кенә нәрсә, астан баш белән дык итеп корсак өстенә бәрә бу, алыптай егетләр җиргә тынсыз тәгәриләр.* А.Гыйләҗев. *Нинди уру ди ул тагын көне буе, эт ялкавы нәрсә...* З.Зәйнуллин

5) Берәр кеше яки әйберне үз исеме белән атамыйча, аңа күрсәтеп, читләтеп әйткәндә кулланыла. *Тик туя торгач кына, гүя Николайның баягы сүзе исләренә төшеп: «Бу нәрсә эчәкләрне бөрештермиме икән?» – дигән сәваль белән зиһеннәре мәшгуль төсле күренә иде.* Ш.Камал

2. *бәйл. мәгъ.* Иярченле кушма җөмләдә баш җөмләгә иярчен җөмләне бәйләүче мөнәсәбәтле сүз ролендә килә. *Оясында нәрсә күрсә, очканында шул була.* Мәкаль. *Нәрсә теләсәләр, шуны кыйлансыннар, ирек куегыз!* З.Зәйнуллин

3. *хәб. мәгъ.* Күренеш, факт, объектив чынбарлык. *Урыс телен белү – кирәк нәрсә, Ләкин Кирәклеген аның бутыйлар ---.* Һ.Такташ. *– Кайда моның [атның] тормозы? – Диеп кенә сорады [кунак егете]. --- – Озак булыр аңлату, Тормоз белү – бер нәрсә, Кирәк атны ярату.* Ш.Галиев

НӘ́РСӘГӘ *а.* 1) Эш яки хәлнең сәбәбен ачыкларга теләп сораганда кулланыла; ни сәбәпле, ни өчен, нигә. *Ләкин мин аптырашта, мин хәйран: «Нәрсәгә артка карыйсың, утка калгач бер адым?»* Г.Тукай. *[Диләрә:] Болардан алдарак чыккан Николай кинәт тукталды да: – Теге шайтан нәрсәгә ашыктыра икән; яңа гына невод ыргыта башлаганнар ич; әйдә, кайт, солдат, нәрсәгә туңып торырга? – диде дә, кулларын җиң эченә тыгып, бөрешкән көе, кире баракка кайтып китте.* Ш.Камал. *Нәрсәгә ул мужикларны колгага элеп куйдың?* И.Зәйниев

2) Эш яки хәлнең максатын ачыклап сораганда кулланыла; нинди максат белән, ни өчен, нигә. *– Ә нәрсәгә кирәк ул миңа? – диде күршесе.* М.Галәү

НӘ́РСӘГӘДЕР *а. к.* **нигәдер**. *Гариф тагы нәрсәгәдер юләрләнеп китте.* Ш.Камал. *Нәрсәгәдер кинәт тамагым кибеп китте...* А.Шамов

НӘ́РСӘДӘН *а.* Сәбәпне сорау өчен кулланыла. *Бар күңеллелек бөтен дөньяда, бар бер ямь бүген. Нәрсәдән бу? – Мин беләм: бәйрәм бүген, бәйрәм бүген!* Г.Тукай

НӘ́РСӘДӘНДЕР *а.* Эш яки хәлнең сәбәбе билгесез булуны белдерә. *Һәр тараф тын. Уй миңа тик әллә ни җырлый, укый; Нәрсәдәндер күз эленгән һәм тәмам баскан йокы.* Г.Тукай. *Нәрсәдәндер шунда мин курыктым.* М.Гафури. *Көмеш шикелле ачык тавышлы кызлар нәрсәдәндер чыркылдашып көләләр.* А.Шамов

НӘ́РСӘДЕР *а.* Билгесез предмет яки күренеш. *Нинаять, карт чиновник, мөтәсарриф белән үзара пышылдашып алгач, Гарифка таба борылды һәм аңа нәрсәдер әйтте.* М.Галәү. *Кинәт томан ярылып китте, нәрсәдер дөп итте.* И.Салахов. *Мөнир үзе нәрсәдер лыгырдый, үзе кимерүен белә.* З.Зәйнуллин

НӘРСӘ́-КАРА *җый. и.* Һәртөрле әйбер, нәрсә. *Йорттa табылган нәрсә-кара барысы да чаналарга төялде.* М.Галәү. *--- Ташкент үзбәгеннән «Кызбармак» исемле затлы виноград үлчәтеп алдым, иң зур тәлгәшкә акча*

кызганмадым, алма-грушаларның иң асылларын өстәдем, шуларга кан кебек кызыл эчле азәрбайҗан гранаты куштым, нәрсә-караларны артка урнаштырдым. А.Гыйләҗев

НӘРСӘКӘЙ *и. сөйл. к.* **нәрсә** II. *И, мин әйтәм, авыл баласы, яхшыдан яман туган нәрсәкәй, ничек инде эчендә җаны бар кешегә урманболын кирәк булмасын, дим.* Р.Сәлим. *Чиләбе егетенең авызы колагына җиткән, минем тере уенчыгым бар, ә сезнеке юк, ди мактанчык нәрсәкәй.* Г.Мөхәммәтшин

НӘРСӘЛЕК *и.* Нәрсә булу; mаһият. *Халык әле Думаның нәрсәлеген аңламаган.* Г.Исхакый. *Бу агачның нәрсәлеген белгән адәм булачактыр бик зур адәм.* К.Тинчурин

НӘРСЕН *и. бот. к.* **нәрен**

НӘСАРА *и. гар. кит.* Христиан динен тоткан кеше, христиан. *Гәрчә Гайсә пәйгамбәр һәр нәсара кешесен гөнаһ кылмаска өндәп торган.* М.Хәбибуллин

НӘСӘП *и. гар. к.* **нәсел**. *Сәбәбен сорамый тоз бирмә, нәсәбен сорамый кыз бирмә.* Мәкаль. *Падишаһлык шул кешегә лаектыр: нәсәбе пакь булсын, хөсне камил булсын вә һәм үткәндәге гадел падишаһларның хакларын тотсын.* К.Насыйри

НӘСЕЛ *и. гар.* 1) Бер бабадан килә торган кешеләр, ыру. *[Ибраһим:] Бу нидән бу, Хәлил абзый, безнең нәселдә аяк авыруы бик күп?* Г.Исхакый. *Ә Шәйхи карт бер дә әллә кемгә түгел, үз нәселләренә әйтеп калдырган икән.* М.Мәһдиев. *Фәләхетдиннең бит нәселендә андый кыска буйлы кешеләр булмаган.* М.Шаһимәрдәнов

2) Тумышы, чыгышы белән ниндидер аерым бер социаль төркемгә караган булуны белдерә. *Морзалар тарафыннан илтифат күрмәк өчен, морза нәселеннән булырга кирәк икән ---.* Ф.Кәрими. *Патша халкы Комсыз нәсел икән ---.* Х.Туфан. *Дөрес, Күчемнең башка балалары да ут уйнатып тора, әмма затлылыкта Сүзгенекеләргә җитми, бөтен яктан ханнар нәселе икәнлеге әллә каян күренеп тора.* Ф.Бәйрәмова

3) Хайваннарның, кош-кортның буыннан буынга күчә торган билгеле бер сыйфатларга һәм үзенчәлекләргә ия булган токымы. *Гыйльметдингә: – Кара, җирән кашка нәселен бетермә. Үкенерсең, терсәгең тешләр идең дә, авызың җитмәс, – дип, ничаклы үгетләдем. Булмады.* Г.Толымбай. *Әйтерсең казлар өстенә үләт явы килде: аларны йөзләп-меңләп кырдылар, күп районнарда аларның нәселе дә калмады.* Ә.Еники. *Елкылдап торган нәсел үгезе генә нигәдер ятсынды, күзенең агын әйләндереп, һаваны иснәштереп, Тәнзиләләр ягына сузылып торды.* А.Гыйләҗев

4) *күч.* Гомуми эш белән, мәнфәгатьләр белән бәйләнгән бер тирә яшьтәге кешеләр, кордашлар; бер буын кешеләре. *Кайда әләксәм, шунда сезнең нәсел Кирәгемне бирде бирүен.* Һ.Такташ. *Һәр көрәшнең Алгы сафына килеп баса ул: Күкрәгенә Ике орден таккан Ленин нәселе – данлы комсомол.* Ф.Кәрим. *Без тезләнә торган нәсел түгел, Без бәйсезлек өчен кан түктек.* Ә.Ерикәй

◊ **Нәсел агачы** Шәҗәрә. *Башкае киселгән нәселем агачы Тамырдан таралып, дөньяга җәелгән.* Р.Әхмәтҗан. *Апанаевлар – Идел-Чулман төбәгендә атаклы нәсел. Аларның шәҗәрәсе (нәсел агачы) Рәсәйнең мөфти хәзрәте Тәфкилефкә барып тоташа.* А.Тимергалин

НӘСЕ́Л БАШЫ *и.* Нинди дә булса нәселгә нигез салучы баба. *Нәсел башын, олыларны хәтерләгәндә, аның сүрән йөзе азга гына ачылып китә дә, уй җебе бүгенгә, бүгенге кешеләргә, борынгыдан догалы, ашлы-сулы йорт-нигезнең бүгенге хуҗаларына әйләнеп кайткач, чыраендагы саран яктылык та югала ---.* А.Гыйләҗев. *Шуның өстенә, ул [Олы Мөхәммәт] Казан ханнары династиясенең атасы, нәсел башы булып тора.* Р.Фәхретдинов. *Атаклы Йосыф бәк кызы, борынгы аксөякләр нәселеннән, нәсел башы Алтын Урда ханнарына барып төртеләдер, ханбикәгә затлылык, гыйффәтлек, нәзбереклек, сөйкемлелек вә мөлаемлык хастыр.* М.Хәбибуллин // Хайваннарда: токым башы. *Карап үстерә алсаң [шул дөяне], нәсел башы булыр, шуның янында көтү оешыр.* Ч.Айтматов

НӘСЕЛДӘНЛЕК *и. биол.* Организмнарның охшашлыкларын, сыйфатларын геннар аша буыннан буынга тапшыру үзенчәлеге. *Ходайга шөкер, татарның гены – нәселдәнлеге көчле.* Б.Рәхимова. *[Гарри:] Ниен аңламыйсың инде! Дезоксирибонуклеин кислотасы нәселдәнлек информациясен саклый һәм буыннан буынга тапшыра!* С.Гаффарова, Й.Миңнуллина. *RX матдәсе тереклек ияләренең нәселдәнлек механизмын какшата.* А.Тимергалин

НӘСЕЛДӘШ *и.* Бер нәселдән булган, бер нәселгә караган кеше. – *Шулай, егетләр, сез безне ерак бабаларыбызның нәселдәшләренә охшаттыгыз охшатуын, – диде Мохтар.* Ш.Камал. *--- безгә шундый яхшылык эшләгән һәм күпмедер дәрәҗәдә миңа нәселдәш булган шушы бик әйбәт, бик хөрмәтле гаилә белән мин ни өчендер соңыннан элемтәне югалттым.* Ә.Еники // Бер төр, төрдәш (хайваннар һәм үсемлекләр тур.). *Культуралы үсемлекләрнең кайбер төрләре үзләренең кыргый нәселдәшләреннән аз аерылалар.* Биология

НӘСЕЛДӘШЛЕК *и.* Бер нәселдән булу, туганлык

НӘСЕЛЛЕ *с.* 1) Яхшы токымнан булган (хайваннар, кош-корт тур.). *Ә ничек мондый шәп фермалар җитештердегез, нәселле сыерлар булдырдыгыз?* А.Гыйләҗев. *Син – күптәнге тәҗрибәле караучы, менә нәселле бозауларның барысын да сиңа җыеп бирәбез.* Ә.Еники. *Анда Ф.Әмирханның «Хәят»ы, Г.Ибраһимовның «Картлык көннәрендә», --- яхшы нәселле сарык, ат, сыер үрчетү турында китаплар, «Ауропа картасы», «Асия кыйтгасының харитасы» бар иде.* М.Мәһдиев

2) Яхшы нәселдән, гаиләдән булган (кешеләр тур.). *Шабайдан яучы килеп, мәһәр акчасын алгач та, карт, башкалар кебек, кияүне кышкы челләдә салкын келәткә ябарга ошатмады, нәселле, затлы кешенең баласы бит дип, Хәмиттән калган өйне тиз генә төзәттеләр.* Г.Ибраһимов

НӘСЕЛЛЕЛЕК *и.* Нәселле булу. *Нәселлек күрсәткечләре*

НӘСЕЛ-НӘСӘП *җый. и.* Туганнар, туган-тумача, кардәшләр. *Нәсел-нәсәпләребезне яхшылап белмәенчә --- ачуланышып йөрү дә мәгърифәттән түгел.* Г.Әхмәров. *Син дә төшеп калганнардан түгел, нәсел-нәсәбеңне генә кара...* А.Гыйләҗев. *[Хания:] Ичкериядән нәсел-нәсәбе белән корытылган, җиреавыллары белән юк ителгәннәр исеменнән әйтәм.* Ю.Сафиуллин. *Сабантуй көнне авылга күрше-тирә авылларындагы нәсел-нәсәп җыела.* М.Мәһдиев

НӘСЕЛ-НӘСӘПЛЕ *с.* Туганнары булган, туганнары күп булган // Яхшы нәселдән, төпле. *Нәсел-нәсәпле, укымышлы кыз, күрер күзгә бик чибәр.* Ф.Әмирхан. *Затлы нәсел-нәсәпле ялгыз калган рус эмигрантлары картайган көннәрен шунда кичерәләр икән.* Р.Мөхәммәдиев

НӘСЕЛ-НӘСӘПСЕЗ *с.* Нәселе, туганнары булмаган // Билгесез нәселдән яки түбән катламнан чыккан. *Аны дөньяга китергән хатын – зинадан туган, нәсел-нәсәпсез зат.* Р.Сәгъди. *Янә нәсел-нәсәпсез адәм тәганәсе дә түгел.* М.Хәсәнов

НӘСЕ́Л-НӘСЕЛДӘН *рәв.* Атабабадан. *Шәүлихан – нәсел-нәселдән килгән бай.* Т. Гыйззәт

НӘСЕЛСЕЗ *с.* 1) Чыгышы билгеле булмаган, нәселе билгесез; затлы нәселдән булмаган. *Берничә нәселсез яман балаларны җыеп, үзеңә вәзир итеп, һәр эшеңне аларга тапшырып тынычлангансың.* К.Насыйри. *Ишегалларында, капка төпләрендә нәселсез авыл этләре күккә карап еладылар, шыңшыдылар.* М.Мәһдиев

2) Нәсел калдыру сәләтеннән мәхрүм булган, кысыр. *Нәселсез хатын*

НӘСЕЛСЕЗЛЕК *и.* 1) Кемнең дә булса затлы, танылган яки борынгы нәселдән булмавы, түбән нәселдән булуы яки чыгышының билгеле булмавы. *Шыр ятимлегең өстенә, нәселсезлегең янына, син ахмак та икәнсең әле.* Т.Галиуллин. *Әлбәттә, бүгенге яшьләребезгә заманның төссезлек, нәселсезлек, ырусызлык, милләтсезлек, космополитизм чире йоккан.* Р.Вәлиев

2) Нинди дә булса хайванның саф токымлы булмавы. *Этнең нәселсезлеге*

3) Нәсел калдыра алмау; тумасы булмау. *Ә мин һәр адымда аның нәселсезлегенә ишарә ясау җаен таба идем.* М.Кәбиров. *Ул төрле чирләр, нәселсезлек, даими арыганлык китереп чыгара ала.* Ватаным Татарстан

НӘСЕЛ-ТОКЫМ *җый. и. к.* **нәсел-нәсәп**. *Илдә булмаганны кыланып бөтен нәсел-токымның абруен төшердең, яманатыбызны чыгардың.* А.Гыйләҗев

НӘСЕЛ-ЫРУ *җый. и. к.* **нәсел-нәсәп**. *Бөтен нәсел-ыруыбызга тап төшерде бу Сафа!..* М.Галәү. *Ләкин аның ата-анасы, бөтен нәсел-ыруы, авыллары, яхшымы-яманмы, христиан динен тота.* Г.Бәширов. *Зәйнетдин дә үз чиратында бурычсыз калмый: чамасыз кыланган Чәкеткә һәм аның нәсел-ыруына үзен судагы чуртан кебек иркен тотарга мөмкинлек биреп, шул судардагы мескен маймычларның бик уяу торуын тәэмин итә...* А.Хәлим

НӘСЕР *и. гар. әд.* 1) Эмоциональлеге, ритмлылыгы белән шигъри сөйләмгә якын торган кечкенә күләмле һәм лирик-патетик характердагы чәчмә-прозаик әсәр. *Әдәбиятта назым яки нәсер рәвешләре дә әкрен генә бер-берсенә якынлашып, яңа бер форма төзү юлында тәрәккый итәләр...* К.Нәҗми. *Ләкин алар шигырь түгел, нәсер ителебрәк язылдылар.* Х.Туфан. *[Дәрдемәнднең] «Сабый» нәсере бишек тирбәтү өчен иҗат ителгән җыр булудан тайпыла кебек.* С.Исмәгыйлева

2) Проза, чәчмә әсәр. – *Син менә беркайчан да шигырь яза алмагансыңдыр, – диде Раушания, минем булдыксызлыгыма дөрес бәя бирде. – Син язсаң да нәсер язар идең.* М.Хуҗин. *Безгә күрше булган милләтнең әдәбият кагыйдәләре китапларын тәфтиш итеп карасак, аларның баш фасыллары менә ниләрдән гыйбарәт: әсәрләрне халык әдәбияты берлә берәр кеше тарафыннан язылганнарга булу, шигырь вә нәсер берлә язылган әсәрләр ---.* Х.Әбүлхан

НӘСЕРЧЕ *и.* Нәсер язучы, нәсер язу белән шөгыльләнүче кеше. *Шул рәвеш, нәсерчеләр Шагыйрь һәм тәнкыйтьчеләр Уяулык, сизгерлектә Ярышырга керештеләр.* Х.Туфан

НӘСЕХ *и. гар.* 1) Хөкемсез калдыру, юкка чыгару, бетерү; үзгәртү. *Аятьтәге хөкемнең нәсехе белән килешмәүче мөфәссирләр*

2) Гарәп хәрефләренең басма һәм кулъязма китапларда иң күп кулланыла торган язылу рәвеше. *Манускрипт һәм табышмак бер кулдан нәсех белән язылган.* Н.Исәнбәт. *Аларны Зәки муллага гына хас стильдәге язулардан һәм ташларның куелу даталарын истә тотып танып алырга мөмкин. Ул нәсех стилендә язган.* М.Әхмәтҗанов

НӘСЕ́Х ИТҮ *ф. иск.* Гамәлдән чыгару, хөкемен юк итү, алмаштырып үзгәртү. *Юкса диннәрне иҗтимагый, мәдәни хокукларыннан тәмам мәхрүм итү, дини тәгълиматларын, шәргый хөкемнәрен нәсех итү тәфрикъ булмас, бәлки тәмам һәдем (бозу, юкка чыгару) булыр.* М.Бигиев

НӘСИМ *и. гар.* Җиңел һәм йомшак җил. *И нәсим, җанны сихерләп, кайдан исеп киләсең?* Дастан. *Нәсим үткәч үйнап, алка ишелгән, Җофар үзе кала таң хуш исеннән.* Котб

НӘСРАНИ *и. гар.* Христиан. *Я Рабби, нәсрани кавемеңнән булган ошбу кыз баланы җәмгы гөнаһларыннан азат кылуыңны эстибез.* Г.Бәширов. *Мәчетләр буш, татарныкы дип аталган мәктәпләрдә урысча укытыла, меңләгән кан кардәшебез нәсрани динен кабул итә.* Р.Зәйдулла

НӘСРАНИ́ЧА *рәв.* Нәсранилар, насаралар, христианнар кебек. *Хикаядәге кешеләрнең исемнәрене һәм нәсранича кылынган гыйбадәтләрне ислам гыйбадәтләренә алмаштырдым.* Г.Исхакый

НӘ́СТӘ *а. сөйл. к.* **нәрсә** I. *[Сәрвәр:] Нәстә эшлибез инде хәзер, ахирәтләр?* З.Зәйнуллин. *Нәстә мыштырдыйсың анда?* Р.Зәйдулла

НӘСТӘ́ *и. сөйл. к.* **нәрсә** II. *Чынлап та, булмас нәстә сөйлисең син, Гариф.* М.Галәү. *Ул да булмады, бер тимер тартмамы, сандыкмы кебек нәстәнең почмагы күренде.* Ә.Еники

НӘСТӘКӘЙ *и. сөйл. к.* **нәмәстә**. *Төшсә, тизрәк канатларын сугып*

имгәтим, бу әкәмәт нәстәкәй йомырка салып, бала үрчетер дә, урманда яшәрлек рәт калмас, дигән. Н.Гыйматдинова. *Юк, ни дисәң дә, безнең нәселгә тиң түгел бу нәстәкәй!* Ә.Галиева

НӘСЫЙХӘТ *и. гар.* Үгет, яхшы киңәш. *Нәсыйхәт бирсәң, аулакта бир.* Мәкаль. *Падишаһ, болардан саклан, минем нәсыйхәтемне тот.* К.Насыйри. *Белмим, ата-ана нәсыйхәте ул чагында безне күпме генә төзәткәндер, әмма соңыннан, еллар узгач, искә төшергән чакларда, вөҗдан авазы шикелле, җанны борчый, үкендерә һәм уйландыра.* Ә.Еники

НӘСЫЙХӘТЛӘҮ *ф.* Киңәш бирү, үгетләү, акыл бирү, яхшылыкка өндәү

НӘСЫЙХӘТЛЕ *с.* Киңәшле, яхшылыкка өнди торган

НӘСЫЙХӘТНАМӘ *и. гар.-фар.* Көнчыгыш мөселман халыкларында дидактик эчтәлекле әсәр. *Адәмнәр моннан гыйбрәт алсыннар, гөнаһларыннан тәүбә кылсыннар, начар эшләрдән тыелсыннар диеп, нәсыйхәтнамә яздым.* Өмет

НӘСЫЙХӘТЧЕ *и.* Үгетләүче, яхшы киңәш, акыл, үгет бирүче

НӘТИҖӘ *и. гар.* 1) Нинди дә булса эш, күренешнең яки нәрсәнең дә булса үсешенең соңгы йомгагы, күрсәткече. --- *Сәгъди, аксавына һәм бер кулының зәгыйфьләнүенә карап кына эштән туктамаса да, җегәре дә, эшенең нәтиҗәсе дә элеккечә түгел.* И.Нуруллин. *[Илһам:] Эшкә ничек карасаң, нәтиҗәсе дә шулай булачак.* И.Зәйниев. *Бибиса план белән нәтиҗә арасындагы каршылыкларны да, салкын су белән әштер-өштер генә юылган бидоннарда сөтнең тиз әчүен дә әйтте.* С.Сөләйманова // Берәр нәрсәнең ахыры, соңы. *Квартал, ел йомгаклары нәтиҗәләре буенча алган премияләре турында әйткән дә юк.* М.Хәсәнов. *Әмма нәтиҗә авыл халкы көткәнчә булмады шул.* Г.Галиева

2) Гомумиләштерелгән йомгак. *Зөһрә ханым үзе дә нидер сизенеп, минем ялгыш нәтиҗә ясавымнан курыккан төсле, тизрәк «төзәтергә» ашыкты ---.* Ә.Еники. *Һәм Бибинур, әһә, миңа да картлык килеп җитте, дип нәтиҗә ясады.* А.Гыйләҗев. *Уйлыймуйлыйм да, катлаулы, ай-һай катлаулы бу тормыш, дигән нәтиҗә ясап куям.* М.Шаһимәрдәнов

3) Файда. *Әхмәтнең тиз арада насосны төзәттереп алып кайтуына кешеләр шатландылар һәм түземсезлек белән аңардан нәтиҗә көтә башладылар.* Ш.Камал

◊ **Нәтиҗә чыгару** Нәтиҗә ясау, йомгаклау. *Ул, үзенең бөтен тормыш юлын башыннан кичереп, анда булган төрле хәлләрне аңларга, шул хәлләрдән үзе өчен файдалы нәтиҗәләр чыгарырга тырыша иде.* М.Галәү. *Аның Вәзилә дән качып фермага төшкәнен, кичке савымга кадәр Сәкинә янында бөтерелгәнен, сыер сава торган аппаратларны көйләшеп йөрүен, эш беткәч икесенең дә Олы су аръягындагы тау итәгендә «подручком гулять итүләрен» күреп торганнар да, быел көзгә туй буласы, дип нәтиҗә чыгарганнар.* А.Гыйләҗев. **Нәтиҗәгә килү** Берәр төрле фикергә килү, нәтиҗә чыгару. *Минемчә, безгә билгеле бер нәтиҗәгә килергә вакыттыр инде...* Ә.Еники. *Берен бере «авыз иткәчтен», Нәтиҗәгә килә икесе дә: «Син бит мәм-мәм түгел икәнсең...»* Х.Туфан. *Яран гөленең чәчәгенә төклетура кунган тәрәзә турысында утыручы Ризван шундый нәтиҗәгә килде: Кәрим кимсенеп елый...* М.Шаһимәрдәнов

НӘТИҖӘДӘ *рәв.* 1) Шуның аркасында, шул сәбәпле, шуңа күрә. *Нәтиҗәдә Рим плебейларыныкы гына түгел, патрицийларның да табигате, үзаңы үзгәргән.* И.Хуҗин. *Галим Авит әйтмешли, империя җирләренә варварлар бәреп керә башладылар, нәтиҗәдә империя икегә аерылырга мәҗбүр ителде.* М.Хәбибуллин

2) Ахырда, ахыр чиктә, соңыннан. *Нәтиҗәдә Идегәй үзенең куркыныч дошманнарының берсеннән [Аксак Тимердән] котыла.* Ф.Урманче

НӘТИҖӘЛӘНҮ *ф. сир.* Тәмамлану, бетү. *Икенче якта, поездга артык тоткарлык ясау фронттан кайтучы «дезертирларның» кораллы кузгалышлары белән нәтиҗәләнү куркынычын китереп бастырган иде.* Ш.Камал

НӘТИҖӘЛЕ *с.* 1) Нәтиҗәсе уңышлы булган; нәтиҗә (*1 мәгъ.*) белән бетә торган. *Бүтәннәр катнашыннан башка гына, күзгә-күз сөйләшеп, Зөфәр эшне, ниһаять, нәтиҗәле ахырына җиткерергә булды.* Ә.Еники. *Илебездә тарихыбызны яңарту, андагы ак тапларны бетерү буенча нәтиҗәле эш алып барыла.* К.Ситдыйков. *Мин бит үземнең эшемнең кирәкле һәм нәтиҗәле икәненә ышанам.* М.Мәһдиев

2) *грам.* Сөйләүче үзе күрмәгән, катнашмаган яки анык белмәгән эш, хәл, хәрәкәт турында бары аның нәтиҗәсе буенча гына хәбәр иткәндә кулланылган (хикәя фигыльнең заман формасы тур.); билгесез. *Нәтиҗәле үткән заман -ган, -гән, -кан, -кән кушымчалары белән ясала.* Татар грамматикасы

НӘТИҖӘЛЕЛЕК *и.* Нәтиҗәле булу дәрәҗәсе. *Шунысы мөһим: Тукай үз иҗатының нәтиҗәлелеге, иҗтимагый яңгырашы хакында да җитди уйлана.* Х.Миңнегулов. *Һәр учреждениенең эш нәтиҗәлелеге үзләренчә бәяләнәчәк.* Ватаным Татарстан

НӘТИҖӘСЕНДӘ *бәйл.* Берәр нәрсә аркасында, сәбәпле. *Әдәби телдән читләшү, туган телне белмәү нәтиҗәсендә әхлакый яктан тәрбиясез булып үскән кешеләр белән очрашырга мөмкин.* С.Мәхмүдов. *Сөйләшүләр нәтиҗәсендә Мостафин үзе дә йорт салдыру мәсьәләсен хәл кылынып беткән шикелле тоя башлый иде.* Ә.Еники. *Сыгылу һәм ярылулар нәтиҗәсендә коры җирнең шактый зур өлеше Тын океан төбенә төшкән, Яңа Гвинея һәм Тасмания утраулары аерылган.* Материклар һәм океаннар географиясе

НӘҮБӘТ *и. гар.* 1) Чират. *Бик мөһим сәхнә әсәрләре басмаханәдә нәүбәт көтәләр.* Г.Ибраһимов. *Паровозлар, берсен-берсе этеп, Нәүбәт тора ишек янында.* Х.Туфан. *Әнә Тукай кичәнең өченче бүлеген, ягъни үзенең нәүбәтен көтеп утыра.* И.Нуруллин

2) Пост; постта тору

НӘҮБӘТЛӘП *рәв.* Чиратлап, чират белән. *Бакча остасы Хәйрүш бабай әллә кайчан инде торып, үзенең сөекле гөлләренә нәүбәтләп авыз эченнән әллә нинди догасын укып, чандыр вә*

сөяктән гыйбарәт булган кулындагы киң борынлы гөл сипкечтән суын сибә иде. К.Тинчурин

НӘҮБӘТЛӘШҮ *ф.* Чиратлашу. *Юан Зәки, Гыйният, Нургали һәм тагы берничә шәкерт, челтәрле тимер капка төбендә нәүбәтләшеп сакта торып, урамга бер шәкертне дә чыгармадылар.* К.Тинчурин. *Кафия – ишетелүләре бертөрле авазларның нәүбәтләшүе ул.* Х.Туфан

Нәүбәтләшеп тору Ниндидер бер вакыт аралыгында нәүбәтләшү; һәрвакыт нәүбәтләшү. *Күңелендә өмет һәм өметсезлекнең, кайгы һәм шатлыкның нәүбәтләшеп торуын шагыйрь үзе дә әйтә...* И.Нуруллин

НӘҮБӘТТӘГЕ *с.* Чираттагы. *Ишек, нәүбәттәге ике корбанны иректән мәхрүм итеп, яңадан шапылдап ябылды.* М.Галәү. *Күпмедер вакыттан соң «Яшь ленинчы»ның нәүбәттәге юбилее җитте.* Р.Зәйдулла

НӘҮГЪ *и. гар. иск.* **1.** Төр, җенес; зат; сорт. *Бу дәхи симия нәүгыннандыр.* К.Насыйри. *Бу ике нәүгъ хәерчедән соң халык та җыела башлады.* Г.Ибраһимов

2. *с. мәгъ.* Төрле. *Тукаевның сөю шигырьләре башка нәүгъ шигырьләреннән бер дә калыш түгел.* Ж.Вәлиди

НӘҮГЫ *и. гар. иск. к.* **нәүгъ**. *Мәсәлән, иске зиратлар казылса, күбесенчә тимер нәүгысеннән ясалган болгар нәрсәләре чыгадыр.* Г.Әхмәров. *Тарихта бөеклек вә ихтирам илән урын алган әрбабе кәмаль – һәммәсе дә менә шул нәүгы инсаннардыр.* Г.Ибраһимов. *Я Ходa, шулай да була микәнни? Шундый икейөзле микәнни хатын-кыз нәүгысы?* А.Расих

НӘҮМИЗ *с. фар. кит.* **1.** Күңелсез, боек, өметсез. *Яңгырады аһым, чөйде таулар, Кайтты, сулгып, нәүмиз кайтавазлар, Сине табалмадым.* М.Галиев. *Тимерчеләр башы авызыннан бу сүзләрне ишетүгә, Атилла олан бермәлгә ачкан авызын ябалмый торды, ул нәүмиз рәвештә остага текәлде.* М.Хәбибуллин. *Раян нәүмиз карашын аңа төбәп, каударланып кабатлады: – Ярдәм итегез... Зинһар, ярдәм итегез миңа!!!* Р.Габделхакова

2. *рәв. мәгъ.* Боегып, күңелсез генә, чарасыз бер хәлдә. *Рәшидә, кичерү сорагандай, нәүмиз генә елмаеп, ике кулын да күкрәгенә куеп, халыкка кат-кат башын иде.* Ә.Еники

НӘҮМИ́З БУЛУ *ф. к.* **нәүмизләнү**. *Вә һәм болар солтан ишегеннән нәүмиз булып, бу шәһәргә бәла иңсен, дип киткәннәр.* К.Насыйри. *Гәүһәрия мондый кинәтлекне көтмәгән иде, борчылып, нәүмиз булып, контора ишеге төбендә аларны [Гәрәйләрне] озатып калды.* А.Гыйләҗев. *Хәйрун нәүмиз булып читкә борылды.* Р.Зәйдулла

НӘҮМИ́З ИТҮ *ф.* Күңелне боектыру, күңелне төшерү, өметсезлеккә төшерү. *Нәүмиз, ятим иттең бәгырь кисәгеңне «Әни» дигән назлы сүзләрдән.* Р.Каюмов. *Ул, кемдер нәүмиз иткән сабыйны юатырга җыенган кебек, Самат янына килде һәм шундый ук эчкерсезлек белән аңлатмакчы булды.* Р.Ишморатова

НӘҮМИЗЛӘНҮ *ф.* **1.** Күңелсезләнү, боегу, өметсезлеккә бирелү. *Аңа нәүмизләнергә ярамый, юк, ярамый, аның үз эше, үз урыны бар.* Ә.Еники. *– Нигә берәр кеше алмыйбыз соң, Рәкыйп абый? – диде Идрис, нәүмизләнеп.* А.Гыйләҗев. *Кайчан ул үзалдына кызарып куя, ниндидер яман гөнаһта тотылган баладай нәүмизләнә, хафага кала иде.* М.Хәбибуллин

2. *и. мәгъ.* Өметсезлек, боегу, чарасызлык. *Атилла олан үзалдына сөйләнгәндәй: «Килер бер көн, мин дә Тәңре кылычын тотып яу чыгармын һәм Рим легионерлары кулындагы канкардәшләремне мәңгегә азат итәрмен», – дип, балаларга хас нәүмизләнү белән кинәнде.* М.Хәбибуллин. *Милициянең үз ятьмәсенә эләккән кешене, кем генә булса да, җиңел генә чыгарып җибәрәсе килми... Шәхси әйберен югалткандай нәүмизләнү кичерә.* Р.Зәйдулла

Нәүмизләнә төшү Бераз гына нәүмизләнү, боегып калу. *– Олан, Атилла олан, – диде тимерчеләр остасы нәүмизләнә төшеп. – Атилла олан, ясармын мин сиңа ул кылычны.* М.Хәбибуллин

Нәүмизләнеп йөрү Озак вакыт нәүмизләнгән хәлдә булу

Нәүмизләнеп калу Кинәт өметсезлеккә бирелү, чарасыз калу. *Салих, минем боегып, нәүмизләнеп калуымны күреп, ике кулымнан тотты ---.* Ә.Еники. *Тугандыр да бала чак, үсмер чак, егет чак дигән матур, ulаһu төшләр күреп кенә ымсынып, кызыгып, нәүмизләнеп калгандыр?* А.Гыйләҗев. *Кыз кайтып киткәч, Кутуй сабыйларча нәүмизләнеп калган дустының җилкәсенә кулын салып, көйли-көйли: «Сездә галим булса, бездә галимә бар, Сездә шагыйрь булса, бездә – шагыйрә», – ди.* Р.Туфитуллова

Нәүмизләнеп китү Соңгы вакытларда нәүмиз хәлгә төшү. *Габбас мулла кызының янә дә караңгыланып, нәүмизләнеп киткән чыраена карап торды, бер сүз дә әйтмәде.* Г.Ахунов

Нәүмизләнеп тору Нишләргә дә белмичә тору, чарасыз калу

Нәүмизләнеп утыру *к.* **нәүмизләнеп тору**. *Аның мулла песие кебек нәүмизләнеп утыруын күрер өчен төштекмени без җәяүләп Җидегәннән?* А.Хәлим

НӘҮМИЗЛЕК *и. кит.* Күңелсезлек, өметсезлек, боеклык. *Оныт нәүмизлекне, оныт; Күрәмсең, күктә бар болыт, Явар рәхмәт, явар әле.* Г.Тукай. *Нәүмизлек баса мине, авыр миңа, әмма ләкин түзәргә кирәк инде, сабыр итәргә, өметне учтан төшермәскә кирәктер...* Ә.Еники

НӘҮРӘП *и. рус диал.* Баз, өсте ябык азык-төлек саклау чокыры. *--- картның үзенә дә ике мәртәбә кагылдылар. Ләкин өйгә түгел, нәүрәп белән келәткә генә.* Г.Ибраһимов. *Нәүрәп өсләрен ныгытасы, бура тактасын алыштырасы юк: кар базларын тоташтан күмгәннәр, аларын дәү-дәү ак аюлар – холодильниклар алыштырган.* А.Гыйләҗев

НӘҮРҮЗ *и. фар.* 1) Борынгы Шәрык календаре буенча яңа ел башы көне, төрки һәм иран халыкларында яңа елны каршылау бәйрәме (төн белән көннең язгы тигезлек көне, 21 нче мартка туры килә). *Нәүширван патша нәүрүз көнендә үзләренең гадәтләренчә зияфәт ясады.* К.Насыйри. *Гасырлардан гасырларга, офыклардан офыклар-*

га Оча-оча Нәүрүз кайта тарихтан оныкларга. Д.Гыйсметдин

2) *бот. к.* **нәүрүз гөле**. *Хәзер нәүрүз түтәлләрдә зур булып үсте тәмам.* Ә.Ерикәй. *Кыргый нәүрүзнең тамырларын һәм тамырчаларын көз көне, үсемлек шиңгәч казып алалар.* Урман аптекасы

НӘҮРҮЗГӨЛ *и. бот. к.* **нәүрүз гөле**

НӘҮРҮ́З ГӨЛЕ *и. бот.* Нәүрүзгөлчәләр семьялыгыннан язын һәм көзен төрле төстә күп чәчәк ата торган гөл; яз гөле; *русчасы:* **примула, первоцвет**. *Ә менә бусы, җәй башы гына булуга карамастан, чәчәген коеп та өлгергән нәүрүз гөле бугай.* Ф.Шәфигуллин

НӘҮРҮЗГӨ́ЛЧӘЛӘР *и. күпл. бот.* Күбесенчә яфраклары тоташ, чәчәкләре ике җенесле үләннәр рәте һәм семьялыгы

НӘҮРҮ́ЗЧӘЛӘР *и. күпл. бот. к.* **нәүрүзгөлчәләр**. *[Кыргый нәүрүз –] Нәүрүзчәләр семьялыгыннан.* Урман аптекасы

НӘҮХӘ *и. гар. иск.* Мәет озатканда тавыш белән такмаклап-такмаклап елау; сыгыт. *Вәзир падишаһның бу нәүхәсен ишетеп әйтте: «И падишаһ, ник бу кадәр тоташ егълайсың?»* К.Насыйри

НӘФАСӘТ *и. гар. иск. кит.* Нәфислек, гүзәллек. *Бу вакытта миндә нәфасәт белән ләззәтләнүдән башка бернәрсә дә юк иде.* Ф.Әмирхан. *Нәфасәт багында мөхтәрәм төрек бәйләре белән култыклашып йөрер вакытлар җитмәгән әле, күрәсең...* Ә.Еники

НӘФӘКА *и. гар. иск.* 1) Яшәү өчен кирәк булган мал, азык, акча кебек нәрсәләрнең бөтене. *Бу хәдис нәфәкалары лязем булган кешеләргә нәфәка бирми торуның гөнаһы никадәр зур икәнлекне аңлата.* Р.Фәхретдин

2) Берәүгә насыйп булган, язган нәрсә, берәүнең өлеше. *Син бер кешенең нәфәкасен бирмәенчә үзеңә алсаң, аның җанын алган кебек булырсың.* К.Насыйри

НӘФӘКАЛӘНҮ *ф. иск.* Яшәү, тереклек итү өчен кирәк нәрсәләр белән тәэмин ителү. *Хәмелчеләр янына барып утыр, кемнең йөген күтәреп илтсәң, сиңа дүрт-биш тиен бирерләр. Шуның белән нәфәкаләнерсең.* К.Насыйри

НӘФӘКАЛЕК *и. иск. к.* **нәфәка**. *Бу көннән йөзәр ел хисап итеп, бер кешегә һәр көндә меңәр акча нәфәкалек биргәч, йөз елга күпме җыелыр, боларга һәм шулкадәр бирәм.* К.Насыйри. *[Үзбәк хан] Безгә нәфәкалек хәзерләү хакында әмер бирде, урын әзерләтте.* Р.Фәхретдин

НӘФЕГЪ *и. гар. иск.* Файда. *Дәхи гыйлем үгрәтерсә талиблары арта калыр, Монларның нәфегъ кабрә доташыр имди.* Кол Мөхәммәд

НӘФЕЛ *и. гар. дини* Савап казану өчен фарыз һәм вәҗиблардан тыш кылынган гамәл-гыйбадәт. *Байлар нәфел корбаны дип бер сарык чалдылар.* Ә.Фәйзи. *Мәдрәсәдә күп яткан пишкадәмнәр вә хәйләле яшьләр, халык акшамнан чыкканчы нәфел намазы укып калырга да, халык чыккач, алгы сафны эләктерергә уйлап, акшамга кесәләренә күмәч тыгып киттеләр.* Г.Ибраһимов. *Ләкин без фарыз, нәфел уразаларны бөер-бавырларны чистарту өчен түгел, ә Аллаһ риза булсын дигән ният белән тотабыз.* Ватаным Татарстан

◊ **Нәфел уразасы тоту** Ач тору

НӘФЕС *и. гар.* 1) Нәрсәгә булса ия булырга көчле омтылыш; күпне өмет итү, комсызлык. *Ә бай кешенең нәфесе арта бара, диләр, Юстин хуҗа ниндидер юллар белән ясак түләүдән котылып калмакчы.* М.Хәбибуллин. *Нәфес дигән азгын нәрсә миндә дә бар, Ирек кенә бир син аңа, йөгәнләмә...* З.Мансур // Көчле теләк. *Лимон авыру карчыкның нәфесе бик теләп торган нәрсәсе иде ---.* Ә.Еники. *Нәфесе зур иде егетнең, һәм ул иренмәде, чакрымнар урап, нарат эзләде.* Н.Гыйматдинова. *Һәр адәмдә дүрт нәрсә бар: дәрт, нәфес, күңел, йөрәк, Ни эшләмә, кая барма – шулар барсы да кирәк.* С.Хәйруллин

2) Күңел. *Нәфес тартса, кулга керсә, кайсыбыз соң тартына.* М.Гафури // Җан, рух. *Хак Тәгалә аларга [фәрештәләргә] адәм нәфсе кебек нәфес бирде, җир йөзенә иңдерде.* К.Насыйри // Кешенең үз-үзен генә, үз мәнфәгатьләрен генә кайгырткан, начар юлга этәргән, тискәре сыйфатларга гына ия хайвани, бозык җаны. *Ләкин шулай да, нәфес дигән нәрсә туймыйдыр, күрәсең.* М.Галәү.

3) *иск.* Үзе. *Безнең теләгәнне эшләп, теләмәгәнне ташлап йөргән, нәфсемез белгәнне укытып, белмәгәннәремезне мөгаллимнән укыттырырга ничек разый улыр?* Г.Ибраһимов

◊ **Нәфес сузу** Өметләнү, кызыгу; күпне өмет итү, комсызлык күрсәтү. *Менә шушы җиләктәй мәхзүмәгә безнең Коръәнхафиз нәфесен суза да инде.* Ә.Еники. *«Рәис түгел икәнсең, нәфесеңне сузма, агай-эне» дигән кагыйдә күпләрнең дәртен баса килде.* Т.Миңнуллин. *Мине ал дип әйтмим, дөньяда кыз бетмәгән, ләкин Зөбәйдәгә нәфесеңне сузма.* М.Шаһимәрдәнов. **Нәфес тыю** Ярамаган эштән тыелу, тукталу; аз белән канәгатьләнә белү, күпкә кызыкмау, комсызлык күрсәтмәү. *Кеше кылмас гөнаһ эшне, әгәр дә нәфсен тыйса...* М.Гафури. *Бу йорт хакына нәфесне бераз тыярга да була.* Ә.Еники. *– Авызыңны тегеп куя алмыйм ич!.. – Монда, Тайфәбикә, авызны тегәргә түгел, нәфесне тыярга кирәк!* М.Шаһимәрдәнов. **Нәфес төшү** Кызыгу, күз кызу. *Аннары каената шунысын да ишеткән иде: сугыш чорында Карибулла Нурсадә белән Әлфиягә нәфесе төшеп, аларның икесен дә хатыны итәргә чамалап йөргән ләбаса!* М.Шаһимәрдәнов. **Нәфескә баш булу** *к.* **нәфес тыю**

НӘФЕСЛЕ *с.* Нәфесен тыя белмәгән, күпне өмет итүчән; туймас, комсыз. *Нәфесле булгай үзе, Үтемле булгай сүзе; Корсагы гәр туйса да, Туймагай һич тә күзе.* Г.Тукай

НӘФЕС-ШАЙТАН *и. гар.* Бозыклыкка, азу-тузуга өнди торган эчке тойгы, теләк. *Нәфес-шайтан, бик явыз ул, һәр адәмне аздыра.* Ш.Бабич. *Буйсынып нәфес-шайтанга Ырғылмак булам өскә...* Ф.Яруллин

НӘФИС *с. гар.* **1.** 1) Гүзәл, матур; зифа, сылу. *Озын зифа буйлы, алсу иреннәре арасыннан энҗедәй тигез ак тешләре ялтырап торган нәфис йөзле бер хатын иде ул [Гөлнар ханым].* М.Галәү. *Башта, болан баласыдай, эчке калтырану белән курка-курка гына*

кулга бирелгән нәфис, сылу Нәҗия тиз арада аңа шулкадәр ияләнеп китте, әйтерсең аның сулышына әверелде... Ә.Еники. *Ә инде мәшһүр Урал таулары, бай, гүзәл, матур табигатьле башкорт җире, Агыйдел, Дим, Караидел буйлары, хуш ис бөркеп торган чәчәкле хозур болыннар, зәңгәр күзле күлләр... – бөтенесе, һәммәсе, нәфис сынлы зифа кызга әверелеп, үз кочагына ала сине.* С.Поварисов // Формасы, күләме ягыннан җыйнак, килешле булган. *Сөләйман кызга каршы барып, аның нәфис, матур кулларын үз кулларына алды.* К.Тинчурин. *Күзләре тулы күл кебек зәп-зәңгәр иде бикәнең, керфекләре озын, кайтарылып тора, төз вә нәфис борыны сипкелләр белән чуарланган.* М.Хәбибуллин. *Артымда басып торган хәлдә, озын нәфис бармакларыгыз белән чәчләремне сыйпарсыз.* Р.Зәйдулла

2) Матур, юка һәм затлы (тукыма һ.б.ш.). *Мөбарәк булсын, падишаһ, бик нәфис шәл булган.* К.Насыйри. --- *алар [сатып алучылар] үзләрен бик иркен тоталар, төрле төстәге нәфис ефәк төргәкләрендә актарынган булып, сөйкемле кибетчеләр белән уен-көлке сөйләшәләр, көязләнәләр, чытлыкланалар.* М.Галәү. *Галия, нәфис шәленә төренеп, булмәнең бер почмагыннан икенче почмагына йөренә.* Ф.Әһлиуллина

3) Тотып карауга рәхәтлек тудыра торган, йомшак. *Минем күз алдымда моннан сигез ел элек: «Сезнең чәчегез нинди йомшак, нәфис», – дип килеп танышкан Искәндәр иде.* Г.Кутуй. *Тәне әүвәлгечә җылы, йомшак, затлы, нәфис киемнәреннән хуш исләр бөркелеп тора.* Н.Фәттах. *Нәфис мамык*

4) Тиз бозылучан, зәгыйфь кенә. *Нигә, язын бакчага утыртканда, кәбестәнең дә ике нәфис яфрагы гына була.* С.Сөләйманова

5) Нәзакәтле, матур; артыгын кыланмаган (хәрәкәтләр, үз-үзеңне тотыш тур.). *Сәхнәгә кара фрак кигән, матур сынлы, нәфис хәрәкәтле бер егет чыгып басты.* Г.Бәширов. *Юк, бу мактанулы илбасарлар биюе дә түгел, шапырынулы таптанулар да түгел, татарның биюе үзе шикелле үк тыйнак, нәзакәтле һәм нәфис.* А.Гыйләҗев

6) Матур, ягымлы, аһәңле (тавыш тур.). *Алар [талантлы яшьләр], барыннан да элек үзләренең давыллы, дулкынлы, кайнар фикерләрен нәфис, ягымлы, пөхтә тел белән – җырлап тора торган шигъри тел белән – метафорик итеп әйтеп бирә алалар.* Х.Туфан. *Кинәт Диләнең колагына «зеңзең» иткән нәфис тавыш ишетелде.* Н.Гыйматдинова. *Шул чакны кайдадыр бик якында, янәшәдә генә үтә нәфис, үзәк өзгеч көй ишетелә.* Ф.Әһлиуллина

7) Тәмле, хуш (ис тур.). *Мин хәтта әйтер идем, бу «интеллигентлык» аңардан ничектер менә нәфис бер ис шикелле аңкып тора кебек иде.* Ә.Еники. *Европача костюмнан, галстуктан, штиблеттан, тук чырайлы, юантык гәүдәле ирләр нәфис хушбуй исләрен бөтен утарга тараткан, асыл күлмәкле, калфаклы хатыннарын, кулларыннан тотып, җиргә төшерделәр.* Г.Ахунов

8) Бик оста һәм тәмле итеп пешерелгән, әзерләнгән (ашамлык тур.). *Әмма зәнкиләр шаһзадәне, кырык хезмәтчеләрен нәфис вә ләззәтле тәгамнәр белән тәрбия кыйлдылар.* К.Насыйри

9) Сәнгатьчә эшләнгән, сәнгатькә, сәнгать өлкәсенә караган; чынбарлыкны образлар аша чагылдыра торган. --- *уртак шәхесләребез турында һәм документаль, һәм нәфис фильмнарны Төркия киночылары белән Татарстанныкылар уртак эш итеп башкарсын иде.* Р.Батулла. *Хәзерге кыргый базар шартларында безгә, мәсәлән, төрекнең поэзиясеннән бигрәк каеры туны (дублёнкасы) кирәк, төрекләргә безнең нәфис әдәбиятыбыздан бигрәк нефтебез кирәгрәктер.* Ә.Еники. *Түрә, әлбәттә, нәфис әдәбиятны күздә тоткан.* Р.Зәйдулла

10) *спорт.* Гимнастиканың музыка ритмына коршау, туп, тасма һ.б.ш әйберләр белән яки бернәрсәсез төрле гимнастик һәм бию күнегүләре ясаудан гыйбарәт төренә караган. *Ә менә мәгълүм заводта инженер-конструктор булып эшләүче Гадилә туташ спорт белән, аның да нәфис гимнастика төре белән шашып мавыга, имеш.* М.Шаһимәрдәнов

11) Рәсем сәнгате, сынлы сәнгать, архитектура һәм музыканы берләштергән, һөнәрчелектән аермалы буларак саф сәнгатькә генә караган. *Сез әлегәчә әдәбиятка, нәфис сәнгатькә, бигрәк тә музыкага мөнәсәбәтегездә яхшыны – яманнан, чынны ясалмадан аера алуыгызны расладыгыз.* Х.Туфан

2. *рәв. мәгъ.* 1) Күркәм итеп, мөлаем, ягымлы итеп. *Ак яулык аның --- йөзен тагын да чистарак, нәфисрәк күрсәтә кебек.* Ә. Еники

2) Нәзакәт белән, матур итеп, назиканә, артык кыланмыйча (хәрәкәтләр, үз-үзеңне тотыш тур.). *[Михаил] озын вә матур сынын нәфис бөкрәйтебрәк тора.* Ф.Әмирхан. *Кыз нәфис кенә итеп скрипканы кулына алды.* А.Шамов

◊ **Нәфис зат** Хатын-кыз. *Белем дәрәҗәсе, тормыш тәҗрибәсе буенча да нәфис затлар ирләрдән югарырак тора.* Мәдәни җомга

НӘФИСЛӘНҮ *ф.* Нәфис булып китү, матурлану, ямьләнү. *Мәңгеяшел чыршының ылыслары тагы да нәфисләнеп, юкарып китте.* Казан утлары

Нәфисләнә бару Торган саен нәфисләнү. *Нәфисләнә барса безнең хисләр, Күркәмләнә бара күңелләр.* Х.Туфан

Нәфисләнә башлау *к.* **нәфисләнеп китү**

Нәфисләнә төшү Элеккедән дә ныграк нәфискә әйләнү

Нәфисләнеп калу Ниндидер процедура һ.б.ш.дан соң нәфисләнү. *Шулай йөри торгач, ул атның биле зифа буйлы кызларныкыдай нечкәреп, нәфисләнеп кала.* Ватаным Татарстан

Нәфисләнеп килү Әкренләп кенә нәфисләнү

Нәфисләнеп китү Соңгы вакытта, күзгә күренеп нәфисләнү. *Аның шигырьләрендә гап-гади, көндәлек, без инде тәмам күнегеп беткән көнкүреш кинәт яктырып, нурланып, нәфисләнеп китә.* Г.Рәхим

НӘФИСЛӘ́Ү *ф.* Нәфис итү, матурлау, ямьләндерү. *Дуслык кешенең күңелен сафландыра, димәк, ул кешенең барлык башка хисләрен нәфисли.* Г.Әп-

сәләмов. *Табигать матурлыгы аның хис-тойгыларын нәфисли.* Кызыл таң

Нәфисләп тору Нәфислек бирү; хәзерге моментта нәфисләү, матур итү

Нәфисли төшү Элеккедән дә ныграк нәфисләү

НӘФИСЛЕК *и.* Нәфис булу. *Нәфислекне бик нечкә тоя торган гаҗәп сизгер җан бар иде аңарда...* Ә.Еники. *Болар бары тик буш, артык төче сүз булып кала, аның нәфислеген, мөлаемлыгын, гүзәллеген аңлар өчен, унсигез яшьлек бу кызның үзен күрергә кирәк.* Р.Батулла

НӘФИС СҮЗ *и.* Әдәби әсәрләрне сәнгатьчә сөйләүдән гыйбарәт эстрада жанры. *Бүген клубта концерттамаша була. Программада: җырлар, биюләр, оригиналь жанр һәм нәфис сүз.* Г.Шакирова. *«Галия» мәдрәсәсенә мөгаллимлек итәргә килгәнче ук Галимҗан Ибраһимов татар, башкорт һәм башка төрки телле халыклар арасында мәшһүр язучы, көчле тәнкыйтьче, нәфис сүз сәнгате остасы --- буларак таныткан иде инде үзен.* С.Поварисов

НӘФРӘТ *и. гар.* Иң көчле дошманлык, кемгә дә булса начарлык теләү, җирәнү хисе, күралмау. *Миллион йөрәктәге нәфрәт уты Кояш булып янар бу язда...* М.Җәлил. *Ләкин ул [Галиуллин] шулай ясалма кыланган саен, минем нәфрәтем тагын да арта барды.* Г.Кутуй. *Адәм балаларын дарга асучы палачларга булган нәфрәтем, эчемә сыймыйча, ташып чыга.* М.Юныс

НӘФРӘ́Т ИТҮ *ф.* Кемгә яки нәрсәгә карата нәфрәт хисләре кичерү. *Кирәк мәктәп эчендә, кирәк башка җирдә әдәпсез сүз сөйләшмәгез, тиешсез ишарәләрдә булмагыз, чөнки мондый әйберләрдән тәрбияле балалар нәфрәт итәр.* Р.Фәхретдин. *Итәм кайчак бөтен инсанга нәфрәт, Бу нәфрәттән туа күңлемдә хәсрәт.* Г.Тукай. *Күрәсезме?! – Сезгә нәфрәт итеп, Көлә-көлә кылыч сайлыйбыз!* Һ.Такташ. *Шунлыктан ачык итеп әйтәм: моннан 35 ел элек вафат булган мәрхүм язучыбызның рухын рәнҗәтмик, ул немецларның Гитлерына нәфрәт итә иде.* Г.Акыш

НӘФРӘТЛӘНДЕРҮ *ф.* Нәфрәт уяту, нәфрәт хисләре кузгату. *Болар иҗат кешеләрен борчый, уйландыра, нәфрәтләндерә, үз кичерешфикерләрен әсәрләргә күчерергә этәрә.* А.Әхмәдуллин. *Аннары, аучыны әйтеп аңлата алмаслык ачу да уттай өтә, нәфрәтләндерә иде.* З.Мурсиев

Нәфрәтләндерә бару Торган саен ныграк нәфрәтләндерү

Нәфрәтләндереп йөрү Күптәннән бирле, шактый вакыт нәфрәтләндерү

Нәфрәтләндереп кую Кинәт, сирәк кенә нәфрәтләндерү

Нәфрәтләндереп тору Гел нәфрәтләндерү; хәзер нәфрәтләндерү

НӘФРӘТЛӘНҮ *ф.* Бик көчле нәфрәт кузгалу, бик нык ачу килү. *Бозыклыклардан нәфрәтләнү генә аз.* Г.Әпсәләмов. *Ярсымыйк һәм нәфрәтләнмик тә, нинди вазгыятьтә ни көтәсен белеп эш итик – бары шул гына.* Рәф.Юныс. – *Чынлап та! – дидем мин нәфрәтләнеп һәм кинәт артка чиктем дә уң аяк белән бар куәтемә ишеккә типтем.* М.Шаһимәрдәнов

Нәфрәтләнә бару Торган саен ныграк нәфрәтләнү

Нәфрәтләнеп йөрү Күптәннән бирле, шактый вакыт нәфрәт саклау

Нәфрәтләнеп кую Кинәт, сирәк кенә нәфрәтләнү. *Дөрес, соңыннан ул [Зөфәр] еш кына бу йомшаклыгы өчен әрнеп үкенә, бик кимсенә, хәтта үз-үзеннән нәфрәтләнеп тә куя иде.* Ә.Еники

Нәфрәтләнеп тору Гел, һәрвакыт нәфрәтләнү; хәзер нәфрәтле булу

НӘФРӘТЛЕ *с.* 1) Күңелендә нәфрәт хисе булган, нәфрәтләнгән (кеше тур.). *[Уел:] Ник шулкадәр нәфрәтле сез аңа [Касыймга]?* З.Хәким

2) Нәфрәт белән сугарылган. *Дошманга нәфрәтле, ә дусларына чиксез мәхәббәтле нәни йөрәгенә мин сөйләгәннәрнең барын да чәчми-түкми сыйдырырга, һәммәсен дә аңларга, төшенергә тырышып утыруы иде бу аның.* А.Хәсәнов

3) Нәфрәт хисен чагылдырган. – *Рәсәйдән аерылырга ярыймыни инде, – дип мыгырданды Сөләй Акт, тирәюньдәге кешеләрнең нәфрәтле карашын күрмәмешкә сабышып. – Рәсәй бит ул! Зур бит ул!* М.Шаһимәрдәнов. *Канәгать артына борылып, нәфрәтле карашы белән яланны көйдереп алды.* А.Хәлим

НӘХҮ *и. гар. лингв. иск.* Синтаксис. *Язу өстәлендә Әминәнең Анна Петровнадан алып укый торган китаплары (рус нәхүе, рус тарихы вә француз --- китаплары) һәм бер-ике сурәтле журнал да саклана иде.* Ф.Әмирхан. *Гарәп сарыфы (морфология) һәм нәхүенә (синтаксис) шәкертләр шактый буй үстергәч төшәләр.* И.Нуруллин. *Шуның өчен сарыф вә нәхү мәсьәләләрендә яңарак кына кылган хаталарыбызны тизрәк төзәтергә --- тиешбез.* Х.Әбүлхан

НӘҺӘР *и. гар. иск.* Көн, көндез, тәүлекнең якты өлеше. *Качан соң, и фәкыйрь милләт, бәһарең! Качан китәр кичең, килер нәһарең!* Г.Тукай

НӘҺЕР *и. гар. иск. кит.* Елга, дәрья. *Алла биргән су юлларын, бабаларымызның милке булган Идел нәһерен үземезнең штат эченә кертергә тиеш.* Г.Исхакый. *Әллә кемнәр күкрәгең белән шаярмакчы була. Чү! Аны болгатмасыннар, анда илһам нәһере бар.* Х.Туфан. *Идел нәһре кайсы диңгезгә коя?* Г.Бәширов

НӘЧӘ́ЛНИК *и. рус сөйл. к.* **начальник**. *Халык бирмәгән инде ул исемне, әлбәттә, ниндидер нәчәлникләр биргән.* Р.Зәйдулла. *Нәчәлник чыкмый миннән, валлаһи!* Н.Гыйматдинова

НӘШАТ *и. гар. иск.* Шатлык, сөенеч, кәефлелек, җанлылык, дәрт. *Халыкта кичәге нәшат, кичәге җан калмаган иде: бүген тын, басынкы, авыр.* Г.Ибраһимов. *Менә икенче көн Мостафа нәшатсыз, рухсыз, кәефсез йөри.* Ф.Әмирхан

НӘШӘ *и.* Киндераштан ясала торган көчле наркотик матдә; анаша. *Аларда тик шул гына бар: әтәч, бүдәнә сугыштыру, нәшә тарту, әфьюн салу!..* З.Бәшири

НӘШЕР *и. гар.* Матбугатта бастыру эше, басма. *Һәм бу газетаны һәркем белә; шуның өчен күп вакытта бер дә заглавиесез чыга, фәкать хосусыйрак көннәрдә генә заглавие куела. Анда да иртәнге нәшерендә генә.* Ш.Камал. *Күпмедер вакыттан соң [Тукай] ---*

«Крылов басняларын тәмам итүен, --- Камил Мотыйгыйга нәшер өчен биреп, калэм хакына 25 тәңкә алырга муафикъ булганын» бик куанып яза. И.Нуруллин

НӘШЕ́Р ИТҮ *ф.* Матбугатта бастырып чыгару. *«Әдәби ярдәм мәҗмугасы»ның икенче китабын нәшер итеп, бөтен килерен ач балаларга багышларга --- карар бирелде.* Г.Ибраһимов. *Мәскәүдә яшәү чорында ул, минемчә, урыс телендә бер генә китап нәшер итә алды.* Р.Зәйдулла

НӘШРИЯТ *и.* Матбугат әсәрләрен чыгару һәм тарату эше белән шөгыльләнүче учреждение. *Мәктәпләр юлга салынып килә, дистәләгән исемдә газета-журналлар чыгып тора, китап нәшриятлары, бер-бер артлы туып, меңәрләгән тираж белән китап басып тараталар ---.* И.Нуруллин. *Кульязманы инде нәшриятка тапшырырга әзерләп бетергән көнне төнлә мин төш күрдем.* М.Мәһдиев. *Аны төрлечә кыса башлыйлар (мәсәлән, язган әйбереңне басмыйча йөдәтәләр яки нәшрияттагы китабыңны планнан сызалар).* Ә.Еники

НӘШРИЯТЧЫ *и. сөйл.* Нәшриятта эшләүче; нәшрият хезмәткәре

НЕВРАЛГИ́Я *и. гр. мед.* Периферия нервларының зарарлануы сәбәпле аерым әгъзаларның өянәк тотуы белән характерлана торган нерв авыруы. *Невралгия еш кына 40–45 яшьтән соң башланып китә.* Ватаным Татарстан. *Кабырга арасы невралгиясе. Өчьяпле нерв невралгиясе*

НЕВРАСТЕ́НИК I *и. рус мед.* Неврастения белән авыручы кеше

НЕВРАСТЕ́НИК II *с.* Неврастениягә караган, неврастениягә мөнәсәбәтле. *Неврастеник симптом*

НЕВРАСТЕНИ́Я *и. гр. мед.* Нерв системасының какшавы, талчыгуы нәтиҗәсендә барлыкка килә һәм тиз ярсып китү, ару һ.б.ш. симптомнар белән характерлана торган авыру. *Соңгы вакытта неврастения белән авыручылар саны артканнан-арта бара.* С.Шәрипова

НЕВРИТ *и. гр. мед.* Нерв ялкынсынуы һәм аның салкын тию, бәрелү, инфекция эләгү һ.б.ш. сәбәпләр аркасында тагын да көчәеп китүе

НЕВРОЗ *и. гр. мед.* Үзәк нерв системасының какшавы нәтиҗәсендә психикада, төрле органнарда һәм үзүзеңне тотышта төрле симптомнар белән характерлана торган авыру. *Башлап та җиренә җиткерелмәгән эшләрең күбәеп китсә дә, невроз килеп чыгуы ихтимал.* Ватаным Татарстан

НЕВРО́ЛОГ *и. мед.* Неврология белгече. *Баш мие функциясе эшчәнлеген элеккеге халәтенә кайтарыр өчен, берничә көн рәттән тирән йокыга талырга кирәк, дигән фикердә Пенсильвания университеты (АКШ) неврологлары.* Ватаным Татарстан

НЕВРОЛО́ГИЯ *и. гр. мед.* Нерв системасын һәм аның авыруларын өйрәнә торган медицина-биология фәннәре тармагы. *Аның акылына зарар килгән, диделәр, шахтаның үзәк больницасына неврология бүлегенә салдылар.* М.Мәһдиев

НЕВРОПАТ *и. гр. мед.* Нерв авырулы кеше. *Бала дөньяга психик чирле, невропат булып туарга мөмкин.* Кызыл таң

НЕВРОПАТО́ЛОГ *и. гр. мед.* Невропотология белгече. *Невропатологның газета аша җавап бирүе генә Гөлчирә ханымның баш әйләнүен туктатыр дип уйламыйм.* Ватаным Татарстан

НЕВРОПАТОЛО́ГИЯ *и. гр. мед.* Медицинаның нерв системасы авыруларын һәм аларны дәвалау юлларын өйрәнә торган тармагы

НЕГАТИВ I *и. нем. махс.* Пыялага яки тасмага төшерелгән сурәтнең кире чагылышы (караңгы урыннары якты, якты урыннары караңгы) булып төшкән рәсем; шундый рәсем төшерелгән пыяла яки тасма. *Монысын да ерткаларга мөмкин, миндә тагын шулкадәр, өч җиргә яшереп куелган, берсе янса, берсен урласалар дип, негативларын таш астында саклыйм.* Р.Батулла

НЕГАТИВ II *с. кит.* **1.** Тискәре, кире. *Халкыбыз характерындагы бик күп негатив үзенчәлекләр – инертлыклар, пассивлыклар кысылып калган мөселманнар арасында Ш.Мәрҗани, К.Насыйрилар башлаган юнәлеш үсеп китә алмауның нәтиҗәсе булып тора.* М.Гайнетдинов. *Демократиябез белән капитализмыбыз да башка илләрдәгедән үзгә килеп чыккан кебек, ил нигезен җимерә, халкыбызның дәүләткә, хөкүмәткә булган ышанычын кимергәннән-кимерә барган негатив күренешләр белән көрәшүебез дә үзенчәлекле.* Ватаным Татарстан

2. *и. мәгъ.* Тискәре, кире нәрсә; тормышның һ.б.ш. тискәре ягы; тискәре кабул итү үзлеге. *Үзара мөнәсәбәтләрне ике яссылыкта корырга мөмкин: негатив һәм позитив аша!* Безнең гәҗит

НЕГАТИВЛЫК *и.* Тискәрелек, тискәре булу, негатив булу

НЕГАТОСКОП *и. лат.-гр. мед.* Рентгенограммаларны, томограммаларны һ.б.ш.ны тонык пыяла аша үтеп чәчелгән яктылыкта карау җайланмасы. – *Әйе. Менә йөрәкнең зонд ярдәме белән алынган снимогы. – Профессор негатоскопны кабызды.* Г.Әпсәләмов

НЕГР *и. лат.* Негроид раса вәкиле; зәнки. *Негр йөри Мәскәү урамында --- Урамда кар --- Ул беренче тапкыр тота аны: «Әллә салкын, әллә пешерә?..»* Ш.Галиев. *Ап-ак спорт киемнәреннән кап-кара негр ап-ак диярлек сары чәчле Лэйсәрияне бер кулы белән биленнән кочаклаган, икенче кулына чалгы тоткан.* Җ.Юныс. *Каршыларына чабышкы атлардай дөп-дөп басып килгән алып гәүдәле негр егетләре ике арадагы нечкә җепне өзеп үтте.* Ватаным Татарстан

НЕГРО́ИД *с. исп.* **1.** Кешелекнең төп расасының берсенә хас булган сыйфатларны үз эченә алган: кара бөдрә чәч, каракучкыл тән, киң ямьшек борын, калын ирен; шундый кыяфәттәге

2. *и. мәгъ.* Шул раса вәкиле. *Җир йөзендәге негроидлар расасы 3 нче кешелек дөньясыннан калган халыклардан тора, дигән караш та бар.* С.Шәмси. *Нилның югары агымы районнарында яшәүче негроидлар бик кара тәнле булулары белән аерылып торалар.* Материклар һәм океаннар географиясе

НЕ́ГУС *и. абиссин. к.* **нәҗаши**

НЕДОИ́МКА *и. рус сөйл.* Салымның яки башка җыемнарның вакытында түләнми калган өлеше. *Хәйрулла*

агайның өлешенә тигән җирнең барлык игене бурычны түләргә дә җитми иде, шуның өстенә әле, ил булгач, түләү, недоимкаларны түләтеп теңкәгә тиеп, актык акчаларны алып китәләр иде. К.Тинчурин. *Кем белә бит, бәлки, әле ул [Тукай] недоимка җыюны да, түли алмаганнарның барлы-юклы әйберләрен сатуны да, недоимка өчен суктыруны да (Кырлайда андый хәл дә булган) күргәндер...* И.Нуруллин

НЕЙЛОН *и. инг.л.* **1.** Ясалма сүснең бер төре һәм шул сүстән эшләнгән тукыма. *Ай-һай, сиңа кыен, ә? Ә мин – түз! --- Минем нервлар капроннанмыни? Нейлоннанмыни? Ә?* М.Мәһдиев

2. *с. мәгъ.* Шул тукымадан эшләнгән, тегелгән, бәйләнгән. *Кәрим абзыйның өстендә ак нейлон күлмәк белән бик килешле утырган кара костюм.* Ә.Еники. *Ян өстәл кырыенда ак нейлон күлмәгенең җиңнәренә янтарь запонкалар эләктергән шома битле яшь оппонент сөйли башлаган иде.* М.Мәһдиев. *Урын-җирне өр-яңадан җәеп, мендәрләрен кабартып, нейлон япмаларны ябып куйды.* Д.Каюмова

НЕЙРОН *и. гр.* Нерв күзәнәге һәм шуннан төрле якларга таралган җепселләр. *Чөнки андый шәхесләрнең нерв системасындагы ун миллиард чамасындагы нейрон күзәнәкләре иҗат эшендә күбрәк катнаша.* Ватаным Татарстан. *Арадаш нейрон*

НЕЙРОХИРУРГ *и. гр. мед.* Табиб – нейрохирургия белгече. *Аны тагын бер мәртәбә нейрохирургка күрсәтергә булдылар.* С.Сөләйманова. *Моннан тыш, өлкәннәр нейрохирург, гинеколог, психотерапевтка күренеп киңәшләр алалар.* Шәһри Чаллы. *Тикшерү үткәргәч, ашыгыч рәвештә Казаннан табиб-нейрохирург Владимир Филатовны чакырттык.* Безнең гәҗит

НЕЙРОХИРУРГИ́Я *и. гр. мед.* Хирургиянең нерв системасы авыруларын операция ярдәмендә дәвалау белән шөгыльләнә торган тармагы. *[Аллаяров] Урам этләренә операция ясап, баштарак нейрохирургия буенча баш миенә тәҗрибәләр үткәрде.* С.Сөләйманова. *Ниязны берничә көннән Мәскәүдәге Н.Н.Бурденко исемендәге нейрохирургия үзәгенә озаттылар.* Д.Каюмова. *Кайбер бүлекләр башка хастаханәләрдән күчерелсә, ике гинекология, терапия, нейрохирургия, кардиология, урология, пешү авырулары, реанимация бүлекләре яңабаштан оештырыла.* Шәһри Чаллы

НЕЙТРАЛИЗА́ЦИЯ *и. лат.* 1) Нейтральләштерү эше

2) Нейтральләшү хәле

НЕЙТРАЛИТЕТ *и. нем. махс.* 1) Халыкара хокукта: сугыш вакытында берәр дәүләтнең сугышка катнашмыйча, сугышучы дәүләтләргә карата битараф позициядә булу, тыныч чорда хәрби блокларга кермәү хәле; битарафлык. *Ярый әле, Рәсәй үз вакытында нейтралитет алып калган.* В.Исламетдин

2) Гомумән читләшү, катышмау позициясе. *Нинди генә конфликт булмасын – ул нейтралитет саклый икән.* Җ.Юныс

НЕЙТРАЛЬ *с. лат.* **1.** 1) Сугышучы дәүләтләргә карата битараф, нейтралитет саклаган. *Нейтраль дәүләтләр*

2) Сугышучы якларның берсенеке дә булмаган. *Дүрт йөз метр киңлектәге ачык коридор – нейтраль зона аша күпме шуышканбыздыр, әйтүе кыен.* Ә.Маликов. *Һәрхәлдә, бу бит – нейтраль полосада бер ай яткан кеше.* М.Мәһдиев

3) Аңлашылмаучанлык, бәхәс, сүз көрәштерү, көрәш һ.б.ш. очракларда бер якка да катнашмаучы, бер якны да якламаучы, битараф. *[Сафа:] Мин беркем яклы да түгел, нейтраль.* Ф.Галиев. *Нейтраль күзәтүче*

4) Кемгәдер яки нәрсәгәдер аерым кагылмаган, һәркемгә яки һәрнәрсәгә караган, гомуми. *Әлбәттә, атаклы язучының моңарчы язылган тәрҗемәи хәлләрендә аның әтисе Хәйрулла хәзрәтнең һәм хафиз (мәдрәсәләрдә Коръән нигезләрен өйрәтүче), һәм хажи булуы күрсәтелми, бәлки «педагог» дигән нейтраль төшенчә генә кулланыла иде.* М.Госманов. *– Ниишләп йөрисез? – диде ул, каршысында пәйда булган ике пенсионерга карата нейтраль реакция белән. – Сез кемнәр?* Җ.Юныс

5) *махс.* Организмга бернинди файдасы да, зыяны да булмаган (дару, укол һ.б. тур.). *Нейтраль матдә*

6) *хим.* Ни кислота, ни селте реакциясе бирми торган. *Тәҗрибә аларның [аминокислоталарның] эремәләре нейтраль булуын күрсәтә.* Органик химия. *Нейтраль матдә*

7) *геол.* Җирдә ел буе даими температура саклана торган. *Татарстанда нейтраль катлам уртача 35 м тирәнлектә ята*

8) *физ.* Электр корылмасы булмаган. *Нейтраль кисәкчек*

9) Бер дәүләтнеке дә булмаган. *Чөнки нейтраль сулардагы корабларга хәрби десант төшерүне «башкисәрләр гамәле» дип кенә аңлатырга мөмкин.* Ватаным Татарстан

10) *лингв.* Стилистик төсмерләре булмаган, гомумкулланылышта булган. *Нейтраль сүзләр белән берәттән, реклама текстларында татар әдәби теле сүзлек хәзинәсенең төрле катламнарга караган сүзләре дә очрый.* Татар рекламасы теле

2. *рәв. мәгъ.* Битараф, бер якны да якламыйча, бер як тарафына да чыкмыйча. *Төркия милли хәрәкәтләрне үзара якламау турында Россия белән килешү төзергә ашыкты, башкалары нейтраль калды...* З.Мифтахов

НЕЙТРАЛЬЛӘШТЕРҮ *ф.* 1) Халыкара хокукта: сугыш вакытында нинди дә булса дәүләтне яки районны «сугышучыларның берсе яклы да түгел» дип игълан итү; битарафлаштыру. *Территорияне нейтральләштерү*

2) *хим.* Селте тәэсирендә эремәнең кислоталык үзлекләрен яки, киресенчә, кислота тәэсирендә селтелек үзлекләрен бетерү. *Ток тәэсире астында тоз кисәкчәләре ионлаша, мембрана аларны сортларга аера, ә ионнарны кире нейтральләштерүе кыен түгел.* Химиянең киләчәге. *Мәгълүм булганча, океан суы ракета җибәрү вакытында барлыкка килә торган зарарлы тәэсирне коры җиргә караганда тизрәк нейтральләштерә.* Шәһри Казан. *Чөнки без ашаган ризык бу әчелекне нейтральләштерә, һәм трихомонадлар зарарланмаган хәлдә үт*

куыгына үтеп кереп, эчәклеккә тарала, кире ашказанына әләгә. Безнең гәҗит

НЕЙТРАЛЬЛӘШҮ *ф.* 1) Нейтраль (*6 мәгъ.*) хәлгә килү. *Бер функциональ группаның индикаторга тәэсире икенче группаның капма-каршы тәэсире белән нейтральләшә булса кирәк.* Органик химия

2) *грам.* Бер аллофонда ике фонеманың тәңгәл килүе

Нейтральләшә башлау Нейтральләшүгә таба бару

Нейтральләшеп бетү Бөтенләй нейтральләшү

НЕЙТРАЛЬЛЕК *и.* 1) Нейтраль булу, битарафлык, тарафсызлык. *[Яктыбаш:] Мин бу конфликтта нейтральлегемне сакларга телим!!!* И.Зәйниев

2) *хим.* Эремәнең лакмус кәгазендә ни кислоталы, ни селтеле реакция бирмәве

НЕЙТРОН *и. ингл. физ.* Атом төше составында электр корылмасы булмаган элементар кисәкчек. *Башак нуры, икмәк нуры бассын Нейтрон нурларының сөремен.* Р.Рәкыйпов. *Билгеле булуынча, кисәкчәләр – молекула, атом, нейтрон, протон һ.б.ның бүленеше чиксез.* А.Хәлим. *Атом, нейтрон бомбалары арта, Арткан саен дөнья афәтле.* Ф.Суфияр

НЕКРОЛОГ *и. гр.* Берәр кешенең үлүе сәбәпле, аның тормышы һәм эшчәнлеге турында язылган мәкалә; мәрсия, тәгъзия, тәгъзиянамә. *Шәриф Манатов исә тиз арада Петербурда чыга торган большевистик легаль «Звезда» газетасына Ямашев турында некролог язарга булды.* А.Расих. *Әнә некролог язганда да имза җыеп йөрмиләр иҗ!* Ә.Еники. *«Петербургские ведомости» газетасы да Х.Фәезханов турында тәэсирле некролог бастырып чыгара.* Я.Абдуллин

НЕКРО́ПОЛЬ *и. гр.* Борынгы чорда шәһәр читендәге зур каберлек; зират, мазарлык. *Галимнәр, һич икеләнмичә, биредә борынгы некрополь-мазарлык булуын язалар.* Безнең гәҗит

НЕКТАР *и. гр. бот.* Чәчәкләр бүлеп чыгара торган татлы, баллы сыекча; чәчәк балы. *Димәк, [бал кортлары] буш кайтмый, нектарлы чәчәкләргә юлыккан!* Г.Бәширов. *Чәчәк нектарында су кырык процентны алып сиксән процентка кадәр урын тота.* Умарта кортлары. *Гадәттә, алар [бөжәкләр ярдәмендә серкәләнүче үсемлекләрнең чәчәкләре] нектарга, серкәгә бай, һәм күбесе хуш исле.* Биология. *Моннан тыш, башка бөжәкләрнең интересларын да искә алмый калырга ярамый бит әле: нектар һәм серкә тагын кимендә 20 мең төр бөжәк өчен азык булып тора.* Үсемлекләр һәм бал кортлары

НЕКТАРИН *и. рус бот.* Шәфталуны слива яки өрек белән серкәләндерү нәтиҗәсендә килеп чыккан сусыл, итләч татлы җимеш; шома шәфталу

НЕКТАРЛЫК *и. бот.* Чәчәктәге нектарны бүлеп чыгара торган орган. *Чәчәкләр дөньясы юмарт һәм бай, матур җәй көнендә ул бөтен һаваны тулы нектарлыклар һәм серкәчләргә сибелгән төрле төстәге серкә бөртекчәләренең хуш исе белән туендыра.* Үсемлекләр һәм бал кортлары. *Чәчәкнең нектарлык бизләре*

НЕ́ЛЬМА *и. лат. зоол.* Сөләйман балыклар семьялыгыннан, төньяк елгаларда һәм диңгезләрдә яши торган, ашарга яраклы кыйммәтле балык. *Нельма уылдыгы*

НЕ́МЕЦ *и. рус* Үзәк Европада яшәгән һәм герман телләренең берсендә сөйләшкән халык һәм шул халыкның бер вәкиле, алман. *Барсам, биле урталай өзелгән бер немец солдаты ята...* Г.Ибраһимов. *Тоткын итеп сиңа китерде дә «Кол» дип мине немец атады.* М.Җәлил. *Янә иң кече сеңлебез госпитальда эшли иде, мәҗрух немец пычак белән кулына чәнечкән.* Ә.Еники

НЕ́МЕЦЧА *рәв.* **1.** Немец телендә. *Без немецча, французча әйтелгән сүзләрнең күбесен аңламыйбыз.* З.Бигиев. *Шәйхи солдат аның нәрсә сөйләгәнен аңламады, ак якалы, кара казакилы, кара биек эшләпәле бу татар егете саф немецча сөйләде.* М.Мәһдиев. *Немецча төтенем йөрми.* А.Гыйләҗев

2. *с. мәгъ.* Немец телендә булган. *Ул: «Рапид! Рапи!» – дип ай-һайлап кычкырып, уенчыларны дәртләндерергә тырыша, немецча сүзләр дә кыстыргалый.* А.Гыйләҗев

3. *и. мәгъ.* Немец теле. *Немецчаны син үзең дә бик каты ыжлатасың икән!* А.Гыйләҗев. *Ул чакта инде немецчасы да ару гына иде.* Казан утлары

НЕ́МЕЦЧАЛАП *рәв. сөйл.* Немец телендә. *Заварзин үзенең автоматын суга-суга, немецчалап майорга нәрсәдер аңлатты.* З.Зәйнуллин

НЕ́НЕЦ *и.* Россиянең Ненец, Ямал-Ненец, Таймыр округларында яшәүче, Урал телләренең берсендә сөйләшүче төп халык һәм шул халыкның бер кешесе. *Алты ай кояш күренмәгән салкын якларда да яшәп ята бит чукча, ненецлар.* А.Гыйләҗев. *Ненец йолалары*

НЕО- *гр.* Кушма сүзләрдәге «яңа» мәгънәсен белдерә торган беренче кисәк: *неологизм, необорокко, неоген* һ.б.ш.

НЕОГЕН *и. гр. геол.* Өченчел чорның миоцен һәм плиоценга бүленә торган икенче яртысы; дөньядагы нефть ятмаларының иң зурлары шушы чорда барлыкка килгән

НЕОЛИТ *и. гр. археол.* Яңа таш гасыры, халыкның утрак тормыш барлыкка килү, хайван үрчетү һәм җир эшкәртү, керамика уйлап табу белән характерланган таш гасырының иң соңгы чоры. *Неолит чорында таш корал ясау эше камилләштерелгән – кешеләр балта, пычак һәм башка коралларның йөзен шомарту, үткенләү ысулларын уйлап тапканнар.* Р.Фәхретдинов

◊ **Неолит революциясе** Кешелек җәмгыятенең аучылар һәм җыючылар примитив икътисадыннан игенчелеккә я (яки) терлекчелеккә нигезләнгән авыл хуҗалыгына күчүе. *Неолит революциясенең бу казанышлары борынгы кешеләр тормышын шактый җиңеләйтеп кенә калмаган, ә җәмгыятьнең алга таба үсеше өчен дә зур этәргеч булган.* Р.Фәхретдинов

НЕОЛОГИЗМ *и. гр. лингв.* Телдә барлыкка килгән яңа сүз яки сүз тезмәсе, шулай ук иске сүзнең яңа мәгънәсе. *Неологизмның ярарын ала, ярамасын ташлый ул [тел].* Х.Туфан. *Неологизмнарның бер төре галимнәр,*

язучылар, шагыйрьләр тарафыннан уйлап табыла. М.Зәкиев

НЕОЛО́ГИЯ *и. гр. лингв.* Тел белеменең яңа сүзләрне, аларның ясалышын, мәгънә төрләрен, кулланылыш үзенчәлекләрен һ.б.ш.ны өйрәнә торган тармагы

НЕОН *и. лат. хим.* **1.** Химик элемент, һава составында була торган иссез һәм төссез инерт газ (электр, сигнал лампаларында, реклама һ.б.ш.ны яктырту приборларында кулланыла)

2. *с. мәгъ.* Шул газны кулланып ясаган. *Шәһәр күгендә йолдызлар юк. Неон утлар яктысында югалалар алар.* Зөлфәт. *Неон сүзләр черки шикелле безелдиләр. Күзеңә сукыр чебен булып керергә торалар.* М.Юныс

НЕОНАЦИЗМ *и. гр.-нем.* Икенче Бөтендөнья сугышыннан соң барлыкка килгән, нацизмны яклаган һәм кабат торгызуны пропагандалаган иҗтимагый-сәяси агым

НЕОНАЦИСТ *и.* Неонацизм тарафдары. *Болар, неонацистлар, Россия бары тик православие халыклары өчен генә, дип фикер йөртә.* Ватаным Татарстан. *Ә 17 яшьлек неонацист, пычак чыгарып, бер егеткә чәнчеп тә ала.* Безнең гәҗит

НЕОНАЦИ́СТИК *с.* Неонацизмга, неофашистларга бәйле, шуларга караган. *Анда Көнбатыш Европа илләреннән җыелган 1500 ләп кеше, неонацистик рухтагы төркемнәр вәкилләре, исламның Европада таралуына каршы чыгыш ясадылар.* Татарстан яшьләре

НЕОФАШИЗМ *и. гр.-нем.* Икенче Бөтендөнья сугышыннан соң туздырылган фашистик оешмаларның эшләрен дәвам иткән үтә реакцион иҗтимагый-сәяси һәм идеологик агым. *Хакимият ксенофобия һәм неофашизм чаткыларын күрмәскә тырыша.* Татарстан яшьләре

НЕОФАШИСТ *и.* Неофашизм тарафдары. *Неофашистлар шәһәр урамнарын тутырып атлый.* Татарстан яшьләре

НЕОФАШИ́СТИК *с.* Неофашизмга яки неофашистларга бәйле, шуларга караган. *Ачыктан-ачык неофашистик идеяләр белән чыгучы һәм башка милләт вәкилләренә карата дошманлык хисләрен тыя алмыйча дистәләрчә кешенең башына җиткән скинхедлар хәрәкәте һаман көчәя бара.* Ватаным Татарстан. *Бу очракта дини секталарга кергән яшьләрнең дә, неофашистик төркемнәргә мөрәҗәгать итүчеләрнең дә сәбәбе бер үк.* Татар заманы

НЕРВ *и. лат. анат.* 1) Кеше һәм хайван организмында ярсытуны периферидән баш һәм арка миенә яки, киресенчә, баш һәм арка миеннән периферигә тапшыручы махсус җепселләр. *Нишлисең, күпме генә бөек булмасыннар, алар да – кеше, мускул, нервлар җыелмасы, аларның күкрәгендә дә гадәти йөрәк типкән.* И.Нуруллин. *Дөрес, җир үсемлекләрендә махсус нерв күзәнәкләре, нерв системасы юк, ләкин аларда тынычсызлануны тапшыра һәм җавап сигналлар килә торган махсус каналлар бар ---.* А.Тимергалин

2) Шул җепселләр системасының кешенең гомуми эшчәнлегенә, үзүзен тотышына тәэсир итү күренеше. *Нервлар әйтерсең тимерчыбыкка әйләнделәр.* Ә.Еники. *Аның рәвешен күргәч үк нервлар туарылып, бушап китә.* М.Мәһдиев. *Нервлар соңгы чиккәчә тартылган, елыйм.* Идел

◊ **Нерв бозу** Кәефне бозу, ачуны китерү. **Нерв бозылу** Сәламәтлек какшау, тынычлыкны югалту. *Сату эшендә нервлары бозылып беткән мескен хатыннармы, әллә үзебезме?* М.Юныс. **Нерв кайнау** Бик нык ачу килү, ярсу. **Нерв кузгалу** Ачу килү, тынычсызлану. *Чын булса, нервлары кузгалган кешенең аппетиты бик яман ачылып китә, имеш.* Ә.Еники. **Нервта уйнау** Кемнең дә булса ачуын китереп, нәрсә булса да эшләү, сөйләнү, көлү, кычкыру, аның кәефен бозу һ.б.ш. *Аннан [Сәкинә] һәр көнге планёрка бетешенә идарә алдына килеп торып, аннан чыгучылардан сорашып, алай дөрес түгел, болай кирәк иде дип, коткы салып, гел Ахиярның нервларында уйнады.* М.Мәһдиев. **Нерв уйнау** *к.* **нервлану**. **Нервларны бастыру** Тынычлану

НЕ́РВ ҖЕПСЕЛЕ *и. анат.* 1) Глиаль тышча белән капланган нейрон үсентесе. *Былбылның тамагы нинди өлешләрдән тора? Әллә кайларга ишетелә торган саф тавышны барлыкка китерүче ярылары, нерв җепселләре кайда аның?* Зөлфәт

2) *күч.* Ниндидер бербөтеннең аерым тармагы, мөһим өлеше. *Төче катлама сыман әдәбиятчылык исе килеп торган «лирик герой» атамасын кулланудан баш тартып, Сажидә Сөләйманова иҗатының нерв җепселе булган олуг мәхәббәт темасын яктыртасым килә.* А.Хәлим

НЕ́РВЛАНДЫРУ *ф.* Кемнең дә булса нервысына тию, кемне дә булса борчулы хәлгә китерү, гасабиландыру. *Менә шушы чарасызлык, гасабилык, килеп туган гарип ситуациядән чыгу юлын таба алмау безнең ачуны китерә, нервландыра, як-якка бәргәләндерә һәм, ахыр килеп, җаныбызны, иманыбызны, иҗатыбызны ваклый иде.* Г.Рәхим. *Көмәнле чагында нервландырасым килми.* Р.Сәгъди

Нервландыра башлау Нервландырырга тотыну

Нервландырып бетерү Тәмам нервландыру

НЕ́РВЛАНУ *ф.* Нервлар киренке хәлдә булу, нервлар ярсу, тынычсызлану, борчылу. *Флейталар иңри... Нервлана... Кабалана... Тына.* Ә.Фәйзи. *Мәгыйзь тәмәке тарта алмаган вакытта гел нервлана иде.* М.Мәһдиев. *Соңгы вакытларда бик нервландым, шуның өчен кан басымым күтәрелде.* Татарстан яшьләре

Нервлана башлау Нервланырга тотыну. *– Да брось син! – диде Кәрим, нинаять, нервлана башлап.* Г.Ахунов. *Шул ук мизгелдә Сталин нервлана башлады.* З.Зәйнуллин

Нервланып алу Кыска гына вакыт, бераз тынычсызлану

Нервланып бетү Тәмам тынычсызлану, борчылу

Нервланып тору Нервлы хәлдә булу

НЕ́РВЛЫ *с.* 1) Тиз ярсып китүчән, тиз кызучан, тынычсыз. *Илвирның апасына врач ханым әйткән: кызың*

бик нервлы, аның белән әчеләнешмәскә тырыш, әгәр дә тагын бер мәртәбә авызы кыегайса – тураймаска мөмкин, дигән. М.Шаһимәрдәнов. *Нәрсә булган бу апага?! Җизни үзгәрткән моны! Нервлы, калтырана торган хатынга әверелдергән!* Г.Хөсәенова

2) Эчке ярсуны, дулкынлануны белдергән, сиздергән, күрсәткән. *Сүзләреңне баштан алып киттең. Нервлы иде башта сүзләрең.* Х.Туфан. *Нервлы хәрәкәтләр. Нервлы тавыш*

3) Борчулы, ыгы-зыгылы; тыныч-сызланырга, борчылырга мәҗбүр итә торган. *Нервлы эш. Нервлы тормыш. Нервлы вазгыять*

НЕ́РВЛЫЛЫК *и.* Нервлы булу халәте

НЕРВЫ *и. сөйл. к.* **нерв**. *[Гүзәл:] Нервылар какшаган. Бөтен авырулар да нервыдан, дип әйтә иде безнең бер укытучы.* К.Ситдыйков

◊ **Нервы бозу** *к.* **нерв бозу**. *Әйтергә кирәк, соңгы вакытларда аңа гасабилану, нервы бозу бер дә ярамый иде.* Ә.Еники. **Нервыга тию** *к.* **нерв бозу**. *Анда һәрвакыт дымлы, тоз исе һәм якорь чинавы нервыга тия.* И.Салахов. *Столыпин реакциясе чорында студент фуражкасы, Горький эшләпәсе, озын чәч, кызыл күлмәк полициянең нервысына тия торган атрибутлар иде.* И.Рәмиев. *Йокла! Ичмасам, син нервыма тиеп ятма.* Ф.Шәфигуллин. **Нервыда уйнау** Кемнең дә булса ачуын китереп, нәрсә булса да эшләү, сөйләнү, көлү, кычкыру, аның кәефен бозу һ.б.ш. *Кайвакыт көне буе йоклый иде (бу да – вампирларга хас нәрсә, аның каравы алар, төне буе нервыда уйнап, кыштыр-кыштыр йөриләр).* Татарстан яшьләре. **Нервы уйнау** *к.* **нервлану**. *Чыннан-чын нервысы уйный башлаган Нургали түзмәде: шактый дорфа итеп Сөләймановның сүзен тагын бүлде.* Ә.Еники

НЕРГӘ *и диал. этн.* Бирнәгә каршы кызга бирелә торган бүләк. *Бирнәсе булмаса, нергәсе дә булмый.* Мәкаль

НЕ́РПА *и. фин. зоол.* Тюленьнәр семьялыгына кергән, ишкәк аяклы имезүче хайван һәм шул хайванның мехы

НЕСЕССЕР *и. фр.* Тегү, гигиена, косметика, маникюр кирәк-яраклары кебек вак әйберләр саклый торган кечкенә савыт, сумка, тартма. *[Кызыл-армеец] туалет әйберләре тутырылган несессердан бритва белән сабын порошогын алып, пыяла савыт, щётка, маникюр коралларын читкә ыргыткан.* Ш.Усманов

НЕТБУК *и. ингл.* Кечкенә, җиңел, техник мөмкинлекләре чикләнгән һәм чагыштырмача арзан ноутбук. *Бөекбритания нең Ритлингтон шәһәрендә белем алучы үсмерләр нетбуклы булган.* Ватаным Татарстан

НЕ́ТТО *и. ит. махс.* Товарның савытыннан, төрелгән кәгазеннән, полиэтиленнан һ.б.ш.дан башка саф авырлыгы; алыкман; *киресе:* **брутто, толыкман**. *Нетто авырлыгы. Нетто бәясе*

НЕФРИТ I *и. гр. мед.* Бөерләр ялкынсыну авыруы. *Күрем авыртып килгәндә, җенес бизләре ялкынсынганда, дерматит, нефрит, таш утыру авырулары вакытында да кабул итәләр.* Ватаным Татарстан. *Ничә еллар нефрит белән интектем.* Татарстан яшьләре. *Кыр наратбашын нефрит һәм нефрозонефрит белән авырганда эчәргә ярамый.* Урман аптекасы

НЕФРИТ II *и. гр. махс.* Нәрсәне дә булса бизәү, матурлау өчен кулланыла торган ярым үтә күренмәле минерал. *Чыңгыз хан җавап рәвешендә Харәзем шаһына бүләкләрне мулдан кубып җибәрә: дөя өркәче зурлыгындагы саф алтын кисәге ---, алтын-көмеш коелмалар, нефрит, ягъни кыйммәтле таш җәүһәрләр, --- кондыз һәм кеш тиреләре, бүтән асыл нәрсәләр була анда.* Р.Фәхретдинов. *Ак нефрит. Ачык яшел нефрит. Зөбәрҗәт яшел нефрит. Зәңгәр нефрит*

НЕФРОН *и. гр. анат.* Умырткалыларда һәм кешедә бөернең сидек бүлеп чыгару берәмлеге

НЕФТЕБА́ЗА *и. рус* Нефтьтән алынган ягулык һәм төрле майлар белән тәэмин итә торган база. *Менә сезгә мин уйлап та тормыйча кияүгә чыгар идем, ә нефтебаза директоры малае, шуның өстенә гади авыл малае, мине кызыксындырмый.* Р.Мирхәйдәров. *«Карагай», «Юлтимер», «Маяк» һәм башка хуҗалыкларда, бушатутөяүне тизләтү өчен, махсус мәйданчыклар, нефтебаза төзиләр.* Ватаным Татарстан

НЕФТЕХИ́МИЯ *и. рус* 1) Химиянең нефть һәм табигый газ компонентларының составын, үзлекләрен, химик әверелешләрен, шулай ук аларны эшкәртү процессларын өйрәнә торган өлкәсе

2) Нефть эшкәртү сәнәгате. *Кешеләр елга-күл, диңгез-океаннарга нефтехимия, бигрәк тә атом индустриясе ташландыкларын агызып, суларны шул дәрәҗәдә пычратканнар ки, елгаларның яртысында балыклар үлеп беткән, хәтта океаннарда да балык кырыла...* А.Тимергалин

НЕФТЬ *и. фар.* 1) Җир астыннан табыла торган, реактив һәм дизель ягулыгы, бензин, керосин, мазут һ.б.ш. ясау өчен чимал буларак кулланылган сыек янучан минераль матдә; карамай, җир мае, кара алтын, сыек алтын. *Без, геолог Рәхимә Сәлимова белән, соңгы тикшерүләр нигезендә, Бизмән тауда нефть булырга тиеш, дибез.* А.Әхмәт. *Шөгер, аның артыннан Азнакай, Бөгелмә, Әлмәт яклары, пыр тузып күтәрелеп, нефть патшалыгы булып киткәндә, Зәйдә --- шылт иткән тавыш та юк иде әле.* А.Гыйләҗев. *Нефть безнең җиребездән суыртып алынса да, нефтьнең нигъмәтләре безгә тимәде.* Б.Рәхимова

2) *сөйл.* Нефть чыгару эше, нефть эшкәртүгә бәйле предприятие һ.б.ш. *Анда кыш буе нефтьтә эшләп, инде менә балыкка чыкканнар икән...* Ш.Камал. *Армиягә киттем дә сугыштан туры нефтькә кайттым, хәзер Әлмәттә яшәп ятам.* А.Гыйләҗев. *Механик булып йөрүең җитәр. Нефтькә күчәрсең.* Г.Ахунов

НЕ́ФТЬЛЕ *с.* 1) Составында нефть булган. *Ул нефть шламнарын эшкәртканнан соң калган каты калдыкларны һәм элекке нефть амбарлары төбендә калган нефтьле туфракны яндыру өчен кулланыла.* Кызыл таң

2) Нефть ятмалары булган, нефть табылган. *Татарстан республика-*

сының беренче ун елы эчендә генә дә татар пролетариаты эченнән: шахтадан, завод-фабрикадан, нефтьле өлкәләрдән дистәләрчә язучылар үсеп чыкты. Г.Ибраһимов. *Җир маен эзләп төшерелгән скважина еш кына нефтьле катламга түгел, су агымына юлыга.* Ватаным Татарстан

3) Нефткә буялган. *Алексей Шмарёв, яныма килеп, нефтьле кулымны кысты да, башта үзенең, аннан башкаларның битенә нефть сылады.* Заман сулышы

НЕ́ФТЬ МАЕ *и. хим.* Нефтьтән ясала торган майлау мае; *русчасы:* **олеонафт**

НЕ́ФТЬҮТКӘРГЕЧ *и.* Нефть яки аны эшкәртү нәтиҗәсендә барлыкка килгән продуктларны еракка җибәрү өчен салынган система. *Хәзер ни, кая карама, электр чыбыклары узган я нефтьүткәргечләр сузылган, урманнар кишәрлек-кишәрлек тоташтан киселгән, кояш нуры ургылып килеп керә дә кыш тупланган карларны дәррәү кузгата, ашыктыра башлый.* А.Гыйләҗев

НЕ́ФТЬ ХИМИЯСЕ *и. махс. к.* **нефтехимия**. *Без шулай ук нефть химиясен, машина төзелешен, энергетика һәм авыл хуҗалыгы комплексын үстерүгә зур игътибар бирәбез.* Ватаным Татарстан

НЕ́ФТЬЧЕ *и.* Нефть сәнәгатендә эшләүче кеше. *Нефтьчегә әйтәек без: Җир күчәрен майласын* --- Х.Туфан. *Үйланып кайта торгач, яңа Кәлимәткә – төзелеп ята торган нефтьчеләр шәһәренә килеп чыгуын күреп, [Арслан] аптырап китте.* Г.Ахунов. *Без, әле 60 нчы еллар нефтьчеләре, нефть бирмәгән яки нефткә ярлы скважиналарны нәкъ шулай [«кысыр скважина» дип] атап йөртә идек.* Хәзинә

НЕЧКӘ *с.* **1.** 1) Аркылы кисеме кечкенә булган: *киресе:* **юан**. *Кайберәүләр юл кырыендагы тәбәнәк баганалар өстенә утырышканнар һәм, ярым бөгелеп, нечкә чыбык очлары белән асфальтка ниндидер күзгә күренми торган сызыклар сызгалыйлар.* М.Галәү. *Нечкә башка юан башны саласың да, бура тип-тигез күтәрелә.* М.Мәһдиев. *Ничек ул шартламый калгандыр да, үткер ташларга тырналып, туңып беткән куллары кыл кебек нечкә тимерчыбыкларны ничек сизеп алгандыр – анысын Мостафа үзе генә белә.* Г.Әпсәләмов

2) Нәфис җептән тукылган, бәйләнгән, ишелгән; *киресе:* **калын**. *Кулларын артка каерып бәйләгәннәр, нечкә иске бишмәте телгәләнгән, якалары суелып төшкән, кан катыш балчыкка пычранган коточкыч йөзе һәм гәүдәсе белән Җолкынбай ята.* Г.Ибраһимов. *Гөлҗамал әби дә чыгып баскан, нечкә йон күлмәк кигән, башына яңа яулык бәйләгән.* Б.Камалов. *Мин --- [иске фанера чемоданны] дүрт ягыннан нечкә сүс бау белән атландырып бәйләгәч, икеләнеп-нитеп тормыйча, авылдан Бөгелмәгә чыгып киттем.* Ф.Садриев

3) Юан, симез булмаган; нәфис (кеше, аның фигурасы һәм тәненең аерым әгъзалары тур.). *Торна шикелле нечкә озын аяклы, какланып беткән бу чандыр бабайны авылның иң карт кешесе диләр.* Ә.Еники. *Искәндәрнең бармаклары никадәр нечкә вә нәфис булсалар да, нарасый мыек төкчекләре, аның бармакларына эләкмичә, әүвәлге көенчә иске урыннарында калдылар.* К.Тинчурин

4) Киңлеге, иңе зур булмаган, тар. *Искәндәрнең су шикелле саф, акыллы, моңчан коңгырт күзләре өстендә шәркый рәвештәге кара нечкә кашлары, озынчарак яңаклар арасындагы алсу бит урталары һәм чия шикелле кызыл, шактый калын иреннәреннән яшьлек, тазалык җиле исеп торадыр иде.* К.Тинчурин. *Озак та үтми, чыгып килгән кояшның нечкә кавын телемедәй сары кырые күренде.* Ә.Еники. *Аякта читек, тез астыннан нечкә каеш белән кысып бәйләнгән.* Г.Гобәй

5) *сөйл.* Югары тондагы (тавыш, аваз). *Син сабыйдай нечкә аваз берлә сайрый сандугач.* Г.Тукай. *Милиционер булып киенгән бер кеше нечкә тавышлы сыбызгысын сызгыртып җибәрде.* А.Алиш. *Көчле нечкә тавыш, агачларга бәрелә-сугыла, еракларга китеп тынды.* Г.Гобәй

6) Зур осталык, сәләт, зәвык белән эшләнгән, иҗат ителгән. *Моны безгә дуслар бирә, Венгрия Халык Республикасы эшли мондый нечкә техниканы.* М.Мәһдиев. *Ә Салих Сәйдәшевнең нечкә лирик вә нәзакәтле музыкасы ямь өстенә ямь биреп, спектакльне тагын да тулыландыра, зур уңыштан канатланган композитор яңа көйләр, ариялар яза.* М.Сәлимҗанов. *Аерата төгәллек таләп итүче нечкә эшне ювелир әйберләр ясауга тиңлиләр.* Безнең гәҗит

7) Җаваплылык таләп иткән, четерекле. *Әйе, бик четерекле сорау, үтә шәхси, нечкә, авыр мәсьәлә бу минем өчен...* Ә.Еники. *Бу чиксез нечкә, катлаулы мәсьәлә әле тиешенчә тикшерелеп җитмәгән хәлдә тора.* Х.Туфан. *Гаилә тормышы кебек үтә нечкә, үтә четерекле эшләргә тыгылырга синең ни хакың бар?* Г.Ахунов

8) Серле, тирәнгә яшерелгән, яшерен, бик кыенлык белән күренә, сизелә торган. *Халык күңеле шундый инде ул, туташ: иң нечкә кичерешләренә дә көен-җырын таба белә.* Ә.Еники. *Катнашып китү өчен, кечкенәдән бу көннең иң нечкә нюансларын сизеп үсәргә кирәк.* М.Мәһдиев

9) Исе, тәме нәзакәтле, нәфис булган (аш-су тур.). *Ирен, авыз, тел бу җимешләрнең гаҗәп үткен, нечкә, һич туя алмаслык тәмнәреннән эриләр* ---. Г.Ибраһимов. *Нечкә хуш ис*

10) Нәзакәтле (тәрбия, үзеңне тоту, сөйләшү һ.б.ш. тур.). *Аның нечкә зәвык, тәмле тел, күркәм сүзләр белән язылган «Яшь йөрәкләр» романы, «Яз башы», «Диңгездә», «Табигать балалары», «Сөю – сәгадәт» кебек хикәяләре күпме укучыларга рухи ләззәт, мәгънәви шифа, хәяти мәгълүмат бирде.* С.Поварисов

11) Үтә оста, тапкыр; үткер; ниндидер яшерен мәгънәсе булган. *Йорт белән бәйле кызыклы алым күзәтелә: кадими, иске карашлы кешеләрнең йорт-җирләре тасвирланганда, авторның нечкә ирониясе тоемлана.* А.Батталова

12) Сак, әдәпле, игътибарлы мөгамәлә таләп итә торган. *Ул [остазбикә] шундый эшкә бервакытта да сабак кызларын кушмый, ул андый*

нечкә эштә беркемгә дә ышана алмый. Г.Исхакый

13) Сизгер, йомшак (кеше, аның характеры һ.б. тур.). *«Шагыйрь» күңеле нечкә бит, Йомшап китә яңадан...* Ә.Фәйзи. *Ә бит бала күңеленнән дә сизгер, сабый күңеленнән дә нечкә берни юк.* Ф.Яруллин. *Яшь бер кыз рәсемен шигырьдә тудырган Һади Такташ үзе дә нечкә хисле, тойгыларга бай ир-ат булып ачыла.* Р.Рахман

14) *лингв.* Йомшак, палаталь. *Нечкә тартыклар*

2. *рәв. мәгъ.* 1) Үтемле итеп, җентекләп. *«Милләтә» әсәрендә миллилек, милләтпәрвәрлек кебек төшенчәләр бик нечкә ачыла.* Р.Рахман

2) Хисләнеп, юмакайлык күрсәтеп. *Хатыңны син бик нечкә, әйтергә яраса, бик төче язгансың.* Г.Кутуй

3) Бик зур осталык белән. *Җитмәсә тагын, кайбер турыларда каенананың үзеннән нечкәрәк, остарак та ясап куя.* Г.Ибраһимов

4) Тирәннән, зирәклек белән. *Тормышның ямен, яшәүнең кыйммәтен алар сыман нечкә сиземләүче бар идеме икән әле монда?!* М.Шаһимәрдәнов. *Түткиләргә килгәндә, алар сәвиттән курку сәбәпләрен бик нечкә сиземи һәм, бу курку ничек кенә көчле булса да, Аллаһтан куркулары теге куркудан күпкә көчлерәк икәнлеген тагын да яхшырак төшенәләр иде.* А.Хәлим

◊ **Нечкә бил** Зифа буйлы, гүзәл хатын-кызга карата кулланыла. *Ташып ярдан ашканда, Таң сөмбелем, нечкә билем, Йөзеп сиңа кайтыр идем, Күлне томан япканда.* М.Җәлил. *--- әле малайлык чыңлап торган нәзек тавыш белән сүгенгән булалар, нечкә билләр артыннан озак кына карап калалар ---.* А.Тимергалин. **Нечкә билле** Биле тар итеп тегелгән (кием тур.). *Аның башында каракүл, озынча нечкә бүрек, өстендә нечкә билле, күкрәге, якасы укалы бишмәт иде.* Г.Ибраһимов. **Нечкә тамак** Нәберек, талымчан кеше; кылтамак. *Нечкә тамакланып кыланган була, димәсеннәр өчен, [Гөлбану] ике чокыр чәй эчте дә чынаягын каплады.* Г.Ибраһимов

НЕЧКӘАЯК *и. бот.* Кыяклылар семьялыгыннан күпьеллык үсемлекләр төре; нечкәсабак, келерия

НЕЧКӘБИЛ *и. диал.* 1) Бал корты. *Ходайның йөзләгән төр үләннәре, үсемлекләре һәм чәчәкләре, йөзләгән төр чикерткәләре, кетнәкичләре, үрмәкүчләре, күбәләкләре, кырмыскалары, нечкәбилләре, энәкараклары – барысы да, барысы да нәкъ укытучы Гаяз абыйлары кебек нечкә билле мандолинада уйный һәм кояшлы гомер кичерәләр икән!* А.Хәлим

2) Шөпшә

НЕЧКӘЛӘНҮ *ф.* 1) *к.* **нечкәләү** (*1 мәгъ.*)

2) *к.* **нечкәрү** (*3 мәгъ.*)

3) Тарттырылып буылу. *Кызларның, хатыннарның алъяпма бавы берлә нечкәләнгән биллəре өстеннән язгы ак су кеби агып төшкән озын сачтакмалары, --- аларның кулларындагы нечкә үткен уракның селкенүе берлә селкенеп, кояшка каршы елтыр-елтыр уйныйлар ---.* Г.Исхакый

Нечкәләнә бару Торган саен нечкәләнү

Нечкәләнеп тору Нечкә булып күренү

НЕЧКӘЛӘ́Ү *ф.* **1.** 1) Нечкә итү

2) *күч.* Җентекләп уйлау, нәрсәнең дә булса һәр ягын, барлык ваклыкларын исәпкә алып төптән уйлау. *[Таибә абыстай:] Һай, артык нечкәлисең, улым! Өйләнү кебек эштә бераз күзне йомыбрак тәвәккәлләү дә кайчак хәерлегә була ул!* Ә.Еники. *Бик нечкәләргә өйрәтмәгез баланы.* Г.Ахунов

3) *күч.* Нәрсәне дә булса ахырына, җиренә җиткерү, кагыйдәсенә китереп эшләү. *Хәят портретны бик озаклап, бик нечкәләп карады, иң вак нәрсәләрне дә күзеннән төшереп калдырмаска тырышты.* Ф.Әмирхан. *– Кунак җиңги, сиңа Фәтхия әби әйтте, тегендә, өндәүче Чокыр Хәбип йортында кияүнең атын җигә башлаганнар инде, дип әйтте, [кияү керәсе йортны әзерләүдә] бик нечкәләмәсеннәр, тизрәк булсыннар, дип әйтте, – диде [Мифтах].* Г.Ибраһимов

2. *рәв. мәгъ.* **нечкәләп**. 1) Нечкә генә итеп. *[Гөлбану] Бик нечкәләп токмач кисте, чиләк сыярлык зур самавырга су салып, ут кабызды.* Г.Ибраһимов

2) Төпченеп, җентекләп. *Кешене алар [сыер савучылар] шулай нечкәләп өйрәнәләр.* С.Сөләйманова. *Аңлый алмый торсам, ул аны панель стена аша булса да бик нечкәләп аңлата.* Р.Зәйдулла. *Аңа шигырь техникасын остә үзләштерүе, ләкин әлегә табигыйлек җитешмәү, аларның ясалмарак хискә корылган булулары турында нечкәләп язып җибәргәннәр иде.* М.Шаһимәрдәнов

◊ **Нечкәләп тору** Вакчыллану, җентекләп, төпченеп белү. *«Юк! Бу сөремне ничек тә куарга, таратырга, бетерергә кирәк», – диде ахырда Әхмәтвәли башын чайкап һәм, солдат гадәтенчә бик нечкәләп тормыйча, аз гына кабалана төшеп, күңеленә килгән сүзләрне сөйләп китте.* Ә.Еники. *Ничек уйларга икәнен ул нечкәләп тормады, әлегә гомуми сүзләр белән котылып калды.* А.Гыйләҗев

Нечкәли башлау Нечкәләргә тотыну. *– Карап-карап торам да, бик нечкәли башлагансың әле син, Нәфисә кодача, – диде [Сәйфи].* Г.Бәширов. *Бер уйлаганда, татар – кайда да татар кебек, ә нечкәли башласаң, дөньябыз төрле икән бит.* Ватаным Татарстан

Нечкәли китү *к.* **нечкәли башлау**. *Аларның эшен нечкәли китсәң, бу дөрес тә.* Ватаным Татарстан

Нечкәли төшү Тагын да ныграк нечкәләү

НЕЧКӘЛЕК *и.* 1) Нечкә булу. *Без Мусаның бер генә намазны да калдырмавын – үтә диндарлыгын күрәбез. Күңеленең нечкәлеген әйтеп тә торасы юк!* Р.Рахман

2) *күч.* Кечкенә ваклыклар, детальләр, нюанслар. *Әнә шуңа, шушындый авырлыклар корбаны булганга күрә, мин «Уралда гына» җырын бөтен нечкәлекләре белән бирелеп җырлыйм.* Г.Кутуй. *Билгеле, мәхәббәтнең төрле нечкәлекләрен энекәшенә ачып салу әдәпсезлек булыр иде.* Г.Бәширов. *Иркә шартларда үскән, тормыш нечкәлекләрен әле ныклап аңларга өлгермәгән Роза өчен үзләренең туеннан соң, та-*

бигый булганча, якты-көләч көннәр башланып китте. Р.Низами

3) *лингв.* Палатальлек, йомшаклык (тартык авазларда). *Нечкәлек буенча корреляция*

НЕЧКӘЛЕ́К БИЛГЕСЕ *и. лингв.* 1) «ь» хәрефенең атамасы

2) Транскрипциядә тартык авазларның нечкә әйтелешен белдерү өчен, аларның уң ягына өскә куела торган билге (ʹ)

НЕЧКӘРТЕЛҮ *ф. төш. юн. к.* **нечкәртү**. *Йолкып нечкәртелгән кашлар астындагы яшькелт күзләре сынамчыл карап әйтәләр төсле: «Алсаң, үз эшең, алмасаң да кайгырган юк».* Д.Булатова. *Брежнев чорында иҗтимагый фикернe тыюның сталинчыл иң тупас алымнарыннан ваз кичкән хәлдә, бу тыюның яңа, «ипле», хәйләкәр һәм нечкәртелгән төрләре эшли башлады.* Г.Рәхим

НЕЧКӘРТҮ *ф.* 1) Тагын да нечкәрәк итү

2) Җентекләп сорашу, нәрсәнең дә булса һәр ягын, барлык ваклыкларын төпченү. *Әхмәтгәрәй, табигый инде, бернәрсә дә сөйли алмый икән. Яшьтәш исә аның саен нечкәртә, сораша икән.* М.Мәһдиев

3) Югары тонга күчерү, гадәттәгедән нечкәгә әйләндерү (аваз, тавыш тур.). *– Бая ни әйтә башлаган идең әле син? – дип сорады Хәйретдин агай, юри тавышын нечкәртеп.* А.Гыйләҗев

4) *күч.* Күңелен йомшарту, тәэсирләндерү, хисләндерү, шәфкатьләндерү. *Мин моны һич тә укучы күңелен нечкәртер өчен язмыйм.* М.Мәһдиев. *Һәм шул өзлеккән «тупаслыгы» белән үзен тагын да тормышчанрак, халыкчанрак итеп, хисне нечкәртә, җаннарны өйки торган тавыш иде!..* А.Хәлим

5) *лингв.* Йомшарту, палатальләштерү (аваз тур.)

Нечкәртә бару Торган саен нечкәртү. *Тавышын нечкәртә бару. Юнаюна таякны нечкәртә бару*

Нечкәртә төшү Элеккедән ныграк нечкәртү

Нечкәртеп җибәрү Кисәк кенә нечкәртү; артык нечкәртү. *Тик әти аңа бик нечкәртеп җибәрергә урын калдырмады.* Г.Бәширов. *Яшь кызның шулай газаплануы Илгизнең дә күңелен нечкәртеп җибәрде.* М.Шаһимәрдәнов

НЕЧКӘРҮ *ф.* 1) Нечкәгә әйләнү, нечкәрәк хәлгә килү. *Бәләкәй Игорь, әтисен күргәч, пышын-пышын гына еларга тотынды, – шактый ук ябыккан, нечкәргән һәм... кечерәеп калган иде малай!* М.Шаһимәрдәнов

2) Югары тонга күчү, гадәттәгедән нечкәгә әйләнү (аваз, тавыш тур.). *Кыңгырауның нечкәргән моңлы тавышы кияү кызлары, егетләре белән бергәләп урам әйләнергә чакыра.* Р.Рахман

3) *күч.* Тәэсирләнү, хискә бирелү, шәфкатьләләнү (күңел һ.б. тур.). *Менә хәзер, анасы белән сөйләшкәндә, күңеле никадәр нечкәрүгә карамастан, үзенең элекке Анна булып түгел, Нуржиһан булып сөйләшүенә бик канәгать иде.* Г.Бәширов. *Туган авылым белән мине бәйләгән җепләр соңгы елларда бик нечкәрде.* Ә.Еники. *Иң гажәбе – нечкәрде карт: гомер күз яше күрсәтмәгән төксе, төмсә әтисенең беркөнне лапас эчендә елап торганын күрде ул.* Р.Зәйдулла

4) *лингв.* Йомшару, палатальләшү (аваз тур.)

Нечкәрә бару Торган саен нечкәрү. *Тигез итеп шомартылган, югарыга таба нечкәрә барган карагай баганаларның өчесе дә астан өскә чаклы саф алтын белән тышланган.* Н.Фәттах. *– Картаям, ребятки, күңел нечкәрә бара, – дип, кыңгырау чылтыраганчы ук чыгып китте.* М.Мәһдиев

Нечкәрә башлау Нечкәрергә тотыну

Нечкәрә төшү Элеккегә караганда тагын бераз нечкәрү. *Ләкин аның күпьеллык тәҗрибәсе сак булырга өнди, катлаулы вакыйгаларда чарланган сизгерлеге тагы да үткенләнә, тагы да нечкәрә төшкән иде.* А.Расих. *Ананың күңеле тагын да нечкәрә төште, ул Һадины тагын да кысыбрак кочаклады.* А.Гыйләҗев

Нечкәреп бетү Тәмам нечкәрү

Нечкәреп калу Берәр нәрсәдән соң, ни сәбәпледер нечкәрү. **---** *нечкәреп калган кулларына таянып, ул [Гөлфәрваз] шушы җәһәннәм күңелсезлеге белән чолганган һавадан ниндидер ярдәм көтә иде.* К.Тинчурин

Нечкәреп китү Кинәт, капыл нечкәрү. *Кайчакны ул вакыт-вакыт шулай, чамасыннан тыш мавыгып, үтә нечкәреп китүеннән үзе үк көлә башлый иде.* Г.Бәширов. *Аларны күргәч, Гәрәйнең күңеле нечкәреп китте, балачагын хәтерләде...* А.Гыйләҗев. *Мин Гөлшат янәшәсендәге урындыкка утырдым һәм, күңелем нечкәреп китеп, шундук аны, нечкә биленнән кочаклап, үземә таба тарттым.* М.Шаһимәрдәнов

НЕЧКӘСАБАК *и. бот. к.* **нечкәяк**

НИ I *а.* 1) *к.* **нәрсә** I (*1 мәгъ.*). *Кем күз буды? Каранган ни туды?* А.Хәлим. *Гаиләдән дә нечкә, нәзберек ни бар икән тагын?!* Сөембикә

2) Гомумән нинди дә булса берәр нәрсәне, әйберне белдерә. *Машинаны гараждан чыгаруга, өстән атылып улыгыз килеп төште дә иң беренче каравылчы Габдулла абзыйның башына ни белән тондырды.* Ф.Яруллин

3) Риторик сорау һәм өндәү җөмләләрдә «нинди» мәгънәсендә килеп, нәрсәнең дә булса бөтенләй булмавына ишарәли. *[Ялкын:] Ә ул гөнаһсыз сабыйның ни гаебе бар?* И.Зәйниев. *Гөлниса булмагач, миңа анда баруның ни кызыгы бар?* Л.-Х.Таналин. *Ансыз яшәүнең ни кызыгы кала, ди, инде!?* З.Зәйнуллин. *Мин аңламыйм: ни файда бар сиңа ул эштән?* Э.Яһудин

4) Нәрсәгә дә булса кимсетүле мөнәсәбәтне белдерә. *Атаңнан башка чыкканда ние бар иде аның?* А.Алиш

5) Риторик сорауларда һәм өндәүләрдә «нинди» мәгънәсендә килеп, үзеннән соң килгән сүзнең мәгънәсен көчәйтә. *Ah, ни гарьлек: кызым чәчәкләрне Тәрәзәдән тышка ыргытkан.* М.Җәлил. *Әгәр бу фәлсәфә дөрестән дә һәркемгә ярый торган булса, һәркемне ышандыра алса, ни яхшы булыр иде.* Ә.Еники

6) «Шул» алмашлыгы белән мөнәсәбәткә кереп, иярчен җөмләне баш җөмләгә бәйли. *Әле үз куршебез булгач, телгә ни килде, шуны сөйләшеп утырдык.* А.Алиш

7) Исемнәргә ялганып, парлы сүзләр ясый һәм мәгънәгә җыймалык

төсмере өсти. *Юләр, шыр тиле син, үзең күлмәгең-ниең белән бер катлы булгач та, башкаларны да шулай дип уйлыйсың.* Ә.Еники. *Авылны кешесе-ние белән саклап калу өчен иң әһәмиятле чара – аны асфальт юл белән шәһәргә тоташтыру.* М.Мәһдиев

◊ **Ни арада** Нәрсәнең дә булса бик тиз эшләнүен сизми калуны белдерә. *--- ни арада кайтып клубка чыгып йөргәннәрен дә күрми калдым үзләренең.* Р.Мөхәммәдиев. *Виноградлары ни арада өлгергән тагын.* Ф.Яруллин. *– Ни арада табып, ни арада киенеп өлгердең? – дип, әнисе аны әйләндерә-әйләндерә карады.* Г.Галиева. **Ни ары, ни бире** Бер карарга килә алмыйча тору. *Егетем көтә, әти-әнием көтә – бар да көтә, ә мин, селкенүдән туктаган маятник шикелле, ни ары, ни бире!* Ә.Еники. *Ни ары, ни бире сөйләшеп утыруым өчен дә үз-үземә ачуым килде.* Р.Зәйдулла. **Ни әйтсәң дә** *кер. сүз к.* **ни дисәң дә**. *Ни әйтсәң дә, Габдулла ир затыннан бит.* И.Нуруллин. *Ә нәселдә тавыш бар, Митрийнең энесе Константин, ни әйтсәң дә, шәһәрдә җырчы.* М.Мәһдиев. *«Ә урлау (әзме ул, күпме), ни генә әйтсәң дә, гөнаһлы эш!» – ди Илвирның әбисе.* М.Шаһимәрдәнов. **Ни бар** Барлык, һәммә, бөтен. **Ни булган** *к.* **ни бар**. **Ни генә булса да** *кер. сүз* Бернигә дә карамастан, нинди генә каршылыклар булмасын. *Ни генә булса да, яңгырлар тоташтан шәбәргә керешкәнче, иген үз урынында – коры амбарда булырга тиеш.* А.Гыйләҗев. *Мөгаен, Гарифның күңеленә ком иртәрәк утыргандыр, ни генә булмасын, Алсу кебек итеп, ул матур һәм самими җиңеллек белән ярата белмәде.* Ф.Яхин. *Юк, Маһирәкәй, ни генә булса да, без монда яшәргә, табигать биргән бай хәзинәнең кадерен белеп яшәргә тиешбез.* Г.Галиева. **Ни генә булмасын** *кер. сүз к.* **ни генә булса да**. *Ни генә булмасын, шул хәлдән соң мин дөньяда Хәмзә Бикмуллин булып яши башладым.* М.Галәү. *Табигать законының көчеме, семья тормышын сагынумы – ләкин ни генә булмасын – өйләнәсе килү теләге аны [Шакирны] көннәнкөн ныграк йота барды.* Ә.Еники. *Әмма ни генә булмасын, бәндәләрнең яманлыгы да, яхшылыгы да җирдә калмый, бер кайтарыла шул.* Ф.Яхин. **Ни гомер** Бик озак вакыт. *Бу ни хәл бу, әни? Киявеңә ни гомер ияләшә алмыйсың!* Ә.Еники. *Ни гомер яшәп, булган хәл түгел иде мондый давыл.* Н.Гыйматдинова. *Болар ни гомер кабатлана торгандыр инде, белмим.* М.Шаһимәрдәнов. **Ни гомердән бирле** Күптәннән бирле; озак вакыт. *Күрәмсең, ни гомердән бирле азапланам лабаса.* Г.Тукай. **Ни дип** 1) Нәрсә дип, (тагын) нәрсә; нинди. *Ни дип җавап бирәсең инде аларга?!* М.Галәү. *[Айбулат:] Ни дип әйтсен инде, шулай кушкач.* Р.Сабыр. *Түти, ни дип җавап бирергә дә белмичә, аптырап, солдатның аз гына көлемсери төшкән күзләренә сынап карап куйгач, үзе дә сизмәстән, көрәген солдатка бирде.* М.Шаһимәрдәнов; 2) Ни өчен, нинди сәбәп белән, нишләп. *Галошларың салмый, ни дип инде Килеп кердең, атаң башына?!* Һ.Такташ. *[Хәлил:] Уйна да көл, Садыйк абзый, мин һаман шул тиле Әхмәтҗанның эшен аңламыйм, ни дип [кызын кияүгә] биргән?* Г.Исхакый. *[Гәрәй:] Ни дип шул савымчы булырга бик атлыгып торасың соң әле син?* С.Поварисов. **Ни дисәң дә** *кер. сүз* Бернигә дә карамастан. *Олы Газизә апасын инде әйткән дә юк: ни дисәң дә, Габдулла – газиз туганының баласы.* И.Нуруллин. *Ул ничектер уңайсызланыбрак тора иде, ни дисәң дә, төп рольне башкаручы бит.* Р.Сабыр. *Ни дисәң дә, без бит мөселманнар.* Р.Зәйдулла. **Ни җитте** 1) Начар, яхшы түгел. *Уенга мавыгып, кушылган эшне дә ни җитте генә эшләп ташлый яисә бөтенләй оныта [Габдулла].* И.Нуруллин. *Таштан мәһабәт итеп салынган, иркен-киң заллары, төрле-төрле уңайлы эш бүлмәләре булган, зур тамаша залы һәм бай сәхнәсе белән ни җитте салаларны гына түгел, шәһәрләрне дә кызыктырырлык бу йорт чын мәгънәсендә мәдәният сарае иде.* Ф.Яхин; 2) Юньсез, җыйнаксыз, тәртибе начар булган кеше турында. *Шуңа күрә бирегә ни җитте солдатны куеп булмый.* Ә.Еники. *Әбинең карты ни җитте генә кеше булмаган икән.* Ф.Яхин. *Чөнки Әхмәт чын сөюне куәтләгән, мәхәббәтне данлаган мондый «дәрәҗәле бүләк»ләрен юлына очраган теләсә кемгә биреп, ни җитте хатын-кызларга өләшеп йөрми иде шул!..* М.Шаһимәрдәнов. **Ни күзем белән күрим (ни күрәм)** *кер. сүз* Көтелмәгән, уйламаган хәлдән гажәпләнеп, аптырап калуны белдерә. *Ни күзем белән күрим: өстеннән яхшы киемнәрен, ак якаларын салып ыргыткан да эчке күлмәктән генә караватына сузылып яткан.* Г.Камал. *Чыксам, ни күзем белән күрим, Ибраһим абый сирин астында утырып тора.* Г.Исхакый. *[Низам:] Барып җитүен җиткән бу, тик, ни күзе белән күрсен, Мисыр патшасы Кыйтфир бу кыз төшендә күреп гашыйк булган егет түгел икән.* Р.Сабыр. **Ни пычагым?** Нәрсә? *Шундый иртә, яшь кәләш кочагыннан торып йөрергә ни пычагым калгандыр аңа [Сөләймановка]...* Ә.Еники. **Ни пычагыма** Кирәкмәгәнгә, «нигә кирәк, ни хаҗәтемә» дигән мәгънәдә. *Шулчаклы байлыгы белән, аңар ни пычагыма кирәк булган динсез мулла күбәйтү?* М.Галәү. *Ни пычагыма кирәк булгандыр миңа тагылып йөрергә!..* Ә.Еники. *Ни пычагыма дип шул тирес корты белән тормыш корды икән?* Ф.Яхин. **Ни тора** 1) Җөмләдә әйтелгән фикерне ассызыклый, көчәйтә, куәтли. *Арыпталып, янып-көеп көне буе йөргәннән соң, каяндыр ташлы ярдан бәреп чыккан терекөмештәй саф, боздай салкын суны учың белән алып, чөмерә-чөмерә эчү үзе ни тора!* А.Гыйләҗев. *Әнә урам уртасыннан өч кеше ашыкмый гына фермага таба килә. --- Әллә, кире борылып, абзарларга китәргәме? Бу бит качу булачак. Ояты ни тора?!* Ә.Еники. *«Шильон тоткыны» тәрҗемәсен редакцияләгәннән соң, үз кулы белән күчереп чыгып, кереш сүз язып нәшриятка бирүе һәм бастырып чыгаруы үзе генә ни тора!* И.Нуруллин; 2) Әллә ни түгел, авыр түгел. *Моны гына эшлисе безгә ни тора.* **Ни хикмәт(тер)** *кер. сүз*

Ни сәбәпледер, сәбәбе нидәдер. *Ни хикмәттер, Габделхәй дә, күп кенә кибетчеләр шикелле үк, колхозның җитәкче кешеләреннән ихтыярсыз шүрли иде.* Ә.Еники. *Һәм дә, ни хикмәттер, язга таба, зәхмәт кагылып, шәкертләр хәстәләнергә башлыйлар иде.* Ф.Кәрими. *Үргәнеч, ни хикмәт, Сарайдан читләшә бара.* Ф.Яхин

НИ II *кис.* **1.** 1) «Никадәр», «күпме» мәгънәләрендә килеп, мәгънәне көчәйтә төшә. *Бозавын ни сорадым, күрше хакы дидем, ялвардым, бирмәдегез...* А.Гыйләҗев. *[Хәдичә:] И Фәрхетдин, син дә дөньяда икәнсең! Кайтканыңа ни көн үтте, шунда бер килеп чыкмадың.* А.Расих. *Ни чакырып, кияве-кызы янына күчеп килми, ялгыз яши [Сәкинә].* М.Мәһдиев

2) *-мый, -мыйча* кушымчасына беткән хәл фигыльләр янәшәсендә килеп, каршы килүне, ризалашмауны белдерә. *Шунда [фермада] эшләгәч, [аның хәлен] кайгыртмыйча ни... Бар да кайгырта.* Ә.Еники. *[Хәйбулла:] Күрде, ди, күрми ни! Хәзер патша заманасыдыр сиңа?!* З.Зәйнуллин

3) Шарт фигыль белән килеп, ис китмәүне, нәрсә белән булса да тиз генә ризалашуны һ.б.ны белдерә. *[Кара Гобәй:] Бәләкәй булсалар ни?! Сабыйлар бит алар гөнаһсыз.* З.Зәйнуллин

4) Ирония төсмере өсти. *Нигә, барыбер түгелмени? Акча җимеше ни, бакча җимеше ни?* Ә.Еники. *[Гәрәй:] Хәер, сиңа – аңгыра башка сөйләдең ни, сөйләмәдең ни...* Ф.Яруллин

2. *терк. мәгъ.* Тиңдәш кисәкләр арасында кабатланып килеп, нәрсәне дә булса инкяр итүне белдерә. *Сугышка хәтле Закир ни яхшы, ни яман ягы белән телгә кермәгән йомыкый гына бер яшүсмер иде.* Ә.Еники. *Ни тел, ни ишарә белән бернинди җавап алмагач, [шәфкать туташы] дежур торучыларның берсе ярдәмендә авыруны торгыза төшеп, рюмка белән дару суза.* И.Нуруллин. *Ни ямь, ни тәм таба иде соң Мөнәвәрә бу көтүләрдән?* Н.Гыйматдинова

НИ́БАРЫ *кис.* 1) Ниндидер бер күплектән аеруны, чикләүне белдерә; бары тик, тик, бары, фәкать. *Күз күрмәгән, колак ишетмәгән цех ишегеннән беренче мәртәбә атлап кер, берни белмә, үзең нибары өйрәнчек кенә бул, ә шулай да ниндидер начальник кисәге булып йөр!..* Ә.Еники. *[Дильяр:] Мин – нибары сезнең оста уеныгызга таң калган тамашачы гына...* Р.Сабыр. *Юк, үлмәгән әнкәй, югалмаган, Суга гына киткән нибары.* Р.Чурагул

2) Күләмне белдергән сүзләр (гадәттә саннар) янында килеп, аларның шуннан артмавын белдерә. *--- кабер тәмамланмыйча, нибары бер аршин тирәнлегендә генә казылган иде.* З.Бигиев. *Бу якты дөньяда нибары егерме дүрт ел яшәгән ул.* В.Нуруллин. *Бу чакта Шорага нибары унике яшь була.* Ф.Урманче

НИ́БАРЫСЫ *кис. к.* **нибары**. *Ә тегермәндә нибарысы өчәү эшлибез.* А.Гыйләҗев. *Ямгырчы би яши торган Шуран катаудан Болгар-торага нибарысы алтмыш-җитмеш чакрым ара иде.* Н.Фәттах. *Югары уку йортларына имтихан тапшыручыларга да нибарысы өч куш бит кәгазь бирелә, шуннан да арттырмаска тырышуларын сорыйлар.* Р.Рахман

НИВЕЛИР *и. нем. махс.* Нивелирлау эшендә кулланыла торган геодезик әсбап. *Нивелирның горизонталь планкасы калкулык битенә юнәлгән булырга тиеш.* Башлангыч география курсы

НИВЕЛИРЛА́У *ф.* Җир өстендә нинди дә булса ноктаның берәр билгеләнгән нокта белән яки диңгез өсте тигезлеге белән чагыштырмача биеклеген билгеләү

НИВЕЛИРЛАУЧЫ *и.* Нивелирлау эшен башкаручы. *Планка өслеге буенча карап, нивелирлаучы планка бантының нинди ноктага туры килүен билгели һәм шул ноктага ярдәмче казык кагып куя.* Башлангыч география курсы

НИВХ *и.* Монголоид расасына караган, палеоазиат телләренең берсендә сөйләшкән, Амур елгасының түбән агымында һәм Сахалин утравында яшәүче халык атамасы һәм шул халыкның аерым бер вәкиле. *Нивхлар бу татар әбисен бик хөрмәт итә.* Кызыл таң

НИ́ГӘ *а.* **1.** 1) Нинди максат белән. *Я, аңа, Закирга, мин әйтәм, синең эштә чокыну нигә кирәк булды әле?* Ә.Еники. *– Нигә миңа кем беләндер берләшергә! – диде Кара Козгын, масаюлы тавыш белән.* И.Хуҗин

2) Ни сәбәпле, ни өчен, ник. *Нигә хикәянең күңелдә уйланганы шундый дулкынландыра да, нигә ул кәгазьгә төшкәндә зәгыйфьрәк чыга?* Г.Бәширов. *[Һади:] Нигә эштә түгелсез?* З.Зәйнуллин. *Бәй, янәсе, татар була торып, Сырышасың нигә ятларга?* Х.Туфан

3) Сорау кисәкчеге мәгънәсендә килеп, сорау җөмләнең башында сорауны көчәйтү өчен кулланыла. *[Бамбыр:] Нигә, улың синдә унтугыз яшькә җиткәнче түшәмгә төкереп кенә, эшләмичә тик яттымыни?* З.Зәйнуллин. *Бик үк аңлап та җиткермәдем: нигә, Аллага ышанучы кешенең барлыгына ышанмый микәнни?* Ә.Еники. *Нигә, язын бакчага утыртканда, кәбестәнең дә ике нәфис яфрагы гына була.* С.Сөләйманова

2. *терк. мәгъ.* Иярчен кире җөмләне баш җөмләгә теркәү өчен кулланыла. *Нигә шунда дөньясы асты-өстенә килми, уйлап та бирмәм*

НИ́ГӘДЕР *а.* 1) Ниндидер билгесез сәбәп аркасында. *Егеткә күзе төшү белән, ул да нигәдер каушады, хәтта агарынып китте.* Г.Бәширов. *[Сәрвәр:] Киявең дә исән. Түбән Очка Көрпә бабайга дип чыгып киткән иде – нигәдер озаклады.* З.Зәйнуллин. *– Чукындырылган татарлардан, – дип әйтергә теләгән иде, ләкин нигәдер тынып калды.* И.Хуҗин

2) Аңлашылмаган бер максат белән

НИГЕЗ *и.* **1.** 1) Төзеләчәк, корылачак, урнаштырылачак нәрсәнең терәге булып хезмәт иткән аскы өлеше; фундамент. *Урам як читәнне алып ыргыттылар, бик аз гына нигез ясадылар да уңган күл белән кечкенә дүртпочмак өйне күтәрделәр.* Г.Ибраһимов. *Түбә калае тутыгып, күп җирдән тишкәләнгән, нигез өстендәге бүрәнәләре һәм тәрәзә аслары яртылаш черегән --- иде.* Ә.Еники. *Ташы булмагач, өйләрнең нигезе ныктүгел.* Г.Гыйльманов

2) Йортның тышкы дивары буенча, җылыту өчен, гадәттә туфрактан өелгән

бик биек булмаган өем; эргә. *Әхмәтвәли кушуы буенча өйнең нигезенә туфрак та салып киттеләр, утын да китереп аударды лар.* Ә.Еники. *Яңгырда бөрешеп беткән, ышыкланырга дип өй нигезенә сыенган кәҗә бәтиенең ябык, дерелдәгән гәүдәсе генә күземә чалынды.* А.Гыйләҗев. *Тавык-чебеш тузгып, кабарынып, Нигез туфрагында коена.* Ш.Галиев

3) Төп йорт, ата-баба йорты; туып үскән, гомер иткән йорт. --- *карчык борчылып уйламыйча булдыра алмый: туган җирләрен дә, кечкенә Юлкотлыны да, аталарыннан калган нигезне дә алар бөтенләй онытып баралар кебек.* Ә.Еники. *Гайшәтти дөньяга китергән бик күп кызлар, яшьтән егетләре сугышта шәһит китү аркасында, карт кызлар булып туган нигезләрендә утырып калдылар һәм ата-анага игелек күрсәтеп картайдылар.* М.Мәһдиев. *Туган изге нигезен карый-карый, бәрәңге бакчасы ягына таба ындыр капкасыннан чыкса, исе китте.* Ф.Яхин

4) *күч.* Нәрсәнең дә булса барлыкка килүе өчен матди база, мая

5) *күч.* Нәрсәнең дә булса төп асылын тәшкил иткән, нәрсәне дә булса барлыкка китерү өчен төп материал булып хезмәт иткән чыганак; зәмин. *Халык әдәбияттан, бер уңайдан, әдәбиятның нигезе булган телдән дә бизде.* М.Юныс. *XIII–XIV гасыр мөселман кабер ташларындагы текстларның телен тикшерүдә татар галимнәре Х.Фәезханов, Һ.Йосыпов һәм Ф.Хәкимҗановларның хезмәтләре төп нигезне тәшкил итәләр.* М.Әхмәтҗанов

6) *күч.* Нәрсәнең дә булса җирлеге, таянычы. *Дөрес, ул һич нигезе булмаган гайбәт кенә, ләкин әнә Нургали абыеңның мыегын чуалтыр өчен җитә калган.* Ә.Еники. *[Сәфәр:] Безнең җәмгыятьнең ныклы нигезе булсын өчен, Рәис абый, кем кем белән тели, шуларны өйләнештерәм, дип әйтә, ди.* Ф.Галиев

7) Нинди дә булса фәннең башлангычы, төп фикере. *Бик җайлы бит югыйсә: монда урыс мәктәбе – православие нигезләрен өйрәнәләр, анда татар мәктәбе – мөселман диненнән сабак алалар.* Р.Зәйдулла. *Тормыш иминлеге нигезләре. Ислам мәдәнияте нигезләре*

8) Нәрсәнең дә булса асылы. *Һәр диннең нигезендә кешене яхшырак итү нияте ята.* Р.Зәйдулла. *Хаклык нигезе. Тормыш нигезе*

9) Кешенең үз-үзен тотышын, тәртибен һ.б.ны аңлата, аклый торган сәбәп, дәлил, аргумент. *Һәрбер өйләнүнең нигезендә чын мәхәббәт ятарга тиеш – шулай түгелме?* Ә.Еники

10) Мөмкинлек; хокук, хак. *Аңлашыла, авылның бу Миләшә дигән исеме дә шуннан алынган, дип уйларга нигез бар.* Н.Дәүли. *Үз каланчаларыннан караганда, аларның һәммәсенең дә Исхактан ризасыз булырга нигезләре бар.* А.Гыйләҗев

11) *тех.* Тукымадагы буй җепләр

12) *мат.* Геометрик фигураның биеклегенә перпендикуляр як, кыр. *Тигезьянлы өчпочмакның нигез янындагы почмаклары тигез.* Геометрия

13) *хим.* Тозның кислоталар белән үзара тәэсир итешүе аркасында хасил булган кушылма. *Кислота буларак, алар [аминокислоталар], нигезләр белән реакциягә кереп, тозлар хасил итәләр, ә спиртлар белән тәэсир итешеп, катлаулы эфирлар барлыкка китерәләр.* Органик химия

14) *лингв.* Сүзнең төп лексик мәгънәсен белдергән һәм тамырдан башка ясагыч кушымчаны да үз эченә алган өлеше. *Аныңча [Р.С.Абдуллина фикеренчә], паронимнар – охшаш яңгырашлы сүзләр, һәм аларда тамыр яки нигез морфемаларының этимологик уртаклыгы күзәтелә.* Ф.Сафиуллина. *Тамыр нигез. Ясалма нигез. Кушма нигез*

2. *с. мәгъ.* 1) Аскы өлешне тәшкил иткән, фундамент булган. *Нигез бүрәнәләр*

2) Нәрсәнең дә булса асылы булган, төп. *Нигез директивалар*

◊ **Нигезен корыту** Нәрсәне дә булса бөтенләй юкка чыгару; бетерү; тамырын корыту. *[Абдулла:] Сүтәргә яман тырышып карадылар каравын, өстән сүтеп тә алдылар хәтта. Әмма тик нигезен корыта алмадылар шул.* Ф.Бүләков. **Нигез кору** Гаиләле булып бергә яши башлау, оя кору. *Гыйльфан белән Сара туташ, кавышып нигез корганда, бер ялгыш җибәрделәр шикелле.* М.Мәһдиев. *Безнең хәлгә килгәндә, Юлдашлар, Кызлар сездә кияүдә, Юлдашлар, Әйбәт нигез корсыннар, Әйбәт, тигез торсыннар.* С.Хәким. **Нигез күрше** Янәшә күрше, ут күрше. *Соңгы кайтуыбызда нигез күршеләребезнең уллары Искәндәр белән Зөлфәт күңелгә коткы салып җибәрде.* Безнең гәҗит. **Нигез салу** Нинди дә булса эш башлап җибәрү. *XIX гасырның беренче яртысында, җир кешесе мәхәббәтен җырлап, дөньяви поэзиягә нигез салган Габделҗаббар Кандалый да – башыннан аягына кадәр мулла...* И.Нуруллин. *Татарлар тарафыннан без белмәгән күпме мәмләкәтләргә нигез салынган!* Р.Зәйдулла. **Нигез салучы** *к.* **нигезләүче**. *Әкрәм кари килеп кергән бу кечкенә куыш яңа татар әдәби теленә нигез салучы, --- мәгърифәтче галим яшәгән йорт булып, --- каләмен очлап утыручы кеше шул галим үзе – халык телендә «Сукыр Каюм» дип йөртелгән мәшһүр Каюм Насыйри иде.* М.Галәү. *Шиһаб Әхмәров татар мәдәнияте тарихында «Мәктәб» журналына нигез салучы буларак билгеле.* Р.Зәйдулла. **Нигез ташы** Нинди дә булса эшнең башлангычы. *Татар шигыре төзелешенең нигез ташлары булган төп үзенчәлекләр шактый төсмерләнде инде.* Х.Туфан. *Шуны-сын да онытмаска кирәк: ислам дине төрки мәдәниятнең асыл нигез ташын тәшкил итә.* Р.Зәйдулла. *Цивилизациянең өч нигез ташы бар: тел, дин һәм алфавит.* Ватаным Татарстан

НИГЕ́З БОТКАСЫ *и. этн.* Татар халкында нигез салу өмәсеннән соң өй төзүдә катнашучыларны сыйлап үткәрелә торган борынгы халык йоласы

НИГЕЗДӘ *кер. сүз.* Гомумән алганда, асылда. *Бу ике иптәшнең фикере нигездә дөрес.* Х.Сарьян. *Тау ягы – Болгар дәүләте һәм Болгар олысының провинциясе, Иделнең уң ягы, нигездә, Тәтеш шәһәре киңлегенә кадәр керә.* М.Әхмәтҗанов

НИГЕЗДӘН *рәв.* Бөтенләй, тулысынча. *Нигездән үзгәртү*

НИГЕЗДӘШ *с.* Нигезләре янәшә булган, күрше яки уртак нигездә салынган йортта торучы; ут күрше, нигез күрше

НИГЕЗЕНДӘ *бәйл.* Нәрсәгә дә булса нигезләнеп, таянып. *Европа интернационалистлыгы менә шушы кагыйдә нигезендә исбат ителә.* М.Юныс. *Кайбер Мәскәү тарихчыларының, татарлар болгарларны 1236 елда кырып бетергәннәр, дип матбугат битләрендә ясаган чыгышлары XIII–XIV гасырлар эпиграфик материаллары нигезендә дөреслеккә туры килми.* М.Әхмәтҗанов

НИГЕЗӘ́-ТӨБЕ *и.* Асылы, башлангычы, иң әһәмиятле өлеше

НИГЕЗЛӘМӘ *и.* 1) *юр.* Билгеле бер мәсьәләгә кагылышлы законнар, кагыйдәләр җыентыгы. *Нигезләмәнең икенче пункты. Нигезләмәгә үзгәрешләр кертү. Законның аерым нигезләмәләре*

2) Исбатланмыйча, дәлилләнмичә дә дөрес дип кабул ителә торган башлангыч, нигез фикер; постулат

НИГЕЗЛӘНҮ *ф.* 1) Җитди, төпле дәлилләр белән исбатлану, дәлилләнү

2) Йорт, каралты-кура салып килеп утыру, шул урында төпләнеп калу

3) Нәрсәгә дә булса таянып эш итү, шуннан файдалану. *Чириков теленкитләр белән хәйлә һәм мәкергә нигезләнгән сәясәт алып барды.* И.Хуҗин. *Бүтән барлык галимнәрнең дә хезмәтләре аларның фәнни казанышларына һәм ачышларына нигезләнә, киләчәктә башкалар да алар туплаган бай материалга таянып эшләрләр.* М.Әхмәтҗанов. *Бу чорда татар әдәби теленә нигезләнгән дәреслекләр дөнья күрә.* Ф.Солтанов

НИГЕЗЛӘ́Ү *ф.* 1) Нигез салу, башлап җибәрү, эш башлау

2) Дәлилләү, исбатлау, ышандырырлык дәлилләр китерү. *Кыскасы, суд алдына килгәнсез икән инде, рәхим итеп, үзегезнең үтенечегезне нигезләгез!* Ә.Еники. *Тәлгать Бариев --- бик нигезләп, туган телендә укый һәм сөйләшә алмаган урыс телле татарларны җәлеп итәрдәй бик тә үтемле мәкаләләр язды.* Б.Рәхимова

3) Нәрсәгә дә булса таянып эш итү, шуннан файдалану, нәрсәне дә булса чыганак итү

Нигезли бару Эзлекле рәвештә, рәттән, шунда ук нигезләү

НИГЕЗЛӘҮЧЕ *и.* Нигез салучы, башлап җибәрүче, башында торучы. *Ләкин XVIII гасыр башларында бу системаны нигезләүчеләрнең берсе Кантемир шигырьләре турында шактый кызыклы фикерләр бар.* Х.Туфан

НИГЕЗЛЕ *с.* 1) Нигезе (*1 мәгъ.*) булган

2) Йорты-җире булган

3) Тирән эчтәлекле, төпле (белем, фикер, чыгыш һ.б.ш. тур.). *Бүген ул ишек төбендә икеләнеп тормады, ният нык, фикере нигезле иде.* А.Гыйләҗев. *Татар морзалары нәселеннән булган әнисе Таисиядән Алексей ныклы, акыллы, нигезле татар морзаларында булган тәрбия алган.* З.Зәйнуллин

4) Тиешле дәлилләре, сәбәпләре булган; нигезләнгән, төпле, ышандырырлык. *Мин биолог булмасам да, бу дәлилләрнең нигезле икәнен белә идем.* А.Тимергалин

5) Чынбарлыкка туры килә торган, дөрес. *Нигезле булган икән ул шомлы кисәтүләр!* А.Гыйләҗев

6) Урынлы

НИГЕЗЛЕК 1. *и.* Нигезгә (*1 мәгъ.*) дигән, нигез салыр өчен билгеләнгән материал. *Нигезлекне алданрак әзерләргә кирәк*

2. *с. мәгъ.* Нигезгә (*1 мәгъ.*) дигән, нигез салыр өчен билгеләнгән. *Нигезлек таш ташып кую*

НИГЕЗЛЕЛЕК *и.* Нигезле булу. *Чөнки әлеге вакытта берничә төрле проектның нигезлелеге, икътисади отышлылыгы проблемасы тикшерелә.* Кызыл таң

НИГЕЗСЕЗ *с.* 1) Нигезе булмаган. *Нигезсез салынып, иламсез яңтайган йортларны Мансурларның авылында күп очратырга мөмкин.* Г.Гыйльманов

2) Нигезе, дәлиле булмаган, исбатланмаган, расланмаган. *Ләкин бик тиз мин бу борчылу-куркуның нигезсез икәнен аңлап алдым.* Ә.Еники. *Бу – беркатлы, нигезсез караш.* Х.Туфан. *Аны барыннан да бигрәк Алла урынына ышанган, чиксез хөрмәтләгән бөек кешесе Иосиф Виссарионович Сталинның, үзен һәм ата-анасын нигезсез җәберләве ачындырды.* И.Хуҗин

НИГЕЗСЕЗЛЕК *и.* Дәлилсезлек; нигезләнмәгән, исбатланмаган булу

НИГЕЗЧЕ *с.* Төп, нигез итеп алынган, иң көчле (интонация, басым тур.). *Әгәр дә төп, нигезче басымнар буынның икенче иҗекләрендә булса, ачык иҗекләр алардан алда (беренче иҗекләрдә) киләләр.* Х.Туфан

НИГИЛИЗМ *и. лат. кит.* 1) Рус иҗтимагый фикере тарихында дворян җәмгыяте нигезләрен, аның мәдәниятен, традицияләрен, крепостнойлыкны кире каккан юнәлеш

2) *күч.* Һәммә нәрсәне инкяр итү, кабул ителгән нормаларны танымау. *Тик аның үсүенә комачауламаска, телнең үсү юлына нигилизмнан киртәләр кормаска, бәлки, киресенчә, ярдәм итәргә кирәк.* Г.Бәширов. *Фуаттагы нигилизмның төп сәбәбе хәтфә альбомдагы рәсемгә бәйле икәнлеген Суфия элек үк эчке сиземләү белән тоя иде.* С.Сөләйманова

НИГИЛИСТ *и. лат.* 1) Нигилизм тарафдары

2) *күч.* Һәммә нәрсәне инкяр итүче, кабул ителгән нормаларны танымаучы кеше. *Ниса да кимен куймый: «Нигилист! Барыбер муеның сыначак синең беркөн!» – дип җибәрә.* А.Гыйләҗев

НИГИЛИ́СТИК *с. кит.* Нигилизмга хас, нигилизмга караган. *Үткәндәге хаталар, соңгы елларда көчәйгән игътибарсызлык, сансызлык аркасында, бигрәк тә совет һәм партия аппаратларында утыручыларның нигилистик мөнәсәбәте нәтиҗәсендә, туган телебезне бүгенге хәленә китереп җиткердек.* Ә.Еники. *Ф.Әмирхан дусты һәм замандашы Г.Тукай мирасын аеруча пропагандалый, аның шәхесен һәм иҗатын төрле нигилистик һөҗүмнәрдән саклый.* Р.Әмирхан

НИГИЛИСТЛЫК *и.* Нигилист (*2 мәгъ.*) булу. *Тора-бара, белемдә өстенлеген күрү белән бәйле рәвештә, [Г.Ибраһимовның] бунтарьлык, инкяр итү, нигилистлык сыйфатлары көчәеп китә.* И.Нуруллин

НИГЪМӘТ *и. гар.* 1) Муллык, байлык, иркенлек. *Шулай итеп, дөньяның ләззәтеннән, Алланың хәләл иткән нигъмәтеннән үзеңне үзең мәхрүм итүдән ни файда туар икән?* Г.Исхакый. *Җир йөзе җәннәт иде: дәүләт вә нигъмәт бар иде.* Г.Тукай. *Әгәр дә син Аллаһ биргән нигъмәтләреңбулганда үзең гафләттә йөрмәсәң, --- күз тими.* Р.Юныс

2) Ашамлык-эчемлек, азык-төлек, аш-су. *Казан нахиясендә аның сөфрәсеннән нигъмәт ашамаган адәмнәр бик аздыр.* К.Насыйри. *– Аштан олы түгелсең бит, Шәрифулла туган, – диде карчык, – утыр, безнең нигъмәттән дә авыз итеп кара.* А.Шамов. *Үлеп арыгач, каты таш мамык мендәрдән дә йомшак, өшегәч, мич башы җәннәттән дә рәхәтрәк, ачыккач, ипи катысы оҗмах нигъмәтләреннән дә татлырак ---.* И.Нуруллин

НИГЪМӘТЛЕ *с.* Нигъмәте булган; нигъмәт бирелгән. *Мондый мул нигъмәтле табын бары тик олуг кунак хөрмәтенә генә хәзерләнәдер.* М.Хәсәнов. *Әче бал эчеп, каклаган каз, өчпочмаклар, бәлешләр, зур-зур ит кисәкләрен ашап, үз гомерләрендә дә андый нигъмәтле бай өстәл күрмәгән ач урыслар караңгы төшеп күз бәйләнгәнче рәхәттә йөзделәр.* З.Зәйнуллин

НИДА *и. гар. иск.* 1) Өндәү, чакыру авазы, тавышы. *Агач, таш эчләре шаңрап, Киләдер бер нида яңрап!* Дәрдемәнд. *Азатлык! Көрәшләр ярсуы бу сүздә, Җиңүләр нидасы, Тынычлык нидасы ул безгә.* Х.Туфан. *Шул заман Хак Тәгаләдән нида килде: – Әй Сәүри! Тәнреңнән оялмыйча, әдәпсезлек кылып, аякларыңны сузып ятасың, – дип.* Гыйбрәтле хикәятләр

2) *шигъ.* Зар-ыңгырашу тавышы. *Кара тупрак тулы мәзлум нидасы, Алар кемдер?.. Алар кемнәр фидасы?* Дәрдемәнд

НИДА́ ИТҮ *ф.* Эндәшү, дәшү, тавыш белән чакыру. *Бөтен аңлы мөселманнарга, милли азан тавышын ишетергә өйрәнгән мөселманнарга нида итте.* Г.Исхакый. *Мин «бәхет» диеп нида итсәм дә, булмый берни дә; Баткан ул бәхет кояшы, мисле чыкмас мәңгегә!* Г.Рамазанов

НИДА́ КЫЛУ *ф. к.* **нида итү**. *Анда [поэзиядә]: «Менә нинди шатлыклы вакыйга бит бу!» – дип илгә кычкырырлык, нида кылырлык, оран салырлык уңышлар да бар.* Х.Туфан

НИДАЛЫ *с. иск.* Күтәренке күңелле, шат (тавыш тур.)

НИДАЧЫ *и. тар.* Боерык, карар, хөкем һ.б.ш. рәсми мәгълүматны киң катлам халыкка кычкырып хәбәр итүче. *Ходайның бер бирмеш көнендә Исмәгыйль кебек йөзәрләгән вак сәүдәчеләр базарда утырып һәр кешегә «ал инде» дигән карашлары белән тилмерә язып карап калганда, халык шавын басып нидачы тавышы яңгырады.* З.Мурсиев

НИ́ДӘН *а.* Ни сәбәптән, ни өчен, нигә, ник. *Нигә кызыл чукларың? Нидән алсу төсләрең?* М.Җәлил. *[Ибраһим:] Бу нидән бу, Хәлил абзый, безнең нәселдә аяк авыруы бик күп?* Г.Исхакый. *Куанычлы хәл: Нургали аларны [ферма эшчеләрен] күпме генә шикләнеп йөрмәсен, ә алар әнә ничек аңа үз итеп карыйлар. --- Нидән икән бу?* Ә.Еники

НИ́ДӘНДЕР *а.* Нинди дә булса сәбәптән, аңлашылмаган сәбәптән, ни өчендер, никтер. *Акчаны алгач, әби киткән нидәндер Әтнәгә.* Г.Тукай

НИ́ДЕР *а.* Ниндидер билгесез бер әйбер, нәрсә, күренеш, предмет. *Ничектер бик әдәпле телдә, бик китапча итеп, җинаятьче турында нидер сорый.* М.Әмир. *Ике кызчык көләшаркылдаша, Кызып-кызып нидер сөйләшә ---.* М.Хөсәен. *Гүя аларның һәркайсы хәзер генә үтәлгән эшнең нәтиҗәсе турында үзалдына эченнән генә нидер уйлана иде.* Ә.Еники

НИДЕРЛАНД *и.* Көнбатыш Европаның төньягында, Төньяк диңгез буенда урнашкан ил; шуның җирле халкы. *Бургундларның король сараена данлыклы нидерланд батыры Зигфрид килеп төшә һәм корольларнең сеңлесе Кримхильдага гашыйк була.* Ф.Урманче

НИЗАГ *и. гар.* Ызгыш, талаш, гауга. *Бу арада коридорда низаг тавышы ишетеп, Әхмәт тә чыгып җитте.* Ф.Әмирхан. *Яңа килгән прораблар, начальниклар белән низаг һәр җирдә бара.* А.Гыйләҗев. *Шушындый үзара низаглар, хакимият өчен көрәшләр аркасында дәүләтләр җимерелә, халыклар юкка чыга.* Г.Садыйкова

НИЗАГЛАШУ *ф.* Талашу, ачуланышу, ызгышу. *Алар шулай байтактан бирле үзара ызгышып, низаглашып яши торгач, бу бәхәсне рәсми төстә үзләре әле һаман буйсынган «Урда ханы гына чишсә чишә алыр» дип, Олуг Мөхәммәткә киләләр.* Р.Фәхретдинов

Низаглашып алу Бер ара низаглашу

Низаглашып йөрү Гел, һәрвакыт низаглашу; күптәннән бирле низаглашу. *Кайбер илләрдә милләттәшләребезнең таркау булуы, бер-берсенә ярдәм итү урынына низаглашып йөрүләре дә безне бик борчый.* Ватаным Татарстан

Низаглашып тору Регуляр, әледән-әле низаглашу

НИЗАГЛЫ *с.* Шау-шулы, бәхәсле, тавышлы, гаугалы. *Әлеге низаглы мәсьәләне тикшергәндә, 1625 һәм 1640 еллардагы биләмә хокукы биргән документларда (грамоталарда) Җөремеш Сөендек улының исеме телгә алынган.* Гасырлар авазы

НИЗАГЛЫЛЫК *и.* Низаглы, тавышлы, гаугалы, бәхәсле булу

НИЗАМ *и. гар.* 1) Төрле предметларның урнашуында, куелышында, торышында билгеле бер эзлеклелек, җыйнаклык хәле, тәртип. *Йорт эчендә дә элгәреге низам вә интизам бетте.* Г.Исхакый

2) Иҗтимагый төзелешнең, идарә итүнең билгеле системасы, дәүләт төзелеше, төзем, тәртип. *Әз бәягә ашыгып сатып җибәрүнең хикмәте исә – табылган кешене кол урынына сатарга ярамауда. Чөнки бу – низамга каршы килә...* Р.Юныс. *Заманасына күрә кытайлыларда низамсыз булса да гаскәрләре, начар булса да кораллары булган.* Г.Монасыйп

3) Эш барышында яки тормышта урнашкан, кабул ителгән билгеле бер кагыйдә, закон яки кагыйдәләр, законнар җыелмасы. *Маһруйның бар сөйләгәннәре низам-закон каршында*

расланмыйча һәм кабул ителмичә, синең котылып калачагың шөбһәсез. З.Бигиев

НИЗАМ-ИНТИЗАМ *җый. и. кит. к.* **низам**. *Әлхәмдүлилләһи, Йосыф бәгиям, сәңа низам-интизам тугры калыр.* М.Хәбибуллин

НИЗАМЛЫ *с. иск.* Системалы, планлы, билгеле кагыйдәләргә салынган. *«Низамлы мәдрәсә» дигән сүз ул бит куркынычлы сүз түгел.* Г.Исхакый

НИЗАМНАМӘ *и. гар.-фар.* Норматив документ, рәсми рәвештә расланган кануннар, кагыйдәләр җыелмасы. *Шуның ничек төзелүе, кирәклеге хакында махсус низамнамә эшләнде.* Г.Исхакый. *Эшне оештырырга хокукый җирлек булсын өчен, Татарстан мөслимәләре берлегенең низамнамә проекты да кабул ителде.* Шәһри Казан

НИЗАМСЫЗ *с. иск.* Системасы, планы, билгеле эзлеклелеге булмаган; тәртибе бозылган. *Шкафның өстендә әллә никадәр низамсыз газеталар тузылып ята.* Г.Исхакый

НИК *а.* 1) Ни өчен, ни сәбәпле, нигә, нидән, нинди максат белән. *Ник баш бөктең залимнәргә?* Г.Тукай. *Түрә тагы: «Ник бунт чыгарасың, ник котыртасың?» – ди.* Г.Исхакый. *Ник аның белән кабергә кереп ятмадым, дия-дия яшәдем мин [Сара].* Н.Гыйматдинова

2) Тойгылы җөмләләрдә өченче зат боерык фигыльләр белән килеп, эш яки хәлнең бөтенләй бетүен, булмавын белдерә. *Көн эссе, көн бөркү, ник чыпчык җиле иссен...* А.Гыйләҗев. *Елга тирәләре тәмам шәрә калган, ник бер үлән сабагы, яфраклы агач яки талчыбык күзгә чалынсын.* Ф.Яхин. *Ул шунда Заһир абыйга карата мөнәсәбәтен белгертеп ник бер сүз әйтсен.* М.Шаһимәрдәнов

◊ **Ник бардым көненә төшү** Берәр җиргә барып уңышсызлыкка, хурлыкка һ.б.ш дучар булуга карата. **Ник дисәң** «Чөнки, аның сәбәбе ---» мәгънәсендә. --- *Габдулланың кәефе һич тә начар түгел. Ник дисәң, өстендә яңа бишмәт, башында яңа бүрек, аягында яңа киез ката, янында Бәдри абзасы.* И.Нуруллин

НИКАБ *и. гар.* Мөселман хатын-кызлары, күзләрен генә ачык калдырып, йөзләрен каплый торган пәрдә. *Ач никабыңны йөзеңдин.* Г.Тукай. *Аерым хатын-кызларыбызның гарәп, төрек киемнәренә тәкълит итүләре, капкарага бөркәнеп йөрүләре, никаб киюләре һичничек аңлашылмый, милләтебезне кимсетү булып тора.* В.Ягъкуб

НИ́КАДӘР *а.* 1) Предметларның саны, күләме, микъдары турындагы сорауны белдерә; күпме

2) Гадәттә тойгылы җөмләләр составында килеп, нәрсәнең дә булса бик күп санда яисә микъдарда, күләмдә булуын күрсәтә. *Аһ, никадәр кадерле һәм якын Газиз җанга туып үскән җир ---.* М.Хөсәен. *Никадәр яла яккан бит кешегә, юкабаш!* Ф.Баттал. *Белсәгез, никадәр авыр иде миңа бу минутта!* Ә.Еники

3) Иярченле кушма җөмлә кисәкләрен бәйләүче мөнәсәбәтле сүз функциясендә кулланыла. *Солтан әмер итте, мәмләкәттә никадәр харап шәһәрләр бар иде, барчасын төзәттеләр.* К.Насыйри. *Райком секретаре икәнсең – җитди бул, никадәр җитди булсаң, халык алдында шулкадәр дәрәҗәң, абруең зур булыр.* М.Мәһдиев. *Гитлер никадәр катырак каршы торып маташкан саен, аңа карата булган ачу-нәфрәт шулкадәр көчәя бара...* Ә.Еники

НИ́КАДӘРЛЕ *а. к.* **никадәр**. *Никадәрле җырласаң да, Тыңлап туярлык түгел.* Х.Туфан. *Никадәрле кайнарлык, хис, дәрт... Башын корбан итте, әмма үзенекен эшләде...* А.Гыйләҗев. *Әнә никадәрле май таплары йөзеп йөри, барысы да аныкы.* И.Хуҗин

НИКАХ *и. гар.* 1) Ислам дине буенча өйләнешүне, гаилә төзүне махсус хөтбә укытып беркетү йоласы. *Кыз белән кияүне никахтан соң шунда ябарга хәзерләделәр.* Г.Ибраһимов. *Шулвакыт аны [хәзрәтне] никах мәҗлесенә чакырдылар.* М.Мәһдиев. *Муллаларның берсе дә никах укырга теләмәделәр.* Ф.Яхин. *[Мулла] Кәгазьгә урыс хәрефләре белән язылган никах хөтбәсен кычкырып укый башлады.* Р.Зәйдулла

2) Ир белән хатынның рәсмиләштерелгән гаиләсе. *Катнаш никах ул, беренче чиратта, төптән уйланмыйча, язмышларын бергә бәйләгән ике яшь йөрәкнең гаиләсе һәм киләчәк тормышы өчен зарарлы.* И.Сабиров. *Мәгәр илаһи кануннар безгә хәрам вә хәләлне аерып куя: бар зина, бар никах.* Р.Юныс

◊ **Никах яңарту** 1) Шәригать буенча никахта торуның нинди дә булса бер шарты бозылган очракта, никахны яңадан укыту. *– Бәлкем, никахны яңартырга кирәктер? – дип сорады [Габдулла бай]. – Ул гына аз, – диде хәзрәт. – Син бит ул сүзне өч тапкыр әйткәнсең.* М.Галәү. *Төн булуга карамастан, әбекай кушуы буенча, урам аша гына торган Гыйният мулланы чакырып, никах яңарталар.* Ә.Еники. *Карибулла башта «өегезгә бозым керткәннәр, нигезегезне дә зәхмәтле итәргә теләгәннәр» дип, Коръән укыды, аннары хуҗа белән хуҗабикәгә изге һәм саваплы эшләрдә читтә калмауны теләп, аларның никахын яңартты, соңыннан җиде төрле ризыкка «әр-Рахман»ны укып өрде.* М.Шаһимәрдәнов; 2) Башка хатынга өйләнү. *Минем ризалыгымны алып, мулладан тизрәк никахыгызны яңарттырып, кыска вакытлы шушы төннәремне дә минем белән бүлешү кирәк икән...* Г.Галиева

НИКАХЛАНУ *ф.* Өйләнү; кияүгә чыгу. *Сезләрдән берегез фәкыйрь булып азат булган кызны яки хатынны алырга көче җитмәсә, ул сезнең кулыгызда булган мөэминә кәнизәкләрдән никахлансын!* Ногмани. *Руфәга исемле кеше хатынын өч талак белән талак кылгач, хатын Зөбәер улы Габдеррахманга никахланды.* Ш.Хәмиди. *Бу кеше [Ибраһим хан] Хәлил үлгәннән соң, аның Нур-Солтан исемле тол калган хатынына никахланып, ханлык итә башлый.* Һ.Атласи

НИКАХЛАП *рәв.* Нихах белән, никах укытып. *Хәтта сирәк-мирәк килгәләүче абыйсы Закирҗан да болар турында, никахлап өйләнешмичә генә ир белән хатын кебек торалар, дип уйлый.* С.Сабиров. *Икенче көнне инде патшаның бердәнбер кызын ишан*

хәзрәтләренә никахлап бирү турында бөтен илгә рәсми хәбәр дә таратыла. Ә.Еники

НИКАХЛА́У *ф.* Никах уку, дин кушкан шартлар белән өйләндерү. *[Вафа:] Мин бит синең кызыңны урлап та, алдап та алмадым. Шаһитлар алдында үзең никахладың.* М.Галәү. *– Анда өйләнүең ничегрәк килеп чыкты соң, Нургали улым? – дип, мәхәлләнең аерата үзе никахлаган һәр кешесе өчен Аллаһы Тәгалә каршында үзенең гаять җаваплы булуын искәртеп, сорау арты сорау яудырды хәзрәт.* Г.Галиева

НИКАХЛАШУ *ф.* Кем белән дә булса никахка (*2. мәгъ.*) керү, өйләнешү. *Габбас мулла --- никахлашкан елны Шәмсениса абыстайның --- гел дә менә ярарга тырышып йөргән көннәрен күңеленнән кичерә.* Г.Ахунов. *Ә алар мине бүтәнгә бирделәр бит инде, никахлашасы гына калды...* Ф.Яхин. *Инде моннан соң озакламаслар, кайтып җитәрләр, дип кенә йөргәндә, Нургалинең үзе эшләгән кибет хуҗасының кызы белән никахлашуы турында хәбәр килеп төшмәсенме...* Г.Галиева

Никахлашып кую Озакка сузмыйча никахлашу

Никахлашып калу Берәр вакыйга яки вакыт җиткәнче никахлашу. *Бәлки, ул сугышка киткәнче үк, безгә никахлашып калу кирәк булгандыр?* Ватаным Татарстан. *Рамазан ае җиткәнче никахлашып калырга тырышу*

НИКАХЛЫ *с.* **1.** 1) Никахы булган, никах укытып өйләнгән, кияүгә чыккан. *Минем никахлы хатыным буларак, аның миннән ярдәм һәм булышлык көтәргә хакы бар.* З.Бигиев. *[Искәндәр:] Кит аның яныннан! Син хәзер – никахлы кыз.* М.Фәйзи. *Ни дисәң дә, никахлы хатыным бит син минем!* Ф.Яхин

2) Законлы, закон нигезендә рәсмиләштерелгән (ир, хатын)

2. *рәв. мәгъ.* Нихах укытып, никах нигезендә. *Кем белгән, булуы ихтимал, мут кеше ул Гыйбадулла, өч тапкыр никахлы өйләнде, күпме яшь кызларның башына җиткәнен бер Ходай беләдер!* А.Гыйләҗев. *Шәригать тә мөселманга, мөмкинлеге булса, хәтта дүрт хатын белән никахлы яшәүне хуплаган.* Г.Галиева

НИКАХСЫЗ *с.* **1.** Никахы булмаган, никах укылмаган

2. *рәв.* Законсыз, никах укытмыйча. *Татар хатын-кызларының никахсыз, сөяркә булып торулары, зинадан бала табулары да бернинди шәригать кысаларына сыймый, әмма бу да татар тормышында гадәти хәлгә әйләнеп бара.* Ф.Бәйрәмова

НИКАХСЫЗЛЫК *и.* 1) Рәсмиләштерелгән никах булмау яки никах йоласы үткәрелмәү күренеше. *Милли хиссез татарымны никахсызлык аздыра.* Р.Сафин

2) Буйдак булып яки кияүгә чыкмыйча яшәү, никахсыз яшәү рәвеше. *Күрәзәче дустыбызның баш очында никахсызлык тажы барлыгын әйтте.* Кызыл таң

НИ́КЕЛЬ *и. нем.* Көмеш кебек ак төстәге, бик ялтыравыклы, авыр эри торган металл. *Ләгән-комганнары һәммәсе никельдән булачак, ди.* Г.Камал. *Өй эче тәмам шәһәрчә --- никель карават та, шифоньер да, китаплар тулы этажерка да, хәтта зур радиоалгыч та бар иде.* Ә.Еники. *Табличканы суырып алды да (карават никелендә нечкә тимерчыбык зеңгелдәп калды) баш врач янына йөгерде.* М.Мәһдиев

НИ́КЕЛЬЛӘҮ *ф.* Никель белән каплау, никель йөгертү. *Шәмдәлле стена буенда никельләнгән карават, аяк очында кием шкафы, тәрәзә буенда язу өстәле тора.* А.Тимергалин

Никельләп кую Нәрсәнең дә булса өстен тиз арада никель катламы белән каплату

Никельләп тору Әледән-әле, регуляр никельләү, никель белән каплау

Никельләп чыгу Тулысынча никельләү; һәммәсен никельләү

НИ́КЕЛЬЛӘҮЧЕ *и.* Никельләү остасы

НИ́КЕЛЬЛЕ *с.* Никель белән капланган, никель йөгертелгән. *Түрдә никельле, сыгылмалы зур караватта Тавис йоклап ята иде.* М.Мәһдиев. *Шарлы лампалар – Польшадан, ваннадагы никельле краннар, идәндәге метлах плитәләр барысы да Чехословакиядән китерелгән иде.* А.Гыйләҗев. *«Москвич» кына димәссең, тәрәзәләренә кара плёнка ябыштырылган; бампер алдында джипларда гына була торган никельле ялтыравык «кенгуру»; фаралар стандарт түгел, ә әллә ниткән формалы.* Ж.Юныс

НИКОТИН *и. фр.* Кайбер үсемлекләрдә, башлыча тәмәкедә була торган агулы матдә. *Өчәүләшеп үпкәләренә никотин тутырырга керештеләр.* Ж.Юныс. *Бу яшьтән никотин суыруы яхшыга илтми. Спорт белән шөгыльләнер идең, ичмаса.* Р.Зәйдулла. *Өченче көнне иртән мин өстәлемдә никотинны оныттыра торган таблеткалар таптым.* А.Тимергалин

НИКРУТ *и. тар. сөйл.* Рекрут. *Шулар артыннан ук быел караласы никрутларны алып киттеләр...* Г.Ибраһимов. *Югары авыл урамнарын бер итеп никрутлар булып йөрибез...* А.Гыйләҗев. *Билгеле инде, Тукай – Әтнәдә булсын, Мәңгәрдә булсын – никрутларның да, авыл кешеләренең дә бик тиз күзенә ташланган.* И.Нуруллин

НИКРУТЛЫК *и. тар. сөйл.* Рекрутлык. *Ул никрутлык бер бәла бит.* Г.Ибраһимов. *Мәргәнне никрутлыкка моннан биш ел элек алдылар.* И.Хуҗин

НИ́КТЕР *рәв.* Билгесез сәбәп аркасында, нигәдер, ни сәбәптәндер. *Никтер кичә озак йөрдем урамда мин, Гаҗиз булдым эчем-тышым туңганга мин.* Г.Тукай. *Мәрдән абзый да, Бикмүш бабай да никтер кунакны кыстамадылар.* Г.Гобәй. *Никтер кинәт кенә Хәйрүшнең куллары бушады, үзе яман тавыш белән: «Ой, кулым, өзде бит кулымны!» – дип акырып җибәрде ---.* Л.-Х.Таналин

НИЛ *и. гар.* Кыйммәтле куе зәңгәр буяу һәм шул буяуның төсе; индиго. *Табигатькә караш ташла, күңел куй, Белек күзең җәте булсынга нил куй!* Котб

НИ́ЛЕКТӘН *а.* **1.** Ни өчен, ни сәбәптән, ни сәбәпле. *Шулкадәрле хуш исле һәм Тәмле икән нилектән [күмәч]?* Ш.Галиев. *Менә шунда беренче тапкыр күңелендә ниндидер үзгәреш кузгалуын тойды Роза. Нәрсә булды, нилектән бу?* Р.Низами. *Сөйләсә тикшерерләр*

иде, сүгәрләр иде. Ә сөйләмәгән булса, анысы нилектән? Л.Шәфикова

2. *рәв. мәгъ.* Нинди сәбәп аркасында, ни өчен. *Нилектән күңеле Ризваннан бизә баруын да аңлый алмый [Рәмзия].* Н.Гыйматдинова

НИЛҮФӘР *и. фар. бот.* Төнбоек, су лаләсе. *Үз кулы белән нилүфәр өзде.* Р.Гаташ

НИМ *с. фар. иск.* Ярым, ярты. *Ним сабыйдыр ул – сабыйлык көннәрен бик сагына.* Дәрдемәнд

НИМЕС *и. сөйл. к.* **немец, алман**. *Кайда гына булмаган үзе! Нимес җирендә дә, Төркиядә дә, Кытайда да булган.* М.Галәү. *[Айбулат:] Нимесләр боларның авылын басып алгач, яшьләрне Германиягә озата башлыйлар.* Р.Сабыр. *[Кара Гобәй:] Белəм мин нимес белән сугышуның нәрсә икәнен.* З.Зәйнуллин

НИ́МФА *и. гр.* 1) *миф.* Борынгы грек мифологиясендә төрле табигать көчләрен гәүдәләндерүче хатын-кыз сурәтендәге илаһә (илаһ)

2) *зоол.* Кайбер буынтыгаяклыларның икенче үсеш стадиясе. *Талпан нимфасы*

НИ-НӘ́РСӘ *а.* Нәрсә икәнлеге бик үк ачык булмаган әйбер, нәрсәдер; теләсә нәрсә. *Ул камзулны һәртөрле материядән тегәләр, кемнең күңеленә ни-нәрсә ошый.* К.Насыйри. *Моның нинәрсә булуын аңышып өлгергәнче, шапылдап, салкын, дымлы балчык өстенә барып та төштем...* Г.Гыйльманов. *Ә иртән күзе ялгыш кына ян тәрәзәгә төште: күлмәк сәдәфе кадәр ике тишек, ни-нәрсә бу?!* Н.Гыйматдинова

НИ́НДИ *а.* 1) Кемнең яки нәрсәнең дә булса үзенчәлеге, сыйфаты турында сораганда кулланыла. *[Кара Гобәй:] Сез әйтмисез дә, нинди ат җигәргә уйлыйсыз?* З.Зәйнуллин. *Менә әйтегез әле: минем күзләрем нинди төстә?* Г.Гыйльманов. *Нинди гаебе бар икән соң Рәхимҗанның авыл каршысында?* Н.Гыйматдинова

2) Риторик сорау һәм өндәүләрдә нәрсәне дә булса тулысынча кире кагуны, инкяр итүне аңлата. *Эх, нинди акыллы баш син, карчык!* Ә.Еники. *Шул тамашадан соң, җебегән малай янында нинди кыз торып калсын икән, җә?* М.Шаһимәрдәнов. *Гамиләләре белән Канәгать йөрергә тиеш булып чыга микәнни? Нинди йөрү ди ул?* А.Хәлим

3) Кире җөмләләр составында килеп, «теләсә кем», «һәркем», «һәркайсы», «кем дә» дигән мәгънәләрне аңлата. *Күзләрендә яшьлек, ямь, матурлык, Нинди йөрәк күреп сөенмәс!* М.Җәлил

4) Риторик җөмләләрдә кешеләргә, күренешләргә, әйберләргә эмоциональ бәя бирүне яки шул сыйфатның, үзенчәлекнең иң югары дәрәҗәсен белдерә. *Төн нинди матур, нинди җылы, нинди тын!* Г.Исхакый. *Нинди ачы бу яшь, нинди кайнар!..* М.Җәлил. *Белсәң иде син, нинди гадел, тугры, дөрес дин бу, нинди саф күңелле яхшы кешеләр бу мөселманнар!* Г.Бәширов

5) *Менә, әнә* кебек күрсәтү алмашлыклары янында килеп, алда сөйләнгән сыйфат һәм үзенчәлекләрне атамыйча, гомумиләштереп, аңа ишарә буларак кулланыла. *– Кара әле, туганым, әнә нинди сөйкемле күзләр, – диде [Хәят].* Ф.Әмирхан. *Тик әле менә җылылар кирәк иде, кичә бит менә нинди салкын булды, хәерсез!* Ш.Камал // Шул ук алмашлыклар белән килеп, нәрсәнең дә булса сыйфаты, үзенчәлеге турында гомумиләштереп әйтүне белдерә. *Җил бит ул менә нинди тиле, Нечкәбилне дә әллә кая алып китәргә тели.* А.Алиш

6) Мөнәсәбәтле сүз функциясендә килә. *Сорау нинди, җавап шундый*

7) Кемгә дә булса каршы килгәндә, инкяр мәгънәсендә кулланыла. *– Сезне вакытсыз борчырга туры килде. – Нинди борчу ди ул!* Ә.Еники

◊ **Нинди булса да** Теләсә нинди, берәр төрле. **Нинди дә булса** Берәр төрле, берәр нинди. *Укулар башланганчы дип, нинди дә булса эш эзләргә кереттек.* М.Әмир. *Лəкин малай барган җирендә дә, үтә кызыксынучанлыгы һəм тикторманлыгы аркасында, нинди дә булса бер мажарага тармый калмый иде.* М.Шаһимәрдәнов. *Дулкынланган, каушаган вакытларда, ул шулай гел кулына нинди дә булса шөгыль эзли иде.* Р.Зәйдулла. **Нинди җилләр ташлады** Кемне дә булса озак күрми торганнан соң күрешкәч, очрашкач әйтелә. *– Я балам, сине монда нинди җилләр ташлады, сөйләп бир, – дигән [карчык].* Әкият. *Бакча түреннән, алмагачлар арасыннан йорт хуҗасының яшьләрчә дәртле тавышы яңгырады: – Сез ни хәлләрдәсез, Наилә Нуриевна? Нинди җилләр ташлады безнең якларга?* Г.Мирһади

НИ́НДИДЕР *а.* Нинди дә булса әйбернең сыйфатын, үзлеген, үзенчәлеген ачык билгели алмаганда, белмәгәндә, билгесез булганда кулланыла. *Гәрәй әфәнде, анда сезне ниндидер бер кеше сорый...* М.Галәү. *Ул бит сиңа каяндыр килгән килмешәк яки анда ниндидер асрау кыз түгел...* М.Хәсәнов. *Тракторның ниндидер валы ычкынган икән, валның башындагы тишеккә Сәхия алып килгән дага кадагы кереп ипләнде.* Ф.Яруллин

НИ́НДЗЯ *и. яп.* Япониядә Урта гасырларда барлыкка килгән, теләсә нинди җиргә үтеп керә ала торган, ялланган профессиональ җасуслар кастасы һәм шуның вәкиле

НИ́ ӨЧЕН *а.* 1) Ни сәбәптән, нигә. *Ни өчен баламны бирмисез?!* З.Бигиев. *Кем икәнегезне, ни өчен болай эшләгәнегезне төшенмәсәм дә, бурычлы булуымны белдерергә телим!* Ф.Яхин. *Лəкин шунысы да бар: ни өчен ташлап киткән соң әле Гөлсылу апа Илвир җизнине?* М.Шаһимәрдәнов

2) Нинди максат белән, нәрсәгә дип. *Ахун Әкрәм каридан калага ни өчен килүен сорагач, тегесе бер-ике сүз белән генә аңа йомышын сөйләп бирде.* М.Галәү. *Мостафин тәмам хәйран калып: – Бусы тагын ни өчен? – дигәч, юмарт «әби» көрсенеп куйды.* Ә.Еники. *[Дильяр:] Чынлап әйтəм, егетләр, ни өчен алай эшләгәнемне хәзер дә белмим, аңлата алмыйм.* Р.Сабыр

НИ́ ӨЧЕНДЕР *а. к.* **нигәдер**. *Без язгы ташкын кебек, каты җил белән кузгалган диңгез дулкыннары кебек, каядыр, ни өчендер, җимерелеп, ишерелеп ага, куыла башладык.* Г.Ибраһимов. *Лəкин ни өчендер Рәшидәнең күзләре бүген уйчанрак та, моңсурак та кебек.* Ә.Еники. *Ул кызга минем ни өчендер ачуым килә.* Ф.Яхин

НИ́ППЕЛЬ *и. ингл. махс.* Гадәттә очларында сырлар булган көпшә формасындагы тоташтыргыч деталь. *Затворның раструблы пластмасс трубка тоташтырылган ниппеле бар.* Янгын куркынычсызлыгы

НИРВАНА *и. санскр.* Будда диненең тәгълиматы буенча, фани дөньяның барлык нигъмәтләреннән тулысынча баш тарту белән ирешелә торган абсолют тыну халәте; ыраван

НИРГӘ *и.* 1) Бурада бүрәнәләрдән салынган бер рәт. *Менә кайчан гына нигез баганаларын утыртып беренче ниргәне салганнар иде, бүген өй әзер!* А.Гыйләҗев. *Дөрбәнең стеналары нигездән сигез ниргә тәшкил итеп өелгәннәр.* М.Әхмәтҗанов. *Шулай булмый ни, юан нарат бүрәнәләрдән ундүрт ниргәле итеп салдык бит өйне, биек итеп.* М.Хуҗин

2) Нигез, фундамент. *Берәү булса, биллә́hи, мунчаңны ниргәсеннән бозып, мичен өстеңә аударып чыгып китәр иде.* Ф.Яхин

3) *күч.* Нигез, төп эчтәлек. *Бармаклар юанаеп каткан, бер бармак, бер басканда, ике-өч телне бергә баса – зыян юк. Көйнең ниргәсенә килсә ярый. Хикмәт андамыны?* М.Мәһдиев

НИСАН *и. фар. иск.* 1) Апрель. *Вә нисан ягмурының тамчысы еланга төшсә, зәһәр вә агу булыр.* К.Насыйри. *Нисан җилләренең төпчек улы толымнарың тарар – куа күрмә.* Й.Миңнуллина

2) Апрель яңгыры, ләйсән. *Халыкның рухы – татар халкының рухы – йоклаудан торып, күзен ачкан чагындагы Тукайның рәхмәтле нисан шигырьләреннән сугарылмаенча, сусаган хәлендә дәвам итте.* Г.Исхакый

НИСБӘ *и. гар.* Кешенең үз исеме азагында куелып, шул кешенең кайсы төбәктән, шәһәрдән, ырудан яки кабиләдән чыкканын күрсәтә торган исем компоненты (мәс., *Болгари, Кандалый, Каргалый, Уфави, Бохари; Казанлы* һ.б.ш.). *Әдип үзе дә [К.Насыйри] бу бабасына шундый зур әһәмият бирә ки, «Җәваһирел хикәят» (1882) китабында, мәсәлән, үзенең нисбә исемен «әш-Шырдани әр-Раззакый» дип атый.* М.Гайнетдинов

НИСБӘТ *и. гар.* 1) Кешеләр яки әйберләр арасындагы бәйләнеш, мөнәсәбәт, галәка

2) Ике яки аннан күбрәк әйбернең үзара үлчәү, күләм, микъдар һ.б.ш. ягыннан тәңгәллеге. *Ә чынлап тикшерә башласаң, дарулар кайтып тора, тик аларны бүлгәндә нисбәт югала: берәүләргә артыграк язылып, икенчеләренә җитми кала.* Кызыл таң

НИ́СБӘТӘН *рәв. гар.* Чагыштырганда, тиңләштереп караганда. *Ләкин Мостафа, морза халкына нисбәтән үзен түбән дәрәҗәдә санавыннан тыш, гаять гыйффәтле вә горур бер егет булдыгыннан, Фатыйма кеби тәрбияле кызга үзенең кальбен ачарга --- вакыт кичерәюрде.* Ф.Кәрими. *Х.Ямашев һәм аның фикердәшләре Тукай һәм каләмдәшләренә --- демократлар белән либераль буржуазия идеологлары --- арасында социаль мәсьәләләргә нисбәтән каршылык ятканын аңларга --- булышканнар.* И.Нуруллин

НИСБӘТЕНДӘ *бәйл.* Исемнәрдән соң килеп, «мөнәсәбәтендә», «аркасында», «шартларында», «карата» дигән мәгънәне аңлата. *Сыйфатланмыш (ачыкланучы кисәк) ачыклаучы кисәк составындагы сүз белән иялек нисбәтендә тора.* Ф.Хисамова. *Кыяфәт бер хәл әле, холык-фигыльләребез нисбәтендә дә капма-каршы без.* М.Шаһимәрдәнов

НИСБӘ́Т ИТҮ *ф.* Нәрсәләрнеңдер үзара мөнәсәбәтләрен билгеләү, нисбәтләү. *Чиләбе өлкәсенең Варна посёлогы янында 16 метрлык корылманы легенда вариантлары шушы вакыйгага нисбәт итәләр.* Ф.Яхин

НИСБӘТЛӘ́Ү *ф. к.* **нисбәт итү**

Нисбәтләп кую Тиз арада нисбәтләү. *Ул урыннарда тоташтан төрки кабиләләр яшәгән булганнар, ләкин аларны, сакалиба дип, тагын славяннарга нисбәтләп куйганнар.* И.Хуҗин

НИСБӘТЛЕ *с.* **1.** Нинди дә булса нисбәте, мөнәсәбәте булган. *Мин аңа Атна авылына нисбәтле кайбер фактларны табыштым һәм тора-бара авылның тарихы һәм аның эз калдырган кешеләре белән тәмам кызыксынып киттем.* А.Тимергалин

2. *хәб. функ.* «Нисбәте бар, кагыла» мәгънәсендә. *Күпчелек әдәби текстлар Сания Гыйффәт, Хөсәен Габдүш, Мансур Арысланбәк һәм кайбер башка мөһаҗир татарларга нисбәтле.* Х.Миңнегулов

НИСБӘТЛЕЛЕК *и.* Нисбәтле булу. *Язмадагы «Бикәҗ» исеме кабернең татарның югары катлавыннан булган дәрәҗәле хатын-кызга нисбәтлелегенә дәлил.* Ф.Гарипова

НИСБӘТТӘН *рәв.* 1) *Шул, бу* алмашлыкларыннан соң килеп, алда әйтелгән сүздән чыккан сәбәпне белдерә; сәбәпле, аркасында. *Шагыйрьләр аны әдәби сабантуй буларак кабул итәләр. Шул нисбәттән Яушырмә исеме шигырьләргә дә килеп керә.* Ф.Хәсәнова. *Авыл укытучылары да Интернет белән таныш, һәм бу нисбәттән дә бик кызыклы, эшлекле сөйләшү үтте.* Безнең гәҗит

2) Шул яктан, шул караштан

НИСБИ *с. гар.* Нәрсәгә дә булса бәйләнешне, мөнәсәбәтне күрсәтә торган. *Нисби сыйфатлар*

НИСБИЛЕК *и.* 1) Нисби булу

2) Нәрсәнең дә булса башкалар белән чагыштырган чакта гына ачыкланган мәгънәсе. *Нисбилек теориясе*

НИСЕБ *и. гар. к.* **нисбә**

НИТӘК *рәв. фар. иск. к.* **нитәкки**. *Хәмерсез дә мин исерекмен: эчәм мин шуннан айныргамен – Нитәк гөлләр була мохтаҗ эссе көннәрдә яңгырга.* М.Гафури

НИТӘККЕМ *рәв. фар. иск. к.* **нитәкки**

НИТӘККИ *рәв. фар. иск.* Ничек, ни рәвешле, ничек итеп, булганы кебек. *Нитәкки ул авырлыклар күрде һәм котылды, син дә котылырсың.* Г.Исхакый. *Хәкимнәр әйтмешләрдәр ки, җыр-музыка – җаннарның азыгыдыр, нитәкки, ашамлык – тук булу азыгыдыр.* К.Насыйри

НИ́ТКӘН *а. сөйл. к.* **нинди** (*1, 2 мәгъ.*) *Карчык Газизәгә дигән кызыллы күлмәген күз алдына китереп уйлап торганда, картның әллә ниткән бер русны мактауларын, сагынып сөйләүләрен бер дә әһәмият биреп тыңламый.* Ш.Камал. *Ниткән та-*

выш булды бу тагын? А.Гыйләҗев. *Мәйтәбез, кайнар башын суытсын, ниткән кешедән аерылу ул, --- эчәләр икән – эч, җырлыйлар икән – җырла.* Н.Гыйматдинова

НИТРАТ *и. гр. хим.* Азот кислотасы тозы. *Әгәр дә аның уртасы аксыл икән, бу инде анда нитрат күп дигән сүз.* Ватаным Татарстан

НИТРОГЛИЦЕРИН *и. лат. хим.* Шартлаткыч һәм дару буларак кулланыла торган сыек, майлы матдә, азот һәм күкерт кислоталарының глицерин белән кушылмасы. *Әти-әнисе эштә чакта, сабый бер уч нитроглицерин ашаган, картәтисе соң күргән.* Кызыл таң

НИТРОН *и. гр.* Йонны алмаштыра торган ясалма җепсел

НИТРОЭМАЛЬ *и. гр.-фр.* Буяуның бер төре

НИТҮ *а.* 1) Нәрсә дә булса эшләүне, башкаруны белдергән сүзне атамыйча, аны алмаштырып кулланыла. *Нишләмәк кирәк, – ике-бер йотым нитәсең дә, аз гына уңайланган шикелле була...* Ш.Камал. *Сөйләгән сүзләре – ата-баба нәсыйхәте: «Сабыр итсәң, морадыңа нитәрсең», «Хезмәт итсәң, хөрмәт күрерсең» кебек сүзләр иде.* Г.Исхакый. *[Габдулла:] Теге ни... Теге нине ниттеләр, Айсылу Акбулатовна!* Ф.Яруллин

2) Парлы сүзләр составында килеп, мәгънәгә җыйнау, гомумиләштерү, абстрактлаштыру төсмерен өсти. *[Садыйк:] Уйламаганда-нитмәгәндә, [Әхмәтҗан] базарда килешеп кайткан да җәмәгатьләренә аш-су хәзерләргә кушкан.* Г.Исхакый. *Кунакка чакыранитә калсаң, «Франциядә эшләнгән» дигән мөһер белән генә алдый алмыйсың аны.* Р.Мөхәммәдиев. *Ә Вәлетдин ише кансызга барыбер, ул тикшерепнитеп тормаячак, суды үзендә аның.* Н.Гыйматдинова

Нитеп тору Нинди булса эшнең нәрсә икәнен әйтергә ярамаганда яки кирәк сүзне искә төшерә алмаганда кулланыла; шулай итеп тору. *Бер актив әйтте шунда: «Без бераз нитеп торыйк һәм шул арада бу хакта Массаның фикерен сорыйк».* Х.Туфан

НИФАК *и. гар. иск. кит.* Тыштан яхшы булып күренгән әшәкелек, начарлык; икейөзлелек, монафикълык, күз буяу, алдакчылык. *Бүгенге көндәге әфкяре гомумиябездәге чуалулар, аңлашылмаулар --- шул беренче «Ит-тифак»ның нифак чишмәсеннән ага башлавыннандыр.* Г.Исхакый. *Йөреп кайттым әле мин дөнья гизеп, Кайда хак, кайда нифак күреп, сизеп.* Г.Камал. *Иркен сезгә хәзер: ни эшләрсез; Моңар хәтле нифак саттыңыз...* Г.Сөнгати

НИФАКЛЫ *с. иск. кит.* Икейөзле. *Нифаклы елмаю*

НИФАС *и. гар.* Бала тудырганнан соң килә торган кан. *Тәһарәтне нәрсәнең бозуы, нәҗасәте хәфифә белән нәҗасәте гализа арасындагы аерманы, мәсехнең шартларыны, тагы хәез, нифас мәсьәләләрендә, ай күрү, шәһадәт бирү мәсьәләләрене – һәммәсен үтте.* Г.Исхакый

НИФТЕ *и. фар. сөйл. к.* **нефть**. *Дөрес булса, җир астыннан май тапканнар, ди. Нифте мае, диме, керәчинме – белмәссең хәзергене.* Г.Ахунов

НИ́ХӘЛ *ы.* Кемнең дә булса хәлэхвәлен, исәнлеген-саулыгын сораганда, белергә теләгәндә кулланыла. *– Нихәл, арумы, Миңлебай агай? – диде [карчык], авызын учы белән генә каплый төшеп.* Ә.Еники. *Менә ят бабай тагы Илсөяргә таба борылды: – Я, нихәл, тәти кыз?* Г.Гобәй. *--- күзенә күренгән беренче шәкерткә: «Нихәл, мелла фәлән», – дип, яктавына төртеп ала [Тукай].* И.Нуруллин

◊ **Нихәл итәсең (итмәк кирәк)** Теләсәң-теләмәсәң дә булган хәлне кабул итәргә мәҗбүрлекне белдерә. *– Син дә, әбекәем, моның белән килешә торгансыңдыр? – Килешмичә нихәл итәсең инде...* Ә.Еники. *Нихәл итәсең, тормышыбызда күңелсез хәлләр дә күп шул ---.* Б.Рәхимова. *«Ничек түзәсең шуларга?» – дип сораганнар. «Телем бар иде – телсез булдым, ике күзем бар иде – күзсез булдым. Түзмичә нихәл итәсең...» – дип җавап биргән, имеш.* Р.Низамиев

НИ́ХӘЛДӘ *рәв.* Нинди хәлдә. *Нихәлдәләр икән мескенкәйләр [ата-аналары], яшиләр микән әле якты дөньяда?* И.Хуҗин

НИ́ХӘТЛЕ *а. к.* **никадәр**. *Туган туфрак никадәр генә үзенә бәйләмәсен, авыл артындагы канау белән әйләндереп алган зиратта ятучылар нихәтле генә якын булмасын, әмма болар гына аның тормышын тутыра, ялгызлыгын җиңеләйтә алмыйлар иде.* Ә.Еники. *Чит җирләрдә нихәтле торып та мин, Исләремнән чыгармадым, Сагындым, онытмадым.* Ш.Галиев. *Әйе, ничаклы кызны – кияүле, нихәтле егетне кәләшле итте Хәмәтдин.* М.Шаһимәрдәнов

НИһАЯ *и. гар. иск. к.* **ниһаять** (*1 мәгъ.*). *Шигырь вә шагыйрь – һәр икесе ниһаясе булмаган азатлыкка малик.* Г.Ибраһимов. *Кибетләр дә кунаклар китүе белән бергә ябылып өлгергәнгә, эшләр уңайсызлыкның ниһаясенә терәлде.* К.Тинчурин

НИһАЯСЕЗ *с. иск.* Иксез-чиксез, очсыз-кырыйсыз, гаять күп, озак. *Шагыйрь үзенең төнен «таңы ерак» ди. Димәк, ниһаясез түгел, кайчан да булса бер таң ата.* Г.Ибраһимов. *Идея кулы белән бер якка күрсәтә, ераста матур сарайлар, гөл-чәчәкләргә күмелгән урманнар, күм-күк күген яктыртып торган нурлы ай һәм ниһаясез күләгәләр күренә.* һ.Такташ

НИ́ҺАЯТЬ *и. гар.* **1.** Нәрсәнең дә булса очы, чиге, ахыры, кырые

2. *кер. сүз* 1) Соңгы чиктә, ахыр чиктә, иң ахырда, соңыннан. *Биш-ун минуттан, ниһаять, ул [Нәкәс мулла] да килде.* З.Бигиев. *Унсигез көн булды дигәндә, алар [Габдуллалар], ниһаять, кичкә таба Җаек каласына килеп җитәләр.* И.Нуруллин. *Урман эчендә менә югалам, менә югалам дип барган сукмак, ниһаять, бер ачыклыкка килеп чыкты.* Г.Гыйльманов

2) Өстәвенә, шуның өстенә, тагын. *Колониянең шуннан соңгы тормышы өч юнәлештә барды: яңа җирләрне картага төшерү һәм аларны Русия милке дип игълан итү, җирле халык белән ике арадагы мөнәсәбәтләрне җайлау һәм, ниһаять, икътисади эшчәнлек җәелдерү.* И.Хуҗин. *Каурыйлары тузгып беткән шул кара кош, зурайганнан-зурая барып, баганадан баганага, тупылдан тупылга күчә-күчә, ниһаять, аның корымлы*

кирпеч моржасына килеп кунды. Ә.Гаффар

3) Сабырсызлыкны, канәгатьсезлекне һ.б.ш.ны, аларның иң югары дәрәҗәдә булганнарын белдергәндә, яки нәрсәгә дә булса басым ясалганда кулланыла. *– Узең әйтеп каласыңмы, әллә терелэй тиреңне туныйкмы? – дип, шактый каты бәрелде ул тоткынга, нинһаять.* И.Хуҗин. *– Күзең очлы синең. Әнә шунда, келәттә!.. – диде бабасы, нинһаять.* А.Хәлим

3. *с. мәгъ.* Чиктән тыш, бик көчле, зур

НИһАЯТЬСЕЗ *с. иск. к.* **нинһаясез**. *Нинһаятьсез гүзәл ахшам – бу ахшам ---.* Г.Тукай. *Бу тау бик биек булу белән бергә, кыйбла ягы нинһаятьсез текә, ул яктан менеп-төшеп йөрү мөмкин түгел.* М.Гафури

НИ́ЧАКЛЫ *а. к.* **никадәр**. *Кемгә игелек күрсәткәнем бар, ә кешегә ничаклы борчу салдым.* С.Сөләймановa. *Күрче, ничаклы тәрәзәләр!* А.Гыйләҗев. *Сабан туе көрәшчеләрен күреп, әкиятләр тыңлап, --- батырларга ничаклы гына сокланмасын, --- малай [Тукай] күңелсез хакыйкать белән килешергә мәҗбүр: буй юк, гәүдә юк, көч юк.* И.Нуруллин

НИ́ЧАРАДАН БИЧАРА *рәв.* Гаҗизлектән, аптыраганнан, башка чара булмаганнан гына. *Ул [Мирвәли] Шәмсегаянны иярттe дә авыл читенә, япа-ялгыздан ничарадан бичара тереклек кылып азапланган ятим карчык Таифә йортына барып урнашты.* А.Гыйләҗев. *Уйлап-уйлап табалмагач бер чара без, Мөңрибез шул ничарадан бичара без.* Г.Афзал

НИ́ЧӘ *а.* **1.** 1) Нәрсәнең дә булса санын, күләмен, микъдарын һ.б.ны белергә теләп сораганда кулланыла. *– Ничә сугышчы бар икән бу сафларда? – дип сорады Уан.* И.Хуҗин. *Менә бу татар теле җөмләсендә ничә татар сүзе бар?* Х.Сарьян. *Гариф, көлә төшеп, төртеп куйды: – Ничә этажлы иде әле бу ялган?* Ш.Камал

2) Нәрсәнең дә булса санына, күләменә, микъдарына һ.б.ш.га бәйләнешне күрсәткәндә кулланыла; никадәр, күпме. *Өйдә ничә сәгать бар – Һәммәсен узып тора!* Ш.Галиев. *Өйдән чыгып киткәнгә ничә көн узганын искә төшерергә тырышып карыйм, очына чыгалмыйм.* Н.Әхмәдиев. *Бу илнең ничә портында булуымны санап торасым килми.* М.Юныс

2. *рәв. мәгъ.* Берничә, бик күп, шактый гына. *Зәңгәр күлмәген әллә ничә яз җилләре, көзнең саран кояшлары киптерделәр.* А.Гыйләҗев. *[Бамбыр:] Ничә тапкырлар әйткәнем бар сиңа, энем: шул язган кәгазьләреңнең өске уң мөешенә япьләрен өскә каратып сәнәк төшереп куй дип.* З.Зәйнуллин

◊ **Ничә әйтсәң дә** Ничек кенә булмасын, һәрхәлдә. *Ничә әйтсәң дә бер сүз: тәүфыйкка утырды Мөнәвәр карт, культурный балалар кайткач.* Ф.Хөсни. **Ничә җәй, ничә кыш** *сөйл.* Озак вакыт күрешмәгән кеше белән очрашкач әйтелә торган сүз. *– У-у, Шөкер дус! Ничә җәй, ничә кыш күрешмәдек!* Г.Ахунов

НИ́ЧӘДЕР *а.* Нинди дә булса күренешнең, предметның, хәлнең билгесез күләмдә, микъдарда, санда булуын белдерә. *Тагын ничәдер көн үтте.* Н.Дәүли. *Бу көтүченең булган, ди, ике малае, тагы ничәдер кызы.* Әкият. *Акча димәктән, кесәдә ничәдер сум бар кебек.* Ватаным Татарстан

НИ́ЧӘЛӘП *а.* Якынча, чама белән күпме булуны белергә теләп сораганда кулланыла, күпме. *Ничәләп кеше булыр?*

НИ́ЧӘЛЕ *а. сөйл.* Нәрсәнең дә булса нинди номерлы булуын, үлчәмен, яки кемнең дә булса нинди билге алуын белергә теләгәндә кулланыла. *Ничәле алдың? Ничәле итек?*

НИ́ЧӘМӘ *рәв. к.* **ничәмә-ничә**. *Ничәмә йөз тәңкәлек әйберемне әрәм иттең!* Г.Ибраһимов. *[Сәрвәр:] Инде бит ничәмә айлар яшибез шушы баздуш өйдә.* З.Зәйнуллин. *Ничәмә буын кешеләр алышынган, патшалар берберсен алыштырган, Мәскәү дәүләтендә ниндидер чуалышлар булган, читләр белән һаман сугышлар булып торган, ә безнең татар дөньясында ниләр, нинди зур вакыйгалар булганын без ачык кына белмибез.* Ә.Еники

НИ́ЧӘМӘ-НИЧӘ *рәв.* Бик күп, әллә ничә. *Шуннан соң ул [Мостафа] ничәмә-ничә сугышларда булды.* Г.Әпсәләмов. *Шуның өстенә ничәмә-ничә гектар җирнең иген-таруын җыйнап аласы бар.* А.Гыйләҗев. *[Хәйбулла:] Мин аңа батрак урынына ничәмә-ничә еллар эшләгәннән соң, буш кул белән безне урамга кумакчы.* З.Зәйнуллин

НИ́ЧӘНЧЕ *а.* 1) Санаган вакытта, санау тәртибендә нинди урында торуны сорау өчен кулланыла; тәртип буенча, исәп буенча нинди яки кайсы урында, дәрәҗәдә һ.б.ш. *Балаларына ничә яшь, ничәнчедә укыйлар, нәрсә ашый, нәрсә эчәләр – Вәлиулла абзый андый мәшәкатьләрдән азат иде.* М.Мәһдиев. *[Локман:] Ничәнче елны кайттың, дип, тагын бер сора, Айбулат.* Р.Сабыр. *[Дилбәр:] Син ничәнче автобус белән кайттың?* З.Хәким

2) Беренче генә түгел (гадәттә «көн», «ел», «тапкыр», «мәртәбә» сүзләре белән кулланыла). *Менә ничәнче көн инде, буш вакыты булды исә, бушпритның төбенә утырып, ул океанны күзәтә.* И.Хуҗин. *Ничәнче мәртәбә инде аның йөрәге тетрәнеп куйды, елганың теге ягындагы авылдан килен булып төшкән чагы хәтеренә килде.* М.Шаһимәрдәнов

НИ́ЧӘСЕ *а.* 1) Айның кайсы көне булуын белергә теләп сораганда кулланыла. *Бүген ничәсе?*

2) Нинди дә булса төркемдә кайсы ягы беләндер аерылып торучылар санын ачыклау өчен бирелгән сорау сүзе. *Йөз кешенең ничәсе аңлый икән картинаны?* З.Хәким

НИ́ЧӘҮ *а. сөйл. к.* **ничә** (*1 мәгъ.*). *Бәләкәй Мансур гына: – Синең өең Казандамы? Зурмы? Балаларың ничәү? – дип сораган иде.* А.Гыйләҗев. *Алар хәтта омончы киемендәге егетләрнең ничәү икәнен санарга да өлгермиләр.* Ф.Яруллин. *Берәү, икәү, өчәү – барысы соң ничәү? Эх, минутлар мәңге түгелләр.* Р.Тимерова

НИ́ЧӘШӘР *а.* 1) Нәрсәне дә булса күпмешәр итеп бирү, бүлү, алу һ.б. турында сораганда кулланыла. *Ничәшәр хөрмә?*

2) Берничә мәртәбә, бик күп, бик озак. *Гөлфәрвазның --- яныпторган көләч йөзләре, Искәндәрнең сөйләп килгән сүзләренең хәбәрләрен җүйдырып,*

туктатып, каршында аны мәсхур иткән (сихерләгән) күзләргә карап, ничәшәр минут тик торырга мәҗбүр итәләр иде. К.Тинчурин. *Кырым, Пицунда, Дубулты, Малеевка йортларында ничәшәр мәртәбә булдык без...* Ә.Еники. *Ахмак галимнәр кешенең ризык капмыйча, су йотмыйча ничәшәр тәүлек җан асравын исәпләп баш ваткаННар.* А.Гыйләҗев

НИ́ЧӘШӘРЛӘП *а. к.* **ничәшәр** (*1 мәгъ.*)

НИ́ЧЕК *а.* **1.** 1) Эш яки хәлнең ни хәлдә, ни рәвешле булуын сорагында кулланыла. *Ничек асрарсың син бу йортны?..* Ә.Еники. *[Мөнәвәрә:] Син, Гобәйдулла абзый, дөньяның әчесен-төчесен бик күп күргән кеше. Ничек кенә итеп барырга безгә атсыз килеш шул каһәр суккыры Раёвкага?* З.Зәйнуллин. *Ә халык, күпчелекне тәшкил иткән крестьяннар Тукайның үлемен ничек кабул иткән соң?* И.Нуруллин

2) Эш яки хәлнең торышы, сыйфаты турында сорауны белдерә. *[Кара Гобәй:] Исәнме, кызым! Сабый исәнсаумы? Киявүнең хәлләре ничек?* З.Зәйнуллин. *Я, ничек соң анда өстәгеләр?!* М.Шаһимәрдәнов

3) Риторик сорау һәм өндәү җөмләләрдә нәрсәне дә булса эшләми калырга, булдырмый калырга мөмкин түгеллеген белдерә. *Ничек язмый чыдыйм соң мин?* Г.Тукай. *Мондый вакытта кешене ничек кызганмыйсың да, ничек аның хәленә керергә тырышмыйсың, ди.* М.Шаһимәрдәнов

4) Соклану, гажәпләнүне белдерә. *Баласы булган кешеләр – Бәхетле алар ничек!* Х.Туфан. *[Дилбәр (стенадагы рәсемнәрне күзәтеп):] Ничек шулай матур итеп ясарга мөмкин?!* З.Хәким

5) Гадәттә *менә, әнә* сүзләре янында килеп, алдан сөйләнгән сыйфат һәм үзенчәлекләрне атамыйча, гомумиләштереп, аңа ишарә буларак кулланыла. *[Хәят:] Кара әле, әни, якшәмбе көн эш тотарга бер ярамый миңа, менә ничек телеп ташлаганмын, – дип, теге батистларны алып күрсәтергә тотынды.* Ф.Әмирхан. *Зөфаф кичәсенә ашыккан яшь кияү кебек әнә ничек тураеп басты --- [әтисе].* Р.Зәйдулла. *Баярак кына ул коридорда Луиза белән әнә ничек елмаеп сөйләшеп тора иде.* М.Шаһимәрдәнов

6) Парлы мөнәсәбәтле сүзләр составында килеп, иярчен рәвеш җөмләне яки иярчен аергыч җөмләне баш җөмләгә бәйли. *Җыйдым җиләк, җыйдым җиләк, Җиләктән кайтып киләм. Җир җиләгә ничек тәмле, Сезне дә шулай сөям.* Җыр. *Аллаһе Тәгалә үзе карар, ул ничек кушкан, шулай булыр.* И.Хуҗин. *[Жан:] Ничек тоясың, шулай эшлә...* И.Зәйниев

2. *рәв. мәгъ.* «Ни рәвешле», «нинди итеп» дигән мәгънәләрне аңлата. *Габдулла, сүзен ничек башларга белмичә, таптангалап тора.* Ф.Яруллин. *Кара әле, Мәргән, үзләрен ничек тыныч һәм ваемсыз тоталар болар.* И.Хуҗин. *Нахак сүзләр, гайбәтләргә тол хатыннар ничек түзә?* Э.Шәрифуллина

◊ **Ничек кирәк (житте) алай** 1) Көч-хәл белән, көчкә-көчкә, авырлык белән. *Ата кеше озын, авыр төнне ничек кирәк алай үткәреп җибәрде дә, кырынып-чистарынып, парад мундирына орден-медальләрен тагып һәм ашап та тормыйча, үз машинасында калага юл тотты.* М.Шаһимәрдәнов. *Дөрес, ничек җитте алай бер мичкәне тутырдым тутыруын.* М.Шабай. *37 нең кышын әйберләрне саткалап, ничек кирәк алай очын-очка ялгап чыктылар да җәйгә авылга киттеләр.* Ф.Бәйрәмова; 2) Өстән-өстән, аннан-моннан гына. **Ничек кенә** 1) Борчылуны аңлата. *Ничек кенә сагышларны Сөйләргә икән җилгә.* З.Гыйльфанова. *Ничек кенә басыйм икән Йөрәгем януларын?* Р.Вәлиев. *Изге өметләрен әниемнең Ничек кенә итеп аклыйм соң?* Л.Халикова; 2) Көчле теләк, омтылуны аңлата. *Ничек кенә кулга төшерергә?!* 3) Алда әйтелгән эш, хәл, вакыйганың интенсивлыгын күрсәтү өчен кулланыла. *Түрәләр аларны соңыннан башларыннан сыйпадылар, ә безне эскәмиягә яткызып чыбык белән сыйладылар. Ничек кенә сыйладылар әле!..* М.Галәү. *– Бу җирдәге төп халыкның хәле сезнең язмышыгызны хәтерләтә түгелме соң? – Әлбәттә, сәр! Ничек кенә хәтерләтә әле, – дип җавап бирде Мәргән.* И.Хуҗин. *– Уңамы соң анда борчаклар? – Ничек кенә әле! Армия борчагы автомат пулясыннан бер дә ким түгел.* М.Шаһимәрдәнов. **Ничек кенә булмасын** Бернигә дә карамастан. *Ләкин, ничек кенә булмасын, ул [Акъәби] бу уйчан, сәер кешене көтеп ала иде.* Ә.Еники. **Ничек [кенә] булса да** Теләсә нинди юл белән. *Боерыкны үтәмичә мөмкин түгел, аны ничек кенә булса да җиренә җиткерергә кирәк иде.* М.Галәү. *Ничек булса да июнь ахырларына кадәр монда торырга тугры килер.* Г.Исхакый. *Ләкин аюны да биергә өйрәтәләр, ә болар бит – кеше! Кеше! Һәм боларны ничек кенә булса да яңадан кавыштырырга кирәк!* М.Шаһимәрдәнов. **Ничек тә** 1) Һич кенә дә, берничек тә. *Уф, арыдым... эш харап: Ничек тә булмый ярап!* М.Хөсәен. *Чү, анасы, монда гашыйкларны Кавыштырып булмый ничек тә.* М.Хөсәен; 2) Берәр ничек, теләсә нинди юлын табып, ничек кенә булса да. *Ә сиңа ничек тә бер җай чыгар әле.* М.Галәү. *Әлбәттә, Хәмитнең үзен Рәшидә күзенә ничек тә күрсәтмәскә кирәк булыр.* Ә.Еники. *Һәр елда максат куям: ничек тә Сөһәйл вә Гөлдерсен каберен барып күрергә иде, дим.* Ф.Яхин

НИ́ЧЕКТЕР *а.* 1) Ни рәвешледер, ниндидер ысул белән. *Эшләнүе ничектер, мин белмим*

2) Ни сәбәптәндер (билгесезлекне белдерә). *Карчык шуларның барысын да ничектер балаларча кызыксынып тыңлап ята.* Ә.Еники. *Колхозчылар да, Галиуллин куылгач, ничектер яхшырак эшлиләр кебек тоела.* Г.Кутуй. *Ничәмә-ничә тарихи, дини вә фәлсәфи дәфтәр һәм китапларны гарәптә, кайвакыт фарсыда төпләгән, теркәгән, төзәткән олуг остаз өчен кабаттан төркигә кайту ничектер күптән хәтереннән чыккан бала чагын күңелендә яңартты.* Ф.Яхин

3) Ниндидер юл белән, бер чарасын табып. *Ничектер бик әдәпле телдә, бик китапча итеп, җинаятьче турында нидер сорый.* М.Әмир

4) Күпмедер дәрәҗәдә, бераз. *Аның бу хәрәкәтләре миңа ничектер «чәнчелеп китегез!» дигән шикеллерәк*

тоелды. Ә.Еники. *[Дильяр:] Мин, чәчәкләрне алып, сәхнәгә чыкмакчы идем, аякларга герләр бәйләп куйганнар диярсең, батырчылыгым җитми ничектер.* Р.Сабыр. *Ничектер куркынып та, әрнеп тә чакыра төсле иде ул.* Ф.Яхин

НИШАН *и. иск. гар. кит.* 1) Билге, тамга, эз, галәмәт. *Бу дөньяны, бер сәгать дип, фани белсә, Әүлиялык нишаннары бардыр анда.* Мәүла Колый. *Нә дәүләт калды да нә шан, Һич калмады шаннан нишан!* Г.Тукай. *--- күкрәк өстендә кадалган көмеш герб белән гаскәри бер нишан Искәндәрне хикәяләрдәге шаһзадәләр кыяфәтенә кертеп --- хис иттерәләр иде.* К.Тинчурин

2) Егет һәм кызның бер-берсенә биргән вәгъдә бүләкләре (мәсәлән, балдак, йөзек)

3) Бүләк, орден. *Баш улып бер гаскәрә, алтын нишан алмактамы?* Г.Тукай

4) Мәрә, мишень. *Синең ачуыңа нишан булудан сакланам, раббым!* Г.Монасыйп

НИШАНЛЫ *и. иск.* Ярәшелгән кыз яки егет. *Ул кызның бер башка нишанлысы, ягъни вәгъдәләшкән егете бар иде.* К.Насыйри. *Яшен уты кебек «аның нишанлысы төрмәдә ачлыктан үлде» дигән хәбәр таралды.* Г.Исхакый

НИШАТЫР *и. гар. к.* **нашатырь**. *Арт ягыңа нишатыр кыстырсалар, бүтән кая качасың?* Г.Бәширов

НИ́ШЛӘП *а.* Ни өчен, ни сәбәпле, нигә. *[Гарифә:] Сез бигрәк инде, нишләп өч мең [сум] китсен!* Г.Исхакый. *[Әнсәр:] Улым, нишләп үзең генә [килдең], ипташләрең кайда?* И.Зәйниев

НИ́ШЛӘПТЕР *а.* Билгесез бер сәбәп белән, ни өчендер. *Нишләптер бик сирәк керә башладыгыз әле?* Ә.Еники. *Фәһад абый, нишләптер гел читтә торасың?* Ю.Сафиуллин

НИ́ШЛӘТҮ *ф.* Нинди дә булса үзгәрешкә дучар итү, берәр хәлгә төшерү. *Әнә карагыз, нишләтә көймәне!* Ш.Камал. *Нишләтим соң, янда паспорт та бар, Бар хикмәте: буем кечкенә.* М.Хөсәен. *[Садриевич:] Рәмзияне нишләттең? [Рөстәм:] Акчасы түләнгән, дидең бит, нишләтсәм дә ярыйдыр ---.* Н.Гыйматдинова

НИ́ШЛӘҮ *ф.* 1) Эш яки хәлне ачыкларга теләп сораганда кулланыла. *Нишлим, нишлим, соңгы минутымда Пистолетым итте хыянәт!* М.Җәлил. *[Газизә:] Гариф абзый, нишләдең болай? Битең каный ич!* Ш.Камал. *Гатауллин, бүртенеп: – Нишлисез сез, ни сөйлисез? Оят түгелме? – дия башлаган иде, исерек тагын да җәелебрәк китте.* Ф.Яхин

2) Нәрсә булса да эшләү, нинди дә булса эш башкару, нитү. *[Ибраһим:] Мин хәзер үземнең кем икәнлегемне оныттым, мин хәзер үземнең нишләгәнемне белмим.* Г.Исхакый. *Менә күрдеңме нишли: сандугач булып кына сайрамый инде.* Ф.Яхин. *Малай ике җөмлә белән генә нишләргә җыенганын төшендереп бирде.* М.Шаһимәрдәнов

◊ **Нишләмәк кирәк** «Бернәрсә дә эшләп булмый, башка чара юк» дигән мәгънәдә. *Нишләмәк кирәк, әйе, нишләмәк кирәк, фактлар чыннан да бик усал нәрсәләр икән!* Ә.Еники. *Нишләмәк кирәк? Иртәгәге көнне көтәргә кала инде!* А.Гыйләҗев. *[Низам:] Нишләмәк кирәк, без бит сугышта.* Р.Сабыр. **Нишлисең (бит, инде)** *к.* **нишләмәк кирәк**. *Нишлисең, койма артындагы Гарәфигә дә бирергә туры килде.* Ф.Яхин. *Нишлисең, тарихны җиңүчеләр яза.* Р.Зәйдулла

НИШТӘР *и. фар. иск.* Ланцет, скальпель, хирургия пычагы. *Хәҗҗам аның [Зөләйханың кан] тамырына ништәр орса.* Кол Гали

НИЯЗ *и. фар. иск. кит.* 1) Үтенеч, ялыну, ялвару, ялынып сорау

2) Кайбер парлы сүзләрнең икенче компоненты булып, беренче сүзнең мәгънәсен гомумиләштерә, мәс., *намазнияз (төрле намазлар, гыйбадәтләр); нәзер-нияз (төрле нәзерләр, һәртөрле нәзер)* һ.б.

НИЯ́З ИТҮ *ф. иск.* Ялвару, ялыну, үтенеп сорау. *Шаһзадә, ул хәлне күреп, күңеленнән Хак Тәгаләгә нияз итеп, кувәт белән бер мәртәбә тартылды ---.* К.Насыйри. *[Фәрештәләр:] Рөхсәт бир, Аллаһы Тәгаләдән нияз итик, Аллаһы Тәгалә адәм балаларыннан тимерне бетерсен.* Г.Исхакый

НИЯТ *и. гар.* 1) Нинди дә булса эш башкару өчен уй-план; теләк, максат. *Әхмәтша хәзрәтнең нияте мәдрәсә тотып дәрес әйтүдә иде.* Ф.Кәрими. *[Арыслан:] Мин бит Сараны кызык өчен арбага утыртмадым, терелсен дип, изге ният белән эшләдем ---.* Н.Гыйматдинова. *Шулай да ул [Туктамыш], ничек тә булса, Идегәйне Алтын Урдадан куу ниятеннән баш тартмый.* Ф.Урманче

2) *иск. дини* Теләк тормышка ашсын өчен, әүлиялар рухына багышлап дога уку. *[Гарифә:] Я Рабби, үзең ярлыка! Шул эшләр тын гына бетсә, Хуҗа Баһаветдин рухына җиде ният бирермен.* Г.Исхакый

НИЯ́Т ИТҮ *ф. к.* **ниятләү**. *Әгәр --- Фатыйма дигән --- бер нур парчасы булмаса иде, Мостафа --- җаныннан да, малыннан да ваз кичәргә ният иткән иде.* Ф.Кәрими. *Табигатьнең матурлыгы, дөньяның иминлеге, кылырга ният ителгән эшләрем изгелектә булу сәбәпле, җан сәгадәт диңгезендә йөзә, мәхәббәтем – Сәлимәм – күңел түрендә һәм каршымда ямь өстенә ямь, сөенеч вә шатлык өсти иде.* Ф.Яхин. *Хыянәтче биюченең Көнбатышта ничек шулай бик тиз абруй казануын күреп эчләре пошкан совет җитәкчеләге --- тешен күрсәтә башларга ният итте.* Казан утлары

НИЯ́Т КЫЛУ *ф. к.* **ниятләү**. *Башта бераз ышанмаска ният кылган идем, соңыннан аның хәзер үзеннән эш күрмәгәнлеге, бәлки наширләр әмере илә заказ мәкаләләр язганлыгы хәтергә килгәч, ул хакта да канәгать иттем.* Г.Тукай. *Әгәр ике кеше үзара сөйләшкәндә, вәгъдәләшкәндә, «безнең сөйләшүгә Аллаһ вәкил» дип әйтүенә карамастан, үзенең әшәке ниятен кылса, Аллаһтан ләгънәт киләсен белеп торсын.* Р.Юныс. *Юк сәбәпне бар итеп, Җәмиләләр турыннан әйләнеп кенә килергә берничә тапкыр ният тә кылып карады.* Ф.Яхин

НИЯТЛӘНҮ *ф. к.* **ниятләү**. *Таминдар Тураев --- үзенең Идел-Кама пароходчылыгында эшләргә тиешле булдыклы, белемле кеше тәрбияләргә*

ниятләнә иде. Г.Ахунов. *Без, уйланып, ниятләнә алмый торганда, Гапсаттар инде икенче якта иде.* Ф.Яхин

НИЯТЛӘҮ *ф.* Нинди дә булса эш эшләргә, нәрсә дә булса башкарырга уйлау, исәпләү, план кору. *Ул [Һади] тиз генә Сәйфуллиннар тәрәзәсен карап килергә һәм өйгә керергә ниятләде.* А.Гыйләҗев. *Теге мин язган Сәлимҗанов дигән адәм илә бергәләп, көзен Хивада мамык чистарту заводы салырга ниятлибез.* М.Галәү. *Әнис белән Илгиз --- бераз алма бакчасындагы урындыкта утырып торырга ниятләделәр.* Казан утлары

Ниятләп йөрү Шактый вакыт билгеле бер нияттә булу. *Ульян өлкәсе мөфтие Сәүбән хәзрәт тә Кулатка районында Р.Гайнетдин тарафдарларының үз мөфтиятләрен булдырырга ниятләп йөрүләренә канәгатьсезлек белдерде.* Ватаным Татарстан

Ниятләп кую Алдан ук ниятләү. *Без үз оябызны быел ук корырга ниятләп тә куйдык.* Ф.Яхин

Ниятләп тору Күптәннән ниятләү. *Авыл араларына чыгып, кире беткән аңгыра халыкка бераз җикеренеп кайтуны ниятләп торган исправник та, әлеге хәбәрне ишетеп, артын кысты.* М.Галәү. *Ләкин башкортлар барыбер аны атасы урынына имам итәргә ниятләп торалар: «Сатан булһа ла, үзебездеке булһын», – диләр иде алар.* Ә.Еники. *Мәгәрем ки бәхетен сыер сөзмәсә, быелга җитешмәсә дә, берике елдан аңа [Кәримәгә] өйләнергә ниятләп тора.* Ф.Яхин

НИЯТЛЕ *с.* Ниятләгән, ниятта булган, ниятендә торган. *Кәримов бу юлы да иркенләп утырырга ниятле иде булса кирәк, бик озаклап, кирәкмәгән эшхәлләр хакында гәп корырга маташты.* Ф.Яхин

НОВА́ТОР *и. лат.* Нинди дә булса өлкәдә яңалык уйлап табучы һәм аларны тормышка ашыручы кеше. *Фәүзия Бәйрәмова – проза өлкәсендә новатор, төрле экспериментлар уздырып, --- укучыларны «үзенеке» иткән язучы.* Д.Заһидуллина

НОВА́ТОРЛАРЧА *рәв.* Новаторлар кебек, новаторларга хас булганча

НОВА́ТОРЛЫК *и.* 1) Новатор булу, алдынгылык. *Кай арада, нинди тизлектә, нинди чыганактан шул дәрәҗәдә новаторлыкка өйрәнгәндер [Х.Туфан], 1924 елның көзендә инде ул Казанда камил бер системага китерелгән --- «яңа татар шигыре»н әдәбият мәйданына куя.* М.Гайнетдинов

2) *күч.* Кирәкмәгән нәрсәләр уйлап табу күренеше. *Ритмик сиземе килделекиттеле генә булган шагыйрьләр «җиңел генә» бу кимчелекләреннән «котылалар», ирекле шигырь дигән нәрсәгә, яңартучылыкка – «новаторлык» юлына кереп китәләр.* Х.Туфан

НОВА́ЦИЯ *и. лат.* Ниндидер яңалык, яңа гына кулланылышка кергән нәрсә. *Хисаплау техникасы җитештерү өлкәсендәге новацияләр*

НОВЕ́ЛЛА *и. ит. әд.* Зур булмаган хикәя, кыска повесть. *Инде мин дә новелла белән хикәятне тәңгәл куеп бетерә алмыйм, чөнки новелла дигәннәре татардагы хикәя икән бит, әмма хикәят түгел!* Ф.Яхин. *Ш.Камал новеллалары*

НОВЕ́ЛЛАЧЫ *и.* Новелла язучы, новелла авторы

НОВОКАИН *и. лат. мед.* Авыртуны басу яки тоймаслык итү һәм дәвалау өчен кулланыла торган химик препарат; кокаинның синтетик аналогы. *Аннары [Җәүдәт]: «Шприц, новокаин...» – дигән өзек-өзек сүзләр ишетте, һәм менә инде энәнең, авырттырып, күзнең кайсы төшенәдер кереп кадалуын тойды.* М.Шаһимәрдәнов. *Новокаин блокадасы*

НОГМАН *и. гар. бот.* Лалә чәчәге, тюльпан, кызалак

НОГЫР *и. тар. этн.* Кулаткы мишәрләренең Казан татарларына карата кулланган атамалары

НОГЫТ *и. фар. бот.* 1) Кузаклылар семьялыгыннан эре орлык (борчак) бирә торган үсемлек; нугыт; *русчасы:* **нут**. *Помидор, борыч, баклажан һәм ногыт үсемлекләре үзеннән серкәләнгәндә дә, шулай ук читтән серкәләнгәндә дә орлыкланалар.* Яшелчәчелек

2) Шул үсемлекнең борчагы (орлыгы); төрек борчагы, койрыклы борчак. *Июнь ахырында – июль башында өлгермәгән яшь ногытны беренче тапкыр җыя башлыйлар.* Яшелчәчелек

3) *диал.* Вак кына, борчакка охшаш йомшак җимешле, тау битләрендә үсә торган куак; тәбәнәк бадәм; *русчасы:* **бобовник**. *Анда тау битендә сөрергә дә, чабарга да ярамаган ташлы, чокырлы, ногыт, тубылгы чыбыклы тигезсез урыннар бар.* Г.Ибраһимов. *Тау бите хуш исле үлән-чәчәкләр белән түшәлгән. Аның өстенә гөлҗимеш, чилык, ногыт куаклары.* Г.Кашшаф. *Ногыт куаклары арасында суер оялый иде.* М.Юныс

◊ **Ногыт салу** Ногыт борчакларының ничек төшүенә карап киләчәкне әйтү; күрәзәлек итү. *Татар һ.б. кайбер халыкларда ногыт яисә башка шундый борчаклар белән юрау-юрамалау, күрәзәлек итү дә булган. Ул – ногыт салу дип атала.* Ф.Урманче. *Төмән Башлыгы Багучыга рөхсәт дип баш какты: «Ногыт сал, әйдә, соравыңа җавап табып кара!» – янәсе.* С.Гаффарова. **Ногыт салдыру** Киләчәкне белер өчен, ногыт белән багучылык итү. *Иң якын ахирәте Шиһаб Мәликәсе исән чагында, ногыт салдырып карый торган иде. Ә хәзер, Мәликә булмагач, ногыт салучы да, төш юраучы да юк инде.* З.Зәйнуллин

НОГЫ́Т БОРЧАГЫ *и. к.* **ногыт** (*2 мәгъ.*). *Шулвакыт ниндидер чырчу ишетелде: кызлар ногыт борчагы җыеп кайталар икән.* И.Хуҗин. *Ногыт борчагының нәрсә икәнлеген дә белүче юк.* М.Юныс. *Ногыт борчагын (фасоль һәм борчак кебек үк) җитлеккән һәм җитлекмәгән килеш тә азык итеп файдаланалар.* Яшелчәчелек

НОГЫТЧЫ *и. иск.* Ногыт борчаклары белән күрәзәлек итүче, күрәзәче

НОЙОН *и. монг. тар.* Монголларда бәк (би) дәрәҗәсендәге кеше. *Начин нойон Байык буенда яңа тәртип, яңа йорт – Дунху йорты урнаштыру белән мәшгуль булган көннәрнең берсендә төньяк-көнбатыш якта бер төркем сөннәр килеп чыкты.* Н.Фәттах. *Бу (тарак тамгалы) ыру Уразмөхәммәднең ата-анасына хезмәт күрсәтеп килгән; ерак бабасы Сәртак Чыңгыз хан вакытында нойон (бәк) булган.* Ш.Абилов

НОКА́УТ *и. инг. спорт* 1) Бокста боксёрның очрашуны дәвам итә алмаслык хәлгә килүе. *Кавказлы нокаут алган иде, ул идәнгә егылды.* Р.Батулла. *Көндәшләренең күбесен нокаут белән җиңде, ягъни сугып екты*. Татарстан яшьләре

2) *күч.* Көчле психологик тәэсир, тетрәнү, шок. *Хатынын 15 тәүлеккә озатканнан соң, Мәннан шахтага сикергән ата мәчене өенә алып керде. – Нокаут! – диде ул, мәченең башыннан сыйпап. – Көчләр тигез булмау сәбәпле, икенче раундтан соң чиста җиңү Мәннан абзаңа бирелде!* Аманулла

НОКДА́УН *и. инг. спорт* Бокс уенында боксёрның, кулы яки тезе белән идәнгә таянып, берничә секунд эчендә аягына басып, көрәшне алга таба дәвам иттерә алырлык хәлгә килүе. *Боксчылар термины белән әйткәндә, бу – нокдаун гына, әлегә нокаут түгел.* Татарстан яшьләре

НОКРАТ *и. фар.* 1) *тар.* Болгар чорында сугылган көмеш акча. *Нократның нуктасы юк.* Мәкаль

2) Вятка елгасы. *Аларның [гарәпләрнең] бу өлкәдә көмеш ятмалары табып, зур бер елганы һәм мәгълүм өлкәне гарәп телендә «Нократ елгасы» һәм ул өлкә халкын «Нократ болгарлары» дип атаганнары шуны күрсәтә.* Ш.Мәржани. *Урыслар Казан тирәсен генә тулысынча буйсындыра алган, турыдан-туры Россия властена кергән татарлар, билгеле булганча, «ясаклы татарлар» дип аталганнар, әмма мондый власть Кама аръягына да, Нократ елгасының көнчыгыш ярына да үтеп керә алмаган.* З.Мифтахов. *Ак каеннар кала, Сары сагыш яна, Озата бара еглап Нократ су.* Ч.Хөснетдинова

3) *күпл.* **нократлар**. Нократ татарлары, Нократ елгасы буенда яшәгән татарлар

◊ **Нократ заманыннан** Бик күптәннән, әллә кайчаннан бирле. *Әнә басып тора бит нократ заманыннан калган иске капкасына сыланып.* М.Мәһдиев

НОКСАН *и. гар. иск.* Кимчелек, җитешсезлек. *Һәр заман күз алдыма кимлек вә ноксаным килә.* Г.Тукай. *Хәтта пьесаның үзендә булган ноксаннар, бик күп тәкмил кылынып, тәмам төзәтелмеш иде.* Г.Исхакый. *Йомма күзең, ач та дикъкать ит вә ноксаныңны күр!* Г.Рамазанов

НОКСАНЛЫ *с. иск.* Кимчелекле, җитешмәгән ягы булган

НОКСАНЛЫК *и. иск.* Ноксанлы булу, кимчелекле булу. *Моңганчы Русия идарәсенең ноксанлыгында, Русия үзенең граждannарының хокукы сәясиләрен бирмәенчә, --- иҗтимагый (социальный) хокукларыннан мәхрүм итүенең дә бик зур катышы бардыр.* Г.Исхакый

НОКТА *и. гар.* 1) Нинди дә булса очлы нәрсә (энә, без, карандаш, каләм очы һ.б.) белән кагылудан калган эз, кечкенә түгәрәк тап, төртке. *Нокталар да төртмимен, керсә ярар дип, киртәгә ---.* Г.Тукай

2) Язуда җөмләләр ахырында, кыскартылган сүзләрдән соң куела торган тыныш билгесе (.); нокталар тезмәсе һәм башка тыныш билгеләре (күп нокта, нокталы өтер, ике нокта, сорау билгесе, өндәү билгесе) ясаганда да кулланыла. *Шуңа күрә бер юлда берничә фразеологик берәмлекнең берберсеннән нокталар белән аерылуы да гаҗәп түгел.* Г.Халит. *Чынлап сөйсәң, кат-кат уйлап куй син, нокта түгел, хәтта өтерне.* М.Хөсәен

3) Алгебрада, нота язуында, телеграф кодында, географик карталарда һәм планнарда шартлы билгеләү өчен кулланыла торган график тамга (.). *А.В.Псянчин иллюстрациягә китергән карталарда «Башкортстан» исемле дәүләт тә, аның башкаласы да күрсәтелмәгән, анда фәкать кабиләләр тупланган конкрет географик нокталар гына чагыла.* М.Әхмәтҗанов

4) Математикада шартлыча тапкырлау билгесен күрсәтү өчен кулланыла торган график тамга (·)

5) Геометрия, топология, механика, физикада пространстводагы бернинди дә үлчәме (авырлыгы, мәйданы, озынлыгы һ.б.ш.) булмаган абстракт объект, сызык кисеменең чиге. *Бер турыда ятмаган өч нокта дан һәм аларны тоташтыручы кисемтәләрдән төзелгән геометрик фигура өчпочмак дип атала.* Геометрия

6) Нәрсәнең дә булса өстендәге, пространстводагы бер урын. *Башка вакыт булса, Гәрәй кызның үтәли тишкән карашын теләсә кайсы ноктадан да сизгән булыр иде.* А.Гыйләҗев. *Чиксезлекнең ерак ноктасыннан Карап тора кебек синең күзләр.* Ф.Яруллин. *Тауның иң югары ноктасы*

7) Нәрсә дә булса урнаштырылган, куелган яки нәрсәдер башкарылган, эшләнгән урын. *Килеп машинадан төшкәч тә алдан билгеләнгән пост нокталарына беренче часовойларны куябыз.* Ә.Еники. *Балачакта хыялга бирелеп текәлеп торган нокта иде бу.* Ф.Яхин. *Дөрес, командирлардан беркем дә аларга кайсы ноктага кадәр баруларын әйтмәде.* Р.Зәйдулла

8) *физ.* Матдәләрне бер хәлдән икенче хәлгә әверелдерә торган чик температура. *Эрү ноктасы. Кайну ноктасы*

9) Морзе әлифбасында: кыска гына электр тогы җибәрү. *Нокта – сызык, нокта – сызык*

10) *күч.* Күренер-күренмәс, сизелерсизелмәс кенә кечкенә нәрсә. *Әмма шул вакытта [торналар очып барган] кырыйдагы сызыкның берсе кителде, һәм аерым соры бер нокта сызыктан аерылды.* М.Мәһдиев. *Яныннан аккан саф, зәңгәр инештә төркем-төркем ак нокталар күренде. Казлар. Су коеныргa төшкәннәр.* Ф.Яхин. *Лачын яңадан күккә күтәрелә башлады. Озак та үтми, ул андагы хәрәкәтсез ноктага әверелде.* А.Хәлим

11) *күч.* Нәрсәнең дә булса чиге, дәрәҗәсе. *Бу процесс әдәби телнең яңа ноктага күтәрелүен, үсүен һәм камилләшүен күрсәтә.* В.Хаков. *Үзләренең эшен бер дә югары нокта дип карамаганга, сауган сөтләрен азсынып йөргән Бибинур андый чакларда ни әйтергә дә белми аптырап кала.* А.Гыйләҗев. *[Зәкәржан] хикәянең иң кульминацион ноктасында калай кружка төбендәге спиртны су кушмый гына йотты ---.* М.Мәһдиев. *Унсигез – яшьлекнең иң биек ноктасы.* Ф.Яруллин

12) Ниндидер мәсьәләгә билгеле бер караш, нәрсәгә дә булса бертөрле

мөнәсәбәт. *Бу, куәт вә кабилият (сәләт) ноктасыннан, артык мактаулы эш түгел.* Г.Ибраһимов. *Димәк, мин аңа ташлаган гаепнең чынмы-ялганмы икәнен белмим, шулай булгач, кешелек ноктасыннан караганда, минем аны гаепләргә хакым бармы?..* Ә.Еники

◊ **Ноктаи назар** *иск.* Караш ноктасы, назар ноктасы, теге яки бу фактка бер позициядән карау. *--- Шиһабетдин әл-Мәрҗани белән Габделкаюм ән-Насыйригa татарның хәзерге хәле хакында доклад укып, булган, булачак бөтен хәлләр вә вакыйгаларга Маркс ноктаи назарыны буяп, кычкырышып моназарә кылышып ята.* Г.Исхакый. *Монда һәрбер әсәргә шул кагыйдәләр, тәгърифләр ноктаи назарында кылына.* Х.Әбүлхан. **Нокта кебек (төсле)** Бик кечкенә әйбер турында. *Әнә ул ак болыт таулары фонында кара нокта кебек кенә булып леперди.* И.Гази. *Шунда теге хатын кайный-кайный бер нокта кебек җимешкә әйләнә дә киредән кабарып үз хәленә кайта.* Безнең гәҗит. **Нокта кую** 1) Эшне тәмамлау, төгәлләү, бетерү. *Ярый, сүз күпкә китте, инде нокта куярга да ярый торгандыр.* Ә.Еники. *Патша тарихына Наган белән нокта куелды!* Х.Туфан. *Җиһанша түзмәде, тәмам онытылып китеп һәм безгә дә дөньяларны оныттырып юк-бар мажараларны сөйләгән Сабирны бүлдерде: – Син әллә кайларга кереп киттең, ерып кына чыга алмыйсың барыбер. Нокта куй!* Ф.Яхин; 2) Араларны, мөнәсәбәтләрне өзү, аралашуны туктату. *Ләкин Зөфәр буфетчы хатынның артык әрсезлеген, оятсызлыгын һәм эчкәләргә яратуын белеп алгач, ике дә уйламыйча, тотты да нокта куйды.* Ә.Еники. *Барысын да әйтеп хат язарга, башка минем хакта уеңа да алма дип, мөнәсәбәтләренә нокта куярга уйлады [Җәмилә].* Ф.Яхин

НОКТАЛА́У *ф.* 1) Нокталар теземе итеп сызу яки рәсем төшерү, нокталар белән билгеләп чыгу

2) *лингв.* Хәрефләр өстенә яки астына тиешле нокталар кую. *Нокталы гарәп хәрефләрен нокталап чыгу*

НОКТАЛАП *рәв.* Аерым урыннарга, нокталарга гына игътибар итеп, туктalып. *Тарихи биналарны нокталап кына түгел, ә Иске Татар бистәсен төзекләндергән кебек районлап торгызсак, алар туристларны җәлеп итмәс дип кем генә әйтер икән?!* Ватаным Татарстан

НОКТАЛЫ *с.* Ноктасы булган. *Югыйсә ташның үзендә ул бер нокталы «җ» хәрефе белән уелган.* Гасырлар авазы

НОКТАЛЫ БЕГО́НИЯ *и. бот.* Бегониячәләр семьялыгыннан яфраклары кәмешсыман нокталы бизәкләр булган ал чәчәкле декоратив үсемлек; миңле гөл

НОКТАЛЫ ӨТЕР *и. линг.* Тезмә кушма яки үз эчендә өтере булган тиңдәш кисәкле җөмләләрдән җәенке, азмы-күпме төгәлләнгәнрәк мәгънәле кисәкләрне аеру өчен куела торган, нокта белән өтердән гыйбарәт тыныш билгесе. *Син атаклырак шагыйрьләрнең шигырьләрен кат-кат укы, башын – ахырга, ахырын – уртага, уртасын башка китер, ике-өч юлын – бер, бер юлын өч ит, матуррак сүзләрне ике-өч кат эт, бер дә кирәкмәс урыннарга өч нокталар, өтерләр, нокталы өтерләр куй.* Ф.Бәйрәмова. *Олуг әдибебез Әмирхан Еникинең бик тә тирән һәм мәгънәле мәкаләсе белән ачылган әлеге китапның (Х.Сарьянның китабы) исеме дә «Нокталы өтер» дип атала.* Р.Миңнуллин

НОКТАСЫЗ *с.* **1.** Ноктасы булмаган, куелмаган. *Беләзекләрдә гарәп хәрефе белән, ләкин ноктасыз язулар бар.* Р.Зәйдулла

2. *рәв. мәгъ.* Нокта куймыйча. *Ноктасыз яз! Ноктасыз калдырма!*

НОКТЮРН *и. фр. муз.* Кечкенә лирик, ешрак фортепьяно өчен язылган музыкаль әсәр. *[Р. Яхин] Вальс, ноктюрн, музыкаль мизгел, юмореска, программалы миниатюра һ.б. шундый жанрларда кызыклы әсәрләр иҗат итә.* Мәдәни җомга

НОЛЬ *и. лат.* 1) *мат.* Нинди дә булса санга кушудан аны үзгәртмәгән чын сан. *Сан нольгә бүленәме?*

2) «0» санының цифр билгесе һәм шулай ук саннар белән бирелгән зурлыкларның булмавын белдерә торган билге. *Инде исәп өчкә ноль булгач та, соңгы ике минутка өмет баглап утырды бит, бичаралар.* Безнең гәҗит. *[Дильяр:] Хәким, ә синең рекордыңны бәрдем бит мин! Әнә теге компьютергa барып кара. Унбишкә ноль!* Р.Сабыр

3) Берәр нәрсәнең чагыштырма зурлыгын, берәмлеген күрсәтә торган шартлы зурлык

4) *күч.* Ниндидер бик вак, бик әһәмиятсез, файдасыз нәрсә турында. *Киек казлар хакында язгаладылар бит инде. Тик нәтиҗәсе нольгә тиң.* Г.Бәширов. *Яңгыр булганда, комбайн – ноль.* М.Мәһдиев

5) *күч.* Җәмгыятьтә үз урынын тапмаган, бернинди әһәмияте булмаган түбән, начар кеше. *Миңа шундыйларның икесе белән эшләргә туры килде. Беренчесе тарих факультетының икенче курсында читтән торып укый иде. Белгеч буларак – ноль.* Татарстан яшьләре

◊ **Нольдән башлау** *сөйл. к.* **нульдән башлау**. *Совет властеның җитмешенче елында нишләп бер мин генә әле эшемне нольдән башларга тиеш.* М.Мәһдиев. **Ноль-ноль** 1) Вакыт турында әйткәндә, төгәл сәгатьне белдерә. *Җыелу вакыты – җиде ноль-ноль.* М.Мәһдиев. *Әйе, җәмәгать, бүген нәкъ унҗиде сәгать ноль-ноль минутта анда рекорд куелды.* А.Хәлим; 2) Ниндидер сан белән кулланылган нәрсәнең төгәл, бөтен, вакланмасыз, калдыксыз булганын белдерә. *Ун литры дүрт сум да ноль-ноль тиен аның.* М.Мәһдиев

НОМЕНКЛАТУ́РА *и. лат.* 1) Нинди дә булса фән тармагында, җитештерү һ.б.ш. өлкәләрдә кулланыла торган атамалар җыелмасы; терминнар системасы. *Ләкин мондый номенклатура белән берәттән, хәзер систематик (халыкара) номенклатура күбрәк кулланыла бара. Бу номенклатура буенча углеводородларның исемнәре -ен кушымчасы белән бирелә (этен, пропен, бутен һ.б.).* Органик химия. *Хайваннар һәм үсемлекләр дөньясындагы төрләрне исемләү номенклатурасы*

2) *җыйг. и.* Кадрларының кандидатуралары югары партия, совет, профсоюз оешмалары тарафыннан карала,

тәкъдим ителә һәм билгеләнә торган әһәмиятле эш урыннары исемлеге; шул урыннарда эшләүчеләр. *Шуның иң хәвефлесе – бөтен җирдә, шул җөмләдән безнең Татарстанда да, яңа власть тирәсендә иске коррупция һәм яңа номенклатура бик әрсезләнеп башын күтәрә.* Ә.Еники. *Шагыйрь дә, мәңгелектән килгән «болгатучы» буларак, шул «экстремистлар» исәбендә йөри, чөнки ул империячел номенклатура күрмәгәнне күрә һәм ярып әйтә.* А.Хәлим. *Мәһди белән бер табында утыру, язучы белән әңгәмә кору, аның әсәрләре турында фикер алышу партия һәм хуҗалык эшләренә кереп баткан номенклатура өчен әйтеп бетергесез бәйрәм булгандыр.* Р.Миңнуллин

НОМЕНКЛАТУ́РАЛЫ *с.* Номенклатурага (*2 мәгъ.*) караган, номенклатура (*2 мәгъ.*) булып саналган. *Номенклатуралы урыннар. Номенклатуралы кадрлар. Номенклатуралы хезмәткәр*

НО́МЕР *и. лат.* 1) Тиңдәш, бер иш предметлар рәтенең тәртип саны; шул санны белдергән цифр. *Шунда ук телефон трубкасын алды, номерын җыйды, кем беләндер коры гына исәнләште ---.* Ә.Еники. *Анда юан баганалар утыртылган, һәм аларның дүрт ягын квадратлап уеп, кара буяу белән номер сукканнар.* М.Мәһдиев

2) Тәртип саны белән билгеләнгән берәр нәрсә. *Минем номер килә ахрысы* (трамвай, троллейбус, автобус тур.)

3) Нинди дә булса цифр язылган планка, ярлык, регистрацияләнүне белдерә торган документ һ.б. *Зур авылның каравыл өенә охшаган фабриканың тыгыз конторында, аларның фамилияләрен дәфтәргә теркәп, кулларына пропуск номерлары тоттырдылар.* К.Тинчурин. *Жирәбә дигәне – номер язып бөтерелгән кәгазь.* И.Нуруллин. *Таныш-улары да кызыклы гына булды: алар икесе бергә киемнәрен алырга гардеробка килделәр, Гатауллин ялгышлык белән номерын төшереп җибәрде, ә егет тиз генә иелеп алып бирде.* Ф.Яхин

4) Нинди дә булса әйбернең (гадәттә кием-салымның) цифралар белән билгеләнгән үлчәме. *Ак яка Тукай муенынан бер вершок зур муен өчен ясалган номер булганга, бер фатирчы кирәксенгән сымак тора.* И.Нуруллин

5) Вакытлы матбугат басмаларында: сан. *Мәдрәсәдә яшерен чыга торган «Телчән» журналының ашыгыч номеры чыгып, --- һөҗүмгә «корал» белән каршы торырга өндәде.* К.Тинчурин. *Журналыбызның бу номерына урнаштырылган «Онытылган җырлар турында»гыз шуңар мисал була ала.* Х.Туфан. *[Тукай] «Яшен»нең һәр номерын тизрәк чыгарырга тели, рәсемнәр өлгермәүгә борчыла иде...* И.Нуруллин

6) Кунакханәдә, мунчада һ.б. аерым бүлмә. *Ягъкуб әфәнде, кунакханә номерына кереп ишек ябылуга ук, Маһруйны битәрләргә тотынды.* З.Бигиев. *Кыш буенча Мәскәүнең номер һавасында талчыгып беткән аның яшь, зифа әгъзаларына яңадан-яңа көч кергәндәй булды.* К.Тинчурин. *Кырыгынчы номерның Тукай яшәгән чагындагы эчке күренеше якынча әнә шундый.* И.Нуруллин

7) *иск.* Кунакханә, мосафирханә. *Хатыным, йортым юк – ятам номерда.* Г.Тукай. *Җаекка алып китәчәк Алты-биш Сапый дигән кешенең килеп җитмәгәнлеге сәбәпле, Габдуллага Печән базары тирәсендәге бер номерда ике атна чамасы вакыт үткәрергә туры килә.* И.Нуруллин. *Габделбарый Казанның Проломный урамындагы «Бристоль» номерлары астында хәрчәүник ачты да җибәрде.* М.Мәһдиев

8) Концерт, кичә һ.б.ш.ның аерым башкарыла торган бер өлеше. *...Менә концертның чираттагы номерын әйтеләр.* М.Мәһдиев. *Гамил Афзалныкы дисеңме? Миңа димәгәе, чуртныкы булсын, иллә дә мәгәр батмый бу номер, батмый.* Ф.Баттал

9) *күч. сөйл.* Хәйлә, махинация; берәр көтелмәгән гамәл, кыланыш. *Менә гаебең! Сез берәү дә сизми дип уйлагансыздыр. Безнең күз җир астыннан да күрә. Номерыгыз барып чыкмады. Яндыгыз.* И.Салахов. *Безнең авылның сугыштан соңгы беренче кияве шәл бәйләү кичәсендә әнә шундый номер күрсәтте.* М.Мәһдиев

10) *хәрби* Туп, пулемёт, миномёт расчётындагы сугышчы. *Әнә икенче номер пулемётчикның хатыны кияүгә чыккан ич.* Г.Әпсәләмов

НО́МЕРЛАМА *и. иск. к.* **нумерация**

НО́МЕРЛАУ *ф.* **1.** Номер кую, номер сугу. *Кызлар күп булгач, Кәшфи үзе генә түгел, күршеләр дә исемнәрен хәтерләмичә, чама белән өченче, дүртенче дип, номерлап сөйләшәләр.* М.Мәһдиев. *Ул [Г.Сәйфуллин] үзе ясаган тәлинкәләрне номерлап, аларның кайсы елда, ничәнче айда һәм көндә эшләнгәнен махсус дәфтәргә теркәп барган.* Р.Исламов

2. *и. мәгъ.* Берсе артыннан берсе урнаштырылган, куелган, төзелгән әйберләрнең цифрлар белән белдерелүе. *«Файдалы киңәшләр» бүлегендә дә бишtән соң номерлау беткән.* Татар иле

Номерлап бару Рәттән, гел номерлау, даими рәвештә номер кую. *Һәр аудиоальбомыбызны без номерлап барырга булдык.* Мәдәни җомга

Номерлап кую Алдан ук номерлау

Номерлап тору Гел, һәрвакыт номерлау

Номерлап чыгу Барысына да номер кую, барысын да номерлау. *Әйдәгез, үсемлекләрнең исемнәрен укып, номерлап чыгыйк*

НО́МЕРЛЫ *с.* 1) Номеры булган, номер куелган, номер сугылган

2) Билгеле номер йөрткән. *Капотына ут өруче аждаһа сурәте ясалган һәм без тапкан номерлы «ундүртле» нинди дә булса җинаять эшендә төп фигурант булып тормыймы икән?* Ф.Бәллүр. *Бара торгач, Куйбышев мәйданын кичеп, беренче номерлы автобус туктый торган төшкә җиттеләр.* Г.Минский

НОМИНА́Л *и. махс. лат.* Кыйммәтле кәгазь, акча һәм товарларның өстенә язып куела торган хакы, кыйммәте. *Арткы ягында исә канатларын салындырган ике башлы бөркет, «Россия банкы» дигән сүзләр урын алачак, тәңкә номиналы һәм аны кою елы күрсәтеләчәк.* Ватаным Татарстан

НОМИНА́ЛЬ *с. махс.* 1) Берәр нәрсәнең өстендә акча бәясе белән күрсәтелгән, акча бәясе белән билгеләнгән. *Мәсәлән, 1999–2008 елларда тораккоммуналь хезмәтләргә тарифлар*

9,5 тапкыр артты, шул ук вакытта сатып алынылучы товарлар бәясе – 3,5, халыкның номиналь керемнәре 5,5 тапкыр гына артты. Кызыл таң. *Номиналь бәя. Номиналь эш хакы*

2) Исеме генә булып, чынлыкта билгеләнгән вазифасын үтәмәгән; фиктив; формаль. *Сентябрьдә үк әлеге төбәкләрнең парламентлары Конституциягә үзгәрешләр кертеп, үз милләтләрен номиналь, кәгазьдә генә булган, ләкин халык үзаңына шактый тәэсир ясаган Президентыннан мәхрүм итәчәкләр.* Безнең гәҗит. *Номиналь җитәкче*

НОМИНАНТ *и. лат.* Номинациягә (*2 мәгъ.*) кергән зат яки әсәр. *Номинантлар исемлекләре «Ватаным Татарстан» һәм «Республика Татарстан» газеталарында басылып чыгачак.* Ватаным Татарстан

НОМИНАТИВ *с. лат. лингв.* **1.** Атау, исемләү өчен хезмәт итә торган. *Термин семантик яктан туры, номинатив мәгънәдә була, аның өчен контекст мәҗбүри түгел, чөнки термин аерым бер терминология составында яши, аерым кулланыла ала.* Г.Галиуллина. *Номинатив җөмлә. Номинатив функция*

2. *и. мәгъ.* Баш килеш

НОМИНА́ЦИЯ *и. лат.* 1) *лингв.* Атау, исем бирү. *Номинация принциплары. Номинация теориясе*

2) Фестивальләрдә һәм конкурсларда бүләкләр, мактаулы исемнәр һ.б.ш. бирер өчен сайланыла торган әсәрләр яки шәхесләр категориясе // Фестивальләрдә һәм конкурсларда бүләкләр, мактаулы исемнәр һ.б.ш. биргәндә тематик позиция. *«Яшь талант» номинациясендә дә Сарман кызы Гөлназ Сафинага бәхет елмайды.* Ватаным Татарстан. *Драматурглар арасында «35 яшькә кадәр» дип аталган номинациядә дә бүләкне аңа [Илгиз Зәйниевка] тапшырдылар.* Ватаным Татарстан

НОМОГРА́ММА *и. гр. мат.* Төрле исәпләүләрдә кулланыла торган геометрик зурлыклар графигы

НОНЕТ *и. лат. муз.* Тугыз уен коралы өчен музыкаль әсәр яки тугыз башкаручыдан торган ансамбль

НОНПАРЕЛЬ *и. фр. махс.* Петиттан ваграк шрифтның атамасы

НОРВЕГ *и.* Норвегиядә яшәүче төп халык һәм шул халыкның бер вәкиле. *--- горур поляк, чех, югослав, норвег һәм француслар – Германия турында ике ятып төшләренә бер кермәгән, бары тик үз илләрен, үз җирләрен генә яраткан, кеше малына кул сузуны җирдә иң зур җинаять дип санаган бу иң гадел ирләр, бу каһәр суккан дошман җирендә актык сулышларын өзәрләр дип кем уйлаган?* Г.Әпсәләмов. *Соңгы елларда гына итальян, португал, гарәп телен өйрәтүче лагерьлар ачылган. Моннан тыш, ике испан, өч француз, фин, норвег, алман, кытай, япон һәм башка тел өйрәнү авыллары бар.* Ватаным Татарстан

НОРВЕ́ГИЯЛЕ *с.* Норвегиядә яшәүче, тумышы белән Норвегиядән булган. *1911 елның 11 декабрендә норвегияле Руаль Амундсен, ә бер айдан соң – 1912 елның 18 гыйнварында – инглиз Роберт Скотт Көньяк полюска аяк басалар.* Материклар һәм океаннар географиясе

НОРД *и. нидерл. махс.* 1) Төньяк, шималь

2) Төньяктан исә торган җил, төньяк җиле

НОРД-ВЕСТ *и. нидерл. махс.* 1) Төньяк-көнбатыш

2) Төньяк-көнбатыштан исә торган җил

НОРД-ОСТ *и. нидерл. махс.* 1) Төньяк-көнчыгыш

2) Төньяк-көнчыгыштан исә торган җил

НО́РМА *и. лат.* 1) Нәрсәнең дә булса гадәттәге, гомуми кабул ителгән, мәҗбүри булган тәртибе, торышы. *Умартачы булганлыктан, ул үзенә кайбер гадәт нормалары эшләгән һәм боларны закон төсенә керткән иде.* М.Мәһдиев. *Болай да, тормыш куша, әхлак-мораль нормалары шуны таләп итә дип, борынгылар шулай өйрәтә дип, атлаган саен, бер-беребездән чынлыкны, чынны яшереп гадәтләнгән гөнаһлы җир уллары --- нигә чынны сөйләргә талпынмыйбыз?* А.Гыйләҗев. *Үз-үзеңне тоту нормалары. Әдәби тел нормалары*

2) Берәр нәрсәнең булырга тиешле үлчәме, күләме. *Кайбер азыкның, мәсәлән, бәрәңгенең терлек башына нормасын арттырып бирде.* Ә.Еники. *Кырын ятып кына акча көрәгәндә, яңа кешеләр килделәр дә, тәртип, норма, план дип, өзеп сөйләшә башладылар.* А.Гыйләҗев. *Трактористың ул көнне ике ярым норма бирде.* М.Мәһдиев

◊ **Нормага керү** 1) Норма булып китү. *Гаепсез башы өчен хәвефләнеп яшәү бер нормага керде дияргә була, тик кеше, яшерен чиренә ияләшкәндәй, хәвефкә дә ничектер күнегебрәк китте.* Ә.Еники. *Мәсәлән, өйләнешмичә яшәп алу, ЗАГСта теркәлмичә генә яки бер җенес кешеләре бергә яшәү, ясалма орлыкландыру ысулы белән бала табу кебек күренешләр нормага керә башлады.* Мәдәни җомга; 2) Гадәти халәткә керү, нормаль хәлгә кайту

НО́РМАЛАНУ *ф.* Нормага салыну, нормага китерелү

НО́РМАЛАУ *ф.* Берәр нәрсәнең нормасын билгеләү, аны чикләү

Нормалап бару Баштан алып, тоташ нормалау

Нормалап кую Тиз-тиз генә нормалау

Нормалап тору Гел, һәрвакыт нормалау

Нормалап чыгу Барысын да нормалау

НО́РМАЛАШТЫРУ *ф.* Норма билгеләү, норма кую

Нормалаштырып кую Тиз-тиз генә нормалаштыру

Нормалаштырып тору Гел, һәрвакыт нормалаштыру

НО́РМАЛАШУ *ф.* Норма хәленә килү, норма булып китү. *Гади сөйләмдә экономия максаты белән әнә шундый гыйбарәләр барлыкка килгән. Алар, гади сөйләмнән әдәби телгә үтеп, нормалашкан.* Р.Абдуллина. *Бу факт әлеге күренешнең ул чорда нормалашып өлгермәгәнлеген раслый.* Ә.Йосыпова

Нормалашып җитү Бөтенләй нормалашу. *Бу очракта, гарәп, фарсы сүзләренә параллель рәвештә, татар әдәби телендә нормалашып җиткән сүзләр кулланыла.* А.Булатова

НО́РМАЛЫ *с.* 1) Нормага салынган, норма куелган, норма белән билгеләнгән. *Фәнискә, мәктәптә тарих укытучысы җитмәү сәбәпле, ике айлык педагогия тәҗрибәсе үткән чорында ук, бер ярым нормалы, ягъни 27 сәгатьле эш атнасы билгеләнде.* Ш.Алпар. *Нормалы уртак сүзләр, сүзтезмәләр, формаль җөмләләр, фәкыйрь синонимнар, тәгъбирләр, тапталган рифмалар, «төзек» килешләр, һәртөрле шаблоннар әдәби тел үсешенә, димәк ки, матур әдәбият теле үсешенә үзләре үк киртә булып торалар.* Х.Бәдигый

2) Кирәк кадәр генә, тиеш булганча, нормадан арттырылмаган да, киметелмәгән дә. *Нормалы ашау. Нормалы йокы*

НОРМАЛЬ *с.* 1) Нормага туры килә торган; нинди булырга тиеш булса, шундый; гадәттәге, табигый. *Шагыйрьләргә, композиторларга гына түгел, һәрбер нормаль кешегә билгеле булган бер аксиома бар: шигырь ул – ритмик сөйләм.* Х.Туфан. *Ләкин бу елмаю нормаль елмаю түгел иде, моны икебез дә сиздек.* М.Мәһдиев. *Йөрәк нормаль тибә, бөтен әгъзалар саусәламәт...* А.Гыйләҗев

2) *сөйл.* Психик яктан сәламәт. *Бик үк нормаль кеше түгел*

НОРМАЛЬЛӘШТЕРҮ *ф.* Нормаль хәлгә китерү. *Операторның төп эше – технологик процессны инструкция һәм контроль-үлчәү приборларының күрсәтүләре буенча алып бару, бирелгән режимнан читкә тайпылулар килеп чыкканда, процессны нормальләштерү өчен кирәкле чараларны тиз күрә белү.* Органик химия. *Инҗир ашказаны тракты өчен дә файдалы. Ул ашкайнату системасын яхшырта, ашказанының лайлалы тышчасы ялкынсынуын киметә, бөер һәм бавыр эшчәнлеген нормальләштерә.* Ватаным Татарстан. *Шунысын онытмыйк: бүлмә гөлләре өйне бизәп кенә калмый, һаваны чистарту, микроклиматны нормальләштерү өчен дә үз көчләрен кертә.* Кәеф ничек?

Нормальләштерә башлау Нормальләштерергә керешү

Нормальләштерә төшү Бераз нормальләштерү

НОРМАЛЬЛӘШҮ *ф.* Нормаль хәлгә килү. *Бүген, күрүемчә, ситуация нормальләшә кебек.* Р.Хәким. *Менә аның ярдәме белән авыруның температурасы нормальләште, тиешле дарулар эчертеп, уколлар кадаганнан соң, хәле аруланып китте.* Т.Нәҗмиев. *Баш, йөрәк, шикәр авыруларыгыз юкка чыга, кан басымнарыгыз нормальләшә, бөерегездәге таш юкка чыга...* Н.Хәсәнов

Нормальләшә бару Торган саен нормальләшү

Нормальләшә башлау Нормага керү

Нормальләшә төшү Бераз нормальләшү

Нормальләшеп алу Беразга гына нормальләшү. *--- вакыт-вакыт зиһене ачылып, нормальләшеп алса да, җитди сырхауга санап, аны Чистайдагы психик авырулар хастаханәсенә озаткаллар.* Ә.Халидов

Нормальләшеп бетү Тәмам нормальләшү

Нормальләшеп килү Әкренләп нормальләшү. *Хәтта азмы-күпме нормальләшеп килгән бәяләрне бәйдән ычкындырган 1998 елгы дефолтны да әбибабалары, әти-әниләре сөйләгән буенча гына күзаллыйлар.* Ватаным Татарстан

НОРМАННАР *и. күп. сканд.* VIII–XI гасырларда Көнбатыш Европа халкы тарафыннан, диңгездән һөҗүмнәр ясап, Европа илләрен тар-мар иткән скандинавларга карата кулланылган атама (Скандинавиянең үзендә хәрби сәфәрләрдә катнашучыларны – викинглар, Русьта варяглар дип атаганнар). *X гасырдагы Хәзәр дәүләтенең норманнар вә урыслар белән көрәше, --- нигаять, Казан төшкәннән алып 1557 елга кадәр дәвам кылган татар вә башка гайре русның Мәскәүгә каршы күзгалышлары – һәммәсе дә шушы эпопеяның тарихка мәгълүм булган бер кисәкләре генә.* Г.Гобәйдуллин

НОРМАТИВ I *и. лат.* Берәр төрле эш башкару өчен билгеләнгән нормалар күрсәткече. *Моннан тыш торак микрорайоннар төзүдә социаль нормативлар билгеләнергә, алар төгәл үтәлергә тиеш.* Ватаным Татарстан. *Техник нормативлар. Спорт нормативы*

НОРМАТИВ II *с.* 1) Нормага туры китереп куелган, норма буенча билгеләнгән. *Детальләрнең норматив запасы*

2) Нәрсәнең дә булса нормасын, кагыйдәләрен билгели торган. *Норматив грамматика. Норматив документлар*

НОРМИРО́ВЩИК *и. рус* Нәрсәне дә булса нормалаштыручы, нормалар билгеләүче. *Хәзер аның конторасы зур гына: диспетчеры да бар, нормировщиклары да... [бар].* А.Гыйләҗев. *Идрис биредә нормировщик булып эшли икән.* Ф.Бәйрәмова

НОРСЫЗ *с.* Шөкәтсез, чырайсыз, җирәнгеч. *– Абау-абау норсыз, – дип мыгырданды карчык, – син нәрсә, әллә кешегә җүнләп сүз ката белмисеңме?* М.Мәһдиев. *Норсыз чырайлы, үте сытылган бер бәндә.* Р.Батулла // Ямьсез, соры. *Ялгызак яшәеш, норсыз тормыш туйдыра башлаган иде инде.* Т.Галиуллин

НОРСЫЗЛЫК *и.* Норсыз булу. *Хәлимә, трибунадан бик уңайлы файдаланып, дошманын тар-мар китерергә кереште: – Күр әле, күр норсызлыгын! Ун сум акчаны кайчан түлисең, хөрәсән?* Р.Сәлим

НОСИ́ЛКА *и. рус* Авыр әйберләрне ташу яки авыру, яралы кешеләрне урыннан урынга күчереп йөртү өчен кулланыла торган җайланма; лачинка. *Сыңар аягы өзелгән бер солдатны, носилкага салып, санбатка китерәләр.* Ә.Еники. *Юка күлмәкләр кигән кызлар, носилка белән күтәреп, бөгелә-сыгыла бетон ташыйлар.* А.Гыйләҗев. *Шуннан соң носилкадан төшерделәр и һәм дә сразы операция өстәленә салдылар.* М.Мәһдиев

НОСИ́ЛЬЩИК *и. сөйл. рус* Вокзал, пристаньнарда багажларны ташып, күчереп йөрүче кеше, шулай ук кемне яки нәрсәне дә булса носилкада ташучы, күчереп йөртүче; хәмелче, хәммал. *Носильщикка ишарәт итеп, әйберләребезне вагонга кертергә булдык.* Ф.Кәрими. *Багажын күтәргән носильщикларны иярткән килеш, шундый ук вәкарь, шундый ук олысымак кыяфәтен саклап, як-якка күз салмыйча, ярга чыга да каршыларга*

килгән фаэтонга менеп утыра. И.Нуруллин

НОСРӘТ *и. гар. иск. кит.* Җиңү, өстенлек. *Хак Тәгалә аларны дүрт төрле бәлагә тоткын итәр: --- өченче – дошманнарына ярдәм биргән булып, дошманнары носрәт табарлар.* К.Насыйри. *Намаз укылганнан соң, патшага, аның гаскәрләренә Алладан носрәт сорап, заказ ике рәкәгать нәфел намазы укылды.* К.Тинчурин

НОСТАЛЬГИ́Я *и. гр.* Үткәнне яки туган җирне сагыну хисе; җирсү. *Бу ностальгия генә түгел, ә аңлы рәвештә сагыну.* Р.Миңнуллин

НО́ТА I *и. лат. муз.* 1) Музыкаль авазны күрсәтү өчен шартлы график билге һәм әлеге аваз үзе. *Әлеге ике катлы таш йортка күчкәч, Төхфәтуллиннар гаиләсенә рояль килеп кергән, кызлар нота укырга өйрәнә башлаганнар, җыр тавышлары яңгыраган, «экспромт» концертлар оешкан.* И.Нуруллин. *Югары нотадан алыйм, кешене шаккатырыйм дип, кирәгеннән артык акырып, тавышларыннан бөтенләй колак кагучылар да булды.* И.Шакиров. *Әмма җыры гына ялган чыга, ноталары дөрес түгел, әйеме?* Ф.Яхин

2) Шартлы график билгеләр белән язылган музыкаль әсәр тексты; шундый текстлардан торган дәфтәр, китап һ.б. *«Мин сине көтәрмен» дигән җөмлә аның колак янында әллә нинди югары һәм эч өзгеч ноталардан җырланып бара, аның җанын ләззәт катыш ачыта, сызлата иде.* Ш.Камал. *Мин сезгә «Туган тел»нең үзем язган нотасын китердем.* Ә.Еники. *Әбисе кайчандыр Казан гимназиясендә укыган Мәдәния апасы рояль капкачын күтәреп ача, аннан ноталарын рәтли: хәзер җыр дәресе булачак.* Н.Көбәш

3) *күч.* Нинди дә булса тойгыны, хисне белдерә яисә кемгә яки нәрсәгә карата берәр төрле мөнәсәбәтне күрсәтә торган тон, төсмер, нюанс. – *Бик ябыккансың!.. – дип, Сөләйман тавышына кызгану ноталары кертергә тырышты.* К.Тинчурин. *Күрешүләр, кочаклашуубешүләр, вәгъдәләр, планнар ашыгыч ноталарда башкарылды, машиналар газ бирде.* М.Мәһдиев. *Татар тарихында тирән эз кадырган шәхесләргә, әйтик, Ф.Кәримгә, Җәлил һәм җәлилчеләргә багышланган әсәрләрендә героик, патетик нота өстенлек итсә, күпчелек поэмаларында аналитик башлангыч һәм психологик анализ төп гомумиләштерү чарасы булып китә.* Р.Харис

◊ **Нотага салу** Музыкаль әсәрне шартлы график билгеләр белән язу. *Шулай да Коръән укучылар тавышын һәм көен Флёра Баязитова, Гүзәл Сәйфуллина, Мәсгудә Шәмсетдинова кебек тикшеренүчеләр яздырып калган булган. Соңгы икесе аларны хәтта нотага да салган.* Безнең гәҗит. **Нотага төшерү** *к.* **нотага салу**. *Татарга гына хас булган моңны беркайда укытып та, аны нотага төшереп тә булмый.* И.Шакиров. *Баянын алып, Марат экспедициядә туплаган көйләрне нотага төшерә башлады.* Р.Батулла

НО́ТА II *и. лат. махс.* Бер ил хөкүмәтенең икенче ил хөкүмәтенә язма рәвештә җибәргән рәсми дипломатик мөрәҗәгате. *Үзем теләп, унбер тәңкә биреп «Чемберленга җавап» фондына, Нота язам янган йөрәк белән Англиянең мәгърур лордына.* һ.Такташ. *Бу язу – Мәскәү хөкүмәтенең, ни өчен безнең гаскәребезне кырдыгыз, дип язган нотасына җавап хаты.* Г.Гобәйдуллин. *Ә Голио елгасы аша салынган ике километрлы асма күпер суга чумгач, күрше илгә катгый нота җибәрелде. Нотага зәһәр итеп язылган җавап алынды.* А.Тимергалин

НОТАБЕ́НА *и. лат. кит.* Текснтагы берәр фикергә укучының игътибарын ныграк юнәлтү өчен, китапның яки берәр документның читенә куела торган NB яки ɴʙ билгесе (NB хәрефләре – латинча *nota bene* «игътибар ит, исеңдә тот, онытма» сүзтезмәсенең график кыскартылмасы)

НОТАБЕ́НЕ *и. лат. к.* **нотабена**

НОТАРИАЛЬ *с. лат.* Юридик актларны раслауга, документлардагы һәм аларның күчермәләрендәге имзаларның дөреслеген таныклауга бәйләнешле; нотариуста танылган. *Нотариаль таныкланган күчермә*

НОТАРИАТ *и. фр.* Төрле килешүләрне раслау, васыять, ышанычнамә, күчермә кебек документларга юридик көч бирү белән шөгыльләнгән рәсми оешма

НОТА́РИУС *и. лат.* Вазифасына юридик актларны, килешү кәгазьләрен, документларның күчермәләрен, тәрҗемәләрне һ.б.ш. рәсми рәвештә таныклау кергән хокук белгече. *Нотариуста доверенность раслату өчен – тагын илле сум...* М.Галәү. *Фатирда торуыма карама, бер тиен бурычым юк, бөтен кибетем үземнеке, алай-болай күңелең шикләнә икән, менә тот та нотариус белән бөтен малыңны кызыңа яздыр.* Г.Исхакый. *Мин сиңа бит нотариус вазифасын гына йөкләгән идем.* Р.Зәйдулла

НОТА́ЦИЯ I *и. лат. махс.* Нинди дә булса белем яки эшчәнлек тармагында кабул ителгән шартлы билгеләр системасы. *Шахмат нотациясе. Музыкаль нотация. Математик нотация*

НОТА́ЦИЯ II *и. лат. сөйл.* Озынозак сөйләнгән үгетләү сүзе, нәсыйхәт, үгет-нәсыйхәт, вәгазь. *Нотация түгел, биллəһи, Киңәш кенә, Белла, бу сиңа...* Х.Туфан. *Нотация уку. Нотацияләр тыңлау*

НОТИФИКА́ЦИЯ *и. лат. махс.* Нинди дә булса халыкара оешмага яки аның җитәкчесе исеменә нота белән берәр нәрсә белдерү, берәр нәрсә турында хәбәр итү

НОТЫК *и. гар.* Халык алдында ясалган чыгыш. *Мостафа, Фатыйманың сүзләреннән бик әсәрләнеп бер нотык сөйләмәкче булса да, --- ничек итеп сөйләргә белмәде ---.* Ф.Кәрими. *Мәрхүм [Тукай] турында нотыклар сөйләнгәч, халык чәчәк өеме булып күтәрелгән кабер яныннан акрын гына тарала башлый.* И.Нуруллин. *Туйда сөйләгән нотыкны Хуплап бокал тоттылар.* Ш.Галиев

◊ **Нотык тоту** Нотык сөйләү, халык алдында чыгыш ясау. *Мазлум халыкларга азатлык кояшы чыкты, дип сөйләделәр нотык тотучы мөхтәрәм абзыйлар.* Ә.Еники. *Сөембикә капка каршына җыелган халык алдында нотык тотты.* М.Хәбибуллин. *Әсхәт Лотфиеч һаман кәперәйде, һаман, аягүрә басып, нотык арты*

нотык тотты, һаман үзен мактады. М.Шаһимәрдәнов

НОУТБУК *и. ингл.* Дисплее сыек кристаллы, янда йөртергә уңайлы яссы персональ компьютер. *Ә ул ноутбугына төртелгән иде.* Н.Гыйматдинова. *Укытырга вакыт калмый, отчёт белән утырталар, Бар нәрсәне портфолио, ноутбукка тутырталар.* Казан утлары. *Ә бу – көллият бинасына заманча ремонт ясарга гына түгел, классларны интерактив такталар, өр-яңа компьютерлар, ноутбуклар белән тәэмин итәргә дә җиткән.* Ватаным Татарстан

НОЯБРЬ *и. лат.* Календарь елның унберенче ае. *Ноябрь җиле кара күк буйлап болытлар ташыды.* А.Гыйләҗев. *Сталинград сугышы кызганнан-кызып, ноябрь урталары җитеп килгән бер төнне тыштан акрын гына тәрәзә какты.* З.Зәйнуллин. *Бишенче ноябрьдә көзге каникул башланды.* Н.Көбәш

НӨБҮВӘТ *и. гар. кит.* Пәйгамбәрлек, нәбилек; пәйгамбәр, нәби, рәсүл булу. *Нөбүвәтнең алтынчы елында булган вакыйга*

НӨГӘР *и. монг.* 1) *тар.* Борынгы төрки һәм монгол дәүләтләрендә хан гвардиясендә хезмәт итүче сугышчы, гвардияче. *Алты кара ат җиктергел, Күп түшәкләр түшәткел, Мамык ястыклар ясаткыл, Ике яхшы нөгәрең утырткыл...* Дастан. *[Җанбай:] Ә син болай иттерсәң: пар атларга көймәле алтын арбаң җиктереп, кат-кат түшәк салдырып, нөгәрләрең җибәрсәң...* Ю.Сафиуллин. *Алар артында урыс явыннан исән калган меңләп нөгәр ияргә берегеп үскәндәй тынып калган.* Р.Зәйдулла

2) *этн. к.* **нәгәр**

НӨҖҮМ *и. гар. иск. кит.* Йолдызлар. *Һавада нөҗүм никадәр, Суда сәмәк шул кадәр.* Җыр. *Бөтен инсан вә җир күккә, нөҗүмгә Күңел башлый, котырган күк һөҗүмгә.* Г.Тукай

НӨҖҮМ ГЫЙЛЕМЕ *и. иск.* Йолдызларны өйрәнә торган фән; астрономия, гыйльме нөҗүм. *Мәгәр падишаһ углын, гыйльме һәйәт вә нөҗүм гыйльмен үгрәнмәк өчен, остазга бирмеш иде.* К.Насыйри. *[Факир:] Кырык ел өйрәндем нөҗүм гыйлемен тау тишекләрендә, мәгарәләрдә ятып ---.* Г.Камал. *[Хуҗа Насретдин:] Кара син аны. Нөҗүм гыйлеме белән дә шөгыльләнәсең икән син. Алай булгач, күккә карап та уйлыйсың булыр?* Н.Исәнбәт

НӨКТӘ *и. гар.* 1) Һәркем аңламый торган үткен мәгънә. *Күкрәгендә нокталар бар, сүзләрендә нөктә бар, Бу кешенең кем икәнен кем зирәк, тик шул табар.* М.Гафури.

2) Үткен мәгънәле, кинаяле, серле сүз

3) Кемгә дә булса күңелдәге үпкә, кер; хәтер калу. *Ата булган кешегә андыйлар өчен генә күңелдә нөктә сакларгa ярыймы соң!* Г.Бәширов. *Хуҗа Насретдиннең Хулиганга нинди нөктәсе бар икәнен сорадым.* А.Тимергалин

НӨКТӘЛЕ *с.* Нөктә белән әйтелгән, нөктәсе булган, мәгънәле. *Әбүгалисинага киная белән күп шелтәле сүзләр вә нөктәле гыйбарәтләр әйтте.* К.Насыйри. *Шәфкать туташы мондый тәкъдимнәрдән, кинаяле, нөктәле сөйләшүләрдән туйган бугай.* Т.Галиуллин

НӨМАИШ *и. фар. иск. к.* **нәмаеш**. *Зур шәһәргә керде зур шатлык төсе, Яңгырады шатлык, нөмаиш алкышы.* Ш.Бабич. *--- бик күп шәһәрләрдә «Бетсен һөҗүм, яшәсен солых!» лозунгысы астында гаскәрләр, матroслар, эшчеләрнең коралланган нөмаишләре булды.* Г.Исхакый

НӨРЕ *и. диал.* 1) Бал кортларының, бөҗәкләрнең бергә торган кортлары

2) Бер үк төрдәге бөҗәкләрнең берьюлы барлыкка килүе, чыгуы. *Кырыска нөресе*

3) *күч.* Бер гаиләдә чама белән бер үк яшьтәге балалар

НӨРЕ́ КОРТЫ *и. зоол.* Бал кортларына зыян китерә торган бөҗәк; бал корты бете

НӨРЕ́ КҮБӘЛӘГЕ *и. зоол. к.* **көньяшәр**

НӨРЛӘ́Ү *ф. диал.* 1) Берьюлы барлыкка килү (бөҗәкләр тур.)

2) *күч.* Берьюлы һәм тигез үсү. *Балалары нөрләп үсеп бара*

НӨСХӘ *и. гар.* 1) Бик күп бер иш (гадәттә язма) предметларның берсе; данә, экземпляр. *Альбомны һаман күреп булмый. --- Чыгу белән миңа --- өч нөсхә җибәрергә куш әле [Әхмәтгәрәй Хәсәнигә].* Г.Ибраһимов. *Игъланны тагын берничә нөсхә күчерткәннән соң, хәлфә, Чикерткәне ялгызын гына калдырып, үзе каланың базар мәйданнарына йөгерә-чаба китеп тә бара.* Ә.Еники. *Мәсәлән, район яисә берәр оешма башлыгы белән сөйләшеп, [язучы үзе] күпмедер нөсхәне шуларга сатарга тиеш иде.* Р.Зәйдулла

2) Күчермә, копия. *Ә Ибне Фадланның үз кулъязмасы әлегәчә табылмаган. Аның китабы безгә төрле күчермәләрдә генә килеп җиткән. Шул нөсхәләрнең берсендә без моңарчы «кеш» дип укыган сүз гарәпчә «үгез» дигәнгә туры килә.* Р.Фәхретдинов. *Әмма шартнамәнең бер нөсхәсен үзенә алды.* М.Хәбибуллин

НӨФҮС *и. гар. иск.* Бер өлкәдә, төбәктә яки өйдә билгеле бер вакыт аралыгында яшәүче җәмәгатьнең гомуми саны. *Яһүдиләр нөфүстә аз булып та нәрсәләр эшли?..* М.Гафури

НУ *ы. рус сөйл.* 1) Нәрсә дә булса эшли башларга өндәүне белдерә. *– Ну, егетләр, кызурак тотыгыз, бүген бетерергә кирәк, иртәгә калмасын, кич белән неводчылар килә, иртәгә невод салырга булыр, – диде [Исак].* Ш.Камал

2) Ис китү, гажәпләнү яки ризасызлык, канәгатьсезлек, ирония хисләрен белдерә. *[Талия:] Мөршидә апа, ну курыктылар, малай, тегеләр.* Р.Мөхсинова. *[Фәния:] Ну бу телеңне, Нурания.* К.Ситдыйков. *[Милиционер:] Ну шәп ясыйсың икән әйрәнне!* Э.Яһудин. *Ну бәхетле дә син, Сабир, нинди зур төзелешкә эләктең бит.* А.Алиш

3) Сорау җөмләнең башында килеп, берәр эш-хәлдән соң, киләчәктә нишләячәге турында сорауны белдерә. *Берничә тапкыр уңга-сулга әйләнгәләп яткач, ул [Фәридун абзый] хатынына гадәттәге сорауны бирде: – Ну, ничек яшибез соң, карчык, ә?* В.Юныс. *Галиулланың күзләренә карап, ул һич көтмәгән сорауны бирде: – Ну, Клавдия ничек соң, шәпме?* З.Зәйнуллин. *...Беркөнне Тәлгать аны кабинетына чакыртты. – Ну ничек? Күнегеп була-*

мы? – Була-а, – дип сузды Фәрит, кул сөрткән чүпрәген учында әвәли-әвәли. Ә.Дусайлы

4) Йомгак яки кереш ясауны белдерә. *[Гөлназ:] Кичә күрдем мин сезне... Энҗе белән... [Дильяр:] Ну әйе... Без Энҗе белән сирәк-мирәк очрашабыз!* Р.Сабыр. *Ну инде, ул көннәрдә мин кешеләр белән әллә исәнләштем, әллә юк...* М.Мәһдиев

НУГА *и. фр. кулин.* Куе шикәр сиробы яки балга йомырка агы һәм чикләвек (гадәттә фындык) оны кушып әзерләнә торган сузылучан татлы масса

НУГАЙ *и.* 1) Төньяк Кавказда – Дагстан, Чечня, Карачай-Чиркәс республикаларында, шулай ук Ставрополь, Әстерхан өлкәләрендә яшәүче төркы халык һәм шул халыкның бер кешесе. *Нугай юлы дип йөртелгән бу тирәне нугайлардан саклау өчен төзелгән шушы шәһәргә хан бер кешесен би итеп куйган.* Риваять. *Ул нугай мирзаларының барысын җыеп, рус йорты өстенә йөрергә теләгәнлеген аларга белдерде.* Һ.Атласи. *Безнең әдәби телебез шундый җылы көчкә хуҗа ки, ул барлык диалектларны алган: нугайлар, мишәрләр һәм себер татарларын ирекле рәвештә үзенә куша алган.* Х.Туфан

2) Урта Азия халкы телендә: татар. *Баштарак Төхфәт абзый казакълар белән бер сменада иде. Казакълар аңа атлаган саен «нугай» диләр. – Юк, мин нугай түгел, мин саф татар, – ди Төхфәт абзый, күкрәк сугып.* Ә.Еники. *[Белла:] Нигә сез миңа нугай дисез? [Жолдас:] Белмим. Борынгыдан ук бездә татарларны шулай атыйлар.* Р.Зәйдулла. *Бу сүзне ишеткән башкорт шәкерте: – Ә-ә, нугай ата, бәнем бәрәңге кабартмам калган ие, бирәемме-е... – дип аваз салгач, Хәләфнең йөзенә горурлык йөгерде.* Ф.Яхин

НУГАЙБӘК *и. к.* **нагайбәк**. *1920 нче елларга кадәр кайбер төбәкчелек исемнәренең (мишәр, типтәр, керәшен, бохарлы, нугайбәк, карагаш) сакланулары татарларда этник консолидациянең төгәлләнеп җитмәгәнлеге белән аңлатыла.* Д.Исхаков. *Нугайбәкләрнең башка керәшеннәрдән аермасы шунда гына: алар (араларында бәкләр, морзалар күп булганга мы?) казак сословиесендә булалар һәм Рәсәйнең яңа яулаган җирләрен күчмә халыклар һөҗүменнән саклыйлар, баш күтәргән җирле халыкны (мөселман динендәге кардәшләрен) бастыруда катнашалар.* Р.Зәйдулла. *Ни өчен татар халкында Нократ, Кыстым, Чепца буе, Касыйм, нугайбәк татарлары дигән бүленеш бар? Аларның бит һәркайсының үз тарихы бар.* Ф.Йосыпов

НУГА́Й КАМЧЫСЫ *и.* 1) Нагайка, каештан үрелгән кыска камчы

2) *диал. бот.* Оешмачәчәкләр семьялыгыннан чәнечкеле үләнчел үсемлек, шайтан таягы; *русчасы:* **чертополох**

НУГА́Й САБЫНЫ *и. бот. диал.* Сабын үләне, кыр сабыны, карпыч

НУГА́ЙЧА *рәв.* **1.** Нугай телендә. *Нугайча сөйләшү*

2. *с. мәгъ.* Нугай телендә булган. *Нугайча сүз*

3. *и. мәгъ.* Нугай теле. *Нугайчасы бик шома икән*

НУГЫТ *и. фар. бот.* 1) *к.* **ногыт**

2) *к.* **ногыт куагы**. *Анда, тау итәгендә, сөрергә дә, чабарга да ярамаган ташлы, чокырлы, нугыт, шилек, тубылгы чыбыклы тигезсез урыннар бар.* Г.Ибраһимов

◊ **Нугыт карау** *к.* **ногыт салу**. *Аю бүреләргә әйткән: – Сез утырыгыз, мин нугыт карыйм, – дигән.* Әкият

НУДИЗМ *и. фр.* Нигезендә ялангач тән культы яткан хәрәкәт

НУДИСТ *и. фр.* Нудизм тарафдары, нудизм хәрәкәтен яклаучы кеше. *5 июль көнне 50 нудист бер самолётта Балтыйк диңгезендәге утрауга оча алачак.* Татарстан яшьләре. *Нудистлар пляжы*

НУЖА *и. рус* 1) Яшәү өчен иң кирәкле нәрсәләрнең җитешмәве, юк дәрәҗәсендә булуы, мохтаҗлык; ярлылык, фәкыйрьлек. *Нужа юкны таптыра, барны саттыра.* Мәкаль. *Нужа печән ашата.* Мәкаль. *Кайсын – ханы, Кайсын – бояры, Кайсын нужа асып үтергән.* Х.Туфан

2) Мәшәкать, авырлык, кыенлык, читен хәл. *Яшь чактагы нужалар уйнап-көлеп узалар, карт чактагы нужалар елап-сыктап узалар.* Мәкаль. *Тормышта бик сирәк зарлана торган әнисенең бөтенләй чит-ят кешегә, җитмәсә пыялачыга, үз нужасын сөйләвен ишетеп үртәлгән һади бер читкәрәк китте.* А.Гыйләҗев. *[Кара Гобәй:] Я, еламагыз, балалар! Хәзер инде, сугыш башлангач, нужа белән михнәткә чыдагыз гына.* З.Зәйнуллин

◊ **Нужа әчесен эчү** *к.* **нужа чигү**. *Рәшидә үзе дә – андый җиңел тормышка өйрәнмәгән, нужа әчесен шактый күп эчкән хатын...* Ә.Еники. **Нужа бабай** Кыенлык, мохтаҗлык. *Җыен йолкыш зимагурлар --- Бүген нужа бабаларын танымаска булганнар.* Н.Исәнбәт. *Нужа бабай җилкәмнән төшмәде.* Н.Гыйматдинова. **Нужа йөген тарту** *к.* **нужа чигү**. *Ләкин күбрәк истә Җәберләрдән мине саклавың, Нужа йөген үзең тартуларың.* Ш.Маннапов. **Нужа калачы ашау** Кыенлык кичерү, авырлык күрү. **Нужа камыты** Мохтаҗлык, кыенлык, мәшәкать. *Аның нужа камытын үзәргә омтылышы, бәхет кошы турындагы сагышы телдән-телгә күчеп, нәсел-нәсәбен, оныкларын җилкендереп килгән.* А.Гыйләҗев. *Әнә бит, кичә генә давылланып күтәрелгән крестьяннар һәм завод-фабрика эшчеләре яңадан тәртә арасына керделәр дә, нужа камытын киеп, сыртларында уйнаган чыбыркыга илтифат итмичә, күндәм генә йөк тарта башладылар.* И.Нуруллин. **Нужа куу** *к.* **нужа чигү**. *Кешеләр ашыйлар-эчәләр, яталар-йоклыйлар, көн дә торып нужа куалар, ә бәхетләме алар, яратышу дигән нәрсә бармы алар өчен – моны һич сизеп булмый иде.* Ә.Еники. *Шулай итеп, яшьтән нужа куып, тормышның ачысын-төчесен күреп үскән Шәйдулла агайга Шәрәфнең әлеге хыялы беркадәр сәеррәк күренде.* Г.Минский. *Авыл ире, нужа куып, яратырга өлгерми дә.* Н.Гыйматдинова. **Нужа күрү** *к.* **нужа чигү**. *Бер дә генә нужа күрмәенчә, Ир була алмый ата баласы.* Җыр. *«Күпме азап чиктек җир өчен без, Әзме нужа күргән кеше без...»* Х.Туфан. *Тагын берәр ай чамасы шул солдатлар белән окоп нужасын күрсәң, күп нәрсәне аңларсың...* З.Зәйнуллин. **Нужа тырнагыннан ычкыну** Мохтаҗлыктан

чыгу, мәшәкатьләр бетү; ачлыктан котылу. *Сугыштан соң да әле ул, нужа тырнагыннан тиз генә ычкына алмыйча, авылдан авылга, сукыр музыкантларны җитәкләп, тамак хакына концертлар куеп йөрергә мәҗбүр була.* Ә.Еники. **Нужа чигү** Төрле авырлыклар, мохтаҗлыклар күрү, төрле кыенлыклар кичерү. *Ул болай да бик яхшы аңлый, минем белән байтак юллар үткән, шактый нужа чиккән иптәш ул.* А.Гыйләҗев. *Байгильдеев үзе ятимлек белән, нужа чигеп үсте* ---. М.Мәһдиев. *[Насыйбулла:] Мин әле хет, нужа чигә-чигә булса да, дөнья күреп кайттым, ә ул бит авыл көтүлегеннән ерак киткән кеше түгел!* Р.Сабыр. **Нужадан чыкмау** Өзлексез мохтаҗлыклар кичерү, авырлыклар күрү, авыр тормышта яшәү. *Чыгыйк, дисәк, нужадан – Узып булмый хуҗадан. Малыбызга хуҗа булсак, Чыгар идек нужадан.* М.Саттаров

НУЖАЛАНУ *ф. к.* **нужа чигү**. *Әни нидер мыгыр-мыгыр килә, янә әтинең тавышы ишетелеп китә: «Ул зур кеше булырга тиеш, шул чакта гына безнең шикелле нужаланмас».* Р.Зәйдулла

Нужаланып алу Бер вакыт аралыгында нужалану

НУЖАЛЫ *с.* **1.** Мәшәкатьле, авыр, кыен; мохтаҗлыкта үткән. *Бу аваз әйтерсең лә ат җене кагылган, кырдагы төнге учакка гашыйк, бер генә дә юньле көн күрмәгән, нужалы, авыр эшләп гомер кичергән Сәләхетдин Учакның авылдашларына, таза гәүдәсеннән калган кисәкләрен җыйнап җирләргә әзерләүләренә рәхмәтен белдерүе иде.* З.Зәйнуллин. *Андый нужалы тормыш сезнең төшкә дә керми.* Татарстан яшьләре

2. *и. мәгъ.* 1) Авыр, кыен шартларда берәр нәрсә эшләргә мәҗбүр булган кеше. *Шундый буранда юлга чыкканнар, нужалылар!*

2) *күч. диал.* Буш эш белән йөрүче, юк эшне бар итеп йөргән кеше. *И, нужалы, йөри шунда эшем бетереп!*

НУЖАРУ *ф. к.* **нужа чигү**. *Шул үгезләр белән нужаралар.* Х.Камалов. *Нужара идек ягулык эзләп, тирә-якның урманын кисеп бетерә яздык, хәзер рәхәтләнәбез.* А.Гыйләҗев

НУКЛЕИН *и. фр. хим.* Составына нуклеин кислотасы һәм аксым кергән катлаулы органик кушылма. *Нуклеин кислоталары – табигый полимерлар алар. Аларны XIX гасырда ук инде күзәнәк төшләрендә (латинча nucleus – төш) табалар, ләкин нуклеин кислоталарының организм тереклегендәге роле галимнәргә озак вакытлар буена билгеле булмый.* Органик химия

НУКТА *и.* Авызлыксыз йөгән (ат, бозау һ.б.ш.ны бәйләп, арканлап кую өчен). *Нукта киертеп алып чыга да сикереп атлана өстенә [диюнең].* Әкият. *Тотылган җылкы Карлыгач-Сылуга дигән ала айгыр иде. Хәзер бишенче яшьтә булып, әле гомерендә нукта орылмаган, адәм кулы тимәгән иде.* Г.Ибраһимов. *Син, энекәш, ике атның да нукталарыннан тот.* А.Гыйләҗев

НУКТАЛА́У *ф.* Нукта кидерү. *Бирсәң аңа [бай баласына] бер рисалә, укый алмый туктала, Ишәктән ишәк туадыр, хәзер тот та нуктала!* Ш.Мөхәммәдев. *– Мине ике адым уза алсаң, туры атымны үзем нукталап кулыңа тоттырам! – дип, зур йодрыгы белән тәгәрмәчкә шундый каты сукты* ---. Г.Ибраһимов. *Уянган карчыклар, кыз-киленнәр, Кайсы ат я дөя нукталый.* З.Ярмәки

Нукталап алу Тиз арада нукталау. *Малкайны нукталап алып, салып бәсәргән авызлык, алып чыкты ишегалдына* ---. Р.Харис

Нукталап кую Нукта кидерү

НУКТАЛЫ *с.* Нуктасы булган, нукта кидерелгән. *Укталы да чукталы, Муены яшел нукталы, Түбәсендә тарагы, Койрыгында урагы, Тәпиендә сәнәге, Шул ни булыр, я әле?* Табышмак. *Син булсаң да нукталы, Бик мактанма, туктале.* Г.Тукай

НУЛЕНЧЕ *сан* Рәт, тәртип белән санаганда нуль урынында килә торган. *Хәзерге вакытта географик озынлык координатасын Гринвич меридианыннан башлап исәплиләр, ягъни ул нуленче меридиан дип кабул ителгән.* А.Тимергалин. *Киңлекләрне экватордан саный башлыйлар, экваторның барлык ноктaлары да – нуленче киңлектә.* Башлангыч география курсы. *Нуленче километр. Нуленче пациент*

НУЛЬ *и. лат. к.* **ноль**. *Бары тик нульгә тапкырланган хәлдә теләсә нинди зур сан да нульгә әверелә...* А.Хәлим. *Сан категориясенең берлек төре һәрвакыт нуль формасы була, берлекнең үзенә аерым формативы юк.* В.Хангилдин. *Утызга кадәр шуларга ирешә алмаган ир – нуль.* А.Гыйләҗев

◊ **Нульдән башлау** Алдан әзерләнмичә, бернәрсәсез ниндидер эшкә керешү. **Нульгә бәрабәр** *к.* **нульгә тигез**. *Үйлап карагыз әле: әүвәлге шәхес буларак сезнең юридик хокукларыгыз нульгә бәрабәр, ә дөреслекне эзли башласагыз, үзегезне исән итеп тануы өчен, сезгә ике-өч ел кирәк...* А.Тимергалин. **Нульгә тигез** Файдасыз, буш. *Менә шуңа күрә вузларга үтеп кергән мондый «татар» балаларыннан татар милләте өчен файда нульгә тигез булды, әнә шулар инде татар егетенә кияүгә чыгуны, татар кызына өйләнүне түбәнлек дип карый башладылар.* Ә.Кәримуллин. **Нульгә тигезләнү** Бөтенләй бетү, юкка чыгу. *Чит ил капиталистлары кулына күчми торып, аларның исән калу ихтималы нульгә тигезләнде.* Ә.Дусайлы. **Нуль-нуль** *к.* **ноль-ноль**. *Менә сезгә язу, менә сезгә тере кеше, нәтиҗәсен белергә нуль-нуль унсигез сәгатьтә керермен.* Г.Ахунов

НУМЕРАТИВ I *с.* Нумерация, номерлама белән бәйле. *Нумератив сүзләр. Онимнарның нумератив компоненты. Нумератив суффикс*

НУМЕРАТИВ II *и. лат.* Санау өчен хезмәт итә торган сүз төркеме. *Нумеративлар системасы*

НУМЕРА́ТОР *и. лат. махс.* 1) Документларга тәртип номеры суга торган аппарат

2) Электр звоногы янында шалтырауның кайсы номердан килгәнен күрсәтә торган җайланма

НУМЕРА́ЦИЯ *и. лат. махс.* 1) Эзлекле тәртиптә урнаштырылган предметларны цифрлар белән билгеләү, тәртип саны куеп чыгу эше; номерлау

2) Шул номерларның үзләре. *Ул башта 1 нче мәктәп булып йөри,*

ә 1940 елда башкалабыздагы мәктәпләрнең нумерациясе үзгәртелә, һәм ул Ш.Камал исемендәге 80 нче мәктәпкә әйләнә. Мәдәни җомга

НУМЕРА́ЦИЯЛӘҮ *ф.* Номер сугу, тәртип саны кую, номерлау

Нумерацияләп тору 1) Хәзерге моментта нумерацияләү

2) Гел нумерацияләү

Нумерацияләп чыгу Барысын да, баштан ахырына кадәр нумерацияләү

НУМИЗМАТ *и. лат.* Нумизматика (*1 мәгъ.*) белгече; нумизматика (*2 мәгъ.*) белән шөгыльләнүче кеше. *Чын сенсациягә әверелгән чех акчасын Мәскәү һәм Петербург нумизматларыннан соң Прагадан доктор Ярмила Һаскова җентекләп өйрәнде һәм аны, кенәз Вацлав тарафыннан 929/930 елда сугылган, әлегә кадәр дөньяда бердәнбер чех денарие, дип бәяләде.* Ф.Хуҗин. *Кем соң ул Андрей Лихачёв? Археолог, тарихчы, нумизмат, диләр музей хезмәткәрләре.* Ватаным Татарстан

НУМИЗМА́ТИК *с.* Нумизматика фәненә һәм шулай ук борынгы акчалар һәм медальләр җыюга, коллекцияләүгә караган. *Нумизматик материаллар. Нумизматик аукцион*

НУМИЗМА́ТИКА *и. лат.* 1) Борынгы тәңкәләрнең, медальләрнең тарихын, сугылуын, тәңкә акчаларның әйләнешен өйрәнә торган фән тармагы. *Археологик эзләнүләр нәтиҗәсендә табылган керамика, алтын-көмештән коелган бизәнү әйберләре, эш һәм сугыш кораллары, тимер һәм бакырдан ясалган йорт кирәк-яраклары, әле җитмәсә – металл кою һәм чүлмәк ясау остаханәләре, торак йортлар, эпиграфика (ташка язу һөнәре), нумизматика әнә шул хакта сөйли.* Р.Фәхретдинов. *Бәлки, моңа кызыксыну өлкәсенең киңлеге дә сәбәпче булгандыр, чөнки 40 мең тарихи әйбернең 15 меңе археология, этнография, тарихи-көнкүреш өлкәләренә караса, 24 меңләбе – нумизматика өлкәсеннән.* Ватаным Татарстан

2) Борынгы акча тәңкәләрен һәм медальләрне җыю, коллекцияләү. *[Безнең Гайшә Хәлиловна] һәр ялын диярлек чит илләрдә сәяхәттә уздыра, нумизматика, филателия белән кызыксына, кино-фото белән мавыга.* А.Гыйләҗев. *Нумизматика белән шөгыльләнү*

НУР *и. гар.* 1) Нинди дә булса яктылык чыганагыннан сузылган яки ялтырап торган предметтан чагылган яктылык сызыгы. *Елга аръягындагы чыршы-нарат ларның киртләч башларын беренче кояш нурлары яктыртканда, кунаклар китәргә җыена башладылар.* М.Хәсәнов. *Түбәләләрдән беренче тамчылар, нурлар чагылдырып, ак мамыктай күперенгән кар өстенә тамалар.* Ә.Еники. *Нур пиксель челтәренең бөтен юлларын йөгереп чыга (сканерлый).* Санак графикасы

2) Яктылык. *Шәмнең нуры үз төбенә төшми.* Мәкаль. *Аннан [керосин лампасыннан] өйгә гөлт итеп нур тула.* М.Мәһдиев. *Йортның мәчет ягы тәрәзәләреннән таң нуры өй эченә кыюсыз гына үрелә башлаган, казна буйларында күләгә ята иде.* Г.Ахунов

3) *күч.* Берәр нәрсәнең тиз арада, көтелмәгәндә күренеп китүе, чаткысы. *Искә төшерик: 1905 ел инкыйлабыннан соң, патша режимы халыкта өмет нуры, киләчәккә ышаныч чаткылары кабызган сәяси, шәхси, иҗат иреге бирергә мәҗбүр була.* Н.Акмал. *Гомернең дә ниндиен өстәде диген әле – мәхәббәт нуры белән яктыртылганын, гыйшык уты белән җылытылганын.* А.Гыйләҗев. *Бу күзләрдән балкыган сөю нурын сизенми-күрми һич мөмкин түгел иде.* Ф.Яхин

4) *күч.* Ачыклык, мөлаемлык, җылылык (күздә, йөздә). *Йөзендә шәфкать нуры балкыган әнә теге мулла ярдәм итәр, бәлкем?* М.Галәү. *Картлыктан нурлары беткән күзләрен яшьләндереп, тешсез авызларын ачып, Ташлытау юлына карап торалар.* М.Мәһдиев. *Көтә-көтә, күзендә нур сүнеп, өмете киселде.* Н.Гыйматдинова

5) *физ. күпл.* Кисәкчекләр яки электромагнитик тирбәнешләр агымы. *– Синдә рак түгел, – дидем, – шулай да рентген нурларына күренәсең калган.* Г.Кутуй. *Лазер нурлары*

◊ **Нур галә нур** *иск. к.* **нур өстенә нур**. *Садыйк хәзрәт Одессага мәхәллә имамы итеп тәгъйин кылынган. Гаскәри имам булып та тәгъйин кылына икән, бик яхшы, нур галә нур.* Г.Исхакый. **Нур качу** Төссезләнү, тоныкланы; яме китү. *Рухия шундук искәрде: бүлмә буйлап йөргәндә дә сөрлегә язып, сөрлегә язып йөри торган бу бик бетәшкән җан иясенең йөзеннән нур качкан иде.* Г.Гыйльманов. *Сәүдә берләшмәсенә җитәрәк, бөкре кыз кинәт туктады, йөзен кара болыт баскан сыман булды, күзләреннән нур качты.* М.Шаһимәрдәнов. **Нур китү** *к.* **нур качу**. *Балалы өйдән нур китмәс.* Әйтем. **Нур өстенә нур** Берәр уңай нәрсәгә, уңай күренешкә икенче бер уңай нәрсә, уңай күренеш өстәлү турында. *Офык читендә, нур өстенә нур булып, хыялый бер сарай сыман Зәңгәр кыя күтәрелгән.* Г.Әпсәләмов. *Үз урыныңа лаеклы бала калдыру нур өстенә нур була.* А.Гыйләҗев. *Шул ук вакытта Пермь татарларының, шушы зур татар тарихы эчендә, үз җирле тарихлары, милли каһарманнары, халык авыз иҗаты, үз җирле сөйләшләре дә бар. Бу – нур өстенә нур булып тора торган хәл.* Ф.Бәйрәмова. **Нур сибү** 1) Төрле якка нур тарату, чыгару; 2) Яктыру, агару, җанлану. **Нур уйнау** Ачык күңелле, якты йөзле, көләч, шат булу турында. *Пензятканың кызларының Битләрендә нур уйный.* Җыр. *Һәр кешенең дә йөзендә Гел шатлык нуры уйнасын.* М.Гобәйдуллин. *Кояш күл өстендә ничек ялтыраса, аның да күзләрендә шундый нурлар уйный иде.* Ф.Яхин. **Нур чәчү** *к.* **нур сибү**. *Аш ашамас, Кара су эчәр, Дөньяда кош кебек очар, Күңелләргә нур чәчәр.* Табышмак. *Шәкертнең соңгы сүзләреннән соң кызның йөзе, яңгырдан соң чыккан кояш төсле, тирә-юнәнә нурларын чәчеп алды.* К.Тинчурин. *Бу кояшлар гадәттәге кояш кебек балкып нур чәчми, бик сүрән кызарып кына торалар.* И.Салахов

НУ́Р АВЫРУЫ *и.* Радиоактив нурланыш алган кешедә була торган чир. *Нур авыруы әле бүген дә, байтак еллар уткәч тә, корбаннарын чүпләп тора...* А.Тимергалин

НУРАНИ *с. гар. иск. кит.* Нурлы, якты, ялтыравыклы. *Әбүгалисина әйләнеп карады, күрде: бер пире нурани*

вә газиз руханидыр. К.Насыйри. *Курса хәзрәт – нураниның сирәге, Хак ислам-га яңа капка ачучы.* С.Әхмәтҗанова

НУРЛАНДЫРУ *ф.* 1) Кемне яки нәрсәне дә булса яктырту, нурга күмү

2) *күч.* Мөлаемландыру, матурлык, ямь, нур өстәү (йөзгә). *Гәүһәрия күзләрен нурландырып аңа [Гәрәйгә] талпынды.* А.Гыйләҗев. *Ул синең барлыгыңнан бирле күңел түреңдә тәхет корып, шул сараеңны нурландырып утыра.* Ф.Яхин

3) *күч.* Илһам, дәрт, көч бирү. *Бел: гыйлем – нур ул, сине нурландырыр, ә наданлык – ут, сине ул яндырыр.* Г.Утыз Имәни. *Синең шундый җылы күз карашың Нурландырды боек җанымны.* Х.Туфан. *Иман гына нурландыра Күңел галәмен.* Г.Садә

Нурландыра төшү Тагын да бераз нурландыру

Нурландырып алу Бик тиз вакыт эчендә нурландыру

Нурландырып җибәрү Көтмәгәндә нурландыру. *Ул [Диләрә] яулыкны башына каплады, һәм чибәр яулык чынлап та аны бердән нурландырып җибәргәндәй итте.* Ә.Еники

Нурландырып тору Гел, һәрвакыт, даими рәвештә нурландыру

НУРЛАНУ *ф.* 1) Нур чыгару, нур чәчү, яктырту

2) Нурларны үзенә йоту, нурларга туену

3) *күч.* Җанлану, мөлаемлану, яктыру (күз, йөз). *И гомернең нурланып үскән яшел яфрак чагы!* Г.Тукай. *Кыз, бөтенләй шатланып, йөзе, күзе балаларча саф шатлык белән нурланды.* Г.Ибраһимов. *Тавышы аның тигез, бәхете дә тигез, кызының әтисе соң булса да кайтып җиткәнгә, йөрәк түрендәге рәнҗеш инде югалган, чыраена алсулык чыккан, күзләре дөньяга нурланып карыйлар иде.* Г.Ахунов

Нурлана бару Торган саен нурлану. *Үзе елмая, күзләре челт-челт йомылып тора, йөзе нурланганнан-нурлана бара.* Ф.Баттал

Нурлана төшү Элеккегә караганда тагын да бераз нурлану

Нурланып алу Бик азга гына нурлану

Нурланып китү Соңгы вакытта, хәзер нурлану. *Карчыкның күзләре нурланып китә.* М.Мәһдиев. *Күңелем нурланып китте. Хәтта сызгыргалап та куйдым.* Ф.Яхин. *Сөйгәнеңне таба алсаң әгәр, Тормышлар да китә нурланып.* М.Гобәйдуллин

Нурланып тору Гел, даими рәвештә нурлану; якты хәлдә булу. *Кояш диңгезгә әле яңа гына батып өлгергән, бөтен офык буе, төньяк балкышы кебек, яп-якты нурланып тора.* Ә.Еники. *Җанлы бер букет шикелле Нурланып торсын табын.* Х.Туфан. *Сыйныф нурланып тора, такта һәм өстәлләр ялтырый. Иң әһәмиятлесе – бөтен җирдә чәчәкләр.* Ф.Яхин

НУРЛАНЫШ *и.* Нурлы энергия чыгу, нурлы энергия таралышы. *Мин быелга икенче темага – радиоактив нурланыш тәэсирен өйрәнүгә керештем.* А.Тимергалин. *--- кешеләрнең күпчелеге шул вакытта ук нурланыш авыруы ала.* Ф.Бәйрәмова. *Галимнәр тикшеренүеннән күренгәнчә, кактус нурланышны кире кайтара торган махсус җайланманы хәтерләтә.* Мәгариф

НУРЛА́У *ф.* 1) Яктырту, нурга күмү. *Офыкларны нурлап балкып киткән Салават күпере күк бу гомер.* Д.Булгакова

2) *күч.* Берәр кешене яки әйберне ямьләү, матурлау, бизәү. *Төш кебек күңлемне нурлый Изге гыйшкың яктысы.* С.Сүнчәләй. *Ирен чите белән елмайса да Нурлый ала Җирне хатын-кыз.* Н.Акмал. *Яшәеш никадәр генә авыр, катлаулы булмасын, аны нурлый, ямьләндерә, мәгънәләндерә торган бер сыйфат бар.* Х.Миңнегулов

Нурлый бирү Бернигә дә карамастан нурлау

Нурлап җибәрү Көтмәгәндә нурлау, нурга күмү

Нурлап тору Гел, һәрвакыт, даими рәвештә нурга күмү; бизәп тору. *Үзенчәлекле Көнчыгыш архитектурасы булган бу бина төньяк башкаланы бизәп, нурлап тора.* Нур

НУРЛЫ *с.* 1) Нур чәчеп торган, нурга күмелгән, якты. *Әле генә шундый якты, шундый нурлы сыман булып тоелган өй эче караңгыланып, кысанланып калды.* Н.Фәттах. *Ул ачык ишекнең яңагына килеп тотынды, өйалдының тәрәзәсе юк, көндез дә күз бәйләнә, шуңамы, өй эче тагын да яктырак, тагын да нурлырак булып күренде.* А.Гыйләҗев. *Синдә бит изге бабамнар яткан урын, синең өчен атам каны тамган, синдә минем әнкәй дип әйткән иң беренче кадерле сүзләрем һәм ул – җир йөзендәге иң нурлы кояшның бөеклеге, миңа балам дип әйтүче анам, кырларым, тугайларым, синдә – сөйгән ярым!* Ф.Яхин

2) *күч.* Шатлыклы, бәхетле. *Мәзлумнарга якты, нурлы көннәр килде, – Азатлыкның кояшы тугды имди.* Г.Тукай. *Өй эчендә нурлы тынлык...* Ә.Еники. *Тормыш нурлы, тормыш матур, Якты булсын күңелләр.* Н.Яппарова

3) *күч.* Ягымлы, матур, көләч (йөз, күз һ.б.). *Кунак җәгәте Сылуның нәфис, кечкенә, йомшак кулларын җибәрмичә бераз кысып, ләкин нурлы кара күзләрен аңардан алмыйча [сәлам бирде].* Г.Ибраһимов. *Аннары Таңнур белән ниләр булганын, егетне алда ниләр көтәчәген нурлы йөзле председательгә түкмичәчми сөйләп бирде.* М.Шаһимәрдәнов. *Каушап калган нурлы йөзләреңә Ак яулыгы бигрәк килешә.* Р.Хәлилова

НУРЛЫЛЫК *и.* Нурлы булу. *Газеталарда да кирәкмәгән мәгълүмат тулып ята, ә кирәген, халыкка файдалысын бастыру дигән нәрсә юк, төтен җибәрү, гомум сүзне төрле яклап әйләндерү генә: һәммәсе матур, һәммәсе ал да гөл, ул яктылык, ул нурлылык, ул өметлелек!* М.Гайнетдинов. *Сандугачтан моң алгансың. Чәчәкләрдән – матурлык, Язның алсу кояшыннан – Балкып торган нурлылык.* Т.Шәрипова. *Ул җылылык – газ өстендә сызгырырга көч туплап утыручы чәйнек, тәрәзә төбен тутырып кояшка елмаючы гөлләр, өйнең дивар-ларына кадәр сеңгән нурлылык, гадилек кенә була ала.* Шәһри Казан

НУРСЫЗ *с.* 1) Караңгы, күңелсез. *Ай исә тулып килгән чакларында күренә, ләкин ул шундый нурсыз, шундый төссез була: аңа берәү дә күтәрелеп карамый.* Г.Әпсәләмов

2) *күч.* Нуры (*4 мәгъ.*) сүнгән, ялтыраусыз, җансыз, бернинди дә хис белдерми торган. *Сабира ябык, газаплы*

җыерчыклар белән капланган карт битен күтәрде, эчкә баткан нурсыз күзләре белән киленә карады. Г.Ибраһимов. *Күз карашы аның нурсыз, котсыз һәм комсыз иде.* Н.Фәттах

3) *күч.* Бәхете, шатлыгы булмаган, куанычсыз. *Синсез – нурсыз көнем, Аййолдызсыз төнем, Сөю-назлар көтеп үтә гомерем.* Р.Чурагул. *Хәдичә ападан соң өйнең эче дә нурсыз калган кебек булды.* Ф.Яхин

НУРСЫЗЛАНУ *ф.* 1) Нурын (*4 мәгъ.*) югалту, сүнү. *Аның күзләре шундый нурсызланган, йөзе шундый усал – котыңны алып, йөрәкне ярырлык иде.* В.Нуруллин

2) Төссезләнү, нур (*3 мәгъ.*) чәчми башлау

Нурсызлана башлау *к.* **нурсызланып китү**

Нурсызлана төшү Элеккедән дә ныграк нурсызлану

Нурсызланып калу Берәр вакыйгадан соң нурсызлану. *Күзләре нурсызланып, ничектер тоныкланып калган.* М.Хәсәнов. *Гаҗиз кыяфәттә эскәмиядә яткан гөлләмәне кулына алып, чәчәкләргә карады – бая гына җете купшы кыяфәттә балкыган гөлләр патшасы нишләптер тоныкланып, төсен җуйгандай нурсызланып калган иде.* А. Әхмәтгалиева

Нурсызланып китү Соңгы вакытта нурсызлану

НУРСЫЗЛЫК *и.* Җансызлык, рухсызлык, дәртсезлек, төссезлек. *Әнисенең хәле авырлыгын ул менә хәзер генә ныклап тойды, ананың күзләрендә ниндидер нурсызлык, өметсезлек иде.* Х.Камалов

НУ́РСЫМАН *с.* Нур кебек, нурны (*1 мәгъ.*) хәтерләтә торган. *Әгәр шампиньон яки баллы гөмбәнең өлгергән эшләпәсен сабыннан кисеп алып, кәгазь өстенә салсаң һәм чынаяк белән ябып куйсаң, берничә сәгатьтән соң коелып төшкән спораларның нурсыман эзе кала.* Ашарга яраклы һәм агулы гөмбәләр

НУ́ТРИЯ *и. исп. зоол.* Кимерүчеләр отрядыннан көрән төстәге кыйммәтле мехы өчен фермаларда үрчетелә торган Көньяк Америка имезүче җир-су җәнлеге, саз кондызы; шул җәнлекнең мехы. *Уң як күршем Миңнулла керпе тота. --- Тимерханнарда – кәлтә елан, Әхмәдиләрдә – ташбака, Гомәрләрнең подвалларында – нутрия, Зөһрәләрдә – йорт куяны...* Р.Сәлим. *Бервакыт саз кондызы (нутрия) һәм ак төлке үрчетү белән шөгыльләндем.* Н.Шаминов. *Әйтик, кайдадыр абзар тутырып дуңгыз асрыйлар, кем – нәселле куян, кемдер нутрия үрчетә...* Ватаным Татарстан

НУХ *и. гар.* Коръәндә исеме телгә алынган, туфан вакыйгасы белән танылган пәйгамбәрнең исеме. *Бөтен кеше Нух галәйһиссәламнең шул өч улыннан тарала.* Г.Исхакый. *Эш эшләнгән, сүз әйтелгән, инде дөньяны су басса да, миндәй үрдәккә Нух көймәсе кирәк булмаячак иде.* Ф.Яхин. *Мәчетне әйләндергән дивар көймәне хәтерләтәчәк, монысына архитекторны Нух пәйгамбәр көймәсе илһамландырган.* Шәһри Казан

◊ **Нух заманы** Борын заман, бик күптәнге, әллә кайчангы заман. **Нух пәйгамбәр заманы** *к.* **Нух заманы.** *Әнә шул хәл әсәр сюжетының агышына бик тә үзенчәлекле бизәк, дөресрәге, нур өсти. Мәсәлән, студент Рәшитнең әлеге фәрештәдәй кыз белән «Нух пәйгамбәр заманында салынган клуб»та танышуын сурәтләгәндә.* Ф.Урманче. *Рәис түземен җуеп, йодрыгы белән сандыкка сукты, Нух пәйгамбәр заманыннан бирле җыелып килгән тузан, болыт булып күтәрелеп, үтүкләп кигән кәчтүменә кунды.* Р.Батулла

НЫГАЮ *ф. сир. к.* **ныгу**. *[Галия:] Никадәр кыссаңыз да, --- ул тиреслəр (тискәрелекләр) яшь тормышның тазаруына гына сәбәп булалар, яңы тормышның ныгаюына гына сәбәп булалар.* Г.Исхакый

Ныгая бару *к.* **ныгый бару**. *Безнең бүгенге масса телендә басымнар (удареңиелəр) ныгая бара.* Х.Туфан

НЫГУ *ф.* 1) Ныкка, чыдамлыга әйләнү, чыныгу. *Кыз йон юып ныгыган гәүдәсен бер талпыну белән аның кочагыннан коткарып, берничә адым читкә китте.* К.Тинчурин. *Атна кичендә, чана юллары ныгыгач, авылдан унбиш чакрым ераклыктагы пристаньгә ат чаптырды [Фагыйлә абыстай].* Ф.Яхин

2) Сәламәтләнү, савыгу, яңадан көч керү, хәл җыю

3) Көч, энергия керү, үсеп җитү. *Тәненә күзәнәкләр үстерә [адәм баласы], мускулы, сөяге ныгый, чәче калына.* М.Мәһдиев. *Аның каты, көләч шигъре саен сеңерләрем ныгый иделәр.* Х.Туфан. *Малайлар үсеп, ныгып, иңнәре киңәеп, егетләнеп, авылга каникулга кайттылар.* А.Гыйләҗев

4) Куәтләнү, көчәю. *Колхозлар «кызамык авыруын» уздырып ныгыдылар, авыл тулы ирләр – сытып эшләүче юк.* М.Мәһдиев

5) Көчәя төшү, көче, интенсивлыгы арту (җил, тавыш һ.б. тур.). *Балаң милли мәктәптә ныгысын, --- куркыныч агымнарга иярмәсен дисәң, --- ярты ел гына кайбер читенлекләргә түзәргә туры киләчәк.* Б.Рәхимова. *[Зәй-Каратай кешеләре] Кар төшеп суыклар ныгыгач килен алганнар, кызларын биргәннәр.* З.Зәйнуллин

6) Үзгәрмәслек булып, нык булып урнашу, катгыйлашу (карар, уй һ.б. тур.). *Әмма шуның белән бергә үк, реакциягә каршы көрәштә аның [Тукайның] демократия идеалларына булган ышанычы сыналды, үсте һәм ныгыды.* Г.Халит. *Димәк, авылда мондый бәя таралып та, ныгып та өлгергән икән.* А.Гыйләҗев

Ныгый бару Торган саен ныгу. *Ел артыннан ел узган, казакъларга хас яшәеш рәвеше урнаша, ныгый барган.* И.Нуруллин. *Һәркем һәр көн үзенең җиренә барып төшкән саен, арышның саламга озынлыгын, башакка туклыгын, көлтәнең күп чыгуын, чүмәләләрнең ешлыгын, зурлыгын күреп, бу өметләр дә, бу уйлар да ныгый бара.* Г.Ибраһимов. *Безнең җиңү Ныгый барган саен, Иске семья бер-бер сүтелер.* Х.Туфан

Ныгый башлау Ныгуы сизелү, ныклыгы артуга бару

Ныгый төшү Тагын да бераз ныгу. *Хакыйкать безнең якта икән, дигән ышану куылучылар арасында ныгый төште.* К.Тинчурин. *Шулай булгач, алар арасындагы борыннан ук килгән дуслык-туганлык тагы да ныгый төшәргә тиеш иде.* Ә.Еники.

Соңыннан, гыйлем якларыбыз ныгый төшкәч, Паузаны тора салып сәхнәгә чыгармый башлаганнан соң да әле, халык: «Нигә Пауза юк? Паузаны нишләп катнаштырмыйсыз? Әллә чирлиме?» – дип теңкәгә тиде. А.Тимергалин

Ныгып бетү Тәмам ныгу. *Үзе дә чак үлми калды, шуның авыруыннан соң ныгып, терелеп бетмәгән иде әле.* Г.Ибраһимов

Ныгып җитү Тәмам ныгу; нык хәлгә килү. *Әллә буын яшькә күкрәк юка, әллә куллар ныгып җитмәгән.* Ш.Маннур. *– Үлде, бетте, юк инде ул! – дигән уй аңыбызда һаман әле ныгып җитә алмый...* Ә.Еники. *Алай гына түгел икән ул, сөякләр ныгып җитмәсә, тәнгә көч керми.* Ф.Яхин

Ныгып калу Озакка ныгу; ниндидер вакыйгадан соң ныгу. *Ак әбиләр күрсәткән могҗизадан соң безнең – балаларның да күңелләре ныгып калды.* Ф.Яхин. *Әлтафи егерме сигезенче елгы, аның, әлбәттә, сугыш башланганчы ук мускуллары ныгып калган.* М.Мәһдиев

Ныгып килү Ныгуга таба бару. *Сукыр булгандыр шул Вәзиләнең мәхәббәте: Язкилдедә Сәкинә шытып калкынганын да күрмәгән, Зөфәр ныгып килгәнне дә абайламаган.* А.Гыйләҗев

Ныгып китү Соңгы вакытларда ныгу. *Күпчелек очракта руханилар арасыннан чыксалар да, халыкка якын торган яшь интеллигенция исә крестьяннар, һөнәрчеләр, приказчиклар, шәкертләр мәнфәгатен яклап көрәшкә ташланды һәм революцион-демократик агымның туып, ныгып китүенә сәбәпче булды.* И.Нуруллин. *Ул төкерде генә, әмма хуҗалык эшләрендә терәк барлыкка килүне, аның тагын да ныгып китүен, кул арасына яңа көч кергәнлеген күршеләре тоймый калмадылар.* Ф.Яхин

НЫГЫТМА *и.* 1) Аерым гына урнашкан яки тулы бер комплекстан торган саклану корылмасы; кальга. *Шәһәр ныгытмасының тышындагы бистәләрнең вак йортлары, рум бистәсенең чиркәү гөмбәзе күренде...* Г.Гобәйдуллин. *[Фәрһад:] Егетләр, сез дошман күргән коттедж кәефсафа кора торган җир генә түгел, ул – ныгытма!* Ю.Сафиуллин. *Уңда – текә кыялар эченә кереп урнашкан Сант Эльма ныгытмасы. Сулда – авыр ташлар астына яшеренгән Рикасоли порты.* М.Юныс

2) Нәрсәне дә булса ныгытып, беркетеп кую өчен җайланма. *Штрек [кеше йөрерлек коридор] стеналарын, түшәмнәрне тотып тора торган агач ныгытма шыгырдый, яки аннан күмер вагы коела башласа, көт тә тор, берничә секундтан ул җимереләчәк.* Кызыл таң

НЫГЫТКЫЧ *и.* **1.** 1) Нәрсәне дә булса ныгыта торган матдә. *Бетон измәсенә ныгыткыч өстәү*

2) *фото* Фиксаж, беркеткеч. *Элекеге заманнардагы кебек плёнка, сурәт кәгазьләре сатып аласы, караңгы бүлмәдә плёнкадагы кадрларның фиксаж, ныгыткыч (закрепитель) кебек сыекчаларда фоторәсемгә әйләнгәнен көтеп утырасы юк.* Татарстан яшьләре

2. *с. мәгъ.* Нәрсәне дә булса беркетеп, эләктереп, ныгытып кую өчен билгеләнгән. *Ныгыткыч детальләр*

НЫГЫТУ *ф.* **1.** 1) Нәрсәне дә булса кадаклап, кысып бәйләп, беркетеп кую. *Фәсхи, балта алып, тал кисте, киселгән талларны дилбегә белән алып арбаның күчәренә ныгытты ---.* Г.Ибраһимов. *Сарай тирәсен дә ныгытасы бар, улак башындагы почмактан су да үтә, түбәне ябарбыз! Эш күп!* А.Гыйләҗев. *Икенче көнне Миңлебай карт такта түбә өстендәге моржаны озынайтып, аңа төпсез чиләк ныгытып төште.* З.Зәйнуллин

2) Арттыру, туплау, җыю (көч, хәл һ.б.ш.); чыныктыру; яхшырту. *Бүген сүзне шунда туктатабыз, Иртән тагын сөйләп үтәрбез. Ә биш көннән, көчне ныгытып, Авылларга кайтып китәрбез.* Һ.Такташ. *Рухыгызны ныгытасы урынга, аны ватудан ни мәгънә бар?* Ф.Яхин. *Милләтне савыктыру өчен, халыкның милли аңын уятырга, милли рухын ныгытырга, милли телен көчәйтергә кирәк.* Н.Фәттах

3) Өстәмә көчләр белән сан һәм сыйфат ягыннан берәр нәрсәне үстерү, көчәйтү; камилләштерү. *[Урыс] Казан кальгасын Көнчыгыш җирләрне яулап алыр өчен төзегән, ныгыткан, яңа диварларны таштан салдырган.* З.Зәйнуллин

4) Тәгаенләү, тирәнәйтү, ышанычлы итү (карар, фикер һ.б.ш. тур.). *Фикерне ныгыту*

5) Ирешелгән нәрсәне, үзгәрмәслек итеп, ныклы хәлгә китерү, тотрыклы итү. *Сүз әйтеп, вәгъдәләр биреп араны ныгытмасалар да, егет белән кыз быелның көзен җиткерә алмыйча зар булдылар!* А.Гыйләҗев. *Иртән тагын --- өстәлгә китапларны куеп, конспектларны ачып, алдагы кичтә алган гыйлемнәребезне ныгытырга утырабыз.* М.Шаһимәрдәнов

2. *рәв. мәгъ.* **ныгытып**. Бик нык кисәтеп, кат-кат аңлатып, катгый рәвештә. *– Иртәгә урдага килерсең, шунда ныгытып сөйләшербез, – диде хан кенәз энесенә.* Н.Фәттах. *Врачлар ныгытып әйтеп чыгардылар теге вакытта: «Сак бул!»* А.Гыйләҗев // Конкрет кына, төгәл итеп; җиренә җиткереп. *Билгеләмиләр бит шуның [Сабан туеның] көнен ныгытып, июньнең өченче якшәмбесе, яки инде Татарстан бәйрәмендә, дип көнен гомерлеккә ныгытып кына куясы да бит...* А.Гыйләҗев. *– Бу турыда бик ныгытып уйларга кирәк безгә, Нәҗип туганкай, – дип, беренче мәртәбә парторгка исеме белән дәшеп сүзен бетерде Лотфулла абзый.* Г.Ахунов

Ныгыта бирү Бернигә дә карамыйча ныгыту. *Мәркет белән татар җүләр түгел, ике арада җиде дәрья ятса да, туганлык җепләрен һаман ныгыта бирә.* В.Имамов

Ныгыта төшү Тагын да бераз ныгыту. *Бу көннәрдә без, илебезнең тынычлыгын бозарга маташучы бандитларны нык кына туздырып, чик буйларын тагын да ныгыта төшеп кайттык.* К.Нәҗми

Ныгытып алу Тиз арада ныгыту. *Тик Кырымга сине озатыр идек: «Ныгытып ал, – дип, – башта саулыгың...»* Х.Туфан. *– Машиналары әйбәтме? – дип белеште һәм, улы җавап бирмәгәч, – болай бик матур күренә икән, – дип, фикерен ныгытып алды.* А.Гыйләҗев. *Үзәген пешкалар белән ныгы-*

тып алган кызый фигураларын аямый һөҗүмгә күчте. С.Сөләйманова

Ныгытып кую 1) *к.* **ныгытып алу**. *Төшерүче өчаякны кабаланмый гына тигезләде, аның өстенә кайсы җире беләндер гармунга охшаган бәләкәй генә фотоаппаратны ныгытып куйды.* З.Зәйнуллин. *Укытучыбыз --- борыны өстенә алтын кысалы пенснесын ныгытып куйгач, озын нәзек бармагын һавага чөеп, сүзен башлады.* Э.Касыймов; 2) Алдан ук ныгыту. *Колхоз идарәсендә: – Үзәккә йорт салып бирәбез! – дисәләр дә, Сәлимәмнең инде ныгытып куйган хыялларын җимерәсем килмәде.* Ф.Яхин

Ныгытып чыгу Барысын да рәттән ныгыту. *Лапас-кураларның тишек-тошыкларын сылап, өрлек-казыкларны ныгытып чыга [Исхак].* А.Гыйләҗев

НЫГЫТУЧЫ *и. махс.* Ныгыту эшләре белгече, тау эшчесе; *русчасы:* **крепильщик**

НЫГЫТЫЛУ *ф. төш. юн.* Файдаланырга хокук бирелү, карамагына тапшырылу. *Ләкин һәммә рәсми урыннарда башкортларның үз илчеләре ризалыгы белән Шибайга ныгытылганга, [болынны] яңадан кире кайтара алмадылар.* Г.Ибраһимов

НЫК *с.* **1.** 1) Өзүе, ватуы, сындыруы һ.б. авыр, кыен булган, таза эшләнгән. *Өстәвенә, атауда балта белән юнып эшкәртеп була торган җиңел, нык сары таш чыга.* М.Юныс. *[Мулла:] Бу мәчетебез дә, әлхәмделилләһи, нык безнең, салынганына өч кенә ел.* Н.Гыйматдинова. *Нык имән ишек өстенә көрән буяу белән «Сельмаг» дип язылган җыйнак кына калай кадакланган киберкә шактый ук дулкынланып килеп керде Мисхәт.* М.Шаһимәрдәнов // Ертылмаган, тузмаган, бөтен (аяк киеме, өс киеме һ.б. тур.). *Нык капчык*

2) Көчле, сәламәт, чыдам. *Сәлим карт, тимердәй нык йодрыкларын һавада селкеп, сүзен дәвам итте.* М.Галәү. *Һади Атласов – инде алтмышның аръягында булуына карамастан, таза, нык, җиңел сөякле, хәрәкәтчән кеше.* И.Салахов. *Нык булыгыз, адәм балалары!* М.Мәһдиев

3) Көчле, яңгыравык (тавыш тур.). *Тавышы нык, ышанычлы иде.* М.Әмир

4) *күч.* Рухи яктан көчле, түземле, какшамас. *Минем әнием – нык хатын, сабыр хатын, күз яшен бик сирәк чыгара...* Ә.Еники. *Гайни кебек нык терәк Бик күп кешегә кирәк.* Ф.Яруллин

5) Ышанычлы, таянырга мөмкин булган; җитди, төпле. *Болай бары тик киң күңелле, бүгенгесе һәм киләчәге нык, ышанычлы булган кешеләр генә көләләр.* Г. Әпсәләмов. *Нык сүз*

6) Бик көчле дәрәҗәгә җиткән, каты (җил, салкын тур.)

7) *сөйл.* Бай, таза, зур мөмкинлекләре булган. *Нык хуҗалык*

2. *рәв. мәгъ.* Эш яки процессның бик каты, көчле, төпле, ныклы булуын күрсәтә. *Иң элек шуны әйтергә кирәк: төрекнең безгә никадәр нык йогынты ясаганын шул елларда туган балаларга күшылган исемнәрдән дә күреп була.* Ә.Еники. *Бушап калган бураларны тутыру өчен, бик нык эшләргә, бик күп хезмәт көне җыярга кирәк иде.* М.Мәһдиев. *Галимҗан агага сәламебезне тапшыр һәм бик нык ихтирам итүебезне белгерт.* И.Салахов

◊ **Нык тору** 1) Бирешмәү. *Шуңа күрә ул [Нечкәбил] постында нык тора, килгән каракларның барысын да кире бора.* А.Алиш. *Кичә, Югары Совет сессиясендә, шовинист депутатлар мөстәкыйльлегебезгә каршы нык тордылар.* М.Шаһимәрдәнов; 2) Әйткән сүздән, фикердән һ.б. кире кайтмау. *Аннары алар өчәүләп Сәлим картны үгетләргә тотындылар, ләкин тегесе үз сүзендә нык торды.* М.Галәү. *Син ныграк торган булсаң, без мондый чытырманлыкка килеп капмаган булыр идек.* Ф.Хөсни

НЫКЛАП *рәв.* Нык итеп, җитди рәвештә, чынлап, җентекләп; кирәгенчә. *Еллар узды, колхоз тормышы белән дә ныклап кызыксындылар.* М.Мәһдиев. *Сай Кичү дигән урында арбасы дүрт тәгәрмәч белән кичү төбендәге ләмгә батып, бик ныклап утыра.* З.Зәйнуллин. *Ничекләр алга барырга Ныклап киңәшсәң иде.* Р.Рахмани

НЫКЛЫ *с. к.* **нык 1.** (*5 мәгъ.*). *Муллалар, бер-берсенә тыгыз бәйләнгән булып, ныклы бер катлау – сословие тәшкил иткәннәр.* И.Нуруллин. *Үкенми ул [Зөфәр] үзе бу эшкә, оныткан инде ул аны, чөнки башта ук аларның бәйләнешләре ныклы була алмаган.* Ә.Еники. *Хәер, өйләнәм дип ныклы нияткә керешсә дә, акылга зәгыйфьрәк һәм ярым сукыр кешегә кияүгә чыгарга атлыгып торучылары да табылмас иде, бәлки.* М.Хуҗин

НЫКЛЫК *и.* 1) Нык булу; чыдамлылык. *Шуның белән дәүләтләреңең зурлыгын, тәхетләреңең ныклыгын күрсәтергә тырышканнар [патшалар].* К.Тинчурин

2) Көч, кодрәт. *«Көчле» сүзен тагу аркасында тән ягыннан ныклыгы гына төсмерләнеп, социализм төзү энергиясе белән тулган чын ударник күздән югала.* Х.Туфан. *Ләкин без «корыч» кушаматын йөртүченең ныклыгына артыграк ышанганбыз.* Ә.Еники

3) Какшамаслык булу, тотнаклылык. *Бу эштә безнең вәкилләрдән уяулык та, ныклык та талән ителә.* Ә.Еники. *Стахиев аның ныклыгын, зиһенен бәяләп, белемле зур инженерына ярдәмче итеп билгеләде.* Г.Ахунов

НЫ́КЧА *с. сөйл.* Шактый нык, чыдам. *Ләкин ул зарланмады, эшкә күнеккән, ныкча авыл малайлары көләр дип курыкты.* А.Тимергалин. *Әлеге тегәрҗеп кыллар – итек тегәр өчен киндердән эрләнгән һәм балавызланган ныкча җептән шомартылып эшләнгән.* Г.Макаров

НЫКЫШ *с. диал.* Үзсүзле, үҗәт. *Хәер, үтә ныкыш, эшен башлап алып китәргә акча тапкан егет фермер хуҗалыгын оештырып җибәрде дә, ди.* Кызыл таң

НЫКЫШЛЫК *с. диал.* Үзсүзлелек, үҗәтлек. *Ул үзенең хәленең яман да эшәке икәнен, түбәнлек икәнен дә сизә, әмма акылын биләгән үҗәтлек хисе, ныкышлык, кирелек аны кыз артыннан әйди иде.* А.Гыйләҗев

НЫКЫШМАЛЫ *с. диал. к.* **ныкыш**. *Бүген ныкышмалы булырга, үз өстеңдә эшләргә, заман белән бергә атларга кирәк.* Өмет. *Ныкышмалы хезмәт*

НЫКЫШМАЛЫЛЫК *и. диал.* Ныкышмалы булу. *[Галимҗан Ибраһимов] Моңа чаклы булган ныкышмалылыгын, гаярьлеген, рухи вә җисмани*

көчен күрсәтергә тырышты. С.Поварисов. *Холкына ныкышмалылык хас булган Фирдәвес үзенә ошаган сортны теләсә нинди юл белән алып кайтып, үзендә сынарга һәм үрчетергә күнеккән.* Кызыл таң

НЫКЫШУ *ф. диал.* Үҗәтләнү, үҗәтлек күрсәтү, үз дигәнендә тору. *[Голәманың] Бер төрлесе, элек кабу сөннәт, дисә, икенчеләре, аштан соң кабу фарыз, дип ныкышты.* М.Галәү. *Каян килде миңа мондый әшәке кирелек? Нигә ныкышып маташам?* А.Гыйләҗев. – *Шагыйрь Гамир Гайнуллин монда торамы? – дип ныкыша иде теге бәндә.* Р.Хәкимов. *Профессор Малкин аны Казанда калырга үгетли, үзеңә бер бүлмә дә табып бирербез, дип ныкыша.* Кызыл таң

Ныкыша бирү һаман да ныкышу. *Әмма алар һаман ныкыша биреп, ары китәргә теләмәде һәм хәлне ачыкларга, аның асылына төшенергә этәргеч бирде.* Кызыл таң

Ныкышып йөрү Озак вакыт ныкышу. *Ә теге «кара елан» һаман ныкышып йөри.* Р.Риян. *Ныкышып йөри торгач, бер үшән генә ат эләкте.* Кызыл таң

НЬЮ́ТОН *и.* Халыкара системада 1 кг массалы җисемгә 1 м/с^2 тизләнеш бирә ала торган көч берәмлеге (инглиз физигы И.Ньютон (Newton) исеменнән)

НЬЮФА́УНДЛЕНД *и. ингл. зоол.* Суга батучыларны коткарганда файдаланылган көчле, яхшы йөзә белгән, озын куе кара яки көрән төстәге йонлы зур эт токымы. *Ньюфаундленд көчекләре*

НЭП *и. рус тар.* Яңа икътисади сәясәт – Советлар дәүләтендә халык хуҗалыгын торгызу максаты белән 1920 елларда үткәрелгән махсус сәясәт. *Чын булса (үзе сөйләгән – чындыр инде), Идият абзый нэп заманында волостьта милиционер булып йөргән, ди.* Ә.Еники. *Габделбарый агай НЭП чорында Казанда сәүдә эшендә әвәрә килеп алды.* М.Мәһдиев. *Нэп бер-ике ел эчендә илне азыктөлеккә күмеп ташлады, кибетләрдә җаның теләгән бөтен нәрсә бар иде.* Ә.Еники

НЭ́ПМАН *и. рус тар.* Нэп чорында: хосусый эшмәкәр, сәүдәгәр. *Казандагы нэпман Шәрәфләрнең бөтен эшләргә тыгылырга маташулары шулай «шәрәфләү» дип аталды.* Г.Толымбай. – *Тагын кемнәр? – Сана! Кулак, нэпман, мещан чурбаннар! Әй сез, ботка караклары!* Һ.Такташ. *Иргали менә ничәнче кат инде, әллә, чыннан да, нэпман Иван дәдәйгә барып эшкә ялланып караргамы, дип өмсенеп куйгалады.* М.Хәсәнов

НЮАНС *и. фр. кит.* Төстә – күренер-күренмәс, тавышта сизелер-сизелмәс күчеш; гомумән берәр нәрсәнең бик нечкә аерымлыгы, үзлеге, төсмере; нечкәлек. *Һәркайсының шигъри авазында үзенә генә хас тембры, аерата нюансы булу белән бергә, барчасы өчен дә уртак --- сыйфатлары бар.* Х.Туфан. *Катнашып китү өчен, кечкенәдән бу көннең иң нечкә нюансларын сизеп үсәргә кирәк.* М.Мәһдиев. *Төс нюанслары. Көйнең нюанслары*

НЯ́НЯ *и. рус сөйл.* 1) Балалар карау белән шөгыльләнүче хатын-кыз, бала багучы (яследә, балалар бакчасында, өйдә). *Якшәмбедә [балалар бакчасында] пешекче белән няня гына кала...* А.Гыйләҗев

2) Хастаханәдә санитарка. *Рөхсәт сорарга кереп киткән няня әле һаман юк иде.* И.Гази. *Больница тәртибе буенча, имеп туйган балаларны икенче палатага алып китүгә, күчтәнәчләр өләшүче няня килеп керде.* Л.Шафикова

О

О *ы.* 1) Курку, соклану һ.б. төрле хис-кичерешләрне көчле экспрессия белән белдергәндә кулланыла. *О, тал чыбыгы кебек нечкә зифа буйларга ничек итеп карамаска, ничек итеп күз төшермәскә кирәк!* А.Шамов. *О, кыйналган чаклары булды аның!* Я.Зәнкиев. *О-о! Андый кыз дөньяда берәү генә ---.* Ф.Яруллин

2) Раслау, инкяр итүне белдергән сүзләр янында алар белдергән мәгънәне көчәйтә, раслый. *О-о, юк! Ул бу тирәнеке түгел. Синең аны күргәнең юк.* Г.Гобәй. *О-о, җан бизәге булган милли хисләргә саксыз кыланып кагыла күрмик!* А.Гыйләҗев. *Рәнҗисеңме кешеләргә? О, юк димә!* Н.Гыйматдинова

3) Риторик эндәшләрдә сәнгатьлелекне арттыру чарасы буларак кулланыла; ah. *О, бәрәңге, утырасың бакча тулып, Кишер, суган арасында патша булып.* Г.Афзал. *О-о, акыл чүлмәгем минем. Менә шәп!* Ф.Яруллин

ОА́ЗИС *и. гр.* 1) Чүлдә үсемлекләр һәм су (грунт сулары, елгалар) булган урын. *Чүлләрдә сәяхәт итүчегә дә, сусагач, гөлбакчадай оазислар, суы ташып торган күлләр күренә.* В.Комаров. *Чөнки безнең көннәрдә дә Сахара чүле оазисларында яшәүчеләр саранчаны җыялар ---.* Кызыклар дөньясында. *Дуз оазисында эчә торган судан тоз тәме килә.* Мәгърифәт

2) *күч.* Әйләнә-тирәдән аерылып, күзгә бәрелеп торган бик күңелле, уңай күренеш, нәрсә. *Ләкин әти-әни белән үткәргән кыска сроклы балачакның истәлеге булып 1916 елда әти утыртkан көяз акацияләр, сиреньнәр, крыжовниклар, миләшләр тыгыз каралтылы авылда бер оазис булып утыралар.* М.Мәһдиев. *Татар дөньясы (Зур Татарстан) – бүген теллурократик империя чүлендәге талассократик оазис.* Р.Сафин

ОБЕЛИСК *и. гр.* Биек, астан өскә тараеп килгән һәм очында зур булмаган пирамидалы дүртпочмаклы бүрәнә формасындагы борынгы монументаль корылма. *Жюри членнары заманча итеп эшләнгән обелискларны яхшы дип таптылар*. М.Маликова. *Кызлар кулы тотып өлгермәстән Алдык кулга сугыш коралын. Бергә үскән малайларның исемен Обелисктан укып торамын.* М.Рафиков. *Мәктәп янындагы мәйданчыкта акшарлы обелиск куйганнар.* М.Мәһдиев

О́БЕР- *нем.* Кушма сүзләрдә өлкәнрәк хезмәт урынына, хәрби дәрәҗәгә ишарә итә торган беренче компонент (мәс., *обер-кондуктор, обер-мастер*)

О́БЕР-ЕФРЕ́ЙТОР *и. нем. хәрби* Германия, Швейцария армиясендә хәрби дәрәҗә. *Операция тәмамлангач, комендант үз янына обер-ефрейторны чакырып, аңа төртеп күрсәтте дә нидер әйтте.* Р.Сибат. *Ике «тел» алып кайттык. [Берсе] обер-ефрейтор иде.* Г.Әпсәләмов

О́БЕР-КОМЕНДАНТ *и. нем.-фр. тар.* Өяз һәм андагы гарнизон белән җитәкчелек итүче, кайвакытта вице-губернатор яки губернаторны алыштырып торучы түрә. *Сөембикә башнясы – XVIII йөзнең беренче яртысында Казан Кремленең ныклап реконструкцияләнгән оборона-саклау корылмаларының бер элементы, обер-комендант (губернатор) сарае комплексына керү юлында монументаль корылма буларак калкып чыккан.* Татарстан

О́БЕР-ЛЕЙТЕНАНТ *и. нем.-фр. хәрби* Германия, Австрия, Швейцария армиясендә кече офицер. *Обер-лейтенант, резервыгызда нинди көчләр бар?* Т.Әйди. *Стенада подполковник һәм обер-лейтенант погоннары тагылган ике китель эленеп тора.* Ә.Айдар. *22 яшьлек офицер Фёдор Ильченко --- урыс, поляк, румын, инглиз һ.б. телләрдә ярыйсы гына сукалаган нимес обер-лейтенантын «тел» итеп кулга төшергән.* Р.Гаффар

О́БЕР-ОФИЦЕР *и. нем.* Кайбер гаскәрләрдә: түбән офицер чиннарының гомуми атамасы // Шул чиндагы гаскәри. *Элек 1783 елда фельдмаршал Потёмкинга биргән указында Екатерина шулай диде: «Әгәр татарлардан булган морза вә «чиновные люди» гаскәри хезмәткә керсәләр, аларга югарыгы офицер – обер-офицер чины бирергә…»* Г.Гобәйдуллин

ОБЕРТОН *и. нем. муз., физ.* Төп тон яңгыраганда барлыкка килеп, тавышка үзгә төсмер я тембр өсти торган һәм шул сәбәпле бер тавышны яки музыка коралын икенчесеннән аерырга мөмкинлек бирә торган тон; обертон тирбәнешләре ешлыгы төп тоннан 2, 3, 4 һ.б. тапкыр зуррак

ОБКОМ *и. рус тар.* Советлар Союзында коммунистлар партиясенең өлкә комитеты. *Китәр алдыннан мин обкомда булган идем.* Ә.Еники. *Обкомда сүз зур булды!* А.Гыйләҗев. *--- Динмөхәммәтов дигән түрә бар иде. Обкомның оештыру бүлеге мөдире.* Мәдәни җомга

ОБЛА́ВА *и. рус* Махсус гаскәрләр тарафыннан дошманны, җинаятьчене тоту, юк итү максаты белән билгеле бер территорияне чолгап алып үткәрелә торган чаралар комплексы. *Яшь партизан аңлы рәвештә дошманга каршы көрәшә башлаган, икенче бер үсмерне облава вакытында эләктереп алганнар.* Я.Зәнкиев. *Көннәрнең берендә аның әлеге туганын, урамдагы облава вакытында тотып, комендатурага илтеп яптылар.* С.Җәлал. *Күрәсең ич, облава. Бөтен яр буена прожектор уйнап тора.* Ф.Шәфигуллин

ОБЛИГАТ *с.* Мәҗбүри, тиешле. *Алар – күзәнәк эчендә була торган*

облигат (мәҗбүри) паразитлар ---. Гомуми биология

ОБЛИГА́ЦИЯ *и. лат.* Хуҗасына алдан килешенгән күләмдә керем китерә торган кыйммәтле кәгазь. *Ә бит ул аппаратураларда пасторттан башлап шофёр таныклыгына кадәр теләсә нинди дәүләт документын, акцияләрдән башлап дәүләт займы облигацияләрен – теләсә нинди эш кәгазьләрен – җиңел генә эшләп була.* Р.Мирхәйдәров. *Кешеләр фронт фондына акчаларын, дәүләт займы облигацияләрен, кыйммәтле бизәнчекләрен керттеләр.* Казан утлары. *Облигация хуҗасы, акционердан аермалы буларак, предприятие милкенең билгеле бер өлешенең хуҗасы була алмый.* Икътисад теориясе нигезләре

ОБЛИ́ГО *и. ит.* 1) Предприятиенең вексельләр буенча гомуми бурычы

2) Банкларда аерым шәхесләрнең әлеге банк вексельләре буенча бурычлары күрсәтелгән китап

ОБЛИТЕРА́ЦИЯ *и. лат.* 1) *мед.* Нинди дә булса көпшәле орган куышлыгының томалану, кысылу күренеше

2) *бот.* Органнар үсү процессында кайбер күзәнәкләрнең яньчелгәнлеге

ОБЛО́МОВЧЫЛЫК *и. кит.* Пассивлык, артта калганлык, булдыксызлык, рухи торгынлык кебек характер сыйфатларының җыелмасы. *Автор икенче бер персонаж – гайрәтле эшмәкәр, энергиясе ташып торган Штольц авызыннан әлеге яшәү рәвешенә «обломовчылык» дигән бәя бирдерә.* Х.Мәхмүтов

ОБМО́ТКА *и. рус* Аякның ботинкадан тезгә кадәр өлешен урау өчен, тыгыз тукымадан озын чолгау. *[Камилнең] аякларында да обмотка белән киелгән иске ботинкалар иде.* М.Әмир. *Данилов дустының яшел обмотка чорналган балтырларын шинель итәге белән каплады.* Г.Бәширов

ОБМО́ТКАЛЫ *с.* Обмотка чорналган; обмотка чорнап кия торган. *Итек урынына обмоткалы ботинкалар кия башлагач, дөньяның рәте китте.* Ә.Маликов. *Олаучының өстендә җылы тун, башында йолдызлы бүрек, аягында обмоткалы ботинкалар, кулында кыска чыбыркы.* К.Латыйп

ОБМУНДИРОВА́НИЕ *и. рус* Формалы кием комплекты. *Шуннан соң, хәрби обмундирование алганчы, Хисмәт бөтен взводка чабата ясап торды.* М.Мәһдиев

ОБОЗ *и. рус к.* **олау** I (*3 мәгъ.*). *Обоз урман эчендәге шактый зур аланга килеп туктады.* М.Әмир. *Көзге юллар буйлап, көзге кояшта ялык-йолык килеп, автомашиналар чабыша, ашлык төягән обозлар агылалар, җиңелчә тарантаслар тәгәри.* К.Басыйров. *– Да-а, кызыл обоз киләсе көн иде бит бүген, – диде Хәйруллин, папиросын чәйнәп, – болай булса, эш харап.* М.Мәһдиев. *Обозны очрату мөмкин булган барлык төбәкләрне тикшердек.* С.Таһиров

ОБОЙ *и. рус* 1) Стеналарга ябыштыру өчен, бизәкле, гадәттә киң кәгазь тасмадан гыйбарәт эчке бизәлеш материалы. *Ул [Нагаев] обойдагы бер ноктага карап утырды да утырды.* Р.Зәйдулла. *Түшәмнәргә буяу тигез төшкән, обойлар матур итеп ябыштырылган, гомумән, пөхтәлек менә мин дип тора.* М.Әмирханов. *Бүлмә шактый шыксыз: түшәмнәре купкан, обойлары саргаеп, кыршылып беткән* ---. Ф.Яруллин

2) *неол.* Телефоннарда, компьютерларда: экранга куела торган рәсем. *Обойны алыштыру*

ОБОЙЛА́У *ф.* Обой ябыштыру. *Әнисе терәүне дә җөвен җөйгә обойлаган булган.* Ф.Шәфигуллин. *Квартираны яңабаштан буярга, обойларга туры килә.* М.Әмирханов. *Килеп керүгә үк Венераны башта Сабираның мул итеп кабымлык-ризыклар әзерләве, аннары обойларга дигән бүлмәнең стенасы әле аз гына да искермәгән булуы гажәпләндергән иде.* З.Фәйзи. *Обойлаганнан соң стеналарны бер генә тәүлек булса да киптерергә һәм мебельне шуннан соң гына урыннарына куярга кирәк.* Файдалы киңәшләр

Обойлап алу Тиз генә обойлау

Обойлап ату Бик тиз обойлау

Обойлап бетерү Тулысынча обойлау

Обойлап кую Тиз генә обойлау. *Куярмын, дип, өем обойлап.* М.Саттаров

Обойлап чыгу Тулысынча обойлау

Обойлый башлау Обойларга тотыну

ОБО́ЙМА *и. рус* 1) Ату кораллары (күп кенә винтовкалар, карабиннар, автоматлар, кайбер пистолетлар, эре калибрлы пулемётлар, кече калибрлы пушкалар) коруны һәм атуны тизләтү өчен, берничә патрон (5–10) берьюлы урнаштырыла торган махсус җайланма. *Комендант --- кобурасыннан пистолетын чыгарды. --- Обоймасын ачып, патроннарын тикшерде.* А.Хәсәнов. *Менә котелок, әнә кружка, берничә обойма патрон.* Г.Бәширов. *Капшанганда, обоймага тезгән Биш патронга тия куллары* ---. Ф.Кәрим // Шундый җайланмадагы патроннар

2) *күч.* Уңай шартлар, мөмкинлекләр. *Аннары [бу иркә балалар] тотрыклы обоймага эләгеп, гомерләре буе дан бишегендә тирбәләләр.* М.Гали

3) *күч.* Кыса. *Күпмилләтле әдәбиятыбыз тарихын яхшы белүчеләр генә аның исемен «классиклар обоймасы»на кертәләр.* Казан утлары

4) *күч.* Бер төркем кешеләр турында

◊ **Обоймага керү** Билгеле бер кешеләр төркемендә (социаль, профессиональ) тиешле урын алу. *Әмма иҗатың саф, олы икән, «обойма»га кермәсәң дә, әшнәлек кора белмәсәң дә, сине таныргa мәҗбүр булачаклар.* Р.Батулла

ОБОЛ *и. гр.* Борынгы грекларда вак көмеш акча: драхманың 1/6 өлеше

ОБОРО́НА *и. рус* 1) Нәрсәне яки кемне саклау-яклау өчен кирәк булган чаралар. *Көткән дошман күренмәде, Тынычлыкта бил бөктек; Оборона ныгытуга Лаеклы өлеш керттек!..* Р.Рахмани. *[Дошман] оборонаны өч катлы итеп корган булып чыкты.* Х.Камалов. *--- XII гасырдан башлап Европада феодальләштерү процессы бара: җирле общиналар үзләре өчен гомуми бурычларны – оборона, икътисади үсеш һ.б. хәл итү өчен, ирекле рәвештә һәм максатчан кушылалар.* Татарстан

2) Илнең куркынычсызлыгын тәэмин итә торган тармак. *Оборона продукциясен җитештерүдә аларның күләме күзгә күренеп үскән.* Татарстан. *Бу – төрле дәүләтләрнең экономика һәм оборона потенциалы сугышы гына*

түгел, ике капма-каршы идеология сугышы да. Казан утлары. *Федераль хөкүмәт «КамАЗ»ның хәлен оборона өчен заказлар санын арттыру юлы белән берникадәр җиңеләйтмәкче була.* Ватаным Татарстан

3) Саклау, яклау корылмалары системасы. *Ә бу өч солдат хезмәт иткән батальон, шушы кабахәт хакимлек эшләгән көннән бер атна чамасы элек кенә дәүләт чигенә килеп, оборона ныгытмасын төзергә керешкәннәр иде.* Ә.Еники. *Җыйнап әйткәндә, шәһәрлек – оборона ныгытмалары булган борынгы шәһәр ---.* Р.Фәхретдинов

4) Алдан әзерләнгән яки сугыш барышында алынган позицияләрдә шул позицияләрне яклау һәм һөҗүмгә күчәргә уңай шартлар тудыру өчен алып барыла торган көрәш. *Яңа көчләр, пехота дивизиясе подразделениеләре оборонаны ныгытырга тиеш.* Х.Камалов. *Ике як та оборона тоткандa, мондый «тел»не кулга төшерү өчен, дистәләрчә арслан кебек чая егетләрнең башларын югалтасың ---.* Ф.Кәрим. *1944 елның көзендә Висла елгасының аръягындагы плацдармда оборонада ята идек.* М.Саттаров

О́БРАЗ *и. рус* 1) Объектив чынбарлыктагы күренешләрнең, предметларның аңда чагылышы

2) Чынбарлыкны сәнгатьчә гомумиләштерү формасы; кеше яки берәр нәрсә, аның тышкы кыяфәте турында җанлы күзаллау, кем яки нәрсәнең хыялдагы сурәте. *Әмма ул аның күңелендә беркайчан да онытылмый торган изге образы булып гәүдәләнеп калды.* Г.Бәширов. *Халыкның туган, үскән нигезен, яшәү нигезен гәүдәләндереп торучы якты, матур образ да бит әле ул – учак.* М.Вәлиев

3) Матур әдәбиятта, сәнгатьтә: иҗат ителгән, тудырылган тип, характер. *Шәехзаман образы атказанган артист Х.Уразиков уйнавында оригиналь образ булып гәүдәләнде.* М.Җәлил. *[Сәхнәдә Дания] образга шулкадәр керә һәм берегә, аның үзен онытасың, бу хатынны әсәр героинясы итеп тоя башлыйсың.* Б.Камалов. *[Җырчының] сәхнә стиле, образы юк.* Мәдәни җомга. *Образлар белән эш иткәндә, халкыбызның гореф-гадәтләрен, матур сыгылмалы телен, тапкырлыгын, оптимистлыгын --- кертеп җибәрергә яратам.* Ф.Яруллин

◊ **Образга керү** Төп, асыл сыйфатларны яшереп, үз-үзеңне төрлечә тоту. *Ә тормышта һәркем төрле образларга керә башласа, яшәү уенга гына әйләнеп калмасмы соң?* Ф.Яруллин. *Сәхнәдәге Илназ – җан халәтем, икенче образга керәм, димәс идем.* Безнең гәҗит

О́БРАЗЛЫ *с.* Образларга бай, сәнгатьле; тасвирлы. *[Халыкның] гади һәм образлы әсәрләре балалар күңеленә тиз үтеп керә.* Ә.Хуҗиәхмәтов. *Образлы итеп әйтсәк, адәм баласы, чыннан да, Раббыбыз мисалында, Аңа охшатып яратылган зат булып чыга.* С.Шәмси. *Образлы итеп күз алдына китерсәк, моны кеше организмы белән чагыштырырга мөмкиндер.* Мәдәни җомга // Кинаяле, күчерелмә. *--- Марат Сибгатуллин «яңарыш авазлары» кебек канатлы, образлы сүзләрне бик төшенеп бетми, билгеле.* Т.Нәҗмиев. *Образлы әйтем* // Образларга нигезләнгән. *Светлана Червонная «Чыңгыз» төркеменең үзенчәлеген кабатланмас форма, образлы эчтәлек, авангардизм, --- искечәлеккә охшатып стильләштерү, ислам гамәли-бизәү сәнгатенең классик традицияләрен иҗади эшкәртеп ясалган абстракцияне берлегендә күрә һәм, нәкъ шушы кушылма аны таныттты, ди.* Мәдәни җомга

О́БРАЗЛЫЛЫК *и.* Образ(лар)га ия булганлык. *Ә образлылык ул гап-гади сүздән, күчерелмә мәгънәле гыйбарәканатлы сүздән башлана ---.* И.Низамов. *Уртак сөйләмнең мондый үзенчәлеккә ия булуы хикәя стиленә аеруча җанлылык кертә һәм аның эмоциональ көчен, образлылыгын арттыра.* М.Зәкиев. *Шигърияттәге образлылык, икенче төрле әйтсәк, Эзоп теле, шигъриятнең үзен дә, шагыйрьләрне дә күп вакыт коткара килде.* Ф.Яруллин

О́БРАЗ-СУРӘТ *и. к.* **образ**. *Образ-сурәт тудыруның төрле әдәби чаралары бар ---.* И.Низамов. *Шагыйрь өчен шигырьдә иң элек – акыл, образ-сурәт.* И.Юзеев. *Ә поэзиядә --- мифик образ-сурәтләр аша хәзерге көн проблемаларына тоташкан эпик әсәрләр күбәйде.* Т.Галиуллин

ОБРЕЗ *и. рус* Көпшәсе кисеп кыскартылган мылтык. – *Обрез бит бу, Ильяс! – диде ул, тавышы күтәрелә төшкәндәй булды.* М.Әмир. *Кулдан килгән барлык чараларны күрәбез, баш врач үзе аның янында, обрез ядрәләрен дә үзе операцияләп алды, дип аңлатты [врач].* Б.Камалов. *Ул пәлтәсен чишеп, биленә кыстырган обрезны янәшәсендә торган урындык өстенә куйды.* Р.Зәйдулла

ОБРОК *и. рус тар.* Алпавытка крепостной крестьяннар ел саен акчалата яки әйберләр белән түләргә тиешле салым; феодаль рента формасы. *Крестьяннар вотчина хуҗасына оброк --- тиеш булалар.* Урта гасырлар тарихы. *Урта гасырларда оброк җыйган кебек, комсызланып, бер кулга азык-төлекне туплап әрәм-шәрәм итү җәмгыятьнең законлаштырылган җинаяте иде.* М.Гали. *Идел буенда умартачылар өчен бал оброгы кертелә.* Россия тарихы: XVII–XIX гасырлар

ОБРОКЛЫ *с. тар.* 1) Оброк түләү яки җыю белән бәйле // Оброк түләүче. *Оброклы крестьян*

2) Оброкка эшләтү, оброкка бирү белән бәйле. *Оброклы хуҗалык*

ОБСЕРВАТО́РИЯ *и. лат.* Системалы рәвештә астрономик, магнит, метеорологик, сейсмик күзәтүләр алып бару өчен махсус җиһазландырылган фәнни учреждение; шундый бина. *«Фудзияма» обсерваториясе хәбәр итүенчә, бүген илебезнең символы булган Кояшта таплар саны кинәт арта башлаган.* А.Тимергалин. *Тагын да кечерәк астероидларга обсерваторияләр һәм галәм маяклары куелды ---.* Кызыклар дөньясы. *Моның өчен тикшеренүчеләр Чилиның төньягындагы Америка обсерваториясе һәм Гавайдагы Франция-Канада телескопларыннан файдаланганнар.* Мәдәни җомга

ОБСЕРВАЦИОН *с. лат.* Күзәтү, тикшерү, өйрәтү өчен булган

ОБСЕРВА́ЦИЯ *и. лат. астр.* 1) Галәмдәге объектларны күзәтү. *Кояш*

чыгуы күренгән көннәрдә, йолдызлы төннәрдә корабның урынын обсервация юлы белән үзем хисапларга тырышам. М.Юныс

2) *мед.* Сәламәт дип саналган, ләкин йогышлы авыру белән зарарлануда шик туган кешеләрне махсус бинада тоту, изоляцияләү чарасы

ОБСИДИАН *и. лат. геол.* Пыяласыман вулканик токым

ОБСКУРАНТ *и. лат. кит.* Фән һәм мәгариф дошманы

ОБСКУРАНТИЗМ *и. лат.* Фән һәм мәгарифкә каршы, дошманнарча мөнәсәбәт

ОБСТАНО́ВКА *и. рус сөйл.* Хәл, вазгыять, эшнең торышы. *Базар обстановкасын ул тиз чамалап алды: ничә әйтсәң дә, разведчик – монда ялт-йолт китерсәң генә уңасың.* М.Мәһдиев. *Болардан тыш сөйләм обстановкасы, контекст, мимика, жестлар --- сөйләм оештыруда катнаша.* М.Зәкиев. *Кирилл кирәкле пунктларны картадан эзләп табарга булыша, офицерлар обстановканы пөхтә итеп тиз генә картага сыза баралар.* С.Таһиров

ОБСТРУКЦИОНИЗМ *и. лат.* Каршылыкның бер төре, көрәш ысулы (гадәттә парламент өчен хас)

ОБСТРУ́КЦИЯ *и. лат. кит.* 1) Гадәттә парламентта утырышларны, җыелышларны, кемнәрнең дә булса чыгышларын сузарга яки өзәргә юнәлтелгән көрәш методы

2) Ачыктан-ачык берәр эшне булдырмаска юнәлгән хәрәкәт, чара

ОБХОД *и. рус мед.* Хастаханә палаталарында табибның авыруларның хәлен, дәвалау барышын билгеләү өчен һәркөн карап торуы. *Шулай итеп Зәйтүнә Хәйруллина янына керергә ашыкмады, обходны өске каттан башлады.* М.Маликова

ОБЩИ́НА *и. рус* 1) *тар.* Кешеләрнең борынгы сыйныфсыз җәмгыятьтә һәм сыйныфлы җәмгыятькә күчү чорында җитештерү чараларына күмәк милек, бергәләп хезмәт итү һәм тигезләп бүлү белән характерлана һәм тулысынча яки өлешчә мөстәкыйль идарә ителә торган берләшү формасы. *Тәрбия эшен ыруглык общинасы билгеләгән аерым кешеләр тормышка ашыру --- шуны раслый: ыруглык строе вакытында тәрбия җәмгыять эшчәнлегенең аерым формасы буларак аерылып чыга башлый.* Ә.Хуҗиәхмәтов

2) Борынгы чор һәм Урта гасырларда, нинди да булса территориаль берәмлектә (мәс., авылда яки шәһәрдә) мөстәкыйль идарә ителә торган оешма. *Ян Коменский «чех туганнар» общинасына кергән гаиләдә туа ---.* Ә.Хуҗиәхмәтов. *Ричард (телефонга): Общиналар палатасымы? Мин Ричард Уилли.* Д.Салихов. *Община, барыннан да элек, хуҗалык эшләрен алып бара.* Урта гасырлар тарихы

3) Билгеле бер милләт, дин, территория, һөнәр һ.б.ш. нигезендә уртак эшчәнлек максаты белән берләшкән кешеләр җәмгыяте. *Молдованың татар общинасы. Петербургның мөселманнар общинасы*

ОБЩИ́НАЧЫ *и.* Общинага кергән кеше, община әгъзасы. *Хуҗалык итүдә бөтен общиначыларның шартлары бертигез булсын өчен, чәчүлек җир туфрак сыйфаты төрлечә булган участокларга бүленә ---.* Урта гасырлар тарихы

ОБЩИ́НАЧЫЛЫК *и.* Община хезмәтенә, тормышына тартымлык. *Общинаны «социализмның яралгысы» дип карап, народниклар аңарда крестьянның «общиначылык рухы» чагылышын күргәннәр*. СССР тарихы

ОБЪЕ́ЗДЧИК *и. рус* Берәр зур участокның сакчысы, шул участокны әледән-әле карап йөрүче. *Фронттан кайткан солдатлар [алпавыт] урманын кисәргә керешкәннәр, объездчик барып туктатырга теләгәч, мылтыгын алып, кыйнап киткәннәр*. Т.Гыйззәт

ОБЪЕ́ЗДЧИКЛЫК *и.* Объездчик хезмәте, вазифасы. *Мине объездчиклыктан алдылар инде.* Ю.Әминов

ОБЪЕКТ *и. лат.* 1) *филос.* Кеше аңыннан тыш яши торган тышкы дөнья, материаль чынбарлык

2) Кемнең дә булса эшчәнлеге, игътибары юнәлтелгән күренеш, предмет, зат. *Галәм күзлегеннән караганда, кешелек дөньясы тәрбия кылу объекты булып тора.* С.Шәмси // Билгесез предмет, зат. *Бу малай заты каяндыр күктән төшкән объект та, ягъни мәсәлән җан иясе дә, ниндидер җенмазар да түгел.* Х.Ибраһим

3) Хуҗалык яки оборона өчен зур әһәмияте булган берәр предприятие, төзелеш, аерым участок һ.б. *Монда тәүлекләр буена, чиратлашып, стратегик мөһим объектны саклау белән мәшгуль булалар.* Р.Мөхәммәдиев. *--- Объектларның хәвеф-хәтәрсез эшләве нәкъ менә аларның хезмәтенә бәйле.* Татарстан. *Шуңа күрә әлеге объектларны конкурска куеп сатарга булганнар.* Ватаным Татарстан

4) *лингв.* Тәмамлык. *Кайбер галимнәр синтаксиста да логика терминнарын кулланалар: ия урынына – субъект, хәбәр урынына – предикат, тәмамлык урынына объект дип язалар.* М.Зәкиев

ОБЪЕКТИВ I *и. лат.* Оптик приборның бер яки берничә линзадан (оптик пыяладан) торган һәм күзәтелә торган әйбергә юнәлдерелгән өлеше. *«Казан утлары» журналыннан язучылар килгәч тә, алар бик теләп объектив алдына бастылар.* М.Әмирханов. *Мин фотоаппаратка куелган МТО объективын борып алып, шуның аша күл буен күзәтергә керештем ---.* И.Гайфуллин. *Күзнең хрусталигы – объективка, ә челтәр катлау сурәт төшерелә торган плёнкага охшаган.* Кызыклы ихтиология

ОБЪЕКТИВ II *с.* **1.** 1) *филос.* Кеше аңыннан тыш һәм аңардан бәйсез рәвештә яши торган. *Моның, әлбәттә, һәм объектив, һәм субъектив сәбәпләре күп булгандыр.* Р.Миңнуллин. *Ул гына да түгел, алар [яңа белемнәр] аны [материяне] конкретлаштырырга, объектив дөньяның иң әһәмиятле үзлекләрен шуларга беркетергә мөмкинлек бирәләр.* Галәм, җир, кеше

2) Чынбарлыкка туры килә торган, ялгышлыкка юл калдырмаган. *Арттырырга булдык берникадәр, Объектив мөмкинлекләр булса әгәр.* Г.Афзал. *Миңа ике яклы һәм купшы мәгълүмат кирәкми, ә объектив мәгълүмат кирәк.* Татарстан

3) Гадел, риясыз. *Объектив бәя шул.* К.Миңлебаев

2. *рәв. мәгъ.* Чынбарлыктагыча, дөрес итеп. *Объектив карау*

ОБЪЕКТИВИЗМ *и. лат. кит.* 1) *к.* **объективлык** (*2 мәгъ.*)

2) Җәмгыятьне фәнни өйрәнүдә, җәмгыять фәннәренең сыйнфый характерда булуы мөмкин түгел һәм җәмгыять тормышы үзгәртүләргә бирешми, дип санаган концепция

ОБЪЕКТИВИСТ *и.* Объективизм (*2 мәгъ.*) тарафдары

ОБЪЕКТИВЛАШТЫРУ *ф.* 1) Реаль, объектив яши торган итү

2) Гомумиләштерү, типиклаштыру. *Чынбарлык күренешләрен объективлаштырып сурәтләү*

Объективлаштыра төшү Бераз объективлаштыру

ОБЪЕКТИВЛАШУ *ф.* 1) Реаль, объектив яши торган хәлгә килү

2) Гомумиләшү, типиклашу

Объективлаша бару Торган саен объективлашу

Объективлаша башлау Объективлашу билгеләре күренү

Объективлаша төшү Бераз объективлашу

Объективлашып бетү Тулысынча объективлашу

ОБЪЕКТИВЛЫК *и.* 1) Объектив II (*1 мәгъ.*) булу сыйфаты, үзенчәлеге. *Объективлыкны кешенең дустыннан да, дошманыннан да эзләмә.* Ә.Фәйзи. *--- Бүгенге тарихи әсәрләрдәге дөреслек, объективлыкның җитеп бетмәвенә хәтер калып, артык үпкәләп йөрерлек тә түгел.* Х.Бадыйков. *Журналистларның һөнәрмәндлеге, объективлыгы, җаваплылыгы җәмгыятьнең тотрыклылыгын саклау һәм аның үсеше өчен мөһим.* Мәдәни җомга

2) Объектив чынбарлыкка туры килүчәнлек, чынлык; гаделлек, риясызлык

ОБЪЕКТЛЫК *и.* Объектны белдерү үзлеге. *Биредә җөмләләр арасында объектлык мөнәсәбәте урнаша.* М.Зәкиев

ОБЫВА́ТЕЛЬ *и. рус* Иҗтимагый тормыштан читләшкән, тар карашлы, вак, шәхси мәнфәгатьләр белән генә яшәүче кеше. *--- Аңа бик җитди гаеп ташладылар, халыктан аерылдың, халык кайгысыннан бигрәк, үз кайгыңны күбрәк кайгыртасың, кыскасы, обывательгә әйләнеп барасың, диделәр.* Ә.Еники. *Обыватель чын коллекционерлардан көлсә дә, җыю эшен бер дә артка ташламый ---.* М.Юныс

ОБЫВА́ТЕЛЬЛӘРЧӘ *рәв.* Обывательләргә хас булганча. *Обывательләрчә, кая барсыннар, салып алып китәрләр, дип фикер йөртүчеләр гаҗәпләндерә.* Ютазы таңы

ОБЫВА́ТЕЛЬЛЕК *и.* Обыватель булу; тар карашлылык. *Обывательлеккә юл куймау*

ОВАЛ *и. лат.* **1.** 1) Йомыркасыман форма. *Күпчелек хайваннарның эритроцитлары түгәрәк, хәер, кайчагында аларның формасы үзгәрә, овал сыман була.* Кызыклы физиология. *Күзәнәкнең бу мембрана органоидлары овал формасында, ә диаметры 0,5 мкм.* Гомуми биология

2) *мат.* Йомырканың буйга кисемен хәтерләткән кәкре

2. *с. мәгъ.* Йомыркасыман формадагы. *Язын сарғылт яшел һәм көзен сарғылт кызыл төстәге бу овал талпаннар 0,3–0,4 мм озынлыкта.* Биология: хайваннар. *Һава линияләрен төзегәндә, төрле изоляторлар, ыргаклар, штырьлар, овал тоташтыргычлар кулланыла.* Авыл хуҗалыгы электригы белешмәсе

ОВЕРДРАФТ *и. ингл.* Банкның клиентлары түләүләрен автомат рәвештә башкарудан гыйбарәт кыска сроклы кредит бирү формасы. *Карточканың бер төре банк тарафыннан овердрафт суммасына билгеле бер лимит урнаштырылуын аңлата.* Икътисад теориясе нигезләре

ОВЕРТАЙМ *и. ингл. спорт* Хоккей, футбол уеннарында җиңүче команданы ачыклау өчен, уенга бирелгән төп вакыттан соң билгеләнгән өстәмә вакыт. *Овертайм да җиңүчене ачыклый алмады.* Татарстан яшьләре. *Кем җиңәчәген овертайм хәл итәргә тиеш иде.* Шәһри Казан

ОВУЛЯ́ЦИЯ *и. лат. биол.* Күкәйлектән күкәй күзәнәк бүленеп чыгу. *Овуляция айга бер генә тапкыр булганлыктан, менструация циклы һәр ай саен кабатлана.* Биология: кеше һәм аның сәламәтлеге. *Кешенең күкәй күзәнәге овуляциядән соң бер тәүлек үтүгә һәлак була ---.* Кызыклы физиология

ОВЧА́РКА *и. рус* Башта көтүчелектә кулланылган күп кенә токымлы этләрнең гомуми исеме. *Марта инде яше тулып узган киң күкрәкле, зур гәүдәле, сабыр һәм акыллы карашлы нәселле овчарка иде.* Н.Акмалов. *Төннәрен прожекторлар кабына, овчаркалар өргән тавыш ишетелә.* Р.Мостафин. *Овчаркаларны чылбырга эләктер, ят кеше дип, кунакка ташланмасыннар ---.* Н.Гыйматдинова

ОГНЕМЁТ *и. рус* Дошманга якыннан торып һөҗүм итү коралы. *Дөрес, сугыштан соң ук немецлар һәм французлар корткычка каршы тагын да камилләшкән агулар, хәтта огнемёт белән чыгып карыйлар.* Кызыклар дөньясында

ОГУ *ф. диал.* Ишетү. *Аны огып, болар күлмәк тегәргә үзләренә алып киләләр.* Әкият. *[Мешәк алып] --- саескан очмас сары чүлгә чыкты, окты торна тавышын.* Дастан

О́ДА *и. гр.* Нинди дә булса әһәмиятле вакыйга яки берәр атаклы кешегә багышлап, тантаналы, күтәренке тонда язылган мактау шигыре, мәдхия. *Язмалар авыл тормышына ода булып яңгырый.* Ватаным Татарстан

ОДЕКОЛОН *и. фр.* Хуш исле матдәләрнең косметик чара буларак кулланыла торган спирттагы эремәсе. *Одеколон, сабын, теш щёткасы, паста кебек әйберләрен бармак төртеп күрсәтеп кенә җыялар.* Т.Нәҗмиев. *Загранкадан кайткан диңгезчеләрдән кыйммәтле одеколон исе килә.* М.Юныс

ОДЕЯЛ *и. рус* Ябынып яту өчен, тукып, бәйләп һ.б.ш. эшләнгән махсус япма. *Карават та юк, матрас та, одеял да юк, үзегез табыгыз, диделәр.* Ә.Еники. *Егетләр одеялларын аяк очына тибәреп, я булмаса бөтенләй асфальтка ташлап йоклыйлар.* Г.Кашапов. *Мин аны, купега кергәч, йомшак одеалга бәби кебек итеп төреп, вагонның икенче киштәсенә төшмәслек итеп урнаштырдым.* Т.Нәҗмиев

ОДИССЕ́Я *и. гр. кит.* Вакыйгаларга, мажараларга бай сәяхәт; катлаулы хәлләр; мажаралар турындагы хикәя. *Мәгълүмат агентлыклары бөтен дөньяга совет диңгезчеләренең*

одиссеясе турында хәбәр тарапканда, безнең илебездә кагэбэчылар әле һаман --- интектерүләрен дәвам итәләр. Татарстан

ОДОНТОЛО́ГИЯ *и. нем. мед.* Стоматологиянең тешнең төзелешен, физиологиясен, авыруларын һәм ул авырулардан дәвалауны, профилактикалауны өйрәнә торган тармагы

ОЕК *и.* Җептән, йоннан бәйләнгән яисә туладан тегелгән озын кунычлы эчке аяк киеме. *Карт хәзрәтнең кызын --- башында ирләрдән калган мескен бүрек, аягында тула оек өстенә юкәдән үреп ясалган башмаклы иттереп күрү хәйран калдырды.* Г.Исхакый. *Жураның аягында хатын-кызлар оегы иде.* М.Юныс. *Әни чынлап та торган, оек ямап утыра.* Ф.Шәфигуллин

ОЕКБАШ *и.* Кыска кунычлы, балтырсыз оек. *Бер-ике оекбаш я кулъяулык өчен генә күпләрнең әллә кая барып, вакыт уздырып йөрисе килми ---.* М.Маликова. *Урамда инде мине берәү дә куркыта алмый иде, хәтта оекбаштан йөгереп чыккан Рүзәлдән дә көләсем генә килде.* К.Тимбикова

ОЕК-БИЯЛӘЙ *җыйг. и.* Оек һәм бияләйләр. *Авыр түгел ул: бер кадак май да оек-бияләй.* Т.Таһиров

ОЕК-КҮЛМӘК *җыйг. и.* Һәртөрле кием-салым. *Егетнең керләнгән оек-күлмәкләрен шәйләүгә үк, Әнисә һич тарсынмый-нитми барысын җыеп алды, юды, рәткә кертте.* В.Имамов

ОЕКТОТКЫЧ *и.* Оек будыргыч, кереш

ОЕК-ЧАБАТА *и.* Тула яки йон оек белән киелгән чабата. *--- Халык арасында җыен кызыкларны карап йөргәндә, безгә киез эшләпә, ак күлмәк, кызыл ыштан, оек-чабата кигән бер таза-чибәр егет иярде.* Ә.Еники. *Аның өстендә җилкәләре умырылып беткән сатин казаки, билендә керле кызыл пута, бер аягында оек-чабата --- иде.* Ш.Маннур

ОЕКЧАН *рәв.* Оек белән генә, оек кына кигән хәлдә. *Иң тыштагы ишек төбенә җиткәч тә туфлиемны кияргә кыймадым, аларны кулга гына алып, оекчан элдерттем.* К.Тимбикова. *Монда да идәнгә шул үк киез җәелгән, хезмәткәрләрнең һәммәсе, өендәге кебек, оекчан йөри.* Т.Әйди

ОЕК-ЧУ *җыйг. и.* Төрле оеклар, оекбашлар, чолкалар. *Оек-чу сату*

ОЕРЧЫК *и. кулин.* Әстерхан чикләвеге, фындык, көнбагыш төше яки көнжет кебекләрне балга яки шикәргә катырып әзерләнә торган ашамлык. *Оерчык ясау*

ОЕРША *и.* Вак төер (кар, балчык кисәкчекләре һ.б. тур.). *Саранча --- җиргә күкәй сала, күбексыман сыекча бүлеп чыгара, күкәен шуның белән төрә һәм, туфрак кисәкләре белән ябыштырып, махсус оерша ясый.* Якты юл. *Замазка оершалары*

ОЕТКЫ *и.* **1.** 1) Кайнаган сөтне оету, катык хәленә китерү өчен салына торган аз гына катык. *Әче сөт продуктлары пастеризацияләнгән сөткә сөт әчеткеч бактерияләр нигезендә әзерләнгән оеткы салып эшләнә.* Табында сөт ризыклары. *Оеткы тигез бүленсен өчен, тәүлекнең беренче яртысында шешәне берничә мәртәбә селкетеп куярга кирәк.* Файдалы киңәшләр. *Оеткы салган сөт 25–30 минутта оеп җитә.* Юлдаш

2) *күч.* Кемгә дә булса хас булган гадәт яки холыкның йогынтысы, тәэсире. *Үзе алай дип уйламаса да, бүгенге йокысызлык, һичшиксез, шушы оеткының камырны күпертә башлавыдыр, әлбәттә.* Г.Кашапов

3) *күч.* Берәр төрле иҗади эшнең туган идеясе, планы. *Күрәсең, үзендә ниндидер оеткы барлыгын сизгәндер инде.* Ә.Еники

4) *күч.* Коткы. *Укучылар да ышана: акча эшләү «каннарында» булган Алан балалары күңеленә оеткы салу да җитәчәк.* Сөембикә

2. *с. мәгъ.* Оету өчен кулланыла торган. *Оеткы йогыртны башта бераз җылы сөттә сыеклап, бер литр сөткә биш бал кашыгы оеткы исәбеннән, савыттагы сөткә салалар.* Мәдәни җомга

◊ **Оеткы салу** 1) Нәрсәне дә булса башлап җибәрергә этәреш бирү. *--- Сез оеткы салган нинди эшләр озын гомерле булып чыкты?* Сабантуй; 2) Берәр төрле эш башларга фикер, идея бирү. *--- Ә яңгыр әле тиз генә туктарга уйламый, ахры, шулай булгач, вакытны монда гына башваткычлар чишеп уздырыйк. Оеткы салынды инде.* Кызыклы математика; 3) Нәрсә дә булса эшләргә котырту, үгетләү; 4) Икенче бер юнәлеш бирү. *[Жан] аннары, әңгәмәгә күңеллерәк оеткы салуны кирәксенеп: – Жан ике сөйләми! – дип өстәде.* Ш.Рәкыйпов. **Оеткысы төче** Йомшак характерлы, ихтыяр көче, үҗәтлеге җитмәгән кеше турында. *Камыры йомшак шәһәр кешеләренең, оеткысы төче.* Р.Вәлиев

ОЕТКЫЛЫК *и.* **1.** Оеткыга дип әзерләнгән продукт. *Оеткылык бетү*

2. *с. мәгъ.* Оеткыга дигән, оеткы өчен аерылган (сөт продуктлары тур.). *Оеткылык катык алып калу*

ОЕТКЫЧ *и. к.* **оеткы** (*1 мәгъ.*). *Аннан эремчек ясыйлар, оеткыч һәм әчеткеч буларак, тавык ите маринадлау, коймак камыры кую өчен кулланалар.* Мәдәни җомга

ОЕТУ I *ф. з.-сыз* 1) Йокы китерү, йокыга талдыру, изрәтү. *Оета бугай бишекне Баланың җылы пары.* М.Әгъләмов. *– Мендәргә генә утырып килгәндәй килсәм дә, карт сөяк бит, улым, оеткан ахры, – дигән булды карчык ---.* З.Фәйзи

2) Онытылдыру, үз-үзеңне тоймау хәленә китерү. *[Ярашовичның] кына төшерелгән тырнаклары, --- сыгылмалы зифа гәүдәсе, оетып кына йөреше, балдан татлы тавышы нәкъ алиһәләрнеке төсле!* Ш.Рәкыйпов

Оета башлау Оетырга тотыну. *Курай моңы аны оета башлады.* Г.Гыйльманов

Оетып җибәрү Бераз оету. *Әйдә, әнкәй! Әллә юл оетып җибәрдеме?* З.Фәйзи. *Оетып җибәргәндәй итте.* Г.Гыйльманов

Оетып тору Даими оету. *Күңелне оетып тора.* Г.Гыйльманов

ОЕТУ II *ф.* Әчетү. *Катык оеттым. Яратсаң аша.* Ф.Шәфигуллин. *--- Кичләрен хатын-кызларның күңелле итеп сарык савуы, катык оетып, сөзмә, эремчек ясап, корт кайнатып, аны киптереп йөрүләре, аш-су әзерләүне дә үз кулларына алулары аңа үзе бер бәйрәм шикелле тоелды.* Т.Әйди

Оетып җибәрү Бераз оету

Оетып карау Булу-булмавын тикшерер өчен оету

Оетып кую Алдан ук оетып әзерләү

Оетып тору Даими оету

ОЕШ *с.* Кисәк-кисәк булып оешкан, укмашкан. *Оеш кисәкләр*

ОЕШКАНЛЫК *и.* Бердәмлек, бер максатка омтылучанлык. *Бу бөтенлек анда мәгънәнең эчке бер бөтенлеге, аерым өлешләрнең структур яктан оешканлыгы һәм бер-берсенә грамматик бәйләнгән булуы нәтиҗәсендә барлыкка килә.* М.Зәкиев. *Һәр җирдә бердәмлек, оешканлык, хәрби көчкә ышану сизелеп тора.* С.Таһиров. *Оешканлык, бердәмлекнең сере әллә туганлыктамы?* Сөембикә

ОЕШМА I *и.* Иҗтимагый берләшмә яки дәүләт учреждениесе. *Югары оешмалардан килгән җитәкчеләр кисәтү ясап китәләр.* Ф.Яруллин. *Тагын берничә дистә елдан төзелештә дә, партия, дәүләт оешмаларында да эш башында социологлар, идеологлар утырачак!* Р.Вәлиев. *1854 елда Севастополь камалган вакытта Пирогов үз теләге белән «шәфкать туташлары» оешмасын булдыра һәм аның җитәкчесе итеп фронтка җибәрелә.* Ә.Хуҗиәхмәтов

ОЕШМА II *с.* 1) *бот.* Бер төпкә оешып, укмашып үскән. *Мәсәлән, әрекмәннең оешма җимеш дип аталган җимеше – тигәнәге – хайваннар йонына яисә кеше киеменә сарыла ---.* Ботаника. *Тукранбашның оешма чәчәге дару чималы булып исәпләнә.* Иң шәп календарь

2) *лингв. иск.* Ике яки берничә тиңдәш кисәктән торган. *Оешма ия. Оешма хәбәр. Оешма җөмлә*

3) *лингв.* Составында ике элемент булган кушык (тартык авазлар; аффрикатлар). *Оешма тартыклар*

4) *лингв.* Составында тиндәш кисәкләр булган (җәенке җөмлә тур.). *Оешма җөмлә*

ОЕШМАЛЫ *с. бот.* Катмарлы. *Оешмалы чәчәк*

ОЕШМА́ЧӘЧӘКЛЕЛӘР *и. бот.* Чәчәкләре бер төпкә укмашып үсә торган үлән үсемлекләр семьялыгы. *Оешмачәчәклеләр семьялыгындагы кайбер үсемлекләрнең чәчәк төркеме бары көпшәсыман чәчәкләрдән генә тора.* Ботаника. *Оешмачәчәклеләрнең чәчәк төркемен еш кына бер генә чәчәккә исәпләп ялгышалар.* Биология. *Шөлдерутның хуҗалары кыяклылар, оешмачәчәклеләр һәм кузаклылар булырга мөмкин.* Татарстанның үсемлекләр һәм хайваннар дөньясы

ОЕ́Ш-ОЕШ *рәв.* Кисәк-кисәк булып оешкан, кисәкләр рәвешендә. *Ә әрәмәлек өстендә оеш-оеш булып та, сибелеп тә кара ноктalар бөтерелә: куаклар арасында кыр үрдәкләре бала чыгарган, хәзер шуларны зур юлларга әзерлиләр, чыныктыралар.* М.Маликова

ОЕШТЫРМА *и. сир.* 1) Төпле, нигезле, тотрыклы булмаган нәрсә

2) **оештырмалар** *мат. күпл.* Бирелгән элементлардан төзелгән һәм берсе икенчесеннән элементларның составы белән аерылып торган тоташтырмалар

ОЕШТЫРУ *ф.* 1) Иҗтимагый характердагы берәр оешма булдыру, шуңа нигез салу

2) Төрле чаралар белән булдыру, гамәлгә кертү. *Дөньяви мәктәпләрне оештыру белән бергә руханилык белеме алуда да реформалар үткәрелгән.* Ә.Хуҗиәхмәтов // Берәр максат белән күмәк рәвештә нәрсә дә булса үткәрү, ясау. *Турнирларны корольләр һәм аксөяк феодаллар оештыра.* Урта гасырлар тарихы. *Чыршы бәйрәмнәрен оештыру һәм кабул итү комиссиясенә мине дә кертәләр.* Т.Нәҗмиев. *«Тиктомалдан ат суеп булмас иде, чәчүгә чыгучылар өчен берничә көн кайнар аш оештырырбыз», – дигән иде [Самат].* Г.Галиева

3) Туплау, берләштерү; нинди дә булса эшкә, оешмага җәлеп итү. *Җыр берләштерә, җыр оештыра, җыр эшне тәртипкә салып, көйләп тора.* М.Юныс. *Яздан ук алар, ике авыл яшьләрен оештырып, «Галиябану» пьесасын сәхнәгә куярга булдылар.* Т.Таһиров

4) Билгеле кагыйдә, принциплардан чыгып җайлау, күзәтеп тору. *Килдебәковның өлгерлегенә сокланuын белдереп: «Син эшне ничегрәк оештырасың соң?» – дип кызыксынды ул бер көнне.* Г.Гомәр. *[Зәйни] Матур итеп, күңелләр ашкынырлык итеп оештырды эшне.* Г.Ахунов. *Эшне тиешенчә оештырсаң, алтын һәм асылташларны көрәп алырга мөмкин – бер генә миллионлык булмас.* З.Фәтхетдинов

5) Вак кисәкләрне бергә җыю, өю яки ябыштырып кушу, укмаштыру. *Учактагы күмерләрне оештыру*

6) Башлап җибәрү. *[Неделин] үзгәртеп кору елларында уңышлы гына итеп бизнес белән шөгыльләнә башлаган, үз эшен оештырган ---.* Р.Мирхәйдәров

7) Кисәкләрдән бөтен ясау, берәр әйбер эшләү; тезү. *--- Аны [якорьны] 0,3–0,5 мм калынлыктагы аерым-аерым корыч пластинкалардан оештырып ясыйлар.* Физика курсы

8) Нәрсә дә булса хәстәрләү, әзерләү. *Көз көне мин тегеләй итеп, болай итеп үземә «командировка» оештырып, Балтачка бардым ---.* М.Мәһдиев

9) Билгеле бер тәртипкә кертү, җайга салу. *Пушка белән яулап алганнан соң, әле тормышны оештыра белергә дә кирәк.* Мирас

10) Тәртипкә салу, тиешле рәвешкә китерү. *Үзебезне чын күңелдән яратканда һәм хөрмәт иткәндә, акылыбыз һәм эшебезне билгеле бер рәвештә оештырабыз.* Иң шәп календарь

11) Хәрефләрне, сүзләрне кыенлык белән кушып уку, сөйләү // Сөйләү, фикерне эзлекле итеп формалаштыру һәм җиткерү. *[Таукашның] --- хатынына нигезле җавап оештырырга зиһене җитмәде.* М.Хуҗин. *Хәбәр итүне сөйләүче чынбарлыктан алып оештыра ---.* М.Зәкиев. *Ә бу инде үз чиратында укучының әйтәсе фикерен оештыра белмәвенә китерә.* Мәдәни җомга

12) Язу, язып әзерләү, бастыру (мәкалә, рецензия һ.б.ш). *Юбилей уңае белән Тел һәм әдәбият институты һәм Язучылар союзы күп кенә темага гыйльми тәнкыйть мәкаләләре оештырдылар.* М.Җәлил

Оештыра башлау Оештырырга тотыну. *Сорыйбыз: нигә үз белдегегез белән экспозицияне ваттыгыз да анда бүтән төрле күргәзмәләр оештыра башладыгыз?* Ф.Яхин

Оештыра төшү Бераз оештыру

Оештырып алу Тиз генә оештыру. *Киресенчә, аның кашлары шатлыктан урын тапмый маңгаена сикерде, һәм ул, --- ашыгыч кына булса да, чәй мәҗлесе оештырып алды.* А.Хәлим. *Хәлләреннән килгәнчә туй кебек нәрсә дә оештырып алгандай иттеләр.* М.Хәсәнов

Оештырып бетерү Тулысынча оештыру

Оештырып җибәрү Оештырып эшне башлау. *Дәресләрнең күплегенә карап тормадык, Сибгат Хәким һәм Габделхәй Хисмәтуллин булышлыгы белән әдәбият сөючеләр түгәрәге оештырып җибәрдек.* Ф.Ибраһимов. *Хатын җиләк-җимеш һәм яшелчә консервлап, үз бизнесын оештырып җибәрә.* Мәдәни җомга

Оештырып җиткерү Тиешле дәрәҗәдә оештыру

Оештырып йөрү Оештыру эшләре белән мәшгуль булу. *Аны А.Шамов бик ошаткан һәм, әдәбият музее белән сөйләшеп, музейда шул темага Дания Баһаветдинова белән бергә конференция дә оештырып йөргән иде ---.* М.Мәһдиев

Оештырып килү Билгеле бер вакыт дәвамында оештыру. *Ә «Сәләт» андый укуларны 2001 елдан бирле оештырып килә.* Мәдәни җомга. *Без дә аның истәлегенә турнирлар оештырып киләбез.* Туган як

Оештырып кую Тиз арада яки алдан оештыру. *Степан бабай участкагы күмерләрне оештырып куйды.* Э.Касыймов. *Мичтә чарт-чорт килеп ак чыршы утыны яна, ул, тезләре башына куеп, минем диктантны тикшерә һәм, хатама озак-озак тукталып, мине сүтә, тарата, аннан тагын җыеп оештырып куя иде.* М.Мәһдиев

Оештырып ташлау Бик тиз оештыру

Оештырып тору Даими оештыру; оештыру белән шөгыльләнү. *Авыл советы әйбәт кенә эшләп килгәч, аны оештырып торуның хаҗәтен күрмибез.* В.Нуруллин. *Наил, концертларыңны еш кына оештырып торасың.* Өмет

Оештырып утыру *к.* **оештырып тору**. *Аның иҗеген-иҗеккә китереп оештырып утырырга минем вакыт [юк].* Р.Ишморат

Оештырып чыгу Тиешле дәрәҗәдә оештыру. *Ләкин дистәләрчә мең кешене оештырып чыгарлык ультрауң, милләтчел берләшмәләр бу көнгә кадәр нигә тыныч кына эшләгән соң?* Безнең гәҗит

Оештырып яту Оештыру процессында булу. *[Җитәкче кеше монда] очрашулар оештырып ята.* Ф.Галиев. *Бу нинди кәмит оештырып ятасыз монда? Ә?!* И.Зәйниев

ОЕШТЫРУЧЫ *и.* Берәр эшне башлап йөрүче, булдырырга тырышучы кеше. *Төп оештыручы булган Насыйбуллин, Ишмурзин, Душкин һәм башкорт егете Азнабаевларны, ике сөйләшеп тормыйча, мәктәптән сөрделәр.* Р.Мөхәммәдиев. *Оештыручылар «Беренче канал кубогы»н оештырудан баш тарткан*. Ватаным Татарстан. *Фестивальне оештыручылар аны халыкара дәрәҗәгә күтәрү турында хыяллана.* Мәдәни җомга // Оештыру эшләренә сәләтле кеше. *Мефодий, яхшы оештыручы буларак, ун елга якын Византия өлкәләре белән идарә итә ---.* Урта гасырлар тарихы

ОЕШТЫРУЧЫЛЫК *и.* Нәрсә дә булса оештыруга юнәлтелгән эшчәнлек

ОЕШТЫРЫЛЫШ *и.* Нәрсәнең дә булса төзелеше, төзелеш яки эшләнеш формасы; оештыру үзенчәлеге, дәрәҗәсе. *Берлек үзе дә соңгы елларда кадрлар һәм оештырылыш ягыннан ныгыды, матди-техник базасы яхшырды*. Татар-информ

ОЕШУ I *ф.* **1.** 1) Барлыкка килү, төзелү (берәр иҗтимагый оешма, берләшмә, учреждение, дәүләт тур.). *Әллә берәр яңа секта оешканмы?* М.Маликова. *Искә төшерик, ГУАМ узган гасыр ахырында демократик үсеш юлын сайлаган дәүләтләрнең төбәк берлеге буларак оешты.* Мәдәни җомга. *Заманалар үзгәрә, дәүләтләр оеша һәм таркала ---.* Р.Әхмәтьянов

2) Нинди дә булса максат белән берләшү, бергә туплану. *Оешмаган халык – көтү, Аны һәрчак кирәк көтү.* Ә.Синугыл-Куганаклы. *Бушлай сыр тәбедә генә була, дисәләр дә, ашау дигәндә без оешкан халык бит инде.* Т.Нәҗмиев. --- *Ислам дине һәм мәдәнияте яшәешнең барлык өлкәләрендә, халык булып оешу һәм үсеш процессында бик зур роль уйнаган.* Мәдәни җомга

3) Бергә ябышу, укмашу, камыр, замазка кебек хәлгә килү (таркау кисәкләр тур.). *Квадрат рәвешендәге дәү тимер ящиклар рәтендә ишек-бусага, такта-плинтус, плитә һәм измә, гәҗит калдыклары өем-өем оешып ята иде.* Р.Низамиев. --- *Краб зур ташлар һәм оешкан балчыклар аркылы атлый гына бирә, аңар аларны атлап үтүнең кирәге юк.* Диңгез тирәлегендә

4) Җыелып килү. *Ул башмагын салып, бармак тирәсендә оешмаганмы дип, оек кунычларын тартып-тартып карады, кат-кат какты: «Вак таш тәгәрәп кермәгәнме?»* А.Гыйләҗев

5) Чуалу, киезләнү (чәч, йон тур.) *[Рахмановның] төркем-төркем булып оешкан озын сары чәчләре, үзләренә башка җаннары бар шикелле, өзлексез хәрәкәтләнеп тора.* М.Әмир

6) Кисәкләрдән бөтен хасил булу, ясалу. *Кабарган болытлар оешып тыгызлансын гына, дөнья мунча керәчәк!* Н.Гыйматдинова // Бергә аңлаешлы булып туплану. *Уйлары да бер оеша, бер тарала аның.* М.Маликова. *Карар бик күп вакытта шул фикер тирәсенә оеша.* Ф.Әмирхан. *Сөйләшүдә ачык эзгә төшкән икенче яссылык --- прозаның үсеш тенденцияләрен билгеләргә, прогноз ясауга омтылудан туган уйланулар рәвешендә оешты.* А.Әхмәдуллин

7) Бер тирәгә җыелу, өелешү, туплану. *Мескеннәр, булдыксызлар күбрәк бергә оеша.* Н.Гыйматдинова. *Умарта кортлары һәм кырмыскалар кимендә 25 зат булып оешырга тиеш.* Кызыклы физиология // Бергә килү. *Телебездәге гарәп һәм фарсы сүзләре орфографик мәсьәләләргә бераз катлаулылык кертәләр, тик алар да күп җәһәттән төрки сүзләргә охшаш (мәсәлән, тартыкларның сүз башында күпләп оешып килә алмавы һ.б.) булганлыктан, язма телебезгә диссонанс кертмәгәннәр.* Р.Әхмәтьянов

8) Формалашу. *Нуһаять, җир өстендә булган хәзерге тере табигатьне*

характерлаучы тереклекнең барлык төрле өлкәләре оешкан. Тереклек һәм аның җир йөзендә таралышы. *Өермә эчендәге һавасы сирәкләнгән бушлыкка килеп эләккәч, су парлары тамчылар булып оешалар* ---. Дөньяда ниләр бар

9) Сизүчәнлеген, хәрәкәтчәнлеген, сыгылмалылыгын югалту (тән әгъзалары тур.). *Йомшак тәннәр оешып, Эшләп каннар саугачтын, Ягез инде уйнарга, Иркен һава суларга.* М.Җәлил

10) Куеру, тыгызлану. --- *Бик каты тирләгән бит ул, каны оешып, бөтенләй хәлсезләнеп китүе бар...* В.Нуруллин. *Ул [күнегү] тамырларда кан йөрешен яхшырта, кан оешып тыгылуына ирек бирми.* Иң шәп календарь

11) *күч.* Ялгану, бәйләнү, берберсенә туры килешү. *Сүзләр, җөмләләр бер-берсе белән оешмау*

12) *күч.* Тиешле дәрәҗәгә, осталыкка җитү. *Аның [балалар әдәбиятының] тәнкыйтьчеләре, оешкан тудыручылары юк.* Ф.Кәрим

13) *күч.* Бербөтен хәлгә килү, тиешле дәрәҗәдә эшләнү (сәнгать әсәрләре тур.)

2. оешып *рәв. мәгъ.* 1) Күмәкләшеп, бергә. *Авыр операция вакытында табибларның бер йодрык сыман булып оешып эшләве мөһим.* Өмет

2) Кузгалмыйча, хәрәкәтсез калып. *Тик тауны күчереп буладыр, оешып утырган болганчык томанны күчерү түгел, кузгатып та булмый икән.* М.Маликова

◊ **Оешып җитмәгәнлек** Тиешледән кайтыш булу, таркаулык. *Аның кызын кулларында тотканына карап, мин көлә идем, оешып җитмәгәнлеген күреп кызгана идем.* З.Садыйков

Оеша бару Торган саен оешу

Оеша башлау Оешырга тотыну. *Республикабызда мәктәп урманчылыклары 1968 елда оеша башлый.* Сабантуй

Оеша язу Аз гына оешмыйча калу

Оешып бару Оешу процессында булу. *Татарстанда яңа хакимият оешып бара.* Безнең гәҗит

Оешып алу Тиз арада оешу. *Монда алар бер иш оешып алганнар инде, араларына бүтәннәрне кертмиләр.* М.Маликова. *Оешып алган мужиклар, яше-карты, патша куштаннарын авылдан сөреп чыгарырга кереште.* М.Мөхәммәдиев. *Алар анда төркем булып оешып алдылар.* З.Зәйнуллин

Оешып бетү Тулысынча оешу. *XV йөз башларында Алтын Урданың таркалуы татар халкының шәкелләнеп оешып бетүенә комачаулый* ---. Р.Фәхретдинов. *Кайберләре, көзге җил агач ботакларыннан йолкып-йолкып алган коры яфраклар сыман, кыштыркыштыр арлы-бирле талпындылар, тик билгеле бер фикергә оешып бетә, укмаша алмыйча тузгып, чәчелеп беттеләр.* Ә.Гаффар

Оешып җитү Тулысынча оешкан хәлгә килү. *Әдәби планкаларны елдан-ел түбән төшерә бару аркасында, роман булып оешып җитмәгән язмалар саны елдан-ел туктаусыз арта тора.* Казан утлары. *Бүтән көннәрдә табын оешып җитми: кайсы – кайта, кайсы китә тора иде.* М.Хуҗин. *1905 елның көзенә таба оешып җиткән «Әльислах комитеты»н күздә тотып, ул болай ди: «Бу татар социал-демократлары тәэсирендәрәк барырга тырыша иде».* И.Нуруллин

Оешып килү Соңгы вакытта, яңарак кына оешу. *Әртил – яңа эш, әле оешып кына килә* ---. Я.Зәнкиев. *Әмма әлеге репутация дигән нәрсә шундыйрак оешып килә синең турыда.* Р.Төхфәтуллин. *Инде урам булып оешып килгән йортлар арасыннан үтеп, озын-озын тәпиләргә менеп кунаклаган тугыз катлы йорт каршына килеп туктадылар.* Р.Вәлиев

Оешып китү Әкренләп яки билгеле моменттан оешу. *Пенсиядә ятып, сөякләр генә оешып китмәгән булса, бүтәненә кайгырган юк.* Ф.Яруллин. *Бу фермада ике сменалы эш шунан оешып та китте.* Казан утлары. *Сөйләшү оешып китмәде.* М.Хуҗин

Оешып кую Тиз арада оешу

Оешып тору Даими оешу; оешкан хәлдә булу. *Авыздан бөркелеп чыккан пар тиз генә таралмый, беразга оешып тора.* М.Маликова. *Сыер һәм бозау ите әгъзаларда кан оешып торуны яки артык күп килүне бетерә.* Серле календарь. *Тугайлы болынында оешып торган таллыклар төркемләшеп серләшәләр кебек тоелса, анда-монда кочаклашып үскән ялгыз карамалар моңсуланып уйга талганнар кебек.* З.Фәйзи

Оешып яту *сөйл.* Оешу процессында булу. *Көз бозлар катып, Оешып ятып, Чишмәкәй шымды, Бар җиһан тынды.* Дәрдемәнд. --- *Шул елны Татарстан Матбугат йортына, оешып яткан Культура төзелеше институтына Максим Горький исеме бирелә.* М.Мәһдиев

ОЕШУ II *и.* Канның куеру сәләте. *Кара миләш аппетитны ача, канның оешу сәләтен арттыра.* Акчарлак

ОЕШУЛЫ *с. сир.* 1) Алдан әзерләнеп, тиешле дәрәҗәдә оештырылган

2) Берләшкән, оешкан, берәр оешма составына керә торган

ОЕШУЧАНЛЫК *и.* Берәр нәрсәнең оешу сәләте. *К витамины канның оешучанлыгын тәэмин итә.* Мәдәни җомга. *Караҗиләк составында канның оешучанлыгын киметүче матдә барлыгы да ачыкланды.* Таң

ОЕШЫК *с.* 1) Бергә укмашкан, оешкан, чәбәләнгән

2) *диал. күч.* Тыныч, талгын. *Башня сәгате торып-торып өч мәртәбә сукты... Оешык тынлыкны кузгаткан аның моңлы тавышлары әллә кайларга озаеп бара иделәр...* Ш.Камал

ОҖМАХ *и.* 1) Җәннәт

2) *күч.* Тыныч, җайлы, уңайлы урын; иркен, мул тормыш. *Өйләре – җылы, якты оҗмах оясы.* З.Кадыйрова

◊ **Оҗмах байлыгы** Иксез-чиксез байлык

ОҖМАХ КОШЛАРЫ *и. күпл.* 1) *зоол.* Чыпчыксыманнар отрядыннан башлыча тропикларда яшәгән һәм бик матур ялтыравыклы каурыйлары белән аерылып торган кошлар семьялыгы; *русчасы:* **райские птицы**

2) *күч.* Гөнаһсыз сабый балалар (үлгәч әйтелә)

3) *күч.* Беркатлы, ышанучан кешеләр

ОҖМАХЛЫ *с.* Оҗмахка керергә лаеклы, җәннәтле

ОЗАГАЙТУ *ф. диал.* Вакытны, юлны сузу, дәвамлы итү. *Мин үзем дә, кешелек бара торган юлны озагайту*

өчен, аның дәвамында үземнең йөрәкне дә бер таш итеп сала алсам, дим. М.Маликова

Озагайтып тору Озагайту хәлендә булу. *Аны сузып, озагайтып торуның ни мәгънәсе бар?* Ә.Гаффар

ОЗАЙТКЫЧ *и.* **1.** Электр приборларын ераkта торган розетка белән тоташтыру өчен, озын электр шнурдан гыйбарәт махсус җайланма. *Берничә розеткалы озайткыч*

2. *с. мәгъ.* Озайту өчен хезмәт итә торган. *Ике яшь кыз җәһәт кенә кардиограмма ясарга ниятләгән иде дә, теге «тройник» дип аталып йөртелә торган озайткыч шнурны эзләп алып килергә хәлем булмады.* Безнең гәҗит

ОЗАЙТМА *и.* Озынайтылган яки ялганган өлеш

ОЗАЙТУ *ф.* 1) Озын иттерү, озынлыкка сузу // Сузу, кая да булса юнәлтү (кул тур.)

2) Нәрсәнең да булса срогын арттыру, дәвамлырак иттерү. *Әмма табигать хатын-кызны нәсел озайту өчен яраткан* ---. Н.Гыйматдинова. *Туктап-туктап төшә сары яфрак, Манчылган да көзнең төсләренә. Озайтмакчы булып гомеркәен, Килеп куна чыршы өсләренә.* Р.Низамиев. *Утыз ел буе ике якын дустың белән бәйләнештә булу кеше гомерен биш елга, ә шундый дүрт дустың булу җиде елга озайта.* Кызыклар дөньясы

3) Озакка сузу. *Эшне озайту*

4) *сөйл.* Озакка калдыру, озаклату. *Барган җирдән хат язармын, Тиз җавап бир, озайтма.* Җыр

Озайта башлау Озайтырга тотыну

Озайта тору *к.* **озайтып тору**. *Чөнки зәркәнче, кырык төрле сәбәп табып, үтәлү сроkларын озайта тора.* Безнең гәҗит

Озайта төшү Бераз озайту

Озайтып бетерү Бик озын итү; тулысынча озынайту

Озайтып җибәрү Көтмәгәндә озайту

Озайтып йөрү Озайту процессында булу

Озайтып кую Кинәт озайту

Озайтып тору Даими озайту

ОЗАЙТЫЛУ *ф. төш. юн. к.* **озайту**. *Тик озайтылган көн дигән төркем ачылгач, шунда бирделәр дә баланы, өйгә йокмый хәзер.* Ә.Әминев

ОЗАК *рәв.* **1.** 1) Күп, дәвамлы вакыт эчендә. *Ләкин шушы хыял кочагына гына сыярлык болында җаныңа якын чәчәкне озак тапмый йөрисең.* Ф.Яруллин. *Чәчәк исе озак тормый, Озак торган – кунак булмый.* Ә.Сингыл-Куганаклы. *Озак кына сүзсез утырабыз.* Ф.Яруллин

2) Ерак, озын. *Юл озак булды*

3) *сөйл.* Әкрен, ашыкмыйча. *Эшне озак эшлисең*

4) *күч.* Озын, тәфсилләп, җентекләп. *Озак сөйләү*

2. *с. мәгъ.* 1) Саны, дәвамлылыгы ягыннан күп булган, байтак. *Озак сроклы кредит күбесенчә капиталь төзелешләргә хезмәт күрсәтә.* Политэкономия

2) Күп вакыт сорый торган, ерак

ОЗАККА *рәв*. 1) Озак вакытка. *Озакка бармый Тынлык сугышта, – Җай гына эзли Аяусыз дошман.* Ф.Кәрим. *Ак каурыйның ап-ак төсе Сакланырмы озакка?* Ф.Яруллин. *Хис җиңүе вакытлыча, фикер җиңүе озакка шикелле.* Ш.Галиев. *Озакка сузылган бәйрәм түйдыра.* М.Юныс

2) Еракка, ерак киткәнче. *Шәкертләр аларны күзләре белән шактый озакка кадәр озатып калдылар.* Ф.Әмирхан

◊ **Озакка бару** Дәвамлы, гомерле булу. *Тик бу бәхет озакка бармады.* Х.Камалов. *– Менә бандитлар белән исәп-хисапны төгәллибез дә кайтабыз туган якларга. Инде озакка бармас, – диде икенче солдат.* Н.Дәүли. **Озакка җибәрү** *к.* **озакка сузу**. **Озакка китү** 1) Күп вакытка сузылу, тартылу. *[Ярасы] Озакка китсә, дәвага сучәкән үләнен ничек тә эзләп табарбыз.* М.Хужин. *Сүз көрәштерү шактый озакка китте.* Ф.Яруллин; 2) Озын, зур күләмле булу. **Озакка сузу** Күп вакыт сарыф итү. *Хөрмәтулланың сүзне озакка сузарга исәбе юк иде* ---. Ф.Яруллин. *Мин озакка сузмыйча министрлыкка киттем.* Ф.Яруллин

ОЗАККА́ЧА *рәв*. Озак вакытка чаклы, озакка чаклы

ОЗАКЛА́МЫЙ *рәв*. Тиздән, якын арада, күп тә үтмичә. *Озакламый ул кулына конвертлы хат тотып кире чыкты.* Ф.Яруллин. *Озакламый таң атар инде.* Ш.Рәкыйпов. *Озакламый язгы ташулар башлана.* В.Нуруллин. *Озакламый безгә дигән көмеш кораб әнә теге причалга килеп тукталачак.* М.Юныс

ОЗАКЛА́МЫЙЧА *рәв. к.* **озакламый**. *[Габбасовка] озакламыйча җитмеш булачак.* А.Шамов

ОЗАКЛАП *рәв.* Озак итеп, шактый вакытка сузып яки сузылып. *Башта, кайта-кайта, бик озаклап күк күкрәде, аннары шыбырдап яңгыр яварга кереште.* Г.Бәширов. *Шулай озаклап утыруының тагын бер сәбәбе бар: Фәләхкә Розаны ничек булса да көйләргә кирәк иде* ---. В.Нуруллин. *Әллә эчелгән хәмер телен чиште, әллә Хәйдәр алдында иркенләп мактанасы килде, башлаган сүзеннән туктала алмыйча, Миңнехан озаклап шапырынды* ---. В.Имамов

ОЗАКЛАТУ *ф.* Озакка, күпкә сузу

Озаклата төшү Бераз озаклату

ОЗАКЛА́У *ф.* 1) Озак маташу, иркенләү, озакка сузу. *Мөкә бай озакламас, дөнья куяр.* Я.Зәнкиев. *Тик ниишләп озаклады әле ул?* Н.Гыйматдинова. *– Сез анда нәрсә озакладыгыз, нигә өйгә кермисез? – дип кычкырды сержант, өй ишеген ачып.* Ә.Галиев

2) Озак килмичә, кайтмыйча тору. *--- Үзем көтәм мин аны, берәттән мунча да кереп чыгар, озакламасын, юкса минем характерны белә ул, диде [әти]...* Ф.Шәфигуллин. *Әйткән иде ул соңгы кат: «Тагын кил, озак торма!» Озакламадың, килдең син. Бу юлы – озатырга.* Р.Миңнуллин

Озаклый башлау Берникадәр озаклау сизелү, беленү

Озаклый төшү Бераз озаклау

ОЗА́К-ОЗАК *рәв.* Бик озак итеп, озаклап. *Искәндәр мондый төндә озак-озак сөйләшергә ярата.* М.Мәһдиев. *Ишек кыңгырауларына бик озак-озак басуга карамастан, эчтә тавыш-тын ишетелмәде: йоклаганнар, ахры, дип уйладым.* Ф.Яруллин. *Давыллаганда, мин дулкын шавын тыңларга яратам, тын чагында суга озак-озак карап торам.* М.Маликова

ОЗАКСЫНУ *ф.* Озак дип санау, озак булып тоелу. --- *Базилефс сарациннар*

белән сугышка киткән, улы Юстиниан, син куйган вакытны озаксынып, Фанәгүргә кузгалырга җыена икән. М.Хәбибуллин

Озаксына башлау Озаксынырга тотыну

Озаксына төшү Бераз озаксыну

Озаксынып йөрү Күптәннән бирле озаксыну

Озаксынып тору Хәзер, әле озаксыну

ОЗАН *и.* Ата көртлек. *Кооперативтан бер берданка алып, --- көзен озанга киттем.* Ш.Маннур

ОЗАТКЫЧ *и. этн.* 1) Киндер сукканда, буйлык җепләрне җайлап сузу, озату өчен, чөйләр кагып эшләнгән махсус стан

2) Кәләшне егет йортына озата килүчеләр

ОЗАТМА *и.* Туку станына корырлык итеп, билгеле бер озынлыкта хәзерләнгән җеп

ОЗАТУ I *ф.* 1) Аерылышканда, саубуллашканда, китүче белән бераз вакыт бергә бару. *Безнең беребез сугышларга китте, Беребез калды озатып, кул болгап.* Ә.Ерикәй. *Беркөнне завклуб Фирдәүсәне озата кайткан, ди.* Ф.Шәфигуллин. *Озата килгән дуслар белән озатышып йөргәнгә, урын буш булган.* Р.Муллануровa

2) Саубуллашу, аерылышу. *Казанда мине җылы каршы алдылар һәм бик зурлап озаттылар.* М.Җәлил

3) Кая да булса илтү, алып бару (юл күрсәтеп, ярдәм итеп, саклап, күзәтеп). *Җиде ай лазаретта яттым. Күннән, агачтан, резиннан миңа аяк ясадылар. Озатырга бер солдат бирделәр.* Г.Ибраһимов. *Атна-ун көн дигәндә Илдар, мәктәп атын җигеп, әнисен станциягә озатып китте.* Г.Гобәй

4) Кая да булса куу, куып алып бару (маллар тур.). *Малларны көтүгә озату*

5) Зиратка алып барып җирләү (үлгән кеше тур.). *Без бүген халык шагыйре Тукайны озатабыз.* Ф.Әмирхан. *Кеше, кызым, үз гомерендә җиде кешене гүргә озатсын, дигән, ә мәшәкать димәгән.* Ә.Гаффар. *Дәүләкәннең беренче комсомолын бик зурлап җирләгәннәр, бөтен яшьләр, бөтен мәктәп укучылары озата барган ---.* Ә.Еники

6) Берәр төрле максат белән кая да булса җибәрү; барырга мәҗбүр итү. *Интернатка озатырмын әле, бел!* Н.Гыйматдинова. *Ничек кенә аны измәделәр: Зинданнарга аны яптылар, Этапларда аны озаттылар ---.* Р.Вәлиева. *Шунысын да әйтәм: дәвалау курсын үтеп чыккач, хәрби өйрәнүләргә озатам мин сине.* Б.Камалов

7) Кызны кияүгә бирeп җибәрү. *[Карлыгач:] Ай ярымнан, туй кылып, мине озатырга телиләр.* Г.Ибраһимов

8) Китүче кешене кирәкле нәрсәләр белән тәэмин итеп, булышып яки бу вакыйганы махсус билгеләп, юлга чыгару. *– Мин аны Җәмилә янына җибәрәм, – диде Сөембикә. – Мөхәммәдьяр утарына озатам үзләрен.* М.Хәбибуллин. *Әгәр киләчәген кайгыртса, үстергән бер баласын таш калаларга озатыр идеме ул?* Н.Гыйматдинова. *Озатмагыз мине ерак юлга, Үзем чыгып, үзем кайтырмын.* Л.Юнысова

9) Китүче, яннан үтүче, чыгыш ясаучы кешегә карата мөнәсәбәт белдерү. *Мыскыллы караш белән озату*

10) Китүче, ерагаючы кем яки нәрсәне игътибар белән күзәтү, карап калу. *Барлык хезмәткәрләр, апалар [ана белән баланы] күздән югалтканчы озатып калдылар.* Г.Минский. *Сабый бала аны [чебенне] ятканда ук күрә, стена буйлап барганын елтыр күзләре белән карап озата.* Ә.Халидов. *Төнки хыянәтчене мәктәптән ун пар күз озаткан!* Н.Гыйматдинова

11) Билгеле бер урынга нәрсә дә булса җибәрү (йөккә, машинага төяп). *Директор соңгы грузовигын Икмәк белән юлга озата.* М. Җәлил

12) Чыгарып җибәрү (килгән, кергән кешене). *Губернатор, картны көч-хәл белән тынычландырып озаткач, үз янына полицмейстерны чакырып алды.* К.Нәҗми. *Бай хатыны булгач, килгән кунакны буш кына озатырга ярамый бит.* Ш.Мөхәммәдев

13) Эштән азат итү. *Бюрода аны учёт карточкасына каты шелтә язып озаттылар.* В.Имамов. *Егерме өч көннән майор Гавриловны гражданкага, запаска озаттылар.* З.Зәйнуллин

14) *махс.* Буйлык җепләрне, туку станына кору өчен, озаткычка чорнау. *Ак укадан җеп озаттым Бер бөртеге калганчы.* Җыр

15) Тиз, өсте-өстенә кабу, йоту. *Ашны, коймакларны, барлык тәмтомны авызга озатырга*

16) Кулланылыштан алу, юкка чыгару

17) *күч.* Кемнең дә булса артыннан ияреп баргандай булу. *Аны хәтта авыл этләре дә өреп озатмады.* Н.Гыйматдинова. *Кояшның мине озата баруы микәнни: юл читендәге имәннәр белән куыша-куыша поезд артыннан йөгерә ул.* Р.Низамиев

18) *күч.* Үтерү. *Орден алды ул Төз аткан өчен, Өч йөз фашистны Озаткан өчен.* Ф.Кәрим

19) *күч.* Яшереп, урлап тиешсез урынга җибәрү, кемгә дә булса бирү. *Шомарак, саграклары исә алтынкөмешне чикнең теге ягына ук озатырга маташты.* З.Фәтхетдинов

20) *күч. сөйл.* Нәрсәнең дә булса тәмамлануын, ахырын билгеләп үтү, шул уңай белән тантаналы кичә, мәҗлес, күңел ачулар оештыру. *Кышны озату. Иске елны озату* // Пенсиягә китүче кешене хөрмәтләү мәҗлесе, кичәсе үткәрү. *Күпме еллар Марго янәшәсендә --- биегән Майкл Сомсны әле шушы арада гына ялга озаттылар.* Р.Вәли. *Еллар узган. Туктал, дигәч, Оста аптырап калган... Мактап-мактап озатканнар Аны «лаеклы ялга».* Ш.Галиев. *Пенсиягә озату*

Озата бару Даими кабатлану, гел булу. *Узганнарның үкенеч ялкыннары Озата бара мине гомергә.* Ш.Маннапов. *Очам, очам, әлеге музыка мине һаман озата бара.* Р.Вәлиев. *Менә район Советы депутаты вазифасы да егерме ике ел озата бара үземне.* Т.Нәҗмиев

Озата башлау Озатырга тотыну. *Бомбардировщикларны свалкага озата башладылар.* М.Юныс. *Егетләр дә үз кызларын курыкмыйча озата башладылар.* Ф.Яхин. *Бу кырда эшләр беткәч, сенажга массаны күпьеллык үлән басуыннан озата башлыйлар.* Әлки хәбәрләре

Озата килү *к.* **озата бару**. *Чарльстоннар, роклар, джазларны Чәчрәп чыгып якладым мин. Тик артымнан гел озата килде Мине тик Мин иткән «Баламишкин».* Г.Рәхим. *Инде башлык кабинетына таба барганда, Шамилне, корт күче сыман сарылып, уйлар озата килде.* З.Фәтхетдинов

Озата тору Бер-бер артлы һәрберсен озату. *«Татарстан» кунакханәсе администраторы аның соравына җавап та бирмәде, кемнәрнедер елмаеп, хәтта басып кабул итә торды, Мисыр күгәрченедәй сөйләшә торды, көлеп озата торды.* Ф.Садриев. *Авылыбыз көн саен фронтка ирләрне озата торды.* Ф.Галиев. *Дөньяның кайсыдыр бер читенә килеп урнашкан зиратка охшаган төбәк бу кешеләрне бишектән алып кабергә кадәр әледән-әле озата торыр иде.* Н.Дәүли

Озатып бару *к.* **озата бару**. *Гомер буе озатып бара безне Бәйрәмнәрнең керсез ак төсе.* Х.Әюпов

Озатып бетерү Барысын да озату. *Тик бераздан ай, гашыйкларны озатып бетердем, инде әз-мәз черем итеп алсам да ярыйдыр, дигәндәй, болытларга төренеп йокларга ятты.* Ф.Яруллин. *Ул --- фермадагы мал-туарны төрле хәйләле юллар белән шәһәрдәге ит кибетләренә озатып бетерде.* Ф.Яхин

Озатып җибәрү Әзерләп озату. *Син күзгә-башка чалынмассың, үзем озатып җибәрермен.* М.Маликова. *Шуны озатып җибәргәннән соң ант итәрсең.* М.Юныс. *Кыз егетне озатып җибәрде.* Әкият

Озатып йөрү Озату эше белән мәшгуль булу. *Пароход төнлә генә килә, озатып йөрмә, дип күпме әйттем.* Ә.Хәсәнов. *Сәүдә кәрваннарын озатып йөрү бәхетен татыган берничә сәйях ир авыз суларын корытып тасвирлады.* В.Имамов. *Үзләрен һичшиксез озатып йөреячәк КГБ шымчыларына артык мәшәкать тудырмас өчен, башта әлләни ерак китеп тормадылар [алар].* Р.Вәли

Озатып калу Калган җиреннән озату. *Равил абый! Иң элек сиңа бик күп сәлам озатып калам.* В.Нуруллин

Озатып кую Тиешле урынга кадәр яки тиз генә озату. *Таң атып, агач башында төн үткәргән кошлар күңелле чекердәшә башлагач кына, Закир үзенең Разиясен озатып куя.* И.Гази. *– Мин сине өеңә кадәр озатып куям, яме, – диде Санька.* Ф.Латыйфи

Озатып тору Даими, әледән-әле яки хәзер озату. *Гәрәй белән Гриша кызылгвардеецларны, көймәләргә урнаштырып, аргы якка, Андрей Петрович отряды сугыш алып барган турыга озатып тордылар.* К.Нәҗми. *Разъезд һәр көнне йөзләгән кешене көнчыгыштан һәм көнбатыштан кабул итә дә ике якка – Арча һәм Саба ягына озатып тора.* М.Мәһдиев. *Бабамыз Ягъкуб урыслардан җыйган ясакны Казанга озатып тора.* М.Хәбибуллин

Озатып яту Даими озату. *Бу читтән торып укучылар имтихан алучыларына я каз түшкәсе, я капчыгы белән бәрәңге озатып яталар ---.* К.Тимбикова

ОЗАТУ II *и.* Билгеле бер затларның сак астында булуы. *--- Ул сарайга йөзәр-йөзәр юлбасарлар озатуында кайтып керде.* В.Имамов

ОЗАТУЧЫ I *и.* Китүче кеше белән саубуллашып, озатып баручы, озатып калучы. *Озатучылар, байрак болгап, Җырлар белән озатып калдылар.* Ф.Кәрим. *Хәлим белән Салават, иң арттагы арбага яңа гына чабылып салынган хуш исле үлән өстенә утырып, озатучыларга таба карап баралар.* А. Шамов. *Озатучыларның вагоннан чыгуын үтенәбез.* М.Юныс

ОЗАТУЧЫ II *и. махс.* Булачак тукыманың җепләрен туку станына корырга хәзерләүче // Җеп озату станында эшләүче

ОЗАТЫШУ *ф.* 1) *урт. юн. к.* **озату** (*1–7 мәгъ.*). *– Мактый бабай белән Мөбарәкша абый да үз ояларында [безне] озатышып бардылар.* Ш.Маннур

2) Күп кешеләрнең бергәләп озатулары турында. *Безне үстергән аналар, ак сакаллы аталар Озатышып калалар: без китәбез сугышка.* Ш.Мөхәммәдев

Озатышып йөрү *к.* **озатышып тору**. *Озатышып йөрергә судно вокзал түгел.* М.Юныс

Озатышып тору Даими озатышу

ОЗАЮ *ф.* **1.** 1) *к.* **озынаю**. *Җил көчәйгән саен, дулкын арта, Төн озайган саен, пошыну арта ---.* Ф.Кәрим. *Ә менә Хатип абый белән танышып киткәч һәм үзлегеннән укуын дәвам итә башлагач исә, киресенчә, көннәр озаюга таба барса да, кыска булып тоела аңа.* В.Нуруллин. *Менә хәзер синең гомерең озая инде.* М.Маликова

2) *күч.* Ерагаю, ераклашу. *Китте егет, кыз озатты Аны фронтка. Озайды аралары.* Ф.Кәрим

2. озаеп *рәв. мәгъ. күч. диал.* Озак вакыт дәвамында, озаклап. *Яңгыравыклы [чаң] тавышы моңлы гына озаеп чыңлап китте.* Ш.Камал

Озаеп китү Кисәк озаю. *Бәлки, бу хикәя шуның белән беткән дә булыр иде, бер дә уйламаганнан бераз озаеп китте.* Г.Гали

Озаеп бетү Бик озаю

Озаеп калу Нинди дә булса вакыйгадан соң озайган хәлгә килү

Озаеп китү Көтмәгәндә озаю. *Ләкин, әллә ни эшләп, мәҗлесләр озаеп китепме, яисә эчемлек азрак булып китепме, Шәмси вакытыннан иртә айныса, ул тәмам кара җут кебек булды.* Г.Исхакый

Озаеп тору Әледән-әле яки хәзер озаю. *Диңгезгә таба өч-дүрт чакрым алда, берничә җирдә нефть коеларының вышкалары, кадап куйган шикелле, югары озаеп торалар.* Ш.Камал

Озая бару Торган саен озаю. *Картая барган саен, хан колы – осталарның остасы Алпар өчен көннәр дә озая бара кебек тоела башлады.* М.Хәбибуллин. *Кояш һаман югарырак күтәрелә, көннәр озая бара.* К.Тәхау. *--- Ул томан баганасы әкренләп җиргә таба озая бара.* Дөньяда ниләр бар

Озая башлау Озаерга тотыну. *Көннәр озая башлап, кояш күбрәк җылыта башлагач, урамнарда сулар җыела башлагач, адәм тәнендәге кан да кояш җылысында эрегән кар кеби языла башлый.* Г.Исхакый. *Камыт бавы бераз озая башлаган...* Р.Батулла. *Әнә бу атна азагына көннәр дә озая башлаячак, димәк, яктылык артачак, кышның иң кәттә чагы булса да, язга таба борылачакбыз.* Татарстан яшьләре

Озая төшү Бераз озаю. *Күзен ачып йибәргәндә, агачларның шәүләләре озая төшкән иде.* Г.Исхакый

ОЗОКЕРИТ *и. гр. махс.* Балавыз сыман минерал; тау балавызы (крем, мазьлар ясау өчен кулланыла). *Шуныcы мөһим: битум катламының өстендә озокерит катламы булганы мәгълүм.* Фән һәм тел. *Ләм Бәкер шифаханәсеннән махсус кайтартыла, шунда ук парафин, озокерит белән дә дәвалыйлар.* Ватаным Татарстан

ОЗОН *и. гр.* Кислородның өч атомы кушылудан гыйбарәт кискен исле зәңгәр төстәге газ; һаваны, суны чистартуда, техникада кулланыла. *Рәхәтләнеп суладым бер Наратларның озоннарын.* И.Юзеев. *[Аит:] Озон? Ялгышмасам, моны бездә саф һава диләр.* Ә.Гаффар. *Бу вакыт һавада берникадәр озон барлыкка килә.* Физика курсы

ОЗОНА́ТОР *и.* Һаваны озонлау приборы. *Озонаторлар начар исне, төтенне бетерү өчен дә кулланыла.* Файдалы киңәшләр

ОЗОНЛАНУ Озон белән туену, озон ярдәмендә зарарсызлану

ОЗОНЛА́У *ф.* Йогышсызландыру һәм начар һавадан арындыру өчен, озон җибәрү, озон белән эшкәртү. *Ә бу су бераз тозлы кислота һәм озонланган газ кушылган гади судан гыйбарәт.* Татарстан яшьләре

Озонлап алу Тиз генә озонлау

Озонлап тору Даими озонлау

Озонлап чыгу Башыннан ахырына кадәр озонлау

Озонлый башлау Озонларга тотыну

Озонлый төшү Бераз озонлау

ОЗОНЛАШТЫРУ *ф.* Озонга әйләндерү

Озонлаштыра башлау Озонлаштырырга тотыну

Озонлаштырып тору Даими, әледән-әле озонлаштыру

ОЗОНЛАШУ Озонга әйләнү

Озонлаша башлау Озонлашырга тотыну

Озонлашып тору Даими, әледән-әле озонлашу

ОЗОНЛЫ *с.* Составында озон булган; чиста, саф (һава тур.). *Яшел төс – ямьле төс, Гомерләр бизәге: --- Озонлы айлы төн, яфраклы җил төсе ---.* Г.Афзал

ОЗЫН *с.* **1.** 1) Озынлыгы зур булган; сузынкы; *киресе*: **кыска**. *Кара күзлек сөйләшеп тә тормады, егетләрнең кулына озын бау тоттырды.* Г.Гомәр. *Зур колаклы, озын йонлы Дүрткүзне иярттәм дә Димгә яки наратлыкка, аннан болынга, печән чабучылар янына яисә басуга элдертәм.* Ж.Тәрҗеманов. *Башкалар арасыннан эзләп таптым мин ул чәчәкне. Озын, матур роза иде...* Сәхнә

2) Озынлыгы кирәгеннән артык, таман түгел. *Аклы ситса кулмәгемнең итәге тар, ә җиңе озын.* Җыр

3) Буйга зур булган (кеше тур). *Озын, ябык кеше аның каршысына чыгып басты.* Я.Зәнкиев. *Озын буйлы, озын мыеклысы Тау буеннан алмый күзләрен ---.* Ф.Кәрим

4) Озакка сузылган, озак дәвам итә торган. *Инһаять, колакны кытыклап торган озын гүләү авазын бүлеп, телефоннан таныш тавыш ишетелде.* Р.Вәлиев // Чагыштырмача дәвамлы. *Дүшәмбедә – унбишенче майда – син озын тәнәфестә уен оештырдың ---.* М.Хуҗин // Озак, дәвамлы. *Бу очрашу кыска булса да, Озын булсын безнең танышлык.* Х.Туфан. *Алда гомер озын булып тоела ---.* М.Маликова. *Озын төннәр буе уйланамын, Сине канат итә бу уем ---.* Ф.Кәрим

5) Сузынкы, озак яңгырый торган, салмак (тавыш, көй, җыр һ.б.ш. тур.). *– Кичә синең шаян уен барганда, үзеңне күрсәтергә теләп, озын җыр җырлавыңнан көлгәндер, бәлки, – дип сөйләнә-сөйләнә эчкә узды Камил.* Г.Галиева. *[Сираҗетдин абзый] озын көйләргә җырлап та җибәрә, скрипкада да уйный.* Р.Ишморат. *Озын көйләр белән беррәттән кыска көйләр дә бар.* Мәдәни җомга

6) Озак, күп вакыт сорый торган, дәвамлы сроклы. *Без Надя белән ерак диңгезгә таба озын сәфәргә чыгып китәбез.* Р.Төхфәтуллин. *Алар, үзләре озын солдат юлы узган кешеләр булгач, армия тормышы белән гаять кызыксыналар.* Ә.Еники

7) Зур күләмле. *Озынрак хикәяләр, мәкаләләр укырга ни өчендер Фәттахның күңеле тартмады.* Ф.Кәрим. *– Ходаем, теләсәң ни эшлә, бер кияү тап миңа! – дип, гадәти озын монологын сөйләп, [Хәлимә апай] барыбызны да көлдереп, уфтанып ала.* А.Хәсәнов. *Озын сүз сөйләмә, Вакыт юк тыңларга: Озын уй, кыска сүз заманы.* Г.Афзал

8) *махс.* Агач ташу өчен үрәчәсез, төпсез, озынча итеп эшләнгән (арба тур.). *Исән калган атларга озын арбалар җигеп, исемлек белән шуңа кешеләр төяп, --- халык Чепья базарына юл салды.* М.Мәһдиев

9) *лингв.* Сузынкы. *[а] – арткы рәт, түбән күтәрелешле, иренләшмәгән, озын сузык аваз.* Ф.Сафиуллина

10) *күч.* Күптәннән, озак вакытлардан килгән. *Озын тарихлы гыйлем сарае коридорларыннан мин сак кына атлап чыктым ---.* Т.Әйди

2. *рәв. мәгъ.* 1) Озак вакыт дәвамында; озак итеп. *Вәкил энем! Уралда узган елларым турында сорашсалар, озын сөйләмә.* Ә.Баян. *Гәүдәсе артык озын күренә.* Ватаным Татарстан

2) *кбт. форм.* Киң, эре-эре итеп. *Як-юненә каранып, Хәлим озын-озын атлый.* И.Гази

3) Озак итеп, тәфсилләп, бик җентекләп. *Нәгыйм белән Мәдинә шактый озын сөйләделәр.* Ш.Камал. *Теге шәкерт мөдәрриснең бик озын итеп биргән җавабына тагы бик озын итеп бәхәс әйтте.* Ф.Әмирхан. *[Әминәнең әнисе хатта] озын итеп, чын совет гаиләсе коруның авырлыгы, коммунизм төзүдә хәзерге яшьләрнең тоткан роле турында язган.* Р.Вәлиев

3. *и. мәгъ.* Озынлык. *Кайберләренең [балыкларның] гәүдәсе торпеда кебек озынга сузылган.* Су асты дөньясы

◊ **Озын аяклы** Тиз таралучан, билгеле булган (сүз, хәбәр тур.). **Озын берлек** Җиңел юл белән яки хәрәмләшеп табылган зур акча. *Димәк, һаман да «озын берлек» турында кайгыртучылар артачак.* Мәдәни җомга. **Озынга җибәрү** Күп вакыт сарыф итү. *Зәйтүн хата җибәргәнен тиз аңлады, әтәч турындагы ярыш сүзен артык озынга җибәрергә ярамый иде.* А.Гыйләҗев. **Озынга китү** *к.* **озакка китү**. *Югыйсә озынга китте лә ул [хикәя], сузылды, дәфтәр тулды.* М.Хуҗин.

Хәзер аңлата башласам, бик озынга китәр. Бер сөйләрмен әле. Р.Вәли. *Бөртекләп сөйләсәң, озынга китәр.* Т.Әйди. **Озынга сузу** Нәрсәне дә булса иркенләп, озак итеп башкару. *Озынга сузмыйча гына әйткәндә, бер айга якын эзләдек без ул каһәр төшкән нәрсәне.* В.Нуруллин. **Озын гомер бирсен** Кешегә яхшы мөнәсәбәт белдереп әйтелә торган теләк. *Ходай тәгалә сиңа озын гомер, ишеп бәхет бирсен, кенәз.* М.Хәбибуллин. **Озын гомерле булу** Озак яшәү. **Озын гомерле булыр(сың)** Сүз барган кеше килеп кергәндә, күренгәндә әйтелә торган гыйбарә. **Озын койрыклы җен** Билгесез кеше. *Сиңа булмый озын койрыклы җенгә әйтмәм тагын. Фамилияң ничек?* Ф.Шәфигуллин. **Озын колак** 1) Куян; 2) Имеш-мимешләр таратучы кеше. *Иртәгесен эшкә килүгә, озын колаклар котларың алынырдай хәбәр җиткерделәр ---.* Р.Төхфәтуллин. *Озын колаклар ишеттерделәр, имеш, Кәримә Азатованы Казанга җибәрү мәсьәләсендә өлкән укытучы Вәсилә Хакова үзе директор янына кереп сөйләшкән.* М.Хәбибуллин. *Фенстер, андый-мондый озын колаклар тыңлап тормыймы дип шикләнгәндәй, башта як-ягына каранып куйды.* Р.Вәли. **Озын колаклы** Күпне ишетүче, һәрнәрсәдән хәбәрдар булып торучы. **Озын колактан** Кемнән ишеткәнне белгертергә теләмәгәндә әйтелә. **Озын колак хәбәре** Ачык билгеле булмаган хәбәр, имеш-мимешләр. **Озын куллы** 1) Юкка-барга сугышучы, кешегә сугарга яратучы; 2) Көче, йогынтысы кайда да җитә торган, мөмкинлекләре чикләнмәгән. *Әлбәттә, могҗизалы мондый чылтыратулар артында очлы күзле, сизгер колаклы, озын куллы КГБ торуы Мәнди анасы Гөләп җиңгигә дә җиңел аңлашылырлык!* Р.Вәли; 3) Урлашучы, кеше әйберенә тиюче. *[Карчык:] Актык сүзем шул сиңа: --- озын куллы кыз, моннан соң кеше әйберенә тимәскә, алдап сөйләмәскә вәгъдә бирәсеңме?* А.Әхмәт. **Озын сүзнең кыскасы** Җыеп, кыскача гына әйткәндә. *Озын сүзнең кыскасы шул: ил картлары, мөэмин мөселманнар безнең бүгенгедәй шартларга разый түгелләр.* М.Хәсәнов. *Озын сүзнең кыскасы; тамагыңны ертса да, тәнкыйтьне чәйнәп йотарга кирәк.* Н.Гыйматдинова. *Озын сүзнең кыскасы шул: баламны әллә кайларда җиде ят кулларында йөртеп интектермә.* Ф.Яруллин. **Озын телле** Гайбәт сөйләүче, урынлы-урынсыз кирәк-кирәкмәгәнне сөйләп йөрүче кеше. *Әгәр кичләрен беркая чыкмыйча гел өйдә утырса, озын телләрнең --- гайбәт таратуларыннан курка иде ул.* М.Юныс. *Ниндидер бер озын теллесе җиткергән бугай.* Р.Вәлиев. *Озын теллеләр юлына очрамаса әйбәтрәк булыр.* Г.Гомәр. **Озын торык(лы)** Озын буйлы кешегә карата. *Озын торыклы немец, тез астына китереп суккандай, артка чайкалып куйды да аптырашып торган солдатлар арасына авып төште.* И.Гази. *Ул Вакыйф, Озын торык Мөхәррәм белән өч борынга керде.* Ә.Гаффар. **Озын чәч** *иск.* 1) Руслар турында; 2) *кимс.* Хатын-кыз турында

-ОЗЫН Кушма сүзләрдә вакытны белдергән кайбер сүзләр белән килеп, «буе» мәгънәсен белдерә торган икенче кисәк. *Хәйретдин агай черкиләр явы белән төнозын сугышып чыкты.* А.Гыйләҗев

ОЗЫНАЙТУ *ф. к.* **озайту** (*1, 2, 4 мәгъ.*). *Ул үзбәк ефәгеннән тегелгән күлмәгенең кыска җиңнәрен озынайтырга теләгәндәй тарткалап куйды.* М.Маликова. *Кеше үзен-үзе дә сакласын, Үз гомерен үзе озынайтсын ---.* И.Юзеев. *Юк, хәзер үк контрактны озынайту кирәклегенә басым ясарга ярамый.* Р.Вәли

Озынайта башлау Озынайтырга тотыну

Озынайта төшү Бераз озынайту. *Аны [битне] тагын да озынайта төшеп, ап-ак кәҗә сакал сузылып төшкән.* И.Салахов

Озынайта бару Торган саен ныграк озынайту. *Фикерләү сәләте үскән, рухи дөньясы баеган саен, кеше киемен озынайта барган.* Безнең гәҗит

Озынайта килү Билгеле бер вакыт дәвамында һаман озынайту

Озынайта тору Даими озынайту

Озынайтып бару Торган саен озынайту. *Без һәрдаим үзебезнең язмыш җебен озынайтып барабыз.* Р.Нуруллин

Озынайтып бетерү Бик озын итү

Озынайтып җибәрү Кинәт озынайту

Озынайтып тору Даими, әледән-әле озынайту. *«Бәхетле» сәүдә галереясы хакимияте кыяр, помидор һәм яшел үлән алуга килешүне озынайтып тора.* Татар-информ

ОЗЫНАЮ *ф.* I 1) Озынракка әйләнү; ераккарак сузылу. *Озынны кыскартып була, ә кыска озынаймый.* Мәкаль. *Авылыбызны яртылай әйләндереп алган Агыйдел озынайды, борылышлары ешайды.* М.Әмир. *Галия апа кинәт буйга озынайды шикелле, аннан соң тагын кечкенәрәк булып китте.* Н.Дәүли

2) Озынчарак форма алу, тартылу (йөз, яңак, борын тур.). *--- Самавыр йөзендә Рәсимнең яңаклары да, маңгай, колаклары да, тельняшкасы да озынаеп, көлке бүлмәсендәге шикелле гарипләнеп күренә...* Ф.Шәфигуллин

3) Озынрак булып үсү. *Бәбәк үсә, һәм буын арасы озыная.* Биология. *Әлтафи күрде аны [атны] бүген ат абзарлары яныннан кайтканда: янбаш сөякләре чыккан, --- йоннары озынайган.* М.Мәһдиев

4) Озаккарак сузылу, дәвамлылыгы арту (вакыт тур.). *Көннәр күзгә күренеп озынайды.* Г.Әпсәләмов. *Хәзер безнең очрашу сроклары, ай-һай, ничек озынайды.* Р.Төхфәтуллин

5) Күләме, зурлыгы арту, зураю. *Заман кояшының ничек каравына карап, Кечерәйгән күләгәләр Озыная кабат.* М.Әгъләмов

Озынаеп бару Торган саен озынаю

Озынаеп калу Озынайган формаы саклау. *[Белов,] кичерешләрен сиздермәскә тырышып, тешләрен кысканга, арык битендәге яңак сөяге шыксыз булып калкып чыкты, озынаеп калган муеннан бөкредәй кабарып торган кәдиге аска-өскә хәрәкәт итте.* Ш.Рәкыйпов. *Толыптан суза-суза, борын озынаеп калды.* Сәхнә

Озынаеп китү Соңгы арада, соңгы моментта озынаю. *Шуңа күрәдерме, [Тәслимәнең] муены озынаеп киткән*

сыман. Ф.Шәфигуллин. *Хикмәт шунда: ул бер озынаеп, бер нечкәреп китә, яссы хәлгә килеп, бик тиз үз хәленә кайта ала иде.* Х.Ибраһим

Озынаеп кую Кинәт озынаю. *Менә бер заман көннәр озынаеп куя да, салкын кыш китәр якка күз сала.* К.Тәхау

Озыная бару *к.* **озынаеп бару**. *Шулай итә торгач, салам арканы озыная бара.* Р.Батулла. *Озыная бара чираты.* Ш.Маннапов. *Ламарк фикеренчә, аларның гадәти кошлардан берни белән дә аерылмаган борынгы элгәрләре --- үзләренең аякларын бик көчле эшләтә-күнектерә башлаганнар, һәм алар, озыная барып, әкренләп хәзерге заман челәне аягы кебек озын булып киткәннәр.* Галәм, җир, кеше

Озыная башлау Бераз озынаю сизелү. *Төш авышып, күл буендагы өянкеләрнең кара күләгәләре озыная башлаган.* И.Гази. *Бер атнадан көннәр акрынлап озыная башлаячак.* Татарстан яшьләре

Озыная килү Күптәннән, эзлекле рәвештә озынаю

Озыная төшү Бераз озынаю. *Вәсиләнең керфекләре тагын да озыная төшкән төсле.* Ф.Хөсни. *Л.Н.Гумилёв версиясе буенча кайту юлы озыная төшә.* С.Шәмси. *[Павлушинның] Кылыч сыман очлаеп торган дәү борыны тагын да озыная, сузыла төште...* Х.Ибраһим

ОЗЫНАЮ II *и.* Озынракка әйләнү, ераккарак сузылу хәле. *Моның белән безнең язуда моңарчы килгән күләм ягыннан озынаю түгел, киресенчә, кыскару туачак.* Х.Курбатов. *Бу закончалык озынаю х зур булмаган эластик деформацияләрдә генә үтәлә.* Физика

ОЗЫНАЯК *и. зоол.* Икеканатлылар отрядыннан буынтык-буынтык озын нечкә мыеклы һәм озын нечкә аяклы корткыч бөҗәк, озынборыннарның бер төре; *русчасы:* **долгоножка.** – *Без монда чебен-чырак, озынаяк арасында азап чигәбез, ул симереп ята, – диләр болар.* Әкият

ОЗЫ́НАЯКЛЫЛАР *и. күпл. зоол.* Икеканатлылар отрядыннан кечкенә гәүдәле, озын аяклы бөҗәкләр семьялыгы

ОЗЫНБОРЫН *и. зоол.* 1) Икеканатлылар отрядыннан кечкенә гәүдәле, ике канатлы, озын аяклы кан эчүче бөҗәк; черки. *Урман өстендә миллиард озынборыннан торган оркестр.* М.Мәһдиев. *Ибрайның борынына озынборын кунды ла, каһәр!* Ә.Гаффар. *Очканда, алар [әнә караклары] озынборыннар һәм башка бөҗәкләр белән тукланалар.* Биология

2) Коңгызлар отрядыннан башының алгы өлеше көпшә сыман озынаеп торган корткыч бөҗәк; *русчасы:* **долгоносик**

ОЗЫ́НБОРЫНЛЫЛАР *и. зоол. күпл.* Коңгызлар отрядыннан озынча башлы, үсемлек азык белән туклана торган бөҗәкләр семьялыгы; *русчасы:* **долгоносики**

ОЗЫНБОРЫНЧА *и. зоол.* Чаянчебеннәр семьялыгыннан корткыч бөҗәк; *русчасы:* **комаровка**

ОЗЫНБОРЫНЧЫК *и. зоол.* Оры чебеннәре семьялыгыннан черкигә охшаган гәүдәле, соргылт канатлы, җирәнрәк төстәге озын нечкә аяклы зарарлы чебен; *русчасы:* **гессенская муха**

ОЗЫ́НКАНАТЛЫЛАР *и. зоол.* Гомерләренең күпчелек өлешен диңгез өстендә очып үткәрә торган озын канатлы, кыска аяклы кошлар отряды; керәшәсыманнар; *русчасы:* **длиннокрылые**

ОЗЫ́НКОЙРЫКЛЫЛАР *и. зоол.* Зур башлы, кыска гәүдәле, ян-яктан сыланып торган бик озын койрыклы тирән су балыклары семьялыгы; *русчасы:* **долгохвостовые**

ОЗЫН-КЫСКА *с.* һәм озын, һәм кыска; төрле озынлыктагы. *Кием бирсәң, бир татарга: Озын-кыска, ничә димәс ул.* Ә.Синугыл-Куганаклы

ОЗЫНЛЫК *и.* 1) *махс.* Сызыкның, яссылыкның, җисемнең ике чик ноктaлары бер-береннән ераклашкан юнәлештә сузылып киткән буе. *Бу китапны язу өчен, ул [К.Насыйри] --- үлчәү, озынлык, вакыт берәмлекләрен өйрәнгән һәм җирле материалны гомуми кабул ителгән берәмлекләр белән чагыштырган.* Ә.Хуҗиәхмәтов. *Кинематикада төп ике зурлык – озынлык һәм вакыт кулландык.* Физика

2) Нәрсәнең дә булса бер очыннан икенчесенә кадәр булган арасы. *Эзли торгач таптым, ниһаять, итек табанына ярты шырпы озынлыгы кадак кергән.* Ф.Шәфигуллин. *Рауза белән бергә булганда, юлның озынлыгы белән исәпләшәләр димени, җир читенәчә янәшә атларга риза.* М.Мөхәммәдиев. *Елан үзе чем кара, болай да болай бара. Озынлык мо-о-ның чаклы! Юанлык мо-о-ның чаклы!* Ш.Галиев

3) Вакытның дәвамлылыгы, озаклык. *Гомер озынлыгы, вакыт берәмлеге – Адәм аша узган ризык ул.* Ш.Маннапов. *--- Һәрхәлдә аның [иң борынгы токымнарның барлыкка килүе] озынлыгы миллиардларча еллар белән билгеләнә.* Тереклек һәм аның җир йөзендә таралышы

4) *геогр.* Башлангыч (нуленче) меридианнан көнбатышка яки көнчыгышка таба градуслар белән күрсәтелгән ара (җир өслегенең ноктaларын билгеләү өчен хезмәт итә). *--- Без һәр сәгать саен озынлык сызыгына карата 20 минут почмакча тизлек белән, ягъни Айдан һичбер артка калмаслык тизлек белән көнчыгышка таба бара идек.* Кызыклы физика

5) *лингв.* Авазлар әйтелгәндә, билгеле бер вакыт эчендә тавыш ярыларының тирбәнешләре дәвамлылыгы. *Гомумән алганда, татар телендә сузык фонемалар дүрт билге буенча аерылалар: рәт, күтәрелеш, иренләшү, озынлык.* Ф.Сафиуллина

ОЗЫНЛЫ́КЧА *с. махс.* Бары озынлыкка үлчәнә яки үлчи торган. *Озынлыкча сажин*

ОЗЫНЛЫ́-КЫСКАЛЫ *с.* Төрле озынлыктагы, озын һәм кыска

ОЗЫ́Н-ОЗАК *рәв.* **1.** 1) Озаклап, иркенләп. *[Хан:] Озын-озак йөрмә.* М.Хәбибуллин

2) Күп. *Шуның өчен ул сигезенчедән соң озын-озак уйлап тормады, тотты да Минзәлә медучилищесына барып керде.* А.Гыйләҗев. *Кичәге кунаклар шикелле озын-озак итеп сөйләшми болар: әйткәнне ярып әйтә, хет җир астына кереп кит ---.* Р.Вәлиев

2. *с. мәгъ.* 1) Ераккa сузылган. *Никадәр генә озын-озак булмасын, һәр юлның азагы була.* З.Фәтхетдинов

2) Озакка сузылган, бик озак булган. *Озын-озак бәхәсләшүләрдән соң шушы*

як өстенлек алды. Г.Кашапов. *Озын-озак кул чабулар --- һаман тынмагач, Рудольф ачык ишекле тамбурга чыгып басты.* Р.Вәли. *Озын-озак яңа ел каникулы бу күрсәткечне тагын да арттырачак.* Безнең гәҗит

◊ **Озын-озакка сузу** *к.* **озакка сузу**. *Алар, бу эшне озын-озакка сузып тормыйча, Хавтанның кабинетын һәм залны карап чыктылар ---.* Р.Мирхәйдәров. *Алар, озын-озакка сузмыйча, бу куанычлы хәбәрне бар дөньяга ирештерсеннәр, янәсе.* М.Зарипов

ОЗЫ́НТАБАНЛЫЛАР *и. зоол.* Арткы очлыклары алгыларыннан күпкә озынрак булган зур сары күзле ярыммаймыллар семьялыгы; *русчасы:* **долгопятовые**. *Ярыммаймыллар асотряды лемурлар, озынтабанлылар, тупайаларны берләштерә.* Биология

ОЗЫНТОМШЫК *и. зоол.* Шөлдиләр семьялыгыннан көрән төсле, гәүдәсенең өске өлешендә кара, көрән, җирән таплары, аскы өлешендә кара аркылы буйлары булган, озын, көчле томшыклы кош; тәлләтәвеч; *русчасы*: **вальдшнеп**

ОЗЫНЧА *с.* 1) Буйга сузылган, озынлыгы аркылысыннан зуррак. *Озынча платформада брезент белән томаланган йөк.* Ш.Рәкыйпов. *Аларга, бер-берсенә терәп, озынча саргылт төргәкләр тезелгән.* М.Маликова. *Ике йомры арасындагы озынча күләгә Киек Каз Юлына тиң иде...* Р.Низамиев

2) Эллипссыман, овал формасындагы, сузынкы. *Аксыл костюм кигән, ак чәчле, озын буйлы һәм озынча ак йөзле кешене --- күрсәттеләр.* К.Булатова. *--- Аның озынча каратут йөзенә моңсулыкка охшаш шатлык кунган иде.* М.Хәбибуллин. *Озын, юка борынлы, озынча кысык күзле, тар күкрәкле бу чирләшкә Күк углын җир угылларыннан беркем дә яратмады.* Н.Фәттах

ОЗЫНЧАЛАНУ *ф.* Озынаю, озынча формага килү

Озынчалана башлау Бераз озынчалану

Озынчаланып калу Ахырда озынча форманы алу. *Ял көннәрендә кырынып тормаган бугай: болай да ябык йөзе тагын да каралып, озынчаланып калган.* Мәдәни җомга

Озынчаланып китү Кинәт озынчалану. *Зуфирәне күрүгә, аның йөзе тагын да озынчаланып, агарып китте, күзләре зур ачылды.* М.Маликова. *Яшь, әле җимеш бирергә өлгермәгән агачларның артык озынчаланып киткән бүлбеләрен чеметеп алалар.* Ватаным Татарстан

ОЗЫНЧАЛЫК *и.* Озынча булу сыйфаты

ОЗЫНЧЫК *и. геом.* Турыпочмаклык

ОЙ *ы.* 1) Кинәт курку, авырту, бик нык борчылу кебек хис-кичерешләрне белдерә. *Ой, нәрсә булды сезгә, нәрсә булды?* Г.Кашапов

2) Гаҗәпләнү, шатлану, соклану хисләрен белдерә. *Ул ирексездән: – Ой, нинди тәмле, нинди хуш ис... – дип куйды ---.* Г.Кашапов. *Ой! Кичә балачагалар белән мәшләнеп, сигнализациягә куймаганмын икән.* Ф.Яруллин. *– Ой, Зәйнәп, матур да соң син, ә! – диде ул аңа.* Х.Ибраһим

3) Шикләнү, үкенү, күңелсезләнү хисләрен белдерә. *Ялкыттымы зур сәясәт – Таң, кич канлы көрәш?! Китәр идең – контракт, Ой, нишләрсең, Кояш?!* Р.Рахмани. *Ой, андый зур эшне булдыра алырмынмы икән?* В.Нуруллин. *Зәйнәп: Ой... һич кенә дә сиңа әнкәй дип эндәшергә өйрәнмәдем.* Х.Ибраһим

ОЙ-ОЙ *ы.* Гаҗәпләнүне, шаккатуны белдерә. *Ой-ой, салдырып та караган өйне!* З.Фәйзи

ОЙРОТ *и. иск.* Таулы Алтайда яшәүче һәм хәзер алтайлылар дип йөртелгән төрки халыкның элеккеге атамасы; шул халыкның аерым бер вәкиле. *Гәрчә төрле авторлар төрлечәрәк фикер йөртсәләр дә, төрки-татар кабиләләренең язмышы монгол, ойрот, меркит һ.б. язмышыннан аерылып тора.* Р.Фәхретдинов

ОЙ-ҺОЙ *ы.* 1) Шикләнү, икеләнү хисләрен, кисәтүне белдерә

2) Авыртудан сызлануны белдерә. *Шофёр авыртуга түзалмыйча: «Ой-һой, һой», – дип куйды күзләрен йомып.* Г.Кашапов

ОКА́ПИ *и. афр. зоол.* Жирафлар семьялыгыннан Үзәк Африка тропик урманнарында яшәүче, жирафтан бераз кечерәк, гәүдәсе куе көрән, аяклары буй-буй төстә булган имезүче хайван. *Урман кырыйлары һәм су буйларында җир йөзендә сирәк очрый торган хайваннарны – кәрлә бегемотларны һәм жирафлар нәселеннән Африкада гына яши торган окапиларны күреп була.* Материклар һәм океаннар географиясе

ОКЕАН *и. гр.* 1) Бөтен Җир шарын чолгап алган сулык. *Океан тирән, төбе энҗе тулы, ләкин анда төшү җиңелме?* Р.Гатауллин. *Дөнья океанының бик озын гомере белән чагыштырганда, эчке сулар бик тиз килеп чыгалар һәм тиз югалалар.* Тереклек һәм аның җир йөзендә таралышы. *--- Рус экспедицияләре океандагы тереклек турында бик күп кыйммәтле мәгълүматлар алып кайттылар.* Су асты дөньясы

2) Җир шарын чолгап алган һәм аны материкларга бүлгән дүрт сулыкның берсе. *Әнә, күплэп нефть агыза торгач, хәтта океаннарда балык кимеде.* Р.Низамиев. *Кайсы океан аша нинди илләргә юл тота икән бу кораб?* М.Юныс. *Ул [Балтыйк диңгезе], Баренц диңгезе кебек үк, Атлантик океан белән тоташа.* Су асты дөньясы

3) *күч.* Бик күп, бик зур, иге-чиге булмаган нәрсә. *Диңгез инде ерак калгандыр, болыт океаны астында, мөгаен, Себер тайгасыдыр хәзер.* Ф.Шәфигуллин. *Алайса, Салих абыйның күңеле – океандыр.* К.Латыйп

ОКЕАНА́РИЙ *и. гр. к.* **океанариум**

ОКЕАНА́РИУМ *и. гр.* Диңгез, океан хайваннарын һәм балыкларны тоту, аларны күзәтү, фәнни тикшерү һәм тамаша кылу өчен махсус сулык, бассейн. *Дүрт метрлы юлбарыс акуласы океанариумда ел буена нибары 86 килограмм балык ашаган.* Серле календарь. *Бу хакта Оберхаузен шәһәрендәге Sea Life океанариумы вәкиле Таня Мунциг хәбәр иткән.* Безнең гәҗит

ОКЕАН-ДӘРЬЯ *и. к.* **океан-диңгез**. *Элек иксез-чиксез океан-дәрьялар, кара урманнар, чүлләр – барысы да бүгенге көн, бүгенге тизлекләр белән*

чагыштырганда югалып кала кебек. Казан утлары

ОКЕАН-ДИҢГЕЗ *җыйый. и.* Океаннар һәм диңгезләр; барлык сулыклар. *Океан-диңгезгә кушылгач, чишмә дә саф мөстәкыйльлеген югалта.* Ш.Галиев. *Җирдә тормышның тәрәккыять итүендә урман-далалар, тау куышлары, елга-күлләр, океан-диңгезләр генә түгел, ә җирнең асты, аның байлыклары да зур урын тоткан.* Кызыклар дөньясы

ОКЕАНО́ГРАФ *и. гр.* Океанография белгече. *Танылган океанограф*

ОКЕАНОГРА́ФИК *с.* Океанографиягә бәйле, шуңа караган

ОКЕАНОГРА́ФИЯ *и. гр.* Физик географиянең океан һәм диңгезләрне төрле яклап өйрәнә торган тармагы. *Боларның барын да океанография – диңгез һәм океаннар турындагы фән өйрәнә.* Диңгез тирәнлегендә. *Совет океанография экспедицияләре Арктикадан алып Антарктикага кадәр булган су киңлекләрен тикшерделәр ---.* Физик география

ОКЕАНО́ЛОГ *и. рус* Океанология белгече. *Ләкин Нью-Йоркта булган Беренче халыкара океанологлар конгрессында, тәрәч балыкларының өере – бер ата балык җитәкчелегендә оешкан бер берләшмә ул, дигән фикер әйтелә.* Кызыклы ихтиология. *Бу [кышның салкын булуы] турында немец океанологлары сөйли.* Акчарлак

ОКЕАНОЛО́ГИК *и.* Океанологиягә бәйләнешле

ОКЕАНОЛО́ГИЯ *и. гр.* Океан һәм диңгезләр турындагы фән. *--- Ватан океанологиясенә нигез салучылар Ю.М.Шокальский (1856–1946), В.Ю.Визе (1886–1954), Н.Н.Зубов (1885–1960), П.П.Ширинов (1905–1960), К.К.Марковның (1905–1980) тикшеренүләре һәм дистәләрчә экспедицияләренең эше нәтиҗәсендә кешеләр Дөнья океанының серләренә төшенделәр.* География

О́КИСЬ *и. рус хим.* Оксид. *Терекөмеш окисе, тәҗрибәләр ясау өчен, теләсә кайсы аптекада алырга мөмкин булган марганцовка һәм бертолет тозы шундыйлар рәтенә керә.* Күзгә күренми торган матдәләр турында хикәяләр. *Әгәр дә ягулык итеп, мәсәлән, азот окисе һәм хлор кулланылса, ягулык элементында хлорлы нитрозил барлыкка киләчәк.* Химиянең киләчәге. *Анод пластинканы электролиттан аера торган юка гына окись ярысы диэлектрик булып тора.* Физика курсы

О́КИСЬЛӘШТЕРҮ *ф.* Оксидлаштыру. *Әгәр җылытыла торган әйберне окисьләшүдән сакларга яки, киресенчә, окисьләштерергә кирәк булса, 2:1 пропорциясен үзгәртергә дә ярый.* Күзгә күренми торган матдәләр турында хикәяләр. *Ультратавыш азотны окисьләштерергә ярдәм итәчәк ---.* Химиянең киләчәге. *Уңай пластинка алюминий окисеның юка гына катлавы белән каплана (окисьләштерелә), тискәре пластина исә окисьләштерелми ---.* Физика курсы

О́КИСЬЛӘШҮ *ф.* Оксидлашу. *Майлар окисьләшкәндә, су аерылып чыга, менә шул су инде кыргаякның тереклек эшчәнлегенә тотыла.* Ә.Халидов. *Бик тиз окисьләшүчән металл әйберләрнең өсләрен күп вакыт никель, көмеш, цинк һәм башка шундый авыр окисьләшә торган металлар белән каплыйлар.* Физика курсы

ОККАЗИОНАЛИЗМ *и. лат. лингв.* Аерым кеше сөйләмендә, иҗатында гына кулланылган сүз яки сүзтезмә. *Окказионализмнарны өйрәнү*

ОККАЗИОНАЛЬ *с. лингв.* Аерым кешеләргә, аерым урынчалыкка гына хас булган. *Ә сөйләмдә болардан тыш әле аерым сөйләшләргә, аерым кешеләргә генә хас булган очраклы (окказиональ) сүзләр дә --- кулланылырга мөмкин.* М.Зәкиев. *Шул рәвешле, реаль сүз булган неологизмнардан контекстуаль ясалышка ия булган окказиональ сүзләрне аерырга кирәк.* Ф.Сафиуллина

ОККУЛЬТИЗМ *и. лат.* Кешедә һәм космоста яшерен көчләр бар һәм аларны махсус психик күнекмәләр алган аерым кешеләр генә аңлый ала, дип таныган өйрәтмәләрнең гомуми атамасы. *СССР заманында тузга язмаган «астрал-мастрал»лар, оккультизм турында китап чыгарып кара!* Безнең гәҗит

ОККУПАНТ *и. лат.* Оккупациядә катнашучы, басып алучы кеше. *[Алар] Оккупантлар тарафыннан җәбер-золым күрмәгәннәр [шул].* Х.Камалов. *Оккупантларга тынгы бирмәделәр алар.* Э.Касыймов

ОККУПАЦИОН *с.* Оккупациягә бәйләнешле. *Шул җәйне үк дивизионны Көнчыгыш Пруссиягә, совет оккупацион гаскәрләренең Төньяк группасына күчерделәр.* Т.Tahиров. *Гыйрактагы оккупацион көчләрнең күпчелек өлеше 2010 елның 31 августына чыгарылып бетәчәге мәгълүм булды.* Мәдәни җомга

ОККУПА́ЦИЯ *и. лат.* Берәр дәүләтнең икенче бер дәүләт территориясен кораллы көч белән басып алуы. *Елдан артык герман оккупациясе җирендә – балалар йортында булдым ---.* Т.Нәҗмиев. *Нәкъ шул яшьтәге үсмерләрне Украинадан һәм оккупациягә эләккән башка төбәкләрдән сугыш вакытында Алманиягә озату турында дистәләгән томда китаплар язылган.* М.Юныс

ОККУПА́ЦИЯЛӘҮ *ф.* Чит территорияне, корал кулланып, законсыз басып алу. *Тәүге төзүчеләр Нур гаиләсеннән булган затларны Җиргә килергә, оккупацияләнгән планетада берәмберәм гәүдәләнергә (туарга) --- чакырдылар.* С.Шәмси. *Яшүсмер малай авыру әнисе белән фашистлар оккупацияләгән Кадиевкада кала.* Т.Нәҗмиев

Оккупацияли бару Рәттән оккупацияләү

Оккупацияли башлау Оккупацияләүгә керешү. *Әнә шундый болгавырлыклардан файдаланып, колхозлардагы дәүләт җирен дә, милек паен да кертеп, инвесторлар авылларны «оккупацияли» башлады.* Безнең гәҗит

Оккупацияләп алу Тиз арада тулысынча оккупацияләү

Оккупацияләп бетерү Тулысынча оккупацияләү

Оккупацияләп килү Эзлекле, тоташтан оккупацияләү

Оккупацияләп тору Даими оккупацияләү

ОКЛАД *и. сөйл.* Билгеле бер хезмәткә даими рәвештә түләнә торган акча; эш хакы. *Уфа өязе Казан юлы*

Турай авылы татары Колмәт Еналиев 1677 елда бобыль ясагын ясаксыз кешеләргә күчерә һәм оклад ясагы түли башлый ---. Ф.Хисамова. *Шуның айлык оклады унбер мең икән!* З.Фәйзи. *--- Гәрчә аларда зуррак оклад һәм премия вәгъдә итсәләр дә, Верочка үзен тәрбияләгән коллективтан китмәгән.* Р.Мирхәйдәров

ОКОЛО́ТОК *и. рус тар.* 1) Революциягә кадәрге Россиядә: шәһәр полиция бүлеге. *--- Патша Россиясенең околоток полицейскийлары һәм квартал надзирательләре, узган гасырның 20 нче елларындагы участок надзирательләре участковыйларның элгәрләре булган.* Татар-информ

2) Хәрби бүлек каршында дәвалау пункты; лазарет

ОКОП *и. рус* Пуля, снарядлар һ.б. тиюдән саклану өчен, тирән һәм озын чокыр формасында казып, кырыйларга балчык өеп эшләнгән ныгытма. *--- Окопларда туңган, утларда янган, Кеше булып калган көчле рухым минем.* Г.Афзал. *[Сугышчылар] окоп, траншеялар корыштырып, тәмам хәлдән таеп, таң алдыннан йоклап китәләр.* Х.Камалов. *Сугыш үткән урыннарда Окоплар тора һаман ---.* Г.Шәмсетдинов

ОКОПТАШ *и.* Бер окопта сугыш алып барган кеше; сугышта бергә катнашучы

ОКРО́ШКА *и. рус* Куаска ит, йомырка, яшелчә турап әзерләнгән салкын аш. *Кичке салатны ашаганнан соң, беренчегә окрошка китерелә.* Т.Нәҗмиев. *Юк, өстәлләрендә спагетти, окрошка һәм гөбәдия янәшә торган интернациональ гаиләдән түгел иде егет.* Идел. *Официант тиз генә боларның теләген үтәп, алларына бик хикмәтле итеп әзерләнгән окрошка китереп утыртканы.* Мәдәни җомга

О́КРУГ *и. рус* Дәүләт территориясенең хуҗалык, сәяси, икътисади, хәрби яктан бүленешендәге берәмлек. *Бүтән хәрби округларның штаблары да шундый хәчтерүшләр белән тулган.* З.Фәтхетдинов. *Округ госпиталеннән хирург чакырылык булгач, димәк, хәлем шәптән түгел.* Р.Вәлиев. *Икенче баскыч мәктәбе халкы 4000 гә җиткән һәрбер шәһәр яисә округта ачыла.* Ә.Хуҗиәхмәтов

ОКСИД *и. гр. хим.* Элементларның кислород белән кушылмасы. *Насыйри графит, фосфор, гипс, --- сода, бакыр оксидын кулланырга өйрәткән.* Ә.Хуҗиәхмәтов. *Тәмәке төтенендәге углерод оксиды гемоглобин белән бәйләнешкә керү сәбәпле, тартучы кешеләрнең йөрәк мускулларына кислород килү азая.* Идел. *--- Бетонга өстәлгән титан оксиды һавадагы агулы матдәләрне зарарсызландыра икән.* Мәдәни җомга

ОКСИДЛА́У *ф.* Коррозиядән саклау яисә декоратив максатлар белән металлның өсйөзен ясалма окисьләү

Оксидлап алу Тиз генә оксидлау

Оксидлап бетерү Тулысынча оксидлау

Оксидлап җибәрү Тиз генә җиңелчә оксидлау

Оксидлап тору Даими оксидлау

Оксидлый башлау Оксидларга тотыну

Оксидлый төшү Бераз оксидлау

ОКСИДЛАШТЫРГЫЧ *и. хим.* Оксидлаштыру сыйфатына ия матдә. *Оксидлаштыргычлар итеп бакыр оксидын, водород пероксидын һәм кислород атомын бирә ала торган башка матдәләрне кулланалар.* Химия

ОКСИДЛАШТЫРУ *ф. хим.* Оксидлашуга дучар итү. *Ә аның алтыннан башка бөтен әйберләрне оксидлаштырганын беләсездер.* З.Фәйзи. *Заводта аммиакны лаборатория шартларындагыга караганда бераз башкачарак оксидлаштыралар.* Неорганик химия

Оксидлаштыра төшү Бераз оксидлаштыру

Оксидлаштырып бетерү Тулысынча оксидлаштыру

Оксидлаштырып җибәрү Кисәк аз гына оксидлаштыру

Оксидлаштырып җиткерү Тиешле дәрәҗәдә оксидлаштыру

ОКСИДЛАШУ I *ф. хим.* Берәр элементның кислород белән кушылуы. *Теләсә нинди органик матдәләр оксидлашканда, углекислый газ һәм су хасил була ---.* Биология: кеше һәм аның сәламәтлеге. *Күп кенә матдәләр, шул исәптән кайбер майлар да, оксидлашканда яктылык бирү сәләтенә ия.* Кызыклы физиология. *Әмма толуол молекуласында метил группасы чагыштырмача җиңел оксидлаша.* Химия

ОКСИДЛАШУ II *и.* Берәр элементның кислород белән кушылуыннан барлыкка килә торган химик реакция. *Оксидлашу – энергия булдыруның бик әһәмиятле ысулы.* Кызыклы физиология. *Бензол оксидлашуга бик тотрыклы.* Химия. *--- шахталарда күмернең оксидлашу процессы бара.* Неорганик химия

Оксидлаша бару Торган саен оксидлашу

Оксидлаша башлау Оксидлашырга тотыну

Оксидлаша төшү Бераз оксидлашу

Оксидлашып бетү Тулысынча оксидлашу. *Аэроб хайваннар яңадан кислороды булмаган урыннарга күчәргә «ниятләгәч» --- оксидлашып бетмәгән продуктларны зарарсызландыруның элеккеге ысулларын исләренә төшерергә туры килгән.* Кызыклы физиология

Оксидлашып җитү Тиешле дәрәҗәдә оксидлашу

ОКСЮМОРОН *и. гр. лингв.* Логик яктан капма-каршы ике төшенчәне берләштерүдән барлыкка килгән стилистик фигура

ОКТА́ВА *и. лат. муз.* 1) Диатоник гаммада сигезенче тон

2) Беренчесе һәм соңгысы бер үк исемдәге (мәс., «до» һәм аннан соңгы «до») унике ярымтонны берләштерә торган интервал. *[Ятаган] кылларының көйләнеше ре октавадан ре диез беренче октавага кадәр.* Казан утлары. *Аларның [ярканатларның] ишетү органы 15 октаваны колачлый.* Кызыклы физиология

3) Иң калын ирләр тавышы; бас

4) *әд.* Шигырьдә махсус рифмалы сигез юллы строфа (беренче юл өченче һәм бишенче юллар белән рифмалаша, икенче юл – дүртенче, алтынчы юллар белән, җиденче юл – сигезенче юл белән)

ОКТА́ВАЧЫ *и. муз.* Калын тавышка, октавага (*3 мәгъ.*) ия җырчы

ОКТАН *и. гр. хим.* Молекуласы сигез атом углеродтан һәм унсигез атом водородтан торган углеводород. *Октан молекуласы мисалында крекинг процессларын чагыштырыгыз.* Органик химиядән дидактик материаллар. *Кайвакыт, октан санын арттыру өчен, аны [толуолны] бензинга өстиләр.* Химия

ОКТА́ЭДР *и. гр. мат.* Өслеге сигез өчпомак белән чикләнгән җисем, сигезкырлык. *Алар күзгә күренми торган күппочмаклар яки күпкырлыклар – квадрат яки тетраэдр, куб яки октаэдр һәм башкалар түбәсенә урнаша алалар.* Химиянең киләчәге. *Тетраэдр, параллелепипед һәм октаэдр – кабарынкы күпкырлыклар.* Геометрия

ОКТЕТ *и. лат. муз.* 1) Сигез мөстәкыйль тавыш яки уен коралы белән башкару өчен музыкаль әсәр

2) Сигез башкаручыдан торган ансамбль

ОКТЯБРИСТ *и. рус тар.* 1905 елдагы 17 октябрь манифестыннан соң Россиядә төзелгән эре буржуазия һәм алпавытларның контрреволюцион партиясе әгъзасы. *Урнәк өчен ике программа игътибар үзәгенә куела: кадетлар һәм октябристлар программасы.* И.Нуруллин

ОКТЯБРЬ *и. лат.* 1) Календарь елының унынчы ае. *Октябрь башлары иде инде бу.* Г.Ахунов. *Октябрь кичендә Укмаста булган хәлләр турында язылган иде ул хатта.* В.Нуруллин. *Октябрьнең унысы бит бүген.* Г.Әдһәмова

2) 1917 елның 7 ноябрендә (искечә 25 октябрендә) Россиядә Бөек Октябрь социалистик революциясе дип танылган тарихи вакыйга. *Г.Ибраһимовның Октябрьгә кадәрге әдәби иҗатының югары ноктасы – «Безнең көннәр» романы.* Казан утлары. --- *Унҗиденче елның Октябреннән соң булган тарихны да шик астына алабыз, кем әйтмешли, күзгә карап тәнкыйтьлибез.* Идел

3) Шул вакыйгага багышлап үткәрелә торган бәйрәм. --- *Октябрь һәм Май бәйрәмнәре көннәрендә авылның әле яңа туган баласыннан алып тәнендә җаны булган карт-карчыкларына тикле колхоз хисабына бәйрәм ашы әзерлиләр*. В.Нуруллин. *Кызыл мәйданда Октябрь бәйрәменә хәзерләнәләрме әллә...* Р.Мөхәммәдиев

ОКТЯБРЯТ *и. рус тар.* СССРда пионер сафларына керергә әзерләнеп йөргән башлангыч сыйныф укучысы. *Моңа кадәр гаилә атмосферасында һәм берничә дусты арасында үскән бала катлаулы мохиткә килеп керә. Укытучыга мөнәсәбәт, дуслар-иптәшләр, коллектив белән мөгамәлә, октябрят булу, пионерга керү, дружина, отряд сборлары һ.б. һ.б.* Р.Вәлиев. *Һәм үлеп беләсе килә: үзең белән бергә тәүге адымнарын ясаган, бер мәктәптә укыган, бер партада утырган, бер урамда, бер кварталда яшәгән, бергә октябрят булган --- кемнәр кайларда, кайсы кем булган, аларның язмышлары нинди икән?* Р.Мирхәйдәров. *Хәзер яңа буын. Октябрятлар, комсомоллар буыны.* М.Әмирханов

ОКУЛИСТ *и. фр.* Күз авырулары врачы. *Окулист түгел мин түгелен, андый штат бездә буш тора хәзергә.* Р.Төхфәтуллин. *«Окулист» дигән язулы ишекне ачып кердем.* Идел

ОКУЛЯР *и. лат. физ.* Оптик приборның бер линзадан яки линзалар системасыннан торган күзәтү-карау җайланмасы. *[Танклар] Калкып чыкты! Окулярда Үрмәлиләр, зураялар. Секунд саен нинди чиккә Якынлаша шулай алар?!* Р.Әхмәтҗан. *Көпшәнең өске өлешендә зурайткыч ике пыялалы окуляр бар.* Ботаника. *Тубусның өске өлешендә кысадан һәм зурайткыч ике пыяладан торган окуляр бар.* Биология

ОЛАГУ *ф. гади с.* 1) Берәр кая китеп югалу, юкка чыгу (яратмаган, юкка чыгуы теләнгән кеше хакында яки озак йөрүгә ачуланып әйтелә). *[Малайларың] олактылар шәһәрләргә, Җайлы эшкә, чиста эшкә.* Г.Афзал. *Сигнал! Сигнал! Кая китеп олактың әле син?* Н.Хәсәнов. *Сине эт белән дә тапмассың, җәһәннәмгә олактың.* Н.Гыйматдинова. *[Гөлсем:] Олак, кайтып керәсе булма!* М.Хәбибуллин

2) Югалу, китү (күңел төшенкелеге, нәрсәдәндер качарга теләк булганда әйтелә). *Сөйгәнеңне алып, дөньяның әллә кайсы читенә олагасы иде, дип уйлады Димка.* З.Фәтхетдинов // Югалу, тыну, басылу (табигать күренешләре тур.)

3) *боерык ф. форм.* Каргышлы теләкне белдерә: бетсен, юкка чыксын, кирәге юк; чәнчелеп китсен

Олагып тору Билгеле бер вакытка олагу. *[Зәкиулла абый] барган саен озак кына олагып торса да, йорт яңартылрлык акча, авылдашларын сокландырырлык кием киеп кайта алмады ---.* М.Юныс

ОЛАКТЫРУ *ф. гади с.* 1) Кая да булса еракка җибәрү. --- *Ул мине спекулянтлыкта гаепләп ике елга төрмәгә олактырды.* Г.Нурлы. *Шундыйларның «хәер-фатихасы» миллионнарны олактырды кайтмас җирләргә.* Э.Мостафин

2) Һәлак итү; үтерү; юк итү. *Ә [Фәһимә] өтекне олактырырга тиеш [ул]!* Н.Гыйматдинова

3) Берәр нәрсәне юкка чыгару // Үзләштерү. *Әллә вентиле җитәрлек кайтмый, әллә, кайтып та, «сулга» олактыралар.* Н.Әхмәдиев

Олактыра башлау Олактырырга тотыну. *Андыйларны Себергә олактыра башлагач, Римманың әтисен Мәскәү якларына баручы юлчының атына утыртып җибәрә ул.* Татар-информ

Олактырып бетерү Тулысынча олактыру. *Чиркәүне тиз арада бушату максатыннан, бәясен доллар белән дә исәпләп чыгара алмастай кыйммәтле «Цейс и К» аппаратларын, приборларны кайсын кая олактырып бетерделәр.* Ватаным Татарстан

Олактырып тору Даими олактыру. *Әгәр ремонт чорында аны берәр кая олактырып тора алсагыз, калган барлык проблемалар да хәл итәрлек.* Татарстан яшьләре

Олактырып яту Олактыру процессында булу. *Бәлки, син, без үзебез дә закон белән бик үк дус түгел бит, диярсең, ләкин без, Коста, дәүләтне какшатмыйбыз, чимал байлыкларын, башка кыйммәтләрне чит илгә олактырып ятмыйбыз.* Р.Мирхәйдәров

ОЛАН *и. диал.* **1.** 1) Бала. *Олан, менә шушы кулъяулыкка бер генә уч туфрак салып бирче, дидем.* М.Мәһдиев. *Синең атаң Хаҗимөхәммәт белән минем әтием Хаҗиәхмәт – бер ата*

балалары, бабабыз Зөбәернең нәсел тамырын дәвам иткән ике бөртек олан. Р.Мөхәммәдиев. – *Оланнарны йорттан биздермә, яме, Галикәй! – дияр иде Сарасы.* Р.Мулланурова

2) Малай. *Синең әле хатының гажәп тә гүзәл, бала табамы соң, тапса, кемне китерә – кыз баламы, оланмы?* М.Хәбибуллин

3) *ешрак күпл.* Өлкәннәр башкаларга якын итеп мөрәҗәгать иткәндә әйтелә: «туган(нар)», «иптәш(ләр)» мәгънәсендә. *Ярый, оланнар, бу тынгысыз карт эшебезне бүлдерде, дип ачуланмагыз.* Р.Ишморат. *Һи, йөрәгеңне кан белән юдырма, олан.* Н.Гыйматдинова

2. *с. мәгъ.* Бала, тиешле яшькә җитмәгән, яшь. *Өстәлдә сабый олан кенәзнең анасы җибәргән фәрман ята.* М.Хәбибуллин

ОЛАНЛЫК *и. диал.* Балачак. *Оланлыкта азар – картайгач тәүбә итәр.* Мәкаль

ОЛАНСЫТУ *ф. диал.* Баласыту. *Ә Зөләйха балакай илханга олансытып карый.* М.Хәбибуллин

ОЛАНШАК *җыйн. и. диал.* Балачага. *Оланшак тумый башлады, иренәхатынына кысырлык зәхмәте сукты.* Н.Гыйматдинова

ОЛА́У I *и.* 1) Йөк йөртү, кешеләр утыртып алып бару өчен атлы транспорт. *Олау артына Тәслимә менеп кунаклаган.* Ф.Шәфигуллин. *Кая таба китәр икән татар төялгән олау?* Р.Харис

2) Йөк төялгән һәм бер-бер артлы тезелеп бара торган атлы транспорт төркеме. *Кечкенә дигәч тә, олаулар саны утызлап бар иде.* В.Имамов

3) Бер олауга сыешлы йөк. *Аның каравы, юктан бар ясап, ике олау икмәк төяп озаттык.* Р.Мөхәммәдиев

4) *иск.* Крестьянга үз ат-арбасы белән казна малын түләүсез күчереп йөртү йөкләмәсе. *Кесәлне сосарга вакыт җиткәч, теге кешегә олауга әйтергә килделәр, ди: «Олау башы синдә, бармасаң, сугабыз», – диделәр, ди.* Мәзәк

5) *юн. кил. форм.* Олаучы хезмәте. *Врангель офицерлары, чигенә башлагач та, әбинең улын аты-ние белән олауга алып киткәннәр.* Г.Бәширов. *Сабан сөрү дә ошады миңа, олауга йөрү дә.* М.Юныс

ОЛА́У II *ф. диал.* 1) Ялгау, тоташтыру 2) Ялгап озайту

ОЛАУЛАП *рәв.* Бик күп, йөге-йөге белән

ОЛА́У-ОЛАУ *рәв.* Бик күп. *Ә адәм баласы үзенең гөнаһларын гомер буе җилкәсенә олау-олау итеп төяп йөрсенмени?* В.Имамов

ОЛАУЧЫ *и.* Олау (*1–2 мәгъ.*) йөртүче. *Кирәк икән, алар ук-корал ясаучылардан, олаучылардан бер-ике төмән оештырып, елганың уң ягына чыга алалар.* М.Хәбибуллин. *Олаучы белән Ырсытдин элек таныш түгел иде.* Я.Зәнкиев. *Казанга барышлый олаучылар төнге ялга туктый.* З.Нури

ОЛАУЧЫЛЫК *и.* Олау йөртү эше

ОЛАШТЫРУ *ф. лингв.* [а] авазын, шулай ук сүзнең [ӧ] авазыннан соңгы иҗекләрендәге [ы] авазын [ӧ] итеп әйтү

Олаштырып җибәрү Бераз олаштыру

Олаштырып тору Даими олаштыру

ОЛАШУ *ф.* Ирешү, тоташу

ОЛАЮ *ф. сөйл.* 1) *к.* **олыгаю**. --- *Мин инде байтак олайгач, егерме җиденче съезд һәм апрель Пленумнары кебек тарихи-революцион җыелышлар булды.* М.Мәһдиев. *Хәлбуки сугыштан соң авыр еллар узып, тормышлар да бер эзгә төшкәч, үзем дә инде олаеп, язучы да булып киткәч, үзәлгән элемтәне яңартырга бик мөмкин иде.* Ә.Еники

2) *диал.* Зураю (күләм ягыннан)

Олаеп бару *к.* **олая бару**. --- *Инде олаеп та барган ярлы балаган артистлары миңа нигәдер бик кызганыч булып тоелган иде шул чакта.* Ә.Еники. *Бүген уенда кызлар – ябык, тузган-таушалган киемнәр, сугыш авырлыгын кичкән, инде олаеп бара торган кызлар һәм Асаф исемнәрен белмәгән, быел калыккан яшүсмерләр...* М.Мәһдиев. *– Олаеп барган көнемдә бер сыер алып унны кайтарасымны белсәм, гомеремдә сөтле чәй күрмәсәм дә риза булыр идем кана, – дип кенә әйтә алды [Җиһанша].* Р.Рахман

Олаеп бетү Бик нык олаю

Олаеп китү Соңгы арада олаю. *Ләкин элеккеге Ялта җылылыклары юк иде инде: ул олаеп китте, минем дә чәчләргә ак йөгерде, элеккеге «балакай»лыктан чыктым.* М.Мәһдиев

Олая бару Торган саен олаю. *Без сөртендек инде яшь чакта. Хәзер олая барабыз...* М.Мәһдиев. --- *Яшәү өчен көрәшә-көрәшә, ниндидер максатларга ирешергә тырышып, елдан-ел әкренләп олая барган һәм, үзем дә сизмәстән, ниһаять, картлыгыма килеп җиткән чагым.* Я.Зәнкиев

Олая башлау Олаю билгеләре күренү

Олая төшү Бераз олаю. *Зәкәрҗан инде олая төшкән, авыр сулап куйды.* М.Мәһдиев

ОЛГАШУ *ф. к.* **олашу.** *Биредә, янында гына очы-кырые күренгесез диңгез тирбәлгәндә, күккә олгашкан мәһабәт наратлар күләгәсендә җырның сүзләре башкачарак яңгырый.* Д.Булатова.

ОЛЕАНДР *и. фр. бот.* Киндерчәләр семьялыгыннан көньякта үсә торган, ланцетсыман тар яфраклы, хуш исле эре ак, алсу, кызыл, сирәгрәк сары чәчәкле мәңгеяшел агулы куак; зәйтүн гөле, тал гөле. *Бүлмә гөлләреннән – олеандр, аквариумдагылардан – элодея, кыргый үсемлекләрдән – төньяк йогырты --- һ.б. үләнчел үсемлекләрнең яфраклары божра рәвешендә урнашкан.* Ботаника. *Олеандр – яктыны яратучан үсемлек.* Йорт эшләре

ОЛЕИН *и. лат. хим.* Майларны таркатып ясала торган сыек майлы кислоталар кушылмасы. *F витамины --- алыштырғысыз майлы олеин, линоль һәм линолен кислоталары буларак карала.* Урман аптекасы. *Олеин һәм линоль кислоталары глицериннең катлаулы эфирлары хәлендә үсемлек майлары составына керәләр.* Химия

ОЛЕОГРА́ФИЯ *и. лат-гр. сәнг.* XIX гасырның икенче яртысында майлы буяулар белән ясалган төсле рәсемне полиграфик юл белән башкару ысулы

ОЛИВИН *и. лат.* Токым хасил итә торган саргылт яшел минерал. *Ә менә Ай ташлары арасында кыр шпаты һәм оливин күп булуы ике күрше планетаның кардәш икәнлеген дәлилли.* Кызыклар дөньясы. *Бу йолдызлык*

[арыслан] астында туучыларга гәрәбә, хризолит, оливин, топаз тагарга киңәш ителә. Безнең гәҗит

ОЛИГА́РХ *и.* 1) Борынгы һәм Урта гасырларда: олигархик хөкүмәт әгъзасы

2) Эре монополистик капитал вәкиле. *[Гали телефоннан:] Әлү. Кем әле бу?[Берәү:] Мин бу. --- Ә кая төзәгән идең соң, олигарх сыңары?* Р.Гаффар. *Олигархлар Россиядә үзләрен бик иркен һәм уңайлы тоталар.* Татарстан. *Астролог Павел Глоба фаразлавынча, кризистан нигездә олигархлар зыян күрәчәк.* Татарстан яшьләре

ОЛИГА́РХИК *с.* Олигархиягә нигезләнгән. *Олигархик капиталга корылган трансмилли корпорацияләр башлап җибәргән глобальләштерү дип аталган сәясәт кешелек җәмгыятен моңарчы күрелмәгән фажигагә якынайта.* Ватаным Татарстан

ОЛИГА́РХИЯ *и. гр.* 1) Бер төркем колбиләүчеләрнең, капиталистларның, эре монополистик капитал вәкилләренең сәяси һәм икътисади хакимлеге. *Шуңа да халыкара олигархия финанс мәйданына алтынның әйләнеп кайтуыннан курка.* Татарстан яшьләре

2) Шундый идарәле дәүләт

ОЛИГОПОЛИСТ *и. рус* **1.** Берәр өлкәдәге төп продукцияне җитештерү һәм сатуда көндәшлек итүче берничә эре фирма-монополист. *Эре олигополистлар алып бара торган реклама, ассортиментны яңарту алар продукциясенә сорауны арттыра* ---. Икътисад теориясе нигезләре

2. *с. мәгъ.* Шундый монополиягә ия булган. *Олигополист фирмаларның базар тәртибе вариантларын истә тотарга тиеш.* Икътисад теориясе нигезләре

ОЛИГОПО́ЛИЯ *и. гр.* Берәр өлкәдәге төп продукцияне җитештерү һәм сатуда көндәшлек иткән берничә эре фирма монополиясе. *Олигополиянең теләсә кайсы моделе конкурентлар ихтыярын истә тотарга тиеш.* Икътисад теориясе нигезләре

ОЛИГОФРЕНИ́Я *и. гр. мед.* Тумыштан булган яки балачакта кайбер авырулардан соң калган акыл зәгыйфьлеге. *Әлеге хәйрия чарасы олигофрения, даун синдромы кебек авырулар белән чирле балаларга, балигъ булып, мөстәкыйль тормышка аяк баскач ярдәм итү йөзеннән күрелгәнгә, һичшиксез, зур әһәмияткә ия була.* Безнең гәҗит

ОЛИМП *и. гр.* 1) Грециядә иң югары тау массивы; борынгы грек мифологиясендә аллалар яши дип ышанылган тау. *Борынгы спорт уеннарында Олимп тавына акыл ияләреннән җиде кешене менгереп утыртканнар.* М.Мәһдиев. *Баланы Гермес дигән алла табып, Олимп тавына аллалар янына алып барган.* Н.Фәттах

2) Танылган шәхесләрнең югары катламы (язучы, шагыйрьләр һ.б. тур.). *Бөек композиторлар плеядасы яшәгән чорда алар инде олимп иде.* М.Галиев. *Әдәби олимп*

3) *күч.* Берәр эшчәнлектә ирешелгән югары баскыч (әдәби иҗат һ.б. тур.). *Алар ел саен яңа көч белән шигърият олимпын штурмларга ташланалар.* Мәдәни җомга

◊ **Олимп тынычлыгы** *кит.* Салкынканлылык, бик тыныч булу. *Сез артык пафос белән сөйләшәсез, фән аны яратмый, ул Олимп тынычлыгын сөя.* А.Расих

ОЛИМПИА́ДА *и. гр.* 1) Халыкара олимпия комитеты тарафыннан Грециядәге олимпия уеннары үрнәгендә дүрт елга бер үткәрелә торган халыкара спорт ярышлары. *Олимпиада уеннарында ярышырга да исәп бар әле.* Ф.Яруллин. *Шуннан бирле һәр олимпиада саен безнекеләр бөтен дөнья алдында үзләренең осталыкларын, җитезлекләрен, батырлыкларын, һәвәслекләрен күрсәтәләр.* Р.Миңнуллин. *Якташыбыз, Сидней һәм Афина олимпиадаларында медальләр яулаган, берничә тапкыр Россия чемпионы булып танылган Ирек Зиннуров моннан соң ярышларда чыгыш ясамаячак.* Ватаным Татарстан

2) *иск.* Үзешчән сәнгать ярышлары

3) Уку-укыту системасында төрле фәннәрдән иң белемлеләрне ачыклау максаты белән ел саен үткәрелә торган укучылар ярышы. *Математикадан олимпиадада катнаштым.* Д.Салихов. *Олимпиада вакытында без бер татар интернат-мәктәбендә яшәдек.* Ш.Җиһангирова. *Укучылар ел саен фәннәр буенча республика олимпиадаларында катнашып киләләр, җиңүчеләре дә бар.* Мәдәни җомга

ОЛИМПИА́ДАЧЫ *и.* Олимпиадада катнашучы. *Ә менә Корея Халык Демократик Республикасы олимпиадачыларын зур бүләкләр белән узындырмый.* Мәдәни җомга

ОЛИМПИ́ЙКА *и. рус* Спорт киеменең бер төре, трикотаж кофта. *Жбан кыш буе диярлек аның ул чакта бик модада булган олимпийкасын – ачык зәңгәр төстәге спорт фуфайкасын киеп йөрде.* Ә.Мушинский. *Түр башында зәңгәр олимпийка кигән, бөдрә чәчле, кыйгач кашлы, юкарак аксыл йөзле бер кыз язып утыра.* Р.Кәрами

ОЛИ́МПИЯ *и. гр.* 1) Борынгы Грециядә Зевс культы таралган һәм шуның хөрмәтенә спорт ярышлары үткәрелә торган өлкә

2) Шуның исеме белән аталган спорт уеннары; олимпиада (*2 мәгъ.*). *Олимпия уеннары, белгәнебезчә, дүрт елга бер тапкыр гына үткәрелә, шуңа күрә анда катнашу – зур дәрәҗә.* А.Гафиятов. *Кышкы Олимпия уеннары Канадада өченче тапкыр оештырылды.* Р.Хафизова. *Олимпия системасы*

ОЛИ́МПИЯЧЕ *и.* 1) Борынгы грек мифологиясендә: Олимп тавында яшәгән унике илаһның һәркайсы

2) Олимпия уеннарында катнашучы; олимпиадачы. *Күптән түгел Ханты-Мансида үткән дөнья чемпионатында олимпиячеләр бер медаль дә яуламады.* Кызыл таң

ОЛИФ *и. гр. к.* **олифа**. *Андый байлыктан бер тәэминатчының, әйтик, түбәсен буярлык кына олиф белән буяу табу ни тора ул?!* Ә.Еники. *Стеналар пөхтә итеп юка такта белән тышланган һәм бик шәпләп олиф белән буялган.* А.Гыймадиев. *Олиф үсемлек (җитен, киндер һ.б.) майларын эшкәртеп җитештерелә.* Төзү материаллары

ОЛИ́ФА *и. гр. кит.* Агач өслекләрне каплауда кулланылган лак, майлы буяу, шпаклёвка һ.б.ш.лар әзерләү өчен файдаланыла торган, үсемлек майлары һәм сумалаларыннан гыйбарәт тиз кибүчән

состав. *Буяудан бушаган өч литрлы банкага олифа тутырып алам да, камбузга кереп, шуны чиләктә кайнап торган суга утыртам.* М.Юныс. *Ядкәр буяу пумалалары табын куя, Гамил белән Таймас олифа алып кайталар, Рәүф үзе шпангоутларны почмактан беркетә торган тимерләр хәстәрли.* А.Тимергалин. *Авыл кырларына олифа, ацетон исе алып бара бит алар!* Р.Рахман

ОЛИФЛА́У *ф.* Олиф белән буяу, әйбернең өслегенә олиф сөртү, сылау. *Кипкәннән соң, ярыкларны чистарталар һәм өслекне олифлыйлар.* Юлдаш

Олифлап алу Тиз генә олифлау

Олифлап бетерү Тулысынча олифлау

Олифлап тору Даими, әледән-әле олифлау

Олифлап чыгу Бөтенесен олифлау

Олифлый башлау Олифларга тотыну

Олифлый төшү Бераз олифлау

ОЛПАТ *с.* **1.** 1) Җитди, дәрәҗәле, бөек. *Дөнья олы, кырыс һәм катлаулы, Шул ук вакыт ихлас ул, садә; Киң кодрәтле олпат ирләр кебек Гади, көче ташып торса да...* Р.Рахмани. *Олпат кыяфәтле, ялтыратып кырылган башлы, эре сөякле академик Староверов ачык йөз белән каршы алды ---.* Р.Вәлиев. *--- Мәгънәле сабырлыгын тел байлыгына күчереп сөйләшә белгән олпат ил агалары, кайда сез бүген?* М.Гали

2) Зур. *Алар юмарт, киң күңелле, олпат гәүдәле.* Мәдәни җомга

2. *и. мәгъ.* Бөеклек, мәһабәтлек

ОЛПАТЛА́РЧА *рәв.* Җитди рәвештә. *Инеш буендагы өянкеләр, без моны инде күптән беләбез дигән шикелле, олпатларча тын гына утыралар.* М.Галиев

ОЛПАТЛЫК *и.* Җитдилек, бөеклек, дәрәҗәлелек. *Мәшһүр кеше көче меңнәр күңеленә гайрәт, акыл, олпатлык өсти.* С.Поварисов. *Шул ук вакытта аңардан берничек тә аңлатып булмый торган олпатлык, рухи куәт бөркелә иде!* Ф.Садриев. *Кыяфәтенә, атлап килүләренә, гәүдә тотышларына гына күз салыгыз: олпатлык, тәвәккәллек, хакимлек ярылып ята бу кешедә.* Г.Гомәр

ОЛТАН *и.* 1) Аяк киеменең табан формасындагы аскы өлеше (махсус өлгедә киселә һәм тегеп яки кагып беркетелә). *53 тире эшкәртү заводы һәм 70 сбруй әйберләре ясау мастерское аяк киеме, олтан, кызыл һәм ак юфть (йомшак күн), бозау күне --- җитештерәләр.* Г.Кашапов. *Ачык һавада озак торгангамы, эчкә салкын төшә башлады, җылы ботинканың гүя олтаны юкарды ---.* М.Хәбибуллин. *Беркөнне әнинең киез итегенә олтан сала башладым.* Г.Галиева

2) *диал.* Тау итәге. *Ул, Айбулатовның кисәтүләренә карамыйча, Калатауның олтанын казып, причалга дамба салырга рөхсәт бирде.* Г.Кашапов

◊ **Олтан астына эләгү** *к.* **олтан астында яшәү**. *Империя олтаны астына эләккән халыкларның язмышлары уртак.* М.Юныс. **Олтан астында яшәү** Буйсынып яшәү. *Испания гомергә тиран олтаны астында яшәмәс әле...* М.Юныс. **Олтан бит (йөз)** Оятсыз, намуссыз. *[Бибкәй Хашиягә:] Их... оятсыз, олтан бит! Күпме яшь кызларны минем күз алдымда башка илләргә сатып җибәрдең!* Т.Гыйззәт. **Олтан булу** Тулысынча буйсыну. *[Әҗмәгол:] Кенәзем, олтаныгыз булыр идем...* Батулла. *Олтан булсам булдым изге туфрагымда, Чит җирләрдә солтан булып калалмадым.* Н.Арсланов. **Олтан хезмәте итү** Буйсынып, хезмәт күрсәтеп көн күрү. *Гарәп патшаларына олтан хезмәте итәргә китерелгән егетләрнең, солтанга әверелеп, Каһирәдә даны ерак гасырларга яңгыраячак корылмалар салулары --- хакында сөйли.* Т.Әйди. **Олтанга әйләндерү** Буйсындыру, ихтыярсыз кеше итү. *Бу йортка төшеп ике ай үтмәде, Сабира аның җилкәсенә менеп атланды, көндәшен бөтенләй олтанга әйләндерде.* Г.Ибраһимов

ОЛТАНЛЫ *с.* Олтан салынган. *Ул өстендәге кайры тунның якасын күтәреп куйды, бүрегенең колакчыннарын төшереп бәйләде, олтанлы киез итегенең яңа чагында ук кайтарып куелган кунычларын күтәрде, кулларын, кушырып, җиң эченә тыкты.* В.Нуруллин. *Кайчандыр шәһәрнекеләр икәнен искәртеп пальто кигән, хәзер инде тәмам авыллашып, --- олтанлы зур итекләр кигән рус, украин хатыннары – бер тирәгә, авылныкылар бер тирәгә укмашып, бердәм тындылар.* М.Галиев. *Фазыл туган йорт җылысын сеңдергән олтанлы итеген мич башыннан алып киде.* Н.Әхмәдиев

ОЛТАНЛЫК *и.* **1.** 1) Олтанга яраклы, олтан салу өчен кирәкле материал. *Олтанлык сатып алу*

2) *к.* **олтан**. *Соңыннан ул олтанлык тегәргә, иске киез итекләрне ямарга өйрәнде.* Ш.Еникеев

2. *с. мәгъ.* Олтанга яраклык

ОЛТЫРАК *и.* 1) Махсус өлгедә киселеп, аяк киеменең эченә салына яки олтанга эчке яктан беркетелә торган юка күн, киез, катыргы яки материя кисәге. *Аяк тирли торган булганда, аяк киеме эченә олтырак салырга, төнгә аны алып киптерергә кирәк.* Татарстан яшьләре. *Аяк киеме эченә таза, йомшак олтырак (стелька) салыгыз.* Ялкын

2) *күч.* Начар, беткән кеше. *[Әнием:] Беләм, шәфкатең киң. Ә мин?! Олтырак! Беткән кеше.* А.Гыйләҗев. *Ул аны ачыктан-ачык дошман күрә, олтырак дип кенә атый бит.* Г.Тавлин

◊ **Олтырагына да тормау** Кемнән дә булса чагыштыргысыз түбән, начар булуына ишарә. *Олтырагыма да тормаслык шәһәр ялкавыннан гафу гына үтенәсем калган!* Ф.Садриев. **Олтырак бит (йөз, чырай)** *к.* **олтан бит**. **Олтырак йөз** *к.* **олтан бит**. **Олтырак булу** *к.* **олтан булу**. *Патшаны алласыннан да югары куеп, аның олтырагы булырга да әзер торган бу ак сакаллы дивана картка (бу минутта ул миңа шулай булып күренде) кырт кына кисеп әйттем ---.* Р.Ишморат. **Олтырак итү** *к.* **олтанга әйләндерү**. **Олтырак үбү** Бик нык ялыну, зур түбәнчелек күрсәтү. **Олтырак чырай** *к.* **олтан бит.** *Оятсыз, олтырак чырай ---. Малаеңнан оялыр идең!* Ф.Садриев. **Олтыракка әйләнү** Дәрәҗәне югалту, тулысынча буйсыну. **Олтыракка әверелү** *к.* **олтыракка әйләнү**. *Хәер, ахырдан үзе дә тәмам олтыракка әверелде ул.* Ш.Рәкыйпов

ОЛТЫРАКЛЫК *и.* **1.** Олтырак өчен материал

2. *с. мәгъ.* Олтыракка яраклык

ОЛУГ *с. кит.* **1.** 1) Бөек. *Олуг профессорның үзен шулай «асыл сөяк» дип*

атавы кызга бик ошады. Ф.Яруллин. *Ике олуг мәмләкәт арасында сәүдә кәрваннары гына йөреп торсын.* В.Имамов

2) Олы, зур. *Бу – безнең олуг утенечебез.* М.Хәсәнов. *Һәммәбезгә олуг сынау узасы... Сират аша кичерер кем догасы?* Р.Гаташ

2. *и. мәгъ.* 1) Олы яшьтәге кеше

2) Билгеле бер даирәдәге абруйлы, дәрәҗәле, сүзе үтемле кеше. *Корәешнең олуглары даре нәдвәгә җыелып, Пәйгамбәр галәйһиссәлам хакында мәшвәрәт кыйлдылар.* К.Насыйри. *Казанның олуглары Сөембикәне Мәскәү кенәзенә бирергә була*

ОЛУГЛА́У *ф. кит. к.* **олылау**. – *Арабызда бер чал бар, яше өлкән, акылы югары: маңлай күзе күрмәгән белән, ак күңеле казакъ йортының каты кайгысы өчен ялкынланып янып тора, – дип, башта Биремҗан аксакалны олуглады.* Г.Ибраһимов

Олуглап тору Даими олуг санау

Олуглый төшү Бераз олуглау; тагын да ныграк олуглау

ОЛУГЛЫК *и. кит.* Бөеклек, мәртәбәлек, абруйлылык. *Син үзең күкләр илчесе, пәйгамбәрсең, олуглыклар иясе һәм аксакал син ---.* Кол Гали. *Японнарның чәйгә әзерләнү һәм чәй эчү ритуалы – үзе бер симфония, яшәүгә мәдхия, үткәнең, бүгенгең, киләчәгең каршында сабыр олуглык тантанасы.* М.Гали

ОЛУГЛЫКЛЫ *с. кит.* Мәһабәт, тантаналы. *Айның диңгезгә төшкән шәүләсе җир белән күкне тоташтырган нур күпере шикелле һәм гажәп матур, олуглыклы иде.* Ф.Әмирхан

ОЛЫ *с.* **1.** 1) Яшь ягыннан өлкәнрәк, алданрак туган. *Көтүгә олы малае Габделгазизне калдырып китте бу.* В.Нуруллин. *Олы кызы Казанда төпләнде, аңа да кайгы иртәрәк килде.* Р.Мулланурова. *Тажи исә, гаиләдә олы бала буларак, тормышның бөтен авырлыкларын үз өстенә ала.* Казан утлары

2) Өлкән, зур (яше, эш тәжрибәсе, хезмәт урыны һ.б. белән). *Олы кеше шулай шигырьләр белән кызыксынадыр дип, башыма да китермәгән идем.* Ф.Яруллин. – *Җүләрләнмә, Сафуан, олы кешеләр янында, – дип, Мәдинә апа аны битәрләгән була, үзе муеныннан кысып кочаклаган...* М.Галиев

3) *сөйл.* Күләме, үлчәме белән үз ишләреннән зур. *Ярый инде, гел елмаеп, гел сөйләшеп торучы олы авызы бар.* Ф.Садриев. *Олы тәнәфес вакытында кайнар аш ашау икенчеме, өченчеме кластарга кадәр булды.* Н.Фәттах. *Ул чорда самавыр – олы бер хәзинә, аны югалту зур бер фажига иде.* М.Маликова

4) Абруйлы, дәрәҗәле, ихтирам ителә торган. *Олырак кунакларның үзләрен генә калдырып булмый, алар белән Ханәфигә дә Хәснижамалларга кергәләргә туры килә.* В.Нуруллин. *Аштан олы кеше юк, шуңа мин дә, әлбәттә, йоланы үтәп, яңа пешкән күмәч сыныгын кулыма алдым.* Т.Әйди. *Берзаман Болгар ханлыгына читтән олы кунаклар килергә тиеш булган.* М.Маликова // Талантлы. *Һәм ул, полк алдында чыгыш ясаган олы командир сыман, көр, нык тавыш белән --- сөйләргә тотынды.* Я.Зәнкиев. *Кәримә күптән түгел генә олы шагыйрьнең авторлык кичәсендә булды.* М.Хәбибуллин. *Тукай безнең мәдрәсәгә килеп китә торган иде. Татарның олы шагыйре.* Н.Дәүли

5) Әһәмиятле. *Синдә, Казан, олы тормыш тәҗрибәсе, Хак сүз эзләп бүген сиңа барам.* Р.Рахмани. *Тормыштан да олырак мәктәп юк, энем.* Ә.Гаффар. *Олы эшкә тәвәккәлләгәндә, йомшаклык күрсәтергә ярамый ---.* Я.Зәнкиев

6) Көчле; интенсив; тирән. *Пар канатлы олы сөю килсә, Без әзербез кыя таудан ташланырга.* Р.Рахмани. *Өстемә кинәт мондый олы бәхет ишелүдән башым әйләнеп китте.* Ф.Яруллин. *Бер йотым су эчү дә олы бәхет булып тоела.* М.Маликова // Тәэсир көче зур булган. *Аның кайтуы өй эчендә олы бер бәйрәм була...* Я.Зәнкиев

7) Төп. *Олы көтү чыкмаган әле.* Ә.Гаффар. *Машинаның кызыл утлары Әнвәрне үчекләп җемелдәгәндәй ераклашты һәм олы урам борылышында күздән югалды.* М.Маликова

8) Дәһшәтле, зур. *Ул [бөек каган] мине олы яуга чакыра.* Н.Фәттах

9) Тормыш мәгънәсенә тиңләрлек югарылыктагы. *Карга булып, бернинди максаты, олы хыяллары булмаган гап-гади карга да йөз ел яши, диләр.* Р.Вәлиев

2. *и. мәгъ.* 1) Зур, өлкән кеше, карт кеше. *Олылар көйсезләнсә, балалардан яманрак шул.* Ф.Яруллин. *Олылардан күрмәкче балалар да тынып калдылар.* Н.Фәттах. *Олылар сүзен ишетмәмешкә салышу мөмкин түгел иде инде ---.* Р.Мулланурова

2) Өлкән бала. *Зәкиянең олысы кайткан.* А.Гыйләҗев

3. *рәв. мәгъ.* Зур, эре итеп. *Аның артыннан олы-олы атлап, озын буйлы, тузган сары чәчле егет килә.* Р.Вәлиев

◊ **Олы авыз** Күп һәм кирәкмәгәнне сөйләргә яратучы кеше. **Олы бавыр** Үзен бик эре тотучы кеше. **Олы базар – кече туй** Шау-шуы зур, сый-хөрмәте аз булган мәҗлес. **Олы башы белән** 1) Беркатлы, уйлап тормыйча теләсә нәрсә сөйләүче өлкән яшьтәге кешегә ачу-үпкә, ризасызлык белдереп әйтелә. *[Галияр:] Олы башың белән болгатып йөрисең, адәм көлкесе!* М.Хуҗин. *Сәрбиназ: Олы башың белән тузга язмаганны сүләмә әле, апа.* Ф.Яруллин; 2) Үзенең өлкән, тәжрибәле кеше булуын авторитет, дәрәҗә итеп күрсәтү өчен кулланыла. *Олы башым белән ялганлап тормам инде.* **Олы башны кече итү** 1) Кече күңеллелек, түбәнчелек күрсәтү. *Тагын килдем синең янга Олы башым кече итеп. Бу юлы да кире кагып, Борырсыңмы көчең җитеп?* И.Гыйләҗев. *Олы башын кече итеп, правлениегә килә ул, дүрт-биш кило бөртек язып бирегез әле, ди.* Б.Камалов. *Яңа директор хатыны олы башын кече итеп үзе чакырып торганда, ник бармаска да, ник чәйләмәскә?* Г.Галиева; 2) Балачагалану, беркатлылану; дәрәҗә, абруй төшерү. **Олы дөрес** Дөреслеккә якын, ихтимал булган хәбәр. **Олы җан (иясе)** Эчкерсез, киң күңелле кеше. *--- Түбән җаннар ил кайгысын аңлый алмас, Олы җаннар гына әрнеп сулкылдар...* Г.Мөхәммәтшин. *Авыл кешесенең олы җаны Камырда да хәтта күренә.* М.Әгъләмов. **Олы җанлы** Эчкерсез, киң күңелле, кешелекле. *[Михай дәдәй татарларны] олы җанлы, тугрылыклы,*

хезмәт сөючән батыр халык, дип атады. М.Хәсәнов. **Олы йөрәкле** *к.* **олы җанлы**. *Эшчеләр, билгеле, гади, эчкерсез, киң күңелле, олы йөрәкле халык.* С.Поварисов. --- *Халкыма үзен аңларга ярдәм итә торган, олы җанлы, олы йөрәкле гади җир кешесен – эре бөртек бодайга тиң роль уйныйсым килә.* Сөембикә. **Олы җанлылык** Эчкерсезлек, киң күңеллелек. *Кыздагы эчкерсезлек һәм олы җанлылыкны Мортазин беренче атнада ук татып белде.* В.Имамов. **Олы көн** Христиан динендә: Пасха бәйрәме. *Нинди генә бәйрәм булмасын: Раштуа, Нардуган, Олы көн, Торойсын, Элҗән, Симек, Питрау, Покраумы – керәшеннәр аларны матур итеп билгеләп үтәләр.* Г.Ибушев. *Шулай ук христианнар өчен ел чиркәү бәйрәмнәре – Раштуа һәм Олы көн (Пасха), газап кичергән күпсанлы изгеләр көннәре белән бүлгәләнгән булган.* Урта гасырлар тарихы. **Олы күңел** *к.* **олы җан**. *Каян килгән аңа мондый олы күңел, ихтыяр көче, талант?* М.Маликова. **Олы күңелле** *к.* **олы җанлы**. *Сезнең алда тез чүгәм, Каракашлы авылында яшәүче олы күңелле горур татар кызы!* Ж.Тәрҗеманов. **Олы күтәрү** Булмастай эшкә тотыну. **Олы сабый** 1) Беркатлы, кече күңелле кеше; 2) Олы яшьтәге, әмма акылга җиңел кеше. **Олы сөйләү** Мактанып, арттырып сөйләү. **Олы юлга чыгару** Максатка ирешүдә төп юнәлешне бирү, үсешкә этәргеч булу, ярдәм итү. *Ал минем малайны, Зәйнетдин, рас син аны таныгансың, ал, олы юлга чыгар, кеше ит!* Г.Ахунов. **Олы юлга чыгу** Максатка ирешүдә төп юнәлешне табу, үсеш алу. **Олыга китү** Эшнең барышы теләмәгән якка китү, кирәкмәгән төс алу. **Олыдан кубу** 1) Эшне зурдан башлау. *Дөресен әйткәндә, З.Мансуровның иҗаты турында бик олыдан кубып, тирәнгә төшеп, киңгә җәелеп язылган мәкаләләрне мин очратмадым шикелле.* Р.Батулла. *Туры сүзле Мөхибә белән Назыйм да – фикер иясе кешеләр, ил язмышы турында олыдан кубып уйлану аларга һич ят түгел ---.* М.Хуҗин; 2) Чамадан чыгу; тыйнаклык, мөмкинлек чигеннән чыгу

ОЛЫ АНА *и. иск.* Борынгы заманда: гаилә, ыруг башлыгы булган хатын

ОЛЫ АНАЛЫК ЧОРЫ *и. тар.* Матриархат

ОЛЫ БҮЛМӘ *и.* Өйнең иң зур бүлмәсе, түр як, кунак бүлмәсе. *Олы бүлмәнең буеннан-буена сузылган өстәлләр затлы савыт-сабадан, сыйнигъмәттән сыгылып тора, диярлә була.* М.Маликова. *Олы бүлмәгә җыйналсалар, бер урын да калмый.* Безнең гәҗит

ОЛЫГАЙМЫШ *с.* Картайган (көн, гомер тур.). *Олыгаймыш көнеңдә бәла-казага тармагансыңдыр бит?* Б.Камалов

ОЛЫГАЙТУ *ф.* 1) Олы итү, олыга әйләндерү. *Шулайдыр, борчулар, югалтулар олыгайта кешене, сагыш олыгайта.* Г.Гыйльманов

2) Үз яшеннән олырак итеп күрсәтү. *Аңлаштык шикелле, әмма бер нәрсә һаман күңелне тырный: Чукмарёвның яшен нишләп олыгайталар соң әле болар?* М.Галиев. *Илленче еллар уртасында Фәрит, үзен бер яшькә олыгайтып күрсәтеп, армиягә китә.* Кызыл таң

Олыгайта төшү Бераз олыгайту; тагын да олыгайту

Олыгайтып җибәрү Сизелерлек олыгайту. *Мондый көчне аңа әнисе үлгәннән соң үзен олыгайтып җибәргән ниндидер үзгә хисләр, Мәрдән абзыйга һәм Имаметдиновка үз көчен күрсәтәсе килү һәм җаны-тәне белән савыгасы, тереләсе килү теләге бирде.* Г.Рәхим. *Бу хәл безне ничектер олыгайтып җибәрде.* Ф.Яруллин

Олыгайтып кую Тиз арада олыгайту

ОЛЫГАЮ *ф.* 1) Өлкәнәю; картаю. *Олыгайган саен, елларның йөгереше кызулана бара: чылк – бер ел узган, чылк – икенчесе...* М.Маликова. *Олыгайдым мин, ханша, картлык шулай сиздермичә генә киләмедер.* М.Хәбибуллин. *Алар янына холыксызлык, әйләнә-тирәдәгеләр белән тынышып яши белмәү дә өстәлсә, кеше күзгә күренеп олыгая.* Серле календарь

2) Үсү, җитлегү, тиешле осталыкка ирешү. *Шагыйрь дә, хикәяче дә, сатирик та булып Фаил Шәфигуллин күз алдыбызда үсте, көннән-көн яңарды, олыгайды.* Н.Арсланов

Олыгаеп бару Аз-азлап, акрынлап олыгаю. *Саниянең укуы сөенеч булса, олыгаеп барган ир өчен көенеч иде.* Я.Зәнкиев. *Күптән түгел юбилеен билгеләп узган, олыгаеп барса да, яшьлек чибәрлеген, сылулыгын җуймаган Венера ханым Шәрипова белән әңгәмә корып утырганда, бу гыйбарә күңелемә кат-кат килде.* Ватаным Татарстан. *Күрегез, инде олыгаеп барам.* Мәдәни җомга

Олыгаеп бетү Бик олыгайган булу. *Бары олыгаеп беткәч кенә без, ниһаять, яңадан очраша алдык.* Ә.Еники. *Олыгаеп беткәч... Кешедән оял.* М.Хуҗин. *Ничек инде ул олыгаеп беткән ир кешене биклән китсеннәр, ди?* Б.Камалов

Олыгаеп җитү Тәмам олыгаю. *Олыгаеп җиткән карчыкның шулай җилбәзәкләнүе ошап җитмәсә дә, аны гаепләргә ашыкмадым.* Т.Миңнуллин. *Олыгаеп җитәргә өлгермисең, ул арада гомер йомгагың түбәнгә таба тәгәрәргә керешкән була.* Р.Мөхәммәдиев

Олыгаеп килү Әкренләп олыгаю. *Анысын [ул баланы] мин аның табам дип тапмадым. Олыгаеп килә идем.* Ф.Яруллин. *Менә нәрсәне аңладым шушы олыгаеп килгән көнемдә.* З.Дәүләтов. *Шул карашы белән квартираны гына түгел, өстенә ефәк халат, аягына йомшак башмак кигән --- олыгаеп килгән кызны да үз бизмәненә салып үлчәгәндер һәм аның бәһасен шунда ук чамалагандыр ул...* М.Маликова

Олыгаеп китү Соңгы вакытта, көтмәгәндә олыгаю. *Әтиең сугыш башланганчы кайта-китә йөрде, анысын үзең дә беләсең. Олыгаеп та киттек.* М.Хуҗин. *Күтәрелеп караса, каршында Мәрзизә басып тора, үз яшеннән әллә күпмегә олыгаеп киткән, иренәре юкарып, күкселәнеп калган иде.* Р.Төхфәтуллин. *Егетнең йөзе суырылып калды, әллә ничек күз алдында олыгаеп китте.* Ф.Латыйфи

Олыгая бару Торган саен күбрәк олыгаю. *Олыгая барган саен яшьлеккә тартылу көчәядер, күрәсең.*

Ф.Яруллин. *Олыгая барган саен болай да йокы кыскара бит.* З.Фәйзи

Олыгая башлау Олыгаю билгеләре күренү, сизелү. *Укыган чакта безне санлап бетермәсә дә, олыгая башлагач безгә тартылды.* Р.Батулла. *Олыгая башлаган, басынкыланган, күпмедер акыл утырган, күпмедер акылын җуйган, әмма бәхетен таба алмыйча иза чиккән газаплы-гамьле бер бәндә.* Г.Гыйльманов. *Олыгая башлагач кына ирләр дә «рамка»га кергән кебек, теге ата каз да акылга утырды, әй.* Өмет

Олыгая төшү Бераз олыгаю. *Олыгая төшкәч кенә аңладым: иллә дә хәйләкәр, иллә дә шаян кеше булган икән Малик абзый.* И.Юзеев. *Умарта корты никадәр олыгая төшсә, ул яктылыкны шулкадәр яхшырак аера, аңа көчлерәк омтыла.* Умарта кортлары. *Әмма, олыгая төшкәнгә микән, җан башканы уйлап сызлана.* Сөембикә

ОЛЫ́ ИТҮ *ф.* Олылау, санлау, исәпләшү. *--- Хәзерге яшьләрдә олыларны олы итү дигән нәрсә юк.* В.Нуруллин. *[Миләүшә:] Бердәнбер олы абзагызны олы итегез!* Р.Вәлиев

ОЛЫ-КАРА *җыйн. и. к.* **олы-кары**. *– Бик рәхмәт! Алай олы-карага илтифатлы булгач, бик рәхмәт, – дип, кабат-кабат әйтте Дәүли.* С.Рафиков

ОЛЫ-КАРЫ *җыйн. и.* Олы яшьтәге кешеләр. *Хатын-кыз, яшүсмер һәм олы-карыны сугышның котылгысыз кыенлыкларына каршы кыюлык белән җитәкләп барырга, фронтка күп итеп икмәк җитештереп бирергә кирәк иде.* Г.Бәширов

ОЛЫЛА́РЧА *рәв.* Олы (*2 мәгъ.*) кеше шикелле. *Елады ул олыларча үксеп, Үзе өйгән бура артында.* С.Хәким. *– Әйбәт җыр! – Илсур олыларча җитди итеп әйтте.* Б.Камалов. *Өлкән углы белән ул ачуланмыйча, тыныч һәм олыларча сөйләште.* Н.Фәттах

ОЛЫЛА́У *ф.* 1) Хөрмәтләү, ихтирам күрсәтү. *Үз халкының әйбәт гореф-гадәтен, йолаларын тирәнтен олылаган, алардан хәбәре булган кеше – әлбәттә, җиңә торган кеше.* Ш.Рәкыйпов. *Бу, күрәсең, бала табучы ананы олылаудыр.* Ф.Яруллин. *Олыларны олылый белергә вакыт.* Я.Зәнкиев // Тантаналы рәвештә хөрмәтләү

2) Мактап, горурланып искә алу. *Сафия, театр дөньясында Бикашин исеме бик олылап телгә алынадыр, дип уйлаган иде.* М.Маликова

3) Хөрмәтләү, изге санау. *Ничәмә мең ел үтүгә карамастан, хайваннарны олылау, аларга табыну һиндуизмда әле дә булса көчендә.* Мирас. *Җиһангирым борынгыны бик олылый иде.* А.Гыйләҗев. *Ризыкны олылау, ризыкка табыну – соклангыч ашау культы.* М.Гали

Олылап килү Билгеле бер вакыттан әйтеп, сөйләп торган вакытка кадәр олылау. *Табигый ки, кеше --- тереклек итү чыганаклары булган чишмәләрне борын-борыннан олылаган һәм олылап килә.* Безнең гәҗит

Олылап тору Даими олылау

Олылый башлау Олыларга тотыну. *Ата мәче Мырыйны хөрмәтләп «Йонкотыйк Мыек хуҗабыз» дип олылый башлаганнар.* Р.Батулла. *Моның өчен аны бигрәк тә Илгизәр әфәнде кабат олылый башлады.* Ф.Яхин

ОЛЫЛЫК *и.* 1) Яшь ягыннан олы булу, өлкәнлек. *Олылык гәүдәдә түгел, акылда.* Мәкаль

2) Дәрәҗә, абруй; хөрмәткә лаеклылык. *Бу дөньяда һәркем лаек ихтирамга, раслый алса яшәвенең олылыгын.* Р.Фәйзуллин

3) *сөйл.* Зурлык (күләм, көч һ.б. тур.). *Бәхетнең олылыгын яки кечелеген үлчи торган бизмән юк лабаса.* Г.Галиева. *Менә ничә ел инде Айбулатов шушы иксез-чиксез кебек күренгән корылмаларга, туган якларга килгән байлыкның зурлыгына, кеше хыялы җитмәслек эшләрне чынга ашырырлык көч-куәтнең олылыгына, колачларның киңлегенә карый да күңелендә иркенлек, канәгатьләнү хисе тоя ---.* Г.Кашапов. *Бу кайгының олылыгы безгә бераз соңрак барып җитте.* Ф.Яруллин

4) *күч.* Зурлык, бөеклек. *Шушы гүзәллек, мәгъруранә биеклек һәм олылыкка гажәпләнеп карап торган Гөлфирәнең күңелен искәрмәстән эчке бер калтырану, әллә нинди курку хисләре биләп алды.* Г.Кашапов

ОЛЫЛЫ́-КЕЧЕЛЕ *с.* 1) Төрле яшьтәге; һәм олы, һәм кече яшьтәге

2) *сөйл.* Төрле зурлыктагы; һәм зур, һәм кечкенә

ОЛЫЛЫКЛА́У *ф. к.* **олылау**. *Ничектер ул аларны бик үз итеп, хөрмәт белән, олылыклап карый.* Г.Бәширов. *[Ул] Бер папирос алды да, кабызып та тормыйча, Мамакны бик олылыклап саубуллашып, баскычтан менеп китте.* Х.Камалов

Олылыклый башлау Олылыкларга тотыну

Олылыклый төшү Бераз олылыклау; тагын да ныграк олылыклау

Олылыклап тору Әле, хәзер олылыклау; даими олылыклау

ОЛЫЛЫКЛЫ *с.* Ихтирамга, хөрмәткә лаек. *Аның дәрәҗәле, олылыклы кыяфәтенә берәүнең дә исе китми.* Ш.Маннур

ОЛЫС *и.* 1) *тар.* Монгол империясе, татар ханлыклары чорында төрле зурлыктагы административ-территориаль берәмлек. *Әйтерсең лә ханлык бер Карача олысыннан гына тора!* Ф.Бәйрәмова. *Шушы ватандашлар сугышы дәверендә дәүләт аерым олысларга бүленә башлый.* С.Шәмси. *Олыс әмирләре ханның ниятен хупладылар, Иранда аларны алтын-көмеш, затлы келәмнәр, коллар, сылу кызлар көтә иде.* Р.Зәйдулла

2) Бурятиядә төп халык яшәгән авыл зурлыгындагы торак пункт

3) Якутиядә муниципаль район

ОЛЫСЫ́-КЕЧЕСЕ *җыйн. и.* Төрле яшьтәге кешеләр. *Тирән кесәләренә көнбагыш тутырып, капка төбендә чырт-чырт көнбагыш яручы Сәхиягә авылның олысы-кечесе карап үтте.* Ф.Яруллин. *--- Уеннарда олысы-кечесе бергә катнаша.* И.Сирматов. *Олысын-кечесен хөрмәтләү, арулык-пакълек, тыйнаклык, көнкүреш культурасы бүген дә татар халкы арасында югары бәяләнә, яшәү кануны булудан туктамый.* М.Мәхмүтов

ОЛЫСЫМАК *рәв.* **1.** Олы итеп, олыларча. *«Батька-Атакай» дип эндәшүләре дә, ихтимал, олысымак итеп күрсәтәдер.* З.Фәтхетдинов. *Алар тиргә батканнар, йөзләре олысымак булып*

ябыгып киткән, чырайларын тимгел-тимгел күләгә каплаган. С.Таһиров

2. *с. мәгъ.* Олыларныкы кебек. *Олысымак кыяфәтле, чибәр-чибәр киенгән кешеләр монда да сүзләрне сайлап кына сөйләделәр.* А.Гыйләҗев

ОЛЫСЫМАКЛАНУ *ф.* 1) Олыгаю. *Хәзер, сабырлангач, олысымаклангач, тугызынчы-унынчы класс укучылары аны аеруча ярата торган булдылар.* М.Маликова

2) Үзен олыларча тоту, олыларча кылану

Олысымаклана башлау Олысымакланырга тотыну

Олысымаклана бару Торган саен олысымаклану

Олысымакланып китү Көтмәгәндә олысымаклану

ОЛЫСЫ́-ЯШЕ *җыйм. и. к.* **олысыкечесе**. *Ләкин Сәйфулов җәбеп төшә торганнардан түгел, үзенең хаклыгына аерымачык инанган чакта олысынаяшенә турыдан бәрергә тарсынмый.* М.Хуҗин

ОЛЫ́ ТУЙ *и. этн.* Туйның төп өлеше. *Бу юлы олы туй безнең яктан.* М.Хуҗин. *Бүген олы туй башлану көне.* Я.Зәнкиев

ОЛЫ́ ХАН *и.* Урта гасырларда кечкенә җирле ханлыкларның һ.б.ш.ның дәүләт башлыгы. *Олы хан дәрәҗәсен алуга ирешкән Булат-Тимер, күпсанлы гаскәр белән килеп, Өяк, Болгар, Биләр шәһәрләрен җимерә, андагы утрак халыкны кырып сала* ---. Р.Әхмәтьянов

ОЛЫ́ ХАТЫН *и. иск.* Күп хатынлы гаиләдә беренче хатын

ОЛЫ́ЧА *рәв.* Олылар кебек. *Олыга – олыча, кечегә – кечечә була белә торган бик тә прастуй, бик тә әгъла җан иде, мәрхүм.* В.Нуруллин

ОЛЫ́ ЮЛ *и.* 1) Эре торак пунктлар арасындагы киң юл; тракт. *Әллә олы юлга йөгерергә микән?* Н.Гыйматдинова. *Олы юл әйләнгеч, өстән үтә, бусы – алар ягына турыдан бәреп чыга торган ташландык, иске юл гына.* Р.Муллануров. *Олы юлга кадәр атлый торырга булдык.* Ж.Тәрҗеманов

2) Үзәк, магистраль юл. *Кеше генәме соң, олы юллар да тузанга әйләнә.* Ә.Гаффар. *Хәер, олы юл өсте шул, үтеп-сүтеп йөрүчеләргә халык күнегеп беткән.* М.Хәсәнов

3) *күч.* Эштә, үсештә, максатка ирешүдә төп, дөрес юнәлеш. *Олы юлга, тормыш-көрәш юлына мин Зәйдән, Югары Баграҗ авылыннан – керәшенстаннан чыгып киткән кеше.* А.Гыйләҗев

ОЛЫ ЯК *и.* Өйнең зур бүлмәле ягы, түр як. *Олы яктагы яшьләр кыздылар.* М.Мәһдиев. *Балалар икесе – олы якта, ул кече якта йоклый.* Я.Зәнкиев. *Олы яктагы паласта чүп-чар җитәрлек икән, ләкин аларны җыярга вакыт юк иде.* Ф.Яруллин

ОМ *и. нем. физ.* Электр каршылыгын үлчәү берәмлеге (немец физигы исеменнән). *Токны җиргә үткәреп җибәрә торган һәр чыбыкның каршылыгы терлекчелек фермалары өчен күп дигәндә 100 Ом һәм бүтән объектларның күпчелеге өчен күп дигәндә 200 Ом булырга тиеш.* Авыл хуҗалыгы электригы белешмәсе

ОМАР *и. фр. биол.* Унаяклылар отрядыннан зур диңгез кысласы. *Миногалар, омарлар, краблар, еланбалыклар алырга вәкилләр Балтыйк буена, Калининградка ашыкты.* А.Гыйләҗев. *Диңгез кысласыманнары – креветка, краб, омар да шуларга керә.* Биология: хайваннар. *Аларга [югары төзелешле кыслаларга] елга кысласы, омар, магуст, креветка, ялгызак кысла, краблар керә.* Татарстанның үсемлекләр һәм хайваннар дөньясы

ОМБРО́МЕТР *и. гр.* Явым-төшемнең микъдарын билгеләү җайланмасы

ОМБУДСМЕН *и. швед* Җәмәгать яки дәүләт структураларының һәм шунда эшләүче затларның эшчәнлегендә гаделлек принциплары, аерым гражданнарның һәм катламнарның мәнфәгатьләре, хокуклары саклануга күзәтчелек итүче зат

ОМБЫ *и. диал.* Чөгә балыгы. *Омбы эләктерү*

ОМЕ́ГА *и. гр.* Грек алфавитында соңгы хәреф атамасы (Ω)

ОМЛЕТ *и. фр.* Сөткә болгатып яки берәр нәрсә кушып (яшелчә, яшел үләннәр һ.б.ш.лар) пешерелгән йомырка тәбәсе. *Шунда әнисе керә һәм: «Кызым, апаңа да омлет салып бирер идең», – ди.* М.Хәбибуллин. *Туглаган йомыркага крахмал, тоз кушып, юка гына омлетлар пешереп суыталар.* Серле календарь

ОММЕТР *и. гр.* Электр үткәргечеңең токка каршылыгын үлчәү җайланмасы. *[Гата] физика шкафлары куелган класста унынчы класс укучылары белән көн яттты, төн яттты. Линзалар, амперметр, омметрлар, магнит дугалары* ---. М.Мәһдиев

ОМО́ГРАФ *и. гр. лингв.* Язылышы бертөрле, әйтелешләрендә аерма булган сүзләр; омонимнарның бер төре. *Ш.Галиевтә омоним, омограф һәм этимологиягә таянган бик күп үрнәкләр очратабыз.* Татар балалар әдәбияты

ОМО́НИМ *и. гр. лингв.* Язылышлары һәм әйтелешләре бер үк, мәгънәләре төрле булган сүзләр. *Аңлашылганча, омонимнарны үткәндә генә түгел, сүзләрнең күпмәгънәлелеген өйрәнгәндә дә мондый мисалларга мөрәҗәгать итә алабыз.* И.Бәширова. *Сөйләм телендә омонимнар әллә ни кыенлык тудырмыйлар.* Р.Әхмәтьянов. *Омонимнар матур әдәбиятта бик үзенчәлекле стилистик чара булып йөриләр, алар нигезендә телдә каламбурлар – сүз уйнатулар барлыкка килә.* Ф.Сафиуллина

ОМОНИ́МИК *с. лингв.* Омоним булган. *Күпмәгънәле сүзнең мәгънәләре үзара бәйләнгән була; омонимик сүзләрнең мәгънәләре арасында андый бәйләнеш табып булмый* ---. Ф.Сафиуллина

ОМОНИ́МИКА *и. рус лингв.* 1) Лексикологиянең омонимнарны өйрәнә торган тармагы

2) Телнең омонимнар җыелмасы

ОМОНИМИ́Я *и. гр. лингв.* Мәгънәләрендә уртаклык булмаган сүзләрнең аваз тәңгәллеге. *Омонимия телнең үз сүзләре һәм алынма сүзләр аваздашлыгы аркасында барлыкка килә* ---. Ф.Сафиуллина

ОМО́НИМЛЫК *и.* Омоним булу. *Омонимлык күренеше – телнең тарихи үсеш нәтиҗәсе.* Р.Сәлахова

ОМОФОН *и. гр. лингв.* Омонимнарның бер төре: язылышы төрле, әйтелеше бердәй сүзләр

ОМОФО́РМА *и. рус лингв.* Омонимнарның бер төре: билгеле бер грамматик формада гына омоним булган сүзләр

ОМТЫЛУ *ф.* 1) Берәр якка бик кызу хәрәкәт итү, ыргылу, ташлану; нәрсәгә дә булса кискен хәрәкәт ясау. *Күзләрне йомып, түбәнгә омтылдым.* Ф.Шәфигуллин

2) Нинди дә булса максатка ирешергә яисә нәрсәне дә булса тормышка ашырырга тырышу, теләү. *Алтынга омтылган югалган, акылга омтылган юл алган.* Мәкаль. *Дөньяга яралганнан бирле кеше үзенең кемлеген һәм ниндилеген белергә омтыла.* М.Маликова

3) *күч.* Талпыну, ашкыну (йөрәк, күңел тур.). *Бер-берсенә омтылып яшәгән гашыйкларның күз явын алып җемелдәде алар [йолдызлар].* Р.Мөхәммәдиев. *Киләчәккә никадәр омтылсаң да, узган гомердән аерылып булмый.* М.Юныс. *Шуңа күрә аны ташлап, үз туган анабыз янына кайтырга омтылабыз.* Р.Вәлиев

4) *күч.* Тартылу. *Омтылабыз Сиңа җавап тоту өчен, Котылгысыз язган киләчәккә.* Р.Рахмани

Омтыла башлау Омтылырга тотыну. *Аларның лидерлары, референдум белән шөгыльләнәсе урынга, парламент сайлауларына омтыла башлаган иде.* Өмет

Омтылып йөрү Озак вакытлар омтылу. *Күп еллар буена укырга омтылып йөргән Ибраһим бу тәкъдимне кабул итә.* Фән һәм тел

Омтылып кую Кисәк омтылу. *Азык исен сизгәч, эт башта алга омтылып куйды, әмма килеп ашарга йөрәге җитмәде, яңадан үз почмагына сыенды.* Г.Сабитов. *Егет автобуска табан омтылып куйды һәм, үзенең бу тилелегеннән кыенсынып, тыелып калды.* М.Кәбиров

Омтылып тору Даими яки әледән-әле омтылу. *Моның янына халык мул һәм бай яшәргә, үз туган иле өчен горурлык хисе тоярга, аны сакларга омтылып торырга тиеш.* М.Хәбибуллин. *Шуңа күрә шәһәрдә яшәүче немец халкы Англия яисә Франциянең шәһәр халкы кебек бердәм дәүләт булырга әллә ни омтылып тормый.* Урта гасырлар тарихы

ОМТЫЛУЛЫ *с.* Омтылуы (*2 мәгъ.*) күренеп, сизелеп торган. *Омтылулы йөрәк. Омтылулы караш*

ОМТЫЛУЧАН *с.* Нәрсә дә булса эшләргә омтылып торган. *Бүген яшьләр белемле, омтылучан, зирәк, киң карашлы булып үсә.* Өмет

ОМТЫЛУЧАНЛЫК *и.* Омтылучан булу. *Ирләрдә ирлек сыйфаты җитми, хатын-кызны каһәрләүчән булалар, баерга омтылучанлык белән аерылып торалар.* М.Мәһдиев

ОМТЫЛЫШ *и.* 1) Нәрсә дә булса эшләргә тырышып ясалган гамәл, эш. *Егет килеш картаеп барган кешенең авыр көннәр ашаган яшьлеген кире кайтарырга омтылышы иде бу.* К.Тимбикова

2) Кыска гына вакыт эчендә ясалган эш-хәрәкәт. *Малай аларны бер омтылышта сындырырга итте.* А.Хәлим

3) Максатка ирешергә, нәрсәгә дә булса ия булырга омтылучанлык; теләк, ният. *Гомерләрнең генә чиге була, Омтылыш ул уттай мәңгелек.* Ш.Галиев. *Һәр заман яңа мәшәкатьләр, яңа омтылышлар уята бит.* Ф.Галиев

4) Нәрсә дә булса башкарырга яки нәрсәгә дә булса ирешергә юнәлтелгән эш-хәрәкәт; тәжрибә характерындагы башлангыч. *[Бу әсәрне] безнең татар Совет драматургиясендә бүгенге көн темасына күңелле комедия тудырырга беренче омтылыш дияргә мөмкин.* М.Җәлил

ОМТЫЛЫШЛЫ *с.* **1.** 1) Нәрсәгә дә булса омтылучан; максатчан. *Омтылышлы кызның шуңа күрә бүген уңышлар баскычы да биек.* Өмет

2) Зур тизлекле, кискен, җитез. *Омтылышлы хәрәкәт*

2. *рәв. мәгъ.* Зур тизлек белән, кискен, җитез итеп. *Дивизия бервакытта да чигенмәде, һөҗүмдә омтылышлы хәрәкәт итте.* Казан утлары

ОМТЫЛЫШЛЫЛЫК *и.* Омтылышлы булу

ОМТЫЛЫШСЫЗ *с.* Дәртсез, пассив. *Омтылышсыз күңел*

О́МУЛЬ *и. зоол.* Сөләйман балыклар семьялыгыннан ак балык. *Омуль ашамаган кеше Байкалда булмаган санала, диләр, без дә шул балык белән сыйландык.* Шәһри Казан

ОН *и.* 1) Бөртекле ашлыкларның тегермәндә тарттырылып, порошок хәленә китерелгән төре. *Ак төс – пакь төс, Беренче кар төсе, Он төсе, сөт төсе, Гөнаһсыз яр төсе ---.* Г.Афзал. *Он кар түгел, күктән яумый.* Ф.Шәфигуллин. *Чылбырлы сәгатькә алыштырган он белән алар кыш чыктылар.* Р.Мулланурова

2) Икмәк. *Он ашаган кеше әллә каян билгеле шул: бер тондыруга, авыздан ике теш очып чыкты.* Ф.Яруллин

3) Төрле үләннәрне, орлыкларны, җимешләрне киптереп, төеп яки тарттырып порошок хәленә китерелгән нәрсә. *– Ни хәлләр? – диде ул, [Шәйдулла] атка башак бирә-бирә ярылгалаган, ярыкларына фураж оны тулган каты кулларын сузып.* М.Мәһдиев. *Маннур үзе кибән куюда иде, яланөс, бөтен җиреннән тир ага, җилкәсенә, күкрәгенә тир белән печән оны, үлән сабаклары ябышкан ---.* Я.Зәнкиев. *Дуңгызларга печән оны, балык һәм ит калдыклары, витаминнар һәм минераль өстәмәләр кергән катнаш азык бирәләр.* Биология

4) Нәрсәнең дә булса ватылып, сынып, төеп бик вак хәлгә китерелгән өлеше. *Агач оны кушып көрпәдән пешергән ипине дә ыргытмыйлар: ачлык өйрәтә, нибуч!..* З.Фәйзи. *--- Прожекторларның пыялалары секунды белән онга әйләнеп, тимер палубага сибелде.* Ф.Шәфигуллин. *Тутырмалар булып агач оны, асбест, тальк, каолин һ.б. тора.* Химия

5) Порошок хәленә китерелгән минераль матдәләр. *Болардан тыш, терлекчелек продуктларыннан кайбер терлек азыгы (мәс., ит-сөяк оны), дару препаратлары, ашламалар эшләп чыгарыла.* Биология: хайваннар. *Суперфосфат суда тиз эресен өчен, төеп он итәләр.* Серле календарь

◊ **Он да юк, тоз да юк** *к.* **он суы да, тоз суы да юк**. *Он да юк, тоз да юк большевиклардан һәм булмаячак та.* Р.Мөхәммәдиев. **Он суы да, тоз суы да чыкмый** *к.* **он суы да, тоз суы да юк**.

Он суы да, тоз суы да юк Булдыксыз, бернәрсә дә белми, эшли алмый торган кеше турында

ОНАНИЗМ *и. лат. мед.* Җенси теләкне табигый булмаганча канәгатьләндерү; кул зинасы. *Азакта түзә алмады һәм бер мәртәбә ул ничек --- бәдрәфкә килеп кергәч, анда бөгелеп онанизм белән гөнаһланып маташучы Жбанга юлыгуын сөйләп бирде.* Ә.Мушинский

О́Н АШЫ *и.* Камыр ашы

ОНДА́ТРА *и. зоол.* **1.** Кыр тычканнары ассемьялыгыннан куе көрән төстәге кыйммәтле мехлы кимерүче җәнлек. *Күлләр арасында хикмәтле әрәмәлекләр, анда балык яратучы челәннәр, кыр үрдәкләре, яр буенда елтыр ондатралар.* М.Мәһдиев. *Безнең елгасуларда һәм урман-кырларда Америкадан китерелгән чәшке, ондатра, саз кондызы, янутсыман эт киң таралды.* Кызыклар дөньясында. *Ондатраның туган иле – Төньяк Америка.* Биология

2. *с. мәгъ.* Шул хайван мехыннан эшләнгән. *Ондатра бүрек*

О́НИКС *и. гр.* Кара һәм ак төстәге катламнары чиратлашып килгән минерал; ахакның бер төре. *Агат, аметист, тау бәллүре, оникс кебек үк, кычыткан энәсе дә кремний двуокисеннән тора һәм эче куыш цилиндрны хәтерләтә.* Мәдәни җомга. *Кызыл якут, караңгы төстәге оникс һәм яшел малахит аларның [кәҗәмөгезләрнең] талисманы булачак.* Безнең гәҗит

ОНКОГЕН *с. гр.* Яман шеш тудыручы. *Онкоген вируслардан иң беренче булып Раус саркомасы вирусы ачылды, ул тавыкларда яман шеш китереп чыгара.* Гомуми биология

ОНКО́ЛОГ *и. гр. мед.* Онкология белгече. *Беләсеңме, бер онколог миңа нәрсә сөйләде?* М.Маликова. *Онколог дигән врачның дөньяда бар икәнен дә белми яши иде, әле тагы да яшәр иде.* Р.Габделхакова. – *Чит илләрдә бу сан [койканың бер көнлек бәясе] 200–250 мең доллар тәшкил итә, – ди булек мөдире тәҗрибәле онколог Рафаэль Зәкәрия улы Шаммасов.* Мәгърифәт

ОНКОЛО́ГИК *с. мед.* 1) Онкологиягә караган, онкология белән бәйләнешле. *Әлеге бик файдалы бәлзәм нерв көйсезлекләреннән, ашказаны-эчәк, йөрәк-кан тамырлары системасы, онкологик авырулардан котылырга булыша ---.* Иң шәп календарь

2) Яман шеш авырулы

ОНКОЛО́ГИЯ *и. гр. мед.* 1) Медицинаның шешләрне һәм аларны дәвалау ысулларын өйрәнә торган тармагы. *Аны онкология клиникасына салдылар, операция ясадылар.* М.Мәһдиев. *[Валентина:] Гафу итегез, ялгышмасам, сез онкология диспансерында эшлисез бугай?* Ф.Латыйфи. *Республиканың онкология шифаханәсенә дәваланырга дип киткән әниләреннән хәбәр булмау аларның бәгырен телде.* М.Садыйков

2) *сөйл.* Яман шеш авыруы. *Үзенең караңгылыгы, шомлыгы белән ул онкология дигән XX гасыр чумасына бик туры килә иде.* М.Әмирханов

ОН КОҢГЫЗЫ *и. биол.* Катыканатлылар отрядыннан гүдәсенең өске ягы кара көрән, аскы ягы кызгылт төстәге, тегермәннәрдә, икмәк пешерү йортларында яшәүче, личинкалары он, ипи, бөртекләр белән туклана торган бөҗәк; *русчасы:* **хрущак мучной**. *Әгәр бөҗәкнең, мәсәлән, он коңгызының личинкасын, лабиринтта йөргәндә, гел уңга борылырга өйрәтсәң, үсеп җитеп коңгыз булгач та, бөҗәк шул күнекмәне саклый.* Кызыклы физиология. *Өйдә сакланган онда, гадәттә, алда әйткәнебезчә, он коңгызы ешрак очрый.* Мәдәни җомга

ОН КОРТЫ *и. биол. к.* **он коңгызы**

ОНЛАЙН *и. ингл.* **1.** 1) Интернетның реаль вакыт режимындагы бер өлеше. *Онлайнда күпме вакытны үткәргән мөмкин?*

2) Реаль дөньядан аермалы буларак, Интернеттагы мәгълүмат киңлеге

2. *с. мәгъ.* Реаль вакыт режимындагы. *Узган кышта «Саба дулкыннары» каналында онлайн режимында район мәдәният йортында бара торган «Бөек Җиңүдә яулап алганнарны чагылдырыйк әле җырларда» дигән исем белән оешма-предприятиеләр иҗат концертларын турыдан-туры күрсәтә башладылар.* Т.Нәҗмиев. *Шул ук вакытта электрон китаплар һәм гәзит-журналларның онлайн вариантларын укучыларның артуы күзәтелә.* Мәдәни җомга

3. *рәв. мәгъ.* Реаль вакыт режимында. *Онлайн эшләү. Онлайн тавыш бирү*

ОНЛАНУ *ф.* Онга буялу. *Куллар онлану*

Онлана башлау Онланырга тотыну

Онлана төшү Бераз онлану

Онланып бетү Тәмам онлану

Онланып китү Онны күбрәк салудан составында он күбрәк булу

ОНЛАТА *рәв.* Он хәлендә. *Ләкин онлата түгел, игенләтә ашлык тараткан өчен, Хөкүмәткә чакыртып, эштән алдылар.* Өмет

ОНЛА́У *ф.* Он сибү, онда әвәләү; онга буяу. *Камырны тагын онларга кирәк*

Онлап бетерү Тулысынча онлау; бик нык онлау

Онлап җиткерү Тиешле дәрәҗәдә онлау

Онлап тору Даими яки әледән-әле онлау

Онлый башлау Онларга тотыну

Онлый бирү Бернәрсәгә карамыйча онлау

ОНЛЫ *с.* 1) Онга буялган; он сибелгән. *[Әнкәй], онлы кулларын сузып, каршыга йөгереп чыкты.* Р.Вәлиев

2) Он салынган, он тутырылган. *Соңыннан онлы капчыкларны өйләренә алып киттеләр.* Ватаным Татарстан

ОНЛЫК *с.* 1) Он итеп тарттырырга билгеләнгән

2) Он алырга җитәрлек. – *Менә сиңа акча... – диде ул, кулындагы бер уч кәгазь акчаны Камилгә сузып. – Бер пот онлык...* Ш.Маннур

ОНЛЫЧА *и. диал.* Алабута

ОНОМА́НИЯ *и.* Кибет-базарларга йөрүдән тәм табу, ләззәт алу белән характерлана торган психик авыру. *Ономания – заман авыруы.* Татарстан яшьләре

ОНОМАСИОЛО́ГИЯ *и. гр. лингв.* Лексикологиянең әйбергә атама бирүне өйрәнә торган тармагы. *Лексикологиянең әйбергә атама бирүне өйрәнә торган ономасиология тармагы бар.* Ф.Сафиуллина

ОНОМА́СТИК *с. лингв.* Ономастика белән бәйләнешле, ономастикага

караган. *Октябрьдән соңгы чорда ономастик материал җыю дәвам итә.* Ф.Сафиуллина

ОНОМА́СТИКА *и. гр. лингв.* Тел белеменең ялгызлык исемнәрен өйрәнә торган тармагы. *Ономастика татар тел белемендә үзенчәлекле урын тота.* Ф.Сафиуллина. *Ф.Гарипова доклады ономастиканы өйрәнүдә И.Износков хезмәтләренең әһәмияте мәсьәләсенә багышланды.* Т.Хәйретдинова. *Шулай итеп, татарның мең еллык исем кушу йоласы бетте, исемнәр бакчасы – ономастика фәне – чүплеккә әверелде.* А.Хәлим

О́Н СУЫ *и.* Малларга эчерү өчен сыек апара

ОНТА *и. диал.* Он тузаны. *Гомеопатик даруханәләрдә хәзер дә «ликоподий порошогы» (сибә торган онта) алырга була («ликоподиум» – плаунның латинча исеме).* Татарстанның үсемлекләр һәм хайваннар дөньясы

ОНТА́У *ф.* 1) Он хәленә китереп төю, ваклау

2) *күч.* Изү, сыту. *Смеляков, үз атабабаларына эндәшеп, «Урыс тегермәнендә онтадыгыз килмешәк татар телен» дип шигырь язган иде.* Н.Нәҗми

Онтый башлау Онтарга тотыну

Онтый бару Эзлекле рәвештә барысын онтау

Онтый төшү Бераз онтау

Онтап кую Алдан яки тиз генә онтау

Онтап тору Әле, хәзерге вакытта онтау; даими онтау

ОНТОГЕНЕЗ *и. гр. биол.* Хайван яки үсемлек организмының барлыкка килүеннән алып соңгы яшәешенә кадәр булган индивидуаль үсеше. --- *Онтогенезны дүрт төп периодка бүлеп була.* Биология. *Онтогенез, организм үзенең төзелеше белән катлаулылыкның нинди баскычында торуына карамастан, барлык тереклек ияләренә хас.* Гомуми биология. *Онтогенезда гомеостазны саклау механизмнары шулай ук камилләшә.* Физиологияне өйрәнәбез

ОНТОГЕНЕ́ЗИС *и. гр. биол. к.* **онтогенез**

ОНТОГЕНЕ́ТИК *с.* Онтогенезга бәйләнешле. *Онтогенетик ысул катлаулы конкрет күзаллауларны анализлаганда да --- кирәк.* Атаклы галимнәр

ОНТОЛО́ГИК *и. филос.* Онтологиягә бәйләнешле, онтологиягә караган. *Аның иҗатында онтологик тема белән антропологик темалар үрелеп бара.* Фән һәм тел

ОНТОЛО́ГИЯ *с. гр. филос.* Фәлсәфәнең барлык-яшәеш, аның төп принциплары, категорияләре турындагы тармагы

О́Н УТЧЫЛЫ *и. биол.* Утчыллар семьялыгыннан кортлары он, ашлык, фураж запасларында яшәүче, алгы канатлары саргылт буйлы шәмәхә-көрән, арткылары куе соры төстәге күбәләк; *русчасы:* **огнёвка мучная**. *Ярмаларда, оннарда кайвакыт ашлык (он) коңгызы, амбар филчеге, он утчылы һәм башка корткыч коңгызларны очратырга мөмкин.* Мәдәни җомга

ОНЧЫ *и.* Он белән сату итүче. *Алтын балдак бармакта, әйләнәдер салмакка; Ончы хаҗи хәлен сөйлим, әйдә, барыйк аулакка.* Г.Тукай

ОНЧЫЛ *с.* 1) Составында он яки крахмал булган. *[Турак утының] хәтта җимешләре дә нарат җиләгенекен хәтерләтә, бары тик тәме белән генә аерыла: нарат җиләгенең – әче һәм сусыл, ә турак утының – төче-баллы, ончыл.* Татарстанның үсемлекләр һәм хайваннар дөньясы

2) Структурасы белән онга охшаш. *Алар [орлыклар] майлы, ончыл һәм бик туклыклы булалар.* Робинзон эзләреннән

ОНЧЫЛ ЧЫК *и.* Үсемлекләрдә ак кунык барлыкка килү белән характерлана торган авыру. *Дымлы җылы һава ончыл чыкның үсүенә булышлык итә.* Бакчачы календаре. *Күкерт-известь кайнатмасы – ончыл чыкка һәм пәрәвез талпанчыгына каршы яхшы чара.* Яшелчәчелек. *Бакчаларда без яфраклары он белән капланган кебек үсемлекләрне еш күрәбез. Бу – үсемлекләрдә гөмбәләр тудырган ончыл чык авыруы.* Татарстанның үсемлекләр һәм хайваннар дөньясы

ОНЫК *и.* 1) Баланың баласы. *Тик менә акчаны оныкларым бик ярата.* Ф.Яруллин. *Оныкларым татар китапларын Булыр микән укырлык.* Ш.Маннапов

2) Борынгыдан килгән нәселнең, ыруның дәвамчысы. *Ирексездән Башкортстан, Дунай болгарларына тугандаш Идел төркиләренең оныклары яшәүче күрше Татарстанның кичәгесе һәм бүгенгесе турында уйлады [Рудольф].* Р.Вәли

ОНЫК-НӘБӘР *җый. и.* Оныклар. *Онык-нәбәрләр үзләренең хәбәрсез югалган бабаларын, әтиләрен юксынып аваз салалар.* А.Гыйләҗев

ОНЫТТЫРУ *ф.* 1) *йөкл. юн. к.* **оныту**. *Өзелеп сагыну хисе Кеше исен генә түгел, әллә нинди тирән үпкәләрне, шикләнүләрне дә оныттыра ул.* А.Хәсәнов. *Бахар сихерли барын да, Ул оныттыра ярың да.* Ә.Синугыл-Куганаклы

2) Юкка чыгару. *Ләкин кайвакыт бер яхшылык ун яманлыкны оныттыра.* Р.Вәлиев

3) *сөйл.* **оныттырмагыз** *юкл. һәм боеру форм.* Тиешле вакытта искә төшерү кирәк булганда әйтелә

Оныттыра бару Торган саен күбрәк оныттыру. *Кызганыч, болгавыр чорларда кергән рәтсез гадәтләр моны оныттыра бара.* М.Галиев

Оныттыра башлау Оныттырырга тотыну. *Карале, Аллаһының рәхмәте, шушы гөнаһсыз сабый Маһирә өчен борчылуыбызны да оныттыра башлаган түгелме соң?* Г.Галиева

Оныттырып бетерү Тулысынча оныттыру. *Ияр өстендә егерме ел буе сөңге һәм кылыч тотып яшәү саулыкны гына какшатып калмый, ә яшьтән өйрәнгән иген игү, мал үрчетү һөнәрен дә оныттырып бетерә торган иде.* М.Глухов

Оныттырып җибәрү Кинәт оныттыру. *Купшы итеп бизәлгән Яңа ел чыршысы, мәдәният йорты хезмәткәрләре әзерләгән музыкаль композиция балаларның күңелләрен күтәреп, авыруларын, борчуларын оныттырып җибәрде.* Әлки хәбәрләре

Оныттырып кую Көтмәгәндә оныттыру. *Дөнья мәшәкатьләрен оныттырып куя беләләр бездә.* Шәһри Казан

Оныттырып тору Даими яки вакытлыча оныттыру. *Үз әти-әнием исән*

түгелләр инде, аларның юклыгын Гөлсинә апа белән Камил җизни онытырып торалар. Биектау хәбәрләре. *Җырым белән тамашачыны сөендерәсем, тормыш мәшәкатьләрен бераз онытырып торасым, күңелләренә шатлык өстисем килә.* Тамаша

ОНЫТУ *ф.* 1) Кемне яки нәрсәне дә булса хәтердән чыгару, искә төшермәү, күңелдә сакламау. *Күзгә бәрелеп тормаган нәрсәне хәтер бик тиз оныта.* Ф.Яруллин. *Җырлаучы күп, тик оныта күрмә Үз халкыңа җырлау кирәген.* М.Әгъләмов. *Онытма: киләчәктә сине картлык көтеп тора.* М.Юныс

2) Истән чыгарып җибәрү, кирәк вакытта хәтерли алмау. *Бик күп, бик күп яхшы кешеләргә Онытканмын рәхмәт әйтергә.* Г.Афзал

3) Очраклы рәвештә калдыру. *Сабын савытымны алырга онытканмын.* М.Юныс

4) Башка бер эш белән мавыгып, төп эштән читләшү. *Кара-чутыр малай, самолётын онытып, елаудан туктады.* Р.Вәлиев

5) Нәрсә белән булса да исәпләшмәү, игътибар итмәү. *Әдәп дигән нәрсәне онытасыз.* Ф.Яруллин

6) Кимсетү, санга сукмау; кайгыртмау. *Олыларны оныту*

7) Онытылу, мавыгып китү, бик нык бирелеп, нәрсәнедер игътибардан төшерү. *Ул гаҗәпләнүеннән саклыкны онытып алгарак атлады.* М.Маликова

◊ **Онытканда бер** Әллә нигә бер. *[Аның] Хатлары да онытканда бер генә килгәли.* Р.Вәлиев. *Кайчандыр ерак чакрымнардан ук таныла торган, йөрәккә килеп бәрелмәле гаярь тавышлы эт, хәзерге өнсез тавышыннан уңайсызланыпмы, онытканда бер генә өргән сыман итә.* М.Галиев. *[Гәүһәршад] чынаягына кагылмады да диярлек, ара-тирә, онытканда бер генә, иренәрен тигезеп куйгалады.* М.Әмирханов

Оныта бару Әкренләп оныту, торган саен оныту. *Бер-берсеннән бик ерак торулары сәбәпле, кешелек дөньясы аларны оныта барган ---.* Р.Шәмси. *Ләкин Бибинур башка тавышларны шунда ук оныта бара.* А.Гыйләҗев. *Соңгы елларда компьютерлар, коммуникаторлар һәм кәрәзле телефоннар көнкүрешебезгә шулкадәр нык кереп китте ки, без хәтта каләм белән --- язуны да оныта барабыз бугай.* Идел

Оныта башлау Онытуга табан бару, оныту билгеләре күренү. *Кайбер авырулар турында кешеләр оныта башлады, әмма, кызганыч, алар вакыт-вакыт үзләре турында искәртәләр.* Ютазы таңы

Оныта төшү Бераз оныту. *Кодакодагыйлыкны оныта төшеп, таләпчәнлекне аз гына арттырганда, аларның санын җиңел генә унга җиткереп булыр иде.* Казан утлары

Оныта килү Күптәннән бирле, даими оныту. *Баштарак берничә тапкыр әйтеп карадым каравын, ләкин аның көчле ихтыярына буйсынып, ул сүзләрне оныта килдем.* Г.Кашапов

Онытып бару Әкренләп оныту. *--- Рәхмәтулла җылылыкны онытып бара иде, аңа ялгызлык булсын да тамагы туйсын.* Я.Зәнкиев. *Газдалның чик-чаманы онытып баруына эченнән кайнап утырган Кәүкәбелҗәннәт бик матур елмаеп --- [касыгына төртте].* Ф.Садриев. *Без хәзер сатираны онытып барабыз түгелме?* Казан утлары

Онытып бетерү Бөтенләй оныту. *Тамашачылар минем «курчак»ны хәзер дә онытып бетермәгәннәр әле.* М.Маликова. *Үзең дә онытып бетермәссең.* Ф.Шәфигуллин. *Киңәш-табыш итәргә кирәк булган очракларда сез аның янына баргаларсыз, ул да сезне бөтенләй үк онытып бетермәс, дип уйлыйм.* В.Нуруллин

Онытып җибәрү Кисәк оныту. *Адәм балаларының бәгъзеләре исә гомеренең мондый чорларында иң алдан үз куышларын булдырырга кирәклеген онытып җибәрә.* М.Маликова. *Эш белән мавыгып, алар --- Фаягөлне онытып та җибәрделәр...* Я.Зәнкиев. *Ә менә кичә Рухияне күргәч, онытып җибәргән шул ул аны.* В.Нуруллин

Онытып йөрү Билгеле бер вакытка оныту

Онытып кую Кинәт оныту. *Имтихан вакытында төрле хәлләр була, кайберәүләр кирәгеннән артык дулкынланалар, каушыйлар, белгәннәрен онытып куялар дип, кызны тынычландырырга керештеләр ---.* Т.Миңнуллин. *Кызганыч, моның турында күп вакыт онытып куялар шул.* Өмет

Онытып тору Даими яки вакытлыча оныту. *Кардәшләрең янына бар, бергә бул син, гамьнәрең-кайгыларың читкә куй син, дәртләрең-рәнҗүләрең онытып тор син ---.* Кол Гали. *Әтисез дә калгач, кием-салым, ашау-эчү мәсьәләләре дә шактый кыен булгач, миңа институт турындагы хыялларымны онытып торырга туры килде.* В.Нуруллин. *Хатын-кыз турында онытып торырга туры килер.* М.Хәбибуллин

ОНЫТУЧАН *с.* Тиз оныта торган, хәтере начар

ОНЫТУЧАНЛЫК *и.* Онытучан булу

ОНЫТЧАК *с.* **1.** Онытучан. *Сеңергә янә бу кондыз кайрысы онытчак кешеләргә файдалыдыр.* Фән һәм тел

2. *и. мәгъ.* Онытучан кеше. *Онытчак бүркен югалтыр, куркак башын югалтыр.* Мәкаль

ОНЫТЫЛМАС *с.* Онытырга мөмкин булмаган; онытырга ярамый торган; истәлекле. *Әмма әнә шул беренче үбешү хисе Фәләх күңелендә һаман саклана әле һәм, мөгаен, гомере буена онытылмас, кайнар бер хатирә булып сакланыр.* В.Нуруллин

ОНЫТЫ́ЛМАСЛЫК *с. к.* **онытылмас**. *Аниме фестивальгә катнашучылар һәм аның кунаклары өчен онытылмаслык мастер-класслар һәм конкурслар әзерләнгән иде.* Сабантуй

ОНЫТЫЛУ *ф.* 1) *төш. юн. к.* **оныту** (*1–4 мәгъ.*). *Гайбәт сөйләнер дә онытылыр.* Ф.Яруллин

2) *з.-сыз* Хәтердән чыгу, искә төшмәү. *Ирләр өйдә вакытта кислота алдырырга онытылган.* Г.Камал

3) Үз-үзеңне, чынбарлыкны оныту; нык мавыгу, бирелү. *Ялгыз калганда гына түгел, кеше арасына чыкканда, чишмә янында да онытылып шуны җырлап җибәрә [Мөхлисә әби].* Ф.Яруллин. *Бер генә минутка күзне йомып онытыласы иде.* М.Юныс. *Тормыштагы иң якын кешеңне ничек онытылып яратырга мөмкин булса, шулай яраттым.* Х.Вахит

4) һуштан язу, аңны югалту. *Онытылган ул, тагын һушсыз тынган, Саташкан ул, газап кичергән.* Ш.Маннур

5) Үз-үзеңне тота алмау, кызып китү, ихтыяр көчен югалту. *Юк, барыбер онытылырга ярамый.* М.Маликова

6) Кабул ителгән, тәкъдим ителгән тәртипне бозу

Онытыла бару Торган саен күбрәк онытылу. *Башка сүзләре онытыла барды, шул бер сүз йөрәгемә кадалды, юшкын булып бәгыремә утырды.* К.Тимбикова. *Хәтернең психологик үзенчәлегенә бәйле андый хәлләр онытыла бара.* Өмет

Онытыла башлау Онытылу билгеләре күренү. Ләкин телне озак кулланмасаң, ул онытыла башлый. Р.Вәлиев. *Әлеге бәйрәмне үткәреп, Татьяна Николаевна чуваш халкының инде онытыла башлаган күпме матур йолаларын барлады, яңартты*. Әлки хәбәрләре

Онытыла тору Бер-бер артлы онытылу. *Тормышлар яхшыра, ә кыенлыклар онытыла торды, кибет, базар киштәләрендә ят ризыклар, җиләк-җимешләр артканнан-артты һәм күпләр... бакчалары барлыгы хакында онытуны хуп күрде.* Өмет

Онытыла төшү Бераз онытылу. *Тора-бара янаулар, ләгънәт укулар онытыла төште.* М.Хәсәнов. --- *Классицизм эстетикасы үткән гасырларда урнаштырган кырыс кагыйдәләр ничектер онытыла төште.* Ш.Маннапов. *Ләкин вакытлар узу белән кисәтү онытыла төшкән булса кирәк* ---. Р.Мирхәйдәров

Онытылып бару *к.* **онытыла бару**. *Илләр белән илләр кушылганда, Телләр белән телләр кушылганда, Онытылып барган чишмәнең Суын таптым, Җырын тыңлап кара, Бер могҗиза!! Китә исләрең.* М.Әгъләмов. *Верандада инде онытылып барган «Карурман» көе агыла.* Т.Таһиров. *Инде онытылып бара, дигәндә генә тиздән аны кабат ачтылар, ачтылар да җәрәхәтенә учлап-учлап тоз сиптеләр.* Р.Низамиев

Онытылып бетү Тулысынча, бөтен ваклыкларына кадәр онытылган булу. *Күз алдында бала чагының онытылып беткән, ә хәзер кинәт искә төшкән бер күренеше җанланды.* Ә.Гаффар. *Улының дәфтәр бите кичергән бәла онытылып та бетмәде, Сәгъдетдин өстенә икенче кайгы төште.* Я.Зәнкиев. *Синең туган телең нинди? Урыс чамы, әллә инде онытылып бетә язган татарчаңмы?* Р.Вәли

Онытылып калу Билгеле бер вакытка онытылу. *Ә монда мәсьәләнең иң авыры, иң четереклесе онытылып калган икән.* В.Нуруллин. – *Суфия, – дип кабатлады аталары, атларга да, атламаска да белмичә онытылып калган кызына.* Р.Мөхәммәдиев

Онытылып килү Күптәннән бирле онытылу; билгеле бер вакыт дәвамында исәпкә алынмау. *Күңел түрендә посып яткан, инде онытылып килгән горурлык хисе баш калкытып куйды.* Р.Вәлиев. *Ләкин тора-бара ияләштеләр, халык җырын гармунга кушылып ялгыз җырлау дип аңлаучылар да инде онытылып килгән «Дисәнә»не көйләп йөри башладылар.* Р.Вәлиев

Онытылып китү Соңгы арада онытылу. *Юк... гафу итегез, мин... онытылып киткәнмен.* Р.Вәлиев. *Бары таң алдыннан гына онытылып киткәндәй булды [Сөембикә]* ---. М.Хәбибуллин. *Һәм ул, таныш булмаган класс алдында басып торганда, нибары бер-ике минутка гына онытылып киткән Рухиясен яңадан исенә төшереп, күзләре белән аны эзли башлады.* В.Нуруллин

Онытылып тору Билгеле бер вакытка онытылу. *Аны күрүгә күңелне борчып торган уйлар онытылып тора.* М.Маликова. *Өйдә дә шундый чаклары була иде: [әни] өстәл артына утыра да башын иеп, керфек тә какмыйча, күзләрен бер ноктага текәп, онытылып тора.* Р.Вәлиев. *Җыр тәмамлангач та табын артында аларны тыңлап утырган туган-тумача бертын сүз башларга кыймый онытылып торды.* Р.Мөхәммәдиев

ОНЫТЫЛУЛЫ *с.* Хафасыз, борчусыз, бик тыныч

ОҢГЫ *и.* Балта күзе, сап кидерә торган урыны

ОҢГЫТ *и. диал.* Мәче башлы ябалакның бер төре. *Кош яманы оңгыт, ил яманы мангыт.* Мәкаль

ОҢКЫТ *с. диал.* 1) Кешегә ачык чырай күрсәтми торган, сөмсез

2) *к.* **оңгыт**

ОҢКЫТЛЫК *и. диал.* Оңкыт булу. *Бертигез бай ярлы белән, юк аның артыклыгы. Булса тик артыклыгы – оңкытлыгы һәм мутлыгы.* Ш.Бабич

ООМИЦЕТЛАР *и. күпл. биол.* Башлыча, паразитлык итүче гөмбәләр классы. *Оомицетлар – үзенә бертөрле гөмбәсыман организмнар.* Татарстанның үсемлекләр һәм хайваннар дөньясы

ОПАК *и. лат.* **1.** 1) Табак-савыт эшләүдә кулланыла торган ак балчык төре

2) Юка фаянска охшаш ак төстәге чүлмәкчелек эшләнмәләре

2. *с. мәгъ.* Шундый материалдан эшләнгән. *Опак савыт*

ОПАЛ *и. лат.* **1.** Аксыл зәңгәр яки саргылт ак төстәге минерал. *Кремнийлы комташта кварц комы сулы комташ белән берегә, һәм опал минералы барлыкка килә.* Төзү материаллары. *Ләкин опалны бүләк итәргә ярамый.* Безнең гәҗит

2. *с. мәгъ.* Шундый минералы булган, шундый минерал куеп эшләнгән. *Опал йөзек*

ОПА́ЛУБКА *и. рус махс.* Тимер яки тимер-бетон конструкциянең арматура яисә бетон катнашмасы белән тутырыла торган формасы. *Җомга көнне китерелгән бетонны төзүчеләр опалубкага койганнар* ---. В.Нуруллин. *Заводка өр-яңа рейкалар, опалубка такталары өзлексез килеп тора.* А.Гыйләҗев. *Стеналарны, читән үреп эшләнгән каркаслар һәм опалубкалар кулланып, даими катыру юлы белән дә ясарга мөмкин.* Яшелчәчелек

ОП-АРТ *и. инг. сәнг.* Тасвири сәнгатьтә бизәкләр ярдәмендә барлыкка китерелгән оптик эффектны куллана торган модернистик юнәлеш. *Оп-арт күргәзмәсе*

ОПЕ́КА *и. рус* 1) Хокукка сәләтсез затларның (ата-анасыз калган балаларның, психик авыру кешеләрнең) шәхси һәм мөлкәткә хокукларын саклау формасы. *Син карчыкны опекага аласың.* Х.Камалов. *Опекага алган әти кеше балаларны үзе китереп куйган.* М.Авзалова. *Җирле үзидарә органнары*

опекага бала алганнарга җирле бюджет исәбеннән өстәмә түләү билгеләргә хокуклы. Мәдәни җомга

2) Шундый эшчәнлек алып баручы оешма. *Опека бүлеге*

ОПЕКУН *и. рус* Хокукка сәләтсез затларның (ата-анасыз калган балаларның, психик авыру кешеләрнең) шәхси һәм мөлкәткә хокукларын саклаучы кеше; васый. *Аңлашылса кирәк, Харилай әллә ни хакимлек итә алмаган, илне аның абзыйсы һәм опекуны Ликург идарә иткән.* Кызыклы физиология

ОПЕКУНЛЫК *и.* Опекун вазифалары. *Әбисенең эшкә сәләтсез икәнлеген суд аша раслаганда гына, оныгы аны опекунлыкка ала.* Татарстан яшьләре. *Тәрбия эшен опекунлык белән алыштырмагыз.* Серле календарь

ОПЕР *и. рус сөйл. к.* **оперативник**. *Ашханәгә аш пешерүче булып урнашкач та, аны ГПУда опер булып эшләүче Нәбиуллин күреп алды.* М.Мәһдиев. *Оперлар әллә кайдан ишетергә сәләтле.* Безнең гәҗит

ОПЕРА *и. ит.* 1) Вакыйгалары вокаль һәм инструменталь музыка белән бәйле музыкаль драма. *Менә шундый гаҗәп талантлы кеше [Моцарт], биш яшьлек чагында ук опера язган ---.* Т.Таһиров. *Бу – татар халкының меңьеллык тәҗрибәсеннән тупланган шигърият, халык операсы...* М.Мәһдиев

2) Сәхнәдә шундый әсәрне гәүдәләндерә торган тамаша. *Болар, әйтерсең, опера караудан бигрәк, үзләрен күрсәтер өчен килгәннәр.* Ә.Еники. *Күземне ачып җибәрсәм, опера беткән була.* М.Юныс

3) *сөйл.* Шундый тамаша өчен махсус театр. *Опера бинасы моннан да гүзәлрәк.* М.Юныс. *Иң зур умарталар Париж операсы бинасы түбәсендә һәм Елисей кырларындагы күргәзмәләр үзәгендә урнашкан.* Мәдәни җомга

ОПЕРА-БАЛЕТ *и.* Опера һәм балет. *1803 елда Петербургның Зур театры ике тигез өлешкә бүленә: опера-балет өлешенә һәм драматик өлешкә.* Сөембикә

ОПЕРАТИВ *с.* **1.** 1) Операция белән бәйләнешле. *Лапароскопия ысулы белән башкарылган оператив дәвалауда исә күкәйлекләрне саклап калу мөмкинлеге бар.* Сөембикә

2) Турыдан-туры практик тормышка ашыра торган. *Шуннан соң [Миронов], кешеләр җыеп, ниндидер оператив совет, отрядлар оештыра башлады.* Ф.Галиев. *Районнар белән оператив идарә үзәк диспетчерлык хезмәте тарафыннан тормышка ашырыла.* Идел

3) Тиз эшли торган. *Болай уйлауның нигезендә иң әйбәт оператив работникларны да хаталандырып куя торган ашыгу ята.* Ф.Галиев. *Бу эштә [кунакны эзләүдә] оператив бәйләнеш кирәк.* М.Юныс

4) *неол. информ.* Микропроцессор, операцияләр башкарганда, эчтәлеге тиз үзгәрә торган мәгълүматны һәм программаларны вакытлыча саклап торган (хәтер тур.)

2. *рәв. мәгъ.* Тиз, кыска вакытта, эшлекле рәвештә. *Мөмкин булган кадәр оператив булырга тырышырбыз.* Г.Әдһәмова

ОПЕРАТИ́ВКА *и. рус сөйл.* 1) Кичектергесез эшләрне хәл итү өчен үткәрелә торган киңәшмә. *Майор Хаков киңәшмәләрдә дә, оперативкаларда да сүзен әйтергә ашыкмас, барысын да тыңлап бетерер ---.* М.Хәбибуллин. *Оперативкага материаллар әзерме?* М.Мәһдиев

2) *сөйл. информ.* Оператив (*4 мәгъ.*) хәтер. *Оперативканың минималь күләме*

ОПЕРАТИВЛЫК *и.* Оператив (*3 мәгъ.*) булу. *Мирсәетнең эше гадәттән тыш оперативлык таләп итә иде.* М.Мөхәммәдиев

ОПЕРАТИ́ВНИК *и. рус* Оператив төркем әгъзасы. *Мамак оперативникка кыю карады, ачуы да килмәде шикелле.* Х.Камалов. *Оперативниклар тарафыннан алардан 13 автомат, 10 пистолет, револьвер, пистолет-пулемёт --- алынды.* Мәдәни җомга

ОПЕРАТИВ-ТА́КТИК *с.* Хәрби операцияләргә һәм тактикага караган. *Аны шулай ук оператив-тактик максатларда да кулланып була.* И.Хәйруллин

ОПЕРАТИВ-ТЕ́ХНИК *с.* Оператив техникага караган. *Оператив-техник чаралар*

ОПЕРА́ТОР *и. ингл.* 1) *информ.* Компьютерда эшләүче белгеч. *Операторга бу санны машинага язу өчен биш минут кирәк була ---.* Кызыклар дөньясы. *Төрле информацион техника эшләп чыгару җитештерүнең фән сыешлы өр-яңа тармакларыннан берсенә әверелде, ә аңа хезмәт күрсәтүгә дөньяда программист, оператор һ.б. белгечлекләр барлыкка килүгә сәбәпче булды.* География

2) Кинооператор. *Операторларның шул җәнлекләрне генә саклап торып плёнкага элә́ктерүләрен кем белгән!* Г.Мөхәммәтшин. *Димәк, Гамил оператор буларак техниканы яхшы өйрәнсә дә, тәҗрибә тупларга, осталыкны тагын да арттырырга тиеш икән әле.* Г.Кашапов. *Аны [аквалангны] су туризмы белән шөгыльләнүчеләр, биологлар, археологлар, аучылар, фотографлар, операторлар киң куллана.* Кызыклы ихтиология // Телевидениедә сурәт тапшыру эшләрен башкаручы белгеч. *Безнең операторга Мәскәү телевидениесеннән дуслары киләсе икән.* Р.Вәлиев. *Оператор, ракурсны үзгәртеп, әлеге йөзне анфастан, профильдән, кайбер детальләрен зурайтып күрсәтте.* Сөембикә

3) Оешмаларда телефонга җавап бирүче хезмәткәр. *Авария хезмәте операторы бик оператив кыз булып чыкты үзе.* Безнең гәҗит

4) Пейджинг компанияләрендә: клиенттан телефон аша алган мәгълүматны тиешле абонентның пейджерына җибәрүче хезмәткәр. *Пейджинг компаниясендә оператор булып эшләү*

5) Элемтә хезмәте күрсәтүче оешма. *Шуңа күрә элемтә операторлары [шундый] --- команда бирделәр.* Т.Нәҗмиев. *Кәрәзле элемтә операторлары да форсаттан файдаланып калырга булдылар.* Татарстан яшьләре. *Моның өчен «Ростелеком» кебек эре операторлар, өстәмә каналлар ачып, шәһәр һәм илләр арасында берөзлексез элемтә урнаштыралар.* Акчарлак

6) *биол.* ДНКның махсус өземтәсе. *Сустрат молекуласы белән бәйләнешкә кергән репрессор оператор белән үзара*

тәэсир итешү сәләтен югалта ---. Гомуми биология

7) Хезмәт күрсәтү яисә товар базарында актив эшләүче оешма

ОПЕРА́ТОРЛЫК *и.* Оператор булу сыйфаты. *Биредә сценарий язу, режиссёрлык, операторлык серләрен үзләштерергә мөмкин.* Мәдәни җомга

ОПЕРА́ЦИЯ *и. лат.* 1) *мед.* Дәвалау максаты белән тән тукымаларын һәм эгъзаларны яру, кисү, тегү һ.б. *Аны җитәкләп операция бүлмәсенә алып кереп китәләр. Монда да тыгызлык икән.* М.Маликова. *Бөер, кан тамырларына операция ясатырга ярамый.* Мәдәни җомга

2) *хәрби* Зур төркем гаскәрләрнең билгеле бер максатка ирешү өчен башкарылган эш-хәрәкәтләре. *Операциягә өч дивизия, бер аерым полк, күп кенә танк частьлары һәм авиация катнаша.* С.Таһиров. *Теге вакыттагы уңышсыз һөҗүм операциясен тикшерүдән соң, бер-берсенә кул биреп, дусларча аерылышканнар иде.* Х.Камалов. *Ул [Гамир] --- булып узган канлы операцияне ачыкларга тырыша иде.* З.Фәйзуллин

3) Финанс, кредит, сәүдә һ.б.ш. мәсьәләләрне хәл итү. *Аның [кешнең] мехына алтын белән түлиләр, шулай ук ул валюта операцияләрендә дә кулланыла.* Кызыклар дөньясында. *Банкның актив операцияләре исәбенә беренче чиратта банк ссудалары керә.* Икътисад теориясе нигезләре

4) *информ.* Компьютерда: башкарыла торган эш, гамәл берәмлеге. *Суперкомпьютер секундына 700 млрд операция башкара*

5) *күч.* Ниндидер бер эш. *Тәмамланды бугай пош-пош операциясе.* Ф.Шәфигуллин

ОПЕРГРУ́ППА *и. рус хәрби* Оператив төркем. *Күп дигәндә ун-унбиш минуттан опергруппа килеп җитәр.* М.Хәбибуллин

ОПЕРЕ́ТТА *и. ит.* 1) Комик операның күңелле музыкалы һәм җиңел эчтәлекле бер төре. *Композитор Кальманның чардаш короле «Сильва», «Цирк принцессалары», «Монмартр миләүшәсе», «Марица» оперетталарында мадьяр көйләре, биюләре таң калырлык итеп бирелгән.* К.Латыйп. *Сугышның беренче айларында ук --- М.Пятницкий исемендәге хор, еврей опереттасы, Мәскәү дәүләт миниатюралар театры гастрольләре башланып китә.* Казан утлары. *Оперетта да татарларга борынгыдан ят түгел.* Сәхнә

2) Шундый әсәрне сәхнәгә кую эше. *Оперетта остасы*

ОПЕРОН *и. лат.* Бер, ике һәм аннан да күбрәк үзара бәйләнгән структур геннардан торган генетик материалның бер өлеше

ОПИАТ *и. хим.* **1.** Табигый мәк алколоиды яисә шуның кебек тәэсир итә торган ярымсинтетик матдә. *Опиат тәэсире*

2. *с. мәгъ.* Табигый яки синтетик опиумлы. *Опиат наркотик*

О́ПИЙ *и. лат.* Мәкнең өлгермәгән орлык тартмачыкларыннан ясалган, составында төрле алколоидлар булган, медицинада авыртуны басу чарасы буларак кулланыла торган матдә. *Наркоманнарның даими торагына әверелгән әлеге фатирга килгәч, хокук сакчылары опий белән миңгерәгән тагын берничә егетне табып алганнар.* Татарстан яшьләре

О́ПИСЬ *и. рус* 1) Исәпкә алына торган нәрсәләрнең исемлеге. *Документлар описе*

2) Шундый исемлекне төзү эше

О́ПИУМ *и. лат. мед.* Опиатлар төркеменнән көчле наркотик матдә; әфьюн. *Зур күләмдә кулланылганда, ул организмга опиум (наркотик) кебек тәэсир итә икән.* Татарстан яшьләре

ОПОЛЧЕ́НЕЦ *и. рус* Ополчение сугышчысы. *Тик, бер ай чамасы үтүгә, ополченецларның күбесе фронтка киттеләр, һәм отряд акрынлап таралды.* Т.Таһиров. *Атлы сугышчыны коралландыру ополченецны коралландыруга караганда шактый кыйммәткә төшә.* Урта гасырлар тарихы. *1815 елның февралендә ополченецлар Казанга кайталар.* Татарстан тарихы

ОПОЛЧЕ́НИЕ *и. рус* 1) Хәрәкәттәге армиягә ярдәм итү өчен төзелгән, гадәттә, иреклеләрдән торган гаскәр. *Ләкин башка ягын да уйладым: кырык беренче елгы ополчение, оборонаны күргән кешеләр күпме калды соң хәзер?* М.Мәһдиев. *Фронт Мәскәүгә якынлашкач, студия шәкертләре, күмәк рәвештә военкоматка барып, ополчениегә язылып кайтканнар.* М.Юныс

2) Патша армиясендә: хәрби хезмәттә булмаган яисә яше буенча запаска чыккан кешеләрдән төзелгән гаскәр

ОПО́ССУМ *и. инг. зоол.* Америка урманнарында, дала-чүлләрендә, таулы урыннарда яши торган, койрыгы эләктереп алуга җайлашкан, затлы мехлы, сумкалы имезүче хайван. *Опоссум балалары, нечкә койрыклары белән ябышып, аналарының аркасына утырып йөриләр.* Кызыклы физиология. *Төньяк Америка опоссумы – мәче кадәр зурлыктагы хайван, үсемлекләр белән дә, хайваназык белән дә туклана.* Биология

О́П-ПА *ы.* Көч куеп, тырышып эшләгәндә яки егылганда әйтелә. *Кара бу кәкре ботакны, ярылмаска чамалый. --- Солдат абыйсы белән көрәшмәкче! Баш аркылы томырыйк әле. Оп-па!* Н.Хәсәнов

ОППОЗИЦИОН *с.* 1) Оппозициядәге, оппозициягә бәйле. *Н.Н.Суханов большевикларның оппозицион матбугатка каршы һөҗүмнәре турында [сөйли] ---.* Казан утлары. *Әлбәттә, парламенттагы оппозицион партияләр мондый мөмкинлекләрне кулдан ычкындырмаска тырыша.* Мәдәни җомга

2) Нәрсәгә дә булса каршы мөнәсәбәт яки берәр нәрсә белән килешмәүчәнлек белдерә торган

ОППОЗИЦИОНЕР *и. рус* Оппозициядәге зат. *Беренче карашка ничек кенә пародоксаль тоелмасын, барлык либераль оппозиционерлар тарафыннан тәнкыйть утына тотыла торган финанс министры --- финанс бәйлегеннән коткарып калучы булды.* Татарстан

ОППОЗИЦИОНЛЫК *и.* Берәр нәрсәгә каршы мөнәсәбәт, ни белән дә булса килешмәүчәнлек

ОППОЗИ́ЦИЯ *и. лат. сәяси* 1) Билгеле бер партия, фракция һ.б.ларның рәсми хөкүмәткә каршы торуы. *Өстәвенә, ул вакытта сәясәттә оппозициядә торучы тынгысыз җаннардан һәм башка төрле «балласт»тан котылу тенденциясе көчәйгән ---.*

М.Госманов. *Яшәү шартлары төрлечә булуга карамастан, алар барысы да феодаль тәртипләргә оппозициядә торалар.* Ә.Хуҗиәхмәтов

2) Официаль хөкүмәткә каршы партия, фракция һ.б. *Шик юк, аның артында Идегәй морза оештырган оппозиция торган.* С.Шәмси. --- *Н.Белых сәяси оппозициянең оешып килүче «Солидарность» хәрәкәтеннән дә чыгуы турында белдерде.* Мәдәни җомга. *Оппозиция берничә мөһим функция үтәргә тиеш.* Татарстан

3) Каршы як. *Ярар, мин хәзер ни генә әйтсәм дә, син – оппозициядә.* И.Иксанова

4) Каршылык. *Властька иң бирелеп хезмәт итүченең дә күңелендә оппозиция яши.* Р.Зәйдулла

ОППОНЕНТ *и. лат.* 1) Бәхәстә, диспутта каршы чыгып сөйләүче зат. *[Телевизордан күрсәтелгән тапшыруда] ике оппонентның яклау төркемнәрендәге фикерләр дә төрлечә булды.* Мәдәни җомга

2) Чыгыш ясаучыга яки диссертантка каршы чыгучы. --- *Утыз галим, ун дипломант, Ассистентлар вә доцентлар, киңәшчеләр, оппонентлар Утыралар харап кына* ---. Г.Афзал. *Чөнки дипломник – ун минут, оппонент унбиш минутлар сөйләде.* М.Мәһдиев. *Баш архитектор Урманов – минем оппонент.* Р.Вәлиев

3) *сәяси* Сайлауларда: сәяси көндәш

4) Гомумән, кемгә дә булса каршы төшүче. *Шулай да бренд «КУ» түгел, ә «УДУ» диләр оппонентлар.* Татарстан

ОППОРТУНИЗМ *и. лат.* 1) *тар.* Эшчеләр хәрәкәтендә буржуазия, буржуаз партияләр һәм дәүләт белән турыдан-туры хезмәттәшлек итү, килешү сәясәтен алга сөрү. *Оппортунизмга каршы адым*

2) Принципсызлык, җайлашучанлык

ОППОРТУНИСТ *и. рус* 1) Оппортунизм сәясәтен тормышка ашыручы зат. *«Оппортунист! – диде [Саматов]. – Районның хуҗалык планнарына аяк чаласың!» – дип ычкындырды.* Я.Зәнкиев. *Милләтчеләрнең бөтен төрләрен, оппортунистларның һәр төстәгесен үрчетеп яткан бит ул занында.* Ф.Сафин. *Мине әллә кемгә санамагыз, мин оппортунист та, оппозиционист та түгел, ә гади бер кеше генә.* Татарстан яшьләре

2) Җайлашучан кеше. *Үзенә кирәккәндә оппортунист булу*

ОППОРТУНИ́СТИК *с.* Оппортунизмга бәйләнешле, оппортунистларга хас. *Шунысы кызык: Мирсәй Әмир утыз биш ел узгач, олы әдип булгач, яңадан шул оппортунистик хикәяне алып укып карый һәм иҗатына кызыллык китерми торган әйбәт хикәя икәненә тагын бер кат инана.* Р.Батулла

ОППОРТУНИСТЛАШУ *ф.* 1) Оппортунист булып китү

2) Җайлашу

Оппортунистлаша бару Торган саен оппортунистлашу

Оппортунистлаша башлау Оппортунистлашырга тотыну

Оппортунистлашып бетү Тулысынча оппортунистлашу

Оппортунистлашып китү Кинәт оппортунистлашу

ОППОРТУНИСТЛЫК *и. к.* **оппортунизм**

ОПРИ́ЧНИК *и. рус тар.* Опричнина гаскәрендә хезмәт итүче сугышчы. *Патша опричнигы*

ОПРИ́ЧНИНА *и. рус тар.* 1) Явыз Иван тарафыннан бояр-князь оппозицияләрен тар-мар итү һәм үзәкләштерелгән Русь дәүләтен ныгыту өчен үткәрелгән гадәттән тыш чаралар системасы. *Опричнина үткәрү*

2) Дәүләтнең Явыз Иван идарәсенә буйсынган, бояр-князь оппозициясенә каршы көрәштә терәк булган өлеше

3) Шул вакытларда махсус патша гаскәре. *Иван Грозный Вологдада берничә тапкыр була һәм аны үзенең башкисәрләре (опричнина) башкаласы итәргә җыена.* Безнең гәҗит

4) Борынгы Русьта: князь үлгәч, аның хатынына бирелгән җир кишәрлеге

ОПТАНТ *и. лат. махс.* Гражданлыкны сайлап алу хокукы булган зат. *Оптант гаиләсе*

ОПТА́ЦИЯ *и. лат. махс.* Бер дәүләттән икенче дәүләт карамагына күчкән территориядә яшәүчеләргә бирелгән гражданлык хокукы. *Оптациягә хокук*

О́ПТИК I *и. рус* 1) Оптика (*1 мәгъ.*) белгече. *Аның хуҗасы Андерсон – һөнәре белән оптик.* Иң шәп календарь

2) Оптик пыялалар, приборлар эшләүче оста

О́ПТИК II *с.* 1) Оптикага караган, оптика куллануга нигезләнгән. *«Йөнтәс» мыскыллы елмаеп: «Оптик приборлар барында, чит кеше квартирасында нәрсәнең кайда ятуын белү өчен, анда үзеңә кереп йөрүнең һич кирәге юк», – дип җавап бирде.* З.Фәтхетдинов. *Оптик приборлар ясаучы осталар мондый кимчелекләрдән кача белә-ләр.* Кызыклы физика. *Тарих башланганда ук инде, кешеләр беренче оптик җайланмалар – яссы көзгеләр ясарга өйрәнгәннәр.* Кызыклы физиология

2) Яктылыкка мөнәсәбәтле, яктылык тәэсирендә була торган. *Яктылыкның оптик тыгызрак тирәлектән оптик тыгызлыгы кимрәк тирәлеккә күчү очрагын тулырак тикшерик.* Физика курсы. *Шул мускул ярдәмендә хрусталик күзнең оптик күчәре буйлап күчеп йөри ала.* Кызыклы физиология. *Кристалларның оптик үзлекләре дә юнәлешкә бәйле.* Физика

О́ПТИКА *и. гр.* 1) Физиканың яктылык күренешләрен өйрәнә торган тармагы. *Параболаның оптикада һәм техникада кулланыла торган үзлеген чыгарыйк.* Алгебра

2) Оптик җайланмаларның гомуми исеме. *Оптика кибетендә күзлеккә чират тора идем.* Б.Камалов. *Оптиканы температураның кискен үзгәрүләреннән сакларга кирәк.* Файдалы киңәшләр

ОПТИМАЛЬ *с.* **1.** Иң яхшы, иң җайлы, иң туры килгән. *Беренчесе – кешелек цивилизациясе өчен куркыныч юл, икенчесе – оптималь юл.* Р.Сафин

2. *рәв. мәгъ.* Иң яхшы, дөрес итеп, отышлы. *Оптималь тереклекне тәэмин итә торган шартлар төрнең таралуы өчен киртә булып тора.* Биология

ОПТИМАЛЬЛӘШТЕРҮ *ф.* Мөмкин булган вариантлардан иң яхшысын сайлау, нәрсәне дә булса оптималь сыйфатлы, күрсәткечле итү. *Оптимальләштерәбез дип, кечкенә авылларда-гы мәктәпләрне ябалар* ---. Мәдәни җомга

Оптимальләштерә башлау Оптимальләштерергә тотыну. *Инде менә милли берәмлекләрне һәм милләтләрнең үзләрен дә оптимальләштерә башладылар.* Татарстан яшьләре

Оптимальләштерә тору Бер-бер артлы оптимальләштерү. *Оптимальләштерә торгач, ниһаять, мәгариф системасын бөтенләй «күмеп» тә куюыбыз ихтимал.* Татарстан яшьләре

Оптимальләштереп кую Тиз арада оптимальләштерү. *Үзләре дә бетә бит ул милләтләр, мәктәпләрдән милли компонентны алып, оптимальләштереп куясың да, вәссәлам!* Татарстан яшьләре

ОПТИМАЛЬЛЕК *и.* Оптималь булу. *Оптимальлек аларның гармониясендә.* Р.Сафин. *Оптимальлек заманы килергә өлгермәде, койрыгын сөйрәп китеп тә барды.* Ф.Яхин. *Оптимальлек турында кем нинди күзлектән карап фикер йөртә бит.* Ватаным Татарстан

ОПТИМИЗА́ЦИЯ *и. лат.* Кулайлаштыру, иң отышлы юлны сайлау эше. *Фәния (уфтанып): Ә бездә оптимизация, реструктуризация...* К.Ситдиков. *Әнә күп кенә җирләрдә оптимизация аркасында социаль тармакта эшләүчеләр кыскартылды.* Ватаным Татарстан. *Оптимизация дип уфтансалар да, мәктәпләрен саклап калган районнар республикада бар.* Безнең гәҗит

ОПТИМИЗМ *и. лат.* Киләчәккә ышаныч, күңел күтәренкелеге белән характерлана торган тормыш-яшәешкә мөнәсәбәт; *киресе:* **пессимизм**. *Ләкин Ибраһимдагы бетмәс-төкәнмәс оптимизмны хәтта ул әшәке бөҗәкләр дә бетерә алмадылар.* Ф.Хөсни. *Аерма шунда: режиссёр, төшергән саен, бер үк сүзне әйтеп куя: – Оптимизм кичәгедән сыеграк, елмаю сүрәнрәк!* Ф.Баттал. *Ә сәхнәдә оптимизм – бөек җиңүгә ышану.* Сәхнә

ОПТИМИСТ *и. рус* **1.** Оптимистик карашлы, оптимистик рухтагы кеше; *киресе:* **пессимист**. *Биредә күпне күргән, тагын да күбрәкне ишеткән, утлар-суларның теләсә ниндиен кичергән кешеләр, күпчелек очракта оптимистларның да оптимистлары җыелган иде.* Г.Кашапов. *Оптимистлар әйтсеннәр, ниһаять: Яшәргә, дип, теләге булган көчле – Шуңа да бит комнар диңгезеннән өстә калган кеше!* Р.Әхмәтҗан. *Тормышның һәр ягын үзе тоеп, сынап карарга омтылып, шуннан тәм табып, оптимист булып, тормышны яратып яши ул.* Сөембикә

2. *с. мәгъ.* Оптимистик рухлы. *Татар ашыкмый гүргә: Ул оптимист гомергә!* Г.Рәхим

ОПТИМИ́СТИК *с.* Оптимизм белән сугарылган. *Шундый фантастик сюжетка корылган пьеса оптимистик фикерне үзенчәлекле итеп раслый.* А.Әхмәдуллин. *80 нче елларда дөнья футурологиясендә киләчәккә оптимистик бәя бирүгә күчү башланды.* География. *Сүз дә юк, оптимистик рухлы, дәртле җыр.* Мәдәни җомга

ОПТИМИСТЛАНУ *ф.* Оптимистка әверелү

Оптимистлана төшү Бераз оптимистлану

Оптимистланып китү Кинәт оптимистлану

ОПТИМИСТЛА́РЧА *рәв.* Оптимист кешеләргә хас булганча. *Менә син киләчәккә оптимистларча карыйсың.* М.Юныс. *Ялланып эшләүчеләрнең яки вак хосусый җитештерүчеләрнең күпләре үз перспективаларын оптимистларча бәяли ---.* Икътисад теориясе нигезләре

ОПТИМИСТЛЫК *и.* Оптимизм. *Бу чорда иҗат ителгән күпчелек әсәрләр, нинди генә темага язылмасын, уртак өч үзенчәлек – күмәк тормыш, оптимистлык һәм патриотизм тойгысы белән сугарылган.* Р.Кукушкин. *Образлар белән эш иткәндә, халкыбызның гореф-гадәтләрен, матур сыгылмалы телен, тапкырлыгын, оптимистлыгын --- кертеп җибәрергә яратам.* Ф.Яруллин. *Ләкин болар алган файда аларның оптимистлыгы нигезле булган очракта гына күңелсез хәлләрне китереп чыгармаска мөмкин.* Икътисад теориясе нигезләре

ОПТЫ *и.* Карп балыклар семьялыгыннан сырты һәм ян-яклары карасу, барлык йөзгечләре кызгылт төстәге, төче сулыкларда яши торган балык; *русчасы:* **язь**. *Монда шым, мәрсин, нельма, муксун, щокур, сырка, ала балык, чөгә, чуртан, опты --- кебек илле биш төрдәге балыкларны тоталар.* Ж.Рәхимов. *Тирес кортына кызылканат, опты кебек балыклар каба.* М.Әмирханов. *Ак диңгез бассейны елгаларында опты, судак, кызылканат балыклары яшәгән.* Кызыклы ихтиология

ОПУ́НЦИЯ *и. лат.* Кактуслар семьялыгыннан яссы яфраклы, җимешләре ашарга яраклы Үзәк Америка үсемлеге (декоратив үсемлек буларак та үстерелә). *Опунция дигән кактус Австралиягә бүлмә гөле буларак кертелә.* Гомуми биология. *Озынлыгы ярты сантиметрга җиткән әлеге бөҗәкләр Үзәк һәм Көньяк Америкадагы опунция кактусларында яши.* Мәдәни җомга

ОПЦИОН *и. икът.* 1) Контрактта күрсәтелгән вакыт дәвамында билгеле бер товарларны, кыйммәтле кәгазьләрне сатарга яки алырга хокук бирә торган биржа килешүе

2) Шундый биржа килешүенә контракт, кыйммәтле кәгазь

ОР *и. диал.* Текә ярлы коры елга, ур. *Әй сез, чыбыклы юл буендагы чокырлар, орлар!* М.Мәһдиев. *Йөрим, күзәтәм, борчылам: әле татар җирендә фәрештәләр үкереп җылый торган орлар күп икән.* А.Гыйләҗев

ОРА́-ЕРА *рәв. к.* **орып-ерып**. *Менә ул, чуалган сафларны ора-ера алга атылып, Мохтар агайны куып җитәргә --- ашыкты.* Г.Минский

ОРА́КУЛ *и. лат.* 1) Антик дөньяда илаһ исеменнән күрәзәлек иткән каһин, багучы, күрәзәче. *Кабилә башлыгы белән берәттән бездә дини идеология, культ башлыгы, күрәзәче, багучы (шаман), башкаларда жрец, каһин, оракул кебекләр килеп чыккан.* Н.Исәнбәт. *Оракул, күрәзәчеләр юраган төшләргә нигезләнеп, хакимнәр һәм гаскәр башлыклары карарлар кабул иткән.* Безнең гәҗит

2) *күч. кит.* Сүзләре, фикерләре үзгәртелмәс хакыйкать итеп кабул ителгән зат

ОРАН *и.* 1) Бәрелешләрдә дошманнарны куркыту, алардан үзеңнекеләрне аеру, тану һәм яудашларны дәртләндереп яуга чакыру авазы. *Кыпчак*

халыкларының уртак ораны алач булган. Р.Әхмәтьянов. *Борын заманда аларның карт әниләре болай әйтер булган: ыруыбыз – кыпчак, агачыбыз – карагай, кошыбыз – карчыга, ораныбыз – тәңре, ә тамгабыз – дага.* Кызыл таң

2) Бик көчле кычкыру тавышы. *Бер оранның кайтавазы булып Гомер кичерәбез илдә без...* М.Әгъләмов. *--- Гайфулланың дәртле ораны кичке һаваны ярып таралды да якын-тирәдәге тупыл очларына барып бәрелде.* Р.Абзал. *Төн уртасында барчасы да хәвефкә баткан мөнадинең оран авазыннан сикереп торды.* В.Имамов

◊ **Оран кычкыру** *к.* **оран салу** (*3 мәгъ*). *Давай ашлык, давай сөт, дип оран кычкыруны җитәкчелек итүгә саныйсыз.* М.Хуҗин. **Оран салу** 1) Кемнедер кычкырып чакыру. *Сөрәнче, оран сал, җыелсыннар тәхет бүлмәсенә.* М.Хәбибуллин; 2) Шатлык хисе белән яки әйдәп чакыру. *Оран сала йөрәк сыкрый-сыкрый, Юл бирмәскә тели сагышка ---.* Х.Туфан. *Киләчәккә таба оча заман: Бергә оча күге, уҗымнары. Тәүлек саен кайнар бәхәсләшеп, Оран сала чуар «изм»нары.* Р.Низамиев; 3) Кычкыру, тавыш чыгару. *Гакылы булган кеше моны аңлый, вакытында туктала, ә менә гакылы сай кеше оран сала, буза куптара.* М.Хәбибуллин. *– Мин түзмәдем! – дип кабат оран салды Сафура.* Х.Ибраһим. *[Мирсәет]: «Юк, бу – ялган! Ялган сөйлисең, князь Кудашев!» – дип оран салырга җөрьәт итмәде.* М.Мөхәммәдиев

ОРАНГУТАН *и. малай зоол.* Кешесыман зур маймыл. *Аларга [кешесыман маймылларга] Африка горилласы, шимпанзе, шулай ук Калимантан һәм Суматра утрауларында яшәүче орангутаннар керә.* Биология: хайваннар. *Малай архипелагының Зур Зонд утрауларында бу төркемнең өченче вәкиле булган җирән төстәге орангутан яши.* Хайваннар турында очерклар

ОРАНЖЕРЕ́Я *и. фр.* Теге яки бу җирлектә ачык грунтта үсә алмаган культуралы үсемлекләрне үстерү өчен бина. *[Хуҗа] --- коттедж салырга кереште, өч катлы, берничә яруслы итеп, балык күле, бассейны, оранжереясы белән.* Г.Гомәр. *Күп кенә үсемлекләр оранжерея һәм бүлмә шартларында үзләренең туган илләрендәге кебек үсәләр ---.* Ботаника. *Оранжереяда азык күп ---.* Кызыклы физиология

ОРАНЛА́У *ф.* Оран салу; кычкыру. *Ак болытлар зәңгәр күкне кага! Күк оранлый (күк ул – кыңгырау): – Чәчәкләр, кошлар, бөҗәкләр!..* Р.Хисмәтулла

ОРА́ТОР *и. гр.* 1) Чыгыш ясаучы кеше. *Җитмәсә, оратор чыгышының уртасында мактап та җибәрде.* Т.Нәҗмиев. *Ораторлар әйтер бер көн: «Сәйдәш – Тукае ул безнең көйләрнең!»* Р.Фәйзуллин. *Иң мөһиме, башка ораторлар да тәнкыйть күзлегеннән чыгыш ясадылар.* Казан утлары

2) Оста, ышандырырлык итеп сөйләүче. *Эчке һәм тышкы политикабызны аңлатты. Оратор. Ут чәчеп сөйли.* Г.Ахунов. *Тик митингта төпле итеп чыгыш ясарлык ораторларыбыз азрак.* Р.Вәлиев. *--- Абеляр яхшы лектор, диспутларда җиңелүне белмәс оратор булып таныла.* Урта гасырлар тарихы

ОРАТО́РИЯ *и. ит. муз.* Драматик сюжетка хор, солист-вокалистлар, оркестр өчен язылган музыкаль әсәр. *Күбрәк опера, балет, симфоник оркестр яки орган өчен язылган әсәрләр, һич югында, оратория иҗат итәргә тырышалар.* К.Тимбикова. *--- Татар шагыйрьләре дә, республиканың тимер адымнарын данлап, озын-озын поэмалар, шигырьләр, гимннар, ораторияләр яздылар.* Казан утлары. *Биредә авторның Казан дәүләт камера оркестры башкаруында Рабит Батулла либреттосы буенча иҗат ителгән «Изге ядкәр» ораториясе яңгырады.* Акчарлак

ОРА́ТОРЛАРЧА *рәв.* Оста итеп (сөйләү тур.). *Алар кебек үк ораторларча сөйли алмасам да, сүзгә мин дә кесәгә кермим, анысы.* Шәһри Казан

ОРА́ТОРЛЫК *и.* Халык алдында нотык сөйләү осталыгы. *Афинада хәрби сәнгать белән берәрттән ораторлык сәнгатенә дә бик югары бәя бирелгән.* Ә.Хуҗиәхмәтов. *Моның өчен аларга ораторлык дәресләре укытыла, чит теллар өйрәтелә, зиһенне үстерә торган уеннар (шахмат, брэйн-ринг) оештырыла.* Мәдәни җомга

ОРБИ́ТА *и. лат.* 1) *астр.* Күк җисеменең икенче бер күк җисеменә карата пространствода хәрәкәт юлы. *2013 елга кадәр бөтен Плеядалар йолдызлыгы Сириус тирәсендәге орбита буенча хәрәкәт башлаячак.* С.Шәмси. *Скорпион планетасының җиденче орбитасында бер вакансия бар, ди... Галәм тузанын себерергә.* Ф.Фәизов. *Кызганычка каршы, орбитадан кешенең бәрәкәтле эшләре, ул салган матур калалар, казыган каналлар, төзегән зур плотиналар гына түгел, кешелек дөньясының Җиранага китергән гаять зур зыяннары да ачык күренә.* Кызыклар дөньясы

2) *хим.* Электроннарның хәрәкәт юлы. *Бу химик реакцияләр процессында электроннары югарырак орбиталарга күчкән, тәэсирләнгән молекулалар хасил була.* Кызыклы физиология

3) *анат.* Күз алмасы урнашкан чокыр; күз чокыры

4) *күч.* Өлкә. *Йөрәк әле интим орбитада. Түбән әле аның очышы.* Р.Юнысов // Дәрәҗә. *Әйдә, хыял, син күтәрче безне романтиклар орбитасына.* Р.Әхмәтҗан

5) *күч.* Эзлекле тоткан юл, мәсләк. *Кая гына тибәрсә дә язмыш, Этәрсә дә адәм баласын, Әйтерсең лә тугры юлдан аны, Орбитадан сөрә аласың!* Х.Туфан

ОРБИТАЛЬ *с.* Орбитадагы. *Кичә орбиталь станциянең аэронавтлары ачык космоска өч тапкыр чыктылар.* К.Кәримов. *Бу технологияне орбиталь комплексларда озак вакыт авырлык югалу халәтендә булып, космоста гына тормышка ашырып була.* Физика. *Бөтен сәяхәтләре «Мир» орбиталь станциясе белән бәйле.* Мәгърифәт

О́РГАН *и. гр.* 1) Тәннең тиешле функцияне башкара торган һәм билгеле бер төзелештәге өлеше; әгъза. *--- Балалык чорында буй һәм сизү органнары яхшы үсә ---.* Ә.Хуҗиәхмәтов. *Нәкъ менә ул [нерв системасы] эчке органнар, йөрәк-кан әйләнеше, иммун һәм сулыш алу системасы эшчәнлеге өчен җавап бирә.* Кызыклар дөньясы

2) Билгеле бер идарә системасына кергән дәүләт яки җәмгыять оешмасы. *Сәламәтлек саклау органы*

3) *күпл.* Эчке эшләр министрлыгы, дәүләт хәвефсезлеге учреждениеләре. *Менә шул чакта инде закон, гадел хөкем органнары, милиция, прокуратура искә төшә.* Ф.Латыйфи. *Ул милиция органнарында эшләп алган булса кирәк* ---. Ф.Галиев. *Ул Урта Азия якларына барып чыгып, сарык тиресе ябынып, чыраен битлек белән каплап, совет органнарында эшләде.* Я.Зәнкиев

4) Берәр партия, оешма, учреждениенең вакытлы басмасы. *Әлбәттә, 1905, 1917 елларда гамәлдә булган татар матбугаты, Россиядәге башка барлык телләрдәге басма органнар төсле үк, бихисап сәяси вә иҗтимагый төркемнәргә бүленеп эш итә.* Р.Әмирхан

ОРГА́Н *и. гр. муз.* Күрек ярдәмендә һава тутырылган торбалардан тавыш чыгара торган, тынлы, клавишлы бик зур музыка коралы. *Мәскәү консерваториясенең Кече залында орган музыкасын тыңлаган кичә исемә төште.* М.Юныс. *Анда орган музыкасы уйный, имеш, дип ишеткән иде Мостафин.* Х.Камалов. *Урман – яшел храм, залларында орган музыкасы ишетелә...* Р.Әхмәтҗан

ОРГАНА́ЙЗЕР *и. ингл.* 1) Атна көннәре аерып бирелгән көндәлек дәфтәр. *Органайзер сатып алу*

2) Калькулятор, будильник һ.б.ш. функцияләре булган электрон көндәлек

3) Кесә компьютеры. *Мәгълүматны органайзерда саклау*

4) Вак-төякне салып кую, төрле вак кирәк-яракны саклау өчен бүлемтекле тартма

ОРГАНИЗМ *и. гр.* 1) Мөстәкыйль яшәү, үсү, үрчү сәләтенә ия булган теләсә нинди тереклек иясе. *Плактон һәм су төбендәге организмнар белән тукланучы балыклар да яхшы күрәләр.* Кызыклы ихтиология. *Чөнки генетика дәрәҗәсендә кеше организмы картаерга түгел, ә матдәләр алмашуга җайланган.* Кызыклар дөньясы. *Үсемлекләрнең, хайваннарның һәм башка организмнарның генетик фондын үзгәртүгә яисә юкка чыгаруга, табигать ресурсларын ярлыландыруга китерүче төзелеш эшләрен башкарырга ярамый.* Мәдәни җомга

2) *күч.* Тулы эшчәнлек алып бара торган оешма. *Клиника – үзе бер катлаулы организм бит ул.* М.Маликова

ОРГА́НИК *с.* **1.** 1) Хайваннар яки үсемлекләр дөньясына караган. *Аксым, крахмал һәм майлар – органик матдәләр.* Ботаника. *Бәрәңгенең иң яхшы сыйфатларыннан берсе шунда: андагы крахмал, глюкоза, фруктоза, сахароза кушылмасы (башка туклыклы матдәләр, витаминнар, органик матдәләр кебек үк) кеше организмы өчен уңай.* Серле календарь

2) *хим.* Составында углеводород булган, гадәттә молекуляр төзелешле, янучан, җылытканда җиңел таркала торган. *Органик кушылмаларның изомериясе киң таралган: аның белән без органик матдәләрнең барлык классларын өйрәнгәндә дә очрашабыз.* Химия

3) Углеводородлар һәм алардан килеп чыккан кушылмаларны өйрәнә торган. *Органик химиядә башлангыч кушылмалар итеп углеводородларны исәплиләр.* Химия

4) Нәрсәнең дә булса асылына караган, табигый. *Шунлыктан аларның әдәби иҗатлары да шул социализм төзүдәге иҗатларының бер органик элементы була ала.* М.Җәлил

2. *рәв. мәгъ.* Табигый рәвештә. *Ударникларны чакыру пролетариат әдәбияты хәрәкәте алдындагы бөтен яңа бурычлар белән органик бәйләнә.* М.Җәлил. *Шулай итеп, эндәш һәм кереш сүзләр җөмләгә эчтәлек ягыннан да, форма ягыннан да органик бәйләнгән тулы хокуклы кисәкләр булалар* ---. М.Зәкиев

ОРГА́НИКА *и. рус* Органик ашлама. *Органика сыйфатында черегән тирес, торф кулланыла.* Иң шәп календарь. *[Талпаннарның] тукланган нәрсәләре – органика, ягъни тиренең үлгән кисәкчекләре.* Таң

ОРГАНО́ИД *и. гр. биол.* Күзәнәктәге билгеле бер функция башкара торган структура. *Цитоплазмада – күзәнәкнең ярымсыек эчке тирәлегендә – бик вак структуралар – органоидлар урнашкан.* Биология. *Ультрацентрифугада бик тиз әйләндергәндә, алдан вакланган күзәнәкләрнең органоидлары катлам-катлам булып урнашалар* ---. Гомуми биология

ОРГАНЧЫ *и. муз.* Органда уйнаучы. *Шубертның «Аве Мария»сен уйнаучы органчы карт та яшь һәм матур иде.* М.Юныс

ОРГА́У *ф. диал.* 1) Бәрәнләү

2) *иск.* Бала табу

Оргый башлау Оргарга тотыну

ОРГАЧ *и. диал.* 1) Теше сарык; ана хайван (вак терлек тур.)

2) *иск.* Кендек әбисе

О́РГИЯ *и. гр.* 1) Борынгы грекларда: шәраб һәм күңел ачу илаһы Вакх хөрмәтенә бәйрәм тантанасы

2) Бик шау-шулы, тыйнаксыз эчке мәҗлесе. *Менә сезгә культуралы, югары зәвыклы сөйкемле ханым!.. Оргиядән соңгы кыяфәтен күрсәтер идем мин сезгә...* Ш.Рәкыйпов. *Алар, җиңүче сыйфатында, өч көн-төн үтерүталау-көчләү оргиясенә биреләләр.* Безнең гәҗит

О́РДЕН I *и. лат.* Сугышта, эштә, җәмгыять тормышында күрсәткән зур батырлыклар, хезмәтләр өчен бирелә торган төрле дәрәҗәдәге һәм исемле махсус билге: югары дәрәҗәдәге дәүләт бүләге. *Орденнарым, медальләрем – бер катыргы тартма.* Г.Афзал. *Уз илен сунардай бик арзан сатканнар, Тел сатып, дин сатып, орден бар такканнар...* Ә.Синугыл-Куганаклы

О́РДЕН II *и. лат.* Уртак максат һәм аерым яшәү кагыйдәләре нигезендә төзелгән, шулай ук үз уставы булган затлар берләшмәсе. *Алардан XIII гасыр башында дингә өндәүче монахлар ордены оеша.* Урта гасырлар тарихы

О́РДЕНЛЫ *с.* Орден белән бүләкләнгән. *Агач төбендә комиссар – Орденлы кеше.* Ф.Кәрим. *Колхоз рәисе Рафаэль Камалович, ниндидер йомышы төшеп, орденлы тракторчы Хәлил Хөрмәтшинны чакыра.* Т.Нәҗмиев

О́РДЕН-МЕДАЛЬ *җыйд. и.* Орден һәм медальләр; шундый төрле бүләкләр. *Ил-Ватанның өлгер ул-кызына Орден-медаль тиеш, әлбәттә!* Р.Рахмани. *Орден-медальләрен таккан әтисе түргә барып утырды.* Р.Зәйдулла

О́РДЕР *и. нем.* Язма күрсәтмә, боерык; берәр нәрсә бирү-алу өчен

рәсми документ. *Боларны без ай буе өйрәндек кебек, һәм мин почта переводлары алганда, саклык кассасына ордер язганда, бу мәсьәләдә бер хата да җибәрмим ---.* М.Мәһдиев. *[Солтаниянең] Әхмәтнурны ордерга кертмичә, иске йортта калдырырга иде исәбе.* Мәгърифәт. *Аларга ордер биргәнгә кадәр, яңа урынның ошау-ошамавын бик җентекләп өйрәнергә кирәк.* Кызыклы ихтиология

ОРДИНА́РЕЦ *и. нем.* Командир янында яки штабта йомышлар үтәүче гаскәри хезмәткәр. *Әмма кая гына барса да [Мостафин] орденарецы белән йөри.* Х.Камалов. *Янындагы ординарецы, тау төшкәндә, аны култыклап ала, командирына блиндажга барган юлны күрсәтә.* С.Таһиров. *Пулемётчыны чормадан алып төштеләр ---, мин аны шунда ук таныдым, чөнки ул баштарак минем ординарецым иде.* Г.Нәбиуллин

ОРДИНА́ТА *и. лат. геом.* Пространстводагы ноктаның торышын билгели торган өч координатаның берсе. *Димәк, $O_a P$ һәм L кисешү ноктасының ординатасы α ның тангенсына тигез.* Алгебра. *М ноктасы координаталары – (х, у) – ОХ һәм ОУ күчәрләренә ноктаның проекцияләре: х – абцисса, у – ордината.* Математикадан кыскача белешмәлек

ОРДИНА́ТОР *и. лат.* Дәвалау учреждениесендә бүлек мөдире җитәкчелегендә эшләүче табиб; фәнни тикшеренү яки белем бирү институтының клиникасында билгеле белгечлек буенча әзерлек алучы врач. *Доцент белән ординатор арасында минут эчендә бер-берсенең уртаклыгын тою хисе урнашты.* М.Маликова

ОРДИНАТУ́РА *и. лат.* 1) Медицина буенча практик аспирантура. *Ординатураны тәмамлап, читтән торып аспирантурага кергәч кенә гаиләсен алып килде Алмаз.* З.Садыйков. *Казан дәүләт медицина академиясендә студентлар клиник ординатурага 22 белгечлек буенча имтихан тапшырды.* Мәдәни җомга

2) Ординатор вазифасы

ОРДЫ́-БӘРДЕ *рәв.* **1.** 1) Ашыгып, кабаланып; дуамалланып. *Ярый әле орды-бәрде чыгып китмәгән икән.* М.Маликова

2) Тиешле дәрәҗәгә җиткермичә; ничек эләкте, шулай; күңел бирмичә. *Карчык орды-бәрде кыланмады, егетне капка төбеннән үк кире борып җибәрергә ашыкмады, өенә чакырды, түрдән урын күрсәтте.* К.Тимбикова

3) Әдәпсез; тупас рәвештә. *Илфатка улының орды-бәрде сөйләшүе ошамады.* Б.Камалов

2. *с. мәгъ.* Ашыгучан, кабаланучан, дуамал. *Орды-бәрде идең син, Хабул, Нишләп хәзер Шундый түгел син, ә?* Х.Туфан

ОРДЫ́М-БӘРДЕМ *рәв. к.* **орды-бәрде**. *[Кәрам:] Авыл халкына ордым-бәрдем шыңшып күрсәтерсең, анысына шигем юк.* Ә.Яһудин

ОРЕГА́НО *и. лат. бот.* Аш тәмләткеч буларак мәтрүшкә. *[Ашамлыкны] тоз һәм орегано белән тәмләндереп җибәрегез.* Серле календарь

ОРЕОЛ *и. фр.* 1) Нинди дә булса бик якты әйбер тирәсендәге балкышка охшаш нур, яктылык каймасы; һалә. *--- Тау түбәсе кинәт балкып китә, һәм альпинист елкылдап торучы ореол эчендә кала.* Могҗизалар энциклопедиясе

2) Икона, миниатюра һ.б.ш.ларда сурәтләнгән әүлия затларның баш тирәсен уратып алган нур, яктылык бөжрасы; һалә

3) *күч.* Данга, хөрмәткә күмелгәнлек. *Яшерен-батырын түгел, ул елларда, соңрак та Рөстәм Яхин ижаты --- хатын-кызлар арасында гаять тә популяр, хәтта ниндидер бер серле ореол белән өретелгән, нурланган иде.* Л.Шагыйрьҗан

ОРИГИНАЛ *и. лат.* Төп нөсхә. *Шкаф башларында Александр Сергеевич Пушкин статуэткалары гына да биш-алты иде. Күбесе оригиналлар.* Г.Әпсәләмов. *Татарның кайбер күренекле романнарын мин урысча да укып карарга яратам, кызыксынып, ничегрәк «яңгыраганнарын ишетү» өчен. Оригиналга җитәме соң инде!* Казан утлары. *Нәрсәне оригинал, төп нөсхә, электрон документның күчермәсе дип атарга?* Мәдәни җомга

ОРИГИНАЛЬ *с.* 1) Төп, оригинал булган. *Оригиналь нөсхә*

2) Мөстәкыйль иҗат нәтиҗәсендә туган, беркемне кабатламаган, һичкемгә ияреп эшләнмәгән. *Оригиналь әсәрләр тудыруның төп кимчелеге әле һаман да зур язучыларны үз тирәбезгә тарта алмаудан тора.* Ф.Кәрим. *Руссо балага бу белемнәрне бирүнең --- оригиналь методикасын тудыра.* Ә.Хуҗиәхмәтов. *Ләкин бу шигырь дә рус шагыйренең оригиналь әсәре түгел икән.* Казан утлары

3) Кабатланмас, үзенә бер төрле. *[Җырчының] чыгышы тавышның шәп булуы белән генә түгел, сәхнә пространствосын оригиналь файдалануы --- белән дә отышлы булды.* Мәдәни җомга // Гадәти булмаган, үзенчәлекле. *– Бик оригиналь бүләк! – диде Зөһрә.* Ф.Яруллин

ОРИГИНАЛЬЛЕК *и.* 1) Төп нөсхә, оригинал булу сыйфаты

2) Кабатланмас, үзенчәлекле булу. *Бүгенге драматургиядә тематик төрлелеккә, конфликт кискенлегенә, вакыйга-ситуацияләр оригинальлегенә, эре типлар табуга омтылыш юлында авторларны һаман бертөрле кимчелекләр сагалап тора.* А.Әхмәдуллин. *Кайбер чебеннәрнең личинкалары туклана торган консервлар да оригинальлек ягыннан тегеләреннән кайтыш түгел.* Кызыклы физиология. *Оригинальлеге ягыннан әлләни аерылып тормаса да, Сәрби образын актриса төгәл һәм эзлекле итеп башкаруга ирешкән.* Сәхнә

ОРИЕНТАЛИСТ *и. лат.* Көнчыгыш халыклары мәдәнияте, телләре белгече. *[М.Гайнуллин хезмәтендә] --- рус ориенталистларының татар әдәбиятын өйрәнүдәге хезмәтләре бай фактик чыганаклар җирлегендә күрсәтелә.* Н.Юзиев

ОРИЕНТАЛИ́СТИКА *и. лат.* Көнчыгыш халыклары тарихын, мәдәниятен, телләрен өйрәнә торган фәннәр җыелмасы. *Ләкин ориенталистикада иң киң таралган төшенчә – инглизчә «маршлэнд эрабз» – «сазлык гарәпләре».* В.Юныс. *Ни дисәң дә дөнья ориенталистикасының мондый зур форумы гасыр ярым эчендә*

илебездә нибары өч тапкыр --- узды ич. Мәгърифәт

ОРИЕНТА́ЦИЯ *и. фр.* 1) Ориентлашу. *Молекулаларның төгәл ориентациясе кристалларның бөтен күләмендә түгел, домен дип аталган зур булмаган өлкәләрдә генә була.* Физика

2) Фәнни, иҗтимагый эшләрдә билгеле бер юнәлеш, кемгә яки нәрсәгә дә булса тотылган исәп. *Бу уңайдан игътибарга лаек тагын бернәрсә бар: профессиональ ориентация куелышы.* М.Әмирханов. *Фатих һәм аның фикердәшләре социал-демократларга ориентация тотсалар да, либераль буржуазия һәм аның идеологлары белән дә араны өзмиләр.* И.Нуруллин. *Үз нәүбәтендә, алар гаять күп төрле булырга һәм илләрнең социаль-икътисади үсеш дәрәҗәләрен, аларның социаль ориентациясен --- исәпкә алырга мөмкин.* География

3) *күч.* Нинди дә булса мәсьәләләрне, хәлләрне ачыклауга, аңлауга юнәлтелгән эшчәнлек

ОРИЕНТА́ЦИЯЛӘҮ *ф.* 1) Горизонт якларына карата мөнәсәбәттә тиешле юнәлеш бирү

2) *күч.* Билгеле бер максат, бурыч кую; киләчәк эшчәнлекнең юнәлешен билгеләү

ОРИЕНТИР *и. лат.* 1) Урында хәрәкәт юнәлешен билгеләргә, кирәкле җирне тиз табарга ярдәм итә торган предмет. *Азимут – 345 градус, ориентир – питомник түрендәге лесхоз бинасы.* М.Мәһдиев. *Ориентирларны хәтерләдегезме?* С.Таһиров. *Чебен-черкиләр гадәттә калкурак ориентир янына тупланырга яраталар.* Ә.Халидов

2) *күч.* Төп максат, юнәлеш. *Кызыгы калмады, яшәү ориентирларын югалтты [Надыйр].* Р.Мулланурова. *Тик бәхет җиренә, энекәш, солдат чактагыча әйтсәк, бүтән кеше куйган ориентир белән барып булмый!* М.Хуҗин

ОРИЕНТЛА́Ү *ф.* Горизонт якларына һәм әйләнә-тирәдәге урынга мөнәсәбәттә нәрсәнеңдер урынын билгеләү. *Моның өчен компасны горизонт якларына ориентларга кирәк. Аннан планшетны горизонт яклары буенча ориентлыйбыз.* Физик география

ОРИЕНТЛАШУ I *ф.* Горизонт якларына һәм әйләнә-тирәдәге урынга мөнәсәбәттә үзеңнең торган җиреңне билгеләү, тиешле юнәлеш ала белү. *Балыклар да шулайрак ориентлашалар ---.* Кызыклы физиология. *Ярканатларның күрүе начар үсеш алган, ләкин караңгыда алар искиткеч яхшы ориентлаша.* Биология. *Алар аучылык иткәннәр, ашарга яраклы кыргый үләннәр, төрле бөҗәк, хайваннар җыйганнар, табигатьтә яхшы ориентлаша алганнар һәм урыннан урынга күчеп йөргәннәр.* Материклар һәм океаннар географиясе

Ориентлаша башлау Ориентлашу сәләте барлыкка килү

ОРИЕНТЛАШУ II *и.* Горизонт якларына һәм әйләнә-тирәдәге урынга мөнәсәбәттә үзеңнең торган җиреңне билгеләү эше, процессы. *Ориентлашу рефлекслары башны тынычсызлагыч ягына боруда чагыла.* Биология. *Галимнәр идарә итүнең, локациянең, ориентлашуның нинди генә принцибын тәкъдим итмәсеннәр, соңыннан табигатьнең ул принципны инде әллә кайчаннан бирле файдалануы ачыкланган.* Кызыклы физиология. *[Нәшриятта] сугыш алып бару тактикасы, --- дошманнан яшеренү, урманлы урыннарда ориентлашу --- мәсьәләләре буенча күп санлы кулланма, брошюралар әзерләнде.* Казан утлары

ОРКЕСТР *и. фр.* 1) Музыкаль әсәрне төрле уен коралларында күмәк башкару өчен берләштерелгән музыкантлар төркеме. *Дүрт-биш кешелек оркестрда, билгеле, беренче нәүбәттә, скрипка-мандолина тавышлары яңгырый.* Ә.Еники. *Кинәт оркестр тынды, залда тирән сулыш алуга охшаш «ш-ш-ш» дигән аваз ишетелде.* М.Маликова. *Оркестры, хоры, җырчылары, биючеләре бар: кырыклап кешене берләштерә.* Т.Әйди

2) Сәхнә алдында музыкантлар урнашкан урын. *Оркестр чокыры да тик тормый, анда музыкантлар үзләренчә мәшгуль.* Р.Низамиев

ОРКЕСТРАНТ *и. рус* Оркестрда уйнаучы музыкант. *Демонстрация бетте, халык өенә таралды, университетның профком председателе оркестрантларны үз бүлмәсенә чакырды.* М.Мәһдиев. *[Сөмбел] эшкә гадәттәгедән алдан килеп, сәгатьләр буе оркестрантларны көтеп утыра ---.* Р.Вәлиев. *Җыр төгәлләнде, торбалар, барабаннар тынды, --- оркестрантлар инструментларын куеп сәхнәдән төштеләр: тәнәфес башланды.* М.Маликова

ОРКЕСТРИОН *и. фр.* Тышкы күренеше белән органга охшаш механик музыка коралы

ОРКЕСТРЛАШТЫРУ *ф.* Музыканы оркестр өчен үзгәртеп язу. *Дивизиянең бик тә сәләтле капельмейстеры минем танышым иде, маршны аның белән бергәләп оркестрлаштырдык.* К.Латыйп

ОРКЕСТРО́ВКА *и. рус* Билгеле бер составтагы оркестр яисә инструменталь ансамбль өчен музыканы махсус типтагы нота текстына күчерү эше. *Башта оркестровка ясарга, җырны «бизәргә», баетырга кирәк.* Р.Вәлиев

ОРКЕ́СТРЧЫ *и. к.* **оркестрант**

ОРЛЫ́ГАШАР *и.* Грушасыман гәүдәле, орлык, чәчәк, яфрак белән тукланучы коңгыз; *русчасы:* **семяед**

ОРЛЫК *и.* 1) Үсемлекнең яралгы һәм тышчадан торган җимеш бөртеге; үрчем башлангычы. *Сәрби кузаклары четердәп ярылып китә дә, коры орлыклар җиргә коела.* Ә.Хәсәнов. *Ә инде иң кыйммәтлесе – орлыклар, эре һәм майлы эрбет чикләвеге.* Кызыклар дөньясы. *Тропик илләрдә кыйммәтле орлыклар бирә торган кофе һәм какао агачлары үсә.* Ботаника

2) Үсемлекләрнең чәчү өчен махсус әзерләнгән бөртекләре. *Анда чәчергә орлык бетәдер.* З.Зәйнуллин. *Ахырзаман җитеп, дөньяның асты-өскә килсә дә, туфракта яңадан орлык шытар, үлән үсәр.* Н.Гыйматдинова // Үсемлекләрнең чәчү, утырту өчен билгеләнгән кисәкләре, бүлбеләре. *Орлыкка дип чүпләгәнебез менә монысы була.* Г.Бәширов. *К.Насыйри уңышның нигезе кешеләрнең хезмәтендә, орлыкларның сортында, ашлауда икәнлеген раслый.* Ә.Хуҗиәхмәтов. *[Вагонны] орлык бәрәңгесен күмгән шикелле итеп [күмәләр].* Кызыклар дөньясы

3) *физиол.* Ирләрнең җенес бизләре эшләп чыгара торган җенес күзәнәкләре. *Котлыйм, сез сирәк очрый торган ирләрнең берсе икәнсез. Орлыкларыгызның ник берсе буш булсын.* Г.Галиева. *Тәмәке тартучы аналарның балалары диабеттан һәм симерүдән өчтән бер өлешкә ешрак интегә, малайларының мәниендәге аталык орлыгының тупланышы тәмәке тартмаучыларның балаларыныкына караганда 20 процентка түбәнрәк була.* Идел

4) Нәсел, токым. *Орлыгы әйбәт булу*

5) *күч.* Нәрсәнең дә булса башлангычы. *Без бит кешеләр – Мәхәббәт орлыклары.* М.Әгъләмов. *Күңелемдә әллә кайчаннан чәчелеп яткан шигырь орлыклары шытып чыкты.* Ф.Яхин

6) *күч.* Төп сыйфат, нәрсәнең дә булса асылы. *Бөтен спектакльнең үзәге, орлыгы бу!* М.Маликова. *Орлыгы бар, чәчәге бар – өмете бар, димәк.* Г.Афзал

7) *күч.* Берәр эш-хәлнең нәтиҗәсе. *Мин хәтерләгәндә, уйларым чәчәк ата, фикерем орлыгы өлгерә.* Ә.Гаффар

◊ **Орлыгы Бохарада түгел** Табып, эшләп булу турында. *--- Бала кирәксенсәләр, тагын булыр әле: орлыгы Бохарада түгел, яшь чаклары.* М.Маликова. *Бетмәс, бетмәс... – Иблиснең дә көче җитмәс – Орлыгы да, аңа киткәч, Түгел аның Бохарада...* М.Әгъләмов. *Бик алай бетеренмә. Табылыр, яхшырагы табылыр, орлыклары Бохарада түгел.* Р.Вәлиев

ОРЛЫКБӨРЕ *и. бот.* Җимешлекнең калынайган түбәнге өлеше, җимшән. *Орлыкбөреләр җимшәннең эчке стенасында үсә.* Ботаника. *Чәчәк атканнан соң орлыкбөредән – орлык, ә җимшәннән җимеш үсә.* Биология

ОРЛЫ́К КҮБӘЛӘГЕ *и. зоол.* Утчыллар семьялыгыннан игеннәргә зарар китерә торган кечкенә корткыч күбәләк; *русчасы:* **огнёвка зерновая**

ОРЛЫКЛАНДЫРУ *ф.* Үрчем алу өчен, ана җенес күзәнәкләрен ата җенес күзәнәкләре белән ясалма кушылдыру, аталандыру. *Мансур Салиховичны бигрәк тә ясалма орлыклandыру, ягъни мөгезле эре терлекләрне генә түгел, хәтта бал кортларын да ясалма юл белән чиста нәселгә аеру процессы кызыксындыра.* Т.Нәҗмиев. *Минем әти кохозда ветфельдшер, төп вазифасы өстенә сыерларны ясалма орлыклandыру эшен дә алып бара, дип әйтеп кара син!* Ф.Садриев. *[Илдар:] Абый, абый, орлыклandыра алмый ул хәзер.* К.Ситдиков

Орлыклandыра башлау Орлыклandырырга тотыну

Орлыклandырып бетерү Тулысынча орлыклandыру

Орлыклandырып карау Булу-булмавын сынар өчен орлыклandыру

Орлыклandырып тору Даими, әледән-әле орлыклandыру

Орлыклandырып чыгу Барысын да орлыклandыру

ОРЛЫКЛАНУ *ф.* 1) Орлыгы барлыкка килү. *Алардан шул ук җәйдә яңа үсемлек үсә һәм орлыкланып та өлгерә.* Биология

2) Аталану

Орлыклана бару Торган саен орлыклары күбрәк, тулырак булу

Орлыклана башлау Орлыкланырга тотыну. *Кышкы азыкларны үлән орлыклана башлаганчы әзерлиләр.* Агулы үсемлекләр

Орлыклана төшү Бераз орлыклану

Орлыкланып бетү Тулысынча орлыклану

Орлыкланып җитү Орлыклар тулылану, өлгерү

ОРЛЫКЛЫ *с.* Орлыклана торган, орлыгы булган. *Күп орлыклы җимешләр эчендә бер генә орлык түгел, бәлки берничә, хәтта күп орлык өлгерә.* Ботаника

ОРЛЫКЛЫК *и.* **1.** 1) Үсемлекнең орлык барлыкка килә, үсә торган оясы

2) *к.* **орлык** (*2 мәгъ.*). *Орлыклык аерым үстерелә.* Мәгърифәт. *Орлыклыклар үсешкә сәләтле, шиңмичә, үрмичә, сәламәт сакланган булырга тиеш.* Яшелчәчелек

3) Ата җенес бизләре. *Орлыклыклар тиречел капчыкта – күкәй янчыгында урнашканнар.* Биология: кеше һәм аның сәламәтлеге. *Ирләрнең һәр орлыклыгында меңгә якын бормалы-бормалы кечкенә каналлар бар.* Кызыклы физиология. *Балыкларның үрчү органнары ана балыкларда – парлы күкәйлекләр, ата балыкларда – орлыклыклар.* Биология. Хайваннар

2. *с. мәгъ.* 1) Орлык өчен билгеләнгән, сайлап алынган. *--- Орлыклык кукурузны ничек кояшта җылытасын үзең күрсәтеп бирмичә булмый.* Р.Төхфәтуллин. *--- Умарта кортлары ел саен кешеләргә күп миллионнарча сумлык яшелчә, җиләк-җимеш һәм орлыклык үсемлекләр үрчетергә ярдәм итәләр.* Дөньяда ниләр бар

2) *күч.* Аз гына. *Раслап килде тормыш «түрәләр»дә Орлыклык та хаклык калмавын ---.* К.Булатова

ОРЛЫКЛЫЛЫК *и.* Орлыклы булу сыйфаты. *Кабакның орлыклылыгы*

ОРЛЫ́К МАЕ *и.* Киндер орлыгыннан алынган май

ОРЛЫ́К ОНЫ *и.* Киндер орлыгыннан төеп ясалган яшькелт он

ОРЛЫ́К ӨЛЕШЕ *и. бот.* Орлыкта яфрак яралгысы

ОРЛЫКСЫЗ *с.* **1.** Орлыгы булмаган. *Ләкин бер уч орлыксыз хуҗалыклар да бар.* Татарстан яшьләре

2. *рәв. мәгъ.* Орлыктан башка, вегетатив юл белән. *Орлыксыз үрчү*

ОРЛЫКСЫЗЛАНДЫРУ I *ф.* Стерилизация юлы белән аталандыра алмаслык итү

ОРЛЫКСЫЗЛАНДЫРУ II *и.* Стерилизация юлы белән аталандыра алмаслык итү эше; нәрсәнең дә булса аталандыра алу сыйфатына кире тәэсире. *Дөрес, элегрәк эт-мәчеләрнең нәсел арттыру, балалау сәләтен бетерү, ягъни орлыксызландыру, стерильләштерү турында сүз шактый булган иде.* Т.Нәҗмиев. *Пестицидлар, ягъни һәртөрле ашламалар, химикатлар ирләрне орлыксызландыруга китерде.* Татарстан яшьләре

ОРЛЫКЧА *и.* Кайбер үсемлекләрнең үзлегеннән ачылмый торган каты тышчалы җимеше. *Бәрелгәндә, аларның чуклары сына, һәм орлыкчалар җиргә коела.* Биология. *Орлыкча – юка тиречел кабыклы коры җимеш, аның кабыгы орлыкка тиеп тора, ләкин аңа тоташып үсми.* Ботаника

ОРЛЫКЧЫ *и.* Сортлы орлыклар уйлап табу, орлыкларны сайлап алу, саклау белән шөгыльләнә торган кеше,

галим. *Һәр орлыкчы төрле яшелчә культураларының биологик үзенчәлекләрен, аларның формасын, төзелешен --- белергә тиеш.* Яшелчәчелек

ОРЛЫКЧЫЛЫК *и.* Сортлы үсемлекләр җитештерү, орлык өчен үсемлекләр үстерү, аларны саклау белән шөгыльләнә торган авыл хуҗалыгы тармагы. *Хафиз агай, район орлыкчылык лабораториясе мөдире, колхозларда икән.* Б.Камалов. *Мондагы урманчылар орлыкчылык белән шөгыльләнә.* М.Мәхмүтов. *Махсус яшелчә һәм яшелчә орлыкчылыгы чәчү әйләнешләрендә күпьеллык үләннәрне ике ел файдаланырга кирәк.* Яшелчәчелек

ОРЛЫ́К ЯРГЫЧ *и.* Орлык яру җайланмасы

ОРНА́МЕНТ *и. лат.* Геометрик яки төрле дәрәҗәдә стильләштерелгән сурәтләрнең (үсемлекләр, хайваннар) кушылмасыннан гыйбарәт график, скульптур бизәкләр. *Йортның фасадын каплаган бизәкләр гарәп орнаменты белән ярыша алырлык.* М.Юныс. *Капка-читәннәр, сәүдә итү урыннары чыбыктан үрелгән, төрле орнаментлар кулланылган.* Т.Нәҗмиев. *Халык культурасының кайбер үрнәкләрендә, мәсәлән, кием бизәү ысулларында, бизәнү әйберләрендә, йортларның орнаментларында матди һәм рухи культура бергә үрелеп яши.* Р.Мөхәммәдова

ОРНАМЕНТАЛЬ *с.* 1) Орнамент белән бәйле, шуңа кагылышлы. *Гобеленның ачык аңлаешлы булуы композиция төзелешенең гадилегенә, орнаменталь мотивларның һәм төсләрнең ритмик бүленешенә бәйле.* Казан утлары. *Рәссамның орнаменталь стиле, җылы, якты төсләр белән берләшеп, китапка камиллек өсти, бөтенлек бирә.* Р.Вәлиев

2) *фольк.* Җырлы-биюле. *Балалар уеннарын фәндә өч төркемгә бүлеп өйрәнәләр: драматик, спорт һәм җырлы-биюле (орнаменталь) уеннар.* Татар балалар әдәбияты

ОРНАМЕ́НТИКА *и. рус* 1) *сәнг.* Орнамент үзенчәлеге; билгеле бер стильдә орнамент элементлары җыелмасы

2) *муз.* Төп мелодияне бизи торган авазлар җыелмасы

ОРНА́МЕНТЛАУ *ф.* Орнаментлап эшләү

Орнаментлый башлау Орнаментларга тотыну

Орнаментлый төшү Бераз орнаментлар ясау, төшерү

Орнаментлап бетерү Тулысынча орнаментлау

Орнаментлап чыгу Булган берсен яки бөтен булган урынны, нәрсәне орнаментлау

ОРНА́МЕНТЛЫ *с.* Орнаментлар, бизәкләр төшерелгән. *Унтугызынчы йөзнең беренче яртысында хатын-кыз осталарның иҗатында --- орнаментлы әйберләр күренми башлый.* Ф.Вәлиев. *Орнаментлы келәм татар халык иҗатына хас тантаналы милли бәйрәм рухын бирә.* Казан утлары. *Алтын, көмеш, кара, кызыл төрле җәнлек сурәтләре төшерелгән орнаментлы төсләр санала.* Сөембикә

ОРНА́МЕНТЧЫ *и.* Орнаментлар ясаучы оста

ОРНИТО́ЛОГ *и. гр.* Кошларны өйрәнүче белгеч. *Биология фәннәре докторы минем сорауны республиканың орнитологлары алдына куйган.* М.Мәһдиев. *Россия орнитологы профессор Владимир Евгеньевич Флинтның башына менә дигән үй килә.* Кызыклар дөньясында. *Кошларны өйрәнүче белгечләр – орнитологлар – кошларның 8700 гә якын төрен исәплиләр.* Татарстанның үсемлекләр һәм хайваннар дөньясы

ОРНИТОЛО́ГИК *с.* Орнитологиягә караган, орнитологиягә мөнәсәбәтле. *Орнитологик фауна*

ОРНИТОЛО́ГИЯ *и. гр.* Зоологиянең кошларны өйрәнә торган тармагы. *Ул махсус орнитология фәне белән шөгыльләнмәгәндер.* М.Юныс

ОРОК *и.* Россиянең Себер һәм Ерак Көнчыгышында яшәүче, тунгус-маньчжур телләреннән берсендә сөйләшүче азсанлы халык һәм шул халыкның бер вәкиле. *«Өч» саны хәзерге монгол телендә – пурван, тунгус-маньчжур телләреннән нанай телендә – илан, орок телендә – ила(н), эвенк телендә – илан, маньчжур телендә – илань, эвен телендә илън дип атала.* Н.Фәттах

ОРОЧ *и.* Россиянең Ерак Көнчыгышында яшәүче, тунгус-маньчжур телләреннән берсендә сөйләшүче азсанлы халык һәм шул халыкның бер вәкиле. *Көндәлегемә кирәкле уйларымны язып куйгач, мин орочлар башлыгы Антон Сәгъди янына киттем.* Дөньяда ниләр бар

ОРТОДОКС *и. гр.* **1.** Ортодоксаль карашлы кеше. *Шундаен соң [халык] Карл Маркс мәзһәбенә (юлына) яки ортодокс мәзһәбенә керергәме – анысын үзе белер.* Г.Тукай. *Әхлак мәсьәләләрендә гадәттән тыш каты, ортодокс халык мәҗүсилек заманыннан килгән ышану буенча күбрәк кояшка табына иде. Доганы гарәпчә укый, гарәп алласына табына, ураза тота ---.* М.Мәһдиев. *[Мөнхенда] --- берничә «ортодокс» галим тарафыннан берсеннән-берсе куркыныч эпитетлар белән «бүләкләнгән» журналист Али Акыш яшәп ята.* И.Нуруллин

2. *с. мәгъ.* Ортодоксаль карашлы. *Булган, ди, сезнең кебек намуслы, ортодокс начальник.* М.Мәһдиев

ОРТОДОКСАЛЬ *с. кит.* Тайпылышсыз нинди дә булса бер юнәлеш, тәгълимат принципларын яклаучы. *Галимнәрнең әйтүенчә, бүгенге көндә борынгы диннең бар таләпләрен үтәп яшәгән ортодоксаль яһүди алты йөздән артык кагыйдәне башкарырга тиеш икән.* С.Шәмси. *--- Ислам дине барлыкка килгәч, ортодоксаль исламның мәҗүсилеккә каршы көрәш ачуы нәтиҗәсендә, безнең халыкта ырымнарга карата --- ачыктан-ачык тискәре мөнәсәбәт урнашты булса кирәк.* Мәдәни җомга

2) *күч.* Даими үзгәрешсез. *Чүлдә, ягъни көндезге һәм төнге температуралар кискен аерылып торган үтә континенталь климатлы өлкәләрдә яшәүче тереклек ияләре һәрхәлдә бу ортодоксаль җылы канлылыктан бераз читкә тайпылганнар.* Кызыклы физиология

ОРТОДОКСАЛЬЛЕК *и. кит.* Ортодоксаль булу сыйфаты

ОРТОДО́КСЛАНУ *ф. кит.* Ортодокс булып кылану. *Казанда Халиковның аңлатмаларына ышанып, бу ифрат яшь әтәч булып кыйлана, артык*

ортодокслана, дип карадылар һәм аңлашырга, тату булып эшләргә киңәш бирделәр. А.Расих

ОРТОПЕ́Д *и. гр.* Ортопедия белгече. *Казанның ортопедлары могҗиза ясадылар.* М.Мәһдиев. *Нинди дә булса тайпылыш сизсәң, кичекмәстән ортопедка мөрәҗәгать ит.* Мәгърифәт

ОРТОПЕ́ДИК *с.* Ортопедия белән бәйле. *Инвалид балага елына дүрт пар ортопедик аяк киеме бирелергә тиеш.* Безнең гәҗит. *30 караватка ортопедик матраслар җәеп куйдык.* Кызыл тан

ОРТОПЕДИ́Я *и. гр. мед.* Умыртка сөягенең, очлыкларның деформациясен өйрәнә, профилактика үткәрә һәм дәвалый торган медицина тармагы. *[Камилнең] Горький урамына урнашкан травматология һәм ортопедия институтында танышы эшли иде.* Ф.Яруллин. *Бүгенге көндә югары технологияле операцияләр ясала, ортопедия һәм травматология юнәлешләре камилләште.* Хәзинә. *Кургандагы ортопедия һәм травматология үзәгендә кешенең буен ярты метрга озайта алалар* ---. Мәдәни җомга

ОРТОРЕ́КСИК *и. гр.* Дөрес туклануга фанатикларча табынган авыру кеше. *Тик тора-бара кайбер орторексикларның мавыгуы чиктән аша: алар бары тик үрдерелгән бөртек кенә ашый, бәвел генә эчә, баллы әйбер ятучыларны исә җинаятьчегә тиңли.* Мәдәни җомга

ОРТОРЕ́КСИЯ *и. гр. мед.* Дөрес туклануга фанатикларча табынудан гыйбарәт психик авыру. *Кайбер психиатрлар орторексияне – дөрес туклануга фанатикларча табынуны – яңа психик чир дип саный.* Мәдәни җомга

ОРУ *ф.* 1) Бәрү, сугу. *Басты аңсыздан, килеп, койрыкка шунда әллә кем, Орды камчы аркага һич юкка гына әллә кем.* Г.Тукай. *Алпавыт Шәйхиләргә яхшы мөнәсәбәттә булды: ормады, сукмады, хәтта бер тапкыр бәйрәмдә кечкенә генә бүләкләр дә бирде.* М.Мәһдиев. *Я Раббым, мондый хатынга орган ирнең кулы корыр!..* М.Маликова // Бер-берсенә каты итеп бәрелдерү. *Ордым, бәрдем, Карнын ярдым.* Табышмак

2) Берәр нәрсәне читкә яки кемнеңдер өстенә ташлау, ату. *Һичбер кеше берсен-берсе күрмәс булды, дөм караңгы: һәммәсе таң катып калды, күк күкрәп, яшен-елдырым каты орды* ---. Кол Гали

3) Көчле итеп яву (яңгыр тур.) *Көннәрдән бер көнне, чиләкләп орган яңгырга эләгеп, урактан шактый иртә кайттык.* А.Хәсәнов. *Моңа берәү дә рәнҗемәячәк, [яңгыр] чиләкләп орса да, мәйдан уртасында басып торачаклар иде югыйсә.* Б.Камалов

4) *диал.* Ат башына йөгән кидерү

5) *күч.* Бәреп үтерү, юкка чыгару. *Николай патшаның әмере, аның гаделлек кылычы, Домокл кылычы барысын да орачак.* Р.Батулла

6) *күч.* Һөҗүм итү, ташлану (дошманга)

◊ **Орып бирерлек** Күпкә өстен. *Хәер, син үзең дә, Тосечка, патша кызларын орып бирерлек...* З.Фәтхетдинов. **Орып бирү** Җиңү, өстен чыгу. *Корчаңгы гына булса да, ул синең айгырыңны орып бирәчәк!* Р.Батулла. **Орып салу** *к.* **орып бирү**

Орып бетерү Тулысынча ору. *Чыннан да, ул тора-бара халыкны орып бетерергә уйлый бугай* ---. Татарстан яшьләре

Орып тору Даими, әледән-әле ору. *Башына бертуктаусыз күсәк белән орып тордылар*. Татарстан яшьләре

ОРУ́ДИЕ *и. рус* Артиллерия коралларының гомуми атамасы. *Орудиеләр тавышы һаман якынлаша бара.* Г.Бәширов. *Зур калибрлы орудиеләр гөрселдәп алды.* М.Мәһдиев. *Цыбудив дигән каланы алу өчен сугышканда, Закир орудиесе урнашкан төбәккә немецларның гаскәр тулы унике бронетранспортёры һөҗүм итте.* Ш.Рәкыйпов

ОРФОГРА́ММА *и. гр. лингв.* Мөмкин булган берничә вариантта сайланып, тиешле кагыйдә яки традиция нигезендә дөрес язылу. *Әйтелеш белән бәйле булган орфограммалар. Орфограммаларны таный белү*

ОРФОГРА́ФИК *с. лингв.* Дөрес язылышка караган. *Телебездәге гарәп һәм фарсы сүзләре орфографик мәсьәләләргә бераз катлаулылык кертәләр* ---. Р.Әхмәтьянов. *Язганда, җиңел һәм тиз аңлау өчен, орфографик кагыйдәләрнең һәр кеше өчен уртаклыгы кирәк булса, сөйләм телендә шул ук максатларда әйтелеш кагыйдәләренең уртаклыгы кирәк була.* Ф.Сафиуллина. *Кайвакытта язмаларда орфографик хаталар кала.* Мәгърифәт

ОРФОГРА́ФИЯ *и. гр. лингв.* Тел белеменең дөрес язу нормаларын өйрәнә торган тармагы, имла. *Орфографиядә төп принцип итеп ишетелгәнчә язу (фонетик принцип) алына.* Х.Курбатов. *Докладчы орфографияне камилләштерү чараларына тукталды* ---. Т.Хәйретдинова

ОРФОЭ́ПИК *с. лингв.* Дөрес әйтелешкә караган, дөрес әйтелешкә буйсынган. *Хәзерге татар әдәби әйтелеше орфоэпик кагыйдәләрнең гадиләшүе, радио, телевидение --- тәэсирендә аерым урынчалыкка хас әйтелешләрнең кимүе һәм бетүе, үрнәк әйтелешнең язылыш белән якынаюы юнәлешендә бара.* Ф.Сафиуллина

ОРФОЭ́ПИЯ *и. гр. лингв.* 1) Тел белеменең үрнәк әйтелеш нормаларын өйрәнә торган тармагы. *Орфоэпия әдәби әйтелеш нормаларын билгели.* Ф.Сафиуллина. *[Сүзләрнең] язылышын орфография билгеләсә, әйтелешен орфоэпия талап итә.* Ф.Латыйфи

2) Шундый әйтелешнең үзе. *Сүзнең орфоэпиясе*

ОРХИДЕ́Я *и. гр.* Сәхләбчәләр семьялыгыннан төрле формадагы хуш исле чәчәкле күпьеллык үлән үсемлек һәм шуның чәчәге. *Орхидея куаклары арасыннан муеннарын сузып, серле шәүлә сурәтләнеп кала.* М.Юныс. *Тропик урманнарда эпифит үсемлекләр, әйтик орхидеялар, агачларның юан ботакларында үсәргә җайлашкан.* Ботаника

ОРЧЫК *и.* 1) Бер башы нечкә очлы, икенчесе тупыйк, уртасы юантыграк итеп агач таякчыктан эшләнгән кулдан җеп эрләү коралы. *Тәрәзәдән алтын орчык үткән.* Табышмак. *Әбиләр кичке озын төннәрдә, орчыкларын эрли-эрли, яннарына түгәрәкләшеп утырган балаларга ул хәрабә турында әллә нинди куркынычлы әкиятләр сөйлиләр.* С.Җәлал. *Сары сагыз кебек сузылып*

килгән йон, нәзек, сөякчел бармак араларында нечкәреп бөтерелә-бөтерелә, алъяпкыч итәгендә зырылдап әйләнгән орчыгыңа чорнала бара. Н.Хәсәнов

2) Нечкә итеп эшләнгән таякчык. *Орчык селкеп торган дирижёрлар түгел, бастырык белән эш иткән абзыйлар туендыра халыкны.* М.Маликова

3) Төрле механизмнарда, җайланмаларда әйләнү күчәре хезмәтен үти торган кендек. *Капка орчыгы*

◊ **Орчык буе** Бик кечкенә (бала тур.). *Орчык буе да юк... Теге баланы әйтәм.* Р.Мулланурова. *Клубка барып кергән орчык буе малайның андагы аппаратураны күргәч куркып калуын күз алдыңа китерәсеңдер инде.* Безнең гәҗит. **Орчык булып (шикелле, сыман) бөтерелү** 1) Бик җитез хәрәкәтләр ясап бию; 2) Берәр кеше тирәсендә яраргa, ярдәм итәргә, күңелен күрергә тырышып йөгереп йөрү. *Фёкла түти ишектә күренүгә, әбием дә орчык булып бөтерелә башлый.* А.Хәсәнов. **Орчык кадәр (хәтле)** 1) *к.* **орчык буе**. *Орчык кадәр бер малайны ничек тә үстерешерләр.* Б.Камалов. *Орчык кадәр генә баланың кызык итүе гарьләндерде, әлбәттә.* Т.Нәҗмиев. *Орчык кадәре генә кыз басып тора.* К.Тимбикова; 2) Кечкенә гәүдәле, җитез, елдам (кеше тур.) *Миңсылуның хәтта: «Бу сабый чырайлы, орчык хәтле генә хатын каян шулкадәр күп белә икән?» – дип, чыннан гажәпләнеп сөйләгән чаклары да булгалады.* Ә.Еники

ОРЧЫКБАШ *и.* 1) Орчык башына салмаклык һәм бераз авырлык бирү өчен киертелә торган, уртасы тишекле балчык, таш, кургаш һ.б.ш.дан ясалган пластина (җеп чорналып, орчык авырая башлагач, аны алып куялар). *Орчыкбаш ясау*

2) Шуңа охшашлы, шуны хәтерләткән нәрсә. *Эче куыш, тышы таш, Түбәтәе орчыкбаш.* Табышмак

ОРЧЫКЛЫ *с.* 1) Орчыгы, орчыклары булган. *Ике орчыклы каткыч*

2) Орчык белән кулдан эрләнгән. *Орчыклы җеп*

ОРЧЫКЛЫК *с.* 1) Орчык ясар өчен яраклы яки шуңа дип билгеләнгән. *Орчыклык каен пүләне*

2) Бер орчык күләмендә эрләрлек. *Ике-өч орчыклык мамык тетеп кую*

ОРЧЫКСӨЯК *и. анат.* 1) Кешедә: беләк сөякләренең берсе. *Ул бер кулбаш сөягеннән, ике беләк сөягеннән (терсәк һәм орчыксөякләр), берничә чук сөякләреннән һәм өч үсеп җитмәгән бармак сөякләреннән тора.* Биология

2) Кошларда: балтыр белән бармаклар арасындагы сөякләренең берсе

ОРЧЫКЧА *и.* 1) Бакыр кәлтәләр семьялыгыннан ялган аяклы еланга охшаган кәлтә; *русчасы:* **веретенница**. *Җитез орчыкча*

2) Үләнбетләре семьялыгыннан алма, груша агачларына зыян китерә торган борча; *русчасы:* **медяница**. *Орчыкчага каршы көрәш*

ОРЧЫКЧЫ *и.* Орчык ясау остасы. *Оныгы да бабасы кебек оста орчыкчы булып үсте*

ОРШЫШУ *ф. диал.* Үзара ызгышу, тиргәшү. *Шуның кушуы буенча, менә хәзрәтләр берлә оршышып булса да, мөгаллимә китерттем.* Г.Исхакый. *Кайчан төшкән, кайчан килгән бит, оршышырга да өлгергән.* С.Поварисов. *Ант итегез, оланнарым, сез дә, арагызга дошман кертмәскә, күңелегездә хөсет йөртмәскә, сугышмаска, оршышмаска, тату булырга!* Р.Батулла

Оршыша башлау Оршышырга тотыну

Оршышып алу Кыска вакыт арасында оршышу

Оршышып тору Әледән-әле, даими оршышу

Оршышып яту Оршышу процессында булу

ОРЫ *и.* 1) Кеше, хайван тәнендә зур булмаган каты үсенте, үлексез шеш; *русчасы:* **шишка**. *Бу орыларның пәйда булу сәбәбе бер үк – матдәләр алмашы бозылу.* Серле календарь

2) Кайбер хайваннарның башында, борын-күз тирәсендә кечкенә үсенте; *русчасы:* **нарост**

3) Кайбер хайваннарда майлы бүлтәймә. *Курдюклы сарыклар үзләренә бер группа тәшкил итәләр, аларның артында 10–15 кг туң май чыга торган зур оры асылынып тора.* Биология

4) Агачларда бүлтәеп торган авыру үсенте, үскен; *русчасы:* **кап**. *Безнең төче сулыкларда су асты предметларында оры (үскен) барлыкка китерүче бодяга дигән болытсыман хайван очрый.* Биология

ОРЫЛА́-БӘРЕЛӘ *рәв. к.* **бәрелә-сугыла**. *Белсәләр, болай орыла-бәрелә үлемгә ташланмаслар иде.* М.Әмирханов. *Гөлнара, сикереп торып, ишеккә орыла-бәрелә чыгып киткәч кенә аңнарына килделәр.* Г.Гыйльманов

ОРЫЛА́-СУГЫЛА *рәв. к.* **бәрелә-сугыла**

ОРЫЛЫ *с.* Орысы булган

ОРЫН *рәв. диал.* **1.** *к.* **орынтын**

2. *с. мәгъ.* Яшерен. *[Бикташ] орын ишектән чыгып китә.* Т.Гыйззәт

ОРЫНМА *и. мат.* **1.** Әйләнә белән бер генә уртак ноктасы булган туры. *Автомобиль тәгәрмәченнән атылып киткән балчык кисәкчекләре тәгәрмәчкә орынма буенча чәчеләләр.* Физика. *f функциясенең нинди нокталарында орынма горизонталь була?* Алгебра. *Камаучы почмак – ике орынма ярдәмендә ясалган почмак.* Математикадан кыскача белешмәлек

2. *с. мәгъ. физ., мат.* Орынып торган. *Сфераның яссылык белән орыну ноктасына үткәрелгән радиусы орынма яссылыкка перпендикуляр була.* Геометрия

ОРЫНТЫН *рәв. диал.* **1.** Астыртын, яшерен рәвештә

2. *с. мәгъ.* Яшерен. *Нишләргә?.. Әйе, әйе, китәргә. Орынтын юллар белән анда барып хәбәр итәргә.* Т.Гыйззәт

ОРЫНУ *ф.* 1) Тию, кагылу. *Сирәкмирәк кар бөртекләре тәрәзәгә килеп орына ---.* М.Хәбибуллин. *Орынмый да, кагылмый да үзе, ә җылысы тия.* М.Маликова. *Матур иде Толымнарың, Мин аларга Орынмадым.* Ш.Галиев

2) Каты һәм кинәт бәрелү. *Хәлим килеп орынуга, егет сөртенеп китте.* Г.Гобәй

3) Нәрсәгә булса да рөхсәтсез тию, кагылу. *Элек чыбык-чабыкка орынырга куркып торган кешеләр хәзер алпавыт урманына үз бакчаларына кергән кебек кыю керәләр.* И.Гази

4) Тәэсир итү. *Көз сулышы бөдрә каеннарга орынды.* Г.Әпсәләмов

5) *мат*. Гадәттә бер ноктада тиеп үтү. *Әгәр әйләнәнең уртак орынмасы булса, бу әйләнәләр уртак ноктада бер-берсенә орыналар.* Математикадан кыскача белешмәлек

6) *күч.* Иминлекне, тынычлыкны бозу; һөҗүм итү. *[Таңана сөрәнчесе:] Кайтып кит чирүеңне алып туган илеңә, орынма безгә.* М.Хәбибуллин

Орынып алу Сизелер-сизелмәс кенә яисә тиз генә орыну. *Әни кытыршы кулы белән иңемә орынып алды.* Ф.Шәфигуллин. *Бик мавыгып киткән чакларда куллар кулга тиеп, иңнәр иңгә орынып алгалый.* М.Маликова. *Мәдинә апа, чәйнәвеннән туктап, терсәге белән иренә орынып алды һәм аңа нидер пышылдады*. Безнең гәҗит

Орынып китү Көтмәгәндә, ялгыш орыну. *Ялгыш кына берәр нәрсәгә катырак орынып китсә дә, тәненә каракучкыл булып күгәрекләр килеп чыга.* Безнең гәҗит

Орынып кую Тиз генә орыну. *Искәрмәстән генә Гәүһәршадның кулы фал китабына орынып куйды.* М.Әмирханов

Орынып тору Әледән-әле, шактый дәвамлы вакыт яки даими орыну. *Без сезгә чит кешеләр түгел, орынып торган күршеләр.* Г.Тавлин. *Тар тыкрыкларда кара-каршы балконнар орынып тора диярлек.* Т.Әйди. *--- берсе – кискән җиргә, икенчесе зарарланмаган җиргә орынып тора*. Кызыклы физиология

ОРЫНЧАК *с.* Нәрсәгә дә булса җиңелчә бәрелеп, ышкылып йөри торган. *Орынчак атта ял юк.* Мәкаль

ОРЫ́П-БӘРЕП *рәв.* 1) Кискен хәрәкәтләр ясап, саксыз. *Усал җил әллә кайлардан ажгырып килә дә, шәрәләнеп, караланып калган агач ботакларындагы соңгы яфракларны йолкып алып, сәбәпсез ачу белән орып-бәреп алып китә.* М.Маликова

2) Бик каты, чиләктән койган кебек. *--- орып-бәреп яңгыр яварга тотынды.* Г.Ахунов

3) *сөйл. к.* **орды-бәрде**. *Орып-бәреп эшләү*

4) *сөйл.* Эткәләп, төрткәләп. *Халык арасыннан орып-бәреп үтү*

ОРЫ́П-ЕРЫП *рәв.* Кискен хәрәкәтләр белән аралап, эткәләп

ОРЫ́П-СУГЫП *рәв.* Кыйнап, җәберләп. *Әсирләрне бу дәрәҗәдә җәбер кылып, орып-сугып ачлы-туклы хезмәт иттерү һич инсаниятлек түгелдер.* Ш.Мөхәммәдев

ОРЫ́ ЧЕБЕНЕ *и. зоол.* Икеканатлылар отрядыннан канатлары төкле булган, озын мыекчалы кечкенә генә бөҗәк; *русчасы:* **галлица**

ОРЫШ *и.* 1) Сугыш, бәрелеш. *Кем риза булсын хурлыклы шартка, Орышка чыгу кала ир-атка.* Н.Әхмәдиев. *Орыш кырында үлү алар өчен дан санала.* М.Хәбибуллин. *Кояш чыгу белән орыш башлана ---.* С.Шәмси

2) Ызгыш, талаш. *Торак коммуналь хуҗалыгы бәяләре тирәсендә орыш көчәйгәннән-көчәя бара.* Татарстан яшьләре

3) Тиргәү, битәрләү сүзләре. *Көне буе югалып йөргән өчен әти дә, әни дә орыша торган булсалар да, аларның бу орышлары зәһәрле, йөрәк әрнет[кеч] --- тәэсир калдырмый иде.* М.Гафури

ОРЫШ КЫЛУ *ф.* Сугышу. *Әй безнең олугыбыз, инде безләр ошбу өстебезгә килгән Аксак Тимер белән орыш кылыйкмы?* Әкият

ОРЫШ-КЫРЫЛЫШ *и.* 1) Бик каты талаш, дау

2) Кан койгыч сугыш

ОРЫШ-КЫРЫШ *и. к.* **орыш-кырылыш**. *Орыш-кырыш бик кыска булды ---.* М.Хәбибуллин

ОРЫ́Ш-КЫЧКЫРЫШ *и. к.* **орыш-талаш**

ОРЫШ-ТАЛАШ *җыйм. и.* Ызгыш, кычкырыш. *Бу авырудан җәфа чиккән кешеләр сәламәт бөерлеләргә карганда төрле кичерешләргә – гаиләдәге орыш-талашка, финанс проблемаларына өч тапкыр күбрәк зарланганнар.* Иң шәп календарь

ОРЫШТЫРУ *ф.* 1) *йөкл. юн. к.* **орышу**

2) *күч.* Котырту, коткы салу, бәрелешкә китерү. *Икенчедән, аларны маңгайга-маңгай орыштырып, үзара сугыштыру фасылын да (урынсыз булса да, матур сүз тапканына елмаеп куйды) күз уңыннан ычкындырырга ярамый.* Т.Галиуллин

ОРЫШУ *ф.* 1) *урт. юн.* Бәрелешү, бер-беренә бәрелү

2) *урт. юн*. Сугышу. *Ул борын-борыннан җир, су, сары тимер, хатын-кыз өчен яу тоткан, орышкан, сугыш кырында ятып калган яисә рәхәттә йөзгән.* Т.Галиуллин. *Ярасының әрнүенә, кан тамуына игътибар итмәскә тырышып орышты ул.* Р.Сәгъди

3) Кемне дә булса тиргәү, битәрләү, бик нык ачулану. *Орышыгыз, сүгегез, теләсә ни эшләтегез, тик җавап кына бирегез.* К.Тинчурин. *Әни тәрәз төбендәге чәчәкләрне күреп алды да орышырга тотынды.* Н.Хәсәнов. *Нигә аны апасы бастырып орыша?* Н.Гыйматдинова

Орыша башлау Орышырга тотыну. *Генерал хәрби бүлекне карап йөргәндә, бер старшинаның кимчелекләрен күреп, тегене бик каты орыша башлаган.* Мәзәк

Орыша калу Берәр эш-хәл беткәннән соң да орышуын дәвам итү. *Кемдер аңа каты гына бәрелеп китте, җитмәсә: «Күзең чыккан мәллә, әтрәк-әләм!» – дип орыша калды*. М.Хәбибуллин

Орыша килү Күптәннән бирле орышу

Орыша тору Берәр эш-хәл барган арада орышу

Орышып алу Бераз орышу. – *Мин сезгә минем әни төргән тәмәкеләрне күрсәтер идем, – дип, [Җиһангир] кызларны орышып алды, аннары гына тылмачлык итәргә кереште.* А.Хәсәнов. *Узе малайны орышып та алган ---.* М.Мәһдиев. *«Көмеш чүмеч кая, нигә алтын чүмеч белән аш саласың?» – дип, [Җангали] тик торганда бавырчыны орышып алды.* М.Хәбибуллин

Орышып ату Көтмәгәндә тиз арда орышу. *Әби: «Ник сөйләшмисең?» – дип орышып та атты үземне ---.* Безнең гәҗит

Орышып йөрү Берникадәр вакыт дәвамында орышу. *Император Ираклий Патшакалада юк, сараҗиннар белән орышып йөри.* М.Хәбибуллин

Орышып карау Орышу алымын сынау. *Сәбилә аларны бераз орышып*

та карый, үзенә игътибар итүче кеше күрмәгәч ---, кул селтәп чыгып китә. Р.Вәлиев

Орышып китү Көтмәгәндә, кинәт орышу. *Биредә ике якның җансакчылары үзара орышып киттеләр.* М.Хәбибуллин

Орышып ташлау Тиз генә орышу. *Ахыр килеп, ана кешенең улына җен ачулары чыгып, тегене орышып ташлый, хәтта күз яше белән үтенә, ялвара.* М.Хәбибуллин. *Шуны сизеп, әби үземне орышып ташлады.* Безнең гәҗит

Орышып тору Даими, әледән-әле орышу. *Гүзәл бикәм, сарматлар һәрчак аланнар, готлар белән орышып тордылар, кыен чакта сарматларга унуклар һәрчак ярдәмгә килделәр.* М.Хәбибуллин. *Без, әниләр, шулай инде, балаларыбызны орышып кына тарабыз...* Ф.Яхин

ОРЫШЧЫ *и.* Сугышчы. *Шунда сөн кызы кинәт кенә борылып, артыннан һөҗүм итүче орышчыга сөңгесен ыргытты.* Р.Сәгъди

ОСЕМЕНА́ТОР *и. рус* Хайваннарны аталандыру белгече. *Сыерларны ясалма орлыкландыру белән шөгыльләнгән осеменатор дигән белгечләрне әйтүем.* Мәдәни җомга

ОСЕТИН *и.* Төньяк Осетия һәм Көньяк Осетиянең төп халкын тәшкил иткән Кавказ халкы. *Балтыйклылар безләрне ник таплый, Осетиннар гомер безне яклый.* Ә.Синугыл-Куганаклы

ОСЕТИ́НЧА *рәв.* **1.** 1) Осетиннарга хас булганча. *Осетинча бию*

2) Осетин телендә. *Осетинча сөйләшү*

2. *и. мәгъ.* Осетин теле. *Осетинчаны җиңел өйрәнү*

3. *с. мәгъ.* Осетин телендәге. *Бу шәрехләү буенча, албасты сүзенең тамыры урысча «бес» яисә осетинча «уас» сүзләре белән бәйләнгән икән.* Ф.Урманче

ОСЁТР *и. рус к.* **мәрсин**. *Илбарис, син нәрсә, Иван Кирилловичка хөрмәтенә рәтлерәк балык китермәдең? Анда осётр бар иде бит.* С.Сабиров. *--- 30 килограммлы осётрлар Кара һәм Каспий диңгезләрдә яшиләр* ---. Биология

ОСЁТРСЫМАННАР *и. күп. зоол. к.* **мәрсинсыманнар**. *Даими рәвештә диңгездә яшәп, үрчү өчен генә елгаларга күчүче үзгынчы балыкларга шулай ук осётрсыманнарны һәм кайбер башка балыкларны кертәләр.* Биология

ОСЁТРЧАЛАР *и. күпл. зоол. к.* **мәрсинчәләр**

ОСКЫРТУ *ф. диал.* Котырту

Оскыртып яту Даими, әледән-әле котырту. *Үзең эшләмәвең генә җитмәгән, башкаларны да оскыртып ятма!* В.Нуруллин

ОСМО́ТИК *с. физ.* Диффуз (басым). *Тозларның турыдан-туры катнашы белән бара торган физиологик күренешләрдән, иң элек, осмотик басым турында әйтеп үтәбез.* Тереклек һәм аның җир йөзендә таралышы. *Акула һәм скат каннарындагы осмотик басым диңгез суындагыдан шактый югары.* Кызыклы физиология

ОСОБНЯК *и. рус* Аерым урнашкан, бай итеп бизәлгән зур йорт. *Диңгезчеләрнең Культура сарае Потёмкин баскычы каршындагы элекке генерал-губернатор особнягына урнашкан иде.* М.Юныс. *Казанның эре промышленниклары Ушковлар үзләренә төзетәсе особняк проектын кемгә ышанып тапшырырга икәнен белеләр*. М.Галиев

ОСТА *и. фар.* **1.** 1) Нинди дә булса һөнәр белән шөгыльләнүче квалификацияле белгеч. *Ниндидер кәсепкә өйрәнсеннәр өчен, балаларны остага тапшырганнар.* Ә.Хуҗиәхмәтов

2) Билгеле бер өлкәдә зур белгеч, югары уңышка ирешкән кеше. *Портретны оста рәссам ясаганлыгы сәнгатьтән ерак торган кешегә дә аңлашыла иде.* Ф.Яруллин. *Ялган язулар, документлар ясау остасы, имеш.* З.Фәтхетдинов. *Сәхнә осталары режиссёр М.Сәлимҗановның иҗат эшчәнлеген төгәл, тулы бәяләгән, минемчә.* Сәхнә

3) Билгеле бер эшкә осталыгы, маһирлыгы булган кеше. *Кыскасы, мин дә шыңшу остасы* ---. Л.Лерон

4) Мастер. *Әтигә мәктәп түбәсен төзәтергә осталар эзләп Чокырлыга барырга туры килмәячәк.* Г.Тавлин. *Осталар кайчан килә соң әле?* Ф.Шәфигуллин. *Әткәй сәгатьне бер остага биреп төзәттерде.* И.Сирматов

2. *с. мәгъ.* Нәрсәгә дә булса осталыгы, тиешле күнекмәсе, тәҗрибәсе булган. *Оста кеше дөнья малын табар инде Культуралы ысуллары булгач имде.* Г.Афзал. *Ә безнең вожак оста көтүче булып чыкты.* Ф.Яруллин

3. *рәв. мәгъ.* Яхшы, сыйфатлы итеп, җиренә җиткереп. *Ул бик актив бәндә – карт бүре төсле эшен бик оста йөртә.* З.Фәтхетдинов. *[Рафаэль] Оста һәм ягымлы сөйләшә, күңелгә ятышлы тәмле сүзләрен тыңлавы рәхәт.* Р.Низамиев. *Ювелирлар алтын-көмештән нәфис савытлар ясаганнар, асылташларны оста эшкәртә белгәннәр.* Урта гасырлар тарихы

◊ **Оста сайрау** Тиешле сүзләрне кулланып, ышандырырлык итеп сөйләү. *Оста сайрыйсың, дускай.* Ф.Яруллин. **Оста тел** Матур, мавыктыргыч итеп сөйли белүче кеше. *Оста телләр сандугач сайрата, бала-чага колак шомартып тыңлый.* Н.Гыйматдинова. **Оста телләнү** Матур итеп сөйләү. *– Минем йөрәгем атлыгып тибә, шуңа калтырыйдыр ул, – диде кияү, оста телләнеп.* Н.Фәттах. **Оста телле** Матур, мавыктыргыч сөйли торган. *Хәмит Ярми дидекме, әнә шул банкет заманындагы иң әдәпле, оста телле тамада искә төшә.* М.Мәһдиев

ОСТАБИКӘ *и.* 1) Мулла хатыны. *Ә соң тирә-якта гыйлеме вә әхлагы белән беренче урын тоткан Зөләйха остабикәнең тәрбияле мәхдүменә, мулла булырга якынлашкан углына бу килешәме?* Г.Ибраһимов. *Остабикә монда да читтә калмаган, хәзрәтне матур сүзләр белән мактаган* ---. Л.Садри. *Остабикәнең дә йөрәге үзенекеннән ким янмаганлыкны тоя ул.* С.Поварисов

2) Дини уку йортларында мөгаллимә

ОСТАЗ *и. фар.* 1) Фән һәм сәнгать өлкәсендәге зур тәҗрибәсе белән уртаклашучы галим кеше. *Шаккатып торам: сез – абый. Сез һаман остаз лабаса, Без һаман бала икән...* Р.Гаташ. *Яшьләрнең остазлары, галим-табиблар иде болар.* М.Маликова. *Остаз белән ара ярты юлда өзелсә дә, укучысы аны барыбер узарга тиеш.* М.Гали

2) Мәсләгенә күпләрне өйрәтүче кеше, җитәкче. *Остазның сөйләгәннәре нигезле, ышандырырлык булып тоелды.* М.Маликова

ОСТАЗБИКӘ *и.* Остабикә

ОСТАЗЛА́РЧА *рәв.* Остазлар кебек

ОСТАЗЛЫК *и.* Остаз булу. *Гомумән, әдәбиятта остазлыкны һәм шәкертлекне өнәмим.* Т.Миңнуллин. *Анда электән килгән остазлык, фәнни традицияләр әле дә яшәп килә.* Татарстан яшьләре

ОСТАЛА́РЧА *рәв.* Осталар кебек. *Билгеле инде, Саматның осталарча уйнавы, Саимәнең җырлавы «беренче»не таңга калдырды.* Г.Галиева. *Әмма бөтен очракта да ул сүз белән, тел белән эш итә һәм үзенең төп эш коралыннан осталарча файдалана.* Р.Батулла

ОСТАЛЫК *и.* 1) Нәрсә дә булса эшләргә белем, тәҗрибә нигезендә туган сәләт // Берәр эшкә зур һәвәслек. *Бенефис иясе ике пьесаны да осталык белән уйнады.* Г.Исхакый. *Алар зур осталык белән үзәнгә дамба сала башладылар, ә Йортта эшләүчеләр тиз генә иркен залга җыелдылар.* Р.Зәйдулла. *Рәссамнар кояш яктылыгының тәэсир көчен зур осталык белән сурәтләгәннәр* ---. Урта гасырлар тарихы

2) Оста (*4 мәгъ.*) хезмәте, вазифасы. *Осталыкка яллану* // Оста хезмәтен үтәүче. *Бу озын буйлы, калын гәүдәле, ярым русча киемле карт --- рус тегермәнендә осталык хезмәтендә торучы икән.* Г.Ибраһимов

3) Максатка ирешүдә тапкырлыкка, хәйләкәрлеккә нигезләнеп эш итү ысулы. *Осталык белән алдау*

ОСТАРУ *ф.* 1) Эшне оста эшләргә, башкарырга өйрәнү. *Язмыш, инде остардым мин синнән, Шатлыкларым үзем таба беләм.* Э.Нигъмәтҗан. *Остарасы да остарасы әле аңа.* Б.Камалов. *Кышлактагы уен-җыеннарда чичәннәрдән тегесен-бусын ишетеп остара торган яшьтә ул кырыс Кызылком чүлен аркылыга-буйга гизә башлады.* Т.Әйди

2) *ирон.* Үз-үзен белдекле тоту. *Машаның кире җавап бирәсен чамалагач, остарырга була иде инде.* Б.Камалов. *Остардык, һай: соң җелеген җирнең Агу өреп кудырабыз өскә.* Ә.Баян

Остара бару Торган саен күбрәк остару. *[Фәнияр] образлар белән эш итүдә остара бара.* Ф.Яруллин. *Борауны борам, борам, Борам – остара барам! Боравымны күлдан алып, Колакны борды бабам...* Ш.Галиев

Остара башлау Остару билгеләре сизелү

Остарып бетү Тәмам остару, белгеч булып китү. *Остарып беткәч, каенанасы: «Балага зыян килмәсме?» – дип туктатмакчы булган иде дә, кая ул!* Р.Мулланурова. *Ләйлә: Төлкеләр, койрык болгарга остарып беткәннәр.* К.Ситдиков

Остарып җитү Бик оста булып җитешү, осталыкның югары дәрәҗәсенә ия булу. *--- Мөгаен, хатын-кыз заты кырык яшьтә генә шулай остарып җитәдер.* Н.Гыйматдинова. *Гармун уйныйм, гармун уйныйм, Һаман гармун уйныйм мин: Остарып җиткәч, барысын да Биетергә уйлыйм мин.* Ш.Галиев. *--- Хөснуллин да тәмам сүзгә остарып җиткән иде, кайбер профессиональ композиторлар кебек авыз эчендә ботка пешермәде* ---. Х.Ибраһим

Остарып китү Соңгы вакытларда остару. *Язарга ярата икән бит, тырыша торгач, тагын да остарып китәр иде әле.* М.Маликова. *Соңгы елларда профсоюз спорт ярышлары уздырырга бик остарып китте.* Татарстан яшьләре

ОСТАХАНӘ *и.* 1) Нинди дә булса әйберләр ясау, ижат итү, ремонтлау өчен махсус бина, бүлмә. *Бу коедан ерак та түгел Күчемнең корал ясый торган остаханәләре булган.* Я.Зәнкиев. *Остаханәдә зур балта, бәләкәй балта, зур пычкы, бәләкәй пычкы, тишкеч, өтерге, келәшә, кыскыч... – тагы әллә нинди кораллар бар.* С.Поварисов. *--- Күчемхан су юлы белән корал остаханәләрен карап кайтырга булды.* Ф.Бәйрәмова

2) *күч.* Уңай тәҗрибә тупланган һәм аны өйрәнергә мөмкин булган урын, осталык чыганагы. *Мәктәпне Коменский гуманлык остаханәсе дип саный.* Ә.Хуҗиәхмәтов. *Татарстан Язучылар берлегенең шигърият остаханәсе җитәкчесе шагыйрь Зиннур Мансуров Ватан сугышында иң күп югалтуларның татар язучылары өлешенә туры килүен искәртте.* Мәдәни җомга

ОСТЕОМИЕЛИТ *и. гр. мед.* Умыртка җелеге авыруы. *Бу авыру арка миенең каты авыруларыннан: ютәл авыруының спондолиты, остеомиелит һ.б.дан соң да калырга мөмкин.* Иң шәп календарь

ОСТЕОПОРОЗ *и. гр. мед.* Сөяк тукымасының тыгызлыгы һәм структурасы бозылудан гыйбарәт авыру. *Организмнан кальций «юылу» остеопорозга китерергә мөмкин.* Ватаным Татарстан. *Өлкән яшьтәге кешеләр остеопороздан интегә.* Мәдәни җомга

ОСТЕОХОНДРОЗ *и. гр. мед.* Тукымаларның туклануы бозылу сәбәпле, буыннарның кимерчәкләрендә барлыкка килгән үзгәрешләр комплексы. *Артрит, остеохондрозны дәвалау өчен яхшы вакыт.* Мәдәни җомга. *Баш авырту – остеохондрозның юлдашы.* Серле календарь. *Остеохондроз белән авыручыларга халык медицинасы дөге диетасы кулланырга тәкъдим итә.* Юлдаш

ОСТИТ *и. гр. мед.* Сөяк ялкынсынуы

ОСЦИЛЛОГРА́ММА *и. лат.-гр.* Осциллограф ярдәмендә язып алынган кәкре. *151 нче рәсемдә, алмаш ток осциллограммаларын сыздыру өчен, приборларны ничек урнаштыру схемасы күрсәтелгән.* Физика курсы

ОСЦИЛЛО́ГРАФ *и. лат.-гр.* Бик тиз алмашынучан төрле электромагнитик процессларны тикшерү приборы. *Су асты оциллографы – парапсихология өчен табыш ул.* Кызыклы физиология. *Осциллографның төп өлеше – вибратор.* Физика курсы. *Осциллограф – электр чылбырындагы тиз үзгәрешле процессларны тикшерә торган прибор.* Физика

ОСЦИЛЛОСКОП *и. лат.-гр. махс.* Электрик процессларны күз белән күзәтү өчен махсус прибор

ОТВЁРТКА *и. рус* Винтларны, шөрепләрне бору өчен махсус корал. *Махсус кораллар белән башкара торган нечкә эшне Әхтәм кадак ярымлы чүкеч, карыш ярымлы отвёртка ярдәмендә эһтә итмичә әмәлләп куйды.* Ф.Шәфигуллин. *[Ул] балта-пычкы, отвёртка тотарга да уңайсызланмый.* Т.Нәҗмиев

ОТГУЛ *и. рус* Эш сәгатеннән тыш эшләгән өчен бирелә торган ял көне.

Лабораториягә телефоннан шалтыратып, чирлим, температурам утыз сигезгә күтәрелде дип, бер көнгә отгул алды. М.Маликова. *Отгул приказын китердем.* М.Юныс

ОТДЕЛЕ́НИЕ *и. рус хәрби* Армиядә иң кечкенә гаскәри берләшмә, взводның бер өлеше. *Сугышта пулемётчылар отделениесе командиры Вергилий Дикопольцев каты яраланып әсирлеккә эләгә.* Г.Кашапов. *Минем отделение елгага кереп алга йөзеп китте, ә мин йөзә белми идем.* Х.Камалов

ОТЕЛЬ *и. фр.* Кунакханә. *--- Зур-зур отельләрдә, кафе-ресторанларда виски эчеп, сигара тартып утыручы бизнесменнар, без генә рәхәт чигәбез дип, никадәр ялгышканнарын белмиләр!* М.Мәһдиев. *Күпләрдән аермалы рәвештә, ул мин урнашкан «Троя» отеленә бик тиз килеп җитте ---.* Т.Әйди. *Комлык белән яшел яфракларга төренеп утырган кыялар арасында ымсындыргыч тыныч ял йортлары, отельләр, ак коттеджлар.* М.Юныс

ОТЕЛЬЕР *и. фр.* Отель хуҗасы, отель тотучы

ОТЗОВИЗМ *и. рус тар.* РСДРПда 1905 елгы революциядән соң барлыкка килгән һәм Дәүләт думасыннан социал-демократларны чакыртып алуны, массачыл партия эшенең легаль формаларыннан баш тартуны талэп иткән сәяси агым

ОТИТ *и. гр. мед.* Колак бизләре шешү белән характерлана торган авыру. *Шуңа күрә моны үлекле отит дип тә ялгышалар, нәтиҗәдә, авыруны дөрес дәвалап булмый.* Иң шәп календарь

ОТКРЫ́ТКА *и. рус* 1) Конвертка салмыйча гына җибәрергә мөмкин булган почта карточкасы. *Ун ел буе шундый открытка алып кара әле син!* М.Маликова

2) Шул ук форматтагы рәсемле карточка. *Алтынчәч өч тиенлек открыткаңы суд криминалисты кебек тикшерде.* М.Маликова. *Туганнарга открыткалар язган идем.* Р.Вәлиев

ОТ-КУТЮР *и. фр.* 1) Тегүчелекнең иң югары осталыгы, тегүчелек сәнгате, югары мода

2) Танылган кутюрьеларның фирмалары атамасы

3) Шул фирмаларда, гадәттә кулдан, бердәнбер экземплярда эшләнгән киемсалым

ОТКЫР *с.* Бик зиһенле, тиз отып алучы, яхшы хәтерле. *Откыр яшьләр*

ОТЛИ́ЧНИК *и. рус* 1) Барлык уку предметларыннан югары бәя алган кеше. *Мәктәптә укыганда отличник булуы әллә ни авыр түгел.* М.Юныс. *Монда, билгеле, --- тимурчылар, отличниклар, пионер активистлары белән гөр килеп торган повестьлар, хикәяләр күз алдында тотыла.* А.Әхмәдуллин. *Отличник ук булмасам да, өчлем юк иде.* В.Нуруллин

2) Эшне югары сыйфатлы итеп эшләүче хезмәткәр яки хәрби. *«Атказанган укытучы» яки «мәгариф отличнигы» кебек исемнәргә өмет баглаулар да – бары көлке.* В.Имамов. *Ә аның белән озак еллар буена мәгариф отличнигы Сафа Нәсихов җитәкчелек итте.* Ә.Хәсәнов. *--- Россия Федерациясенең мәгариф отличнигы Шәүкәт Хәмзин кызык ясамакчы булган.* Т.Нәҗмиев

ОТЛИ́ЧНО *и. рус* **1.** Бишле билгесе, иң югары билге. *Укуга алай искитәрлек һәвәс түгел иде ул кыз. «Отлично» турында әйткән дә юк инде, «яхшы» билгеләрен дә бик сирәк алгалап килә.* В.Нуруллин

2. *рәв. мәгъ.* Бик шәп, бик яхшы. *Шәп булып китте бит әле, Людочка... Шәп бу. Отлично.* М.Мәһдиев

3. *мод. сүз мәгъ.* Нәрсә белән дә булса тулысынча килешүне белдерә. *[Гали:] --- иртәгә ничек-ничек тәрҗемә итәсең сөйләшербез. [Газиз:] Отлично.* Ф. Әмирхан

ОТОЛОРИНГО́ЛОГ *и. гр. мед.* Колак, тамак, борын авыруларын дәвалаучы табиб. *«Лор» дип, гадиләштереп, отоларингологларны, ягъни колак, борын, тамак авыруларын дәвалаучы табибны әйтәләр.* М.Маликова. *Отоларингологка күренгәч, егетнең борын бүлгесе кәкрәйгәне ачыклана.* Мәдәни җомга. *Отолоринголог В.Щербинин әйтүенчә, тамак бизләрен алдыру операциясе тиз башкарыла.* Юлдаш

ОТОЛОРИНГОЛО́ГИЯ *и. гр. мед.* Медицинаның колак, борын, тамак авыруларын, аларны дәвалау, диагностика һәм профилактика ысулларын өйрәнә торган тармагы

ОТОМИКОЗ *и. гр. мед.* Колакта гөмбәчекләр авыруы. *Отомикозның кинәт һәм көчле авырту белән башлануы да мөмкин.* Иң шәп календарь

О́ТПУСК *и. рус* Ял итү яки башка максатлар белән билгеле бер вакытка эштән, хезмәттән азат ителү. *Мин хәзер отпускта гына киләм.* Ф.Шәфигуллин. *Әүлияга отпуск юк аңа!* М.Маликова

ОТПУСКНОЙ *и. рус сөйл.* Ял вакыты өчен алдан түләнә торган акча. *Отпускной алу*

О́ТПУСКЫ *и. рус сөйл. к.* **отпуск**. *Мин гомумән отпускыдагы кеше.* М.Маликова. *Чөнки, хәрби-тактик әзерлек һәм очуда зур уңышларга ирешкән өчен, бу – аңарга, чират буенча, алдан ук вәгъдә итеп куелган бер атналык отпускы вакыты иде.* Р.Мөхәммәдиев

ОТРЯД *и. рус* 1) Махсус гаскәри группа. *Блюхер дивизиясе составына кергән Белкин җитәкчелегендәге отряд, атна-ун көнлек әзерлектән соң, һөҗүмгә күчәргә боерык алды.* Я.Зәнкиев. *Мондый җәза отрядларына халык тарафыннан «абжур командасы» дигән хурлыклы исем тагыла.* Х.Мәхмүтов. *Ул заманда хәтта яхшы коралланган хәрби отрядлар да бу явызлардан зыян күргәннәр.* Кызыклар дөньясында

2) Бергә эшләү өчен оештырылган кешеләр төркеме. *Геологлар отряды*

3) *зоол.* Хайваннар дөньясы классификациясендә: классларга берләшә торган төркем. *Бу отрядка керүче хайваннарның (кәлтә һәм еланнар) тәне тәңкәләр белән капланган, моны отрядның исеме үк әйтеп тора.* Биология. *Маймыллар приматлар дип йөртелә торган иң югары төзелешле имезүчеләр отрядына карый.* Кызыклар дөньясында

ОТСТА́ВКА *и. рус* 1) Хәрби хезмәттән азат ителү. *Отставкада булсам да, өченче ранг капитаны мин...*

Ф.Галиев. *Һы, кызык заман китте: хәзер генераллар отставкага чыкса – мемуар язарга тотына ---.* Ф.Яруллин

2) Дәүләт учреждениесендәге хезмәттән китү. *Трибунага кинәт кәтүктәй бер хатын йөгереп менде: – Ышанычыбыз юк сезгә! – дип әче тавыш белән кычкырды ул. – Долой! Отставкага!* Р.Зәйдулла. *85 яшьлек баронесса Тэтчер отставкасыннан соң ике дистә ел узгач та «тутыкмаган».* Таң

◊ **Отставкага җибәрү** Берәр урыннан куу, эштән алу; араны өзү. **Отставкага чыгу** Картаю, яраксызга әйләнү. *Сөяркәне отставкага чыгару.* **Отставкага чыгару** *к.* **отставкага җибәрү**

О́ТТИСК *и. рус мәхс.* 1) Текст, рәсем һ.б.ш.ның полиграфик ысул белән алынган күчермәсе. *Мәгәр соңыннан да әйбергә оттиск төшерү, штамплау яки кою юлы белән орнамент куеп, элеккечә әвәләп ясау ысулы да бөтенләй үк юкка чыкмаган.* Ф.Вәлиев

2) Журналда яки җыентыкта басылган мәкаләнең аерым брошюра формасындагы төпләнмәсе

ОТТЫРУ *ф.* 1) Нәрсәне дә булса югалту, материаль зарар күрү. *Сукбайлыкка чыктыңмы? Оттырдыңмы, оттыңмы?* Ф.Мөслимова

2) Уңмау, уңышсызлыкка очрау. *Бу ел әйләнәсендә ул шактый оттырды.* Ә.Фәйзи

3) Җиңелү (уенда, көрәштә, бәхәстә). *Уенны Әминә башлады, оттырса, үзенә үпкәләсен, кһым.* Н.Гыйматдинова. *Ә без оттырсак, ул карт-корылар, ул мал кемгә кала?* В.Имамов. *Авантюралы чараларны кире кагу кирәк, югыйсә оттырачаксыз.* Мәдәни җомга

Оттыра бару Эзлекле рәвештә оттыру. *[Ул] --- бер инстанциядә судны оттыра барды, икенчесенә бирә торды.* Безнең гәҗит

Оттыра башлау Оттырырга тотыну. *Әйтик, шул ук «Салават Юлаев»ка рәттән оттыра башлагач, Зиннәтулла Билалетдинов буталчык мәсьәләдән чыгу юлын таба алмады.* Безнең гәҗит. *Моңарчы үз мәйданында җиңелүне белмәгән «УНИКС» хәтта аутсайдерларга да оттыра башлады*. Татарстан яшьләре

Оттырып бетерү Тулысынча оттыру. *Бөтен акчасын оттырып бетергәч, һич югы шул төргәкне уртага салыр иде.* З.Фәтхетдинов

Оттырып килү Эзлекле рәвештә оттыру. *Әлегә оста «шахматчылар» --- халык[ка] «мат»ны куя торалар, халык әлегә гел оттырып килә.* Безнең гәҗит

Оттырып тору Әледән-әле оттыру

ОТТЫРЫШ *и.* 1) Оттырылган нәрсә, сумма (комарлы уеннарда)

2) Уңышсызлык, җиңелү. *--- Узганнар нинди генә булмасын, алар киләчәктә дә оттырыш кына китерәчәкләр.* Казан утлары

3) Зарар, югалту

ОТТЫРЫШЛЫ *с.* Оттыра торган; уңышсыз; *киресе:* **отышлы**. *Буш чаклар берәүгә отышлы, икенчегә оттырышлы.* Г.Хөсәенов

ОТТЫРЫШСЫЗ *с.* Уңышлы, оттыру ихтималы бөтенләй булмаган. *Предприятие өчен бу оттырышсыз вариант кына түгел.* Хәзинә

ОТУ I *ф.* 1) Комарлы уеннарда отыш алу. *Яңа елның беренче сәгатендә, кемгә дә булса шалтыратып, әңгәмә өзелгәнче, аны тәбрик итеп калу мөмкинлеге казинода миллион сум акча оту белән бер икән.* Акчарлак // Шундый уеннарда җиңеп, салынган акчаны, кассаны алу. *Откач бирермен дип, кузаларны әҗәткә теләнеп алып, хәрәмләшә-хәрәмләшә уйныйсың әле.* Г.Тавлин

2) Үз файдаңа хәл итү, җиңү (спорт уеннары, бәхәс һ.б. тур.). *Уенда да салкын канлы кешеләр күбрәк ота.* Х.Камалов // Ярышларда, бәйгеләрдә өстен булу, җиңү, югары бәя алу. *Ул бәйгеләрдә гади яулык яисә бакыр кашык кына отып калмыйлар, монда затлы гарнитур белән машиналарга хәтле отып китәләр.* Х.Ибраһим. *[Укытучылар] «Ел укытучысы»нда даими катнашалар, 100 мең сумлык грант та оттылар, ноутбугын да алдылар, фәнни язмалары ил күләмендәге газета-журналларда басылып тора.* Безнең гәҗит

3) Өстенлек алу, файда күрү. *Акча санаган политика я ота, я оттыра.* М.Хәбибуллин. *Нәрсә оттык, ни югалттык – Кирәк акыллы исәп.* Р.Сафин. *Өч яклап отарга исәп: ташландык җирләрдән файдаланачакбыз – бер, бал табышы арта – ике, өшкерүче-төкерүчеләрдән котылабыз – менә буладыр өч!* К.Тимбикова

4) Үз файдаңа саклап калу. *Без шул рәвешле бер-ике көн отачакбыз.* М.Мөхәммәдиев

Ота башлау Отырга тотыну. *Моннан бер өч ай элек булыр, мин рәттән ота башладым, һәм бу шактый озак, биш-алты атналап дәвам итте.* Р.Мирхәйдәров

Отып бару Рәттән барысын да оту

Отып бетерү Тулысынча оту

Отып калу Отарга өлгерү

ОТУ II *ф.* 1) Күргәнне, ишеткән, өйрәнгән һ.б.ш.ларны бик тиз аңлап алу, истә калдыру. *Бу сүзне Сәхәрия әбием еш кабатлый, аңардан оттым мин аны.* М.Хуҗин. *Әле теле дә ачыла башламаган бала әйткәнне бик яхшы аңлый, күрсәткәнне тиз ота.* М.Маликова. *Минем көйгә зиһен шәп, оттым мин аны.* Ә.Гаффар

2) Үрнәк итеп алу, файдалану. *Яңалыкны оту*

Ота башлау Отарга тотыну

Отып алу Бик тиз оту. *Җырыңны отып ала белмәдек [Мирзажан]...* М.Хуҗин. *Ул җырлар Нинди иделәр! – Отып алды Иделәр.* Н.Сафина. *Хәтта күп кенә дару үләннәрен һәм дәвалану ысулларын адәм баласы нәкъ менә хайваннардан отып алган, дияргә тулы нигез бар.* Кызыклар дөньясы

Отып бару Рәттән һәммәсен дә оту. *[Юеш борыннар] авызыңнан чыккан бар сүзеңне төшенеп, аңлап, отып баралар.* А.Хәсәнов

Отып бетерү Тулысынча оту. – *Кайлардан шулай бакыйлык сыман отып бетергән диген, ә? – диде Өлкән Фатыйма, ихлас гаҗәпсенеп.* Ә.Гаффар

Отып калу Отарга өлгерү; форсаттан файдаланып оту. *Кара син: фамилиясен дә отып калган бит моның!* Э.Касыймов. *Сине уйлап, сиңнән отып калган җырны көйләп юанырга тырышам.* М.Маликова. *Күрсәтеп биргән нәрсәне тиз отып кала ул: әнә бит парашют җыюны ничек оста, ничек җәһәт башкара.* Ф.Яруллин

О́ТЧЕСТВО *и. рус* Атасының исеменә *-ович, -евич (-овна, -евна*) кушымчасы ялганып ясалган һәм үз исеменә кушып кулланыла торган исем; тулы исемнең ата исеме белән ясалган өлеше. *Безнең татар отчество белән сөйләшмәгәч, кешенекен хәтерләми, аңа зур игътибар да бирми.* М.Мәһдиев

О́ТЧЕСТВОЛЫ *с.* Отчествосы булган. *Ике ирдән тапкан балаларының берсе отчестволы, берсе отчествосыз*

О́ТЧЕСТВОСЫЗ *с.* Отчествосы булмаган. *Отчествосыз граждannар*

ОТЧЁТ *и. рус* Эшләнгән, башкарылган эшләр, тотылган акча һ.б.ш. турында бирелә торган хисап. *[Баш акушер-гинеколог] Мәскәү өчен отчётлар әзерли, юл уңаеннан киңәшеп чыгарга дип кергән.* М.Маликова. *Булмас иде бу җыелыш – имгәк, Отчёт өчен беркетмәсе кирәк.* Г.Афзал. *Мөхәммәт ашыгыч отчёт белән утыра, иртәгесен РОНОга барырга кирәк.* Я.Зәнкиев

◊ **Отчёт бирү** Кирәксә-кирәкмәсә дә кемнең дә булса алдында аклану. *Мә квитанция, хатыныңа отчёт бирерсең.* Р.Вәлиев

ОТЫЛУ *ф.* Оттыру, уңышсызлыкка дучар булу. *Инде отылдым, инде чираттагы дулкын юып төшерде дигәндә генә, тиктормас мичкә трал җәтмәсенә чорналып калды ---.* Ф.Шәфигуллин. *Тотылсак та, алдашып котылдык, Отылсак та, һәрчак без оттык...* Ә.Синугыл-Куганаклы. *Берәүләр отыла, икенчеләр ота.* З.Фәйзи

Отыла башлау Отылырга тотыну

Отылып кую Көтмәгәндә отылу. *Отам дип, отылып куюыгыз бар.* Өмет

Отылып тору һаман, даими отылу

ОТЫРЫ *рәв. сөйл.* Торган саен, һаман. *Аның теге утырыштан соң ук авырып егылуы күңелен отыры ныk газаплады.* А.Расих. *Аңа, чыннан да, бер фикергә килү кыен, мондый тәкъдимнәр отыры каушата, кыюлыгын шиңдерә иде.* З.Фәтхетдинов. *--- Аннары яңгыр отыры көчәеп, урап-урап коярга керешә.* М.Маликова

ОТЫРЫДА́Н-ОТЫРЫ *рәв. диал.* һаман, тагын да көчлерәк итеп

ОТЫШ *и.* 1) Комарлы уенда отып алган нәрсә // Заём, лотереяда откан нәрсә. *Отыш чыгу*

2) Җиңү, ирешелгән уңыш. *Фани дөньяда отыш, яуланыш, хәтта җиңү өчен дә тутырып хак түләргә туры килә.* М.Юныс. *Сезнең авылыгызга кайтуыгыздан олы отыш булмаган.* М.Хуҗин. *Мин үземнең режиссёр һәм ассистентларыма һәр отышымнан егерме процентны чыгарып салам.* Р.Мирхәйдәров

3) Файда, өстенлек. *Ул мондый хәлдән отыш алырга, дөреслекне яшерергә, һәр сүзен теш арасында кысып тотарга өйрәнде ---.* Ф.Садриев

ОТЫШЛЫ *с.* **1.** 1) Отыш мөмкинлеге бирә торган (уеннар тур.). *Тормыш кору – лотерея инде ул, һәркемнең отасы килә, тик отышлы билеты гына сирәк кешегә эләгә.* М.Маликова. *Мөселманнарга аракы эчү, отышлы уеннар уйнау тыела ---.* Урта гасырлар тарихы

2) Файдалы, максатлы. *Отышлы сүз*

3) Уңышлы, тиешле дәрәҗәдә эшләнгән. *Г.Камалның тагын бер отышлы типларыннан асрау типлары хисапланалар.* М.Гали

2. *рәв. мәгъ.* Уңышлы, файдалы итеп. *--- Бүгенге көндә кызын институтка керту, киләчәктә аны отышлы итеп кияүгә бирү кирәк.* З.Садыйков. *Классик әсәрнең һәрчак отышлы булуына ачык мисал бу.* Сәхнә

3. *и. мәгъ.* Комарлы уен. *Рушад шатланып куйды: әһә, сез, монда җыелышып, отышлы уйнап утыручылар икәнсез әле, менә эләктегезме, дип шатланып, тегеләрнең ничек элэккәннәрен кararга бер читкә басты.* М.Мәһдиев

ОТЫШЛЫЛЫК *и.* Отышлы булу, файдалылык, нәтиҗәлелек. *Реформаның соңгы этабы дәүләт финансларын идарә итүнең отышлылыгын анализлаудан һәм аны камилләштерү тәкъдимнәреннән башланды.* Татарстан

ОТЫШСЫЗ *с.* **1.** Отыш китермәгән, файдасы булмаган. *– Аннары, Гөлшәһидә, сер итеп кенә шуны да әйтим үзеңә, – дип тартынып кына елмайды Маһирә ханым. – Врач буларак сезнең отышлы ягыгыз белән бергә отышсыз ягыгыз да бар.* Г.Әпсәләмов. *--- аларның куәте соңгы елларда шактый зәгыйфьләнеп өлгерде, шуңа күрә дә, мөгаен, аларның кыйммәтле кәгазьләрен сатып, отышсыз җитештерүчеләрдән котылырга, бераз тишекләрне ямарга тырышу ниятләре бардыр.* Ф.Фәтхи

2. *рәв. мәгъ.* 1) Отыш казанмыйча, отыш алмыйча, отыш булмый торып. *Отышсыз эшләү. Елны отышсыз тәмамлау*

2) *спорт.* Командаларның, уенчыларның берсе дә отмыйча да, оттырмыйча да; тигез исәп белән. *Тагын бер уенда җиңсә, башкаларында отышсыз уйнау да җитә.* Р.Бәшәр

ОТЫ́Ш УЕНЫ *и.* Уртага салынган акчаны билгеле кагыйдәләр нигезендә отуга корылган уен төре. *Кешеләр, кулларына билетларын тотып, отыш уенында катнашырга ниятлиләр.* Ф.Галиева

ОТЫШХАНӘ *и.* Комарлы уеннар уйнар өчен махсус йорт; казино

ОФЕ́РТА *и. лат. икът.* Барлык мөһим шартлары исәпкә алынган килешү тәкъдиме. *Ирекле оферта*

О́ФИС *и. ингл.* Предприятие, конторaның административ бүлеге. *Кайбер көннәрдә аларның фатирлары офисның бер филиалына әйләнә.* Ф.Яруллин. *Көннәрдән бер көн булмәмә аграрсәнәгать банкының Сабадагы өстәмә офисы идарәчесе Салават Бадыйков килеп керде.* Т.Нәҗмиев. *Мондый кабарынкы рәвештәге туфли офис өчен дә, опера тыңларга бару өчен дә кулай санала.* Сөембикә

ОФИУ́РАЛАР *и. гр. зоол. күпл.* Энәтирелеләр тибыннан умырткасыз диңгез хайваннары классы. *Офиуралар нурлары ярдәмендә тәннәрен грунттан күтәреп хәрәкәт итәләр.* Биология

ОФИЦЕР *и. нем.* Хәрби хезмәттә командирлар составындагы зат. *Малайларда хәрби эшкә мәхәббәт шулкадәр: бик күбесе үзләрен киләчәктә бары тик офицер итеп кенә күз алдына китерәләр иде.* М.Мәһдиев. *Тәки сүзендә торды Нәфисәм: чыкты кияүгә! --- Авылга кунакка кайткан бер офицерга...* Ф.Яруллин

ОФИЦЕРЛА́РЧА *рәв.* **1.** Офицерлар кебек, офицерларга хас рәвешле. *Солтан ага, алар белән беренче очрашканда ук офицерларча пөхтә күренү өчен, өс-башын рәтләргә, чистарынырга, кырынырга дип китте.* С.Таһиров

2. *с. мәгъ.* Офицерларга хас; офицерларныкына охшаш. *Сиңа ерак-ерак далалардан офицерларча сәлам җибәрәм.* М.Мәһдиев

ОФИЦЕРЛЫК *и.* Офицер дәрәҗәсе, чины. *Командование аның оста, булдыклы сугышчы икәнлеген күрә һәм аны офицерлык дәрәҗәсенә күтәрә.* Г.Кутуй. *Суворов училищесын бетерүчеләр офицерлыкка укырга китә.* Ф.Яруллин

ОФИЦИАЛЬ *с.* Рәсми. *Официаль дидактика кагыйдәләреннән тайпылу элеккечә берничек тә рөхсәт ителмәгән.* Ә.Хуҗиәхмәтов. *Татарлар, официаль мәгълүмат күрсәткәнчә, 30% ка кимегән.* Р.Мөхәммәдиев

ОФИЦИАНТ *и. нем.* Ашханәдә, ресторанда заказны алып өстәлгә ашамлык китереп бирүче, түләүләрне алучы хезмәткәр. *Официант аңлады, графин тотып буфет янына юнәлде.* Ф.Шәфигуллин. *Официант тиз генә, боларның теләген үтәп, алларына бик хикмәтле итеп әзерләнгән окрошка китереп утыртkан.* Мәдәни җомга

ОФИЦИА́НТКА *и. рус* Хатын-кыз официант. *Авызларында яхшы папирос, официантка яннарында бөтерелеп йөри.* М.Мәһдиев. *Официантка өстәлгә салатлар, шешәләр китереп куйды, чәнечке-пычакларны шудыргалады, аннары аракы шешәсен ак салфеткага урап тотты да кечкенә рюмкага салырга үрелде.* М.Маликова

ОФЛАЙН *и. ингл.* **1.** Компьютер челтәрендә, шул исәптән Интернетта, операцияләр автоном, ягъни челтәргә тоташмыйча гына башкарыла торган эш режимы. *Офлайнда эшләү*

2. *с. мәгъ.* Шундый режимдагы. *Кайбер төшенчәләр онлайннан офлайн тормышка күчә*

ОФСЕТ *и. ингл.* **1.** Буяу цинк, алюминий басу формасыннан башта арадаш резина цилиндрга, аннан кәгазьгә күчерелүдән гыйбарәт кәгазьгә төшерү ысулы. *Ә ул нәшрият типографиясенең офсет цехында начальник булып эшли.* Ф.Яруллин. *Яңа офсет машинасында «Идел-Пресс» полиграфистлары Мәскәүдән килгән заказларны --- бастыруга кереште.* Мәгърифәт

2. *с. мәгъ.* Шундый ысул белән эшләнгән, шундый ысул белән басылган. *Офсет басма*

ОФТАЛЬМО́ЛОГ *и. гр. мед.* Күз авырулары табибы. *Бер танышым офтальмологка дүрт ай алдан язылып куйды.* Татарстан яшьләре. *Телевидениедән чыгыш ясаганнан соң, яшүсмергә Мемфистагы Гамильтон институты офтальмологы шалтыраткан һәм үзенең ярдәм итәргә әзер булуын белдергән.* Мәдәни җомга. *Бу операцияне офтальмолог ясый, һәм аның киңәшләренә колак салу кирәк.* Иң шәп календарь

ОФТАЛЬМОЛО́ГИЯ *и. гр. мед.* Медицинаның күз авыруларын һәм аларны дәвалауны өйрәнә торган тармагы. *Югары курсларда, медицинаның төп предметлары патология һәм терапия, фармакология һәм рецептура, хирургия һәм офтальмология белән танышканнан соң, фән буларак ул вакыттагы медицинадан Сеченовның күңеле кайта.* Атаклы галимнәр. *Илгизе әни сүзен җиргә салмаган, Казан медицина институтының офтальмология факультетына укырга кергән.* Мәдәни җомга

ОФТАНУ *ф.* Уфтану. *Офтаналар, баш чайкыйлар авылдашлар.* Р.Төхфәтуллин. *Офтансын, соклансын каласысаласы, Мактаулы юллардан барасы.* Г.Афзал. *«Юк, берәү дә күрмәгән», – ди ул [участковый] офтанып.* Сөембикә

Офтана башлау Офтанырга тотыну

Офтана төшү Бераз, җиңелчә офтану. *--- Ул, гадәтенчә офтана төшеп, әмма үзенә күрә бер горурлык белән: «Боларны әйтә алмыйм. Хәрби сер», – дип котылды.* Р.Мөхәммәдиев

Офтанып алу Бераз, җиңелчә офтану. *– Бирешәбез шу-ул, – дип офтаныp алды карт.* Р.Вәлиев. *Бер кырыйда Камил Кәримов офтанып алды: «Кирәк бит, ә! Атна буена борынгы нигез буйларын казыдым, югыйсә».* Мәдәни җомга

Офтанып кую Бер мәртәбә офтану. *Зыятдин карт кына, туктый алмыйча, вакыт-вакыт көрсенеп, офтанып куя.* Р.Вәлиев. *– Күзне генә саклап кала алмадылар, – дип офтанып куйды Айрат.* Р.Мөхәммәдиев

Офтанып тору Даими офтану; озак вакыт дәвамында офтану; офтану процессында булу. *Мөһаҗирләр берникадәр вакыт ык-мык килеп, офтанып тордылар ---.* М.Галәү

Офтанып яту *сөйл. к.* **офтанып тору**

ОФТАНУЛЫ *с.* Авыр, сагышлы; әрнүле; сагынулы

ОФФ-БИТ *и. ингл. муз.* Джаз ритмикасының төгәл метрик пульсациядән даими микротайпылуларга нигезләнгән төре

ОФШОР *и. ингл. икът.* Финанс-кредит операцияләре үткәргәндә, чит ил кәсәбәчеләренә ташламалар бирә торган халыкара эшмәкәрлек үзәге. *Офшор темасы*

ОФЫК *и. гар.* 1) Күкнең җир яки су өсте яссылыгы белән тоташкан сыман булып күренгән сызыгы; горизонт. *Офыкларга китә бормалы юл, Яшел үргә китә шат булып.* Г.Афзал. *Әнә анда, офыкта, ком бураны күтәрелеп килә. --- Икенче карыйсың, миллион тамчыларга әверелеп күккә күтәрелә дә, тирә-юньне балкытып, офыктан офыкка салават күпере күтәрелә.* Ф.Яруллин. *Офыклар киң, һава биек һәм суларга рәхәт иде.* В.Нуруллин

2) Күз күреме иңли алырлык мәйдан, ераклык. *Офыктан офыкка кадәр җәелеп, арыш кырлары чайкалып ята.* М.Хәсәнов

3) *күч.* Мөмкинлекләр, күзаллаулар даирәсе. *Әдәбият офыклары*

4) *күч.* Гомер азагы. *Безнең кояш төбәнгә тәгәри инде хәзер. Офыкка да ерак калмагандыр.* Р.Мөхәммәдиев

◊ **Офык артында** Ераkта, киләчәктә. *Яшьлек үз яшәешеннән беркайчан да канәгать түгел, анда, ераkта, серле тоелган офыклар артында, сине бәхет һәм сәгадәт көтеп зарыгадыр кебек.* А.Гыйләҗев. **Офык киңәю** Мөмкинлекләр арту. *Теләкләрем чиксез иде, Офыгым киңәймәде.* Б.Сөләйман.

Ерақларга барып карасаң, --- күз күреме белән күңел офыклары да киңәя. М.Маликова. *Аның фикеренчә, археология – тарихның офыгын киңәйтүче иң изге фән икән.* К.Тимбикова. **Офыклар ачылу** *к.* **офык киңәю**. *Югыйсә эш мәне белгән ир-егетләргә нинди офыклар ачыла хәзер.* Р.Мулланурова

ОХ *ы. к.* **ой**. – *Ох, – диде карчык, куркынып, искәрмәстән кулыннан сумкасын алгач.* М.Хәбибуллин. *Рузинә: Ох, әйтте дә соң. «Просто Мария»дәгечә, «Санта Барбара»дагыча булды!* Р.Мөхсинова

О́ХРА *и. гр.* Сары төснең төрле төсмерләрендәге табигый минераль буяу. *Буяу охрадан һәм суриктан, сыек каймак куелыгында булганчы, олифа өстәп ясала.* Файдалы киңәшләр. *--- диварларны буяу өчен әзерләнгән ак төскә бераз терракота, я булмаса охра пигментын кушарга киңәш ителә.* Кәеф ничек?

О́ХРАЛАУ *ф.* Охра белән буяу

О́ХРАЛЫ *с.* Составында охра булган. *Охралы балчык*

ОХРА́НКА *и. рус сөйл.* 1) 1917 елга кадәр Россиядә Эчке эшләр министрлыгының сәяси җинаятьләргә каршы көрәшү, җәмәгать тәртибен саклау белән шөгыльләнгән бүлеге. *Патша охранкасы булса да курыкмыйм.* Р.Ишморат. *Кем белә, бәлки, ул Исхак атлы кеше охранкадан җибәрелгәндер ---.* А.Расих. *С.Аитовның мондый эшчәнлеге, табигый, охранканы сагайткан.* И.Нуруллин

2) Шул оешма урнашкан бина. *Охранкага алып китү*

ОХШАТУ I *ф.* 1) Бер нәрсәне яки кемне икенчесе белән чагыштырып, уртаклык, охшашлыклар табу. *Аны инде хәзер беркем дә өрсәң очып китәргә торган Тузганак Төшенә охшатырга батырчылык итмәс иде.* Ә.Дусайлы

2) Кем яки нәрсәгә охшаш дип санау. *Шуңа күрә кайберәүләрне инде тышкы кыяфәтләре буенча гына да ирләргә охшатырга була.* Безнең гәҗит

3) Кем яки нәрсәгә охшаш итү. *Үзең иҗат иткән якты, матур образларны кемгә дә булса охшатырга тырышасыңмы син?* Шәһри Казан

Охшата башлау Охшатырга тотыну

Охшата төшү Бераз охшату. *Беренченең чәчен кырдырып алдырганлыгы да аны Дучега охшата төшә иде кебек.* Р.Мирхәйдәров

Охшатып кую Кинәт охшату. *Кинәт кенә аны шул җырдагы умырзаяга охшатып куйдым.* Н.Гыйматдинова. *Кызыл кепкадан йөргән Дамирны иректән чебен гөмбәсенә охшатып куйдым.* Р.Низамиев

ОХШАТУ II *и.* Чагыштыру (әдәби әсәрләрдә сурәтләү чарасы). *Шагыйрьләрне йолдызга охшату Тукайның үзеннән үк килә.* Фән һәм тел

ОХША́У *ф.* 1) Берәр кемгә яки нәрсәгә охшаган булу. *Бүген ай әбекәйнең чулпысындагы биш тәңкәлек көмеш акчага охшаган ---.* Ф.Яруллин. *Әгәр холкы-табигате белән дә әнисенә охшаса?* М.Маликова

2) Юнәлеш килешендәге исемнәр, исем фигыльләр янында «кебек» мәгънәсендә кулланыла. *Гомумән, сез бик акыллы кызга охшагансыз.* Ф.Яруллин. *Бу ничектер сорау алуга охшаган иде ---.* Х.Ибраһим

3) Инфинитив формасындагы билгесез үткән заман хикәя фигыльләр янында чамалап нәтиҗә ясауны белдерә: бугай, ахрысы. *Сүз авыр, хәбәр күңелсез булырга охшаса да, Чырыкны тыңламыйча ярамый.* Я.Зәнкиев. *Көн кояшлы, аяз һәм искиткеч матур булырга охшаган бүген.* Р.Мөхәммәдиев

Охшап бетү Бик охшашка әйләнү. *Бүтән гөмбәдәй эшләпә дә кимәгән, әле үз агай-энеләренә дә охшап бетмәгән.* К.Тәхау. *Гомер буе өй – кибет – эш, өй – кибет – эш арасында йөгереп йөреп, шул тегермән атына охшап беткәнмен, ахры.* Р.Вәлиев

Охшап калу Ахырда нәрсәгәдер охшаган хәлгә килү, охшаш күренү. *Ак болыт артында югалып торганда, көшел өсте сөрмә белән бизәлгән көмеш тавына охшап кала ---.* Ф.Шәфигуллин. *Шагыйрь такыр басу кебек Шып-шыр бушап кала, Өстәлендә торган агач Сынга охшап кала.* М.Әгъләмов. *Шуңа күрә сәке йөзлегендә балта очының эзләре дага кадагына охшап калды.* М.Хуҗин

Охшап китү Соңгы арада яки кыска гына вакытка охшау. *[Уразаев] башта аны-моны уйламыйча гына юныштыра башлый, юна-юна, агачы я кеше башына, я берәр хайванга охшап китә.* Я.Зәнкиев. *Кай ягы беләндер минем Сәкинәгә дә охшап китә шикелле иде ул.* В.Нуруллин. *Диңгез өсте кәефе бозылган кеше битенә охшап китә: җыерчыклана, кырыслана, чырае сытыла.* М.Юныс

Охшап кую Көтмәгәндә нәрсәгә яки кемгәдер охшау. *Кайчак җилне кылыч белән кискән донкихотка охшап куясың.* С.Сөләйманова. *Охшап куя икән бүреләргә Туган белән кайчак туган да.* Г.Садә. *Озак тыңлап утырсаң, буран улавы гажәп тә моңлы, гажәп тә сагышлы көйгә охшап куя.* Р.Вәлиев

Охшап тору Даими яки хәзерге вакытта охшаган булу. *Тыгыз тәнлегә охшап торасың!* Р.Батулла. *Учак уты яктысында ул үзенең җыерчыклы йөзләре белән әллә нинди серле, әкияти затка охшап тора.* Г.Гыйльманов

Охшый башлау Охшашлык сизем-ләнү. *Дини яктан карасаң, кыямәт алдыннан хатыннар ир-атларга охшый башлар, диелә.* Безнең гәҗит

Охшый төшү Бераз охшау. *Гәүдәсе тупасрак, аяк-куллары да аю тәпиләренә охшый төшә иделәр.* Ш.Камал

ОХШАУЛЫ *с.* Охшаш. *Ул Гарифның күзенә карамый, барлык дикъкате белән җәрәхәткә су тигезмәскә тырыша, гөл чәчәгенә охшаулы иреннәре беленер-беленмәс кенә тетри...* Ш.Камал

ОХШАШ *с.* 1) Тышкы кыяфәт, холык, хәрәкәт, зурлык, төс, күләм һ.б. яклардан кем яки нәрсә белән якынлыгы булган; кемне яки нәрсәне хәтерләткән. *Сары йөзле көзнең төннәренә Охшаш минем нурсыз көннәрем дә.* Ә.Синугыл-Куганаклы. *Игезәкләр кебек бер-берсенә охшаш көннәр үтә торды.* Р.Вәлиев. *Дүшәмбе көнне исә шуңа охшаш фажига Мисырда килеп чыкты.* Ватаным Татарстан

2) *мат.* Формалары белән тиңдәш, ләкин зурлыклары төрле булган. *Охшаш күппочмаклыклар*

ОХШАШЛАНДЫРУ *ф.* Охшаш итү. *Бер тартык аваз үзеннән алда*

килгән тартык авазны охшашландырса, регрессив ассимиляция була. Ә.Әфләтунов

Охшашландыра башлау Охшашландырырга тотыну

Охшашландыра төшү Бераз охшашландыру

Охшашландырып бетерү Тәмам, тулысынча охшашландыру

Охшашландырып җибәрү Охшашландыру төсмерләре бирү

Охшашландырып кую Кинәт охшашландыру

ОХШАШЛАНУ I *ф.* Охшаш булып китү, охшаш сыйфатлары барлыкка килү

Охшашлана бару Торган саен күбрәк, ныграк охшашлану

Охшашлана башлау Охшашлык барлыкка килү

Охшашланып калу Нәрсәдер тәэсирендә охшашлык барлыкка килү

Охшашланып килү Соңгы арада охшашлану билгеләре күренү

Охшашланып тору Даими яки сөйләү моментында охшашлану

ОХШАШЛАНУ II *и.* 1) Нәрсә белән дә булса охшашка әйләнү, бердәй диярлек үзлекләр алу күренеше. *Тау марилары һәм чувашлар арасындагы борынгы бәйләнешләр тау мариларының шактый өлешенең чувашларга охшашлануына китерә.* Б.Хәмидуллин

2) *лингв.* Авазларның әйтелеш һәм яңгыраш ягыннан охшашу күренеше; ассимиляция. *Тартыклар ассимиляциясенең тагын ике төрен аерып карарга кирәк: ясалу урыны буенча охшашлану һәм акустик охшашлану.* Татар грамматикасы. *Мондый охшашлануның тагы бер төре бар, ул – юклык һәм сорау кушымчасындагы [м] тартыгының [б]/[п] тартыгына алмашынуы.* Д.Рамазанова

ОХШАШЛЫ *с.* Охшаш. *[Скатта] камчыга охшашлы озын, электр тогы җибәрә торган койрык.* М.Юныс. *Ул да булмады, малай машинасын ташлап, әллә каян гына пистолетка охшашлы бер нәмәстәкәй тартып чыгарды.* Х.Ибраһим. *Әмма моңа охшашлы хәлләр әле күптән түгел генә күзәтелде.* Кызыклар дөньясында

ОХШАШЛЫК *и.* Ниндидер сыйфатларның, билгеләрнең тышкы күренеш яки башка яктан якынлыгы; тиңдәшлек, бердәйлек. *Җентекләбрәк карасаң, араларында охшашлык та бар кебек үзе ---.* М.Маликова. *Кәбир бит сукыр түгел, бу охшашлыкны бер күрәчәк.* Ф.Яруллин. *Имеш, төскыяфәтең охшашлыгыннан файдаланып, бер йолкыш синең тәхеткә менеп утырган.* Р.Зәйдулла

ОХШАШСЫЗЛАНУ I *ф.* Охшашсыз булып китү, охшашлыгын югалту

Охшашсызлана бару Торган саен күбрәк охшашсызлану

Охшашсызлана башлау Охшашсызлануга табан үзгәрү

Охшашсызланып калу Ниндидер тәэсирдән соң охшашсызлану

Охшашсызланып килү *к.* **охшашсызлана башлау**

ОХШАШСЫЗЛАНУ II *и. лингв.* Ике бертөрле яки охшаш авазларның берсен охшаш булмаган икенче аваз белән алыштыру күренеше; диссимиляция. *Диссимиляция, яки охшашсызлану – азрак таралган күренеш.* Татар грамматикасы

ОХШАШУ I *ф.* Бер-берсенә охшау; охшаш булу. *– Кызым, без икебез дә бер-беребезгә нык охшашканбыз, – дип котылды Фирая.* Д.Бүләков. *Абый белән сеңел диярсең, бер-берсенә ничек шулхәтле охшашкан болар?* Р.Габделхакова

Охшаша бару Торган саен күбрәк охшашу

Охшаша башлау Охшашлык арту

Охшашып бетү Тәмам охшашу, бик охшаш була башлау. *Әле карап-карап торам да, кызларның нәкъ әниләре төсле үк охшашып беткәннәренә шаккатам.* Ватаным Татарстан

ОХШАШУ II *и.* 1) Бер-беренә охшау күренеше

2) *лингв. к.* **охшашлану** (*2 мәгъ.*)

Оһ *ы. к.* **ой**. *Ат мине көтә икән. – Оһ-һы-һы, – дип дәшеп үк куйды.* М.Мәһдиев. *Оһ, зирәк икәнсең син, Җолдас ага...* Р.Мирхәйдәров. *Хәзер авылда кеше күзенә күренеп йөрер чамам калмады! Нәләт миңа, нәләт, ләгънәт!.. Оһ!..* С.Поварисов

ОһО *ы.* Гаҗәпләнүне, соклануны белдерә. *– Юк, юк, акча бездә бер букча! – Оһо!* Ф.Садриев. *Оһо, агайэне, син безнең братны гомумән шәп беләсең икән бит!* Ш.Маннап. *Оһо, буш урын калмаган.* М.Юныс

ОһО-һО *ы.* Ачулану, аруны, гаҗәпләнүне белдерә. *Бетле бандитлар! Оһо-һо... Уһ-һу-ну... Башыгыз бетсен!* М.Мәһдиев. *[Зәһидә:] Оһо-һо-һо, Мутин?* Р.Батулла

ОЧ *и.* **1.** 1) Нәрсәнең дә булса очлаеп торган яки очлаеп, нечкәреп беткән өлеше. *Борын очы*

2) Сузынкы, озынча әйберләрнең бетем чиге, шул чик тирәсендәге өлеше. *Ул, буш җиңенең очын сыңар кулына алып, күзләрен сөрткәндәй итте.* Р.Мулланурова. *Аяк бармакларында бик күп нерв очлары тупланган.* Мәдәни җомга

3) Нәрсәнең дә булса үзәктән ераклашкан ягы, чиге. *Бүә очына таба өйләр елганың икенче ягына да чыкканнар.* Н.Фәттах. *Кайсыдыр утлы ук җибәрде, корабның койрык очына ут капты.* М.Хәбибуллин. *Баягынак Мәһинурттәй түбән очтан менеп килә, алъяпкычына төреп нидер күтәргән.* Р.Мулланурова

4) Бит уртасы. *Бит очларыннан башланган кызыллык колакларына кадәр барып җитте.* Ф.Яруллин. *Канат очлары Зарифәнең бит очларын тырнап ала, күзләрен әллә нинди аклык кисә.* Р.Мулланурова

5) Очлык, башак. *Сөяктән ук очлары, сөңге очлары әмәлли беләләр, аларны чәер яки җилем белән таякка ябыштыра алалар.* Т.Нәбиуллин

6) Төреп куелган тукыма кисәге. *Җиһангирны озатып калган очтан кисеп алынган комач бит!* А.Гыйләҗев

7) *күч.* Нәрсәнең дә булса башы, башлангычы; асылы, нигезе. *Татар милли культура тармакларының зур бер өлешенең очы Каюм Насыйригa барып тоташа, икенче зур өлешенең очы, һичшиксез, Г.Камалга барып тоташа.* М.Гали

8) *күч.* Нәрсәнең дә булса ахыры, бетеме. *Хат очы*

2. *с. мәгъ.* Очта урнашкан. *Оч бөредән – төп сабак, ә ян бөреләрдән ян*

сабаклар үсеп чыга. Ботаника. *Бәбәк очында гадәттә оч бөре --- була.* Биология

◊ **Очы-башы булмау** 1) Берни билгеле булмау; 2) Буталчык хәлдә булу. **Очы-башы күренмәү** *к.* **очы-башы булмау**. **Очы булмау** 1) Озакка сузылган эш-хәл турында; 2) Берәр төрле эш-хәлдә ачыклык булмау. **Очы күренмәү** *к.* **очы булмау**. *Айлар чаклы озын булды бу көн, һәм ул озын – очы күренми ---.* Ф.Кәрим. **Очы-кырые күренмәү** Ахыры күренмәгән булу; чикләнмәгән булу. *Туксанышар битлек өч дәфтәрне тутырдым инде, тик әлегә очы-кырые күренми.* Ф.Яруллин. *Карьераның, фәнни очышның очы-кырые юк.* Ватаным Татарстан. **Очы-кырые юк** Бик күп. *Ул максатка тотылган чыгымнарның очы-кырые юк.* Кызыклар дөньясында. **Очына чыгарлык түгел** 1) *к.* **очы-кырые юк**. *Саный китсәң, очына чыгарлык түгел, Ул кылдырткан күп эштән бизә күңел.* Ә.Синугыл-Куганаклы; 2) Буталган, ачыклавы бик кыен булган. **Очына чыгу** 1) Берәр эшне ачыклау, хәл итү, чараларын күрү. *Бу дөньяда өч каен, Очына кеше чыгалмас, Ансыз кеше торалмас.* Табышмак. *[Зитта] бер фикеренең дә очына чыга алмады.* Х.Камалов; 2) Аныкбер карарга килү. *Чөнки күңелдә яңыраган хатирәләр шул тикле күп, шул тикле каршылыклы һәм буталчык: очына чыгу мөмкин түгел иде...* В.Нуруллин. **Очын очка туры китерү** *к.* **очын очка ялгау**. **Очын очка ялгау** 1) Матди яктан иркен яшәмәү турында. *Имтиханнарга әзерләндем, нужа куучыларга кушылып, баржа бушаттым, көнлек ихтыяҗларымның очын очка ялгап барырлык акча эшләдем.* Б.Камалов. *Очын очка ялгап барабыз бит әле тормышның.* Р.Мулланурова. *Болай да очын очка ялгап барган авыл хуҗалыгының киләчәген күз алдына китерергә авыр.* Мәдәни җомга; 2) Тиешле хәлгә, тәртипкә китерү; 3) Логик яктан берберсенә бәйләнгән, төзек булу турында. *Ул яктан бездә очы очка ялганмаган нәрсәләр күп булды.* Х.Камалов. **Очын табу** Берәр мәсьәләнең чишелешен табу. *Ул кара сукмакның очын тапкандай булдым...* Б.Камалов. *Ни уйласа да уйларының очы юк, көчәнеп-көчәнеп очын тапса, уйлары барыбер караңгы килеш яшәгән җире сыман дымлы-сөремле килеш кала.* Я.Зәнкиев. **Очын югалту** Төп асылдан читләшү, оныту. *Бер-беребезне бүлдерәбез, сораулар яудырабыз, аннары сүзебезнең очын югалтып, сәбәпсез-нисез, тирә-юньне яңгыратып көлергә тотынабыз.* З.Фәтхетдинов. *Өченчеләре, үзләре тарих комына күмелеп калмасалар да, исемнәрен җуйганнар, нәсел-нәсәпләре очын югалтканнар.* М.Мәхмүтов. **Очын суга яшерү** 1) Берәр начар, яшерен эшне, җинаятьне һ.б.ш.ны ачыкларга мөмкинлек бирә торган билгеләрне юкка чыгару; 2) Сүзне ачык итеп әйтеп бетермәү. **Очын яшерү** *к.* **очын суга яшерү**. **Очы очка ялгану** Дөрес булу, туры килү. *Без инженерлар, әгәр берәр нәрсәнең очы очка ялганмый икән, катка тикшереп, сәбәбен ачыкларга тырышабыз.* М.Маликова. *Кыз сөйләгәннәрнең очы очка ялганмый кебек.* З.Садыйков. **Очы-чиге булмау** 1) Чиксез күп, күләмле, озын булу турында; 2) Хисләрнең көчле булуы турында. **Очы-чиге күренмәү** *к.* **очы-чиге булмау**. **Очы (килеп) чыгу** Берәр төрле эш-хәлнең ачыклануы, нинди дә булса нәтиҗә белән тәмамлануы турында

ОЧА *и. анат.* Арка ягында билдән түбәнге урын, бот төпләре; арт сан (хайваннарда). *Оча урынындагы ике кечкенә сөяккә карап, китсыманнарның бабаларында арткы очлыклар булган, дигән фикергә килә алабыз.* Биология. *Күкәйлекләр, аналык көпшәсе, аналык һәм аналык җиңсәсе оча куышлыгында урнашып, хатын-кыз җенес системасын тәшкил итәләр.* Биология: кеше һәм аның сәламәтлеге

ОЧА́ БАШЫ *и. анат.* Умыртка сөягенең тоташып үскән биш умырткадан гыйбарәт һәм оча сөягенә тоташкан (койрык) өлеше

ОЧА-БОТ *и.* Оча һәм бот. *Сөякләрнең хәрәкәтчел тоташуын буыннар дип атыйлар, мәсәлән, оча-бот, тез, терсәк буыннары.* Биология: кеше һәм аның сәламәтлеге

ОЧА́-КУНА *рәв.* 1) Бик җитез, җиңел хәрәкәтләнеп. *Оча-куна кайт кунакка Күчмә кошлар белән яз булып [яшьлек].* Ә.Синугыл-Куганаклы

2) Шатланып, ашкынып. *Оча-куна җырлады моңга сусаган сары сандугачыбыз.* Т.Нәҗмиев

ОЧАЛЫК *и.* Атның оча сөяге өстенә туры килә торган тоташтыргыч эшлия каешы

ОЧАН *и.* Балалардагы эч кибү авыруы

ОЧАНАК *с.* Бик тиз ярсып, кызып китә торган. *Арсланның үз акылы үзе белән. Сәгыйдә кебек очанак түгел ул, сүзен үлчәп кенә сөйли.* Г.Ахунов

ОЧАР *с.* Оча торган. *Көзләрен очар кошлар җылы якларга юнәлә.* Б.Камалов. *Очар кошны гел читлектә асрасаң, ул үзенең читлеген сагына, иреккә җибәрсәң кире кайта, диләр, дөрестер, мөгаен.* Ф.Яруллин

◊ **Очар кош** Эш яисә яшәү урынын еш алыштырырга, урыннан-урынга күченеп йөрергә ярата торган кеше; очкалак

ОЧА́ СӨЯГЕ *и. анат.* Скелетның түбәнге (хайваннарда – арткы) очлыкларга тоташкан һәм умыртка сөягенә терәк булып торган өлеше. *Гәүдәне кыймылдатып булмый, бил туры, оча сөякләре чимә-чи булып беткәннәр.* Х.Камалов. *– Алар – авыртуны җиңеләйтә торган ноктала р, – дип, оча сөягенең алгы ягындагы ике урынны күрсәтте акушерка.* Г.Галиева

ОЧА́ ТОРГАН БАЛЫК *и. зоол.* Саргансыманнар отрядыннан судан ерак арага сикереп чыгып хәрәкәтләнә торган балык. *Оча торган балыклар судан атылып чыгалар да бер минут чамасы су өстеннән очып баралар.* М.Юныс. *Оча торган балыклар да шулай ук су өстеннән йөзләрчә метр юл үтәргә мөмкиннәр.* Кызыклар дөньясында. *Оча торган балыкларны күпләрнең ишеткәне бардыр.* Кызыклы ихтиология

ОЧА́ ТОРГАН ТӘЛИНКӘ *и.* Фаразлар буенча икенче планетадан килгән затларның космик корабле. *Оча торган тәлинкә белән килгән адәми зат булса да, кызлар кызлар булып кала.* Ф.Яруллин

О́ЧЕРК *и. рус* 1) Реаль тормыш вакыйгаларын үзгәртмичә сурәтли торган кечкенә күләмле әдәби әсәр. *Син, начальник иптәш, газетлар актара тор, югыйсә вакытың калмыйдыр очерклар укырга.* М.Хуҗин. *Синең дә Берлин турындагы бер очергыңны укыйсы килә.* Г.Әпсәләмов. *Ни өчен мин – очерк авторы – очергымның артык нөсхәсен аңа җибәрү өчен, кемнән булса да рөхсәт алырга тиешмен?* А.Яхин

2) **очерклар** *күпл.* Үзара бәйләнешле берничә мәсьәләгә караган тикшеренүләрне эченә алган махсус фәнни хезмәт. *Тел белеменнән очерклар*

ОЧЕРКИ́СТ *и. рус* Очерк язучы. *Хәзер шушы маршрут буйлап очеркист килә.* Г.Ахунов

ОЧЕРКИ́СТИКА *и. рус* Билгеле бер язучы иҗатында яисә аерым бер чордагы очерклар

О́ЧЕРКЛЫК *и.* Очерк билгеләре, очеркка хас стиль һәм жанр үзенчәлекләре булу. *Моның нәтиҗәсе буларак, күп кенә әсәрләрдә очерклык һәм эскизлык шактый сизелде.* Ф.Мусин

О́ЧЕРК-ХИКӘ́Я *и.* Вакыйгаларны чынбарлыктагыча сурәтләгән хикәя. *«Мишәрләр тормышыннан бер ләүхә» очерк-хикәясендә автор үзе бала чакларында күргән бер фажигале вакыйганы тасвирлый.* М.Мәһдиев

О́ЧЕРКЧЫ *и.* Очерк язучы. *Теманы төпле өйрәнер, иркенләп иҗат итәр өчен, очеркчыга районда, төбәктә атна-ун көн яшәргә мөмкинлек бирелде.* И.Низамов

ОЧКАК *с.* **1.** Йомшак һәм үтә жиңел. *Очкак кар*

2. *и. мәгъ.* Җимеш тирәлегендә җепсел үсентеләре булган яки ике орлыклы, җил белән жиңел тарала торган җимеш; *русчасы:* **летучка**

ОЧКАЛАК *с.* **1.** 1) *к.* **очар кош**

2) Жиңел; йомшак. *Бу сүзләрдән кыз йөрәгендәге авырлык җуелды, җилкәсендәге сулы чиләкләре очкалак мамыктай калып жиңеләйде.* М.Хуҗин

3) Тиктормас, шаян холыклы. *Гәүдәң генә түгел, жаның да очкалак синең.* М.Хуҗин. *Очкалак кыз*

2. *и. мәгъ. бот. к.* **очак**. *Күп кенә оешмачәчәклеләр орлыгының очкалагы – җимешләрнең җил белән таралуы өчен җайланмасы була.* Биология

ОЧКАЛАКЛЫ *с. бот.* Очып тарала торган. *Очкалаклы орлык*

ОЧКАЛАКЛЫК *и.* Очкалак булу сыйфаты

ОЧКАЛА́К ТИЕН *и. зоол.* Кимерүчеләр отрядыннан кечкенә колаклы, тиенгә охшаш, йомшак кына соргылт мехлы, зур күзле, агачтан агачка сикерү өчен җайлашкан алгы, арткы очлыклары һәм койрыгы арасында йон белән капланган ярылы кечерәк җәнлек. *Очкалак тиен яшәү рәвеше белән чын тиеннәрне хәтерләтә.* Татарстанның үсемлекләр һәм хайваннар дөньясы

ОЧКО *и. рус* 1) Спорт ярышларында куела торган бәяләрне исәпләү берәмлеге; кайбер ярыш-бәйгеләрдә отыш күрсәткече. *Сергей ун уенда нибары ике очко җыйды.* Мәдәни жомга. *Шул рәвешле Алексей НХЛ хоккейчылары арасында очколар буенча беренче урында.* Ватаным Татарстан

2) *сөйл.* Комарлы карта уены төре

◊ **Очко бирү** Берәр эшне башкалардан оста башкару турында

ОЧКЫЛЫК *и.* Күкрәк пәрдәсенең кинәт кысылуы сәбәпле, иректән тын алу хәрәкәте; шундый хәрәкәт вакытында бугаздан кысылып чыккан өзек-өзек тавыш. *Ул миңа ниндидер очкылык вирусы йоктырды.* Т.Гыйззәт. *Кешене куркытканда да, очкылык туктап кала.* Юлдаш

ОЧКЫЛЫ́К ТОТУ *ф.* Күкрәк пәрдәсе кинәт кысылганда, бугаз кысылу сәбәпле, өзек-өзек тавышлар чыгару. *Куркынган карашын Мөхәммәткә төбәгән килеш, аны [Йомабикәне] очкылык тота башлады.* Я.Зәнкиев. *Очкылык тотуны хәтерләткән тавыш кызны туктарга һәм сак кына кире төшәргә мәҗбүр итте.* Л.Ихсанова. *Очкылык тотып интеккәндер мескен.* Э.Касыймов

ОЧКЫЛЫ́К ҮЛӘНЕ *и. бот. к.* **кәҗә чәчәге**

ОЧКЫН *и.* 1) Янып торган яки бик кызган нәрсәнең очып, таралып киткән вак кисәкчеге; чаткы. *Борынга көек исе килеп керде. Ленарның яңа бишмәт итәгенә очкын кунаклаган, тишеп тә өлгергән.* Н.Хәсәнов. *Очкынга җәеп кочакны Сүндереп кара учакны.* Ә.Синугыл-Куганаклы. *Очкын алып шәмнән учак тергез: Кайнарлыгың белән юандыр!* Г.Садә

2) Таш, тимер кебек нәрсәләр бәрелгәндә, ышкылганда чыга торган ут кисәкчеге. *Станокта корыч кырам, Очкыннар җем-җем итә.* З.Мансур

3) Нәрсәнең дә булса жемелдәп ялтырап торган кисәкчеге. *Күз алдымда зәңгәрле-яшелле очкыннар чәчелде.* Ә.Айдар

4) *күч.* Берәр нәрсәнең (иҗади эш, сәләт) яралгысы, барлыкка килү билгесе. *Шулайдыр, ләкин күңелдә Очкын кабынып китте.* Н.Сафина. *--- Җәмилә Закировнаның күңелендәге очкын көйдереп торган нокта янә сызлый башлады.* М.Маликова. *Очкын чәчте шатлык йөрәгемнән ---.* Г.Афзал

5) *күч.* Берәр нәрсәнең чагылышы, тәэсире. *Эзләмичә генә бәхет табылмый ул, Очкын булмаса, ялкыннар кабынмый ул ---.* Г.Мөхәммәтшин // Хис белдерү билгесе (күзләр тур.). *Ямьяшел күзләрендә очкыннар чәчрәтеп, хатын көлә.* Р.Мулланурова

6) *күч.* Дәртле, ашкынучан, үткен, елдам кеше. *Кыз түгел – очкын.* Д.Аппакова

◊ **Очкын очу** Бик тиз, ялкынланып эшләү турында. *Әйтерсең аның бармак очларыннан очкын оча.* Г.Нурлы. **Очкын чәчү** 1) Бик нык шатлану. *Бу хакта аларның очкын чәчеп торган күзләре сөйли иде.* Сабантуй; 2) Житез хәрәкәтләнү

ОЧКЫНЛАНУ *ф.* 1) Очкыннар (*1 мәгъ.*) чыгару, очкын барлыкка китерү

2) Очкын (*3 мәгъ.*) сыман жемелдәү. *Шәһәрдә кар пычрак, ә монда ап-ак, очкынланып, җем-җем итеп ята.* Татар виртуаль гимназиясе

3) *күч.* Көчле, интенсив чагылыш табу; сиземләнү. *Аерым-аерым шигырьләрдә очкынланган шигъри җөмләләре белән бик күп яшь көчләр кинәт үзләренә дикъкатьне алдылар.* Һ.Такташ

4) *күч.* Хисләр белдереп жемелдәү (күзләр тур.). *«Мина»лар кармагына эләккән элемтәченең йөзе кәгазь кебек агарган, күзләре ярдәм сорап*

очкынланалар иде. Х.Камалов. *Ә Гөлфирәнең күзләре очкынланган.* Р.Мулланурова. *Кеше чәчен кистергәч, начар энергиядән котыла, баш җиңеләя, күзләр очкынлана.* Ватаным Татарстан

Очкынлана башлау Очкынланырга тотыну. *Соңыннан политик оппозиция дәрәҗәсенә күтәреләсе «туры Тукайлык» шәхес күңелендә кайчан очкынлана башлый?* З.Мансуров

Очкынлана бару Торган саен күбрәк очкынлану. *Ларисаның исә күзләре торган саен киңрәк ачыла, очкынлана барды, ул иркенәеп, табынны үзенчә көйләргә кереште.* М.Маликова

Очкынлана төшү Бераз очкынлану

Очкынланып алу Бик кыска вакытка очкынлану

Очкынланып китү Көтмәгәндә, кинәт очкынлану. *Йосыф абыйның күзләре тагын очкынланып китте.* В.Нуруллин. *Каһирның күзе очкынланып китте.* Ә.Гаффар

Очкынланып кую Кинәт кыска вакытка очкынлану. *Алар килгәч, биредә тәрбияләнүчеләрнең күзләре шатлыктан очкынланып куйды инде.* Авыл офыклары

Очкынланып тору Билгеле бер вакыт дәвамында очкынлану. *Яка кыекларындагы петлицаларда – очкынланып торган ромблар.* И.Салахов

ОЧКЫНЛА́У *ф. сир. к.* **очкынлану**. *Әгәр дә учак очкынлап янса, күңелсез хәлләргә юлыгырсың.* Мәдәни җомга

ОЧКЫНЛЫ *с.* 1) Очкын чәчеп торган

2) *мах.* Очкыннар чыгарып эшли, хәрәкәткә килә торган

3) *күч.* Берәр төрле хис белдерә торган. *[Малайның] --- күзе очкынлы... Усалга охшый!* Ф.Кәрим. *Син – очкынлы күз, Сиңа сокланып Җилкенәбез без.* Г.Афзал

ОЧКЫ́НСҮНДЕРГЕЧ *и. махс.* Паровоз, локомобиль, вагранкаларның төтен торбаларында очкын чәчрәп чыгуны тоткарлау өчен махсус прибор

ОЧКЫР *с. диал.* Яхшы, җитез очучан. *Торымтай очкыр кош булмас, тургай ташлап каз алмас.* Мәкаль

ОЧКЫЧ *и.* Оча торган транспорт; самолёт. *Барыбер кайда да булса бер очкычтан икенчесенә күчеп утырырга кирәк иде.* М.Маликова. *Бишкәккә Мәскәүдән очасы очкычыбыз биш сәгатькә тоткарланды.* Мәдәни җомга

ОЧЛАГЫЧ *и.* Карандашны очлау өчен махсус әсбап. *Анда [портфельдә] линейка, ручка, карандаш, фломастер, --- карандаш очлагыч, бетергеч, дәфтәрләр, аларга тышлар – кыскасы, барысы да бар.* Мәгърифәт

ОЧЛАЙТУ *ф.* 1) Очлы итү, очлы формага китерү

2) Иреннәрне алга таба чыгару. *[Ө] ([көзгө] дигәндәге) авазын әйткәндә, телнең уртасы хәрәкәтләнер һәм ирен очлайтып әйтелер.* Фән һәм тел

Очлайта башлау Очлайтырга тотыну

Очлайтып тору Даими яки билгеле бер вакыт дәвамында очлайту. *Әхнәф иренен очлайтып торды, апасының отыры сабырсызлана баруын күреп, ипләп кенә, ерактан уратып сөйли башлады ---.* Г.Ахунов

ОЧЛАМ *и.* 1) Нинди дә булса әсәрнең соңгы, йомгак өлеше. *Көйләр дә нигездә – чеп-чи халтура, аннан-моннан йолкыштырылган умырыкларны корыштырып теркәлгән, япон тактасы банкындагы әзер протез башлам һәм очламнар белән ялганып тәпәләнгән нәмәрсәкәйләр...* Татарстан яшьләре. *Әкиятнең очламы*

2) *тар.* Хәрбиләрнең сугышканда бәрелүдән, ук тиюдән саклый торган очлы түбәле металл баш киеме. *Тәнне саклау өчен тимер түбәтәй, очлам (шлем) төрләре – кирәгә, тулка, алпак һәм тимер боҗралардан яисә калайлардан торган көбә күлмәк кулланылган.* Р.Әхмәтьянов

3) *махс.* Биналарның түбәсендә өскә таба бик нык очлаеп торган конус яки пирамидасыман корылма, манара очы; *русчасы:* **шпиль**. *Манара җиде буынлы иде, әмма каланы тупка тотканда очламы белән өстәге ике каты җимерелгән булу сәбәпле, астан бишенче каты исән иде.* Р.Батулла

ОЧЛАНДЫРУ *ф. к.* **очлайту**. *[Козгыннар] йоннарын кабартып, канатларын селтәп, борыннарын очландырып, бер-берсенә һөҗүм итәләр.* Кызыклар дөньясында

Очландыра төшү Бераз очландыру

Очландырып җибәрү 1) Кинәт очландыру; бик, артык очлы итү

Очландырып кую Алдан яки тиз арада очландыру

ОЧЛАНУ *ф.* 1) *төш. юн. к.* **очлау** (*1 мәгъ.*)

2) *к.* **очлаю**. *Яр буенда бик тирән булмаган урында, ягъни сайлыкта, дулкын сыртлары күтәрелә һәм очлана.* Башлангыч география курсы

3) Бер-бер артлы җигелү. *Бикмөхәммәт, Заһир дигән малайларның, бәләкәй чанага очланып, мине урам буйлап йөртүләрен әле дә булса уйлап көләм.* М.Гафури

4) *күч.* Тәмамлану. *Зур юл шулай тар сукмак белән очлана инде.* Ә.Гаффар. *Комсомол райкомында сүз шулай очланды ---.* Б.Камалов. *Һай, алдан ук белгән булса соң тиле белән булышуның азагы ничек очланганын!* Н.Гыйматдинова

Очлана бару Торган саен ныграк очлану; даими очлану. *Ул, еллар үткән саен, ныграк очлана барсын, аның күзеннән читтә калган проблемалар булмасын, дигән фикер дә яңгырады.* Сарман

Очлана башлау Очланырга тотыну

Очлана төшү Бераз очлану

Очланып бетү Тулысынча очлану. *--- Мин сөйләячәк вакыйгаларның очланып бетмәгәннәре дә бар.* Ф.Яруллин

Очланып җитү Тиешле дәрәҗәдә очлану

Очланып калу Ниндидер тәэсирдән соң очлану һәм шундый торышны саклау. *Аның йөзеннән кан качты; борыны очланып калды.* И.Гази

Очланып килү Эзлекле рәвештә очлану. *Өй түбәсенә мендем дә, аның иң очланып килгән җиренә басып, кулларым белән морҗага ябышып тора башладым.* Ф.Әмирхан. *Болар [балыклар] зур түгел, барлыгы ун сантиметр чамасы озынлыкта гына иделәр. Туры һәм нечкәләр, очланып килгән озын танаулылар.* Диңгез тирәнлегендә

Очланып китү Кинәт очлану

ОЧЛАП I *рәв.* Кисәкләп, очы (II) белән. *Тукыманы очлап сату*

ОЧЛАП II *рәв.* Ике яки өч пар атны бер-бер артлы итеп. *Очлап җигү*

ОЧЛА́У *ф.* 1) Оч ясау, очлы итү. *Очлый торган казыгыңның башына бер бүдәнә килеп кунды.* Әкият. *Карандашыңны иплəп кенә очла да кәгазеңне алдыңа куй.* Н.Дәүли. *Шундый гади генә корал ит кисәргә, сөяк ватарга, --- таяк очларга яраган.* Табигать белеме

2) Оч ишү (чыбыркыга). *Җептән бушаган кәтүкне, нәкъ урталай кисеп һəм киселгән башын аз гына очлап, мөгезгә тыгыз итеп кидерəлəр.* Казан утлары

3) Нәрсәнең дә булса (кибән, эскерт, манараның) оч, югары өлешен эшләү. *Кырда кибəн очлау да Гатият абзый карамагында булды.* М.Мəһдиев

4) *диал.* Төбәү, төзәү (мылтыкны, сөңгене, штыкны). *Мылтыкны очлап алга сузу*

5) Тәмамлау, төгәлләү. *Ил җимерек, халык гаҗиз, кеше ят – Ник гомерне болай ямьсез очладык?* Г.Мөхəммəтшин. *Гафу итегез, хəзер сүзебезне очлыйбыз.* Т.Әйди. *Табышмагым чишелде, Сер капчыгым тишелде... Уйнап кына башладым, Чынлап кына очладым!* Ш.Галиев

6) Берәр төркемнең, колоннаның иң алдында яки иң артында бару. *Иң алдан ана бүре атлаганы күренə. Аның эзеннəн – быелгы бала бүреләр. Карт ата бүре арттан очлап бар[а].* Г.Хəсəнов

7) *күч. гади с.* Әрәм-шәрәмгә бетерү, юк итү. *Байлыкны очлау*

8) *күч. гади с.* Һәлак итү

◊ **Очлап чыгу** Тулысынча, тиешле дәрәҗәдә очлау. *– Гөлләрия, иркəм, – ди. – Син булмасаң, диплом дигəн нəрсəне очлап чыга алмый идем.* К.Тимбикова. *Синнəн башка да уракны очлап чыгарбыз ---.* Б.Камалов. *– Белəсең бит, апагыз күптəн вафат, ялгыз интегүемне күреп торасың, менə моны да очлап чыгасы бар, – ул төзелеп бетмəгəн йортка ишарəлəде, – синсез барып чыкмаячак.* Г.Гомəр

Очлап бетерү Тулысынча очлау. *[Тутакай] сүзен очлап бетерə алмады, ишек шакылдады.* Г.Исхакый. *Əхəт чыбыркысын очлап бетерə, шартлатып җибəрə.* Һ.Такташ. *Ул [командир] сүзен очлап бетерə алмады.* Г.Кашапов

Очлап карау Булу-булмавын сынау өчен очлау

Очлап килү Очлап бетерү алдында тору. *Атасы Бикбулат килгəндə, Нəфисə яза торган хəбəрен очлап килə иде.* Г.Бəширов

Очлап кую Берәр нәрсәне алдан яки тиз арада очланган хәлгә китерү. *Кəшифəкəемнең сəламəтлеген бер минутка да истəн чыгармыйм, тик əлегə диплом эшен тəмам очлап куймыйча, аның белəн шөгыльлəнеп булмый.* К.Тимбикова. *--- Ездовойның фронтта тоткан урыны хакындагы гəпне шуның белəн иплəп кенə очлап куярга иде Хəнəфигə.* В.Нуруллин. *Ихтыярның инде атна буе күңелен борчып йөргəн уйларны тизрəк очлап куясы, бу туйдырган темадан читкə китəсе килə иде.* Р.Вəлиев

Очлый башлау Очларга тотыну

ОЧЛАШУ *ф.* 1) *урт. юн. к.* **очлау** (*1–2 мәгъ.*)

2) *иск.* Җир кишәрлекләренең башбашлары, очлары бер-берсенә терәлеп тору

Очлаша башлау Очлашырга тотыну

Очлашып тору Даими очлашу

ОЧЛАЮ *ф.* Очлы форма алу. *Алдыбызда өскə таба очлаеп калыккан һəм иң очына кызыл йолдыз беркетелгəн конус рəвешендəге зур һəйкəл – обелиск басып калды.* Ф.Хөсни. *Силос базының төбе аска очлаеп казылган ---.* Безнең гәҗит

Очлаеп бетү Бик нык очлаю. *[Эвглена] Тəненең алгы очы йомры, ə артқысы очлаеп бетə.* Биология

Очлаеп калу Очлы формага килү һəм шул форманы саклау. *Янə пыяла ишек аша караватта үлек сыман ятучы, битləре очлаеп калган этиемə күз аттым.* Идел. *Азот җитмəгəндə, кыяр яфраклары саргая, ə кыяр үзе очлаеп кала.* Бəйрəм

Очлаеп килү Очлырак, сузынкырак форма алу. *Түгəрəк йөз, киң маңгай, аска таба очлаебрак килгəн яңаклар, зəңгəр күзлəр, кайтарылып торган озын керфекләр хан кызы Чəчкəне əйтеп тə, күреп-карап та туймаслык матур итə иде.* М.Хəбибуллин. *Үрелеп утны кабызса, бу тимер очлаеп килгəн түгəрəк агач башына беркетелгəн җиз ай булып чыкты.* Р.Вəлиев. *Суның өске катлауларында яши торган балыкларның түшləре, кагыйдə буларак, очлаеп килə.* Кызыклы ихтиология

Очлаеп китү Кинәт очлаю. *Барысы да кара җиләннəн, өскə очлаеп киткəн башлыктан икəн.* Г.Гыйльманов. *Текə түбə, өскə таба очлаеп киткəн аркалар, биек манаралар – болар барысы да ашкынып югарыга омтылу тəэсирен тудыра.* Урта гасырлар тарихы

Очлаеп тору Даими яисә билгеле бер вакыт дәвамында очлайган хәлдә булу. *Сөембикəнең өстендə кеш туны, башында очлаеп торган шəмəхə төсендəрəк җофар тиресеннəн тегелгəн калфак ---.* М.Хəбибуллин. *[Йомры суалчанның] Озынча цилиндрик тəне гадəттə баш-баштан очлаеп тора.* Биология: хайваннар. *[Павлушинның] Кылыч сыман очлаеп торган дəү борыны тагын да озыная, сузыла төште...* Х.Ибраһим

ОЧЛЫ *с.* 1) Очы (*1 мәгъ.*) бик нечкә булган, үткен; чәнчә, кадый, тишә торган. *Агач башларын тиз генə тарап киткəн җил тагын тынды, күл юка боз белəн капланган шикелле, аны тик суүсемнəрнең очлы уклары гына чəнчеп тора.* Ə.Гаффар. *Барлык пираньяларның да, суга элəккəн корбан тəненнəн ит кисəкləрен үзеп алу өчен, очлы тешləре бар.* Биология

2) Очы (*2 мәгъ.*) тараеп, нечкәребрәк, озынчаланыбрак беткән яки ясалган. *Очлы тау башында өч каен, Очлары тирбəлə җилləргə Зəңгəрсу ефəктəй көннəрдə.* Г.Афзал. *Мондый очлы түбəле кайры-тире алачыкларда кыргый җəнлекләр аулап көн күрүче урман кешеləре ягы иде.* Н.Фəттах. *Тəңкəләре очлы, артка таба бөгелгəн ромбсыман пластинка рəвешендə.* Биология

3) *күч.* Әйбәт күрә торган, үткен. *– Əлфриднең күзləре очлы, чибəр кызларны күрə белə, – диде Ирфат.* Ф.Яруллин. *Холык-фигылендəге бəлəкəй генə кимчелегең дə аларның очлы күзləреннəн читтə калмас.* Р.Мулланурова

◊ **Очлы колак** Күп ишетә торган кеше. **Очлы күз** Күп күрә торган, игътибарлы кеше. *Кайбер очлы күзләргә абый белән сеңелнең мөнәсәбәте бик шикле тоелды.* Н.Фәттах. **Очлы күзле** Күп күрә торган (кеше тур.). **Очлы сүз** Үткен, усал, төртмәле сүз. **Очлы тел** Усал, үткен телле кеше

ОЧЛЫБОРЫН *и.* Кефаль балыклар семьялыгыннан кыйммәтле промысел балыгы; *русчасы:* **остронос**. *Очлыборын канаты*

ОЧЛЫК *и.* 1) Нәрсәнең дә булса очына, башына кидертелә торган очлы нәрсә. *Шуны ничек кирәк алай чүкеп, ук һәм сөңге очлыклары, савыт-саба, балта-пычак ясау да әлләни осталык сорамый.* З.Мифтахов. *Сәяк очлыкның башына кремний кисәкләре куелган булган.* Кызыклы ихтиология

2) *анат.* Кешедә аяк һәм кулларның һәрберсе. *Кешенең түбәнге очлыкларының зур сөякләре кул сөякләреннән шактый калын ---.* Биология

3) *анат.* Хайваннарның гәүдәсе һәм башыннан аерымланган, гадәттә мускул көче белән хәрәкәтләнә торган үсенте. *Кысланың авыз кырыенда алты пар үзгәргән очлыклар урнашкан ---.* Биология. *Алгы очлыклары бушап калгач, австралопитеклар аларны азык табуда һәм, корал тотып, дошманнарыннан сакланууда файдалана башлаганнар.* Табигать белеме

4) Нәрсәнең дә булса бетми калган кечкенә кисәге, калдыгы. *Күзгә ташланган өч-дүрт өстәл, иске урындыклар, идәндә чәчелеп яткан тәмәке очлыкларыннан башка [бүлмәдә] бернәрсә дә юк.* Ш.Камал

ОЧЛЫКТЫРУ *ф. диал.* 1) Этеп, атып ераккa җибәрү, очыру

2) *күч.* Юкка чыгару, яшерү

ОЧЛЫМ *и.* Өске өлеше очлаеп килгән хәрби баш киеме. *--- Дәһшәтле бу сугыш вакытында аның да тимер очлымы тәгәрәп җиргә барып төште.* Ф.Бәйрәмова. *Очлымнары, путалары, калканнары, орыш киемнәре, ат кирәк-яракларына кадәр алтын белән бизәлгән.* М.Хәбибуллин. *Тәреле очлымнар астына оялаган шөпшәләрнең зәһәр угы соңыннан коточкыч бәлаләр китерде.* З.Фәтхетдинов

ОЧЛЫПЫЙ *с. диал.* Очлы формалы

ОЧЛЫЯФРАК *и. бот.* Агулы кызыл, сары яки башка төсле җимешләре булган, күп кенә төрләре декоратив максатлар белән үстерелә торган, куе яшел ялтыравык яфраклы куак яки кечкенә мәңгеяшел агач; *русчасы:* **падуб**

ОЧМА *с.* Оча торган

◊ **Очма кальга** Саклану кораллары белән яхшы җиһазландырылган күпмоторлы зур очкыч. *Очма кальгага утыру*

ОЧРАК *и.* 1) Булган хәл, вакыйга. *Һәрхәлдә андый очракның моңарчы булганы юк.* М.Маликова

2) Уңайлы, җайлы момент, мөмкинлек. *Билгеле инде, мондый очракның тиз генә булмасын аңлый идем.* Г.Кашапов

3) Көтелмәгәндә килеп чыккан хәл. *Ә шушы очрак өчен без синең белән бер җай әзерләгән идек ---.* Х.Камалов

ОЧРАКЛЫ *с.* **1.** 1) Көтелмәгәндә барлыкка килгән, булган. *Савыт-сабаларны җыйган вакытта, әллә махсус, әллә очраклы рәвештә, Нажия белән Чәчкә генә калдылар.* Ф.Яруллин. *Анысы – көтелмәгән, очраклы хәл.* В.Нуруллин

2) Искәрмәстән килеп чыккан, очраган, тап булган. *Очраклы кеше түгел, бер-беребезне күптән беләбез.* М.Маликова. *Син бит очраклы юлчы гына.* Ф.Яруллин. *Күзгә төртсәң күренмәслек мондый караңгыда нинди очраклы шаһит, ди, ул?* Т.Әйди

3) Сирәк кенә, вакыт-вакыт булгалый торган. *Сез бу хәлне Шәриповның очраклы бер ялгышы, аның юмартлыгыннан килгән бер нәрсә итеп карадыгыз.* Р.Ишморат

4) Нигезсез, тиешле җирлексез барлыкка килгән. *Универсиадада авыр атлетика буенча очраклы медальләр булмады.* 2013 Универсиадасы блогы

5) Очраклылыкка (*2 мәгъ.*) нигезләнгән

2. *рәв. мәгъ.* 1) Искәрмәстән, уйламаганда. *Очраклы гына күреп алу*

2) Нигезсез рәвештә, бәйләнеш, сәбәп булмый торып. *Кулинария сәнгате осталары безнең тарафтан очраклы сайланмады ---.* Ютазы таңы

ОЧРАКЛЫЛЫК *и.* 1) Очраклы хәл. *Һәр танышу очраклылыктан башлана.* Ф.Яруллин. *Күрәсез, кеше язмышы гел очраклылыклардан тора.* М.Гали. *Мине бу очраклылык гаҗәпләндермәде.* Ә.Гаффар

2) *филос.* Нигезләре һәм сәбәпләре әйберләрнең, вакыйгаларның эчке бәйләнешләреннән, асылларыннан килеп чыкмаган күренеш, хәл. *Әйе, дөньяда ике бөек тиран мәгълүм: Вакыт һәм Очраклылык!* Г.Гыйльманов

ОЧРАКТА *бәйл.* Эшнең торышын, барышын характерлаганда кулланыла. *Мин үзем дә гел синең белән бергә йөрер идем дә, бу очракта берни эшләр хәл юк шул, Фәләхҗан.* В.Нуруллин. *Чөнки бу очракта «белмим» яки «килешәм» дигәнегез – ялагайлык, хәтта ялган.* Ф.Яхин

ОЧРАТУ *ф.* 1) Кемне дә булса берәр җирдә туры китерү, күрү // Кемгә яки нәрсәгә дә булса тап булу, юлыгу; күрергә, белергә туры килү. *Кеше асылы: үрнәк яки гыйбрәт – Очратырсың начарын да, яхшысын да...* Р.Рахмани

2) Эзләп табу, туры китерү. *Сине очратыр сәгатьне гомер буе көткәнмендер, бәлки.* Р.Мулланурова

3) Өйрәнү, тикшерү, уку вакытында ачыклау, искәрү, белү. *Журналда Г.Камал тарафыннан ясалган гаҗәп уңышлы карикатуралар очратырга мөмкин.* М.Гали

Очрата башлау Очратырга тотыну

Очрата килү Әледән-әле очрату. *--- [Әлеге] табышмакны байтак елардан бирле «Борынсыз чыпчык боз тишә. – Тамчы» вариантында очрата киләбез.* Х.Мәхмүтов

Очратып кую Көтмәгәндә очрату. *Әгәр инде [Кадыйр Мөхәммәт бабайны] ялгыш очратып куйса, теше сызлаган кеше сыман, йөзенә газап билгеләре чыгарып, көчкә-көчкә генә сөйләште.* Ф.Яруллин

Очратып тору Гел, һәрвакыт очрату

ОЧРАУ *ф.* 1) Барганда, кайдадыр булганда, кемгә яки нәрсәгә дә булса тап булу, юлыгу, каршысына килеп чыгу. *Анда [базарда] инде татар*

агай-энесе очрамый калмас. Ә.Еники. *Чикләвек очрамады, дисә, Йосыф абыйсы барыбер ышанмаячак иде.* В.Нуруллин. *Урманда очраган кешеләрнең мине күрүгә котлары очып йөгерә башлаулары минем өчен кызык иде.* Ф.Яруллин

2) Берәр хәлгә тап булу. *Уңышсызлыкка очрау*

3) Сирәк кенә булып тору. *Түбән җирләрдә, елга буйларында гына кара туфраклы басулар очрый.* Н.Фәттах

◊ **Очраган берсе** Теләсә кем. **Очраган бер кеше** *к.* **очраган берсе**. *Янә бер хәдис шәрифтә: «Кешедән һәр ишеткәнне очраган бер кешегә сөйләп йөрү – ялган сөйләүгә бәрабәрдер», – диелә.* Өмет

Очрап кую Көтмәгәндә очрау. *Без яшь чакта кура җиләге җыйганда, арада ап-агы очрап куяр иде.* И.Низамов. *Пассажирскийда мәшәкатьлерәк: әле проводник килеп чыга, әле контролёр очрап куя.* Н.Фәттах. *Бәлки, әле МТС машинасы очрап куяр.* А.Хәсәнов

Очрап тору Даими очрау. *Алай дисәң, урамнарда төрле гариплэр – зур башлы кәрләләр, бөкреләр, сукырлар очрап кына торалар.* Ә.Еники. *Хәер, утыз җиденче, кырык сигезенче еллар истәлеге миңа адым саен очрап тора.* М.Мәһдиев. *Фатыйх абый анда да үзен бик иркен хис итә, танышлары очрап кына тора иде.* В.Нуруллин

Очрый башлау Очрарга тотыну. *Глаукома да (вакытында дәвалamасаң – сукыраюга китерүе бар) 39 – 40 яшьлекләрдә очрый башлый.* Өмет

Очрый килү Хәзергә кадәр очрау. *Күп еллар дәвамында авыру билгеле җирлекләрдә генә очрый килде, ләкин соңгы елларда аның торган саен зуррак территорияләрне яулый баруы күзәтелә.* Өмет

ОЧРАШТЫРУ *ф.* 1) Очрашуны оештыру, очрашырга мөмкинлек тудыру. *Ул аны Җир кешеләре белән очраштырырга булды.* З.Мифтахов

2) Сирәк кенә очрашу, очраштыргалау. *В. аларны сирәгрәк очраштырырга тырыша.* Ватаным Татарстан

ОЧРАШУ I *ф.* 1) Кара-каршы очрау, юлыгышу, күрешү. *Аерым планеталар булсак та, көннәрдән бер көнне без мәхәббәт йолдызлыгында очрашабыз.* Ф.Яруллин

2) Танышу, күрешү, аралашу һ.б.ш. максат белән вакытлыча бер урынга җыелу. *Очраштык, белештек, ул безнең ерак кардәш тиеш кеше икән.* Я.Зәнкиев

3) Күңел ачу өчен, сөйгәнең, аралашып йөргән егет яки кыз белән күрешү. *Берничә тапкыр алар Заһриның бакча башында яшерен генә очраштылар.* М.Мәһдиев. *Бүтән очрашу насыйп булмады безгә!* М.Вәли. *Сания күрешүдән баш тартты, очрашырга риза булмады ---.* Я.Зәнкиев

4) Кара-каршы уйнау, ярышу, көч сынашу (спорт ярышлары тур.). *Иң элек «Газовик» белән «Спартак» очраштылар.* Әлки хәбәрләре

5) Якынаю, кушылу (җансыз әйберләр тур.). *Озакламый Идел, ашкып, Яңа юллар белән очрашыр.* Ә.Ерикәй

6) Күзләр, караш туры килү. *Күзләре картның нур чәчеп торган якты соры күзләре белән очрашты.* Д.Булатова

7) Нәрсәгәдер юлыгу, баштан кичерү һ.б.ш. *Тормыш – кырыс чынбарлык ул, аның катылыгы белән очраша калсаң, ул беркемне дә аямый!* Я.Зәнкиев

Очраша башлау Очрашырга тотыну. *Хәзер инде ешрак очраша башладылар, ресторанга бардылар, шәһәр читенә пикникка чыктылар һәм бергә эшләүләренә ике ел тулганда өйләнешеп куйдылар.* З.Мурсиев. *Тренировкалардан соң егет булачак тормыш иптәше белән очраша башлый.* Өмет

Очраша бирү Бернигә карамый очрашу

Очраша тору Әледән-әле очрашу; хәзергә очрашу

Очрашып алу Бер тапкыр яки кыска вакыт аралыгында очрашу. *Юк йомышларын бар итеп кергән берничә күрше хатын кичкырын Хуҗа абзыйларның болдырында бер очрашып алды.* Р.Мөхәммәдиев

Очрашып йөрү Озак вакытлар очрашу. *Тимерханның гыйшкы Фаягөлгә төшкән, очрашып йөри башлаганнар иде.* Р.Мулланурова

Очрашып кую Көтмәгәндә очрашу. *Залдагы ыгы-зыгыны олы канәгатьлек хисе белән күзәтеп утырган Сталин белән Куйбышевның шул мәлдә гел көтмәгәндә карашлары очрашып куйды.* Р.Мөхәммәдиев

Очрашып тору Даими, регуляр рәвештә очрашу. *Студент елларда шәһәр һәм республика күләмендә уздырыла торган киңәшмәләрдә әледән-әле очрашып тора идек.* Б.Камалов

ОЧРАШУ II *и.* 1) Бергә үткәргән вакыт. *Авылыгызга, синең белән очрашуга барулар миңа газап та, әйтеп бетергесез рәхәт тә иде.* Ф.Яруллин. *Очрашуларны да яшереп кенә үткәрәбез.* М.Маликова. *Очрашуларыбызның берсендә ул кулымны алды да анда үз исемен язды.* Безнең гәҗит

2) *спорт* Кара-каршы уен, ярыш. *Беренче звеноның соңгы очрашулардагы искиткеч чыгышы нәкъ менә Евротурдагы нәтиҗәләргә бәйле дә инде.* Ватаным Татарстан

ОЧСЫЗ I *с.* 1) Очы ашалган, тупак. *Очсыз карандаш*

2) Чикләре күренмәгән, чиге булмаган; бик күп. *Очсыз уйлар төрлесе төрле якка таралдылар, ләкин ышанычлы бернәрсәгә дә барып туктый алмадылар.* Ф.Кәрим

ОЧСЫЗ II *с.* **1.** 1) Арзан, түбән бәяле. *Көньяк гөлләре бик горур була, Бик очсыз да булмый үзләре...* Ә.Синугыл-Куганаклы. *Мәскәүдә ипигә интеккән чаклар бар иде, ә монда барысы да мулдан, аннары бермә-бер очсыз.* М.Хәбибуллин. *Товарлар кайда очсызрак, шуннан мин машина белән барып алырмын.* Ф.Яруллин

2) *күч.* Кешелек өчен бәһасе булмаган. *Юк, кешеләр, адәм балалары бу бөек могҗиза алдында үзләренең никадәр юк нәрсә, вак, кешелексез мәшәкатьләр, очсыз мәшгулият белән шөгыльләнергә мәҗбүр булулары өчен үкенмәде дә, оялмады да.* А.Хәлим

2. *рәв. мәгъ.* Түбән бәягә. *Ул колны бик очсыз гына алырсың син, сатып аны бик күп нигъмәт табарсың син ---.* Кол Гали

ОЧСЫЗГА *рәв.* Түбән бәягә, бик арзанга. *Бәлки, кемнәрдер кыйммәтле алтынны очсызга алып, иртәгәсе көнгә мая җыядыр.* Безнең гәҗит

◊ **Очсызга төшү** Сатып алучы өчен кыйммәт булмау. *Харис абый: Соң ул электрик белән эшләү башка нәрсәләр белән эшләүгә караганда очсызракка төшәмени?* Ф.Кәрим

ОЧСЫ́З-КЫРЫЙСЫЗ *с.* 1) Бик зур, бик озын, бик киң, чикләре күренмәгән. *Һавада җиргә җай гына иңә баручы очсыз-кырыйсыз ак челтәр пәрдә тирбәлә кебек.* Г.Тавлин.--- *Алда якты кояш нурына коенган очсыз-кырыйсыз сахра җәелеп ята.* М.Вәлиева. *Шуны тамаша кылырга очсыз-кырыйсыз чират тезелә.* Мәдәни җомга

2) Бик күп, чиксез, әллә никадәр. *Милли мәктәпнең киләчәге нинди булачак, очсыз-кырыйсыз реформалар безне кая китереп чыгарыр?* Идел. *Менә шундый очсыз-кырыйсыз мәшәкатьләре белән тормыш дәвам итә.* Безнең гәҗит

3) *күч.* Бик озак вакыт дәвам иткән, дәвамлы, мәңгелек. *Сөюләрнең чиге буламыни? Сөю бит ул очсыз-кырыйсыз.* К.Булатова. *Безгә очсыз-кырыйсыз кебек тоелса да, күпмедер вакыттан соң шартлау-сызгырулар туктады.* Казан утлары

ОЧСЫЗЛАНУ *ф.* 1) Бәясе төшү, арзанлану. *Аларның бәйдән ычкына барулары нефть очсызлану һәм финанс кризисы белән бәйле.* Татарстан яшьләре

2) *күч.* Кемнең яки нәрсәнең әһәмияте кимү, дәрәҗәсе, авторитеты төшү. *--- югары белемле дипломлы кешенең җәмгыятьтә тоткан урыны, аңа караш очсызланды.* Татарстан яшьләре. *Шуның кадәр очсызланган хатын-кызга, инде тулаем ир-атлардан гына торган компания булса да, борылып карар идеме икән?* Шәһри Казан

3) *күч.* Үз дәрәҗәңне төшерү. *Соңгы чиктә ул Ниязов янына үземә керергә туры килер микән? Алай итсәң, очсызлану гына була инде.* В.Имамов. *Бирүче очсызланырга яратмый ул, кемнең алдатасы килсен!* Ф.Яхин. *Иҗат бит ул очсызлану яисә актуальлегеңне югалтмас өчен генә кеше каршында бөтерелү дигән сүз түгел, ул киңрәк һәм югарырак төшенчә булырга тиеш.* Шәһри Казан

Очсызлана бару Торган саен очсызлану, эзлекле рәвештә очсызлану. *--- товарларының очсызлана баруына закон проекты гына сәбәпче түгел ---.* Ватаным Татарстан. *Сум салмак кына, әмма зур тизлек белән очсызлана барганда, саклыкка дип җыйган акчаларны читек балтыры да, оекбаш та, пыяла банка да коткара алмаячагын алар инде яхшы аңлый.* Шәһри Казан

Очсызлана башлау Очсызлануга табан үзгәрү. *Рубль доллар һәм еврога карата очсызлана башлады.* Ватаным Татарстан

Очсызлана тору Торган саен очсызлану. *Инде үземнең ир аламасын әйтер идем, очсызлана торгач, балык ыслый торган җиргә каравылчы булып урнашты.* Әдипләр

Очсызлана төшү Бераз очсызлану; тагын да очсызлану. *Татарстан башкаласында мотор ягулыгы бәясе соңгы бер атнада тагын очсызлана төште.* Татар-информ

Очсызланып алу Кыска вакытка очсызлану. *Тимер һәм цементның очсызланып алуы торакның, күп дигәндә, 1–2 процентка гына очсызлануына китерәчәк.* Татарстан яшьләре

Очсызланып бару *к.* **очсызлана бару**. *Фатир бәясе ай саен очсызланып бара.* Татарстан яшьләре

Очсызланып бетү Нык очсызлану, тәмам очсызлану

Очсызланып калу Ахырда очсызлану. *Бер атна дигәндә урыс акчасы тагын да очсызланып калды.* Ф.Яхин

Очсызланып тору Гел яки әледән-әле очсызлану

ОЧСЫЗЛЫ *с. ялг. к.* **очсыз**. *Алупкада бераз торганнан соң, алар, тыныграк булыр дип, Симеиздән очсызлы гына бер дача алып, анда күчәләр.* С.Җәлал. *Туктатыгыз бу очсызлы комедиягезне!* Р.Вәлиев. *– Күрәсеңме, ул нинди башлы, син аңламаганнарны да җиңел генә төшенә! – дип, көтмәгәндә егете белән мактанып, очсызлы сафсата сатып ташлады.* Ф.Яхин

ОЧСЫЗЛЫК *и. сөйл.* 1) Очсыз булу, арзанлык. *Хезмәт кешеләрен торак белән тәэмин итү, коммуналь хезмәтләр өчен символик түләү, эшсезлек булмау, илебездә җитештерелгән продукциянең очсызлыгы – боларны хәзер сагынып кына искә аласы кала.* Ватаным Татарстан

2) *күч.* Буш, ясалма кыланыш яки характердагы шундый сыйфатлар, түбәнлек. *Аны аңлар дәрәҗәдәге кеше андый түбәнлек-очсызлыкка төшмидер дә инде ул.* Шәһри Казан

ОЧУ I *ф.* **1.** 1) Һавада канатлар хәрәкәте ярдәмендә бер урыннан икенче урынга күчү. *Киек казлар очып бара иде, Вакыт ага иде битараф.* М.Әгъләмов. *Ярый әле кош мине тыңламаган, туктамаган икән. Очты да китте.* И.Низамов. *Җирнең тарту көчен әгәр Үзгәртә алсам, Канатлар да үсеп чыгып, Мин оча калсам...* Н.Сафина

2) Һавада, бушлыкта хәрәкәт итү, бер урыннан икенче урынга күчү (очкыч һ.б.ш.лар тур.). *Кайвакыт күктә кошлар түгел, тезелешеп, йолдызлар очып бара сыман.* Ф.Яруллин. *Аның артыннан ук таң алды эңгер-меңгерен калтыратып, күк биеклегендәге салкыннарны ярып, өлгер самолёт очып үтте.* Г.Кашапов

3) Җил белән яисә ыргыту, ату сәбәпле һавада хәрәкәт итү. *--- Форточкадан Җәүһәрнең портреты очып керде.* Ф.Яруллин. *[Туп] оча, сызгыра, сакчы малайлар аның артыннан өлгерә алмыйлар, өмет бары тик Зөфәрдә!* А.Гыйләҗев. *Снарядлар баш очыннан очып китәләр дә кайдадыр ярылалар.* Казан утлары

4) Өстән аска төшү, ыргытылу. *Алар артыннан бизәкле зур чәйнек идәнгә очты.* М.Маликова // Салмак кына төшү. *Менә бер вакыт Рифаның кулъяулыгы идәнгә очты.* Х.Камалов

5) Тирә-якка чәчрәү, таралу, тузгу. *Аның аты сөлектәй сузылып чаба, корсак астыннан уч-уч күбекләр очып кала.* М.Хәбибуллин. *Пычкы чүбе бөтерелеп-бөтерелеп очты, кар бураны кебек өермәләп-өермәләп сибелде.* Д.Каюмова

6) *хим.* Һавада таралу. *Спирт очу*

7) Егылу, мәтәлү, тәгәрәү. *Корабтагы ике алып, аркаларына ук кадалып, суга очтылар.* М.Хәбибуллин. *Бишекле*

мотоцикл кызулык белән суга очты. Ватаным Татарстан

8) *күч.* Бик тиз хәрәкәт итү. *Канатланып оча зур эшелон, Күксел төтен кала таралып ---.* Ф.Кәрим. *Акныкараны күрми чаба, юк, чапмый – оча гына.* Р.Мулланурова. *Горизонт чиста, траулер борыны белән вак дулкыннар ерып оча гына.* Ф.Шәфигуллин

9) *күч.* Бик тиз үтү (вакыт тур.). *Җилләр өзгән яфрак сыман Көннәр оча – еллар кими.* Ф.Сафин

10) *күч.* Таралу, еракларга, күпләргә ишетелү. *Хәбәр очу. Яңалык очу*

11) *күч.* Эштән чыгарылу, дәрәҗәле урыннан алыну. *Ә аның [Ханәфинең] һич кенә дә «очасы» килми. --- Барыбер председатель урындыгыннан төшәсе килми.* В.Нуруллин. *Экраннарда кайный халыклар! Оча президентлар!* Р.Фәйзуллин

12) *күч.* Омтылу, ашкыну (күңел, хыял тур.) *Уйларым еракта калган Казан тирәсенә очтылар.* Г.Бәширов

13) *күч.* Юкка чыгу, югалу. *Ачы җил исә башлауга, томан күтәрелде, иртәнге чык тамчысы төсле, ул да китте, җилгә очты.* Г.Бәширов. *Үткән еллар, алышынган заманнар, Очкан тәхет, падишаһлар, бароннар ---.* Ф.Сафин. *Тозлы җил шикелле бушка өреп, яшьлек каядыр очып бара.* Ә.Гаффар // Талану, урлану, алдану һ.б.ш. сәбәпле бетү

14) *күч.* Онытылу (хис тур.). *Кайчак ул сагышлана, әмма аның сагышы, иртәнге чык кебек, тиз оча иде.* Г.Әпсәләмов

15) *күч.* Тормышка ашмау (өметхыяллар тур.). *Бетте, очты, юкка чыкты бөтен планнар, дип уйлады Нияз.* Д.Каюмова

2. *рәв. мәгъ.* **очып** 1) Усалланып, ярсып. *Очып талашырга*

2) Тиз генә, кызу. *Әй, очып кына кайтасы иде дә атасы янына, барысын да аңлатып, төшендереп бирәсе иде.* М.Хәбибуллин. *Мин салга бәйләнгән юеш арканны әле һаман да җибәрмәгән идем – очып диярлек суга кереп киттем.* Ф.Шәфигуллин

3) Күңел күтәренкелеге белән. *Хат ташучы Сәрвәрнең хат көтүен белә, шуңа күрә тавышы очып, уйнаклап чыкты.* Я.Зәнкиев

◊ **Очарга тору** Ашкыну, ашыгу. **Очып барганда тартып төшерү** Көтмәгәндә начарлык эшләү. *Бу сорау Мидхәтне очып барган җиреннән тартып төшергәндәй итте.* М.Маликова. **Очып барып төшү** Бик каты егылу. *[Хәйдәргали агай:] Сугып торып җибәрермен... Очып барып төшәрсең...* Р.Мөхәммәдиев. **Очып йөрү** Күтәренке кәеф белән тиз-тиз хәрәкәтләнү. *Эссәт әкә казанлык янында маташкан хатыны тирәсендә очып йөри башлады ---.* Я.Зәнкиев. **Очып куну** 1) Кискен хәрәкәт белән кемгә дә булса һөҗүм итү, ташлану. *Кәүкәбелҗәннәт аңа очып кунар чиккә җитте.* Ф.Садриев; 2) Кемне дә булса гаепләү

Оча башлау Очып китү, очарга тотыну. *Мин өйдән чыкканда, урамда җилләргә ияреп, беренче кар бөртекләре оча башлаган иде.* Сабантуй. *--- андый фактлар өчен командованиенең погоннарыннан йолдызлар оча башласа, казармаларның барлыгын данлы генералларыбыз да исләренә төшерер һәм ул очракта яшь солдатлар өчен андагы төнге «сеанслар»га чик куелыр иде.* Татарстан яшьләре

Оча бирү Бернигә карамый очу

Оча тору Әледән-әле очу; һаман очу. *Уйлар оча торды, [Хәнәфинең] гәүдәсе авырая бара.* Э.Касыймов

Очып бетү Тулысынча очу, һәммәсе очу. *Бар булган байлыгым шул җыр белән бергә очып бетмәсә ярый инде.* Х.Ибраһим. *Аштамырлар һәм суганны чи килеш салсаң, пешкән чакта аларның су парлары белән хуш исләре һәм тәмнәре очып бетә.* Йорт эшләре

Очып йөрү Шактый вакыт очу. *Кар бөртеге очып йөри күктә, безне уйлы-моңлы иттереп.* К.Сибгатуллин. *Балык тота торган кошлар елга һәм күлләр өстендә сәгатьләр буена очып йөриләр.* Кызыклы ихтиология

Очып китү Очар өчен кискен хәрәкәт итә башлау. *Елмаеп кына торган зур кара күзле, түгәрәк йөзле, кашлары очып китәргә канат җәйгән кошны хәтерләткән, йомшак холыклы кеше иде.* Д.Булатова. *Мескен торна, очып китәр өчен күпме генә талпынса да, ядрә чәрдәкләгән сыңар канатын җәеп җибәрә алмады.* Ватаным Татарстан

Очып тору Туктаусыз очу. *[Рафаэль] лапас кыегыннан мәче мыегыдай берөзлексез очып торган кар тузанын сокланып күзәтте.* Р.Мөхәммәдиев. *Кап-караңгы төндә тирә-юнендә миналар шартлый, утлы пулялар башы тирәсендә күч кебек гөжләп очып тора ---.* Х.Камалов. *Көннәр очып тора, Төннәр очып тора; Өмет канатларын Җилләр кисеп тора...* Ф.Яруллин

ОЧУ II *и.* Канатлар ярдәмендәге хәрәкәт, очыш. *Очу сәләте бөҗәкләргә планетада киң таралуны тәэмин иткән ---.* Биология

ОЧУЧАН *с.* 1) Очарга сәләтле; билгеле рәвештә оча торган. *Минем башыма килгән вакыйганы атам илә анама барып хәбәр бирүче, кеше теле илә сөйләүче, тиз очучан кош кайдан алыйм икән?* һ.Атласи

2) *хим.* Тиз таркалып газ халәтенә күчүчән, очып парга әйләнүчән. *Моннан тыш эт җиләге үләненең очучан матдәләре кешегә дә тискәре йогынты ясый: баш авырта, эшкә сәләтлелек кими.* Туган як

ОЧУЧЫ *и.* Очкычлар белән идарә итүче. *Очучы булып хезмәт иткән Мисбахетдин ут эченә беренче кергәндер.* В.Гали. *Без утырган «Джип»ның йөртүчесе – элекке очучы ---.* Мәдәни җомга

ОЧУЧЫ-ИНСТРУ́КТОР *и.* Очучыларны очкыч белән идарә итү эшенә гамәлдә өйрәтүче белгеч. *Балашов авиация училищесын тәмамлап, очучы-инструктор белгечлеген алган.* Т.Нәҗмиев

ОЧУЧЫ-КОСМОНАВТ *и.* Космоска очкан һәрбер космонавтка бирелгән шәрәфле исем. *Очучы-космонавт, ике тапкыр Советлар Союзы Герое Г.Гречко Алабугада булып китте ---.* Мәдәни җомга

ОЧУЧЫЛЫК *и.* Очкычларны йөртү, алар белән идарә итү эше, очучы һөнәре. *Очучылык һөнәрен мин дөньядагы бер һөнәргә дә алыштырмас идем.* М.Юныс. *Аңлашылды, диагноз*

билгеле: синдә очучылык чире, аның да «сәяхәт теләү» стадиясе ---. Ялкын

ОЧЫК I *и.* Ашлык җилгәргәндә очкан чүп; кибәк, башак һ.б.

ОЧЫК II *и.* 1) Сидекне тота алмау авыруы, боелыгын тотмау. *Бары очык авыруы гына җәфалый икән үзен.* Ватаным Татарстан

2) *сир.* Күзнең очлары кызарып, пешегеп авырту

ОЧЫНГЫЧ *и. сөйл.* **1.** Мактанчык, һаваланучан кеше. *Ә авылда шәһәр кешесе гомер бакый «ялкау», «очынгыч», «кыланчык» булды.* Тамаша

2. *с. мәгъ.* Шундый холыклы. *Очынгыч кыз булып үсәрсең инде.* Идел

ОЧЫНДЫРУ *ф.* 1) Җилфердәтү, тузгыту. *Халат чабуларын очындыру*

2) *күч.* Мактап һаваландыру; узындыру, аздыру. *Чит илләрнең бик бай кешеләре дә үз балаларын бик очындырмыйча, гади генә шартларда, иң мөһиме – бәләкәйдән үк хезмәткә күнектереп үстерергә тырыша.* Өмет

3) *күч.* Дәртләндерү, ашкындыру, җилкендерү; мактау. *Күңелемне кабат очындыр!* Г.Гыйльманов. *Шәмси ага һәрберебезне шулай очындырып эшләтә белә иде.* Ватаным Татарстан

Очындыра башлау Очындырырга тотыну

Очындыра төшү Бераз очындыру; тагын да очындыру

Очындырып алу Бераз, тиз генә очындыру. *Фазыл иң башта аны кулларында югары күтәреп, очындырып алды.* Шәһри Казан

Очындырып жибәрү Тагы да интенсиврак очындыра башлау. *Саниянең ул җырны беренче кат ишеткәчтен дә шулай ошатуы мине бермә-бер канатландырып, тагы да очындырып җибәрде кебек.* Р.Мөхәммәдиев. *Әхмәтхан тагы аны какмый да, әллә ни очындырып та җибәрми: хатын хатын урынында булырга тиеш.* Р.Камал

Очындырып кую Бер мәртәбә, аз гына очындыру. – *Синең кебек егетләрне табарга кирәк әле, – дип, очындырып куйды тагы сүзенең ахырында.* Р.Мөхәммәдиев

Очындырып тору Гел, даими очындыру. *«Кар көрәсә – буран уйната», – дип, җай чыккан саен үземне мактап, туганнарым алдында салпы якка салам кыстырып, очындырып торганнарын һич онытасым юк.* Р.Мөхәммәдиев. *«Музыка үзе очындырып биетеп тора, сезгә көчәнәсе дә юк», – ди торган иде балет төркеме җитәкчесе Мансур Гатиятуллин биючеләргә.* Татарстан яшьләре

ОЧЫНКЫ I *и. бот.* Сыраҗчалар семьялыгыннан сабак очында урнашкан башак яки чукчәчәкле берьеллык, сирәк кенә күпьеллык ярымпаразит үсемлек; күз уты; *русчасы:* **очанка**. *Очынкы чәчәкләре*

ОЧЫНКЫ II *с.* 1) Оча торган. *Очынкы орлыклар*

2) *күч.* Җиңел, җитез. *Аның яшьләрчә җиңел, очынкы йөрешен һәм яшькелт күзләренең иртәнге чык шикелле елтыравын күргәч, мин иркен сулап җибәрдем, чөнки күңелемне кичәдән бирле нидер тырнап, борчып торган иде.* А.Тимергалин

ОЧЫНУ *ф.* 1) Үзалдына арлы-бирле очу. *Аның башында, ялкын сыман очынып, кызыл флаг җилферди.* Г.Әпсәләмов. *Очынып кына калмыйча, бераздан ул, якын ук килеп, кыя читендә асылынып торган Мәдинәнең йөз каршында җилпенеп тора башлады...* Г.Гыйльманов. *Бары бал кортлары гына, нидер әйтергә теләгәндәй, безелдәшә-безелдәшә, аның тирәли очынып йөриләр иде...* Л.Шәех

2) Канат кагу, җилпенү. *Диңгез өстендә очынып йөргән акчарлакларны Газизә җентекләп кенә күзләре белән эзләгән хәлдә, карчыкның күзенә алар җил белән очкан йон кисәкләре кебек кенә чагылгалый иделәр.* Ш.Камал. *Күктә очынып-очынып сабан тургайлары сайрый.* Р.Хәбибуллина

3) *күч.* Тиз хәрәкәтләнү. *Әле генә үзүзләрен белешмичә очынган атлар шып туктадылар.* Ф.Әмирхан

4) *күч.* Дулау, тавыш чыгару. *Очына апагыз, тагын нәрсәдер әйткән иде дә, түзем тезгенем ычкынды да китте.* Г.Кашапов

5) *күч.* Мактану, масаю; артыгын кылану. – *Очындыгыз болай! – дия-дия, Бүрегем алып баштан, күккә чөя.* М.Саттаров. *Солтан Җәләевич кебекләргә мактап сүз әйтергә дә ярамый, юкса очынып, үсенеп китәләр.* Ф.Яхин. *Башым әйләнеп, очынып китәргә сәбәп юк.* Тамаша

6) *күч.* Дәртләнү, ашкыну. *Очынып йөрим яшь чактагы кебек Әлмәт урамында.* К.Булатова. *Камил очынып аның каршысына килеп басты.* Г.Галиева. *Шул ук вакытта, иҗат кешесе алга таба да очынып эшләсен өчен, җылы сүзләр ишетү дә мөһим.* Шәһри Казан

7) *күч.* Нинди дә булса хис белдереп текәлеп карау. *Разиянең күзләре йомшак кына очындылар, --- мине каһәрләделәр, иркәләделәр.* Ф.Әмирхан

Очына башлау Очынырга керешү. *Күңел ниндидер билгесез, ләкин татлы бер талпыну белән талпынып, илəсмиләсләнеп очына башлый.* И.Гази. *Мансурны этеп җибәргән идем, Әзһәре килеп ябышты: – Әле син сугыша да белəсеңмени? – дип очына башлады.* Л.Гыймадиева

Очына төшү Бераз очыну; тагын да ныграк очыну. *Үлəр аның яныннан үтеп киткəндə, артистка тагын да очына төшеп, кулларын туп керткəн футболчы сыман күккə чөеп исəнлəште.* Татарстан яшьләре

Очынып җибәрү Көтмәгәндә очыну. *Бүген бигрәк артыгын очынып җибәргән идегез, дигән мәгънәне аңлата иде.* Н.Яһудин

Очынып йөрү Шактый вакыт, күптәннән бирле, берара очыну. *Кешеләргә сиздермәскә тырышса да, ул инде әле генә очынып йөргән Саимә түгел иде, йөзе уйчан, аяклары авыр атлый.* Г.Галиева

Очынып китү Кинәт очыну. – *Шулай дисәң генә, – дип, җанланып, очынып китте Рафаэль.* Р.Мөхәммәдиев. *Аларның геройлары да, юктан гына очынып китеп, теләсә кемне кысып кочакларга яки кочагына ташланырга әзер тормыйлар.* Т.Миңнуллин. *Сабыр гына тыңлап торган Габдулла очынып ук китте: – Шулай, дөрес, малайлар, безнең өй каршында бабай заманыннан калган бик тармаклы юкә бар.* М.Рәфыйков

Очынып тору Хәзер яки гел, даими очыну. *Күңелләрдә – очынып торган дулкынлану.* М.Галиев

ОЧЫНУЛЫ *с.* Ашкынулы, дәртле. *Минем шушы очынулы сүзләремне [Гафури] башкалар шикелле үк тыныч кына, әмма игътибар белән тыңлап утыр[ды].* З.Бәшири

ОЧЫНУ-ШАШЫНУ *ф.* Дәртләнү. *Шунда үк арба тирәсенә җыр ыратучылар җыелышып та алдылар, һәм китте җырлау, очынып-шашынып җырлау, ара-тирә өздереп сызгырып та җибәрү – һавадагы тургайлар тавышы да ишетелмәс булды...* Ә.Еники

ОЧЫНЫП *рәв.* 1) Тиз. *Кулындагы җиз башлы зур камчыны селеккәләп, авылдан чыккančы кешеләргә күрсәтеп һәм очынып барды.* Н.Яһудин

2) Күңел биреп. *Югыйсә тырышкан да иде инде [Гөлшат]. Очынып эшләде.* М.Әмирханов. --- *Хәдичәнең кулыннан көрәкне тартып алып, бәрәңгене үзе казый, яшьлек дәрте килгәндәй очынып эшли иде [Минхаят карчык].* Татарстан яшьләре

3) Усалланып, ярсып, ыргылып. *Берәр мескен фермерның җир кишәрлегенә кемдер кергән дип, очынып прокурор урынбасары килеп җиткәнен [күргәнегез бармы]?* Безнең гәҗит

ОЧЫ́П-ОЧЫП *рәв.* 1) Бик җиңел, матур, җитез хәрәкәтләр белән. *Классташларым очып-очып вальс әйләнә, әбез, бер-беребезнең аягына баса-баса, бер урында таптанабыз.* Л.Закиров. *Минем урамга чыгып йөгерәсем, очар кошка әйләнеп йолдызларга күтәреләсем, һинд киноларындагы матур кызлар кебек очып-очып биисем, хәтта, ни гажәп, йомшак чирәмдә тәгәри-тәгәри елыйсым килә!* Р.Габделхакова

2) Күтәренке күңел белән

ОЧЫРГЫЧ *и. к.* **очырткыч**. *Ул бик тыныч оча, әйтерсең лә малайлар очыргыч җибәргәннәр дә, безгә күренми торган җебен каяндыр тотып баралар.* М.Пришвин

ОЧЫРТКЫЧ *и.* 1) Кәгазь я тукыма ябыштырылган җиңел киергедән гыйбарәт һәм озын җеп белән һавага җибәрелә торган уенчык. *Яшен һәм очкынлы бушануның бердәйлеген Америка галиме Франклин үзенең һава очыртқычы белән ясаган тәҗрибәләрендә исбат иткән.* Физика курсы

2) Гадәттә җиңел материалдан эшләнгән төрле формадагы (өчпочмак, параллелограмм, түгәрәк), һавага атып җибәрелә торган уенчык. *Балалар кулындагы җепкә бәйләнгән очырткыч үзенең күбәләктән зур булуы һәм биектә очуы белән мактана.* Ватаным Татарстан

ОЧЫРТУ *ф.* **1.** 1) *йөкл. юн. к.* **очыру** (*1–2 мәгъ.*). *Аэроплан очыртып уйнаулар Ихтыярны да, малайларны да туйдырган булыр иде.* Р.Вәлиев. *Ул [җил] җир өстендә аунаган олы-олы нәрсәләрне дә урыныннан кубарып алып, туздырып, очыртып алып китте.* Х.Ибраһим

2) Ташлау, ату (кирәксез нәрсә тур.). --- *тагын берничә иннек, бит тиресен чистарта торган тоникны чүп савытына «очыртырга» туры килде...* Ватаным Татарстан

3) *к.* **очыру** (*5 мәгъ.*). --- *абый кырыйга качып өлгерә, ә мине исә шул мотоцикл бәреп ерakka очырта.* Р.Нуруллин. *Вәлия белән Ярмөхәммәт «сталавай ашап» туйганчы, ирләр сургуч башларын уч төбе белән очыртып кына ике шешә аракы эчеп бетерделәр.* Р.Батулла

4) *күч.* Бик кызу йөртү (транспорт тур.). *Егетләр машиналарны очыртalar гына*

5) *күч.* Җитез эшләү. *Байгышның --- таза беләкләре көлтәләрне йон очыртkан шикелле очыртудан туктамый.* Ф.Сәйфи-Казанлы

6) *күч.* Ашыгып уку, сөйләү. *Очыртып уку*

7) *күч.* Ялганлау, арттырып сөйләү. *Очыртасыз да, Закир әфәнде. --- [клиентлар] сездән ишетмичә дә фирманы беләләр.* Ф.Әмирхан

2. очыртып *рәв. мәгъ.* Бик тиз. *Очыртып кына кибеткә барып кайту*

◊ **Очыртып мактау** Бик нык мактау. *Захар Петровичның Ксенья Петровнаны, шундый шәп врач дип, очыртып мактавы --- Камилне өметләндереп җибәрде.* М.Әмир. **Очыртып чыгару** Куу. *Их, хәлемнән килсә, мин ул бөкре карчыкны моннан очыртып кына чыгарыр идем.* Н.Дәүли. *Түли алмасаң, очыртып чыгаралар.* Безнең гәҗит

Очыртып бетерү Тулысынча очырту. *Анда калкурак төш, булган хәтле дымын да очыртып бетерә язгандыр инде.* Э.Касыймов

Очыртып җибәрү Кисәк очырту; җиңел генә очырту. *Сайгушев паспортны эчке кесәсеннән имән һәм урта бармаклары арасына элэктереп чыгарды да Назыймга таба очыртып җибәрде.* М.Хуҗин. *Әхсән аны әләкче Хәниягә төбәп очыртып җибәрәчәк.* Ватаным Татарстан

Очыртып тору Гел, даими очырту; хәзер очырту. *Җил үзе себереп алып килгән карны үзе үк очыртып тора.* Сабантуй

ОЧЫРУ *ф.* 1) Очып китәргә мөмкинлек бирү. *Һавадагы торнага ышаныp, кулыңдагы чыпчыкны очырма.* Мәкаль

2) Һавада хәрәкәт иттерү (җил тур.). *Очырырга җил көчле, очыртмаска ир көчле.* Мәкаль

3) Очарга өйрәтү (кошлар тур.). *Уҗымнарның тишелеп чыгышына карап, сыерчык бала очырган атнаның җомга көнендә үткәрелә, июнь аеның беренче җомгасына туры килә.* Ватаным Татарстан

4) Берәр нәрсәне көч белән ату, ыргыту, чөю.– *Таш ничек шома очты! Җиңел очты, әй, – диде берсе артыннан икенчесен очырырга торган Рамзан.* Х.Ибраһим

5) Берәр нәрсәне көч белән сугып, тибеп, төртеп, селтәп җибәреп урыныннан күчерү, тәгәрәтү, мәтәлдерү. *Үз баласы дип уйласа, имгәтерлек итеп сугар, йөк өстеннән очырып төшерер идеме?* Р.Мулланурова

6) *күч. сөйл.* Вазифадан азат итү, эштән куу. *Әмма белеп торам: очырачаклар мине председательлектән...* В.Нуруллин. *Әнә бит әле, Казанда күптән түгел генә, ялган детекторы аша уздырып, күпме түрәне эшләреннән очырдылар.* Ватаным Татарстан

Очыра башлау Очырырга тотыну

Очыра тору Әледән-әле, һаман саен очыру. *Камыржан, җилләнеп,*

Гыйфрит өстенә куна торды, тегесе аны йөгереп килгән мәлгә бертуктаусыз очыра торды. Х.Ибраһим. *Дошманнар машинаның килүен күреп калганнар булса кирәк, пуляларны, шартлаткычларны бер-бер артлы очыртып кына тордылар.* Безнең гәҗит

Очырып бетерү Тулысынча очыру, һәммәсен очыру. --- *Көчек сатып алган акчаларын морожныйга, кинога әллә кайчан очырып бетергәннәр иде теге ташбашлар.* Ф.Хөсни. *Тәрәзәгә ябышкан карларны җил очырып бетергәнме, үзләре эрегәнме – ни генә булса да, тәрәзәләр чиста кала.* Ф.Шәфигуллин

Очырып җибәрү Кисәк очыру. *Поездны куып чапкан җилбәзәк җил иркенә Алсу эшләпәне очырып җибәрде...* Ф.Дәүләтгәрәева

Очырып тору Гел, даими очыру; хәзер очыру. *Ерак түгел бер карт тары җилгәрә: җил миңа кибәкне очырып тора, мин, шуларны тотып, аркан ишә башладым.* Әкият. *Яшьләргә гел бет коярга, адреналиннарны селкетеп, очырып торырга кирәк.* Безнең гәҗит

Очырып яту *сөйл.* Күптәннән бирле очыру; ашыкмыйча, салмак кына очыру процессында булу. *Яңгыр юклыктан сусап, кара тузан очырып ятkан кара җиргә алтын кебек бодай бөртекләре чәчеп, шуларны әрәм итүдән йөрәкләре өзгәләнгән берничә авыл карты кичләтеп кенә колхоз идарәсенә килделәр.* З.Зәйнуллин. --- *юрганнарын идәнгә үк очырып ята бирә кара чәчле сипкелле кыз.* Р.Гаязетдин

ОЧЫШ *и.* 1) Һавада бер урыннан икенче урынга хәрәкәт итү. *Очыш вакытында җир белән күкнең урыннары алмашып-алмашып ала.* Ф.Яруллин

2) Авиациядә, космонавтикада: очу рейсы. *Хезмәт чорында [ул] 700 сугышчан очыш ясый.* Биектау хәбәрләре

3) Һавада хәрәкәт итү рәвеше, манерасы. *Яшел чирәм өстенә чалкан ятып күзәтә идем мин тилгән очышын...* Р.Мөхәммәдиев

4) *күч.* Хезмәт баскычында бик тиз үсеп китү, уңышлы карьера. *Карьераның, фәнни очышның очы-кырые юк.* Ватаным Татарстан

5) *күч.* Күңелдә күтәренке хисләр кичерү халәте. *Мидхәт үзен кайнар өермә күтәреп алып киткәндәй хис итте, һәм бу очыш бернәрсә белән чагыштырып булмаганча татлы иде.* М.Маликова

ОЧЫШЛЫ *с.* Билгеле бер арага яки зур тизлек белән оча торган. *Әмма ул тавыш тизлегеннән дә тизрәк очышлы самолётларда юкка гына очмаган шул.* А.Хәсәнов

ОШАК *и. диал.* Әләк. *Минем кулымнан тотып ук диярлек яздырган шушы аңлатма кәгазен Сез, әле ошак, әле донос дип, төрле җирдә төрлечә әвәләпме әвәлисез.* Ислам – татарлар һәм мөселманнар

ОШАКЛА́У *ф. диал.* Әләкләү

ОШАКЧЫ *и. диал.* Әләкче. *Ошакчы бул, ялачы – яз шикаять, – Аннан, оялмый, күкрәк сугып әйт: йөрәк – Халкыма чын мәхәббәттән гыйбарәт!* Р.Гаташ

ОШАТУ *ф.* **1.** 1) Хуплау, ярату; кабул итү; лаеклы, яраклы дип табу. *Бергә эшләүче Равил исемле егет шул кыска гына вакыт эчендә аны ошатырга өлгергән.* Туган як

2) Күңелгә якын күрү, үз кабул итү. *Беләсеңме, минем иптәш кызым Фәридә бик ошаткан сине.* З.Фәтхетдинов

2. ошатып *рәв. мәгъ.* Килештереп; ышандырырлык итеп. *Ай ахмак, ошатыбрак алдый да белмисең.* М.Фәйзи

Ошата төшү Бераз ошату; тагын да күбрәк ошату. *Шуңа мин үземнең фамилияне ошата төшәм.* М.Мөхәммәдиев

Ошатып бетерү Тулысынча ошату, тәмам ошату. *Бу сүзне ошатып бетермәүчеләр бар.* Т.Нәҗмиев. *Эмигрантларны ошатып бетермиләр.* Татарстан яшьләре

Ошатып җиткерү Билгеле бер дәрәҗәдә ошату. *Бу яңалыкны бик ошатып җиткермичә, Рудольф теш агартып куйды.* Р.Вәли. *Шома йөзле, ачык маңгайлы, озын чәчле бу егетне нигәдер ошатып җиткермәде [Җәмилә].* М.Әмирханов

Ошатып йөрү Күптәннән бирле ошату. *Җитмәсә, күңелдә мәхәббәт дигән нәрсә үзен сиздерә башлады, үзебезнең күрше кызы Хәлимә апайның сеңлесе Филсинәне ошатып йөрим.* А.Хәсәнов. *Бу көләч кызны ул мәктәптә укыганда ук ничектер ошатып йөри ---.* М.Хуҗин. *2004 елда Мәҗит ошатып йөргән кызына дүрт тапкыр кияүгә чыгарга тәкъдим ясаган ---.* Мәдәни җомга

Ошатып кую Кисәк яки кыска гына вакытта ошату

ОША́У *ф.* **1.** 1) Күңелгә хуш килү; яхшы тәэсир калдыру // Кызыксыну, рухи якынлыкка омтылу хисе барлыкка килү. *Яшәү рәвешең ошамый, ә үзгәртергә көчең юк.* Н.Гыйматдинова

2) Кемнең дә булса зәвыгына, теләкләренә туры килү. *Үсмер чакта зур буласы килә, Мөстәкыйльлек ошый нигәдер...* Р.Рахмани

3) Берәр нәрсә белән мавыгу, шул эштән канәгатьлек, ләззәт табу. *Миләүшәгә шундый затлы әйберләргә хуҗа булу бик ошый.* Ф.Яруллин

2. ошамаганны *ы. мәгъ.* Дөрес булмаган, ярамаган, килешмәгән, гайре табигый булып тоелган хәл турында. *Бер үземне ялгыз калдырып китмәкчеләр. Ошамаганны...* Р.Төхфәтуллин

◊ **Ошап тору** Тулысынча ышанып әйтмәүне белдергәндә кулланыла. *Безнең эшләр барып чыгарга ошап тора әле, Фәнис энем.* Ф.Яруллин. *Бала үзе дә ата кулына бик тиз ияләшергә ошап тора.* Н.Гыйматдинова

Ошап бетү Тулысынча ошау. *Кенәзгә хезмәте ошап бетми бугай.* Батулла. *Шуңа күрә власть вәкилләренә дә бик ошап бетми ул.* Казан утлары. *Ә бу исә күпләргә ошап бетми, шуңа күрә Фәнне юлдан читкә алып ташларга тырышучылар күп булды...* Идел

Ошап җитү Тиешле дәрәҗәдә, тулы күләмдә ошау. *Аның [Жанның] акча төртеп ычкынырга теләмәве ауга чыгучыларның җиңенә язулы чүпрәк бәйләгәненә ошап җитмәде, ахры.* Ш.Рәкыйпов. *Беләсеңме тагын ни, Сөембикә. Миңа синең теге мөгаллимең Искәндәр дә ошап җитми.* М.Хәбибуллин. *Мондый үзгәреш аңа бик үк ошап җитмәде.* Н.Фәттах

Ошап калу Алдан ук бер ошап, шул фикер үзгәрмәү. *Сиңа да, эч пошканнан кызык итеп түгел, күңелемә ошап*

калганга хат язам һәм үз күңелемдә, үз телемдә булган сүзләр белән язам. Р.Мөхәммәдиев

Ошап китү Билгеле бер моменттан ошый башлау. *Тора-бара бу ярыш бик кызык булып, барысына да ошап китте.* Н.Әхмәдиев. *Күренеп тора: агайга килүченең мөселман кешесе булуы һәм шул рәвешле сәламләве ошап китте.* М.Мөхәммәдиев. *Күңелегезгә ошап китсә, шушында гына торып калырсыз.* Р.Вәлиев

Ошап кую Кисәк ошау. *Ә хатын-кызлар шулай: кем дә булса аларның башын әйләндерә икән, кем дә булса аларга ошап куйган икән – башта алар ул кешегә эттән дә турылыклырак булалар.* В.Нуруллин. *Ефәкнең бу үзлекләре Рим аристократиясенә бик ошап куя, ефәкне бик сорталар, хакына тормыйча, даулашып алалар.* Р.Әхмәтьянов. *Оныгының шаяртып сөйләве Сәрвиягә ошап куйды, шулай да сүзне уенга кайтарып калдырмады.* М.Хуҗин

Ошый бару Торган саен күбрәк ошау. *Телгә оста, анекдот-мәзәкләргә бай Гамбәр Әлфинурга торган саен ныграк ошый бара.* З.Фәйзи

Ошый төшү Бераз ошау; тагын да күбрәк ошау. *Шунда Миңлегөл Сәфәргали абзыйга тагын да ошый төште.* З.Фәйзи. *Шулай да ул миңа романтик буларак күбрәк ошый төшә.* Х.Бәдигый. *Тышкы күренеше, озын йонлы тиресе һәм түгәрәкләнгән колаклары белән ак төлке --- дала төлкесенә (карсак дип атала торган төлкегә) ошый төшә.* Хайваннар турында очерклар

ОШАУЛЫ *с. сөйл.* Ошый торган, яхшы. *Ә хатын-кызга ошаулы әйбер табасы да читен.* Шәһри Казан

ОШАШЛЫ *с. сөйл. к.* **ошаулы**. *--- Сату турында белдерүләр күп булса да, ала башлагач, күңелгә ошашлы фатир табуы авыр икән.* Акчарлак

ОШАШУ *ф. урт. юн.* Бер-беренә ошау, яратышу

ОШБУ *а. иск.* Бу, шушы. *Ошбу әүлия кеше белән бәхәсләшкәнче, ул язган китапларны уку хәерлерәк булыр.* М.Хәбибуллин. *Тормышта язмышлар төрле булган кебек, ошбу китапта да хикәя-повестьлардагы геройларның үй-кичерешләре --- үзләренә генә хас кичерешләр аша бирелә.* Ф.Яруллин. *Ошбу мизгелдә ул үзен бөек акыл иясе итеп хис итте.* Х.Ибраһим

ОЮ I *ф.* 1) Йокымсырау, изрәү. *Башын куюга онытылып йокыга ойый торган бәхетле көннәрен сагынды [ул].* Р.Мулланурова

2) *иск.* Йоклау. *Ул Зөләйха бер көн ятып оер иде, Бер даясе кереп аның хәлен белде ---.* Кол Гали. *Бахбай канәгать бер изрәү кичереп, аягүрә ойый.* Р.Батулла

3) Берәр нәрсәгә бирелеп, үз-үзеңне оныту, онытылу. *Оеган, аңгырайган чырайлар бердән сискәнеп, куркудан агарып катып калды.* З.Фәтхетдинов. *Актарылып-актарылып, болыт Киләчәктә... оеп явачак.* М.Әгъләмов. *Мин үземә төбәлгән күзләргә карап оеп утырам.* Р.Габделхакова

4) Тып-тын булу, хәрәкәтсез тору. *Суынып барган мич арты. Дөм караңгы өй. Оеп йоклый авыл йорты.* Сөләйман

5) Йомшару, изрәү (тән әгъзалары тур.). *Карчык аның беләгеннән сыпырасыпыра пышылдаган саен, тән ойый, ми күзәнәкләренә йокы дулкыны агыла иде.* Н.Гыйматдинова. *Куркыныч төштәге кебек, вакыт туктап калды: зиһен богаулангган, күл-аяк каушаудан оеган, коточкыч әкрен кыймылдаган төсле.* З.Фәтхетдинов

6) *күч.* Йомылып яшәү; акыл эшчәнлеге күрсәтмәү. *Миңа көрәш кирәк иде, тыныч тормышта оерга минем җилкенчәк йөрәгем риза түгел иде.* М.Максуд

Оеп бетү Тәмам ою

Оеп калу Билгеле бер вакытка оеган булу. *Бөтен гәүдән рәхәтлеккә талган – Оеп калган...* Р.Гатауллин. *Ай, --- ачыклыкка килеп чыккач кына тукталып, чиксез күк йөзендә бер ялгызы өметсез елмаю булып оеп кала.* М.Галиев

Оеп китү Әкренләп ойый башлау. *Оеп китә Габдуллабыз, Сизми поезд туктаганны.* С.Гәрәева. *Көндезләрен нужа арбасын өстерәп, кичкә, хәлдән таеп, урынга барып ятуга оеп китә торган җан ияләре...* М.Маликова

Оеп тору Билгеле вакыт дәвамында яки хәзерге моментта оеган хәлдә булу. *Бичара хайван ашавын онытып, оеп тора.* Р.Батулла. *Ә син, Хаммат дус, Бохар мәчесе шикелле оеп торма, үзең дә әүлия түгел.* Р.Вәлиев

Оеп утыру *сөйл. к.* **оеп тору**. *Язгы көндә оеп утырган Сакмар урманы да, аксыл томанга уралып беткән ераклыклар да дәшмиләр иде.* Ф.Сафин

Оеп яту Ою процессында булу; хәзерге вакытта ою. *Әйе, әйе, берни эшләми, киләчәкне онытып, Җаек мәдрәсәсендә оеп ятуның бер чиге булырга тиеш иде.* Ә.Фәйзи

Ойый бару Акрынлап, эзлекле рәвештә ою. *Һәм үз тәненең акырын гына ойый баруын, йөрәк тибешенең югалуын тойган.* М.Кәбиров. *Шул җылыга ойый барган Тәңгәрәй, маңгаен руль өстенә куеп, күзләрен йомды...* Г.Гыйльманов. *Мин үземнең ойый баруымны сиздем.* Идел

ОЮ II *ф.* Сиземлелеген югалту, матрау (тән әгъзалары тур.). *Куллар ойый, күз аллары караңгылана.* С.Таһиров. *Билем ката, куллар ойый, башым тубал күк була торган иде.* К.Тимбикова. *Баянны Фиданга тоттырып, оеган аякларын көчкә яза-яза, Рүдәл янына килде.* Р.Вәлиев

Оеп бетү Тәмам ою. *Мансур Ибраһимовичның, утыра-утыра, тез башлары оеп бетте, арка умырткасы чеметкәли башлады.* Х.Ширмән

Ойый башлау Ою билгеләре күренү. *Сәүбән каршы килмәде, көне буе өйдә утырып ойый башлаган аякларын үз иркенә җибәрде – бию дигән тылсым ихтыярына тапшырды...* Г.Гыйльманов

ОЮ III *ф.* Билгеле бер реакциягә кереп (әчеп, югары температурада һ.б.) куеру, оешу, койка сыман хәлгә килү (сыеклыклар тур.). *Турсыкта сөтем оемый.* Табышмак. *Тормыш итү, яшәү сөте саваплы бер савытта оеган да, мине, шул оеткыны әйрәнме, эремчекме итәр өчен, иләк, марля урынына келәт диварындагы чөйгә, кадакка элеп куйганнар.* Ә.Гаффар. *Сабынлы суның үзен генә купороска салырга ярамый, чөнки катнашма ойый.* Файдалы киңәшләр

Оеп бару Ою процессында булу. *Шул караш аның монда берьялгызы*

гына түгел икәнлеген искәртеп, Микәйнең оеп барган канына яңадан кайнар учак якты. Р. Мөхәммәдиев

Оеп бетү Тәмам ою

Оеп җитү Тиешле дәрәҗәдә ою. *Оеткы салган сөт 25–30 минутта оеп җитә.* Юлдаш

Оеп китү Әкренләп ойый башлау. *Сөт шул арада оеп китте.* Казан утлары

Ойый башлау Ою билгеләре күренү. *Наил палатага кергәч тә, тәрәзә төбендәге ойый башлаган сөтне түгеп, савытын юып куярга булды.* Мәдәни җомга

ОЮ IV *ф.* Эштә, үз-үзеңне тотышында кемгә дә булса иярү, буйсыну. *Талип, намазга оеган мөселман шикелле, кулларын кендегенә куеп, җирән керфекләрен җиргә терәп, тик кенә тора.* Ә.Еники. *Кеше намазга оеганда, башкалар дини китаплар укып утыруын әйттем.* Т.Әйди. *Иң яхшысы: аларга кеше белән бергә имамга оеп уку, әтеләк-догаларны татарча да кылырга була.* Ф.Бәйрәмова

Оеп тору Билгеле вакыт дәвамында яки хәзерге моментта оеган хәлдә булу

ОЮЛЫ *с.* Оета (I) торган; йокылыуяулы. *Оюлы тынлык*

ОЯ *и.* 1) Кош-кортның, җәнлекләрнең ышыклану, йомырка салу, бала чыгару өчен җайлаштырылган яки кеше тарафыннан ясалган урыны. *Ә беркөнне урманда шөпшә оясын таптым.* Ф.Яруллин. *Түбәсе калай белән ябылган, ачык зәңгәргә буялган оясын Актырнак бик килештерде.* А.Хәсәнов. *Тавык оясында маяга һәрвакыт бер йомырка калдырырга киряклеге дә мәгълүм.* Ә.Хуҗиәхмәтов

2) Бал кортлары яши, бал җыя торган эче куыш багана яисә әрҗә, умарта. *Дымлануга юл куелмагач, кортлар оя эчен коры тоткач, кәрәзләр күгәрми дә, бозылмый да.* Өмет

3) Бер ана кош басып чыгарган һәм шул ана белән бергә йөргән кош балалары. *Арырак су өстендә бер оя үрдәк күренде ---.* М.Хәбибуллин. *Капкадан бер оя каз куалап чыгып килгән кыз урамнан узып барган егеткә башын күтәреп карады.* М.Маликова. *Үрдәкләребез дә ике оя безнең.* М.Хуҗин // Бер умартада яшәүче бал кортлары. *Ул үзе дә 25 ләп оя умарта тоткан, совхозныкын да карарга өлгергән.* Әлки хәбәрләре. *Көчле ояларга рам белән ясалма кәрәзне беренче баллы культуралар чәчәк ата башлау белән куялар.* Сарман

4) Бергә тупланып, күпләп үскән үсемлекләр төркеме. *Ак кар – бәлки, ак чәчәккә баткан балан оясыдыр: тузгый.* Р.Мулланурова. *Салкыннар куркынычы бетүгә, цукини, патиссон, кабак утыртылган һәр ояда берәр әйбәтрәк үсеш алган үсентене калдырырга кирәк.* Ватаным Татарстан

5) Бер төр җәнлекләр күпләп яшәгән, булган урын. *Кандыр буе, ай, кара урман – Киек җәнлеккәйләр оясы.* К.Тинчурин

6) Төркем-төркем булып урнашкан корылмалар. *Шушы калкулыкта бер оя булып өч-дүрт йорт утыра.* Н.Фәттах

7) Чикләвек, җимеш кебекләрнең орлыгы урнашкан каты катлавы. *Чикләвек төше дә оясында шулкадәр җайлы ятмый торгандыр.* Ф.Шәфигуллин

8) Нәрсәне дә булса салу, урнаштыру өчен махсус эшләнгән урын, уенты. *Тәгәрмәчләр җыелып ояларына кереп утырганда, очкыч калтыранып куйды.* М.Юныс. *Зур йозак аңа юри генә элеп куелган икән: теге яктан этүләре булды, авыр бик бөтен оясы белән шап итеп идәнгә төште.* З.Фәтхетдинов. *Күн ояларга грек уты тутырылган чүлмәкләр куелган, филтәләр кабызылган, керешләр тартылган.* М.Хәбибуллин

9) Үсемлек орлыгын туфракка чәчү, үрентесен утырту өчен чокыр. *Сәрвия казыган чокырларга иелмичә генә бәрәңге сала, ялгыш төшкән бәрәңгеләрне Сәрвия ояларга җайлап куярга мәҗбүр иде.* М.Хуҗин. *Һәм ул, көрәген батырып-батырып, бәрәңге оялары казып бара башлады.* В.Нуруллин

10) Сугыш кырында: яшерен ут ноктaлары, пулемёт һ.б.лар урнашкан урын. *Зур оялар казып, пушкалар да позициягә куелды.* Х.Камалов. – *Сөйләшмә! Пулемёт оясын тизрәк казы! – ди шәүлә.* С.Таһиров

11) *лингв.* Тамырдаш яки мәгънәдәш сүзләр төркеме; сүзлек мәкаләсенең шундый төркем рәвешендәге төзелеше. *Ояда ясалма сүзләр саны бердән артса, мондый оя макроя була.* И.Сабитова

12) *анат.* Организмда, аерым бер әгъзада эчкә батып, чокырланып торган урын. *Һәр тешнең казналык сөягендәге тирән ояда утырган тамыры --- бар.* Биология

13) *махс.* Таблицада вертикаль баганалар горизонталь юллар белән кисешүдән барлыкка килгән шакмакларның берсе; күз, күзәнәк

14) *күч.* Вакытлыча яшәп яки качып тору өчен ясалган кечкенә куыш, өн. – *Качабыз, малай, – диде Хәбир, минем эчкә пошаман кергәнне сизеп, – печәнлеккә оя ясыйбыз да шунда кереп ятабыз.* Ф.Шәфигуллин. *Ә Рәмис, теләсә-теләмәсә дә, көннәр буе караңгы оясында качып ятарга мәҗбүр.* Р.Габделхакова

15) *күч.* Гаилә. *Болары инде Касыймны ишетеп кенә белә, бәйләмеш җепләр генә күптән өзелгән, мәгәр нәсел җепләре өзелмәгән, кайлардадыр, аерым ояларда, нәселләре дәвам итә.* Ә.Еники. *Һәр ояда балалар дөньяга килә, уллар-кызлар үстерәләр.* Ватаным Татарстан

16) *күч.* Дошман урнашкан, яшәгән урын. *Алман илендә нимес фашистларының оясын туздырыштым, Җапуниядә самурайларның сыртын сындырыштым.* Ф.Яруллин. *Гади исәп буенча, фриц үз оясын саклауны күбрәк кайгыртырга тиеш ---.* Х.Камалов

17) *күч.* Явыз максатлы кем яки нәрсә тупланган, гадәттә яшерен урын. *Минем максатым шулдыр: белергә – кайсы ояда шайтан күбрәк, һәм шунда мин яу йөрермен, шайтан оясын туздыру өчен.* М.Хәбибуллин. *Аларга күп кенә мәгълүмат чараларының Туваны җинаятьчеләр оясы дип күрсәтүе ошамаган.* Ватаным Татарстан

18) *күч.* Эш-хәрәкәт, хезмәт урыны. *Билгеле, эшли белмәгән кеше унбиш елдан бирле бер ояда гына утыра алмас.* Ә.Еники

19) *күч.* Берәр нәрсәнең төп чыганагы, башланган җире. *Аста, упкыннан читтәрәк, бер оядан чыгып, төннең соргылт караңгылыгына чумган*

прожектор көлтәләре сыман өч үр сузылып китә. Г.Кашапов

20) *күч.* Нәрсәнең дә булса киң таралган, хөкем сөргән урыны. *Урамнарда даңгыр-доңгыр узган ломовойлар, тротуар буйларында сала агайларының ат арбалары, кыскасы, нэп тудырган чын базар, чын сәүдә оясы!* Ә.Еники. *[Гөлзәйнәп]--- пляжларны «шүрәле оясы» дип атый, шәһәр халкының бу кыланмышын кыргыйлык дип саный иде.* М.Маликова. *Каланча исә көлке-мәзәк оясы иде: оста телләр сөйли, шома колаклар тыңлый.* Н.Гыйматдинова

21) *күч.* Яшәгән, торган җир. *Туган оям, кичер, яшьлек белән, Бәхилләшминитми киткәнмен.* Ш.Маннап. *Читтән килгән кешеләрме алар, әллә, авыл корыганда, тормыш зилзиләсенә бирешмичә, төп ояларыннан купмый калган кешеләрме?* Ф.Яруллин // Билгеле бер территория, яшәү урыны, торак. *1913 елда исә тайга арасында күмелеп югалгандай тоелган ояга да җәдит укуы килеп керә ---.* Т.Әйди

◊ **Оя башы** Гаилә башы, хуҗа, ата. *Әниләрдән тора инде бу: алар оя башына хөрмәт күрсәтсә, аның сүзен сүз итсәләр, балаларын да шуңа күнектерсәләр, өйдә генәме, илдә нинди тәртип булыр иде бит.* Сөембикә. **Ояга бәйләнмәгән** Ялгыз, гаиләсе булмаган, буйдак. **Оя кору** 1) Гаилә кору, йортлы, хуҗалыклы булу. *Әнә Луиза дигән кыз язылганда ук акыллы була белгән: хатын-кыз эше – оя кору, бала табу, дигән дә оештыручыларның авызларын япкан.* Х.Камалов. *Ник дисәң, егетнең әле укып кына йөргән чагы, ни акчасы, ни баш тыгар урыны юк, дигәндәй, оя корырлыкмыни?* М.Маликова. *Шул мизгелдән башлап, Уразаевның да тыныч оя корып, рәхәтләнеп гомер сөрер чаклары җитте.* Я.Зәнкиев; 2) Берәр эшкә җайлы гына урнашу; 3) Берәр кем-нәрсә тирәсенә елышу. *Бу авылда Ватан дошманы Оя кормак була озакка ---.* Ф.Кәрим. *Шуннан Каратау итәге башланып китә, усаллар яшерен оя корырлык аулак җирләр.* Т.Әйди; 4) Мәкерле план кору. *Дошманыңа каршы кайвакыт Пәрәвездәй оя корасың [кеше].* Ә.Синугыл-Куганаклы. **Оя тарату** 1) Хуҗалыкны, малны туздыру; 2) Берәр кемне (гаиләсе, якыннары белән) юк итү. **Оя тибү** *к.* **оя кору**. *Кайда оя тибә икән алар, Бәпкә чыгаралар кай җирләрдә.* М.Рафиков. **Оя төбе** 1) Кечкенә, шыксыз, соңга калып чыккан чебеш; 2) Төпчек бала. **Оя тоздыру** *к.* **оя тарату**

ОЯДАШ *с. лингв.* Бер тамырдан ясалган. *Оядаш сүзләр табу ул әле шигырь язу түгел.* Кызыл таң

ОЯ́ ИТҮ *ф.* Оялау; оя өчен яраклаштыру, ояга әйләндерү. *Күптән түгел безнең тәрәзә капкачын Оя итте минем сөйгән карлыгачым.* Г.Тукай

ОЯЛА́У 1) Оя ясап урнашу. *Уылдык чәчү вакыты җиткәч тә, чуртаннар --- уылдыкны «оялап» – бер ана балык белән берничә ата балык кына берләшеп чәчәләр.* Кызыклы ихтиология. *Бу гажәп хәлне тикшергәч, шул ачыклана: мичкә такталарына агач шөпшәсе оялаган булган икән.* Кызыклар дөньясында

2) *лингв.* Оядаш, тамырдаш сүзләрне төп сүз мәкаләсе эченә туплау

3) *күч.* Кая да булса урнашу, төпләнү. *Арчага барып оялаган Юныс морза бөтенләй өметсез кеше түгел кебек иде ---.* М.Хәбибуллин. *Авылыгызны ташлап, Казанга оялыйсыз да шуннан безгә акыл өйрәтеп ятасыз!* Р.Вәлиев

4) Мәкерле максат белән урнашу, тамыр җәю. *Сәфәров – карьерист, --- идарәдәге җылы урынга кереп оялады.* Г.Кашапов. *Башта авыл советына кереп оялап, үзенә тиешле салымнарны да алдап-йолдап безгә бүлә идең.* М.Хуҗин

5) Күңелгә, йөрәккә һ.б.ш. урнашу (хис, фикер тур.). *Әгәр күңелгә көнләшү уты ояласа, яман бит ул.* Р.Мулланурова. *Сүнәсе, бөтенләйгә суласы булса, күңелгә сүнек оялый, дилəр ич...* Б.Камалов. *Үз-үзең белән, дөресрәге, җаныңа кереп оялаган шайтан белән көрәшүе ай-һай авыр икән!* Ф.Яруллин

Оялап алу Тиз арада оялау. *Үз йортында оялап алган ике егет Габделбәр белән Назардан исә Туры карт бик канәгать, бик разый иде.* Э.Касыймов. *Амбарчы Ниса – Бүре Бадулның олы кызы – ашлык амбарына сугышның беренче елында ук оялап алган иде.* Г.Ахунов. *Ә менә мин хәзер Тургай абыйның кабинетында спектакльләр башланганчы оялап алам да, спектакль башланып, залдагы утларны сүндергәч, кешеләр арасына ыргып кысылам.* Ф.Яруллин

Оялап калу Вакытында, берәр форсаттан файдаланып ояларга өлгерү. *Ничә сөйләсәң дә, телдән төшми, күңел түрендә оялап калган да һаман үзен сиздереп тора.* Ватаным Татарстан

Оялап яту *сөйл.* Озак вакытлар оялаган булу. *Таушалган кәгазьләрдә оялап яткан хәзинәнең урыны күрсәтелгән булса?..* Я.Зәнкиев. *Никадәр «радикаль фикерле» булсам да, әле һаман ул даирәдә бөтенләй үк Иблис ялчылары оялап ятмыйдыр дип ышанырга телим икән шул.* З.Мифтахов

Оялый башлау Ояларга тотыну. *Чөнки ул минем терелүемә ышаныч тудырды, җанга оялый башлаган шик-шөбһәләрне куып юкка чыгарды.* Безнең гәҗит. *17 яшь бит, күңелгә күбәләкләр кереп оялый башлаган чак.* Кызыл таң

ОЯЛТУ *ф. йөкл. юн.* 1) Берәр нәрсә өчен шелтәләп, оялу хисе тудыру. *Оялтыйм кояшны Күзеннән кайнар яшь тамганчы.* М.Әгъләмов. *Ул аны юатырга да, оялтырга да белмәде.* Р.Вәлиев

2) Уңайсыз хәлдә калдыру. *Аның кызларга хас мондый табигый хәрәкәтләре Рифатны да оялтырга җитә калдылар.* Ф.Яхин

Оялта башлау Оялтырга тотыну. *Уртанчы апа бу хәлләрне олысына җиткереп, болар икесе бергә мине әти-әни янында оялта башлады.* Безнең гәҗит

Оялта төшү Бераз оялту; тагын да ныграк оялту

Оялтып алу Бераз оялту. *Шунда әни: «Әнә абыеңнан үрнәк ал», – дип, мине оялтып та алды.* Шәһри Казан. – *Нишләп алдалап язып ятасыз? – дип, кырыс тавышлы ир-ат оялтып алды хезмәткәребезне.* Әлки хәбәрләре

Оялтып бетерү Бик нык оялту

Оялтып җибәрү Көтмәгәндә оялту. *Шәрәфнең мине үз итеп, якын дус итеп каравы, шул ук вакытта Хатип турында да кайгыртуы мине оялтып җибәрде.* М.Ягудин. *Алагаем зур таза гәүдәле, матур ачык йөзле бу урыс хатыны егетне оялтып җибәрә язды.* Р.Гаязетдин

Оялтып кую Кисәк оялту. – *Сез бит Сергеев балалары, папагыз исән булса, нәрсә әйтер иде икән? – дип оялтып куя иде.* Туганайлар

Оялтып тору Даими яки хәзер оялту. *Намусың әгәр дә итәгеңнән тартып оялтып тора икән, берни дә кыла алмыйсың.* Ф.Яхин. *Дин әһелләре «намазга басмыйсыз» дип, хаклы рәвештә сүгеп, оялтып торсалар да, мәчетчиркәүләргә йөрүчеләр саны ишәя бара.* Хезмәт даны

ОЯЛУ I *ф.*1) Тартыну, уңайсызлану. *Их, оялам шул мин кызлардан.* Г.Афзал. *Дөнья шундый инде ул: исәннәр оялмаса, үлгәннәр кулдан тотмый.* Ә.Гаффар. *Яшь вакытыңда ярату хисен Күңел түрендә яшереп тотасың. Сөйгән кешеңә сөям дияргә Әллә ояласың, әллә куркасың.* Ш.Маннапов

2) Оятсыну, хурлану, оят тойгысы кичерү. *Ә миңа калса, өлкәнәя төшкәч, бу хикәяне ишеткән саен отыры ояла, намуслана идем.* М.Кәрим. *Җизнигә күтәрелеп карарга да оялам.* Ф.Яруллин. *[Ай] җирдәге гаделсезлектән оялды бугай, янә болытлар артына яшеренде.* Р.Мулланурова

Ояла башлау Оялырга тотыну. *Айнысам, үз-үземнән ояла башлыйм, бөтен кеше миннән көләдер төсле.* Р.Вәлиев. *Ә үсә килә бер-берсеннән ояла башладылар.* З.Кадыйрова

Ояла төшү Бераз оялу

Оялып бетү Бик нык оялу

Оялып йөрү Озак вакытлар оялу. --- *Табам икән, барысын да әйтәчәкмен, теге вакытта оялып йөргәнем өчен үкенгәннәремне белсәң икән син, Кәримәкәй-Каракүзкәй.* М.Хәбибуллин. *Без үзебезнең көчсезлегебездән гаҗиз калып, бер-беребезнең күзләренә карарга оялып йөрдек.* Ф.Яруллин. *Аннан соң ничаклы мин сиңа күренергә оялып йөрдем.* Т.Миңнуллин

Оялып китү Кинәт оялу. *Чит кеше белән концертка баруын ире беләдер шикелле тоелды, шуңа оялып китте [Гөлбикә].* М.Хәбибуллин. *Аңлады Әнис, аңлады. Кызарып, оялып китте.* Ә.Хәсәнов. *Үзе рәтләп белмәгән кыз турында җиңелчә уйлавы өчен Гөлсәйдә оялып китте.* Ф.Яруллин

Оялып кую Кинәт оялу. *Тавышының алай чыгуыннан ул үзе дә оялып куйды.* Н.Әхмәдиев. *Аның мәгънәле карашыннан хәтта оялып куям.* М.Галиев. *Әле хәзер дә, шул искә төшсә, оялып куя.* Р.Вәлиев

Оялып тору Даими яки хәзер оялу. – *Миннән оялып тормассың, – диде Әлфинә.* М.Маликова. *Хәрефләрне бик дөрес әйтмәсәң дә, оялып торасы юк.* Сабантуй. *Ә мин бер эштән дә курыкмадым, урам себерергә дә оялып тормадым.* Өмет

Оялып утыру *сөйл. к.* **оялып тору**. *Ә хәзер еш кына радио-телевидениедән телебезне вата-сындыра сөйләүчеләрне ишетеп, кызарып, алар өчен оялып утырасың.* Р.Вәлиев. *Көҗмә дус, елмаеп кына, сүз әйтмичә генә, үз өендә үзе оялып утыргандай утырган ипле Көҗмә, унсигез яшендә үтерелеп, әллә кайда ят җирдә ята...* Р.Батулла

Оялып яту *сөйл. к.* **оялып тору**. *Ничә көннәргә кадәр кеше күзенә күренергә оялып яттым.* Г.Камал

ОЯЛУ II *и. мәгъ.* Тартыну, читенсенү хисе. *Инсаф ияләре булганга, берберсен ничек кенә якын итсәләр дә, оялу хисен югалтмадылар* ---. М.Маликова. *Оялудан кызаралар, Куркудан агарыналар.* Ә.Синугыл-Куганаклы

ОЯЛЧАН *с.* **1.** 1) Бик тыйнак, базымсыз, тартынучан. *Ул – оялчан, тыйнак кыз, мин дә үземне кулда тота беләм.* М.Маликова. *Калган өч урынны француз комигы Фернандельгә охшаган, ләкин бик оялчан типтәр малае, тагын гадәттән тыш тыныч, тәртипле, безнең арада иң төпле саналган Казан арты егете һәм мин – өчәү бүлештек.* Р.Вәлиев. *Ул шушы оялчан карчыктан үзе дә тартына иде.* Н.Гыйматдинова

2) Оялуны чагылдырган, оялу күренеп торган. *Фәридә оялчан карашын аска яшерде* ---. Р.Вәли

3) *күч.* Яшеренгән. *Оялчан ай урагы читләтеп кенә йортлар арасыннан күтәрелеп килә.* М.Гали // Яшерен. *Кыяр-кыймас кына чәчәк аткан Бик оялчан изге хис иде.* Г.Афзал

2. *рәв. мәгъ.* Оялып, тартынып, уңайсызланып. *«Үземнең аккошыма бүләк итәчәкмен», – дип, инде яшь булмаган ир оялчан елмайды.* Ютазы таңы. *Кыяфәте баһадирларныкына охшамаган: уртачадан түбәнрәк буй, коңгырт кара күзләре бик әдәпле, хәтта оялчан карый.* Өмет

ОЯЛЧАНЛАНУ *ф.* Оялчанга әйләнү; оялчанлык күрсәтү. *Нюраның бит очында алсу бизәкләр кабынды, ул, яшүсмерләрчә оялчанланып, башын иде.* Г.Бәширов

Оялчанлана төшү Бераз оялчанлану

Оялчанланып бетү Бик оялчанлану

Оялчанланып тору Оялчанланган хәлдә булу

ОЯЛЧАНЛЫК *и.* Оялчан булу. *Ул кызлар аның карашыннан ук күзләренең аңа охшаганлыкларын беләләр, оялчанлыгын да беләләр, шуңа көтәләр* ---. З.Садыйков. *Флора белән Сабадырев, оялчанлыкларын җиңеп, бер-берсенә караштылар* ---. З.Фәтхетдинов. *Ә егетләре, итагатьлелектәнме, оялчанлык галәмәтеме – чакырмыйлар үзен.* М.Мөхәммәдиев

ОЯЛЧЫК *с.* Оялчан. --- *Мин рәшәткә капканы ачып, оялчык Нурны шунда кертеп тә җибәрдем.* М.Мәһдиев

ОЯЛЫ *с.* 1) Оясы булган. *Бу – оялы киек кошларның санын исәпкә алу өчен кирәк* ---. Татар-информ

2) *махс.* Газ яки һава белән тутырылган тишемле (бетон тур.). *Моннан тыш юл чатларында махсус оялы тактиль плитка җәячәкләр, ул сукырларга юнәлешне билгеләргә ярдәм итәчәк.* Кама ягы

3) *күч.* Өйләнгән, ирдәге, гаиләле

ОЯЛЫК *и.* 1) Оя корырга ярарлык материал

2) Тавыкларның йомырка салуы өчен, өсте ябык кечкенә әрҗә формасындагы махсус оя. *[Тавык фермасындагы] бишәр-алтышар катлы йортларга охшап торган оялыклар, почмакка сибелгән кабырчык, вак ташлар,*

кетәклектәге чисталык – һәммәсе Татьяна Родионовнаның күңеленә хуш килде. С.Рафиков

ОЯЛЫ КҮ́З БӘЙЛӘШ *и.* Күзе бәйле «көтүче»нең, сызык белән тирәләп алынган «оялар»дагы уендагыларның берсен табып, аны тану, исемен дөрес әйтүгә корылган уен. *Балалар оялы күз бәйләш уйныйлар*

ОЯТ *и.* **1.** Начарлык яисә гаеп эш эшләүне аңлаудан туган көчле уңайсызлану, үкенү, хурлану хисе. *Кешедә иман да, оят та калмады.* Н.Гыйматдинова

2. *с. мәгъ.* Хурлыклы, әдәпсез. *Халык бик озаклап көлде, тагын әллә нинди оят сүзләр кычкырдылар.* Г.Ибраһимов. *Әйтерсең мин гафу итмәслек оят эш эшләдем.* М.Юныс. *Оят эшне эшләү бер кыен, ә кешеләргә сөйләү икеләтә кыен.* Ф.Яруллин

3. *хәб. функ.* Хурлыклы булу, оялу хәле. *Безгә бүген ул хакта уйларга оят булырга тиештер.* М.Хәбибуллин. *Оят та, кыен да булып китте миңа.* В.Нуруллин

◊ **Оят белән алыш-бireш бетү** *к.* **оят җую**. **Оят белү** Тәртипле, әдәпле булу. *Оят белмәсә картлар яшьләрдән, Яшьләр дә белмәс оят картлардан.* Ә.Синугыл-Куганаклы. **Оят җир** Гаурәт. *[Сара:] Кешедән оят, биллаһи! Сәгыйдулла: Оят җир күрсәтеп йөрим мәллә?* Ә.Гаффар. *Киенүен карагыз әле: күлмәк итәге, ташка үлчим, оят җирен дә капламаган.* М.Юныс. *Кем әйтмешли, оят җирләр каплангач, гаеп итү юк инде хәзер.* З.Фәйзи. **Оят җую** Әдәпсезләнү. *Оятын җуйганнар өчен заман һаман кулай әле.* Р.Муллануров. **Оятка калдыру** Кыен хәлдә калдыру. **Оятка калу** Ярамаган эше ачыкланып, уңайсыз хәлгә калу, хур булу. *Аның алдында оятка калмас өчен, Равил шуңа һәрвакыт иң элек математика белән физикадан бирелгән мәсьәләләрне чишеп куярга гадәтләнгән иде.* В.Нуруллин. **Оят качу** Әдәпсезләнү. *Ак мамыкка охшаган кар бөртекләре җиргә төшәргә ашыкмыйча гына очалар, әйтерсең Нурлыбикәнең ояты качкан йөзенә бәрелүдән, күз-керфекләренә кунудан куркалар иде.* Г.Кашапов. *Намус төшенчәсенә сан бетте, оят качкан җирдә аңа урын тарайды.* Н.Гыйматдинова. *Оятың качкан икән инде тәмам.* Ф.Шәфигуллин. **Оят качыру** Әдәпсезлек күрсәтү. **Оят килү** *к.* **оятка калу**. **Оят кирәк** Оялырга тиешле. *Чигенүгә инде чик куелды, Җитәр... оят та кирәк.* Ф.Кәрим. *Оят кирәк, миһербан-шәфкать кирәк.* Мәдәни җомга. **Оят китерү** Оятлы итү. *Рәхмәт, йөземә оят китермәдең.* М.Хәбибуллин. **Оятны оныту** Ояла белмәү, оятсызлану. **Оят өлеше** Кунак ашаганнан соң, савыт төбендә калырга тиешле ашамлык. *Оят өлеше табада калыр.* Мәкаль. **Оят пәрдәсен ерту** Оятсызларча гамәл кылып, кешене рәнҗетү. **Оят сату** Фахишәлек кылу. **Ояттан ашу** Оялуны белмәү. **Оятына көч килү** Оялу. *[Мияссәр һаман Рәсим ягына ишарәләп:] Яшьләр оятына көч килсен.* А.Гыйләҗев. *Оятларына көч килде, күрәсең. Шулчак француз коммунистлары, кыяр-кыймас атлап, тамаша залыннан үкчәләрен ялтыратмадылар.* Р.Вәли. *Анаң сөтен имгән йорт хәзер ят булдымы? Оятыңа көч килер...* Ф.Латыйфи. **Оятын җыеп бетерерлек түгел** Зур хурлык, рисвайлык турында. *Улым, начар сөйлиләр синең турыда. Оятын җыеп бетерерлек түгел...* М.Хуҗин. **Ояты ни тора** Бик оятлы булу турында. *Өйләнмәгән, туйлар ясамаган килеш балалы хатын иярtеп кайтуның ояты ни тора...* М.Маликова. *Ояты ни тора бит, директор башың белән ат танымыйча йөре инде.* Я.Зәнкиев. **Оятын кая куярсың?** Оятка түзү, оятны күтәрү турында. *Тик качып котыла алырсыңмы?! Моның оятын кая куярсың?* М.Хәбибуллин. *Синең ярдәмеңә мохтаҗ түгел, дип өстәсә? Оятын кая куярсың?* Р.Мирхәйдәров. *Хәбирә алдында оятын кая куярсың?* Х.Ширмән. **Оятын күзенә кырып эчкән** Оятны оныткан. **Оятыннан җир тишегенә керердәй булу** Бик нык оялу. *Димәк, сарайдагы тынычлык бетәчәк, йөз оятыннан җир тишегенә кереп китердәй оятсыз хәлләр башланачак.* М.Хәбибуллин. *Оятыннан җир тишегенә кереп китәрдәй булса да, ул таллар арасында чәчелеп калган киемнәре янына бара алмый иде инде.* Ф.Латыйфи. **Оятыннан кая кереп качарга белмәү** Бик оятлы булу. *Оятыннан кая кереп качарга белмәгән Павлушин, калтыранып, гәҗитен кат-кат әйләндереп карап чыкты.* Х.Ибраһим. *Улыннан мондый эшне һич көтмәгән Әкрәм карый, оятыннан кая качарга белмичә, башын түбән иеп утыра иде.* М. Галәү. **Оятыннан кая керер җир тапмау** *к.* **оятыннан кая кереп качарга белмәү**. **Оятыннан керер тишек (җир) тапмау** *к.* **оятыннан җир тишегенә керердәй булу**. *Әгәр шулай булса, Ханәфи ише бәндәләр оятларыннан кая керер тишек таба алмас иде.* В.Нуруллин. *Маэмаем дәшми. --- Оятыннан керер җир тапмагандай кылана.* А.Хәсәнов. – *Гомер буена оятыңнан керер тишек тапмассың, – дип сискәнеп китте Әкрәм абзый ---.* Р.Мирхәйдәров. **Оятын олтырак итү** Оятны оныту, оятны бар дип белмәү. *[Гыйрфан мулла] оятын олтырак итеп [Зыя Камалиның] фатирына да барды.* С.Поварисов. **Оятын югалту** Оятсызлану. *Оятын югалтып, яңасын сорап кергән егетне колхоз рәисе: «Техникада йөри алмыйсың икән, җәяү йөре!» – дип, каты итеп сүгеп чыгарды ---.* Х.Ибраһим. *Югыйсә бер намуссыз хуҗаның сөткә су кушып яки бөтенләй оятын югалтып, коры сөтне су белән болгатып тапшыруы нәтиҗәсендә, сыйфатлы сөт тапшыручыларга да тап төшәргә мөмкин ---.* Әгерҗе хәбәрләре. **Ояты юк** Оятсыз

ОЯ́ ТАВЫГЫ *и.* 1) Чебиләр чыгарырга утыра торган яки чебиләре булган тавык; *русчасы:* **наседка**. *Оя тавыгын дөрес сайлап алуның әһәмияте бик зур.* Йорт эшләре

2) *күч.* Өйдә утырырга яратучан хатын-кыз; өй тавыгы

ОЯТЛА́У *ф.* Икенче берәү өчен оялу. *Торна оятын оятлап, ябалак урман түренә качкан.* Мәкаль

ОЯТЛЫ *с.* **1.** 1) Ояла белә торган, намусы булган. *Оятлы бала*

2) Хурлыклы, түбән. *Хәбирәнең оятлы хәлен сәгате-минутында ярты авыл белеп алган.* Ф.Яхин

3) Уңайсызлану, үкенү хисе чагылган. *Калтыраган куллары белән ул*

оятлы йөзен каплады һәм идәнгә бала алдына егылды. Н.Фәттах

2. *рәв. мәгъ.* Уңайсыз, гаепле итеп. *Оятлы хис итү*

ОЯТЛЫ́ БУЛУ *ф.* Хур булу, уңайсыз хәлдә калу. *Каладан килгән кеше алдында оятлы булуың бар.* М.Юныс. *«Фәнис алдында оятлы булдым, ничек күзенә күреним?» – дип әйтә, ди...* Г.Гыйльманов

ОЯТЛЫ́ ИТҮ *ф.* Хурлыклы итү, уңайсыз хәлгә кую. *[Зифа] аның иң яшерен хисләрен дөньяга чәчеп, оятлы итте.* Н.Гыйматдинова. *Ул аның йөз аклыгын саклый, күршеләр алдында оятлы итәргә теләмидер.* М.Маликова

ОЯТЛЫК *и. к.* **оят өлеше**. *[Кунаклар] бәлешне ашаганда мактап бетерә алмадылар, --- зур таба төбендә тик оятлык кына калдырдылар.* Г.Ибраһимов

ОЯТСЫЗ *с.* **1.** 1) Гаепле эшләрдән оялмый торган; әдәпсез, тыйнаксыз (кеше тур.). – *Сүз минем турыда бармый, синең оятсыз тәртибең турында бара, – диде [Хәлим].* Р.Айзатуллин. *Галәветдин утынга кистерде бит, оятсыз!* Т.Таһиров

2) Оят нәрсәне белдерә торган, әдәп кагыйдәләренә сыймый торган. *Астан аның якасына ябыштылар, чалбарыннан өстерәделәр, яман, оятсыз сүзләр әйттеләр ---.* М.Мәһдиев. *Оятсыз сүзләр язып, ул бит безнең яшьләрне боза.* Х.Ибраһим. *Җиде яшьлек әлеге кош ни өчендер нәкъ менә оятсыз сүзләрне генә исендә калдыра икән.* Татарстан яшьләре

2. *рәв. мәгъ.* Әдәпсезлек белән, тыйнаксыз итеп. *Авызын турсайта төшеп, чал төшкән калын мыекларының астыннан оятсыз елмаеп куйды Оруджиев.* М.Мөхәммәдиев. *Күзләрен оятсыз майландырып ялт-йолт карануларында, түшне киеребрәк, итәкне җилфердәтебрәк атлауларында ук дәрт-шәһвәтләрен баса алмый интегүләре күренә.* З.Фәтхетдинов

◊ **Оятсыз бүкән** Ояла белмәүче кеше. *Ә аның миендә дә юк. Оятсыз бүкән.* Ф.Яруллин.

ОЯТСЫЗЛАНУ *ф.* 1) Оятсызга әйләнү. *Шадра отыры аза, халык отыры оятсызлана ---.* Н.Гыйматдинова. *Була оятсызланырга, Була кычкырырга... Нигә әле эт шикелле Бәйдән ычкынырга?!* Р.Миңнуллин

2) Оялмыйча эш итү. *[Варя:] Оятсызланма, кенәз. Государыняның ишетүе бар.* М.Хәбибуллин. *Озакламый әни дә кайтып керде һәм оятсызланып: «Нәчәлство хатыны ул, аның акчасын тавык та ашамый, ире тагын алып кайтыр әле», – дип сөйләнде.* Б.Камалов. *Бу юлы немецлар бөтенләй оятсызландылар: төне буе сәгать саен берәр снаряд җибәреп тордылар ---.* Казан утлары

Оятсызлана бару Торган саен оятсызлану. *Ә ул торган саен оятсызлана барды.* Ф.Яруллин. *Ханым оятсызлана барып, Библиядән өзекләр китереп сайравын дәвам итте.* Безнең гәҗит

Оятсызлана төшү Бераз оятсызлану. *Шифоньердашым тагын да оятсызлана төште.* З.Мәхмүди

Оятсызлана башлау Оятсызланырга тотыну

Оятсызланып бетү Бик оятсызлану

Оятсызланып җитү Тәмам оятсызлану

Оятсызланып йөрү Берникадәр вакыт оятсызлану. *Чөнки хакыйкать эзләүче ул мәнле, игелекле кеше була, татар җирендә яшәп, татар телен өйрәнүгә каршы чыгып оятсызланып йөрми...* Безнең гәҗит

Оятсызланып килү Соңгы арада оятсызлану билгеләре сизелү

Оятсызланып китү Кинәт оятсызлану

Оятсызланып тору Әледән-әле яки хәзер оятсызлану

Оятсызланып утыру *сөйл. к.* **оятсызланып тору**. *Аек килеш оятсызланып утырганчы, эчеп оятсызлану әйбәтрәк, минемчә...* Т.Миңнуллин

Оятсызланып яту *сөйл. к.* **оятсызланып тору**

ОЯТСЫЗЛА́РЧА *рәв.* Оятсыз рәвештә, оятсызларга хас булганча. *Ни өчен дәүләт халыкны шулкадәр оятсызларча алдарга юл куя икән?* Х.Арсланов. *Нияз оятсызларча хыянәт итте, алдады ---.* Д.Каюмова

ОЯТСЫЗЛЫК *и.* Оятсыз булу сыйфаты; әдәпсезлек, үтә тыйнаксызлык. *Оятсызлыкның, намуссызлыкның соңгы чигенә җиттең бит син ул чагында.* Ф.Шәфигуллин. *Мондый оятсызлык, күрәлмәтә яла ягу Шамилне куркытты да, ярсытты да.* З.Фәтхетдинов. *Юк, бу кичәге оятсызлыкның дәвамы иде.* Н.Гыйматдинова

ОЯЧЫК *и.* Күзәнәк, кечкенә тишем. *Моның өчен башта оячык ясала, ул яхшылап дымландырыла.* Маяк

Ө

ӨГЕ *и. диал. к.* **өке**. *Өгемә шоңкар чөярмен ---.* Дастан. *Талгынлыкмы? Нидер коя кышның күге. Төп өстендә йокымсырый сукыр өге*. Ш.Гаделша

ӨГӘ-ҖӨГЕ *иярт.* Үзара дусларча, ягымлы сөйләшү рәвешен белдерә

◊ **Өге-җөге килү** 1) Якын дусларча сөйләшү, серләшү, гөрләшү. *Кызлар, Ләйлә янына җыелып, өге-җөге килделәр*. Г.Бәширов; 2) Бик якын, тату, дустанә мөнәсәбәттә булу. *Өге-җөге килеп яшәгән күршеләр бер-берсе белән кинәт дошман булдылар да куйдылар.* Татарстан яшьләре

ӨЕГҮ I *ф.* 1) Җенси ихтыяҗларын үтәү өчен, төркем-төркем җыелып йөрү (гадәттә хайваннар тур.). *Киләсе язның өегү вакытында мижнәкләр, үз нәүбәтләрендә, урман тавыклары өеккән урынга баралар.* Хайваннар турында очерклар

2) *күч. туп.* Кемнәр белән дә булса чуалу, буталу. *Кеше ирләре белән өегәсең, дип җанны кыйнады.* Мәдәни җомга

Өегә башлау Өегергә тотыну. *Минем малай кәнизәкләр белән өегә башлаган, ә син ни карыйсың?* В.Имамов

ӨЕГҮ II *и.* Хайваннар яки кошларның, төркем-төркем җыелып, женси ихтыяҗларын үтәү чоры; *русчасы:* **гон**, **ток**. *Яз керүе белән, суерларның барысызга да билгеле булган өегүләре (ток) башлана.* Хайваннар турында очерклар

ӨЕК *и.* Җенси ихтыяҗларын башкарыр өчен тупланган хайваннар яки кошлар төркеме (этләр, бүреләр, мәчеләр, суерлар һ.б.). *Имәнлек чокыры язгы өеккә чыккан ач бүреләрнең янып ялтыраган күзләре белән кайнап тора.* А.Хәлим

ӨЕЛМӘ *и.* **1.** 1) Ком, таш, туфрак кебекләрне өеп ясаган калкулык, өем; дамба. *Зәки, тимер юлы өелмәсе буйлап бер-ике чакрым баргач та, уңга борылып, тимер юл күпере астыннан узды.* Х.Мөҗәй

2) Җил, агым һ.б. тарафыннан китереп өелгән өем, көрт

2. *с. мәгъ.* Өем булып тупланган, җыелып торган. *Өелмә болытлар*

ӨЕЛҮ *ф.* 1) *төш. юн. к.* **өю**. *Калай мичкәләр, зур пыяла баллоннар, тау-тау өелгән тоз, тагын әллә ниткән ташлар, мәгъдәннәр, кыр буенда дистәгә якын баржалар.* Ш.Камал. *Мәйсәрәләрнең читәне буенда өелгән бүрәнәләргә авыл агайлары җыелып, төрле бабтан кызык-кызык хәлләр сөйләшеп утыралар иде.* М.Әмир. *Анда каралып беткән утын түмәрләре әрдәнәләп өелгән иде.* М.Галиев

2) Өемнәр барлыкка килү, өем булып тору. *Кайнап чыга җирнең байлыклары, Таудай өелә кара алтыннар.* Ә.Исхак. *Безнең чапкан ташкүмерләр Тау-тау булып өелер.* Ш.Маннур. *Айсылу алдына ап-ак итеп юган йомшак оекбашлар, ике бармаклы солдат перчаткалары өелә.* Г.Бәширов

3) Төзелү, салыну. *Ул тәбәнәк кенә, иске кызыл кирпечтән тигез итеп өелгән иде.* Ф.Галиев. *Бабайның: «Болар, улым, ярлыларның, ятим балаларның, тол карчыкларның каберләре өстенә өелгән кибәннәр», – дигән сүзләре әле дә исемдә.* Г.Гобәй

4) *сөйл.* Бер урынга тыгыз итеп, күпләп туплану, бергә җыелу. *Аның тирәсенә бер-берсен таптап халык өелде.* Г.Ибраһимов. *Һәммәгез монда өелмәгез, исем, фамилиягез белән үзем кычкырам.* М.Гали. *Тыгызлана ара, Арка тала, өелделәр, арттан кыстылар.* М.Җәлил

5) *күч.* Бик күп булып, туктаусыз берсе өстенә икенчесе өстәлеп тору. *Алдында өелеп эш ятканда, алар белән чуалырга ярыймы соң?* Ш.Камал. *Бу сораулар берсе артыннан берсе өелеп киләләр, һәм Мисбах аларга берничек тә җавап бирә алмый.* Г.Әпсәләмов. *Кыскасы, бәхетсезлекләр өелеп килгән инде бичарага.* Ф.Галиев

Өелә бару Туктаусыз өемнәр барлыкка килү, өелү процессы дәвам итү. *Машинаның астына коелган башаклар, кибәкләр дә шунда ук чыгарылып, аерым өемнәргә өелә баралар.* М.Гали. *Читләре кетердәп торган нәни кояштай түгәрәк коймаклар тәлинкәгә өелә бара, хуш исләреннән башлар әйләнә*. Г.Әдһәм

Өелә башлау Өелергә тотыну. *Карый башласам, барлык хәрефләр берсе өстенә берсе өелә башлый.* А.Әхмәт. *Кешеләр атлар чаба торган әйләнмә тирәсеннән тагын да ераккарак кача һәм көрәш мәйданы уртасына җыелып өелә башлады.* Н.Яһудин

Өелә тору Туктаусыз, берсе артыннан икенчесе, һаман өелү. *Алар берсе өстенә берсе өелә тора, тормыш низаглары һәм кеше характерлары ачыла бара*. Фән һәм тел. *Бозлар ага, өелә торды, ул арада халык, бер-берсенә шалтыратышып, бик күпләп җыела башлады.* Ватаным Татарстан

Өелә төшү Бераз, беркадәр өелү; тагын да күбрәк өелү

Өелеп бару Рәттән бер-бер артлы өелү. *Алар артына саламын-саламга китереп, бөртекләп тезгәндәй пөхтә бәйләнгән, кызлар кебек нечкә билле җыйнак көлтәләрдән бәпкәләр өелеп бара, чүмәләләр калкып чыга иде.* Г.Бәширов

Өелеп бетү Тулысынча, тәмам өелү. *Клубның стеналары инде өелеп беткән.* Туган як

Өелеп калу Кем яки нәрсәдән соң өелү. *Ә менә хәзер торып киттек исә, урыныбызда никадәр эш өелеп кала.* М.Фәйзи. *Алар киткәч, күл читендә пыяла, калай савытлар өелеп кала*. Ф.Сафин

Өелеп тору Бер өемгә тупланган булу. *Әнә шул гаскәрләрдән читтә тау кебек өелеп торган дары, снаряд ящикларын күрәсезме?* Ш.Мөхәммәдев. *Ике фанза арасына кереп кысылган*

капкалар янында ак ташлар өелеп тора. А.Шамов

Өелеп яту Бер урында тик өелеп тору. *Аларның берсендә бер пычрак һәм өелеп яткан тирес күрмәссең.* М.Гали. *Азык булырга тиеш кенә түгел, хәтта, уйлана торгач, аның хыялында таутау өелеп ята иде инде.* Ә.Еники. *Хәлим, карчыкның сәнәген тартып ала да, өелеп яткан ботакларны арбага төйи башлый.* И.Гази

ӨЕМ *и.* **1.** 1) Нинди дә булса урында калку итеп өеп куелган яисә калкулык сыман нәрсә. *Бункеры өстенә бишек элеп, ашлык өемнәре белән басуны тутырган нугай малае түгелме соң бу?* А.Хәлим. *Тиресне вак өемнәргә салырга ярамый, чөнки вак өемнәрдә ул тизрәк таркала һәм юыла.* Яшелчәчелек. *Әниләр ашлык көрәгәндә, бөртек өеменең убылып-убылып ишелеп китүен күзәтү, табаннарны рәхәт кытыклаган бодай өстендә йөрү, ятып аунауның ләззәтен аңлатып бетererлек түгел!* Татарстан яшьләре

2) Берәр урында тәртипсез рәвештә өелеп яткан нәрсәләр. *Шулар арасында ватык кирпеч өемнәре, кара кисәүләр, ялгыз моңаеп утырган морҗалар --- тагын әллә ниләр.* Ә.Еники. *Бүлмә уртасында мич салу өчен ташып куелган кирпеч өемнәре.* Г.Гобәй. *Казлар үлән арасына, ташлар өеме эченә, таш ватыклары арасына оялыйлар.* Хайваннар турында очерклар

3) Берсе өстенә икенчесе тәртип белән өеп куелган нәрсәләр. *Ике якта көлтәдәй итеп бауга бәйләнгән печән өемнәре.* Г.Минский. *Хәзергә койма буйларында өелеп яткан бүрәнә өемнәренә менеп йөгереп йөрде.* Г.Гобәй. *Ишек төбендә торган агач кровать өстендәге мендәрләр өеменә сөялеп йокыга киткән җиңги дә, без керүгә, сискәнеп уянды.* М.Әмир

4) Киптерү өчен җиргә утыртылып, өстеннән көлтә белән каплап куелган берничә көлтә. *Урак та тота белми икән Фәтхеттиннең хатыны. Фәтхеттин урганда, ул өем өстенә утырып карап торды.* И.Гали. *Абыйсыннан көлдермәс өчен, ул кичкә кадәр биш көлтә урып, дүрт көлтәне җиргә утыртып, бишенчесен башы белән өскә каплап, бәпкә ясап, бер өем куйды.* М.Гали

5) *сөйл.* Бергә җыелып тупланган кешеләр төркеме; өер. *Бары үзләренең, ягъни бер өем генә сорыкортларның корсак интереслары өчен генә файдаланалар.* Урал. *Аның артыннан бер өем яшерен полиция кешеләре йөриләр...* Урал

2. *с. мәгъ.* Түгәрәк-түгәрәк, катлы-катлы (болытлар тур.). *Җәй көне һәм көз көне өем болытлар дип йөртелә торган болытларны күрергә мөмкин.* Физик география

ӨЕМЛӘҮ *ф.* Өю, өемнәр ясау

Өемли бару Барысын да бер-бер артлы өемләү

Өемли башлау Өемләргә тотыну

Өемләп кую Тиз генә яки алдан өемләү. *Трактор күтәрткән чөгендерне йолкып өемләп куйдым, әниемнәр чистартып бетереп килә.* Г.Якупова

Өемләп тору Даими өемләү; хәзерге моментта өемләү

Өемләп чыгу Барысын да рәттән өемләү

ӨЕ́М-ӨЕМ *с.* **1.** 1) Берничә өем хасил иткән. *Тау өсләрендә өем-өем ташлар аунап ята.* А.Әхмәт

2) Бик күп. *Өем-өем кулъязмалар монда, йөрим гүя тарих урманында.* Р.Низамиев. *Китапханәләрдә ачып та каралмаган басмаларны, нәшрият складларында сатылмыйча яткан өем-өем китапларны күргәч җан әрни...* Р.Фәйзуллин

2. *рәв. мәгъ.* Берничә өем хасил итеп. *Ике кардәш ындыр табагында өем-өем яткан бодайны күрде.* Дәрдемәнд

ӨЕР *и.* 1) Бер айгырлы бияләр көтүе; бер көтү булып йөри торган атлар төркеме. *Арыслан ат өренә баш булса, арыслан өере булыр.* Мәкаль. *Тай дулап өреннән чыкмас.* Мәкаль

2) Этләр яки бүреләр көтүе. *Шушы икән инде ул бәйдән ычкындырып җибәргән өер!* Ә.Еники. *--- ә Равил Сәйдәшевич... өердән куылган яралы бүредәй, ерактан гына тыңлап-күзәтеп йөрде.* Н.Гыйматдинова. *Артыңнан куа чыккан эт өреннән котылып, тере дә кал.* Казан утлары

3) Балыклар, бөҗәкләр, кошлар һ.б.ш. төркеме. *Чыпчык өере кебек дәррәү күтәрелеп, малайлар авылга таба очтылар.* И.Гази

4) *сөйл.* Үзеннән-үзе оешкан кешеләр төркеме. *Менә ниндидер бер киңәшкә килеп, өерләре белән басу капкасына таба йөгерделәр.* И.Гази. *Габдрахманны ураткан малайлар өере урам буйлап китеп барды.* З.Зәйнуллин. *Яңа ел мәҗлесе кызып киткәч, авыл агайлары, тәмәке пыскытып керик әле дип, өерләре белән ишегалдына чыгып баскан.* Мәдәни җомга

5) *сөйл.* Нинди дә булса явыз максатка ирешер өчен, бер төркемгә оешкан кешеләр; банда, шайка. *Ата-анасы юк чагында, шәһәрдән өерләре белән үзе шикелле тотнаксыз яшьләр төяп килә...* М.Насыйбуллин. *20 сумлык билет ясап, миллионлаган керем алган өер турында сөйләмәслек тә түгел.* Н.Вахитов. *Аңлашыла ки, кышкы салкын көндә төрмәдәшләр өере юньле ният белән йөрми.* Мәдәни җомга

6) *күч.* Бик тиз хәрәкәт итә торган нәрсәләр, әйберләр җыелмасы. *Бөтермәле өер үтеп киткән.* Г.Гобәй. *Яктырткыч пулялар өере Мисбахның баш очыннан гына выжлап узды.* Г.Әпсәләмов

ӨЕРЕЛМӘ *и. к.* **өермә**

ӨЕРЕЛҮ *ф.* **1.** 1) Өермә рәвешендә күтәрелеп, бөтерелә-бөтерелә хәрәкәт итү. *«Ah!» – дисәң, шундук бөтен сабырың, карарың җимерелә, Эчтә дулкыннар куба, дәһшәт, өермә өерелә.* Ш.Бабич. *Болар гүя бер-берсе арасына революция тузаны кебек буталганнар, өерелгәннәр диярсең.* Г.Нигъмәти

2) *сөйл.* Бер урынга күп булып җыелу, күпләп туплану. *Галимҗан абыйлар, Әмирхан өенә Намуссыз, битсезләр өерелә.* Х.Туфан. *Тикшерүче башында өерелгән уйларны читкә куды.* Ф.Галиев. *Ятьмәгә эләккән кошлар, берсен-берсе тапап, пычратып, бу дустанә тоткынлыкта өерелде-өерелде дә, йөрәкләре ярылып, җиргә капланды.* А.Хәлим

3) *диал.* Күзгә нинди дә булса чүп кергәндәге кебек авырту барлыкка килү, күздә шундый авырту сизү. *Күз өерелү*

2. өерелеп *рәв. мәгъ.* Ябырылып, күпләп, зур тизлек белән. *Алар кара болыт кебек өерелеп килгән дошманнарны кырып-себереп ташлый алырлар идемени?* А.Шамов. *Ара-тирә җил чокыр эченә дә өерелеп килеп керә һәм, битләргә бәрелеп, чабулардан тартып, агач башларын шаулатып үтеп китә.* И.Гази

Өерелә башлау Өерелергә тотыну. *Ул Бәгърем тирәсендә өерелә башлады.* А.Хәлим

Өерелеп йөрү Һаман бертуктаусыз өерелү. *Гайниямалның себерке я идән чүпрәге тоткан килеш бүлмәдән бүлмәгә җил кебек өерелеп йөрүен Габдулла бу йортка төшкән көннән алып күрә иде.* Ә.Фәйзи

Өерелеп килү Тоташ, күп булып, зур тизлек белән хәрәкәт итү

Өерелеп тору Бертуктаусыз, бик еш өерелү

ӨЕРЛӘ́Ү *ф. диал.* Бер урынга туплау (хайваннарны). *Бәпкәләрне [ул] җилтерәтеп чиннеккә өерләде.* А.Гыйләҗев

Өерләп алу Тиз генә өерләү

Өерләп кую Алдан ук өерләү

Өерләп тору Әлеге вакытта, хәзер өерләү

ӨЕРЛЕ *с.* 1) Өер булып берләшкән, өердә йөргән. *Өерле эт аксагын белдермәс.* Мәкаль

2) *диал.* Төркем булып торган, төркем ясаган. *Кайбер урыннарда өерле таллар арасында кечерәк кенә камышлы күлләр дә күренеп алалар.* М.Гали

ӨЕРМӘ *и.* 1) Болытта барлыкка килеп, җиргә табан торба рәвешендә сузылып төшә, эчендәге түбән басым аркасында үзенә тузан, кар һ.б.ш.ны суырып югарыга күтәрә торган көчле һава агымы; гомумән бөтерелеп-бөтерелеп искән көчле җил. *Бөтерелә тышта өермә, Котырына буран бүген.* Х.Туфан. *Кай арада килеп чыккандыр, алан буйлап җил шаулап узды, өермә булып бөтерелде, каен төбендә кипкән үләннәрне, тузанны багана итеп күтәрде дә туп-туры аның өстенә таба килә башлады.* Ф.Галиев. *Еш кына өермә суның тамчысын да калдырмыйча алып бетерә.* Кызыклар дөньясында

2) *күч.* Бик тиз хәрәкәт итә торган зур төркем, көчле агым. *Әмма шул ук «нечкә күңелле» солдат, атакага барганда, дошман өстенә дәһшәт булып, өермә булып ташлана.* Г.Бәширов

3) *күч.* Берәр нәрсәнең бик күп булуы. *Сүзләр өермәсе көчәеп, һәммә сөйләүчеләрне каплап китте.* Г.Ибраһимов. *Дошман миналары өермәсен Ерып, алга бара дусларым.* Ф.Кәрим. *Язгы аклы-карада чабатаңда бер пот балчык өстерәп, туң җирне казып-чокып, кияргә чабатаң да булмаса, бозлардан бозларга яланаяк сикереп, салкынның утлы өермәсендә табаннарны пешерә-пешерә, черек бәрәңге эзләп үтә бит аларның көннәре...* А.Хәлим

4) *күч. сөйл.* Бик каты бәхәс, талаш, гауга, шау-шу. *Телефонда шау-шулар өермәсеннән тавышны бастырып кемдер сөйләргә тотынды.* Г.Бәширов

5) *күч.* Күңелдәге тынгысызлык, хисләрнең бик көчле һәм буталчык булуы. *Хисләремдә давыл, Уйларымда өермә.* Ш.Маннур. *Үзендә моңарчы барлыгы да беленмәгән хисләр өермәсен кузгаткан кечкенә кешене хәтеренә сеңдерәсе килү теләге аны тукталырга мәҗбүр итте.* Ф.Латыйфи

◊ **Өермә кубару** Тавыш, ызгыш чыгару. **Өермә күтәрү** *к.* **өермә кубару**. *Зинһар, өермә күтәрмә әле.* Б.Камал

ӨЕРМӘЛӘНДЕРҮ *ф.* Өермә китереп чыгару, өермә рәвеше бирү; өермә вакытындагы кебек итү, дулкынландыру. *Ләкин тагын әйләнде, тагын арыш өстен өермәләндереп, улап, җирне гаять зур тегү машинасында теккәндәй, тырылдап узды.* Ә.Еники

Өермәләндерә башлау Өермәләндерергә керешү

Өермәләндереп җибәрү Кисәк өермәләндерү

Өермәләндереп тору Гел, даими өермәләндерү

ӨЕРМӘЛӘНҮ *ф.* 1) Өермә булып бөтерелү; бик тиз, бик көчле, ашкынып хәрәкәт итү. *Алар дошман тылына кереп, өермәләнеп үткән көчле давыл кебек, аларның яңа көчләрен кырып, туздырып, юл өстендә очраган запасларны юк итеп, ныгытмаларны җимереп әйләнеп чыктылар.* А.Шамов. *Шулкадәр кыздыра, шулкадәр кыздыра: баш түбәсендә ялкыннар өермәләнә.* М.Әмир

2) Көчле җилдән дулкынлану. *Су өсте өермәләнә*

Өермәләнә башлау Өермә билгеләре күренү

Өермәләнә төшү Бераз өермә кебек бөтерелү

Өермәләнеп китү Өермә рәвеше алу

Өермәләнеп тору Гел өермә хәлендә булу

ӨЕРМӘЛЕ *с.* 1) Өермә (*1 мәгъ.*) белән бергә барган, өермә чыгарган. *Өермәле давылларда Сөмбелдәй сибелмәдем.* Ә.Ерикәй. *Мин хәтерлим карлы, өермәле салкын кышта туңып, күшегеп окопларда яткан чакны.* Казан утлары

2) *сөйл.* Гадәттән тыш тынгысыз, бик борчулы вакыйгаларга бай. --- *данлы чорның алга чабышында Өермәле еллар агышында...* Ә.Ерикәй

ӨЕРМӘ́ ҮЛӘНЕ *и. бот.* Гөлчәчәкләләр семьялыгыннан, өлгерүе җиткәч, җир өсте өлеше тамырыннан аерылып, җил белән күчеп йөри торган үлән үсемлек; дүңгәләк; *русчасы:* **перекати-поле**. *Җил тәгәрәтеп йөртә торган мондый үсемлекләрне «өермә үләне» (дүңгәләк) дип атыйлар.* Биология

ӨЕ́Р-ӨЕР *рәв.* **1.** Берничә төркем булып, аерым-аерым өер хәлендә, төркемләшеп. *Өер-өер булып, урам уртасында, тыкрык авызында, капка төпләрендә сөйләшеп, бәхәсләшеп торучылар һаман бар иде әле.* И.Гази

2. *с. мәгъ.* Бик күп санлы төркемнәрдән торган, төркем-төркем. *Көмеш кыңгыраулар күңелләрне җилкендереп, йөрәкләрне дәртләндереп зеңли башларлар, авыл-кала саен өер-өер халык чыгар.* М.Хәбибуллин. *Тирәләрендә өер-өер күселәр кайнаша.* А.Хәлим. *Урамда өер-өер хуҗасыз этләр йөри, фатирларда эт-мәче, тычкан, елан һәм хәтта селәүсеннәргә хәтле тоталар.* Татарстан яшьләре

ӨЕРТҮ *ф.* **1.** *сөйл. к.* **өерү** (*1 мәгъ.*)

2. өертеп *рәв. мәгъ.* Пыр туздырып, тиз-тиз. *Йортны себерде, ишек алдындагы бердәнбер тал агачының кайрысын кимереп торучы кәҗәләрне себерке белән өертеп куып чыгарды һәм, капканы ябып, келәне элеп куйды.* Ә.Фәйзи

Өертеп бару Рәттән бер-бер артлы барысын да өертү

Өертеп китү Кисәк кенә, бик тиз рәвештә өертү

ӨЕРҮ *ф.* 1) Бөтерү, әйләндереп, үзенә тартып алу. *Җил-давыллар бәрелгәнме, Өермәләр өергәнме – Тирәк башы иелгән.* Ш.Маннур. *«И-и-их, хәзер менә шундый өермә чыксын иде дә Сәрви белән икебезне бергә кушып өереп алып китсен иде, миңа аңардан башка яшәү юк!» – ди иде.* Ә.Фәйзи

2) Бер өергә туплау, өергә җыйнау (хайваннарны)

3) *күч. гади с.* Комсызланып ашау, тыгыну. *Өерсә, синекен өерәмени, өеннән килгән ярты ипиен өерә.* Мәзәк

Өереп алу Кинәт өерү

Өереп бетерү Барысын да өерү

ӨЗӘ *рәв.* Каты итеп, нык итеп. *[Көлдербай:] Тукта әле, Бытырбикә, алай өзә сукма.* М.Сәлим. *Күрерләрем күргәннәрдән азрак, Ярсуларым, бәлки, шуңадыр. Өзә басып йөргән юлларым да Бер төш кебек кенә югалыр.* Р.Бикбаев. *Өзәңгегә өзә бастым, Җир китте чыңлап. Иярга үзе күтәреп Утыртты сымак.* Р.Назаров

ӨЗӘН *и. диал.* 1) Ызан. *Түтәлләр бүлеге белән кәбестә, помидор бүлекләрен аерган өзән турысында камышлы күл белән сөзәк арасындагы тигез чирәмдә учак корылган.* Ш.Камал

2) Үзән. *Каз бәпкәләрен өзән елгага илтеп кайт, диде, – аларны илттем.* Г.Ибраһимов

ӨЗӘҢГЕ *и.* 1) Атка атланучы җайдакка аягын кую өчен, иярнең ике ягындагы каеш очына тагылган җайланма. *«Фиу!» дип, өзәңгеләрен какты, атын әйдәде дә, кош кебек очып, бая килеп әйләнгәннәрнең каршысына барып чыкты һәм, сүз әйтеп авыз йомганчы, койрык очындагы арканны бер айгыр муенына салды.* Г.Ибраһимов. *Өзәңгемә басып көтеп торам Иптәшемнең чабып үткәнен.* Ш.Маннур. *Инде тыңла, мөгаллимем. Аякларың икесен дә өзәңгегә куй.* М.Хәбибуллин

2) *анат.* Урта колак эчендә тавыш кабул итә торган сөяк

3) *сөйл.* Көпчәк тугымының өзек җирен беркетеп кую өчен тимер деталь

◊ **Өзәңгегә басу** Иярнең өзәңгесенә басып, атка менеп йөрерлек яшькә җитү. *Улым алты яшенә җитте, өзәңгегә басты инде, ат башына менде, шуңа куанам.* **Өзәңгегә җитү** *к.* **өзәңгегә басу**

ӨЗӘРӘМ *с. диал.* Ашарга азык беткән, нәрсәгәдер кытлык булган (вакыт)

ӨЗГӘЛӘГЕЧ *и. тех. к.* **өзгеч**; *русчасы:* **прерыватель**. *Терекөмешне өзгәләгеч*

ӨЗГӘЛӘНҮ *ф.* 1) Ертылу, теткәләнеп бетү, тузу (кием һ.б.ш.). *Аның йөзе тузанга баткан, күлмәкләре өзгәләнгән.* Һ.Такташ. *Һәм ул Гыймадилар киткән икенче көнне, китап-дәфтәрләрен тутырып, култык астына өтек кенә мендәрен, өзгәләнгән юрганын кыстырып, мәдрәсәгә күчте.* Ә.Фәйзи

2) Аерым-аерым кисәкләргә бүлгәләнү; нәрсәдә дә булса ертылган, теткәләнгән кебек ачыклыклар барлыкка килү. *Давылда өзгәләнгән җилкән кебек сәләмә читләреннән Илдар белән Фәритнең шәрә тәннәренә соңгы тамчылар тамып кала иде.* Г.Гобәй. *Ләкин анда еракка сәфәргә юнәлгән озын составның төтене өзгәләнеп тирбәлә дә, ераклаша баручы тәгәрмәчләрнең рельслар буйлап килгән моңлы көе генә яңгырый.* К.Нәҗми. *Тоба, корбанын өзгәләгән ерткыч кебек, аның арык гәүдәсен зыр-зыр әйләндерде-тулгандырды да төпкә сөйрәде.* Н.Гыйматдинова

3) *күч.* Бик кайгыру, нык борчылып бәргәләнү, ачыргалану, газаплану. *Читтәрәк, хатын-кызлар әйләнәсендә, өзгәләнеп, Мохтарның әнисе елый иде.* Ф.Галиев. *Кардәш-ыру, таныш-белеш өзгәләнеп аһ итте, барчасы да газиз затның хозурына ашыкты.* З.Мансуров. *Менә шул әсәрендә язучы: «Бүгенге укучы мине аңлармы?» – дип өзгәләнә.* Татарстан яшьләре

Өзгәләнә башлау Өзгәләнү билгеләре күренү

Өзгәләнә төшү Бераз өзгәләнү; тагы да ныграк өзгәләнү

Өзгәләнеп бетү Тәмам, тулысынча өзгәләнү. *Службасын тутырган паспорты элмә-телмә өзгәләнеп беткән.* Ш.Камал. *Егет дошман белән бик нык көрәшкән булса кирәк: киемнәре, казакиеның яка төймәләре өзгәләнеп беткән иде.* Г.Минский

Өзгәләнеп китү Кисәк өзгәләнү. *Таңбатыр диюне күтәреп ала да җиргә китереп бәрә, тегенең сөякләре өзгәләнеп-өзгәләнеп китә.* Әкият

Өзгәләнеп кую Аз гына өзгәләнү

Өзгәләнеп тору Хәзерге моментта өзгәләнү; даими, гел өзгәләнү. *Үзләренең дүрт баласы янына җиде ятимне сыендырган, һәркайсын үз бәгыре шикелле якын итеп тәрбияләгән, һәркайсының язмышы өчен өзгәләнеп торган Маликовлар ятимлек проблемасын чиксез ихластан ярату белән хәл итә.* Сөембикә

ӨЗГӘЛӘ́Ү *ф.* 1) *кбт. форм к.* **өзү**. *Бу суык хәнҗәр минем Өзгәләр бәгъремне сырган Бар әсирлек бауларын...* Һ.Такташ. *Нәфисә кулындагы салам кисәген өзгәли, акылын башына җыярга, коточкыч бу хәлнең серен аңларга теләгәндәй, зур булып ачылган күзләре белән бер – байракка, бер кашын җимереп торган Фирдәвескә карап ала иде.* Г.Бәширов. *Белер-белмәс маташып, минем алтын җепләремне өзгәләп харап итәрсең.* Д.Аппакова

2) Ерту, ертып бетерү; кисәкләргә аеру. *Ачу вә әрнүемнән әллә ниләрне өзгәләп ташларлык мәртәбәгә җитәм.* Г.Ибраһимов. *Искереп беткән афишаларын җил өзгәләгән витрина төбендә яңа яуган карда яшь кенә бер хатын хәрәкәтсез ята иде.* Г.Гобәй

3) Яралау, тәнне умырып алып җәрәхәтләү. *Тиздән ул һушын җуеп авачак, аннары инде һавада бөтерелгән козгыннар, җирдә сөйрәлгән хәшәрәтләр егетнең ябык тәнен өзгәли башлаячак – җаны чыкканны да көтмәячәкләр.* З.Мурсиев

4) Борчу, рухи газаплау. *Чәйни бәгъремне еланнар, өзгәлиләр, мин тәмам шаштым.* Һ.Такташ. *Минем йөрәгемне өзгәлисең.* Р.Ишморат

Өзгәләп ату *к.* **өзгәләп ташлау**. *Әлеге мизгелдә Мансур Ибраһимовичка Хәйдәр очраса, өзгәләп атыр иде.* Х.Ширмән. *Инде өзгәләп ата дигәндә, әле ярый телефоны шылтырады.* И.Хәйруллин

Өзгәләп бетерү Тәмам вак кисәкләргә өзгәләү. *Аннан Марат каршысына чүгәләде дә аның учындагы эт өзгәләп бетергән колбасаны алып*

ташлады. Г.Гобәй. – *Чыбыкны өзгәләп бетергән, табып булмады, – диде Тәкәнәев.* Х.Камалов. *Бик иплəп кенә, сакланып кына орынырга кирәк булган күңел кылларын тарталар, йолкалар, өзгәләп бетерәләр.* Л.Ихсанова

Өзгәләп ташлау Бик нык, вак-вак кисәкләргә өзгәләү; бик тиз, ачу белән өзгәләү. *Аны өзгәләп ташларга торган кебек тора иде.* М.Гафури. *Сәфәрнең күзендә әллә нинди куркыныч ут кабынган, бик каты бер сүз әйтергә җыенып та сүзен таба алмагандай, аның иреннәре тетрәнеп торалар, ә үзе, кемнедер өзгәләп ташларга теләгән кебек, куллары белән кыска һәм кискен хәрәкәтләр ясый иде.* Ә.Фәйзи. *Күрә дустым: бүрода артыграк акыл саталар, кешене өзгәләп ташларга әзерләр.* К.Миңлебаев

Өзгәләп чыгу Барысын да бер-бер артлы өзгәләү, башыннан ахырына кадәр өзгәләү. *Сакчылар, хәрби эшләр вәзире патшага ярдәмгә ыргылганнар иде, Алып Бәргән кылычы белән аларны урталай өзгәләп чыкты.* Р.Батулла

Өзгәли башлау Өзгәләргә керешү. *Эт, кара яшен кебек, тоткын өстенә ташланды, аны бәреп егып, үткен тешләре белән өзгәли дә башлады.* Г.Әпсәләмов. *Ә елга аны ишетми дә, инеш тәмам ярсына, юлындагы ташларны актара, үз-үзен өзгәли башлый.* Ф.Зыятдинов

ӨЗГЕЧ *и. махс.* Электр чылбырында токның үтүен туктатып тору җайланмасы; *русчасы:* **выключатель**. *Индукцион ярсытулар булдыру өчен, Дюбуа Реймон аппаратының беренчел чылбырына секундына 2, 5, 10, 25, 50 һәм 100 тапкыр өзелү тәэмин итә торган Энгельман өзгече куелды.* Фән һәм тел. *Электр челтәрләренә автомат өзгечләр һәм сүндерүгә исәпләнгән саклагычлар куела.* Сарман

ӨЗДЕРТҮ *ф.* 1) *йөкл. юн. к.* **өзү** (*2 мәгъ.*). *Ул сул кулын фронтта өздертеп кайткан иде.* Г.Галиев

2) *сөйл. к.* **өздерү** (*2, 3 мәгъ.*)

Өздертеп алу Тиз генә өздертү. *– Борылмасалар, сваркаң белән өздертеп алырсың, – диде, эш башларга кирәклеген искәртеп.* Н.Хәсәнов

ӨЗДЕРҮ *ф.* **1.** 1) *йөкл. юн. к.* **өзү**. *Исламгали – колхозның менә дигән тракторчысы – сугышта ике кулын беләзектән өздереп кайткан иде.* М.Мәһдиев. *Юк, кызым, ди атасы, ул инде бик күп кешеләрнең башларын чабып өздерде.* И.Гази

2) *күч.* Музыка коралында бик матур, искиткеч оста итеп уйнау. *И сихерле, серле, илһамлы, гаҗәеп мандолин!.. Әйдә, сыздыр, әйдә, өздер, сафланыйм, илһамланыйм.* Ш.Бабич. *Өздерә генә, ләкин тыңлаучысы чамалы.* Ш.Камал. *Анда өздереп музыка уйныйлар, монда матур тавыш белән җырлыйлар, тегендә эчке шатлык.* Г.Ибраһимов

3) *күч. Бәгырь, җан, күңел* һ.б.ш. сүзләр белән килеп, нәрсәнең дә булса бик авыр тәэсир итүен, рухи газаплауны белдерә. *Нинди ялкынлы, ул – салкын йөрәкне кыздыра! Бер җылап, бер моңланып, бер сызгырып җан өздерә.* Ш.Бабич

2. өздереп *рәв. мәгъ.* 1) Катгый карарга килеп, кистереп. *[Газинур:] Алай ук өздереп сөйләшмәгән идек сөйләшүен дә, эшләр шуңа таба бара иде.* Г.Әпсәләмов. *Ислам ык-мык килеп маташкан арада, Нәгыйм өздереп әйтергә өлгерде.* Татарстан яшьләре

2) Кыска гына, аңлаешлы итеп, юкбар сүз өстәмичә. *Гафиятуллин ачык тавыш белән өздереп рапорт бирде.* Г.Әпсәләмов

3) Кискен итеп, каты итеп; бик нык, үзәккә үтеп. *Тик өздереп искән салкын җил аны бу дөньяга кире кайтарды.* Г.Бәширов. *Сөйләшә торгач, шактый вакыт узган ахры. Кинәт кенә өздереп кыңгырау шалтырады.* Р.Хафизова

4) Бик текәлеп, тәэсирле итеп. *Комбайнчы җегет аңа, бертуган энесе сыман, яшьтән дымланган күзләре белән өздереп карый иде.* А.Хәлим. *Ул Газинурга шундый өздереп карый, кулларын аның кулларыннан тартып алу түгел, үзе аңа ныграк сыена бара.* Г.Әпсәләмов

5) Нык тәэсир итеп, күңелгә үтерлек итеп. *Газинур – үз гомерендә күп җырлар җырлаган һәм ишеткән кеше, әмма разведчиклар шикелле йөрәкләрне айкап, үзәкләрне өздереп җырлаганны моңарчы күргәне дә, ишеткәне дә юк иде.* Г.Әпсәләмов

Өздерә башлау Өздерергә тотыну. *Аны (радионы) беренче башлап өлкәннәр үзләре өздерә башлаганнар иде.* Шәһри Казан

Өздереп алу Кинәт, шул минутта ук өздерү. *Һаваларга ашып торган агачлар арасын тутырып аркылы-торкылы үскән куаклар юлыбызны киртәлиләр, сыдырылалар, кулларыбызга, битләребезгә килеп бәрелеп өздереп алалар.* А.Шамов

Өздереп җибәрү Кинәт кенә өздерү; өздерә башлау. *Өч гармун бер булып өздереп җибәргән иде, кызлар биюеннән көнләшеп, Сәет җилкәсендәге тәкә дә тыпырчына башлады.* К.Кәримов

ӨЗЕК *с.* **1.** 1) Өзеп алынган, өзелгән. *[Ат] кешни-кешни, өзек нуктасын өстерәп, кавалеристлар артыннан куып җитте.* А.Шамов. *Иң азактан, җеп өзекләренә элəгə-элəгə, теләр-теләмəс кенә чыккандай, тышына фашист свастикасы төшкән бер соры кенәгә килеп чыкты.* М.Галиев

2) Тулы булмаган, аерым өлешләрдән, кисәкләрдән торган. *Алар тик күрүченең хәтерендә калганнары, өзек истәлекләре рәвешендә яки хроника кыскалыгы белән хикәя итү юлында гына күрсәтелә.* Г.Нигъмәти. *Күрше камерадагы иптәшнең өзек бер җөмләсен Баязит ике-өч хәреф чиертмәч үк аңлап алды.* Г.Ибраһимов

3) *сөйл.* Паузалар белән бүлгәләнгән, кинәт өзелгән; калтыравык. *Ишектән кергән кешеләрнең берсе, башка иптәшләреннән алгарак килеп, өзек һәм калтыравыклы тавыш белән: «Хәзрәт, эш зур!..» – диде.* М.Гафури. *Бу юлы да тыелып калды, өзек тавыш белән йодрыгына йөткереп кенә куйды.* М.Галиев

2. *и. мәгъ.* 1) Бербөтен нәрсәдән өзеп алынган кисәк. *Үзләрендә булган уңышларны, өзекләрне санап төштеләр.* Һ.Такташ. *Композиторларның һәм либреттистларның беренче тәҗрибә рәвешендә кечкенә күләмле опера өзекләре өстендә эшләүләре табигый иде.* М.Җәлил. *Гражданнар сугышының бер өзеген бирүдә «Яңа кешеләр»нең зур*

гына урын тотканын югарыда әйтеп киткән идек. Г.Нигъмәти

2) Берәр әсәр яки китап текстының зур булмаган өлеше, текст кисәге, күчермәсе; цитата. *Аерым өзек итеп бастыру өчен иң уңайлы глава.* М.Җәлил. *Китергән өзекләрдә югарыда әйтелгән сыйфатларның һәр каюсына мисал бар.* Г.Нигъмәти. *Аның 1901 нче елда язылып, басылмыйча, Мәкәрҗәдә халык алдында декламировать ителгән беренче шигырьләреннән «Приказчик» өзекләре генә сакланып калган.* М.Гали

◊ **Өзек вакыт** 1) Юл өзелгән чор; 2) Акча яки ашау-эчү нәрсәләре бетеп торган ара. **Өзек ел** Ачлык ел

ӨЗЕКЛЕ *с. диал.* **1.** Төгәл, өзеп, катгый әйтелгән. *Бу юлы шушындый өзекле тәкъдимнең Халыкътан чыгуына Нәгыйм эчтән хурланып куйды.* Ш.Камал

2. *рәв. мәгъ.* Катгый, кискен итеп. *Өзекле сөйләшү*

ӨЗЕКЛЕК *и.* 1) Өзелгән булу, өзек булу. *Өзеклекне ялгау*

2) Буш ара, бушлык. *Чыгышлар арасында өзеклекләр килеп чыгу, залны көттерү, музыканы бутаулар «Асыл кәләш» кебек дәрәҗәле конкурсны бизәми.* Мәдәни җомга

3) Билгеләнгән вакытка эшне үтәп өлгермәү, бик нык артка калу, артталык. *Өзеклек ул җиңелү түгел, ләкин Ул туктата җиңү үсешен.* һ.Такташ. *Аннары бетон сыйфатын бик нык тикшереп барырга, андагы өзеклекне бетерергә кирәк иде.* А.Шамов. *Ә МТС директоры Хәбибуллин ничек соң, газета теле белән әйткәндә, тирән өзеклектә утырмыймы?* Ә.Еники

4) *сөйл.* Җитешмәү, җитәрлек булмау, кытлык. *[Хәерниса:] Алар бу тимерче өзеклегеннән чыга алмыйлар.* Т.Гыйззәт

5) Язгы ташу яки явымнар нәтиҗәсендә юл өзелгән вакыт. *Өзеклек башланганчы, ашлыкны ташып бетерергә тырышыйк.* Татарстан яшьләре

6) *күч.* Фронтның һөҗүм итүче гаскәрләр өзгән урыны. *Без исә алдагы частьларга башта флангтан ярдәм итәчәкбез, аннары, фронт өзелгәч, ачык капкага кергән кебек, шул өзеккә кереп китәчәкбез. --- Һавада – безнең авиация; өзеккә безнең пехота омтыла, безнең танклар килеп керәләр.* И.Гази

ӨЗӘК-ӨЗӘК *с.* **1.** 1) Тулы булмаган, аерым өлешләрдән генә гыйбарәт; аз бәйләнешле. *Өзек-өзек чуалчык хыяллар, бер фикер, бер план тудырырга ирек бирми, минем теңкәмә тияләр.* Ф.Әмирхан. *Ныклап искән җил аның сүзләрен читтәге тамашачыларга яхшылап ишеттерми, кайбер өзек-өзек җөмләләр генә ишетелеп куя иде.* Ш.Камал. *Ләкин ни сәбәптәндер бөтен белгән догаларымны онытып җибәргәнмен, бары өзек-өзек сүзләрне генә кабатлап, ахырдан «бәхет телим, бәхет телим» дип, битемне сыйпап куйдым.* Ә.Еники

2) Тукталып кала торган, урынсыз паузалар белән бүленгән. *Бер-берсенә тотынышып утырган балалар шаулыйлар, нәрсәдер әйтеп кычкыралар, көләләр, ә берсе өзлексез гудок кнопкасына баса, өзек-өзек сигнал бирә иде.* А.Шамов. *– Чүп өстенә чүмәлә, дигән кебек, барысы бер җиргә килеп өелде инде, – диде хәлсез өзек-өзек тавыш белән Мирхәйдәр абзый.* Ә.Фәйзи. *Әхмәтша абзыйның төшенке һәм карлыкканрак өзек-өзек тавышы ишетелде.* Казан утлары

3) Басым ясап әйтелгән, конкрет; кыска. *Минем сөаль ләремә каршы берәр генә җөмләле өзек-өзек җаваплар бирде.* Ф.Әмирхан

2. *рәв. мәгъ.* 1) Кинәт өзелеп, бүленеп; тукталып. *Хәлим аның өзек-өзек сулаганын ишетә, һәм кулы аның йөрәк тибешен бик ачык тоя иде.* А.Шамов. *– Зыян юк, – Салихов сулышын өзек-өзек ала иде.* Ф.Галиев. *Ул прокурорга текәлеп карады да кинәт кенә тыны кысылгандай өзек-өзек сөйләп китте.* М.Галиев

2) Тоташтан түгел; кыска гына. *Бер читтә йорт артында хуҗалык командасы начальнигының өзек-өзек биргән приказлары, кызылармеецларның ашыгып-ашыгып эндәшүләре, караңгылыкка кереп югалган аяк тавышлары ишетелә.* А.Шамов. *Ләкин бу – Калинин өлкәсендәге гади фронт төне, автоматлардан, пулемётлардан аталар, миномётлар, төш күреп уянган ялкау этләр кебек, өзек-өзек өреп алалар, кайчак артиллерия дә ут ача.* Г.Әпсәләмов

ӨЗЕКСЕЗ *с. сөйл. к.* **өзлексез**

ӨЗЕЛЕШ *и.* 1) Өзелү күренеше. *Электр чыбыгының өзелеше*

2) Өзелү урыны. *Чыбыктагы өзелешне табу*

3) Бер вакыйга, эш-гамәл һ.б.ш. белән икенчесе арасында үткән байтак вакыт. *Эштәге өзелеш*

4) *сир.* Аерылышу, үзара мөнәсәбәтләрдә бәйләнеш югалу, аңлашылмаучанлык туу. *Яшьләрнең өзелеше җиңел булмады*

ӨЗЕЛҮ *ф.* **1.** 1) *төш. юн. к.* **өзү**. *Ахыр барып, матур Кырымны коткару өчен көрәшкәндә, Перекоп сугышында дошман тубыннан башы өзелде.* Г.Ибраһимов. *Колактан колакка төрле хәбәрләр йөри башлады: имештер, шушы арада һөҗүм башланачак икән, дошман фронты нәкъ безнең участокта өзеләчәк икән.* И.Гази

2) Тартылудан аерым кисәкләргә бүленү, аерылу. *Баш бавың өзелмәсен, бастырыгың сынмасын.* Әйтем. *Үлгән илләр яңадан терелер, коллык зынҗырлары өзелер.* М.Гафури. *Тартып карый, теше белән чәйни, чехол бавы түзми... өзелә.* Ф.Кәрим

3) Бер бөтеннән аерылып төшү; ертылып, киселеп аерылу, сыну. *Корып, вакытсыз өзелгән яфраклары, сабакларыннан ерак китәселәре килмәгән кебек, һавада очып йөрделәр.* Г.Гобәй. *Төште авызыннан авызлык, һәм өзелде тезгене.* Н.Исәнбәт. *Аның ак «сакалы» өзелеп үк чыкты.* А.Әхмәт

4) Бетү, юкка чыгу, яраксыз хәлгә килү. *Мин, берәр әһәмиятле тамыры өзелгән булса шундый нәрсә булырга мөмкин, дигән идем, чөнки белер хәл юк, ни дип әйтәсең.* Ш.Камал. *Кымыз бөтен тамырларга таралып өлгергән, артык сыйдырырга урын калмаган иде, ничектер сүзнең дә җае өзелгән иде, бу һәммәсенә сизелде.* Г.Ибраһимов. *Аланга җитәрәк машина эзе өзелә.* Ф.Галиев

5) Нәрсәдер берара булмый тору, җитмәү, кытлык сизелү. *Сиңа май, йомырка теләгәнчә булыр, коймак, бәлеш өзелмәс.* Г.Ибраһимов. *Нәбиулла*

өстәленнән балы да, каймагы да өзелми. Т.Гыйззәт. *Ит, колбасадан өзелмиләр, тоткынга җан асрар өчен бирелгән сыек баландага борын да төртмиләр.* Н.Хәсәнов

6) *күч.* Берәр төрле эш-хәрәкәт бетү, тукталып калу. *Уйлар бердән өзелделәр, чөнки поезд туктады, һәм ашыгырга кирәк иде.* Г.Минский. *Радионың морзе белән сөйләве бердән өзелде.* Ә.Айдар. *Ул хәзер хәтта үзенең юлы өзелү күңелсезлеген дә онытты.* Г.Гобәй

7) *күч.* Үзара мөнәсәбәтләр бозылып, бәйләнешләр алга таба дәвам итмәү, тукталу, бетү; аерылу. *– Нәрсә, суд белән аерылыштыгызмы, әллә инде гаилә элемтәләрегез күптән өзелдеме? – дип, мин шунда ук сүз агышын үзгәртеп җибәрәм.* Ф.Галиев. *Шуннан соң безнең аралар тәмам өзелде.* И.Гази. *Сугыштан кайткач та, аларның дуслыклары өзелмәгән.* А.Шамов

8) *күч.* Көчле борчылу хисе кичерү, әрнү. *Ул бит Шәмсинең атасын да әнә шул ук станциядән, шулай ук өзелеп, герман сугышына озатып калган.* Г.Бәширов. *Өзелсә, синең өчен өзелми булыр әле, курыкма.* Ф.Бурнаш

9) *күч.* Бик нык ашыйсы килү теләге кузгалу, тамак ачу. *Зәйнәпбануның әнисе: «Йөрәгең бик өзелгәндә кабып җибәрерсең», – дип, бераз эремчек кыстырган икән, аны да куйдылар.* Г.Бәширов. *[Гөлҗамал:] Сәхи улым, тамак ялгап ал. [Сәхи:] Тамакны ялгарга була, тәмам өзелеп китә язды.* А.Гыйләҗев

10) *күч. диал.* Үлү, җан бирү. *Чәчәк кебек гомер өзелгән.* Ф.Кәрим. *Куркусу белмәс Данлы гомер ничек өзелде?* Ә.Исхак. *Дус кызы, Айдарның үлемендә беркем дә гаепле түгел, аның тормышы фажигале очраклылык аркасында өзелгән, дип хәбәр иткән.* Ф.Галиев

2. өзелеп *рәв. мәгъ.* 1) Бик тирән хисләр кичереп, бик тәэсирләнеп. *Нигә әнә теге мескен җиде төн уртасында йоклый алмыйча өзелеп җырлый, әнә бит.* М.Әмир

2) Бик көчле итеп, соң дәрәҗәдә. *Нәфисәне мин дә өзелеп сөя идем.* А.Шамов. *Нәсимәнең кинәт өзелеп йоклыйсы килеп китте.* Д.Аппакова. *Шул күкегә тартым булып чыкты Сине «өзелеп сөйгән Фазылың».* З.Мансур

3) Сагынып. *Өзелеп такмак әйтмәс идем, Үз халкымны сөймәсәм.* Җыр. *Менә шуларны күз алдына китергәндер Мария, шул көнне өзелеп көткәндер.* М.Маликова

◊ **Өзелгән дә төшкән** Кемгә яки нәрсәгә дә булса бик охшаган. **Өзелеп тору** Кемгә дә булса бик яхшы мөнәсәбәттә булу, аның өчен һәртөрле яхшылыклар эшләргә әзер тору. *Әйбәт кенә карчык инде. Гөлсинәм дип өзелеп тора.* Р.Ишморат. *Сине бер сүзе белән эретеп җибәрә, җаннарын ярып бирерлек булып өзелеп тора.* Г.Бәширов. *Укытучылар белән укучылар бер-берсе өчен өзелеп торалар.* А.Хәлим

Өзелә бару Бер-бер артлы өзелү. *Әмма чылбырлар, халык теләгенә каршы килә алмыйча, берәм-берәм өзелә бара.* Р.Миңнуллин. *Биредә яшәешнең кануны: кешенең гомере ялгыз үтү, өметләр өзелә бару, яшәүнең чикләнгәнлеге кайгы һәм моң кичерергә мәҗбүр итә, дигән экзистенциаль фәлсәфә бик ачык әйтелә.* Д.Заһидуллина. *Ә Наил инде беркемне дә күрми, аның бу дөнья белән алыш-биреше өзелә бара.* Д.Гайнетдинова

Өзелә башлау Өзелүгә табан бару. *Карлар эреп, юллар өзелә башлаган вакыт иде, базарга атка атланып кына китәргә туры килде.* Г.Бәширов. *Юк, үкенмәскә, кире уйламаска! Яңадан аңа карамаска! Тиз генә кереп китәргә. Аның өзелә башлаган өметләрен терелтмәскә!* Р.Рахман. *Карт йөрәген тотты, аның хәле авырайды... «Йөрәккә урнашкан җанның җебе өзелә башлады бугай», – дип уйлады ул.* Р.Сибат

Өзелә тору Башка бер эш-гамәл барган арада өзелү. *Еллар елга охшамый шул, язлары үзгә тора. Үзәкләр өзелә тора, – кемнәрдер сагындыра.* Р.Мингалим

Өзелә язу Чак кына өзелми калу. *Рәшидә озак көттереп, йөзен читкә борып, көчкә генә җавап бирде: – Авыр миңа! – Һәм тавышы аның өзелә язып куйды.* Ә.Еники. *Улының сагышын күреп, Хурлыгаянның бәгыре өзелә язды.* Р.Батулла. *Шулай да яшәү өмете бар кебек иде әле. Әмма Галимҗан турындагы хәбәр килгәч, бу өмет кылы бөтенләй өзелә язды.* С.Поварисов

Өзелеп бару *к.* **өзелә башлау**. *Ике атна вакыт үтеп, инде өмете өзелеп барганда гына, Гөлфиядән җавап хаты килеп төште.* Ф.Зариф

Өзелеп бетү Барысы да өзелү. *--- Һәр җәһәттән бер милләт булсак та, күптән инде элеккеге бөтенлекне югалттык, үзара бәйләнешләр өзелеп бетте диярлек.* Ә.Еники

Өзелеп җитү Тәмам, бөтенләйгә өзелү. *Йосыфҗан белән аралары әле дә өзелеп җитмәгән шикелле.* Г.Ибраһимов

Өзелеп калу Ниндидер бер вакытта, бер урында өзелү. *--- тау битләрендә җир җиләге һәм каен җиләге кызарып пешкән ямьле җәй уртасында өзелеп калды ул балачак.* Р.Мөхәммәдиев. *Телефондагы тавыш, кит-кит, кит, дигәндәй өзелеп калды.* К.Кәримов. *– Мин бит инде...– дип, Мөхәммәтов янә нәрсәдер әйтә башлаган иде дә, сүзе өзелеп калды, буйсынган кыяфәттә башын түбән төшерде.* М.Галиев

Өзелеп китү Кисәк кенә өзелү. *Аның әкренәйгәннән-әкренәя барган моңсу, әрнүле тавышы кинәт өзелеп киткән сыман булды, ул [Хәлил абый], сүзен әйтеп бетермичә, башын ике кулы белән тотып тынып калды.* А.Шамов. *Атом бомбалары бишек тирбәлгән саен селкенеп куя... Җирбишек – кешелекнең бишеге өзелеп китмәсен...* Ш.Галиев

Өзелеп кую Көтмәгәндә өзелү. *– Һай кубыз тарткан бармакларың ---! – дип, тирән соклану белән өзелеп куйды.* Ә.Фәйзи

Өзелеп тору Туктаусыз өзелү; бер-ара өзелгән хәлдә булу. *Без булганда, киткәннәргә догам Нигеземдә өзелеп тормасын.* Р.Зәкуанов. *Чире дә, ачлыгы да гел өзелеп тормады.* Ф.Галиев. *Кыскасы, бу яшелчә өстәлдән өзелеп тормасын.* Татарстан яшьләре

Өзелеп чыгу Бөтенләй өзелү. *Мәченең койрык очы өзелеп чыга.* А.Алиш. *Нимесләр тарткалаган саен, аяккуллар өзелеп чыгардай булып авырта.* Ф.Яруллин. *--- арада чегән төсле кара, биле өзелеп чыгардай нечкә, бераз*

кысыграк шомырттай күзләреннән ут чәчеп торучы бер кыз бар иде. Ф.Садриев

ӨЗЕМТӘ *и.* Берәр тексттан сүзгә-сүз китерелгән кисәк, өзек; цитата. *Әсәрнең бу характерын күрсәтү өчен, берничә өземтә алыйк.* Г.Нигъмәти. *Үзем булачак сүзлекнең аерым өземтәләрен «Казан утлары»нда күреп алганнан бирле җыйнап-төплап бардым.* Р.Галләм. *Автор, шигырь өземтәләреннән мисаллар китереп, рус теле һәм әдәбияты белгече буларак, аларны татарчадан русчага үзе тәрҗемә итеп, әлеге сорауларга җавап эзләшә.* Мәгърифәт

ӨЗЕП *рәв.* 1) Бүлеп, өлеш чыгарып, уртаклашып. *Ул аны тапкан, үстергән, үз авызыннан өзеп, барлы-юклы ризыкнигъмәте белән туендырган, үзе кимичә киендергән.* Н.Хәсәнов

2) Ныклы бер кararга килеп; ачык; катгый итеп, кистереп. *«Чыгарам, менә хәзер үзем чыгарам», – дигән кебек өзеп сүз дә әйтә алмый, эш тә кыла алмый икән.* Г.Ибраһимов. *Котылдылар дигәч тә, алай өзеп әйтү өчен иртәрәк иде.* И.Гази

ӨЗЕ́П-ӨЗЕП *рәв.* 1) *к.* **өзеп** (*1 мәгъ.*)

2) Паузалар белән бүлгәләп, бүлеп-бүлеп. *Ләкин Әхми эчтән өзеп-өзеп пышылдады.* Г.Ибраһимов

3) Ишетелерлек, аңлашылырлык итеп, һәр сүзгә басым ясап. *Пахомов ротаны тыгызлап дүртәр кешедән тезде дә өзеп-өзеп кенә бер-ике сүз әйтте.* Г.Бәширов. *Өзеп-өзеп әйтелгән салмак сүзләр кенәзне чыгырыннан чыгара язды.* Р.Батулла

ӨЗЕШ *и. сөйл.* Гауга, үзара тиргәш

ӨЗЕШҮ *ф.* 1) *урт. юн. к.* **өзү** (*1–5 мәгъ.*). *Бу ике дус инде, Дәгъвалашып, судка йөрмәсен. Өйләренә кайтып, Ничек кирәк, Өзешсеннәр шулай араны.* З.Мансур

2) *сөйл.* Талашу, тиргәшеп, нәрсә дә булса таләп итү. *[Рамазан:] Инде килеп яңадан аңа мич бирәләр, ул, юк, тагын Тимергалиев белән өзешә!* Н.Исәнбәт

Өзешеп бетерү өзешүне тәмамлау

Өзешеп кую Кинәт кенә, кисәк өзешү

ӨЗЛӘ́Ү I *ф. муз.* Тамак төбе белән төрле авазлар чыгарып көйләү

Өзли башлау Өзләргә тотыну

Өзләп тору Әле, хәзер өзләү; даими өзләү

ӨЗЛӘ́Ү II *и.* Тамак төбе белән төрле авазлар чыгарып көйләү күренеше һәм шундый көй; *русчасы:* **горловое пение**. *Бер үк вакытта кубызда уйнау һәм өзләү, яки тамак белән җырлау, зур осталык, җитди әзерлек таләп итә.* Кызыл таң. *[Ул] үзлегеннән өзләү башкарырга өйрәнде.* Туган як

ӨЗЛӘҮЧЕ *и.* Өзләү башкаручы. *Иң яхшы кубызчылар, өзләүчеләр бәйгесе 16 яшькә һәм аннан өлкән булган солистлар, балалар һәм өлкәннәр ансамбльләре арасында ике көн барды.* Кызыл таң

ӨЗЛЕГҮ I *ф.* 1) Берәр авыр эш организмга тискәре тәэсир итү, көч килү. *Әминә ханым 1944 елда Енисейск шәһәрендәге судноларга төзү верфьләрендә авыр эштән өзлегеп вафат булган.* А.Мәхмүтова

2) Нинди дә булса берәр авырудан сәламәтләнеп җиткәндә генә кабаттан авыру. *Баланы ана карыныннан тартып алалар, әмма хатын өзлегә һәм Йосыфын көтеп ала алмый дөнья куя.* М.Хәбибуллин

3) *диал.* Берәр нәрсәнең башланган хәрәкәте туктау, тукталып тору. *Картның тавышы өзлекте, ул күзләрен ял иттерергә теләгәндәй, карашын каядыр Массандра якларына төбәде.* А.Хәлим

Өзлегә башлау Өзлегү билгеләре күренү. *Берзаманны ул күзгә күренеп өзлегә башлады, килеш-килбәте язгы боз шикелле көпшәкләнде.* В.Имамов

Өзлегә язу Чак кына өзлекми калу. *Төне буе аягөсте чыктым, әллә кайда йөрде; ярый кайтты, ул түгел, үзем өзлегә яздым...* Р.Камалов

Өзлегеп калу Ниндидер вакыйгадан соң өзлегү

Өзлегеп китү Уйламаганда, көтмәгәндә генә өзлегү. *Утәр, утәр дип аяк өстендә йөри торгач, өзелеп китә күрмә.* Р.Ишморат. *[Хафиз:] Ят, Сибгать абзый. Өзлегеп китә күрмә.* Т.Миңнуллин. *– И Тәңрем, бала исәнсау тусын да, әнисе өзлегеп китә күрмәсен! – дип, чын күз яшьләре белән елап, изге теләкләр теләп, ашамый-эчмичә кайгырды бичаракай.* Р.Батулла

Өзлегеп кую Тиз арада өзлегү. *Сиңа, кызым, хәзер сакланырга кирәк, өзлегеп куйма тагы...* Г.Гыйльманов

Өзлегеп тору Гел өзлегү. *Рәниба җиңгинең тавышы бик тә матур. Моңы аның ничектер гел генә өзлегеп тора.* А.Хәлим

Өзлегеп чыгу Тәмам өзлегү. *Әмир инде үзе дә өзлегеп чыккан иде, кабат әйттереп тормый ризалашты.* В.Имамов

ӨЗЛЕГҮ II *и.* Сәламәтләнеп килгәндә яки килгәннән соң, авыруның яңадан кабатланышы. *Колхоз председателе Хәнәфи аның өзлегүеннән борчылып, кайтарып җибәрмәкче иде ---.* Г.Әпсәләмов. *Әнинең өзлегүендә гел мине гаепләде.* Н.Гыйматдинова. *Хәер, артык борчылу, нервлану һәркемне вакытсыз өзлегүгә китерә.* Мәгърифәт

ӨЗЛЕКСЕЗ *с.* **1.** 1) Һәрвакыт башкарыла торган; туктаусыз дәвам иткән, даими рәвештә бара торган. *Аерым хуҗалык булып яшәгән чактагы өзлексез борчылулары, үзенең дә теңкәсенә тиеп беткән икеләнүләре, йоклаган чагында да җанын тындырмый торган иртәнге көнгә булган ышанычсызлыгы бөтенләй юкка чыга.* Г.Әпсәләмов. *Бу – алардан өзлексез һәм озак файдалануның беренче һәм төп шарты.* Файдалы киңәшләр

2) Өзеге, арасы булмаган; бербөтен буй булып сузылган. *Язгы сабан тургайлары, үзләренең өзлексез моңнары белән җырлый-җырлый, нәкъ безнең турыда, әллә кая югарыга, биек күккә таба китеп югалалар иде.* Г.Ибраһимов

3) *мат.* Санаучысына һәм ваклаучысына чиксез рәвештә вакланмалар кушыла торган (вакланма). *Һәрбер өзлексез вакланманы гади вакланмага әйләндерергә мөмкин.* Алгебра

2. *рәв. мәгъ.* Даими рәвештә, бер дә тукталмыйча. *--- мин аларның [чәчәкләрнең] тереклекнең беренче шатлыгыннан елмайган яшь бала йөзе шикелле куаныч тулы йөзләренә сәгатьләр буенча өзлексез карап торырмын.* Ф.Әмирхан. *Көзге аяз тын һавада үзенә бер моң белән өзлексез сузып*

кына шаулаган чыбык тавышы үзалдына уйланып барган Сабир абзыйга әллә ничек кенә тәэсир итте. Ә.Еники. *Су өзлексез арта барды, дулкыннар шаулавы торган саен якынлаша барды, су аяк йөзенә менде, балтырга үрмәли башлады ---.* Г.Бәширов

ӨЗЛЕКСЕЗЛЕК *и.* Дәвамлылык, даимилек. *Менә бу дәвамлылык, өзлексезлек семасы нигезендә, Дәрдемәнднең кайбер шигъри юллары мәкальгә әверелгәннәр ---.* Д.Рамазанова. *Лейбниц, үзенең өзлексезлек законына таянып, үзгәрмәүчән абсолют каты җисемнәр һәм үзгәрмәүчән атомнар булу мөмкинлеген кире кага.* Фән һәм тел

ӨЗЛЕКТЕРҮ I *ф. йөкл. юн.* Сәламәтләнеп җиткәндә, кинәт яңадан авырып китүгә сәбәп булу. *Зөфәр фажигасе авыру әнисен бик өзлектерде.* Н.Хәсәнов. *Әтиләре Камәретдин фронттан язган хатларында хатыны Мәнсурага балаларны сакларга, авыр эшләр эшләтеп өзлектермәскә кушып яза да бит.* Ж.Дәрзаман

Өзлектереп җибәрү Кинәт өзлектерү

ӨЗЛЕКТЕРҮ II *и.* Сәламәтләнеп җиткәндә, яңадан авырып китүгә сәбәп булу күренеше. *Ләкин яшьләр, сине өзлектерүне искә алып булса кирәк, баруны, синең белән күрешүне яңыңа кереп чыгу белән генә чикләделәр.* Х.Туфан

ӨЗМИ-КУЙМЫЙ *рәв.* Бертуктаусыз; бер үк сүзне кабат-кабат тәкрарлап, үзенә кирәк нәрсәгә кабат-кабат кайтып. *Болында тегермән суында бер дә өзми-куймый парлашып кычкыра ике бака.* М.Гали

ӨЗҮ *ф.* 1) Бауны, җепне һ.б.ш. бик нык тартып, сузып, бөтенлеген юкка чыгару. *Инәгә бик озын җеп саплап ала, төймәнең сукыр күзеннән бер генә кат үткәзә, төенләп җепне өзә...* Г.Ибраһимов. *Чылбырны өзде дә йөгерде Хуҗамның бәйдәге зур филе.* Ә.Исхак. *Җебен теше белән өзеп, инәсен изүенә чәнчеде.* А.Шамов

2) Кисеп, ярып яки башкача икегә аерып чыгару. – *Кайтып синең тешеңне сындыру белән генә калмам, муеныңны өзәрмен! – диде Йосыф һәм шундук китеп тә барды.* Ә.Фәйзи. *Бәлки, самурай кылычы белән аның башын да чабып өзәрләр иде.* А.Шамов. *Үзегез әгәр бармак белән генә кагылсагыз да, кулларыгызны өзәрмен! – дип янаган.* М.Галиев

3) Үсеп утырган берәр нәрсәне сабагыннан, ботагыннан, тамырыннан аеру. *Ул, яфрак араларыннан эзләп, кечкенәкечкенә ямь-яшел кыярларны чеметеп кенә өзә ---.* М.Әмир. *Үрелеп, тармакланып үскән шомырт куагыннан кызгылт җимешен өзде.* Н.Гыйматдинова. *Уртача һәм соң өлгерешле сортларны рассададан үстергәндә, төп сабакның очын беренче тапкыр өченче яфрак өстеннән өзәләр.* Яшелчәчелек

4) Беркетеп куелган нәрсәне каерып, йолкып алу, аерып чыгару. *Шул арада ул кызыл алма кебек пешеп тә өлгергән инде, суыр да йот, тик иреннәреңне генә өзмә.* Г.Ибраһимов. *Моратның ул өзде орденын.* Н.Исәнбәт

5) Башланган сүзнең, эш-хәрәкәтнең, процессның барышын кисү, туктату. *Мин сөйли торган сүземне өзсәм, оныта башлыйм.* Г.Коләхмәтов. *Догасын өзми алып барырга теләгән иде.* М.Гафури. *Кем өзде безнең җырны?* А.Әхмәт

6) *күч.* Нинди дә булса мөнәсәбәтләрне туктату, бетерү. *Мин бүген сезнең эшләрегез – качкыннар белән хисабымны өзәчәкмен.* Ф.Бурнаш. *Әүвәлгеләр белән булган барлык мөнәсәбәтләрне өзгәч, бик озак йокыдан, ниһаясез төннән яңа уянган кебек бер халәт хис иттем.* Г.Ибраһимов. *Үзләре саклаган стройны мәңгелек дип бала чактан ук ышанып яшәүче бу чиновниклар белән элекке ведомстволар багланыш җепләрен кинәт кенә өзгән.* К.Нәҗми

7) *күч.* Берәр мәсьәләне хәл итү, берәр эшне тәмамлау. *Мәсьәләне хәзер үк өзеп куярга тиешсез.* Ш.Камал. *Получканы алып, өзәсе эшләремне генә өзим.* Ф.Хөсни. *Ләкин ул зарар күрүчеләр белән исәп-хисапны өзү чарасын күрми.* Мәдәни җомга

8) *күч.* Каршылыкны җиңеп, фронт, оборона аша үтү. *Бер авыр танк, безнең алгы оборонабызны өзеп булса кирәк, кәбестә, кабак, кавын бакчалары өстеннән урамга чыгып килә.* И.Гази. *Безне дошман йота алмады: Утлы божраларны өздек без.* Ә.Ерикәй

9) *күч.* Үтү, йөрү мөмкинлеген бетерү, юлның, коммуникация һ.б.ш.ның бер өлешен үтмәслек хәлгә китерү. *Фашист этләр уйлаганнар анда башкалага юлны өзәргә.* Ә.Исхак. *Диңгездән бәргән көчле җил, суны Сивашка куып, күп урында юлны өзгән.* Г.Бәширов

◊ **Өзми дә куймый** Өзлексез, туктаусыз бер үк сүзне кабат-кабат кабатлап, берәр нәрсә хакында сөйләү. *Ә ул мине җибәрми, әйдә, шәһәргә алып бар, ди. Өзми дә, куймый да.* Ф.Галиев

Өзә бару Бер-бер артлы өзү. *Әле һаман үзен җиргә, туфракка бәйләгән тамырларын – ныклык һәм тотрыклылык тамырларын өзә бара ул.* М.Вәлиев. *Дөньядагы бөтен бәйләнешен инде өзә барган чагында... Сөйләмәскә иде исәпләрем, искә төште менә тагын да.* З.Мансуров

Өзә башлау Өзәргә керешү. *Фатыйма башкалардан да уздырып җибәрде, шул чәчәкне кулына алып берәмләп өзә башлады: – Ярата, яратмый, ярата, яратмый...* А.Алиш. *Алмагач башындагы шаян кыз: «Шәмәрдән кайтып килә Самардан, аяклары кабарган», – дип такмаклый-такмаклый, тагын алма өзә башлады.* И.Гази. *Шулай диде дә тау читенә барып кузгалак өзә башлады.* Р.Вәлиев

Өзә килү Эзлекле рәвештә өзү; күптәннән бирле өзү. *Репрессияләр куркынычы, яңадан «халык дошманы» рәтендә булу мөмкинлеге һәм тормыш юлындагы башка куркынычлар акрын-акрын буыннар бәйләнешен өзә килде...* Т.Кәримов

Өзә тору Регуляр рәвештә өзү; берәр башка эш-гамәл белән берьюлы өзү. *--- бер генә помидор да өлгерә алмады. Балалар аны әле яшел чагында ук иртә дә, кич тә өзә тордылар.* Ф.Зыятдинов. *Ә табиблар өметләрне бер-бер артлы өзә тордылар...* Р.Габделхакова

Өзә язу Чак кына өзми калу. *Шулай булыша торгач, Озак тырыша торгач, Тартып чыгардылар алар, Өзә язып кармак җебен, Икесенә бер бик әйбәт Талдан үргән кәрзин төбен...* Р.Вәлиева.

Беркөнне ата дуңгыз кулымны тешләп өзә язды. Д.Гайнетдинова

Өзеп ату *к.* **өзеп ташлау**. *Шулай икән, ни тота аны? Тор, селтән, өзеп ат...* А.Әхмәтгалиева

Өзеп бару Акрынлык белән, эзлекле рәвештә өзү. *Уз кулыбыз, уз көчебез белән Телне өзеп бара.* В.Хәйруллина

Өзеп бетерү Барысын да өзү; бөтенләй өзү. *Бераз тын торганнан соң, ул өзелгән әңгәмәне яңадан ялгап җибәрде: – Борчылма, Гриша. Әле өметне өзеп бетерергә ярамый.* Г.Бәширов

Өзеп җибәрү Кинәттән өзү

Өзеп йөрү Өзү белән мәшгуль булу; очраган берсен өзү. *--- еллар үткән, кем беләндер исәп-хисап өзеп йөрергә Йосыфның уенда да юк!* З.Хөснетдинов

Өзеп карау Өзәргә тырышу

Өзеп килү Эзлекле рәвештә, электән ук өзү; әкренләп өзү, өзә язу. *Мескенчәк, бу вакыйганы күреп, Тәңрегә тилмереп вәзарилык кылып, җаныйдан өмет өзеп килә торганда, бер Ак елан очрады.* Әкият

Өзеп кую Алдан ук өзү эшен башкару; кисәк бөтенләй өзү. *Дәүлигә Әхмәтсафа үзе кайтып кергәнче исәп-хисапны өзеп кую яхшырак иде*. Ф.Сафин. *--- моннан ун ел элек әти белән ике арасын кырт өзеп куйган да, хәзер өчебез өч тарафта сыңар-сыңар канат белән тилмерәбез.* А.Әхмәтгалиева

Өзеп ташлау Кисәк кенә, бөтенләй, тиз яки ачу белән өзү. *Алай гына эш чыкмагач, теге кочаклап ала да моның борын очын тешләп өзеп ташлый.* Ш.Камал. *Әнә шул ирекне тою аны юлга ныграк этәрә, тик күңеленең кайсы чирегендәдер туган икеләнү божрасын тиз-тиз өзеп ташлый алмау гына аны сәерсендерә иде.* А.Гыйләҗев

Өзеп тору Хәзер өзү; даими өзү. *Үзәген өзеп торган уйны никадәр яшерергә тырышса да, берни дә килеп чыкмады.*К.Тимбикова

Өзеп чыгару Ахырына кадәр өзү. *[Гөлфия:] Ай, әтисе, өзеп үк чыгардың бит. [Хәллә:] Кирәге дә шулкадәр генә ---.* А.Гыйләҗев

Өзеп чыгу Бер-бер артлы, рәттән өзү

ӨЙ *и.* 1) Яшәү өчен салынган бина, корылма; яши торган урын. *Габдулла яңа урында алты почмаклы зур өйнең ак бүлмәсендә түгел, зур-зур ләгәннәр, комганнар, сөлгеләр, иске туннар белән тулган кара ягында күзләре бетәшкән бик карт бер әби белән бергә яшәде.* Ә.Фәйзи. *Иһаять, өй артындагы тирес өеменә килеп төртелде.* М.Насыйбуллин. *Нурлан килүгә, өен гөлчәчәкләр белән бизәячәк ул!* Казан утлары

2) Аерым бер максат өчен махсус билгеләнгән бина, корылма. *Бер көнне, йомыш тапкан булып, аш өенә кергән.* Г.Камал. *Шулай итеп, өй саен йөреп, ул көнне кичкә кадәр ярты авылның әтәчен җыеп, каравыл өенә китереп яптылар.* М.Гали. *Каравыл өенең ишеген тибеп җибәрде дә коты очкан Шәмсетдинне, җилтерәтеп, ай яктысына чыгарып бастырды.* Г.Бәширов

3) *күч.* Бер өйдә яшәүче гаилә яки бер өйдә булган кешеләр. *Садыйк соңгы көннәрдә өйнең тәртипсезләнүеннән пошына башлаган иде.* Г.Ибраһимов. *Бөтен өй эчләре белән елыйлар...* Т.Гыйззәт. *Әхмәдинең өеннән хат алмавына байтак вакыт булган иде.* Г.Бәширов

◊ **Өй борынча** Йорттан йортка, йорт саен кереп. *Шупырырга бәрәңге шулпасы булмасын да, өй борынча тәмәке сасытып, аракы эчеп йөрсен, имеш, адәм имгәге.* Ф.Бурнаш. **Өйгә бату** Хуҗалык эшләреннән, гаилә караудан бушый алмау. **Өйгә йокмау** Өйгә кайтып кермәү, күбрәк вакытын өйдән читтә үткәрү. **Өйгә кыз төшерү** Өйләнү. **Өйдәге чүпне тышка чыгару** Гаиләдәге вакытояк ызгышны, сүзне кешегә сөйләп йөрү. **Өендәген күршедән сора (ишет)** Кешенең үз өендәге хәлне күбесенчә белмәве, күршеләре яхшырак белеп торуы турында. **Өйдән өйгә җеп йөртү** Сүз йөртү, гайбәт ташу. **Өй тавыгы** Беркая да бармыйча, өйдә утырырга яратучы кеше. **Өй түбәсенә менеп төшү** Башка сугу, башка тондыру. *[Крестьяннар] инде [становойның] өй түбәсенә менеп төшәләр --- дип торабыз.* Х.Кәрим. **Өй эче** Бер гаилә булып яшәүче кешеләр яки бер өйдә булган кешеләр. *Семьялылар бөтен өй эчләре белән килә*. Р.Төхфәтуллин. *Бөтен өй эче гөрләп көләргә тотынды.* Г.Бәширов

ӨЙАЛДЫ *и.* 1) Өйнең яши торган өлеше белән тышкы ишеге арасындагы ягып җылытылмый торган корылма. *Канәгать, яңа чабаталарының шат шыгырдауларыннан ләззәтләнеп, өйалды аша тышка чыкты.* А.Хәлим. *Аннан соң алар шифоньерны, шкафны, сандыкны, ике иске чемоданны карадылар, берни дә тапмагач, өйалдына чыктылар.* М.Галиев. *Нурсөя туп кебек өйалды баскычыннан мәтәлде.* Н.Гыйматдинова

2) Башка төрле корылманың төп өлеше белән тышкы ишеге арасындагы өлеше. *[Хәлим] колагын бәрәңге бакчасы ягына сузып тыңлап торды да мунча өйалдына керде.* Г.Гобәй

3) *к.* **ишегалды**

ӨЙ БАШЫ *диал. к.* **өй түбәсе**

ӨЙГЕЧ *и. диал. к.* **күмгеч**. *Тракторлы өйгеч белән сыртчалар ясаганда, өйгечнең алым киңлеге трактор культиваторының алым киңлегенә туры килергә тиеш.* Яшелчәчелек

ӨЙДӘШ *и.* **1.** Хуҗаның гаиләсе белән бер өйдә, квартирда торучы кеше. *Күршесендә ялгыз яшәгән сукыр Газизә карчык бар иде, шуны өйдәш итеп алды.* М.Галиев. *Сидоровкада шулай ук ике балалы Мәликәгә өйдәш булып кергән булган.* А.Хәлим. *Синең бу усал өйдәшең өстебезгә кайтып кермәс бит инде, баг алмасы.* Н.Гыйматдинова

2. *рәв. мәгъ.* Өйдәш булып, өйдәш итеп, өйдәш сыйфатында; өйдәш белән. *Беренче ике елын солдатка Гайния апада өйдәш яшәп, мәктәптә урыс теле укытты...* А.Хәлим. *Өйләнешкәч, «байтак еллар кемдә туры килсә шунда өйдәш торып гомер иттеләр» дип яза автор.*Ф.Хатипов

ӨЙДӘШЛЕК *и.* Өйдәш булу, кем белән дә булса бер квартирда яшәү

ӨЙ-КАРАЛТЫ *җыйл. и. к.* **каралты-кура**. Өй һәм аның янындагы хуҗалык корылмалары. *Җәйдә генә җиткерелгән өй-каралтылары бер төн эчендә кара күмергә әйләнде.* Сөембикә

ӨЙКӘЛӘҮ *ф. диал.* Аннан-моннан гына, җиренә җиткермичә башкару (юу, себерү һ.б.ш.). *Гадәттәгечә, ак металлда берничә вак тамчы май калган. Ваннага тутырып бөтенесен*

берьюлы өйкәләгәндә була торган хәл. М.Мәһдиев

Өйкәләп алу Тиз-тиз өйкәләү

ӨЙКӘЛҮ *ф. диал.* Тетрәнү, өзелү. *Йөрәк өйкәлү*

Өйкәлеп алу Кинәт, беразга өйкәлү

Өйкәлеп китү Кинәт өйкәлү

Өйкәлеп тору Хәзерге моментта өйкәлү

ӨЙ КУЯНЫ *и. к.* **йорт куяны**

ӨЙ КЫЕГЫ *и.* Кыек түбәнең эчке почмагы. *Өй кыекларына оялаган күгәрченнәрдер дисәң, аңа бик ошамый.* М.Гафури. *Ә шул чак әлеге песи посып кына өй кыегы буйлап тәрәзә башына таба ұрмәләде...* А.Алиш

ӨЙЛӘ *и.* 1) Төш вакыты, көн уртасы. *Өйлә вакытында әтәч кычкырса, көн алышына.* Сынамыш. *[Алар] өйлә ашын ашыйлар.* Г.Минский. *Бүген әтисе өйләдән соң, гадәттәгечә, өйгә кермәде.* Мәдәни җомга

2) *дини* Төш вакытында укыла торган намаз. *Башкалар бүген өйлә укыгач та сәфәргә чыкмакчылар.* Г.Ибраһимов. *Сәхәр намазыннан соң чыгып китсә, өйләгә барып ирешер сыман.* Ф.Яхин

ӨЙЛӘНДЕРҮ *ф.* Егетне, ир кешене берәр хатын-кыз белән никахка кертү, аны җәмәгатьләндерү, гаиләле итү. *Алар өчен бүген Ипай белән Гөлгенәне, Мөхәммәтша белән Машаны өйләндерү төп мәсьәлә булып тора.* М.Җәлил. *Өйләндерсәң дә вакыт инде.* Н.Гыйматдинова

Өйләндерә язу Чак кына өйләндермичә калу. *--- моннан байтак еллар элек безнең әнкәйләр сезнең теләүдән башка безне өйләндерә язганнар иде.* Г.Ибраһимов

Өйләндереп бетерү Барысын да өйләндерү. *Хәзер бик ансатка өйрәнеп алды ир-ат. Өйләнми һәм вәссәлам. Гаилә юк – кайгы юк! Ансат яшәмәкче ---! Бөтенесен дә өйләндереп бетерәбез.* Н.Гаитбай

Өйләндереп җибәрү Озакка сузмыйча, тиз арада өйләндерү. *Казан тәхетенә тәгаенләнгәч тә, яшь ханны өйләндереп җибәрделәр.* Р.Батулла. *Бик яхшы гына мастер булып эшли башлаган иде, өйләндереп җибәргән идек үзен, ике оныгыбыз булган иде.* Т.Мөбарәков. *Әллә өйләндереп үк җибәрербез микән соң үзеңне, Габдулла?* М.Хуҗин

Өйләндереп йөрү Шушы араларда өйләндерү, өйләндерү эшләре белән мәшгуль булу. *Кызы гүрдә ята, сиксән яшьлек анасы кияү өйләндереп йөри...* Р.Габделхакова

Өйләндереп калдыру *к.* **өйләндереп калу**. *Әле без атаң белән, исемеңатың чыкмас борын өйләндереп калдырыйк, димез...* Г.Исхакый

Өйләндереп калу Ниндидер бер вакытка кадәр, үз вакытында өйләндерергә өлгерү

Өйләндереп кую Озакка сузып тормыйча, тиз арада өйләндерү. *Барып йөрмәсен, яңадан ияләнмәсен дип, Рамилне тиз генә өйләндереп тә куйдылар, яңа өй салу мәшәкатьләренә кұмделәр.* Ф.Тарханова. *Менә бит, әнкәй, синең бердәнбереңне монда синнән башка өйләндереп тә куйдылар.* Р.Сибат

Өйләндереп ташлау *сөйл. к.* **өйләндереп кую**. *Менә туй да ясап алдык. Абыйны өйләндереп тә ташладык.* Х.Вахит

Өйләндереп яту *сөйл.* Өйләндерү эшләре белән мәшгуль булу. *Миңа калса, Тубыкбайда энесе кайгысы калмагандыр, атам. Угылларын өйләндереп ята, диделәр.* М.Хәбибуллин

ӨЙЛӘНЕШҮ *ф.* Ир белән хатын булып бергә тора башлау, гаилә булдыру, никахлашу. *Болар бик яшьли яратыштылар, бик иртә өйләнештеләр.* Г.Ибраһимов. *1919 елда Кәрим Тинчурин белән Заһидә Әхмәрова өйләнешәләр.* Р.Батулла

Өйләнешә бирү Бернигә карамый өйләнешү. *Сугыш вакыты бит әле, җитмәсә!.. (Хәер, сугыш дип тормаганнар, җае чыкса өйләнешә биргәннәр).* Ә.Еники

Өйләнешеп алу Тиз генә, көтмәгәндә өйләнешү

Өйләнешеп бетү Барысы да өйләнешү. *Берзаман башын күтәреп якягына караса, яшьтәшләре өйләнешеп беткән, бала-чага үстергән, ә моның, чәчләре чалара башласа да, сукыр тиенә дә юк.* Р.Вәлиев. *Күбесе өйләнешеп бетте. Кызлар да башлы-күзле булдылар.* Р.Батулла

Өйләнешеп җибәрү Бик озакка сузмыйча өйләнешү. *1963 елның сентябрендә миңа фатир биреп, без Нурсөя белән өйләнешеп җибәргәч, ул безнең туебызда Марс Шабаев белән алмаштилмәш тамада булды.* Ф.Яруллин

Өйләнешеп калу Моменттан файдаланып яки берәр вакыйгага кадәр өйләнешү

Өйләнешеп кую Озакка сузып тормыйча, тиз арада, кисәк өйләнешү. *Яшьләр тимерне кызу чагында сугарга яраталар. Өйләнешеп тә куялар.* А.Хәсәнов. *Озакка сузмыйча, әниләреннән хәер-фатиха алып, өйләнешеп тә куйдылар.* Ф.Мөслимова

ӨЙЛӘНҮ *ф.* Нинди дә булса хатын-кызны хатынлыкка алу, аның белән никахлашу (ир кеше тур.). *Өйләнмичә – сөйләнеп, сөйләнмичә өйләнеп булмыймыни?* А.Хәлим. *Ашот та, Карлен да, күпчелек дуслары да, яшьләре утызларга җитеп килсә дә, ә кайберләре инде ул чикне байтактан узган булсалар да, әле өйләнмәгән буйдаклар иде.* Р.Мирхәйдәров. *Ә миңа бүген үк өйләнергә кирәк.* Н.Гыйматдинова

Өйләнә башлау Өйләнергә җыену; өйләнү гамәленә күчү; бер-бер артлы өйләнү. *--- болгар егетләре җирле халык кызларына өйләнә башлаганнар, шул ук вакытта гореф-гадәтләр һәм тел дә үзгәреш кичергән---.* А.Тимергалин. *Ә өйләнә башласалар тагын? Бригадада берсенең бер торасы юк!* Ш.Бикчурин

Өйләнә калу Өйләнү очрагы булу. *Әгәр аңа өйләнә калса, теге иблис Хәмит әйтмешли, сылу артистка үзе белән бу йортка шатлык, җыр, музыка алып килер иде.* Ә.Еники. *Я Ходаем, әгәр бу яшеннән өйләнә калса, халык нәрсә әйтер?* Ф.Яхин

Өйләнә китү Өйләнүгә кадәр барып җитү. *Йөргән бер кызга өйләнә китсәң!* Р.Хәбибуллина

Өйләнә язу Чак кына өйләнми калу. *Я, сөйләп кара: ничегрәк була икән ул өйләнә язып калу.* Ф.Яруллин

Өйләнеп алу *к.* **өйләнеп җибәрү**. *Мурат, өйләнеп алгач, тагын уйчанланды,*

басылды, тулысы белән эшкә җигелде. Р.Батулла

Өйләнеп бетү Барысы да өйләнү. *Сүз ябышмады, сержант Шәйдулла үзенең нык, дәү кулларын кызның җилкәсенә куйды да туры ярып әйтте: – Яшьтәшләр өйләнеп беткән. Мин ялгыз калганмын. Минем хатын булырга ризамы?* М.Мәһдиев

Өйләнеп карау Өйләнү тәҗрибәсе булу. *--- әгәр аны өйләнү дип атап булса, ул бер мәртәбә өйләнгән, дөресрәге, өйләнеп караган иде инде.* З.Хөснетдинов. *Өйләнеп караган булмаса да, югалып калмаска тырышырмын.* З.Дәүләтов

Өйләнеп кую Кинәт кенә, уйламаганда, тиз арада өйләнү. *Каян беләсең, бәлки, мин сиңа өйләнеп куярмын! Ә?!* Г.Бәширов. *Фатих аның белән рәтләп йөрмәгән дә килеш өйләнеп куйды.* Ф.Яруллин

Өйләнеп җибәрү Озакка сузып тормыйча өйләнү. *Килгән шәпкә өйләнеп җибәреп, төпле тормыш корырга күңеленә ятышлы чибәркәйләр булмаса, парсыз морякларны да монда бәйләп тә тота алмассың.* А.Хәсәнов. *Авылның буеннан-буена адым саен туктаталар моны: – Һай, маладис, энем, өйләнеп җибәргәнсең икән!..* Ф.Баттал

Өйләнеп ташлау *сөйл. к.* **өйләнеп кую**. *Кара әле бу калай әтәчне! Ансат кына өйләнеп ташламакчы, ә! Вәгъдәме, имеш!* Г.Бәширов. *Морат, көтмәгәндә генә, урта мәктәптә укытучы олыгаеп бара торган боек кына, сабыр гына бер кызга өйләнеп ташлады.* Р.Батулла

ӨЙЛЕК *с.* **1.** 1) Өй салырга яраклы; өй салырга җитәрлек; өй салу өчен билгеләнгән. *Егетләр урман эшенә китеп, өйлек бүрәнә әзерләргә керешәләр.* Татарстан яшьләре. *Өйлек бүрәнәләр китертте.* Мәгърифәт

2) Билгеле сандагы өйләрдән торган. *Киттек чыгып, егерме өйлек, утыз өйлек керашен авылларына.* Р.Батулла. *Ралиф әфәнденең 60 өйлек кенә бетеп яткан туган авылын әкияттәгедәй танымаслык итеп үзгәртүе турында сүзләр телдән телгә күчә.* Кәеф ничек?

3) Өйдә кию өчен билгеләнгән, өйдә кию өчен генә яраклы. *Өйлек күлмәк кенә бу*

2. *и. мәгъ.* 1) Өй салырга яраклы агач; бер өй салырга җитәрлек агач (бүрәнә)

2) Өйдә кия торган кием. *Өйлеге юк кешелееген кияр, кешелеге юк – кешенекен кияр.* Мәкаль

ӨЙМӘКЛӘШҮ *ф. сөйл.* Бер-берсенә бик тыгыз, якын килеп, бер төркемгә җыелу, туплану. *Көч кулланылган бар нәрсәдән – өймәкләшеп сугышулардан читтә йөр.* Өмет

Өймәкләшеп тору Өймәкләшкән хәлдә булу

ӨЙРӘ *и.* Ярма салып пешерелгән сыек аш. *Тары ярмасыннан ботка, өйрә пешереп, мулла чакырталар.* Р.Батулла. *Өйрәне төрле ярмалардан: тары, дөге, карабодай, солы ярмасыннан һ.б. пешерәләр, шуннан чыгып, тары өйрәсе, дөге өйрәсе һ.б. диләр.* Татар халык ашлары

◊ **Өйрәңне өйдә суыт** «Гаиләдәге үзара үпкәләшүләрне, әйтешүләрне кешегә сөйләп йөрмә» дигәнне аңлата

ӨЙРӘГЕ *и. диал.* Кибәндә печән черемәсен өчен, аның эчендә агачлардан ясап калдырылган куыш. *Өйрәге кую*

ӨЙРӘЛЕК *с.* **1.** Өйрә пешерү өчен билгеләнгән, шуңа җитәрлек

2. *и. мәгъ.* Өйрә пешерергә җитәрлек яки билгеләнгән ярма. *Боткалык дип торган идем, өйрәлек тә калмады.* Әйтем

ӨЙРӘНГЕЧ *с. сөйл. к.* **өйрәнчек** (*2 мәгъ.*). *Өйрәнгеч эш*

ӨЙРӘНҮ I *ф.* 1) Берәр эшне башкарырга, эшләргә күнекмә алу. *Бер елны шулай Рәхмәтулла карт, читтән малай алып килгәнче, тамагы да узар, эшкә дә өйрәнер дип, үзенең ун яшьлек кенә бер шадра малаен ияртеп китергән иде.* М.Гали. *Аз акча белән дә кешечә торырга өйрәнделәр.* Һ.Такташ. *Тагын да шәбрәк сызгырырга өйрәнгәч, минем янга кереп чыгарсың.* Г.Әпсәләмов

2) Нинди дә булса һөнәрне, белгечлекне үзләштерү. *Мин итек тегәргә өйрәндем.* А.Шамов. *Сиңа да, Газинур, трактор йөртергә өйрәнергә кирәк иде.* Г.Әпсәләмов. *Үсә төшкәч, тегүчигү һөнәрен өйрәнеп, приютны ташлый.* К.Нәҗми

3) Фәнни әдәбият укып, тиешле мәгълүмат алу, нинди дә булса белемгә ия булу. *Иманны яхшы өйрәнеп, намаз ниятләрен белсәң, кирәкле догаларны ятласаң – шул җиткән сезгә, ди торган иде карт абыстай.* М.Гали. *Госпитальдә ул аз-маз гына булса да сугыш белеменә өйрәнде.* Г.Әпсәләмов

4) Ия булу; үзләштерү (башка бер телне). *Менә коммерческийны бетереп, яхшы немецча өйрәнгән булсам, хәзер аның әллә никадәр файдасы тияр иде дә бит.* Ф.Әмирхан. *– Юк, Газинур, рус телен олыгайгач та өйрәнергә кирәк, – диде.* Г.Әпсәләмов. *Бөтен күңелен биреп рус телен өйрәнде.* Г.Гобәй

5) Кемнән дә булса үрнәк алу, шуңа иярү. *Бөтен СССР халыклары әдәбияты әченә керерлек җәүһәрләр иҗат итүендә Ш.Камал бөек рус классиклары А.П.Чехов һәм М.Горькийдан өйрәнде.* М.Җәлил. *Владимир Маяковскийны яшь Кутуй үзенең шагыйрьлек идеалы итә. Ул аңардан өйрәнә, үрнәк ала ---.* Р.Нуруллина

6) Фәнни-тикшерү юлы белән ачыклау, белү. *Дөнья классикларының иҗатларын өйрәнү һәм югары музыка культурасын үзләштерү нигезендә эшләнгән бу әсәрләр татар музыкасын яңа жанр һәм яңа үрнәкләр белән баеттылар.* М.Җәлил

7) Нәрсәне дә булса ачыклау өчен, бик җентекләп карап чыгу, тикшерү. *Кайсы котырып искән җилләрне өйрәнә.* А.Алиш. *Полк командиры, тынып, әйләнә-тирәне җентекләп өйрәнергә тотынды.* А.Шамов

8) Нинди дә булса шартларга, хәлгә күнегү, ияләшү. *Авырлыкка хәзер өйрәнегез, чын сугышлар булган чагында --- Авыррак булыр тагын да.* Һ.Такташ. *Мускуллары ныгып җитмәгән һәм ул эшкә өйрәнмәгән Габделкаюм өчен көне буе балта тотып агач юну бик авырга килде.* М.Гали

9) Ияләнү, билгеле бер тәртипкә күнегү, шуны гадәткә кертү. *Безнең тирәдә урман шәп булганга күрә, урманда йөрергә өйрәнгән идем.* М.Гафури. *Аннан соң син беләсең инде безнең көтүче*

кешене, без кунак булып йөрергә өйрәнмәгәнбез бит. М.Гали. *...Иртә белән урыныннан торган вакытта, ул мондый хәлне күргәнмәгән иде.* А.Шамов

10) Берәр текстны ятлау, отып алу, үзләштерү. *Кыш буена алган бөтен белемем абыстайның беренче көнне минем «Иман шарты»ның беренче битеннән бармакларын йөртеп укып күрсәткән 28 Коръән хәрефләрен ятлау һәм «Иман кәлимәсе» өйрәнү белән чикләнде.* М.Гали. *Аннары, бакчада өйрәнгән җырларын җырлый-җырлый, курчагын тирбәтә.* Д.Аппакова

11) Җигеп яки атланып йөрергә күнектерелү. *Ләкин өйрәнмәгән ала айгырга бергә бару да кыен иде.* Г.Ибраһимов

Өйрәнә бару Бер-бер артлы өйрәнү; торган саен ныграк өйрәнү. *Җаны мунча керә апрель саен һәм өйрәнә бара Шагыйрьләрчә мәгърур яшәргә.* Х.Бәдигый

Өйрәнә башлау Өйрәнергә керешү. *Тел хәятын урап алган гомуми томаннан аның төзелешен аерып чыгарып, катгый бер система итеп өйрәнә башлаган галимнәргә, иң әүвәл Ф. де Соссюрга зур рәхмәт*. И.Низамов. *Тансык уйларын беркемгә дә сөйләмәскә өйрәнә башлады, тагын дүрт көн узгач, балалар колониясеннән качты*. З.Зәйнуллин

Өйрәнә килү Элек-электән, күптәннән эзлекле рәвештә өйрәнү. *«Фән» сүзенең ясалышын Тирәк Төбәки туганнан бирле өйрәнә килеп, нuһаять, асылына төшкән галим.* Р.Батулла. *Сернең ачкычы шунда ки, кешеләр белем туплап, нuһаять, фикер йөртергә өйрәнә киләләр*. Р.Нуруллин

Өйрәнә тору Билгеле моментка, эшгамәлгә кадәр өйрәнү, алдан ук өйрәнү. *--- бүген идарә начальнигы – иртәгә министр, министр икән, димәк, ил башлыгының эш стилен өйрәнә тор!* К.Кәримов. *Өйрәнә торырга кирәк. Сыртыңа бомба төшкәч кенә соң була ул.* Р.Бәшәр

Өйрәнә төшү Беркадәр өйрәнү; тагын да әйбәтрәк өйрәнү. *Инде Таңсылу сагышына өйрәнә төшкән күңелем дөньяны тагы күрмәс булды*. Х.Сарьян. *Күзләре бераз өйрәнә төшкәч, кояшка омтылган чәчәк сыман, талгын гына торып басты.* М.Кәбиров

Өйрәнеп алу Тиз генә, вакытны бушка уздырмыйча, вакытында өйрәнү. *Кайсы илгә аяк басса, шул ил халкының телен тиз арада өйрәнеп алган Баянҗар акын – бердәнбер ул ---.* М.Галиев. *Габдулла абый безнең кире холыкны инде өйрәнеп алган иде булса кирәк, каршы килмәде, без сәхнәгә чыктык.* Р.Батулла

Өйрәнеп бару Даими рәвештә өйрәнү, рәттән, тоташ өйрәнү. *Җиңел акча табарга өйрәнеп барасың.* Т.Миңнуллин

Өйрәнеп бетерү Барысын да өйрәнү. *Һәр тукталыш минем өчен соңгы тукталыш кебек. Шул тукталышны ачып, өйрәнеп бетермичә, алга бара алмыйм мин.* Р.Вәлиев

Өйрәнеп бетү Ахырына кадәр, тәмам өйрәнү. *Казарма тормышына өйрәнеп беткән карт солдатлар да ярата башладылар.* М.Гафури. *Мәҗлесләрдә кеше эчкәнгә исерергә өйрәнеп беттем инде.* М.Галиев

Өйрәнеп җибәрү Озакка сузып тормыйча өйрәнү. *Бүре телен дә өйрәнеп җибәрсәң, әллә ничаклы үсеп китәчәк әле ул.* Т.Миңнуллин

Өйрәнеп җитү Тәмам, тиешле дәрәҗәгә кадәр өйрәнү. *Үзе дә усаллыкка өйрәнеп җитте малай.* Ш.Камал. *Өйрәнеп җиттегез, ә! Газ кирәк, имеш. Утын ягып, казанда быгырдатып аш пешерәсе урында.* М.Галиев

Өйрәнеп йөрү Шактый вакыт өйрәнү, өйрәнү белән мәшгуль булу, өйрәнүгә вакыт сарыф итү. *Мостафа агай үзе дә улының һөнәргә өйрәнеп йөргән җирдән Ходайга каршы баручы көфер бәндәләргә кушылуын хупламады.* Ф.Сафин

Өйрәнеп калу Вакытында, тиешле урында, билгеле кешедән өйрәнү. *--- бала, урта мәктәпне бетергәнче, үзенең табигый мохитендә яши, укыту сыйфаты әллә ни югары булмаган тәкъдирдә дә, ул инде ана телен гомерлеккә өйрәнеп, белеп кала.* Ә.Еники

Өйрәнеп карау Өйрәнү тәжрибәсе ясау, өйрәнергә тырышу. *Мәсәлән, рәсем ясарга өйрәнеп карамыйча, рәсемгә сәләтне белеп булмый.* А.Низамов

Өйрәнеп килү Аз-азлап, акрын гына өйрәнү. *Син инде шул юлдан барырга акрын гына өйрәнеп килә идең, ләкин бөтен дөньяның астын-өскә әйләндерергә теләгән Кызыл фикерне башыңа кертеп харап булдың.* Г.Камал. *Бала сөйләшергә өйрәнеп килә*. Ш.Галиев

Өйрәнеп китү Билгеле бер моменттан алып өйрәнү. *Күз караңгылыкка өйрәнеп китте.* М.Гафури. *Тәнкыйтьләргә өйрәнеп киттек, ә файдасы юк, дип уйламыйсызмы?* Т.Миңнуллин // Билгеле бер эзлеклелектә, үз чираты белән өйрәнү. *Инде аны [карбюраторны] ничек тончыктырмаска, ничек тыгылдырмаска һәм күп тыгынмый торган итәргә – шуны өйрәнеп китик.* Ф.Яхин

Өйрәнеп кую Алдан ук өйрәнү яки бик тиз өйрәнү. *Мин инде сөйләргә сүзләр дә өйрәнеп куйган идем.* Аманулла. *Шакмакларны бер-берсе өстенә өярга дә, рәсемнәрдә куянны, баканы, маймылны күрсәтергә дә берничә көн эчендә өйрәнеп куйды.* М.Маликова

Өйрәнеп тору Хәзер өйрәнү; өйрәнүгә вакыт сарыф итү. *Аннары ракета яктысын өйрәнеп тордылар.* Х.Камалов. *Шулай булгач, татар балаларына башкорт телен махсус өйрәнеп тору да кирәкми.* Ф.Фәтхи

Өйрәнеп утыру Җентекләп, озаклап өйрәнү. *Зөһрә кулындагы бүләк сәгатьне исенә төшерде, аны озак кына өйрәнеп утырды*. Г.Гыйльманов. *«Сөембикә» журналыннан тагы да матуррак сүзләр өйрәнеп утыра идем – кайткан бу.* И.Шиһапов

Өйрәнеп чыгу Башыннан ахырынача өйрәнү, барысын да өйрәнү. *--- Фәрваз Миңнуллин, зиһенгә үткәзерлек итеп: – Син Тукайны яңадан өйрәнеп чык! Такташ – зур шагыйрь, Тукай исә – гасырлар шагыйре! – дигән иде, мәрхүм.* Р.Батулла. *Җәнлекләр, гадәттә, яңа җиргә күченгәч, үз өне тирәсен барлап, өйрәнеп чыга.* Р.Вәлиев

Өйрәнеп яту *сөйл.* Озаклап өйрәнү; өйрәнү белән шөгыльләнү. *Батареяда матчасть өйрәнеп яталар.* Х.Камалов. *Лена Шагыйрьҗан кебек кантарлы куәгә ия шәхесләрнең иҗатын толыкманы белән кем өйрәнеп ята?* Р.Батулла

ӨЙРӘНҮ II *и.* Тикшеренү, анализлау эше. *М.Х.Хәсәнов фәнни тикшеренүне нигездә берничә юнәлештә алып барды. Иң әүвәл ул татар әдәбияты тарихын өйрәнүгә зур көч салды.* Ф.Галимуллин

ӨЙРӘНҮЧЕ *и.* 1) Нинди дә булса эшкә, һөнәргә өйрәнү белән шөгыльләнүче кеше. *Өйрәнүчеләр һәркайсы аерым стойкалардагы винтовкаларны алмага төзәп куйганнан соң, Мостафа чыратлап аларны карап үтә.* Ш.Камал. *Бу алым тәрҗемәдә чыккан әсәрләргә карата аеруча кызыксыну да уятыр һәм чит телне өйрәнүчеләргә чагыштырып өйрәнергә дә ярдәм итәр иде*. Казан утлары

2) Махсус фәнни тикшеренү эше алып баручы, галим. *Авторларның бу китаплары, гомумән, аларның тулы иҗаты, үзенең өйрәнүчеләрен, галимнәрен, тәнкыйтьчеләрен көтә.* Р.Батулла. *Диңгезләр торышын махсус өйрәнүче белгечләр мондый поляр (капмакаршы) күренешләрне «прилив» һәм «отлив» дигән термин белән дә атыйлар*. Кызыл таң

ӨЙРӘНЧЕК *и.* **1.** Кайда да булса берәр белгечлеккә өйрәнүче, эш-һөнәр күнекмәсе алучы кеше. *Өйрәнчек остадан узган.* Мәкаль. *Немец төрмәчеләре безнекеләр янәшәсендә сабый, өйрәнчек булып кына калалар түгелме соң?* А.Гыйләҗев. *Аҗаган уйнап китә: Алсулыгы болытлардан Офыклар буйлап китә. Әйтерсең лә карт тимерче Өйрәнчеген өйрәтә ---.* Ж.Дәрзаман

2. *с. мәгъ.* 1) Кемнән дә булса һөнәргә өйрәнә торган. *Шәһәрдәге бүрек тегүчеләрнең берсенә өйрәнчек малай булып кердем.* Г.Толымбай

2) Берәр һөнәргә өйрәнгәндә башкарылган, эшләнгән. *Өйрәнчек рәсемнәр*

3) Үзлегеннән берәр эшкә өйрәнүче, шул эштә көч сынап караучы. *Балет цехы, аз сандагы солистлардан тыш, байтак кына өйрәнчек яшь көчләрне берләштерә.* М.Җәлил

ӨЙРӘНЧЕКЛЕК *и.* Өйрәнчек (*1 мәгъ.*) булу, квалификацияле хезмәткә өйрәнү вакыты. *Көзен исә көрәксәнәкләрне калдырып, бер тегүчегә өйрәнчеклеккә тагылды һәм авылдан авылга гизеп көн күрергә кереште.* Т.Әйди. *Өйрәнчеклек чоры*

ӨЙРӘТКЕЧ *и. иск.* Берәр төрле белемгә, эшкә, шөгыльгә өйрәнү өчен кулланма; дәреслек. *Шул кешеләр урысча-татарча сүзлекләр төзеде, урыс телен өйрәнү өчен өйрәткечдәреслекләр яздылар.* Р.Батулла. *1913–1914 елларда Г.Сәйфуллин, рояль һәм пианино уйнау өчен, унҗиде татар көенең нотасын, мандолина өчен цифрлы һәм ноталы өйрәткечләр дә бастырып чыгара.* Гасырлар авазы

ӨЙРӘТМӘ *и.* Берәр фәнни юнәлешнең яки галимнең, акыл иясенең карашлары системасы, тәгълимат. *Дин Аллаһы Тәгалә тарафыннан камил, мөстәкыйль, тәмамланган тәгълимат, өйрәтмә буларак иңдерелгән.* Мәдәни җомга

ӨЙРӘТҮ *ф.* 1) Нинди дә булса эшне башкарырга, үтәргә, эшләргә күнекмә бирү. *Яшь киленне эшкә өйрәт.* М.Гафури. *Ул егетне рояльдә уйнарга иң элек мин өйрәттем.* Ф.Бурнаш. *Наташаның тәҗрибәсе дә зур, безнең яшьләрне өйрәтер дә иде ул, игенне күп алырга өйрәтер иде.* Г.Бәширов

2) Берәр төрле һөнәргә, белгечлеккә ия булырга, аны үзләштерергә ярдәм итү; шул һөнәр, белгечлек күнекмәләрен бирү. *Акча бирмәм, өс-башын карамам, тамагын туйдырырмын, балта эшенә өйрәтермен, дигән балтачы Әхмәтҗан аңа.* М.Гали. *– Тыныч булыгыз, мин аны шактый хәлле һәм бик биндар бер карчыкка тегү-чигү һөнәре өйрәтергә бирдем, – ди.* Ә.Фәйзи. *Балага күп төрле һөнәр эзләп тә уйлаштылар, музыка остасы, очучы, доктор, балерина, җырчы, тагын шуның ише бик күп төрле һөнәр өйрәтергә булдылар.* Г.Минский

3) Белем бирү; нәрсәне дә булса аңларга, төшенергә ярдәм итү. *Әллә нинди узгынчы черкаслар керә, им-том өйрәтеп китәләр иде.* Ш.Камал. *Тормыш итәргә өйрәткән өчен, аңа күп итеп рәхмәт язган.* Г.Бәширов. *Апакаем, өйрәнә алмасаң, мөдиргә әйт, белмим, диген, ничек саварга кирәклекне мөдир өйрәтер, алай да булмаса, аякларыңны салындырып, мич башында гына утыр.* Ә.Айдар

4) Үзләштерергә, өйрәнергә ярдәм итү, булышу (башка бер телне). *Минем шуңа бигрәк ачуым килә: бу корсак үзе Россиядә торып русча белми, ә үзе мине русча сөйләшергә өйрәткән булып азаплый.* Ш.Мөхәммәдев. *--- елмайганда яңаклары чокырлана торган бу яп-яшь рус кызы аңа бер дә иренмичә рус телен өйрәтә, кайчагында аның берүзе өчен генә калып та берәр-икешәр сәгать утыра торган иде.* Г.Әпсәләмов

5) Аңлатып киңәшләр бирү, нинди дә булса акыл бирү. *Үзең төпле белмичә, кешене өйрәтмә.* Мәкаль. *Ләкин ул төп асылда мондый теләми каршы алуларына очрармын дип алдан ук хәзерләнгән, ире аны таяклап куганга-чә, һәммә нәрсәгә, һәммә шелтәгә түзәргә, баш иргә юл буйлап өйрәтеп кайткан иде.* Г.Ибраһимов

6) Нинди дә булса күнекмә бирү, күнектерү. *Монысы инде бала-чагаларга күз-колак булу һәм аларны акылга, тәртипкә өйрәтү эшенә кирәк, ди икән.* Ш.Камал. *Егетләр, моның серкәсе су күтәрми икән, мәдрәсә тәртибенә өйрәтик.* Т.Гыйззәт. *Колхозчының хезмәтенә түләмичә начар гадәткә өйрәттеләр.* Татарстан яшьләре

7) Хайваннарны билгеле бер эш-хәрәкәтләр ясарга күнектерү. *Атсызлыктан газап чиккән әткәй бу муены камыт күрмәгән симез бияне ике көн эчендә җигәргә өйрәтте дә дөнья җимереп эшләргә тотынды.* Г.Ибраһимов. *Мин алып бара торган утыз биш аюны эшкә өйрәтерсең.* Һ.Такташ. *Быел сыерларны җигәргә өйрәттек.* Ә.Айдар

8) Аңлатып бирү; күрсәтү (юлны). *– Урман эченәрәк керсәң, һичшиксез табарсың, – дип, юл өйрәтеп җибәргән.* А.Алиш

9) Үзләштерергә, өйрәнергә ярдәм итү. *Әнкәй миңа кечкенәдән җыр өйрәткән, Җырлый-җырлый әби бишектә тирбәткән.* Ә.Ерикәй. *Зәйни абый яңа көйләр өйрәтте.* Ф.Бурнаш. *Сабантуй һәм Яңа ел бәйрәмнәре алдыннан әти безгә шигырь һәм җырларны үзе әйтеп торып өйрәтә.* Татарстан яшьләре

10) Акыл сату, кирәкмәгән киңәш бирү, мораль уку. *Вафин энем, өйрәтә димә, иң элек райкомны ныгыт!* Р.Камалов. *Өйрәтә, кеше эшенә тыгыла, дип әйтмәсәң, бер киңәшем бар сиңа, кем, ни, Мәһди энем.* Гөлшәһидә

11) Котырту, котыртып начар киңәш бирү. *Әлбәттә, аңа алдан өйрәтеп куйганнар, шулай дип әйт, дигәннәр.* Г.Ибраһимов. *Кем өйрәтте коткы таратырга, фетнә борчасы!* К.Нәҗми

12) *күч.* Нинди дә булса яман эшләрне кисәтү йөзеннән җәза бирү; сабак бирү. *Юк, без әле бу кулак бандасының арт сабакларын өйрәтербез.* А.Шамов

◊ **Өйрәтермен мин сине** Азынган, узынган кешегә янау

Өйрәтә бару Башка эш-хәрәкәт белән берәттән өйрәтү. *Тышкы фактлары белән бер уңайдан телнең эчке мәгънә аерымлыкларын да өйрәтә бару – анысы метод мәсьәләсе булса кирәк.* Г.Алпаров

Өйрәтә башлау Өйрәтергә керешү. *--- «шәкертләремне» хәреф танырга, иҗекне иҗеккә кушып сүзләр ясарга, сүзләрдән җөмлә төзергә өйрәтә башладым.* Г.Бәширов. *Тегенди-мондый көчек түгел. Мин эт белән җик күргән инде, беләм. Аны хәзер үк өйрәтә башларга кирәк.* Г.Мөхәммәтшин

Өйрәтә килү Эзлекле рәвештә өйрәтү. *Аның [С.Сәйдәшев] музыкасы татар кешесенең рухына, милләтебез йөрәгенә таза-бәрәкәтле орлыклар салган, моңланырга, язмыш фаҗигаләрен кичерергә, яшәү бәхетен тоярга өйрәткән һәм әле дә булса өйрәтә килә.* Р.Низамиев. *«Дилбегәне тартмалама, Ат үзе юлны таба...» Шулай өйрәтә килгәннәр Улларын ата-баба.* Х.Хөснуллин

Өйрәтә төшү Бераз өйрәтү

Өйрәтеп алу Кыска вакыт эчендә, бераз өйрәтү. *Әйдә, азрак өйрәтеп алыгыз әле укучыларыгызны.* З.Зәйнуллин

Өйрәтеп бетерү Тәмам өйрәтү. *--- үзен русча уйларга өйрәтеп бетергән Тәнзилә: «Әнкә-ә-әй!» – дип кычкырырга авызын ачты да, әйтә белмәмдер ахры, дип кыенсынып: «Мама», – дип пышылдады.* Ф.Мөслимова. *Заводта үзе токарь булып эшләгәч, төгәллекне ярата, ирен дә микрометр белән яшәргә өйрәтеп бетерде инде.* Г.Гомәров

Өйрәтеп җибәрү Озакка сузмыйча тиз арада өйрәтү. *Әбекәем, сөйдерүнең Мәгълүм сиңа күп сере, Өйрәтеп җибәрче, зинһар, Миңа да шуның берен.* Ш.Галиев

Өйрәтеп җиткерү Тиешле дәрәҗәдә, барысына да өйрәтү. *Балаларны яхшы булырга тәмам өйрәтеп җиткердек, начарлыктан сакланырга үзләре өйрәнер инде.* Ш.Галиев. *Баласын очарга өйрәтеп җиткермәгән килеш, ана үз оясын ничек ташлап китсен?* А.Гыйләҗев

Өйрәтеп йөрү Кеше саен өйрәтү, һәркемне өйрәтү; шактый вакыт өйрәтү. *Гражданин, сез әгәр ул хәлләрне язарга килдегез икән, языгыз. Ләкин тикшерүчеләргә ничек эшләргә икәнен өйрәтеп йөрмәгез.* Р.Сәгъди. *Сыйфат комиссиясе әгъзасы буларак, фермаларда, басуларда кем очраса, шуны әрләп, өйрәтеп йөрде.* Г.Мөхәммәтшин

Өйрәтеп калу Вакытында өйрәтү; өйрәтү белән чикләнү. *Исән-имин илемә кайтсам, үзем укыткан балаларга гыйлем генә өйрәтеп калмам, бәлки күңел пакьлеге дә бирергә тырышырмын, дип уйладым.* Э.Шәрифуллина

Өйрәтеп карау Өйрәтү тәҗрибәсе ясау. *Әлеге ир тугыз ел буе малайны кешечә яшәргә өйрәтеп карый, ләкин алга китеш аз була.* А.Вергазов

Өйрәтеп кую Алдан ук ни эшләргә кирәклекне өйрәтү. *Әлбәттә, аңа алдан өйрәтеп куйганнар, шулай дип әйт, дигәннәр.* Г.Ибраһимов. *Без, алдан өйрәтеп куйганча, минут эчендә яшеренеп беттек: кызлар идән астына төшеп посты, без, малайлар, лапаска чыгып, салам астына сеңдек.* Г.Бәширов

Өйрәтеп тору Даими рәвештә өйрәтү. *Хәсәнә абыстай мулласын да, балаларын да бу сәнгатькә даими өйрәтеп тора.* С.Поварисов

Өйрәтеп утыру Шактый вакыттан бирле өйрәтү; өйрәтеп вакыт әрәм итү. *Нәрсә, сиңа инде акыл өйрәтеп утырыймы?* Т.Миңнуллин. *Сезне эштән куалар, аңлыйсызмы? Ә мин сезгә шуңардан котылуның бердәнбер юлын өйрәтеп утырам.* К.Кәримов

Өйрәтеп яту *сөйл. к.* **өйрәтеп тору**. *Авылыгызны ташлап, Казанга оялыйсыз да шуннан безгә акыл өйрәтеп ятасыз!* Р.Вәлиев. *Аларга җиңел, начальник булып өйрәтеп ятарга.* Р.Сәгъди

Өйй тараканы *к.* **кызыл таракан**. *Өй тараканын, нигез тараканын очратуны борын-борынгыдан яхшыга юраганнар ---.* М.Хәсәнов

Өйй туе *и. этн.* Яңа өйгә күчү уңае белән оештырыла торган кунак мәҗлесе. *Бүген сезнең өй туе, Өстәлләрдә туй сые. Һәр кунакның күңелендә Зурлап өй котлау уе.* Э.Шәрифуллина

Өйй чикерткәсе *и.* Турыканатлылар отрядыннан канатларын аяклары ышкып тавыш чыгара торган чикерткә төре; *русчасы:* **сверчок**. *Кайдадыр өй чикерткәсе «черрек! черрек!» итеп куя.* Ә.Фәйзи. *Мөҗип абыең машинасының тартмасы өй чикерткәсе тавышы чыгара.* Р.Батулла

Өй-чөй *и.* Эшнең, тормыш-көнкүрешнең гадәтләнгән җае, тәртибе

◊ **Өйгә-чөйгә китерү** Нормаль хәлгә китерү, рәткә салу. *[Хәмзә:] Ничә елдан бирле өйрәтеп тә, өйгә-чөйгә китерер хәл юк, һәр көн шулай башымны катырып бетерәләр.* Г.Камал

Өке *и. диал.* Мәче башлы ябалак. *Өке йоны белән, былбыл өне белән.* Әйтем

Өкé-төке *рәв. диал.* Ачлы-туклы, аз-маз. *[Карт юлчы:] Киленебез эшләгәндә, өке-төке булса да туена идек.* И.Туктар

Өкешү *ф. иск.* Мактанышу. *Ишан, ишәк өкешер, Өкешмәктә мәгънә бар ---.* Г.Тукай. *Шул ук шигырьдә өкешмәк сүзенә синоним рәвештә аның хәзерге телдә кулланыла торган вариантын да китерә.* В.Хаков

Өләшкеч *и.* Нәрсәне дә булса билгеле күләмгә бүлеп өләшә торган машина, җайланма. *--- азык өләшкечләр дип аталган компьютер җайланмалары да шулай ук зур тәэсирләр уята.* Авыл таңнары

Өләштерү *ф. лингв.* Кайбер сөйләшләрдә сүздәге [ү] авазы урынына [ө] әйтү (мәс., *күңел – көңел, түгел – төгел*)

ӨЛӘШҮ *ф.* 1) Нәрсәне дә булса кешеләргә бүлеп бирү. *Колхозчыларына итен, сөтен мул итеп бирү генә түгел, акчалата да өләшә икән.* Ә.Еники. *Ярмалы бәлешне табынга табасы белән чыгаралар, башта аның өстен кисеп өләшәләр.* Татар халык ашлары

2) Тарату, таратып бирү. *Никах хөтбәсеннән соң садака өләшүгә дә, бу туй өчен муеннан бурычка батуына карамастан, бик нык әзерләнде.* Г.Ибраһимов. *Аларның малын русларга өләшергә телиләр.* И.Гази. *--- зираттагы бала-чагага Тәфкил хәер-садака өләште.* Р.Шәрипов

3) *күч.* Нәрсәне дә булса бик мулдан, уйлап тормастан, жәлләмичә, һәркемгә бирү. *Тел белән үзләре бик оста юмалыйлар, вәгъдәләрне тау-тау өләшәләр: менә сиңа тегенди ирек, менә сиңа мондый ирек, иректән күбе юк ---.* И.Гази

Өләшә бару Эзлекле рәвештә өләшү, рәттән өләшү. *Әйе, америкалылар кебек милли байлыкны туплыйсы урынга, без аны шушы африкалыларга өләшә бардык.* Р.Ибраһимов

Өләшә башлау Өләшергә керешү. *Баштарак меньшевиклар, бигрәк тә эсерлар, барлык авылларда диярлек зур-зур докладлар белән чыгып, вәгъдәләрне бик юмарт өләшә башлаганнар иде.* И.Гази. *Жыелган «казна» акчасын өләшә башлыйлар, фетнәчеләр эчеп исермәсен өчен, шәраб тулы мичкәләрне бәреп ваталар.* В.Имамов

Өләшә тору Башка эш-гамәл булганчы, аннан алда өләшү; шактый вакыт яки әледән-әле өләшү.*--- иске киемне фәкыйрь, мохтажларга өләшә торабыз.* Г.Ибраһимов. *Менә шулай, эчендәге байлыкны һәркемгә өләшә торгач, картның капчыгы бушап калган, ул бер ай ашамаган бүренең корсагына охшап калган.* Ф.Яруллин

Өләшеп бетерү Берсен дә калдырмыйча өләшү. *Ничектер бер алган идем дә кешегә өләшеп бетердем шунда.* Ә.Еники. *Әллә әдәп дигән нәрсәне онытып, үзеңдә нәрсә бар – бөтенесен теләгән бер кешегә уңлы-суллы өләшеп бетерергәме?* Д.Бүләков

Өләшеп йөрү Барсына да рәттән өләшү. *Шушы кеше сәхнәдәге тәжрибәсен өләшеп йөри: әрсезләрне туктата, китек күңеллеләрне юата, мохтажларга җор сүзен садака итеп өләшә.* К.Кәримов

Өләшеп кую Алдан ук өләшү. *Очучы киемнәрен безгә кичтән өләшеп куйдылар. Комбинезон, күн шлем, планшет.* М.Юныс

Өләшеп ташлау *сөйл.* Бик тиз, озак уйлап тормыйча өләшү. *Ут чыккандай чаптырып ведомость төзеттерә, хезмәт көненә бер килодан иген өләшеп ташлый ---.* Г.Ахунов

Өләшеп тору Даими рәвештә өләшү; хәзерге моментта өләшү. *Тузмыйлар бу мичләр, тузмыйлар, Торалар гел җылы өләшеп.* Ф.Яруллин. *Ул [татар халкы], гасырлар буе асылларын юмарт рәвештә башкаларга өләшеп торса да, һаман затлыларның яңаларын тудыра килгән.* И.Таһиров

Өләшеп утыру Озаклап өләшү, өләшеп вакыт уздыру. *Әйттем әле квартбюродагы Михайлов дигән адәмгә, син монда атаң малын өләшеп утырмыйсың, дидем.* М.Маликова. *Дөрес, шагыйрь дә килгән бер кешегә акча өләшеп утырмагандыр, кемгә киңәшен биргән, кемгә киләчәк юлын өйрәтеп чыгаргандыр.* Л.Хәмидуллин

Өләшеп чыгу Һәммәсенә дә, беркемне калдырмыйча өләшү. *Догадан соң Саимә касәләр белән чәй өләшеп чыкты.* Р.Батулла. *Ә ул инде үз чиратында иң олы тугайларны, иң сусыл җәйләүләрне, билгеле ки, үз уллары Алтын, Кучар, Сачә бәкләргә өләшеп чыкты.* В.Имамов

Өләшеп яту *сөйл. к.* **өләшеп тору**. *--- Черновлар Берлин вокзалында автономия өләшеп яталар, Гаязлар шул һавадагы торнага ышаналар һәм башкаларны да ышандырырга көчәнәләр.* М.Сәгыйдуллин. *--- әйтерсең лә мин монда алтыннан койган баллон өләшеп ятам!* М.Галиев

ӨЛӘШҮЧЕ *и.* Берәр нәрсәне таратучы, биреп торучы. *Скупщик аларга билгеле бер хакка чимал, мәсәлән, туку өчен җеп өләшкән һәм шулай итеп өләшүчегә әверелгән.* Политэкономия

ӨЛГӘШҮ *ф. диал.* Өлгерү (*1, 8 мәгъ.*)

ӨЛГЕ I *и.* 1) Үрнәк. *[Җиһанша], Таһиржан хәлфәдән өлге алып, Бохарага барып кайтканга, авыл халкы Җиһаншаны күркәм холыклы, галим вә белекле бер зат дип беләләр.* З.Һади. *Өлгеләр һәм ияртү өчен үрнәкләр бирделәр.* Г.Нигъмәти. *Үзе исән чакта, бер генә китабы – «Тәлгәшләр»е генә чыгып калса да, без, студент егетләр, аның шигырьләрен өлгедәй кабул итеп, сокланып укый идек.* Р.Корбан

2) Өс яки аяк киемен теккәндә, аерым өлешләрен кисеп әзерләү өчен үрнәк; шаблон. *Низами карт үзе сәке түренә, тәрәзә яктысына аяк бөкләп утырып, иске киемнәрне турап, сәкегә кәгазь өлге салып, тәвәккәл бүрек тышлыгы кисә.* М.Гали. *Башмагымның, ай, башлары Бигрәк матур өлгеле.* Т.Гыйзәт. *Арка ягы өлгесен тукыма өстенә җәеп салганда, аның уртасын буй җепкә туры китерергә кирәк.* Йорт эшләре

ӨЛГЕ II *и.* 1) Тәрәзә рамының бер өлешен тәшкил иткән аерым пыяласы; күз. *Аллы-зәңгәрле электр лампалары белән яктыртылган международный вагонның урта купесында киң өлгеле тәрәзәдән Юныс Вәлишин йөзе чагылып китте.* К.Нәҗми. *Сыңар тәрәзәнең бака кабыгы төсле утлы-яшелле өч өлгесе өчесе өч якка кылайган.* Г.Бәширов. *Без калага кергәндә, эре өлгеле тәрәзәләр аша яктылыкның урамнарга сирпелгән вакыты иде.* Х.Кәрим

2) Тәрәзә пәрдәсе. *Күтәрдеңме, күрермен дип, Ап-ак өлгеңне.* Җыр. *Тәрәзәләреңә матур өлгеләр, гардиннар эленгән.* С.Бакый

3) Чигү өчен төсле шакмаклар сугып эзерләнгән әйбер, рәсемле канва. *Әзер өлге сатып алу*

4) Чигеп эшләнгән картина, панно кебек әйбер. *Пианино белән диван өстендә пөхтә итеп чигелгән өлгеләр тора.* Г.Ахунов

ӨЛГЕЛӘҮ *ф.* Берәр материалдан өс яки аяк киеменең аерым өлешләрен өлге буенча кисеп әзерләү

Өлгеләп кую Алдан ук өлге буенча әзерләү

Өлгеләп тору Өлге буенча әзерләү белән шөгыльләнү

Өлгеләп чыгу Барысын да өлге буенча әзерләү

ӨЛГЕЛЕК *с.* **1.** Өлге I (*2 мәгъ.*) өчен билгеләнгән, өлгегә яраклык. *Өлгелек материал*

2. *и. мәгъ.* 1) Өлге өчен билгеләнгән, өлгегә яраклык, өлге итеп киселгән материал

2) *диал.* Гыйбрәт, үрнәк. *Кешедән өлгелек алырга кирәк.* Ж.Вәлиди

ӨЛГЕР *с.* **1.** Җитез, уңган, булдыклы; елгыр. *[Ояларга] сыерчыклар килгәнче, өлгер чыпчыклар оялап алган.* Г.Гобәй. *Егет җитез акыллы, өлгер сүзле кеше түгел иде, ахрысы.* Г.Әпсәләмов

2. *рәв. мәгъ.* Тиз генә, бик җитез рәвештә. *Айсылу хат өстеннән бик өлгер генә күзен йөртеп, кирәкмәс урыннарын төшергәли барып, чүпли-чүпли генә укырга тотынды.* Г.Бәширов. *– Шәп дару алып җибәр әле булмаса! – ди Чикерткә, сәүдәгәрләрчә өлгер генә.* Ә.Еники

ӨЛГЕРГӘНЛЕК *и.* 1) Өлгергән, җитлеккән, пешкән булу; өлгерү дәрәҗәсе. *Җимешләрнең өлгергәнлеген тикшерү*

2) *күч.* Үсешнең югары дәрәҗәсе, камиллек. *Казанның зур драма театры да, Казанда беренче тапкыр буларак «Ленин» әсәрен куеп, үзенең үскәнлеген күрсәтте, өлгергәнлеккә имтихан тотты.* М.Җәлил

ӨЛГЕРГӘНЛЕК АТТЕСТАТЫ *и.* Төрле чорларда һәм төрле илләрдә гомуми белем алу, урта мәктәпне яки гимназияне тәмамлау турындагы таныклыкның атамасы. *Өлгергәнлек аттестаты алганнан соң, Мөбарәк, төгәл фәннәрне яхшы үзләштергән егет буларак, Будённый районының «Волга» колхозында бухгалтер --- булып эшли.* Ш.Мостафин

ӨЛГЕРЕШ *и.* 1) Укучыларның белемнәрне үзләштерү дәрәҗәсе. *Бер кашык дегет бер мичкә балны боза дигәндәй, мәктәпнең өлгереш күрсәткечен түбәнәйтмик.* Н.Акмал. *Кайбакытларда ата-аналар балаларының укуда өлгереше начар булуын, аларның, имештер, сәләт ягы йомшаклыктан килә, дип аңлатмакчы булалар. Чынлыкта исә балаларның өлгереше түбән булу, гадәттә, аларда эшләү сәләте булмаудан, эшли белмәүдән килә.* Йорт эшләре

2) Өлгерү дәрәҗәсе, пешү дәрәҗәсе (иген, яшелчә, җимешләр тур.). *Министр бодай басуына кереп, бөртекләрнең өлгерешен карады.* Зәй офыклары. *Иген өлгерешенә карап, хуҗалыклар акрынлап уракка кереп бара.* Саба таңнары

ӨЛГЕРЕШЛЕ *с.* Өлгерешендә билгеле үзенчәлек булган (икмәк, яшелчә, җимеш һ.б.ш.). *Иртә өлгерешле башлы кәбестә – чәчүдән соң 100–120 көн үткәч, урта өлгерешлесе 120–150 көн үткәч, соң өлгерешлесе, югарыда әйтелгәнчә, 180 һәм аннан да күбрәк көн үткәч өлгерә.* Яшелчәчелек. *Хәзер бакчада миләш, балан, сырганак, соң өлгерешле алмалар, кабаклар гына утырып калды.* Шәһри Казан. *Тозлау өчен, кәбестәнең соң өлгерешле сортлары әйбәтрәк.* Яңа тормыш

ӨЛГЕРЕШЛЕЛЕК *и.* 1) *к.* **өлгереш** (*1 мәгъ.*). *--- «бишле капчыгы»ның үзенең өлгерешлелек күрсәткеченә артык игътибары да, үз эченә йомык малайның башка укучылар белән үзара мөнәсәбәте дә, аның компьютер уеннары белән мавыгуы да җентекләп тикшерүгә мохтаҗ.* Шәһри Казан

2) *к.* **өлгереш** (*2 мәгъ.*). *Бер-берсеннән тиз өлгерешлелеге һәм озак саклау мөмкинлеге, чи һәм тозланган хәлдә куллануга яраклы булулары белән аерыла торган ак һәм кызыл башлы кәбестәнең бик күп сортлары бар.* Биология

ӨЛГЕРЕШТӘН *рәв. сөйл.* Ашыгып, бер-берсен уздырырга тырышып. *Чокыр-чакырларга кар сулары өлгерештән ярыша-ярыша йөгерәләр.* Ш.Камал

ӨЛГЕРЛӘНҮ *ф.* Өлгергә әйләнү, уңганга, җитезгә әйләнү

Өлгерләнә төшү Беркадәр өлгерләнү

Өлгерләнеп бару Торган саен өлгергә әйләнү

Өлгерләнеп җитү Тәмам өлгерләнү

Өлгерләнеп китү Шактый өлгергә әйләнү

ӨЛГЕРЛЕК *и.* Өлгер булу, уңганлык, җитезлек. *Әмма монда инспектор Усманов өлгерлек күрсәтте.* Ф.Галиев. *Үзенә күрә бу – бик мәшәкатьле эш, бик күп вакыт һәм өлгерлек, җитезлек таләп итә торган эш иде.* Ш.Еникеев. *Аларның төгәллекләренә, өлгерлекләренә исем китә.* Татарстан яшьләре

ӨЛГЕ́РМӘҮЧЕ *и.* Мәктәптә яки башка уку йортында начар билгесенә укучы, бирелгән материалны үзләштерә алмый артта калучы укучы. *Өлгермәүчеләргә өстәмә дәресләр оештыра, һәр атна эшенең нәтиҗәсен тикшереп тора.* Мәгърифәт

ӨЛГЕРТҮ *ф.* 1) Билгеле бер вакытка ясап, эшләп җитештерү, хәзерләп җиткерү. *Бер-ике атна тыныч, ирекле иҗат эше булса, мин бер унлап әсәрне өлгертеп тапшыра алам.* М.Җәлил. *Булмый, апа җаным, ике көнсез өлгертә алмыйм.* Р.Ишморат. *Кияү егете «Максим»ны төзәттереп алдык бит, туйга өлгертергә дип чабабыз.* Г.Бәширов

2) Билгеле бер вакытта төзеп бетерү, салып бетерү. *Тәвәккәллә тотынганда әллә кая китми, бер җәйдә өлгертеп була [өйне].* Ә.Еники. *Яңа өебезнең арткы ягын өлгертеп, кышны исән-сау чыктык.* Татарстан яшьләре

3) Ашау-эчү өчен әзер хәлгә китерү. *Гөлҗамал, иртәнге чәйгә кайнар сумса өлгертеп, бераз вакыт кухняда савыт-саба рәтләү, камыр әчетеп кую шикелле эшләр белән маташты.* Ш.Камал. *[Фәрхия:] Ашап-эчеп китәр идең, Нурия килен, хәзер аш өлгертәм.* Р.Ишморат. *Әйе, мин дә аш өлгертеп кенә чыккан идем, әйдә.* Г.Бәширов

4) Кая да булса тиешле вакытына алып барып җиткерү. *Кичке пассажирскийга өлгертик.* Г.Гобәй

Өлгертә бару Һәрберсен бер-бер артлы өлгертү

Өлгертеп бетерү Билгеле бер вакыт эчендә эшләп, ясап, эшне тәмамлау

Өлгертеп бирү Кирәкле вакытына әзерләп өлгертү. *Хәбәрне сәгать өчкә өлгертеп бирергә кирәк.* Г.Минский

Өлгертеп җиткерү Билгеле вакытка эшләп өлгертү

Өлгертеп кую Алдан ук эшләп өлгертү. *«Мәхәббәтсез апа, ник мин*

кайтуга ашны өлгертеп куймадың?» – ди. Ф.Әмирхан

Өлгертеп тору Тоткарлыксыз вакытына өлгертү

ӨЛГЕРҮ *ф.* 1) Нәрсәне дә булса үз вакытында эшләргә җитешү, башкарып чыгу. *Бүген без ул кадәр курыкмыйбыз, чөнки таң алдыннан майор Ильин безгә күп итеп гранаталар һәм сыекчалы бутылкалар китереп өлгерде.* И.Гази. *Акылга тулы түгел ир «себерке»не урталай сындырырга өлгермәде.* Н.Гыйматдинова. *Без коймак белән мәйләгәнчәйләргән арада, ул җиңгине юатырга да өлгерде.* Ә.Айдар

2) Кая да булса билгеле бер вакытка барып җитү, килеп җитү. *Бүген пароходка өлгермәм дип котым оча.* Г.Ибраһимов. *Бодай салып барадыр иде дә, кичке базарга өлгермим, дип ашыгып тора.* М.Фәйзи. *Кичә поездга өлгермәдем.* Р.Ишморат

3) Үсеп утырган игеннәр, яшелчә, җиләк-җимеш турында: ашарлык хәлгә килү. *Элекке кебек җырлап-җырлап урак урасы, --- шунда эшләп аргач, күләгәдә утырып, әле яңа гына өлгергән бәрәңгеләр ашыйсы килә.* Г.Ибраһимов. *Менә бер вакыт урманны яшел үлән каплый, кырмыска оясы җанлана, саз җиләкләре булган кара бөрлегән, күкҗиләк, морошка өлгерә.* Хайваннар турында очерклар. *Яз утыртылган сарымсак бераз соңрак, август ахырында – сентябрь башында өлгерә.* Яшелчәчелек

4) Пешеп яки кайнап торган ризык ашау-эчү өчен әзер хәлгә килү. *Алай булса, тәкъсир, чәй өлгергәнче карта уйный торабызмы?* Ф.Әмирхан. *Әйдә, чәй өлгерде, эчеп алыйк.* Т.Гыйззәт. *Менә Хәлим ашның өлгерүе турында хәбәр итте.* Г.Гобәй

5) Әзер булу, эшләнеп бетү, куллану, файдалану өчен әзер хәлгә килү. *Әгәр безнең элекке технорукны Мәскәүгә алмаган булсалар, безнең план точь-в-точь үз вакытында өлгергән булыр иде.* Ш.Камал. *Ызба өлгерү белән, башка хәсрәт төште әле монда, әти.* Ф.Бурнаш. *[Нәгыймә] дару өлгергәндер дип сискәнеп китте дә сикереп урыныннан кузгалды.* Г.Ибраһимов

6) Әчетү, әзерләү процессында кирәкле сыйфатны алу. *Бал өлгерү. Камыр өлгерү*

7) Дәресләрне тиешенчә үзләштереп бару, уңышлы уку. *Калган фәннәргә ничек йөри Нуриев, өлгерәме, укыймы?* Р.Батулла. *Математикадан өлгерү. Барлык предметлардан да өлгерү*

8) Кайбер хәл фигыльләрдән соң килеп, анда белдерелгән мәгънәгә, үзенчәлекле сыйфатка ия булуын яисә эшхәрәкәтнең билгеле бер вакыт эчендә тулысынча башкарылуын, үтәлүен белдерә. *Мин киенеп, юынып алганчы, карчык та әзерләнеп өлгергән иде инде.* Г.Минский. *Ләкин шунда Сәфәр Габдулланы күреп дәшеп өлгерде.* Ә.Фәйзи. *Журналистлар аның бу әйберләрне Вахитов урамындагы трамвай божрасы тирәсендә табуын гына белешеп өлгерәләр.* Н.Вахитов

9) *күч.* Аң-белем ягыннан, рухи яктан югары үсеш алу, камил хәлгә җитү; үсешнең югары дәрәҗәсенә җитү. *Синең көндәлек эшең – уку, белем алу, техника белән коралланган совет кешесе булып өлгерү.* А.Әхмәт. *Ул тиешле тәрбия һәм белем алып, шәхес буларак өлгереп, ил йөкләрен иңнәрендә күтәрердәй граждан булып җитешергә тиеш.* Кызыл таң

Өлгерә бару Бер-бер артлы өлгерү

Өлгерә башлау Өлгерү алдында тору

Өлгерә төшү Бераз өлгерү; тагын да өлгерү

Өлгереп җитү Тәмам өлгерү. *Ромен октябрь башында өлгереп җитә.* Яшелчәчелек. *Әгәр дә сатып алынган балда мондый үзенчәлекләр күзәтелми икән, ул аның өлгереп җитмәгәнлеге хакында сөйли.* Ватаным Татарстан

Өлгереп калу Берәр эш-хәлгә кадәр өлгерү

Өлгереп тору Бер-бер артлы өлгерү

ӨЛГЕРҮЧӘН *с. к.* **өлгерешле**

ӨЛГЕРҮЧЕ *и.* Мәктәптә яки башка уку йортында уңышлы укучы, өлгереше начар булмаган укучы

ӨЛЕНГЕ *и.* 1) *иск.* Үрнәк. *Язу язган егетләргә бүгенге язу үлчәр өчен булсын өленге.* Дәрдемәнд

2) Зур гына тукыма кисәге. *Байрак өленгесе*

3) Йөзне каплый торган челтәр яки юка тукыма. *Элек, хатын-кызлар кунакка-фәләнгә барганда, өленге кору бар иде.* Ж.Вәлиди

4) Мунчада гаурәтне яшерер өчен бәйләп куела тукыма кисәге, озын сөлге. *Беркөн бер мәҗүнүн өленгесез вә пәрдәсез хәммамга кермеш.* К.Насыйри

5) *диал.* Туым-җитем, үлем-китем булганда тәрәзәләргә эленә торган пәрдә; гомумән пәрдә. *Ул инде тәрәзәнең өленгесен беразга күтәреп яисә читен генә ачып, бер күзе белән генә, чак кына карар.* Г.Толымбай. *Шактый вакыттан соң гына сукыр лампа кабыздылар булса кирәк, соры төстәге өленге белән капланган тәрәзәдә тоныклы кына яктылык күренеп китте.* А.Фәлах

ӨЛЕШ *и.* **1.** 1) Нинди дә булса бербөтеннең аерым кисәге. *Аның артыннан ук эшкә керешкән пычкычылар, шул тамгаларга карап, бүрәнәне төрле зурлыктагы өлешләргә кисәләр.* Г.Әпсәләмов. *Ул юлның күп өлешен абаланып кайтканга арыган, мышкылдаган һәм нәрсәдәндер бераз каушаган иде.* А.Шамов

2) Барлык халыктан аерым бер билгесе белән аерылып торган кешеләр төркеме, группасы. *Эшчеләрнең күп өлеше винтовкага ябышып партизан сугышчыларга әвереләләр, чиксез батырлыклар күрсәтәләр һәм байтак кына кыйммәтле корбаннар бирәләр.* Ш.Камал. *Бу сүзне ишетүгә, солдатларның бер өлеше, штыкларын ялтыратып, Болак буенча элекке постоялый двор йортындагы лазаретка йөгерделәр.* К.Нәҗми. *Халыкның артта калган күпчелек өлеше, байлар, куштаннар һәм муллалар коткысына бирелеп, яшьләрне хөкем итә.* М.Җәлил

3) Кем өчендер билгеләп, атап куелган ашамлык яки эчемлек. *Анасы аштан кайтса, өлешнең зурын, тәмлесен калдырсын.* Г.Ибраһимов. *Ул үз өлешенең дә яртысын Маратның учына төртте һәм энесен ике куллап кочып алды.* Г.Гобәй. *Абыйсының өлеше һаман күз алдында, күңелне кытыклап тора.* Д.Аппакова

4) Ризыктан бер кешегә бер ашарлык итеп бүлеп бирелгән ашамлык

микъдары; порция. *Тәбәнәк бәлешне юка бәлеш диләр, аны өлешләргә бүлеп, кеше саен өлеш тәлинкәләрендә бирәләр.* Татар халык ашлары

5) Кем өчен дә булса тормыш шартлары китереп чыгарган хәл; язмыш. *Ләкин бу – Рәүфә өлешенә төшкән хезмәт, ул аннан котыла алмый.* А.Шамов. *Укы, улым, дидем, безнең өлешкә эләкмәгән бәхет сезгә эләкте, дидем, тик, дидем, кара аны, укыган саен белемең дә, аңың да үссен: тәрбияләп үстергән атаанаңны, туган халкыңны онытма, дидем.* Г.Минский. *Читләр, ятлар, усаллар Өлешемә кермәсен.* В.Хәйруллина

6) Уртак бер эшкә катнашучылар тарафыннан кертелгән акча яки хезмәт; пай. *Өлеше барның өмете бар.* Мәкаль. *Гүзәл сарай төзүдә өлеш кертергә чыкты зур юлга.* З.Мансур

7) Бердәй яки бериш нәрсәләрнең билгеле бер микъдары, билгеле бер микъдардагы состав кисәге. *Дүрттән өч өлешен чәчтек инде, Җәүдәт абый.* Г.Бәширов. *Бу почмакка элекке Ковно губернасы, Сувалки губернасының биш өязе, Вильно губернасының бер өлеше һәм Мемель округы керәләр икән.* Г.Гобәй. *Аның сәхнә әсәрләренең күп өлешен комедияләр, аннан соң драма һәм пьесалар алып тора.* М.Гали

8) Берәр әсәрнең композицион яктан бербөтен булган бүлеге. *Хикәянең актыккы өлешен тыңлаган чагында, Фәтхинең күзләре өстәл кырыеның бер ноктасына текәлгән, маңгай тиреләре җыерчыкланган һәм күңеленнән авыр тойгылар кичергәнлеге сизелеп тора иде.* Г.Ибраһимов. *Хәзрәт «Бәкара» сүрәсеннән «Аятелкөрси»не, мөхтәсиб исә үзе белгән «Ясин» сүрәсенең башлам өлешен укыды.* А.Хәлим

9) *мат.* Бер зурлыкны икенче зурлыкка бүлүдән килеп чыккан нәтиҗә. *Сумманы нинди дә булса санга бүлү өчен, һәр кушылучыны аерым-аерым бу санга бүлү һәм чыккан өлешләрне кушу җитә.* Арифметика

2. *рәв. мәгъ.* Мәртәбә, тапкыр. *Мондый баланың булганыннан булмаганы мең өлеш артык.* Г.Камал. *Без бу җәйдә иген уңышын Күтәрербез өч өлеш.* М.Җәлил. *Чәчәкнең хуш исе дә, аның бизәкләре белән төсе дә, моңарчы күргәннәр белән чагыштырганда, мең өлеш нәфисрәк!* Г.Бәширов

◊ **Өлеш алу** 1) *иск.* Ишаннардан фатиха яки сабак алу; 2) Керәшеннәрдә чукындыру вакытында савыттан шәраб сеңдерелгән ак икмәк кисәкләрен алып кабу йоласын башкару, шул йолада катнашу. **Өлешкә керү** 1) Бер эшкә уртак буларак катнашу. *Өлешкә кереп, йорт, фатир төзүгә кагылышлы «долевое строительство», бигрәк тә «дольщик» дигән сүзләр телебезгә ныклап кереп урнашты.* Мәдәни җомга; 2) Башка берәүгә тиеш булган өлешне үзләштерү. **Өлешенә тию** 1) *к.* **өлеш тию**; 2) Насыйп булу, туры килү. **Өлеш тию** *к.* **өлеш чыгу**. **Өлеш чыгару** Нәрсәнең дә булса берәр кисәген, өлешен бүлеп бирү. *Һәрбер уразада бер-ике баласының фитырыннан моңа да өлеш чыгара икән.* Г.Ибраһимов. *Сиңа да шул арада бик нык шаукым тияргә, һәм миңа да бераз өлеш чыгарга мөмкин.* Ш.Камал. *Әнә Сөембикә сеңелкәш үзенең яшелчә бакчасыннан һәр көз диярлек безгә өлеш чыгарып килә.* Ә.Еники. **Өлеш чыгу** 1) Берәр нәрсәнең кемгә дә булса бер кисәге, өлеше бүлеп бирелү. *Марат килгәч, аңар да өлеш чыкты.* Г.Гобәй. *Дусларга да өлеш чыкты.* Ә.Айдар; 2) Гомуми бер эштән нинди дә булса эш бүлеп бирелү

ӨЛЕШЛӘ́Ү *ф.* 1) Нәрсәне дә булса аерым өлешләргә, кисәкләргә бүлү

2) Нинди дә булса ашамлыкны өлешләргә (*3 мәгъ.*) бүлү, аерым кешеләргә бүлеп бирү. *Күрше урамда кооператив бар. Ул ара-тирә, өлешләп икмәк тараткалый.* Г.Ибраһимов

Өлешли башлау Өлешләргә керешү

Өлешләп бетерү Өлешкә бүлү эшен тәмамлау

Өлешләп бирү Һәр кешегә өлешләргә, кисәкләргә бүлү

Өлешләп карау Өлешләргә тырышу

Өлешләп кую Алдан ук өлешләү

ӨЛЕШСЕЗ *с.* **1.** *иск.* Фәкыйрь, ярлы

2. *и. мәгъ.* Иң хәлсез, фәкыйрь крестьяннарны эченә алган социаль катлау. *Колхоз хәзер ике өлешсезне бәхетле һәм матур тормышлы көр кеше иткән.* М.Җәлил

◊ **Өлешсез калдыру** 1) Кемгә дә булса ашамлык бирми калдыру; гомумән берәр нәрсә бирми калдыру. *Үз балаларына ашарга биргәндә, моны өлешсез калдыра икән.* Г.Ибраһимов; 2) Нинди дә булса гомуми эшкә катнаштырмау. **Өлешсез калу** 1) Кемгә дә булса бүтәннәргә бирелгән әйбер бирелмәү; 2) Башкалар белән берәрттән гомуми эшкә катнашмау. *Безнең әти белән әни дә өлешсез калмадылар.* Г.Әпсәләмов

ӨЛЕШСЕЗЛЕК *и. иск.* Фәкыйрьлек, ярлылык

ӨЛЕШТӘН *рәв.* Эш нәтиҗәсенең бер өлешен бирү шарты белән (эшләү). *Луизиана штатында өлештән эшләүче негр гаиләсендә туган Джесси яшь вакытыннан ук --- авыр хезмәтне татый.* Социалистик Татарстан

ӨЛЕШТӘШ *и. махс.* Нинди дә булса берәр эштә яки предприятиедә өлеше (*4 мәгъ.*) булган кеше, пайчы

ӨЛЕ́ШЧӘ *с.* **1.** Тулы булмаган, беркадәр берәр нәрсәнең аерым өлешенә генә караган. *Өлешчә эшсезлек*

2. *рәв. мәгъ.* Тулысынча түгел, өлешләп. *Судка тапшырылган дәлилләр нигезендә район суды банк таләпләрен өлешчә үтәде ---.* Минзәлә. *Хезмәткә өлешчә түләү. Чыгымнарны өлешчә каплау*

ӨЛЕШЧЕ *и.* 1) Табында ашамлыкны бүлеп өләшүче кеше (гадәттә, итнең). *Өлешчегә өч үрдәк, өләшә белмәсәң, берәү дә юк.* Мәкаль

2) *к.* **өлештәш**. *Бигрәк тә Гроссман, Пауль оештырган корыч кою фирмасының бер өлешчесе булып алгач, әсирләр комендантының һәм офицер киеменә киенгән капиталистның нәфесе чамасыз үсте.* Н.Дәүли. *Чөнки торак салырга дип акча җыеп та, йөкләмәләрен үтәмәгән фирмалар тарафыннан акчасыз да, фатирсыз да калдырылган өлешчеләр турында күп сөйләнелә.* Мәдәни җомга

ӨЛКӘ *и.* 1) Илнең бер өлеше. *Поезд Германия белән Франция арасында җәнҗаллы калҗа булган Эльзас – Лотарингия өлкәсенә таба йөгерә.* Г.Гали. *Теләмиләр немец җәзалаган Өлкәләрдән очып үтәргә.* Ф.Кәрим

2) Эре административ-территориаль берәмлек. *Аннары, һөҗүмгә күчеп, яңадан Калинин өлкәсен, Белоруссияне үттек һәм Литва җиренә килеп кердек.* А.Шамов. *Сәйфулла башта Москва өлкәсендәге бер хәрби мәктәптә укыды, мәктәпне бетереп чыккач, Ерак Көнчыгышка озатылган иде ---.* Ә.Еники. *Мондый сортларны Москва, Горький өлкәләрендә һәм аннан да төньяктагырак өлкәләрдә грунтка чәчеп үстерергә мөмкин.* Яшелчәчелек

3) Шул административ-территориаль берәмлекнең үзәге яки андагы җитәкче оешмалар. *Ничек булды, Мария Максимовна, нәрсә диләр анда, өлкәдә?* Ш.Маннур

4) Белемнәрнең яки эшчәнлекнең аерым бер тармагы, аерым бер юнәлеше. *Татар әдәби телен эшләүче бу ике гигант – берсе проза өлкәсендә, икенчесе поэзия өлкәсендә – гомерләренең ахырына кадәр бер-берсе белән ярышып эш алып баралар һәм нәтиҗәдә хәзерге татар әдәби телен барлыкка китерәләр.* М.Гали. *Шагыйрь Әхмәт Ерикәйнең җыр-романс өлкәсендәге активлыгы аеруча шушы елларда күтәрелде.* М.Җәлил. *Ә кызның авыл хуҗалыгы өлкәсендәге эшләрен, уңышларын сөйләп тә бетерә алмадылар...* А.Шамов

5) Нинди дә булса берәр сыйфаты, үзенчәлеге белән аерылып торган район, урын, пространство. *Җирнең тропик өлкәсе*

ӨЛКӘН *с.* **1.** 1) Яше башкаларныкына караганда олырак булган, яше зур булган; башкаларыннан алдарак туган. *Карчык, ике өлкән кызының авыр язмышыннан соң, бу төпчеген кемгә дә булса көчләп бирергә бер генә дә уйламый иде.* Г.Ибраһимов. *Ике ел тимер мич белән торып, өлкән балаларга салкын тидердек...* Т.Гыйззәт. *Авылдагы өлкән буын шушы заманга яраклашып беткәндә, «сәяхәтче бака» һаман күкләр гизә иде.* Н.Гыйматдинова

2) Хәрби званиесе яки эш урыны буенча бүтәннәргә караганда югары булган. *Ул хәтта янына килеп баскан өлкән лейтенант Григорьянны да күрми торды.* Г.Әпсәләмов. *Мин мәшһүр Сеҗге мәктәбендә өлкән пионервожатый булып эшлим, тырышып эшлим.* М.Мәһдиев

3) Уку йортын, мәктәпне һ.б. тәмамлау алдында торган; югары класста (курста) укучы. *Калын китап күтәргән өлкән ике шәкерт керә.* Н.Исәнбәт. *Ләкин өлкән курс студентларын алмыйлар, имеш.* И.Гази

4) *диал.* Зур. *Хәбәр дөрес: өлкән өйнең артында көмешләнгән иярле сылу айгыр көннең кызулыгыннан, йөрүдән тирләп, башын чайкап тора.* Г.Ибраһимов

2. *и. мәгъ.* 1) Олы яшьтәге кеше. *Сигез-тугыз яшьлек малайлар өчен генә түгел, үз заманы, ягъни 1936 елның җәе өчен, бу якларда өлкәннәрнең дә төшенә кермәгән вакыйга иде ул.* Р.Мөхәммәдиев. *Самими ярату белән, шул ук вакытта өлкәннәргә хөрмәт һәм авыл үсмерләренә генә хас булган тыйнаклык белән өртелгән ул шигырь.* Мәдәни җомга. *Өлкәннәр көнендә хакимият башлыгы үз кулы белән әбигә мамык шәл бүләк итте.* Мәгърифәт

2) Берәр ыругның, кабиләнең, коллективның олы яшьтәге мөхтәрәм кешеләре. *Өлкәннәр советы*

ӨЛКӘНӘЙТҮ *ф. к.* **олыгайту**. *Чал чәче, сулган йөзе аны үз яшеннән өлкәнәйтебрәк күрсәтә, шуңа күрә һәм урыны да югары булганга, үзеннән өлкәнрәк профессорга чак кына өстәнрәк карый иде ул.* М.Маликова

Өлкәнәйтә төшү Тагын бераз өлкәнәйтү

Өлкәнәйтеп җибәрү Сизелерлек дәрәҗәдә өлкәнәйтү

Өлкәнәйтеп кую Тиз арада өлкәнәйтү

Өлкәнәйтеп тору Өлкәнәйтеп күрсәтү

ӨЛКӘНӘЮ *ф.* Олыгаю, яше зураю, олы яшьтәге кешегә әйләнү. *[Җаббар:] Юкка чабата туздырып йөрүдән файда юк, яшегез өлкәнәйгән, акчагыз юк.* Г.Ибраһимов

Өлкәнәеп бару Өлкәнәюгә йөз тоту. *Өлкәнәеп барган ханым зарлана: – Тигез җирдә абына башладым, әкәмәт.* Ш.Галиев

Өлкәнәеп бетү Тәмам өлкәнәю. *Нәҗип бу! Өлкәнәеп беткәч шәһәргә китеп барды ул. Күптән инде... Бер дә кайтканы булмады...* Г.Гыйльманов

Өлкәнәеп килү *к.* **өлкәнәя башлау**. *Инде өлкәнәеп килүенә карамастан, яшьлек елгырлыгын саклаган, заводтагы хатын-кызларның ким дигәндә ярты сын мәхәббәт утында яндырган Лукьянов та баштарак сәерсенеп куйган иде ---.* М.Маликова

Өлкәнәеп китү Вакытның бер аралыгында өлкәнәюе сизелә башлау. *Икебез дә азрак буйга калкып, өлкәнәеп киткәнбез.* М.Ибраһимов

Өлкәнәеп җитү Шактый зур яшькә җитү. *Гомер буе кешеләргә акыл саттым, Өлкәнәеп җиткәч кенә акыл таптым ---.* Г.Мөхәммәтшин

Өлкәнәя бару Әкренләп өлкәнәю. *Димәк, өлкәнәя барган, дөньяның төрле якларын күргән, кешеләрнең төрлеләре белән аралашкан кешенең башкаларга әйтер сүзе күп.* Т.Миңнуллин. *Без өлкәнәя барган саен, бала чагыбызга ешрак әйләнеп карыйбыз.* Ф.Яруллин

Өлкәнәя башлау Өлкән яшьләргә керү. *Өлкәнәя башлагач, уку читенрәк икән ул.* Ф.Яруллин. *Бу әйтемнең чын мәгънәсен мин бары үсеп җитеп өлкәнәя башлагач кына аңлый һәм ни икәненә төшенә алдым.* Т.Кәримов

Өлкәнәя төшү Беркадәр өлкәнәю. *Инде өлкәнәя төшсә дә, әле эшен куймады. Кирәк чакта үз машинасында оча гына.* Ә.Гадел. *Тик өлкәнәя төшкәч кенә шигырь кысалары эчендәге иреклнең тәмен-ләззәтен тулысынча тоеп буладыр, мөгаен.* Р.Вәлиев

ӨЛКӘНЛЕК *и.* Өлкән (*1, 2 мәгъ.*) булу. *[Степаныч:] Һаман-һаман шул сакалга бәйләнәсез. Акыллылык, өлкәнлек билгесе бит ул.* А.Шамов

ӨЛКӘР *и.* Үгезбозау йолдызлыгындагы Иләк йолдыз төркеменең халык телендә йөргән атамасы. *Өлкәр җиргә төшкәндә, сыер суга төшәр.* Сынамыш

ӨЛКӘЧЕЛЕК *и.* 1) *тар.* Революциягә кадәрге Россиядә: үзенең өлкәсендә мәдәни һәм икътисади яктан мөстәкыйльлеккә омтылган буржуазлибераль иҗтимагый агым. *Өлкәчелек тарафдары*

2) Үзенең җирле мәнфәгатьләрен башкаларныкыннан югары кую, үз

файдасын гына кайгырту. *Өлкәчелек тенденцияләре*

ӨЛТЕРӘК *с. диал.* Өлтерәп торган, кечелекле булган. *Өлтерәк ир олтырак булыр.* Әйтем

ӨЛТЕРӘ́Ү *ф.* Бик кунакчыл булу, кечелекле булу; нәрсә дә булса эшләргә әзер тору. *Хатыны аша-аша дип өлтерәп тора, ди.* Әкият

ӨЛФӘТ *и. гар.* 1) Аралашу; дус булу. *Өлфәт илә без дә итик өлфәт.* Г.Тукай

2) Бергәлек, бердәмлек. *Дуслык вә карендәшлек – өлфәткә вә өлфәт куәткә сәбәптер.* К.Насыйри. *Өлфәт хасил иткән иде.* М.Гафури

ӨМӘ *и.* 1) Аерым хуҗалык яки кеше өчен күмәк көч сорый торган нинди дә булса зур эшне ирекле рәвештә җыелып, бергәләп, түләүсез башкару эше. *Бала чагын, егет вакытларын, каз өмәләрен, туйларын, җыеннарын, ярминкәләрен – барысын да кызык итеп, тәмле итеп, көрсенеп һәм юксынып сөйләп утырырга ярата торган иде.* Ә.Еники. *Бердән, Хафизның уйтойгылары, икенчедән, авылның печән өмәсе, шул өмәдә Хафизның үз сөйгәне Бибиәсманы ярәшүе һәм соңыннан, өйләнеп, аларның бергә тора башлаулары языла.* Г.Нигъмәти. *Бу бәлешне, гадәттә, көз көне казлар суйгач, каз өмәсендә пешерәләр.* Татар халык ашлары

2) Оешма, учреждение өчен башкарыла торган шундый ук эш. *Без моны комсомол җыелышына куйыйк та яшьләр өмәсе оештырырга тәкъдим кертик.* Г.Бәширов. *Чын-чынлап бер массовый күтәрелешкә әйләнде бу өмә!* Г.Гобәй

3) *күч. сөйл.* Өмәдә катнашучы кешеләр, өмәчеләр

ӨМӘЛӘП *рәв.* Өмә белән, өмә ясап, өмә оештырып. *Һаман-һаман, минәйтәм, өмәләп, күмәкләп, әртилләшебрәк эшләү ягын каералар, дим.* Г.Ибраһимов. *Кода-кодагый өй тутырып кунак җыйганда дәшәргә ашыкмады, күрше-күлән белән бер-бер эшне өмәләп башкарганда да балта-көрәк күтәреп килеп җитмәде.* Р.Рахман

ӨМӘЧЕ *и.* Өмәдә катнашучы кеше. *Ә көндезгә таба, өмәчеләрнең тар сукмак буйлап тезелешеп, тирес тартып басуга барганнарына, шау-гөр килеп, бер-берсен тартышып кайтканнарына кызыгып, бөтен авыл баласы купты.* Г.Гобәй. *Менә өмәчеләр таралды исә, хорга репетиция башлыйбыз.* М.Фәйзи

ӨМЕТ *и. фар.* 1) Теләгән нәрсәнең киләчәктә булуына, чынга ашуына ышаныч. *Шулай да өмет белән яшәде: бүгенгесе авыр, бүгенгесе кыен, бәлкем, иртәгә бераз җиңеләер.* И.Гази. *Һәр мәхбүскә ияреп, беренче нәүбәттә, тынчу, кысан камераларга өмет керә.* А.Гыйләҗев. *Егеттә өмет бар иде әле.* А.Хәлим

2) *сөйл.* Хыял. *Шундый якты уйлар, якын өметләр эчендә яшәп, Әминә сугыш елларын уздырып та җибәрде...* Г.Минский. *Шундый яшерен өмет белән янганда, я?* Н.Гыйматдинова. *Бу елмаюда бәхет һәм якты өмет үзе яктырган иде.* А.Хәлим

3) *сөйл.* Нинди дә булса уңыш, файда көтелгән нәрсә; ышаныч багланган кеше. *Елама син, өметемнең кояшы!* Ф.Бурнаш. *Минем өметем, минем гомерем, Минем җырым син, Хәят.* Ә.Ерикәй

◊ **Өмет баглау** *иск. к.* **өмет итү**. *Һәр авырлыкны, һәр җиңелүне шул кораллы күтәрелеш чаралары белән яндырып бетерергә өмет баглыйлар.* Г.Ибраһимов. *Ул да, күрәсең, борчыла һәм бу разведкага зур өмет баглый иде.* А.Шамов. *Аның көченнән күп артыкка өмет баглаган иделәр.* Ш.Камал. **Өмет киселү** Ышаныч бетү, өмет бетү, өмет юкка чыгу. *Әтиләр белән кире кайтырга да өмет киселми иде.* Х.Кәрим. **Өмет кисү** 1) Берәүнең өметен бетерү. *Бу Гитлер субака бөтен өметемне кисте бит.* Ә.Айдар; 2) *к.* **өмет өзү**. *Безнең аучы аудан өмет кисте.* Г.Тукай. *Матур тормыш, якты көн күрүдән Өметләрен тәмам кискәннәр.* М.Гафури. **Өмет өзелү** Ышаныч бетү, өмет юкка чыгу. *Аңарчы, бәлки, күз алдыннан югалып торгач, Кәримнең дә өметләре өзелер.* Г.Камал. *Ләкин... Бар да юкка булган, Инде өметем өзелде.* М.Җәлил. *Өзелсә дә җепләр, өзелмәсен безнең өметләр.* Ә.Фәйзи. **Өмет өзү** Нәрсәгә дә булса ышаныч бетү, киләчәктә берәр нәрсәнең булуына ышанмый башлау. *Дога кыла, ялварына --- булмый һаман, Бара торгач, өмит өзеп ташлый эшен.* М.Гафури. *Миңлебаев бу тирәдә юньле эш табудан өмет өзде.* Г.Ибраһимов. *Соңгы минутына кадәр өметен өзә белми ул.* И.Гази. **Өмет сузу** Булмастайны өмет итү. *Өметең сузып, егетем, үз тиңеңнән буш калма.* Җыр. **Өмет тоту** Нәрсәгә дә булса өметләнү, өметләнеп йөрү

ӨМЕТДАР *с. фар. иск.* Өметләнүче, өметләнеп торучы, ышанып, хыялланып торучы. *Кичә-көндез өметдармын сиңа, Сак белән Соклар кебек зармын сиңа.* Дәрдемәнд

ӨМЕ́Т ИТҮ *ф.* Өметләнү, нәрсәгә дә булса ышану. *Унлаган мәктүпләремә каршы бер җавабыңны кызганмасмы дип өмет итәм.* Г.Ибраһимов

ӨМЕТЛӘНДЕРҮ *ф.* 1) Нәрсәнеңдер булуына ышаныч уяту, өмет (*1 мәгъ.*) барлыкка китерү. *Аның артыннан, аксыл нурлары белән өметләндереп, ак таң килә.* Г.Ибраһимов. *– Тәҗрибәле врачлар кешеләрне өметләндерү турында бик алай юмарт булмыйлар, – диде Фәтхи ---.* Ш.Камал. *Бер вәгъдә бирде, кешене өметләндерде, инде айный.* М.Фәйзи

2) Киләчәктә уңышлар көтәргә мөмкинлек бирү. *[Бу ике постановка театрның] киләчәктә күп нәрсә өметләндерә торган яшь, талантлы көчләргә ия булганын күрсәтә.* М.Җәлил

Өметләндерә бару Торган саен ныграк өметләндерү

Өметләндерә башлау Өмет уяту. *Урам буйлап бәрелә-сугыла йөри торгач, аның башына бер уй килеп өметләндерә башлаган иде.* Г.Бәширов

Өметләндерә төшү Бераз өмет уяту

Өметләндереп җибәрү Өмет уяту. *Бу сүз Гайфулланы нәрсәгәдер өметләндереп җибәрде.* Ф.Яруллин. *Океан уртасында ике татар, ике якташ очрашу Хәммәтне дә, Гатаны да өметләндереп, канатландырып җибәрде ---.* З.Хәким

Өметләндереп йөрү Вакытны сузып, һаман өметләндерү. *Аның ак чәчәкләр ташып, өметләндереп йөрүе өйләнәм дигән сүз түгел лә.* Н.Гыйматдинова

Өметләндереп калу Юкка өметләндерү, өметләндереп тә өметен акламау

Өметләндереп карау Өметләндерергә тырышу. *Шулай да ул Беккины үгетләп, өметләндереп карады; шомланып көтә торгач, инде гасырлар үткәндер кебек тоела башлады, тавышлар исә башка ишетелмәде.* М.Твен

Өметләндереп килү Күптәннән бирле өметләндерү. *Моңа кадәр безнең идарә, аны эшлибез дә моны эшлибез дип, бик күп өметләндереп килде.* Т.Гыйззәт

Өметләндереп кую Алдан өметләндерү. *Бер-ике айга кайтарырлар, дип өметләндереп куйган иде.* А.Шамов

Өметләндереп тору Һәрдаим өметләндерү. *Җанга сары май булып ягылган бу тавыш каядыр якында гына бер почмакка кереп поскан да яшәргә өметләндереп, ымсындырып тора.* Н.Хәсәнов. *--- һәрдаим камиллеккә омтылуы, өметләндереп һәм киләчәккә чакырып торуы белән гүзәл ләбаса ул шигърият!* М.Вәлиев

ӨМЕТЛӘНҮ *ф.* Нәрсәгә дә булса ышанып тору, ышанып көтү; өмет итү. *--- бераз акча эшләп булмасмы, дип өметләнгән идем, булмады.* Т.Гыйззәт. *Эчтән генә, яшерен генә Хәлидә дә егеткә өметләнгән, әмма качкан кыланып, эзләттереп, үз бәясен күтәргән.* Н.Гыйматдинова. *Сөмбел 30–40 яшьләр тирәсендәге ир-егетләр белән танышырга өметләнә.* Татарстан яшьләре

Өметләнә башлау Өмет барлыкка килү. *Бу юлы аңа эче авыртадыр сыман тоелды, һәм ул авырту көчәймәсме дип өметләнә башлады.* М.Твен. *Кыска гына сораулардан торган юллар шигырьдәге киеренкелекне арттыра, укучы лирик герой белән бергә нәрсәгәдер өметләнә үк башлый.* Р.Вәлиев

Өметләнә төшү Бераз гына булса да өметләнү

Өметләнеп йөрү Күптәннән бирле, бик озак өметләнү. *Ана дәртләнеп, өметләнеп, канатланып йөри иде.* А.Гыйләҗев. *Бәлки, кайтыр дип, малай эченнән күпме генә өметләнеп йөрмәсен, әти кеше алар капкасын ачып кермәде.* Р.Мулланурова

Өметләнеп калу Өметләнеп тә өмете акланмау. *Ымсынып, өметләнеп калганнары үпкәле, кичермидер. Сайлап, кимсетеп калдырдың, дигәннәрдер.* Ш.Галиев

Өметләнеп китү Кинәт өметләнә башлау. *Һәр көн, ишекне ачып, бер кеше килеп керсә, әллә синнән яучы килдеме икән дип өметләнеп китәм.* Г.Камал

Өметләнеп кую Берара өмет уянып алу. *«И-и, яшьләрне аермаска кирәк иде инде» дип уйлап-өметләнеп куйса да, Хәдичә аны-моны дәшмәс булды.* К.Тимбикова. *Карт сөйләвеннән Миша ул бичараның Тәүгиз булу ихтималына өметләнеп куйды.* Г.Ахунов

Өметләнеп тору Әлегә өметләнү, күпмедер вакыт өметләнү. *Шуңа күрә ул сайлауларны көтәргә булды: ихтимал, шул чакта җәнҗалсыз гына төшеп калырмын дип өметләнеп торды.* Ә.Еники. *Мал була дип өметләнеп торганда гына... Бар карап торганнары шул башмак иде.* Р.Батулла

Өметләнеп утыру *сөйл.* Шактый вакыт өметләнү. *Агай сусаган иреннәрен ялмап, нәрсәдер булырына бик өметләнеп утырса да, көткәненә ирешә алмады ---.* Х.Ибраһим

Өметләнеп яту *сөйл.* Өметен тормышка ашыру өчен, берни эшләмичә, шактый вакыт өметләнеп көтү

ӨМЕТЛЕ *с.* **1.** 1) Өметләндерә торган, ышанычлы. *Шуның белән бергә әллә нинди өметле хәбәрләр дә сөйләнә башлады.* Г.Ибраһимов. *Җиңүле үткән еллар, Өметле барыр юллар.* Ә.Ерикәй. *Яшьләр – җирне, күкне мирас итеп алып кала торган өметле кешеләр кирәк.* А.Гыйләҗев

2) Эшчәнлекнең нинди дә булса өлкәсендә киләчәктә зур уңышлар көтәргә ышаныч уята торган. *Тулаем коллектив турында шуны әйтергә кирәк: театр өметле яшь көчләрне берләштергән.* М.Җәлил. *Чехов «Елак», «Неврастеник»ларны язу белән бергә, әсәрләрендә кайбер өметле карашларын да күрсәткәли.* Г.Нигъмәти

3) Киләчәктә уңай нәтиҗә бирү ихтималы зур булган; киләчәгә уңыш белән бәйләнгән. *Бәхетле аның кулы, Өметле аның юлы.* Ә.Ерикәй. *Киләчәккә өметле уйлар уятты.* Һ.Такташ. *Я, Степан Андреич, бүгенге породалар ни сөйлиләр, өметлеме?* А.Әхмәт

2. *рәв. мәгъ.* Ышанып, өмет белән; уңай бәяләп. *Гали абзыйның болай да чандыр йөзе тагын да ябыккан, кылыч борыны да юкара төшкән кебек, әмма йомшак соры күзләре әүвәлгечә күңелле һәм өметле карыйлар.* Г.Әпсәләмов. *Һе, бик өметле әйтә икән алайса, бәрәкалла, бик ышанычлы әйтә икән...* Г.Бәширов. *Әлбәттә, безнең алда бик зур эшләр тора, ләкин киләчәккә өметле карыйбыз.* Ә.Еники

ӨМЕТЛЕЛЕК *и.* Өметле булу; ышаныч, оптимизм. *--- Хуҗа Насретдин образы аша халыкның үткенлеге, тапкырлыгы, зирәк һәм тирән акылы, шаянлыгы һәм өметлелеге чагылган.* М.Җәлил. *«Көнчыгышның яңа баласы» дигән шигырендә Туфан, өметлелек ноталарын тагын да күтәрә төшеп: «Җырлап үсик», – дип куя.* Г.Нигъмәти

ӨМЕТСЕЗ *с.* **1.** 1) Берәр эш-хәлнең ахыры уңыш вәгъдә итми торган, ышаныч уятмый торган. *Батырхан ипташ, безнең эшләр шулай бөтенләй өметсезмени соң?* Г.Ибраһимов. *Сәгыйтьнең йөзенә карагач ук, эшнең өметсез икәнен төшенеп алдым.* А.Шамов

2) Дәвалап булмый торган, үлүгә йөз тоткан (авыру кеше тур.). *Әнинең бөтенләй өметсез бер хәлгә төшүе мине дә өйгә кайтырга мәҗбүр итте.* М.Гафури

3) Бөтенләй өмете югалган, өмет чагылмый торган. *Сөләйман абзыйның бу кыска сүзе үзенең өметсез яңгырашы белән мине аптыратып калдырды.* Ф.Әмирхан. *Тегеләр капчыкларыннан консерва, икмәк, шикәр чыгардылар да, хозяйкага тагын бер өметсез караш ташлап, ашарга җыендылар.* И.Гази. *Соң ишеттең бит, өметсез кеше шушылай дип язамыни?* Г.Бәширов

4) *күч. гади. с.* «Начар», «юньсез» мәгънәсендә тиргәү сүзе буларак кулланыла. *[Вәлия:] Өметсез! Шулкадәр иткән яхшылыкларның кадерен белми, нинди явызлыклар эшләп йөри.* М.Фәйзи. *– Кабергә кергәч инде безгә җир, – дип куйды бер өметсезе.* И.Гази

2. *рәв. мәгъ.* Нәрсәгәдер өмет багламыйча. *Өметсез яшәү кыен*

◊ **Өметсез шайтан** Нинди авыр хәлләргә төшкәндә дә өметне өзәргә ярамауны белдерә. *Шунда да, хатын, өметсез шайтан, мин үзем бу турыда күптән уйлап йөрим йөрүен, син караштыргала әле, араларында вәгъдә-мәгъдә барын белеп булмасмы.* М.Фәйзи

ӨМЕТСЕЗЛӘНДЕРҮ *ф.* Кемнең дә булса өметен юкка чыгару, өметен өзү. *Ну инде, кешене алай өметсезләндермиләр, күрше.* Ш.Камал

Өметсезләндерә төшү Беркадәр өметсезләндерү

Өметсезләндереп җибәрү Кинәт кенә өметен юкка чыгару

Өметсезләндереп кую Кисәк ышанычын, өметен юкка чыгару

ӨМЕТСЕЗЛӘНҮ *ф.* 1) Өмет итми башлау, ышанычны, өметне югалту (кеше тур.). *Тукта әле, мин ни өчен бу кадәр өметсезләнәм, ни өчен мин бу кадәр кайгырам?* Г.Камал. *Һәрхәлдә өметсезләнергә ярамый, кулда нинди чара булса, шуны хутка җибәрәсең.* Ш.Камал. *Анда да түзгән ул, өметсезләнмәгән.* А.Әхмәт

2) Начар якка үзгәрү, уңышлы булуына өмет кимү (хәл, ситуация һ.б. тур.). *Ә бүген, көннән-көн хәлләре өметсезләнә барган шартларда әлеге «халыкның» үзләрен кара җәяүгә калдыручыларны яклап тавыш бирергә өндәп йөрүләре – чып-чын абсурд.* Р.Зарипов

Өметсезләнә бару Вакыт үткән саен, өметсезлеккә ныграк бирелү. *Салихның тавышы өметсезләнгәннән-өметсезләнә барды: – Их, югалган булса иде ул башта ук!* Н.Әхмәдиев

Өметсезләнә башлау Өметсезлек барлыкка килү. *Әнә шундыйлардан берәү өметсезләнә башлый, әкрен генә әйтеп тә ташлый: – Сөйгән корабыбыз, «Челюскин»ыбыз, су төбенә китте, димәк, безнең экспедициябез шуның белән бетте, – ди.* А.Алиш. *«Байлар фиргавеннән туганнар бит алар, һөнәрле яшь егетләрнең кадерен беләләрмени!» – дип өметсезләнә башлаганда, аның ниндидер бер танышы мине Якимовлар пароходына машинист ярдәмчесе итеп урнаштырырга сүз биреп китте.* Г.-Х.Садри

Өметсезләнә төшү Беркадәр өмет, ышаныч югалту

Өметсезләнеп бетү Бөтенләй өметсезләнү

Өметсезләнеп йөрү Шактый вакыттан бирле өметсез булу. *Хат булмагач өметсезләнеп йөргәндә, бу ике хат, посылка минем өчен никадәрле күңелле булуын сез белмисез.* Ф.Сафин

Өметсезләнеп утыру *сөйл.* Шактый вакыт өметсезләнү. *Балалык, малайлык барыбер үзенекен итте: яшьлеккә озак кайгыру, өметсезләнеп утыру хас түгел бит.* Ф.Бәйрәмова

ӨМЕТСЕЗЛЕК *и.* 1) Киләчәккә ышанмау, алдагы тормышны, тирәяктагы барлык нәрсәне начар дип күрү халәте. *Өмет белән өметсезлек арасында күренә.* М.Гафури. *Минем йөрәгем өметсезлек газабы белән түгел, иҗат шатлыгы белән дулкынлана.* Ш.Камал. *Әйе, күпчелек очракта безнең газиз җаннар һәммәсен кире кагарга тырышу, өметсезлек һәм дөреслекнең барлыгына ышанмау хисе белән тулган.* Идел

2) Берәр эшнең уңышлы чыгуына өмет булмау. *Өмет урынына өметсезлек күңелдәге хәят вә тойгылар урынына бушлык китерделәр.* Ф.Әмирхан. *Ул минутта Гаязның йөзенә чыккан өметсезлек, таянычсызлыкка карап елыйсым килә иде минем.* М.Әмир. *«Барыбер минеке түгел» дигән өметсезлек күз алдына кара пәрдә корган иде.* Н.Гыйматдинова

◊ **Өметсезлеккә бирелү** *к.* **өметсезлеккә төшү**. *Өметсезлеккә бирелеп, кул кушырып утыру безнең халыкка хас түгел.* Ватаным Татарстан. **Өметсезлеккә салу** Өметен бетерү, өметсез итү. *Укенечләр, сызланулар бүгенге зыялыны да сәяси битарафлыкка китергән, өметсезлеккә салган...* Кызыл тан. **Өметсезлеккә төшү** Ышаныч бетү, киләчәккә берәр нәрсәнең булуына ышанмый башлау. *Халык тәмам өметсезлеккә төште.* М.Галәү. *Үзе яна, көя, өметсезлеккә төшә, кайбер чакта бик зур дәрт вә һәвәс илә дә керешеп, өмитенең якынаюын да хис итә башлый иде.* Г.Ибраһимов

ӨМЕТЧӘН *с.* Өмет белән караучы, оптимист

ӨМЕТЧӘНЛЕК *и.* Өметчән булу, оптимизм

ӨМИТ *и. фар. иск. к.* **өмет**. *Өмит берлән карый башлыйм булачакка.* Г.Тукай

ӨММӘТ *и гар.* 1) Нинди дә булса бер динне тотучы, бер пәйгамбәр өндәгән диндә булган кеше; бер динне тоткан, бер диндәге халык. *Барысы да Мөхәммәд өммәтеннән.* И.Гази. *Кайда, кайсы дини өммәттә бар бу кадәр Китапка сәҗдә кыйлу?!* А.Хәлим. *Аннан элекке пәйгамбәрләр дә ураза гыйбадәте кылган һәм өммәтләренә дә шуны киңәш иткән.* Мәгърифәт

2) *иск.* Милләт

3) Зат, токым, кавем. *Җен өммәтеннәнме, адәм өммәтеннәнме?*

ӨММЕЛХӘБАИС *и. гар. иск.* Аракы, исерткеч эчемлек (гарәпчә «әшәкелекләрнең анасы» дигән сүз)

ӨММИ *с. гар. иск.* Укый-яза белми торган. *Өмми пәйгамбәр*

ӨМСЕНДЕРҮ *ф. диал. к.* **ымсындыру**. *Мәскәүлеләр намус белән эш итмиләр: җир биреп, өмсендереп, безнең морзаларны яшертен генә сатып алалар.* Х.Камалов

ӨМСЕНҮ *ф. диал. к.* **ымсыну**. *Йөрәге яшүсмер кызларныкыдай талпынды, күңеле өмсенде.* Н.Көбәш

ӨН I *и.* Төшкә капма-каршы буларак чынбарлык, реальлек; төш-саташу түгел, хыял түгел. *Бераздан соң гына мин бу вакыйганың кадерле төш кенә түгел, бәлки кыйммәтле өн икәнен аңлап ала алдым.* Ф.Әмирхан. *Юк, Шәмсия, өн бу, өн!..* Т.Гыйззәт. *Өммегөлсем алты төн һәм алты көн эссе табада кайнаган май шикелле куырылды, саташуыннан өн белән төш бергә буталды.* А.Хәлим

◊ **Өнме, төшме?** Бик нык гажәпләнгәндә яки көтелмәгән хәл булган вакытта әйтелә. *Я ходай, бу өнме-төшме? Бу түгелме әнкәсе?* Н.Исәнбәт. *Давытны эзләргә дип, номерга кереп барса, баскычтан нәкъ моның каршысына Гөлбикәнең төшеп килгәнен күреп, Сәхип шаша калды, башта күзләренә ышанмады: «Бу нәрсә? Төшме, өнме?»* Г.Ибраһимов. **Өнемдә түгел, төшемдә дә күргәнем юк** Бер дә, беркайчан да күргәнем юк

ӨН II *и.* 1) Сулыш, сулыш алу. *Баланың өне бармы?*

2) *диал.* Аң, һуш

◊ **Өне алыну** Бик нык курку, кот алыну, кот очу. – *Зираттагы нәрсәләргә тимиләр, бала! – диде Нурсөя, өне алынып.* Н.Гыйматдинова. **Өне качу** *к.* **өне алыну**. **Өнгә килү** Нинди дә булса көчле тәэсирдән соң бераз вакыт үткәч, тирә-юньне абайлый башлау, аңга килү. *Бераздан соң өненә килгән кеше шикелле, [ул] ак чәчләрен эчкә тыгып, яулыгын рәтләп бәйләде.* М.Гали. **Өн керү** Курку бетеп тынычлана башлау, җан керү. **Өн китү** Нинди дә булса көчле тәэсирдән аң китү, аңгыраю, миңгерәү. *Өне киткән вак буржуй халкы банк ишегенә барып тыгылды.* З.Фәтхетдинов. **Өнне алу** Бик нык куркыту. **Өннән язу** Һуштан язу

ӨН III *и.* Нинди дә булса тавыш, аваз. *Кара урманнардан бер өн килә, Аккош тавышына охшатам.* Җыр. *Көй пристаньнардан яулык селкеп калучы кызлар кебек, яшьлек өннәре белән яңгырый, таң җиленә селкенгән арыш башаклары төсле шаулый* ---. К.Нәҗми. *Язгы өннәр, язгы тавышлардан Яңрап тора урман, күл.* С.Гәрәева

◊ **Өне киселү** Тавышы бетү. *Шуның аркасында аклар батареясының өне киселде.* К.Нәҗми. **Өне кысылу** Тавышы чыкмау. *Җөмәдиләүвәл шулай гына әйткән иде, Сәфәрнең өне кысылды! Ник бер генә сүз әйтсен.* Ш.Камал. **Өне тыгылгыры** *тирг.* Елаган балага яки нәрсәдән дә булса риза булмыйча тавышланган кешегә карата әйтелә. **Өнең чыкмасын!** «Дәшмә, тик тор!» мәгънәсендә

ӨН IV *и.* Җирдә берәр хайванның үзенә яшәү өчен казып ясаган чокыры, оясы. *Әрлән өненә печән-салам күп ташыса, кыш салкын булыр.* Сынамыш. *Аюларның өне актарылды, Бүреләрнең юлы бозылды.* Ә.Ерикәй. *Газинур аны яз көне беренче тапкыр өненнән чыгучы аюга охшатты.* Г.Әпсәләмов

2) *күч.* Сугышта дошманның качып яткан урыны; аның туган җире, туган иле; үз территориясе. *Ташкын булып бара безнең һөҗүм, Актарыла фашист өннәре.* Ш.Маннур. *Кайткан идек тар-мар итеп Дошманны үз өнендә.* Ә.Исхак

ӨН V *и. иск.* 1) Тиренең йон төбе, җирлеге. *Айгыр куйсаң – өнледән куй, кучкар куйсаң – йонлыдан куй.* Мәкаль

2) Тән тиресендәге тишек

ӨНӘЛҮ *ф. төш. юн.* Әйбәт мөнәсәбәт күрсәтелү, яратылу. *Хатын-кыз тарафыннан кире кагылган, өнәлмәгән ир икенче мәртәбә телендә сандугач биетер микән?* Н.Гыйматдинова

ӨНӘМЛЕ *с. иск.* Ягымлы, күңелгә ятышлы. *Сөйгән ярның өне өнәмле.* Әйтем

ӨНӘМСЕЗ *с. иск.* Ягымлы түгел, күңелгә ятышсыз. *Өндәүле кунак мендәрле, өндәүсез кунак өнәмсез.* Мәкаль

ӨНӘ́Ү *ф. гадәттә юкл. форм.* 1) Кемне яки нәрсәне дә булса яратып кабул итү, уңай мөнәсәбәттә булу. *Әмма өниме ул аларны, әллә өнәмиме, егетне кызыксындырган сорау җавабын көтә иде: нишләп үсемлекләрне бары тик алар чәчкә аткан чорда гына кырау суга?* А.Хәлим. *Мөгаен, хуҗабикәнең әмер-боерыкларын өнәмидер.* Н.Гыйматдинова

2) Нәрсәне дә булса ярату, ошату (ашамлык тур.). *Аннары Марат ул кәбестә шулпасын бик үк өнәп тә бетерми.* Г.Гобәй. *Бичара, ят ризыкны өнәмәде, иснәде дә, борыны кытыкланып, өч тапкыр төчкерде.* Н.Гыйматдинова

3) *диал.* Сизү, тану, абайлау. *Тиз генә өнәмәү*

4) *диал.* Кайда да булса ияләнеп, нигезләнеп яшәп китү

Өнәми башлау *юкл.* Өнәмәү сизелү; күңелгә ятмый башлау. *Чегән җырчыларының артык үксүен өнәми башлыйсың. Тышкы калтыраудан бигрәк, тирәндә – җанда булырга тиеш тетрәнү!* Ш.Галиев. --- *Сталин соңгы вакытларда күбрәк Маленковка ышанган, күбрәк аны үзенә якын тоткан, әменә Молотовны нигәдер өнәми башлаган, имеш.* Ә.Еники

Өнәми йөрү *юкл.* Шактый вакыт өнәмәү

Өнәми тору *юкл.* Бераз вакыт өнәмәү

Өнәп алу Тиз арада өнәү, тану. *Атласов райбашкарма комитеты председателе Фәрит Яһүдин икәнен шунда ук өнәп алды.* С.Рафиков

Өнәп бетермәү *юкл.* Яратмау, күңелгә хуш килмәү, хупламау. *Шумбутский исә моны өнәп бетермәде булса кирәк, тирән сулап, урындыгында боргаланды.* М.Насыйбуллин. *Канәгать аталы балаларны бик өнәп тә бетерми.* А.Хәлим. *Бер-берсенә шырпы капларыдай охшаш күпкатлы йортларда яшәүчеләр аны бик өнәп бетерми.* Ф.Латыйфи

ӨНДӘМ *и. иск.* Боеру, кушу, әйдәү. *Күндәм өндәмсез эшләр.* Мәкаль

ӨНДӘМӘ *и.* 1) Халыкка телдән яки язма рәвештә мөрәҗәгать. *Большевиклар өндәмәсен тарату уен эш түгел ул.* Т.Гыйззәт. *Шуңа күрә дә мин бу хатны шул ук өндәмәдә китерелгән бер революцион җыр сүзләре белән тәмамлыйм.* К.Нәҗми

2) Бик кыска формадагы мөрәҗәгать. *Партиянең өндәмәсе Шул, иптәш, безгә.* Г.Гобәй. *Партиянең Беренче май өндәмәләре*

ӨНДӘМСЕЗ *рәв. иск.* Кушмыйча, өндәмичә. *Күндәм өндәмсез эшләр.* Мәкаль

ӨНДӘ́Ү I *ф.* 1) Нинди дә булса эшхәрәкәт башкарырга үгетләү, чакыру, тәкъдим итү. *Хәзер кешеләрне радио аша Фән-белемгә таба өндибез.* М.Гафури. *Хәзер исә ул урамның нәкъ уртасыннан киерелеп атлый, бөтен халыкны патша төшерергә, патша хәтле патшаны бәреп төшерергә өнди!* Г.Бәширов. *Хезмәт дәресләрендә укучыларын олы тормышка әзерли, мөстәкыйль, эшчән булырга өнди.* Мәгърифәт

2) Берәр рәсми оешмага керергә үгетләү. *Колхозга өндәгән җыелышларда беркайчан да каршы әйтмәс, берәүгә дә каты бәрелмәс иде, ди.* Г.Бәширов. *Аның җиле Ибрай әнисенә дә – Ибрайны Тимур командасына өндәп йөргәндә, улын яклап калган анага да килеп бәрелде.* Г.Гобәй

3) Берәр динне кабул итәргә чакыру; дәгъвәт кылу. *Җир йөзендә «азган» кешеләрне Дингә өндә, күрсәт туры юл!* М.Гафури. *Ләкин Мөхәммәднең исламга өндәве белән Чыңгыз ханның басып алулары арасында аерма шактый зур.* Р.Батулла

4) Үзеннән алда килгән исемнең мәгънәсенә бәйләнешле рәвештә, кемгә дә булса тегеләй яки болай эш итәргә кушу, чакыру. *Шул көнне булган сугышта кызыллар отрядларын көрәшкә өндәп, үлем кырларында хатын-кыз тавышы яңгырады.* Һ.Такташ. *Ул шигырьләр – һәрберсе дә дип әйтерлек демократлык трибунасыннан торып, наданлыкка, караңгылыкка каршы һәм уку-укытуга өндәп язылган прогрессив характердагы шигырьләр.* М.Гали. *Жырлаганнар бертуктаусыз, – Ялны белмәгәннәр, Дошманнарга каршы барысын Яуга өндәгәннәр.* Ә.Исхак

5) Кая да булса чакыру. *Ләкин аш пешерүче җиңгиләр, орышып-орышып, кешеләрне ашка өнди башладылар.* Ш.Камал

Өндәп алу Бераз гына өндәү

Өндәп йөрү Гел өндәү; барысын да өндәү. *[Маһруй:] Бүген, гимназиядән чыкканнан бирле, менә Галиев белән кунак өндәп йөрибез.* Ф.Әмирхан. *Кешеләрне шулай өндәп йөри, Өндәп йөри тыныч яшәргә.* Р.Назаров

Өндәп карау Өндәп маташу, өндәргә тырышу. --- *[кайнанасы] бәддога белән дә куркытты, кешеләрдән оялырга да өндәп карады, үлгәндә бәхиллегемне бирмәм, дип тә какшатырга тырышты, ләкин боларның берсе дә Сәкинәгә тәэсир итмәде.* Ә.Еники. *Балыклы күл авылыннан агай-энеләре килеп, Нурулладан аерылып кайтырга өндәп тә карадылар, яшертен яучылар да йөрде.* А.Гыйләҗев

Өндәп килү Күптәннән бирле, эзлекле рәвештә өндәү. --- *һәрчак аны халыкның беренче тапкыр кузгалышын күргән әнә шул онытылмас мизгелдә туган тойгылар кыю булырга өндәп киләдер.* М.Галиев. *Билгеле, кечкенә чагыннан ук балаларын мөмкин кадәр күбрәк укырга өндәп килгән әнисе авызыннан мондый сүзне ишетүе җиңел булмады Санияга.* А.Фәлах

Өндәп тору Һәрвакыт, даими рәвештә, бертуктамый өндәү. *Тик күңел һич тынычлык бирми, сугыш башыннан бирле һаман тарта, һаман өндәп тора.* Г.Бәширов. *Әйтерсең аны нинди дидер шайтан изге ниятләренең гел киресен эшләргә котырта, яманлык эшләргә өндәп тора.* Р.Габделхакова

Өндәп чыгу Һәркемне, рәттән, берсен дә калдырмыйча өндәү

Өнди башлау Өндәргә керешү. *Назимов үзен лейтенант дип атаган бер егет белән дуслашты, аны бергә качарга өнди башлады.* Г.Әпсәләмов. *Демобилизация башлангач, Прокопьевск шахталарының берсеннән вәкил килеп, солдатларны эшкә калырга өнди башлады.* Г.Галиев

Өнди бирү Бернигә карамый өндәү. *Ә үзе ярдәмгә ашкынган муллаларны алга өнди бирде* ---. З.Зәйнуллин

Өнди тору Башка эш-гамәлгә керешкәнче яки шуның белән берәттән өндәү. *Әйтегез бөтен мөәзиннәргә: манарадан кычкырып, гелән халыкны чакырып, өнди торсыннар.* Р.Батулла

ӨНДӘҮ II *и.* 1) Чакыру эше, чакыру гамәле. *Монда әле генә өндәүдән йөреп кайтты.* Г.Камал. *Ләкин аның бу өндәве – өметсез өндәү, ул боларның нинди дә булса булышлык күрсәтүенә үзе дә ышанмый.* Г.Нигъмәти. *Инде җыелышка өндәүгә килгәндә, революция елларыннан бирле ул барында зур җыелышның җыелганы юк иде.* Г.Бәширов

2) Өндәүчеләр. *Акча алынды, мәһәр килешенде, шимбә көн туйга килергә дип, бу яктан өндәүләр барып кайтты.* Г.Ибраһимов. – *Гади җыен кунаклары гына түгел, алдан ук өндәү җибәрелеп чакырып куелган, җыенның түрендә утыра торган төп кодалар инде болар, – диде.* М.Гали

ӨНДӘ́Ү БИЛГЕСЕ *и. грам.* Һәртөрле көчле тойгыны белдергән җөмләдән соң куела торган тыныш билгесе. *«Бик мөмкин!» дигән өндәү билгесе калкып чыгып, әңгәмәгә нокта куя.* А.Хәлим

ӨНДӘ́Ү ҖӨМЛӘ *и. грам. иск.* Эмоциональ киеренкелекне белдерә һәм көчле хис, тойгы белән әйтелә торган; боеру җөмлә. *Җөмләләр өч төрле булалар: 1) хикәя җөмлә; 2) сорау җөмлә; 3) өндәү җөмлә.* Татар теле грамматикасы

ӨНДӘҮЛЕ *с.* Чакырулы, чакырылган, чакырылып килгән. *Өндәүле кунак мендәрле.* Мәкаль

ӨНДӘҮСЕЗ *с.* Чакырылмаган, чакырусыз килгән. *Өндәүсез кунак өнәмсез.* Мәкаль

ӨНДӘҮЧЕ *и.* 1) Җыелышка, кунакка һ.б.ш. чакыручы кеше. *Авазның беренче дулкыны урамнарга сыеша алмыйча авыл өстендә чарпышып барганда, йомшак һаваны тетрәтеп, өндәүченең соңгы сүзләре шыңгырдап куйды: «Һәй, җыенга!»* Г.Бәширов

2) *этн.* Кияүне кыз куенына керергә чакырырга җибәрелгән кеше. *Яхшы бер ат җигеп, кияү егете белән икәве бер чанада килделәр, никах укылганчы, шул өндәүче өендә калачак, аннан кыз катына киләчәк.* Г.Ибраһимов

3) Берәр фикергә кушылырга чакыручы, берәр эшкә җәлеп итәргә, этәргә тырышучы. *Хак, кулга-кул сузып, дустанә-тату яшәргә өндәүчеләр дә бар, әмма кылыч белән бәхәсне хәл итүчеләр дә ишәеп китте.* М.Хәбибуллин

ӨНЛЕК *и.* Йомран, әрлән кебекләрнең өненнән чыгу өчен запас юлы. *Өнлекне каплау*

ӨНСЕЗ *рәв.* **1.** Тавышсыз, тавыштынсыз, тавышланмыйча, тавыш-тын чыгармыйча. *Ашаганда телсез бул, эшләгәндә өнсез бул.* Мәкаль. *Залдагы халык тын алуын, кайда утыруын, кемлеген онытып, сихерләнгән кебек, өнсез, хәрәкәтсез оеп кала.* Г.Бәширов

2. *с. мәгъ.* Сөйләшмәгән, тавышсыз

ӨҢ *и. сир.* Уңмаган, саф төс. *Өңе киткән тукыма*

ӨҢГӘЛ *и.* Хайваннарда муен белән сырт тоташып киткән урын; җилкә калкымы. *Ат өңгәле*

ӨҢГЕР *и.* Ярда су белән юылып ясалган чокыр, уелма

ӨҢЕЛҮ I *ф. диал.* Туфрагы юылып, ашалып һ.б.ш. юллар белән җирдә чокыр яки куыш урын барлыкка килү, убылу. *Җир өңелү*

Өңелә башлау Бераз өңелү

Өңелеп бару Акрынлап өңелү. *[Варя:] Биредәге тишекләр өңелеп баралар инде.* М.Шабай

Өңелеп бетү Нык өңелү

ӨҢЕЛҮ II *и. диал.* Туфрагы юылып, ашалып һ.б.ш. юллар белән җирдә ясалган чокыр, куыш урын, убылма.

Язгы сулар тау битендә өңелүләр ясап калдырган

ӨҢЕР *и. диал.* Күкрәк өсте, муенның алгы өлеше, изү. *Өңере ачык, шарф урамаган*

ӨҢРӘЮ *ф. диал.* 1) Эчкә бату, чокырланып тору (кешенең яңаклары, хайваннарның янтыклары тур.)

2) Аулактарак, башкалар сафыннан эчтәрәк, түбәндәрәк тору

Өңрәеп утыру Өңрәйгән хәлдә булу. *Менә почмакта торган магазин караңгыда өңрәеп утыра.* Өмет

ӨҢҮ *ф. диал.* Туфракны юып алып, ашап һ.б.ш. юллар белән җирдә чокыр яки куыш урын барлыкка китерү; ишеп төшерү. *Элекке дегет базын язгы сулар өңгән.* Н.Исәнбәт

ӨР- *кис.* Кайбер сыйфатларның һәм рәвешләрнең алдында килеп, «бик», «үтә» дигән мәгънәне белдерә, артыклык дәрәҗәсе ясый. *Күршеләренең коймасын өр-яңадан корган икән.* Т.Миңнуллин. *Узенә өр-яңа комбайн эләктерде.* А.Хәлим. *Әүвәл үзем бу мәхшәр эчендә өр-яңадан яшәргә тиеш.* Н.Гыйматдинова

ӨРӘК *и.* 1) Хорафат карашлар буенча, үлгән кешенең башкаларга күренә торган рухы, чалымы. *Һәр кече атна кич Әсманың өрәге ишек алдыбызга килә, бик хафалый.* Ф.Әмирхан. *Я йөриме буш каберләрдән терелгән бер өрәк?* Н.Исәнбәт. *Нурсөя кычкырып-кычкырып догаларын укырга кереште. Ләкин өрәк килә дә килә иде.* Н.Гыйматдинова

2) *күч. кимс.* Артык ябык яки бик ямьсез кеше яки хайван турында. *Бай дигәч тә бик исләре киткән, аның кеше чыкмаган өрәк шикелле кызын, бүләге дә булмагач, шайтаным ала, улым, син дә бер дә хафаланма!* Г.Камал. *Бу өрәк атка кем шундый хурлыклы исем биргәндер, ул кадәресен Газинур белми иде.* Г.Әпсәләмов

◊ **Өрәге каты** Кырыс, каты холыклы. *Картның өрәге бик каты иде. Кияү буласы кешенең хуҗалык итү сәләтенә ышанмаса, гүпчи тузгытып ташларга да күп алмас.* Г.Бәширов. **Өрәге качу** Куркудан-нидән каушап калу. **Өрәге кубу** *к.* **өрәге качу**

ӨРӘҢГЕ *и.* **1.** *бот.* Чаганчалар семьялыгыннан Европа, Азия һәм Төньяк Америкада таралган, аерчалы киң яфраклы агач үсемлек; чаган. *Дистәләрчә хуторларны азат иткәннән соң, элмә, өрәңге һәм башка шундый яфраклы агачлар белән капланган шушы биеклектә туктады.* А.Шамов. *Корыч кебек өрәңгеләр, Имәннәр утыртырга.* Ә.Ерикәй. *Чаган, өрәңге янындагы алмагач беркайчан да мантый алмый.* А.Хәлим

2. *с. мәгъ.* Шул үсемлекнең үзагачыннан ясалган. *Өстәлдә бүтән бернәрсә дә юк, ипи заты да, сөт-мазар да күренми, алай да дәү-дәү өрәңге кашыклар чуен белән авыз арасында тиз-тиз йөреп торалар.* А.Гыйләҗев. *Тау башыннан без дә кайтабыз: кичке аш инде казаннан табакка бүленгән, сәкегә киҗе ашъяулык җәелеп тәлинкәләр тезелгән, өрәңге кашыклар таратылган.* М.Мәһдиев

ӨРГЕЧ *и. сөйл.* Күрек, һава өрдерү җайланмасы (мәс., тимерчелектә). *Өргеч өрдергән саен, ут гөлт итә.* Н.Исәнбәт

ӨРДЕРГЕЧ *с. тех.* **1.** Һава яки газ өрдерә торган, өрдерү өчен ясалган

2. *и. мәгъ.* Шундый җайланма

ӨРДЕРҮ I *ф. йөкл. юн. к.* **өрү** I. *Капкараңгы төндә урам этләрен өрдереп, барып әбине уятты.* М.Гафури. *Эт өрдереп, кеше көлдереп, караңгыда кем йөри?* Г.Камал

Өрдереп тору Бик озак өрдерү

ӨРДЕРҮ II *ф.* 1) Күрек яки башка берәр нәрсә ярдәмендә һава өрү, һава агымы юнәлтү. *Шикләнмә, авызымнан ут өрдертергә мин аждаһа түгел.* Н.Гыйматдинова

2) *тех.* Һава агымы белән берәр өслекне яки куышлыкны чистарту. *Өрдерү краны. Өрдерү клапаны*

Өрдерә башлау Өрдерергә тотыну. *Бабай, җирдән икенче бер озынча тимер алып, мичкә күмер салды да мех белән өрдерә башлады.* Г.Гобәй. *– Хәзер, менә болай итәбез аны, – дип, төтенлеген алып килде дә, кабызып җибәреп, өрдерә башлады.* В.Нуруллин

Өрдерә тору Берәр эш барышында яки ул башланганчы өрдерү. *София Палеолог ире йөрәгенә үрләгән утлы нәфрәткә җил өрдерә торды: – Литвадагы киявебез Александр да бик вәгъдәсез кеше булып чыкты.* Равил Вәлиев

Өрдерә төшү Бераз өрдерү

Өрдереп җибәрү Кинәт кенә өрдерү; билгеле бер моментта, җае белән өрдерү. *Иртәнге якта бар кешене мәйданга кудылар, анда, кызыл байраклар болгап, җиз торбалар уйнатып, кайнар нотыклар сөйләп, мичне өрдереп җибәрделәр.* Ф.Бәйрәмова

Өрдереп карау Өрдереп тикшерү. *«Сухой закон» көннән-көн корылана бара. Хәзер райком кешеләре дә ГАИ инспекторы кебек өрдереп карыйлар.* К.Кәримов

Өрдереп тору Даими рәвештә өрдерү. *--- тимерне кып-кызыл итеп кыздыру өчен, аны утлы күмер өстендә тотарга, өстәвенә әле тимерче күрегеннән бик нык һава өрдереп торырга кирәк.* Г.Бәширов. *Аяктан егарлык итеп җил исә, ниндидер торбадан безгә генә өрдереп торалар диярсең.* Ә.Гаффар

Өрдереп утыру Өрдерү белән мәшгуль булу; озаклап өрдерү. *Ягъфәр чишмә янына килеп җиткәч күргән: юлдан аз гына читтә, чишмә янында бер карт учак ягып, шуны кул күреге белән өрдереп утыра икән.* З.Зәйнуллин

ӨРЕ *и.* Итле шулпа өстенә чыккан май. *Җиңгәчәсе аның өстенә суганлы, борычлы кайнар өре салып җибәрде.* Ә.Еники. *Әгәр кош ите симез булмаса, кыздырыр алдыннан өстенә эретелгән туңмай сибәргә, аннары, 5–8 минут уткән саен, өстенә иттән чыккан өрене сибеп торырга кирәк.* Файдалы киңәшләр

◊ **Өресен җыю** Хезмәттә катнашмыйча, нәрсәнең дә булса иң яхшысын, иң әйбәтен алу

ӨРЕК *и.* 1) Гөлчәчәклеләр семьялыгыннан көньякта үсә торган җимеш агачы; абрикос. *Ул олпат өрек агачы ихатасыннан чыгып ярты урамны күләгәләгән йорт каршында кискен сулга борылды.* А.Хәлим. *Госпиталь бакчасында үсеп утырган өрек, чия агачлары ап-ак чәчәккә күмелгән.* Ә.Айдар

2) Шул агачның каты төшле сусыл җимеше. *Өлгергән өрек*

3) Шул агачның төшләре алынмыйча киптерелгән җимеше. *Кияү егетләре чикләвек, өрек белән чаршау сүтекләренә төзәп ата башлыйлар.* М.Фәйзи. *Атланмай, бал, әйбәт бодай икмәге, сельпо кибетеннән алдырган өрек, хәтта телемләп кисеп куйган сыр да бар иде.* Ә.Еники. *Өрекне берничә кат юып, шикәр белән кайнап торган суга салалар һәм өрек йомшарганчы кайнатып суыталар.* Татар халык ашлары

ӨРЕЛЕ *с.* Өресе булган. *Аннан өреле шулпа килә, шулпа артыннан – каз бәлеше, бәлеш артыннан табак өеме ит килә.* Ә.Еники. *Кичен, өреле куе кара балык ухасы ашап, сүнәр-сүнмәс янган учак тирәсендә озак кына гәп сугып утырдылар [алар].* А.Гыйләҗев

ӨРЕЛМӘЛЕ *с. лингв.* Сөйләм органнары арасында ясалган ярыкка һава ышкылудан барлыкка килгән; фрикатив. *Йомык авазларны әйткәндә, сөйләм органнары арасында йомыклык хасил була, өрелмәле авазларны әйткәндә, бераз ярык кала, һава агымы, шуннан үткәндә, ышкылып чыга. Өрелмәле авазларны фрикатив дип тә атыйлар.* Тел белеменә кереш

ӨРЕЛҮ *ф.* 1) *төш. юн. к.* **өрү** II (*2–4 мәгъ.*)

2) һава тулып кабару, күләме зураю (куык, шар хасил булу). *Бака күпме өрелсә дә, үгез булалмый.* Мәкаль. *Рус мәүлүде үтеп китте, көннәр суык. Колакларда, борыннарда өрелә куык.* Г.Тукай

3) *сөйл.* Кабару, шешү. *Халикъ бу вакытта икмәкнеме, балыкнымы – кайсындыр күбрәк алу сәбәпле, бер як урты тавык күкәе хәтле өрелгән иде.* Ш.Камал

4) Тулып пешү, тулышу. *--- янып утырган тәмле чияләр хәзер өрелеп, каралып баралар.* Г.Ибраһимов

Өрелә бару Вакыт узган саен ныграк өрелү

Өрелә тору Торган саен өрелү. *Бик өрелә торгач, синнән матуррак егетләр дә әйләнеп төшкәлиләр.* Ф.Әмирхан

Өрелеп алу Бераз вакытка өрелү. *Минһаҗетдин үзендә көч барлыгын сизенеп,--- ата күркә шикелле бер өрелеп алды.* К.Тинчурин

Өрелеп китү Кинәт өрелә башлау. *Яңакларының өрелеп китүеннән, күз карашының сүрәнләнеп калуыннан Рәфис әйткәннәр белән килешмәве ярылып ята иде.* А.Вергазов. *Яңа урынга әле үзе дә, күңеле дә урнашмаган бер мизгелдә, бу сөйләшүдән бераз бушанып, күңеленең кайсы почмагынадыр өмет җылысы өрелеп киттеме?* М.Әхмәтшина

Өрелеп җитү Тиешле күләмдә кабару

Өрелә төшү Беркадәр өрелү

Өрелеп тору Өрелгән, тулы, кабарган хәлдә булу; хәзерге вакытта өрелү. *Өрелеп торган җиңел күлмәкле, биек итеп өеп куйган кабарынкы чәчле, кара күзле бу кызчык баянчыны вальс уйнарга өйрәтә.* К.Тимбикова

ӨРЕТЕЛҮ *ф. сөйл. к.* **өртелү**. *Политик цензура шартларында пейзаж лирикасының сәяси рух белән өретелгән булуы бер дә гаҗәп түгел бит.* Р.Фәтхрахманов. *Бу тавышлар бөтенесе бергә әллә кайдагы болыннарга, үтә күренмәле аксыл томан өретелгән уйсу җирләргә җәелә иде.* Ә.Дусайлы

ӨРЕТМӘ *и.* Йөз пәрдәсе, битне каплый торган юка тукыма кисәге, челтәр һ.б.ш. *Йөзне өретмә белән каплап йөрү*

ӨРЕТҮ *ф. сөйл. к.* **өртү**. *Ул бөтен дөньяны кып-кызыл иткән, күк гөмбәзен, бакчадагы агачларның кәүсәләрен кызыл нәкышь белән өреткән.* Ф.Садриев

ӨРКӘК *с.* **1.** 1) Курка торган, өркә торган. *[Шиһап:] Менә шулай кирәк. Нигә өркәк ат кебек, ирләрдән өркеп, урамның икенче ягыннан китәргә.* М.Гафури. *Өркәк ат яугирне хурлыкка калдыра, ә Кылкөлтә һичбернидән курыкмый.* З.Мурсиев

2) *сөйл.* Куркак табигатьле, характерына куркаклык хас булган, кыю булмаган. *– Кара-кара, өркәк адәм баласы түгел бу! – диде Ялмавыз.* Әкият. *Ул минем хыялымдагы күз күтәреп карарга да ояла торган, өркәк, нәфис Газизә түгел инде.* Д.Булатова

2. *и. мәгъ.* Шундый кеше. *Син һаман да шул өркәк икәнсең әле.* А.Гыйләҗев

ӨРКӘКЛЕК *и.* Өркәк булу. *Гаянның өркәклеге кызларга да йокты, аларның алтысы гына батыраеп миңа иярде.* Н.Гыйматдинова

ӨРКӘЧ *и.* 1) Кайбер хайваннарның аркасында май туплана торган бер яки ике зур оры. *Бер дөядә ике өркәч, бере шилсә, беренең көче юк.* Табышмак. *Тычкан шул арада анда йөгергән, монда йөгергән дә, кинәт Дөя өстенә атылып менеп, өркәченең башына ук менеп утырмасынмы?* Г.Дәүләтшин

2) *күч.* Тау өстендәге текә калкулык. *Ераккә, бик ераккә чаклы сузылган ул тауларның эреле-ваклы өркәчләре арасыннан, яртылаш әлсерәгәндәй булып, төнге агачлар сузылып калалар.* Ф.Хөсни. *Тармак-тармак Урал өркәчләре каралып күренә.* Г.Якупова

ӨРКӘЧЛЕ *с.* Өркәче булган. *Арада тоташ өркәчле, калын, озын ботлы бик зур төя бар иде.* Г.Ибраһимов. *Дәште Кыпчакның ике өркәчле дөяләрен фарсылар 25 дукат (үзләренең бер генә өркәчле дөяләре 10 дукат торган) түләп ала торган булганнар.* Р.Фәхретдинов

ӨРКӘ́Ч-ӨРКӘЧ *рәв.* Өркәчләр (*2 мәгъ.*) хасил итеп, текә калкулыклар булып. *Безнең каршыда өркәч-өркәч күтәрелгән таулар, текә таш кыялар тезмәсе.* С.Сабиров

ӨРКЕЛҮ *ф. диал.* Ургылу, ургылып-ургылып хәрәкәт итү. *Бик ераста күкри күк, яшьни яшен: яңгыр килә; Кыйбла яктан җил исә, зур-зур болытлар өркелә.* М.Гафури

ӨРКЕНЕЧ *с. диал.* Куркыныч

ӨРКЕНҮ *ф.* Өркү, курку. *Иясе белән булган бу хәлдән өркенгән ат, читәннәрне аударып-тапап, икенче якка ыргылды.* Г.Минский

ӨРКЕТҮ *ф.* 1) Куркыту, куркытып читкә тайпылдыру (хайваннарны). *Килде чыкты бер заманны Чын бүре, куй өркетеп.* Н.Исәнбәт

2) *сөйл.* Гомумән куркыту, курку хисе уяту. *Баскынчылар әүвәлгечә бездән хәрам мал көтә. Табан ялап, сый куймыйбыз, аларны шул өркетә.* Р.Шәфи. *Учакка табан турыласа, я кунакны өркетер.* Н.Гыйматдинова. *Хәтта төрлечә җәзалаулар да аны өркетмәгән.* Татарстан яшьләре

Өркетә башлау Өркетергә керешү. *Сакманов, Башорин, Баһапов кебек китларны өркетә башларга кирәк дип*

саныйм. Вакыт җитте аларны селкетергә. Т.Галиуллин

Өркетә тору Еш кына, гел өркетү. *Уйдырмалар белән башкаларны өркетә торгач, үзе шүрләп калган.* Ш.Галиев

Өркетә төшү Бераз гына өркетү; тагын да ныграк өркетү

Өркетеп алу Аз гына өркетү; бер мәртәбә өркетү

Өркетеп бетерү Тәмам өркетү

Өркетеп җибәрү Уйламаганда, кинәт өркетү. *Алар, отрядны кырып бетереп, терлекләрне куып китәргә, иң кимендә, аларны таркатып, өркетеп җибәрергә --- тиешләр иде булса кирәк.* А.Шамов

Өркетеп кую Алдан ук, көтелгәннән алда өркетү

Өркетеп тору Даими, берөзлексез куркыту. *Абзасын гел өркетеп тормакчы булган.* Ә.Еники

ӨРКҮ *ф.* 1) Кисәк килеп чыккан берәр нәрсәдән яки нинди дә булса тавыштан куркып китү, куркып китеп, берәр хәрәкәт ясау, читкә тайпылу; чыгымчылый башлау һ.б. (хайваннар тур.). *Комбатның колоннага орынырорынмас барган аты, нидәндер өркеп, читкә тайпылды.* Г.Бәширов. *Аның тавышыннан хәзер генә сыерлар өркеп качалар, балалар үкереп елап җибәрәләр.* А.Шамов. *Ат өркеп читкә тайпылды, ләкин Гали абзый дилбегәне нык тоткан иде.* Г.Әпсәләмов

2) Нәрсәдән дә булса курку, каушау. *Җәһәннәмнән өрекми, өтермәдән курыкмый.* И.Гази. *Куркак кешеләр куркып өркәләр.* М.Гафури. *Өрекмә, сакчы фәрештәләреңә баскан эзләреңә канатын җәяр, бәпкә.* Н.Гыйматдинова. *Чукындырылудан өркегән халыкның хөкүмәткә бернинди ышанычы да калмаган, билгеле.* С.Алишев

Өркә башлау Өркү гадәте барлыкка килү

Өркә төшү Бераз өркү; тагын да ныграк өркү

Өркеп йөрү Озак вакыт, күптәннән бирле өркү

Өркеп калу Нинди дә булса бер вакыйгадан соң өркә торган булу. *Хәтәр минутта өркеп кала торган булмасынар.* И.Гази

Өркеп китү Кинәт өркү. *Ул арада атлар, өркеп китеп, аны ике арба арасына китереп кыстылар.* А.Шамов

Өркеп тору Хәзерге вакытта өркү; бераз вакыт өркү. *Беләсеңме нәрсә, Гөлнарый җан, мин өркебрәк торам.* Ә.Айдар

ӨРЛЕК *и.* 1) Идән, түшәм һ.б.ш.ны күтәреп тору өчен, очлары ике як диварга яки нигезгә беркетелгән агач, тимер яки бетон борыс. *Тал ярый дип, тал кисмәгез, Тал ярамый өрлеккә.* Җыр. *Сүзнең шул җирендә туктalып, ул өрлеккә үрелде һәм нәрсәдер куптарып авызына капты.* Ә.Фәйзи. *Менә өрлеккә асылган үлчәү көянтәсе әле бер якка, әле икенче якка атынгалап торды да тынып калды.* Г.Бәширов

2) Корылманың атламасын (кайчысын) тотып тора торган аркылы борыс. *Ләкин чирек сәгатьтән авыл буйлап коточкыч кара хәбәр йөгерде: Ихсан үз лапасларының өрлегенә асылынып үлгән...* М.Мәһдиев. *Лагерьдан килеп җитә алган хатларымны әни җыя барган, аларны кайсын кайда: мич арасында, лапас өрлегенә кыстырып куеп яшереп тоткан.* А.Гыйләҗев

ӨРЛЕКЛЕ *с.* Өрлекләргә салынган, өрлекләп эшләнгән. *Өрлекле күпер*

ӨРЛЕКСЕЗ *с.* **1.** Өрлек куймыйча эшләнгән, өрлеге булмаган. *Өрлексез түшәм*

2. *рәв. мәгъ.* Өрлек куймыйча. *Өрлексез өй салмыйлар.* Мәкаль

ӨРПӘЙТҮ *ф. диал.* Кабарту, торгызу, тырпайту

Өрпәйтеп җибәрү Бераз өрпәйтү

Өрпәйтеп тору Әледән-әле өрпәйтү

ӨРПӘК *и.* 1) *иск.* Өчпочмаклы яулык. *Башындагы кызыл өрпәген арттан бәйләгән чандыр гына бер кыз, алгы машинадан җитез генә сикереп төшеп, шлагбаумны ачмакчы булган иде, Шәрипов аны коры гына кисәтеп куйды.* С.Рафиков

2) *диал.* Гомумән яулык. *[Бүләк итеп] карчыграк хатыннарга өрпәк бирәләр.* К.Насыйри

ӨРПӘЮ *ф. диал.* Кабару, тырпаю

Өрпәеп тору Өрпәйгән булып күренү; өрпәйгән хәлдә булу

Өрпәя төшү Бераз өрпәю; тагын да өрпәю

ӨРПЕ *и. диал.* Имчәк. *Каты өрпеле сыер*

◊ **Өрпесе каты** Үзсүзле, усал кеше турында

ӨРТЕЛҮ *ф.* 1) Берәр нәрсә белән каплану, томалану, биләп алыну. *Бүлмәм бүген гөлгә өртелгән.* М.Җәлил. *Иртәнге томан белән өртелеп, таудан Хәлидә төшә иде.* Н.Гыйматдинова. *Томанга өртелгән Темза буендагы соры Лондон калка.* Казан утлары

2) *иск.* Киенү. *Асыл киемнәргә өртелеп, Атлас ефәкләргә төренгән.* М.Гафури

3) *күч.* Берәр сәбәп, сылтау, гамәл һ.б.ш. белән аклану, шуның артына яшерелү. *Еллар буенча кабилә, ыруг пәрдәсе эченә өртелеп, җир-су өчен, җәйләү өчен, ил өстендә баш булу өчен дәвам итеп тә җәназа сәбәбеннән тышкы ягы капланган дошманлыклар – һәммәсе бәреп өскә чыкты.* Г.Ибраһимов

4) *күч.* Кешенең йөзендә, чыраенда нинди дә булса хис-тойгы беленү, чагылу. *Бу сүзләрдән Карлыгач-Сылуның кара туткыллы сылу йөзенә, нечкә хәсрәт пәрдәсе белән өртелгән матур, кара күзләренә нур чәчелде.* Г.Ибраһимов. *Ниндидер бер җансыз җитдилек белән катып калган йөзе аз гына сагыш белән өртелгән.* Ә.Еники

5) *күч. диал.* Яшеренү, качу. *Таш шулай шайтан эчендә өртелә... Бездә шул «йолдыз ату» дип йөртелә.* Ш.Бабич. *Мин монда вакытлыча кеше сүзеннән өртелеп торыр өчен генә килгән идем; шулай ук бәласеннән өртелер өчен китәм дә.* М.Фәйзи

Өртелә бару Торган саен ныграк өртелү

Өртелә башлау Әкренләп өртелү

Өртелә килү Электән үк, гел өртелү

Өртелә төшү Бераз өртелү; тагын да күбрәк өртелү

Өртелеп бетү Бар җире дә өртелү, барысы да өртелү

Өртелеп җитү Тулысынча өртелү, тиешле дәрәҗәдә өртелү

Өртелеп калу *к.* **өртелеп китү**

Өртелеп килү *к.* **өртелә килү**

Өртелеп китү Капланып калу, берәр нәрсәнең ышыгында калу, әһәмияте бетү

Өртелеп тору Әлегә өртелгән хәлдә булу; даими өртелү

ӨРТЕНҮ *ф.* Киенү; гәүдәне берәр нәрсә белән каплау. *Өртенә белми өртенгән – оят җирләре күренгән.* Мәкаль

ӨРТКЕЧ *и.* Каплавыч, ябу, ышыклау өчен берәр нәрсә. *Яфрактан тегелгән гаурәт өрткечләрен табып алып кигәндерме, юктырмы – анысы Коръәндә әйтелмәгән.* Г.Гобәй

ӨРТҮ *ф.* 1) Каплау, өстенә ябу. *Чыдамсыз бер кием ул Җанны өрткән!* Г.Тукай. *Кар чикмәне хәзер җитми Кырның коңгырт кара тәнен өртергә.* М.Җәлил

2) *күч.* Каплап китү, берәр нәрсәне үз ышыгында калдыру, аның әһәмиятен калдырмау

3) *күч.* Чынын, асылын берәр нәрсә артына яшерү

Өртә башлау Өртергә керешү

Өртә килү Электән үк, гел өртү

Өртә төшү Бераз өртү; тагын да өртү

Өртеп бетерү Бар җирен дә өртү, барысын да өртү

Өртеп җиткерү Тулысынча өртү, тиешле дәрәҗәдә өртү

Өртеп китү Тәмам өртү

Өртеп кую Өртеп әзер хәлгә китерү. *Әйтерсең аны зәңгәрсу төстәге бик юка, бик җиңел пәрдә белән генә өртеп куйганнар.* Г.Әпсәләмов

Өртеп тору Хәзер өртү; вакытлыча өртелгән хәлдә тоту; даими өртү

ӨРТҮЛЕ *с.* Капланган, өсте нәрсә белән булса да каплап куелган. *Яшел яфрак белән өртүле чыршылар, каеннар да Торалар тик кенә...* М.Гафури. *Сыек кына томан белән өртүле диңгез өстендә очынып йөргән акчарлакларның гыйгылдап көлгән шикелле үткен һәм күңелне кытыкландыра торган тавышлары, диңгез өстендә асылынып торган әллә нинди тылсымлы сарайдан ишетелгән шатлыклы шаркылдауларына охшый иделәр.* Ш.Камал

ӨРТҮСЕЗ *с.* Капланмаган, өсте ачык; ялангач. *Өртүсез пакь, ак йөзеннән ай үбә, нурлар тама.* Н.Думави

ӨРҮ I *ф.* 1) Өзек-өзек тавышлар чыгару (эт, төлке һ.б.ш. тур.). *Эттән күреп көчек өрә.* Мәкаль. *Әле бер, әле икенче колагын шомрайткан эт нигәдер өрмәде, иренеп кенә күзен ачты да кире йомды.* Н.Гыйматдинова. *Бәладән котылдым, дип уйлап та өлгермәдем, койма буйларында эсседән иренеп, әлсерәп яткан әнчекләр минем кыяфәтемне күреп алдылар, артымнан өреп чаба башладылар.* Ә.Айдар

2) *күч. гади с.* Тиргәшү, әрләшү, орышу; әшәке сүзләр әйтү, кычкыру; урынсызга бәйләнү. *Бер-ике өреп, ниндидер сүзләр әйтеп үтте.* М.Гафури. *Бик күп өрсәң, эте бар, диярләр.* Г.Ибраһимов. *Меньшевик Семёновлар, уңмаган умартачы этләре шикелле, бушка гына өреп сару кайнаталар.* Ш.Камал

Өрә башлау Өрергә тотыну. *Без флигельгә якынлашканда, арттан бик калын тавыш белән эт өрә башлады.* Ш.Камал. *Әйдүк йокы аралаш сүзен кайдан башларга белми торганда, урамда Караборын ачы-ачы өрә башлады, һәм тәрәзә алдында ике күләгә күренде.* Һ.Такташ

Өреп алу Бераз гына өреп туктау. *Авылның төрле урыннарында сирәк-мирәк кенә, иренеп кенә этләр өреп ала.* А.Шамов. *Берара этләр өреп алгалый, тоник кына итеп, кар шыгырдап кала.* Ә.Гаффар

Өреп җибәрү Кинәт өрә башлау. *Ул тагын да колак йоннарын үрә торгызып өреп җибәрде.* Һ.Такташ. *Гали абзыйлар турысына җиткәч, Сарбайлары өреп җибәрде.* Г.Әпсәләмов

Өреп калу Өрүен дәвам итү; өрергә өлгерү. *Без барабанны кагып үткән саен, Шушы капкадан бер өреп кала ---.* М.Җәлил. *Кыз сарайга йөгерде, аның артыннан һау-һаулап каравыл этләре өреп калды.* М.Хәбибуллин

Өреп кую Кисәк кенә бер тапкыр өрү. *Эт, ниһаять, үзенә эш чыкканны күреп, матур өреп куйды.* Г.Гобәй. *Ачык капкадан бер эт йөгереп чыкты да аяк астында буталырга тотынды, чананы иснәштергәләде дә, малайга карап, юаш кына өреп куйды.* Ә.Гаффар

Өреп тору Бертуктаусыз өрү. *Әле һаман да өреп торасыңмы?* Ш.Камал. *Ул шулай кычкырып, колак төбендә өзлексез өреп торыр өчен генә туган кебек.* Л.Лерон

Өреп яту *сөйл. к.* **өреп тору**. *[Дилә-фрүз:] Бурзай булсагыз, өреп кенә ятар идегез.* Т.Миңнуллин. *Читтә өреп яткан һәр көчеккә каршы таш ыргытып булмас.* В.Имамов

ӨРҮ II *ф.* 1) Һава агымын куу, һаваны хәрәкәткә китерү, куып күчерү. *Тышта тавыш-тын юк, караңгы, йомшак кына җил өрә.* Ш.Камал. *Моң гына сызгырып, көзге җил өрә.* А.Шамов. *Җәйләр үтәр, көз җитәр, Кырда салкын җил өрер.* Ә.Ерикәй

2) Кая да булса салкын һава керү, үтәли җил барлыкка килү. *Муртайган бүрәнә ярыкларыннан, сыланмаган тәрәзәләрдән будка эченә җил өрә.* Г.Гобәй. *Һичбер ярык калдырмыйча, бик тыгыз ябылган тәрәзәдән дә җил өргәли.* Кызыклы физика

3) Авыздан көчле һава агымы чыгару. *Аптыраган, тәмам канатлары сынган ана, яшь каен чаукасы кебек сыгылып, үле баласын вагон бәдрәфенә алып кереп бикләнде һәм шашкан күзләр белән сабыйның кара көйгән иреннәренә авызын куеп тын өрә башлады.* А.Хәлим. *Карчык, дога укып, Нурсөянең битенә өрде.* Н.Гыйматдинова

4) Һава тутыру, эченә һава агынтысы җибәреп кабарту. *Унбиш минуттан соң без, елгага төшеп, [резин] көймәне өреп тутырдык.* Ә.Айдар. *Сабын куыгы өреп ясагыз һәм аңа карап торыгыз ---.* Кызыклы физика

5) Тынлы музыка коралында тавыш барлыкка китерү өчен, авыздан аңа һава агынтысы кертү. *Быргысына ул бер өрсә, әлегә беркайда да ишетелмәгән, әлегә беркем дә белмәгән моңлы һәм дәртле көйне уйнап җибәрә, ди.* А.Алиш

◊ **Өреп кабартылгандай (кебек)** *к.* **өреп тутырылгандай (кебек)**. *Штанга күтәрү буенча дөнья чемпионы, өреп кабартылган кебек гәүдәле Жаботинский сурәтен ул елларда күплəр белə иде*. М.Галиев. *Сары чәчен чүмәлә кебек итеп өйгән, өреп кабарткандай ап-ак битле, ярымшәрә утырган хатын: – Бездә андый нәрсә юк, – диде.* Ф.Чанышева. **Өреп очырган**

кебек *к.* **өреп очырган шикелле**. **Өреп очырган шикелле** Бик зур тизлек белән. *Хәкимҗан шундук өреп очырган шикелле юк булды.* Г.Бәширов. **Өреп очыру** Юкка чыгару. *Мин аның барлык гаепләүләрен йон урынына өреп очырдым, әмма шулай да, иптәшемнең йөрәгемә төбәп аткан угы үзенең ярасын калдырды.* А.Шамов. **Өреп очырырлык** Бик аз, бик вак, бик кечкенә нәрсә турында. *Бүгенге көндә өйдә өреп очырырлык ризык заты юк.* М.Хәсәнов. **Өреп тутырылгандай (кебек)** Таза, тулы яки ныk кабарып, күпереп торган гәүдә, әгъза һ.б.ш. турында. *Кызыксынып китеп, Алгай күз кабаклары өреп тутырылгандай кабарган шакмак гәүдәле бер кеше янында тукталды.* М.Әмирханов. *«Кырык яшькә безнең кебек булыр әле», – дигәннәр иде сүз арасында өреп тутыргандай таза гәүдәле акушеркалар.* Идел. **Өреп чыгару** Берәр җирдән бик тиз, бик җиңел генә куып чыгару. *Тизрәк эшләрем генә бетсен, аннан ары мин сезнең барыгызны да ничек итеп өреп чыгарырга белермен.* Г.Камал. *Алар [олы малайлар] яр башында мүк тәмәкеләрен пыскытып тордылар-тордылар да бәләкәчләрне дегеттәй кара судан өреп чыгардылар* ---. А.Гыйләҗев. **Өреп эчә торган** Бик сак эш итә торган. *Шуннан соң инде ул, үз теле белән әйтсәк, салкынын да өреп эчә торган булып калган.* Г.Минский. **Өрмәгән җиргә утыртмау** *к.* **өрмәгән урынга утыртмау**. --- *Өрмәгән җиргә дә утыртмам.* А.Шамов. **Өрмәгән урынга утыртмау** Кемгә дә булса бик ныk кадерхөрмәт күрсәтү. *Үзеңне өрмәгән урынга утыртмас идем.* Ә.Айдар. **Өрсәң очып китәрлек** Бик ныk ябык һәм арык кеше турында

Өрә башлау Өрергә керешү. *Тышта шактый гына салкынча икән, өрә башлады.* Г.Камал

Өрә тору һаман өрү. *Эт өрә тора, бүре йөри тора.* Мәкаль

Өрә төшү Бераз өрү; тагын да өрү

Өреп алу Бераз гына өрү. *Варис папирос утына өреп алды*. Х.Камалов. *Аскы иренен алга сузып, шул тыңлаусыз чәчләренә әледән-әле өреп ала.* С.Зыялы

Өреп җибәрү Кисәк өрү; өрә башлау. *– Укып чыктык, Гәүһәр апа. Бик күңелле китап! – диде алдан кергән кыз һәм күзенә төшкән чәч бөтеркәсен өреп җибәрде.* А.Тимергалин

Өреп карау Өреп тикшерү; өреп маташу, өрү белән тәэсир итәргә тырышу. *Рәшәткәләр буядым! Яңгыр килеп юып карады. Кошлар килеп кунып карады. Җилләр килеп өреп карады.* Р.Фәйзуллин. *Сакланып кына бер кураны кисеп алды. Чиерткәләп, өреп карады*. Р.Хафизова

Өреп кую Кинәт, бераз, бер мәртәбә өрү. *Әткәй дә, җылы өйгә килеп керүе белән, ух дип кулларына өреп куйды.* Ә.Еники. *Битараф бер кыяфәт белән елмая төшеп, авызыннан төтен өреп куйды Сталин.* Р.Мөхәммәдиев

Өреп тору Туктаусыз, даими өрү. *Торсын иде җил өреп ватык тәрәзәдән!* А.Гыйләҗев. *Җилкәннәреңә һәрчак шәфкатьле җилләр генә өреп торсын.* А.Хәсәнов

Өреп яту *сөйл. к.* **өреп тору**. *Нинди гыжлаган тавыш анда? Курай? Нәрсә анда курай өреп ятасыз?* И.Юзеев

ӨРФӘ *и. к.* **өрфия**. *Май башларында тал һәм ак каеннар бөреләрен ача: өрфә «күлмәк»ләрен кия.* К.Тәхау

ӨРФИЯ *и. фар.* **1.** 1) Бик юка, үтәкүренмәле челтәр тукымадан һ.б.ш. ясалган япма

2) *күч.* Нәрсәнедер биләп алган, каплап, чорнап, өртеп торган уйдырма пәрдә, томан һ.б. *Гадәттә болай була: кайгылы кешеләр бүгенгедәй матур көнне дә үзләренчә моң өрфиясе эчендә килеш күрәләр.* Ш.Рәкыйпов

2. *с. мәгъ.* Челтәрле итеп бәйләнгән; бик нечкә. *Сылу тәненә сыланып торган өрфия күлмәк кигән Наилә бу кичәдә сусылланып пешкән җиләкне хәтерләтте.* М.Әхмәтшина

ӨС *и.* **1.** 1) Нәрсәнең дә булса өслеге. *Диңгез өсте тип-тигез, шоп-шома, бөтен җир йөзенә җәелеп ятkан бер гажәеп көзге шикелле күренә иде.* Ф.Әмирхан. *Бөтен дала өсте су сибеп катырган кебек бозланып ялтырады, җир өстендәге үлән юеш кар белән сыланып туңды.* Г.Ибраһимов. *Малайлар, аның калкып чыгуын көтеп, су өстенә карап тора башладылар.* И.Гази

2) Нәрсәнең дә булса югары өлеше. *Аларның ишекләренең өсләренә тактага эре итеп ул бүлмәдә тора торган атның, сыерның яше, караучысының һәм савучысының исеме язылган.* М.Гали. *Менә асты таш, өсте агач булган ике катлы йорт.* Ш.Мөдәррисов

3) Нәрсәдән дә булса югары урнашкан пространство, ара, шуның турысы. *Бөтен диңгез өсте үзенә бер төрле тонык яктылык белән яктырды.* Ф.Әмирхан. *[Пароход тавышы] Тимеркүк белән юыртып барган юлчыларыбыз өстеннән каты яңгыратып үтеп, арттагы кечек урманның куакларында югалды.* Г.Ибраһимов. *Илсөяр будкадан чыкканда, яңгыр туктаган, җил тынган, бөтен күк йөзен каплап торган калын, кара болытлар үз эшләрен бетереп, Агыйдел өстеннән киткәннәр иде инде.* Г.Гобәй

4) Берәр нәрсәнең тышкы ягы, тышкы өлеше. *Булган кадәрлесе дә бик зәгыйфь вә күбесенең комедия икәнлеге өсләренә шулай дип язылып куелганлыктан гына беленәдер.* М.Гали. *Йөк машиналарыннан башка тагын полк миномётлары дивизионы, аннары өсләре брезент белән ябылган машиналар да әледән-әле узып китәләр.* Г.Әпсәләмов

5) Сөтнең өстендә җыела торган куе, майлы утырмасы. *Кичә аның артыннан ук нәүрәпкә төшкән идем, ни күрим, кара чүлмәктәге сөтнең өстен эчкән дә чыккан.* А.Шамов. *– Атна буе җыйган сөт өстен әрәм иткәннәр, – диде әнисе ачулы тавыш белән.* Д.Аппакова. *Өсте алынмаган сөткә азрак су кушып кайнатып чыгаралар да алдан чистартып юган дөге ярмасы салалар.* Татар халык ашлары

6) Капкач. *Нәфсем төшеп, калын бер мичкәнең Өстен ачып, эчтем чүмечләп.* М.Җәлил

7) Гәүдәнең кием киелә торган тышкы ягы. *Көзге суык пычракларда яланаяк, яланөс, балчык эчендә батачума, безнең отрядка патроннар ташып йөрдең.* Ш.Камал. *Ачлык елда авылны ташлап, ире, бала-чагалары белән калага күчкәч тә, тамагы ашка, өсте киемгә туймады.* Г.Ибраһимов. *Алтыпочмаклы өй салып җибәрә,*

каралтылар торгыза, өс киемнәрен, өй җиһазларын өр-яңадан алмаштыра, балалары укырга керәләр. Г.Әпсәләмов

8) Берәүнең кигән киеме, кигән киемсалым. *Әйдә, сал өстеңне.* Г.Камал. *Матур уйлар белән өенә кайтты, өстен чишенде дә юынды.* Ш.Маннур. *Суга манып алган төсле Була аның бөтен өсте, Трибунадан төшкәндә.* З.Мансур

9) Авыл хуҗалыгы эшләрен белдерә торган сүзләрдән соң килеп, «шуларны эшләү вакыты, чагы» мәгънәсен белдерә. *Бервакытны шулай сабан өсте, Кырда бергә сабан сөрәбез.* һ.Такташ. *Бу минутларны ул бик сагынып, бик зарыгып көткән иде бит: урак өстеннән бирле, урман буенда күргәннән бирле...* Г.Бәширов. *Ягъни җәй көне миңа да чүп утарга һәм печән өстендә аш әзерләп торырга туры килде.* Х.Ширмән

2. *с. мәгъ.* Өске, югарыда булган. *Афишалар зур хәрефләр белән өс яктан кызыл, астан яшел буяу белән басылган булып, афишаларның урта бер җирендә ике буяу салават күпере төсләре шикелле бергә кушылып киткән иделәр.* Ш.Камал

◊ **Өс бөтен** «Тиешле киемнәре бар, киемнәре җитәрлек» дигән мәгънәне белдерә. *[Фатыйма:] Бүтән малайларның аларның нәрсә: тамаклары тук, өсләре бөтен.* И.Гази. **Өскә атлану** Кешегә салыну, үзенең эшен, авырлыгын, мәшәкатен башка берәүгә йөкләү. *Әле укырга кермәс борын шул тамаша өскә атланырга тора бу, ә укый башласа нишләр бу, дим.* Г.Ахунов. **Өстә калмау** 1) Бурыч түләнеп бетү. *[Хафиз:] Менә тиреләрне генә тапшырып кайтыйм, барысызга да түләрмен. Минем өстә калмас.* Ә.Фәйзи; 2) Нинди дә булса әйтәсе килгән сүзне җиткерү. *Минем өстә калмасын, әйтим: Ковнога тукталып, вокзал площадкасына төшкәч, без аның белән тагын очраштык.* Г.Гали. **Өсте тәти, асты тәпи** Тыштан гына матур күренгән әйбер турында. *Өсте тәти, асты тәпи.* Г.Ахунов

ӨСӘК *и.* Келәттә ашлык, он һ.б.ш. салып саклау өчен такта белән бүлеп ясалган урын яки зур агач әрҗә; ашлык бурасы; лар. *Өсәккә кермәсә, исәпкә кермәс.* Мәкаль

ӨС-БАШ *җыйм. и.* Өскә кигән кием, өс киеме (баш һәм аяк киеме белән бергә). *Әстерханнан менеп килә торган Кавказ-Меркурий пароходының беренче классында килә торган юлчы – Тарабаров исемле бер бай – өстенә-башына бик яхшы киенгән бер кеше белән белешләнгән.* Г.Камал. *Килене кай арададыр торган һәм, нәрсәгәдер хәзерләнеп, өстен-башын киенеп куйган иде.* А.Шамов. *Килгәндә, күрәсең, кырыкмаса-кырык егылгандыр, өстебашы кар гына...* Г.Гобәй

◊ **Өс-баш ясау** Өскә киергә кием-салым булдыру. *Менә инде ничә ай булды, фатир өчен бер тиен түләгәне юк. Өс-башыбызга бер тиенлек нәрсә ясаганы юк.* Г.Камал. *Өс-баш ясыйсың, берәр тибәсең, карасаң, кесә тагы саеган.* Г.Ибраһимов

ӨСЙӨЗ *и. мат. иск. к.* **мәйдан**

ӨСКӘ *рәв.* 1) Әйбернең югары өлешенә; өслегенә, тышкы ягына. *Алтын аска бата, чүп өскә калка.* Мәкаль. *Клейстерның күп сыланмавын күзәтергә кирәк, югыйсә басып ябыштырган вакытта ул өскә чыгарга һәм обойның кырыйларын пычратырга мөмкин.* Файдалы киңәшләр

2) Биеклеккә, югарыга. *Очыргыч шактый өскә күтәрелгәч, һавада уйнаклап алды да яңадан килеп төште.* Казан утлары. *Ә биредә трубага тоташтырылган баскыч буйлап өскә күтәреләсе, үзең белән бергә флаг алып менәсе.* Мирас

3) Югарыга таба. *Ирхәт тәрәзә белән өстәл арасына аякларын өскә каратып куйган аксыл тукымалы урындыкны тартып чыгарды.* М.Хуҗин. *Утка 3–4 м кала, сүндергечне төбе белән өскә әйләндерәләр һәм кнопкасы белән идәнгә, тәрәзә төбенә яки нинди дә булса берәр каты әйбергә бәрәләр.* Файдалы киңәшләр

4) Югары катка. *– Әйдәгез, тиз, анда сезне абыстай чакыра, – диеп, безне өскә алып менде.* А.Таһиров. *Ул ачык тышкы ишектән кереп өскә күтәрелде, бишенче катны узгач, идәннән түшәмгә кадәр корылган калын тимер рәшәткә каршында тукталып калды.* М.Маликова. *Алдагылар, агач баскычны шыгыр-шыгыр китереп, өскә менеп киттеләр.* Р.Гыйззәтуллин

5) Тышка, ачыкка. *Кайчагында ул су төбенә дә чума, ә өскә калыккач, чалкан ятып, бернинди кайгысыз көенчә тагын рәхәтләнә, уйный, йөзә иде.* В.Имамов

◊ **Өскә аудару** Гаепне, җаваплылыкны үзеннән башкага сылтау, кайтарып калдыру. *Нургали гаепне Сөләйманов өстенә аударып карады.* Ә.Еники. **Өскә җибәрү** Узындыру, аздыру, артык кылануга юл кую. *– Минем болай калуыма шул Әхмәт сәбәп. – Соң син аны нигә өскә җибәрәсең?* Г.Камал. **Өскә йөзеп чыгу** *к.* **өскә чыгу** *(2 мәгъ.). Олайгач, аның яшерен хәле өскә йөзеп чыкты.* Сөембикә. **Өскә кайнар су койгандай булу** Гажәпләнүдән, куркудан һ.б.ш.дан сискәнеп китү. **Өскә пычрак ыргыту** Яла ягу, нахак сөйләү. *Мин кеше өстенә нахакка пычрак ыргытырга теләмим.* Р.Ишморат. **Өскә салкын су койгандай булу** *к.* **өскә кайнар су койгандай булу**. **Өскә төшү** Алланың һәм, гомумән, рәнҗетелгән кешенең ачуыннан, каһәреннән берәр кешегә авырлык килү. *[Заһидулла хәзрәт:] Аллаһы Тәгаләнең каһәрле ачуы безнең өскә төшә күрмәсен.* К.Нәҗми. **Өскә чыгу** 1) Җиңү. *Беләм, хаклык чыгар өскә.* М.Җәлил. *Батыр ега, батыр өскә чыга, Җиңүчеләр бүләк алалар.* Ә.Ерикәй. *Ләкин гаделлек өскә чыга: 1905 ел революциясе матбугатка юл ача.* М.Әхмәтҗанов. *Халык сүзе өскә чыкты.* Мәдәни җомга; 2) Берәр нәрсә ачыклану, билгеле булу, фаш булу. *Җеназа сәбәбеннән тышкы ягы капланган дошманлыклар һәммәсе бәреп өскә чыкты.* Г.Ибраһимов

ӨСКЕ *с.* 1) Югарыда урнашкан. *Син эзләгән китап, мөгаен, өске рәттәдер.* Мәдәни җомга

2) Эчке кием өстеннән киелә торган. *Алсу, бүлмәсенә керү белән, өске киемен салып ташлады.* һ.Такташ

◊ **Өске ягы** Үзеннән алда килгән саннан югары яшьне, шуннан узган яшьне белдерә. *[Тимери:] Белем ягы да бик сай инде минем, яшем дә алты дистәнең өске ягына менеп бара.* Г.Бәширов

ӨСКОРМА *и.* Җәмгыятьнең билгеле бер икътисади төзелеше – базис тарафыннан барлыкка китерелгән сәяси, хокукый, дини, фәлсәфи карашлары һәм шуларга туры килә торган сәяси, хокукый һәм башка шундый оешмалар. *Марксизмның төп проблемаларыннан бере дә – базисның өскормага мөнәсәбәте проблемасы.* Х.Бәдигый

ӨСКУЙМА *и.* Берәр нәрсә өстенә куеп беркетелгән әйбер

ӨСЛӘП *бәйл.* Өстеннән. *Яр буйлата бару бик кыенайгач, аска төшеп, боз өсләп бармакчы булдылар.* И.Гази

ӨСЛӘТҮ *ф. к.* **өстерү**. *Эткә өсләтергә этең булсын.* Мәкаль

Өсләтеп килү Элек-электән, бик күптәннән бирле өсләтү. *Безне авылыбызда һаман әле тамырлары, калдыклары йолкынып бетмәгән паразитлар бөтен гомер буенча бер-беребезгә каршы өсләтеп килделәр.* К.Нәҗми

Өсләтеп карау Булып чыгучыкмавын тикшерер өчен өсләтү. *Әхмәт: «Актырнак, өс-өс!» – дип өсләтеп тә карый.* М.Гафури

Өсләтеп тору Бертуктаусыз, даими рәвештә өсләтү

ӨСЛӘ́Ү *ф. сөйл. к.* **өсләтү**. *[Кәрим] Син монда эт шикелле өреп торма әле. Гәрәй өсләп җибәрдеме әллә сине монда?* Ш.Камал

ӨСЛЕ́К *и.* 1) Предметның тышкы ягы, нәрсәнең дә булса йөзе. *Җил дә исми, агач-куаклар да селкенми, авыл янәшәсендә җәйрәп яткан елганың өслеге көзгедәй ялтырый.* Р.Фәизов. *Аның өслегендә җайдак сурәте, Новгород князе Всеволодның исеме һәм 1222–1224 еллар дигән язу бар.* Г.Дәүләтшин

2) *мат.* Геометрик җисемне тышкы пространстводан яки башка җисемнән аерып тора торган чик. *Диңгез өслегеннән 4000 м биеклектә яткан Дансар тау яссылыгына килеп чыккач, ул хәйран кала.* М.Галиев. *Җисемнең чиге өслек була.* Геометрия

ӨСЛЕ́-ӨСЛЕ *рәв.* Берсе өстенә икенчесе, катлы-катлы итеп. *--- тәрәзәләрдән сибелгән яктылык стенага терәп куелган биек өстәлне, андагы кәгазь, каләм, буяуларны, диварларга өсле-өсле сөялгән рамнарны, түр почмактагы ятакны --- яктырта иде.* М.Маликова

ӨСЛҮП *и. гар.* Стиль, ысул, рәвеш. *Бу кеше үзе гаскәри булмаса да, аның торыш-килбәтендә, хәрәкәтләрендә, сөйләү өслүбендә гаскәриләргә хас булган бик күп уртак алымнарны күреп була иде.* К.Тинчурин. *Бабич теле, өслүбе белән безнең әдәбият дөньябызда бөтенләй аерым бер урында тора.* Г.Ибраһимов. *Театрның баш режиссёры Ренат Әюпов спектакльне заманча өслүптә сәхнәләштергән, пластик чишелеш тапкан.* Р.Батулла

ӨС-ӨС *ымл. к.* **өсс**. *Шапырай карт бу юлы да сүзсез калмады: – Куштылар, котырттылар, имеш! Өс-өс дигән саен котырырга этме әллә син?* М.Хәсәнов

ӨСС *ымл.* Этне өстергәндә әйтелә

ӨССИ *ымл. к.* **өсс**. *Эткә – өсси, куянга – кач!* Мәкаль

ӨСТӘ *рәв.* **1.** 1) Югарыда, биектә; югары, биек урында. *Өстә, югарыда ирекле җил исеп китте.* Н.Фәттах. *Өстә яшен яшьни, күкләр үкерә, аста җир улап яна.* Ф.Бәйрәмова. *Өй түбәсендә җил ул кадәр сизелмәсә дә, тагын да өстә нык исә бугай.* Казан утлары

2) Югары, өске катта, өске өлештә. *[Габдулла:] Өстә чагында атна саен мин лампаларның филтәләрен кисеп, куыкларын тазарта идем.* Ә.Фәйзи. *Эскерт куйганда да, богыл салганда да, каралты түбәләрен япканда да, ул һәрвакыт өстә эшләргә тырыша.* Г.Әпсәләмов

3) Өске якта. *Иһаять, соңгы дүртбиш метр да артта кала – без өстә!* И.Гази. *Ир барыбер өстә калачак иде.* Н.Гыйматдинова

4) *күч. сөйл.* Югарыда, югарыда торган оешмаларда. *Борын ул өстә булган, дөньяда бик зур урын тоткан.* М.Гафури. *Өстә килешенгән эш. Өстә мин бу мәсьәләне хәл иттем.* Мирас

2. *хәб. сүз.* Җаваплылык йөкләүне белдерә. *Нефть белән керосин өчен җаваплылык синең өстә.* И.Гази. *Шул чәчәкләрне кыраудан саклап, тәрбияләп үстерү бурычы безнең өстә.* Д.Аппакова

ӨСТӘВЕНӘ *рәв.* 1) Өстәмә рәвештә, булган өстенә тагы, теге яки бу нәрсәгә өстәмә итеп. *Колмөхәммәт көнчыгыштан килергә тиеш, өстәвенә, Салават һәм Колмөхәммәт Билал төркеме атакага ташлангач кына чыгарга тиешләр.* А.Таһиров. *Анасы Мөнәвәрә кулында тагын ике бала – Зөбәрҗәт һәм Нажия бар, өстәвенә дүртенчегә дә йөкле.* Ә.Кәримуллин. *Өстәвенә, табиб балалар психологиясен яхшы белергә, аларны үз балаларыдай якын күрергә, яратырга тиеш.* Мирас

2) Шуның өстенә, шуңа өстәп, тагын. *Залда пышылдау, көлү башланса, өстәвенә, берәрсе сызгырып та җибәрсә – күз алдыгызга китерәсезме?* Ә.Еники. *Һәм өстәвенә минем кем икәнемне дә белмисең.* Т.Миңнуллин. *Моның өстәвенә аларның меңләгән шәкерт белем ала торган 250 гә якын мәдрәсәләре бар.* Мирас

◊ **Өстәвенә өч калач** Бер бәла өстенә тагын да зурлары өстәлү турында. *Мә сиңа, җитмәсә, өстәвенә өч калач!* **Өстәвенә өч чүмеч** *к.* **өстәвенә өч калач**

ӨСТӘГЕ *с.* Югарыдагы. *Өстәге төтен юлыннан саран гына булып ай яктысы сибелә, тирмә түрендә берничә шәм яна ---.* В.Имамов. *Болай эшләгәндә, обойның өстәге кырыеннан күләгә төшеп тормый.* Файдалы киңәшләр. *Утызынчы елларда социалистик ярыш тактасы болай эшләнә иде: иң өстәге урында – алдынгы ударник самолётта оча.* Мирас

ӨСТӘЛ *и. рус* 1) Өстенә нәрсә дә булса кую яки өстендә эшләү, ашау-эчү өчен, терәккә яисә аякларга яссы өслек беркетелгән өй җиһазының бер төре. *Доцентның язу өстәленә аягымы, кулымы белән таянды да идәнгә, аксыл келәмгә төшеп басты.* Т.Галиуллин. *Венера чәчәкләрне сулы вазага тыгып өстәлгә куйды.* З.Фәйзи. *Бүлмәнең уртасында диярлек зур өстәл, урындыклар, ә өстәл өстендә папкалар өелеп куелган.* Мирас

2) Теге яки бу эш белән махсус шөгыльләнүче учреждение яки аның бер бүлекчәсе. *Коммуналь хуҗалык бүлеге мөдире Зәйнетдинов Хакимовның милиция бүлегенең паспорт өстәлендә*

эшләүче хатынына тел-теш тидерергә базмады булса кирәк. М.Хәсәнов. *Адресны белешмәләр өстәленнән алып булыр шикелле.* Р.Сәгъди

3) *тех.* Кайбер механизмнарның берәр нәрсә куя яки сала торган яссы бер җайланмасы. *Эре-эре авыр башакларның барабан алдындагы өстәлгә бакыр сыман чыкылдап бәрелүләрен ишетеп, [Нәфисә] тагын җанланып китә.* Г.Бәширов

4) *күч.* Ашарга дип әзерләп куелган ашамлыклар; табын. *Өстәл әзерләшер урында, мин, түземсез, табакка сузылдым.* Ш.Галиев. *Шул уңай белән өстәл әзерләп, берничә интәшне чакырган идем.* В.Нуруллин. *Әти, ишек тоткасына бәйләп, чыбыркы ишә, әни өстәл әзерли.* Ф.Баттал

◊ **Өстәл башы** *иск.* Элек мәдрәсәләрдә: шәкертнең дәрәҗәсенә карап билгеләнгән урын

ӨСТӘЛДӘШ *и.* Кем белән дә булса бер өстәл артында бергә утырган кеше. *Кулларын бутый-бутый, өстәлдәшенә үзенең дуслыгын изһар кыйлучылар да юк.* К.Тинчурин

ӨСТӘЛМӘ *с. к.* **өстәмә** (*1 мәгъ.*). *Сабактан үсеп киткән тамырларны өстәлмә тамырлар дип атыйлар.* Ботаника

ӨСТӘЛҮ *ф.* 1) *төш. юн. к.* **өстәү**. *Без аның кабинетында яңа бер әсәр – Сарьянның үзенең портреты өстәлгәнне күрдек.* Г.Ахунов. *Шуннан соң бераз агач җилеме өстәлгән салкын крахмал клейстеры белән газета кәгазе ябыштыралар.* Файдалы киңәшләр

2) Моңа кадәр булганга иш ителү, кушылу, тагы да арттырылу. *Яшь өстәлү, тәҗрибә арту бәрабәренә фантазия кимергә тиеш кебек булса да, миндә, нишләптер, арта гына барды ул.* Ә.Баян. *Мохиткә тагын бер җан иясе – тагын бер язмыш өстәлә.* Ш.Галиев. *Чуалышлар көчәйгәннән-көчәя бара. Сарай әһелләре арасындагы хыянәткә чит ил коткысы, шымчылык килеп өстәлә.* Р.Фәхретдинов

3) Ачыклык кертелү, яңа мәгълүмат бирелү. *Әмма анда бер яңа мәгълүмат өстәлгән: җәяләр эчендә әдип «Кол Сәйф Сараи» дип бирелгән.* Мирас

Өстәлә бару Моңа кадәр булганга даими өстәлү. *Хәлбуки әлеге серле «Себер язулары» турында мәгълүмат һаман арта, өстәлә бара.* Мирас

Өстәлә башлау Өстәлергә тотыну. *Шуннан соң «Күңел күзе»нә һәр иртәдә яңа рәсем өстәлә башлады.* Г.Сабитов

Өстәлә тору Торган саен тагы да өстәлү. *Ул еллардан бирле шактый озын гомер дисбем тезелде, тормыш сандыгыма гыйлеме дә, михнәте дә өстәлә торды...* Х.Гарданов

Өстәлә төшү Бераз өстәлү. *Шулай азаплана торгач, төзәтү барышында яңа эпизодлар да өстәлә төшеп, 11 нче июльгә әсәр төгәлләнде.* Ш.Алпар

Өстәлеп бару Эзлекле рәвештә өстәлү. *Гафу үтенү гыйбарәсенә үрелеп, Аллаһыга дан җырлау, яхшы теләк, аклануны белдергән җөмләләр өстәлеп бара ---.* Р.Абдуллина

Өстәлеп бетү Өстәлү процессы тәмам тукталу

Өстәлеп килү Баштан ук, электән үк эзлекле өстәлү. *Наласа мәктәбенә, бишенче сыйныфтан башлап, ел саен бер-ике Шәләңгер укучысы өстәлеп килә иде ул чакта.* Г.Әдһәм

Өстәлеп китү Өстәлү процессы дәвам итү. *Шушы исемнәргә элегрәк укыган китаплардан истә калган төрле кызык һәм гыйбрәтле вакыйгалар өстәлеп китә.* Г.Бәширов

Өстәлеп кую Кисәк кенә, көтмәгәндә өстәлү. *Чибәр кассирша кызның балаларча пөхтә почеркы белән тагын бер айлык акча өстәлеп куйгач, кенәгә тагын да матураеп киткәндәй була.* Ф.Яруллин

Өстәлеп тору Булган өстенә даими рәвештә һаман өстәлү. *Көн саен яңа фикер, яңа белем өстәлеп торган студентлар тормышы ошый иде миңа.* М.Юныс. *Бер югалту артыннан икенчесе өстәлеп кенә торды.* М.Хәсәнов. *Өзлексез нур таратып тору өчен, җисемгә читтән энергия өстәлеп торырга тиеш.* Физика

ӨСТӘМӘ *с.* **1.** 1) Моңа кадәр булганга кушылып, өстәлеп арттырыла торган. *Саңгыраулык, битарафлык чире тагын да хәсрәткә батыра, илнең өстәмә мәшәкатьләрен арттыра, кыйммәткәрәк төшерә.* Н.Хәсәнов. *Аның тагын өстәмә золымы, дәвамы була.* Р.Фәизов. *Мондый бичараларга барыр, үтәр, теләгән җирләренә җитәр өчен, тагын бер тапкыр өстәмә маяклар тезеп кую кирәк.* Мирас

2) Берәр нәрсәгә яңадан өстәп оештырылган. *Җавап төсендә Татарстанның премьер-министры Рөстәм Миңнеханов Уфада булып, шул мәсьәлә буенча өстәмә сөйләшүләр алып барды.* М.Әхмәтҗанов. *Өстәмә тукландыру өчен, төрле минераль ашламалардан файдаланалар.* Ботаника

3) Булганнан тыш, булган өстенә башкарылган, кулланылган һ.б., икенчел. *Өстәмә агач ныгытмалар булганмы-юкмы, казылмыйча, анысын әйтүе кыен.* Р.Фәхретдинов. *Икенчесе тема буенча өстәмә чыганаклар белән кызыксына, өченчесе теоретик механикага бөтенләй бәйле булмаган сорау бирә...* Казан утлары. *Хәер, чыганаклардан күренгәнчә, соңга калган өстәмә көчләрдән башка да төркитатар гаскәре сан ягыннан һөҗүм итүчеләрдән ким булмый.* Мирас

4) Өстәлеп әйтелгән яки язылган. *Шул ук хатның азагында кыска өстәмә җөмлә: «Их, Айдар әфәнде! Бу хатны җибәреп өлгермәгәнмен».* А.Хәлим

5) Арттырып түләнә торган, тапшырыла яки таратыла торган нәрсәгә өстәп бирелгән. *Бер төн эчендә бурычыннан котылып, түш кесәсен тагын өстәмә акча белән тутырган Черки Әхми башын күтәреп, кодасына яратып карады.* З.Зәйнуллин. *Кирәк булса, өстәмә акча түләп, теләсәң күпме баллон алырга мөмкин.* Файдалы киңәшләр. *Өстәмә рәвештә алынган җирле бюджет керемнәренең шактый өлеше автомобильләр, мебель, компьютерлар сатып алуга тотылды.* Мирас

6) *бот.* Өстәлеп барлыкка килгән. *Өстәмә үсенте*

7) *икът.* Түләүле хезмәт мөнәсәбәтләреннән тыш барлыкка килгән; *рус часы:* **прибавочный**. *Өстәмә кыйммәт эшченең түләнмәгән хезмәте нәтиҗәсе булып тора.* Политэкономия

2. *и. мәгъ.* 1) Нәрсәгә дә булса өстәлгән нәрсә. *«Казан ханлыгы халыклары»*

китабына килгәндә, ул өч бүлектән, кереш һәм сигез өстәмәдән тора. М.Әхмәтҗанов. *Ярдәмчесеннән алып җыештыручыга кадәр, хезмәткә керткән өлешенә карап, «өстәмә» чыгарып бара.* З.Фәйзи. *Шулай булуына да карамастан, Дума кабул иткән өстәмә --- «кеше үзенең төп иреклеренннән һәм хокукларыннан мәхрүм ителә алмый, чөнки алар аңа тормыштан бирелгән» дип язылган 17 нче маддәсенә каршы килә.* Мирас

2) Өстәп әйтелгән яки язылган сүз яки сүзләр. *Исмәгыйльнең бу өстәмәләре барысы да дөрес булганга, мин аларны бер дә үзгәртмичә язып куйдым.* Г.Гали

3) Нинди дә булса түләүгә өстәп бирелә торган матди нәрсә (акча һ.б.ш.). *[Бикбулат карт Нәфисәгә] Өстәмәгә тигән бодаең белән өйне сипләтербез, бик искергән!* Г.Бәширов

4) Гаскәрләргә ярдәм итү яки кушу өчен җибәрелә торган хәрби часть(лар). *Землянкада бер атна ятканнан соң, 8 нче ротага өстәмә килеп, аларны --- яңадан беренче линия окопларга җибәрделәр.* М.Гали

3. *рәв. мәгъ.* Кемгә яки нәрсәгә дә булса өстәп. *Алачыкны эшләү өчен, Мостафага өстәмә итеп Халикъ белән Ишмайны, яшьләрдән Габделхәйне билгеләделәр.* Ш.Камал. *Генпланы булмагач, булганы төгәл үтәлмәгәч, нәтиҗәдә төзелеш килде-киттеле, стихияле алып барылгач, бер йорт янына, ниндидер аңлашылмаган принциптан чыгып, соңыннан өстәмә төзелгән йортлар текәшеп утырган.* А.Хәлим. *Инде шуларга өстәмә итеп, Чишмә янындагы татар кабер ташларының үзебез кадәрле текстларын укучылар игътибарына тәкъдим итәбез.* М.Әхмәтҗанов

ӨСТӘН *рәв.* **1.** 1) Югарыдан аска таба, югарыдан түбәнгә таба. *Такта читенә ябыша-ябыша менеп җитте дә, манара төбенә атланып утырып, өстән төшкән каеш бауга аркан очын бәйләп куйды.* Х.Сарьян. *Әйтерсең ул бу вакыйгаларга өстән карап тора.* Х.Ширмән. *Машинаны җайлап керткәнче, кышкы ачы җилдә, өстән явып торган кар астында, ярым караңгылыкта биш сәгатьтән артык эшләдек.* Н.Габдуллин

2) Кемнән яки нәрсәдән дә булса югарырак урыннан, күктән. *Ә өстән, җиде кат күкләрдән, әнә шул дәһшәтле тавыш яңгырап тора...* Ф.Бәйрәмова

3) Нәрсәнең дә булса өске өлешеннән; югары ягыннан. *Агач йортның стеналары өстән такта белән капланып, яхшы гына ремонт ясалган.* Ш.Камал. *Стеналар һәм манаралар өстән кыек түбә белән ябылган.* Р.Фәхретдинов

4) Югары органнардан, җитәкче оешмалардан. *Өстән бирелгән күрсәтмәләрне без үтәргә тиешбез.* З.Зәйнуллин. *Керү имтиханнары алучыларга өстән, егетләрне кире бормаска, дигән катгый әмер төшерелгән иде.* Т.Галиуллин. *Шуңа күрә ил, халык мәнфәгате белән яшәү ягыннан караганда, аны өстән аска таба икенче баскычка бастырырга мөмкиндер.* С.Поварисов

5) *күч.* Эшнең, мәсьәләнең асылына төшенмичә, бары гомуми танышу белән генә чикләнеп, җентекләп, нечкәләп тормыйча, аннан-моннан гына. *Ислам дине халык тарафыннан өстән генә үзләштерелгән.* Мирас

2. *бәйл. мәгъ.* 1) Үзенә карата нинди дә булса мөнәсәбәт күрсәтелә торган, эш эшләнә торган предметны яки затны белдерә. *Ул малайлар минем өстән дә судка биреп маташалар бит әле.* М.Әмир. *Бу пычрак эшегез өчен мин сезнең өстән Уфага – әһле мәгарифкә язачакмын.* С.Поварисов

2) Кемгә яки нәрсәгә дә булса өстәп, алардан башка тагын, алардан тыш, кем яки нәрсә була торып. *Син минем өстән йөрисең күрше егете белән!* Н.Исәнбәт

◊ **Өстән йөзү** Эш-хәлнең асылын аңламау; бары бер гомуми танышу белән генә чикләнү. *Фән өлкәсендә өстән генә йөзгәч, алар аргументларга корылган полемикалардан качалар, үзләрен башын комга тыккан тәвә кошы кебек тоталар.* И.Измайлов. **Өстән йөк төшү** *к.* **өстән төшү**. **Өстән карау** 1) Берәр нәрсәгә бик җиңел карау, җитди карамау. *Үзе һавалы булып, мәдрәсәнең хуҗасы үзе иттереп хис итеп, «мохтәсәр ханнар»га өстән карый, анлар белән низагка керешеп китеп, күп вакыт анлардан таяк та ашый.* Г.Исхакый; 2) Мәсьәләнең тирәнлегенә үтеп кермичә, гомуми бер танышу белән чикләнү, эшнең асылына кагылмау. *Өстән караганда, чынлап тикшермәгәндә, матур гына бер моназара хасил булган иде.* М.Гафури. *Бездә әле идеология мәсьәләсенә өстән генә карап, төп игътибарны формага бирүчеләр байтак кына.* М.Җәлил. **Өстән кармый, астан тырмый** Астыртын, хәйләкәр кеше турында. **Өстән тау төшү** *к.* **өстән төшү**. **Өстән төшерү** Кыен хәлдән, авыр вазифадан, җаваплылыктан котылу. **Өстән төшү** Зур эштән, нинди дә булса кыенлыктан котылу. *Шәңгәрәйнең өстеннән авыр шөбһә төште.* Г.Ибраһимов. **Өстән юа** Тыштан мактап, астан усаллык эшли

ӨСТӘ́Н-ӨСТӘН *рәв.* 1) Аннан-моннан, җиңелчә, эштер-өштер генә. *Пристав, бер жандарм, ике пүнәтәй – шулай дүртәүләп керделәр, аннан-моннан, өстән-өстән генә тентеделәр.* Г.Ибраһимов

2) Эшнең асылына кереп тормыйча, нечкәлекләренә тукталып тормыйча, бик гомуми рәвештә генә. *Менә ни өчен укытучылары бу турыда өстән-өстән генә сөйләп үткән икән.* Ф.Бәйрәмова

ӨСТӘ́П-ӨСТӘП *рәв.* 1) Берничә мәртәбә өстәп. *Кунаклар, мондый тәмле аш ашаган юк иде, дип мактый-мактый, өстәп-өстәп ашадылар*

2) Кабат-кабат, өсте-өстенә. *Бәкерле рәисен яклыйсың икән, ә? Әхлаксыз Әюповны өстәп-өстәп хурларга кирәк.* Н.Гыйматдинова. *Тагын өстәп-өстәп уйланды: – Серле-хикмәтле димә инде бу дөньяны.* Г.Гыйльманов

ӨСТӘ́Ү I *ф.* **1.** 1) Моңа кадәр булганга, берәр нәрсәгә яңадан кушу, салу һ.б.ш. *Улларым шуны сорый башлады, әмма мин аларга, магнитофон хакының яртысын үзегез эшләп аласыз, яртысына мин өстим, дидем.* М.Шәймиев. *Бу очракта кабакка шикәр комы, бал яки алма повидлосы өстәмиләр, майда кыздырып башлы суган салалар.* Татар халык ашлары.

Нинди куелыкта кирәк булуына карап, җилемгә кайнар су өстәргә мөмкин. Файдалы киңәшләр

2) Арттыру (көчен, күләмен, тигезлеген, сыйфатын һ.б.ш.). *Йөрәгеңә тагын яра өстәргәме?* Х.Сарьян. *Арыган чакларында, Габдрахман абзый өлгерткән мунча яшьләргә икеләтә егәр өсти.* М.Галиев. *Ул шифалы бальзам кебек сулыш юлларын ача, тәндәге барлык күзәнәкләргә үтеп кереп, бөтен халәтенә җиңеллек кенә түгел, ниндидер дуамаллык, әтәчлек тә өсти иде.* М.Әмирхан

3) Моңа кадәр әйтелгәнгә яки язылганга кушып, өстәмә рәвештә бирәр сүз, фикер әйтү яки язу. *Олаучым Мөстәкыйм бабай да шулай ук көрсенеп: – Замана! – дип өстәде.* М.Әмир. *Исенә төшереп яткач өстәде: – Сакалы, мыегы бакыр төсле, үзе, азрак урысчалап әйтсәң, сутулый иде.* З.Зәйнуллин. *Кызлар яңа мәзәкләр сөйли, аларга без дә өстибез.* М.Вәли

4) Арттырып тулыландыру. *Ә инде Г.Исхакый иҗаты турындагы үзенчәлекле чыганакларны да өстәсәң, алар ике мең өч йөз данәгә җитә.* Казан утлары. *Бу ике ел арасындагы аерма тулы бер ай тәшкил иткән очракта, ай елына унөченче айны өстәгәннәр.* Мирас

2. өстәп *рәв. мәгъ.* Арттырып, күпертеп. *Председатель – җор телле егет, өстәп сөйләргә дә ярата.* Т.Миңнуллин

Өстәп бетерү Кирәк булса да, булмаса да, яраса да, ярамаса да әллә ниләр өстәү. *Ахрысы, шуңадыр, бу вакыйга кешеләргә ниндидер бер җен әкияте сыман булып тоела, башта аңа ышанырга да, ышанмаска да белмиләр, аннары, гадәттәгечә, үзләреннән әллә ниләр өстәп бетерәләр.* Ә.Еники

Өстәп җибәрү Тагы да бераз өстәү

Өстәп кую Бераз гына, бер мәртәбә өстәү. *Куллары белән туны астыннан күкрәген сыйпаштырып, тоткалап утырды да акрын гына өстәп куйды: – Юк инде хәзер атаклы ат карагы кушбаш Рәвил...* З.Зәйнуллин. *Ахырда болай дип өстәп куйды: – Ничә төрле йөрәкләр бар – таштан да каты, ничә төрле йөрәкләр бар – ефәктән дә йомшак!* Ф.Яхин

Өстәп тору Гел, даими рәвештә өстәү. *Әйтерсең кемдер: «Соңгы тапкыр, соңгы тапкыр!» – дип, югарыдан дәрт өстәп торды.* Сөембикә

Өстәп чыгу Һәммәсенә дә рәттән өстәү

Өсти бару Процессны туктатмыйча, бер-бер артлы өстәү

Өсти тору Әледән-әле өстәү. *Аның вакыт-вакыт Галимәгә карап куюлары, кызның да аны тоюлары, оялгандай сүзсез калулары шушы рәхәтлеккә тагын да яңа көч һәм дәрт өсти торды.* Ф.Яхин

Өсти төшү Беркадәр өстәү, тагын да өстәү

ӨСТӘ́Ү II *и.* Сату-алмашу вакытында бирәр нәрсәгә кушып бирелгән нәрсә, өстәмә. *Өстәү биреп алмашу*

ӨСТӘҮЛЕ *с.* Ишәеп, өстәлеп торган (әйбер, кием һ.б.ш тур.). *Өстәүле кием булсын.* Теләк. *Өстәүле мал булсын.* Теләк

ӨСТЕН *с.* **1.** 1) Хакимлек итә торган, хакимият башында торган, башкаларны хөкем итәргә хокукы булган. *Дөнья тарихына мөрәҗәгать итсәк тә, шуны күрербез: өстен катлам кешеләренең теле, мәдәнияте төп халыкныкыннан нык аерылып торган.* И.Измайлов. *Шуннан соң, ниндидер бездән өстен көчләр бар, дигән нәтиҗәгә килә.* М.Әхмәтҗанов. *Израильдә теләсә кайсы милләт балаларына, гәрчә яһүдләр өстен милләт саналса да, мөнәсәбәт бертөрле.* Сөембикә

2) Җәмәгатьчелектә сүзе-фикере үтемле, авторитетлы, абруйлы. *Ул иде өстен вә кул җитмәс кеше, йолдыз кеби.* Г.Тукай. *Мәдрәсә хуҗасы Вәли мулла, тамагын кыра-кыра, үзен Мөхәммәд пәйгамбәрдән дә өстен бер олы зат – шәхес санап, аның өчен махсус тәгаенләнеп куелган йомшак мендәргә менеп утыра.* С.Поварисов

2. *рәв. мәгъ.* Кайсы ягы белән дә булса берәр кешедән яки нәрсәдән яхшыраграк итеп, югарырак итеп. *Ә иң мөһиме, үзләрен өстенрәк күрсәтергә мөмкинлек алачаклар.* Ә.Баян. *Мәскәүдә эт теле калынлыгы булса да китап чыгарган кемсә Казанда менә дигән китапларның авторыннан үзен өстенрәк саный иде.* Т.Миңнуллин. *Гөлсем ханым гомер буе ир-егетләр белән, аларның да талантлылары белән дус булуны өстен санады.* Казан утлары

3. *хәб. функ.* Кайсыдыр ягы белән югары булу, аерылып тору. *Әмма тормыш кануннары һәммәсеннән дә өстен.* М.Әхмәтҗанов

◊ **Өстен булу** 1) Нинди дә булса үзенчәлек, сыйфат белән башкалардан аерылып тору, яхшырак булу, югары сыйфатка ия булу. *Бу илдә, гомумән, законнан өстен булу мөмкин түгел.* М.Әхмәтҗанов. *Гадәттә, бу өлкәдә мондый дәрәҗәгә ирешү өчен хатын-кызга ирләрдән ничә башка өстен булу кирәк?!* Сөембикә; 2) Катнашмау, игътибар итмәү, исәпкә алмау. *Гайбәтләрдән дә өстен булырга омтылам, гайбәтне үзем дә сөйләмим, сөйләгән кешене дә хөрмәт итмим.* Р.Мотыйгуллина. **Өстен калу** *к.* **өстен чыгу**. *Ул --- Сабантуйларда һәрвакыт көрәшә һәм һәрвакыт өстен кала торган булган.* Ак юл. **Өстен кую** Башкалардан аерып, өстен итеп, югарырак дәрәҗәдә итеп күрергә тырышу. *Чыңгыз хан кимектиннәрне барысыннан да өстен куя.* М.Хәбибуллин. *Чибәрлеге, сабыйларча елмаюы, үзен бер дә юкка өстен куярга тырышмавы да бизи иде аның кешелеклелек сыйфатын.* С.Поварисов. **Өстен күрү** Башкалардан югарырак бәяләү. *Табигый инде, сул якны өстен күрү соңыннан хуннардан аларның варислары-дәвамчылары булган төркиләргә дә күчкән.* М.Бакиров. **Өстен тору** *к.* **өстен булу**. *В.И.Ленинның «Дөньяда идеологиядән дә көчле нәрсә юк, ул армияләрдән дә, сәясәттән дә өстен тора» дигән мәшһүр сүзләре бар.* М.Әхмәтҗанов. *Дөньяда барыннан да өстен торган сөешү кебек мәңгелек, сихри бер бөек көч бар икән.* С.Поварисов. *Хәзерге заман яшелчәләре, үзләренең файдалы сыйфатлары буенча, үзләренең кыргый элгәрләре булган яшелчәләрдән бик күп өстен торалар.* Яшелчәчелек. **Өстен тоту** Үзен эре тоту, горур, һавалы тоту. *[Җәлә] һәммә мөгамәләсендә үзен булган мәртәбәсеннән өстен тота.* Г.Ибраһимов. *Бер дә үзләрен өстен*

тотмыйча, тиң күреп сөйләшәләр, тәмәкеләре белән сыйлыйлар. Ә.Еники. **Өстен чыгару** Нәрсәнең дә булса җиңүен тәэмин итү. *Гаяз үзенең хата фикерен минем дөрес фикеремнән өстен чыгара алды.* М.Әмир. **Өстен чыгу** Җиңү; уңышка ирешү. *Ярышта кем өстен чыккан – шул кеше.* Г.Бәширов. *Әлегә бу көрәштә Олуг Мөхәммәдне үз улыдай якын иткән һәм аңа бик күп изгелекләр кылган Витовтның туганы Зигмундтан кенәз Свидригайло өстен чыкты.* Р.Вәли. *Сугышта бер як та өстен чыкмый.* Мирас

ӨСТЕНӘ *бәйл.* 1) Эш-хәрәкәтнең аталган предметның өслегенә, өске ягына юнәлгәнлеген белдерү өчен кулланыла. *Кавалеристлар атлары өстенә сикереп менделәр.* А.Шамов. *--- кайсы ящиклар, капчыклар өстенә утырып бара торган кешеләрнең сөйләшкәннәре дә боларга ишетелеп калды.* М.Гали. *Балалар үзара сөйләшкәләп, башта кыймыйча, соңыннан батырланып, кайсы койма өстенә, кайсы капканың аръягында үсеп торган агач ботакларына менеп утыралар.* Д.Аппакова

2) Нинди дә булса эш-хәрәкәтнең юнәлү ноктасын, объектын, максатын тәгъбир итә торган предметны яки затны белдерү өчен кулланыла. *Аның бу кычкыруы, кеше кычкыруыннан бигрәк, тешләргә, өскә ташланырга килгән этнең ырылдавын хәтерләтә иде.* А.Шамов. *Мөхәммәд безгә каршы үзе белән киткән корәеш гаскәрен һәм Ясриб шәһәренең сугышчыларын алып килгән, алар ярдәмендә сугышырга ниятли, бергә-бергә безнең өскә кылыч күтәрергә уйлаганнар.* Ф.Яхин

3) Кемгә яки нәрсәгә дә булса өстәп, шулардан башка тагын, шулардан тыш. *Шаулыйлар ич, бу тавышка бала ничек йокласын, шуның өстенә көн эссе.* Т.Гыйззәт. *Аз-маз гына акыл кергән, шуның өстенә тагын сабан туе вакыты.* Ф.Хөсни. *Тыйнак, итагатьле, ягымлы булуы өстенә ул аның Маратына яшьтәш тә иде бит әле.* Г.Гобәй

4) Үзенә нәрсә дә булса өстәлә, кушыла торган предметны, күренешне, эш-хәлне белдерү өчен кулланыла. *Алма өстенә шикәр һәм дарчин салу*

5) Нинди дә булса эш, вазифа, җаваплылык, авырлык, кайгы һ.б.ш. йөкләтелгән яисә шуларны үзенә ала торган затны яисә коллективны белдерә. *Менә монысын мин, ягъни Сәетҗан бабаегыз, үз өстенә ала.* Р.Фәизов. *Өстеңә алган эшеңне, аның нинди булуына карамастан, сыйфатлы башкарырга тиешсең.* М.Юныс. *Әниләре үлгәч, Мөгафурны карау да Гаффар өстенә төште.* А.Таһиров

◊ **Өстенә барып (килеп) чыгу** Берәүне җинаять я бер ярамаган эш белән шөгыльләнгәндә тоту. *Бандитларның һәр минут өскә килеп чыгу куркынычы тугач, кинәт [начхоз] никтер солдатларның сугыша алу сәләтлелекләре турында шикләнә башлады.* А.Шамов. **Өстенә басу** Дөресен әйтү, вакытында әйтү. *Вәт картлач, өстенә үк каплый. Дөрес әйтә. Өстенә үк басты.* Г.Толымбай. **Өстенә чыгу** Кемнең дә булса җаваплылыгында булган акча яки башка мөлкәт җитмәү; *русчасы:* **растрата**. **Өстенә сөйләү** Кешегә яла ягу, кешенең гайбәтен сату. *Син анда барып минем өстемә сөйләгәнсең.* **Өстенә үлән үскән** Беткән, үткән, күптәннән онытылган эш турында. *Булган – беткән, өстенә үлән үскән, ташлагыз.* З.Шаһиморатов. **Өстенә үлчәнгән** Бик тә килешле, таман (кием-салым тур.)

ӨСТЕНГЕ *с. иск.* 1) Җиңүче, җиңеп чыккан

2) Югары торган, югары булган. *[Феодализм җәмгыятендә] җир милекчеләренең иң өстенгеләре корольләр булган.* Политэкономия

ӨСТЕНДӘ *бәйл.* 1) Берәр предметның башка предмет турысында югарыда урнашуын белдерә. *Ераклаша барган көймәләр өстендә әледән-әле аларның тавышлары яңгырап торды.* К.Нәҗми. *Тулган ай үзенең моңсу нурларын урманнар, кырлар өстендә чәчеп әкрен генә йөзә иде.* Г.Әпсәләмов

2) Эш-хәрәкәт предметның өслегендә, өске ягында башкарылуын белдерү өчен кулланыла. *Кыз бер үк вакытта биология факультетында да, балет мәктәбендә дә укый, ат өстендә йөрергә өйрәнә, парашют белән дә сикерә.* И.Гази. *Җыр тавышы, ямьле Идел буйлары белән саубуллашкандай, тау өстендәге урманнарга, яр буйларына кагыла-кагыла, яшел болыннар, Идел дулкыннары өстендә чайкала-чайкала шаулап бара.* Г.Бәширов. *Тузанлы таш юл өстендә туктап, сүзсез генә юлның көнбатыш очына карап тордылар.* Ә.Еники

3) Нинди дә булса вазифа, җаваплылык һ.б.ш.ның берәр затка яки коллективка йөкләнгән булуын белдерә. *Мәктәптән кайткач, ашарга пешерү, өй эшләрен карау --- Женя өстендә икән.* Г.Гобәй

4) Эш-хәрәкәтнең билгеле вакытта, шартларда баруын белдерү өчен кулланыла. *Җәмиләнең таза беләге эш өстендә чыныгып дан ала.* М.Җәлил

5) Нинди дә булса эшчәнлекнең билгеле максатка юнәлгән, төбәлгән булуын белдерү өчен кулланыла. *Киләчәктә НАСА озаграк очып йөри торган космик кораб булдыру өстендә эшләүне планлаштыра.* Мәдәни җомга

◊ **Өстендә тору** Кемнең дә булса эш-хәрәкәтен күзәтеп, тикшереп тору. *Дамир син сөйләгәннәрне бик тиз төшенә, ләкин күзләре гел урамда, өстендә тормасаң, дәресләрен бар дип тә белми.* Г.Әпсәләмов. **Өстендә тоту** Җинаять, ярамаган бер яман эш эшләгән урында тоту, эләктерү, фаш итү. *[Байтирәк:] Менә шулай эшләгәндә, каракны өстендә тоткан булсаң.* Т.Гыйззәт

ӨСТЕНДӘГЕ *бәйл.* Берәүгә йөкләтелгән, тапшырылган, шуның җаваплылыгындагы. *[Мәрхәбә:] – Мин анда аш-су эчендә кайнаштым, – диде дә хуҗа хатын өстендәге мәшәкатьләрнең яртысын үз җилкәсенә күтәрде.* Г.Ибраһимов

ӨСТЕНЛЕК *и.* 1) Кемне яки нәрсәне дә булса уңай яктан аерып тора торган сыйфат, үзлек. *Уфаның үз өстенлеге: агачлар күп.* Ә.Баян. *Башка төрле җылыткыч приборларга караганда майлы электр радиаторларының күп кенә өстенлекләре бар: алар яссы, радиатор куркынычсыз, ул көйдерми, чөнки аның җылыту өслегенең температурасы югары булмый.* Файдалы

киңәшләр. *Ахырда Марсель Сәлимжанов, Гаяз Исхакыйның «Җәмгыять» пьесасы камилрәк язылган дип, өстенлекне «Җәмгыять»кә бирде.* Мирас

2) Башкалардан югары булу, өстен булу. *Көннәрдән бер көнне ул яуланган калалардагы барлык дин әһелләрен тирмәсенә җыя һәм һәммәсенә дә үз диненең өстенлеген расларга куша.* М.Хәбибуллин. *Фәкать XX йөзнең икенче яртысында гына Шәрык һәм ислам белгече америкалы Александр Беннигсенның исламны яңартуда татар фикер ияләренең өстенлеге төрле яктан фәнни нигезләнгән хезмәтләре пәйдә булды.* М.Хәсәнов. *Безнең Ишмәмәт моның ише тиргәүләргә ниндидер бер өстенлек белән сабыр гына елмаеп карый...* Ә.Еники

3) Берәр күренешнең яки предметның башка күренеш яки предмет белән чагыштырганда артык булуы, сан ягыннан артыклык, өстен булу. *Ләкин сан ягыннан өстенлек дошман ягында була, һәм ул камалыштагыларны әкренләп кысыклый, чигендерә башлый.* Р.Фәхретдинов. *Алар бит һәр эшне күмәкләшеп башкара. Көчләре дә, өстенлекләре дә шул бит аларның.* Сөембикә. *Хәзер, тактик һәм мораль факторлардан тыш, моңа сан ягыннан өстенлек тә кушылды.* Мирас

4) Предметка яки затка бирелә торган аерым хокук, ташламалы хокук; башкалардан аларны югары куя торган хокук. *Россия белән мөнәсәбәттә Декларация кабул итмәгән республика һәм регионнар белән чагыштырганда, безнең нинди өстенлекләребез бар?* М.Галиев. *Беләсезме, суверенитет игълан итү факт буларак эмоциягә күбрәк карый, гамәли тормышта әллә ни өстенлекләр бирми.* Ф.Мөхәммәтшин. *Дворяннар үзләренең чыгышы, өстенлекләре, мәнфәгатьләре белән халыктан читләшкәннәр.* Мирас

5) Хакимлек, хакимлек итү. *Социализм системасы хосусый милек өстенлеген җимерде.* М.Җәлил. *Өстенлек иткән сәясәтнең илдәге халыкларга төрлечә карашы, җитмеш еллык тырышлыгы, культурага, аеруча татар культурасына мөнәсәбәте – бөтен нәрсәне асылда әнә шул хәл итте.* Ә.Баян

◊ **Өстенлек алу** 1) Җиңү, җиңеп чыгу. *Нәтиҗәдә, рухи-әхлакый югарылык өстенлек ала.* Ф.Хатипов. *Әмма «читтә солтан булганчы, үз илеңдә олтан бул» дигән мәгълүм фикер өстенлек ала.* Мирас; 2) Хөкем сөрү, күбәю, басып китү. *Кайнар, тәмле, авызда эреп торган сумса ашап, берике чынаяк чәй эчкәннән соң, сүз тезмәләре өстенлек алды.* С.Поварисов. *Җәмгыятебездә тагын бер тискәре күренеш өстенлек ала.* Мәдәни җомга. **Өстенлек казану** *к.* **өстенлек алу** (*1 мәгъ.*)

ӨСТЕНЛЕ́К ИТҮ *ф.* 1) Хакимлек итү; идарә итү; җитәкчелек итү. *Бу инде кешелекнең киләчәктәге үсеш юлында хатын-кыз заты өстенлек итү ихтималының беренче яралгылары булмады микән?* Р.Фәизов. *Аның бу сүзләрендә өстенлек итү дә, ачыктаначык каһкаһә да сизелә иде.* Ш.Бикчурин. *Безнең авиация күктә өстенлек итте.* Мирас

2) Төп урынны алып тору, өстен тору; сан ягыннан күбрәк булу. *Биредә татар теле өстенлек итә.* Мирас. *Казан татарларында утыртма якалы күлмәкләр өстенлек итә.* Сөембикә

ӨСТЕНЛЕКЛЕ *с.* Башкаларга караганда өстенлекләре булган. *Бик әйбәт, өстенлекле, җитеш тормышта гомер кичерде.* Х.Камалов. *Шушы көннәрдә генә Мәскәүдә РФ сәламәтлек саклау һәм социаль үсеш министры Татьяна Голикова катнашында киңәшмә булып, анда РФ пенсия системасын үстерүдәге өстенлекле юнәлешләр билгеләнде.* Мәдәни җомга

ӨСТЕННӘН *бәйл.* 1) Эш-хәрәкәтнең билгеле предмет, зат, урыннан югарыда, шуның турысында өстә башкарылуын белдерү өчен кулланыла. *Сабанчы өстеннән сайрап-сайрап һавага күтәрелә торган тургайлар үзләренең гыйшык моңнары белән яңа шатлыкларга чакыралар.* Г.Ибраһимов. *Менә Илсөяр, камышлык өстеннән урман читенә караган хәлдә, кычкырып җибәрде.* Г.Гобәй. *Ялгыз нарат өстеннән Очтылар самолётлар.* Ә.Исхак

2) Эш-хәрәкәтнең берәр предмет, урын өслеге буенча башкарылуын белдерү өчен кулланыла; аркылы, аша. *Без сезнең дүшәмбе көн кич Идел өстеннән ничек куркыныч хәлдә чыкканыгызны да шул сәгатьтә белдек.* Г.Ибраһимов. *Су өстеннән искән җылымса җил сыйпап үтте минем битемне.* Ә.Исхак. *Бер авыр танк, безнең алгы оборонабызны өзеп булса кирәк, кәбестә, кабак, кавын бакчалары өстеннән урамга чыгып килә.* И.Гази

3) Берәр нәрсәнең башка бер предметның өске, тышкы ягыннан ябылуын, киелүен, бәйләнүен белдерү өчен кулланыла. *--- сатин күлмәк өстеннән пиджак элеп чыгып киттем.* Ф.Хөсни. *Хәзер ул, кар шикелле ак тула оек өстеннән өр-яңа җыйнак чабата кигән килеш, тимер бүкән янында бик тырышып эшли.* К.Нәҗми. *Эчтән юка гына яшел яулык бәйләгән – анысы чәче тузгымасынга, аның өстеннән, Нәфисәләр кебек үк, ак яулык япкан – анысы башка кызу капмасынга.* Г.Бәширов

4) Эш-хәрәкәтнең предметның өслегеннән кире якка, тышкы якка таба юнәлгән булуын белдерү өчен кулланыла. *Сәгъди бабай намазлык өстеннән торганда, ярты төннәр чамасы иде инде.* Ш.Камал. *Казак, ат өстеннән сикереп төшеп, абына-сөртенә, ишек алдына ташланды: аның күзләре акайган, камчысы һавага чөелгән иде.* И.Гази. *Ләкин Мораталй коймадан чыкканда, морзаның сакчылары аны ат өстеннән атып екканнар.* Г.Бәширов

5) Эш-хәрәкәтнең берәр предмет аша юнәлгән булуын белдерү өчен кулланыла. *Федотычевның командасы бер көн эчендә шпаллардан багаиалар тезеп, өстеннән рельслар суздыл.* Ш.Усманов. *Кемдер аның өстеннән атлап чыгып китте.* Г.Гобәй. *Ә күзләре Габдулланың баш өстеннән каядыр еракка текәлгәннәр.* Ә.Фәйзи

6) Нинди дә булса эшчәнлекнең берәр нәрсәгә, затка юнәлтелгән, төбәлгән булуын белдерү өчен кулланыла. *Халыкларның көрәшеп килгән эше: һич кичекмәстән демократик солых тәкъдим итү, җиргә алпавытчылык милкен бетерү, [җитештерү]*

өстеннән контроль кую, советлар хөкүмәтен төзү эше тәэмин ителде. Т.Гыйззәт

7) Зарлану, әләкләү һ.б.ш.ның объекты буларак берәр затны яки предметны белдерү өчен кулланыла. *Каюмны күрү белән, балалар өстеннән зарланырга, аларны тагын да шелтәләргә керешә.* Ш.Камал. *Ничек итеп хатын башың белән ир өстеннән барып әйтергә кирәк?!* А.Шамов

8) Берәр предмет яки затның башка бер затның карамагында, аның хакимлеге астында булуын һ.б.ш. белдерү өчен кулланыла. *Без үзара бик артык якынаеп киткәч, авыл малайлары өстеннән бөтенләй башлык кебек булдык.* Г.Ибраһимов. *Ирнең бит аның ябага тай кебек хәчтерүше дә хатыны өстеннән командовать итәргә ярата.* Р.Ишморат. *Милләтләр үзара ызгышкан саен, алар өстеннән хөкем йөртү җиңелрәк бит.* Ә.Фәйзи

9) *сөйл.* Кемгә яки нәрсәгә дә булса өстәп, алардан башка тагын, алардан тыш; булуга карамастан, була торып. *Бар өстеннән кеше шулай торыр микән?* Ш.Камал. *– Ике атың бар өстеннән, нәрсә шул хәерче кебек лыртлырт бер белән йөрисең?.. – ди.* Г.Ибраһимов. *Хәзер менә ирең бар өстеннән тол дүдәк булып утыр инде.* Р.Ишморат

◊ **Өстеннән ашау** Кем яки нәрсәнең дә булса исәбенә ашау, кемнекен дә булса ашау. **Өстеннән кош та очыртмау** Бик ник кадерләү, иркәләү, саклау. *Өстеннән кош та очыртмыйча өфөф итеп кенә яшәтер иде.* Г.Мөхәммәтшин. **Өстеннән таракан таеп төшәрлек** «Бик шома» дигән мәгънәдә

ӨСТЕ́-ӨСТЕНӘ *рәв.* 1) Берсен икенчесе өстенә салып, берсе өстенә икенчесен куеп. *Бу --- өсте-өстенә күп кенә шартлы билгеләр ясау аркасында танырлыгы калмаган, кайбер җирләре тишелеп чыккан карта иде.* Г.Гобәй

2) *күч.* Бер-бер артлы өстәлеп, туктаусыз, берсенә икенчесе өстәлеп; булган өстенә тагын да өстәп. *Өсте-өстенә чыгып торган сүзләргә, күңелле көлүләргә мавыгып, тагын [чәйне] эчкәнебезне сизми дә калдык.* М.Әмир. *Акчаны өсте-өстенә биреп кенә торалар, өс-баш та бик шәп боларның.* Г.Бәширов. *Ярабби ходаем, үзең китер уңаен, ат бир, дөя бир, өсте-өстенә өя бир!* Әйтем

ӨСТЕРӘЛҮ *ф.* 1) Нәрсәнең дә булса өслегеннән аерылмыйча хәрәкәт итү, сөйрәлеп бару. *Әнә бит ул [эт] Булатның балагыннан ничек эләктергән: өстерәлеп барса бара, әмма җибәрми.* Ф.Яруллин. *[Зәйтүнә:] Юк, юк, кәҗә түгел, Габдуллалар бозавы иде бугай... арканыннан ычкынган, муенчагы өстерәлеп бара иде.* Н.Кәримова

2) Бик акрын, кыенлык белән, көч-хәлгә бару (килү). *Бичара бәти, үлемнән котылгач, көчкә-көчкә генә өстерәлеп, сарыклар абзарына барып керә алды.* Г.Тукай. *Тракторы күренә, ә комбайны урынына тузан болыты өстерәлеп килә шикелле.* Ә.Гаффар. *Хәзер ул куасы килсә куа машинаны, өстерәлеп барасы килсә өстерәлә, туктап каласы килсә туктый.* Ж.Юныс

3) *сөйл.* Иярең, тагылып йөрү. *Татар буржуасы сыйнфый файдасы өчен чех, Колчак артыннан өстерәлгән кебек, татар-башкорт ярлылары да үзләренең икътисади азатлыкларын саклауда рус һәм башка пролетариатның ярдәменә таяна, алар белән кулга-кул бара.* Г.Ибраһимов

4) *сөйл.* Теләр-теләмәс, киреләнеп, авырсынып бару (килү). *Шундый хурланды Рамазан, шундый хурланды, күз яшьләрен йотып, һич карышмыйча, милиционер артыннан өстерәлеп китте.* Л.Гыймадиева

5) *сөйл.* Бер урыннан икенче урынга күчеп, бушка, нәтиҗәсез йөрү. *Ороба хәзер сараенда ял итеп, шәраб чөмереп ятадыр, Тигранга җәһәннәм читендә өстерәлеп йөрергә язган.* Мирас

6) *күч. сөйл.* Ярышта, укуда, өлгерештә һ.б.ш.да башкалардан артка калып бару, иң арткы рәткә калу, күрсәткечләре начар булу. *Бу командалар барлык ярышларда да соңгы урыннарда өстерәлә.* Ватаным Татарстан

7) *күч. гади с.* Азгынлык, бозыклык, уйнашлык итү, бозык тормыш рәвеше алып бару; кем артыннан булса да йөрү. *Соң сез нигә кайттыгыз: эчәргә кайттыгызмы, мөгаллимәбез артыннан өстерәлергә кайттыгызмы?!* М.Әмир. *Инде олыгаю ягына авышуга карамастан, әле һаман берничә хатын-кыз белән өстерәлүен дәвам итә.* З.Фәйзи

◊ **Өстерәлеп бару** Башкалардан күпкә калышу. *Халык артыннан өстерәлеп бармаска, азрак алданрак барырга кирәк.* М.Макаров. *Алар башка илләр тәрәккыят юлында алга киткән чагында, татар халкының артта өстерәлеп баруына сызланып борчылалар.* К.Гыйззәтов. **Өстерәлеп йөрү** 1) Кем артыннан да булса иярү. *Сине үстергән чагында шулай булырсың да һаман хатының артыннан өстерәлеп йөрерсең дип үстердеммени?* Г.Камал; 2) Кирәксезгә, бушка йөрү, эшсез йөрү. *Йөриләр шунда өстерәлеп, эш юкка.* Г.Исхакый. *Ичмасам, син йөрмә шунда өстерәлеп. Сихереңдер әле бу да. Йөрмә, дим, монда, йөрмә, дим!* К.Тинчурин. **Өстерәлеп килү** 1) Чакырылмаган җиргә килү яки килгән җиргә тиешле рәвештә килмәү. *Буш кул белән өстерәлеп килүчеләр дә җитәрлек.* Р.Вәлиев. *Мин сине чакырмадым, үзең өстерәлеп килгәнсең бит.* Х.Ибраһимов; 2) Күптәннән бирле дәвам итү; 3) Иярү. *Синең артыңнан өстерәлеп килүче койрыгың юк.* Р.Мулланурова

Өстерәлә башлау Өстерәлүгә күчү. *Хәлим атка ярдәм итү түгел, йөк булып арттан өстерәлә башлады.* Г.Исхакый

Өстерәлә килү Күптәннән бирле өстерәлү

Өстерәлеп бару Кыенлык белән генә өстерәлү

Өстерәлеп йөрү Гел өстерәлү. *Курск дугасында имгәнеп-яраланып калган сул аягы таккан аяк кебек өстерәлеп йөри аның.* Ә.Сафиуллин. *Яшь солдат берничә көн көч-хәлгә өстерәлеп йөргән.* Татарстан яшьләре

Өстерәлеп килү Көчкә-көчкә өстерәлү. *Әнә тагын берәү өстерәлеп килә ---.* Х.Ибраһимов

ӨСТЕРӘЛЧЕК *и. гади с.* **1.** Ирләр яки хатын-кыз артыннан йөрергә яраткан кеше, уйнашчы, сөйрәлчек. *[Шәймәрдән:] Синең күк уйнашчылар безгә кирәк түгел. Синең кебек өстерәлчекләрне без...* К.Нәҗми. *Син,*

сазаган кыз, өстерәлчек, мине кем дип белдең әле шулай мыскыл итәргә? Л.Әбүдәрова

2. *с. мәгъ.* Бозык тормыш алып бара торган. *Теге өстерәлчек немка, минем хатыным, сөяркәләренең ярдәме белән патшалыгымны тартып алгач, үземне ябып куйдылар.* М.Галәү

ӨСТЕРӘҮ *ф.* 1) Нәрсәнең дә булса өслегеннән аерылмыйча, берәр предметка тагып яки кул белән тартып бару, сөйрәү. *Мотордан чыккан электр көче корыч арканга бәйләнгән «баба»ны чыгыр буенча югары өстери.* А.Алиш. *Томилин көчкә исен туплады һәм полицайның гәүдәсен якасыннан өстерәп, кузладан аякларын ычкындырды да арба төбенә сузып салды.* Х.Камалов. *Чаптар бия биш ел чамасы ике эрзинкә көпчәкле җиңел арба өстерәп, ипподром юлларында беренчелекне алып, зурдан тоткан асыл хайван булган икән шул.* З.Зәйнуллин

2) Көч куеп үзе артыннан кая да булса тартып алып бару. *Ярулла аны кулыннан өстерәп парта арасыннан чыгарды.* Ә.Галиев. *Биш-алты «карт» солдат Рәмисне урыныннан йолкып алды, өстерәп, типкәләп, аны казарма читенә алып киттеләр.* Р.Гыйззәтуллин. *Дамир белән Касыйм ага Җирән сакалны түрдәге тәрәзәсез бүлмәгә өстерәп керттеләр дә ишекне биклән үк куйдылар.* Казан утлары

3) Атлаганда, аякны шудыру, сөйрәп алу. *Краснов, бер аягын өстерәп атлый-атлый, чыбыкларга тотынып торды.* Х.Камалов. *Аннан соң аякларын көчкә өстерәп, урам буйлап китте.* М.Әмирханов. *Йөргәндә, аякларыгызны өстерәмәгез, кешедән көлеп калмагыз, берәр кешене мәсхәрәләп, аның кебек йөреп күрсәтмәгез.* Ватаным Татарстан

4) *сөйл.* Кемне яки нәрсәне кая да булса илтү, күтәреп алып бару. *Төлке кая юл тотса да, койрыгын арттан өстери.* Мәкаль. *Малай тартылып чәбәләнде, җиргә ятып карады, ләкин тотучы – нык, каршыдан килә торган милиционерга табан өстерәде.* А.Шамов. *Аны сарайга өстерәп алып керделәр.* Р.Сибат

5) *сөйл.* Өндәп, үгетләп үз артыннан ияртеп алып бару, кемне дә булса берәр урынга барырга мәҗбүр итү. *Шуңа күрә теңкәсе корган карчыклар [кечкенә балаларны] үзләре белән бергә монастырьга өстериләр.* К.Нәҗми. *Өстериләр аны сыйлы түргә ---.* Р.Әхмәтҗән. *Үзе кая тели, ирен дә шунда өстери.* Ватаным Татарстан

6) *сөйл.* Иске яки зур аяк киемнәре киеп йөрү; кадерсезләп кию. *Аягымда да һәр авыл кызы өстерәгән танкеткалар түгел, ә үкчәле түфли иде!* Г.Әдһәм

7) *күч.* Өндәп, үгетләп һ.б.ш. юллар белән бер-бер хәлгә тарту, дучар итү, этәрү. *Монда, Ризаэтдин әфәнденең башка әсәрләрендәге шикелле, бик күп җирләрдә Шәрыкның әүвәлге халәтенә өстерәргә тырышу күренә.* Ф.Әмирхан

8) *күч.* Нинди дә булса авыр вазифаны үтәү, кыен эшне башкару. *Бер ай була инде менә Самарадан чыкканыбызга, һәр көн бер караңгыдан икенче караңгыга кадәр өстерибез инде шул балластны.* М.Гали. *Алар үлде, туганнар таралышты, тормышны өстерәү аның берүзенә калды.* Ватаным Татарстан. *Уку белән эшне бергә өстерәү авыр инде ул.* Татарстан яшьләре

Өстерәп йөрү Гел, һәрвакыт өстерәү

Өстерәп килү Дәвамлы рәвештә, озак вакыт өстерәү

Өстери башлау Өстерәргә керешү. *Ул ашыгып килде дә, бәһбайның йөгәненнән тотып, әйдә, бәһбай, дип өстери башлады.* Һ.Такташ. *Егет аны куаклар арасына өстери башлады, ләкин Зилә кечкенә йодрыклары белән егеткә каршылык күрсәтергә, кычкырырга тотынды.* Безнең гәҗит

Өстери төшү Бераз, беркадәр өстерәү

ӨСТЕРҮ *ф.* 1) Һөҗүм итәргә, эзәрлекләргә кушу (эткә). *Каравылчы, сизеп алып, малайларның өсләренә бозаудай этләр өстереп җибәргән иде.* И.Гази. *Шулай ук этләрне бер-берсенә яки кешеләргә өстерү дә закон бозу булып саналачак.* Татарстан яшьләре

2) *күч.* Кемгә дә булса каршы берәр хәрәкәт ясарга котырту, кешеләргә каршы котырту. *Ә бит гәзитә башкорт халкын урысларга каршы юкка өстерә.* А.Таһиров. *Бу максатны күздә тотып, Казандагы төрле фиркаларга караган хаким сыйныф һәм төркемнәрне бер-берсенә каршы өстереп, төрле-төрле җәнҗаллар оештырып, бу төрки дәүләтне юкка чыгаралар.* Мирас

Өстерә башлау Өстерергә керешү. *Этенең мөмкинлекләрен сынап карыйсы иттеме, аны хуҗасыз эткә өстерә башлады.* Й.Миңнуллина

Өстереп карау Тикшереп карау өчен өстерү. *Көтүчеләр этләрен өстереп карааннар.* А.Хәсәнов

Өстереп килү Күптәннән бирле өстерү

Өстереп тору Һаман бертуктаусыз өстерү. *Әтәчләнепме әтәчләнә Муса! Өстереп тә торгач, тәмам тугарылды.* М.Әмирхан

Өстереп җибәрү Һич көтмәгәндә, уйламаганда котырту; башта өстерү. *Өстереп кенә җибәр бу шайканы, теләсә нинди явызлыкларны эшләп атарга да әзер алар.* Ф.Сафин. *Менә бервакыт моңа кадәр яр читендә эшсез торган этләрне, бәйләреннән чишеп, елга буена өстереп җибәрделәр.* Г.Гыйльманов

ӨСЬЯЗМА *и. махс.* Нинди дә булса каты материалга чокып, кисеп язылган борынгы язу, текст. *Енисей өсьязмалары*

ӨТӘЛӘНДЕРҮ *ф.* Ашыктыру, кабаландыру. *Өтәләндереп өйдән алып чыккач, әллә бер-бер хәл булганмы дип торам.* В.Нуруллин

Өтәләндерә башлау Өтәләндерергә тотыну

Өтәләндерә төшү Тагын бераз өтәләндерү

Өтәләндереп алу Бераз өтәләндерү

Өтәләндереп тору Әле, хәзер өтәләндерү; гел, һәрвакыт өтәләндерү

ӨТӘЛӘҢУ *ф.* 1) Өтелү; йолкыш кыяфәткә керү. *Соң бит, анда сугылып, монда бәрелеп, өтәләнгән тавык кебек булып беткән иде.* С.Поварисов

2) Берәрсенә ничек кенә булса да ярарга тырышып артык илтифат күрсәтергә әзер тору, берәрсенең бөтен теләкләрен үтәргә артыгы белән тырышу, каударлану. *Әлбәттә, бу ризасызлыкны аның өчен өтәләнеп торган*

хуҗаларга сиздерергә ярамый иде. Ә.Еники

3) Ашыгудан, ыгы-зыгыдан нишләргә белмәү, кабалану. – *Күрмисеңмени? – диде Сабира өтәләнеп. – Анда утырган егетләрнең берсе Салих абый ич!* Ә.Еники. *«Ни булды, ни булды?» – дип өтәләнде.* Х.Камалов. *Аларда, эшсезлектән тилмереп, көннәр буе як-якларына каранып басып торган сакчылар һәм, син килеп керешкә, яныңа өтәләнеп килеп җитүче сатучы-консультантлар, әллә ниткән мерчендайзер, супервайзерлар сатып алучыларга караганда да күбрәк.* Татарстан яшьләре

Өтәләнә башлау Өтәләнергә тотыну

Өтәләнә төшү Беркадәр өтәләнү

Өтәләнеп алу Кыска гына вакытка, бераз гына өтәләнү

Өтәләнеп бетү Тәмам, бик нык өтәләнү

Өтәләнеп йөрү Туктаусыз өтәләнү. *Бибиҗамалым куанып бетә алмады, Гәүһәрем кайтты, Гәүһәрем кайтты, дип өтәләнеп йөрде.* М.Хәбибуллин

Өтәләнеп тору Даими, һәрвакыт өтәләнү

ӨТӘЛӘ́Ү *ф. диал.* 1) Төрле яклап өтү, яндыру, көйдерү. *Ул чакта Газинур, чыннан да, аларны утлы чыралары белән чак тотып өтәләмәде, йоннарын көйдермәде.* А.Хәсәнов. *Куе таллыкка алып төшеп, учак пыскытып, аны [карга итен] өтәләп ашаудан башка ни кала ди аңа?..* К.Җәмит

2) Чагу (үсемлекләр тур.). *Кычытканнар арасыннан иң яшьләрен, яшелләрен, шәпләп өтәли торганнарын җыя башлады [ул].* Р.Галиуллин

3) Кыздыру, яндыру (кайбер ашамлык, эчемлекләр тур.). *Әй яндырды, әй өтәләде ул чакта кызыл борыч Газинурның тел очын.* А.Хәсәнов

4) Пешергән кебек тәэсир итү, чеметтерү. *«Салкын тын юлларын өтәли, үпкәләрне меңгә телә», – ди [ул].* М.Хәсәнов

5) *күч.* Орышу, пыранлату; тәнкыйтьләү; җәзага тарту. *Урман-күл буйларын, Кәүсәр суларын дус-ишләргә тараткан җир комитеты башлыгы Харис... Галиевичны өтәләргә иде.* Д.Гыйсметдин

6) *күч.* Яндыру, әрнетү, борчу. *Бөтен күңелен өтәләп, аны яңадан сагыш басты.* М.Хәсәнов

Өтәләп алу Кисәк өтәләү. *Шундый вакытларда тагын бер шыксыз уй туып, бәгырен өтәләп алгалый ---.* М.Хәсәнов. *Мидхәт улларын ничек тә булса югары белемле итү ният белән янып йөргән Саниясенең борчулы да, шатлыклы да йөзен күз алдына китерде, һәм күңелен тагын авыр уйлар, чарасызлык өтәләп алды.* Р.Фәизов

Өтәләп бетерү Бик нык өтәләү. *Яшь авторның беренче китабын ни өчендер шулай өтәләп бетереп чыгаралар шул.* Ф.Яруллин

Өтәләп тору Әле, хәзер өтәләү; даими өтәләү

Өтәли башлау Өтәләргә тотыну. *Югыйсә өтәли дә башлады монда суык.* М.Хәсәнов

ӨТӘСЛӘ́Ү *ф.* 1) Төтен белән эшкәртү; төтен җибәрү, төтәсләү (мәс., умартага)

2) *диал. к.* **өтү** (*1 мәгъ.*)

Өтәсләп алу Тиз арада өтәсләү

Өтәсләп тору Хәзерге моментта өтәсләү

Өтәсли башлау Өтәсләргә керешү

ӨТЕ *и. диал. к.* **үтүк**

ӨТЕК *с.* **1.** 1) Өтелгән

2) Сәләмә, ерткаланган, тузган (берәр кием һ.б.ш. тур.). *Әгәр аклар Кырымга кереп бикләнәләр икән, бу бит инде – шушы өтек өс-баш, шушы тишек ботинкалар белән тагы кыш буе Кырым капкасы төбендә таптанырга, кыш буе сугышырга кирәк дигән сүз.* Г.Бәширов

3) *сөйл.* Арык һәм кечкенә кыяфәтле. *Өтек бер төркинең биш меңсәяхәтчене куркытуы гына да ни тора.* М.Хәбибуллин. *Кыскасы, үзем кебек өтекне һәм арыкны мин монда очратмадым.* Ә.Еники

4) *күч.* Кимчелекле, җитешсезлекләре булган, тулы булмаган. *Әгәр либераллар, патша монархиясе сакланган шартларда, өтек конституция теләү белән чикләнгән булсалар, эшчеләр партиясе массаларны патша самодержавиесен бәреп төшерергә чакырды.* КПСС тарихы

5) *күч.* Кыска. *Бусагаларны таптады таптавын, тик барыбер өтек койрык җиңде.* М.Әмирхан. *Өтек тун*

2. *и. мәгъ. с.* 1) Берәр нәрсәне өткәндә, көйдергәндә була торган тәм (ис). *Өтек исе чыгу*

2) Ярлы, фәкыйрь кеше. *Фәхри кебек бер өтеккә бәйләнмәсәң, сиңа үз тиңең табылмас дип белдеңмени?* Г.Ибраһимов

3) Ямьсез, сөйкемсез кеше. *Шунсыз син өтеккә авылда кызлар карамас.* Р.Сибат. *Бибиҗамал апа: «Алай бик кадерле кешең булсам, шушы өтеккә алыштырмас идең әле», – дип уйлап, улына карады.* Ш.Хөсәенов

ӨТЕКЛӘНҮ *ф.* 1) Өтек (*2 мәгъ.*) хәлгә килү, тузу, сәләмәләнү, ерткалану

2) Фәкыйрьләнү, ярлылану

Өтекләнә бару Вакыт узган саен сәләмәләнү

Өтекләнә төшү Бераз өтекләнү

Өтекләнеп бетү Тәмам өтекләнү. *Аның затлы койрыгы, каурыйлары өтекләнеп беткән, матур тажы шиңеп төшкән.* Р.Хафизова

Өтекләнеп китү Берара күзгә күренеп өтекләнү

Өтекләнеп калу Ниндидер сәбәптән өтекләнү

ӨТЕКЛӘ́Ү *ф.* Өтек хәлгә китерү; кыскарту. *Мәсәлән, шагыйрьнең Сафа-Гәрәйгә мөрәҗәгать иткән сүзләрен өтекләп бирүнең хаклылыгын мин берничек тә аңламадым.* М.Госманов

Өтекләп бетерү Тәмам өтекләү

Өтекли төшү Беркадәр, бераз өтекләү

ӨТЕКЛЕК *и.* Хәерчелек, фәкыйрьлек. *Хәерчелектән башы чыкмаган илдә авырлыкларны сәләмә кием белән генә күрсәтү, сәнгатьтәге өтеклек культы табигыйдер, мөгаен.* М.Галиев

ӨТЕЛӘНҮ *ф.* Өтекләнү, шыксызлану

Өтеләнә бару Торган саен ныграк өтеләнү

Өтеләнеп бетү Тәмам өтелгән хәлгә килү

Өтеләнеп калу Ниндидер сәбәптән өтеләнү

Өтеләнеп китү Кинәт өтеләнү. *Һади --- сайлаудан төшеп калгач, суга*

баткан чебеш шикелле өтеләнеп китте. Г.Тукай

ӨТЕЛӘ́Ү *ф. диал. к.* **үтүкләү**. *Казакины чистартырга, җитмәсә тагын өтеләргә кушу Бибисара апада төрле шикләрне кузгаткан иде кузгатуын.* Г.Минский. *Берсе самавыр куя, бүтәннәре юл кирәкләре әзерли, кием-салымын рәтли, күлмәкләрен өтели.* Г.Бәширов

ӨТЕЛҮ *ф.* 1) *төш. юн. к.* **өтү** (*1, 5 мәгъ.*). *Чорның байрагы белән сәясәт шәме сүнгә, утка ташланып өтелгән күбәләкләр күмере шикелле, төбендә үкенечле шигырь эзләре генә калмыймы?* М.Галиев

2) Яну, чит-читләре көю. *Киемнәре өтелә башлаган Газинур белән Һашим башкалар артыннан йөгереп чыгуга, түбә ишелеп тә төште.* Г.Әпсәләмов. *Булдыксыз гына түгел, ахмак булырга кирәк моның өчен: заданиене үтәмәү генә җитмәгән, үзең дә баштанаяк өтелеп кайткансың бит.* В.Нуруллин

3) *күч.* Ярлылану, фәкыйрьләнү; йолкышлану. *Гыйльмүш зимагурлыкта йөреп тәмам өтелеп кайткан.* Н.Исәнбәт. *«Сызгыру» дигән юморескам үзгәртеп кору чорларында гади кешенең ничәмә-ничә юл чатында аптырап, өтелеп, алданып калуын тасвирлый.* Р.Вәлиев

Өтелеп бетү Бөтенләй, тәмам өтелү. *Тиренең бөтен йоны өтелеп бетте дә куырылып, кызарып килде.* Р.Батулла

Өтелеп калу Берәр хәлдән соң өтек хәлгә керү. *Шулай итеп, заманында урамга ямь биреп торган әлеге мәһабәт йортлар, «инде Тукай бездән китте» дигәндәй, мескенләнеп, өтелеп калганнар...* З.Рәсүлева

Өтелеп төшү Бер тотарлыгы да калмыйча, тәмам өтелү

Өтелеп чыгу Бик нык өтелү

ӨТЕР *и. лингв.* 1) Тиңдәш яки аерымланган җөмлә кисәкләрен, җөмләләрне һ.б. аера торган тыныш билгесе (,). *Сибат аганың күзләре укучы дәфтәрендәге самими өтер сыман рәхәт кысылган.* М.Галиев. *Ниндидер бер кәкре саплы өтер өчен генә дә алар сине, әйләнчек сарык кебек, атналар буе үз тирәсендә әйләндерәләр иде.* М.Әмирхан

2) Гарәп хәрефләре белән язылган язуда: даммә хәрәкәсе. *Автор гарәп алфавитында 29 хәреф барлыгын, ә татар алфавитында исә аларның саны 35 кә җитүен күрсәтә, чөнки татар, төрек, фарсы телләрендә гарәпләрдә кулланылмый торган п, ч, ж, ң, в хәрефләренең дә булуын, болар өстенә сузыкларны белдерү өчен ас, өс һәм өтер кебек билгеләр кулланылуын әйтә.* Р.Гыйлемханова

3) *иск. күпл.* Куштырнаклар. *Һади Максуди әфәнде үзенең яңа чыккан «Төрки нәхүе»ндә болай дип әйтә: «Өтерләр, күбесенчә, мәшһүр затлар исемнәренең һәр ике ягына куелалар, "Йолдыз" газетасы Казан шәһәрендә чыга кеби».* Г.Тукай

ӨТЕРГЕ *и.* Төрле тирән булмаган уемнар һәм тишекләр чокып ясау өчен, сапка утыртылган, бер башы үткен корыч пластинкадан гыйбарәт булган корал. *Кешеләр биек итеп, агач идәнле һәм түшәмле, тәрәзәле-ишекле йортлар салырлар иде дә, моның өчен балта, пычкы, өтерге кебек кенә булса да бернинди кораллары юк.* Р.Фәизов. *Юшкынны өтерге, пычак кебек очлы әйберләр белән кырырга ярамый.* Файдалы киңәшләр

ӨТЕРГЕЛӘҮ *ф.* Уемнар, тишекләр чоку, тигезсезлекләрне кистереп алу эшен өтерге ярдәмендә башкару

ӨТЕРЛЕ ТӨРТКЕ *иск. к.* **нокталы өтер**

ӨТЕРМӘ *и. гади с. к.* **төрмә**. *Үзегез утырырсыз өтермәгә, мине дә алып китәрләр.* З.Зәйнуллин. *Өтермәгә ябып куйганчы, ул мокытны коткарырга кирәк, дигән фикергә килде.* М.Әмирхан. *Безнең өйгә көтелмәгәндә кергән кайгы авыл өстенә таралды: «Тимерче Шәйхулланы өтермәгә алып киткәннәр».* Мирас

ӨТЕРМӘН *и. гади с. к.* **төрмә**. *Өтермәндә озак утырмабыз, без бит кунак кына ич монда.* З.Мансуров

ӨТКЕЧ *и.* 1) Агач өслеген яндырып, билге яки бизәк ясау коралы; *рус часы:* **выжигалка**

2) *диал.* Бик усал һәм бәйләнчек кеше

ӨТҮ I *ф.* 1) Ут белән яндырып, ут өстендә тотып йонын, каурыйларын һ.б.ш. яндыру, чистарту. *Ерак әби, олы мичкә салам ягып, сарыкның аякларын һәм башын кыра-кыра, чын күңелдән бирелеп өтте.* Б.Ислам. *Ә аларга [патшаларга] мәңгелек әһрамнар торгызган колларның сакалларын, каз төкләрен өткән төсле, утта гына өткәннәр.* К.Тинчурин. *Каз өтү. Дуңгыз өтү*

2) Гомумән яндыру. *Кайнар ялкын Бар дөньяны өтә.* М.Шабаев

3) Тән пешкән, янган вакыттагы кебек тәэсир итү, шундый тойгы барлыкка китерү, чеметтерү, әрнетү. *Айтуганның йон чөлкәдән чыккан хәлсез аякларын салкын су өтеп алгандай итә, табан асларын су төбендәге вак ташлар авырттыра.* Р.Мөхәммәдиев. *Эссе өтә генә!* Татарстан яшьләре

4) *күч.* Көтмәгәндә бик нык тәэсир итү (сүз, караш һ.б.ш.). *– Биргән бүләкне кире алу йоласы юк, – диде Бузбала да, Исәнтәйне усал күз карашы белән өтеп.* Н.Фәттах. *Гомерләр үтә икән ул, Бәгырьне өтә икән.* Р.Миңнуллин

5) *күч. сөйл.* Талау, талап алу, көчләп алу. *Өтәргә дип барып, өтелеп кайту.* Әйтем

Өтеп алу Кисәк кенә, көтмәгәндә, бик тиз өтү. *Ут шулай ук урман буендагы аерым куакларны да өтеп алды.* Н.Фәттах. *Себерке җиле Розаның нәфис аркасын баштарак, чыннан да, өтеп алгандай итте.* Р.Низамиев. *Сине күрсәм, нидер өтеп Ала үзәгемне.* Миз.Хәбибуллин

Өтеп ташлау Бик тиз вакыт эчендә өтү. *Иске гореф-гадәт – ябага ул, Җан өстенә сырган ябага. Йөрәкләрдән шуны өтеп ташлап, Яшәртсәң бер җанны яңадан.* Х.Туфан

ӨТҮ II *и. диал.* Әче камырдан әзерләнгән көлчә

ӨТҮЧЕ *и. махс.* Кайбер җитештерү тармакларында: берәр нәрсәне өтеп (*2 мәгъ.*), яндырып эшкәртү белән шөгыльләнүче эшче. *Тукымалар өтүче*

ӨФ *иярт. к.* **өф-өф**

◊ **Өф итеп** *к.* **өф-өф итеп**. *Их, моннан чыга алсам, биллаһи дип әйтәм, өф итеп кенә тотар идем дә үзен... Чыгып кына... булмас... шул...* Г.Гыйльманов. *Мин синнән, бабай, ярышка... әнә теге... фабрик чаңгыларыңны бирәп*

тормассың микән, дип килгән идем... Ватмам-сындырмам, өф итеп кенә тотармын... А.Хәлим. *Әгәр дөнья йөртсә сине өф итеп, Уйлый күрмә, килде тоташ бәхет, дип.* Р.Вәлиев

ӨФЕЛДӘТҮ *ф.* **1.** Өф-өф итеп өрү, өреп суыту. *Өф-ф дип өреп җибәрәм дә эчәм, өфелдәтәм дә эчәм.* Ватаным Татарстан

2. өфелдәтеп *рәв. мәгъ. сөйл.* Бик кадерләп, саклап

ӨФЕРТҮ *ф.* 1) *йөкл. юн. к.* **өферү**

2) *күч. сөйл.* Куып чыгару, куып җибәрү. *Карбызчылар, алмачылар янынnан да егетне бик тиз өферттеләр.* И.Гази

3) *күч. гади с.* Урлау, урлап китү, чәлдерү. *Әйберләрне өфертү*

ӨФЕРҮ *ф. сөйл.* 1) Өрү, өф дип һава агымы җибәрү, өф итү

2) Кайгыру-борчылуның чагылышы буларак авыр сулау; уфыру. *Кеше бер эссегә өферә, бер суыкка өферә.* Әйтем

3) *күч.* Куу, куып чыгару; өфертү. *Эштән өферү*

4) *күч.* Өшкерү, им-том итү. *Әбүгалисина --- бер әфсүн укып үзенә өферде, һаман су башы [гаскәр башы] сурәтенә кереп, бу һәм аның якасына ябышып: – Әйдә тизрәк, кайда качып йөрисең? --- – дип, якалаша-якалаша барганда күрделәр, су башы ике булмыш.* К.Насыйри. *[Мәхбүбә] Бисмилла әйтеп йөзенә өферә. Бабай күзләрен ача.* Г.Исхакый

Өфереп алу Бераз гына өферү

Өфереп кую Кинәт кенә өферү

Ө́Ф ИТҮ *ф.* Өрү, өф дип өрү. *Пар бөркегән боткага Өф-өф итеп өрермен.* Җыр. *– Юк шул, – диде, – тешләнгән урынны өф итү кебек кенә тоелды.* Ф.Яхин. *Егет кызга: «Өф итеп өрсәм, мамыктай очып китәсең инде син, ә кочагыма алып кыссам, майдай эреп төшәчәксең», – дигәндәй, шаяртып күз кысты.* М.Шаһимәрдәнов

ӨФКЕЛДЕК *и. бот.* Казаякчалар семьялыгыннан туры сабаклы, тажсыман сары, ак яки күк чәчәкле күпьеллык агулы үсемлек; аю көпшәсе; *русчасы:* **борец**

ӨФЛӘҮ *ф.* 1) *сөйл. к.* **өферү** (*1 мәгъ.*). *Өенә кайткач, ул самавырын яңартты. Өфләп кенә, бу юлы ике өрек җимеше салып чәй эчте.* Ә.Гаффар

2) *күч.* Артык иркәләү, назлау

Өфләп тору Гел, һәрвакыт өфләү

ӨФ-ӨФ *иярт.* Берәр нәрсәгә өргәндә (ут сүндергәндә, кайнар чәй эчкәндә) барлыкка килә торган тавышны белдерә. *Кәбабен-шәрабен – өф-өф, Исәбен-хисабын – ах-вах.* Әйтем

◊ **Өф-өф итеп** 1) Бик кадерләп, саклап. *Алтын Урда ханнарының, үзләре, халкы мөселман була торып, чиркәү-монастырьларны өф-өф итеп саклауларына гына кара инде син!* Б.Рәхимова; 2) Артык иркәләп, назлап, узындырып. *Малай туды безнең. Нинди шатлык! Икебезгә уртак бәхет таптык. Сокланабыз аңа исебез китеп, Өф-өф итеп, өф-өф итеп. Егет үстерәбез туган илгә, Мондый асыл малай бездә генә. Тирбәтәбез йоклаганын көтеп, Өф-өф итеп, өф-өф итеп.* Г.Афзал

ӨФ-ӨФЛӘП *рәв.* 1) Берәр кайнар нәрсәгә өреп

2) *күч.* Бик кадерләп, саклап. *[Серёжа] Өс киемнәрен, аяк киемен, урынҗирен өф-өфләп кенә тора.* Ватаным Татарстан

ӨФ-ТӨФ *и. сөйл.* Им-том

ӨФ-ТӨ́Ф ИТҮ *ф.* Өшкерү

ӨЧ *сан* **1.** 1) Ике белән дүрт арасындагы бөтен сан; шул санның микъдарын һәм цифрын белдергән берәмлек атамасы. *Өчкә өчне кушсаң – алты, өчне өчкә тапкырласаң тугыз була*

2) Шул санча микъдарлы, микъдары шул сан кадәр булган. *Мә, алайса, шуның белән аптекадан порошок алырсың. Көнгә өч тапкыр эчәрсең.* Г.Кутуй. *Трактор тирәсендә кара комбинезон кигән, куллары-битләре кара майга буялган таза өч егет кайнаша иде.* М.Мәһдиев. *Шул өч шәһәрнең күңелемә иң хуш килгәне – Түбән Кама.* М.Юныс

2. *и. мәгъ.* 1) *сөйл. к.* **өчле** (*2 мәгъ.*). *Урыс теленнән диктантларын «көчкә өчкә» язар инде.* Р.Гаязетдин. *Шуннан соң биш алырмын дисеңме әллә? Алырсың! Икеле сиңа ул көнне, күп булса – өч.* Г.Мөхәммәтшин. *Өчкә уку*

2) **өче, өчесе** *этн.* Берәр кеше үлгәннән соң, өч көн үткәч, аны искә алу йөзеннән үткәрелә торган йола. *Карчыгын җиргә тапшырып кайткач та атна буе ялгызы булды [Хәйретдин агай], бу юлы да кеше арасына чыкмады. Өчесен дә, җидесен дә уздырмады.* А.Гыйләҗев. *Егетләр шәһәрдән кайткач, әтиләренең өчесен, җидесен шәпләп билгеләделәр ---.* М.Мәһдиев

◊ **Өч адымны бер итү** Бик ашыгу, зур-зур адымнар белән бару. *Өч адымны бер иттем дә иркәмә барып җиттем.* М.Җәлил. **Өч аяклап** Бик тиз, бик шәп, бар көчкә (чабу, йөгерү тур.). *Өч аяклап, куе үләннәрне, Куакларны ерып юл ала ---.* Ф.Кәрим. **Өч бөртек** Бик сирәк, аз. *Кибетче Фәсхетдин, бөкресен җилкәсендә сикертеп, өч бөртек сары сакалын учлап: «Хәйретдин агайның бер чакта да чүллидән ары аракы алганы булмады», – дип ышандырып торгач, авылдашлары ул уйдан кире кайттылар.* А.Гыйләҗев. **Өч камыт кию** Берничә вазифа башкару, өстенә авыр йөк алу. **Өч көнлек хәлифә** Бик кыска вакытка гына хакимияткә ия булып алган кеше. *Өч көнлек хәлифәләрнең фетнәсе әлеге кул куюны да өзде.* Ә.Еники

ӨЧАЯК *и.* **1.** 1) Ашамлык әзерләгәндә чуен, таба яки казан утырту өчен кулланыла торган, өч тимер аякка беркетелгән божра; таган. *Өчаякның бер аягы сынса, калган икесе сынмавыннан файда юк.* Мәкаль

2) Ашамлык әзерләү өчен, өч тимер аякка ябыштырып беркетелгән казаннан гыйбарәт җайланма. *Шуннан соң алдыбызга өчаяк белән йомырка тәбәсе килде.* Ә.Еники. *– Карының да ачтыр инде синең, мескенем, – диде карчык, мич алдындагы өчаяктагы җылы сөтне хәтерләп.* А.Гыйләҗев. *Язын, сыер бозаулаган көннәрдә, Гыйльмениса апаның өстәлендә мунча чыгышына – өчаякта кыздырган угыз сөте.* М.Мәһдиев

3) Берәр нәрсәне беркетү, асу һ.б.ш. өчен, югары очлары бергә тоташтырылган өч таяк; мольберт; штатив. *Төшерүче өчаякны кабаланмый гына тигезләде, аның өстенә кайсы җире беләндер гармунга охшаган бәләкәй генә фотоаппаратны ныгытып куйды.* З.Зәйнуллин. *Анда гаять зур өчаякка*

бастырылган антенна көзгесе – металл челтәрдән эшләнгән касә күренә. А.Тимергалин. *Хатын-кыз, өчаяк бастырып, таган аса, ир-ат утын җыя.* А.Гыйләҗев

2. *с. мәгъ.* Өч аяктан гыйбарәт булган. *Калкулык артларында ирләр өчаяк таганга куелган карачкыларга ук аттылар, сөңге ыргыттылар.* Н.Фәттах

ӨЧӘМ *и.* Бишташ уенында өч таш куеп ату алымы

ӨЧӘР *сан* һәркемгә яки һәрнәрсәгә өч, бертигез күләмдә өч булуны белдергән бүлем саны. *[Шаһзадәләрнең] Һәрберсе өчәр көн тәхеткә менеп падишаһлык итсен, кайсының гәүһәре бар булса, мәгълүм булыр.* К.Насыйри. *Әмма күрше алпавыт --- бер эш эшләмичә типтереп кенә йөрсә дә, аның пулаты да бар, әллә ничә мең дисәтинә җире дә бар, берьюлы өчәр ат җигеп, эшләпәсенә тутый кош койрыгы кыстырган кучерлар белән генә йөри.* К.Тинчурин. *Асфальт түшәлгән киң урамның ике ягы буйлап тезелгән өчәр, дүртәр катлы ташпулатларның тәрәзәләрендә – пәрдәләр.* И.Салахов

ӨЧӘРЛӘНҮ *ф.* Өч булып китү, өчкә аерылу. *Бык-бык итү икешәрләнде, өчәрләнде. Әнә ерак кына урман эченә кертеп салынган бер йорттан, дачаданмы, фин өеннәнме, үрдәк кәрваны сузылып төшә.* Г.Исхакый

Өчәрләнеп китү Билгеле бер моментта өчәрләнү

ӨЧӘРЛӘП *рәв.* Өч заттан яки предметтан гыйбарәт төркемнәр белән, шундый төркемнәр хасил итеп. *Монда Костин партизаннарга поход юнәлешенең үзгәргәнлеген аңлатты һәм өчәрләп тезелергә команда бирде.* Г.Гобәй. *Миңнисаның күп уйный торгач шомарып беткән, чикләвек кадәр генә вак ташларны нәни бармаклары белән җелт-җелт китереп кенә элек берәмләп, аннар соң икешәрләп, өчәрләп, дүртәрләп, башта учына, аннары бөтенесен өскә чөеп, берсен дә җиргә төшермичә, кул аркасына алуын сокланып карап торам.* Г.Бәширов

ӨЧӘРЛӘ́Ү *ф.* 1) Өч кат итү, өч катлау (мәс., җепне, бауны). *Өчәрләгән өзелмәс.* Әйтем

2) *сөйл.* Өчәр-өчәр итеп аерым төркемнәргә бүлү яки җыю

3) *а.х.* Өч кат сөрү (берьюлы). *Өчәрләгән җирдән зур уңыш алу*

Өчәрләп кую Өчәр-өчәр итеп әзер хәлгә җиткерү

ӨЧӘРЛЕ *с.* 1) Өч кат ителгән, өч катланган. *Өчәрле җеп*

2) Өч бер төрле кисәк бергә тоташкан, бергә тоташып үскән. *Икенче спермий диплоидлы үзәк төш белән кушыла, нәтиҗәдә өчәрле хромосома җыелмасы булган триплоидлы күзәнәк барлыкка килә.* Биология. *Тукранбаш чәчәгенең өчәрле яфраклары көндез горизонталь хәлдә була, кичкырын алар югары күтәрелә...* А.Тимергалин. *[Бөрлегәннең] Яфраклары өчәрле.* Урман аптекасы

ӨЧӘ́Р-ӨЧӘР *рәв.* Өчәрләп, өчәр итеп. *Шунда ук туктап, һавага күтәрелеп карадым, һәм, ни күрим, посёлок артындагы урман өстеннән генә безгә таба, өчәр-өчәр тезелешеп, немец самолётлары ашыкмыйча гына киләләр!* Ә.Еники. *Әсирләрне өчәр-өчәр итеп шунда алып керәләр.* Х.Камалов. *Төрлесе төрле яшьтәге, төрле милләттән булган малайларны өчәр-өчәр итеп башта ике сәндерәгә, аннары тагын өчесен аска – Азатларга каршы урнаштыралар.* А.Тимергалин

ӨЧӘ́Ү *сан* **1.** 1) Нинди дә булса бер төркемдә өч предмет яки зат булуын белдергән җыю саны. *Безне тыңлаучылар өчәү иде.* Ә.Еники. *Иң ахырдан өчәү калдык: берсе Кавказдан иде – чечен егете, икенчесе – Мәскәү урысы.* Г.Гыйльманов

2) Санаганда микъдар саны мәгънәсендә кулланыла. *Берәү, икәү, өчәү, дүртәү, Бишәү генә шикелле; Йөрәгемдә утлар яна – Яратуы икеле.* Җыр. *Мөбарәк тә майка итәген эчтә калдырып, трусигын кендегеннән дә өскәрәк күтәреп куеп, шалкан тутырырга кереште. Берәү, икәү, өчәү, дүртәү, бишәү...* М.Шаһимәрдәнов. *Берәү, икәү, өчәү – барысы соң ничәү? Эх, минутлар мәңге түгелләр.* Р.Тимерова

2. *рәв. мәгъ.* Өч кеше бергәләп, өчәүләп. *Ахияр ни түзеп карады теге серне саклап, әмма Мәгыйзь, Рәиф өчәү бергә киңәшеләр дә чакырып әйттеләр: кызыңны исән.* М.Мәһдиев. *Алар наратлар янына килеп җиткәндә, агачлар артыннан финнар өчәү чыктылар.* З.Зәйнуллин. *Мин ялгыз гына түгел, өчәү барабыз икән ләбаса.* И.Салахов

ӨЧӘҮЛӘП *сан* **1.** Чама белән өч, якынча өч булуны белдергән чама саны. *Бүген өчәүләп кунак килергә тиеш*

2. *рәв.* Өчесе бергә, өч кеше бергәләп. *Каршы торуның файдасыз икәнен аңлагач, капитуләтсия ясарга патша да, аның баш министры да, гаскәр башлыгы да безнең янга өчәүләп йөгереп чыктылар.* Н.Әхмәдиев. *Бераздан алар туган йортка өчәүләп кайтып йөри башладылар.* М.Мәһдиев. *Өчәүләп, җәелеп китеп сөйләшмичә генә, тамак ялгап алдылар.* Г.Гыйльманов

ӨЧӘҮЛӘШЕП *рәв. к.* **өчәүләп** (*2 мәгъ.*). *Бакчада күпмедер сөйләшеп утырганнан соң, өчәүләшеп йөрергә чыгып киттек.* Ә.Еники. *Алар өчәүләшеп берәр атнадан кайтырга сөйләштеләр.* Г.Бәширов. *Тугайга төшеп, өчәүләшеп күп итеп күрән урдылар.* З.Зәйнуллин

ӨЧБАРМАК *и. зоол.* Шөлдисыманнар отрядыннан, тропикларда һәм субтропикларда яши һәм тышкы кыяфәте белән бүдәнәне хәтерләтә торган кош; *русчасы:* **трёхпёрстка**

ӨЧ БАСУ *и. а.х.* Чәчү әйләнешенең иске системасы: игелә торган җир өч басуга бүленә, шуларның һәрберсенә чиратлаштырып башта уҗым, аннан сабан ашлыгы чәчелә, өченче елда паргa калдырыла

ӨЧБАСУЛЫ *с.* Өч басуны чиратлаштыруга нигезләнгән. *Игенчелектә өч басулы чәчү әйләнеше кулланышта булуы тарихи язмаларда еш искә алына.* Н.Гариф. *Ул вакытта игенчелектә өч басулы чәчү әйләнеше өстенлек итте, һәм тимер сабан башлыча алпавыт хуҗалыкларында гына кулланылды.* Тирән тамырлы Түнтәрем

ӨЧБЕРЛЕК *и. дини* Христианлыкның төп догматы: асылы белән бер, ләкин өч рәвештә гәүдәләнгән (атасы, улы һәм изге рух) илаһ; троица. *Мөкатдәс өчберлек*

ӨЧБУЫН *и. мат.* Өч бербуыннан торган алгебраик күпбуын; трином.

$ax^2+bx+c=0$ квадрат тигезләмәсенең тамырлары квадрат өчбуынның тамырлары була. Тригонометрия. *Квадрат өчбуыннан икебуынның квадратын аерып алу кулланылган мәсьәлә карыйк.* Алгебра

ӨЧБУЫНЛЫ *с.* 1) Өч кисәктән, өч элементтан, өч буыннан гыйбарәт. *Берөлешлеләр күп кенә билгеләре белән икеөлешлеләрдән җитди аерылып тора: 1) аларда чук тамыр системасы; 2) күбесенең яфраклары гади, сеңерчәләре дугасыман яки параллель урнашкан; 3) чәчәкләре өчбуынлы, ягъни аларда кәсә һәм таҗ яфракчыкларының саны һәрвакыт өчкә кабатлы.* Биология. *Өчбуынлы ракета*

2) *мат.* Өч буыннан торган, өч буыннан гыйбарәт. *Өчбуынлы тигезләмә*

ӨЧ-ДҮРТ *сан* Нәрсәнеңдер өч яки дүрт тирәсендә булганын белдергән чама саны. *Өч-дүрт бүре утырганнар каршы утка, Тырышып-тырышып пешермәктә алар бутка.* Г.Тукай. *Сез, ирләрнең бозык өлеше, бер үк «сөям» сүзен ике-өч көн эчендә өч-дүрт кешегә әйтә аласыз.* Г.Кутуй. *Өч-дүрт атна дигәндә өйдә низаг чыгып, килен әти-әнисе янына кайтып китте.* М.Мәһдиев

ӨЧЕН *бәйл.* 1) Эш-хәрәкәтнең максатын белдерә; максаты белән. *Җирән кашкага ашатырга печән чабып алып кайту өчен, чалгы да алдык.* Г.Ибраһимов. *Шәһәр дә, ничек кенә булса да бу яңа төзелешкә ярдәм итү өчен, төрле чаралар күрү эшенә кереште.* А.Алиш. *Баскыч борылышындагы киң генә бер идәнле җиргә килеп менгәч тә, хәл җыяр өчен ясалган утыргычка утырдым да, Мәҗиткә эндәшеп: – Дәү әбиеңне көтик инде... Артка калды... – дидем.* Н.Фәттах

2) Эш-хәрәкәтнен сәбәбен, башкарылуының нигезен белдерә; аркасында, сәбәпле. *Гали һаман миңа бәйләнә, Шаһбазны сүгә: – Солтан, – ди, – нәрсә шул уйнаштан туган хәерче малай өчен минем белән сугышып йөрисең? – ди.* Г.Ибраһимов. *Бу куәте өчен ул Разия тарафыннан мактала, Фатыйма тарафыннан сөелә, Сабир тарафыннан якын күрелә.* А.Алиш. *Өйдә бала-чага эшләгән бөтен шуклык өчен әнисеннән Рәсимәгә эләгә иде.* М.Мәһдиев

3) Эш-хәрәкәтнең яки нинди дә булса предметның кем яки нәрсәгәдер билгеләнүен белдерә. *Каз өмәсенә җыелган кызлар өчен дә берәр шуклык әзерләп куя ул: тазартылган каз куыкларын өреп тутыра да, кеше күрмәгәндә генә, аларны сәкегә җәйгән көрпәләр астына тыгып куя.* М.Галәү. *Төзеләчәк электр станцасының безнең завод, шәһәр һәм республика өчен нинди әһәмиятле икәнлеге барыбызга да билгеле булса кирәк.* А.Алиш. *Нишләптер гел безнең өчен генә Яфрак-яфрак булып кан тама...* Зөлфәт

4) Теге яки бу хәлнең, предметның, сыйфатның берәр зат һәм предметка карата берәр төрле мөнәсәбәте, әһәмияте, көче булу-булмавын белдерә. *Минемчә, халык өчен порох, пуляга караганда, ипи, чәй-шикәр, ситсы кирәгрәк түгелме икән?* К.Тинчурин. *Укытучы өчен бу кечкенә малай үзе бер могҗиза кебек тоелды.* З.Зәйнуллин. *Бу өч ел Газзәбану өчен ялгызлыкның ачы газаплары, тирән сагышлары белән иксез-чиксез озын-озак елларга әйләнде.* Г.Галиева // Нинди дә булса күренешнең, вакыйганың берәр затка яки нәрсәгә туры килү-килмәвен белдерә. *Тыныч тормыш вакыты өчен ул картиналар ярап бетми.* Г.Нигъмәти

5) Эш-хәрәкәтнең кемдер яки нәрсәдер файдасына башкарылуын белдерә. *Безнең өй авылның читендә, олы юлга салынган күпер башында булганга, бу базар көннәре минем өчен дә байтак төшем бирәләр.* Г.Ибраһимов. *Туган ил өчен шәһит киткән изге җаннарга хөрмәтсезлек була түгелме соң, иптәшләр?!* Х.Сарьян. *[Колхозга керү] Үзең өчен кирәк. Минем өчен, кешеләр өчен кирәк.* М.Мәһдиев

6) Берәр эш-хәрәкәтне, вазифаны алыштыра торган затны яки предметны белдерә; урынына. *Бүген Стариков диктант өчен икенче бер әйбер хәзерләп куйган иде.* Г. Әпсәләмов. *Аның өчен эшләү*

7) Эш-хәрәкәтнең кем яки нәрсә хакына, хөрмәтенә башкарылуын белдерә. *Беренче нәүбәттә элек солдат булып хезмәт иткәннәрне кырык яшькәчә сөргәннәр иде; алар китеп, алар өчен түгелгән күз яшьләре кибеп өлгерә алмады – ополчиннарга хәбәр килде...* Г.Ибраһимов. *Кеше матур шул вакыт – иле өчен, халкы өчен яшәгәндә җан атып ---.* Р.Харис. *Сугыш елларында «Фронтка икмәк кирәк!», «Бар да җиңү өчен!» дигән яңгыравыклы патриотик шигарь-лозунглар белән авылга грамм да иген калдырмыйча хәрәкәт иткән хөкүмәт халыкны тагын да ач-ялангач калдырып талавын дәвам итте.* З.Зәйнуллин

ӨЧЕНЧЕ *сан* **1.** 1) Рәт, тәртип белән санаганда өч урынында килә торган тәртип саны. *Закирова иптәшнең өченче соравына җавап бирәбез.* Х.Сарьян. *Пётр – семьяда өченче малай.* М.Мәһдиев. *Аның үлек гәүдәсен авыл очындагы таш койма белән уратып алынган зыяратка илтеп күмгәнгә инде ике ел тулып өченчегә киткән.* З.Зәйнуллин

2) Әһәмияте белән төп урынны, беренче урынны алып тормаган, түбән дәрәҗәдәге. *Сталинның милли сәясәте аркасында өченче сортлы милләткә әйләнеп, милли хокукны югалту.* М.Юныс. *Вакытны тизрәк үткәрү өчен мин, өченче класстагы үз урыныма утырып, китап укырга тотындым.* Н.Фәттах

2. *и. мәгъ.* Табынга икенчедән соң чыгарыла торган төче ашамлык; десерт, татлы. *Өченчегә чия суы иде.* Г.Ибраһимов. *Шулардан берсе: аш өстәленә, тәлинкәләргә тутырып, икмәк кисәкләрен табын уртасына куя: беренчегә аш аласың – син бер кисәк икмәк өчен акча түлисең, икенчегә итле ризык – тагын бер кисәк түлисең, өченчегә чәй, кесәл, кофе, сөт алган очракта, икмәк өчен түләмисең.* Безнең гәҗит

3. *кер. сүз мәгъ. сөйл. к.* **өченчедән**

◊ **Өченче әтәч(ләр)** Таң, таң вакыты. *[Байтирәк:] Ярый инде, хәерле булсын, өченче әтәчтән соң килерсез.* Т.Гыйззәт. *[Сабир бабай:] Өченче әтәчләргә кадәр сайрашмаганда да ярый торгандыр бит!* Г.Әпсәләмов. *Икенче, өченче әтәчләрдән соң төн рухларының көче бетә икән бетүен.* Г.Гыйльманов. **Өченче әтәч(ләр)**

кычкыру Әтәчләрнең өч тапкыр: төн уртасында, таң алдыннан һәм таң вакытында кычкыруыннан вакытның таңга таба баруы турында. *Инде өченче әтәчләр кычкырып, сүрән эңгер дөньяга иңгәндә, аның шик-шөһбәләр тулып авырайган мие томаланды, ул тирән, караңгы упкынга очкан сыман булды һәм тагын сискәнеп уянды.* А.Гыйләҗев. *Икенче әтәч тә, өченче әтәч тә кычкырды. Сания, белгән догаларын укып, Хәлимнең түшәген өстән берничә мәртәбә сыпырып алгандай итте.* Г.Гыйльманов. *– Кызлар, өченче әтәч тә кычкырды! – дип кычкырды тыштан керештән Гөлдиттәй. – Таралырга вакыт! Тышта бәйрәм түгел!* А.Хәлим

ӨЧЕНЧЕ́ БУЫН *и.* Баланың балалары, оныклар

ӨЧЕНЧЕ́ БҮЛЕК *и. тар.* Россиядә 1826–1880 елларда: сәяси күзәтү һәм җинаятьчеләрне эзләү дәүләт органы

ӨЧЕНЧЕДӘН *кер. сүз.* Нәрсәне дә булса санаганда, өченче пунктны белдерү өчен кулланыла. *Беренчедән, синең аягың авырта. Икенчедән, син – минем кунак, өченчедән, мин яшьрәк...* И.Салахов. *Өченчедән, гади халык ислamга тартыла башлаган булса, зыялыларыбызның зур өлеше дингә һаман битараф.* Р.Мөхәммәтдинов. *Өченчедән... Син, олан, кояш чыгышына ачык торган агач эзлә.* Г.Гыйльманов

ӨЧЕНЧЕ́ ЕЛ *рәв.* Моннан ике ел элек. *Нәҗип бу вакытта өченче ел сәхнә артында көтүче малай турында укыгандагы кебек ярсу иде.* Г.Гобәй

ӨЧЕНЧЕ́КӨН *рәв.* Моннан ике көн элек. *Ә безнекеләр әйтә, өченчекөн төнлә белән ул каенатасының ындырына килгән, ди... Исмәгыйль белән дуслашып алган, имеш.* М.Галәү. *«Яңа Юл» колхозы әле өченчекөн генә ике машина сарык озаткан иде ит комбинатына.* М.Мәһдиев. *...Өченчекөн сугыш башланды.* Ә.Еники

ӨЧЕНЧЕЛ *с.* Нәрсәнең дә булса өченче стадиясе, баскычы, өченче чагылышы булган. *Дөрес, бу юнәлештә тәкъдимнәр күп, әмма алар башлыча материалистик карашка бәйле икенчел, өченчел факторларны чагылдыра.* Р.Сафин. *Өченчел структура полипептид чылбыр радикалларының функциональ группалары тәэсир итешүе нәтиҗәсендә барлыкка килә.* Органик химия

ӨЧЕНЧЕЛӘЙ *кер. сүз иск. к.* **өченчедән**. *Икенчеләй ни яман? Фарыз укымас – ул яман. Өченчеләй ни яман? Өзелеп чыгар җан яман.* Дастан. *Өченчеләй, милләтебезнең бик күп кызлары шушы мәктәп эчендә изге тәрбия алып чыгачак, милләтебезгә бик күп хезмәт итәчәк, вә үзләренең бу дәрәҗәләренә ирешүләренә сәбәп булган хөрмәтле Гайния ханым вә Латыйф әфәнделәргә һәрвакыт догада булыначак вә рәхмәтләр укыячаклардыр.* М.Буби

ӨЧЕНЧЕ СОСЛО́ВИЕ *и. тар.* Франциядә XV гасырдан 1789 елга кадәр, дворяннардан һәм руханилардан аермалы буларак, салым түләргә тиешле, привилегиясез катлам

ӨЧЕСЕ *сан* Нинди дә булса бер иштән булган предметлардан яки бертөр затлардан өч предмет яки өч зат булуын белдергән җыю саны. *Бервакыт Аккош, Чуртан, Кыскыч – өчесе бер йөккә җигелеп, аны алга алып бармакчы булдылар.* Г.Тукай. *[Кызларның] Өчесе дә бигрәк чибәр, Өчесе дә бигрәк шәп. Берсе – җәүһәр, берсе – гәүһәр, Берсе – энҗе-зөбәрҗәт.* Ә.Ерикәй. *Сигез ирнең бишесе сәкегә менеп утырып, өчесе идәнгә урнашып, табын ачтылар.* З.Зәйнуллин

ӨЧИГЕЗ *с.* **1.** Бер анадан бер үк вакытта туган (өч бала тур.). *Өчигез бала анасы*

2. *и. мәгъ.* Бер анадан бер үк вакытта туган өч бала. *Өчигез табу*

ӨЧ КАРА *и. этн.* Өч кара төстәге җепкә башка төстәге ике яки дүрт җеп атып суккан алача. *Йорттa тотар өчен, өч карадан ашъяулык сугарсың.* М.Гали

ӨЧКӘ-КӨЧКӘ *рәв. сөйл.* Көч-хәл белән, авырлык белән. *--- сигез классны өчкә-көчкә бетергән малайларны җыю дөрес түгел.* М.Мәһдиев

ӨЧКЕЛ *и.* Мичнең почмагында лампа утыртыр өчен ясап калдырылган куыш

ӨЧКЕЛЛӘП *рәв.* Өчпочмак ясап, өчпочмак рәвешендә. *Ак яулыкны өчкеллəп бәйләгән, бала итәкле зәңгәр ситсы күлмәген бөрмәсенә кыстырып, җиңнәрен сызганып куйган әнисе, кулына табагач тотып, почмакта мич каршысында кайнаша.* Г.Ахунов

ӨЧ КӨНЛЕК *с.* **1.** 1) Өч көн дәвам итә торган, өч көнгә сузыла торган. *--- өч корбан алып киткән өч көнлек фетнә бетерелде ---.* Ә.Еники. *--- икенчедән, Имәнкискә культурасы Идел Болгарының төп этник территориясен биләгән, ә бортаслар болгарларга күрше булып көн иткәннәр, аларның арасы өч көнлек юл саналган.* Р.Фәхретдинов. *Новосибирск өлкәсе губернаторы Василий Юрченко җитәкчелегендәге делегациянең Казанга өч көнлек эш визиты дәвам итә.* Ватаным Татарстан

2) Тууына өч көн булган; өч көн элек барлыкка килгән. *Өч көнлек бозау*

3) Өч көнгә җитәрлек. *Менә көннәрнең берендә болар җыелышып сүз күешканнар да, ди, барысы да өч көнлек азык хәзерләп, юлга ил-җир күргәргә чыгып киткәннәр, ди.* Әкият. *Улгәч тә өч көнлек эш кала.* Әйтем. *Тәңре илчесе – Әҗәл – Шимбай хан җаны артыннан килгәнче дип, кабергә өч көнлек ризык һәм кымыз куйдылар, аннары мәет өстенә, догалар укый-укый, алтын кебек арпа бөртекләре сиптеләр.* М.Хәбибуллин

4) *күч.* Бик тиз уза торган. *[Мәрьям Зәйнәпкә:] Сез өч көнлек дөнья өчен бөтен ахирәтне онытасыз.* Ф.Әмирхан. *Өч көнлек гастрит ул, белдегезме шуны?* М.Мәһдиев. *Үйла аны [дөньяны] тик өч көнлек тәхет дип, Бу турыда сиңа һәрчак искәртер...* Р.Вәлиев

2. *и. мәгъ. дини к.* **өч 2.** (*2 мәгъ.*). *Баязитның өч көнлеге уңае белән яшьләрне җыеп, кайбер турыда, бәлки, аңлашып та үтәргә булыр дип өметләнгәннәр иде.* Г.Ибраһимов

ӨЧКЫРЛЫК *и. бот.* Оешмачәчәкләләр семьялыгыннан бер яисә күпьеллык үләнчел үсемлекләр ыругы; *рус часы:* **трёхрёберник**

ӨЧЛӘНҮ *ф.* 1) Өчкә аерылу, өч булып китү

2) Өчесе бергә кушылу; өчләтә арту. *--- ләкин баш эчендәге уйлар, дәртләр берсе артыннан берсе йөгерде, берсенә-*

берсе кушылып икеләнде, өчләнде, матур, ямьсез төсләр алды. Г.Исхакый

ӨЧЛӘП *сан* **1.** Якынча өч тирәсе, чама белән өч, ике-өч, өч-дүрт. *Мич астында өчләп күкәй, Ал, апаем, онытма.* Җыр

2. *рәв. мәгъ.* Өчәрләп, өчәр-өчәр итеп; өчесен бергә. *Әй унҗиде, унҗиде! Өчләп салсаң өч булмас, Кушлап салсаң куш булмас, Бишкә бүлсәң, бүленмәс.* Дастан. *Теге --- Мөбарәкне очратып, очына каеш куеп сүс җептән өчләп үргән озын һәм зәһәр камчысын баш очында айкый-айкый: – Минем әнигә нинди такмак әйттең син? – диде.* М.Шаһимәрдәнов

ӨЧЛӘТӘ *рәв.* 1) Өч мәртәбә артык, өч тапкыр артык микъдарда. *Әйтик, шыксыз гына бүлмәдә яки өйдә кунып чыкканы өчен, Әдигәев бу кешедән өчләтә бәя түләтеп, моңа тагын нинди-дидер өстәмә «мәшәкатьләр» хакын да куша, хәтта пароход билетын да аңа ничектер икеләтә артыграк бәядән сату җаен таба иде.* М.Галәү. *Яныңа --- явыз, тешләк, ачәрвах, тилемсә, вак, ахмак, өчләтә юньсез тоткыннарны китереп тыга [ул].* А.Гыйләҗев. *Урланган мал икеләтә, өчләтә, унлата гөнаһлы итә, моны кем генә белми икән...* Г.Гыйльманов

2) *диал.* Өч тапкыр, өч кабат. *Бер эшне өчләтә башкару*

ӨЧЛӘТҮ *ф.* 1) Өч катлы итү, өч катлау, өчәрләү (мәс., бауны, җепне); өчесен бергә тоташтыру. *Җепне өчләтү*

2) Өч мәртәбә арттыру, зурайту. *Капиталны өчләтү*

ӨЧЛӘ́Ү *ф. к.* **өчләтү** (*1 мәгъ.*)

ӨЧЛЕ *с.* **1.** 1) Өч кисәкле, өч данәле, өч компонентлы

2) Нинди дә булса предметның өч саны белдергән үлчәүле булуын, шул зурлыкта булуын белдерә. *Өчле галуш. Өчле филтә*

3) Өч шәм яктылыгы бирә торган (лампа тур.). *Яңарак кына яндырылган өчле, бишле лампалар сүндерелеп, казарманың ул як башы караңгылык эчендә калды.* М.Гафури. *Мич уентыгында – өчле лампа!* М.Шаһимәрдәнов. *Өчле лампаның сүрән утында утырып чәй эчтеләр.* Ф.Яхин

2. *и. мәгъ.* 1) 3 цифрының исеме. *Аннары юл билетына карап, өчле һәм бишле санының нәрсәдер аңлатырга тиешлеге хакында фикер йөртергә кереште.* М.Шаһимәрдәнов

2) Өлгерешне биш балл белән бәяләү системасындагы «канәгатьләнерлек» билгесе. *Зәйнәп апа физикадан да, химиядән дә сиңа тәки өчле куйдырды.* З.Зәйнуллин. *Аттестатында аның [Сабирның] иң яраткан фәне алгебрадан өчле тора.* Ә.Дусайлы. *[Суфиҗан:] Үземнең сораулар буенча белгәнемне сөйләп бирдем. Өчле, ди бу [укытучы] миңа!* Р.Сабыр

3) Өч күздән гыйбарәт уен картасы яки бер ягында өч күзе булган домино. *[Дүртенчесе:] Каплагыз, зинһар, шуның өчлесен, ул өчлегә уйный.* Г.Камал

ӨЧЛЕК *и.* 1) Кыйммәте өч сум булган акча, өч сумлык. *Шуннан [Бибинур] күлмәк кесәсеннән таушалып беткән өчлек тартып чыгарды.* А.Гыйләҗев. *Үги ана яфрагыдай яшел бумажник. [Эчендә] Утыз сум акча. Ике унлык, бер бишлек, бер өчлек, ике берлек.* Р.Сәлим. *Дөрес, бүген хатыныннан яшереп йөрткән өчлегенә аракы алып эчте ул [Хәлим].* Р.Зәйдулла

2) Өч кешедән яки предметтан гыйбарәт төркем. *Ә бит Казанга килеп бер-ике ел да үтми, Тукай наширләрдән иң зур гонорар ала торган өчлекнең берсе (калган икесе – Г.Исхакый белән Ф.Әмирхан) булып китә.* И.Нуруллин. *– Менә нәрсә, әби, – диде яшь лейтенант. – Сезнең ирегезнең эшен Верховный суд карады һәм, аны гаепсезгә кулга алынган дип табып, Өчлек судының карарын юкка чыгарды.* М.Мәһдиев

3) *к.* **өчле 2.** (*3 мәгъ.*). *[Домино уйнаганда дүртенчесе икенчегә:] Ачасыңмы өчлекне?* Г.Камал. *– Өчлек, җиделек, туз! – дип хырылдады ул, башын күтәреп.* А.Тимергалин

ӨЧ НОКТА *и. грам. к.* **күп нокта**. *Җәя эчендәге өч ноктаны тутырыймы?* М.Мәһдиев. *Әсәрнең өч ноктадан белән чуарлануы гына да аның әйтелеп бетмәгән уйларга байлыгын күрсәтеп тора.* Р.Рахман. *Мисалга С.Рәмиевның, К.Бәкернең күп кенә урында өч нокта белән тәмамланган хатирәләрен китерергә буладыр.* Кызыл таң

ӨЧПОЧМАК *и.* 1) *мат.* Өч эчке почмак ясап кисешкән өч туры белән чикләнгән геометрик фигура. *Тигезлетигезсез өчпочмак шикелле калку җир кисәге текә ярлар буенча сузылган ике катлы койма белән уратып алынган иде.* Н.Фәттах. *Сул як якасы өчпочмак ясап ачылган.* С.Поварисов. *Әгәр зур катетны 4 дм га арттырып, икенчесен 8 дм га киметсәк, табылган турыпочмаклы өчпочмакның гипотенузасы баштагы өчпочмакның гипотенузасы озынлыгында булыр.* Алгебра

2) Шундый формадагы берәр фигура яки предмет. *Йомшак күн белән тышланган, нечкә каешка тагылган өчпочмакны ул иренең муенына такты.* Н.Фәттах. *Институтка килеп кергәндә шинель петлицаларымда чия кызыл өчпочмаклар яна иде...* И.Салахов. *Каралҗым болытлар төркеме арасыннан өчпочмак койрыклы ракеталар күренде.* А.Тимергалин // *сөйл.* Шундый формадагы хат

3) *сөйл.* Шундый формадагы җир үлчәү таягы; сажин. *Өчпочмак белән җир үлчәү*

4) *кулин.* Эченә ит, бәрәңге һәм суган салып, өчпочмак (*1 мәгъ.*) рәвешендә бөгеп пешерелә торган камыр ашамлыгы. *Бер көнне кич Сольма өчпочмак пешереп, балаларын өстәл янына утыртып, әтиләре кайткач бергәләп ашыйбыз дип көттереп торган.* М.Мәһдиев. *Тагын әле анда әнисе кәгазьгә төреп салган ике-өч белен белән ике өчпочмак та бар!* М.Шаһимәрдәнов. *Өчпочмакны тавык, каз, үрдәк итләрен салып та пешерергә була.* Татар халык ашлары

5) *сөйл.* Башка ябына торган өчпочмаклы яулык; косынка

ӨЧПОЧМАКЛА́Ү *ф.* Нәрсәгә дә булса өчпочмак формасын бирү, нәрсәне дә булса өчпочмак хәленә китерү

ӨЧПОЧМАКЛЫ *с.* Өч почмагы булган, өчпочмаклап ясалган. *Түгәрәге, өчпочмаклысы, дүрткеллесе: һәр хуҗа мачтаны һәм антеннаны күршесенекенә охшатмаска тырышып ясаган һәм теләгенә ирешкән.* А.Гыйләҗев.

Бу өчпочмаклы хатының бер почмагына берничә бөртек орлык кыстырган... Г.Гыйльманов. *Сафатдин абый чалбар кесәсеннән өчпочмаклы хат чыгарды.* М.Шаһимәрдәнов

ӨЧ СУМЛЫК *с.* **1.** Кыйммәте өч сум дип билгеләнгән яки бәясе өч сум торган. *Городовой, мундирының артқы кесәсенә өч сумлык кәгазь акчаны яшерә-яшерә, мәдрәсә капкасыннан чыкканда, мәдрәсә күршесендәге Шәрәфи кибетеннән бер төркем халык бәрелеп чыкты.* К.Тинчурин

2. *и. мәгъ. сөйл.* Кыйммәте өч сум булган акча. *Аның өч сумлыклары күп*

ӨЧ ТИЕНЛЕК *с.* **1.** 1) Кыйммәте өч тиен дип билгеләнгән яки бәясе өч тиен торган. *Анда – үзенең пачкасы өч тиенлек папиросын кабызып җибәрде.* Г.Тукай

2) *күч. сөйл.* Бик арзан, бик очсыз. *Өч тиенлек куян, биш тиенлек зыян.* Мәкаль. *--- гомуммилли интересларны онытып, кулда тупланган өч тиенлек байлыкны саклап калу өчен, вак җанлылык күрсәтеп, милләтеңә каршы көчләр белән хезмәттәшлеккә керү, --- тормышка май бөргән күзләр, тук карын аша гына карау сыйфатларыннан арыну.* А.Хәлим. *Өч тиенлек дөньяда яшәүчеләр арасында бер тиенлек бәһа алмаучылар да бар.* Н.Гариф

2. *и. мәгъ.* Кыйммәте өч тиен булган вак акча. *--- ул төенчек эчендә вак төенчекләр, яулык, яулык эчендә, вак төенчекләрнең эчендә, һәр каюсында төрле-төрле акчалар, каюсында – ике тиенлек, каюсында өч тиенлекләр куелган иде.* З.Һади. *Акча алышынган ел бит ул, бер кәгазь пакетта 100 штук өч тиенлекләр бирделәр.* Сәхнә

ӨЧТОМЛЫК *и.* Өч томнан гыйбарәт әсәр, җыентык яки сүзлек. *Бу сан әлеге өчтомлыкта кыйммәтле мирасның (Тукай каләме белән якынча 770 ләп текст языла) иң зур өлеше укучылар игътибарына тәкъдим ителгәнлеген күрсәтә.* З.Рәмиев

ӨЧ ТӨР ЯРЫШ *и. спорт* 1) Спортның өч төреннән гыйбарәт спорт ярышы

2) Бер спорт төренең өч төрле күнегүе буенча спорт ярышы. *Авыр атлетика өч төр ярышы*

ӨЧУРЫНЛЫ *с. мат.* Өч билгедән (тамгадан, цифрдан) гыйбарәт. *5 кә кабатлы өчурынлы х санын бер үк натураль санның кубы һәм квадраты суммасы рәвешендә язарга мөмкин.* Алгебра

ӨЧЬЕЛЛЫК *и.* Өч елга дип исәпләнгән, өч ел буена дәвам итә торган. *Безнең өчьеллык планыбыз бар, партиянең, шул планны үтәү өчен, безгә сызып биргән юлы бар.* Ә.Еники. *Рәис – өчьеллык партшкола тәмамлаган кеше.* Х.Камалов. *Әнием өчьеллык авыл мәдрәсәсен бетергән, укый-яза белә иде.* Р.Вәлиев

ӨЧЬЯКЛЫ *с.* Өч ягы булган, өч яктан гыйбарәт. *Фәния өчяклы көзге алдында киенгән арада, Юлия фермада булган яңалыкларны сөйли иде.* Р.Юсупова. *Пермь краеның Барда районы хакимияте һәм андагы Каенлы авылы белән КФУның Алабуга институты арасында өчяклы килешү төзелде.* Мәдәни җомга

ӨЧЬЯФРАК *и. бот.* 1) Өч аерчадан торган яфрак төре

2) Вахтачалар семьялыгыннан Төньяк ярымшарның баткак урыннарында үсә торган күпьеллык үлән үсемлек; *русчасы:* **трилистник, клевер ползучий**. *Йокысызлыктан интеккәндә, 2 шәр өлеш бөтнек яфрагы, кондыз үләне (өчьяфрак), песи үләне тамыры, колмак яфрагын кушып, 2 стакан кайнар суда 20 минут төнәтәләр, марля аша сөзәләр, иртән, көндез һәм кич яртышар стакан эчәләр.* Мәдәни җомга

ӨШӘЛӘК I *и. диал.* Кар эченә ясалган куян өне

ӨШӘЛӘК II *с. диал. к.* **өшүчән**

ӨШӘЛӘ́Ү *ф. диал.* Бик тиз генә, аннан-моннан гына эшләп ташлау

ӨШӘЛЕК *и.* Кар эченә ясалган куян өне. *Өшәлеккә тап булу*

ӨШӘН *с.* Хәлсез, ябык, йончыган. *Өйдән кечерәк буйлы, ак чырайлы, җирән сакаллы, арык-өшән генә бер абзый чыкты.* Ә.Еники. *Шуңа сабыйлары да бик өшән, еш чирли.* З.Фәйзи

ӨШӘНГӘНЛЕК *и.* Хәлсезлек, арыганлык, йончыганлык. *Әни кешедә картлык, өшәнгәнлек тә бик сизелә иде.* Ф.Хөсни

ӨШӘНДЕРГЕЧ *с.* Хәлсезләндерә, йончыта торган (мәс., авыр эш)

ӨШӘНДЕРҮ *ф.* 1) Хәлсезләндерү, талчыктыру, арыкландыру, йончыту, хәлдән тайдыру (гадәттә атлар тур.). *Бертөрлерәк атлылар өчен таңда чыгып, чакырылган вакытка килеп җитү авыррак та, атны да бик өшәндерә.* Г.Ибраһимов

2) *диал.* Мәшәкатьләү, борчу

Өшәндереп бетерү Тәмам өшәндерү

ӨШӘНҮ *ф.* 1) Хәлсезләнү, арыклану; йончу, хәлдән таю. *Әхмәтвәли, картка карап, аның күпме картайган, өшәнгән булуына гына түгел, бигрәк тә менә шулай яшен суккан агачтай сүнеп калуына гажәпләнә иде.* Ә.Еники. *Коръәнхафиз моны искәрде һәм, килеп, Чибәркәйгә «кечтеки» генә черем итеп алырга кирәклекне сеңдереп азапланды: – Ялсыз булмый ла ул! Ял итмәсә, ат та өшәнә бит, тарта алмый башлый!* М.Шаһимәрдәнов. *Крестьянның утлауга җибәргән аты көн саен өшәнеп кайта.* И.Нуруллин

2) *диал.* Мәшәкатьләнү, борчылу, тынгы күрмәү. *Кайтыйк әле, Наис, Мөслимгә бер – Өшәнгән бу бәгырь җылынсын...* Зөлфәт

Өшәнеп бетү Тәмам өшәнү

Өшәнеп калу Ниндидер вакыйгадан соң өшәнгән хәлгә килү. *Хәнҗәр дә күк айгырның алда барганын күрде. Ул бөтен көчен җыеп чаба башлады. Вилдан аның кызуланып китеп өшәнеп калуыннан курка иде.* Ш.Алкин. *Өшәнеп калган фетнәчеләрнең күпчелеге әүвәл Алабуга янына, аннары инде бөтенләй Әгерҗе районындагы хәзер су астында калган Барҗы авылына кадәр чигенә.* В.Имамов. *Бөкрәеп, өшәнеп калган иде хәрәм атакай. Карт «алашаның» гәүдә-сынында гына түгел, йөрү рәвешендә дә ир-ат сыйфаты калмаган иде инде.* М.Хәбибуллин

Өшәнеп китү Соңгы арада гына өшәнү. *Менә, исмасам, минем җирәнне сөйлә! Хайванга әле йөрү күп булды, өшәнеп китте.* Г.Исхакый. *Тик бик өшәнеп киткән син, Хөсәен, әллә чирлән йөрисеңме?* А.Расих

ӨШӘНЧЕК *и. этн.* Кияүгә чыга торган кызның үзе сугып яки тегеп

әзерләгән бирнәсе (мәс., чаршау, ашъяулык, сөлге һ.б.ш.). *Менә шулай итеп, унҗиде яшенә кергәндә, кызның өшәнчеге, бирнәсе бик бай булып әзерләнеп җитте.* Г.Ибраһимов. *Зөһрәбану да җиткән кыз булгач, Бибинур йорттан әллә ни әйбер алып чыкмады, күлмәк-күнчеген, сөлге-тастымал ише хаҗәт вак-төякне генә алды, үзенә дип әзерләнгән өшәнчекләрне туганына калдырды.* А.Гыйләҗев

ӨШЕТКЕЧ *с.* 1) Бик салкын, туңдыра, өшетә торган

2) *күч.* Коточкыч, бик куркыныч. *Бу хәлдән безнең эчебезгә, салкын бизгәк шикелле, өшеткеч бер курку йөгерде.* Ә.Еники. *Ана-кам башын югары күтәрде һәм Исәнтәйгә салкын, өшеткеч бер караш ташлады да, үтергеч итеп: – Син, Исәнтәй, мине алдамакчы булып утырасың! – диде.* Н.Фәттах

ӨШЕТТЕРҮ*ф.* 1) *йөк. юн. к.* **өшетү**

2) *з.-сыз* Суыкның, тәнгә үтеп, зарарлы тәэсир итүе; тәндә өшү тойгысы барлыкка килү; өшетү, туңдыру. *Салкынча җил өрә, бераз өшеттерә дә башлады: күлмәктән генә чыгып йөргәнбез.* Л.-Х.Таналин

ӨШЕТҮ *ф.* 1) Туңдыру, туңарга ирек бирү, юл кую яки мәҗбүр итү. *Алар [шәкертләр], оек яисә юка читек өстеннән аякларына агач башмаклар элэктереп, сәгатьләр буенча, аяк бармакларын өшеткәнче, 20–30 градус салкында сугышка китүче солдатларны тамаша кылуны үзләренә гадәт иттеләр.* К.Тинчурин. *[Миңлебай:] Ходай хакы өчен кертегез инде, аяк-кулларымны өшеттем, ахрысы.* З.Зәйнуллин. *Кыш үзенең хозурлыгын саклап, эре кыяфәте белән урманнарда йөрде, ак сакалын межаларда тарый-тарый, басуларда йөрде, битләрне өшетте, әле борыннарга чиртте...* Ф.Яхин

2) *сөйл.* Берәр дару ярдәмендә тәнне сизмәслек хәлгә китерү, туңдыру (операция вакытында). *Егеткә үзенең теләгенә күрә операцияне наркозсыз гына, өшетә торган уколлар кулланып кына ясаганнар иде.* М.Шаһимәрдәнов

3) *сөйл. з.-сыз к.* **өшеттерү**. *Башта өшетте, аннары яндыра башлады. Ә менә хәзер тагын калтырата...* Ә.Еники. *– Ярар, мин керим инде, – диде кыз. – Өшетә дә башлады.* Р.Зәйдулла

Өшетә башлау Өшетергә тотыну. *Кулдан күчкән суык дымлы маңгае аша ми шәрәфләрен өшетә башлагач кына күзләрен ачты.* Г.Гыйльманов

Өшетеп алу Бераз вакыт өшетү. *Ләкин бу наздан ниндидер салкынлык бөркелеп тора, шул салкынлык Искәндәрнең күңелен өшетеп-өшетеп ала иде.* Г.Гыйльманов

Өшетеп бетерү Тәмам өшетү, бөтен җирен өшетү

Өшетеп җибәрү Кинәт өшетү. *Бераздан боз салкыны баш сөяген өшетеп җибәргән кебек булды.* М.Шаһимәрдәнов. *Халисәдәге салкынлык, битарафлык кинәт аны өшетеп җибәрде.* Р.Юсупова. *Ярсып та, ачуланып та әйтелгән бу сүз мине өшетеп җибәрде.* Г.Минский

Өшетеп кую Тиз арада өшетү

Өшетеп тору Гел, һәрвакыт өшетү. *Яшьләрнең бәхетле көннәре бик санаулы булды, --- һәркайсының йөрәген өшетеп торган рәхимсез сугыш кара канатын, ниһаять, алар өстенә дә җәйде.* Ә.Еники

ӨШКӘ *и.* Кисә торган өлеше түгәрәкләнеп торган өтерге

ӨШКЕ *и.* Бораулап тишелгән тишек эчен шомарта торган корал

ӨШКЕРТҮ *ф.* 1) Кемнән дә булса сихри көчкә ия булган сүзләр әйттереп һәм төкертеп, авыруны дәвалаганда куллану өчен, берәр нәрсәне шифалы иттерү. *Әллә нәрсәләр өшкертеп, шуларны [Галимә апага] көчләп эчертү кебек эшләрнең берсе дә калмады.* М.Гафури. *Дәва эзләп, шифа кайгыртып йөрим, менәгенәк Хөббихуҗа мәзиннән лимун суы өшкертеп китердем.* Ш.Камал

2) Берәр авыруны кемнән дә булса сихри көчкә ия булган сүзләр әйттереп һәм төкертеп дәвалау; имләү. *Атасы-анасы, малаебыз акылдан язган дип, өшкертә-төкертә башлыйлар.* Әкият. *Ул, мәхдүмне көнләп, фәлән хатын боздырган, фәлән кеше сөйдергән дип, ырымланырга, шул боздыруларны бетертер өчен өшкертергә тотынды.* Г.Исхакый. *Ташаякка бару урынына, аны Мөхетдин суфига өшкертергә алып киттеләр.* Ә.Фәйзи

Өшкертеп алу Тиз генә, шушы арада гына өшкертү. *Кара мулладан өшкертеп алган агач маен ул эссе мунчада һәм мунчадан соң да кабат-кабат сөртте.* Ш.Камал

Өшкертеп тору Гел, һәрвакыт, даими рәвештә өшкертү

ӨШКЕРҮ I *ф.*1) Сихри көчкә ия булган сүзләр әйтеп, өреп, төкереп, авыруны дәвалау. *– Нигә әтигә төкерәсең? – дип, карчыкка килеп ябыштым. – Нигә төкерәсең аңа, нигә? – Төкермим, улым, төкермим, – диде әби, – өшкерәм.* Н.Дәүли. *Егетнең үзен генә калдырмыйлар диярлек: ниндидер урта яшьләрдәге хатын (имче булса кирәк) яраларын өшкерә, дәвалый, көненә биш тапкыр ашарга китерәләр.* И.Хуҗин. *[Мөсәллим карт] Кемгәдер догалык-бөти язып бирә, кемгәдер шамаил-тугра ясый, кемнедер хәтәр авырудан өшкереп имләгәндәй итә, кемнеңдер югалган әйберен эзләп, язмышын юрап, китап ача...* Г.Гыйльманов

2) Сихри көчкә ия булган сүзләр әйтеп, өреп, төкереп, авыруны дәвалаганда куллану өчен, берәр нәрсәне шифалы итү. *Алай да Көнбаш атакайның тырышлыгы бушка китмәгән икән, өшкергән ялкынның ярдәме тидеме – бермәлгә аңын югалтып торган Шимбай хан күзләрен ачты ---.* М.Хәбибуллин. *Динебездә Коръән аяте белән суга уку (өшкерү һәм эчү), тмин мае белән өшкерү рөхсәт ителгән.* Ватаным Татарстан

3) *күч. гади с.* Арт сабагын укыту, өйрәтү. *[Булат:] Минем кулыма эләксә, өшкерермен мин аны.* К.Тинчурин. *[Сафа Галимҗанга:] Бераз өшкерә төш үзен! Дулаган атны да туктаталар.* Ф.Бурнаш. *Мәкшыя аларның «тимер саплы пәке», «кастет», «иманын өшкерәбез» дигән хәтәр сүзләрен ишетте.* М.Шаһимәрдәнов

Өшкереп алу Тиз генә өшкерү

Өшкереп кую Бер вакыт эчендә өшкерү

Өшкереп тору Гел, һәрвакыт өшкерү

ӨШКЕРҮ II *и.* Сихри көчкә ия булган сүзләр әйтеп, өреп, төкереп,

авыруны дәвалау яки берәр нәрсәне шифалы итү эше. *Хәзрәт, остабикәсе башына сөлге урап, аның очларын каты кысып бәйләде дә, бер кулы белән хатынының авыру башын селеккәләп, ә икенчесе белән әкрен генә аның маңгай турысына суккалап, өшкерү сүзләре пышылдарга тотынды.* М.Галәү. *Ләкин авыр таш астында калып сөякләре челпәрәмә килгән аякка Мәфтуха әбинең өшкерүе түгел, хәтта яшел чалмалы ишанның «хасиятле» сулары, тозлары да файда китермәде.* К.Тинчурин. *Галимулла хәзрәтнең чынаяк язып өшкерүләре, земской шифаханәдән китерелгән яһүд духтыры, кара канын ишаннан суыртулары – берсе дә ярдәм итмәде.* Ф.Яхин

ӨШКЕРҮ-ТӨКЕРҮ I *ф. к.* **өшкерү** I (*1, 2 мәгъ.*). *Карт өшкереп-төкереп, аның күзенә ниндидер тамчылар тамызды.* Ә.Фәйзи. *Ыру шаманы Акай күз өшкереп-төкереп бакты, файдасы тимәде.* Н.Әхмәдиев. *Имтом, өшкерү-төкерү белән гадәттә динчеләр шөгыльләнгән.* Г.Гыйльманов

ӨШКЕРҮ-ТӨКЕРҮ II *и. к.* **өшкерү** II. *Өшкерү-төкерү галәмәтләренең хикмәте бар икәнлегенә чын күңелдән ышанган ярлы-ябагайның күңеленә хуш килгән, балаларына үрнәк саналган кешенең болай адәм рәтеннән чыгуы авылдагы көнкүрешнең тәртибен бозарга мөмкинлеген сизенгән байлар, ике көн рәттән, үзен һәм абыстаен ашка чакырып, шактый сыйлагач кына сихәтен тапты Аллаһ бәндәсе.* Ф.Яхин

ӨШКЕРҮЧЕ *и.* Өшкерү I (*1, 2 мәгъ.*) эшен башкаручы, өшкерү эше белән шөгыльләнүче. *Өченче берәүләре исә берәр им-томчы яки өшкерүче чакырырга тәкъдим иттеләр.* М.Галәү. *--- һәм шундый бер иманлы хезмәткәр, бик җитди рәвештә, Мирбулатка: «Хатыныгызны психиатрик хастаханәгә тикшерелергә илткәнче, иң элек өшкерүче әбигә яки бабайга күрсәтеп карагыз әле», – дигән.* М.Шаһимәрдәнов. *Чын өшкерүче кешенең кай төше, нинди әгъзасы авыртканын әйтә алмый, ә сихерче бавырың, үпкәң яки башка җиреңнең сәламәт булмавын әйтә.* Ватаным Татарстан

ӨШКЕРҮЧЕЛЕК *и. кит.* Өшкерү I (*1, 2 мәгъ.*) шөгыле

ӨШКЕРҮЧЕ-ТӨКЕРҮЧЕ *и. к.* **өшкерүче**. *Өшкерүче-төкерүче, төш юраучы Сәрви карчыклар да абыстайның хәлен белергә киләдер.* Ш.Мөхәммәдев. *Баштагы өч елда моны ничектер уйламадылар, дүртенче, бишенче елларда хатын үз эченнән көенде, Алладан елап сорады, им-том итүче, сихерләүче, сихер кайтаручы, күрәзәлек кылучы, өшкерүче-төкерүче карчыкларның берсен дә калдырмады, һәммәсеннән шифа эзләде.* Г.Ибраһимов

ӨШҮ I *ф.* 1) Салкынны, суыкны начар кичерү, тәненә суык үтү. *Беркөнне шулай лычма су булып, өшеп кайтып керүем булды: – Менә сиңа хат, – дип, Маһинур конверт тоттырды.* И.Салахов. *Без өшедек. Ah, хәерсез сәгать! Туңып үләбезме далада?* А.Хәлим. *Иртәнге салкыннан түгел, Камилә күбрәк шул шомлы, шыксыз төштән өшү, шул ямьсез хатирәләрне кабат-кабат күзаллап, калтыранып, тетрәнеп утыра...* Г.Гыйльманов

2) Салкыннан, суыктан һәлак булу, туңып үлү. *Колхоз идарәсе онытмасын: быел кышкы салкыннарда өшегәннәре урынына яшь алмагач утыртырга кирәк булыр.* Г.Бәширов

3) Туңу. *Үсемлекләрнең өшеп юкка чыгу куркынычы бар. Бүген үк, хәзерге минуттан үк чарасын күрергә кирәк.* А.Алиш. *Кичәдән бирле безнең полкка бик күп җәрәхәтле һәм өшегән кызыл-армеецлар киләләр.* Ә.Еники. *Иң куштан симез сары тавык әтәч артыннан келәт астына кереп йомылды, ябыграк кара тавык, кысыла-кысыла, капка астыннан урамга ук чыгып китте һәм егылган әтәчнең иң явыз дошманы булган өшегән кикрикле ак әтәч тирәсендә сырпаланырга тотынды.* А.Гыйләҗев

◊ **Өшегән авыз** Юньсез, булдыксыз кеше турында. *[Гөлҗиһан:] Бирермен, өшегән авыз, сиңа йомышыңны. Күзең чыккан нәрсә!* Г.Камал. **Өшегән күркә** *к.* **өшегән авыз**. *Син, өшегән күркә, анда Коръән укыган булып гыдырама.* Х.Кәрим

Өшеп бетү Тәмам өшү; булган бар нәрсә дә өшү. *– Шту син, шту син, – ди икән Хәмит абзый, – базның стеналары начар, өшеп бетәр ул [бәрәңге].* М.Мәһдиев

Өшеп китү Хәзерге моментта кинәт өшү, өши башлау. *Шәйдулланың йөрәге өшеп китте.* М.Мәһдиев. *Әхмәтвәли, картның сүзләренә әллә ничек өшеп, калтыранып китте.* Ә.Еники. *Бу уеннан ханбикә өшеп китте, күз алдына җимерелгән Казан, Хаҗитархан килде, әнисенең фаҗигале язмышы исенә төште.* Ф.Бәйрәмова

Өшеп кую Кинәт кенә өшү. *Бу сүзне ишетүгә, җитмәсә императорның тутасы авызыннан, Таҗчулпанның аркасы өшеп куйган иде.* М.Хәбибуллин

Өшеп тору Хәзер өшү; гел, даимән өшү. *Яле, Гайниҗамал, әнә теге төенчектә азрак әлеге ни... бардыр азрак, азрак нитеп алыйк, кичәдән бирле әллә нишләп аркалар өшеп торган шикелле була.* Ш.Камал. *Күрәсең, авыруның башы миндә «Шәрык кичәсе»нә барганчы ук булгандыр инде, тик салкын арандай сәхнәдә өшеп торуым аны көчәйтеп кенә җибәргәндер.* Ә.Еники

Өши башлау Өшү билгеләре сизелү. *Энемнең аягын тегәргә дип, хирургыбыз хөрмәтле Булат әфәнде өшетә торган («местный наркоз» дибез аны) укол кадый да, аякның өши башлаганын да көтмичә, тегәргә тотына.* Безнең гәҗит

ӨШҮ II *и.* 1) Салкынның тәнгә чамадан артык тәэсир итүен тою. *Өшүе дә, ярасы да онытылган кебек булды.* Х.Камалов

2) Һәлак булуга, үлемгә яки имгәнүгә китерә торган түбән температура һәм шул температураның тәэсире. *Өшүдән саклау өчен, каен җиләген кышка 4–5 сантиметр калынлыкта салам, агач яфраклары яки башка материаллар белән каплыйлар.* Җиләк-җимеш бакчасы утырту

ӨШҮЧӘН *с.* Салкынга, суыкка чыдамсыз, тиз өши торган. *Туган йортында үскән шомырт чәчәкләре карлы буран яугандагыча, шагыйрьнең өшүчән тәнендә бала йоннары калкып куймадымы икән?!* З.Мансуров

ӨШҮЧӘНЛЕК *и.* Өшүчән булу. *Тукай үзенең мәхәббәт тарихын да*

өшүчәнлек бәласенә китереп бәйли. З.Мансуров

ӨЮ *ф.* 1) Нәрсәләрне дә булса бергә җыеп, тәртип белән берсе өстенә икенчесен куеп урнаштыру. *Коймалар, мичкәләр өйгән рәттә Выжылдап куышалар кургашын уклар.* К.Нәжми. *Аннары нәкъ урта бер җиргә тәбәнәк кенә өстәл куеп, аның өстенә зур-зур, калын-калын китапларын өяләр.* Ә.Еники. *Сугыш алды елында, көздән җир туңгач, алма бакчасына такта-бүрәнә кертеп өйгәннәр иде.* М.Хуҗин

2) Бер урынга, бергә китереп күпләп салу, кую. *Астына мендәр өйгән – күрдем түрендә хәлфәсен, Ул кырын салган начар, очлы вә кыршылган фәсен.* Г.Тукай. *Сәлим абзый шулай сөйләнә-уйлана, йомычкаларны-кайрыларны бер җиргәрәк өеп маташкан балта остасы Латыйп абзый янына килеп тукталды.* Ф.Яхин

3) *сөйл.* Салу, төзү (өйне, мичне). *Мич ишелсә, мичне үзе өйде; арба, чана ватылса, үзе төзәтте [әти].* Г.Толымбай. *Бу хәл римлыларның җен ачуларын чыгара, һәм консул Агриппа яһүдләр өйгән диварны җимерергә боера.* М.Хәбибуллин. *Шулай да үзем баш булып беренче тапкыр бура өям.* Ф.Яхин

4) Салу, кую (кибәнне, чүмәләне). *Өйгән кибәнне җилләр тарата, Кавышабыз дигәч, хәзер таң ата.* Бәет. *Сәнәк каерылса да, билләр түзде, Салам өйдек, кибән куйдык без.* Ш.Галиев. *Кемнәр чапкан, кемнәр өйгән: Болыннарда – кибән... кибән...* Ә.Харрас

5) Өем ясау, өем барлыкка китерү. *Үгез чөя-чөя дә өстенә чүп өя, дигән сүз бар, хатын. Син дә шулай булма.* Г.Толымбай. *Печәнне чабу гына түгел, аны вакытында киптереп кибәнгә куясы, кайтарып өясе дә бар.* Ф.Яхин

6) Үсемлек төбендәге туфракны йомшартып, аның сабагы тирәли өем ясау. *Һәр бакчада ике-өч кеше (мөгаен, шәһәрнекеләр дә бардыр), кайсы күлмәктән, кайсылары пляж киеменнән генә калып бәрәңге төбе өяләр.* Ф.Яхин

7) *күч.* Бер кешегә бик күп вазифа, җаваплылык йөкләү. *Бер кешегә генә дөнья эш өю*

8) Берәүне гаепләү, гаеп ташлау, төрле гаепләр тагу, сылтау, аудару. *Бөтен гаепләрне минем өскә өйде дә куйды.* Г.Толымбай. *Алар бер-берсе өстенә шундый гаепләр өяләр ки, тыңлап утырганда, колаклар яна башлый.* Ә.Еники. *Сез – зиһенле, укымышлы кеше, иптәш прокурор, аңлыйсыз инде, милициядәге кебек, мәктәпләрендәге бөтен тәртипсезлекне бер минем малай өстенә өйгәннәр.* Ф.Дәүләтбаев

Өеп кую Тиз арада өю, өеп әзер хәлгә китерү. *Хәтта әле капка төпләренә, бакча яннарына, койма буйларына өеп куелган кайбер сусылрак агачларның кабыкларын да чәйнәп суыра ул.* М.Шаһимәрдәнов. *--- болын тирәләреннән җәй буена җыйнаштырып туплаган печәннәрен дә лапас астына яхшылап өеп куйган җирдән алып чыгып киттеләр.* Ф.Яхин. *Алда – кеше кулы белән өеп куелган төсле зур булмаган текә һәм биек тау.* Д.Каюмова

Өя бару Рәттән, берсе артыннан берсен өю. *[Бүрларның] Менгән берен үтереп, уң колагын кисеп алып, гәүдәләрен шунда өя бара егет.* Әкият. *Айсылу бүләк әйберләрне өсте-өстенә өя бара, һәм аңа шушы бүләкләрдән халыкның күңел җылысы бәрелеп торадыр шикелле тоела.* Г.Бәширов. *Ачкычын оясында калдырып, эчкә керде, дивангa тотына-тотына, мыштырдап чишенде, киемнәрен кул астындагы урындыкка алак-шалак өя барды.* А.Гыйләҗев

Өя башлау Өяргә тотыну. *Корена (исеме шулай иде кызның) минем өскә тиз генә салам өя башлады.* З.Мәхмүди. *Күңеле тулуын сиздермәскә була, тиз үк, элекке гадәтенчә, аларга эшне дә өя башлады.* Д.Булатова

Өя бирү Бернигә дә карамый өюен дәвам итү. *Фазылның әнисе дә шулай акрын гына маташа, берни дә сизенмичә, бәрәңге төбен өя бирде.* Ф.Яхин

Өя төшү Тагын бераз өю

Өя тору Башка эш-хәл белән бер үк вакытта яки ул башланганчы өю. *Солдат монда шулай алтынны чөя тора, тегермәне тегендә һаман тозны тартып өя тора икән.* Әкият. *Апажиңгилар һәм кыз-кыркын кипкән печәнне аерым күбә, чүмәләләргә җыйды, ә олырак яшьтәге агайлар болын буйлап тезелеп киткән шул күбәләрне көшел бауларына эләктереп, ат белән тарттырдылар һәм китерелгән берен богыл, кибәннәргә өя тордылар.* М.Галәү. *Бу яктан машинадан чыккан саламнарны чүмәлә-чүмәлә өя тораларлар.* Г.Ибраһимов

ӨЯЗ *и. рус тар.* 1) Россиядә 1929 елга кадәр районнарга бүлгәнче губернаның бер состав өлеше булган административ-территориаль берәмлек. *– Мин үзем Хвалын өязендә бер кечкенә авылда имам булып торам, – диде мулла.* М.Галәү. *Мин элекке Кузнецк өязендә, караңгы мишәр авылында – Ялгашта тудым.* Г.Кутуй. *Ул патша заманында өяз үзәге булып торган, үзенең базарлары һәм кибетләре белән дан тоткан, иң укымышлы, бай, үткен кешеләр Караболак татарлары булган.* Ф.Бәйрәмова

2) Шундый административ-территориаль берәмлектә яшәүче халык. *Борын заманда бер ата-анадан түгел, бөтен өязеннән бу кадәр укымышлы башкорт чыкмагандыр.* Ә.Еники

ӨЯК *и. махс.* **1.** Нинди дә булса хайван тиресенең корсак асты өлеше

2. *с. мәгъ.* Шундый тиредән тегелгән. *Өяк тун*

ӨЯЛӘП *рәв. диал.* Җәелеп, зур ябалдаш ясап. *Нарат төз карап үсәр, өянке өялән үсәр.* Мәкаль

ӨЯН *и. диал.* Ишиас авыруы; бил сызлау

ӨЯНӘК *и.* 1) Нинди дә булса авыруның, чирнең вакыт-вакыт була торган кинәт көчәеп китүе; тотанак. *Әмма шул вакытта алган көчле нурланыш һәм соңыннан өстәлгән радиация аны гомер буе эзәрлекли, йөрәк өянәкләре белән ега һәм нәтиҗәдә, газаплап, дөньядан алып китә.* Ф.Бәйрәмова. *Зөһрә аптырап бетте: иренең тагын авыру өянәге кузгалдымы?* Г.Гыйльманов. *[Әкрәм:] Югыйсә йөрәк өянәге ала яздым ич...* Р.Зәйдулла

2) Баш сызлау авыруы, мигрень авыруы. *Шауларга ярамый: әбекәйнең баш өянәге кузгала.* Ә.Дусайлы

3) *сөйл.* Бума, бума чире, зыяндаш авыруы, эпилепсия. *[Нәзифә:]*

Өянәктән үләсең килә мәллә, ипташ юлдаш? Р.Зәйдулла

4) *күч.* Нинди дә булса бер хәлнең, халәтнең һ.б.ш. кабатлану күренеше. *Ялгыз гына хакимлек итәргә ярату-чыларның бу – котылгысыз бер өянәге булса кирәк.* Ә.Еники. *Минем барыннан да битәр ялкаулыктан котыласым килә, вакыт-вакыт аның өянәге кузгалгалый.* Р.Мостафин

5) *күч.* Рухи кризис, читен хәл. *Айлар буе җир җимертеп эшләде [Җилкуар Тимбик]. Өянәге кузгалып, атна буе эчте...* Г.Ахунов

◊ **Өянәге килү** Өянәге тоту. *Мин аны өянәге килгән берәр кешеме дип торам тагын!.. --- Саташып сөйләнүе һаман дәвам итте, көн саен өянәге килеп җәфалады.* М.Галәү. **Өянәк тоту** 1) Бума чире, зыяндаш авыруының кинәт көчәеп китүе. *Өянәге тоткан авыру кебек, түшәгендә калтыранып утырган Газинурның иләс-миләс хәлгә төшүен чамалап, Гөлнәзирә үзе дә исен-акылын җуя язды.* Г.Гыйльманов. *Мәңгелек кала дигәнне алганнан соң, Аларих король өянәге тотып үлә.* М.Хәбибуллин; 2) Рухи кризис кичерү. *Тукайны оныткан саен татарны өянәк тота.* Р.Харис

ӨЯНӘКЛӘ́Ү *ф.* 1) Авыруы, өянәге кузгалу

2) Бума чирдән, зыяндаш авыруыннан интегү

Өянәкләп китү Кинәт өянәкләү

Өянәкләп тору Әле, хәзерге вакытта яки гел, һәрвакыт өянәкләү

Өянәкли башлау Өянәк билгеләре сизелү

ӨЯНӘКЛЕ *с.* 1) Нинди дә булса авыруның көчәюе еш кабатлана торган. *«Халык дошманы»ның килене булып, аңын югалттырырлык сорау арты сораулардан соң, йөрәк өянәкле бер хатынга әйләнде Маһисәрвәр апасы.* Идел

2) Бума чирле, зыяндаш авырулы. *Яңа ел алдыннан 25 декабрьгә кадәр «Радость детства» хәйрия фонды церебраль өянәкле балаларга булышлык итү максатында «Вак-төяк – вак-төяк түгел» дигән акция үткәрә.* Безнең гәҗит

3) *күч.* Борчулы, борчу тудыра торган. *Аларның [Сәгыйдулла Хафизов белән Марсель Котлыгалләмовның] җәмгыятьтәге иң өянәкле ноктага әледән-әле тамып торган ялкынлы, әмма шифалы публицистик мәкаләләре гәзит өчен йөзек кашына тиң.* Кызыл тан

ӨЯНКЕ *и. бот.* Таллар семьялыгыннан карасу соры кабыклы, озын тар яфраклы, зур булып үсә торган агач; *русчасы:* **ветла**. *Яр буенда, безнең бакча артында колач җитмәслек уникә өянке үсеп утыра, әле аста вак таллык иде.* Ф.Яруллин. *Шушы якта, шушы туфрактан без. Читтә йөрсәк, шуңа күрәдер, Чишмәләре чыңлап, өянкеләр елап, Таллар җырлап төшкә керәдер.* К.Булатова. *Бер-бер артлы тезелешеп баскан Моңсу өянкеләр тыңлый аны.* И.Диндаров

ӨЯНКЕЛЕК *и.* Күпләп өянкеләр үсә торган урын, өянке урманы. *Ләкин Рәхилә карчыкның күңеле үз урынынан купкан иде инде. Ул һаман-һаман өянкелеккә карап ала, анда кемнедер эзли...* Г.Гыйльманов

П

ПА *и. фр. сәнг.* Биегәндә аякларны үзенчәлекле итеп басудан гыйбарәт ритмик хәрәкәт; бию адымы. *Үз күчәрләре тирәсендә әйләнә-әйләнә, гажәеп па ясый-ясый, әкрен генә төшкән ак кар бөртекләре дә балериналарга охшаган иде*. Идел. *Җәйге ял вакытында артистларның шактые балет башмаклары һәм палар турында онытып тора*. Шәһри Казан

ПАБЛИ́СИТИ *и. инг.л.* 1) Массакүләм мәгълүмат чаралары ярдәмендә, публика алдында күпсанлы чыгышлар ясау нәтиҗәсендә ирешелә торган популярлык, танылганлык

2) Сатып алу күләмен арттыру максаты белән ясалган реклама, белдерү һ.б.ш. кызыксындыру чаралары

ПАВИАН *и. нем. зоол.* Мартышкасыманнар семьялыгыннан Африкада һәм Гарәбстанда яши торган эре гәүдәле, озынча танаулы маймыл; эт башлы маймыл. *Ата павианнарның баш һәм күкрәк өлеше куе, озын йонлы мантия белән әйләндереп алынган*. Кызыклы география. *Кайбер маймыллар, мәсәлән, павианнар җирдә яшәргә яхшы җайлашканнар, ләкин андый маймыллар аз.* Хайваннар дөньясы. *Башка маймыллардан «банда» оештырып, 2010–2011 елларда ул шәһәр халкының теңкәсенә тигән павианнар туристларга һәм җирле халыкка һөжүм иткән, ризык урлаган, автомобильләрне әйләндереп каплаган.* Мәдәни җомга

ПАВИЛЬО́Н *и. фр.* 1) Бакчаларда, паркларда гадәттә ял итү өчен бизәкләп эшләнгән җиңел корылма. *Читтәге павильоннарда сыра, кымыз, тәмлетомлы нәрсәләр саталар*. А.Расих. *Ә хәзер монда ял итүчеләргә өсте ябулы ике павильон хезмәт күрсәтә һәм юллар ремонтлау бара.* Кама ягы

2) Күргәзмә, сәүдә экспонатларын урнаштыру өчен төзелгән зур, ләкин гади корылма. *1937–1941 елларда Б.Урманче Бөтенсоюз авыл хуҗалыгы күргәзмәсенең төрле павильоннарында нәкышь һәм скульптура эшләрен башкара.* К.Миңлебаев. *Павильон корылык бина юк...* Р.Батулла. *Технополисның беренче павильоны шәхси эшмәкәрләргә һәм юридик затларга арендага бирелде, икенче павильон файдалануга тапшыру алдында*. Шәһри Казан

3) Кино яки видеоклиплар төшерү өчен җиһазландырылган корылма. *Фильмның 30–40 процценты гына павильонда төшә ләбаса.* Сәхнә. *Павильонны кино төшерү өчен әзерләргә кушылды*

ПАГИНА́ЦИЯ *и. лат. кит.* Басма яки кулъязма әсәрләрдә бит яки баганаларның номерлар белән билгеләнүе. *Архив пагинациясе 249*. Ф.Әхмәтова-Урманче

ПА́ГОДА *и. санскр. дини* Буддистлар яки индуистларның күпьяруслы башня рәвешендә төзелгән гыйбадәтханәсе. *Мин һиндуси гыйбадәтханәдә һәм борынгы пагодада да булдым, тик анда да аның эзләре юк иде.* Фән һәм тел. *Бүген ТР Президенты Рөстәм Миңнеханов эш сәфәре барышында Мьянманың төп истәлекле урыны, дөньяда иң танылган будда пагодаларының берсендә – Шведагон пагодасында булды*. Татарстан яшьләре

ПАДЕГРА́С *и. фр. сәнг.* Салмак нәфис хәрәкәтләрдән торган парлы бию. *Уртада пар-пар тезелешеп падеграс бииләр.* Г.Мөхәммәтшин. *Укучылар хореография укытучысында мастер-класслар ала һәм балның төп элементлары булып саналган бию формаларына: вальс, полонез, падеграс һәм полькага өйрәнә.* Р.Батулла

ПА-ДЕ-ДЕ *и. фр. сәнг.* Классик балетта төп ике башкаручының бергә бию. *Нуриев белән Сизова «Эмеральда»дан па-де-де, аннан соң Нуриев үзе генә «Лауренсия»дән Фрондосоны башкарырга тиеш иде.* Р.Батулла. *Чайковскийның «Щелкунчик» балетыннан па-де-де бу.* Ватаным Татарстан

ПАДИША *и. фар.* Патша, монарх, мәлик. *Падиша хәзрәтләре, сез сакалыгызны кырдырырга уйласагыз, бик тә йомшак, әйбәт итеп алучы кеше бар.* Әкият. *Уң ягында – падишалар, муллалары, поплары. Сул ягында – канлы байрак, Янган ирек утлары.* Н.Исәнбәт

ПАДИША́Һ *и. фар. к.* **падиша**. *Бу тарафта Багдад падишаһы: «Сәба шәһәренә киткән илчеләр, гажәба, кайчан кайтыр вә ни хәбәр китерер икән?» – дип монтазыйр булып (көтеп) торганда, илчеләр кайтып җиттеләр*. К.Насыйри. *Көннәрдән беркөн бер падишаһ сунарга чыккан иде.* Дәрдемәнд. *Падишаһ хәзрәтләренә яхшы хезмәт итегез.* М.Гафури

ПАДИША́ҺЛЫК *и. иск. к.* **патшалык**. *Тәхет өстендә бер падишаһ утырмыш: ак сакалы – күкрәгендә, падишаһлык тажы – башында, алтын кәмәр – биленда, падишаһлык киеме – иңендә.* К.Насыйри. *Кечкенә бер халыкның зураеп падишаһлык ясавы, ул падишаһлыкның дөньяның иң зур падишаһлыклары арасына керүе, соңыннан аның акрын-акрын гына җимерелүе күз алдымнан кичте.* Г.Исхакый. *Алладан сораган идең, ул изге сәгатьтә сиңа шул падишаһлыкны бирде.* Һ.Атласи

ПАЕТ *и. диал.* Лапас, киртә яки абзар. *Ат торган араталы пает астына якын килергә без, әлбәттә, шүрли идек.* Р.Зәйдулла. *Авылларда төзелеш туктамый бара, кайсы нигезен яңарта, кайсы яңасын сала, паетлар таштан салалар, яхшы күренеш.* М.Миначев

ПАЁК *и. рус* Билгеле бер срокка һәм билгеле бер күләмдә бирелә торган азык-төлек. *Менә следователь килгәч, тагын өстәмә паёк алырсың, бас аягыңа!* И.Салахов. *Өндәү-димләүләр –*

политрук эше, ул шуның өчен паёк ала, шуның өчен казна киемен туздыра. Г.Бәширов. *Тик ничек кенә булмасын, акча һәм паёк китерә торган укымышлы килен алдында куштанланырга Корбангали карт тәмам өйрәнеп җитте.* Ф.Хөсни

ПАЁКЛА́У *ф.* Паёкларга бүлү. *Паёклап бирелү*

Паёклап бетерү Барысын да паёклау; ахырга кадәр, беткәнче паёклау

Паёклап чыгу Башыннан ахырына кадәр паёклау

ПАЖ *и. фр. тар.* 1) Урта гасырларда Көнбатыш Европа илләрендә сарай хадиме булып, берәр асылзадәгә хезмәт итүче дворян улы – үсмер яки егет. *Үзенең чын йөзендә: Бегемот – ябык кына яшь кеше, шайтан – паж булып күренә.* Әкият. *Граф пажына сукмакчы була, ләкин ялгыш Фигарога кундыра.* М.Җәлил

2) Иске Россиядә өстен хокуклы хәрби училище (пажлар корпусы) шәкерте. *Минем буылып ютәлләвемә игътибар итмичә, пажлар уза торалар.* Р.Батулла. *Академия ул, минем карашымча, әгәр тарихтан хәтерләсәгез, патша вакытындагы Царское Село лицее, Паж корпусы, Преображенский полк кебек.* Р.Мирхәйдәров

ПАЙ *и. фар.* 1) Бүлеп биргәндә җан башына, исәптәге кеше башына туры килә торган өлеш. *Башын башка, аягын аякка ботарламыйча пай чыкмый.* Мәкаль. *Ул аталарыннан еш кына акча һәм күчтәнәч алып тора, бүгенге юача белән чикләвек аның пае иде.* Ә.Фәйзи. *– Алдап-йолдап безнең пай җирләрен алды да хәзер сөйләнеп торган була, – диде Сәлим.* Ф.Хәбибуллин

2) Уртак чыгымга катнашучыларның шул чыгымга керткән исәпле өлеше. *Пае бар ич, юккамы шул хәтле тырыша дип беләсең?* Ш.Камал

3) *күч.* Бәхет, өлеш, насыйп. *Уз паеңны ташлап, кеше пае артыннан йөрмә.* Мәкаль

◊ **Пайга керү** Берничә кеше, уртаклашып, күп акча таләп итә торган берәр эшкә керешү. *Байга кергәнче, пайга кер.* Мәкаль. **Пай салу** Кешеләр белән уртаклашып, өлеш җыеп, кирәк кадәр акча туплау. *Бер заманны ярлылар да чәй эчә иде май кабып, Инде бер шакмак шикәр юк, чәй алалар пай салып.* Ш.Бабич

ПАЙЗА *и. монг.* Кытай, монгол, татар хөкемдарлары тарафыннан кая да булса җибәрелгән затка аерым вәкаләтләр бирә торган язулы металл яки агач тактачык формасындагы ышаныч тамгасы. *Тагын әле җиз шәмдәлләр, инкрустацияләп эшләнгән сугыш балталары, тимергә алтын йөгерткән шишәк, инкрустацияле һәм гарәп хәрефләре белән язулы көмеш яки чуен пайза ише нәрсәләр хәтсез күп.* Р.Фәхретдинов

ПАЙЛАШУ *ф.* Пайга кереп бүлешү, уртаклашу. *Ике эт бер сөякне пайлашмый.* Мәкаль

Пайлашып йөрү Озак вакытлар дәвамында пайлашу эшен башкару

Пайлашып кую Тиз арада яки алдан ук пайлашу

ПАЙЛЫ *с.* Пайга нигезләнгән, нәрсә дә булса салышып, тиешле өлеш кертеп эшләнә торган. *Пайлы система*

ПАЙЛЫК *с.* Пай, өлеш өчен билгеләнгән, шуңа җитәрлек *Пайлык акча*

ПАЙОЛ *и. фр.* Диңгез йөк судноларының трюмында идәнгә җәелгән агач түшәмә

ПАЙП *иярт.* Каз һәм каз бәпкәләре бергә йөргәндә чыгара торган авазны белдерә торган сүз

ПАЙПАК *и. фар. диал.* Башы күн белән сабылган йомшак киез итек. *Пайпак киеп йөрү*

ПАЙПАКЛЫ ИТЕК *и. диал.* к. **пайпак**. *--- аякларында башлары очланып күтәрелгән пайпаклы итекләр.* И.Салахов

ПАЙП-ПА́ЙП ИТҮ *ф.* Күп тапкыр пайп авазы чыгару. *Урамда каз бәпкәләренең пайп-пайп килгән тавышлары ишетелә*

ПАЙПЫЛДА́У *ф.* 1) Пайп-пайп итү (каз бәпкәләре тур.)

2) *күч.* Ялынып, үтенеп сорау, сүз әйтү. *Шулкадәр әйттем, шулкадәр пайпылдадым – китте дә барды.* Ә.Баян

ПАЙТӘХЕТ *и. фар.* 1) к. **башкала**. *Истанбул шәһәре – Төркиянең пайтәхете дигән хакыйкатьләр – бөтен милләтләргә гам нәрсәләр.* Ф.Әмирхан. *Көнбатыш Двинаны үттек тә без яңа илгә – Литвага, аның пайтәхете Ковнога киттек.* Г.Гобәй. *Пайтәхеткә язган үтенечләр җавапсыз кала.* Ә.Кәримуллин

2) *күч.* Нәрсәнең дә булса мәркәзе, үзәге. *Кайтамын туган ягыма Елның бай вакытында; Утырам Казан артында – Телнең пайтәхетендә.* С.Хәким

ПАЙЧЫ *и.* 1) Уртак чыгымга катнашучы кеше. *Элегрәк, теге яки бу нәрсә кайтса, пайчылар исемлеге төзеп, граммлап өләшәләр иде.* Р.Рахман

2) Уртак финанс эшләрдә катнашучы кеше; пайга керү нигезендә төзелгән оешманың әгъзасы. *Пайчыларның чыгымнарын хәвеф-хәтәрдән саклау өчен, пай фондының эшендә бер үк вакытта берничә компания катнаша. Гомуми капиталны булдыруда катнашкан пайчылар «дивиденд» дип атала торган үзләренең табыш өлешләрен дә алырга тиешләр.* Ватаным Татарстан. *Пайчылар елына бер мәртәбә 666,97 сум күләмендә җир салымы түлиләр.* Өмет

ПАЙЧЫЛЫК *и.* Уртакка, пайга кереп эш итү. *Зарифулла агай, ---күршекүлән белән пайга кереп, [корбанга] тәкә я тана кебегрәген чалып килгән килүен, ә соңга табарак --- мондый пайчылыктан баш тарткан.* Г.Минский

ПАКАРАЧ *и. морд. зоол.* Тритон

ПАКГА́УЗ *и. нем.* Таможняларда, тимер юл станцияләрендә, портларда килеп төшкән яки җибәрелә торган йөкләрне вакытлыча саклау өчен корылган склад. *Портка килеп керү белән, чакрымнарга сузылган пакгаузларга тутырылган, ачык һавада өсләренә брезент япкан тау-тау өелеп торган товарлар күрәсең.* М.Юныс

ПАКЕТ *и. фр.* 1) Зур булмаган кәгазь яки полиэтилен капчык, янчык. *Әзер чималны салкынча коры урында кәгазь пакетларга салып сакларга кирәк.* Дару кабарга ашыкма. *Җиләкне, юмыйча, дымны үткәрми торган пакетта сакларга кирәк.* Өегез ямьле булсын. *Кеше аз вакытта бигрәк тә, алар кулларына пакет яисә перчатка кимичә генә печенье, прәннек ише азык продуктларын пакетларга тутыралар.* Акчарлак

2) Төргәк, кап. *Ул аны каршыдагы киберкә алып керә дә ике пакет он алып бирә.* Г.Гобәй. *Пакетларның тышында бу ашламаларны куллану буенча рекомендацияләр бар.* Бакчачы, яшелчәче һәм умартачы календаре

3) *к.* **конверт**. --- *губернатор тарафыннан бирелгән әмер буенча, почта илә килгән барлык хатларны полиция ачып, эчендә политический сүзләр юкмы дип укып, янәдән шул пакетларына салып җибәреләдер иде.* Ш.Маннур

4) Рәсми хат; документлар салынган, махсус мөһер салынган конверт. *Аның да кыска койрыклы атка яисә мотоциклга атланып, яшерен пакетлар, приказлар, фәрманнар йөртәсе килде.* К.Тинчурин. *Аннан бутылкага охшаган бер граната белән яхшылап яулыкка төрелгән пакет килеп чыкты. Пакетның уртасына зур гына итеп сургучтан печать сугылган иде.* Ә.Айдар

5) Рәсми кәгазьләр, документлар комплекты

6) *информ.* Үзара бәйләнешле компьютер программалары җыелмасы. *Һәрбер блок «конверт»ка куелган кебек була, шуның нәтиҗәсендә пакет барлыкка килә. --- Пакет мәгълүматларның үзен дә һәм эш өчен кирәк булган информацияләрне дә үз эченә ала.* Гомуми информатика

ПАКЕТБОТ *и. голл.* Почта һәм пассажирлар йөртә торган диңгез судносы. *Икенче булып «Изге Павел» дигән пакетбот, ә аңардан берничә кабельтов ара калдырып кечерәк кораблар бара.* И.Хуҗин. *Озак та үтмәде, төтенгә күмелгән судно – ике морҗалы пакетбот үзе дә күренде.* А.Толстой

ПАКЕТЛАУ *ф.* Пакетларга бүлгәләп тутыру. *Клиентлар продукцияне пакетлауны таләп итә*

Пакетлап алу Тиз арада пакетлау

Пакетлап бетерү Барысын да пакетлау

Пакетлап кую Алдан ук пакетлап әзерләү

Пакетлап тору Пакетлау эше белән шөгыльләнү

Пакетлый башлау Пакетларга керешү

ПАКЕТЛЫ *с.* 1) Пакетларга салып ябыштырылган. *Пакетлы бөтнек чәен кайнар суга тыгып торып, аз гына суынгач, күз кабагы өстенә куегыз.* Шәһри Казан. *Сөт кирәксенгән кешеләр бик күп, бигрәк тә сөтле чәй эчәргә яратучы татар апалары, кем сөт сата икән дип, өй борынча эзләнеп йөрми, ә кибеттән пластик шешәлесен яки пакетлысын алып кайтып куллана.* Татарстан яшьләре. *Офис хезмәткәрләре куллана торган пакетлы чәйдә кофеин күп була*. Кәеф ничек?

2) Пакетка (*5 мәгъ.*) ия булган. *Мондый юмартлык, бер яктан, кыйммәтле кәгазьләрнең зур пакетлы акционерлар кулында тупланып бетүен күрсәтсә, икенче яктан, «Татнефть»нең 2007 елда аеруча уңышлы эшләвен раслый.* Ватаным Татарстан

ПАКИЗӘ *с. фар. иск.* **1.** 1) Чиста, керсез, пөхтә, пакь, таза. *Йортларының эчләрен тышларына кадәр тәэсир итәр дәрәҗәдә пакизә итә алган бу авылның татарлары белән үземнең кардәшлегемне мин --- аермачык сизә идем.* Ф.Әмирхан. *Раббел Хак бу турыда болай ди: «Сезгә никахланган вакытта мөэминә хатыннардан пакизә булганнары да хәләл һәм китап әһелләреннән пакизә булган хатыннар да хәләл»*. Безнең гәҗит

2) Керсез, саф күңелле. *Бер дөхтәре пакизә гәүһәремезне һәр кичәдә йокларга яткан җиреннән алып китәләр, таң белентәч, янә китереп куялар.* К.Насыйри. *Бичара кыз, тәҗрибәсез пакизә булдыгыннан, аның сүзләренә ышанган.* Шура

2. *рәв. мәгъ.* Пакь килеш, чиста хәлдә, саф булып. *Кыз булсаң, пакизә бул.* Мәкаль. *Мөбарәк күзенә сөрмә тарта, тырнакларын озын йөртүне сөйми, чәчләрен майлап пакизә йөртә, хуш исле майлар сөртә, пакизә вә хуш исле булып йөрүләрен сөя вә шуңа кызыктыра*. Татарлар

ПАКИЗӘЛЕК *и. иск.* Чиста, керсез, саф, пакь булу сыйфаты. *Ләкин шул кадәресе бар, бу пакизәлек Европа халкы аңлый торган пакизәлек түгел, бәлки, игътибар вә тәрбияләре буенча намаз укырга мәҗбүр халыкка йорт эче пакизәлегенең йортның тышына чыгышы вә хәтта ишек алды һәм урамга тәэсир итеше иде.* Ф.Әмирхан. *Бәеттә Сөембикәнең пакизәлексафлыгы, кешеләрне өзелеп яратуы, аларга ышануы да бәян ителә*. Ислам – татарлар һәм мөселманнар

ПАКТ *и. лат.* Аеруча зур сәяси әһәмияткә ия булган халыкара килешү. *Билгеле булганча, 1939 елның 23 августында Гитлер белән Сталин арасында бер-береңә һөҗүм итмәү буенча Пакт төзелә.* М.Гайнуллин. *Берләшкән милләтләр системасында «кеше хокуклары турындагы пакт эшләп чыгарырга кирәк» дигән карар кабул ителде.* Хокук һәм сәясәт. *Әлеге иҗтимагый пакт нигезендә парламент партияләре чит илдән бернинди ярдәм алмаска, «алар сыбызгысына биемәскә» тиеш була.* Ватаным Татарстан

ПАКУС *и. рус* Чабылган печән яки иген теземе. *«Их, киерелеп, үткен чалгы белән бер-ике пакус чыксаң иде!» – дип куйды Сабир.* А.Алиш. *Болыннарга чыктым әле, эшләп үскән җирләремә: Тасма печән пакуслары, чәчәкләрнең хуш исләре керсен әле җырларыма.* Ф.Яруллин. *Без ул көнне борчак басуында пакус әйләндерергә тиеш идек.* Г.Гыйльманов

ПАКУСЛАП *рәв.* Теземнәргә салып, пакус-пакус итеп. *Әле кичә генә шаулап үсеп утырган биек кындырак уләне кырылып җиргә салынган, пакуслап өеп түгел, ә баса җәйгән кебек, тигез генә, юка гына итеп, тиз арада кибәрлек итеп.* Р.Ишморат

ПАКУСЛЫ *с.* Пакусларга салынган

ПАКЬ *с. фар. кит.* **1.** 1) Саф, чиста, ару, болганмаган, пычранмаган (сыеклык тур.). *Берәү дә судан пакь, сөттән ак түгел.* Мәкаль

2) Чип-чиста итеп юылган, чистартылган, тазартылган, керсез. *Безнең залның ак, пакь караватларында авыру солдатлар буй-буй тезелеп яткаңнар.* Г.Ибраһимов. *Пакь җаның һәм пакь тәнең – барлык вөҗүдең пакь синең...* Г.Тукай

3) *күч.* Начар ниятләрдән яки начар хисләрдән азат, саф, керсез. *Күпме тамды пакь күңелдән изге саф күз*

яшьләре. Н.Исәнбәт. *Галиулла да аны шундый ук пакь, саф мәхәббәт белән яратты.* А.Шамов. *Менә кемгә тапшырырга тиеш ул тормыш эстафетасын! Үзе кебек үк пакь җанга, хакыйкатьне кыйбла итеп алучыга.* Ф.Бәшир

4) *күч.* Тап төшерелмәгән, кара ягылмаган, хур ителмәгән. *Халкымның вөҗданы шикелле Саф безнең, пакь безнең байраклар. Һаман да көрәшкә чакырып яналар бу якты маяклар.* Ф.Яруллин *Миңа бу депутатның соңгы сүзе ошады: «Партиябезнең пакъ исемен оппонентлардан пычраттырмас өчен, үз теләгем белән китәм».* Безнең гәҗит

2. *рәв. мәгъ.* Чиста итеп, пөхтә итеп. *Үзе һичбер авыл малаена чагыштырылмас мәртәбә пакь кенә, чибәр генә киенә.* Г.Ибраһимов

ПАКЬЛӘНДЕРҮ *ф. кит. к.* **пакьләү**. *Бәлки, ул сыек ялкын минем күңелемне пакьләндерәдер, бәлки, мин аның белән йөрәгемә утырган юшкынны юып төшерә торганмын!* Г.Бәширов. *Византия греклары салган храмны мәчеткә көйләгән чакта, аны пакьләндерү өчен, төрекләр собор эчен роза чәчәге мае белән юганнар.* М.Юныс

ПАКЬЛӘҮ *ф. кит.* 1) Сафлану, керсезләнү, чистару. *Хәзрәт хадимнән икенче киемнәр, шәригатьчә юылып пакьләнгән киемнәр сораргa тотынды.* Ф.Әмирхан. *Госел бабы – Коръәндә юыну, пакьләнү турындагы бүлек.* Г.Исхакый. *Олы бер вакыйга алдында торуларын хәзрәт Хәлимгә дә сиздерде. – Улым, сиңа да тәһарәт алып пакьләнү фарыз булыр, – диде.* Г.Бәширов

2) *күч.* Бозык хисләрдән, начар ниятләрдән арыну. *Сине тыңлап һәммә таптан, һәммә кердән сафланам, сафланам да, пакьләнәм дә: Алла, Алла, Алла! – дим.* С.Сүнчәләй. *Бәлки, кирәктер бу – хатының, балаларың белән аерылышу? Тансыклык тойгысы уяту, сагыну, пакьләнү өчен.* М.Юныс

Пакьләнә бару Әкренләп, аз-азлап пакьләнү; эзлекле рәвештә пакьләнү

Пакьләнеп бетү Тәмам, тулысынча пакьләнү

Пакьләнеп китү Пакьләнгән хәлгә килү

ПАКЬЛӘҮ *ф.* 1) Чистарту, тазарту; сафландыру, пычрактан арындыру. *Аның кичә кич, төнлә шәригатьчә пакьләгән киемнәре – һәммәсе куырылып катканнар.* Ф.Әмирхан. *Үз баласын ул юа, пакьли, теле белән ялый.* Г.Тукай

2) *күч.* Начарлыклардан яки бозык уйлардан, хисләрдән, начар теләкләрдән арындыру. *Кайтмады үч, бетте көч, сынды кылыч – шул булды эш: Керләнеп беттем үзем, дөньяны пакьли алмадым.* Г.Тукай. *Килде көннәр, исте җилләр, нинди сулар акмады, Якты ирек көне килде, дөнья йөзен пакьләде.* Г.Камал

Пакьләп бетерү Тулысынча, ахырынача пакьләү

Пакьләп кую Пакьләгән хәлгә китерү

Пакьләп алу Тиз арада, аз гына пакьләү

ПАКЬЛЕК *и. кит.* 1) Пакь, чиста, керсез булу. *Хәзрәт хәзер инде үз бүлмәсендәге намазлыкның пакьлегенә ышанмый башлады.* Ф.Әмирхан. *Каеннарның ак мәрмәр кебек кәүсәләре тирә-якны яктыртып җибәргәннәр, алардан бер җиңеллек, пакьлек бөркелеп тора кебек.* Г.Әпсәләмов. *Ак төс пакьлек билгесе буларак гомумән картинаны эчтән яктырткан кебек.* Ә.Миңнуллина

2) *күч.* Бозык уйлардан, начар хисләрдән азат булу, сафлык. *Безнең Исергәптә намусның сафлыгын, иман пакьлеген саклау шулкадәр зарур иде.* М.Юныс. *Ләкин Син бит миндә Пакьлек күрәлмадың. Сафлыгымны җанга биклән куям.* Р.Әхтәмова

ПАЛ *и. гар. диал.* Фараз, гипотеза, эш-хәрәкәт планы

◊ **Палга керү** *диал.* Эшкә ашарлык булу

ПАЛАНКИН *и. португ.* Ике озын киртәгә беркетелгән, өсте һәм кайвакыт янтыклары да бөркәүле утыргыч яки ятак рәвешендә ясалган, берничә кеше күтәреп йөртә торган юлчы йөртү җайланмасы, михәффә. *Дүрт хезмәтче паланкин күтәреп Бонифаций чыгасы тарафка чабалар.* Р.Батулла. *Кияү яссы таш өстенә баса да берничә кешенең ачык кызыл төстәге сари кигән, бик күп бизәнгечләр таккан кәләшне агач паланкин белән күтәреп чыкканнарын көтә.* Татарстан яшьләре

ПАЛА́НТИН *и. фр.* 1) Хатын-кызлар өчен мехтан, ефәктән яки хәтфәдән эшләнгән купшы киң япма. *Йомшак йонлы палантин. Туташ зәңгәрсу палантин ябынган иде*

2) Гадәттә мамыктан челтәрләп бәйләнгән зур һәм киң шарф. *Модельерлар тәкъдим иткән башлыкларны ошатмасагыз, алар урынына шәл, яулык яки палантин бәйли аласыз.* Шәһри Казан. *Ул шәл бәйләү өчен эш кораллары гына ясап калмый, ә мамык шәлләр, палантиннар, оекбашлар бәйли.* Татарстан яшьләре

ПАЛАС *и. фар.* Кулдан яки машинада тукылган йончасыз, шома келәм. *Палас өстендә йомшак кәнәфи, ике кресло һәм өстенә кыймәтле, бәйләнгән эскәтер япкан түгәрәк өстәл.* Г.Коләхмәтов. *Пакь итеп юылган сары идәнгә бусагадан ук чуар палас сузылган.* Г.Бәширов. *Киленебез Гөлчәһрә үз куллары белән тукыган палас.* Р.Батулла

ПАЛА́ТА *и. лат.* 1) Дәвалау йортларында авырулар ятып дәвалана торган аерым бүлмә. *Ә ул үзе больница палатасында ук урта мәктәп программасы белән укый башлады.* М.Шабаев. *Больницаның ул шыксыз палаталарында унбиш-егермешәр кешедән дә ким булмас.* Ф.Хөсни. *Палатада тагын биш псих ята иде: тарих укытучысы, район гәҗитендә эшләүче шагыйрь, элекке партия шәһәр комитеты инструкторы, мунча директоры һәм яшелчә базасы нәчәлниге.* З.Хәким

2) *тар.* Зиннәтләп эшләнгән, бик бай җиһазландырылган мәһабәт бина; пулат. *Пушкинодагы патша палатасы үзенең зиннәтлелеге, байлыгы белән күпләрне сокландыра*

3) Кайбер илләрдә парламентның яки башка хөкүмәт органының аерым бүлеге. *Англия лодлары палатасының рәисе дә, бәлки, ул хокукы белән болардан уздыра алмас иде.* Ф.Әмирхан. *Югары палата. Түбән палата. Ике палаталы парламент*

4) Нәрсә белән дә булса идарә итә торган кайбер дәүләт учреждениеләренең исеме. *СССРдагы һәр басмаханәдә*

чыккан китапның 25 данәсе Үзәк китап палатасына җибәрелә. Ә.Кәримуллин. *Хисап палатасының һәм Русфиннадзорның рәсми мәгълүматларына караганда, һәр елны Россия бюджетыннан триллионга якын сум акча урлана.* Р.Юсупов. *Париж сәүдә палатасының исәпләүләренә караганда, бөтен дөньядагы өч миллион кеше ел саен дүрт мең халыкара конференциядә катнаша.* Әдәп төбе – матур гадәт

ПАЛАТАЛИЗА́ЦИЯ *и. лат. лингв.* Тартык авазларны нечкәртеп әйтү. *Палатализация күренеше тартык авазларга карый: капитал / капиталь*

ПАЛАТАЛЬ *с. лат. лингв.* Нечкә әйтелешле (тартык авазлар тур.). *Рус фонетикасында бу фонема [т]дан аеручы дифференциаль билгеләр итеп беренчесенең палаталь һәм озын булуы күрсәтелә.* Татар грамматикасы. *--- алгы рәт сузыклары янында тартыкларның бары йомшак палаталь вариантлары гына --- килә ала. Барлык фонемаларның да диярлек икешәр аллофоны була – палаталь һәм веляр. Тартыкларның палаталь вариантларын белдерә торган аллофоннар бары алгы рәт сузыклары алдында очрыйлар.* Татар грамматикасы

ПАЛАТАЛЬЛӘШҮ *ф. лингв.* Нечкә әйтелү, палатальгә әверелү. *--- алгы рәт сузыклары янында тартыклар палатальләшәләр, йомшак әйтеләләр, ә арткы рәт сузыклары янында велярлашалар, каты әйтеләләр. Рус телендәге палаталь тартыклар белән чагыштырганда, татар телендәге тартыклар азрак «нечкәрәләр», палатальләшәләр.* Татар грамматикасы

ПАЛАТАЛЬЛЕК *и. лат. лингв.* Тартык авазларны нечкәртеп әйтү күренеше. *Палатальлек татар теле өчен фонематик билге түгел, шуңа «озынлык» билгесе генә кала.* М.Зәкиев. *Шунысын да билгеләп үтәргә кирәк: татар әдәби телендә тартык авазның палатальлеге күршесендәге алгы рәт сузыгына бәйле булса, диалектларда ул мөстәкыйль билге дә булырга мөмкин.* Татар грамматикасы

ПАЛА́ТКА *и. рус* 1) Тукыма яки башка тыгыз материалны казыкларга бау белән тарттырып ясалган вакытлы җиңел торак, чатыр. *Ак палатка астында йокыга киткәнбез.* М.Гафури. *Ял иттек без палаткалар корып. Җиләк җыйдык яшел аланда.* З.Мансур. *Инде барысы да шактый арыган һәм тизрәк Зөя елгасы буена әйләнеп кайту, палаткалар корып, учак тирәсендә ял итү турында гына хыяллана иде.* Б.Ситдиков

2) Вак сәүдә өчен төзелгән җиңел, ал ягы ачык, сүтеп җыела торган корылма. *Авыл агайлары, чыбыркыларын билбауларына кыстырып, кибетләр рәте буйлап узалар, кибет, палаткалар алдына туктап, күлмәклек ситсы, чәй-шикәр, тоз, йөзем, тәмәке, төймә, каптырма, энә, җеп ише әйберләр сатып алалар.* М.Галәү

ПАЛАЧ *и. рус* 1) Үлемгә хөкем ителгәннәрне берәр корал яки җайланма белән үтерүче кеше, җәллад. *Чишелде бик соңлап табышмак: Палач өзгән Әхәт гомерен!..* М.Хөсәен. *Сөю кошы, канат җилпеп, Сәлам бирмәс Палачка!* Зөлфәт. *Палачлар, кызмагыз! Без ирек куймабыз кешелек бәхетен буарга.* М.Хөсәен. *Нижегородцев ике кулы белән ишекне кыйный башлады: – Сез нишлисез, палачлар!* И.Салахов

2) *күч.* Явыз изүче, җәзалаучы. *Без «төрек-татар байрагы» ди идек. Милли азатлык намына чехка, милли идарәгә, Колчакка тагылдык... Эшче-крестьянның палачлары булдык.* Г.Ибраһимов. *Көчлеләр күп, явызлыкка бирмиләр юл! Авызлыклый палачларны дөнья халкы, Ә бит халык тынычлык һәм хаклык яклы.* З.Мансур. *Без барыбыз да шуны белергә тиеш: халыклар палачы, канлы кара елан Гитлер үзенең мәкерле юлын Мюнхеннан башлады.* С.Шакир

ПАЛАЧЛЫК *и.* 1) Палач булу; палач вазифасы. *Зинданның бөтен сәяси тоткыннары арасында күптән инде бер авыр шик бар иде: --- егерме елга каторгага хөкем ителгән тоткын Тарбашев палачлык хезмәтен үти икән.* Г.Ибраһимов

2) *күч.* Җәберләү, җәзалау, асу-кисү күренеше, террор. *Илләр белән без дә бергәләшеп Көрәш мәйданына чыгабыз, Чыгабыз да Җирдә кан коюга, Палачлыкка чикләр куябыз!* Ш.Маннур

ПА́ЛЕО- *гр.* Кайбер кушма сүзләрнең «борынгы заманнарга караган» дигән мәгънәне белдерә торган беренче кисәге (мәс., *палеоботаника, палеогеография, палеозоология*)

ПАЛЕОАЗИАТ *и. гр.* Төньяк Себер халыкларының (чукча, коряк, юкагир, нивх һ.б.) һәм шулар сөйләшкән телләрнең уртак атамасы. *Палеоазиат халыклары. Палеоазиат телләре*

ПАЛЕОАНТРОПО́ЛОГ *и. рус* Палеоантропология белгече

ПАЛЕОАНТРОПОЛО́ГИК *с.* Палеоантропологиягә кагылышлы, шуңа караган. *Инглиз галимнәре Луис һәм Мери Ликиләрнең, шулай ук аларның уллары Ричард Лики һәм башка галимнәрнең Көнчыгыш Африкадагы палеоантропологик табышлары мондый карашның бик үк дөрес түгеллеген күрсәтте.* Н.Фәттах

ПАЛЕОАНТРОПОЛО́ГИЯ *и. гр.* Антропологиянең казылмаларда табыла торган кеше сөякләренең калдыкларын өйрәнә торган бүлеге. *Конференциядә --- палеоантропология, антропология, археология һәм этногеномика, башкортларның һәм Евразиядәге башка халыкларның матди һәм рухи мәдәнияте, гореф-гадәтләре турында тирән мәгълүматлы докладлар төрле секцияләрдә дәвам итте.* Фән һәм тел

ПАЛЕОБОТА́НИК *и. гр.* Казылма үсемлек калдыкларын өйрәнүче белгеч. *Нефтьчеләр тапкан үсемлек калдыкларын палеоботаник Е.Ф.Чиркова-Залесская өйрәнде.* Борынгы гасырларда Татарстан

ПАЛЕОБОТА́НИКА *и. гр.* Палеонтология фәненең төрле геологик чорларга караган үсемлекләрнең казылма калдыкларын өйрәнә торган бүлеге. *Борынгы үсемлекләрнең казылма калдыкларын өйрәнә торган палеоботаника күрсәткәнчә, үсемлек бергәлекләренең төр составы гасырлар дәвамында үзгәрә барган.* Биология. *--- разведкалар, казу эшләре үткәргәндә һәм дә табылган материалларны тикшергәндә, яңа ысуллар (геофизика, антропология, палеозоология, палеоботаника,*

палинология, металлография, спектраль анализ һ.б.) актив кулланыла башлый. Фән һәм тел

ПАЛЕОГЕН *и. гр. геол.* Кайнозой эрасының иң борынгы чоры. *Галимнәр хәзерге заманда яши торган варанарның палеоген периодының урталарында, эоцен чорында, моннан 60 миллион еллар элек Австралиядә яшәгән казылма вараннардан бернинди дә аермасы юк дип табалар.* Борынгы гасырларда Татарстан

ПАЛЕОГЕО́ГРАФ *и. рус* Палеогеография белгече

ПАЛЕОГЕОГРА́ФИЯ *и. гр.* Җирнең борынгы геологик чорларындагы физик-географик шартларын өйрәнә торган фән. *Табигый географик фәннәргә комплексы физик география һәм аннан аерылып чыккан геоморфология, туфрак географиясе, гидрология, климатология, биогеография, палеогеография, тарихи география һ.б. карый*

ПАЛЕО́ГРАФ *и. рус* Палеография белгече. *Бу юлы сүз Казан турында, Казан губернасында туган күренекле тарихчы, археолог һәм палеограф Николай Петрович Лихачёв хакында барачак*

ПАЛЕОГРА́ФИК *с.* Палеографиягә мөнәсәбәтле. *Сүзебез дәлилле булсын өчен, Салагыш ташының әйтеп үтелгән палеографик үзенчәлекләрен төгәл күрсәтеп китик.* Гасырлар авазы. *Бүтән кулъязмаларга хас булганча, текстта хаталар, төзәтүләр һәм палеографик үзенчәлекләр бар, язуы уртача камиллектә*. Татар әдипләре

ПАЛЕОГРА́ФИЯ *и. гр.* Борынгы кулъязмаларның язу ысулларын, хәрефләрнең формаларын, язу өчен кулланылган материалларны өйрәнә торган фән. *Әлеге коллекция соңыннан СССР Фәннәр академиясенең палеография музеена тапшырылган*. Ватаным Татарстан. *Галимәнең татар филологиясе һәм тарихы факультеты студентлары өчен укыту-методик комплекс буларак төзелгән «Гарәп язуы палеографиясе һәм каллиграфиясе» кебек хезмәтләре дә һаман да шул гарәп каллиграфиясенә кайтып кала*. Шәһри Казан

ПАЛЕОЗАВР *и. гр.* Борынгы заманнарда яшәгән гаять зур кәлтә елан. *Кояшта кызынып ятучы палеозаврлар юра чорыннан бирле беркая да китмәгәннәр дип уйларсың.* Борынгы гасырларда Татарстан

ПАЛЕОЗОЙ *и. гр.* Җирнең геологик тарихында архей һәм протерозой эраларыннан соңгы өченче эра. *Тоташ җәйгә алмашка кыш килгән, ләкин бу инде пермь периодында – палеозой эрасының соңгы чорында булган.* Борынгы гасырларда Татарстан

ПАЛЕОЛИТ *и. гр.* Археологик чор – таш гасырының иң борынгы дәвере. *Әлеге мәгарәләрнең стеналарында палеолит чоры сурәтләре сакланып калган.* Р.Нигъмәтуллина. *Идел һәм Чулман буйларына кешеләр борынгы таш гасыры – палеолит чорында ук килеп төпләнгәннәр.* Без тарихта эзлебез

ПАЛЕОНТО́ЛОГ *и. гр.* Палеонтология белгече. *Скелетлар табылган катламнарны җентекләп өйрәнгәннән соң, палеонтологлар, моннан ике йөз миллион еллар чамасы элек хәзерге Зөя һәм Корыган Үлемә елгалары урынында якындагы диңгезгә коя торган елганың тамагы булган, дигән нәтиҗәгә киләләр.* Борынгы гасырларда Татарстан

ПАЛЕОНТОЛО́ГИЯ *и. гр.* Борынгы чорларда яшәгән үсемлекләр һәм хайваннарның тереклеген аларның казылма калдыкларына нигезләнеп өйрәнә торган фән. *Палеонтология залының стеналары зур мөгезле бизоннар, казылма пошилар һәм турның баш сөякләре (кыргый үгез) белән бизәлгән.* Борынгы гасырларда Татарстан

ПАЛЕ́ТКА *и. фр.* Кәгазьгә яки башка өслеккә басылган фигураларның мәйданын якынча үлчи торган, үтә күренмәле пластинкага яки пыялага төшерелгән масштаблы челтәр. *Палетка ярдәмендә мәйданнарны төгәл үлчәп булмый.* Геометрия

ПАЛИ́ТРА *и. лат.* 1) Рәсем ясаганда буяуларны кушып катыштыру өчен махсус җиңел такта яки катыргы. *Көзнең барлык яме, Чуарлыгы Палитрага сыймый – Мин беләм.* Н.Арсланов. *Рәссам палитрасын да үзе белән алган*

2) *күч.* Рәссам кулланган барлык төсләр, төсләр гаммасы

3) *күч.* Төрле нәфис әдәби тел чараларының барлыгы. *Аларның жанр үзенчәлекләре әдипнең бай, оригиналь иҗат палитрасын гәүдәләндерә.* Н.Ханзафаров

ПАЛИ́ТРАЛЫ *с.* 1) Нинди дә булса палитрасы булган

2) Күптөрле төсләрдән торган. *Алар [татар халкының үзенчәлекле ир-ат һәм хатын-кыз баш киемнәре, бизәкләп эшләнгән аяк киемнәре үрнәкләре һәм затлы зәркән-бизәнү әйберләре] асыл-ташларның ачык палитралы булуы һәм үрмәле бизәкләп эшләнүе белән аерылып тора.* Ислам – татарлар һәм мөселманнар

3) Күпкырлы, төрле, бизәү чаралары киң кулланылган. *Әлбәттә, иң бай палитралы мәхәббәт лирикасы Пушкинда.* Н.Хисамов. *Кыскасы, Марсель Гыймазетдинов авыл тормышының бай палитралы сурәтен тасвирларга омтылды, авыл кешесе – игенчегә мәдхия җырлады.* Ә.Дусайлы

ПАЛЛА́ДИЙ *и. лат.* Үзенең водородны бик күп микъдарда йоту үзлеге белән аерылып торган химик элемент – көмешсыман ак металл. *АКШтагы бердәнбер платина һәм палладий җитештерү предприятиесе, Канададагы уран җитештерүче бердәнбер завод безнекеләр кулында икән.* Татарстан яшьләре. *Профессор В.К.Половняк лабораториясендә палладий, агалтын, родий элементлары кергән комплексы органик кушылмаларны синтезлау һәм тикшерү үткәрелә, комплекс төзүче атомнарның оксидлашу дәрәҗәсен тотрыклыландыру мәсьәләләре хәл ителә.* Фән һәм тел

ПАЛЛИАТИВ I *и. фр.* 1) Авырудан терелтми, ләкин авыртуны басып, хаста кешегә бераз җиңеллек бирә торган дару

2) *күч.* Мәсьәләнең, кыенлыкның вакытлыча яки өлешчә генә хәл ителүенә китерә торган чара

ПАЛЛИАТИВ II *с.* Вакытлыча авыртуны баса торган. *--- бу ике палата гына паллиатив ярдәмгә мохтаҗларның мәнфәгатьләрен канәгатьләндерә алмый. Паллиатив ярдәмне көйләгән кануннарның ил күләмендә әлегәчә булмавын, хосписларда эшләүче*

персоналның махсус әзерләнмәвен башкача ничек аңларга? Безнең гәҗит

ПА́ЛУБА *и. рус* Суднодагы терәкләргә яки судно өстенә җәелеп яруслар хасил итә торган түшәмә һәм шул түшәмәнең судно стенасына орынып торган өлеше. *Соңгы елларда кораб палубаларына такта җәйми башлаганнар. Аның каравы җәй көннәрендә комлап юылган җылы тактага яланаяк басып йөрүе, чиста палубага сузылып, кояшта кызынып ятуы шундый рәхәт була иде.* М.Юныс. *Егетләр инде өске палубага, күперчеккә менеп басканнар иде.* И.Низамов

ПА́ЛЬМА *и. лат.* Ботаксыз биек кәүсәсенең башында гына җилпәзә сыман як-якка җәелеп торган, эре яфраклы мәңгеяшел көньяк агачы. *Сарай каршында шәмдәй төз, очларына яшел җилпәзә беркетелгән сылу пальмалар.* М.Юныс. *Бу кипарислар, бу пальмалар, магнолияләр, «бөек таллар», бу акация, лавр, олеандр куаклары, ун елдан соң килсәң дә, шулай тыныч кына үсеп утырмаслармыни?* Ә.Еники

ПАЛЬМЕ́ТТА *и. фр.* Пальма яфрагы, таҗ сыман бизәк һәм шундый бизәк төшерелгән нәрсә үзе. *Элек рекламаланган пальметта бакчалардан аермалы буларак, иркен үсә торган яссы ябалдашлы тар рәтле типтагы бакча даими терәктәге тимерчыбык шпалера сорамый.* Бакчачы календаре

ПАЛЬПА́ЦИЯ *и. лат. мед.* Тәндәге авырткан урынны яки гомумән авыруны бармаклар яки уч белән капшап тикшерү ысулы

ПАЛЬТО *и. фр.* Гадәттә чабуы тездән югары булмаган һәм салкында киелә торган өске кием. *Әмма безнең ул сеңел һәм энеләребез ялтыравыклы матур ботинкалар, кара, зәңгәр, соры кепкалар, җыйнак матур пальтолар кигән булырлар.* Г.Бәширов. *Аның өстендә зәңгәр сукнодан җәйге пальто иде.* Ә.Еники. *Соңгы килүендә Суфияның пальтосы нәкъ үзе теләгәнчә тегелгән иде.* Ф.Яруллин

ПАЛЬТОЛЫК *с.* **1.** 1) Пальто тектерергә ярый яки җитә торган. *Син миңа пальтолык коверкот алып бирсәң, мең өлеш артык булыр.* К.Тинчурин

2) Пальтога дип билгеләнгән. *Пальтолык акча*

2. *и. мәгъ.* Пальто материалы. *Пальтолык алу*

ПАМПА́С *и. исп.* Көньяк Американың көньяк-көнчыгышында, субтропик зонада урнашкан, куе үлән һәм куаклык белән капланган дала. *Кайчандыр пампасның иркен сахраларында тиз чабучы хайваннар: пампас боланы һәм пампас мәчесе, ламалар яшәгәннәр.* Материклар һәм океаннар географиясе

ПАМФЛЕ́Т *и. лат. әд.* Фаш итү характерында язылган кечкенә күләмле әдәби әсәр. *Күп вакыт киң катлау массаларга аңлаешлы сатирик формада языла торган памфлетларда иҗтимагый стройның тискәре күренешләре, аерым кешеләрнең пычраклыгы, төрле оешмаларның җинаятьчел эшчәнлеге һ.б. фаш ителә.* Н.Гыйззәтуллин. *Хат рәвешендә романнар, шигырьләр, фәлсәфи трактатлар, социаль-политик памфлетлар, әдәби тәнкыйть мәкаләләре язылган.* Әдәп төбе – матур гадәт

ПАМФЛЕТЧЫ *и.* Памфлетлар язучы әдип, памфлетлар авторы. *Хәзерге татар памфлетчыларыннан Ш.Мөдәрриснең «Янки базары, яхут Яңадан-яңа Кисекбаш» исемле шигъри памфлеты, «Сыңар колак вакыйгасы», «Ревизор» һ.б. памфлетларында Америка империалистлары фаш ителә.* Н.Гыйззәтуллин

ПАН *и. гр. иск.* 1) Иске Польша, Литва, Украина, шулай ук Белоруссиядә: алпавыт, барин. *XI гасырдан алып әле немец рыцарьлары, әле швед боярлары, әле поляк паннары һәм иң ахырдан рус помещиклары тарафыннан тапталган, таланган бу илләр һаман да ирек ала алмаганнар икән!* Г.Гобәй. *Качтылар сатлык җаннар, Качтылар явыз паннар – Безнең утка түзәлмичә Егерменче елларда.* Ә.Ерикәй. *Биредә поляк паннары яһүдләрне арендаторлар, утар управляющийлары… һәм православие динендәге җәберләнгән украин крестьяннары арасында арадашчы буларак киң файдаланалар.* Диннәр тарихы

2) Кайбер славян халыкларында өлкән ир кешегә хөрмәтләп эндәшү сүзе. *– Хәерле көн, пан! – диде Гаяз. – Әйтегез әле, пан, Вонцево биредән еракмы?* А.Расих

ПАН- *гр.* Кушма сүзләрдә «бөтен, барлык» дигән мәгънәне белдерә торган беренче кисәк (мәс.: *пангерманизм, панславизм, пантюркизм* һ.б.)

ПАНА́МА *и. фр.* Челтәрләп эшләнгән яки тукымадан тегелгән киң кырыйлы җәйге эшләпә. *Катя, ваннадан кайтып ашап-эчкәч, тиз генә өстен-башын алмаштырды да ак күлмәктән, ак панамадан, күңелле җыр көйликөйли, мәрмәр баскыч буйлап җилдәй җилфердәп төшеп китте.* И.Гази. *Панамасы белән (яңа егетләр инде киң кырлы эшләпәнең шулай аталганын беләләр иде) телефон аппаратын каплап куйган.* Г.Кашапов

ПАНАРИ́ЦИЙ *и. лат. мед.* Кул яки аяк бармагына чыга торган эренле шеш. *Искермәгән лимон панарицийны дәвалауда уңышлы файдаланыла.* Р.Зиляева

ПАНАЦЕ́Я *и. лат. кит.* Һәртөрле бәла-казадан ярдәм итә ала торган чара. *Әлбәттә, панацея дигән нәрсә, ягъни барлык очракларда да ярдәм итә торган чара юк һәм, ихтимал, булмас та.* Р.Камалова

ПАНБӘРХЕТ *и.* **1.** Тарап пресслау нәтиҗәсендә елкылдап тора торган юка, нәфис бәрхет. *Бәрхетне, панбәрхетне, чигелгән әйберләрне һәм сырган юрганнарны химик чистарту пунктларына тапшыру киңәш ителә.* Өегез ямьле булсын

2. *с. мәгъ.* Шул тукымадан тегелгән, әзерләнгән. *Илһам Гөлиянең туган көнендә бүләк итеп панбәрхет күлмәклек бирде.* И.Салахов

ПАНДЕМИ́Я *и. гр.* Тулы бер өлкә, ил яки берничә өлкә халкына таралган эпидемия. *Чир, элеккеге еллар белән чагыштырганда, эпидемия генә түгел, пандемия хәленә килеп җитте.* Ватаным Татарстан. *Галим фикеренчә, пандемия «кош гриппы» вирусыннан килеп чыгачак.* Татарстан яшьләре

ПА́НДУР *и. груз.* Грузиннарның чиртеп уйный торган кыллы музыка коралы. *Пандур теле булса сиңа читят, Аңа орынма син.* Н.Арсланов

ПАНЕГИ́РИК I *и. гр.* 1) Борынгы Греция белән Борынгы Римда кемне дә булса мактап сөйләгән нотык

2) *күч.* Кемне дә булса чамасыз, чиктән тыш мактау. *Панегирик язу*

ПАНЕГИ́РИК II *с. гр.* Мактауга багышланган, панегирик (I) характерында булган (әдәби әсәр, нотык тур.). *Панегирик шигырьләрнең төп жанры булган касыйдәдән аермалы буларак, мәдхиянең тотрыклы төзелеш структурасы, тышкы формасы юк.* Х.Миңнегулов. *Г.Тукай солтанны күкләргә чөя торган панегирик төрек поэзиясенең сәнгатьчә мәгънәсезлегеннән, иҗтимагый һәм әхлакый бушлыгыннан көлде.* Г.Халит

ПАНЕЛЬ *и. нем.* 1) Урамның ике ягыннан җәяүлеләр өчен ясалган юл; тротуар. *Безнең шәһәребезне эре мозаика түшәлгән мәйданнар, төсле панельләр бизәп торачак.* Эврика

2) Бинаның эчке стенасының такта яки башка материаллар белән тышланган аскы өлеше. *Стенага агач панельләр ябыштырылган кечкенә генә кабинет.* А.Тимергалин

3) Электр щиты, идарә пульты ише җайланмаларда контрольлек итү, сигнал алу һәм башка аппаратура урнаштырылган махсус каймаланган өслек. *Ерактан идарә итү панеле. Контроль панеле*

4) Җыелма конструкцияләрдән биналар төзү өчен кулланыла торган тимербетон яки башка материалдан ясалган плита. *Арттан чаба кран-торна, Берсе тарта зур панельләр, Өлгерсен дип тизрәк өйләр.* Ф.Яруллин. *Панельләрдән корылган индустриаль кетәкләр төрек җиренә дә юл тапканнар.* М.Юныс

5) *махс.* Шахта, карьер кебек урыннарда махсус аерып билгеләнгән турыпочмаклы яки квадрат участок, кишәрлек

ПАНЕЛЬЛЕ *с.* 1) Панельләрдән торган. *Һәм менә ярты ел дигәндә бөтен кварталда бишәр катлы эре панельле матур йортлар калкып чыкты.* Г.Рәхим. *Казанда эре панельле йортлар төзү комбинатын ярты ел элек бетерделәр.* Шәһри Казан

2) Панель рәвешендәге. *Даими эшләп торган сыек кристалл панельле олы телевизорына – моның барчагыз өчен дә әһәмияте бар, тыңлагыз дигән кыяфәт чыгарып – Гали Даутович көч бирә.* Ф.Яхин

ПА́НИКА *и. гр.* Бер яки берьюлы бик күп кешене кинәт биләп алган көчле курку хисе һәм шуның нәтиҗәсендә аек акылны югалту. *Паникага бирелгән яралылар, аның ыңгырашуына карамыйча, аны тап тап уза, өстеннән атлап чыга башладылар.* А.Шамов. *Алар паника куптарган арада, икенче взвод менә бу таш йортларны атакалар.* И.Гази. *Кешеләр белән аралашканда, без әңгәмәдәшебезнең кәфеннән, халәтеннән йогышланабыз, я бер төрле (эчкерсезлеккә – эчкерсезлек белән, антипатиягә – антипатия, паникага – паника белән) җавап бирәбез.* Ф.Зыятдинова

ПА́НИКАЛЫ *с.* Нык шүрләтә, куркуга сала торган; аек акылны югалтырдай. *Мин, как начальник милиции, сиңа андый паникалы сүзләр таратуны заприщать итәм...* З.Зәйнуллин. *Әмма теш табибыннан паникалы курку – бу инде авыру һәм аны чын-чынлап дәваларга кирәк.* Шәһри Казан

ПА́НИКАСЫЗ *рәв.* Паникага бирелмичә, тыныч һәм тотнаклы рәвештә. *Паникасыз, аек, тыныч, ләкин җитди төстә барысы турында да уйла, барлык нәрсәгә хәзер булырга кирәк.* М.Җәлил. *Иң мөһиме, тиз һәм паникасыз эш итәргә, сирена тавышы килә икән, аның белән кызыксынырга кирәк.* Шәһри Казан

ПА́НИКӘР *и. рус* Паникага бирелүче; паника таратучы. *Ләкин, теләсәң ни әйт, Закирич, безнең халык паникәр.* Р.Ишморат. *Панекёр дип куып чыгарачак ул сине.* Р.Вәлиев. *Мин паникёр түгел.* Ялкын

ПАНИСЛАМИЗМ *и. гр.* Ислам динендәге халыкларның милләткә һәм социаль хәленә бәйсез рәвештә бер дәүләттә берләшүен күздә тоткан сәяси идеология. *Панисламизм – сәясиләнгән рус миссионерлары уйлап чыгарган бер нәрсә ул.* С.Максуди. *XIX гасыр азагында барлыкка килеп, панисламизм мөселман халыкларын чит ил изүчеләреннән азат итү лозунгысы төсен ала.* М.Мәһдиев. *Элек ошамаган рухи җитәкчеләрне панисламизм, пантюркизм кебек сүзләр белән эзәрлекләсәләр, хәзер исә башка төрле «-изм» кушымчалы яңа сүзләр табылды.* Безнең гәҗит

ПАНИСЛАМИСТ *и. гр.* Панисламизм тарафдары. *Бөек Октябрь социалистик революциясе чорында һәм аннан соң да татар панисламистлары контрреволюция ягында булдылар.* Я.Абдуллин. *Шовинист депутатлар Садри Максудига каршы дәлилләр таба алмагач, аны панисламист, пантюркист дип гаепләргә тырыштылар.* Ә.Кәримуллин. *Мөхәммәт Гайнуллин, Ягъфәров әдәбият дәреслегендә ата панисламист Исмәгыйль Гаспралыны мәгърифәтче дип буталганнар иде.* Р.Батулла

ПАНИСЛАМИ́СТИК *с.* Панисламизмга мөнәсәбәтле, панисламизм идеяләренә ярашлы. *Кадимчеләр һәм җәдитчеләр, бер яктан, панисламистик, пантюркистик буржуаз милләтчелек идеологиясен таратырга тырышсалар, икенче яктан, царизмның, патша самодержавиесенең агентурасы ролен дә үтиләр.* Х.Мөхәммәтов

ПАНИСЛАМЧЫ *и. к.* **панисламист**. *Панисламчылар карагруһчылар белән союзга керделәр һәм татар хезмәт ияләренең аңын милләтчелек, дини фанатизм белән агуларга омтылдылар.* М.Мәһдиев. *Жандармерия тарафыннан Бөгелмә исправнигына җибәрелгән хатларда өяздә мөселманнар арасында бик киң танылган зат, «чик дәрәҗәдә панисламчы Атласов» яшәве турында еш искәртелә.* Мәдәни җомга

ПАНКРЕАТИТ *и. лат. мед.* Ашказаны асты бизе ялкынсынуы. *Үз чиратында, ураза алдыннан яисә ураза тотканнан соң комагайланып ашау еш кына каты авырулар, мәсәлән, миокард инфаркты, кискен формадагы панкреатит һ.б. авыруларны китереп чыгара.* Дөрес туклану серләре. *Хроник панкреатит белән авыручы кешеләрне дәвалауда диетик туклану мөһим роль уйный, ул системалы рәвештә һәм озак вакытлар буе алып барылырга тиеш.* Татар халык ашлары

ПАННО *и. фр.* 1) Диварның яки түшәмнең махсус орнамент белән уратып

алынган, нинди дә булса рәсем, бизәк төшерелгән өслеге. *Ул интерьер яки бина фасадын бизәү, сәнәгый композиция яки мозаик панно эшләү, фасадны тышлау өчен кулланыла.* З.Камалова. *Аскы залда исә болгарларның ислам динен кабул итү мизгелен сурәтләгән мозаик панно һәм Ибн Фадланның Идел буена сәяхәт турында язмасы, татар, рус, инглиз һәм гарәп телләрендә басылып, үзенең лаеклы урынын алачак.* Ватаным Татарстан

2) Дивар, түшәм өстендәге рәсем яки кабарынкы сурәт. *Анда рәссам татар орнаменты стилендә бизәлгән панно, яулык һәм палантиннар тупламасын тәкъдим итте.* Шәһри Казан. *Күргәзмәдә салкын батик техникасында татар орнаменты стилендә башкарылган бизәкле ефәк панно, яулыклар һәм башкалар урын ала.* Татарстан яшьләре. *Адәм баласының бәхете, чигелгән панно кебек, төрле-төрле төсләрдән гыйбарәт*. Туган як

ПАНОРА́МА *и. гр.* 1) Биек яки ачык урыннан караганда күренеп торган киң манзара. *Киев-Печёра лаврасындагы чиркәүләр, чаң сугарга көйләнгән кыңгыраулы манаралар, калкулык битендәге таш диварлар ерактан караганда бу урынның чыннан да изге булуын исбатларлык искиткеч панорама барлыкка китерә.* М.Юныс. *--- безнең дә бит Кәҗә тавының иң биек түбәсенә басып көньяк юнәлешкә карасаң, нәкъ шундый ук панорама дип хисләнәсең...* Безнең гәҗит

2) Түгәрәк, ярымтүгәрәк бинаның яки бүлмәнең стенасына тоташ төшерелгән макетлы зур картина. *Биредә яу кыруннан туган якларына исән-сау кайтып, сугышта алган яраларыннан вафат булганнар һәм тыл ветераннары истәлегенә барельеф-панорама ачылды.* Ә.Дусайлы. *Ишектән керүгә үк каршы алган панорама Брест крепостенда сугыш башланган көнне бөтен дөреслеге белән күз алдына китерергә ярдәм итә.* Туганайлар

3) *күч.* Тарихи бер күренеш; күз алдына китерелгән яки сурәтләнгән эпизод. *Тик шуны әйтеп үтәргә кирәк: киң тарихи панораманы күз алдына китерү идеясе белән мавыгып, автор ара-тирә гади тарих сөйләүгә күчә.* Ф.Урманче. *Күпсанлы пьесаларында халкыбыз тарихының гаять катлаулы, каршылыклы чорларының тулы панорамасы чагылыш таба.* Казан утлары

ПАНОРА́МАЛЫ *с.* 1) Киң манзара ачылган. *Яңа бинада 9 мең кв. м мәйданда «А» класслы офислары белән заманча бизнес-үзәк, 50 дән алып 150 кеше сыйдырырлык 8 заллы конгресс-үзәк, «4 йолдызлы» категориясендәге 213 кунакханә номеры, 200 кешелек панорамалы ресторан бар*. Ватаным Татарстан. *Моннан бөтен Димәшкъка панорамалы манзара ачыла.* Шәһри Казан

2) Берничә ноктадан төшерелеп, 180 градустан да киңрәк күзәтү мөмкинлеге бирә торган

3) *күч.* Төрле яклап чагылдырган. *Аның [А.Тимергалинның] 2007 елда басылып чыккан «Миллият сүзлеге» татарның милли космосын киң һәм панорамалы итеп ача*. Фән һәм тел

ПАНРУСИЗМ *и. гр.* Барлык көнчыгыш славяннарны да руслар дип исәпли һәм аларның мәдәният һәм сәясәт ягыннан берләшүен күздә тота торган идеология

ПАНРУСИСТ *и. гр.* Панрусизм тарафдары. *[Мирсәет Солтангалиев] чын мәгънәсендәге күрәзәчелек мисалы итеп бәяләнерлек хезмәтендә республикаларны бетерергә тырышучыларны панрусистлар дип атый.* И.Таһиров

ПАНСИОН *и. фр.* 1) 1917 нче елга кадәр Россиядә һәм кайбер чит илләрдә үз тулай торагы яки интернаты булган, ябык типтагы, дәүләткә караган яки хосусый урта мәктәп. *Мин атаклы педагог Сюар әфәнде пансионына йөрим һәм, тулай торакта урын җитмәгәнгә күрә генә, квартирда торам.* А.Тимергалин

2) Яшәүчеләрне азык-төлек белән тулысынча тәэмин итеп тора торган кунакханә

ПАНСИОНАТ *и. фр. к.* **пансион** (*2 мәгъ*). *Ялтага килеп төшкәч тә, Ялтаның матурлыгына, аның зифа буйлы кипарисларына, чәчәкләр эченә күмелгән пансионатларга да карамыйча, иң элек --- Галимҗан Ибраһимов янында буласы килде.* Г.Кутуй. *Бу мәктәп янына тора-бара яңа биналар корыла, --- Маньчжуриянең башка якларыннан укырга килгән татар балалары өчен пансионат эшли.* Ә.Кәримуллин. *Ял итәсе килә башлагач, «Парус» пансионатына барып, бераз ял итеп алырбыз.* М.Юныс

ПАНСИОНЕР *и. лат.* Пансионда яшәп торучы кеше (укучы, турист, мөсафир һ.б.)

ПАНСЛАВИЗМ *и. гр.* Славян халыкларының этнос, мәдәният һәм тел уртаклыгы нигезендә берләшүен күздә тоткан сәяси идеология. *Пантюркизм – урыс панславизмына каршы табигый рәвештә туган бер сәяси агым ул.* М.Галәү. *Самодержавие һәм рус буржуазиясе, панславизм байрагы астында Балкан дәүләтләренә ярдәм кулы сузган булып, Истанбул һәм атаклы бугазларны тартып алырга теләгән бер вакытта, --- Тукайның да симпатиясе Төркия ягында булган икән, бу – бик табигый.* И.Нуруллин

ПАНСЛАВИСТ *и. гр.* Панславизм тарафдары. *Ләкин панславистлар күерганда, панислам, пантөрек уянмый калмаячак.* Р.Батулла

ПАНТАЛОН *и. фр.* 1) Тар балаклы чалбар төре. *Өстендә кара фрак, ак жилет һәм зәңгәр панталон.* Ж.Тәржеманов

2) Гәүдәнең билдән түбәнге өлешен каплап тора торган хатын-кыз эчке киеме

ПАНТЕИЗМ *и. гр.* Алланы җиһан, табигать белән тәңгәлләштергән, аннан аерылгысыз итеп таный торган динифәлсәфи тәгълимат. *Феодализм чорында пантеизм, рәсми дини идеологиягә капма-каршы торып, прогрессив роль уйнаган.* М.Мәһдиев

ПАНТЕИСТ *и. гр.* Пантеизм тарафдары

ПАНТЕЙСТИК *с.* Пантеизмга мөнәсәбәтле, шуңа караган. *Дингә ышанучылар арасында пантеистик настроениеләрнең көчәюе хәзерге дини аңның кризисын раслый.* Я.Абдуллин

ПАНТЕОН *и. гр.* 1) Нинди дә булса бер диннең яки мифологиянең барлык илаһлары төркеме. *Тәңречелек*

мифологиясе пантеонында янә Умай, Йер-Су, Гуар/Куар һәм ут аллалары бар. И.Шәрипов

2) Борынгы грекларда һәм римлыларда төрле илаһларга багышланган гыйбадәтханә. *Борынгы мәҗүсилек аллалары урынына Борынгы Мисырда Ра дигән аллага, Римда Юпитерга буйсынучы барлык аллаларга багышланган гаять зур пантеоннар пәйда була.* Диннәр тарихы

3) Атаклы кешеләр күмелгән урынның гомуми атамасы. *Халкыбызның милли азатлыгы, бәйсезлеге өчен корбан булган каһарман бабаларыбызның пантеоны булган бу изге җиргә хаҗ кылу – җаны туңа башлаган, милли, тарихи аңы томалана баручы адәмнәрне айныту өчен үзенә күрә бер мәктәп, әйтеп бетергесез зур сабак та.* Ә.Кәримуллин

ПАНТО́ГРАФ *и. гр. геогр.* План һәм карталарны оригиналына караганда зурайту яки кечерәйтү өчен кулланыла торган прибор

ПАНТО́МЕТР *и. гр.* Якынча төгәллек белән топографик план төшерүдә кулланыла торган почмак үлчәгеч инструмент

ПАНТОМИ́МА *и. гр.* Персонажларның уй-хисләре, теләк-омтылышлары йөз һәм тән хәрәкәтләре аркылы белдерелә торган театраль тамаша. *Пантомима тамашачының өзлексез көлүе астында дәвам итә.* И.Рәмиев. *--- тамаша баштанаяк бары тик уен, җыр-бию һәм пантомимага корылган.* Н.Исәнбәт

ПАНТЮРКИЗМ *и. гр.* Төрки халыкларның этнос, мәдәният һәм тел уртаклыгы нигезендә сәяси берләшүне кирәклеген алга сөргән мәдәни һәм сәяси агым. *Аны панисламизмда, пантюркизмда, революциягә кадәр чыккан татар басмаларын мактауда гаеплә язылган яла хатлары да җыела башлый.* Р.Рахмани

ПАНТЮРКИСТ *и. гр.* Пантюркизм тарафдары. *Идел буе төркитатарларның төрекләр белән этник һәм мәдәни якынлыгы, алар арасында мең еллар яшәп килгән әдәби, мәдәни элемтәләр турында сүз кузгатучыларны «пантюркист» яки «төрек шпионы» дип атарга --- гына торалар иде.* Ә.Кәримуллин. *Дүртенчедән, син – басмачылар башлыгы – ата пантюркист, панисламист, авантюрист һәм хаин Әнвәр пашаны яшертен күмүче.* Р.Батулла. *Пантюркистлар төрек телен яки ул телгә бик якын торган кырым телен барлык төрки халыклар өчен дә уртак тел итеп алуны дәгъва итәләр.* Татар грамматикасы

ПАНТЮРКИ́СТИК *с.* Пантюркизмга мөнәсәбәтле, шуңа бәйле. *Кадимчеләр һәм җәдитчеләр бер яктан, панисламистик, пантюркистик, буржуаз милләтчелек идеологиясен таратырга тырышсалар, икенче яктан, царизмның, патша самодержавиесенең агентурасы ролен дә үтиләр.* Х.Мөхәммәтов

ПАНТЮРКИСТЛЫК *и.* 1) Пантюркист булу

2) *к.* **пантюркизм**. *Бу хикәядә алынган сурәт – пантюркистлык белән саташып йөргән милләтче Харисов.* Г.Нигъмәти. *Пантюркистлык гадәттә Төркия дәүләте йөрткән агрессив политикага мөнәсәбәттә бик ачык чагыла.* Казан утлары

ПА́НЦИРЬ *и. нем.* 1) *тар.* Металл пластиналарны һәм божраларны берберсенә беркетеп ясаган хәрби кием, көбә. *Әгәр аны утыртып, алгы ягы белән үзебезгә борсак, панцирь кигән Урта гасыр рыцарен күрербез.* Борынгы гасырларда Татарстан

2) *зоол.* Кайбер хайваннарның тиресе урынына үскән сөяк кабык. *Аларның озын гәүдәләре панцирь белән капланган, ә ул панцирь ике рәт каты сөяк калканнардан һәм аеллардан тора.* Борынгы гасырларда Татарстан

3) Хәрби корабларның, поездларның махсус металл тышлыгы; броня

ПА́НЦИРЬЛЫ *с.* Панцире булган, панцирь белән капланган. *Казан геология музеенең девон коллекциясе витринасында ике панцирьлы балык бар.* Борынгы гасырларда Татарстан

ПА́НЦИРЬЛЫЛАР *и. күпл. зоол.* Сөяк кабык белән капланган борынгы хайваннар классы. *Силур диңгезләрендә балык сыман панцирьлылар яшәгән.* Үткән заманга сәяхәт

ПАҢГЫ *и. мордв. диал.* Гөмбә. *Паңгы булдыңмы – кер кызауга.* Мәкаль

◊ **Паңгы баш** *туп.* Ахмак, аңгыра. *Хәзерге заманда кешенең яхшы аты – кубышка. Паңгы баш булма, аңларга кирәк!* Г.Әпсәләмов

ПА́ПА *и. гр.* Католик чиркәвенең иң югары башлыгы. *Урсуланың күңелкәе бер дә тыныч түгел иде: менә папа буласы малайны ничек тә сүлпәнлектән чыгарасы, чыныктырасы бар.* К.Миңлебаев. *1932 елда Г.Исхакый Рим папасы тарафыннан кабул ителә. М.Гафуриның «Гаяз Исхакыйның папа алдында сәҗдә»се шигырьләре шуның мисалы.* Х.Миңнегулов. *Ватикан – католицизм дөньясы үзәге, Рим папасының резиденциясе.* Без тарихта эзлебез

ПАПА́ХА *и. төрки* Йонлач ягы тышка каратып тегелгән цилиндр формасындагы тирән мех бүрек. *Мин Чапаев абыемны кинодан күреп беләм, Аңа охшарга тырышып, кара папаха киям.* Җыр. *Бүгенгедәй хәтеремдә: Ибрай солдат, папахасын салып, башын түбән иде.* М.Сөндекле

ПАПА́ХАЛЫ *с.* Папаха кигән. *Ротаның алдыннан баручы биек соргылт папахалы, таза гәүдәле командир турысына килеп җитүгә, Митричев атларны туктатты.* Г.Бәширов

ПАПИРОС *и. пол.* Эченә тәмәке тутырылган кәгазь көпшә. *Мин шинелемне киеп, тумбочкадан бер пачка папирос элэктердем дә ишеккә атладым.* И.Салахов. *Чыгып китәр алдыннан аңа ун сум, бер шешә көмешкә өстенә бишалты папирос та бирделәр...* З.Хәким. *Мунштук яки папиросны авызга еш кабу, бик кайнар һәм әче азыклар ашау, иренне тешләү һәм ялау гадәте иренгә начар тәэсир итә.* Р.Зиляева

ПАПИ́РУС *и. гр.* 1) Күрәнчәләр семьялыгыннан озын сабаклы, төбендә кабырчыксыман яфраклы күпьеллык тропик үсемлек. *Папирус тропик Африкада елга һәм күл буйларында акрын агымлы суда киң куе куаклыклар ясап үсә*

2) Шул үсемлекнең сабагыннан телеп эшләнгән борынгы язу материалы

3) Шундый язу материалына язылган һәм хәзерге көннәргә кадәр

сакланган кулъязма ядкәр. *Антик чор галимнәренең китаплары (папирус төргәкләре), йөзләгән мәрмәр сын, йорт җиһазлары, стена фрескалары һәм әллә никадәр башка әйберләр табалар.* Без тарихта эзлебез

ПА́ПКА *и. нем.* Эченә кәгазьләр, рәсемнәр салып яки кыстырып куя өчен тышча. *Утыздан артык папка: приказлар, күрсәтмәләр, документлар, экипаж әгъзаларының чит ил паспортлары, таможня декларацияләре…* М.Юныс. *Икенче папка да шап итеп Таһировның алдына килеп ятты. Нәүбәт өченче папкага җитте.* Ф.Яруллин. *Бу документлар --- гестапоның «БСВ»ны фаш итү» дигән эш папкасына теркәлгән.* С.Шакир

ПА́ПРИКА *и. венг.* Киптереп төелгән кызыл борыч. *Паприканы төрле ашларга тәмләткеч итеп сибәләр, кызыл аракы ясауда файдаланалар.* Бакчачы, яшелчәче һәм умартачы календаре. *Табага тәгәрмәчләп туралган суган салып, тоз, паприка, карри сибеп, болгата-болгата кыздырырга.* Ватаным Татарстан

ПАПУАС *и. малай* Яңа Гвинея утравы һәм шуның янындагы башка ваграк утрауларның җирле халкы; шул халыкның аерым бер кешесе. *– Ә җирле халык, ягъни папуаслар, кайда яши? – дип кызыксынуында булды швед.* Р.Мөхәммәдиев. *Нәкъ менә шуңа күрә 2012 елгы халык санын алу вакытында Татарстанда яшәүче ике кеше үзләрен инк һәм папуас дип теркәткән.* Татарстан яшьләре. *Башка утрауларның җирле халкы үзенә аерым полинезия төркеменә керә, алар папуаслардан аксылрак тәнле, бөдрә чәчле булулары белән аерылып торалар.* Материклар һәм океаннар географиясе

ПАПЬЕ-МАШЕ *и. фр.* Кәгазь вагыннан җилем, крахмал, гипс кушып ясалган масса; шул массадан ясалган әйбер. *Укытучы өстәлгә ваза һәм аның кырына папье-машедан ясалган алма куйды да, шуларны ясагыз, диде.* Н.Көбәш. *Әйтергә кирәк, ул җитәкли торган нәфис сәнгать бүлегендә рәсем ясап, картиналар иҗат итеп кенә калмыйлар, интерьер дизайны буенча рефераглар язалар, папье-маше, архитектура буенча макетлар ясыйлар.* Ватаным Татарстан

ПАР I *и. рус* 1) Сыек яки каты матдә кисәкчекләренең күпләп очып күтәрелүеннән барлыкка килгән газ; бу. *Исебез китте. Ишек төбендә – ризык кисмәге. Пар чыгып тора – чумар.* И.Салахов. *Авызыннан сулар килсә дә, пар бөркеп утырган өчпочмакларны этеп җибәрде.* Ф.Яруллин

2) Атмосферадагы эссе һәм салкын һаваның тәэсир итешүе нәтиҗәсендә барлыкка килә торган дым, томан. *Цехта пар бөтерелә, пар айкала: көзге болытлар кебек тау-тау күтәрелеп, бөтен корпус буенча җәелә.* И.Гази. *Сулыш алганда, үпкәгә су парлары тула, кайнар су парлары тамакка тыгыла.* М.Юныс. *Җылынган һәм бик дымлы һава атмосфераның өске салкын катлаулары белән очрашканда, су парлары болыт булып куера.* Могҗизалар энциклопедиясе

3) Бик нык җылытылган дымлы һава. *– Мунча әзер, әни. – Барыгыз, алайса, пары сүрелгәнче юынып алыгыз!* Н.Гыйматдинова

4) Үсемлекләр бүлеп чыгара торган газ хәлендәге органик матдәләр (эфирлар һ.б.ш.). *Үсемлекләрнең исле пары борынны кытыклый һәм үпкәләргә сыланган кебек була.* Ә.Еники

5) *күч.* Кызулык, дәрт, темперамент. *Бөтен парың биреп омтыл алга, Үртәләмә йөрәк ярасын.* Ф.Кәрим. *Фазылҗанов, сугышчан әтәч кыяфәтеннән чыгып, үз кыяфәтенә кергән, пары яхшы ук басылган.* Ф.Хөсни

ПАР II *и. рус* 1) Туфрагының сыйфатын яхшырту өчен, бер җәйгә чәчелми калдырылган кыр; такыр басу. *Бары пар кырында гына соңга калган кайбер сукачыларның ялкау гына атлап йөргән атлары күзенә чагылды.* Һ.Такташ. *Пар басуларында елына ике тапкыр уңыш алына, чөнки чиста пар басулары биләмле парларга алыштырылды.* Г.Галиев. *Таш булып каткан пар басуын сөргәндә, сабан тоткасы сине, сабаннан аз гына калкурак үсмер малайны, чөеп-чөеп ыргыта…* Г.Бәширов

2) *сөйл.* Парга сөрү эше. *Яңгыр чакыра басуларга, язгы парга.* М.Җәлил. *Колхозның ике туры алашасын парга җиктеләр.* А.Алиш. *Пар иртәгә бетә.* Г.Бәширов

ПАР III *с.* **1.** 1) Җенси теләк чорында яки даими рәвештә гаилә тәшкил итеп торган (иркәк белән теше). *Пар былбыллар кавышкандай, ничек кавыштыгыз сез?* Җыр. *Безнең мәхәббәткә шаһит пар сандугачлар киткән.* Г.Зәйнашева. *Нәҗипләрнең тәрәзә каршысындагы каенга пар сыерчык кунып сайрап китте.* Ф.Яруллин

2) Тиң; лаеклы, кулай, тигез, бердәй. *Матур егет пар кыз таба, Йөрми гомер уздырып.* Г.Камал. *Эштә көчем шул егетләр белән пар минем.* Ф.Кәрим

3) Охшаган, охшаш. *Әгәр шул кызны миңа димләп, чыгарып бирә аласың икән, --- шахтадан беренче кайтканда ук, сиңа әни белән пар күлмәк.* А.Шамов

2. *и. мәгъ.* 1) Бер бөтен тәшкил итә һәм бергә кулланыла торган, бериш ике предмет. *Миңа шушы тиреләрдән тун белән бүрек өстенә бер пар бияләй тегеп бирерсең инде, яме.* Ф.Яруллин. *Кесәсеннән тимер ачкыч, бер пар резин перчатка һәм ике данә йөзәр сумлык кәгазь акча табылды.* М.Насыйбуллин

2) Ниндидер уртак шөгыль яки башка максат белән берләшкән ике зат. *Лидерлар өчлеген Венгрия спортчылары пары йомгаклады.* Ватаным Татарстан

3) Егет белән кыз яки ир белән хатын. *Бу кадәр матур пар булып Ничек табыштыгыз сез?* Җыр. *Әле кайчан гына алардан матур пар юк иде кебек.* Ф.Яруллин. *Басу кырыенда берәнсәрән генә агачлар утырып калган. Һәркайсының төбенә берәр пар кунаклаган.* Я.Абдуллин

4) Егет белән кызның яки ир белән хатының берсе; гашыйкларның берсе (бер-беренә карата). *Парым булса да, ярым түгел Рәмис, яратмыйм мин аны, әз генә дә яратмыйм!* Н.Гыйматдинова

5) Тиң, лаеклы яр, иш. *Язмыш миңа мәрхәмәтле булды, Пар таптым мин үземә синнән соң.* Р.Маннапов. *Әй Халисә, Халисә... Синең дә бәхетләрең юк инде... Син дә берьялгызың... һе, Гаделша әйтә, Халисә сиңа менә дигән пар*

булыр иде, ди... З.Хәким. *Бу җәһәттән мәмләкәтнең нинди төбәгендә булуга карамастан, кавышу яшенә җиткән яшьләргә пар сайлауда, гомумән, килешү-табышуда, кодалауда гамәлдә бернинди кыенлыклар күзәтелми.* Р.Әмирхан

6) Ике академик сәгать дәвамында уздырыла торган дәрес, лекция. *Мин монда укудан соң гына эшлим. Бүген беренче пар юк иде. Болай университетта укыйм, чит телләр бүлегендә.* Ф.Хәбибуллин

◊ **Парга килү** Бер-берсенә туры килү. *Карлыгачның тавышы иптәш кызының тавышы белән шундый парга килә.* Г.Бәширов. **Пар килү** Бер-берсенә тиң булу. *Әй икегез, икегез, Икегез дә бертигез; Икегез дә пар килгәнсез, Тигез гомер итегез!* Җыр. *Аларның пар килмәгән җирләре юк. Буй-сыннарының зифалыгы, төс-битләренең чибәрлеге җәһәтеннән дә, холыклары ягыннан да алар бер-берсенә сокланғыч дәрәҗәдә тиңнәр.* Г.Бәширов. **Пар күгәрчен кебек** Бер-берсен сөеп, яратышып. *Пар күгәрчен кебек гөрләшеп, Ике йөрәк бергә берләшеп, Ике ялкын бергә кушылган.* Ш.Маннур

ПАРАБЕ́ЛЛУМ *и. лат.* Автомат принцибында ата торган пистолет төре. *Өстәл өстендә ялтырап яткан парабеллум һәм --- пистолетны алып Беркутовка бирдем.* Ә.Айдар. *Шпигель әфәнде --- хәтта кобурындагы парабеллумын суырып чыгармакчы була иде.* Ш.Маннур

ПАРА́БОЛА *и. гр. мат.* Ике очы үзара кисешми һәм тоташмый торган симметрик кәкре сызык. *Парабола күчәре*

ПАРАБО́ЛИК *с.* 1) Парабола формасындагы. *Параболик антенна*

2) *мат.* Парабола функциясе нигезендә. *Параболик тигезләмә*

ПАРАБОЛО́ИД *и. гр. мат.* Параболаны үз күчәре тирәсендә әйләндереп чыгарудан барлыкка килгән фигура. *Соңгы вакытта параболоид, эллипсоид, гиперболоид, параболоид өзекләр рәвешендәге фәзаи япсар (түбә) конструкцияләре дә тәкъдим ителә.* Төзү материаллары

ПАРА́ГРАФ *и. лат.* 1) Текст яки бүлек, бүлекчә эчендә үзенә аерым әһәмияте булган өлеш, өземтә. *Телефонограмманы язып бар! Беренче параграфның «а» пункты: биредә ничәнче кабинетта борын тишекләрен тикшерәләр?* А.Расих. *Уставның алтмыш өченче параграфыннан башлап, капитанның конкрет вазифалары саналып китә...* М.Юныс. *«Эрмитаж уставы»ның икенче параграфында Әби патшаның кунакларыннан горурлык, дәрәҗә һәм өлкәнлекне онытулары сорала.* Әдәп төбе – матур гадәт

2) Шундый бүленешнең баш тамгасы (§). *Языгыз! § 82, пункт «а», подпункт 1. Яздыгызмы?* А.Расих

ПАРАД *и. фр.* 1) Рәсми бәйрәм уңаеннан хәрби көчләрнең тантаналы рәвештә тезелеп узуы. *Күкрәге киерелеп алга чыккан. Башы югары күтәрелгән, парадта Мавзолей яныннан узамыни!* И.Салахов. *– Командир, әллә безне Җиңү парадына чакыралармы? – диде ул, Сәләхов янына килеп җиткәч.* М.Юныс. *Исе китеп, карап, Аны Җиңү бәйрәмендә Узар беркөн парад!* Зөлфәт

2) Спортчылар, яшьләр һ.б.ш.ның тантаналы йөреше. *Парадта безнең спортчылар да катнашты*

ПАРАДИ́ГМА *и. гр.* 1) *лингв.* Сүзнең төрләнеш үрнәге итеп бирелгән формалар системасы. *Сүзъясалыш типларының грамматикадагыча парадигмалар рәвешендә төзү мөмкинлеге гомуми морфология буенча хезмәтләрдә дә искәртелә.* Ф.Хисамова. *Югарыда китерелгән төрләнеш парадигмасыннан күренгәнчә, килеш кушымчалары барысы да тартык авазга башлана (кыпчак телләренең үзенчәлеге), һәм аларның ике, дүрт, алты фонетик варианты бар.* Татар грамматикасы

2) *филос.* Билгеле бер тарихи чор дәвамында фәнни җәмәгатьчелек тарафыннан кабул ителгән проблемаларның куелыш һәм аларның хәл ителеш моделе, концептуаль схемасы. *Илнең икътисадын савыктыру өчен, ди Р.И.Нигъмәтуллин, хакимияткә һәм сәяси партияләргә интеллектуаль басым ясап, икътисади парадигманы --- алмаштырырга кирәк.* Р.Юсупов

ПАРАДИГМА́ТИК *с.* Парадигмага хас булган; парадигмага нигезләнгән. *Төп, парадигматик мәгънәдә категорик үткән заман сөйләү моментыннан алда сөйләүченең күз алдында булган, тәмамланган, кабатланмаган эшхәлләрне процесс рәвешендә белдерә.* Ф.Хисамова. *Парадигматик анализ вакытында омонимик, синонимик, антонимик рәтләр ачыклана.* М.Вәлиева

ПАРА́ДНЫЙ *и. рус сөйл.* **1.** Йортның, бинаның урам ягына чыга торган төп, зур ишеге. *Парадный төбенә җиткәч, син йөрәккә ятышлы гажәеп бер елмаю белән минем иреннәремә карадың.* Г.Кутуй. *Үтеп барам шулай урам буйлап, Парадныйда күрәм бер бала. Звонокка үрелә, буе җитми, Аптырагач карап уйлана.* М.Җәлил. *Мин каршы бер сүз әйтергә дә өлгермәдем, кеше мине җилтерәтеп парадный ишегеннән алып кереп китте.* А.Расих

2. *с. мәгъ.* Төп, алгы (ишек, баскыч, капка һ.б.ш.) *Киң асфальт юл туптуры парадный баскычка алып бара.* Г.Әпсәләмов

ПАРАДОКС *и. гр.* Гомуми кабул ителгән һәм дөрес дип саналган фикерләргә, күзаллауларга кискен каршы булган, ышанмаслык булып тоела торган фикер, күренеш һ.б. *Парадокс килеп чыга. Нәкъ менә шул «егылырга ярамый» дигән нәрсә егылу ихтималын арттыра!* Ф.Зыятдинова. *Кызыклы парадокс, әмма факт: галимнең моннан соңгы төп гыйльми хезмәтләре дә «тыелган тема»га һәм «планнан тыш» – буш вакытларда эшләнә.* Р.Рахмани. *Менә шушы парадокс заман фәлсәфәсен тәшкил итә дә инде.* Ф.Бәшир

ПАРАДОКСАЛЬ *с.* Парадокс булып күренә торган; парадокска бәйле. *Соңгы елда вузлардагы милли тел һәм әдәбият белгечлекләренә студентлар кабул итүдә дә парадоксаль хәл хөкем сөрә: Россия Мәгариф министрлыгы әмере белән, татар мәктәпләрен тәмамлап, татар филологиясе факультетына укырга керүче абитуриентлар мәктәптә рус теленнән һәм рус әдәбиятыннан биргән бердәм дәүләт имтиханнары нигезендә кабул ителәләр.* Р.Юсупов. *Кеше шактый*

күңелсез тозакка эләгә, аңарда асылда парадоксаль хәлнең бер варианты – ихтыяр богаулану барлыкка килә. Ф.Зыятдинова

ПАРАЗИТ *и. гр.* **1.** 1) Башка бер организмның тукымалары белән туклана һәм аңа зарар китерә торган организм (үсемлек, хайван). *Нинди бактерияләрне – сапрофитлар, ә ниндиләрен паразитлар дип атыйлар?* Биология. *Үпкәсенә оялаган мәкерле микроб-паразитлар белән дүрт ай буе көрәшә Дуглас.* Р.Ишморат. *Аскарида – иң гадәти паразитларның берсе, аеруча җылы, җәй озын, ә туфрак җитәрлек дымлы булган өлкәләрдә күп очрый. --- Кеше организмында тереклек итә торган иң эре паразитларның берсе – үгез тасма суалчаны.* Татарстан үсемлекләр һәм хайваннар дөньясы

2) *күч.* Икенче берәүнең көченнән, хезмәтеннән файдаланып яши торган кеше; әрәмтамак, сорыкорт. *Әсәрдә муллалар, мәзиннәр, хәлфәләр --- халыкны эксплуатацияләп яшәүче паразитлар итеп биреләләр.* Х.Мөхәммәтов

3) *сөйл.* Сүгү яки сүгенү сүзе. *Менә бу паразит сезнең намусыгызга тап төшерә торган сүзләр сөйли.* Т.Гыйззәт

2. *с. мәгъ.* 1) Башка бер организмдагы органик матдәләр белән туклана торган. *Паразит бактерияләр арасында авыру тудыручылар күп. Паразит гөмбәләр белән зарарланган алмалар кубакланып куба торган таплар белән каплана, ә аннары ярыла.* Биология. *Камчылылар арасында паразит формалар да аз түгел. Споровиклар – паразит организмнар, аларның күбесе – кешедә һәм йорт хайваннарында куркыныч авыруларны кузгатучылар.* Татарстанның үсемлекләр һәм хайваннар дөньясы

2) *күч.* Икенче берәүләрнең көченнән файдаланып яши торган. *Паразит сыйныф катлавыннан булган бик күп кешеләр ватан геройлары булып күренергә азапланалар.* М.Гайнуллин

ПАРАЗИТАР *с.* **1.** 1) *биол.* Паразитлар тарафыннан таратыла торган. *Хәмит Әюпов бик җитди эзләнүләрдән, йөзләрчә фәнни-гамәли экспериментлардан соң бу куркыныч паразитар чирне [дикроцелиозны] таратучыларның гап-гади кырмыскалар булуын ачыклый.* Кызыл таң

2) *күч.* Паразитларча, сорыкорт булып яши торган. *Илдәге яңа торгынлыкның, кирәкмәгән стабильлекнең беренче авторлары – чиновниклар, алар хакимияте, алар диктаты --- балда, майда йөзүче, барысыннан да канәгать паразитар катлау.* Ватаным Татарстан

2. *рәв. мәгъ.* Паразитларча, паразитлар кебек. *Тукай әдәби образ булырак тудырган хезмәт кешесенең яшәү шартлары аның хезмәтеннән үк лаексыз, паразитар файдаланган байларныкына каршы куела.* Р.Рахман

ПАРАЗИТИЗМ *и. гр.* 1) Бер организмның (паразитның) икенче организм (хуҗа) тукымалары белән туклануына нигезләнгән тереклек итү күренеше. *Энтомология фәненнән билгеле булганча, бөҗәкләр «нигездә паразитизм һәм тышкы шартлар белән көйләнә торган тормыш дулкыны» белән үрчи.* Фән һәм тел

2) Башка берәүнең хезмәтен кулланып яшәү рәвеше; әрәмтамаклык, паразитлык. *Монополияләр хакимлеге --- капитализмны паразитизмга, черүгә китерде.* Иң яңа тарих

ПАРАЗИТЛАРЧА *рәв.* Паразитларга хас булганча; паразитларга охшап. *Колларның хезмәт шартларын, алпавытларның крестьяннар исәбенә паразитларча яшәвен, крепостнойларның бертөрле хокуктан да файдаланмавын һ.б. күрсәтү либреттода җитенкерәми әле.* М.Җәлил. *Тик икътисад факультетларына кергән яшьләрнең бүгенге буыны ярык тагарак янында калачак, якындагы ун-уникә елда куәтле җимерелү һәм газаплар аша яңа системаның тууы көтелә, ә ул системада инде паразитларча яшәү рәвеше булмас дип ышанылык.* Ватаным Татарстан. *Үзе үк шул җыенда катнашкан профессор Мәҗит Хуҗин рәсми газета битләрендә Зайнур, Айрат әфәнделәрне милли мәсьәләне паразитларча файдалануда гаепли.* Татарстан яшьләре

ПАРАЗИТЛЫК *и.* 1) Паразит булу

2) *к.* **паразитизм**. *Иренчәк һәм эшсезләрне дөнья бетереп хурлау, ялкаулык, паразитлыкка каршы аяусыз көрәш, уяулыкка, активлыкка өндәүләр – татар мәкальләренең иң яраткан эше.* А.Низаметдинова

ПАРАЗИТЛЫ́К ИТҮ *ф.* Паразит булып яшәү. *Тасма суалчаннар кеше һәм хайван организмында паразитлык итәләр, алар эчәк стенкаларына берегеп, бөтен тән өслеге белән туклыклы матдәләрне суыралар.* Татарстанның үсемлекләр һәм хайваннар дөньясы

ПАРАЗИТЛЫ́К КЫЛУ *ф. к.* **паразитлык итү**. *Бизнеста паразитлык кылучы тикшерүче органнарны юкка чыгаруга юнәлтелгән җәза бирү чаралары Грузия элитасының югары сыйфатка ирешүенең бердәнбер чарасы гына булмый.* Р.Юсупов

ПАРАЗИТОЛО́ГИЯ *и. гр.* Биологиянең паразитизм күренешен өйрәнә торган тармагы. *Биредә санитария-эпидемиология өлкәсендә куркыныч хәлләрне булдырмау максаты белән киң күләмле тикшерүләр уздыру өчен, даими рәвештә химия, бактериология, паразитология лабораторияләре, санитария һәм дезинфекция бүлекләре эшли.* Дару кабарга ашыкма

ПАРАЛИ́ТИК I *с.* Паралич суга торган, параличлый торган. *Бу чирләр паралитик, вируслы, бактериологик, гөмбәчекле һәм аллергик төрләргә бүленәләр.* Безнең гәҗит. *Еш кына мөгезле эре терлектә котыру авыруы паралитик формада була*

ПАРАЛИ́ТИК II *и. гр.* Паралич суккан, параличланган кеше. *[Шәмгун:] Бөтен җаны, дәрте, теләге, ихтыяры суырылып алынган паралитик хәлендә мин хәзер.* Ә.Фәйзи

ПАРАЛИЧ *и. гр.* 1) Нерв системасының зыян күрүе нәтиҗәсендә тәннең нинди дә булса бер әгъзасын үз функциясен үтәүдән, хәрәкәтләнүдән тулысынча яки өлешчә туктата торган авыру; фалиҗ. *Ничек кенә дисәң дә, бу кәһәр төшкән параличка хәтлесе, яхшымы-яманмы, тормыш булган икән.* Ф.Хөсни. *Аны салкын тиеп баш авыртканда, паралич сукканда, шулай ук бит нервысына паралич булганда, нерв авырулары вакытында кулланалар.* Р.Газизов

2) *күч.* Берәр затның төрле сәбәпләр аркасында үз функцияләрен үти алмау хәле. *Чит илләрдән килгән татарлар һәм мөселманнар, Болгар белән таныша башлагач, рухи паралич хәлендә калалар.* Ә.Кәримуллин. *Фатих Кәрими, ислам җәмгыятьләрен «паралич суккан җәмгыятьләр» дип бәяләгән һәм бу хәлне җәмгыятьтә хатын-кызлар алган урын белән бәяләгән.* Р.Сафин

ПАРАЛИЧЛАНУ *ф.* 1) Паралич хәленә килү, төп функцияләрен үтәүдән туктау (тән әгъзалары һ.б. тур.). *1938 елда туган Әхмәд Ясин 12 яшендә футбол уйнаганда егылып параличлана һәм бик нык сукыраеп кала.* Татарстан яшьләре. *Хайваннар белән үткәрелгән тәҗрибәләр андый шартларда организмның зыян-зарар күрми генә озак вакыт бик нык суынуны да кичерә алуын күрсәтте. Ул чагында тән температурасы 5–7 градус кына җылы булырга мөмкин, сулыш алу параличлана, йөрәк эшчәнлеге туктый.* Могҗизалар энциклопедиясе

2) *күч.* Үз функциясен башкарудан туктау (иҗтимагый оешмалар һ.б.ш. тур.). *Башкалада анархия, хөкүмәт параличланган.* К.Нәҗми. *Чираттагы көчле циклон нәтиҗәсендә АКШның Филадельфия, Пенсильвания, Нью-Джерси, Мэриленд һәм башка штатлары «параличланган».* Татарстан яшьләре

ПАРАЛИЧЛА́У *ф.* 1) Паралич хәленә китерү. *Елан кебек, ул үз корбанын карашы белән параличлады.* Ф.Яруллин

2) *күч.* Үз функциясен үтәүдән туктату. *Ачлык кешене дистрофиягә дучар иткән шикелле, аның рухи тормышын параличлаган, бары тик ашау турында гына уйларга мәҗбүр иткән шикелле, секс ачлыгы да барлык кыйммәтләр системасын үзгәртә, рухи дистрофия, авырулар китереп чыгара.* Р.Камалова

ПАРАЛИЧЛЫ *с.* Тулысынча яки өлешчә үз функциясен үтәүдән туктаган. *– Ә мин группада, уң ягым параличлы, – диде ул, таягына таянып.* Өмет. *Бу бүлек «шуышучылар бүлеге» дип атала, монда чын гарипләр, мутантлар, церебраль параличлы балалар ята.* Татарстан яшьләре. *Параличлы балалар өчен бик зур алга китеш инде болар.* Ватаным Татарстан

ПАРАЛЛЕЛЕПИ́ПЕД *и. гр. мат.* Капма-каршы яклары үзара параллель булган алтыкырлык. *Кирпечләрнең тышкы күренешләре һәм үлчәмнәре төрле: күбесе параллелепипед рәвешендә булып, горизонталь өслекләре параллель, яннары фигуралы кирпечләр дә шактый.* Фән һәм тел. *Әйтик, икенче урынга чыккан Азәрбайҗан җырчысы Фәрид Мамедовның чыгышы пыяла параллелепипед эчендәге биюче белән залдагыларны таң калдырды.* Безнең гәҗит

ПАРАЛЛЕЛИЗМ *и. гр.* 1) *мат.* Параллель булу күренеше, параллельлек

2) Ике күренешнең бергә, берьюлы баруы. *Спектакльдә указның, факелның һәм курайның кулдан кулга йөрүе кебек параллелизм – бер үк алымны кабатлаулар --- уңышсыз.* М.Җәлил

3) *әд.* Тасвирлылыкны яки эмоциональлекне көчәйтү чарасы буларак синтаксик конструкцияләр кабатлану (мәс.: *Айның да бар йолдызы, Суның да бар кондызы.* Җыр). *Параллелизмнар халык җырларында бик еш очрыйлар, алар бигрәк тә табигать күренешләрен кеше тормышындагы вакыйгалар белән янәшә куеп сурәтләүдә күренәләр.* Н.Гыйззәтуллин

ПАРАЛЛЕЛОГРАММ *и. гр. мат.* Капма-каршы яклары үзара тигез һәм параллель булган дүртпочмак. *Параллелограммның диагонале аны үзара тигез булган ике өчпочмакка бүлә.* Геометрия. *Квадрат – барлык почмаклары туры булган дөрес дүртпочмаклык яки ромб, яисә, башкача әйткәндә, барлык яклары һәм почмаклары тигез булган параллелограмм.* Геометрия

ПАРАЛЛЕЛЬ I *с. гр.* **1.** 1) *мат.* Икенче бер сызык яки яссылыкка тигез ара саклап сузыла һәм чиксез дәвам иткәндә дә кисешми торган (бирелгән бер сызык яки яссылык тур.). *Геометрия буенча мәгълүм ки, параллель сызыклар кисешмиләр.* Г.Нигъмәти

2) Бер-берсенә янәшә, бер юнәлештә булган (объектлар тур.). *Параллель юл Нил елгасы аша бара.* Р.Сафин. *Параллель урамнарны йөри-йөри, Нариманга килеп җиттеләр.* Ш.Хөсәенов

3) Бер системада, бер-берсен кабатлый торган, янәшә. *Параллель класслар булгач, план төзүгә, дәрескә хәзерләнүгә әллә ни вакыт китмәс.* А.Тимергалин. *Түбәндәге кагыйдәләрне хәтердә тотыгыз: параллель номердан файдаланганда, куршеләрегез барын онытмагыз.* Әдәп төбе – матур гадәт

2. *рәв. мәгъ.* 1) Бер-берсенә карата тигез ара саклап; бер юнәлештә кисешми торган булып. *Башта тәртипсез урнашкан тимер кисәкчекләре кыр тәэсирендә бер-берсенә параллель булып борылалар, һәм кадак үзе дә магнитка әверелә.* Могҗизалар энциклопедиясе. *Әгәр дә ашап бетерүегезне күрсәтәсегез килә икән, тәлинкәне үзегездән читкә этәреп куймагыз, ә пычак белән чәнечкене бер-берсенә параллель итеп тәлинкә өстенә куегыз.* Әдәп төбе – матур гадәт

2) Бер үк вакытта, икенче бер шөгыль белән берәттән. *Шул үк вакытта «Париж колледжы»нда параллель рәвештә әдәбият факультетында да укый.* Ә.Кәримуллин. *Минемчә, бюрократизм, формализм, кәгазь волокитасы, узган гасырның 80 нче елларыннан алып, җитештерү кимүгә параллель рәвештә арта бара: производство бетә, җитештерү белән бәйле булмаган өлкәләр киңәя.* Р.Юсупов

ПАРАЛЛЕЛЬ II *и.* 1) *мат.* Бер үк яссылыктагы кисешми торган ике туры сызыкның берсе

2) *геогр.* Җир шары өстендә экваторга параллель I (*1 мәгъ.*) рәвештә берберсеннән тигез ераклыкта күңелдән үткәрелгән сызыклар; киңлек үлчәме. *Ә инде экватор аша узып, Кәҗә мөгезе тропигына чыккач, аны да артта калдырып, «үкереп торган кырыгынчы» параллельләргә җиткәч, кышкы кием кирәк була.* М.Юныс

3) *күч.* Тормышта, табигать, сәнгать һәм әдәбиятта бер-берсе белән янәшәлек, бергәлек һәм берәр яктан беришле үзгәрүчәнлек күренеше. *Контраст параллельләр, градацияле сурәтләр, куе буяулар белән бирелгән тормышчан детальләр, ритмик төгәллек, камил рифмалар, аллитерацияләр бу әсәрне классик лирика югарылыгына күтәрә.* Татар әдәбияты тарихы

ПАРАЛЛЕЛЬЛЕК *и.* Параллель булу; параллелизм. *Лобачевский параллельлек төшенчәсен киңәйтә һәм баета. --- Кисешмәүче сызыкларның ул фәкать икесен генә параллельләр дип атый.* Ж.Тәрҗеманов. *Киңәшмәдә Булат белән Андрей образларындагы параллельлек һәм бер-берсен кабатлавы хакында да әйтелгән иде*. М.Җәлил. *Роман фашизм белән коммунизм арасындагы параллельлек идеясе белән сугарылган, бу янәшәлек аеруча милли мәсьәләдә ачык чагыла.* В.Хаков. *АКШ белән СССР язмышларындагы параллельлек бүген артык күзгә ташлана*. Ватаным Татарстан

ПАРАМАГНЕТИЗМ *и. гр. физ.* Тышкы магнит кырына урнаштырылган матдәләрнең шушы тышкы кыр юнәлешендә магнитлану күренеше

ПАРАМАГНЕ́ТИК *и. гр. физ.* Парамагнетизм үзлегенә ия матдә (аз магнитлы кайбер газлар һәм металлар). *Әлегә кадәр без парамагнетик дип аталган җисемнәр хакында сүз алып бардык. Алардан тыш, магнитка тартылмый, аннан читкә этәрелә торган матдәләр дә бар, болар – диамагнетиклар. Көмеш, висмут, мәсәлән, шундыйларга керә.* Могҗизалар энциклопедиясе

ПАРАМАГНИТ *с.* Парамагнетиклар белән бәйле, шуларга хас булган. *1944 елда электрон парамагнит резонансын ачкан Казан галиме Евгений Завойский эшен дәвам иттерүче тикшеренүчеләр хезмәтләренә без зур әһәмият бирәбез.* Ватаным Татарстан. *Бу тикшеренүләр химик физикада яңа фәнни юнәлеш ачуга – парамагнит комплексларның төзелешен һәм үзлеген ЭПР ысулы белән өйрәнүгә китерде.* Фән һәм тел

ПАРА́МЕТР *и. гр.* Процесс, күренеш яки җайланма системаның нинди дә булса төп үзлеген билгели торган зурлык. *Эчке энергия, ничә параметр белән билгеләнүгә карамастан, кайтма процесслар өчен генә параметрлар үсемтәләренә карата тулы дифференциал була.* Фән һәм тел. *Спутникның хәрәкәтен һәм орбитасының параметрларын белгәннән соң, штурман кайсы төштә булуын төгәл исәпләп чыгара ала.* Эврика. *Барысы 96 параметр буенча нәтиҗә чыгарыла.* Мәдәни җомга

ПАРАНО́ЙЯ *и. гр. мед.* Барлык логик фикерләү сәләте сакланган хәлдә, төрле манияләр булу белән характерлана торган психик авыруларның гомуми исеме. *Үзаңнан туучы уңайсызлык хисләре кайвакыт тартынучанлык яки паранойя белән бәйле була ала.* Әдәп төбе – матур гадәт. *Беренчедән, мин эшләрнең кайсы якка баруын бер дә ошатмыйм һәм анда паранойя булуын күрәм.* Безнең гәҗит

ПАРАПЕТ *и. ит.* Күпер, баскыч, түбә һ.б.ш.ларның читенә эшләнеп куела торган култыкса, рәшәткә. *Халык, җыенып, эшкә чыгуга тротуарлар себерелгән, чәчкәләргә су сибелгән, хәтта бакчаларны уратып алган мәрмәр парапетлар юеш чүпрәк белән сөртеп алынган була иде*. И.Гарифуллин. *Корылмаларның ачык өлешләре – цоколь, кәрниз, багана, парапет саклансын өчен, аларны су агып төшәрлек итәләр, өслекләрен ялтыраталар, гидрофоб (су сеңдермәс) яки өслекне тыгызлагыч составлар сөртәләр*. Төзү материаллары

ПАРАПСИХОЛО́ГИЯ *и. гр.* Кеше, хайван һәм үсемлекләрнең гайре табигый мөмкинлекләрен табып ачуга юнәлгән псевдофәнни дисциплиналар. *Парапсихология дигән фән турында ишеткәнегез бармы сезнең?* М.Юныс

ПАРАТИФ *и. гр. мед.* Сальмонелла ыругына караган микроорганизмнар китереп чыгара торган йогышлы эчәклек авыруы. *Күрәсең бит, Фәтхия, фермада сөт планы тулмый, качыру планы прорывта, бозауларда паратиф, үгезләрдә төрле вак чирләр.* Т.Гыйззәт

ПАРАФИН *и. лат.* Сәнәгатьтә һәм медицинада кулланыла торган, балавызсыман тиз эрүчән, нефтьтән алынган аксыл яки саргылт төстәге синтетик матдә. *Нефть чыгу юлына парафин бик тыгыла, аны гел арчып торырга кирәк.* Р.Төхфәтуллин. *Үтүкнең йөзе чиста булып, ялтырап торсын өчен, чиста тозны вак итеп туралган парафин белән аралаштырып, тигез катлау итеп кәгазьгә җәяргә һәм җылымса үтүк белән берничә мәртәбә ышкырга кирәк.* Өегез ямьле булсын

ПАРАФИНЛА́У *ф.* Нәрсәгә дә булса парафин сеңдерү яки өстен парафин белән каплау

Парафинлап алу Тиз арада парафинлау

Парафинлап кую Алдан ук хәстәрен күреп парафинлау. *Сарымсакларны көздән парафинлап куйсаң, озак сакланалар*

Парафинлап тору Вакыт-вакыт парафинлау; даими парафинлау; хәзерге моментта парафинлау

ПАРАФИНЛЫ *и.* Парафин сеңдерелгән. *Күз кабаклары җилсенгәндә, пар ваннасы, парафинлы маска, электр ярдәмендә җылыту һәм тирене купшакландыра торган башка процедуралар алу зарарлы.* Р.Зияева

ПАРАФРАЗ *и. гр.* 1) Нинди дә булса текстны үз сүзләрең белән бәян итү

2) *муз.* Башка бер автордан алынган музыкаль темага үз вариацияләреңне, үз бизәкләреңне кушып эшкәртеп язылган инструменталь пьеса. *Халык җырларына парафраз башкару*

ПАРА́ША *и. рус гади с.* Төрмә камераларында тәрәт итү өчен чиләк. *Баязит ишек төбендә тынчып, сасып утырган пычрак парашаны җирәнә-җирәнә ике кулы белән күтәреп ала да коридорга чыга.* Г.Ибраһимов. *Сөйләшә торгач, камерага да, мәхбүсләргә дә ияләштем. Кемдер торып, параша янына китеп, миңа урын бирде.* И.Салахов

ПАРАШЮТ *и. фр.* Биеклектән сикергән кешенең, очкычтан төшерелә торган йөкнең, утыруга барган очкычның, узышу автомобиленең тизлеген киметү өчен, һавада гөмбәз шикелле ачыла торган тукыма җайланма. *Әнә парашютта дөнья рекорды ясаган Фёдорова.* Г.Кутуй. *Алданрак сикергән штурман Әмитов парашютын ачып өлгергән иде. Курку, парашютны ачтырмыйча, бер-ике секунд түзәргә мәҗбүр итте.* М.Юныс. *Вышка янына киләм дә Карап торам югары; Парашют белән һаман да Сикергәнем юк әле...* Ш.Галиев

ПАРАШЮТЧЫ *и.* Парашют белән сикерүче яки парашют спорты белән

шөгыльләнүче. *Таня институтта парашютчылар түгәрәге оештырды: врач өчен парашюттан сикерә белү – иң кирәкле нәрсә.* Г.Әпсәләмов

ПАРАШЮТЧЫЛЫК *и.* Парашют спорты. *Парашютчылык белән шөгыльләнү*

ПАРӘ *и. фар.* 1) Нәрсәнең дә булса бер кисәге, өлеше, парчасы

2) Ятларга яки укырга уңайлы булсын өчен, Коръәннең якынча тигез күләмдә бүленгән утыз өлешенең һәрберсе. *Хәммад хаҗи углы Садыйкны --- унбер яшьләренә җиткәндә тугыз парә Коръән бикләткән иде.* Г.Газиз. *Ястүдән соң бер парә Коръәнен тәмам итеп, Фатыйма бикә дә рәхәт йокыга бирелә.* Г.Ибраһимов

3) *күч. Йөрәк, күңел* кебек сүзләр белән килеп, «иң кадерле нәрсә, иң кадерле өлеш» дигәнне аңлата. *Кешелек әле милләтнең таянычы булган, йөрәк парәседәй нечкә, кадерле башка төр могҗизаны уйлап тапмаган, таба да алмас, бу бөек көчне бернәрсә дә алыштыра алмый.* Ә.Кәримуллин. *Үзе кебек үк пакь җанлыга, хакыйкатьне кыйбла итеп алучыга – йөрәк парәсенә (тапшырыр)!* Ф.Бәшир. *Бакыр булса, балдак хәрам... Хикмәт шунда, йөрәк парәм!..* М.Хөсни

ПАРӘ-ПАРӘ *рәв.* Кисәк-кисәк, вак-вак өлешләргә бүлгәләнеп. *Бер кара гарәп сурәтендә булмыш, киемнәре һәм үзенә муафийкъ парә-парә ертылмыш.* К.Насыйри. *Нинди тар дөнья! Шуларны уйлап, күбәләк сыман нәфис җаным парә-парә телгәләнә.* Н.Гыйматдинова

◊ **Парә-парә булу** 1) Челпәрәмә килү; вак-вак кисәкләргә парчалану. *Зур көзге булды шунда парә-парә.* М.Гафури; 2) Өзелү, әрнү, сызлау (күңел тур.). *Файдасыз бер ит кисәгеннән гыйбарәттер йөрәк, Парә-парә телмәсә гыйшык-мәхәббәт кайчысы.* Г.Тукай. **Парә-парә килү** *к.* **парә-парә булу**. *Йөрәгем элекке шикелле парә-парә килмәде. Күңелем дә ашкынмады.* М.Әмирханов. *«Әтием-әнием, җан кисәкләрем, – дип башлаган иде ул хатны, – мондагы хәлләрне әгәр сез килеп күрсәгез, мине җәлләүдән йөрәкләрегез парә-парә килер иде...»* Ф.Яруллин. **Парә-парә китерү** Челпәрәмә китерү, җимерү. *Ходай мәкерле ялганнан сакласын, язмышларны парә-парә китергән, кешеләрне бәхетсез иткән, әллә нинди куркыныч нәтиҗәләргә илткән алдау-ялганнар бар.* Шәһри Казан

ПАР-БУ *җыл. и.* Төрле парлар, булар. *Хәлим үзе дә ялындырмады, ә дигәнче күлмәк-ыштанын салып атты да ләүкәгә үрмәләде, аның да пар-бу бөркеп торган мич авызы турынарак елышты.* Г.Гыйльманов

ПА́РБҮЛГЕЧ *и. тех.* Пар двигателенең цилиндрларындагы парны автомат рәвештә бүлә торган механизм

ПАРДАН *рәв.* Икесе дә бер төрледән. *Менә Гөлшат белән икегезгә пардан сәгатьләр алдым.* Г.Гыйззәт. *Без Рабига абыстай җитәкчелеге астында һәммәбез пардан күлмәкләр тегеп киябез, һәм бу безнең өчен үзе бер бәйрәм була торган иде.* Р.Әмирхан

ПАРДАШ *и.* 1) Ике кешелек эштә бергә эшли торган кеше; ике сменалы эштә алмашчы. *Пардашы эшкә чыкмагач, аны вакытлыча башка цехка күчерделәр*

2) Үзеңә тиң, якын кеше, дус, иптәш. *Без күптән кан кардәшләр, --- Игезләр һәм пардашлар.* З.Нури

ПАРЕНХИ́МА *и. гр. мед.* 1) Кайбер органнарның (бавыр, бөер, тамак бизләре, үпкәләр һ.б.) төп тукымасы

2) Үсемлекләрдә бер үк зурлыктагы күзәнәкләрдән тора торган тукыма. *Паренхима күзәнәк тышчалары гадәттә юка булып калалар*

ПА́РҖЫЙГЫЧ *и. тех.* Парны җыя һәм аны үткәргеч торбаларга бүлеп җибәрә торган сыешлык. *Паржыйгыч ватылу*

ПАРИ *и. фр.* Җиңелгән очракта нәрсә дә булса үтәү шарты белән төзелгән килешү; бәхәс (ядәч) шарты. *Мин пари тәкъдим иттем: кем шул кыя астындагы оясыннан каракошның баласын тотып алып чыга...* Ә.Фәйзи

ПАРИК *и. фр.* Башка киелә торган табигый яки ясалма чәчтән эшләнгән причёска. *Чәчләрен йолкып кара, парик түгелме?* И.Гази. *Кайда синең дөрес кыяфәтең? Йөзең грим, чәчең парикта.* М.Җәлил. *Хәдичә рус карты дип уйлаган бу кеше Хөсәен үзе иде. Ул сакал-мыек ябыштырган, парик кигән.* А.Расих

ПАРИКМА́ХЕР *и. нем.* Чәчне кисеп, буяп, бөдрәләтеп, үреп төрле причёскалар ясау, шулай ук сакал-мыек кыру, чәч алу белән шөгыльләнүче оста; чәчтараш. *Мөгаен, әле яңа гына парикмахерда булган: бик пөхтә итеп кырынган, хушбуй исе аңкый.* И.Салахов. *Парикмахерлар өчен махсус китаплар укыганым бар, бик файдалы киңәшләр бар анда. Парикмахерлар барыннан да бигрәк дулкынсыман чәчне яраталар, чөнки андый чәч «тыңлаучан» була һәм иң катлаулы причёскалар ясарга мөмкинлек бирә.* Үзең нинди – көзгең шундый

ПАРИКМА́ХЕРЛЫК *и.* Парикмахер булу; парикмахер һөнәре. *Анна Андреевна парикмахерлык хезмәтендә егерме икенче елын эшли.* Ф.Хөсни. *Парикмахер һөнәре һәм парикмахерлык сәнгате белән кызыксынучыларга Е.Р.Мушкинаның 1970 елда Мәскәүдә басылып чыккан --- китабының «Виртуоз кулындагы тарак» дигән бүлеген укырга киңәш итәм.* Үзең нинди – көзгең шундый

ПАРИКМА́ХЕРСКИЙ *и. рус сөйл.* Чәчтарашханә. *Магазиннарның күбесе ябык, тик вывескалары гына кайчандыр бу йортта универмаг булганын, икенче йортта парикмахерский икәнен сөйлиләр* М.Мөҗәй. *Улымны парикмахерскийга җибәргәндә, мин һәрвакыт Самсон турындагы борынгы легенданы искә төшерәм.* Үзең нинди – көзгең шундый

ПАРИТЕТ *и. лат.* 1) *юр.* Якларның тигез хокуклы булуы. *Аның бу кушаматка исе китми, --- очлы башында сирәгәеп калган аксыл чәчләрен --- ныкъ, таза бармаклары белән сыпырып ала да тагын сораулар яудыра: «Христианнар белән мөселманнар арасында хәзерге паритет нәрсә белән аңлатыла?»* Т.Галиуллин. *Мәгълүм булганча, быелның февралендә ике оешма паритет нигездә уртак предприятие төзергә җыену хакындагы меморандумга кул куйды.* Ватаным Татарстан

2) *икът.* Төрле дәүләт валюталары арасындагы закон нигезендә билгеләнгән нисбәт

ПА́Р ИТУ 1) Үзеңә пар итеп сайлау, пар итеп алу. *Пар итмәсәң, яр итмәсәң, чәчәгем, Күлен җуйган аккош кебек яшәрмен.* М.Хөсәен

2) Бер парга берләшү. *Янымда – иркәм. Безне яр иткән, Безне пар иткән, Гашыйклар иткән – Вальс! Вальс!* М.Хөсәен

ПАРК *и. лат.* 1) Аллеялары, чәчәк түтәлләре, сулыклары булган ял итү бакчасы. *Инде күптән караңгы төшкән; күктә – нур диңгезендә – түгәрәк ай йөзә, паркта электр лампалары балкый.* И.Гази. *Бакчага чыгып, иртәнге табигатьнең йомшак тынлыгына сокланырга һәм җан дәвасыдай шифалы һаваны киерелеп-киерелеп суларга өлгерә алмадым, паркның төп аллеясы буйлап Зөһрә ханымның каяндыр кайтып килгәнен күрдем.* Ә.Еники

2) Транспорт чараларының эштән туктап тору, ремонтлау урыны. *Без колхозыбызның машиналар паркына барып чыктык.* Г.Галиев. *Кыр-басуларда, терлекләр янында, урман юлларында, атлы эшләрдә эшләгән, машина-трактор паркын аякка бастырган кешеләр --- сине борчымый.* Г.Ахунов. *Ире таксомотор паркында механик, хатыны сәүдә тармагында эшли.* В.Юныс

3) *хәрби* Армия частьларын тәэмин итә торган күчмә склад. *Артиллерия паркы*

ПАРКЕТ *и. фр.* **1.** Идәнгә түшәү өчен кулланыла торган төрле геометрик формадагы шома такта кисәкләре. *Идән паркетын һәр буынның олтаны ышкып ялтырата торган, башыңны иеп карасаң, идәндә үзеңнең шәүләңне күрәсең.* М.Юныс. *Имәннең үзагачы мебель һәм паркет ясау өчен яхшы материал буларак һәрвакыт югары бәяләнгән.* Татарстанның үсемлекләр һәм хайваннар дөньясы

2. *с. мәгъ.* Паркет җәелгән. *Паркет идәннәре адәм угылы аяк белән басарга оялып, күкрәге белән генә шуарлык.* Г.Тукай. *Таңсылу, менә карагыз дигән сыман, зифа буен төп-төз тоткан килеш, иске паркет идәнгә шык-шык басып, өстәл янына килде.* Х.Сарьян

ПАРКЕТЛЫ *с.* Паркет түшәлгән. *Командир шома боздай ялтыраган паркетлы идәнгә саклык белән баса.* И.Туктар

ПАРКЕТЧЫ *и.* 1) Паркет такталарын, шакмакларын ясаучы кеше. *Казандагы Лок фабрикасының паркетчылары баш күтәрде.* И.Туктар

2) Идәнгә паркет җәюче кеше. *Реставрация ясарга тәҗрибәле паркетчыларны чакырдылар*

ПА́РКИТӘРГЕЧ *и. тех.* Артык парны чыгарып җибәрә торган тишек яки көпшә

ПАРКО́ВКА *и. рус* Автомобильләрне вакытлыча куеп калдыру өчен, гадәттә койма яки махсус билгеләр белән аерып алынган, кайвакытта түләүле мәйданчык. *Кибет янындагы парковка*

ПАРКО́ВКАЛАУ *ф.* Автомобильне парковкага кую; машинаны юл читенә, берәр нәрсә янына туктату. *Оста парковкалау*

ПАРЛАГЫЧ *и. тех.* **1.** 1) *а.х.* Терлеккә азык пешекли торган казан

2) Тукыма әйберләрне кайнар пар бөркеп үтүкли торган җайланма

3) Мунчада себерке парлый торган чиләк яки башка савыт

2. *с. мәгъ.* Пар белән йомшарта торган. *Авыл хуҗалыгы предприятиеләре исә механизаторлар өчен кыр вагоннары, трактор чаналары, автомашина кузовлары, бозау читлекләре, азык парлагыч тартмалар, ат чаналары һәм арба көпчәкләре сатып алалар.* Биектау хәбәрләре

ПАРЛАК *с. төрек кит.* 1) Якты, нурлы; нур чәчеп торган. *--- бу җыр [«Бер алманы бишкә бүләек»] алмаз кебек парлак, булат кебек нык, аның көе дә, сүзләре дә тәңгәл килә, Илһам Шакиров башкаруында бу җыр камиллекнең иң югарыгы ноктасына менә.* Татарстан яшьләре

2) *күч.* Данлыклы, шанлы, шөһрәтле, күрекле. *Безнең бабаларыбыз булган төрек-татарлар борынгы заманнарда иң атаклы халыклардан булганлыклары сәбәпле, аларның тарихлары иң парлак тарихлар җөмләсеннәндер.* Һ.Атласи. *Яп-якты, парлак өметләре урынына хурлыклы җиңелү көткәнме аны Истанбулда?* Р.Батулла

3) *күч.* Бай, зиннәтле. *Падишаһ, бу көнге парлак бәйрәмең...* Әкият

4) *күч. сөйл.* Хыялга бай. *Парлак әкиятләр*

◊ **Парлак заман** Киң танылу, чәчәк ату, көч-куәт, дәрт-иҗатның иң камил чоры. *Бу чорда, башларында Миргалишир Нәваи торган хәлдә, иң көчле әдипләр эшләгәннәр, шуңа күрә бу чор Урта Азия төрек әдәби теле үсүенең иң парлак заманы булып өлгерде һәм классик әдәби тел булып берләшү һәм формалашу дәрәҗәсенә иреште.* Х.Бәдигый. **Парлак чак** *к.* **парлак заман**. *Ләкин Кутуй иң парлак чагында, дәртле, куәтле чагында гына арабыздан китеп барды...* Р.Батулла. *Кәрим Тинчуринның данлы вә парлак чагы.* Р.Низами

ПАРЛА́МЕНТ *и. фр.* Сайланган вәкилләр катнаша торган һәм дәүләт күләмендә законнар чыгарырга хокукы булган югары җыелыш. *Бер горурлык хисе яна миндә, Эчтән бәреп яна битләрдә. Сөйләр идем аны дөньядагы Барлык-барлык парламентларда.* С.Хәким. *Минем телем Басынкы ул: Халыкара конгресслар, парламентлар ачып йөрми, Акча, чеклар битенә менми.* Р.Фәйзуллин. *Ул – Халыкара библиография ассоциациясенең, Халыкара Биографик үзәкнең гыйльми советы әгъзасы. Гуманизм һәм гаделлек өчен көрәштә Халыкара парламент конференциясенең Дәүләт секретаре һәм илчесе.* Р.Рахмани

ПАРЛАМЕНТАР *с.* Парламенты булган (дәүләт системасы). *Татарстан – парламентар республика*

ПАРЛАМЕНТАРИЗМ *и. нем.* Башында парламент тора торган дәүләт системасы. *Сезгә конституция турында, парламентаризм турында сайрадылар.* Г.Ибраһимов

ПАРЛАМЕНТА́РИЙ *и. рус к.* **парламентчы** (*1 мәгъ.*). *Аңа [махсус төркемгә] тәҗрибәле парламентарий, Аграр мәсьәләләр, экология һәм табигатьтән файдалану комитеты рәисе урынбасары Валерий Лебедьков җитәкчелек итә.* Кызыл таң

ПАРЛАМЕНТЁР *и. фр.* Сөйләшүләр алып бару өчен, сугышучы якларның берсеннән икенчесенә җибәрелгән

кеше. *Фашистлар, --- халыкара нормаларны бозып, безнең парламентёрларга аттылар.* С.Шакир

ПАРЛА́МЕНТЛЫ *с.* Парламенты булган; парламентар. *Урыс хөкүмәте 1905 елның 17 октябрендә парламентлы идарә вәгъдә итәргә, матбугатка аз-маз хөррият бирергә --- мәҗбүр була.* Х.Миңнегулов. *Россия Президенты Торонтода чыгыш ясаганда кыргыз хакимиятенең парламентлы идарә итү рәвешенә күчү турындагы планнарына карата шик белдергән иде*. Ватаным Татарстан

ПАРЛА́МЕНТЧЫ *и.* 1) Парламент әгъзасы, парламентарий. *Семинарда катнашучыларга йомгаклау сүзе белән мөрәҗәгать итеп, Фәрит Мөхәммәтшин парламентчыларны үз эшләрендә пөхтә, намуслы, тыйнак булырга чакырды*. Ватаным Татарстан

2) Парламент тарафдары, дәүләтнең парламентар төзелешен хуплаучы

ПАРЛАНДЫРУ *ф.* 1) Парга әверелдерү; пар ясау. *Якуб абзый махсус парландыру камералары төзегән.* М.Хәсәнов

2) Нәрсәне дә булса пар астында тоту; азыкны парда җылыту. *Тавык, каз, күркә итен пешерәләр, кыздыралар һәм парландырып пешерәләр.* Татар халык ашлары

Парландырып алу Бераз парландыру. *Ул каен себеркесен кайнар суда парландырып алды*

Парландырып тору Билгеле бер вакытка кадәр парландыру; гел парландыру

ПАРЛАНУ I *ф.* 1) һавада вак кына су тамчылары хасил булу; пар, бу белән тулу. *Бертуктаусыз кайнап торган судан өй эче парланды*

2) Пар чыгару, пар бөркеп тору. *Яз җиткәч, җир өсте парлана.* Бакчачы календаре

3) Пар эчендә торып җылыну, җебенү. *Без үз тәнебездән чыккан тиргә үзебез парланып изрәгәнбез, хәлсезләнгәнбез.* М.Әмир

4) Нәрсәнең дә булса өслеге һавадагы пардан хасил булган вак кына сыеклык тамчылары белән каплану. *Тыштан килеп кергәч, күзлек парлана да, бернәрсә дә күреп булмый.* Г.Камал. *Кайбер өйләрдә, ягу системасының яхшы эшләвенә карамастан, тәрәзәләр парлана.* Өегез ямьле булсын

Парланып алу Бераз, кыска вакытка парлану

Парланып бетү Тәмам парлану. *Балчыклы туфраклар бик тыгыз, аларга һава һәм җылылык начар керә. Су парланып беткәч, җир өстендә тоташ кабык хасил була*. Бакчачы календаре

Парланып тору Парланган хәлдә булу. *Мулла бер-ике чынаяк чәй эчкәч, парланып торган кайнар чәен бүлде.* А.Шамов

Парланып яту Озак вакыт парлану. *Пионерлар сабаннарын тирес астында парланып яткан, җылы кояш нурлары белән күпереп киткән җиргә батырдылар.* Г.Гобәй

ПАРЛАНУ II *ф. к.* **парлашу**. *Парлылар йөри парланып, Без йөрибез зарланып.* М.Фәйзи. *Тамаша кылып, карап торырга килгән олылар юк. Шуңа күрә кемнең кем белән парланганы ачыграк күренә*. Я.Абдуллин. *Без парланып рәсемгә төштек.* Ә.Айдар

Парланып алу Тиз арада парлану

Парланып бетү һәммәсе дә парлану

Парланып кую Көтмәгәндә, кинәт кенә парлану

ПАРЛАП *рәв.* 1) Егет белән кыз, ир белән хатын бер пар хасил итеп, парлашып. *«Алайса, парлап өч көнгә кунакка кит!»* Г.Бәширов. *Майҗамал яратмады аның маржасын. Күптән инде парлап бер кайтканнар иде, шунда да якты чырай күрсәтмәде.* И.Низамов. *Ярым, дидем, Җаным, дидем, Һич жәл түгел малым, дидем. Оя корыйк парлап, дидем. Вәгъдә, дидең, Балдак кидең.* М.Хөсәен

2) Икәү бергә, икәүләшеп. *Хәмзә белән Рәхмәт парлап җырлыйлар.* М.Фәйзи. *Безне бит, дус кеше, төрмәгә парлап утыртачаклар. Яшерен документлар буенча без икебез дә тигез җаваплы.* М.Юныс. *Ә нигә бәла дигәнең ялгыз йөрми, парлап йөри икән?* Г.Ахунов

ПАРЛА́П-ПАРЛАП *рәв.* Икәүләшеп, парлашып. *Яшьләр авылга таба юнәлә парлап-парлап.* Я.Абдуллин

ПАРЛА́У I *ф.* 1) Кайнар суда тотып пешекләү, йомшарту. *Зур бакларда --- кайбер маллар өчен генә печән вагы парлыйлар.* Ә.Еники. *Бәрәч, янәшәдә генә мунча бугай. Парланган себерке исе килә…* Н.Гыйматдинова

2) Парда дымландыру, дәмләү. *Әтәчне дә йолыктым, пылау да парларга куйдым.* К.Тинчурин

3) Нәрсәне дә булса пар эчендә тотып җылыту, йомшату, җебетү. *--- аякларны сабынлы кайнар суда, бер литр суга бер бал кашыгы исәбеннән чәй содасы салып парларга мөмкин.* Өегез ямьле булсын

4) Кайнар су белән, парда тотып зарарсызландыру. *Мин, юри ашыкмыйча, бидоннарны озаклап парладым.* Н.Гыйматдинова

5) Тукыма әйберләрне пар ярдәмендә чистару, тигезләү. *Әгәр, чистарткында, бәрхетнең төкләре чуалса, аны спирт белән чистартып, 3–4 минут пар өстендә тоталар, изелгән урыннарны берничә мәртәбә парлыйлар.* Өегез ямьле булсын

6) Мунча пары эссесендә себерке белән чабу

7) *күч.* Бик каты кыйнау, тәпәләү. *Безне --- каеш чыбыркы белән парларга кирәк.* һ.Такташ

8) *күч.* Тиргәү, сүгү, бик нык ачулану. *Пар сөруне үз вакытында бетермәсәк, анысы өчен райком секретаре барыбызны да парлый.* Ф.Хөсни

Парлап алу Тиз генә парлау

Парлап бару Берсе артыннан икенчесен парлау

Парлап тору Берөзлексез парлау

Парлап җибәрү *к.* **парлый башлау**

Парлый башлау Парларга тотыну

ПАРЛА́У II *ф.* Икешәрләп кую, ишен өстәп парлы итү. *Шәмсекамәр егетләрне, кызлар белән парлап, түгәрәк ясап утырта.* А.Әхмәт. *Аның өчен ике атны парладылар да атлар арасына бишек сыман итеп киез тарттырдылар – сугышта авыр яраланган ирләрне шулай йөртәләр иде.* Н.Фәттах

ПАРЛА́У III *ф.* Парга сөрү. *Сабан басуларын, былтыр көз көне үк парлап, --- яз көне чәчеп калдырганнар иде*

ПАРЛАШУ *ф.* **1**. Бер пар хасил итү (егет белән кыз, ир белән хатын тур.). *Кыз атаклы Израиль патшасы Давид нәселен дәвам итүче Иосиф исемле карт монах белән парлашкан була.* Диннәр тарихы

2. парлашып *рәв. мәгъ.* Икәүләп, бер пар булып, парлы булып. *Посылка тирәсендә парлашып йөри торгач, Гыймайның хатыны, иренә әйтүдән бигрәк, үз-үзенә сөйләнгәндәй әйтеп куйды…* Ф.Яруллин. *Ярты сәгать үтәр-үтмәс, кем кайда урын табып, хатыннары белән парлашып, йортның төрле почмакларында – печәнлектә, келәт эчләрендә – тирән йокыга талдылар.* З.Зәйнуллин

Парлашып кую Көтмәгәндә яки тиз арада парлашу

Парлашып тору Гел парлашу; вакытлыча гына парлашу

ПАРЛЫ I *с.* 1) Пар бөркеп торган; бу чыгып торган. *Ике яшүсмер юеш, парлы тиресне чаналарына төйиләр.* Ә.Еники

2) Эссе пары булган; парланырга мөмкин булган. *Менә ни өчен монда тынчу һәм мунчадагы кебек парлы икән.* И.Салахов. *Парлы мунчага кереп, яшь каен себеркесе белән чабынсак, дөнья түгәрәкләнә инде.* М.Гали

ПАРЛЫ II *с.* **1**. 1) Пары белән, икешәрле; ирле-хатынлы. *Пар балдаклар бергә нурлар сибәр җиргә, Бары бергә парлы булганда.* З.Вәлиәхмәтова

2) Нәрсәне дә булса икәүләп эшләгән, икәүләп башкарган. *Сексологлар җенси ихтыяҗны парлы функция диләр: ачлыкны һәм сусауны без һәркайсыбыз аерым-аерым канәгатьләндерәбез, ә сексуаль ачлыкны канәгатьләндерү өчен, ике кеше кирәк.* Р.Камалова. *Парлы уенда ике очко аерма белән оттырдык.* Универсиада яңалыклары

3) Компонентлары грамматик яктан бер-берсенә бәйле булмаган тигез хокуклы, тезүле бәйләнештәге, куш (сүзләр тур.). *Татарча тау-тау, өем-өем, эт-бет, бала-чага, мал-туар кебек парлы сүзләр моңа мисал була ала.* Н.Фәттах. *Парлы сыйфатлар ясалышы, гомумән, парлы сүзләр ясалышындагы структур типларны кабатлый диярлек мөмкин.* Ф.Хисамова

2. *и. мәгъ.* Ир белән хатын, егет белән кыз. *Бәхет ул – парлылар канаты, Бәхет ул – тугрылык юлдашы.* И.Фазлуллин. *Син минем парлылар исемлегендә, үскәнем. Исемең Рәмис белән янәшә тора.* Н.Гыйматдинова. *Доминочылар китүгә, ишегалдына парлылар кайтты. Белеп кенә булмый, хуплыйлармы алар парлыларны, әллә ашыкмаска өндәп кисәтәләрме?* А.Гыйләҗев

ПАРЛЫ-ПАРЛЫ *рәв. к.* **парлап-парлап**. *Ялгыз күгәрчен шикелле Йөрисең син урамнарда. Туктап калып юл бирәсең, Парлы-парлы узганнарга.* Г.Зәйнашева

ПАРНИК *и. рус* Яшелчә һәм җиләк-җимешләрне иртә үстереп өлгертү өчен яки аларның үрентеләрен үрчетү өчен, өсте пыяла рамнар яки полиэтилен плёнка белән каплана торган корылма. *Редисны тыгызлагыч үсемлек буларак теплицаларда, парникларда һәм, аннан соң кыяр яки помидор утыртырга мөмкин булсын өчен, беренче культура итеп плёнка каплап та үстерәләр. Парникларга март башында чәчәләр.* Бакчачы, яшелчәче һәм умартачы календаре. *Парниктагы кыярлар әле чәчәккә генә бөреләнгән, кишерләре бөтенләй нәзек икән: ашарлыгы да юк.* Т.Әйди

ПАРОВОЗ *и. рус* Пар машинасы белән йөртелә торган локомотив. *Тау менгән чакта, авыру йөрәкле кеше шикелле сулуы каба торган хәлсез паровозларны хәзер яшендәй атлыга торган электричкалар алыштырды.* И.Гази. *Колак исә паровозның, чажчож килеп пар клапаннарын ачып, урман яңгыратканын ишетә.* М.Мәһдиев

ПАРОВОЗЧЫ *и. к.* **машинист**

ПАРОДИСТ *и. гр.* 1) Пародияләр авторы, пародияләр язучы әдип

2) Кемнәргә дә булса пародия ясаучы кеше, имитатор. *Хөрмәтле тамашачылар, кичәбездә атаклы пародист, эстрада артисты Хазанов чыгыш ясарга вәгъдә итте.* Р.Батулла. *Пародистлар зал тутырып тамашачы җыя, халык дәррәү килеп кул чаба.* Идел. *Ул чакта мин сине пародист булып китәр дип уйлаган идем.* Мәдәни җомга

ПАРО́ДИЯ *и. гр.* 1) Танылган әсәрнең уникаль үзенчәлекләрен махсус үзгәртелгән формада аңлы рәвештә кабатлау хисабына укучы, тамашачы, тыңлаучыда көлке тудыруны максат иткән сәнгать әсәре. *Пародия жанры, бу максатларга бермә-бер туры килеп, шагыйрьнең сатирик сүзен әйтеп калырга мөмкинлекләр бирә.* И.Нуруллин. *Сатира шәкеленнән пародия шәкелен аерып алып караганда, пародиянең башында, әлбәттә, Габдулла Тукай тора.* Р.Батулла. *Бүген пародия кешене мыскыл итүгә кайтып кала.* Безнең гәҗит

2) Билгеле бер үрнәккә охшатырга тырышып та, кирәкле таләпләргә җавап бирмәгән, начар эшләнелгән эш, берәр нәрсә. *Г.Минскийның «Гөлчәчәк» пьесасы «Красная Татария» битендә «Чынбарлыкка пародия» дигән бәяне алды.* М.Җәлил

ПАРО́ДИЯЛӘҮ *ф.* Нәрсәгә дә булса пародия ясау, язу, күрсәтү. *Музыкаль клипларны уңышлы пародияләү, шоубизнесның «кухня»сын күңелле итеп күрсәтүләре жюрига аеруча ошаган.* Татарстан яшьләре

ПАРО́ДИЯЧЕ *и. к.* **пародист**. *Мәскәүдә пародия өчен чәчәкләргә күмәләр, алкышлыйлар, Казанда пародияченең башына таш белән оралар икәнен мин шунда аңладым.* Р.Батулла

ПАРОДОНТИТ *и. гр. мед.* Теш яны тукымасының ялкынсынуы. *Әйтик, кешенең шикәр авыруы, пародонтит, пародонтоз кебек хроник чирләре бар икән, аңа һич кенә дә имплант куярга ярамый.* Ватаным Татарстан

ПАРОДОНТОЗ *и. гр. мед.* Сөяк тукымасының зәгыйфьләнүе, тешләрнең ояларыннан кузгалу һәм төшүеннән гыйбарәт теш авыруы. *Пародонтоз булганда теш альвеолаларында (ояларында) атрофия күзәтелә. --- Стоматологиядә каланхоэ сыгынтысының пародонтоз, стоматит авыруларын дәвалауда файдасы зур.* Ватаным Татарстан

ПАРОЛЬ *и. фр.* Берәр җиргә керү, катнашу, файдалану рөхсәте алу, вәкаләтләрне раслау һ.б.ш. өчен яшерен сүз яки шартлы билгеләр җыелмасы; серсүз. *Якында гына: «Туктa! Кем килә?» – дигән катгый, коры тавыш*

ишетелде. – Разводящий! – Пароль?! М.Кәрим. *Домбровский... көтүче картның исән булуын, ә парольнең яңа булуын әйтте.* Ш.Маннур

ПАРОМ *и. рус* Юлчыларны, машина, йөк һ.б.ш.ларны елга, күл, диңгез култыгы кебек зур сулыкларның бер ярыннан икенче ярына күчерү өчен, зур палубалы махсус судно яки сал. *Паром, саңгырау гына кычкыртып, пристаньга килеп туктады.* Г.Ахунов. *Истанбулда автобуска утырдык, төне буе барып, паромда Мәрмәрә диңгезләрен кичеп, иртәнге якта гына Мугла шәһәренә килеп җиттек.* Ф.Бәйрәмова

ПАРОМЛЫ *с.* Паромы булган, кичү өчен паром кулланылган. *Паромлы кичүләр эшләүдән туктау*

ПАРОМЧЫ *и.* Паром йөртүче кеше. *Бу вакытта паромчылар буламы соң?* Г.Әпсәләмов. *Ригадан бомбага тотылуларны күргән хатын өч баласы белән урыс өлкәсенә эвакуацияләнә һәм паромчы булып эшли.* Р.Зарипов

ПАРОТИТ *и. лат. мед.* Колак яны бизенең ялкынсынуы. *Кызылча, кызамык, эпидемик паротит авыруына каршы «тере» вакциналар кулланыла, прививкалар ике мәртәбә – 1 яшьтә һәм 6 яшьтә ясала. Шуңа күрә эпидемик паротит, кызамык, кызылча белән авыру очраклары күпкә сирәгәйде.* Татарстан яшьләре. *Грипп, кызылча һәм паротитның таралу юлы берникадәр кыскарак: бер яки берничә бүлмә яисә мәктәпнең бер классы белән чикләнә.* Балалар сәламәтлеге турында китап

ПАРОХОД *и. рус* Пар двигателе ярдәмендә хәрәкәт итә торган зур судно. *Җилкәнле корабларны пар белән йөрүче пароходлар юкка чыгарды. Пароходларга алмашка теплоходлар килде.* М.Юныс. *Көн кояшлы, матур, пароходыбыз ярга якынлашканда, якындагы кафе-ресторанныардан музыка тавышы ишетелә, аларны да уздырып, биек манаралардан азан авазы яңгырый башлый...* Ф.Бәйрәмова

ПАРОХОДЧЫ *и. иск.* Пароход яки пароходчылык хуҗасы. *Булса да, ул [налог] пароходчылар өчен генә булыр, сезнең бит пароходларыгыз юк.* Ш.Мөхәммәдев

ПАРОХОДЧЫЛЫК *и.* Пароход транспорты белән идарә итү оешмасы. *Мәскәүдән Ждановка килгәч, «Моряк» гостиницасында төн кундым да, язган гаризамны тотып, Азов диңгезе пароходчылыгының кадрлар булегенә юнәлдем.* М.Юныс. *Пароходчылык җитәкчеләре өстенме, әллә портныкымы?* И.Низамов

ПА́Р-ПАР *рәв.* 1) Икәү бергә, икешәрләп. *Дошман самолётлары күренә калса, тизрәк агачлар арасына яшеренергә уңай булсын дип, кызылармеецлар юлның ике ягыннан пар-пар тезелешеп баралар.* Ә.Еники. *Ләкин монда ни өчендер кызлар гына пар-пар биеде.* Ф.Яруллин

2) Ир-ат һәм хатын-кыз, егет белән кыз парлап. *Рыцарьлар заманында хатын-кызлар белән ир-егетләр табынга пар-пар булып утырганнар.* Әдәп төбе – матур гадәт. *Ходай шуңа адәм баласын ике җенестән яраткан, кушылып пар-пар яшәсеннәр өчен.* Н.Гыйматдинова

ПАРТ- *рус* Кушма сүзләрдә «партиягә бәйләнешле» дигән мәгънәне белдерә торган беренче кисәк (мәс., *партоешма, партаппарат, партком, парткомиссия, партконтроль, партконференция* һ.б.)

ПАРТА *и. рус* Мәктәп укучылары өчен утыргычы белән бергә беркетелеп ясалган авыш өсле өстәл. *Тәрәзә янындагы шушы партада ике көн берүзе утырды Рәис. Боргаланды-сыргаланды, терсәкләрен як-якка җәеп җибәрде, китапларын партаның әле бер җиренә, әле икенче җиренә күчерде.* Ф.Яруллин. *Ачык калган ишектән класска керде. Башына: «Әле парталарны да чыгармаганнар икән», – дигән уй килде. Парта араларында укучы балалар утырадыр кебек тоелып китте.* Ф.Бәйрәмова. *Бер үк йорттта Тора алар, Бер партада утыралар.* Ш.Галиев

◊ **Парта арасыннан чыгу** Мәктәпне тәмамлау. *– Мин тартмыйм бит, Борһан ага. – Инде парта арасыннан чыккач ярый ул. Кабыз, әйдә!* Р.Төхфәтуллин

ПАРТАДАШ *и.* Бер партада утыручыларның һәркайсы. *Партадашы, «икеле капчыгы» Фәрит, укытучыларның бәрәңге бакчасын казый, утыннарын яра, шулай ялагайланып, куштанланып, класстан класска күчеп бара.* Н.Гыйматдинова. *Сыйныфташлар яки партадаш белән сөйләшү оештыру өчен, кызыклы һәм файдалы темалар тәкъдим ителә.* Шәһри Казан

ПАРТАППАРАТ *и. рус* Партиянең җитәкче органы. *Үзгәртеп кору партаппаратта бер дә сизелми бит.* Г.Ахунов. *Сез гел: «Мине КГБ кысты, кыерсытты, партаппарат сөймәде!!!» – дип зарланып йөрдегез.* Р.Батулла

ПАРТБИЛЕТ *и. рус* Нинди дә булса партиядә әгъза булып торуга таныклык билеты. *1938 елда аның партбилеты үзенә кире кайтарылды.* Р.Җиһаншина. *Бу сүзләрне әйтеп бетергәндә, Мәрдәншаның бите Миңлебаевның партбилеты кебек кып-кызыл иде.* З.Хәким

ПАРТБЮРО *и. рус* Башлангыч партия оешмасының сайлап куелган җитәкче органы; шул бюроның утырышы. *Үзем рота командиры, единоначальник, партбюро члены.* Х.Мөҗәй. *Сорау биреп тормасам да сизәм: идарәдәме, партбюродамы әңгәмә кызу булган булырга тиеш.* Р.Ишморат

ПАРТЕР *и. фр.* Тамаша залының сәхнәдән алып амфитеатрга яки артқы стенага кадәр тамашачы урыннары булган төп өлеше; шул урыннардагы тамашачылар. *Фәтхулла хәзрәт, ложага кереп, партерда тезелгән кеше башларының күплегенә гажәпләнеп утырганда, кинәт звонок шалтырады.* Ф.Әмирхан. *Балкондагылар да, ложадагылар да, партер да Николай патшага текәлеп каткан. Балконнар тулы урта чиновниклар, партер тулы югары даирәләр.* Р.Батулла. *Партер идәне сәхнәдәге тамаша теләсә кайсы урыннан яхшы күренерлек итеп күтәртеп эшләнгән.* Ватаным Татарстан

ПАРТИЗАН *и. фр.* **1.** Дошман тылында үзлегеннән оешып, мөстәкыйль рәвештә хәрәкәт итә торган хәрби отряд сугышчысы. *Бу урманда, бәлки, Партизаннар кичке ашка учак яккандыр. «Бабакай»ның батыр егетләре Разведкадан йөреп кайткандыр.* М.Җәлил. *Кичә генә авылга партизан һөҗүме*

булган икән. М.Мәһдиев. *Биграк тә сугыш, партизаннар турындагы китапларны ярата иде ул.* Ф.Яруллин

2. *с. мәгъ.* Партизаннардан торган, партизаннарга бәйләнешле. *Күп адашулардан, күп эзләнүләрдән соң арып, хәлдән таеп, авырып, данлыклы бер партизан гаскәргә барып егылдым.* Г.Ибраһимов

ПАРТИЗА́НКА *и. рус* Партизан хатын-кыз. *Ант иткән ул партизанка дошманнарны кисәргә.* Г.Кутуй. *Партизанка хәзер, корал тотып, Украина бакчалары кабат чәчәк атсын өчен көрәшә.* Г.Хуҗиев

ПАРТИЗАНЛЫК *и.* 1) Партизан булу, партизан тормышы белән яшәү. *Немецлар кергәч, бөтен авыл партизанлыкка китә.* Г.Гобәй

2) *күч.* Киңәшмичә, сөйләшмичә, үз белдегең белән генә эш итү; башбаштаклык. *Оешмаганлык һәм партизанлык тупаслыгын инде тәмам ватарга кирәк безгә.* Ә.Баян

ПАРТИЗАННА́РЧА *рәв.* Партизаннар кебек. *Партизаннарча киенгән кара күзле чандыр кеше аңарда бернинди дә шик кузгатмады.* А.Расих

ПАРТИТУ́РА *җый. и. ит.* Күптавышлы музыкаль әсәрдә барлык партияләр җыелмасы. *Хәбир театрда сезон ачылып, репетицияләр башланганчы, партитураны төгәлләргә уйлады.* Ш.Хөсәенов

ПА́РТИЯ *и. фр.* 1) Билгеле бер иҗтимагый сыйныф мәнфәгатьләренә хезмәт итә торган киң масштаблы сәяси оешма; фирка. *1942 елда Сталинград фронтында Гадел Кутуй коммунистлар партиясенә кабул ителә.* Р.Нуруллина. *1943 ел. Мюнхенда милләтчесоциалистлар партиясе туды…* С.Шакир. *Госман гасыр башында Петербургта яши, анда меньшевиклар партиясенә керә һәм революцион эшчәнлеге аркасында патша төрмәсендә утырып чыккан була.* Ә.Кәримуллин

2) Уртак теләк, уртак фикер нигезендә берләшкән кешеләр төркеме, груһ. *Моңарчы кабилә, партия талашын оныты, бары бергә кайнашкан казакълар, атка менеп далага чыгу белән, --- тагын үз хәлләренә кайттылар.* Г.Ибраһимов

3) Теләсә нинди төркем, группа, отряд. *Кыскасы, җир катлауларының структураларын картага төшерү өчен чыгарылган партия үз алдына куелган бурычын уңышлы башкарып кире кайтырга чыккан вакытта, Миләүшә Тәбәнәкиевкә бөтенләй гашыйк иде инде.* М.Әмир

4) Бериш предметларның, бер төркемгә кергән җан ияләренең беркадәр сандагы төркеме. *Куяннарны читлеккә япканчы, бөтен әйберләргә бик яхшылап дезинфекция ясала, бу эш һәр партия куяннарны иткә озатканда кабатлана.* Өегез ямьле булсын

5) *муз.* Күптавышлы яки күп кешеләр тарафыннан башкарыла торган музыкаль әсәрдә аерым бер инструментның яки аерым бер башкаручының өлеше. *Муса --- операларда музыкаль партияләрең ничек башкарылуы белән кызыксына иде.* Ш.Маннур. *Бу җыентыктагы җырлар фортепиано партиясенә салынган.* Көмеш тавышлар

6) Шахмат, шашка, карта һ.б.ш уеннарның тәмамланган бөтен бер уйналышы. *Әйдә әле, бер партия шахмат уйнап җибәрик.* Т.Гыйззәт. *Безнең партия тәмам булып, студентның унбер сум җитмеш өч тиен отканлыгы заһир булды.* Ф.Әмирхан

ПА́РТИЯДӘШ *и.* Кем белән дә булса бер үк партиядә торучы. *Давыт һәм аның партиядәшләре --- яңа эш күрсәткәннәр.* Г.Нигъмәти. *Аларның күзгә-күз очрашуларын күргән кешеләр дә хәйран вә вәйран булыр иде, партиядәш дусиптәшләр бер мизгелдә кан дошманнарга әйләнде.* Р.Мирхәйдәров. *1906 елда Бакуда Кобаның партиядәш иптәше Александр Сванидзе аны үзенең сеңлесе Екатерина (грузинча Като) белән таныштыра.* Ватаным Татарстан

ПА́РТИЯЛЕ *с.* **1.** 1) Билгеле бер партиядә әгъза булып торучы. *Иң беренче – капитан Грязевский Константин Николаевич, 1938 елны туган, рус, югары белемле, партияле, хатыны бар, балалары юк.* М.Юныс

2) Партия мәнфәгатьләреннән чыгып эш итә торган, партиячел. *Әдәбият – партияле ул, гомумпартия эшенең аерылмас бер өлеше ул.* Г.Иделле

2. *и. мәгъ.* Партиядә әгъза булып торучы кеше. *Күрдем, комсомоллар белән партиялеләр җыелышын уздырып яталар.* Т.Гыйззәт

ПА́РТИЯЛЕЛЕК *и.* 1) *сәяси* Партияләрнең билгеле бер санда булуы. *Күп партиялелек күренеше барлык илләргә дә хас түгел*

2) Әдәбиятта һәм сәнгатьтә билгеле бер сыйныфның, партиянең тормышын чагылдыру; билгеле партиягә, аның идеологиясенә хезмәт итү. *Язучылар оешмасы киләчәктә дә совет әдәбиятының партиялелеге, халыкчанлыгы, идея нигезләренең какшамас нык булуы өчен көрәшүчеләрнең иҗат союзы буларак эш итәргә тиеш.* СССР язучыларының дүртенче съездыннан. *Г.Әпсәләмовның башка романнары кебек үк, ул да югары коммунистик партиялелек идеяләре белән сугарылган.* Р.Сверигин

ПА́РТИЯСЕЗ *с.* 1) Бернинди партиядә дә әгъза булып тормаган; элегрәк: Советлар Союзының Коммунистлар партиясендә булмаган. *Кәлимуллин Шәяхмәт, чыгышы крестьян, фәлән елгы, фәлән елда коммуна оештырган, партиясез, чит партияләрдә тормаган, чит илдә туганнары юк...* Х.Сарьян. *Күзем бер мәзәк фамилияне эләктерде: Перечепидорога Владимир Иванович, моторист-электрогазосварщик, 1938 елда Ждановта туган, белеме ун класс, партиясез, хатыны, ике баласы бар.* М.Юныс

2) Партиялелек (*2 мәгъ.*) принципларына таянмаган, шуның таләпләренә җавап бирмәгән. *Партиясез әсәр безгә кирәкми.* М.Җәлил

ПА́РТИЯСЕЗЛЕК *и.* 1) Бер партиядә дә тормау, партиягә кермәү хәле. *Партиясез куркаклар куркынычрак була. Андыйлар партиясезлекләрен гаепләмәсеннәр өчен, партиялеләргә ялагайланалар ---.* Р.Батулла

2) Бер партия яклы да булмау, бернинди партия мәнфәгатьләрен дә якламау; бернинди партиягә дә буйсынмау. *Ә буржуаз объективизм – партиясезлек флагына төренгән буржуаз партиялелек ул.* Әдәбият

ПА́РТИЯЧЕЛ *с.* Партия идеологиясенә, эшенә бирелгән, шуңа

тугрылыклы. *«Коммунист» журналы партиячел журнал иде. Маяковский көннең җанлы, актуаль лозунгларын поэзияләштергән, чын сугышчан партиячел поэзияне тудырды...* М.Җәлил. *Нәкъ менә шул соңгысына таянып, партиячел догматиклар яңа иҗат методын тормышны буяп-бизәп күрсәтүгә хезмәт иттерә башладылар.* Татар әдәбияты

ПАРТКАБИНЕТ *и. тар.* КПСС комитетлары карамагындагы партия мәгарифе кабинеты. *Парткабинетка яңа газета-журналлар килгәндер.* Э.Касыймов. *1964 елда, университетны тәмамлагач, ул Сарман районына эшкә җибәрелә: Чукмарлы авылында мәктәп директоры, КПСС райкомында парткабинет мөдире вазифаларын башкара.* Фән һәм тел. *Шул ук елны Әнвәр Гыйләҗ улын Миякә районының парткабинет мөдире итеп эшкә билгелиләр.* Кызыл таң

ПАРТКОМ *и. рус* 1) Партиянең урындагы комитеты. *Инструкция буенча капитанның кораб белән идарә итәргә сәләтсезлеген мин пароходчылыкка һәм парткомга шундук хәбәр итәргә тиешмен.* М.Юныс. *Партком бүлмәсендә безне көтеп утырган Хөсәенов янына кергәнгә кадәр, Камильянов мине колхоз председателе Марс Шәвәлиев бүлмәсенә алып керде.* Р.Ишморат. *Казанга күчерүне сорап, мин парткомга гариза бирдем.* Г.Кутуй

2) *сөйл.* Партия комитеты секретаре. *Хатны тыңлап бетергәннән соң, партком сузып кына: «Әй-е», – диде.* Г.Кутуй. *Бу, партком уенча, халыкның берберсенә карата бик борынгыдан килә торган ихтирамлык билгесен сакларга тиеш иде.* Г.Ахунов

ПАРТНЁР *и. фр.* 1) Берәр эштә, уенда яки уенчыларның бер үк командасында бергә катнашкан кеше

2) Билгеле бер уртак эш мөнәсәбәтләренә кергән кеше. *Проектның төп авторы – инглиз фирмасы «Фримен Фокс һәм партнёрлары», инженеры – Уильям Браун.* М.Юныс

3) Сәхнәдә, спорт уеннары, бию һ.б.ш.ларда бергә катнашкан пардаш. *Шул ук гөнаһ саркытканТөчкелтем музыка, башларын артка ташлап, чалкан ята язып партнёрлары кочагында йөзүче биючеләр сурәте.* М.Юныс. *Сәхнәдә ул партнёр буларак бик игътибарлы, һәм аның белән янәшә торып сәхнәдә уйнавы бик уңай иде.* Р.Җиһаншина

4) Нинди дә булса бер ширкәтнең әгъзасы; компаньон. *Солдат яхшы уйный. Шәрәфи агайның яхшы партнёрларны читкә җибәрәсе килми.* Ш.Камал

ПАРТНЁРЛЫК *и.* Партнёрлар булу күренеше, хезмәттәшлек. *Хатын-кызларның сәясәттә һәм бизнестагы мөмкинлекләрен киңәйтү, җәмгыятьне социаль модернизацияләү, шулай ук дәүләт белән эшкуарлыкның партнёрлык перспективалары саммитта тикшерелгән төп темалар булды.* Г.Нургалиева. *Уфа белән Казан арасында тугандашлык һәм партнёрлык бәйләнешләре турындагы килешүгә кул куелачак.* Кызыл таң

ПАРТОЕШМА *и.* СССРда партиянең урындагы оешмасы. *Партоешма секретаре Дускаевны район үзәгенә ниндидер киңәшмәгә чакырып алганнар.* Ә.Еники. *Боларны яхшы белгәнгә, Мөхәммәт Сиражиев, үҗәт бер ныклык белән, авыл халкы арасында партоешманың абруен күтәрергә кереште.* Г.Ахунов

ПАРТОКРАТ *и. гр.* Партократия вәкиле

ПАРТОКРА́ТИЯ *и. гр.* 1) Югары дәүләт хакимияте дәүләт системасына кертелгән бер генә сәяси партия кулында тупланган сәяси строй. *Мәсәлән, Н.С.Хрущёв һәм Н.А.Косыгинның партия эшчәнлегендә, икътисадта реформалар үткәрергә омтылыш ясаулары билгеле, әмма алар партократия тарафыннан хупланмый, аларга үзләренең менталитеты да, Суслов кебек идеологик догматиклар да комачаулый.* Ислам – татарлар һәм мөселманнар

2) Партиянең идарә аппараты; власть башында торган югары катламы. *Үзенең башка күпчелек хезмәтләрендә дә шундый «уяулык» күрсәткән бу адәм партократия парафыннан тарих фәне «классигы»на хәтле күтәрелде, аңа иң дәрәҗәле орденнар тагылды.* Ә.Кәримуллин. *Ул да шул ук партократия вәкиле бит, җәмәгать.* Ф.Яхин

ПАРТОРГ *и. рус* Партия оешмасы бүлекләрендә җитәкче итеп сайлап куелган кеше. *Киләсе атнада дүшәмбе көнне иртәнге тугызга председательләрне, совхоз директорларын, барлык парторгларны чакырыгыз.* Г.Ахунов. *– Совет семьясы ныклыбулырга тиеш! – диде парторг чыгып китәндә.* Р.Батулла. *Парторг (мәктәп директоры да ул) вәгъдәсендә торды диярге була.* Р.Миңнуллин

ПАРТОРГЛЫК *и.* Парторг булу эше. *Айтуганов аның күзгә күренеп үсүен югары бәяли, аңа авыл Советыннан парторглыкка күчәргә кирәк дип, лаеклы дип саный.* Г.Ахунов

ПА́РТОЯКЛЫ *с. зоол.* Партояклылылар отрядына кергән; куштояклы. *Сайгак – партояклы, борыны филенекенә ошап кәкрәеп килгән хайван, антилопаның бер төре.* Фән һәм тел

ПА́РТОЯКЛЫЛАР *и. күпл. зоол.* Һәр аягында икешәр аеры тоягы булган имезүче хайваннар отряды; куштояклылар. *Атамаларның күпчелеге исем+-лы+-лар моделендә ясала: саңагаяклылар, тигезаяклылар, төрлеаяклылар, партояклылар, куштояклылар, ишкәгаяклылар.* О.Бятикова

ПА́РҮЛЧӘГЕЧ *и. тех.* Парүткәргеч торбадагы пар күләмен үлчи торган прибор

ПА́РҮТКӘРГЕЧ *и. тех.* Бер урыннан икенче урынга пар күчерә торган җайланма. *Нефть чыгару һәм суыртып агызу өчен суырту җайланмасы. Әзер продукцияне суырта торган нефтьүткәргечләр. Югары басымлы парүткәргеч.* Ватаным Татарстан

ПАРФЮМЕР *и. фр.* Парфюмерия әйберләре җитештерүче яки шулар белән сәүдә итүче кеше. *– Арыш серкәсенең исеннән татлырак бүтән хуш ис дөньяда юк, беләсегез килсә! – диде Әнвәр. – Парфюмерлар моны ничек аңламый, мин шуңа шаккатам.* М.Маликова

ПАРФЮМЕ́РИЯ *и. фр.* 1) Нәрсәгә дә булса хуш ис бирү өчен кулланыла торган эшләнмәләрнең гомуми атамасы. *Чөнки Гөлчирә бу килүендә баш әйләндергеч дәрәҗәдә матур иде. Дөньяда юкны да кимәгән, парфюмерия күленә дә батмаган.* Ф.Хөсни. *Товарлар*

күп. Кием-салым, йорт җиһазлары, парфюмерия, савыт-саба, кызыл мал, көнкүреш машиналары – әллә ниләр. М.Юныс. *Косметика һәм парфюмерия товарлары хәзер купшылар өчен генә түгел инде, алар көндәлек куллану әйберләренә әйләнделәр.* Р.Камалова

2) Җиңел сәнәгатьнең шундый продукция җитештерә торган тармагы

ПАРЧА I *и. фар.* 1) *иск.* Бөтеннең бер кисәге, ярчык. *Чиксез кыенлыклар аша алар шушы тәшкиләт янына барлык мөселман татарларны туплап, таралган татар милләтенең бер парчасын гына булса да саклап калырга тырыштылар.* Р.Батулла

2) Берәр әйбернең үрнәге итеп алынган кечкенә кисәге, өлеше. *Менә, җәмәгать, сачәргә җир бирмәсәләр дә, күзләрегезгә сөрмә кылып тартырга берәр парча туфрак алып кайттым.* Ш.Мөхәммәдев

3) *әд.* Югары осталык белән язылган шигырь яки кыска хикәя. *Инде укый калса, аның әйберсе башкаларныкы төсле зар еламыйча гына язылган, күбрәк табигать күренешен гади генә сурәтләгән яки үзенчә берәр тормыш фәлсәфәсе әйтергә тырышкан кыска гына шигъри парча булып чыга торган иде.* Ә.Еники. *Без аның әдәбият һәм сәнгать әһелләренә тирән хөрмәт белән карап, аеруча өлкән буын вәкилләрен олылап язылган фәлсәфи парчаларын яратып укыйбыз.* М.Гайнуллин. *Алар арасында җитди юмористик, сатирик парчалар да, робагый, фәрд, мәсәл жанрлары да, дүртьюллык һәм икеюллыклар белән язылганнары да бар.* Х.Миңнегулов

ПАРЧА II *и. фар.* **1.** 1) Тукыма өстенә чигеп, чүпләмләп һ.б.ш. ысул белән ясалган яки төшерелгән бизәк, орнамент, чәчәк-яфрак рәсемнәре. *Ул абзый нечкә генә каурый каләм белән хәрефләрне, сүзләрне шундый матур итеп тезеп барган, нечкә җепләр белән ефәккә парчалар чиккәнмени!* Г.Бәширов

2) Алтын яки көмеш җепләр белән чигелгән, путаллы орнамент төшергән авыр ефәк тукыма. *Кичке күлмәккә ефәк яки челтәр перчатка, парчадан, бәрхеттән, ефәктән, атластан эшләнгән кечерәк кенә сумка килешә.* Әдәп төбе – матур гадәт. *Һуһаять, уртадагы зур өстәл каршында мөнбәрне хәтерләткән һәм бөтен ягыннан парча, бәрхет белән тышланган шактый биек ике корылма тора.* М.Галәү

2. *с. мәгъ.* Шундый тукымадан тегелгән. *XIX гасырда гомер кичергән билгесез бер әбиемнең бик затлы парча камзулына үреләм дигәндә, бармакларым салкын пыялага төртелде.* Мәдәни җомга

ПАРЧАЛАНУ *ф.* 1) Вак кисәкләргә аерылу, телгәләнү; ваткалану. *Сугышларда парчаланган байрак әле дә музейда саклана*

2) *күч.* Газаплану, өзгәләнү. *Ауды ана таеп һушыннан, Парчаланган йөрәк түзмәде. Елый-елый улы сагышыннан Сукырайды аның күзләре.* М.Җәлил

Парчалана башлау Парчаланырга тотыну

Парчаланып бетү Тәмам парчалану, вак кисәкләргә телгәләнү

ПАРЧАЛА́У I *ф.* 1) Бозу, җимерү; челпәрәмә китерү

2) *Йөрәк, күңел* сүзләре белән килгәндә, «газаплау, парә-парә итү» мәгънәсен белдерә. *Күңелем[не] парчалама, Арыслан абыем, мине кызган син.* Ә.Фәйзи

ПАРЧАЛА́У II *ф.* Парчалар II (*1 мәгъ.*) төшерү. *Ул җәймәне төн утырып парчалады*

ПАРЧАЛЫ *с.* Парча II (*1 мәгъ.*) төшерелгән яки парчалап чигелгән. *Сөйгәнемә читек эзләп, Урап кайттым Арчаны. Рәхим итеп, Мә, ал читек, Аллы-гөлле, парчалы!* М.Хөсәен. *Уртада озынча өстәл, чиккән парчалы кызыл эскәтер ябылган.* Х.Камалов. *Бохараның укалап чигү остаханәләрендә полковник бик күп итеп затлы-зиннәтле, парчалы бизәкле бәрхет халатлар тектереп алды, һәрберсенә тирән вә киң кесәләр салдырды.* Р.Мирхәйдәров

ПАРЧА́-ПАРЧА *рәв.* Кисәк-кисәк. *Дәхи җир өстендә булган зиннәтләрне һич үлән үсми торган итеп парча-парча кылачакбыз.* Ногмани. *Анда парча-парча йолдызлар ерак.* М.Җәлил. *Яралы бүре --- ак-күк атны парча-парча өзгәләп ыргытты, ди.* Х.Кәрим

◊ **Парча-парча булу** 1) Челпәрәмә килү, уалу; вак кисәкләргә яргалану, өзгәләнү. *Ваза идәнгә төшеп парча-парча килде. Бутылка --- лампага бәрелеп парча-парча булды.* Ш.Мөхәммәдев; 2) Әрнү, өзгәләнү, рухи газап чигү. *Янды, көйде, парча-парча булды мескен күкрәгем.* Ш.Бабич. **Парча-парча килү** *к.* **парча-парча булу**

ПА́РЪЯСАГЫЧ *и. тех.* Төрле максатлар өчен пар эшләп чыгара торган җайланма

ПА́РЪЯСАЛЫШ *и.* Пар хәленә күчү процессы. *Паръясалыш һәм конденсация*

ПАРЫЛДА́У *ф. иск.* 1) Тавыш чыгарып җилфердәү. *Ал әлəмнәр каберем өстендә парылдасын.* С.Сүнчәлəй

2) Ялкынлану, ялт-йолт итү, яп-якты булып күренү. *Кояшка парылдап тора торган ул тирмәләрдә кымыз да бик тәмле була, имеш.* Аң

ПАС *и. ингл. спорт* 1) Тупны үз командасындагы икенче уенчыга тапшыру. *Пас дигән нәрсәне белүче дә юк, киресенчә, безнең малайлар тупны күбрәк үзенә генә элəктерергә тырыша, чөнки аның да куасы, аның да капкага тибәсе килə.* Ә.Еники. *Гади кешенең күңелен күбрәк голлар, кискен моментлар «кытыклый», ə без профессиональ уенчыларның пас бирү рəвешларен җентекләп күзəтəбез.* Л.Закиров

2) Карта уенында «бу уенны уйнамыйм», «бу йөрешне ясамыйм», «уздырып җибәрəм» мәгънəсендə əйтелə торган сүз. *– Козырь капут! – диде генерал. – Мин пас инде, – диде адмирал.* Х.Туфан

3) Нинди дә булса эшне башкарганда, көч җитмәү, булдыра алмау, хәлдән килмәү билгесе итеп әйтелә торган сүз. *Чөнки тора-бара «мин – пас» дип, тормыш карталарын ачып салды: баксаң, ул авторларның байтагында татар каны ага икән бит!* Идел. *Монда сукыр күзгə дə күренеп тора: бу ярышта иргегетлəрнең барысы да пас.* Сəхнə

ПАСКАЛЬ *и. фр. физ.* Басым үлчəү берəмлеге

ПАСКВИЛЬ *и. ит.* Берəр кешене, төркемне, партияне кимсетү, хурлау максаты белəн чынбарлыкны бозып,

яла ягып язылган әсәр. *Ни өчендер Хәсән абзый шул әсәрне телебезне бетерергә юнәлдерелгән бер пасквиль дип кабул итте.* Ә.Еники. *Карт ишан яңача укытуның зарары турында бер пасквиль яза.* М.Мәһдиев

ПАСЛЁН *и. рус бот.* Аерым бер семьялык барлыкка китерә торган кайбер үләннәр, куаклар һәм ярымкуакларның ыруг атамасы; карга җиләге, саескан чиясе, карга борыны. *Россия территориясендә паслённың 20 ләп төре куаклыкларда, су буйларында, дымлы чокырларда очрый. Республикада тилебәрән үләне, скополия, паслён һәм тиле ут ырыгларына керә торган агулы үсемлекләрнең 6 төре очрый.* Татарстанның үсемлекләр һәм хайваннар дөньясы. *Паслён, алоказия, олеандр, синадениум дигән гөлләрне дә өйдә үстермәү хәерлерәк.* Ватаным Татарстан

ПАСЛЁНЧАЛАР *и. күпл. биол.* Дөрес урнашкан биш аерчалы, йолдызсыман чәчәкле үләннәр, лианалар, куаклар кергән сыраҗсыманнар рәтендәге ике өлешле үсемлекләр семьялыгы атамасы (бәрәңге, баклажан, тәмәке һ.б.ш. төрләр керә). *Паслёнчалар арасында төрле тереклек формасындагы төрләр бар.* Татарстанның үсемлекләр һәм хайваннар дөньясы. *Борыч, баклажан һәм помидор кебек үк, паслёнчалар семьялыгына керә. Бик тә җылы ярата торган культура.* Бакчачы, яшелчәче һәм умартачы календаре

ПА́СПОРТ *и. фр.* 1) Шәхесне таныту өчен бирелә торган рәсми документ. *Матрос Петровның керәшен татары икәнлеген миннән башка беркем белми, аның паспортында милләте рус дип язылган.* М.Юныс. *Кайчан да булса бездә яңа паспортлар кертәчәкләр, я булмаса, иске паспортларга «Гражданин России и Татарстана» дигән штамплар басачаклар.* Ә.Кәримуллин

2) Берәр төрле машина, җиһаз, хуҗалык әйберләренең кайда һәм кем тарафыннан эшләнгәнен, кайда теркәлгән булуын һ.б.ш. мәгълүмат теркәлгән документ. *Һәр суднoның үз исеме бар, флагы, паспорты бар.* И.Низамов. *Һәрбер консерва банкасының да паспорты була, шуның буенча аның кайда һәм кайчан эшләнгәнен белергә мөмкин.* Татар халык ашары

3) Гомумән, нәрсәнең дә булса төп үзлекләрен, сыйфатларын, торышын, яраклылык дәрәҗәсен һ.б.ш.ны тасвирлаган документ

ПАСПОРТИСТ *и. рус* Паспорт тутыру, рәсмиләштерү, теркәү, пропискага кертү һ.б.ш.лар белән шөгыльләнүче хезмәткәр; паспорт-виза бүлеге хезмәткәре

ПА́СПОРТЛАШТЫРУ *ф.* 1) Паспортлар системасы кертү, халыкка паспортлар бирү. *Авыл җирлегендә тулысынча паспортлаштыру бары 1976 елның 1 нче январеннан гына башлана, һәм ул 1981 елның 31 декабрена кадәр дәвам итә*

2) Нәрсәнең дә булса паспортын (*2, 3 мәгъ.*) булдыру, шуны тутыру. *Ирек Ялалов башкаладагы барлык социаль объектларны паспортлаштыру бурычын куйды.* Р.Вәлитова. *Бөтенрусия фәнни-тикшеренү институты белән берлектә республикада атларны исәпкә алу, токымлы үрчемне паспортлаштыру буенча җитди эш дәвам итә.* Т.Вәлиев

ПАССАЖ *и. фр.* 1) Ике яклап сәүдә нокталары тезелеп киткән ябулы галерея. *Пассаж – Казанның элеккеге Воскресенский урамында 1880–1883 елларда төзелгән, кешеләр йөри торган, урта өлеше пыяла белән ябылган зур йорт.* З.Бигиев. *Көн шактый соң булса да, урамда шактый халык бар иде, һәм дә пассаж ягыннан ике яшь кенә хатын да үтеп бара иде.* Г.Исхакый. *Ул бу көннәрдә Кремль урамындагы элеккеге пассаж бинасын яңартуда эшли.* Татарстан яшьләре

2) Музыкаль әсәрдә һәртөрле күчеш, чиратлашулардан гыйбарәт булган фраза, музыкаль әсәрнең бер өлеше. *Остаз, Хәбирнең шактый кыю һәм кызыклы эшләнгән полифоник комбинацияләренә, пассажларына булган сокланuын яшермәсә дә, йомшак җирләрен табып торды.* Ш.Хөсәенов

3) Әсәр текстының стиле һәм тематикасы белән аерылып торган бер өлеше. *Романга стиль берлеге җитми. Аллегорик манерда язылган бүлекләр публицистик пассажлар белән чиратлаша.* Р.Мостафин

ПАССАЖИР *и. нем.* Поезд, автобус, пароход, самолёт һ.б.ш. транспорт төрендә утырып баручы кеше. *Аэрофлот чит илләргә оча торган пассажирларына латин хәрефләре белән язылган билетлар сата.* Ә.Кәримуллин. *Милиция машинасы, --- паромның бушаганын көтеп алгач, башта пассажирлар белән тулы өч автобусны, аннары Тимергалиев белән Айтуганов машиналарын алып керде.* Г.Ахунов. *Автобус янына килеп, пассажирларның җыелып беткәнен көтә башладым. Китәргә биш минут калды, пассажирлар урыннарына кереп урнаштылар.* М.Юныс

ПАССАТ *и. исп. геогр.* Югары басымлы субтропик өлкәләрдән экваторга таба ел буена гел бер юнәлештә исә торган коры тропик җил. *Альбатрос гомерен туктаусыз хәрәкәттә, очышта уздыра, даими искән көнбатыш пассат җилләре агымына иярep, ул ел тәүлегендә Җир шарын әйләнеп чыга.* М.Юныс

ПАССИВ I *и. лат. бухг.* Оешманың барлык бирәчәкләре, бурычлары җыелмасы. *Пассивның күләмен ачыклау*

ПАССИВ II *с.* Пассив (I) белән бәйле, шуңа караган. *Пассив счётлар*

ПАССИВ III *с.* **1.** 1) Битараф, сүлпән, һәртөрле эшкә, көрәшкә катнашмый торган, дәртсез. *Сәләте, ихтыяр көче, кешелек сыйфатлары нинди? Барысын да белергә кирәк миңа! Белү генә җитми, шушы сыйфатларның нинди шартларда актив, кай очракта пассив булуын да белергә тиешмен.* М.Юныс. *Дөньяда барган үзгәрешләрне аңлаучы төрки халык лидерлары төрки халыкларның милли аңы һәм мәгърифәте дөньясына шифалы җилләргә юл ача башладылар, төрки халыклар пассив каршылыктан уянып, үзләренең азатлыгы өчен көрәш юлына күчтеләр.* Ә.Кәримуллин

2) Мөстәкыйль түгел, кемгә яки нәрсәгә дә булса бәйле. *Пассив роль уйнау*

3) Кулланылышы актив булмаган. *Телнең пассив сүзлек байлыгы*

2. *рәв. мәгъ.* Нинди дә булса эшхәрәкәтнең барышына катнашмыйча.

Кеше климатны пассив күзәтеп торудан аныа актив төстә үзе формалаштыруга күчәчәк заманны озак көтәсе түгел инде. А.Тимергалин. *Ә иң күңелгә тигәне: белем бирү системасына кагылышлы мәсьәләләрдә ата-аналар пассив.* Безнең гәҗит

ПАССИВЛАНУ *ф. к.* **пассивлашу**. *Алдашуларга күнеккән халык тагын да йомыла, пассивлана*. Безнең гәҗит

Пассивлана бару Торган саен пассивлану

Пассивлана башлау Пассивлануга табан үзгәрү

Пассивлана төшү Бераз пассивлану; тагын да пассивлану. *Халык пассивлана бара, хәтта бушлай тәкъдим ителүче спектакльләргә, концертларга йөрергә ренәләр*. Безнең Чирмешән

Пассивланып бетү Нык пассивлану; тәмам пассивлану

Пассивланып китү Күзгә күренеп пассивлану; соңгы вакытта пассивлану

ПАССИВЛАШУ *ф*. 1) Активлыкны, хәрәкәтчәнлекне югалту; сүлпәнләнү. *Әгәр тәнкыйтьчеләребез чыннан да пассивлашканнар икән, моның сәбәпләре нәрсәдә дип уйлыйсыз?* Казан утлары

2) Актив кулланылышын югалту. *Сүзләрнең пассивлашу сәбәпләрен әйтегез.* Г.Галиуллина

Пассивлаша бару Вакыт узган саен күбрәк пассивлашу

Пассивлаша башлау Пассивлык билгеләре сизелү

Пассивлашып китү Соңгы вакытта пассивлашу, сүлпәнләнү

Пассивлаша төшү Тагын да бераз пассивлашу

ПАССИВЛЫК *и.* Пассив булу; битарафлык, сүлпәнлек. *Моны аңламаганнар да тигезсезлекнең объективлыгын танымаганнар кебек үк кризиска юлыга, пассивлыкка бирелә һәм бөлгенлеккә төшә.* Р.Сафин. *Кешеләрдәге илебезнең артка калуына китерә торган начар сыйфат – пассивлык, битарафлык менә шушы инде.* Р.Юсупов

ПА́СТА *и. ит.* 1) Нинди дә булса катнашмаларның куе массасы. *Балалар өчен билгеләнгән теш пасталары һәм порошоклары олыларныкыннан составларында хуш исле һәм дезинфекцияли торган катнашмаларның азрак булуы белән аерыла.* Тигез гомер итегез! *Раковинаны һәр көнне паста белән юарга кирәк, югыйсә ул саргая, аннан соң инде аны агарту өчен шактый вакыт кирәк булачак.* Өгез ямьле булсын

2) Бодайның каты сортларыннан ясалган макорон; шул макароннан әзерләнгән ризык. *Ул үзенә паста китерүләрен сорады*

ПАСТЕЛЬ *и. фр.* **1.** 1) Буяу порошогыннан пресслап ясалган йомшак карандаш. *Пастель белән рәсем ясау*

2) Шундый карандаш белән ясалган рәсем. *Рәссамның бу пастеле аеруча матур*

3) Шундый карандашлар куллануга нигезләнгән рәсем сәнгате техникасы. *Конкурска эшләрнең төрле жанрда һәм төрле техника белән ясалганы (тушь, гуашь, акварель, пастель, компьютер графикасы, дивар рәсемнәре, катнаш техника һ.б.) кабул ителә*. Сабантуй. *Теләсә нинди жанрда һәм техникада ясау да рөхсәт ителә – тушь, гуашь, акварель, пастель ярдәмендә дә, компьютер графикасында да, катнаш техникада да.* Татарстан яшьләре

2. *с. мәгъ.* Җете булмаган, йомшак аксыл (тоннар тур.). *Көндәлек макияж өчен кулай булган иннек пастель тоннарында булса яхшы.* Кәеф ничек? *--- гомумән, тарихи үзәк пастель төсләрдә булырга тиеш, ә яңа төзелеш кварталлары теләсә нинди җете төскә маныла ала – журналистларның соравына җавабында проектларны һәм шәһәр дизайнын карап тикшерү бүлеге башлыгы Жанна Белицкая шулай диде.* Татарстан хәбәрләре

ПАСТЕРИЗА́ТОР *и. лат.* Сөт, сөт өсте, сок һ.б.ш. ишеләрне пастеризацияләү аппараты. *Якын киләчәктә үз хуҗалыгымда сөт эшкәртү белән шөгыльләнергә, моның өчен пастеризатор корырга ниятем бар.* Кызыл таң

ПАСТЕРИЗА́ЦИЯ *и. фр.* Азык-төлек продуктларының тәме, туклыклылыгы сакланырлык итеп, җылыту юлы белән зарарсызландыру. *Күп көч, күпме чыгымнар тотып җитештерелгән сөтнең хакы маслозаводта пастеризация һәм упаковка үтеп сатучы алдына басканчы 6,7 тапкыр арта!* Татар заманы. *Пастеризация дип аталган процесс лаборатория һәм азык сәнәгатендә бүген дә киң кулланыла. Ә эшкәртүче һәм сәүдә тармакларына әзер сөтне алып пастеризация эшләргә дә, пакетларга тутырып, магазинда сатарга гына кала.* Ватаным Татарстан

ПАСТЕРИЗА́ЦИЯЛӘҮ *ф.* Пастеризация ясау. *Эремчекне өсте алынмаган, пастеризацияләнгән сөттән ясыйлар. Өй шартларында сөтне болай пастеризацияләргә мөмкин: сөтне болгатмыйча гына 10–15 минут 80 градуска кадәр җылыталар.* Татар халык ашлары. *Чөнки анда әчү процессы пастеризацияләү ярдәмендә туктатылган була*. Шәһри Казан. *Нәтиҗәле эшләүче бу хуҗалыкның сөтне пастеризацияләү һәм пакетларга тутыру линиясе бар*. Кызыл таң. *Пастеризацияләп сатуга чыгарган өчен 10–15 процент кына өстәләр, килешер дә идең*. Ватаным Татарстан

Пастеризацияләп алу Тиз генә, тиз арада пастеризацияләү

Пастеризацияләп тору Гел, һәрвакыт пастеризацияләү

ПАСТИЛА *и. исп.* Шикәрләп пешерелгән җиләк-җимеш измәсе, шуннан ясалган татлы ризык; как. *Бер атна эчендә --- кус-кус, харира, пастила пешерергә дә өйрәтте мине әнием.* Ялкын. *Оренбур мөселманнары безне хәләл татлы әйберләр: пастила, мармелад белән сыйлады.* Безнең гәҗит

ПА́СТОР *и. лат.* Протестант руханиe. *Протестант пасторларны билгеләү, провославиелеләр һәм католиклардагы изге дәрәҗәгә күтәрүдән аермалы буларак, серле йолаларга керми. Протестант өчен пастор – язманы белүче иң абруйлы зат.* Диннәр тарихы. *Америка мәгълүмат чаралары бу хакта теләмичә генә язалар, чөнки ике пастор да үзләрен популярлаштыруга иреште.* Татарстан яшьләре. *Леонард Эйлер Базель шәһәрендә пастор Пауль Эйлер гаиләсендә 1707 елның 15 апрелендә дөньяга килә.* Фән һәм тел

ПАСТОРАЛЬ *и. лат.* Көтүчеләр тормышын гади һәм бәхетле итеп,

идеаллаштырып күрсәтә торган шигырь. *Тарихтан Антик поэзиянең пастораль жанры авыл көтүчеләре, игенчеләре, балыкчылары турында язылган әсәрләрне тәшкил итүе мәгълүм.* Татар әдипләре

ПА́СТЫРЬ *и. гр.* Христиан динендә: дин тотучыларны кайгыртучы, җитәкләүче священник. *Гитлер һөҗүменең беренче көнендә үк митрополит Сергий «Христос Православие Чиркәвенең пастырьларына һәм мәхәлләдәгеләргә» дип аталган мөрәҗәгать төзи...* Диннәр тарихы. *Аның бер үзенчәлеге шуннан гыйбарәт: моңарчы үзен атеист, тәңрече, христиан яки мөселман дип исәпләгән кеше католик диненә күчәргә җыена икән, пастырь әүвәл аңа, бер ел сынау вакыты үтәсе, дигән шарт куя.* Ватаным Татарстан. *Шуннан яныма татар йөзле, 40–45 яшьләрендәге берәү килеп: «Мин пастырь, үзем татар», – дип сүзен башлады.* Ислам – татарлар һәм мөселманнар

ПА́СХА *и. лат.* 1) Христианнарда һәм яһүдиләрдә Христосның яңадан терелүен искә алып уздырыла торган язгы дини бәйрәм, Олы көн. *Пасха алдыннан соңгы якшәмбе кызыл тал якшәмбесе дип атала.* Татарстанның үсемлекләр һәм хайваннар дөньясы. *Шушы елның 15 апреленнән 16 апреленә каршы төндә Союзның православие чиркәүләре эшләгән барлык шәһәрләрдә һәм районнарда төнге Пасха гыйбадәте уздырылды...* Диннәр тарихы

2) Яһүдиләрнең Мисырдан чыгып китүләренә һәм коллыктан котылуларына багышланган язгы дини бәйрәмнәре. *«Пасха» атамасы яһүдиләрне Мисыр тоткынлыгыннан азат итү истәлегенә билгеләнгән Тәүрат бәйрәме белән бәйләнешле.* Диннәр тарихы

3) Пасха (*1 мәгъ.*) бәйрәменә эремчек кушып пешерелгән татлы күмәч. *Кристина ул көнне кичке бишләр тирәсендә өй телефоны аша үзенә шалтыраткан сеңлесе Мариягә Пасха рецептын әйтеп яздыра.* Туган як

ПАСЬЯНС *и. фр.* Уен яки фал ачу максаты белән, уен карталарын үзенә бер төрле кагыйдәләргә нигезләнеп тарату ысулы. *Шимбә һәм якшәмбе көнне Сәлим белән икесе ике көн өйдән чыкмадылар, пасьянс уйнаган кебек, документларны әле болай, әле тегеләй салып карадылар.* Р.Мирхәйдәров

ПАТ *и. фр.* Шахмат уенында уенчыларның берсе, королен шах астына куймыйча, бер фигурасы белән дә йөри алмый, һәм шуңа күрә уен уртак исәпкә тәмамлана торган очрак. *Уен беткәч, осталар күбәйде: «Гәрәйгә алай йөрергә кирәкми иде, болай кирәк иде, пат булмаган булыр иде!» – дип, үзләренең белдеклелеген күрсәтә башладылар.* И.Гази

ПАТЕНТ *и. лат.* 1) Уйлап табучының авторлык хокукы турындагы таныклыгы

2) Берәр аерым эш белән шөгыльләнергә бирелгән хокук һәм шундый хокук турындагы документ. *Исәбе – патент алып, капка түбәсенә «Чүлмәк сатучы Шәвәли Гаптелмәликов» дип язулы такта куярга --- иде.* С.Рафиков

ПАТЕНТЛАНУ *ф.* 1) *төш. юн. к.* **патентлау**

2) *күч. с. мәгъ.* **патентланган**. Билгеле бер максат яки урын өчен бөтен сыйфатлары белән туры килгән, ярый торган. *Хафаланма, Нургали, --- беребез дә патентланган парторг булып тумаган.* М.Хәсәнов

ПАТЕНТЛА́У *ф.* Нинди дә булса берәр ачышны, уйлап тапкан яңалыкны рәсми рәвештә танып теркәү, аңа патент бирү. *Госманның --- югары сыйфатлы саф гипосульфат җитештерү технологиясенә караган уйлап табуын хәтта чит илләрдә дә патентламакчылар.* Э.Касыймов

Патентлап кую Тиз арада патентлау

ПАТЕНТЛЫ *с.* Билгеле бер эшчәнлек белән шөгыльләнергә хокукы булган. *Патентлы оешма*

ПА́ТЕР *и. лат.* Католикларның рухание

ПАТЕ́ТИК *с.* Дәрт, ярсу, дулкынлану белән сугарылган. *Әхмәт Фәйзи Ленинград эпопеясен «Туу сулышы» исемле патетик поэмада чагылдырды.* Г.Кашшаф

ПАТЕ́ТИКА *и гр.* Сөйләмдә, сәнгать әсәрләрендә дәртле, ярсулы хисләр чагылышы. *[Тукай шигырьләрендә] салкын канлы риторик түгел, ә көрәш сафларында шаулап, күкрәп килүче яшьләрнең йөрәгенә кайнар дәрт һәм өмет өстәүче патетика, ялкынлы илһам бар.* Г.Халит

ПАТЕФОН *и. фр.* Янда йөртү өчен уңайлы, тартма эченә урнаштырылган рупорсыз граммафон. *Райздрав үземә, ашлык җыю вакытында медицина эшләрен яхшы куюым өчен, патефон бүләк итте.* Г.Кутуй. *Кушылып җырлар идем дә, Булмый шул, булмый, җаным: Патефон тәлинкәсендә Бармыни тавышы аның?!* Х.Туфан. *Шунда ук кибән төбендә бер патефон әйләнеп утыра.* М.Мәһдиев

ПАТОГЕНЕЗ *и. гр.* Төрле авыруларның килеп чыгу һәм көчәю процессының эзлеклелеге һәм шул эзлеклелек закончалыкларын өйрәнә торган фән тармагы

ПА́ТОКА *и. рус кулин.* Крахмалдан ясала торган куе, сузылучан татлы матдә. *Беләсеңме, син бәрәңге боламыгына патока кушып кара әле.* Аманулла.

ПАТО́ЛОГ *и. гр.* Патология белгече

ПАТОЛО́ГИК *с.* Патологиягә бәйләнешле. *Бу вакытта кеше организмына В12 витамины керми, һәм анемия өчен, шулай ук бу витамин җитмәүдән башка патологик симптомнар килеп чыгу өчен алшартлар туа.* Дөрес тукланы серләре. *Организмга тавышның патологик тәэсире ачык күренеп торуга да карамастан, без көндәлек тормышта аңа каршы көрәшкә аз әһәмият бирәбез.* Йөрәгегезне саклагыз

ПАТОЛО́ГИЯ *и. гр.* 1) Кеше яки хайван организмындагы төрле авыруларның, нормадан тайпылышларның барлыкка килүен һәм агышын өйрәнә торган фән. *Галимнәр Коръәндә эмбриология, анатомия, физиология, патология, психиатрия, психология, патологоанатомия, туу һәм үлем турында фикерләрне күрә.* Безнең гәҗит

2) *мед.* Организмдагы авыру процесслары яки нормадан тайпылыш. *Егетне караган район терапевты объектив патология тапмаган, ЭКГсында да патология күрмәгән.* Татарстан яшьләре. *Инвалидлыкка китергән авырулар арасында беренче урында нерв системасы авырулары, икенчедә –*

соматик патология, өченчедә – психика бозылу һәм бары тик дүртенче урында гына тумыштан килгән аномалияләр тора. Мәдәни җомга

3) *күч.* Нормаль булмаган хәл яки күренеш. *Әгәр кеше вакыты-вакыты белән азартка кереп китә, уйный икән, бу – нормаль күренеш. Ләкин ул якынтирәдәгеләргә материаль, рухи зыян салу исәбенә башкарылса, димәк, бу инде – патология.* Р.Исхакый

ПАТРИАРХ *и. гр.* 1) Ыруг башлыгы булып саналган тәжрибәле, ихтирамга лаек өлкән яшьтәге ир кеше

2) Нинди дә булса коллективта иң хөрмәтле, иң абруйлы өлкән шәхес. *Күренекле язучы һәм галим Нәкый ага Исәнбәт болай дигән иде: «Бакый Урманче – сынлы сәнгатебезнең патриархы, аның башы, аксакалы..!»* К.Миңлебаев

3) Православиедә дин башлыкларының иң югары титулы. *Ары таба патриарх титулы алган Никон христиан динендәге Русия халкына язып бетермәслек фажига китерә.* М.Хәбибуллин. *Православие патриархының сүзләре гаҗәеп ихлас, рухи яктан зирәк һәм гади яңгырый, яңа сайланган патриарх Тихон дин белгече дә, сәясәтче дә булмый.* Диннәр тарихы. *Моңарчы башкалага элеккеге патриарх Алексий II ике тапкыр килгән иде.* Ватаным Татарстан

ПАТРИАРХАЛЬ *с.* 1) *тар.* Патриархатка бәйләнешле, патриархат чорына карый торган. *Шәмсегаянга өйләнгәч, Мирвәли әтисенә каршы баш күтәрә, Шахразыйның патриархаль гаиләсе өчен бу инде кеше ышанмаслык хәл була.* Р.Салихов. *Һун-төрки бабаларыбыз патриархаль тәртиптә яшәсәләр дә, аларда хатын-кызны җәмгыять тормышыннан читләштерү гадәткә кермәгән булган.* Р.Сафин

2) *күч.* Иске, консерватив йолаларга нигезләнгән. *М.Гафуриның өченче иҗат мотивы – патриархаль-феодаль мөнәсәбәтләргә каршы көрәшү.* М.Җәлил. *Бу язучылар --- буржуаз җәмгыятьнең зарарлы, политик һәм мораль яктан череп таркалган социаль катлауларын, аларның реакцион идеологиясен, патриархаль һәм буржуаз семья мөнәсәбәтләрен тәнкыйть иттеләр.* Х.Мөхәммәтов

ПАТРИАРХАЛЬЛЕК *и.* 1) Патриархаль традиция, иске гореф-гадәтләр; борынгылык. *Яшеллек, борынгы матур особняк йортлар, бәпкә үләнле урамнар, үз гадәтләре белән, олы бер гаилә булып яшәгән ихаталар – Русия шәһәрләренә төс биргән патриархальлек сыйфатлары – элекке Уфаны да тарихлы, традицияле шәһәрләр рәтенә кертә иде.* М.Котлыгалләмов

2) Патриархаль традицияләрне, иске гореф-гадәтләрне үзгәртмичә дәвам иттерү күренеше, шуңа бирелгәнлек

ПАТРИАРХАТ *и. гр.* Хуҗалыкта һәм җәмгыятьтә ирләр хатын-кызларга караганда зуррак роль уйнаган, матриархаттан соң килгән дәвер. *Тулаем алганда, патриархатның бөтен Җир шарында уртак күренеш икәнлеген әйтә алабыз.* Р.Сафин. *Мисал өчен, монда Америка галиме Л.Морганның матриархат, патриархат формацияләре турындагы теориясен искә төшерергә була. Морган уйлаганча, дөньяда иң элек, имеш, аналар хакимлеге (матриархат), шуннан соң, имеш, аталар хакимлеге (патриархат) булган, патриархаттан соң, имеш, сыйнфый җәмгыять барлыкка килгән.* Н.Фәттах

ПАТРИАРХЛЫК *и.* 1) Патриарх дәрәҗәсе; патриарх вазифасы. *Шундый кыен шартларда Соборның төп нияте гамәлгә ашырыла: Рус Чиркәвендә патриархлык торгызыла.* Диннәр тарихы

2) Башында патриарх торган чиркәү административ-территориаль берәмлеге. *Мәскәү шәһәрендә Пасха гыйбадәте патриархлыкның 30 чиркәвендә һәм яңарту юнәлешендә бер чиркәүдә узды.* Диннәр тарихы

ПАТРИОТ *и. гр.* **1.** 1) Үзенең туган илен, телен, халкын, ватанын сөюче кеше; ватанпәрвәр. *Дөрес, шигырьләрдә, җырларда шагыйрьнең имзасы юк, тик аларны чын патриот язганлыгы шик уятмый.* Г.Әпсәләмов. *Хәйретдин Мөҗәй Ватанны фашистлардан азат итү өчен җаны-тәне белән бирелгән чын коммунист, патриот була ул.* С.Шакир. *Мин тумыштан һәм канымнан патриот идем.* М.Гайнуллин

2) *күч.* Нинди дә булса эшкә, һөнәргә һ.б.ш.га бик бирелгән, шуңа һәрвакыт тугры калган кеше. *Үз эшенең патриоты*

2. *с. мәгъ.* Ватаны өчен һәртөрле корбаннарга әзер булган. *Муса Җәлил фашизм тоткынлыгындагы патриотик эшчәнлеге һәм иҗаты белән генә түгел, ә бөтен тормыш юлы, --- иҗаты белән көрәшче әдип, патриот шагыйрь дигән исемнәрне тулысынча аклады.* Н.Юзиев. *Шул көннән патриот шагыйрьнең фашист тоткынлыгындагы газаплы һәм героик тормыш этабы башлана.* Шигърият

ПАТРИОТИЗМ *и. гр.* Үзенең туган иленә, халкына, милләтенә, ватанына карата булган горурлык, мәхәббәт хисе. *Капитализм шартларында кабатланып торган барлык гадел булмаган сугышларга хас булганча, рус-япон сугышы вакытында да Россиядә ялган буржуаз патриотизм бик күпертелә.* М.Гайнуллин. *Габдрахман Әпсәләмов үзенең соңгы әсәрендә, «Агыла болыт» исемле романында, үзенең башка әсәрләрендәгечә, олы гражданлык идеяләрен – ватанга лаеклы хезмәт итү, патриотизм идеяләрен күтәрде.* Р.Сверигин

ПАТРИОТИК *с.* Патриотизм хисе белән сугарылган. *Патриотик декламация сөйләү бик ансат, ә сөекле илегез сезне җавапка тартса?* И.Гази. *«Агыла болыт» романы – гражданлык пафосының югарылыгы белән яисә яшьләрне патриотик рухта тәрбияләү көче ягыннан үзенә тиешле урынны алырлык әсәр.* Р.Сверигин. *Бер җырга икенчесе ялгана, икенчесенә – өченчесе, патриотик җырларны лирика алыштыра.* Татар әдәбияты тарихы

ПАТРИОТЛЫК *и.* 1) Патриот булу. *Солдатларның поход җырлары --- патриотлыкның гүзәл үрнәге булып тора.* К.Нәҗми

2) Патриотизм. *Нигә безнең бер патриотлыгыбыз да юк, бер оешмабыз да юк...* Ш.Маннур. *Татар телен саклауга юнәлтелгән бурычларның иң әһәмиятлесе: татар кешеләренең рухларын, кәефләрен савыктырырга,*

психологик хәләтләрен тиешле юнәлештә үзгәртергә, аларны милли патриотлык рухында тәрбияләргә тырышырга кирәк. Р.Юсупов. *Бу геройларны патриотлык, гражданлык, демократик уй-фигыльләр һәм симпатияләр бизи.* Татар әдәбияты тарихы

ПАТРИ́ЦИЙ *и. лат.* 1) Борынгы Римда өстенлекләргә ия булган югары катлау кешесе. *Борынгы римлылар Карфаген белән сугышканда, Катон дигән бер патриций Рим сенаты утырышында һәрвакыт речь сөйли икән.* М.Мәһдиев

2) Урта гасырларда Германиядә шәһәр аристократиясе вәкиле

ПАТРОН I *и. фр.* Эченә дары тутырылган һәм пуля яки ядрәләр белән бөкеләнгән гильза. *Патроннары, гранаталары белән, коры паёк белән беррәттән Йөртте аны солдат ут эчендә, Дусты итеп, сөеп йөрәктән.* М.Садри. *Озакламый тагын карталар, документлар, пистолетлар, автоматлар, патроннар, бинокльләр китерделәр.* Х.Мөҗәй. *Пулемётчы үзе манма су булса булсын, патрон тасмасы юешләнмәсен!* З.Зәйнуллин

ПАТРОН II *и. лат.* 1) Борынгы Римда ярлы-ябаганы үз канаты астына алган бай кеше

2) Тәрбияче, опекун

ПАТРОНАЖ *и. лат.* Яңа туган балаларга һәм башка кайбер категория авыруларга әледән-әле өйгә килеп ярдәм күрсәтү. *Мәсәлән, инде берничә ел буена Алабуга балалар йорты һәм Түбән Камадагы берничә социаль учреждение безнең патронаж астында тора.* Шәһри Казан. *Бу очракта оныкәбисен патронаж рәвешендә генә тәрбиягә ала ала.* Татарстан яшьләре

ПАТРОНАТ *и. лат.* Ата-аналарын югалткан балаларны дәүләт органнары күзәтүе астында башка гаиләдә тәрбияләү формасы. *Сүз уңаеннан: РФ Дәүләт Думасында «социаль патронат» кертү турындагы закон проекты каралган иде.* Шәһри Казан. *Алар фикеренчә, башта ятимлекне профилактикалау буенча эшне җайга салырга, патронат гаиләләр институтына аякка басарга ярдәм итәргә кирәк.* Татарстан яшьләре. *Беркөнне телевизордан патронат гаилә турында төшерелгән тапшыруны исе китеп карый Рәвилә.* Кызыл таң

ПАТРО́НИМ *и. лат.* Баланың атасы яки атасы ягыннан берәр бабасының исеме ярдәмендә ясалган ыру исеме; тулы исемнең өлеше. *Патроним – антропонимик берәмлек, ата исемнәре яисә ата исеме белән бәйле башка төр атама.* Г.Галиуллина

ПАТРОНИ́МИК *с.* Патроним белән бәйле, патронимнан ясалган. *Урта гасырларда кайбер укымышлыларның үз исеме белән янәшә әтисе яки бабасы исемен, бернинди кушымча алмаган килеш, патронимик фамилия функциясендә кулланулары да очрый.* Ватаным Татарстан

ПАТРОНТАШ *и. нем.* Патрон йөртү өчен оялары булган махсус сумка яки тасма. *Винтовка бир, егет, патронташ бир...* М.Җәлил. *Саквалларга солы тутырып, иляр өстенә бәйләдек. Патронны патронташларга тутырдык.* Ә.Айдар. *Иртән торгач, туксаншар боевой патрон, патронташ һәм граната сумкалары алдык.* Фән һәм тел

ПАТРУЛЬ *и. фр.* **1.** 1) Берәр урынга, гомуми тәртипне саклау өчен, хәрби частьтан, полициядән җибәрелгән кешеләр төркеме яки хәрби самолёт, кораб. *Урынны ныклап өйрәнгәннән соң, мин, дошманның танклары һәм пехотасы урман-сызыкларга килеп кермәячәк, шуңа күрә анда патруль оештырып, разведка җибәрергә, дигән карарга килдем.* Г.Сафиуллин. *Офицер патруль чакыра.* З.Мәхмүди

2) Шундый төркем составындагы бер кеше. *Ләкин миңа озак ятарга туры килмәде, тыштагы патрульне алмаштырырга чыктым.* Ә.Айдар. *Мин – яшел патруль.* Р.Батулла. *Адреслар да алмашканнар иде, язмыштыр инде: ул язулы кәгазьне Казан вокзалында очраган иң беренче патруль алып калды.* Г.Гыйльманов

2. *с. мәгъ.* Патруль (*1 мәгъ.*) белән бәйле, шуңа мөнәсәбәтле. *Патруль катер*

ПАТРУЛЬЛЕК *и.* Патруль (*2 мәгъ.*) вазифасы, эше. *Һавадан патрульлек итү пилотсыз очу аппараты һәм ТР буенча Эчке эшләр министрлыгы вертолёты ярдәмендә башкарылды.* Ватаным Татарстан. *Тегеләр китеп бара, һәм, озак та үтми, таксистка шәһәр урамында патрульлек итүче ведомстводан тыш сак экипажы очрый.* Заман сулышы. *Аның кысаларында полиция хезмәткәрләре көн саен шәһәрдә яшәүчеләрнең күпләп ял итү урыннарында – шарлавыклы буалар, шәһәр күле тирәсендә, Ленин һәм Гагарин урамнарында патрульлек итәләр.* Әлмәт таңнары

ПАТРУЛЬЧЕ *и.* Патрульдә булган кеше. *Патрульчеләр төркеме*

ПАТША *и. фар.* 1) Илдә чикләнмәгән хакимлеккә ия булган кеше, монарх титулы; мәлик. *Тәхеткә яңа патша менү уңае белән туган өметләр шундук җимерелде.* М.Галәү. *Борын-борыннан ул шулай патшага баш орып өйрәнгән.* Г.Бәширов. *Урыс патшаларының дини һәм милли изүеннән аеруча безнең халык җәфа чикте.* Н.Фәттах

2) *күч.* Билгеле бер урында, җәмгыятьтә, мохиттә төп көч һәм хөкемдар булып торучы шәхес. *Ә-ә, Әхәт, авылның патшасы икән, безнең икмәкне талаучы...* А.Алиш

3) *күч.* Үз төркемендә иң көчле, иң зур яки башка гадәттән тыш әһәмияткә ия хайван. *Бака – күлендә патша, балык – суында патша, егет – илендә патша.* Мәкаль. *Арысланны хайваннар патшасы дип йөртәләр, ул – ерткыч хайваннарның иң эресе, авырлыгы 280 кг га җитә.* Хайваннар дөньясы

4) *күч.* Берәр өлкәдә иң танылган, иң авторитетлы белгеч. *Без бара торган галим – үсемлекләр патшасы академик Караваев.* Г.Кутуй

ПАТШАБИКӘ *и.* 1) Патша хатыны. *Безнең эрага кадәр 353 елда Мәүсәл патша үлә. Патшабикәнең кайгысы сөйләп булмаслык көчле иде, ул акылдан язу чигенә барып җитте, дип аңлаталар борынгы тарихчылар.* М.Юныс. *Патшабикә, тәпәнне күтәреп, кара өйгә чыгып китте.* М.Кәрим

2) Хатын-кыз патша. *Пётрдан соң тәхеткә килгән патшабикәләрдән Екатерина Беренче заманында бу эш [китап басу] сүнә.* И.Рәмиев. *Мисыр*

патшабикәсе Клеопатра – шуларның берсе. Без тарихта эзлебез

ПАТШАЛА́РЧА *рәв.* Патшаларга хас булганча; патшаларга охшатып. *Өстәл иң затлы азык белән сыгылып тора. Патшаларча.* Р.Төхфәтуллин

ПАТШАЛЫК *и.* 1) Патша дәрәҗәсе. *Патшалык яу белән, яу мал белән.* Мәкаль

2) Башында патша торган дәүләт. *Патшаның комсызлыгы, каты бәгырьле булуы, саранлыгы патшалыкта яшәүчеләрнең нәфрәтләрен туктаусыз көчәйтеп торган. Патшалыкта аны бары тик бер кеше – патшабикә генә яраткан.* М.Юныс

3) Нинди дә булса патшаның хөкемдар булып торуы. *Самсон бик озак һәм бик бәхетле патшалык чоры кичергән.* Үзең нинди – көзгең шундый

4) *махс.* Органик дөньядагы дүрт югары тармактан берсе. *Китапның икенче кисәге хайваннар дөньясына багышлана. Аны икенче төрле хайваннар патшалыгы дип йөртәләр.* Татарстанның үсемлекләр һәм хайваннар дөньясы

5) *күч.* Берәр төрле күренеш хөкем сөргән урын. *Бу – аның күптәннән төзегән сафлык дөньясы, аңа ул үзе генә патша, күпме генә, ничек кенә һөҗүм итмәсеннәр, бу патшалыкка беркемнең дә теле дә, кулы да зарар сала алмаячак иде.* Ф.Бәшир. *Ә бу мәңгеяшел урман патшалыгыннан өстәрәк мамонт агачлары, ягъни секвойялар күренә.* Борынгы гасырларда Татарстан

ПАТШАЛЫК ИТҮ *ф.* Патша буларак ил белән идарә итү. *Татарларның хөкемдары үлеп, ике улы кала; өлкәне патшалык итә башлый, кече улының көнчелеге кузгала, ул Шад исемле була.* Р.Фәхретдинов

ПАТШАЧЫЛЫК *и. к.* **монархия**. *Шулай да Курмаши патшачылыкның үзен гомумән социаль төзелеш буларак гаепләүгә, фаш итүгә кадәр күтәрелеп җитә алмаган.* Х.Госман

ПА́УЗА *и. гр.* 1) *муз.* Тавыш яңгыраган вакытта, кыска гына тукталыш һәм нота язуында шул тукталышның озынлыгын күрсәтә торган билге

2) *күч.* Эштә, сөйләүдә, ниндидер эшчәнлек вакытында кыска гына тукталыш, туктап тору. *– Ә хәзер, – диде ул, бераз паузадан соң, – мин картны шатландыруыгыз өчен, сезгә кечкенә генә бүләк тәкъдим итәргә рөхсәт итегез.* И.Гази. *Алкин идәнгә җайлабрак утырды да торбага янә чиртә башлады. Бер чиртә – пауза, ике чиртә – пауза. Әйтерсең лә Морзе аппаратында телеграмма бирә.* И.Салахов. *Рәхәтләнеп күзәтеп өлгерсеннәр дигәндәй, пауза озакка сузылды.* К.Кәримов

ПАФ *иярт.* Мылтыктан атканда барлыкка килгән авазны белдерә. *Хәтерлисеңме, атай, сез Кәҗә Газизулласы белән әрәмәлектә мылтык атыш уйный идегез. Паф та паф, паф та паф чыпчык чүпләдегез.* Н.Гыйматдинова

ПА́ФОС *и. гр. кит.* Рух күтәренкелеге, дәрт, энтузиазм, рухлану. *Җаваплы эш турында диңгезчеләрнең пафос белән сөйләгәннәрен ишеткәнем юк минем.* М.Юныс. *Әсәрдә әнә шундый пафос, яшәү гимны яңгырый. Дөресрәге, бу пафос әсәрне укучының күңелендә генә яңгырый.* Р.Сверигин. *Алар шагыйрьнең шигырьләрен яттан, зур пафос белән сөйләде.* Р.Батулла

ПА́ФОСЛЫ *с. кит.* Дәртле, ялкынлы, күтәренке рухлы. *Әмма бу трагизм югары пафослы һәм героик картиналардан түгел, ә җиргә иңдерелгән, үтә аңлаешлы, һәркем өчен якын бер гадилектән, Хикмәтулланың артык бай булмаган лексиконыннан да калкып чыга.* Р.Сверигин. *Аларның сүзләрендә дәрт, хис, ачу ташып торса да, дәлилләре җитәрлек булмаганга, бу сүзләр, пафослы буш шигырь сыман, һавада бераз тирбәлеп торалар да оратор җиргә төшүгә үк онытылалар иде.* Р.Вәлиев. *Мәгълүм булганча, бу – чор үзенчәлеге белән бәйле, чөнки заман таләбе буенча пьесаларда революцион пафослы, социализм төзүче актив геройлар сурәтләү сорала.* Фән һәм тел

ПАХ-ПАХ *иярт.* Утлы коралдан атканда барлыкка килгән авазларны белдерә. *Командир кулына пистолет тотып пах-пах ата.* Ф.Яруллин. *Олы чуар ОМОН плащы эченнән кыска мылтыгын чыгара да – этнең авызына пах-пах.* Г.Галиуллин

ПАЦИЕНТ *и. лат.* Табибка күренергә яки дәваланырга килгән авыру. *Врач пациентның кан басымын үлчи, йөрәген һәм үпкәсен тыңлый, ә аннары бик җентекләп авыруның... уч төбен карый башлый.* Могҗизалар энциклопедиясе. *Эндокринолог булмаган районнарда пациентларны участок терапевты, педиатр яки гомуми практика табибы дәвалый.* Татарстан яшьләре. *Һәр кешенең организмы, холык-фигыле төрлечә була, әңгәмәдән пациент турында үземә кирәкле мәгълүмат тупларга тырышам.* Шәһри Казан

ПАЦИФИЗМ *и лат.* Һәртөрле сугыш идеяләреннән, хәрби хәрәкәтләрдән баш тарту идеологиясе

ПАЦИФИСТ *и. лат.* Пацифизм тарафдары

ПАЦИФИСТЛА́РЧА *рәв.* Пацифистларга хас булганча

ПАЦИФИСТЛЫК *и.* Пацифист булу; пацифистларга хас сыйфатлар яки идеяләр. *М.Гафуриның талантлы иҗаты --- пацифистлык йогынтыларын баштан кичереп --- үсә.* М.Җәлил

ПАЧАС *и. рус диал.* Өй мүкләү өчен кулланыла торган җитен чүбеге. *Райпланнан ике йөз килограмм пачас бирергә тиешләр иде.* М.Мәһдив

ПА́ЧКА *и. нем.* 1) Беришле предметларның бер төргәге; кап, бәйләм. *Чишенеп өстәл буена килгәч, ул костюмының эчке кесәсеннән берничә пачка акча чыгарды...* А.Алиш. *Ул көтүне кабул итеп алган кешегә юлда армия частьларына биргән мал башы турында бер пачка расписка сузды: «Бу хайваннар үз вазифаларын вакытыннан алда үтәде!» – диде.* М.Кәрим. *Берничә пачка акчаны чалбар төбенә яшергән идем.* Н.Акмал. *Колхоз кәнсәләренә бер пачка повестка килгән иде.* Х.Сарьян

2) Балериналарның берләштереп тегелгән катлы-катлы кабарынкы кыска итәге. *Мөнирә рояль янына килеп утырды. Киемнәрен салып, балет пачкасын киеп өлгергән.* Г.Әпсәләмов

ПА́ЧКАЛАП *рәв.* 1) Төргәк-төргәк, пачкалар берәмлегенчә. *Акчаны пачкалап бирәләр, малай.* Ф.Яруллин. *Мәгәр сайлау әрҗәләренә пачкалап*

бюллетень ташлау, я булмаса, сайлау нәтиҗәләрен үзгәртү шикелле тупас хәрәмләшүләрнең булуы да ишетелми сыман. Мәдәни җомга

2) *күч.* Күпләп, зур күләмдә. *Билгеле ки, шундый «югары белемле» белгечләр пачкалап әзерләнгәч, эшче кадрларга – юньле тимерчеләргә, эретеп ябыштыручыларга, электрикларга кытлык, ихтыяҗ бермә-бер арта*. Казан утлары. *Җыр индустриясе дә сынатмый: бар көченә эшләп, үзешчән композиторларны, чиле-пешле җырчыларны, өр-яңа җырларны «пачкалап» чыгарып кына тора*. Татарстан яшьләре

ПА́ЧКАЛАУ *ф.* Билгеле бер санда пачкалар рәвешендә күпләп төрү. *Вакланган чимал турау станогыннан --- иләк аша үтә һәм пачкалау автоматына озатыла.* Ватаным Татарстан

ПА́ЧКА-ПАЧКА *с.* **1.** 1) Күпсанлы пачкалар итеп төрелгән; төргәк-төргәк. *Ярар иде кеше ирләре кебек пачка-пачка акча кайтарган эшең булса.* М.Кәбиров

2) *күч.* Күпсанлы. *Бер караганда укытучылар шактый күп, педагогика институтлары ел саен пачка-пачка яшь белгечләр укытып чыгара кебек.* Татарстан яшьләре

2. *рәв. мәгъ.* 1) Пачкалар рәвешендә, төргәк-төргәк итеп. *Фирдүс валюталарын санап биреп тора, хатыннар санап алалар, рубльләрне санап Фирдүскә бирәләр, ул, санап, пачка-пачка өстәлгә куя.* Татарстан яшьләре

2) *күч.* Күпләп. *Әгәр бездә дә пачка-пачка шундый китаплар чыкса, мин дә татарчасын алып укыр идем.* М.Кәбиров

ПА́ЧТЫР-ПЫЧТЫР *иярт.* Су белән төрле эшләр эшләп йөргәндә, су ерып барганда барлыкка килгән авазларны белдерә. *Мин җылы юрган астында йокы рәхәтенә җиңелеп, хатынның пачтыр-пычтыр эшләп йөргәнен тыңлап ятам.* М.Әмир

ПАША *и. фар.* 1) Госманлы империясендә, Мисырда (1952 елга кадәр) һ.б. кайбер илләрдә югары хәрби һәм гражданлык титулы. *– Бер Төркиягә ике паша башы сыймый! – диде Кәбир.* Р.Батулла

2) Шул титулга ия булган кеше. *Гидыбыз бик тәмләп кайчандыр бу корольлекнең башында хатын-кыз торганлыгы, кайсыдыр төрек пашасының аның сөяркәсе булганлыгы, пашаның диңгез баржасында төннәрен аның янына килгәнлеген сөйләде.* Я.Абдуллин. *Йосыф Акчура Төркия Бөек Мәҗлесендә депутат һәм Хокук факультетында профессор булып эшли, яңа төрек дәүләтенең корылышында Гази Мостафа Кәмал паша тарафыннан аңа зур вазифалар бирелгән иде.* С.Максуди. *Өйләдән соң паша шәрәфенә татар театрында бер драма уйнадылы*. Р.Батулла

ПАШАЛЫК *и.* 1) Паша булу, паша дәрәҗәсе. *Дәрәҗәдә үсәчәк, ул генераллык (пашалык) дәрәҗәсенә менәчәк, дип хыялланган дивизия командиры – татар полковнигы Тимергалиев – ничектер айнып китә.* Татарлар

2) Госманлы империясендә паша идарә иткән өлкә, вилаять

ПАШТЕТ *и. ит.* 1) Ботка хәленә җиткерелеп тартырылган ит, бавыр, балык һ.б. шундый азык массасы. *Ә сөт, колбаса, сосиска, паштет, пилмән ише ризыклар әзерләгәндә, модификацияләнгән соядан файдаланырга була.* Ватаным Татарстан. *«Гринпис» шулай ук фарш, колбаса, пилмән, паштет, майонез һәм хәтта бик күп төр балалар ризыгы да этикеткаларында ГМ барлыгын күрсәтмичә сатуга чыгарылуы турында кисәтә*. Татарстан яшьләре

2) Өстенә нинди дә булса җиләк-жимеш изеп ягылган камыр ашы. *Чәй янына куела торган балан, эремчек бәлешләре, баллы паштет, кортлы сумсалар, чәкчәк, бавырсак, кош теле шикелле татлы ризыклар өчен бодай онын җиз иләктән генә илиләр*. Г.Галиева. *Эченә татлы азыклар салып пешерелгән бәлешләрне халык паштет дип йөртә. Паштетны повидло, джем яисә куе варенье белән пешергәндә, эченә шикәр комы салмыйлар.* Татар халык ашлары. *Татар ашлары тиз өлгерә торган татлы камырдан әзерләгән ашамлыкларга бик бай: чәлпәк, катлама, кош теле, ләвәш, паштет һ.б. шундыйлар, аларны чәй янына бирәләр.* Өегез ямьле булсын

ПАЯ́ЛЬНИК *и. рус* Вак металл әйберләрне маяп ябыштыру өчен кулланыла торган корал. *Радиоалгычлар төзәтү ателъесында миңа бер кызны очратырга туры килде. Ул паяльник белән бик оста эш итә.* Үзең нинди – көзгең шундый. *Кечкенәдән без диодның ни икәнен белеп, үзебезчә чәнечкедән дә радио ясап, соңрак паяльник белән эш кырып йөрдек*. Шәһри Казан. *Пластина иң югары сыйфатлы корычтан коелган, елтырап тора торган итеп эшкәртелгән, бернинди паяльник та, ябыштыргыч эретмә дә кулланылмый.* Татарстан яшьләре

ПАЯЗ *и. лат. иск.* Клоун. *Әллә син дә кәмиттә паяз булмакчы буласыңмы?* Г.Камал

ПАЯЗЛАНУ *ф.* Шамакайлану, кылану

Паязлана башлау Паязланырга керешү

Паязланып тору Әле, хәзерге вакытта, күз алдында паяслану

ПӘДӘР *и. фар. иск.* 1) Ашатып, туйдырып торучы ата, әти. *Әхмәтнең пәдәреннән миңа бер хат бар иде.* Ш.Мөхәммәдев. *Пәдәре вафат булганлыктан, [Мөстәкыймовның] ярдәмгә җитешәчәк кешесе юктыр.* Г.Камал

2) Кемне дә булса уллыкка алган ир кеше

ПӘЕЧ *и. диал.* 1) Яшь бала башының лепкәсе өслегендәге саргылт кутыр; йокылык

2) Сөтне кайнатканда савыт төбенә, стеналарына утыра торган кызгылт касмак. *Сөт савытына пәеч каткан*

3) Кайнаган сөт, кесәл һ.б.ш.ларның өстендә барлыкка килә торган элпә

ПӘЕЧЛӘНҮ *ф. диал.* 1) Яшь бала башында йокылык барлыкка килү

2) Сөт, кесәл һ.б.ш.ларның өстендә элпә барлыкка килү

Пәечләнә башлау Пәечләнүгә табан бару

Пәечләнеп бетү Нык пәечләнү

ПӘЖҮ *ф.* Шиңү, сулу, йомшару. *Балтырганнардан --- зур-зур көлтәләр бәйләп, пәжемәсеннәр өчен салкын коелар эченә асып куйганнар.* З.Бәшири. *Уң як басудагы игеннәр, күптән яңгыр әсәре күрмәгән төсле, пәжегәннәр.*

М.Гафури. --- *алар балта-пычкы, көрәк-мазар алып керделәр, болдырга җил тутырган чүп-чарларны, пәжеп укмашкан карлы-бозлы яфракларны җәһәт-җәһәт чистарттылар* ---. А.Гыйләҗев

Пәжеп бетү Бөтенләй, булганның барысы да пәжү

Пәжеп яту Озак вакытлар дәвамында пәжү

Пәжи башлау Пәжү билгеләре күренү, беленү

ПӘҖЕ *и.* **1.** 1) Киндер. *Җирән бия камытының чөелдереге пәҗедән икән шул. Яңгыр сәбәпле бик бүртенгән дә, чишеп булмый.* Г.Ибраһимов

2) Киндер сүсе. *Пәҗе тәрәшләү*

2. *с. мәгъ.* Шундый сүстән, чүбектән ясалган яки тукылган. *Киеп пәҗе кара күлмәк --- йөрерсең, и Җәмиләкәй.* Г.Кандалый

ПӘҖИ *и. диал. к.* **пәҗе**. *Пәҗи килегә кермичә, мае чыкмас*. Мәкаль. *Әни төннәр буе сүс эрли, пәҗи суга, аның чүбе кала.* Сөембикә

ПӘҖҮ *и. диал. к.* **пәжү**. *Фатыйма букетны ала да арасында иң пәҗегән бер розаны алып күкрәгенә кадый*. Г.Исхакый. *Суганым, пәҗеп, ләпшегән, минем учыма сыярлык кына калган* ---. В.Халитов

ПӘЙВӘСТӘ *рәв. фар. иск*. Тоташтан, өзлексез, һаман да. *Пәйвәстә аны нәфсем эстәр.* К.Гали

ПӘЙГАМБӘР *и. фар.* 1) Кешеләргә Аллаһы Тәгаләнең әмер-боерыкларын хәбәр итүче, аларны иманга дәгъвәт итүче кеше; илче, рәсүл, нәби. *Әгәр Мөхәммәд пәйгамбәр укый-яза белгән булса, кешеләр Коръәннең аңа Ходай Тәгаләдән иңгәнлегенә ышанмаган булырлар иде.* А.Хәлим. *– Җитте! – дип кычкырды ул. – Син гомер буе газап чигүче Гайсә пәйгамбәр ролен уйнадың.* Ф.Садриев. *Мөхәммәд пәйгамбәрне дә бабасы гарәпләрдән булган, тау араларындагы үзәндә яшәүче көтүче хатыны Хәлимәгә тапшырган*. Ак калфак

2) *күч.* Эчкерсез, риясыз; башкаларга изгелек итә торган, яхшы, саф күңелле кеше. *Күңел тоемы, җан-рухы пәйгамбәрнеке булса да, Рухия шул ук кешеләр тормышы белән яши иде.* Г.Гыйльманов

3) *күч.* Бериш нәрсәләр арасыннан иң матуры, иң яхшысы, аеруча өстен сыйфатларга ия булганы. *Чыктым алан җиргә, әлван чәчәк, Бәйрәм итә монда җәй ае; Җәй аеның да пәйгамбәре: Иң мөкатдәс булган май ае.* М.Укмасый

◊ **Пәйгамбәр каш** Куе озын, калын каш. *[Гофрайның] пәйгамбәр каш дип йөртелә торган озын кашлары зур күзләр өстендә алга очлаеп, зонт төсле торалар.* Н.Исәнбәт. **Пәйгамбәрләрдән калган** Борынгыдан, бик күптәннән килгән. **Пәйгамбәр сөннәте** *иск*. Эшфигыльдә, үз-үзен тотышта Мөхәммәд пәйгамбәрдән алынган үрнәк канун ителгән гореф-гадәт. *Пәйгамбәр сөннәте, ягъни өч чынаяк [чәй] киттеме, аның өсте астына каплану тавышы ишетелә*. С.Баттал. **Пәйгамбәр яшенә җитү** 63 яшькә кадәр яшәү

ПӘЙГАМБӘ́Р АГАЧЫ *и. бот*. Паръяфраклылар семьялыгыннан биек, үзагачы авыр, каты булган мәңге яшел тропик агач; *русчасы:* **дерево гваяковое**

ПӘЙГАМБӘ́Р БАЛЫГЫ *и. зоол.* Көрән сары, ян-якларында түгәрәк кара таплар булган диңгез балыгы; *русчасы:* **солнечник**

ПӘЙГАМБӘРЛӘ́РЧӘ *рәв*. **1.** Пәйгамбәрләргә хас булганча, пәйгамбәрләр кебек. *Халык күңеленең тагын бер ягын онытмыйк: дөньялыктан пәйгамбәрләрчә яшьли янып китү – мәңгелеккә баруның тәгаен бер ышанычлы юлы.* Р.Фәйзуллин. *Никадәр әүлиялек, пәйгамбәрләрчә алдан күрүчәнлек булган бит бу шәхестә.* Т.Шәрәфетдинов. *--- төрекләрдә дә цивилизациябезне коткаручы, аның рухи җитәкчесе роленә әзерлек юк; алар да, гарәпләр кебек үк, заман таләбен пәйгамбәрләрчә аңлаудан ерак тора* ---. Мәдәни җомга

2. *с. мәгъ*. Пәйгамбәрләрдәй, пәйгамбәрләрнеке кебек. *«Синең хатларыңда – пәйгамбәрләрчә акыл», – дип, эч серләрен, кайгыларын бүлешә, шатлыклары белән дә уртаклаша ул.* Кызыл таң

ПӘЙГАМБӘРЛЕК *и*. Пәйгамбәр булу, рәсүллек. *Пәйгамбәрлек мөһерләре була, әүлиялык тамгалары була дөньяда* ---. Р.Батулла. *Шушында ул бик күп мәртәбәләр «раст төш» күрә, Мөхәммәд үзенең пәйгамбәрлегенә ышана башлый.* Гасырлар авазы. *Нәкъ шушы вакытларда Аллаһы Тәгалә Габдулла углы Мөхәммәдкә пәйгамбәрлекне иңдерде*. Ак калфак

ПӘЙГАМБӘРЛЕ́К ИТҮ *ф.* Пәйгамбәр вазифасын үтәү, кешеләрне иманга, дингә өндәү, аларга Аллаһның әмерләрен җиткерү. *Асланян фикеренчә, ул пәйгамбәрлек итмәгән, Библияне үзенә җайлы итеп күчереп язган, миссиясен уңышлы башкарырга аңа беренче хатыныннан бирелгән бай капитал ярдәмгә килгән*. Фәнни Татарстан

ПӘЙГАМБӘРЛЕ́К КЫЛУ *ф. к.* **пәйгамбәрлек итү**. *Шушы вакыттан бирле Мөхәммәд галәйһиссәлам пәйгамбәрлек кыла башлаган.* Ак калфак. *Ни кызганыч, ул өч кенә ел пәйгамбәрлек кыла алган, 12 бөртек кенә шәкерт калдырган*. Мәдәни җомга

ПӘЙГАМБӘ́Р САКАЛЫ *и. бот*. Кыяклылар семьялыгыннан далада үсә торган күпьеллык үлән үсемлек; әби чәче, кылган; *русчасы:* **ковыль-волосатик**

ПӘЙГАМБӘ́Р ТЫРНАГЫ *и. бот.* Оешмачәчәклеләр семьялыгыннан әфлисун сары төстәге чәчәкле гөл һәм дару үсемлеге; тырнак гөл; *русчасы*: **календула, ноготки**

ПӘЙГАМБӘ́Р ЧӘЧӘГЕ *и. бот*. Оешмачәчәклеләр семьялыгыннан болында үсә торган иссез ромашка; *русчасы*: **ромашка луговая**

ПӘЙДА *хәб. с. фар*. Барлыкка килү, килеп чыгу, туу

ПӘЙДА́ БУЛУ *ф.* Барлыкка килү; килеп чыгу, күренү, күз алдына килү. *Ул ара да булмады, мин бая куа башлаган карачкы кеше кыяфәтенә кереп, чишмә сукмагында пәйда булды*. А.Гыйләҗев. *Аның артыннан янә бер шамакай мәйданда пәйда булды.* М.Хәбибуллин. *Офыкта, күз күреме ераклыктагы урманнар өстендә, салават күпере пәйда булды.* Ф.Латыйфи

ПӘЙНИР *и. фар. иск.* Сөттән ясалган ашамлык төре, сыр. *Әүвәлдә укасы җиде-сигез грошка сатыла торган*

пәйнирләр (сыр) хәзерге көндә унсигезегерме грошка җитте. Г.Камал. *Пакетның эчендән хатыгыз берлә бергә өчпочмаклы пәйнир (сыр), бер пар елы оек, ярты кило кадәр ак май чыкты.* Г.Исхакый. *Табага җәеп пешерелгән ләвәш, ләвәш өстенә мул итеп помидор измәсе сыланган, суган, борыч, тоз бутап салынган, измә өстенә пәйнир (сыр) җәелгән, төрле тәмләткечләр сибелгән.* Р.Батулла

ПӘЙШӘМБЕ *и. диал. к.* **пәнҗешәмбе**

◊ **Пәйшәмбе кәҗәсе** *к.* **пәйшәмбе сыеры**. **Пәйшәмбе сыеры** Акча түләп, вакытлыча файдаланып торырга алынган әйбер

ПӘК *рәв. иск. кит.* **1.** Бик, гаять, чиктән тыш. *Волга буенда улган пароход конторалларының беренән утыз чакрым ераклыкта улган ислам авылында ялгыз бер кечкенә һәм дә пәк кечкенә бер үдә хатын-кызы илә торыр иде.* Р.Фәхретдин. *Яравой намилә мәгъруф кырларның күренеше пәк гүзәл иде ---.* М.Акъегет

2. *с. мәгъ.* Нык, үткен, көчле

ПӘКЕ *и.* 1) Йөзе сабына бөкләнеп кертелә торган пычак. *Хисами, бу мескен картның җаны калмавына тәмам ышангач, кесәсеннән теге көнне Хәйри онытып калдырган пәкене чыгарды.* Г.Минский. *Табылдыклар арасында аны аерата куандырганы ярымай сыман бөгелеп торган артыш саплы пәке иде.* Р.Мөхәммәдиев. *Мин, --- үземнең исемне дә янәшә язып куярга ниятләп, пәкемне капшап тора идем.* Г.Мөхәммәтшин

2) Кырыныр өчен үткен корыч пычак; бритва. *Вафа, хезмәтчеләр өенә кайтып, үтмәс пәке белән сакалын төзәтте, мыегын җыйнаклады ---.* М.Галәү. *Һәммәсенең дә чәчләрен пәке белән кырып алдылар аннан соң.* Р.Мөхәммәдиев. *Тик шуннан соң гына кап-кара сакал-мыегына күптән инде пәке тимәгән --- бер кеше тегеңә якынрак килде ---.* В.Нуруллин

3) *диал.* Пычак. *Пәке белән ипи кисү*

4) Кыска киң йөзле пычак; финка. *Әгәр яклаучысыз калган Зилә булмаса, Дамир теге егеткә пәке белән ташланмаган булыр иде.* Н.Вахитов. *--- кемдер Украина кунагының күкрәгенә өч мәртәбә пәке сыман нәрсә белән орган.* Ф.Бәллүр

ПӘКӘ КАДАШ *и.* Пәкене, төрлечә хәрәкәтләндереп, җиргә яки агач кәүсәсенә кадаудан гыйбарәт уен. *Нимҗан хәтта шундук, җиргә утырып, пәке кадаш та уйнап алды.* Г.Бәширов

ПӘКӘ КАДАШЛЫ *и. к.* **пәке кадаш**. *Тупыл төбендәге шәрәләнгән җирдә көн саен пәке кадашлы уйныйбыз.* Р.Рахман

ПӘКЕЛЕ *с.* **1.** Пәкесе булган. *Пәкеле корал*

2. *и. мәгъ. к.* **пәке кадаш**. *Читән буендагы чирәмдә пәкеле уйнап утырган малайлар сискәнеп киттеләр.* З.Зәйнуллин. *Баштарак бер читтә пәкеле уйнаган малайлар да бераздан безгә килеп кушыла.* Ф.Мөслимова. *Балачакта качышлы, чүрәкәйле, пәкеле, әбәкле, таудан чана шуып, кәшә сугып, туп тибеп һәм ыргытып уйный идек.* Татарстан яшьләре

ПӘКӘСЫМАН *с.* Тар, ике ягы очлаеп килгән, ике йөзле пычакка охшаган. *Пәкесыман яфрак*

ПӘЛТӘ *и. фр. сөйл.* Пальто. *Ялан баш көе, якасыз пәлтә белән йөрсеннәрме?* Н.Әхмәдиев. *Пәлтәсе җиңеннән әткәй кулын чыгара.* Ф.Яхин. *Озын кара пәлтәсенең итәкләренә җил малае ияреп бара, --- кызның кызылга кара сурәтләр төшкән шарфын килешле генә уйнатып ала ---.* Х.Ширмән

ПӘНҖАБ *и.* Һиндстанның төньяк-көнбатышында һәм Пакъстанда яшәүче халык атамасы һәм шул халыкның бер вәкиле

ПӘНҖАБИ *и.* Һинд-Европа семьялыгының яңа һинд телләре төркеменә кергән тел, пәнҗаб теле

ПӘНҖӘРӘ *и. фар. кит.* 1) Тәрәзә яки ишек рамы, рәшәткәсе

2) Челтәрле, гадәттә зур булмаган тәрәзә. *Ишек өстендәге пәнҗәрә*

3) Мылтыктан, пулемёттан ату өчен, ныгытма диварларына ясалган тишек; бойница

ПӘНҖЕКИ *и. фар. жарг.* Биш яки биш йөз сумлык акча купюрасы. *[Теге ир] бер чиләк йомырка алып килде. Әпипәгә күзен кысып: «Пәнҗеки! – диде. – Җүн, шалкан бәясе».* Г.Бәширов. *Ну шту сез, егетләр! Шушындый малны кулга төшергәч, мәгәричтән берәр «пәнҗеки» жәлләп торырга!* М.Мәһдиев

ПӘНҖЕШӘМБЕ *и. фар.* Атнаның дүртенче көне; кече атна көн. *Борһан абзый ястү намазыннан соң, һәр пәнҗешәмбедәге гадәтенчә, намазлык өстендә килеш моңлы һәм карт тавыш белән кычкырып Коръәннән бер аять укый башлады.* Ф.Әмирхан. *...Пәнҗешәмбе. Сәгать җиде тулып килә.* Р.Кәрами. *Пәнҗешәмбе көнне атна буе укылганнар кабатлана, ә җомга көнне дәресләр булмый.* Эзләнүләр, уйланулар, табышлар

ПӘП *и. сөйл.* Үбеш, үбү

ПӘПӘ *с. диал.* **1.** Телсез, сөйләшә алмый торган

2. *и. мәгъ.* 1) Шундый кеше. *Пәпә телен кем белә? Телсез ни пупаламас!* Ш.Маннур

2) Сакау кеше

ПӘ́П ИТҮ *ф. сөйл.* Үбеп алу, үбү (күбесенчә балалар телендә). *Йөз миллион тапкыр пәп итәм.* А.Гыйләҗев. *Форсаттан файдаланып, җан сөйгәнеңне шунда бер пәп итеп тә алмагач, егет исеме күтәреп, кызлар озатып йөрүеңнән ни файда?* Г.Әдһәм. *– Кая, бер пәп итеп алыйм әле үзеңне, – дип, Сөмбел, балчыклы куллары белән Әлфиснең яңакларын тотып, борын очыннан үбеп алды.* З.Кадыйрова

ПӘП-ПӘ́П ИТҮ *ф. кбт. к.* **пәп итү**. *[Кыз] Үзенең матур курчагын Кочаклап пәп-пәп итә.* Н.Гайсин

ПӘРӘВЕЗ *и. фар.* 1) Корбанын аулау өчен, үрмәкүч үзе бүлеп чыгарган ябышкак сыекчадан корган ятьмә. *Әбисе --- тиз генә бөтен почмаклардан үрмәкүч пәрәвезен җыеп алды да Фатыйманың кансырап торган ярасына салып, аягын кысып бәйләп куйды.* З.Кадыйрова. *Аннары, гөнаһлы уйлар пәрәвезендә чәбәләнмәсен дигәндәй, язмыш аның маңгаена таш томырды.* Н.Гыйматдинова. *Бите һаман әрнешә, иске ылыслар, пәрәвезләр, тагы әллә нәрсәләр ябышып катты.* Х.Ширмән

2) *күч.* Шуңа охшашлы бик юка, челтәрләнеп торган җиңел әйбер. *Аның*

итеге астында боз пәрәвезләре челтер-челтер ватыла. И.Гази

◊ **Пәрәвезгә эләккән чебендәй талпыну** Төрле юллар белән берәр авыр хәлдән котылырга тырышу. **Пәрәвез кору** Хәйлә кору. **Пәрәвез оясы** Пәрәвезләр белән капланган, тузанлы, җыештырылмаган урын

ПӘРӘВЕЗЛӘНҮ *ф.* 1) Пәрәвез белән каплану

2) *күч.* Искереп, тузып сизрәү, вак тишекләр хасил булу. *Тукыма пәрәвезләнгән*

3) *күч.* Нинди дә булса сыйфатның, үзлекнең бозылуы, начарлануы. *– Китик! – дип ыңгырашты күзләре пәрәвезләнгән Иблис. – Бозыклар болай да җитәрлек монда...* З.Мәхмүди. *Бабай да, пәрәвезләнгән начар күзләре берлән карый торгач, угылының киемнәре таланган вә йөзләре саргайган булса да, таныды да: – Син Җәгъфәрме? – диде.* Идел. *Пәрәвезләнгән миләребезне чистартыйк.* Фәнни Татарстан

Пәрәвезләнә бару Торган саен ныграк пәрәвезләнү

Пәрәвезләнә башлау Пәрәвезләнү билгеләре күренү

Пәрәвезләнеп бетү Бөтенләй, тәмам пәрәвезләнү

Пәрәвезләнеп килү Соңгы арада әкренләп пәрәвезләнү. *[Чалбарның] тез башлары да пәрәвезләнеп килә.* Г.Гобәй

ПӘРӘВЕЗЛӘ́Ү *ф.* Берәр нәрсәне пәрәвезсыман челтәрләндерү яки чәрдәкләү. *Төнге март салкыны нечкә бозларны пәрәвезләгән.* С.Баттал

Пәрәвезләп бетерү Тулысынча, бөтенләй пәрәвезләү

Пәрәвезләп кую Тиз генә пәрәвезләнгән хәлгә китерү

Пәрәвезләп ташлау Тиз арада пәрәвезләү

Пәрәвезли бару Әкренләп, эзлекле рәвештә булган берсен рәттән пәрәвезләү

Пәрәвезли башлау Пәрәвезләргә тотыну

ПӘРӘМӘЧ *и.* **1.** 1) Әче камырдан әзерләнгән җәймәгә тарттырылган ит, суган салып, авызын бераз ачык калдырып, түгәрәкләп бөреп, майда йөздереп пешерелә торган татар милли ризыгы. *Кухнядан тәмле булып пәрәмәч исе агыла иде ---.* А.Гыйләҗев. *Әмма урам пәрәмәчләре, өчпочмакларында ит түгел, ә сеңер, ит җепселләре генә була.* Р.Батулла. *Кыз, боларга гына риза булмагандай, сумкасыннан әнисе пешереп җибәргән пәрәмәчләрне чыгарып өстәлгә куйды.* Р.Габделхакова

2) Өстенә изгән бәрәңге, эремчек сылап пешерелгән түгәрәк камыр ашы; шәңгә. *--- авырсына күрмәгез инде, оланнар, менә монда Исмәгыйлемә дип эремчек пәрәмәче төйнәгән идем.* М.Кәрим. *Ул да, яңгыр булганлыктан, бүген эшкә чыкмаган, мунча яккан һәм бәрәңге пәрәмәче пешереп йөри иде.* М.Мәһдиев. *Берәрсенә «ашыгыч ярдәм» күрсәтеп кайткан иде булса кирәк: --- йөзе бөтен шарты килеп пешкән бәрәңге пәрәмәченеке шикелле кызарып киткән --- иде.* В.Нуруллин

3) *күч.* Козырёксыз, түп-түгәрәк баш кием. *[Солдатларның] башларына козырёксыз кокардалы пәрәмәчләр кигезделәр.* М.Гали

2. *ы. мәгъ.* Кинәттән булган яки көтелмәгән эш-хәлгә гаҗәпләнгәндә әйтелә. *Мине күргәч, абзыкай гаҗәпләнүеннән кычкырып әйтә куйды: «Пәрәмәч, син кайдан?»* Ә.Еники. *Менә сиңа пәрәмәч! --- Классташ дусларыңнан яшерерлек нинди куркыныч серләрең бар икән синең?!* А.Гыйләҗев. *Һәй! Пәрәмәч! Соң мин бит, әбекәем, кызганганнан гына әйтәм.* Г.Мөхәммәтшин

◊ **Пәрәмәч күзе** *сөйл.* Әрсез, үзенә генә каратып торырга, игътибар үзәгендә булырга ярата торган кеше турында. *Ай, сүз кыстырырлык хут юк, пәрәмәч күзе, бер кешегә авыз ачарга ирек бирми!*

ПӘРӘМӘЧӘ *и. диал. к.* **пәрәмәч** (*1 мәгъ.*). *Яңгыр, яу-яу, иләктән, чиләктән, пәрәмәчә, коймактан.* Такмак. *Итле күзле пәрәмәчәләре генә ни тора.* В.Ильясов

ПӘРӘМӘЧЛЕК *с.* **1.** 1) Пәрәмәчкә җитәрлек. *– Икесен берьюлы балта белән юнсаң, бер пәрәмәчлек ит чыкмас! – дигән.* Р.Батулла. *Ике таба пәрәмәчлек камыр кую*

2) Пәрәмәч өчен махсус әзерләнгән. *Бибиҗамал апа --- пәрәмәчлек камыр куйды.* Ш.Хөсәенов. *Пәрәмәчлек итне иттарткычтан чыгару*

2. *и. мәгъ.* Пәрәмәч пешерү өчен билгеләнгән камыр яки ит. *Пәрәмәчлек әзерләү*

ПӘРӘМӘЧЧЕ *и.* Пәрәмәч пешереп сату белән шөгыльләнүче кеше. *Пәрәмәччеләр, Габделкадыйр Сәгъдиев, Мөхәммәтҗан Галиев вывескалары кеби, медальле вә пәрәмәч сурәте төшерелгән зур вывескалар ясатачаклар, имеш.* Г.Тукай

ПӘРӘМИ *и. диал.* Хатын-кызлар арасында уен катыш бер-берсенә мөрәҗәгать итү сүзе. *– Туктале, ул тикле куырма әле син безне, – дип, янә, Маһисәрвәр апа сикереп торды. – Уйларга ирек бир әле әзрәк, пәрәми!* В.Нуруллин. *Ит түгел, тозлап куймассың аны, пәрәми.* М.Гали

ПӘРӘНҖӘ *и. фар.* 1) Үзәк Азия һәм Якын Көнчыгышның кайбер илләрендә хатын-кызларның, йөз каплау өчен, ат кылыннан куе итеп ясалган челтәр пәрдә белән тоташтан тегелгән озын, киң халат рәвешендәге ялган җиңле өс киеме. *Тукай һични әйтмәстән тик утыра калды, ләкин аның уй-фикерләре сабырсыз иде, ул пәрәнҗәнең йөз тирәсенә, күз турысына багып алды, челтәр пәрдә артындагы күзләр дә аны җентекләп күзәтә иде ---.* Р.Батулла. *Хәзер гаделлек нәрсә ул? Пәрәнҗә ябынган фахишә кебегрәк бер әйбер...* Ф.Садриев. *Аягында арзанлы кәвеш, пәрәнҗә астыннан чыккан күлмәк итәге, ыштан балагы да затлыдан түгел.* Т.Әйди

2) *күч.* Берәр нәрсәне, берәр эшне серлелек өстәп яшерә торган билгеле бер кыяфәт, уйдырма, сүз, сәбәп һ.б. *Үзеннең булдыксызлыгыма һәм шуның аркасында бәхетсезлегемә акылым ризалык тотмаса да, мескенлек һәм чарасызлык пәрәнҗәсе йөземә капланган, язмышым дәфтәренә язылган караңгы сүзләрне юкка чыгарыр көчем дә калмаган.* Ф.Яхин. *Үз теләгебез белән кяфер куйнына әзер без... Чит кавем үрчетүче «халык кызлары» хәзер без. Җариядәй күндәмлек пәрәнҗәсе ябынабыз, Һуш китеп, телдән язып «ушкуйник»ка табынабыз.* С.Әхмәтҗанова. *Әтием*

яткан карават башында урнашкан аппарат кына тынлык пәрәнҗәсен ертып пипелдәп куя. Идел

3) *күч.* Әйләнә-тирәне каплый, күрсәтми торган нәрсә. *Төннең кара пәрәнҗәсе күк йөзен каплагач, мин хыял дөньясына чумам.* Ф.Яруллин

ПӘРӘНҖӘЛЕ *с.* Пәрәнҗәсе булган, пәрәнҗә кигән. – *Әйтеп китсәң, кулы бушагач, үзе үк артыңнан куа кайтыр әле, – дип тынычландырды аны пәрәҗәле хатын.* Т.Әйди. *Һәм ул, сүзгә мавыгып, мин искәрмәгән, әмма ләкин үзе әледән-әле күз уңында тоткан утыз-утыз биш яшьләрдәге пәрәнҗәле хатын-кызга гарәпчә берничә сүз әйтте дә кабат миңа таба борылды.* Сөембикә

ПӘРӘНҖӘСЕЗ *рәв.* **1.** 1) Пәрәнҗәдән башка, пәрәнҗә кимичә. *Чит ир чырае күрмәгән бу гүзәлләргә атлас-ефәк кенә түгел, чибәр ир-җегет Кәбир Бәкерне күрү дә зур шатлык, яңалык; ышанычлы сәүдәгәр янына кызлар, хатыннар пәрәнҗәсез дә чыгалар, мал үлчәтәләр.* Р.Батулла

2) *күч.* Ачыктан-ачык; яшермичә. *Бу китапта без сугышның чынбарлыгын, коточкыч фәлсәфәсен, әче хакыйкатьне, сугыш мохитендәге зур язмышларның фаҗигасен пәрәнҗәсез күрәбез.* Р.Батулла

2. *с. мәгъ.* Пәрәнҗәсе булмаган, пәрәнҗә кимәгән. *Пәрәнҗәсез хатын-кыз*

ПӘРӘ́-ПӘРӘ *рәв. диал. к.* **пәрмә-пәр**. *Тавык фермасыннан Тәзкирә, миңа [яңасын] калдырмагансың дип, пәрә-пәрә килеп талаша.* А.Расих

ПӘРӘ́У *и.* Татарстан Республикасының Лаеш районындагы торак пункт. *Кандалый Пәрәү кызы Сәхипҗамалга сөю хатлары яудыра башлый.* Р.Батулла. *Лаеш районының Пәрәү авылында яңа мәдәният йорты ачылды.* Татарстан яшьләре

◊ **Пәрәү хәерчесе** *тирг.* Әледән-әле йомышка кереп, һаман нәрсә дә булса сорап йөдәтә торган кеше

ПӘРВАЗ *и. фар. кит.* 1) Очыш. *Фикер пәрвазы*

2) *күч.* Рухи күтәренкелек, илһам

ПӘРВА́З ИТҮ *ф.* Күтәрелеп китү, рухланып китү, дәртләнеп китү

ПӘРВА́З КЫЛУ *ф. к.* **пәрваз итү**

ПӘРВАЙ *и. фар.* 1) Кайгырту, тәрбия; игътибар, илтифат

2) Тәрбия, тәрбиялелек

3) Сак булу, саклык, абайлылык

ПӘРВА́Й КЫЛУ *ф. иск.* Тәрбияләү; багу, асрау

ПӘРВАЙСЫЗ *с.* **1.** 1) Игътибарсыз, ваемсыз, гамьсез, кеше һәм үзе турында кайгыртмаучан. *Чыгып киткәндә, күңел өчен генә булса да, бер җылы сүз әйтмәде бит пәрвайсыз бала.* Ш.Хөсәенов. *Ә минем аркама ук терәп әйтә: – Мин аңа бәйнә-бәйнә аңлатып торам, ә ул, пәрвайсыз җан!.. Әйттем ич мин сиңа тегәм дип!* В.Астафьев

2) Саксыз; җыйнаксыз

3) Әрсез, оятсыз, әдәпсез, тәрбиясез

4) *иск.* Караучысыз, күзәтүчесез

2. *рәв. мәгъ.* 1) Гамьсез, ваемсыз рәвештә. *Әбүгалисина берничә көн пәрвайсыз йөрде.* К.Насыйри. *Егетләрнең күбесе пәрвайсыз кыйшаеп, я утырып, сүзсез ял итәләр.* А.Расих

2) Оятсыз рәвештә. *Тотып ярды үги атам һич пәрвайсыз.* Акмулла

ПӘРВАЙСЫЗЛАНУ *ф.* 1) Игътибарсызлану, гамьсезләнү, кеше һәм үзе турында кайгыртмау. *Соңгы араларда Фатыйма гомумән пәрвайсызланды*

2) Әрсезләнү, әдәпсезләнү, әдәпсез кылану; оялмау, оятны белмәү

Пәрвайсызлана бару Торган саен ныграк пәрвайсызлану

Пәрвайсызлана башлау Пәрвайсызлануга таба бару

Пәрвайсызлана төшү Бераз, беркадәр пәрвайсызлану

Пәрвайсызланып бетү Тәмам, бөтенләй пәрвайсызлану

Пәрвайсызланып китү Кинәт кенә пәрвайсызлану

Пәрвайсызланып кую Кинәт кенә пәрвайсызлык күрсәтү

ПӘРВАЙСЫЗЛЫК *и.* 1) Игътибарсызлык, илтифатсызлык

2) Тәрбиясезлек, әдәпсезлек

3) *иск.* Караучысы, күзәтүчесе булмау

ПӘРВАНӘ *и. фар. иск.* 1) Ут әйләнәсендә очып йөри торган күбәләк; ут күбәләге. *Синең гыйшкың мине пәрванә кылды.* Г.Сәмитова

2) *күч.* Өметсез гашыйк күңеле

-ПӘРВӘР *фар.* Кушма сүзләрдә «нинди дә булса гамәлне яки юнәлешне өстен күреп, аны яклаучы, тарафдар» мәгънәсен белдерә торган икенче кисәк (мәс., *ватанпәрвәр, тәрәккыйпәрвәр* һ.б.ш.). *Фәүзия Бәйрәмова белән Фәндәс Сафиуллин кебек милләтпәрвәрләребезнең тырышлыгы республика суверенитетын яулауда зур роль уйнады.* Р.Юнысов. *Һәр килүемдә күңелләр ташып, Азнакай сәнгатьпәрвәрләр шәһәре икән, дип сөенеп кайтам.* Шәһри Казан

ПӘРДӘ *и. фар.* 1) Берәр нәрсәне каплап яки аерып торган тукыма кисәге. *Ә Рәшидәнең шар ачык күзләре тәрәзәдәге тасмалы пәрдә – жалюзи аркылы чак кына саркыган аксыл яктылыкка төбәлгән иде.* М.Маликова. *Кызыл бәрхет пәрдә белән томаланган тәрәзәләрдән төшеп торган тонык кына яктылыкта өй эче аеруча серле тоела иде.* Р.Мөхәммәдиев

2) Сәхнәне тамашачылар залыннан аера торган зур чаршау. *Әминә, бераз кызарыныбрак, уен башланганны көтә; Рокыя сәхнә пәрдәсендә бер русалка (су фәрештәсе) сурәте табып алган да, күзләрен бер дә алмыйча, шуңар карап утыра ---.* Ф.Әмирхан. *--- ул анда аксыл стена түгел, ә театр сәхнәсендәге кызыл бәрхет пәрдә күргәндәй булды ---.* Р.Кәрами. *...Менә спектакль бетте. Соңгы кат пәрдә төште.* Г.Мөхәммәтшин

3) *театр* Драма әсәренең яки спектакльнең тәмамланган бер бүлеге; акт. *Пәрдә арасында пирожный берлә эчелгән чәй дә тамак ялгарлык булмаганга, чыгу берлә тиз-тиз ашханә эзләргә тотындылар вә беренче очраган польский столовойга кереп ашарга тотындылар.* Г.Исхакый. *Озаклама-ды, икенче пәрдәнең звоногы да бирелде...* Ф.Әмирхан. *Беренче пәрдәдән соң Фоат аны сыра эчәргә димләп караган иде ---.* Г.Мөхәммәтшин

4) Хатын-кызның йөзен каплау өчен үтә күренмәле юка челтәр, тукыма кисәге; өленге, вуаль, никаб. *Йөзеңнән пәрдәңне ал, җир йөзе яктырып китсен ---.* Г.Тукай. *Унбер яшебездән йөзебезгә пәрдә ябып, үз гаиләбездә*

генә булса да өстәл янында ашаудан тыеп, песи җамаягы белән чаршау эченә кудыгыз. Т.Гыйззәт. *[Кыз] битендәге пәрдәсен ачты, эшләпәсен төзәтте.* Г.Ибраһимов

5) *анат.* Тере организмда бер әгъзаны яки куышлыкны икенчесеннән аерып, каплап торган юка, сыгылмалы элпә, яры. *Әгәр бер хатын тәрәзәдән бер ирне күрсә, аңар кальбеннән кызыкса, күз чите белән бер карап алса, аның белән күрешүне уйласа, хакыйкатьтә – зина бу, аның белән бу хатынның гыйффәт пәрдәсе ертылды.* Г.Бубый. *Куркынган официанткалар, ыгы-зыгы килеп, колак пәрдәләрен ертырлык итеп, ачы тавыш белән: «Милиция-ә!» – дип кычкыра башладылар.* З.Мәхмүди. *Корт чактымыни: Морат колак пәрдәләрен ярырлык итеп чырылдап җибәрде.* Р.Батулла

6) *муз.* Кыллы музыка уен коралларының грифындагы аркылы тар кабарынкы сызыкларның һәрберсе; лад. *Металл пәрдәләр. Саз пәрдәләре*

7) *күч.* Берәр нәрсәне каплап, томалап торган нәрсә. *Төннең кара пәрдәсе җиһанның һәммә ваклыкларын – баракны, комлыкны, куакларны --- яшергән.* М.Маликова. *--- бу сүз Әхмәдинең башында чуалып, куерып, авыраеп йөргән томан пәрдәләрен бер минут, бер секунд эчендә таратып җибәрде, юк итте.* Г.Иделле. *Тәрәзә артында, кара төн пәрдәсенең сары ямаулары булып, анда-санда утлы тәрәзәләр чагылып узды.* Р.Вәлиев // Тирә-якны тоныкк күрсәтә торган нәрсә. *Ирексездән күзләре дымлана, һәм шул юеш пәрдә аша Самат әнисен күрә.* Р.Кәрами. *Күз кабаклары авырайды, керфекләр, үзләрен чолгап алган йокы пәрдәсен күтәрә алмый, әкрен генә аска шуыштылар.* Әдипләр. *Яшь пәрдәсе белән өртелгән күзләрен күтәреп хатынына карап торды.* Инешләр Иделгә кушыла

8) *күч.* Берәр эш-гамәл, хис-тойгы өчен киртә, тоткарлык булган нәрсә. *Кайбер кыюсыз, тартынучан кешеләрдә дә җитдилек пәрдәсенә яшеренү гадәте була.* Ш.Камал. *Кешеләр белән аралашканда, ясалма бер элпә барлыкка килә – ихласлык үтми торган пәрдә.* Ш.Галиев. *Миңа алар [күзләр] еллар пәрдәсе аша карап торалар.* Инешләр Иделгә кушыла

9) *күч.* Берәр нәрсәнең асылын чагылдырырга, аңларга комачаулый торган өртү. *Сез монда хәзергә чаклы сөйләүчеләрнең сүзләреннән аларның сезгә бүгеннән хәл кылынырга кирәк булган мәсьәләләрне алга сузып, кичектерү пәрдәсе астында калдырырга теләүләрен күрдегез.* М.Гафури

10) *күч.* Билгеле бер хисне, тойгыны белдерә торган кыяфәт. *Аның тышкы кайгы пәрдәсе астында йөзендә һәм күзендә зәһәрле шатлык күренә иде ---.* Г.Ибраһимов. *Йөзенә сары сагыш пәрдәсе эленгән, күз читләренә җыерчык кунган яңа Зөһрәсенә һаман күнегә алмый әле.* Г.Гыйльманов

◊ **Пәрдә белән туган** Бәхете ташып торган

ПӘРДӘЛӘНҮ *ф.* 1) *иск.* Пәрдә (*4 мәгъ.*) кию, пәрдә (*4 мәгъ.*) белән томалану. *Пәрдәләнгән хатынны таныргa мөмкин булмаганлыктан вә, шуңар күрә ул шул пәрдә астында бер дә курыкмаенча күңеленә килгән һәрбер аздыргыч хәрәкәтне кыла бирдекеннән, бу чадра – ирләрне фетнәгә төшерү сәбәпләреннән иң зурысыдыр.* Г.Бубый

2) Пәрдә (*6 мәгъ.*) белән өртелү, каплану, тоныклану, томанлану. *Әллә аның күзләре, шатлык яшьләре белән пәрдәләнеп, ялгыш күрәләрме?* А.Шамов

3) *күч.* Нинди дә булса ялгыш, ялган, кирәкмәгән нәрсә белән томалану. *Дингә пәрдәләнгән миллионерлар – фабрикантлар, байлар, хуҗалар – сарайларына һәм соборларга карап, иңрәшеп еларлар.* М.Гафури. *Сәфәргә чыккан вакытларында юл аркылы бер нәрсә үтеп китү яки карга һәм саескан кебек кош тавышы ишетелү, тән тарту һәм төш күрүдән шомланучылар һәм шикләнеп йөрүчеләр – шундый акыллары пәрдәләнгән кешеләр.* Р.Фәхретдин

4) *күч.* Нинди дә булса хис, тойгы белән биләнү. *Әни, аны юату, аның кайгы белән пәрдәләнгән күңелен ачу өчен, төрле сүзләр сөйли.* М.Гафури

Пәрдәләнә бару Торган саен ныграк пәрдәләнү

Пәрдәләнә башлау Томалану, пәрдәләнү билгеләре беленү. *Ләкин тагын бер афәт өстәлергә тора: аның күзләре пәрдәләнә башлаган.* Казан утлары

Пәрдәләнеп бетү Тулысынча пәрдәләнгән хәлгә килү

Пәрдәләнеп тору Билгеле бер вакыт дәвамында пәрдәләнгән булу

ПӘРДӘЛӘҮ *ф.* 1) Пәрдә, чаршау ишеләр белән бүлеп алу

2) Элпә, болыт, газ һ.б.ш.лар белән каплау. *Гөлсем апа яшь пәрдәләгән күзләре белән бала атасына мескен карады.* Г.Гобәй. *Пәрдәли кем яктылыктан үз йөзен?* Н.Исәнбәт

3) *күч.* Яшерү, сер итү, сиздертмәү, белгертмәү. *Чын дөресе шул иде: тыйнаклык күрсәтеп моңарчы бик әйтмәсәк тә, бизәлеш ярдәмендә котсыз эчтәлекне «пәрдәләп» булмасмы дип тырыша идек күбрәк.* З.Мифтахов. *Халыкның явызлыгы боларның явызлыкларын пәрдәли алмый.* Р.Фәхретдин

Пәрдәләп алу Пәрдәләнгән хәлгә китерү

Пәрдәләп бетерү Барысын да пәрдәләү. *Аның тыйнак чибәрлеген зыялы ханымнарга хас җитдилек тә пәрдәләп бетерә алмый иде.* А.Тимергалин

Пәрдәләп карау Ярау-ярамавын, килешү-килешмәвен тикшерү өчен пәрдәләү

Пәрдәләп кую *к.* **пәрдәләп алу**

Пәрдәли бару Эзлекле рәвештә пәрдәләү

Пәрдәли башлау Пәрдәләргә тотыну

ПӘРДӘЛЕ *с.* 1) Пәрдәсе булган. *Русларда да унсигезенче гасырның башларына кадәр аксөяк хатыннары пәрдәле, дүрт дивар арасында мәхбүс, хәтта кояш яктысыннан да качарлар иде.* Г.Бубый. *Тагын батыраеп килгән булды, челтәр пәрдәле тәрәзәләргә карап узды, туктап, төнге тамчылар тавышына колак салып торды, аннары --- башын түбән иеп кире кайтып китте.* Ә.Еники

2) *к.* **пәрдәлек** (*2 мәгъ.*). *Драматургның иҗат мирасында бер пәрдәле пьесалар, скетчлар, юмор-сатира әсәрләре, хикәяләр, фельетоннар да бар.* Казан утлары

3) *күч.* Төп асылы аңлы рәвештә яшерелгән, ачык булмаган. *Аңа пәрдәле җавап кайтардылар*. Г.Ибраһимов

ПӘРДӘЛЕК *с.* 1) Пәрдә (*1, 2, 4 мәгъ.*) өчен яраклы, пәрдәгә диелгән. *Тракторчының яшь хатыны --- тәрәзә пәрдәлек тюль таба алмый йөри икән*. Р.Төхфәтуллин

2) Ничә дә булса пәрдәдән (*3 мәгъ.*), акттан торган. *Миңа Нәмыйк Камалның «Зәваллы чуҗык» дигән өч пәрдәлек драмасы аерата ошады.* Г.Камал. *«Паралич» – ике пәрдәлек трагедия, катнашалар: паралич суккан ана, аның улы.* Р.Батулла. *Аның иң беренче ижат җимеше – «Упкын өстендә уен» – ике пәрдәлек трагифарс жанрында язылган әсәре --- Татарстан, Башкортстан, Оренбург, Мари Иле драма театрларында сәхнәгә куелды*. Ватаным Татарстан

ПӘРДӘСЕЗ *с.* 1) Пәрдәсе булмаган, пәрдә корылмаган. *Чыннан да, күз тиз ияләште, пәрдәсез тәрәзәләрдән урам фонарьларының яктысы саркый, аннан да бигрәк тулган ай идәнгә киң итеп нур тасмасы сузып салган иде.* М.Маликова. *Йөзләре, борыннары каплаулы, бары тик күзләр, керфекләр генә пәрдәсез иде.* Р.Батулла. *Тәрәзәләр пәрдәсез иде, яулыклары тузгач, авыл хатыннары тәрәзә пәрдәләрен алып башларына бәйләде*... Р.Хәбибуллина

2) *күч.* Төп асылы яшерелмәгән, ачык булган. *Ахыр чиктә кеше томанпәрдәсез, артык челтәрсез һәм чукчачаксыз гына ялан уй-фикерләр белән эш итәргә өйрәнә.* Ә.Мушинский

ПӘРДӘЧЕ *и.* Сәхнәдә пәрдәне күтәреп-төшереп яки ачып-ябып торучы хезмәткәр. *Ул арада пәрдәче килеп чыкты. Тиз генә пәрдәне төшерделәр*. А.Расих

ПӘРИ *и. фар. миф.* 1) Кешене аздыра, ялгыш юлга этәрә торган табигатьтән өстен явыз зат, кара көч, җен. *Бу кызны бала чагында пәриләр урлап киткән булган икән, ди.* Әкият. *Бер җитез гыйфрит җибәрдем мин сиңа, Атланып кил шул пәринең өстенә!* Ш.Бабич. *Әхмәтша мунча пәриедәй кап-кара, сакал-мыек басмыйча кырынмый, көчләп салдырып алмасаң, өстен алыштырмый.* Ф.Яруллин

2) Җеннәрнең матур, гүзәл төрләреннән бер вәкиле. *Пәри кызы! Ник чыктың да юлларыма, Утлы кызыл гөлләр тотып кулларыңа, Гөлләреңне ыргытып бер елмайдың?* Һ.Такташ. *Ул кызның сарае тирәсендә кырык хезмәтче бар иде, барчасы зифа йөзле пәриләр иде*. Г.Гыйльманов. *Сихерле үбүдән туган һәм шул ук үбүләр белән туенып үскән пәри кызлары бар, дип сөйлиләр. --- дөньяда ул кызларның чын өлгесен күреп торам. Фәридә, син шуларның берсе буласың.* Р.-Н.Гүнтәкин

3) *гади с.* Җиңелчә әрләү яки тиргәү сүзе. *Әй син, кара пәри, якын киләсе булма*! А.Тимергалин. – *Озак торма, улым, тизрәк кайт, дигән булып, син аңа ни әйтергә уйладың, пәри карчыгы?! – дип кычкырды килен.* Р.Батулла. *Ике-өч метр киттеме икән, машинасы туктап калды. «Әнә теге пәринең каргышы төште, ахры», – дип, мине суккәне ишетелде*. Р.Хәбибуллина

4) *күч. гади с.* Ниндидер тискәре, күңелгә ятышсыз күренешне чагылдыру өчен кулланыла торган образ. *Кайдагыдыр бушлыкта чыннан да ниндидер концерт бирелә, ниндидер пәри музыкасы уйнап тора кебек иде.* Ш.Маннур. *Тәне яна, йөрәге кага, ләкин аңа ничек булса да үзен якларга, бер абайламастан килеп юлыккан пәри өермәсеннән котылырга кирәк иде.* Д.Булатова. *Шул мәлдә палубада Фикус пәйда булып, пәри җитезлеге белән, Җәмилгә төбәп, шампан шешәсе томырды*. Ватаным Татарстан

◊ **Пәри авыз** *тирг.* Зур авызлы яки күп сөйләүче мәгънәсез кешене тиргәгәндә әйтелә. *Тукта, тукта, диләр ич сиңа, пәри авыз!.. Балалар ишетер!..* А.Шамов. **Пәри алмаштырган** 1) Бик көйсез, елак бала турында (тугач, баланы кырык көнгә кадәр ялгыз калдырырга ярамый, пәри-җеннәр үз баласы белән алмаштыра, имеш, дигән ышанудан калган тәгъбир); 2) Үтә ямьсез, коточкыч кыяфәтле яки начар кеше турында. **Пәри алмаштырмасы** *тирг. к.* **пәри алмаштырган**. **Пәри арбасы** Тотрыксыз, җилкуар, принципсыз кеше турында. **Пәри баласы** Берәр балага яратып яки, киресенчә, ачуланып, әрләп әйтелә. *Өйгә кайтып керүемә, кунак апаның сүзләре исемә төште: «Бигрәк шөкәтсез, пәри баласы кебек!» Нигә алай мыскыллавын әнкәйдән сорамакчы идем, онытып җибәргәнмен*. Ф.Яхин. **Пәри башка, җен башка** Икесе ике төрле, бөтенләй башка (әйбер, эш). *Пәри башка, җен башка дигәндәй, түрәләр урлавы белән безнең урлау – икесе ике нәрсә*. Ф.Дәүләтбаев. *Пәри башка, җен башка. Степанның ни катнашы бар?* Р.Габделхакова. *Әмма пәри башка, җен башка дигәндәй, беренчедән, алга киткән илләрдә бурычка алган акчаны арттырып түләү проценты бездәге кебек зур түгел; икенчедән, аларның хезмәт хакын да безнеке белән чагыштырып булмый*. Татарстан яшьләре. **Пәригә үлчим** Кемнең яки нәрсәнең дә булса түбән дәрәҗәдә икәнлегенә ишарәләп әйтелә. *Боларның ташчылыгын пәригә үлчим менә...* С.Зыялы. *Табибларның хезмәт хакы да пәригә үлчим генә шул*. Кәеф ничек? **Пәригә яулык – миңа саулык** 1) Бер ят җирдә утырып ял иткәч я суын эчкәч, яки суга кергәч, киемнән берәр җепне шул урынга ташлап киткәндә, шулай әйтелә торган мәҗүси йола сүзләре; 2) Берәр начар кешенең явызлык кылуыннан саклану өчен, аңа бүләк яки күчтәнәч биргәндә әйтелә. **Пәрие белән бер күрә** Кемне дә булса яратмау, сөймәүне белдерә. **Пәрие кагылу** *шелт*. Берәр нәрсә белән артык мавыгу, нәрсәгә дә булса артык ихласлык күрсәтү. *[Ул] бернәрсә сөйләшми, һаман сәгать, һаман сәгать, әллә инде үзенә сәгать пәрие кагылган*. Г.Газиз. **Пәрие килү** 1) Берәр нәрсә белән шөгыльләнү омтылышы көчәю; нәрсә белән дә булса кирәгеннән артык мавыгу; 2) Берәр нәрсәгә ачуланып, кызып, дулап китү. *Аның тупаслык күрсәткәннән соң да болай әдәп саклап маташуы мине өшетеп җибәрде. Пәрием килеп, төксе генә әйтеп куйдым ---*. Р.-Н.Гүнтәкин. **Пәрие киреләү** Кәефе кырылу. **Пәрие котыру** *к.* **пәрие килү** (*2 мәгъ.*). *Хайсның тагын пәрие котырды. --- Ул яңадан үзенең элекке экзекуцияләренә тотынды.* Ш.Маннур. **Пәрие кузгалу** *к.* **пәрие килү** (*2 мәгъ.*).

Карт сүзен бүлдергәнне бер дә өнәми иде, шуңадыр, Ятманов юлына аркылы төшкәч, пәрие кузгалды. Б.Камалов. **Пәрие кушмау** Киреләнү, үзсүзләнү. **Пәрие сөймәү** Яратмау, сөймәү, күралмау. *Мәзинне пәрием бер дә сөйми.* Әкият. *Вәлит монда килгәннән бирле, ул шулай түзми башлады. Беләсез, әллә нишләп Вәлитне аның пәрие сөйми.* Г.Рәхим. **Пәрие чыккан** *к.* **пәрие котырган**. **Пәри кебек** 1) Тупас, килбәтсез гәүдәле кеше турында; 2) Бик таза, көчле булу турында. **Пәри кияүләгән нәрсә** *мыск., шаярт.* Бик иртә ятып йоклый торган ялкау кыз. *Сәгать бештә кибетен бикләүгә, чабып өенә кайта торган ул пәри кияүләгән нәрсәгә ни булды икән?* Н.Көбәш. **Пәри кияүләү** *миф.* Төннәрен берүзе генә калырга яратучы хатын-кызлар турында (андыйларга ир-ат сурәтле пәри ияләшә, имеш, дигән ышанудан). *Ирләре сугышта үлеп калган бик күп хатыннар, пәри кияүләгәндәй, ялгыз картайды* ---. Ю.Әминев. **Пәри күзе** 1) Сукыр лампа. *Консерв банкасыннан ясалган пәри күзе яктылыктан бигрәк сөрем чыгара.* Г.Әпсәләмов; 2) Караңгыда күңелне шомландырып ялтырап торган кечкенә ут шәүләсе. **Пәри (итеп) күрү** Яратмау, күралмау. **Пәригә авырлык – миңа җиңеллек** Урманда, кырда һ.б.ш. җирләрдә утырып торган урыннан торып киткәндә әйтелә. **Пәриләре туры килми, килешми** Бер-берсен яратышмый торган ике кеше турында. **Пәри оясы** Тузыган, таркалган йорт-җир турында. **Пәри табагачы** *тирг.* 1) Шыксыз, килбәтсез озын буйлы кеше турында; 2) Карага буялып пычранып беткән кеше турында. *Ул да миңа текәлеп карап торды да: «Бу чегән кызын каян таптыгыз, пәри табагачы шикелле кап-кара үзе!»* М.Нурулла. **Пәри түе** 1) Җил бөтерелүдән барлыкка килгән тузан-туфрак баганасы; тузан өермәсе. *Орчыктай бөтерелеп купкан пәри түйлары тузанны өере белән әле тегендә, әле монда күчерә башлады.* Н.Хәсәнов. *--- урамда арлы-бирле сугылып йөргән кар бөртекләре, ургылып, Галимнең ишегалдына үтеп керде дә, туфрак тузанын «биетә» торган пәри түе сыман зыр-зыр әйләнгәләргә тотындылар ---.* Р.Гатауллин; 2) Шау-шулы, тәртипсез җыелыш, мәҗлес һ.б.ш. турында. *Шулчак кемдер ачы итеп сызгырып җибәрде, вагонда пәри түе купкан сыман кычкырыша-шаулаша башладылар.* Р.Вәлиев. *Хәзер йөз грамм эчсәләр, пәри түе башланачак.* Р.Сәгъди. *Очсызкырыйсыз, өзлексез дәвам иткән юморсатира кичәләре һәм пәри түен хәтерләткән шоу-концертлар шундый фикерне ныгыта.* Татарстан яшьләре. **Пәри үпкән** Иреннәре чабырып чыккан кешегә карата әйтелә. **Пәри чабаклаган** Бик ямьсез, шыксыз йөзле кеше турында әйтелә. *Егетләр, төкерегез үзләренә – шул пәри чабаклаган чалыш аяклы кызларга!* А.Шамов. *Агыйделдә берәр пәри чабаклаган кыз су керсә, шулай ялтырый ул [кояш].* Г.Гобәй. *Әй, пәри чабаклаган Зарипа, төгән ит!* Р.Батулла

ПӘРИ́ АКБАШЫ *и. диал. бот.* Оешмачәчәклеләр семьялыгыннан акбашка охшаган аксыл чәчәкле, хуш исле күпьеллык үлән үсемлек; меңьяфрак, ярмабаш; *русчасы*: **тысячелистник**

ПӘРИ́ АРБАСЫ *и. бот.* Алабутачалар семьялыгыннан шарсыман формадагы, орлыгы өлгергәндә тамырыннан аерылып, җил белән күчеп йөри торган үлән үсемлек; дүңгәләк, өермә үләне, әйләнчек, йомарлак, гөнҗәлә, пәри уты; *русчасы:* **перекати-поле**. *Көзләр җитәр, җил чыгар, пәри арбасы юл чыгар.* Мәкаль.

ПӘРИ́ БОРЧАГЫ *и. бот.* Кузаклылар семьялыгыннан бөтерелмә сабаклы, куш чәчәкле күпьеллык үлән үсемлек, тычкан борчагы; *русчасы*: **горох мышиный**

ПӘРИ-ҖӘН *җыйм. и. миф.* Кешене ялгыш юлга кертүче явыз кара көчләр. *Бу – адәмме, пәри-җенме, бу нинди зат икән, дип әйттеләр, ди.* Әкият. *Былтыр Маймыл Хафизга пәри-җен ияләште.* Г.Тукай

ПӘРИЗАТ *и. кит.* 1) *к.* **пәри** (*1 мәгъ.*)

2) *күч.* Сокландыргыч матур, чибәр хатын-кыз. *Янда – ай йөзле пәризат.* Г.Хәйям. *Пәризатлар арасында пәризат*

ПӘРИЗАТЛЫК *и. кит.* Искиткеч, искитәрлек, тылсымлы гүзәллек, матурлык

ПӘРИ́ КАКЫСЫ *и. бот.* Иренчәчәклеләр семьялыгыннан каты туфраклы басуларда күпләп үсә торган, кечкенә яфраклы, сары чәчәкле, төкле озынча сабаклы үлән; *русчасы:* **яснотка пятнистая**

ПӘРИ́ КЫЧЫТКАНЫ *и. бот. к.* **пәри какысы**

ПӘРИЛӘНҮ *ф.* Котыру, ярсу, дуамаллану

Пәриләнә башлау Пәриләнергә тотыну

Пәриләнеп алу Бер ара, кыска гына вакыт пәриләнү

Пәриләнеп бетү Бөтенләй, тәмам пәриләнү

Пәриләнеп йөрү Шактый озак пәриләнү

Пәриләнеп китү Кинәт пәриләнү

ПӘРИЛЕ *с.* 1) Пәрие бар дип ышанылган; тормыш кору, яшәү өчен тынычсыз. *Ибрук чарасыз гына пәриле өйгә юнәлде.* С.Сүнчәләй. *Уземне хикәя китапларындагы «кергән кеше сәламәт чыкмый торган» пәриле йорттa кеби тойдым.* Г.Тукай

2) *күч.* Холыксыз, дуамал

3) *күч.* Аз вакыт эчендә бик күп эшләр эшләп ташлаган (кеше тур.)

ПӘРИ́ УТЫ *и. бот. к.* **пәри арбасы**

ПӘРИ́ ҮЛӘНЕ *и. бот.* Кузаклылар семьялыгыннан терлек азыгы буларак кулланыла торган тармаклы икееллык үлән; ак тәкәмөгез, чебен кунаксасы, борча үләне; *русчасы*: **донник белый**

ПӘРИШАН *с. фар. диал.* Тәртипсез таратылган, тетелгән, тузыган. *Шул җәһәттән күңелем хәйран вә гакылым пәришан булып, кальбем пәрдәләнде.* К.Насыйри. *Пәришан чәчләр*

ПӘРМӘ́-ПӘР *рәв. диал.* Бергә-бер, кара-каршы; аяусыз, рәхимсез. *--- ә үзем усал итеп карыйм, усал итеп сөйләшәм, пәрмә-пәр талашам.* Ф.Садриев. – *--- хәзердән үк үзем белән пәрмә-пәр килеп бәхәсләшеп биремнәр чишүче укучыларым --- булуга куанам, – ди педагог.* Гасырлар авазы. *--- «Пусть говорят» тапшыруының берсендә сәхнә йолдызларының спермасын урлап бала*

тапкан хатыннарның, ДНК тикшеренүләре уздырып, балаларына пәрмәнәр килеп алимент юллауларын тикшерәләр. Ватаным Татарстан

ПӘ́ТӘМӘЧ-КҮМӘЧ *ы. к.* **пәрәмәч 2.** *Пәтәмәч-күмәч! Кеше бар икән ләбаса, әйтмисең дә!* Г.Ахунов

ПӘТӘЧ *ы. гади с.* Көтелмәгән хәлдән нык гаҗәпләнүне белдерә; бәтәч. *Пәтәч, чөгендер белән бәрәңгедән генә катырып эшләнгән ләбаса!* Ш.Камал

ПӘХЛӘВӘ *и. төр. кулин.* Берничә катлы бик юка төче камыр җәемнәре арасына шикәр комы катнаштырып, төелгән кузы төше сибеп, соңгы катлам өстенә сыек бал яки ширбәт коеп пешерелгән милли ашамлык. *Пәхләвәне гадәттә 6–8 катлы итеп ясыйлар ---.* Татар халык ашлары. *Пешеп җитәрәк, пәхләвәне мичтән алып, кискән урыннарына җылы сыек бал сибәргә --- кирәк.* Сөембикә. *Аш пешерүчеләр конкурслар нәтиҗәсендә сайлап алынган, анда катнашучылар токмач, --- пәхләвә әзерли белүдә үз осталыкларын күрсәткән.* Шәһри Казан

ПӘҺЛӘВИ *и.* Фарсы телләренең көньяк-көнбатыш төркеменнән III гасырдан VII гасыргача әдәби һәм рәсми буларак кулланышта йөргән тел (хәзерге вакытта үле телләрнең берсе). *Иран патшасы Дарий вакытында Иранның борынгы чөй язуын --- алыштырган пәһләви язуын эшләткәннәр.* Г.Сәгъди. *Ул --- Иранның ул заманда гы ике әдәби телен дә – гарәп һәм фарсы телен – яхшы белә; бәлки, Иранда ислам чорына кадәр кулланылган әдәби пәһләви телен дә белгәндер.* Гасырлар авазы. *Гарәпләрнең атаклы бер вәзире, язучысы VIII гасырда борынгы пәһләви теленнән тәрҗемә итә аны.* Фән һәм тел

ПӘҺЛЕВАН *и. фар.* **1.** 1) Зур гәүдәле, бик көчле кеше; батыр, баһадир. *Пәһлевандай бульдозерчы, кабинасыннан башын тыгып, рәхәтләнеп көлә.* Ш.Галиев. *Пётр патша заманында машиналар булмаган, ул пәһлевангa карета ничек чыдагандыр, әле дә булса шаккатам ---.* Р.Кәрами. *Элекке председательнең – үгезне мөгезеннән тотып җиргә ега торган пәһлеван Камалиның – урындыгында яшь хатын Гөлзәбирә утыра.* Г.Мөхәммәтшин

2) Зур гәүдәле көрәшче. *Һәр мәйданда бәйгене рус алды, Һич батыр каршы тора алмаганнан соң, Пәһлеваннар барчасы калды таңга.* М.Гафури. *Пәһлеван шул чакта көчен күрсәтеп, Җибәрә берәүне нык мәтәлләтеп.* Н.Баян. *Төрле-төрле кешеләрне күрдең ---, сорнай уйнаганны ишеттең. Ул егетләрнең биюе дисеңме, ул пәһлеваннарның көрәшләре дисеңме.* Р.-Н. Гүнтәкин

3) *күч.* Зур, биек, мәһабәт. *Шушы пәһлеван вышканы күчереп йөртүләрен күрәсең дә адәм баласының баһадирлыгына, зурлыгына хәйран каласың!* Ш.Галиев. *--- куаклыклар белән капланган ямь-яшел пәһлеван таулар аксыл болытларны кайчак бау итеп бәйлиләр ---.* Д.Гайнетдинова

2. *с. мәгъ.* Таза, зур гәүдәле. *Калын гөрги тавышлы, пәһлеван гәүдәле, түгәрәк кара сакаллы Ибраһим морзаның, Йосыф бәк белән бәхәсләшеп, бер утыруда бер сарык түшкәсе ашап бетергәне бар.* М.Хәбибуллин

ПӘҺЛЕВАНЛЫК *и.* Кыюлык, батырлык. *Аның дию белән көрәшеп йөрүче «Салсал батыр» кебек көлке пәһлеванлыгына каршы киләләр.* Г.Кашшаф. *Пәһлеванлыгы белән генә түгел, гадилеге белән дә бөек кешенең тормышын хәзер дә әкият итеп сөйлиләр.* С.Сөләйманова

ПӘҺЛЕВАННА́РЧА *рәв.* Пәһлеваннарга хас булганча, пәһлеваннар кебек. *Борынгы пәһлеваннарча көрәшү*

ПӘЧ *иярт. сөйл.* Авызны чапылдатканда, кулларны чапканда, сукканда, бәрелгәндә һ.б.ш. хәрәкәтләр ясаганда барлыкка килгән тавышны белдерә; чәп

◊ **Пәч иттереп** Кисәк кенә, көтмәгәндә. *[Юләр] бу мескеннең битенә пәч иттереп бер уч туфрак бәргән.* Ш.Камал

ПӘЧКЕЛДӘ́Ү *ф.* Пәч итеп бәрелү, пәч итеп төшү

ПӘЧНӘТҮ *ф. диал.* 1) Чалтыратып сугып җибәрү

2) Егу, бәреп егу

3) *күч.* Берәр җинаять өчен сөргенгә җибәрү. *Ат урлап, өч кат төрмәдән качкан өчен, Миңлегали агайны сигез елга каторгага пәчнәтерләр.* К.Тинчурин

Пәчнәтеп җибәрү Кисәк кенә, көтмәгәндә пәчнәтү

ПӘЧНӘ́Ү *ф. диал.* Егылу, пәч итеп егылу

ПӘ́Ч-ПӘЧ *иярт. сөйл. к.* **пәч**. *Балалар, авызларын пәч-пәч китереп, бөтен битләрен, ярты күлмәкләрен буяп ашыйлар.* М.Әмир

ПӘЧРӘЙТҮ *ф. гади с.* Чекрәйтү. *Прилавка өстендә, көн буе оя баскан тавык кебек, күзеңне пәчрәйтеп утырасың.* К.Әмири

ПӘЧТЕРҮ *ф. гади с.* Төрле юллар белән нәрсәне дә булса кулга төшерү, эләктерү. *Квартир пәчтерү. Акча пәчтерү*

ПӘЧҮ *ф. гади с.* Берәр эштән уңу. *Гайнулла пәчте, малай, литерга керерлек эш бар.* К.Әмири

ПЕБЕТ *и. диал.* Бытбылдыкның бер төре; *русчасы*: **перепёлка**. *Кара урманның уртасында карчыгалар куа пебетне.* Җыр

ПЕГАС *и. гр.* 1) Борынгы грек мифологиясендә канатлы ат, тулпар

2) *күч.* Поэтик рухлану, иҗади илһам. *Пар пегасым, тулпарым син – Нәфрәтем, мәхәббәтем.* Х.Туфан

ПЕД *и. рус сөйл.* Педагогика университеты яки пединститут, яки педучилище. – *Кайсы авылдан? – Училищедан. Педтан.* М.Мәһдиев

ПЕД- *гр.* Кушма сүзләрдә «педагогик» мәгънәсен белдерә торган беренче кисәк (мәс., *пединститут, педпрактика, педсовет, педучилище*). *Рәмзия яшьли ата-анасыз калып балалар йортында үскән һәм аннан соң педтехникум бетергән чибәр генә кызый иде.* М.Мәһдиев

ПЕДАГОГ *и. гр.* 1) Педагогика белгече

2) Тәрбияләү һәм белем бирү эше белән шөгыльләнүче кеше, укытучы, мөгаллим. *Әлбәттә, Гасыйм Сәләхович, хәзерге заман педагогы буларак, андый «ысулларның» бетүе белән һичшиксез килешә...* Ә.Еники. *Аларда Тукай бер үк вакытта һәм әдип, һәм остаз-педагог буларак чыгыш ясый.* Ә.Кәримуллин. *Ф.Әмирхан яшь*

чагыннан ук укытучы-педагог та булган икән әле. Р.Әмирхан

ПЕДАГО́ГИК *с.* 1) Педагогка хас булган. *Әмма нинди генә болгавыр заман булмасын, Зәйнәп укытучылык һөнәрен ташламый, әтисеннән, бабаларыннан мирас булып калган педагогик эшчәнлеген дәвам иттерә.* Р.Әмирхан

2) Педагогикага караган, педагогикага бәйләнешле. *Мәскәүдән ул Уфага кайта һәм татар-башкортлар арасында мәктәп-мәгърифәт эшенә чума, бер-бер артлы дәреслекләр, педагогик хезмәтләр язып килә.* Ә.Кәримуллин. *К.Д.Ушинский хатын-кызларга педагогик белем бирүне башлап җибәрүчеләрнең иң беренчеләреннән була да.* Т.Биктимирова. *Шуңа күрә без аны Гуманитар һәм педагогик тикшеренүләр институты дип үзгәрттек.* Безнең гәҗит

ПЕДАГО́ГИКА *и. гр.* Белем бирү һәм тәрбияләү турындагы фән. *Педучилищеның каравылчысы да педагогиканы белә торган кеше була икән!* М.Мәһдиев. *Болардан тыш, педагогик фәннәр: педагогик психология, педагогика тарихы һәм дидактика укытыла башлый.* Т.Биктимирова. *Безнең бүлек студентлары өчен иҗтимагый, психология, педагогика фәннәре рус телендә укытылды.* Р.Юсупов

ПЕДАГО́ГИЯ *и. гр.* 1) *иск.* Педагогика. *Педагогия училищесына быел бик күп бала алдылар.* М.Мәһдиев. *Ул педагогия институтында кафедра мөдире һәм университетта партия тарихы буенча доцент та булды.* Я.Абдуллин

2) Тәрбияләү һәм белем бирү эше; шул эшнең, шөгыльнең алымнары. *1921 елның ахырында Мамадышта эшләп килгән педагогия курслары ябыла.* Ватаным Татарстан. *Гомумән, педагогия коллективына ул җитәкчелек иткән чор иң нәтиҗәле саналырга хаклы.* Кызыл таң

ПЕДАГОГЛА́РЧА *рәв.* Педагогларга хас булганча. *Бер төркем укытучы ярсынып завхозга ташланды: мәсьәләгә педагогларча килү түгел бу.* Г.Ахунов

ПЕДАГОГЛЫК *и.* Педагог булу

ПЕДАЛЬ *и. фр.* Кайбер транспорт чараларында һәм музыка уен кораллларында механизмны аяк көче белән хәрәкәтләндерү яки тотып тору өчен эшләнгән басма; тәбелдерек. *Гаяз педальне әйләндерүдән туктады да, велосипедны үз иркенә куеп, таудан түбән очып төшә башлады.* И.Гази. *Ләкин күгәргән бармаклы апа шыгырдап каткан ботинкалары белән пианиноның педальләренә баскан да балаларны җырлата: до-си-ля-соль-фа-ми-ре-до...* М.Мәһдиев. *Карап торуга кызык инде: бер рам, ике тәгәрмәч булса да, ике утыргыч һәм дүрт педаль.* Ватаным Татарстан

ПЕДАНТ *и. фр.* Билгеле бер кагыйдәләрне кирәгеннән артык төгәллек белән үтәргә тырышучы кеше. *Антоновның холкына бәя биреп, штабтагы көнчеләр: «Бигрәк педант инде генерал Антонов!» – дип, аңа исем тагарга тырышалар. Шундый эшчән, күзе тулы нурлы кеше педант була димени инде?!* З.Зәйнуллин. *Ә болай Михаил Александрович – педант, әгәр аның өстәлендәге бер кәгазьне мыштым гына урыныннан күчереп куйсаң, ул аны шундук күреп ала.* М.Юныс. *Бәлки, инглизләр бик педант халыктыр.* Әдәп төбе – матур гадәт

ПЕДАНТЛА́РЧА *рәв.* Педантларга хас булганча. *Немецлар – кагыйдә һәм тәртип, педантларча төгәллек һәм бердәм хәрәкәт ярата торган кешеләр.* Ш.Маннур

ПЕДАНТЛЫК *и.* Педант булу. *Немец кешесенең аккуратлыгы, педантлыгы мәкальләргә кергән.* И.Гази. *Мөдәррис Мусинович – --- педантлык дәрәҗәсендә пөхтә, гаҗәеп оста нотыкчы, оештыручы, милли мәсьәләдә менә дигән демагог.* Р.Батулла. *Без, аның хезмәттәшләре исә, Фәлван Нуриевичның педантлык дәрәҗәсендә пөхтәлеген, үзенә дә, башкаларга карата да таләпчән булуын сокланып искә алабыз.* Заман сулышы

ПЕДЕРАСТ *и.* Педерастиягә бирелгән, шуның белән шөгыльләнгән кеше. *Борыныңа киртләп куй, Юра, мин педераст түгел!* Р.Батулла

ПЕДЕРА́СТИЯ *и. гр.* Ир кешенең малай яки яшь егет белән җенси мөнәсәбәттә булуы, ир-ат арасындагы гомосексуализм, ливата

ПЕДИАТР *и. гр.* Балалар врачы, педиатрия белгече. *Балалар коллективына йөри башлау моментыннан алып сезнең балагыз икеләтә медицина күзәтүе астында була: участок педиатры һәм балалар учреждениесе врачы.* Балалар сәламәтлеге турында. --- *кадрлар мәсьәләсе биредә йөз процентка хәл ителмәгән: районга офтальмолог, анестезиолог, педиатр һәм башка белгечләр кирәк.* Татарстан яшьләре. *Апам – терапевт, сеңлем – педиатр, мин исә акушер-гинеколог һөнәрен сайладык.* Мәдәни җомга

ПЕДИАТРИ́Я *и. гр.* Балалар авыруларын һәм балаларны дәвалау ысулларын өйрәнә торган фән. *Фәридә, укуын дәвам иттерү өчен, университетның химия факультетына, Зөлфия медицина институтының педиатрия факультетына керделәр һәм уңышлы гына укып киттеләр.* Я.Абдуллин. *Педиатрия бүлеге табибәсе Әлфия Исмәгыйлевага ундүрт ел эшләү дәверендә биредә күпне күргән туры килгән.* Татарстан яшьләре. *Бүгенге көндә Татарстанда педиатрия хезмәтендә координатор ролен --- Республика балалар клиник хастаханәсе үти.* Ватаным Татарстан

ПЕДИКЮР *и. фр.* Аяк тырнакларын чистартып, шомартып, буяп, билгеле бер формага кертү һәм аяк табанын йомшартып чистарту, каты катламнан арындыру. *Педикюр, маникюр, чәч дип кенә яшәсәң, ай-һай, иреңне яраттыруың да, үзеңнең бәхетле булуың да, Мәһдиев әйтмешли, едва ли...* Шәһри Казан. *Күргәзмә профессиональ косметологлар, маникюр һәм педикюр осталары, косметик студия, матурлык салоны җитәкчеләре, дистрибьютерлар өчен тәкъдим ителә.* Татарстан яшьләре

ПЕДИКЮРЧЫ *и. сөйл.* Педикюр ясаучы; педикюр остасы. *Педикюрчы инструментларын дезинфекцияләргә куйды*

ПЕДИКЮРЧЫЛЫК *и.* Педикюрчы булу. *Педикюрчылыкка ике-өч ай дәвамында укыталар*

ПЕДИНСТИТУТ *и. рус* Педагогика институты; югары белемле тәрбиячеләр,

укытучылар әзерләп чыгара торган уку йорты, вуз. *Пединститутка килгәнче, ул Кушнаренко районының Шәрип авылында мәктәп директоры булып эшләгән.* М.Кәрим. *Ул монда пединститутның чит телләр факультетына укырга керде.* Ф.Яруллин. *Исемфамилиясен үзгәртеп, илдә калган; крестьян кызы дип, пединститутка укырга кергән.* Р.Нуруллина

ПЕДУНИВЕРСИТЕТ *и. рус* Педагогика университеты. *Казан педуниверситетының фәнни потенциалы нык күтәрелде: гыйльми дәрәҗәле һәм исемле укытучыларның саны берничә мәртәбә артты.* Р.Юсупов

ПЕДУЧИ́ЛИЩЕ *и. рус* Педагогика училищесы. *Революциягә хәтле татарның милли педучилищесы да, пединституты да, бернинди махсус мәктәпләре дә эшләмәде.* Ә.Кәримуллин. *Имтиханга килгән егет-кызлар белән таныштым. Арада 8, 9 сыйныфны, педучилищеның 1, 2 курсларын бетергәннәре дә бар.* Я.Абдуллин

ПЕ́ЙДЖЕР *и. ингл.* Кыска мәгълүматны кабул итә һәм дисплеенда күрсәтә торган берьяклы элемтә җайланмасы. *Юлия Латынина алып барган «Код доступа» тапшыруы пейджерына килгән ике хәбәрдән башланды ул.* Татарстан яшьләре

ПЕ́ЙДЖИНГ *и. ингл.* Пейджер ярдәмендә башкарыла торган элемтә системасы. *Пейджинг элемтәсе операторы*

ПЕЙЗАЖ *и. фр.* 1) Билгеле бер урынның табигый күренеше. *Шулай итеп, нефтьчеләр кайгыртуы белән җирле пейзаж елдан-ел күркәмләнә.* Ватаным Татарстан

2) Табигать күренешләре төшерелгән картина, рәсем. *Рифкать ага Вахитов натюрморт, пейзаж кебек жанрларда да иҗат итә* ---. Ватаным Татарстан. *Шунысы да игътибарга лаек: күргәзмәдә татар туфрагында – Алабуга шәһәрендә туып үскән рәссам Иван Шишкинның пейзаж картиналары да урын алган.* Шәһри Казан

3) Әдәби әсәрдә табигать күренешләренең тасвирламасы. *«Эшче» поэмасында табигать картиналары – пейзаж юк диярлек.* Г.Нигъмәти. *Шагыйрь иҗатында табигать тасвирлары, пейзаж лирикасы, ел фасыллары турында мәгълүмат бирә торган әсәрләр дә байтак.* Р.Фәтхерахманов. *Яшь автор Г.Ибраһимов бу әсәрендә кешенең рухи дөньясын ачып бирүче оста психолог, фольклор белгече һәм табигать матурлыгына мәдхия җырлаучы пейзаж остасы буларак ачыла.* Татар фольклористикасы

ПЕЙЗАЖИСТ *и. рус* Пейзажлар төшерүче рәссам; пейзажчы. *А. Моруа: «Портретист һәм пейзажист кебек, биограф бөтен материалдан сурәтләү өчен иң мөһимен сайлап ала белергә тиеш», – дип күрсәтә.* Г.Галиуллина

ПЕЙНТБОЛ *и. ингл.* Пневматик мылтыклардан буяу тутырылган шарчыклар атып уйнала торган командалы уен. *Пейнтбол клубында һәркемгә мылтык, махсус кием һәм 200 патрон тәкъдим ителде*

ПЕКА́РНЯ *и. рус* Икмәк, күмәч һ.б.ш. камыр азыклары пешерә торган кечерәк предприятие; икмәкханә. – *Пекарня төзелешенә өч машина, – диде Батыркаев. – Пекарня никадәр тизрәк өлгерсә, шулкадәр тизрәк ипиле булырбыз.* Г.Ахунов

ПЕКТИН *и. гр.* Җиләк-җимешләрдә, тамырча сокларында эрегән хәлдә очрый һәм ашамлык, дару, косметик әйберләр җитештерүдә кулланыла торган шикәрсыман матдә. *Пектин матдәләренә алма, чөгендер, гөләп һәм кара карлыган аеруча бай. Суда бүрткәннән соң, пектиннар койкасыман консистенциягә керәләр.* Урман аптекасы. *Сәламәт кеше рационына һичшиксез азык җепселләре дә һәм барыннан элек петкин һәм клетчатка кебек үсемлек җепселләре дә керергә тиеш.* Дөрес туклану серләре

ПЕЛ *и. фар. диал.* 1) Тоташ зур ит кисәге

2) Казылык

3) *сөйл.* Мускул. *Пеленә карама, фигыленә кара.* Мәкаль

ПЕЛӘМӘ *и. рус гади с.* Йорт хайваннары яки кайбер башка хайваннарның буыннан буынга күчә торган билгеле бер сыйфатларга һәм үзенчәлекләргә ия булган токымы, нәсел

ПЕЛӘМӘЛЕК *с. гади с.* Нәселгә дип калдырылган (иркәк терлек тур.). *Пеләмәлек үгезебез, айгырыбыз белән үзебезнең тирәдәге авылларга үрнәк булып торабыз.* Г.Толымбай

ПЕЛӘШ *с. рус* **1.** Чәче коелып, баш тиресенең бер өлеше яки бөтен башы ялтырап торган (кеше тур.). *Үзе яшь кенә булса да, башы пеләш кенә доктор нәрсәдер язып утыра. Безнең алда аның шалканнан такыр пеләш башы гына ялтырый.* М.Әмир. *Дияр Диярович, пеләш башын язу өстәленнән күтәрмичә, нәрсәдер эшләвендә булды.* Ф.Яруллин. *Кода тиешле кеше иде ул безгә. Бик оялчан иде, шуңадырмы, пеләш башын күлмәк якасына яшерергә теләгәндәй, гел муенын җыерып йөри иде.* Н.Гыйматдинова

2. *и. мәгъ.* 1) Кешедә, өлешчә яки тулае белән чәче коелып, баш тиресенең ялтырап торган, хайваннарда, йоны коелып, тиресенең такыр калган урыны. *Әхмәт писарь Егорның пеләшен чеметкәләп алды.* Х.Кәрим. --- *гәүдәләре Су анасыныкына охшаган, ә башлары нәкъ Мәрдәншаныкы шикелле: пеләш.* З.Хәким

2) Чәче коелып, баш түбәсе тулысынча яки аның бер өлеше ялтырап торган кеше. *«Мин, гомумән, пеләшләрне яратам». Гөлиянең бу сүзе әллә ни арада бөтен институтка таралып өлгерде. Чәчләләр пеләшләрдән көнләшә башлады.* Ф.Яруллин

ПЕЛӘШЛӘНҮ *ф.* Пеләш булып калу. *Ир-атларда хатын-кыз тибындагы симерү барлыкка килә, хатын-кызларда, киресенчә, ир-атларга тартым үзгәрешләр барлыкка килә: ир-атлардагы кебек пеләшләнү башлана, тавыш тембры түбәнәя.* Үзең нинди – көзгең шундый

Пеләшләнә башлау Пеләшләнү билгеләре күренү. – *Фикерләрегез аңлашылды, – диде ул, пеләшләнә башлаган кап-кара чәчле башын олы учы белән артка таба сыпырып.* Ф.Яхин. *Тестостерон гормоны җитмәгән очракта, баш пеләшләнә башлый.* Шәһри Казан

Пеләшләнә төшү Тагын да пеләшләнү. *Бу әфәнденең башы шактый гына пеләшләнә төшкән булса да, акылы*

ягыннан куәте бар иде. Ф.Яхин. *Кара кайгыдан кечерәеп, ябыгып калган, чаларган чәчләре пеләшләнә төшкән Назар абыйны урамда очратса, Рөстәм таный да алмас иде.* А.Хәйретдинова

Пеләшләнеп бетү Тәмам пеләшләнү

Пеләшләнеп калу Ниндидер тәэсирдән, вакыйгадан соң пеләшләнү

Пеләшләнеп тору Пеләшләнгән хәлдә булу

ПЕ́ЛЕНГ *и. голл. махс.* Күзәтү меридианының төньягы белән күзәтүчедән объектка илткән юнәлеш арасындагы, 0°тан 360°ка кадәр горизонталь почмак. *Пеленг белән маташабыз.* Х.Камалов. *Бу сурәтне, пеленг алып яисә обсерватория ясап, корабльның торган урынын ачыклаганнан соң куялар.* М.Юныс

ПЕЛЕНГА́ТОР *и. голл.* 1) *махс.* Компаста урнаштырылган, пеленглар алу яки җирдәге предметларга яисә күк җисемнәренә юнәлешләр билгеләү өчен хезмәт итә торган прибор. *Пеленгатор палубасында бер шәүлә күренде.* М.Юныс

2) Пеленгация белгече; пеленг кабул итүче аппаратчы. *Диңгезне тыңлый алу җиңел эш түгел. Хәтта тәжрибәле пеленгатор да 75–80 пеленг кабул иткәннән соң арый.* Эврика

ПЕЛЕНГА́ЦИЯ *и. голл.* Нәрсәнең дә булса пеленгын билгеләү эше

ПЕ́ЛЕНГЛАУ *ф. тех.* Пеленгатор ярдәмендә нәрсәнең дә булса урынын ачыклау. *Телефон аппаратының иясе ачыкланмагач, пеленглау ысулын кулланырга, ягъни сигналның кайдан килүен ачыкларга булалар.* Кәеф ничек?

ПЕЛЛА́ГРА *и. ит. мед.* Организмда никотин кислотасы җитмәүдән килеп чыга торган тире авыруы. *Цинга, пеллагра, рахит, полиневрит ---, гемофилиянең кайбер төрләре, шулай ук күп кенә башка авырулар азыкта теге яки бу витаминнарның кискен кимүе нәтиҗәсендә килеп чыга.* Дөрес туклану серләре

ПЕЛЛӘҢҮ *ф. диал.* 1) Симерү (терлек-туар тур.)

2) Тәндәге мускулларның юанаеп, кабарып торуы; таза булу, эреләнү. *Пелләнмәгән – телләнгән.* Мәкаль

ПЕЛЛӘ́Ү *ф. диал.* Суелган терлекне махсус өлешләргә бүлгәләү, ботарлау. *Симерде ул, (сыер) шуңа азына. Актык көне аның бүген. Пеллибез аны иртәгә.* М.Мәһдиев

ПЕЛТ *иярт.* 1) Шәм уты, кечкенә лампочка кебекләрнең кинәт кенә сүнү рәвешен белдерә. *Стереовидеотелефон экраны пелт итеп сүнде.* З.Мәхмүди

2) *к.* **пелт-пелт**

ПЕ́ЛТ-ПЕЛТ *иярт. кбт. форм.* 1) Күзне йомып алу хәрәкәтен чагылдыра. *«Шейх» ак керфекләрен пелт-пелт уйнатып, сүзсез күзен Кәримгә төбәде.* К.Тимбикова

2) Кинәт кенә яки көттереп су өстенә тамган су тамчылары тавышын белдерә. *Самавырда су бетә, тамчы гына тама: пелт-пелт килә.* М.Әмир

ПЕ́МЗА *и. ингл. геол.* Төзү материалы буларак һәм нәрсәне дә булса ышкып шомарту өчен файдаланыла торган көпшәк, җиңел вулканик пыяла. *Әрмәнстан төрле төзү материалларына: туфка, пемзага, базальтка, мәрмәргә, известьташка, гранитка бай.* География. *Җәй көне аякларны һәр көн җылы су белән сабынлап юарга, әгәр табан асты һәм үкчә тиресе калынаеп катса, аны пемза белән ышкырга кирәк.* Өгез ямьле булсын

ПЕНАЛ *и. лат.* Каләм, карандаш һ.б.ш. язу әсбаплары салып йөртү өчен махсус ясалган кечкенә озынча тартма. *Пистолет – пенал, циркуль шикелле сумка төбендә ауный торган әйбер инде ул Марат ишеләрнең.* А.Гыймадиев. *Портфелен ачса, бизәкле пенал, егерме дүрт төсле фломастер, мультфильм геройлары төшкән ялтыравык тышлы көндәлекдәфтәрләр...* Ялкын. *Көндәлек, пенал, альбом, карандаш кебек вак-төяк товарларның да ниндие генә юк хәзер.* Татарстан яшьләре

ПЕНА́ЛЬТИ *и. ингл.* Футбол уенында, капкадан унбер метр ераклыкта торып, штраф тубы тибү. *Шунда янәшәдә генә өчкә өч булып мини-футбол уйныйлар. «Пас! Аут! Почмактан тибү! Пенальти!» – дигән сүзләр ишетелеп тора.* Үзең нинди – көзгең шундый. *--- өстәмә вакыт тәмамланырга бер минут калып, тамашачы кемнең пенальти тибәсен фаразлап утырганда, «Вольфсбург» тагын бер туп кертте.* Ватаным Татарстан

ПЕНЕПЛЕН *и. ингл. геогр.* Тышкы көчләрнең бик озак вакытлар буенча тәэсир итеп килүе аркасында, кайчандыр таулы урыннан барлыкка килгән тигезлек

ПЕ́НИС *и. лат.* Ирлек әгъзасы

ПЕНИЦИЛЛ *и. лат.* Күбрәк азык продуктларында барлыкка килә торган күгәрек гөмбәчекләрнең бер төре. *Бу күгәрек гөмбәләренең аспергилл һәм пенициллыруларыннан булган төрләре --- азык продуктлары – сырлар (рокфор, камамбер) әзерләү өчен киң кулланыла.* Татарстанның үсемлекләр һәм хайваннар дөньясы. *Вареньеда, бозыла башлаган алма яки апельсиндагы күгелҗем яшел төстәге күгәрек элпәсе пенициллның споралар барлыкка килү стадиясе ул.* Өгез ямьле булсын

ПЕНИЦИЛЛИН *и. лат.* Күгәрек гөмбәчекләренең бер төре булган пенициллгөмбәсеннән алына торган, бактерияләр үсешен тоткарларга сәләтле матдә, антибиотик. *1928 елда инглиз микробиологы А.Флеминг беренче булып пенициллинның бактерияләр үсешен тоткарларга сәләтле матдә бүлеп чыгаруына игътибар итә һәм бу матдәне пенициллин дип атый.* Татарстанның үсемлекләр һәм хайваннар дөньясы

ПЕНО- *рус* Кушма сүзләрдә «күбекләндерелгән» мәгънәсендәге беренче кисәк (мәс., *пенобетон, пеносиликат, пенометалл*)

ПЕНОБЕТОН *и. рус* Тишеклетишекле структуралы җиңел бетон. *Бездә тоткыннар металл конструкцияләр, пенобетон, брусчатка җитештерү, киемнәр тегү белән мәшгуль.* Ватаным Татарстан

ПЕНОПЛАСТ *и. рус* Күбекләндерелгән пластмасса. *Моның сере бик гади: утыргыч үлчәмендә пенопласт кисеп алыгыз да скотч белән урындыкка ябыштырып куегыз.* Ватаным Татарстан

ПЕНСИОНЕР *и. фр.* Пенсия алып тора торган кеше. *– Ха! – диде егет, башын чөя биреп. – Көлке! Өйдә пенсионерлар да ял итми хәзер.* Ә.Еники. *Бер төркем карт пенсионерлар лаеклы*

ялга чыкканнан соң үзләрен кая куярга, ни эшләргә белми интегәләр. Р.Сверигин. – *Пенсионер башыгыз белән нигә өйдә генә утырмыйсыздыр? – диде егет, ямьсез итеп.* Үзең нинди – көзгең шундый

ПЕ́НСИЯ *и. лат.* 1) Билгеләнгән еллар хезмәт иткән кешеләргә һәм гарип-инвалидларга хөкүмәт тарафыннан даими рәвештә бирелә торган акча. *Күпме ил гизде, нинди зур дәрәҗәгә иреште, олыгайды, үзенең дә ул-кызлары үсеп җитте, инде хәзер беркайда да эшләми, зур пенсия ала...* Ә.Еники. *Кызларым булса – бер дигән! Кияүләр – искитәрлек! Карчыгым да үз янымда, пенсиям дә җитәрлек.* М.Хөсәен. *Ул яшькә җиткәч, беркемне дә йорт-илсез, ач-ялангач калдырмыйлар бу илдә, бер тиен акчасы, пенсиясе булмаса – бигрәк тә калдырмыйлар.* Н.Измайлова

2) Хезмәт карьерасын төгәлләп, шундый акча алып яшәү хәле. *Хәзер Иван Андреевич пенсиядә. Пенсиягә чыкты, әмма юашлыгы аркасында бакча ала алмады.* М.Юныс. *Максуди Анкара университетының юридик факультеты профессоры булып эшли, 1945 елда пенсиягә чыга.* Ә.Кәримуллин. *Бер дә юктан чөеп күкләргә Мактасалар әгәр берәрсен, Уйлап куям шунда: бу кеше Пенсиягә китә, күрәсең.* Ф.Яруллин

ПЕНСНЕ *и. фр.* Борынга пружина ярдәмендә генә эләктереп куела торган сапсыз күзлек. *Рәшат, әйле-шәйле бераз торганнан соң, йомшак креслоларның берсенә киерелебрәк кырын ятты, пенснесын уңайлап куйды да сөйләргә тотынды.* Ф.Әмирхан. *Өстәл янында ак чырайлы, ач яңаклы, кылыч борынын пенсне белән чеметтергән бер кеше кәгазьләр актарып утыра иде.* И.Гази

ПЕНЬЮАР *и. фр.* 1) Хатын-кызларның нәфис тукымадан тегелгән өй киеме, халат. *Тәрәзәдән --- хатын-нарның гәүдәләре күренә. Үтә күренмәле тәрәзә пәрдәсе, үтә күренмәле газ тукымадан тегелгән пеньюар.* М.Юныс. *Ак атлас тышлыгына сапсары чәчәкләр кадалган диванда чия төсендәге тасмалар белән бизәлгән гажәеп матур юка ефәк пеньюар кигән бер хатын ярым ятып тора.* Н.Көбәш. *Луизадан ефәк халатлар, тәнне назлый торган пеньюарлар алып элде.* Татарстан яшьләре

2) Чәч алганда, өскә чәч коелмасын өчен каплана торган махсус япма. *Чәчтараш өстемә зәңгәр ефәк пеньюар япты*

ПЕРӘШКӘ *и. рус* 1) Каеш яки билбауны беркетеп куя торган каптырма; аел. *Өсләрендә соры шинель, Билләрендә перәшкә; Сөйгән ярым җиңеп чыкты Гитлер белән көрәштә.* Җыр. *Аю маңгаенда җиз перәшкә, Тулган айлар кебек ялтырый; Үз аюым мине ашаганда, Яшь тә йөрәкләрем калтырый.* Бәет. *Гимнастёрка төймәләрен, каеш перәшкәсен чистартып --- ул беренче этажга – гаражга төште.* Р.Кәрами

2) Атны янга җиккәндә тәртә хезмәтен үти торган каеш; мичәү. *Аңа һәрвакыт перәшкә аты җигәргә кирәк булган.* Г.Газиз. *Җизнинең күк айгырын төпкә, Госманнарның кара туры алашаларын перәшкәгә җигеп, пар ат белән киттек тә бардык.* Ф.Хөсни

ПЕРӘШКӘЛЕ *с.* Перәшкәсе булган. *Идриснең көне буе пычрак ерган зур итекләре янәшәсендә алтын перәшкәле --- итек урын алды.* Г.Бәширов. *Дуамалланып, җиз перәшкәле бил каешын суырып чыгарыр идеме, әллә анысы да: «Миңа маржа булмагае, чурт булсын, тик адәм җанлы булсын!..» – дип, улын яклар идеме?* Э.Касыймов. *Фәридә белен зур перәшкәле киң каеш белән кысып буган ---.* Р.Вәли

ПЕРГА́МЕНТ *и. гр.* 1) Борынгы заманда язу-сызу өчен махсус эшкәртелгән яшь терлек тиресе. *Аның пергамент кебек сап-сары куллары кытыршы иде.* Р.Мостафин. *Пергам шәһәрендә китапларны бозау һәм яшь сарыкларның эшкәртелгән тиреләренә яза башлыйлар. Менә шушы тирене пергамент дип атап йөртәләр.* Робинзон эзләреннән

2) Шундый материалдагы кулъязма

3) Сыекчаларны, юешне үткәрми торган нәфис юка кәгазь. *Киптерелгән яшел тәмләткечне, пергамент пакетларга салып, коры, караңгы урыннарда саклыйлар.* Татар халык ашлары

ПЕРЕВОД *и. рус* Почта яки банк системасы аркылы җибәрелгән яки күчерелгән акча

ПЕ́РЕКИСЬ *и. рус* Кислород атомнары бер-берсе белән кушылган катлаулы химик матдә. *Керне агарту өчен, бер чиләк кайнар суга 1–2 аш кашыгы өч процентлы водород перекисе һәм бер аш кашыгы нашатырь спирты салып тоталар.* Өегез ямьле булсын

ПЕРЕКУР *и. рус сөйл.* Тәмәке тартып алу өчен, берничә минутка эштән, шөгыльдән туктап алу. *Перекур, ипташ бригадир.* Р.Ишморат. *Кая монда бездәгедәй ярты сәгать саен «перекур»га тукталу?!* Шәһри Казан

ПЕРЕС *ы.* Мәчеләрне куып җибәргәндә әйтелә торган сүз. *Җалай мәчене: – Кит, мур кыргыры, перес! – дип куып төшерде.* Г.Толымбай. – *Син генә җитмәгән идең монда. Көш! Перес! – диде бабай. – Көш дип куарга ул кош түгел, перес дияр идең – песи түгел, – диде әби.* Р.Батулла

ПЕРИГЕЙ *и. гр.* Күк җисеме, гадәттә Ай яки ясалма иярчен орбитасының Җиргә иң якын ноктасы; *киресе:* апогей. *Әл-Бируниның «Масуд Кануны»нда кояшның апогей һәм перигей тирәлегендә хәрәкәтен тикшерүе – кинематик тикшеренүләрнең менә дигән үрнәге.* Фән һәм тел

ПЕРИГЕ́ЛИЙ *и. гр. геогр.* Кояш системасындагы планета яки башка күк җисеме орбитасының Кояшка иң якын ноктасы; *киресе:* афелий. *Җир орбитасының кояшка иң якын ноктасы – перигелий (147 млн. км), Җир бу ноктада 1 январьда була.* З.Дусаев

ПЕРИ́МЕТР *и. гр.* 1) *мат.* Яссылыктагы геометрик фигураның барлык якларының озынлык суммасы. *Турыпочмаклыкның периметры 28 см га тигез, ә турыпочмаклыкның чиктәш якларына төзелгән квадратларның мәйданнары суммасы 116 см² га тигез.* Алгебра. *Тартма төбе зурлыгында пыяла һәм озынлыгы пыяла периметрына тигез, ә киңлеге 2–3 см булган картон тасма кисәргә кирәк.* Яшь натуралистларга

2) Берәр корылманың, гадәттә йбык, койма тотылган бинаның, тышкы

ягы, әйләнәсе. *Сакчылар периметрны күзәтә*

ПЕРИ́ОД *и. гр.* 1) Дәвамында берәр нәрсә булып үткән, башкарылган яки тәмамланган вакыт аралыгы, чор, дәвер. *Зур бер залның экспозициясе геологик периодлар буенча төзелгән. Җирдәге тау токымнары катламнарының «яшен» галимнәр эраларга һәм периодларга бүләләр.* Борынгы гасырларда Татарстан

2) *мат.* Чиксез унарлы вакланмада кабатланучан цифрлар төркеме

3) *лингв.* Бер-берсенә бәйләнгән яки берәр аерым сүз, җөмлә белән берләштерелгән җөмләләрнең зур төркеме; тезем

ПЕРИО́ДИК *с.* 1) Билгеле бер шартларда тигез аралык белән кабатлана торган. *Элементларның периодик таблицасы*

2) Билгеле бер вакыт берәмлеге үткән саен, бер мәртәбә бастырылып чыгарыла торган. *Периодик басма*

ПЕРИСКО́П *и. гр.* Яшеренгән җирдән, су астыннан һ.б.ш. урыннардан тирә-якны күзәтергә мөмкинлек бирә торган оптик прибор. *Муса --- наводканы төгәл нокталарга куйды да күзләре белән перескопка ябышып калды.* Ш.Маннур

ПЕРИФЕРИ́Я *и. гр.* Илнең яки берәр административ берәмлекнең үзәгеннән ераkта урнашкан җирләр, өлкәләр. *Периферия, провинция, калыма, кышлак, хутор һәм тагын әллә ниткән шуның ише атамалар белән шәһәр егетләренең теленә кергән бер авыл үзәгендә яңгыратып яшәр ул...* К.Кәримов

ПЕРИФРАЗ *и. гр.* Нәрсәне дә булса турыдан-туры түгел, берәр үзенчәлеге, сыйфаты белән тасвирлап билгеләү (мәс., *ак халатлы кешеләр – табиблар, кара алтын – нефть*)

ПЕРИФРА́СТИК *с.* Перифраз белән бәйләнгән, перифразга хас, тасвирлама. *Ярдәмче мәгънәдә исә 'бул' фигыле төрле модаль мәгънәләр белдерә торган һәм заман төсмеренә ия булган тасвирлама, перифрастик фигыль формалары ясый.* Ф.Хисамова

ПЕРЛАМУТР *и. нем.* **1.** Бака кабыгы, молюск кабырчыгы кебекләрнең эчке ялтыравык катлавы. *Диңгез кабырчыгыннан перламутр алу*

2. *с. мәгъ.* 1) Шуннан эшләнгән. *Алар, гадәттәгечә, перламутр чәчәкләр белән бизәлгән түгәрәк өстәл янына утырдылар.* К.Нәҗми. *Мәйданның бер кырыенда Иргали утыра, кулында – баян. Аның зур бармаклары перламутр төймәләр өстендә гажәеп җитез йөгерәләр.* И.Салахов

2) Шундый төстәге, шуңа охшаш. *Кораб янына зәңгәрсу перламутр төскә буялган япон машинасы «Ниссан» килеп туктады.* М.Юныс

ПЕРЛОН *и. нем.* **1.** 1) Нейлонга охшаган нык синтетик сүс

2) Шул сүстән тукылган тукыма. *Ул төшендә дә креп-жоржетлар, нейлоннар, перлоннар, лавсаннар гына күрә торгандыр.* Г.Афзал

2. *с. мәгъ.* Шул тукымадан тегелгән, ясалган

ПЕРМАНЕНТ *и. фр.* Махсус ысуллар кулланып, чәчне озак вакыт саклаырлык итеп бөдрәләтү. *Химик бөдрәләтү (перманентның барлык төрләре) чәчне киптерә ---.* Өегез ямьле булсын

ПЕРПЕНДИКУЛЯР *и. лат.* **1.** Башка бер туры сызык яки яссылык белән туры почмак ясап кисешә торган туры сызык. *Евклид үзенең геометриясендә, ике параллель бер үк турыга перпендикуляр булырга тиеш, дигән фаразга таяна.* Ж.Тәрҗеманов

2. *с. мәгъ.* Башка бер туры яки яссылык белән туры почмак ясап кисешә торган

ПЕРРОН *и. фр.* Вокзал янына килеп туктаган поезд вагоннарындагы пассажирлар менеп-төшеп йөрсен өчен ясалган платформа. *Ул, состав туктар-туктамас, перронга сикереп төште дә, поезд тизлегендә йөгерә-атлый барып, вагон баскычындагы биштәре белән чемоданын үрелеп алды.* М.Яһудин

ПЕРСО́НА *и. лат. кит.* Шәхес, кеше, зат

ПЕРСОНАЖ *и. фр.* Әдәби әсәрдә, тамашада, шулай ук нинди дә булса картинада тасвир ителгән образ. *Б.Урманченың портрет скульптурасы персонажлары гади тарихи шәхесләр генә түгел, нәкъ менә геройлар, югары әхлак сыйфаты әһелләре, идеалга якын кешеләр.* К.Миңлебаев. --- *Без шул сәхнәләрдә үзебезгә характер табарга, ниндидер үзенчәлекле персонаж булырга тырыша идек.* Р.Җиһаншина. *Бу сүзләр автор тарафыннан хупланмый, тискәре персонаж Саттар тарафыннан әйтелә.* Х.Миңнегулов

ПЕРСОНАЛ *җый. и. лат.* Предприятие яки учреждениенең профессиональ яки техник хезмәткәрләре. *Ашханә персоналының мондый составына ышанмаучылар «Дарья» исемле ашханәдән справка ала алалар.* Г.Гали. *Америкада басылган «Югары идарә персоналы өчен кулланма» исемле фундаменталь хезмәтнең авторлары әйткәнчә, конструктив идеяләрнең күпчелеге --- башкалар фикере белән контактка кергәндә туа.* Әдәп төбе – матур гадәт. *Америкада тимер юл компанияләре персоналы арасында коронар җитешсезлек нәтиҗәсендә үлүчеләрнең ни дәрәҗәдә булуын өйрәнгәннәр.* Йөрәгегезне саклагыз

ПЕРСОНАЛЬ *с.* 1) Шәхси, аерым кешегә караган. *Төн урталарында пароходчылык башлыгының персональ машинасы чакырылмаган кунакларны алып китте.* М.Юныс. *Зур шау-шу белән Әбрарның партия әгъзасы буларак шәхси (персональ) эше тикшерелә.* Я.Абдуллин

2) Гомуми закон буенча түгел, хөкүмәт яки берәр төрле оешма тарафыннан махсус билгеләнгән. *Моның өчен персональ рәвештә эшкә билгеләү буенча махсус комиссия төзелә.* Тигез гомер итегез! *Г.Гафуров, Бөек Ватан сугышы башланганчыга кадәр, Мәскәүдә тора, персональ пенсия ала*. М.Гайнуллин

ПЕРСПЕКТИВ *с.* 1) Перспективага бәйләнешле, перспективага нигезләнеп билгеләнелә торган. *Перспектив сызыкларны билгеләп чыгу*

2) *күч.* Киләчәктәге үзгәрешләрне исәпкә алып эшләнгән; киләчәкне күз алдында тотып уйланылган. *«Хәзерге вакытта Россия базарына чыгу буенча эш алып барабыз, һәм Татарстан моның өчен иң перспектив регион булып тора», – дип белдерде Д.Рубини.* Безнең гәҗит

ПЕРСПЕКТИ́ВА *и. лат.* 1) Яссы өлектә өч үлчәмле пространствоны ераклык арту белән предметларның кечерәеп күренүен исәпкә алып сурәтләү сәнгате. *Перспектива законнары*

2) Ерактан күренгән табигать күренеше, манзара. *Хәзер дә сезнең күз алдындадыр: яшеллеккә күмелеп утырган матур гына авыл, аның аргы ягында еракларга киткән киң перспектива, сызылып кына күренгән ерактагы урман.* Г.Бәширов

3) *күч.* Алда көтелгән үсеш мөмкинлекләре, киләчәк. *Татар дәүләт опера театры коллективының перспективасы зур.* М.Җәлил. *Әйе, менә шул, үзенең заводын мактады, эшенең бик интересный булуын әйтте. Перспектива бик яхшы, диде.* Ә.Еники. *Җитди итеп уйлап карасаң, татар теленең бүгенге торышына объектив анализ ясап, аның перспективасын аңларга тырышсаң, бүгенге көндә туган телебезнең --- хәле борчылырлык икәнлеген --- ачык күрәсең.* Р.Юсупов

ПЕРСПЕКТИ́ВАЛЫ *с.* 1) Үсеш яки файдалану мөмкинлеге зур булган, өметле. *Нинаять, яшәеш шартлары шактый көйләнгәч, эш тә перспективалы барганда, --- мин тормыш юлымны бөтенләй икенче якка борып җибәрдем.* Х.Миңнегулов. *Ул моннан берничә ел элек, төзелеш башлануның беренче көннәрендә үк, перспективалы һәм перспективасыз авыллар турында газетада мәкалә бастырган иде.* Р.Вәлиев. *Ул Депардье күчеп килә калса, авылыбыз перспективалыга әйләнә бит, шуны аңлыйсызмы?* Ф.Хәбибулин

2) Белемле, талантлы, киләчәге өметле (кеше тур.). *Ә.Исхак – үзенең иҗаты өстендә җентекләп, бирелеп эшләүче, --- зур перспективалы шагыйрь.* М.Җәлил

ПЕРСПЕКТИ́ВАЛЫЛЫК *и.* Перспективалы булу. *Шул үк вакытта перспективалылык исәпкә алына.* Кызыл таң

ПЕРСПЕКТИ́ВАСЫЗ *с.* 1) Үсеш мөмкинлекләре аз булган яки киләчәктә бетүгә йөз тоткан. *Ул моннан берничә ел элек, төзелеш башлануның беренче көннәрендә үк, перспективалы һәм перспективасыз авыллар турында газетада мәкалә бастырган иде.* Р.Вәлиев. *Баштагы елларда инвестор куйган сак хезмәте – камуфляж форма кигән һәм, берни эшләми, кырлар буйлап машинага утырып элдерткән типсә тимер өзәрлек егетләр – вак-төяк урлашуның юлына аркылы төшәргә азапланып карадылар да, хәзер бу эшнең перспективасыз икәнен аңлап, үзләре дә кыек ятканны чәлдерергә керештеләр.* Ватаным Татарстан

2) Киләчәкне, алдагы үсешне күз алдына китерми торган. *Фантазиясез, перспективасыз кеше сез, шул кызганыч.* М.Җәлил

ПЕРСПЕКТИ́ВАСЫЗЛЫК *и.* Перспективасыз булу үзлеге. *Моннан башка проблемалар да килеп туа: инвесторлар өчен перспективасызлык, балаларны торак пунктларга кадәр кайтарып куя алмау.* Авыл таңнары

ПЕРТУРБА́ЦИЯ *и. лат. астр.* 1) Күк җисемнәренең үз орбиталарын үзгәртүе

2) *күч.* Гадәттән тыш хәл, көтелмәгән үзгәрешләр. *Мондый пертурбацияләрнең максаты акча күчерү-бүлешүләр дә булуы ихтимал.* Безнең гәҗит

ПЕРФО- *лат.* Кушма сүзләрдә «тишекле» мәгънәсендәге беренче кисәк (мәс., *перфокарта, перфолента*)

ПЕРФОКА́РТА *и. лат.* Кодлаштырып бирелгән мәгълүматы булган, стандарт формадагы һәм зурлыктагы карта. *Дәресләрдә --- перфокарта, таблица, диаграмма, башка күргәзмә әсбапларны киң файдалану теманы күрү, ишетү әгъзалары аша берьюлы хәтергә беркетү мөмкинлеген бирә.* И.Мостафина. *Галәмәт зур җиһаз перфокарта ярдәмендә генә эшли иде.* Кызыл таң

ПЕРФОРА́ТОР *и. лат.* 1) Тау токымнарын, бетон, асфальт һ.б.ш.ны бораулый торган машина. *Ул кичне йокыбыз йокы булмады, квартирның бер ягында перфоратор тавышы --- шактый вакыт ишетелеп торды...* Туган як. *Аларга профессиональ перфоратор һәм газон чапкычы бирелде.* Татарстан яшьләре. *Беркөнне кичен, бөтен кеше ял итәр вакытта, өстәме, астамы, әллә күршедәме шунда, перфоратор үкертә башладылар.* Безнең гәҗит

2) Кәгазь, катыргы, кинотасма кырыйларына тишекләр тишә торган әсбап

3) Перфокартага кодлаштырып бирелгән мәгълүматларны яздыру җайланмасы. *Электромагнитик перфоратор*

ПЕРФОРА́ЦИЯ *и. махс.* 1) Нидидер махсус корал белән тишекләр ясау. *Аңа станокларны тоташтырырга, перфорация машиналарын эшләтергә, хезмәткәрләрне аларда эшләргә өйрәтергә туры килә*

2) Нинди дә булса материалга махсус кораллар белән тишелгән тишекләр. *Быел ачык, якты төсләр, гадәти булмаган фактура һәм бизәкләр (мәсәлән, перфорация), төрле аксессуарлар (мәсәлән, бантлар), нәфис образлар модада.* Безнең гәҗит

3) *мед.* Ялкынсынудан барлыкка килгән тишекләр. *Күзәнәкләрнең аркылы тышчасында бер кечкенә тишек (перфорация) урнаша, аның аша үткән плазмодесмалар ярдәмендә күзәнәкләр бер-берсе белән тоташа.* Балалар сәламәтлеге турында китап. *Шуларның иң киң таралганнары – кукәй күзәнәгенең өлешчә калуы, --- перфорация; кольпит, аднексит, эндометрит кебек авырулар.* Безнең гәҗит

ПЕРФОРА́ЦИЯЛӘНҮ *ф.* Тишекләнү. *Конверт читләре перфорацияләнгән, почта аша килгән шушы корреспонденцияне саклык белән ачарга кирәк була ---.* Акчарлак

ПЕРЧА́ТКА *и. рус* 1) Һәр бармак өчен аерым-аерым бармакчалы кул киеме; бишбармак. *Барый керфекләренә сарган бәсне мамык перчаткасы белән сыпырып алды ---.* М.Галәү. *Заводның складлары да ачык, андагы перчатка, бияләй кебек нәрсәләрнең һәммәсен дә Кызыл Армия частьларына тапшыралар.* Х.Мөҗәй. *Перчаткаларны бәйләргә колхоз идарәсендә табельщица булып эшләүче Гаделия керергә тиеш иде.* М.Мәһдиев

2) *спорт* Боксёрлар кия торган калын, авыр бияләй. *Перчатка кигәч авыртмый инде, аннары, рингка чыккач, авыртуны бөтенләй тоймыйсың.* Туган як

◊ **Перчаткадай алмаштыру** Сирәк үзгәртелә торган нәрсәләрне еш алмаштыру. **Перчаткадай алмашыну** Бик еш алышынып тору. *Сугыш тирәсендәге авылларда власть перчаткадай алмашынып торды.* Г.Бәширов. **Перчатка кебек алмаштыру** *к.* **перчаткадай алмаштыру**. **Перчатка ташлау** 1) *иск.* Дуэльга чакыру билгесе итеп, берәрсенең аяк астына перчаткаңны салып ыргыту; 2) Көрәшкә чакыру, берәрсе яки берәр нәрсә белән ачык көрәшкә чыгу. *Үз сүзе белән әйткәндә, «кара икмәк ашап үскән» Г.Камал --- бу тормышка дошман булып кала һәм үзенең миссиясен ул тормышка перчатка ташлау белән тәмамлый.* М.Гали. **Перчатка урынына алмаштыру** *к.* **перчаткадай алмаштыру**. *Безнең Оля ул егетләрне перчатка урынына алмаштырып тора.* Ф.Яруллин

ПЕСЕТА *и. исп.* Испаниядә акча берәмлеге. *Безнең инде алтмыш өч песета акчабыз бар.* А.Әхмәт

ПЕСИ *и.* 1) *сөйл. к.* **мәче**. *Тычкан өчен песи дә – зур ерткыч.* Мәкаль. *Шуннан өй эченә сузылган ак ефәк бау төсле кояш яктысына песи кызыл борынын китереп куйды…* Г.Бәширов. *Мыегы белән кытыклап, Песи ята мыраулап.* Ш.Галиев

2) Талның йомшак чәчәк бөреләре. *Табигать кыш белән саубуллашты. Бозлы елга читләрендә, ерым буйларында, үзәнлекләрдә үскән кызыл талда йөнтәс песиләр кабарынды.* Р.Сверигин. *Песине тычкан ашый, дип, Шаяртмыйм ла мин сине. Болар бит чын песи түгел, Болар бит – тал песие!* Ш.Галиев

3) *күч.* Эләргә җайлы булсын өчен, шапылдык белән таралган бер уч чамасы мамык. *Бер орчыкны тутырыр өчен, унбишләп песи кирәк*

◊ **Песи борын** Кыска гына төз борын. *Песи борынлы, ак алъяпкычлы җилбәзәк асрау Хәсәнне --- бер бүлмәгә алып керде.* Ф.Әмирхан. **Песи булу** Тавыш-тынсыз калу. **Песи кебек** Бик тыйнак, тавыш-тынсыз гына. *Әле дә ул ишек янына песи кебек кенә атлап килде дә шомарып беткән баганага сөялеп торган кораллы сакчының якасыннан эләктереп алды.* Н.Фәттах. **Песи учы кадәр** Бик кечкенә мәйдан турында. *Австриядәге крестьяннарның җирләре песи учы кадәр генә: бер таяк кукуруз, бер таяк бәрәңге.* А.Таһиров. **Песи шикелле** *к.* **песи кебек**. *Мин, серне бирмәскә тырышып, песи шикелле генә тыңлап утырам.* А.Шамов. *Расиха инде тынычланып өлгерде, иплэп кенә, песи шикелле йомшак басып килде дә Мирзаханны кочаклады.* Р.Батулла. *Әйтәм бит, бигрәк мокыт иде дип, табын янында да песи шикелле генә утыра иде.* Ватаным Татарстан. **Песием генә** Бик тыйнак кына, шым гына. *Хәлфә килеп җиткәндә, --- малайлар песием генә булып калалар.* Г.Бәширов

ПЕСИБАШ *и. бот.* Кузаклылар семьялыгыннан тармакланып үскән туры озын сабаклы, оешма чәчәкле берьеллык үлән үсемлек; *русчасы:* **клевер пашенный**

ПЕСИ́ БОРЧАГЫ *и. бот. к.* **мәче борчагы**. *Песи борчагы тамырыннан эшләнгән дару препаратлары, башлыча, --- йомшарткыч һәм ялкынсынуларга каршы чара сыйфатында кулланыла.* Урман аптекасы

ПЕСИ́ БӨТНЕГЕ *и. бот. к.* **мәче бөтнеге**

ПЕСИ́ ГӨЛЕ *и. бот.* Яранчалар семьялыгыннан бүлмә гөле итеп яки эфир майлары алу өчен үстерелә торган ак, кызыл, алсу чәчәкле үлән үсемлек; яран. *Аларны шулай ук нәркәмәс гөле, песи гөле, песи тәпие, песи борчагы дип тә йөртәләр.* Шәһри Чаллы

ПЕСИ́ КАТЛАМАСЫ *и. бот.* Тырнакгөлчәләр семьялыгыннан түгәрәк яфраклы, яшь орлыклары ашарга ярый торган үлән үсемлек; *русчасы:* **просвирник**

ПЕСИ́ КОЙРЫГЫ *и. бот.* **мәче койрыгы**. *Бик матур исемле «Идиллия» кибете каршында шундый ямьсез күренеш: алабута, песи койрыгы кебек чүп үләннәр үсеп утыра.* Кызыл таң

ПЕСИЛӘНҮ *ф.* 1) Юашлану, тыйнаклану

2) Песиләр чыгару (тал тур.)

Песиләнә башлау Песиләнергә тотыну. *Әле март ахыры гына булуга карамастан, тал песиләнә башлаган*

Песиләнеп килү Акрынлап, азаслап кына песиләнү

Песиләнеп китү Соңгы арада песиләнү

ПЕСИЛЕ ТАЛ *и. бот.* Талчалар семьялыгыннан су буйларында үсә торган йонлач бөреле агач яки куак үсемлек; кызыл тал; *русчасы:* **верба**. *Песиле талларның ботакларын, өйгә алып кайтып, сулы савытка утыртсаң, --- өеңә тынычлык килә, тәнеңә тидерсәң – сихәтләнәсең, дигән ырым яши.* Ватаным Татарстан. *Песиле тал ботаклары им-дәва көченә ия дип исәпләнә.* Хезмәт даны. *Песиле һәм башка таллар бары тик 12–15 апрельдән соң гына чәчәк ата.* Якты юл

ПЕСИ́-ПЕСИ *рәв.* Тавышсыз, юаш кына; мескен кыяфәт белән. *Песи-песи генә йөрү*

ПЕСИТАБАН *и. бот.* Тырнакгөлчәләр семьялыгыннан сары чәчәк ата, биек булып үсә торган үлән үсемлек; *русчасы:* **бессметрник**

ПЕСИ́ ТАРЫСЫ *и. бот. к.* **песи койрыгы**

ПЕСИ́ ТӘПИЕ *и. бот. к.* **песи борчагы**. *Песи тәпие (кошачья лапка) – майда, июньдә чәчәк ата*. Ватаным Татарстан

ПЕ́С ИТҮ *ф. сөйл.* Балалар телендә сию. *Похмельдән интеккәндә йөрим тегенең капка төбендә, пес итәсе килгән мәче кебек ---.* Ф.Бәшир. *Чыннан да, эт пес итеп киткән җирдә сабыйлар уенчыкларына ком тутырып уйный бит*. Ватаным Татарстан. – *Бабай, пес итәсем килә! – дип кычкыра өч яшьлек оныгым.* Татарстан яшьләре

ПЕСИ́ ҮЛӘНЕ *и. бот. к.* **валериан**. *Песи үләне ярсучан, актив, шулай ук тиз генә йокыга китә алмаган, тынычсыз йоклаган балаларга килешә.* Ватаным Татарстан. *Песи үләне, мәтрүшкә, бөтнек төнәтмәләре эчү тынычландыра.* Мәдәни җомга

ПЕСИ́ ЯФРАГЫ *и. бот. к.* **песи гөле**. *Тәрәзә төпләрендә – песи яфрагы, ак кына гөлләре.* Г.Әпсәләмов

ПЕСК *иярт.* Нечкә генә тавышлар чыгарып чыелдау, пипелдәү авазын белдерә

ПЕСКӘЙ *и.* Песине иркәләп атау, аңа иркәләп эндәшү сүзе. *Мияу-мияу пескәем, Хыянәтче икәнсең – Саклый торган маеңны Үзең ашап киткәнсең.* М.Җәлил. *Каратуп исемле пескәй моңа бик үпкәләгән.* Р.Батулла. *Кечкенә йомшак пескәй дә бер кочак авыру бүләк итәргә сәләтле бит.* Безнең гәҗит

ПЕСКЕЛДӘҮ *ф.* Песк-песк итү. *Радиоалгычлар эфир белән тоташуга, бүлмә эче морзе әлифбасының пескелдәүләре белән тула.* Ш.Маннур

Пескелдәп тору Бертуктаусыз пескелдәү

ПЕСНӘК *и. зоол.* Чыпчыксыманнар отрядыннан кечерәк кенә чуар сайрар кош. *Кунма син, песнәк, Агач башына, Мин бодай чәчтем Тәрәз каршына.* Г.Афзал. *Кайвакыт шул каен ботагына кара бантлы, яшел түшле песнәкләр килеп куналар да үз телләрендә нәрсәдер сөйләшергә, сайрашырга тотыналар.* Ф.Яруллин. *Татарстанда песнәкләрнең тагын берничә төре яши: күк песнәк, көрән башлы песнәк, кара песнәк, бүрекле песнәк һ.б.* Татарстанның үсемлекләр һәм хайваннар дөньясы

ПЕ́СО *и. исп.* Испаниянең элекке колонияләре булган кайбер илләрдә акча берәмлеге. *Мексика укытучылары профсоюзы җитәкчесе Эльба Эстер Кордильо 2,5 млрд. песо яки 160 миллион долларга якын акча исраф итүдә гаепләнә.* Безнең гәҗит

ПЕ́С-ПЕС *ы.* Песиләрне чакыру сүзе. *Күмәчләрен инде калдырып китсәм, песи-мазар тияр микән, рәхмәт төшкере? Пес-пес, пес-пес!.. Песие югын юк, ахры.* М.Фәйзи. *Императив ымлыкларга шулай ук кош-кортларны, хайваннарны чакыру, куу сүзләре дә керә: көш, прес, пес-пес, mah-mah, чәбә, на, на-на, ти-ти-ти һ.б.* Ф.Хисамова. *Без аларны «пес-пес-пес» дип чакырабыз, «перс!» дип куабыз.* Сабантуй

ПЕССИМИЗМ *и. лат.* Өметсезлек, төшенкелек, дәртсезлек; киләчәкне бары тик начар итеп кенә күзаллау. *Аннан соң язган «Соранучылар» (1903) һәм «Тәмуг» (1908) атлы романнары да шундый ук разыйсызлык, күңелсезлек һәм пессимизм белән сугарылган иделәр.* М.Җәлил. *1908–1910 елларда Тукай поэзиясендә күз яше, кайгы-хәсрәт мотивлары, пессимизм элементлары арта.* И.Нуруллин. *Пессимизмга бирелүдән котылу өчен, Финляндия татарлары эшчәнлегеннән үрнәк алу зыян итмәс.* Ә.Кәримуллин

ПЕССИМИСТ *и. лат.* **1.** Бик тиз төшенкелеккә, өметсезлеккә бирелә торган, рухи яктан көчсез кеше. *Ул, пессимист кебек, һәрнәрсәгә шикләнеп карый, ләкин оптимист кебек хәрәкәт итә иде.* С.Максуди. *Уң ярымшар өстенлек итә башласа, кәефнең яхшыруын көтмә, андый кешене күңелсез уйлардан аерып алып булмый. Ул – аермачык пессимист.* Могҗизалар энциклопедиясе. *Ата-анадан күргән тәрбиясе, күңелсез тормыш тәҗрибәсе кешедән пессимист ясаган кебек, тарихи уңышсызлыклар да тулы бер халыкны пессимист итәр.* Ватаным Татарстан

2. *с. мәгъ.* Төшенке күңелле, тиз өметсезлеккә бирелә торган. *Лекцияләрдә Йосыф бәй белән бергә булдык, һәм мин аның укуны, уйлануны яраткан, дөреслекне эзләгән, тик табачагына бик ышанмаган, бераз пессимист кеше икәнен аңладым.* С.Максуди. *Бүгенге пассив, пессимист яшьләргә аннан күпме үрнәк аласы бар!* Шәһри Казан. *Ярты тартма чикләвек күргән пессимист тиен: «Уф! Яртысы беткән бит!» – дип борчылган.* Татарстан яшьләре

ПЕССИМИ́СТИК *с.* Пессимизм белән сугарылган. *Тукайның лирик герое еш кына, тормышта мәхәббәт сафлыгына урын юк, инде яратудан баш тартырга кала дип, күңеле олы хисләрдән тәмам бушаган пессимистик рухлы бер шәхес булып күз алдына торып баса.* Р.Рахман. *– Кем әйтмешли, минем пессимистик шигырьләремнең кемгә кирәге бар? – диде Сәгыйть Рәми.* Р.Батулла. *Шул рәвешле, пессимистик уйларга бирелеп, юк-барга борын салындырып йөрүебездә тышта коеп яуган яңгырның да, ишеп яуган карның да бер мыскал гаебе юк икән!* Татарстан яшьләре

ПЕССИМИСТЛА́РЧА *рәв.* Пессимистларга хас булганча, төшенке рухта. *Ул күп очракта пессимистларча куркып, шикләнеп эш итә*

ПЕССИМИСТЛЫК *и.* Пессимист булу үзлеге. *Бу романтика һәм пессимистлык әнә шул вак буржуа психологиясеннән килде.* М.Җәлил. *Белгечләр фикеренчә, пессимистлык шулай ук хезмәт җитештеручәнлеге кимүгә һәм эмиграциягә бер сәбәп булып тора.* Ватаным Татарстан. *Аннан, җырга пессимистлык ноталары салынмаган: ул позитив рухны саклый.* Шәһри Казан

ПЕСТӘ *и. бот. үйг.* Сумахчалар семьялыгыннан җылы якларда үсә торган каурыйсыман яфраклы агач; *русчасы:* **фисташка**. *Мондагы сый-хөрмәт инде Казандагы татарларныкына охшаш: кура җиләге кагына йөзем, өрек күрәгә, кара җимеш, пестә чикләвеге өстәлә.* Казан утлары. *Бәхет агачын чүлмәккә утыртканнан соң, каткан цемент өстенә дөге, вак ташлар белән ком, төсле тоз сибә аласыз, нарат күркәсе, кабырчык, каһвә бөртекләре, пестә (фисташка) чикләвеге түшәргә мөмкин.* Шәһри Казан

2) Шул агачның яшькелт яки коңгырт яшел төстәге чикләвеге

ПЕСТИЦИД *и. лат.* Үсемлек кортларына һәм авыруларына, шулай ук чүп үләннәренә, йогышлы авырулар таратучыларга каршы көрәшү өчен кулланыла торган химик матдәләрдән торган кушылма. *Беренче тапкыр кулланыла торган пестицидларның кешеләргә нинди зарарлы яклары барлыгын бригадир да белергә тиеш бит.* Р.Ишморат. *«Пестицидсыз» дип тә куйганнар, тик монысы инде ышанырлык түгел: бал кортының нинди үсемлеккә кунганын бер Ходай гына белә.* Н.Измайлова

ПЕТА́РДА *и. фр.* 1) Эченә дары тутырылган металл савыттан гыйбарәт борынгы шартлаткыч төре

2) Фейерверк итеп кулланыла торган дарылы пиротехник эшләнмә. *Мәктәптән кайтучы малайларның петарда белән шаяруы икән. Иң арзанлы ике сумлык петарда да фажигагә китерергә мөмкин бит.* Татарстан яшьләре. *Яңа ел бәйрәме якынлашкан саен, пиротехник җиһазлар: петарда, фейерверк, ракеталар, салют, хлопушка, бенгаль*

уты кебек уенчыкларга тартыла башлыйбыз. Безнең гәҗит

ПЕТИТ *и. фр.* Басма шрифтның вак төрләреннән берсе. *Наборныйда петит җитешми.* М.Җәлил

ПЕТИ́ЦИЯ *и. лат.* Хөкүмәт органнарына язма формада тапшырылган коллектив үтенеч. *Без дә, мәсьәләне бик әтрафлы һәр яктан тикшереп, петиция яздык.* А.Расих. *Кырым татарлары, үзләренең милкен кайтару буенча, петиция компаниясен башлый.* Ватаным Татарстан

ПЕТЛИ́ЦА *и. рус* Хәрби һ.б. форманың якасына дәрәҗәне, чинны аеру билгесе итеп тегелгән тукыма кисәге, төсле тасма. *Сырма якасына яшел петлица тегеп, биленә наган аскан ирдәүкә хатын пәйда булып, юлыма аркылы төште.* З.Хәким. *Табылган сөякләр, петлица, 15–20 тиен акчалар турында тиз арада «Солдат.ру» сайтын оештырган Игорь Ивлевка хәбәр ителә.* Кызыл таң

ПЕТРОГРА́ФИК *с. минер., геол.* Петрография белән бәйле. *Акбур чорының исеме, ташкүмернеке кебек, катламнарның петрографик составына бәйле, чөнки алар арасында акбур катламы бигрәк тә күп таралган.* Фән һәм тел

ПЕТРОГРА́ФИЯ *и. гр.* Тау токымнарының минераль составын, яту шартларын һәм аларның тарихи чыгышларын өйрәнә торган фән. *Шул рәвешле, яшь буынның геология җене кагылганнары Татарстан төбәгенә җир турында белем эстәргә килә, шуңа күрә мәктәп балаларының палеонтология, петрография, минералогия, кристаллография, геохимия, экогеология, структур геология, тарихи геология, инженерлык геологиясе, гидрогеология, файдалы казылмалар геологиясе һ.б. буенча алган белемнәрен гамәлдә файдалану юнәлешендә эш оештырыла.* Татарстан яшьләре

ПЕТРУ́ШКА *и. лат. бот.* Чатырчәчәклеләр семьялыгыннан ак тамыры кишерне хәтерләтә, яфраклары һәм тамыры аштәмләткеч буларак кулланыла торган үсемлек. *Тагын бер мәртәбә гафу үтенәм, петрушка беткән иде, аның урынына укроп белән бизәсәк ярамасмы?* Ф.Хәбибуллин. *Тамыр һәм яфрак петрушкасы була. Тамыр петрушкасының ашка яфракларын да, азыктамырларын да, ә яфрак петрушкасының яфракларын гына файдаланалар.* Бакчачы, яшелчәче һәм умартачы календаре

ПЕТУ́НИЯ *и. лат. бот.* Паслёнчалар семьялыгыннан төрле төстәге эреэре чәчәкле декоратив үлән үсемлек. *Гадәттә, петуния --- чәчәкләре алып кайтабыз, алар көзнең соңгы көннәренә кадәр тирә-юньне ямьләндереп «утырачаклар».* Өегез ямьле булсын. *Май аенда без түтәлгә төрле төстәге петуния үсентеләрен утырттык.* Мәдәни җомга. *Әнә Кадрия апа ел саен тәрәзә төбендә петуния рассадалары үстерә.* Байрак

ПЕХО́ТА *и. рус* Җәяүле гаскәр. *Дивизиянең башка полклары исә, үз урынларында калып, Кунья елгасы буенда дошманның күпсанлы танкларына һәм пехотасына каршы каты сугыш алып бардылар.* Г.Сафиуллин. *Оренбургта Александр II кадетлар мәктәбенә, аннан төрмәгә, гарнизон пехота казармасына, Неплюев хәрби мәктәбенә, больницага бара.* Татар әдәбияты тарихы

ПЕХО́ТАЧЫ *и.* Пехотада хезмәт итүче солдат. *Карасалар, бу бер яралы пехотачы икән.* Х.Камалов. *Өч йөзләп пехотачы, мылтыкларына багинетларын беркетеп, саф-саф булып, тауга үрмәли башладылар.* И.Хуҗин. *Пехотачы Рәшит, мылтык күтәреп, җәяү Мәскәүдән Берлинга кадәр барып җитә.* Шәһри Казан

ПЕЧӘН *и.* 1) Мал-туарларга азыкка дип махсус үстерелә яки болыннарда, аланнарда үзеннән-үзе үсә торган үлән. *Быел исән-сау булсак, һава шартлары да уңайлырак килсә, иген уңышы да, печән уңышы да яхшырак булыр, дип торабыз.* Р.Ишморат. *Кая ул анда бездәге шикелле үз иркендә урак уру, печән чабулар!* Г.Бәширов. *Дымлы җир. Печән котырып үсә.* Я.Абдуллин

2) Мал-туарга азыкка дип чабылган яисә чабып киптерелгән үлән. *Әти астан печән биреп тора, абый өстән өеп тора.* Г.Бәширов. *Арыш саламы белән тотылгач та ярты кышлык печәнемне совхозга тапшырдым бит, хәтерлисеңдер...* З.Хәким

3) *сөйл.* Печән чабу эше. *Озакламый печән өлгерә, кешеләрең күп өлеше печәндә булачак.* Ш.Камал. *Әле Хәнәфи туганга әйттем, печәнгә кешене күбрәк җибәр, дидем.* Г.Әпсәләмов. *Аннан печәнгә төшәсе, игеннәрне урып-җыясы бар иде.* М.Мәһдиев

◊ **Печән өсте** Печән чабу вакыты. *Печән өсте, шуңа ялганып урак өсте килә.* Р.Ишморат. *Менә печән өсте дә җитте.* Г.Бәширов

ПЕЧӘНЛЕК *и.* 1) Печәнгә яраклы яшел үлән үсә торган болын, тугай яки алан. *Үзебезгә һәйбәт печәнлек чыгартасым килеп, мин дә һаман картлар тирәсендә бөтереләм... Көтмәс идең, начар печәнлек чыкса, әти, кашларын җимереп, тагын да кырыслана төшәчәк.* Г.Бәширов

2) Печән саклау өчен махсус ясалган урын. *Печәнлектә, бөтен фани дөньяның мәшәкатен онытып, сабый балалар йокысы белән ике яшь егет мышныйлар.* М.Мәһдиев. *Әйдә печәнлеккә! Анда бер уч та печән әсәре юк.* Н.Гыйматдинова. *Хуҗалыкта карамаган урын калмады. Печәнлекне актарырга керештеләр.* Н.Ямашев

ПЕЧӘНЧЕ *и.* 1) Печән чабу, җыю, өю эшләрендә катнашучы кеше. *Бөтен болын өстенә, күз күреме җирне чуарлап, әллә никадәр печәнче сибелгән.* Г.Бәширов. *Якында гына печәнчеләр кунып ята иде.* М.Мәһдиев. *Ә син үзең печәнче эзлисең, үзең шәһәргә китәргә җыенасың. Моны ничек аңларга?* А.Хәлим

2) *зоол.* Саранчасыманнар семьялыгыннан көтүлекләргә, печәнлекләргә зур зыян сала торган корткыч вак чикерткә; *русчасы:* **кобылка**

ПЕЧЕ́НЕГ *и. к.* **бәҗәнәк**. *Чынлап та, үткән җан исәбен алу вакытында, үзләрен эльф, гот, печенег, тагын әллә кемнәр дип яздыручылар булган.* Өмет

ПЕЧЕ́НЬЕ *и. рус* Татлы камыр кисәгеннән төрле формалар ясап пешерелгән кондитер ашамлыгы. *Комодыннан алып, печенье кебек нәрсәләр куйды.* Г.Исхакый. *Иртәгесен ул бездән*

алдарак торган да, ваннага кереп, Федяны печенье вагы белән сыйлап маташа. М.Мәһдиев. *Кочак-кочак лимонад, вафля, печенье алабыз.* З.Мәхмүди

ПЕЧТЕК *с. сөйл.* **1.** Бик аз, аз гына. *Иртәгә Шидловский килеп төшә, дигән көнне печтек кенә чатаклык булып алды.* А.Гыйләҗев. *Алай булгач пианино нәрсәгә ул, дисезме? Печтек кенә бер сер белән Алдым мин ул юньсезне.* Ф.Яруллин. *Әмма икенче яктан... үз алдыңа максат куй да, ниндидер бер печтек кенә каршылык, күзгә ташланырлыгы да булмаган киртә аркасында шуннан баш тарт, имеш!* Ж.Юныс

2. *рәв. мәгъ.* Аз гына, чак кына, бераз, күп түгел. *Әни, дим, печтек кенә бирерсең инде, яме.* Г.Галиева. *Әйе, дип уйлады Тимер, аз-маз укыган һәм башында печтек кенә булса да мие бар кеше беркайчан да акылны эт белән чагыштырырга тиеш түгел.* Г.Рәхим. *Тормаслар, әле тагын әз генә, печтек кенә булса да иркәләнеп ятарлар, сыңар күзләрен генә йомып черем итәрләр иде, ярамый.* Н.Әхмәдиев

ПЕЧТЕ́Р-ПЕЧТЕР *иярт. к.* **пычтыр-пычтыр**. *Лилия суны яратмый, Суга керми ялгыш та. Урдәк кебек, печтер-печтер Юына ул ялгашта.* Г.Гыйльманов. *Печтер-печтер пычрак кар суы ерып, кар атышырга хыялланып йөр әле син!* Шәһри Казан

ПЕЧТЕРҮ *ф. йөкл. юн. к.* **печү** (*1, 2 мәгъ.*). *[Кара Гобәй:] Бик шәп айгыры бар. Шуңа бар, сатып ал шул айгырны. Печтереп, алаша итеп җигәрсең.* З.Зәйнуллин

ПЕЧҮ *ф.* 1) Иркәк хайванның аталык бизләрен кисеп алу яки орлык каналын өзеп бәйләү. *Баш ветврач Черипанов авыл халкына таныш. Ел саен айгырлар печәргә килә.* Х.Камалов. *Аның карчыгы Нәсимә әби тәкә печә иде.* Н.Гыйматдинова. *Печәргә кирәк моны. Печкән дуңгызлар тизрәк симерәләр дә.* Аманулла

2) Тоташ тукымадан кием кисү. *Ике каен кистем бер эздән, Ике күлмәк печтем бер бүздән.* Җыр. *Атасыннан күргән ук юныр, анасыннан күргән тун печәр.* Әйтем. *Киемчегә рөхсәт бетәр Тар чалбарлар печәргә.* М.Укмасый

3) *күч.* Артык кыскарту, күләмен киметү. *Соңгы повестен «Казан утлары»нда шактый гына печеп тә чыгардылар, кыскарттырып, үлгән геройларын терелттереп, кискенрәк урыннарын шомарттырып интектерделәр...* Р.Миңнуллин. *Тукайның каләмен җаныңа канына манып язган шигырьләрен печеп, турап бетерделәр.* Р.Батулла

4) *күч.* Кемне дә булса бик нык алдау, алдап, берәр нәрсәсез калдыру. *Эчкән – үзен үзе печкән.* Әйтем. *Әй ант эчтек, ант эчтек. Үгез дип тана печтек.* Р.Фәйзуллин

Печә башлау Печәргә тотыну. *Март кояшының җылысында рәхәтләнеп кенә утарда сикерешеп йөргән кырыкмышларны печә башлыйлар.* М.Мәһдиев

Печеп алу Тиз генә, кыска гына вакыт эчендә печү. *Кисмәк төбенә ризык куеп, кисмәкне аударуга, дуңгыз шуның эченә башы белән кереп китә икән. Ветсанитар кисмәкне бастырып та куя, шырыйлатып, тегене печеп тә ала икән.* М.Мәһдиев

Печеп бетерү Барсын да печү. *Кызыл замана албастысы шагыйрьләрне никадәр генә печеп бетерергә тырышмасын, ул үзенең иң заманча шагыйрен дә ахыргача үтереп бетерә алмаган икән.* Р.Хисмәтуллин

Печеп йөрү Бик күптәннән, һәрвакыт печү. *Әнә керәшен Вәчили гомере буе ат печеп йөри. Рәхәттән йөриме әллә?* Г.Сабитов

Печеп ташлау Озак уйламыйча, тиз арада печү. *Узган ел кыш ул җигеп йөргән җирән яшь айгырны, әллә нәрсәсенә генә үҗәтләнеп, ветфельдшер печеп ташлаган.* М.Мәһдиев

Печеп тору Әле, хәзерге вакытта печү

ПЕШЕ *с.* 1) Сыгылмалы һәм нык. *Чыбыкны пеше чакта бөгәләр.* Мәкаль. *Габдулланы, бәлки, ай-ваена куймый, төртеп чыгарган да булырлар иде, әмма шул вакыт әлеге фәррашның, кереп, шау-шуны басар өчен, кулындагы пеше чыбыгы белән шәкертләр өстеннән уңлы-суллы чажлатып, селтәнеп алуы --- белән Габдулла мәсьәләсе оныгылды.* Ә.Фәйзи. *Күрше малайларның --- әтиләре --- матча ярыгында тал чыбык тота. Чак кына шуклык күрсәттеләрме, пеше тал чыжларга керешә.* Ә.Баян

2) *күч.* Эшкә нык, уңган, булдыклы. *Бик пеше кыз икән бу, бер дә эшләмәгән эше юк*

ПЕШЕГҮ *ф.* Эсседән яки башка тәэсирләрдән тән тиресе кызарып бозылу. *Плауннарның спораларын медицинада яшь балаларның пешеккән урыннарына сибү өчен --- кулланалар.* Биология. *Ике-өч көн шулай әйбер ташый торгач, түзмәдем: «Нишләп глюкоза, балага пешеккәннән сибә торган порошок кебек вак-төякне дә бездән сорыйсыз, тудыру йортларын дәүләт тәэмин итмимени?» – дидем, озын телләнеп.* Татарстан яшьләре

Пешегә башлау Пешегергә тотыну

Пешегеп бетү Тәмам, бик нык пешегү. *Кызчыкның тәне пешегеп беткән*

Пешегеп китү Бераз, берникадәр пешегү. *Бала пешегеп киткән*

ПЕШЕК *и. диал.* 1) Эссе пар, кояш нурлары һ.б. тәэсирендә тиредә барлыкка килә торган кабарчык, түгәрәк кызыл тимгел. *Тәнгә пешек чыгу*

2) Артык эсселектән агач кәүсәсендә барлыкка килә торган чәер. *Ак чыршының җептән юнылган ботак урыннарыннан, тамчы-тамчы булып, сары бал төсле пешек сытылып чыккан.* Н.Фәттах

ПЕШЕКЛӘГЕЧ *и. к.* **парлагыч** (*1 мәгъ.*)

ПЕШЕКЛӘ́Ү *ф.* 1) Чи нәрсәләрне йомшарту, чистарту өчен, кайнар суга салып алу. *Тавыкмы, казмы, күркәме – күзенә нәрсә элгәгә, тота да чала, йолкый, пешекли, камыр баса, токмачын кисә, ашын пешерә ---.* А.Хәлим. *Эчкарынны пешекләү. Эчәкне пешекләү*

2) Йомшарту, пешерү өчен, кайнар суга салып җебетү; парлау. *Бүген иртән карт келәт буеннан кычыткан җыеп керде, карчыгы аны кайнар суда пешекләде.* М.Мәһдиев. *Чи баланны сытып, кайнар чәйдә пешекләп эчәргә кирәк иде.* К.Кәримов

3) Дезинфекцияләү (йогышсызландыру) һ.б. максатлар белән кайнар су

белән чайкау. *Чүлмәкләрне кайнар су белән пешекләү*

4) *күч. к.* **пешерү** (*7 мәгъ.*). *Байтак интектергәч, ханым аны ачыктаначык пешекләргә кереште.* А.Гыйләҗев. *Кайтырга да бераз пешекләргә кирәк үзен.* Ф.Яхин. *Мөхәммәт абый: «О, Толстой! Ну, Толстой!» – дип, үзенчә пешекләде.* Мәдәни җомга

Пешекләп алу Тиз генә яки аз гына пешекләү. *Бүлмәләрне җыештыру да, киемнәрне үтүкләү дә, соңгарак калып килгәннәрне үз итеп кенә пешекләп алу да аның өстендә булды.* А.Әхмәтгалиева. *Кычытканны да башта кайнар суда пешекләп ала идем.* Шәһри Казан

Пешекләп кую Пешекләгән хәлгә китерү. *Кунакларны җитәкләп ләүкәгә менгезделәр дә --- алдан пешекләп куелган каен себеркесенең яфраклары коелып беткәнче чабындырдылар.* М.Галәү

Пешекләп чыгу Барысын да берәм-берәм пешекләү

Пешекли башлау Пешекләргә тотыну. *Йомры Гарифның Никтуган Әгъләметдине казаннан чүмеч белән кайнар су алып җиргә сибә, җирне пешекли башлый.* А.Хәлим

ПЕШЕКТЕРҮ *ф.* 1) *йөкл. юн. к.* **пешегү**. *Кояш нурлары тәнне пешектерергә мөмкин*

2) *к.* **пешекләү** (*2, 3 мәгъ.*) *Приказда --- «крестьяннарны җыеп суктырырга пешектерелгән чыбыклар хәзерлә» – диелгән.* Х.Кәрим

Пешектереп алу Тиз генә пешектерү. *Тал чыбыгын пешектереп алу*

Пешектереп бетерү Пешектерү эшен тәмамлау

Пешектереп кую Тиз арада пешектерү

ПЕШЕКЧЕ *и.* Аш-су әзерләүче, ашчы, повар. *Ә тукучы һәм пешекче, Кодагый карчык – кендекче, Хатынга үч тоталар. Илчене туктаталар.* А.Пушкин. *Шул бетмәс-төкәнмәс киңәшләр йөге белән, пешекче Зифа карчык «Хезмәт»кә килеп төште.* Г.Ибраһимов. *Ул, ак алъяпкыч бәйләп, башына да ак берет кигән, корабльләрдәге пешекче – кок диярсең.* А.Тимергалин

ПЕШЕКЧЕЛЕК *и.* Пешекче һөнәре, пешекче шөгыле. *Әгәр пешекчелекне дәвам иткән булсам, күптән берәр ресторан директоры булыр идем.* Шәһри Казан. *Пешекчелеккә укыса да, аңа хәзер өйдәгеләрне генә сыйларга туры килә.* Безнең гәҗит

ПЕШЕРЕНҮ *ф.* Төрле ризыклар пешерү белән мәшгуль булу. *Безнең авылда көзен хатын-кыз пешеренергә бик ярата иде.* М.Мәһдиев. *Илдус белән Илгиз икесе дә урамда, әнә Рузилә, гадәттәгечә, пешеренә иде.* Г.Мөхәммәтҗанова. *Яшелчә бүлгән көнне китә пешеренү! Чөгендер пәрәмәче, кишер бөккәне.* Казан утлары

Пешеренә башлау Пешеренергә тотыну. *[Карчык] Артык тавыш-тын чыгармыйча гына пешеренә башлады.* И.Салахов

Пешеренеп алу Тиз генә анысын-монысын пешерү

Пешеренеп йөрү Пешеренү белән мәшгуль булу. *Әбиләр янәшәдәге тәбәнәк мич казанында пешеренеп йөриләр.* Г.Гыйльманов. *Ишекне ачып өйгә керсәм, кухняда күрмәгән-белмәгән яшь кенә бер хатын пешеренеп йөри.* С.Сабиров

Пешеренеп кую Алдан пешеренеп әзерләнү

Пешеренеп тору Гел, һәрвакыт пешеренү. *Гел пешеренеп кенә торды Алинә – яшь әтәч итен дә, өчпочмагын да, бәлешен дә, шулпасын да.* Х.Ширмән

Пешеренеп яту *сөйл.* Пешеренү процессында булу. *Туйга әзерләнеп, пешеренеп ятканда, боларга бер хәерче килеп керә.* Әкият

ПЕШЕРЕНҮ-ТӨШЕРЕНҮ *ф.* Ашсу, гомумән төрле ашамлыклар хәзерләү белән мәшгуль булу. *Әни пешеренә-төшеренә. Күчтәнәчкә ул төш пешерергә ярата иде.* М.Мәһдиев. *Ничек кенә булмасын, --- яратам мин үз телендә сөйләшә, үзенчә җырлый-бии, пешеренә-төшеренә торган кешеләрне.* Татарстан яшьләре

ПЕШЕРҮ *ф.* 1) Азык-төлек әйберләрен югары температурада тотып, ашамлык итеп хәзерләү. *Галимә апаң көн саен ярмаланып торган сары бәрәңге пешерә торган иде.* Г.Бәширов. *Киндер орлыгы кушып төелгән чөгендер пәрәмәче пешерерләрме безнең балалар?* М.Мәһдиев. *Бер җомга кунак булганнан соң, Хәят абыстай Мәгъсумга кышлык киемнәр хәзерләде, яхшы ашлар пешерде.* З.Һади

2) Тән тиресен югары температура тәэсирендә авырттыру, җәрәхәтләү. *Утлы күмер белән шаярасың, кулың пешерерсең.* А.Алиш. *Аһ орырга өлгермәде, кайнар аш аның өстенә түгелде, аякларын-кулларын пешерде.* Ф.Яхин

3) Кайнатып яки кайнар суга салып, тәмен, шифасын чыгару. *Яулык очын иреннәре белән капкан килеш, кайнатасына янбашы белән торып, чәй пешерергә кереште.* Р.Батулла. *Дару үләннәре пешерү*

4) Сыгылмалы итү өчен, кайнар суда яки парда тотып җебетү, пешекләү. *Тыштан: «Хәлим улым, чык, мунчаны юып чыгардым, миллекне пешердем, чык...» – дигән тавышы ишетелде.* Г.Гыйльманов. *Тал чыбыгы пешерү*

5) Кояш турында: һаваны бик нык эсселәтү, кыздыру. *Ә синең мәңге түбә астында, өстән яумый, кояш пешерми.* Г.Гобәй. *Әле кояш пешерә, әле җылы җил назлап, яфраклар шавында йокыга талдыра.* А.Нәҗми

6) Кайнатып эшкәртелә торган берәр фабрикатны әзерләү. *Гали җәй көне, тәгътыйль вакытларында, атасы янында заводта сабын пешерергә өйрәнә торган иде.* Ш.Мөхәммәдев

7) *күч.* Ачулану, бик нык тиргәү, орышу. *Икенче көнне, --- Фәсхине тауга алып чыгып, Искәндәр качып торган җиргә китереп, бик яхшылап, тәүбә иттергәнче пешердек.* Ш.Усманов. *Көннәрдән бер көнне әти аны чакыртканда яхшылап кына пешергән ---.* Г.Толымбай

8) *күч.* Сугышта дошманга җимергеч ударлар ясау, тукмау. *Эх, пешердек Японны без Хасан күле буенда.* Ә.Ерикәй

9) *күч.* Кирәген бирү, җәзалау. *«Кулакларны пешерәләр икән», – дигән җылы хәбәр ишетелгәч, прокурор ярдәмчесе янына ул да үзе килде.* Г.Толымбай

Пешерә башлау Пешерергә тотыну. *Поход кухнялары, урамнарны*

төтенләтеп, итле аш һәм карабодай боткасы пешерә башладылар. Г.Бәширов. *Телефон трубкасы Искәндәрнең кулын пешерә башлагандай тоелды.* Р.Вәлиев

Пешереп алу Тиз генә пешерү. *Егет тиз генә бер җиләкне өзеп авызына каба һәм шунда ук кире төкерә. Авызын җиләк пешереп алгандай була.* Агулы үсемлекләр. *Яратмаса, якын итмәсә, егетнең иреннәре Кәримәне алай пешереп-пешереп алыр идемени?* С.Шәмси

Пешереп бетерү Пешерүне төгәллә. *Әни, коймак пешереп бетергәч, чәй хәзерли башлады.* М.Гафури

Пешереп җиткерү Пешеп җиткәнче пешерү; чиле-пешле калдырмау

Пешереп йөрү Әле, хәзерге вакытта пешерү. *Васфикамал бүген эшкә чыкмаган, мунча яккан һәм бәрәңге пәрәмәче пешереп йөри иде.* М.Мәһдиев

Пешереп кую Алдан пешеренеп әзерләнү. *Күрше әбисе пешереп куйган карабодай боткасын ашап, бакчадагы беседкага чыгып аварга иде.* Г.Бәширов

Пешереп тору Әле, хәзер яки гел, әледән-әле пешерү. *Сәйләнәнең анасы Фәтхия алардан китми, булыша, бала караша, кирәк булса, ашарга пешереп тора.* Р.Батулла

ПЕШЕРҮЧЕ *и. к.* **пешекче**. *Абыстайның бер-ике асрау кызы, аш пешерүче хатыннары да бардыр.* Ш.Мөхәммәдев

ПЕ́Ш ИТҮ *ф. сөйл.* Балалар телендә пешү. *Якын барма, пеш итәрсең!*

ПЕ́ШКА *и. рус* 1) Шахмат уенында иң түбән дәрәҗәле фигура, пиядә. *Уйнаганда, берәр пешка отса, Берлинны алгандай сөенә, үзенекен ашасалар, башын учлары белән кочаклап, коридор буйлап йөренә.* Т.Миңнуллин. *Пешка белән йөрү. Пешкалар һөҗүме*

2) *күч.* Дәрәҗәсе түбән кеше, буш кеше. *Попов кебек кешеләр алдында син гап-гади пешка гына бит, бәбекәчем.* З.Мәхмүди. *Пешка хәлендә калдым мин, әни.* Д.Салихов

ПЕШКӘК *и.* 1) Гөбедә кымыз яки май атлау өчен, агачтан эшләнгән тишекле йомры атлагыч. *[Тукал] Зинһәтле зур, бай тирмәнең ишеге төбендә сабадагы кымызны пешкәк белән шапырып тора иде.* Г.Ибраһимов

2) Сыеклык, газ яки парны кысып тутыра яки суырып чыгара һәм цилиндр эчендә тыгыз йөри торган озынча яки диск формасындагы деталь. *Ярлар башында нефть эзләүчеләр буровое эшли. Пешкәк тасмасын яңага алыштырганнар да искесен чыгарып ташлаганнар.* М.Хәсәнов. *Эчендә пешкәк йөри торган калай көпшә.* Х.Камалов

3) Карга батмасын өчен, чаңгы таягына беркетелә торган агач бөжра

ПЕШКӘКЛӘ́Ү *ф.* Пешкәк белән атлау, язу, туглау. *Гөбедә каймак пешкәкләү. Кымыз пешкәкләү*

Пешкәкләп алу Тиз генә пешкәкләү

Пешкәкләп тору Әле, хәзерге вакытта пешкәкләү

Пешкәкләп бетерү Пешкәкләүне тәмамлау

Пешкәкли башлау Пешкәкләргә тотыну

ПЕ́ШМӘГӘН *с.* 1) Чи, пешү дәрәҗәсе тиешенчә, җитәрлек булмаган. *Пешмәгән ипи*

2) *күч.* Тиешле дәрәҗәгә җиткереп эшкәртелмәгән, эшләнеп җитмәгән (әсәр тур.). *Бу әсәр бик мәгънәсез эшләнгән, пешмәгән.* З.Мансур

3) *күч.* Булдыксыз, уңмаган

4) *күч.* Беркатлы, юаш, усаллык белмәгән. *Мин, янәсе, наив, пешмәгән.* Р.Миңнуллин

ПЕШҮ I *ф.* 1) Кайнап яки югары температурада тотылып ашау-эчү өчен әзер хәлгә килү. *Мәүлиханың боткасы да пеште, чәе дә өлгерде.* Г.Бәширов. *Сыер ите шулпасында пешкән кәбестә ашыннан да ким булмый бу.* Г.Гобәй. *Майга салгач, чәкчәк үзенә бертөрле формага кереп пешә.* Татар халык ашлары

2) Кайнап яки кайнар суда җебеп, тәме, шифасы чыгу. *Шәйхи карт матур сөйли: – Һәй Алла, эштән кайтышыңа һәйбәт такта чәй пешеп, табада арпа коймагы чыжлап утырсын иде, – ди.* М.Мәһдиев

3) Югары температура тәэсирендә тән, тире авырту, зарарлану. *Сәйфулла хәзрәткә акчасын ышкып, кыздырып тоттыра, хәзрәтнең кулы пешә.* Ф.Бурнаш. *Шүрлектә, чөйдә – мунча чабыну өчен кирәк булачак реквизит. Болар сукно баш киеме – баш пешмәсенгә, аска киез, кулга бияләй – чабынганда кул пешмәсенгә.* М.Мәһдиев

4) *күч.* Кояш, тир һ.б.ш.лар тәэсирендә тән тиресе кызару, бозылу. *Шәһәр халкының бәераклары сайфияләргә күчтеләр, фәкыйрь сыйныф кояш эссесеннән пешәргә шәһәрдә калдылар.* Г.Тукай. *Малай елый, эссе кояш астында ул пешкән, янган, битләре кубалаклангән.* М.Мәһдиев. *Авыл клубы шыгрым тулы. Бөркү. Тынчу. Тирләп-пешкән кешеләр ярым чишенгәннәр.* М.Хәсәнов

5) Үсеп утырган игеннәр, яшелчә, җиләк-җимеш турында: ашамлык итеп әзерләрлек хәлгә җитү; өлгерү. *Кайчандыр, әле бөтенләй сабый чакта, Якуб чиянең --- каралып пешкән түгәрәк җимешләрен авызы белән җыярга ярата торган иде.* И.Гази. *Җәй азакларында менә пешәм, менә өлгерәм дип чәчкә атып күкрәп утырган яшелчә-җимеш өстенә әллә нинди күкертле яңгыр явып уза.* Р.Мулланурова

6) *күч.* Оялудан кызару, оят тойгысы кичерү. *Кунак килсә, ит пешә, ит пешмәсә – бит пешә.* Әйтем

7) *күч.* Тиешле дәрәҗәгә җитеп эшләнеп бетү, әзер булу. *Ачы булгач күңелем, Шигърем ачы чыга. Бәгъзан пешкән дип уйласам да, чи чыга.* Г.Тукай

8) *күч.* Җайлану, барып чыгу. *Бер минутка зиһенемдә дөнья әйләнде, эчтәге иблис әкрен генә баш күтәреп: – Чү, егет, эш пешә! – диде.* Г.Ибраһимов. *Мин хәзрәтнең сүзләрен башымны кагып, тәсдыйк итеп кенә утырам. Эчемнән шатланам. «Эш пеште, юлым уңды», – дип уйлыйм.* М.Гафури. *Шаулама, иптәш, эш пеште.* Г.Камал

◊ **Пешкән ашка су кату** Булган, беткән эшне бозу. **Пешкән дә төшкән** Бар нәрсәне ансат кына күреп, сораган яки сорашкан кешегә карата әйтелә. **Пешкән шалкан** Булдыксыз, уңмаган кеше турында. *[Әхмәди:] азрак телләнеп алды: «Һәй, егет димәсәң, хәтерең калыр. Пешкән шалкан – төшкән калган, ди безнең татар».* Г.Бәширов. **Пешмәгән нәрсә** *к.* **пешкән шалкан**.

– Дурак! – диде [Шәрәфи карт]. – Пешмәгән нәрсә! Бер дә юкка нинди җәнҗәллар кузгатасың! Ш.Камал.
Пеште ни, төште ни (барыбер) Ваемсыз, гамьсез кешегә карата

Пешә башлау Пешәргә тотыну. *Маңгаена тир бөртекләре бәреп чыккан, ике бит очы яңа гына пешә башлаган алма кебек кызарган.* Г.Галиев

Пешә тору Башка бер эш-гамәл белән берьюлы пешү. *[Нәсимә:] Хәмидә, син бәрәңгене юып, казанга сал. Пешә торсын.* Ш.Камал. *Ул арада кухнядагы газ плитәсендә аш пешә тора.* М.Мәһдиев. *Әйдә, үлән алып килик, чәй әзрәк пешә торсын.* Г.Якупова

Пешә язу Аз гына пешми калу. *Хатыным кулындагы кашыгын төшереп җибәрде, мин исә чәйгә пешә яздым.* Н.Дәүли

Пешеп бетү Тәмам пешү; бик нык пешү. *Пешеп бетәр алдыннан, алып, табада кыздырасың.* З.Зәйнуллин

Пешеп җитү Тиешле дәрәҗәдә пешү. *Хәзер бәлешем пешеп җитә.* Г.Сабитов. *Кыз кеше, пешеп җиткәч, азамат егеткә чыгарга уйлана.* Г.Хөсәенов

Пешеп килү Пешү алдында булу, пешәргә аз гына калу. *Без килгән вакытта шашлыклары пешеп килә иде инде.* Ватаным Татарстан

Пешеп чыгу Тәмам пешү. *Әбекәе көлчәнең кайчан пешеп чыгасын каян белә торгандыр, табагач белән табаны тегеләй-болай боргалаганнан соң, берара җитез генә хәрәкәт белән көлчәне кабат теге кызыл шакмаклы ашъяулыкка төшерә дә өстен тастымал белән каплап куя.* А.Юнысова. *Казандагы итле аш, ниһаять, пешеп чыкты.* Н.Фәттах

Пешеп яту *сөйл.* Пешү процессында булу. *Аның бер дә пешеп яткан коймакны ташлап китәсе килмәде.* Н.Фәттах. *Калайда, кабарып, ак көлчәләр пешеп ята.* М.Юныс

ПЕШҮ II *ф. диал.* Туглау, атлау, язу. *Кырыс җиңги кымыз пешәр; әрле җиңги әйрән пешәр.* Мәкаль. *Май пешү*

ПИ I *и. гр. мат.* Әйләнә озынлыгының үз диаметрына чагыштырмасы

ПИ II *и. фар.* Фарсы әлифбасында өченче хәреф

ПИ III *иярт.* Тавыш сигналы биргәндә сызгырган авазны белдерә. *--- Дыкы-дыкы... Пи-и-и! Ниндидер станция. --- Поезд сызгырта-сызгырта туган илгә таба чаба...* М.Мәһдиев

ПИАНИ́НО *и. ит.* Киллары астан өскә таба тартылган клавишлы, басып торган зур корпуслы уен коралы. *Анда мин беренче мәртәбә пианино күрдем һәм, музыка мәктәбенең мөдире күрмәгәндә генә, пианино бармакларына баса башладым.* Һ.Такташ. *Сәлимовларның бүлмәсе дүртәү. Бизәкле шкафлар, паласлар, яшел хәтфә белән тышланган урындык-кәнәфиләр, пианино... алтын рамлы картиналар.* Г.Ахунов. *Асия бик кечкенәдән ук пианинода әйбәт уйнаган, аның музыкаль хәтере бик яхшы булган.* Казан утлары

ПИАНИ́НОЧЫ *и. к.* **пианист**. *Һәр икесе – үзе дә, пианиночы Маргарита Коварская да – ап-ак костюмнан.* Мәдәни җомга

ПИАНИСТ *и. ит.* Пианинода уйный белүче музыкант. *Пианист дигәнебез композитор Заһид Хәбибуллин булып, ул искиткеч киң күңелле, нечкә хисле кеше иде.* Мирас. *Ул вакытта кино тавышсыз, кинодагы вакыйганы пианист музыка аркылы чагылдырып бара, бу гамәл киноны ныграк аңларга ярдәм итә.* Мәдәни җомга

ПИАНИ́СТКА *и. рус* Пианинода уйнаучы, пианинода уйный белүче хатын-кыз музыкант. *Музыка училищесында укытучы пианистка Нина Александровна Шевалинаның уңышлы чыгышыннан соң, Александр Окаемов күренде.* Ж.Фәйзи. *1925 елны, апрель аеның соңгы көннәрендә, унбиш яшьлек пианистка беренче мәртәбә сәхнәгә чыга.* Мирас

ПИАНИСТЛЫК *и.* Пианист булу. *Пианистлык хезмәте. Пианистлыкка укырга карар бирү*

ПИА́НО *рәв. ит. муз.* **1.** Тын гына, әкрен генә, басынкы (музыкаль әсәрне башкарганда, кыскартып, *P* латин хәрефе белән белдерелә)

2. *и. мәгъ.* Музыкаль әсәрнең тын, басынкы уйнала торган өлеше

ПИАНО́ЛА *и. англ.* Гадәти фортепьяноны механик фортепьянога әйләндерергә (әверелдерергә) ярдәм итә торган өстәмә җайланма

ПИАНО-ПИАНИ́ССИМО *җый. рәв. ит.* Мөмкин кадәр әкрен, ишетелер-ишетелмәс, бик басынкы

ПИАР *и. ит.* Халык арасында кемне яки нәрсәне дә булса максатчан таныту, билгеле яктан күрсәтү эше. *Бөтен матбугат шаулап-гөрләп торды ул чакта. Бу – үзенә күрә пиар идеме, әллә акча эшләүнең бер юлымы?* Шәһри Казан

ПИАРЧЫ *и.* Пиар белән шөгыльләнүче кеше. *Ә менә маркетолог, пиарчы, рекламачы, финансчы, төзүчеләрнең якын араларда эш табуы бик шикле.* Татарстан яшьләре

ПИА́СТР *и. исп.* 1) Кайбер илләрдә вак акча берәмлеге һәм шуның тәңкәсе. *Бәрәкалла, дүрт йөз пиастр ничек булыр?* М.Мәһдиев

2) Борынгы испан тәңкәсе

ПИБЕК *и. диал.* Шөлди кошлар семьялыгыннан тавышы елауга охшаган кечкенә саз кошы; тәкәрлек; *русчасы:* **пигалица, чибис**. *Агыйделнең аръягында кычкыралар пибекләр.* Г.Тукай

ПИБЕП *и. диал.* Чеби, чебеш. *Бардым урманнарга, кичкә калдым. И алмалым, Карчыгалар куа пибепне.* Җыр

ПИВЕТ *и. диал. к.* **пибек**

ПИВНОЙ *и. рус сөйл.* Сыраханә. *Әйдәле, бер пар пирәшләп чыгыйк, дип әйтүенә, Сәлим карт белән бергә болар пивнойга атлый башладылар.* Ф.Сәйфи-Казанлы. *Пивнойларда әче ис, тәмәке төтене, пычрак, кычкырыш, сугыш.* К.Тинчурин. *Менә заводлар, трактирлар, пивнойлар, ночлежный домнар, койма аслары, төрмәләр...* Ш.Камал

ПИГАМБӘР *и. фар. сөйл. к.* **пәйгамбәр**. *Сәлам язмак пигамбәр сөннәтедер, Сәлам алмак – матур кыз хөрмәтедер.* Г.Кандалый. *Әүвәл заманда пигамбәрләрне дә кавемнәре азган кешеләр, безнеңчә тормыйлар, безнеңчә йөрмиләр, дип гаеп иткәннәр.* Ф.Әмирхан. *Мөхәммәд пигамбәрнең бер хәдисендә, игелек кылганда, эшне иң әүвәл якын-тирәңнән, туганнарыңнан башларга кирәклеге турында әйтелгән.* Мирас

ПИГМЕЙЛАР *и. гр. күпл.* 1) Үзәк Африкада һәм Көньяк-Көнчыгыш

Азиянең кайбер өлкәләрендә яшәүче тәбәнәк буйлы кешеләр кабиләләре атамасы һәм шул кабиләләрнең бер вәкиле. *Тик менә алар барысы да пигмейлар кебек, буйга бездән шактый кыскалар.* Р.Фәизов. *Экваториаль урман зонасы кешеләре – пигмейлар – кыска буйлы.* Материклар һәм океаннар географиясе

2) *күч.* Начар кеше, адәм актыгы. *Кеше иреген тыеп булмый, ул Табигатьтән килә! Ул Илаһи көчтән килә! Җир киредә әйләнә алмый, Пигмейлар әйтеп кенә...* Р.Фәйзуллин

ПИГМЕНТ *и. лат.* 1) Тере организмда тукымаларга берәр төс бирә торган табигый буяу. *Ул матдә химик төзелеше ягыннан тән пигментына охшамаган микән? Негрлар тәнен кояш пешерүдән шул каралҗым пигмент саклый бит.* А.Тимергалин. *Пигментлар чәчәк яфракчыкларына, яфракларга, җимешләргә кызыл һәм зәңгәр яисә сарғылт төс бирәләр.* Ботаника

2) Буяу әзерләгәндә, порошок сыйфатында кулланыла торган буялучан матдә; минераль буяу. *Буяучы матдәләр гадәттә сары һәм кызгылт сары пигментлардан торалар.* Е.Солодухин. *Табигый минераль пигментлар, табигый материалларны тарттырып, илән, суда утыртып табыла.* Төзү материаллары. *Силикат кирпеч аксыл сары төстә, селтегә чыдам пигмент керткәндә төрле төстә була.* Р.Шакиржанов

ПИГМЕНТЛАНУ *ф. биол.* 1) Төрле органнарда һәм тукымаларда пигментлар туплану. *Җирне ташлап киткәч, озон катламы ультрашәмәхә нурланыштан сакламаячак инде, шунлыктан тире пигментланачак.* Мәдәни җомга

2) Пигмент тәэсирендә нинди дә булса төскә керү, буялу. *Пигментлану күбрәк яшелләнү, сарғаю формасында була.* Биология

Пигментлана башлау Пигментлануга табан бару

Пигментлана бару Торган саен ныграк пигментлану

Пигментлана төшү Бераз пигментлану

Пигментланып бетү Нык пигментлану

ПИДЖАК *и. ингл.* Алдан төймәләнә торган, ачык кайтарма якалы курткасыман кием; ирләр костюмы. *Гыйлажи кара пиджактан, Бикмулла билен бумыйча кигән солдат гимнастёркасыннан иде.* Ә.Еники. *Пиджагын иңенә генә салган, биек арышлар эченнән башы гына чайкалып күренгән Әгъзам, бара торгач, яшь урманга килеп керде.* Г.Әпсәләмов. *Берсендә, Тифлис–Мәскәү поезды белән кайтканда, әтисенең пиджак кесәсеннән акчасын урладылар.* М.Мәһдиев

ПИДЖАКЛЫК *с.* **1.** Пиджак тегәргә яраклы; пиджак тегәргә җитәрлек; пиджак алырга җитәрлек. *Пиджаклык тукыма сатып алу. Бер пиджаклык материал калган*

2. *и. мәгъ.* Пиджак тегәргә яраклы тукыма

ПИДЖА́К-ЧАЛБАР *җыйм. и.* Бербөтен һәм киемнең бер төре буларак пиджак белән чалбар. *Егетнең өсбашына да бераз культура йокты: майка өстеннән күлмәк киеп йөри башлады, пиджак-чалбары үтүкләнгән, чистартылган булды.* Ә.Еники

ПИЕЛИТ *и. лат. мед.* Бөер лаканнарының ялкынсынуы

ПИЕЛОНЕФРИТ *и. ингл.-лат. мед.* Бөер тукымасы һәм бөер чокыры ялкынсынудан гыйбарәт авыру

ПИЖАМ *и. сөйл. к.* **пижама**. *Яшь әти дә, мин дә өсләрне алмаштык. Юл пижамыннан иркен һәм рәхәт булып калды.* Г.Ахунов

ПИЖА́МА *и. ингл.<фар.* Өйдә йөргәндә яки йоклаганда кияр өчен, җиңел тукымадан иркен итеп тегелгән костюм. *Таушалган пижамаларын киеп, китап тотып чыккан эчпошыргыч «командировочныйлар», ул үтеп киткән саен, китаптан башларын күтәреп, аның артыннан карап калалар.* Ә.Еники. --- *Бу сәгатьләрдә «министрлыкта утырырга» тиеш булган Сөләйманов авылдашы квартирына килеп кергәндә, ул пижамадан килеш әле иртәнге чәй яныннан ялкау гына күтәрелеп килә иде.* Ф.Хөсни

ПИЖАМАЛЫК *с.* **1.** Пижама тегәргә яраклы, пижамага җитәрлек

2. *и. мәгъ.* Пижама тегәргә яраклы материал (тукыма)

ПИЖОН *и. фр.* Соңгы мода белән киенүче һәм тышкы кыяфәте белән генә кызыксынучы көяз егет; гомумән фырт кеше. *Ялган романтика, тышкы бизәкләр исерткән сине --- Төче телле пижоннарның матур сүзләренә эреп алдангансың.* Р.Фәйзуллин. *Әгәр дә минем әти бай булса, мин дә шундый пижонга әверелер идемме? Бәлки...* Р.Зәйдулла

ПИЖОНЛЫК *и.* Пижон булу сыйфаты

ПИК *и. фр.* 1) Тауның очлы түбәсе, аның иң югары ноктасы

2) *махс. кит.* Берәр нәрсәнең кинәт кенә күтәрелеше яки күтәрелеш чоры. *Сәйдәш иҗаты белән таныш кешеләр белә булыр: Салих аганың иҗади пигы 30 нчы елларда була.* Р.Фәйзуллин. *Анда катнашу – күңелеңдә туардай матур хыялларның пигы, үзе зур бәхет!* А.Хәсәнов. *Эпидемия пигы*

◊ **Пик вакыты** *к.* **пик сәгате**. *Инде сигезенче ярты. Бу бит инде, Мәскәү теле белән әйткәндә, пик вакыты.* М.Юныс. **Пик сәгате** Эш-хәрәкәттә иң тыгыз, киренке вакыт. *Казан урамнарында пик сәгатьләрендә автомобильләрнең очсыз-кырыйсыз тоташ агып торуын күзәтергә мөмкин.* Мәдәни җомга

ПИКАДОР *и. исп.* Махсус тамаша мәйданында (башлыча Испаниядә һәм Көньяк Америкада) үгезне сөңге кадап котырта торган җайдак; тореадор, тореро. *Аренада ялгыз калган үгез янында җайдак, таза бәдәнле ике ир-ат – пикадорлар пәйда була.* Р.Фәйзуллин

ПИКАП *и. ингл.* Йөк яки пассажирлар ташый торган кечкенә автомобиль. *Автохуҗалыкка берничә пикап сатып алу*

ПИКЕ I *и. фр.* **1.** Бер ягына кабарынкы рәсем төшерелгән киҗе-мамыктан эшләнгән тукыманың бер төре

2. *с. мәгъ.* Шундый тукымадан тегелгән. *Пике күлмәк тектерү. Пике япма сатып алу*

ПИКЕ II *и. фр.* Бик зур тизлектә борын белән аска таба очыш (самолёт тур.). *Пе-2 самолётында пикега кереп, бомба ыргытырга өйрәнгәннән соң, очучыларның күбесенең аяк тамырлары*

кабара башлаган иде. М.Юныс. *Очкычны пикега кертеп, Сәләхов самолётны чорнаган ялкынны сүндерергә тырышып карады.* Казан утлары

ПИКЕТ I *и. фр. хәрби* 1) Зур булмаган сакчы отряд, хәрби дозор

2) Шул отряд урнашкан урын. *Пикет янына кичләрен солдатлар җыела торган иде.* Казан утлары

3) Патрульлек итүче төркем, шулай ук забастовканы төрле һөҗүмнәрдән саклау өчен куелган сакчы отряд. *Нургали агай, Андрей белән киңәшләшеп, завод пристане тирәсенә үз кешеләрдән пикет куюны кирәк тапты.* Г.Минский. *Пикет оештыру*

ПИКЕТ II *и. фр.* 1) Тимер юл линиясенең озынлыгын үлчәү берәмлеге (километрның уннан бер өлеше – 100 метрга тигез)

2) *махс.* Геодезиядә берәр урынның югарылыгын билгеләү өчен алынган нокта

3) Җир үлчәү эшендә җиргә кагып куела торган номерлы казык

ПИКЕТАЖ *и. фр. геод.* Җир өстен нивелирлау алдыннан, билгеле бер югарылыктагы нокталарны рейка яки казыклар белән билгеләп чыгу

ПИКЕТАЖИСТ *и. махс.* Пикетаж белгече

ПИКЕТЛА́У *ф.* Эш ташлау вакытында штрейкбрехерларны предприятиегә кертмәү өчен, капка янын саклау

ПИКЕТЧЫ *и.* Пикетта (I) катнашучы кеше. *Маёвканың кайсы урында уздырылачагын аныклап, юлда очраргa тиешле пикетчылар хәбәр итәчәк.* А.Расих. *Пикетчыларның таләпләре. Пикетчылар белән очрашу*

ПИКЕШ *и. рус диал.* Кечкенә чүлмәк

ПИ́КИ *и. фр.* Сөңге очына охшатып ясалган кара төстәге уен картасы; карга. *[Бәкер:] Юләр, простой белән козырьны ябалармени? [Әхтәм:] Козырь пикимени? [Бәкер:] Пики шул.* Г.Коләхмәтов

ПИКИРО́ВКА *и. рус. а.х.* Шытымнарга үсүдә яхшы шартлар булдыру өчен, аларны зуррак мәйданнарга күчереп утырту

ПИКНИК *и. ингл.* Бер төркем кешеләрнең табигать кочагына, сахрага чыгып күңел ачулары; сәйран. *Кичә Идел аръягына пикникка чыккан идек.* Г.Ибраһимов. *Ул үзенең бөтен буш вакытын укучыларга багышлый, Оренбург тирәсендәге табигатьнең иң матур урыннарына пикникка чыгуны да ул оештыра.* Ж.Фәйзи. *Алар [Әмирханнар] табигать кочагына хозурга чыгып, бик күңелле, гомергә истә калырлык, хәзергечә әйтсәк, пикниклар оештыра.* Р.Әмирхан

ПИКНИКЧЫ *и.* Пикникта катнашучы, сәйранчы

ПИКНО́МЕТР *и. физ.* Каты һәм сыек җисемнәрнең тыгызлыгын үлчи торган прибор

ПИКТОГРА́ММА *и. гр.* Билгеле бер сүзнең яки төшенчәнең символы булып хезмәт иткән рәсем

ПИКТОГРА́ФИК *с.* Пиктография белән бәйле, шуңа караган. *Пиктографик билгеләр төшерелгән балчык кисәкләренең күбесендә хуҗалык исәп-хисабы һәм административ язулар булган.* Н.Фәттах

ПИКТОГРА́ФИЯ *и. лат.* Хәреф системасына хәтле булган, рәсемнәр ярдәмендә язылган иң борынгы язу системасы

ПИ́КУЛИ *и. кулин. ингл.* Серкәгә салып маринадланган вак яшелчә

ПИ́КША *и. рус* Тәрәч балыклар семьялыгыннан озынлыгы бер метрга кадәр җитә, күбесенчә Атлантик океанның төньяк өлешендә яши торган кыйммәтле промысел балыгы. *Ак диңгездә пикша балыгы үрчи башлый, Баренц диңгезеннән... сайра балыгы күчеп килә.* Кызыклы ихтиология

ПИЛИГРИМ *и. нем.* Изге дип санала торган җирләргә гыйбадәт кылырга баручы; зиярәтче

ПИ́ЛИНГ *и. ингл.* Йөз һәм тән тиресен билгеле матдәләр ярдәмендә үле күзәнәкләрдән һәм кердән чистарту. *Мондый пилингны ике атна буе кич саен ясарга кирәк.* Мәдәни җомга

ПИЛМӘН *и. фин-угор* Тышы төче камырдан, эче төрле тәмләткечләр салып тарттырылган ит яки эремчектән әзерләнеп, кайнар шулпада пешерелә торган вак бөккән. *Җирән сакаллы кеше мискидәге катыклы пилмәнне тирән тарелкага салып ашарга кереште.* К.Тинчурин. *Җәмилә, әтисенең тәлинкәсен алып, пилмән салып килде, аннары абыйсын, бабасын, Гәүһәрне кыстарга кереште.* Г.Әпсәләмов

ПИЛМӘНЛЕК *с.* **1.** Пилмән пешерергә яраклы, пилмән пешерергә җитәрлек. *Иттарттыргычтан пилмәнлек ит чыгару. Суыткычта аз гына пилмәнлек фарш калган*

2. *и. мәгъ.* Пилмәнгә җитәрлек нәрсә, мөмкинлек һ.б.ш. *Ник дисәң, Рәдиф кырык беренче елның сентябреннән бирле колхоз председателе булып эшли икән. Нигә аның пилмәнлек кенә рәте булмасын, ди.* В.Нуруллин

ПИЛМӘНХАНӘ *и.* Ашарга пилмән әзерләнә торган ашханә; шулай ук шул ашханә урнашкан бина. *Район үзәгендә бер дигән пилмәнханә ачып җибәрделәр.* Мәдәни җомга

ПИЛМӘНЧЕ *и.* Пилмән әзерләп, шуны сатучы кеше

ПИЛОН *и. гр. архит.* Кайбер корылмаларның төз яки гөмбәзләп эшләнгән түбәләре өчен терәк булган, шулай ук күпер, парк кебекләргә керә торган урыннарның, капкаларның як-ягына урнаштырыла торган юан, еш кына дүрткырлы багана. *Монда күпер төзү буенча архитектура үзенчәлекләрен, детальләрен – вант, пилон, эстакада, колонна, капитель, ростверк һ.б.ны өйрәнергә кирәк.* Татарстан яшьләре

ПИЛОРАМ *и. рус* Электромотор белән эшли торган янәшә пычкылар ярдәмендә такта яру җайланмасы. *Буйдак Әхмәт пилорамда эшли.* К.Кәримов. *Апа колхоз пилорамыннан бер йөк сөян такта китерткән.* Ф.Яруллин

ПИЛОТ *и. фр.* Очу аппаратын, самолётны идарә итүче кеше, очучы. *Ярый әле Пе-2 самолётында пилот белән штурман бер үк кабинада очалар.* М.Юныс. *--- Нәкъ бер ел элек Хайрамның улы – югары класслы пилот – Көньяк Монтана күгендә һәлак булды.* А.Тимергалин

ПИЛОТАЖ *и. фр.* 1) Очу аппаратының төрле манёврлар ясап очуы

2) Очу аппаратын идарә итү осталыгы. *Пилотажның күренекле остасы*

ПИЛО́ТКА *и. рус* Хәрбиләрнең махсус формалы козырёксыз җәйге җиңел баш киеме. *Аннан берсе пилоткасының эче белән тирләгән битен сөртте.* Ә.Еники. *Өстендә гимнастёрка, биләндә киң каеш, башында кояшта уңган, яңгырлар юган, җилләр киптергән пилотка.* Казан утлары

ПИЛОТЛЫК *и.* Пилот булу. *Пилотлыкка имтихан тапшыру. Пилотлык һөнәрен үзләштерү*

ПИЛЮЛЬ *и. лат.* Сәдәф формасындагы йомры дару

ПИЛЮ́ЛЯ *и. лат. к.* **пилюль**. *Җәй көне плауннарның югарыга таба күтәрелгән бәбәкләрендә башакчыклар үсә, алардан вак сары «порошок», ягъни өлгергән споралар коела... Спораларны җыеп алалар да пилюлялар өстенә сибәләр.* Ботаника

ПИМА *и. коми* 1) Киез итек. *Былтыргы бишмәт тузган, былтыргы пима тишелгән, аякларның табаны кырылган иде.* М.Гафури. *Ике очлы җеп белән тегүнең серенә төшендем. Бу инде пима төпләргә, казанча әйтсәк, киез итеккә ас салырга өйрәнү дигән сүз иде.* М.Әмир. *Искереп таланган, табаннары гына түгел, кунычлары да кат-кат ямалган, көя шадралаган пималарга мин әрнү катыш кызыгып карадым.* А.Гыйләҗев

2) Төньяк халыкларында: мех итек

ПИМАЧЫ *и.* Пима басучы кеше. *Авылга пимачылар килде.* Кызыл таң

ПИМАЧЫЛЫК *и.* Пима басу эше. *Бикъярлар – бик көяз халык. Араларында күбе --- кырык тартмачылык, көмешчелек, йон тетүчелек, пимачылык кебек --- вак һөнәрләр белән дөнья гизгәнгә, телгә бик шомалар.* Г.Ибраһимов

ПИНӘ *и. диал.* Кинә, үпкә. *Үпкә-пинә сүземне, Күкне угым аралап әйтмәсә, Үз авызымнан әйтмәмен.* Дастан. *Син безгә ярдәм иткән идең, карт, бала тудырырга, аның өчен бик зур рәхмәт, тик балабыз адәм баласы булып туды, анда сиңа пинә юк.* В.Ильясов

ПИНӘЛӘ́Ү *ф. диал.* 1) Үпкәләү, үпкәсен белдерү

2) Битәрләү, ачулану

ПИНӘ́Ү *ф. диал. к.* **пинәләү**. *Нарасый сөйкемленең шундый пинәүләре мине кинәт чигендерә.* З.Бәшири

ПИНГВИН *и. фр.* Канатлары тәңкәсыман каурыйлар белән капланган, гәүдәсенең арка ягы кара, түше һәм корсагы ак төстә булган, ишкәксыман аяклы очу сәләтен югалткан диңгез кошы. *Бер пингвин боз өстендә бер хатын-кыз итәге табып ала да шуны киеп куя.* Т.Миңнуллин. *Пингвиннар колония булып оялыйлар, балык, башаяклы моллюсклар һәм кысласыманнар белән тукланалар.* Биология

ПИНГВИНСЫМАННАР *и. күпл. биол.* Антарктида, Көньяк Австралия, Африка һәм Көньяк Америка яр буйларында көтүләре белән яши торган очу сәләтен югалткан диңгез кошларының бер отряды

ПИНГ-ПОНГ *и. ингл.* Өстәл теннисы. *Без аның белән көн саен кич белән пинг-понг уйнадык.* М.Юныс. *Алан җиргә тезелгән пинг-понг өстәлләре янына килеп чыккач, икебез берьюлы туктап калдык.* Казан утлары

ПИНЭ́ТКА *и. рус* Иң кечкенә балаларның йомшак табанлы аяк киеме

ПИНЖӘК *и. сөйл. к.* **пиджак**. *Дөрес, минем өс-башым болай бик хөртидән түгел, бик яңадан булмаса да пинжәк, чалбар, аякта ботинка...* Ә.Еники. *--- Карт, чынлап та, әле аның пинжәк төймәләрен бөтерә, әле җиңеннән тотып тарткалый иде.* Р.Мирхәйдәров

ПИНЖӘКЛЕК *с. сөйл. к.* **пиджаклык**. *Әнә шул буйлы материалдан бер чалбар белән бер пинжәклек бирергә кирәк аңа.* Ш.Маннур

ПИНКӘ *и. рус диал.* Киндер сүсе, пәҗе. *Пинкә тетә-тетә, бармак битләре тишелеп чыга, каннар саркып чыга бармактан. --- Баш һәм ишарә бармакларга тырнак үсмәс була: хет тешең белән тот пинкәңне.* Г.Гобәй

ПИНЦЕТ *и. фр.* Медицинада һәм техникада кулланыла торган эскәк. *Дулкынланудан аның кулындагы пинцет сизелер-сизелмәс кенә калтырана башлый.* М.Юныс. *Күршем --- хирургныкы кебек пинцеты белән сәгатемнең төртмәгән-капшамаган бер генә шөребен дә, бер генә кылын да калдырмады.* Р.Төхфәтуллин. *Ике яклы хирургия пычагы ланцетлардан тыш Биләрдән табылган әйберләр арасында пинцетлар да бар.* Г.Дәүләтшин

ПИОДЕРМИ́Я *и. гр. мед.* Тиренең махсус микроблар эләгү нәтиҗәсендә эренләве

ПИОН *и. лат.* Казаякчалар семьялыгыннан юантык тамырлы, эре, ачык төстәге катмар чәчәкле, хуш исле күпьеллык декоратив үләнчел үсемлек; чалмабаш. *Пионнар яз яки иртә җәй чәчәк аталар*

ПИОНЕР *и. нем.* **1.** 1) Тикшерелмәгән, өйрәнелмәгән җиргә беренче булып килгән һәм шунда урнашкан кеше

2) Беренче, башлангыч нәрсә, нигез. *Лишайникларны икенче төрле үсемлекләрнең пионеры дип тә йөртәләр.* Гомуми биология

3) Яңалыкка беренче булып юл салган кеше. *Бармак белән генә санаулы калган татар театры пионерларының кандидатураларын бу каберлекләргә куярга ирек бирмәскә кирәк.* К.Тинчурин. *Космос пионерлары*

4) Советлар Союзында 10 яшьтән 15 яшькәчә булган балаларны эченә алган коммунистик оешма әгъзасы. *Без мәктәптә, пионер дружинасында имтомга, дини гореф-гадәтләргә каршы сугыш ачкан еллар иде ул.* М.Мәһдиев. *Пионерларның ду кубарып бер кешегә концерт куюларын күреп, курорттагы башка авырулар да шул төбәккә җыелдылар.* Ф.Яруллин

2. *с. мәгъ.* 1) *биол.* Билгеле территориягә, берәр өслеккә беренче булып урнашкан. *Пионер үсемлекләр*

2) Берәр эшчәнлек өлкәсендә беренчеләрдән булган. *Пионер галим*

ПИОНЕРВОЖА́ТЫЙ *и. рус* Советлар Союзында мәктәптә, пионер лагеренда пионер отряды яки дружинасы белән җитәкчелек иткән кеше. *Мин тарих, география, конституция укытудан тыш өлкән пионервожатый, агитколлектив җитәкчесе идем.* М.Мәһдиев. *Монда ул үзен бик актив пионер итеп күрсәтә, үзешчән сәнгать кичәләрендә катнаша. Аны пионервожатый итеп куялар.* Сөембикә

ПИОНЕ́РИЯ *җый. и. рус* Төрле пионер оешмалары; пионерлар. *Бик озак вакыт бөтен илне бердәм идеология берләштерде: пионерия, комсомол, профсоюз һ.б.* Р.Гарифуллин. *Башта балачак, пионерия, комсомол, укылган китаплар, яшәеш мәгънәсе турында сүз чыкты.* З.Мәхмүди

ПИОНЕРЛА́РЧА *рәв.* Пионерларга хас булганча, пионерлар кебек. *Шуңа без ниндидер пионерларча күтәренкелек белән эшлибез, йөрәкләр ашкынып тибә.* Х.Камалов

ПИОНЕРЛЫК *и.* 1) Нәрсәне дә булса беренче булып эшләү, башкару күренеше. *Аннары галим, беренчеләрдән булып Кандалый иҗатының төп үзенчәлекләреннән тел-стильдә һәм рухта чагылган табигый халыкчанлык, хатын-кыз хокукын күтәреп чыгудагы пионерлык, үзе сайлаган юлга гомер буе тугрылык сыйфатларын атап күрсәтә.* Ә.Дусайлы

2) Пионер оешмасында әгъза булу. *Ипташләренең ышанычларын аклап чыгу, йөзгә кызыллык китермәү, пионерлык исеменә тап төшермәү – шундый зур бурычларны йөкләделәр аңар.* А.Алиш. *Берәү чыгып Вәлиулла-Владимирның пионерлар сафына кабул ителгәнен сөйләп, аңар пионерлык билеты бирде...* А.Әхмәдуллин

ПИПЕЛДӘ́У *ф.* Пип-пип дигән тавыш чыгару. *Алар шулай икеле-микеле ишек төбендә таптанып торганда, караватта нидер чыелдап, пипелдәп кычкыра башлады.* Ф.Бәйрәмова. *Кесә телефонының төймәләре пипелдәде: «Сезнең очрак безнең компетенциягә керми... Тынычлык саклагыз. Иртән чыгарырлар».* Д.Булатова. *Әйтик, математикадан контроль эш барышында тәрәзә буенда утыручы күзлекле кызның телефоны пипелди.* А.Гыймадиев

Пипелдәп алу Кыска гына вакыт эчендә, тиз генә пипелдәү. *Район юлыннан барганда, антирадар бер-ике машина янында пипелдәп алды да туктады.* Шәһри Казан

Пипелдәп кую Бер тапкыр пипелдәү. *Әтием яткан карават башында урнашкан аппарат кына тынлык пәрәнҗәсен ертып пипелдәп куя.* Идел

Пипелдәп тору Бертуктаусыз, әледән-әле пипелдәү. *Акрынлап ул тына барды, пипелдәп торуга күчте.* Ф.Яхин

Пипелди башлау Пипелдәргә тотыну. *Шуны гына көткән кебек, аның кесәсендә дә нидер чыелдый, пипелди башлады.* Ф.Бәйрәмова. *– Шуңа ничәдә генә йокларга ятсам да, сәгать пипелди башлаганчы ук, биш тулырга биш минутта күзләремне ачам, – дип елмая ул.* Кызыл таң

ПИПЕЛДӘШУ *ф. урт. юн. к.* **пипелдәү**. *Чебиләр пипелдәшеп аның артыннан йөгерә, туктагач, сөенешеп, тупка сыеналар икән.* Казан утлары. *Яшел хәтфә каплаган ишек аллары да, пипелдәшеп йөрүче бәбкә көтүләре дә бетеп бара шул инде...* Татарстан яшьләре

ПИПЕ́ТКА *и. фр.* Сыеклык суыртып алу һәм аны тамчылап тамызу өчен кулланыла торган резин башлы нечкә пыяла көпшә; тамызгыч. *Балалар аны пинцет белән ашаталар, пипетка белән су эчерәләр.* З.Зәйнуллин. *[Зиләйлә] шкафтан нәни генә шешә, пипетка алып, салкынча бармаклары белән егетнең күз кабакларын киереп, дару тамызды...* М.Маликова

ПИПИ *и.* Балалар сөйләмендә: каз яки үрдәк бәпкәсе. *Бәпкәләр куркуларыннан әрле-бирле килеп буталыштылар, юлдан читкә чәчелделәр, Җылак Пипи генә өлгерә алмыйча уртада калды.* Көмеш кыңгырау

ПИ-ПИ *иярт.* 1) Каз бәпкәләре, чебиләр, вак кошлар кычкырганда чыккан тавышны белдерә. *Сандугачның балалары пи-пи, пи-пи дип әйтә...* Җыр. *Ул тынгысыз акчарлакның яр читендәме, маяк өстендәме пи-пи, пи-пи-пи дип сызгырганын тыңлап тора.* Г.Гобәй

2) Төрле радиосигналлар биргәндә чыккан тавышны белдерә. *Радиопост төрле төстәге индикаторлар белән җемелдәгән морзянка тавышлары (пи-пи ---) белән тулган иде.* М.Мәһдиев

ПИ-ПИ́ ИТҮ *ф.* Шундый аваз, тавыш чыгару. *[Марат:] – Абыем, ник пи-пи итә ул? [акчарлак] – дип сорый.* Г.Гобәй

ПИ-ПИ́ КИЛҮ *ф. к.* **пи-пи итү**. *Каз бәпкәләре озын борыннары белән үләнгә үреләләр, үзара пи-пи киләләр.* Н.Фәттах. *Шуны боргалап бетерүгә, каз бәбкәсе кебек бер нәмәрсә озын-озын итеп бибелди, пи-пи килә башлый.* Ф.Яхин

ПИП-ПИП *иярт.* 1) Каз бәпкәләре, чебешләр, вак кош-корт чыгарган тавышны белдерә. *Анда ике чирле бәпкә зәгыйфь тавыш белән: «Пип, пип, пип...» – диешеп, эчәргә су сорап тора-лар.* Г.Ибраһимов. *Утырганда, каз юньләп ашамады, урамга да әллә нигә бер генә чыгып керде, бервакыт карават астыннан пип-пип дигән тавыш ишетелде.* Ф.Садриев. *Ана каздан да бәхетле кош юктыр сыман, янында пип-пип килеп сап-сары, йоп-йомшак йомгаклар тәгәрәп йөри.* Татарстан яшьләре

2) Машина кычкырткан тавышны белдерә. --- *Моны күреп, башкаларның да машинаны пип-пип иттерәселәре килде.* Ф.Яруллин. *Минутлап, сәгатьләп бер урында туктап калган машиналарның пип-пип дип сигнал бирүеннән аерым бер музыкаль композиция язып булыр иде бугай.* Безнең гәҗит

3) Телефон яки башка шундый аппаратлар чыгарган өзек-өзек сигналлар тавышын белдерә. *Баядан бирле пип-пип кычкырып торган телефонын куйды да Рәфилә кухня ягына атлады.* Ф.Җамалетдинова

ПИР I *и. фар.* 1) Карт, өлкән яшьтәге ир кеше. *Бар ирде бер шәһәрдә ике фәкыйрь. Берсе егет ирде, янә берсе пир.* XVIII гасыр татар әдәбияты

2) Берәр тарикатькә нигез салучы; шәех, мөршид, ишан

3) *күч.* Нинди дә булса бер юнәлештә югары осталыкка ирешкән, остаз булган кеше. *Урта гасыр әдәби ядкәрләрдә пирләр шактый еш очрый. Мәсәлән, Мәрьям ана – тегермәнчеләр пире, Идрис пәйгамбәр – читек-кәвешчеләр пире дип исәпләнгән.* М.Әхмәтҗанов. *Г.Н.Снесарев бу хакта бераз башкачарак яза: Зәнки атаны ул шәйх дип атый, аның бөтен Урта Азиядә мөгезле эре терлек көтүчеләренең пире – яклаучысы һәм саклаучысы булуын күрсәтеп үтә.* Татар мифологиясе

ПИР II *и. рус* Мул сыйлы күңел ачу мәҗлесе. *– Без иртәгә дә шулай кабатларбыз, – дип җавап бирде Фәйзулла,*

һәм алар икенче көнне дә пирны дәвам иттерделәр. Ф.Хөсни. *[Илдар:] Пир ясыйбыз, энекәш! Ипи әгәр, ясыйбыз.* Г.Гобәй

ПИРАМИ́ДА *и. гр.* 1) *мат.* Нигезе күппочмаклыктан, ян кырлары исә очлары тоташкан өчпочмаклардан төзелгән күпкырлык

2) Борынгы Мисыр фиргавеннәренең каберләре өстенә төзелгән шул формадагы гаять зур таш корылма. *Әнә пирамидалар иле – Гиза, Фиргавеннәр үзәне... Тау сыртына салынган таш Акрополь.* М.Юныс. *[Пифагор] озак еллар Мисыр буйлап сәяхәт кылып йөри, пирамида төзүчеләрдән геометрия башлангычлары турында мәгълүмат ала.* Ж.Тәрҗеманов. *Мисыр фиргавеннәре пирамидаларында да хәзер игелә торган бодай бөртекләренә охшаган бөртекләр табылган.* Биология

3) Югарыга таба очланып килә торган киң нигезле предмет, корылма һ.б.ш. *Шома ташлы һәйкәл дә юк өсләрендә [каберләрнең], кызыл йолдызлы калай пирамида да...* Ш.Рәкыйпов. *Пирамида өч ярустан тора. Пирамидага каршы якта зур төзелеш бара, инде кайбер корылмалар сафка баскан.* Мәдәни җомга

4) Шул рәвешле өелгән әйберләр, предметлар. *Бер читтә пирамида итеп лимон өелгән иде...* М.Мәһдиев. *Мөдирнең осталыгына хәйран калырлык: шешәләрне ул шундый итеп өйгән, цементсыз-кадаксыз, дигәндәй, пирамида корган да куйган.* Р.Мөхәммәдиев

5) Берсе өстенә икенчесе басып торган кешеләрдән гыйбарәт гимнастик яки акробатик фигура

6) Уен башланыр алдыннан өчпочмак итеп тезелгән бильярд шарлары

7) Ату кораллары саклау өчен, шкаф яки пирамида формасындагы җиңел корылма. *[Унтер-офицерлар:] – Пирамидага мылтыкларны куйганда, затворын ачып куегыз! – дип кычкыралар.* А.Таһиров

8) *анат.* Чигә сөягенең бер өлеше

9) Үзәк органнарга буйсынган берәр оешманың, структураның вертикаль төзелеше. *Генерал Гәрәев, җәмгыять пирамидасының иң югары баскычына күтәрелүенә карамастан, онытмаган: ана телен саклый алган.* М.Юныс

ПИРАМИДАЛЬ *с.* Формасы белән пирамидага (*1 мәгъ.)* охшаган, өскә таба очланып торган. *Төркиядә күзгә иң күп ташланганы – пирамидаль тупыл, кәрлә наратлар, чаган.* Г.Ахунов. *Куе, биек чинарлар, пирамидаль тупыллар белән әйләндереп алынган аллеяда ул күренгәч, күләгәле бакча минем өчен яктырып киткәндәй була.* М.Маликова

ПИРА́НЬЯ *и. гуарани зоол.* Сөякле балыкларның бер семьялыгыннан Көньяк Американың елгаларында яши торган яссы гәүдәле, үткен тешле ерткыч балык. *--- Үгез кебек зур тереклек ияләре дә пираньядан һәлак булалар.* Кызыклы ихтиология. *Балыклар арасында аеруча ерткыч пиранья, электрлы еланбалык, акулалар --- киң билгеле.* Материклар һәм океаннар географиясе

ПИРАТ *и. гр.* 1) Диңгез юлбасары. *[Гид:] Моннан биш-алты еллар элек булса кирәк, әлеге утрауга ниндидер качаклармы, әллә пиратлармы килеп чыккан, дип кисәткәнем бар.* Р.Мөхәммәдиев

2) *күч.* Тыныч шәһәрләрне һәм авылларны бомбага тотучы дошман очучысы

3) *күч.* Аудио-видео товарлар, компьютер программалары, китапларны һ.б.ш. законсыз рәвештә җитештереп сатучы зат. *Китап пиратлары*

ПИРАТЛЫК *и.* Пират булу. *Дөрес, белгечләр сулыкларда кизү торып кына пиратлыкка каршы көрәшеп булуга ышанмый.* Ватаным Татарстан

ПИРӘШ *и. иск.* Исерткеч эчемлек буларак сыраның бер төре. *Азрак эчкәч, башка киткәчтен пирәш, – Кемгәдер ул иске серне итте фаш.* Г.Тукай. *Әйе, профессор әфәнде, ашыйсыгыз килсә, бездә 183 аш бар, эчәсегез килсә, пирәш бар, йоклыйсыгыз килсә, түшәк бар, әмма ярлык-марлык бездә юк.* К.Тинчурин

ПИРӘШЛӘ́Ү *ф. сөйл.* Кәефләнеп эчеп утыру, исерткеч эчеп кәеф-сафа кору. *[Зәйнулла хаҗи] Харамлыгы шөбһәле булган сыраны егерме дүртәр шешә пирәшләп кайтып, хезмәтчеләрен, асрауларын һушларыннан тайдырганчы кыйнаса да, атка бисмилласыз чыбык ормый торган «йомшак күңелле» аллаяр бәндә иде.* К.Тинчурин. *Әйдәле, бер пар пирәшләп чыгыйк, дип әйтүенә, Сәлим карт белән бергә болар пивнойга атлый башладылар.* Ф.Сәйфи-Казанлы

Пирәшләп алу Кыска гына вакыт эчендә пирәшләү. *Хәл-әхвәл сорашып, бераз пирәшләп алганнан соң, әти ишегалдына чыга.* Р.Низамиев. *Истәлекләрдә аның [Тукай әтисе Мөхәммәдгариф] намуслы, гади һәм самими кеше булуын телгә алалар. Мажиклар күрмәгәндә, бераз пирәшләп алырга яратуы турында да хәбәрләр бар.* Идел

ПИРЕС *и. рус иск.* **1.** Калын ефәкнең бер төре. *Хәзерге көндә татар әдәби телендә һәм аның төрле сөйләшләрендә --- пир, пирес, постау, сәре, сәренҗе (Гаяз Исхакыйда – сарынҗы), --- хөтнә кебек «милли» тукыма исемнәре белән беррәттән, батист, бәрхет, плүш --- кебек рус теленнән яисә рус теле аша кергән, әмма татар теле тарафыннан инде нык үзләштерелгән тукыма исемнәре очрый әле.* Р.Әхмәтьянов

2. Шул тукымадан тегелгән. *Кара пирес түбәтәй, кәләш алып бир, әтәй.* Такмак

ПИРЕ́ТРУМ *и. лат.* Ромашканың кайбер төрләреннән ясала һәм авыл хуҗалыгы корткычларын, паразит бөҗәкләрне юк итү өчен кулланыла торган саргылт соры төстәге порошок. *Баланың шактый керләнгән күлмәк якасына пиретрум сиптеләр дә санобработка үтте дигән әзер кәгазь кисәге тоттырдылар.* Г.Гобәй

ПИРИТ *и. гр. хим.* Җизсыман төстәге, металл кебек ялтыравыклы минерал; күкертле тимерташ. *Пирит сульфат кислотасы җитештерүдә күпләп кулланыла.* Химия

ПИРНАМӘ *и. фар.* Пирләрнең I (*2 мәгъ.*) догалары, зикерләре, өшкерү сүзләре язылган китап, язу. *Аннан җирле гореф-гадәтләр, чир-сырхаулардан арындыру сәләтенә ия булган пирнамәләр, җен-пәриләр афәтеннән саклаучы чәлпу ырымнары белән танышты, пирнамәләр ишетте.* Т.Нәбиуллин

ПИРОГ *и. рус < төрки* Эченә ит, төрле яшелчәләр, җиләк-җимеш кебек нәрсәләр салып пешерелгән камыр ризыгы. *Шәмси пирогларны мактый-мактый, ашый-ашый, иксез-чиксез чәй эчте.* Г.Исхакый. *Командир артыннан тәлинкә белән кайнар пироглар күтәргән хуҗа хатын да күренде.* А.Шамов. *Инәсе балалар бакчасыннан эштән кайтканда, калдык-постык ипи кисәкләре, кайчагында хәтта пирог, бәлеш кисәкләре алып кайта, шуларны тип-тигез итеп өч кисәккә бүлә дә әлеге табакка салып куя.* Н.Фәттах

ПИРО́ГА *и. исп.* Үзәк һәм Көньяк Америка индеецларында һәм Океания халыкларында кулланыла торган тар, озынча агачтан чокып эшләнгән көймә

ПИРОГЕННАР *и. күпл. англ.* Тән температурасын күтәрә торган биологик актив матдәләр

ПИРО́ЖНЫЙ *и. рус* Татлы төче камыр эченә крем, чикләвек һ.б.ш. салып әзерләнгән кондитер ашамлыгы. *Шулай да официант кыз салонга килеп кергәч, ул аңа бер стакан чәй белән пирожный китерергә кушты.* Ә.Еники. *Пирожный булса иде ул менә!* Л.Гыймадиева. *Әнә бер әби пирожныйлар сатып йөри ләбаса.* С.Шәрипов

ПИРОКСИЛИН *и. гр.* Шартлату эшләрендә һәм төтенсез дары ясау өчен кулланыла торган матдә. *Боларда [яшерен оешмада] маузерлар, бомбалар, динамитлар, пироксилиннар, бикфорд җепләре бар.* Г.Ибраһимов

ПИРО́МЕТР *и. гр.* Югары температураларны үлчи торган прибор

ПИРОП *и. гр. минер.* Кызыл төстәге асылташ, гранатның бер төре

ПИРОТЕРАПИ́Я *и. лат. мед.* Тән температурасын ясалма күтәрү белән дәвалау ысулларының гомуми атамасы

ПИРОТЕ́ХНИК I *и. рус* Пиротехника белгече

ПИРОТЕ́ХНИК II *с.* Пиротехника белән бәйле. *Пиротехник әйберләр шартлату тыела.* Шәһри Казан

ПИРОТЕ́ХНИКА *и. рус* Фейерверклар, сигнал бирү системалары яки сугыш кирәк-яраклары җитештерү һәм куллану белән бәйле техника яки сәнгать. *Пиротехниканы рөхсәт ителмәгән урыннарда сату*

ПИРС *и. англ.* Кораблькәр килеп туктау өчен, яр кырыеннан су эченә кертеп эшләнгән корылма. *Портта эшли башлаганга ике тәүлек үткәч бугай, ашлык бушата торган пирска бер машина алып килделәр.* М.Юныс. *Пирста сигнал утлары гына яна, чөнки бомбага тотудан куркалар.* А.Тимергалин. *Пирс култыксаларына таянып торам: елгада ни хәлләр бар икән, шуны күзлим, тик берни күрмим.* Т.Кәримов

ПИРУК *рус < төрки к.* **пирог**. *Бу көнне Покрау пируклары пешереп, ятимнәргә, ялгыз карт-корыга табак йөрткәннәр...* Туганайлар

ПИРУЭТ *и. фр.* 1) Хореографик элемент: бер аяк очына басып, үз тирәндә тулы бер түгәрәк ясап әйләнү; сикергән вакытта һавада әйләнү. *Рудик артка таба чигеп, пируэт ясап, йодрыкланган ике кулын җәеп бер аягында әйләнергә тотынды*. Р.Батулла

2) *күч.* Фикерләүдә, үз-үзен тотышында кинәт борылыш, көтелмәгән үзгәреш

ПИРЧӘТКӘ *и. сөйл. к.* **перчатка**. *Әминә: – Юк, ярамый! Без Ильяс абыйга кунакка киттек! – дип, пирчәткә ыргытты.* Г.Рәхим. *Искәндәрнең кулында ап-ак пирчәткәләр... Пирчәткә эчендә аның бармакларының тагын да җитезрәк, газаплы хәрәкәтләнгәне сизелеп тора.* Казан утлары

ПИС *с. фар.* **1.** Пычрак, начар, әшәке; түбән кеше, эш, мохит һ.б.ш. турында. *Яхшылыкны пис кеше белмәс.* Мәкаль. *Булса пис эшләргә үч, бирмәскә Иблискә көч. Мин теләрмен: «Бир, Ходай, дип, һәр ике Идрискә көч!»* Ш.Бабич. *Өстәвенә, килен булып төшкән йорты үзенең үскән җиренә бөтенләй нәкыс булып, тәрбиясез, низамсыз, пис, хәсис булуы да аңарга авырлык сала иде.* Мирас

2. *и. мәгъ.* Әшәке, начар, кабахәт кеше. *– Кит, сиңа ләгънәт!.. Күгемнән кит! – диде. – Бар, хәзер шайтанга баш бул, пис! – диде.* Ш.Бабич

ПИ́ САНЫ *мат.* Әйләнә озынлыгының үз диаметрына чагыштырмасын күрсәтә торган сан (ул 3,14 кә тигез)

ПИ́САРЬ *и. рус* 1) Канцелярияда язу-сызу эшләре белән шөгыльләнүче хезмәткәр. *Фәйзулла солдатка китми калуына үкенә дә башлады. Ләкин соң иде инде. Гармонь үз эшен эшләгән, комиссияләр үз карарларын чыгарганнар, писарь язасын язып куйган иде.* Ф.Хөсни. *Шуннан явыз Иван писарьлары, аннан соңгы писарьлар, килә-килә, бу тирәгә дә борын сузганнардыр...* М.Мәһдиев. *Аннан [әтием] беренче бөтендөнья сугышына алына, писарь хезмәтен үти.* Г.Ганиева

2) Күчереп язучы. *Авылның старостасы, писарь, берничә дисәтник һәм берничә куштан урам буйлап халык өстендәге недоимкаларны җыеп йөриләр иде.* Ф.Хөсни

ПИСАРЬЛЫК *и.* Писарь булу, писарь хезмәте. *Мин бу писарьлык эшеннән ничек кенә булса да [китәргә] ниятләп куйдым.* Ә.Еники

ПИСЕР *и. рус сөйл. к.* **писарь**. *Кишердән кишер туа, писердән писер туа.* Мәкаль. *– Старшина белән писердән сорыйсы булыр. Алар ни әйтерләр, – диде Фәйзулла.* М.Галәү. *Әйдә, писер булып, гел язулар гына язып йөрмә әле.* Г.Бәширов

ПИСЕРЛЕК *и. сөйл.* **писарьлык**. *Шул карт писерлектән төшкәч бик тәүфикъланды. Сакалларын үстереп җибәрде, мыекларын кыскартты.* Г.Камал

ПИСЛЕК *и. иск.* Әшәкелек, кабахәтлек, түбәнлек, начарлык. *Тугры килгән урны чүплеккә, тиреслеккә аның: Каплап алган төрле шакшы, төрле пислек һәр ягын.* Г.Тукай

ПИССУАР *и. фр.* Бәдрәфтә кече хаҗәт үтәр өчен генә куелган унитаз төре. *Санитар (чисталык өчен) керамик эшләнмәләр – юынгыч, унитаз, агызу багы, биде, писсуар, раковина һәм башка шундый эшләнмәләр бериш материаллардан ясала торган фарфор, ярымфарфор, фаянс һәм шамот массаларыннан җитештерелә*. Төзү материаллары

ПИСТОЛЕТ *и. фр.* Якын аралыктан ату өчен кулланыла торган, кыска көпшәле утлы ату коралы. *[Кеше], уң кулын әкрен генә кесәсенә шудырып, имән бармагын пистолет курогына*

тыкты һәм пистолетын чыгарып Акбүзгә төзәде. Г.Гобәй. *Өстендә тар погонлы яшькелт соры френч, аякларында краги белән кара ботинкалар, билендә портупеялы каеш, шуның сул ягында зур пистолет кабурасы...* Ә.Еники. *Пирга баргач та, үз гомеремдә беренче тапкыр станковый пулемёттан ут чәчеп карау, ПМ пистолетыннан (пистолет Макарова) атып, мишеньның үзәгенә тиерү шатлыгыннан да мәхрүм итте.* М.Мәһдиев

ПИСТОЛЕТ-ПУЛЕМЁТ *и. фр.* Якын аралыкта ату өчен кулланыла торган автоматик корал; автомат

ПИСТОН *и. фр.* 1) Гильза төбендә урнашкан шартлагыч матдәле кечерәк металл капсюль. *Дары белән атыла торган ау мылтыгы авызы белән күккә карап тора; аз гына күтәрелгән чакмалары астыннан елтырап күренгән сары пистоннары аның һәр ихтималын күздә тотып әзерләнгән (корылган) икәнлеген белгезәләр.* М.Галәү. *Мылтык атылмаган, әллә нәрсә генә булган: әллә дары дымыккан, әллә пистон бозылган.* Ш.Маннур

2) Уенчык мылтыклардан, пистолетлардан ату өчен, эченә бераз дары салып ябыштырылган тыгыз түгәрәк кәгазь. *Мидхәт пугачын каргаларга төзәде. Ләкин бая базда аунаганда, кар белән пистоннары җебеп беткән булганлыктан, пугачы атылмады.* Ф.Хөсни

3) Катыргы яки күн әйберләрнең тасма үткәрер өчен тишелгән тишекләренә механик ысул белән беркетелгән тимер кыса

4) *муз.* Тынлы музыка коралында клапан

5) *авиа.* Самолёт төзү эшендә заклёпка урынына кулланыла торган махсус көпшә

ПИСТОНЛЫ *с.* Пистон белән ата торган (корал тур.). *Пистонлы мылтык*

ПИТЕКА́НТРОП *и. гр. кит.* Табигый үсеш процессында кеше һәм кешесыман маймыллар арасында торган бик борынгы казылма зат; маймыл-кеше. *Питекантроп, яки маймыл-кеше, моннан бер миллион ел чамасы элек яшәгән: питекантроп, бераз гына иелә төшеп, ике аякта йөргән.* Дарвинизм нигезләре

ПИТЕКА́НТРОПЛАР *и. гр. күпл.* Неандерталецлардан элегрәк яшәгән маймыл-кешеләр, казылма кешеләр. *Питекантропларның калдыклары беренче мәртәбә Ява утравында 1890–1892 елларда Э.Дюбуа тарафыннан табылган.* Биология. *Аңлашылды. Питекантроплар заманыннан ук яшәп килгән үзгәрмәс канун: хакимият бүгенге көндә үзенә кирәкле кешеләрне генә ашата.* М.Юныс

ПИТИЛ *и. литв.* Аска таба тарая барган капчык шикелле ятьмәне коршауларга беркетеп ясалган балык аулау коралы; *русчасы:* **вентерь**. *Кышларын ау үрә, питил бәйли, кышка кармак салу өчен селекмә әзерли, кургаштан «ялган балыклар» коя.* Д.Каюмова

ПИТО́МНИК *и. рус* Хайваннар, балыклар, үсемлекләр үрчетү, үстерү урыны һәм аларны өйрәнү өчен тәҗрибә участогы. *Аннан питомниктан бик күп төрле агачлар китереп аудардылар аңа.* М.Мәһдиев. *Гибрид чәчкеннәрдә уңайсыз климат шартларына карата ныклык тәрбияләү өчен, Мичурин үзенең бөтен питомнигын кара туфраклы участоктан туклыклы матдәләргә ярлы булган комлы туфраклы яңа урынга күчергән.* Дарвинизм нигезләре

ПИТОН *и. гр.* Көнчыгыш ярымшардагы тропик һәм субтропикларда яшәүче озын гәүдәле агусыз эре елан. *Гыйззәтуллин питон авызына үз ихтыяры белән кереп барган гипнозланган куян шикелле, берни аңламыйча, аның артыннан кабатлый.* М.Мәһдиев. *Питоннар чуар яки бер генә төстә булалар.* Биология. *7 классның зоология китабында сарык бәрәнен чолгап алган питон рәсеме бар.* Казан утлары

ПИТРАС *и. к.* **питрач**

ПИТРА́У *и. рус* 1) Христианнарның иске стиль буенча 29 июньдә була торган дини бәйрәме. *Тиздән тургайлар сайраудан туктыйлар, белдеңме? Питрау гына җитсен.* А.Гыйләҗев. *Питрау да җитте: Эңгер-меңгер вакыт, Көн аяз, кечкенә генә дә җил юк.* Г.Рәхим. *«Питрау үтте, җәйләр бетте», – диләр Безнең якта халык сүзендә. Питраудан соң чәчәк атмый гөлләр, Сары йөгерә кырлар йөзенә.* К.Булатова

2) *күч.* Нинди дә булса вакыт арасының уртасы. *Питрау үтте, димәк, җәйләр бетте, Болыннарга сары йөгерде... Бу тормышның питраулары җитте, Кыл урталай бүлеп гомерне.* К.Булатова

◊ **Питрау күкесе** Урынсыз сүз сөйләүче, вакытсыз кычкыручы кеше. *Син алдан кычкырып кына эшне боздың. Әйттем мин сиңа, алдан шаулама дип, питрау күкесе.* Н.Исәнбәт. **Питрау тәкәсе** 1) Питрау көнгә махсус симертеп, печәнгә төшкәндә суела торган яшь тәкә; халык ышануынча, яз көне туган сарык бәтиенең итенә шул көннән соң гына тәм керә. *Зур казанда питрау тәкәсен турап салган аш кайный иде.* М.Мәһдиев; 2) *мыск.* Кызлар артыннан йөри башлаган яшүсмер

ПИТРАЧ *и. диал.* 1) Ипи салганда, күәс төбендә калган ачы камырдан пешерелгән кечкенә түгәрәк ипи. *Әни атнага ике мәртәбә ипи сала иде, һәрвакыт бер питрач ипине Бәнат апага кертә идек.* Ватаным Татарстан

2) Төче камырдан пешерелгән вак күмәч. *Төче питрач белән чәй эчү*

ПИТРАЧЛЫК *с.* Питрачка караган, питрачка җитәрлек, питрач пешерерлек. *Күәс төбендә бер питрачлык камыр калган*

ПИ́ХТА *и. нем.* Наратчалар семьялыгыннан конуссыман куе ябалдашлы мәңгеяшел ылыслы агач; ак чыршы. *Пихта – караңгы ылыслы тайгада төп токым.* Ботаника. *Ак чыршының яшь бәбәкләреннән зарарлы бактерияләрне үтерергә сәләтле шифалы пихта мае алалар.* И.Рәхимов, К.Ибраһимова

ПИЦЦА *и. ит.* Камыр җәймәсе өстенә башлыча помидор, гөмбә, сыр салып пешерелгән ризык. *Әлбәттә, мин аңа Интернеттан гына заказ биреп, итальяннар пиццасы ашап, сыра эчеп ятуымны әйтмәдем.* Ф.Хәбибуллин. *Төнгә каршы ашарга ярамаса да, җомга көнне диета саклап утырып булмас дип, пиццаны ашыйм.* Идел

ПИЦЦЕРИЯ *и. ит.* Менюында башлыча төрле пиццалар булган җәмәгать туклану урыны. *Үз милли ашларын да онытмыйлар мондагы мөселманнар: күпсанлы пиццерияләр янәшәсендә*

хәләл кафелар да бар. Шәһри Казан. *Сезне пиццерия кунак залында көтеп калабыз.* Безнең гәҗит

ПИЧ *и. рус диал. к.* **мич**. *Бер дә тавыш чыгармаска тырыша иде, ләкин пич буендагы комганны алганда, ниндидер бер тимер шалтырап идәнгә төште.* Г.Ибраһимов. *Ул пич башы булса, үзем дә риза булыр идем дә бит.* Т.Гыйззәт. *Сездә элмә белән өрәңге кисәкләрен дә пичкә ташлыйлар.* М.Мәһдиев

ПИЧӘТ *и. рус сөйл.* 1) Мөһер. *Хатны – пичәтенә карап, атны – тешенә күз салып, кешене тыңлап беләсең.* Мәкаль. *Гербовой пичәт һәм имзалар белән расланган шушы белешмәдән сез Хәйдәрнең өченче бала булуын белдегез инде.* А.Гыйләҗев. *– О-о, егетләр, – диде берсе, – монда председательнең пичәте калган. Кайсыгызның маңгаена сугабыз, э? Маңгаена пичәт суктыручы табылмады.* Ф.Яруллин

2) Этикетка, ярлык. *Низамый пичәтенә биш йолдыз сурәте төшкән сары бутылканы ача.* М.Әмир. *Аннан соң ул куен кесәсеннән әллә нинди ялтыравыклы кәгазьләр, чәй пичәтләре чыгарды.* Ә.Фәйзи

◊ **Пичәт басу** *к.* **пичәт сугу**. *Әнисенә әйтмим, э үзем әллә кайчан пичәтне басканмын: «Юк, рәт чыкмас бу шайтан малайдан, рәт чыгардай кеше шулкадәр күп ботинка туздырамы соң!»* Ф.Хөсни. **Пичәт сугу** 1) Кемнең дә булса сүзен раслау, җөпләү. *Син миңа контр-мунтр дип пичәт сугарга ашыкма, яме!* Ф.Хөсни; 2) Нәрсә беләндер килешү, эшне шуның белән өзү, кул куешу. *Я, ярый, шуңа пичәт суктыкмы, үзара килештекме?* 3) Раслау, карар кабул итү, рәсми рәвештә хәл итү

ПИЧӘТКӘ *и. диал. к.* **перчатка**. *Ызба артында рәшәткә, Кулда – яшел пичәткә.* Җыр. *Олы кызлар урыннарына кире утыралар, --- берни булмагандай, кайсы шәл, кайсы пичәткә бәйләвен дәвам итә.* М.Мәһдиев

ПИЧӘТЛӘҮ *ф.* 1) Мөһер басу, пичәт сугу. *«И падишаһ, Аллаһы Тәгалә гыйшкына безнең ягымыздан булыш», – дип, хатны пичәтләп, падишаһка бер адәм аркылы җибәрделәр.* К.Насыйри. *Бер сызгырды – син конвертта, пичәтләп үк куячаклар, сакчыны мыскыллаган өчен.* М.Юныс

2) Сургычлап, пломба салып бикләү. *[Рөстәм]: Кызма, Габдулла агай! (Госмановка.) Хәзер сез барып, келәтен пичәтләп кайтыгыз.* Һ.Такташ. *Шулай да булса үзләренең ялгышларын төзәтеп, законга туры китергән булып кыланып, алган нәрсәләрен пичәтләп, икебезне дә тотып частька алып киттеләр.* С.Рәмиев. *Суд карары буенча әлеге гаилә яшәгән йорт пичәтләп ябып куелган.* Татарстан яшьләре

3) Машинкада текст бастыру яисә рәсем төшерү. *Тикшереп карый алмасыз: тиз һәм чагыштырмача арзанга «пичәтләп» биргән мондый фирманың арткы ишеге һәрвакыт ачык.* Милли нәшрият һәм китап редакторы. *Равил абый аларны [мәкаләләрне] төзәтеп редакцияләү генә түгел, мәктәп машинкасында пичәтләп үк бирә иде.* Татарстан яшьләре

4) Бал кортының бал тутырылган кәрәз күзәнәкләрен балавыз белән каплавы. *Бал корты пичәтләгән кәрәзне ачкан кебек, мин аның тупланмасыннан кайбер сүзләрне алып, мисалга китерәм.* Татарстан яшьләре. *Тиз бозыла торган продукт буларак, аны кортлар башлары белән кәрәз күзәнәгенә тыгызлап тутыралар да, өстенә бал агызып, балавыз белән пичәтләп куялар.* Шәһри Казан

5) *күч.* Ирешелгән нәрсәне үзгәрмәслек итеп нығыту, тотрыклы итү. *Шагыйрьнең әдәбият белгечләре, тәнкыйтьчеләр һәм каләмдәшләре тарафыннан дистә еллар дәвамында «һәр маңгай сыры»на хәтле эшләнеп, «Заман, иҗат, шәхес» дигән китап белән инде «пичәтләп куелган» образының әңгәмә вакытында ни рәвешле тагын да ачыла төшкәнен гүяки үз күзләрең белән күреп торасың.* Г.Галиева

6) *күч.* Катгый рәвештә әйтү, сөйләү. *Ул һәр сүзен ачык итеп, яңакка китереп сукканда пичәтләп әйтә иде.* З.Хәким. *Әле гади сүзләр белән генә сөйләсә иде Васил абый. Юк бит, шәп-шәп итеп кенә халык әйтеме, кызык сүз белән пичәтләп тә куя.* Э.Гарипова

7) *күч.* Күбәйтү, ишәйтү. *Бүген республиканың югары уку йортлары гуманитар-социаль юнәлештәге белгечләрне «пичәтләп» кенә тора.* Татарстан яшьләре

Пичәтләп бетерү Пичәтләүне тәмамлау

Пичәтләп кую Бер тапкыр пичәтләү; алдан пичәтләү. *Бәхәсне исә бер чирек белән нығытып, пичәтләп тә куйдылар.* З.Хөснияр. *Бүген пичәтләп куярсың, дәресләр арасында иртәгә почтага барып ябыштырып җибәрермен, әгәр дә миңа ышанып тапшырсаң...* Р.Гаязетдин

Пичәтләп тору Һәрвакыт, гел пичәтләү; хәзерге моментта пичәтләү. *Дәүләт Думасында исә законнарны пичәтләп кенә торалар.* Безнең гәҗит

Пичәтли башлау Пичәтләргә тотыну

ПИЧӘТЛЕ *с.* 1) Мөһер басылган, пичәт төшерелгән, пичәт белән расланган (язу, хат һ.б.ш. тур.). *Ә, кирәкле җәзу бар идемени? Пичәтле кәгазь булмагач, без аны тоттык шул: казан астын үрләттек ---.* Г.Бәширов. *– Бабай, кире башы белән тоткансың язуны, пичәтьле ягын өскә тотып укымыйлар аны, менә болай әйләндереп тот! – дип, минем кулымдагы язуның башын аска әйләндерде.* М.Гали. *[Вәли:] ...әйдә, пичәтле кәгазьләренә тәмәке төреп тартсыннар. Без иплән кенә колхоздан таярбыз.* Ф.Яруллин

2) Пичәт сугып бикләнгән, пломба салынган (ишек, сейф һ.б.ш. тур.)

3) Билгеле рәсемле, билгеле төсле (гадәттә, кап, кәгазь төргәк тур.). *Хәер, әле безнең җәй көне алган теге яшел пичәтле чәйнең дә берәр кадагы булырга тиеш ---.* Ф.Әмирхан. *Шул онны зәңгәр пичәтле махсус капчыкларга тутырып, вагон-вагон Мәскәүгә --- озаталар.* Ә.Еники

4) Пичәт тоткан, үзендә пичәте булган. *Пичәтле егет, өстәлдәге газеталарны ертып, сораучыга пичәт сугып бирде.* Казан утлары

ПИШӘ *и. фар. иск.* 1) Эш, һөнәр, шөгыль. *Ул эт кыйлса усаллыкны пишә, Чыгып торса ул эт һаман урамга, Үтеп киткән кешеләрне таларга ---.*

Бәет. *Инде, и угыл, пишә вә һөнәр дигәнемездән морад, дөкяндә утырып, алыш-биреш итмәк түгелдер, һәр эш ки, адәмнең мәшгулияте булыр, пишә вә һөнәр диерләр.* К.Насыйри

2) Ия. *Шәһри Кашан – җиһан гөшә, Олуг, кечег һөнәр пишә.* Тарихи җыр

ПИШӘЮ *ф. иск.* Масаю, үзен зур күрсәтү, горурлану

ПИШКАДӘМ *и. фар. иск.* **1.** 1) Укуда алдынгы шәкерт. *Безнең мөдәррис белән пишкадәмебез рус студентының каршында торып та гомердә бер кәррә исемен ишетмәгән сүзләрдән дәрес алырга башладылар.* Ф.Кәрими

2) *тар.* Мәдрәсәнең тулы курсын яхшы билгеләргә тәмамлаган хөрмәтле кеше. *Сәлах хәзрәт мәдрәсәсеннән Исмәгыйль дигән «бик гыйлем» бер пишкадәмне мулла итеп куйганнар.* Г.Камал. *[Мирсәяф] Мәдрәсәне тәмамлагач, гәрчә яхшы мәгълүматлы булса да, эш таба алмау сәбәпле, анда пишкадәм булып кала.* С.Поварисов

3) *күч.* Берәр өлкәдә алдынгы кеше. *Юртыш Хәмид хәзрәт бин Габдессәлам. Мәмдәл кешесе. Казан өязе Юртыш илендә имам вә мөдәррис вә һәм тарикать юлында пишкадәм.* К.Насыйри

2. *с. мәгъ.* Алдынгы. *Фагыйләтен, фагыйләтен, фагыйләт, Пишкадәм остазымызның рухы шат.* Г.Тукай. *Әдәбият бабында хәзергә без мөбтәдиләремез гарәбиләрнең пишкадәм шагыйрьләре илә кыяс кыйлу бик урынлы булып җитмәс.* Г.Камал. *Мәдрәсәне тәмамлагач, миңа – пишкадәм шәкертькә – мәдрәсәнең имам-мөдәррисләре хәлфә булып калырга тәкъдим иттеләр.* Т.Мөбарәков

ПИШКАДӘМЛЕК *и.* Пишкадәм булу. *Мәдрәсәдә унбиш ел буе шәкерт булып михнәт чиккән, --- соңыннан шул ук мәдрәсәдә пишкадәмлек хезмәте үтәп чыләнгән --- Гыйрфан мулла боларның барысын да биш бармагы кебек яхшы белә.* С.Поварисов. *Гаҗәп халык без. Гел шул мескенлектән, үз күләгәсеннән үзе шүрләп йөри торган пишкадәмлектән чыгып булмый әле.* Г.Бәширов

ПИШТАК *и. фар.* Якын һәм Урта Көнчыгыш илләрендә мәчет, мәдрәсә, кәрвансарай кебек җәмәгать биналарының алгарак чыгарып салынган әйванлы турыпочмаклык рәвешендәге порталы

ПИШТӘР *и. диал. к.* **биштәр**. *Пиштәр аскан юлаучы*

◊ **Пиштәр корсак** Зур корсак. *[Сәрмәдия:] Такта күкрәк, гәрбил бил, ач яңак, пиштәр корсак, салам сыйрак!* Д.Салихов

ПИЩЕБЛОК *и. рус* Җәмәгать туклануына караган урыннарда ризык әзерләү яки ашау бүлмәсе. *[Банкетка барырга] Пищеблоктан Анастасия Аристарховна белән кок Протычкинны билгеләделәр.* М.Юныс. *Пищеблок ишегенә элеңгән язуга караганда, әлеге продукция сәгать 12 дән бирелә башлый.* Кызыл таң

ПИЯДӘ *и. фар.* Шахмат уенында пешка

ПИЯЗ *и. фар. диал.* Суганның көмешсыман ак төстәге ачы булмаган сорты. *Пияз утырту*

ПИЯШ *и. диал.* 1) Мич янына куела, сәндерәне яки шүрлекне тотып тору, чаршау бавын бәйләү өчен кулланыла торган нәзек терәк багана. *Тик торган пияшкә берәү дә кагылмый.* Мәкаль

2) *күч.* Ялгыз юаш кеше турында әйтелә

ПЛАВБА́ЗА *и. рус* 1) Диңгез корабларына хезмәт күрсәтү, азык-төлек, ягулык һ.б. төрле запаслар белән тәэмин итү өчен билгеләнгән, каюталары, ремонт мастерское булган, ешрак яр буенда тора, сирәгрәк диңгезгә чыга торган рейд корабы. *Зинһар, ешрак яз, плавбазага барган саен буш кул белән кайтырлык булмасын.* М.Маликова. *Солдатның торагы казарма булса, диңгезчеләр укыган чакта плавбазада яшәгәннәр.* Татарстан яшьләре

2) Промысел алып барган суднолардан әле генә тотылган балык, краб һ.б.ш.ны кабул итеп, шунда ук алардан консерв, балык оны, май кебек продуктлар җитештереп, аларны портка илтеп тапшыра торган судно

ПЛА́ВИК КИСЛОТАСЫ *и. хим.* Фторлы водородның судагы эремәсе; пыяланы ашый торган агулы, көчле кислота. *Кислотага чыдам бетон, измә һәм мастикалар төрле концентрациядәге кислота (кайнар фосфор, плавик һәм кремний-фтор-водород кислоталарыннан тыш) тәэсиреннән саклау өчен кулланыла.* Төзү материаллары

ПЛА́ВИК ШПАТЫ *и. геол.* Кальций фторидыннан гыйбарәт, металлургиядә, химия промышленностенда, оптикада һ.б. кулланыла торган төссез һәм төсле кристалл рәвешендәге тиз уалучан минерал. *1 кг HF табу өчен ничә килограмм плавик шпат (флюорит) CaF_2 һәм ничә литр массача 98% лы H_2SO_4 эремәсе кирәк булыр?* Г.Хисамиев. *Тоныклаткычлар (криолит, плавик шпаты, икеләтә суперфосфат) пыяланы тонык итәләр.* Төзү материаллары

ПЛА́ВКИ *и. рус* Су кергәндә яки кызынганда, ирләр кия торган тар һәм кыска трусик. *Председатель машина эчендәге сумкадан Япониядә эшләнгән плавкиен алып киде.* М.Мәһдиев. *Су коенганда кия торган җиңелчә плавкига охшаган һәм ачкыч белән бикләнә торган корыч пояс булып чыкты ул ---.* М.Юныс. *Безнең балачак, плавкиның нәрсә икәнен дә белмичә, --- ялантәпи йөреп үтте бит инде.* Т.Нәҗмиев

ПЛАГИАТ *и. лат.* Әдәбиятта, фәндә, сәнгатьтә башка автор хезмәтен өлешчә яки бөтенләе белән үзенеке итеп күрсәтү; үз хезмәтендә башка автор фикерләрен сылтамасыз куллану. *Әдәбиятта яшәп килгән плагиатлар тиктомалга килеп чыккан әйберләр түгел.* һ.Такташ. *Әйе, заманалар үзгәрде. Әмма кешенең статусы алай үзгәрмәде: ялагай – ялагай, плагиат – плагиат, эгоист шул ук эгоист булып кала бирә.* Р.Әхмәтҗанов. *Закон күп очракта дәшми дә кала бугай, чөнки плагиатны исбатлавы – бик четерекле, авыр мәсьәлә.*Татарстан яшьләре

ПЛАГИАТЛЫК *и.* Плагиат белән шөгыльләнү, әдәбиятта, фәндә, сәнгатьтә караклык. *Тотты да беркөнне туп-туры плагиатлык белән шөгыльләнә башлады Карлен ---.* Р.Мирхәйдәров. *Шулай да прозаны игътибар белән өйрәнгәндә, сирәк булса да, охшаш сюжетларга очрарга мөмкин. Нәрсә бу? Плагиатлыкмы, әллә охшаш тормыш ситуациясен күзәтүдән туган*

объектив хәлме? Р.Фәтхрахманов. *Плагиатлыкның закон тарафыннан эзәрлекләнүе хакында беләм.* Татарстан яшьләре

ПЛАГИАТЧЫ *и.* Плагиат белән шөгыльләнүче кеше. *Инде беренче шәлкеме басылып чыгу белән үк, бер танылган шагыйрь, кат-кат редакция телефоннарына шалтыратып, Рәсимнең иҗаты, нигездә, аның шигъри табышларын үзләштерүләрдән торганлыгы хакында бәян итте, якташын плагиатчы дип атады.* Кызыл тан

ПЛА́ЗМА *и. гр.* **1.** 1) *биол.* Канның сыек өлеше, кан сүле. *Бер куб сантиметр кан плазмасында фәкать 0,003 куб сантиметр кислород эрергә мөмкин.* Кызыклы физиология. *Кан тапшырган очракта организм 2–3 айдан үз халәтенә кайтса, плазма тапшыргач, моңа ике атна вакыт җитә, ди белгечләр.* Ватаным Татарстан. *Бал составында барлык микроэлементлар да диярлек бар, һәм ул составы буенча кеше каны плазмасын хәтерләтә.* Татарстан яшьләре

2) *биол. к.* **протоплазма**. *Хинолин алкалоидлар күзәнәк плазмасы агулары буларак билгеле.* Агулы үсемлекләр

3) *физ.* Бик нык ионлашкан, уңай һәм тискәре корылмалары тигез тупланышта булган газ матдәсе (мәс., Кояш, яшен шары). *Тугандаш ил галимнәрен космик физика, --- планетаара плазма, космик медицина һәм биология кызыксындыра.* Галәмгә юл. *Бу вакытта Кояшта шартлаулар башланып, аннан атылган плазма оершалары безнең планетага таба оча.* Мәгърифәт. *Белгечләр киләсе елда Кояштан зур күләмдә плазма чыгасын фаразлый.* Ватаным Татарстан

4) *сөйл.* Эшләү принцибы шул матдәне кулланута нигезләнгән прибор. *АКШта цифрлы тапшыруларны кабул итмәүче модельле телевизорларны яңа мөмкинлекле плазма, сыек кристаллыларына алыштыралар икән.* Татарстан яшьләре

2. *с. мәгъ. к.* **плазмалы**. *Фетнәчеләр --- ноутбуклар, плазма экранлы телевизорлар алып качканнар.* Ватаным Татарстан

ПЛА́ЗМАЛЫ *с.* Ионлашкан газның, ягъни плазманың (*3 мәгъ.*) электр бушануы нәтиҗәсендә барлыкка килгән ультрафиолет нурлар тәэсирендә люминофорның яктыруына нигезләнеп эшли торган. *[Алсу] Телевизорны сатып алганда ничек сөенгән иде! Плазмалы, соңгы модель дип, дусларына да мактанды бит әле!* А.Галиева. *Купеда --- музыкаль үзәк һәм хәтта плазмалы экран да бар.* Татарстан яшьләре

ПЛАЗМА́ТИК *с.* Плазмадан (*2 мәгъ.*) гыйбарәт, плазма хәлендәге. *Холестерин бигрәк тә хайван күзәнәкләренең плазматик мембранасында күп ---.* Сәламәт яшәү нигезләре

ПЛАЗМО́ДИЙ *и. лат. биол.* Паразит булып канда яши һәм кайбер төрләре бизгәк авыруы тудыра торган беркүзәнәкле организм. *Кешенең кызыл кан тәнчекләрендә паразит булып тереклек итә торган малярия кузгатучы плазмодий споралар хасил итеп үрчи.* Кызыклы физиология. *Плазмодий амёба сыман хәрәкәт итүгә сәләтле.* Ботаника

ПЛАЗМО́ИД *и. рус физ.* Плазма (*3 мәгъ.*) оершасы; магнит кыры һәм плазманың чикләнгән конфигурациясе. *Фотода барлыкка килгән шарларны мәрхүмнәрнең җаннары, биоплазма төеннәре, прамнар, плазмоидлар, асуралар дип тә йөртәләр.* Ватаным Татарстан. *Фото һәм киноаппаратлар --- дөньябызда плазмоид җан ияләре, ягъни кеше күзе күрә алмый торган икенче төрле яшәеш формалары да барлыгын раслыйлар.* Татарстан яшьләре

ПЛАКАТ *и. нем.* Җәмәгать урыннарында агитация, белешмә, реклама яки укыту-өйрәтү максаты белән эленә торган, гадәттә эре хәрефле, рәсемле язу. *Ататөрек мавзолеенда биек диварга бик эре хәрефләр белән язып куелган плакат күрдем ---.* Г.Ахунов. *Менә шул ике плакат училищеның ишеген ачып килеп керүгә бөтенләй икенче атмосфера тудыра.* М.Мәһдиев. *Берничә тапкыр Казан тирәсендәге колхозларга барып, авыл урамнарына куяр өчен, плакатлар да ясап кайтты Зуфирә.* М.Маликова

ПЛАКАТЧЫ *и.* Плакатлар ясаучы рәссам. *[Фәһим] 1979 елда плакатчы рәссамнарның Бөтенсоюз конкурсы лауреаты исемен яулады.* Н.Гамбәров

ПЛАКАТЧЫЛЫК *и.* Сәнгатьтә эчтәлеккә зарар китерү хисабына тышкы күренешләр белән артык мавыгу күренеше. *Мәсәлән, «Качкын» постановкасында күзгә бәрелә торган формаль алымнар, тышкы эффект артыннан куулар, урынсыз кабатлаулар, плакатчылык элементлары --- иҗат уңышсызлыкларына керәләр.* М.Җәлил. *Бу темага багышланган әсәрләрдә күтәренке рух, хәтта урыны белән плакатчылык хакимлек итә.* А.Әхмәдуллин

ПЛАКЕ́ТКА *и. фр. махс.* 1) Күппочмак рәвешендәге истәлекле яки декоратив медаль. *Татарстанда үткәрелеп килә торган «Йолдызлык» ачык телевизион яшьләр эстрада сәнгате фестивалендә уңышка ирешкән вокалистка ТҮРКСОЙның махсус плакеткасы һәм 1000 долларлык акчалата премия биреләчәк.* Р.Алтай. *Пруссиянең әби патшасы Луиза --- портреты төшерелгән плакетка игътибарны аеруча җәлеп итә.* Шәһри Казан

2) Мебель һәм көнкүреш предметларын бизәү өчен кулланыла торган өсте кабарынкы рәсемле металл яки керамик пластинка (*1 мәгъ.*)

ПЛАКИРЛА́У *ф. махс.* 1) Металл эшләнмәләрнең өслеген коррозиядән яхшырак саклый торган яки тышкы күренеше матуррак булган башка металл белән юка итеп каплау

2) Гади агач эшләнмәләрне кыйммәтле агач фанер белән тышлау

3) Яңгыр сулары юудан саклау өчен, сөзәк җирләрне, туфрак өемнәрен кәс белән каплау. *Яр буен плакирлау*

ПЛАН *и. лат.* 1) Берәр урын, корылма, әйберләрнең, пропорцияләрен саклаган хәлдә, туры горизонталь проекция ысулы белән кәгазьгә төшерелгән масштаблы сызымы. *Чуерташлар шыбыр да шыбыр күчереләләр, берсе үзенең терлек абзарларының планын күрсәтә, икенчесе үз басуының рельефын тасвирлый.* М.Мәһдиев. *Монда миңа көчле тәэсир ясаган нәрсә – --- Финляндиянең һәр шәһәрен, аерым йортын, чишмә-суларын, авыл*

хуҗалыгында кулланыла торган җирләрнең кадастры теркәлгән планнарның булуы. М.Юныс. *Йорт урамга кырын итеп салынган. Бу – шәһәрнең 1782 нче елгы генераль планы нигезендә урамның юнәлеше үзгәрү аркасында килеп чыккан.* Р.Шәмсетдинова

2) *диал.* Авыл җирендә: йорт, ихата урыны. *Безнең күршедә план буш иде, авылдашлар кайтып йорт салдылар*

3) Бер билгеле максат белән берләшкән һәм алдан уйланылган гамәлләр, чаралар үтәүне таләп иткән ният. *Шул беренче материал аңа үзенең тикшерү эшен кайдан, ни рәвештә башлап китүнең планын төзергә тәмам җитте.* Г.Ибраһимов. *Аларга ияреп йөргән татар манкортларының да планнары җимерелде.* Г.Ахунов. *Шунда минем башка бер план килә.* М.Мәһдиев

4) Халык хуҗалыгының барлык тармакларында үтәләчәк эш-чараларның алдан уйлап, исәпләп куелган системасы; проект. *Ул, май бәйрәмнәрендәге, октябрь парадларындагы кебек, кычкырып-кычкырып, бер генә секундка да сөйләвеннән туктамыйча хәбәр итте колхозның эш планын, ул аны яттан диярлек өйрәнеп чыккан иде.* Г.Ахунов. *– Сөт белән тәгәрәделәр, ит планы өзелү алдында, төзелешләре туктадлы... – диде Батталов, ике кулын ике якка җәеп.* Ф.Садриев. *Авылда авыр хезмәттән бөгелгән крестьян, --- дәүләт планын изге санап, гадәттәгечә көн күрде.* З.Хәким

5) Алдан күздә тотылган чаралар нәтиҗәсендә ирешелергә, табылырга, эшләнергә тиешле булган эш күләме, бирем. *Без еллык планны үтәдек. Уз көчебез белән. Җиңеп чыктык!* А.Гыйләҗев. *Елны нибары егерме өч пожар белән тәмамладык, узган елда егерме биш иде, план үтәлмәде.* М.Галиев. *Республика шикәр чөгендере әзерләү буенча еллык планны үтәде.* Татарстан реформалар чорында

6) Гомумән теге яки бу эшнең, нинди дә булса вакыт аралыгында үткәрелә торган чараларның тәртибе. *Кырымга һөҗүм итүнең оператив планы безгә тулысынча мәгълүм түгел.* З.Зәйнуллин. *1925 елның 30 январенда, нигаять, ТТГКның перспектив планы ТҮБК президиумы тарафыннан раслана һәм басылып чыга.* З.Кириллова. *Лицей Татарстан Республикасы үзенчәлекләрен --- исәпкә алган уку планы нигезендә эшли башлады.* Милли мәктәп: тәрбия нигезләре

7) Нәрсәне дә булса хикәяләгәндә, язганда, аның аерым өлешләренең үзара бәйләнеше, урнашу тәртибе, композициясе. *Я ул була бер тол хатын. Менә аңа әләгә! Балалары белемсез. Дәрес планнары кыска.* М.Мәһдиев. *Мәктәптә үз фәнең буенча дәресләргә әзерләнеп, планнарыңны язып, дәресләр үткәрәсең.* Татарстан яшьләре

8) *сәнг.* Сурәтләү объектының караучы, күзәтүче, тамашачыдан ерак яки якын торышы, шуның күзлегеннән карагандагы торышы. *Сул як сәхнәнең беренче планында: акка буялган бозаулар абзары.* Т.Гыйззәт. *Зуфирәне беренче карауга ук сәерсендергән өйрәнчек рәсем иде ул: анда алгы план белән арткы планның бер-берсенә ябышмаганлыгы әллә каян күзгә ташланып тора иде.* М.Маликова

9) *махс.* Кино, фото, видео эшендә сурәтләрнең масштабы. *Хәзер инде шушы халык эре планда. Үзәктә – кинооператор.* Ж.Дәрзаман. *Эре планда татарга хас йөзләр күбрәк күренсен иде.* Р.Батулла

10) Берәр нәрсәгә караш, берәр нәрсәне тикшерү, эшләү, башкару, ясау юнәлеше, яссылыгы; нәрсәнең дә булса күренү, беленү өлкәсе. *Сюжет чынчынлап әкият планында бара. Димәк ки, Түләк баһадир белән гүзәл Сусылу турындагы әкият сюжеты операга яраклы.* М.Җәлил. *Әхсән Баянның «Сез аңларсыз мине» поэмасына нигәдер «Яшьлегемне эзлим»нән күчәсе килде. Бер үк тема – сугыш, авыл... Икесе дә биографик планда.* С.Хәким. *Бөек шагыйребез Г.Тукайның фикерләре бу планда тагын да тасвирлырак һәм үтемлерәк.* Ш.Җәләлиев

11) *күч.* Тәртип саннары, тәртипне аңлата торган сүзләр белән бергә нәрсәнең дә булса әһәмиятлелек дәрәҗәсе. *Икенче пәрдәдә беренче планда салкынлык белән көрәш темасы сурәтләнгән, шуңа күрә, бик табигый рәвештә, корткычлык темасы икенче планга күчә һәм үзенең әһәмиятен югалта.* М.Җәлил. *Болгар чоры халык прозасында батырлык темасы беренче планда тора.* Ф.Урманчеев

12) *күч.* Кемнең яки нәрсәнең дә булса күзгә ташлануы, әһәмиятлелеге, кирәклеге ягыннан тоткан урыны турында. *Боларның барысы да яшәр, һәммәсе дә алгы планда булыр дип әйтү кыен.* Г.Ахунов. *Аракы томаны биләп ала башлагач, беренче мәхәббәтләре ургып торган яшь-җилкенчәкләр халәтенә керделәр. Оят арткы планга күчте.* Ә.Моталлапов. *Балетның беренче өлешләрендә үк өч лейтмотив бәрелеше – Шүрәле, Былтыр һәм Сөембикә кичерешләре алгы планга чыга, киеренкелек көчәя.* Р.Низамиев

◊ **План кору** *к.* **планлаштыру**. *Балаларны сөя, әниләрен мактый, киләчәккә планнар кора.* М.Мәһдиев. *Ә теге йорт шул урында һаман тора, Чәчне чәчкә бәйләргә дип план кора.* Г.Афзал. **План куу** Алдан билгеләнгән эш күләмен вакытында төгәлләргә тырышу. *Бик тыгыз вакыт, ай азагында план куа идек, хатны укыдым да, оныттым да.* Т.Миңнуллин

ПЛАНА́РИЯ *и. рус зоол.* Төкле суалчаннар классына караган, бөтен Җир шарында таралган, күбесенчә – төче сулыкларда, сирәгрәк диңгездә яшәүче, вак умырткасыз хайваннар белән тукланучы яссы суалчан. *Байкал күлендә планариянең 60 ка якын төре яши, аларның күбесе шул сулыкта гына очрый.* Татарстанның үсемлекләр һәм хайваннар дөньясы

ПЛА́НЕР *и. фр.* Һава агымнары ярдәмендә моторсыз оча торган аппарат. *Тиен агачтан агачка сикергәндә, койрыгы планер ролен уйный, руль булып та хезмәт итә, парашют сыман, төшү тизлеген дә киметә.* Хайваннар дөньясы: имезүчеләр. *Институт түгәрәге II Бөтенсоюз планер ярышлары өчен КПИР дигән планер төзеп ята.* Галәмгә юл. *Лариса Хәмитова – планер спорты буенча Русия чемпионы, ул һәр көнне җирне очар кош биеклегеннән күзәтә.* Ватаным Татарстан

ПЛАНЕРИЗМ *и. рус* Планер белән идарә итү теориясе һәм практикасы; планерда очу сәнгате; планер спорты белән шөгыльләнү эше. *Аның үзенең тазалыгына нинди зыян килүе турындагы соравымны кузгатмадым. Чыннан да, --- планеризм, парашют спорты --- буенча төрле разрядлар иясенә --- шундый сорау бирү әдәпсезлек булыр иде, мөгаен.* Ватаным Татарстан

ПЛА́НЕРЛАУ *ф*. Планерда яки моторы сүндерелгән очкычта һава агымнарыннан файдаланып очу, яки салмак кына түбән төшү, яки өскә күтәрелү. *Очучы урмандагы ачыклыкка таба планерларга тырышты*

Планерлап тору Дәвамлы рәвештә планерлау

Планерлый башлау Планерларга тотыну

ПЛАНЕРОДРОМ *и. рус* Планерлар һавага күтәрелә һәм төшә торган махсус мәйдан

ПЛА́НЕРЧЫ *и*. Планерда очучы. *Теория сәгатьләре тәмамлангач, планерчылар һәм очучылар Балтач аэродромында шөгыльләнә, ә парашютчылар – Коркачык аэродромында.* Татарстан яшьләре

ПЛАНЕТ *и. фр. а.х.* Игенчелектә һәм яшелчәчелектә культураларның рәт араларын кул көче белән яки ат җигеп эшкәртә торган культиватор. *Планет белән чөгендер арасын йөреп чыктым*

ПЛАНЕ́ТА *и. гр.* 1) *астр.* Билгеле бер йолдыз тирәсендәге орбита буенча әйләнә һәм гравитация нәтиҗәсендә шомарып, шар формасына кергән күк җисеме. *Җир күршесендәге берәр планетаны телескоптан күзәткәндә, астроном һәрвакыт анда су һәм кислород булу-булмавы белән кызыксына.* Кызыклы физиология. *«Планета» сүзе борынгы грекчадан «ил гизүче» дигәнне аңлата.* Ирек мәйданы

2) *кит*. Бөтен дөнья, Җир шары. *Мин бу планетада берьялгызым икән бит...* Т.Кәримов. *Татулык, дуслык, тынычлык Барсын планета буйлап!* Р.Вәлиева. *Доллар планетада төп акча берәмлегенә әверелеп бара.* Р.Мирхәйдәров

ПЛАНЕ́ТААРА *с*. 1) Планеталар арасында булган. *Планетаара киңлекләргә очу идеясе үзенең тирәнлеге һәм кыюлыгы белән Королёвны тәмам әсир итә.* Галәмгә юл. *Әгәр Җир күчәренең тизлеге әкренәйсә, газ молекулаларының планетаара пространствога китү тизлеге дә әкренәер --- иде.* Татар мөселман календаре

2) Планеталар арасында хәрәкәт итә торган. *Планетаара станция ашханәсендә һәрвакыт кош-корт һәм урман җәнлекләре ите була --- иде.* Р.Мөхәммәдиев. *--- совет планетаара станциясе «Венера-4»нең Венера планетасына иплән төшеп утыруы турындагы хәбәр шатлык китерсә, аның атмосферасында ирекле кислород булмавы --- турындагы хәбәр бераз кәефне китәрде.* Кызыклы физиология. *Сәгатьләрнең берсен космонавтка бирәбез. Ул аны, планетаара корабльгә алып кереп, хәрәкәт юнәлешенә перпендикуляр итеп урнаштырды, ди.* Физика

ПЛАНЕТАР *с*. 1) Планеталар яки билгеле бер планетага нисбәтле, шуның белән бәйле. *Мәсәлән, ди ул үз-үзенә, планетар системалар төзелешенең атом төзелеше белән охшашлыгы очраклымы?* Ж.Юныс. *Планетар томанлыклар*

2) Бөтен Җир шарына караган, гомуми, бөтендөнья. *Кешелекнең хуҗалык эшчәнлеге планетар характер алды.* Ә.Баян. *Илне Ленин алып чыкты ласа Брест солыхлары аркылы. Планетар шундый солых кирәк!* Р.Харис. *«Планетар позиция»дән карасак кына, без һәр милли үзенчәлекнең кимчелек түгел, ә нәкъ менә өстенлек икәнен күрербез.* Р.Хәкимов

3) *күч*. Бик киң колачлы, глобаль, масштаблы. *Ә кем кылды Җирдә иң зур игелек? Шул ук затлар искә төшә иң элек, чөнки алар – планетар аң үзәге!* Р.Харис. *Күпме шагыйрьләр, шушы робот-поэмага ияреп --- планетар шигырьләр яза башладылар.* М.Галиев. *--- күңел Ленин белән Чыңгыз хан шәхесләренең планетар дәрәҗәдә кылган игелекләрен барлап, аларны Мөхәммәд, Гайсә пәйгамбәрләр белән беррәттән кую-куймау мәсьәләсен, «планетар аң үзәге» белән бәйле булу-булмавын кире кага.* А.Шәмсутова

ПЛАНЕТА́РИЙ *и. лат.* 1) Гөмбәзсыман экранда йолдызлы күк рәсемен чыгара, планеталар һәм башка күк җисемнәренең хәрәкәтен күрсәтә торган аппарат. *– Планетарий йолдызлары җансыз... – дип юатты аны малай. – Алар җемелдәми, Сәрия.* А.Тимергалин

2) Шул прибор ярдәмендә йолдызлы күкне тамашачыларга күрсәтеп, астрономия буенча яхшы аңлаешлы (популяр) лекцияләр оештыра торган фәнни оешма, шул оешма урнашкан бина. *Белем көнендә Казанда планетарий ачылу да бәйрәм ителде.* Татарстан яшьләре. *Планетарий космик корабль салоны кебек ясалган.* Мәдәни җомга

ПЛАНЕТО́ЛОГ *и. рус* Планетология белгече

ПЛАНЕТОЛО́ГИЯ *и. гр.* Кояш системасындагы планеталарны һәм аларның иярченнәрен өйрәнә торган фәннәр комплексы. *Менә шундый планеталарны эзләп табу – күзәтү планетологиясенең иң мөһим өлеше инде хәзер.* Казан утлары

ПЛАНЁР *и. фр. к.* **планер**

ПЛАНЁРКА *и. рус сөйл*. Агымдагы эш планын (*3 мәгъ*.) тикшерүгә багышланган кыска гына производство киңәшмәсе. *Алексей Лукич кабинетында иртәнге планёрка бара.* Г.Әпсәләмов. *Планёрка беткән, бригадирлар, ферма мөдирләре --- таралышканнар иде.* Г.Галиев. *Минемчә, һәр оешмада көн саен спектакль бара. Һәр җыелыш яки планёрка – үзе бер серия.* Р.Зарипов

ПЛАНИМЕТР *и. лат.-гр.* Яссы фигураларның мәйданын билгеләү өчен кулланыла торган математик прибор

ПЛАНИМЕ́ТРИК *с.* Планиметриягә караган. *Аңлаган очракта да ул [укучы], бердәм дәүләт имтиханы таләпләренә китереп, планиметрик һәм стереометрик мәсьәләләрне чишү ысулын рус телендә кирәк дәрәҗәдә язып аңлата алмый.* Р.Гатауллин

ПЛАНИМЕ́ТРИЯ *и. лат.-гр.* Элементар геометриянең яссылыкта яткан фигураларның үзлекләрен өйрәнә торган бүлеге. *«Галия»дә түбәндәге*

фәннәр укытыла: тәфсир (Коръән Кәримгә аңлатма); --- һәндәсә – геометрия (планиметрия, стереометрия, тригонометрия); --- физкультура. Фән һәм тел

ПЛАНИРО́ВКА *и. рус* Берәр бөтен нәрсәдә аерым кисәкләрнең үзара урнашуы, үзара торышы; берәр корылманың эчке төзелеше. *--- Атлантида башкаласы да, Фест дисбесе дә һәм иске татар авылларының планировкасы да... бөгәрләнеп яткан еланны күз алдында тота!* Н.Фәттах. *Бераздан Морат килде. Түр як стенага төрле системалар: --- вертикаль планировканы --- һәм микрорайонның өстән караганда күренешен эләргә кушты.* М.Маликова. *Киң даирә чыганакларга нигезләнеп язылган китапта татар йорты интерьеры һәм аның өлешләре: йортның эчке планировкасы, предмет өлеше --- сурәтләнә һәм анализлана.* Д.Сөләйманова

ПЛАНИСФЕ́РА *и. лат.-гр. астр.* Җирне яки күк йөзен ярымшарлар формасында сурәтли торган карта. *Намаз укыганда, Мәккәдәге Кәгъбәгә таба юнәлешне төгәл билгеләү өчен, планисфера яки яссы астролябияләрдән файдаланганнар.* Татар милли педагогикасы

ПЛА́НКА *и.* 1) *сөйл.* Зур булмаган шома юка озынча такта, пластинка; агач, металл һ.б.ш.дан ясалган тар буй. *Кар капламының биеклеген кар үлчәү рейкасы ярдәмендә үлчиләр. Ул сантиметрларга бүленгән планкадан гыйбарәт.* Башлангыч география курсы

2) Уен коралларында шундый формадагы бер деталь. *--- Заһидулла калай почмаклар эшли, җиздән таптап планкалар ясый, картоннан күрек коя, почмакларын күн белән ябыштыра.* Р.Низамиев

3) Орден һәм медальләр урынына йөртелә торган, шуларның ленталары беркетелгән җайланма. *Вафин бик пөхтә киенә, --- күкрәгенә орден-медаль планкалары тагылган була.* Ф.Садриев. *Бер көнне кабинетка шулай ук күкрәгенә байтак орден-медаль планкалары таккан бер ветеран килеп керде.* Мәдәни җомга

4) Утлы коралда төзәү җайланмасының бер детале. *Үзе пулемётның бер планкасының торышын үзгәртте дә кабаланмый гына гашеткасына басты.* З.Зәйнуллин

5) *спорт* Спорт җайланмаларының бер өлеше: йөгерү, сикерүдә каршылык буларак, ераклык яки югарылык чиге буларак урнаштырылган аркылы таяк. *Спортчы кыз, шест белән сикерүдә 4,5 метр биеклектәге планкага җитеп, турнирның иң яхшы нәтиҗәсенә ирешкән.* Г.Гаттарова

6) *спорт* Идәнгә терсәкләр һәм аяк очлары белән генә таянып, гәүдәне төп-төз, идәнгә параллель итеп тотудан гыйбарәт физик күнекмә

7) *күч.* Нинди дә булса эшчәнлектә, үсештә ирешелергә тиеш булган дәрәҗә, таләп, норма. *Миндә шундый тәэсир калды: алар арасында генераллыкны аванс төсендә, икеле-микеле алучылар юк. Киресенчә, планканы запас калдырып сикереп үтәргә туры килмәде микән әле аларга?* М.Юныс. *Нишлисең, шигъриятнең планкасы биегәйде.* Р.Миңнуллин. *Планканы иң югары өлгесенә куйганда да, бу чибәркәйне мәктәп завучы я директоры хатыны карьерасы көтә.* А.Хәсәнов

ПЛАНКТОН *и. гр. биол.* 1) Диңгез, елга, күл суында яшәп, су агымы белән хәрәкәт итә торган вак үсемлек һәм хайван организмнары җыелмасы. *Судагы фосфор уты шундый көчле, диңгез яшькелт ут чыгарып пыскый, яна сыман. Диңгездәге балыклар һәм планктон чәчкән ут бу.* М.Юныс. *Планктоннар булмаса, кит үлә.* Т.Миңнуллин. *Әгәр судагы бик вак хайваннарны, ягъни планктонны тотарга кирәк булса, капчыкны я бәздән, я юка ефәктән (газдан) тегәләр.* Яшь натуралистларга

2) *күч.* Офисларда өстәл артында утырып, иҗадилыктан ерак торган акыл эшчәнлеге алып бара торган, үз кул астында буйсынучылары булмаган түбән катлау хезмәткәрләр. *Халык телендә «офис планктоннары» дип аталган затлар, ягъни өстәл артында утыручылар үрчегәннән-үрчи бит.* Татарстан яшьләре

ПЛАНЛАШТЫРУ *ф.* 1) Берәр урын, корылма, төзелешнең проектын, планын (*1 мәгъ.*) төзү. *Казанның үзәген планлаштыру берләшмәсе, әдәбият-сәнгать җәүһәрләрен халыкка җиткерү буенча фотокооператив эшли башлады.* Г.Ахунов. *Юлларны, бакчаларны, гөл түтәлләрен әле болай планлаштыра, әле икенче төрле.* М.Маликова

2) Берәр эш яки чараның тәртибен билгеләү, планын (*3 мәгъ.*) төзү. *Докторлык диссертациясе язылып беткән, алдагы уку елында ул монография әзерләргә тиеш, гомер әнә шулай алдан ук бүлгәләнеп, планлаштырылып куелган.* М.Мәһдиев. *Ялны алдан планлаштыра белмибез без.* М.Юныс. *Россиядә 90 нчы елларда барган үзгәртеп кору процессында дәүләт тарафыннан уздырылган планлаштыру системасының бетерелүе илнең күп кенә предприятиеләрен банкротлыкка төшерде ---.* Философия

3) Берәр нәрсә яки эш эшләргә ниятләү, исәпләү. *Беренче көнне ике колхозга чыгарга планлаштырдылар.* Ф.Садриев. *«Алдан планлаштырып эшләнгән янгын түгел иде микән бу?» дигән фикер аның башында кат-кат бөтерелде.* Ә.Моталлапов. *Болгарда иң зур Коръәне Кәрим куелу белән бергә Ибн Фадланның Болгар дәүләтенә сәяхәтенә багышланган картасын да урнаштыру планлаштырыла.* Мәдәни җомга

Планлаштыра башлау Планлаштырырга керешү

Планлаштырып бетерү Тулысынча планлаштыру

Планлаштырып кую Алдан планлаштыру. *Ата-аналар, гадәттә, Яңа ел каникулының һәр көнен алдан ук планлаштырып куя: бүген нәниебезне Чыршы бәйрәменә алып барабыз, иртәгә – балалар өчен спектакльгә, берсекөнгә – кунакка...* Ватаным Татарстан. *Безнең монда һәр көн алдан планлаштырып куелган.* Көмеш кыңгырау

Планлаштырып тору Әледән-әле планлаштыру; хәзерге моментта планлаштыру. *Сез башта ук Рим Бәримгә яла ягарга планлаштырып торгансыз.* Ф.Бәллүр. *Әле менә мартта булачак концертларым алдыннан да аннан*

дәресләр алырга планлаштырып торам. Шәһри Казан

ПЛАНЛЫ *с*. **1.** Алдан төзелгән план (*3 мәгъ.*) буенча эшләнә, тормышка ашырыла, алып барыла торган. *Иң авыр вакытлар инде артта. Хәзер планлы эш бара.* Р.Фәйзуллин. *Зур капитал салулар белән беррәттән планлы реконструкция эшләре алып барыла.* Т.Нәҗмиев. *Электромонтёрлар планлы эшкә – өйләр янындагы чыбыкларны кисәргә керештеләр.* Я.Шәфыйков

2. *рәв. мәгъ*. Алдан төзелгән план буенча, билгеле планга нигезләнеп, эзлекле рәвештә. *Китап ничегрәк языла, дигәндә, планлы яки плансыз эшләү мәсьәләсен берничек тә истән чыгарырга ярамый, һәм моның механизмын белгечләр – әдәбиятчылар – төрлечә бәялиләр.* Р.Низамиев

ПЛАНЛЫЛЫК *и*. Планлы булу; эшне план (*3 мәгъ.*) нигезендә алып бару. *Правление секцияләрнең эшенә тиешенчә контроль куймады, тиешенчә талән итмәде, эштә планлылык аз булды.* М.Җәлил. *Планның вазифасы – педагогик эшчәнлекне тәртипкә салу, педагогик процесска карата планлылык, системалылык --- кебек таләпләрнең үтәлешен тәэмин итү дигән сүз.* Ә.Хуҗиәхмәтов

ПЛАН-МАКЕТ *и. лат.-фр.* Төзеләсе, салынасы объектның төгәл үлчәмнәре, масштаблары истә тотылып эшләнгән моделе. *Озакламый Гаяз Исхакый музей-утары булыр дип өметләнәбез. Менә аның план-макеты да бар.* Т.Нәҗмиев

ПЛАН-НАРЯД *и. лат.-рус* Нинди дә булса конкрет эшне башкару өчен, аның үтәлеш вакыты, күләме, башкаручысы һ.б. күрсәтелгән планы, шул турыдагы боерык, документ. *План-наряд буенча без Италия порты Тарантада зур диаметрлы газ үткәрү торбалары төяргә тиеш идек.* М.Юныс

ПЛАНОВИК *и. рус* Производство планнарын төзүче белгеч. *Аларның [хатыннарның] берсе Казаннан, заводта плановик булып эшләүче татар хатыны.* З.Фәйзи. *Инһаять, плановик-йөкләмәче ханым: – Мин риза! – диде.* М.Шаһимәрдәнов

ПЛАН-ПРОЕКТ *җыйм. и*. Төрле ниятләр, планнар. *Әгәр дә бүген кем дә булса илнең җитмеш ел эчендә мәтәштергән эре план-проектларын – авылларны колхозлаштырудан алып хәзерге азык-төлек программасына кадәр булганнарын тикшерә калса, без үзебезнең аңгыралыгыбызга һәм наданлыгыбызга шаклар катар идек ---.* Р.Мирхәйдәров

ПЛАН-ПРОСПЕКТ *и. лат.* Берәр эшнең, гадәттә, фәнни тикшеренүнең, максаты, эчтәлеге, башкарылу тәртибе һ.б.ш. күрсәтелгән, киңәйтеп төзелгән планы. *Хезмәтнең гыйльми концепциясе һәм план-проспекты төзелеп, җәмәгатьчелек тикшерүенә куелды.* Х.Миңнегулов

ПЛАН-СХЕ́МА *и. лат.-гр.* Нәрсәнең дә булса системасын, төзелешен яки өлешләренең үзара мөнәсәбәтен күрсәтә торган сызым. *Ул чыганаклар күптөрле: борынгы елъязмалар, сәяхәтнамәләр, дәүләт органнары тарафыннан чыгарылган законнар, карарлар, --- газета-журналлар, элеккеге карталар, план-схемалар...* Ф.Хуҗин

ПЛАНТАЖ *и. лат. а.х.* Питомникларда, җимеш бакчаларында һәм урманда агач утырту алдыннан җирне, туфрак катламнарын күчереп, тирән итеп сукалап, сөреп, казып чыгу

ПЛАНТАЖЛА́У *ф. а.х.* Туфракны плантаж сабаны белән тирән итеп сөрү

Плантажлап бетерү Барысын да плантажлау

Плантажлап чыгу Баштан ахырга чаплантажлау

Плантажлый башлау Плантажларга керешү

ПЛАНТА́ТОР *и. рус* Плантация (*1 мәгъ.*) хуҗасы. *Заманында Африкадан куып китерелгән кара тәнле коллар йөзләрчә еллар буена ак тәнле плантаторларга бил бөккән ---.* Р.Низамиев. *Плантаторлардан соң яшел тукымага төренгән бер төркем хатыннар узды.* М.Юныс. *--- Гаити утравын яулап алган француз плантаторлары, авыр кара эшләрне башкарыр өчен, бирегә Африканың төрле төбәкләреннән негрлар китерәләр.* Р.Зәйдулла

ПЛАНТА́ТОРЛЫК *и*. Плантатор булу

ПЛАНТА́ЦИЯ *и. лат.* 1) Шикәр камышы, дөге, кофе, банан, какао, кокос һ.б.ш. культураларны игү белән шөгыльләнә торган, зур мәйданлы, ялланып эшләүче эшче көчләр кулланган эре җир биләү хуҗалыгы. *Җиләк-җимеш плантацияләре, ихтимал, диңгез ярлары ягындадыр, тауларда күбесенчә ылыслы агачлар икәне самолёт түбәнәя башлау белән күзгә ташлана.* Г.Ахунов. *Испания яулап алучылары 1660 елда Үзәк Американың Ямайка утравында плантацияләр ясап, коллар хезмәте кулланып, шикәр камышы үстерә башлыйлар.* Кызыклар дөньясында

2) Махсус техник яки азык-төлек культурасы чәчелгән зур җир мәйданы. *Вәзыйх ел саен мәктәп плантациясендә тәҗрибәләр үткәрә.* Х.Камалов. *Балык, устрица плантацияләре агуланып юкка чыга.* М.Юныс. *Чөгендер плантацияләренең һәрберсендә халык чәчүлекләрне эшкәртә, Сабантуйларга кадәр кулын чишеп, җиңел суларга омтыла.* Ф.Садриев

ПЛАНШЕТ *и. фр.* 1) *махс*. Берәр урынны топографик планга төшергәндә кулланыла торган, кәгазь беркетелгән дүрткырлы шома такта; гомумән, язусызу эшендә кулланылган шуңа охшаш нәрсә. *Мин аны [карандашны] егерме биш сантиметр чамасы җепкә бәйләп, җепнең икенче очын тезләрем өстендәге планшетка беркетеп куйган идем.* С.Баттал. *Үтеләчәк темага туры китереп, стенд, картон планшетлар урнаштырыла.* З.Хисамов. *Алып баручының кулында бүре, кырмыска, тукран, карга, козгын, черки рәсемнәре төшерелгән планшетлар.* Могҗизалы мәктәп сәхнәсе

2) *махс.* Геодезик план, сызым. *Стена буйларында, идәндә, өстәлләрдә, шкаф өсләрендә бихисап планшетлар, кәгазь рулоннары, мәрмәр, җиз һәм пластилин фигуралар.* М.Маликова

3) Карталар салып йөртү өчен, алгы ягы үтәкүренмәле материалдан эшләнгән яссы сумка. *Очучы киемнәрен безгә кичтән өләшеп куйдылар: комбинезон, күн шлем, планшет.* М.Юныс. *Янгураз кәфе киткәндәй карап торды да планшетыннан баш мөхәррире үзе булган*

журналны чыгарды. Т.Әйди. *Шунда ук планшеттан картасын чыгарып, комиссар Васильевны хәрби объектның координатлары белән таныштырды.* Р.Ибраһимов

4) Театрда сәхнәнең рельефын үзгәртергә мөмкинлек бирә торган, алынмалы такталардан торган идән. *Сәхнә планшетында (шулай ук шартлылык кулланып, ширмалар ярдәмендә эшләнгән) Әлмәндәр картның алма бакчасы.* М.Арсланов

5) Яссы формадагы, бармак яки стилус белән кагылып идарә ителә торган сенсор экранлы мобиль җайланмаларның, компьютерларның җыелма исеме. *Моннан тыш Думаның утырышлар залын да камилләштерергә --- һәр депутатның эш урынына махсус планшетлар урнаштырырга --- җыеналар.* Татарстан яшьләре. *«Мини мисс» дәрәҗәсе белән бергә, Е.Артемьевага «Роста-М» төзелеш компаниясе бүләге – компьютер планшеты һәм «Натали-турс» компаниясеннән 20 мең сумлык сертификат тапшырылды.* Мәдәни җомга

ПЛАНШЕ́ТКА *и. рус* 1) *к.* **планшет** (*1, 3 мәгъ.*). *Взвод командиры Газинургa карта белән планшеткасын сузды.* Г.Әпсәләмов. *Кешелек җәмгыяте капчыктан өстен булырга тырышып күп әйбер уйлап тапты: саквояж, --- планшетка --- һәм тагын әллә ниләр.* М.Мәһдиев

2) *иск.* Корсетны каптыру, эләктерү өчен металл пластинка

ПЛАНШЕТЛЫ *с.* 1) Планшеты булган

2) Планшет (*5 мәгъ.*) формасындагы. *Русиянең Саклану министрлыгы якын арада ---- һәр офицерны планшетлы компьютерлар белән тәэмин итәргә уйлый.* Ватаным Татарстан

ПЛА́НШИР *и. инг.л. махс.* Көймәләрнең, корабларның фальшбортына яки палуба кырыена ныклык өчен куела торган иң өске калын борыс. *Авып китмәс өчен, ике куллап фальшбортның планширына ябышып, бакка таба Феликс бара.* М.Юныс

ПЛАСТ *и. рус* 1) Нәрсәнең дә булса тыгыз катламы. *Кар пласты*

2) Утырма тау токымының горизонталь катламы. *«Профессорым» аңлатып бара. Аның сөйләвенә караганда, күмер тигез пласт булып җир астында ятмый икән.* Һ.Такташ. *Урманнар күп булган җирдә грунт сулары пласты да калынрак, аның запасы да мулрак, елгалар да тулырак.* Татарстан яшьләре

3) *күч.* Нәрсәнең дә булса билгеле сыйфаты ягыннан бертөрле, тиңдәш җыелма өлеше, төркеме. *Повестьта иҗтимагый пласт геройлар аша ачыла.* А.Шәмсутова. *XIX йөз ахыры – XX йөз башына төзелеш ысулларында аерымлыклар булса да, үзенчәлекле пласт оешуын искәреп китмичә булмый.* Әстерхан төбәгендә татар әдәбияты

ПЛА́СТИК *с.* **1.** 1) *физ.* Материаллар турында: басым астында деформацияләнә, ләкин ватылмый торган, сыгылмалы, үзле

2) Салмак, нәфис, зифа, сыгылмалы (хәрәкәт, ишарә һ.б.ш. тур.). *Биючеларнең нәфис пластик хәрәкәтләре матур эстетик тойгылар, горурлык хисләре уята.* Р.Фәйзуллин. *Шартлы театр актёрны --- пластик хәрәкәтләр ритмына буйсындыра.* М.Арсланов

3) *сәнг.* Күләмле формалар тудыра торган сынлы сәнгатькә бәйле, скульптур. *--- скульптураны икенче төрле пластик сәнгать дип тә йөртәләр.* Ф.Хатипов

4) Табигый яки ясалма кушылмалардан – полимерлардан ясалган. *Нишләп пластик шешәләрдә рассол сатылмый?* З.Хәким. *Теплоход, Хиҗазга алып кайту өчен, пластик капчыкларга тутырган йөк төйи.* М.Юныс. *Һиндстанда бер укытучы берникадәр вакыт миллиардер булып алган: банк аның пластик картасына ялгыш 496 миллиард рупий --- акча күчергән.* Татарстан яшьләре

5) *мед.* Нинди дә булса организм тукымаларының формасын яки эшчәнлеген торгызуга булышлык итә торган. *Ничек диләр әле, йөзгә пластик операция ясатып җиффәрсәң, йөзеңдә бер җыерчык та калмый, ди бит.* Ф.Яруллин. *Ләкин [Македонский] ныклап аягына баскач, --- пластик операция ясатыр --- да янә Россиягә кайтып төшәр.* Р.Мирхәйдәров. *Яхшы пластик операция ясатырга кирәк.* З.Хәким

6) Өлешләре бер-берсенә ярашкан, төгәл, гармонияле

7) Нәфис, үзенең сурәтләү чараларында гармонияле, сәнгатьчә тәэсирле булган. *Шигъри сүзне тавыш куәте белән, --- пластик тембр белән илаһи сүзгә сәҗдә кылып уку сораладыр.* Д.Заһидуллина. *Рәссам Абрек Абызгилдин – үз иҗатында классик традицияләргә гомере буе тугры калган оста. Бу исә рәссамның натурадан ясап, һәрвакыт кулын күнектереп торуында да, картиналарының пластик тулыканлылыгында да --- чагыла.* Мәдәни җомга

8) Үзгәрүчән табигый һәм башка шартларга яраклаша торган (тере организмнар тур.)

2. *и. мәгъ.* Полимер материалдан эшләнгән әйбер. *Стеналарга фанер урынына пластик ябыштырганнар.* М.Юныс. *Викториянең тәменә килгәндә, ясалма – пластик кисәге чәйнәгән кебек.* Татарстан яшьләре

ПЛА́СТИКА *и.* 1) *сәнг.* Ябыштыру, кисү, сырлау һ.б.ш. ярдәмендә күләмле формалар тудыру сәнгате, скульптура, сынлы сәнгать. *Безнең заманга яраклаштырылган борынгы стильләр Шубин тарафыннан савыт-саба җыелмаларының, --- кече пластика идән вазаларының бизәлү формаларында кулланыла.* Р.Әхмәтҗанов. *Шуңа күрә бу төбәктә пластика, ташны сәнгатьчә эшкәртү традицияләре дә гаять югары була.* Мәдәни җомга. *Даши Намдаковның станлы скульптуралары янында сынның егәрен, көчен, иреген тоясың, пластиканы шуның кадәр тоемлавына сокланасың.* Шәһри Казан

2) Тән хәрәкәтләренең һәм ишарәләрнең нәфислеге, сыгылмалылыгы, үзара килешүе-ярашуы, аларның гомуми гармониясе. *Әлбәттә, талдай буйсын, балыкган ачык йөз, грация, сәхнәдә үзеңне тоту рәвеше, хәрәкәттәге пластика – сәхнә кешесенә иң кирәкле сыйфатлар.* Р.Әхмәтҗанов. *Грим салырга осталыгы, --- искиткеч пластика, менә дигән дикция – болар Усман Әлмиевның артист буларак төп сыйфатлары.* Е.Домбаева. *Бу төркемдәге*

биюче кызларның пластикасына сокланырга гына кала. Шәһри Казан

3) *әд.* Матур әдәбият әсәрендә язучыга җанлы, тәэсирле образлар тудырырга булыша торган тел һәм стиль чараларының җыелмасы. *Шигъри пластика урнәге буларак тәкъдим ителерлек «Сурәт» шигырендә кешене сыный да, үстерә дә торган мәхәббәт хисе үзәккә алына.* Ф.Солтан

4) *сәнг.* Сәнгатьтәге пластиклык, эмоциональ сәнгатьчә чагылыш, гармония, нәфислек. *Япон һәм Кытай сәнгатендәге нәзбереклек, иероглиф тәэсиреннән туган тылсымлы пластика түгелме бу?* М.Юныс. *Ул гына да түгел, актёрның табигатьтән бирелгән пластика белән берәттән матур тембры да бар!* Р.Сәгъди

5) *мед.* Тән тиресен яки органнарны күчерү, трансплантация яки аларны алыштыручы материаллар белән имплантацияләү (пластик операция) ярдәмендә тәннең аерым өлешләренең формасын яки эшчәнлеген торгызу буенча хирургияысулларының гомуми атамасы. *Баш табиб Дирк Рихтер тән пластикасы бүлегендә операцияләр ясый.* Татарстан яшьләре. *Корсакны тарттыру – биш мең евро, чырай пластикасы – җиде мең евро.* Акчарлак

ПЛАСТИКАТ *и. рус* Йомшак пластик массаның бер төре, пластик каучук. *Рөстәм Хәмитов сәнәгать эшләнмәләре өчен ярымфабрикатлар җитештерүче «Башкортстан пыяла компаниясе», кабель пластикатлар эшләп чыгаручы «Башпласт», төзелеш ихтыяҗлары өчен күбек-пласт җитештерүче «Башмонолит» җәмгыятьләрендә эш барышы белән таныштым.* Кызыл таң

ПЛАСТИКЛЫК *и.* 1) *физ.* Матдәләрнең басым астында теләсә нинди формага кереп, шул форманы басым тукталгач та саклау үзлеге, сыгылмалылык, үзлелек. *Модификацияләү һәм яндыру чуенның пластиклыгын, бәрүгә үзлелеген һәм чыдамлыгын арттыра.* Төзү материаллары. *Деформацияләнүче каты җисем механикасындагы яңа фәнни казанышларны исәпкә алып, И.Г.Терегулов «Материаллар каршылыгы, эластиклык һәм пластиклык теориясе нигезләре» дигән дәреслек иҗат итә.* Фән һәм тел

2) *сәнг.* Нәфислек, гармониялелек, сәнгатьлелек

ПЛАСТИЛИН *и. гр.* **1.** Балчыкка балавыз, май, вазелин яки кибүгә каршы башка нәрсә кушып эшләнгән, әвәләп нинди дә булса фигуралар ясау өчен төрле төстәге йомшак пластик материал. *Бу бүлмәдә сабыйларга пластилиннан сын, буяп рәсем ясарга өйрәтәләр, әкият сөйлиләр, уеннар оештыралар.* М.Юныс. *--- Тиешле центровка бирү өчен, егетләр шарның өстенә пластилин ябыштыралар.* Галәмгә юл. *Мин дәрес биргән арада, ул рәсем ясап, пластилиннан нидер әвәләп, сабыр гына көтеп утыра ---.* Татарстан яшьләре

2. *с. мәгъ.* Шундый массадан ясалган. *Стена буйларында --- бихисап планшетлар, кәгазь рулоннары, мәрмәр, җиз һәм пластилин фигуралар.* М.Маликова. *Гипс, пластилин массаларын төрле шәкелгә китерергә мөмкин.* Философия

ПЛАСТИ́НА *и. гр.* **1.** Яссы формадагы юка материал катлавы. *Бу имезүчеләр мыеклы китлар төркеменә керә; аларның 10 төренең дә авызында теш урынына мөгез пластиналары ---.* Татарстан яшьләре

2. *с. мәгъ.* Шундый формадагы, шуннан гыйбарәт. *Пластина саңаклы --- моллюскларны яратканда, табигать аларның йөрәге аша Амур уклары түгел, туры эчәкне уздырган.* Кызыклы физиология

ПЛАСТИ́НКА *и. рус* 1) Яссы формадагы бик юка тыгыз яки каты материал кисәге (пыяла, металл һ.б.). *Ул бармак очы хәтле генә көмеш пластинканы үгез тиресенә төрә ---.* М.Юныс. *Яле, карап карыйк дигәндәй, башын хикмәтле генә селкеп алды да нәни яфрак чаклы пластинка белән кылларга чиртә башлады.* Р.Низамиев. *Б.э.к. IV гасырда Кытайда акча урынына ташбакалы пластинкалар әйләнештә йөргән.* Кызыклар дөньясында

2) Уйнату өчен, тавыш яздырылган, пластик материалдан эшләнгән диск. *Финляндиядә «Керим әле урманнарга» җырын андагы татар җырчылары пластинкага яздырганнар.* Г.Ахунов. *Пластинкадан бию такмагы ишетелә.* М.Мәһдиев. *Чәйдән соң Вилдан пластинкалар уйнатты.* М.Маликова

3) Фотографиядә: яктылыкка сизгер эмульсия белән капланган пыяла. *Инглиз галиме Томсон һәм рус галиме Тартаковский фото-пластинкада тәртипсез рәвештә үстерелгән микрокристаллар белән капланган махсус мишеньнән кайтарылган электроннар дифракциясен теркәгәннәр.* Физика

4) *физ.* Юка сыеклык катламы. *Сыек пластинкаларның барлыкка килү закончалыгы*

5) *бот.* Үсемлек яфрагының киңәйгән өске өлеше. *Яфрак пластинкасы. Пластинка сапка беркетелгән*

6) *бот.* Кайбер гөмбәләрдә эшләпәнең аскы ягын тәшкил иткән сырларның берсе. *Эшләпә астында җилпәзә сыман бик күп пластинкалар урнашкан*

◊ **Пластинканы алыштыру** Сүзнең гадәттә туйдырган яки күңелсез темасын үзгәртү; башка нәрсә турында сөйли башлау. *Рөстәм теманы бик тиз үзе яраткан пластинкасына алыштырып куйды.* З.Дәүләтов. *«Пеләш баш» урынына «Бөдрә каш» утыргач, Ярый Ярыйич пластинкасын алыштырды. Бертуктаусыз: «Коммунизм! Коммунизм!» – дип талкыды.* М.Сәлим

ПЛАСТИ́НКАЛЫ *с.* 1) Пластинкасы (*1, 5 мәгъ.*) булган; пластинкалардан гыйбарәт булган; пластинка формасындагы. *Кайтып, әни карчыктан: «Әни, теге, дуга сыман пластинкалы, металл чыбыктан ясалган уен коралыңны бир әле», – дисәм, әни мескен артларына авып китәр иде!* Х.Сарьян. *Кабыргаларның төренә карап, көпшәле конденсаторларны чыбыклы, пластинкалы, --- чорнаулы төркемнәргә бүләләр.* Суыту машиналары һәм криоген техникасы. *Приборлар һәм җиһазлар: пластинкалы ротор насос, сирәгәйтү баллоны һәм --- секундомер.* Идеаль газның халәте

2) Пластинка (*2, 3 мәгъ.*) ярдәмендә эшли торган. *Ләкин хәзрәтнең --- гаҗәпләнүенә каршы, Әхмәт азан кычкырган нәрсәнең мәәзин түгел, бәлки*

махсус пластинкалы бер машина икәнлекне сөйләде. Ф.Әмирхан. *«Ресторан» дигәне дә ашау-эчү кирәк-яраклары төялгән грузовик, ә «оркестр»ы – бердәнбер пластинкалы патефон икән.* С.Баттал. *Подъездга керер алдыннан, Шәркәй, бертуктаусыз: «Иман – вәгъдә!..» – кебегрәк кәлимәләрне юлын саташтырган пластинкалы патефон кебек кат-кат кабатлап торды.* Ф.Баттал

ПЛАСТМАСС *и.* **1.** *к.* **пластмасса**. *Пальма пластмасстан ясалган уенчыкны хәтерләтә.* М.Юныс

2. *с. мәгъ.* Пластмассадан эшләнгән. *--- диңгезче, стюардесса күтәреп килгән подностан пластмасс стакан алып, Зуфирәгә суздыы.* М.Маликова. *Хәкимҗан тәрәз төбендәге пластмасс тешләргә карап куйды.* Н.Хәсәнов. *Чәйгә кечкенә пластмасс савытларда бал, джем ише нәрсәләр бирәләр*. Безнең гәҗит

ПЛАСТМА́ССА *и. рус* **1.** Пластик (*3 мәгъ.*) масса. *Шулчак секретарь нишләптер аның колакларына игътибар итте: алар пластмассадан ясалгандай хәрәкәтсез һәм төссез иде.* Ф.Садриев. *Европа илләрендә аларны пластмассадан ясыйлар һәм җилем белән беркетеп куялар.* Кызыклар дөньясында. *Борыныңны терәп иснәмәсәң, исе дә килми, кыярның ике башын берберсенә тидергәнче бөгеп була, пластмасса кебек.* Ирек мәйданы

2. *с. мәгъ.* Шундый материалдан ясалган. *Алсу борын берөзлексез коляска өстенә элгән яшел, сары пластмасса шарларны шудыра, елмая.* М.Мәһдиев. *Врач сейфыннан пластмасса флаконга тутырылган дару алды.* Ф.Садриев. *--- эретеп ябыштыруга җиңел бирелүе пластмасса торбаларны монтажлауны механикалаштырырга мөмкинлек бирә ---.* Төзү материаллары

ПЛАСТУН *и. рус тар.* Кубан казакларының разведка һәм каравыл хезмәтен үти торган махсус пехота отрядында сугышчы. *Бүген ул – Идел казак гаскәренең җиденче пластун бригадасы сотнигы һәм Русиядә Абхазия Республикасы консулының ярдәмчесе.* Кызыл таң

ПЛАСТУ́НЧА *рәв.* Терсәкләргә таянып, гәүдәне җирдән аермыйча (шуышу тур.). *Гәүдәгә таза һәм салмак хәрәкәтле булганга күрә, кырдан-кырга чабу, пластунча үрмәләү --- кебек практик дәресләр Фәриткә гаять авырдан бирелә.* Р.Низамиев. *Шуышабыз пластунча, җиргә терәп күкрәкне, Безне шулай шуышырга Айдар үзе өйрәтте.* Ж.Дәрзаман. *Көндез без иртәдән кичкә кадәр стройда йөрергә өйрәнәбез, пластунча шуышабыз ---.* М.Юныс

ПЛАСТУНЧЫ *и.* Терсәкләргә таянып, гәүдәне җирдән аермыйча шуышучы солдат. *[Опанас] түмгәктән түмгәккә ышыклана-ышыклана шуышып китте. Ротада ул – иң оста пластунчы.* Г.Әпсәләмов

ПЛА́СТЫРЬ *и. лат.* 1) Медицинада кулланылган бәйләвеч төре: яраны, җәрәхәтле урынны ябу өчен ябышкак тукыма кисәге. *Зәнфирә --- бармагы белән тоткан мамыкны пластырь белән ябыштырып куйды.* Ф.Садриев. *Алиханның үзенә көлергә ярамый, катырак көлеп җибәреп, корсагына ябыштырылган пластыре ычкынып китүдән курка ул.* З.Хөснияр

2) Шул бәйләвечкә дару сеңдереп яки сылап ясалган дәвалау чарасы. *Ася аркадагы яраларны спиртлы тампон белән чистартты, аларга яра пластыре ябыштырып чыкты.* Х.Камалов. *Бактерицид пластырь. Борычлы пластырь*

3) Көймә, корабларның тишелгән урыннарын вакытлыча томалый торган, калын киндердән ясалган җайланма. *«Маякчы»ның арткы ягы суга иңә төшкән, матрослар, берсен берсе ашыктыра-ашыктыра, аның корпусындагы зур гына тишекне киндер пластырь белән каплап маташа ---.* С.Сабиров

ПЛАТАН *и. лат. бот.* Платаннар семьялыгының бердәнбер вәкиле булган, киң яфраклы һәм яшькелт соры кайрылы, бик зур булып үсә торган мәңгеяшел яки яфрак коючан агач; чинар. *Чал платан төбендә дә – көз. Утыра шунда бер карт – нәкъ Мәржани! Биредә гүя гыйлем мәгарәсе... Чал платан – манма кояш!* Р.Әхмәтҗанов. *Юк, автор көньяк курортларына барып рәхәт чиккәндә, кипарисларны, платаннарны яманлап, авылның иске мунчасын, муртайган киртәләрен мактап җырлап ятучылардан түгел.* М.Мәһдиев

ПЛА́ТИНА *и. лат.* Катализаторлар, химик аппаратлар ясаганда, электр һәм радиотехникада, зәргәрчелектә һ.б. файдаланыла торган көмеш ак төстәге ялтыравык, алтыннан кыйммәтрәк бәяләнә торган затлы металл; агалтын. *«Мәскәү яшькә ышанмый» халык әйтеме түгел, халыкларның алтын, алмаз, платина приискаларын – Миасларын, Бодайболарын тартып алган буржуа мәкале.* Х.Туфан. *Орден чиста платинадан, рәсемнәре алтыннан.* Р.Сәгъди. *--- андый термометрның төп элементы итеп фарфор я слюда каркасына чорналган платина чыбыгын алалар.* Физика

ПЛА́ТИНАЛАУ *ф. тех.* Төрле химик тәэсирләрдән саклау өчен, металл эшләнмәләр өстенә платина йөгертү

Платиналап бетерү Тулысынча, барысын да платиналау

Платиналап чыгу Булган берсен платиналау

Платиналый башлау Платиналарга керешү

ПЛАТИНИТ *и. рус хим.* Пыялага үткәргечләр эретеп ябыштырганда, платина урынына кулланыла торган тимер һәм никель эретмәсе

ПЛАТО *и. фр. геогр.* Тирә-ягындагы тигезлекләрдән күзгә күренерлек булып калкып торган яссы таулык; тау өстендәге киң тигезлек. *Төзелеш материалларына да кытлык булмаган, урыны белән өскә чыгып торган таш катламы Кремль тавы астында бөтенләе белән зур бер яссылык (плато) тәшкил иткән.* Ә.Мөхәммәдиев. *Кыска гына вакыт эчендә пассажирлар --- тау платосыннан диңгез култыгына килеп чыгалар.* Татарстан яшьләре

ПЛАТОНИЗМ *и. гр.* 1) *филос.* Борынгы грек фәлсәфәчесе Платонның идеалистик философиясенә нигезләнгән фәлсәфи юнәлешләрнең гомуми атамасы. *«Оча торган кешеләр...» романы мөселман платонизмы кысаларында карала алыр --- иде.* А.Шәмсутова

2) *кит.* Мәхәббәттә, мавыгуда рухи омтылыш, кызыксыну гына булу, дәртлелекнең, җенси теләкнең, шәһвәтнең булмавы

ПЛАТО́НИК *с. кит.* Бертөрле дә дәрт, җенси теләк катнашмаган, рухи омтылышка, мәхәббәткә нигезләнгән. *Мәхәббәт – иләһи (платоник) һәм хайвани.* Г.Бәширов. *Платоник сөюдән генә булса да, Чибәркәйләр миңа карап уфтансыннар.* Р.Харис. *Әллә сөюләре платоник мәхәббәткә әйләнеп бара инде?* З.Хөсният

ПЛАТФО́РМА *и. фр.* **1.** 1) Каты, нык материалдан ясалган тигез калку мәйданчык. *Басып торган урыныма карыйм, без --- ясалма платформа, ягъни күтәртелеп эшләнгән мәйданчыкта икәнбез.* Р.Сәгъди. *Баһадир Николай Жеребцов, югарыдагы махсус басмага менеп, --- камытка нык баулар белән бәйләнгән зур һәм киң платформаны күтәрде.* Кызыклар дөньясында

2) Тимер юл полотносы буена ясалган калку мәйданчык, перрон. *Алар Анклам поезды килеп туктаячак платформага таба атладылар.* Т.Әйди. *Электр поезды, «Әбҗәлилов» --- платформаларын узып, «Дәрвишләр» станциясенә бара.* Мәдәни җомга // Автовокзалларда автобусларның пассажирларны утырту өчен билгеләнгән урыны. *Автобус торган таш платформа моннан караганда күренми.* М.Юныс // Поездлар, гадәттә шәһәр тирәсе электр поездлары, зуррак тимер юл станцияләре арасында кыска вакытлы тукталыш ясый торган кечерәк станция. *Поезд, Юдин ягындагы платформаны узып, Арча юнәлешендәге платформага барып туктады ---.* М.Хуҗин. *Без Мәскәүнең Ярославль юлындагы Клязьма дигән платформада бер ялгыз карчыкка фатирга урнаштык.* Ф.Чанышева. *Дөрес түгел, аның станция дип әйтерлеге дә юк, кечкенә генә платформа шунда.* Татарстан яшьләре

3) Нинди дә булса механизмнарның, корылмаларның төп элементын тәшкил иткән нигезе. *Инһаять, менә комбайны киндер җире башына платформадан төшерделәр.* Х.Камалов. *Норвегиянең нефть платформаларында эш тәкъдим итәләр.* Татарстан яшьләре

4) Тимер юлда кыска бортлы түбәсез йөк вагоны. *Танклар, туплар, автомашиналар төялгән платформалар күренә.* Г.Әпсәләмов. *Перрон белән ике арага каршы яктан --- брезент белән капланган платформалар таккан хәрби эшелон килеп керде.* М.Мәһдиев. *Яңа пломба куелган контейнер тимер юл платформасына утырып порттан чыгып киткәч, мин калага таба юл тоттым.* М.Юныс

5) *геол.* Җир кабыгының тектоник хәрәкәт һәм магматик эшчәнлекнең түбән интенсивлыгы, яссы рельефы белән аерылып торган эчке тотрыклы өлеше, плита. *Русия, --- Латвия, Эстониядә – Рус һәм Себер платформасы дип атала торган геопатоген зоналар территориясендә --- гомер озынлыгы максимум 83 яшь.* Татарстан яшьләре. *Тектоник ярык тагы да эчкәрәк китәргә һәм --- озынаерга мөмкин. Чөнки ул хәрәкәт итә торган ике тектоник платформа арасында.* Ватаным Татарстан

6) Аяк киеменең гадәттәгедән калынрак табаны; шундый табанлы аяк киеме. *Башка шагыйрьләрнең хатыннары өч бүлмәле фатирда тора, өсләрендә модный күлмәк, аякларында платформа ---.* Р.Батулла

7) *күч.* Берәр конкрет эш яки гомумән эшчәнлек өчен нигез итеп алынган нәрсә, җирлек. *Белгечләр, ВАЗ-2116 ның нигезе итеп шул ук «десятка»ның платформасы алыныр, дип белдерәләр.* Мәдәни җомга

8) *күч.* Берәр партиянең, төркемнең, иҗтимагый оешманың эш программасы, карашлар системасы, сәяси таләпләре. *1990 елның февраль пленумында кабул ителгән платформаны укыгач аңладык: безнең партия дип табынган нәрсәбез партаппарат --- булып чыкты.* М.Юныс. *Баркашовның «Русское Национальное единство» хәрәкәте --- матур сүзләрне яратмый. Платформалары – Русиядәге кечкенә милләтләрне кылыч астында тоту.* В.Юныс

2. *с. мәгъ.* Калын табанлы. *[Әнисә] Тар, кыска юбка, платформа үкчәле туфли киде ---.* М.Мәһдиев. *Ул кыска аяклар шулкадәр хәйләкәр: егетләр алдында матур күренер өчен, платформа үкчә кияләр.* Р.Сибат

◊ **Платформада тору** Билгеле бер сәяси карашларны яки партия интересларын яклау. *Мин алар турында, алар совет платформасында торалар, --- дип кенә әйтә алам.* Х.Туфан. *Галимҗан Ибраһимов озак еллар дәвамында социал-революционерлар, ягъни эсерлар партиясе платформасында тора.* Ә.Рәшит

ПЛАУ́Н *и. лат. бот.* Сабаклары җиргә җәелеп ята торган вак яфраклы, споралы, абагасыман үләнчел үсемлек; су мүге, бүре аягы, ликоподий. *Плаунларның Европада үсә торган барлык төрләрендә дә алкалоидлар бар.* Агулы үсемлекләр. *Плаун вегетатив юл белән дә үрчи ала.* Ботаника. *Хәзерге плауннар – гади яфраклы, күпьеллык үләнчел үсемлекләр.* Татарстанның үсемлекләр һәм хайваннар дөньясы

ПЛАУ́НСЫМАННАР *и. бот.* Ике класска, өч рәткә, алты ыругка караган меңнән артык төрне берләштерә торган тәбәнәк, күпьеллык үләнчел үсемлекләр классы. *Үсемлекләрнең бүгенге классификациясе буенча плаунсыманнар бүлеге югары төзелешле үсемлекләрнең иң борынгы төркемнәреннән санала ---.* Агулы үсемлекләр. *Риниофитларның төрле формаларыннан мүксыманнар, плаунсыманнар --- башлангыч ала.* Ботаника

ПЛАУ́НЧАЛАР *и. бот.* Плаунсыманнар классына кергән мәңгеяшел үләннәр семьялыгы. *Плаунчалар семьялыгына 2 ыруг: плаун һәм --- филлоглоссум керә.* Ботаника

ПЛАФОН *и. фр.* 1) Рәсемнәр, мозаика һ.б. төрле бизәкләр, сурәтләр төшерелгән түшәм; гомумән түшәм. *Паоло Кальяри --- рәсем сәнгатендәге үз юлын плафон сәнгатендә һәм дивар рәсемендә таба.* Х.Якупов // Түшәмгә төшерелгән, ябыштырылган рәсемнәр, бизәкләр, сурәтләр үзләре. *Гипслы һәм гипсбетонлы эшләнмәләрне куллану өлкәсе түбәндәге төркемнәргә бүленә: --- архитектура-бизәү детальләре (кәрниз, түшәм розеткасы, плафон, кайма һ.б.).* Төзү материаллары

2) Гадәттә түшәм яки диварда урнаштырылган яктырткыч лампаларның пыяласы, үтәкүренмәле абажур. *Тамаша залы --- плафоннарга тезелгән сирәк лампочкалар белән яктыртылган.* М.Маликова. *Кайда икәнлегемә төшенә алмыйча бертын ятканнан соң, түшәмдәге пыяла плафонга төшкән ай яктысын күреп алдым.* М.Юныс. *Иза чикте студент халкы бер атамага да туктала алмыйча: --- патефон, карт төлке, плафон...* Т.Галиуллин

ПЛАЦ *и. нем. хәрби* Парадлар һәм сафка тезеп хәрби өйрәнүләр, смотрлар үткәрелә торган мәйдан. *Яңа елның беренче көнендә, плацка тезеп, егетләргә хәрби ант кабул иттерделәр ---.* М.Мәһдиев. *Үзбәкләр исә, плацка чыгып сафта йөргәч, унбиш минуттан отделение командирына ялына башлыйлар.* Р.Кәрами. *Кайчакта төнге атыш булганын да ишетми калалар, иртә белән бөтен плац буенча чәчелеп яткан буш гильзалардан гына беләләр.* И.Сиражи

ПЛАЦДАРМ *и. фр.* 1) Дошман территориясенә һөҗүм итү өчен кораллы көчләрне туплау һәм хәрби хәрәкәтләр җәелдерүнең башлангыч пункты, базасы булып хезмәт итә алырлык башка яки үз дәүләте территориясе. *Хәзер километр ярым тирәнлектәге дошман оборонасы безнең якта иде. Көч тупларлык, ныгырлык плацдарм бар дигән сүз.* Х.Камалов. *Вятка җире рус дәүләте составына кертелгәннән соң, рус гаскәрләре өчен Казан ханлыгы чикләре янында уңайлы плацдарм барлыкка килә.* И.Гафаров. *Гыйрак Урта Азиягә үтеп керү өчен уңайлы плацдарм ролен үтәргә тиеш иде ---.* Татарстан яшьләре

2) Һөҗүм итүче гаскәр елганың аръягында яулап алган яки чигенүче гаскәр саклап калган территория. – *Без --- плацдарм корган җирне кararга барабыз, – диде Степан Васильевич.* М.Юныс. *Полклар, дивизияләр, зур югалтуларга карамыйча, теге ярга чыктылар һәм яр буенда ике-өч чакрым киңлегендә плацдарм биләделәр.* И.Хуҗин. *1941 елның 26 сентябренә каршы төндә --- Ленинград фронты гаскәрләре Нева елгасын --- кичеп чыктылар һәм Нева елгасының сул як ярында плацдарм яулап алдылар.* З.Зәйнуллин

3) *күч.* Берәр нәрсә өчен нигез, башлангыч пункт, нокта. *Гасыр башында барлыкка килгән мәдәни-агарту җәмгыятьләренең --- сәхнә эшчәнлеге үзенчә бер иҗат лабораториясе булды, киләчәктәге профессиональ сәнгать өчен ныклы плацдарм формалаштырды, дисәк тә, арттыру булмас.* К.Миңнуллин

ПЛАЦЕ́НТА *и. лат. анат.* Ана карынында үсү чорында ана белән бала яралгысы арасында бәйләнеш һәм матдәләр алмашын тәэмин итә торган орган, бала урыны, соңгылык. *Балага узган хатынның алкоголь куллануы зәгыйфь бала туу ихтималлыгын күпкә арттыра, алкоголь ана канынан плацента аша яралгыга үтеп керә, ә ул – аның өчен агу.* Сәламәт яшәү нигезләре. *Никотин тәэсирендә ана кешенең кан тамырлары кискен төстә кысыла башлый, шул исәптән плацента тамырлары да.* Татарстан яшьләре

ПЛАЦКАРТ *с.* **1.** Плацкарта буенча пассажирларга тәкъдим ителә торган. *Урыны плацкарт, аның да ян кырыйдагысы, аның да бәдрәф янәшәсендәгесе иде.* А.Гыйләҗев. *Ә безнең сыйныфсыз илебездә вагоннар алты төрле: гомуми, комбинированный, плацкарт, купе, люкс һәм халыкара вагоннар.* М.Юныс. *Плацкарт булса да, пассажирлар белән шыгрым тулы, һавасыз, ыгы-зыгылы вагонда биш сәгать теркелдәү улыма бик авыр булды ---.* Г.Галиев

2. *и. мәгъ.* 1) Шундый вагон яки урын. *Андыйлар, абзыкаем, плацкартта йөрми инде.* Т.Галиуллин. *Бер поездга булмады, икенчесенә булмады билет, өченчесенә уптым-илаһи плацкартка ике вагонга алты билет таптык.* Т.Миңнуллин. *Ерак араларга йөри торган поездларда --- гомуми һәм плацкартлар 12 процентка кыйммәтләнәчәк.* Татарстан яшьләре

2) *к.* **плацкарта**. *Өченче класстан плацкарт белән билет алына һәм Кәбир Бәкер Тукайны Мәскәүгә кадәр озата бара.* Габдулла Тукай: тормыш һәм иҗат елъязмасы

ПЛАЦКА́РТА *и. нем.* Поезд вагонында билгеле бер урынга утырырга (ятарга) хокук бирә торган квитанция яки йөрү билетына өстәмә билет // Шундый билет хакына пассажирга тәкъдим ителә торган урын. – *Мягкая плацкарта булды бу, әни, – диде Асаф, юрган астында рәхәтлек белән киерелеп.* М.Мәһдиев

ПЛАШКО́УТ *и. голл.* 1) *махс.* Порт эчендә бер урыннан икенче урынга йөк ташу, йөзмә пристань ясау яки күпер итеп файдалану өчен кулланыла торган палубасыз, яссы төпле зур судно. *Кайбер кораблар, елгага якорь ташлап, йөкләрен --- плашкоутларга бушатып маташалар.* М.Юныс. *Плашкоут Зуфирәне Усть-Хайрюзово дигән посёлокта төшереп калдырды да үз юлы белән китеп барды.* М.Маликова

2) *иск.* Паром. *Шикотан утравы белән Сахалин утравы арасында пассажирлар өчен плашкоут (паром) йөреп тора.* Татарстан яшьләре

ПЛАЩ *и. рус* 1) Су үткәрми торган җиңел пальто. *Ул кара болонья плащының төймәләрен ычкындырган, кара костюмы бик пөхтә, ак күлмәге керсез.* М.Маликова. *Өйдән алып чыккан җылыны озаккарак сакларга тырышып, йөземне плащ якасы астына яшергән килеш күпме барганмындыр, кинәт колагыма бер тавыш килеп ягылды.* Г.Гыйльманов

2) Җилкәгә салына торган җиңсез киң өске кием. *Плащка төренгәнмен, Гитарам кулымда, Гайрәтле йөренәм мин, Кылычым кынымда.* М.Җәлил. *Баскычта --- беләгенә юл плащы салган Гали абзый үзе дә күренде.* Г.Әпсәләмов. *Трап саклаучы матростан брезент плащ сорап алдым да шәһәргә чыгып киттем.* М.Юныс

ПЛАЩЛЫК *с.* **1.** Плащ тегү өчен яраклы, плащка дип билгеләнгән

2. *и. мәгъ.* Плащ тегү өчен материал

ПЛАЩ-НАКИ́ДКА *и. рус* Офицер һәм прапорщикларның стандарт экипировкасының бер элементы: су үткәрми торган бөркәнчек. – *Кайда кыр сумкаң? Кайда плащ-накидкаң? – Карпович артык бәйләнмичә, тик кимсе-*

теп сорый, тып-тын торган батальон ишетә дә, күрә дә. С.Шәрипов

ПЛАЩ-ПАЛА́ТКА *и. рус* Хәрбиләрнең плащ та, кирәк вакытта бер кешелек палатка да булып хезмәт итә торган су үткәрмәс җиләне. *Янгураз легиончылар янында төн кунарга җыенгач, рота командиры аңа бер плащ-палатка табып китерде.* Т.Әйди. *Лейтенант сәкегә плащ-палаткасын бөкләп җәйде ---.* Х.Камалов. *Николай дустын плащ-палаткасына сала да безнекеләр ягына шуыша.* Г.Гыйльманов

ПЛАЩ-ПАЛЬТО *и. рус-фр. к.* **плащ** (*1 мәгъ.*). *Божедомов эчтән генә, Дамирга шинель дә алырга, плащ-пальтога гына ышанмаска киңәш бирергә кирәк, дип калды.* С.Шәрипов

ПЛӘМӘШ *и. рус сөйл.* Бертуган кардәшнең баласы, гадәттә улы. *Син миңа пләмәш буласың, канатым! Ник дисәң, синең атаң белән мин ике бертуган малайлары булабыз.* Ә.Еники. *Кайталар инде, пләмәш шулай диде.* М.Мәһдиев. *Нурислам, пләмәшенең аркасына сугып: – Булдырасың, Рудәл! – диде.* Р.Батулла

ПЛЕБЕЙ *и. лат.* 1) *тар.* Борынгы Римда: хөр, әмма һичбер төрле сәяси һәм гражданлык хокукларына ия булмаган иң түбән иҗтимагый катлау вәкиле. *[Г.Ибраһимов] Борынгы Римда сәяси хокукы булмаган плебейлар кебек яши.* С.Поварисов. *Ай заманнар, вай заманнар, ну заманнар! Бәдбәхетләр алтынымны урлаганнар, Плебей да урлап ташый, жрецлар да, Ничек итеп бөтен илне асыйм дарга?!* Г.Афзал. *Беренче аллалык патрицийлар (римлылар җәмгыятенең югары катлау төркемнәре) аллалыгы булса, икенче аллалык плебейлар (ирекле, ягъни коллар төркеменә кермәгән, ләкин түбән катлау төркеме) аллалыгы дип саналган.* К.Гыйззәтов

2) Аксөяк нәселдән булмаган, түбән катлау кешесе, кара халык. *Нигилизм аны – Әмирханны – Күмдерергә тели терелә. Ул, янәсе, аристократ әдип, Без, янәсе, люмпен, плебей!* Х.Туфан. *Сыра – плебейлар эчемлеге.* М.Юныс. *«Плебей!» – дип, үзенә Бикләмишев атлы дворян фамилиясен биргән борынгы бабасы шушы кавемнән икәнен онытып, «Татарва!» – дип, ясалма теш арасыннан ысылдады министр.* М.Галиев

ПЛЕБЕЙЛЫК *и.* 1) Чыгышы ягыннан плебей булу

2) *күч. иск.* Үзен плебейларча тоту рәвеше, плебей гадәтләре. *Ф.Энгельс терминын кулланып әйткәндә, «пролетар-плебейлык аскетизмы», ягъни «революцион аскетизм» карашы өстенлек алды, сәхнә әдәбиятының үсешенә тоткарлык ясады.* А.Әхмәдуллин

ПЛЕБИСЦИТ *и. лат. кит.* Аеруча әһәмиятле мәсьәләгә карата бөтен халыкның тавыш бирүе; референдум. *Алмания Чехословакиядәге Судет алманнарына үзләренең теләкләре берлә, теләсәләр, Чехословакиядә калырга, теләсәләр, Алманиягә кушылырга плебисцит (референдум) ясауны алга сөрәдер ---.* Г.Исхакый. *Әмма иҗтимагый үзидарә, плебисцит демократиясе итеп аңлап, --- турыдан-туры халык тарафыннан идарә ителә торган власть анархик идея белән сугарылган, дип санала.* Политология

ПЛЕ́ВРА *и. гр. анат.* Имезүчеләрдә һәм кешедә үпкәләрне тыштан һәм күкрәк читлеге стеналарын эчтән каплаган яры; үпкә пәрдәсе. *Барысын да беләбез, күп беләбез. Аорта белән плевраны да, сангвиник белән меланхоликны да, ахтунг белән дифтонгны да беләбез.* М.Мәһдиев

ПЛЕВРИТ *и. рус* Үпкә пәрдәсе ялкынсыну, шешү. *Шәмсидә плеврит башланганлыгы вә аны бик чынлап карамаганда, тырышып даруламаганда ютәл авыруына күчәчәге мәгълүм булды.* Г.Исхакый. *Мин – сезнең игъландагы сорауларга тулысы белән җавап бирә ала торган кеше. Эчмим. --- Тартмыйм. Үпкәмдә плеврит.* Р.Батулла. *Үпкәнең тышчасына салкын тиеп, плеврит дигән авыру башланган булган.* Т.Нәҗмиев

ПЛЕД *и. инг.* 1) Шотландларның шакмаклы йон тукыма япмадан гыйбарәт милли кием элементы

2) Юрган яки шәл булып хезмәт итә торган, гадәттә чачаклы йон япма. *Гондольер пассажирның алдына дөя йоныннан тукылган кыйммәтле плед япты ---.* М.Юныс. *Һәрбер пассажирга плед һәм мендәр куеп чыкканнар – күпләр йокыга талды.* Сөембикә. *Нина --- бәйләргә өйрәнде, бер зур плед бәйләде ---.* Татарстан яшьләре

ПЛЕ́ЕР *и. инг.* 1) Берәр йөрткечтән музыка һ.б.ш. тыңлау, видео карау өчен, гадәттә, кеше үзе белән йөртә ала торган кечкенә уйнаткыч. *Колагына плеер тыккан малай «Девятка»сын юа тырышып.* С.Әхмәтҗанова. *Шулай да ул --- кечкенә күн янчыгыннан наушниклы плеерга охшаш бер нәрсә тартып чыгарды.* Р.Мирхәйдәров. *Плеер, кәрәзле телефоннарын муеннарына асалар да йөриләр шунда әллә кем булып!* Л.Закирова

2) Шундый ук максатлар белән кулланыла торган зуррак стационар җайланма. *DVD плеер*

3) Компьютерда цифрлы аудио- яки видеосигналны тану һәм тапшыру өчен махсус компьютер программасы яки программалар җыелмасы

ПЛЕЗИОЗАВР *и. гр.* Борынгы заманда триастан алып мел чорына кадәр диңгездә яшәгән, хәзер бөтен континентларда казылмаларда табыла торган озын муенлы, кечкенә башлы, ишкәгаяклы бик зур кәлтә. *Плезиозаврлар миллионнарча еллар буе Антарктиканы чолгап алган җылы океан суларында яшәгәннәр.* Татарстан яшьләре

ПЛЕЙБОЙ *и. инг.* Күңел ачып үз рәхәтенә генә яшәүче, хатын-кызлар яратучы бай ир-егет. *Ә хәзер алай кысынкы яшәү мәҗбүрилеге юк, һәм ул гөрләп торган плейбой ир-егетләрчә яши ала.* Р.Мирхәйдәров

ПЛЕЙ-ОФФ *и. инг. спорт* 1) Ярышта катнашучы беренче җиңелүдән соң ук (бер уен яки берничә уеннан торган серия нәтиҗәсе буенча) турнирдан төшеп кала торган ярыш системасы

2) Зур ярышларның шундый принциплар нигезендә үткәрелә торган соңгы этабы. *Җитди һәм тәҗрибәле командалар тизлек сыйфатларын плей-офф вакытында күрсәтә.* Ирек мәйданы. *Плей-оффта иң көчлеләр очрашып, җиңүчеләрне дә билгеләделәр.* Заман сулышы

ПЛЕКСИГЛАС *и. нем.* **1.** Органик полимерлар нигезендә җитештерелә

торган үтәкүренмәле төссез каты материал, пластмасса; органик пыяла. *Үтәкүренмәле изотроп матдәдән, мәсәлән, плексигластан әзерләнгән берәр детальнең я конструкциянең моделе ике үзара перпендикуляр поляризатор арасына урнаштырыла.* Физика

2. *с. мәгъ.* Шундый материалдан ясалган. *Дроголовларның берсендә күзгә ташланмый торган җиңел плексиглас кастет бар икән ---.* Р.Мирхәйдәров

ПЛЕН *и. рус сөйл.* Әсирлек. *[Гөлшат:] Син үзең уйлап кара, әткәй, ак финнарга плен калып, унике сәгать буена сугышканнар.* Т.Гыйззәт. *Плен әшәке! Качтык без аннан, Сөләйман абзый, пленнан, дим.* Д.Салихов. *Әти – сугышта катнашкан, әсирлеккә төшеп, пленнан котылган кеше.* Ирек мәйданы

◊ **Плен алу** *сөйл.* Сугыш вакытында әсирлеккә алу. *Мин җиңелдем синең алда, мине Үчектерде синең уңышың: Мин бер разведкада плен алдым Фашистларның шактый зурысын.* Ә.Фәйзи. *Контратакага барсак, берничә танкны плен алырга була иде, эх!* Х.Камалов. *Немец та, үз тылында үзен хәвефсез санап, моның янына утырган һәм плен алмакчы булган.* С.Баттал. **Плен төшерү** *к.* **плен алу**. **Плен төшү** Сугыш вакытында дошман кулына әсирлеккә эләгү, әсирлеккә төшү. *1941 елның 12 октябрендә Брянск янында чолганышта калып плен төштем.* А.Алиш. *Пленга төшкәнче, лутчы су төбенә китәргә.* М.Мәһдиев. *Яббар да нимескә плен төшкәч, алар ягында сугышырга ризалык биргән.* З.Хәким

ПЛЕНАР *с.* Оешманың, сайланып куелган органның, берәр зур чарада катнашучыларның барлык әгъзалары белән берлектә үткәрелә торган. *Съезднының пленар утырышларында --- җәмгысы 73 кеше чыгыш ясаган.* Р.Фәйзуллин. *Бу мәсьәләне пленар сессиягә куярга, анда аны бөтен җитдилеге белән карарга.* Т.Миңнуллин. *Чыннан да, конгресс, аның пленар утырышының без төзегән сәнгать сараенда, – Зур концерт залында узуы миңа бигрәк тә кадерле иде.* Р.Юсупова

ПЛЕ́ННЫЙ *и. рус сөйл.* Әсир. *Лагерьда – меңләгән пленный.* С.Баттал. *Кайту юлы болай: алдан мин, минем арттан Верещагин белән пленный, иң артта Урманов.* Г.Әпсәләмов. *Гыйбаш абзый --- борыны белән пошкырып җибәрде: – Нишләп пленный аны якласын? Ач тоткан өченме?* Г.Бәширов

ПЛЕ́НУМ *и. лат.* Оешманың сайлап куелган җитәкче органы әгъзаларының тулы составтагы утырышы; пленар утырыш. *Вәлиәхмәт --- бюро, пленум әгъзасы булган атаклы ир алдында көя күбәләге, вак черки иде.* А.Гыйләҗев. *Кинәт кенә беркөнне райком пленумы җыйдылар.* М.Мәһдиев. *Пленум карарлары буенча җыелыш үткәрергә кирәк.* М.Юныс

ПЛЕНЭР *и. фр.* Рәсем сәнгатендә объектларны аларның табигый шартларында һәм табигый яктылыкта, ягъни ачык һавада төшерү алымы (мастерскойда эшләүдән аермалы буларак); рәсемдә табигый яктылык һәм табигый төсләрне реаль төсмерләре белән бирү сәнгате. *Мөгаен, [рәсемнәрнең] тегесе, әбисенә ярты гасыр чамасы элек бүләк ителгәне, пленэрда язылган, ә бу музейдагысы остаханәдә эшләнгән ---.* Р.Мирхәйдәров. *Хатта исә --- төрки халыкларның рәссамнары өчен оештырылачак пленэрда катнашырга Татарстаннан танылган бер рәссамны җибәрүләрен сорыйлар.* Мәдәни җомга

ПЛЕОНАЗМ *и. гр. лингв.* Мәгънәләре белән бер-берләрен өлешчә кабатлаган тел берәмлекләреннән торган әйтелмә; сөйләмдә кулланылган шундый алым (мәс., буш вакансия, вакыт периоды)

ПЛЕЯ́ДА *и. гр.* Бер үк чорда нинди дә булса өлкәдә дан казанган атаклы эшлеклеләр төркеме. *Бу плеяда үз арасына читләрне кабул итми.* М.Галиев. *Бөек Ватан сугышыннан бик талантлы бер плеяда татар язучылары --- кайтты.* М.Әхмәтҗанов. *Аның [Т.Гыйззәт] әсәрләрендә уйнап актёрларның тулы бер плеядасы үсүе турында да күп сөйләп булыр иде.* А.Әхмәдуллин

ПЛЁНКА *и. рус* 1) Нәрсәнең дә булса өслеген каплап торган юка катлам; элпә. *Туфайловның йөзен тир, тузан каплаган. Күзен томанлы плёнка япкан кебек иде.* Х.Камалов. *Улән сабагының юка гына итеп кисеп алынган урынында үтәкүренмәле плёнка барлыкка килә.* И.Низамов. *Вакыт узу белән, буяу өстендә элпә (плёнка) барлыкка килә, аны аерып алу авырлаша.* Татарстан яшьләре

2) Бер ягына яктылыкка сизгер катлау сыланган һәм фотосурәттә, кинога төшерүдә кулланыла торган эластик тасма. *Райнер --- запас плёнкалар, фоторәсемгә төшергәндә кулланыла торган барлык кирәк-яракларны кесәләренә тутырып бетерә.* М.Юныс. *Аңа [Габделнурга] плёнка, ачыгайткыч, ныгытыкыч кебек нәрсәләр дә таныш һәм ни рәвешле сурәткә төшерергә кирәген дә яхшы чамалый иде.* Р.Кәрами. *Үзегез беләсез, авыллар шактый күп, әмма безнең телестудиядә плёнка чамалы гына – дефицит.* З.Хәким

3) Тавыш яздыру өчен махсус материалдан ясалган эластик тасма. *[Шәрифҗан:] Менә. (Куеныннан плёнка чыгара.) --- Мәктәпкә керегез дә тыңлагыз. Магнитофон төзек.* А.Гыйләҗев. *Кафедрада мине лаборант туктатты: беркемне дә кертмәскә боерык булган, бөтен сәяси кафедраларның башлыклары җыелып, яшерен тасма-плёнка тыңлыйлар, имеш.* З.Зәйнуллин. *Искәрмәгәнмен, дусларым, Плёнка беткәнне дә, Җәйге кояш арып-талып Йокларга киткәнне дә.* Р.Могыйнов

4) Нәрсәнең дә булса өстенә ябыштыру яки ябу, каплау өчен синтетик матдәдән ясалган бик юка материал; полиэтилен. *Рамнары алынган тәрәзә бушлыгына целлофан плёнка кактым.* А.Хәсәнов. *Башта парникны плёнка белән тарттырабыз.* Т.Нәҗмиев. *Махсус әзерләнгән тукымадан кирәкле формаһы кисәргә, --- эчке ягына үзе ябыша торган плёнка ябыштырырга кирәк.* Гомер агачы

ПЛЁНКАЛЫ *с.* Плёнкасы (*2 мәгъ.*) булган, плёнка ярдәмендә эшли торган. *Конкурста катнашучылар төрле күренешләрне цифрлы фотоаппаратка түгел, ә элекке заманнардан калган плёнкалы фотоаппаратка төшерергә тиешләр.* Татарстан яшьләре

ПЛИ *ы. рус хәрби* Утлы коралдан атарга бирелгән боерык. – *Внимание!*

Әзер торыгыз! – диде өлкән штурман. – Пли! М.Юныс. *Менә хәзер елга буена алып барырлар, --- аннары офицер солдатларга: «Целься!» – дияр. Тегеләр мылтыкларын төзәгәч, офицер: «Пли!» – дип кычкырыр.* В.Нуруллин. *Сиксән колак – тешсез сиксән авыз – «Пли!» дигән канлы калҗа көтә хәзер...* Р.Харис

ПЛИН *и. рус сөйл. к.* **плен**. *Белеп барсыннар сугышның каты булачагын, анда барып, нимеснең плин төшкәнен көтеп йөрмәсеннәр, ныклап торып сугышсыннар.* З.Зәйнуллин. *Илендә малсыз калган татар солдатының плингә төшкәндәге байлыгын барла!..* А.Хәлим

ПЛИ́НТУС *и. гр. махс.* 1) Стена белән идән арасындагы ярыкны каплый торган тар гына такта, планка (*1 мәгъ.*). *Квадрат рәвешендәге дәү тимер савытлар рәтендә ишек-бусага, такта-плинтус, плитә һәм измә, газета калдыклары өем-өем ята.* Р.Низамиев. *«Гаебеңне танымыйсыңмы, елан? --- Стенага йөзең белән, аягыңны – плинтуска... Кулыңны өскә күтәр!» һәм төн буена шулай.* Репрессияләнгән татар әдипләре. *Яшерен акчаны кайда саклarга? Плинтус артыннан һичшиксез табачак.* Татарстан яшьләре

2) Нинди дә булса бинаның, корылманың, мичнең, колоннаның аскы өлешендәге чыгынтысы

◊ **Плинтустан түбән** Бик түбән дәрәҗәдә; бик аз. *«Үз жаргоннары белән әйткәндә, плинтустан түбән төшәргә ярамас, – дип уйлады. – Юкса «шестёрка»га әйләнүеңне көт тә тор».* Р.Кәрами. *Сөйләгән мәзәкләре билдән түбән, дию генә бик йомшак булыр. Плинтустан түбән.* Татарстан яшьләре

ПЛИОЦЕН *и. гр. махс.* Җирнең геологик тарихында өченчел периодның соңгы чоры. *Плиоцен чорында австралопитеклар яшәгән*

ПЛИС *и. лат.* **1.** Тупас киҗе-мамыктан тукылган хәтфәгә охшаш озын йончалы тукыма; киҗе-мамык бәрхет

2. *с. мәгъ.* Шундый тукымадан тегелгән. *Чыбылдыгың баулары Плис микән, яр-яр; Безгә төшкән кияүләр Мулла микән, яр-яр.* Җыр

ПЛИССЕ *и. фр.* **1.** Тукымада, гадәттә итәктә, махсус машина белән яки үтүк белән бастырып ясалган вак параллель сырлар. *Машина таптап киткәч, Хөббениса сикереп тора да шофёрның якасына барып ябыша: – Харап иттең юбкамның плиссе-гофресын, ничек кеше күзенә күренim хәзер!* Ш.Галиев

2. *с. мәгъ.* Шундый сырлары булган. *[Ленизаның] Әллә кайчан алынып та, моңарчы рәтләп киелмәгән плиссе юбкасы бар иде.* М.Маликова

ПЛИТА *и. рус к.* **плитә**. *Измә, бетон, кирпеч, плита төяп, Шул юллардан балчык, ком ярып, Машиналар уза.* Ә.Баян. *[Максимов] Тулай торакта да дежурлыгын юньләп итми, аш-мазар пешерер өчен плитага чират ала башласаң, гел алдан керергә тырыша.* Х.Сарьян. *Уртада, --- таш мичнең плитасы өстендә, гөрләп кайнап торган шулпаның тәмле исе вагон эченә җәелгән.* Р.Гайфуллина

ПЛИТӘ *и. рус* 1) Гадәттә төзелештә файдаланыла торган шома өслекле, дүртпочмаклы зур яссы таш, металл һ.б.ш. кисәге; плита. *Аяк астындагы тимер плитәләргә бәрелеп су чыпылдый.* М.Юныс. *1896 елда Сент-Луис шәһәрендәге өермә вакытында нарат таяк бер сантиметр калынлыгындагы корыч плитәне ансат кына тишеп чыккан.* Кызыклар дөньясында. *--- кирпеч һәм төзү плитәләренең сыйфаты безнең илдәге белән бөтенләй чагыштырмаслык югары.* В.Юныс

2) *геол.* Җир кабыгының тектоник хәрәкәтенең һәм магматик эшчәнлегенең түбән интенсивлыгы, яссы рельефы белән аерылып торган эчке тотрыклы өлеше; плита, платформа. *Япониядәге җир тетрәүнең сәбәбен Евразия материгында тектоник плитәләрнең хәрәкәтләнүе белән аңлаталар.* Татарстан яшьләре. *Җир кабыгы бертуктаусыз хәрәкәтләнә торган төрле плитәләрдән тора.* Ватаным Татарстан

3) Ризык пешерү өчен, түгәрәк тишекле чуен пластина белән капланган, утын, күмер ягып җылытыла торган кечерәк мич яки зур мичнең шундый өлеше; плита. *Плитәне ягып җибәрдек.* Ә.Еники. *Плитә өстендә итек киптерү*

4) Ризык пешерү өчен, металл яки керамик өслегендә конфоркалары булган көнкүреш приборы; кухня миче; плита. *Сиражи--- савытны электр плитәсеннән алды һәм, өстендәге капкачын ачкач, яктыга – тәрәзәгә таба кыйшайтты.* Ф.Садриев. *Өметгали, чәйнеккә су салып, плитәгә утыртты.* М.Юныс

5) *к.* **плитка** (*1 мәгъ.*). *--- ванна бүлмәсе кара кафель плитәләр белән әйләндерелде.* Ф.Садриев. *Өч йорт та тышкы яктан юка таш плитәләр белән тышланачак.* М.Маликова

6) Кабер ташы. *Рәт-рәт тезелгән йөз җитмеш матәм плитәсе – гүя партитура битләре.* Р.Низамиев. *Каберлекләр елга буйларына урнашкан; мәет аякларын елгага таба каратып җирләнә, кабер өстенә таш плитә куела.* Татар халкы һәм Татарстан тарихы. *Кем әйтмешли, тәреле плитә кирәкме, яисә өстенә ярымай төшерелгәнеме – рәхим итеп заказ бир дә --- Интернеттан якын кешеңнең кабер ташын карап ят.* Татарстан яшьләре

ПЛИ́ТКА *и. рус* 1) Гадәттә диван, идән, тротуарга түшәлә торган зур булмаган керамик, таш яки башка шакмаклар. *Проект буенча стеналар алсу плиткалардан торырга тиеш.* М.Маликова. *Хәзер ул галәмәт биеклектәге бер плитканы алыштыру да йөзләрчә сумга баса ---!* Р.Мирхәйдәров. *Хәзер инде бүтәнчәрәк манзаралар: тимер рәшәткәләр белән урап алынган, --- плиткалар белән тышланган «элитный» йортлар китте әнә.* Р.Низамиев

2) Дүртпочмаклы пластинка рәвешендә прессланган яки коелган нинди дә булса матдә кисәге. *Ә өстәлдә күптән күрмәгән ризыклар: ак май, --- печенье, хәтта берничә шоколад плиткасы да ята.* Ә.Еники. *Көннәрдән бер көнне бу ач, ялангач кешеләргә шоколад плиткасы күрсәтеп, аларны Гитлер армиясенә язылырга өнди башлаганнар.* Г.Әпсәләмов. *Немец куенына тыгылды, бер зур плитка шоколад чыгарып, агачтан юнып ясалган өстәлгә куйды.* З.Зәйнуллин

3) Гадәттә электр белән җылытыла һәм ризык пешерү өчен кулланыла

торган көнкүреш приборы; кечерәк плитә (*4 мәгъ.*). *Плиткада бик әйбәт төсле кофе кайнатып ала ---.* Ә.Еники. *Сандык янып беткән. Аның эчендә янган плитка калганын кем белсен?* Ә.Моталлапов. *Аннары тирене спирт лампасы яки плиткада җылынган җиз кисәге өстендә тоталар.* Яшь натуралистларга

ПЛО́МБА *и. лат.* 1) Теш кариесын дәвалагач хасил булган куышлыкка тутырыла торган тыгыз, катып китүчән материал. *Себердәге иң зур завод директоры төнен йокысыз уздыра бүген: тешенең пломбасы төшкән.* М.Мәһдиев. *Бер айдан вибрация тештәге пломбаларны бәреп чыгарды.* М.Юныс. *Пломба куйганда яки теш суырткан-да, әгәр тамактан эчкә кан яки башка берәр матдә үтмәсә, ураза бозылмый.* Инсан һәм дин

2) Таможня, сәүдә, техника һ.б. тармакларда, рөхсәтсез ачуны кисәтү өчен, төрле предметларга, приборларга, бикле ишекләргә салына торган, берәр тамга, мөһер сугылган калай, кургашын, сургыч һ.б.ш. кисәгеннән гыйбарәт бер мәртәбә кулланылышлы җайланма. *Кораб-тан бушатканда, бүген бер контейнерның пломбасы өзелгән булып чыкты.* М.Юныс. *Хатын, йозакларга сургычлы пломба салып, архивтан иң соңгы булып чыга.* Х.Камалов. *Ул арада Гыйзди --- фатир ишегенә пломба салып куйды.* Р.Гаффар

ПЛО́МБАЛАУ *ф.* 1) Теш куышлыгын пломба (*1 мәгъ.*) белән ямау, тешкә пломба салу

2) Товарга, приборга, ишеккә пломба (*2 мәгъ.*) салу; пломба сугу. *Федераль закон нигезендә, исәпләү приборларын пломбалау торак белән идарә итү компанияләренең агымдагы эш исемлегенә кертелгән.* Татарстан яшьләре. *Приборларны пломбаламый торып, аны исәпкә дә куймыйлар, күрсәткечләрен дә кабул итмиләр.* Шәһри Казан

Пломбалап бетерү Пломбалауны тәмамлау

Пломбалап тору Әледән-әле, даими яки сөйләү моментында пломбалау

Пломбалап чыгу Һәрберсен, булган берсен пломбалау

Пломбалый башлау Пломбаларга керешү

ПЛОМБИР I *и. фр.* Сөт өстенә шоколад, чикләвек һ.б.ш. нәрсәләр кушып ясалган туңдырма төре. *Колька мине ярылганчы пломбир белән сыйларга сүз бирде...* А.Тимергалин. *Сәрвиназның әлегә тикле күрсәтмәгән тагын бер күчтәнәче – пломбир мороженое булган икән.* С.Сабиров. *Малай кулында йөзем кыстырып туңдырылган унтугыз тиенлек пломбир.* К.Кәримов

ПЛОМБИР II *и. нем. к.* **пломбиратор**

ПЛОМБИРА́ТОР *и. нем.* Товарга, ишеккә һ.б.ш.га пломба (*2 мәгъ.*) сала торган келәшчә сыман кыскыч җайланма

ПЛОСКОГУ́БЦЫ *и. рус сөйл.* Эләктереп ала торган өлеше яссы өслекле кыскычтан гыйбарәт эш коралы; каргаборын. *Ә син үзең машинаның оборотын плоскогубцы белән үлчисеңме?* М.Юныс. *Пычкының читкә карап торган тешләрен, плоскогубцы белән бөгеп, урыннарына утыртам ---.* З.Зәйнуллин

ПЛОТИ́НА *и. рус* Су агымын тоткарлап, суның биеклеген күтәрү өчен төзелгән корылма; буа. *[Балыклар] уылдык чәчәр вакыт җиткәч, көтү-көтү булып агымга каршы күтәрелә башлыйлар да таш плотинага очрыйлар.* М.Юныс. *--- орбитадан кешенең бәрәкәтле эшләре, ул --- төзегән зур плотиналар гына түгел, кешелек дөньясының Җир-анага китергән гаять зур зыяннары да ачык күренә.* Кызыклар дөньясында. *Кондызлар төзегән плотина агымны нәкъ 45 градуслы почмак ясап туктата.* Татар мөселман календаре

ПЛО́ТНИК *и. рус сөйл.* Балта остасы. *Борын-борын заманда, кәҗә – команда, саескан – сотник, бака – плотник, үрдәк үрәтник булган заманда яшәгән, ди, бер ярлы егет.* Әкият. *Плотниклар тегендә, яңа магистральдә эшлиләр.* Ш.Камал. *Ул бит штат буенча плотник санала*. М.Юныс

ПЛОЩА́ДКА *и. рус* 1) Кечкенә тигез җир кисәге, ачык урын

2) Бинада, корылмада һ.б.ш. урында буш калдырылган тигез мәйданчык; ике баскыч арасындагы тигез мәйданчык. *Площадкада алардан башка берәү дә юк иде.* Г.Кутуй. *Трапның өске площадкасында теге Зеленовскийга керергә чират торганда очраган җирән чәчле диңгезче тора иде.* М.Юныс. *--- башта фатирының озын коридорыннан, аннары баскыч площадкасыннан узды да чыгуга табан юнәлде Тәүфикъ.* Л.Ибраһим-Вәлиди

3) Техникада берәр авыр җайланманың йөрткеч станы, нигезе. *Ялкын күтәрелеп, күпер ишелеп төште, орудиеләр куелган ике площадка зыңгылдап мәтәлде.* Г.Кутуй

4) Вагонның пассажирлар керә һәм чыга торган алгы яки арткы өлеше; тамбур. *Менә шушы нотыкны ул вокзалда, икенче звонок бирелгәч, үзен озатырга төшкән халыкка карап, вагон площадкасыннан сөйләргә ният иткән иде.* Ш.Камал. *Поезд кузгалгач, син утырган площадкага беркем дә килә алмый.* М.Мәһдиев

5) Поезд яки автобус, туктап, пассажирларны утырта торган платформа

6) Төзелеш яки монтажлау эшләре алып бару, төзү материаллары өю һ.б.ш. максатлардан файдаланылган, тирәсе уратып алынган махсус мәйдан. *Менә шушы кәгазь белән площадка начальнигына барырсың.* Т.Гыйззәт

7) Спорт мәйданчыгы. *Волейбол площадкасы*

8) Аерым максатлар өчен билгеләнгән урын. *Площадкага җыелган яшьләр, әйдәгез, бер биибез дип, «Гомерләр мизгел генә»сен дә җырлады*. Татар заманы. *Эт площадкасы*

9) *хәрби* Полигонда аерым максатлар – сынау, яшәү һ.б.ш. өчен файдаланыла торган, тирәсе уратып алынган һәм керү өчен берничә тикшерү пункты булган махсус участок

10) *күч.* Берәр нәрсә эшләү, ниндидер эшчәнлек алып бару өчен җирлек, нигез. *Һәм безнең өчен иң күңеллесе: ишегалды белән янәшә зур гына бакчасы да бар... --- Безгә уйнар өчен бик әйбәт «площадка»!* Ә.Еники. *Эксперименталь площадка. Электрон сәүдә площадкасы*

ПЛУГАРЬ *и. рус сөйл.* Трактор-да җир сөрүченең ярдәмчесе, трактор

сабанын карап (күтәреп, төшереп) йөртүче кеше; сабанчы. *Әти үлгән елны, яз җитү белән, әнкәй трактордa плугарь --- булып эшләде.* Ә.Баян. *Менә шулай, Былбылнисаның мәҗлестә утыруы берәүнең җәйге эссе көндә бер смена плугарь булып йөрүенә бәрабәр.* М.Мәһдиев. *Ул --- әле трактордa плугарь булып эшләде, әле ашлык суктыра торган двигатель тирәсендә йөрде ---.* Н.Фәттах

ПЛУТОКРАТ *и. гр.* Байлыгы аркасында хакимлеккә һәм йогынты көченә ия булган аеруча бай катлам вәкиле. *Хакимияткә плутократлар килә*

ПЛУТОКРА́ТИЯ *и. гр.* 1) Дәүләт белән югары сыйныфның иң бай төркеме идарә итә торган сәяси строй. *Мин Англия – Америка плутократиясен фаш итә торган материаллар туплый идем.* Г.Кашшаф

2) *җыйн.* Плутократлар

ПЛУТО́НИЙ *и. лат. хим.* Радиоактив үзлекләре булган (уран рудасында бик аз күләмдә генә табыла торган) ясалма химик элемент. *Бөтен эш кәгазьләрендә плутонийны «продукт» --- дип атыйлар.* Ф.Бәйрәмова. *Атом электр станциясе реакторының аерылгысыз компоненты – плутонийның таркалуы миллиард еллар буена дәвам итә.* Ә.Салах

ПЛЮРАЛИЗМ *и. лат. кит.* 1) Дөньяның бердәмлеген, бертөрлелеген инкяр итеп, яшәешнең асылын бик күп мөстәкыйль, бәйсез башлангычлар һәм чынбарлык төрләре тәшкил итә, дип раслаган фәлсәфи тәгълимат

2) Иҗтимагый тормышта, сәясәттә фикер төрлелеген тану, фикер төрлелегенә юл кую сәясәте. *Плюрализм дигән демократия бик алама нәрсә икән, бернәрсәне дә хәл итеп булмый.* Ә.Баян. *Сез булмасагыз, демократиясе, плюрализмы, альтернативасы да булмый иде, рәхәтләнеп яши идек.* Т.Миңнуллин. *Көндәлек нәшрият битләрендә «плюрализм» сүзе еш кулланыла башлады.* В.Юныс

ПЛЮРАЛЬ *с. кит.* Күпсанлы, күптөрле

ПЛЮС *и. лат.* **1.** 1) *мат.* Зурлыкның уңай булуын яки кушу гамәлен белдерә торган график символ (+). *Менә [райком вәкиле] бер фамилиягә минус куйды, ә икенчесенә плюс билгесе төшерде.* Х.Камалов

2) *мат.* Кушу гамәле. *Әбекәй плюс Кәтүк бабай – любовь!..* Г.Зәйнашева. *– Шулай булгач, 91 плюс 25 ничә була? – Белмим шул.* Ф.Әһлиуллина

3) *мат.* Уңай зурлык. *Плюс унлы күзлек белән булса да, ул яңадан күрә башлый.* Ш.Мостафин

4) Температураның нульдән югары булуын күрсәтү өчен кулланыла. *Арктикада иң югары – плюс 14,4 градус – «Эсперанс» поляр станциясендә була.* Кызыклар дөньясында. *Тышта минус 10 градус булганда, тиеннең оясында җылылык плюс 10 нан арта.* Табигать бизәкләре. *Казанда плюс 20 булганда, бездә плюс 30.* Ирек мәйданы

5) Электр техникасында: чылбырның даими электр агымында электроннар дефициты күзәтелгән башы (мәс., аккумуляторда). *Электр тишегенә приборны плюс ягы белән тыксаң – җылыта, минус ягын кыстырсаң – суыта.* М.Юныс. *Минус һәм плюс корылмаларының үзара бәрелешләре.* Т.Миңнуллин. *Каршылыклар һәр өлкәдә дә бар: электр тогында плюс һәм минус, барлык тереклек өчен хас булган яшәү һәм үлем ---.* Философия

6) Мәктәп эшендә укучының белеме яки үз-үзен тотышы теге яки бу балладан бераз югары булуына ишарәли, әмма гамәлдә кулланылмый торган билге. *– Бишле. Плюс билгесе белән. Шулай бит? – Бертавыштан – бишле.* Ә.Баян. *– Бишле сиңа, Каләмгөл апа! – дип, аның аркасыннан сөеп кактым Фидая. – Плюс белән.* М.Маликова. *Депутатлар аның премьер-министр постындагы шушы дәвердәге эшен плюс бишлегә бәяләделәр.* Татарстан яшьләре

7) *күч.* Яхшы сыйфат, уңай як, өстенлек. *Төркиядә --- тел мәсьәләсе бөтенләй юк. Бу хәл госманлы теле өчен бик зур плюс хисапланырга тиеш.* Җ.Вәлиди. *Сезнең әле органнарның күзенә чалынганыгыз юк. Бу – плюс! Шуңа күрә сездән шикләнмәячәкләр, аңлашылдымы?!* Р.Сәгъди. *Л.Әмирова фикеренчә, быелның тагын бер плюсы: аттестат ала алмаучылар нык кимегән.* Татарстан яшьләре

8) *жарг.* Эстрадада музыка һәм җырчы тавышы яздырылган фонограмма. *Әнә хәзерге замана җырчыларына кара! Тасмалары әйләнә, җырлары язылган! Плюс дип атала инде ул, шуңа кушылып, авызларын ачып-ябып торган булалар инде.* Ә.Афзалова

2. *хәб. функ. сөйл.* Өстәвенә, шуның өстенә. *Хәзер кабул ителгәнчә, ун мең бакс, мин белештем инде: тиз үтәлүе өчен тагын биш мең плюс.* Р.Мирхәйдәров. *Америка бирәнлегенең төп сәбәпләреннән берсе – --- хәйләкәр реклама ---. Плюс американнарның күп ашарга (хәтта тыгынганчы ашарга) яратуы.* Ватаным Татарстан. *Көн саен 1,5 литр бик чиста, газсыз су эчегез. Плюс яшел чәй, үлән чәйләре.* Татарстан яшьләре

ПЛЮС-МИ́НУС *җыйн. и.* **1.** Уңай һәм тискәре яклар, төрле сыйфатлар. *Мөби плюс-минусларның очына чыга алмады.* М.Мәһдиев. *Плюс-минусларын бергә кушып, Уземнеке итеп яратам.* К.Булатова. *Әҗәткә акча сораган фирманың бөтен тарихы, бөтен эшчәнлеге, бөтен плюс-минуслары энәсеннән җебенә кадәр тикшерелә.* В.Юныс

2. *рәв. мәгъ.* Үзеннән соң килгән саннар белән «чама белән, якынча» мәгънәсен, тирбәнү чиген белдерә. *Ә безнең «Спартак» плюс-минус ике размерны алдан ук кайгыртып куя.* М.Галиев. *Үз гасырыма, үз дөньяма гына кайтып төшим, ә плюс-минус биш-ун елга төзәтмә кертү миңа кыен булмаячак.* А.Тимергалин. *– Әти-и, уникедә авыллар клубка чыга гына башлый бит әле. – Уникедә чыгып, өчтә кайтырга түгелме исәбең? Плюс-минус кырык биш минут. И бетте!* А.Галиева

ПЛЮШ *и. нем.* **1.** Уң ягындагы йомшак йончасы хәтфәнекеннән озынрак һәм сирәгрәк булган киҗе-мамык, ефәк яки йон тукыма. *Әти --- плюш белән тышланган бик матур Коръән алып кайтып бирде.* Ф.Әмирхан. *Зөһрә карчыкның кызгылт кара плюш җәелгән йомшак диванында китап укып утырам.* Р.Сибат. *Монда кунак булып*

килгән язучыларга казахларның милли киеме – кызыл плюштан тегелгән, чигелгән чапан белән түбәтәйләр киделәр. Ф.Чанышева

2. *с. мәгъ.* Шундый тукымадан тегелгән, ясалган. *Кызый апасыннан калган иңбашы күпертмәле яшел плюш жакетын кигән* ---. Г.Бәширов. *Хәдичә җиңги --- плюш пальтолы бер карчыкка түшкәне тиз генә тоттырды. Шул көннән бирле --- плюш пальтолы бу карчык Хәдичә җиңгинең төшенә керә.* М.Мәһдиев. *Әгәр экологик катастрофа шушы темп белән барса, безнең оныкларыбыз кибеттә сатыла торган плюш аюдан башка җәнлекне белмәячәкләр.* М.Юныс

ПЛЯЖ *и. фр.* Су коену яки кояшта кызыну өчен уңайлы комлы сөзәк яр буе. *Ярмалы карны шәфкатьсез рәвештә биткә бәрә торган тыштагы буран, бәлки, аңа июль аендагы диңгезнең ак дулкыннар валын салмак кына Рига пляжына тәгәрәтүен хәтерләтәдер.* М.Мәһдиев. *Йортлар арасыннан ак ком пляж – Плайя Мальваросса килеп чыкты.* М.Юныс. *Диңгездәй җәелгән елга өсте тулы көймә, пляжда халык мыж килә.* М.Маликова

ПНЕВМА́ТИК *с. махс.* Кысылган һава, пневматика ярдәмендә эшли, хәрәкәткә килә торган. *Дзот эченә яшерелгән немец тубы һаман да атып тора иде. Ул шундый тиз ата, әйтерсең пневматик чүкеч белән таш чокый.* Г.Әпсәләмов. *Стадионда пневматик чүкеч белән таш ваталар.* М.Юныс. *Кытай спортчысы И Сылин пневматик коралдан 10 метр арага ату ярышларында җиңде.* Ватаным Татарстан

ПНЕВМА́ТИКА *и. гр.* 1) *махс.* Кысылган һава энергиясе ярдәмендә эшли, хәрәкәт итә торган механизмнар системасы. *Дисклар өстеннән, чыжлап һәм ухылдап, пневматика белән хәрәкәткә китерелә торган магнит «энәсе» йөри.* Татарстан яшьләре

2) *сөйл.* Пневматик корал. *Пистолеты – пневматика гына югыйсә.* Казан утлары. *Пневматиканы кулга алгач та мишеньгә төзәп ата башладым.* Ялкын. *Болай пневматика әлләни көчле пистолет булмаса да, чыгарып янасаң, талаучылар тимиләр, куркалар.* Татарстан яшьләре

ПНЕ́ВМО- *гр.* 1) Кушма сүзләрнең «пневматикага бәйле» мәгънәсен белдерә торган беренче компоненты (мәс., *пневмоавтомат, пневмотишкеч*)

2) Кушма сүзләрнең «үпкә белән бәйле» мәгънәсен белдерә торган беренче компоненты (мәс., *пневмограмма, пневмосклероз*)

ПНЕВМОБУШАТКЫЧ *и. тех.* Йөкне пневматик механизм ярдәмендә бушата торган җайланмалы машина

ПНЕВМОКИПТЕРГЕЧ *и. тех.* Нәрсәне дә булса кысылган һава ярдәмендә киптерә торган җайланма. *Максималь диаметры 3 мм булган 2000 кг/м тыгызлыклы кристалларның хәрәкәтен тәэмин итү өчен, пневмокиптергечнең вертикаль торбасындагы һава тизлеге нинди булырга тиеш?* Химия технологиясе

ПНЕВМОКОККК *и. гр. мед.* Пневмония авыруының иң еш сәбәпчесе булган бактерия. *Грипп вируслары һәм пневмококк бактерияләре җылы һава ярата, анда үрчи, ә ачык һавада мондый куркыныч мең тапкырга кимрәк.* Шәһри Казан. *Җир җилләге --- канны сыегайта, дисбактериозны дәвалый, организмнан токсин һәм шлакларны чыгара, шулай ук стафилококк, стрептококк, пневмококкларны, грипп вирусларын үтерә.* Мәдәни җомга

ПНЕВМО-МЕХА́НИК *с.* Берьюлы ике ысул – кысылган һава һәм механизмнар ярдәмендә башкарыла торган, шуның белән бәйле. *Нинди аэрацион җайланмалар куллануга карап, аэротенклар механик, пневматик, пневмомеханик аэрацияле булырга мөмкин.* Тирә-юнь мохитне саклау

ПНЕВМОКҮТӘРГЕЧ *и. тех.* Йөкне пневматик механизм ярдәмендә күтәрә торган җайланмалы машина

ПНЕВМОНИ́Я *и. гр. мед.* Үпкә тукымаларының һәм бронхларның тармак очларының төрле бактерияләр (ешрак пневмококк) үрчү аркасында ялкынсыну белән характерлана торган авыру; үпкә ялкынсыну. --- *ул башта ике яклы пневмония белән авырган* ---. Г.Әпсәләмов. *Саф кислородны озаграк сулаганда, пневмония башлана* ---. Кызыклы физиология

ПНЕВМОТО́РАКС *и. гр. мед.* 1) Үпкә альвеолалары ертылу (туберкулёз, эмфизема авырулары нәтиҗәсендә) яки күкрәк куышлыгы җәрәхәтләнү аркасында, плевра куышлыгына һава яки газ керү, туплану

2) Туберкулёз белән зарарланган үпкәне дәвалау өчен, үпкә белән үпкә пәрдәсе (плевра) арасына махсус энә белән газ, һава өрдерү. *Моннан соң бөтен Җир шарында гамәлдә булган, 100 еллар дәвамында уңышлы гына кулланылган ясалма пневмоторакс --- дип аталган дәвалау методын бүтән кулланмаска.* Татарстан яшьләре

ПОБЕДИТ *и. рус* **1.** Каты токымны бораулау яки кисү инструменты өчен кулланыла торган, вольфрам һәм кобальт монокарбиды порошогыннан ясалган бик нык металлокерамик эретмә. *Белмим, табигать аны корычтан яратты микән, әллә победит металлыннанмы?* М.Юныс. *Пычкыларның теше әби-бабайларныкы сыман коелып кына тора --- һәм аларга победит дигән каты материал ябыштыралар.* Р.Кәрами

2. *с. мәгъ.* Шундый эретмәдән эшләнгән. *Әхтәм гади резецлар урынына тиз кисә торган победит резецлар куллана башлады.* Г.Әпсәләмов

ПО́ВАР *и. рус сөйл. к.* **пешекче**. *Повар казга сокланып, каз исә поварга ышанып карый.* Ә.Еники. *Повар кызлар һәммәсе эштә, бушана алмыйлар.* Р.Гаффар. *Мулланур Гәрәев төрмәдә повар булып эшләгәндә, ул, повар калфагы астына яшереп, Мусага кәгазьләр бирә торган булган.* Р.Мостафин

ПО́ВАРЛЫК *и. сөйл. к.* **пешекчелек**. – *Алсинә апаны поварлыкка алмаслар. Ул авыл өчен генә пешерә бит, – диде Флүн.* Г.Мөхәммәтшин. *Мәхмүзә апаның баласы авырый, поварлыкны үзем алып калган идем.* Л.Гыйззәтуллина. *Пылау пешерергә оста диптерме, поварлыкка кулинария училищесын бетергән ике-өч үзбәк егетен беркетеп куйганнар.* С.Шәрипов

ПОВЕ́СТКА *и. рус* Берәр рәсми оешмага чакыртып язылган кыска

документ; җәлепнамә. *Следовательдән җәлепнамә – повестка китердем...* З.Бигиев. *Болар сугышка китәләр, энем. Сиңа да повестка бар.* Г.Ахунов. *Шул ук повестка, шул ук бүлмә, шул ук офицер.* М.Мәһдиев

ПО́ВЕСТЬ *и. рус әд.* Идея, тема, сюжет катлаулылыгы һәм күләме ягыннан хикәя белән роман арасында торган проза әсәре. *Инде күптән --- без Марсель Зарипов белән «Без Казаннан, Иделдән» дигән документаль повесть язган идек.* Г.Ахунов. *Америка фантасты Р.Хайлан үзенең повестенда атом бомбасында Уран-235 кулланылачагын язган булган.* Кызыклар дөньясында. *Әдип үзе әсәрне жанр ягыннан беренче басмасында – роман, икенче һәм өченчесендә хикәя дип билгеләсә дә, әдәби үзенчәлекләре ягыннан ул күбрәк повестька туры килә.* Казан утлары

ПОВИ́ДЛО *и. пол.* Кабыгыннан, төшеннән арындырылган җиләк-җимешне изеп, шикәр яки патока белән кайнатып ясалган куе татлы ашамлык. *– Күр, онытканмын бит, мин дә сезгә буфеттан күчтәнәч алып кайткан идем. – Мирзаһит кесәсеннән кәгазьгә төргән ипи кисәге чыгарды. – Повидло яккан.* Г.Әпсәләмов. *Аларның [коймакларның] өстенә көнбагыш бөртеге чаклы гына алма повидлосы салалар.* А.Хәсәнов. *Барый биргән акчаны ул төргәге белән чемоданына салып куйды; --- аннары аны повидло белән чәй эчәргә чакырды.* Н.Фәттах

ПОГОН *и. рус* Хәрби яки башка формалы киемдә шәхси званиене, дәрәҗәне, билгеле оешмага, гаскәр төренә мөнәсәбәтне һ.б.ш. белдерә, иңбашка тегеп яки башкача беркетелә торган билге. *--- абыйсы яңа гимнастёркасын киде, --- өр-яңа сержант погоннарын такты.* М.Мәһдиев. *Сержантның погонындагы ука тасмаларның икесе иске, берсе яңа.* М.Юныс. *Алдан сөйләшү буенча легионерлар коралларын яр буенда торган партизан чаналарына аталар, аннары ачу белән иңнәрендәге немец погоннарын өзеп ташларга тотыналар.* Р.Мостафин

ПОГОНЛЫ *с.* **1.** 1) Погоннары булган, погоннар таккан. *--- Вәсимә, биек үкчәле туфлиләре белән урам ташына шык-шык басып, озын буйлы, погонлы әфисәр егет белән култыклашып, алар өе яныннан узып киткәндә, Фәндиләнең күңелләре тула, эченә кайнар утлар йөгерә торган иде.* Г.Ахунов. *Уполномоченный погонлы, фуражкалы кеше иде районның милиция начальнигы.* М.Мәһдиев. *Чәүчәләк апасы: – Алмам, шушы погонлы абыеңа һәммәсен дә сөйлә!* Н.Гыйматдинова

2) Хәрби яки башка шундый дәүләт хезмәтендәге. *– Мин үзем кебек үк погонлы коллегаларым тарафыннан җибәрелгән хаталар өчен, соң булса да, сезнең алда башымны иеп гафу үтенәм, – диде.* Ватаным Татарстан

3) *күч.* Югары дәрәҗәле, җаваплы эш урынындагы. *Ник соң погонлы господиннар кеше язмышы турында да уйланмый икән?!* Безнең гәҗит

2. погонлылар *и. мәгъ. күпл.* Хәрби яки башка шундый дәүләт хезмәтендәге кешеләр. *Әмма погонлылар да сәяси тормыштан читтә калмый.* Ватаным Татарстан. *Сер түгел, яшьлегенең иң матур еллары исәбенә тиешле срогын хезмәт итеп пенсиягә китүче погонлыларга хөкүмәт пенсияне азрак түләргә тырышты.* Татарстан яшьләре

◊ **Погонлы албасты** *к.* **погонлы убыр**. *Эчке эшләр органында погонлы албастыларга каршы даими көрәш алып барыла.* Шәһри Казан. **Погонлы гүзәл** Армия, полиция һ.б.ш. көч структурасында эшләүче хатын-кыз. *Соңгы өч елда Франциядә погонлы гүзәлләр саны 12 процентка артты һәм 26 меңгә җитте.* Татарстан яшьләре. **Погонлы өрәк** *к.* **погонлы убыр**. *Мөгаен, Русия Эчке эшләр министрлыгының погонлы өрәкләргә каршы көрәшүе юкка гына түгелдер.* Шәһри Казан. **Погонлы рейдер** Предприятиене законлы хуҗасыннан тартып алырга ярдәм итә торган полиция һ.б.ш. оешма вәкиле. *Эшмәкәрләр, алар [полиция вәкилләре] кылган законсызлыкны күреп, бары тик йөрәгенә ябыша, дистә еллар буе тир түгеп тапкан малын «погонлы рейдерлар» талавын карап торып, көчсезлектән чиргә сабыша ала.* Ватаным Татарстан. **Погонлы убыр** Җинаятьчелек белән көрәшү урынына, эш урынныннан законсыз файдаланып, үзе җинаять кылучы дәүләт көч структуралары хезмәткәре. *Менә шул погонлы убырлар тиешле-тиешсез кешеләргә җинаять эше кузгатып, тегеләрдән «эш»не йомган өчен зур акчалар алып ятканнар.* Татарстан яшьләре. *Русиядә чираттагы гадәттән тыш хәл: Мәскәү үзәгендә погонлы убырларны электерделәр.* Ирек мәйданы. **Погонлы шайтан** *к.* **погонлы убыр**. *Бездә дә шул, әлеге дә баягы, погонлы шайтаннар болгатты дөньяны.* Р.Мөхәммәдиев

ПОГОНОФОР *и. гр. зоол.* Хитин торбаларда яшәүче умыртксасыз диңгез хайваннары төркеме. *Зоолог Иванов погонофорларны тышкы ашкайнату ысулыннан файдалана дип исәпли.* Кызыклы физиология

ПОГОНСЫЗ *с.* **1.** 1) Погон тагылмаган яки погоны алынган. *Ир кеше бу юлы да погонсыз гимнастёрка кигән.* М.Маликова. *Машина әрҗәсендә, аркасын кабинага терәп, өстенә иске, погонсыз шинель, башына йолдызсыз пилотка кигән солдат кебегрәк бер бәндә утырган.* З.Зәйнуллин. *Фронттан кайткаңнар бара, алар погонсыз гимнастёрка кигән.* Р.Батулла

2) *күч.* Хәрби хезмәткә мөнәсәбәте булмаган, гаскәри булмаган

2. *рәв. мәгъ.* 1) Погоннан башка, погон такмаган көе. *Ике көн погонсыз йөргәч, төнге унбердә Әхәтне старшина уятты да погоннарына ашыгыч төстә лычка тагып куярга кушты.* Казан утлары

2) *күч.* Хәрби хезмәттә булмыйча, хәрби хезмәттән тыш. *Өстәмә акча билгеләнгәндә, кешенең «погонсыз» эшләгән чордагы хезмәт еллары гына исәпкә алына.* Ватаным Татарстан

◊ **Погонсыз солдат** Фидакяр кеше

ПОГРАНИ́ЧНИК *и. рус сөйл.* Чик сакчысы, чик буе гаскәрендә хезмәт итүче хәрби. *Пограничник киеме кигән, кулына агач винтовка тоткан Ләлә ераккa-ераккa карап тора.* Г.Әпсәләмов. *Чит илләрдән йөреп кайткан корабны таможенниклар һәм пограничниклар тикшермичә, аңа чикне ачмыйлар.* М.Юныс. *Тимерхан моннан*

берничә ел элек яшел фуражка киеп кайткан егет иде, аны беренче категорияле запастагы пограничник дип йөртәләр иде. М.Мәһдиев

ПОГРАНПОСТ *и. рус* Чик буен саклау посты. *Трансфлот диспетчеры --- погранпостка һәм таможняга шылтыратып, «Академик Арцимович»ны каршы алырга, аңа чик ачарга кирәклекне әйтеп, сөйләшеп куйды.* М.Юныс

ПОГРОМ *и. рус* 1) Тәртипсезлек ясау, тар-мар итү, туздыру, юкка чыгару. *Мәгыйзь ул көнне соңга калып килгән иде, белмәде: аңарчы инде класста яңача ысул белән погром узган иде.* М.Мәһдиев. *Капитанның рундугын ачтым. Әйтерсең тентү, погром узган.* М.Юныс. *Погром булган өйдә ялгыз калудан да шомлырак нәрсә бармы икән?* Р.Батулла

2) Берәр милләт яки аерым катлау кешеләрен үтерү, милкен кыру, малларын талау белән алып барыла торган шовинистик чыгыш. *Шушы хәлләргә бик салкын акыл белән бәя бирүчеләр бар: боларны погром юлы белән түгел, конституцион юл белән эшләргә кирәк иде, диләр.* Г.Ахунов. *Бу карагруһның хыялы – яһүдләргә погромнар оештыру, урыс җирен басурманнардан чистарту.* Р.Зәйдулла. *Немец безнең кешеләрне лагерьларга озата, яһүдләргә погромнар ясый.* Р.Зарипова

ПОГРОМЧЫ *и.* Погромда катнашучы кеше. *Әй монафикъ погромчы! Ике тиенгә дин сатучы.* Г.Тукай. *Әйтерсең лә күптән мәрткә киткән, Летаргик төш күргән монархист Уянган да, погромчылар кебек, Тел тибрәтә: «Татар-матар...» – дип.* Х.Туфан. *--- милиция түрәләре тарафыннан бу погромчыларның явыз гамәлләренә каршы тиешле приказ бирелгәндә, безнең җәмгыятьнең тәнен яман сыйфатлы шештән арындырып булыр иде.* М.Миңнуллина

ПОДА́ГРА *и. гр. мед*. Организмда матдәләр алмашы бозылу аркасында, буыннарга, тукымаларга тоз утырып, аларның сызлавыннан, деформацияләнүеннән, сыгылмалылыгы бозылудан гыйбарәт авыру. *Подагра авыруы аутосомада урнашкан доминант ген белән билгеләнә.* Генетикадан лаборатор практикум һәм мәсьәләләр. *Аның шифалы үзлекләрен элек-электән белгәннәр һәм, подагра белән авыручыларга шифасы булганга, руслар аны «донник» дип атаганнар.* Татарстанның үсемлекләр һәм хайваннар дөньясы

ПОДАУКА *и. рус* 1) Бер пот (16,3 кг) сибелүчән әйбер сыешлы агач яки калай савыт, чиләк. *--- Фәхри абый читләре кыршылган, чукланган тимер подауканы сыңар кулы белән генә күтәреп үлчәүгә сала.* А.Гыйләҗев. *Без табышыбызны шул подаука эченә салып, аны тип-тигез җиргә каплап куйдык.* К.Миңлебаев. *Ишәк җигеп киткән хуҗа, Урамнарны иңләтеп, Алданып үз ялганына, Подаукасын җилләтеп.* Ф.Гыйльфан

2) Нинди дә булса сибелүчән әйбернең шундый савытка сыйган күләме; шуңа тигез күләм үлчәү берәмлеге. *[Бу кеше] Бер подаука богдай состы да углына бирде.* К.Насыйри. *Биек тауның башыннан Күренә пәри шәһәре; Быел кызларның мәһәре – Бер подаука бәрәңге.* М.Фәйзи. *Елы-елы белән халыкның соңгы подаука ашлыгын җыеп алалар, тирә-як урманын кырып бетерәләр.* Г.Госман

3) *к.* **пот** I. *Батман – дүрт подаука керешле үлчәү.* Н.Исәнбәт. *Абзаң, Гыйльманнарга язгы сабанга ялланып, --- тары --- чәчкән булган иде, --- ике арба тары алдык, төшемгә дә яхшы, арбасыннан сигез подаука төште...* А.Таһиров

ПОДАУКАЛАП *рәв*. Подаукага кергән күләмдә, подаука үлчәве белән; подаукага тутырып, подаука-подаука. *Өлкәнрәк кешеләрдән сораштыра торгач, шуны ачыкладым: чынлап та, сәүдәгәрләр металл акчаны подаукалап, чиләкләп йөрткәннәр һәм шулай санаганнар да икән.* Татарстан яшьләре

ПОДАУКА́-ПОДАУКА *с.* **1.** 1) Подаукалап үлчәнгән, билгеле подаука күләмендә яки авырлыгында булган; подаукаларга тутырылган. *Әнә аның --- инәкие һау-һаулап Җидегән юлыннан Колтамакка карап дөяләр кәрваны куа: дөя өркәчләрендә капчык-капчык бәрәңге, подаука-подаука иген, --- капкап кием-салым, кәнфит, маннпачыйлар...* А.Хәлим

2) Һәрберсе подаука зурлыгында булган

2. *рәв. мәгъ. к.* **подаукалап**. *Ашлыкны подаука-подаука тарату*

ПОДВАЛ *и. рус* 1) *сөйл*. Йортның җир өстеннән түбән аскы каты. *Испаниянең Балеар утрауларындагы шәраб подвалында испаннар белән бергә без «Мәскәү янындагы кичләр»не җырладык.* М.Мәһдиев. *Ике машина сыярлык итеп эшләнгән гаражның подвалы бик зур иде.* Ф.Яруллин. *Ашханәләре Комлев урамында, подвал сыманрак бер нәрсә.* Р.Низамиев

2) *махс*. Газета битенең аскы өлеше һәм шунда басылган зур мәкалә. *Подвал ярымлык --- озын мәкалә тулысынча романның кимчелекләрен фаш итүгә багышланган.* Г.Бәширов. *Менә минем турыда Фатих Хөсни, «халык дошманы» дип, «Кызыл Татарстан»га бер подвал мәкалә язып чыкты. Мин аңа рәнҗемим.* М.Галиев. *Баксаң, газета битенең аскы өлеше подвал дип атала икән!* Татарстан яшьләре

ПОДВАЛЧЫ *и. иск*. Читтән килгән сәүдәгәрләрнең малларын үз өенең идән астында саклау белән шөгыльләнгән кеше, бай. *Шунда бер атна элек кенә бер казакның мең тәңкәлек куй маен подвалчы Җамалый белән бергәләп япканнар.* Г.Камал

ПОДВО́ДНИК *и. рус сөйл.* 1) Су асты көймәсендә хезмәт итүче хәрби диңгезче. *Строй белән барган диңгезчеләр аңа кычкыралар: – Эй, кореш! Подводник! Яшьти!* М.Мәһдиев. *Араларында дизель һәм атом су асты көймәләрендә хезмәт иткән подводниклар да, --- диңгез пехотасы, авиациясе, чик сакчылары, яр буе гаскәрләре вәкилләре дә бар*. Маяк

2) Су астында эшләүче кеше, водолаз

ПО́ДВОЛОК *и. рус махс.* Диңгезчеләр телендә түшәм. *Идәнне монда палуба дип йөртәләр, стена урынына – переборка, түшәм – подволок.* М.Юныс. *Комингс, переборка, подволок – --- һөнәрчелек лексикасы, фәнчә үк әйтсәк, профессионализмнар.* И.Низамов

ПО́ДДАННЫЙ *и.* 1) Билгеле бер монархка сәяси-хокукый бәйлелектә булган физик зат; табигъ. *Патша инородец подданныйларының зыялыларын, руханиларын тоташтан юк итүне күз алдына да китермәгән.* Р.Зәйдулла

2) *тар.* Бай кешенең, хуҗаның биләмәләрендә аңа буйсынучы һәм аңа экономик яктан бәйле кеше. *Бу аксөякләрне үзләренең подданныйлары яраталар һәм аларга ихлас күңелдән бирелгән булалар.* Н.Макиавелли

ПО́ДДАННЫЙЛЫК *и.* Подданный статусы; табигълык. *Подданныйлык – сәяси институтларның эшчәнлегенә зур ышаныч белән карау, шул сәбәпле граждannардагы шәхси активлыкның түбән булуы.* Политология

ПОДДО́Н *и. рус сөйл.* Йөкне күчереп йөртү өчен яки техник максатларда кулланыла торган, сыйдырышлы яссы киң аслык. *Шәһәр базарларында, төрле складларда буш агач әрҗәләр, зур-зур бүрәнәле поддоннар өелеп ята.* Татарстан яшьләре. *Пилорамада бүген, нигездә, поддон --- ясыйлар.* Ирек мәйданы

ПО́ДИУМ *и. лат.* 1) Эстрадада, зал, рәссам студиясе, стадион, кибет салоны кебекләрдә калку, күтәренке урын. *Подиумга – машиналар куела торган мәйданчыкка игътибар итмәгез, кибетебез кечкенәрәк булганлыктан, хәтта иң соңгы супермодель үрнәкләрен дә күрсәтеп бетерә алмыйбыз.* Р.Мирхәйдәров

2) Модалы кием күрсәтү чаралары, дефилелар үтә торган мәйданчык. *«Смолино Парк» отелендә бер атна буе кызлар подиумда йөрергә, бию серләренә төшенергә, макияж салырга, сәхнәдә үз-үзләрен тотарга өйрәнгән, тел буенча күнекмәләр алган.* Г.Сафиуллина

3) *күч.* Модалы кием күрсәтү шөгыле, манекенчы эше. *Подиум өчен таш курчакка әверелдерелгән балаларны күреп күңел кырыла.* Кызыл таң

ПОДКОМИ́ССИЯ *и. рус* Махсус мәсьәлә белән шөгыльләнү өчен, төп комиссия әгъзаларының кайберләреннән төзелгән кечерәк төркем һәм шул төркем әгъзалары. *Бу комиссия яңадан үзенә бер подкомиссия төзер, кооптациягә хак бирелер.* Р.Раскулова

ПОДКОМИТЕ́Т *и. рус* Махсус мәсьәлә белән шөгыльләнү өчен, төп комитет әгъзаларының кайберләреннән төзелгән кечерәк комитет һәм шул комитет әгъзалары. *БМОның Генераль ассамблеясында подкомитет утырышлары*

ПОДКРЕПЛЕ́НИЕ *и. рус* 1) *хәрби* Сугыш алып баручыларга ярдәмгә җибәрелә торган хәрби часть, отряд, өстәмә көчләр. --- *немецларның артиллериясе безнең тылны дөмбәсли, самолётлары, күтәрелеп, безнең өстә шөпшәдәй йөри – җир селкенә. Ә безгә подкрепление килеп җитә алмый, кыскасы, беттек.* М.Мәһдиев

2) *күч.* Гомумән, берәр мәсьәләдә тарафдар, теләктәш, ярдәмче. *Аларның Зифаны бушлай гына биреп җибәрергә бер дә исәбе юк. Менә шуңа Боергандагы Гыйлай абыйларга кереп, подкрепление белән кире борылып кайттым.* В.Имамов

ПОДНО́С *и. рус* Савыт-саба ташу яки өстәлгә аш чыгару өчен, гадәттә читләре өскә табан бераз бөкләнгән яссы калай, пыяла яки башка материалдан ясалган такта. *Стаканнарны, кәнфитне өстәлгә куйгач, буш подносын кулына тоткан хәлдә, биек үкчәле туфлиләре белән янә дә паркет идәнгә шык-шык басып чыгып китте.* Г.Ахунов. *Алар каршында ике ят ир утыра, тирә-якта поднос күтәргән кешеләр айкала: ике авыз сүз дә сөйләшә алмадылар.* М.Маликова. *Әнә бит, милли көйләр тыңлап ләззәт алучы кунаклар подноска акча арты акчаны ташлап кына торалар!* Р.Низамиев

ПОДПИ́СКА *и. рус сөйл.* 1) Төрле басмаларны алдыру өчен төзелгән договор; газета-журналга язылу. *Бу форсаттан хезмәтчәннәргә затлы китаплар, еллык подпискалар да кушып бүләкләргә була бит.* Р.Фәйзуллин. *Ә Туфан Миңнуллинның, подписка җитә башласа, казакъ телендә чыга торган газета-журналларга язылуын ни белән аңлатырга?* Р.Миңнуллин. *Быел, подписка башлану белән, без, бердәм рәвештә, яраткан гәзитебезгә йөз процент язылдык.* Л.Лерон

2) Үз өстеңә нәрсә дә булса эшләргә яки эшләмәскә язмача йөкләмә алу. *Сез шул чакта, крестьяннар белән аралашмаска, общественный урыннарда политик темаларга бер сүз дә сөйләшмәскә дип, кулыгыздан подписка биргән идегез.* Т.Гыйззәт. *Һәммәсен сөйли алмавымның сәбәбе: органнарга подписка биргән кеше бит мин.* Ш.Рәкыйпов

3) *фин.* Билгеле сандагы акцияләрне яки эмиссиядәге облигацияләрне түләп алуны үз өстеңә йөкләү. *Әнә дүртенче фабрикның заём комиссиясенә авыруның шундые эләккән булырга кирәк: ул йоклап калган да подписка җыя алмаган, диләр.* Г.Камал

4) *иск. к.* **расписка**. *Алай булса, менә нәрсә: ун процентның һәммәсен дә иртәгә бирәп бетерергә кулыгыздан подписка бирәсезме?* Г.Камал

ПОДПИ́СЧИК *и. рус сөйл.* Газета-журнал яки китап яздырып алдыручы кеше; мөштәри. *Сез җибәргән календарьлар минем подписчикларыма сездән һәм миннән зур бүләк булды ---.* Татарстан яшьләре

ПОДПОЛКО́ВНИК *и. рус хәрби* Майордан өстен һәм полковниктан түбән рангтагы офицер званиесе яки чины; шул дәрәҗәдәге хәрби кеше. *Районның хәрби комиссары – юан гәүдәле, аксыл чәчле подполковник – Рушадны каршысына утыртты.* М.Мәһдиев. *Өч кеше складтан йөк автомобиленә артиллерия подполковнигының Германиядән кайткан багажын төяп азапланалар.* М.Юныс. *Урта яшьләрдәге подполковник: «Пүчтәк нәрсәләр белән аптыратып йөрмәгез әле...» – дип чыгарып җибәрде.* З.Хәким

ПОДПО́ЛЬЕ *и. рус сөйл.* 1) Хакимият органнарына каршы яшерен рәвештә алып барылган иҗтимагый-сәяси эшчәнлек. *Ике властьлылык бетә, большевиклар тагын подпольеда.* Р.Низамиев

2) Шундый эшчәнлек алып барган кешеләр, иҗтимагый төркем, оешма. *Шунда ишеткән хәбәрләрне Роза ярдәмендә подпольега тапшырып тордым.* С.Баттал. «*Кызыл Армия командирлары – ун адым алга!» дигән команда булу белән, --- строй алдына иң элек подполье оешмасы членнары чыгып басты.* Р.Мостафин

ПОДПО́ЛЬЩИК *и. рус* Хакимият органнарына каршы яшерен иҗтимагый-сәяси эшчәнлек алып баручы кеше. *Владимирның язмышы оешмага немец подпольщиклары аркылы мәгълүм булды.* Г.Әпсәләмов. *Кыю подпольщиклар бер ел эчендә дошманга байтак зарар сала ---.* Р.Низамиев. *Батыр подпольщик оккупация елларында гитлерчылар тарафыннан өч мәртәбә кулга алына.* Ш.Мостафин

ПОДПОРУ́ЧИК *и. рус хәрби тар.* Россиядә 1703–1917 елларда һәм кайбер Көнчыгыш Европа илләрендә прапорщиктан югары һәм поручиктан түбән кече офицер дәрәҗәсе, чины һәм шул чиндагы кеше. *Ахыр чиктә, әүвәлге подпоручик ризалаша, мобилизациягә эләгүен икърар итәргә була.* Р.Әмирханов. *Подпоручик зур исемме ул?* З.Хәким. *Батыршаның көрәштәшләрен каравыллау Преображенский лейб-гвардия полкы солдатларына һәм подпоручик Пётр Насоновка тапшырыла.* Ф.Ислаев

ПОДПРА́ПОРЩИК *и. рус хәрби* Россия армиясендә 1907 елга кадәр унтер-офицер составының югары дәрәҗәсе, фельдфебельдән югары һәм прапорщиктан түбән чин, шул дәрәҗәдәге кеше. *«Йортка» кулларында командирларыннан рөхсәт кәгазьләре булган биш-алты подпрапорщик, унлап унтерлардан башка килүче булмады.* А.Тahиров. *Майор Лопатин, --- подпрапорщик Буткевич кулга алынып, Казандагы Яшерен комиссия карамагына озатыла.* В.Имамов

ПОДРАЗДЕЛЕ́НИЕ *и. рус хәрби* 1) Эрерәк хәрби частьның составына кергән гаскәри берәмлек (полкта: батальон, дивизион; батальонда: рота; ротада: взвод һ.б.). *Бу бик тиз арада булып алды, безнең тылдан килгән яңа подразделение тавышын ишетеп, алар күз ачып йомганчы кире элдерделәр.* Х.Камалов. *Печән артиллерия атларына, йөк ташучы подразделение атларына әзерләнә.* Ә.Айдар. *Немец офицерларын үтереп, төрле авыллларда урнашкан подразделениеләргә сигнал бирелә, һәм восстание башлана.* З.Хәким

2) Зуррак оешманың аерым төр эшчәнлек алып барган структур өлеше. *--- структур подразделениеләр җитәкчеләре белән индивидуаль әңгәмәләр үткәрелә*. Ватаным Татарстан. *Моның өчен һәр подразделениедә компьютерлаштырылган белешмәләр базасы бар*. Шәһри Чаллы

ПОДРЯД *и. рус* Түләүле нигездә берәр эш эшләргә йөкләмә алу һәм шул йөкләмә буенча эшләнелә торган эш үзе. *Миңа калса, барыбер колхоз эчендәге колхоз инде ул сезнең подрядыгыз.* М.Хуҗин. *Татар сәүдәгәрләре, --- атлар җыеп, подряд белән гаскәргә җиткереп бирүгә алыналар.* М.Гайнетдинов

ПОДРЯ́ДЧИК *и. рус к.* **подрядчы**. *Моннан соң үз гомеренә подрядчик булып йөргән Галимгә безнең хакны ашау тәтеми инде.* А.Тahиров. *Аю Гатаулла артелен подрядчиклар да бик теләп ялларганнар ---.* Г.Әпсәләмов. *Минем белән калага күчәсеңме? Күчсәң, акча бирәм, подрядчик булып, зур йортлар салдырып йөрерсең!* Р.Гайфуллина

ПОДРЯДЧЫ *и.* Подряд килешүен төзегән ике якның берсе; подряд нигезендә эш алып баручы кеше яки оешма. *Подрядчы исә торган саен котырды, Әхмәтсафаның якасына килеп ябышты ---.* Ф.Сафин. *Ләкин бу юан торбаларны монтажлауны йөз дә ундүртле торба сузган ПМК гына башкарып чыга алмый. Икенче подрядчы кирәк.* З.Дәүләтов. *Подрядчы белән эшләгәндә, акча да тиз күчә икән.* Ватаным Татарстан

ПОДСТА́НЦИЯ *и. рус* 1) Үзәк электр станциясеннән килгән токның көчәнешен, көчен, төрен үзгәртә торган һәм электр энергиясен кулланучылар арасында бүлә торган электротехник корылмалар җыелмасы; ярдәмче станция. *Бу җәһәттән Кояш безгә иң якын йолдыз буларак электр энергиясен кулланучыларга җиткерүче подстанция ролен уйный.* Р.Сафин. *110 вольт көчәнешле подстанция дә шул елларда сафка басты.* Т.Нәҗмиев. *Яңа су алу җайланмасы, котельныйлар, подстанцияләр төзелгәнлектән, шәһәр халкы электрга, газга, җылылыкка һәм суга тиенәчәк.* Ирек мәйданы

2) Ике зур телефон станциясе арасындагы ярдәмче станция. *Күптән түгел генә телефон челтәрендә эшләүче егетләр авылыбызга куелган подстанцияләрен карарга килгәннәр иде.* Татарстан яшьләре

3) Ашыгыч ярдәм күрсәтү станциясенә караган кечерәк станция. *Казанда исә махсус һәм педиатрия бүлекләреннән торган бер үзәк станция һәм сигез подстанция эшләп килә.* Ватаным Татарстан

ПОДСТРО́ЧНИК *и. рус әд.* Текстның сүзгә-сүз, юлга-юл тәрҗемәсе. *Тик китабыңны (Гослитиздатка подстрочник ясап) җибәр.* М.Җәлил. *Югыйсә бик тә көчле иде теләге Мальцевның, яз башында ук шул эшкә тотынам, подстрочнигын --- әзерләгез, дип язган иде.* Г.Ахунов. *Әмма алда торган сораулар да шул көе кала бирә: тәрҗемә өчен тел белү зарурмы? Подстрочник булу җитәме?* Р.Гаташ

ПОДТАНЦО́ВКА *и. рус сөйл.* Сәхнәдәге җырчының әйләнә-тирәсендә җыр тактына биеп йөрүчеләр. *Җырчының артында һәм әйләнә-тирәсендә биючеләргә игътибар итегез. Подтанцовка дип атала.* З.Хәким. *[Наилә:] Минус бергә җырлыйсың, димәк. Алайса, без – подтанцовка, әйдәле, Фарис.* Р.Зарипов

ПОДТЯ́ЖКА *и. рус* Чалбарны күтәртеп тору өчен, иңбашлары аша үткәреп чалбарга каптырып куела торган резиналы куш тасма. *Чалбарын подтяжка белән ныгытkан, җиңнәрен сызганган Ильяс ---.* Г.Әпсәләмов. *Башта ук пиджагын салып утырган Зариф абзый, ниһаять, изүен чиште, подтяжкасының ике ләмкәсен дә төшерде, җиңнәрен тартып куйды.* Ә.Еники. *--- Кияү шәп, чалбарын подтяжкалар белән аскан, акчаны санап тотмый, балалары бар, җитмәсә.* М.Мәһдиев

ПОДШИ́ВКА *и. рус* Бергә беркетеп куелган газеталар, документлар һ.б.ш.лар тегелмәсе; төпләмә. *Безнең тулай тораклның уку залында «Комсомолка»ның подшивкасы бар иде.* А.Хәсәнов. *--- укытучыларның --- бер төрлеләре зур тәрәзә янындагы газета подшивкалары өйгән өстәл янына*

җыелып, дөньяларын онытып гармун тавышын тыңлады. М.Мәһдиев

ПОДШИ́ПНИК *и. рус* Әйләнә яки тирбәлә торган механизмнарда, җайланмаларда каршылык көчен киметә, хәрәкәттәге өлештән йөкләнешне калган өлешләргә тапшыруда катнаша торган деталь. *Сиңа үзеңнең тракторыңны йөртә белсәң, шул җитте. Подшипникларыңны эретмәсәң...* М.Мәһдиев. *Гребной валның подшипниклары кызды, механиклар суыту системасын көйлиләр.* М.Юныс. *Без утрау яныннан үтеп барганда, моторның подшипнигы чәчелде, ярга чыгып, аны төзәттек.* Кызыклар дөньясында

ПОДЪЕЗД *и. рус* Өйнең, бинаның кешеләр кереп-чыгып йөрү урыны; күпкатлы йортта баскычлы, мәйданчыклы гомуми кулланылыштагы мәйдан. *Подъездга кергәч, теге яки бу фатирдан аңкыган аш исе ялгыз ирнең аңын, зиһенен ничек томалаганын нинди сүзләр, нинди төсмерләр белән аңлатмак кирәк?* З.Хәким. *Өй подъездындагы җимерек почта әрҗәләренең кыйшайган авызларына ара-тирә кемнәрдер белдерүләр белән тулган күпбитле гәҗитләр кыстырып киткәлиләр.* Татарстан яшьләре

ПОДЪЁМ *и. рус* Коллективны бердән йокыдан уятуның төгәл билгеләнгән вакыты; шул вакытта бирелә торган сигнал. *Подъёмга кадәр ишекне ачып чыгучы да булмады.* Г.Әпсәләмов. *Подъёмга кадәр тыныч йокы, иптәш ефрейтор!* М.Мәһдиев. *Төнге сорау алулар отбойдан алып подъёмга кадәр бик төгәл алып барыла.* Р.Мостафин

ПОДЪЁМНЫЙ *и. рус* Диплом алган яшь белгечкә, эшкә билгеләнгән урынга барып җитәр өчен, бер тапкыр гына түләнә торган махсус акча. *– Ә подъёмный кая? – диде бөркет. – Пенсиягә бер ел калыр-калмас, Берегез дә мине алдый алмас!* Г.Афзал. *Дәүләт имтиханнарын тапшырдык. Дипломнар алдык. Подъёмный акчаларын бирделәр.* А.Хәсәнов. *Акча бездә бер букча. Подъёмныйлар бирделәр.* М.Мәһдиев

ПОДЬЯ́ЧИЙ *и. рус тар.* Россиядә XVI–XVIII гасырларда дәүләт учреждениесендә дьяк ярдәмчесе, приказ канцеляриясендә писарь яки эш башкаручы. *1768 елның 18 июнендә, дәүләт оешмаларында --- руслар гына тылмач, подьячий булырга тиеш дигән күрсәтмәне Я.Гуляевның үз кулына да тоттыралар.* М.Гайнетдинов

ПО́ЕЗД *и. рус* Локомотив яки моторлы вагон ярдәмендә хәрәкәткә китерелә торган бер-берсенә тоташкан вагоннар составы. *Баку белән Дәрбәнт арасында бер кечкенә генә станциядә безне поезддан төшерделәр ---.* Ш.Камал. *Каршыбыздан гына елан төсле елкылдап, җемелдәп, дизель поезд узып китте.* А.Гыйләҗев. *Метро поезды кешеләрне төркемләп һәм берәмләп шәһәргә тарата.* М.Юныс

◊ **Поезд китте** Хәлне төзәтер, нәрсә дә булса эшләр өчен артык соң булу; вакытны, форсатны кулдан ычкындыру турында. *Теге заманнар үтте. Ә син һаман теге заман гадәтләрен куасың. Син калдың, Вил Садриевич, ә поездың китте.* Х.Камалов. *Поездың китте, дисәләр, Йөрәк калсын ялкында. Инде беттем дигәндә дә Үкенми яши алсаң.* В.Фатыйхов. *Кыскасы, мин кайтыр вакыт җиткәч кенә каты яндым. Юләрлегем аркасында. Хәзер поезд китте – терсәкне тешләп булмый.* Н.Хәсәнов

ПОЖАР *и. рус сөйл.* Янгын. *Синең утка керүеңнең поты бер тиен, пожар чыгармау чарасын күрергә кирәк иде...* Ә.Моталлапов. *Пожар чыгудан куркып, электрик биш йөз ваттлы лампочканы борып алды.* М.Юныс

◊ **Пожар бармы әллә?** Ашыктырганга ризасызлык белдереп әйтелә. *[Саттар]: Нәрсә, әллә пожар бармы?* Ш.Усманов. *Нәрсәгә шулкадәр акырасың, пожар бармы әллә?* Т.Гыйззәт. *Бераз хушына килгәч, карчык абзарга йөгерде. – Атасы! Атасы, дим! – Нәрсә, пожар бар мәллә?* З.Мәхмүди. **Пожар чыккандай** Бик ашыгып, кабаланып, бәргәләнеп. *Нигә пожар чыккандай кабаланасыз?* В.Нуруллин. **Пожар чыкканмы әллә?** *к.* **пожар бармы әллә?** *Пожар чыкканмы әллә, Рафис дус?* Г.Сабитов

ПОЖА́РКА *и. рус сөйл.* Янгын сүндерү пункты. *[Сәгыйрь] --- әнисе, абыйлары янына кереп чыкты да, пожарка янында кәрт суккан ирләргә дә байлыгын күрсәтеп тормастан, Казанга чыгып китте ---.* Т.Галиуллин. *Пожаркалардагы атлар беркайчан да юньле булмый.* Татарстан яшьләре

ПОЖА́РНИК *и. рус сөйл. к.* **пожарный 1.** *Суткасына егерме дүрт сәгать йоклап, эшсезлеккә тәмам өйрәнде безнең пожарниклар.* Ә.Моталлапов. *Галимҗан пожарник булып эшләгәндә, авылда бары тик бер тапкыр гына янгын чыкты.* З.Хәким. *Пожарниклар килеп җиткәндә, ялкын йортны бар яктан да чорнап алган иде инде.* М.Юныс

ПОЖА́РНЫЙ *и. рус* **1.** 1) Янгын сүндерүче, янгынчы; янгын куркынычсызлыгы командасында хезмәт итүче кеше. *Зыялыларыбызга һәр ничек, җәсарәтле пожарныйлар кеби, җәһаләт ялкыны эчендә дөрләп янган милләтне тизрәк утка атылып коткарырга тырышу фарыздыр.* Г.Тукай. *Салам түбә, бер очкын урамы белән авылны юк итә. Шуңа күрә пожарныйлар көне-төне сакта торды.* Ф.Садриев. *Ярый әле күршеләре калды, Пожарныйлар саклап калдылар.* Л.Кәшфи

2) *сөйл.* Янгын сүндерү пункты. *Айсылу алар янына пожарныйда торучыны төшереп җибәрде.* Г.Бәширов. *Авылда «пожарный» турысыннан узганда, тачанкадан җиргә сикерә, тәртәләрен күтәртеп куйган арбага атларны җигеп, инештән су ташырга керешә.* Г.Ахунов. *--- ул Әхмәтзарифның халат чабуын кулына чорнап тотты. – Хәзер үк пожарныйга илтеп бушат йөгеңне, Алланың нәгъләте төшкере!* М.Мәһдиев

2. *с. мәгъ. сөйл.* Янгын сүндерү белән бәйле. *Сез югында пожарный инспектор килеп, ут сүндерү коралларын тикшереп китте.* М.Юныс. *Әниләре – урта мәктәптә завуч, әтиләре – Арчада пожарный частьтә майор.* Татарстан яшьләре

ПОЖА́РНЫЙЛЫК *и.* Янгын сүндерүче эше, һөнәре; янгынчылык. *Бездән пожарныйлыкка укырга кеше сорыйлар.* Г.Ахунов

ПОЖЫМ *и. диал.* 1) Курку, шик

2) Берәр бик ашыгыч эшнең хәстәрен күрү уе

◊ **Пожым керү** Курку, шүрләү

ПОЖЫМЛА́У *ф. диал.* 1) Курку, шүрләү. *[Гариф:] Пожымладыңмы?! Кулга алдыру белән шаярырга яраамый шул, Мөкип абзый! Шаярасың икән, үзең килеп капкач, шүрләмә инде.* Ш.Камал. *Җиңгәсеннән пожымлаган Сәлимә хатасын төзәтсә дә, соң иде инде.* Н.Гыйматдинова

2) Берәр бик ашыгыч эш белән йөрү

Пожымлый башлау Куркуга бирелү

ПО́ЗА *и. фр.* Гәүдә торышы, утырып яки басып тору рәвеше. *Укытучылар, --- китап-дәфтәрләрен урнаштырып, директордан күрсәтмә көткән сыман позада калдылар.* М.Мәһдиев. *Үзеннән биек кукурузлар арасында атка атланган позага баскан Сакал Шәйхи рәсеме кайда?* К.Кәримов. *Бөжәкләрнең яшәү рәвешен күрсәтә торган коллекцияләр төзегәндә, личинкаларны алар өчен генә характерлы позада киптерү кирәклеге килеп чыга.* Яшь натуралистларга

◊ **Позага басу** Үз сүзен сүз итү өчен киреләнү; тәкәбберләнү. *Ул [Т.Миңнуллин] үз күңелендәге туры сүзне --- бәреп әйтә, --- әмма берчакта да позага басмый, урам себерүчене дә үзе белән тиң күреп аралаша, президентлар янында да мескенләнмичә сөйләшә белә.* Р.Вәлиев. *Берничә ай элек --- бик каты бәхәс кубып, күп нотыклар сөйләнгәннән соң, депутатларыбыз «позага басып файда чыкмас» дип таралышканнар иде инде.* Татарстан яшьләре. **Поза ясау** Ясалма кылану, тыштан матур күренергә тырышу. *[Бүгенге шагыйрьнең] Яңа шигырьләрен укыган саен ышана барасың: сүздә саксызлыкларын, бераз поза ясауларын искәрткән хәлдә дә, яшьләрдән әлеге юлга иң якыны Ркаил Зәйдуллин бугай.* Балачак әдипләре

ПОЗИТИВ I *и. лат. махс.* 1) Негативтан төшереп алынган, ак һәм кара өлешләре чынбарлыкка туры килә торган фоторәсем; фотография эшенең төп максаты һәм нәтиҗәсе. *Голограмманың позитивы да, негативы да бер үк төрле сурәт бирә.* Физика

2) *җыл.* Уңай эмоцияләр, уңай тәэсирләр. *Аннан алып кайткан позитивны кая куеп бетерәсе булыр?!* Безнең гәҗит. *Конференциядә балаларда тискәре күренешләрне, начар гадәтләрне бетерүгә, позитивка юнәлдерелгән күптөрле секцияләр оештырылган иде.* Шәһри Казан

ПОЗИТИВ II *с.* 1) *филос.* Позитивизмга караган, шуңа нигезләнгән. *Позитив социологиядән аермалы буларак, гуманитар социология кешенең үз-үзен тоту мотивларына ныграк игътибар итә.* Социология буенча лекцияләр курсы. --- *позитив фәннәр барлыкка китергән мөмкинлекләрдән файдалану югары әхлак иясе булган кешенең вазифасы булырга тиеш.* Инсан һәм дин. *Позитив психология өлкәсендәге танылган белгеч, профессор Дэвид Майерс сүзләренә караганда, һәркем дә бәхетле була ала ---.* Татарстан яшьләре

2) *кит.* Уңай; *киресе*: **негатив**. *Кешенең рухи халәте позитив дулкынга көйләнгән булуы әһәмиятле.* Х.Хөснуллин. *Байлар һәм ярлылар бергә генә була ала, алар берсе икенчесенең яртысы (позитив + негатив = бербөтен, ягъни җәмгыять).* Р.Сафин. *Позитив сәясәтнең бурычы мәсьәләне хәтта сөйләшүләр юлы белән хәл итеп була торган конфликт хәленә дә китереп җиткермәүдән гыйбарәт.* Ватаныбыз тарихы

ПОЗИТИВИЗМ *и. лат. филос.* Фәлсәфәнең реаль белем чыганагы булуын инкяр итеп, чын белемнәрне махсус фәннәр ярдәмендә, тәжрибә туплап, тасвирлау һәм фактларны системага салу юлы белән генә алып була, дип раслый торган субъектив-идеалистик фәлсәфи юнәлеш. *Гегельнең Кеше һәм Яшәеш хакында өйрәтүе позитивизм фәлсәфәсенең капма-каршысы буларак карала ала.* Д.Зәһидуллина. *Икътисадта либерализм һәм капитализм; фәндә детерминизм --- һәм позитивизм --- өстенлек ала.* Инсан һәм дин. *Позитивизм белән берәттән гуманитар социология дә бар.* Социология буенча лекцияләр курсы

ПОЗИТИВИСТ *и. лат.* Позитивизм тарафдары. *Позитивистлар, барлык фәннәрне файдаланып, уртак бер яңа фән барлыкка китерергә, аны социологиягә нигезләргә телиләр.* Д.Зәһидуллина. *Позитив фәнне үзләштергән кешегә позитивист дип әйтелә.* Инсан һәм дин. *Позитивист буларак, И.Ковалевский социаль үсеш һәм социаль бердәмлек теориясенә зур игътибар бирә.* Социология буенча лекцияләр курсы

ПОЗИТИВЛЫК *и.* Позитив булу. *Аның яшьләр белән шулай олы җанлы булуы, алтын киңәшләре, канатлы сүзләре, позитивлыгы әйтеп бетергесез соклану уятты.* Ирек мәйданы

ПОЗИТРОН *и. лат. физ.* Массасы электрон массасына тигез булган уңай корылмалы элементар кисәкчек. *Дүртесе – протон, антипротон, электрон, позитрон кисәкчекләре – җисемдәге туу, таркалу процессын җитәклиләр ---.* Татар фәлсәфәсе һәм милли мәгариф. *Матдәнең электрон һәм позитрон кебек кисәкчәләре билгеле шартларда электромагнит кырының кисәкчәләренә, фотоннарга әверелүе ачыклана.* Философия. *Тәҗрибәләрдә без хәрәкәтләнгән электрон белән позитронның аннигиляциясен файдаландык.* Физика

ПОЗИЦИОН *с.* 1) *хәрби* Озак вакыт даими сугышчан позицияләрдә алып барыла торган. *Билгеле булганча, бу фронт гаскәрләренә елларга сузылган йончыткыч позицион сугышлар алып барырга туры килә*

2) Шахматта һ.б. уеннарда: акрын-акрын яхшырак позиция алуга юнәлдерелгән

3) Нәрсәнең яки кемнең дә булса урнашу тәртибенә бәйле. --- *татар телендәге [а] фонемасын алсак, әйтелештә аның өч төрле позицион варианты булуы күренә.* И.Бәширова. *Сузыкларга кагылган башка үзенчәлекләр аваз тәңгәллекләренә, төрле позицион күренешләргә кайтып кала.* Татар халык сөйләшләре. *Бу хезмәтнең беренче бүлегендә позицион унарлы санау җыелмасында исәпләү алымнары бәян ителә ---.* Татар милли педагогикасы

ПОЗИ́ЦИЯ *и. лат.* 1) Кемнең яки нәрсәнең дә булса урнашу тәртибе, урнашу ноктасы. *Хәйбулла кечкенә бер калкулык янында туктады. «Ярар, шунда көтәрмен. Позициясе дә җайлы, обзоры да киң», – диде ул үз-үзенә ---.* Г.Әпсәләмов. *Безнең позиция шәп. Күзәтәбез.* М.Мәһдиев. *1989 елда уздырылган исәп алудан соң, башкортлар –*

икенче, ә татарлар өченче позициягә күчә булып чыга. Татарстан яшьләре

2) *хәрби* Сугышчан берәмлекнең сугышка әзерләнү һәм аны алып бару өчен урнашкан җир кишәрлеге яки сулык. *Кызыл Армия частьларының позициясе күренә.* М.Җәлил. *Чикләнгән төбәкләрдә уңайлы позиция эләктерү һәм шунда ныгып калу өчен барган вакытяк сугышлар гына кабынгалап ала.* Р.Низамиев. *Немецлар үз позицияләрен бик яхшылап маскировкалаганнар.* Казан утлары

3) Хореографиядә гәүдәнең, аякларның билгеле рәвештә торышы. *Бию белән шөгыльләнгәч, йөргәндә дә беренче позициядәге кебек баса идем.* Ф.Бикчәнтәев

4) Шахмат, шашка яки башка уеннарда уенның теге яки бу моментында фигураларның торышы. *Позициясе яхшы булуына да карамастан, ул шахмат тактасындагы фигураларын сыпырып төшерде ---.* Н.Фәттах. *Малай, бөтен дөньясын онытып, бар игътибарын үз фигураларын уңай позицияләргә урнаштыруга юнәлдерә, кайбер йөрешләрне 15–20 шәр минут уйлап, өстенлеккә ирешә.* Ватаным Татарстан. *Рубик кубигын, теләсә кайсы позициядән башлап, 20 тапкыр борып җыеп була.* Ирек мәйданы

5) *лингв.* Тел берәмлеге урнашкан тирәлек. *Борынгы төрки теле өчен хас интервокаль позициядә тартыкларның саңгырау әйтелеше сакланган ---.* Ф.Нуриева

6) Реестр, исемлек, прейскурант һ.б.ш. документларда күрсәтелгән, теркәлгән берәмлек. *Товарлар исемлеге җитмеш позициядән тора*

7) *күч.* Кемнең дә булса үз принципларыннан, эшчәнлегеннән чыгып тоткан урыны, яулап алган, лаек булган дәрәҗәсе. *Көч бар чакта, эшлисе эшне эшләп, яулыйсы позицияләрне яулап калырга кирәк.* М.Юныс. *Бу чакта Уралдан килгән яшь талантның Казан әдәби даирәсендә позициясе нык була дияргә мөмкин.* Гасырлар мирасы

8) *күч.* Кемнең яки нәрсәнең дә булса үз-үзен тотышы, эшчәнлеге нигезенә салынган принцип, берәр мәсьәләгә карата фикер, мөнәсәбәт, караш. *Әмма аларның үз кайгысы кайгы, һәм аерылганда икесе дә үзләренең элекке позицияләрендә калалар...* В.Юныс. *Күп кенә әсәрләр башка язучылар әсәрләренә җавап, авторның үз һәм үзгә позициясен белдерүе рәвешендә иҗат ителәләр.* Р.Гали. *НАТО да үз позициясен белдерде: бу сугышта агрессор – Русия, аның Грузия территорияләренә керергә хакы юк.* Татарстан яшьләре

ПОЗЫВНО́Й *и. рус* Радиостанция, кораб, хәрби часть һ.б.ш.ны тану өчен, шуңа гына дип билгеләнгән махсус сигнал. *Бер юнәлештә хәрәкәт иткән частьлар даими элемтәдә торырга тиешләр, моның өчен алар берберсенең позывнойларын белешәләр.* М.Маликова. *«ТК» позывноен Тарханкут маягы бирә.* М.Юныс

ПО́КЕР *и. ингл.* Карталарның иң отышлы комбинациясе яки көндәшләрен уеннан кысрыклау ярдәмендә конга куелган акчаны отарга тырышудан гыйбарәт комарлы уен. *Ул көнне покер уены уйнарга булдылар ---.* Р.Мирхәйдәров. *Узган атнада Русия Спорт министрлыгы покер уенын спорт төрләре реестрыннан сызып ташлады.* Татарстан яшьләре

ПОКОС *и. рус* Бер кеше алын алып чабып узгач кала торган печән, тезем. *Каяндыр, тургай сайрауларына кушылып, чалгы янаган тавышлар ишетелә кебек, йомшак җил кибеп яткан покосларның хуш исен китерә кебек.* Ә.Еники. *Ирләр бер покос чыкканда, ул бер ярымны чыгып өлгерә иде.* Ә.Гаффар. *Менә шулай берәр покос чыкканнан соң, карт имән төбенә утырып, мәтрүшкә чәе эчеп алабыз.* Н.Гамбәров

ПОКРА́У *и. рус* Православиедә 14 октябрь көнне уздырыла торган дини бәйрәм. *Покрау җылысы алып кал, ягъни Покрауда йорт тирәңне кара.* К.Насыйри. *Инде пешкән Покрау пироглары Төрле ярма, төрле орлыктан.* К.Булатова. *Көннәр суытты, Покрау җитеп килә.* Г.Сабитов

ПОКРЫ́ШКА *и. рус* Велосипед, автомашина һ.б.ш.ларның тәгәрмәч камераларына кидерелә торган калын резин тышлык. *Фатих йөк машинасының тәгәрмәч покрышкасыннан башмак ясап бәйләгән ---.* Р.Батулла. *– Покрышканы шул тимерчыбык кына тота, – диде Мәрдегалләм. – Алар булмаса, покрышка тәгәрмәчтән бүселеп чыга.* Ф.Баттал. *[Ф.Кәримнең] Аркасында киндер биштәр, аягында автомобиль покрышкасыннан эретеп эшләнгән --- аяк киеме була.* Репрессияләнгән татар әдипләре

ПОЛЕ́МИК *с. кит.* 1) Бәхәс тудыра торган, бәхәсле мәсьәләләр күтәрелгән. *Әдипнең тәнкыйть мәкаләләре һәм монографик хезмәтләре күтәргән мәсьәләләрнең актуальлеге, конкретлыгы, полемик характерда булуы белән җәлеп итә.* Әдипләребез

2) Сүз көрәштерүгә, бәхәскә корылган, бәхәс характерындагы. *Мәкалә Исхакыйга хас булган публицистик кайнарлык, полемик рух белән язылган.* Х.Миңнегулов. *Парадокс сатирик, юмористик һәм полемик әсәрләрдә бик еш кулланыла.* Тел – белемнең ачкычы

ПОЛЕ́МИКА *и. гр. кит.* Гыйльми, әдәби, сәяси һ.б.ш. мәсьәләләрне җыелышта, матбугатта тикшергәндә, ачыклаганда була торган бәхәс. *Без моңа каршы бик каты сугыш ачарга, кат-кат полемика ясарга мәҗбүр булдык.* Г.Ибраһимов. *Ихтимал, хатлашу тәртибендә алып барылган һәм бераз озаккарак сузылган бу әңгәмәнең, полемика сәнгате күзлегеннән караганда, --- беркадәр файдасы булыр, дип ышанам.* Р.Фәйзуллин. *Публицистлык ул янә дискуссия, полемика, бәхәс оештыру осталыгын да күз уңында тота.* И.Низамов

ПОЛЕМИСТ *и. гр. кит.* Полемикага, бәхәскә оста кеше. *Мин бигрәк тә Миркасыйм Госманов белән очрашып сөйләшергә яратам. Холкы белән ул – полемист.* Т.Миңнуллин. *Әхсән ага Баян – --- зур белемле, интеллектуаль фикри көчкә ия булган ярсу полемист-моназарачы.* Р.Гаташ

ПОЛИ- *гр.* Кушма сүзләрдә «күп» яки «төрле» мәгънәсен белдерә торган беренче кисәк (мәс., *поликлиника, полипропилен, полиэтилен*)

ПОЛИАКАНТ *и. гр. зоол.* Макроподлар семьялыгына карый, Көньяк-

Көнчыгыш Азия, Малайя, Суматраларның сазлыклы яки акрын агымлы сулыкларында яши, начар йөзә торган вак балык төре. *Кислородка байрак тирәлектә яшәүче полиакант үзенең оясын --- таш яисә суга баткан агач ботагы астында кора.* Кызыклы физиология

ПОЛИА́НДРИЯ *и. гр. кит.* Бер хатынның берьюлы берничә ир белән никахта торуы (полигамиянең сирәк очрый торган төре); күбирлелек. *Борынгы Шумер мифологиясе мәгълүматлары буенча, Лулла, берьюлы күпсанлы ирләргә кияүгә чыгып (халыкара мифологиядә һәм Борынгы Шәрык тарихында яхшы мәгълүм булган күбирлелек – полиандрия мотивы!), бик күп кызлар тапкан.* Ф.Урманче. *Полиандрия --- шактый сирәк очрый, аның каравы, полигамия --- бик киң таралган.* Кызыклы физиология

ПОЛИАРТРИТ *и. гр. мед.* Берьюлы яки бер-бер артлы берничә буынның ялкынсынуы, буыннар сызлаудан гыйбарәт авыру. *Полиартрит дигәннәр иде хастаханәдә – шулдыр.* Т.Миңнуллин. *[Тәүфыйк:] Полиартрит аңарда. [Сабир:] Полиартрит түгел, ялкаулык көчле аңарда, ялкаулык.* Х.Ибраһим. *Хәзер дөнья табиблары балык маен ишемиядән, --- полиартритны дәвалаганда кулланалар.* Татарстан яшьләре

ПОЛИВИТАМИН *и. гр.-лат.* **1.** Витаминнар комплексы; шундый комплекстан торган дару. *Аннары без җәй буена күпме поливитамин ашый торган идек, җир ачылганнан алып беренче кар төшкәнчегә кадәр.* Ә.Еники. *Поливитаминнар хәтерне яхшыртырга булышалар.* Татарстан яшьләре

2. *с. мәгъ.* Составында төрле витаминнар булган. *Серкә, биологик актив өстәмә буларак, бик күп авыруларны дәвалауда табигый поливитамин препарат буларак кулланыла башлады.* Татар балы

ПОЛИГА́МИК *с.* Полигамиягә нигезләнгән, полигамия формасындагы. *Хәзерге заманда полигамик никах – никахның таралган төре, чөнки күп диннәр һәм культуралар күпхатынлылыкны рөхсәт итәләр, хәтта хуплыйлар*

ПОЛИГА́МИЯ *и. гр.* 1) Берьюлы берничә хатын яки берничә ир белән тору; күбирлелек яки күпхатынлылык. *Полигамия --- хатын-кызны ир-ат белән тигезсез хәлгә куя ---.* Р.Хәкимов. *Заманында кеше мәңге бергә яшәргә дип гаилә корган, хәзер исә кыска вакытлы никахлар популярлаша. Социологиядә бу эзлекле полигамия дип атала.* Татарстан яшьләре

2) *зоол.* Ата хайванның бер үрчү сезоны эчендә берничә ана хайван белән җенси мөнәсәбәткә керүе. *Полигамия маймыллар һәм бигрәк тә тавыксыманнар отрядына кергән кошлар арасында билгеле.* Кызыклы физиология. *Полигамия, ягъни берничә партнёр белән бәйләнешкә керү, маймылларда, арысланнарда, куяннарда күзәтелә.* Шәһри Казан

ПОЛИГИНИ́Я *и. гр.* Бер ирнең берьюлы берничә хатын белән никахта торуы (полигамиянең бер төре); күпхатынлылык

ПОЛИГЛОТ *и. гр.* Күп телләр белүче кеше. *Равил Бохараев дигән гаҗәеп колачлы шагыйрь, публицист, полиглот, гыйлем иясен татар дөньясында әлегә бик үк белеп бетермиләр кебек.* Р.Әхмәтҗанов. *– Китап яраткан кешене полиглот диларме әле? – Юк, библиофил диләр.* К.Кәримов. *Иң күп тел белүче – полиглот дип, 1914 елда Франциядә туган Джордж Шмидт санала.* Кызыклар дөньясында

ПОЛИГОН *и. гр.* 1) Корал, хәрби техниканы сынау яки хәрби өйрәнүләр өчен махсус җиһазландырылган зур җир яки су мәйданы. *– Яшьлегемә кире кайттым бит әле, туганкай, – диде Шәрәф. – Полигонда булдым, хәрби учениеларне күрсәттеләр.* М.Мәһдиев. *Тирән кар белән капланган кышкы полигонда бүгенгә билгеләнгән эшләрен бетергәч, офицерлар --- кышкы тораккa солдатларны озатып куйды.* М.Вәли-Баржылы. *Полигонда тыныч буламы соң?! Анда корал сыныйлар.* А.Хәсәнов

2) Җыелма тимер-бетон конструкцияләр һәм детальләр җитештерүче ачык мәйдан. *Җитмешенче елларда Иләбәр авылында төзелгән һәм хәзер дә халыкка һәм оешмаларга игелекле хезмәт күрсәтә торган тимер-бетон эшләнмәләр заводы да (полигон) Минтимер Шәймиев инициативасы белән барлыкка килде.* Борынгы Калатау итәгендә

3) Фәнни һәм башка төрле сынаулар үткәрү мәйданы. *Алма-Ата шәһәре сейсмологлары, махсус биологик полигон оештырып, анда тотылучы бурсыклар, --- чәүкәләр ярдәмендә җир тетрәүләрне алдан белеп тору мөмкинлекләрен өйрәнәләр.* Х.Мәхмүтов

4) Калдыкларны, чүпне әйләнә-тирә мохиткә йогынты ясамыйча күмү өчен махсус җиһазландырылган мәйдан. *Калдыкларны заводтан 30 км ераклыкта урнашкан полигонга чыгаралар.* Тирә-юнь мохитне саклау. *Чүп полигонын ерактарак ачсаң, болынга якын, якындарак ачсаң – борынга якын!* Ватаным Татарстан. *Самосырово полигонына көн саен 300 машина чүп килә.* Шәһри Казан

5) *күч.* Нәрсәне дә булса сынау, әзерләү өчен җирлек, нигез, зәмин. *Курчак театры ул чакта Татарстан театрлары өчен директорлар тәрбияләп бирү полигоны кебек иде.* Р.Батулла. *Җир – Кояшның полигоны. Җылылыгының куәтен, яктылыгы хасиятен Җирдә сыный Кояш.* Р.Харис. *Бүгенге Америка иле ул – кеше җанын үзенчә бертөрле сынап карау полигоны кебек кабул ителергә тиештер инде.* М.Вәли-Баржылы

ПОЛИГРА́ФИК *с.* Полиграфиягә караган, полиграфиягә мөнәсәбәтле. *Безнең дәүләт нәшриятларында чыккан китапларга карагач, татар китабының --- полиграфик эшләнеше шактый ук зәгыйфь икәнлеген күрәсең.* Р.Фәйзуллин. *Хәзер инде «Татарстан» – ике дәүләт телендә нәшер ителә торган, --- полиграфик яктан затлы журнал.* Р.Миңнуллин. *Үзебезнең компьютерларга нигезләнгән басмаханәбезне булдыру максатында, профессор Галим Улумбеков җитәкләгән полиграфик төркем белән элемтә урнаштырдык.* И.Әмирханов

ПОЛИГРАФИСТ *и. рус* Полиграфия белгече; полиграфия хезмәткәре. *--- атаклы полиграфист Мөҗәһит*

Шәйхетдинов та Самара өлкәсенең Камышлы авылында дөньяга килгән ---. Т.Нәҗмиев. *1962 елда Мәскәү шәһәренә китеп, --- басмаханәдә полиграфист булып эшли.* Балачак әдипләре. *Яңа офсет машинасында «Идел-Пресс» полиграфистлары Мәскәүдән килгән заказларны --- бастыруга кереште.* Мәгърифәт

ПОЛИГРАФИ́Я *и. гр.* Басма продукция чыгаруның бөтен төрләрен үз эченә алган сәнәгать тармагы; шуңа караган техник чараларның җыелмасы. *Нигә дип әдәбият кануннарын да, полиграфия кагыйдәләрен дә бозып, кереш сүзеңне китабыңның уртасына китереп керттең?* М.Әмир. *Әйе, полиграфия – матбугатның да, әдәбиятның да нигезе.* М.Вәли-Баржылы. *Республикада полиграфия базасының үсеше турында --- кем кайгыртырга тиеш?* Р.Миңнуллин

ПОЛИКАРБОНАТ *и. гр.-лат.* **1.** Күмер кислотасының һәм фенолның синтетик полимерлар классына керә торган катлаулы полиэфирлары; чыдамлы һәм диэлектрик үзлеккә ия булган төссез үтәкүренмәле продукт. *15 нче мартта полиция хезмәткәрләре --- поликарбонат төягән йөк машинасын тоткарлыйлар.* Ватаным Татарстан. *Полимер материаллар, төгәлрәк әйтсәк, поливинилхлорид, --- поликарбонат тормышыбызның аерылгысыз өлешенә әйләнде.* Татарстан яшьләре

2. *с. мәгъ.* Шундый материалдан ясалган. *Хәзер кәрәзле поликарбонат теплицалар киң кулланылышта.* Ирек мәйданы

ПОЛИКЛИ́НИК *с.* Поликлиника учреждениесе белән бәйле. *Күрелгән чаралар тиешле амбулатор-поликлиник ярдәм күрсәтергә, бер сменада 600 кеше кабул итәргә мөмкинлек бирә.* Кызыл таң. *Республика хастаханәсенең поликлиник бүлеге*

ПОЛИКЛИ́НИКА *и. гр.* Амбулатор авыруларны кабул итеп яки өйләренә барып ярдәм күрсәтә торган киң профильле яки махсуслашкан дәвалау-профилактика учреждениесе. *Ялга каршы нинди поликлиника эшләсен, ди!* М.Насыйбуллин. *Иртәнге сигездә поликлиникага юнәлдем.* М.Юныс. *Поликлиникада иртәнге биштән чират торырга кирәк.* М.Маликова

ПОЛИМЕР *и. гр.* **1.** 1) *хим. күпл.* Молекулалары кабатланган атомнар төркеменнән торган чылбыр хасил итә, башлыча техник тармакта киң кулланыла торган югары молекуляр химик кушылмалар. *Полимерлар --- үзләренең кайбер сыйфатлары белән металлга караганда өстенрәк тә ---.* Философия. *Боларга [табигый булмаган яңа материалларга] --- кирәкле үзлекләргә ия булган полимерлар һәм башкалар керә.* Физика. *Полимерларның иң арзанлысы һәм иң киң кулланыш тапканы – поливинилхлоридның нигезендә хлор ята.* Татарстан яшьләре

2) Составы белән шундый кушылмалардан тора торган материал. *Россия ихтыяҗлары өчен җитәрлек дәрәҗәдә полимерның әлегә кытлык булган төп төрләрен җитештерү җайга салынырга тиеш.* Ә.Маликов

2. *с. мәгъ.* Шундый кушылмалардан гыйбарәт булган, шуннан эшләнгән, ясалган. *Кызганыч, быел --- полимер плёнкалар --- эшләү, электр энергиясе бирү кимеде.* М.Галиев. *Техниканың төрле өлкәләренә бик киң үтеп кергән синтетик полимер һәм силикат материалларның ассортименты туктаусыз артуга карамастан, --- металлар төп конструкцион материал булып калалар.* Коррозия һәм металларны саклау

ПОЛИМЕРИЗА́ЦИЯ *и. к.* **полимерлашу** (*2 мәгъ.*). *Полимеризация (полимерлашу) − мономерларның бер-бер артлы тезелеп бәйләнешүе процессы.* Төзү материаллары

ПОЛИМЕРЛАШТЫРУ I *ф. хим.* Полимерга әверелдерү, полимер итү. *Полистирол (ПС) – стиролны полимерлаштырганда хасил булган синтетик термопластик полимер.* Төзү материаллары

Полимерлаштыра башлау Полимерлаштырырга керешү

Полимерлаштырып бетерү Тулысынча полимерлаштыру, барысын да полимерлаштыру

Полимерлаштырып тору Полимерлаштыру процессында булу

ПОЛИМЕРЛАШТЫРУ II *и.* Полимерлар ясау процессы, гамәле. *Утызынчы еллардан башлап полимерлаштыру ысулларын киң куллану нәтиҗәсендә, полистирол, поливинилацетат, поливинилхлорид, полиметилметакрилат, синтетик каучук, ә соңрак поликонденсация ысулы белән полиамид, полиуретан һ.б. полимерлар җитештерелә.* Төзү материаллары

ПОЛИМЕРЛАШУ I *ф. хим.* Полимерлар ясалу; бер төрле молекуляр кушылмалардан эрерәк органик молекуляр кушылмалар ясалу. *Дуплагыч матдәләр кислоталы әче тирәлектә тагын да көчлерәк полимерлашалар: тыгызланалар.* Агулы үсемлекләр

Полимерлаша башлау Полимерлашу билгеләре барлыкка килү

Полимерлашып бетү Тулысынча полимерлашу

Полимерлашып тору Полимерлашу процессында булу

ПОЛИМЕРЛАШУ II *и.* Полимер ясалу күренеше, полимерга әверелү процессы. *Берәүләр фикере буенча, полимерлашу температура һәм әче тирәлек нәтиҗәсендә барлыкка килә.* Агулы үсемлекләр

ПОЛИМЕТАЛЛ *и. гр. геол.* **1.** Составында күптөрле химик элементлар, шул исәптән берничә металл булган комплексы руда. *Кентау – полиметаллның туган җире, шунлыктан монда экскаватор, трансформатор ясый торган һәм башка төрле заводлар күп.* Татарстан яшьләре

2. *с. мәгъ.* Берничә металлдан тора торган. *Аеруча составында цинк, кара кургаш, көмеш булган кыйммәтле полиметалл рудаларының чыганаклары билгеле.* Материклар һәм океаннар географиясе

ПОЛИМОРФИЗМ *и. гр.* 1) *биол.* Бер үк төрдәге хайваннар яки үсемлекләр арасында бер-берсеннән бик нык аерыла торган затлар, формалар (мәс., бал кортлары арасында сорыкортлар, бал җыючы, сакчы һәм ана кортлар) булу. *Ябыгорлыклыларда югары дәрәҗәдәге полиморфизм, экологик үзгәрүчәнлек һәм җир өстенең төрле*

яшәү шартларында үсәргә җайлашу гаҗәпләндерә. Ботаника

2) *хим.* Бер үк матдәнең төрле формада кристаллаша алу үзлеге. *Полиморфизм үзлеге кургаштан башка күп кенә химик элементларда да күзәтелә.* Физика

ПОЛИМО́РФИК *с.* Полиморфизм сыйфатларына ия булган; төрле формада очрый торган. *Диагнозы – холангит, киң таралган гепатит һәм геноцитларның полиморфик дистрофиясе.* Безнең гәҗит

ПОЛИНЕВРИТ *и. гр.-лат. мед.* Күп төрле нервларның төрле сәбәпләр аркасында төрле дәрәҗәдә ялкынсынуыннан гыйбарәт авыру. *В витамины җитмәү сәбәпле, тире авырулары, полиневрит башланырга мөмкин.* Сәламәт яшәү нигезләре. *Нәтиҗә: --- нерв системасын ныгыта, радикулит, полиневрит, буын чирләрен савыктырырга сәләтле.* Кызыл таң

ПОЛИНЕ́ЗИЯЛЕ *и.* Тын океан утрауларында (Полинезия һәм кайбер Меланезия утрауларында) яшәүче төп халыкның бер вәкиле. *Полинезиялеләрнең татуировканы нинди кораллар ярдәмендә төшерүләрен күрсәткән борынгы рәсемнәр сакланып калган. Кайбер полинезиялеләр татуировканы берничә кат ясатканнар һәм бөтен тәннәрен рәсем белән каплатканнар.* Кызыклар дөньясында

ПОЛИНОМ *и. гр.-лат. мат.* Берничә бербуынның алгебраик суммасыннан яки аермасыннан гыйбарәт алгебраик аңлатма (тәгъбир); күпбуын. *Өрлек яки яссы рамнарның ныклыгын һәм катылыгын исәпләгәндә, гадәттә өченче дәрәҗәле төп элемент кулланыла, чөнки бөгелеш өченче дәрәҗәле полином белән тасвирлана ---.* Фән һәм тел

ПОЛИОМИЕЛИТ *и. гр. мед.* Арка миендәге соры матдәнең ялкынсынуыннан гыйбарәт, параличка китерә торган йогышлы авыру; балалар параличы. *Полиомиелит яшь балаларда була. Полиомиелит белән авырганда, еш кына паралич суга. Тап-таза аяклар, куллар җансыз әйбер кебек салынып кала.* Н.Фәттах. *Бала чакта полиомиелит авыруы аның аякларын корыткан.* М.Юныс. *Туберкулёз, кызамык, кызылча, полиомиелит, --- паротит кебек авыруларны кичерүнең ахыры бик аянычлы тәмамланырга мөмкин.* Мәгърифәт

ПОЛИП *и. гр.* 1) *биол.* Бер очы белән кузгалмый торган әйбергә береккән, икенче очында авызы булган эчәккуышлы хайван. *Тропик диңгезләрдә яшәүче мәрҗән полипларының кайбер төрләре сай урыннарда --- мәрҗән рифлары барлыкка китерәләр.* Биология. *Рифларны мәрҗән полипларының --- төзегәннәр.* Физик география. *Колония булып яши торган полипларда, гадәттә, скелет хасил була.* Зоология

2) *мед.* Лайлалы яры өстенә үсә торган зарарсыз шеш. *Доктор кызның борынында ниндидер полип барлыгын һәм аны кистерергә кирәклеген әйтте.* С.Сабиров. *«Аналыгыңда – миома, өстәвенә, полип та бар, операция кирәк», – диюләрен гел колак янынан гына уздыра килдем.* Сөембикә. *Эчке әгъзаларга полип үссә, тирегә «асылмалы» миңнәр, сөял чыга.* Ватаным Татарстан

ПОЛИПЛО́ИД *и. гр. биол.* Күзәнәкләрендә хромосомаларның берничә җыелмасы булган организмнар. *Полиплоид үсемлекләрнең күзәнәкләре эрерәк, шуның аркасында үсемлек тә зуррак була.* Кызыклы физиология

ПОЛИПЛОИДИ́Я *и. гр. биол.* Күзәнәктә хромосомаларның берничә җыелмасы булу күренеше. *Полиплоидия үсемлекләрдә аеруча киң таралган. Хайваннарда полиплоидия очраклары шактый сирәк.* Кызыклы физиология

ПОЛИРО́ВКА *и. рус* 1) Берәр нәрсәне шомартып ялтырату эше. *Иң яхшысы – тешләргә чистарту үткәрү, ягъни тешләрне махсус порошок, су һәм һава ярдәмендә чистарту: тешләргә полировка ясау.* Шәһри Казан. *Атнага бер мәртәбә барлык машиналарга да полировка ясыйлар ---.* Татарстан яшьләре

2) Берәр нәрсәнең шомартып ялтыратылган өслеге. *Өстәлнең полировкасында тырналган эз бар*

ПОЛИРО́ВКАЛАУ *ф.* Берәр нәрсәнең өслеген махсус шомартып ялтырату. *Завод зур түгел, тәүлегенә 200 кв. метрга якын полировкалаган плитәләр чыгара ---.* Татарстан яшьләре

ПОЛИРО́ВКАЛЫ *с.* Шомартып яки лаклап ялтыратылган. *Полировкалы тәбәнәк өстәл янында Тамара кайнаша икән.* М.Мәһдиев. *– Алай икән, – диде Шәвәлиев, бармакларын полировкалы өстәл өстендә биетеп.* Ф.Садриев. *Стенаның бер ягы иңеннән иңенә ике метр чамасы биеклектәге полировкалы такталар белән тышланган.* М.Кәбиров

ПО́ЛИС I *и. гр.* Борынгы Греция һәм Рим өчен типик булган иҗтимагый-икътисади тормышны оештыру формасы

ПО́ЛИС II *и. ит.* Милекне, гомерне страховкалау турында рәсми документ. *Медицина ярдәме күрсәтелсен өчен, алардан бары тик полис кына таләп ителә.* Р.Закирова. *Мәҗбүри медицина страховкасы полисы булганнарга быел 7633 сум күләмендә бушлай медицина ярдәме күрсәтү каралган.* Татарстан яшьләре

ПОЛИСЕМА́НТИК *с. лингв.* Күпмәгънәле, берничә мәгънәсе булган. *Бу аваз үзгәрешләре --- сүзләрнең күпмәгънәле, полисемантик булуларыннан котылуга чара эзләү ихтыяҗыннан килеп чыккан.* Г.Алпаров. *Полисемантик сүздә барлык мәгънәләр дә үзара бәйләнештә яши һәм шактый катлаулы саналган сүзнең семантик структурасын барлыкка китерәләр.* Г.Галиуллина

ПОЛИСЕМИ́Я *и. гр. лингв.* Бер сүзнең берничә мәгънәгә ия булуы, күпмәгънәле булуы; күпмәгънәлелек. *--- хәзерге татар телендә бер үк сүзнең үзара бәйле булган берничә лексик мәгънә белдерә алу мөмкинлеге полисемия, күпмәгънәлелек --- дигән исемнәр белән атала.* И.Бәширова. *Бу очракта сүзнең мәгънәсе киңәю (полисемия) нәтиҗәсендә яңа сүзләр ясала: күз (глаз), күз (петля); йомгак (клубок), йомгак (итог) ---.* Татар теле морфологиясе

ПОЛИСМЕН *и. ингл.* Англиядә һәм АКШта полиция хезмәткәре. *Бүлмәгә башта ике полисмен, аннары Гренвиль үзе атылып керде.* А.Тимергалин. *Каяндыр полисмен калкып чыкты,*

кесәсеннән блокнот чыгарып язарга кереште. М.Юныс

ПОЛИСПАСТ *и. гр. тех.* Йөкне бер урыннан икенче урынга күчерү яки күтәрү өчен, берничә күчмә һәм кузгалмас блоклар тоташтырылып ясалган механизм. *Нәкъ менә авыш яссылык теориясе белән «җепле машиналар» (блоклар, полиспастлар һ.б.) теориясен бәйләп чишкән мәсьәләләрендә Стевин иң мөһим нәтиҗәләр ала да инде*. Фән һәм тел

ПОЛИСТИРОЛ *и. гр.-лат. махс.* **1.** Сәнәгатьтә һәм көнкүрештә изолятор сыйфатында файдаланыла торган үтәкүренмәле, яктыга бирешмәүчән пластик масса, синтетик полимер. *Узган елда поликарбонат, бензинның күп октанлы компонентларын, пластмасса һәм резина-техника эшләнмәләре җитештерү үзләштерелде, полиэтилен заводы, полистиролның өченче линиясе файдаланууга тапшырылды*. Ватаным Татарстан. *Завод ачу тантанасы истәлеге итеп, Минтимер Шәймиевкә полистиролдан ясалган бер сувенир бүләк иттеләр*. Татарстан яшьләре

2. *с. мәгъ.* Шундый пластик массадан ясалган. *Полистирол торба. Полистирол савыт-саба*

ПОЛИТ- *рус* Кушма сүзләрдә «политик», «сәяси» мәгънәсендәге беренче кисәк (мәс., *политграмота*, *политуку*, *политмәктәп* һ.б.)

ПОЛИТӘҢГӘМӘ *и. тар. к.* **политинформация**. *«Боевой листок» чыгарганда яки политәңгәмә әзерләгәндә, Рушадны ул күп нәрсәгә өйрәтте*. М.Мәһдиев. *Политәңгәмә сәгатендә замполитлар, вак-төяк бәрелешләрне исәпләмәгәндә, совет-герман фронтында вакытлыча тынлык, дип аңлаталар*. Р.Низамиев

ПОЛИТБҮЛЕК *и.* Политик бүлек; СССРда җитәкчелек һәм сәяси эшне көчәйтү өчен, Коммунистлар партиясе Үзәк комитеты тарафыннан армия һәм флотта төзелгән сәяси орган. *Комсомол секретаре сөйләп туктагач, политбүлек начальнигы урынынан торды*. М.Юныс. *Тагы өч көннән Көнчыгыш фронтының 5 нче армиясе политбүлегенә башкорт гаскәриләренең Кызыл Армия белән бер сафка басып --- көрәшергә әзер булуы хакында хәбәр җиткерелә*. Р.Мөхәммәдиев. *– Сез әле һаман коммунист түгел? – диде аны үзенә чакыртып алган политбүлек начальнигы Бема*. А.Хәлим

ПОЛИТБЮРО *и. рус* Берәр сәяси партиянең Үзәк комитеты тарафыннан сайланып куелган сәяси бюро // СССРда: Коммунистлар партиясенең җитәкче органы. *Син әллә политбюро членнары көн-төн Кремльдә генә ята дип беләсеңме?* М.Мәһдиев. *Политбюроның Татар-башкорт республикасының язмышына нокта куйган утырышы --- хакында --- М.Солтангалиев юлда --- ишетә*. Р.Мөхәммәдиев. *Мәскәүдә, политбюрода, ЦКда авыллларның, зиратларның су астында калуын телиләр дип уйлыйсыңмы әллә син?* З.Хәким

ПОЛИТДӘРЕС *и. тар.* Политик дәрес; политуку. *Сталинның Ватан сугышы полководецлары мәҗлесендә әйткән тостын өйрәнәбез. «Тигезләр арасында беренче булган бөек рус халкы хөрмәтенә тост тәкъдим итәм». Политдәреснең темасы – шушы җөмлә*. М.Юныс. *Политдәрестә, миңа мөрәҗәгать итеп, эскадрилья офицерлары, энциклопедиягә караган шикелле, үзләренең әдәби белемнәрен тикшерәләр*. Р.Мөхәммәдиев

ПОЛИТЕИЗМ *и. гр. филос.* Күбилаһлыкны икърар итә торган дин; күбилаһлык. *Бу – политеизм түгел, чөнки политеизм дөньядагы һәр нәрсәне аллага тиңләштерә, әлеге фаразыбыз исә «алла – һәрнәрсәдә» дип кенә расслый, ягъни ул һәрнәрсәдә алланың чагылышын гына күрә*. Фән һәм тел. *Гадәттә монотеизм политеизмга (күбаллалык) каршы куела*. Казан утлары

ПОЛИТЕИСТ *и. гр.* Политеизм тарафдары; күп илаһка ышанган кеше

ПОЛИТЕ́ЙСТИК *с.* Политеизмга нигезләнгән, шуның белән бәйле. *Политеистик ышанулар белән бәйле мифологик традицияләрнең әкренләп бетеп баруы. Политеистик тәгълиматны яклау*

ПОЛИТЕХНИЗА́ЦИЯ *и. рус к.* **политехникалаштыру**. *Узегез беләсез: политехнизация чоры, техника дәвере хәзер. Мәктәпләргә хезмәт дәресләре кертелде, машиналар өйрәтелә*. А.Тимергалин. *Коридорга, директорның өстәл тартмасыннан табып, физкультура-спорт, политехнизация турында матур-матур плакатлар ябыштырып куйдылар*. Г.Мөхәммәтшин

ПОЛИТЕХНИЗМ *и. гр.-рус* Укучыларны теоретик яктан да, практик яктан да җитештерүнең төп тармаклары белән таныштыруны күздә тоткан уку-укыту системасы. *Укучыларда эшче һөнәре, производствода эшләүнең гомуми алымнарын үзләштерү һәм һөнәр сайлау өчен кирәкле политехник күнекмәләр тәрбияләү политехнизм принцибын гамәлгә ашыруда мөһим шарт булып тора*. Идел

ПОЛИТЕ́ХНИК I *с.* 1) Политехнизмга нигезләнгән. *Сезнең заводта политехник белем бирү өчен шартлар бик уңай*. Э.Касыймов

2) Техниканың төрле өлкәләрен өйрәнү һәм куллану белән бәйле. *«Иң яхшы актриса» дип – Түбән Кама нефтехимик көллиятендә укучы студент кыз Алинә Степанова, «Иң яхшы актёр» дип Зәй политехник көллияте студенты Николай Пукаев билгеләнде*. Татарстан яшьләре

ПОЛИТЕ́ХНИК II *и. рус* Политехник (I) институтта, политехникумда укучы студент яки шул уку йортын тәмамлаган инженер

ПОЛИТЕ́ХНИКУМ *и. рус* Техниканың төрле тармагы буенча урта белем бирә торган уку йорты. *Мәктәпне 1927 елны тәмамлагач, Казан индустриаль политехникумының күнчеләр бүлегенә укырга керә*. Фән һәм тел. *Җинаять җаваплылыгына тартылыр алдыннан гына, имтиханнарны уңышлы биреп, Әлмәт политехникумының алтынчы курсына күчерелә*. Ватаным Татарстан

ПОЛИТЗАНЯ́ТИЕ *и. рус тар.* Политик занятие; политуку. *Бәлки, безгә ячейкалар төзү кирәктер? Ике-өч палатага бер ячейка. Үз даирәсе, үз политзанятиеләре, э?* Ш.Рәкыйпов. *Помполит политзанятиегә әзерләнеп утыра иде*. М.Юныс. *Беркөн политзанятиегә*

кереп утырган идем, Гыйльманов бишлегә җавап бирде. Р.Кәрами

ПОЛИТИДАРӘ *и. тар.* Политик идарә (СССРда: армиядә, флотта һәм кайбер ведомстволарда сәяси эш һәм җитәкчелекне көчәйтү өчен, Коммунистлар партиясе Үзәк Комитеты тарафыннан оештырылган сәяси орган). *Ул – «Советлар Союзының Бөек Ватан сугышы турында» дигән китап. Моны демобилизацияләнгән һәр кешегә Флотның политидарәсе биреп җибәрә иде*. М.Мәһдиев

ПОЛИ́ТИК I *с.* 1) Сәясәт (*1 мәгъ.*) белән бәйле, теге яки бу сәясәтне тормышка ашыруга мөнәсәбәтле. *Шәмсетдинов укытучыларның политик белемнәрен дә тикшергән.* М.Мәһдиев. *Башкарган эшнең сыйфаты, чит илдә йөргәндә таләп ителгән политик уяулык, тәртип саклау, --- авариясез йөзү – экипажның --- әнә шундый эшләре өчен без капитан белән икәү җавап бирәбез*. М.Юныс

2) Сәяси яктан көчле, аңлы. *«Яшь гомер»[нең] политик иң үткер булган 2 нче пәрдәсенә шундый дөрес бәя Г.Камалның ул чордагы дөньяга карашын билгеләргә дә мөмкинлек бирә.* М.Гали

3) Дәүләтнең хокукый системасына караган. *Эшчеләрнең һәм крестьяннарның патша Россиясендә бернинди дә политик хокуклары булмады.* М.Җәлил. *Тайвань политик системасында нинди үзенчәлекләр күрергә мөмкин?* В.Юныс. *Патриархаль татар дөньясының богауларыннан ычкынган шәхеснең рухи ихтыяҗларына яшәп килүче политик строй үзенең богавын сала.* Фән һәм тел

4) Бик нечкәләп, оста итеп уйланылган (үз-үзен тотыш, эш итү һ.б.ш. тур.). *Политик тактылык*

5) Революцион, гамәлдәге хакимияткә каршы юнәлдерелгән эшчәнлек белән бәйле. *1905 елгы Канлы якшәмбене билгеләп үтү уңае белән Петроградта, Мәскәүдә, Бакуда сугышка һәм патшага каршы политик стачкалар үткәрелгән.* Ш.Рәкыйпов. *Бирегә Үзәк Россиядән политик тоткыннар җибәрелгән, монда алдынгы фикер ияләре, --- революцион демократлар сөргендә яшәгәннәр*. Россия тарихы. *Казаннан барган вәкил П.П.Лебедевның сөйләвенчә, ул чорда --- Воркута лагеренда политик тоткыннар ике тапкыр бунт күтәрергә омтылып караганнар*. Казан утлары

ПОЛИ́ТИК II *и. рус* 1) Сәяси мәсьәләләр белән шөгыльләнүче кеше, сәясәт эшлеклесе. *Хөкүмәт, ягъни политиклар җитәкчелегендә яңа комиссия төзергә туры килде.* А.Тимергалин. *Политиклар аны [халыкара космик эксперименты] тарихи дип, шагыйрьләр Мәңгелек белән Җаваплылык каршында очрашу дип атадылар.* Галәмгә юл. *Кандидатлар арасында Татарстан Язучылар берлеге рәисе Ринат Мөхәммәдиев, политик Флёра Зыятдинова һ.б. бар*. Сөембикә

2) *күч.* Эшне алдан уйлап, бик оста һәм нәтиҗәле оештыра белүче, башкалар арасында үзен иркен, ышанычлы тотучы кеше. *Салават бит ул – хәйләкәр, тәҗрибәле кеше. --- Ерактан уйлап эш итә ул. Политик.* А.Шамов. *--- Дәүләтьяров – политик кеше, ул хәтле шыр ялангач итеп сөйләүне яратмый иде.* И.Гази

ПОЛИ́ТИКА *и. гр.* 1) Дәүләт хакимиятенең, берәр партия яки иҗтимагый төркемнең үз мәнфәгатьләрен тормышка ашыруга юнәлдерелгән эшчәнлеге; сәясәт. *Укытучы сыйфатында җибәрелгән бу кешеләр --- руслаштыру политикасын үткәрергә тиешле булалар*. Р.Мөхәммәдиев. *Эчке политика. Тышкы политика*

2) Халыкара, иҗтимагый яки дәүләт тормышына бәйле мәсьәләләр һәм вакыйгалар. *Син, энекәем, минем сүзне политикага борма, яме?* Ш.Рәкыйпов. *Хезмәт ветераны Габдрахман абзый, балта остасы, безнең белән күрешкәч, беренче сүзе итеп: «Яшәсен Горбачёв! Яшәсен перестройка! Яшәсен яңа политика!» – диде*. Г.Ахунов. *Кешенең, диде ул, политика, белем, сәнгать белән шөгыльләнү өчен, өч төрле шарты булырга тиеш*. М.Мәһдиев

3) *сөйл.* Берәр нәрсәгә ирешү өчен файдаланылган шәхси алым, юнәлеш; эш итү чарасы. *[Ул] бер эшкә дә катнашмау политикасы алып бара.* Т.Гыйззәт. *– Аны университет җибәрмәячәк, – диде Камил. – Китәм дип, берәр политика белән генә тыпырчынадыр.* Х.Сарьян. *Кайсыдыр ки, безнең яңа килгән иптәшләр мәктәптә электән килгән өлкәннәргә, чыныккан кадрларга карата бик үк дөрес булмаган политика алып баралар*. М.Мәһдиев

4) *сөйл.* Берәр нәрсә эшләргә астыртын ният, хәйлә, мәкер. *Мин хәзер --- сезнең политикагызны белдем инде: безне кулга төшермәкче булгансыз!* Ф.Әмирхан. *Безнең өйдә син урнаштырган кагыйдә белән яшибез, тик син моны әтинеке итеп күрсәтергә тырышасың. Ә ныклап уйласаң, бу – бик нечкә политика ---*. З.Кадыйрова

5) *тар. сөйл.* Революцион эшчәнлек, революцион хәрәкәттә катнашу. *[Галиулла:] Таш капчык моннан җиде генә чакрымда, --- утырып караганың юкмы? [Якуб:] Бер туры килде. Политика өчен, Казанда.* И.Гази

ПОЛИТИКАН *и. рус кимс.* 1) *сөйл.* Принципсыз сәясәтче, интригачы; җәмгыятьтәге төп бурычларны вакытыннан кайтарып калдыручы, төрле сәяси темаларга сөйләнүдән узмаучы политик. *Чыннан да, шундый зур, бөек шәхесме ул, әллә Галиҗәнап Очрак өскә төртеп чыгарган оста, шома политиканмы?* Р.Зәйдулла. *Хәзер политик мотивка корылган авыр җинаятьләр бар, ә политиканнар уголовщина белән элемтәгә керүдән чирканмыйлар ---*. Р.Мирхәйдәров

2) Үз максатына ирешү өчен бернидән дә тартынмый торган, мәкерле, хәйләкәр, принципсыз кеше. *Үзләрен тәнкыйтьче дип атап йөргән, әмма «тәнкыйтьләре» теге яки бу язучының үзен һәм аның иҗатын матбугатта сүгүдән, хурлаудан, аңа кара мөһер басудан узмаган шәрә политиканнар: --- «Тукай безнең шагыйрь түгел, --- ул – либераль буржуа шагыйре», --- дип, төрле урыннарда сафсата сатарга керешкәннәр.* А.Шамов

ПОЛИТИКАНЛЫК *и. кимс.* Җәмгыятьтәге мөһим бурычларны вак-тәяк мәсьәләләргә кайтарып калдырып, үз файдасына гына эш йөртү. *Политиканлык белән шөгыльләнүчеләр*

иҗтимагый фикер тудырырга тырышалар. Ватаным Татарстан. *Мондый очракларда Туган ил, Татарстан, татар образлары политиканлык, сәяси кычкыру, буш мичкә дөбердәтүгә әйләнә.* Шәһри Казан

ПОЛИТИ́К ЭКОНО́МИЯ *и. к.* **политэкономия**. *Хәзер барыннан да биграк хокук фәнен һәм политик экономияне өйрәнергә кирәк.* Г.Әпсәләмов

ПОЛИТИНФОРМА́ТОР *и. рус* СССРда: ил эчендәге яки халыкара көндәлек сәяси вакыйгалар турында мәгълүмат бирүче. *Көне-төне мәктәптә генә түгел, әле лектор да, политинформатор да, стена газетасы редакторы да булырга туры килде.* Ф.Садриев. *Мин үзем, мәсәлән, гомерем буе комсомол, партия мәгарифе системасында даими пропагандист һәм политинформатор идем.* Татарстан яшьләре

ПОЛИТИНФОРМА́ЦИЯ *и. гр.-лат.* СССРда: ил эчендәге яки халыкара көндәлек сәяси вакыйгалар турында нинди дә булса коллектив алдында мәгълүмат бирү. *Болай да йөрәге селкенеп кенә торган Хисмәт бу хәлләргә түзмәде, бер көнне политинформация вакытында үзен фронтка җибәрүләрен сорап тавыш чыгарды.* М.Мәһдиев. *Ленин авырый, хәле яхшыдан түгел; ул инде Политбюро утырышларында катнашмый, --- кирәкле политинформацияләрне белми.* Р.Мөхәммәдиев. *Иртәнге яктагы тәрбия сәгатьләрендә байтак вакытны политинформация ала иде.* А.Тимергалин

ПОЛИТКАТОРЖАН *и. гр.-рус тар.* 1917 елга кадәр Россиядә: сәяси, революцион эшчәнлек өчен каторгага сөрелгән кеше. *Алгы сафта – данлы гвардия, Байкалларны кичкән партизан, Якты гомерен шушы таңга биргән Көмеш чәчле политкаторжан.* Ш.Маннур

ПОЛИТКОМИССАР *и. гр.-рус тар.* Совет Армиясенең зур хәрби берләшмәләрендә (мәс. дивизиядә) идеология өчен җаваплы җитәкче, командир. *Гордов элеккеге көрәштәше Ян Фрицевич Фабрициусны очратты. Политкомиссар, тәртә мыекларын кабартып, текәлеп карады да: – Ба... Гордов! – диде.* Ш.Рәкыйпов. *Менә сезгә яңа политкомиссар. Таныш булыгыз. Фамилиясе – Огоньков.* Д.Галимов

ПОЛИТО́ЛОГ *и. рус* Халыкара һәм эчке сәясәт мәсьәләләрен өйрәнүче галим, сәясәт белгече. *Алжирда туып үскән Әхмәт Зитуни – политолог, француз әдәбиятында күренекле урын тота.* М.Юныс. *«Медведевның акчасы нигездә биналар арендалау һәм штаб хезмәткәрләренә түләү өчен киткән», – ди политолог Андрей Кынев.* Татарстан яшьләре. *Аны Ангела Меркельнең партиядәше – Христиан-демократлар берлеге әгъзасы, политолог Гертруда Хелер язган.* Мәдәни җомга

ПОЛИТОЛО́ГИЯ *и. гр.* Иҗтимагый фәннәрдә җәмгыятьнең сәяси тормышын өйрәнә торган тармак. *Адәм баласының җирдә калган эзен, аның кичерешләрен --- һәм, нинаять, үзен тарих, этнография, --- политология, --- юриспруденция – тагын әллә ничә дистә катлаулы фәннәр өйрәнә.* М.Юныс. *Ә тест дигәннәре политология буенча белемеңне һәм эрудицияңне тикшерә.* Сабантуй. *Американың политология профессоры Дэниел Трейсман кайсы ил кешеләренең күбрәк куркып яшәвен тикшергән.* Ватаным Татарстан

ПОЛИТПРОСВЕТ *и. гр.-рус тар.* СССРда 20–30 нчы елларда: сәяси агарту эшләре белән шөгыльләнә торган оешмаларның, учреждениеләрнең кыскартылган атамасы. *Әхмәт Фәйзи – Арчада политпросвет инспекторы. Ул, авылдан авылга чабып, халыкны, яшьләрне культурага өнди.* Ф.Хөсни. *Политпросвет, ни өчендер, бенефиска куелачак пьесаның репертуарга кермәгән пьесалардан булуын шарт итеп куйды.* Сәхнә. *Оренбургтагы татар, политпросвет курсларында белем алганда, Муса Җәлил белән таныша.* Ватаным Татарстан

ПОЛИТРАБО́ТНИК *и. гр.-рус тар.* Совет Армиясендә һәм флотында сәяси тәрбия эшләрен алып баручы кеше. *Мине матбугат бүлегеннән икенче бүлеккә – политработниклар бүлегенә күчерделәр.* М.Җәлил. *Запастагы полковник Фәндәс Сафиуллинга, озак еллар политработник булып хезмәт иткән дип, сүз бирделәр.* З.Зәкиев. *Немецлар бөтен политработникларны, аларча әйтсәк, комиссарларны, рәхимсез рәвештә юк итеп баралар.* Казан утлары

ПОЛИТРУК *и. гр.-рус тар.* 1919–1942 елларда Совет Армиясендә сәяси эш белән җитәкчелек иткән, үз подразделениесенең сәяси хәзерлеге һәм сугышка сәләтлелеге өчен командир белән бер үк дәрәҗәдә җавап биргән хәрби җитәкче. *Әмма, әсирлеккә төшкәнче, Җәлил бит фронтта сугышкан әле, политрук булып, гаскәрләрне һөҗүмгә-атакаларга күтәргән.* Г.Ахунов. *Тиздән ул армиягә китте. Фин кампаниесенә эләкте. Разведчик, политрук, комиссар.* Х.Сарьян. *Беренче көнне үк яшьләр алдында чыгыш ясаган өлкән политрук Тихвин Волхов ягында канлы сугышлар барганын, Олонец ягыннан дошманның --- Ленинградка көнчыгыштан бәреп керергә җыенганын сөйләде.* М.Мәһдиев

ПОЛИТСОСТАВ *и. гр.-рус тар.* Совет Армиясе һәм флотында хәрби-сәяси эш алып баручыларның һәммәсе. *Армиядә мине рациональрәк файдаланып булмыймыни, политсостав яки начсостав итеп?* М.Җәлил. *Мин --- артиллериядә рядовой булып хезмәт иттем, кыска вакытлы урта политсостав курсларын үттем.* Р.Мостафин

ПОЛИТТОТКЫН *и.* Хакимияткә каршы алып барылган эшчәнлек өчен хөкем ителгән кеше, сәяси тоткын. *Лагерьда кемнәрне генә күрмәде дә кемнәр белән генә очрашмады Сәлимҗан! Политтоткыннар, кеше үтерүчеләр, караклар, тагын әллә кемнәр белән...* З.Хәким

ПОЛИТТҮГӘРӘК *и.* Тарих, фәлсәфә, политэкономия һәм агымдагы сәясәтне өйрәнү түгәрәге. *Уткән ел Солтан укытучылар арасында политтүгәрәк алып барды.* Г.Кутуй. *Мәскәүдә укыган чагында Нәҗип Гыйсметдин улы ВКП(б)ның Мәскәү комитеты исеменнән заводларда агарту эше алып бара, татар фракциясе бюросы сәркатибе, политтүгәрәк җитәкчесе була.* Фән һәм тел

ПОЛИТУКУ *и.* СССРда политтүгәрәкләргә йөреп, марксизм-ленинизмны,

фәлсәфәне, политэкономияне, агымдагы сәясәтне һәм Коммунистлар партиясе тарихын өйрәнү; сәяси уку; шуның бер дәресе. *Аның гомере кич утырып контроль эш язулар, төннәр буе сессиягә хәзерләнүләр, халыкара темага клубта лекцияләр, политуку дәресләре белән узды.* М.Мәһдиев. *Дүшәмбе – техник белемне күтәрү көне. Сишәмбе – политуку.* М.Юныс. *Гомер буе политукуларны да алып бардым.* Ф.Садриев

ПОЛИТУ́РА *и. лат.* Агачны шомартып ялтырату өчен кулланыла торган спиртлы лак яки буяу. *Политура каралган булса, фланель тукыманы аш серкәсе белән үсемлек мае катнашмасына салып, ялтыравыгы чыкканчы чистартырга.* Ватаным Татарстан

ПОЛИТЭКОНО́МИЯ *и. гр.-нем.* Кешелек җәмгыяте үсешенең төрле баскычларында ижтимагый җитештерү һәм матди байлыкларны бүлүне, җәмгыятьтә икътисади мөнәсәбәтләр үсеше законнарын өйрәнә торган фән. *Студентларга политэкономия фәненнән шәп кенә грамота бирәме, әллә бирергә тырышамы, дип сөйлиләр...* Э.Касыймов. *Клубка чыкмады, Маркс, Энгельс, Ленин томнарына, философия, политэкономия, тел гыйлеме чытырманлыкларына чумды [Ирек].* Ф.Садриев. *Мин хәзер пропагандист. Мәктәптә политэкономия түгәрәген алып барам.* Г.Мөхәммәтшин

ПОЛИТЭМИГРАНТ *и. гр.-фр.* Сәяси сәбәпләр аркасында эмиграциягә китәргә мәҗбүр булган кеше. *Романовлар династиясе буенча иң зур белгеч, аларның --- генеалогиясен төзүче политэмигрант кенәз Пётр Долгоруков Тихон Стрешневны император Пётр Беренченең чын атасы --- дип исәпләгән.* Мәдәни җомга

ПОЛИФО́НИК *с. муз.* Күп тавышлы. *Таләпчән остаз Хәбирнең шактый кыю һәм кызыклы эшләнгән полифоник комбинацияләренә, пассажларына булган сокланuын яшер[ми].* Ш.Хөсәенов. *Күп тавышлы, ягъни полифоник планда язылган әсәрләр өчен бу аеруча әһәмиятле.* Р.Башкуров

ПОЛИФОНИ́Я *и. гр. муз.* Вокаль яки инструменталь әсәрдә берничә тавыш бергә кушылу; күптавышлылык. *Алар [абыйлар] үзләренең шушы кечкенә оркестрларында кайбер татар көйләрен полифония нигезендә, ягъни төрле тавышта уйнаячаклар икән.* Ә.Еники. *Өстәвенә дирижёрга музыка өлкәсендәге барлык фәннәрне – гармония, полифония, сольфеджио, аранжировка, хәтта музыка сәнгате тарихын да яхшы белергә кирәк.* Р.Низамиев

ПОЛИФОНИ́ЯЛЕ *с. к.* **полифоник**

ПОЛИФОНЛЫЛЫК *и. махс.* Күп тавышлылык. *Шагыйрьнең замандашлары арасында, аның иҗатындагы бу гражданлык сыйфатларына, шигъри күп тавышлылыгына, полифонлылыгына эчке бөтенлек һәм эзлеклелек хас түгел, диючеләр дә булды.* Г.Халит

ПОЛИХРОМ *с. сәнг.* Күп төсле. *Полихром сурәт. Полихром стиль*

ПОЛИХРО́МИЯ *и. гр. сәнг.* Күп төслелек. *Полихромия – ул төрле төсләрне чыратлаштырып буяу, аның үзенең закончалыклары бар.* Казан утлары

ПОЛИЦАЙ *и. нем. тар.* Бөек Ватан сугышы вакытында дошман тарафыннан вакытлыча оккупацияләнгән районнарда җирле халыктан полициядә хезмәт иткән кеше. *Киресенчә, сугыш азатлык ягына борылгач, теге «яхшы украинлылар», «яхшы белоруслар» фашистларга сатылган полицайлар булып чыкты.* М.Юныс. --- *Мирсәет шунда янә аны бүлдереп сорап куйды: – Полицай килеп үзеңне кулга алыр дип тә курыкмыйсыңмы?* Р.Мөхәммәдиев. *Ләкин немецлар кибәнгә аяклары белән типкәләп китеп тә бардылар. Бераз эчкә җан керергә өлгермәде, русча сүзләр ишетәм – «үзебезнекеләр» – полицайлар.* Х.Камалов

ПОЛИЦАЙЛЫК *и.* Полицай булу, полицай хезмәте. *Ул да булмады, аның аркасына китереп суктылар. Борылып караса, Кызыл гаскәриләрдән полицайлыкка чыккан майлы бит иде.* Ф.Яхин. *Немецлар тикмәгә генә аларны полицайлыкка һәм шымчылыкка иң кулай элементлар дип санамыйлар шул.* Казан утлары

ПОЛИЦЕЙМЕ́ЙСТЕР *и. нем. тар. к.* **полицмейстер**. *Шәһәрнең атаманнары, полицеймейстерлары һәм шуларга охшашлылары да килеп төшеп, --- Недоносковны әллә нинди статья буенча [кулга алмакчы] иделәр.* Г.Тукай. *Губернатор, полицеймейстер, прокурор, жандарм управлениесе начальнигы, шәһәр коменданты һәм башка түрәләр дә, килеп, фабрика ишек алдына кереп киттеләр.* М.Гали

ПОЛИЦЕ́ЙСКИЙ *и. рус* Полициядә хезмәт итүче кеше. *Ике полицейский торган посттан үтеп, Юдин алдан ук хәстәрен күргән кунак йортына җитәрәк, Мильда серле итеп --- пышылдады.* Ш.Рәкыйпов. *Мәрьям киштәдән киштәгә үрелде, ләкин бөтен шкафны саңаклы кешеләр, --- мәкерле һәм хәйләкәр җинаятьчеләр, аларны аулаучы акыллы милиционерлар һәм полицейскийлар тутырган иде.* М.Маликова. *Кешене тоткарлаганда, полицейский үзе белән таныштырырга --- тиеш.* Ирек мәйданы

ПОЛИ́ЦИЯ *и. нем.* 1) Патша Россиясендә сәяси төзелешне һәм ижтимагый тәртипне саклый торган махсус орган, шулай ук революцион хәрәкәткә каршы көрәшә торган җәза гаскәре. --- *Белоруссия полициясе башлыгы Исэльгорт һич тоттырмас Жанны элэктерүдә булышучыларга җитмеш биш мең немец маркасы бирергә вәгъдә итте.* Ш.Рәкыйпов. *Бусы – Аксак Йосыф йорты. Ул патша заманында полициядә хезмәт иткән.* М.Юныс

2) Хәзер Россиядә һәм кайбер илләрдә ижтимагый тәртип һәм тынычлык саклау вазифасын башкара торган административ орган. *Полиция кулына элэккән Самара кешеләренә карата җинаять эше кузгатылган.* Ватаным Татарстан. *23 апрель кичендә транспорт полициясе хезмәткәрләре җинаятьчене Белгородта тимер юл станциясендә тоткарлады.* Ирек мәйданы

3) *сөйл.* Шундый орган урнашкан бина. *Европада Төндә йөргән «шикле» кешеләрне Полициягә тотып озаталар.* Һ.Такташ. *Полиция тирәсендә икеөч меңләп халык җыелган.* Урал

4) *сөйл.* Полицейскийлардан торган кораллы отряд. *Мине фашистларның кыр полициясе тотып, Познань төрмәсенә озатты.* М.Хөсәен. *Беләсең килсә,*

лабораторияңне һәрьяктан полиция уратып алган. А.Тимергалин

5) Салым җыю һәм салым түләү белән бәйле җинаятьләрне тикшерү һәм законда каралганча түләүләрне күзәтү органы

ПОЛИЦМЕ́ЙСТЕР *и. нем.* Патша Россиясенең һәм кайбер илләрнең зур шәһәрләрендә полиция башлыгы. *Тангатаров әллә кайчан ук шул әдәбият кичәсе ясау турында полицмейстердан рөхсәт ала алмый талашып йөри иде.* Г.Ибраһимов. *Көндезге икеләрдә губернатор кабинетына төсләре китеп агарынган полицмейстер ахылдап керде: «Солдатлар, – диде ул, тыны кысылып, – бистә эшчеләре белән кушылдылар».* К.Нәҗми

ПОЛИЭДР *и. гр. мат.* Бөтен яклары да яссы күппочмаклыклардан торган геометрик җисем; күпкырлык. *Полиэдр мәйданын табу*

ПОЛИЭТИЛЕН *и. гр. хим.* **1.** Сәнәгать һәм көнкүреш кирәк-яраклары ясауда кулланыла торган үтәкүренмәле һәм нык синтетик полимер. *Ул безнең шәһәргә полиэтилен ише төрле нефтехимия продуктлары китерә, ә мин, булган танышлар аша юлын табып, аңарга металл юнәтәм.* Р.Мөхәммәдиев. *Ул арада полиэтиленга әйбәтләп төрелгән бер түтәрәм итне китереп тә җиткерде.* Шатлыклы кайгы. *Каркаслы теплицаның полиэтиленын ел саен алыштырабыз.* Ирек мәйданы

2. *с. мәгъ.* Шул продукттан ясалган. *[Хатын] биге ябылмыйча, авызыннан кәгазь төргәкләр, полиэтилен капчыклар күренеп торган сумкасын тезенә куйды да --- күзләрен чәчкәләргә текәде.* М.Маликова. *Миңзаһит полиэтилен капчыкка беркадәр алма, туңдырылган чия, крыжовник салды, --- кухняга керде.* Ф.Садриев. *Рушания --- әле полиэтилен пакеттан да чыкмаган зәңгәр норка тунын кулына алды ---.* З.Кадыйрова

ПОЛК *и. слав.* 1) Дивизия яки бригада составына керә торган мөстәкыйль гаскәри берәмлек. *Полк командиры шундый манёвр ясады: дошман атлылары кинәт ярым алка эчендә калдылар.* А.Шамов. *Гражданнар сугышы көннәрендә бирегә акларның кавалерия полкы урнаша – бар да шуның эзләре.* Р.Низамиев

2) *күч.* Төркем, бергә нидер эшләүче, бергә йөрүче кешеләр. *– Да, бу станциядә безнең полкка тагын берәү өстәлергә тиеш бит әле, – диде Рушад.* М.Мәһдиев

ПО́ЛКА *и. рус сөйл.* Тимер юл вагонында ятып бару, йоклау өчен югарыда урнаштырылган урын; сәндерә, киштә. *Билетлар белән эшен бетереп, Мәскәү – Барнаул поездына кереп урнашуга, Асаф, бернигә карамыйча, өске полкага менеп сузылып ятты.* М.Мәһдиев. *--- озын гәүдәле ир йокларга теләгән Гаяз яткан полка астындагы урыныннан торган саен ачу белән, я башы, я җилкәсе белән тиеп, аны берничә мәртәбә урыны-ние белән селкетеп алды.* Р.Гаязетдин

ПОЛКО́ВНИК *и. рус* 1) Күп кенә илләрнең армиясендә һәм көч ведомстволарында подполковниктан югары, генерал-майордан түбән офицер дәрәҗәсе, чины һәм шул дәрәҗәгә ия булган, шул чиндагы кеше. *Шулар арасында Гречкинның кызу кулы тоткан таяк астына 15 нче армиянең Хәрби Совет әгъзасы полковник Брежнев та элэгә.* З.Зәйнуллин. *Хәрби дәрәҗәләре дә чәчләрне үрә торгызырлык: полковниктан алып генералга кадәр.* Татарстан яшьләре

2) Россиянең хокук саклау органнарында җитәкчелек итү составына караган бер махсус звание. *Полковник үз бүлмәсенә кереп бикләнгәч, урамда үзеннән-үзе митинг башланып китте.* Ш.Рәкыйпов. *Су килүгә, отделение командиры полковникка әзерлек турында белдерде.* Р.Кәрами. *Артём --- читтән торып институт бетергән, хәзер званиесе – милиция полковнигы ---.* Р.Хәбибуллина

ПОЛКОВО́ДЕЦ *и. рус* Зур гаскәри берләшмәләр, флот һ.б.ш. белән командалык итүче хәрби җитәкче; гаскәр башлыгы, сәргаскәр. *Сталинның Ватан сугышы полководецлары мәҗлесендә әйткән тостын өйрәнәбез.* М.Юныс. *Бу моңны --- Ватан сугышы Герое – полководецка җитмеш, сиксән тулган көндә, республиканың авыл хуҗалыгы алдынгыларын, көзге эшләр тәмамлангач, опера һәм балет театрына җыйганда уйнарга кирәк.* М.Мәһдиев. *– Булдыргансыз, иптәш Куйбышев, – дип куя шул урында Генераль секретарь. – Синең чын полководец булуың миңа күптән мәгълүм.* Р.Мөхәммәдиев

ПОЛКОВО́ДЕЦЛЫК *и.* Полководец булу. *Шулар арасында 112 (16) нче гвардия Башкорт дивизиясе --- барлыгы генерал Шәйморатовның полководецлык талантын раслаган өстәмә дәлилләрнең берсе булып тора.* Кызыл таң

ПО́ЛКТАШ *и.* Кем белән дә булса бер полкта хезмәт иткән кеше. *Полкташлары аны үлгәнгә санаганнар.* Ш.Рәкыйпов. *Сугышчан дустым, полкташым белән биш айга бер очрашып, аны сыйламыйча җибәрергә мине кем дип беләсең?* М.Юныс. *Күп нәрсәләрне ачыклау өчен, бәхеткә, Фәритнең сугыштан язган хатлары һәм полкташ дуслары исән калган...* Р.Низамиев

ПОЛЛИНОЗ *и. лат. мед.* Яз көнендә үсемлек серкәсе тәэсирендә томау төшү, күздән яшь агу, күз кычыту кебек симптомнары булган аллергик авыру; печән бизгәге. *Әгәр баланың әтисе яки әнисе поллиноз белән авырса, сабыйда бу чир булу куркынычы 30 процентны тәшкил итә.* Ватаным Татарстан. *Поллиноздан тилмерүчеләр аллергологта күзәтелергә тиеш.* Юлдаш. *Поллиноз куркынычы янаган кешеләргә үсемлекләр тирәсенә бик якын килмәскә киңәш ителә.* Ирек мәйданы

ПОЛЛЮ́ЦИЯ *и. лат. мед.* Яшүсмерләрнең һәм ирләрнең ихтыярсыздан, гадәттә төш күрү вакытында, җенси орлыклары бүленеп чыгу күренеше; төшләнү

ПО́ЛО *и. ингл. спорт* Атка атланган килеш, агач тупны кәшәкәләр белән бәреп, каршы команда капкасына кертергә тырышудан гыйбарәт спорт уены. *Поло ярышлары*

ПОЛОВОЙ *и. рус тар.* Трактирда, кечерәк кунакханәләрдә хезмәтче. *Анда әледән-әле кыска алъяпкычлы җитез половойлар йөгереп уза.* А.Расих. *Ул чагында половойга, иренмәсәң, коридорга*

чыгып кычкырасың. Җ.Вәлиди. *Залга килеп керүгә үк, аларны половой каршы алды.* Р.Батулла

ПОЛОЖЕ́НИЕ *и. рус* 1) Билгеле бер мәсьәлә буенча кагыйдәләр, кануннар җыелмасы; нигезләмә. *Положение буенча аларның үз оешмалары булырга тиеш.* Ватаным Татарстан. *Әлеге четерекле эш белән шөгыльләнүче миграция һәм милиция вәкилләре, закон проектын тикшергән вакытта ук, бу положениегә каршы чыгыш ясадылар.* Кәеф ничек?

2) Берәр канунда, чыгышта, мәкаләдә һ.б.ш. хезмәтләрдәге төп фикер, тезис. *Бу кагыйдә гаилә турындагы законның иң принципиаль положениеләренең берсенә – гаилә тормышының барлык өлкәләрендә дә ир белән хатынның тулысынча тигез хокуклы булуына нигезләнгән.* Тигез гомер итегез! *Диалектик материализм положениеләре*

3) Дәүләт органы, оешма, учреждение кебекләрнең хокукый статусын, эшчәнлек тәртибен һ.б.ш.ларны билгели торган норматив акт

ПОЛОНЕЗ *и. фр.* 1) Польшада барлыкка килгән, өч такттан торган тантаналы бал биюе һәм шул биюнең музыкасы. *Генерал Гремин сараенда бара торган бал кичәсендә аристократлар арасында таралган полонез яңгырый.* Җ.Фәйзи. *Укучылар хореография укытучысында мастер-класслар ала һәм балның төп элементлары булып саналган бию формаларын: вальс, полонез, падеграс һәм полькага өйрәнә.* Мәдәни җомга. *Полонез, бию төре буларак, балларда биелүчән, тантаналы йөреп бию, дигәнне аңлата.* Кызыл таң

2) Шул бию тактына язылган музыкаль әсәр. *Огинскийның полонезын --- егет онытылып уйнарга кереште. Сугыш елларында бөтен экипажыбыз белән гашыйк идек без ул полонезга.* Б.Камалов. *--- Кешенең катлаулы кичерешләрен сөйли торган бу полонезны Назыйм үзе дә сөя иде.* М.Кәримов

ПОЛО́НИЙ *и. лат. хим.* Үзенең үзлекләре белән теллурга һәм висмутка охшаш радиоактив химик элемент

ПОЛОСА *и. рус* 1) *геогр.* Климаты, үсемлекләре, хайваннар дөньясы һ.б.ш. белән күрше районнардан, зоналардан, пояслардан аерылып торган район, пояс, зона. *Кара туфраклы булмаган полосадагы комсу туфракларда сибү нормасын бер гектарга 150–200 кубометр итеп билгелиләр ---.* Яшелчәчелек. *Хәзергә урта полоса өчен районлаштырылган 34 сортлы груша бар.* Ирек мәйданы

2) Урман, кыр, җир һ.б.ш.ның билгеле бер озынлыкка сузылган кисәге; буй. *Марат бу бүлмәгә ияләнә алмады. Басуларны, урман полосаларын, авылның көзге яңгырда үтә алмаслык, тәгәрмәч эзләре изгән урамнарын сагынды.* М.Мәһдиев. *Кыз чакрым ераклыктагы каенлык полосасына борылды.* Н.Гыйматдинова. *Басу кырыйларына кыр ышыклау полосалары – агачлар утырталар.* Җил каян килә?

3) Нәрсә белән булса да аерылып торган участок, территория. *Тәре йөртүчеләрнең биләмәләре яр буйлап тар полоса булып сузыла һәм бик зур территорияне алып тора.* Урта гасырлар тарихы. *Самолёт түбәнәюен дәвам итә, төшү полосасы өстеннән очып үтә ---.* Галәмгә юл. *Маршрут автобуслары полосасыннан барган өчен, алга таба 1,5 мең сум штраф түләргә туры киләчәк.* Татарстан яшьләре

4) *махс.* Газета-журналдагы яки китаптагы басма текстның бер бите. *Басу машинасына иң элек беренче белән дүртенче битләрнең полосалары бирелә.* Г.Минский. *Спорт җәмгыятьләре союзына шалтыратып, көрәшчеләрнең бүгенге ярышы нәтиҗәләрен бел. Дүртенче полосада аңа егерме юл урын калдырылган.* М.Маликова

ПОЛОТНО *и. рус* **1.** 1) *иск.* Һәр буй җебе аркау җепләр белән үрелгән бизәксез киндер яки киже-мамык тукыма; шулай үрелеп тукылган ясалма ефәк тукыма. *Кызыл полотнога: «Партиябез һәм хөкүмәтебезгә биргән вәгъдәне срогыннан элек үтик!» – дигән лозунг язылган.* М.Хәсәнов

2) Гадәттә киндергә ясалган сәнгать әсәре, картина. *Хезмәт кешесен, әйтик, шул ук нефтьчене, буровой манарасы янына бастырып, полотнога төшерү әллә ни авыр нәрсә түгел.* Г.Ахунов. *--- Конгрессның темасы бөек испан рәссамы Гойяның Прадо музеендагы «Нәтиҗәсез дуэль» дип аталган полотносын искә төшерде.* М.Юныс. *Яхшы полотно ераклтанрак карасаң ачык күренә, диләр бит.* М.Мәһдиев

3) Тимер юл, шоссе һ.б.ш. юлларның таш, чуерташ, ком һ.б.ш. нәрсәләр өелгән нигезе, дамбасы. *Тимер юл полотносын сакларга куелган [кешеләрегез] качып бетте.* Ш.Маннур. *Аларның бер өлеше, дошманга каршылык күрсәтә-күрсәтә, тимер юл полотносы буйлап Иделгә таба чигенә ---.* Язмышлар яңарганда

4) *күч.* Тормышны, нинди дә булса вакыйганы төрле яклап сурәтли торган күләмле әдәби әсәр. *Безнең тормышның героикасын киң полотнода сурәтләү*

2. *с. мәгъ. иск.* Бизәксез киндер яки киже-мамык тукымадан тегелгән. *[Хәсәнша] җәй көне соры полотно казаки белән шул ук тигез түбәле каракүл бүрекне кия.* Ш.Камал

ПОЛОТНОЛЫ *с.* 1) Полотносы булган

2) *күч.* Зур күләмле, тормышны, теге яки бу вакыйганы төрле яклап сурәтләгән (сәнгать әсәре тур.). *Әйтик, заманында Римский-Корсаковның «Хованщина», Мусоргскийның «Борис Годунов» кебек киң полотнолы әсәрләрен редакцияләп, өлешчә үзгәртеп чыгулары мәгълүм.* Р.Низамиев. *Милли сәнгатьнең чикләрен тагын да киңәйтү, опера театрын тергезеп җибәрү өчен исә, зур, киң полотнолы әсәрләр, әдәби материал кирәк.* Сөембикә

ПОЛПРЕД *и. рус* 1) *тар.* СССРда тулы вәкаләтле вәкил, илче рангындагы дипломат

2) Нинди дә булса дәүләт оешмасыннан җибәрелгән аерым вәкаләтләргә ия илче. *1922 нче елның 5 декабрендә ип. Тарпищев полпред Солтангалиев белән Татарстан Республикасына, Казанга килделәр.* Р.Мөхәммәдиев

3) Россия Федерациясе Президенты администрациясенә караган, федераль округларда Президентның тулы вәкаләтле вәкиле. *Менә шундый шартларда бу атнада Россия Федерациясендә*

Президент Путин «Бердәм Русия»нең реаль җитәкчесе булып китте, полпред Исхаков башка эшкә күчерелде ---. Гасырлар авазы. *Полпред советның әлеге утырыш барышында кабул ителәчәк карарлар җирле үзидарәне реформалаштыруга нигез булачак дип ышана.* Ватаным Татарстан

ПОЛПРЕДЛЫК *и.* 1) Полпред эше, тулы вәкаләтле вәкил вазифасы. *Уз вакытында Гаринга шактый мәшәкать тудырган ул кәгазьләргә бәйләнерлек түгел, бары тик полпредлык удостовериесе белән мандат кына кулдан ясалган иде*. А.Толстой

2) Башка бер дәүләттә яки административ өлкәдә полпред җитәкчелегендә дәүләт вәкиллеге һәм шул вәкиллек урнашкан бина. *Чит илдә полпредлык ачу*

ПОЛТЕРГЕЙСТ *и. нем. оккульт.* Җансыз предметларның үзеннән-үзе хәрәкәткә килү күренеше; тавышлы, шау-шулы җен. *Аннары Фәхрәзи үзе дә сизмәстән фантастика, полтергейст, сихер һәм башка хикмәтләр, параллель дөньялар турында китаплар укырга һәвәсләнеп киткән иде.* З.Мурсиев. *Мондый шартларда мәгълүмат чаралары --- үз укучыларын очсызлы сенсацияләр, имеш-мимешләр, гайбәтләр, НЛОлар, полтергейстлар, сихерче-күрәзәчеләр белән мавыктырып тораллар*. Ватаным Татарстан

ПОЛТЫРАК *с. диал.* Тузгак. *Полтырак чәч*

ПОЛТЫРАНУ *ф. диал.* Тузгу, таралу. *Аның полтыранган аксыл чәче башын бик зур итеп күрсәтә.* Н.Фәттах

ПОЛУБОТИ́НКА *и. рус* Куныч-сыз, сай ботинка. *[Әсгать] яхшы трикодан, полуботинкалардан.* Ә.Фәйзи. *Асафның өстендә җиңен сызганып кигән ак күлмәк, соры габардин чалбар, аякларында чибәр генә арзанлы полуботинкалар иде*. М.Мәһдиев

ПОЛУВАЛ *и. рус махс.* Үгез яки сыер тиресеннән эшләнгән, олтан итеп файдаланыла торган тупас күн

ПОЛУ́НДРА *ы. ингл.* Моряклар, порт йөкчеләре сөйләмендә куркыныч килгәнне яки ашыгычлыкны белдерә торган сүз. *– Полундра! – дип кычкырдылар кыя итәгеннән. – Ит пеште, чәй кайнады*. М.Юныс. *Казармалар артыннан үткәндә, кемдер, нәкъ кинодагы матрос шикелле кычкыра-кычкыра, аңа таба чаба иде: – Полундра, хыянәт! Хыянәт!..* Х.Камалов. *Корычбай каешыннан пистолетын тартып ала да: – Полундра! – дип кычкырып җибәрә.* М.Галиев

ПОЛУ́ТОРКА *и. рус сөйл.* 1932 елда чыгарыла башлаган, тонна ярымга кадәр авырлыктагы йөкне ташырга сәләтле ГАЗ-АА автомашинасы. *Ләкин бу вахта машинасы түгел, гади бер ачык «полуторка» иде.* М.Хәсәнов. *Элмәк астына бер полуторка килеп туктады. Бераздан полуторкага өч-дүрт офицер менеп басты.* М.Мәһдиев. *Кыска гына допростан соң Яббарны ниндидер келәткә биклəп куйдылар, ә икенче көнне Гомельгә баручы «полуторка»га утыртып, ике конвоир сагы астында Гомель шәһәренә озаттылар*. З.Хәким

ПОЛУ́ЧКА *и. рус сөйл.* Хезмәт хакы. *Хуҗа үзе берничә ел инде кызларында яши, монда тик получка көнендә акча алырга гына килә.* Х.Сарьян. *Получка кесәмә керү белән, күңел кыбырсый да башлады*. М.Юныс. *Күрше бүлмәдә яшәүче егет мин баткан сулы чокырга бер айлык получкасы белән чумган*. Татарстан яшьләре

ПОЛЫН *и. бор.* Әсирлек. *Шамилне полын алырга приказ килде падишадан ---.* Бәет. *Ул җәмәгатьләрдин --- бәгъзысы полын төшеп һәм авырып, сырхап кайткан.* Казан утлары

ПО́ЛЬКА I *и. чех* 1) Ике тактлы җитез бию һәм шул бию көе. *Полька, мазурка, тустепларга биегәннән соң, «Көзге хыяллар» вальсы башланганда, ут сүнде.* И.Туктар. *Ул авыр хәсрәтләр полька һәм мазуркага бии-бии вальс әйләнгән бу кешеләр өстенә дә капланыр микән соң, әллә инде, шинель киеп, ярмангa каршы китүче гади халык җилкәсенә генә төшәрме?* Р.Низамиев

2) Шул бию ритмындагы музыкаль әсәр. *Көй яратучыларны оркестр мәшһүр композитор И.Штрауснының данлыклы «Күк күкрәү һәм яшен» («Гром и молния») полькасы белән сөендерде*. Казан утлары. *Рахманинов полькасы*

ПО́ЛЬКА II *и. рус* Чигәләрдәге һәм баш артындагы чәчне бераз гына кыркып, алда һәм түбәдә мул калдырудан гыйбарәт чәч кисү моделе

ПО́ЛЮС *и. гр.* 1) Җир өслегендә Җир шарының әйләнү күчәрен тоташтырган ике ноктаның берсе; котып. *Җир шарында поляр полюслар ике: Төньяк полюс һәм Көньяк полюс.* Башлангыч география курсы. *Шунысы кызык: традиция буенча җирнең Көньяк полюсы Антарктида булса да, аны «Котыб Җәнүби», ягъни Көньяк Котып дип билгеләгәннәр.* Фән һәм тел

2) Шул күчәр тирәлеге. *Урыс галиме Отто Юльевич Шмидт Котыпны җиңгән, Чкалов, Төньяк полюс аша очып, АКШка барып җиткән.* М.Юныс. *Бозлыкларның иң зур өлеше Гренландия утравында, Антарктидада, Төньяк һәм Көньяк полюсларда тупланган ---.* Җил каян килә?

3) *физ.* Электр чылбыры яки даими магнитның капма-каршы очларыннан берсе. *Мускул очларына электр импульсларын ешрак биреп, полюсларны үзгәртеп торырга кирәк.* А.Тимергалин. *Әмма Разия, ничек кенә тырышмасын, магнит полюслары ни сәбәптән географик полюслардан авышрак булуын аңлый алмады.* З.Вәли. *Уңай полюс. Тискәре полюс*

4) Нәрсәнеңдер иң зур чиге, чик ноктасы. *Оймякон районында төньяк ярымшарның салкынлык полюсы урнашкан.* Физик география

5) *күч.* Бөтенләй туры килмәгән, охшамаган, каршылыклы фикер, караш һ.б. *Беренче карашка, капма-каршы ике полюс очрашкан кебек. Ләкин нәкъ менә шушы җирлектә магнит кыры – бербөрсен баетучы ижади дулкын барлыкка килә.* Р.Низамиев. *Шигырь язучы власть ияләре тарихта шактый. Мәшһүр Бабур, --- Сталин, Мао, безнең чорда Андропов, Лукьянов... Шушы ике полюсның бергә кушылуы хөкемдарның эш-гамәлләренә тагын да аяусызлык, дәһшәт өстәми микән?* Р.Зәйдулла. *Хәзерге заман кешесендә гүя шушы ике полюс үскәннән-үсә: аның индивидуальләшүе, шулай ук кайсыдыр рухи катламнарының стандартлашуы,*

хисләренең сүрелүе һәм саегуы күзәтелә. Тигез гомер итегез!

ПО́ЛЮСТАПКЫЧ *и. тех.* Даими ток чылбырындагы ток полюсларының уңаен һәм тискәресен билгели торган прибор

ПОЛЯК *и. рус* Польшаның төп халкын тәшкил иткән, көнбатыш славян группасының ләх төркеме телендә сөйләшүче милләт атамасы һәм шул милләтнең бер вәкиле. *Гордов поляк коммунисты белән уртак телне тиз тапты.* Ш.Рәкыйпов. «*Тарас Бульба*»ны узган идек без рус әдәбиятыннан. *Хәтерлисеңме, анда Тарас картның улы Андрий бер поляк кызына гашыйк була.* М.Мәһдиев. *Монда безнең белән янәшә бик күп суднолар тора, төрлесе төрле илләрдән. Поляклар, инглизләр, немецлар, шведлар...* М.Маликова

ПОЛЯ́КЧА *рәв.* 1) Поляк телендә. *Кутуй аз-маз полякча белә.* Г.Галиев. *Мин бу вакытка ярыйсы гына немецча һәм полякча сөйләшергә өйрәнгән идем – барысын да ишетеп, аңлап ятам.* Р.Мирхәйдәров. *Аның улы Ян татарча да, полякча да, инглизчә дә бертигез яхшы сөйләшә.* Ватаным Татарстан

2) Поляк халкына хас булганча. *Полякча киенү*

ПОЛЯР *с.* 1) Полюс (*1 мәгъ.*) тирәсенә урнашкан, полюс (*1 мәгъ.*) тирәсендәге. *Мәңгелек поляр бозлар арасында да тереклек бар.* Кызыклы физиология. *Поляр утраулар. Поляр зона*

2) Полюс тирәсендә эшләү белән бәйле. *Лаптевлар диңгезе --- урыс поляр тикшеренүчеләре икетуган Дмитрий һәм Харитон Лаптевлар хөрмәтенә шулай аталган.* Ирек мәйданы. *Поляр станция. Поляр экспедиция*

3) Гомумән полюс, котып белән бәйле. *Җирнең поляр һәм экваториаль радиуслары арасындагы аерма глобуста миллиметрның унынчы өлешләренә әверелә.* Физик география

4) Полюс тирәсендә яши яки үсә торган. *Монда кит, тюлень, нерпа, морж, ак аю яши, навага, поляр тәрәч балыгы очрый.* Ирек мәйданы. *Поляр ябалак. Поляр төлке*

5) *физ.* Уңай һәм тискәре корылмаларга ия булган. *Поляр кушылмалар. Поляр бәйләнеш*

6) *күч.* Капма-каршы. *Үтә чыккан төче ялагай ролендә йөри, ә эчендә – үзен бик югары йөрткән кеше. Шушы ике поляр хис ничек шулай якын-янәшә йөри диген!* Ш.Галиев

ПОЛЯР БАЛКЫШ *и.* Котыпларда атмосфераның югары катлауларында (90–1000 км биеклектә) яктылык нурлары чәчелү күренеше. *Котып балкышын поляр балкыш дип тә атыйлар.* Җил каян килә?

ПОЛЯРИЗА́ТОР *и. рус тех.* Яктылыкны полярлаштыру приборы

ПОЛЯРИ́МЕТР *и. гр. физ.* Яктылыкның полярлашу дәрәҗәсен, полярлашу яссылыгының борылыш почмагын үлчи торган оптик прибор

ПОЛЯРИСКОП *и. гр. тех.* Яктылыкның өлешчә полярлашуын билгели торган прибор

ПОЛЯР КАЗ *и. зоол.* Үрдәксыманнар семьялыгыннан, поляр зонада яши торган кош; *русчасы:* **морянка**

ПОЛЯР КӨН *и.* Поляр түгәрәк артында алты айдан артык кояш батмый торган чор. *22 декабрьдә Көньяк ярымшарда – җәй, Көньяк поляр түгәрәктән Көньяк полюска кадәр поляр көн була.* Физик география. *Июнь – июльдә шәһәрдә – поляр көн, ә декабрь – гыйнварда поляр төн була.* Казан утлары

ПОЛЯРЛАШТЫРУ *ф. физ.* Полярлашу барлыкка китерү. *Электромагнитны полярлаштыру*

ПОЛЯРЛАШУ *ф. физ.* 1) Табигый яктылык дулкыннарының тышкы тәэсирләр нәтиҗәсендә электр һәм магнит кыры көчәнешлелеге үзгәрү. *Яктылык полярлашу*

2) Электродларда электр тогының көчен киметә торган төрле матдәләр утыру. *Гальваник элемент полярлашу*

3) *биол.* Күзәнәкнең эчке һәм тышкы тирәлеге арасында электр потенциаллары аермасы хасил булу

4) *күч.* Нәрсәләрнең дә булса бүленү, төрлеләнү, капма-каршы була баруы. *Хәзерге заман кешесенең психологиясе бик күп яктан элеккеге кешенеке кебек түгел. Шуңа күрә мәхәббәт тә күп яктан үзгәрде. Ул да полярлаша.* Тигез гомер итегез!

Полярлаша бару Торган саен күбрәк полярлашу

Полярлашып бетү Тулысынча полярлашу

ПОЛЯРЛЫК *и.* 1) *физ.* Капма-каршы полюслылык

2) *биол.* Организм, орган, тукыма яки күзәнәкнең капма-каршы якларында барлыкка килгән аермалыклар (мәс., орлыкта яфрак бөресе һәм тамырның формалашуы)

3) *күч.* Кемнәрнең яки нәрсәләрнең дә булса үзара бер-берсенә капмакаршылыгы, абсолют охшашсызлыгы. *Шул ук вакытта (кешеләр) иң яхшы туры килү бу, күрәсең, охшашлыкның һәм полярлыкның бергә кушылуыдыр: рухи кардәшлек, интереслар, идеаллар якынлыгы --- һәм нерв организациясенең капма-каршылыгы.* Тигез гомер итегез!

ПОЛЯ́РНИК *и. рус* Котыпчы. *Материк яр буйларында полярниклар бозлыклар арасында бөтенләй бозсыз, ә җәен карсыз, гадәти булмаган күлле участоклар күрәләр.* Материклар һәм океаннар географиясе

ПОЛЯР ТӨН *и.* Поляр түгәрәк артында алты айга якын кояш чыкмый торган вакыт. *Бу вакытта Көньяк поляр түгәрәктән көньякка таба поляр төн була.* Физик география

ПО́ЛЯР ТҮГӘРӘК *и.* Салкын пояснең чиге булып саналган һәм экватордан көньякта һәм төньякта 66°32'та яткан параллель. *Тропиклар һәм поляр түгәрәкләр сызыклары – Кояш нурлары яктырту вакыты төрлечә булган поясларның чикләре алар.* Физик география. *Гагарин әле кайдадыр Поляр түгәрәк аръягында самолётта оча, озакламый космик корабльгә утырып старт алачагы турында аның әле хәбәрендә дә юк, ә инде Сергей Павловичның конструкторлык бюросы кульманнарында «Восток» корабленең контурлары туып килә.* Галәмгә юл

ПОЛЯРЧЫ *и. к.* **котыпчы**

ПОЛЯ́ЧКА *и. рус* Поляк милләтендәге хатын-кыз. *Безнең ни катнашыбыз бар әле ул сатлык җанга? Син Андрий түгел, мин полячка түгел.* М.Мәһдиев

ПОМА́ДА *и. лат.* Иренне буяу яки йомшарту өчен кулланыла торган косметик май. *Әле генә янда күңелне кытыкларлык помада исе бөркеп торган принцесса бәхет турында сөйли иде.* М.Мәһдиев. *Юкса, аэропортка барып җиткәнче, ул мине помадага буяп бетермәс иде.* Ф.Яруллин. *– Барыгыз, бантиклар, тасмалар, кершәнсөрмәләр, помадалар алып чыгыгыз, хәзер Фәннурдан кыз ясыйбыз, – дидем.* Г.Гыйльманов

ПОМА́ДКА *и. рус* Йомшак конфет төре. *Без, аның учындагы сары һәм ал помадкаларны алып, урамга чыгып чабабыз...* Ж.Фәйзи. *Помадка өчен 3 йомырка агы, стаканның дүрттән өч өлеше вакланган әстерхан чикләвеге, шуның кадәр үк шикәр пудрасы кирәк.* Ю.Әхмәтҗанов. *Помадка йомырка агын күбекләнгәнче күпертеп һәм аны чикләвек, шикәр пудрасы белән туглап ясала.* Тәмле тамак

ПОМЕ́ЛО *и. тамил бот.* 1) Рутачалар семьялыгыннан ак чәчәк ата торган, түгәрәк ябалдашлы мәңгеяшел көньяк агачы

2) Шул агачның зур яшькелт сары шар формасындагы әчкелтем җимеше. *Иң беренче чиратта кәрзингә җиләк-җимеш: виноград, алма, груша, помело, әфлисун, грейпфрут һәм банан керде.* Шәһри Казан

ПОМЕРА́НЕЦ *и. нем. бот. к.* **нарынҗ**

ПОМЕ́СТЬЕ *и. рус тар.* Йорт-каралтылары белән бергә алпавыт җире; утар. *Поместье хуҗасы коляскада торып басты, аның бит алмаларына алсулык йөгерде, күзләрендә очкыннар кабынды.* Р.Вәлиев. *--- җитештерелгән продукцияне оста итеп, үзәкләштерелгән идарә һәм поместьелар системасын аралаштырып бүлү, --- уңай демографик шартлар булу Мәскәү дәүләтенең матди мөмкинлекләрен көчәйтә.* Чын мирас

ПОМЕ́ЩИК *и. рус тар.* Эре җир биләүче; алпавыт. *Элекке помещиклар строен кире кайтару өчен сугышучы ак бандитлар крестьяннарның җир турындагы сүзен ишетү белән дә котырып китәләр.* М.Җәлил. *Йортлар күп, кырларга сибелеп утырганнар. Ара-тирә элекке помещик имениеләре күренәләр.* Г.Гали. *Помещик, кулак хуҗалыклары элеккечә яши, ашлык бәясен колак ишетмәгән дәрәҗәгә күтәрәләр, хәтта фронт өчен дә икмәк бирергә теләмиләр.* Ватаным Татарстан

ПОМИДОР *и. ит.* 1) Паслёнчалар семьялыгыннан, орлыктан үрчи, җылылык ярата торган үлән яки ярымкуак үсемлек. *Түшәмгә хәтле үрмәләгән помидор сабаклары корый башлаган иде инде.* М.Маликова. *Бу коңгызларга каршы шулай ук помидор яфрагы төнәтмәсен файдалану да уңай нәтиҗә бирә.* Сөембикә

2) Шул үсемлекнең кызыл, сары, шәмәхә төстәге җимеше. *Өстәлдә кызарып пешкән озынча помидорлар, хуш ис таратып торган ләвәш, йөзем тәлгәшләре, сулугуни һәм балчыктан ясалган кружкалар.* М.Юныс. *Өстәлдәге помидорлар, кыярлар чумган тозлы суны савыты белән Ниязның чыраена каплыйсым килде ---.* Р.Хәбибуллина. *Безнең өстәлебездәге икенче икмәк булган бәрәңге дә, шулай ук борыч һәм помидор да, --- көнбагыш һәм кукуруз да һәм башка күп кенә азыклар өчен дә без Америка индеецларына бурычлы.* Эзләнүләр, уйланулар, табышлар

ПОМИ́НКА *и. рус* Православиедә үлгән кешене искә алу мәҗлесе. *Әле бит аның катафалкы, автобуслары, веноклары, поминкасы бар. Саклык кассасындагы ярты акчамны алдым – ирем өлешен, поминкасын да кешечә үткәрдем.* Г.Ахунов. *Мәрхүмгә поминка ясарга кирәк.* М.Юныс. *Ахырдан агай-энеләрнең җыйнаулашып аларга килмәве акылга сыймады. Поминкада катнашмыйча таралышалар микәнни?!* Н.Гыйматдинова

ПОМОР *и. рус* Ак һәм Баренц диңгезләре яр буйларында Урта гасырлардан бирле яшәүче, рус милләте составына кергән этник төркем вәкиле. *Борынгы заманнарда ышанычсыз агач көймә һәм каекларда рус кешеләре – поморлар сәяхәткә чыга торган булганнар.* Материклар һәм океаннар географиясе. *Россиянең иң төньягында – Ак диңгез ягындагы урыс авылында туып үскән поморлар, ягъни салкын диңгез ягы урыслары нәселеннән чыккан бу язучының ике романын --- укып чыккач, өр-яңадан Американы, дөресрәге, Россияне ачкандай буласың.* Ватаным Татарстан

ПО́МПА *и. фр. махс.* Газ яки сыеклык кудыра торган насос. *Республика балалар клиник хастаханәсендә шикәр авырулы балаларга инсулин помпалары бирелде.* Ватаным Татарстан. *Сәгатенә 150 чакрымга кадәр тизлектәге җил котырганда, кесә телефоннары --- эшләүдән туктый, скважиналардан эчәргә яраклы су куучы помпалар туктап кала ---.* Мәдәни җомга. *Хәзер үк палубага күтәрел, анда помпа бар, шуны сүтеп җый.* Шәһри Казан

ПОМПАДУР *и. фр. кит.* Ни теләсә шуны эшләргә яратучы дуамал җитәкче. *Россия империясенең помпадурлары һәм помпадуршалары [Февраль революциясеннән соң да] дәүләт белән идарә иткәннәр.* Р.Нәфигов

ПОМПАДУРЛЫК *и.* Помпадур кыланышы

ПО́НИ *и. инг.* Бөекбритания утрауларында ясалма юл белән китереп чыгарылган вак атлар токымы. *Кечкенә ат – пони – зоопаркта балалар күңелен ачуга хезмәт итә.* И.Нуруллин. *Аларга атларның холкы, аларны ничек тәрбияләргә, нәрсә ашатырга икәнен генә сөйләп калмыйча, понида йөрергә дә рөхсәт иткәннәр.* Сабантуй. *Понилар белән генә түгел, тагын әллә ниләр белән шаккаттырдылар әле Кәримовлар Кырлай төбәге халкын.* Татарстан яшьләре

ПОНОМАРЬ *и. гр.* Православие чиркәвендә иң түбән дәрәҗәдәге рухани. *Ишетмәгән пономарьга ике рәт чаң какмыйлар.* Мәкаль. *Чаңы да ишетелми, әллә чаң кагучы пономарь исерек?* Г.Әпсәләмов. *Менә бу бина кайчандыр чиркәү булган, анда поп, пономарь хезмәт иткән, куәтле тавыш белән чиркәү хоры җырлаган.* М.Мәһдиев

ПОНТОН *и. лат.* 1) Вакытлыча салынган күперне яки башка корылмаларны суда күтәреп тора торган яссы төпле көймә. *Елгада понтоннар йөри башлады.* Х.Госман. *Бу понтоннардан*

12–16 тонна йөк күтәрерлек өч паром җыярга мөмкин. Г.Сафиуллин

2) Шундый көймәләр өстенә вакытлыча салынган күпер. Су *уртасындагы понтон өстенә граната килеп төшә. Әгәр ул шартласа, без Днепрны тиз генә кичә алмыйбыз.* К.Нәҗми. *Немецлар Даугава аркылы тиз арада өч понтон күпер салып өлгертәләр, һәм аларның 2 нче пехота дивизиясе, югалтуларсыз диярлек, бу якка чыга.* Ш.Рәкыйпов. *Иртәгесен нәкъ әйтелгән вакытта, сәгать дүрттә, солдатлар Аргунь елгасы буена төнлә корылган понтон күперләрдән чыгу өчен тезелгәннәр иде инде.* Г.Ахунов

3) Баткан корабларны күтәрү өчен кулланыла торган мичкәсыман эче куыш корыч җайланма

ПОНТОНЧЫ *и.* Инженерлык гаскәрләрендә понтоннар төзүче, понтон күперләр салучы хәрби хезмәткәр. *Ул иртәнгә кадәр безнең корпус кичкән полосада --- сапёрлар һәм понтончылар эше белән җитәкчелек итте.* Г.Сафиуллин

ПО́НЧО *и. исп.* < *кечуа* 1) Үзәк һәм Көньяк Америка индеецлары киеп йөри торган, уртасына баш сыярлык тишек уелган дүртпочмаклы тукымадан гыйбарәт кыска плащ. *Беренче пончолар испан хакимлегенә кадәр, Чилидагы мапуче кабиләсендә барлыкка килгән дип санала.* Сөембикә

2) Шундый фасонда тегелгән яки бәйләнгән япма. *Пончо модадан чыкмый.* Сөембикә. *Әлеге чалбарлар кардиган, блузка, водолазка, пончолар белән төрле яшьтәге хатын-кызларга килешә.* Кәеф ничек?

ПОП *и. рус* Православие динендә: рухани; атакай. *Алтынлы-укалы ряса кигән поп борын аркылы сөйли.* М.Мәһдиев. *Ә балаларны, керәшеннәр побы монастырьга озатырга җыенгач, шундагы кешеләр бер ялгыз картка яшергәннәр.* Ф.Мансуров. *– Сез поп кебек, – дип җавап бирде аңа бер чая хатын. – Ул да бит халыкны, теге дөньяда рәхәт күрерсез, дип юата.* М.Маликова

ПОП- *англ.* Тезмә сүзләрдә «популяр», «массакүләм» мәгънәсендәге беренче компонент (мәс., *поп-группа, поп-музыка* һ.б.)

ПОП-ГРУ́ППА *и. англ.* Популяр музыка башкара торган музыкаль төркем

ПОПЕЧИ́ТЕЛЬ *и. рус* 1) Кемне дә булса карау, саклау, тәрбияләү, күзәтү өчен, опека оешмалары тарафыннан рәсми билгеләнгән кеше. *Моны балигъ булмаган хатын үзе, аның әти-әниләре, попечителе, --- яисә прокурор таләп итәргә хаклы.* Тигез гомер итегез! *Хәрби хезмәткә алынуны кичектерү хокукына түбәндәге категория гражданнар ия: балигълык яшенә җитмәгән бертуган энесе яки сеңлесенең опекуны яки попечителе булып торучылар ---.* Ирек мәйданы

2) *тар.* 1917 елга кадәр Россиядә: берәр ведомство (күбесенчә мәгариф ведомствосы) учреждениеләре белән җитәкчелек итүче яки берәр учреждениенең почётлы җитәкчесе итеп билгеләнгән кеше. *Мәгариф министры, әгәр студентлар арасында чуалыш була калса, йомшаклык күрсәтмәгез дип, попечительне кисәтеп куйган.* Р.Ишморат. *Казан университетындагы уку-укыту эшләрен тикшереп, күзәтеп тору өчен, Казан укыту округының попечителе итеп --- Румовский билгеләнә.* Ж.Тәрҗеманов. *Казан укыту округының яңа попечителе М.Н.Мусин-Пушкин --- кешеләр белән мөгамәләсендә тупас --- һәм каты бәгырьле була ---.* Эзләнүләр, уйланулар, табышлар

ПОПЕЧИ́ТЕЛЬЛЕК *и.* Попечитель вазифасы, попечитель эше. *Һәр очракта да эштә опека һәм попечительлек органнары яисә прокурор катнаша.* Тигез гомер итегез! *Лобачевский ректор булып --- Казан укыту округы һәм университет тиңдәшсез карагруһчы Магницкийның җиде елга сузылган --- интектергеч попечительлегеннән котылу белән үк сайлана.* Эзләнүләр, уйланулар, табышлар. *Чарада Татарстан Республикасы Дәүләт киңәшчесе, ТР Тарих һәм мәдәният һәйкәлләрен торгызу фондының попечительлек советы рәисе Минтимер Шәймиев катнашты.* Шәһри Казан

ПОПКОРН *и. англ.* Кукуруз орлыкларын җылылык ярдәмендә кабартып һәм шартлатып әзерләнгән ашамлык. *Кафеларда шашлык пешә, берничә җирдә татлы мамык, попкорн сатып утыралар ---.* Татарстан яшьләре. *Попкорнның сәүдә тарихы 1880 елдан исәпләнә.* Мәдәни җомга

ПОПЛА́РЧА *рәв.* Поп кебек, попка охшатып. *Попларча киенү*

ПОПЛИН *и. фр.* **1.** Аркылыга вак-вак сырлар төшереп эшләнгән ефәк, ярымъефәк яки киҗе-мамык тукыма. *Кызлар --- поплиннан тегелгән озын күлмәк [кияләр].* Г.Тәһиров

2. *с. мәгъ.* Шул тукымадан тегелгән. *Поплин костюм тектерү*

ПОПЛЫК *и.* Поп вазифасы, эше. *Ләкин уйлап карагыз: әйтик, райком секретареның әтисе поплык хезмәтен башкарса, ничек булыр иде сезнеңчә?* Н.Акмал. *«Минем Ходай биргән чын талантым – Иблискә каршы көрәшү, калган гомеремне шул эшкә багышлыйм: поплыкка китәм!» – дип, җыена ук башлаган, ди...* З.Мифтахов. *Улын, Зөләйха төрмәдә вакытта, поплыкка әзерләгәннәр, шул сәбәпле ул әнисенең рухыннан бик ерак тайпылган.* Татар әдәбияты

ПОП-МУ́ЗЫКА *и. англ.* Төрле стиль һәм жанрлардан торган, һәркемгә җиңел аңлаешлы популяр эстрада музыкасы. *Бүтән төрле поп-музыка әсәрләрендә була торган һәлакәт сиземе, усаллык, агрессивлык шаукымы юк монда: җиңел, тыныч моң.* Ә.Баян. *Күршеләр аркасында бөтен поп-музыканы яттан беләм хәзер.* З.Хәким. *Нишләптер, күрше малае нәкъ менә шундый яңгырлы көннәрдә магнитофоннан бар көченә рус поп-музыкасын кычкырта.* Х.Ширмән

ПОПСА *и. рус жарг.* Популяр эстрада әсәрләренең (җыр, инструменталь пьеса һ.б.ш.ларның) гомуми исеме. *Попсадан аермалы буларак, альтернатив музыканың бу төрләрендә уйланырга мәҗбүр итә торган мәгънә ята, попсада күбрәк мәхәббәт, әни, туган авыл темасы өстенлек итә бит.* Идел. *Татар яшьләренең музыкаль культурасы бүген тулысынча диярлек Көнбатыш попсасы чабуына тотынып бара, ахры.* Ватаным Татарстан.

Берәүләр үз бизнесын попсада тапкан икән, икенче берәүләрнең вазифасы әнә шул соңгыларын – «Әллүки»ләрне, «Зиләйлүк»ләрне, Яхин, Җиһанов, Мозаффаровларны күтәрүдә булырга тиештер. Татарстан яшьләре

ПОПУГАЙ *и. гар. сөйл.* 1) Тутый кош. *Попугай инде «исәнме», «сау бул» дигән сүзләрне --- әйтә ала.* Р.Мостафин. *Агачлык ягыннан маймылларның ызгышуы ишетелеп китте, тутый кош – попугайлар кычкыра, кемдер үксеп елаган кебек була.* М.Юныс. – *Җанлы почмак та кирәк, әткәй, – диде Сәрия. – Сап-сары попугайларны, ак күселәрне --- кайда күрер идек?* А.Тимергалин

2) *күч.* Үзенең фикере булмыйча, кеше сүзен, фикерен кабатлаучы кеше. *Бу дөньяда --- Тимербай исемле агач попугайлар [күп].* Г.Тукай. *Әфәндем, сезгә шовинизм дигән прививка ясалган. Шул сәбәп илә, үзегез дә аңламыйча, бер үк сүзне такылдыйсыз. Сез – гап-гади попугай*. Ә.Баян

ПОПУГАЙЛАНУ *ф. сөйл.* Үз фикере булмыйча, башка кеше фикерен, сүзен кабатлау; кемнән ни ишетсә, шуны кабатлау

Попугайланып тору Даими, әледән-әле попугайлану

ПОПУГАЙЛЫК *и. сөйл.* Фикерсезлек; кеше фикерен, сүзен кабатлау

ПОПУЛИЗМ *и. фр. сәяси* Сайлаучылар тавышын, халык фикерен үз мәнфәгатьләренә җайлаштырып, ташламалар ясау, нигезсез вәгъдәләр бирү, хәйләләү кебек сәяси тактика. *Әлбәттә, республикаларны губерналарга әйләндерергә, дип чыгыш ясаган Жириновскийларның, Прохоровларның сүзе рәсми түгел, алар популизм белән шөгыльләнә, дип әйтүчеләр дә бар*. Идел. *«Коррупция белән көрәш массакүләм репрессия ясарга чакыру кебек сәяси спекуляция, популизм кыры түгел, ә гомумхалык эше булырга тиеш», – ди Премьер-министр.* Шәһри Казан. *Политологлар фикеренчә, быелгы сайлау кампаниясе «популизм ярминкәсе»нә әйләнәчәк*. Татарстан яшьләре

ПОПУЛИСТ *и. рус* Популизм тарафдары. *Популист ул – халык өчен Сүздә дөрләп янучы. Ялкынлы чыгышлар ясап, Калын портфель алучы*. М.Саттаров. *Һәм бик күбесе нинди генә юллар белән булса да баеп калырга, депутат статусына омтылган кайбер популист демократлар кебек тарихтан ак таплар эзләргә, без алай яшәмәячәкбез, дип күкрәк кагарга кереште*. Ватаным Татарстан. *Ельцин Татарстанга чагыштырмача бәйсезлекне демократ булганы өчен түгел, популист буларак, бөтен ил байлыгын туздырганда, үзе дә сизмәстән бирелеп ташлады*. Татарстан яшьләре

ПОПУЛЯР *с.* **1.** 1) Һәркемгә җиңел аңлаешлы, гади һәм күпләргә якын булган. *Мәгълүм булганча, сексология буенча махсус монографияләрне дә, популяр басмаларны да нигездә ирләр яза.* Тигез гомер итегез! *[Элекке татар врачларының] берсе дә, шундый популяр әсәр язып, үзенең белемен халык белән уртаклашмаган.* И.Рәмиев

2) Киң җәмәгатьчелек арасында билгеле, танылган, дан казанган. *Белүебезчә, кайбер галимнәр, популяр булу максатында, артык тирәнгә кереп тормыйча, китап артыннан китап чыгару белән шөгыльләнә.* Казан утлары. *Эстраданың иң популяр җырчылары яшь башкаручылардан соң гына чыгыш ясады*. Ватаным Татарстан

3) Киң таралган, һәркемгә дә билгеле. *Стадиондагы динамиктан сугыш тәмамланган чагында бик популяр булган җыр яңгырый иде. М.Мәһдиев. Җыр – музыка сәнгатенең иң таралган, иң популяр жанры.* Ж.Фәйзи. *Үз чорында популяр булып та, артык тар карашларга хезмәт итүләре сәбәпле, вакыт сынавын үтә алмыйча калган сугыш турындагы дистәләгән башка әсәрләрдән әлеге роман шуның белән аерылып тора.* Р.Фәтхрахманов

2. *рәв. мәгъ.* Һәркемгә аңлаешлы рәвештә, гади итеп. *[Тукайның] икенче төрдәге иярүләренә татарның озын яки кыска көйләреннән берәрсе үлчәвенә салынып, гади телдә, популяр язылган лирик шигырьләре керә.* Г.Нигъмәти. *– И-ех! – дип, популяр рәвештә аңлатырга туры килде атасына.* Ж.Юныс

ПОПУЛЯРЛАШТЫРУ I *ф.* 1) Берәр фикерне, әсәрне һ.б.ш.ны халыкка аңлаешлы, гади телдә, артык катлауландырмыйча язып яки сөйләп бирү. *Шуңа күрә татарларның тарихи үткәнен популярлаштыру чиктән тыш әһәмиятле бурыч булып кала*. Чын мирас. *Гыйльми сессия йомгакларын популярлаштыра торган бер генә китап та нәшер ителмәде* ---. Эзләнүләр, уйланулар, табышлар

2) Теге яки бу фикерне, эшне, хезмәтне һ.б.ш.ны халык арасында киң тарату; пропагандалау. *Очерк жанрын үстерү, аны популярлаштыру, идея-художество сыйфатын күтәрү – совет әдәбияты алдында торган мөһим бурычларның берсе.* Г.Иделле. *Яңа үзәкнең төп бурычы – җитештерүчеләр арасында экологик чиста продуктларны популярлаштыру*. Шәһри Казан

Популярлаштыра бару Әкренләп популярлаштыру

Популярлаштыра башлау Популярлаштырырга тотыну. *Усман Әлмиев – опера сәнгатен генә түгел, татарларда эстрада җырын да популярлаштыра башлаган кеше*. Өмет

Популярлаштыра төшү Тагын да популярлаштыру

Популярлаштырып килү Күптәннән бирле, эзлекле рәвештә популярлаштыру

ПОПУЛЯРЛАШТЫРУ II *и.* Фикерне, эшне, хезмәтне һ.б.ш.ны халык арасында киң таныту, тарату, пропагандалау эше. *Милли ризыкларны халык арасында таныту, популярлаштыру өчен, аш йортлары ачу белән берәттән, ниндидер махсус акцияләр дә уйлап чыгарырга мөмкин булыр иде*. Шәһри Казан. *Күренекле журналист Рифат Фәттахов яшь җырчыларыбызны халык арасында популярлаштыру белән шөгыльләнә.* Татарстан яшьләре

ПОПУЛЯРЛАШТЫРУЧЫ *и.* Берәр хезмәтне, яңа фикерне, кемнең дә булса әсәрен һ.б.ш.ны киң җәмәгатьчелеккә җиткерүче, халык арасында таратучы кеше. *Лукреций – Эпикур тәгълиматын популярлаштыручы буларак билгеле.* Фән һәм тел. *Бөтен гомерен тулысынча фәнгә багышлап, тел белемен актив популярлаштыручы --- шәхес иде ул Илбарис Надиров.* Фәнни Татарстан

ПОПУЛЯРЛАШУ *ф.* Җәмәгатьчелек арасында киң таралу; популяр булып китү. *«Гөлшаһидә», «Җидегән чишмә» дигән җырлар, район исеме белән чыккан җырлар кебек, популярлашырга өлгерде*. Г.Ахунов. *Әмма бу серия укучылар арасында шактый ук популярлашып өлгерде.* М.Кәбиров. *Шул вакыттан бирле әлеге дингә пародия шактый илдә популярлаша.* Мәдәни җомга

Популярлаша бару Торган саен күбрәк популярлашу. *Мәгариф хезмәткәрләре профсоюзлар рәисе В.Малакаева үзенең чыгышында районда физкультура һәм спортның барлык буыннар арасында да популярлаша баруына сөенече белән уртаклашты*. Авыл офыклары

Популярлаша башлау Популярлашу билгеләре күренү

Популярлаша төшү Бераз, беркадәр популярлашу; тагын да популярлашу

Популярлашып бару *к.* **популярлаша башлау**. *Лофт рәвешендәге биналар хәзер Санкт-Петербургта популярлашып бара.* Фән һәм тел

Популярлашып китү Соңгы арада популярлашу. *Аннары соңгы вакытта бик популярлашып киткән «Кукарача» җыры яңгырады.* Р.Кәрами. *Һава торышына бәйле рәвештә халык арасында таралган, быел язда кыш әйбәт килде, дигән гыйбарә дә юкка гына популярлашып китмәде инде*. Шәһри Казан

ПОПУЛЯРЛЫК *и.* Халык арасында танылганлык; шөһрәткә, данга ия булу, яратып кабул ителү. *Дөрес, яңа әдипне күсәк тотып каршылаучылар да байтак булды, ләкин шунысы кызык: Рәй Олидрижга популярлык казануда алар булышлык кына иттеләр.* А.Тимергалин. *Чанышев --- Казан гарнизонында да социализм идеяләренең популярлык казана баруын искәртеп узды.* Р.Мөхәммәдиев. *«Һиҗрәт» пьесасы бик хуплап каршы алынды, һәм ул зур популярлык казанды.* Х.Сәлимҗанов

ПОПУЛЯ́ЦИЯ *и. фр. биол.* Ареалның билгеле бер өлешендә күп еллар яшәгән, бер биологик төркемгә караган һәм үзара ирекле кушыла торган организмнар берлеге. *Популяция дип, биологлар бер территориядә яшәүче һәм шундый ук башка төркем затларыннан өлешчә яки тулысынча аерымланган бер төрнең тере организмнары җыелмасын атыйлар*. Биология. *Әлеге канатлы аучыларның популяциясе дә бик тиз арта.* Мәдәни җомга. *Федераль хөкүмәт дөяләр популяциясен җайга салу өчен 19 миллион Австралия доллары бүлгән иде*. Ирек мәйданы

ПОПУРРИ *и. фр.* Бер жанрга караган яки аерым бер композиторның популяр әсәрләреннән төзелгән музыкаль әсәр. *Попурри тезгәндәй, бер көйдән икенчесенә, өченчесенә күчеп, төрле вариацияләр ясап, бик кызу уйнады ул...* Ә.Еники. *Брукның үзе теләгән, үзе уңышлы санаган спектакльләрдән попурри, вариацияләр, «Жизель», --- «Кармен» һәм «Этюдлар»дан үрнәкләр күрсәтте.* Р.Батулла. *Концертны иң шәп җырчылардан һәм иң шәп җырлардан торган попурри белән башлап җибәрделәр.* Кәеф ничек?

ПОРАК *и. диал.* 1) Тегермән стеналарына кунган вак он тузаны; онта. *Менә тышкы стеналарына порак оны кунган кечкенә генә тегермән өе.* Ш.Маннур

2) *тар*. Он тарттырган өчен, тегермәнчегә бирелә торган өлеш

ПО́РНО *җыйм. и. рус сөйл. к.* **порнография**. *Эш бетереп, иртәрәк өйгә кайткан идем дә, синең малай белән минеке видеодан, селәгәйләрен агызып, порно карап утыралар.* Ф.Дәүләтбаев. *Хатын-кыз колагы гына түгел, хәтта күпне күргән ир-ат та чирканырлык сүзләрне ишеткәч, безнең журналистлар эротика, порно тирәсендә вульгарлык ягыннан мәскәүләләрне уздыра икән, дип уйлап куйдым.* Тамаша

ПОРНОГРА́ФИК *с.* Җенси мөнәсәбәтләрне бик оятсыз, ачыктан-ачык, әдәпсез сурәтли торган. *Сүз уңаенда шуны да әйтергә кирәк: яшьләр җырында порнографик урыннар бар («Закир белән ник яттың», «Төнлә егет янында ятсаң...»), аларны бетерергә кирәк.* М.Җәлил. *Ә монда бик матур җыр һәм бию номерлары гына. Бернинди җиңел холыклы кызыйлар юк, порнографик, хәтта эротик күренешләр дә юк.* В.Юныс. *--- Татарстанда порнографик фильмнарны, үтерешкә-суешка корылган фильмнар, китаплар, газета-журналлар күрсәтүне, сатуны, шулай ук аракы һәм тәмәке рекламаларын тыярга вакыт*. Р.Миңнуллин

ПОРНОГРА́ФИЯ *и. гр.* Җенси темага багышланган әдәпсез, кирәгеннән артык оятсыз әдәби әсәр, фильм, рәсем һ.б.ш.лар. *Шәрыкта Көнбатыш илләрендә төшерелгән порнография фильмнарын күрсәтмиләр әле*. М.Юныс. *Кытайларда порнография һәм проституция бөтенләй юк дип әйтеп булмый, анысы, тик ул бик ерак яшерелгән, алар моны беркемгә дә күрсәтмәскә тырышалар*. В.Юныс. *Порнография, секс, эротика, наркотик кебек төшенчәләрнең исемен дә белмәгән бәхетле чак!* Р.Фәйзуллин

ПОРНОИНДУСТРИ́Я *и. гр.-лат.* Порнография индустриясе, порнография җитештерү, сату һ.б.ш. эше

ПОРНОФИЛЬМ *и. гр.-ингл.* Порнографик, порнография жанрында төшерелгән фильм. *--- Үзен ихтирам иткән япон кинога барып, француслар кебек сәгатьләр буе порнофильм карамый*. В.Юныс. *Балаларыгыз Интернеттан порнофильмнар карый дип, син генә әти-әниләренә әләкләдең.* Н.Гыйматдинова. *Видеосалоннарда халыкка «клубничка» дип аталган порнофильмнар күрсәтәләр*. Х.Ширмән

ПОРНУ́ХА *и. рус жарг. к.* **порнография**. *Элеккеге СССР, бүгенге көндә Рәсәй дип аталган илне җинаять һәм порнуха басып китте.* М.Юныс. *Рафил Зәйнуллин спектакльдә ике роль: һәрьяклап уңай герой Фәнилне һәм порнуха яратучы, шантрапа, эретеп ябыштыручы Илмир ролен башкарды.* Сәхнә. *Яшь буын боевик, порнуха карап үсә*. Татарстан яшьләре

ПОРОЛОН *и. гр.* **1.** Күзәнәкләрдән торган, җиңел, көпшәк, эластик полимер материал. *Завод шартларында калайга пардан саклый торган поролон да ябыштырыла*. Төзү материаллары. *Пружина, поролон, кыйммәтле матур тышлыкны Казандагы махсус кибетләрдән сатып ала*. Мәдәни җомга

2. *с. мәгъ.* Шундый материалдан ясалган. *Изил --- шкаф янына килде дә*

әллә каян, арттан, йомшак поролон сырма тартып чыгарды ---. А.Гыйләҗев. *Поролон күбек сыман сизәм үземне!* М.Маликова. *Савыт юа торган йомшак поролон губкалар шулай ук сәламәтлеккә куркыныч тудыра икән.* Ватаным Татарстан

ПОРОШОК *и. рус* **1.** 1) Каты матдәнең төеп, тартып, тузан хәленә китерелгән кисәкләре. *Ул көнне Галәвиев --- күн итекләрен бәрхет белән ялтырата, гимнастёрка төймәләрен теш порошогы белән чистарта.* М.Мәһдиев. *Кояшта уңганга охшашлы зәңгәрсу күзләр. Гайрәтле юу порошогы салган күбекле суда бик озак чайкаганнар диярсең – тоташ төссезлек.* М.Юныс. *Эремәнең тамчылап агарлык, ә порошокларның өлеп-өлеп торырлык булуына юл куярга ярамый.* Яшелчәчелек

2) Шундый формадагы дару. *Аннары ул, һичшиксез, берәр атна өндә матур итеп авырып ятачак, карават янындагы полировкалы тумбочка өсте шешәләр, порошоклар, рецептлар белән тулачак.* М.Мәһдиев. *Бездә төрле порошок-морошоклар, таблеткалар-маблеткалар белән дәвалау булмаячак.* Г.Мөхәммәтшин. *Табиблар күп кенә үсемлекләрдән төнәтмә, таблетка, порошок, мазьлар рәвешендә дарулар ясыйлар.* Урта гасырлар тарихы

2. *с. мәгъ.* Төелгән, онта хәлендәге. *Порошок дару*

ПОРОШОКЛАТА *рәв.* Порошок рәвешендә. *Алып кайтыйм мин сиңа шәмәхә буяу. Порошоклата сатыла ул.* Ф.Хөсни

ПОРОШО́КСЫМАН *с.* Төелгән, тартылган, тузан хәленә китерелгән, порошок кебек. *Майга ярты процент күләмендә порошоксыман бор кислотасы кушсаң яхшы була.* Тигез гомер итегез! *Бөртекле көпшәк материаллар – бетонга салына торган бөртекле яки онтасыман (порошоксыман) материаллар.* Төзү материаллары

ПОРТ *и. фр.* 1) Суднолар туктау өчен уңайлы, йөк төяү яки бушату, суднолар ремонтлау өчен махсус җиһазландырылган урын. *Зур диңгезнең кораблары Керә Казан портына.* Х.Вахит. *Портка элгә алмауны капитан боцманның алдан күрәзәлек итүенә ябып калдырды.* М.Юныс. *Диңгез портларындагы суднолары дулкынарның җимергеч көченнән саклау өчен, портларны тимер-бетон плитәләрдән ясалган дулкынкискечләр белән әйләндереп алалар.* Физик география

2) Диңгез яки зур елгалар буендагы суднолар тукталу, аларга йөк төяү яки бушату, ремонтлау өчен махсус җиһазланган урыны булган шәһәр. *Зур диңгез порты Корсаковка икенче көннең кичендә килеп төштеләр.* Р.Кәрами. *Казанны биш диңгез порты дип тикмәгә генә әйтмиләр.* Л.Харисова

3) *информ.* Компьютер, телефон һ.б.ш.ларда перифирик аппаратура белән тоташу җайланмасы

ПОРТАЛ *и. нем.* 1) Зур бинаның яки тоннельнең бизәкләп, матурлап ясалган керү урыны. *Тоннельнең керү порталы бетонланган инде.* А.Сәләхетдинов. *Сәхнә бизәүнең үзе бер олы шөгыль булуын яхшылап аңлатты. Кашагасындагы өндәү-бизәк сүзләреннән алып даими артбизәк булып торасы полотнога, ян-яктагы порталларга кадәр фикер дә, зәвык та соравын төшендерде.* Д.Гайнетдинова. *Ул энергия, әйтерсең, җилдә дулкынланган яшел әләмнәр, изге порталлардагы алтын-көмеш бизәкләр, күккә төбәлгән мәчет манараларын аша көчәеп, дошманга каршы ургыла...* Чын мирас

2) *тех.* Машинаның «П» хәрефе рәвешендә ясалган рамы

3) *информ.* Кулланучыга төгәл мәгълүмат бирә торган, эзләнү системаларына, Интернет кибет, электрон почта, сәүдә рекламасы, чат, форумнарга бик тиз керү мөмкинлеге булган төрле ресурслар һәм сервислар җыелмасыннан торган бик зур универсаль сайт. *Ислам Интернетын алга җибәрүдә үзләреннән зур өлеш керткән яшь егетләр --- хәзер ислам порталлары барлыгын, яшьләрнең дин, дини терминнар белән китаплардан түгел, ә нәкъ менә шул порталларда танышуларын --- әйттеләр.* Татарстан яшьләре

ПОРТАЛЬ *с. тех.* Аскы яки төп өлеше, рамы «П» хәрефе рәвешендә ясалган. *Палубада басып торучыларга диңгез яры, пакгаузлар, порталь краннар әкрен генә шуышып, суднолардан читкә тайпылган кебек тоела иде.* М.Юныс. *Порталь станок*

ПОРТАТИВ *с.* Зур булмаган, җыйнак, үзең белән йөртергә уңайлы. *Күршем Сәгыйть, юкны бушка аударып энциклопедияләр актарып яткан чы, портатив самогон аппараты уйлап чыгарсын иде.* З.Хәким. *Ризванның кулында батарея белән эшли торган кечкенә телевизор белән ике конфорка лы портатив газ плитәсе --- иде.* Ф.Яруллин

ПОРТАТИВЛЫК *и.* Кечкенә күләмле һәм йөртергә уңайлы булу

ПОРТВЕЙН *и. нем.* Йөзем шәрабының составында спирт күп булган, куәтле, кызыл төстәге сорты. *Кибет ачылуга йөгереп кенә бер шешә салкын портвейн алып керә дә Былбылнисадан калай кружка сорый. Картның салкын кружкага салкын портвейнны салганын күргәч, Былбылнисаның сабырлыгы җуела.* М.Мәһдиев. *Алар очрашу хөрмәтенә Илдар алып килгән портвейннан авыз иттеләр.* Р.Хәбибуллина. *Җыештырылмаган, пычрак бүлмә, өстәлдә бушаган портвейн шешәсе кукраеп утыра.* Р.Мирхәйдәров

ПО́РТИК *и. лат. махс.* Күбесенчә бинага тоташтырылып, түбәсе ябулы итеп эшләнгән колонналы яки аркалы ябык галерея. *Һәрберсе сигез квадрат колонналы портикка нигезләнгән монастырьның өч яруслы фасады геометрия һәм тригонометриягә нигезләнеп эшләнгән, әлбәттә.* М.Мәхмүтов

ПОРТМОНЕ *и. фр.* Акча яки документлар салып йөртү өчен, күн, тукыма һ.б.ш. материаллардан эшләнгән кечкенә яссы предмет. *Ул --- элек, җае туры килгәндә, бу атаклы фирманың портмоне, кейс, чалбар каешы ише вак-төякләрен алгалый иде ---.* Р.Мирхәйдәров

ПОРТМОНЕТ *и. фр. иск. сөйл. к.* **портмоне**. *Тәннәрем чымырдап китте һәм мин, котылу чарасы юклыгын аңлап, портмонетымны кире кесәгә салдым.* А.Тимергалин. *– Алайса, мә, теге демидролыңны кабып кара! – дип, портмонеттан ике таблетка алып,*

сиздермичә генә Фәтхелисламның кулына тоттырдым. Д.Гыйсметдинов

ПОРТО-ФРА́НКО *и. ит. махс.* 1) Портның пошлинасыз товар кертү яки читкә чыгару хокукы

2) Шундый хокукка ия булган порт, шәһәр яки диңгез буендагы өлкә (район). *Сәүдәгәрләрне һәм сәүдә капиталын үзенә тарту өчен, Сингапур – порто-франко, ягъни пошлинасыз сәүдә порты дип игълан ителә.* Р.Мостафин. *Портка порто-франко статусы бирелү*

ПОРТРЕТ *и. фр.* 1) Рәсем сәнгатендә, фотографиядә бер кеше яки кешеләр төркеменең сурәте. *Зур, иркен залларда --- Һиндстан халкының канын койган генералларның портретлары эленеп тора.* М.Юныс. *Портреттагы кыз дөньяга сабыйларча гаҗәпләнеп карый.* М.Маликова. *Ренуар картинасының күчермәсе икән. Исеме белән дә күңелне кытыкларлык: «Жанна Самари портреты».* А.Әхмәтгалиева

2) Әдәби әсәрдә персонажның тышкы кыяфәтен сурәтләү; гомумән, персонажның тулы образы. *Портрет биргән чакта без, гадәттә, бик статик рәвештә персонажыбызның бит сызыкларын хәбәр итәбез. Марсель Гали исә дөнья классиклары үрнәгендә – персонажларының портретын динамикада, эш-гамәлләрендә ачып бирергә ярата.* Г.Ахунов. *Сәгать, Музсәгать, Минут, Секунд, Стрелка исемнәре аның [Псих Сәлимгәрәевичнең] сатирик портретын тагын да тулыландыралар ---.* А.Хәлим

ПОРТРЕТЧЫ *и.* Рәсем сәнгатендә яки фотография эшендә портрет ясаучы, портрет язучы. *Рафаэль – шәп портретчы.* Г.Гали. *Мин үзем портретчы түгел. Шулай да ясадым инде: мондый кешеләрне ничек калдырып китәсең, ди!* Э.Касыймов. *Портретчы рәссам Зөфәр Сибгатуллин үзенең иҗатын да, тормышын да ике чорга бүлеп карый.* Мәдәни җомга

ПОРТСИГАР *и. фр.* Папирос, сигара яки сигарет салып йөртү өчен, металл, тире, агач һ.б.ш.лардан ясалган яссы тартма. *Гата класс ишеген япмаган көе үк, көмеш портсигарын чыгарып, яхшы папирос алды, хикмәтле зажигалка белән ялт итеп кабызды һәм кесәсеннән дүртка бөкләнгән кәгазь чыгарды.* М.Мәһдиев. *– Әйе, безнең солдат күргәнне сөйләсәң, кеше ышанмас! – диде Баһапов, портсигар капкачын шартлатып, папирос алып кабызды...* Х.Камалов. *Ул, портсигар чыгарып, нәфис бармаклары белән Генрига сигарет тәкъдим итте.* А.Тимергалин

ПОРТУГАЛ *и.* Португалиядә яшәүче төп халык һәм шул халыкның бер кешесе. *Һиндстан юлын ачучы португал диңгезчесе Васко да Гаманың корабында гарәп лоцманы булган.* М.Юныс. *Соңрак --- португаллар Лиссабонны алалар һәм үзләренең башкаласы итәләр.* Урта гасырлар тарихы

ПОРТУГА́ЛИЯЛЕ *и.* Португалиядә яшәүче кеше. *Португалиялеләр гарәп, һинд судноларын талый һәм батыралар ---.* Урта гасырлар тарихы. *Беренче тапкыр чәйне үз илләренә 1517 елда – португалиялеләр, 1610 елда голландиялеләр алып кайта.* Кызыклар дөньясында. *Көнчыгыш товарлары белән сәүдә итүдән португалиялеләр гаять зур керем алалар.* Россия тарихы

ПОРТУГА́ЛЧА *рәв.* Португал телендә. *Көньяк Америка халкының күпчелеге – испан телендә, ә Бразилиядә португалча сөйләшә.* Материклар һәм океаннар географиясе

ПОРТУПЕ́Я *и. фр.* Салкын яисә утлы коралны билдә тагып йөртү өчен, иңбашы аркылы үткәрелгән каеш. *Бу вакытта ул район эчке эшләр бүлегенең оператив вәкиле иде. Галифе чалбар, гимнастёркадан, портупея...* Ә.Баян. *Ныкгәүдәле Юдин, итекләрен шыгырдатып, аяк өстенә басты, портупеясын төзәтте ---.* Ш.Рәкыйпов. *Портупеясын ычкындырып маташкан Самат кинәт туктап калды ---.* Р.Кәрами

ПОРТФЕЛЬ *и. фр.* 1) Китаплар, дәфтәрләр, төрле эш кәгазьләре салып йөртү өчен тоткалы сумка. *Шул вакыт, баласын югалткан юлбарыстай ыжгырып, идарәгә Улибаева килеп керде. Ул ачу белән портфелен өстәлгә ыргытты.* М.Мәһдиев. *Эльвирның кулында зур гына кара портфель, аркасында таныш чехол белән аккордеон асылган иде.* М.Маликова. *Аудиториягә, хан заманыннан калган күн портфелен күтәреп, профессор Гудзенко керде.* М.Юныс

2) *җыйк. күч.* Редакцияләү, нәшер итү, сәхнәдә кую һ.б.ш. өчен кабул ителгән кулъязмалар. *Хәзерге безнең репертуар портфелендә гел драматик сюжетка язылган либреттолар гына.* М.Җәлил

3) *күч.* Министр урыны, министр вазифасы. *Ораторлар [анда] ялган пафос сата, Министрлар портфель саталар.* Г.Афзал. *Төркемнәргә бүленеп үзара тарткалашу, портфель --- бүлешү дисеңме...* Р.Мөхәммәдиев

4) *күч.* Гомумән зур эш урыны. *Ә инде берәрсе начальник яки түрә булып алгач, менеп утырган креслосын, портфелен югалта башласа, бетте!* М.Хәсәнов. *Безнең илдә хәзергә ике процесс бара: хакимият органнарында портфель бүләләр, һәм, депутатлар моның белән мавыккан арада, олигархлар белән эре-эре эшмәкәрләр ашыга-ашыга бәя күтәрәләр.* Татарстан яшьләре

ПОРТФЕЛЬЛЕ *с.* Портфеле булган. *Романнарда язылган портфельле әмрикан кызлары кебек фырт кына пароходка менеп утырсам икән.* Р.-Н.Гүнтәкин

ПОРТФЕЛЬСЕЗ *с.* **1.** 1) Портфеле булмаган

2) *күч.* Дәүләт идарәсенә караган, әмма министр статусында булмаган (түрә). *Русиядә милләтләр эше буенча министрлыкны юкка чыгардылар, портфельсез министр Владимир Зорин гына калды.* Татарстан яшьләре

2. *рәв. мәгъ.* Портфель булмый торып, портфельдән башка. *Менә шуңа да таулар арасында яшеренгән, юлларында шлагбаумнар торган әлеге кышлакка портфель өмет иткән яисә портфельсез калган министрлар да баш ияргә, бил бөгәргә киләләр иде.* Р.Мирхәйдәров

ПОРТЧЫ *и.* Портта эшләүче, порт эшчесе

ПОРТЬЕ *и. фр.* Кунакханәнең ишек төбендә, вестибюлендә тәртип

саклаучы, ачкыч биреп торучы, почта таратучы хезмәткәр. *Гадәттә, башкалага килгәндә, кеше бер үк кунакханәдә туктарга күнегә, ул инде отель хуҗалары һәм портье өчен «үз кешегә» әйләнә.* В.Юныс. *Уку белән беррәттән кунакханәдә портье булып эшләргә дә өлгерә.* Ватаным Татарстан

ПОРТЬЕР *и. к.* **портьера**. *Эскәтерләрне, портьерларны матурлау өчен, төрле төсләр белән чигәргә мөмкин.* Йорт эшләре. *Эре чәчәк төшкән тукыманы – портьер, вак чәчәклесен мендәр тышлыгы итеп тегәргә була*. Шәһри Казан

ПОРТЬЕ́РА *и. фр.* Ишеккә яки тәрәзәгә эленә торган калын пәрдә. *Гарин тәрәзәгә ташланды, портьера артына посты*. А.Толстой. *Һәм шуннан ул үзенең портьера тегү бизнесына юл ача.* Сөембикә

ПОРУ́КА *и. рус юр.* Суд тикшерүе астындагы кешене яклап чыгу, шул кеше өчен җаваплылыкны аерым кеше яки берәр оешма үз өстенә алу. *Эше тикшерелеп ачыкланганчы, без [Биктимерне] Григорий Мироныч белән порукага алып торырбыз.* Т.Гыйззәт. *Ә прокурор Улибаева эшне тирәнгә җибәрде. Тимерхан Мәйсүфә карчыкны порукага алырга көн чапты, төн чапты, файдасы тимәде.* М.Мәһдиев. *Унбер тәүлек шул төрмәдә утырганнан соң, үзе оештырган комитет членнарыннан өч кеше, дүрт йөз тәңкә залог калдырып, Миңнулланы порукага алдылар.* В.Нуруллин

ПОРУ́ЧИК *и. пол.* 1) Россиядә: 1917 елга кадәр армиядә подпоручиктан бер рангка югары һәм штабс-капитаннан бер рангка түбән офицер чины һәм шул чиндагы кеше. *Бу шинель эчендә --- провокатор Сәгыйтов. Чины – поручик.* Г.Гобәй. *Ә поручик Юдин беркадәр вакыттан соң: – Күргән-белгәннәрегезне мигә сеңдерә барсагыз яхшы, – диде*. Ш.Рәкыйпов. *Пароходка бер төркем солдат белән яшь кенә бер поручик килеп керде.* С.Сабиров

2) Польша, Чехия, Югославия һ.б. кайбер илләрдә кече офицерлар составындагы хәрби дәрәҗә һәм шул дәрәҗәдәге кеше

ПОРФИР *и. гр.* Тигезсез бөртекле төзелешле, ачы яки уртача составлы вулканик тау токымнарының гомуми атамасы; шуларга караган куе кызыл төстәге минерал. *Эффузив токымнарга --- кварцлы порфир керә.* А.Фәткуллин. *Агып чыккан (эффузив) токымнар пыяласыман, яшерен кристаллик яисә порфирсыман төзелешле була*. Төзү материаллары

ПОРФИ́РА *и. гр.* Монархларның тантаналы вакыйгалар вакытында кия торган куе кызыл төстәге киң, озын ябынчасы, мантия

ПО́РХ-ПОРХ *иярт.* Кагынубәргәләнү вакытында чыккан тавышны белдерә. *Исхакның иптәшләре порх-порх судан чыгып: – Асыл кошны эләктереп кал, йоклама! – дип, уенынчынын бергә укмаштырып үгетләргә керештеләр.* А.Гыйләҗев

ПОРХУ *ф. диал. к.* **порхылдау**. *«Инде бу эш төзәлде», – дип торган чакта, Давылдагы тузан кебек порхып туза.* М.Гафури. *Төтен порхып чыгу*

ПОРХЫЛДАТУ *ф. сөйл.* Җыелган кешеләр төркемен тиз арада куып тарату. *Туктале, порхылдатып килим әле мин аларны!* Н.Фәттах

ПОРХЫЛДА́У *ф.* Кинәттән ургылу, бөтерелү (төтен, тузан һ.б.ш. тур.). *Күн итектән порхылдап тузан очты.* Н.Фәттах. *Туфракка кизәнү белән, китмән астыннан туфрак түгел – порхылдап коры тузан оча, тузан!* А.Хәлим. *Артыннан порхылдап чыккан кара төтен машинаның эчке торышы бик шәп булмаганны күрсәтеп тора*. З.Зәйнуллин

Порхылдап кую Бер тапкыр порхылдау

Порхылдап тору Хәзерге моментта порхылдау; гел порхылдау

ПО́РЦИЯ *и. лат.* 1) Берәр нәрсәнең билгеле күләмдәге микъдары, өлеше. *Тәмәкем бар. Мин бүтән вакытта үз порциямне иптәшемә бирә торган идем.* Н.Дәүли. *Зарифуллин, сеанс башланыр алдыннан, уникә порция арзанлы мороженое ашаган иде, кино барганда, зрәгә генә эче бора башлады.* М.Мәһдиев. *Көнгә икә тапкыр (иртәнге һәм төшке ашка 30 минут кала) әзер порцияне кабарга.* Ирек мәйданы

2) Ашханәләрдә, кафеларда, рестораннарда бер кешегә исәпләп бирелә торган ашамлык яки эчемлек. *– Рәхмәт сезгә, эштиегез бик тәмле иде, тагын бер порция китерегез әле, – дидем*. Н.Дәүли. *Җиһангир бер стакан шәраб, бер шешә сыра эчеп, бер порция шашлыкны күз ачып йомганчы ялтыратып куйды.* Г.Мөхәммәтшин. *Бер порция тонык шулпа пешерү өчен, икә стакан --- сыеклык кирәк.* Тигез гомер итегез!

ПО́РЦИЯЛӘП *рәв.* 1) Аерым порцияләр рәвешендә. *Порцияләп өләшү*

2) Аз-азлап; урык-сурык. *Ә өстән һаман әле кар коела, учлап-учлап, порцияләп коела.* В.Астафьев. *Суверенлык, порцияләп алырга, ит тә, сөт тә түгел.* Р.Миңнуллин

ПО́РЦИЯЛӘҮ *ф.* Порцияләргә бүлү. *Горбуша балыгын сөягеннән һәм кабыгыннан чистартабыз да, порцияләп кисеп, тоз-борыч сибәбез һәм газ мичендә пешереп алабыз*. Шәһри Казан

Порцияләп бетерү Бөтенесен дә, булган берен порцияләү

Порцияләп тору Хәзерге моментта порцияләү; әледән-әле порцияләп алу

ПО́РЦИЯЛЕ *с.* Порцияләр рәвешендә әзерләнгән; порцияләргә бүленгән. *Порцияле балык*

ПО́РШЕНЬ *и. рус* Сыеклык яки газ ярдәмендә хәрәкәткә килә торган машиналарның цилиндрлары эчендәге деталь; пешкәк. *Китаплар арасында майга баткан дизель поршене аунап ята. Шул поршень астына, нишләптер, механик хатынының рәсеме кереп кысылган.* М.Юныс. *Казаннан ургылып чыккан пар машинаның поршенен хәрәкәткә китерә.* В.Юныс. *Ничек кенә тыңлап карасам да, шул үк хәлсез тонык тоннар, йөрәге поршене бушаган насос төсле копыл-копыл итеп тибә ---*. Г.Галиев

ПОРШЫЛДА́У *ф. к.* **пуфылдау**. *Үгез, --- җыелган халыкны күреп, тагын туктап калды, поршылдап җир тырмап куйды*. З.Кадыйрова

Поршылдап алу *к.* **поршылдап кую**

Поршылдап кую Бер тапкыр поршылдау

Поршылдап тору Даими, әледәнәле яки хәзерге моментта поршылдау

ПОСАД *и. рус тар.* Урта гасырларда шәһәр диварларының тышкы ягына урнашып, һөнәрчелек һәм сату-алу эшләре башкарыла торган урын. *Посад диварлары --- ком-таш тутырылган агач буралар тезмәсеннән торган булырга тиеш.* Чын мирас. *Казан ханлыгы чорында (1439–1552) кремльдә инде эчке һәм тышкы кальгалар барлыкка килә, аларга таза агач диварлары һәм биек күзәтү-саклану манаралары булган калачык (посад) килеп сыена, боларга исә берничә якътан бистәләр килеп терәлә.* Гасырлар авазы. *Ә стена буена аларның ашау-эчү, юындырукиендерү ягын кайгыртучы купецлар, сәүдәгәрләр, һөнәрчеләрдән торган посад кешеләре урнаша.* Туганайлар

ПОСА́ДКА *и. рус сөйл.* Билгеле бер киңлектә утыртылган агачлар тезмәсе; гомумән, урманнан аермалы буларак, кеше утырткан агачлык. *Кайбер эшчән адәмнәр урман посадкасы чистартып, печән әзерли.* Х.Камалов. *Бер вакыт кыр юлыннан тарантаслы ат килүен күреп, аның бик дуамал холыклы колхоз рәисе булуына шикләре калмаган «сугышчылар» посадка агачлары арасына посып торырга ниятләделәр.* Ш.Алпар. *Бит-кулларга әлеге хәшәрәтләргә каршы крем сөртмичә --- урманнарга, хәтта посадка, болыннарга да якын килерлек түгел.* Татарстан яшьләре

ПОСЁЛОК *и. рус* Шәһәр янында урнашкан зур булмаган торак пункт. *Ул җыр Муса Җәлилгә аның исемен йөрткән Җәлил посёлогында музей ачылган көнне язылды.* Г.Ахунов. *Яңа мәхәллә дигән посёлоктан бераз читтәрәк, тимер-бетон каркаслы ак плитәләр белән тышлап, яңа йорт салалар.* М.Юныс. *Ике сәгатькә якын барган гарасаттан соң, немецлар кечкенә посёлокны ташлап чыгып киттеләр, кичкә таба бригада штабы посёлок үзәгендәге ике катлы кызыл кирпеч пекарняга кереп урнашты.* М.Мәһдиев

ПОСКЫН *и.* Берәр урында яшеренеп, дошманга кинәттән һөҗүм итәргә әзер торган кечкенә отряд; *русчасы:* **засада**. *Поскын яуны постырыр.* Мәкаль. *[Бурман:] Шушы номер аларга бүген качу оештырган. [Гейфель:] Әһә, сез шуны белеп, анда поскыннар куйдыгыз?* Н.Исәнбәт. *Ахрысы, бу гаскәр поскын булып, аны күптәннән сагалап торгандыр.* Р.Батулла

ПОСО́БИЕ *и. рус* 1) Дәүләт тарафыннан кемгә дә булса ярдәм йөзеннән бер мәртәбә яки даими рәвештә бирелә торган акчалата социаль ярдәм. *Юристлар аңлатуынча, --- закон проекты нигезендә балага яшь ярым тулганчы бирелә торган пособиене өч яшькә кадәр түләргә теләгәннәр иде.* Шәһри Казан. *Әтиләре сугышта үлгән балаларга әз булса да пособие бирелә иде.* Татарстан яшьләре. *Шулай ук әтисе хәрби хезмәттә вакытта аның өч яшькә җитмәгән баласына аена 8882 сум күләмендә өстәмә пособие түләнә.* Ирек мәйданы

2) Уку-укыту эшендә кулланма, ярдәмлек. *География дәресендә, картадан тыш, башка ярдәмлек пособиеләр дә кулланылды.* Мәгърифәт

ПОСТ *и. фр.* 1) Берәр нәрсәне саклый, каравыллый яки күзәтә торган (гадәттә техник җайланмалар белән җиһазландырылган) пункт, урын. *Сабантуйга багышланган киңәшмәдә бәйрәм үткәреләчәк урынның планы белән таныштылар, постлар билгеләнде ---.* Р.Хәбибуллина. *Бер тәүлекне постта Кирам тора, аңа алмашка икенче тәүлеккә дежурга Хәйретдин агай килә.* А.Гыйләҗев. *Кизү торучы сержант белән икенче солдат ишек төбендә таптаналар, ләкин кызыксынулары көчле булса да, постларын ташлап китә алмыйлар.* Р.Кәрами

2) Тимер юлларда поездлар хәрәкәтенең куркынычсызлыгын тәэмин итә торган сигналлар һәм рельс күчергечләрне көйләп тору урыны, будка

3) Часовой тарафыннан саклана торган хәрби объектка караган җирлек. *Ике полицай торган посттан үтеп, Юдин алдан ук хәстәрен күргән кунак йортына җитәрәк, Мильда серле итеп --- пышылдады.* Ш.Рәкыйпов. *Һәр пост милиционерының кесәсендә аның фоторәсеме булган, ул 1988 елдан бирле качкынлыкта саналган икән...* Р.Мирхәйдәров. *Царьков дежурлык иткән пост Арча кырындагы зиратны һәм шул тирәдәге башка участокларны үз эченә ала иде.* Х.Вәлиәхмәтов

4) Берәр нәрсәне күзәтү яки каравыллау, саклау өчен куелган кеше яки кешеләр төркеме. *Шәһәрдән килдем, беркем дә мине туктатмады. Үткән юлы да постларыгыз ятып йоклаган иде.* А.Гыйләҗев. *Посёлок бөтен яктан уратып алынган, аннан дүрт якка чыккан юлларга көчле постлар куелган.* Ф.Вәлиәхмәтов. *--- ул дезертирлар кайтып йөри торган йортларны күзәтү астына ал. --- менә шушы Яңаул станциясендә яшерен пост булдыр.* В.Нуруллин

5) Хастаханәдә медикаментлар, авырулар тарихы һ.б.ш. саклана һәм шәфкать туташы дежурлык итә торган урын. *Анда төнге утлар гына калган; посттагы шәфкать туташы да каядыр китеп югалган ---.* А.Әхмәтгалиева

6) Җаваплы эш урыны. *Менә берәүләр клуб алдында тыныч кына тәмәке тарта, ә районның яңа председателе авыл советы бинасында үзенең яңа постына имтихан тота.* М.Мәһдиев. *Безнең татарча белем алган сөлек кебек балалар, борыннарыннан кан киткәнче тырышсалар да, клуб мөдире постыннан уздыра алмый.* М.Юныс. *Безгә ярдәм кулы сузган олы йөрәкле кешеләргә, хәлбуки алар югары дәрәҗәдәге постлар биләсә дә, табынмыйк.* Н.Гыйматдинова

◊ **Постка басу** Үз вазифаларын, үзенә йөкләнгән эш-бурычны үти башлау. *Бу вакытта батарея тылындагы туп янына замполит Вahапов килгән иде. Коручы Николаев постка баскан.* Х.Камалов. *Зенитчылар сугышчан постка басып, карашларын хәвефле күк йөзенә төбиләр.* М.Маликова. **Постта үлү** Үз өстенә йөкләнгән вазифаларны үтәгәндә һәлак булу

ПОСТА *с. диал.* **1.** Иясез калган, буш, кеше тормый торган. *Поста йорт*

2. *рәв. мәгъ.* Буш, кешесез. *Катюшасын Байтирәккә озатсын иде. Йорты поста тора бит.* Г.Бәширов. *Аның*

поста яткан йортын бер төн эчендә ремонтлап бир[гәннәр]. Г.Ахунов

ПОСТАЛЫК *и. диал.* Кеше тормау, буш булу (йорт тур.). *[Зиннәт] каршы алырга ата-анасы югын да, йортының посталыгын, үзенең ялгызлыгын да уйлап, йөрәге сыкранып китте.* Г.Бәширов

ПОСТАМЕНТ *и. лат.* 1) Һәйкәл, колонна, статуя һ.б.ш.ның нигезе булып хезмәт итә торган калку урын; пьедестал. *Мәйдан уртасында ялгыз һәйкәл. --- Постамент ташына гарәп хәрефләре белән нәрсәдер язылган.* М.Юныс. *Хәсән агаебыз – гүзәл гамь иясе – биек постаментта, табутта ята*. Г.Ахунов. *Һәйкәл күздән югалу белән, котырган халык --- таш постаментка ташланды.* Мәдәни җомга

2) Музейда, күргәзмәдә таш сын астына куела торган бүкән; аскуйма

ПОСТА́У *и. рус* **1.** 1) Уң ягы киезсыман катламлы йон яки ярымйон тукыма; сукно. *Хуҗалар --- өстәл тулы чәчелеп яткан кәгазь битләрен бер почмакка этәреп, постау өстенә газет җәйделәр.* Х.Сарьян. *Ачык тәрәзәдә аларның кул станында постау сугулары, җеп эрләү һәм җеп сарулары күренеп тора.* М.Гали. *Әгәр бу юлы Нугай урдасын, --- Урта Азияне яулау процессында форпостка, трамплинга әверелдереп, дары заводлары, постау фабрикалары --- салмаган булсалар?* М.Юныс

2) Шундый тукымадан тегелгән кием. *Безгә кодачалар килгәннәр. Барысы да постау кигәннәр.* Җыр

2. *с. мәгъ.* Шундый тукымадан тегелгән. *Чалбарларым химчистартуга еш йөрүдән төсен тәмам югалткан булса да, офицерлар кия торган киң балаклы постау чалбар иде.* М.Юныс. *Яшь, таза, бөтерелеп торган мыеклы, өстендә постау френч, имеш.* М.Мәһдиев. *Ә безнең өсләрдә, ышанасыңмы-юкмы, юп-юка постау шинельләр.* Д.Галимов

ПОСТАУЛЫ *с.* Поставы булган; постау ябылган. *Мөдир кызыл постаулы өстәле артында элеккечә үк күзләрен йома төшеп уйланып утыра.* Р.-Н.Гүнтәкин

ПОСТАУЧЫ *и.* 1) Постау тукучы. *Бездә югары җитештерүчәнлеккә ирешкән, аена 35–40 мең сум алып эшләүче постаучылар да җитәрлек.* Кызыл таң

2) Постау белән сату итүче сәүдәгәр

ПОСТАШ *с. диал.* **1.** *к.* **поста 1.**

2. *рәв. мәгъ. к.* **поста 2.** *Аның посташ яткан йортын бер төн эчендә ремонтлап бирүләре --- [Дияровның] юл мәшәкатьләрен, кайгы-борчуларын оныттырып җибәргән.* Г.Ахунов

ПОСТАШЛЫК *и. диал.* 1) Посташ булу

2) Бушлык. *--- почмагындагы посташлык бигрәк тә күзгә нык ташланып тора.* Н.Фәттах

ПОСТИМПРЕССИОНИЗМ *и. лат.-фр. сәнг.* XIX йөзнең ахырында – XX йөз башында Франциядә сәнгатьтә импрессионизмга җавап буларак барлыкка килгән агым. *--- озак елларга сузылган империалистик сугыш, егерме беренче елгы ачлык, полиграфик базаның булмавы һәм, ниһаять, рәссамнарның барысының диярлек ул елларда модада булган төрле агымнар – кубизм, постимпрессионизм, сюррелизмнар белән мавыгулары графика эшенең артка калуына да йогынты итмичә калмаган*. Татар графикасы. *«Хәзинә» милли сәнгать галереясында постимпрессионизм осталарының иң күренеклеләреннән берсе, француз нәкышчесе һәм графигы Анри де Тулуз-Лотрекның (1864–1901) «Paris, Paris...» дип аталган литографияләр күргәзмәсе эшли*. Шәһри Казан

ПОСТИМПРЕССИОНИСТ *и. рус* Постимпрессионизм тарафдары. *Пушкин исемендәге музей. Француз бүлеге. Импрессионистлар залы. Постимпрессионистлар секторы.* М.Юныс

ПОСТМОДЕРН *и. лат.-фр. сәнг. к.* **постмодернизм**. *Аның хакында бит татар әдәбиятында, ниһаять, чын мәгънәсендәге постмодерн әсәре туган дип тә белдереп булмый, чөнки авторының мантыйклылыкка омтылышы сизелеп тора – ул аңа бары тик ирешә генә алмаган*. Сәхнә. *---җәмгыять этник бөтенлеген югалта бара ---, социализм чорындагы «йомык» яшәү рәвешен постмодерн эпохасы космополитизмы алыштыра.* Идел

ПОСТМОДЕРНИЗМ *и. лат.-фр. сәнг.* Сәнгатьтә модернизмнан соң барлыкка килгән стиль, юнәлеш. *Галимҗан Гыйльмановның «Албастылар»ы һәм хәзерге татар прозасындагы шуңа якын әсәрләрнең жанрын һәм иҗат методын билгеләгәндә, --- күп һәм катлаулы, каршылыклы терминнар өермәсенә тап буласың: модернизм, постмодернизм, --- милли реализм һ.б.* Ф.Урманче. *Шигърияттә постмодернизм, символизм стилендә иҗат иткән --- шагыйрь Рәмис Аймәт соңгы елларда эстраданы шигъри яктан баету, матурлау эше белән мәшгуль.* Кәеф ничек?

ПОСТМОДЕРНИСТ *и. рус* Постмодернизм тарафдары. *«Кандинский симптомы» бүгенге рәссамнарның байтагына хас, алар үзләрен бөек талантлар дип танытырга тырышалар һәм үзләре кебек үк авышкан сәнгать белгечләре аларга «модернист», «постмодернист» тамгалары тагып зурлыйлар, пропагандалыйлар.* Татарстан яшьләре

ПОСТПОЗИТИВ *с. лингв.* Үзе караган яки үзе буйсынган сүз яисә җөмлә кисәге артыннан ук тора торган (мәс., килә *ич*, аның *белән*). *«Әллә» кисәкчәсе --- постпозитив позициядә дә килә ала.* Д.Тумашева. *Лингвистика теле белән әйткәндә, лексик-грамматик берәмлекләр, сүз ясаучы препозитив, интерпозитив, постпозитив --- аффикслар, --- табигать күренешләренә, климатка кагылышлы күп сандагы темаларны каплардай семантик төркемнәр анализланды.* Фән һәм тел

ПОСТПОЗИ́ЦИЯ *и. лат. лингв.* Берәр сүзнең яки җөмләнең кисәге үзе караган сүз яки җөмлә кисәге артыннан торуы (мәс., юл *аркылы*, баргач *ук*). *Алла-улла – саф гарәби компонент, ир-ат исемнәрендә бары тик постпозициядә генә кулланыла.* Фән һәм тел

ПОСТРО́МКА *и. рус сөйл.* Атны янга җиккәндә тәртә хезмәтен үти торган аркан яки каеш перәшкә; мичәү. *Постромка бавына ат койрыгыннан кыл йолкый идек ---.* Ш.Галиев. *Көмеш тәңкә тезгән кара каеш йөгән, чуклы постромка, көмеш бизәкле ыңгырчак*

ак юргага шулкадәр килешә. М.Юныс. *Тик Әнвәр чокырдан башын калкытуга, ике яралы атның, постромкаларын өстерәп, --- үзенә таба чабып килүен күрде.* Х.Камалов

ПОСТСКРИ́ПТУМ *и. лат. кит.* Хат яки башка төрле язма мөрәҗәгатьтән соң өстәлгән текст алдына куелган P.S. тамгасы (латинчадан: өстәп язу). *[Ул] аска, постскриптум аша, түбәндәге сүзләрне дә өстәп куйган иде.* Ф.Хөсни

ПОСТСОВЕТ *с.* Совет Социалистик Республикалар Союзы (1917 елдан 1991 елга кадәр) таркалганнан соңгы чорга караган. *«Тачанка» белән постсовет кешесе, бер-берсенә берегеп, грек мифындагы Кентавр рәвешен алды хәзер.* М.Юныс. *Менә нинди мәсхәрәле түбәнлекләргә, кыргый җәнлекләр дәрәҗәсенә китереп җиткергән постсовет чоры!* Мирас. *Элекке Советлар Союзы республикаларына килгәндә, миңа бөтен постсовет мәйданын бәяләве кыен ---.* Чын мирас

ПОСТУЛАТ *и. лат. кит.* Нинди дә булса фәнни теория кысаларында, исбатланмаган яки дәлилләнмәгән булуына карамастан, дөрес дип кабул ителгән башлангыч, нигез, положение. *Биш яшьлек бала, Эвклидның параллель турылар хакындагы постулатыннан канәгать булмыйча, Лобачевский --- юлына баскан.* А.Тимергалин. *XIX йөзнең беренче чирегендә дә әле геометриянең нигезендә, элеккечә, Эвклидның ирекле рәвештә, исбат ителмичә генә кабул ителгән башлангыч раслаулары – постулатлары [ята].* Ж.Тәрҗеманов. *Маоизм. Ул марксизм, ленинизм һәм сталинизмның күп кенә постулатларын үзенә ала (ни әйтсәң дә, коммунистлар бит!).* В.Юныс

ПОСТЫРМА *и.* Һөҗүм итәр өчен, яшерен урында дошманны сагалап торган кеше яки кешеләр төркеме; поскын. *Бар халыкны минем янга саклык белән җыегыз. Шымчы Армайлар сизмәсен. Постырмалар куегыз.* Т.Гыйззәт. *– Хәзер үк, 40 мең атлы гаскәр алып, елганы кич тә, юлларына постырма (засада) корып, искәрмәстән һөҗүм ит! – дип боерык бирә.* В.Имамов

ПОСУ *ф.* **1**. 1) Кешеләр, хайваннарның һ.б. күрмәслек һәм тапмаслык итеп берәр җиргә, берәр нәрсә артына, эченә яшеренү, качу. *Бу яктан ут көтмәгән казаклар бермәлгә аптырап калдылар һәм коралсызландырылган солдатлар артына постылар.* Ш.Рәкыйпов. *--- кош-кортлар ышыкка кереп постылар ---.* А.Тимергалин. *--- урамнар тып-тын. Әйтерсең кешеләр, давылдан куркып, өйләренә поскан.* Н.Гыйматдинова

2) Нәрсәләрнең дә булса эчендә яки арасында кысрыкланып калу (табигать күренешләре, җансыз нәрсәләр тур.). *Каеннар арасына кереп поскан агач йортларны --- кар күбәләкләр сырып алган.* К.Нәҗми. *Кояш инде күптән тауга поскан.* М.Җәлил. *Землянкага кергәч тә, Газинур --- шырпы сызды. Караңгылык почмакларга посты.* Г.Әпсәләмов

3) Кешегә яки җанлы-җансыз нәрсәгә сыену. *Күкрәгемә поскан ач сабыем: «Әттә», – ди дә төелә яшенә.* Н.Исәнбәт

2. посып *рәв. мәгъ.* 1) Күренмәскә тырышып, сиздермичә, яшеренеп. *Тол хатыннарда, ирләрнең елмайган майлы күзләренә карап, аларның татлы сүзләре артына посып торган уйларын сизәрлек тойгылар сүнеп бара иде инде.* Н.Дәүли. *Эх сез! Өйрәтермен посып шулай сүзне тыңларга!* Ш.Мөдәррис. *Әлтафи читән буеннан посып кына кайтып бара иде, Зарифуллинның мокытлыгына каны катты.* М.Мәһдиев

2) Кешеләр белән бик аз аралашып яки бөтенләй аралашмыйча. *Әйдә, улым, оялма, оялма, әй бәпкәм, песи баласы шикелле посып кына, оялып кына тора.* Г.Камал. *Майпәрвәз ханым, киявен бер барып күргәч, чыннан да, вакытлыча посып, тынып торуны үзе өчен хәерлерәк булыр дип тапты.* Ә.Еники

Посып тору Хәзерге моментта поскан булу; күпмедер вакытка посу

Посып яту Күптәннән, озак вакыт дәвамында посу. *Биек үлән арасында посып яткан эре-эре җиләк тәлгәшләре әле дә кызарып бетә алмый ---.* Мәдәни җомга

ПОСЫ́ЛКА *и. рус* Почта аркылы кая да булса җибәрелгән яки кайдан да булса алынган әйбер. *Хуҗасы – 17–18 яшьтәге татар егете – хат тутырылган капчыкларны, посылка әрҗәләрен рәтләп маташа.* Ш.Рәкыйпов. *Хәер, Гайнелвафа карчык бик көтеп караса да, улыннан бер генә тапкыр да өрек посылкасы килмәде.* М.Мәһдиев. *Миңлегөлдән өтерге белән чүкеч сорап алды һәм җитез генә посылка тартмасын каерып ачты.* А.Гыйләҗев

ПОСЫНУ *ф. к.* **посу**. *Тавышлар якынлаша. Рәүф шаярып бер читкә посына.* Ж.Фәйзи. *Әле менә алдагы көнне генә шәһәр үзәгендәге бер скверда кар белән капланган чыршы агачлары арасында посынып утырган ябалакны каргалар көтүе куалап чыгаруын күзәтергә туры килде.* Шәһри Казан

ПОСЫРУ *ф. диал.* Яшерү, качыру, ышыклау. *Агачлар, җилнең теңкә кортқыч дәртеннән котылу мазасы эзләп, башларын әле бер якка, әле икенче якка посырырга азапландылар.* А.Гыйләҗев

ПОТ I *и. рус* Метрик система кертелгәнчегә кадәр кулланылган һәм 16,3 килограммга тигез булган иске авырлык үлчәү берәмлеге. *Мин хезмәт көненә тигән бер пот арышны күтәреп, тегермәнгә киттем.* Х.Сарьян. *Зарифуллинның әнисе хезмәт көненә өч пот ярым борчак алган.* М.Мәһдиев. *Казан банкындагы кырык өч мең пот алтын, утыз бер мең пот көмешне кулга төшерүләре җитмәгән.* Д.Галимов

◊ **Потка тулмаган** *хурл.* Тиле-миле, җиңел холыклы кеше турында әйтелә. *Мин сиңа карап торам-торам да исем китә: әллә инде син азрак потка тулмаган, әллә мин үзем акышмакышрак...* Ф.Бурнаш. **Поты белән** Бик күп, чикләнмәгән күләмдә; күпме кирәк шулкадәр. *Резин җилеме җизнидә поты белән.* А.Тимергалин. **Поты бер тиен** 1) Бик арзан, бик очсыз, юнь. *Кабак бик зур да – поты бер тиен.* Мәкаль; 2) Кирәкмәс, кирәге юк, кирәге булмаган; әһәмиятсез, әһәмияте булмаган. *Гәрәбә чәч, --- бел: минем өчен егетләрнең поты бер тиен, дигән кыяфәттә тәкәббер генә утыра бирде.* М.Юныс. *Сәясәтегезнең дә,*

сәясәтчеләрегезнең дә поты бер тиен! Н.Гыйматдинова. *Менә нәрсә, җанкисәгем, чемоданыңны тутыр да фахишәң янына кит! --- Потың бер тиен!* Р.Хәбибуллина

ПОТ II *и. һинд.* Кеше яки берәр җан иясе кыяфәтендә табыну өчен ясалган һәм илаһ итеп кабул ителгән сын; балбал, санәм. – *Син, нишләптер, борынгы потлар исемен бик еш телгә аласың әле, – дип, авыр гына елмайды капитан.* А.Тимергалин. *Тайваньда теләсә нинди дин тоту, теләсә нинди потка яисә Аллага табыну иреге күптән яши.* В.Юныс. *Һәйкәл саны йөз мең данәгә җитеп ишәя икән, бу инде – идол, пот, икона.* М.Юныс

ПОТАШ *и. инг.л* Үсемлек көленнән, хлорлы калийдан табыла торган ак порошок шикелле селтеле каты матдә; калий карбонаты. *Син, апай кеше, [сабынны] аның эченә салынган сода яисә поташ белән генә ачы дип беләсеңме?* Ә.Фәйзи. *[Ул] авылда поташ заводы ача.* Чын мирас. *Казанда һәм аңа якын авылларда татар сәнәгать оештыручылары көче белән сабын кайнату, кәгазь эшләү, комач яки кытат сугу, күн иләү, поташ җитештерү белән шөгыльләнгәннәр.* Фән һәм тел

ПОТЕНЦИАЛ *и. лат.* 1) *физ.* Пространствоның билгеле бер ноктасында электромагнит, тартылу, сыеклыкта тизлекләр кырларының көчен тасвирлый торган зурлык. *Инженер электр потенциалын тикшерде.* А.Тимергалин. *Потенциаллар аермасы. Тарту көче потенциалы*

2) *күч. кит.* Нинди дә булса эш, максат өчен кирәк булган шартларның, чараларның, мөмкинлекләрнең барысы; нәрсәнең дә булса көч-куәт дәрәҗәсе. *Шуннан соң алар барлык производство потенциалын, хәрәкәтле һәм хәрәкәтсез байлыкны --- сатып алачаклар.* М.Юныс. *Кытай экономик потенциалы белән дөньяда беренчеләр рәтенә чыгып бара хәзер.* З.Фәйзи. *Аларны тормышка ашыру өчен, куәтле индустрия, куәтле космодромнар, куәтле техника кирәк. Ә экономик потенциаллары зур булмаган илләргә нишләргә?* Галәмгә юл

ПОТЕНЦИАЛЬ *с. кит.* 1) *физ.* Потенциал (*1 мәгъ.*) белән бәйле, шуңа караган. *Механик энергия ике төрле була: кинетик энергия һәм потенциаль энергия.* Физикадан мәсьәләләр һәм күнегүләр җыентыгы

2) Потенциядә булган, потенциядә саклана торган, яшерен, эчке. *[Революция], адәмнәр тормышының иң төпке катлауларынача төшеп, гади вакытта күзгә күренмәгән потенциаль көчләрне тартып чыгара.* Г.Нигъмәти. *Халкыбызның потенциаль энергиясен алып үскән яшьләребез, шулай итеп, дөнья фәне һәм культурасы офыгында «эри» бара.* А.Тимергалин

3) Булуы ихтимал, мөмкин саналган. *Совет цензурасы шартларында идеология белән кискен конфликтка кермичә генә, укучыга чынлыкны җиткерү бурычы намуслы художниктан потенциаль эчтәлекнең байлыгын, сайланган сүзләрнең кинаяле күпмәгънәлелеген, фикерне укучы күңелендә дәвам итәрлек тирән итеп салуны таләп итә иде.* Р.Фәтхрахманов. *Потенциаль җинаятьче. Потенциаль дошман*

ПОТЕ́НЦИЯ *и. лат. кит.* 1) Моңарчы яшеренеп яткан һәм билгеле бер шартларда гына хәрәкәткә килүе мөмкин булган көч, сәләт, мөмкинлек. *Бу ягымлы, кешелекле [Дэвиста] без Джонсоннарга каршы көрәш потенциясенең һәр көн үсә баруын күрәбез.* Н.Юзиев. *[Ш.Шамильскийда] башта ук гаҗәп зур иҗат потенциясе ачыла, һәм ул үзенең иҗатында бертуктаусыз үсә, ныгый, камилләшә бара.* Ә.Еники

2) *физиол.* Ирләрнең эрекциягә һәм җенси акт башкаруга сәләте. *Клиника практикасында гадәттән тыш күп тартучы кешеләрдәге импотенция очраклары белән очрашырга туры килә. Тәмәке тартудан туктагач, еш кына потенция тулысынча элекке хәленә кайта.* Тигез гомер итегез!

ПОТЛАП *рәв.* 1) Пот үлчәве белән, пот-пот итеп. *Гомеренә кадаклап икмәк ашаган кешегә йөзәр потлап икмәк бирделәр ---.* А.Алиш. *Сафа Гәрәйне, терелә бәйләп, Мәскәүгә озатсам, кенәз миңа алтынны потлап, көмешне кантарлап, җизне батманлап бирәчәк.* Р.Батулла

2) Билгеле пот чамасында. *Безнең җирдән бит мең потлап бодай чыгарга тиеш.* Г.Бәширов. – *Ха, – диде, – таш дисәң дә таш! Дуңгыз кадәр... – Кузгатып карады. – Мөгаен, биш потлап бардыр, – диде, йөзен җыерып.* Н.Дәүли. *«Бөек» маршаллар, яртышар потлап орден җыеп, ожмахта яшәгән вакытта, һәлак булган сугышчан көрәштәшләрен оныттылар, аларның исемнәрен торгызып, җәсәдләрен тиешенчә җирләүне кирәк санамадылар.* Ватаным Татарстан

2) *күч.* Күпләп, күп итеп. *Кемгәдер ул потлап бирелгән, кемгәдер мыскаллап кына эләккән.* Шәһри Казан

ПОТЛАП-ПОТЛАП *рәв.* Бик күпләп, исәпсез. *Тәкъдир минем башыма бәлане потлап-потлап яудырырга карар биргән икән.* Г.Камал

ПОТЛЫ *с.* 1) Потлап үлчәнгән. *Потлы иген*

2) Бер пот авырлыгында булган, бер пот сыйдыра яки күтәрә торган. *Әкрен генә урыныннан торды. Хәрәкәтләре шултикле авыр: аякларына потлы гер асканнармыни!* Р.Ишморатова. *--- монда Томмазо үзен аркасына потлы рюкзак аскан альпинист кебегрәк хис итә.* А.Тимергалин. *Гүя иңнәренә таш тутырган потлы чиләкләр асканнар --- иде.* Н.Гыйматдинова

3) Билгеле пот сыешлы. *Нәҗип чын солдат капчыгын --- узгынчыдан үзләренең биш потлы яңа киндер капчыкларына алыштырып алды.* Г.Гобәй. *Ул инде бишәр потлы капчыкларны, эһ тә итмичә, үзенең калын, таза җилкәсенә мендереп төшерә ала.* М.Гали

ПОТЛЫК *с.* Билгеле пот авырлыгындагы әйбер сыешлы, билгеле пот тарта торган. *Аның өстеннән мең потлык йөк төшкәндәй булды.* Г.Әпсәләмов. *Дию пәрие, Истюк сөйләп бетергәч, уң кулы белән сузылып, тау ягалый яткан йөз потлык чуен чукмарын кулына алып өскә күтәрә ---.* В.Ильясов

ПОТПӘРӘСТ *и. фар.* Потка табынучы. *[Тимер:] Кытай – мәҗүсиләр, потпәрәстләр иле.* Р.Батулла

ПОТПӘРӘСТЛЕК *и.* Нигезендә потларга табыну идеологиясе яткан дини караш; фетишизм. *Ilahi диннәр булган яһүдилек һәм христианлыкта гына түгел, мәҗүсилектә, потпәрәстлектә (потларга табыну), зәрдүштлектә һәм брaһманизм шикелле илаһи булмаган диннәрдә дә ураза бар.* Кызыл таң

ПО́Т-ПОТ *рәв. к.* **потлап**. *Казнаманан ал пот-пот көмеш-алтын.* Г.Тукай. *Император Валентиан аңа пот-пот алтын вәгъдә иткән, әмма бер потын да бирмәгән.* М.Хәбибуллин. *Тик хезмәт җимешләрен тату өчен, башта пот-пот тоз ашала, чиләкләп тир түгелә шул.* Әлмәт таңнары

ПОТХАНӘ *и. фар.* Мәҗүсиләр потка (II) табына торган гыйбадәтханә. *Хакыйкатьтә пәйгамбәр дип сине белдем, Ләкин бергә потханәгә керик инде.* Кол Гали. *Расүлуллаһ хәзрәтләре үзе дә: «И Раббым! Минем каберемне потханә кылма!» дип дога кыладыр иде», – дип язган иде.* Безнең гәҗит

ПОТЧЫ *и. иск.* Һәркөнне бер сыердан бер пот сөт савучы

ПОФ *иярт. к.* **пуф**. *[Миңсылу] сулаганда, һаваны борын аркылы эчкә тарта да ябык иреннәре аркылы поф иттереп озайтып чыгарып җибәрә.* Ш.Камал

ПО́Ф-ПОФ *иярт. к.* **пуф-пуф**. *Дояркалар эштән кайтыр вакыт җиткәнен көтәр иде дә, ыштан балакларын сызганып, итәген ике якка кыстырып, поф-поф килеп, әй тотыныр ие баскыч юарга!* А.Әхмәтгалиева

ПОФЫЛДА́У *ф. диал. к.* **пуфылдау**. *Миңсылу, нишләп болай пофылдыйсың?* Ш.Камал. – *Гафу үтенәм, яшьләр, – диде [юан ир] пофылдап, – кунагымны җүйдым.* Г.Әпсәләмов

Пофылдап алу Бераз пофылдау

Пофылдап йөрү Күптәннән, озак вакыт дәвамында пофылдау

Пофылдап кую Бер тапкыр гына пофылдау

Пофылдап тору Һәрвакыт, бертуктаусыз яки әледән-әле пофылдау

Пофылдый башлау Пофылдарга тотыну

ПОХОД *и. рус* 1) Гаскәр яки флотның, нинди дә булса бурычны үтәү өчен, бер урыннан икенче урынга күчүе; хәрби сәфәр. *Ул поход дәфтәренә нидер язды һәм, урыныннан торып, портупеяларын төзәткәләде ---.* Ш.Рәкыйпов. *Көмештән коелган поход комганы, алтын бизәкле --- кылычханҗәрләр – Бабыр, Җиһангир, Әкбәрләрнең сугыш кораллары.* М.Юныс. *Тынлы оркестр поход маршын яңгыратты ---.* Д.Галимов

2) Берәр илгә яки халыкка каршы алып барыла торган сугыш хәрәкәтләре. *Әнә шул юлдан тауга күтәрелсәң, Урта гасырларда тәре походлары белән килгән рыцарьлар салган Крак-де-Шевалье замогына килеп чыгасың.* В.Юныс. *Иерусалимны үзләренә кире кайтарырга тырышып, Көнбатыш феодаллары өченче тәре походы оештыралар.* Урта гасырлар тарихы. *XVI гасырда күпсанлы нугай атлары кертелү дворян ополчениесен ерак араларга походлар ясарлык атлы гаскәргә әйләндерергә мөмкинлек бирә.* Чын мирас

3) *сөйл.* Театр, музей, күргәзмә һ.б.ш. җиргә коллектив белән бару. *Кинога коллектив поход оештыру*

4) Берәр максат белән бер төркем кешеләрнең кая да булса баруы, сәяхәте. *--- төньякта бер-берсе белән таныш булмаган этләрне, поход чыгар алдыннан чанага җиккәнче, иң элек талаштыралар икән.* Х.Камалов. *--- туристик походлар, сәяхәтләр вакытында бик еш кына план һәм карта белән эш итәргә туры килә.* Физик география. *Оялу идеме бу, менә шулай, искәрмәстән генә ирләр өстенә килеп чыгып, аларның поход тормышларын яшерен генә күзәтеп торуы өчен уңайсызлану идеме, кыскасы, үзен ниндидер бер ярамаган эш өстендә тотылган кешедәй хис итте.* Ирек мәйданы

5) *күч.* Кемгә яки нәрсәгә дә булса каршы яисә аларны яклап чыгу. *Язучының Донбасска килүен бер культура походына, шахтёрларны әдәбиятка якынайту кампаниясенә әйләндерүләре – бу шахтёрларның пролетариат язучылары алдында үзләренә кирәкле әдәбиятны сора[вы] --- түгелме?* Һ.Такташ. *[Эшсезләр] эш эзләп тә эш тапмыйча, Айлар-еллар эшсез йөриләр. Бу тормышка протест йөзеннән Ачлык походлары ясыйлар.* М.Гафури

ПОХОДЧЫ *и.* Походта катнашучы кеше. *[Айбулатов] походчыларны зур юлга чыгулары белән котлады.* Г.Ахунов. *Тәжрибәле походчы буларак киңәш тә бирә алам хәзер: әгәр походка барырга җыенсаң, беренче эш итеп лупа, берәр плёнка, азык-төлек, гитара һәм минем язманы алырга онытма!!!* Ватаным Татарстан

ПОХОРО́НКА *и. рус сөйл.* Хәрәкәттәге армиядән хәрби хезмәткәрнең һәлак булуы турында килгән язма хәбәр. *Габдрахман абыйның уртанчы улы геройларча һәлак булган дип, авыл халкы чат саен, адым саен сөйләшкәндә, көзгә таба тагын алты похоронка өстәлде.* М.Мәһдиев. *1945 елның язында --- Илсөярнең әнисе коточкыч хәбәр ишетеп кайтты: Кәһир абыйларның Зәкиләренә похоронка килгән!* Р.Хәбибуллина. *Малайларының Кытай чигеннән килгән похоронкасын һаман шул Сәхилә кертеп бирде.* Г.Гыйльманов

ПО́Х-ПОХ *иярт.* Басым астында өзек-өзек һава, газ яисә пар чыкканда ишетелә торган ярым шартлаулы тавышны белдерә

ПО́Х-ПОХ ИТҮ *ф.* Шундый тавыш чыгару. *[Бүген] завод-фабрика биналарының кабыргаларыннан һәрвакытта пох-пох итеп өзек-өзек ак пар чыгарып торган тын юллары эштән туктaлганнар иде.* М.Гафури

ПО́Х-ПОХ КИЛҮ *ф. к.* **пох-пох итү**

ПОХЫЛДА́У *ф.* Авыр сулау, пуфылдау

Похылдап җибәрү Кинәт похылдый башлау

Похылдап кую Бер тапкыр похылдау

Похылдый башлау Похылдарга тотыну

ПОХЫН *и. диал. мыск.* Симезлектән өзек-өзек тын алучы, үз-үзен көчкә күтәреп йөрүче кеше яки хайванга карата әйтелә

ПО́ЧЕРК *и. рус* 1) Һәркемнең үзенә генә хас булган язу рәвеше. *Кешенең почеркы бертөсле була икән, үзгәрми икән ---.* Ш.Галиев. *--- анда Гөлсемгә*

адресланган хат та ята иде. Ул язу почеркыннан ук таныды: Илдустан. Р.Кәрами. *Кызгылт конверт ертылды, Атабаевның авызы да ерылды. Ә язылышы, сүзләре, хәрефләре, почеркы – һәммәсе дә үзе кебек матур, шатлыклы елмаеп торалар...* Г.Иделле

2) *күч.* Берәр эш башкарганда, иҗат иткәндә ачык чагыла торган үзенә генә хас үзенчәлекләр җыелмасы. *[Укучыларның] язучыны, үзен күрмичә дә, китабы, язу ысулы, әдәбиятчылар теле белән әйтсәк, почеркы аркылы тануларын да без иҗат тәжрибәбездән күптән беләбез.* Г.Минский. *Ул үзенә бер төрле Әхмәт. Биографиясе белән дә, кеше буларак та, иҗади юлы һәм әдәби почеркы ягыннан да.* Ф.Хөсни. *Поликлиника табиблары, үзләренә күренергә килгән авыруларны караганда, кабырга тиресе өстендәге сизелер-сизелмәс кенә күренеп торган җөй күреп, хәтта сокланып: «Бу – доктор Клистов почеркы», – диялар иде.* Г.Галиев

ПОЧЁТ *и. рус сөйл.* Хөрмәт; игътибар, ихтирам. *Кая барсаң – почёт, бөтенесе хәленне сорый.* М.Мәһдиев. *Шулай бер заман Казаннан, бик хәтәр вәкилләр иәртеп, тагын кунак килеп төште. Мәскәүдән, министрлыктан кешеләр бар. Район өчен дәрәҗә, почёт!* А.Гыйләҗев

◊ **Почёт тактасы** Мактауга, хөрмәткә лаек кешеләрнең исеме язылган яки сурәте куелган махсус стенд; мактау тактасы. *Чәчәккә күмелгән үзәк мәйданына бездәге почёт тактасын хәтерләткән «Изгелек юлы»ның схемасын ясап элгәннәр.* М.Юныс

ПОЧЁТЛЫ *с.* 1) Хөрмәт йөзеннән сайлана, бирелә торган. – *Мин дүрт ел буе, кулыма корал тотып, илемне сакладым, күкрәк тулы орден-медаль белән кайттым. – Киевның почётлы гражданины, дип тә өстә инде.* Р.Кәрами. *Сезне, Ислам абый, безнең оешманың почётлы пионеры итеп кабул итәбез.* Казан утлары

2) Хөрмәт йөзеннән оештырылган. *Бюро әгъзаларыннан булган бер кыз кулына кызыл тасмалар тотып керде. Почётлы каравылга басканнар беләгенә бәйләр өчен.* Ә.Баян. *Почётлы каравылга язучылар баса: өлкәннәр, заман-дашлары, урта буын, яшьләр.* Г.Ахунов

3) *сөйл.* Аерым хөрмәткә, игътибарга лаек кешеләр башкара торган. *--- Исламнур --- бисмилласын әйтеп, --- үзенә йөкләнгән иң почётлы эшкә керешә.* А.Гыйләҗев. *Сезгә җаваплы һәм почётлы эш тапшырабыз: парадта байракны сез тотачаксыз.* Р.Хәбибуллина

4) Дәрәҗәле, абруйлы. *Ансы шулай инде, Йосыф, чик саклау – почётлы эш...* Г.Кашшаф. – *Сугыш пожарында яну почётлырак! – дип, Мушков аңардан көлеп җавап кайтарды.* Х.Камалов. *Туй мәҗлесләре вакытында алар бик почётлы урында, түр башында утырдылар.* В.Астафьев

ПОЧКАК *и.* Ат, поши һәм башка хайваннарның тәпи, бот, сыйрак тиресе; гомумән кием теккәннән калган күн яки тире кисәге. *Киемчеләр кием кисәдер, Кала микән аның почкагы.* Җыр. *[Гыймран] кара җеп белән бер кара почкак сорап алды, ике җиң очына да тигез итеп ямау салып чыкты.* Ш.Маннур. *Тире-яры почкакларыннан качып-посып теккән товарларын корсакларына урап, --- гамьсез кыяфәт белән йөрүче базар аристократлары да шушында чуала.* А.Гыйләҗев

ПОЧКАКЛА́У *ф.* Тиредән аслык салу. *Чаңгыларны почкаклау*

ПОЧМАК *и.* **1.** 1) Ике нәрсә кисешә торган урын; мөеш. *Көҗмә дәдәйнең тегермән өе почмагыннан, эре адымнар белән юыртып, кара тарантас җигелгән кара айгыр килеп чыкты.* Х.Сарьян. *Гордов --- вокзал эченә керде. --- Почмакны чегәннәр биләп алган.* Ш.Рәкыйпов

2) Ике урам кисешә торган урын; чат. *Гадил, машинасын урам почмагында туктатып, мәрхүмәне ничек алып чыкканнарын тәрәзә аша күзәтеп утырды.* М.Маликова. *Төргәкләрен машина эченә ыргыткач, ул урам уртасына чыкты, почмакка кадәр барып, тыкрык ягына карады ---.* Р.Мирхәйдәров

3) Берәр яссы әйбернең ике ягы кисешкән урыны, чите. *Өстәлнең почмакларында дүрт арыслан башы бар ---.* А.Тимергалин. *Ул көнне Фәхерниса карчык --- сандык төбеннән күптән салып куйган меңенче чәйнең почмагын китеп алды да, лепердәп кенә самавыр кайнагач, күрше-күләнне чәйгә дәште.* М.Мәһдиев

4) *мат.* Бер ноктадан чыккан ике туры арасындагы яссылык. *Бер очтан мин корабльнең тизлек һәм почмак үлчәү җиһазларын да ватып ташладым.* А.Тимергалин. *Почмак координатларын үлчәүдә генә түгел, тоткарлыкларга каршы торуда да бу методның өстенлекләре зур.* Р.Кәрами. *Башлангыч мәгълүматларга караганда, --- орбита яссылыгының экваторга карата авышлык почмагы 65 градус 4 минут.* Галәмгә юл

5) *махс.* Берәр нәрсәне үлчәү берәмлеге буларак бер ноктадан чыккан ике сызыкның үзара авышлык дәрәҗәсе. *Илле бишне почмак градуслары дип саныйк.* А.Тимергалин

6) Өйнең, фатирның, бүлмәнең бүленгән бер өлеше. *Бәлки, берәрсе, картлыгына хөрмәт йөзеннән, аны үз йортына алып, аерым почмак биреп, кадерләп асрый торгандыр.* Г.Ибраһимов. *Бүлмәнең тәрәзә янындагы якты өлеше – шәхси шөгыльләр урыны. Монда укучы балага дәрес хәзерләү өчен җиһаз куярга яисә кечкенә балаларга уйнау өчен почмак оештырырга була.* Тигез гомер итегез!

7) Өйнең, фатирның, бүлмәнең хак түләп вакытлыча файдалануга бирелә торган өлеше. *Башкаларның ничек яшәгәнен: кеше почмакларында интегүче, акча алганнан алганга тиенен санап тотучылар юк дип беләме?* Р.Кәрами. *Аның бит әле, уку өчен түләүдән башка, балаларына яшәргә почмак табарга, тамак туйдырырга --- кирәк.* Татарстан яшьләре // Гомумән тору урыны. *Гаиләм, җылы почмагым, тыныч тормышым, яшәү дәверендә барлыкка килгән элемтәләрем – барысы да түбәндә калды.* М.Юныс. *Аның кайчан да булса үз гаиләсе булганын, берәр торыр почмагы бармы-юкмы икәнен --- белми иде.* Р.Мирхәйдәров. *Хатынының чыбык очы туганнарында берәр атна яшәделәр микән, «иркен почмак» эзләп йөргән җиреннән Рәхилә юкка чыкты.* А.Әхмәтгалиева

8) Төрле тикшеренүләр, түгәрәкләр, өйрәнүләр алып барыла торган махсус урын, бүлмә. *Алар кергәндә, кызыл почмак кызлар белән тула язган иде инде*. Ш.Рәкыйпов. *Бервакыт кызыл почмакта утырганда Шмагин Казан радиостанциясен тотты*. М.Мәһдиев. *Шахмат почмагы кемнең дә исен китәрлек*. А.Тимергалин

9) *диал.* Авыл өйләрендә такта яки чаршау белән бүленеп алынган кечкенә як, аш-су әзерли торган мич алды ягы. *Хуҗа хатын миңа, күрмисеңмени, дигән сыман итеп карап алды һәм почмак якка кереп китте*. З.Вәли. *Кулындагы шәмен өстәлгә куеп, Варвара Сергеевна такта белән бүленеп алынган почмак ягына кереп китте*. Язмышлар яңарганда

10) Нинди дә булса бер як, тараф. *--- корабның һәр почмагында сине әлеге күмәк ялгызлык хисе сагалап тора*. М.Юныс. *Ләкин Әскәрев кайтмады. Коридорның әле бер, әле икенче почмагында эштеренеп йөрде*. М.Мәһдиев. *--- керә-керешкә билбавын чишеп, караңгы почмакка ташлады ---*. А.Гыйләҗев // Нинди дә булса бер урын, җир. *Кече яшеннән миенең бер почмагында сакланып калган --- мизгелне бөтенләй югалтудан курыккандай, бу өйдән тизрәк чыгып китәсе килде*. Р.Хәбибуллина. *Ул, кабаланып, мине аулаграк почмакка алып килде дә чемоданны тикшерергә кереште*. М.Юныс. *Аның хәзер бөтен кайгысы Әлфия: кайчан эшкә бара, кайчан кайта – нинди генә почмаклардан күзәтми ул аны*. З.Кадыйрова

11) *сөйл. иск.* 25 сумлык купюра яки 25 сум акча. *[Гыймади кулын сузып:] Почмак ярыймы? [Гайфулла, Гыймадины этеп җибәреп:] Нәрсә, сорамас борын хак бирәсең?* К.Әмири. *Әмма мөгәричен дә инде чамасыз сорыйсың. Ике пальтога бер почмак җитмәгәнмени?* М.Мәһдиев

12) *күч.* Беркемгә дә белгертми, сиздерми, тирән сер итеп сакланган урын; күңел, йөрәк түре. *Аның болай --- күз көеге булып йөрүеннән котыласы килү теләге күңеленең яшерен бер почмагында торган кебек була*. М.Гафури. *Күңелдә дә җылы почмак юк*. М.Маликова. *Илдус Әлфия йөрәгендә үзенә бер кечкенә почмакка да риза, тик үз почмагына*. З.Кадыйрова

13) *күч.* Үзәктән бик ерак урын, төбәк. *Мине районның иң арткы почмагындагы бер колхозга председателе үзе машинага утыртып алып китте*. Н.Дәүли. *Эләктерсәләр инде, [жандармнар сине] Енисейга гына озатмаслар, Якутстанның ерак, караңгы почмакларына ташларлар*. Г.Ибраһимов

14) *күч.* Ил, шәһәр һ.б.ш.ның читтәге бер өлеше, районы, төбәге, урыны. *Хәнифә апаның улы Фазыл Агиш безгә Анкараның барлык почмакларын күрсәтеп чыкты, безне төрек дөньясына алып керде*. Г.Ахунов. *КамАЗ төзелә башлауга --- йөзләгән профессия кешеләре белән бергә, илнең бөтен почмакларыннан романтик күңелле --- кешеләр дә җыйналды*. Язмышлар яңарганда. *Космик корабльнең нигезенә аның идеяләре салынган, ә хәзер инде илебезнең төрле почмакларында әнә шул идеяләр металлда гәүдәләнә*. Галәмгә юл

2. *с. мәгъ.* Ике предмет яки ике як кисешкән урынга урнашкан. *Ул, үз янындагы почмак өстәлгә таянып, башын бераз вакытка ике кулы белән кысып торды*. Ф.Әмирхан. *Бәһау олы урам юлыннан елга урамына борылганда, почмак йорттан бер төркем халык чыкты*. А.Таһиров

3. почмактан *рәв. мәгъ. күч.* Хыянәтчел, астыртын, качып-посып (ату, үтерү, һөҗүм итү тур.). *Аның өчен бик күп кыюларны үтерделәр качып почмактан*. Ә.Исхак

◊ **Почмакка бастыру** Балага җәза бирү өчен, аны өйнең, бүлмәнең диварына каратып бастыру. *Кичә Валерик Реваны этеп екты. Аны почмакка бастырдылар*. Г.Минский. **Почмакка кую** *к.* **почмакка бастыру**. **Почмакка кысрыклау** Бәхәстә каршы якка чигенергә юл калдырмау. **Почмакка кысу** *к.* **почмакка кысрыклау**. *Фуатка ул хәлне бик кыска рәвештә генә аңлатты да, тын алырга ирек бирмичә: – Кайчан башлыйсың тренировкаларны? – дип, почмакка китереп кысты*. Э.Касыймов. **Почмакка постыру** *к.* **почмакка кысрыклау**. **Почмакка терәү** *к.* **почмакка кысрыклау**. *Грасис, Мирсәеткә уйлап торырга да ирек бирмичә, сорау артыннан сорау яудырырга кереште. Әйтерсең аның төп максаты Мирсәетне почмакка китереп терәү иде*. Р.Мөхәммәдиев. **Почмак саен** Бөтен җирдә, тирә-якта, теләсә кайда. *Әниләрен күндерү җиңел булмас анысы, авыл халкына да бер сабантуй булыр, почмак саен авыз чайкарлар*. З.Кадыйрова

ПОЧМАКЛАНУ *ф.* 1) Почмак хасил булу, почмак ясалу. *Почмакланып тезелешкән торналар каядыр очалар*. Т.Нәбиуллин

2) *күч. Дәрт, күңел* сүзләре белән килгәндә: канәгать булу, күңел булуны белдерә. *Байның кәефе тәмам килде, дәрте почмакланды*. М.Галәү. *Бара торгач, Гәрәйнең дәрте почмакланды: аучылык хирыслыгы сүрелде*. А.Гыйләҗев. *Һай, Сәрвәр апам-түтекәм, ут чәчкән чакларыңны оныттың дамы?! Дәртең почмакланса, урам уртасында да сузылып ятарсың*. Н.Гыйматдинова

Почмаклана бару Торган саен ныграк почмаклану

Почмаклана башлау Почмаклану билгеләре күренү

Почмаклана төшү Бераз, беркадәр почмаклану

Почмакланып җитү Тулысынча, бөтенләй почмаклану. *Дәрт почмаклануып җитмәде*. М.Маликова

Почмакланып калу Ниндидер сәбәпләрдән соң почмаклану

Почмакланып килү Аз-азлап, акрынлап почмаклана башлау

Почмакланып тору Почмак хасил иткән хәлдә булу

ПОЧМАКЛАТЫП *рәв.* Почмак рәвешендә, почмак формасында. *Кинәт минем --- «П» хәрефе кебек почмаклатып салынган зур шәһәр йортының биектәге катыннан төшкән карашыма --- бер адәмзат сыны чалынды*. А.Хәлим

ПОЧМАКЛА́У *ф.* Почмак рәвешенә китерү, почмак ясау. *Хәдичә белән Әнвәр почмаклап ясалган озын кәнәфигә утырдылар*. К.Тимбикова. *Аларның сап-сары эре нараттан, биек*

итеп, алты почмаклап җиткергән өйләре, эшләнә торгач, калай түбәле дә булып чыкты. Ф.Яхин. *Сугыш хатлары кебек почмаклап төрелгән конверттагы хатта, чыннан да, шигырь язылган булып чыкты.* Гасырлар авазы

Почмаклап кую Тиз генә почмаклау

Почмаклап чыгу Булган берсен почмаклау, һәрберсен почмаклау

ПОЧМАКЛЫ *с.* 1) Күпмедер, ниндидер почмагы булган, (бер яки берничә) почмактан торган. *Минем каенанамның авылда алты почмаклы, түбәсе калай белән япкан --- өе бар.* Н.Дәүли. *Гайшәнең баш очында биш почмаклы йолдыз уелган ак таш тора, язуы да күңелгә үтеп керерлек*. А.Гыйләҗев. *Урта бер җиренә, колгага дүрт почмаклы җилкән эленгән һәм --- кызыл буяу белән сакаллы баш сурәте ясап куелган иде.* А.Тимергалин

2) Почмакланып килгән, почмаклап эшләнгән

ПОЧМАКЛЫК *и.* 1) *мат.* Билгеле бер сандагы яки рәвештәге почмаклары булган геометрик фигура. *Биш почмаклык. Кысынкы почмаклык*

2) *махс.* Почмаклар сызу, перпендикулярлар үткәрү өчен, өчпочмак рәвешендәге сызым коралы; *русчасы:* **угольник**. *Сантиметр, кайчы, почмаклык, булавкалар[дан] --- башка үлчәү алырга мөмкин түгел.* Һөнәрленең кулы алтын

3) *махс.* Төзү эшендә почмакларны сызу һәм үлчәү өчен кулланыла торган җайланма; *русчасы*: **малка**

4) *махс.* Аркылы кисеме почмаклы фигура булган тимер эшләнмә, төзү материалы. *Катылык кабыргалары өчен стандарт швеллерлар һәм почмаклыклар кулланылган*. Фән һәм тел

ПОЧМАКЛЫ́-ТҮРЛЕ *рәв. диал.* Бер ишеккә, бер түргә таба, арлы-бирле. *Почмаклы-түрле йөренү*

ПОЧМАКТА́Н БӘРҮ *и. спорт к.* **почмактан сугу**

ПОЧМАКТА́Н СУГУ *и. спорт* Футболда һөҗүм итүче командага тупны югалтканнан соң да һөҗүмне дәвам итәргә мөмкинлек бирә торган алым: тупны кырның бер почмагыннан тибеп уенга кайтару. *XIX гасырга кадәр Англиянең футбол ассоциациясе тагын берничә кагыйдәгә үзгәреш кертә: тупның үлчәме билгеләнә (1871 ел), тупны почмактан сугу (угловой) алымы кертелә ---.* Сабантуй

ПОЧМА́К УРТАЛЫГЫ *и. мат. иск.* Биссектриса

ПОЧМА́КЧА *с. мат., физ.* 1) Почмак (*5 мәгъ.*) үлчәүгә бәйләнешле; почмак үлчәменә бәйле рәвештә каралган. *Почмакча тизләнеш почмакча тизлекнең вакыт берәмлегендә күпмегә үзгәрүен күрсәтә.* Физика. *Бу очракта бары тик почмакча һәм сызыкча зурлыклар арасындагы бәйләнешләр генә өстәлә.* Физикадан мәсьәләләр һәм күнегүләр җыентыгы. *Мондый фикер молекуляр векторның почмакча күчеше потенциаль чокырларның үзәкләре арасындагы чикле почмакларга борылу формасында башкарылуны аңлата*. Фән һәм тел

2) Почмак белән үлчәнә торган. *Почмакча тизләнеш почмакча тизлекнең вакыт берәмлегендә күпмегә үзгәрүен күрсәтә.* Физикадан мәсьәләләр һәм күнегүләр җыентыгы. *Бирелгән тизгелдә А ноктасының тизлеге билгеле булса, нинди очракларда АВ шатуныңың АВω почмакча тизлеге дөрес исәпләнүен бәяләгез.* Фән һәм тел

ПОЧМА́К ЯК *и. к.* **почмак (***9 мәгъ.). Хәкимулла, каникулга кайткан Нургали, күрше Миңлегали атлар җигеп, --- уңыш таратып йөрделәр, һәр йортта аларны аш-су белән каршыладылар, ара-тирә почмак яктан гына, чынаяк чокырына салып, ачы бал бирүчеләр дә булгалады.* М.Мәһдиев

ПО́ЧТА *и. пол.* 1) Хат, посылка, акча, вакытлы матбугат һ.б.ш.ны бер җирдән икенче җиргә җибәрә һәм тапшыра торган элемтә учреждениесе. *Почта, телеграф һәм элемтә транспорты билгеләнгән вакытта берьюлы ставка боерыкларын үтәүдән туктый*. Ш.Рәкыйпов. *Почта бүлегендә Анрины ике ашыгыч телеграмма көтә иде.* А.Тимергалин. *Зур илнең аерым өлешләре арасында почта элемтәсе җайга салына.* Урта гасырлар тарихы

2) Шул учреждение урнашкан бина яки бүлмә. *--- почтасы, әйбәт китапханәсе, --- кибете, урта мәктәбе бар мең ике йөз хуҗалыклы бу авылның.* Ш.Рәкыйпов. *Салкынны, бураннны сылтау итеп, хат ташучы почта бүлегенә йөрми.* М.Мәһдиев. *Хәер, шәһәрдәге бөтен нәрсә бар монда. Уты, радиосы, --- кунак йорты, почтасы, --- тагын әллә нәрсәләр бар.* Г.Мөхәммәтшин

3) Шундый учреждение тарафыннан башкарылган гамәл, адресатка тапшыру чаралары. *Гордов күкрәгендәге орденнан күзен ала алмаган егет сузып кына: – Ярамый. Чит кешене почта каретасына утыртырга ярамый, – диде.* Ш.Рәкыйпов. *Менә хәзер почта атында кайтып киләм.* Инешләр Иделгә кушыла. *Өй подъездындагы җимерек почта әрҗәләренең кыйшайган авызларына ара-тирә кемнәрдер белдерүләр белән тулган күпбитле гәҗитләр кыстырып киткәлиләр.* Татарстан яшьләре

4) *сөйл.* Шундый учреждениеләр тарафыннан китерелгән әйбер (хат, посылка, газета-журнал, бандероль һ.б.ш.); корреспонденция. *Латиф өстәлендә яткан бүгенге почтаны караштыргалады.* А.Расих. *– Телеграмманы алмадыңмыни? – Юк, – диде Эдлай. – Бүген почта булмады әле.* А.Тимергалин. *Әти, ашагач, – китап, почта кайтса, гәзит-журнал укый.* Г.Мөхәммәтшин

5) *тар.* Хат, посылка һ.б.ш.ны кабул итү һәм җибәрүдән тыш, атлы экипажларда даими рәвештә пассажирлар йөртү белән шөгыльләнгән учреждение. *Юк, моны элекке заманда, толып яки чикмән киеп, чана башына утырган, почта станциясендә кайнар борщ ашап чыккан кызыл битле кучер җырлагандыр...* М.Мәһдиев

6) *сөйл. к.* **почтальон**. *Кичке почта китергән хат һәм газеталарны кулыма алам.* Ф.Әмирхан. *Хәзер почта йөргән чакны чамалап тыңланам, коридорда аяк тавышы ишетелсә, ишегебезгә ул кагыла төсле...* А.Гыйләҗев. *Конвертны төкереклəп ябыштырдым да түбән оч почта Сәкинәгә чаптым.* Шатлыклы кайгы

7) Күңел ачу кичәләрендә хатларны тышына язган номерлар буенча махсус

таратып йөрүдән гыйбарәт уен (һәр кешенең күкрәгенә номер беркетелгән була). *Почта уенында Уфаның иң алдынгы, һәр җәһәттән иң өстен торган бер туташка --- көйле итеп бернәрсә яздым.* Ш.Бабич. *[Хәят] почта уены вакытында килгән хат һәм язуларны кабат-кабат кулга алып укып карый.* Ф.Хөсни

8) Торак пункт исеменең беренче хәрефенә башланган сүзләрне тиз-тиз санап чыгудан гыйбарәт интеллектуаль уен

ПОЧТАЛЬОН *и. ит.* Хат, газета, журнал һ.б.ш.ны аларның ияләренә (адресатларына) тапшырып йөрүче почта хезмәткәре; хат ташучы. *Ул, бәгырькәем, сугыштан хатым килгән саен, почтальонга сөенче биргән.* Ш.Рәкыйпов. *Элек почтальон күренүгә, «хат бармы» дип чекерәеп каршысына чыга торган идем ---.* А.Гыйләҗев. *Ә газета-журналларны нәшер итүчеләр пошаманда: почтальоннар булмагач, халыкны матбугатка кем яздырыр*? Татарстан яшьләре

ПОЧТАМТ *и. нем.* 1) Шәһәрнең үзәк почта учреждениесе. *Почтамт директор һәм почтмейстердан башка утызга якын хезмәткәр тота.* Эзләнүләр, уйланулар, табышлар. *Сораргa бик талпындык без башкаланың Баш почтамтында эшләүчеләрдән почта хәлләрен*. Татарстан яшьләре

2) Шул учреждение урнашкан бина

ПОЧТАРЬ *и. рус сөйл. к.* **почтальон**. *[Листовкаларны] бу юлы инде үзе белән алмыйча да мөмкин булмады, чөнки легион почтарьларының башкача килү ихтималы юк, ара бик тар калган иде.* Ш.Маннур

ПО́ЧТАЧЫ *и. сөйл.* Почтада эшләүче, почта хезмәткәре; почтальон. *Ул котларга килгән монда Почтачылар бәйрәмен.* М.Җәлил. *Россиядә халыкка барлыгы 320000 почтачы хезмәт күрсәтә.* Казан утлары

ПОЧТМЕ́ЙСТЕР *и. нем.* Россиядә 1917 елга кадәр почта конторасы белән идарә итүче кеше. *– Соң, хатыны белергә тиеш бит инде, – дип ачуланып әйтеп куйды почтмейстер*. Р.Вәлиев. *Почтамт директор һәм почтмейстердан башка утызга якын хезмәткәр тота.* Эзләнүләр, уйланулар, табышлар

ПОЧТЫ́Р-ПОЧТЫР *иярт*. Берәр нәрсәне ялаганда, чәйнәгәндә яки эчкәндә барлыкка килгән тавышны белдерә. *Ә кәҗә тәкәсе почтыр-почтыр килеп банканы яларга кереште*. Р.Мөхәммәдиев

ПОЧЫК I *и.* 1) *бор*. Нәрсәнең дә булса яртысы

2) *бор.* Ике пот, ике подаука (32 килограмм чамасы) яки ярты батманга тигез авырлык берәмлеге. *Батман бирсәң, күп булыр; Подаука бирсәң, аз булыр; Почык бирсәң, тамандыр.* Бәет. *Үзендә – батманы, кешедә – почыгы.* Мәкаль

3) Шундый авырлыктагы әйбер сыешлы савыт

4) *диал.* Агач кабыгыннан эшләнгән чиләк, тубал; зур тырыс

5) Кечерәк кисәк, кечерәк өлеш. *[Кояш тотылганда:] Сүнә көнебез [кояшыбыз], Кала бер почык.* Н.Исәнбәт

6) *диал.* Дисәтинәнең сигездән беренә тигез җир үлчәү берәмлеге

ПОЧЫК II *с.* Очы өскә күтәрелгән, курнос (борын тур.). *Муенына кызыл галстук таккан бу почык борын нәселгә тап төшермәс ир булыр шикелле.* Ш.Рәкыйпов. *Бер көнне пилмән исе килә торган фатирдан почык борынлы, чепи күзле бер ир чыкты*. З.Хәким. *Ах, шул кызыйга иң кыйммәтле туфли бүләк итәргә иде! Ләкин ничек? Кабул итмәс бит ул почык борын.* М.Мәһдиев

ПОШАЛАНУ *ф. диал.* Берәр нәрсәгә пошыну, борчылу. *--- ул кайбер вакыт киленененең артык иркен, артык уенчак кылануыннан да пошаланып кына: «Балам, Сабир, безнең Камиләбез артык җиңел, артык җиңел лә!» – дип куя.* Г.Ибраһимов. *Хәзер РТС әйтә, председательдән сорагыз, ди. Ә Самат бу турыда аз пошалана.* Г.Мөхәммәтшин

ПОШАМАН *и.* **1.** 1) Нык борчылулы, аптыраулы, куркулы, көенүле халәт. *– Җиңүчеләрне хөкем итмиләр! – дип, Римма Сөенчалин күңелендәге пошаман чаткысына май салгандай итте.* Х.Камалов. *Шулай чарасыз пошаманда торганда, Исхакның күзенә арык атын җай гына атлатып килүче кабык арбалы, чылгый мыеклы бер агай чалынды.* А.Гыйләҗев. *Сәйдә апа пошаманда. Кияү балакаем китәр инде, ди.* Н.Гыйматдинова

2) Үкенеч, үкенечкә калу

2. *с. мәгъ.* Артык борчылып, пошынып йөри торган (кеше тур.)

◊ **Пошаманга бату** *к.* **пошаманга төшү**. *Иртә таңнан пошаманга баткан ирнең гыйшык уйнарга хәле дә, теләге дә юк иде шул.* З.Кадыйрова. **Пошаманга бирелү** *к.* **пошаманга төшү**. *Мәлих үзәге өзелгәнче, колаклары чыңлаганчы тырышып тыңлавына карамастан, таныш моң --- колакка чалынмады. Пошаманга бирелеп, урамга чыкты*. Ә.Баян. **Пошаманга калу** *к.* **пошаманга төшү**. *Саша соңгы ике кич инде өйдә кунганы юк, балалар да пошаманга калып йөриләр ---.* З.Кадыйрова. *– Нишлибез? – ди участок башлыгы, пошаманга калып. Мастер аны тынычландырды: – Ярар, җаен табарбыз, борчылмагыз.* Р.Кәрами. *Кәмран, чыпчык тезеннән генә булган күлдәвеккә очраса да, пошаманга кала.* Р.-Н.Гүнтәкин. **Пошаманга салу** *к.* **пошаман салу**. *Узган төндәге хәлләр аны тәмам пошаманга салды, гүя әлеге дә баягы җәрәхәтенә янә тоз сиптеләр...* Р.Мөхәммәдиев. *Юк, билгесез юл, җиде ят авыл аны пошаманга салмый --- иде.* Н.Гыйматдинова. *Әлеге фикер ата-аналарны да, югары сыйныфларда укучыларны да пошаманга салды*. Татарстан яшьләре. **Пошаманга төшү** Нәрсә эшләргә дә белми аптырау; борчылу, пошыну, куркуга калу. *Мирсәет пошаманга төште: әңгәмәдәше үзүзен белмәс хәлгә якынлаша, бөтен харчевняны яңгыратып кычкырып сөйләшә.* Р.Мөхәммәдиев. *Егет, пошаманга төшеп, бик озак дәшмәде*. Р.Хәбибуллина. *Ирек, үзеннән күпкә олы кешеләрнең бу ишек каршында дер калтырап, куркып торуларын, каушап килеп чыгуларын күргәч, ниндидер пошаманга төште*. Ф.Садриев. **Пошаман китү** Борчылу, аптырау. *Камил пошаман китебрәк дәвам итте: – Былтыр сораган идем – бирмәделәр.* Х.Сарьян.

Пошаман салу Борчуга төшерү, борчулы уйлар тудыру, эчне пошыру, аптырашта калдыру. *Әллә яратмый микән ул мине хәзер? Аның болай булуы минем эчкә пошаман сала.* Ш.Маннур

ПОШАМАНЛАНУ *ф. төш. юн. к.* **пошаманлау**. *Әбием пошаманлана: – Салкын тияр, улым, – ди.* Р.Нуруллин

ПОШАМАНЛА́У *ф.* Борчылу, куркуга калу, пошаманга төшү; нәрсә эшләргә дә белми аптырау

Пошаманлап бетү Бик каты, тәмам пошаманлау

Пошаманлап йөрү Озак вакытлардан бирле пошаманлау

Пошаманлап тору Гел пошаманлау; әле, хәзерге вакытта пошаманлау

Пошаманлый башлау Пошаманлау билгеләре күренү

ПОШАМАНЛЫ *с.* Аптыраулы, борчулы, куркулы. *Ышанып иярген кешеләрнең ышанычларын аклый алырмынмы, диңгез яндырырга вәгъдә иткән песнәк хәленә төшмәмме, дигән пошаманлы уй борчый [аны].* И.Гази. *Бикиевнең тавышы моңсу, пошаманлы иде.* Х.Камалов. *Авылның югары очындагы салам түбәле кечкенә усак өйдә яшәүче Мотаһир андый пошаманлы уйлардан азат иде.* Р.Кәрами

ПОШАМАНЛЫК *и.* Күңел тынычсызлыгы, аптыраган хәлдә булу. *Тышкы яктан безнең өлкән механик та кавказлыларча кайнар күренә иде, ә эчендә таштай каты торганлык, дөм-кара пошаманлык ята.* М.Юныс

ПОШАМАНСЫЗ *с.* Бернәрсәгә дә борчылмый, аптырамый торган, ваемсыз, гамьсез. *Беренче карашта Әмин әкәне чынлап кайгыра да, борчыла да, хәтта кәефсезләнә дә белмәгән гаҗәп ваемсыз, пошамансыз бер кеше диярсең!* Ә.Еники

ПОШИ *и. фин-угор* Боланнар семьялыгыннан күшәүче, имезүче партояклы эре хайван (иркәкләренең мөгезләре киң, тармаклы була). *Берничә көннән аның өстендә поши тиресеннән тегелгән көрән куртка һәм җилкәсендә тагын ярты еллык стипендиясен йотарлык бурыч.* М.Юныс. *Күзләремә ышанырга-ышанмаска белмим: уязлыкта поши бозавы ята.* Р.Мөхәммәдиев. *Җәйләр җиткәч, без синең белән урманнар айкарбыз, улым. Мин сине поши малайлары белән таныштырырмын.* Н.Гыйматдинова

ПОШИМАН *и. диал. к.* **пошаман**. *Хәдичә түтинең теле пышылдап намаз догаларын укыган булса да, күңеленә тагын пошиман төште: «Ай алла, ул хафалы җанына ни булды инде тагын? ---»* Г.Бәширов. *Хәбирнең эченә пошиман керде. Мондый гадәте булгач, бу самолётның тагын бер тәүлек утыруы мөмкин ләбаса.* Ш.Хөсәенов. *– Бөтен малымны терек вакытымда сиңа тапшырыйм. Соңыннан пошиман булырсың. Мине кайгыртма, – дип, күп нәсыйхәтләр әйләде.* Дастан

ПОШКУ *ф. диал.* 1) Тишектән яки ярыктан төтен яки газ чыгып тору

2) Сасу, исләнү

Пошкып тору Һәрвакыт яки даими рәвештә пошку

Пошкып чыгу Бик нык пошку

ПОШКЫЛДА́У *ф.* Пош иткән тавыш чыгару. *Күректән пошкылдап һава чыкты.* А.Хәлим. *Машинаның пошкылдап килеп туктавына сискәнеп киттем.* Г.Гыйльманов

Пошкылдап алу Берара пошкылдау

Пошкылдап җибәрү Кинәт пошкылдау

Пошкылдап кую Бер тапкыр пошкылдау

Пошкылдап тору Даими яки әледән-әле пошкылдау

Пошкылдый башлау Пошкылдарга тотыну

ПОШКЫРТУ *ф.* 1) *сөйл.* Берәр сыеклык яки газны көч, басым белән бөркү, сибеп чыгару. *Фонтан күленең уртасында мәрмәр бала фәрештә скульптурасы курай аркылы су пошкыртып тора.* Ш.Камал. *Ул мотоциклын пошкыртып килеп туктаганда, барлык эш, кеше, техника бүленеп беткән иде.* Г.Гыйльманов. *Әтисеннән чәлдергән махраны тирән генә суырды, авызыннан да, борын тишекләреннән дә төтен пошкыртып чыгарды.* В.Астафьев

2) Борын тишекләреннән тавышландырып һава, сулыш чыгару. *Аның өчен иң авыры, күңел болгатканы Чәмәтнең борын пошкыртуы булды ---.* Х.Сарьян

3) Тәмәке, махорка кебек никотинлы нәрсә тарту. *Абыйсының нинди «уен» белән мавыкканын Йосыф тиз сизенде: ул теге малайлар белән качып кына сасы исле махра пошкырта иде.* Н.Гыйматдинова. *Ниһаять, илгә тәмәке китергән зыянны, кайгы-хәсрәтне аңлаучы түрәләр табылды булса кирәк: җәйдән башлап җәмәгать урыннарында пошкырту тыелачак.* Татарстан яшьләре. *Бергәләшеп тәмәке пошкырткан ир белән хатын яныннан узып, фатирга кереп киткәндә: «Мондый язмыштан үзең сакла, Ходаем», – дип уйладым мин.* Шәһри Казан

4) *күч. гади с.* Кемне дә булса берәр урыннан куу, куып чыгару. *Патшасы белән берәттән боярларны да пошкыртырга кирәк.* А.Таһиров. *[Фәридәне] ир-атка карата үзен бик усал тота дип сөйлиләр, табагач белән пошкыртып чыгармас микән өеннән?* Ш.Бикчурин

5) *күч.* Ачулану, туздыру. *Рамиснең җавабы юк иде, әтисе дә бик каты пошкыртып кайтарган иде бугай.* З.Кадыйрова

Пошкыртып алу Берара пошкырту

Пошкыртып җибәрү Кинәт пошкырту

Пошкыртып кую Бер тапкыр пошкырту

Пошкыртып тору Даими яки әледән-әле пошкырту

ПОШКЫРУ *ф.* 1) Борын тишекләрен киңәйтеп, тавышландырып сулыш чыгару. *--- ул пошкыра-пошкыра ярга таба колач сала.* А.Тимергалин. *Менә ат, Көбәне сизепме, ашаудан туктады, колакларын шомартты, пошкырды ---.* Т.Нәбиуллин. *Тирмә тирәсендә атлар пошкырганы, сыерлар мөгрәгәне ишетелә.* Ф.Мансуров

2) Тавышландырып өзек-өзек һава, газ һ.б. чыгару. *Шуып кына станциядән чыккан поезд кинәт кенә пошкырып тормоз салды.* М.Мәһдиев. *Кузгалыр алдыннан автобус, пошкырып, өстемә сасы төтен өрде.* М.Юныс. *Иске автобус пошкыра-пошкыра алга юырта.* Р.Зәйдулла

Пошкыра башлау Пошкырырга тотыну. *Арттан килеп җитә башлагач*

та минем җирән пошкыра башлады. Г.Исхакый. *Бара торгач, атлар, нидидер ят исләр сизеп, пошкыра, тынычсызлана башладылар.* Н.Фәттах. *Кран һава суырып пошкыра башлады.* М.Юныс

Пошкырып алу *к.* **пошкырып кую**. *Ат үрелеп-үрелеп кенә үлән каба, башын селкеп, башын чайкап, йөгән тимерләрен зеңләтә, пошкырып ала.* М.Хәбибуллин

Пошкырып җибәрү Кинәт, кисәк пошкыру. *Атлар пошкырып җибәрәләр, ком бураны алар өчен дә авыр, киңәйгән борын тишекләренә ком бөртекләре ук булып кадала.* Г.Кашшаф. *Тыштан, салкыннан ашыгып кайткан Зөлфинур шулкадәр сылу иде, --- Кәрим ихтыярсыздан пошкырып җибәрде: – Вот это да!..* Ә.Галиев. *Танышы ачулы пошкырып җибәрде.* Ф.Җамалетдинова

Пошкырып кую Бер тапкыр пошкыру. *Ата кеше, кемгәдер ачулангандай, пошкырып куйды ---.* Ә.Баян. *Җирән бия пошкырып-пошкырып куя.* А.Гыйләҗев. *Безне күргәчтен дә, куанычыннанмы икән, ат пошкырып куйды.* Р.Мөхәммәдиев

Пошкырып тору Даими яки әледән-әле пошкыру

Пошкырып яту *сөйл.* Озак вакыт дәвамында пошкыру. *Бобик, борынына чебен кергән төсле, һаман пошкырып ята.* Ш.Камал

ПОШКЫРЫК *и.* Пошкырганда чыккан аваз, пошкыру авазы

ПОШКЫРЫНУ *ф.* Вакыт-вакыт пошкырып кую; үзалдына пошкырып куйгалау. *Менә маллар, --- ат сыман пошкырынып, ярга күтәрелә башладылар.* А.Хәлим. *Әлфред, көтү үгезедәй пошкырынып-пошкырынып, җирләр тырнап, кызларга ташлана.* Ф.Яруллин. *Ә ишек артында --- атлар пошкырынды ---.* В.Астафьев

Пошкырынып алу Берара пошкырыну. *Шунда синең аяк атлавыңны абайлап, [ат] пошкырынып ала.* К.Миңлебаев

Пошкырынып кую Әледән-әле пошкырыну. *Атлар үзләре дә, берберсенә бик якын торганга күрәме, әзрәк тынычсызланалар, колакларын уйнаткалыйлар, такта идәнне тырнап пошкырынып та куялар.* Ә.Еники

Пошкырынып тору Әле, шушы вакытта пошкырыну. *Менә без паровоз янына килеп җиттек. Ул пошкырынып тора.* А.Алиш. *Рәхмәтулла карт пошкырынып торган ат янына килде.* Х.Ширмән

ПОШКЫТУ *ф. диал.* 1) Төтен яки газ чыгарып тору. *Карт тәмәке кабызды һәм, төтен пошкыта-пошкыта, мәетне шинеле белән төргәләде.* Х.Камалов. *Абыйсының нинди «уен» белән мавыкканын Йосыф тиз сизенде: ул теге малайлар белән качып кына сасы исле махра пошкыта иде.* Н.Гыйматдинова

2) Сасыту

Пошкыта башлау Пошкытырга тотыну

Пошкытып алу Берара пошкыту

Пошкытып җибәрү Уйламаганда, кинәт пошкыту

Пошкытып кую Бер тапкыр пошкыту

Пошкытып тору Даими яки әледән-әле пошкыту

ПОШЛАК *с. диал.* Җитлекмәгән, булдыксыз кеше турында (гадәттә *сары пошлак* тезмәсендә килә). *– Нинди Хәлимә? Сары пошлакмы? Аның монда ни катнашы бар? – Сиңа мәхәббәтен күпме генә яшерергә тырышса да, күрә идек бит. Сары пошлак, имеш.* А.Хәсәнов. *Безнең тартырга беткән икән. --- Бар, берәр ахмак пошлактан табып кер, Әсфан.* А.Гыйләҗев. *– Кайсы якта? – Кама буеннан, Ваше благородие. – Сары пошлак елмайды.* М.Хәсәнов

ПО́ШЛИНА *и. рус икът.* 1) Читкә чыгарылган яки читтән кертелгән товарлар, кыйммәтле әйберләр өчен таможняга түләнә торган салым. *Бохарага да җибәргәннәр: корыч, аккургаш, мылтык көпшәләре кебек, читкә чыгару рөхсәт ителмәгән товарлар. Йөкләре өчен пошлина түләмәгәннәр, тамга бастырмаганнар.* М.Гайнетдинов. *--- узган ел ахырында РФ Премьер-министры Владимир Путин Чаллыда уздырылган киңәшмәдә үз автомобиль төзүчеләребезне яклау йөзеннән чит илләрдән кертелә торган тотылган автомобильләргә пошлина бәясен күтәрү --- турында бәян иткән иде.* Ватаным Татарстан. *Безнең чиновниклар, чит ил машиналарына, самолётларга, компьютерларга, кием-салымга, даруга, көнкүреш техникасына пошлина 10–15 әр процентка төшәчәк, дип белдерделәр инде.* Татарстан яшьләре

2) Дәүләт органнарының берәр эшне рәсмиләштерү өчен гражданнардан, учреждение һәм оешмалардан җыйган акча салымы. *--- дәүләт пошлинасын гына түләп язылышырга теләгән яшьләргә кечкенә генә уңайсыз зал бирелә икән.* Кәр.Миңнуллин. *Алар [крестьяннар] сеньор һәм дәүләт файдасына бурыч түләгәннәр* (*икмәкләтә оброк, юл, күпер пошлиналары --- һ.б.*). Бөтендөнья тарихы. *Феодал приказчиклары шәһәр халкын хөкем итә, алардан пошлина --- башка түләүләр җыя.* Урта гасырлар тарихы

ПО́ШЛИНАЛЫ *с.* Пошлина салынган, пошлина түләтелгән. *Пошлиналы товар*

ПО́ШЛИНАСЫЗ *с.* **1.** Пошлина түләтелми торган, пошлина салынмый торган. *Хәзер хәлләр үзгәрә: чик аша пошлинасыз 35 килога кадәр генә товар алып кереп булачак, җитмәсә, аена бер генә мәртәбә.* Татарстан яшьләре

2. *рәв. мәгъ.* Пошлина түләтелми генә, пошлина салынмый гына. *Русиягә пошлинасыз кертелә торган товарларга карата әле февраль ахырында гына гамәлгә кергән яңа кагыйдәләрне дә шундыйлардан дип аңларга кирәк.* Татарстан яшьләре

ПОШМАН *и. сир. к.* **пошаман**. *Ш.Камал, шаяртып, таможня кешеләре пассажирларның әйберләрен тикшерәләр икән, дип әйтеп куя. К.Нәҗми пошманга төшә. Шушы тәмәкене (чит илнеке, бигрәк тә Төркиянеке бит!) үзеннән табуларыннан коты оча.* Ф.Галимуллин. *Ачыла юл, Кача дошман. Дошманнарга Салып пошман, Иван белән Бари бергә Әле һаман Йөри бергә!..* Ш.Галиев

ПОШМАС *с.* **1.** 1) Бернәрсә турында кайгыртмый, уйламый, бернәрсәгә дә борчылмый торган; ваемсыз, гамьсез. *Киң күңелле, ачык йөзле пошмас*

Гөлгайшә Котлыәхмәт балаларын какмый-сукмый карап үстерде. З.Биишева. *Ярулла бабайның хәләл җефете Мөнирә апа – иренең нәкъ киресе, дөнья мәхлугы. Ул – пошмас дәрәҗәдә сабыр, тыныч, әкрен хатын. Беркайчан ашыкмас, каударланмас.* Т.Галиуллин. *Шушындый пошмас, бер караганда, күп нәрсәгә битараф егет тә һәр сүзнең әйтелешен тоемлый, һәрбер эшнең иң кечкенә төсмерләрен күрә...* Р.Сибат

2) Шундый халәтне белдергән. *Ул Булатовның үз-үзеннән канәгать булган, иренчәк, пошмас йөзен күз алдына китерде.* Н.Фәттах

2. *и. мәгъ.* Шундый сыйфатка ия кеше. *Үгез үлсә – ит, арба ватылса – утын, дип караучы пошмасны гына сораулар, уйлар борчымыйдыр.* Р.Фәйзуллин. *Аягүрә йоклап йөргән бу пошмасны нәрсәдер сискәндереп уятырга тиеш иде.* Н.Гыйматдинова

◊ **Пошмас җан** *сөйл.* Бернәрсә турында кайгыртмый, уйламый торган, ваемсыз, гамьсез кеше. *Юлдашыма эчем пошкан нәрсәләрне сөйләп бардым. Гамьсез иде, сүзгә кушылмады. Уйсыз, пошмас җан, дигән фикер калдырып китте.* Ш.Галиев. *Ата кеше өске каттан күзләрен уа-уа төшкән Шакирҗан белән Габделхәкимгә җикеренде: – Бер аягыгызны атлаганчы, икенчесен эт ашый, пошмас җаннар, йокы чүлмәкләре!* С.Поварисов. *Гаять зур каршылыкларны үткән Баш конструкторның ниндидер пошмас җан аркасында килеп чыккан юк кына бер киртәгә абынып, бик нык бәрелүе ихтимал иде.* Галәмгә юл. **Пошмас җанлы** Бернәрсә турында уйламый, кайгыртмый торган; ваемсыз, гамьсез. *Бу пошмас җанлы юанга минем ачуым кабара башлады.* Г.Мөхәммәтшин. *Ул бервакытта да көлмәс, бары мыек астыннан елмаер гына. Шул тикле түзем, тыныч холыклы, пошмас җанлы булдымы икән әллә?* Х.Камалов

ПОШМАСЛЫК *и. сөйл.* Ваемсызлык, гамьсезлек. *Төнне Мансур йокысыз диярлек үткәрде. Дәү әтисе аны гүя бертуктаусыз орыша, гамьсезлектә, пошмаслыкта гаепли иде.* Г.Әпсәләмов. *Мин вакытның акрын гына шуышкан тавышын да ишеттем шикелле. Җан үртәгеч пошмаслык белән шуыша иде ул. Бик акрын. Бик, бик акрын.* М.Кәбиров

ПО́ШМЫЙЧА *рәв.* Гамьсез, ваемсыз гына; ис китмичә. *Менә алда пошмыйча гына атлаучы өч егет күренде.* Р.Кәрами. *Ә ир-атлар, киресенчә, барысына да өлгерермен, нигә ашыгырга дип, артык пошмыйча гына яши бирә.* Ватаным Татарстан

ПОШНА́У *ф. диал.* Пош-пош килү; мышнау. *Лачтыр-лочтыр күшәгән, пош-пошшш... пошнаган сыер тавышыннан башка тавыш юк.* З.Һади. *[Аның] пошнаганы да ишетелә иде.* К.Тинчурин. *Гайнетдин абзый караңгылыктылы бүлмәдә пошнап-пошнап чишенә вә үзе сөйләнә ---.* Ш.Камал

Пошнап алу Бер тапкыр пошнау

Пошнап кую Кинәт пошнау

Пошнап тору Даими яки әледән-әле пошнау

Пошный башлау Пошнарга тотыну

ПО́Ш-ПОШ *иярт.* Берәр куе массадан һава бөркелеп чыкканда, мышнаганда һ.б. очракларда ишетелгән тавышны белдерә. *Сыер пош-пош башак ашый башлый, бозавы имәргә тотына.* Р.Хәбибуллина. *Гел карадан гына киенгән бер хатын, аяклары суза, түрдәге караватка утырган да пош-пош тәмәке тарта иде.* Н.Гыйматдинова. *Әсирләр колоннасы әлеге состав белән тигезләнүгә, пош-пош-ш сулап, паровоз кычкыртып җибәрә.* Язмышлар яңарганда

ПО́Ш-ПОШ ИТҮ *ф.* Пош-пош иткән тавыш чыгару. *Күпме генә шыпырт булырга тырышмасын, чуендагы кайнар бәрәңгенең тукмак тигән саен пош-пош иткән авазы әллә каян ишетелеп тора.* Р.Мөхәммәдиев

ПО́Ш-ПОШ КИЛҮ *ф. к.* **пош-пош итү**. *Абзый, пош-пош килеп, кибәк ашаган сыер шикелле мышкылдап йөри.* Г.Камал. *Илмира килеп кергәндә, алар, пош-пош килеп, өй кыегы астында торган ләгәндәге суда юынып торалар иде.* Г.Гыйльманов

ПОШТЫР *и. диал.* 1) Поши аягы тиресеннән тегелгән оек

2) Поши тиресе; поши тиресеннән ясалган күн

ПОШТЫРДА́У *ф. к.* **пыштырдау**

ПОШТЫ́Р-ПОШТЫР *иярт. к.* **пыштыр-пыштыр**. *Шәкерт хәзер икенче көнге дәрес өчен, поштыр-поштыр килеп, әллә нинди бәхәсләр бикләп ята.* Ф.Әмирхан. *Алар әнә һаман поштыр-поштыр намаз укыйлар, дога кылалар. Ә Камиләгә тыныч-лану өчен, барысын да оныту өчен, нибары бер-ике төймә дә җитәр иде бит!..*Ф.Бәйрәмова

ПОШУ I *ф.* 1) Нәрсәгәдер борчылу, сагышлану, тынычсызлану, ямансулау. *Пошмыйк әле яшьлек үтә диеп, Туксан бише үтсә, йөзе килер.* Г.Афзал. *Иртән ашыкмый гына йокыдан торды, иркенләп, бөтен шартын китереп физзарядка ясады, --- шулай ук пошмый гына салкынча урман юлыннан бер урап керде.* М.Вәли-Барҗылы

2) Кем яки нәрсә турындадыр кайгырту, борчылу. *Аларга ни: үгез үлсә – ит, арба ватылса – утын, ай-һайларында да юк, пошмыйлар да ичмасам.* Н.Фәттах. *[Тәслия:] Уземнең дә кызым буйга җитте. [Асия:] Бик пошып тормыйм әле. Таптым – үсәрләр. Без үстек.* Т.Миңнуллин

Поша башлау Борчылу, тынычсызлану билгеләре күренү

Пошып бетү Тәмам, бик нык пошу

Пошып йөрү Даими рәвештә пошу

ПОШУ II *ф. диал.* Пычак белән сыдырып җибәрү

ПОШУ III *и.* Күңелсез, борчулы, сагышлы уй яки халәт; пошаман. *Бабайның үзенә дә пошу керде.* Л.Хәмидуллин

ПОШЫГУ *ф.* Эчтән борчылу, кайгыру, хәсрәтләнү, хафалану. *Бирергә ашыкма, пошыкмассың.* Мәкаль. *Үгез җиксәң – ашыкма, җай йөргәнгә пошыкма.* Мәкаль

Пошыгып бетү Тәмам, бик нык пошыгу

ПОШЫЙ *и. фин-угор к.* **поши**. *Ике баласын иярткән ана пошый күренде урман аланында.* Р.Мөхәммәдиев. *Узган елгы «җан исәбе алу» нәтиҗәләре буенча, аучылар хуҗалыгында 87 пошый, 200 башка якын кабан дуңгызы теркәлгән.* Кызыл таң

ПОШЫМ I *и. этн.* Читләренә киндер тукыма тотып, чи күннән

(күбесенчә пошый тиресеннән ясалган) тегелгән бөрмәле ката

ПОШЫМ II *и. сир.* Мәшәкать, борчу, кайгы

ПОШЫМСЫЗ *с. сөйл.* Ваемсыз, гамьсез, борчылмаучан. *Әмин әкәне чынлап кайгыра да, борчыла да, хәтта кәефсезләнә дә белмәгән гаҗәеп ваемсыз, пошымсыз бер кеше диярсең!..* Ә.Еники

ПОШЫНМАС *с. к.* **пошмас**. *Пошынмас җилбәзәк кибәк исә берсенә дә игелек күрсәтергә ашыкмый.* Инешләр Иделгә кушыла

ПОШЫНУ *ф.* Тынычсызлану, хафалану, борчылу. *Урамда берәр мороженое кәгазе күрсәм дә пошынам.* Н.Дәүли. *Ул эчтән генә: «Каян юлыкты соң бу бәйләнчек?» – дип пошынды.* Р.Кәрами

Пошына башлау Пошынырга тотыну. *Безнең биредәге ана филебез дә бик пошына башлады.* Н.Исәнбәт. *Казанга барып, поездга утырганнан соң бик нык пошына, борчыла башлады.* В.Нуруллин. *Әхмәтсафа --- төнне черем итми үткәрүгә пошына да башлады.* Ф.Сафин

Пошынып алу Кыска вакыт аралыгында пошыну. *Аягын ниндидер бер каты нәрсә авырттыра иде. Кайәр суккан пуля эләкте ахры, дип пошынып алды сержант.* Н.Нотфуллина

Пошынып бетү Тәмам, бик нык пошыну

Пошынып йөрү Озак кына, күптәннән бирле пошыну. *Тукай исемендәге бүләккә тәкъдим итү теләге белән пошынып йөрүе дә юкка гына түгел, күрәсең.* М.Макаров. *Сәкинә әнә кашларының чабатадай җәенке булуына пошынып йөри.* Ф.Яруллин. *Газетага язганда арттырыбрак җибәрүемне, тәнкыйть дигәнем мәсхәрә итүгә әйләнүен уйлап, эчтән пошынып йөргән көннәрем күп булды.* Л.Ихсанова

Пошынып карау Пошынырга тырышу. *Ни тоҗырды мастер? Буровой дип бер пошынып караганы бармы аның?* Ш.Бикчурин

Пошынып кую Кинәт пошыну хисе барлыкка килү. *Пошынып та куйдым: идарәдән керткәннәрдер кертүен, хуҗага безнең ябырылу бер дә ошамады, ахрысы!* А.Гыйләҗев. *Кыз аның үз абыйсы булмавына бераз пошынып та куя иде.* Р.Кәрами. *Туган авылында елдан-ел яшьләрнең кими баруын күреп, Мансур пошынып куйды.* Г.Галиев

Пошынып тору Һәрвакыт, гел пошыну; бераз пошыну. *Кай ягыма борылып карасам да, Шөбһәләләр тора пошынып, Хуҗа дигән затның алларында Ялагайлар йөри посынып.* Р.Шиһапов. *Зәкиҗан өйгә кайтмады. «Кайда йөри икән бу бала?» – дип, әни пошынып торганда, мәктәптә җыештыручы булып эшләүче Гөлйөзем апа килеп керде.* Ф.Яруллин

ПОШЫНУЛЫ *с.* 1) Борчулы, хафа белдерә торган. *Әле башланмаган сугыш-кырылыш әнә шундый пошынулы уйларга сала ---.* Р.Мирхәйдәров. *Пошынулы уйлар талый: Изгелек ник кача бездән? Кемдер, чабып, каеннарның Яшәү тамырларын өзгән.* Х.Касыймов. *Әмма, моның ахыры хәерсез бетәргә мөмкин, дигән гасабилы халәт, пошынулы уйлар, аны бимазалап, юл буена озата барды.* Р.Кәрами

2) Борчулы, хафалы (тынлык, кеше һ.б.ш. тур.). *Зәйнак һаман пошынулы һәм өметле уйларда газапланып утыруын ташлады.* Ш.Маннур. *Мин һаман да шул тынгысыз, пошынулы кеше булып яши бирәм. Күңелемдәген үзем генә беләм, үзем генә борчылам, үзем генә кичерәм.* Г.Бәширов

ПОШЫНУСЫЗ *с.* **1.** *к.* **пошмас**

2. *рәв. мәгъ. к.* **пошмыйча**. *Бигрәк тә ана белән һәркөн туганы турында сөйләшү аның исән-сау кайтуын ничектер уйланусыз, пошынусыз көтәргә гадәтләндерде.* Ә.Еники

ПОШЫНУСЫЗЛЫК *и.* Гамьсезлек, ваемсызлык, борчылмаучанлык. *Кадыйровның бу сүзләрне үтә бер салкынлык һәм гаҗәеп бер пошынусызлык белән әйтүе болай да каны кызган сержантка үткер штык белән кадагандай тәэсир итте.* Г.Әпсәләмов

ПОШЫРГАЛАНУ *ф. сөйл.* 1) *к.* **пошыну**. *Анна Ивановна аның пошыргаланып ятуын сизенде, ахрысы ---.* Ә.Галиев. *Башка вакытта ындыр табагына барып җиткәнче рәхәт кенә черем итә торган Хәнәфи бу юлы пошыргаланып, борчылып утырды.* А.Гыйләҗев

2) Үзендә авырлык, җайсызлык сизү, аяк-кулларын төрле якка атып, бәргәләнеп, тынычсыз яту, утыру

ПОЭ́ЗИЯ *и. гр.* 1) Фикерне сүзләр ярдәмендә образлы чагылдыру сәнгате, башлыча шигъри сүз сәнгате

2) Шигърият, тезмә сөйләм; әдәбиятның бер төре. *Поэзия – сүзнең кадерен белеп эш итүгә, эчке җегәрен ачуга оптылган, металогик (күчерелмә мәгънәле) сәнгать.* Т.Галиуллин. *Аннары мин аны шул елның декабрь ахырында, 1960 елны каршылау уңае белән уздырылган поэзия кичәсендә күрдем.* Р.Гатауллин. *Соңрак чорларда Борынгы Грециядә поэзия жанр ягыннан күптөрлелеккә баю процессын кичерә.* К.Гыйззәтов

3) *әд.* Аерым халыкның, чорның, иҗтимагый төркемнең һ.б.ш.ларның шигъри, (тезмә) әсәрләр җыелмасы. *Шушы сыйфатлар авторга татар поэзиясенең гомумкешелек кыйммәтләренә йөз тотуы хакында нәтиҗә ясарга ярдәм итә.* Д.Заһидуллина. *Урта гасырлар татар суфи шигъриятен дөньяга танылган фарсы суфи әдәбияты белән чагыштырсак, төрки поэзиянең гади, төссез стильдә язылуы күзгә ташлана.* Чын мирас. *VIII–IX гасырларны Кытай поэзиясенең «алтын чоры» дип атыйлар.* Урта гасырлар тарихы

4) *күч.* Хис, хыял, нәфислек, гүзәллек, шигърият дөньясы. *Ә мин бу матурлык, поэзия дөньясыннан ничек аерылырмын?* Ә.Фәйзи. *Бу ике шигырьдә нинди ләтафәт, нинди нәфасәт, нинди поэзия!* Г.Тукай. *Тормыш поэзиясе. Табигать поэзиясе. Хезмәт поэзиясе*

ПОЭ́МА *и. гр.* 1) Тарихи, героик яки күтәренке лирик темага шигырь белән хикәяләп язылган зур күләмле әдәби әсәр. *Апа кушса, бер кичтә Һади Такташның озын-озын поэмаларын да ятлап өлгерә торган идек.* Р.Мөхәммәдиев. *Менделеев таблицасы гына да «Мең дә бер кичә» кебек икән, һәр элемент турында әкият, поэма, кыйсса язып була.* М.Маликова. *Поэма латинча түгел, ә итальян телендә языла.* Урта гасырлар тарихы

2) *муз.* Ирекле формадагы, лирик характердагы музыкаль әсәр исеме. *[Остаз] шул кәгазьләрне рояль өстенә туздырып ташлады да, башын чайкый-чайкый, кайбер өзекләрне уйнап, анализлап, поэманы бөтенләй юкка чыгарды.* Ш.Хөсәенов

3) *күч.* Тойгыларга, аңга бик нык тәэсир итә торган нәфис, бик матур, искиткеч гүзәл күренеш. *Гади йортлар түгел, Поэмалар күтәрелә безнең урамда!* З.Мансур. *Кырым таулары – үзе бер поэма ул!* Казан утлары

ПОЭ́ТИК *с.* **1.** 1) Поэзиягә караган; шигъри. *«Кырыгынчы бүлмә» поэмасы – үткән елда басылган иң уңышлы поэтик әсәрләрнең берсе.* Р.Фәйзуллин. *Тәһир белән Зөһрә турындагы борынгы шигъри сюжет нигезендә поэтик әсәр – «Дастаны Бабахан» поэмасын яза.* Ф.Гыйбадуллина. *Такташ, җил, ай кебек традицион поэтик чараларны кулланып, хис-кичереш мәйданын киңәйтеп җибәрә.* М.Җәләлиева

2) Эмоциональ, нечкә күңелле

2. *рәв. мәгъ.* Үтә нечкәлек белән. *Очерк поэтик рухлану белән язылган.* Г.Иделле

ПОЭ́ТИКА *и. гр. әд.* 1) Матур әдәбият теориясе

2) Әдәбият белеменең шигъри әсәрләр структурасын, шигъри формасын, поэтик сәнгать алымнарын, поэзияне анализлау принципларын өйрәнә торган тармагы. *Г.Исхакый пьесаларында милли драматургия төренең поэтика өлкәсендәге казанышларына кертелгән өлешне шулай ук җитди дип бәяли алабыз.* А.Әхмәдуллин. *Татар әдәбиятының поэтикасы, аеруча жанрлар һәм шигырь системасы үсешендә гарәп, фарсы классикасының роле гаять зур.* Х.Миңнегулов. *Әсәрләрнең ничек барлыкка килүен өйрәнә торган бу тармакны фәндә төрлечә атыйлар: поэтика, иҗат лабораториясе, иҗат процессы, иҗат психологиясе дип йөртәләр.* Ф.Хатыйпов

3) Берәр шагыйрьнең яки әдәби мәктәпнең поэтик чаралар һәм принциплар системасы. *Ачыграк итеп әйтсәк, халык иҗаты, халык поэтикасы нигезендә үз йөзен таба башлаган шагыйрь, еллар уза төшкәч, модага, шау-шуга иярепме, ирекле формалар белән мавыга.* Р.Фәйзуллин. *Билгеле булганча, халык әкиятләре, хәтта аларның Үги кыз образы белән бәйләнгәннәре дә, фаҗигале төстә бетә алмый: моны әкият поэтикасы рөхсәт итми.* Ф.Урманчеев

ПОЭ́ТИКЛАШТЫРУ *ф. кит.* Матурлап, бизәп күрсәтү, шигъри төскә кертү; көчле хис белән шигъриләштереп бирү. *XX гасыр башы татар поэзиясендә романтизм --- милләтнең милли азатлыгы, халыкның киләчәк язмышы, романтик образ-символлар, героик, романтик лиризмны поэтиклаштыру, --- формаларында чагылыш таба.* Й.Нигъмәтуллина. *Чынбарлыкны поэтиклаштыру*

ПӨ́ЯС *и. рус* 1) *геогр.* Җир шарының ике меридиан арасындагы өлеше. *Бер дистә чамасы сәгать поясы булган Рәсәйдә Мәскәү чыгарган законнар белән генә яшәү мөмкинме?* Р.Зәйдулла. *Медведев гел нәтиҗәсе ташка үлчим тәкъдимнәр белән чыга: бадминтон уйнарга куша, сәгать пояслары белән сугыша ---.* Ирек мәйданы

2) *геогр.* Җир шарының билгеле бер климат зонасы. *Койрыклы җир-су хайваннары экватордан төньякта – көнчыгыш һәм көнбатыш ярымшарларның уртача поясында яши.* Т.Шакирова. *Әгәр дә бу үзгәреш килеп чыга икән, Аурупа белән Төньяк Америка бик салкын пояста калачак.* К.Гыйззәтов. *Җир шарында кояш яктырту пояслары биш: бер тропик пояс, ике уртача пояс һәм ике поляр пояс.* Физик география

3) Җир шарының үзенә хас табигый үзенчәлекләре, сыйфатлары булган бер кисәге, бүлемтеге. *Тундра акрынлап тайгага күчә бара. Без уртача пояс урманнары зонасына килеп чыгабыз.* Физик география. *Чүлләр поясы*

4) *икът.* Илне икътисади билгеләргә нигезләнеп бүлгәндә килеп чыккан бер өлеш, зона. *Илне промышленность һәм азык-төлек товарлары бәясенә карап поясларга бүлү. Тариф поясы. Пояс тарифы*

ПӨСКЕРТКЕЧ *и.* Чиркәүдә күнлек яндырып төтәсли торган металл савыт

ПӨСКЕРТҮ *ф.* 1) Предметларга газ, төтен, су өрдерү; төтәсләү. *Корсагына көмеш чылбырлап тәре аскан поп, аждаһа кебек ямьсез улап, кулындагы кадилен як-якка айкап, төтен пөскертә.* Н.Исәнбәт

2) *күч.* Кая да булса куып җибәрү; очырту. *Без дошманның көчле фиркаләрен [көнбатышка] пөскерттек.* М.Галәү

Пөскертеп алу Бераз пөскертү

Пөскертеп җибәрү Кинәт пөскертү

Пөскертеп тору Әледән-әле яки даими пөскертү

ПӨСКЕРҮ *ф. сир.* 1) Төтен, пар чыгарып тору; төтәсләү

2) *күч.* Янар-янмас тору, пыску. *[Г.Колахмәтов] төрле төсләрдә тулкынланып, пөскереп торучы бер хис әдибе түгел, бәлки корыч [логика] сызыкларыннан барып, хакыйкать эзләүче --- бер фикер әдибедер.* Г.Сәгъди

Пөскереп тору Даими яки әледән-әле пөскерү

ПӨ́Ф-ПӨФ *иярт. к.* **пуф-пуф**. *Яңаклары бүлтәйгән сабыйның, шуңа күрә уймактай гына авызы пөф-пөф итеп тора.* Ф.Баттал

ПӨХТӘ *с. фар.* **1.** 1) Тышкы күренеше, кыяфәте бик җыйнак, бик чиста булган. *Ә нинди пөхтә, ыспай, озын, төз сынлы үзе, чын заман кешеседәй горур, хәтта бераз тәкәббер басып торышы.* М.Маликова. *Үрелеп карагач, малай аларның уч төбе хәтле генә пөхтә ояларын да күрде.* А.Тимергалин. *Пөхтә, чәчәкле күлмәкләр кигән, аркажилкәләренә ак яулыклар бөркәнгән, үз гомерләрендә бик күпне күргән бу карчыклар белән утырып бер чәй эчүләре – үзе бер гомер.* Язмышлар яңарганда

2) Чисталыкка, төгәллеккә күнеккән, чисталык, төгәллек яратучы (кеше тур.)

3) Җиренә җиткерелгән, җентекле, төгәл. *Эшебез пөхтә, сүзебез кыска.* Ә.Ерикәй. *Натурадан ясаучылар бик игътибарлы, пөхтә булырга тиешләр, натурага һәм үзеңнең рәсемеңә карап чагыштыра белү кирәк.* Ялкын

2. *рәв. мәгъ.* 1) Бик җыйнак, бик чиста итеп. *Малайның пөхтә итеп таралган чәче, ап-ак күлмәк өстеннән бәйләнгән галстугы игътибарны үзенә*

тартып тора иде. А.Шамов. *Крәстиян булса, йорт тирәсен пөхтә тотар --- иде.* Ш.Галиев. *Ул өлкәннәрне хөрмәт итәргә, пөхтә киенеп йөрергә өйрәтте.* Сәхнә

2) Җиренә җиткереп, төгәл итеп. *Пөхтә итеп тигез койма белән әйләндереп алынган зур зират яныннан үткәндә, юлаучы иректән йөрәге сыкрап куйганын тойды.* Р.Кәрами. *Япьяшь кешеләр кирпечләрне тигез, пөхтә түшәләр, мастероклар, оста кулларга буйсынып, күндәм йөриләр.* С.Рафиков. *Сары нарат такта белән пөхтә итеп тышланган бу җыйнак корылма уенчык йортны хәтерләтә иде.* Р.Низамиев

ПӨХТӘЛӘНҮ *ф.* 1) *кайт. юн. к.* **пөхтәләү**. *Рәхәтләнеп тукланганнан соң, песнәкләр томшыкларын кат-кат чистарталар, пөхтәләнәләр.* Канатлы дусларыбыз

2) Пөхтә булып китү. *Лариса белән дуслашкач, егет нык үзгәрде: өс-башы чистарды, пөхтәләнде, чалшайган ботинка башлары да тураеп китте.* М.Маликова. *Гомумән алганда, дәүләт органы буларак, министрлык һәм комитетлар исемендә «буенча»ны кулланмау татар теле нормасына да, бу атамаларның асылдагы мәгънәсенә дә бернинди начарлык эшләми, киресенчә, алар, терминда таләп ителгәнчә, пөхтәләнеп-җыйнакланып кына кала.* Кызыл таң

Пөхтәләнә башлау Пөхтәләнергә тотыну; пөхтәлеге арту. *Урамга чыгып китәр алдыннан, ул пөхтәләнә башлады.* Ш.Хөсәенов

Пөхтәләнә төшү Беркадәр, бераз пөхтәләнү

Пөхтәләнеп алу Тиз генә пөхтәләнү, пөхтәләнгән хәлгә килү

Пөхтәләнеп бетү Бөтенләй, һәрьяклап пөхтәләнү

Пөхтәләнеп китү Кинәт пөхтәләнү

Пөхтәләнеп тору Әледән-әле яки даими пөхтәләнү

ПӨХТӘЛӘ́Ү *ф.* Пөхтә, җыйнак итү. *Үз арбасына менеп утыргач, чылтыр-чылтыр китереп чулпыларын сүтеп алды, бик пөхтәләп башына ак яулык урады.* Г.Бәширов. *Нәтиҗәдә менә өч нөсхә итеп машинкада бастырылган, яңа таза папкага пөхтәләп салынган кулъязма аның өстәлендә ята!* Ә.Еники. *Бераздан абыйның итекләрен пөхтәләп коры чүпрәккә төрдем дә урынына – сандык төбенә салдым.* А.Гыйләҗев

Пөхтәләп кую Алдан ук яки тиз арада пөхтәләнгән хәлгә китерү. *...Ак якалы күлмәк, кара пинҗәк кигертеп, Әхмәтьярны пөхтәләп куйдым.* Р.Батулла

Пөхтәләп тору Даими яки әледән-әле пөхтәләү

Пөхтәләп чыгу Барысын да, бөтенесен дә пөхтәләү. *Табак-савытларны юып, тузаннарны сөртеп, урын-җирне тагын бер кат пөхтәләп чыккач, ул хәлдән таеп креслога утырды.* Р.Вәлиев

Пөхтәли башлау Пөхтәләргә тотыну

ПӨХТӘЛЕК *и.* Пөхтә булу. *--- ул бер карусыз, үзенә генә хас пөхтәлек белән, яңа мөдирнең кылдый-былдый язуын басып утыра иде.* Х.Сарьян. *Аларда тумыштан килә торган нәфислек, төгәллек, пөхтәлек була, кулбармаклары андый эшкә, картлар әйтмешли, ятып тора.* Р.Кәрами. *Өйдә бер генә артык нәрсә дә күрмәссең – бары да үз урынында. Һәркайда пөхтәлек.* Ж.Дәрзаман

ПРАВИ́ЛО *и. рус сөйл.* Кирпечтән йорт һ.б.ш. биналар салганда кулланыла торган линейка, тигезләгеч. *Хәлфә абыйлары, --- бик ачуы килгән чакта, тешләрен кысып, правило белән суга яисә китап белән тондыра.* И.Гази. *[Укытучы] кулындагы китапның правило кыстырган җирен ачты.* Ш.Маннур

ПРАВОСЛА́ВИЕ *и. рус* 1) IX–XI гасырларда Византиядә барлыкка килеп, 1054 елда христианлык православие һәм католицизмга аерылганнан соң барлыкка килгән диннәрнең берсе. *Шул вакыттан Көнбатыш чиркәве – католик чиркәү (бөтендөнья чиркәве), ә Көнчыгыш чиркәве православие (ягъни хак дин) чиркәве дип йөртелә башлый.* Урта гасырлар тарихы. *Идел буе Булгариясе чорында ук инде булгарларның бер өлеше, Мәскәү Русе рөхсәте белән, рус җирләренә күчеп утыра, православие динен кабул итә.* Эзләнүләр, уйланулар, табышлар. *Казан шәһәрендәге ир затлары үтерелә, мәчетләр җимерелә, алар урынына православие чиркәүләре төзелә.* Чын мирас

2) Россиядә рәсми дин

ПРАВОСЛА́ВНЫЙ *и. рус* **1.** Православие динен тотучы, православие динендәге кеше. *Немец этнографы Отто Гетч язып калдырган --- буенча, --- татарда 100 җанга 1 мәктәп булса, православныйларда ул 1500–3000 кешегә бер туры килгән.* Р.Фәхретдинов

2. *с. мәгъ.* Православие диненә караган, шул диндәге. *Патша тәхете идиологлары, --- татарларны «басурман», «магометан» дип атап, аларны --- православный халыкларның да дошманы итеп күрсәтергә тырышалар.* Эзләнүләр, уйланулар, табышлар

ПРАГМАТИЗМ *и. гр.* 1) Идеалистик философиядә: хакыйкать дип объектив чынбарлыкка туры килә торган нәрсәләрне түгел, ә бәлки гамәли яктан файдалы булган нәрсәләрне генә таный торган юнәлеш. *Әйбергә табыну, прагматизм, бүгенге көн белән генә яшәү байтак кешеләрне поэзиядән читләштерде.* Р.Фәйзуллин. *Прагматизм XIX гасыр азагында барлыкка килә. --- Джеймс хезмәтләре дөньяга чыгу белән, прагматизм зур популярлык казана.* К.Гыйззәтов. *Гомумән алганда, модернизмның нәзари нигезендә бер-берсенә каршы килүче фәлсәфи-эстетик идеяләр (интуитивизм, фрейдизм, прагматизм, неопозитивизм) ята.* Д.Заһидуллина

2) Тарих фәнендә: аерым вакыйгаларны, тарихи үсешнең объектив законнарын ачыкламыйча, аларның тышкы бәйләнешләрен һәм тышкы эзлеклелеген генә күздә тотып сурәтли торган юнәлеш

ПРАГМА́ТИК I *и. к.* **прагматист**. *Күрәсең, безнең язучылар – конъюнктура законнарын яхшы үзләштергән прагматиклар, һәм алар, «баш китәрлек» әсәрләр язып, киләчәк буыннарны «бимазаламаска» булганнардыр...* Р.Фәйзуллин. *Кайберәүләр Җәмилне «прагматик» дип атаса, икенчеләр аны әдәпсезлектә гаепләргә тырышты.* Г.Шакиров. *Гәүһәрия тагын ярсып куйды: – Бу кадәр прагматик булмасаң!*

Сиңа фәлән центнер ит булсын да, фәлән гектарда фәлән центнер ашлык уңсын! Д.Гайнетдинова

ПРАГМА́ТИК II *с.* Прагматизмга нигезләнгән. *Әлбәттә, яшьләрнең дә төрлесе бар. Прагматик, рационалист яшьләр хәзер аерата күп төсле.* Р.Зәйдулла. *Бүген бөтен дөнья латинга күчә, һәм монда бернинди дә идеология юк, бу – уңайлылык җәһәтеннән чыгып ясалган прагматик адым.* Р.Хәкимов. *Хәзер дөньяны прагматик акыл басты.* Р.Вәлиев

ПРАГМА́ТИКА *и. гр. линг.* Семиотиканың тамгалар системалары белән алардан файдаланучылар арасындагы мөнәсәбәтләрне өйрәнә торган юнәлеше

ПРАГМАТИКЛЫК *и.* Прагматик булу. *Һәркемгә мәгълүм: татар – бик эшчән һәм булдыклы халык. Аңа иртәгәсе түгел, ә бүгенгесе мөһим. Ягъни мәсәлән, прагматиклык алга чыга.* Ф.Фәткуллин. *Беләсезме... гаепләүченең бик ярсып сөйләвендә прагматиклык күрәм.* Идел

ПРАГМАТИСТ *и.* 1) Прагматизм (*1 мәгъ.*) тарафдары. *Ә Габбаслар зирәк! Прагматистлар фәлсәфәсе – тулы килеш алар яклы.* Ә.Баян. *Төшенчә һәм категорияләрдә объектив эчтәлекнең булу-булмавы, аларда безнең белемнәребезнең гомумиләштерелүе прагматистларны кызыксындырмый.* М.Абдрахманов

2) Тарихи фактларны прагматизм (*2 мәгъ.*) күзлегеннән тасвирлый торган тарихчы

ПРАЙМ-ТАЙМ *и. ингл.* Телевидениедә, радиода рейтинг яулау өчен иң уңышлы дип саналган, караучы һәм тыңлаучылар күп булган вакыт. *Прайм-тайм вакытында чыгучы сериалда татар телен ишетү күп кешеләрне шаккаттырды.* Л.Мөхәммәдиев

ПРАЙС *и. ингл. сөйл. к.* **прайс-лист**

ПРАЙС-БИТ *и. к.* **прайс-лист**

ПРАЙС-ЛИСТ *и.* Товарларның яки хезмәтләрнең бәяләре күрсәтелгән исемлек яки таблица. *Әлеге фирма күплэп прайс-листлар бастырып чыгара.* Ватаным Татарстан. *Кибетләр прайс-листларын рубльгә күчереп исәпләп, үзгәртеп язарга тиеш булалар.* Татарстан яшьләре

ПРАКӘНДӘ *рәв. фар.* **1.** Чәчелеп, тузгып, таралып. *Пракәндә яткан кәгазьләрне бер җиргә җыйнап куярга уйладым.* М.Гафури

2. *с. мәгъ.* Чәчелгән, тузгыган, таралган. *Бервакытны пракәндә кәгазьләр арасында табылган бер төрек шагыйренең бер шигыре аңа гаять тәэсир иткән икән.* Г.Кәрам

ПРАКӘНДӘ́ ИТҮ *ф. иск.* Туздыру, тарату. *Революция капиталны һәм аның хуҗаларын пракәндә иткәч, алар таралалар.* М.Гафури

ПРАКӘНДӘ КИТЕРҮ *ф. к.* **пракәндә итү**

ПРАКӘНДӘЛЕК *и. иск. кит.* Таркаулык, тәртипсезлек. *[Аның] күңеле тәшвишләрдән вә пракәндәлекләрдән [буш] булмас.* К.Насыйри

ПРА́КТИК I *и. рус* 1) Белгечлеге буенча зур тәжрибәсе булган, шул өлкәдә күп эшләп махсус белем туплаган кеше; *киресе:* **теоретик**. *Ә без практик кына булып йөрик, шунда да сер сынатмабыз әле.* Ә.Еники. *Сез ни өчендер практик-геолог Степан Андреевичның, нефть исен иснәп үскән буровой мастер Хәмидуллинның сүзләрен ишетергә теләмисез.* А.Әхмәт. *Аңламыйм дисең инде? Һәм аңламассың да. Чөнки син – теоретик, ә мин практик.* Д.Гыйсметдинов

2) *күч.* Эшнең файда китерү ягын күзәтә, эшнең файдасы булуга игътибар итә торган кеше

ПРА́КТИК II *с.* 1) Практика (*2 мәгъ.*) белән, берәр нәрсәне тормышка ашыру белән бәйле; гамәли. *– Тыныч вакытта укып чыгармын, – диде Җәмилә Закировна. – Ә практик нәтиҗәләр ничек соң?* М.Маликова. *Г.Камал – татар әдәби телен үстерүдә иң зур практик эш күрсәткән язучыларның берсе.* М.Гали. *Хәзер без ионосферада радиодулкыннар таралуны практик яктан бәяли алырбыз.* Галәмгә юл

2) Берәр эш белән турыдан-туры шөгыльләнә яки җитәкчелек итә торган. *Татарстан партия оешмасы һәм хөкүмәте җитәкчеләренең --- практик җитәкчелек итүләре аркасында, коллектив бу зур күләмле катлаулы эшләрне үти алды.* М.Җәлил. *Практик үзәк*

3) Өйрәнгән фәнне, белемне, күнегүне тормышта куллануга бәйләнешле. *Бу бит әле биология буенча практик эш тә булачак.* Г.Гобәй. *Исхакның практик дәресләрдән соң учхоз хәтле җирдән шәһәргә кайтып-килеп йөрүен --- егетләр акылга сыйдыра алмадылар.* А.Гыйләҗев. *Ләкин бит безнең бу бәхәс чисто теоретически бара. Ә инде менә практик мәсьәләгә килсәк, безгә бик ныклап аңлашырга кирәк.* Н.Акмал

4) Белемнең, фәннең берәр тармагын практикада куллану һәм куллана белү белән бәйләнгән. *Практик грамматикаларда сүз төркемнәрен сораулар буенча аерту алымы бик киң кулланыла.* В.Хангилдин. *Павлов хезмәтләре практик медицинаның алга китүенә зур этәреш ясады.* Совет әдәбияты

5) Тормыш, эш мәсьәләләрен яхшы аңлаучы, реаль нәтиҗәләрне, реаль файда китерә торган нәрсәләрне генә кулай табучы; тәжрибәле, булдыклы, эшлекле. *Агроном үтә практик кеше иде.* А.Тимергалин. *Эш сөючән, практик, тыйнак хатын-кыз мин ---.* Ирек мәйданы

6) Теге яки бу сыйфатлары белән файдалы, уңайлы, эшкә яраклы. *Космик телевидение якын арада илебезнең иң ерак почмакларына барып җитәргә тиеш, кешеләр бу тикшеренүләрнең практик файдасын күрергә тиеш.* Галәмгә юл. *Кызны бары тик материаль яисә тормышта практик кулланырга мөмкин булган әйберләр генә кызыксындыра.* Ирек мәйданы

ПРА́КТИКА *и. гр.* 1) *филос.* Кешеләрнең иҗтимагый яшәеш өчен кирәкле шартларны тудыруга юнәлдерелгән барлык эшчәнлеге, гамәле. *Практика дигән төшенчә эченә бер буын, бер токым, яки бер иҗтимагый-экономик формациядә җыелган, яки бер илдә булган тәҗрибә генә алынмый. Монда гасырлар буе, барлык илләр һәм халыклар тарафыннан җыйналган тәҗрибә күздә тотыла.* М.Абдрахманов. *Теориянең практикага тәэсире*

2) Фикерләрне, нәтиҗәләрне тормышка ашыру һәм сынау җирлеге

буларак тормыш, чынбарлык. *Практикада күрдем инде: кабул итү вакытында ишек төбендә тезелешеп пенсионер карчыклар утыра*. М.Маликова. *Йөгерүнең файдасы практикада исбатланган.* Шатлыклы кайгы. *Кеше галәмгә тәэсир итү мөмкинлеге алыр, аны үзләштерә башлар, практика, халык хуҗалыгы интересларын күздә тотып өйрәнергә керешер.* Галәмгә юл

3) Алган белемнәрнең, күнегүләрнең эштә кулланылышы, гамәлдә сынау. *Теорияне яхшы белү генә җитми икән шул. Сезнең белән эшләгән өч ай вакыт минем өчен бик гыйбрәтле практика булды.* Х.Вәлиәхмәтов

4) Уку-укыту процессының состав өлеше буларак, теоретик белемне тормышта куллану һәм ныгыту эше, гамәле. *Иртәгә мәктәп бакчасында җәйге практикаң башлана.* Н.Гыйматдинова. *«По уходу за больными» дәресләренә бәйләп, безнең группаны шәһәр хастаханәсенең терапия бүлегенә практикага йөртә башладылар.* Г.Галиев. *Укулардан соң бер-ике атна мәктәп бакчасында эшләгәч: «Хәзер производство практикасы үттегез. Җиденчегә күчтегез», – диделәр.* Д.Галимов

5) Эшчәнлекнең билгеле бер өлкәсендә тупланган тәҗрибә, эш алымнары һәм күнегүләр җыелмасы. *Медицина фәнендәге практиканың бөтен мөмкинлекләреннән файдаланып, аны көткарырга тырышабыз.* Ш.Камал. *Минем 25 еллык практикам бар.* Р.Ишморат. *Фәрит Хәбибуллович --- элегрәк үзенең эш практикасында очраган куркыныч җинаятьләрне тикшерү эпизодларын исенә төшерде ---.* Х.Вәлиәхмәтов

6) Табиб яки юрист эшчәнлеге. *Ул – гомуми практика табибы, һәм без аңа берничә авылны билгеләдек.* Э.Фатыйхова

7) Эшкә билгеле якын килү алымы, кабул ителгән эш итү рәвеше, гадәт, тәртип. *--- җитди вузларның күбесендә төгәл фәннәр күптән инде инглиз телендә укытыла. Андый практика башка илләрдә дә җитәрлек*. Р.Миңнуллин. *Бездә пианистларның аерым концертларын оештыру практикасы юк*. А.Юнысова

ПРАКТИКАНТ *и. рус* Өйрәнү, тәҗрибә туплау, практик белем алу өчен, берәр учреждениегә, предприятиегә беркетелгән белгеч, эшче, укучы. *Мәктәп укытучысы белән практикантлар класска юнәлделәр ---.* Х.Сарьян. *– Менә безнең практикант, яшь агроном Исхак Батуллин, – дип таныштырды Хөсәен*. А.Гыйләҗев. *Минзәлә кантонында хезмәт практикасы үтә: мелиоратор булып эшли. Монда аны практикант итеп кенә түгел, яшь язучы буларак та җылы каршылыйлар*. А.Алиш

ПРА́КТИКУМ *и. гр.* Башлыча югары уку йортларында: берәр фәнне яхшырак үзләштерү өчен үткәрелә торган практик дәрес төре. *Рифә Рахман күздә тоткан «Әдәби тәнкыйть буенча практикум», --- «Текст теориясе» программалары төзи, шул юнәлештә берничә китап чыгара*. Р.Даутов, Р.Рахмани. *Методик практикум ахырында һәр төркем үз вариантын тәкъдим итә, яклый.* Бәйрәм китабы

ПРАКТИЦИЗМ *и. рус кит.* 1) Теориягә тиешенчә әһәмият бирмичә, практик эшчәнлекне өстен кую. *Ул киң күләмдә формалаша башлаган практицизм, индивидуализм һәм, әлбәттә, кешеләрнең акчага табыну күренешләрен күзәтеп, сәнгатьнең тора-бара үз нәфислеген югалтачагын күзаллый.* К.Гыйззәтов

2) Берәр нәрсәнең практик файдасын күз алдында тотып эш итүчәнлек. *Каян килә хәзерге яшьләрдә шул чаклы практицизм?* Г.Ахунов. *Практицизм күңелләребезне шәрәләндереп барадыр. Бәлки, мәктәпләрдә әдәбиятны өстән-өстән генә укытуны шул практицизм тудыргандыр.* Т.Миңнуллин

ПРАН-ЗАРАН *рәв. к.* **пыран-заран**. *--- бер төн эчендә утыз-кырык чакрым китәбез дә, таң алдыннан, йокының иң каты вакытында, пилсудчиклар лагерена бәреп керәбез, пран-заран китерәбез, аннары син күр дә мин күр!..* Г.Әпсәләмов. *Малайлар дәррәү урыннарыннан кузгалып, берсе алга, берсе артка китеп, этешә-төртешә, пран-заран килеп беттеләр.* М.Гали

ПРАНЛАТУ *ф. к.* **пыр туздыру**. *[Хәллә] бик яман сүз әйтеп сүгенергә теләде. Әптелмәннекеләрне пранлатып куып чыгарырга булды.* Ф.Хөсни

ПРА́ПОРЩИК *и. рус* 1) Патша армиясендә иң кече офицер чины, дәрәҗәсе һәм шул чиндагы, дәрәҗәдәге кеше. *Әмма пышылдашу өзелеп калды, шул урында прапорщик Ильяс Алкин үзенең чыгышын тәмамлап, Гаяз Исхакый янәшәсенә барып утырды.* Р.Мөхәммәдиев. *Шулар өстенә Җәләл мулла малае да реакцион «Иж-Буби» мәдрәсәсендә белем алган, патша армиясендә прапорщик булып хезмәт иткән икән.* Р.Батулла. *Сенат карар чыгару хәбәре Казанга килеп җитү белән үк, прапорщик Иван Посысальщиков җитәкчелегендәге гарнизон солдатлары шәһәрнең Татар бистәсендәге дүрт мәчетне дә җимерәләр*. М.Гайнетдинов

2) Совет армиясендә һәм хәзерге Россия армиясендә билгеләнгән вакыттан тыш хезмәт итүче кече командир. *Армиядән биш елдан соң гына, Грузиядән безнең гаскәрләрне чыгара башлагач кына, ул прапорщик дәрәҗәсендә туган якларга кайтты.* И.Сәйфуллин

ПРАХЛА́У *ф. сөйл.* **1.** Кабалану, атылып бәрелү. *Тавык прахлау*

2. *рәв. мәгъ.* **прахлап**. Кабаланып, атылып-бәрелеп. *Пич астыннан песи чыкты прахлап.* Г.Тукай

ПРӘННЕК *и. рус* Тышы балга, патокага яки шикәр сиробына катырылган һәм төрле тәмләткечләр салып пешерелгән татлы камыр ризыгы. *Әти миңа прәннек тә алып кайта.* Г.Исхакый. *Искәндәр сүзсез генә прәннек кимерде.* А.Гыйләҗев. *Якыннан караганда бер дә искитәрлеге юк икән: фанер белән тышланган, уртасы уелып эчкәрәк кергән кызыл билле прәннек кебегрәк бер тартма инде*. Г.Галиев

◊ **Прәннек белән алдау** Төрле хәйләләр, матур сүзләр белән булмастайга ышандыру; өстенлекләр, уңайлыклар булуына ышандыру. *Борын-борыннан урыс шәһәрләре Мәскәү тозагына эләкмәс өчен көрәштеләр. Мәскәү барыбер үзенекен итте: корал белән куркытып, прәннек белән алдап, урыс шәһәрләрен үз тирәсенә туплады.* Т.Миңнуллин

ПРӘННЕК-КӘНФИТ *җый. и. к.* **прәннек-конфет**. *Ике атнаның*

берендә кайтып-килеп, бал-маен, прәннек-кәнфитен ташып кына торалар. Ә.Хәсәнов. *Еллар имингә таба киткәч, чәй-шикәр, прәннек-кәнфитләр чыга башлар.* Ш.Янбаев. *Тәмле-татлы прәннек-кәнфитләр ашап, булган акчага апаларга әйберләр алганнан соң, өйдә калганнарга да күчтәнәчләр табылды.* Г.Сәгыйров

ПРӘННЕК-КОНФЕТ *җыйм.* Прәннек, конфет кебек кондитер әйберләре. *Кызның кесәсе затлы-затлы прәннек-конфетлар белән тулды.* С.Зыялы. *Өстәлебездән прәннек-конфет өзелми.* Р.Габделхакова. *Хәзер ничектер, без үскәндә, авыл баласының бер гадәте бар иде: әнисе кибеткә прәннек-конфет ише тәм-том алырга җибәрдеме, ул кайтышлый аннан авыз итми калмый торган иде – чоры шундый иде.* Н.Гамбәров

ПРӘННЕКЛӘНҮ *ф. сөйл. шелт.* Кыланчыклану, төчеләнү

ПРӘННЕК-ПЕЧЕ́НЬЕ *җыйм.* Прәннек, печенье кебек кондитер әйберләре. *Прәннек-печеньеның да килосы 70–80 сумга җитә.* Р.Миңнуллин

ПРӘННЕКЧЕ *и.* Прәннек пешерүче яки прәннек сатучы. *Прәннекченең прәннекләре бүген бигрәк тә уңган*

ПРЕА́МБУЛА *и. лат. кит.* Конституциянең, халыкара килешүнең яки берәр мөһим актның кереш өлеше. *– Кабул ителергә тиешле Бала хокуклары турындагы законны ниндирәк итеп күз алдына китерәсез? – Аның, билгеле, преамбуласы да булыр. Аннары күп кенә булекләре бәян ителер.* Р.Миңнуллин. *Преамбула өлешендә ислам, буддизм һәм яһүд диннәрен дә искә алуны яклап чыктылар һәм шундый гыйбарә (формулировка) тәкъдим иттеләр.* Р.Мөхиярова

ПРЕВЕНТИВ *с. кит.* Нәрсәнедер булдырмау өчен алдан кисәтеп башкарылган. *Хөкүмәт кешеләре, белгечләр тарафыннан ясалган анализларны һәм шулар нигезендә эшләп чыгарылган тәкъдимнәрне өйрәнеп, алдан уйланылган (превентив) чаралар күрергә тырышалар. Мәсәлән, илдә салым системасын гаделрәк нигезгә күчерү --- һ.б.* К.Гыйззәтов. *--- М.В.Фрунзенең каттыгый таләбе буенча Төркестан комиссиясе --- җыела һәм анда --- бу идеяне үткәрергә омтылучы милләтчеләргә каршы превентив чикләү чаралары күрү турында махсус документ кабул ителәр.* М.Сәхапов

ПРЕДИКАТ *и. лат.* 1) *грам.* Җөмләнең ия турында хәбәр итә һәм аңа грамматик буйсына торган баш кисәге; хәбәр. *Гомумән, фәнни иншалау стиле өчен ике кисәкле җөмлә – иясе дә, хәбәре дә булган җөмлә хас. Җөмләдәге ия анда – логик субъектка, хәбәр предикатка туры килә.* Х.Курбатов

2) Логикада: фикер йөртүнең предметын – субъектын билгели торган төшенчә; логик хәбәр. *Хөкемдә һәрвакытта да субъект, предикат һәм бәйләгеч була.* М.Зәкиев. *Соловьёвның хезмәтләрендә төп урынны түбәндәге концепцияләр ала: беренчесе – бербөтенлек концепциясе. Бу концепция буенча, булулык – абсолютның предикаты. Абсолютның асылы – бербөтенлек, ә бербөтенлекнең билгесе – гомум идея...* К.Гыйззәтов

ПРЕДИКАТИВ *с. лог., лингв.* Хәбәрлекле. *Ике составлы җөмләнең нигезен тәшкил иткән, үзара предикатив мөнәсәбәттә тора торган җөмлә кисәкләре – ия һәм хәбәр.* Х.Сәлимов. *Мәкальләрдә предикатив берәмлекләрнең бер синтаксик бөтен буларак оешуының күп төрле мөмкинлекләре билгеләнде.* Г.Нәбиуллина. *Җөмләнең предикатив мөнәсәбәткә кергән кисәкләре итеп ия белән хәбәр билгеләнә.* Р.Шәмсетдинова

ПРЕДИКАТИВЛЫК *и. лог., лингв.* Предикатив булу; хәбәрлек. *Җөмләнең төп билгеләре – предикативлык (хәбәрлек) һәм модальлек.* Х.Сәлимов. *Тел галимнәренең күпчелеге исә җөмләнең бу икенче билгесен предикативлык дигән термин белән атап йөртә.* В.Хангилдин

ПРЕДМЕТ *и. рус* 1) Күрергә, тотып карарга мөмкин булган теләсә нинди матди җисем, әйбер. *Аллегориянең асылы – абстракт бер фикерне яисә төшенчәне чынбарлыктагы конкрет бер күренеш яки әйбер (предмет) белән алыштыру.* Ф.Урманчеев. *Автор кайвакыт фигыльләрне сирәгрәк файдалана, --- ул исемнәрне яратарак төшә, предмет яки күренешнең исеме аның өчен мөһимрәк санала.* Г.Морат. *Лейтенант --- каты итеп өстәлгә сукты. Өстәл кырыена авышкан предметлар (тәлинкәләр, чәшкәләр, кашыклар һ.б.), бердәм сикерешеп, озак кына алдагы позицияләренә кайта алмыйча интектеләр.* Х.Ибраһимов

2) Һәртөрле фикерләү, сөйләм, танып белү һәм иҗади эшчәнлекнең эчтәлеген тәшкил иткән тема. *Әмма шунысы бар: бәхәс предметы чын «алтын алма» булырга тиеш.* Т.Миңнуллин. *Кеше тормышының кыйммәте кемнеңдер законсыз шәхси зәвыгы яки өстенлек итү предметы була алмый.* А.Низамов. *Татар халык мәкальләрендә --- һинд, монгол алынмалары күпчелекне тәшкил итмәгәнгә, тикшеренүләрнең предметы итеп сайланмадылар.* Г.Мөгътәсимова

3) Уку-укыту эшендә өйрәнелә торган фән тармагы. *Туризм инде берничә ел рәттән институтта махсус предмет буларак та укытыла.* А.Хәсәнов. *Гомуми белем дәрәҗәсе җитәрлек булмаган, рус телен начар белгән курсантлар уку вакытында махсус предметлар буенча рус телендә үздырылган дәресләрне аңламыйлар, тиешенчә кабул итә алмыйлар.* З.Кириллова

ПРЕДМЕТЛЫК *и.* Предмет булу, нинди дә булса әйбер билгеләренә ия булу. *Сүз төркемнәре предметлык, билге, процесс һ.б.ш. мәгънәләрне белдерү буенча аерылалар.* Д.Тумашева. *Югарыда исемнең төп семантик билгесе предметлык төшенчәсе икәнлек аңлатылды.* В.Хангилдин

ПРЕДМЕТЛЫЛЫК *и.* Берәр нәрсәдә матди эчтәлек булу, предметлар, әйберләр дөньясы белән бәйләнеш. *Тагын бер төркем сүзләр алыйк: китапны, урманны, эшне, идәнне, әтине, сәяхәтне... Бу сүзләр, предметлылыкны белдерү белән бергә, башка сүзгә ияреп кенә килә алалар ---.* Ф.Сафиуллина. *Димәк, исемнәргә – предметлылыкны, фигыльләргә эш-хәлне процесс итеп белдергән сүзләр керә.* Ч.Харисова

ПРЕДОХРАНИ́ТЕЛЬ *и. рус* Эштә, көнкүрештә кулланыла торган техник аппаратуралар, электр приборларын төрле һәлакәтләрдән кисәтү, гамәлсезләнүдән саклау өчен хезмәт итә торган җайланма; саклагыч. *Инженер предохранительне чыкылдатып ычкындырды, мылтыкны аучыларча җиңел генә иңенә терәде.* Г.Ахунов. *Шактый азаплангач кына, Эдуард тавыш бирде: – Бер предохранитель янган, Галимә Галләмовна. Шуны алыштырдым.* Л.Лерон. *Пычкыларның теше --- коелып кына тора, һәм аларга победит --- ябыштыралар; пычкылар кәкрәя, ут сүнә (предохранитель янмасын өчен, электриклар хәтта кадак тыгалар иде), моторлар янып чыга.* Р.Кәрами

ПРЕДПАРЛАМЕНТ *и. рус* 1917 елның сентябрендә Россия Вакытлы хөкүмәтендәге демократик киңәшмә вәкилләренең бер өлешеннән төзелгән, киңәш бирү хокукы булган вакытлы совет, вакытлы шура, вакытлы парламент. *Искәндәр – Учредительное собрание, милләт мәҗлесе, предпарламент әгъзасы.* Г.Газиз

ПРЕДПРИНИМА́ТЕЛЬ *и. рус* Предприятие хуҗасы яисә сәүдә эше белән шөгыльләнүче; эшмәкәр, кәсәбәче. *Тимербулатов көнен-төнен чаба, заводларда, конструкторлык бюроларында, предпринимательләрдә була.* А.Расих. *Ә минем кооператор хуҗам предприниматель --- булып китте. Аны хәзер «коммерсант әфәнде» дип йөртәләр.* М.Сәлим

ПРЕДПРИНИМАТЕЛЬЛЕК *и.* Предприниматель эшчәнлеге, эшмәкәрлек, кәсәбәчелек

ПРЕДПРИ́ЯТИЕ *и. рус* Юридик зат хокукларына ия булган, мөстәкыйль хуҗалык алып бара торган җитештерү яки сәүдә берәмлеге; эшханә, завод, фабрика, мастерская һ.б.лар; шундый берничә берәмлек берләшмәсе. *Вакыт сукканны әллә ничәнче тоемы белән сизеп ала һәм, рәсми эштән китеп, берничә яраннарыннан гына торган кече предприятие ача.* Т.Галиуллин. *Казан шәһәренең Мәскәү районына урнашкан предприятиеләр һаваны агулауга үзләреннән зур өлеш «кертәләр».* А.Низамов. *Байтак кына ачуланышканнан соң, предприятие директоры, кабинетыннан чыгып китү максаты белән, ишеккә юнәлгән.* Я.Шәфыйков

ПРЕДСЕДА́ТЕЛЬ *и. рус* 1) Җыелышны яки утырышны алып бару өчен сайланган кеше; рәис. *– Кем шушы фикерне хуплый, кулларыгызны күтәрегез! Мәрьям башын күтәреп залга караргa куркып калды. – Бертавыштан, – диде председатель.* М.Маликова. *Садри – мәҗлес-җыелыш рәисе, председатель.* Г.Камалетдинов

2) Кайбер учреждение, берләшмә, җәмгыять, оешма яки алардагы бүлекләрнең җитәкчесе. *Мине районның иң арткы почмагындагы бер колхозга председателе үзе машинага утыртып алып китте.* Н.Дәүли. *Председатель Тимерхан, көзгә хезмәт көненә уңыш өч килодан да ким булмаячак дип, күңелләргә дәрт өстәде.* М.Мәһдиев. *--- аттестат һәм дипломнарның күчермәләре белән танышкач, комиссия председателе турыдан-туры: – Ремек кебекләргә иң катлаулы космик техниканы ышанып тапшырырга мөмкин, – диде.* Галәмгә юл

3) Югары дәүләт органы яки хөкүмәт, дәүләт җитәкчесенең рәсми атамасы составында кулланыла. *[Аны] обком секретаре белән Верховный Совет Председателе котларга килә.* Т.Гыйззәт. *Милләтләр Советының председатель урынбасары итеп сезнең кандидатура тәкъдим ителгәч, сөенеп куйган идек.* М.Галиев

ПРЕДСЕДАТЕЛЬЛЕК *и.* Председатель вазифаларын башкару эше, председатель вазифасы. *Әйе, моннан биш ел элек аны капылт кына председательлектән төшермәгән булсалар, ул, бер-бер җаен, әмәлен табып, ничек тә Исхакны авылга өндәгән булыр иде.* А.Гыйләҗев. *--- авылдашлары аның сугыштан яраланып кайткан әтисенә, үзебезнең Ярулла дип, председательлек эшен ышанып тапшырганнар иде.* Н.Хәсәнов. *Миңнулла түзеп тора алмады. Председательлек итүче кешенең рөхсәтен сорап тормастан, атылып трибунага менде дә: – Ипташлар! – дип кычкырды.* В.Нуруллин

ПРЕЗЕНТ *и. фр.* 1) Бүләк. *– Менә дигән презент бу, Алоша, – диде Стаффорд, фильм беткәч.* Галәмгә юл

2) *ирон.* Ришвәт. *Директорга презент бирү*

ПРЕЗЕНТА́ЦИЯ *и. лат.* 1) Нинди дә булса яңа, күптән түгел генә барлыкка килгән, булдырылган, иҗат ителгән берәр нәрсәне җәмәгатьчелеккә тәкъдим итү, күрсәтү тамашасы, акциясе. *Ә Казан зур ул, кызым, Казан кайный! Көн дә банкет анда, көн дә презентация, көн дә бәйрәм!* Аманулла. *Нәшрият үз хезмәтен --- очрашу кичәсе, презентация кебек акцияләр үткәреп тә җәмәгатьчелеккә таныта, потенциаль укучыларны җәлеп итә.* М.Вәлиев. *Теләге булганнар төрле тематик презентацияләр: Пермь төбәкләрендә эшләп килүче мөселманнар берләшмәләре, Диния нәзарәтләре, мәчетләр белән таныша ала.* Шәһри Казан

2) Берәр нәрсә турында кирәкле мәгълүматны кулланучыга уңайлы формада җиткерү мөмкинлеге бирә торган мәгълүмат яки реклама чарасы

3) *информ.* Докладчы чыгышының эчтәлеген чагылдырган рәсем, тест, искәрмә һ.б.ш.ларның бер файлга слайд-шоу формасында туплап бирелгән җыелмасы. *Бигрәк тә дәресләрне заманча технологияләр кулланып, мультимедиа чаралары, презентация программалары файдаланып оештырганда, укучылар актив эшчәнлеккә тартылалар ---.* З.Исламова

ПРЕЗЕНТАЦИЯЛӘ́Ү *ф.* Яңа, күптән түгел генә барлыкка килгән, иҗат ителгән берәр нәрсәне җәмәгатьчелеккә тәкъдим итү, күрсәтү. *Мәскәүдә Мәскәү армеецларын 18 ел үткәннән соң чемпион титулына китергән Валентин Николаевның яңа җыелма командасын тәкъдим итү (презентацияләү) булды.* Т.Кәримов. *Укытучылар үз хезмәтләрен презентацияләделәр, үзләре язган шигырь һәм хикәяләрен укыдылар.* Гасырлар авазы. *Кичә Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетында Президент Рөстәм Миңнехановка «Казансу» елгасының яр буе биләмәсен комплексы үстерү концепциясен презентацияләделәр.* Шәһри Казан

ПРЕЗЕНТЛА́У *ф.* Бүләк итеп бирү. *Егеткә сувенир презентлау*

ПРЕЗЕРВАТИВ *и. лат.* Балага узудан һәм венерик авырулардан саклану өчен кулланыла торган бик юка, кечкенә яры капчык. *Чыннан да, балалар бакчаларындагы сабыйларга наркоманиянең начарлыклары турында сөйләп кенә, төрле шоу-концертлар оештырып кына, дискотекаларга килгән яшьләргә презервативлар таратып кына уңай нәтиҗәләргә ирешеп булмаячак.* Р.Миңнуллин. *Аннан бер презерватив, кулъяулык, фатир ачкычы белән ике мең сум акчадан башка әйбер табылмады*. Р.Сәгъди

ПРЕЗИДЕНТ *и. лат.* 1) Билгеле бер срокка дәүләт башлыгы итеп сайланган кеше; илбашы. *Төркиянең беренче Президенты Ататөрекнең мавзолее гына да ни тора!* Р.Миңнуллин. *Безгә алга таба нишләргә? Менә шушы сорауларны куярга кирәк Россия Президенты алдына*. Ф.Бәйрәмова. *1995 елда Кыргызстанда «Манас» эпосының меңьеллыгын бәйрәм итү --- гаять әһәмиятле чара булды. Анда Төркия президенты С.Демирәл, --- Кыргызстан президенты А.Акаев, Төрекмәнстан президенты С.Ниязов, Үзбәкстан президенты И.Кәримов һәм башка күренекле дәүләт эшлеклеләре катнашты.* Ф.Галимуллин

2) Берәр җәмгыятькә яки учреждениегә җитәкчелек итү өчен сайланган рәис. *Татарстан Фәннәр академиясе президенты, филология фәннәре докторы, академик Мансур Хәсән улы Хәсәнов 1930 елда Зәй районының Бигеш авылында туа.* С.Ибраһимова. «*Мәңгәр» фонды президенты Сафия ханым, аның ире Гыйззәт Имре, фондның вице-президенты Мәхмүт Әллүкәй Сабага да килделәр.* Т.Нәҗмиев. *Хәзер бу игелекле эшне Гомәр аганың улы, Финляндиядәге «Ислам җәмгыяте»нең президенты Окан әфәнде бик уңышлы дәвам иттерә.* Х.Миңнегулов

ПРЕЗИДЕНТЛЫК *и.* 1) Президент дәрәҗәсе, исеме, вазифасы. *Әгәр дә сайлаулар бер генә көн соңрак үтсә, господин Ельцин бу юлы инде президентлыктан, мотлак, колак каккан булыр иде.* Ә.Еники. *Татарча ярты кәлимә белмәгән һәм белергә дә теләмәгән хәсрәт иптәшләргә һәм президентлык дәрәҗәсен түбән төшереп, үзләрен кандидат итеп күрсәткән шофёр, эшче, директор һ.б.га каршы яздым*. Н.Гыйматдинова. *Президентлыкка кандидат итеп күрсәтелүгә үк, шофёрларны үз ягыма аударам.* Ф.Баттал

2) Президент булып торган вакыт һәм президент эшчәнлеге. *Ә безнең бүгенге Президентыбыз – Минтимер ага Шәймиев. Аның президентлыгы татар халкының язмышы хәл ителгән тарихи бер чорга туры килде.* Р.Миңнуллин. *Рөстәм Хәмитов үзе дә, президентлык вазифаларына керешүгә үк, Башкортстанның брендларын арттырырга һәм аларны бар дөньяга танытырга кирәк, дигән бурыч куйган иде*. Идел. *Дмитрий Медведевның 4 еллык президентлык чорында кабул иткән кануннары арасында күпмедер дәрәҗәдә файдалылары да, бер кирәксезләре дә булды.* Шәһри Казан

ПРЕЗИ́ДИУМ *и. лат.* 1) Җыелыш яки киңәшмәне алып бару өчен сайланган орган; шуңа кергән кешеләр. *Сара апа президиум өстәленә җәелгән кызыл ситсы кебек кызарып чыкты*. Х.Сарьян. *Президиум сайлау, көн тәртибен раслау да тып-тыныч кына үтте*. Ф.Садриев. *Президиум, сәхнәгә чыгып, үз урынына урнашты*. Р.Батулла

2) Кайбер оешмаларның яки учреждениеләрнең җитәкче органы. *СССР Верховный Советы Президиумының 1943 ел, 27 август Указы белән Ф.Г.Камалетдиновка Советлар Союзы Герое исеме бирелә.* Ш.Рәкыйпов. *Аның тәкъдиме белән президиум эш планы кабул итте.* Р.Мөхәммәдиев. *Тырыш хезмәте өчен Республика Югары Советы Президиумының Мактау кәгазе белән бүләкләнә ул биредә*. Ф.Фәткуллин

3) *җый. и.* Шул органга кергән кешеләр. *Аппарат янында Төркестан Совнаркомы президиумы.* Ш.Усманов. *Якуб Совет президиумын җыйды.* И.Гази

ПРЕЗУ́МПЦИЯ *и. лат. юр.* Берәр фактны, киресе расланганга кадәр, юридик яктан дөрес дип табу. *Гаепсезлек презумпциясен онытмагыз. Ул үзенең гаепсез икәнен исбат итәргә тиеш түгел.* М.Маликова

ПРЕЙСКУРАНТ *и. нем.* Товарларның төрләре һәм сортлары, хезмәт күрсәтү төрләренең бәяләре (тарифлары) турында белешмә. *[Официант:] Рәхим итегез, нәрсә китерик? Менә прейскурант. Рәхим итеп шуннан карап әйтегез.* Г.Камал. *Ни телисез? Пожалуйста, мәгез прейскурант! Коньяк, дисез: була!* Ф.Кәрим

ПРЕЛАТ *и. лат.* Католик һәм англикан чиркәүләрендә югары дәрәҗәле рухани (архиепископ, епископ, монастырь башлыгы). *Австриянең өстен палатасы --- принцлардан, --- прелатлардан тора.* Г.Коләхмәтов

ПРЕЛЮ́ДИЯ *и. лат. муз.* 1) Музыкаль әсәрнең кереше. *Яшьлек, Гомрең кыска синең, Шундый кыска булып тоела: Кичен чәчәк аткан була, Ә таңында инде коела... Бу – музыка теле белән әйткәндә, прелюдия, гадәти шәкелгә күчергәндә, кереш сүз.* К.Гыйззәтов

2) Ныклы формасы булмаган һәм гадәттә бер инструмент (фортепьяно, клавесин, орган) өчен язылган мөстәкыйль музыкаль пьеса. *Ноталар арасыннан Шопенны табып, шуннан бер прелюдияне ашыкмыйча гына уйный башладым.* Ә.Еники. *Хәбир Шопенның атаклы циклыннан бер прелюдия уйнады.* Ш.Хөсәенов

3) *күч.* Берәр нәрсәнең башлангычы, кереше. *Бөек шагыйрь яшәгән «Болгар» кунакханәсен җимереп, җир белән тигезләделәр. Бу вандаллыкка прелюдия шикелле, язын Тукай исемен йөрткән премияләр дә, Дәүләт бүләгенең дәрәҗәсен төшереп, нигездә үзешчәннәргә бирелде.* Р.Фәйзуллин. *Бу җыр безнең арадагы иҗади элемтәләрнең прелюдиясе булып чыкты.* Ә.Рәшит. *Үзен яклап --- сүз әйтергә базган авыл егетенең вәхшиләрчә кыйналу эпизодын гына укып карагыз, сез анда яндырылган һәм таланган, канга батырылган Кавказ авыллары --- фаҗигасенең прелюдиясен күрерсез.* А.Хәлим

ПРЕМИАЛЬ *с.* Премия итеп бирелгән, премия бирү өчен билгеләнгән. *2008 елда конкурсның гомуми премиаль фонды 2,5 млн. сум тәшкил итте.*

Казан утлары. *Пенсия алыр өчен соңрак мөрәҗәгать итүнең һәр елы өчен иминият пенсиясе тиешле премиаль коэффициентларга арттырылачак.* Кәеф ничек?

ПРЕ́МИЯ *и. лат.* 1) Билгеле бер өлкәдә ирешкән уңышлар, казанышлар, күрсәткән хезмәтләр өчен бирелә торган рәсми бүләк. *Ленин премиясе лауреаты Муса Җәлил язган шигырьләрне белмәгән татар юктыр.* Эзләнүләр, уйланулар, табышлар. *2013 елның 9 февралендә 73 яшендә танылган рәссам, --- Татарстан Республикасының Г.Тукай исемендәге Дәүләт премиясе лауреаты Илдар Мәнсәви улы Ханов вафат булды.* Ватаным Татарстан. *Альфред Нобель үзе исемендәге премияне, динамит уйлап чыгару аркасында, сугыш пропагандисты итеп санамасыннар өчен васыять итә.* Ирек мәйданы

2) Җитештерү нормасын яхшы сыйфат белән арттырып үтәгән өчен, эшче һәм хезмәткәрләргә хезмәт хакыннан тыш бирелә торган матди кызыксындыру чарасы. *Без сезнең белән дәүләткә 100000 сум экономия калдырабыз. Бәс, шулай булгач, миңа моның өчен премия тиешледер дип беләм.* Н.Дәүли. *– Премия ул миңа, яхшы эшләгән өчен, – диде Лариса.* М.Маликова. *Безнең эш турында кешегә сөйләп йөрмәдең, тавыш куптармадың, штраф салмадың, премияләрне кисмәдең.* Н.Акмал

ПРЕ́МИЯЛӘҮ *ф.* Премия бирү. *Җирле бюджеттан премияләү өчен бүлеп бирелә торган акча 700 мең сум тәшкил итә.* Асылъяр. *Барлык эре хуҗалыкларда да диярлек басуда эшләүчеләрне көндезге һәм кичке аш белән тәэмин итәчәкләр, шул ук вакытта аларны премияләү системасы да сакланачак.* Әлмәт таңнары

ПРЕ́МИЯЛЕК *и.* Премия өчен әзерләнгән, премиягә җитәрлек. *Премиялек акча*

ПРЕМЬЕР *и. фр.* 1) *к.* **премьер-министр**. *Премьер өйдә юк иде.* М.Мәхмүтов. *Аңа, тигез җирдә фәкать аз-маз гына калкып торган шушы бүкәнгә, президентлар, премьерлар, министрлар баш ия.* Ә.Рәшит. *Залның беренче рәтендә министрлар, премьер, илбашы, мин.* З.Дәүләтов

2) *театр* Баш рольләрне, партияләрне башкаручы артист. *Труппа премьеры*

ПРЕМЬЕ́РА *и. фр.* Пьеса, опера, балет һ.б. төрле тамашаларның беренче мәртәбә сәхнәгә куелышы. *Шау-гөр килеп премьера кичләре уза торды ---.* А.Гыйләҗев. *«Язгы күкрәү»нең премьерасында халык күп иде.* Г.Мөхәммәтшин. *[Фаягөл] театрга килеп, премьера карап кайтканнан соң китеп тә барды.* А.Әхмәтгалиева

ПРЕМЬЕРЛЫК *и.* Премьер вазифасы, премьер хезмәте. *Президентлык һәм премьерлык чорында Путин барлыгы җиде шундый «эфир» үткәрде.* Татарстан яшьләре. *Ул премьерлык вазифасына керешкәч тә, хәлләр үзгәрмәде, җиде триллион (!) сум акчаны унбер эре банкка бирдерде.* Безнең гәҗит

ПРЕМЬЕР-МАЙОР *и. тар. фр.-лат.* XVIII гасырда (1797 елга кадәр) патша армиясендә офицер чины, дәрәҗәсе һәм шул чиндагы, дәрәҗәдәге кеше. *Премьер-майор Варнстедтка да, губерна территориясендәге крепостьларның гарнизоннарын җыеп, Бөгелмә каласына килергә кушыла.* В.Имамов. *Бу бәла-казадан котылу белән, әлеге авылга, Димитрий атакай үтенече буенча, премьер-майор Юнгер җитәкчелегендә гаскәриләр җибәрелә.* Ф.Ислаев

ПРЕМЬЕР-МИНИСТР *и. фр.* Хөкүмәт башлыгы, Министрлар Кабинеты рәисе. *Шуңа да «чеченнәргә каршы яңа сугыш башлап җибәргән» премьер-министр В.Путинның рейтингы чүпрә кебек күперә.* Р.Зәйдулла. *Фәрит Мөхәммәтшин – Татарстанның һәм Россиянең күренекле дәүләт эшлеклесе, Татарстан Республикасы Югары Советы рәисе, Татарстанның Премьер-министры, Россиянең Федерация Советы әгъзасы булды.* Р.Миңнуллин. *Шунысын да әйтергә кирәк: бу чараны оештыру өчен, Нью-Йоркка Төркия премьер-министры махсус рәвештә килде.* Р.Вәлиев

ПРЕПАРАТ *и. лат.* 1) Фәнни тикшерү өчен файдаланыла торган хайван яки үсемлек организмының махсус әзерләнгән кисәкләре. *Препаратлар ясауга гаять оста булып өйрәнеп җиткәнлеге өчен, ул медицина факультеты студентларының укулары вакытында аларга якын ярдәмче булды.* И.Рәмиев. *Анатомия препараты. Бака йөрәге препараты*

2) Тикшеренү өчен әзерләнгән химик матдә. *Төелгән препаратны микроскоптан караганда, төзек булмаган формалы пластинкасыман кристаллар күзәтелә.* Эзләнүләр, уйланулар, табышлар. *Радиоактив препарат*

3) Фабрикада, лабораториядә әзерләнгән химик яки фармацевтик продукт. *Әгәр иң соңгы яңа препаратлар ярдәмендә дә Исмәгыйльнең кан басымы төшеп, бумасы кимемәсә, актыккы чарага – шушы авыр хәлендә операциягә тәвәккәлләргә туры килер.* Г.Әпсәләмов. *Тикшерә, эзләнә төшсәң, баш миендә эндорфиннарны ясалма рәвештә барлыкка китерә торган препарат эшләп чыгарырга --- мөмкин булыр иде.* Ә.Баян. *Бу авыруны врач язып биргән күкертле препаратлар белән дәвалыйлар.* Тигез гомер итегез!

ПРЕПАРА́ТОР *и. рус* Фәнни учреждениеләрдә препаратлар әзерләүче хезмәткәр. *Сезнең кул астында, әгәр шулай әйтергә мөмкин булса, бары ике генә кеше – препаратор Настенька һәм этләр караучы кала.* А.Расих

ПРЕПАРАТОРЛЫК *и.* Препаратор хезмәте, препаратор вазифасы

ПРЕПОЗИТИВ *с. лингв.* Берәр сүз яки сүзтезмә алдында торган. *Кисәкчәләр сүзнең алдында (препозитив позициядә) һәм азагында (постпозитив позициядә) куелалар.* Д.Тумашева. *Артыклык дәрәҗәсе сыйфаттан алда урнаша торган универсаль 'иң' кисәкчәсе һәм индивидуаль, бары тик бер сыйфатка гына ялгана торган препозитив кисәкчәләр ярдәмендә ясала.* Фән һәм тел

ПРЕПОЗИ́ЦИЯ *и. лат. лингв.* Берәр җөмлә кисәгенең үзе турыдан-туры буйсынган яки ярашкан җөмлә кисәге алдында торуы. *'Мөхәммәт' компоненты препозициядә дә, постпозициядә дә ир-ат исемнәре ясый.* Фән һәм тел

ПРЕ́РИЯ *и. фр.* Төньяк Американың уртача климат зонасындагы куе

биек үлән белән капланган дала тибындагы мәйданнар. *Төп инструмент – электр гитарасы. Анда ерак прериялардәге ковбой гитарасы чакыруларының кайтавазы һәм төнге паровозның ямансу сызгырулары ишетелә бугай.* Ә.Баян. *Кыяклылар семьялыгы – чәчәкле үсемлекләрнең иң эре семьялыкларыннан берсе. --- Далада, болын, прерия һәм пампасларда, саванналарда кыяклылар – өстенлек итүче үсемлекләр төркеме.* Ә.Мәүлетова

ПРЕС *ы. к.* **перес**. *Майлы күз корбанына кабат ташланмакчы иде, Маһирә апа: Прес! – дип кычкырып өлгерде.* Н.Әхмәдиев. – *Прес! – дип, сеңлесен сарайга куалады Илһам. – Бәйләнмә кешегә! – Тыңлама, – диде ир дә.* Н.Гыйматдинова. *Бүлмәдән нәрсәнеңдер шакылдап төшкәне, чылтырап ватылганы ишетелә. [Камилә:] Нәрсә ул анда, кем ул? [Рәхилә:] Берәү дә юк. Мәчедер. (Ишекне ачып, башын тыгып кычкыра.) Прес! Прес, юньсез!* Р.Раскулова

ПРЕСВИ́ТЕР *и. гр.* Бөекбританиядә һәм кайбер башка илләрдә протестантлар оешмасының сайлап куелган җитәкчесе. *Пресвитерның чыгышы фәнгә каршы юнәлдерелгән иде.* Социалистик Татарстан. *Колумб, үз экспедициясен оештыру өчен, нәкъ менә шул пресвитер Иоанн турындагы риваятькә мөрәҗәгать итә дә.* Татар, уян!

ПРЕСС *и. лат.* 1) Һәртөрле әйберләрне кысып тыгызлау механизмы яки машинасы; эскәнҗә. *Узган ел Алексей чүт кенә тәбә булмады. Ходай саклагандыр, дим. Мастеры ватык прессга эшләткән.* Р.Бәшәр. *Йомычкалар авыр пресс белән Кысыла да китә мартенга, Ә бераздан алтын-сары булып Кояш чыга мартен артында!* С.Гәрәева. *Ни экономикада, ни социаль сферада, ни идеология өлкәсендә үзгәртеп корулар сизелми, ә туктаусыз, алга барабыз, дибез. Тимер пресс һаман кысылган хәлдә, режим ничек булды, шулай кала бирә.* Ф.Садриев

2) *сөйл. к.* **пресс-папье** (*2 мәгъ.*). *--- директор аларны [кәгазьләрне] мәрмәр пресс белән бастырып куйды.* М.Маликова

ПРЕ́ССА *и. фр.* 1) Вакытлы матбугатның (газета-журнал һ.б.ш.ның) гомуми исеме. *Ул инде журналист булган да иде. --- Әлбәттә, сул прессада.* Э.Касыймов. *«Бүлмәмә пресса кертегез, дөньядан артта калам!» – ди икән ул, «почта» соңласа.* Сөембикә. *Сары прессада ни язмаслар!* Ватаным Татарстан

2) *җый.* Журналистлар; вакытлы матбугат вәкилләре. *Син – как-никак пресса, хакимиятнең бишенче тәгәрмәче.* Н.Гыйматдинова. *Октябрь аенда «Закрытая школа» һәм «Папины дочки» сериалларының актёрлары пресса һәм тамашачылар белән очрашу уздырды.* Ялкын. *Бу тантанада быелгы бәйгенең җиңүчеләре, --- бәйгене оештыручылар һәм жюри әгъзалары, чакырылган кунаклар, телевидение һәм пресса катнашыр дип көтелә.* Туганайлар

ПРЕСС-АТТАШЕ *и. фр.* Дипломатик вәкиллекнең (илчелекнең, миссиянең һ.б.ш.ларның) матбугат мәсьәләләре белән шөгыльләнүче хезмәткәре. *ТР Президентының Рәхмәт Хатына --- пресс-атташе Ольга Камардина, табиб Пётр Лернер һәм массажист Евгений Добровольский лаек булды.* Ватаным Татарстан. *Алар – Казан хоккей клубы директоры Шамил Хөснетдинов, массажчылар Рамил Сәләхиев белән Евгений Добровольский, пресс-атташе Марат Фәрхиев, һөҗүмчеләр Кирилл Петров белән Томаш Винцоур.* Шәһри Казан

ПРЕСС-БЮРО *и. ингл.* 1) Һәртөрле съездлар, конференцияләр, киңәшмәләр вакытында матбугат органнарына хәбәрләр бирү өчен оештырыла торган редакция аппараты. *Ул елларда район газеталары өчен «Правда» газетасы пресс-бюро мәкаләләре җибәреп тора иде бит әле.* Ф.Баттал

2) Матбугат органнарын әзер мәкаләләр, информацияләр, иллюстрацияләр һ.б.ш. материаллар белән тәэмин итеп тору өчен оештырылган даими бүлек (редакция). *Бу ике номерда гына да 75 – 80 процент тәрҗемә. «Пресс-бюро» тарафыннан җибәрелгән һәр материалны чыгара гына бирәләр. Яхшымы, начармы – анысы редакция эше түгел. Ник, «Пресс-бюро» белми басмагандыр инде.* А.Алиш

ПРЕ́ССИНГ *и. ингл.* 1) Спорт уеннарында: көндәшеңә ирекле хәрәкәт итәргә мөмкинлек бирмәү, бергә-бер уйнау (саклауның бер төре). *Казанлылар петербурглыларны көчле сак нәтиҗәсендә түгел, ә кырның бөтен почмагындагы прессинг сәбәпле туктата алды.* Шәһри Казан. *Футболда прессинг куллану*

2) *күч.* Кемнең дә булса иреген яки эшчәнлеген чикләүгә юнәлдерелгән чаралар, мораль басым. *Күп еллар буе сәяси прессинг астында яшәү. Полиция тарафыннан гаепләнүчеләргә карата психологик прессинг кулланылуы*

ПРЕСС-КЛУБ *и. ингл.* Журналистлар, пресса вәкилләре клубы. *«Үзебез» хәрәкәте һәр атна саен журналистлар һәм экспертлар, дәүләт һәм җәмәгать эшлеклеләре катнашуында Татарстан журналистлар йортында төрле темаларга татар матбугат клубы (пресс-клуб) үткәрә.* Татарстан яшьләре. *Пресс-клуб утырышында катнашу*

ПРЕСС-КОНФЕРЕ́НЦИЯ *и. ингл.* Һәртөрле сәяси, фәнни һ.б. мәсьәләләр буенча мәгълүмат бирү өчен, дәүләт, фән, җәмәгать эшлеклеләренең матбугат вәкилләре белән очрашуы. *[Әхмәт Симай] Көнчыгышның оккупацияләнгән җирләре министрлыгында даими үткәрелә торган пресс-конференцияләргә радио-корреспондент буларак катнашты, рейхсфюрер Розенберг аны махсус кабул итте.* Г.Әпсәләмов. *Небенцаль Берлинда пресс-конференция уздырды.* Г.Кашшаф. *Пресс-конференциягә җыелган журналистлар түземсезлек белән очрашу сәгатен көттеләр.* З.Дәүләтов

ПРЕССЛАГЫЧ *и. к.* **пресс** (*1 мәгъ.*). *Тракторларыбыз, печән чапкыч, пресслагыч, җыйгыч, тырмалар – эш өчен кирәкле бөтен әйбер бар.* Ирек мәйданы

ПРЕССЛАНУ *ф.* Тыгызлану, кысылу, бастырылу. *Күмер порошогыннан прессланган күмер ясыйлар.* Э.Нигъмәтуллина. *Пресслангач, һәр кирпечне чыбыклы аппарат белән кисәргә, киштәләргә тезәргә --- кирәк бит,*

иптәшләр. Ф.Баттал. *Прессланган торф плиталары төзелеш материалы булып хезмәт итә.* Биология

Прессланып бетү Тулысынча, бөтенләй пресслану

ПРЕССЛА́У *ф.* Пресс белән кысу, бастыру, тыгызлау. *Сездән пресслап салам алып китә[без].* М.Хәбибуллин. *Массаны пресслау барышында пресста вакуум тудыру массага форма бирүне җиңеләйтә, яндырылган эшләнмәнең ныклыгын 2 тапкырга арттырырга мөмкинлек бирә.* Төзү материаллары

Пресслап кую Прессланган хәлдә калдыру

Пресслый башлау Прессларга керешү. *Печән һәм саламны дүрт җыйгыч-пресс белән пресслый башлыйлар һәм аларны шунда ук ябык складларга ташыйлар.* Кама ягы

Пресслый төшү Тагы да ныграк пресслау

ПРЕСС-ПАПЬЕ *и. фр.* 1) Язу карасын киптерү өчен, астына киптергеч кәгазь беркетелгән ярымтүгәрәк пластинка яки такта. *Өстәл өстендә Толстой тоткан әйберләр: гади генә кара савыты, пресс-папье.* Ә.Еники. *Сөйләшкән чакта мөдир --- өстәлдәге пресс-папьесын боргалый башлый.* А.Тимергалин

2) Өстәлдәге кәгазьләрне бастырып кую өчен, бронза, мәрмәр һ.б.ш.лардан ясалган авыр әйбер. *Гыйльфан кулына агач счёт алмакчы иде, әмма аннан да якынрак бер нәрсә алды. Ахрысы, ул мрамордан эшләнгән пресс-папье иде...* М.Мәһдиев. *Ул сугарга дип кулын күтәргәндә, күзем өстәлдәге мәрмәр пресс-папьега төште, ничек шуңар сузылганымны белмичә дә калдым, Бикчәнтәев сукканчы, мәрмәр пресс-папьены элә́ктереп алып, аның яңагына бәрдем.* Л.Гыйззәтуллина

ПРЕСС-РЕЛИЗ *и. махс. англ.* Прессада бастырып чыгару өчен, дәүләт учреждениеләре, халыкара оешмаларның штаб-квартиралары, пресс-бюролар тарафыннан әзерләнгән кыска рәсми белдерү. *--- журналистларга пресс-релиз да, чакыру билетлары да бирмәделәр.* Татарстан яшьләре. *Уз чиратында «Татспиртпром», һөҗүм ясауда массакүләм мәгълүмат чараларын гаепләп, пресс-релиз таратты ---.* Безнең гәҗит

ПРЕСС-СӘРКАТИП *и. англ.-фар.* 1) Нинди дә булса рәсми органның, дәүләт эшлеклесе, фирма кебекләрнең карашларын пресс-релизлар әзерләү һәм тарату, пресс-конференцияләр үздыру һ.б.ш. юллар белән массакүләм мәгълүмат чараларына җиткерү вәкаләте бирелгән кеше. *Мин сине пресс-сәркатибем итәм. Үзең шома, үзең түгәрәк. Журналистларның башын әйләндереп бетерерсең.* Ф.Зариф

2) Массакүләм матбугат чаралары белән бәйләнеш тоту өчен җаваплы хезмәткәр; дәүләт җитәкчеләренең, учреждениеләрнең, шул исәптән илчелекнең вәкиле

ПРЕСС-ҮЗӘК *и.* Журналистларны мәгълүмат белән тәэмин итү һәм оештыру мәсьәләләренә бәйле хезмәт күрсәтү бүлеге. *КамАЗ төзелешенең үз пресс-үзәге бар. Читтән килгән журналистлар иң элек шунда керәләр.* Казан утлары. *Бәйге барышын барлык спорт объектларында 30 пресс-үзәк яктыртачак.* Туганайлар

ПРЕСТИЖ *и. фр.* 1) Кемнең яки нәрсәнең дә булса абруе, авторитеты. *Әмма патент алуның престиж ягы да бар бит әле аның...* З.Мифтахов. *Ул сөйләгәннәргә нәтиҗә ясагач, тагын бер кат инанасың: татар теленең престижы да, кирәклеге дә көннән-көн кими.* Сөембикә

2) Җәмәгатьчелек тарафыннан кайбер кешеләрнең, социаль төркемнәр һ.б.ш.ларның социаль хәленә, профессиясе, эш-гамәлләре, психологик сыйфатлары, матди байлыкларына карап өстен саналуы. *Гаҗәп хәл: укытучы белән әлеге мөнәсәбәт иптәшләрем алдында миңа ниндидер өстенлек – престиж бирә түгелме соң?* Ә.Баян. *Профессорның престижы юк хәзер.* Г.Каюмов

ПРЕ́СТО *ит. муз.* **1.** *рәв.* Бик тиз (музыка әсәрен башкару темпы тур.)

2. *и.* Бик тиз уйнала торган музыка әсәре яки шуның бер кисәге

ПРЕТЕНДЕНТ *и. лат.* Нәрсәгә дә булса дәгъва итүче, берәр нәрсәгә ия булырга хакы булган кеше; дәгъвачы, даулаучы. *--- быел бирелә торган льготный урынга йөз чакрымнан ук үкерендулап килгән, җиле белән үк башкаларны егып салачак претендентлар да юк иде.* Х.Сарьян. *Ләкин аның минуслары бар: холкы йомшаграк, кешене жәлли. --- Юк, дип, Шаязның үзенә претендент була алмавын ачыклады. Аны эш аты итеп файдалануны ният итте.* Х.Камалов. *Өстенә кигән сары бикасап казакие аның инде бабалары Болгарлар тора торган галәмгә китәргә вакыт җиткән, карт Мөҗавир урынына претендент булганлыгын халь (хәл, торыш, кыяфәт) теле белән әйтеп тора.* Р.Гали

ПРЕТЕ́НЗИЯ *и. лат.* 1) Дәгъва. *Аларның монда яшәгән квартирасына претензиям юк.* С.Баттал. *Ул биергә риза булды. Биеде. Бу мәсьәләдә аңа претензия юк, яхшы бии. Фигурасы да яхшы.* Ә.Сафиуллин. *– Безнең фирма ягыннан сезгә претензия юк, – диде Сәет, җавапсыз калмас өчен генә.* Т.Галиуллин

2) Берәр нәрсәгә ризасызлык, канәгатьсезлек белдерү; шикаять. *Без бу эшне үзара килешеп эшлибез. Соңыннан безгә претензия белән килүче булмаячак.* Ә.Еники. *– Претензия бармыни? – диде ул, өстәлгә авыру тарихын куеп. Тавил башын күтәрде. – Операция кирәк булмаган, ә сез ясагансыз!* Х.Камалов. *Башта ярыйсы гына эшләде. Эш турысыннан аңа бернинди претензия юк – зверь кебек.* Р.Кәрами

3) Урынлы таләп. *Трестка нинди претензияләрегез бар? Нәрсә белән ярдәм итик?* Г.Ахунов. *– Сезгә претензия юкмы? – Бардыр инде ул, әйтергә генә куркалардыр...* С.Ибраһимова

4) *махс.* Сатып алучының, кредиторның, заказ бирүченең килешү яки шартнамә шартларын бозган подрядчыга, бурыч алучыга, заказ үтәүчегә рәсми протест белдерүе

ПРЕТЕ́НЗИЯЛЕ *с. кит.* Дәгъвачыл, һавалы

ПРЕТЕ́НЗИЯЛЕЛЕК *и.* 1) Дәгъвачылык; дәгъва итүчелек

2) *кит.* Кыланчыклык, һавалылык. *Күтәренке рухта язылган әсәрләрдә*

каһарманнарның исеменә махсус әдәбилек, пафос, шигъри мәгънә белән өртелгәнлек һәм кайчакта беркадәр претензиялелек хас булучан. Ф.Фасиев

ПРЕ́ТОР *и. лат.* Борынгы Римда башта консул һәм диктатор титулы, соңыннан – иң югары суд хакимияте башлыгы. *Гаскәрдә хезмәт итеп, ул, акрынлап, Сиракуза преторы булып күтәрелде.* Н.Макиавелли

ПРЕФЕКТ *и. лат.* 1) Борынгы Римда административ һәм хәрби хезмәт урыннарының һәм шул урыннарда эшләүчеләрнең гомуми исеме. *Мин беләм, префект, Рим тарихчылары мине мактамас, мәгәр мин аларның мактауларына мохтаҗ да түгел.* М.Хәбибуллин

2) Җирле идарә башлыгы. *Префект сезнең өчен пошына.* Ә.Давыдов. *Уйларының чиксез булачагын аңлаган Солтан Җәләевич, префект булудан баш тартырга кирәк, дигән карарга килде.* Ф.Яхин. *Префект исә махсус вәкаләткә ия: ул район хакимияте башлыгы дәрәҗәсенә тәңгәлләштерелә.* Шәһри Казан

3) Кайбер илләрдә полиция начальнигы

ПРЕФЕКТУ́РА *и. лат.* 1) Рим империясендә административ бүленеш берәмлеге

2) Административ-җирле берәмлек белән идарә итү аппараты. *Сезнең командада, округ, префектура җитәкчеләре арасында татарлар күпме?* Я.Шәфыйков. *Озакламый «Иске бистә» дигән префектура, тарихи-мәдәни тыюлык, татар үзәге дигән сүзләр дә, сөйләүләр дә артта калды, бу проект үз җае белән онытылды, юкка чыкты.* Ф.Яхин. *Япониядәге Нарита аэропортының карантин хезмәте Россия Президенты Владимир Путинның Акита префектурасы губернаторы Норихиса Сатакәга бүләк иткән мәчесен иреккә чыгарган.* Ватаным Татарстан

3) Префект (*2–3 мәгъ.*) һәм аның канцеляриясе урнашкан бина

ПРЕФЕРАНС *и. фр.* Карта уенының бер төре. *Аннары, Костя тәкъдиме белән верандага чыгып, преферанс уены өчен түгәрәк сызгаладылар ---.* Ә.Баян. *Үзе ул преферанс сугарга ярата, кайдадыр хәрбиләрдән һәм карт артистлардан якалашып уйный торган кешеләре бар, шулар янына китсә, тәүлекләп тә югала.* Ә.Еники. *Театр әһелләре, безнең өйгә җыелышып, преферанс уйный иде.* Р.Батулла

ПРЕФЕРА́НСЧЫ *и.* Преферанс уйнаучы яки шул уенны яратучы кеше. *Буш вакытлары булса, карта уйнарга тотыналар. Алар икесе дә мөкиббән киткән преферансчылар иде.* Фатих Әмирхан турында истәлекләр

ПРЕ́ФИКС *и. лат. лингв.* Сүзнең алдына ялгана торган кушымча; алкушымча. *Төньяк Тогодагы тем телендә кечерәйтелгән исем ясауда ка- префиксы кулланыла.* Н.Фәттах. *Префикс – тамырның алдына ялгана торган кушымча. Мәсәлән, рус телендә: переписать, подслушать; гарәп телендә: хәкәмә (хөкем итәргә).* Х.Сәлимов. *Барлык кушымчалар да (префикс, конфикс, инфикс, суффикс, интерфикс), гомумиләштерелеп, аффикс дип аталалар.* Фән һәм тел

ПРЕФИКСАЛЬ *с. лингв.* Префикслар кушудан гыйбарәт; алкушымчалы. *Сүз алды (префиксаль) һәм сүз арты (постфиксаль) морфемалар була.* Х.Сәлимов. *Сүз ясалуның префиксаль ысулы*

ПРЕФИКСА́ЦИЯ *и. рус лингв.* Префикс кушып сүз ясау ысулы

ПРЕЦЕДЕНТ *и. лат.* 1) *кит.* Элек булган һәм шуңа охшашлы башка вакыйга-хәлләр өчен үрнәк яки аклану чарасы булып торган хәл. *Әгәр син суд каршына бассаң, бу прецедент яман үрнәк булыр иде.* Кәеф ничек?

2) *юр.* Бертөрле яки охшаш мәсьәләләрне хәл итү өчен, алдан ук үрнәк итеп чыгарылган суд карары. *Бу – прецедент булырга тиеш, сез бит үзегез үк «закон каршында барысы да тигез» дип башладыгыз.* Ватаным Татарстан

ПРИБОР *и. рус* 1) Нинди дә булса эш башкару, берәр нәрсә белән идарә итү өчен кулланыла торган махсус җайланма; әсбап. *Гильзаны махсус приборлар белән эзләделәр, ләкин ул табылмады.* Х.Вәлиәхмәтов. *Метеостанциядә --- тәүлек буена сәгать саен күзәтү алып барасың, приборлар күрсәтүен журналга язасың ---.* Р.Хәбибуллина. *Тигезлек, басым, температура, көчәнешне үлчәү приборларының эшләү принципларын да биш бармагы кебек белә иде инде ул.* Язмышлар яңарганда

2) Нинди дә булса эш башкару әсбаплары җыелмасы, комплекты; җиһаз, дирбия. *Кунаклар, утырышыгыз. --- Рауза, тагын өч кешелек прибор әзерләп куй.* Ә.Фәйзи. *Аннары язу приборлары янындагы өстәл сәгатенә күз төшереп алды да өстәп куйды.* М.Хәсәнов. *Укырга китәр алдыннан, мин аңа кырыну приборы бүләк иттем.* Э.Касыймов

ПРИБОРЧЫ *и.* Төрле үлчәү һәм көйләү приборларының эшләвен күзәтеп торучы, аларга хезмәт күрсәтүче белгеч. *Авиатехникларга ярдәмгә очучылар, штурманнар, приборчылар килә.* С.Баттал. *Япь-яшь быргычы да, приборчылар, заправка ясаучылар, комиссия вәкилләре дә, коткару командасы да – һәммәсе киреренке тынлыкта соңгы командаңы көттеләр.* Галәмгә юл

ПРИВАЛ *и. рус* 1) Сәяхәттә, походта һ.б.ш.ларда ял итү өчен, юлда туктау. *Шулай беркөнне безнең эскадрон бер монастырь янында привалга туктады.* Г.Афзал. *Солдатта чакта привал вакытында котелоктан туенган көннәр хәтеренә килде Кәримнең.* К.Латыйп

2) Сәяхәттә, походта һ.б.ш.ларда ял итү өчен тукталу урыны

ПРИВАТ-ДОЦЕНТ *и. лат.* Патша Россиясендә һәм Көнбатыш Европа илләрендә: югары уку йортында штаттан тыш эшләүче укытучының гыйльми исеме; шул дәрәҗәгә ия булган кеше. *1925 елда Г.Газиз Баку шәһәренә күчеп китә. Шул ук елда ул Азәрбайҗан дәүләт университетының приват-доценты итеп сайлана.* Р.Мостафин. *Кант, шушы шәһәрдә университет тәмамлаганнан соң, өендә дәресләр бирү белән шөгыльләнә, соңрак Кенигсберг университетында приват-доцент, 1770 елдан профессор була.* К.Гыйззәтов. *Язманың икесе, --- Уфадагы Новый клуб залында Петроград университеты приват-доценты*

П.С.Коган укыган лекцияләрнең эчтәлеген китерү, аларга мөнәсәбәт белдерү кебек тәэсир калдыра. Д.Заһидуллина

ПРИВАТ-ДОЦЕНТУ́РА *и. нем.+ лат.* Приват-доцент үзе яки аның хезмәт урыны

ПРИВАТИЗА́ЦИЯ *и. лат.* Дәүләт яки муниципаль милке булган объектларны коллектив яки шәхси милеккә әверелдерү, хосусыйлаштыру процессы. *Реформаның төп максаты уртак ил байлыгын хосусый милеккә әйләндерү иде. Хакимияттәге эреле-ваклы номенклатура «приватизация» дигән хәйләле бер чара ярдәмендә ул байлыкны, төрле яшерен мафияләр белән берләшеп, үзара бүлешеп бетермәктә...* Ә.Еники. *--- мин эшне колхозның исемен үзгәртүдән һәм... хосусыйлаштырудан башлап җибәрдем.* З.Хөсния р

ПРИВАТИЗА́ЦИЯЛӘҮ *ф.* Хосусыйлаштыру, шәхси милеккә әверелдерү. *Кемдер җан-фәрманга капитал кәера, байлык туплый. Юк бәягә дәүләт мөлкәтен үзенеке итә, «приватизацияли».* Ә.Баян. *1 марттан торак фонды объектларын бушлай приватизацияләү тәмамлана.* Шәһри Казан

Приватизацияләп бетерү Тулысынча, ахыргача приватизацияләү

ПРИВИ́ВКА *и. рус мед.* Авырудан саклану өчен, организмга кертелә торган вакцина. *Чәчәк авыруына каршы прививка ясау Кытай медицинасының зур казанышы булып санала*. Урта гасырлар тарихы. *Ә хатыным, нәрсәдән прививка ясауларын ачыклар өчен, табибка китте*. Ватаным Татарстан. *Белгечләр прививка ясатуның грипптан саклану өчен иң нәтиҗәле чара булуын тагын бер тапкыр искә төшерә.* Шәһри Казан

ПРИВИЛЕ́ГИЯ *и. лат.* Өстенлекле хокук. *--- әйе, «морза» дигән хәтәр исем бар барын, әмма аның реаль нигезен (көчен) тәшкил иткән байлык та (мәсәлән, җир-сулар биләү) һәм нинди дер зур өстенлек (привилегия) белән файдалану хокукы да юк, бирелмәгән.* Ә.Еники. *Бу факт – Сталинның өстен хокукларыннан (привилегия), ягъни Кремльдәге фатир, махсус паек, дача һәм башкалардан оста файдаланучы трибун шагыйрьнең исемен мәңгеләштерү иде.* Я.Шәфыйков

ПРИВИЛЕ́ГИЯЛЕ *с.* Өстенлекле хокукка ия булган. *Янәсе, нинди бәхетле безнең балаларыбыз! «Балалар – иң привилегияле класс!» Ә бүген шушы бәхетле балаларыбызның Республика пионерлар сарае юк.* Р.Миңнуллин. *Привилегияле шартлар. Привилегияле катлам кешеләре*

ПРИВИЛЕ́ГИЯЛЕЛЕК *и.* Өстен хокуклы булу

ПРИ́ВОД *и. рус тех.* 1) Нинди дә булса машинаны, механизмны һ.б.ш.ны хәрәкәткә китерү җайланмасы. *Автомобильләр өчен электр чыбыклары, кабельләр һәм привод системалары ясаучы компания үз өлкәсендә Европада – беренче, дөньяда дүртенче урынны били.* Ватаным Татарстан. *Электр приводы. Атлы привод*

2) Электр чыганагыннан, двигательдән машиналарга, станокларга әйләнү хәрәкәтен күчерү җайланмасы. *Кар астындагы ат приводын алыр өчен, берничә кеше тимер көрәкләр белән будка янындагы кар өемнәрен актаралар.* Ш.Камал

-ПРИ́ВОДЛЫ *тех.* Кушма сүзләрдә «машина, механизм һ.б.ш.ны хәрәкәткә китерү җайланмасы» дигәнне белдерә торган икенче кисәк (мәс., *алгыприводлы, арткыприводлы, тулыприводлы*)

ПРИГОВОР *и. рус сөйл.* 1) Судның җинаять эшен тыңлаганнан соң чыгарган карары, хөкеме. *Суд членнары бер-берсенә карап алдылар, һәрберсе башын кагып алды. Бу – приговор иде.* Г.Әпсәләмов. *Бу сискәндергән шартлау белән мәсьәләнең хәл ителүен аңлады Марва: атага карата бала чыгарган хөкем карары – приговор!* Ә.Баян. *Бу сүзләр Шомага приговор сыман яңгырадылар. Аннан уздырып йөрүчеләр... Моның булуы мөмкин түгел, була калсалар, аларның гомере санаулы.* Ф.Сафин

2) Берәр оешма, коллектив яки җыелыш карары. *Җиһанша абзаң әле һаман шул ат караклыгын ташлый алмыймыни? Аны әллә кайчан, приговор җыеп, авылдан озатасы иде.* К.Тинчурин. *Без бит әле бик зур эш башларга йөрибез. Авылдан приговор җыеп, Думага кеше сайлап җибәрергә дә сөйләшкән идек*. Г.Садри. *Ул ---, вагоннан төшеп кала, приговор җыйган өчен, бөтен авылны яндырырга, кара күмергә калдырырга --- ниятли*. Ф.Хатыйпов

ПРИЗ I *и. фр.* Ярышта җиңгән кешегә бирелә торган бүләк. *Илләр гиздең, спорт ярышларында сан-исәпсез призлар яуладың, сувенирлар алып кайттың*. Ә.Баян. *Призларны тапшырып, бүләкләрне өләшеп, кичәне йомгаклап торганда, мине чакырып алдылар*. Р.Хәбибуллина. *Башта бокс, аннары штанга секцияләренә йөреп, ярышларда катнашып, призлар алдым*. Н.Гыйматдинова

ПРИЗ II *и. фр. махс.* Диңгез сугышы вакытында яулап алынган һәм халыкара хокук буенча яулап алучының милкенә әверелә торган дошман судносы яки аның төрле мал-мөлкәте, диңгез трофейлары

ПРИЗЁР *и. рус* Приз (I) алучы кеше. *Озеровның рухы минем призёр буласымны алдан ук әйткән.* Аманулла. *Узган ел җиңүчеләр дүртәү, призёрлар ике мәртәбә кимрәк булган.* Ватаным Татарстан

ПРИЗЛЫ *с.* Ярышларда приз (I) бирелә торган. *Лицей укучыларының төрле олимпиада, конкурс һәм ярышларда катнашу нәтиҗәләренә анализ ясау призлы урыннар алучыларның елдан-ел арта баруын күрсәтә.* А.Низамов. *Ярышларда да күбесенчә призлы урыннарны алды*. Р.Хәбибуллина. *Автокала укучылары иң күп призлы урыннарны математика фәненнән яулаган.* Ватаным Татарстан

ПРИ́ЗМА *и. гр.* 1) *мат.* Ике нигезе бер-беренә параллель яткан тигез күппочмаклардан һәм ян кырлары параллелограммнардан торган күпкырлы җисем. *Ә тамчы үзенең формасы белән геометрик фигурага – призмага охшаган*. Җил каян килә?

2) *физ.* Үтә күренмәле материалдан ясалган һәм катлаулы яктылыкны спектрга таркату, яктылык нурларының юнәлешен үзгәртү һ.б. максатлар өчен оптик, спектраль приборларда,

аппаратларда кулланыла торган күппочмаклык яки өчпочмаклык. *Түгәрәк трубадай өскә сузылып, призма үсә башлый. 30 см озынлыкта булгач, формага кертеп кисеп алалар.* Р.Бәһау. *Кояш нурын призма аркылы үткәрсәк, без салават күперенең җиде төсен күрербез: кызыл, әфлисун төсе, сары, яшел, зәңгәрсу, куе зәңгәр һәм шәмәхә.* Э.Нигъмәтуллина. *Призма – махсус формадагы пыяла кисәге. Ул яктылыкны тарату өчен кулланыла.* Җил каян килә?

3) *күч.* Караш ноктасы. *Ник тормышны өйрәнә белмибез, Төрле призмадан күзәтеп?* Ә.Фәйзи

◊ **Призма(сы) аркылы** *к.* **призма(сы) аша**. *Алардан аермалы буларак, В.Имамов романы совет чорын тулаем тасвирлауга кайтып кала. Һәм әнә шул процесс «татар авылы призмасы» аркылы күрсәтелә.* М.Әхмәтҗанов. *Эчке сурәтнең үзәге – аның иң тотрыклы өлеше, һәм күңелдәге сурәт шушы төп психологик призма аркылы якын кешедән килә торган импульсларны кабул итә.* Тигез гомер итегез!

Призма(сы) аша Берәр нәрсәгә бәйләнештә, мөнәсәбәттә, берәр нәрсә тәэсире астында, объектив булмыйча (күзәтү, тикшерү, карау, үткәрү һ.б.ш. тур.). *Кайдадыр борынгы орган тавышы – Бах. Тыңлаган борынгы стильгә хәзерге заман призмасы аша карыйсың.* Ә.Баян. *Сезнең әсәрләрне без балачактан ук беләбез. Тик бүгенге көндә мин алардан алган элекке тәэсирләрне югалттым. Моны балачакның призма аша бәяләвенә генә кайтарып калдырмас идем.* Т.Миңнуллин. *Төшенкелек фазасында кара, пессимистик оптика хөкем сөрә, һәм бөтен нәрсә дә аның начарайта торган призмасы аша күренә.* Тигез гомер итегез!

ПРИ́ЗМАТИК *с.* 1) *мат., физ.* Призма рәвешендәге. *Барабан валга призматик шпонкалар һәм махсус болтлар ярдәмендә беркетелгән.* Урып җыю машиналары. *Призматик кристалл. Призматик өслек*

2) *физ.* Призма барлыкка китергән. *Призматик спектр*

ПРИЗЫВ *и. рус* 1) Хәрби хезмәткә алу кампаниясе. *Ул ел минем призывка караласы да елым иде.* Г.Садри. *Ул эшне җәелдереп җибәрергә өлгермәде – чираттагы призыв буенча Кызыл Армия сафларына китеп барды.* Г.Иделле. *Командирларына рәхмәт: бер уйласаң, җәберләмәделәр, җәберләтмәделәр. Югыйсә «стариклар» түгел, үзләреңнең призыв егетләре кабыргасын санамакчы иделәр.* С.Шәрипов

2) Хәрби хезмәткә бер үк вакытта алына торган яшьтәш кешеләр. *Язгы призывны Ерак Көнчыгышка җибәрү*

ПРИЗЫВНИК *и. рус* Хәрби хезмәткә чакырылган кеше. *Озак та үтмәгән, май кояшы кебек балкып килеп тә чыккан игезәктәш призывник: – Ә сине алдылар! – дигән.* Т.Нәҗмиев. *--- малайларны озатканда, өстәлгә аракы куймыйсыз! --- Татвоенкоматка салмыш килгән призывникларны туптуры айныткычка озатачаклар ---.* К.Кәримов. *Авызлыклаган кара айгырны дилбегә белән чирткәләп, наёмщик урам әйләнергә чыгып китә. Урамда очраган дусларын, призывник яшьтәшләрен утырта.* Борынгы Калатау итәгендә

ПРИ́ИСК *и. рус* Кыйммәтле казылмалар, ташлар, металлар табыла торган җир. *Төрле урыннардан җыелган, гомерләре буена завод һәм приискларда йөргән бу халыкларның арасында төрле тип, төрле сыйфатлылары бар.* М.Гафури. *Беренче номерлы прииски конторыннан тау-таш коллекциясе – унбиш әрҗә.* А.Тимергалин. *Быел җәй я казакълар арасына бала укытырга, я Рәмиевләрнең алтын приискларына эшкә китмәкчеләр иде.* С.Поварисов

ПРИКАЗ *и. рус* 1) Оешма, учреждение, предприятие, хакимият органы башлыгының катгый үтәлергә тиешле боерыгы. *Директор шундук приказ басып кертергә кушты.* Х.Сарьян. *Приказ игъланнар тактасында эленеп тора иде.* Р.Мөхәммәдиев. *Ул аннан приказ белән баш табиб булып кайтты.* Р.Хәбибуллина

2) *хәрби* Гаскәри башлык тарафыннан бирелә торган, аңа буйсынган кешеләр берсүзсез үтәргә тиешле әмер. *Приказ укылганда, капитан Хәкимовның бөтен буыннары үзгәрде, гәүдәсе, бөтен барлыгы скрипка кыллары кебек соңгы чиккә кадәр тартылды.* Р.Кәрами. – *Приказны үтәми кайтуың гына җитмәгән, корал югалткансың! – диде аңа Мирсәет.* Р.Мөхәммәдиев. *Космодром тормышындагы әнә шул төгәллек, приказ кебек бирелә торган аз сүзле кыска командалар, --- һәммәсе бергә кушылып, үзенә бертөрле музыка хасил итәләр иде.* Галәмгә юл

3) Шундый әмер, боерык язылган кәгазь. *Фрунзе приказын илтү өчен, тагын берничә ординарец күрше авылларга һәм дивизияләргә чыгып чапты.* Г.Бәширов. *Безнең кулда Оборона министрлыгының шуны раслый торган приказы һәм һәркайсыгызда хәрби хезмәткәр документлары булыр.* Р.Мирхәйдәров

4) *тар.* XVI–XVII гасырларда рус дәүләтендә идарә эшләренең аерым тармагын алып барган оешма. *1625 елда Казан сараеның приказы --- князь Еникеевләрнең Зур Аксел елгасы буенда җир биләмәләре бар, дигән документ чыгара.* Эзләнүләр, уйланулар, табышлар. *Приказ палатасы. Приказ идарәсе*

ПРИКА́ЗЧИК *и. рус иск.* 1) Элек кибет хуҗасына ялланып товарлар сатучы хезмәткәр. *--- кара мыеклы, кара күзле, каракүл бүрекле берничә «чын» приказчик, кибет алдына туктап, Хәйрулла агайны күрмәгәнгә салынып, кемнедер көтә башладылар.* К.Тинчурин. *Араларында өч-дүрт яки биш-алты приказчик тоткан зур кибет хуҗалары да бар, болар – Сафа купец, Басыйр купец ---.* Ә.Еники. *Мидхәтнең бабасы – итекче, атасы бер сәүдәгәрдә приказчик була.* Т.Әйди

2) Алпавыт утары белән идарә итүче хезмәткәр. *Феодал приказчиклары шәһәр халкын хөкем итә, алардан пошлина, --- башка түләүләр җыя.* Урта гасырлар тарихы

ПРИКАЗЧИКЛЫК *и.* Приказчик булу, приказчик хезмәте. *Ул үзенең егерме еллык приказчиклык гомерендә кибет ябылуын бу кадәр түземсезлек белән көткәне юк иде.* К.Тинчурин. *--- һәркем белә приказчиклыктан журналист булган Гыйниятулла*

Зәйнуллинны, ләкин аның ничек итеп приказчиклыктан журналист булганын --- беркем дә белми. С.Җәлал. *Приказчиклык белән язучылык – бер-берсенә каршы төшенчәләр. Приказчиклыкта, без аңлаганча, мутлык, хәйләкәрлек, холуйлык, бер тиен файда күрер өчен җанын сатарга да әзер тору төшенчәләре ята.* Т.Миңнуллин

ПРИКЛАД *и. рус* Утлы коралның түтәсе. *Һәм, хатыннарның аркаларына приклад белән төя-төя, якындагы бер өйгә кертеп ябалар*. Ш.Рәкыйпов. *Мин винтовкамның затворын, стволын, прикладын тикшерә башладым.* Г.Кашшаф. *Мин прикладны сул җилкәмә куеп атам, дигән Мөфаздал абзый*. Г.Мөхәммәтшин

ПРИЛА́ВКА *и. рус* Кибеттә сатучы белән сатып алучыларны аерып тору һәм товарларны күрсәтү, сату өчен, алды ябык озын өстәл. *Күпме торганмындыр, бермәлне күрәм: минем янда гына прилавка алдына басып, юан гына бер хатын аш сатып тора.* Ә.Баян. *Күрәсең, монда әйберне прилавка астында тоту гадәте юк.* Р.Кәрами. *Бу хәлнең шулай булачагын алдан чамалаган директор прилавка астына өч мәче китереп куйган иде*. Шатлыклы кайгы

ПРИ́МА *и. лат. муз.* 1) Гамманың беренче баскычы

2) Авазлар рәтенең бер баскычындагы интервал

3) Скрипканың, виолончельнең беренче нечкә кылы

4) Бер үк төрле авазларның, тоннарның үзара туры килүе

5) Инструменталь ансамбльнең бер уен коралында гына башкарыла торган беренче – төп партиясе

6) Ансамбльдә төп партияне башкаручы кеше яки ансамбльдә беренче – төп партия уйнала торган музыка коралы. *Театрның мәһабәт гүзәле, прима актриса, җырчы Сара Садыйкова, үксеп җылый-җылый, караңгы урамда ялгызы йөри дә йөри.* Р.Батулла. *Мәйсәрә роленә режиссёр, тәҗрибә сыйфатында, опера примасы В.Ганиеваны чакыра*. Галиәсгар Камал исемендәге татар дәүләт академия театры

7) Рус халык оркестрында балалайканың сопрано төре

8) *банк* Почта аша җибәрелә торган вексельнең беренче экземпляры

ПРИМА-БАЛЕРИ́НА *и. ит.* Балетта төп партияләрне башкаручы биюче (балерина). *--- анда балет сәнгатенең барлык йолдызлары, дөньядагы барлык атаклы театрларның прима-балериналары җыелачак*. Р.Мирхәйдәров. *Без Нинель Юлтыеваның һәр премьерасын карап бара һәм, аның осталыгына сокланып, аны театрыбызның прима-балеринасы дип атый идек.* Р.Зәһидуллина. *Өстенә буй-буй сызыклы швейцар кәчтүме киеп җибәргән театр хезмәткәре прима-балеринага әллә кайдан янып торган алтын язулы визит карточкасы суздыы*. Р.Вәли

ПРИМА-БИЮЧЕ *и. ит. к.* **примабалерина**. *Аннары прима-биюче, уңган хуҗабикә булуы өстенә, Марго --- һәр табынның күрке була алырлык --- үтә акыллы да бит әле.* Р.Вәли

ПРИМАДО́ННА *и. ит. театр* 1) Опера яки опереттада төп партияләрне башкаручы җырчы хатын-кыз. *Алай гына да түгел, язмыш аны тагын берничә кат татар театры примадоннасы белән очраштырды, һәм ул очрашуларның һәрберсе, хәтергә уелып калып, берсеннән-берсе зуррак әһәмияткә ия булдылар*. Ф.Әһлия. *Синең алда – гүзәл примадонна: Башыңны и, кулымны үп чүгеп*. Л.Янсуар. *Примадоннабыз милли операбыз белән бергә үсә, бергә дан-шөһрәт казана.* Татар теле. Хрестоматия

2) Балетта башлап биюче хатын-кыз

ПРИМАТ *и. лат.* 1) *филос.* Беренчелек. *Рухның приматы*

2) *күпл. биол.* Югары төзелешле имезүчеләр төркеме (ярым маймыллар, маймыллар һәм борынгы кешеләр). *Приматлар дигән хайваннар тармагыннан беренче буларак өченчел чор маймыллары барлыкка килгән.* А.Фәткуллин. *Кеше ул – күп күзәнәкле --- тереклек иясе. Иҗтимагый хайван, приматлар отрядыннан...* А.Тимергалин. *Физик кыяфәте белән төрле расадагы, төрле типтагы кешеләрнең барысының да бик борынгы ата-бабалары приматларның ниндидер аерым бер төренә барып тоташа*. Н.Фәттах

ПРИМИТИВ *с. лат.* **1.** 1) Кешелек җәмгыятенең иң башлангыч стадиясендә булган; борынгы; садә төзелешле. *Британия галимнәре фикеренчә, кешелек үсешнең примитив дәрәҗәсендә генә әле ---*. Мәдәни җомга

2) Катлаулы булмаган, гади. *Ә халык көйләрен үзләрен генә алганда, алар хәзерге тормыш таләпләре күзлегеннән бик примитив бит инде*. Г.Бәширов. *Галиябануның күлмәге бик примитив, бераз затлырак итеп эшләтәсе булыр.* А.Әхмәтгалиева. *Әгәр кисәкчекләр элементар күзәнәкнең түбәләрендә генә булса, андый күзәнәкләр гади яки примитив дип аталалар*. Физика

3) Өстән-өстән генә; артык гадиләштерелгән. *Ләкин тора-бара минем алда дөнья киңәйгән саен, караш үзгәрде, һәм үземнең никадәр примитив фикер йөртүемне аңладым*. Р.Кәрами. *Тарихка болай примитив карарга, бер халыкны икенчесенә каршы куярга ярамый.* М.Сәлимҗанов. *Безнең җәнси мөнәсәбәтләр өлкәсендәге мәгълүматларыбыз соң дәрәҗәдә сай, ул белемнәрне тарату плансыз, примитив юл белән алып барыла ---*. Тигез гомер итегез!

4) Белеме һәм әхлак ягы түбән; тар карашлы. *Бу җәвапларның һәм төпкә куелган имзаларның никадәр тупас һәм примитив ялган икәнлеге бер дә көрәшче булмаган кешегә дә күренеп тора иде.* Ш.Маннур

2. *рәв. мәгъ.* Сай, гадиләштереп. *Әдәбиятны болай примитив, гадиләштереп аңлау, аны асыл, тирән сыйфатларыннан мәхрүм итү кайдан килә соң?* А.Гыйләҗев. *Сез бик примитив фикер йөртәсез. Сез Тәһир, Зөһрәләрне дә рәнҗетәсез, Гаяз әфәнде*. Р.Батулла. *Син, әти, бик примитив фикер йөртәсең. Сыенырга почмак, ашарга ипи булганга гына сөенеп яши торган чак түгел хәзер*. Ф.Яруллин

ПРИМИТИВИЗМ *и. рус к.* **примитивлык**. *Бабайлар примитивизмыннан котылырга вакыттыр сезгә дә... Бу заманда янган барийны кулга лом тотып ватып ятсыннар әле!..* Э.Касыймов. *Бик яратып укыдым һәм аның гап-гади*

итеп әйткән әйберләрен примитивизм дип әйтә алмыйм: эченәрәк кереп карарга кирәк. Идел

ПРИМИТИВЛАШТЫРУ *ф.* Гадиләштерү, садәләштерү. *Без бит төрекләрне, шул исәптән Төркияне дә аз беләбез. Белгән атлы булсак та, бик гадиләштереп, --- примитивлаштырып күрергә, аңлатырга омтылабыз.* Р.Мөхәммәдиев. *Ләкин халыкчанлык төшенчәсе ул гадилекне дә үтә гадиләштереп, «әнә килә афтамабил» дип примитивлаштыру түгел бит әле.* Р.Әхмәтҗан. *--- сәясәтчеләрнең кылган эш-гамәлләре, кайчак чыгышларыннан таныла торган фикерләр дә бар. Шуларны соң чиккәчә гадиләштерү-примитивлаштыру көлке тудыра, гротеск алымына әйләнеп китә.* Д.Заһидуллина

Примитивлаштырып бетерү Бөтенләй, тулысынча примитивлаштыру

ПРИМИТИВЛАШУ *ф.* Гадиләшү. *Әдәбият үсешенә тоныклану, сорылашу янаганда, урта кул өстенлек иткән примитивлашу юлына борылыш башланачак көннәрдә беренчеләрдән булып --- Дәрдемәнд шигъриятен шул котылгысыз хәвефкә каршы аяклandыра.* М.Гайнетдинов

Примитивлаша бару Торган саен күбрәк примитивлашу. *[Маймыл] ларның нәселләре еракка киткән саен, түбәннән түбәнгә төшә барып, примитивлаша барып, яшәүче арка сөяксез мәхлукларга барып тоташа.* Г.Гобәй

Примитивлашып бетү Тәмам, тулысынча примитивлашу

ПРИМИТИВЛЫК *и.* 1) Катлаулы мәсьәләләргә чиктән тыш гади, өстән-өстән генә караш. *Бу елларда чыккан музыка әсәрләренең күбесе техника ягыннан түбән тораlар һәм примитивлык белән күзгә бәреләләр иде.* М.Җәлил. *Шулай итеп, укучыларыбызны примитивлыкта, шигъриятне аңламауда гаепләүдән элек, безгә әүвәл үз ижат «цехыбызда» байтак нәрсәләрне үзара ачыклыйсы бар әле.* Р.Фәйзуллин. *Музыка сәнгате чүпләнмәскә, примитивлык белән пычранмаска, табигый сафлыгын, пакълеген югалтмаска дигән объектив фикергә таянып эш итә.* М.Макаров

2) *сәнг.* XIX–XX гасыр буржуаз сәнгатенең төшенкелек белән сугарылган күп агымнарына хас булганча, примитивка ирү, аңлы рәвештә гадиләштерү

ПРИ́МУЛА *и. лат. бот.* Нәүрүз чәчәге (гөле). *Иртә чәчәк атучылар арасында матур һәм кызыклы нәүрүз гөле (примула) чәчәкләре бар (мәгънәсе «беренче» дигәнне аңлата).* Ф.Ибраһимова. *Примуланың чәчәк үстерүчеләр чыгарган күпсанлы сортлары – нәүрүзгөлнең ырудашлары.* Татарстанның үсемлекләр һәм хайваннар дөньясы. *Үгезбозауларга матур чәчәкле гөлләр: миләүшә, каланхоэ, глоксиния, бегония, примула бүләк итегез.* Шәһри Казан

ПРИ́МУС *и. лат. иск.* Керосин, спирт һ.б.ш.ларны насос ярдәмендә горелкага өрдереп яндырыла торган һәм шуның өстендә кайнар ашлар әзерли торган прибор. *Почмакта, примус астындагы ярыкта, ачкыч бар.* А.Гыйләҗев. *Бухгалтерның хәләл җефете примус яныннан өстәл янына килде.* Г.Галиев. *Арырак үткәндә, уртак кухня күзгә чалынды. Кечкенә өстәлләр тезелгән, һәр өстәлдә примус иде.* Х.Камалов

ПРИ́НТЕР *и. ингл. информ.* Компьютерга яки башка цифрлы җайланмаларга (мәс., фотокамерага) тоташтырылган, текстны, сурәтне кәгазьгә, калькага, үтә күренмәле плёнкага бастырып чыгару җайланмасы. *Документ компьютерда җыелып, принтерда басылгандыр...* М.Маликова. *Компьютер, принтер кебек товарларның биш-алты фирма тарафыннан тәкъдим ителүенә караганда, илне компьютерлаштыру киң җәелгән булырга тиеш.* А.Тимергалин

ПРИНЦ *и. нем.* Көнбатыш Европада король яки кенәз гаиләсе әгъзасы булган ир-атның титулы; шул титулдагы кеше. *Принц, акуладан саклану өчен, солдатларыннан койма ясатып, диңгез эчен уратып алды да, шунда су коендык.* М.Галиев. *Шуннан шатлыгыннан айга сикерердәй булды, чөнки шул мәлдә ул Илнурны ак аттагы принц дип кабул итте.* Ф.Җамалетдинова. *Генрих III һәм тәхет варисы принц Эдуард әсирлеккә төшәләр.* Урта гасырлар тарихы

ПРИНЦЕ́ССА *и. нем.* 1) Көнбатыш Европада король яки кенәз гаиләсе әгъзасы булган хатын-кызның титулы; шул титулдагы кеше

2) Принц хатыны яки кызы. *Барысы да акылдан язар дәрәҗәдә аңа гашыйк булганнар бит, мин инде син дә шуңа табынгансыңдыр дип уйлаган идем. Чынлап та, принцесса шикелле ич, күр әле ---!* Р.Мирхәйдәров. *Гасимә аның каршына килде дә, яшь принцесса шикелле бик җиңел һәм итагатьле реверанс ясап: – Хөрмәтле галиҗәнап Фәләх хәзрәтләре, рәхим итегез, табын әзер! – диде.* В.Нуруллин. *--- бөек урыс Владимир шуннан соң византияле принцесса Аннага өйләнү бәрабәренә бөтен Русьны чукындырып ташлый.* З.Хөсният

3) Яраткан хатын, кыз бала, сөйгән яр. *Янымда – кыска күлмәкле, яңгыр тамчыларыннан таҗ кигән принцесса.* Х.Туфан

ПРИ́НЦИП *и. лат.* **1.** 1) Теория, тәгълимат, фән һ.б.ш.ның төп, нигез кагыйдәсе, тезисы. *Ул бәйнә-бәйнә милли-мәдәни автономияне тормышка ашыру юллары һәм принциплары турында сөйләде.* Р.Мөхәммәдиев. *Бу тартыкны язуда бердәй орфографик принцип (график принцип) сакланса да, кызганыч ки, хәзерге татар әдәби телендә аны бозып әйтүләр еш күзәтелә.* Р.Абдуллина

2) Берәр төр эшчәнлек өчен кирәкле төп кагыйдә, күрсәтмә. *Г.Фәхретдинов, нигездә, төгәл фәннәр буенча мөгаллим булса да, тарих дәреслеге төзү принципларын --- да яхшы белгән.* Чын мирас. *Эш принциплары. Тарихилык принцибы*

3) Берәр нәрсә турында төп фикер, төп караш. *Шигырьдә билгеле бер принцип саклану аны әдәби матурлый.* М.Җәлил. *Әтисе Гафур абый – кырыс холыклы, гадел, кайчагында артыгы белән гадел, үз принципларына тугры кеше.* А.Әхмәтгалиева. *Безнең өчен кемдер килеп эшләр әле, дигән принцип белән яшибез әле һаман да.* Р.Миңнуллин

2. *рәв. мәгъ.* **принципта**. Нигездә, асылда. *Демократияне милли азатлыктан аерып карарга ярыймы? Принципта бу мөмкин әйбер түгел,*

чөнки теләсә кайсы демократия милли азатлыктан башлана. Р.Хәким. *Күмәкләп эшләү авыл өчен принципта бөтенләй үк ят гадәт түгел.* Ф.Хатыйпов. *Аерым шартларда кеше тиресе кисәкләре бик озак вакытлар саклана икән. Дөресме шул? Принципта – дөрес.* Галәмгә юл

ПРИНЦИПИАЛЬ *с.* **1.** 1) Принциплар (*1 мәгъ.*) белән бәйле, принципларга нигезләнгән, предметның, күренешнең асылы белән бәйле. *Бу кулга алыну аның милли республикалар ихтыяҗын кайгыртуы һәм XII съезддагы принципиаль чыгышы өчен кайбер ипташлар тарафыннан үч алу буларак аңлашыла.* Р.Мөхәммәдиев. *Шушы кыска гына әңгәмәдә автор сержант Шилов теле аша тыл белән алгы сызык арасындагы принципиаль аерманы ассызыклап бирә.* Р.Фәтхрахманов. *--- барлык империя структуралары да хатын-кызларны ир-егетләр белән бергә укытуның принципиаль дошманнары була.* Сөембикә

2) Берәр нәрсәнең асылына, нигезенә кагыла торган; әһәмиятле, мөһим. *Фәйзуллин үзенең берничә принципиаль төзәтмәсен тәкъдим иткән иде.* Н.Нәҗми. *Казан тарихчыларының соңгы вакыттагы эзләнүләренең принципиаль яңалыгы нидән гыйбарәт?* С.Ибраһимова

3) Билгеле принципларга гына таянып эш итә, шул принциплардан читкә тайпылмый торган. *Ипташлар, принципиаль булырга тырышыйк. Вак-төяк нәрсәләргә артык тукталып тормыйк.* Н.Акмал. *Кешенең дөньяга принципиаль карашы – «ярый», «ярамый» – еллар үткән саен үзгәрә.* Ш.Галиев. *Беренчедән, шуны искәртеп китәсем килә: миңа ипташларнең принципиаль чыгышлары ошады.* Шатлыклы кайгы

2. *рәв. мәгъ.* 1) Нигездән, тамырыннан, асылыннан. *Драматик көрәшнең идея эчтәлеге белән [әсәр] тегеләрдән принципиаль аерыла.* Г.Нигъмәти. *Харәземшаһка каршы сугышка хәзерләнергә керешкәч тә, Чыңгыз хан, беренче чиратта, үзенең нәкъ шул сугышка принципиаль каршы булуы турында --- искәртә.* М.Гайнетдинов

2) Билгеле бер принципларга таянып, шуннан читкә тайпылмыйча. *Мәсьәләне принципиаль хәл итү*

ПРИНЦИПИА́ЛЬЛӘНҮ *ф.* Принципиаль булу, үзенең фикерендә, карашында нык тору

Принципиальләнеп китү Кайсыдыр бер вакыттан, нинди дә булса сәбәпләрдән соң принципиаль була башлау

ПРИНЦИПИА́ЛЬЛЕК *и.* Билгеле бер принципларны теориядә һәм тормышта эзлекле рәвештә үткәрү; принципиаль булу. *Ә бит безгә күп вакыт принципиальлек җитми, ирләрчә катылык җитми.* Ф.Яруллин. *--- без менә шул принципиальлегебез, булган кимчелекләргә күз йоммавыбыз, аны йөзгә бәреп әйтүебез һәм шуны күтәрә алуыбыз белән аерылып торырга тиешбез.* Р.Кәрами. *16–17 яшьләкләргә кискенлек, принципиальлек, артык горурлык, үз «мин»ен еш кына югары кую, гаделсезлекне авыр кичерү хас.* Ә.Закиржанов

ПРИ́НЦИПСЫЗ *с.* Үзенең ныклы принцибы, карашлары булмаган; әхлак нормалары белән исәпләшми торган. *Принципсыз кеше эзлекле хәрәкәт итә алмый.* Н.Исәнбәт. *Алар – ифрат принципсыз һәм башсызлар.* Ш.Мөдәррис. *Еш кына ирләр принципсыз, вакчыл, юкка-барга бәйләнүчән кешегә әвереләләр.* Тигез гомер итегез!

ПРИНЦИПСЫЗЛЫК *и.* Үзенең ныклы принцибы, фикере булмау, аумакайлык. *Үзләре белән якын аралашып йөргән сәләтле язучы һәм журналист Чыгътайның мондый принципсызлыгы демократик фикерле яшьләрдә, табигый, ризасызлык уята.* Фән һәм тел

ПРИОРИТЕТ I *и. нем.* Фәнни ачыш ясауда, тикшеренүдә, уйлап табуда һ.б.ларда беренчелек. *«Моны берәр шагыйрь әйткән», – диючеләр дә бар иде. Ләкин барыбер моның приоритеты халыкка кайтып кала.* Х.Туфан. *Дөньяда тагын приоритет дигән нәрсә дә бар бит әле. Андый проблема Гаяз Исхакый мирасын халкыбызга кире кайтару буенча беренче адымнарны ясаганда килеп туды.* Ә.Рәшит. *– Чакыру приоритеты бездә булырга тиеш, – дидем мин, бу акыллы сүзләр белән килешеп. – Башта без шалтыратсак, үзебез мәҗлес җыя идек, дип тырылдый алмаслар.* Г.Мөхәммәтшин

ПРИОРИТЕТ II *с.* Иң мөһим, беренче дәрәҗәдә торган. *Технологик белем бирү – безнең илдәге приоритет проектларның берсе.* Фән һәм тел

ПРИОРИТЕТЛЫ *с.* Югары приоритеты (*2 мәгъ.*) булган. *Русия кебек федератив дәүләтнең милли өлкәдәге сәясәте приоритетлы юнәлеш булырга тиеш.* Фән һәм тел

ПРИПАС *и. рус сөйл.* Туплардан, мылтыклардан һ.б.ш.дан ату өчен снаряд, патрон. *Кыш көне ау билеты булганнарга мылтык, припаслар, кирәк нәрсәләрен бирәм.* Г.Мөхәммәтшин. *Аларны район үзәгенә – аучылык хуҗалыгына илтеп тапшырган кешегә он я ярма һәм мылтык припаслары бирәләр иде.* З.Фәйзуллин. *Бар укыту пунктлары пневматик вак калибрлы мылтыклар, Калашниковның күл пулемётлары, командир ящиклары, граната-лар, ату кораллары өчен припаслар белән тәэмин ителделәр.* Г.Шакиров

ПРИ́СТАВ *и. рус* 1) Патша Россиясендә җирле полиция башлыгы. *Менә бер-бер артлы присяжный заседательләр – антлы утырышчылар килә башлады. Хөкем эшләре приставы, секретарь – сәркәтиб ярдәмчесе дә күренде.* З.Бигиев. *Әле кайчан гына авыл халкы становой пристав белән урядникны бер чакрымнан бүрек салып, бил бөгеп каршы алырга мәҗбүр иде.* Г.Бәширов. *Ул китәм дигәндә, ишек ачыла да, аннан дөбердәп участок судьясы, прокурор ярдәмчесе, пристав һәм пүнәтәйләр керә.* Ә.Баян

2) Хәзер: суд карары үтәлешен күзәтүче. *Узган атнада ир-ат суд приставлары янына 5 һәм 50 тиеннәр, 1 һәм 2 сумнар салынган 8 капчык күтәреп килгән.* Ватаным Татарстан

ПРИ́СТАНЬ *и. рус* Сулык ярында пароходлар, суднолар туктау, йөк бушату яки төяү, пассажирлар төшерү яки утырту өчен махсус җиһазланган урын, корылма. *Менә, күп булса 150–200 адымда гына, сирәк утлары белән җемелдәп кечкенә пристань күренә.*

Ә.Еники. *Безне, җилтерәтеп, сәгать ярым эчендә Чаллы пристаненә китереп җиткерделәр.* Р.Хәбибуллина. *Малайлар, ак-кара күрми, нәкъ менә шушы паром борынын китереп төртә торган сөзәк яр буена – Каргалы халкы әйткәнчә, пристаньга юнәлделәр.* Ф.Сафин

ПРИСЯ́ЖНЫЙ *и. рус* Суд эшләрен тикшерүгә катнаштырыла торган кеше. *Залга бер-бер артлы присяжныйлар керә башлады.* М.Галәү. *Халык хөкем залына кереп, эскәмияләргә утырыша башлады. Залга бер-бер артлы присяжныйлар керде.* Р.Гайфуллина. *Ул чорда суд приставлары присяжный утырышчыны суд залыннан чыкканда озату, халыкны билетлар буенча суд залына кертү вазифаларын үти.* Гасырлар авазы

ПРИСЯ́ЖНЫЙ ПОВЕ́РЕННЫЙ *и. рус тар.* 1917 елга кадәр Россиядә суд яклаучысы, адвокат. *Хәбибулла Җиһанша углы Хәлфин – присяжный поверенный.* Х.Ямашев. *Казаннан присяжный поверенный А.Г.Бать килә.* М.Мәһдиев. *Алкин читкә качмый, монда кала. Юрист. Утыз җиденче елда төрмәдә үтерделәр. Сәетгәрәй Алкин – аның атасы. Присяжный поверенный, адвокат.* Р.Батулла

ПРИТОН *и. рус* Әдәпсезлек, бозык эшләр өчен җыела торган урын, йорт. *[Әхмәт:] Нинди кешеләр кирәк тагын, әллә притон дип белдегезме, монда һаман җыелып карта уйнап ятарга?* Г.Камал. --- *безнең Казанда яшерен притоннар оештырган стилягаларның Бауман урамын, Америка формасына охшатып, ниндидер «стрит» дип атап йөртүгәчә барып җитүләре очраклы түгелдер.* Х.Туфан. *[Наил:] Коммерсант булса, шушы бүлмәне склад урынына да тотуы ихтимал. Мафиозник бу. Монда притон урнаштыруы да мөмкин.* З.Хәким

ПРИХОД *и. рус дини* Шәһәрнең яки авылның бер чиркәве тирәсендә берләшкән җәмәгать. *Поп буларак Я.Емельяновның бер авылдан бер авылга, бер приходтан икенчесенә күчеп йөрүе дә хәтер кардиограммасын тоныкландырган, әлбәттә.* Р.Фәйзуллин. *Мондагы чиркәү приход хисабына яши.* Туганайлар

ПРИЦЕЛ *и. рус сөйл.* Утлы коралларда төз атуны тәэмин итү өчен куелган җайланма, төзәгеч. *Взвод командиры Вася Сторублёвцев прицелга текәлгән килеш җан биргән.* Ш.Рәкыйпов. *Мушков шунда ук орудие янына сикереп менде, --- прицелны чамаларга итте, --- көпшәне турыларга маташты.* Х.Камалов. *Бер җәйнең уртасында Кирянов «Динамо» тирына күнегүләргә йөргәндә, --- мылтыкка куя торган оптик прицелны урлый.* Ф.Вәлиәхмәтов

◊ **Прицелга алу** Мылтыкны, тупны һ.б.ш.ны берәр предметка турылап төзәү. *Әле [төшкән] снарядлар безнең позицияләрне якты чакта прицелга алу [өчен] булган.* И.Гази. *Гаптерәхим агай көн саен, таң алдыннан фермага килеп, дүрт аяклы «кошчы»ны прицелга ала торган булды.* Г.Галиев

ПРИЦЕЛЛЫ *с.* 1) Прицелы булган. *Эчке базарда автоматлар, оптик прицеллы винтовкалар, шартлаткычлар һәм башка вак-төяк сатуны исәпкә алып та тормыйк.* Татарстан яшьләре

2) Махсус рәвештә берәр предметка төзәлгән, шуңа төбәлгән. *Миңнемулла машинасының әрҗәсендәге пулемётчы Александр да самолётларга төбәп прицеллы ут ача.* Алабуга нуры

ПРИЦЕП *и. рус* Автомобиль, трактор һ.б.ш. транспорт чаралары артына тагылган җайланма (арба). *Прицеп булып яшисем килми минем дөньяда. Алдан барасым килә, ерып барасым килә.* Т.Миңнуллин. *Алда Башкортстан машинасы бара. Прицеп белән.* З.Зәйнуллин. *Җитмәсә, Мишә күпере озынлыгы шул машинасына өч прицеп таккан!* Шатлыклы кайгы

ПРИЦЕ́ПЩИК *и. рус* Тракторга тагылган сабанда, чәчкечтә һ.б.ш. машиналарда эшләүче кеше. *«Прицепщигын уятырга килгән!» – диде кемдер, кычкырып.* Н.Фәттах. *Миргаязны да язгы чәчүгә прицепщик итеп куйганнар.* Ф.Садриев. *Хөснулла җәйге айларда прицепщик булып эшләп алды.* К.Кәримов

ПРИЦЕПЩИКЛЫК *и.* Прицепщик хезмәте, прицепщик булу. *Студентларның кайберәүләре --- прицепщиклыкта йөрделәр.* Н.Фәттах

ПРИЧАЛ *и. рус* 1) Пристаньның катер, пароходлар туктау, йөк төяү һәм бушату өчен җайланмалары булган урыны. *Пыяла вокзал каршындагы причалларга су өстеннән таудай калкып менгән дизель-электроходлар килеп туктаган.* Х.Сарьян. *Теплоход причалдан ераклашкан саен, кояш та болыт астыннан күбрәк чыга барды.* Г.Әпсәләмов. *Безнең метеор алтмыш өченче причалдан сәгать бердә кузгалачак икән.* М.Галиев

2) Судноны пристаньга бәйләп куя торган юан аркан

ПРИЧЁСКА *и. рус* Баштагы чәчләрнең билгеле рәвеш биреп кистерү яки тарау, бөдрәләтүдән соң килеп чыккан торышы. *Чигәләре тирәсенә таба шомартып тарап куйган чәчләре кызның чиста маңгаена һәм күзләренә аерым бер матурлык биреп тора, гомумән, кичке причёскасы аны танымаслык иткән иде ---.* Р.Мирхәйдәров. *Чәченә матур причёска ясаган, кирпеч төсле күлмәге килешеп тора, аякларында капрон оек.* Р.Хәбибуллина. *Кыска чәчен кабартып, матур итеп причёска ясаган ---.* Р.Кәрами

ПРИЮТ *и. рус* Ятим яки тәрбиячесез калган балаларны тәрбияләү учреждениесе; балалар йорты, ятимханә. *Приютта үскән балалар яшьтәшләреннән соңрак тәпи китә, соңарыбрак телләре ачыла, акыл үсеше белән арттарак кала, диләр.* М.Маликова. *Сүзе беткәч, үзе сорар: «Әни, ник мине приютка бирдең?» – дияр.* Ә.Баян. *Аннары бераздан абый мине приютка, Рәсәйдән килгән ач балалар йортына урнаштырды.* Ә.Еники // Тәрбиячесе булмаган олы кешеләрне, инвалидларны тәрбияләү урыны; картлар йорты. *Приюттагыларның күбесен балалары түгел, туганнары бирегә китергәннәр икән. Авылдашын гына түгел, газиз әнисен, әтисен дә приютларга илтеп куючылар җитәрлек бит.* Шәһри Казан

ПРО́БА *и. рус сөйл.* 1) Нәрсәнең дә булса анализ, тикшерү, сынау өчен алынган өлеше. *Аш пешкәч, устав*

буенча башта пробаны доктор алырга тиеш бит. Поварның журналына язарга тиеш. М.Мәһдиев. *Ул керннарның нинди тирәнлектән алынганлыгын, нинди катлаудан һәм нинди токымнан икәнлеген язып, җыеп бара. Һәрбер пробага аерым паспорт төзи.* М.Хәсәнов. *Проба ясап карадым. Әллә көмешкә йоттым, әллә ялкын йоттым.* Шатлыклы кайгы

2) Эретмәгә кушылган алтынның яки көмешнең микъдары; шундый эретмәләрдән ясалган алтын, ак алтын, көмеш әйберләрдә шул микъдарны күрсәтә торган келәймә. *[Егет:] Оһо! Алтын балдак! Каян алдың мондый затлы нәрсәне? [Ир:] Свияжски төрмәсендә махсус заказ белән эшләделәр. Менә пробасы*. Аманулла. *Проба сугу. Туксан алтылы проба*

ПРО́БАЛЫ *с.* Проба сугылган; пробасы булган (алтын яки көмеш тур.). *Менә күрәсеңме бу пистолетны, ул иң югары пробалы алтыннан эшләнгән...* Р.Мөхәммәдиев. *Аларның чәнечкеләре югары пробалы көмештән иде.* М.Юныс

ПРОБИ́РКА *и. рус* Лаборатория эшендә кулланыла торган бер башы йомык пыяла көпшә. *Людмила кулында пробиркага алынган кан.* Т.Гыйззәт. *Тиз арада тынлык урнаша, һәр икесе пробиркалар белән булашканда яки, бүтән шөгыль табып, арлы-бирле йөренгән вакытта да эштән бигрәк Фәнүзә хакында уй йөртә*. Ә.Баян. *Генри бер пробирканы, амбарның аргы башына илтеп, калай киштәгә куйды*. А.Тимергалин

ПРО́БКА *и. рус* 1) Электр саклагычының бер төре. *Бер биш минут артык утырдыңмы – яткан җиреннән торып, счётчикның пробкасын борып алып куя.* Х.Сарьян. *Әнә малайлар --- коридорда кызларны кыскалыйлар, шуның өчен хәтта тулай торакта пробкаларны борып алалар яки электрны бозып куялар*. В.Астафьев

2) *сөйл.* Юлларда яки елга кичүләрендә транспорт берәмлекләренең артык күп җыелуы нәтиҗәсендә, хәрәкәт әкренәю яки бөтенләй тукталу күренеше. *Кама тамагында һәрвакыт хасил була торган «пробка» борчый аны.* Г.Иделле

ПРОБЛЕ́МА *и. гр.* Хәл ителергә тиешле теоретик яки гамәли мәсьәлә. *Бигрәк тә бу тарихның методологик проблемалары җитәрлек тирән яктыртылмаган.* Х.Госман. *Без – эре ир заты дип, үләргә яткан бәләкәй авылда дөньякүләм проблемалар чишмәссең бит инде*. Н.Гыйматдинова. *Гаилә проблемасын төптән уйлап, ашыкмыйча гына хәл итегез*. Сөембикә

ПРОБЛЕ́МАЛЫ *с.* Нинди дә булса проблеманы чагылдырган, берәр проблеманы тикшерүгә, хәл итүгә багышланган, катлаулы мәсьәләне эченә алган. *Безнең редакторга тормышчан – проблемалы мәкалә язып китерсәң, коты чыга. Ах, тегеләй уйламагайлары, бүтән төс бирмәгәйләре дип, шомарта-шомарта, әйбернең җанын калдырмый.* Х.Камалов. *Мин, мәсәлән, проблема эзләп маташмыйм. Чөнки, әгәр мин бүгенге көндә яшим икән, ни генә язсам да проблемалы була*. Ф.Яруллин. *Әйе, җитди проблемалы драмалар сирәк туа.* А.Әхмәдуллин

ПРОБЛЕ́МАЛЫЛЫК *и.* Проблемалы булу. *Проблемалылыкны теге яки бу кимчелекләрне, җитешсезлекләрне ачу белән генә бәйләп карау мәҗбүри түгел.* Р.Мостафин. *Тормышны тою һәм дөнья белән актив элемтәдә булу А.Гыйләҗев әсәрләрендә перспективалы проблемалылыкка китерә*. М.Вәлиев. *Проблемалылык әсәрнең иң әһәмиятле үзәген тәшкил итә, төп идея, тенденцияләр юнәлеше һәрчак игътибар үзәгендә*. Р.Зарипова

ПРОБЛЕМА́ТИК *с.* Берәр проблеманы тикшерүгә, чишүгә багышланган; берәр проблеманы чишү, тикшерү белән бәйле. *[Тәнкыйтьчеләребез] бүгенге әдәби вакыйгаларны системалаштырып, проблематик планда анализларга омтылалар.* З.Мәҗитов. *Алда исемнәре аталган ир-җегетләрнең тапшыруларында һәрвакыт мәгънәле сораулар яңгырар, алар шушындый проблематик мәсьәләләрне күтәреп, шәхес белән булган әңгәмәне җанландыра, кызыклы итә*. Р.Батулла

ПРОБЛЕМА́ТИКА *и. рус* Проблемалар җыелмасы. *Социаль проблематика Аристотель фәлсәфәсендә киңрәк планда гәүдәләнә.* К.Гыйззәтов. *Әсәрнең балаларга атап язылуына, жанр сыйфатына бәйле тәрбияви проблематика бөтен вакыйгаларны иңләп үтә.* Ә.Закиржанов. *Модернизм әдәбияты исә рух проблемасын югары күтәрә, милли иҗтимагый проблематиканы артка чигереп, мәңгелек мәсьәләләрне көн тәртибенә куя.* Д.Заһидуллина

ПРОБЛЕМА́ТИКЛЫК *и.* Мәсьәләне хәл итү зарурлыгы

ПРОВАНСАЛЬ *и. махс.* Йомырка сарысына үсемлек мае (элек – прованс мае), серкә, горчица һ.б. кайбер аш тәмләткечләр кушып ясалган соус. *--- Провансальне җитештергәндә, тавык йомыркасы да, бытбылдык йомыркасы да бердәй кулланыла ала.* Шәһри Казан

ПРОВИ́ЗОР *и. лат.* Югары квалификацияле аптека хезмәткәре, фармацевт. *Даруханә. Авыру белән провизор аңлаша: – Миңа бер литр спирт! – Рецептың бармы соң, чирлекәем?* Р.Гаффар. *Татарстан Министрлар Кабинетының 2005 елның 7 июнендә кабул ителгән --- карарында әйтелгәнчә, табиблар, провизорлар, урта медицина --- хезмәткәрләре --- коммуналь түләүләргә субсидия-ташламага хокуклы.* Ирек мәйданы

ПРОВИНЦИАЛ *и. рус иск.* 1) Провинциядә (*4 мәгъ.*) яшәүче кеше. *Гадәти дип, үзгә фасон белән тегелгән демисезон пальтосы һәм мехсыз бүреге дә Азатны безнең кебек провинциаллардан аерып тора иде.* А.Тимерханов. *Кешеләр үзләрен провинциал дип хис итмәгән җирдә, шәһәрдә ничә кеше яшәвенә дә, «үзәк»тән ерак урнашуына да карамастан, театрлар үсә һәм таныла.* Сәхнә

2) *сөйл.* Провинциядә яшәүчеләргә хас гадәтләре, сыйфатлары булган кеше; тар карашлы кеше (гадәттә түбәнсетү, кимсетү төсмере белән әйтелә). *Бу – үзенең фантазиясе белән күгәрчен оясыннан узалмаган провинциал иптәш белән провинциал булып сүз көрәштереп торасым килми.* Ә.Фәйзи

ПРОВИНЦИАЛИЗМ *и. лат. лингв. иск.* Әдәбиятта, әдәби сөйләмдә

кулланыла торган диалекталь сүз, форма һ.б., диалектизм. *Тел байлыгыбызны арттыру, әдәби телебезне эластик формалар белән баету өчен, безгә мотлак провинциализмнардан файдаланырга кирәк.* С.Җәлал. *Тел мәсьәләсендә [Г.Камал] провинциализмнан ерак тора.* М.Гали

ПРОВИНЦИАЛЬ *с.* 1) *иск.* Провинциядә (*4 мәгъ.*) булган; провинциядә хөкем сөргән. *Без язганнарны тәрҗемә итеп, Мәскәү театрларында куймакчы. Без икебез дә --- елмаеп тыңлыйбыз. Чөнки икебез дә беләбез: тәрҗемәләрен түгел, үзе язганнарын да Мәскәүдә куймыйлар, провинциаль театрларда гына куела.* Т.Миңнуллин. *Провинциаль ТВ булудан туктау өчен безгә, һичшиксез, татарлар яши торган зур регионнарда корпунктлар булдырырга кирәк.* Р.Миңнуллин. *Бу театрда талантлы һәм индивидуаль үзенчәлекләре, осталыклары нигезендә оешкан артистларны берләштерүче чын профессиональ труппа тупланган. Биредә бернинди провинциаль премьерачылык юк ---.* Д.Гыймранова

2) Зур шәһәрләрдән читтә урнашкан (урын, җир тур.). *Бу инде сиңа ниндидер авыл гына түгел, хәтта провинциаль шәһәр дә түгел: бу – Ка-зан!* Х.Ширмән. *Әгәр дә Казан Россиядә район дәрәҗәсендәге бетәшкән бер провинциаль шәһәр булса, Тишков сөенер иде дә, әмма, нишләмәк кирәк, татарлар алай уйламый шул.* Т.Миңнуллин. *Казан хәтле Казанның үзендә туып үскән, Ленинград кадәр Ленинградта биш ел гыйлем алган Кларабыз, понимаешь, караңгы бер провинциаль шәһәргә юлыктым дип кенә, безгә килүенең беренче көннәреннән үк аягына чүчинкә алып кимәде.* А.Хәсәнов

3) *иск.* Диалекталь, берәр диалектка хас булган. *Әче, әчү дип сөйләү фәкать Арча ягына хас, әмма әченең даирәсе киң ---. Бездә әле мондый сүзләрнең күпчелеге дә дияргә ярый, кайсы әдәби, кайсы провинциаль булуы билгеләнеп җитмәгән.* Җ.Вәлиди

4) *күч.* Тар, колачсыз, масштабсыз. *Озак вакытлар дәвамында сакланып килгән чикләү-тыюлар, түбәнсетүрәнҗетүләр (бигрәк тә адым саен милләтчелектә гаепләүләр), провинциаль фикерләү рәвеше буларак, кыюсызлык, чикләнгәнлек, мәнфәгатьләр тарлыгы сыйфатында калкып чыга.* Ә.Закиржанов

5) *күч. кимс.* Беркатлы, хәйләсез (кеше тур.). *Үз нәүбәтендә Нагиев та тәкәллеф күрсәтү ягыннан провинциаль сәүдәгәрдән калышмый иде.* Ф.Хөсни. *Халыкара күргәзмәдә катнашу өчен, Мөхәммәт Уразовны артык провинциаль һәм әлегә чак кына җитлегеп бетмәгән, диделәр.* З.Хөсният

ПРОВИНЦИА́ЛЬЛӘШҮ *ф.* Тар карашлы, үз мәнфәгатьләре белән генә яшәүче кешегә әверелү

Провинциальләшә бару Торган саен ныграк провинциальләшү

Провинциальләшә төшү Тагын да күбрәк провинциальләшү

Провинциальләшеп бетү Тулысынча, бөтенләй провинциальләшү

Провинциальләшеп китү Кинәт провинциальләшү

ПРОВИ́НЦИЯ *и. лат.* 1) *тар.* Борынгы римлылар тарафыннан басып алынган һәм Рим баскагы идарә иткән өлкә, ил. *Сәләтле һәм тырыш европалыны император да ошата; ул Маркога төрле җирләрдә булуны таләп итә торган төрле эшләр йөкли, аннары бер провинциягә идарәче итеп билгели.* Урта гасырлар тарихы

2) *тар.* XVIII гасырда Россиядә административ-территориаль берәмлек, губернаның бер өлеше

3) Кайбер илләрдә административ-территориаль берәмлек, вилаять. *--- көнчыгышта Тын океанга кадәр, Көньяк Себер далаларын, Якын һәм Урта Азияне, Кытайның төп провинцияләрен үз эченә алган --- Монгол империясе барлыкка килә.* Ф.Урманче. *Дәүләт телләрен тигез дәрәҗәдә куллану мәсьәләсен өйрәнеп, бик күпләр Канаданың Квебек провинциясенә барып кайттылар.* Р.Миңнуллин. *Тагын унөч провинция һәм автономия җирләре яшелләндерелә башлаячак.* З.Фәйзи

4) Илнең башкаласыннан, зур үзәкләрдән ерак булган җир, өлкә, периферия. *Үзәктә кырыкмаса-кырык төрле җаваплы вазифасы бар дип тормыйлар, үзе белән киңәш-табыш итәргә кирәк санамыйлар, ул «провинция»гә җибәрелә.* Р.Мөхәммәдиев. *--- бу Бәләбәй шәһәрмени соң ул? Тузан оясы и гап-гади провинция инде!* В.Имамов. *Казанны гадәти бер провинция шәһәре итеп калдыру, башкала дигән рухны халык аңында бетерүне большевиклар гаҗәп дәрәҗәдә уңышлы башкаралар.* М.Галиев

ПРОВИТАМИН *и. гр.-лат. биол.* Хайван организмында витаминнар барлыкка китерә торган матдә. *Кишер витаминнарга бик бай (аеруча провитамин А – каротинга), һәм анда специфик ис бирүче эфир майлары була.* Л.Мәүлүдова. *Үсемлектә файдалы матдәләр, шул исәптән С витамины, А провитамины, эфир майлары күп.* Татарстанның үсемлекләр һәм хайваннар дөньясы. *Сары помидорга сары төсне А провитамины бирә.* Ирек мәйданы

ПРОВОДНИК *и. рус* Вагонда юлчыларга хезмәт күрсәтүче, чисталык, тәртип саклаучы тимер юл хезмәткәре. *Кат-кат чакырып та врач --- табылмагач --- поезд бригадиры һәм проводниклар дүртенче вагон коридорында тәмәке тартып торучы ир янынарак тартылдылар.* А.Гыйләҗев. *Иртәгесен бу хәлне проводник – вагон эшчесе күреп алган да бер тукталышта милиция хезмәткәрләренә җиткергән.* С.Зыялы. *– Казан! Казан! Подъём! Постельләрне тапшырабыз. – Вагон буйлап проводник хатынның коры, яңгыравык тавышы тәгәри.* Р.Габделхакова

ПРОВОКА́ТОР *и. лат.* 1) Яшерен оешма әгъзаларын полициягә (гестапога һ.б.) тотып бирер өчен, шул оешмага үтеп кергән агент. *Тик шуны онытмагыз: арагызда сатлыкҗан һәм провокатор кала.* Р.Мөхәммәдиев. *--- тентү вакытында листовка табылган бик күп кешеләр кулга алынган иде. Безнең арага гестапо провокаторы үтеп кергәнлегенә бернинди шик калмады.* Р.Мостафин. *Шуңа күрә ул менә бирегә, үз иленә, үз милләттәшләре арасына дөресен сөйләү өчен кайтты. Телиләр икән, аны хыянәтче, провокатор дип атасыннар, әмма татар милләте бу*

кара исемне күтәрергә тиеш түгел. Ф.Бәйрәмова

2) Коткы таратучы, коткы салучы, котыртучы, провокация ясаучы. *Кулаков вә башкалар үзләренең провокаторлары аша сезнең арагызда төрле язулар тараталар.* А.Расих

ПРОВОКА́ТОРЛЫК *и.* Провокатор, яшерен агент булу. *Провокаторлык, шымчылык, хыянәтнең гомум символын белдергән җыелма образ ул Шәүлә.* Р.Фәйзуллин. *С.Рәми дә --- җавапсыз калмый. Үзен «таңчы» дип атаганы өчен, Г.Тукайны провокаторлыкта гаепләүгә кадәр барып җитә.* М.Гайнетдинов. *Милли идеяне югары күтәрүчеләрдән булган бу шәхеснең провокаторлык белән шөгыльләнә башлавы, бәлки, татар дөньясына социалистик идеяләр үтеп керү белән килешергә теләмәвеннән килеп чыккандыр.* Д.Заһидуллина

ПРОВОКА́ТОРЛЫК ИТҮ *ф. сөйл.* 1) Яшерен оешма әгъзаларын полициягә һ.б. тоттыру. *Бер кешегә генә әйтсәң дә, бөтен конспирацияне харап итәрсең, беләмсең, син провокаторлык иткән кебек буласың.* Г.Ибраһимов

2) Провокация белән, коткы тарату белән шөгыльләнү

ПРОВОКАЦИОН *с.* Провокация, котырту, эшне бозу максаты белән эшләнгән. *Бер көнне Казан дәүләт университетының төп бинасында «Эфир» телекомпаниясе хәбәрчесе бер татар егетенә: «Татар теле сезгә кирәкме?» – дигән провокацион сорау бирде.* Т.Миңнуллин. *Тарих галиме Р.Нәфигов язганча, «татарлар арасында панисламизм эзләү – патша самодержавиесенең провокацион уйдырмасы ул».* Ф.Галимуллин. *Спектакль башланыр алдыннан, махсус әзерләнеп киленгән бу провокацион сорауларга җавап биреп тормаска да була иде.* Р.Вәли

ПРОВОКА́ЦИЯ *и. лат.* 1) Сугыш конфликты китереп чыгару максаты белән алып барылган агрессив эш. *Аннары өмет белән үзен-үзе тыныч-ландыра: «Бу хәл – фәкать дошман провокациясе, чөнки Германия белән Советлар Союзы арасында килешү пакты бар».* Х.Камалов. *Парадка әзерләнү крепость алырга әзерләнүдән ким булмады. Немецлар ягыннан провокация көттеләр.* Р.Хәбибуллина

2) Нәрсәне дә булса тар-мар итү, зәгыйфьләндерү, таркату максаты белән алып барылган хыянәтчел эш. *Провокациянең монысы да үз бурычын арттырып үтәде. Инде өйнең иң түрендә җәелеп утырган председатель кинәт сикереп торды.* Ә.Баян. *– Провокация ич бу! – диде Солтангалиев җаны әрнүгә түзә алмыйча. – --- Аны үз милләттәшләре алдында явыз большевик, дошман кеше итеп күрсәтү кемгә кирәк икән?* Р.Мөхәммәдиев. *Зариф абзый аны, провокация, кешеләрне советка каршы кую өчен махсус оештырылган эш, дип атады.* Ф.Сафин

3) *мед.* Авыруны ясалма рәвештә кузгату, көчәйтү

4) *а.х.* Орлыкның шытуын ясалма рәвештә тизләтү. *Икенче, өченче елларны рәис үзе чәчү алдыннан дүрт-биш көнне отарга, солычага «провокация» ясарга булышты.* Х.Камалов

ПРОВОКА́ЦИЯЛӘҮ *ф.* Провокация ясау. *Тапсыннар, белсеннәр, нинди кабахәт провокацияли икән аны.* А.Расих. *Аның шулай артык дәрәҗәдә ашкынып, әле юньләп белеп тә бетермәгән кешегә серен бик тиз ачуын ошатып бетермәде Миңнулла. Моны мине провокацияләү өчен утыртканнар булса кирәк, дип шикләнде.* В.Нуруллин. *--- солыча орлыклары шытып чыгалар. Яшел энәләр җир өстен каплый, һәм шытымнар өстенә дисклы культиватор кертәсең. Бу – солычаны «провокацияләү» дип атала.* Х.Камалов

ПРОВОКА́ЦИЯЛЕ *с. к.* **провокацион**. *– Ни өчен дип, фашистларга каршы көрәшү – минем ил алдында торган бурычым, – дидем һәм кызып киттем. – Соң, шундый провокацияле сораулар биреп, минем патриотлык хисләремне сүндерергә тырышмагыз!* Х.Камалов. *Иптәшләр, хат язганда аң булыгыз, гадел итеп языгыз. Хәрби сер саклау зарурлыгы болай да аңлашыла, ә менә әлеге провокацияле хатлар өчен әдәби премия бирмәделәр. Киресенчә...* С.Шәрипов

ПРОВОКА́ЦИЯЧЕЛ *с. к.* **провокацион**. *--- кайбер татар манкортлары, «Мөстәкыйльлекме, әллә Россиядән бүленеп чыгумы?» дигән провокациячел сорау куеп, татарлар белән урыслар арасын ясалма рәвештә бозарга, хәлне катлауландырырга керешteләр.* Ж.Дәрзаман

ПРОГИМНА́ЗИЯ *и. гр. тар.* 1917 елга кадәр Россиядә тулы булмаган урта мәктәп. *Безнең гимназия һәм прогимназияләр күчер, лакей, кухарка --- балаларыннан тәмам арыначак!* Р.Ишморат. *Татар учительский школасында уку курсын бетереп чыгучылар --- прогимназияләрнең уку курсларын бетереп чыгучыларга бирелә торган хокуклар белән файдаланалар.* М.Гайнуллин

ПРОГНОЗ *и. гр.* 1) Фәнни мәгълүматлар нигезендә берәр вакыйганың, эш-хәлнең, күренешнең киләчәге, нәтиҗәсе турында алдан әйтеп кую. *Газеталар минем хакта ни язалар? Ниндирәк прогнозлар бар?* А.Гыйләҗев. *Ләкин үз оешмасы булган ЦРУның эш алымнарын ул яхшы белә, анда һәрнәрсә тикшерү-анализлау, исәпләп санап чыгару, прогноз һәм фәнни фаразлауга корылган.* Р.Мирхәйдәров. *Прогнозга килгәндә исә, ул төрлечә булырга мөмкин. Кайбер очракларда үсешнең тизләнгән темпы артында, чыннан да, гаҗәеп сәләтләр була, икенче бер очракларда --- тора-бара үсеш акрыная, һәм сабый --- гадәти балага әйләнә.* Тигез гомер итегез!

2) Метеорологик мәгълүматларга таянып, алдагы көннәрдә һаваның ничек булачагын билгеләү. *– Без бит сезгә бары тик прогноз буенча көтелгән һава турында гына мәгълүматлар бирдек, – дип тәмамлый ул гадәттә үзенең сүзен.* Р.Ибраһимов // Шундый мәгълүмат. *Тора-бара һавалар бюросының район үзәгеннән бирелә торган прогнозларын да телефон аркылы ул үзе кабул итә башлады.* Г.Галиев. *Җәй озын, прогноз яңгыр булуын әйтми әле.* Х.Сарьян

3) *мед.* Авыруның ничек узуына карап, аның нәтиҗәсен алдан әйтү

ПРОГНО́ЗЛАУ *ф.* Прогноз ясау, алдан әйтү. *Югарыда әйтелгәннәрдән күренгәнчә, максат билгеләү – күпбаскычлы акыл эшчәнлеге икән. Ул*

анализ, синтез һәм алдан күрә белү (прогнозлау) кебек катлаулы операцияләрдән гыйбарәт. Ә.Хуҗиәхмәтов. *Татарстан Республикасы Премьер-министры урынбасары, икътисад һәм прогнозлау буенча дәүләт комитеты рәисе Ф.Хәмидуллин җитәкчелегендәге хөкүмәт делегациясе Урта Азия республикаларында булып кайтты.* Татарстан реформалар чорында

ПРОГНО́ЗЧЫ *и.* һава торышының яки су температурасының киләчәк көннәрдә ничек буласын алдан билгеләүче, прогноз (*2 мәгъ.*) төзү белән шөгыльләнүче, метеоролог

ПРОГРАММ *с. сир.* Программаны (*1–2 мәгъ.*) чагылдыра, аңлата торган; программа сыйфатындагы. *Һ.Такташ бу программ мәкаләсендә социалистик реализм принципларының татар совет әдәбиятында иҗади үстерелүе мәсьәләсен теоретик фикерләү һәм әдәби иҗат практикасы яктылыгында куйды.* Х.Хәйри

ПРОГРА́ММА *и. гр.* 1) Киләчәктә эшләнәчәк эшләрнең, эшчәнлекнең планы. *Очышның программасын төзегәндә, баллистиканың һәм күк механикасының нинди законнарын кулланып эш итәргә?* Галәмгә юл. *«Федераль структуралар хезмәткәрләре, табиблар, мәдәният хезмәткәрләре, укытучылар шушы программа буенча тораклы булу мөмкинлеге ала», – дип ассызыклады --- торак фондының башкаручы директоры.* Шәһри Казан

2) *информ.* Бер программалаштыру телендә бирелгән, электрон-хисаплау машиналарында аерым мәсьәләләр чишү өчен әзерләнгән алгоритм. *ЭВМ хәтеренә тиешле программалар салыначак.* Тигез гомер итегез! *Инде бүген үк барлык больничныйлар да электрон рәвештә тутырыла. Моның өчен махсус программалар булдырылган.* Шәһри Казан

3) Сәяси партия, дәүләт хакимияте үзәк органнарының, җәмәгать оешмаларының яки дәүләт, җәмәгать эшлекләреңең эшчәнлеген, максатларын, бурычларын, киләчәктәге эшләрен эченә алган, бу эш принципларын аңлатып биргән эш планы; документ. *Аның тарафыннан әзерләнеп, әле күптән түгел генә Милләтләр эше буенча Халык Комиссариатында тикшерелгән «Көнчыгыш халыкларын азат итү берлеге» программасын да күрсәтте Йосыф Акчурага.* Р.Мөхәммәдиев. *Гөлфия, син Күмер Тау тоткынлыгында яшәп, бәлки, Дамир Салиевның сайлау алды программасын укымагансыңдыр.* Н.Гыйматдинова. *Шул утырышта ук оешманың программасы да кабул ителде.* Чын мирас

4) Берәр җыелышны, эшне, кичәне һ.б.ш.ны уздыру планы, тәртибе. *Җитмешенче еллар ахырында бер төркем язучылар белән Донбасс якларына барып чыккан идек. Программада күрсәтелгән бер шахтага барганда, юл уңаенда бер авыл хуҗалыгына кереп чыгарга булдык.* Казан утлары. *Бәйрәм программасын алып барган Рушания ханым Алтайның телгә осталыгы, ягымлы тавышы тамашачыларның күңелен яулады.* Сөембикә

5) Концертта, театрда, циркта һ.б.да куела, уйнала торган әсәрләр, номерлар җыелмасы; радио, телевидение тапшыруларының планы. *Программаның икенче бүлегендә чегәннәр чыгышы – билгеле бер сюжетка корылган, җыр һәм биюләрдән гыйбарәт тамаша күрсәтелә иде.* Р.Кәрами. *Вакытлыча Саратов радиосында программалар чыгаручы булып урнашкан иде.* Р.Мөхәммәдиев. *Кичә кич телевизорда «Вакыт» программасы күрсәтелеп беткәч, гадәтенчә, Айзат бераз һава суларга чыгып китте.* Язмышлар яңарганда

6) Уйнала торган әсәрләр һәм шул әсәрдәге рольләрне башкаручыларның исемлеге; шулар язылган (басылган) кәгазь. *Программа актарган булып, күршесенең ниндирәк кош икәнлеген чамалап утырды ---.* Г.Мөхәммәтшин. *Театр программасы. Концерт программасы*

7) Укытыла торган фәннең кыскача эчтәлеге һәм методологик күрсәтмәләре бирелгән аңлатма. – *Унынчы класс программасын үзләштерү җиңелгә килсен дисәң, сигезенче-тугызынчы класс программасын кабатларга кирәк, – диде ул.* З.Вәли. *Укытучылар: «Программадан тәмам артта калабыз, укытучыларның күбесе яшьләр, тәҗрибәләре юк, методиканы белмиләр, төшкә хәтле укытыйк та төштән соң кырга чыгарбыз», – дип гозерләп идарәгә бардылар.* А.Гыйләҗев. *Әмма Г.Фәхреддинов программаны таркау ясалган дип саный һәм, кайбер пунктлары башлангыч мәктәп өчен туры килмәгәнгә, аннан берникадәр читләшергә дә мәҗбүр була.* Чын мирас

8) Берәр уку йортында, факультетта, курста укытыла торган фәннәр җыелмасы. *Тугыз ай эчендә Айсылу филология факультетының берничә курс программасын тәшкил иткән әдәбиятны үзләштергәнен үзе дә сизми калды.* Р.Хәбибуллина. *Университет программасы нигезендә югары уку йортлары соңга таба Мәскәүдә --- һәм Киевта оештырыла.* Сөембикә

9) Музыка әсәренең темасы, сюжеты. *«Сүзсез җыр», «Сагыш», «Уйлану» кебек исемнәр инструменталь музыканың эчтәлегенә бер төрле дә программа бирмиләр, ә бары әсәрнең күңел кәефен генә билгелиләр.* Ж.Фәйзи. *[Симфоник поэманың] төп программасы итеп Кави Нәҗминең «Язгы җилләр» романындагы вакыйгаларны, бигрәк тә соңгы кузгалышны алдым.* А.Вәлиуллин

ПРОГРА́ММАЛАУ *ф. мат.* 1) Компьютерда математик яки логик мәсьәләләрне чишү өчен, махсус код ярдәмендә программа (*2 мәгъ.*) төзү

2) Компьютерларга, автомат станокларга һ.б.га программа кертү

Программалап бетерү Программалауны тәмамлау

Программалап бирү Кем өчендер программалау, программа төзү

Программалап кую Алдан программалау

ПРОГРА́ММАЛАШТЫРУ *ф. ялг. к.* **программалау**. *Компьютерны эшләтү алымнары бала-чага уены гына, аның әле тагын төпсез тирән бер фәнни-практик юнәлеше – программалаштыру дигән нәрсәсе бар бит...* З.Мифтахов

ПРОГРА́ММАЛЫ *с.* 1) Программасы булган. *Бу көн кич клубта шактый*

киң программалы концерт бирелəчак иде. Ф.Әмирхан. *Төрле карточкалардан файдалану, программалы укыту элементларын кертү, һәр әйткән фикерне тәҗрибәләр белән ныгытып бару – болар бар да Зөфәр Хисамовның педагогик системасын тәшкил итә.* Яфрак белән яфрак сөйләшə

2) Бирелгән программа (*2 мәгъ.*) буенча автоматик рəвештə алып барыла торган. *Шуңа күрə һәрбер татар гаиләсендə кириллица һəм латинда эшлəнгəн татарча программалы компьютер торырга һəм ул Интернетка тоташтырылган булырга тиеш.* Р.Хəким

ПРОГРА́ММАЛЫЛЫК *и.* Программалы булу. *Музыкадагы программалылык Листны, барыннан да бигрəк, чын демократизм элементлары тупланган жанр буларак үзенə тарта.* Совет əдəбияты

ПРОГРА́ММАЧЫ *и. информ.* Компьютерда төрле эшлəр башкару өчен программалар төзүче. *Проектчы, электрончы, диагнозчы, программачы һ.б., ягъни күбесенчə яңа технология, ноу-һау («белəм ничек» дигəн сүз) белəн эш итүчеләр.* Фəн һəм тел. *Казанда яшəүче программачы Алмаз Сəйфетдинов тормышка ашырган бу хезмəттəн файдалану өчен тулырак мəгълүматны www.5namaz.ru сайтыннан белергə мөмкин.* Шəһри Казан

ПРОГРАММИСТ *и. рус информ. к.* **программачы**. *Программист Лəйлə Хисамовна: «Компьютер дошманы – минем дə дошманым», – ди.* Н.Гыйматдинова. *Илсөя һəм Рушан Зəкиҗановлар икесе дə КДУда программист һөнəрен үзлəштергəннəр ---.* Ирек мəйданы

ПРОГРЕСС *и. лат.* Үсеш процессы кичерү, алга бару, үсеш закончалыклары нигезендə түбəнге баскычтан югарыгы баскычка күчү, камиллеккə ирешү, алгарыш; *киресе:* **регресс**. *– Рəүф белəн үзем сөйлəшермен, – диде. – Урманда үскəн бала түгел, прогрессны аңлар...* А.Тимергалин. *Кодрəтеңнəн килсə, бер гасырга чигендереп, син безне чабата чорында яшəтер идең. Вəт прогресс дошманы!* Н.Гыйматдинова. *Американы ачу кешелек прогрессы үсешенə зур этəргеч булды.* Эзлəнүлəр, уйланулар, табышлар

ПРОГРЕССИВ *с.* 1) Акрынлап арта, көчəя бара торган; пропорциональ рəвештə үсə торган. *Прогрессив түләү системасы*

2) Аңлы, зыялы, алдынгы. *Безнең күршедə Татьяна Николаевна Расторгуева дигəн прогрессив карашлы хатын яши иде.* Р.Вəлиев. *Китə шуннан прогрессив татар галимнəре, əдипləре, мөгаллимнəре --- өстеннən доносларъ...* Эзлəнүлəр, уйланулар, табышлар. *Еш кына Казан ханлыгын басып алуның Идел буе халыклары өчен прогрессив күренеш булуын аңлатылырга тырышыла.* Чын мирас

ПРОГРЕССИ́ВКА *и. рус сөйл.* 1) Нормадан тыш эшлəнгəн продукция өчен хезмəт хакына өстəмə түләү формасы (хезмəт хакын эш нəтиҗəләреннəн чыгып түләүнең бер төре). *--- йөк ташу планын шул вакыт эчендə икеләтə диярлек арттырып үтəгəнбез. Күрəсезме, нинди зур отыш? – Арадан берсе балаларча беркатлылык белəн: – Менə бəхет... Прогрессивканы каерабыз икəн, алайса... Шулай бит?.. – дип əйтеп куйды.* С.Сабиров

2) Билгеләнгəн эш нормасын арттырып үтəү. *--- безгə яңа буровойлар бирделəр. Аларның өчесен дə прогрессивка белəн – егермешəр, егерме бишəр көнгə алдан бораулап бетердек.* М.Хəсəнов

ПРОГРЕССИ́ВЛЫК *и.* Прогрессив булу. *Автократлык тамыр җəйгəн Үзəк Азиядə Кыргызстан – прогрессивлыкка омтылучы үзгə бер урын.* Н.Алан

ПРОГРЕССИСТ *и. рус кит. к.* **прогрессчы**. *Узен прогрессистлар арасында санаганга, газета мөхəррирлəренə ачуланып хатлар яза торган чиновниклар --- һəммəсе шул мирзалар арасыннан чыккан.* Ф.Әмирхан. *Рус депутатларыннан трудовик Керенский һəм дə прогрессист Караулов бергə барырга сүз бирделəр.* Г.Исхакый

ПРОГРЕ́ССИЯ *и. лат. мат.* Теге яки бу тəртиптəге саннар рəтенə даими бер санны кушып бару нəтиҗəсендə (арифметик прогрессия) яки даими бер санны тапкырлау нəтиҗəсендə (геометрик прогрессия) барлыкка килə торган саннар рəте. *--- инглиз экономисты Т.Р.Мальтус: «Халыкның тормыш сыйфаты аның санына бəйле; соңгысының үсеш темпы – геометрик прогрессия, ə яшəү өчен кирəк булган материаль байлык җитештерү артуы арифметик прогрессия буенча бара, һəм бу хəерчелеккə китерə», – дип яза.* Р.Сафин. *Аппарат якынайган саен сул күз кабагының тартуы арифметик прогрессия формуласы буенча арта бара.* Р.Батулла. *Ə бит аны сораучыларның саны минут саен, сəгать саен арта, арифметик прогрессия рəвешендə үсə.* Х.Ибраһим

ПРОГРЕ́ССЧЫ *и.* Прогресс тарафдары. *[Шəмигулов] үзен һəрвакыт мəгърифəтчел, прогрессчы итеп күрсəтергə тырышкан.* З.Бəшири

ПРОГУЛ *и. рус сөйл.* Сəбəпсез эшкə чыкмау (килмəү), эштən калу. *Прогул язсаң – яз, мин бер атнага Казанга киттем.* Н.Гыйматдинова. *Бу ятим карт та бəхилləшергə җыенмый. Сəламəтлеге мактанырлык түгел, шулай да чирləмəгəн чакта ул эшкə бара, һич соңармый, прогул ясамый.* Р.Батулла. *Өлгермəсəң – эшкə соңарасың, соңарсаң – проходнойдан кертмиләр, «прогул» куйсалар, унөченче хезмəт хакына зыян килə.* К.Кəримов

ПРОГУЛЧЫ *и. сөйл.* Сəбəпсез эшкə чыкмаучы, эш калдыручы, прогул ясаучы кеше. *[Указ] прогулчыларга каршы юнəлтелə.* М.Җəлил. *Ə шул көрəш Нəфисəнең прогулчы ире Сафи белəн кычкырышу, талашу, фəкать шуннан гына котылу рəвешендə бирелгəн.* Х.Туфан. *«Ни йөзем белəн директор каршына барыйм? Мин прогулчы бит!» – дим əнигə.* Татарстан яшьləре

ПРОДНАЛОГ *и. рус тар.* Россиядə 1921–1923 елларда җитештерелгəн авыл хуҗалыгы продуктлары өчен салымны натуралата түләү. *Бөтен өязлəрдə, авылларда сəнəкчеләр продналог отрядларын кырып бетергəннəр.* К.Тинчурин. *Алар инде Ленин хакимиятенə каршы көрəшүче көч булудан туктаганнар һəм Мəскəүдəн тик мəрхəмəт, продразвёрстка урынына продналог булыр дип өметлəнеп көтеп яталар.* З.Зəйнуллин. *Узенə бер телем*

икмәк тә калмый торган итеп продналог салырга кирәк аңа ---. Ф.Баттал

ПРОДОТРЯД *и. рус тар.* Россиядә «хәрби коммунизм» чорында продразвёрстка нигезендә азык-төлек җыеп йөрүче эшче-крестьяннарның кораллы отряды. *Бу вакытта без, продотряд булып, Идел буендагы ачларга озату өчен кулакларның яшергән ашлыкларын эзләп йөри идек.* Г.Бәширов. *Авылда укытучылар, өй борынча кереп, күкәй, бозау эзләп йөриләр. Революция елларындагы продотрядлар кебек.* Х.Камалов. *Авыл ач, авыл ялангач, авыл большевиклар эчбәргән продотряд тарафыннан тоташ таланган!* З.Зәйнуллин

ПРОДОТРЯДЧЫ *и. тар.* Продотряд әгъзасы. *[Без], коммунистлардан ундүрт продотрядчы, Арып-Балык станицасына юнәлдек.* И.Салахов. *[Кулак] Сәлмән карт, хаты саен диярлек, контрибуцияләрнең күплегеннән, продотрядчыларның катылыгыннан --- зарланып яза.* Ф.Хөсни

ПРОДРАЗВЁРСТКА *и. рус* Россиядә хәрби коммунизм чорында (1919–1921 елларда) җитештерелгән авыл хуҗалыгы продуктларының артык өлешен мәҗбүри рәвештә дәүләткә тапшырудан гыйбарәт булган азык-төлек әзерләү системасы. *Партиянең мартта булып үткән унынчы съездында продразвёрсткадан продналогка күчү турында чыгарган карары исеңдәме?* Ш.Камал

ПРОДУКТ *и. лат.* 1) Кеше хезмәте, кеше эшчәнлеге нәтиҗәсендә барлыкка килгән әйбер, матдә, предмет һ.б. *Ул соңгы елны мин хезмәт иткән сөт продуктлары заводының фельдшеры иде.* Р.Зарипова. *Башлангыч проект 100 мең тонна нефть продукты эшкәртүгә көйләнгән иде.* Я.Шәфыйков. *Игенчелек продуктларының төрләре арта ---.* Урта гасырлар тарихы

2) Составы катлаулы матдәдән химик яки башка юл белән аерып алынган икенче бер матдә. *Керосин, бензин – нефть продуктлары*

3) Азык-төлек, азык. *Кием-салым да туза, ертыла, продуктлар белән тәэмин итүдә дә өзеклекләр килеп чыгарга гына тора.* Ә.Хәсәнов. *Әллә кайдан командир килеп чыгып, ике солдатны үз янына дәште. Бу, әлбәттә, продукт алырга.* Х.Камалов. *Өемдә ике суыткыч, икесе дә җан теләгән продукт белән тулы.* Шатлыклы кайгы

ПРОДУКТИВ *с.* 1) Файдалы, нәтиҗәле. *Гадәттә, профессиональ прозаикның иң продуктив иҗат эшчәнлеге 60–70 яшьләргә кадәр дәвам итә.* Р.Фәтхрахманов. *Моның өчен түбәндәге эш төрләре тәкдим ителә: --- в) эшне продуктив алып бару өчен, укучыларның үзләренең язарга һәм, китап соңында тәрҗемә ителгән сүз һәм әйләнмәләрне файдаланып, бер-ике мәртәбә укып килергә тиешлекләрен аңлатырга.* Ф.Вәлиева. *Мәсәлән: кодрәт, куәт, көч, дәрман, хәл, җегәр, гайрәт синонимик рәтендә көч сүзе синонимик оядагы барлык сүзләрнең мәгънәсен дә берләштерә, --- нейтраль мәгънәгә ия, телдә продуктив, актив кулланылышта.* Г.Галиуллина

2) Терлекчелек продуктларын күбрәк бирә торган. *Эре терлекнең продуктив токымнары*

3) *лингв.* Хәзерге вакытта киң таралган, яңа сүз һәм сүз формалары ясауда еш кулланыла торган; актив. *Аффикслар үзләре кулланышы ягыннан да аерылып торалар: продуктив һәм продуктив булмаган төрләргә бүленәләр.* Ф.Сафиуллина. *Татар телендә исем ясаучы иң продуктив суффикс булган -лык/-лек ярдәмендә соңгы елларда да берничә дистә яңа сүз ясалды.* Р.Мөхиярова

ПРОДУКТИВЛЫК *и.* 1) Нәтиҗәлелек, продукция бирүчәнлек. *Үләннәрдә чәчәк ату һәм җимеш бирү иртәрәк башлана, орлык продуктивлыгы вегетатив масса белән чагыштырганда арта.* Л.Мәүлүдова. *Биш ел дәвамында тәүлеккә сөт җитештерүне 700 тоннага җиткерергә планлаштыралар, моның өчен сыерларның баш саны 40 меңгә кадәр җиткереләчәк, уртача продуктивлык 8000 килограмм тәшкил итәчәк.* Ватаным Татарстан

2) *лингв.* Продуктив (*3 мәгъ.*) булу. *Продуктивлыгын югалткан кушымчалар хәзерге телдә яңа сүз ясамыйлар.* Д.Тумашева. *--- куллану ешлыгы һәм сүз ясау продуктивлыгы ягыннан төрки тамырлар үз позицияләрен югалтмыйлар.* Р.Әхмәтьянов

ПРОДУКТЛАТА *рәв.* **1.** Продукт (*1, 3 мәгъ.*) рәвешендә, азыклата, азык әйберләре белән. *Авыруы көчәю аркасында санаторийга бара алмаганда, путёвкага тиешле паёкны продуктлата аның өенә китерәләр иде.* Г.Ибраһимов. *Шулай ук мондый очракта автобуста шешә белән су һәм продуктлата бирелә торган паёк булырга тиеш.* Шәһри Казан

2. *с. мәгъ.* Продукт рәвешендә булган. *Продуктлата рента*

ПРОДУКТЛЫ *с.* 1) Кайбер сыйфатлардан соң килгәндә: продукциясе шул сыйфат белдергәнчә була торган. *Әңгәмәбездә сүз, нигездә, яшь терлекләрне сәламәт итеп үстерү өчен нинди чаралар күрелеп эшләми, ни өчен мул продуктлы сыерлар аз һәм башка әнә шундый сорауларны анализлауга кайтып калды.* Борынгы Калатау итәгендә. *Галимнең бу дәвердәге эшчәнлеген академик А.Н.Кононов «чагыштырмача аз продуктлы булган» дип саный.* Фән һәм тел. *Билгеле булганча, Татарстанда, Русиянең башка төбәкләреннән аермалы буларак, югары продуктлы һәм кышка чыдам кортлар токымы сакланып калган.* Татарстан яшьләре

2) Эзләнелә торган продукты (*1 мәгъ.*), чималы булган, продуктив. *Борау продуктлы горизонтка эшкәртеп килә.* Ш.Бикчурин. *Продуктлы тау катламнары туран-сантон катламында ята һәм кремнезёмлы-цеолитлы мергелгә карый.* Фән һәм тел

ПРОДУКТЛЫЛЫК *и.* Продукция бирү сәләте (терлекләр, кошлар тур.). *Терлекләрнең нәселен яхшырту, баш санын арттыру, продуктлылыгын күтәрү --- эшчәкчелек осталыгына бәйләнгән бит.* Казан утлары. *2004 елда шәхси хуҗалыкларда умарталарның продуктлылыгы 2 тапкырга артык булды.* Сөембикә. *Савым терлегенең продуктлылык дәрәҗәсенең кимүе күп очракта республикада терлек санының кимүе белән аңлатыла.* Ватаным Татарстан

ПРОДУКТҮТКӘРГЕЧ *и.* Нефть продуктларын нефть чыккан җирдән тиешле урынга кудыру өчен үткәргеч торба. *Продуктүткәргеч салу Русиядә нефть һәм нефть химиясе тармакларын үстерүне күз уңында тотучы һәм 2030 елга кадәр исәпләнгән стратегик планга инвестиция проекты буларак кертелгән.* Кызыл таң. *Әлмәт – Казан продуктүткәргече*

ПРОДУ́КЦИЯ *и. лат.* 1) Берәр предприятие, сәнәгать тармагы яки илнең бөтен халык хуҗалыгы җитештереп чыгара торган әйберләр җыелмасы. *Наил Түбән Кама химия заводларының берсендә коммерция директоры булып эшли, үзләре җитештергән продукцияне тарату буенча аңа бик еш командировкаларда булырга туры килә.* Р.Хәбибуллина. *Биредә игенчеләр яшәгән һәм алар ихтыяҗ булган продукцияне җитештергәннәр ---.* Чын мирас

2) Эшләп чыгарылган, җитештерелгән аерым әйбер. *Ә яңа продукция алуны үзләштерүче цехның беркемгә дә тынгылык бирми торган чагы.* Язмышлар яңарганда. *Инде белгәнебезчә, КамАЗның төп продукциясе зур йөк автомобильләре булса, аның баш продукциясе – кешеләр.* Ватаным Татарстан. *Шулай ук монда халыкны экологик чиста продукция җитештерү юлларына да өйрәтәчәкләр.* Шәһри Казан

3) Сәнгать, әдәбият әсәре, фәнни әсәр. *1900–1916 еллар дәвамында нәшрият көнчыгыш телләрендә чыккан басма китап продукциясенең өчтән бер өлешен үз кулында тотып килә.* И.Рәмиев. *[Г.Камалның] тәрҗемәчелек продукциясенең иң күп өлешен әдәби тәрҗемәчелек түгел, гади тәрҗемәчелек алып тора.* М.Гали

ПРОДЮ́СЕР *и. ингл.* 1) Нинди дә булса сәнгать өлкәсендә зур чаралар уздыруга, фильмнар төшерүгә бәйле оештыру эшләре белән шөгыльләнүче, эшнең финанс ягын тикшереп торучы зат. *Мансур Гыйләҗев шул киностудия белән иҗат ителгән «Упкын» (2003), «Зөләйха» (2004) фильмнарының мөхәррире һәм продюсеры була.* Р.Даутов. *Аның егете – продюсер һәм режиссёр Тимур Вантейн.* Татарстан яшьләре

2) Артистның шәхси агенты. *Чабата – Сөмбелә төркеменең администраторы, дөрес, визиткасына ул үзен эре-калын хәрефләр белән продюсер дип яздырган.* К.Кәримов

ПРОЕКТ *и. лат.* 1) Нинди дә булса корылманың, төзелешнең, әйбернең алдан әзерләнгән язма планы, сызымы. *Институттан бер-ике квартал аста гына берникадәр үзгәртелгән, яхшыртылган проект белән өч йорт салалар иде, ---.* Х.Сарьян. *Күпер, --- иске проект белән салыначак.* М.Хәсәнов. *Бүген аның мөдире яңа бина төзү буенча проектлар юнәтеп йөри.* И.Әмирханов

2) Берәр нәрсә оештыру, төзү уе, ният. *--- хәзер Кытай археологиясендә дә халыкара проектлар актив тормышка ашырыла ---.* Чын мирас. *Фестиваль уңаеннан проект делегациясе шулай ук Нуриев әнисенең туган ягы – Әлки районының Базарлы Матак авылында булды.* Шәһри Казан. «*Беренче канал» оештырган «Голос» проектында катнашкан милләттәшләребез --- беренче, икенче урынны алды.* Мәдәни җомга

3) Берәр документның расланганчыга кадәр фикер алышу, төзәтмәләр кертү өчен алдан төзелгән тексты. *Курсовой проектның эшен бетереп, тизрәк җибәрергә кирәк.* Э.Касыймов. *Комиссиянең председателе карар проекты белән безне таныштырды.* Т.Миңнуллин. *--- пенсияләр буенча соңгы закон проектында тумыштан инвалид балаларга пенсияне арттыру каралган.* Р.Миңнуллин

ПРОЕКТАНТ *и. лат.* Проект (*1 мәгъ.*) төзеп, аны яклаучы кеше. *Яхшы хезмәт хакыннан тыш, Иванның өстәмә кереме дә барлыгын проектантлар һәм төзүчеләр арасында кем дә булса белә идеме икән ---.* Я.Шәфыйков

ПРОЕ́КТЛАУ *ф. к.* **проектлаштыру**. *[Б.Урманче] һәйкәлнең архитектура өлешен дә үзе проектлый.* Казан утлары. *Алда исәпләү эшләре, яңа машинаны проектлау, төзү, сынап карау эшләре тора.* Галәмгә юл. *Казан метрополитенын проектлау һәм төзү галимнәрнең күпьеллык тикшеренүләре нәтиҗәләренә нигезләнде.* Ватаным Татарстан

Проектлап бетерү Тулысынча, ахыргача проектлау. *Әллә сез шәһәр үзәген миннән башка гына проектлап бетердегезме?* М.Маликова

Проектлап кую Алдан проектлау

ПРОЕ́КТЛАУЧЫ *и. к.* **проектчы**. *--- Вахш елгасында плотиналар проектлаучылар исә бу мәгълүматларны искә алып эш итте ләр.* Галәмгә юл. *Татарстан Рәссамнар берлегенең Күргәзмәләр залында Казан остасы З.Низамовның шәхси күргәзмәсе ачылды. З.Низамов – нәкышче, проектлаучы, бизәүче.* Сөембикә. *Шуларның берсе – электр һәм җылылык энергетикасы корылмаларын проектлаучы.* Мәдәни җомга

ПРОЕКТЛАШТЫРУ *ф.* Проект (*1 мәгъ.*) төзү, проект әзерләү. *Бер мәртәбә проектлаштыргач, нигә инде тагын артык расход тотарга?* Г.Ахунов. *Аның тагын бер зур хезмәтен ассызыклап китү урынлы булыр – ул да булса китапханәнең яңа бинасын төзү, аны проектлаштыру.* Ф.Чанышева. *– Кайчан бетерәсез? – дип килеп керә беркөнне Королёв проектлаштыру бүлегенә.* Галәмгә юл

ПРОЕ́КТОР *и. лат.* Нинди дә булса сурәтне экранга зурайтып төшерү өчен кулланыла торган прибор; проекцион аппарат. *[Нуров] атналар буе үзе төшергән кинолента ларны проекторда карап өйрәнеп утыра.* А.Тимергалин. *Соңгы елларда яңа әйберләр кайтарылганы булмаса да, кабинетлар уку процессына җиһазланган: интерактив такта, өч мультимедиалы проектор, укытучыларның һәрберсендә ноутбук, һәрбер ноктада кабельсез Wi-Fi челтәреннән файдаланырга була.* Туганайлар

ПРОЕ́КТЧЫ *и.* Проект (*1 мәгъ.*) төзүче, проектлаштыру белән шөгыльләнүче. *Өлкәдән авторитетлы комиссия килгән. Архитекторлар, проектчылар.* А.Гыйләҗев. *Күпернең баш проектчысы төзелешнең генераль директоры 70 яшьлек Ислам үзе булды.* Т.Миңнуллин. *Ул ни әйтергә белмичә агарынып басып торган яшь проектчы янына килде.* А.Вергазов

ПРОЕКЦИОН *с.* Проекцияләү белән бәйле, шуның өчен хезмәт иткән. *Бернинди оптик җиһазлардан –*

көзгеләр, линза һәм проекцион аппаратлардан башка, буш кул белән моны --- Кио да эшли алмас. А.Тимергалин

ПРОЕ́КЦИЯ *и. лат.* 1) *мат.* Күләмле фигураларны яссылыкта бирү, сызым белән күрсәтү. *Рәсем сәнгатендәге проекция закончалыгын да аңламаган.* Г.Дәүләтшин. *Чөнки ул [Королёв] өч проекциядә фюзеляж рәсеме ясау, матур итеп кильнең сызымын сызу, лонжерон һәм нервюраларның үрелмәләрен сызу белән генә әле эшнең бетмәгәнлеген яхшы аңлый.* Галәмгә юл. *Тәкъдим ителә торган биремнәр ике проекция яссылыгында төзелә. Фигураларның проекцияләре 0,5–1,4 мм калынлыктагы сызыклар кулланып сызыла.* Сызма геометрия

2) *махс.* Рәсемнәрне, сызымнарны, кинокадрларны оптик юл белән экранда зурайтып күрсәтү

ПРОЕ́КЦИЯЛӘҮ *ф.* 1) Яссылык өстендә берәр фигураның, предметның сурәтен төшерү; проекция (*1 мәгъ.*) сызу

2) *махс.* Экранга берәр рәсемнең, сызымның, кинокадрның зурайтылган сурәтен төшерү

ПРОЖЕКТ *и. лат.* 1) *иск.* Проект, план

2) *ирон.* Тормышка ашмаслык, нигезсез проект, план. *Сазны, күлне түшәк итеп, ул туган Корыч челтәр һәм бетон никахыннан. Яңа күпер – купшы бантик, күк чәчәк, Прожектлар кебек гүзәл һәм шома.* Ә.Баян. *Нуров абзаң --- минем кебек йомшак бәндәләрне үз прожектларына катнаштыру өчен үгетли башлаячак.* А.Тимергалин

ПРОЖЕКТЁР *и. рус ирон.* Тормышка ашмаслык, нигезсез планнар белән мавыгучы кеше

ПРОЖЕКТЁРЛЫК *и.* Тормышка ашмаслык, нигезсез планнар төзү белән мавыгу. *Бу фикернең практик нигезе юк, алдан ук уңышсызлыкка дучар ителгән сафсата, прожектёрлык бу!* А.Гыйләҗев. *Һәм бу ышануны Екатерина II нең казакъ халык уку йортлары «оештыруы» кебек «прожектёрлык» кына дип бәяли алмыйбыз.* М.Гайнетдинов

ПРОЖЕ́КТОР *и. лат.* Көчле яктылык чыганагыннан һәм зур батынкы көзгедән гыйбарәт җайланма (бу көзге үзенә төшкән яктылык нурларын билгеле бер юнәлешкә туплый). *Ара-тирә теге яктагы прожектор уты су өстен капшап уза.* Ш.Рәкыйпов. *Сезнең прожекторыгыздан берәр файда бармы?* Д.Гыйсметдинов. *Королёв ракетаны ерактан ук күреп алды. Казахстан далалары үзәгендә, салкынча төн караңгылыгын ярып, прожектор утлары ракетага төбәлгәннәр.* Галәмгә юл

ПРОЖЕ́КТОРЧЫ *и.* Прожектор белән эшләүче белгеч. *Ә анысы [фотограф] фюрерга бер карап алган да: «Яктылык бирегез, яктылык җитми!» – дигән. Прожекторчылар ротасы китерткәннәр.* Р.Могыйнов. *Прожекторчы Тәскирәнең кирәкле ноктaларны табып төгәл яктыртуы аркасында, күп кенә дошман самолётларының җинаятьчел хәрәкәтләре ярты юлда тукталып кала.* Ватаным Татарстан

ПРО́ЗА *и. лат.* 1) Шигъри төзелешкә нигезләнмәгән чәчмә әсәр. *Нәҗми һәм Кутуйның прозага күчүен, Такташның традицион ритмикадан чыкмавын искә алганда, татар шигырендәге, бигрәк тә ритмикадагы яңачалыкның җәваплылыгы минем өстә иде.* Х.Туфан. *Баксаң, болай да гомер буе проза язганмын икән!* Ш.Галиев. *Бу вакытта ул инде язучы, унлап китап авторы буларак (сигезе – шигырь, икесе – проза) татар укучылары арасында шактый танылган була.* Р.Мостафин

2) Чәчмә әсәрләрдән торган әдәбият; сөйләмнең чәчмә төре белән язылган матур әдәбият әсәрләре. *Сугыштан соңгы татар прозасын да карап-күзәтеп барырга вакытын таба иде.* Х.Сарьян. *Айдар Хәлим татар шигърияте, татар прозасы, татар публицистикасы һәм татар әдәби-эстетик тәнкыйте өлкәләрендә зур активлык белән эшли.* Р.Даутов. *Балалар прозасы белән танышып чыкканнан соң, күңелдә шундыйрак хис кала.* Р.Миңнуллин

3) *күч.* Көндәлек тормыш; тормыш өчен кирәкле, гадәти нәрсә. *Мондагы «поэзия»не ташлап, тагы шул «проза»га – эчпошыргыч тормышка кайтырга кирәк.* Ә.Фәйзи. *Юк, Таймас әле боларны белеп бетерми, ләкин кайчакларда ул үзен тормыш прозасыннан тәмам гарык булган карт итеп тоя иде.* А.Тимергалин

ПРОЗА́ИК I *и. рус* Чәчмә әсәрләр, проза әсәрләрен язучы. *Ибраһим Гази, хәйләкәр елмаеп: «Бүгенге шагыйрь – иртәгәге прозаик ул», – ди торган иде.* Ш.Галиев. *Яшь прозаик С.Сабиров бу очеркны Г.Әпсәләмов белән бергәләп язуы белән яхшы эшләгән.* Г.Иделле. *Алтмышынчы еллар башында ук --- яшь шагыйрләрнең, прозаикларның әсәрләре республика матбугаты аша инде күпләргә билгеле булган.* Язмышлар яңарганда

ПРОЗА́ИК II *с.* 1) Проза (*1 мәгъ.*) белән язылган. *Бу биштомлык басмасында аның прозаик язмалары шактый күләмдә җәмәгатьчелек игътибарына тәкъдим ителә.* Х.Туфан. *Шуңа күрә ул шигъри сүзгә мөрәҗәгать итә һәм хатның прозаик текстына җырлар да өсти.* К.Миңнуллин. *Пьесалар белән бер үк вакытта хикәяләр дә иҗат итә, пьесалар һәм прозаик әсәрләр тәрҗемәли.* Г.Камалетдинов

2) Прозага хас, шигъри булмаган, коры, төссез. *Поэтик бизәкләр дә төссезләндерелгән: башка прозаик сүз белән алыштырылган.* Г.Кашшаф. *Прозаик әйләнмә*

3) *күч.* Гадәти, кызыксыз, эчпошыргыч, күңелсез (тормыш, көнкүреш тур.). *Мине бәрәңге һәм ит-сөт дип аталган «прозаик» әйберләр турындагы уйлар [басты].* Казан утлары

ПРО́ЗАЧЫ *и. әд. к.* **прозаик** I. *Без, татар шигырьчеләре һәм прозачылары, исән-саулар.* Һ.Такташ

ПРОЗЕ́КТОР *и. лат. мед.* Мәетләр яру белән шөгыльләнүче врач

ПРОЗЕ́КТОРЛЫК *и. мед.* Прозектор вазифасы, прозектор хезмәте

ПРОИЗВО́ДСТВО *и. рус* 1) Җәмгыять яшәеше өчен зарури булган матди байлыклар җитештерү процессы. *Өченче көн производство киңәшмәсендә безнең эшебезгә комачаулый торган моментларны тәнкыйть итеп чыккан идем.* Р.Ишморат. *Цех бинасы иркенәйтелде, вентиляторлар эшли, производство мөмкин булганча механикалаштырылды.* М.Маликова.

Укулардан соң бер-ике атна мәктәп бакчасында эшләгәч: «Хәзер производство практикасы уттегез. Җиденчегә күчтегез», – диделәр. Д.Галимов

2) Продукция әзерләү, эшләү белән турыдан-туры бәйләнгән эш. *Скворцов Уралда эшче семьясында туып үскән, биш ел производствода эшләгән.* М.Гали. *--- производствода эшләтмәү яисә, киресенчә, эшләргә мәҗбүр итү --- белән бергә залим ир хатынын туганнарыннан, дусларыннан аера*. Сөембикә

3) Халык хуҗалыгының яки сәнәгатьнең бер тармагы. *Май сыгу производстволары безнең терлекчелегебезгә ел саен, ай саен, көн саен аксымга бай булган түп биреп тора.* А.Расих. *Ул елларда безнең Казанда мехлар эшкәртү производствосы бик кызу үсә башлаган иде.* Ә.Еники. *Район авыл хуҗалыгы производствосы идарәсенең баш агрономы мине үз машинасына чакырган иде.* З.Вәли

ПРОКАТ I *и. рус* 1) Кызган килеш эшкәртү ысулы белән ясалган әйбер. *Прокат цехы кайнар тасма суза; Болванкалар – тасма төргәге.* Х.Туфан. *Комплекс составына кокс химиясе, сортлы прокат производствосы, җылылык электр станциясе, кислород станциясе керә*. М.Мәһдиев. *Әрәм булган цемент – тау икән; аста ятып черегән металлны прокат станы аша үткәреп калай ясасаң, төзелеш мәйданын тоташтан капларлык калай чыгачагын исәпләп бирдем*. А.Гыйләҗев

2) *сөйл.* Прокатлау станы. *Метеордай кызган болванка Килеп кысыла прокат валына.* Ф.Кәрим

3) Нәрсәне дә булса түләү юлы белән, вакытлыча файдалану өчен бирелә торган урын. *Ильяс белән Рәйхан чаңгыларын ял базасының прокат бүлегенә тапшырдылар да җәяүләп автобус тукталышына киттеләр*. Р.Муллануров*а. Шуңа күрә Габделнургa үз җаен үзе кайгыртырга туры килде: шампан шәрабы, «Столичный» юнәтте, прокат пунктыннан телевизор, савыт-саба, шул исәптән рюмка-фужер кебек вактәяк алып кайтты.* Р.Кәрами. *Икенче көнне Илһам прокат бүлегеннән кечкенә генә суыткыч алып кайтты*. Х.Ширмән

ПРОКАТ II *ф.* Берәр әйберне түләүле нигездә вакытлыча файдалануга бирү формасы. *Прокатка конькилар алып, пальтоларын салмый гына боз өстенә чыктылар*. И.Гази. *Балалар ач булмасын дип, сату өчен икмәк пешерә, прокатка машина алып кием тегә, бәйләү бәйли*. Ә.Баян. *Менә шул Харрас бер көнне сулуы кабып палатама килеп керде дә: «Әйдәле, Зөфәр абый, чыгып та йөрмисең, прокатка көймә алдым, көймәдә йөреп кайтыйк бер», – ди*. М.Ибраһимов

ПРОКАТЛА́У *ф. тех.* Махсус станокта кайнар металлны әйләнеп торган ике вал арасыннан үткәреп юкарту. *Кайнар хәлдә прокатлау станнарының подшипникларын --- пластмассадан ясау файдалырак булуы 1932 елда ук исбат ителгән иде.* Г.Камай. *Тимер прокатлау*

ПРОКАТЧЫ *и.* Прокатлау белән шөгыльләнүче, прокат станында эшләүче эшче

ПРОКЛАМА́ЦИЯ *и. лат.* Агитация максаты белән таратыла торган сәяси эчтәлекле листовка. *«Оһо! Тентү буласы, ди. Прокламацияләр басалар икән», – дип уйлады малай ---*. А.Тимергалин. *– Прокламация бу... – дип башлады Гыйльметдин тыныч кына, аннары кызыбрак китте. – Без аларны стеналарга ябыштырабыз... Байларның котын ала ул...* Г.Иделле. *Автор Ямашевның революцион эшчәнлеген аның беренче мәртәбә татар телендә прокламация чыгаруыннан башлый*. Р.Зарипова

ПРОКТО́ЛОГ *и. мед. рус* Проктология белгече. *Проктолог юан эчәктә яман шеш барлыкка шикләнерлек нәрсә тапса, операторлар үзләре шалтыратып, өстәмә тикшеренүләр узарга кабат чакыра.* Сөембикә

ПРОКТОЛО́ГИЯ *и. гр*. Медицинада туры эчәк авыруларын һәм аларны дәвалау ысулларын өйрәнә торган бүлек. *Хәзер сез стоматологиядән башлап проктологиягә кадәр бар нәрсәне дә беләсез*. Кәеф ничек?

ПРОКУРАТУ́РА *и. рус* 1) Законнарның дөрес үтәлешен күзәтү һәм закон бозучыларны җавапка тарту белән шөгыльләнә торган дәүләт хакимияте органы. *Вакыйга республика прокуратурасына барып иреште*. Х.Вәлиәхмәтов. *«Субботин эше»н прокуратурага җибәрер алдыннан, аның һәр бите белән танышып чыктым*. Язмышлар яңарганда. *Милиция яки прокуратура хезмәткәрләренә үзегез белән булган бәхетсезлек хакында сөйләгез.* Сөембикә

2) *җыйд.* Прокуратура хезмәткәрләре

ПРОКУРОР *и. лат.* 1) Законнарның төгәл үтәлешен күзәтүче дәүләт хезмәткәре. *Тимерханның эше турында сөйләп биргән хатын тамагын кырды. Бу – районның прокуроры Улибаева икән*. М.Мәһдиев. *Төгәл генә җавап ишетмәгәч, прокурор криминалист Камалетдиновны чакырып кертте ---.* Х.Вәлиәхмәтов. *Шуны искәртәм: бу көнгәчә әле соловецлар җиренә бер прокурорның да аяк басканы юк!* Р.Мөхәммәдиев

2) Суд процессында дәүләт гаепләүчесе. *Прокурор чыгышында Вәсилә өчен бер яңалык та юк иде, әлбәттә, чөнки ул гаепләү нәтиҗәсе белән таныш инде*. Ә.Сафиуллин. *Прокурор үзенең гаепләү речендә җәлилчеләрне, герман командованиесенең «зур ышаныч» күрсәтүеннән файдаланып, рейхка каршы җимерү эше алып барган бандитлар төркеме дип күрсәтергә тырыша*. Р.Мостафин. *Прокурор тутый кош шикелле гел бер үк сүзне кабатлый: – Район судының карарын дөрес дип табам һәм җәзаның үзгәрешсез калдырылуын үтенәм.* И.Сиражи

ПРОКУРО́РЛЫК *и.* Прокурор булып эшләү, прокурор вазифасы. *Минем рәсми прокурорлыгым социализм юлындагы идеяләремне гамәлгә ашыру өчен зур мәйдан гына ачачак.* М.Галәү. *Аңа башта: «Алган акчаларыңны, әйберләреңне кире кайтарып бир, сине прокурорлык эшеннән азат итәбез һәм шуның белән чикләнәбез», – дигәннәр.* Н.Хәсәнов. *Моңа аның эше дә – башта тикшерүче, аннан прокурорлык хезмәте дә сәбәпче булды бугай*. М.Насыйбуллин

ПРОЛЕТАР *с.* **1.** 1) Пролетарий булган. *Пролетар революция ясыйм, дип йөргән большевик Солтангалиев*

Крестовников заводы эшчеләреннән чак качып котылган, дигән сүзне ничек күтәрерсең!.. Р.Мөхәммәдиев. *Мин --- рус халкының пролетар язучысы Максим Горький сүзләрен тагын бер мәртәбә искә төшерергә булдым*. Сөембикә

2) Пролетарийларга хас. – *Болар бакча эчендә калган эткә дә дәрт биреп өрәләр инде, – диде Ирек. – Үзләренчә пролетар теләктәшлек, – дип җөпләде Габделнур.* Р.Кәрами. *Ул чорда бары тик халыклар дуслыгы һәм пролетар интернационализм турында гына сөйләшергә ярады*. Р.Вәлиев

2. *и. мәгъ. сөйл.* Пролетарий. *Үзебез, без йолкышлар түгел, без пролетарлар, пролетарлар, дип әйтә торабыз.* Н.Дәүли. *Синең нәрсә, кашың да күзең, мылтыгың да үзең. Гомер-гомергә пролетар.* А.Гыйләҗев. *Анда Ленинның үзе белән бергә эшләп үскән пролетарлар бармы?* Р.Гайфуллина

ПРОЛЕТАРИАТ *и. лат.* Марксистик концепциядә: үзләренең җитештерү чаралары булмаган, җитештерү чаралары хуҗасына үз хезмәтен сатып көн итә торган яллы эшчеләр, пролетарийлар сыйныфы. *Мәскәү – пролетариат иленең йөрәге – көннән-көн үсә, зурая бара*. А.Алиш. *Үзең уйлап кара, Мулланур: ни өчен дип әле бөтен хезмәт ияләренә азатлык китергән революцияне, яңа тормышны пролетариат диктатурасы белән чикләргә?* Р.Мөхәммәдиев. – *Революцион аңлы пролетариатның колхозчы крестьянга эчкерсез ярдәм кулы сузуы! – дип көлде Әмирхан*. Н.Акмал

ПРОЛЕТАРИА́ТЧА *рәв.* Пролетариатка хас. *[Без] гегемонлык алу бурычын --- пролетариатча тотнаклы, --- көчле әсәрләр тудырсак кына үти алырбыз.* М.Җәлил. *Ипташ Сталин: «Без яңа мәдәният төзибез, аның эчтәлеге пролетариатча, әмма формасы милли булырга тиеш», – диде*. Р.Низамиев

ПРОЛЕТА́РИЙ *и. лат.* 1) Марксистик концепциядә: үз җитештерү чаралары булмаган яллы эшче катлавы. *Без иң элек гәзитнең иң башына язып куелган «Бөтендөнья пролетарийлары, берләшегез!» дигән девизны алып ташладык*. Р.Миңнуллин. *Алар, --- җае чыккан саен, күкрәк сугып: «Без – пролетарий!» – дип кычкыралар*. Г.Сабитов. *Большевиклар --- эшче пролетарийны гегемон дип игълан итеп (гәрчә алар өчен кыл да кыймылдатмасалар да), авыл кешесен, игенчене алар тәкәллефсез генә икенче сортлы, --- кавемгә санадылар*. Р.Зәйдулла

2) *тар.* Борынгы Римда: милке булмаган түбән катлау

ПРОЛЕТАРЛАШУ *ф.* Капитализм шартларында вак товар җитештерүченең (мәс., крестьян, вак һөнәрче һ.б.ш.ның) котылгысыз рәвештә бөлеп, мохтаҗлыкка төшеп, пролетарийга (*1 мәгъ.*) әверелүе. *Горький – шәһәр әдибе. Провинция шәһәренең купец, төрле тип мещан, вак буржуа пролетарлашуының төрле дәверендәге эшчеләр тормышын язган әдип.* Г.Нигъмәти

Пролетарлашып бетү Бөтенләй, тулысы белән пролетарлашу. *Шуның өстенә барлык милләтләрнең әдәбиятлары бер генә идеяне – социализм идеяләрен генә расларга тиешлеген искә алсаң, аларның тора-бара ни рәвешле пролетарлашып бетәчәген күз алдына китерү кыен түгел иде*. Ф.Галимуллин

Пролетарлашып китү Ниндидер сәбәпләр аркасында кинәт пролетарлашу. *Турыдан-туры Х.Ямашев йогынтысы белән революция эшенә тартылган Фәрхетдиннең – пролетарлашып китүче татар крестьяны тибының – тормышын аеруча бер эзлеклелек белән карау, күзәтү игътибарга лаек.* Р.Зарипова

ПРОЛЕТА́РЧА *рәв.* **1.** Пролетарларга хас. *Пролетарча яшәү*

2. *с. мәгъ. Пролетарча рәхмәт, Зөбәржәт ипташ.* Ф.Сәйфи-Казанлы

ПРОЛЕТКУЛЬТ *и. рус* 1917–1932 елларда «лаборатория» юлы белән пролетариат культурасы төзү турында ялгыш идеяләр үткәргән культура-агарту оешмасы. *Пролеткульт һәм романтика. Бу ике төшенчә берберсе белән сыешмый.* Ф.Галимуллин. *Берәүләр, катлаулы үткәндәге казанышлар колына әверелеп, ирешелгән ачышларны кабатлау юлына кереп китсә, икенчеләр, пролеткульт, РАПП вәгазьчеләренә ияреп, мираска арка белән борылалар, яңа әдәбиятны буш урында тудыру турында хыялланалар.* Т.Галиуллин. *Кызганычка каршы, мәдәниятне, гомумән рухи кыйммәтләрне үстерүдә метафизикысуллар белән дә гамәл итү очрый. Пролеткульт агымы вәкилләренең эшчәнлеге моның классик мисалы итеп китерелә.* К.Гыйззәтов

ПРОЛЕТКУЛЬТЛЫК *и.* Пролеткультка хас идеяләр. *Пролеткультлык рухындагы аерым ялгышларына карамастан, [К.Нәҗми] эшчеләр сыйныфына хезмәт итә торган әдәбият һәм сәнгать барлыкка китерү мәсьәләләрен күтәргән иде.* Н.Гыйззәтуллин

ПРОЛЕТКУЛЬТЧЫ *и.* Пролеткульт оешмасы әгъзасы, пролеткульт идеяләрен яклаучы. *Футуристлар һәм пролеткультчылар элекке культурага каршы көрәш лозунгысы белән кизәнделәр, бөтен мирасны инкяр итеп, ниндидер «саф пролетар культура» төзү кирәклеге турында шау-шу күтәрделәр.* Г.Халит. *Тик пролеткультчыларның, яңа, саф пролетар мәдәният төзибез, дип рухланып йөрүләрен исәпкә алганда, монда күпмедер хаклык та булырга мөмкин*. Ф.Галимуллин

ПРОЛЕТКУЛЬТЧЫЛЫК *и.* Пролеткульт идеяләре, пролеткультчылар карашы. *Мондый карашлар шагыйрьнең шул чор әдәбият атмосферасында аерым мәкаләләрдә яңгыраш тапкан пролеткультчылык рухындагы концепцияләргә иярүен күрсәтте*. һ.Такташ. *--- «Идел» повесте сыйнфыйлык идеологиясенә, пролеткультчылык принципларына буйсындырылган рәсми әдәбият белеме тарафдарларының каты тәнкыйтенә очрый*. Р.Даутов, Р.Рахмани. *--- бу юлларда егерменче елларда киң таралган иске мирасны инкяр итү, пролеткультчылык карашлары турында сүз бара*. Фатих Әмирхан турында истәлекләр

ПРОЛЁТ *и. рус* 1) Ике әйбер арасындагы буш, ачык урын. *Пролётларда, бергә култыклашып, Шаулый-шаулый бетон таптаулар Онытылмаслар, гомер онытылмаслар.* Ш.Маннур. *Соңгы пролёт калды үтәсе ---*. Ф.Кәрим

2) Нинди дә булса корылманың ике терәк арасындагы өлеше; торык. *Шундый киң дәрья аша җиңел челтәр төсле сузылган корыч пролётларның нәфислегенә сокланып бара.* К.Нәҗми. *Төп корпусның беренче ике пролётын сафка керту*

ПРОЛЁТКА *и. тар. рус* Ике урынлы, дүрт тәгәрмәчле ачык җиңел тарантас. *Бикә абыстай кызын, --- сабакка барганда, эче селкенмәсен дип, һәрвакытта йомшак пролёткага гына утыртып йөртә иде.* Г.Камал. *Йорт төрле пролёткалар һәм йөк арбаларына җигелгән яки туарылып, печән ашап тора торган атлар белән тулы.* Ә.Фәйзи

ПРОЛОГ *и. гр.* 1) Әдәби яки музыкаль әсәрнең, спектакльнең кереш өлеше. *Поэмадагы әнә шул пролог ханның ни сәбәпле гайрәте килүенә һәм Тахирны җәзалавына ачыклык кертә. Әменә либреттода андый пролог булмавы конфликтның әзерлексез бирелүен китереп чыгара*. М.Җәлил. *Драма авторлары бөтен әсәрнең уңышы шушы проблемага, аның ни дәрәҗәдә тулы һәм дөрес хәл ителүенә бәйле булуын белеп эш йөрткәннәр. Бу прологта ук күренә*. А.Әхмәдуллин. *Батулла үзенең әсәрендә, пролог рәвешендә, Сөембикә токымының һәм, гомумән, татар дәүләтчелегенең тирән тамырларын юллап, аралап, бүгенге укучыга күрсәтә.* Ф.Хатипов

2) *күч.* Нәрсәнең дә булса башлангычы. *Күпме яздым! Әмма китапларымның Әллә ничә мең дистә юлы – Әйтергә теләгәнемә пролог кына.* Ә.Давыдов. *Әхмәт Фәйзи тарихи-эпик вакыйгалар, тарихи шәхесләр белән бик нык кызыксына башлый. «Качкын» операсы либреттосы шагыйрьнең бу юнәлештәге зур эшенең прологы була.* Ф.Хөсни

ПРОМИ́ЛЛЕ *и. лат. махс.* Санның меңнән бер, процентның уннан бер өлеше. *Әлегә бездә машина йөртүченең канында 0,3 промилле алкоголь булу баш бәласе саналмый*. Ватаным Татарстан. *Кызык өчен генә уртача гәүдәле кешегә 0,3 л сыра эчереп тикшереп карадык. Прибор 0,23 промилле күрсәтте ---.* Ирек мәйданы

ПРОМКОМБИНАТ *и. рус-лат.* Шәһәр яки посёлоктагы вак предприятиеләр берләшмәсе. *Ул башта промкомбинатта эшләгән.* Г.Бәширов. *Соңгы көннәрдә бәрәңге басуында колхозчылар, укучылар белән бергә Зәйдән килгән промкомбинат эшчеләре --- шактый тырыштылар ---*. А.Гыйләҗев. *Промкомбинат яныннан үткәндә, Дасаев адымнарын әкренәйтте, аннары, хатирәләргә бирелеп, бөтенләй туктап калды*. Р.Мирхәйдәров

ПРОМОА́КЦИЯ *и. ингл.* Продукцияне киң массаларга таныту һәм тарату, сату күләмен арттыру максаты белән эшләнгән акция, чара. *Промоакция үткәрү*

ПРОМО́УТЕР *и. махс. ингл.* 1) Нинди дә булса чараны (концерт, спорт ярышлары һ.б.ш.ны) оештыруда акчалата ярдәм итүче

2) Фирма җитештергән товарны рекламалау белән шөгыльләнүче зат. *Әмма көндезге бүлектә беренче семестрда укучы студентларга яраклы эшләр бармак белән генә санарлык: промоутер, реклама кәгазьләре ябыштыручы, зур кибетләрдә азык-төлекне пакетларга тутырып торучы һәм өйдәге эш.* Ватаным Татарстан

ПРОМТОВАР *и. рус* Көнкүрештә әһәмиятле булган сәнәгать товарларының гомуми атамасы (мәс., тукыма, кием, аяк киеме, трикотаж һ.б.ш.). *Секретарь сүзендә торды: кампаниянең башлаучы ике колхоз межасына кичке сигезгә раймаг машиналары килеп туктады, берсендә – промтовар, икенчесендә гастроном иде*. М.Мәһдиев. *Әткәйнең складында төрле-төрле сатин-ситсы, аяк киеме кебек промтовар була*. Р.Даутов. *Якындагы промтовар кибете дә, ашханә дә ябык иде*. Н.Фәттах

ПРОМФИНПЛАН *и. рус тар.* Предприятиенең җитештерү-финанс планы. – *Әстерханда да шулай чиертми торган булса, балык тотудагы промфинплан ерак бара алмас, – ди ул*. һ.Такташ. *Сабир әле дә онытмый: ничектер һәр цех саен промфинпланны үтәү турында эшчеләр гомуми җыелыш алдында вәгъдә бирделәр*. А.Алиш

ПРО́МЫСЕЛ *и. рус* 1) Җәнлек, кош, балык һ.б.ш.ны күпләп аулау предприятиесе яки предприятиеләр төркеме. *Хәзерге вакытта кабан дуңгызларының саны меңнәрчә баш белән исәпләнә, һәм ул промысел хайваннары рәтенә керә.* Физик география. *Промысел хайваны – ите, тиресе, йоны яки мөгезе өчен аулана торган хайван*. Хайваннар дөньясы: имезүчеләр. *Беринг диңгезендә --- балык, диңгез мәчеләре, тюленьнәр промыслы үсеш алган.* Ирек мәйданы

2) Чимал табу предприятиесе яки предприятиеләр берләшмәсе. *Шул ук көнне промыселлар идарәсенә барып тавыш куптарды ---*. Ә.Баян. *Нәиләнең күптән инде аны промыселга – үзе эшли торган скважиналар янына алып барасы килә иде.* М.Хәсәнов. *Судагы --- кара төснең нефть икәне беленде дә, Нәҗарның йөрәге жу итеп китте. Кит тоту промыселы идарәсе каршына диңгездә йөзүдәге яңалыкларны белергә теләүчеләр җыела*. М.Юныс

ПРО́МЫСЕЛЧЫ *и.* Промысел эшчесе. *Шәрәфи агай байтак еллардан бирле промыселчы еврейләрдә хезмәт итә.* Ш.Камал

ПРО́МЫСЛО *и. сөйл. рус к.* **промысел**. *Гыйззәт промыслода эшләнеп беткән унбишәр потлы балык мичкәләрен бозлы базга тәгәрәтеп көнен уздыра.* Ф.Сәйфи-Казанлы. *Балык промыслоларында эш хакы яхшы була.* Ш.Камал

ПРОМЫ́ШЛЕННИК *и. рус* Сәнәгать предприятиесе хуҗасы. *Күпләр өчен Табигать – хуҗасыз байлык. Аның хакында кайгыртуның нәрсә икәнен белмәгән промышленниклар җирне, суны, һаваны гына түгел, ә бәлки җаннарны да пычраталар*. Ә.Баян. *Әтием Идел буендагы шәһәрләрнең берсендә зур промышленник булган.* Т.Гыйззәт. *Әгәр дә тыштан – хаким милләттән ярдәм алмыйча, мәктәпләр салып, эшче-крәстиян сыйныфын, үз буржуазиясен булдырып, үз промышленникларын үстереп, үз интеллигенциясе булып, аның матбугаты үз телендә булса, --- бу халык «милләт» дип аталырга тулысынча хаклы*. Р.Батулла

ПРОМЫ́ШЛЕННОСТЬ *и. рус* 1) Халык хуҗалыгының җир асты казылмаларын табу һәм чимал эшкәртү, әйберләр җитештерү һәм куллану кирәк-яракларын булдыру белән шөгыльләнә торган тармагы; сәнәгать. *Фән, сәнгать, промышленность өлкәсендәге көчләрне бер кулга җыйсаң, татарның мөстәкыйль дәүләтле булып яшәрлек кодрәте күз алдына килә дә баса.* М.Галиев. *Ә инде төшке аштан соң хуҗалык һәм промышленность предприятиеләре җитәкчеләре Киров исемендәге колхозга юл тоттылар.* Т.Нәҗмиев. *Промышленность, транспортның үсеше Җир атмосферасына байтак зарарлы матдәләр үтеп керүгә китерде.* Физик география

2) Билгеле бер производство предприятиеләре. *Безнең хәрби промышленностька ташламалар бар, «Мелита»га льготалар бар, ә китап сатуга льготалар юк.* Т.Миңнуллин. *Муса хәрби промышленность предприятиеләрендә эшләүче яшерен оешма членнарының практик эшчәнлеге турында күбрәк сөйләвемне сорады.* Р.Мостафин. *Тургонов уйга калып торды да әкрен тавыш белән болай диде: – Авыр промышленность үсми торып, ил ныгый, байый алмый.* Х.Камалов

ПРОО́БРАЗ *и. рус* 1) Киләчәк өчен үрнәк, образ

2) Әдәби персонаж тудыруда авторга үрнәк булып хезмәт иткән зат; прототип. *--- М.М.Хәбибуллин Александр Невскийның татар кызына өйләнгән булуын хәбәр итә. Ул Вассо исемле булып, Александр аны Василиса дип йөртә. Галимнәр, рус әкиятләрендәге Василиса Прекраснаяның прообразы нәкъ менә ул булган, дип раслыйлар.* И.Гафаров

ПРОПАГА́НДА *и. лат.* 1) Билгеле бер фикерне, идеяне, карашны, тәгълиматны халыкка җиткерү һәм тирәнтен аңлату. *Хәрбиләр арасындагы пропаганда эшен тагы да киңәйтергә, Советларның һәм большевикларның максатын аңлатырга кирәк.* Р.Мөхәммәдиев. *Әлтәф – райкомның пропаганда бүлеге мөдире, ул спектакль алдыннан лекция сөйләгән иде.* Р.Хәбибуллина. *Татарга каршы пропаганда йогынтысында XVII гасырдан башлап татарга каршы «патриотик фольклор» мәйданга чыга.* Эзләнүләр, уйланулар, табышлар

2) Киң массаларга сәяси характердагы идея тәэсире. *Берлинда сәяси яшерен оешмага катнашуда, совет пропагандасы таратуда гаепләнеп кулга алынды, төрмәгә ябылды.* М.Җәлил. *Гомумән, ул заманда – XX гасырның 1960–1980 елларында – Көнбатышның, рәсми совет пропагандасы телендә әйтсәк, «прогрессив» язучыларына үзенчәлекле мода, аларны романтиклаштыру бар иде!* И.Вәлиуллин. *Татар группасы исә милли хәрәкәттә әлеге комитет линиясен үткәрергә, социал-демократик пропагандаңы татар телендә алып барырга гына хаклы була.* Ватаныбыз тарихы

ПРОПАГА́НДАЛАУ *ф.* Пропаганда алып бару. *Ә шул ук вакытта аның әтисе – мулла – авыл яшьләре арасында ислам динен пропагандалый, дини тәрбия алып бара.* Н.Акмал. *Ул татар халкы яшәгән бөтен республика, край, өлкәләрне йөреп чыкты, татар әдәбиятын пропагандалауга үзеннән гаять зур өлеш кертте.* Җ.Дәрзаман. *Анда үлән белән дәвалауны пропагандалаган фитотерапия белгечләренең һәм им-томчыларның гына түгел, рәсми медицинаның күренекле белгечләренең --- бик файдалы тәкъдимнәре, киңәшләре басыла.* Татарстан яшьләре

Пропагандалап йөрү Озак вакытлар дәвамында пропагандалау белән шөгыльләнү. *– Владимир Ильич авырый, Солтангалиев ипташ, – диде Сталин. – Ә син аның саташып язган нәрсәләрен «туземный» коммунистлар арасында пропагандалап йөрисең.* Р.Мөхәммәдиев

Пропагандалап килү Күптәннән пропагандалау белән шөгыльләнү

Пропагандалап тору Даими яки әледән-әле пропагандалау

Пропагандалый башлау Пропагандаларга тотыну

ПРОПАГА́НДАЛАУЧЫ *и. к.* **пропагандист**. *Марксистик тәгълиматны пропагандалаучы әдип, кеше бәхетле тормышны үз куллары белән булдырырга, аның өчен көрәшергә тиеш, фикерен һәрвакыт алга сөрде.* Р.Рахман. *--- хәзерге заман органик химиясенә нигез салучы күренекле химик Россиядә рациональ умартачылыкны пропагандалаучы да булган.* Фәнни Татарстан. *Туган җиреннән читтә яшәсә дә, ул һәрвакыт татар җырларын пропагандалаучы, халкыбыз моңнарына тугрылыклы булып кала белде.* Ватаным Татарстан

ПРОПАГА́НДАЧЫ *и. к.* **пропагандист**. *Хәрәкәтләре берлә ул [Нәлхас паша] җәнүб (көньяк) мәмләкәтләрендә бик күп очрый торган кызу бер пропагандачы кебек иде.* Х.Миңнегулов

ПРОПАГАНДИСТ *и. рус* 1) Берәр фикерне, идеяне, тәгълиматны пропагандалаучы кеше. *Ул елларда аны хөрмәтләп «Бөтенсоюз старостасы» дип тә, «Партиянең иң талантлы пропагандисты» дип тә йөртәләр иде.* Г.Бәширов. *Мөхәммәтулла Шәрифуллин --- үз дәверенең ялкынлы пропагандисты, ораторы да иде.* Э.Шәрифуллина. *1943 елның май башында 25 татар солдатын татар эмигранты Яушев заводында эшләргә Познаньга җибәрәләр. Июльдә мине дә шунда пропагандист итеп җибәрергә булдылар.* Р.Мостафин

2) *тар.* Лекция яки әңгәмәләрдә партия карарларын аңлатучы, сәяси түгәрәкләргә җитәкчелек итүче марксистик-ленинчыл партия әгъзасы. *Андый мәсьәлә турында Фәтхи ашыгып язса, аның нинди коммунист, нинди организатор һәм нинди пропагандист булуы мөмкин?!* Ш.Камал

ПРОПАГАНДИСТЛЫК *и.* Пропагандист булу; пропагандист эше. *---көннәр үтү белән Назимов бер нәрсәне ачыграк аңлый барды: Бруно яшерен оешма белән бәйләнештә булса да, аның бөтен эше шул пропагандистлык белән чикләнә, ул Назимовка бернәрсә дә куша да, йөкли дә алмый.* Г.Әпсәләмов. *Газетада чыккан барлык сәяси, пропагандистлык, тарихи һәм дини мәкаләләр шушы өч кеше тарафыннан язылды.* Р.Мостафин

ПРОПАН *и. нем. хим.* Ягулык итеп кулланыла торган иссез органик кушылма (туендырылган углеводород). *Аның Әлмәттә нефтьчеләр белән*

очрашу мәҗлесендә: «Пропан, бутан... Хәсән Туфан», – дип шаяртканын Гариф Ахунов та еш кына көлеп искә ала иде. Р.Әхмәтҗан. *Углеводородлы чимал базары индивидуаль катнашмалардан (анда күбрәк газсыман чималлар: этан, пропан, бутан өстенлек итә) һәм шулай ук сыек углеводородларның катлаулы катнашмаларыннан тора.* Химия

ПРОПЕДЕ́ВТИКА *и. гр.* Берәр фәннең кыскача башлангыч, кереш курсы. *Әбүбәкер Гәрәй улы Терегулов --- медицина институтында эчке авырулар пропедевтикасы кафедрасы мөдире [булып] эшли.* Социалистик Татарстан

ПРОПЕ́ЛЛЕР *и. лат.* Самолёт, аэрочана, глиссер һ.б.ш.ны хәрәкәткә китерә торган винт. *Һавада «буш чоңгыллар» бар, самолёт ул урында төшеп-төшеп китә: пропеллерга җегәр юк.* Ш.Галиев. *Бер кулына яшел капчыгын тоткан, икенче кулын пропеллер кебек һавада болгый-болгый элдерә.* Х.Камалов. *Нинди пропеллер ул, һич туктауны белми... Әллә мотор шаулыймы?* Г.Кашшаф

ПРОПИЛЕН *и. инг. хим.* Нефть эшкәртүдә бүленеп чыккан һәм техникада файдаланыла торган органик кушылма, төссез янучан газ. *Пропилен заводы булачак урында урман кискәннәр.* Язмышлар яңарганда. *Нефть эшкәртүдә чыккан газдан да этилен, пропилен һәм башка полимерлар җитештерелә.* Төзү материаллары

ПРОПИ́СКА *и. рус* Кемнең дә булса даими торак урынында теркәлү акты; шул хакта паспортка язылган адрес. *Ленинград пропискасы сугылган паспорты белән башкалада Тоглар кунакханәдән кунакханәгә күчеп йөри дә ала.* Р.Мирхәйдәров. *Ул, прописка кереп, эшкә урнашырга өлгергән, аягы да төзәлеп килә.* А.Әхмәтгалиева. *Кирянов Арча кыры тарафларына бөтенләй йөрмәс була, пропискадан төшә.* Ф.Вәлиәхмәтов

ПРО́ПОЛИС *и. гр. а.х.* Умарта кортлары ачылып килгән бөреләрдән җыеп, умартаның эченә, ярыкларына, рам кырыйларына сылый торган, сумалага бай хуш исле антибактериаль матдә; умарта корты җилеме; тома балавыз. *Гомер буена кулымнан прополис исе китмәде.* С.Ибраһимова. *– Кортлар өчен зур ярыкның кирәге юк, – диде Гыйльми. – Шуңа күрә кортлар аны, бал урлаучы бөҗәкләр кермәсен өчен, прополис белән сылап кечерәйткәннәр.* Ф.Зыятдинов. *Бал, кәрәздән тыш, ана кортлар, бал кортлары, прополис һәм бал икмәге җитештерелә.* Татар балы

ПРОПОРЦИОНАЛЬ *с.* 1) Кайсы да булса бер предметның икенче зурлыкка карата функциональ бәйлелеге. *Бер өчпочмакның өч ягы икенче – аңа караганда кечерәк өчпочмакның өч ягына пропорциональ.* Ж.Тәрҗеманов

2) Пропорцияләре дөрес булган; төгәл туры килгән. *Аның [Айгөлнең] чибәрлегенә сокланып туярлык түгел иде. Аңарда дөрес булмаган, пропорциональ булмаган бер генә әгъза да, бер генә сызык та юк иде.* З.Хәким. *Пропорциональ, төзек формалар... – болар барысы да Андрей Боголюбский заманасындагы Владимир-Суздаль архитектурасын Урта гасырлар Европа төзелеш сәнгатенең зур хәзинәсенә әверелдерә.* И.Гафаров. *Гаиләдәге бал кортларының сыйфаты үзгәрү гаиләнең көченә туры пропорциональ рәвештә арта.* Татар балы

3) *мат.* Бер зурлыкның кыйммәте зураюга (кечерәюгә) карап, икенче зурлыкның кыйммәте шулкадәр зурая (кечерәя) торган. *Вакытлар узу белән, мода үзгәрә төшә. Ә күлмәк итәкләре кыскара бара. Монда без кире пропорциональ зурлык дигән математик төшенчәгә килеп төртеләбез.* Р.Батулла

4) Пропорцияләрне, һәр тармакның үзара тигез бәйләнешен сайлауга нигезләнгән. *Думаларга халыктан вәкил сайлау һәр халыкның санына пропорциональ --- система берлән булган.* Х.Ямашев. *Халык хуҗалыгының пропорциональ үсеше*

ПРОПОРЦИОНАЛЬЛЕК *и.* 1) Пропорциональ булу; пропорцияләлек. *Ул сайлап алган модельләрдә ачык беленеп торган сызыклар, тел-теш тидергесез форма, пропорциональлек өстенлек итә.* Ватаным Татарстан. *Бу күрсәткечкә дә аңлатманы кире пропорциональлек законалыгы китереп чыгара, ягъни түләүләр арта, димәк, эшмәкәрләр саны кими бара.* Шәһри Казан

2) *мат.* Пропорциональ рәвештә үзгәрә торган зурлыклар арасындагы үзара бәйлелек. *F көче нинди чикләрдә үзгәргәндә, F көченнән чыбыкның озынаюы бәйлелеге туры пропорциональлек икәнен күрсәтегез.* Алгебра. *Пропорциональлек коэффициенты. Кире пропорциональлек*

ПРОПО́РЦИЯ *и. лат.* 1) *мат.* Ике чагыштырманың үзара тигезлеге. *Квадрат тамыр алу, пропорция төзү ише нәрсәләрне дә күңелдән генә исәпли ала ул.* А.Гыймадиев. *Арифметик пропорция. Геометрик пропорция. Өзлексез пропорция*

2) Кисәкләрнең, өлешләрнең үзара чагыштырма бәйләнеше. *Мондый төзелешләрдә скульптура таләпләре үтәлми, әмма алар үзләренең пропорцияләре һәм сызыкларының аныклыгы белән таң калдыралар.* Урта гасырлар тарихы. *Төрле төсләр комбинациясен кулланып, --- бүлмәләрнең зурлыгы һәм пропорцияләренең төрлечә күренүен китереп чыгарырга, аларның яктыртылышын да яхшыртырга була.* Тигез гомер итегез!

3) Нинди дә булса әйбернең аерым өлешләре, кисәкләре арасындагы микъдар бәйләнеше. *Хәмиди аганы тәкитәк кафедра бүлмәсенә эләргә туры килер; аныкы кече булса, пропорция бозылыр дип, аның портретын да Тукайныкы чаклы итеп ясатырга булды.* Х.Сарьян. *Табигатьтә төп төсләр – зәңгәр, яшел, кызыл. Калганнары шулар пропорциясеннән килеп чыга.* Ә.Баян. *Рәссамнар өчен пространство һәм пропорцияне үтәли «күрү» ничек мөһим булса, шагыйрь өчен Сүзнең куәтен һәм мәгънәви матурлыгын тоя алу – иң кирәк зарурлык.* Р.Аймәт

ПРОПО́РЦИЯЛЕ *с. к.* **пропорциональ** (*1, 3 мәгъ.*). *Болгар төзүчеләре геометрик бәйләнештә торган берничә үлчәм кулланып, булачак корылманың геометрик төзек, пропорцияле, гармонияле булуына ирешкәннәр.* Эзләнүләр, уйланулар, табышлар. *Исәпләгечләр тулысынча куйдырылган йортларда*

яшәүчеләр электр энергиясе өчен исәпләгеч күрсәткече буенча һәм, үз өлешенә пропорцияле рәвештә, гомуми йорт ихтыяҗлары өчен тотылганына да түли. Шәһри Казан

ПРОПО́РЦИЯЛЕЛЕК *и. к.* **пропорциональлек**. *«Матурлык өчен өч сыйфат хас, – ди ул. – Беренчедән, бөтенлек яки камиллек ---. Икенчедән, пропорциялелек яки аһәңдәшлек булырга тиеш һәм, ниһаять, ачыклык ---».* К.Гыйззәтов

ПРО́ПУСК *и. рус* 1) Берәр урынга керү яки чыгу өчен документ, рәсми таныклык. *Зәйтүнәнең кемлеген аңлап җиткермәсә дә, пропуск яздырырга вәгъдә итте.* М.Маликова. *Госпитальгә баргач, Венераны Илдар янына бик озак кертмәделәр. --- Пропусклар бирә торган хатын: – Сез авыруның кеме соң? – дип сорады.* Р.Хәбибуллина. *--- мин сезне махсус пропусклар, радиация объектларына керү хокукы бирә торган документларга ябыштыру өчен фоторәсемгә төшерермен ---.* Р.Мирхәйдәров

2) *к.* **пароль**. *Шәмси, пропускны әйтеп, часовойдан дивизия штабына юл сорады.* Г.Бәширов. *[Часовойны] әле генә алыштырдылар. Пропускларын да белдем – «Прага».* Ә.Айдар

ПРОРАБ *и. рус* Төзелеш белән турыдан-туры җитәкчелек итүче. – *Сез монда, апайлар, нефтьчеләр өчен яңа шәһәр салачаксыз, – диде аларга прораб.* Г.Әпсәләмов. *Хатын --- прорабка күрсәтмә-боерыклар бирмәде, проект кулыгызда, үзегез чамалап эшләгез, диде.* Н.Гыйматдинова. *Флүр Сәхбиевич та үзенең прораб икәнен һәм хәзерге вакытта нинди объект коруын бик озынга сузмыйча, --- әйтеп үтте.* Р.Кәрами

ПРОРАБЛЫК *и.* Прораб булу, прораб хезмәте. *Бакчаның бер почмагында прораблык участогы будкасы.* Ә.Баян. *Бер ел дигәндә, ул гади мастердан прораблыкка, аннары төзелеш идарәсе бүлекчәсе башлыгына кадәр күтәрелә ---.* Р.Мирхәйдәров

ПРОРЕ́КТОР *и. лат.* Ректор урынбасары. *Комиссия председателе, проректор Әмин Айбулатов һәр кандидатурага бәйнә-бәйнә характеристика бирә башлады.* Х.Сарьян. *Институтның проректоры, Мәскәүдә вакытта ВАКка кереп, Маратның диссертациясе расланганны белеп кайткан икән.* М.Мәһдиев. *Янында утырган университет проректоры язмача килгән сорауларны укыган арада, Әмир Әхмәдиев үзенә игътибарлы күзләрнең иясе турында уйланып алырга өлгерә.* Т.Галиуллин

ПРОСПЕКТ I *и. лат.* Шәһәр җирендә киң һәм туры озын урам. *Метро поезды, безне Маркс проспекты станциясендә калдырып, җир тишегенә чумып югалды.* М.Юныс. *Киң проспект салу өчен, бу урамны сүтәргә кирәклеген һәркем аңлый.* А.Хәсәнов. *Ашыгуымны да онытып, Җиңү проспекты метро станциясе ишек төбендә аз гына ышыкланып торырга булдым.* Р.Фәйзуллина

ПРОСПЕКТ II *и. лат.* 1) Басылып чыга торган китап-журналның җентекле планы, программасы, кыскача эчтәлеге. *Һәр укытучыдан гыйльми эшләренең проспектын яздырып алды.* Х.Сарьян. *Сәгать өчтә галим-голәма гомумән кыза, --- проспектлар карау, диссертациягә отзывлар язу – барысы да шушы сәгатьләрдә сөйләшенә.* М.Мәһдиев. *Энциклопедик басмаларны әзерләү барышында лөгатьлек – булачак хезмәтнең бик күп үзенчәлекләре, төзелеше чагылган проспект, басманың тулаем системасын һәм регламентын билгеләүче документ дип әйтергә мөмкин.* Милли нәшрият һәм китап редакторы

2) Сатыласы товар һәм күрсәтеләсе хезмәтләргә күзәтү ясау һәм аларны сатып алу ысуллары язылган реклама характерындагы белешмәлек, каталог. *Факслардан, төрле проспектлардан, чагыштырулар, валюта курсларыннан, яңа технологияләрдән һәм моңарчы миңа билгеле булмаган җиһазлардан, җайланмалардан ардым.* Т.Кәримов. *Туристлар өчен --- чыгарылган проспектта аның [Солтан Санҗар кабере һәйкәле] турында тикшерелә торган мәсьәләгә кагылышлы шундый мәгълүмат бар.* Татар миссиясе: Татар язмышына эзотерик анализ

ПРОСТА́ТА *и. лат. анат.* Ир-атның һәм ата җенесле имезүчеләрнең мәни составына кергән сыекча бүлеп чыгара торган бизе

ПРОСТАТИТ *и. лат. мед.* Простата ялкынсынуыннан гыйбарәт авыру. *Халык табибы Алмаз Зариповка күбрәк --- ир-атлардагы җенси көчсезлек, простатит, аденома кебек чирләр белән мөрәҗәгать итәләр.* Ирек мәйданы

ПРОСТИТУ́ТКА *и. рус сөйл.* Проституция белән шөгыльләнүче хатын-кыз; фахишә. *Хайлыйм, хайлыйм хайларга, без керештек байларга. Сторожлыкка ялландык Чәйдәш абзыкайларга. Яшенче, дип әрлибез, доносчы, дип хурлыйбыз; Проститутка Мәрьям белән парлап торып җырлыйбыз.* Г.Тукай. *Шулай проституткаларныкына капма-каршы ысул белән акча эшләүчеләрне «наёмщик» диләр.* З.Фәйзи. *– Аңлыйм тел төбегезне, – дип бүлдерде аны Мөнирә. – Шулай була торып та, ничек проститутка, ягъни профессиональ тәтәй булдыгыз, дип сорамакчы сез.* А.Хәсәнов

ПРОСТИТУ́ЦИЯ *и. лат.* Акча табу максаты белән, күпчелек очракта хатын-кызларның, сирәгрәк – ирегетләрнең үз тәннәрен башка кешеләргә җенси ләззәт алу өчен сатуы; фәхешлек. *Безнең көннәрдәге сугышлар да, наркомания һәм проституция кебек үк, бизнесның иң төшемле, акчалы, файдалы формалары гына...* Ф.Урманче. *Акча, акча дип, сәхнәне проституция юлына бастырырга телисез икән, әйдәгез, бөтенебез дә чишеник алайса.* А.Әхмәтгалиева

ПРОСТРА́НСТВО *и. рус* 1) *физ.* Чиксез киңлек (бөтен үлчәнешләрдә, юнәлешләрдә). *Җирнең үзендә үк кешелеккә параллель икенче төрле яшәеш, күп үлчәмле киңлекләр (пространстволар) --- бар икән.* Ә.Баян. *«Ачык пространство»га чыккач, җирнең тарту көчен әз генә булса да сизеп буламы, әй?* Н.Хәсәнов. *Без --- пространствода кая теләсәк, шунда иректе күченеп йөри алабыз.* Р.Фәизов

2) *филос.* Туктаусыз үсештәге материя яшәешенең киңлек һәм күләм белән характерлана торган гомуми төп объектив формаларының берсе (вакыт белән бергә). *Кеше өч үлчәм кысаларында*

фикер йөртә: пространство, вакыт, материя. Р.Хәкимов. *Вакыт һәм пространство мөнәсәбәтләрен еш кына хронотоп дип тә йөртәләр.* Х.Миңнегулов

3) Җир өслегенең чиге күренми торган зур кишәрлеге; нәрсәнең дә булса зур мәйданы. *Без иксез-чиксез Россия белән бер пространствода яшәргә дучар ителгәнбез.* Р.Миңнуллин. *Зур пространстволар (дәүләт биләмәләре) киңәйгән саен, иҗтимагый аңда зуррак – төрле аллаларга сыенучы кавемнәрнең уртак территориясе өчен җаваплылык тәрбияләү ихтыяҗы туа ---.* Татар миссиясе: Татар язмышына эзотерик анализ

4) Берәр нәрсә арасындагы бушлык; нәрсәне дә булса сыйдыра ала торган аралык. *Бу хәлләрнең барысы да нинди дер бер йомык, төгәл билгеләнгән пространствода булды.* Т.Кәримов. *Тамыр һәм тамырчалар үлмәсен өчен, үсемлек кислородны яфраклар аша йотып, күзәнәкара пространство аша күчерергә җайлашкан.* Татарстанның үсемлекләр һәм хайваннар дөньясы

ПРОСТЫНЯ *и. рус* Урын-җиргә, ятакка җәелә торган, шулай ук башка максатларда файдаланыла торган озын, зур һәм киң тукыма кисәге. *Бу беренче бәладән мине врачлык сизгерлегем коткарды: авыруны коендырырга, юеш простыня белән төреп тотарга куштым ---.* Г.Кутуй. *[Авыл яшьләре] Кайберләре инде өйләнешеп беткәннәр, дүрт кешелек бүлмәләрдә, уртага простыня корып, икешәр квартира ясаганнар.* М.Мәһдиев. *Илгизәр ялт кына торып басмакчы була да, ыштансыз икәнен белгәч, простыня белән алдын каплый.* Ф.Яруллин

ПРОСЦЕ́НИУМ *и. гр. театр* Сәхнәнең портал алдында чыгып тора торган, тамашачыларга якын өлеше. *Бөркет белән [Нелли] алга, просцениумга чыгалар һәм бии-бии сөйләшәләр.* Р.Ишморат. *Әгәр режиссёр аларны [өстәмә геройларны] просцениум булышчылары буларак күренешләрне бәйләү өчен генә калдырса, аңлашылыр иде. Ә болай – булса ярый, булмаса ярый кебек киряксез эш.* Сәхнә

ПРОТЕЖЕ *и. фр. кит.* Кемнең дә булса протекциясеннән файдаланучы, кемнең дә булса даими химаясендә булган кеше. *Протеже – продюсерның кеше итәсе яшь таланты.* Татарстан яшьләре

ПРОТЕЗ *и. гр.* **1.** Гәүдәнең кайсы да булса өлеше формасында төрле материалдан ясалган яки тәннең югалткан әгъзасын кабатлый торган җайланма; тәннең ясалма өлеше. *Барысы да – йөри торган яралылар. Кайсының ярасы төзәлеп беткән, протез көтә. Кайсына икенче операция ясарга тиешләр.* Х.Камалов. *Каршылык күрсәтү кая, аягымдагы протезны да ныгытырга өлгерә алмый калдым.* Р.Мөхәммәдиев. *Дәү әтинең аягында Протезы шыгырдаса, Куркып китәм: Протез түгел, Әйтерсең җир ыңгыраша.* Х.Халиков

2. *с. мәгъ.* Өзелгән яки операция ярдәмендә киселгән аяк, кул, төшкән теш һ.б. деформацияләнгән органнар урынына ясалган, үзенеке түгел, ясалма. *[Картның] Ап-ак протез тешләре белән протез аңкау чылтырап асфальтка тәгәрәде.* Р.Батулла. *Чиләбе солдаты терелер, савыгыр, аңа протез аяклар куярлар, өйләнер, балалары, оныклары булыр.* К.Сатиев. *Сәфәргали абзый кырынды, протез тешен марганцовкалы суда чайкатып кабып, киемнәренең әйбәт дигәннәрен генә киенде дә чыгып китте.* З.Фәйзи

ПРОТЕ́ЗА *и. гр. лингв.* Ике яки берничә тартыкка башланган сүзләр башында – әйтелештә сузык аваз, сузыкка башланганнарда тартык аваз өстәлү күренеше (мәс., ***ө**стәл, **э**шләпә,* диал. ***й**өзлегү* – әд. *өзлегү*). *Кимчелек, хаталарның кайберләре тора-бара тискәре иҗтимагый күренешкә әверелә. Мәсәлән, протеза, эпитеза --- күренешләрендә нормалардан тайпылу аеруча ешайды.* И.Низамов. *Алынмаларда оригиналь сүзгә татарча әйтелештә өстәмә сузыклар (протеза, эпитеза) ялгана.* Р.Әхмәтьянов. *Рус-европа алынмаларында протеза яки сүз башына аваз өстәлү күренеше характерлы.* Татар халык мәкальләренең лексикасы

ПРОТЕЗЛА́У *ф.* Протез кую, протез белән тәэмин итү. *Биопыяланы терсәк һәм тез буыннарын протезлау, шулай ук бит-теш казналыгына операцияләр ясауда файдаланырга була.* Татарстан яшьләре. *Тыл хезмәткәрләренә ай саен 300 сум акча бирү һәм теш протезлау, колак аппараты чыгымнарын каплау каралган.* Шәһри Казан

Протезлап бетерү Барысын да протезлау; протезлауны тәмамлау

Протезлый башлау Протезлау эшенә керешү

ПРОТЕЗЧЫ *и.* Протезлар ясаучы белгеч. *Һәрбер район сырхауханәсендә теш табиблары, протезчылар бар.* Татарстан яшьләре

ПРОТЕИД *и. гр. биол.* Гади аксым һәм аксым булмаган матдә кушылмасыннан торган катлаулы аксым. *Тиешле сигез сәгать урынына алты сәгать кенә йоклаучы ирләрнең канында --- шикәр диабеты китереп чыгара торган матдәләр ясалу арта. Болар – холестерин, бета һәм липо протеидлар.* Татарстан яшьләре

ПРОТЕИН *и. гр. биол.* Аминокислоталарның калдыкларыннан гына торган гади аксым. *Ураза тоту организмда протеин алмашу процессына тискәре тәэсир итми.* Инсан һәм дин. *Хан үләне --- таулы төбәкләрдә һәм төньякларда үсә. Бу үсемлектә каротин, протеин һәм майлар күп.* Ботаника. *Тикшеренүләр күрсәткәнчә, илдә яшәүчеләр организмына протеин дигән матдә генә дә 26–35 процентка азрак керә.* Ватаным Татарстан

ПРОТЕ́КТОР *и. лат.* 1) *иск. кит.* Яклаучы, саклаучы

2) *тар.* Аерым шартларда тәхет варисы балигъ булганчы дәүләт белән идарә итүне үз өстенә алган кеше; регент. *Сорыйбыз без чын күңелдән, галиҗәнап, Ил турында кайгыртуны, падишалык – Хакимлекне алмассыңмы үз кулыңа? Протектор, урынбасар булып түгел – Васый булып, өлкән абза булып түгел, Патшалыкка каны, жаны, тумышы да, Сафлыгы да шөбһәсез бер варис булып!* У.Шекспир

3) Протекторат урнаштырган дәүләт

4) *махс.* Пневматик шинаның тышында шина белән юлның тоташуын арттыра торган сырлы калын резина

катламы. --- *Сафуанов шоссе юлдан урманга каерып кергән җиңел машина эзләренә тап булган иде. Көпчәкләр арасы, протектор сырлары һәм кайбер башка билгеләр «Москвич-412»гә туры килә.* А.Тимергалин. *Т-150 тракторының протекторы яңа чыгарылган «Беларусь»ныкына охшаган икән.* Татарстан яшьләре

5) *тех.* Төрле җайланмаларны яки аларның аерым өлешләрен механик, химик һ.б.ш. тәэсирдән саклый торган катлам. *Цинк белән капланган тимерне әче тирәлектә коррозиядән саклау өчен, протектор сыйфатында нинди металл кулланып була?* Гомуми химия

ПРОТЕКТОРАТ *и. лат.* 1) Бер дәүләтнең, эчке сәясәттә үзенең бәйсезлеген саклаган хәлдә, тышкы сәясәттә вәкаләтләрен икенче дәүләткә тапшырып, шул дәүләтнең гадәттә хәрби яклавы астында булуыннан гыйбарәт дәүләтара мөнәсәбәтләр формасы. *Бу заманнарда Казан белән Мәскәү арасында берничә сугыш була, Мәскәү татар дәүләтенә каршы гаять активлана ---. Һәм бу хәл 1487–1521 елларда Казан ханлыгының Мәскәү протекторатына калуы белән бетә.* Ф.Бәйрәмова. *Төреклəр аеруча Урта гасыр дәвере, Алтын Урда чорлары белән һәм аннан соңгы татар ханлыклары тарихы белән --- кызыксына. Моны аңларга да була, чөнки нәкъ менә шул дәверләрдә Кырым ханлыгы Төркиянең протекторатында була.* Татарстан яшьләре

2) Шундый яклаудан файдаланган дәүләт

ПРОТЕКЦИОНИЗМ *и. лат.* 1) *икът.* Дәүләтнең милли икътисадны чит ил конкуренциясеннән саклауга юнәлтелгән сәясәте. *Муса Акъегет протекционизм сәясәте тарафдары була.* Ф.Газизуллин. *«Өлешлəп демократия», --- дәүләт һәм базар структураларын кушып үстерү, ришвәтчелек, протекционизм, криминал, мафия – әлеге система шуларга гына сәләтле.* Т.Кәримов

2) Хезмәт урынына кешеләрне сәләт һәм эш башкару сыйфатларына карап түгел, ә танышлык, протекция буенча алу күренеше. *Анда протекционизмга урын юк, аның каршында барысы да тигез, туган-тумачалык та, югарыдагылар белән әшнәлек тә, иске хезмәтләрегез дә коткарып кала алмас.* Р.Мирхәйдәров. *Кадрлар протекционизмы күренешенең коррупциянең бер төре булуы билгеле.* Кызыл таң

ПРОТЕ́КЦИЯ *и. лат.* Кемнең дә булса эшкә урнашуына, хезмәт баскычыннан күтәрелүенә зур йогынтылы, абруйлы кешеләрнең ярдәм итүе, булышуы, аны яклавы. *Бу җирләргә кешене никадәр акча бирсә дә кертмиләр. Бунда керү өчен я падишаһтан ирадәи мәхсусә яхуд да зур бер протекция булырга кирәк.* Г.Камал. *[Марат:] Шуны да эшли алмагач, синең орденлы абый булуыңнан миңа ни файда?! [Шәйхаттар:] Орденны протекция өчен бирмиләр.* Т.Гыйззәт. *Мин ни, ялына белмим, протекция эзләмим, кирәк кешегә яраргa тырышмыйм.* Ә.Еники

ПРОТЕСТ *и. лат.* 1) Берәр нәрсәгә катгый рәвештә каршы төшү, нәрсәгә дә булса кискен ризасызлык белдерү. *Ишәк-прокурор иске законга Әзерләнсен протест ясарга: Каршы килгәннәрне кирәк булыр Террорист дип тотып асарга!* Х.Бәдигый. *Матурлыкка карата вәхшилек чорының кайбер гадәтләрен хәтерләткән тенденцияләр төсмерләнә икән, шигърият аңа каршы протест күтәрергә бурычлы да, хаклы да.* М.Гайнетдинов. *Уйлап баксаң, сәләмә киенеп, кулга арматур таягы тотып сугышып йөрү үзе үк социаль протест бит инде ул.* Р.Зәйдулла

2) Берәр дәүләт, оешма яки рәсми затның башка дәүләт, оешма яки рәсми затның нинди дә булса карарына, боерыгына яки эшенә рәсми ризасызлык белдерүе. *Узган Рамазан бәйрәмендә большевикларның ислам диненә каршы иткән золымларына каршы игълан ителгән протест та шул бөек затның имзасы берлә чыкты.* Г.Исхакый. *[Кайбер иптәшләр] Крыймовның --- иҗатына, иҗат юлына аз гына бәһа бирмәстән, аны бөтенләй эштән чыгарып, табак-табак протест, карар чыгаралар.* М.Җәлил. *Россия Думасы кабул иткән законнарга безнекеләрне тәңгәл китерәбез дип, Республика Прокуроры протест белдерә ---.* Т.Миңнуллин

3) *фин.* Вексель буенча бурыч тиешле срогында түләнмәү турында рәсми раслау. *Кырык мең сумлык вексель протестка керергә тора.* Г.Ибраһимов. *Срогында түләмәсәң, вексельнең протест дигән бәлагә элəгүе бар.* Ш.Мөхәммәдев

4) *махс.* Диңгез корабле капитанының суднода авария булу яки йөкнең бозылуы турында протоколга теркәп рәсми белдерүе. *Дүртенче трюмга төшү белән, аягым юешлеккә батты. --- Протест язмыйча булмас. Күпме юешләнде икән, буйдан-буйга әйләнеп чыгыйм әле.* М.Юныс

ПРОТЕСТАНТ *и. лат.* 1) Христиан диненең протестантлык агымының тарафдары. *Европада католикларга яки протестантларга, Төркиядә мөселманнарга, Кытайда буддачыларга карата да шул ук хәл.* М.Галәү. *[Голландиянең] Төньягында протестантлар, ә көньягында күбрәк католиклар яши.* Татарстан яшьләре

2) *к.* **протестчы**

ПРОТЕСТАНТИЗМ *и. лат. к.* **протестантлык**. *Без европачыл протестантизм мисалында, иҗтимагый үзгәрешләр аң, рухи кыйммәтләр өлкәсеннән башлана, дигән концепцияне алга сөргән М.Вебер карашын хуплыйбыз ---.* А.Юзиев. *Анда гына түгел, башка байтак халыкларда, бигрәк тә протестантизм таралган илләрдә, оят төшенчәсенең универсаль, бик тә утемле, тормышчан булуы билгеле.* З.Закиров

ПРОТЕСТАНТЛЫК *и.* Христиан диненең XVI гасырдагы реформация чорында католиклыкка протест йөзеннән барлыкка килгән, төрле дини тәгълиматларны берләштергән (православие һәм католиклык белән берәрттән) төп юнәлешләреннән берсе. *Католицизм нигездә бер агымнан торса, православие белән протестантлык һәркайсы берничә агымнан тора.* К.Гыйзәтов. *Шунда христиан дине тармаклары – православие, католиклык, протестантлык диннәренең аерма үзенчәлекләре нәрсәдән гыйбарәт*

икәнлеген ачыклау теләген тормышка ашырдым. Ватаным Татарстан. *Мәгълүм булуынча, православие үзе, католицизм һәм протестантлык белән берәттән, христианлыктагы бер юнәлеш кенә*. Кызыл таң

ПРОТЕ́СТ ИТҮ *ф. иск*. 1) Ризасызлык белдерү, протест (*1 мәгъ*.) белдерү. *Матбугат протест итте*. Г.Исхакый

2) *махс*. Вексельгә протест (*3 мәгъ*.) ясау

ПРОТЕ́СТ КЫЛУ *ф. иск*. *к.* **протест итү**. *Әхмәров вексельләренең артына да нотариус печате басылып, протест кылынды*. Ш.Мөхәммәдев

ПРОТЕСТЧЫ *и. кит*. Протест, ризасызлык белдерүче. *Протестчылар Путинга: «Өченче мөддәтне – төрмәдә!» – дип кычкырды*. Н.Акмал

ПРОТИВОГАЗ *и. рус* Кешенең сулыш юлларын, күзләрен, битен агулы һәм радиоактив матдәләрдән, бактерия һәм вируслардан саклау приборы. *Хәзер Әлфия өстендә яшел гимнастёрка, башында кечкенә генә пилотка, иңенә киң каешлы противогаз элгән иде*. Г.Бәширов. *Солдат кесәләрендә, планшетларда, противогаз сумкаларында язылып бетмәгән никадәр хатлар йөри иде ул елларда!* Г.Әпсәләмов. *Иң алда, противогаз киеп, чын винтовканы кулына тоткан Хәкимҗан үзе иде*. М.Мәһдиев

ПРОТОДЬЯ́КОН *и. гр.* Православиедә өлкән дьякон

ПРОТОИЕРЕЙ *и. гр.* Православиедә өлкән рухани, гадәттә зур гыйбадәтханәне җитәкләгән кешегә бирелә торган титул. *Өлкән поп протоиерей Александр атакай, рәхимсез, усал рухани булудан бигрәк, куркак кеше иде*. Т.Нәбиуллин. *1270 елда Мәнгү Тимер түбәндәге указны чыгара: «Русьта берәү дә чиркәүләрне хурларга, митрополитларны һәм аларга буйсындырылган --- протоиерей, иерейларны һ.б. кыерсытырга батырчылык итмәсен»*. И.Гафаров

ПРОТОКОЛ *и. гр.* 1) Факттагы хәлләр, вакыйгалар (җыелыш барышы, суд утырышы һ.б.) теркәлгән рәсми документ; беркетмә. *Х.Туфан: «Гаепләүләрне куәтли торган җаваплары гына протоколга яза иделәр. Үзләренә кулай килмәгән сорау-җаваплар булганда, протоколны бөтенләй язмыйлар иде», – дип күрсәтә*. М.Гайнетдинов. *Егеттән хәзер үк сорау алырга һәм протокол төзергә кирәк иде*. Ф.Вәлиәхмәтов

2) Административ хокук бозу теркәлгән һәм хокук бозучыны административ җаваплылыкка тартырга нигез булып тора торган административ-процессуаль документ. *Тәртип сакчылары килеп кергәндә, Сәях хатынын якалап маташа. Протокол төзегәннәр*. Х.Камалов. *Кавидан сорау ала башлаган иртәдә Усманов аңа узган елгы сорау алган протоколларны тоттырды*. З.Зәйнуллин

3) *махс*. Дәүләтләр арасында язма килешү. *Шушы тырышлыклар нәтиҗәсендә, озонга зыян китерә торган матдәләрне тыю буенча Вена конвенциясе (1985), ә аннан соң Монреаль протоколы (1987) кабул ителде*. Татарстан яшьләре

4) Халыкара мөнәсәбәтләрдә хөкүмәтләр, дипломатик вәкиллекләр һәм аларның хезмәткәрләре тарафыннан саклана, үтәлә торган гомумкабул ителгән кагыйдәләр, традицияләр һәм шартлылыклар җыелмасы. *[Сабир Мансурович] янәшәсендә басып торган ике-өч хатын-кыз да елмайды аңарга кушылып. Протоколда шулай каралган иде, күрәсең*. Р.Мөхәммәдиев. *Протокол тәртибе буенча, ВКП(б) УК секретаре А.Жданов нотыгыннан соң, төп докладны да М.Горький ясый*. Р.Фәйзуллин

5) Алда торган һәм киләчәктә төгәлләштерәсе шартнамәләр, контрактлар, аларны төзү шартлары турында документ. *Күргәзмәне караганнан соң, --- ТРның Транспорт һәм юл хуҗалыгы министрлыгы белән «Уралмашзавод» арасында Татарстанга трамвайлар кайтарту --- турындагы протоколга кул куелды*. Татарстан яшьләре. *Протокол перспективалы берничә проектны, атап әйткәндә, Башкортстанда тире эшкәртү производствосын булдыру проектын гамәлгә ашыруны күз уңында тота*. Кызыл таң

6) *информ*. Ике яки берничә бәйсез компьютер яки процессор арасында мәгълүмат алмашу процедурасын яки форматын регламентлый торган кагыйдәләр җыелмасы

7) *информ*. Компьютердагы кайбер процессларның барышы һәм нәтиҗәләре турында хронологик тәртиптә башкарылган язма

8) *техн*. Кәрәзле элемтә стандарты

ПРОТОН *и. гр. физ.* Барлык атом төшләре составына керә торган бер уңай корылмалы тотрыклы элементар кисәкчек. *Протон белән нейтрон төш көчләре бәйләнешендә гаять дәрәҗәдә тыгыз атом төшен тәшкил итәләр*. И.Әмирханов. *Протонның массасы электрон массасына караганда 1836 тапкырга артыграк булу сәбәпле, протон хәрәкәтсез, ә электрон протон тирәли түгәрәк траектория буенча туктаусыз әйләнә дип исәпләнә*. Физика

ПРОТОНЕ́МА *и. гр. бот*. Мүксыман үсемлекләрнең үсеш фазасы. *Зиготадан субстратта җәелеп үсә торган аз тармаклы бер эре төшле кечкенә үсемлек – протонема үсә*. Ботаника. *Протонема зәгыйфь һәм кыска гомерле*. Ботаника

ПРОТОПЛА́ЗМА *и. гр. биол*. Хайван һәм үсемлек күзәнәкләре эчендәге төп матдә. *Тере күзәнәк тышчадан, протоплазмадан, күзәнәк сыекчасыннан, төштән тора*. Төзү материаллары

ПРОТОТИП *и. гр.* 1) Беренчел үрнәк, прообраз. *Коръәндә яшәеш моделе йорт кебек күзаллана. Алла йорты – мәчет – шушы модельнең җирдәге «прототибы», изге урын*. А.Батталова. *С.А.Соколов «Китап сатылган кибет» җөмләсен мисалга алып, аларны иярченле кушма җөмләләрнең бик борынгыдан килгән архаик төре (прототип) итеп күрсәтә*. Татар халык мәкальләрендә кушма җөмлә синтаксисы

2) *әд*. Авторга әдәби образ тудыру өчен үрнәк булып хезмәт иткән реаль кеше. *Хабул образының үрнәге – прототибы – Лысьва заводы пролетариаты арасында яшәгән бер зимагур металлург иде*. Х.Туфан. *Ләкин әсәрдәге образ белән тормыштагы прототип күп очракта төгәл туры килеп бетми: аерма һәрвакытта була һәм шактый зур да була*. Ә.Еники

ПРОТУБЕРА́НЕЦЛАР *и. лат. күпл. астр*. Кояштан ыргылып чыгып, магнит кырлары аркасында аның өслегендә тоткарланып, чагыштырмача суынып, куерып торган кызган газлар, плазма (*3 мәгъ.*). *Кояш атмосферасындагы таплар, факеллар, протуберанецлар, кабынышлар һ.б.ш. тотрыксыз күренешләр барысы бергә Кояш активлыгы дип атала*. Фән һәм тел

ПРОФ- *рус* 1) Кушма сүзләрдә «профессиональ» мәгънәсендәге беренче кисәк (мәс., *профгигиена, профбелем*)

2) Кушма сүзләрдә «профсоюз» мәгънәсендәге беренче кисәк (мәс., *профбилет, профактив, профҗыелыш*)

ПРОФАН *и. лат.* Берәр өлкәдә бөтенләй мәгълүматы булмаган кеше. *«Яшен» профан, саламторхан вә хаиннәрне үзенең сугуы илә куркыткан шикелле, караңгыда адашып калганнар өчен үзенең яктылыгы илә юллар күрсәтәчәктер.* Г.Тукай. *Сез – медицинага сукыр бер тиенлек файда китермәгән профан.* Т.Миңнуллин. *Хәленнән килсә, агрофирма җирләрен генә түгел, бөтен Татарстанны сатып җибәрергә әзер торган бу профанга исе-акылы китә торган иде аның.* Х.Ибраһимов

ПРОФАНА́ЦИЯ *и. лат. кит.* Берәр нәрсәгә надан, томана, мыскыллы, мәсхәрәле мөнәсәбәт, мөрәҗәгать белән аны бозып күрсәтү, әшәкеләндерү

ПРОФАНЛЫК *и.* Профан булу. *Дәрдемәнднең гавам караш-төшенчәләреннән генә түгел, гадәттә шул ук бу караш-мөнәсәбәте гавам профанлыгы чикләрен үтә алмаган югары катлаудан саналган замандаш-укымышлылар мөмкинлекләреннән дә күпкә өстен.* М.Гайнетдинов

ПРОФАШИСТ *и. рус* Фашизм тарафдары; фашистлар мәнфәгатен яклап эш итүче

ПРОФАШИ́СТИК *с.* Фашизмны яклый торган, фашизм карашларын алга сөргән. *Яшьләр арасында радикаль экстремистик оешмалар --- саны артуы күзәтелә, милләтчел һәм профашистик карашлылар мәсьәләләре актуальләшә бара, дип таный министр.* М.Низаметдинова

ПРОФБЮРО *и. рус* Профсоюз оешмасы бюросы. *Уку елы башлану белән, ректоратка үзем докладной язып бирәм. Профбюродан да комиссия җибәртәм.* Х.Сарьян. *Ул [Идеал] комсомол секретаре да, студсовет рәисе, профбюро члены, культмасса җитәкчесе дә!* М.Шаһимәрдәнов. *Студентлар профбюросы рәисе Илнур Миңнәхмәтов үз эшчәнлегенә кагылышлы докладында төрле яңалыклар ирештерде.* Г.Гаттарова

ПРОФГРУ́ППА *и. рус* Предприятиенең, оешманың беренчел профсоюз оешмасына керә торган төркем

ПРОФГРУППОРГ *и. рус* Профсоюз төркеменең сайлап куелган җитәкчесе, профорг. *Хезмәттәшләре бертавыштан аны профгруппорг итеп сайлый.* Ватаным Татарстан

ПРОФЕССИОНАЛ *и. лат.* 1) Һәвәскәрдән аермалы буларак, нинди дә булса бер эш белән даими рәвештә, төп эше итеп, профессиональ нигездә шөгыльләнүче кеше. *Нишлисең, Матвей кебек профессионалларны безнең арага тартып булмый шул әле.* М.Маликова. *Күбрәк тә, нәтиҗәлерәк тә эшләргә тиеш идек, билгеле. Тик безнең күбебез профессионаллар түгел шул. Тәҗрибә җитми. Яңа өйрәнеп киләбез.* Р.Миңнуллин. *Күреп торам: Смирнов – мал-туар асрауның бөтен нечкәлекләрен үзләштергән чын профессионал.* М.Әмирханов

2) Үз эшенең остасы, үз һөнәрендә, сәнгатендә югары осталыкка ирешкән белгеч. *Профессионал кеше үз эшенең бөтен тармакларын яхшы белергә тиеш.* Р.Фәйзуллин

ПРОФЕССИОНАЛИЗМ *и. рус* 1) Үз профессиясен яхшы белү; профессиональ осталык. *Безнен яшь язучылар еш кына «күпбеләмлек» чире белән, иртә профессионализм белән авырыйлар.* М.Җәлил. *[Гафел:] Матур значок. Ә сез каян белдегез минем значоклар җыйганымны? [Лаббәйкин:] Профессионализм, Гафел Мөфелыч.* Р.Батулла. *Бу коллектив [филармония] өчен сәнгатьне халыкка якынайту, иң күркәм үрнәкләрен пропагандалау, югары профессионализм, көйнең аһәңен тулы саклау, даими эзләнү, иҗади омтылыш хас.* Ф.Хатипов

2) *лингв*. Берәр профессия кешеләре теленә хас булып, шуннан гомумәдәби телгә күчкән сүз яки тәгъбир. *Мөрәҗәгать сүзләре, персонажларның туры сөйләме, профессионализм, жаргон, диалектизм кебек лексик берәмлекләр дә – шәхсилекне, ягъни документальлекне көчәйтү чаралары.* И.Низамов. *Финанс-коммерция өлкәсенә караган күп термин-профессионализмнарның активлашуы турында алда сүз булган иде.* Р.Мөхиярова

ПРОФЕССИОНАЛЛАШУ *ф.* Профессионаллар рәтенә күчү. – *Син бу эшне ташламаска тиеш, тагын да ныграк профессионаллашырга тиешсең, – дип кабатлый торган булды.* Ә.Баян

ПРОФЕССИОНАЛЬ *с*. 1) Профессияләргә бәйле, профессиягә карый торган. *Сәяси партияләр, профессиональ союзлар --- дәүләт эшләрен идарә итүдә дәүләт хакимиятенең сайлаулы органнарындагы үз вәкилләре аша катнашырга хокуклы.* Татарстан Республикасы Конституциясе

2) Профессиясе шушы булган, шушы һөнәр белән генә шөгыльләнгән (кеше тур.). *Шул үзен, мин профессиональ драматургларны, профессиональ артистларны, профессиональ режиссёрларны өйрәтергә тиеш, дип уйлый.* Р.Батулла. *Озын сүзнең кыскасы, моңарчы профессиональ тарихчыларыбыз игътибарыннан читтә калган төбәккә барып җиткән әдип.* Ватаным Татарстан

3) Эшчәнлекнең шушы тармагында профессионал (*1 мәгъ.*) буларак, даими рәвештә эшли торган, үзешчән түгел. *Профессиональ театрыбызга килгәндә, ул, әлбәттә, яшәячәк.* Р.Фәйзуллин. *Үзенең барлыкка килү, оешу, формалашу һәм алга таба үсешендә профессиональ сәнгатьнең барлык төрләре дә халык иҗатына нигезләнә.* Ф.Урманче

4) Профессионаллар (*1 мәгъ.*) тарафыннан тудырылган, башкарылган. *Профессиональ музыканың һәр жанры үзенә хас вазифаларны башкара.* К.Гыйззәтов. *«Бибинур» – югары*

дәрәҗәдәге беренче профессиональ кинофильм. А.Бәдретдинова

5) Профессионалларга хас. *Татарстан законнарын Россия законнары белән тәңгәлләштерүне мин профессиональ күзлектән карап эшләдем.* Р.Вәлиев

ПРОФЕССИОНАЛЬЛӘШҮ *ф.* Профессиональлек дәрәҗәсе күтәрелү, осталыгы арту. *Бер урында таптанып озак тормыйча, шәкертлек чорын сикереп үтеп диярлек профессиональләшә.* Т.Миңнуллин. *8–10 кластарда мин инде «шактый профессиональләшкән артист»ка әверелгән идем.* Р.Батулла

Профессиональләшә бару Торган саен күбрәк профессиональләшү. *Әкренләп кенә булса да, Русия Кораллы Көчләре профессиональләшә бара.* Татарстан яшьләре

Профессиональләшә башлау Професиональлек билгеләре күренү

ПРОФЕССИОНАЛЬЛЕК *и.* 1) Кешенең шөгыльләнгән эше аның профессиясе булу; профессионал булу. *Яшьтән үк иҗат белән җитди рәвештә шөгыльләнә башлаган шагыйрьләр генә --- профессиональлек дәрәҗәсенә ирешәләр.* Н.Гамбәров. *Профессиональлек дәгъвасы белән җырлаган һәвәскәрне мин кабул итә алмыйм.* Р.Батулла

2) Үз һөнәрендә чын белгеч булу, осталык. *Безнең депутатлар арасында, бәлки, профессиональлек җитеп бетми торгандыр.* Т.Миңнуллин. *Законнарны тәрҗемә итү бик тә югары профессиональлек таләп итә.* Р.Миңнуллин. *Элек әдәбият-сәнгать белән шөгыльләнүчеләр профессиональлекнең иң югары баскычына күтәрелгәннәр.* Р.Кәрами

ПРОФЕ́ССИЯ *и. лат.* Махсус белем, әзерлек, күнекмәләр таләп итә һәм, гадәттә, яшәү өчен керем чыганагы булып санала торган хезмәт эшчәнлеге, шөгыль төре. *Кәшфи хәзер җир сөрү һөнәрен генә түгел, өстәмә профессия – речь сөйләү профессиясен дә үзләштерде.* М.Мәһдиев. *Билгеле, актёр профессиясе – бик үзенчәлекле профессия, әмма иң мөһиме: актёр иң беренче нәүбәттә зыялы, белемле кеше булырга тиеш.* М.Сәлимҗанов. *КамАЗ төзелә башлауга, --- йөзләгән профессия кешеләре белән бергә, илнең бөтен почмакларыннан романтик күңелле --- кешеләр дә җыйналды.* Язмышлар яңарганда

ПРОФЕ́ССОР *и. лат.* 1) Югары уку йортларының иң югары квалификацияле укытучыларына яки фәнни тикшеренү институтларында фәнни тикшеренү эшләре белән җитәкчелек иткән галимнәргә бирелә торган гыйльми исем; шул исемгә ия булган кеше. *Коллык чадраларының ертылып ташлануына аз гына вакыт үткән булса да, эшлекле, талантлы --- профессор, эшче, колхозчы хатын-кызлар бездә хәзер искиткеч күп бит.* Г.Кутуй. *Институтны тәмамлар алдыннан, профессор Әбүзәр Таһиров Гөлшәһидәгә ординатурада калырга тәкъдим итте.* Г.Әпсәләмов. *Безнең Караярның һәр укытучысы профессор дәрәҗәсендә.* М.Юныс

2) *күч.* Үз эшенең белгече; бик күп белгән, киң эрудицияле кеше. – *Шул инде «профессор», – диде Фәйрушин. – Укымаган китабы юк. Әллә ниләр белә.* Х.Сарьян. *--- күңелнең иң нечкә кылларын тибрәтә торган бу гамәл дә безнең заманда үзенә бер фәнгә әверелеп, аның «профессор»лары да барлыкка килде бит.* М.Маликова. *Мәхәббәт фәннәре профессоры Әфләтун әфәнде, киңәш биргезче миңа?! Нишлим? Яңа ел мәҗлесенә каян бер чибәр табыйм?* Р.Вәлиев

ПРОФЕ́ССОРЛЫК *и.* Профессор эшчәнлеге, профессор вазифасы. *Профессорлыкка берәр буш урын юкмы?* К.Тинчурин. *Бирсеннәр иде Әлтафига атнасына бер ипи – авыл мичендә пешкән, тегермән ташыдай бер ипи һәм бер кадак шикәр! Әлтафи профессорлыкка имтихан тотар иде.* М.Мәһдиев // Профессор исеме, профессор дәрәҗәсе. – *Галим кеше буласың инде... – диләр. – Фән кандидаты... Аннары профессорлыкка да күп калмый, – диләр.* Шатлыклы кайгы. *1849 елда Г.С.Саблуков Казанга күчеп килә һәм андагы Руханилар академиясендә профессорлык дәрәҗәсенә ирешә.* Бер очрашу – бер гомер

ПРОФЕССУ́РА *и. рус* 1) Профессор вазифасы, дәрәҗәсе. *Г.Толымбайның Мәскәүдәге кызыл профессура институтын тәмамлап, әдәбият профессоры дигән исем алып кайткан еллары иде.* Г.Бәширов. *Ул үзе тырышып-тырмашып профессурага әзерләнә ---.* А.Тимергалин

2) *җый.* Профессорлар. *Ласкала профессурасы яшь, талантлы җырчы Робертиноның нечкә-матур тавышына сокланып, аны шул килеш саклау теләге белән, ата-анасына Робертинога операция ясатырга тәкъдим итәләр.* Р.Батулла. *Шул ук вакытта Г.Баһанов Казан университеты профессурасы белән тыгыз элемтәдә була.* К.Миңнуллин

ПРОФИЛА́КТИК *с.* 1) Профилактикага караган; профилактикага хас; профилактика максаты белән үткәрелә торган. *Сез миңа, ни өчен фермада зоогигиена эшләрен карамыйсыз, ни өчен профилактик чараларны тиешенчә юлга салмыйсыз, дисез.* Т.Гыйззәт. *--- мин «профилактик прививкалар бары тик дәвалау учреждениеләрендә, авыл җирләрендә – медпунктларда ясалырга тиеш» дигән инструкцияне бозdым.* Г.Галиев. *Балалар бакчасы, мәктәпләргә кереп, профилактик чаралар үткәрәбез.* Ирек мәйданы

2) *тех.* Техник объектны төзек килеш саклау максаты белән үткәрелә торган. *Узып китә язган беренче көнне исәпләмәгәндә, ул өч көннең бер генә көне ял булачак иде, чөнки өченче көнне профилактик ремонт булырга, шуннан соң исә каты сука башланырга тиеш иде.* Н.Фәттах. *Тагылма коралларга да профилактик ремонт үз вакытында үткәрелә.* Борынгы Калатау итәгендә

3) *күч.* Нәрсәдән дә булса кисәтү өчен башкарыла торган. *Бирегә чакыруга гаҗәпләнмәгез һәм борчылмагыз, бары тик Сезнең белән профилактик әңгәмә генә уздырырга булдык.* Ф.Зариф

ПРОФИЛА́КТИКА *и. гр.* 1) *мед.* Сәламәтлекне ныгыту, авыру сәбәпләрен булдырмау яки бетерү өчен күрелгән чаралар җыелмасы. *Көтү чыгар алдыннан, барча мөгезле эре терлекләргә ветеринария каравы уздырыла. --- Бу – бик мөһим профилактика.* Х.Камалов. *Көрәш чаралары – --- профилактика максаты белән я зарарланuның беренче*

билгеләрен күргәндә, үсемлекләргә махсус сыекча сиптерү ---. Ботаника. *СПИДка каршы бер генә чара бар, ул – профилактика.* Ватаным Татарстан

2) *тех*. Техник объектны төзек килеш саклау чаралары (детальләрне төзәтү яки алыштыру, чистарту, буяу, майлау һ.б.). *Ипт әшләр... Үзегез беләсез, ремонттан яңа чыккан бу автобус руленә мин очраклы рәвештә генә утырдым, чөнки үземнең автобус профилактика үтә иде.* А.Тимергалин

3) *күч.* Нәрсәдән дә булса кисәтү чаралары. *Кирәксә, сыт, из, танк астына салып тапта... һәм профилактика йөзеннән төрмәгә дә утырт* ---. Н.Хәсәнов. *Мәгълүм органнарга чакыртып, профилактика чаралары уздырдылар.* Р.Миңнуллин. *Кайвакыт сорау алудан соң Моабитка кайтарып тормыйлар, чираттагы профилактика өчен гестапода калдыралар.* Муса Җәлил турында истәлекләр

ПРОФИЛА́КТИКАЛАУ *ф.* Профилактика ясау, профилактика үткәрү

ПРОФИЛА́КТИКАСЫЗ *с.* **1.** Профилактика үткәрелмәгән, профилактика ясалмаган. *Профилактикасыз эксплуатацияләү чоры*

2. *рәв. мәгъ.* Профилактика эшләре үткәрелмичә, профилактика ясалмаган килеш. *Ялсыз, профилактикасыз теләсә кайчан, теләсә күпме эшләргә без вечный двигатель түгел, в конце концов!* З.Фәйзи

ПРОФИЛАКТО́РИЙ *и. гр.* 1) Санаторий тибындагы профилактик дәвалау-сәламәтләндерү учреждениесе. *Түбән Кама «Нефтехим» комбинатының «Корабельная Роща» дип аталган профилакториена путёвка алып бирделәр.* Т.Миңнуллин. *Узган биш елда хуҗалыкта --- медицина профилактории --- салынды.* Т.Нәҗмиев. *Эчке эшләр министрлыгы карамагында саналган хезмәт белән дәвалау профилакторийлары 1990 елларда ук бетерелде.* Татарстан яшьләре

2) Яңа туган хайваннар өчен махсус шартлар тудырылган бина яки бүлмә. *Менә быелдан да калдырмыйча бозаулар абзарын зурайтырга, профилакторий салдырырга кирәк* ---. Ә.Еники

3) Профилактик техник карау һәм ремонт үткәрелә торган бина. *Машиналы профилакторийга кертеп, эстакадага бастырдылар*. М.Маликова

ПРО́ФИЛЬ *и. фр. кит*. 1) Кеше йөзенең яки гәүдәсенең кырыйдан күренеше. *Профиль шәп. Маңгай өстеннән башланып, муенга кадәр төшкән күперенке, нөхтә таралган чәч.* М.Мәһдиев. *Фотографлар! Төшерегез җирнең портретын, зәңгәр портретын – югартын! Төшерегез – анфас, профильгә. Төшерегез уйчан, елмайтып!..* Р.Әхмәтҗанов. --- *бер бүлмәгә керәсең дә чишенми-нитми караңгы кабинага басасың, бер минут дигәндә синең өч төрле рәсемеңне төшереп алалар: профиль, анфас һәм арткы яктан.* Р.Мирхәйдәров

2) Нәрсәнең дә булса киселештәге формасы. *Бер якта үзйөрешле скреперлар туфрак ташый. Алар артыннан ук тагылмалы катоклар йөри. Икенче якта профиль ясап, автогрейдерлар туфрак «кимерә».* Язмышлар яңарганда

3) *геогр., геол*. Җир өслегенең, Җир кабыгының, гидросфераның яки атмосфераның алдан билгеләнгән линия буенча вертикаль киселеше. *Дүрт метр киңлегендәге урман ызаны, геологларча әйтсәк, профиль, төньяк киңлекләр юнәлешендә утыз-утыз биш чакрымга сузылган.* И.Хуҗин. *Идрис, топографлар профильдә эшләгән арада, тайгага урман тавыгы ауларга кереп киткән җирдән югалды.* Татарстан яшьләре

4) *тех*. Валоклар арасында прокатланып, прессланып, калыпланып эшләнгән, аркылы киселеше төрле формада булган тимер, корыч һ.б.ш. эшләнмә; прокат эшләнмәсенең аркылы киселеш формасы. *Бөтен тышчалар өчен дә материал итеп полиэфир нигезле пыялапластик, эпоксид яки полистирол пенопласт, алюминий яки корыч профильләр ябыштырылган агач өрлекләр кулланыла.* Төзү материаллары. *«Расстал» цехлары буйлап йөргәндә, алюминий профильләрне токмач кискән кебек кенә ясаганнарын күрдек.* Ватаным Татарстан. *Галинең уңган кешеләре, бер-берсеннән өйрәнеп, --- калай профиль ясау цехлары ачканнар.* Татарстан яшьләре

5) Нинди дә булса эшчәнлек, профессия һ.б.ш.ның асылын чагылдыра торган типик сыйфатлар җыелмасы. *Госпиталь бетү, икенче профильгә күчү сәбәпле, күп яралыларны шушы поездга төяделәр.* Х.Камалов. *Лицейның профиле – лингвистик, телләр өйрәнү. Профильгә кергән телләр – инглиз, төрек, гарәп.* А.Низамов. *Халыкны төрле профильдәге белгечләр – табиб-онколог, гинеколог, маммологлар кабул иткән*. Ватаным Татарстан

6) *информ.* Кулланучының исәпләү системаларында теркәлү мәгълүматы

ПРО́ФИЛЬЛӘҮ *ф.* 1) Берәр нәрсәгә дөрес профиль (*2 мәгъ.*) бирү; профиль (*4 мәгъ.*) ясау. *Биредә җир эшләре – аерым участокларны профильләү һәм киңәйтү, борылышларның радиусын арттыру кебек хезмәтләр башкарыла*. Әлки хәбәрләре

ПРО́ФИЛЬЛӘШТЕРҮ *ф.* Билгеле юнәлеш бирү, аерым профиль (*5 мәгъ.*) буенча махсуслаштыру. --- *белем бирүне профильләштерү шартларында укыту-тәрбия эшен оештыру, аның сыйфатын күтәрү; мәктәптә яңа технологияләрдән файдалану турында язмалар басыла*. Казан утлары. *Шул уңайдан Казанның 62 нче мәктәбендә «Мәктәпне профильләштерү шартларында сыйныф җитәкчесе эшчәнлеге» дигән темага семинар узды.* Татарстан яшьләре

Профильләштерә башлау Профильләштерү эшенә керешү

Профильләштереп бетерү Барысын да профильләштерү

ПРО́ФИЛЬЛЕ *с.* 1) Билгеле профильдәге. *Бу белеме белән ул, теләсә, табибларны да алыштыра ала, чөнки аларны авыл больницалары өчен махсус шулай киң профильле итеп укыттылар.* Ф.Бәйрәмова. *Чөнки хәзерге чорның бездәй киң профильле, алдынгы карашлы кешеләрендә булган парафрастик сиземләү кимеп калды*. Язмышлар яңарганда

2) Профиле белән туры килә торган, бер үк профильдәге. *Профильле белеме булган кешене эшкә алу*

ПРОФКОМ *и. рус* 1) Беренчел профсоюз оешмасының сайлап куелган органы; җирле профсоюз оешмасы комитеты. *Комскомитет, профком бу мәсьәләне дирекция белән бергә тикшереп, шундый карарга килде ---.* Х.Сарьян. *Рәмзия профкомда көнкүреш бүлегендә эшли иде.* К.Тимбикова. *Наилә профкомга дәшеп алдылар.* А.Гыйләҗев

2) *сөйл.* Профсоюз оешмасы рәисе. *Беләсеңме, Сәлимә апа, мин сиңа җәйгә путёвка алып бирермен. Мин профком да бит әле.* Ф.Яруллин. *Директорны, профкомны, парторгны, комсомол секретарен үрле-кырлы сикертәбез икән, Алла боерса!* Р.Батулла. *Ул [Арсланов] секретарь кызга Сабитовны, --- профком Нәбиуллинны ашыгыч чакыртырга кушты.* Ф.Садриев

ПРОФМӘКТӘП *и.* Профессиональ белем бирә торган махсус уку йорты. *[Исламгәрәй] берәр профмәктәпкә китеп, нинди дә булса һөнәргә ия булырга да бик омтылып караган.* Р.Төхфәтуллин

ПРОФОЕШМА *и.* Профессиональ союзның җирле оешмасы. *Бүген «Татнефть» ААҖ нең төбәкара профсоюз оешмасы 147 башлангыч профсоюз оешмасын, 692 цех профоешмасын, 2717 профтөркемне һәм 11 меңнән күбрәк профсоюз активистларын берләштерә.* Шәһри Казан

ПРОФОРГ *и. рус* Профсоюз оештыручысы – беренчел профсоюз оешмасы эчендәге төркемнең җитәкчесе. *Бу эшләрне алып бару өчен махсус куелган кешеләр – һәртөрле парторглар, профорглар да таралышып беттеләр.* Ә.Еники. *Клубның буфет бүлмәсендә хезмәт алдынгылары хөрмәтенә кечерәк кенә чәй мәҗлесе әзерләгәннәр иде. Безнең пароходтан профорг Мәрфуга белән мине дә дәштеләр.* С.Сабиров. *Шушы елларда мин тулы нагрузка га эшләп, дөнья кадәр җәмәгать эшләре (куратор, профорг, факультетның партбюро члены, бераздан секретаре...) башкарып, кандидатлык имтиханнары тапшырдым.* Х.Миңнегулов

ПРОФСОЮЗ *и. рус* Профессиональ союз, бер тармакта хезмәт итүчеләрне, бер һөнәр кешеләрен берләштергән җәмәгать оешмасы. *Җыелышта барлыгы егермедән артык профсоюз члены катнашты.* Т.Миңнуллин. *Габделнур --- профсоюз эшенең --- вактөяк мәшәкатенә күмеләчәген, төзү идарәсенең ыгы-зыгысына чумасын әле белми иде.* Р.Кәрами. *Мин беркайчан да үземне профсоюз лидеры булырга әзерләмәдем һәм мин ул эшне булдыра да алмыйм.* Ф.Садриев

ПРОФТЕХ- *рус* Кушма сүзләрнең «профессиональ һәм техник» мәгънәсендәге беренче компоненты (мәс., *профтехбелем, профтехмәктәп*)

ПРОФТЕХМӘКТӘП *и.* Профиле буенча программасында техник фәннәргә күбрәк урын бирелгән мәктәп. *Я, мәсәлән, тулы урта белем алу профтехмәктәптә укучыларның күпчелеге өчен мөмкин булмаган эш булып чыкты.* М.Мәхмүтов

ПРОФТЕХУЧИ́ЛИЩЕ *и. рус* Урта профессиональ техник белем бирә торган уку йорты. *Альберт укуга артык хирыслык күрсәтмәде. --- Моторлар төзү заводы каршындагы профтехучилищега барып керде ---.* Ә.Сафиуллин. *[Рота солдатларының] Белемнәре, нигездә, урта, шулай да профтехучилище, техникумнар бетергәннәре дә хәтсез.* С.Шәрипов. *Тегүче булу теләге кызда шулкадәр көчле иде: сигезне тәмамлагач, --- профтехучилищега укырга китеп барды.* Р.Харрасова

ПРОХОДНО́Й *и. рус* Завод, төзелеш, учреждение һ.б.ш.ның территориясенә тикшереп кертү-чыгару өчен махсус контроль бинасы. *Чишенү бүлмәсендә җилкәсенә пәлтәсен эләктерде дә проходнойга юнәлде.* Ш.Рәкыйпов. *Шул турыда уйлап торганда, аны проходнойга чакырдылар.* Р.Хәбибуллина. *Ул проходнойдан заводның поликлиникасына шалтыратты.* М.Маликова

ПРОХО́ДЧИК *и. рус* 1) Җир асты казылмаларын табу урыннарында, шахталарда, туннельләрдә җирне казып баручы эшче. *Гаязетдин солдатка өч ел күмер кисеп, дүртенче разряд проходчик булып алына.* Р.Гаязетдин. *«Забойщик» дигән белгечлек документы булуына карамастан, аны проходчик итеп куйдылар.* Д.Каюмова. *Ул Пермь өлкәсенең Кизел шәһәренә килә һәм тиз арада проходчик хезмәтен үзләштерә ---.* Балтач энциклопедиясе

2) Тау куышлыгы, мәгарәләр, шахталар тикшерүче спелеолог

ПРОХОДЧЫ *и. махс. к.* **проходчик**. *[Галиев] Мәскәү метросында проходчы була, аннары Донбасста шахта проходчысы.* Ш.Маннур

ПРОЦЕДУ́РА *и. лат. кит.* 1) Берәр эш башкаруның рәсми билгеләп куелган тәртибе. *Суд тикшерүчесе эшкә керешә. «Очная ставка» процедурасын үткәрергә тиешле.* Х.Камалов. *Президентны указ нигезендә сайладык. Инаугурация дип аталган процедура үткәрелде.* Т.Миңнуллин. *Барлык сәяси процедуралар да республикада чит ил күзәтүчеләре контрольлегендә барды ---.* Р.Хәкимов

2) *мед.* Врач билгеләгән дәвалау чарасы (ванна, душ, массаж һ.б.). *Процедурадан буш көннәрдә мин урманда йөрим ---.* Г.Әпсәләмов. *Кайда ул, нишли, --- вакытын төрле процедурага йөреп уздырамы? – мин белә алмыйча аптырый идем.* Ә.Еники. *Өчебез катнашлыгында процедуралар тәмамлангач, Маркин белән Соколов --- амбулаториягә авырулар кабул итәргә кереп киттеләр.* Г.Галиев

ПРОЦЕНТ *и. лат.* 1) Бер берәмлек, бер бөтен итеп алынган санның йөздән бер өлеше (% билгесе белән белдерелә). *Без көннәр буе рәсми сүзләр, саннар, процентлар, гектарлар эчендә кибәбез.* Ф.Садриев. *Саннар, процентлар, чагыштырулар... Нигәдер алар минем күңелдә аңлашылмаган бер шик уяттылар.* Г.Шакиров

2) Бер берәмлек итеп алынган нәрсәнең йөздән бер өлешкә кадәр үлчәнә торган микъдары, күләме. *Хәзер колхозда туксан процент эш машина белән эшләнә.* В.Нуруллин. *Эш шунда гына: властька килүченең намусы ничә процент тәшкил итә?* Т.Миңнуллин. *Марттагы сайлауда сайлау участогы көнозын буш торды. Барганы, булса, биш-алты процент булгандыр.* З.Фәйзи

3) Банкка, саклык кенәгәсенә салынган капиталның һәр йөз сумына

(долларына, евросына һ.б.) алына торган килер, керем. *Әгәр бүген имениеләремнән килә торган доход кадәр процент китерерлек акча бирсәләр, ник сатмаска?* Г.Камал. *Әлеге югары катлау төп нефть долларларын ислам банкларына түгел, Америка һәм Көнбатыш Европа банкларына урнаштырып, бу акчалардан процент алып ята ---.* Р.Хәкимов. *Дүрт ваучерымны кочаклап, Фондларга барган идем. «Процентлар» үрчер диеп, Кассага салган идем.* Р.Низамиев

4) Бурычка, ссудага бирелгән акчадан файдаланган өчен кредиторга бурычлы зат түли торган хак, бәя. – *Акча турында уйлама син. Акча – бездә бер букча. Кирәгенчә үзем биреп торырмын, – ди бу. – Әлбәттә, процентка. Баегач, процентлары белән түләрсең.* А.Хәсәнов. *Ул [Фәтхулла] үтә ярдәмчел, әвене янганнарга зур процент белән акча биреп тора, рибачы булса да, әҗәтен түләүне ашыктырмый, процентын гына арттыра.* А.Гыйләҗев

5) Акча яки товар әйләнешенең, керемнең күпме булуына карап түләнә торган хезмәт хакы, өлеш, бүләк. *Әти [алтын-көмешле] сандыкны дәүләт органнарына илтеп тапшыргач, аңа процентын бүлеп бирәләр.* Н.Гыйматдинова. *Берәр банкны бастың мәллә?.. Әһә, --- күзләреңнән күреп торам, баскансың шул. Качырыйк тизрәк, миңа да бераз процентын чыгарырсың.* З.Мәхмүди

6) *тар.* Совет заманында колхозларда хезмәт хакы исәбенә бирелә торган печән, иген һ.б.ш. натуралата түләү. *Ләкин бу дөньяда «процент печәне» дигән нәрсә бар икән әле. Ягъни без шушы ун чүмәләнең бишесен урман каравылчысына тапшырырга тиеш.* Р.Низамиев. *[Талия:] Теге балдак саткан акчаны колхозда печән бүлгән кебек итәрбез инде, яме? [Борһан:] Нинди печән? [Талия:] Процент печәне, дим. Кем күпме өлеш керткән, шуның кадәр ала.* Аманулла

ПРОЦЕНТЛАП *рәв.* 1) Процент исәбе белән; процентларда билгеләнгән нисбәтне саклап. *Сарыкларның ит, йон салымнары Аз тоелды беркөн Аюга: – Тире налогы да салсак, безгә Шәп чыганак булыр баюга. Дөрес, башкалардан уптым түгел, Процентлап кына алына. Үзләренә – тояк, койрык, колак – Җитмәгәнме сарык малына!?* Х.Бәдигый. *Ленинградта үткәрелгән социологик тикшеренүләр нәтиҗәсе буларак, аерылышу сәбәпләрен процентлап күрсәткәннәр иде.* Д.Гайнетдинова

2) Билгеле процент чамасында. *Табыш ун процентлап булыр, дип көтелә*

3) Процентка кадәр төгәллек белән. *Бөтен шартын китереп «ясалган», кечерәйтү-зурайту өчен үлчәмнәре процентлап билгеләнгән рәсем-фотолар исә, аларны махсус яссылыкка төшереп бирсеннәр дип, цинкография цехына тапшырыла.* Милли нәшрият һәм китап редакторы

ПРОЦЕНТЛА́У *ф.* Процентын (*1 мәгъ.*) исәпләп чыгару; процентларга бүлү

ПРОЦЕНТЛЫ *с.* 1) Күләме, куәтлелеге, сыйфаты һ.б.ш.лары билгеле процентта (*1 мәгъ.*) булган. *Либретто да йөз процентлы уңай геройларга каршы кимчелекле ике образ куелган.* М.Җәлил. *[Әби] башта кулларыбызны ун процентлы хлорлы суда чайкатты ---.* К.Кәримов. *Тештәге куныкны бетерү өчен, өч процентлы водород перекисе эретмәсендә чылатылган мамыкны өч минутка тешләргә куеп торырга кирәк.* Ватаным Татарстан

2) Процент (*3 мәгъ.*), керем китерә торган. *Узган август аенда, ачларга ярдәм итү өчен, 50 миллион сумлык дүрт процентлы государственный ренталар чыгарылды.* Г.Камал. *--- шул зур сумманы кечкенә процентлы банкларда яткырганчы, шуңгарга шул нимесләрнең йирләрен, бакчаларны алсалар, файдамыз күбрәк булмас идемени?* Г.Исхакый

3) Процент (*4 мәгъ.*) түләү каралган, процент (*4 мәгъ.*) кайтару таләп ителә торган. *Заём процентсыз булырга мөмкин, ул чагында алынган сумма гына кире кайтарыла, яки процентлы була ---.* Татар теле. Хрестоматия

ПРОЦЕНТЛЫК *с.* Билгеле процент тәшкил иткән. *Алар фикеренчә, саклап калган транзит ташламаларын исәпкә алганда, Украина өчен кабул ителгән 20 процентлык ташлама бер дә начар түгел.* Ватаным Татарстан

ПРОЦЕНТСЫЗ *с.* **1.** 1) Процент (*3 мәгъ.*), керем китерми торган

2) Процент (*4 мәгъ.*) түләү каралмаган, процент (*4 мәгъ.*) кайтару таләп ителми торган. *Шуңа күрә процентсыз заёмны кайтару хәстәрен күргән кирәк.* Безнең гәҗит. *Балалары укый торган әти-әниләргә яисә заводта эшләүче студентларга, укуларына түләр өчен, процентсыз ссуда да бирелә.* Бөгелмә авазы

2. *рәв. мәгъ.* 1) Процент (*3 мәгъ.*), керем алмыйча, процентын (*4 мәгъ.*) кайтаруны таләп итмичә

2) Процент (*4 мәгъ.*) түләмичә. – *Бездә юллама бәяләрен алты айга кадәр процентсыз кичектереп түләргә һәм хәзердән үк май – сентябрь айлары өчен юллама, теплоход круизларын броньлап куярга була, – ди туристлык челтәренең туризм буенча белгече Ильвира Корбангалиева.* Хезмәт даны

ПРОЦЕСС *и. лат.* 1) Берәр күренешнең үсеш-үзгәрешендә халәтләрнең эзлекле алмашып торуы, барышы. *Кеше табигате, аның психологиясе шулай ук акрын үзгәрә, иң мөһиме: бу процесс күзгә күренми, һәм аның белән читтән торып идарә итүе бик кыен.* А.Гыйләҗев. *Шулай итеп, без тере организмнарның үзгәреше, үсеше аны чолгап алган материаль дөнья йогынтысында һәм шул йогынтыга яраклашу процессында барганын күрдек.* М.Абдрахманов. *Ислам дине белән бергә безгә гарәп казанышлары да керә. VII гасыр урталарында башланган бу процесс соңгы дәвергәчә дәвам итә.* Х.Миңнегулов

2) Билгеле бер нәтиҗәгә ирешүгә юнәлтелгән эзлекле эш-хәрәкәт. *Ә чын осталарны, түгелгән көч өчен шактый мул гына түләнә торган акчадан бигрәк, хезмәт процессы үзе кызыксындыра.* Ф.Галимуллин. *--- җисем – нурланыш системасында тигезләнештән тайпылу килеп чыкса, яңадан бу халәткә омтылуны тәэмин итә торган процесслар барлыкка килә.* Физика. *Җитештерү процессы. Технологик процесс*

3) *юр*. Суд һәм административ эшләрне карау, тикшерү тәртибе. *Мондый очракларда бирелергә тиешле сорауларны яхшы белгәнгә күрә, җинаять процессы кагыйдәләренә туры китереп, алдан ук җавап кайтарды ул: – Исемем – Ансар, фамилиям – Субаев, 1980 елгы ---.* К.Кәрами

4) Суд һәм административ эшләрнең үзләре. *Соңгы чорда Италия дәүләте, гомумән илнең прогрессив җәмәгатьчелеге, мафиягә каршы чын-чынлап ныклы көрәш җәелдерде, Палермода бара торган процесс бу җинаятьчелекнең тамырына балта чабу булачак, дип ышанасы килә.* Р.Фәйзуллин. *Яраннар Марияне Ватанга хыянәт итүдә гаепләп җәзаларга карар чыгара. Процесска Пётр үзе дә килә.* Х.Камалов. *Әле бер хөкем процессында да катнашмаган бу яшь егет үзен танылган юрист, адвокат --- итеп игълан итәргә дә тартынып тормаган бер адәми зат иде.* Х.Ибраһим

5) Авыру-чирнең көчәя баруы. *Ялкынсыну процессы*

ПРОЦЕ́ССИЯ *и. лат.* Гадәттә күп кеше катнашындагы тантаналы йөреш. *--- урамда --- бер җинаятьчене җәзага, үтерелә торган җиргә озатучы халык төркемен күрдем. Бу кабахәт процессия белән очрашмас өчен, мин тыкрыкка борылдым.* Х.Туфан. *Ул егылырга өлгергәнче, хәшәрәт аның лазер пистолетын эләктереп тә алды. Хәшәрәтләр дә иярде, бу бик куркыныч процессия иде.* Р.Мөхәммәдиев. *Обком вәкилләреннән яшь кенә бер ипташ, процессия эшенә катнашасы килеп, мәрхүмнең югары дәүләт бүләкләрен чыгарырга тәкъдим ясый.* Р.Низамиев

ПРОЦЕ́ССОР *и. ингл. информ.* Компьютерда мәгълүматны эшкәртү функциясен башкарган электрон блок, җайланмалар комплексы. *Аппарат дүрт төшле процессор белән коралланган, оператив хәтере дүрт гигабайт!* Ф.Бәллүр. *Дөрес, квант компьютерлары белән процессорлар әле һәр офиста да булмас.* Ватаным Татарстан. *КДТУ ректоры Юрий Гортышев әйтүенчә, сигез процессорлы --- суперкомпьютерны төзергә 15 миллион сум акча тотылган.* Татарстан яшьләре

ПРОЦЕССУАЛЬ *с. юр*. Процесска (*3 мәгъ.*) караган. *Беренчедән, «процессуаль», ягъни «кануни хокук»ны аерып карарга кирәк. Бу мәгънәдә гаделлек закон таләпләрен төгәл үтәп чыгарылган карарны яки нәтиҗәне чагылдыра ---.* Ф.Зариф. *РФ Гражданнар процессуаль кодексының 244-1 нче маддәсе нигезендә, Вазыйх бабай, үзенең суд эше акылга муафикъ, нигезле срокларда каралмаган дип, суд аркылы акча компенсациясе таләп итә ала.* Ватаным Татарстан. *«Эшнең күләме һәм процессуаль срокларны үтәү буенча безнең суд алдынгы позицияне били», – дип ассызыклады Наил Латыйпов.* Шәһри Казан

ПРОШЕ́НИЕ *и. рус тар*. Рәсми кабул ителгән формада язма үтенеч, гариза. *Ул Казанда ике урынга прошение биргән икән инде: берсе – хатын-нарга махсус гали курсларга, икенчесе – университетка әзерли торган «тугызынчы класс»ка*. Г.Гали. *Берничә көн йөргәч, губернаторның бер писарен күреп, прошение яздырганнар.* А.Таһиров. *Патша хәзрәтләренә бик четерекле прошение язар өчен киңәшче итеп, писарь Гөргерине сыгылмалы тарантаста Бөгелмә каласына алып китәләр*. М.Галиев

ПРР *иярт. к.* **пыр**. *Син очып йөргәнче, кошчык, прр да прр, Ташла иске тормышыңны, бездә тор.* Г.Тукай

ПРР-ПРР *иярт. к.* **пыр**. *Прр-прр күгәрченнәр оча*

ПРС *ы. к.* **перес**. *Мәче пычракка баскан саен --- аякларын селки. --- – Прс, муеның сынгыры! – Тәкый абзый таш алырга дип иелгән иде, үкчәсе авыртудан егылып китә язды.* Г.Сабитов

ПРУЖИНА *и. слав.* 1) Механик басымга каршы тору өчен файдаланыла торган, спираль рәвешенә китереп бормаланып бөгелгән металл чыбык яки пластина. *Борынгы караватның тутыккан пружиналары кызганыч кына ыңгырашып куйды.* Р.Зәйдулла. *Шамил, кинәт кенә пружинасы ычкынып киткән уенчык кебек, утырган җирдән сикереп торды ---.* З.Вәли. *Пётр Терентьевич сәгать пружинасы төймәсен әледән-әле боргалап куя.* Язмышлар яңарганда

2) Бишек асып тирбәтә торган бормалы тимерчыбык; силә, сиртмә. *Пружинаны алып кайта, бишекне элә*. Әкият. *Түрдә бишек, сиртмә түгел – пружина, әткәй дә шунда тирбәлеп үскән, шәһәрчә, Һидият бабам мәркәздән алып кайткан аны*. Ш.Галиев

3) *күч*. Берәр нәрсәне хәрәкәткә китерә торган көч, сәбәп. *Сугышның әшәкәлеге шунда: кешедәге ерткычны уята ул, әшәкәлек бик ерак – булачак җинаятьләргә этәргеч пружина була*. Ш.Галиев. *Заводның үз эчендә вакыйгаларны хәрәкәткә китерә торган пружина табылмаган.* Казан утлары

◊ **Пружина кебек** Бик көчле, тиз, капыл хәрәкәт турында. *Әле һаман өстәл янында йоклап утырган шкипер, үзе дә шундук уянып, пружина кебек ялт торып басты*. С.Сабиров. *Кинәт ул, ычкынып киткән пружина кебек, яткан урынныннан атылып торды ---.* Н.Фәттах. **Пружинасы бушаган** Гайрәте шиңгән. **Пружинасын бору** Бик нык кисәтү. *Айрат әзерләп бетергән иде инде җыелышны, нишләптер сүрелде әле. Мохтаров пружинасын борган, ахры, аның*. Г.Ахунов. *Әйтерсең еллар шактый туздырабушата төшкән хәтер пружинасын әледән-әле борып-тыгызлап ала...* Язмышлар яңарганда. **Пружинасы ычкыну** 1) Түземлеге бетеп үзконтрольне югалту, артык кызып китү; акылына зәгыйфьлек килү. *Анаңның теленә шайтан төкергән аның. Пружинасы бер ычкынса, җыеп та ала алмый ул аны*. А.Шамов. *Икенче көнне кич --- Заһри кода икмәк тапшырасы атларны --- сорый килде. Ләкин шул минутта Шәяхмәтнең пружинасы ычкынды. Ул ачуланып өстәлгә сукканда, Заһриның бите шәмәхә кара белән тулды.* М.Мәһдиев; 2) Көйсезләнү, бозылу, җае китү. *Тик менә соңгы вакытта гына аның көйләнеп куелган яшәү механизмында бер шөреп бушады, кайсыдыр пружинасы ычкынды.* Р.Кәрами; 3) Нык куркудан, каушаудан аяк буыннары хәлсезләнү. *Кинәт*

каушап калдым, тез буыннарымның пружиналары ычкынды. А.Шамов. **Пружина шикелле** *к.* **пружина кебек**. **Пружина ычкыну** Хәл кире кайтаргысыз төс алу, кискен үзгәрү. *Элек 1905, 1917 елгы революцияләрнең башлану сәбәбен эксплуатация басымының, фәкыйрьлекнең көчәюе аркасында, халыкның түземлеге төкәнеп, --- уңайлы форсат туу белән пружинаның ычкынуы – инкыйлаб ялкыны кабынуы белән аңлаталар иде.* Мәдәни җомга

ПРУЖИНАЛАНУ *ф*. 1) Пружина кебек бөгелү, бөтерелү һәм язылу; пружина рәвешен алу

2) Мускулларны тыгыз, киеренке хәлгә китереп, гәүдәнең кайсы да булса өлешләре белән көчле хәрәкәтләр ясау

Пружиналаныш тору Пружиналанган хәлдә булу. *Бабай белән әби бауның --- пружиналаныш торуы беткәнче, һәр бөртеген сыдырып чыгалар*. Г.Гобәй

ПРУЖИНАЛЫ *с*. Пружинасы булган, пружина куелган. *Диванның пружиналы матрасы шатыр-шотыр килеп тора.* Х.Камалов. *Стена буендагы пружиналы караваттан, кечкенә генә өстәлдән, иске бер шкафтан башка берни дә юк иде өйдә.* Р.Зәйдулла. *Институтның юан пружиналы калын ишеген ачып керүгә бөтенләй югалып калуы әле дә онытылмый*. С.Зыялы

2) *күч.* Сыгылмалы (хәрәкәт, йөреш тур.)

ПРУСС *и*. Балтыйк диңгезенең көньяк ярында, түбән Висла һәм Неман елгалары буенда IX–XVIII гасырларда яшәгән балт телле халык һәм шуның бер вәкиле. *Юк, Ибраһимның башына тай типмәгән әле, американ көллиясен ул эчен прусс штыгы айкап чыксын өчен тәмамламаган.* Р.Әмирхан. *1871 елда Мәскәүдә лютеран динле прусс илчесе гаиләсендә туа*. Тарих. *Тел белгече булмаган кешегә, рус, хетт, әрмән, прусс, литва, инглиз, албан, көрд, тажик, ирланд телләре – генетик яктан туган телләр, дисәң, һич ышанмас.* Эзләнүләр, уйланулар, табышлар

ПРУССАК *и. рус* Алманиянең тарихи өлкәсе Пруссиядә яшәүче яки шуннан чыккан кеше. *Немец шәһәрләрендәге йортлар --- тупас пруссак казармаларын хәтерләтәләр.* Г.Иделле. *Ә пруссаклар бу капканы аеруча ныклы саклыйлар икән.* М.Глухов. *Француз армиянең яртысын гына алып тора, ә калган өлешен поляклар, пруссаклар, австриялеләр, итальяннар, голландлар һ.б. тәшкил итә.* Татарстан яшьләре

ПРУССАКЛЫК *и*. Элеккеге Пруссия дәүләтендә һәм Германия империясендә хакимлек иткән реакцион милитаристик, бюрократик режим. *«Пруссак» дигән, шайтан да йөз елга бер кулланмаган сүз генә җитмәгән – кырында «пруссаклык» дигәне дә бар...* З.Мифтахов

ПРХ *иярт. к.* **пырх**. *– Бала чакта мин [бәрәңгене] кабыгы, күмерләре белән ашый торган идем. Хәзер дәү булдым, кабыгын чистартып ашыйм, – дип, Гөлшәһидә прх итеп көлеп җибәрде.* Г.Бәширов. *Аның артыннан ук берничәсе прх итеп көлеп җибәрде*. Л.Ихсанова. *Агач араларыннан кинәт прх, прх, прх итеп очкан кошлар минем котымны очыралар.* Ш.Әхмәдиев

ПРХ-ПРХ *иярт. к.* **пырх**. *Ишек төбендәге почмакта ике егет, пыш-пыш килеп, әледән-әле прх-прх көлешеп, күрәсең, кызлар турында гайбәт саталар иде*. Н.Фәттах. *Хатыннар прх-прх көлешеп алдылар*. Т.Мөбарәков

ПРЫХ *иярт. к.* **пырх**. *Прых итеп тагын кайсыдыр көлеп куйды*. Р.Батулла

ПРЫ́Х-ПАРЫХ *иярт.* Пырхылдап чыккан бугаз авазларын белдерә. *Теге авызын чапы-чопы китерде дә, пар җибәргән паровоз кебек, прых-парых килеп тагын гырылдый башлады*. Р.Хәбибуллина

ПРЫХ-ПРЫХ *иярт. к.* **пырх-пырх**. *Малайлар бер-бер артлы прых-прых иттеләр.* Ф.Яхин

ПРЮНЕЛЬ *и. фр.* **1.** Аяк киемнәренең өске өлешен тегүгә, мебель тышлауга китә торган юка, тыгыз киҗемамык, ефәк яки йон тукыма. *Иң әйбәт кышкы аяк киеме – күннән тегелгәне, җәйгесе – прюнель, парусина.* Мәдәни җомга

2. *с. мәгъ*. Шундый тукымадан тегелгән. *Прюнель ботинкалар*

ПСАЛОМ *и. гр.* Христианнарда Пластырь составындагы көйләп укыла торган мактау һәм тәүбә догаларының берсе. *29 нчы апрель көнне --- Казан Кремленең Благовещение соборында яшьләр һәм балалардан торган чиркәү җыр коллективларының Олы көнгә багышланган «Пасха Псаломы» дигән концерты узачак.* Туганайлар

ПСАЛТЫРЬ *и. гр.* Библиянең бер өлеше, псаломнар китабы; Зәбур. *Моның өчен сиңа Инҗил белән Псалтырьне ятларга туры килер.* М.Хәбибуллин. *Сандыкта изге кенәгәләр, Псалтырь, Евангелиеләр, үлгәннәр өстендә укыла торган бакыр тышлы иман китаплары бар иде.* Туганайлар

ПСЕ́ВДО- *гр.* Кушма сүзләрдә «ялган, уйдырма, чын түгел» мәгънәсендәге беренче компонент (мәс., *псевдопатриот, псевдоэтноним, псевдоязучы*)

ПСЕВДОДЕМОКРА́ТИЯ *и. гр.* Ялган демократия. *Безнең илдә дә демократия псевдодемократия булып кала бирә*

ПСЕВДОКЛАССИЦИЗМ *и. гр.-лат.* 1) XVII гасырдан алып XIX гасырның башына кадәрге чор әдәбияты һәм сәнгатендә антик үрнәкләргә иярүгә һәм ныклы эстетик кануннар системасына буйсынуга нигезләнгән юнәлеш. *Бу иске әдәбият тарих истилахында псевдоклассицизм дип атала.* Г.Ибраһимов

2) Архитектурада: шул ук чорда антик һәм яңарыш чоры архитектурасы традицияләрен эзлекле рәвештә үстергән төп стильләрдән берсе. *Псевдоклассицизм алымнары белән ясалган биналар модага керә.* Б.Урманче

ПСЕВДОНИМ *и. гр.* Язучы, рәссам, сәнгать әһеле яки башка киң танылган шәхеснең үз-үзенә алган, чын исемен алмаштыра торган исеме яки фамилиясе. *Консультант аның фамилиясенә текәлеп утыра иде. – Чәмәт – псевдониммы? – дип сорады*. Х.Сарьян. *– Имзада хата җибәргәнсез түгелме? – Кушамат ул, псевдоним. Дуслар мине шулай атый.* М.Маликова. *Шамил Анак... Анак дигәне – псевдоним. Тулы исеме – Мәхмүдов Шамил Гомәр улы*. Р.Фәйзуллин

ПСЕВДОНИМЛАШТЫРУ *ф.* Псевдоним итү, псевдонимга әйләндерү. *Кулъязмадан шагыйрьнең исемен һәм нисбәсен таба алмагач, Г.Сәгъди һәр хикмәттә кабатланган традицион «мәуля колый» гыйбарәсен алып, шуны псевдонимлаштырган булса кирәк.* Ф.Фасиев

ПСЕВДОНОМА́СТИКА *и. гр.* Ономастиканың һәр төрле псевдонимнарны ачу һәм өйрәнү белән шөгыльләнә торган тармагы. *Псевдономастика – татар филологиясендә әлегә тиешенчә өйрәнелмәгән фән.* М.Мәһдиев

ПСЕВДОПАТРИОТ *и. гр.* Ялган патриот. *Соңгы елларда псевдопатриотлар күбәйде*

ПСЕВДОПАТРИОТИЗМ *и. гр.* Ялган патриотизм. *Псевдопатриотизм билгеләре күренү*

ПСЕВДОЭТНО́НИМ *и. гр.* Ялган, дөрес булмаган этноним. *--- төрле халыкларны бер үк исем белән атау очраклары, күп кенә псевдоэтнонимнар, бер яктан, бу исемне бирүче үзе исем таккан халыкның телен, культурасын, тарихын белмәгәннән --- килеп чыга.* Эзләнүләр, уйланулар, табышлар

ПСЕВДОЯЗУЧЫ *и.* Ялган язучы. *Әгәр тагын --- кеше исеме белән шаярганыгызны күрсәм, правагыз белән мәңгегә саубуллашачаксыз, иптәш псевдоязучы*. Ф.Яруллин

ПСИХ *и. рус гади с.* Психикасы тотрыксыз яки психик авырулы кеше. *Үз гомерендә, кыюланып, бер тапкыр хак сүз әйтеп бакты – «псих» дип атадылар.* А.Гыйләҗев. *Кем псих, кем акыллы икәнен ачыклап торырга вакыт юк иде.* Г.Мөхәммәтшин. *Мин яңадан синең ише псих белән берәр җиргә бараммы соң!..* Р.Кәрами

ПСИХАСТЕ́НИК I *и. рус мед.* Психастения белән авыручы кеше. *Психастениклар беркемгә дә ышанмыйлар*

ПСИХАСТЕ́НИК II *с. мед*. Психастениягә хас, асылы психастения булган. *Психастеник авырулар*

ПСИХАСТЕНИ́Я *и. гр. мед*. Бик нык кыюсызлык, үз-үзенә ышаныч булмау, куркаклык, һәрнәрсәдән шикләнү һәм бәйләнчек яки хәвефле уйлар уйлаудан гыйбарәт нерв авыруы. *Мондый очракларда балаларда кыюсызлык, куркаклык, шикләнү тамыр җәя башлый, һәм алар психастения, шикләнү неврозы белән тиз авыручан булып китәләр.* Ватаным Татарстан. *Психастения билгеләре*

ПСИХБОЛЬНИ́ЦА *и. рус* Психик авыруларны дәвалый торган хастаханә. «*Тагын шулай йөрсәң, кирәк икән, психбольницага илтеп тыгам мин сине», – диде*. Н.Акмал. *Психбольницада ул шактый озак ятты*. Г.Әдһәм. *--- алар бу хатынның гаризасын алып калдылар. Мондый гаризалар өчен тиле булса – психбольница, акыллы булса, төрмә көтә иде.* Ф.Бәйрәмова

ПСИХИАТР *и. гр*. Психиатрия өлкәсендәге белгеч-табиб. *Мортазаның сискәнеп киткәнен күреп, тыныч-ландырырга ашыкты: – Мин психиатр димим, психолог дим.* М.Маликова. *[Табиб:] Ярар... Сезнең нәселдә психиатрда дәваланучылар булганмы соң?* Х.Ширмән. *Австралия психиатрлары начар кәефнең йогышлы булуын исбатлаган.* Сөембикә

ПСИХИА́ТРИК *с*. Психиатрия өлкәсенә карый торган. *Бу дача психиатрик больница янәшәсендә урнашкан.* И.Рәмиев. *Психиатрик хастаханәләрдәге авыруларның өчтән бер өлешен алкоголиклар һәм наркоманнар тәшкил итә*. Инсан һәм дин. *Илдә --- 14 миллион кеше (халыкның 10 проценты) психиатрик ярдәмгә мохтаҗ.* Татарстан яшьләре

ПСИХИАТРИ́Я *и. гр*. Медицинаның психик авыруларны һәм аларны дәвалау юлларын өйрәнә торган тармагы. *Ә [сабакташларның] берсе күп еллардан бирле инде Казан психиатрия шифаханәсендә икән*. М.Мәһдиев. *Бичаралар [кызлар] ул керәсе дәрес алдыннан, психиатриядән язылган лекция дәфтәрләренә текәлеп, коридор буйлап авыз эченнән укып йөрерләр ---.* Г.Галиев. *Психиатрия больницаларындагы авыруларның 50% ының ата-аналары алкоголиклар яки наркоманнар икәне билгеле*. Сәламәтлек нигезләре

ПСИ́ХИК *с*. 1) Психикага бәйле. *– Моның өчен нәрсә булды аңа? Аткаммы? – Атмадылар, ул психик яктан нормаль түгел дип, Арча кырындагы «сары йорт»ка яптылар*. Г.Тавлин. *Бер якта система корбаннары – Казанда бомбалар ясый торган заводның элеккеге инженеры, Эчке эшләр министрлыгы тәкъдиме белән психик яктан тотрыксызлар исемлегенә теркәлгән --- Йосыф улы Нургалиев ---.* М.Сәхапов

2) Ми үзәкләре зарарланудан, үзәк нерв системасы какшаудан барлыкка килгән (авыру төрләре тур.). *Сез – врач. Сез андый җитди сынау алдыннан авыруга психик травма ясауның җинаять икәнен яхшы беләсез*. Г.Әпсәләмов. *Әллә, чынлап та, кызда бер-бер психик авыру бар дип шикләнәме?* Н.Акмал. *Чыршын йөрәк-кан тамырлары авыруларын дәвалаганда комплексны терапиядә, атеросклероз, нерв һәм психик авырулар вакытында баш мие ялкынсынуын булдырмау өчен --- кулланыла*. Татар балы

3) Кешене куркыту, аның психикасына тәэсир итүгә исәпләнгән. *Ә Мамак участогында немецлар психик атака ясадылар.* Х.Камалов. *Бик тә әһәмиятле әлеге пунктны дошман бөтен көченә саклый. Яңадан-яңа көч белән һөҗүмгә ташлана, психик атакалар ясый.* Э.Шәрифуллина. *Дошман бу кечкенә урынны берөзлексез бомбага, утка тота, көн саен күп тапкырлар психик атакага килә ---.* М.Ибраһимов

ПСИ́ХИКА *и. гр.* Чынбарлыкны үз аңында яки нервларында чагылдыра алуда, тойгыларда, кичерешләрдә, ихтыярда һәм фикерләү үзенчәлекләрендә сизелә торган югары нерв эшчәнлегенең аерым бер үзлеге; рухи халәт // Шул үзлекнең кемдә дә булса конкрет чагылышы. *Ата һәм ана кешене башка берәү дә алмаштыра алмый, бала психикасы үзенә тормыш бүләк иткән кешеләрне көтә*. А.Тимергалин. *Минага басмаганнарга тыныч тормыш юлына баскач та сугышның күлеп үрелеп җиткән, кинәт ега алмаса, психикада, җанда сәламәтлеккә мина булып шартлаган: гомерне кыскарткан я өзгән үк...* Ш.Галиев. *Исереп кайтып, өйдә көн-төн тавышланулар аның психикасында беренче билгеләрен күрсәтә*. Ирек мәйданы

ПСИ́ХО- *гр.* Кушма сүзләрдә «психикага бәйле» мәгънәсендәге беренче кисәк (мәс., *психопатология, психоневрология, психотерапия* һ.б.ш.)

ПСИХОАДАПТА́ЦИЯ *и. гр.-лат.* Психологик шартларга җайлашу, яраклашу. *Күрәсең, психоадаптациягә аның сәләте бик аз булган.* Тигез гомер итегез!

ПСИХОАКТИВ *с.* Үзәк нерв системасы эшчәнлегенә тәэсир итә торган. *Барлык илләрдә психоактив матдәләр куллану нәтиҗәсендә килеп чыккан авыручылар саны 500 млн кешедән артык*. Сәламәтлек нигезләре. *Идарә җитәкчесе Фаяз Шабаев белдергәнчә, героинның яшерен сәүдә итүчеләрдә аз һәм кыйммәт булуы сәбәпле, наркотик кулланучыларның бер өлеше башка төр психоактив матдәләр белән мавыга башлаган.* Мәдәни җомга

ПСИХОАНА́ЛИЗ *и. гр.* Психик авыруы булган кеше белән сөйләшеп, аны әйләндереп алган тирәлекне, авыру белән тирәлек арасындагы мөнәсәбәтне өйрәнеп, чиргә сәбәп булган чыганакны ачыклау һәм аннан котылу чараларын эзләү белән бәйле дәвалау алымы. *Фрейдның психоанализ теориясе психик авыруларны дәвалауда уңай нәтиҗәләр бирә* ---. К.Гыйззәтов. *СССРдагы дәһри (атеистик) режим дистәләгән фәннәрне (шул исәптән генетика, кибернетика, психоанализ, соционика, системотехника, педология, телегония һ.б.) ялганга чыгарды.* И.Әмирханов. *Психоанализ нигезендә физиологиядән психологиягә үтеп керү ята, ул исә аңсызлык белән бик тыгыз бәйле*. Ә.Закиржанов

ПСИХОАНАЛИ́ТИК I *и. гр.* Психоанализ алымнары белән дәвалаучы белгеч. *Франциянең Осер шәһәрендә яшәүче Анри дигән бер кеше, хыянәтләренә түзә алмыйча өченче хатыны да китеп баргач, психоаналитикка мөрәҗәгать итә.* Ватаным Татарстан. *Кайбер психоаналитиклар әйткәнчә, 13 санына шундый карашның, чыннан да, бик борынгы заманнардан килү ихтималы бар*. Мәдәни җомга. *Чит илләрдә кешеләрнең шәхси психоаналитиклары бар, ә безнең ватандашлар нерв какшауга, депрессиягә игътибар итеп тә тормыйлар*. Татарстан яшьләре

ПСИХОАНАЛИ́ТИК II *с.* Психоанализга нигезләнгән, асылы психоанализ булган. *[Идрис] психоаналитик анализлар ясап, --- үз эчәк-бавырларыннан чыгып кына киң дөньяга бәя биреп йөрүчеләрне яратм[ый]*. А.Гыйләҗев. *Чит ил һәм рус әдәбият белемендә шактый тулы өйрәнелгән тәнкыйть юнәлешләре (рецептив, психоаналитик, --- феминистик, субъектив һ.б.) бездә тиешенчә өйрәнелмәде.* Ә.Закиржанов. *Фромм, Фрейд кебек үк, психоаналитик ысуллар белән дәвалаучы табиб булып хезмәт итә.* К.Гыйззәтов

ПСИХОЗ *и. гр.* 1) Баш мие зарарланудан туган авыру халәт. *Акрынлап алкоголизмның соңгы этабы – психозлар, деградация башлана.* Сәламәтлек нигезләре. *Яз-көз башлану белән төрле нерв авырулары кискенләшә, шизофрения психозлары көчәя, агрессия күренешләре ешая*. Казан утлары. *Ә психик чирнең көчлерәге психоз дип атала.* Татарстан яшьләре

2) Берәр вакыйга, идея, күренеш һ.б.ш.ның кешедә ышаныч югалту, баш катыргыч фикерләр, курку тәэсирендә килеп туган халәт. *Сталинны күкләргә чөю, аңа табыну чиктән ашты, шашыну дәрәҗәсенә барып җитте. Бу массакүләм психозга бирелү иде.* Ә.Еники. *Казанда «халык дошманнары»н ачыклауда күмәк психоз кузгала.* З.Зәйнуллин. *Бөтен халык бәрелеп-сугылып, психоз халәтенә бирелеп, нәрсә булганын аңламыйча, Казанның Печән базары – гайбәт оясы ягына чабарга тотына.* Фән һәм тел

3) *сөйл.* Кеше психикасында сәерлек, нормадан тайпылыш. *Капитан --- Макснының тавышында --- янау кебегрәк нәрсә ишеткәч, урынына утырды. «Юк, бу – космик депрессия түгел, психоз да түгел...»* А.Тимергалин. *Монда әллә нинди сәламәт булмаган психоз – һаман кемнедер гаепләргә тырышу, коткы тарату. Бу – наданлыктан килә инде, әлбәттә, ә кемнәрдер шуннан бик оста файдалана.* Ф.Бәйрәмова

ПСИХО́ЛОГ *и. гр.* 1) Психология белгече. *Әнә Көнбатышта һәркемнең үз психологы бар.* М.Маликова. *Психолог Һашим кереп, аларның җанлы әңгәмәләрен бүлдерде*. А.Тимергалин. *Әгәр дә янәшәңдә --- Рәшит Хисмәтуллин шикелле тәҗрибәле психолог белгеч бар икән, ялгыш юлга борылсаң да, бик тиз турысына чыгарыр.* Язмышлар яңарганда

2) Башка кешенең эчке халәтен сизә, тирәнтен аңлый белә торган кеше. *Яшь кенә булуына карамастан, нинди оста психолог бу Нәсимә! Ничек ансат тотты бит каракны*. М.Мәһдиев. *--- Әхмәт коеп куйган белгеч кенә түгел, әле психолог та: кемне кем белән, нинди эшкә куярга икәнен яхшы чамалый*. Ватаным Татарстан. *--- мин укытучы юлын сайламадым, чөнки, беренчедән, моның өчен бик зур психолог булырга кирәк, икенчедән, балалар белән эшләү – аерым тормыш ул*. Шәһри Казан

ПСИХОЛОГИЗМ *и. рус* 1) Фәлсәфәнең нигезе итеп субъектив психологияне алган идеалистик юнәлеш. *Психологизм инглиз фәлсәфәчесе Дж.С.Милль тарафыннан да хупланган*

2) *әд.* Кешеләрнең рухи кичерешләрен, психологиясен тирәнтен сурәтләүгә, нечкәләп анализлауга нигезләнгән иҗат алымы. *Исәнбәт драматургиясендәге психологизм, Исәнбәт әсәрләрендәге каһкаһәле сатира Марсельнең иҗат мәсләгенә бик тә якын, бик тә тәңгәл килә иде.* Р.Батулла. *Әсәрләрдәге мавыктыргыч сюжетка корылган вакыйгалар тирән фәлсәфә, нечкә психологизм аша сурәтләнә*. Г.Якупова. *Драматурглар актив рәвештә шартлы алымнарга, символик-метафорик күренешләргә, мифологик дөнья сурәтләренә, психологизм алымнарына һ.б.га мөрәҗәгать итә*. Ә.Закиржанов

ПСИХОЛО́ГИК *с.* 1) Психология белән бәйле, психологиягә мөнәсәбәтле. *Фрейд – психология фәненә, аның психологик медицина тармагына мөһим өлеш керткән галим*. К.Гыйззәтов. *Ул [Дональд Кент Слейтон] термобарокамерада --- күп баскычлы катлаулы сынаулар үтә, уннарча психологик тестлар, телдән һәм язма имтиханнар тапшыра.* Галәмгә

юл. *Иң яхшысы: авыр вакытта таянырлык, гаиләне саклап кала алырлык яхшы белгечләр әзерләсеннәр, психологик ярдәмнәр булдырсыннар.* Ирек мәйданы

2) Кешенең рухи халәтенә, психикасына бәйле. *Алар инде көрәшә, шул рәвешле үз-үзләрен көрәшкә әзерли, бер-берсенә психологик басым ясарга, куркытырга телиләр.* Р.Мөхәммәдиев. *Кешенең психологик халәте тәүлекнең төрле вакытында төрлечә була.* Ш.Галиев. *Әмма психологик барьер аша ничек үтәргә, салкын мөнәсәбәтләрнең элекке бозын ничек эретергә, ничек уртак тел табарга?* Галәмгә юл

3) Кеше психологиясен белүгә нигезләнгән, кешенең эчке дөньясын ача, күрсәтә торган. *Закирны соңгы актта психологик яктан бай, җанлы образ итеп, бөтен тулылыгы белән күрсәтергә кирәк*. М.Җәлил. *Психологик анализ (психологизм) – киң мәгънәдә кеше характерын, психологиясен тикшерү.* Сөембикә

4) *әд*. Персонажларның психологиясен тирәнтен сурәтләүгә корылган. *Җәләш, иҗтимагый бер тип булудан бигрәк, психологик характер итеп бирелә.* Г.Нигъмәти. *Көчле психологик романнар язучы Фёдор Достоевскийга гашыйк булуым өчен дә мин Фатих абыйга бурычлы*. Х.Сәлимҗанов

ПСИХОЛОГИСТ *и. рус* Психологизм (*1 мәгъ.*) тарафдары. *Кайбер психологистларның, монда аерым шәхес рухы түгел, бәлки милли рух, коллектив психологиясе аңланырга тиеш, дип караулары мәсьәләне төзәтә алмый.* Г.Алпаров. *Психологистлар телне рух эшчәнлеге дип таныйлар*. Ш.Рамазанов

ПСИХОЛОГИСТЛЫК *и. к.* **психологизм** (*1 мәгъ.*). *Ул тел гыйлемендә субъектив идеалистлык, психологистлык карашларын урнаштыра*. Г.Алпаров

ПСИХОЛО́ГИЯ *и. гр.* 1) Рухи, психик эшчәнлекнең закончалыкларын, үсешен, формаларын өйрәнә торган фән. *Иң авыры рус теле, дибез. Юк, алай түгел, иң авыры – психология!* М.Мәһдиев. *Хәзер социаль психология бик модада. «Үз канатың астындагы микроклиматны тирәнтен белү бик тә әһәмиятле», – диләр.* Э.Касыймов

2) Аерым бер эшчәнлекнең шартлары булып торган психик процесслар җыелмасы. *Грета медик дипломы алгач, без аның философияне һәм хайваннар психологиясен өйрәнә башлавын ишеттек*. А.Тимергалин. *Ахыр чиктә ул: «Халык артык үсенеп китмәсен өчен, коллык психологиясен саклау өчен махсус шулай корылгандыр бу», – дигән нәтиҗә чыгарды*. М.Маликова. *Төп сәбәпне безнең үзебездән, үзебезнең милли холкыбыздан, психологиябездән эзләргә кирәк.* Р.Зәйдулла

3) Психика, характер үзенчәлекләре, рухи халәт. *Сазаган кызның психологиясе үзенчә.* Ш.Галиев. *Шул фәлсәфә Тараканов кебекләрнең психологиясенә әйләнгән ---.* А.Хәлим. *Аның логик фикер йөртүе, төрле категория кешеләренең психологиясен нечкәләп белүе күп кенә хезмәттәшләрен сокландыра.* Ф.Вәлиәхмәтов

ПСИХОНЕВРО́ЛОГ *и. гр.* Психоневрология белгече. *Элегрәк бу алымның әһәмиятен аңлап, бакчада психоневролог, невропатолог, өстәмә шәфкать туташы, дәвалау физкультурасы инструкторы штатлары билгеләнә.* Ватаным Татарстан. *2009 елның сентябрендә Питрәч үзәк хастаханәсендә психоневролог булып эшләүче Рифат Галәвиевкә мөрәҗәгать итеп, памперс таләп иттем*. Шәһри Казан. *Нервлар күптәннән борчыса, психоневрологка мөрәҗәгать итәргә кирәк.* Ирек мәйданы

ПСИХОНЕВРОЛО́ГИК *с.* Психоневрология белән бәйле, психоневрологиягә мөнәсәбәтле. *Район оприничиклары Актаныштан тиз арада табиблар чакыралар. Сәкинә апаны алар карамагына тапшырып, Казанга психоневрологик диспансерга, икенче төрле әйтсәк, юләрләр йортына озаталар*. Я.Шәфыйков. *Карт белән карчык – психоневрологик диспансерның типик пациентлары ---.* В.Леви

ПСИХОНЕВРОЛО́ГИЯ *и. гр.* Медицинаның психик һәм нерв авыруларын өйрәнү һәм дәвалау белән шөгыльләнә торган тармагы. *М.Вахитов психоневрология институтында укый.* Р.Нафигов. *Мулланур да артык чишелеп китмәскә тырышып җавап бирде: – Мин Санкт-Петербургның психоневрология институтында укыганда ук сәяси түгәрәкләргә йөрдем.* С.Поварисов. *Күптән түгел Мәскәү өлкәсендә психоневрология хастаханәсендә янгын чыгып, 38 кешенең гомере өзелде.* Мәдәни җомга

ПСИХОПАТ *и. рус* 1) Психопатия белән авыручы кеше; псих. *[Шәехмирза:] Менә, профессор әфәнде, шаһит булыгыз, менә бу шифырт хәлфә кисәге мине ахмак, психопат дип тәхкыйрь итте*. К.Тинчурин. *1917 елның апрелендә «Богаулар өзелделәр» мәкаләсендә Русиянең элекке шәркый цензоры В.Д.Смирновка «кара вә ахмак психопат» дип бәя биргән әдип, совет хөкүмәтен һәм аның мәдәни сәясәтен Смирнов дәвереннән дә котсызрак дип атый ---.* Р.Әмирхан

2) *күч.* Үз-үзен тота алмаучы, дуамал кеше. *«Бу психопат антеннаның коллекторын ваткандыр», – дип уйлады капитан.* А.Тимергалин

ПСИХОПА́ТИЯ *и. гр.* Гадәттә нәселдән килә торган психик авыру, психиканың тотрыксызлыгы

ПСИХОПАТО́ЛОГ *и. гр.* Психопатология белгече. *Психопатолог киңәшләре. Психопатологка күренү*

ПСИХОПАТОЛО́ГИК *с.* Психопатологиягә бәйле, асылы психопатология булган. *Психопатологик билгеләрне комплекслы дәвалау. Төп психопатологик радикалның характерлы алмашынуы. Психопатологик тайпылышларның нозологик формасын дәвалау. Психопатологик тикшеренүләр*

ПСИХОПАТОЛО́ГИЯ *и. гр.* 1) Психиатриянең психик нормадан тайпылышларны өйрәнә торган тармагы. *Үзенең беренче хезмәтендә үк Павлов --- эксперименталь психопатологияне яңабаштан корырга теләге булу турында язды*. Совет әдәбияты

2) *җыл.* Психик нормадан һәртөрле тайпылышлар. *Интеллект югалу, хәтер җуелу, таркаулык, шизофрения, төрле төрдәге психопатология эчә торган кешеләргә генә түгел, ул*

кешеләрнең балаларына да кагыла. Казан утлары

ПСИХОТЕРАПЕВТ *и. гр.* Психотерапия белгече, табиб. *Психотерапевтка сөйләгәннәрем турында бүлмәгә кайткач уйланып утырдым да аны шушы дәфтәргә язып куярга булдым.* Т.Миңнуллин. *--- бу кичерешләренең бик үк нигезле түгеллеген Әхнәф чамалый башлаган иде инде. Казанга алдагы баруында, дөньясының чите кителсә дә, психотерапевтка керергә ныклап карар кылды*. Ф.Садриев. *Мин аларны психотерапевтка җибәрдем, чөнки психика бозылгач, андыйларга психолог кына ярдәм итә алмый.* Ватаным Татарстан

ПСИХОТЕРАПИ́Я *и. гр.* Авыруларны психикага тәэсир итү алымнарыннан (гипноз, үгет бирү, күңеленә салу һ.б.ш.) файдаланып дәвалау методы. *Үзгәртеп кору чорында экстрасенсларга зәңгәр экраннар аша тулы бер ил халкы өстендә психотерапия сеанслары уздырырга форсат бирелде*. Р.Зарипов. *Минем үземчә, аеруча киреренке игътибар талэп иткән эшемдә (психотерапия сеансларында) медитацияләр гадәттән тыш зур ярдәм итәләр*. В.Леви. *Хәзерге заман медицинасының психотерапия дип аталган тармагы белән безнең бабаларыбыз бик күптәннән шөгыльләнгәннәр һәм шуның тәэсирендә шифа да тапканнар ---*. Татар милли педагогикасы

ПСИХОТЕ́ХНИК I *и. гр. иск.* Психотехника белгече. *Хуш, кем инде ул психотехник, ниндирәк белгеч һәм эше аның нидән гыйбарәт? --- мин аны болай аңлатыр идем: психотехник ул – производствода эшләүче кешенең психологиясен һәм физик сәләтен өйрәнү нигезендә аның эш урынын һәм эш алымнарын мөмкин кадәр рациональ итеп оештыручы белгеч ---*. Ә.Еники

ПСИХОТЕ́ХНИК II *с. иск.* Психотехникага бәйле, психотехникага нигезләнгән

ПСИХОТЕ́ХНИКА *и. гр. иск.* Практик психологиядә кешенең берәр эшкә, профессиягә яраклы булу-булмавын билгеләү алымнарын өйрәнә торган тармак. *Психотехника ул үзе – Америкада туган нәрсә, аны үйлап чыгаручы һәм гамәлгә куючы, ялгышмасам, Тэйлор дигән бер инженер булган*. Ә.Еники. *Тирән профессиональ белеме һәм врач буларак бай тәҗрибәсе авторга практик психотехниканың бик нечкә мәсьәләләрен аңлатырга, --- аларны ышандырырлык итеп дәлилләргә мөмкинлек тудыра*. В.Леви

ПСИХОФИ́ЗИК *с.* Психофизикага бәйле, асылы психофизика булган. *--- дәресләр челтәре балалар мәнфәгатеннән һәм мөмкинлегеннән чыгып төзелә; дәресләрнең озынлыгы танып белү бурычларыннан, психофизик зарурлыктан, санитария-гигиена нормаларыннан чыгып билгеләнә*. Ә.Хуҗиәхмәтов. *Чын трагик артист – психофизик яктан сирәк очрый торган, аерым бер үзенчәлекле сыйфатка ия кеше*. М.Арсланов. *Тонус түбәнәю, астения – психофизик кәефсезләнүләрнең иң күп таралганы, аның төрле-төрле эчке көйсезлекләр нәтиҗәсендә булуы мөмкин*. В.Леви

ПСИХОФИ́ЗИКА *и. гр.* Эксперименталь психологиянең тынычсызландыру дәрәҗәсе һәм аны сизү көче арасындагы үзара мөнәсәбәтне тикшерә торган бүлеге. *Психофизикадан практика үтү*

ПСИХОФИЗИОЛО́ГИК *с.* Психофизиологиягә бәйле, асылы психофизиология булган. *Сабый чакларында ук аерылып, һичбер элемтәсез төрле гаиләләрдә тәрбияләнгән игезәкләр арасында аңлаешсыз психофизиологик багланыш гомер буена саклана ---*. А.Тимергалин. *Күрү, психофизиологик эшчәнлек буларак, кабул итү, образлы күзаллау процессында үсә*. Ә.Хуҗиәхмәтов. *[Шаталов] Психофизиологик «иләк» аша үтте, центрифугада, вибростендта, --- чикләнгән хәрәкәт шартларында сынау үтте*. Галәмгә юл

ПСИХОФИЗИОЛО́ГИЯ *и. гр.* Психологиянең психик күренешләр һәм аларның нигезен тәшкил иткән физиологик процесслар арасындагы мөнәсәбәтне өйрәнә торган бүлеге. *1885 елда университет каршында В.М.Бехтерев җитәкчелегендә Россиядә беренче психофизиология лабораториясе ачыла*. Фән һәм тел. *Психофизиология өлкәсендәге галим, зур белгеч Рәүф Мифтах улы да үзен шул сихри җыр дөньясы вәкиле итеп таный*. Мәдәни җомга

ПСИХРО́МЕТР *и. гр.* һаваның температурасын һәм дымлылыгын үлчи торган прибор. *Апа белән шушы сөйләшүдән соң әти термометрлар алып кайтты. Апам, иң төгәл күрсәтә торган икесен сайлап, теге психрометр дигән нәрсәне ясады*. Ф.Яруллин. *Һаваның чагыштырма дымлылыгын ике термометрдан торган психрометр ярдәмендә төгәл билгеләргә була.* Техник термодинамика

ПСОРИАЗ *и. гр. мед.* Нигездә тирене зарарлый торган йогышсыз хроник авыру, дерматоз. *Халык телендә «утлы су» дип йөртелә торган мацеста шифалы суының --- псориаз, экзема, нейродерматит, ихтиоз кебек тире бозылуларына, ашказаны, эчәкләр борчуларына файдасын күрәләр.* Т.Нәҗмиев. *Шулай бер дәрестә тире авыруларын үткәндә, минем кырыемда утырган Миша Соловьёвны псориаз авыруының билгеләрен сөйләргә бастырды.* Г.Галиев. *Псориаз белән экзема да йогышлы тире авыруларына керә дип уйлаучылар бар.* Ирек мәйданы

ПУ *иярт. к.* **пух**. *Минһаҗ малайның борынына бармагы белән баса да, аткан тавыш чыгарып: «Пу!» – дип кычкыра*. С.Баттал

ПУАНСОН *и. фр. тех*. Металлны кысып эшкәртү өчен, штампның кабарынкы өске кисәге. *Син дә бит әле кичә генә бер пуансонны тимерчелектә яндырдың. Оныттыңмыни?* А.Расих. *Европада Урта гасырларда, тәңкә сугу өчен, һәр хәрефкә аерым эшләнгән штемпель – пуансон да кулланганнар*. А.Мөхәммәдиев. *Пуансон белән матрица бергә ябылгач, пресс формада алыначак эшләнмәгә тәңгәл аралык барлыкка килә*. Төзү материаллары

ПУ́БЛИКА *җыйм. и. лат.* 1) Театр, кинотеатр, парк һ.б.ш. урыннарга спектакль, фильм, концерт һ.б. тамаша карар өчен җыелган кешеләр, тамашачылар. *Гәрәй һәм тагын ике егет бергәләп матрос булып биеделәр. Публика барысына да котырып кул чапты*. И.Гази.

Өч матадор, алты үгез... Ике сәгать вакытта без Үлем уены осталарын Күзәтергә бүген тиеш. Публиканы сокландырып, Үлем белән уйнап, алар Хәзер мәйдан тотачаклар. Р.Гаташ. *Көндезге, кичке аш хисабына артистлар җырлап, уйнап, шигырь сөйләп, публиканың күңелен ачарга тиеш булалар.* Р.Батулла

2) *шаярт.* Нинди дә булса бер уртак билге буенча берләшкән аерым кешеләр төркеме; җәмәгать. *Ә хәзер аны публика таныды, ул зур гына чин алуга иреште.* Ә.Баян. *Ахунов «Хәзинә» дигән романы белән --- русча укый торган публика алдында да ике кабат әйбәт сынау бирде*. Х.Сарьян. *Мин Дөбъязга маймыл сурәте төшерелгән галстук тагып кайттым. Дөбъяз халкы – бик нәзберек, зәвыклы публика, андый купшылыкны бер дә килештерми.* А.Хәсәнов

3) *сөйл*. Җыелган халык, кешеләр. *Вагон эчендәге публиканың үзара мөнәсәбәте яхшы ук үзгәргәне күренә*. Г.Гали

ПУБЛИКА́ЦИЯ *и. лат.* 1) Массакүләм мәгълүмат чаралары аркылы халыкка җиткерелү, дөньяга чыгарылу. *Китапны публикациягә тәкъдим итәргә* // Басылып чыгу факты. *Закон публикация моментыннан алып гамәлгә кергән санала*

2) Газета-журналда, китапта басылган, нәшер ителгән әсәр, хезмәт үзе. *Утыз еллар «Казан утлары» журналында эшләгән чорымда, --- һәр сан чыгу белән аны укып, --- бер-бер кызыклы публикация турында иң беренче булып син шылтыратып сөйләшәсең, аннан инде редколлегия утырышларында янып чыгыш ясыйсың*. Х.Миңнегулов. *«Совет Татарстаны» газетасында безнең «Мулланур Вахитов мәкаләләре» дигән публикацияләребез бар*. Р.Нафигов. *Газетабыз «Татарстан Республикасында террорчылык һәм экстремистлыкка каршы тору» --- темасын яктырту буенча басма матбугат чараларындагы иң яхшы публикация» номинациясендә беренче урынга лаек булды*. Шәһри Казан

ПУБЛИЦИСТ *и. рус* Иҗтимагый-сәяси темаларга язучы автор. *Григорий Булах танылган язучы, публицист, дистәләгән киносценарийлар, фильмнар авторы гына түгел, --- Украинаның халык артисты --- да икән.* А.Хәлим. *Г.Исхакый – әдәби иҗат белән генә шөгыльләнүче коеп куйган әдип кенә түгел, ә җәмәгать эшлеклесе, тарихчы, сәясәтче һәм көчле публицист та*. Х.Миңнегулов. *Гази Кашшаф язган соңгы мәкаләсендә --- язучылык хезмәте белән публицист хезмәтенең тыгыз бәйләнештә торуын исбат итте.* И.Низамов

ПУБЛИЦИ́СТИК *с*. 1) Иҗтимагый-сәяси мәсьәләләргә караган. *Аның Казан, Оренбург, Уфа нәшриятларында --- байтак кына публицистик мәкаләләре дөнья күрә*. М.Гафури. *Матур әдәбият әсәрләрендә, публицистик әдәбиятта, матбугатта гади сөйләм сүзләре һәм диалектизмнар, персонаж сөйләмен бирү өчен, билгеле бер дәрәҗәдә кулланылырга мөмкин*. Р.Йосыпов. *Соңгы ярты гасырда һәрбер яңа китап-шигырьләр җыентыгымы ул, --- публицистик газет-журнал мәкаләсеме – иң элек Айрат кулына килеп керә иде*. Р.Заһидуллина

2) Публицистикага мөнәсәбәтле, публицистикага хас. *Очерк публицистик ялкынлылык белән язылырга --- тиеш.* Г.Иделле. *--- татар журналистикасы секциясендә Гази Кашшафның фәнни һәм публицистик мирасын өйрәнү --- юнәлешендәге фәнни эзләнүләр дә бәян ителде.* И.Низамов. *«Акай явы хикәяте» – XVIII гасыр татар әдәбиятының «Батырша гарызнамәсе» кебек үк көчле публицистик үрнәге*. М.Әхмәтҗанов

ПУБЛИЦИ́СТИКА *и. лат.* 1) Җәмгыятьтә барган мөһим икътисади, иҗтимагый-сәяси, мәдәни һ.б. вакыйгаларны яктырткан әдәби жанр. *Фән һәм публицистика телендә алынмалар шактый киңрәк кулланыла ---*. Р.Әхмәтьянов. *Язма сөйләмдә мондый төп стильләр аерылып тора: эш кәгазьләре стиле, фәнни иншалау стиле, публицистика стиле*. Х.Курбатов. *Ул вакытта барыннан да элек язучылардан оперативлык таләп ителә. Шунлыктан сугыш елларында прозада публицистика һәм хикәя жанры өстенлек ала*. Р.Зарипова

2) Иҗтимагый-сәяси әдәбиятның башка жанрдагы әсәрләрдә кулланыла, очрый торган үзенчәлекле сыйфатлары, элементлары. *Язучы күп урында Бикташовны җанлы хәрәкәттә, бәйләнештә, җанлы сурәт итеп художество чаралары белән ачу урынына, турыдан-туры публицистикага бирелеп, аның идеяләрен сөйләп китә*. М.Җәлил

3) *җыйм., әд*. Шул жанр әсәрләре. *Газеталар да лирик шигырьләргә караганда публицистиканы күбрәк басалар.* Л.Ихсанова. *Үзгәреш җилләре исте, үзәк журналлардагы публицистикада авыл хуҗалыгына карата бөтенләй яңа фикерләр әйтелде ---*. Р.Зәйдулла

ПУГАЧ *и. рус иск.* Көчле тавыш чыгарып ата торган уенчык пистолет. *Кая инде ул мондый караңгыда тидерү! Кеп-кечкенә браунингтан ату пугач пүкелдәтү генә булып калачак иде*. Г.Бәширов. *Тәннәре кояшта янган, башларына киң кырыйлы салам эшләпә кигән, биләренә пугач --- таккан малайлар менә дигән сугыш чукмарларына охшыйлар иде*. Г.Әпсәләмов. *Моңынчы яшь-җилкенчәк пугач атып кына шаяра иде ---!* Ж.Дәрзаман

ПУ́ДЕЛЬ *и. нем.* Өч төрле зурлыкта – зур, кечкенә, карлик – һәм төрле төстә була торган, озын бөдрә йонлы декоратив эт токымы. *Чио-Чио-Сан кушаматлы ак пудель – Полкан төркемендәге әнкә этләрнең иң яше, иң матуры*. А.Хәсәнов. *Кешеләр декоратив этләрнең дә 50 дән артык токымын чыгарганнар. Аларга төрле терьерлар, болонка, пудель һәм башка күп кенә токым этләр керә*. Ф.Ибраһимова. *Син болай ит: пудель ал. Үзе кечкенә, аз ашый, матурлыгы да бар.* Ф.Зариф

ПУ́ДИНГ *и. инглл. кулин.* Он, ярма яки эремчеккә шикәр, йомырка, май, төрле җимешләр, тәмләткечләр һ.б.ны кушып әзерләнә торган куе боткага охшаш ашамлык. *Бераз уйлап торгач, кылана төшеп әйтте: – Бер порция сөләйман балыгы, шашлык, пудинг, зәйтүн җимеше, бер шешә сыра*. М.Юныс. *Вьетнамлылар аңардан кайнатма әзерли, европалылар ит яки*

балык ризыкларын әзерләгәндә куллана, инглизләр пудингларына имбир цукаты куша. Шәһри Казан

ПУ́ДРА *и. фр.* 1) Биткә, муенга яга торган гаять вак һәм йомшак, күбесенчә хуш исле порошок; кершән. *Мин әле сөрмә тарта, пудра яга белмим, әмма хушбуйның бик нәфис ислесен сөртергә яратам.* Ә.Еники. *Ефәк халат кигән хатын битенә пудра сөртте, чәчен тарап кабартты.* М.Юныс. *Пудра сөртмәсәң дә ап-ак булган йөзе хәзер кап-кара, касмакланган.* З.Вәли

2) Нинди дә булса бер каты матдәнең (шикәр, күмер һ.б.ш.ның) бик ваклап төелгән рәвеше. *Әзер алмаларга шикәр пудрасы сибәргә.* Тигез гомер итегез!

ПУ́ДРАЛАНУ 1) *төш. юн. к.* **пудралау**. *Пудраланган, кызыл иннекләр сөрткән Фатыймага арткы рәттә утыру авыр була.* А.Алиш. *Сәрвәр ханымның аз гына пудраланган бите буйлап яшь бөртекләре тәгәрәде.* А.Гыйләҗев. *Сәгыйдәнең дә артык тырышып пудраланган йөзе сөйкемсез булып тоела башлады.* Г.Ахунов

2) *кайт. юн. к.* **пудралау**. *Бу кыз ныкпудраланырга ярата*

3) Каты матдәнең бик ваклап төйгәннән соң пудрага әйләнүе. *Шикәрне пудраланганчы төяргә*

ПУ́ДРАЛАУ *ф.* Пудра сөртү; кершән ягу. *Алар сәгать унберләргә кадәр --- рәхәтләнеп биеде, ә җырчылар бу арада сәхнә артында борыннарын пудраларга да, --- интервью бирергә дә – барысына да җитеште.* Мәдәни җомга

Пудралап алу Тиз генә пудралау. *Шулай дип алар аһ вә зарларын җиде кат күккә ашырырлар вә көзгегә карап борын өстләрен пудралап алырлар иде.* Ә.Исхак

Пудралап җибәрү Бераз гына пудралау. *Коендыргач, тирегә балаларга сибә торган порошок яки тальк сибеп, пудралап җибәрәләр.* Тигез гомер итегез!

Пудралап кую Алдан ук пудралау

Пудралап тору Хәзер, шушы вакытта пудралау

Пудралый башлау Пудраларга тотыну

ПУҖУМ *и. рус диал.* Йорт һәм бәрәңге бакчасы урыны; ихата (*2 мәгъ.*). *Ташлыяр аръягында --- яшәп яткан ятим-ялпы хуҗалыклар да тиз-тиз авыл уртасында бушаган пуҗумнарга күченделәр ---.* А.Гыйләҗев. *Ике бертуган булган алар. Янәшә пуҗумда яшәгәннәр, өйләре өйгә орынып кына торган.* Л.Ихсанова. *--- әти илленче еллар башында Тукай урамының хәзерге 35 нче йорты урнашкан җирдән, халыкчан итеп әйтсәк, пуҗум алып, яңа өй җиткерде.* Татарстан яшьләре

ПУК-ПУК *иярт.* **1.** *к.* **пух**

2. *хәб. функ.* Атуны белдерә. *Якын киләсе булма, юкса пук-пук үзеңне!* Ш.Маннур

ПУЛ I *и. гр. иск.* Акча, тәңкә. *--- грек, Рим, Византия, я булмаса гарәп акчаүлчәү системасында барлыкка килгән казанышлар, драхма – дирһәм, статер – сатыр, фоллис – пул кебек атамалар төрки-татар акча-үлчәү системасында да чагылыш тапкан ---.* А.Мөхәммәдиев. *Без Җәгъфәр белән мунча хезмәткәренә ике пул акча тоттырдык та алгы чишенү бүлмәсенә үттек.* А.Тимергалин. *Төркиләр бакыр акчаларны гомумиләштереп, пул дип атап йөрткәннәр.* Г.Мөгътәсимова

ПУЛ II *и. инг.* Предпринимательләрнең махсус гомуми фондка тупланган табышны алдан билгеләп куелган пропорцияләрдә бүлешүгә нигезләнгән берләшү формасы

ПУЛАТ *и. рус* Ташдан салынган зур өй; таш сарай. *Ул куйган бер хезмәтне санап тәли башласаң, пулат салдырырга кирәк булыр иде.* А.Гыйләҗев. *Ай яктысында кешеләр Думпасның пулатын эзләп тапканнар да, ишекләрен ватып, яшереп куйган йолдызларны азат итеп, кире күккә менгезеп куйганнар.* Р.Батулла. *Дәүли моңарга эче пошып, кайчан да булса бер баегач, иркен пулатлар салу хакында хыялланып та йөри иде, әлбәттә.* Г.Мөхәммәтшин

ПУЛЕМЁТ *и. рус* Пуляларны өзлексез һәм зур тизлек белән ата торган автомат корал. *Гражданнар сугышы вакытында шулай без бер рота кызыл-армеец идек, җыеныбызга бер пулемёт, ике винтовка, патроннар да юк...* Г.Кашшаф. *Шунда ук тишекле кожухы еланны хәтерләткән немец пулёметын алып брустверга җайлады һәм атырга кереште.* Х.Камалов. *Әмир абый, җиргә чыбык белән сыза-сыза, йозакның пулемётта кай төштәрәк торуын сөйләп бирде.* Д.Галимов

ПУЛЕМЁТЧЫ *и.* Пулемёттан атучы кеше. *Улым пулемётчы иде. Смоленск янында үлеп калган.* Ш.Галиев. *Бая штабка кергән малай пулемётчы кырыенда аңа ярасын бәйләргә булыша иде.* Д.Галимов

ПУЛЕМЁТЧЫЛЫК *и.* Пулемётчы булу, пулемётчы хезмәте. *Пехота командиры Храбрый Костиннан аны үзенә пулемётчылыкка сорап йөри.* Г.Гобәй

ПУЛО́ВЕР *и. инг.* Гәүдәгә сыланып торган якасыз һәм каптырмасыз трикотаж кофта. *Барысына да бүләкне Наташа үзе сайлап алды: әниләренә бик матур бәйләм кофта, әтиләренә пуловер ---.* Р.Хәбибуллина. *Чегәннәр әллә кайда ерактагы әмеркәнски «Монтана» тамгасы тегелгән ялган, ясалма свитер һәм пуловерлар сатып йөриләр икән.* Р.Мирхәйдәров. *Калын пуловерны салып, юракка алыштырырга кирәк, дигән уй белән, шифоньерның аскы киштәсеннән җиңел киемнәрне чыгарып, иртәгәгә әзерләп куйдым.* Татарстан яшьләре

ПУЛТ *иярт. к.* **пылт**. *[Сәгыйть] сал астыннан пулт итеп килеп чыккан.* М.Шабаев. *Шунда әти: «Беттем!» – диде, пулт итте дә суга чумды.* А.Хәсәнов

ПУЛЬВЕРИЗА́ТОР *и. лат.* һава яки башка газ агымы ярдәмендә сыекчаны бөркү, сиптерү өчен кулланыла торган җайланма. *Яңгыр бик вак ява; гүя яңгыр түгел, тик әллә кайдан караңгы ераклардан пульверизатор белән битләргә салкын су бөркеп торалар; вак су бөртекләре битләрне кытыкландыра, күз эчләренә керә.* Ш.Камал. *Баграт атна саен я бәллүр пульверизатор, яисә маймыл рәсеме төшкән галстук --- күтәреп кайта.* М.Юныс. *Буяу катнашмаларын сылау ысуллары: пумала, валик һәм пульверизатор белән, киптерү шартлары буенча − салкын һәм кайнар ---.* Төзү материаллары

ПУ́ЛЬМАН *и.* Уйлап табучы һәм җитештерүче фирма хуҗасы исеме

белән йөртелгән пассажирлар вагоны төре. *Бер тәүлек эчендә без, барлык боеприпасларны ташып, сигез пульман вагонына --- төяп тә куйдык.* Ә.Еники. *Иң гаҗәбе шул булды: без утырган вагон артындагы тузанлы пульманга болар да утырдылар.* Н.Фәттах. *Терлек азыгы әзерләү цехы ягыннан пульман вагоны кадәрле азык тараткыч таккан «Беларусь» тракторы күренде.* М.Хәсәнов

ПУ́ЛЬПА *и. лат.* 1) *мед.* Тешнең эчендәге йомшак матдә (аңа нервлар урнашкан була); теш йомшагы. *Кариеслы тешне вакытында дәваламасаң, --- тора-бара процесс дентиннан теш йомшагы – пульпага күчә, һәм ул ялкынсына башлый.* З.Хисамов. *Бу очракта сызлау дәваламыйча да бетәргә мөмкин, чөнки пульпа үзенең сизү сәләтен югалта һәм авыру кеше тынычлана: табибка бармый.* Туган як

2) *иск.* Җимешнең, орлыкның кабык эчендәге йомшагы

3) *махс.* Җир һәм тау эшләрен көчле басым астындагы су белән юдырып башкарганда барлыкка килгән масса – тау токымы яки балчык белән су кушылмасы. *Битумлы катлам гидромониторның зур басымлы суы ярдәмендә киселә, тураклана һәм, пульпа булып, улаклар буенча шахта кәүсәсенең ишегалдына – камерага ага.* Фән һәм тел

4) *тех.* Металлны аерып алу өчен, су яки башка эреткеч салып сыеклатылган вак руда

ПУЛЬПИТ *и. лат. мед.* Теш йомшагы ялкынсынуы. *Әгәр дә мондый тешне дәваламасаң, «җимерелү» процессы тагын да көчәеп, пульпит дигән авыру китереп чыгара.* Ватаным Татарстан. *--- гади генә кариес та пульпитка әйләнергә мөмкин.* Шәһри Казан. *Әгәр табибка пульпит белән килгәнсез икән (ул вакытта теш нервысы ялкынсына), тешне дәвалаганда, нерв җепселләре алына һәм теш каналына тирән пломба салына.* Идел таңнары

ПУЛЬС *и. лат.* 1) Йөрәк кысылып кан этәргән саен, артериаль кан тамырлары стенасының өзек-өзек тирбәнеше; тамыр тибеше. *Ара-тирә Казан хирургының: – Капельницаны карагыз!.. Кан басымын күзәтегез!.. Пульс, пульс! – дигән сүзләре генә --- яңгырап китә иде.* Р.Ишморатова. *Тирән сулыш алмагыз, пошаманга да төшмәгез, кискен хәрәкәтләр дә ясамагыз, чөнки ул очракта пульс ешая, һәм һава күбрәк кирәк була.* Сабантуй // Кан тамырларын капшап караганда, шул тирбәнешләр сизелә торган урын. *[Командирның] пульсын карадым, йөрәге хәлсезләнгән булса да, сизелер-сизелмәс кенә тибә иде әле.* Р.Мөхәммәдиев. *Фельдшер аның пульсын карады һәм, башын чайкап, чемоданына үрелде.* Р.Кәрами. *Баш конструктор, үзе дә сизмәстән, үзенең пульсын тотып карады.* Галәмгә юл

2) *күч.* Тормыш, хәрәкәт һ.б. ритмы, темпы. *Паровоз төтеннәренә чумган Казан вокзалы күренде. --- Тегендә дә, монда да күмер төягән арбаларны этеп йөртәләр, паровоз ачы-ачы кычкырта, кайнар бәрәңге боламыгы сатучылар йөгерешәләр. Вокзал – шәһәрнең пульсы.* М.Мәһдиев. *Әнә шулай идеология пульсы белән сугарылып торган әдәбият мәйданына алтмышынчы елларда көчле дулкын булып Фәйзуллиннар плеядасы килүе табигый иде.* М.Галиев

ПУЛЬСАР *и. ингл. астр.* Космостан даими рәвештә төрле көчтәге радио, рентген, гамма импульслар җибәрә торган нурланыш чыганагы. *Мин – тоташ ут: Аңлау кыен мине, Ир-хатынга җирдә ераКмын! Әмма сизәм пульсар йолдыз белән Бергә типкән ритмын йөрәкнең!* С.Гәрәева. *Беренче биттә ул-бу юк: Үрмәкүч планетасы гуманоидлары Кыз йолдызлыгындагы ундүрт пульсар йолдызны урлаганнар.* З.Мәхмүди. *Беләсезме, Габбас абый, минем өчен шундый ике чыганак бар: аның беренчесе – үземә генә билгеле булган якты йолдызым – пульсарым, икенчесе – менә шушы гармун, музыка.* Г.Гомәр

ПУЛЬСА́ТОР *и. лат. тех.* Даими рәвештә тигез ритмик өзеклекләр ясап эшли торган прибор, механизм. *Агрегатны яңабаштан карап, һәр детален җентекләп күздән уздырырга булдылар. Бары тик шунда гына насосларны эшләтә торган редукторның пульсаторы үз урынында юклыгы билгеле булды.* М.Хәсәнов

ПУЛЬСА́ЦИЯ *и. лат.* 1) *физиол.* Йөрәк мускуллары кысылудан барлыкка килгән ритмлы кан тамыры тибеше

2) *физ.* Берәр күренешнең өзлексез кабатланулы үзгәреше (мәс., сыеклыктагы газ куыкчыкларының күләмнәре һәм формалары үзгәрүе). *Бу мәсьәләгә кагылышлы кайбер фаразлар системасына тукталып китик: җилнең нормалаган уртача тизлеге даими ---; җил тизлегенең пульсациясе исәпкә алынмый; һава ламинар һәм яссы агым булып хәрәкәт итә.* Фән һәм тел. *Ток пульсацияләре. Түбән ешлыктагы пульсация*

ПУЛЬСА́ЦИЯЛӘҮ *ф.* 1) *физиол.* Пульсы булу, тибү (йөрәк, артерияләр тур.)

2) *физ.* Берәр күренеш өзлексез кабатланып үтү

Пульсацияләп тору Даими рәвештә пульсацияләү; әле, хәзерге моментта пульсацияләү

Пульсацияли башлау Пульсацияләргә тотыну

ПУЛЬСА́ЦИЯЛЕ *с. физ.* Зурлыгы билгеле бер период белән үзгәрсә дә, юнәлеше бер якка гына булган. *Пульсацияле ток*

ПУЛЬТ *и. лат.* 1) Музыка коралында уйнаганда, ноталар кую өчен озын терәккә беркетелгән авыш тактадан гыйбарәт җайланма. *Дирижёр пульт артына менеп басты. --- Оркестрда кереш музыка башланды.* Ш.Хөсәенов

2) *тех.* Нәрсә белән дә булса идарә итү приборлары куелган урын (өстәл, стенд, колонка яки җайланма). *Стенның өстен салдырып, плащын элеп куйды, үзен идарә пульты янына алып килеп урындыкка утыртты.* А.Тимергалин. *Разия пульт янына килеп аппаратларны тоташтырды, һәм нидер гөжли, зырылдый башлады.* Р.Кәрами. *Леонов --- эчкә карады һәм анда --- кинокамераны, шлюзлау системасының идарә пультын, камераның чирәп түбә кабыргаларын хәтерләтүче сырлы стеналарын күрде.* Галәмгә юл

ПУ́ЛЯ *и. рус* Мылтык, пулемёт, алтатар кебек утлы кораллардан ату өчен, озынча коник формадагы кечкенә

снаряд; шуның патрон эчендә, гадәттә очлы башында була торган өлеше. *Ә бу юлы кешеләр шул җиздән патрон ясаганнар. Эченә дары салганнар, башына кургаш пуля куйганнар.* Н.Дәүли. *Яктыра башлаган иде шул, ятып кына өлгерделәр, төрле яктан выж да выж пулялар оча башлады ---.* А.Гыйләҗев. *Әгәр пуля сезнең мәсьәләләрне шундук хәл итә ала икән, без аны нәкъ маңгаена утыртырбыз.* Р.Мирхәйдәров

◊ **Пуля кебек** Бик тиз (эш-хәрәкәт темпына карата). *Арабыздан бердәнбер ул, батыраеп, баскычлардан өскә менеп китте. Хәтәр биектән, үтәкүренмәле торбалар эченнән, борыла-борыла, пуля кебек атылып төште дә бассейнга чумды.* М.Галиев. *Сорау алучы абый җилкәләрен сикертеп аптырап торган арада, пуля кебек икенче катка атылдым.* М.Әхмәтшина

ПУ́МА *и. исп.* Мәчеләр семьялыгыннан Төньяк һәм Көньяк Американың тау урманнарында таралган, саргылт көрән төсле, зур гәүдәле ерткыч хайван; кугуар

ПУМАЛА *и. рус* 1) Таяк очына бәйләнгән мунчала яки чүпрәктән гыйбарәт эш коралы. *--- Сабира түти, стенага терәп куйган пумаласын тотып, чиләген күтәреп, яшьләр янына кузгалды.* А.Әхмәтгалиева. *Узе чамасыз ябыккан, әйтерсең ел буена кеше яшәми торган утрауда көн күргән: сакал-мыек баскан, чәче мич төбе себерә торган пумала кебек...* З.Вәли. *Таштимерова һаман әле, иелгән килеш, резин итеген сулы пумала белән ышкый иде.* М.Маликова

2) Нәрсәне дә булса буяу өчен, гадәттә кыска таяк очына утыртылган кыл бәйләме. *Әңгәмәнең чамалы икәнен сизенгән директор, пумаласын буяуга манып, киндергә тагын ниндидер сызыклар төшерә башлады.* Ә.Баян. *Ядкәр буяу пумалалары табып куя, Гамил белән Таймас олифа алып кайталар ---.* А.Тимергалин. *Чоланда төрле-төрле пумалалары да, рәссамнарга кирәкле картон да ---, шактый күп буяулар да табылган.* Р.Мирхәйдәров

3) *күч. гади с. кимс.* Тузыган чәчле кеше, гадәттә хатын-кыз турында. *Җитәр, пумала, әйт, дим, мин сиңа, кем тирес түкте?* М.Әмир

◊ **Пумала баш** 1) *к.* **пумала** (*3 мәгъ.*). *Уйладым, уйладым да шул пумала баш чырылдык кызларга әйтмәскә булдым.* Н.Әхмәдиев. *Әллә бу тишек эскәтерне төргәккә чынлап та пумала баш Зөлхәбирә тыкканмы*? А.Хәлим; 2) *кимс.* Гомумән хатын-кыз турында. *Аля – ирдән аерылган хатын, --- өйләп дип бәйләнми, кайбер пумала башлар кебек, нәрсәгәдер өметләнеп, егет күңелен кайтарырдай юк-бар таләпләр куймый ---.* Р.Кәрами. **Пумала тел** Күп сөйли торган. *Мәүлиха апага да ачуым зур иде. Пумала тел инде, нишләтәсең аны.* А.Гыйләҗев

ПУМАЛАЛАНУ *ф.* Пумала кебек булу, тузгу. *Бите-күзе тырналып беткән, чәчләре пумалаланган, киемнәре пычракта аунаган кебек.* Казан утлары

Пумалалана башлау Пумалалану билгеләре күренү

Пумалаланып бетү Бик нык, бөтенләй пумалалану

Пумалаланып тору Пумалаланган хәлдә булу. *[Курчакның] борыны озын, сары чәче пумалаланып, җилләнеп тора.* М.Җәлил

ПУНКТ *и. лат.* 1) Җир өстендә билгеле бер урын, нокта. *Картага иелеп, связной әйткән пунктларны карыйм.* И.Гази. *Без – бергә юлга чыгып та, «а» һәм «б» пунктларыннан төрле вакытта кузгалган, гомергә очрашмаска тиешле юлчылар гына.* А.Гыйләҗев. *6 км йөзеп уткәннән соң, ул ишкәкләрен көймәгә куя, һәм N пунктыннан чыгып 4 сәг. 30 мин тан соң, агым аны яңадан N пунктына кайтара.* Алгебра

2) Кеше яши торган урын (авыл, шәһәр һ.б.). *Ерак пунктлардан иген ташу, йөк йөртү атка йөкләнә.* М.Гафури. *Су басудан аеруча зыян күргән районнарда хәзер җир һәм һава транспорты эшләми, торак пунктлар төзекләндерүгә мохтаж, кешеләр утсыз утыра.* Шәһри Казан. *Ул көнне иртәнге сәгать 8.45 тә һәр пункттан --- берәр автобус берьюлы бәйрәм буласы урынга кузгала һәм бәйрәмнән соң кире алып та кайта.* Татарстан яшьләре

3) Берәр эш-шөгыль өчен махсус җиһазландырылган урын. *Авылда ул чакта медицина пунктлары юк.* Ә.Баян. *Нефть скважиналары белән читтән торып – диспетчер пунктыннан гына идарә итәргә тиешләр бугай...* М.Хәсәнов. *Анда иң беренче эш итеп милиция пункты ачарга туры киләчәк әле!* М.Маликова

4) Рәсми эш кәгазьләрендә яки берәр текстта цифр яки хәреф белән билгеләнгән аерым статья, бүлек, параграф. – *Конкурс шартларының берсе, квартира белән тәэмин ителә, дигән пункт иде, – диде Чәмәт*. Х.Сарьян. *Юк, Аркадий Модестович, анкетадан кайбер пунктларны әйтү ул әле кешене белү дигән сүз түгел*. М.Хәсәнов. *Шуңа күрә көндәлек план төзүнең төп принцибы шул: пунктлар никадәр аз күздә тотылса, шулкадәр яхшырак*. В.Леви

5) Докладта, чыгышта, бәхәстә аерым фикер, мәсьәлә. *Зөһрә туташ, бу пунктта мин сезнең якта инде.* Ф.Әмирхан. *Бу пунктта мин Вәгыйзов ипташ белән тулысынча кушылам*. К.Тинчурин. *Көн тәртибе 18 пункттан торды*. Ватаным Татарстан

6) *махс*. Типография системасында хәрефләрне һәм буш калган урыннарны исәпләү берәмлеге (0,376 мм га тигез)

7) Берәр нәрсәнең үсешендә аерым момент. *Кульминацион пункт*

ПУНКТИР *и. лат.* **1.** Нокталар яки сызыклардан гыйбарәт өзек-өзек сызык, тоташ булмаган линия. *Кинәт төтен эченнән танкның куркыныч зур гәүдәсе килеп чыкты, ул инде берничә метрда гына иде, аның клёпкалар пунктиры белән шадраланган борты күзгә чалынып китте*. Х.Камалов. *Аның әйләнә-тирәсендә пәрәвез кебек тунельләрнең кара пунктир сызыклары җәелгән*. А.Азимов

2. *с. мәгъ*. Нокталар яки сызыклардан гыйбарәт, өзек-өзек. *Пунктир кәкре сызыклар ток тудырган магнит кырының көч сызыкларын күрсәтә.* Магнетик күренешләр физикасы

ПУНКТИРЛА́У *ф*. Пунктир сызу, пунктир төшерү

Пунктирлап бетерү Тулысынча пунктирлау

Пунктирлап чыгу Баштан ахырга кадәр барысын да пунктирлау

Пунктирлый башлау Пунктирларга керешү

ПУНКТЛАП *рәв.* 1) Аерым пунктлар рәвешендә; пунктларга бүлеп. *Әсәрнең беренче битендә үк Коръән аяте китерелү, нәтиҗәләрнең пунктлап, санап чыгу рәвешендә бирелүе – әлеге жанрга хас билгеләр.* Фән һәм тел

2) Эзлекле рәвештә, тәртип белән; җентекләп. *[Алар] бу [кагыйдәләр] дә мәктәпләр өчен төзелгән икәнен пунктлап исбат итәләр икән.* Ф.Әмирхан. *Авылда кануннарны интегеп язып тормаганнарын да белә ул. Тик аларны һәркем чамалый. Чама хисен югалткаларга да пунктлап аңлатмыйлар: төшендерергә кыска гына бер җөмлә дә, кайчакта бер караш та җитә.* Ф.Җамалетдинова

ПУНКТУАЛЬ *с.* Берәр эшне җиренә җиткереп үтәүчән, бик төгәл. *Кызый бик тәртипле, пөхтә, пунктуаль, эшен дә җиренә җиткереп башкара.* Р.Кәрами. *Ринат Галимҗанович – бик пунктуаль, төгәл кеше.* Т.Нәҗмиев. *Өстәвенә, ул – пунктуаль кеше дә: кушылган эшне-йомышны нәкъ вакытында эшләп алып килә иде.* Сәхнә

ПУНКТУА́ЛЬЛЕК *и.* Пунктуаль булу үзлеге. *--- вак кына детальләрдән дә гомумиләштерүләр ясау, детальнең өлешеннән бөтенне күрү – болар шәхестән энциклопедик белем, анализ һәм синтез алымнарын белү, пунктуальлек кебек сәләтләр талап итә.* Р.Фәтхерахманов. *Игезәкләр тыныч атмосфераны ярата. Үз белемнәрен максатчан файдалана белә, пунктуальлек, түземлелек сыйфатлары белән аерылып тора.* Матур буласың килсә. *Татарларда алманнардагы пунктуальлек юклыгын исәпкә алып, 10–15 минутка соңрак килдем.* Шәһри Казан

ПУНКТУА́ЦИЯ *и. лат. лингв.* Тыныш билгеләрен кую кагыйдәләре системасы һәм тел белеменең шуларны өйрәнә торган тармагы. *Ә язуда инде хәзерге орфография һәм пунктуация кагыйдәләренә буйсынырга мәҗбүрбез ---.* И.Низамов. *Өйрәнү материалы булып хезмәт иткән халык җырларының күрсәтелгән чыганаклардагы вариантлары, ягъни шундагы орфография һәм пунктуация сакланды.* К.Миңнуллин. *Әлбәттә, имла кагыйдәләре – грамматика, тыныш билгеләре кагыйдәләре – пунктуация, җөмлә һәм сүз төзелеше морфология һәм синтаксис дип тәгаенләнгән.* Р.Зарипов

ПУ́НКЦИЯ *и. лат. мед.* Авыруны билгеләү яки дәвалау максаты белән, организмга сыекча, һава, газ кертү яки аннан суыру өчен, тәнне кадап тишү. *Палач врачлар аның өстендә эксперимент ясаганнар. Арка миенә пункция эшләп, ниндидер даруларын сынап караганнар.* Х.Камалов. *Ул миңа улымның үпкәсендә яман да усал, әшәке авыру – стафилококк ялкынсынуы башлануын әйтте, һич кичекмичә пункция ясарга кирәклеген --- аңлатты.* Э.Шәрифуллина. *Әле кичтән генә егерме яшьлек Косой җан тәслим кылды: пункция алганда арка миен имгәткәннәр.* И.Сиражи

ПУНСОН *и. фр. махс.* Матрица ясау өчен, бер ягы кабарынкы хәрефтән яки башка билгеләрдән гыйбарәт дүртбурычлы тимер кисәге, калып. *Хәрефләрне кою өчен, калып – пунсон эшләнә.* Ә.Кәримуллин. *Сенат типографиясендәге гарәп хәрефе белән коелган матрицалар һәм пунсоннар Казанга күчерелә.* И.Рәмиев

ПУНШ *и. инг.л.* Кызыл аракыга, коньякка су, шикәр, лимон суы яки берәр төрле җимеш суы кушып ясалган, җылы килеш эчелә торган исерткеч эчемлек. *Әгәр дә сез бәйрәмне үткәрергә дусларыгызга чакырылгансыз икән, үзләре әзерләгән коктейль, пуншлар белән бик мавыкмагыз.* Сөембикә. *Күңеле тулган городничий аларны кочаклап ала да пунш һәм чәй белән сыйлый.* Яңа тормыш

ПУПАЛА́У *ф. гади с.* Сөйләү, сөйләшү. *– Түти, ә сез кияү белән ничек аңлаштыгыз соң? – дип сорады егет. Күрше карчыгы --- кеткелдәп тә алды: – Ул үзенчә пупалый, мин үземчә әйтәм, аңламаганын кызым төшендереп бирә.* Р.Кәрами. *Ул тылмач вазифасын да үти иде, ахры, офицерга барысын да җиткереп бара. Югыйсә тегесе үзе дә русчаны шактый әйбәт пупалый иде.* М.Әмирханов. *Кул астында сүзлек булса, хәтта урысча да аз-маз пупалый беләм!* Ф.Баттал

Пупалый башлау Пупалый алу дәрәҗәсенә җитү. *Ильяс шәкерт өйрәтте мине урыс теленә. Аннан соң, күпмедер пупалый башлагач, Өчнәвер Мәкчим белән тел кайрадым.* Р.Сибат. *Улым тугач, иң беренче алып биргән китабым «Гармунчы аю белән җырчы маймыл» булды. Аны мең дә бер кат укыткандыр миңа, аннан үзе хәрефләп пупалый башлады ---.* Ф.Сафин

ПУПЫНУ *ф. гади с. к.* **пупалау**. *Таня инде татарча ярыйсы гына пупына. Шулай да Тимерҗан әйткәнне тулысынча аңлап җитмәде.* Н.Фәттах

ПУРИЗМ *и. лат.* 1) Әдәп кагыйдәләрен үтәүдә артык кырыслык. *Урта гасырлар пуризмы*

2) Телнең сафлыгын тәэмин итү максаты белән, чит телләр йогынтысыннан саклау, алынма сүзләрне, һәртөрле неологизмнарны булдырмау, булганнарыннан котылу сәясәте; тел нормаларын үтәүдә артык кырыслык. *Пуризм – телне үзгәртмичә сакларга омтылу, телгә яңа сүзләрнең һәм алынмаларның керүенә каршы кирәгеннән артык көрәшү.* Х.Сәлимов. *Унҗиде процент татарның --- үз телен туган тел дип танымавы; пуризм күренешенең бик зәгыйфь булуы (чит тел сүзләрен кабул итмәү түгел, ә, бәлки, аларны графикасын һәм әйтелешен үзгәртми кабул итү) күзәтелә ---.* Фән һәм тел

ПУРИСТ *и. рус* Пуризм тарафдары. *Пантюркистларның төрекчеләгән кире каккан шикелле, пуристларның саф төркичелеккә кире кайтырга маташуларына да Тукай айнык карый алды.* Г.Халит. *Мин пурист түгел, үҗәт рәвештә, телнең сафлыгын саклау өчен, чит телдән кергән бөтен сүзләрне чыбыркылап куарга кирәк, димим.* Р.Батулла. *«Татарчылар» дип әйтсәк тә, Г.Ибраһимовны һәм аның фикердәшләрен һич тә утә пуристлар дип сыйфатлап булмый.* Фән һәм тел

ПУРИ́СТИК *с.* Асылы, нигезе пуризм булган, пуризм белән сугарылган. *Буржуаз милләтчеләр кара реакция*

елларында пуристик алым куллану юлына басалар. Л.Җәләй. *Алынмалардан, халыкара сүзләрдән качып, яңа фәнни-техник, иҗтимагый-социаль терминнарны пуристик нигездә (һәр милли тел җирлегендә генә) ясарга омтылу үзизоляциягә алып барыр иде ---.* Фән һәм тел

ПУРИСТЛЫК *и. к.* **пуризм**. *Тел ярлы түгел, безнең «саф тел»челәр педантлык, пуристлыкка бай.* Х.Туфан

ПУРИТАН *и. лат.* **1.** 1) XVI–XVII йөзләрдә Англия буржуазиясе арасында феодолизмга каршы юнәлдерелгән һәм башта англикан чиркәвен католиклыктан арындыруны максат итеп куйган дини-сәяси агым тарафдары. *Пуританнар сәнгатьне, бигрәк тә аның театр төрен, кешеләрне бозыклык белән агулый торганчарак, дип бәяли торган булганнар.* К.Гыйззәтов

2) Гадәттән тыш әдәпле, әхлаклы тормыш алып бару тарафдары. *[Г.Ильяси] кызларга менә нинди пуритан тәрбиясе бирергә киңәш итә.* Г.Рәхим

2. *с. мәгъ.* Гадәттән тыш әдәплелекне, югары әхлакны алга куйган

ПУРИТАНЛЫК *и.* 1) Пуритан карашлары, пуритан күзаллавы. *Англиядә пуританлык таралгач, этикетка әхлак нормалары үтеп кергән.* Тарих

2) Үз-үзен пуританнарча тоту, артык җитдилек, аскетлык. *[Сергей] гыйффәтле кеше, --- әмма пуританлыгы белән ир-ат даирәсенә комачауламый иде.* С.Баттал. *--- 70 нче елларда АКШ рәссамнары, нинаять, үз милли стильләрен урнаштыра башлыйлар. Бу стиль пуританлыктан һәм аскетлыктан ваз кичү, катгыйлыкка, төгәллеккә омтылуны билгели.* К.Гыйззәтов. *Чынбарлыкта, андагы базар мөнәсәбәтләрен пуританлык кагыйдәләре, җәмгыять ихтыяҗларына буйсындырып, аны тиешле чикләрдә тота.* Ватаным Татарстан

ПУРКИ *и. төр. иск. хурл.* 1) Чакырылмаган җиргә, ашка, мәҗлескә садака алыр өчен йөрүче, соранырга яратучы кеше; сорыкорт (гадәттә, шәкертләр тур.). *Пурки! Пурки! Нәрсәгә мәсҗеттә син тыңкышланып Сайрыйсың, Коръән ватасың, тук сыер күк мышнанып, Җомгадан соң кемдә аш барны сизә ак тешләрең? Соң теге көнге хәмелдән күп төшемме эшләдең?* Г.Тукай. *– Мин Питербурга пурки булып аштан-ашка йөрергә килмәдем, – дип әйтеп салмасынмы!* Р.Батулла

2) Һәрнәрсәгә тыкшынучы, оятсыз, әрсез кеше. *[Кыям:] Хәмит дус, мин сине рәтле генә кешегә хисаплап йөридер идем. Син дә оятсыз пурки икәнсең.* Аманулла

ПУРКИЛАНУ *ф. иск. хурл.* Пуркилык итү

ПУРКИЛЫК *и. иск. хурл.* Лаеклы булмаса да, берәр эшкә әрсезләнеп, комсызланып керешү; оятсызланып хәер эстәү

ПУРЫЙ *и. диал. эвф.* Исемен яшь терлек янында әйтергә ярамаганлыктан, куянга карата кулланыла торган сүз

ПУСТ *и. фар. бор.* Тире савыт, тире кап. *Ышанма син дустыңа: инә тыгар пустыңа.* Мәкаль. *Ул залимнарны ут тик күргел, әй дуст, Якын килсәң – янар, бел, ит белән пуст.* Һ.Салихов

ПУСТАУ *и. рус к.* **постау**. *Кодалар, кодалар килгәннәр, Өсләренә пустаулар кигәннәр; Пустаулар да кими, ни кисеннәр, Бар да бертуганнар килгәннәр.* Җыр. *Пугачау патша бар, диләр, Пустау бишмәтләре тар, диләр ---.* Җыр. *Кызыл пустау җәелгән өстәл янында кара киемле бер кеше күренде.* И.Гази

ПУТА *и. фар.* 1) Озынча тукыма кисәгеннән гыйбарәт билбау; кушак. *Хажи сәндерәгә менеп җиткәч, махсус пута белән үзен үзе бәйләде дә, кулына калын сүс аркан алып, шәмнәрнең күтәрелгәнен көтә башлады.* М.Хәсәнов. *Тимер рәшәткәле гөлбакча капкасы төбендә --- путаларына ялтыр хәнҗәрләр кыстырган зур гәүдәле ике абзый басып тора иде.* А.Тимергалин. *Толя, --- тимерчыбыктан ыргак ясап, шуңа сәләмә чүпрәк эләктерде дә --- мастерның халат путасына элеп куйды.* З.Фәйзуллин

2) *күч.* Түбә тактасының түбәнге башы белән кәрниз арасына кадаклана торган юка агач

ПУТАЛ *и. рус махс.* **1.** 1) Бакыр һәм цинк эретмәсеннән гыйбарәт ялган алтын. *Һәм тикшерә башласаң, бик күп җирдә ул шулайрак икән: ак стенада ак таш, ак ташта сары язу. (Күбесенең сары путалы кубып бетә язган.)* Ә.Еники. *Муса Җәлил исемендәге опера һәм балет театрының алтын путаллар белән бизәлгән зур заллары чагылып үтте.* Р.Ишморатова

2) Шул эретмәдән гыйбарәт буяу. *Батыргали агайны, исемен алтын путал илә язып, кыйммәтле рамкаларга куярга [кирәк].* Ш.Мөхәммәдев. *Пөхтә җыештырылган, келәмнәр түшәлгән бүлмәнең диварларында кара өстенә ак һәм сары путал белән язылган Коръән аятьләре, шәмаиллар...* Ә.Фәйзи

2. *с. мәгъ.* Шул эретмәдән ясалган, шуңа буялган. *Өйнең эчке бүлмәләрендәге бөтен ишекләр орнаментлаштырылып көрән төстәге имәннән эшләнгән; түшәмнәрдә, уңмый торган кыйммәтле путал каймалар белән уратылып, художестволы табигать күренешләре сурәтләнгән.* Ш.Камал. *Кыз аз гына өрсәң дә очып китәргә торган путал кәгазьне бүрек эченә куя.* М.Максуд. *Инде менә бүлмә кояш нурына манылгандай балкып тора. Лимон кабыгы төсендәге ачык сары җирлеккә путал буяу белән кызыллы-сарылы өрәңге яфраклары төшерелгән.* Г.Сабитов

ПУТАЛЛА́У *ф.* Путал белән каплау, путал белән буяу. *Хәзер аның бу яңа кибетенең ишекләре өстендә эре хәрефләр белән путаллап язылган.* М.Гафури

Путаллап бетерү Барысын да путаллау

Путаллап җибәрү Бераз гына путаллау

Путаллап кую Алдан ук путалланган хәлгә китерү

Путаллап чыгу Һәрберсен путаллау

Путаллый башлау Путалларга керешү

ПУТАЛЛЫ *с.* 1) Путал белән капланган, путал йөгертелгән. *Ал медале аның путаллы, Куандырды анай карчыгын.* М.Җәлил. *Озак та үтми, сары путаллы таякка таянып, --- Гарифулла карт, --- аның артыннан --- Өммегөлсем карчык --- автобус туктalышына якынлашып киләләр иде...* А.Хәлим

2) Кырыйлары путал белән бизәлгән. *Стаканым путаллы, Уң кулыңа тот әле, Алай бигүк эреләнмә, Вак-вак итеп йот әле!* Җыр. *Кара сакаллы берәү үзенең чапан бөркәнгән хатыны белән зур-зур путаллы тәлинкәләр сайлый.* Ә.Фәйзи. *Пәйгамбәр белән канатлы фәрештәләр сурәте төшерелгән, --- кызларга гына бүләк ителә торган путаллы открыткалар артына егетләренең рәсемнәре посканлыгын абайлавы да әллә ни кыен түгел.* Р.-Н.Гүнтәкин

ПУТАЛЫ *с.* 1) Путасы булган. *--- Хәбиб шәл якалы, путалы җылы пальтосының куен кесәсенә барышлый гына бер шешә алып салды.* М.Мәһдиев. *Путалы модный пәлтә алам дип, акча җыйды ---.* Р.Батулла

2) Урта бер җиреннән путаны хәтерләткән, путага охшаган горизонталь сызык үткәрелгән. *Менгәч, артына борылып, аста зәңгәр путалы моржасыннан сыек төтен бөркеп утырган теплоходка, чемодан селкеп, сәлам калдырды.* Э.Касыймов. *Кызыл путалы зәңгәр машина – элеккеге еллардагы милиция машинасы.* Ә.Гадел

ПУТЕМАР *и. диал. этн.* Өч-дүрт рәт тәңкә тезеп ясалган һәм бер иңбашыннан икенче култык астына киелә торган укалы киң тасма; хәситә. *Яшел сандык өсләрендә Путемар бөтүемне тышлыймын.* Җыр

ПУТЁВКА *и. рус* 1) Ял йорты, санаторий һ.б.ш. берәр урынга баручыга бирелә торган таныклык; юллама. *Август аена хатыны белән икесенә путёвка тапкан иде.* Х.Сарьян. *Вәли абзыйны ялга, әлбәттә, зур почёт белән озаттылар. Вәли абзыйга үз кулы белән районның почёт грамотасын, Ессентукига путёвка тапшырды.* М.Мәһдиев. *Ул, мең мәртәбә үгетләп, мең тапкырлар каргап, Таһирны көньякка ял итәргә барырга путёвкалар артыннан йөрергә күндерде.* Н.Акмал

2) *махс.* Транспорт йөртүчеләр өчен маршрут һәм үтәлә торган эшнең төре язылган рәсми кәгазь. *[Хәйруш үзбушаткычта] эшләргә ризалыгын белдерде, путёвкалар яздырды.* М.Хәсәнов. *Сәлимнең, китап түгел, каләм тотуы да путёвкага һәм хезмәт хакы ведомостена кул куйган көннәрне генә.* Р.Кәрами. *Бездә бит авыллар арасындагы километрлар төгәл билгеле, алар путёвкага нинди генә сан язса да, артыгы түләнми.* Ватаным Татарстан

3) Кая да булса эшкә җибәрү юлламасы. *1972 елны --- комсомол путёвкасы белән КамАЗ төзелешенә кайтканнар.* Язмышлар яңарганда

4) *күч.* Нинди дә булса эшнең башлангычына юл ача, мөмкинлек тудыра торган нәрсә. *Соңгы сынауны биргәч тә, --- Яруллин аттестат алырга килде. Газизов аңа бу зәңгәрсу кәгазьне үзе тапшырды. – Менә тормышка путёвка, Әхмәт, менә сиңа ике кулым! – диде ул ---.* З.Вәли

ПУТЧ *и. нем.* Бер төркем кешеләрнең дәүләт белән идарә итүне үз кулларына алырга омтылышы; шундый гамәл. *Элек – инкыйлаб иде, ә хәзер – путч.* Т.Кәримов. *Туксан беренче елның август путчына кадәр биш ел буе ул барлык иҗтимагый-сәяси һәм әдәби журналларны укып барды.* Казан утлары. *Бу көнне, Борис Ельцин президент итеп сайланган, дигәнрәк тә сүзләр ишеттем, хәтта, путч булгандыр, диючеләр дә килеп чыкты.* Кәеф ничек?

ПУФ *иярт.* 1) Авыр итеп сулаганда, авыздан күп итеп һава чыгарганда чыккан тавышны белдерә. *Сыерлар шул ук, пуф та пуф кайталар, күәс-күәс җиленнәр як-якка чайкала.* А.Гыйләҗев

2) Күп итеп пар, төтен бөркелү тавышын һәм рәвешен белдерә. *– Пуф, пуф. Гыжт, гыжт... – Әбәү! – малайлар чырылдашып, кычкырышып [пароходан] читкә качтылар.* Безнең юл

3) *к.* **пух**. *Алмаз җирдә яткан таягын табып, «бүре»гә төзәде, «атып» җибәрде: – Пуф! Пуф!* Х.Ширмән

4) *ымл.* Уфтану, көрсенү, зарлану һ.б.ш.ны белдерә. *Пуф! Болар кайда югалдылар инде тагын?* Г.Камал

ПУ́Ф БУЛУ *ф. к.* **пуф итү** (*2 мәгъ.*). *Актәпи дә, әти-әнисе дә, корсаклары пуф булганчы, тәмледән-тәмле ризык белән сыйлана ---.* Н.Әхмәдиев

ПУ́Ф ИТҮ *ф.* 1) Өзек-өзек тавыш, сулыш чыгару. *Поезд килде пуф итеп, Килеп басты тып итеп.* Б.Рәхимова. *Менә берзаман бәрәңгеләр: «Пештек, өлгердек», – дигәндәй, кайнар көлне «пуф-ф-ф...» итеп, астан өреп җибәрәләр.* Г.Сабитов. *Иреннәре сулыш белән я авызына кереп китә әбинең, я пуф итеп тышка җилфердәп чыга.* Шатлыклы кайгы

2) *күч.* Кабару, күперү; көрәю. *[Хәйдәр] – пуф итеп тора торган, менә дигән зур кара мыеклы [егет].* Ә.Фәйзи

3) *күч.* Тәкәбберләнү, үзен әллә кемгә кую. *[Байлар] озын-озын туннарын тектерәләр төлкедән. Пуф итеп йөргәннәрен күрсәң, чыдый алмассың көлкедән.* Ш.Мөхәммәдев

ПУ́Ф-ПУФ *иярт.* 1) Өзек-өзек сулаганда, мышнаганда, пошкырганда чыккан тавышны белдерә. *– Тиз булыгыз! Пароход соңгы гудок кычкырта, – диде кулына яктырткыч тоткан мыеклы кеше. – Пу-уф, пу-уф! Пуф-пуф-пуф!* Р.Батулла

2) Берәр нәрсәнең ургылып, ишелеп чыгу рәвешен белдерә. *«А-ах-ух»тан соң пуф-пуф тәмәке, Өйдә төтен – аркан ишәрлек, – Агыла тәрәзәдән.* Р.Идиятуллин

ПУФ-ПУ́Ф ИТҮ *ф.* 1) Өзек-өзек яки озак-озак сулыш чыгару. *Бәрәңге өстендәге көл су шикелле агып төшә, аның әле бер, әле икенче җиреннән пыш иттереп кайнар сулыш бәреп чыга. Монысы, көл астындагы кайнарга түзә алмыйча, пуф та пуф итеп бәрәңгенең сулыш алуы инде.* Г.Бәширов. *Көндез эшләп, кичен минем белән булышып, ул да шактый талчыккан булгандыр инде, биш-ун минут дигәндә пуф-пуф итеп йоклап та китте.* В.Нуруллин

2) Авыр сулау, пуфылдау. *Батыргали агай илә Шубин да пуф-пуф итеп, ашыга-ашыга пароходка йөгер[деләр].* Ш.Мөхәммәдев. *Таналары, сарыклары җәй буе рәхәтләнеп билдән печән эчендә йөри. Көз җиткәндә, дуңгыз шикелле булып симерә. Пуф-пуф итеп көчкә торалар.* Т.Мөхәммәтшин

3) Күп итеп пар, төтен яки газ чыгару. *Казан өстенә ябылган түгәрәк агач капкачның әле бер читеннән, әле икенче читеннән пуф-пуф итеп пар бәрә.* М.Шабаев

ПУФ-ПУ́Ф КИЛҮ *ф. к.* **пуф-пуф итү**. *Алачыкны әйләндереп алган койма*

күләгәсендә эсселектән гажиз булган ике бозау пуф-пуф килеп мышнап ята. А.Гыйләҗев. *Мәхлук бәти юеш борынын Рушадның яңагына, колагына төрткәләп пуф-пуф килде, иснәде.* М.Мәһдиев. *Ә поезд, пуф-пуф килеп, Мәскәвенә китеп барды.* Г.Гомәров

ПУФЫЛДА́У *ф.* Пуф-пуф иткән тавыш чыгару. *Тимерхан ишек катында күзлеген ялтыратып пуфылдап утырган кешене танып алды: Хәйруллин икән.* М.Мәһдиев. *Керпе – юаш җәнлек. Әмма кирәк чакта энәләрен тырпайтып, усал итеп пуфылдый да ала.* Р.Батулла. *Икенче көнне ике эшче пуфылдый-пуфылдый тагын да зуррак тартма өстерәп керде.* Г.Әдһәм

Пуфылдап җибәрү Кинәт пуфылдый башлау

Пуфылдап кую Бер тапкыр пуфылдау. *Пар ат белән бәрәңге күмдереп йөрүче Шәвәли агай җир башында атларны борганда бер хәл ала, пуфылдап сулап куя, кайвакытта аның җырлаганы да ишетелә.* М.Мәһдиев

Пуфылдый башлау Пуфылдарга тотыну

ПУ́Х *иярт.* Мылтык, туп атканда, берәр нәрсә шартлаганда чыга торган капылт, калын тавышны белдерә. *Таякны мылтык итеп алга таба сузам да «пух, пух!» дим.* Г.Афзал. *– Наил, – диде Равил. – Ә мин сиңа, мин сиңа... пистолет бирәм. Пух, тых, трах, пуф...* Н.Әхмәдиев. *Ул җибәрә алмый андый ракетаны! Җибәрсә дә, аз гына күтәрелә дә – пух!.. Ярыла да кире җиргә әйләнеп төшә!* Г.Бакиров

ПУ́Х БУЛУ *ф. к.* **пуф итү** (*2 мәгъ.*). *Хайваннар тагын таралышып утладылар да, ди, тамаклары туйгач, корсаклары пух булгач, әкрен генә кайтырга чыктылар, ди.* Әкият. *Борынгылар әйтеменә лаек бул бер: Капкорсаклар кабымыннан пух булганчы, Аек бул да каексызга каек бул бер!* Г.Сәлим

ПУ́Х ИТҮ *ф.* 1) Мылтык, туп аткан тавыш чыгару. *– Әби, пух итте, – дип, [Аюхан] зур кара күзләрен әбисенә төбәде. Мылтык башка атмады, тирәяк тагы күнегелгән халәткә кайтты.* Г.Якупова

2) Авыр сулыш алу. *Ә бер егерме минуттан соң инде мин тирләгән-пешкән, пух итеп торган агайларны сафка тезеп, өс-башларын, мылтыкларын тиз генә күздән кичереп, үз артымнан ияртеп постларга алып та киттем.* Ә.Еники

3) *күч.* Сулыш алу авырайганчы күп ашау; тәмам тую. *Корсак тутырып пух иткәнче ашап чыгасың да эшләп торып җибәрәсең, әй.* Г.Бәширов. *Ашказаның пух итеп тормагач, кое суы, чишмә суы нигә?* М.Мәһдиев. *Бездә, Аллага шөкер, ите дә, бәрәңгесе дә җитәрлек. Кызларыбыз да көр тана шикелле пух итеп тора.* Ф.Баттал

4) *күч.* Үзен әллә кемгә кую, тәкәбберләнү, масаю. *Йөри идем мин пух итеп Төлке, янут толыптан, Инде хәзер өтәләндем Янып чыккан күк уттан.* Г.Камал

ПУ́Х-ПАХ *иярт. к.* **пух**. *Аларның бар белгәне машина да мылтык белән пистолет. Әллә нинди куркыныч авазлар чыгарып машина йөртәләр, пух-пах мылтыктан аталар.* Н.Әхмәдиев. *Сунарчы килеп чыкты да: – Пух-пах, пух-пах! Күршеләр йөгереп кергән: – Ни булды сезгә? – диләр. – Куркып киттек, тавышка бит Ду килеп тора өйләр.* Г.Юнысова

ПУХ-ПРА́Х КИЛҮ *ф. сөйл.* Җимерелү, таркалу, юкка чыгу, бозылу (эш, тормыш тур.). *Беттем мин, ди, беттем, авылдашлар, Пух-прах, ди, килде минем эш.* Н.Дәүли. *– Нәрсә, сезнеңчә алар пух-прах килеп аерылышырга тиешмени? Ә гаилә? – Гөлстан күзендәге елмаю чаткылары сүнде.* Р.Батулла

ПУ́Х-ПУХ *иярт. к.* **пух**. *Малай таякны мылтык итеп тоткан да, узганбарган кешегә, машиналарга, эткә, мәчеләргә пух-пух итеп атып кала.* Ш.Галиев. *Истанбул матбугаты ут ачарга әзер. Кул гына селтим: пух!.. пух!.. – Бөтен җирдә зилзилә кубачак.* Р.-Н.Гүнтәкин

ПУХ-ПУ́Х ИТҮ *ф. к.* **пуф итү**

ПУХ-ПУ́Х КИЛҮ *ф. к.* **пух итү** (*2 мәгъ.*). *Биш-алты сәгать бил бөкрәйтеп интеккәннән соң, ашханәгә керәсең, корсак күпкәнче умырасың да пух-пух килеп өйгә кайтасың.* А.Гыйләҗев

ПУ́ШКА *и. рус* 1) Ерак арага ата ала торган озын көпшәле артиллерия коралы; туп. *Коры мылтык белән агулы газларга, кырык икешәр миллиметрлы пушкаларга каршы торып булмый шул.* Т.Гыйззәт. *Безне озатучы истребительләр, үзләренең пушка уты белән зенитчыларның утларын басар өчен, түбән төшеп киттеләр.* Ф.Баттал. *Элегрәк йозакларны пушкаларга да куйганнар.* Д.Галимов

2) *мед.* Радиоактив нурлар белән дәвалау аппараты

3) Корпусы аша үткән һава агымын җылытып чыгару юлы белән төзелеш объекты, гараж һ.б.ш. зур мәйданлы биналарны җылыта торган күчерелмә прибор. *Егәрлеге көйләнми торган пушка*

4) Бура уенында: бишенче таякчыгы дүртпочмак рәвешле тезелгән таякчыклар өстенә куелган фигура. *Уен кызып кына барганда, мин, оядагы пушканы бер бәрүдә сугып чыгарыйм әле дип, тәпәчемне бар көчемә ыргыт[тым].* Р.Төхфәтуллин

◊ **Пушкага алу** Булмаган нәрсә, ялган белән куркытып, ни дә булса әйттерергә, эшләтергә тырышу, ниндидер эш-гамәлгә этәрү. *Тукта әле, син нәрсә? Мине пушкага аласың. Андый хыял минем башыма да кергәне юк.* Р.Ишморат. *Шаярткан, пушкага алган ул сезне, Хөрми Җәмилен белмисез штүли, диярсең.* Р.Зарипов. **Пушка ите** *кит.* Басып алу сугышларында көчләп үлемгә җибәрелә торган солдатлар массасы. *Мондый хәл XVII–XVIII гасырларда Русиядә пушка ите итеп файдаланылган татар гаиләләрендә генә булырга мөмкин.* М.Әхмәтҗанов. *Ватан мәнфәгатьләренең кайда икән чикләре? Без бит бала үстермибез, бары... пушка итләре...* Р.Харис. *Ил язмышы хәл ителгән сугышларда пушка ите сыйфатында файдалану бер хәл, Чиләбе өлкәсендәге милләттәшләребезне атом афәтенә юлыктырып һәлакәткә дучар итүне --- ни дип юрарга?* Р.Зарипов

ПУШНИ́НА *җый. и. рус* Күрек-мехка бара торган җәнлек тиресе; күрек-мех товарлар. *[Әти] әле күптән түгел генә Канаданың Монреаль*

шәһәрендә халыкара пушнина аукционында булып, яңадан бер зур Алтын медаль алып кайтты. М.Хәсәнов. *Тиен тиресе затлы пушнина буларак һәрвакыт кыйммәт бәядә йөргән, ә тиен яки тин исә – вак акча.* Ә.Мөхәммәдиев

ПҮКЕЛДӘТҮ *ф.* Тоник кына шартлау тавышы чыгарту. *Браунингны пүкелдәтү*

Пүкелдәтә башлау Пүкелдәтергә тотыну

Пүкелдәтеп җибәрү Кинәт пүкелдәтү

ПҮКЕЛДӘҮ *ф.* 1) Пүк-пүк иткән тавыш чыгу

2) Шундый тавыш чыгарып эшләү. *--- тау башында Бәшир байның пар белән эшли торган бик шәп тегермәне пүкелдәп утыра.* Г.Бәширов

Пүкелдәп алу Бер тапкыр яки аз гына вакыт эчендә пүкелдәү

Пүкелдәп җибәрү Кинәт пүкелди башлау

Пүкелдәп кую Бер тапкыр пүкелдәү

Пүкелдәп тору Даими яки әледән-әле пүкелдәү

Пүкелди башлау Пүкелдәргә тотыну

Пүкелди бирү Бернәрсәгә игътибар итмичә пүкелдәүне дәвам итү

ПҮ́К-ПҮК *иярт*. Мотор эшләп, билгеле бер ритм белән төтен чыкканда яки кечкенә пистолеттан атканда ишетелә торган тавышны белдерә

ПҮЛӘН *и. рус сөйл*. 1) Агачның ягар өчен кисеп алынган кыска бер кисәге; түмәр, бүкән. *[Акмал] Галанка мичкә башта газета кисәкләре йомарлап салды, аннары балта белән бер пүләнне йомычкага ярып, пөхтәләп өйде дә ут элдерде.* Г.Ахунов. *Китап укырга иренеп, телевизор карап кына утырмый ул өйдә, --- җырлатып утынын кисә, дөбердәтеп пүләннәрен яра!* Ж.Дәрзаман. *Ник бер мәртәбә булса да кайтып, ике пүлән утынын ярып, коймасын рәтләп яисә бакчасын казып китмәдең?* Г.Гыйльманов

2) Шул бүкәннең ярылган бер өлеше. *Мич яна. Әсгать аңа ара-тирә яңа пүләннәр өсти. Пүләннәр, янарга теләмәгәндәй, --- пыскып, бераз чыжлап торалар.* А.Шамов. *Чыгып китсә, аның койкасына одеялы астына утын пүләне салалар*. А.Гыйләҗев. *Санапсанап кына җиде пүлән утынны кочагына төйи дә йорт ишегенә юнәлә Галия*. Шәһри Казан

3) *күч.* Салкын, хиссез кеше. – *Пүлән син, утын пүләне. Йөрәгең – кар базы! – Туйганчы тезде Зәмирә, Рәйхананың бите уттай кызышты*. Р.Ишморатова. *[Әлфия:] Менә шулай инде! Әле генә матурым, кызым, сеңлем, ә хәзер... дивана, пүлән... Рәхмәт сиңа да...* Г.Әкбәр

ПҮНӘТӘЙ *и. рус* Берәр кешенең өен тентегәндә, милкен язганда һ.б.ш. очракларда шаһитлык өчен чакырылган кеше; гуаһ. *Пүнәтәй латыш хатынга русча эндәшә башлады.* Х.Камалов. *Автобуста алардан тыш шаһит Сария Таешова, ике пүнәтәй дә бар иде.* М.Насыйбуллин. *Капитан ике пүнәтәй алып керә, алары исә тын гына бер якка барып чүмәшәләр*. Р.Мирхәйдәров

ПҮНӘТӘЙЛЕК *и.* Пүнәтәй булу. *[Камали] фабрикант та була алмас, пүнәтәйлеген дә яшерә алмас.* К.Нәҗми

ПҮЧИНКӘ *и. рус диал*. Зур авылдан аерылып утырган кечкенә авыл; яңавыл. *Терпеле пүчинкәсенең бөтен кешеләре дә Стәрлетамакка күчерелгәч, ул да бушап калган.* Гасырлар авазы. *Шыгале пүчинкәсенең икенчесе Яңа Мәңгәр составында исәпләнгән, һәм аның белән бер авыл җәмгыяте төзелгән.* Ватаным Татарстан. *Йошкар-Ола шәһәрендә яшәгән Гафиятулла улы Таһир тырышлыгы белән, безнең нәсел башында 1830 елны туган Мәхмүт улы Латыйпның варисларын барлап, Бәрәңге районындагы кеше яшәмәгән Гайфулла пүчинкәсендә җыелдык.* Мәдәни җомга

ПҮЧТӘК *с. рус сөйл*. **1.** Әһәмиятсез, вак-төяк, юк-бар. *Краннар торбаны икенче баштан күтәргәч тә, председатель зарланудан туктамады: – Нинди пүчтәк нәмәрсә аркасында ничә ел сусыз интектек*. Ә.Баян. *Берәүләр, тилереп, бар акчасын туздырып, марка җыя, шырпы кабындагы пүчтәк сурәтләр белән мавыга.* А.Гыйләҗев. *Беркөн Мәскәү радиосыннан яңа җырын тапшырдылар. Искитәрлек бернике юк, пүчтәк җыр*. Р.Кәрами

2. *и. мәгъ*. Юк-бар, әһәмиятсез нәрсә. «*Аларны тоту – пүчтәк ул!*» – *дип пүләне салалар*. А.Гыйләҗев. *Санапсанап кына җиде пүлән утынны кочагына төйи дә йорт ишегенә юнәлә Галия*. Шәһри Казан

3) *күч.* Салкын, хиссез кеше. – *Пүлән син, утын пүләне. Йөрәгең – кар базы! – Туйганчы тезде Зәмирә, Рәйхананың бите уттай кызышты*. Р.Ишморатова. *[Әлфия:] Менә шулай инде! Әле генә матурым, кызым, сеңлем, ә хәзер... дивана, пүлән... Рәхмәт сиңа да...* Г.Әкбәр

ПҮНӘТӘЙ *и. рус* Берәр кешенең өен тентегәндә, милкен язганда һ.б.ш. очракларда шаһитлык өчен чакырылган кеше; гуаһ. *Пүнәтәй латыш хатынга русча эндәшә башлады.* Х.Камалов. *Автобуста алардан тыш шаһит Сария Таешова, ике пүнәтәй дә бар иде.* М.Насыйбуллин. *Капитан ике пүнәтәй алып керә, алары исә тын гына бер якка барып чүмәшәләр*. Р.Мирхәйдәров

ПҮНӘТӘЙЛЕК *и.* Пүнәтәй булу. *[Камали] фабрикант та була алмас, пүнәтәйлеген дә яшерә алмас.* К.Нәҗми

ПҮЧИНКӘ *и. рус диал*. Зур авылдан аерылып утырган кечкенә авыл; яңавыл. *Терпеле пүчинкәсенең бөтен кешеләре дә Стәрлетамакка күчерелгәч, ул да бушап калган.* Гасырлар авазы. *Шыгале пүчинкәсенең икенчесе Яңа Мәңгәр составында исәпләнгән, һәм аның белән бер авыл җәмгыяте төзелгән.* Ватаным Татарстан. *Йошкар-Ола шәһәрендә яшәгән Гафиятулла улы Таһир тырышлыгы белән, безнең нәсел башында 1830 елны туган Мәхмүт улы Латыйпның варисларын барлап, Бәрәңге районындагы кеше яшәмәгән Гайфулла пүчинкәсендә җыелдык.* Мәдәни җомга

ПҮЧТӘК *с. рус сөйл*. **1.** Әһәмиятсез, вак-төяк, юк-бар. *Краннар торбаны икенче баштан күтәргәч тә, председатель зарланудан туктамады: – Нинди пүчтәк нәмәрсә аркасында ничә ел сусыз интектек*. Ә.Баян. *Берәүләр, тилереп, бар акчасын туздырып, марка җыя, шырпы кабындагы пүчтәк сурәтләр белән мавыга.* А.Гыйләҗев. *Беркөн Мәскәү радиосыннан яңа җырын тапшырдылар. Искитәрлек бернике юк, пүчтәк җыр*. Р.Кәрами

2. *и. мәгъ*. Юк-бар, әһәмиятсез нәрсә. «*Аларны тоту – пүчтәк ул!*» – *дип уйларга өлгермәдем, командир мәсьәләнең җитдилеген сөйләп бирде*. Г.Кашшаф. *Бер күрүдә гашыйк булдым, дисәләр, Халидә, пүчтәк, дияр иде.* Н.Гыйматдинова. *Әнә тегендә бер ир яшь кенә кызны эләктергән... һи-һи, болар алдында минем ирнең гөнаһы пүчтәк кенә инде*. М.Кәбиров

ПФЕ́ННИГ *и. нем.* Евро кулланышка кергәнче, Германиядә марканың йөздән бер өлешенә бәрабәр вак акча. *Фрау Якоп кибетендә әйбер унбиш пфенниг торса, күрше кибеттә шул ук әйбер ун пфенниг торыр*. Н.Дәүли. *Алты ай буена бер пфенниг та түләгәннәре юк бит, әфәндем.* А.Алиш. *Егерме пфенниг түләсәң, шул скелет янында рәсемгә төшеп, ул рәсемне танышларыңамы, сөйгән кызыңамы җибәрә аласың*. А.Толстой

ПФИ *ы.* Кемне яки нәрсәне дә булса кимсетеп сөйләгәндә, «аның бернинди әһәмияте, кыйммәте юк» дигән мәгънәне аңлата. *Пфи, сөрсегән ич ул [ит]!* Мәзәк. *Пфи! Тапкан гүзәлләр солтаны!* Г.Камал

ПШЫЙК *ы. рус* Көтелгән нәтиҗә булмаганда әйтелә. *Пшыйк сиңа эшләпә! Бер атуда ике куян аулыйм дип торганда, пшыйк: берсе дә эләкмәде.* М.Хәсәен. *Татарстанның бәйсезлеген Минтимер ага биреп бетерде инде Рәсәйгә, ни Декларациядән, ни Референдумнан берни калмады, пшыйк кына.* М.Миначев. *Күпме якалаштылар, нәтиҗәдә – пшыйк!* Ватаным Татарстан

ПЫВА́Й-ПЫВАЙ *ы*. Бозау чакырганда әйтелә

ПЫВЫН *и. диал*. Кеше гәүдәсенең оча сөяге белән кабырга арасындагы өлеше; бил

ПЫЖ I *и. рус* 1) Ау мылтыкларының патроннарында: дары белән ядрә арасына тыгыла торган киез, катыргы, тире һ.б.ш. кисәге. *[Патронга] дары саласың да пыж тыгасың, аннан менә шуның хәтле ядрә. Яннан янә пыж белән томалап куясың.* Г.Гобәй. *Янган шырпы ыргыту, сүндерелмәгән тәмәке, мылтык атканда җиргә төшкән пыж янгынга сәбәп булырга мөмкин*. Авыл офыклары

2) Көпшә авызыннан корыла торган ау мылтыкларында заряд өстеннән

тыгып куела торган йомарланган киез, катыргы, тире кисәге

ПЫЖ II *иярт.* Бөжәкләр канатлары белән һаваны ярып очканда, берәр нәрсә кыздырганда чыккан тавышны белдерә

ПЫ́ЖИК *и. рус* **1.** 1) Төньяк болан бозавының тиресеннән эшләнгән күрек

2) Шул күректән тегелгән әйбер. *Гыйзди шәп кенә корсак үстереп җибәрде, тәмам кайракланып беткән бүреге урынына пыжик менеп кунаклады.* Р.Гаффар

2. *с. мәгъ.* Шул күректән тегелгән. *Чурмантаев секретарьга аз гына баш иде дә, пыжик бүреген әйләндергәләп, ишеккә таба атлады.* Г.Бәширов. *Менә барысы да бүләкләрен биреп бетергәч, ул алгы яктан түбәсенә пыжик бүрек кидергән ак самавырны җиңел генә күтәреп керде ---.* Ә.Еники

ПЫЖУ *ф. диал. к.* **пәжү**. *[Карчык] өч кадак пыжыган бәрәңге алыр өчен чират торган.* К.Нәҗми

ПЫЖЫГУ *ф. диал.* Эсседән әлсерәү, тирләү. *Терлекләр абзарда пыжыгып ята*

ПЫЖЫК *с. диал.* Үпкәчел, юккабарга турсаючан (кеше тур.)

ПЫ́ЖЫЛДАУ *ф.* 1) Пыж иткән тавыш чыгару. *Күбәләкләр арасында умарта кортлары белән юллы-юллы сары шөпшәләр, юан-юан төклетуралар да пыжылдап очалар.* Г.Рәхим

2) *күч.* Тузыну, бик каты дулау. *Ул минем кебек пыжылдап кыза торган кеше түгел.* М.Гайнетдинов

Пыжылдап тору Озак вакыт дәвамында пыжылдау; һәрвакыт яки әледән-әле пыжылдау. *Газ плитәсе җиде көн һәм җиде төн буе --- бертуктаусыз быгырдап, чыжылдап, пыжылдап торды ---.* Г.Мөхәммәтшин

ПЫЖЫТУ *ф. диал.* Берәр нәрсәне яки эшне харап итү, бөлдерү. *Кулы кычытkан – эшне пыжытkан.* Мәкаль

ПЫЖҒЫРТУ *ф. диал.* Өркетү. *«Күрәсең моны [киленне] малай бераз пыжғырткандыр», – дип кенә уйлады карт.* Ф.Яруллин

Пыжғыртып тору Әледән-әле яки һәрвакыт пыжғырту

ПЫЛ *и. гр. бор.* 1) *к.* **пул** I. *Бакыр йөзегең белән бакыр беләзегең ничә пыл тора?* Ә.Шәмин

2) Калай алка. *Алты аяк, ике тояк, җилкәсе пыл, уртасы тел, гакыллы аңлар, ахмак тыңлар алтмыш алты ел.* Табышмак

ПЫЛА́У *и. фар.* Кыздырылган суган, кишер өстенә ит, дөге һәм төрле махсус тәмләткечләр салып пешерелгән ашамлык. *Мәскәүдә бер сабакташ үзбәк дустым пылау пешереп кунакка чакыра торган иде.* Г.Хөсәенов. *Әнә Рустик сөйләп торды: беркөн пылау пешергәнсең, ярмасы таш кебек, ди, үзе көйгән, ди, җитмәсә, шыр тоз икән.* Г.Зәйнашева. *Көннәр аш бүлмәсендә пылау болгатып, көрпәчәдә чәйләп утырган картларны сыйлап уза торды.* Р.Рахман

◊ **Пылау өстендәге йөзем кебек** *макт.* Бик кадерле, затлы; бизәк өстенә бизәк булырлык

ПЫЛАУЧЫ *и.* Пылау пешерү остасы. *Роза апа пылаучы гына түгел, ә башка милли азыкларны да бик оста пешерә.* Сөембикә. *Каенанам мәрхүмә дә оста пылаучы иде.* Ватаным Татарстан

ПЫЛАЯК *с. сир.* Ак бәкәлле (ат тур.)

ПЫЛДЫРДА́У *и.* Пылдыр-пылдыр иткән тавыш чыгару

Пылдырдап алу Тиз генә, кыска гына пылдырдау

Пылдырдап куя Бер тапкыр пылдырдау

Пылдырдый башлау Пылдырдарга тотыну

ПЫЛДЫ́Р-ПЫЛДЫР *иярт.* **1.** Кошлар канат какканда, тукыма җилдә җилфердәгәндә һ.б.ш. очракларда чыккан җиңелчә тавышны белдерә. *Пылдыр-пылдыр төрелә-төрелә, тургайлар да Таң шатлыгы көен көйләп менеп бара.* Ә.Ярмәки

2. *с. мәгъ.* Мәгънәсез, буш һәм күп (сүз тур.). *Ит кунмаган авызга пылдыр-пылдыр сүз бирә, ди; Мие юк башка бадырайган [күпне күрүчән] күз бирә, ди.* Мәкаль

ПЫЛТ *иярт.* 1) Тамчы тамганда, сыеклыкка берәр вак нәрсә төшкәндә чыккан тавышны белдерә

2) Берәр нәрсәнең кисәк төшеп китү, утның капылт сүнү рәвешен белдерә

ПЫ́ЛТ ИТҮ *ф.* 1) Таму, тамчылау, шундый тавыш чыгару. *Хәләфнең маңгаена беренче мунча тире бәреп чыкты, ул, тамчыга әверелеп, пылт итеп, аның кендегенә тамды.* Х.Ибраһим

2) Кисәк төшеп китү; кисәк сүнү. *Үзбәкстанга бару теләге пылт итеп сүнде.* Н.Гыйматдинова

3) Кинәт, көтмәгәндә килеп чыгу, узып китү, качу һ.б.ш. эш-хәрәкәт башкарылу. *Берсендә диңгез өстенә чалкан ятып җырлап җибәргән идем, яныма су астыннан пылт итеп бер баш калкып чыкты.* Т.Миңнуллин. *Һич селкенер рәт юк: ник алай да ник болай, нәрсә ул да нәрсә бу дип, әллә каян участковый пылт итеп килеп чыга.* Шатлыклы кайгы

ПЫ́ЛТ-ПЫЛТ *иярт. кбт. к.* **пылт**. *Ул гаярьлек турында сөйли, ә арыш капчыгыннан идәнгә пылт-пылт кан тама.* Идел

ПЫ́ЛТ-ПЫЛТ ИТҮ *ф.* 1) Бер күтәрелү, бер кысылу; бер кабыну, бер сүнәр дәрәҗәгә килү (ут яну тур.). *Минем фонарем кыек астында урап йөргән кискен җилдән бер-ике тапкыр гына пылт-пылт итте дә сүнде.* Ә.Еники

2) Борчылудан яки ашыгып эшләүдән тән яки берәр орган еш-еш, нык бәреп тибү. *Юлда барганда, күңел нәрсәдер сизә. Йөрәгем пылт-пылт итеп тибә бит.* Т.Гыйззәт. *[Аның] сул як бите пылт-пылт итеп тибәкалтырый, йөрәге авыртыр дәрәҗәгә җитеп сыкрый иде.* М.Әмир

3) Йомшак кына ритмлы тавыш чыгару. *Күзләрен ачу белән, ул система шешәсеннән пылт-пылт итеп чыккан һава шарчыкларын күрде, эченең ут булып януын тойды.* Ф.Садриев. *Самолёт очарга яраклы түгел. Бер шасси чәлпәрәмә килгән, бер канат төптән үк сынган, мотордан пылт-пылт итеп кайнар май тама.* Р.Ибраһимов

ПЫР *иярт.* **1.** Кечерәк кош канатларын тиз-тиз какканда, очып киткәндә, нәрсә дә булса әйләнгәндә яки дереддәп торганда чыккан тавышны белдерә. *Әле анда, әле монда пыр да пыр очып йөрүче кызылтүшләрнең канат очлары*

кагылып киткән чакларда, сихри ай тузаннары яуган шикелле, җем-җем итеп кар коела. Г.Мөхәммәтшин

2. *рәв. мәгъ.* Бик тиз. *Әйдә, йөгер пыр да пыр!* Н.Исәнбәт

◊ **Пыр китерү** *к.* **пыр туздыру**. *Менәтерәк, пыр китереп бер сүгеп чыгыйм, дип кергән идем ---.* Ж.Дәрзаман. *Җиңги шулай пыр китереп ачуланып торгач, мәктәп кайгылары китте миннән.* В.Нуруллин. **Пыр кубып** *к.* **пыр тузып**. *Бергәләп пыр кубып туп кудылар, бергәләп, күз бәйләнгәч, посёлок халкының котын алып йөрделәр.* Э.Касыймов. **Пыр туздыру** 1) Бар нәрсәне бутап, туздырып бетерү, сибү, чәчү. *Зариф сөйли ачынып: – Өебезгә кергәннәр, Пыр туздырып йөргәннәр. Калмаган бит бернәрсә – Ни юрган, ни мендәрләр.* Г.Афзал. *Шул арада ниндидер бәндәләр, хәзинә эзләп, каберне пыр туздырып, сөякләрне таратып, мәсхәрә итеп китәләр.* М.Галиев. *Калтырана, Актарына Сәнди, Пыр туздыра өстәл асларын.* З.Мансур; 2) Таркату, җимерү, тар-мар итү, юкка чыгару. *[Тотыш] туган җиренә кайтып җитеп, анда атасы-анасы, ырудашлары күзенә күренде исә, яңадан зур көч белән килеп, Алмыш хан акбүреләрне пыр туздырмасмыни*? Н.Фәттах. *Пролетарий яуда ипле: Пыр туздырды интервентны.* Ә.Исхак. *Коточкыч өермәгә охшап, революция килеп кергән дә байларның дөньяларын пыр туздырган.* М.Әмир; 3) Кемгә дә булса бик нык ачулану, дулау. *Фәрхи әби һәммәбезне пыр туздырыр.* Ш.Камал. *Кайнана кайтып, пыр туздырып, килмешәкне куып чыгарырга тырышып карады ---.* М.Маликова. *Юкны бушка аударып, заяга вакыт уздырганнары өчен, укытучыны да, балаларны да пыр туздырырга иде исәбе.* Ж.Дәрзаман. **Пыр туздырып** Бик нык, бик каты. *Кызмача баштан машинасы белән урамда --- ләң-ләң өргән көчекләрне пыр туздырып чапкан Иршат иде.* Р.Кәрами. *Чирәм өстендә керт-керт итеп --- ямь-яшел дәү кыяр ашап утырган Нәбине Гайфулла пыр туздырып орыша иде.* А.Гыйләҗев. **Пыр тузу** 1) Бик нык тузу; таралу, чәчелү, сибелү, һавага очу. *Әни кайтып керде дә: – Пыр тузган өй эче! – ди. – Ах, тәлинкәм ватылган, Кайсыгызның эше? – ди.* Р.Миңнуллин; 2) Таркалу, җимерелү, юкка чыгу, тар-мар ителү. *Әй, «кара көч», кешелек Дөньясыннан көлмә син! Бервакытта пыр тузарсың, Әйләнерсең көлгә син!..* М.Гафури; 3) Бик нык ачулану, дулау, гауга чыгару, котырыну. *Әгәр дә камыт бавы йомшак тартылып селкенә торган булса яки --- арба рәтләп майланмаса, пыр туза: «Болай булса, атны харап итәсез!» – дип, шунда ук тугартып кире җиктерә.* М.Гафури. *Кәлимулла абыйның Арзуга күзе төшкән, дигән хәбәр әнигә дә килеп ишетелде, иртәләрнең берсендә ул пыр тузды.* А.Гыйләҗев. *– Әй, төртелмәсәнә, Халидә! Гыймран сиңа гашыйк, ахрысы. Кичкә сез күрешәсез... – Нәрсә-ә?! – Халидә кинәт кенә пыр тузды.* Н.Гыйматдинова. **Пыр тузыну** *к.* **пыр тузу** (*3 мәгъ.*). *Кәкре Фәтхуллалар башта моңа пыр тузынганнар иде дә, ләкин әллә ни җимерә алмадылар, барыбер үзләренекен итәргә булып, эчтән тынып калдылар.* Г.Иделле. *[Фәридә:] Яратмыйм күз буяуны, алдауны, хәйләне. Китәбез дип пыр тузынгач кына, син хәлне сораша башладың.* А.Гыйләҗев. *Ишек катында пыр тузынган карчыкны Фатыйма чак кына тынычландыра алды.* Г.Гыйльманов. **Пыр тузып** Бик нык, бик каты; бик кызу, бик тиз. *Завод-фабрикалар бертуктамый үкергән пушкаларның снарядларыннан пыр тузып җимерелеп беттеләр.* А.Алиш. *Биергә электән үк яратмаганга, Рәнис, музыка астында пыр тузып сикерешкән парларны бераз гына күзәтеп торгач, бүлмәсенә менеп китәргә җыенды.* Ж.Дәрзаман. *Госман исә Оренбурда, Гомәр абзый кибетендә пыр тузып сәүдә эшенә өйрәнә.* Ф.Сафин

ПЫРАК I *и. гар. диал. дини* Борак (Мигъраҗ кичәсендә Мөхәммәд пәйгамбәрне өстенә атландырып Мәккәдән Иерусалимга күчергән җан иясе). *Атың яхшы булса, бу – дөньяның пырагы.* Мәкаль. *Нур тоташты җиргә күктән, иңде нурдан бер пырак.* Г.Тукай. *Пәйгамбәребез галәйһиссәламгә Җәбраил галәйһиссәлам пырак китергәндә бәйләгән алкасы бар.* Эзләнүләр, уйланулар, табышлар

ПЫРАК II *и. диал. к.* **порак**. *Тегермән стеналарына ак пудра кунган, моны безнең авылда «пырак оны» дип йөртәләр.* М.Мәһдиев

ПЫРАН-ЗАРАН *рәв.* Билгеле бер тәртипне, эзлеклелекне сакламыйча, теләсә ничек итеп

◊ **Пыран-заран килү** 1) Төрле якка тузгу, таралу; тәртип бетү (әйберләр тур.). *Пыран-заран килгән бүлмәгә кергәч, өстәлдәге кәгазь кисәгенә күзе төште.* Безнең гәҗит; 2) Таркалу, рәте китү, тәртибе бозылу, чуалу, болгану. *Түрә-кара, пыран-зыран килеп, әллә кайларга качып һәм яшеренеп беткәнлектән, чуалышка катнашкан бөтен волостьлар, авыллар һаман да хөкүмәтсез, властьсыз килеш иде.* М.Галәү. *Хәзер аның бер җайга салынган, айлар-еллар буе шулай дәвам итәр сыман тоелган тормышының көе китте, ачы җилләр көзен агач яфракларын тузгыткан кебек, дөньясы пыран-заран килде.* Р.Кәрами. *Ә хәзер барысы да пыран-заран килгән: план-графиклар өзелгән, детальләр әллә нигә бер генә килә, вәгъдәләр җилгә оча.* Язмышлар яңарганда; 3) Тузгу, дулау, гауга кубару. *[Ул кеше] сүзенә колак саламы, әллә үз белдегенчә пыран-заран килеп кенә йөриме?* Э.Касыймов. *Узган елның декабрендә медиаторларга пыран-заран килеп талашкан ике бакча күршесен дуслаштырырга туры килгән.* Кәеф ничек?; 4) Юк-барга тотылу, әрәм-шәрәм булып бетү (мал-мөлкәт тур.). **Пыран-заран китерү** 1) Тузгыту, таркату, чәчү. *--- Өй эченә кереп, урын-җирләрен пыран-заран китереп ташлады.* Ф.Яруллин. *Бу дөньяда учакларны пыран-заран китереп таратып ташларлык давыллар, яңгырлар барын уйламады ---.* М.Маликова. *Бервакыт шулай өйгә кайтып керсәм, улларым өйне пыран-заран китереп ташлаган, бер генә әйбер дә урынында түгел.* Яшел Үзән; 2) Бөтенләйгә тармар итү, юкка чыгару. *--- Берәр атна үткәч, Җирдәге газеталарда «Киләчәк турында хатирәләр» фильмын*

пыран-заран китереп ташладылар. А.Тимергалин. *Сәлим Ситдикович бу шомлы уйдырманы көчле дәлил белән шул ук минутта пыран-заран китерде*. Д.Гыйсметдинов. *Кыргый базар әдәбиятны пыран-заран китерә алмады*. Татарстан яшьләре; 3) Мал-мөлкәтне юк-барга тотып бетерү, сарыф итү, тарату. *[Хәбибулла] беренче ирдән калган мал-мөлкәтне пыран-заран китерә башлады*. Ш.Хөсәенов. **Пыран-заран туздыру** *к.* **пыран-заран китерү** (*2 мәгъ.*). *Мәскәү гаскәрләрен пыран-заран туздырган, олы-олы җиңүләр яулаган батыр кеше ул.* Р.Батулла. *Ул кешеләргә тыныч тормыш алып барырга ирек бирмәгән: бәләкәй авылларны талап, пыран-заран туздырып, кызларны урлап интектерә торган булган.* Кызыл таң. **Пыран-заран тузу** *к.* **пыран-заран килү** (*3 мәгъ.*). *Чыгыш ясаучы Әлмөхәммәт Шаһиев исә, «мәчетне 5–6 карт өчен буш тотмыйк» дип пыран-заран туза.* Кызыл таң

ПЫРАНЛАТУ *ф. сөйл.* 1) Куу, туздыру; куркытып качыру. *Әүвәл авыл халкы немецлар биредә озаккадыр дип уйламый, менә-менә Кызыл Армия борылып килер дә фрицларны пыранлатып куып алып китәр, дигән өмет белән яши.* И.Гази. *«Кыз – яшь нәрсә, тәки солдатның баллы теленә алданып башын харап итәр. Аны вакытында бу эштән туктатырга да солдатын пыранлатып куып җибәрергә кирәк!» – дия-дия, тышка атылып чыкты*. М.Шаһимәрдәнов. *Җен ачуы чыккан әти икебезне дә өйдән пыранлатып куып чыгарды*. Ватаным Татарстан

2) Бик каты әрләү, ачулану. *Габделгазизнең үзендә дә гаеп булды. Атларын яхшылап кумаган иде. Хәбир бабай бик дөрес пыранлатты аны.* В.Нуруллин

Пыранлатып алу Аз гына, бераз пыранлату

Пыранлатып ташлау Кинәт бик каты итеп пыранлату

Пыранлатып тору Әледән-әле яки даими пыранлату

ПЫРАНЛА́У *ф. сөйл.* 1) Бик каты ачулану, дулау, тавыш куптару. – *Булдырмас ул! Чабатадай авызы килешеп кенә тора! – диде картый, пыранлап. – Агу салып бирсәң, агу эчәр*. Н.Фәттах. – *Мине атагызның яки үзегезнең дусларыгыз кызыксындыра дип уйласагыз, бик зур хата кыласыз! – дип ярып салдым да пыранлап чыгып киттем.* Р.-Н. Гүнтәкин

2) Очыну, җилкенү. *Менә уртада торган гармунчы янына ялт итеп бер егет килеп керде. Килеп керүе булды, әй китте бөтерелеп, китте сикерә-сикерә пыранлап, аягына күзләр дә иярми!* Г.Бәширов

Пыранлап алу Аз гына, бераз пыранлау

Пыранлап китү Кинәт, юктан гына пыранлау

ПЫРАХЛАТУ *ф. сөйл.* 1) Пырх иткән тавыш чыгарту. *[Ягъфәр] әлеге тавыкны пырахлатып куып чыгарды.* М.Зарипов

2) Пырх иткән тавыш чыгартып куып җибәрү

3) *күч.* Кемнәрне дә булса ачуланып куып чыгару, куып тарату

ПЫРАХЛА́У *ф. сөйл.* Пырх иткән тавыш чыгару

ПЫРАЧТИ *и. рус дини к.* **пырушти**

ПЫРГУ *ф. диал.* 1) *к.* **пыр тузу** (*1 мәгъ.*)

2) Көч белән, зур басым белән су сибү яки сибелү

ПЫРГЫ *и. бор*. Зур басым белән су сиптерә торган насос эчәге очына киертелгән җиз көпшә; су насосы үзе; брандспойт. *Уттан соң пыргы ни дә пешкәк ни!* Мәкаль. *Янгынчылар күргәннәр, Пыргы тотып килгәннәр, Су сиптергәч пыргыдан, Чыдый алмый ыргыган*. Н.Исәнбәт

ПЫРГЫТУ *ф. диал.* 1) Тузан, мамык шикелле нәрсәләрне бик нык туздыру. *«Йөрисең шунда матаең белән ком пыргытып, кеше куркытып бу хәтле эсседә!» – дип ачуланырга тотынды Илзия оныгын.* Әгерҗе таңнары

2) Зур басым белән су сиптерү

ПЫРДЫМ *и.* Басынкылык, түземлелек, күндәмлек. *Кайвакытта Айнурның пырдымы җитеп бетми*

ПЫРДЫМЛЫ *с.* 1) Җайлы, күндәм, басынкы, сабыр. *Пырдымлы хатынны ирләр ярата*

2) Эш рәтен белүче, юньле. *Пырдымлы ярдәмчеләр сирәк очрый*

3) Бәрәкәтле, күпкә җитүчән

ПЫРДЫМСЫЗ *с.* 1) Тиз кабынучан, сабырсыз, холыксыз, үз-үзен тота белми торган. *Кырыс, пырдымсыз хатын. Гомер буе иренә җылы сүзе дә, юньле карашы да булмаган*. Ш.Галиев. *Сәхнәдә бик аз гына вакыт күренеп калган арада, Вера Ивановнаның без, артистка Динара Гыймадиева башкаруында, пырдымсыз, мәгънәсез, юньсез кеше икәнлеген шәйләп калырга өлгерәбез*. Сәхнә

2) Әрсез. *Миңа – яланаяклы пырдымсыз бер малайга – монда искитәрлек берни дә юк иде.* Г.Бәширов. – *Бигрәк пырдымсыз инде мәчегез, – дип ризасызлыгын белдерде күрше.* Ж.Юныс

3) Эшнең рәтен белмәүчән, юньсез, мәнсез. *Пычкы әнә утын сараенда. Тик кара аны, малайларыңа бирep үтмәсләтеп бетермә. --- Синең малайлар – бик пырдымсыз нәмәрсәләр*. Ф.Яруллин. *Берара район мәдәният йортында шактый пырдымсыз җитәкче эшләп алды.* Татарстан яшьләре

4) Бәрәкәтсез. *Йомшак утын пырдымсыз була*. Мәкаль

ПЫРДЫМСЫЗЛАНУ *ф.* 1) Тиз кабынып китү, сабырсызлану, холыксызлану. *Түбән карап кына эшне аңлатты: – Миңниса үзе тавыш чыгарды... --- Үзе гаепле. Кая киткәнен әйтмәде. Зерәгә пырдымсызланды*. М.Мәһдиев. *Аңа рәнҗешемнең нигезсез икәнлеген уема китереп, ачылып китәргә тырышып карадым, күңелемне биләгән ачу, йөгәнсез ат кебек, һаман пырдымсызланды ---*. А.Гыйләҗев. *Һәм аның каршында пырдымсызланып, нәфрәтеннән тагын да сөйкемсезләнгән, --- керле чәч очлары берет астыннан тырпаеп чыккан Ниса нинди ямьсез, котсыз күренде*. М.Маликова

2) Чыгымчылау. *[Ат] иярге өйрәнгән икән, пырдымсызланмады, --- салмак кына юырта бирде.* Г.Мөхәммәтшин. *Ни булган үгезгә, ник ачуланган? Бүтән вакытта бер дә пырдымсызланмый иде бит.* Н.Әхмәдиев

3) Урынлы-урынсыз сүзләр сөйләү, тыйнаксызлану

Пырдымсызлана бару Торган саен ныграк пырдымсызлану

Пырдымсызлана башлау Пырдымсызлану билгеләре сизелү, күренү. *Гадәттә, «бөке»ләрдә машиналар пырдымсызлана, кычкырта башлыйлар бит.* Татарстан яшьләре

Пырдымсызланып алу Берара, бераз пырдымсызлану

Пырдымсызланып китү Кинәт пырдымсызлану

Пырдымсызланып тору Әледәнәле яки һәрвакыт пырдымсызлану. *Санкт-Петербург һәм Мәскәүдә скинхедларның әледән-әле пырдымсызланып торулары – бик хәвефле сигнал.* Ватаным Татарстан

ПЫРДЫМСЫЗЛЫК *и.* Пырдымсыз булу үзлеге. *Аннары һаҗәрне, каты куллы җитәкче дип, райком секретаре иттеләр. Анда да Бәештәге күк дуамаллыгын, пырдымсызлыгын куды.* Ф.Сафин. *Самат --- пырдымсызлыгын танырга теләмичә генә сөйләнә бирде ---.* Р.Ишморатова. *Булыр, әйтер, бер дә жәллән тормас, балта күтәрсә – чаба, тешләсә – өзә торган, пырдымсызлыгы өчен Тупас кушаматы алган Гайфулла бит ул.* Ф.Яхин

ПЫ́Р ИТҮ *ф.* 1) Шундый тавыш чыгару, пырылдау (*1 мәгъ.*). *--- гыйгылдашып очкан шат акчарлаклар, пыр итеп баш өстеннән генә үтеп торучы кыр үрдәкләре, --- түгәрәкләнеп тезелешкән егетләр – үз ишләре, үз тиңдәшләре, аның яшьлек хыялларын әллә кайларга алып киттеләр ---.* А.Гыйләҗев. *Әйтерсең шушы эчке аваз кинәт кенә пыр итеп оясыннан очып чыккан коштай күктә талпына, җиһанны иңләп канат кагына, үзенә тиңдәш рухын эзли.* Н.Хәсәнов. *Баш очыннан пыр итеп ярканат очып китте...* Д.Галимов

2) Шундый тавыш чыгарып очу, әйләнү. *[Песнәк] пыр итте дә тәрәзә төбендәге каенга барып кунды.* Д.Аппакова

3) *күч.* Ачулану, дулау

ПЫ́Р КИЛҮ *ф. к.* **пыр итү**. *Пыр килеп бөтен үрдәкләр күтәрелделәр.* Ф.Кәрим. *Бер чигенә [кош], Бер килә, Пыр тузына, Пыр килә!* Ш.Галиев. *Башка вакытта: «Сиңа урын беткәнме әллә, нигә диванга утырасың, бар өстәл янына!» – дип пыр килгән Айгөл шым гына ята биргәч, дусты шикләнә калды.* Шәһри Казан

ПЫРКЫТУ *ф. диал.* Пыр туздыру, куркыту; пырахлату (*1 мәгъ.*). *Ишек алдындагы тавыкларны пыркыта-пыркыта капка төбенә киләм.* Ш.Маннур. *--- ыштан балакларын бот тиңентен сызганган сипкелле малайлар агач дөмбе белән комырыклардан вак чабакларны, этлиләрне пыркытып чыгарып --- ятьмәләр белән балык сөзәләр.* А.Гыйләҗев

ПЫРЛАВЫК *с.* Пыр итеп оча, әйләнә торган

ПЫРЛАТУ *ф. сөйл.* 1) Пыр иттереп очырту

2) *күч.* Бик нык ачулану, әрләү, тиргәү. *Капкага гына килгәннәр иде, ирем пырлатып җибәрде.* Безнең гәҗит

ПЫРЛА́У *ф.* 1) Пыр итү, пырылдау (*1 мәгъ.*). *Пырлап оча икән тургайлар.* М.Җәлил. *Пырлап мотоцикл кабына.* Ф.Яруллин. *Мөҗип тракторның пускачын кабыза алмады. Пырлый да туктый.* Р.Батулла

2) *күч.* Каты ачулану, дулау. *Шуннан яшь бабай кызып киткән. Нәнә әйтмешли, пырлаган, хәтта кулындагы капчыгы белән нәнәгә кизәнгән дә бугай әле.* Т.Миңнуллин. *Галләм караваты да кузгатылды, авыру дип тә тормадылар, эзләп-эзләп тә Оркыяны таба алмагач, аңа да янап, әйтмәгәннәрен калдырмый, пырлап чыгып киттеләр.* Р.Рахман. *Ул пырлаганда эндәшмәвең артык.* Ф.Баттал

3) *күч.* Үзалдына ачуланып, үпкәләп йөрү. *Әйдә, әйдә, туйганчы ачулансын, эчен бушатсын, дип уйлый Хәбир һәм төп кебек эндәшми, чыдый. Фәрдәнә пырлады-пырлады да Тәүгизне эзләргә чыгып китте.* Х.Камалов

Пырлап карау Сынау өчен пырлау. *Хатыны да пырлап-пырлап караса да, эшне аерылышуга кадәр илтеп җиткермәде.* Н.Әхмәдиев

Пырлап китү Кинәт, көтмәгәндә пырлый башлау. *«Мин ни әйтмәм, үз башы юкмыни аның?» – дип, тагын пырлап китте әни.* Т.Миңнуллин

Пырлый башлау Пырларга тотыну

ПЫРНАЛ *и. төр. < гр. бот.* Бүкчәләр семьялыгыннан шома, карасусоры кайрылы, имәннекеннән ваграк чикләвекле мәңгеяшел агач; *русчасы*: **каменный дуб**

ПЫ́Р-ПЫР *иярт. кбт.* **1.** *к.* **пыр**. *Тирә-ягымда ниндидер кортлар тоныкына безелди, ниндидер кошлар пыр-пыр очып китәләр ---.* Ә.Еники. *– Кара бит син аны, әнкәсе, ничек үсеп беткән, тәмам егет булган, – дип, баскан урынымда пыр-пыр әйләндерергә кереште.* Р.Гыйззәтуллин. *Ишегалдындагы күлдәвектә чыпчыклар пыр-пыр канат чылата.* Н.Гыйматдинова

2. *рәв. мәгъ. күч.* Тузынып, дулап. *Хатын кызулык белән чемоданга киемнәрен тутырды да аннан пыр-пыр кире бушатты.* Н.Гыйматдинова

ПЫ́Р-ПЫР ИТҮ *ф. к.* **пыр итү**. *Зөһрә Шәңгәрәй керүгә яулыгы белән йөзен каплый да пыр-пыр итеп чыгып китә.* Г.Ибраһимов

ПЫ́Р-ПЫР КИЛҮ *ф. к.* **пыр килү**. *– Ярар, сиңа ни, ике дөнья – бер кәнди. Ни беләсең соң син? – Ана пыр-пыр килеп мыгырданды.* Х.Камалов. *Ә баш очында тургайлар! Пыр-пыр килеп очалар.* А.Гыйләҗев. *Яшь укытучы зурлап җыенып эшкә китүгә берничә айлар узгач, безнең өй янына пыр-пыр килеп бер матай туктады.* Т.Галиуллин

ПЫРСЫЛДА́У *ф.* 1) Пырс кебегрәк тавыш чыгару

2) Шундый тавыш чыгарып ярсу, усаллану. *Мәче, пырсылдап, мич башына очты.* Г.Бәширов

ПЫРТ *иярт.* Әйбер кинәт кенә, бик аз гына ертылганда, төтен, газ тоныкшартлап чыкканда булган тавышны белдерә

ПЫРТАЮ *ф. диал.* Үпкәләү, турсаю. *Мин кычкырганга пыртаясы юк.* Т.Миңнуллин

ПЫ́РТ ИТҮ *ф.* 1) Шундый тавыш чыгару. *Биредә «хуш исләр» тагын да көчлерәк үсеш алды: юылмаган носки, тәмәке төтене һәм хәмер болытына ара-тирә пырт иткән авазлар кабатланмас тәм өстәделәр.* Ф.Бәллүр

2) Берәр нәрсә кинәт кенә ертылып китү

3) *күч.* Бик нык ачулану, дулау; үпкәләү. – *Ә-әй, синең белән сату итеп буламы! – Кипшенгән әби пырт итеп урынныннан йолкынды һәм, җиләген күтәреп, юл аша завод капкасы каршына китте.* А.Хәлим

ПЫРТЛАВЫК *и. диал.* Бер өлеше икенче өлешендәге ояга өлешчә кереп, кием капламаларын яки изүләрен төймәли торган металл яки пластмасса сәдәп; каптырма; *русчасы*: **кнопка**

ПЫРТЛАМА *и. диал. к.* **пыртлавык**. *Пыртлама – тавыш чыгарып ябыла торган төймә.* Г.Бәширов

ПЫРТЛА́У *ф. к.* **пырт итү**

ПЫРТЛЫЙ *и. диал. к.* **пыртлавык**. *[Сандыкта] эреле-ваклы сәдәпләр, каптырмалар, пыртлыйлар [бар].* Ш.Маннур. *Ул җиңел, юка күлмәк кигән, тезе ачык, изүенең пыртлые ычкынган, авызында кәгазьгә урап төргән беләк буе тәмәке.* А.Гыйләҗев

ПЫ́РТ-ПЫРТ *иярт. кбт.* Ритмик рәвештә, өзек-өзек гөрелдәп мотор эшләп торгандагы тавышны белдерә

ПЫ́РТ-ПЫРТ ИТҮ *ф.* Шундый тавыш чыгару. *[Сәхип] кабызу рычагына бер генә типкән иде – мотор шундук кабынып, пырт-пырт итеп эшли дә башлады.* В.Нуруллин

ПЫРТЫК *с. диал.* Үпкәчел, юк кына сәбәптән дә хәтере калучан. *Пыртык бала булдың әле син!*

ПЫРУ́ШТИ *и. рус дини* Православие динен тотучыларның уразага пакь күңел белән керү, гөнаһлардан арынып Олы көнне каршы алу өчен, берберсеннән гафу сорый торган зур ураза алды көне, Май атнасының соңгы көне; *русчасы*: **прощёное воскресенье**

ПЫ́Р-ФЫР КИЛҮ *ф.* Пырылдау катыш фырылдау. *Машина пыр-фыр килеп урынныннан кузгалды...* Р.Төхфәтуллин

ПЫРХ *иярт.* **1.** 1) Гадәттә, тыелып торганнан соң, кинәт көлеп җибәргәндәге тавышны белдерә

2) Кош, зуррак бөҗәк очканда барлыкка килгән яки ат пошкырганда чыккан тавышны белдерә

2. *рәв. мәгъ.* Шундый тавыш чыгарып

ПЫ́РХ ИТҮ *ф.* 1) Кисәк пошкыргандагы яки төчкергәндәге, кинәт көлеп җибәргәндәге кебек тавыш чыгару, кисәк чыккан һава агымы шау тудыру. *Малай бик гаҗәпләнеп карап-карап торган да: «Бәй, апа, былтыргы «А» бит бу!» – дип кычкырган. Артта кемдер пырх итеп куйган.* М.Әмирханов. *Кинәт кыр үрдәге пырх итеп һавага күтәрелде ---.* Н.Гыйматдинова. *Кәмран авызына шулкадәр онытылып карап тора иде, чыдый алмыйча, пырх итеп көлеп җибәрдем.* Р.-Н.Гүнтәкин

2) Газ, төтен һ.б.ш. бөркелеп чыгу рәвешен белдерә

ПЫ́РХ-ПЫРХ *иярт. к.* **пырх**. *Урман тавыклары, тагын ниндидер кошлар, аяк асларыннан пырх-пырх күтәрелеп, нервыга тиеп беттеләр.* С.Баттал. *Тавил яңарак чыккан мәзәк сөйләде. Үзе сөйләгәненнән үзе пырх-пырх көлә иде.* Х.Камалов. *Аларның пырх-пырх көлешеп тыкрыктан үзен күзәтеп торуларын Исхак сизеп торды.* А.Гыйләҗев

ПЫ́РХ-ПЫРХ ИТҮ *ф.* 1) *к.* **пырх итү**. *Кинәт трактор шартлауга охшаш коточкыч тавыш чыгарып, икенче мәртәбә пытырдап алды да пырх-пырх итеп тынып калды.* Ә.Вергазов

2) Бер-бер артлы берничә тапкыр пырх иткән тавыш чыгарып көлү

ПЫ́РХ-ПЫРХ КИЛҮ *ф. кбт. к.* **пырх итү**. *Мин шундук көлүдән туктадым, башны югарырак күтәрдем, әле һаман пырх-пырх килеп барган Соняга җиңелчә генә шелтә ясап алдым.* Н.Фәттах. *Полковник пырх-пырх килде, тотлыкты, аннан соң кулын селтәп, атын борып, киргә чапты.* Идел

ПЫРХЫЛДА́У *ф.* 1) Пырх, пырх-пырх иткән тавыш чыгару. *Болай күңелсез бару картны туйдыра башлый. – Әйт әле, улым, – дип сорый ул, – нинди кошчык пырхылдап узды ул куаклар арасыннан?* Әкият. *Абзый бер кызарды, бер агарды. Үзендә әрепләшерлек көч тә тапмыйча, борыны белән пырхылдады да каядыр китеп барды.* Ә.Баян. *Яфраклар арасында пар сандугач пырхылдый.* Н.Гыйматдинова

2) Пырх, пырх-пырх итеп көлү. *Иң элек кәнфит-прәннек күп ашаудан унсигезгә генә калган тешләрен «җемелдәтеп», сипкелле Хәнәфи пырхылдады.* Л.Лерон. *Без, авызларыбызны каплап, туйганчы пырхылдадык.* А.Гыйләҗев. *Авылның кайсы очында күренсәм дә: «Кара, кара, әнә Тореадор килә», – дип пырхылдыйлар иде малайлар.* Язмышлар яңарганда

Пырхылдап алу Тиз генә, кыска гына пырхылдау. *[Җырчы кызлар] өстәл янындагы алыпларны күрү белән, --- бер-берсенә карашып я пырхылдап алдылар, я тыелып кына нидер гайбәтләшеп алдылар.* Н.Фәттах

Пырхылдап җибәрү Кинәт пырхылдый башлау. *Шул чак Асия: – Төрледән кирәк! Сайлап алырлык булсын! – дип пырхылдап җибәрде.* Э.Касыймов. *Һәм Рәүф поскан урынында чыдаша алмыйча пырхылдап ук җибәрде.* Г.Иделле. *Хатыннар дәррәү көлешә башладылар. Мин дә пырхылдап җибәрә яздым.* Шатлыклы кайгы

Пырхылдап кую Пырх иткән кыска тавыш чыгару. *Җыр тынгач, күңелсез бер тынлык урнаша, пырхылдап куйган тавышлар, көлүне томаларга тырышып йөткерүләр ишетелеп тора...* Ә.Баян. *Кемдер пырхылдап куйды.* Ж.Дәрзаман

Пырхылдый башлау Пырхылдарга тотыну. *Укучылар пырхылдый башлагач кына аңына килеп, кадагын чалбар кесәсенә яшереп куйды.* Г.Мөхәммәтшин. *Аннан кулы белән тезенә шапылдатып куйды да учы белән авызын томалап: – Димәк ки, син монда... – дип, тагын пырхылдый башлады.* Р.-Н.Гүнтәкин

ПЫРЫЛДАВЫК *с.* Пырылдый торган

ПЫРЫЛДАТУ *ф. йөкл. юн. к.* **пырылдау**. *[Карт], каты пырылдатып, борынын сеңгерде.* Ш.Камал. *Көпчәкләр тузан пырылдатып юлдан тәгәрәде.* Н.Гыйматдинова

Пырылдата башлау Пырылдатырга тотыну

Пырылдатып җибәрү Кисәк пырылдата башлау

Пырылдатып карау Сынау өчен пырылдату

Пырылдатып тору Әле, хәзер пырылдату

ПЫРЫЛДА́У *ф.* 1) Пыр-пыр иткән тавыш чыгару. --- *таллар башына*

каргалар кунаклаган, ахрысы, инде йокыга да киткәннәр. Ара-тирә берәрсе саташып карылдап ала, кунаклаган ботагыннан ычкынып пырылдый ---. М.Мәһдиев. *Матай, мәче күргән эт шикелле пырылдап, яңадан алга атылды.* Ф.Баттал. *Очкыч бер-ике йортны узып болайга таба килде, утларын балкытып, нәкъ Гафифә әбинең өе турысында, такта түбәгә тияр-тимәс пырылдап, бераз эленеп торды ---.* А.Гыймадиев

2) Җиңелчә пыр-пыр иткән тавыш чыгарып, бер урыннан икенче урынга очу. *Ара-тирә яфраклар шыбырдашып куялар. Пырылдый-пырылдый коңгызлар очып үтә.* Г.Әпсәләмов. *Куркынган бытбылдыклар, тургайлар пырылдап кара һавага күтәрелә.* А.Гыйләҗев. *Баш очыннан гына, «Кая пар-рассыз?» дигәндәй, пырылдап, чыпчыклар өере очып үтте.* А.Хәлим

3) *күч.* Бик тиз һәм җиңел генә хәрәкәт итү, йөрү, бию. *Бу кыз шундый җитез бөтерелә, шундый җиңел пырылдый: ул миңа абый ясап бирә торган салам курчак биюен хәтерләтте.* Г.Бәширов

4) *күч.* Ярсу, дулау, ачулану. *– Нәрсә син, әллә шөрепләрең бушый башладымы? – диде Тәһия, пырылдап.* Х.Камалов. *Ә хатының пырылдый икән, син аны театрга алып барып карале, шуннан күңеле булыр, чынлап әйтәм.* Ватаным Татарстан. *Рәхилә, өстенә кайнар су койдылар диярсең, пырылдап, өстәл артыннан кузгалды да --- ванна бүлмәсенә кереп китте.* Ирек мәйданы

Пырылдап алу Аз гына, бераз пырылдау

Пырылдап китү Кинәт кенә пырылдый башлау. *Ул авызын йомып та өлгермәде, аңа ялгап чиләкле хатын пырылдап китте ---.* Г.Мөхәммәтшин. *Мужикларны бу дәрәҗәгә җиткерүдә дәү әнинең үз гаебе дә бар булса кирәк, ул тик торганнан да пырылдап китә, кирәкмәгәнгә шикләнә ---.* В.Астафьев

Пырылдап кую Кыска гына, бер тапкыр пырылдау

Пырылдый башлау Пырылдарга тотыну. *Кәһәр суккан нәрсә ул көймә моторы. Кайчак егерменче тартуда гына пырылдый башлый.* М.Әмир. *Пырылдый башласа: «80 яшьләреңә кадәр шулай янымда мыр-мыр килеп йөрсәң ярар иде әле», – дим.* Шәһри Казан

ПЫРЫЛДЫК *с. сөйл.* 1) Пырылдау тавышы чыгара торган

2) Тиз ярсып, тиз кызып китүчән. *Пырылдык хатын*

ПЫРЫХ *иярт. к.* **пырх**. *Пырых та пырых Үзе гел көлә. Кинәт шул чакта Җирләр селкенә.* А.Алиш

ПЫРЫХЛА́У *ф.* 1) *к.* **пырхылдау**

2) *к.* **пыранлау**

Пырыхлап алу Тиз генә, кыска гына пырыхлау

Пырыхлап җибәрү Кинәт пырыхлый башлау

Пырыхлап кую Бер мәртәбә, кисәк пырыхлау

Пырыхлый башлау Пырыхларга тотыну

ПЫРЫ́Х-ПЫРЫХ *иярт. көб. к.* **пырх**. *Өстенә кар тәңкәләр тезелгән кош пырых-пырых итеп аның баш өстендә очынды, ачуланып томшыгын шыгырдатты.* Р.Хафизова. *[Бәрән:] Мине ул гел мыскыл итә. Мине күрсә, пырых-пырых итеп көлә.* Т.Миңнуллин. *Ни өчендер шушы кызык тоела, сәхнәдәгеләр – Асия ханым Харисова, Асия ханым Хәйруллина – тыела алмыйча пырых-пырых көлергә тотыналар.* Р.Батулла

ПЫРЫ́Х-ПЫРЫХ ИТҮ *ф.* Пырхылдау, пырх итү. *Мич пырых-пырых итеп өй эченә төтен бөрки башлый, моржа тартмый, --- утын агачлары пыскып ята.* З.Зәйнуллин

ПЫСКАК *с.* 1) Бик вак, томан сыман, иләп ява торган. *Сирәк лампочкалар, пыскак яңгыр күзне алыштыргангамы, әллә артык кабалангангамы, ул абынды-сөртенде ---.* М.Маликова. *Томандай томалап пыскак яңгыр сибәли иде.* Х.Сарьян. *Пыскак яңгыр яуды да яуды.* М.Галиев

2) Сүрән, бик тонык, йомшак. *Пыскак утлар белән яктыртылган автовокзал алды тып-тын һәм бушап калган иде.* М.Галиев

ПЫСКАКЛА́У *ф.* Әкрен генә сибәләү. *Яңгыр пыскаклый гына.* Ш.Камал. *Тышта пыскаклап көзге яңгыр ява.* Л.Ихсанова. *Ләкин урамда кышкы салкын бураннар урынына көзге елак яңгыр пыскаклый.* Ватаным Татарстан

Пыскаклап алу Аз гына, бераз пыску

Пыскаклап тору Даими яки әледәнәле пыскаклау; хәзерге моментта пыскаклау. *Күкләр атна буе пыскаклап торды, тәмам җәлекләргә үтте.* Р.Бәшәр

Пыскаклый башлау Пыскакларга тотыну. *Яңгыр да пыскаклый башлады.* З.Мәхмүди. *Айсинә урамга чыкканда, вак яңгыр пыскаклый башлаган иде.* Н.Көбәш. *– Яңгыр пыскаклый башлады! – дип кычкырам, юеш бүрегемне чөйгә элеп.* Шәһри Казан

ПЫ́СК-ПЫСК *иярт. к.* **пысык-пысык**

ПЫСКУ *ф.* **1.** 1) Ялкынланмый гына төтен чыгарып яну, көйрәү. *Мае бетеп, пыскып утырган лампаның ялкын теле кинәт сикереп куйды ---.* М.Галәү. *Мортаза белән «сары чәч»нең гөнаһысыннан җирәнгәндәй, ут ялкыны да үрләп китәргә ашыкмады, ниедер пыскыды, ниедер эреде, чыжылдады.* К.Тимбикова. *Пыскыган учакны яратмыйм, җылысы юк, төтене генә күзгә керә.* Р.Кәрами

2) Ялкыны сизелер-сизелмәс булып яну. *Янында берничә шәм пыскый, почмакка икона сөяп куелган.* Г.Гыйльманов. *Йорт эчендә пыскып һәм кысылып янган сукыр ут, ярым капланган парлы тәрәзә аша омтылып, күзен урамга төрткән дә үтүче-сүтүчегә әле монда җан әсәре булганлыгын хәбәр иткәндәй иде.* Ф.Яхин. *Өстәл өстендә күгәргән консерва банкасына мылтык мае салынган, шуңа филтә тыгылган кысык лампа пыскый.* Хезмәт даны

3) *к.* **пыскаклау**. *Көннәр буе пыскып елак яңгыр сибәли ---.* Э.Шәрифуллина. *Пыскып кына яуган көзге яңгыр тәрәзә пыялаларына буй-буй эз сала.* Г.Әдһәм. *[Яңгырның] бигрәк пыскып яуганы теңкәгә тия, бер тотынса, туктый белми.* Р.Кәрами

4) *күч.* Бик аз гына, сизелер-сизелмәслек дәрәҗәдә булу. *Кайсы гына суга кармак салсам да, күңелемнең кайсыдыр төшендә яшерен өмет пыскыды: әлеге алтын балыгым килеп*

кабар кебек тоелды. Г.Сабитов. *Әмма күңелендә сүнәр-сүнмәс пыскыган ялгыз чаткы аның өчен караңгы төндә кыйбла булып балкыган якты йолдызга бәрабәр иде*. Ж.Дәрзаман. *Хәзер инде авылның егермеләп хуҗалыгында гына тормыш пыскый*. Ватаным Татарстан

5) *күч*. Эчтән генә, тирә-юньдәгеләргә сиздерми торган, яшерен берәр уй, теләк, хис саклау. *[Шәйхаттар] төптә Советка дошманлык ачуы белән пыскый*. Г.Толымбай

6) *күч*. Үкенү, өметсезләнү, өметсезлеккә бирелү. *Хәзер безне шул өч тиен тормый торган балыкчылар да санга тыкмый, нинди хурлыкка калдык, дип пыскыдылар [алар]*. Г.Толымбай. *Менә монысы – безнең опера ариясе. Яратам шундый героик арияләрне. --- Пыскыма!* Г.Әпсәләмов

2. пыскып *рәв. мәгъ*. 1) *күч*. Акрын гына; бик сүлпән. *Аның сүзләре, миннән яшеренеп пыскып елавы тагы йөрәгемә төште*. Г.Ибраһимов. *Аның сәбәбен барыбыз да күпмедер дәрәҗәдә ишетеп белә: дистә еллар гөрләп торган сәүдә эшләребез пыскып кына бара башлады*. Р.Сәгъди. *Әмма ул инде пыскып та елый алмый иде*. Ф.Яхин

2) *күч*. Зур эшләр белән шөгыльләнмичә, бөек фикерләр белән янмыйча, төссез, борчусыз гына (тормыш алып бару тур.). *Салкын кан белән уйлыйбыз, салкын кан белән яратабыз, салкын кан белән генә янабыз. Пыскып*. Ш.Галиев. *Ә кичен аны биергә чакырды: – Әйдә, ятма пыскып, хәрәкәттә – бәрәкәт. Биючеләрне күрерсең, үзеңне күрсәтерсең*. Ә.Сәлах. *Нигә, йөрәк, Ярсый-ярсый шулай янасың? Көрәш мәйданына атылып чыгып, Киләмени батыр каласың? Еллар буе пыскып йөрүләрдән Ялыктың шул, ахры, ялыктың*. Р.Ягъфәров

Пыскып алу Берара, бераз пыску

Пыскып тору Хәзер, шушы вакытта пыску; озак пыску. *Шулай да янып беткән учакның көле астында утлы күмерләр пыскып тора әле*. Х.Камалов. *Ашарга ризык бетте, баш очында, күңелсез кыяфәтләргә кереп, каракучкыл болытлар чабыша, тоташ дип әйтерлек вак яңгыр пыскып тора*. Ф.Сафин. *Пыскып торган яңгыр да мәйданга җыелган халыкның кәефен төшерерлек түгел иде*. Шәһри Казан

Пыскып яту Озаклап пыску; пыску процессында булу. *Янган йортлар урынында әле һаман пыскып ята торган кисәүләр, янмаган йорларның байтагының түбәләре каерылган, койма-капкалары ауган иде*. Р.Батулла. *Халык арасында, Кәсле шәһәренең канализация сулары да Караболакка агызыла, дигән сүзләр йөри, шуңа күрә елга хәзер кышларын да катмый икән, ул яшелле-зәңгәрле төтеннәр чыгарып пыскып ята*. Ф.Бәйрәмова

Пыскый башлау Пыскырга тотыну. *Тик, беләсеңме, вакыты-вакыты белән синдә, ничектер, ялкын сүнгән кебек була. Дөресрәге, янудан туктап, пыскый башлыйсың кебек*. М.Хәсәнов. *Аның балачагы вакытыннан элек тәмамланды, чөнки илдә сугыш уты кабынды. Мөнәҗия өчен ул ут алданрак та пыскый башлаган иде инде*. К.Тимбикова. *Уч-уч ташлаган туфракка түзмәде, ут пыскый башлады, гөлт итеп тагын кабынырга тырышты*. Р.Хафизова

ПЫСКУЛЫ *с*. 1) Пыскый торган, пыскаклый торган

2) *физ*. Яктырткыч вак газ бөртекләре хасил иткән. *Пыскулы бушану*

3) *күч*. Төссез, борчусыз, хиссез. *Тузанлы, томанлы, пыскулы яшәешне җене сөйми, рухына үткәрми*. Т.Галиуллин

ПЫСКЫЙ *и. диал*. Сукыр лампа. *Тышта, төн карасын ярып, багана башларындагы пыскыйларда карамайлар янды*. Н.Фәттах. *Кичләрен өстәл почмагына, пыскый каршысына утырам да бармак белән иҗек саный-саный сүзләр чүплим*. Ватаным Татарстан

ПЫСКЫЛДА́У *ф*. 1) Пысык-пысык иткән тавыш чыгару. *Моңарчы күз яшьләрен көч-хәл белән тыеп тоткан карчык кинәт әкрен генә пыскылдап елап җибәрде*. А.Шамов

2) Шундый тавыш чыгарып елау. *Аның колагына пыскылдаган тавыш ишетелде*. Атака

3) Пыс итеп һава чыгу. *Гармун күрегеннән һава пыскылдады*

4) *к*. **пыскаклау**. *Ә аты, арбасы белән, бер читтә пыскылдап яуган яңгырга арты белән борылып, тик кенә тора, ди*. Г.Бәширов

Пыскылдап алу Аз гына, бераз пыскылдау

Пыскылдап җибәрү Кинәт пыскылдый башлау

Пыскылдый башлау Пыскылдарга тотыну

ПЫСКЫЛДЫК *с*. 1) Пысык-пысык иткән тавыш чыгара торган; бик әкрен, ишетелерлек булмаган. *Ул тавыш бугазына кургашын кадалган солдатның пыскылдык өнен зур завод эчендәге черки тавышыннан да кечкенә ясый*. К.Нәҗми

2) *күч. шелт*. Юк кына нәрсәгә дә ачкрын гына, пысык-пысык итеп елый торган. *Пыскылдык бала*

ПЫСКЫТУ *ф*. 1) Ялкынсыз яндыру, төтәтү. *Сөенешеп, алар йөгерешеп килеп җиттеләр, учактан пыскытып ут кабыздылар*. Н.Фәттах. *Колхоз бакчачыларының Тимеркыя янында Кыйбазы елгасын буып, түтәлләрне сугарып маташканнарын, кырау төшәрдәй салкынайтса, шунда төтен пыскытып төн үткәргәннәрен авыл бичәләре көлкегә дә чыгардылар*. Ш.Янбаев

2) Тәмәке тарту, төтәтү. *Хатыны үләргә ята, ә аның гамендә дә юк, иртә таңнан чыга да, үзен үзе кочаклап, тәмәке пыскыта*. А.Гыйләҗев. *Җирән сакаллы удмурт карты трубка пыскыта ---*. М.Мәһдиев. *Ул бик сирәк тарта, я дус-ишләре белән очрашканда ---, я бик дулкынланган чагында гына. Ә бүген бертуктамый пыскыта*. Р.Кәрами

3) *эвф*. Сасы ис чыгару, сасыту

Пыскыта башлау Пыскытырга тотыну. *Ул --- янчыгыннан чеметеп махорка алып кәгазьгә салды, --- кабызып пыскыта башлады*.Р.Кәрами

Пыскыта бирү Бернигә карамыйча пыскытуны дәвам итү. *Җәмәгать урыннарында беренче июньнән тәмәке тартуны тыя торган закон әлегә беркемне куркытмый бугай: элеккечә пыскыта бирәләр*. Мәдәни җомга

Пыскытып алу Тиз арада, тиз генә пыскыту. *Ир-ат тәмәке пыскытып алгач, тагын берәмләп автобуска*

тулдылар. Р.Кәрами. *Тамбурга чыгып тәмәке пыскытып алдык.* Д.Гыйсметдинов. *Укытучылардан качып кына тәмәке пыскытып алдык.* А.Гыймадиев

Пыскытып җибәрү Пыскыта башлау. *– Әйдә, өйрәнә тор, – дип, әтисе рульне Әмиргә тапшырды. Үзе, арткы утыргычка ук күчеп, тәмәке пыскытып җибәрде.* Ф.Яруллин. *Хәзер биредә Алмаз булсын, берәр тәмәкесен пыскытып җибәрсен иде, ә дигәнче язып ташлар иде ул мәкаләсен.* И.Сиражи. *Пыскытып җибәрмисеңме дигәндәй, үзенә немец сигаретын суздылар.* Идел

Пыскытып карау Пыскытырга тырышу; сынау, белү максаты белән пыскыту. *Шул авылда мин малайлар белән качып кына тәмәке пыскытып карадым бит!* Казан утлары

Пыскытып кую Бер тапкыр, бераз гына пыскыту. *– Нуриевка кирәкле тән сакчысы менә мин үзем була алам! – диде ул һәм, зур канәгатьлек хисләре кичерә-кичерә, тәмәкесен пыскытып куйды.* Р.Вәли

Пыскытып тору Әле, шушы моментта пыскыту. *Баскычта ике егет тәмәке пыскытып тора.* Р.Кәрами. *Олы юл кырыенда «Колхида» сигареты пыскытып торабыз.* Р.Вәлиев. *Нәрсә хакында әйткәннәрен иптәшләре генә түгел, милиция идарәсенең баскыч төбендә бер-бер артлы тәмәке пыскытып торган теге сержант та аңлады.* Ф.Яхин

ПЫ́С-ПЫС *иярт. к.* **пысык-пысык**. *– Ник дәшмисең, әллә телсезме син? – дигәч, Сәхип пыс-пыс елый башлады.* Г.Ибраһимов. *Күк йөзендә тибрәлгән кайнар һава дулкынында тилгәннең пыс-пыс килеп сулыш алганы ишетелә сыман.* М.Мәһдиев

ПЫСЫ́К-ПЫСЫК *иярт.* **1.** Тавыш чыгарыр-чыгармас, акрын гына елаганда була торган тавышны белдерә

2. *рәв. мәгъ.* Тавыш чыгарыр-чыгармас, акрын гына; мышык-мышык. *Түрдәге караваттан кемнеңдер пысык-пысык елавына охшаш бер тавыш килде.* Г.Ибраһимов

ПЫСЫ́К-ПЫСЫК ИТҮ *ф.* Пыскылдау, үксү

ПЫТПЫТ *и. сөйл.* Кечкенә трактор, йорт шартларында җыелган кечерәк транспорт чарасы һ.б.ш.лар. *Әдһәм ага, аннан баш тартып, нәни трактор алган. Халык телендә пытпыт дип йөртелгән бу трактор арбасы белән ихатада тора.* М.Галиев. *Ләкин трактор үзеннеке. Үз акчама сатып алынган. Рәсми исеме ул тракторның «Т-25», авыл халкы телендә пытпыт дип атала.* Т.Миңнуллин

ПЫ́Т-ПЫТ *иярт.* 1) Мотор эшләгәндә, каты җирлеккә өзек-өзек су тамганда, тиз-тиз сөйләшкәндә чыккан тавышны белдерә. *Рита примуска ут кабызды, ул арада мин кулларны юып алдым. Бераздан карыйм – Рита юк. Бүлмәдән пыт-пыт тавыш ишетелә.* М.Мәһдиев

2) Ут бер кабынып, бер сүнеп яну, нәрсәдер өзек-өзек бөркелү, коелу рәвешен белдерә. *Хайванның күзеннән пыт-пыт тама, Агадыр кап-кайнар яшьләре.* Н.Думави

ПЫТ-ПЫТ ИТҮ *ф.* 1) Өзек-өзек, шартлаулы коры тавыш чыгару. *Өч-дүрт тартканнан соң [мотор] пыт-пыт итеп куйса, бик шөкер инде.* М.Әмир

2) Бытылдау, тытылдау, тиз-тиз сөйләшү

ПЫ́Т-ПЫТ КИЛҮ *ф. к.* **пыт-пыт итү**. *Фатыйма апа туктаусыз пытпыт килә.* Ф.Яхин. *Торбасыннан пытпыт килеп чыгып торган төтене дә – сәер күренеш.* Кызыл таң

ПЫТЫ́Й-ПАТЫЙ *с. диал.* Сакау. *Пытый-патый кеше*

ПЫТЫ́Й-ПАТЫЙ КИЛҮ *ф. сөйл. к.* **пытылдау** (*2 мәгъ.*)

ПЫТЫ́Й-ПЫТЫЙ *иярт. к.* **пыт-пыт**

ПЫТЫ́Й-ПЫТЫЙ ИТҮ *ф. к.* **пыт-пыт итү**. *Фермада «Беларус» тракторының пускачын кабызгандагы пытый-пытый иткән тавыш колакны ярып керә.* Х.Камалов

ПЫТЫЛДА́У *ф.* 1) Пыт-пыт итү

2) Аңлашылыр-аңлашылмас сөйләшү; бытылдау. *Тансык, аңа җавап итеп, үз телендә тагын нидер пытылдый.* Г.Ахунов

3) *күч. шелт.* Бертуктаусыз сөйләп тору, күп сөйләү, такылдау

ПЫТЫМЫР *с. диал. шелт.* **1.** 1) Бертуктамый сөйли торган, күп сөйләшүчән

2) Вак-төяк, әһәмиятсез нәрсәләргә игътибар итүчән, вакчыл

2. *и. мәгъ.* Күп сөйләшүче кеше. *Бу кадәр такылдык булырсың икән. Такыл да токыл. Пытыр да пытыр. Нәкъ пытымыр.* Р.Ишморат

ПЫТЫ́-ПЫТЫ *иярт.* Тиз-тиз, аңлаешсыз итеп сөйләү рәвешен аңлата

ПЫТЫ́-ПЫТЫ КИЛҮ *ф.* Бертуктаусыз һәм күп сөйләү. *Пыты-пыты килеп гомер буе пытырдаудан эшнең тәмен белми йөргәнмен икән.* Р.Ишморат

ПЫТЫРДАВЫК *с. сөйл.* **1.** Бик күп һәм тиз сөйли торган

2. *и. мәгъ.* Юка итеп җәеп, табага салып мичтә пешерелгән камыр азыгы. *Көнаралаш каты күмәч, төче күмәч, таба ипие, пытырдавык --- пешергән хатынына карап, ул ризасызлыгын әйтеп куя иде ---.* М.Мәһдиев

ПЫТЫРДАТУ *ф.* Пытыр-пытыр иткән тавыш чыгару. *[Контролёр] әллә ниткән тимер каптыргыч белән шул билетны пытырдатып, иясенә кире бирә.* Ш.Маннур. *--- барлык пытырдыкларның моторын җыеп алып үтилгә җибәрер идем. Йөрсеннәр [мотоциклны] пытырдатмыйча этеп кенә.* Ф.Яруллин. *Йөрәгемә пытырдатып хәнҗәр кададымыни!* Р.Батулла

Пытырдата башлау Пытырдатырга тотыну

Пытырдатып алу Берара, тиз генә пытырдату

Пытырдатып җибәрү Пытырдата башлау

Пытырдатып кую Бер тапкыр пытырдату

ПЫТЫРДА́У *ф.* 1) Өзек-өзек тигез ритм белән эшләп, шартлаулы яңгыравык тавыш чыгару, пытыр-пытыр итү, пытыр-пытыр килү. *Үләмәнең аръягыннан пытырдап матай килеп чыкты.* Ә.Баян. *Аргы баштагы каланча янында пытырдаган тавыш ишетелә: колхозның шофёрлары машина кабыза.* Р.Кәрами. *Тракторның моторы бөтен көченә пытырдап эшли башлады.* А.Вергазов

2) *күч.* Бик күп, тиз һәм аңлаешсыз сөйләү. *Пыты-пыты пытымыр Пытырдарга тотыныр. Бер пытырдый*

башласа, Юк качып та котылу. Р.Ишморат

Пытырдап алу Берара яки бер тапкыр гына пытырдау. *Кинәт трактор, шартлауга охшаш коточкыч тавыш чыгарып, ике-өч мәртәбә пытырдап алды да пырх-пырх итеп тынып калды.* Ә.Вергазов

Пытырдап җибәрү Пытырдый башлау

Пытырдап кую Бер тапкыр пытырдау

Пытырдый башлау Пытырдарга тотыну. *Кaһәр суккан ул көймә моторы. Кайчак егерменче тартуда гына пытырдый башлый.* М.Әмир

ПЫТЫРДЫК *и. сөйл.* Мопед яки җиңел мотоциклны шаяртып атау сүзе. *--- барлык пытырдыкларның моторын җыеп алып үтилгә җибәрер идем.* Ф.Яруллин

ПЫТЫ́Р-ПЫТЫР *иярт*. **1.** 1) Өзек-өзек тигез ритм белән эшли торган нәрсә чыгарган яңгыравык тавышны белдерә. *Көн туса, пытыр-пытыр мотоцикллар чаба*. Р.Батулла

2) Тукыма ертылганда чыккан коры тавышны, тиз-тиз, ашыгып сөйләгәндә һ.б.ш. очракларда чыккан тавышны белдерә

2. *и. мәгъ*. Пытырдаган тавыш чыгарып эшли торган техника. *Тәгәрмәчле пытыр-пытыр тракторы узып китте.* Т.Нәҗмиев

ПЫТЫ́Р-ПЫТЫР ИТҮ *ф*. 1) Өзек-өзек пытырдаган тавыш чыгару. *Аннары мотоциклның каты гына пытыр-пытыр итеп кузгалып китүе ишетелде ---*. Ә.Еники. *Арбабыз да пытыр-пытыр итә бит, Гөлфия апа.* Н.Гыйматдинова

2) Аңлаешсыз итеп ашыга-ашыга сөйләү

3) Ризасызлык белдереп, ачуланып, үзалдына сөйләнү, мыгырдану, мытырдау

ПЫТЫ́Р-ПЫТЫР КИЛҮ *ф. к.* **пытыр-пытыр итү**. *Бу йөгәнсез хатын --- пытыр-пытыр килеп, җыен юк-барны сөйләп, эшсезлек сатып йөри*. Ф.Хөсни. *--- пытыр-пытыр килеп шәһәр урамнары буйлап чабышкан әлеге мотороллерларны аеруча җенем сөйми.* А.Хәсәнов. *--- янәшәсендәге абый ниндидер тимер ыргакны үзенә таба тарткан иде – тыр-тыр берара пытыр-пытыр, дөбер-шатыр килеп торды да әкрен генә кузгалып китте.* А.Фәләх

ПЫФ *иярт.* 1) Авыздан һава чыгарганда барлыкка килгән тавышны белдерә. *Рауза пыф диде, кызыл буяулы ирене белән үчекләде.* А.Таһиров

2) *к.* **пуф** (*2 мәгъ.*). *Килү белән клуб артына чыгып, кача-поса аракы эчәргә тотыналар, ишек төбендә пыф та пыф тәмәке пыскыталар*. А.Гыймадиев

ПЫ́Ф ИТҮ *ф.* 1) Пыфылдау, пуфылдау, пыф дигән тавыш чыгару. *Шуннан мин тычканны мәченең авызы янына куйдым. Мәче пыф итте дә икенче җиргә күчеп ятты*. Т.Миңнуллин

2) Кисәк кенә берәр нәрсә бөркү, өрү. *Ашыкмыйча гына тәмәке төреп кабызды, чирәм өстенә сузылып ятты, пыф-ф итеп һавага төтен өргәннән соң, --- күзләрен йомды*. Ф.Шәфигуллин. *Илдус абый: «Вакыт-вакыт авызыңа салкын су алып, пыф итеп өсләренә бөрке», – дип өйрәтеп калдырды*. Татарстан яшьләре

ПЫ́Ф-ПЫФ *иярт. к.* **пуф-пуф**. *Черки Гаслимәнең пыф-пыф өрүеннән бер мәлгә тынып торса да, зыян күрмәде бугай, бераздан яңадан безелди башлады.* Ж.Юныс

ПЫ́Ф-ПЫФ ИТҮ *ф. к.* **пуф-пуф итү**. *Малай үсә, буе, яше арта, Бәби чагы инде калды артта. Күн диванга ятып «Казбек» тарта, пыф-пыф итеп, пыф-пыф итеп.* Г.Афзал. *Ике минут үттеме, юкмы, малай пыф-пыф итеп иреннәреннән куык өрә башлады.* М.Әмир. *Симез бәдәнлесе, битенә яулыгы белән җил китереп берничә мәртәбә пыф-пыф итеп өргәннән соң, яңадан сүз башлады*. Р.Гали

ПЫФ-ПЫФ КИЛҮ *ф. к.* **пуф-пуф итү**

ПЫФЫЛДА́У *ф. к.* **пуфылдау**. *Бүгенге шикелле нервлары кузгалган вакытларда [хатынның] пуфылдавы аңар пычак*. Ш.Камал. *[Егет] кичтән ятуга, ул пыфылдап йокыга киткән.* М.Мәһдиев. *Минәт артыннан калмыйм дип кабаланып бара-бара, Шәмсүн бөтенләй тирләп чыкты, пыфылдады, бертуктаусыз йөткеренде*. Ә.Вергазов

Пыфылдап җибәрү *к.* **пуфылдап җибәрү**

Пыфылдап кую *к.* **пуфылдап кую**

Пыфылдый башлау *к.* **пуфылдый башлау**

ПЫХ *иярт*. *к.* **пух**. *Габдерәшит ишекне ачып: «Пых!» – [ди]*. М.Фәйзи

ПЫ́Х БУЛУ *ф. к.* **пух килү** (*3 мәгъ.*). *Эре-эре гәүдәле, ашап пых булган сыерлар да олы җиленнәрен уңга-сулга болгап чаба башлады*. Сабантуй. *Бары тик бездә генә кеше, пых булганчы ашагач, корсагына шапылдатып: «Болай булмый, ябыга башларга кирәк!» – дип куя.* Татарстан яшьләре

ПЫ́Х ИТҮ *ф.* 1) *к.* **пух итү** (*1 мәгъ.*). *Пых итеп сине куркыттым*. М.Фәйзи. *Ни өчендер пых итеп ат та туктады*. Ф.Кәрим

2) *сөйл*. Нинди дә булса терлекне сую. *Гөлле абыстай! Сыерыгызны суябыз! Пых итәбез!* Г.Иделле

3) *к.* **пух итү** (*3 мәгъ.*). *Мәктәптән кайтып, кибеттән ит алып чыгып кәчтрүл тутырып пешерәм дә шуны ашап, корсакны киереп, пых итеп караватка барып авам*. Ф.Яруллин

ПЫ́Х-ПЫХ *иярт*. *к.* **пух-пух**. *Мин аны барыбер кулыма алмыйм, яткан җиреннән генә тамак астын кытыклыйм да пых-пых көлдерәм*. М.Әмир. *Тыныч кына утыралар икән шулай, ни күзләре белән күрсеннәр: каршыларында җир уфылдап куйган, пых-пых пар бөркелгән, кайнар су атылып күтәрелгән.* М.Маликова

ПЫ́Х-ПЫХ ИТҮ *ф. к.* **пух-пух итү**. *Самавыр пых-пых итеп җырлап кайнап утыра.* Н.Дәүли. *Туганда ук, һәр адәм баласының үз кыяфәте, үз холкы. Берсе чырылдап елый, икенчесе калын тавыш белән таләпчән итеп кычкыра, өченчесе пых-пых итеп кыймылдый, ләкин еламый*. М.Маликова. *Нугай, пых-пых итеп, үзе юына, үзе кызны күзәтә.* Ә.Шәмин

ПЫ́Х-ПЫХ КИЛҮ *ф. к.* **пух-пух килү**. *Пых-пых килеп, кызарынып-бүртенеп беткәч, Фаил Зөлфәтне еккан кебек итте, өстенә ныгытып ауды*. Көмеш кыңгырау

ПЫХЫЛДА́У *ф.* Пых иткән тавышлар чыгару. *[Каз], калку күкрәкләрен горур киереп, пыхылдый-пыхылдый җим эзли.* М.Хөсәен. *Пыхылдап пар атып утырган паровозларны күреп шаккатты малай.* Я.Шәфыйков

Пыхылдап алу Бераз вакыт пыхылдау

Пыхылдап җибәрү Пыхылдый башлау

Пыхылдап куя Бер тапкыр пыхылдау

Пыхылдый башлау Пыхылдарга тотыну

ПЫЧАК *и.* **1.** 1) Әйбер кисү, турау, ваклау өчен, бер башына сап куелган үткен, яссы металл кисәге. --- *ул чалгыдан ясаган кәкре пычагын чыгарып күрсәтте. Андый зур агач саплы пычакны без беренче кат күрә идек.* Ә.Гадел. *Җәймә чите бераз ачылып, Идриснең аркасына, нәкъ йөрәк турысына кадалган пычак сабы тырпаеп тора иде.* Ф.Бәйрәмова. *Аннары хан каршына китереп куелган табактан пычак белән бер кисәк кыздырылган ит кисеп капты.* Т.Нәбиуллин

2) Берәр төрле машинаның яки җайланманың кисә, турый, ваклый торган махсус детале. *Авыл хуҗалыгы техникасы итеп, тирән сөрү өчен җайлы болгар сабаны – тимер сука кулланылган. Ул төрәннән, пычактан, тәртәдән һәм калактан торган.* Борынгы Калатау итәгендә

3) *күч.* Кемгә дә булса газап, әрнү, авырлык, начарлык китерә торган нәрсә. *Бүгенге шикелле нервлары кузгалган вакытларда [хатынның] пуфылдавы – аңар пычак.* Ш.Камал

2. *кис. мәгъ.* 1) **пычак, пычагым**. Җөмләдән аңлашылган эш-хәрәкәткә ачулану катыш ризасызлык төсмере биреп, эш-хәлнең булмаслыгын яки начар булуын белдерә. *Төлке тоталар, имеш! Тоттырыр, пычагым!* Н.Әхмәдиев. *[Прокурор] эшкә бар, үзем күзәтеп, белешеп торырмын, дигән була. Күзәтә, пычагым, оныткандыр да инде!* А.Гыйләҗев. *Күршеләре: – Авыл ничек? Тормыш әйбәтме? – дип сораштылар. – Әйбәт, пычагым! – диде Байтимер, ачу белән үпкә катыш.* Шатлыклы кайгы

2) **пычагыма**. Ачулану катыш ризасызлык төсмере белән «нигә? ник? ни өчен?» дигән сорауларны алыштырып килә. *Инде яңгыр яугач, пычагымамы тагы корбан чалып торырга?* Г.Иделле. *Миңа хәзер Солтаныгыз пычагымамы?* Н.Гыйматдинова

◊ **Пычагы майда (май өстендә)** «Бай, мул тормышлы, тук яши» мәгънәсендә. *Гомере буе пычагы май өстендә булганлыктан, авырлыкка бер көн түгел, бер генә минут та түзәсе килми.* Э.Шәрифуллина. *Әйткәне – закон, пычагы май өстендә була аның.* Кызыл таң. **Пычагым кергере** Әрләү, нык ачулану катыш ризасызлык белдерү өчен әйтелә; җитди яки шаяртып каргау сүзе. *Нәрсә бар соң төнлә берләп, и пычагым кергере!* Г.Тукай. *Әбәү! Пычак кергере, башымны яра язды...* К.Тинчурин. **Пычагым кирәкме** «Тагы нәрсә җитми, тагын нәрсә кирәк?» дигән мәгънәдә. **Пычагымны да (пычак та) кырып булмау (кыра алмау)** «Берни дә эшләп булмый, бер чара да юк» мәгънәсендә. *Пычак та кыра алмадым мин, әшнә, теге кешенең машинасында бер рычаг сынган, --- синсез эш чыкмый анда.* К.Тимбикова. *Бердәм булсак, пычагым да кыра алмый ул.* М.Галиев. **Пычак астына** 1) Үтерү, юк итү турында. *Хак, кыз бала сугым түгел, пычак астына алып китмиләр, әмма нигә алай шатлана, көлә-елмая кызы Айбиби?* М.Хәбибуллин; 2) Хирургик операциягә керү турында. *– Йөрәк тә бар икән үзеңдә! Белә торып пычак астына килгәнсең. Ә бит операциянең төрлечә чыгуы ихтимал, – дим.* Э.Шәрифуллина. *– Менә шулай, килә-килә килеп җиттек... пычак астына, – дип куйды ул, үзенең хәленә исе китмәгәндәй. – Ходай ни язган булса, шул булыр инде... Безне берничә көн операциягә әзерләделәр.* Р.Харис; 3) Куркыныч астына кую. *– Егет кеше үз кылганнары өчен үзе җавап бирергә тиеш, – дип дәвам итте Алия Фәргатовна, тавышын йомшартып. – Намус белән. Үз баласын пычак астына салып түгел!* М.Маликова. *Гомерендә дә кәҗә ите ашамаска сүз биргән малай инде бу көнне тагын бер кат күңеленә туганы урынына калган Муллагалине пычак астына куймаска дип сүз беркетте.* Р.Рахман. **Пычак астына керү** *к.* **пычак астына яту**. **Пычак астына яту** 1) Операциягә яту. *– Тирәнгә киткән бу, тамыр җибәргән. Ярып алырга туры килер. – Юк, пычак астына ятмыйм, – диде Гаптери, коты алынып.* Ф.Зариф; 2) Суелу. *Берсеннән-берсе матур утыз-утыз бишләп каз озакламый пычак астына ятачаклар.* И.Гази. **Пычак аша үткәрү** Үтерү, юк итү. *Ике-өч француз солдаты туры килсә, берсен исән калдырып, калганнарын пычак аша үткәрәләр дә авылдан юкка чыгалар.* З.Зәйнуллин. **Пычак белән кисеп алырлык (алышлы) караңгы** Бик караңгы, дөм караңгы. *Ничек таныйсың, кызым, пычак белән кисеп алышлы караңгыда?* С.Рафиков. **Пычак белән кырып юарлык** Бик керләнгән, шакшы, пычрак. **Пычак булып кадалу** Авыр тәэсир итү. *Соңгы сүзләр Айсылу йөрәгенә пычак булып кадалды.* Ф.Бәйрәмова. *Агарынды, кабаланды Хуҗа шулчак: синең сүзләр, Илдар абый, булып пычак, Кадалды экспериментчы күзенә.* Р.Миңнуллин. **Пычакка алу** Пычак белән кадау; сую. *Этен алдым пычакка, Кызын алдым кочакка.* Такмак. **Пычак кайрау** Кемгә дә булса янау, ачу-үч саклау, берәр төрле зыян салырга җыену. *Улың кайта, әткәй, улың кайта, Син инде аңа пычак кайрама.* Ф.Кәрим. *Кул бирүче дә, юл бирүче дә җиде катлам болыт артында пычак кайрый.* К.Нәҗми. *Берәү яши безгә пычак кайрап, Берәү яши сайрап. Юата да елата безне Былбыл телле Айрат.* Р.Вәлиев. **Пычакка пычак** Үзара килешмәслек рәвештә, килешмичә, гомерлек дошманлыкта. *[Марзыя:] Ул аның авырудан түгел бит, сезнең икегезнең дә характерларыгыз шундыйдыр, бер-берегезгә юл куймыйсыз, пычакка пычак!..* Т.Гыйззәт. *[Хөбби] күптән инде бар кардәшләре, якыннары белән дә пычакка пычак әчелешле булып беткән.* Р.Төхфәтуллин. **Пычакка пычак килү** 1) Үтерешү. *Икмәкне байлардан алганнар да ярлы-ябагайларга*

чәчүлек орлык биреп торганнар, кала эшчеләренә озатканнар, пычакка пычак килгәннәр. А.Гыйләҗев; 2) Бик нык тиргәшү, кычкырышу, ызгышу. *Мин дә сиңа, пожалуй, шулай гына диярмен: тату, дус торсак – «Мирыч», ә инде эш ачуланышуга китсә, пычакка пычак килсәк, «Мирзавич»*. Э.Касыймов. *Зыятдин карт авылдашлары белән пычакка пычак килеп яшәмәсә дә, шулай ук кочакка-кочак килергә дә атлыгып тормады*. Р.Вәлиев; 3) Килешмәслек, гомерлек дошман булу. *Алар пычакка пычак каршы килә торган ике сыйныфны бергә катыштырмакчы булалар*. Г.Коләхмәтов. *Шул сәбәпле вак-төяк үпкәләшүдән алып пычакка пычак килүгә кадәр барып җитәргә була.* Безнең гәҗит. **Пычак кергән (нәрсә)** Елаган, кычкырган яки тиешсез вакытта көлгән кешегә карата әйтелә. *Тешсез авызын ачып, Чатта басып тора бер әби: – Нигә көлә алар, пычак кергән, Әйтерсең лә булган әллә ни?!* Р.Әхмәтҗан. **Пычак кергере** *к.* **пычагым кергере**. **Пычак кердеме?** Елаганны яки кычкырганны яратмыйча әйтелә. *– Пычак кердеме әллә, шул тикле акырасың? – диде ул, коры гына итеп.* В.Нуруллин. **Пычак керсен** *к.* **пычагым кергере**. *Пычак керсен җиһанның барча сандугачына!* Г.Тукай. **Пычак кирәкме** *к.* **пычагым кирәкме**. *Артыгын каян аласың? --- Тагын пычакмы кирәк үзегезгә?* Ш.Камал. **Пычак та** Берни дә, бернәрсә дә; берничек тә, һич. *Тракторсыз монда пычак та эш чыгарып булмаячак*. И.Гази. *Озак кына хат язмый тордым, сәбәбе бардыр, дип уйлый күрмә. Пычак та юк, кешеләргә игътибарсызлана барам, шуның бәласе.* А.Гыйләҗев. *Ахырда Вафа, резюме итеп, Хәбибкә шуны әйтә: «Син «тегеләргә» пычак та эшли алмаячаксың, ә Хафазаны, үзең әйткәнчә, хур итеп ташларга мәҗбүр булачаксың».* Ә.Еники. **Пычак тел** Үткен, ачы телле кешегә карата әйтелә. *Син әйтәсең: «Пычак тел син», – дисең... Пычактан да яман минем тел: Пычак үтмәслә, кискән саен Үткерлә бара минем тел.* Ә.Фәйзи. *Халидә, әлбәттә, бармас өчен йөз сылтау табар --- иде. Шулай эшләсә, бәлки, Сафиянең пычак теленә дә эләкмәс иде.* Н.Гыйматдинова. **Пычак телле** Үткен, ачы телле. *Зөһрәбануны Зәһәрбану дип йөртәләр авылда. Безнең авылда пычак телле хатыннарны өнәмиләр, татарга аңа хатын юаш булсын.* А.Гыйләҗев. *--- авылдашлар Варис хәлен дә аңламаслар, юк, аңламаслар. Пычак телле берәрсе әйтми калмас шулай да, буең җитмәскә үрелмәскә иде, егеткәем, Варис, дияр.* Д.Гайнетдинова

ПЫЧАКБАЛТА *и.* Шикәр камышын, куаклыкларны чабу өчен кулланыла торган зур киң пычак, мачете. *Рәшидә аның кулындагы урак кебек кәкре, балтадай авыр сәер коралга гаҗәпләнеп карады. «Мачете бит бу! Шикәр камышын чаба торган пычак-балта!»* М.Маликова

ПЫЧАКЛА́У *ф.* Кемне дә булса пычак белән яралау, кисү, сую

ПЫЧАКЛАШУ *ф*. Пычаклар тотып сугышу

ПЫЧАКСЫЗ *с.* **1.** Пычагы булмаган. *Ерткычның үткен күзе, сизгер танавы тиз шәйләде: кеше ялгыз, кешенең мылтыгы юк, кеше пычаксыз, кеше кулында бер таяк кына.* Р.Батулла

2. *рәв. мәгъ*. Пычак кулланмыйча гына. *Ашавы сездән, дип, бу нәрсәне пычаксыз ашап булмый инде аны.* Н.Яһүдин

◊ **Пычаксыз кисү** *к.* **пычаксыз сую**. *Сөмбел үзенең салкын, коры сөйләшүе белән пычаксыз кисә, ичмасам, еласын, битәрләсен иде.* З.Кадыйрова. **Пычаксыз сую** Кемне дә булса бик кыен хәлдә калдыру. *«Гатаулла имезлексез имә икән шешәсен», – дигәнме? Пычаксыз суйган бу, Мәчтүрә янына кайтырлыкны гупчым да калдырмаган!* Ж.Дәрзаман. *Айтуганов аның «гариза язам» дигән сүзен ишеткәч йөрәгенә ябышты: – Нәфисә Фәрвәзовна, сез бит мине пычаксыз суясыз! – диде ялварулы тавыш белән.* Ф.Садриев. *Зинһар, пычаксыз суя күрмә, Гыйльметдин абзый, җаным!.. --- Бер йөк печән бирермен үзеңә.* Шатлыклы кайгы. **Пычаксыз телгәләү** Күңелне әрнетү, рухи газаплау. *Аңа һичничек ярдәм кыла алмавымны тою йөрәкне пычаксыз телгәли иде*. Г.Галиев. **Пычаксыз тирау** *к.* **пычаксыз сую**. *Телләренә эләксәң, пычаксыз турыйлар*. Г.Әпсәләмов

ПЫЧКЫ *и*. Агач, металл яки башка материалларны кисү өчен, бер ягы тешле корыч эш коралы. *Әтиемнең ике сүзнең берендә: «Бу малайның кулы нык булырга охшаган, пычкыны әйбәт тарта» --- – дип, --- үземне мактап --- торганнарын һич онытасым юк.* Р.Мөхәммәдиев. *Пычкы башын тартышырга, ярган утынны ташып өяргә, чапкан печәнне арбага төяргә булышчы кирәк*. Р.Мулланурова. *Фаяз лапаста «Дружба» пычкысы белән утын турады.* Х.Камалов

◊ **Пычкы сораганга ышкы тоттырган** Аңламыйча, уйламыйча, рәтсез эш итүче, мәгънәсез кеше турында

ПЫЧКЫБАЛЫК *и. зоол*. Акулага охшаган, озынча борынында пычкы тешләренә охшаш үсентеләре булган эре, ерткыч диңгез балыгы; *русчасы*: **пила-рыба**. *Акула, пычкыбалык һәм дельфиннар аның [кашалот] янында вак балык кебек кенә*. Р.Мөхәммәдиев

ПЫЧКЫ́ ВАГЫ *и. к.* **пычкы чүбе**. *Мирхәйдәр абзыйга --- такта арасына пычкы вагы тутырып, өстәмә бүлмә ясарга туры килде*. Ә.Фәйзи

ПЫЧКЫЛА́У *ф*. Пычкы белән кисү. *Әллә берәрсе шуның күчәрен пычкылап, аннары шуны минем балаларга күрсәткәнме?* С.Баттал

ПЫЧКЫЛДА́У *ф*. 1) Чиләнеп, суланып тору; җылыда йомшарып, сүле агып тору. *Җылыда ит пычкылдый*

2) Бик аз су белән юган-юынган, аруланган сыман булу

ПЫЧКЫЛДЫК *с*. Төсе уңган, төссез, тоныk. *Менә аның буш чиләге шушы чәчләре тузгыган баш, чүкелгән җиз маңгай, шушы табак бит һәм пычкылдык күзләр чайкалган су көзгесенә төшеп килә.* А.Хәлим. *Егерме ике ел бармакта йөреп, сыдырылып-ышкылып кечерәйгән, нечкәргән, төсе уңган, җуелган. Мал-туар астындагы пычкылдык саламның төсе дә моннан арурак*. Л.Лерон

ПЫЧКЫЛЫ *с.* Пычкысы булган. *Ике ташлы су тегермәне янына алар, үз көчләре һәм үз материаллары белән,*

җиде пычкылы такта яргыч эшләгәннәр. М.Гали. *Бер елдан завод эшли дә башлады. Беренче көнне бөтен өяз халкы җыелгандыр: алты пычкылы гыйфритнең бер башыннан бүрәнәне биреп тораллар, икенче ягыннан шалтырап такталар килеп чыга.* М.Мәһдиев

ПЫЧКЫ́ ОНЫ *и. к.* **пычкы чүбе**

ПЫЧКЫ́ СТАНЫ *и.* Пычкы белән утын кисү өчен дүрт яки алты аяклы борыс, кузла

ПЫЧКЫ́ ЧҮБЕ *и.* Пычкы белән киселгән агач яки башка материалның ярма яки порошок сыман калдыгы. *Миңа авыр эш ошый. Пычкы чүбе бушатырга я башка җиңел эш булса, мин ялкауланам, яратмыйм андыен.* Ш.Галиев. *Ленинградта үлем белән яшәү өчен көрәш бара. Халыкка бирелә торган икмәк паёгы илле граммга кала, анысы да пычкы чүбе белән катнаштырылган.* Т.Нәҗмиев. *Ә калку урыннарда, киресенчә, карны нигыталар, аның өстенә тирес, черемә, торф, пычкы чүбе ташлыйлар.* Татарстан яшьләре

ПЫЧКЫЧЫ *и.* Пычкы белән урман кисүче, утын кисүче, такта яручы кеше. *Пычкычылар шул тамгаларга карап бүрәнәне төрле зурлыктагы өлешләргә кисәләр.* Г.Әпсәләмов. *Менә Гөлчирә үзенә билгеләнгән пычкычы янына килеп басты.* Д.Каюмова

ПЫЧКЫЧЫЛЫК *и.* Пычкы белән урман кисү, утын кисү, такта яру эше. *Безнең авылыбызда балтачылык, тегүчелек, пычкычылык кеби вак һөнәр ияләре [бар].* Шура

ПЫЧКЫ ЯРМАСЫ *и. к.* **пычкы чүбе**

ПЫЧРАК *с.* **1.** 1) Юешләнеп йомшарган балчыктан гыйбарәт, өсте җебегән; баткак, изрәгән. *Урамның болай да пычрак юлын тагы бер кат актарып бара торгач, кирәкле капка турына килеп җиттеләр.* Р.Габделхакова. *Их, шушы авыл-район тирәләрендәге газаплы пычрак юлларны, җимерек күперләрне тизрәк бетерәсе иде.* З.Фәйзи

2) Саф, чиста булмаган; зарарлы катнашмалар кушылган. *Дүрт тәгәрмәченең өчесе шулпаланып беткән пычрак сулы чокырга --- төшеп утырган.* А.Гыйләҗев. *Пычрак су коесында табылган үле бала эшенә ул Сакманов теләге, аның язма үтенече буенча алынмады.* Т.Галиуллин. *Күп очракларда кеше организмына пычрак һава тәэсиренең билгеләре булып баш авырту, --- хәлсезлек, эш сәләте кимү тора.* Сәламәтлек нигезләре

3) Тузан яки башка төрле катнашмалар белән капланган. *Тәрәзәдән карады да: «Һава бозык ифрат!» – диде. Ә нибары үз өенең Тәрәзәсе пычрак иде.* Ә.Баян. *Аның барлык киемнәре генә түгел, бөтен бите-башы да тәмам пычракка буялган иде.* Г.Иделле. *Менәменә ул пычрак, сасы, гаугалы камерада, дөньяның иң кабахәт адәмнәре – үтерүче-көчләүче бурлар белән бергәбер калачак.* И.Сиражи

4) Керләнгән, пычранган, чистартылмаган, юылмаган; шакшы. *Кабинага кереп утыргач кына, Ибраһим кызның өс-башы шактый юеш, пычрак икәнлеген абайлады ---.* А.Гыйләҗев. *Гыйлаҗи абзый аның башына күз төшергән дә: – Фасонный чәч йөртергә син үсмәгәнсең әле, күрәсеңме, башың нинди пычрак, чәч төбеңдәге балчыкка шалкан чәчерлек бит, – дигән.* Ф.Яруллин. *Өйдәге пычрак савыт-сабаны капка төбендәге чирәмгә чыгарып тезде.* Н.Гыйматдинова

5) Тәнне, киемне пычрата, буйый торган. *Кеше кебек юньле эш тә таба алмаган: үзе авыр, үзе пычрак, үзе хәтәр, имеш.* М.Хәсәнов. *Сәяхның помбур буласы килә иде. Төрле пычрак, майлы эштә йөреп туйган иде. Помбурның эше чистарак.* Х.Камалов. *Итек басу эше – пычрак эш, дигән сылтау белән, итекчеләр кунак йорт хуҗаларының мунчасында торып эшләүне кулайрак күрделәр.* Т.Мөбарәков

6) *күч.* Бозык, әхлакый нормалардан тайпылган. *Автобуста кайтканда күрәсең: исерек, пычрак сүзле ир, ә хатыны түзә, күнеккән.* Ш.Галиев. *Яңа кеше бугай ул. Мөгаен, Әфганда сугышкан адәмдер... Теле пычрак, үзе псих...* М.Маликова. *Бер-берсе өстеннән яла ягып язылган, коточкыч пычрак анонимкаларны Мәскәү кабинетларында --- мыскыллы көлә-көлә укыдылар.* М.Галиев

2. *и. мәгъ.* 1) Юешләнеп йомшарган җир, туфрак; сыекланган балчык, быкырдык. *Борылыштан, як-якка пычрак чәчрәтә-чәчрәтә --- зәңгәр автобус килеп чыкты.* Г.Мөхәммәтшин. *Пычракка баткан машиналар фараларны кабызганнар ---.* М.Маликова

2) Яз башында һәм көзен була торган, юллар җебеп, бозылып торган чор; юл өзеклеге. – *Соң, алла бәндәсе, тиздән барыбер җәяүгә каласың лабаса, пычрак башлана, кар ява бит озакламыйча! – дип тә әйтеп караган иде Равил.* В.Нуруллин. *Язгы пычраклар үтеп, урам читләреңә ялтырап сукмаклар төшкәндә, Хәерлебанат кыз бала табып, аңа Сания дип исем куштылар.* А.Гыйләҗев. *Минзәләгә укырга киткәч, әни абыйга җибәрергә төенчек әзерли иде, ә әти, көзге пычрак, кышкы суык булуына карамастан, аны Минзәләгә кадәр илтә.* Л.Шәех

3) Керле тап (тәндәге, киемдәге һ.б.). *Күлмәктәге пычракны чистарту*

4) *күч.* Кабахәтлек, бозыклык, әхлакка сыймый торган гамәл. *Затсызлык сүздән гамәлгә бик тиз күчә. Шөкер, үз балаларыбыз азат ул пычрактан.* Ш.Галиев. *Кызык телле һәм холыклы, үз бурычын үтәр өчен теләсә нинди пычракка кереп барган беркатлы, эчкерсез кеше иде ул.* А.Хәлим

5) *күч.* Намустагы, характердагы, күңелдәге начарлык, начар як, тискәре сыйфат. *Күңелдәге пычрактан арыну җиңел түгел икән.* З.Кадыйрова

3. *рәв. мәгъ.* 1) Чисталык тәэмин итмичә, чисталык җитмичә; шакшылыкта. *Рәмзия исенә төшүгә, Мөниргән ирексездән өен күздән кичерде: пычрак яшәми ул.* Н.Әхмәдиев

2) *күч.* Намуссыз, әхлаксыз рәвештә

◊ **Пычрак ату** Яла ягу, гаепсезгә кемнең дә булса яман атын чыгару. *Мин әйтәм тегеңә, мыскалламаган ефәк кебек балага пычрак атарга ничек телең корымый, дим.* М.Маликова. *Гайсә Батталович миңа күпме пычрак атты – мин барысын да күтәрәм. Ә менә мин аңа ташланды дигәне – күрәлмәдә ялган!* Ф.Садриев. *Үзе гаепле була торып, бер гаепсез кешегә пычрак атты.* Р.Ишморатова. **Пычрак**

ору *к.* **пычрак ату**. *Бу дөньяның берәр сволочы Йөзгә пычрак орган чакларда, Башны ташка орып елар идем, Ирлегемнән оят еларга*. Р.Ягъфәров. **Пычрак өю** *к.* **пычрак ату**. *Юк, ул үткәннәргә мөкиббән китеп дан да җырламый, шулай ук, хәзерге кайбер «ачы хакыйкать»не ярып салучылар шикелле, пычрак өяргә дә теләми*. Р.Мирхәйдәров. *Кәтиб Хафиз ялганлый башласа, Саксин казый аны шундук туктатыр, алай түгел, болай булды, ханым, дип, Хафиз өстенә пычрак өяр*. М.Хәбибуллин. **Пычрак сибү** *к.* **пычрак ату**. *Бу сүзләрне ишеткәч, залдагы бик күпләр мәрхүм бабасы өстенә пычрак сипкән кияү кешегә нәфрәт тулы карашларын юнәлттеләр.* Римзил Вәлиев. *Чит-ятлар койрыгына ябышып туганың өстенә шундый пычрак сибүнең ничаклы әхлаксыз гамәл икәнен аңласалар иде башкорт «галимнәре»*. Т.Миңнуллин. **Пычрак сылау** *к.* **пычрак ату**. *Кайберәүләр үскәч тә явыз «шаярып» пычрак сылаучан – чистарынып кына өлгер*. Ш.Галиев. **Пычрак ташлау** *к.* **пычрак ату**. *– Үз абыеңа үзең пычрак атасың, – диде Фазыл бабай, офтанулы тавыш белән. – Ә миңа пычрак ташларга ярыймы?* Ә.Баян. *--- иң кадерләп үстергән кече малайның кылган эше абыйларының өстенә, әтисе белән әнисе йөзенә һич юып төшермәслек пычрак ташлый түгелмени?!* Ш.Янбаев. **Пычрак ыргыту** *к.* **пычрак ату**. *Менә сез, Маһибәдәр әби, динле кеше... Коръәндә ни дип язган? Ялган сөйләмәскә, кеше өстенә пычрак ыргытмаска, ялган бәла такмаска, дигәнме?* Гөлшаһидә. *Ә бүген, хәтер калу-калмау белән бөтенләй чутлашмыйча, иренең кешелек дәрәҗәсенә пычрак ыргытырлык нинди сәбәп бар иде соң?* Д.Гайнетдинова. **Пычрак ягу** *к.* **пычрак ату**. *Нәрсә соң ул язылмаган шигырь? Йөрәгемә җәйгән әрнүләр, Рәнҗетүләр, яла, пычрак ягу, Бер дә юкка каты бәрелүләр.* К.Сатиев. **Пычрак яудыру** *к.* **пычрак ату**. *Ул гаепләп мине сөйләп йөри, Минем өскә пычрак яудыра, Теләсә нинди очракта да үзен Мир күзендә аклап калдыра*. Х.Камалов

ПЫЧРАКЛЫК *и*. 1) Пычрак, шакшы булу; чисталык, пөхтәлек җитмәү күренеше. *--- инде сүтелеп бетүгә якынлашкан бистәгә барып җитүен абайламыйча да калды ул. Гадәти юллардан тайпылуына аяк асты пычраклыгы игътибар иттерде аны.* М.Хуҗин. *Апа --- күгәргән кәрәзләрне яңага алыштыра. «Кортлар пычраклыкны бер дә яратмый», – ди.* Ф.Яруллин

2) Кухнядан, завод-фабрикалардан түгелә торган калдык, нәҗес; чүплек. *Кыска буйлы җирән урыс егете Иван бервакыт яз көне ашханә тирәсендәге пычраклыктан сөяк-саяк җыеп йөри икән*. С.Поварисов

3) *күч.* Әшәкелек, түбәнлек. *Заманаңың пычраклыгы авылны гына, татарны гына читләтеп үтә алмый, диделәр. Дөньяда намуссыз, пычрак кешеләр бар дип, пычраклык турында гына уйлыйкмы?!* Т.Миңнуллин. *Бернинди дин дә дөньяны бозыклыктан, пычраклыктан, кабахәтлектән саклап тота алмаячак!* Р.Батулла. *Каенанасының һич тайчынмыйча, читләтеп тә тормыйча, турыдан-туры аны пычраклыкка чакыруы аның җәрәхәтле күңеленә бик авыр ишетелде.* Ә.Галиев

ПЫЧРАНУ *ф*. 1) Яңгыр яки юеш кар яву нәтиҗәсендә, җир өсте, туфрак, балчык изрәү. *Аяк асты бик ныкпычранган, кайбер урыннарда тротуар өсте тоташ боламык хәленә килгән.* А.Шамов. *Октябрьның уннарында яңгырлар башланып, юллар пычрангач, Рухия --- мәктәп интернатында торып укый башлады.* В.Нуруллин. *Юл бик тиз пычранды*. Р.Батулла

2) Нәрсәгә булса да буялу. *Иртән бозаулар эчергәндә, күлмәк итәгенең очы сөткә кереп тагын пычранды ---.* З.Кадыйрова. *Соляркалы бармагы белән аның танавына «пи-ип» дип баскан иде, борын пычранды ---.* Д.Булатова. *Маңгае кулындагы балчыктан пычранды.* Д.Каюмова

3) Каралу, керләнү. *Сукно пинжәге астыннан бүселеп килеп чыккан зәңгәр сатин күлмәге пычранып беткән ---.* А.Гыйләҗев. *Ниндидер пычранып беткән күлмәк, гади пиджак-чалбар кигән үсмер егетнең җитезлеген һәм кыюлыгын күргән командир бераз гаҗәпләнеп тора*. М.Хәсәнов. *Ачык төстәге пәлтәм, киеп йөрергә бик матур булса да, тиз пычрана.* Шәһри Казан

4) Шакшылану, чисталыгы, сафлыгы югалу; зарарлы әйберләр кушылу. *Иң коточкычы: хәзер елга пычранды*. Р.Батулла. *Әмма җиребезнең байлыгы күп еллар буена вәхшиләрчә таланды, җиребез, һавабыз пычранды*. Татарстан тарихыннан хикәяләр. *Табигать пычрана, дип күпме генә лаф орсак та, җир-суның зарарлануын никадәр генә тоткарларга тырышсак та, илнең экологик хәле сизелерлек яхшырмый әле.* Татарстан яшьләре

5) *күч.* Әшәке, түбән җанлы кеше белән аралашу яки ярамаган эшкә катнашу. *Ай-һай, сөйкемсез егет! Әллә нинди яманлыклар эшләп, үзе дә пычранды, яхшы кешеләрне дә буяды!* Ж.Дәрзаман. *Зөһрә апа өч бишлекне чыгарып ташлавына сөенеп тә йөрде, иртәгәсен Хәкимҗан абыйга: – Әле ярый юк белән пычранмаганбыз, – диде.* А.Гыйләҗев. *Ялгышымны төзәтерлек көчем бар әле минем. Пычрансам да, аякка басарлык көч табармын!..* Ф.Садриев

6) *күч.* Хурлыклы хәлгә калу яки яхшы исеменә тап төшү. *Мин сеңлемнең хур булмавы, фамилиянең пычранмавы --- юлында кулымнан килгәнне кызганмый эшләргә вәгъдә бирәм.* М.Фәйзи. *Хәзер бит аларның барысының да исемнәре пычранган.* В.Юныс. *Чөнки бу хәл билгеле булган очракта, укытучының, мәктәпнең, авыл-районның исеме пычрана.* Кызыл таң

7) *күч.* Норма-кагыйдәләргә туры килмәгән башка стиль үзенчәлекләре катнашу, сафлыгын югалту, чүпләнү. *--- авылның бу исеме каян килеп чыкты, дип сораган идем. Ул әйтә, ул авылда чепчиклар теккәннәр, ди. Ә бит ул авылның чын исеме – Чыпчык. Менә, русчага дөрес тәрҗемә ителмичә, безнең телебез ничек пычрана.* Т.Миңнуллин. *Күз алдында милләт сыйфатын үзгәртә, йолалар бетеп бара, тел пычрана, озакламый татарча китап укучы калмаячак.* Р.Батулла

8) *күч.* Берәр төрле, гадәттә әһәмиятсез, вак-тояк эш белән мәшгуль булу.

Дүрт белән пычранып тордылар ди сиңа. Т.Галиуллин. *Сәгадәтнең, батаклыкта пычранып калмыйча, Петербургка югары белем курсларына укырга китүе бик үк типик булмаса да, кешенең нинди хәлдә дә өметен югалтмаска, яктыга омтылырга тиешлеген раслау ягыннан бик әһәмиятле.* Татар әдәбияты

Пычрана бару Торган саен күбрәк, ныграк пычрану. *Кара буяуларны артык куертмыйбызмы? Юктыр, күңел табигате дигән мохитнең пычрана баруына күз йомып кына котылып булмый.* Ш.Галиев. *Суыбыз елдан-ел пычрана бара.* Р.Батулла. *Бу – беренче чиратта эчкән суыбызның, сулаган һаваның пычрана баруыннан ачык күренә.* Татарстан яшьләре

Пычрана башлау Пычрану билгеләре күренү. *Тәсбих, хөрмә төшеннән ясалганлыктан, пычрана да башлаган.* Ирек мәйданы

Пычранып бетү Тәмам, бик нык пычрану. *Аның йөзе агарган, өс-башы пычранып беткән, чәче тузгыган, сулышы капкан иде.* Н.Акмал. *Сумала чәчрәп, пычранып беткән чалбар, ботинкаларын Әзһәр ишегалдына чыгарып томырды*. Р.Кәрами. *Малайлар белән уйнасаң, бөтен киемең пычранып бетәр.* Инешләр Иделгә кушыла

Пычранып йөрү Гел пычрану; шактый вакыттан бирле пычранган булу. *Гайнавал: Бик шуның белән генә пычранып йөрисем калган.* Т.Гыйззәт. *Минем анда авыл хатыннары кебек кызыл балчыкка пычранып йөрүемә үзең дә каршы килер идең әле, әйеме?* Н.Фәттах. *Хатын: «Кеше көлдереп, тиеннәргә пычранып йөрисең инде, өйдә генә утырмыйча», – дип тирги*. Р.Әхмәтов

Пычранып калу Нинди дә булса сәбәп аркасында пычранган хәлгә килү

Пычранып кую Көтмәгәндә пычрану. *Бу бик хәтәр нәрсә иде, бөтен биографияң пычранып куюы ихтимал дип, Идрисов чын борчуга төште*. Х.Камалов

Пычранып тору Гел пычрану; хәзерге моментта пычрану; пычранган хәлдә булу. *Катыкка буяп ташласаң, эт яламас нәрсә. Ислам шуның белән пычранып тора, ди.* Н.Фәттах

Пычранып утыру *сөйл. к.* **пычранып тору**. *Габделхәйнең шигырь белән пычранып утыруын күргәч, аның күңелендә үзеннән-үзе яшьлек хатирәләре калкып чыкты*. Н.Фәттах

Пычранып яту *сөйл. к.* **пычранып тору**. *– Юкса, эчен алып, казларыгызны эшкәртеп бетердем генә дигәндә, янә бер каз өчен пычранып ятасыгыз булмасын, – ди*. Г.Габидуллина

ПЫЧРАТУ *ф*. 1) *з.-сыз* Нәрсәнең дә булса табигый сәбәпләр белән бозылуы, пычрануы. *Кирәгеннән артык яуган яңгыр Яңа тынган. Юлны пычраткан.* К.Булатова

2) Пычракка буяу, пычрак тидерү. *Нурсибә, уңайсызланып, [куртканы] алмаска маташты: – Мин аны пычратам бит, – диде*. Ә.Сәлах. *--- егетләр, чалбар балакларын пычрата-пычрата --- чиләкләрне трактор арбасына ташый*. Р.Рахман. *Рафак бәйрәмгә дип тегелгән әлинур күлмәген пычратып та өлгергән.* Инешләр Иделгә кушыла

3) Чисталыгын, сафлыгын бозу, шакшылату. *Табигатьне адәм заты гына пычрата бит. Кулы белән дә, уе белән дә.* Н.Гыйльматдинова. *Сулыкларны промышленность, коммуналь-көнкүреш предприятиеләреннән, терлекчелек фермаларыннан аккан сулар пычрата.* Сәламәтлек нигезләре. *Без, кешеләр, --- ял иткән урыннарыбызны чистартмыйбыз, сулыкларны пычратабыз*. Кошлар: табигатькә сәяхәт

4) Керләндерү, каралту. *Син аларны югалтма, пычрата күрмә инде, алайса, бик кадерле китаплар алар, улым.* М.Гали

5) *күч.* Пычрак итеп кәкре-бөкре хәрефләр белән язу, ялгышларны төзәтеп сызгалау. *Мин, карандаш белән язылган сорауларны бетереп, әсәр төзәтеп утырганда, тугыз яшьлек Розалия: – Ә сезгә пычраткан өчен начар отметка куялармы? – дип сорады*. Ә.Баян. *– Мә, читкә алып китеп пычрат, алайса, – дип, Габденнасыйр аңа кәгазь белән кара һәм каурый каләм бирә.* М.Гали. *Иртәдән кичкә кадәр әле анда, әле монда бер кәгазь артыннан икенчесен акварель белән пычрата идем.* Р.Гали

6) Яхшы исемгә тап төшерү, хурлау, яманатын сату. *Кем ул себерке? Ә? Кем? Минем әнине пычратмакчы буласыңмы шакшы телең белән?* Ә.Баян. *Җәмилдән хәрәм акча алып торып, гомере буе намус белән көн күргән хатыным истәлеген пычратмыйм.* З.Фәйзи. *Минем абруема тап төшерергә ниятләгән кешеләр татарның иң күренекле зыялыларын да пычратмакчы булдылар бит*. С.Зыялы

7) *күч.* Ямьсезләү, ямьсез итеп күрсәтү; бозу. *– Затсыз бәндәләр сүзнең иң матурын да пычратырга җай таба, – диде моңа каршы Рәшидә*. М.Маликова. *Синең кебекләр турында язып, газета бите пычратырга дип килмәдем*. Ж.Дәрзаман. *Беләм, заводтан хезмәт кенәгәңне пычратып китсәң дә, югалмассың син*. З.Фәйзуллин

◊ **Пычратмаган куагы юк** һәр җирдә гайбәт, әләк белән кешеләрне яманлап йөрүче кеше турында

Пычрата башлау Пычратырга тотыну. *Синең бармагыңа карап, шайтани затлар ылаһи тамгаңны таныйлар да, аның аша җаныңа үтеп керәләр, йөрәк-бәгыреңне кимерәләр, күңелеңне пычрата башлыйлар.* Г.Гыйльманов

Пычратып ату *к.* **пычратып ташлау**

Пычратып бетерү Тәмам, бик нык пычрату. *40–50 ел буе нефть чыгару күпме басу-кырларыбызны ертып, бозып, пычратып бетерде ---.* Ә.Еники. *Чебеннәр пычратып бетергән көзге каршына басып, үзен өйрәнде.* Т.Галиуллин. *– Хатын, – ди бу, – сүзең синең, валлаһи, дөрескә чыкты, эч тотмый башлады бит әле минем, ыштан төбен дә пычратып бетердем.* Р.Сибат

Пычратып карау Сынау өчен пычрату. *Пычратып карадылар, әмма пычрата алмадылар.* Казан утлары

Пычратып кую Көтмәстән, теләмәстән пычрату. *Тазарынабыз дип, яңадан пычранып һәм пычратып куймыйк.* Ю.Гәрәй

Пычратып ташлау Тиз арада, бик тиз пычрату. *--- бая карачкы дигән нәрсә ишекне ачты да --- өйгә килеп керде һәм эшне үзеннән дә тупасрак мәгънәсезлек белән пычратып ташлады.*

Ә.Баян. *Ткаченко үләргә ятса да, аның командасы үлмәгән, ул һәр дөрес сүзгә чәчрәп каршы чыгарга һәм һәр намуслы кешене пычратып ташларга әзер тора иде.* Ф.Бәйрәмова. *Ләкин тормыш шулай корылган, күрәсең: әнә шул матур башланган хисләрне кем дә булса начарлыкка юрарга, пычратып ташларга тайчанмый.* Р.Кәрами

ПЫЧРА́У *ф. к.* **пычрану**. *Ак төс – сафлык, әмма көчсез артык, Кай арада пычрый, карала.* Ә.Баян

Пычрап бетү *к.* **пычранып бетү**

ПЫЧТЫРДАТУ *ф.* Пычтыр-пычтыр китерү. *Урамдагы суларны, юеш балчыкларны пычтырдатып килгән грузовик капка төбенә туктады.* Г.Кашшаф

ПЫЧТЫРДА́У *ф.* 1) Нык чылану, юешләнү сәбәпле пычтыр-пычтыр килү. *Аяк астында сазлы җир пычтырдады, ат тояклары баскан саен батып-батып китте.* Н.Фәттах. *[Шәяхмәт] капчыгын бөркәнеп, таякка таянды да, яшен яктысында, пычтырдап, урман якка таба атлады.* М.Мәһдиев. *Аяк асты пычтырдый, иске түшәк кебек җәелгән яфраклардан су сыгылып чыга.* М.Рәфыйков

2) *күч.* Берәр вак, әһәмиятсез эш белән озаграк шөгыльләнү. *[Ул] мичкә яга, икмәк сала, су җылыта, тагын шунда әллә нәрсәләр белән пычтырдый.* М.Әмир

3) *к.* **пычкылдау** (*2 мәгъ.*). *Узенчә пычтырдаган малай барыбер аңа йөкләнгән, аннан котылып булмый.* Ф.Латыйфи

Пычтырдап алу Бераз гына пычтырдау. *Тик үзбәкләр генә, иртәнге якта килеп, яр эргәсендә бераз пычтырдап алалар да кире китеп баралар.* М.Маликова

Пычтырдап тору Пычтырдаган хәлдә булу. *Аяклары, сазлы җир булганлыктан, баскан саен, чүпрә салган кебек кабарып, пычтырдап торган кызыл балчыкка бата ---.* Н.Көбәш

Пычтырдый башлау Пычтырдарга тотыну

ПЫЧТЫ́Р-ПЫЧТЫР *иярт.* Сай судан, сыек пычрактан атлаганда, аны болгатканда, өстенә сукканда яки су акканда, тамганда чыккан тавышны белдерә. *Яңгыр һаман пычтыр-пычтыр сибәләп торды.* А.Гыйләҗев. *Түбәдән пычтыр-пычтыр су ага; ишегалдында, урамда гөрләвекләр акканы ишетелә.* Р.Батулла. *Пычтыр-пычтыр яңгыр суларын ерып, аның артыннан тагын кемдер килә иде.* Фән һәм тел

ПЫЧТЫ́Р-ПЫЧТЫР ИТҮ *ф.* 1) Пычтырдау, чыпырдау

2) *күч.* Әһәмиятсез, вак-төяк эш белән маташу

ПЫЧТЫ́Р-ПЫЧТЫР КИЛҮ *ф. к.* **пычтыр-пычтыр итү**. *Тансык, чыннан да, яратып эчте суын, сазлыкта пычтыр-пычтыр килеп, тездән батып, сары чәчәкле үләннәрне дә өзде.* М.Рәфыйков

ПЫЧУ *ф. иск.* Кисү, турау, кисәкләргә бүлү. *Утын пычу. Бүрәнә пычу*

Пыча башлау Пычарга керешү

Пычып алу Беркадәр (бераз) пычу

Пычып бетерү Пычуны тәмамлау

Пычып тору Даими рәвештә пычу; пычу эшен башкару

ПЫЧЫМ *и. диал.* Силуэт, кыяфәт, рәвеш, сыйфат. *Пычымы эре*

ПЫЧЫНКЫ *с. диал.* Лычкылдык, чиле-пешле (икмәк тур.). *Яшелләтә урган ашлыкның камыры пычынкы була, диләр.* К.Насыйри

ПЫЧЫРГЫ *и. вет.* Ат һәм мөгезле эре терлекнең аягында була торган юеш тимрәү; *русчасы*: **мокрец**

ПЫШ *иярт.* **1.** Утлы нәрсә суга тиеп сүнгәндә, утлы яки кызган нәрсәгә су сипкәндә чыккан тавышны белдерә. *--- мунчасының пары сүрелгән икән шул инде. Чүмеч белән селтәп торып су җилпесә дә, мунча ташлары әллә «пыш», әллә «сез» дигән шикелле генә чыжылдады.* Ә.Гаффар

2. *с. мәгъ.* Файдасыз, бернигә дә яраксыз. *Биргән җире таш булды, биргән орлыгы пыш булды, шытмады.* Н.Исәнбәт

ПЫШАН *рәв. сир.* Акрын гына, пышылдап; чит кешегә ишетелмәслек итеп. *Тышкы ишек ярымачык, йорт яклап пышан гына сөйләшкән тавышлар ишетелә.* М.Хәбибуллин

ПЫША́Н-ПЫШАН *рәв.* 1) Пышылдап, ишетелер-ишетелмәс кенә. *Тынып калдылар, аннары пышан-пышан сөйләшә башладылар: – Ник елый ул? Ни булган?* М.Маликова. *[Малайлар] баштарак сагаеп, басынкыланып калдылар, аннары үзара пышан-пышан сөйләшеп, серләшеп йөри башладылар.* Г.Гыйльманов

2) Кешегә сиздерми генә, мыштым гына. *Пышан-пышан гына басып, кире залга керәм.* М.Галиев. *Мәетне ниш ләтергә белми басып торганнар кайсы кая пышан-пышан тайдылар.* Х.Камалов. *Тамызса, каты тамызыр бу, дип шүрлән, карт пышан-пышан гына капкага юнәлде.* Н.Гыйматдинова

3) Астан гына, астыртын гына. *Шундук урамга чыгып, бер-ике кибет янында пышан-пышан хәбәр тараттык. Куәтле машина кайтканны да, каравылчыбыз юклыкны да кирәкле кешеләргә җиткерсеннәр.* К.Кәрами

ПЫША́Н-ПЫШАН КИЛҮ *ф.* Пышылдашу, акрын гына сөйләшү. *Пышан-пышан килеп, үзара нидер сөйләшеп яткан кызлар көлешеп алдылар.* А.Хәсәнов. *Башка вакытта Фидаяны дикъкать белән тыңлый торган кешеләр бу юлы пышан-пышан килә башладылар.* М.Маликова

ПЫ́Ш ИТҮ *ф.* 1) Чыжлау, шундый тавыш белән берәр куышлыктан, өслектән кисәк кенә һава, пар яки төтен чыгу. *Бәрәңге өстендәге көл су шикелле агып төшә, аның әле бер, әле икенче җиреннән пыш иттереп кайнар сулыш бәреп чыга.* Г.Бәширов

2) *күч.* Тупланган энергия, дәрт, көч һ.б.ш.лар бушка китү, тиешле нәтиҗә бирмәү, әрәм булу. *Чая сибелә башлаган шушы сатира уты кайдадыр бер урында пыш итеп сүнеп кенә калмаса ярар иде.* Ф.Хөсни. *Кемнәрдер оештырып йөргән бу конференция дигәннәре, казённый бер эш буларак, халыкны үзенә җәлеп итә алмыйча, пыш итеп кенә калмасмы?* Ә.Еники. *Җәмиләнең усал сүзләренә шагыйрь җегет аптырап калды. Бөтен күңелен биләп алган дәрте, тилелеге төртеп тишкән куык кебек кинәт пыш-ш! итте.* Н.Фәттах

ПЫШКЫЛДА́У *ф.* 1) Пышык-пышык итү. *Пароход, яман карлыккан тавыш белән сәламли-сәламли, кара*

төтен болыты чыгарып, пышкылдап килеп туктады. А.Гыйләҗев. *--- сарык-кәҗәләргә олтырактай булса да печән салырга, кыткылдаган, пышкылдаган кош-кортка җим сибәргә кирәк.* Ш.Янбаев

2) Акрын гына үзалдына елау; мышкылдау. *Нәрсә пышкылдап утырасың? Бар, сыерларны сау!* А.Шамов. *--- Әхми эчтән өзеп-өзеп пышкылдады, канлы күзен керле җиңе белән сөртте дә рәискә текәлеп карады, кире урынына утырды. Елавыннан туктады.* Г.Бәширов

Пышкылдап алу Озакка сузмыйча, бераз пышкылдау

Пышкылдап йөрү Гел, һәрвакыт пышкылдау

Пышкылдап кую Бер тапкыр, кинәт пышкылдау

Пышкылдап тору Әлеге моментта, хәзер пышкылдау. *Аларның күреге пышкылдап торган гармуны бар.* А.Хәлим

Пышкылдый башлау Пышкылдарга тотыну

Пышкылдый бирү Бернигә карамыйча пышкылдауны дәвам итү

ПЫШКЫРТУ *ф* 1) Төтенне күп итеп чыгарып тәмәке тарту, төтәтү

2) *диал. күч.* Ачуланып, тиргәп куркыту. *Аңа сүз салып караса, «бабай» дип көлмәс микән Фәридә? Ир-атка карата үзен бик усал тота, дип сөйлиләр, табагач белән пышкыртып чыгармас микән өеннән?* Ш.Бикчурин

Пышкырта башлау Пышкыртырга тотыну

Пышкырта бирү Бернигә дә карамыйча пышкыртуны дәвам итү

Пышкыртып алу Тиз арада бераз пышкырту. *Чоланга кергәч, Хәмәтнур абый азрак гармунын пышкыртып алды да, «Урам көе»нә үзе уйнап, үзе җырлый да башлады*. Өмет

Пышкыртып җибәрү Пышкырта башлау. *[Әпрәй] челемен суырып, төтенен ашыкмый гына бер пышкытып җибәр[де].* Ш.Маннур

Пышкыртып йөрү Гел, һәрвакыт пышкырту

Пышкыртып кую Бер тапкыр пышкырту

ПЫШКЫТУ *ф. к.* **пышкырту**. *Ул --- кесәсеннән тәмәке янчыгы, бөкләп салган газет чыгарды, эре генә кыланып төрде, кабызды, кое тирәсенә ачы ис таралды. – Әллә пышкытырга тотынган инде?* А.Гыйләҗев. *Берсе тәмәке пышкыта, икенчесе лач-лоч сагыз чәйни, минем улавыма игътибар итмичә генә, алар элек башланган сүзләрен дәвам иттеләр*. Р.Батулла. *Җәмәгать урынында тартырга ярамый, дигәнгә алар: «Шулаймыни, без ишетмәдек», – диделәр һәм тәмәкеләрен пышкытуларын дәвам иттеләр*. Мәдәни җомга

Пышкыта башлау *к.* **пышкырта башлау**. *Кабызып, кем белән булса да тагын пышкыта башлыйлар.* Ж.Юныс

Пышкыта бирү *к.* **пышкырта бирү**

Пышкытып алу *к.* **пышкыртып алу**

Пышкытып йөрү *к.* **пышкыртып йөрү**

Пышкытып җибәрү *к.* **пышкыртып җибәрү**

Пышкытып кую *к.* **пышкыртып кую**

ПЫШЛАК *и.* **1.** Өйдә әзерләгән сыр, брынза. *Бигрәк тә сарык сөтеннән ясалган сырлар, эремчекләр – пышлак билгеле.* Р.Әхмәтьянов

2. *с. мәгъ.* Пешмәгән, өлгермәгән; хәлсез, зәгыйфь

ПЫШЛА́У *ф.* Пыш иткән тавыш чыгару. *Ялмавызның тыны пышлап чыга башлады.* Р.Батулла

ПЫШЛЫГУ *ф.* Кат-кат уранып яки калын кием киеп, бик нык тирләү. *Пышлыккан – мич башында кыш чыккан*. Әйтем. *Шушындый ямьле яз көнендә өйдә пышлыгып утырып булмас*. Р.Вәлиев

Пышлыга башлау Пышлыгырга тотыну. *Шыбыр тир булып, тончыга язып, ике юрган астында пышлыга башлагач, ул юрганның бер читен күтәрде, иркенләп сулыш алып җибәрде.* Ф.Садриев

Пышлыгып бетү Бик каты пышлыгу

Пышлыгып яту Озак вакыт пышлыгу. *Мин монда өйдә пышлыгып ятар өчен күчтеммени?* Ф.Яруллин

ПЫ́Ш-ПЫШ *иярт*. **1.** 1) Әкрен генә сөйләшкәндә чыккан тавышны белдерә. *Башта тыштагы җил генә шулай үкерәдер дип уйлаган иде, ләкин ике кешенең пыш-пыш үзара сөйләшкәнен ишеткәч, ул үзеннан кайтты*. А.Алиш. *--- Әнвәр шуларны [догаларны] пыш-пыш әйтергә тотынды*. Х.Камалов. *Янәшә өстәлдә утыручы ике хатын пыш-пыш серләшүләрен дәвам иттеләр.* Р.Мөхәммәдиев

2) Пар, төтен чыкканда, авыр сулаганда, елаганда һ.б. очракларда була торган тавышны белдерә. *Инде янып китте дигәндә, усак утын пыш-пыш пыскытып, бер-берсен сүндереп тә куя әле ул!* Ш.Янбаев. *Карт уянып киткәндә, карчыгы бөгәрләнеп, пыш-пыш сулап, татлы йокыга оеган иде*. Ф.Җамалетдинова. *Минһадый, пыш-пыш тәмәке тартып, бүлмә буйлап арлы-бирле йөренде.* Д.Гыйсметдинов

2. *и. мәгъ. сөйл. шелт.* Пышылдап, шыпыртлап сөйләшкән тавыш. *Без киткәч сөйләшерләр. Без бит монда аларның пыш-пышларын тыңларга килмәгән.* Г.Насрый. *[Абдулла] берничә кешенең ара-тирә пышылдашып алуларын гына тоеп ятты. Хәер, аның ул пыш-пышка артык исе китмәде.* Э.Касыймов

ПЫ́Ш-ПЫШ ИТҮ *ф.* Пышылдау; пышлау. *Халык һәм концерт куючылар шул якка борылып, пыш-пыш итә --- башладылар.* Ф.Яхин. *--- җир, табага салган чүпрәле ипи камыры кебек пыш-пыш итеп, үзенә орлык салганны көтә*. Татарстан яшьләре

ПЫ́Ш-ПЫШ КИЛҮ *ф. к.* **пыш-пыш итү**. *Кичләрен яткач, юрган астында пыш-пыш килеп, һаман шул үзебезнең авылда уйнаганнарны искә төшерә идек.* Р.Мостафин. *Сәрия --- аннары пыш-пыш килеп елый ук башлады*. Л.Гыймадиева. *Аяк астында чупырдаган көзге сулар, пыш-пыш килеп: – Бәхетлеме ул, бәхетлеме ул? – дип йөдәтәләр*. Р.Рахман

ПЫШТ *иярт*. Пар яки берәр нәрсә кинәт кенә пышылдап чыкканда барлыкка килгән тавышны белдерә

ПЫ́ШТ ИТҮ *ф.* Кисәк пышлау, өзек кенә пыш итү. *Ярлының җаны пышт*

итеп чыга, Байның җаны шарт итеп чыга. Мәкаль. *[Фирдүс] Сыра шешәсен ачты, аннан пышт иткән тавыш чыкты.* М.Маликова. *Өенә барып интервью алганда да, ул әледән-әле ислемай флаконы сыман бер әйберне авызына якын китереп, пышт итеп бер йотым даруны сиптереп ала, һәм әңгәмәбез дәвам итә.* Әдипләребез

ПЫ́ШТ-ПЫШТ *иярт. к.* **пышт**

ПЫ́ШТ-ПЫШТ ИТҮ *ф. к.* **пышт итү**. *Чиләк астындагы бәрәңгеләр ярыклардан пышт-пышт иттереп пар ат[алар].* М.Шабаев

ПЫШТЫК I *с. диал.* Эшне акрын эшләүче, мыштырдык. *--- ялкау, пыштык Тәзкирә, бер мәртәбә пешергәч, әзерләгәч, шуның белән эшем бетте, дип уйлады.* Н.Фәттах

ПЫШТЫК II *с. диал.* Кысан, тыгыз. *Пыштык офис*

ПЫШТЫ́К-ПЫШТЫК *рәв. к.* **пышык-пышык**. *Пыштык-пыштык борынын тартып, әнисе килеп җитәр.* Г.Сафиуллин

ПЫШТЫН *с. диал.* **1.** Тавыштынсыз. *Пыштын укучы*

2. *рәв. мәгъ.* Шыпырт кына. *Кайсыдыр пыштын гына: «Үзләре ишетерләр, бик кычкырмагыз», – диде.* Г.Толымбай

ПЫШТЫРДА́У *ф.* 1) Пыштыр-пыштыр килү. *Аны җиңел генә пыштырдаган тавыш уятты.* М.Мәһдиев

2) *сир. шелт.* Акрын эшләү, мыштырдау

Пыштырдый башлау Пыштырдарга тотыну. *Халык пыштырдый башлады. Күп тә үтмәде, шаулаша башладылар, ул ара да булмады, кычкырыша да башладылар.* М.Әмир

Пыштырдап тору Хәзерге моментта пыштырдау; артык озак пыштырдау

ПЫШТЫ́Р-ПЫШТЫР *иярт.* 1) Кыштырдау яки мышкылдау катыш пыш-пыш итүдән, пыш-пыш сөйләшүдән гыйбарәт тавышны белдерә. *Безнең арттан бина эченә кереп тулган баягы карчыклар, пыштыр-пыштыр укып, куллары белән кабер ташларын сыпыралар да аннан соң битләрен сыпыралар.* Гали Рәхим. *Балалар яткан җирләреннән пыштыр-пыштыр әллә нәрсә укыйлар иде.* Г.Рәхим

2) *к.* **пышык-пышык**. *Карчык пыштыр-пыштыр елый иде.* Ш.Камал. *Габдуллага Захарны күрсәтеп, әллә нәрсә пыштыр-пыштыр гына сөйләшәләр.* Г.Исхакый

ПЫШТЫ́Р-ПЫШТЫР ИТҮ *ф.* Шундый тавыш чыгару

ПЫШТЫ́Р-ПЫШТЫР КИЛҮ *ф. к.* **пыштыр-пыштыр итү**. *[Ул] төн буена авыз эченнән пыштыр-пыштыр килеп утыра.* Ф.Сәйфи-Казанлы

ПЫШТЫРТ *рәв. сир.* Шыпырт кына, шыпыртлап, сиздермичә. *Пыштырт кына китеп бару*

ПЫШТЫРТЫН *рәв. сир. к.* **пыштырт**

ПЫШУ *ф. диал.* Шиңү, пәжү. *Бәрәңге пышкан*

Пыша башлау Пышу билгеләре күренү

Пышып бетү Бөтенләй, тәмам пышкан хәлгә килү

ПЫШЫГУ *ф. диал. к.* **пышлыгу**. *Алты почмаклы булган мәдрәсәдә йөздән артык шәкерт торуы, аларның ашау-эчү әйберләре, --- ятак нәрсәләре – һәммәсе дә шунда булганлыктан, мәдрәсә гаять тыгыз булып, салкын кыш булуга карамастан, һәммә кеше тиргә батып пышыгып утыра.* М.Гафури

Пышыга башлау Пышыгу билгеләре сизелү

Пышыгып бетү Бөтенләй, тәмам пышыккан хәлгә килү

Пышыгып йөрү Озак вакыт пышыккан хәлдә булу

ПЫШЫ́Й-ПЫШЫЙ *рәв. к.* **пыш-пыш** (*1 мәгъ.*). *[Ул] докторларның үзеннән яшереп пышый-пышый гына [сөйләшүләрен белә].* Ш.Камал. *Чокып, тишеп бетерделәр, пышый-пышый ике мәртәбә «мышьяк» куеп җибәрделәр.* Татарстан яшьләре

ПЫШЫ́К-ПЫШЫК *иярт.* **1.** Акрын гына, сиздермәскә тырышып, яшерен генә елаганда чыккан тавышны белдерә; мышык-мышык

2. *рәв. мәгъ.* Шундый тавыш чыгарып; сулкылдап. *Үлем турында, яраланулар турында берәр сүз ишетсәләр, башларын аска иярләр дә пышык-пышык балавыз сыгарга тотыналар...* Г.Ибраһимов. *Ул, иренең үзенә шикләнеп карауларын күрмәс өчен, почмакта я ишегалдында пышык-пышык еларга мәҗбүр.* Н.Хәсәнов. *Иртән ул кемдер пышык-пышык борын тартып елаган тавышка уянып китте.* Х.Камалов

ПЫШЫЛДАВЫК *с.* Акрын гына, ишетелер-ишетелмәс. *– Тордыңмы, Һидая? – диде [Рәхимә] пышылдавык тавыш белән.* Н.Фәттах

ПЫШЫЛДА́У I *ф.* Акрын гына, ишетелер-ишетелмәслек итеп әйтү, сөйләү; шыпырт сөйләшү, шыпыртлап әйтү. *– Рәхмәт! – диде ул [Салих], ахрысы, дулкынлануыннан пышылдап кына. – Рәхмәт, Гөләндәм!..* Ә.Еники. *Фәттах: – Кайда икән соң хәзер Гали? – дип пышылдады.* Н.Дәүли. *«Булды... Җитте...» – дип пышылдады ул һәм күзләрен зур ачып, бер ноктага текәлде.* Язмышлар яңарганда

Пышылдап алу Берара пышылдау. *Гүяки дога укып куйгандай пышылдап алып, битләрен сиздерми генә сыпырды.* Ф.Яхин. *Һәм шулчак уң күршесенең колагына иелеп, нидер пышылдап алды.* Шатлыклы кайгы

Пышылдап кую Кинәт кенә яки бер мәртәбә пышылдау. *Ак яулыклы, көләч йөзле әнисен күз алдына китергән Хәкимҗан иректән пышылдап куйды ---.* Н.Хәсәнов. *Мөбарәкҗан түзми, колагыма кайнар сулышын бөркеп: «Менә бу педиатр, ичмасам», – дип пышылдап куя.* Г.Галиев. *Дәү әни лампа куыгына өреп утны сүндерә, ерагая барган егетләргә колак салып пышылдап куя ---.* В.Астафьев

Пышылдап тору Даими яки әледән-әле пышылдау. *Фамилиясе Хаккыев икәнен беләсез инде, анысы да үзенеке түгел, беренче хәбәрен язганда, кемдер колагына пышылдап торып яздырган иде.* Ф.Сафин. *Малай үзалдына горур пышылдап торып басты да шаккатып балбалга карады.* М.Галиев. *Тормыш үзе институт минем өчен. Кирәкле темаларны ул үзе колагыма пышылдап тора.* Җ.Дәрзаман

Пышылдый башлау Пышылдарга тотыну. *Болар илә эш пешмәгәч, Заһидә күркәләрне дә сыйларга уйланып караган иде дә, ата күркәнең кабарып пы-*

шылдый башлаганын күргәч, келәт артына качты. М.Думави. *Барый --- бала йоннары тырпайган йөзен миңа терәп диярлек үк пышылдый башлады ---*. А.Гыйләҗев. *Аннары колагына назлы сүзләр пышылдый башлады*. Р.Кәрами

Пышылдый бирү Бернәрсәгә карамастан пышылдауны дәвам итү

ПЫШЫЛДА́У II *и.* Ишетелер-ишетелмәс пышылдаган тавыш. *Һәр шимбә-якшәмбе саен Кадермәткә йөрү, бәхетле яшьләрнең кайнар пышылдауларын тыңлап тору аның өчен инде ияләнгән гадәткә әверелгән иде*. В.Юныс. *Гадәттәге чыелдаулар, пышылдаулар басылгач, трубкада Саматның тавышы яңгырады ---*. Г.Мөхәммәтшин. *Иреннәрен авырлык белән кыймылдатып, гыжлауга охшаган пышылдау белән сөйли башлады*. Ф.Латыйфи

П Ы Ш Ы́ М - П Ы Ш Ы М *рәв. к.* **пышын-пышын**. *[Әби] кызы белән озаклап пышым-пышым сөйләшә*. Ә.Еники. *Ни өчен алар инде ике-өч сәгатьтән бирле читәнгә сөялеп пышым-пышым сөйләшеп торалар?* Г.Гобәй

ПЫШЫН *рәв. к.* **пышын-пышын**. *Сафа, бабайның бар кеше таралып беткәч тә пышын гына сораган үтенечен, кабат йөрмәслек итеп, турылатып [җавап бирде]*. Л.Хәмидуллин

П Ы Ш Ы́ Н - П Ы Ш Ы Н *рәв.* Ишетелер-ишетелмәс, шыпыртлап; акрын гына. *Ирләр ындыр табагының түрендәге каравыл өе турында җыелып әңгәмә корырга да өлгерде. Пышын-пышын гына мәзәк хәлләр сөйләргә дә вакыт чыкты*. Р.Мөхәммәдиев. *Пышын-пышын сөйләшергә без бит монда Тәлгать Таҗетдин хәзрәтләренә каршы фетнә күтәрергә җыенмыйбыз!* А.Хәлим. *Нәрсәдер кыштырдауга, пышын-пышын сөйләшүгә уянып киттем*. Ф.Баттал

ПЫШЫ́Н-ЧАШЫН *рәв. сөйл.* **1.** *к.* **пышын-пышын**

2. *с. мәгъ.* Колактан-колакка пышылдап әйтелә торган, имеш-мимеш. *Халык эчендә тагын пышын-чашын сүз китә: «Вафа акларны алып кайтырга дип чыккан икән...», «Әтрәт китертә икән...» – ди башлыйлар*. Ш.Маннур

ПЫШЫ́-ПЫШЫ *рәв. к.* **пышын-пышын**. *Зал халкы, үзара пышы-пышы сөйләнеп, бер-беренә елмаешып куйды*. Г.Ибраһимов. *Болынкыр халкы арттан пышы-пышы килеп кала, йөзләрендә курку билгесе, ә мин эчтән генә көләм*. Ф.Садриев

ПЫЯЛА *и. фар.* **1.** 1) Кварц комына поташ һ.б. матдәләр кушып эретеп, химик эшкәртеп ясалган үтә күренмәле материал. *Кызганычка каршы, монда --- Венеция һәм чех пыяласы турында гына китаплар бар ---*. А.Тимергалин. *Ул сугышка кадәр пыяла заводы директоры булып эшләгән ---*. Язмышлар яңарганда. *Пыяла − химик формула белән күрсәтеп булмый торган һәм төгәл химик составы билгесез матдә*. Төзү материаллары

2) Шундый материалның ватылган, уалган кисәге, ватыгы. *Теге чакта, аягыңа пыяла кадалгач, кем апкайтты соң?* Ф.Яруллин. *Ышкафны ватканда, җегетнең битенә вә кулларына пыяла керә*. Р.Батулла

3) Шул материалдан ясалган юка табак яки башка бер формадагы әйбер. *Чуар пыялалар белән бизәкләтеп эшләнгән зур тәрәзәдән кабинеттагы авыр мебельләргә йомшак яктылык сибелә*. К.Нәҗми. *[Директорның] Күзлек пыялалары тирләп чыкты*. Н.Дәүли. *Беркөн, хатынын кыйнап туктагандыр инде, дип бүлмәмнән чыксам, зал ишеге пыяласын тишеп, имән уклау чәчрәп чыкты да корсагыма бәрелде*. Ф.Баттал

4) Киң авызлы тоткасыз чынаяк; касә, йомры, чокыр. *– Без эшкә әзер, шеф, көзге төндә без башкарып чыга алмас эш юктыр дип, яшел кытай чәе эчә-эчә тыңларбыз, – дип елмайды Бармаксыз һәм аркадашларының пыялаларына чәй агыза башлады*. Р.Мирхәйдәров

5) *диал.* Шешә. *Дару пыяласы*

6) *диал.* Тәрәзә. *Иске кат пыяланың аргы ягында ул – муенсалы ак күгәрчен, биргесендә – мин*. Р.Мөхәммәдиев

7) *сөйл.* Өслегенә махсус сыеклык ярдәмендә текст яки гади рәсем төшерелгән күбәйткеч тонык пыяла; стеклограф. *Без [листовканы] пыялада бастырып күбәйттек*. И.Гази

2. *с. мәгъ.* 1) Пыяладан (*1 мәгъ.*) ясалган. *Нигә ватылды соң теге кайәр суккан көнне пыяла банка?* А.Гыйләҗев. *Үзе кулындагы пыяла савытны, төшереп җибәрүдән курыккан кебек, икенче кулына күчереп тотты*. Х.Камалов. *Пыяла фужерларда вак һава бөртекләре кайнады*. Ф.Яхин

2) Шундый материал куелган. *Тәрәзә арасындагы пыяла шкафларда бик күп китаплар тезелеп тора ---*. Г.Бәширов. *Менә пыяла ишекле зур гына бер залга килеп чыкты*. Х.Ширмән. *Безнең кышка ябып куя торган пыяла верандабыз бар*. Сабантуй

3) Шома, көзге кебек. *Агыйдел өстенең пыяла тигезлеге челпәрәмә килде*. М.Әмир

◊ **Пыяла ашаган** Кемнең дә булса каршына басып, аңа алдагы әйберне күрергә комачау тудыручыга карата әйтелә. **Пыяла белән түбә ябу** Булмастай эш эшләү (кулдан килмәстәй эшне, эшләдем, дип мактанучыга карата әйтелә). **Пыяла күз** Бернинди хиссез, битараф караш. *Туп-туры текәлеп торган пыяла күз – җансыз*. Ш.Галиев. **Пыяла самавыр** Шешәле аракы. **Пыяла чикмән** *к.* **пыяла самавыр**

ПЫЯЛАБАСМА *и.* Стеклограф ярдәмендә күбәйтеп басу ысулы; стеклография

ПЫЯЛАКАНАТ *и. зоол. к.* **пыялач**

ПЫЯЛА́КИСКЕЧ *и.* Пыяла, көзге һ.б.ш. материалларны кисә торган махсус кул коралы. *Минем беренче «әсәрләрем» Шомбай турында иде. Пыялакискеч ул, шуны «Шомбай» дип йөртә идем*. Г.Габделхакова

ПЫЯЛАКҮБЕК *и. зоол.* Суда яши торган болытсыман сүүсемнәрнең бер төре; *русчасы*: **стеклянная губка**

ПЫЯЛАЛАНУ *ф.* 1) Пыяла шикеллегә әверелү, пыялага охшый башлау; пыяла кебек ялтырый башлау. *Көннәр гел кояшлы, җылы торганга, басуда кар иңгән, утырган, чана юллары пыялаланган иде*. И.Гази. *Клинкер кирпеч ясаганда, балчык тулысынча укмашканчы яндырыла, ләкин өслек пыялаланмый*. Төзү материаллары

2) Пыяла катламы белән махсус каплану. *Эченә парафин утырмасын*

өчен пыялаланган торбаларны халык, урлап, койма баганаларына утыртты. Ф.Яруллин. *[Торба] нигәдер пыялаланмый гына.* Ш.Бикчурин

3) Тәрәзәләргә, ишеккә һ.б. нәрсәләргә пыяла куелу. *Корпусларның түбәләре ябылган, ләкин тәрәзәләре пыялаланмаган әле.* А.Расих. *Арттан чаршау ябылды, һәм Габдулла стеналарына чиккән намазлыклар, сөлгеләр, пыялаланган шәмаилләр эленгән --- бүлмәдә әллә нинди өч ят кеше алдында басып калды.* Ә.Фәйзи

4) *күч.* Җансызлану, нурсызлану. *Нургалинең исә чәч араларына, колак тишекләренә ком тулган, өстеннән су, чалбар кесәләреннән ташлы ләм ага, күзләре пыялаланган.* М.Мәһдиев. *Ул көнне Рафис салмыш иде. Аракыдан чирканган ирнең күзләре пыялаланган, иреннәре чалшайган иде.* Н.Гыйматдинова. *Аны Таксист бүлдерде. Ул да мәлҗерәгән, күзләре пыялаланган.* Р.Кәрами

Пыялалана бару Аз-азлап, акрынлап, торган саен ныграк пыялалану

Пыялалана башлау Пыялаланырга тотыну. *Чем кара күзләре пыялалана башладылар, ыңгырашканга охшаш тавыш чыгарды да... җан бирде.* З.Зәйнуллин. *Аның куркудан киң ачылган күзләренең пыялалана башлавын күргәч, янәшәдәге койкада ятканавыруга игътибар итми, ишеккә атлады.* З.Мурсиев

Пыялаланып китү Кинәт пыялаланган хәлгә килү. *Аның күзләре пыялаланып киткән, ул берөзлексез метмелдәтеп нәрсәдер ашый иде ---.* М.Мәһдиев

Пыялаланып тору Пыялаланган хәлдә булу. *Күз алмасы пыялаланып торса да күрү сәләте түбән икәнлегенә ишарә.* Мәдәни җомга

ПЫЯЛАЛА́У *ф.* 1) Тәрәзәгә, ишеккә һ.б.ш.ларга пыяла кую. *Аннан-моннан казыкка яры тарттырып куйган куыш түгел, кирпечләп, тимерләп, пыялалап, гомерлек итеп эшләнгән, су кертелгән, әастан торба белән җылытыла торган икән.* А.Тимергалин. *Шуңа күрә тәрәзәне пыялалаганда рам белән пыяла арасында җитәрлек ара калдырырга кирәк.* Төзү материаллары

2) Пыяла белән каплау, пыяла астына кую. *Алтынлы рамка эченә пыялалап куелган уставны, иске программаны Сөләйман Сәйфуллин [ерта].* Г.Ибраһимов

Пыялалап бетерү Бөтесен дә, барысын да пыялалау

Пыялалап җибәрү Тиз арада пыялалау

Пыялалап карау Пыялаларга тырышу

Пыялалап кую Пыялаланган хәлгә китерү; алдан пыялалау. *Балконнарын да киявем Мөдәрис үз куллары белән пыялалап куйды.* Ватаным Татарстан. *Дөрес, рамлап, пыялалап кую бер яктан файда булды, чөнки сүнмәгән тәмәке төпчекләре балконнарга азрак эләгә.* Безнең гәҗит

Пыялалап чыгу *к.* **пыялалап бетерү**

Пыялалый башлау Пыялаларга тотыну

ПЫЯЛАЛАУЧЫ *и. к.* **пыялачы**

ПЫЯЛАМАМЫК *и.* Пыяла сүсеннән эшләнгән җылы саклаучан җиңел материал; *русчасы*: **стекловата**. *Бу – пыяла мамыгы һәм аннан продукция җитештерү проекты.* Ватаным Татарстан. *Заводта эшкәртеләчәк агачлар башта бик вак итеп, пыяламамык рәвешенә килгәнче эшкәртеләчәк.* Шәһри Казан

ПЫЯЛАМӘРҖӘН *и.* Пыяладан ясалган, җепкә тезү өчен, уртасы тишекле булган төрле төстәге кыска көпшәчекләр; сәйләннең эре төре; *русчасы:* **стеклярус**

ПЫЯЛА́ ӨРҮЧЕ *и.* Эретелгән пыяладан өреп төрле әйберләр ясаучы эшче

ПЫЯЛА́ СҮСЕ *и.* Эретелгән пыяладан эшләнгән җепсел; *русчасы*: **стекловолокно**. *Пыяла сүсеннән ясалган материаллар янмаучанлык, коррозия һәм биойогынтыга түземлелек, гаять югары чыдамлылык һәм чагыштырмача аз тыгызлык кебек кыйммәтле үзлекләргә ия.* Төзү материаллары. *Татарстан – Саксония предприятиесе – --- елына 19 мең тонна чамасы пыяла сүсе һәм аның нигезендә эшләнгән продукция җитештерәчәк.* Ватаным Татарстан

ПЫЯЛА́СЫМАН *с.* 1) Үтәкүренмәле. *Үтәкүренмәле шлифта кварцның йомры һәм төзек булмаган бөртекләре, --- карбонат кристаллары һәм аларның пыяласыман матдә белән цементлашкан булуы яхшы күренә.* Эзләнүләр, уйланулар, табышлар

2) Үзлеге, структурасы белән пыялага охшаш. *Пластмасса дип нигезендә югары молекуляр кушылмалар − полимерлар яткан, формалаштырган чакта пластик хәлдә, әфайдаланган чакта пыяласыман яисә кристаллик хәлдә булган материаллар атала.* Төзү материаллары. *--- сыек һәм пыяласыман хәлдәге парамагнитик комплексларны тикшерү --- парамагнитик үзәкләрнең әйләнәтирәсендә шактый күп мәгълүмат алу мөмкинлеген бирде.* Фән һәм тел

ПЫЯЛАТАШ *и. махс.* Үтә күренмәле катлы-катлы минерал; слюда

ПЫЯЛАЧ *и. зоол.* Канатлары пыяла кебек үтә күренмәле, күренеше төклетураны хәтерләткән күбәләк, җимеш агачлары корткычы; *русчасы*: **стеклянница**

ПЫЯЛАЧЫ *и.* Пыяла куючы эшче. *Һашим абзыйның ачылып киткән чагын мин дә очраттым, кулсыз пыялачы Фәхриев һәм аның шәкерте Һади турында миңа ул сөйләде ---.* А.Гыйләҗев. *Авылда көмешче, сәгатьче, пыялачы --- һәм балта осталары шикелле һөнәр ияләре дә бар.* Гасырлар авазы. *Хәзрәтләр бер дигән һөнәр ияләре – пыялачы, мич чыгаручы, балта остасы булган.* Идел

ПЬЕДЕСТАЛ *и. фр.* 1) Һәйкәл, колонна, ваза һ.б.ш. әйберләрнең сәнгатьчә бизәлгән нигезе; постамент. *Калкулык өстендә, пьедесталга баскан һәйкәлгә охшап, кулына винтовка тоткан җайдак тора иде.* Р.Вәлиев. *Каршыдагы --- мәчетнең юан, тәбәнәк ак манарасы калкып күренә: Габделнурга ул, солдатларга күз-колак булыр өчен, махсус пьедесталга бастырып куелган сержант кебегрәк булып тоелды.* Р.Кәрами. *Мәрмәр пьедестал өстендә бронзадан эшләнгән яшь кенә хатынкыз басып тора.* Гасырлар авазы

2) Спорт ярышларында җиңүчеләрне бүләкләгәндә менеп баса торган өч

баскычлы корылма. *Бу «кояшка» сәхнә яисә спортта уңышлар яулаган чемпионнар менеп баса торган пьедестал бик килешер иде*. Сөембикә. *Командалар беренчелегендә мактау пьедесталына менгән өч район вәкилләренә исә тәүге тапкыр «Газель» микроавтобуслары тапшырылды.* Татарстан яшьләре

3) *күч. кит*. Җәмгыятьтә тоткан югары урын; дәрәҗә, абруй. *[Г.Рәхим] аны Иранның борынгы суфи шагыйрьләреннән үк килә торган мәңгелек идеалларны җырлаучы --- романтик пьедесталына бастырды.* Г.Халит. *Ә бит соңгы елларда гына «авыл темасы»на күпме әсәрләр язылды, күпме колхоз председателе пьедесталга күтәрелде!* Р.Зәйдулла

ПЬЕ́ЗА *и. гр. физ.* Метр-тонна-секунд системасында механик көчәнешне һәм басымны үлчәү берәмлеге

ПЬЕ́СА *и. фр.* 1) Сәхнәдә уйнау өчен язылган драма әсәре. *Артистларның күбесе фронтка китеп барды. Безгә бер пьесада икешәр, өчәр роль уйнарга туры килә иде.* Н.Дәүли. *Бер көн түздем, ике көн, яңадан укып чыктым һәм, пьесаны күтәреп, тагын Баязит абый янына юнәлдем...* А.Гыйләҗев. *«Миңлекамал» пьесасы Татар дәүләт академия театры сәхнәсендә беренче тапкыр 1944 елда куелды*. Г.Иделле

2) Кечерәк музыкаль әсәр. *Ике дәрес арасында инде мин ул күрсәтеп киткән көйне бик әйбәтләп өйрәнергә тырышам, шуның өстенә даими күнегүләр рәвешендә әлеге этюдларны һәм бүтән җиңелрәк пьесаларны әледән-әле кабатлый торам.* Ә.Еники. *Гөлмирә торып скрипканы алды ---, башта нидидер пьеса уйнады.* Р.Кәрами. *--- музыкаль пьеса белән «канәгатьләнү» – музыканы тоюдагы барлык башка үзенчәлекләр кебек үк индивидуаль*. Казан утлары

ПЭР *и. лат.* Англиядә һәм Франциядә 1848 елгы инкыйлабка кадәр иң югары катлау дворян титулы; шул исемгә ия булган зат. *Инглиз короле зур аристократларга пэр дигән дәрәҗә бирә, һәм [өске] палата шул пэрлардан тора*. Г.Колахмәтов. *Ул --- генерал-лейтенант һәм Франция пэры килеш 1845 елда вафат була.* Кызыклар дөньясында

ПЭРЛЫК *и*. Пэр титулы, пэр дәрәҗәсе

ПЮПИТР *и. лат.* Ноталар, китаплар һ.б.ш.ларны кую өчен, авыш тактачык рәвешендәге җайланма. *Мин, кадерле укучым, рояль пюпитрындагы нота кәгазьләремне калдырып, язу өстәле янына утырдым*. Җ.Фәйзи. *Марго Тито күкрәгенә тактадан эшләнгән җайланма – пюпитр куйды, аның өстенә бер бит кәгазь салды, карандашны Титоның авызына каптырды*. Р.Батулла

Р

РАБАТ *и. инг.л. икът.* 1) Күпләп алучыга, товарның сыйфаты начарланганда, килешенгән вакытка аны китереп җиткерә алмаганда, шулай ук танышларга яки даими сатып алучыларга товарның бәясен киметеп сатылган хак

2) Кредитны билгеләнгән вакыттан алда түләп бетергән очракта, кредиттан файдаланган өчен, алдан килешенгән суммадан киметелгән хак

РАБА́ТКА *и. рус* Гадәттә стена, юл буйлап сузылган, декоратив үсемлекләр, чәчәкләр үстерелә торган озынча түтәл. *Өй кырыйлары төрле төстәге чәчәкләр үскән рабатка белән бизәлгән*

РАББАНИ *с. гар.* Раббыга мөнәсәбәтле, илаһи

РАББЫ *и. гар. дини* Аллаһ, Ходай, Тәңре. *Дөньяда диннәр күп булса да, һәр диннең үзәген кешелек дөньясына җиткерелергә тиешле төп фикерләр тәшкил итә: адәми затның Раббыбыз тарафыннан яратылуы, кешенең илаһи зат булуы, Раббысы белән рухи элемтәдә торганда, Ул күрсәткән юлдан барганда, бәхеткә, һәртөрле бәрәкәткә ирешүе, андый адәмне Раббыбызның явыз көчләрдән саклавы һ.б.* С.Шәмси. *Я Раббым, гакыл бирче колларыңа.* Ватаным Татарстан

РАБФАК *и. рус тар.* «Рабочий факультет» сүзтезмәсенең кыскартылмасы: 1919–1930 елларда урта белеме булмаган эшче-крестьян яшьләрен югары белем алуга әзерли торган, югары уку йортлары алдында оештырылган гомуми белем бирү факультеты. *Рабфак кичәсендә Зал эчендә ул да бар, Әүвәл авыл улы иде, Хәзер – комиссар.* Һ.Такташ. *Үзем Казанда бер олаучы абыйга карап, «барабыз» булып эшләп үстем. Аннан рабфакта укыдым.* И.Салахов. *Ярый, минәйтәм, агаңның дус-ишләре булуы сиңа да ярдәм итсен, дидем, сыйнфый чыгышыбыз да зарарсыз, мин әйттем, тоттым да кыш уртасында рабфакка күчердем.* Г.Гали

РАБФАКЧЫ *и.* Рабфакта укучы

РАББА *и. бор. яһүд к.* **раввин**. *Әнә яраткан кызын Түрә хан улына ярәшергә дә өлгермәде, көне белән диярге була, кахан раввалары калага килеп җиттеләр.* М.Хәбибуллин

РАББИН *и. яһүд* Яһүдиләрдә: дини белем алган кешегә бирелгән, мәхәллә җитәкчесе яки дини суд әгъзасы булу хокукы бирә торган квалификация, дини китаплар белгече (рухани түгел). *Урта гасыр, Яңа заман чорында раввиннар дин белән генә түгел, ә яһүд общиналарының сәяси һәм икътисади тормышы белән дә идарә иткәннәр.* Тарих. *Яһүд рухание – раввин әйтә: «Мөселманнарныкы барыбызга да ярый, шулай булгач, хәләл булсын», – ди.* Безнең гәҗит

РАВЕЛИН *и. фр. иск. тар.* Борынгы крепостьларда берәр стенаның тышкы ягына чыгарып эшләнгән өстәмә ярдәмче ныгытма. *Петербургтагы Петропавел крепостеның Алексей равелины*

РАВИ *и. гар.* Башка берәүдән ишетеп сөйләүче, риваять итүче. *Равилардан килгән хәбәр, аңлагыз, Барыгыз да чынлап, әйбәт тыңлагыз.* Мөхәммәдьяр. *Рави сахихның сүзенә караганда, бу кырмыска ике, хәтта өч бөртек богъдай ярмасын ялгыз күтәрә аладыр иде.* Г.Тукай

РАВИО́ЛИ *и. ит.* Эчлеге ит, кош ите, балык, яшелчә кебекләрдән торган, сөткә, майга изелгән төче камырдан әзерләнгән вак пилмән төре

РАГУ *и. фр. кулин.* Вак итеп турап, бераз кыздырып алынган иткә яки балыкка яшелчәләр һәм тәмләткечләр өстәп, томалап пешергән ашамлык. *Итле рагу ирланд халкының милли ризыгы санала һәм бөтен дөньяга аталы.* Файдалы киңәшләр. *Буар елан итеннән пешерелгән кәтлитләр, рагу Вьетнам ресторанларында төп урынны алып тора.* Шәһри Чаллы

РА́ДА *и. пол.* 1) *тар.* Украинада: халык җыелышы; җыен, киңәшмә

2) Украина, Белоруссия, Литва, Польшада төрле чорларда: халык вәкилләре советы; парламент. *Кырым мөфтие Бакчасарайда булган хәлләр уңаеннан Югары Рада рәисе белән фикер алышты.* Шәһри Казан

3) 1917–1918 елларда Украина һәм Белоруссиядә Совет властена каршы оешма

РАДАР *и. инг.л. тех.* Радиодулкыннар кулланып, ераклыгын, тизлеген, зурлыгын билгеләү, күзәтү өчен корылган радиолокацион станция, радиолокация җайланмасы, радиолокатор. *Капитан, йөзе белән радар экранына капланган килеш, пароход барасы юлны күзәтә.* М.Юныс. *Радиостанцияләр һәм телевидение тапшырулары, радар һәм рентген җайланмаларының электромагнитик нурланышы, галәмнән килгән башка нурланышларның да бик нык артуын исәпкә алып карыйлар.* Кызыклар дөньясында. *Моряклар радар ярдәмендә яңа утрау барлыкка килүен беләләр.* Могҗизалар энциклопедиясе

РАДЖА *и. санскр. к.* **ража**

РАДИАЛЬ *с. фр. махс.* **1.** 1) Радиус буенча урнаштырылган; радиус буенча юнәлтелгән. *1954 елның 4 январенда ракета --- Айга иң якын булган ноктасын үтте. Бу вакытта ракетаның радиаль тизлеге якынча 2,45 км/сек иде.* В.Казневский

2) Үзәктән таралган нурлар рәвешендәге. *Яңа яуган карда мондый бизәк аерым ачык булып ята: үзәктә – диаметры 40–50 см зурлыктагы божра, шуңардан дөрес радиаль формадагы божралар киңәеп киткән.* Татарстан яшьләре

2. *рәв. мәгъ.* Радиус буенча тезелеп. *Радиаль урнашу*

РАДИАЛЬЛЕК *и.* Радиаль булу

РАДИАН *и. лат. мат.* Үзенең радиусы озынлыгындагы дугага тигез почмак – яссылыктагы почмакларны үлчәү берәмлеге

РАДИАНЛЫ *с.* Үлчәү берәмлеге буларак радиан кулланылган (система тур.). *Радианлы үлчәмнән градуслы үлчәмгә һәм градуслы үлчәмнән радианлы үлчәмгә күчүгә мисаллар карыйк.* Алгебра

РАДИА́ТОР *и. лат.* 1) Эчке янулы двигательләрне сыеклык ярдәмендә суыту җайланмасы. *Йөк машинасында йөрүче безнең бер шофёрның радиаторына ябалак бәрелгән булган.* Г.Әпсәләмов. *--- тыгылган радиатор двигательне бик авыр суыта*. Кәеф ничек?

2) Үзәктән ягып җылыту системасында пар яки кайнар су йөри торган торбаларга тоташтырылган җайланма. *--- бу йортка гына да 400 метрлап полипропилен торба, 420 ләп секция радиатор, су өчен якынча 90 метр торба кирәк.* Дуслык

РАДИАЦИОН *с.* Радиациягә бәйләнешле, радиациягә караган. *Төнәтмә ярдәмендә кеше организмындагы авыр радиацион матдәләрне чыгарырга була.* Ватаным Татарстан. *Радиацион фон үзгәрү*

РАДИА́ЦИЯ *и. лат. физ.* 1) Теләсә кайсы җисем тараткан радиодулкыннар формасындагы энергия агымы

2) Ионлаштыручы нурланыш

3) Җылылык тарата торган нурланыш

4) Нурланыш, энергия тарату процессы. *Бүгенге бәндәләрнең котын алган рак, инфаркт, паралич кебек чирләр дә, радиация көчләре дә киләчәктә ачылачак, гап-гади генә бер чара алдында артка чигенәчәк.* Казан утлары. *Кесәдәге дозиметрлар безнең нормадан икеөч мәртәбә артык рентген радиация алуыбызны күрсәтә* ---. Шәһри Казан

5) Кояш тараткан электромагнитик һәм корпускуляр нурланыш. *Кояш радиациясен тотып кала торган калын пыялалар астында авыл хуҗалыгы культуралары үсә.* Кызыклар дөньясында

РАДИА́ЦИЯЛЕ *с.* 1) Радиация чыганагы булган. *Ул елларда радиацияле зонада лесник булып эшләдем...* Татарстан яшьләре. *Радиацияле химик элемент. Радиацияле металл*

2) Радиациягә дучар булган, радиацияләнгән, радиация белән зарарланган. *Владивосток таможнясы хезмәткәрләре чиктә Япониядән кайтарылган радиацияле автомобиль тапкан*. Ватаным Татарстан. *Мин 40 елга якын радиацияле, силикозлы шахтада эшләдем.* Безнең гәҗит

РА́ДИЙ *и. лат. хим.* Югары химик активлыкка ия, табигатьтә уран рудасы составында була торган радиоактив химик элемент, ялтыравыклы металл. *Радий – сирәк элемент; бер грамм саф радий аерып алу өчен, иң кимендә 5 т уран рудасын эшкәтергә кирәк. --- Радийның радиоактивлыгы уранныкына караганда берничә миллион тапкыр артыграк.* Физика курсы. *Диңгез суында эрегән хәлдә бик күп матдә: калий, кальций, магний, тимер, барий, хром, йод, хлор, марганец, мышьяк, көмеш, алтын, әз күләмдә уран, радий бар*. Татарстан яшьләре

РА́ДИЙЛЫ *с.* Составында радий булган

РАДИКАЛ I *и. лат.* 1) Үтә кискен караш һәм чараларны яклаган сәяси юнәлеш. *Радикаллар активлаша*

2) Радикаллык (*2 мәгъ.*) тарафдары. *«Яшьләр» лагерена Газиз, Йосыф, сеңелләре Зәйнәп, атасы ишаннан ваз кичкән Гали, радикал Әхмәт, учитель Зәкәрия, гимназистка Сара һәм башкаларны кертергә мөмкин.* Г.Тукай

РАДИКАЛ II *и. лат.* 1) *мат.* Арифметик тамыр алу гамәленең һәм тамыр алу нәтиҗәсенең тамгасы (√)

2) *хим.* Молекуладагы атомнарның бер химик кушылмадан икенче химик кушылмага үзгәрешсез күчә торган тотрыклы төркеме

РАДИКАЛИЗМ *и. лат. кит.* 1) Карашларда, гамәлләрдә, проблемалар чишкәндә, кискен чараларны алга кую; кискенлек, катгыйлык. *Фашизмга, экстремизмга, радикализмга һәм башка шундый авантюраларга каршы көрәшләргә дөрес дини юнәлеш бирү шулай ук җитди әһәмияткә ия.* Рәмзи Вәлиев. *Милли республикалар никадәр яхшы яшәсәләр, радикализм аларда шулкадәр азрак булачак.* Татарстан яшьләре

2) Зур һәм тиз реформалар үткәреп, сәяси курсны һәм иҗтимагый-сәяси мөнәсәбәтләрне тамырдан кискен үзгәртүне яклаган, бернинди компромиссны танымаган агым

РАДИКАЛЛАНУ *ф. сөйл.* Радикаллык күрсәтү, радикал булып күренергә тырышу

Радикаллана төшү Бераз радикаллык күрсәтү

Радикалланып китү Кинәт радикаллану

РАДИКАЛЛАШУ *ф.* Радикаллык тарафдарына әйләнү, радикал булып китү (кеше тур.)

Радикаллаша башлау Радикаллык ягына үзгәрү

Радикаллашып бетү Тәмам радикаллашу

РАДИКАЛЛЫ *с.* Радикалы II (*1 мәгъ.*) булган, радикал белән бирелгән

РАДИКАЛЛЫК *и. к.* **радикализм** (*2 мәгъ.*). *Вак буржуа зыялыларының бер өлеше эре буржуа ягына чыгып китсә, икенче бер өлеше иҗтимагый хәрәкәттән кул селтәү, өметсезлеккә бирелү, пассив радикаллык күрсәтү кебек омтылышларда булды*. Г.Тукай

РАДИКАЛЬ *с. лат.* **1.** 1) Кискен, катгый; капма-каршы карашларга корылган; тамырдан үзгәртү яклы булган. *--- ул [прокурор Азларханов] һәрвакыт безнең эштә радикаль үзгәртүләрне күтәреп чыкты.* Р.Мирхәйдәров. *Радикаль чаралар дигәннән, яшь буынны наркомания афәтеннән йолып алу максатында, киләсе уку елыннан Россиянең барлык мәктәпләрендә дә наркотест үткәрелә башлаячак.* Шәһри Казан. *Халыкның күпчелеге искечә яшәргә теләми, радикаль үзгәрешләр таләп итә.* Гасырлар авазы

2) Шундый карашларда торган. *Узган елның декабрендә Мәскәүнең Манеж мәйданында радикаль яшьләр төркеме тәртипсезлекләр оештырды.* Кызыл таң

3) Радикаллар партиясенә караган, радикализм (*2 мәгъ.*) тарафдары булган. *Тик мөселманнар арасында зур*

абруйга ия булган, киң радикаль карашлы Нәҗип хәзрәт, карагруһчыларның юлын кисү өчен, Чистайда һәм өязда мөселманнарның кадетлар белән блокка керүен куәтли. Р.Әмирхан

2. *рәв. мәгъ.* Кискен, катгый рәвештә, нигездән, тамырдан. *Русия армиясендә хәрби киемне радикаль алмаштыру беренче тапкыр 1992 елның октябрендә, Борис Ельцин күрсәтмәсе буенча башкарылды.* Өмет

РАДИКАЛЬЛӘШТЕРҮ *ф.* Кискенләштерү, кырыслаштыру

Радикальләштерә бару Торган саен ныграк радикальләштерү

Радикальләштерә төшү Тагын да ныграк радикальләштерү

РАДИКАЛЬЛӘШҮ *ф.* Кискенләшү, кырыслашу, радикаль төс алу (хәл, ситуация, юнәлеш һ.б.ш. тур.)

Радикальләшә бару Торган саен ныграк радикальләшү

Радикальләшә башлау Радикальләшүгә табан бару

Радикальләшә төшү Тагын да ныграк радикальләшү

Радикальләшеп китү Билгеле моменттан башлап радикальләшү. *Әйткәнемчә, аның иң куркыныч ягы – безнең җирлектән аерылып, маңкортка әверелү, радикальләшеп китү ихтималы булу.* Мәдәни җомга

РАДИКАЛЬЛЕК *и. к.* **радикализм**. *Аның әсәрләрендә дә радикальлек, иҗтимагый гаделсезлекләргә нәфрәтләнеп, үтә бер кискенлек белән каршы чыгу, байлык һәм ярлылыкны антитеза рәвешендә сурәтләү күзгә бәрелеп тормый.* Г.Тукай

РАДИКУЛИТ *и. лат. мед.* Арка мие нерв җепселләренең ялкынсыныу белән бәйле авыру. *Хәлләрне сорама инде, бабай. Өч ай буе радикулит белән кузгала алмый яттым.* Ф.Яруллин. *Досомов бер шешә йод белән бөтен елан агуын эләктереп качкан. Радикулит белән авыручыларга бик кирәк нәрсәләр.* З.Фәтхетдинов. *Киләчәктә Хуҗа-Обигарма дип йөртелгән родон чишмәкүлләренә барырсың, алар Памирдамы, Варзоб тарлавыгындамы шунда, радикулит, артрит кебек нәрсәләрнең бар икәнен дә онытырсың.* Р.Мирхәйдәров

РА́ДИО *и. лат.* 1) Электромагнитик дулкыннар җибәрү юлы белән сигналларны, тавышларны ерак араларга тапшыру яки кабул итү ысулы; шул ысул белән хәбәрләшү, элемтә тоту. *Электр чыбыкларын, радио чыбыкларын өзәрләр.* Р.Батулла. *Теләсә кайсы ил белән эфир дулкыннары ярдәмендә аралашу, радио спорты буенча төрле ярышларда катнашу, һәр радиоэлемтә өчен җибәрелгән открыткаларны җыеп бару укучылар өчен ниндидер яңалыклар ача, аларны уйлануларга этәрә.* Яңа тормыш. *Уфаны дистәләрчә электр объектлары, йөзләрчә радио һәм кәрәзле элемтә антенналары чолгап алган.* Өмет

2) Фән һәм техниканың шушы ысулга нигезләнгән физик күренешләрне өйрәнү өлкәсе. *Ул аларның кызыксынуларын күреп, радио түгәрәгенә язылырга тәкъдим итә.* И.Нуруллин. *Радио түгәрәгендә заманасы өчен шактый катлаулы радиотапшыргычлар һәм радиоалгычлар җыю белән мавыга.* Фән һәм тел

3) Шул рәвешле тапшырулар алып бара торган оешма. *Сабан сөрүдә районда беренче урынны алган идем. Бу турыда газетага яздылар, районга барып, радиодан чыгыш ясадым.* М.Юныс. *Радио оешуга 70 ел булса, сез шуның төгәл яртысын үз язмышыгыз белән бәйләгәнсез.* Р.Вәлиев

4) Шул рәвешле алып барылган, яңгыратылган программа, тапшыру. *Бер кермәсә, бер керер, дигән ният белән телевидение, радио аркылы да вәгазь-нәсыйхәт кылабыз.* Г.Исхакый. *Француз әсирләре шахмат уйнап, гәзит-журналлар укып, радио тыңлап утыра, кайсылары казарма янындагы мәйданда волейбол уйнап йөри.* Т.Әйди

5) *сөйл. к.* **радиоалгыч**. – *Әхәт, син безгә, энем, радио алып җибәрерсең инде, онытма, – дип, Әхәтнең исенә төшерде.* А.Алиш. *--- күрше Хәерниса иртә белән радиодан көлкеле бер тапшыру тыңлаган да кичке капка төбе «җыелыш»ында шуны сөйләде.* М.Мәһдиев

РАДИО- I *лат.* Кушма сүзләрдә «радиога (*1 мәгъ.*) бәйләнеше булган», «радиога мөнәсәбәтле» мәгънәсендәге беренче кисәк (мәс.: *радиокомитет, радиототаштыргыч* һ.б.)

РАДИО- II *лат.* Кушма сүзләрдә радий, радиоактивлык, радиациягә нисбәтлекне белдергән беренче кисәк (мәс., *радиодәвалау, радиоэлемент*)

РАДИОАКТИВ *с.* 1) Радиоактивлык үзлегенә ия булган. *Радиоактив углеродның калган процентыннан чыгып, сөяк, агач яки нинди дә булса тереклек яки үсемлек калдыкларының җирдә күпме ятуын исәпләп чыгарырга мөмкин.* В.Сабуев. *Ашламалар составына радиоактив изотоплар кертүнең дә әһәмияте бик зур.* М.Зарипов, С.Салихов. *Радиоактив нурланышка магнит кыры белән тәэсир итеп, бу өч нурны (α, β, γ) бер-берсеннән аерырга мөмкин.* Физика курсы

2) Радиацион таркалыш продуктлары белән туенган, зарарланган. *Радиоактив зона*

РАДИОАКТИВЛЫК *и.* Кайбер химик элементларда атом төшенең үзлегеннән яки ясалма таркалу күренеше; тотрыксыз атом төшләренең, альфа, бета, гамма нурлар бүлеп чыгарып, башка элемент атомнарына әверелүе. *Радийның радиоактивлыгы уранныкына караганда берничә миллион тапкыр артыграк.* Физика курсы. *Искәртергә кирәк, Япониядә радиоактивлык дәрәҗәсе һаман да арта тора.* Шәһри Казан

РАДИОАЛГЫЧ *и. тех.* **1.** Радио буенча җибәрелгән сигналларны кабул итеп, тавышка әверелдереп яңгырату өчен махсус аппарат. *Хәбиб, хыялын бүлеп, машинаның радиоалгычын кабызды.* М.Мәһдиев. *Белоштаннның радиоалгычыннан джаз музыкасы ишетелеп тора.* М.Юныс. *Равил, күзләрен радиоалгычтан алмаса да, бабасының сүзләрен игътибар белән тыңлады.* А.Әхмәт

2. *с. мәгъ.* Радиодулкыннар тоту белән бәйләнешле, радиодулкыннар кабул итә торган. *Җитәрлек кадәр сизгер радиоалгыч аппаратлар төзелгәч, космик радионурланышны өйрәнү өчен дә мөмкинлек ачылды.* Галәм, Җир, Кеше

РАДИОАППАРАТУ́РА *җый. и. лат.* Радиодулкыннарны тапшыру,

кабул итү, үзгәртү өчен кулланыла торган аппаратлар, радио җиһазлары. *Яшенле яңгыр вакытында, кар яуганда, тузанлы коры җил искәндә һ.б. шундый сәбәпләр аркасында антенна чыбыгында электр корылмалары җыелырга мөмкин. Моның исә радиоаппаратураны бозуы, кешеләр өчен дә куркыныч тудыруы бар.* Н.Хәбибуллин

РАДИОАСТРОНОМ *и. рус* Радиоастрономия белгече. *[Ул] 1980–1982 нче уку елында Казанның радиотехника мәктәбен тәмамлап, КДУга укырга кергән, анда инженер-радиотехник һәм радиоастроном белгечлеге алган*. Татарстан яшьләре

РАДИОАСТРОНО́МИЯ *и. лат.-гр.* Астрономиянең күк җисемнәрен алар үзләре чыгарган радионурлар аша өйрәнү бүлеге. *Украина Милли академиясенең Радиоастрономия институты хезмәткәре Алексей Архипов, америкалыларның «Клементина» ясалма юлдашыннан алынган фотоларны өйрәнеп, көтелмәгән ачыш ясый.* Кызыл таң

РАДИОАТЕЛЬЕ *и. лат.-фр.* Радиоаппаратура төзәтү урыны

РАДИОБИО́ЛОГ *и. рус* Радиобиология белгече. *– Радиобиолог буларак, анда бернинди генетик эффектлар була алмый, дип әйтә алам, – ди Роберт Ильязов*. Безнең гәҗит

РАДИОБИОЛО́ГИЯ *и. лат.-гр.* Радиоактив нурларның тере организмга тәэсирен өйрәнә торган фән. *Мәскәүдән, Чиләбедән врачлар, галимнәр килеп, аларны өйрәнә башлыйлар, еллар буе үлем зонасында яшәгән татарларның үләләре дә, тереләре дә радиобиология фәне өчен зур табыш була*. Ф.Бәйрәмова

РАДИОБУЙ *и. лат.-голл.* Сай яки башка куркынычлы урыннарны белдереп, автомат рәвештә радиосигналлар биреп тора торган тапшыргычы булган навигация буе

РАДИОВЫ́ШКА *и. лат.-рус* Радиодулкыннарны тоту һәм тарату өчен махсус биек антенна

РАДИОГРА́ММА *и. лат.-гр.* Радио аша тапшырылган яки кабул ителгән хәбәр. *Лейтенант, үзенә билгеләнгән «ояда» антенналарны көйләүгә, исәнсау килеп җитүе һәм эшкә тотынуы турында Мәскәүгә беренче радиограммасын тапшырды.* З.Фәтхетдинов. *Капитан, пароходка кире кайтаруларын сорап, кадрлар начальнигына радиограмма биргән.* М.Юныс

РАДИОГРА́ФИЯ *и. лат.-гр. физ.* Радиоактив элементлар нурланышы тәэсирендә плёнкага фотосурәтләр төшерү ысулы. *Рентген сурәтен радиография системасы аша җибәрү*

РАДИОДУЛКЫН *и. физ.* Буш киңлектә яктылык тизлеге белән тарала торган, дулкын озынлыгы инфракызыл спектрга кадәр булган электромагнитик дулкын. *Радиодулкыннар тирбәнү контурындагы электромагнитик тирбәнүләрдән хасил булалар.* Физика курсы. *Яктылык дулкыннары белән чагыштырганда, радиодулкыннарның берничә мөһим өстенлеге бар.* Галәм. Җир. Кеше. *Шарсыман яшеннәр радиодулкыннар аеруча зур интенсивлыкка ирешкән урында барлыкка килә.* Могҗизалар энциклопедиясе

РАДИОҖАЙЛАНМА *и.* Радио дулкыннарын тапшыру, кабул итү, үзгәртү өчен кулланыла торган аппарат, радио җиһазы. *Фәнни һәм үлчәгеч аппаратлар белән бергә контейнерга куелган радиоҗайланмалар ракета Айга килеп төшкән вакытта эшләрен туктаттылар.* В.Казневский

РАДИОҖИҺАЗ *и. к.* **радиоаппаратура**

РАДИОЗОНД *и. лат.-фр.* Төрле биеклекләрдә атмосфераның төрле күрсәткечләрен: һава басымын, температурасын, дымлылык дәрәҗәсен һ.б.ш.ны үлчәп, автомат рәвештә радио аша хәбәр итеп тора торган метеорологик әсбап. *Казанда беренче радиозонд Рөстәм Усманов тарафыннан 1935 елның 11 октябрендә җибәрелгән*

РАДИОКИҢӘШМӘ *и.* Радио аша үткәрелгән киңәшмә. *Язгы чәчү һәм урак вакытында Министрлар Кабинеты республика радиокиңәшмәсе үткәрә.* Т.Нәҗмиев

РАДИОКОЛАКСА *и.* Колакка киелә яки куела торган тыңлау приборы, наушник. *Катодлы реле кулланып, Термен приборның сизгерлеген арттыра да аңа гади индикатор урынына радиоколакса тоташтыра.* Б.Галиев

РАДИОКОЛГА *и.* Җир өсте радиостанцияләренең антенналарын биеклеккә күтәреп беркетү өчен терәк

РАДИОКОМБАЙН *и. лат.-инг.л.* Радиоалгыч, телевизор, магнитофон, пластинка уйнаткычтан торган аппарат

РАДИОКОМИТЕТ *и. лат.-фр.* Радио коллективының эшчәнлеге, тапшыруларның эчтәлеге, төре һ.б.ш. өчен җаваплы орган. *Радиокомитет булып радиокомитетта шундый грамотасызлык җибәргәч, нәрсә була инде ул?* М.Мәһдиев. *Ә ул – Хәсән Сарьян – октябрь аеның яңгырлы юеш бер көнендә хәбәрсез-нисез генә килде дә керде! Радиокомитетка, минем эш бүлмәсенә.* М.Шабаев. *Танылган укытучы Ковальковның җыр классында ике елдан артык укып, авыруы сәбәпле, ниһаять, мәктәптән чыгарга мәҗбүр булган Гөлсем 1927 нче елда Казан радиокомитетына даими җырчы булып хезмәткә урнаша.* Ф.Хөсни

РАДИОКОММЕНТА́ТОР *и. лат.-фр.* Сәнгать, спорт, икътисад, сәясәт һ.б. мәсьәләләр буенча радио аша күзәтү ясаучы; радиорепортаж алып баручы кеше. *20 секунд эчендә радиокомментатор 100 сүз әйтеп өлгерә.* Кызыклар дөньясында

РАДИОКО́МПАС *и. лат.-ит.* Җирдәге радио станцияләреннән алынган сигналлар белән очкычның, корабның хәрәкәт юнәлешен даими чагыштырып, аның курсын билгели торган навигация приборы. *Штурман радиокомпасның һәм электромагнитлы башка приборларның сафтан чыгуын, радиоэлемтәнең бозылуын ачыклаган.* Могҗизалар энциклопедиясе

РАДИОКОРРЕСПОНДЕ́НЦИЯ *җыйм. и. лат.* Радио элемтәсе ярдәмендә тапшырылган хәбәрләр. *Радиокорреспонденция күп булу*

РАДИОКҮЗӘТҮ *и.* Радиосигналларны кабул итеп, нинди дә булса объектны өйрәнү. *Радиокүзәтүнең тәүлек әйләнәсенә һәм һава хәленә бәйле булмавы да шактый әһәмияткә ия.* Галәм, Җир, Кеше

РАДИОКҮПЕР *и.* Мәгълүмат тапшыру, әңгәмә оештыру һ.б.ш. өчен, нинди дә булса ике нокта арасында урнаштырылган элемтә. *Тапшыру радиокүпер режимында узды: алып баручы – Мәскәүдән, ә Президент Казаннан торып сөйләште.* Татарстан яшьләре

РАДИО́ЛА *и. лат. тех.* Радиоалгыч һәм пластинка уйнаткыч җайланмадан торган аппарат. *Әйбәт кенә, чиста гына ике бүлмә. Шифоньеры, буфеты бар. Тумбочка өстендә радиола.* Г.Нәбиуллин. *Радиолада иске пластинка бер ноктада әйләнепме әйләнде ---.* Р.Хафизова. *Нина, радиола кабызып, уйнатырга пластинка куйды.* М.Юныс

РАДИОЛА́МПА *и. лат.-гр.* Радиоалгычларга, радиотапшыру җиһазларына һ.б.ш.га куела торган электрон лампа

РА́ДИОЛАУ *ф.* Радио элемтәсе ярдәмендә тапшыру; *русчасы:* **радировать**. *Антеннаны беренче мәртәбә А.С.Попов уйлап тапкан. Радиотапшыру һәм радиолау эшендә җирләүне беренче мәртәбә ул кулланган.* Физика

Радиолый башлау Радиоларга керешү

Радиолап тору Даими рәвештә радиолау

РА́ДИОЛАШТЫРУ *ф.* 1) Радио элемтәсе үткәрү, радиостанцияләр челтәрен киңәйтү, җәелдерү; *русчасы:* **радиофицировать**. *Ш.Усманов татар әлифбасын үзгәртеп кору, интернациональ тел – эсперантоны популярлаштыру, республикада радиолаштыру эшләрен киңәйтү кебек иҗтимагый тормыш мәсьәләләренә һәм әдәбият-сәнгатьнең актуаль проблемаларына багышланган мәкаләләре белән дә егерменче-утызынчы еллар татар публицистикасында күренекле урын тота.* Адымнар

2) Радиостанцияләр челтәренә тоташу

3) Производствода, җитәкчелектә радиометодлардан файдалану. *Алар [радиосөючеләр]--- производствоны автоматлаштыру һәм радиолаштыру эшендә актив катнашалар.* Н.Хәбибуллин

Радиолаштыра бару Көннән-көн күбрәк радиолаштыру

Радиолаштырып чыгу һәр яктан, тулысынча радиолаштыру

РАДИО́ЛОГ *и. лат.-гр.* Радиология белгече, радиоактив матдәләр белән дәвалаучы табиб. *Бүлегебездә талантлы 12 радиолог эшли, шуларның җидесе югары категорияле.* Кызыл таң

РАДИОЛО́ГИЯ *и. лат.-гр.* Медицинаның ионлаштыру нурларының организмга йогынтысын һәм аны файдаланып диагностикалау, дәвалау, нурланыштан саклау методларын өйрәнү бүлеге. *Аның кысаларында, халык кулланылышында булган товарларга билгеләнгән күрсәткечләрнең барлык спектрлары, шул исәптән физик химия, микробиология, радиология, ГМО буенча экспертизалар уздыру планлаштырыла.* Шәһри Казан

РАДИОЛОКА́ТОР *и. лат.* Радиолокация җайланмасы; радиодулкыннар ярдәмендә объектның урынын һәм ераклыгын төгәл билгеләү җайланмасы. *Радиолокатор экранында боз тавы яхшы күренә.* Могҗизалар энциклопедиясе

РАДИОЛОКАЦИОН *с.* Радиолокациягә нисбәтле. *Корабта ышанычлы радиоэлемтә ысуллары, камилләшкән телевизион һәм радиолокацион аппаратлар булырга тиеш.* В.Казневский

РАДИОЛОКА́ЦИЯ *и. лат.* 1) Радиодулкыннар ярдәмендә объектны табу, тану, ераклыгын билгеләү методы. *Радиолокация самолётларга җир өстен ачык күрмичә очарга һәм аэродромны күрмичә аэродромга туры килеп төшәргә мөмкинлек бирә.* Физика курсы

2) Фән һәм техниканың шул методларны өйрәнү бүлеге

РАДИОЛОКА́ЦИЯЛӘҮ *ф.* Радиолокация эшен башкару

РАДИОЛОТ *и. лат.-голл. тех.* Очкычның очу биеклеген электромагнит дулкыннар ярдәмендә үлчәү әсбабы

РАДИОМАЯК *и. лат.-рус* Корабль һәм самолётларның координатларын билгеләү өчен, махсус сигналлар җибәреп торган радиостанция. *Ул, С.Королёв һәм А.Туполевлар белән бергә, ябык конструкторлык бюросында эшли. Самолётлар өчен радиомаяк уйлап таба.* Б.Галиев. *Янәшәдә утыручы Геннадий Китайгородскийга радиомаякка турылап очу турында сөйләргә керештем.* М.Юныс

РАДИОМЕТР *и. лат.-гр.* Кояш яктылыгының яки теләсә нинди башка электромагнит нурланыш энергиясенең зурлыгын үлчәү приборы. *Тимербетон өрлек өслекләрендә хасил булган аномаль өлкәләрдәге температураның абсолют зурлыкларын теркәү өчен, сынауларда «Компьютер термографы ИРТИС 2000» маркалы тепловизор-радиометр кулланылды.* Фән һәм тел

РАДИОНАВИГАЦИОН *с.* Радионавигациягә бәйле, радионавигациягә караган. *Заманча, яңа радионавигацион җиһазлар*

РАДИОНАВИГА́ЦИЯ *и. лат.* Самолёт һәм корабльләрне билгеле курс буенча йөртү өчен, радиотехникадан файдалану чаралары. *Радиолокациянең, сугыш эшләре өчен генә түгел, тыныч-лык максатлары өчен дә әһәмияте бик зур. Мондый максатларга, иң беренче чиратта, һавада, диңгезләрдә самолёт һәм корабльләрнең радионавигациясе керә.* Физика курсы

РАДИОНОКТА *и. лат.-гар.* Радио кергән һәркайсы урын, радиотапшыруларны тыңларга мөмкинлек биргән теләсә нинди җайланма. *Чөнки ул вакытта һәр йортта радионокта булдыруны тәэмин итү хакимият органнарының мөһим бурычларыннан саналды.* Шәһри Казан

РАДИОНУКЛИД *и. лат.* Радиоактив нуклид; радиоактив таркалуга сәләтле төш. *Хөрмә йомшагында азык җепселләре – пектин, целлюлоза күп, шулар эчәклек эшчәнлеген яхшырта, организмнан радионуклид, авыр металл, агулы катнашмаларны чыгарырга ярдәм итә.* Ватаным Татарстан

РАДИОНУР *и.* Радиодулкыннар барлыкка китергән сигнал. *Германия конструкторлары ракета техникасында әллә никадәр эшләнмәләр ясыйлар. Радионур белән идарә ителә торган ракеталар, төрле типтагы «оча торган бомбалар»...* Кызыклар дөньясында. *Җирдән җибәрелгән радионур ярдәмендә күк җисемнәренең өслеген «капшарга» һәм алардан кайтарылган*

сигналларны да тотарга өйрәнделәр. Галәм, Җир, Кеше

РАДИОНУРЛАНЫШ *и.* Радиодулкыннар барлыкка килү процессы. *Җитәрлек кадәр сизгер радиоалгыч аппаратлар төзелгәч, космик радионурланышны өйрәнү өчен дә мөмкинлек ачылды.* Галәм. Җир. Кеше

РАДИОПЕЛЕНГА́ТОР *и. лат.-голл.* Сигнал җибәрелгән радиостанциянең юнәлешен билгели торган радиоалгыч җайланма

РАДИОПОСТАНО́ВКА *и. лат.-рус* Радиостудиядә куелып, радио аша тапшырыла торган әдәби инсценировка. *Анда эшләүче шагыйрь Якуп Колмый Тәһир Ахунҗановның повестеннан радиопостановка куярга инсценировка язган.* Кызыл таң

РАДИОПРОТЕ́КТОРЛАР *и. күпл. лат.-нем.* Тере организмнарны радиоактив нурланыштан саклый торган химик матдәләр

РАДИОРЕПОРТАЖ *и. лат.-инг.* Эшнең торышы, вакыйгалар, хәлләр турында турыдан-туры шул урыннан радио аша мәгълүмат тапшыру; шундый хәбәр бирелгән программа. *Татарстан турында мөселман һәм христиан культурасының үзара тыныч яшәүләре темасына багышланган ярты сәгатьлек радиорепортаж әзерләнә.* Татарстан яшьләре

РАДИОРО́ЛИК *и. лат.-нем.* Реклама характерындагы кыска радиотапшыру. *Аерым очракларда радиоролик вакыт ягыннан озакка сузылмаган танылган җыр формасында була ала.* Кәеф ничек?

РАДИОРУ́БКА *и. лат.-голл.* Радиоаппаратура урнаштырылган бүлмә; радистның эш урыны (корабльдә һ.б.). *Тавык кетәге кадәр радиорубкасында төтенгә буылып калгач, кычкырмый нишләсен [Рәсим]!* Ф.Шәфигуллин

РАДИОРУ́ПОР *и. лат.-голл.* Рупор формасындагы репродуктор

РАДИОСИГНАЛ *и. лат.* Радиодулкыннар тарата торган сигнал. *Өйрәнелә торган космик объектның радиосигналлары берьюлы ике инструмент белән кабул ителә.* Галәм. Җир. Кеше. *Мәскәүдән җибәрелгән радиосигнал Антарктикага 0,05 секундта, Айга 1,28 секундта, Марска 43,5 секундта, безнең Кояш системасының иң ерак планетасы Плутонга 4,5 сәгатьтә, иң якын йолдызларның берсе булган Сириуска ун елда барып җитә.* В.Казневский

РАДИОСӨЮЧЕ *и.* Радиоалгычлар, телевизорлар конструкцияләүче, ясаучы, радиоэлемтә буенча тәжрибәләр үткәрүче һ.б.; радиотехника һәвәскәре; радиоһәвәскәр. *Радиосөючеләр радиоалгычлар, телевизорлар һәм кыска дулкынлы тапшыргычлар ясау белән генә чикләнмиләр, алар халык хуҗалыгының төрле тармакларына яңа радиометодлар кертәләр.* Н.Хәбибуллин

РАДИОСПОРТ *и. лат.-инг.* Радиоэлемтә һәвәскәрләренең кыска һәм ультракыска дулкыннарда радио аша телеграмма сугу һәм кабул итү, радио ярдәмендә урынын, ераклыгын билгеләү, пеленглау һ.б. тизлекләрдә узышудан гыйбарәт техник спорт төре. *Студентлар «телеграф ачкычы»н башка, тыныч максатларда файдалана: радиоспорт нечкәлекләренә төшенәләр, Җир шарының төрле ноктaларында яңа дуслар табалар.* Кызыл таң

РАДИОСТА́НЦИЯ *и. лат.* 1) Радиодулкыннар тарата һәм кабул итә торган техник җиһазлар җыелмасы. *Зур сугышларга әле бик күп катнашмаган бу отрядның радиостанцияләре, берничә пушкасы, кухнялары, хәтта медицина пункты да бар.* С.Тәһиров. *Радиостанциядә эшләү тәжрибәсе һәм музыкаль зирәклеге дә эшкә ярап куя.* Б.Галиев. *Бу очкыч агитация максатларын да күздә тотып төзелә. Аның бортына берничә радиостанция --- кәела.* Кызыклар дөньясында

2) *сөйл.* Шул җиһазлар урнаштырылган пункт. *Мин белештем, һәр пароходта радиостанция бар.* М.Юныс

РАДИОСТУ́ДИЯ *и. лат.-ит.* Радиотапшырулар алып бару өчен махсус җиһазландырылган бүлмә. *Кырмыскалы һәм Авыргазы районнарын берләштергәннән соң, Кырмыскалыда радиостудия ачтылар.* Кызыл таң

РАДИОСУГЫШ *и.* Радио аша алып барыла торган сәяси көрәш

РАДИОТАПШЫРГЫЧ *и. тех.* **1.** Радиосигналлар тапшыру җайланмасы, аппараты. *Радиотапшыргычтан килгән дулкыннар радиоалгыч антеннасында бик кечкенә электр йөртү көче индукциялиләр.* Н.Хәбибуллин. *Ул сигналлар иярчендәге радиотапшыргычка керәләр һәм радиодулкыннар рәвешендә Җиргә җибәрелләр.* В.Казневский

2. *с. мәгъ.* Шул җайланмага нисбәтле, шуңа бәйләнешле. *Таракан җилкәсендәге антенналар, микроскопик микрофон һәм радиотапшыргыч тараканны чын мәгънәсендә «007 агенты» дәрәҗәсенә күтәргән.* Кызыл таң

РАДИОТАПШЫРУ *и.* Массакүләм мәгълүмат чараларының берсе буларак радио аша тапшырылган чыгышлар: текст, музыка, җыр, хәбәрләр һ.б. *Минем җирле радиотапшырулар оештыручысы булып эшли башлаган вакытым иде.* Т.Нәҗмиев. *Антенналы беренче мәртәбә А.С.Попов уйлап тапкан. Радиотапшыру һәм радиолау эшендә җирләүне беренче мәртәбә ул кулланган.* Физика

РАДИО-ТЕЛЕВИ́ДЕНИЕ *җый. и. лат.-гр.* Радио һәм телевидение. *Радиотелевидениедә атна саен диярлек тапшыруларда катнашучы сәнгатькәр Рабит Батулланың «Кем ул әдип?» дигән әңгәмәсеннән кыска гына үзек китерсәк, отышлы булыр.* Т.Нәҗмиев

РАДИОТЕЛЕГРА́ММА *и. лат.-гр. к.* **радиограмма**

РАДИОТЕЛЕГРАФ *и. лат.-гр.* 1) Радио аша телеграмма сугу һәм кабул итү аппаратлары җыелмасы

2) Шул аппаратура ярдәмендә шул эшне башкара торган учреждение; станция

РАДИОТЕЛЕГРАФИ́Я *и. лат.-гр.* Телеграф кодлары ярдәмендә радио аша хәбәрләр тапшыру һәм кабул итү эшчәнлеге. *Казанның РОСТО (ДОСААФ) әгъзаларыннан торган Татарстан командасы тизләнешле радиотелеграфия буенча Россия чемпионатында дүрт призлы урынга лаек булды.* Татарстан яшьләре

РАДИОТЕЛЕМЕ́ТРИК *с.* Радиотелеметриягә караган, шуңа мөнәсәбәтле. *Мәгълүматларны тапшыру өчен,*

радиотелеметрик аппаратлар периодик рәвештә махсус программа буенча тоташтырылдылар. В.Казневский

РАДИОТЕЛЕМЕТРИ́Я *и. лат.-гр.* Радиодулкыннар ярдәмендә ерактан торып технологик процесс, табигать күренеше, берәр организмның халәте һ.б.ш.ны чагылдырган физик күрсәткечләрне үлчәү ысулы

РАДИОТЕЛЕСКОП *и. лат.-гр.* Электромагнитик нурланышлары буенча күк җисемнәрен өйрәнә торган астрономик җиһаз. *Радиотелескопның эшләү принцибы гадәти телескопның эш принцибына охшаган.* Галәм. Җир. Кеше

РАДИОТЕЛЕФОН *и. лат.-гр.* Телефон элемтәсен радиодулкыннар ярдәмендә кора торган аппаратлар җыелмасы. *Василий Степанович радиотелефон аша грек капитаны белән инглизчә сөйләшә иде.* М.Юныс. *Шәһәр челтәре белән тоташкан радиотелефон сыбызгысы икән, әле өй эчендә яңа техника тавышына һаман ияләшә алмыйлар.* К.Кәримов

РАДИОТЕЛЕФОНИ́Я *и. лат.-гр.* Чыбыксыз телефония; сөйләмне кодлаштырып, чыбыксыз элемтә ярдәмендә ерак арага тапшыру белән шөгыльләнә торган техника тармагы

РАДИОТЕРАПИ́Я *и. лат.-фр. мед.* Радий һәм башка радиоактив матдәләр ярдәмендә дәвалау методы; дәвалауда ионлаштырудан файдалану. *Былтыр Казанның Себер тракты, 29 адресы буенча сафка бастырылган махсус Төш медицинасы үзәгендә (Центр ядерной медицины) урнаштырылган әлеге заманча җиһаз яман шешле авыруларга радиотерапия уздыру өчен файдаланыла.* Безнең гәҗит

РАДИОТЕ́ХНИК I *с.* Радиотехникага караган. *Л.Берия талантлы уйлап табучының «Буран» дигән радиотехник җайланмасын Сталинның кабинетын астыртын тыңлау өчен файдаланган икән.* Б.Галиев. *Иярчендәге программа җайланмасы --- радиотехник аппаратлар эше белән идарә итте.* В.Казневский. *Радиотехник аппаратларның иң төп элементы – тирбәнү контуры.* Физика курсы

РАДИОТЕ́ХНИК II *и. лат.-нем.* Радиотехника белгече. *«Россия» дизель-электроходына радиотехник кирәк булган. Штат буенча радиотехник тоту каралмаган. Мине шунда электрик итеп урнаштырдылар да радиотехник эшен башкарырга куштылар.* М.Юныс

РАДИОТЕ́ХНИКА *и. лат.-нем.* 1) Югары ешлыклы электромагнитик тирбәлешләрне һәм радиодулкыннарны өйрәнә торган фән. *Л.С.Термен баштанаяк радиотехника диңгезенә чума: Мәскәүдәге радиотехника лабораториясендә, илдәге иң куәтле радиостанциядә эшли.* Б.Галиев. *Монда Ялта белән Әнкара арасында таулар юк, тавыш туп-туры диңгез өстеннән килә, дип, Хәмит ага үзенең радиотехникада да гыйлемле икәнлеген исбат итте.* М.Мәһдиев. *Мин Эдикның нинди эш белән мавыкканлыгын белә идем. – Бәлки, сиңа радиотехниканы ташламаска кирәктер.* М.Юныс

2) Практик максатларда радиодулкыннарны файдалану техникасы. *Радиотехника үзе дә физика фәнен төрле фәнни тикшеренүләр алып бару өчен кирәк булган гадәттән тыш сизгер приборлар һәм яңа идеяләр белән коралландырды.* Физика курсы

РАДИОТРАНСЛЯЦИОН *с.* Радиотрансляциягә караган, радиотрансляция белән бәйләнеше булган

РАДИОТРАНСЛЯ́ЦИЯ *и. лат.* Радиопрограммалар тапшыру. *Бүлмә антеннасы электр челтәре, радиотрансляция һәм телефон чыбыкларыннан мөмкин кадәр ераграк сузылырга тиеш.* Н.Хәбибуллин

РАДИОУ́ЗЕЛ *и. лат.-рус* Радиотапшырулар алып бару, трансляцияләү, радиоэлемтә тоту өчен махсус җиһазландырылган пункт; радиодулкыннар тота һәм тапшыра торган урындагы станция. *Биредә торак биналар, хуҗалык каралтылары, ат абзары (чабышкылар өчен), водокачка, зур мунча, бассейн, фонтаннар, чәчәкләкләр, медпункт, кибет, ашханә, китапханә, радиоузел, кино залы, бию мәйданчыкларына кадәр булган.* А.Тимергалин

РАДИОҮЛЧӘ́Ү *и.* Радио дулкыннарын үлчәү эше. *Радиосөючеләр --- радиоүлчәү җайланмалары, аппаратлары ясау белән шөгыльләнәләр.* Н.Хәбибуллин

РАДИОФИ́ЗИК I *с.* Радиофизикага караган, шуның белән бәйле

РАДИОФИ́ЗИК II *и. лат.-гр.* Радиофизика белгече. *Шул «җен» Лилияне, радиофизик булырга дип дүрт ел укыганнан соң, Казан театр училищесына тартып китерә.* Ватаным Татарстан

РАДИОФИ́ЗИКА *и. лат.-гр.* Радиотехника һәм электрониканың физик нигезләрен өйрәнә торган физика фәнендәге аерым бер тармак. *Һөнәр сайлавыгызда, радиофизика юлына кереп китүегездә әтиегезнең дә өлеше булмый калмагандыр?* Шәһри Казан

РАДИОФИКА́ЦИЯ *и. лат.* Радиолаштыру эше, процессы

РАДИОХӘБӘР *и.* Радио аша тапшырылган хәбәр, радиограмма. *Әлеге радиохәбәрләрдән кондукторлар көлә генә.* Ватаным Татарстан

РАДИОХИ́МИЯ *и. лат.-гр.* Радиоактив элементларның үзлекләрен, аларның фән һәм техникада кулланылыш мөмкинлекләрен өйрәнә торган химия фәнендәге аерым бер тармак

РАДИОХИРУРГИ́Я *и. лат.-гр.* Радиацион техник чаралар куллана торган хирургия. *Хөкүмәт йортында Премьер-министр урынбасары Фидус Ямалтдинов рәислегендә «Башкортстан Республикасында радиохирургия белән позитрон-эмиссион томография үзәге булдыру проекты»н гамәлгә ашыру мәсьәләләре буенча киңәшмә үтте.* Кызыл таң

РАДИОҺӘВӘСКӘР *и. к.* **радиосөюче**. *Элекке НАСА хезмәткәре Отто Биндер сүзләренә караганда, Айга аяк баскан астронавтлар һәм очыш белән идарә итү үзәге арасындагы сөйләшүне берничә радиоһәвәскәр ишетә.* Кызыл таң

РАДИОҺӘВӘСКӘРЛЕК *и.* Һәвәскәр дәрәҗәсендә радиотехника белән шөгыльләнү. *Безнең илебездә радиоһәвәскәрлек хәрәкәте киң колач җәйде.* Н.Хәбибуллин

РАДИОЧЕЛТӘР *и.* 1) Тапшыра һәм кабул итә торган радиостанцияләр челтәре. *Кыш көне торак радиочелтәре*

аша Йосыфның шигырьләрен үз башкаруында укып тапшырылган кичтә Марс Гани берничә инттәше белән --- Хәбирәне сорап кергәннәр иде. Ф.Яхин. *Безнең 128 фатирлы йорттагы фатирларның 70–80 ендә шәһәр радиочелтәренең ноктасы бар, халык аннан телән файдалана*. Ватаным Татарстан

2) Радиодулкыннарны тарата һәм кабул итә торган тимерчыбыклар системасы

РАДИОЭКОЛО́ГИЯ *и. лат.-гр.* Радиоактив матдәләрнең биосферада күчеп йөрүен һәм тере организмнардагы тупланышын өйрәнә торган экология фәненең бер тармагы

РАДИОЭЛЕКТРО́НИК I *с.* Радиоэлектроника белән бәйле

РАДИОЭЛЕКТРО́НИК II *и.* Радиоэлектроника фәне белән шөгыльләнүче галим яки шуның гамәли өлкәсендә эшләүче белгеч. *Космик ракеталарның төшү төгәллеген тәэмин итү – радиоэлектроникларматематиклар һәм астрономнар эше.* В.Казневский

РАДИОЭЛЕКТРО́НИКА *и. лат.-гр.* Физика һәм техниканың радиоэлемтә белән бәйле күп кенә тармакларының берләштерелгән атамасы. *Химия товарлары, автомобильләр, радиоэлектроника әйберләре күплэп башка илләргә чыгарыла.* Материклар һәм океаннар географиясе. *Мин инде әни телә-ге буенча фортепьяно, гитара, гармунда уйнарга, биергә, радиоэлектроника белән эш итәргә, агачтан уенчыклар ясарга, хәтта чигәргә дә өйрәндем.* Сабантуй. *Биопротезлар – радиоэлектроника җимеше*. Ватаным Татарстан

РАДИОЭЛЕМТӘ *и.* Радио ярдәмендә урнаштырылган элемтә. *Штурман радиокомпасның һәм электромагнитлы башка приборларның сафтан чыгуын, радиоэлемтәнең бозылуын ачыклаган.* Могҗизалар энциклопедиясе. *Радиоэлемтә Максвелл тарафыннан үстерелгән электромагнитик кыр турындагы тәгълиматка нигезләнгән.* Физика курсы

РАДИОЭФИР *и. лат.-гр.* Радиодулкыннар тарала торган һава бушлыгы, пространствосы. *Мөгаллимнәр исә, мәктәп белән генә чикләнмичә, рай-он газетасы, радиоэфир аша да яшь йөрәкләргә юл эзли*. А.Смирнова. *Телевидение һәм радиоэфир аша җавап биргәндә, президент бер тапкыр да кәгазьгә карамады һәм өч мәртәбә блокнотына нидер язып куйды*. Татарстан яшьләре

РАДИ́СТ *и. лат.* Радио аша сигналларга салынган мәгълүмат тапшыручы һәм кабул итүче белгеч. *Миннән радист чыкмас, ахры, ул теге морзянканы --- тоту өчен музыкаль сиземләү кирәк икән.* Т.Нәҗмиев. *Укчы радист стартка чыгарга рөхсәт сорады.* М.Юныс. *Хәрби транспорт самолёты салонындагы гади киемле ике ир кеше, радист кыз һәм үзәк газета хәбәрчесе – барысы да атучыга таба борылдылар.* З.Фәтхетдинов

РАДИ́СТКА *и. рус* Хатын-кыз радист. *Тик ул радистка Кәримәнең кара төндә, япа-ялгыз, самолёттан дошман тылына сикерәчәген, партизан отрядында җитди сынаулар узасын, дошман белән бер бәрелештә батырларча һәлак буласын белми иде.* Р.Хафизова

РАДИ́СТЛЫК *и.* Радист булу, радист вазифасы. *Авиациядә чакта ук мин радистлыкка күчмәкче булып йөри идем бит.* М.Юныс

РА́ДИУС *и. лат.* 1) *мат.* Шарның өслеген яки әйләнәсенең берәр ноктасын аның үзәге белән тоташтырган туры сызык, шул сызыкның озынлыгы. *Җир бөтенләй үк түгәрәк түгел, Җир ул экваторга таба җәелебрәк китә. Шунлыктан Җирнең полюстан сузылган радиусы экватор ноктaларыннан сузылган радиуска караганда егерме бер километрга кыскарак, диләр.* Дөньяда ниләр бар

2) *күч.* Нәрсәнең дә булса таралу киңлеге, тәэсир итү, йогынты ясау өлкәсе. *Шунысын да онытмагыз: изелгән сарымсак парга әйләнгәндә, 20 сантиметрлы радиустагы бактерияләрне үтерергә сәләтле.* Тәмле тамак

РА́ДИУСЛЫ *с.* Билгеле радиуска ия булган. *Ә монда йөз километр радиуслы мәйданнан халыкны бер-ике көндә чыгарып бетерәләр, өй җиһазларыннан һәм хәтта кием-салымнан да берни алырга рөхсәт ителми*. А.Тимергалин

РАДОН *и. лат. хим.* Радий таркалганда барлыкка килә торган төссез инерт газ; радиоактив химик элемент. *Киләчәктә Хуҗа-Оби-Гарма дип йөртелгән радон чишмә-күлләренә барырсың, алар Памирдамы, Варзоб тарлавыгындамы шунда, радикулит, артрит кебек нәрсәләрнең бар икәнен дә онытырсың.* Р.Мирхәйдәров

РАҖА *и. сансk.* Һиндстан феодаль дәүләтендә падишаһ, бәк кебек хөкемдарларның гомуми титулы; шул титулга ия кеше. *Ража титулына ия булу*

РАЗ *и. фар.* Сер, яшертен эш. *Дәгый ни гизле (яшерен) разың булса, кемирсә катында ачмагыл.* С.Сараи

РАЗВЕДГРУ́ППА *и. рус-нем.* Разведкачылар төркеме, разведка группасы. *Разведгруппаларның кинәт һөҗүме, дошманга зур зыян китерү белән бергә, безнең отрядны сугыш кирәкяраклары белән тәэмин итү өчен дә бик әһәмиятле.* С.Таһиров

РАЗВЕ́ДКА *и. рус* 1) Нинди дә булса максат белән билгеле бер урынны тикшерү, өйрәнү, табигый шартларын ачыклау; күзләү. *Ул елларда районда нефть разведкасы эшли иде.* Г.Ахунов. *Разведканың инженер-техник эшчеләре таулардан кайтарылган җиһазларның иң кыйммәтлеләрен түбәнгә, вадига озаталар.* Ә.Айдар. *Геология разведкасында да катнаша алар [этләр] хәзер. Җир астындагы казылма байлыклар исен сизеп алалар һәм хәбәр итәләр.* Кызыклар дөньясында

2) Фронтта дошман турында мәгълүмат туплау максаты белән аның тылында алып барылган яшерен эш яки сугыш хәрәкәте; шул хәрәкәттә катнашучы гаскәри төркем. *Разведка мәгълүматларына караганда, отряд урнашкан төбәктә дошманның көче алты йөз кешедән артмый.* З.Фәтхетдинов

3) Икенче бер дәүләтнең икътисади, сәяси һәм хәрби хәле турында мәгълүмат туплау эшчәнлеге һәм шуның белән шөгыльләнә торган оешма

4) *күч.* Гомумән, вазгыятьне, фикерне, карашларны ачыклау, тикшерү, белешү, сораштыру. *Ә шулай да яфрак хуҗасы турында дөрес чамалыйсың бугай син, аның ерактан разведка*

ясавы гына булуы мөмкин. М.Хуҗин. *Берәү, ишекне аз гына ачып, разведка ясады һәм: «Илсвяр, Тәлгат Саматович монда», – дип дәште.* Т.Нәҗмиев

РАЗВЕ́ДКАЛАУ *ф.* Разведка ясау, разведка белән шөгыльләнү. *Тиктомалга бронемашинадан аталар, самолётлары урманны разведкалый.* С.Таһиров

РАЗВЕ́ДКАЧЫ *и. к.* **разведчик**. *Әле кичә кич кенә шушы тирәләрдә кызылларның разведкачылары йөргәнне үз күзләрем белән күреп кайттым!* В.Нуруллин. *--- малай чактан разведкачы булырга хыялланам.* Ватаным Татарстан

РАЗВЕДРО́ТА *и. рус* Разведчиклар ротасы. *Танкка кадәр разведротада булдым мин.* М.Мәһдиев

РАЗВЕ́ДЧИК *и. рус* **1.** 1) Разведкага җибәрелгән гаскәри; махсус разведка частенең (*2 мәгъ.*) хәрби хезмәткәре. *Берничә минут эчендә разведчиклар кырыклап автомашина, уналты туп һәм башка күп кенә корал кулга төшерделәр.* Г.Әпсәләмов. *Көннәрнең берендә немец ягын капшарга барган безнең разведчиклар битараф мәйданда бер немец лейтенантының үле гәүдәсенә тап булдылар.* Ш.Маннур. *Разведчикларга җавапны бурыч йөкләнде.* З.Фәтхетдинов

2) Разведка (*3 мәгъ.*) агенты, разведка органнарында эшләүче кеше. *Сез – тәҗрибәле разведчик, немец һәм инглиз телләрен беләсез.* И.Хуҗин. *Мәгълүм булганча, ул чагында аның ире Владимир Путин разведчик була*. Безнең гәҗит

3) Разведка (*2 мәгъ.*) самолёты яки корабы

4) Җир асты байлыгын, файдалы казылмаларны эзләүче белгеч. *Аны уңышлы тәмамлагач, су юлы буенча геолог-разведчик итеп Себергә эшкә җибәрелә.* Кызыл таң

5) *күч.* Берәр нәрсәне күрергә, тикшерергә, белергә тырышучы. *Күзәтүләрдән күренгәнчә, шөпшә – разведчик, оя тирәсендә әйләнеп йөреп, үз өенә кайта һәм соңрак «экспедитор» дуслары белән бал кортлары очкан үсемлекләр янына ашыга.* Шәһри Казан

2. *с. мәгъ*. Разведка ясаучы. *Разведчик самолёт ул*. З.Зәйнуллин. *Разведчик кортлар кайсы басуда нинди чәчәк барлыгын белешә һәм калганнарга хәбәр итә.* Шәһри Казан

РАЗВЕ́ДЧИКЛЫК *и.* Разведчик булу, разведчик алып барган эшчәнлек. *Исхакыйның разведчиклык эшчәнлеген раслый торган конкрет материал таба алмаганга булса кирәк, алар әлеге «Шольц» дигән исемгә чытырдап ябышалар.* И.Нуруллин

РАЗВЁРСТКА *и. рус* 1) Нәрсәне дә булса планлы рәвештә бүлү (мәс., эш көчләрен, продукцияне һ.б.); шул турыдагы документ, күрсәтмә, наряд

2) *тар.* Сугыш, икътисад кризисы һ.б.ш. чорда кертелгән авыл хуҗалыгы продуктларын дәүләткә тапшыру, сату системасы. *Беренче, ул – контрреволюционер, кулак ---, авыл кулакларын развёрсткадан саклый, дезертирлар асрап ята, аларда сыйланып йөри.* һ.Такташ

РАЗВОД *и. рус махс.* Постларга тарату алдыннан, сакчыларның постта тора алу әзерлеген тикшереп чыгу, аларга элекке сакчыларны алмаштырырга хокук бирү; сакчыны алмаштыру эше. *Иртән эшкә развод ясаганда, старшина, мыегын бөтереп, строй алдыннан рәхәтләнеп бер уза*. М.Мәһдиев. *Божедомов ротасына нәкъ развод барганда китереп, «тыңларга һәм яратырга» кушып киткәннәр иде ---.* С.Шәрипов

РА́ЗЕР *и. рус махс.* Кыскартылма сүз: рентген лазеры

РАЗМЕР *и. рус сөйл.* Өс-баш, аяк киемнәре үлчәме. *Бу эз аяк киеменең үлчәмен ачыкларга ярдәм итте: 45 нче размер.* З.Фәтхетдинов

РАЗМЕРЛЫ *с.* Билгеле размердагы. *Ачуына буылып, идәннән иренең кырык бишенче размерлы туфлясын электерде.* Ф.Садриев

РАЗМЕ́ТКА *и. рус* Юл хәрәкәтен җайга салу өчен юлга төрлечә төшерелгән сызыклар, билгеләр, тамгалар. *Аның машина йөртү рәвеше генә начар: ул көзгегә карамый, тормозга басып мәшәкатьләнми, юл разметкаларына, тизлекне тыю билгеләренә игътибар итми*. Сабантуй

РАЗНОЧИН *и. рус сөйл.* **1.** *к.* **разночинец**. *Разночиннар исә Арчаның үзәк өлешендә яшәгәннәр.* Гасырлар авазы

2. *с. мәгъ.* Шул катлаудан булган

РАЗНОЧИ́НЕЦ *и. рус* XVIII йөз ахырыннан XIX йөз ахырына кадәр Россиядә рәсми кабул ителгән бер катлауга да (дворян, купец, рухани, мещан һ.б.) теркәлмәгән, бер катлаудан икенчесенә күчү сәбәпле, юридик статусы анык булмаган граждан. *Бу вакытта бигрәк тә руслардагы халыкчылык (народниклык) хәрәкәте, аның идеологиясе, шул идеологияне уздырган әсәрләр (шул исәптән Тургенев иҗаты) йогынтысында татар әдәбиятында да халык арасында аңлату алып барган разночинец образлары тудырыла*. Р.Рахман. *Әмма минем «разночинец» (бу кушаматны миңа А. Гыйләҗев таккан иде) фикерләрен аңгәмәдәшем хупламаган булып чыкты ---.* Ә.Рәшит

РАЗРЯД *и. рус* 1) Квалификация дәрәҗәсе (белгечлектә, спортта һ.б.). *Башта өченче разряд алдым, аннары дүртенче разрядка җиттем.* Р.Миңнуллин. *Менә инде ничә кеше беренче разрядка чыкты, икесе спорт мастеры булды.* Т.Галиуллин. *Хәрби частьларны тулыландыру өчен җибәрелүчеләрнең 6 процентында гына спорт буенча нинди дә булса разряд бар.* Кызыл таң

2) *мат.* Санны язма рәвештә күрсәткәндә цифрның урыны. *--- һөнәрчеләр һәм сәүдә итүчеләр исәпләү өчен баганаларга бүленгән тактадан файдаланганнар, анда вак ташлар ярдәмендә төрле разряд берәмлекләре күрсәтелә торган булган.* Алгебра

3) *иск.* Уртак яклары булган кешеләр төркеме; үзара охшаш әйберләр, күренешләр төркеме

РАЗРЯ́ДКА *и. рус тип.* Хәрефләрне сирәкләтеп, киңрәк ара калдырып җыю тәртибе

РАЗРЯДЛЫ *с.* Разряды булган, разрядка ия. *Ул үзе бишенче разрядлы слесарь иде.* А.Алиш. *Икенче берәү, Кремльгә керер алдыннан, беренче разрядлы боксёрдан ияген күчерттергән.* М.Галиев. *Гомерендә бер генә сәгать тә тик утыруны белмәгән бишенче разрядлы арматурчы, эшсезлектән җәнин кая куярга белмичә, җитәкчеләр янына керә.* Л.Ихсанова

РАЗЪЕЗД *и. рус* 1) *иск.* Төп көчләрдән алда җибәрелә торган зур

булмаган атлы разведка, сакчылар подразделениесе

2) Тимер юлда: бер юллы линиядә каршы килгән поездны үткәреп җибәрү өчен икенче юл; шундый юлы булган пункт. *Ул разъезднының вокзал йорты утызынчы елларда ук салынган.* М.Мәһдиев. *Поезд исә вак-төяк разъездларны бар дип тә белми алга йөгерде дә йөгерде.* Т.Әйди. *Кеше кулы тимәгән катнаш урманнар аркылы уза торган тимер юлның Иштуган разъездында иң беренче итеп станция будкасы төзелә.* Т.Нәҗмиев

РАЗЫЙ *хәб. сүз гар. кит. к.* **риза**. *Безнең максудымыз, я Рәсүлаллаһи, синең мәхәббәтең торыр, дөнья малы түгел, нә кем кылсаң, без разыйбыз.* Мәхмүд әл-Болгари. *Бу кадәр җәбер күргәнче, үләргә дә разыймын.* Г.Коләхмәтов. *Буш кул белән өйгә кайтып китүгә аның күңеле разый түгел.* С.Җәлал

РАЗЫЙЛА́У *ф. кит. к.* **ризалату**

РАЗЫЙЛЫК *и. кит. к.* **ризалык**. *Баштарак разыйлык күрсәтеп йөрсә дә, газет чыгар алдыннан, башка эшкә керешкәнне мәгълүм итеп, газетта даими булышучылардан аерыла.* Г.Тукай

РАЗЫЙСЫЗЛЫК *и. кит. к.* **ризасызлык**. *Аннан соң язган «Соранучылар» (1903) һәм «Тәмуг» (1908) атлы романнары да шундый ук разыйсызлык, күңелсезлек һәм пессимизм белән сугарылган иделәр*. М.Җәлил

РАЙ *и. фар. диал.* Җай, тәртип, рәт

◊ **Рае килү** Җае, кәефе килү. *Раем килмәсә, ник муеныма бау такмыйсың.* **Рай белән** Җае белән, тәртибе белән, рәте белән. *Рай белән генә алып бирү.* **Рай чигү** Рәхәт чигү, рәхәтләнү

РАЙ- *фр.* Кушма сүзләрдә «район» мәгънәсен белдергән беренче кисәк (мәс., *райбашкарма, райком, райүзәк*). *Аннары, кабат райздравка барган идем, үзебезнең авылда пункт ачарга куштылар.* Р.Кәрами

РАЙБАШКАРМА *и.* «Район башкарма комитеты» сүзтезмәсенең кыскартылмасы. *Борһанов, райбашкарма председателе булганда, күп эшне үзенә алды, монысы – аның эше, дип вакланып тормады.* Г.Ахунов. *Әтисе озак еллар райбашкарма комитеты рәисе булып эшләгән.* Т.Нәҗмиев

РА́ЙДЕР *и. ингл.* Велосипедта йөрүнең спорт стильләре белән шөгыльләнүче кеше. *Райдер үзенең трюкларын шушы махсус бөгелгән конструкциядә күрсәтә дә инде*. Шәһри Казан

РАЙКОМ *и. рус* «Район комитеты» сүзтезмәсеннән кыскартылган: Советлар Союзы Коммунистлар партиясенең район комитеты. *Райбашкарма, райком белән киңәшеп, алар куйган эш бәяләрен кабул итте.* Г.Ахунов. *Прокурор да дус кеше – икебез дә райком члены.* М.Мәһдиев. *Шул уңай белән райкомда, район Советы башкарма комитетында берничә көн рәттән киңәшмәләр үздырылды.* М.Хәсәнов

РАЙОН *и. фр.* 1) Республика, өлкә яки зур шәһәр эчендәге административ-территориаль берәмлек. *[Дускаев] – күрше районнарның берсендә туып үскән егет.* Ә.Еники. *Министрлыкта эшләнгән чаралар нәтиҗәсендә республиканың байтак районнарында күпьеллык үләннәр терлек азыгы мәйданнарының 70–80 процентында үстерелә башлады.* Шәһри Казан

2) Шул берәмлек чикләрендәге территория. *Гер күтәрү буенча авылда да, районда да беренчелекне бирми [ул].* Н.Хәсәнов

3) *сөйл. к.* **райүзәк**. *Мәршидә апаны районга алып киттеләр.* Н.Гыйматдинова. *Иң кирәкле чакта, кибеттә әйбере булмый. Районга барырга туры килде.* Ф.Яруллин

4) География, икътисади һ.б.ш. билгеләр, үзенчәлекләр белән аерылып торган мөстәкыйль төбәк, як. *Мин [хәрби хезмәткәр Баранов] үзебезнең өлкәнең (Камчатканың) төньяк районнарының берсендә булдым.* Могҗизалар энциклопедиясе. *Туфраклардагы су режимы процессларына үләннәрнең тәэсир итүләренең монда санап үтелгән үзенчәлекләре корылыклы районнарда зур роль уйный.* Күпьеллык үләннәр

5) Нәрсәгә дә булса якын торган, берәр нәрсә тирәсендәге урын. *Маршалл утраулары районында куәтле тропик циклон яралуы беленгән. Ярты сәгатьтән әлеге районга метеосамолёт-бомбардировщиклар оча.* Могҗизалар энциклопедиясе

6) *сөйл.* Райүзәктә урнашкан идарә оешмасы, җитәкчелек. *Күн тужурка кигән район агенты, күркәдәй түшләрен киергән дә, бернигә игътибар итмәстән, үзен ил хуҗасыдай тоеп, ишегалдында басып тора...* Н.Хәсәнов

РАЙО́НАРА *с.* 1) Районнар арасында урнашкан. *Районара юллар*

2) Берничә район өчен уртак булган. *Ул көндезге ашка кайтмады, комбайнарга запчасть эзләп, районара базага баргач, тимер юл станциясе ашханәсендә сыек шулпа һәм ботка белән тамак ялгаган иде.* М.Хуҗин

РАЙОНДАШ *и.* Бер-берсенә карата: бер үк районда туган яки яшәгән кешеләр. *Кассиры да, диспетчеры да үзебезнең кеше. Берсе хәтта минем райондаш, Чирмешәннеке.* К.Тимбикова. *Хөрмәтле Фоат дус, райондаш, замандаш, мин сине шәхсән бик хөрмәт итәм*. Ватаным Татарстан

РАЙОНЛАШТЫРУ *ф.* 1) Зур бер территорияне аерым-аерым районнарга бүлү. *Яңа административ бүленеш – районлаштыру мәсьәләсе тугач, 1930 елның 12 сентябрендә үткән район партия оешмасының беренче конференциясендә бу мәсьәлә карала ---.* Татар энциклопедиясе

2) Билгеле бер районга хас үзенчәлекләргә яраклаштыру, шул районга туры килгән табигый шартларга җайлаштыру. *Авыл хуҗалыгы культураларының күп кенә яңа сортларын районлаштырып, республика колхоз-совхозларын элита сортлы чәчүлек орлык белән тәэмин итеп, гаять нәтиҗәле эш башкара*. Г.Мөхәммәтшин. *Дәүләт сынаулары мәгълүматларына караганда, республикада районлаштырылган эре ак токым дуңгызларының симерү сыйфатлары шактый югары.* Татарстанда терлекчелек

Районлаштырып бетерү Тулысынча яки барысын да районлаштыру

Районлаштырып килү Акрынлап районлаштыру

РАЙОНЛАШТЫРЫЛУ *ф. төш. к.* **районлаштыру** *Уңайлы булмаган, түбәнлекле участокларга урнашкан*

бакчаларда хәтта районлаштырылган күп кенә сортлар да кышка җитәрлек кадәр чыдам булмыйлар. Бакчачы белешмәсе

РАЙОНЛАШУ *ф.* 1) Районнарга бүленү, район булып оешу

2) Билгеле бер райондагы шартларга яраклашу, шул урынга җайлашу. *Мөсәлим Сабиров җыелышка безнең басуларда районлашкан «Татьяна» сортлы арышны алып килгән, ул яшел, сусыл һәм бик матур үсә.* Идел таңнары

Районлаша бару Акрынлап, азазлап районлашу

Районлашып бетү Тәмам, тулысынча районлашу

Районлашып китү Билгеле бер моменттан соң, ниндидер шартлар нигезендә районлашу

РАЙПО *и. рус сөйл.* Район кулланучылар җәмгыяте: «районное потребительское общество» сүзтезмәсенең кыскартылмасы. *Шактый җирдә райпо системасына кергән кибетләрне кыстылар, аннан бөтенләй ябып та куйдылар.* Татарстан яшьләре. *Райпо кибетен яптылар, хәзер авыл советы рәисенең малае исемендәге кибет кенә эшли.* Кызыл таң

РАЙПОТРЕБСОЮЗ *и. рус к.* **райпо**. *Мин бит райпотребсоюзда эшлим.* Ф.Яруллин. *Аның үзенә дә еш кына райпотребсоюз рәисе Сәлим Хәсәновичка баш ияргә туры килә: Ташкенттагы киленнәре җанга тия, әле велюр пәлтә, әле кайры тун, я булмаса твид костюм кирәк, имеш.* Р.Мирхәйдәров

РАЙСОБЕС *и. рус сөйл.* Район социаль тәэминат бүлеге: «районное социальное обеспечение» сүзтезмәсенең кыскартылмасы. *Интернат директорларына боерыклар бирү, райсобеслар белән элемтәгә керү, Министрлар Советына кереп, аерым мәсьәләләрне хәл итү, Мәскәү белән сөйләшеп алулар – барысы да аңа йөкләнә, һәм ул аларны авырсынмыйча башкарып килә.* Г.Ахунов. *Җәмгыятебезнең пошмаслыгын тарихи сәбәпләргә дә бәйләргә була: СССР вакытында безнең өчен бөтен нәрсәне профсоюз, райсобес, партком, обком, ЦК һ.б. уйлый, хәл итә, көйли иде.* Ватаным Татарстан

РАЙСОВЕТ *и. рус* Район советы: «районный совет народных депутатов» сүзтезмәсенең кыскартылмасы; совет чорында сайлап куелган вәкилләрдән торган, район күләмендәге дәүләт хакимияте органы. *Хәзер теге вакытта Дидаровның райсовет депутаты Җәгъфәр Мәүлиханов яныма ни өчен килүе аңлашыла.* Г.Әпсәләмов. *Сугыш башланганда, мин – Зиннур – Львов каласында райсовет рәисе идем.* З.Зәйнуллин

РАЙҮЗӘК *и.* «Район үзәге» сүзтезмәсенең кыскартылмасы. *Җитмәсә, су буе булудан файдаланып, колхоз зур каз-үрдәк фермасы ачып җибәргән, хатын-кызларның күбесе шунда чуала, ир-ат теге ярдагы райүзәк белән бу як арасында Агыйдел аркылы паром йөртә ---.* Ф.Хәсни. *Тимерхан, Миңлеасиясен култыклап, райүзәкнең культура йортына танцы көйләре уйнарга йөри.* Г.Ахунов

РАЙФО *и. рус* Район финанс бүлеге: «районный финансовый отдел» сүзтезмәсенең кыскартылмасы. *Әмма райфо дигән җиргә ниндидер таблица кебек язма әзерләргә кирәк.* Ә.Баян

РАК *и. рус* 1) *мед.* Кеше яки хайваннарның эчке һәм тышкы әгъзаларында була торган яман шеш (грек теленнән калька); үтмәс чир. *Япония галимнәре исә, чәй белән нурланыш һәм рак авыруларыннан да дәваланып була, дип баралар.* Кызыклар дөньясында. *Гистология нәтиҗәсе әйләнеп килә: рак.* С.Сөләйманова. *Бүгенге бәндәләрнең котын алган рак, инфаркт, паралич кебек чирләр дә, радиация көчләре дә киләчәктә ачылачак гап-гади генә бер чара алдында артка чигенәчәк.* Казан утлары

2) Үсемлекләрнең сабакларында, тамырларында һәм агач кәүсәсендә бүлтәеп торган авыру үсенте; оры

РАКЕ́ТА *и. нем.* 1) Реактив двигательле очу аппараты. *Йөртүче ракетаның сыекчалы алты ракета двигателе --- очышта, тулаем алганда, 20 миллион ат көченә кадәр файдалы егәрлек бирә.* А.Романов. *Астероидларның кайберләре тоташтан диярлек тимердән һәм бүтән металлардан тора. Мондыйларны ракеталар ярдәмендә Җир тирәсенә алып кайту, шунда эшкәртү проектлары да бар.* Кызыклар дөньясында

2) Фейерверклар һәм сигналлар бирү өчен, һавада төрле төсләргә кереп яна торган снаряд. *Бары вакыт-вакыт, төнге караңгылык чаршавын ертып, ак ракеталар гына күккә күтәрелде.* Г.Әпсәләмов. *Немецлар, ракета күренүгә, тревога күтәрәләр, партизаннарны әзерләнеп каршы алалар.* З.Фәтхетдинов. *Төнлә ракеталар җибәреп, болан көтүенә якынлашкан ерткычларны куркытыр өчен, тундрадагы көтүчеләргә ракета җибәрә торган пистолетлар биргәннәр.* Кызыклар дөньясында

3) *хәрби* Еракта урнашкан цельләрне юк итү өчен билгеләнгән, реактив принципта хәрәкәт иткән сугыш снаряды. *Сәяси экспертлар фикеренчә, эш белән түләүне аңлатучы әлеге шартлар рәтендә Беларусь территориясендә «Искәндәр» ракеталарын урнаштыру, ике илне берләштерүдә яңа адымнар ясау һәм Абхазия белән Көньяк Осетиянең бәйсезлеген тану кебек сәяси адымнар торырга мөмкин.* Мәдәни җомга

4) Тизйөрешле елга пассажир судноларының сөйләмдәге атамасы. *Кайтканда Кама буйлап ракетада кайтырга мөмкин.* Г.Әпсәләмов

РАКЕ́ТАЙӨРТКЕЧ *и. техн.* Ракеталар ташыган яки ракеталар белән коралланган очкыч, кораб яки су асты көймәсе. *Яңа гына төзелгән су асты ракетайөрткече хәрби флотка тапшырылды*

РАКЕ́ТАЛЫ *с.* Ракета (*2, 3 мәгъ.*) җибәрү җайланмасы булган, ракета белән коралланган. *Зенитчыларның яки ракеталы җайланмаларның утыннан котылыр өчен, самолётлар я бик биеккә – стратосферага чаклы күтәрелергә тиеш булалар яки җиргә елышып ук очалар.* Казан утлары

РАКЕ́ТАЧЫ *и.* 1) Ракета чөеп сигнал бирүче кеше

2) *хәрби* Ракета гаскәрендә хезмәт итүче хәрби хезмәткәр. *Шунысы игътибарга лаек, малайларның бишесе дә хәрбиләр юлын сайлый: бишесе дә ракетачы!* Ватаным Татарстан. *Хәтта*

армиядә дә югалып калмадылар: Ләбиб – сержант, Минсур – ракетачы, Илсур – танкист, Мансур – элемтәче, Илдархан – укчы полкта рядовой. Шәһри Казан

РАКЕ́ТКА *и. фр. спорт* Теннис уенында: теннис тубын каршы якка бәреп очыру өчен, каты челтәрле махсус калак; теннис калагы. *Мин дә, теннис ракеткасы тотып «дошман» каршысына бассам, үземне кулыма кылыч алып атакага барган кеше итеп сизә башлыйм.* М.Юныс. *Ракетка һәм туплардан файдалану да бушка, үзең сатып ала башласаң, бер ракетканың бәясе 1200 сумнан башлана.* Шәһри Казан

РАКЕ́ТНИЦА *и. рус* Ракета (*2 мәгъ.*) ату җайланмасы, пистолеты. *Бомбалар нәкъ база өстенә ява башлагач, ракетницам барлыгы исемә төште...* З.Фәтхетдинов. *Алга таба тикшерү эшләре вакытында аның өеннән дә винтовка, ракетница, пистолет һәм патроннар табыла.* Татарстан яшьләре

РАКЕ́ТО- *нем.* Кушма сүзләрдә «ракета» мәгънәсен белдергән беренче кисәк (мәс., *ракетодинамика, ракетодром, ракетомоделизм*)

РАКЕТОДИНА́МИКА *и. нем.-гр.* Ракеталар хәрәкәтен өйрәнә торган фән. *Ракетодинамикада ракета тизлегенең тотылган ягулык микъдарына һәм газларның реактив двигательдән агып чыгуының чагыштырма тизлегенә ничек бәйле икәнен күрсәткән мөһим формула бар.* В.Казневский. *Ф.А.Цандер һәм Ю.В.Кондратюк реактив двигательләр теориясенә кагылышлы һәм ракетодинамика буенча бик күп мөһим мәсьәләләрне тикшерәләр.* Фән һәм тел

РАКЕТОДРОМ *и. нем.-гр.* Ракеталар (*1 мәгъ.*) җибәрү һәм сынау өчен, махсус җиһазландырылган комплекс; шул комплекс урнашкан мәйдан

РА́КОВИНА *и. рус* Су краны астына кулланылган су агып төшәр өчен куелган бүрәнкәсыман җайланма. *Сезнең ванна бүлмәсендә раковина, смеситель бар, шуның раковинасын – бер завод, смесителен – икенче завод, раковина астындагы кәкре-бөкре трубаларны өченче завод эшли, дүртенче оешма шуны монтажлый.* М.Мәһдиев

РА́КУРС *и. фр.* 1) Предметны сурәтләгәндә, перспективада аның арткы пландагы өлешләрен кечерәйтеп бирү. *Фотографмы син, юкмы?! Ракурс!* Э.Ибраһимова. *Дөрес ракурс сайласаң, кнопкага гына басу авыр хезмәт соламый, диләр.* Шәһри Казан

2) *махс.* Төшерелгән предметның өлешләрен объективтан төрлечә алу, аның предметка почмак ясап юнәлтелүе нәтиҗәсендә туган гадәти булмаган перспектива. *Ракурс белән фотога оригинальлек бирергә була, яңа әйберләрне күрсәтеп була, ракурс белән фотога салынган фикерне үзгәртеп була.* Күрше

3) Нәрсәнең дә булса билгеле бер ягы, билгеле яктан алынган күренеше. *Шуңа күрә мондый язмалар бүген икенче ракурста ачылырга тиеш.* Ватаным Татарстан. *Бүген мине белмиләр, дип әйтә алмыйм, әмма кичә-бүген генә сәхнәгә чыккан яңа ракурс, яңа образдагы Илназар – ул бөтенләй башка иҗатчы.* Шәһри Казан

РА́ЛЛИ *и. ингл. спорт* Махсус спорт автомобильләрендә, мотоциклларда билгеле бер маршрут буенча куелган таләпләрне саклап йөрү осталыгын ачыклау өчен уздырыла торган ярыш; автоярыш. *--- ралли башланганда юлга 217 мотоцикл чыккан һәм финишка шуның 113 е генә килеп җиткән.* Ватаным Татарстан. *Менә бу юлы да Владимир Чагин җитәкчелегендәге «КамАЗ-Мастер» экипажы үз тарихында алтынчы тапкыр легендар «Дакар» ралли ярышларын беренче урында тәмамлады.* Кәеф ничек?

РА́ЛЛИЧЫ *и. спорт* Раллида, автоярышта катнашучы

РАМ *и. нем.* 1) Нәрсәнең дә булса кырыйларын беркетеп тотып тору яки матурлау өчен ясалган кыса. *Иске рамнарны балавыздан чистартасы, тимерчыбыкларын тарттырасы бар.* Н.Хәсәнов. *Боларның берсен дә онытмаска, стендларның, рамнарның, тагын башка кирәк-яракларның үлчәүләрен язып алырга кирәк иде.* Г.Ахунов. *Ул рәсемнәр! Аларның иң яхшыларын сайлап, үзләре үк ясаган матур рамнар эченә куеп, стенага элгәннәр.* Г.Әпсәләмов

2) Пыялалар куелган тәрәзә кысасы. *Тәрәзәдән кемдер ике кулын рам читенә терәп карап тора иде.* Д.Бүләков. *--- ир кеше, такталарга матур сырлар, бизәкләр уеп, рам ясый.* Гәр.Рәхим

3) *тех.* Машиналар, механизмнар, техник корылмалар һ.б.ш.ның нигез өлеше, станы. *Тимерчелектән табып алып кайткан велосипед рамының көпшәсен бер башын янечтем дә агачка беркеттем, ут кабызыр өчен, игәү белән өстән ярык ясадым – үзенә күрә бер мылтык булды.* М.Мәһдиев

РА́МА *и. нем. сөйл. к.* **рам**. *Тышкы яктан, агачмы, тимер әйбер беләнме, пыялалары коелып төшәрдәй итеп, тәрәзә рамасын төя башладылар. Бу көтелмәгән хәлдән Гази да каушап төште.* М.Хәсәнов. *Мин сиңа Газ-63 нең рамасын бирә алам.* М.Мәһдиев

РАМАЗАН *и. гар.* Мөселманнарда: ай календаренда тугызынчы ай, ураза тоту ае. *Рамазан ае бетеп бара.* Ш.Камал. *Ул [Иске бистә зиратындагы] тәкыядә [мавзолей] һиҗри 1058, милади 1648 елның 9 рамазанында вафат булган Әфган Мөхәммәд солтан Гарәб Мөхәммәд хан улы күмелгән.* М.Әхмәтҗанов. *--- бу ел рамазан шәрифтә пәнҗешәмбе көн зәвал вакытында мәгъриб тарафындин бер койрыклы йолдыз пәйда булды.* М.Госманов

◊ **Рамазан агай килде** Рамазан ае, ураза керде дип, җанландырып әйтү

РА́МКА *и. рус* 1) *к.* **рам (***1 мәгъ.***)**. *Тик Җиһангир генә алгарак сузылды, шунда, стенага, агач рамкалар белән пыялалап асылган мәдрәсәнең уставы-програмы янына ук килде ---.* Г.Ибраһимов

2) Текстны, рәсемне әйләндереп алган график кыса. *Район гәзитендә аның рәсемен, кара рамкалар эченә алып, беренче биткә бастылар.* М.Мәһдиев

3) *күч.* Шартлы чик, шартлы кагыйдә, кыса. *Анда вәзен рамкалары бер дә юк.* Г.Тукай. *Нәрсә, әллә тере капиталист белән сөйләшеп утырасы килмиме безнең бер әдәп-әхлак рамкалары эчендә генә?* М.Мәһдиев

◊ **Рамкага сыймау** Үтәлүе мәҗбүри кагыйдәләр белән санлашмау, билгеләнгән кагыйдәләргә туры килмәү. *Торак-коммуналь хезмәтләр өчен*

түләмәүчеләргә карата ниндидер чаралар күрү кирәктер анысы, тик менә алар белән берәттән тиешле акчаны вакытында түләп баручыларны да кайнар сусыз һәм җылысыз утырырга мәҗбүр итү бернинди рамкага да сыймый. Татарстан яшьләре. **Рамкадан чыгу** Ижтимагый яшәеш кагыйдәләрен, әхлак-мораль нормаларын үтәмәү, аларны сакламау, тәртип бозу. *Аның [Әсфанның], рәсми корылык рамкасыннан чыкмыйча, дөресрәге, чыга алмыйча, авыз эченнән ботка пешерү белән калуы --- Гөлчирәне актык чигенә җиткезеп ярсытты.* Ф.Хөсни

РА́МКАЛАУ *ф.* 1) Рамка эченә урнаштыру, рамага кую

2) Текстның яки рәсемнең әйләнә-тирәсен рамка белән әйләндерү, рамка ясап чыгу. *Азмы тапкыр таланды бу җаным, Азмы минем гомерем киселде, Азмы тапкыр үлем каралары Рамкалады минем исемне.* Х.Туфан

Рамкалап алу Рамкалы итү; бөтен тирә-ягын әйләндереп рамка ясау

Рамкалап бетерү Тулысынча рамкалау

Рамкалап кую Рамкаланган хәлгә китереп калдыру

РА́МКАЛЫ *с.* 1) Рамкага куелган, рамкасы булган

2) *күч.* Чикләнгән, аерым таләп, кысаларга буйсындырылган. *Ул үзе дә ирек, киң тормыш күрергә бөтен вөҗүде белән омтыла, аңар тар рамкалы гади тормыш зиндан кебек тоела, аңар мәйдан кирәк, һава кирәк.* Г.Тукай

РАМЛА́У *ф.* 1) *к.* **рамкалау**

2) *махс.* Рам кую, тәрәзәләү. *Дөрес, рамлап, пыялалап кую бер яктан файда булды, чөнки сүнмәгән тәмәке төпчекләре балконнарга азрак эләгә.* Безнең гәҗит

Рамлап кую Рамлаган хәлгә китерү. *– Бар юанычыбыз – менә шушы фотолары, – ди Ютазы районы Әбсәләм авылында яшәүче Фәһирә апа Шәрәфетдинова, шкаф өстендәге рамлап куелган сурәтләргә ишарәләп.* Ватаным Татарстан

РАМЛЫ *с.* 1) Рамланган, рамга (*1 мәгъ.*) куелган. *Тик түр стенадагы калын рамлы, буяулары тоныкланып, кайбер урыннары кубып та беткән бер картина гына булмәнең ямен бераз җибәреп тора иде.* Кызыл таң

2) Рам (*3 мәгъ.*) өстенә куелган

РАМЛЫК *с.* **1.** Рам өчен билгеләнгән, рамга яраклы, шуңа җитәрлек. *Имеш, пыяла да, рамлык агачы да калмаган.* Яңарыш. *Уңнан яки сулдан берәр рамлык урынны буш калдырырга мөмкин.* Безнең гәҗит

2. *и. мәгъ.* Рамга яраклы, рамга җитәрлек материал

РА́МПА *и. фр. театр* 1) Сәхнәне яктырту өчен, сәхнә алдына тезелгән лампаларны каплап торган тәбәнәк барьер. *Нуриев, аларның арасына кереп, икесен дә рампа янына алып чыкты да, үзе бераз артка чикте, халык тәрбиячеләрне алкышлый башлады.* Р.Батулла

2) Шул барьер артына урнаштырылган һәм сәхнәнең алгы ягын түбәннән яктырта торган аппаратура

3) *күч.* Сәхнә. *Рампа утлары*

РАМЧЫ *и.* Рам ясау, рам кую остасы, шул эш белән шөгыльләнүче кеше. *Рамчы булып эшкә урнашу*

РАНГ *и. нем.* 1) Дипломатия, хәрби хезмәт, дәүләт эше кебек өлкәләрдә чин, дәрәҗә, махсус исем. *Строй каршына баскан беренче ранг капитаны ак кулъяулыгы белән битен каплаган да калын җилкәләрен селкетеп елый.* М.Мәһдиев. *Алты тулып килгәндә, беренче ранг капитаны, кара дерматин белән тышланган ишекне ачып, кабинетына узды.* М.Юныс

2) *махс.* Сугыш судноларының категориясе, разряды

3) Биологик систематикада: тереклек организмнарның иерархияле системасында билгеле дәрәҗә (*мәс.*, класс, отряд, семьялык)

4) *сөйл.* Статус, дәрәҗә, даирә. *Эшендә артык күзгә ташланмый, шулай да аның белән күрешергә трест мөдире иң беренче йөгереп үзе килә, кечерәк рангтагы нәчәлникләрне әйтәсе дә юк.* Р.Мирхәйдәров

РА́НГЛЫ *с.* 1) Билгеле дәрәҗәгә ия булган. *Капитан каютасында завод директоры, Римнан килгән консул, сәүдә вәкиле, Венеция каласының мэры, тагын әллә нинди югары ранглы кунаклар.* М.Юныс. *Галияне икенче ранглы капитанның тонык шәүләсе каплап тора иде.* А.Тимергалин

2) Югары дәрәҗәле. *«Тройка» рәисе – ранглы юрист Ульрих.* З.Зәйнуллин

РАНГО́УТ *и. голл. махс.* Судноларда: җилкәннәрне күтәрү, киерү, тотып тору һәм төшерү, сигнал флаглары күтәрү, йөк урнаштыру җайланмалары һәм корылмалары җыелмасы. *Көлтә йөген бастырык белән басканда, нибары бер-ике төен белгән малайлардан унөч төрле диңгез төенен бәйләп күрсәтү, шлюпкалар, җилкәннәр, такелаж, рангоут, шпангоутлар кебек баш бетәрлек нәрсәләр турында гыйлем таләп ителә иде.* М.Мәһдиев

РАНДЕВУ *и. фр.* 1) Гашыйкларның алдан сүз куешып очрашуы

2) *хәрби* Диңгезләрдә, океаннарда кораблъләрнең яки аларның берләшмәләренең алдан килешенгән урында, вакытта, шартларда очрашуы

3) Шундый очрашу урыны

РАНЕТ *и. фр.* Салкынга чыдам, вак җимешле алма сорты. *Әбиебез кичәгенәк, теге алдан өлгерә торган ранет алмаларын каргалар, чыпчыклар быел да ашап бетерер инде, дип зарланды-мы?* Мәдәни җомга

РАНЕ́ТКА *и. рус к.* **ранет**

РА́НЕЦ *и. нем.* Җилкәгә асып йөртелә торган рюкзак рәвешендәге сумка, букча. *Аркасындагы әсбаплар букчасын, дәү әтисе әйтүенчә, --- «рюкзак», «ранец» дип тә атыйлар икән.* А.Хәлим

РА́НЕЦЛЫ *с.* 1) Ранецы булган

2) Ранецка охшаган, ранец формасында эшләнгән. *Кечкенәрәк участоклар өчен, ОРП маркалы, цилиндрик резервуарлы, ранецлы пневматик бөркегеч бик уңайлы.* Яшелчәчелек

РАНЖИР *и. нем. иск.* 1) Буйга карап сафка тезелү тәртибе

2) *күч.* Нәрсәдә дә булса билгеле бер тәртипнең булуы, билгеле бер тәртипнең сакланышы

РАНТ *и. нем.* Аяк киемендә: өске өлешне, тышкы яктан тегеп, олтан белән тоташтырган тар күн кайма

РАНТЛА́У *ф.* Рант куеп тегү

РАНТЛЫ *с.* Рант белән тегелгән (аяк киеме)

РАНТЬЕ *и. фр. икът.* Рента, ягъни кыйммәтле кәгазьләргә, облигацияләргә салынган капиталдан килә торган процентлар исәбенә яшәүче кеше

РА́НЧО *и. исп.* Латин Америкасында: утар, җир биләмәсе; АКШның көнбатышында: терлек тоту фермасы. *Бер сәүдәгәр атлар үрчетергә ранчо сатып ала*. Шәһри Казан

РАПА *и. рус махс.* Тозлы күлләрдә һәм диңгез култыкларында тоз белән туенган, сәнәгатьтә һәм медицинада кулланыла торган су

РАПИДИ́СТИЯЛӘР *и. күпл. лат. махс.* Судан коры җиргә күчкән җир-су хайваннарының борынгы бабасы дип фаразланган чукканатлы балыклар отряды. *Рапидистияләр коры җиргә тизрәк һәм яхшырак җайлашалар, шулай итеп, тереклек тагын бер баскычка күтәрелә. Рапидистияләр үзләре озак яшәмиләр, тиз арада үлеп бетәләр.* В.Сабунаев

РАПИ́РА *и. фр.* 1) Чәнчү өчен кулланыла торган, шпагадан җиңелрәк, дүрткырлы озын, сыгылмалы салкын корал

2) *спорт* Шул коралга охшаш, фехтованиедә кулланыла торган, очында чәнчү моментын күрсәтү өчен сигнал җайланмасы булган спорт коралы. *Башкортстанда яшәүче танылган татар спортчысы, рапира остасы Руслан Нәсибуллин чираттагы зур җиңүгә иреште.* Кызыл таң

РАПИ́РАЧЫ *и. спорт* Фехтованиедә рапира кулланып ярышучы спортчы. *Менә үткән атна ахырында да Казанга илнең төрле почмакларыннан штангачы егетләр, нәфис гимнастика осталары һәм рапирачы кызлар җыелды.* Татарстан яшьләре

РА́ПОРТ *и. фр.* 1) Хәрбиләрнең начальникка биргән рәсми доклады. *Инспектор рапортын өстәлгә куйды.* З.Фәтхетдинов. *Дежур сержант, ике отделениене дә сафка тезеп, янгын сүндерү командасы начальнигына рапорт бирде.* Р.Кәрами. *Минем күзәтү пунктыма килеп, гаубица батареясының разведка отделениесе командиры --- полк командиры исеменә рапорт язарга булышуымны үтенде...* Казан утлары

2) Нинди дә булса эш-хәлнең торышы турында телдән яки язмача югары инстанциягә бирелгән кыскача рәсми мәгълүмат. *Мин килүгә, Дәүләтшин рәсми рапорт бирде.* И.Гази. *Диңгез инспекциясенә рапорт язып илтсәм, пароходны диңгезгә чыгармаячаклар.* М.Юныс. *Мөслимдә икенче секретарь чагында бер елда өч еллык ит тапшыру планын үтәү хакындагы рапортка үзе кул куйган иде.* Г.Ахунов

РАПС *и. нем. бот.* Әвернәчәчәкләләр семьялыгыннан элпәле кузаклы, майлы орлыклы, терлек азыгы буларак кулланыла торган баллы үлән үсемлек һәм аның орлыгы. *Борчакны, рапсны җилләтеп, чистартып, амбарга салып куйганнар.* Г.Ахунов. *Югары җилемсәле бодай булса, тәүлегенә 30 тонна тарта торган ак тегермәнен худка җибәреп, бер-бер артлы карабодай, солы, арпа, бодай, борчак, тары ярмалары ясала башлый, рапс цехы төзелә.* Т.Нәҗмиев. *«Агрохим» җәмгыяте киләчәктә тагын да киңәюне һәм рапс мае сыгуны максат итеп куйган*. Кызыл таң

РАПСОД *и. гр.* Борынгы Грециядә: халык җырларын башкаручы илгизәр җырчы, нәфис сүз остасы

РАПСО́ДИЯ *и. гр.* Ирекле, импровизацияле стильдә, башлыча халык көйләре темасына язылган инструменталь яки вокаль-инструменталь музыка әсәре. *Популяр рапсодияләр, сюиталар, бик җылы яңгырашлы симфонияләр авторы, нечкә күңелле шәхес бу кайгыны ничек күтәрсен?* А.Хәсәнов. *Композитор Ренат Еникеев иҗатында бу кичерешләр җырлар, инструменталь әсәрләр, виолончель һәм фортепиано өчен пьесалар, рапсодия һәм сонаталарда чагылыш таба.* Шәһри Казан. *«Керәшен моңнары» рапсодиясен язып, ул [Алмаз Монасыйпов] керәшен татарларының гаять бай традицион культурасы мөмкинлекләрен ачты.* Мәдәни җомга

РАРИТЕТ *и. нем. кит.* **1.** Үтә сирәк очрый торган, гадәттә югары тарихи һәм сәнгатьчә кыйммәткә ия әйбер. *Кайбер гаилә ядкәрләрен санап үтәм, араларында чын раритетлар да бар.* Гасырлар авазы. *Мондый раритетлар музейда гына була*

2. *с. мәгъ.* Үтә сирәк һәм үтә кыйммәт. *Казанның тарихы белән кызыксынучыларга раритет открыткаларны шул ук ракурстан төшерелгән яңа фотосурәтләр белән чагыштыру мөмкинлеге бар.* Шәһри Казан. *Мирный авылындагы бакчаларына еш кына кайтып йөрүче әлеге кешенең раритет автомобиленә күптән кызыккан Андрей, ниһаять, аны 2005 елда 15 мең сумга сатарга күндерә.* Кызыл таң

РАС *с. фар. сөйл.* **1.** Чын, хак, дөрес, чынбарлыкка туры килгән. *Ялганчының рас сүзе дә зая китәр.* Мәкаль. *Рас сүзнең дә урыны бар*. Мәкаль

2. *рәв. мәгъ.* Дөрес, төгәл, анык, урынлы. *«Күктә һәркемнең үз йолдызы бар» дигәннәре рас булып чыкты.* Н.Хәсәнов

3. *хәб. сүз* Дөрес, чын; шиксез. *Юл дигән идең, рас икән.* Н.Гыйматдинова. *Аларның [милләтләрнең] динен кысып, күнегелгән милли тормышын ватып-җимереп, фажига арты фажига китерүе рас.* Т.Әйди

◊ **Рас әгәр** Антның бер төре: дөрестән дә, һич алдаусыз. **Раска чыгу** *к.* **рас килү** (*3 мәгъ.*). *Әллә ишегалдындагыларның сүзе раска чыгамы, хулиган, башкисәр булып үсәме әллә аның улы?* А.Гыйләҗев. **Рас килү** 1) Туры килү, очрау, тап булу, юлыгу; 2) Нәкъ үзенә, үзәгенә туры килү; 3) Дөрескә чыгу, чынга ашу, тормышта урын алу (әйткән сүз, төш һ.б.). *Убырлының юравы әллә рас килде, әллә рас килмәде, моны кистереп кенә әйтүе кыен иде.* Ф.Садриев

РА́СА *и. фр.* 1) Кешелекнең килеп чыгышы һәм нәсел үзенчәлекләрендәге кайбер гомумилек (бит, тән төзелеше, тире, чәч төсе һ.б.) белән берләшкән, тарихи рәвештә формалашкан төркем. *--- расаларның бертигез булмаулары турындагы ялган теория буржуазиягә империалистик сугышларны, колониаль политиканы, бер халыкның икенче халыкны изүен --- аклар өчен кирәк булды.* Дарвинизм нигезләре. *Раса аермалыклары турындагы идея тарафдарлары төп аерманы психик даирәдә, ягъ-*

ни, икенче сүзләр белән әйткәндә, баш мие эшчәнлегендә күрәләр. Кызыклы физиология

2) *сөйл. к.* **расачалык**

РА́САЧЫ *и.* Расачылык тарафдары. *--- расачылар хәзергә кадәр, культура үсешенең төрлелегенә таянып, европалы булмаган халыклар мөкәммәл түгел, дип расларга маташалар.* Кызыклы физиология

РА́САЧЫЛЫК *и.* Аерым расаларның акыл үсеше, мәдәниятлелек дәрәҗәсе ягыннан түбән яки өстен булуны исбатларга тырышу тәгълиматы; шуңа нигезләнгән реакцион сәясәт. *Миркасыйм Госманов Сталин сәясәтендәге әлеге гамәлләрне расачылык галәмәтләре дип белдерә.* Безнең гәҗит

РАСИЗМ *и. фр. к.* **расачалык**. *--- Һитлерчеләрне гел яманлап, шовинизмда, расизмда гаепләделәр, ялган социалист булуларын фаш итеп тордылар.* Т.Әйди. *Бу [Дарвин фикерләре] аларга --- социал-дарвинизм һәм расизм теорияләрен --- «табигый-фәнни яктан нигезләү» өчен кирәк.* Дарвинизм һәм дин

РАСИСТ *и. рус* **1.** *к.* **расачы**. *Ләкин ни өчендер мине милләтләрне, аеруча урысларны күралмаучы, хәтта расист дип атыйлар.* Татар трибунасы

2. *с. мәгъ.* Расачылык карашларын хуплаган, шул карашта торган. *«--- ләкин көчле расист партияләр, аерым популяр шәхесләр бу дулкынны җанландырып кына тора», – [дип], көненечен белдерә Фәләстинле иммигрант.* Татар заманы

РАСКЛАДУ́ШКА *и. рус* Тимер кысага тукыма яки брезент тартты-рып эшләнгән җиңел җыелма карават. *Балдызның үзенә раскладушкасын, урын-җирен чыгарам, күләгә күчкән саен, аларны да күчерә торам.* Ф.Яруллин. *Алар узган айны ике бүлмәле квартирага күчтеләр. Газлы, туалеты ваннасыннан аерым, балконына раскладушка сыя.* М.Юныс

РАСКОЛ *и. рус* 1) Чиркәүдә яки башка дини җәмәгатьтә каршылыклар барлыкка килеп, аерым агымнарга аерылу, бер-берсен танымау күренеше (*мәс.*, лютеранлык, протестантлык, гуситлар, староверлар һ.б. барлыкка килү). *Реформа Россия православный чиркәвендә раскол китереп чыгара, күп кенә православныйлар яңа йоларны башкарудан баш тарталар, бу төрле протестлар, официаль Мәскәү епархиясенә каршы чыгуларга китерә.* Татар, уян!

2) Фикер каршылыклары нигезендә билгеле бер оешма, берләшмә һ.б.ның коллективында аерым төркемнәр барлыкка килү, бердәмлек югалу. *Әлегә Татарстан дин әһелләре арасында (халкы арасында, Аллага шөкер, алай түгел) аерымачык таркалу – раскол барлыкка килде, алда һәрберсе үз мөфтиятен оештырмаса ярар инде...* Безнең гәҗит

РАСКОЛЧЫ *и.* 1) Аерым бер дини мәзһәбтә торучы; сектант

2) *күч.* Таркатучы, билгеле бер иҗтимагый тәртипне бозучы

РАСЛАМА *и.* Дөреслекне расланган факт, исбатларлык дәлил. *Г.Гобәйдуллинның расламаларына яңадан әйләнеп кайтмас өчен, биредә аның хезмәтләреннән тагын бер-ике гыйбрәтле өземтә китерербез.* Р.Әмирхан

РАСЛА́У *ф.* 1) Исбатлау; гамәлгә ашыру. *Студентларның мөстәкыйль эшен оештыру аларның үзлектән аңлап белем алу максатыннан чыгып башкарыла һәм студентларның әдәби процесска, аерым язучының иҗатына, аерым әсәргә карата үз фикерләрен формалаштыру, бу фикерләрне раслап, дәлилләп бирә алу күнекмәләрен булдыру бурычларын тормышка ашыру шарты булып тора.* Ф.Сафиуллина

2) Дөресләү, дөреслегенә ышандыру, дөреслеген дәлилләү, раслыгын куәтләү. *– Шулай, шулай, балам, – диде хатын гажәпләнеп, башын селкеп раслады. – Каян белдең син моны, бер Ходай?!* Н.Гыйматдинова. *Бу сүзне Татарстанның халык шагыйре, сатира-юмор остасы, «Чаян» журналының якын дусты Шәүкәт ага Галиевның шунда яшәүче балдызы белән бәҗәе да расладылар.* Т.Нәҗмиев

3) Рәсми рәвештә карар кабул итү, карар чыгару. *Без аның сметасын төзедек, сез шуны раслап, ремонт башларга рөхсәт иттегез.* Г.Ахунов

4) Юридик рәвештә, закон тәртибендә рәсмиләштерү. *Мондый нәтиҗәне, реаль кандидатны барыбер Президент тәкъдим итүен, ә закон чыгару җыены раславын исәпкә алып, бераз гына төзәтмә кертеп чыгарырга мөмкин.* Татарстан

5) Кабул ителгән рәсми карарларны закон көченә кертү; гамәлгә кертү

Раслап алу Тиз арада раслау

Раслап бару Һәрберсен, булган берсен раслау. *Хәлбуки, язучы, телиме ул моны, юкмы, һуннарның римлеләрдән өстен торуын адым саен конкрет фактлар белән раслап бара.* Ф.Урманче

Раслап килү Элек-электән һәр очракны бер-бер артлы раслау. *Раслап килде тормыш «түрәләр»дә Орлыклык та хаклык калмавын.* К.Булатова

Раслап кую Рәсми расланган хәлгә китерү; сүз арасында, игътибарны махсус юнәлдереп раслау. *– Шул, шул, кода, – дип, җәтрәк раслап куйды Миңлегаяз. – Азат шул була инде.* Р.Мөхәммәдиев

Раслап тору Һәрвакыт, гел, бертуктаусыз раслау. *Безгә бит ирләрнең ратуларын раслап торуы кирәк. Шунсыз күңелсез.* Ф.Яруллин. *Татарстан Фәннәр академиясе вице-президенты Җәүдәт Сөләйманов белдергәнчә: «Без үзебезнең барлыгыбызны һәм зур эшләргә сәләтле икәнлегебезне һәрвакыт раслап торырга тиешбез».* Шәһри Казан

РАСЛЫК *и.* Хакыйкать, дөреслек, чынбарлыкка туры килү, чынлык. *Яр читендәге болындагы шау-шу, көймәләрдән мал ташучыларның күплеге Куртның фикеренең раслыгын белдерәдер иде.* Г.Гобәйдуллин

РАСПАШОНКА *и. рус* Муеныннан итәгенә кадәр аерып тегелгән балалар күлмәге. *Күкрәк баласын йоклаган вакытында төреп куярга яки бияләйле распашонка кидерергә кирәк.* Ватаным Татарстан

РАСПИСА́НИЕ *и. рус* Нинди дә булса эшнең, хәрәкәтнең үтәлү вакыты, урыны, үтәлеш эзлеклелеге турында мәгълүмат тупланган таблица, график, җәдвәл, эш планы. *Без расписаниеләрне карап утыра идек.* Г.Әпсәләмов. *Бездә әхлак тәрбиясе һәрвакыт үзәккә куела.*

Аның расписание буенча уткәрелүен әйтү дә җитәдер. Мәгърифәт

РАСПИ́СКА *и. рус* Нәрсә дә булса алуны раслап төзелгән, кул куелган рәсми язу, документ. *Максудовта алачагы бар адәмнәр һәркаюсы, вексель яки распискасы буенча судка биреп, хакын сорый башлады.* Ш.Мөхәммәдев. *Ул өстә яткан кәгазьләрне алды, алар распискалар, хезмәт хакы бирү буенча төрле сәер ведомостьлар булып чыкты.* Р.Мирхәйдәров

РАССА́ДА *и. рус сөйл.* Үрген, үренте; күчереп утырту өчен үстерелгән үсенте. *Үсә барган айда рассадага помидор, ташкабак, баклажан, кабак, борыч утырту башлана.* Татар мөселман календаре. *Иртә язда рассада итеп үстереп, язын бакчага утыртабыз һәм төрле тикшерүләр оештырабыз.* Хезмәт аша тәрбия

РАССО́ЛЬНИК *и. рус махс.* Тозлы кыяр салып пешерелгән итле яки балык ашы. *Авыл халкы умач, токмач һәм чумар белән әвәрә килгәндә, ул үзе үк әмәлләгән примуста борщ, щи, рассольник кебек ят ризыклар пешерә.* Ә.Рәшит. *Тозлы кыяр, помидор, солянка, борщ, щи, рассольник – бик үтемле товар.* Шәһри Казан

РАСТАН *рәв. сир.* Чынлап, дөрестән дә

РАСТР *и. лат. махс.* 1) Оптикада яктылык нурларының структурасын үзгәртү өчен махсус рәшәткә

2) Компьютер мониторында яки кәгазьдә төрле сурәтләрне күпсанлы ноктала рәвешендә барлыкка китергән махсус рәшәткә һәм барлыкка килгән рәсем үзе

РАСТРА́ТА *и. рус сөйл.* Кемнең дә булса җаваплылыгында булган акча яки башка мөлкәт җитмәү; өскә чыккан сумма; законсыз тотылган акча, милек. *Әлбәттә, вак-төяк растрата, җитмәүчелекләр генә аны куркытмый.* Ә.Еники. *Кунаклар дип ул кадәр акча туздырма, растрата ясап, тыгып куймасыннар тагын!* Р.Батулла

РАСХО́Д *и. рус сөйл.* 1) Берәр максат өчен сарыф ителгән яки тотылырга планлаштырылган акча; чыгым. *Ләкин бервакытта да ул [Гыйниятулла Зәйнуллин] хәзер үз расходына акчасын җиткерә алмый.* С.Җәлал

2) Бухгалтерия кенәгәсендә чыгымнар языла торган бүлек, графа

◊ **Расходка җибәрү** *к.* **расходка чыгару**. *Башта сынарга кирәк үзләрен, күнәрлек булмасалар, расходка җибәрү беркайчан да соң түгел.* Ә.Еники. **Расход каплау** Чыгымнарны түләү, расходларны кайтару. *Ашау расходларын төзелеше каплый*. А.Алиш. **Расходка чыгару** 1) Тоту, куллану, сарыф итү; 2) Расходлар исәбенә язу, исәптән чыгару; эшләтүдән, кулланудан туктату. *Аннан, иптәш персидәтел: бишнең икесе – сез суйдыртып каядыр олактырган бишәр центнерлы үгезләр, үлде дип расходка чыгарырга кушкан идегез бит, оныткансыз да...* Ф.Дәүләтбаев. *Ватасыз-җимерәсез дә расходка чыгарасыз. Без юктан бар ясый идек.* Р.Вәлиев; 3) Атып үтерү. *Дәшмәсә, икенче төркемне кертеп атачаклар, аның тере икәнен белсәләр, бероктан аны да расходка чыгарачаклар.* Р.Батулла. **Расходка чыгу** Тотылып бетү, сарыф ителү, кулланылып бетү. **Расход чыгару** *к.* **расходлану**. *Хәер, ул, зур расход чыгарасы булмаганда яисә яхшы исемен таратасы килгәндә генә, мәктәпләр белән кызыксына иде.* М.Галәү. *Кайгыртып, күпме расходлар чыгарып эзләттермәдеммени мин сине?* Ә.Фәйзи. *Моның ремонтлап расход чыгарырлыгы калмаган инде*. Безнең гәҗит. **Расходын күтәрү** Расходын үзе түләү, чыгымнарны үз өстенә алу. *Бөтен расходларны үзем күтәрдем*. Өмет. **Расход ясау** *к.* **расходлану**

РАСХОДЛАНУ *ф. сөйл.* Күп акча тоту, чыгымлану. *Иң гади бухгалтериядән чыгып әйтәм: табигать сезгә бу чаклы изгелекне бирде дә бушка гына расходланды дип уйлыйсызмы?* Н.Исәнбәт. *Болай да минем өчен бик күп расходланды бит алар.* Ф.Яруллин. *Минем исем-акылым китте: аның аркасында кеше расходланып җәфа чигәргә тиеш түгел!* С.Ибраһимова

Расходлана төшү Бераз расходлану

Расходланып алу Әле, соңгы вакытта расходлану

Расходланып бетү Бик нык расходлану. *Ул орлыкны юл әйбәтрәк вакытта иртәрәк тә бүләрләр инде, чәчүгә кадәр расходланып бетәргә мөмкин.* Өмет

Расходланып йөрү Әле, хәзерге вакытта расходлану. *Камил абый, нигә шулай расходланып йөрисең инде? Минем бит акчам бар.* Ф.Яруллин

Расходланып тору Еш, әледән-әле расходлану

РАСХО́ДЛЫ *с.* Зур расходлар сорый торган, чыгымлы

РАСЧЁТ I *и. рус* **1.** 1) Хезмәт һ.б. өчен түләү; хезмәт хакы. – *Мин хезмәт көненә эшлим, үзегез беләсез. Расчёт мәсьәләсен онытмагыз, – дип, җилҗил чыгып китте.* М.Мәһдиев. *Кызларым китеп, ун минутлар үткәч, официант белән расчёт ясап, мин дә урынымнан тордым*. А.Хәсәнов. – *Менә гыйнварга акчалата расчёт ясадык, февраль-мартны да бирәбез, лизингка яңа МТЗ тракторы алдык бит әле, – диде җитәкче уңайсызланыбрак.* Татарстан яшьләре

2) Тиешле хезмәт хакын түләп бетереп эштән чыгару. *Расчёттан соң, иртәгә китәсе дигән көнне, иптәшләр белән бераз төшердек тә урамга чыгып киттек.* Ф.Хөсни. *Карл Янович, миңа алмаш килде. Сез миңа, зинһар, расчёт әзерләгез.* М.Юныс. *Расчёт ясап, бу бригаданы озатырбыз, мөгаен.* Р.Габделхакова

3) Исәп-хисап. *Андрей Андреевич һаман үзенең расчётлары белән мәшгуль.* Г.Әпсәләмов. *Штурман Бригас расчётында биш кенә мильгә ялгышса да --- илебезгә кирәкле корычның күләме кечерәя.* М.Юныс

4) *сөйл.* Киләчәккә план, алдан уйланылган ният. *Менә бу юлы бальшуйны алырга расчёт бар.* Г.Камал

5) *күч. сөйл.* Араны өзү, алачак-бирәчәк калдырмау; алыш-бирешне туктату

6) *күч. сөйл.* Табышлы эш, файда алуга нигезләнгән ният; үз мәнфәгатьләрен кайгыртып эшләнгән гамәл. *Андый расчёт белән кияүгә чыгып, кеше җәфаларга нигә кирәк инде, дим.* Э.Яһудин. *Кайсы парларның гаиләсе*

ныграк була: яратышып өйләнешкәннәрнекеме, әллә мәхәббәткә исләре китмичә, беренче чиратта алдынартын уйлап, ягъни расчёт белән өйләнешкәннәрнекеме? Ватаным Татарстан

2. *хәб. сүз мәгъ.* «Бетте, тәмам, ара бөтенләй өзек, аласы-бирәсе калмады» мәгънәсендә. *Хәзер инде ул тыныч-ланган, шактый шыпырт сөйли иде: – Хатын белән расчёт. Бик эт халык булып чыкты ул, малай.* М.Мәһдиев. *Менә калганы, санап ал, мин синең белән расчёт.* З.Зәйнуллин

РАСЧЁТ II *и. рус хәрби* Сугыш коралына (пулемёт, туп, миномёт һ.б.) хезмәт күрсәтүче яки хәрби техникада хезмәт итүче гаскәриләр төркеме. *--- әгәр сораса, гвардия капитаны Ермилов та, расчёт командиры өлкән сержант Степашкин да каршы килмәсләр иде.* Г.Әпсәләмов. *Эх, молодец җиденче расчёт, дүртенче танкны да яндырды.* Х.Камалов. *Немецларның сигезенче атакасын кире кайтарганда, бер сугышчы Миргәйгә беренче пулемёт расчёты командирының яралануын әйтә.* В.Казыйханов

◊ **Расчёт алу** Эштән китү. *Судтан соң ук ул [Вәли] үз-үзенә урын таба алмады. Расчёт алып, районнан ук китеп барды.* М.Хәсәнов. *Хәтта эшеннән расчёт алып тормый ул, хатыны аша эштән үз теләге белән китүе турында гариза гына җибәрә.* Ватаным Татарстан. **Расчёт бирү** Эштән чыгару, эштән азат итү. *Бай хәзер инде сине расчёт биреп чыгарып җибәрәчәк.* Г.Камал. *Гәрәй аңа расчёт бирә икән, аның бер дә исе китми, менә дигән забойщик ич ул.* Ш.Камал. *Забастовщикларның барысына да расчёт бирәбез.* К.Нәҗми

РАСЧЁТЧИК *и. рус* Техник, инженерлык эшләрендә исәпләүләр ясау белгече

РАСШИФРО́ВКА *и. рус* 1) Кодлар, шифрлар белән язылган язманы уку эше

2) Шул язмада бирелгән хәбәр

РАСШИФРО́ВКАЛАУ *ф.* Кодлар, шифрлар белән язылган язманы уку, аның мәгънәсенә төшенү

РАСЫНДА *рәв.* Чынбарлыкта, чынында, дөреслектә. *Расында хәл бөтенләй башкача*

РАТИН *и. фр. иск.* **1.** Тышкы өс киемнәре тегү өчен, уң ягы төкле йон тукыма

2. *с. мәгъ.* Шул тукымадан тегелгән

РАТИФИКА́ЦИЯ *и. лат.* Документның югары дәүләт хакимияте, вәкаләте булган махсус орган тарафыннан расланып, юридик көч алуы, гамәлгә керүе. *Әгәр дә әлеге мәсьәлә анда да консенсус нигезендә яклау таба икән, документларның ярты ел эчендә Русия парламентында ратификация узасы гына кала.* Мәдәни җомга

РАТИФИКА́ЦИЯЛӘҮ I *ф.* Ратификация ясау, раслау

РАТИФИКА́ЦИЯЛӘҮ II *и. к.* **ратификация**. *Татарстан парламенты җитәкчесе Фәрит Мөхәммәтшин үз чыгышында, ТР Дәүләт Советының ил җитәкчелегенә Европа төбәкләре телләре яки аз санлы халыклар телләре хартиясен ратификацияләү турында мөрәҗәгатен яклауга әзер булуы өчен, Башкортстан Президентына рәхмәт белдерде.* Ватаным Татарстан

РАТНИК *и. рус тар.* 1) Сугышчы

2) Патша Россиясендә дәүләт ополчениесе солдаты

РА́ТУША *и. пол.* Шәһәр үзидарәсе органы; шул идарә урнашкан бина. *Венаның үзәк урамнарында үзеңне ачык һавадагы олы бер музейда йөргәндәй хис итәсең. --- Төрле стиль белән төрле чорларда салынган биналар: ратуша, университет корпуслары ---.* Т.Галиуллин. *Шәһәр халкы базар мәйданына шәһәр советы бинасы – ратуша салып куя.* Урта гасырлар тарихы

РАУВАН *рәв. фар. диал.* Бик тиз, тиз арада, шунда ук. *Ул рауван китеп тә барды*

РАУЗА *и. гар. иск.* 1) Гөл бакчасы, бакча, чәчәклек. *Инде бу дәфга рауза хисабы күп артмаса да, ләкин һәрбер раузада ничә-ничә нәфис җимешле агачлар утырттым*. К.Насыйри. *Торса ул яд иттереп җәннәт сарае раузасын.* Г.Тукай

2) Бүлек, бүлекчә (китапта). *Дүртенче рауза. Гыйлем. Хикмәт. Әдәп. Китабәт.* К.Насыйри

3) *диал.* Роза чәчәге. *Монысы – рауза чүпләме. Якты, зиһенле сурәт, әйеме? Монысы – канәфер чүпләме. Бөгелешләренә игътибар ит!* А.Хәлим

РА́УНД *и. ингл. спорт* 1) Бокс ярышында бер алышу дәвам иткән, гадәттә өч минутлык вакыт аралыгы. *Рушан чак кына нокаутка егылмый калды, ярый әле, гонг коткарды: беренче раунд тәмамланган иде.* Р.Мирхәйдәров

2) *күч.* Берәр эш-процессның чагыштырмача мөстәкыйль этабы, аерым кисәге, өлеше. – *Икенче раунд сөйләшүләр туганнарча дуслык шартларында башлана, – дип җил-җил килде ул [Фәррах]*. М.Хуҗин

РАУШАН *с. фар.* 1) Якты, нурлы, нур сибеп, балкып торган. *Таң алдыннан якты яна Ай белән раушан йолдыз.* Җыр. *Белергә кирәк ки, халык җырлары – халкыбыз күңеленең һич тә тутыкмас вә күгәрмәс саф вә раушан көзгеседер*. Г.Тукай. *Күктә йөзгән раушан айдай син балкыйсың!* Р.Батулла

2) Ачык; саф, чиста, пакь. *Раушан йөз*

РАФИНАД *и. фр.* Нык чистартып эшләнгән, тиз эри торган шакмаклы шикәр, шикәрнең иң югары сорты. *Шикәр – шикәр комы һәм рафинад кисәкчекләре генә түгел, бәлки татлы матдәләрнең тулы бер семьялыгы ул.* Ватаным Татарстан. *Людмила гомере буе шикәр заводында, рафинад цехында аппаратчы булып эшли*. Дуслык

РАФИНАДЛА́Ү *ф. ялг. к.* **рафинацияләү**

РАФИНА́ЦИЯЛӘҮ *ф.* Нәрсәне дә булса төрле чит катнашмалардан арындыру, чистарту, тазарту. *Нефтьне рафинацияләү. Шикәрне рафинацияләү*

Рафинацияләп бетерү Барысын да рафинацияләү

Рафинацияләп кую Алдан рафинацияләү

Рафинацияли башлау Рафинацияләргә тотыну

РАШКЫЛЫ *и.* Рашкы катыш. *Рашкылы яңгыр*

РАХИТ *и. гр. мед.* 1) Бала организмына D витамины җитешмәү сәбәпле, сөякләрнең йомшак булып, тигезсез үсүеннән гыйбарәт авыру. *Тавык күзе, цинга, рахит һәм пеллагра авырулары акрынлап тарихта гына калып бара*. Ватаным Татарстан. *Балаларның*

тешләре дөрес үссен, рахит, азканлылык авыруы булмасын өчен дә менә дигән кабымлык икән ул төелгән йомырка кабыгы. Кәеф ничек?

2) *к.* **рахитик**

РАХИ́ТИК *и. рус* Рахит белән авыручы бала. *Нигә әлеге дәү корсаклы, камыт аяклы, рахитик гарәп малае ялантән каты идәндә йокларга, сасы тар урамда уйнарга мәҗбүр?* М.Мәһдиев

РАХИТЛЫ *и.* Рахит авырулы, рахит белән авырган. *Бала табу йортында калдырып чыгармын. Намуслы, вөҗданлы Вильдан белән Наиләнең оныгы шешә имеп үсәр. Олы корсаклы, кәкре аяклы, нечкә муенлы рахитлы бала булыр.* Ф.Яруллин. *Бөтен балаларыгыз да рахитлымы, әллә монысы гынамы?* И.Иванов

РАХИТЛЫК *и.* Рахит авырулы булу. *Рахитлык билгеләре*

РАҺИБ *и. гар. иск.* Монах. *Раһиб әйтте: «Әфәндем, гаеп булмасын, сезне кайдан сорашаек? Кайдан киләсез? Кая барасыз?» – диде.* К.Насыйри. *Тирә-якта күземә хөрмә агачлары чалынгач, һәрхәлдә, бу раһиб әйткән җир булырга тиеш дип, шунда калдым.* Мәңгелек нур

РАЦИОН *и. лат.* Билгеле бер срокка исәпләнгән азык порциясе, паёк һәм аның составы. *Рацион алай артык мул да түгел бит инде. Нигә бу кадәр сыек калдыралар икән?* М.Юныс. *Азыктамырлар чи килеш яхшы сакланалар һәм ел буе халыкның азык рационының аерылгысыз өлеше булалар.* Яшелчәчелек

РАЦИОНАЛИЗА́ТОР *и. лат.* Җитештерү процессын рациональләштерүче, рационализация өчен чара күрүче, тәкъдим кертүче. *Рәнис: «Үзеңнең нәрсә майтарганың бар соң синең, рационализатор кисәге!» – дип җавап кайтармакчы булган иде дә, яхшысынмады.* Ж.Дәрзаман. *Татарстанның атказанган агрономы, җир эшкәртү машиналарын сынаучы галим, рационализатор, безнең Байлангар авылы кияве Сабир Шәйхетдинов кырчылыкта югары үрләр яулады.* Т.Нәҗмиев

РАЦИОНАЛИЗА́ТОРЛЫК *и.* Рационализатор эшчәнлеге, рационализация кертү эше. *Минем кесәмдә әнә ун рационализаторлык таныклыгы ята.* Ф.Яруллин. *Менә шул Лилия компьютерлар җыя торган бер фабрикада эшли һәм әледән-әле рационализаторлык тәкъдимнәре кертеп, бүләкләр алып тора.* М.Кәбиров

РАЦИОНАЛИЗА́ЦИЯ *и. лат.* Эшне аеруча нәтиҗәле, максатка ярашлы итеп оештыру; эш процессын, эш коралларын, эшчәнлекне яхшырту, җитештерүчәнрәк итү, тизләтү, камилләштерү чаралары җыелмасы. *– Интәш Хәсәнев, – диде председатель, – заводның атаклы стахановчысы, ул үзенең эш коралларына рационализация ясады.* А.Алиш

РАЦИОНАЛИЗМ *и. лат. филос.* 1) Фикерләүнең тормыш тәҗрибәсенә бәйләнешен инкяр итеп, дөньяны танып белүнең бердәнбер чыганагы акыл, дип саный торган идеалистик фәлсәфи юнәлеш

2) Кеше акылы чиктән тыш көчле, чынбарлыкны тулысынча танып белеп була, дигән фәлсәфи караш; шул каршта торган әдәби агым. *«Яшь хатын» пьесасына карата галим Һ.Мәхмүтов бәяләмәсе: «1907 елда басылган бу әсәрдә мәгърифәтчелек идеяләре, рационализм өстенлек итүе бик табигый...»* Эхо веков

3) *күч. кит.* Тормышта эмоцияләр катыштырмыйча, акыл белән, нык уйлап кына эш итүчәнлек. *Безнең тамырлардан аккан сөмсез агуга шигырьләр дару була алырмы? Тик рационализмны, прагматизмны байрак иткән бәндәләр шигырь укымый шул.* Идел

РАЦИОНАЛИСТ *и. рус* **1.** 1) Рационализм тарафдары. *--- милләттәшләрем арасында ике чын әдип йитешә: берсе – хәссас, атәшле милләтпәрвәр идеалист вә романтик Гаяз, икенчесе – гасаби тешләүчән, милләтне чеметеп сөя торган рационалист вә реалист – Фатих.* Г.Сәгъди

2) Акылга муафикъ гамәлләр генә кылучы, акылга нигезләнеп, уйлап эш итүче кеше. *«Хаҗнамә»нең авторы, ерак сәфәргә юнәлеп, үзен чын рационалист, юлда очраган хәлләр турында нык уйланучы, акыл бизмәне аша уздырып фикер йөртүче, аңларга тырышучы шәхес буларак күз алдына баса.* Фән һәм тел

2. *с. мәгъ.* Акылга муафикъ гамәлләр генә кылган, акылга нигезләнгән, уйлап кына эш йөртә торган. *Юк, ул андый кеше түгел, салкын рационалист кеше ул, намус аның өчен абстракт төшенчә генә.* Ә.Еники

РАЦИОНАЛИ́СТИК *с.* 1) *филос.* Рационализмга нигезләнгән, рационализмга бәйләнешле

2) Бары акылга гына нигезләнгән, акыл таләпләренә генә таянган, акылга муафикъ булган. *Р.Мингалим шигырьләрендә фикер, егәрле деталь, рационалистик башлангыч өстенлек итә, дигән идек.* Казан утлары

РАЦИОНАЛЬ *с. лат.* **1.** 1) *филос.* Рационализмга бәйләнешле

2) Акылга ятышлы, акылга муафикъ; нигезле; нәтиҗәле, файдалы. *Авыл хуҗалыгы фәне крестьянның җиргә мөнәсәбәтенә кагылышлы фәлсәфәдән башка яши, үсә алмый. Картның сүзләрендә рациональ орлык бар, бу – бәхәссез.* М.Мәһдиев

3) *мат.* Гади вакланма белән белдерелә ала торган. *Рациональ сан*

2. *рәв. мәгъ.* Төптән уйлап, җентекле тикшереп; белемгә нигезләнеп; нәтиҗәле итеп. *Яшь терлекләрне симертүне яхшыртуда, жомнан гына түгел, спирт бардасыннан рациональ файдалану да әһәмиятле.* Татарстанда терлекчелек

РАЦИОНАЛЬЛӘШТЕРҮ *ф.* Рациональ итү, рационализация кертү. *Башта аның тарафыннан төрле рациональләштерү тәкъдимнәре кертелә.* А.Алиш

Рациональләштерә килү Күп еллардан бирле аз-азлап рациональләштерү, акрынлап рациональләштерү

Рациональләштерә төшү Бераз рациональләштерү

Рациональләштереп тору Һәрвакыт, даими рациональләштерү

РА́ЦИЯ *и. рус* «Радиостанция» сүзенең беренче һәм соңгы ижекләреннән торган кыскартылма сүз: күчмә радиостанция. *--- иелгән вакытта бер милиционерның рациясе төшеп китә.* Т.Нәҗмиев. *Димәк, бу үзгәрешне рация*

аша хәбәр итү өчен шымчының вакыты җитәрлек булган. З.Фәтхетдинов

РАШИ *и. гар. иск.* Ришвәт бирүче

РАШИЗМ *и. инг. к.* **русизм** (*2 мәгъ.*)

РАШКЫ *и.* Ярмасыман каты вак бөртекле кар. *Каз томшыгын шыкырдатса, рашкы явар.* Сынамыш. *Аерылды җәй көздән, Кул болгап озатты. Астра керфегенә Тәүге рашкы ятты.* Х.Мөдәрисова

РА́ШПИЛЬ *и. нем.* Эре сырлы игәү. *Әмма [кара туры атны дагалау өчен] арт аякларга, рашпиль тотып, әле берәүнең дә үрелгәне юк иде.* М.Мәһдиев. *Өйдә аяк астына салып тапта, муенын рашпиль игәве белән ышкы, кәҗә маен чыгар, ә инде кеше алдында күккә чөй, табын, зурла, шул чакта аны да кеше итәрсең, үзең дә яхшы хатын булырсың.* Ф.Садриев

РАШТУА *и. рус дини* Христианлыкта 12 мөһим бәйрәмнең берсе: декабрь ахырында үткәрелә торган дини бәйрәм; төрләнү бәйрәме. *1916 елда Изге Синод, дошман немец тәэсире, дип, раштуа чыршыларын бизәүне тыя.* Т.Нәҗмиев. *Урамда Раштуа салкыннары булса да, кояш барыбер нурларын мулрак чәчә башлады.* Авыл таңнары

РӘБИБ *и. гар. иск.* Үги ул, асрамага алган бала. *Әй бүре, куемны үтердең, хәлбуки син ул куйның рәбибесең.* К.Насыйри

РӘБИГЫЛЬАХЫР *и. гар.* Мөселманнарда: һиҗри елның дүртенче ае атамасы

РӘБИГЫЛЬӘҮВӘЛ *и. гар.* Мөселманнарда: һиҗри елның өченче ае атамасы. *Туй вә никах көне бонлар тарафыннан рәбигыльәүвәл аеның уникенче көне уларак билгеләнмеш иде.* Р.Фәхреддин

РӘВА *хәб. сүз фар. иск.* **1.** 1) Яраклы, ятышлы, начар түгел. *Мәсәлән, голямалар мәҗлесе дип әйтәсе җирдә голяма мәҗлесенә дип әйтергә табигать рәва күрмидер, чөнки мондаен кәлимәләр тәмам үз сүзебезгә әйләнеп беткәндер.* К.Насыйри

2) Ярый, мөмкин. *И падишаһ, хатын сүзенә оеп, шаһзадәне үтермәк рәва түгелдер.* М.Гайнетдин

2. *с. мәгъ.* Хәләл, тыелмаган. *Тәрәзә төпкәем рәва җимеш, Рәва җимеш хәләл, имеш. Рәва җимеш хәләл, имеш, Хәләл җефтең булам, ди, имеш.* Ә.Еники

РӘВАҖ *и. фар. иск.* 1) Таралу, әйбәт сатылу, базары югары булу

2) Алдынгылык. *Болгарларның дәүләтләре бетеп, бәхетләре түбән килеп, әүвәлге рәваҗлары югалмыштыр.* Р.Фәхреддин

◊ **Рәваҗда булу** Популяр булу

РӘВАН *с. фар. иск.* 1) Күптән узган, үтеп киткән, югалган. *Рәван заманнар*

2) Тиз уза торган. *Рәван гомер*

РӘВА́Н БУЛУ *ф.* Юкка чыгу, китеп бару. *Әбүгалисина, дәхи акчаны алып, бер тарафка рәван булды.* К.Насыйри. *Вә Бөре суы буендагы карьяләрнең беренән бер итекче мөселманны үзенә юлдаш итеп, Хиҗаз сәфәренә рәван улды.* Г.Камал

РӘВӘҖ *и. фар. бот.* Карабодайчалар семьялыгыннан, яшь сабаклары ашамлык (кесәл, компот һ.б.) әзерләү өчен файдаланыла торган, әрекмәнгә охшаган зур яфраклы, калын тамырлы күпьеллык үлән үсемлек; *русчасы:* **ревень**. *Май уртасында рәвәҗ, спаржа, кузгалак үсеп өлгерә.* Кәеф ничек?

РӘВЕШ *и. фар.* 1) Тышкы күренеш, кыяфәт, килеш-килбәт; форма. *Керамика үзенең рәвеше һәм бизәлеше белән әүвәлге Идел Болгары җирләрендә һәм бигрәк тә Түбән Иделдә, Алтын Урда шәһәрләрендә киң таралган балчык савытларга ныкохшаган.* Р.Фәхреддинов. *Бер үк рецепт белән басылган камырның ике рәвеше бөтенләй ике төрле тәмгә ия.* Б.Хаков. *Рептилияләр – күбесенчә ерткычлар: аларның конус рәвешендәге тешләре табышны эләктерү һәм тоту өчен хезмәт итә.* Биология

2) Нинди дә булса эшне башкару үзенчәлеге, үтәү формасы, характеры. *Кайвакыт Илаһи Күктән иңдерелгән алиһә рәвешендә чыгыш ясый.* Ф.Урманче. *Актанышлыларның киенү рәвеше аеруча ошады: кызлары да, егетләре дә аклы-каралы.* Татарстан яшьләре

3) *лингв.* Эш-хәлнең билгесен яки билгенең билгесен белдерә, морфологик яктан төрләнми торган сүз төркеме. *Бу ысул белән рәвеш ясалышында урын-ара килешләрдә килгән исемнәр, башка сүзләр һәм функциональ яктан рәвешләргә якын торган хәл фигыльләр катнаша.* Ф.Хисамова

РӘВЕШЛӘНҮ *ф. диал.* Нинди дә булса рәвеш алу, рәвешкә керү, охшау, охшап китү. *Ни өчен дигәндә, кечкенә чакта кыланып йөргәндә, миңа бер туганым: «Рәвешләнеп йөрмә әле!» – дип әйтә иде.* Безнең гәҗит

РӘВЕШЛӘШҮ *ф.* Рәвеш (3 мәгъ.) функциясен үти башлау, рәвешкә әйләнү. *Чөнки бу – шундый ук рәвешләшү (адъективация) күренеше, ягъни алар билгеле бер килеш формасында аерылып, рәвешкә күчкәннәр ---.* Ф.Хисамова

РӘВЕШЛЕ *с.* **1.** Билгеле формадагы. *Соры томан рәвешле болытлар җирне баскан төсле тоташып җиргә салынганнар.* Ш.Камал

2. *рәв. мәгъ.* Билгеле ысул, юл белән, берәр төрле итеп. *Моны ни рәвешле эшлисез?*

РӘВЕШСЕЗ *с.* Тышкы күренеше ямьсез, килешсез булган, килбәтсез. *Үги атасының бу тиклем рәвешсез чалыш чыраен болай якыннан күргәне юк иде әле аның.* Л.Ибраһим-Вәлиди

РӘВЕШТӘ *бәйл.* 1) Эш-хәрәкәтне, хәлне икенче берәр эш-хәрәкәткә, хәлгә охшату өчен кулланыла: кебек, шикелле, сыман. *Аңарчы да эфирга чыгулар тәҗрибә рәвешендә булса да, рәсми телевидение тарихы шушы датадан башлана.* Безнең гәҗит

2) Эш-гамәлнең үтәлеш үзенчәлеген бәяләп, аныклап килгән сүз белән кулланыла. *Шартлы рәвештә әйткәндә, бу – конституцион закон инде.* Р.Миңнуллин. *Ул, демонстратив рәвештә ишекне бу яктан бикләп, ачкычын күтәрде.* Р.Батулла. *Әмма Русия рәсми рәвештә империя дип тик 1721 елда игълан ителә.* М.Әхмәтҗанов

РӘВЕ́ШЧӘ *рәв.* **1.** Теге яки бу рәвешле, рәвешендә, шулай. *Шул рәвешчә чабышып җиттек авылга бервакыт.* Г.Тукай

2. *бәйл. мәгъ.* Шикелле, кебек, сыман. *Каспий диңгезе буендагы балык промыслоларында елдагы рәвешчә хәрәкәт башланган.* Ш.Камал

РӘГАИБ *и. гар.* 1) Хыяллар, теләкләр 2) *к.* **рәгаиб кичәсе**

РӘГАИ́Б КИЧӘСЕ *и.* Рәҗәп аеның беренче җомгасына каршы кичә; бу кичәдә пәйгамбәрнең атасы хәзрәте Габдулла белән анасы Әминәнең никахлары булып беренче кавышкан көннәре. *Рәҗәп аендагы Рәгаиб кичәсе бөтен кешелек өчен нурлы бер иртәнең башлангычы булып тора.* Татар мөселман календаре. *Рәҗәп аеның ике күркәм кичәсе бар: беренчесе Рәгаиб кичәсе булса, икенчесе – рәҗәп аеның 27 нче көнендә үткәрелә торган Мигъраҗ кичәсе.* Ислам

РӘГЫЯТЬ *и. гар. иск.* Бер дәүләтнең халкы; *русчасы*: **подданные**. *Ил көче рәгыять белән, рәгыйять гаделлек белән.* Мәкаль. *Адәмнең гакылы падиша, ә башка төрле мөгамәләсе вә кыйлмышлары рәгыять мәнзилендәдер.* К.Насыйри

РӘД *с. гар. иск.* Кабул итмәгән, кире каккан, тискәре карашта булган. *Иван Грозный исә тагы рәд җавабы бирде.* Г.Гобәйдуллин

РӘ́ДДЕ *кис. гар. иск.* Инкярлау кисәкчәсе: түгел. *Сәхнә әдәбиятының беренче үрнәкләреннән булган «Рәдде бичара кыз» (1888) пьесасында Ф.Халиди бер ел элек дөнья күргән «Бичара кыз» (Г.Ильяси, 1887) әсәренә мөнәсәбәтен белдерә.* Татар әдипләре

РӘДДИЯ *и. гар. иск.* Берәр нәрсәне кире кагып, дөрес түгеллеген күрсәтеп, язмача яки башкача ясалган чыгыш; шундый эчтәлектәге документ. *Дингә, фәлсәфәгә карашлары исә миссионер Е.А.Малов китабына карата язылган «Ефим Маловка рәддия» (1886), шәригать кануннарын шәрехләгән «Ысул фикъһ тарихы» (1890) хезмәтләрендә бәян ителә.* Фән һәм тел

РӘ́Д ИТҮ *ф.* Кабул итмәү, кире кайтару, кире кагу. *Безнең фракция бу канун проектын рәд итә.* С.Максуди. *Ләкин Иван хөкүмәте бу шәһәрләр мәсьәләсен тагы рәд итте, Мәскәүдә янгын булганлыктан, күп итеп бүләкләр дә җибәрә алмаганлыгын белдерде.* Г.Гобәйдуллин

РӘ́Д КЫЛУ *ф. к.* **рәд итү**. – *Борадәредер, рәд кыйлмас, килсә, аның белән килер, – диделәр.* К.Насыйри

РӘЕШ *и. фар.* **1.** Кеше арасына чыгу, бәйрәмчә киенү. *Маһирә сугыш елларында күп кыенлыклар, кысанлыклар кичереп, артык-портык әйберләрен генә түгел, рәешкә асраган кием-салымын базарга илтсә дә, зәңгәр күлмәген бик кадерләп саклады.* А.Гыйләҗев

2. *с. мәгъ.* Яхшыга, чистага киелә торган, кеше арасына чыкканда кулланылган. *Мендәр-ястыкны ишеп төшерде дә сандыктан бабайның саклап кына кия торган рәеш киемнәрен алды.* Р.Батулла. *Өстенә һәр ел саен Бөек Җиңү көнендә генә кия торган, берничә орден-медале ялтырап торган рәеш костюмын, быел туган көненә бер туруны – оныгының малае алып биргән өр-яңа ак күлмәген кидерделәр.* Ватаным Татарстан

РӘҖӘП *и. гар. кит.* Ай елының җиденче ае исеме. *Безнең исәпләү буенча, һиҗри 926 елның рәҗәп ае григориан (милади) календаре буенча 1520 елның июнь-июль айларына туры килә.* Гасырлар авазы

РӘИС *и. гар.* 1) Кайбер учреждение, оешма, җәмгыять яки аларның бүлекләренең җитәкчесе; председатель. *Чыңгыз Айтматов Казанга килгән һәм Татарстан Язучылар союзына кереп чыгасы икән, дигәч, рәис Гариф Ахунов, идарәгә Әмирхан ага Еники белән Сибгат абыйны китер дип, машина җибәрергә кушты.* М.Хәбибуллин. *1901 елда туган Шаһишәрип Шәймиев (соңрак исеме Шәрип дип кыскартыла) – 25 ел колхоз йөген җигелеп тарткан данлыклы рәис.* Ватаным Татарстан

2) Җыелышны, утырышны алып баручы, председатель. *Шуннан соң рәис [утырышта] нинди эш каралачагын әйтеп үтә.* Р.Батулла. *Сүз алып сөйләүчеләрнең һәммәсе рәис фикерен бертавыштан хуплый, мәктәп өчен буш торган мәчет бинасын кулланырга кирәк, дигән тәкъдим кертә.* Кызыл таң

РӘИСЛЕК *и.* Рәис вазифасы, рәис булу. *Дума рәисе Н.А.Хомяков рәислектән китә, ә аның урынына рәис булып октябристлар партиясе җитәкчесе А.И.Гучков сайлана.* С.Максуди. *Их, нигә генә рәислек дилбегәсен кулына алырга ризалык бирде икән.* Г.Галиева. *Чөнки сугыш чоры күмәк хуҗалыгына рәислек итүне үзең сорап алу өчен куш йөрәкле булырга кирәктер.* Әдәбият

РӘЙХАН *и. гар. бот.* Иренчәчәклеләр семьялыгыннан зәңгәр чәчәкле, эфир майларына бай, тәмләткеч һәм декоратив культура буларак үстерелә торган хуш исле берьеллык үсемлек; базилик. *Суган кыяклары белән рәйхан үләне өзәсе генә калды, алардан башка салат салат булмый.* Р.Мирхәйдәров. *Мәтрүшкә, рәйхан исе кичерешләрне җиңеләйтә.* Мәдәни җомга

РӘКАБӘТ *и. гар. иск.* Ярыш, көндәшлек, башкалардан өстен булырга тырышу, конкуренция. *Кием-фәлән җәһәтеннән хатыннар арасында берберсенә рәкабәт итешү булганга күрә, күзләре бер-берсенең киемендә улдыгы кебек, сүзләре дә шул кием-фәлән кебек әһәмиятсез мәсьәләләр турысында иде.* М.Гафури

РӘКӘГАТЬ *и. гар. дини* Намаз вакытында укыла торган догаларның һәм башкарыла торган хәрәкәтләрнең бер циклы (аягүрә тору, иелү һәм башны җиргә кую). *Ике рәкәгать намаз укылды, аннан соң сәед Кол Шәриф җәнаплары соңгы вәгазен сөйләде.* Р.Батулла. *Бүген дә хаҗилар, Кәгъбә тирәли җиде мәртәбә әйләнгәннән соң, шул урынга барып, ике рәкәгать намаз укыйлар.* Шәһри Казан

РӘМЕЗ *и. гар.* Карта уенының бер төре. *Мин рәмезгә шактый өйрәнеп килә башлаган идем, аларны берничә мәртәбә откан идем.* Г.Бәширов. *– И ахирәтләр, башка азгынлыгым юк, әйдәгез әле, утырып бер рәмез уйныйк, – дип, бисмилласын әйтеп, уйный башлар иде.* Р.Батулла

РӘМЕЛ *и. гар.* 1) *иск.* Ташлар, ногытлар һ.б. ярдәмендә күрәзәләү, «ерактан күрү» ысулы. *– И остаз әфәнде, безгә дә бер рәмел ачсаңыз булмасмы? – диде.* К.Насыйри. *Өс-башы ертык, аягы ялангач, бер кулында думбра, берсендә яулык белән төрелгән такта һәм вак рәмел ташлары – комалаклар иде.* Г.Ибраһимов

2) *әд.* Шигъри үлчәмнең бер төре

РӘММАЛЬ *и. гар. иск.* Ком, вак таш белән күрәзәлек итүче. *Күрде,*

шәһәр капкасы төбендә бер рәммаль утырыр, һәркемгә рәмел ачып, яхшысын, яманын хәбәр бирер. К.Насыйри

РӘНҖЕТКЕЧ *с.* Рәнҗетерлек, рәнҗетә торган. *Үзегез дә сизмәстән, бик рәнҗеткеч берәр сүз әйтеп ташлавыгыз бар.* Ватаным Татарстан

РӘНҖЕТҮ *ф.* Кемне дә булса кыерсыту, урынсызга кимсетү; хаксызлык күрсәтү, җәберләү. *Юләр сөальнең хатын-кызны рәнҗетә, кимсетә торган ахмаклык, томаналык икәнлеген аңлады Сәет.* Т.Галиуллин. *Мине әнә шул рәнҗетә, атакай: һәр халык үз алласын күккә чөеп мактый, шуннан гына мәгънә эзли.* М.Хәбибуллин

Рәнҗетә башлау Рәнҗетергә тотыну. *Салкын рәнҗетә башлагач, тәрәзәләргә күчкәннәр икән чәчәкләр: аларның үзләренең дә кыздан егеткә бүләк буласылары килгән.* М.Хуҗин. *Берәрсе рәнҗетә башласа, хәзер Касыймычка кереп әләкләде.* Ф.Яхин

Рәнҗетә бирү һаман да рәнҗетү, рәнҗетүен дәвам итү

Рәнҗетә төшү Тагы да рәнҗетү

Рәнҗетә язу Чак кына рәнжетми калу. *Һәйбәт шаяру бит! Әмма аның бер хәле мине рәнҗетә язды.* К.Нәҗми

Рәнҗетеп йөрү Әле, хәзерге вакытта рәнҗетү; гел рәнҗетү. *Тугыз сәгатькә бер телгә килә торган ике кәүсәле тере агач Искәндәр шаһны тирги: «Нишләп, мөстәкыйль илләрне яулап алып, бик күп халыкларны рәнҗетеп йөрисең?» – ди һәм тизрәк туган ягына кайтып китәргә киңәш итә.* Ф.Урманче

Рәнҗетеп килү Күптәннән, даими рәнҗетү. *Каенананың ачуы һаман басылмый, киленен җәберли, нахакка рәнҗетеп килә.* Кызыл таң

Рәнҗетеп кую Кинәт, искәрмәстән рәнжетү. *Үз кызым булса, әйткәләр идем, чит-ят гаиләдән «очып» төшкән киленне я рәнҗетеп куярмын.* К.Тимбикова

Рәнҗетеп ташлау Кинәт, ялгыш рәнжетү. *Ә син шушында анаңны кыйнап, рәнҗетеп ташладың...* Г.Гыйльманов

Рәнҗетеп тору Гел, һәрвакыт рәнжетү. *Бер яктан караганда, аңлашыла да инде, әмма барыбер күңелне үртәп, җанны рәнҗетеп тора.* Ж.Юныс. *Нәкъ менә шушы ялгыз, ишек-тәрәзәләренә такта кадакланган өйләр авылга бер мескенлек өстәп, күңелне рәнҗетеп торалар шикелле.* Безнең гәҗит

РӘНҖЕТҮЛЕ *с.* Рәнҗетү сизелеп торган, кимсетеп караган. *Ятим үскәне, кайберәүләрнең, синең әтиең юк бит, дип рәнҗетүле сүзләр әйтүе аңа әтисе каберен эзләп табарга этәргеч бирә.* Шәһри Казан

РӘНҖЕШ *и. гар.* 1) Хаксызга, урынсызга кимсетү, нахакка кыерсыту; җәбер-золым. *Албастылардан кеше ясау ай-һай кыен, ә менә кеше албастыга әверелсен өчен, бер рәнҗеш тә җитә...* Г.Гыйльманов. *Хадим һәм кәнизәкләр әйттеләр: – Бу эшнең чарасын үзең яхшырак беләсең һәм бу рәнҗешнең дәвасын, имен дә син белерсең, – диделәр.* Борынгы татар прозасы

2) Үзенә карата булган хаксызлыктан, урынсызга кимсетелүдән, кыерсытылулардан туган рәнҗү, ачыну, әрнү тойгысы, җәберсенү; үпкәләү, хәтер калу. *Ул минем шаянлыкны белгәнгә, күмәчен алганга һич рәнҗеш күрсәтмәү өстенә, кайчакта миңа бирә торган өлешне арттырып бирә башлады.* М.Гафури. *Шаярганда да, аның йөзендә ниндидер олы сагыш, рәнҗеш галәмәтләре чагыла иде.* Р.Батулла. *Белеп яшә: Шакир абый рәнҗешләре дә ерак китмәс әле...* Г.Галиева

◊ **Рәнҗеш төшү** Кемне дә булса рәнжеткән, кимсеткән кеше үзе берәр төрле бәла-казага, авырлыкка дучар булу. *Павлик кызганыч... Ул миңа рәнҗеп үлгәндер... ул изге кеше иде, әллә аның рәнҗеше төште микән миңа?* Д.Каюмова

РӘНҖЕШЛЕ *с. к.* **рәнҗүле**. *Зәлия дәшмәде, әмма аның яшь тулы рәнҗешле карашы Халидәне өтеп алгандай булды.* Ватаным Татарстан

РӘНҖҮ *ф.* 1) Нәрсәне дә булса авыр кабул итү, хәтер калу, үпкәләү, җәберсенү. *Газзәбану җаным, ахираткәем, зинһар, тыңла сүземне, тик рәнҗи генә күрмә, яме.* Г.Галиева. *Алар үпкәли, рәнҗи белмиләр, алар тоташ изгелектән торалар...* Г.Гыйльманов

2) Ризасызлык белдерү, килешмәү, күңеле каршы булу. *Баштан ахырга кадәр Җәләйне күзәтеп утырган Хисамый: «Димәк, картның уенда нәрсәдер бар, ул бүген борчыла һәм рәнҗи булырга тиеш», – дигән фикергә килде.* Н.Яһудин

Рәнҗеп алу Бераз гына рәнҗү. *«Сиңа кәмит, безнең әткәй төсле Магаданга сөрелгән булсаң, хәзер мич авызы кебек буш яисә ясалма тешле авызыңны чәпелдәтеп утырыр идең», – дип рәнҗеп алды Әхсән Сакмаровның төпчек оланы.* Т.Галиуллин

Рәнҗеп йөрү Озак кына рәнҗегән хәлдә булу. *Аңа да Идмас Фәсхетдинов, бөтен акчамны алдап-йолдап алып бетерде, дип рәнҗеп йөрде.* Ә.Хәсәнов. *Мин укытучыма шактый вакыт рәнҗеп йөрсәм дә, соңыннан аның гаепсез икәнлеген аңладым.* Я.Шәфыйков

Рәнҗеп калу Билгеле бер сәбәптән, вакыттан соң рәнҗегән хәлдә калу. *Иртәнгә хәтле тормавы мөмкин аның. Актык минутында, врач килмәде, дип рәнҗеп калмасын инде.* Г.Әпсәләмов. *Урынбасарының теләге булса да, аны мунчага чакырмадылар. Ул тагын рәнҗеп калды.* Р.Сәгъди

Рәнҗеп кую Көтмәгән җирдән рәнжү. *Мин моны кызык өчен генә эшләдем, рәнҗеп куймагыз тагы.* Кызыл таң

Рәнҗеп тору Күпмедер вакыт рәнжү. *Ә син мең билет сатылган өчен рәнҗеп торасың... Ул күзле бүкәннәр сәхнәгә менеп рәхмәт тә әйтә белмәделәр...* К.Кәримов

Рәнҗеп утыру *сөйл. к.* **рәнҗеп тору**. *Сиңа рәнҗеп утырам, Сираҗетдин. Инешкә батканда, мин бит сиңа кулларымны суздым, Сирай.* Д.Салихов

РӘНҖҮЛЕ *с.* Рәнжү, җәберсенү белдергән, рәнҗегәне күренеп торган. *– Эшли алмыйм мин сезнең ул Закировыгыз белән, – диде Мәрсинә, рәнҗүле мескен тавыш белән.* Ә.Дусайлы

РӘҢ *и. фар. иск.* Төс, төсмер, тон. *Сачы коңгыр рәңдә улып...* М.Акъегетзадә. *Ул арада Кәрим Сәгыйть әфәнде, тагын бер-ике кеше килеп, алар да һәркайсы үзләренчә мәҗлескә бер рәң бирделәр.* К.Бәкер

РӘСЕМ *и. гар.* 1) Берәр предмет, зат һәм күренешнең карандаш, каләм, күмер, пумала, төрле буяулар һ.б. белән ясалган сурәтләнеше, күчермәсе. *Сугыш вакытында мин шагыйрьләрнең шигырь язуын, язучыларның хикәяләр иҗат итә алуын аңлыйм, әмма туплар гөрелтесе, ядрәләр яңгыры астында пумала тотып рәсем ясауны күз алдына китерә алмыйм.* Р.Вәлиев. *Хәтта без бөек дип атаган рәсем дә табигатьтән генә урланган.* З.Мәхмүди

2) Кемнең яки нәрсәнең дә булса фотосурәте; фоторәсем. *Зиннәт инде фотоаппаратны гына түгел, хәтта үзе төшергән рәсемнәрне дә ап-ачык күрә.* А.Шамов

◊ **Рәсем алдыру** Рәсемгә, фотога төшү

РӘСЕМЛӘ́Ү *ф. сөйл.* 1) Рәсем белән бизәү; иллюстрация ясау. *1922 елны мин өйләнгәч, Муса, безне котлап язган шигырьләрен үз кулы белән ясаган альбомга язып, акварель буяу белән рәсемләп бүләк иткән иде.* И.Җәлилов

2) Бизәү, бизәкле итү, бизәкләр төшерү. *Шагыйрь кеше күңелендәге үтә нечкә кичерешләрне, сизелер-сизелмәс хәрәкәт-үзгәрешләрне, нюансларны рәсемләп күз алдына бастыра.* Татар әдипләре

Рәсемләп җибәрү Бераз рәсемләү

Рәсемләп кую Алдан рәсемләү, рәсемләгән хәлгә китерү

Рәсемләп тору Әле, хәзерге вакытта рәсемләү

Рәсемли төшү Тагы да бераз өстәп рәсемләү

РӘСЕМЛЕ *с.* Рәсем төшерелгән, рәсем ясалган, рәсемнәр урнаштырылган, сурәтле. *Күп тә үтмәде, Әнисәсе рәсемле зур китап күтәреп, ялгызы гына күбәләктәй очып килеп тә җитте.* Д.Бүләков

РӘСЕ́М СӘНГАТЕ *и.* Образларның бирелеше буяуларны нинди дә булса өлеккә ягып сурәтләү белән бәйле тасвири сәнгать төре. *Монда балалар өчен театр да, музыка да, ТВ-радио да, көндәлек матбугат та, кино сәнгате дә, рәсем сәнгате дә, әдәбияты да, һөнәрчелек тә керә дигән сүз.* Р.Миңнуллин

РӘСЕМЧЕ *и. сир. к.* **рәссам**. *Чөнки ул хәзер күпләр өчен элекке төсле әдәби походларда, радиода катнашып үсә торган җырчы да түгел, музыкант та түгел, шагыйрь дә түгел, рәсемче дә түгел.* М.Җәлил

РӘ́СМӘН *рәв. гар.* Рәсми яктан; рәсми рәвештә. *Гәрчә гәзитнең рәсмән мөхәррире һәм нашире башта М.Путиляков, аннары Ф.Туктарый һәм С.Рәмиев исәпләнсәләр дә, «Таң йолдызы»ның фактик җитәкчесе, аңа рух биреп торучы кеше Г.Исхакый була.* Р.Әмирхан

РӘСМИ *с. гар.* **1.** 1) Хөкүмәт, администрация, урындагы кеше тарафыннан билгеләнгән, расланган, шулар тарафыннан чыгарылган; шулар катнашында үткән. *ГДРда үткән бер рәсми чарада Дин Рид Советлар Союзында төшерелгән «Карл Маркс. Молодые годы» кинофильмында Женни Марксны уйнаган өчен Ленин премиясенә лаек булган актриса Рената Блюме белән таныша.* Кызыл таң. *Мәдрәсә ачылган көннән бирле шул киенү гадәтен кертергә, аны мәдрәсәнең рәсми формасы итәргә бөтен көчләрен куялар.* Безнең гәҗит

2) Хөкүмәт тарафыннан куелган, билгеләнгән, законлы. *Муса Мусалаев узган ел Татарстан президенты фәрманы белән 2013 елда Казанда узачак Универсиаданың рәсми илчесе итеп билгеләнгән иде.* Ватаным Татарстан. *Рәсми делегация Уфа тимер юл вокзалын карагач, бу документка кул куелды.* Кызыл таң

3) Легаль; хөкүмәткә, администрациягә караган; закон тарафыннан билгеләнгән. *А.Әхмәдуллинның гыйльми, тәнкыйди, педагогик һәм иҗтимагый эшчәнлеге җәмәгатьчелек, рәсми оешмалар тарафыннан һәрчак уңай бәяләнеп килде.* Х.Миңнегулов. *Аңарчы да эфирга чыгулар тәҗрибә рәвешендә булса да, рәсми телевидение тарихы шушы датадан башлана.* Безнең гәҗит

4) Хөкүмәт документларына, эш кәгазьләренә хас булган. *Рәсми стиль шулай ук татарчалашмады, татар теленә күчеп, хокукый, хакимият, идарә, дипломатия өлкәләрендә хезмәт итә башламады.* Фән һәм тел. *Рәсми телдә коры гына «адреслы ярдәм» дип аталган гамәлне Лилия ханым болай аңлата: «Бик нык сусаган чакта бер чынаяк чиста суы адәмне коткарып калала, ә эчәсе килмәгәндә, ул аның күзенә дә чалынмый».* Кызыл таң

5) Кабул ителгән формага туры китереп үткәрелә торган, барлык формаль яклары сакланган. *Мөхәммәд Әминнең татарча язылган рәсми хаты, ягъни бетеге (битиге), Хәким Бирде исемле илчесе аркылы 1506 елда Польша хөкемдары Александрга җибәрелә.* Х.Миңнегулов. *Туплы хоккей Халыкара олимпия комитеты тарафыннан --- әлегәчә кышкы Олимпия уеннарының рәсми программасына кертелмәгән.* Шәһри Казан

6) *күч.* Бик тыйнак, салкын; үтә җитди. *Инһаять, Талиянең әле рәсми, әле ипле-ягымлы яңгыраган тавышы ике ирне дә ипкә китерде, тын калдырды.* Г.Галиева

2. *рәв. мәгъ.* 1) Закон нигезендә. *Һәм бу затлы исемнең Мөхәммәт ага Мәһдиевкә рәсми бирелгәнен ишетү чын әдәбиятка мөкиббән меңнәргә --- сөенечле бер вакыйга булганына иманым камил.* М.Галиев. *Ел башыннан бирле исә 60 пар рәсми никахлашкан.* Безнең гәҗит

2) Стиль ягыннан коры, формаль. *Сүзләр авыр вә рәсми бардылар, авыр вә салкын булып, бер-берсе белән оешмыйча калдылар.* Ф.Әмирхан

РӘСМИЛӘШТЕРҮ *ф.* 1) Законлаштыру, закон нигезендә раслау, рәсми көч бирү, рәсми форма бирү, гамәлгә кертү. *Икетеллелекне дәүләтнең махсус кануны белән рәсмиләштерү*

2) Рәсми төс бирү, теркәү. *Әхмәровны тизрәк алтарь каршына бастырырга, христиан диненә күчүен тизрәк рәсмиләштерергә кирәк.* Т.Миңнуллин. *Ислам белән Зәлия никахларын рәсмиләштерә, тыныч кына яши башлый, мәхәббәт җимешләре булып Ләлә дөньяга аваз сала.* Безнең гәҗит. *Матбугат тарихына кереп калган Әгъләм Зараев булып ул малай чагыннан йөргән һәм 1951 елның сентябрендә шушы исем-фамилияне рәсмиләштереп, паспортын алмаштырган.* Кызыл таң

3) Легаль ясау, легальләштерү, законлаштыру. *Исерткеч эчемлекләр җитештерүне рәсмиләштерү. Накротик матдәләр әйләнешен рәсмиләштерү*

4) *күч.* Ныгыту, беркетеп кую. *Мондый транзакция терминаллары пассажирларга Интернет аша заказ бирелгән һәм сатып алынган билетларны бастырып алырга, шулай ук юл йөрү билетын мөстәкыйль рәвештә рәсмиләштереп, аның өчен банк картасы белән түләргә ярдәм итә.* Ватаным Татарстан

Рәсмиләштерә башлау Рәсмиләштерергә керешү. *Узган ел җәй башында моның өчен документлар рәсмиләштерә башладым.* Шәһри Казан

Рәсмиләштерә килү Электән, системалы рәвештә рәсмиләштерү

Рәсмиләштереп бару Эзлекле рәвештә һәрберсен, булган берсен рәсмиләштерү. *Фонд аша сафка баса торган йортлар төзелеп бетү белән, яшьләргә дигәнен рәсмиләштереп баралар икән.* Ватаным Татарстан

Рәсмиләштереп бетерү Тулысынча рәсмиләштерү. *Шулай итеп күпләр йортларын үз исеменә рәсмиләштереп бетерде.* Татарстан яшьләре

Рәсмиләштереп җибәрү Бераз рәсмилек бирү; тиз арада рәсмиләштерү

Рәсмиләштереп җиткерү Бөтен шартларны да үтәп, тиешенчә рәсмиләштерү

Рәсмиләштереп калу Рәсмиләштерергә өлгерү. *Моннан 15 еллап элек бакыйлыкка күчкән иптәше, кызганыч, үз хокукларын рәсмиләштереп калырга җитешмәгән.* Акчарлак

Рәсмиләштереп кую Рәсмиләштерелгән хәлгә китерү, законлаштыруны төгәлләү. *[Зөфәр:] Дөресрәге, безнең килешүне беркадәр рәсмиләштереп куярга кирәктер, дип уйлыйм.* Ә.Еники. *Документларыгызга да күз төшерик әле. --- Ярар, калдырыгыз, эшкә урнашуыгызны рәсмиләштереп куярбыз.* Ә.Дусайлы

Рәсмиләштереп тору Әле, хәзерге вакытта рәсмиләштерү; һәрвакыт, гел рәсмиләштерү; рәсмиләштерү белән шөгыльләнү. *Көннәрдән бер көнне ул үзе иҗат иткән сыннарны сәнгать музейханәсенә тапшырды да, бибәһа зур бүләген рәсмиләштереп тә тормастан, тәвәккәлләп, Петербург каласына юл тотты ---.* А.Тимергалин. *Өстәвенә, аны даими рәсмиләштереп торырга кирәк.* Ватаным Татарстан

РӘСМИЛӘШҮ *ф.* Законлашу, законлыга әйләнү, закон көченә керү, рәсми форма алу, рәсми төс алу. *Ул СССР Язучылар берлеге рәсмиләшкән беренче көннән үк (1934) аның тулы хокуклы члены иде.* Ә.Дусайлы

Рәсмиләшә бару Торган саен ныграк рәсмиләшү. *Сабан туе турында язуымның да сәбәбе шул: бәйрәмебез елдан-ел рәсмиләшә бара.* Татарстан яшьләре

Рәсмиләшә башлау Рәсмиләшүгә табан йөз тоту

Рәсмиләшеп бетү Тәмам, тулысынча рәсмиләшү

Рәсмиләшеп җитү *к.* **рәсмиләшеп бетү**

Рәсмиләшеп калу Ниндидер сәбәптән соң рәсмилек алу

Рәсмиләшеп килү Акрынлап рәсмилек ала бару

РӘСМИЛЕК *и.* 1) Эшнең, мәсьәләнең рәсми ягы, тәртибе, кагыйдәләре. *Хөкемне башлап җибәрү өчен кирәкле гадәттәге рәсмилекләр үтәлеп, гаепләнүчеләр һәммәсе барланып-тикшерелеп чыгылгач, залда утыручылар арасыннан шаһитлар – Сабиржан мәзин, Фәйзулла староста, Гыймади карт һәм Таҗиның туган энесе Вафа куштан – хөкем өстәле янына чакырылдылар.* М.Галәү

2) Мөгамәләдә дистанция саклау; сүздә корылык, салкынлык. *Моңарчы судта булмаган, суд тәртибе күрмәгән Гөлчирә бу үтә рәсмилекне авырга алды.* Ф.Хөсни. *Идарә башлыгы, аягөсте торып сөйләшүнең рәсмилекне арттыра төшүен шәйләп, урынына утыргач, халык бераз тын торды.* Р.Кәрами

РӘСМИЯТ *и. гар. кит. к.* **рәсмилек**. *Көн үтә-үтә вә никадәр бер-берсенә үзләшеп китеп, эч пошканда килү-китүләр рәсмият даирәсеннән күптән чыкса да, Шәмси һәрвакыт үзен өйләнмәгән, җае туры килгәндә өйләнәчәк бер егет итеп хис итүдән туктамады.* Г.Исхакый. *Әгәр рәсмият таләп иткәнчә, теге яки бу очрашуларга Фәрит Мөхәммәтшин хатыны белән килергә тиеш булса, әлбәттә, андый очракта мин дә барам.* Сөембикә

РӘСМИЯТСЕЗ *с. кит.* **1.** Рәсми булмаган, рәсмилек сакламаган. *Бернинди рәсмиятсез, дусларча гына җавап кайтарды*

2. *рәв. мәгъ.* Рәсми булмаган рәвештә, рәсмилек сакламыйча

РӘССАМ *и. гар. кит.* Рәсем сәнгате өлкәсендә иҗат итүче, художник. *Училищеда рәсем сәнгатеннән укыткан атаклы рәссам!* Г.Гыйльманов. *Әнә шул могҗизаны хасил итүдә рәссам Әхәт Закирның өлеше бәһаләп бетергесез зур.* Р.Батулла

РӘССАМЛЫК *и.* Рәссам һөнәре, рәссам булу. *Әгәр дә кечкенәдән мөмкинлекләр тудырсаң, вакытында талантын ачарга булышсаң, балаларның күбесендә шагыйрьлек, рәссамлык яисә композиторлык сәләте ачылган булыр иде.* Р.Миңнуллин

РӘСҮЛ *и. гар. дини* Пәйгамбәр, Алланың җирдәге илчесе. *Рәсүл әкрам саллаллаahү галәйhи вә сәллəм янә әйткән: «Дөреслектә Коръәндә бер сүрә бар, ул сүрә укучыга шәфәгать китерер һәм тыңлаучыга ярлыкау эстәр».* Дога китабы

◊ **Рәсүл тырнагы** Изге саналган, кадерләп сакланган нәрсә. *Киләчәк буын өчен мирас булып калган һәр истәлек, еллар узгач, рәсүл тырнагыдай кадерле ядкәргә әйләнәчәк!* Безнең гәҗит

РӘТ *и. рус* **1.** 1) Берсе янына берсе урнашкан, бер-бер артлы яки бер сафка тезелгән кешеләр, әйберләр җыелмасы. *[Авыл картлары] Тип-тигез өч рәт булып сафка басканнар, кулларын колак янына күтәргәннәр ---.* М.Мәһдиев. *Июль башында рәт арасын 25 сантиметр, һәр яшелчә арасын 20 сантиметр итеп, кышкылыкка дигән тормаңы чәчәләр.* Кәеф ничек?

2) Саф, шеренга. *Ротаның арткы рәтендә кызылармеец Зариф, алдан баручы иптәшләренең тигез генә тирбәлгән аркаларына карап, салмак кына атлап бара.* Ә.Еники

3) Театр, кино һ.б.ш. урыннарда буйга тезеп куйган урындыкларның бер-

бер артлы чираты. – *Беренче рәт, уникенче урын, – дип, каядыр йөгерде, күп тә узмады, тагын йөгереп килде.* Р.Батулла. *Нигәдер ул, Кәримә янына килмичә, дәшми-тынмый, мыштым песи сыман хәрәкәтләр ясап, иң арткы рәтләрнең берсенә барып утырды.* Ф.Яхин

4) Бер төрле товарлар сату өчен, базарда бер буйга урнашкан ларёк яки прилавкалар тәртибе. *Рәт буйлап базар корольләре йөри, алар яхшы киенгән, ялтыравыклы эштиблитләрдән, мыеклары өскә каратып бөтерелгән.* Р.Батулла. *Базар рәтләрен күзләп йөргәндә, ул киң тәрәзәле, биек ишекле кибеткә юлыкты*. Р.Низамиев

5) Урамның бер ягына тезелеп киткән йортлар теземе. *Ә менә универмаг рәтендәге өйләрнең барысының да диярлек ишек төпләрендә, тәрәзә каршыларында чәчәкләр үсеп утыра.* Кызыл таң

6) Өй бурасының дүрт яклап куелган бер әйләнәсе; ниргә. *Бер рәт бүрәнә, ягъни ниргә куелып беткәч, нигез ботказы ашала*. Татар халык ижаты. *Дини китапларда, йорт җиткергәндә, «Һәр көндә бер рәт салу сөннәт булыр (таш бинада кирпечне бер рәт тезү, агач бинада бүрәнәне бер рәт салу)» дигән юллар бар*. Безнең гәҗит

7) Бәйләмдә башыннан ахырына кадәр бер кабат бәйләп чыгылган тезем яки әйләнә. *Ике рәт бәйләгәч, башка төскә алмаштырабыз, биш рәт бәйлибез.* Сөембикә

8) Аслы-өсле салынган әйберләрнең бер катламы. *Агач кап төбенә коры ком салып, рәт итеп алманы тезеп чыгабыз*. Бакчачы киңәшләре

9) Билгеле бер төркемдәге һәр кешегә бер тапкыр әйләнеп килгән чират. *Тоткасыз чынаяк инде берничә рәт әйләнеп чыкты.* Ш.Камал

10) *күч.* Берәр нәрсәнең тәртибе, җае, нечкәлекләре. *Баксаң, Артём әнисенең ноутбугында казынып, Интернетка чыгуның рәтен бозган икән*. Татарстан яшьләре

11) *күч. сөйл.* Чират, нәүбәт. *Карлыгач тотып өлгерә алмый; җегет аны куып җитеп, сүз әйтеп авыз йомылганчы, бөркет коштай кагына биреп, Сылуның биленнән ала да үзенә тарта; ат туктый, кызның аяклары – өзәңгедән, үзе иярдән чыгам дигәндәй асылынып кала, егылырга рәт җитә.* Г.Ибраһимов. *Шулай итеп, әкренләп бер-берсен ега-ега, зурларга көрәшергә рәт җитте*. М.Гали

12) *күч. сөйл.* Мөмкинлек; барлык, байлык, җитешлек; акча. *Райбашкарманың да, безнең дә анлык рәт югын сез үзегез дә әйбәт беләсез.* Х.Хәйруллин. *Ресторан-мазарларына «рәт тә юк», хәер, моны миннән көткән кеше дә юк*. Р.Гаязетдин

13) *күч.* Кемнәр, нинди кешеләр исәбендә, арасында саналу, нинди сыйфатларда исәпләнү; кешенең даирәсе. *Картәтәй бик үк риза булмаган, ләкин ул каршы килгән саен, яшь бабай, киреләнеп, алдынгылар рәтендә йөри биргән.* Н.Фәттах

14) *күч.* Уңай, җае туры килгән вакыт, форсат. *Сүз рәте килгәч, итәм әзрәк бәян.* Г.Тукай

15) *күч.* Инкяр итә торган сүзләр белән килеп, берәр нәрсәнең сыйфат, көч һ.б.ш. яктан начар, зәгыйфь булуын аңлата. *Исән агачларның да рәте юк: кабыкларын гөмбә, мүк баскан.* Р.Мостафин. *[Бәрәңгенең] Сирәк-мирәк чыкканнарының да рәте юк, июль ае булуга карамастан, төбенә өярлек булып та үсмәгәннәре күп.* Ватаным Татарстан

16) *күч.* Юнь, мәгънә, уңай нәтиҗә, файда. *Әгәр сине биредә күрсәләр, икебезгә дә рәт булмас.* Р.Батулла. *Укуының да рәте булмады, эшләп тә кинәндермәде колхозны.* Ф.Шәфигуллин

2. *рәв. мәгъ.* Мәртәбә, кат, тапкыр. *Мулла абзыйга әллә ничә рәт бардым: «Ул бит ир хатыны, дим, мулла абзый, ничек итеп сез бу эшне тиз генә бетереп куясыз?»* Ш.Камал. *[Һади Такташ] «Кабил белән Һабил» дигән 26 юллык шигырен --- беренче рәт укыганда, Нургали ага Надиев та бар иде.* Мәдәни җомга

3. *бәйл мәгъ.* Төсле, кебек, сыман. *Тәннәр булыр җир белән бер рәт.* Р.Гарифуллин

◊ **Рәт бетү** 1) Мөмкинлекләр бетү, тормыш хәле начарлану, таркалу. *Өч ел эчендә өч миллионга якын кеше кырылган, төрмәләрдә газапланган, бигрәк тә кытай яисә кхмер булмаганнарга рәт беткән.* Р.Рахман; 2) Сәламәтлек начарлану, какшау. – *Кояш яктысы күрмичә ятып рәт беткән, – дип мыгырдады яшь гыйфрит, еш-еш сулап*. З.Мәхмүди; 3) Бозылу, сыйфаты начарлану; яраксыз хәлгә килү. **Рәтен белү** Берәр нәрсәнең җаен, тәртибен белү. *Былгахтирия рәтләрен беләсеңме соң? Телгә үткен булсагыз да, эшкә чамалы буласыз шул.* К.Тинчурин. *Шәяхмәтне куян фермасына куйдылар: авылда куян асрауның рәтен белгән кеше бары тик ул гына иде*. М.Мәһдиев. **Рәтенә төшенү** Берәр нәрсәнең тәртибен, җаен аңлау, белү. *Хатыны бу тимерне әйләндереп-әйләндереп карый да, бер дә рәтенә төшенмәгәч, авызына каба.* М.Мәһдиев. *Хәзер бер рәтенә төшенеп, тәҗрибә туплагач, алай куркыныч түгел*. Р.Мостафин. **Рәтен җибәрү** Берәр нәрсәне бозу, җимерү. *Җай гына барган тормышның рәтен җибәрде*. **Рәтен табу** Чарасын табу, җайлау, берәр эшнең асылын, башкару тәртибен аңлап алу. *Мин бу хакта бер иптәшкә язу калдырырмын, ул берәр рәтен табар.* А.Алиш. *Хәер, шома, үткен Михаил биредә дә югалып калмас, үз кесәсен калынайту рәтен табар...* Безнең гәҗит. **Рәте чуалу** Тәртибе бозылу. *Бөтен кеше берьюлы тиз-тиз эчсә, исереп бетәләр дә, мәҗлеснең рәте чуала.* Р.Батулла. **Рәткә кермәгән** Юлдан язган, бозылган, тәртибе беткән. **Рәткә кертү** 1) Берәр нәрсәне тәртипкә салу, тәртипкә китерү; эзлекле бер уйга, фикергә килү. *Сабир берникадәр баскан җирендә үйларын бер рәткә кертте, бу зур эшне башкарып чыгар өчен, ни-нәрсәдән башлап җибәрергә кирәк икәнен үзе өчен ниятләде.* В.Ильясов; 2) Берәр нәрсәне рәтләү, төзәтү, уңайлау. *«2012 ел – тарихи-мәдәни мирасны саклау елы» дип игълан ителгәч, татар җәмәгатьчелеге, Казанның Татар бистәсендәге биналарны рәткә кертүгә дә аерым игътибар булыр, дип өметләнә*. Р.Батулла. **Рәткә керү** 1) Тәртипкә салыну, тәртипкә килү; 2) Рәтләнү, төзәлү, уңайлану, терелү. *Хәлен белешергә кергән күрше-күләнгә*

ул, кып-кызыл чыраена мескен кыяфәт чыгарып: «Менә чирләп киттем бит әле... Белмим, рәткә кереп булырмы», – дип зарланырга гадәтләнеп китте. И.Хәйруллин; 3) Хәл, тормыш яхшыру. **Рәткә килү** *к.* **рәткә керү**. *Кайбер табиблар, вакыт алмашканнан соң, кешенең иммун системасы өч атна дәвамында рәткә килә алмый, кеше көчле стресс кичерә, дип исәпли.* Безнең гәҗит. **Рәткә китерү** *к.* **рәткә кертү**. *Җәйге ялдан соң эшкә чыгар алдыннан, чәч-башны рәткә китерергә дип, тагын шунда киттем.* Шәһри Казан. *Һәр җәй саен Камилә, берничә мәртәбә зиратка килеп, әби-бабайлары, әти-әнисе, туганнары рухына дога кылып, кабер өсләрен чистартып рәткә китерә, чәчәкләр куя.* Безнең гәҗит. **Рәткә салу** Тәртипкә китерү, җайга салу. *Пар вә электрик куәтләрен дә болар ачтылар, аларны үзләренә хезмәт кылдырдылар, гыйлем вә дәрәҗә юлында хәятларын рәткә салдылар.* Г.Бубый. *– Пенсиягә чыккач, башка эш белән шөгыльләнмичә, мин шушы кулъязмаларны рәткә салып, күптомлык итеп әзерләргә уйлыйм! – диде галим.* Р.Батулла. **Рәт китү** *к.* **рәт бетү**. *Кунак килгән саен, аракы-шәраб эчелә, бәхәс-кычкырыш башлана дигәндәй, элек сирәк эчә торган әти кеше салырга әвәсләнеп, тормышның рәте китте.* Р.Батулла. *Икесе дә укып бетермәгән, шуның өстенә бала да бар, алар еш кына талаша башлады, бергә яшәүләренең рәте китте.* Безнең гәҗит. **Рәт күренмәү** Берәр нәрсәнең булуына өмет баглый алмау, ышана алмау. *– [Сугыш туктагач] Тормыш рәтләнергә мөмкин, – диде [Мохтар]. – Шулай гына булмаса, хәзергә бер дә рәт күренми.* Ш.Камал. **Рәттән чыккан** *к.* **рәткә кермәгән**. **Рәт хастасы** Киң таралган эпидемия характерындагы авыру турында әйтелә. *Әйе шул, хәзер теш авыруы рәт хастасы булып йөри.* Ак юл. **Рәт чыгару** Файдалы, эшкә яраклы нәрсә булдыру; үз дигәненә ирешү, җаен табу. *Йөрепйөреп тә рәт чыгара алмагач, печән кибәне итәгенә чүгәләп тешләрен кайрады, иреннәрен ялап, улап та алды.* Р.Мөхәммәдиев. **Рәт чыгу** 1) Җае, вакыты туры килү; 2) Көтелгән эш, файда, уңай нәтиҗәгә ирешү, берәр нәрсә булу. *Шуннан әлеге Бугаз Кәбире әйтә: «Миннән дә, Гыйният, рәт чыкмады, иң яхшысы сезне тыкрыктан үткәрмәскә булган икән», – ди.* З.Зәйнуллин

РӘТКӘ *рәв. диал.* Тоташтан, тукталышсыз. *Бу Яңил егете икән, калада өч ел рәткә батыр калып, алтын сәгатьләр алган, ди.* М.Гали

РӘТЛӘНҮ *ф.* 1) *төш. юн.* Төзәтелү, эшләнү, яңартылу. *Хәзер инде ул яктан караганда либретто шактый рәтләнгән һәм, гомумән, бербөтен сюжеты булган, тыгызайтылган әсәр булып күз алдына килеп баса.* М.Җәлил. *Көзге уңыш җыелган, мал азыгы әзерләнгән, утын юнәтелгән, йорт-куралар рәтләнгән.* Г.Гыйльманов

2) Билгеле бер тәртипкә килү, җайга салыну. *Кайчан да булса барыбер Балканда да, Гыйракта да, Көньяк Осетиядә дә, Днестр буенда да, Чечняда да тәртип урнаштырылачак, Конституция буенчамы, әллә башка юл белән ме – барысы да җайга салыначак, рәтләнәчәк.* Мәдәни җомга

3) Җайлану, көйләнү, барып чыгу. *– Хәзер, хәзер... барысы да рәтләнер! – дип, Фәләх аның артыннан дәшеп караса да, туктамады.* В.Нуруллин

4) Яхшыру, әйбәтләнү (тормыш, һава һ.б.). *Шомлы булса да тормышлар бераз рәтләнде дип торганда гына, ачлык башланды.* Р.Батулла

5) Төзәтенү, кием-салымны, гомумән тышкы күренешне тәртипкә китерү. *Габдуллажан кызына: «Теге мутный күлмәкләреңне киеп, рәтләнеп, әзерләнеп тор», – ди.* М.Хәсәнов

6) Төрле аңлашылмаучылык, каршылыклар юкка чыгу, бетү. *Һәм аннары – яшьләр бит әле, гомер-бакый болай бармас, киләчәктә (кем белә, дөнья бу!), бәлки, рәтләнер барысы да.* Казан утлары

7) Терелү, уңайлану, савыгу, алга китү (сәламәтлек, авыру кеше тур.). *Моннан ел ярым элек ул [ир] шулай кинәт торыксыз, телсез, колаксыз калды. Ятмаган больницасы, күрсәтмәгән профессорыбыз калмагандыр. Вакыты-вакыты белән чак кына рәтләнгән дә кебек күренгәли иде баштарак.* Ф.Хөсни. *Бала хастаханәләрдә озак дәваланганнан соң гына рәтләнә.* Ватаным Татарстан

Рәтләнә бару Акрынлап, аз-азлап рәтлерәк була бару; торган саен ныграк рәтләнү. *Әмма тормышлар елдан-ел рәтләнә бара иде.* Ә.Рәшит. *Мозаффар агайның да сәламәтлеге рәтләнә бара: мендәреннән башын күтәрерлек хәл кергән.* Ф.Баттал. *Әни ярый әле, озаграк яшәп, тормышның рәтләнә баруын бераз күреп китте.* Татарстан яшьләре

Рәтләнә башлау Рәтләнүгә табан үзгәрү. *Йорт-җир тирәсе дә рәтләнә башлады.* Һ.Такташ. *Сөмбел рәтләнә башлады, тәненә әзрәк ит тә кунды, бит очлары да алсуланды.* З.Кадыйрова

Рәтләнә төшү Бераз рәтләнү; тагын да рәтләнү. *Операциядән соң, хәлем әзрәк рәтләнә төшкәч, сестрадан укырга берәр нәрсә алып килүен үтендем.* Г.Әпсәләмов

Рәтләнеп бару *к.* **рәтләнә башлау**. *Хәзер менә рәтләнеп барам.* Р.Батулла

Рәтләнеп бетү Тәмам, тулысынча рәтләнү. *Рәтләнеп бетеп, ишек төбендә туктап бер тын алгач, мин залга чыктым.* Ә.Еники. *Әле 50 нче елларда да тормыш рәтләнеп бетмәде*. Татарстан яшьләре

Рәтләнеп җитү Тиешенчә, тиешле дәрәҗәдә рәтләнү. *Белмим, баш һаман да рәтләнеп җитми әле.* Г.Бәширов. *Шәһәр көннән-көн байый бара, сугыштан соң әле рәтләнеп җитә алмаган кибетләргә көннән-көн яңа товарлар чыга тора.* М.Мәһдиев. *Ләкин нәкъ рәтләнеп җитте дигәндә генә тагын Ленин яки Ельцин кебек бер акыллы баш реформатор табылыр да яңабаштан үзгәртеп кора башлар, илне янә киregә өстерәр*. И.Хуҗин

Рәтләнеп килү Акрынлап, аз-азлап рәтләнә башлау. *Менә бу яңа авырулар рәтләнеп килә торган сәламәтлекне тагын да какшаталар, борчыйлар*. Г.Ибраһимов. *Хәзер ярый инде, рәтләнеп киләм.* Г.Бәширов

Рәтләнеп китү Соңгы вакытта, ниндидер сәбәптән соң гына рәтләнү.

Тик икенче көнне генә эшләр рәтләнеп китте. М.Гафури. *Сугышны, гадәттә, эчке хәле рәтләнеп киткән, куәт, дәрт алган дәүләтләр башлаганнар.* М.Мәһдиев. *Дуслар килгәч, бәлки әле, Мәрьямнең дә хәле рәтләнеп китәр.* Ф.Яруллин

Рәтләнеп тору Әле, хәзерге вакытта рәтлерәк булу. *Акча ягы рәтләнеп тора.* Һ.Такташ

РӘТЛӘП *рәв.* 1) Рәт-рәт итеп, рәтләр ясап. *Кемнәрдер ишек төбенә рәтләп тезелгән мендәр, сумка кебек юл әйберләрен алып чыкты.* Г.Ибраһимов

2) Җиренә җиткереп, тиешенчә. *Ике атын да рәтләп карамый.* Ф.Кәрим. *Бактың исә, батыр кенәз ат өстендә рәтләп сугыша белмәгән икән ләбаса!* М.Хәбибуллин

3) Яхшылап, юньләп. *Аның баш мие шулхәтле чуалган, ул бернәрсә дә рәтләп уйлый алмый иде.* Ш.Камал. *Аның ничә яшьтә икәнлеген һичбер кеше ачык белмәгәнлеге шикелле, ул үзе дә рәтләп белми.* Р.Гали. *Берзаман җир дә рәтләп күренми башлады.* Мәдәни җомга

4) Канәгатьләнерлек, кирәгенчә, җитәрлек дәрәҗәдә. *Рәтләп дөнья яктысын да күрә алмый...* Н.Хәсәнов. *Өч көн буе рәтләп йокы күрмәгән организм бирешә башлады.* Х.Ширмән. *Әле рәтләп кар да ятмаган.* Ватаным Татарстан

РӘТЛӘ́Ү *ф.* 1) Рәт-рәт итү, рәтләргә тезү

2) Билгеле бер тәртипкә китерү; җайга, көйгә салу. *Кызлар, киленчәкләр, бүз балалар уен-көлке, шау-шу белән шул арбалар тирәсендә нидер бәйләп, төргәк-төргәк киезләрне, җон тутырылган капчыкларны рәтләп азапланалар иде.* Г.Ибраһимов. *Концертмейстер ноталарын рәтләп утыра, балалар хәрәкәтләр кабатлый.* Р.Батулла

3) Нәрсәне дә булса уңайлау, җайлап кую. *Аркалык бавын рәтләп булашкан юлчы карт Хәлимгә игътибар да итмәгән кебек.* Г.Гыйльманов. *--- егет иңбашындагы каешларын рәтләп, җайлабрак утырып алды да акрын гына гармунын тартып җибәрде.* З.Мурсиев

4) Төзәтү, нинди дә булса эшкә яраклы, файдаланырлык хәлгә китерү. *Ник бер мәртәбә булса да кайтып, ике пулән утынын ярып, коймасын рәтләп яисә бакчасын казып китмәдең?* Г.Гыйльманов. *Электр тоташтыргычын рәтләгәч, чәй эчәргә утырыштык.* Р.Батулла. *Тәрәзәсен рәтли, ишек ясап куя.* Безнең гәҗит

5) Төзәтенү, кием-салымны, гомумән тышкы күренешне тәртипкә китерү. *Башына чөелгән яулыгын рәтләргә дә онытып, түр тәрәзәгә барып капланды.* Р.Мөхәммәдиев. *Чәчен тарый, матурлана, мыегын рәтли, бәләкәй көзге алып, арт чүмечендәге чәчен карый, үзенә-үзе соклана.* Р.Батулла. *Хыялыйның сүрелә башлаган күзләре тагын очкынлана, күлмәк якасын рәтли, такыр башын сыпыра.* Ф.Яхин

6) *күч.* Җайлау, көйләү, оештыру (мәс., эшне, тормышны). *Анда теләсә нинди эшкуарлыкка кирәкле рөхсәт кәгазьләрен дә шулай ук өч-дүрт көн эчендә рәтләп була икән.* Р.Вәлиев. *Чит илләрдән килгән долларларга, бәлки, тормышны рәтләп булыр?* Татарстан яшьләре

7) *күч.* Яхшырту, әйбәтләү. *Эшкә урнашу, яшәү өчен үзеңә почмак табу кайгысы, кеше күзенә күренерлек өсбаш рәтләү яклары алга килеп басты.* Ф.Хөсни. *--- шуны әйтим: син, Хәйдәрем, базардан кабак төшен алып көнбагыш урынына чиертеп йөр, эчне бик рәтли, ди.* Ватаным Татарстан

8) *күч.* Булган кадәрле әйберләрдән әзерләү, нәрсә дә булса юнәтү, әмәлләү. *– Безгә кәбестә шулпасы, солдат боткасы рәтли алсаң, баштан ашкан, – ди.* Ә.Дусайлы

Рәтләп алу Тиз генә рәтләү. *Хәлим, алгарак талпынып, аркасындагы капчыгын рәтләп алды да, артыш таякка таянып, таш юл буйлап китте.* Г.Гыйльманов

Рәтләп бетерү Барысын да тулысынча, ахырга кадәр рәтләү. *--- юлларны бүген үк рәтләп бетерергә кирәк.* Г.Гыйльманов

Рәтләп җибәрү Бераз, берникадәр рәтләү, рәтләгәндәй итү

Рәтләп йөрү Әле, хәзерге вакытта рәтләү белән шөгыльләнү. *Без --- иртәдән кичкә хәтле көрәкләр, казылмалар белән юл төзәтеп, юл рәтләп йөридер идек.* Ш.Камал

Рәтләп калу Рәтләргә өлгерү, мөмкинлектән файдаланып рәтләү. *Бурычлылар бурычларын түләргә, атсызлар ат алырга, өйсезләр өй салырга, улы җиткәннәр килен алырга, кызы җиткәннәр кыз биреп туй ясарга – һәркем шулай бу байлыктан үзенең дөньясын рәтләп калырга уйлый.* Г.Ибраһимов

Рәтләп карау Рәтләргә тырышу, рәтләргә омтылу

Рәтләп кую Рәтләнгән хәлгә китерү; алдан рәтләү. *Ярмөхәммәт маллар өстендәге каплавычларны рәтләп куйды.* Р.Батулла. *Абзарның түбәсе тишелгән, яңгыр үтә икән, салкыннар башланганчы рәтләп куярга кирәк.* Х.Ширмән

Рәтләп тору Һәрвакыт, гел рәтләү. *Каралты-курасын рәтләп тора.* Р.Батулла

Рәтләп утыру *сөйл.* Әле, хәзерге вакытта, сөйләү моментында рәтләү. *Исхак агай, чабата башларга дип, юкәләр рәтләп утыра.* Һ.Такташ

Рәтләп чыгу Башыннан ахырына кадәр рәтләү

Рәтли башлау Рәтләргә тотыну. *Шул арада карт кайдандыр иске вә алама гына күренештә мандолинага охшашлы бер нәрсә чыгарды да, утырып, кылларын рәтли башлады вә берничә мәртәбә үткен генә чиертеп тә җибәрде.* Ш.Камал

Рәтли бирү Рәтләвен дәвам итү, һаман да рәтләү. *Кара бөдрәле чәчләрен, кысынкы күзләрен, ак йөзен сыпыргалап, көзге алдында Игорь ак якалы күлмәген рәтли бирә, кара буйлы галстугын төзәтеп ала.* Ф.Яхин

Рәтли төшү Тагын да бераз рәтләү

РӘТЛӘШТЕРҮ *ф.* 1) Аннан-моннан, җиренә җиткерми генә тәртипкә китерү, тиз генә, якынча тәртип булдыру. *Ике-өч көнгә бер мәртәбә Ирек авылга кайта, маллар астындагы тиресне чыгара, абзар-курадагы сынган-купкан урыннарны рәтләштерә.* Ф.Садриев. *Җимерек ферманы рәтләштереп, шунда сыерлар алып кайтып, эш башлап җибәрдем.* Мәдәни җомга

2) *күч.* Тартып-сузып, көч-хәл белән уңайлау, рәткә салу (эшләрне, тормышны, материаль якны һ.б.)

Рәтләштерә төшү Бераз, берникадәр рәтләштерү

Рәтләштереп алу Тиз генә рәтләштерү. *Пластинкалар уйналып беткәч, Зәлия сүстәй эре бөртекле чәчләрен, ике кулын өскә күтәреп, рәтләштереп алды.* Х.Камалов. *Габдрахман маклер да, озын какча йөзен сыпырып, куе сакалларын рәтләштереп алды.* Ф.Яхин

Рәтләштереп йөрү Рәтләштерү белән мәшгуль булу. *Берсе биек баскычка баскан да чаршауларны түшәм астына беркетә, икенчесе чүпрәкне астан тартып, рәтләштереп йөри.* М.Маликова

Рәтләштереп җибәрү Аз гына рәтләштерү

Рәтләштереп кую Алдан рәтләштерү

РӘТЛЕ *с.* **1.** 1) Юньле, әйбәт, яхшы тәрбия алган. *Әгәр дә без Р.Яхинның җыр, романсларын аңларлык дәрәҗәгә дә үсә алмасак, беркайчан да рәтле халык та, дәүләт тә була алмаячакбыз.* Р.Вәлиев. *«Бар, ничек булмасын!» – диде ул һәм архивыннан «Рәтле кешеләр» (1959) китабын кулыма тоттырды.* Ә.Дусайлы

2) Акыллы, төпле, кирәкле, юньле. *Ни хәтле тырышып уйлап та, башыма бер рәтле фикер килми!* Ш.Фәрхетдин

3) Канәгатьләнерлек, нормаль, тиешле дәрәҗәдәге. *Монда килеп урнашкач та, без бөтен көчебезне куеп, рәтле тормыш корып булмасмы дип тырыштык, әмма бернигә дә ирешә алмадык.* М.Галәү

4) Нинди дә булса таләпләргә туры килерлек, җавап бирерлек, канәгатьләнерлек; яхшы. *Газнәви Габдулычтан соң рәтле председатель күрмәде инде «Үрнәк» колхозы.* Г.Мирһади. *Кулымда рәтле һөнәрем юк, хәлемә керер кешем юк.* М.Маликова

5) Тәртипкә китерелгән, яхшы итеп эшләнгән. *Гомер-гомергә олы трассадан читтә яшәп, рәтле юл күрмичә чиләнгән авыллар.* Ватаным Татарстан

2. *рәв. мәгъ.* Тиешенчә, тиешле дәрәҗәдә. *Нурия әби, сыерын сауганда бик зур авырлык тоеп, эшен рәтле башкара алмыйча озак газапланды.* Ф.Яхин. *Үзләрендә хәлләр рәтле булса, туган йортларын, гаиләләрен ташлап, шулай чит җирләрдә каңгырап йөрерләр идемени алар?* Татарстан яшьләре

РӘТЛЕ́-БАШЛЫ *с. сөйл. к.* **рәтле**. *Сафагәрәй ханның Казан тәхетенә утырганнан соң кырык ике көн эчендә төн йокламый, рәтле-башлы тәгам җими башкарган эше шушы – Казанны кара яу талавыннан, халыкны әсирлектән, коллыктан саклап калу булды.* Р.Батулла. *Сөйләшер-аңлашыр сүзләре күп, ә үзләре рәтле-башлы берни сөйләшми.* Р.Мөхәммәдиев

РӘТ-РӘТ *рәв.* Рәт (*1 мәгъ.*) белән, берничә саф булып. *Бик хозур рәт-рәт тора гаскәр кеби чыршы-нарат.* Г.Тукай. *Ә аннан рәт-рәт булып үсеп утырган наратлар уч төбендәге кебек күренә.* М.Рәфыйков

РӘТСЕЗ *с.* **1.** 1) Рәте чуалган, тәртипсез, билгеле бер тәртипне сакламаган; буталчык. *Рәтсез исемлек. Рәтсез китаплар өеме*

2) Җайга салынмаган, еш кына кыенлыклар чыгып торган, авыр (эш, тормыш тур.). *Рәтсез заманада бәндәләрнең кадере була димени?* Ф.Яхин

3) Тәртипсез, оештырылмаган, оешуы җитмәгән. *Рәтсез хуҗалык шулай чабу кисеп җиң ямый һәм шуңа күрә һич мантый алмый.* Х.Камалов. *Рәтсез җыелыш*

4) Нинди дә булса эш өчен көйләнмәгән, төзәтелмәгән. *Рәтсез техника. Рәтсез юллар*

5) Берәр нәрсәне булдырырлык, башкарырлык булмаган. *Атларың рәтсез булса, ындырыңда да рәт булмас.* Р.Ишморат

6) Тынычсыз, борчулы, буталчык. *Чиксез хыял дәрьясына чумган шул рәтсез дөньяның бер үги баласына әверелгән Бибинур әкрен генә кайчандыр Шакир белән бергә көйләгән җырны суза ---.* Х.Ибраһим. *Рәтсез көннәр*

7) Юньсез, тәртипсез, мәгънәсез. *Хатын-кызга карата да бик рәтсез булды, мал тотуга, акча тотуга да бик пәрвайсыз булды.* М.Мәһдиев

8) Мәнсез; булдыксыз. *[Кулаев Гөлҗамалга:] Малаегыздан мин риза түгел. --- Рәтсез егет булып чыкты.* Ш.Камал. *Минем кебек рәтсез кешеләргә күрше Бибинур тәтә мондый бәя бирә иде: аяз-аяз көннәрдә җиләк җыяр Исәкәй; яңгыр-яңгыр көннәрдә кибән куяр Исәкәй.* М.Мәһдиев

2. *рәв. мәгъ.* 1) Тәртипсез рәвештә. *Зинһар, барыгыздан да үтенәм, болай рәтсез шауламагыз.* Ш.Мөхәммәдев

2) Җайсыз, уңайсыз. *Аның рәтсез, ашыга-пошыга киенгән аяклары кабарып беткән.* һ.Такташ

3) Вакытлы-вакытсыз, вакытын, урынын, җаен туры китереп тормыйча, теләсә ничек. *Рәтсез йөрсәң, менә шулай була ул.* Т.Гыйззәт

РӘТСЕЗЛӘНҮ *ф.* 1) Тәртибе чуалу, рәвеше, чираты, формасы һ.б. бозылу. *--- соры болытлар, заманча кызларның тузгыган чәчләре кебек рәтсезләнеп, элеватор һәм су башняларына кагылып узалар ---.* М.Мәһдиев

2) Авырлашу, начарлану, рәте китү. *Тормыш рәтсезләнү. Авыллар рәтсезләнү*

3) Юньсезгә, мәгънәсезгә әйләнү, юньсез, мәгънәсез булып китү. *Әдип үз заманы зыялылары арасындагы төрле катлауның рәтсезләнүен --- күрсәтә.* Г.Нигъмәти

Рәтсезләнә бару Торган саен ныграк рәтсезләнү

Рәтсезләнә башлау Рәтсезләнүгә табан бару

Рәтсезләнә бирү һаман да рәтсезләнү, рәтсезләнүен дәвам итү

Рәтсезләнә төшү Бераз, берникадәр рәтсезләнү; тагын да рәтсезләнү

Рәтсезләнеп алу Берара, кыска вакыт эчендә рәтсезләнү

Рәтсезләнеп бетү Тәмам, бик нык рәтсезләнү

Рәтсезләнеп йөрү Гел, һәрвакыт рәтсезләнү

Рәтсезләнеп калу Билгеле бер сәбәптән, хәлдән, вакыйгадан соң рәтсезләнү

Рәтсезләнеп китү Кинәт яки соңгы араларда рәтсезләнү

Рәтсезләнеп тору Әле, хәзер, хәзерге вакытта рәтсезләнгән булу

РӘТСЕЗЛЕК *и.* 1) Тәртипсезлек, таркаулык; буталчыклык. *[Маллар] Дала туздырып чабыша башладылар. Җылкычы атаның кәефе китте. Ул мондый рәтсезлекне яратмый.* Г.Ибраһимов

2) Җайга салынмаганлык, авырлык. *Һәммәбез берәм-берәм авылда эшнең рәтсезлеге --- турында зарлана [идек].* М.Гали

3) Юньсезлек, мәгънәсезлек, мәнсезлек. *Кешеләрнең рәтсезлеге яшәү ямен боза*

4) Сыйфатсызлык, түбән сыйфат. *--- урамның аръягында алма сатканнарын күреп, син мине шунда алып чыктың, алманың рәтсезлеген күргәч һәм минем кабат троллейбус ягына чыгарга чамалавымны сизгәч: – Әйдә, шушы урамнан бераз гына бергә узыйк инде, – дидең.* Ә.Баян

РӘТСЕ́З-ЧИРАТСЫЗ *с.* **1.** 1) Рәтечираты булмаган, буталчык, тәртипсез

2) Юньсез, мәгънәсез

2. *рәв. мәгъ.* 1) Тәртипсез рәвештә, тәртипне саклап тормыйча. *Оя өсләрендә алар томшыкларын суырдылар, карт өянке башында, рәтсез-чиратсыз чыркылдап, чыпчыклар тыпырчындылар.* М.Мәһдиев. *Буталып бетте ул, җөмләләрен дә рәтсез-чиратсыз төзеде.* Х.Ширмән

2) Җайсыз, уңайсыз рәвештә; тиешенчә түгел, теләсә ничек. *Юл саен ритмикасы ике аяклап аксаган, әрифмасы рәтсез-чиратсыз төзелгән мондый шигырьне мин үз гомеремдә беренче тапкыр укыдым бугай.* А.Алиш

РӘТТӘН *рәв.* 1) Берәр нәрсә яки кем белән дә булса янәшә, бер үк рәттә; янында. *Баксаң, урыс җирләренә татар-монголлар түгел, рәттән генә яшәгән татарлар килгән.* И.Хуҗин. *Кайбер галимнәр Җалмавыз карчык образын урыс фольклорында, аеруча әкиятләрдә киң таралган Баба-Яга образы белән рәттән куялар.* Ф.Урманче

2) Берсе артыннан (янына) берсен куеп, тезеп. *Капкорсак патша барлык сарай хезмәткәрләрен җыеп, рәттән тезеп, дер селкетеп тиргәп алды.* Әкият. *Энҗе төсле бу шигырьләрне язып, рәттән тезим.* М.Гафури

3) Беррәттән, бер үк сафта торып, берәүдән дә калышмыйча, бертигез дәрәҗәдә. *Ун яшеннән колхоз эшендә ул зурлар белән рәттән бил бөккән.* Татарстан яшьләре

4) Бер-бер артлы, берсе артыннан икенчесен. *Кинәт сигналын рәттән берничә кат кычкыртып алды.* Ф.Яхин

5) Тоташтан, тукталышсыз. *Берничә көн рәттән килеп шулай яңгыр яуды.* Ф.Яхин. *Моңарчы бер көнен дә калдырмыйча ураза тоттым, алты ел рәттән корбан чалдырдым.* Кәеф ничек?

6) Бер уңайдан, нәрсә белән дә булса бергә, берьюлы. *Төп план эшчәнлеге белән рәттән, фәнни-нәшрият бүлеге хезмәткәрләренә бик күп көндәлек эшләрне дә башкарырга туры килә.* Ш.Асылгәрәев

7) Тоташ, барысын да, берсен дә калдырмыйча. *– Сөйлә, улым, барысын да рәттән сөйлә, – дип күәтләде аны Зыятдин карт.* Р.Вәлиев. *Шуңа күрә дә без ул китапларны рәттән укып бара идек.* Р.Миңнуллин

2. *хәб. функ.* Янәшә булу. *Мирхәйдәр абзыйның өе йортның түрендә – хуҗаның ике катлы өеннән түбәнрәк мунча белән рәттән иде.* Ә.Фәйзи

РӘТ-ЧИРАТ *җыйм. и.* Берәр нәрсәдәге тәртип, рәт, җай, юнь. *Картлар колактан колакка сөйләшкәннәр дә: «Рәте-чираты да күренми, йортыҗиренең дә юне юк, исеме дә, җитмәсә, шундый күңелсез икән», – дип, алга таба киткәннәр.* Әкият. *Шундый җәй була: айлар буе яңгыр ява. Яңгыр яумаганда да, көннең рәте-чираты булмый.* Ә.Дусайлы

РӘТ-ЮНЬ *җыйм. и.* 1) Кем яки нәрсәнең дә булса мәгънәсе, файдасы, нәтиҗәсе, юне, рәте. *Иртәдән кичкә кадәр ул хәзер бушамаячак, ашау-эчү, яту-торуның да рәте-юне булмаячак, кыскасы, авырга киләчәк аңа.* Ә.Еники

2) Берәр эшнең тәртибе, җае, ибе. *Кешеләр белән сөйләшүнең дә рәте-юне юк бүген.* М.Хуҗин. *--- әле яңа гына җилтерәп йөрүче дәртле карт кинәт бөкшәйде, кечерәеп калды, атлавының да рәте-юне юк ---.* Р.Батулла

3) Сәламәтлек, физик мөмкинлекләр. *Уе шунда ук үз баласына күчте. Ул да авырый иде. Башта ук рәте-юне булмады.* Х.Камалов

4) Матди мөмкинлекләр. *Бик дөрес! Булмады исә рәт-юнең, Ак тарыдан фәркы [аермасы] юк шул энҗеңең.* М.Гафури

РӘХӘТ *и. гар.* **1.** 1) Материаль муллык, иркенлек; яшәү, эшләү һ.б. өчен бик уңайлы шартлар, мөмкинлекләр булган, бәхетле, имин яшәеш. *Бер тиенлек рәхәт күрсәткәнең юк.* Г.Толымбай. *Казанда яшәүче туганым бервакыт: «И апа, рәхәттә яшисез дә соң авылда, сөт, май сатып алмыйсыз, бәрәңге үзегезнеке», – ди.* Татарстан яшьләре

2) Күңелле, җанга ягымлы, ләззәтле кичерешләр, сиземләүләр нәтиҗәсендә туган шатлык, канәгатьләнү хисе, тойгысы; хозурлык, ләззәт, җан тынычлыгы. *Ул аңар гүзәл чәчәк күк, искиткеч музыка күк рәхәт бирә, ләкин илаһи тынычлык бирми ул аңар.* Р.Гали. *Таҥчулпан суны көмеш бокалга койды һәм бөтен җаны-тәненә рәхәт коелуын тоеп, су эчте.* М.Хәбибуллин. *Шулай булгач, бу тормышның бөтен ямен татып, рәхәттә, бәхеттә яшәп калырга кирәк.* Г.Гыйльманов

2. *с. мәгъ.* 1) Мул, иркен, әйбәт. *Бер генә фонд та рәхәт тормыштан, муллыктан төзелми.* Р.Миңнуллин. *Тик соңгы вакытта кызларның күбесен мондый мәхәббәт кызыксындырмый, алар бай кияү табып, рәхәт тормышта яшәү хакында хыяллана.* Безнең гәҗит

2) Шатлык, канәгатьләнү хисе, ләззәт, җан тынычлыгы биргән. *Хезмәттән тәм таба, авыр хезмәт – аның өчен рәхәт ял, дип күп яздык.* Р.Батулла. *Сүз дә юк, аларны алу һәм уздырылган очрашулар вакытында музейга килүчеләрне хатларның эчтәлекләре белән таныштыру бик тә күңелле һәм җанга рәхәт мизгелләр иде.* Р.Могыйнов

3. *рәв. мәгъ.* Тыныч, борчусыз; уңай, яхшы шартларда, кыенлыклар кичермичә. *Аның киң урамнарында, җылы апрель башының алтын кызыл кояш нурларында, туфли үкчәләрен шак та шок китереп, курчактай киенгән чибәр кызлар рәхәт көлешеп сөйләшә-сөйләшә узалар.* Ф.Яхин. *Бөтен сугышлар беткәч, Мөхәммәд пәйгамбәргә сахабәләре әйтә, хәзрәт, без җиңдек, сугышлар булмас, иншалла, рәхәт яшәрбез, диләр.* Р.Вәлиев

4. *хәб. функ.* Күңелле, яхшы, канәгатьлек хисләре кичерү турында. *Җиңүчегә ул рәхәт, ә җиңелүче хәленә дә керә белергә кирәк.* Р.Мөхәммәдиев. *Җәең авылда узса, аеруча рәхәт.* Р.Рахман. *Игелек кылсаң, җанга рәхәт, яшь-җилкенчәк кебек канатланып, очып йөрисең.* Татарстан яшьләре

◊ **Рәхәт(ен) күрү** 1) Кемнең яки нәрсәнең дә булса файдасын, яхшылыгын, игелеген күрү. *Ә Адәм галәйһиссәллам үзе үстергән тәмле йөземнең рәхәтен күреп ашый, төрле тәм-том кайната, җимеш итеп киптерә.* Г.Хөсәенов. *Мәгъмүрә әбигә --- үз почмагының рәхәтен күреп яшәргә Ходай насыйп итсен инде.* Татарстан яшьләре; 2) Яхшы яшәү, рәхәтлек кичерү. **Рәхәт сөрү** *к.* **рәхәт чигү**. **Рәхәт табу** Берәр нәрсәдән канәгатьләнү хисе сизү, ләззәт табу, канәгатьлек кичерү, җанга тынычлык табу. *Күңелем тынычлана, җаным рәхәт таба*. М.Гафури. **Рәхәттә йөзү** 1) Мул тормышта яшәү. *Ул борын-борыннан җир, су, сары тимер, хатын-кыз өчен яу тоткан, орышкан, сугыш кырында ятып калган яисә рәхәттә йөзгән.* Т.Галиуллин; 2) Берәр нәрсәдән канәгатьләнү хисе кичерү. *Әче бал эчеп, каклаган каз, өчпочмаклар, бәлешләр, зур-зур ит кисәкләрен ашап, үз гомерләрендә дә андый нигъмәтле бай өстәл күрмәгән ач урыслар караңгы төшеп күз бәйләнгәнче рәхәттә йөзделәр.* З.Зәйнуллин. **Рәхәт чигү** Ләззәтләнү, рәхәтләнү; рәхәт яшәү. *Кичләрен тәрәзәләрдә утлар балкый, һәркем үзенең җылы, якты өендә якынары арасында рәхәт чигә.* Р.Батулла

РӘХӘТЛӘНДЕРҮ *ф.* **1.** 1) Рәхәтлек хисе тудыру. *Эчемдә әллә нинди бер дулкын башлана, бүлмәмдә аннан калган әгъла хуш исе акрын гына дулкынланып, тойгыларымны рәхәтләндерә.* Г.Ибраһимов. *Җил юк, йомшак кына саф һәм ләззәтле бер салкынлык сулыш белән эчкә керә дә, бөтен тамырларга җәелеп, җанны рәхәтләндерә иде.* Ш.Камал

2) Берәр нәрсәне җитәрлек күләмдә бирү, артыгы белән тәэмин итү, кинәндерү. *СССР чорында да, хәзер дә авыл халкы җитештерүчене арзанлы чималга рәхәтләндерә.* Ватаным Татарстан

3) Рухи тынычлык, ял, җан тынычлыгы, ләззәт бирү. *Көлке кешене рәхәтләндерә, күңелне ача, эч пошуны баса, җитди нәрсәләрне тыңларга бөек бер ияҗтиһад бирә, ялыккан кешеләрне җиңеләйтеп җибәрә.* Ш.Бабич. *Диңгез ягыннан искән йомшак кына җил, чак хис итәрлек таза су һәм тоз исләре аңкытып, битләрне сыйпый, миләрне кытыкландырып, күңелләрне рәхәтләндерә иде.* Ә.Дусайлы

2. рәхәтләндереп *рәв. мәгъ.* 1) Җитәрлек дәрәҗәдә, күп, мул итеп. *[Яңгыр] Рәхәтләндереп, утырып яусын иде, ичмасам*. Д.Булатова

2) Һичбер кыенлык кичермичә, җиңел, иркен. *Кызым Таңсылу, мәсәлән, инглиз телендә рәхәтләндереп кичәләр алып бара*. Р.Миңнуллин. *Ә марилар исә рәхәтләндереп өч телдә (марича, урысча, татарча) чип-чиста сөйләшәләр иде*. Татарстан яшьләре

Рәхәтләндерә бару Торган саен ныграк рәхәтләндерү

Рәхәтләндерә башлау Рәхәтләндерергә тотыну

Рәхәтләндерә килү Даими, системалы рәхәтләндерү

Рәхәтләндерә төшү Тагы да рәхәтләндерү

Рәхәтләндереп җибәрү Кинәт рәхәтлек бирү. *Төнге су искиткеч йомшак, җылы, тәннәрне рәхәтләндереп җибәрә.* Р.Батулла. *Яңгыр сулары җыелган чокыр-чакырлы, сазламыклы юлдан эчкә керә башлагач, тәрәзә аша тулган салкынча һава аларның тәннәрен рәхәтләндереп җибәрде, сулышлары иркенәйгәндәй булды*. Ф.Садриев

Рәхәтләндереп тору Әле, хәзерге вакытта рәхәтлек бирү; гел, һәрвакыт рәхәтләндерү. *Тавышы нинди ягымлы, колакларны рәхәтләндереп тора!* Ф.Яхин

РӘХӘТЛӘНҮ *ф.* **1.** 1) Рәхәтлек хисе кичерү, ләззәтләнү, канәгатьлек сизү. *Шунда янып-көеп урак урган чакларда, бу күлдә су коенып та бик рәхәтләнә идем.* Г.Ибраһимов. *Юл буе рәхәтләнеп үз телебездә сөйләшеп кайтасы булганбыз икән югыйсә.* Р.Мөхәммәдиев. *Нәрсә, әллә аңа рәхәтләнеп көньяк кояшында бер-ике атна кызыну ярамасмы?* Х.Ширмән

2) Рәхәтен, игелеген күрү; файдасын, уңай тәэсирен, ярдәмен күрү. *Шәдчедә ак он тегермәне төзелде, тирә-яктан бөтен авыл халкы рәхәтләнде генә үзе эшләп алган ашлыкны тарттырып, шул оннан үз икмәген пешереп.* Татарстан яшьләре

3) Нәрсәгә дә булса мул, күп күләмдә ирешү. *Халык рәхәтләнде быел җиләк җыеп!* Татарстан яшьләре

2. рәхәтләнеп *рәв. мәгъ.* Бик теләп, ихлас күңелдән. *Бик рәхәтләнеп, Акмал-әкә, бик рәхәтләнеп...* Р.Мирхәйдәров

Рәхәтләнә бару Торган саен күбрәк рәхәтләнү

Рәхәтләнә төшү Тагы да рәхәтләнү. *Мортаза бай, берәр сүз табып мәсьәлә кузгатып җибәрә дә, карый белән теге мулла сүз көрәштерә башлагач, кәефләнеп, читтән генә тамаша итә; ике якның берсе җиңә башласа, я җиңелгән якка булышлык иткән булып сүзне үстереп җибәрә, яки өр-яңа бер мәсьәлә кузгата да тагы да рәхәтләнә төшеп тамаша итәргә керешә иде.* М.Галәү

Рәхәтләнеп алу Кыска вакытка, бераз рәхәтләнү

Рәхәтләнеп йөрү Әле, хәзерге вакытта рәхәтлек кичерү

Рәхәтләнеп калу Ниндидер вакыттан, сәбәптән соң рәхәтлек килү; моментыннан файдаланып рәхәтләнергә өлгерү. *Авыр, юеш капчыкларны салып ташлагач, җилкәләреннән тау төшкән кебек рәхәтләнеп калдылар.* И.Гази

Рәхәтләнеп китү Кинәт кенә, соңгы вакытта рәхәтлеккә ирешү. *Газап чигеп ятучылар берәр табиб тарафыннан бирелгән дәва яки киңәш белән гамәл кылу сәбәпле хәл алалар һәм гүя тәмугтан чыгып җәннәткә кергән шикелле рәхәтләнеп китәләр*. Р.Фәхреддин

Рәхәтләнеп тору Һәрвакыт, гел рәхәтлек кичерү

РӘХӘТЛЕК *и.* 1) Рәхәт булу. *Суда аяклар җебегәч кенә, авырту басылып, тәнгә рәхәтлек йөгерде.* Ф.Яруллин. *Суның рәхәтлеген, җылылыгын*

сөйләп-аңлатып бирерлек түгел. Р.Мөхәммәдиев

2) Рәхәт тормыш, тыныч, мул тормыш. *Нинди рәхәтлектә торсаң да, еллар узгач, олыгая барган саен, шул каты сәке, сандык өстендәге йокылардан да татлы йокылар, мичкә тәгәрәткән, яртылаш көйгән бәрәңгеләрдән дә тәмле ризык юк икән.* Безнең гәҗит

◊ **Рәхәтлек табу** *к.* **рәхәт табу**. *Наис шигырьләреннән ялгызың калып укыганда гына җанга рәхәтлек табасың.* Ә.Дусайлы

РӘХӘТ-ЛОКЫМ *и. гар.* Он, крахмал, шикәр һәм төрле чикләвек төшләре, җимеш сулары кушып әзерләнгән кондитер азыгы. *Шулай ук тәмле ризыклар, рәхәт-локым, җиләк-җимешләр һәм тәмләткечләр сата торган Мисыр базары да бар*. Шәһри Казан

РӘХИМ *и. гар.* Мәрхәмәт, миһербан, кызганучанлык, кешене аяу хисе, аяучанлык, шәфкать. *Юк, бу ата фашистан рәхим көтеп булмый инде.* Ә.Еники

РӘХИ́М ИТҮ *ф.* **1.** 1) Мәрхәмәтлелек күрсәтү, кемнеңдер хәленә керү, аяу

2) Рәхимлелек күрсәтеп, үтенечне кире кайтармау, үтәү, башкару, сораганны бирү. *[Сәркатип кәгазьне алып:] Монысы, юлга акчам юк иде, бераз рәхим итмәсләр микән, ди*. Г.Камал

3) Килү, бару (кунакка). *Бервакыт, җир туңдырып та кар төшәргә өлгермәгән чакта әле, Петрух озата чыккач, аңа болай дигән иде: – Мин генә кунак булу килешми, үзең дә, Петрух дәдәй, безгә рәхим ит*. М.Хуҗин

2. рәхим итеп *рәв. мәгъ.* 1) Берәр төрле үтенеч белән мөрәҗәгать иткәндә кулланыла: зинһар. *Әгәр дә инде үз көнебезне үзебез күрергә уйлаганбыз икән, рәхим итеп, эшлик, иҗат итик, үз Ватаныбызга – Татарстаныбызга хезмәт күрсәтик.* Р.Батулла. *Капитан чәчәкләрне сузды: – Бу сезгә, рәхим итеп алыгыз!* Р.Сәгъди

2) Берәр нәрсә турында тәкәллеф белән сорауны белдерә. *Әйдә, алай булгач, социолог әфәнде, рәхим итеп, монысын да аңлатып күрсәт инде безгә.* Р.Вәлиев

3) *кер. сүз функ.* «Боерган булса, язган булса, Аллаһы Тәгалә теләсә» мәгънәсендә. *Бер-ике көннән кайтып җитәчәк, шуннан соң, рәхим итеп, алырга мөмкин булачак.* И.Гази

◊ **Рәхим ит!** 1) Нәзакәтлелек белән берәр нәрсә эшләргә чакыруны, тәкъдим итүне аңлата. *Метеорга да, автобуска да билетлар җитәрлек – рәхим ит, ал да җилдерт, дүрт ягың кыйбла!* М.Насыйбуллин. *Көне-төне ялсыз эшләргә әзерсең икән, рәхим ит, умарта тот.* Шәһри Казан; 2) Сорауга, үтенечкә уңай җавап, ризалык, рөхсәт белдереп җавап бирүне аңлата. *Шуларны аңлаган хәлдә минем отрядка кушылырга ниятлисез икән, рәхим итегез, бер каршылыгым да юк.* Ф.Сафин; 3) Килүче кунакларны каршы алу сүзе: хуш киләсез. *– Рәхим ит, күрше, әйдә, кер, кер!.. – дип каршы ала торды.* М.Галәү

РӘХИ́М КЫЛУ *ф. к.* **рәхим итү** (*1 мәгъ.*). *Киләмдер мин, рәхим кыл мин ятимгә*. Дастан

РӘХИМЛЕ *с.* 1) Мәрхәмәтле, кызганучан, ярдәмчел, йомшак күңелле, шәфкатьле. *Ул рәхимле бәндәне күрмәдем дә, рәхмәт тә әйтмәдем – йөгердем.* И.Салахов. *Аллаһ ярдәменнән ташламасын үзегезне, дип эченнән генә бу рәхимле җаннарга рәхмәт укыды хатын.* Д.Булатова

2) Кеше өчен яхшы, игелекле. *– Әй егет, – дигән, – сине нинди рәхимле җилләр ташлады?* Әкият

РӘХИМЛЕЛӘНҮ *ф.* Рәхимлегә әйләнү, рәхимле булып китү

Рәхимлеләнә бару Торган саен ныграк рәхимлеләнү

Рәхимлеләнә төшү Бераз рәхимлеләнү

Рәхимлеләнеп китү Билгеле бер вакыттан, сәбәптән соң рәхимлеләнү

РӘХИМЛЕЛЕК *и.* Рәхимле булу, шәфкатьлелек, миһербанлылык. *Әйе, яшьләр өлкән буынга хөрмәт һәм рәхимлелек күрсәтергә, үзләренең дә шул хәлгә җитәсен онытмаска тиеш*. Ватаным Татарстан. *Укытучы, беренче чиратта, ул – бала күңеленә яхшылык, рәхимлелек, сафлык орлыкларын салучы*. Безнең гәҗит

РӘХИМСЕЗ *с.* **1.** 1) Мәрхәмәтсез; кызганмый торган, каты күңелле, шәфкатьсез. *Сез – рәхимсез кешеләр, өстәвенә кәпрәючән.* И.Хуҗин. *Артист Әхтәм Зарипов күп көч сарыф иткән, нәтиҗәдә балыкчыларны талап ята торган кансыз, рәхимсез бер кабахәт образы туган.* Р.Батулла

2) Рәхимсезлек, катылык, ачу белдергән. *[Гаязның] Рәхимсез төс алган кара күзләре миңа туктарга кушалар иде.* М.Әмир

3) Бик көчле, артык каты. *Табигатьнең рәхимсез көчләре алдында кешенең көчсезлеге борынгы табынулар барлыкка килүгә этәргән.* Р.Фәхретдинов. *Ә рәхимсез авыру карчыкны астыртын гына кимерә, акрынлап кына ул эрисыза...* Ә.Еники

2. *рәв. мәгъ.* 1) Аяусыз, жәлләмичә, кызганусыз, мәрхәмәтсез рәвештә. *Ш.Камал халыкның газаплы тормышын тасвирлап кына калмый, бәлки реакция вәкилләреннән, буржуазиядән, дин әһелләреннән, сатлык милләтчеләрдән рәхимсез көлә дә.* М.Җәлил. *Югославияне рәхимсез бомбага тоту – тыныч-лык урнаштыру гамәлемени?* Р.Батулла

2) Бик көчле итеп, нык. *Аның саен нурлар рәхимсезрәк кыздыра.* Р.Батулла

3. *и. мәгъ.* Мәрхәмәтсез, каты күңелле, шәфкатьсез кеше. *Тормыш кагыйдәсен бозган рәхимсезләр аркасында, байтак төрләр саклауга мохтаж*. Безнең гәҗит

РӘХИМСЕЗЛӘНҮ *ф.* Рәхимсезгә әйләнү, рәхимсез булып китү

Рәхимсезләнә бару Торган саен ныграк рәхимсезләнү. *Яшәгән төбәгебезне тулыландырган, баеткан, ямь биргән, безне өлкән агалары итеп таныган, олылаган кош-корт, җәнлек-җанварларга көннән-көн рәхимсезләнә барабыз*. А.Хәсәнов

Рәхимсезләнә төшү Тагы да рәхимсезләнү. *Кызның тавышы тагын да рәхимсезләнә төште*. Г.Әпсәләмов

Рәхимсезләнеп китү Билгеле бер сәбәптән соң, соңгы вакытта рәхимсезләнү

Рәхимсезләнеп тору Әле, хәзер, күз алдында рәхимсезләнү

РӘХИМСЕЗЛЕК *и.* Рәхимсез булу. *Харәзем җирендә монголлар кылган рәхимсезлек чыганакларда ачык язылган.* Р.Фәхреддинов. *Бүген уйлап уты-*

рам да яшьлекнең рәхимсезлегенә акылым китә. Р.Батулла

РӘХИМЧЕЛ *с. сөйл. к.* **рәхимле**

РӘХИМ-ШӘФКАТЬ *җый. и. гар.* Рәхим һәм шәфкать; хәлгә керү, кызгану хисе. *Томан аша акаеп караган дөньядан рәхим-шәфкать көтмәле түгел иде.* М.Кәбиров. *Аның кырыс чырае рәхим-шәфкатьнең ни икәнен дә белмидер кебек иде.* И.Хуҗин. *Киләчәктә Шамил абый, аның уңган уллары мохтаҗларга тагын да рәхим-шәфкать кылырлар әле.* Кызыл таң

РӘХИМ-ШӘФКАТЬЛЕ *с.* Рәхим-шәфкатькә ия булган, кызганучан. *Рәхимә исеменә лаек рәхим-шәфкатьле кыз булып чыкты, Интернеттан бик тиз табып, берничә нөсхә доверенность бланкасын бик тиз генә бастырып чыгарды да берсен тутырып та бирде* ---. Ә.Зарипов. *Төн йокыларын йокламыйча багып үстергән балалар ата-анага карата рәхим-шәфкатьлерәк булсын иде.* Безнең гәҗит

РӘХЛӘ *и. гар.* Өстенә куеп язу язу, китап (аеруча Коръән) уку өчен, ачылып ябылмалы Х формасында ясалган яки төз капкачлы кечкенә тар өстәл. *Уеп бизәлгән рәхлә. Эбен агачыннан ясалган рәхлә*

РӘХМӘТ *и. гар.* **1.** 1) Аяу, кичерү, мәрхәмәт. *И Раббем, рәхмәтең вә ярдәмеңнән ташлама!* Г.Галиева. *– Аллаһының рәхмәте киң, бүгенге көндә матур һәм җитеш тормышта яшибез, – ди Мирхәт абый.* Кызыл таң

2) Яхшылык эшләгән, ихтирам күрсәткән, берәр игелекле эш эшләгән өчен зур канәгатьлек белдерү хисе һәм шуны белдергән сүзләр. *Әйтерсең лә аллә ни эшләгән, мине рәхмәт белән коендыралар гына.* Ф.Хөсни

3) Кемнең дә булса эшчәнлегенә, хезмәтенә рәсми уңай бәя. *Дәүләткә ашлык тапшыруның айлык планын тутырып, райком югарыдан рәхмәт алды.* Г.Бәширов

2. *хәб. сүз мәгъ.* 1) Яхшылыкка җавап итеп әйтелә торган сүз. *– Рәхмәт инде, кызым, тәмле телең, ягымлы сүзләрең өчен рәхмәт, – дип, күңелендәген яшерә алмый, әйтергә ашыкты хуҗа хатын.* Р.Мөхәммәдиев

2) Нинди дә булса тәкъдимне тәкәллефле генә кире кагуны белдерә. *– Сез туктар дип, [бәрәңгене] күп итеп пешердем. – Рәхмәт, Мәрдәнша бабай, соңга калабыз, төн җитә бит.* Г.Гобәй

◊ **Рәхмәт әйтмәс** Берәр ялгыш, ярамаган һ.б.ш. гамәлне хупламыйча, кисәтеп әйтелә. *Сукыр мәхәббәт юньлегә илтми, Полина түтәй. Петруха сиңа рәхмәт әйтмәс иде.* Ә.Баян. *Сезнең әлеге кырын эшегезне өлкә комитетында белсәләр, үзегезгә рәхмәт әйтмәсләр.* К.Миңлебаев. **Рәхмәт йөзеннән** Берәр кешенең яхшылыгына җавап яхшылык буларак. *Рәхмәт йөзеннән кыз кичләрен аны борщ, тәмле салатлар белән сыйлый иде.* М.Маликова. *Аякка баскач, рәхмәт йөзеннән, үзенә диваннан урын биргән фатирны ремонтлатып куясы булыр.* Т.Галиуллин. **Рәхмәтеңә рәхмәт** Рәхмәт әйткәнгә каршы җавап сүзе. **Рәхмәт төшкере!** Рәхмәт хисен белдереп әйтү. *Рәхмәт төшкере, Зурәптәйләрдә беркадәр яшәгәч, көннәр акрынлап җылыга борылгач, үзебезнең балчык ызбабызга күченү ягын кайгырта башладык.* К.Миңлебаев. *Хәзер зур мәҗлесләргә бик йөрми, диләр иде, санлаган Солтанай толпарлыларны, рәхмәт төшкере.* Г.Якупова. **Рәхмәт төшсен!** *к.* **рәхмәт төшкере!** *Рәхмәт төшсен, кызым! Миннән алда килеп җиткәнсең.* Т.Миңнуллин. **Рәхмәт уку** Ихлас күңелдән кат-кат рәхмәт әйтү. *– Аягыңкулың сызлаусыз булсын, – диде карчык, миңа рәхмәт укып.* Н.Фәттах. *Син гүзәлне очратканга, Рәхмәт укыйм язмышка.* Г.Каюмов. **Рәхмәт яңгыры** Көтеп алган вакытлы яңгыр. *Бәлки, рәхмәт яңгырыдыр, Яшьнәсен ул, яшьнәсен!* Г.Тукай. **Рәхмәт яугыры!** *к.* **рәхмәт төшкере!** *– Ай, рәхмәт яугыры! – Болай булгач, тормышлар яхшыра дигән сүз!* Н.Фәттах. **Рәхмәт яудыру** Күп мәртәбә рәхмәт әйтү. *--- Шәяхмәт Киекбаев отчёт доклады белән чыгыш ясый икән. Партия куйган бурычлар хакында сөйләп, Сталинга мактау һәм рәхмәт яудырып алгач, колхозда еллык план үтәлешенә күчкән* ---. Г.Якупова. **Рәхмәт яусын!** *к.* **рәхмәт төшкере!** *Эшнең зурын комиссия рәисе итеп сайланган Әдип абый Маликов башкара килә. Аңа рәхмәт яусын!* К.Тимбикова. *Рәхмәт яусын, озын гомерле булыгыз, бәхетле булыгыз...* Н.Кәримова

РӘХМӘТДАР *с. фар. иск.* Рәхмәт хисе белдергән, миннәтдар. *Кылган изгелекләреңә рәхмәтдармын*

РӘХМӘТЛЕ *с.* 1) Рәхмәт хисе белдергән, миннәтдар. *--- рәхмәтле сүзләр белән безнең балачак һәм яшьлек елларында бригадир булып эшләгән Назыйф Гомәровны искә алдык.* Кызыл таң

2) Рәхимле. *Бу инде Ходайның рәхмәтле мизгеледер сыман иде.* Ф.Яхин. *Нинаять, бер рәхмәтле бәндәсе туктап, безне Саратов шәһәренә кадәр җиткерде.* Безнең гәҗит

РӘҺБӘР *и. гар. иск.* 1) Үрнәк, өлге

2) Өндәүче, җитәкче; лидер. *Гаскәргә корал җитми; туплар, сугыш машиналары, сугыш көймәләре аз, булганы да искереп беткән, --- ватанга, гаскәргә рәһбәр, өндәр бер шәхес, юлбашчы кирәк иде.* Р.Батулла

РӘШӘ *и.* 1) Эссе көндә җирдән күтәрелгән җылы пар; төтен сыман аксыл пар, томан. *Урамда кояш нурларыннан күзләр чагыла, тирә-юнь рәшә дулкынында тирбәлә иде.* Р.Вәлиев. *Кызудан көне буе һавада зәңгәрсу рәшә уйнаган кебек иде.* В.Гали

2) Атмосфера катлауларының төрле дәрәҗәдә җылынулары нәтиҗәсендә ачык һәм тын һавада була торган оптик күренеш; бу вакытта горизонт артындагы күренми торган әйберләр һавада чагылып күренәләр; мираж. *Ул ниндидер далага элэккән, эссе, җил дә исми, эчәсе килә, каяндыр су тавышы ишетелә, ләкин ул барып җитә алмый, рәшә күрә.* Сөембикә

3) *күч.* Чынбарлыкка туры килмәгән әйбер. *Мин дәшми калам: хатын-кыз белән сугышкан, бәхәсләшкән кешенең җиңеп чыкканын әлегә күргәнем-ишеткәнем юк. Болай да вакланып беттек инде социалистик җәмгыять дигән бу рәшәдә.* М.Мәһдиев

◊ **Рәшә уйнау** Җир өстендәге һава дулкынланып, селкенеп торган кебек күренү. *Күк читендә рәшә уйный.* Р.Батулла

РӘШӘЛӘНҮ *ф.* һавада рәшә күренү. *Алда хәзер – Түбән Сарыманның Рәшәләнгән бодай җирләре.* Ш.Мөдәррис

Рәшәләнә төшү Тагы да рәшәләнү

Рәшәләнеп тору Әле, хәзер, күз алдында рәшәләнеп күренү. *Рәшәләнеп торган тау битенә кадәр чаба-чаба да, туктап бераз уйланып торгач (ни уйлый микән ул?), кинәт борылып, минем яныма юнәлә.* Р.Бәшәр

РӘШӘЛЕ *с.* Рәшәләнеп торган. *Димәк, бу су буйларында күп вакыт томан күтәрелә дер, шуңа аңа рәшәле яки томанлы исемен биргәннәрдер.* И.Хуҗин

РӘШӘТКӘ *и. рус* 1) Тар такталардан яки металл планкалардан тезеп эшләнгән, гадәттә кеше керү-чыгуны булдырмау яки чикләү өчен куелган киртә. *Абдулла, аның җилкәсенә менеп басып, куллары белән тәрәзә рәшәткәсенә тотынды да салкын ай нуры яктырткан ишегалдына карады.* М.Галәү. *Тутый исә, читлек рәшәткәләренә бәрелә-сугыла, чыркылдады да чыркылдады.* Г.Гыйльманов

2) Такта яки металл таяклар белән берәр нәрсәне, урынны әйләндереп алган койма, киртә. *Айдар, рәшәткә янына ук килеп, кара янып пешкән тагы бер чия үзеп авызына капты.* Р.Мөхәммәдиев. *Шулчак, бакча рәшәткәләренә сырышып диярлек, озын торыклы, салпы колаклы ала эт йөгереп үтте.* Ф.Шәфигуллин

3) Каты ягулык янганда көле аска төшсен өчен куелган тимер челтәр. *Самавыр рәшәткәсе. Мич рәшәткәсе*

4) Тоташ эшләнгән агач койманың бер планкасы, бер тактасы. *Аннан, [Мөхәммәтсапа бабай] купкан рәшәткәгә күрсәтеп, Айдарны үз янына чакырды. – Син аны, Айдар, әниең күрмәгәндә, менә шушы тишектән генә кер дә, уртасына утырып, [чияне] рәхәтләнеп аша моннан ары, яме!* Р.Мөхәммәдиев

◊ **Рәшәткә артына утырту** Төрмәгә утыртү. **Рәшәткә артына утыру** Төрмәгә утыру

РӘШӘТКӘЛӘ́Ү *ф.* 1) Нәрсәне дә булса рәшәткә белән әйләндереп алу, берәр нәрсәгә рәшәткә тоту

2) Рәшәткә формасында ясау. *Янындагы кыя башына йөз илле метр биеклегендә рәшәткәләп манара эшләнгән, ул манара җир астыннан Гаринның йокы бүлмәсенә килеп тоташкан.* А.Толстой

Рәшәткәләп алу Тиз арада яки тоташ, әйләндереп рәшәткәләү. *Рәшәткәләп алыйк без, күрше, шушы кашлакны.* Р.Фәизов. *Иң тәүдә шифалы чишмәне матур итеп рәшәткәләп алалар, өстенә бизәкле чатыр корып җибәрәләр.* Кызыл таң

Рәшәткәләп бетерү Тулысынча рәшәткәләү

Рәшәткәләп кую Алдан рәшәткәләү; рәшәткәләнгән итү. *Артып калган такталары белән чишмәне дә рәшәткәләп куйды ул.* А.Хәйретдинова

Рәшәткәләп чыгу Бөтен тирә-ягын әйләндереп рәшәткәләү

РӘШӘТКӘЛЕ *с.* Рәшәткә тотылган, рәшәткә куелган. *Рәшәткәле чуен баз койдырып, Алпамшаны шул зинданга ябып китәләр.* Әкият. *Чуен рәшәткәле борынгы каминда утын пүләннәре чытырдап яна.* Р.Вәлиев

РӘШӘТКӘЛЕК *с.* **1.** Рәшәткә ясау өчен әзерләнгән; рәшәткә тотарга җитәрлек

2. *и. мәгъ.* Рәшәткә ясау өчен билгеләнгән яки шуңа җитәрлек материал. *Бу акчага алар түгәрәк таш, тимер баганалыклар, рәшәткәлекләр, насос, түбә өчен калай алалар.* Хезмәт даны

РӘШКЕ *и. диал. зоол.* Вак чебен

РӘШМӘН *и. фар. диал. зоол.* Үрмәкүченең эре төре

РЕ *и. лат. муз.* Музыка гаммасында «до»дан соң килгән икенче аваз; шул авазны белдерә торган нота. *Көйнең башындагыча, секунд аралары буйлап югары күтәрелә – «ре», «ми», «фа» – «Рау-ша-ни-ям».* М.Мәһдиев. *Яңадан клавишларга каты гына суга башладым: до, ре, ми, фа, соль... Менә шулай, авазлардан гамма хасил була.* Ә.Еники. *Өченче мотив исә киресенчә, форшлаг аша секстага күтәрелеп, «ре» буйлап квинтага төшә.* Х.Курбатов

РЕАБИЛИТА́ЦИЯ *и. лат.* 1) Ялгышлык яки явыз ният белән хаксызга гаепләнгән, хөкем ителгән кешенең эшен яңадан карап, гаепсезлеген тану, репутациясен кире кайтару, аклау. *Шул абзыйга [Бәкергә] Хрущёв заманында реабилитация ясаганнар.* К.Тимбикова. *Башкалар өчен реабилитация 1956 елдан ук башланган булса, М.Солтангалиевның акланган исеме 1988–1990 елларда гына безгә кабат әйләнеп кайта алды.* Рәмзи Вәлиев

2) Сәламәтлекне кире кайтару, торгызу чаралары. *Буынсыз калган организм берничә ай реабилитация үткәннән соң гына үз хәленә кайта.* Өмет

РЕАБИЛИТА́ЦИЯЛӘНҮ *ф.* Реабилитация ясалу, аклану, гаепсез дип табылу. *Сезнең иregезнең эшен Верховный суд карады һәм аны гаепсезгә кулга алынган дип табып, Өчлек судының карарын юкка чыгарды. --- Ул үлгәннән соң реабилитацияләнде һәм сезнең семьягыз өстендә еллар буе торган бу ямьсез исем шуның белән алып ташланды.* М.Мәһдиев. *Л.Термен реабилитацияләнә. 60 нчы еллар башында аның исеме кабаттан дөньяга чыга, галим Мәскәү консерваториясендә эшли башлый.* Б.Галиев

РЕАБИЛИТА́ЦИЯЛӘҮ *ф.* 1) Реабилитация ясау, аклау, гаепсезлеген тану. *Татарстан Министрлар Кабинеты каршындагы Дәүләт иминлеге комитеты 1955 елның 12 сентябрендә Г.Гали исеменә (Казан адресы белән): «Сентябрь аенда Сезнең реабилитацияләү мәсьәләсендә комитетка килүегез сорала», – дигән чакыру кәгазе җибәрә.* Шәһри Казан. *Репрессия корбаннарын реабилитацияләү СССРда 1954 елда башлана, 1960 елның урталарына бу эш туктатыла һәм бары тик 1980 еллар ахырында гына яңартыла.* Безнең гәҗит

2) Кире кайтару, торгызу (сәламәтлек тур.). *--- инфаркт һәм инсульт кичерүчеләрне санаторий-курорт шартларында аякка бастыру, ягъни аларны тулыканлы тормышка өйрәтү, реабилитацияләү актуаль булып кала.* Кызыл таң

Реабилитацияли бару Эзлекле рәвештә бер-бер артлы реабилитацияләү

Реабилитацияли башлау Реабилитацияләү эшенә керешү

РЕАГЕНТ *и. лат. хим.* Химик реакциянең бер элементы. *Бозлавык хасил*

булмасын өчен, автомобиль юлларына 514,5 тонна тоз-ком катнашмасы, 72,4 тонна реагент сиптерелгән. Шәһри Казан

РЕАКТИВ I *и. фр.* Химик реакция ясау өчен кулланыла торган матдә. *--- чолан сыманрак җирдә өелеп яткан химия җиһазларын һәм реактивларны тәртипкә китереп, --- лаборатор эшләрнең һәрбersen җиренә җиткереп үткәрергә тырышам.* З.Мифтахов

РЕАКТИВ II *с.* 1) *физиол.* Тышкы тәэсирләргә җавап бирергә сәләтле

2) *физиол.* Шундый җавап реакция белән бәйле. *Вегетатив нерв системасының реактив үзенчәлеген киметә, аналыкның шома мускулатурасы эшчәнлеген яхшырта.* Агулы үсемлекләр

3) Химик яктан актив, реакциягә керүчән. *Без, Дәүләт Советы депутатлары, промышленность калдыклары белән нишләргә, дигән сорауга җавап эзләдек. Әгәр элеккеге законда, реактив калдыкларны республика территориясенә читтән кертмәскә, дип язылса, прокурор протестында ул җөмлә сызылырга тиеш иде.* Т.Миңнуллин

4) *физ.* Атылып чыккан газ яки парның этү көче белән барлыкка килгән. *Реактив тизлек*

5) Шул принцип нигезендә эшли торган, шул көч ярдәмендә хәрәкәт итә торган. *Реактив самолёт Җир шарын берничә сәгатьтә урап чыга.* М.Юныс. *Реактив самолёт бик югары менә һәм кисәк кенә, двигателен эшләтмичә, түбәнгә егылып төшә башлый. Реактив двигатель эше өчен кирәкле энергия ягулык янганда барлыкка килә.* В.Казневский

РЕАКТИВЛЫК *и.* 1) *хим.* Реакциягә керә алу сәләте, реактив II булу

2) *физиол.* Тышкы тәэсирләргә җавап бирә алучанлык

РЕА́КТОР *и. нем.* Физик-химик реакцияләрнең төрле типлары нигезендә эшли торган аппарат яки җайланма. *Ә менә безнең Татарстанда салына торган станция өчен проектланган реактор исә --- камилрәк.* Казан утлары. *Русиянең «Росатом» федераль агентлыгы 14 чит илдә, аерым алганда, Һиндстан, Болгария, Иранда атом электр станцияләре төзүне күздә тота. Моннан тыш, Мәскәү биш ел элек ил эчендә 40 яңа реактор төзү проекты белән чыккан иде.* Л.Харрасова

РЕАКЦИОН *с.* Реакциягә II хезмәт иткән; яңалыкка, алдынгы карашларга каршы килгән, бетүгә барган, искелекне яклаган. *Әсәрнең икенче басмасында Казан бае Кәрим белән Уфа бае Сәгыйть образлары, нык кына эшләнеп, беренчесе – реакцион буржуа, икенчесе либераль буржуа вәкилләре итеп бирелгәннәр.* М.Гали. *Октябрь революциясенә кадәрге татар көндәлек матбугаты турында киң таралган ялгыш карашларның берсе шуннан гыйбарәт: имеш, ул тулысынча дини булган, реакцион идеяләрне алга сөргән.* Р.Мостафин. *Реакцион голәма балаларны кулай вә уңай ысул белән укытуны хәрам дип игълан итә.* Н.Гасрый

РЕАКЦИОНЕР *и. фр.* Сәяси реакцияне яклаучы кеше; алгарыш, демократия дошманы; кадимче. *Реакционерларның Ламарк тәгълиматын яман атлы итәргә тырышулары шактый гына уңышка иреште.* Дарвинизм һәм дин

РЕАКЦИОНЛЫК *и.* Реакцион булу. *Җәдитчелекне бездә дә, Урта Азиядә дә сәяси агым итеп карап, аңа реакционлык тамгасы салынган иде.* Казан утлары

РЕА́КЦИЯ I *и. лат.* 1) Берәр төрле тәэсиргә, йогынтыга карата барлыкка килгән эш-хәрәкәт, каршы җавап. *Ярый әле тәэҗрибәле шофёр тиз генә реакция ясап өлгерде, үз ягына каерып алды.* Т.Нәҗмиев. *--- шартлы тыныч сызлагыч (савыт шалтырату) әйтерсең лә икенче тыныч сызлагычның сигналына әверелә һәм шуңа күрә элек азык кына китереп чыгарган барлык реакцияләрне тудыра ала.* Кызыклы физиология. *Сәламәтлеккә организмның эчке тирәлек даимилеген саклауга һәм яшәү шартларына күнегүгә юнәлдерелгән саклану-җайлашу реакцияләре ярдәм итә.* Анатомия

2) *хим.* Ике яки берничә матдә, химик элементлар үзара тәэсир итешеп, составы һәм төзелеше белән үзгә матдәләр хасил итү. *Бал әзерләүнең беренче этабы кортның авыз куышлыгында ук башлана. Нектардагы шикәр химик реакциягә керә.* Кызыклар дөньясында. *Карбышев беренче, өченче төзү идарәләре корачак объектларны – газларны чистарту, реакция, активлаштыру, катализатор һәм водород алу бүлекләре, --- булачак корпусларны карап китте.* Р.Кәрами

РЕА́КЦИЯ II *и. лат. сәяси* Алдынгылыкка, яңалыкның үсешенә актив каршы тору сәясәте, иске тәртипләрне ныгыту яки торгызырга тырышу. *Бишенче елдан соң реакция еллары килә.* Г.Нигъмәти. *Монда да реакция үзенең пычрак тырнакларын тыгып пайткан, революцион хәрәкәтне буып ташларга ашкына иде.* А.Расих. *1905 елгы революция бастырылганнан соң башланган кара реакция кайбер катлауларда, бигрәк тә вак буржуа интеллигенциясе арасында өметсезлек тудырды.* Мәдәни җомга

РЕА́КЦИЯЧЕЛ *с. кит. к.* **реакцион**. *Буржуа катлаулары вәкилләреннән торган Беренче Дума да патшаның реакциячел хөкүмәте каршында сул табылып кудырылды.* Г.Тукай

РЕАЛ *и. исп.* Испан һәм португал телле илләрдә төрле чорларда әйләнештә йөргән акча берәмлеге

РЕАЛИЗА́ЦИЯ *и. лат.* 1) Гамәлгә кертү, тормышка ашыру процессы, башкарылу, үтәлеш. *Ибраһимов һәм аның тарафдарлары латин алфавитына бары реализация моментында гына каршы чыга.* Б.Хәкимов. *Генераль директор, компаниянең агымдагы ярты еллык нәтиҗәләренә караганда, биредә ел ахырына реализация күләме узган елгы дәрәҗәдә калачак, дип ышандыра.* Безнең гәҗит

2) Сату процессы; сату күләме. *Көтелгән реализация күләме – 105 мең тонна.* Байрак

РЕАЛИЗА́ЦИЯЛӘҮ I *ф.* 1) Тормышка ашыру, гамәлгә кертү, үтәү

2) Булган товарны акчага әйләндерү, сату. *Уртача бер елда һәр ана куяннан 177 сумлык продукция реализацияләнде.* Татарстанда терлекчелек

РЕАЛИЗА́ЦИЯЛӘҮ II *и.* 1) Тормышка ашыру юлы, ысулы, системасы, эшләре. *Юл төзелеше, торак*

йортларны капиталь ремонтлау, өстенлекле милли проектларны реализацияләү буенча җәелдерелгән эшчәнлегебез хуплау тапты. Шәһри Казан

2) Товарны сату эше. *Ит-сөтне җитештерү генә түгел, аны реализацияләү дә бик мәшәкатьле.* Кызыл таң

Реализацияләп бетерү Барысын да тулысынча реализацияләү

Реализацияләп тору Һәрвакыт, даими рәвештә реализацияләү

Реализацияли бару Һәрберсең, булган берсен аз-азлап системалы реализацияләү

Реализацияли башлау Реализацияләргә керешү

РЕАЛИЗМ *и. лат.* 1) Тормышчанлык, реальлек, тормышка аек карау; тормыш шартларын, реаль мөмкинлекләрне исәпкә алып эш итү

2) *әд.* Әдәбиятта һәм сәнгатьтә чынбарлыкны дөрес чагылдыруны максат итеп куйган иҗат методы һәм шуңа нигезләнгән юнәлеш. *Ул [Л.Шагыйрьҗан] – төрле тематик, мәгънәви юнәлешле, төгәллек, назиклык һәм ассоциатив фикерләү мөмкинлекләренә таянган, романтизм белән реализм мөмкинлекләрен иҗади үзләштергән сүз осталарының берсе*. Т.Галиуллин. *Реализм ул – дөньяга аек күз белән карау, ди рәссам Әнвәр Сәйфетдинов. Реализм тарафдары булса да, ул үзенең иҗатында әкияти хыял дөньясына да чума.* Мәдәни җомга

3) *филос.* Реаль чынбарлык кешенең танып белүеннән, аңлавыннан бәйсез рәвештә яши, дип раслаган фәлсәфи юнәлеш

РЕАЛИСТ *и. рус* **1.** 1) Реаль тормыш шартларын, аның асылын, гамәлдәге мөмкинлекләрне дөрес исәпкә алып эш итүче кеше. *Әйдәгез, реалист булыйк: татарның талантлы уллары хәрби хезмәт юлын сайлады икән, аның инде язмышы да, киләчәге дә бары тик Россия мәнфәгатьләренә бәйләп куелачак.* Шәһри Казан. *Мин – реалист һәм закон кабул ителү генә бу вазгыятьне автомат рәвештә үзгәрүенә китермәвен аңлыйм.* Татарстан яшьләре

2) *әд.* Реализм тарафдары, реализм методы нигезендә иҗат итүче язучы, рәссам һ.б. *Афзалга реалист Тукай карашы якынрак.* Т.Галиуллин. *Димәк, без аны яки романтик, яисә реалист язучы дип кенә, бер генә якны алып һәм алга куеп раслау юлына бара алмыйбыз икән әле.* Ф.Яхин

3) *тар. сөйл.* Патша Россиясе чорында: һөнәр училищесы (реальный училище) укучысы

2. *с. мәгъ.* Сәнгатьтә һәм әдәбиятта реализм методы белән иҗат итә торган. *Әдәби хезмәтнең икенче дәверендә инде Горький реалист әдиплек нигезенә утыра бара.* Г.Нигъмәти. *Икенче төрле әйткәндә, реалист шагыйрь тормышны ничек булганча, аның ачы һәм төче, якты һәм караңгы яклары белән чагылдырырга тиеш.* Әдәбият

РЕАЛИ́СТИК *с.* **1.** 1) Тормыштагыча булган, чынбарлыктан аерылмаган. *Бу әсәрдә --- авылның реалистик картиналарын --- бирергә омтылу һәм шуның үзенә күрә бер формасы да табылу (орчык тавышына ияру, эвфоник алымнар) [сизелә].* Н.Исәнбәт. *--- рәссамның шулай реалистик планда тасвирлавы безне әнә шул дөньяга [җанлылык дөньясына] алып керә.* К.Нәфыйков. *Халык фантазиясенә хас котылгысыз арттыруларны алып ташласаң, легенда шактый ук реалистик төс ала.* Р.Мостафин

2) Реаль вакыйгаларга, чынбарлыкка нигезләнгән. *Алга таба аның иҗаты реалистик вакыйга-күренешләр, образ-сурәтләр белән байый барды.* Х.Миңнегулов

3) Реализм принципларына нигезләнгән, реализм методы кулланылган. *Г.Ибраһимов үзенең реалистик әсәрен романтикларча төгәлли: халыкның тулып ташыган сабырлыгын, кискен ризасызлыгын табигать күренешләрендә чагылдыра: Үзән елгасы ярларыннан ташып, буаны ерып ата.* А.Садыйкова. *XX гасыр башында татар поэзиясе үсешенең яңа – реалистик чорына килеп керә.* Т.Галиуллин

2. *рәв. мәгъ.* Чынбарлыкка туры китереп, реаль итеп; реализмга нигезләнеп. *Каләм остасы булу ягыннан Бабич иҗаты чынлыкны реалистик чагылдыруы, чын талантларга хас булган иркен фантазияле, бай телле булуы һәм, иҗат иткәндә, һичбер көчләнми, ясалмалыксыз яза алуы белән характерлана.* Х.Туфан. *Дөрес, Г.Кандалыйның «мажик хәлен» сурәтләвендә, һичшиксез, күренешләрне реалистик рәвештә сурәтләү омтылышы бар, әмма бәя бирү һәм аңлау тулы, төгәл булмагач, әлеге реализм да өлешчә гәүдәләнеп, башлангыч хәлдә генә калган.* Ф.Яхин

РЕАЛИСТЛЫК *и.* Реалист булу

РЕА́ЛИЯ *и. лат.* Реаль, чынбарлыкта булган, тормышта, яшәеш шартларында урын алган әйбер. *Ләкин тәҗрибәле автор, болгавыр заман реалияләренә һәм тормыш чынлыгына тугры калып, алга таба Сәет Сакмановны төрле мафиоз төркемнәр яки кланнар арасында керемле-йогынтылы урын һәм күбрәк мал-табыш чумыру өчен барган көрәшкә бәйләп тасвирлый.* М.Бакиров. *Кешелек дөньясының кануннарын бозып, гөнаһ эшне – сәвап, изелүне урек --- итеп күрсәтүне фаш итү – хәзерлекле укучыны әдәби әсәрдә менә шушы реалияләр белән очрашу тетрәндерә.* М.Юныс

РЕАЛЬ *с.* **1**. 1) Чынбарлыкка туры килгән, чынбарлыкта булган, чын, гамәлдәге. *Гипербола – кыю фикер нәтиҗәсе булып торган баһадир образ ул, аның ярдәмендә реаль җирлектәге иң фантастик вакыйгаларны күрсәтеп була.* З.Нури. *«Единая Россия» сайлаучыларның, илдә, ниһаять, реаль властьны кулына алып, президент белән берлектә көкүмәтне формалаштыручы --- партия барлыкка килсен, дигән өметләрен аклый.* Татарстан яшьләре // Чынбарлыкта яшәгән, яшәве төгәл билгеле булган, уйлап чыгарылмаган. *Әлеге кешенең реаль шәхес булуы, конкрет җирлектә тууы һәм яшәве укучыда зур кызыксыну тудыра.* Мәгърифәт

2) Тормышның асылын, төп шартларын аңлап, мөмкинлекләрдән чыгып эш итә торган. *Сеаль сәясәт*

3) Тормышка ашырырга, үткәрергә мөмкин булган, гамәлгә ашырлык; тормышчан. *Бөтен төрки телләр фонемаларын берләштерә алырдай графика төзү реаль нәрсә түгел.* Ә.Кәримуллин.

Мондый нәтиҗәне – реаль кандидатны барыбер Президент тәкъдим итүен, ә закон чыгару җыелышын раславын исәпкә алып, бераз гына төзәтмә кертеп чыгарырга мөмкин. Татарстан

2. *рәв. мәгъ.* 1) Тормыштагыча; чынбарлыкта ничек булса, шулай. *Композиторның музыкаль телендә --- кешеләрнең эчке кичерешләрен реаль тасвирлап бирү бик уңышлы итеп романтик дулкынлану, саф күңеллелек һәм импрессионистик матурлык белән алып барыла.* Ч.Бәхтиярова

2) Чынбарлыкка нигезләнеп, уйлап, аек акыл белән. *Менә шундый реаль уйлый белүче кыз кирәк аңа. Фәнүзә кебек бәйрәмчел чикерткә түгел.* Х.Камалов

РЕАЛЬЛӘШТЕРҮ *ф.* 1) Реаль итү, тормышка ашыру, башкарып чыгу; гамәлгә кертү, реализацияләү. *Конференциядә катнашучылар яшьләрнең реаль чынбарлыкта социаль җайлашуы, аларның белемнәрен, сәләтләрен, якты омтылышларын һәм хыялларын реальләштерү өчен шартлар тудыру һәм яшьләр сәясәтенә кагылышлы кануннарны камилләштерү турында сөйләштеләр һәм фикер алыштылар.* Татарстан яшьләре

2) Реаль дип күзаллау, реаль итеп күрсәтү, чынлыкка якынайту. *Алар иҗаты шул конфликтны гәүдәләндерә, реальләштерә, аны сәнгать, шигърият күренешенә әйләндерә.* М.Гайнетдинов

3) *ялг.* Үз мөмкинлекләреңне сынау, тормышка ашыру, сәләтеңне күрсәтү, үзеңне таныту. *--- Үзен радиода сынап карарга теләүчеләр бар икән, безгә рәхим итсеннәр! Үз-үзеңне реальләштерү, тәҗрибә туплау өчен менә дигән эш урыны, минемчә.* Л.Локманова

РЕАЛЬЛӘШҮ *ф.* Тормышта урын алу, гамәлгә куелу, гамәлгә ашу. *Анализ өчен нигез итеп функциональ-семантик кыр эчендәге төп грамматик категориянең мәгънәсе алына һәм бу мәгънәнең башка фигыль формалары белән реальләшүе карала.* Татар грамматикасы

РЕАЛЬЛЕК *и.* 1) Чынбарлык; тормыш. *Шуның аркасында балалыкка төшелгән, кырыс реальлекне исәпкә алмыйча, җиңел, беркатлы уй йөртелгән.* Х.Камалов. *Ни дәрәҗәдә реальлеккә охшаш ситуацияләр һәм геройлар тудырган?* А.Әхмәдуллин

2) Реаль булу, дөреслек, чынлык, тормышчанлык. *Соңрак фәлсәфи нигез арткарак күчеп, реальлеккә омтылыш, бәндәчелек, җир акылы, яшәеш мотивлары өстенлек алгандыр кебек.* Ф.Әмәк. *Тик җиде кат үлчә, бер кат кис дигәндәй, боларның реальлегенә ышанырга ярыймы?* Р.Сафин

РЕАНИМАТО́ЛОГ *и. лат.-гр. мед.* Реаниматология белгече. *Октябрь аенда Чаллыдан алты кешелек икенче төркем: реаниматологлар, кардиохирурглар, анестезиологлар тәҗрибә өйрәнү өчен Германиягә юл тотачак.* Ватаным Татарстан

РЕАНИМАТОЛО́ГИЯ *и. лат.-гр. мед.* Медицинаның үлем хәлендәге яки мәрткә киткән организмны терелтү проблемаларын өйрәнә, реанимация һәм интенсив терапия ысулларын камилләштерә торган тармагы. *Аның каруы фтизиатрия, онкология, анестезиология, реаниматология белгечлекләренә кытлык.* Татарстан яшьләре

РЕАНИМАЦИОН *с.* Реанимациягә бәйләнешле. *Бәлагә таручыны заманча реанимацион җиһазлар белән тәэмин ителгән «Ашыгыч ярдәм» автомобильләре тиз арада махсус травма үзәкләренә илтәчәк.* Ватаным Татарстан

РЕАНИМА́ЦИЯ *и. лат.* 1) *мед.* Клиник үлем халәтеннән чыгару, организмны авыр хәлдән тергезү, яшәү сәләтен кайтару чаралары. *Реанимация палатасында яткач, хәле мөшкелдер, дип уйладык.* Ф.Яруллин. *Бервакыт булган хәл – реанимациягә эләктем. Миндә бит шундый дәвалап булмый торган чир: Бульбульгеймер синдромы аның аты.* В.Исламетдин

2) *күч.* Нәрсәнең дә булса яңадан торгызылуы, кабат урнашуы

РЕ́БУС *и. лат.* 1) Эзләнә торган сүзне, фразаны хәрефләр, билгеләр, фигуралар комбинациясе белән сурәтләгән рәсемле табышмак, башваткыч төре. *Билгеле, орнамент ул ребус түгел, бертөрле бизәк төрле кабиләләрдә төрле мәгънәдә булырга мөмкин.* Г.Дәүләтшин

2) *күч.* Аңлавы кыен булган, буталчык әйбер. *Очрашканда, ул бит бу хакта ләм-мим берни әйтмәде. --- Менә тагын ребус.* Ә.Хәсәнов. *Ярый ла аңлатып бетерә алса! Нәрсә әйтергә тели соң бу дип, ребус чишеп утырырга калдырылмаса.* Ф.Гарипова

РЕВАКЦИНА́ЦИЯ *и. лат. мед.* Билгеле вакыт узганнан соң, кабат ясала торган вакцинация. *Ныклы иммунитет барлыкка килсен өчен, күпмедер вакыттан соң ревакцинация үтәргә кирәк.* Мәгърифәт

РЕВАЛОРИЗА́ЦИЯ *и. лат. финанс.* Милли валютаны номиналы буенча алтынга алмаштыруны яңадан торгызу; акчаның, товарның бәясе кинәт төшкәннән соң, яңадан үз хәленә кайту

РЕВАЛЬВА́ЦИЯ *и. лат. финанс.* Милли валютаның алтын белән тәэмин ителешен рәсми күтәрү, һәм шуның аркасында аның курсы күтәрелү

РЕВАНШ *и. фр.* Җиңелгән, көчсезләндерелгән якның өстенлеккә ирешү, җиңү өчен кабат көрәше. *Бер яктан, хәзерге көндә диннәрнең кабат җәнлануы, бастырылып яткан еллар өчен реванш алырга, мөмкин кадәр күбрәк җаннарны үз канаты астына кертергә омтылуы күзәтелә, икенче яктан, җәмгыятьнең укымышлы катламы диннең һәр сүзен сукырларча кабул итүдән ерак тора.* С.Шәмси

РЕВАНШИЗМ *и. рус* Җиңелгәннән соң реванш алу максаты белән яңа сугышка әзерләнү сәясәте

РЕВАНШИСТ *и. рус* **1.** Реваншизм тарафдары, реваншизмны яклаучы кеше. *– Икегез дә путчист сез, белдегезме шуны! Реваншистлар! – Малай дулап чыгып китте, ата-ана телсез калды.* М.Мәһдиев

2. *с. мәгъ. к.* **реваншистик**. *Вермахтның үткән сугыштан соң суд карары белән асылмый калган реваншист генераллары җинаятьле кулларын Көнчыгышка сузалар.* Ш.Мөдәррис

РЕВАНШИ́СТИК *с.* Реваншизмга караган, реваншизмны яклый торган, аны пропагандалаган. *Сугышның иң төп сәбәбе – Гитлер Германиясенең нацистик һәм реваншистик карашы.* Ватаным Татарстан

РЕВАНШИСТЛЫК *и.* Реваншист булу

РЕВАНШЧЫ *и.* **1**. *к.* **реваншист** **2**. *с. мәгъ.* Реваншизм яклы

РЕВАНШЧЫЛЫК *и. к.* **реваншизм**. *Реваншчылык сәясәте*

РЕВВОЕНСОВЕТ *и. рус тар.* 1918–1921 елларда Советлар Россиясе чорында фронтта, армиядә, флотта хәрби власть һәм сәяси җитәкчелекнең югары коллегиаль органы. *Әгәр беренче декабрьгә Врангель юк ителеп Кырым алынмаса, Сезне реввоенсовет утырышына чакырып, җавап бирдерәчәкбез.* З.Зәйнуллин

РЕВЕНЬ *и. фар. бот. к.* **рәвәҗ**. *Тамырчадан үрчеткәндә, ревеньның сорт сыйфатлары ныкланa.* Яшелчәчелек

РЕВЕРАНС *и. фр.* 1) Хатын-кызның хөрмәтләү йөзеннән җиңелчә тез чүгеп ясаган сәламләү хәрәкәте. *Мин торып баш игәч, сез миңа реверанс ясадыгыз, ләкин шунда ук чыгып та киттегез.* Ә.Еники. *Мария Пётр алдында реверанс ясый. Патша аның кичерү соравын, ялваруын көтә.* Х.Камалов

2) *күч.* Кирәгеннән артык илтифатлылык, ялагайлану билгесе. *Бәлки, ул моны әйтеп миннән рәхмәт көткәндер, мин реверанс ясарга ашыкмадым.* Т.Миңнуллин. *Гомер бакый мир, җыен сүзенә колак салып гамәл кылуны гадәт иткән кенәз, узаман – бүген диңгезләр артындагыча президент – Көнбатышка барып реверанс ясый, мәҗлесләр уздыра.* Кызыл таң

РЕВЕРБЕРА́ЦИЯ *и. лат. физ.* Тавышның күп тапкырлар бәрелеп кире кайтканда, әкренләп интенсивлыгын югалту, көчсезләнү күренеше; махсус прибор ярдәмендә тудырылган шундый эффект. *Беренчедән, артык көчле йотылыш тавышны тоныкландыра, икенчедән исә реверберацияне шулкадәр көчсезләндерә, хәтта тавышлар өзек-өзек һәм коры булып ишетеләләр; шуңа күрә, артык озын реверберациядән котылу кирәк булган кебек үк, артык кыска реверберация дә ярап бетми, гомумән, иң яхшы реверберация төрле заллар өчен төрлечә, һәм бу һәр залны проектлаштырганда исәпкә алынырга тиеш.* Кызыклы физика

РЕ́ВЕРС *и. лат.* 1) Медаль яки металл акчаның кире (иләк) ягы

2) *икът.* Берәр нәрсәне гарантияләүне үз өстенә алу

3) *махс. к.* **реверсор**. *Кайбер иттарткычларда реверс функциясе бар, ягъни шнек кире якка әйләнеп, иттарткыч чыгара алмаган итне кире чыгара торганы да бар.* Ватаным Татарстан

4) Артка таба әйләнмәле хәрәкәт. *Бәеннән ычкынган пароход әкрен генә акваториягә чыкты да, берничә реверстан соң, диңгезгә таба борылды.* М.Юныс

РЕВЕРСИВ *с. махс.* Әйләнү яки хәрәкәт итү юнәлешен үзгәртеп була торган. *Реверсив электродиализ системасы. Реверсив светофор*

РЕВЕ́РСИЯ *и. лат.* 1) *биол.* Тереклек һәм үсемлекләрдә: якын бабаларында булмаган борынгы баба билгеләренең яңадан килеп чыгу күренеше; атавизм

2) *юр.* Мөлкәтне элекке иясенә кайтару

РЕВЕ́РСИЯЛӘҮ *ф.* Реверсия (*2 мәгъ.*) ясау

РЕВЕ́РСЛАҮ *ф.* Хәрәкәт юнәлешен кирегә таба үзгәртү

РЕВЕ́РСОР *и. ингл. махс.* Двигатель валларының әйләнү юнәлешен үзгәртә торган җайланма

РЕВИЗ *и. сөйл. к.* **ревизия** (*2 мәгъ.*). *1858 елдагы ревиз кенәгәсендә исә бер генә урыс исемле кеше дә калмаган, «Ислам дәфтәре»нә авылы белән кайтканнар*. Ислам – татарлар һәм мөселманнар. *Ревиз исемлеге*

РЕВИЗИОНИЗМ *и. лат. филос.* Нинди дә булса тәгълиматның, теориянең төп нигезләрен кабат карауны таләп иткән сәяси агым

РЕВИЗИОНИСТ *и. рус* Ревизионизм тарафдары; ревизионизмны яклаучы

РЕВИЗИОНИСТЛЫК *и.* Ревизионист булу

РЕВИ́ЗИЯ *и. лат.* 1) Башкарылган эшләрнең законлылыгын билгеләү максаты белән үткәрелә торган тикшерү. *Декабрьнең соңгы көннәрендә колхозда ревизия комиссиясе эшли башлады.* М.Мәһдиев. --- *атна-ун көн уздымы икән, кибеткә ревизия килеп төште.* Г.Ахунов. *Ләкин барыбер ревизия, килгән саен, эшеннән әллә никадәр җитешсезлек таба.* В.Нуруллин

2) *тар.* XVIII йөздә һәм XIX йөзнең беренче яртысында Россиядә: җан башына салым салу өчен халык санын исәпкә алу эше. --- *1781 елгы дүртенче ревизия мәгълүматы буенча, «типтәр» дип аталган ирекле крестьяннарның саны 43656 ир булган.* Г.Гобәйдуллин. *1850 нче елдагы 9 нчы ревизия нәтиҗәләре буенча, Әртә-Шигер авылында 80 ир-ат, 76 хатын-кыз яшәгән.* И.Хуҗин

3) Нәрсәне дә булса тамырдан үзгәртү максаты белән тәнкыйть күзлегеннән яңадан карау (берәр теорияне, тәгълиматны). *Кайбер шикле сәясмәннәрнең Интернет-сайтларда милләтара бердәмлеккә, Башкортстанның казанышларына ревизия үткәреп, үз йөзен табарга тырышуы уңышсызлыкка дучар булачак.* Кызыл таң

РЕВИ́ЗИЯЛӘҮ *ф.* Ревизия (*1 мәгъ.*) үткәрү, тикшерү

РЕВИЗОР *и. фр.* 1) Ревизия (*1 мәгъ.*) үткәрүче дәүләт хезмәткәре. *Май заводында ревизор Санап бакса – җитмәү зур.* Ш.Галиев

2) Тимер юл хезмәтенең аерым өлкәләрендә хезмәт күрсәтүче, поезд контролёры. *Элеккеге елларда Арчада, Курса разъездында пассажирский поездларның баскычларына асылынып, товар составының тормоз баскычларында туңып-өшеп, ревизорлардан тотылып, штрафлар түләп --- йөргән көннәремне исемә төшердем.* М.Мәһдиев

РЕВИЗОРЛЫК *и.* Ревизор эше

РЕВКОМ *и. рус тар.* Революцион комитет – Совет властеның гражданнар сугышы һәм хәрби интервенция чорында (1918–1920 еллар) вакытлы гадәттән тыш орган. *Бер ягына кызыл йолдыз, икенче ягына якорь төшерелгән бу зур соры таш астында Бөгелмә ревкомының членнары Петровская белән Просвиркин иптәшләрнең һәм янә бер билгесез матроснының гәүдәләре ята.* Г.Әпсәләмов. *1920 елның 10 июнендә ТАССР ревкомы составы хакындагы карар кабул ителә.* Рәмзи Вәлиев

РЕВКОМИ́ССИЯ *и. рус* Ревизия комиссиясе. *Ревкомиссиянең эше тәмамлануга, колхозда уңыш бүлү башланды.* М.Мәһдиев

РЕВМАТИЗМ *и. гр.* Башлыча йөрәк-кан тамырлары системасының һәм буыннарның тоташтыргыч тукымалары зарарланудан гыйбарәт йогышлы авыру. – *Бик күпләр, ревматизм аяк-кулларны гына авыртыра, дип уйлыйлар, – диде ул [профессор Әбүзәр Таһиров] ---. Хәлбуки ревматизм, барыннан да элек, йөрәккә, нерв системасына, эчке органнарга зур зыян китерә.* Г.Әпсәләмов. *Ревматизмнан һәм төрле паразитлардан котылу өчен, җәнлекләр кырмыска оялары өстенә ятып ауныйлар.* Кызыклар дөньясында. *Ревматизмнан дару үләннәре белән генә котылып булмый, әмма хәлне җиңеләйтеп була.* Мәдәни җомга

РЕВМА́ТИК I *и. рус* Ревматизм белән авыручы кеше

РЕВМА́ТИК II *с.* Ревматизм белән бәйле, ревматизм характерындагы. *Казанда ревматик авырулары булган пациентларга үзләренең халәтен билгеләү өчен, терминал эшли башлады.* Шәһри Казан

РЕВМАТО́ЛОГ *и. рус* Ревматология белгече. *Казан поликлиникаларының да берничәсендә генә ревматолог штаты сакланып калган.* Ватаным Татарстан

РЕВМАТОЛО́ГИЯ *и. гр.* Медицинаның ревматизм авыруын өйрәнә һәм аны дәвалау белән шөгыльләнә торган тармагы. *Казанда Россия медицина фәннәре академиясенең ревматология институты филиалын оештыру Татарстанны Идел буе округының ревматология үзәгенә әйләндерәчәк.* Ватаным Татарстан

РЕВОЛЬВЕР *и. лат.* **1.** Әйләнмә барабанлы магазины булган күп зарядлы кечкенә утлы корал; алтатар. *Зәһри исә револьверны аның [дежур милиционерның] өстәленә китереп куйды. – Санап ал, нәкъ алты патрон, – диде.* М.Мәһдиев. *--- безнең гасыр башында һәм аеруча инкыйлаб елларында киң билгеле булган маузер дигән револьверны һәм шул исемдәге мылтыкны милләте белән немец Маузер уйлап тапкан.* Кызыклар дөньясында

2. *с. мәгъ.* Шул коралның барабаны принцибындагы борылма җайланмасы булган. *Револьвер станок. Револьвер мич*

РЕВОЛЬВЕРЧЫ *и. махс.* Револьвер станокта эшләүче

РЕВОЛЮЦИОН *с.* **1.** 1) Революция идеяләрен хуплаган, революциягә өндәгән, революция ясауны максат итеп куйган. *Көнчыгыштагы бер генә революцион оешма да Европа империализмына җитди йогынты ясый алмаячак.* Р.Хәйретдинов. *Заманының алдынгы карашлы кешесе Мансур Халиков революцион эшчәнлекнең җитәкче органнарында була.* Кызыл таң

2) Революция тарафыннан билгеләнгән, аның уңышлары сагында торган, революция нәтиҗәләрен яклый торган

3) *күч.* Кискен рәвештә алга китеш, үзгәрешләр китереп чыгара торган; тамырдан үзгәртеп корган. *Кешенең тормышка – субъектның объектка мөнәсәбәтен революцион практика рәвешендә аңласак кына, тарихта шәхеснең ролен дөрес аңлаган булырбыз ---.* Г.Нигъмәти. *Әгәр дә батареяны микроүлчәмгә кадәр кечерәйтү юлы табылса, бу – югары технологияләр өлкәсендә революцион ачыш булачак.* Шәһри Казан

2. *рәв. мәгъ. сөйл.* Революция ихтыяҗларына, таләпләренә туры китереп

РЕВОЛЮЦИОНЕР *и. фр.* 1) Революцион хәрәкәттә катнашкан көрәшче; көрәшнең революцион методларын яклаучы; революция эшлеклесе. *Йөрәгенең бөтен ялкынын, бөтен сәләтен революция юлына биргән Дзержинский кебек батыр йөрәкле революционерлар, я булмаса үзебезнең Сарьян абыйлардай ныклы большевиклар искә төшә.* Г.Бәширов

2) *күч.* Фән, техника, тормышның нинди дә булса тармагында яңа юллар табучы, тамырдан үзгәреш кертүче кеше

РЕВОЛЮЦИОНЕРЛЫК *и.* Революционер булу, революционер эшчәнлеге. *Ул революционерлык, даһилык рухын Далида да сизә.* Адымнар

РЕВОЛЮЦИОНЛАШТЫРУ *ф.* Революцион идеяләрне сеңдерү, революция яклы итү

Революционлаштырып бетерү Барысын да, тулысынча революционлаштыру

Революционлаштырып җибәрү Бераз, берникадәр революционлаштыру. *Автор, мөгаен, бераз революционлаштырып җибәрү теләге белән пьесаны шулай тәмамларга уйлагандыр.* М.Җәлил

РЕВОЛЮЦИОНЛАШУ *ф.* Революцион идеяләргә тартылу, революцион карашлар, хәрәкәт көчәю; революция яклы булып китү, революционерга әйләнү

Революционлаша бару Акрынлап революционлашу, революционлыгы акрынлап көчәю. *Бу дәвер аның көннән-көн революционлаша баруы, эшчеләр сыйныфына якыная баруы белән характерлы.* М.Җәлил. *Февраль революциясе аның дөньяга карашында тарихи оптимизмны көчәйтте, бу оптимизм көннән-көн революционлаша барды.* Ә.Дусайлы

Революционлаша төшү Тагы да революционлашу; бераз революционлашу

Революционлашып бетү Тәмам, тулысынча революционлашу

Революционлашып китү Ниндидер сәбәп, этәргеч белән революционлашу

РЕВОЛЮЦИОНЛЫК *и.* Революцион булу үзлеге. *Ул бит социализмга эшчеләр хәрәкәте аркылы түгел, ә вак буржуаз революционлык аша килде.* Адымнар

РЕВОЛЮ́ЦИЯ *и. лат.* 1) Табигать, җәмгыять, танып белү күренешләренең агышында булган тирән үзгәреш, сыйфат ягыннан кискен алга сикереш – үсешнең бер юлы. *Геологик революция. Фәнни-техник революция*

2) Яшәп килгән иҗтимагый һәм сәяси стройны көч куллану юлы белән бәреп төшереп, сәяси хакимиятне алмаштырудан гыйбарәт җәмгыятьтәге үзгәртеп кору; инкыйлаб. *Бишенче ел революциясе, бердән, буржуаз демократик революция булса, икенчедән, ул пролетариат революциясе дә [иде].* Г.Нигъмәти. *Революциянең беренче канлы көрәш елларында ул бала булды.* Г.Ибраһимов. *Россиядә көчле пролетариат революциясе дулкыннары*

күтәрелгәч, бу язучыларның бертөрлесе, ак эмиграциягә китеп, фашизм ялчысына әйләнде, бертөрлесе контрреволюцион көрәш алып барды. М.Җәлил

3) *күч.* Тамырдан үзгәртеп кору, берәр өлкәдә кискен алмашыну, борылыш (фән, сәнгать, әдәбият һ.б.ш. өлкәләрдә). *Әлеге хезмәт фәннең күренекле әсәрләреннән санала, аның белән И.Ньютонның хәзерге физикада революция ясаган хезмәте генә көндәшлек итә ала.* Мәгърифәт

РЕВОЛЮ́ЦИЯЧЕ *и. сир. к.* **революционер**. *Революцияче партияләр идән астына киттеләр.* Г.Тукай

РЕВОЛЮ́ЦИЯЧЕЛ *с.* Революцион идеяләргә бирелгән; революция яклы булган. *Бишенче елдагы һәм аннан соңгы еллардагы татар эшчесе нинди карашлар белән көрәш алып бара, революциячел зыялылар бу көрәштә нинди урын тоталар һәм башка шуңа охшаш сорауларга әле монда җавап юк.* Г.Тукай. *Көнбатышта ирекле шигырьне яклап, шуның буенча язып чыгучыларның күпчелеге революциячел бунтарь, вак буржуа шагыйрьләре булды.* Г.Нигъмәти

РЕВТРИБУНАЛ *и. рус тар.* Революцион трибунал (1917–1922 елларда революциягә каршы көрәшүчеләрне эзәрлекләү, хөкем итү өчен оештырылган суд учреждениесенең исеме). *Ревтрибунал карары белән алты винтовкадан шул егетне атып үтерделәр.* Адымнар

РЕВЮ *и. фр.* 1) Әдәби, фәнни һәм сәяси вакыйгаларга күзәтү бирә торган журнал

2) *театр* Актуаль бер темага багышланган, аерым күренеш, эпизод яки номерлардан берләштереп ясалган тамаша. *Шунда ук Татарстан халыклары ассамблеясы һәм Казан милли мәдәни оешмалары катнашында «Бердәм дуслык белән көчле без!» дигән театральләштерелгән чара – ревю була, балалар өчен уен мәйданчыклары, аттракционнар, күчмә зоопарк эшли, клоуннар парады, рольле уеннар, конкурслар оештырыла*. Шәһри Казан

РЕГА́ЛИЯ *и. лат.* 1) Монархия хакимияте, падишаһлык яки дини сан билгесе, символы булган әйберләр (таҗ, патша таягы һ.б.)

2) *тар.* Феодаль монархларның берәр нәрсәне җитештерүгә, берәр төрле керем алуга мополистик хокукы

3) *сөйл.* Орден, медаль һ.б.ш. билгеләр

РЕГА́ТА *и. ит. спорт* Ишкәкле, җилкәнле яки моторлы көймәләрдә үткәрелә торган зур ярыш. *Соңыннан исә ТР Яшьләр эшләре, спорт һәм туризм министры Рафис Борһанов оештырган регата – җилкәнле көймәләрдә ярышлар башланды.* Татарстан яшьләре

РЕ́ГБИ *и. инг. спорт* Овал формадагы тупны уенчылар, куллары, аяклары белән бер-берсенә тапшырып, каршы як капкасына мөмкин кадәр күбрәк туп кертүдән гыйбарәт командалы спорт уены. *Югары лига командалары арасында регби буенча Россия чемпионатында әле быел гына чыгыш ясый башлаган «Агроуниверситет» командасы икенче уен рәттән җанатарларын сөендерә.* Ватаным Татарстан

РЕ́ГБИЧЫ *и. спорт* Регби уйнаучы. *Казанның яшь регбичыларына алтын медаль һәм кубокларны Татарстан Республикасы Регби федерациясе президенты, Казан дәүләт аграр университеты ректоры Җәүдәт Фәйзрахманов тапшырды.* Татарстан яшьләре

РЕГЕНЕРА́Т *и. лат. тех.* Бер кат файдаланылганнан соң, кабат беренчел сыйфатлары торгызылган материал

РЕГЕНЕРАТИ́В *с. тех.* Регенерация белән бәйле, регенерацияли яки регенерацияләнә торган. *Төкле суалчаннар көчле регенератив сәләткә ия.* Биология. *Әлеге чара вакытында ТР Фәннәр академиясенең мөхбир әгъзасы А.Кыясовның «Медицинаның яңа перспективалары – регенератив медицина» дигән темага ачык лекция укуы көтелә.* Шәһри Казан

РЕГЕНЕРА́ЦИЯ *и. лат.*1) *тех.* Нәрсәнең дә булса үсеше, үзгәреше, эшкәртү процессында яңару, яңадан эшкә яраклы хәлгә кайту, элекке хәленә кайту (мәс., файдаланылган материал)

2) *биол.* Тән, әгъза, тукыма, күзәнәкләрнең юкка чыккан, зарарланган өлешләрен организмның яңадан торгызу күренеше, яңадан үз хәленә кайтуы. *Гәүдәнең юкка чыккан һәм җәрәхәтләнгән өлешләрен шулай яңадан торгызу процессы регенерация дип атала.* Биология

РЕГЕНЕРА́ЦИЯЛӘҮ *ф.* Регенерация ясау. *Кабинаның [Советлар Союзында җибәрелгән Җирнең икенче ясалма иярченендәге] һавасын кондицияләү системасы регенерацияләү җайланмасыннан һәм нормаль температураны саклаучы системадан тора.* В.Казневский. *Күпчелек суалчаннарда гәүдәнең югалган өлешен регенерацияләү сәләте бик көчле* ---. Кызыклы физиология

РЕ́ГЕНТ *и. лат.* 1) Монарх урынына вакытлыча идарә итүче кеше. *Ханның васыяте буенча, Казан тәхетенә аның яраткан хатыныннан туган улы сабый Үтәмешгәрәй утыртыла, Сөембикә үзе сабый ханның җитәкчесе, регенты --- була.* Ф.Урманче

2) Чиркәү хоры дирижёры

РЕ́ГЕНТЛЫК *и.* 1) Монархияле илләрдә: монархның яшь булуы, авыруы яки озак вакытка кая да булса китеп торуы сәбәпле, аның урынына бер яки берничә кешенең вакытлыча дәүләт белән идарә итү чоры

2) Регент дәрәҗәсе, урыны. *Атасы Сафа-Гәрәй вафатыннан соң ханлык тәхетенә әнисе Сөембикә регентлыгында өч яшьлек Үтәмешгәрәй күтәрелә.* Р.Әмирхан

РЕГИОН *и. лат.* Нинди дә булса уртак билгеләр белән берләшкән район, төбәк, территория, зур өлкә, янәшә урнашкан илләр төркеме. *Бүгенге көнгәчә татарлар яши торган регионнарга ясалган археографик экспедицияләр нәтиҗәсендә халык арасыннан «Кыйссаи Йосыф»ның 160 тан артык кулъязма нөсхәсе табылган.* М.Хәсәнов. *Сәетгалиев, азык-төлекне Татарстаннан үзәккә һәм башка регионнарга җибәрү өчен, барысын да эшли.* Рәмзи Вәлиев. *Регионның геополитик хәле тотрыксыз була, бу чорда әле бер көч, әле икенче көч өстенлек ала*. Мирас

РЕГИОНАЛИЗМ *и. рус* Сәяси яки икътисади мәсьәләләрне хәл иткәндә, аерым регион мәнфәгатьләреннән чыгып эш итү күренеше

РЕГИОНАЛЬ *с.* 1) Аерым бер өлкәгә, регионга бәйләнешле, регионга

караган. *Инженердан талантлы эшмәкәргә «әверелгән» ханым Россиядәге иң эре иминият брокерларыннан саналучы Генераль Агентлар Төркеменең Казан региональ бүлегенә җитәкчелек итә.* Сөембикә

2) Җирле, урындагы; төбәкчел. *Кайбер белдерүләргә һәм раслауларга караганда, әдәбиятыбыз тирән кризис хәлендә, ул вак темалар, региональ һәм провинциаль проблемалар белән генә мавыга.* Т.Миңнуллин. *Балтач районының мөхтәсибе, региональ казыебыз, вәгазьләр остасы, байтак дини китаплар авторы, исерткеч эчемлекләрсез үтә торган туйлар алып баручы җор сүзле тамада Җәмил хәзрәтнең --- сүзләре искә төште.* Т.Нәҗмиев. *Менә шуның нәтиҗәсендә беркадәр региональ аң, төбәкчел аң үсте.* Татар милләт календаре

РЕГИСТР *и. лат. махс.* 1) Исемлек, күрсәткеч; теркәү кенәгәсе. *Тагын бер кызыклы момент: кенәгә буенча, регистр буенча түләнгәнгә күрә, Уфа губернасында җир биләүчеләрнең ясагы да XVI гасырда һәм XVII гасыр башларында типтәр ясагы дип йөртелгән.* Фән һәм тел

2) *муз.* Җырчы яисә музыка коралы тавышының югарылык һәм көч дәрәҗәсе. *Мәсәлән, скрипка авазы югары регистрда яңгырый, мондый тавыш психикага уңай йогынты ясый.* Сәхнә

3) Клавишлы музыка коралларында бердәй тембрдагы трубалар яки телләр группасы

4) Музыкаль инструментларда тавышның көчен, тембрын, югарылыгын үзгәртү җайланмасы

5) Машина һәм приборларда регуляторның бер төре

6) Язу машинкасында хәрефләр һәм клавишлар рәте

7) Суднолар төзү һәм алардан файдалану буенча күзәтчелек итә торган дәүләт органының исеме. *Регистр вәкилләре, коридорга чыгу белән сулга борылып, капитан каютасына юл тоттылар.* М.Юныс

8) *информ.* Процессорның мәгълүматларны эшкәртә торган махсус ячейкасы

РЕГИСТРА́ТОР *и. лат.* 1) Регистрация алып баручы, рәсми таләпләр нигезендә нәрсәнеңдер исәбен алу, рәсми статус бирү һ.б. максатлар белән теркәүче кеше, юридик зат яки җайланма. *Регистратор ханым алар белән маташкан арада, мин шыпырт кына чыгып тайдым.* С.Сабиров. *Регистратор, «бернәрсә дә белмим» дигәнне аңлатып, иңсәсен генә җыерып куйды.* Ф.Латыйпов

2) *махс.* Рәсми кәгазьләрне теркәп саклау өчен махсус катыргы папка

3) *тех.* Юл йөрү кагыйдәләре үтәлешен күзәтеп, яздырып бара торган җайланма. *«Машина йөртүчеләр юлда йөрү кагыйдәләрен регистратор янында гына түгел, ә бөтен юл дәвамында үтәргә мәҗбүр булачак», – ди ул.* Безнең гәҗит

4) *тех.* Видеокүзәтү алып барыла торган системаларда видеоязманы теркәү һәм саклау җайланмасы

5) *тех.* Очкычта очышның төп параметрларын, төрле системаларның эшен, экипажның сөйләшүләрен яздырып бара торган җайланма

РЕГИСТРА́ТОРЛЫК *и.* Регистратор (*1 мәгъ.*) вазифасы; регистратор булу

РЕГИСТРАТУ́РА *и. лат.* Регистрация алып бару бүлеге; регистрацияләү эше. *«Бәкер»гә – санаторийга килгәч, башта теркәлү бүлмәсенә, ягъни регистратурага мөрәҗәгать итәсең.* Т.Нәҗмиев

РЕГИСТРА́ЦИЯ *и. лат.* 1) Язып теркәп кую, исемлеккә кертү, реестрга кертү; законлаштыру, рәсмиләштерү максаты белән билгеле бер тәртиптә язып, билгеләп кую. *Үзегезнең эшегезне төгәлләгәннән соң, үзегез я булмаса миссис Пигденның аска төшеп регистрация үтүен сорар идем.* Д.Салихов. *Барып җитеп билетына регистрация ясаткач, аэропорт артындагы типтигез киң яланга чыктылар.* Ф.Садриев

2) Никахны законлаштыру

3) Регистрацияләү белән шөгыльләнә торган бүлекнең үзе. *Регистрациядә эшләүче кыз безгә уку билеты язып бирде.* М.Юныс

РЕГИСТРА́ЦИЯЛӘҮ *ф.* Регистрация ясау, теркәү. *[Советлар Союзында җибәрелгән Җирнең икенче ясалма иярченендәге] Кабинага хайванның пульсын, сулыш алуын һәм кан басымын регистрацияләү, электрокардиограмма алу өчен аппаратлар --- урнаштырылган иде.* В.Казневский

Регистрацияләп бару һәрберсен бер-бер артлы регистрацияләү. *Парашютта төшү бер сәгатькә якын сузылган. Бу вакытта приборлар этнең температурасын, пульсын һәм сулышын регистрацияләп барганнар.* В.Казневский

Регистрацияләп бетерү Барысын да регистрацияләү

Регистрацияләп кую Алдан регистрацияләү, регистрацияләнгән итү

Регистрацияләп тору Даими рәвештә регистрация эшен башкару

РЕГЛА́МЕНТ *и. фр.* Утырыш, җыелышларны алып бару тәртибе, кагыйдәләр, таләпләр; чыгыш өчен билгеләнгән вакыт. *– Регламент! – дип карый киңәшмәне алып баручы.* Т.Нәҗмиев. *Ата-бабаларының нинди нәселдән булуын аныклау, зал каршында озаклап гәп куертып тору регламентта бөтенләй каралмаган каралуын.* А.Хәлим. *Эш шунда ки, регламент нигезендә сессияләр дәүләтнең ике телендә ачылырга һәм ябылырга тиеш.* Мәдәни җомга

РЕГЛА́МЕНТЛАШТЫРУ *ф.* Регламентка буйсындыру; нәрсәне дә булса төгәл, дөрес билгеләү, тәртипкә салу. *--- субсидияләргә исәп-хисап ясаганда, --- куллану системасын регламентлаштыру һәм башка проблемаларны күтәрү күздә тотыла.* Ватаным Татарстан

Регламентлаштыра башлау Регламентлаштырырга керешү

Регламентлаштырып бетерү Барысын да регламентлаштыру

Регламентлаштырып кую Алдан регламентлаштырылган хәлгә китерү

Регламентлаштырып тору Даими рәвештә, һәрвакыт регламентлаштыру. *Хәзерге вакытта ремонтчылар насос белән янәшәдә зур булмаган тартманы хәтерләтүче таймер урнаштыра, ул фонтан двигателе эшен регламентлаштырып торачак.* Шәһри Казан

РЕГЛАН *с. ингл.* **1.** Иңбашы һәм җиңе тоташ итеп тегелгән. *Киң*

иңбашлылар өчен --- реглан җиңле киемнәр әйбәт. Кәеф ничек?

2. *и. мәгъ.* Шулай тегелгән, бәйләнгән өс киеме. *– Алайса, теге кыек җилкәле, шакмаклы [күлмәгеңне ки]... – Таптың, реглан килешми миңа...* М.Әмир. *Бу дүрт күзнең һәрберсе реглан сызыгын барлыкка китерә.* Йорт эшләре

РЕГРЕСС *и. лат. кит.* 1) *икът.* Вексель буенча түләүченең каршы таләбе

2) Үсештә чигенеш; артка таба хәрәкәт; *киресе:* **прогресс**. *Археология материалларына караганда, сяньбиләр чорында Үзәк Азиядә мәдәниятнең түбән төшүе һәм Сөннү дәүләте белән чагыштырганда иҗтимагый регресс күзәтелә.* Г.Фәйзрахманов. *Дикъкать белән күзәтүче өчен фәнни фикер регрессының бу билгеләре --- күптән уйлап куелган клерикаль-капиталистик һәм политик реакциянең аерым күренешләре генә иде.* Дарвинизм һәм дин

РЕГРЕССИВ *с.* 1) Регресска илтүче, артка этәрүче; бетүгә йөз тоткан; реакцион. *--- кадими мәктәпләр арасындагы аерымлыклар шактый җитди. Әмма бу – табигый процесс. Шуңа күрә аларның берсен прогрессив, икенчесен регрессив дип бәяләргә ашыгырга кирәкми.* И.Әмирханов. *Фән алга киткән саен, аның прогрессив һәм регрессив ягы үзенчә үзгәрә бара.* Г.Хөсәенов

2) *лингв.* Соңыннан килгән авазның үзеннән алда килгән авазга тәэсир итүе белән бәйле. *Регрессив ассимиляция. Регрессив аккомодация*

РЕГУЛИРО́ВЩИК *и. рус* Урам чатларында һәм юлларда хәрәкәтне тәртипкә салып торучы хезмәткәр. *Анда, юл чатында ук, регулировщик тора – аңа менә шушы кәгазьгә язылган пунктны күрсәтерсез.* Ә.Еники. *Вahапов машинаны туктатып төште дә регулировщик кыздан юлны сорап менде.* Х.Камалов. *Офицер ишарәсен күргәч, регулировщик безне олы юл аркылы чыгарырга ашыга.* С.Таһиров

РЕГУЛЯР *с. лат.* **1.** 1) Даими һәм эзлекле рәвештә булып тора торган; кабатлана торган. *Бүгеннән «Казан» халыкара аэропортында Мәскәүгә кадәр яңа регуляр рейс ачыла.* Ватаным Татарстан

2) Вакытлыча оештырылган, гамәлгә кертелгәннән аермалы буларак, даими нигездә, системалы эшли торган. *Калькутта шәһәрендә инглизләрнең регуляр гаскәре торуына, Һиндстан товарларына аларның югары пошлиналар салуына нәфрәт белдерә.* М.Мәһдиев. *Пётр I язган указында үзе төзегән регуляр армия рекрутларына карата таләпләрне кыска һәм ачык итеп формалаштырган.* Кызыклы психология

2. *рәв. мәгъ.* Һәрвакыт, даими; үз вакытында. *Физик эш, физкультура һәм спорт белән регуляр шөгыльләнгәндә, мускул җепселләре тизрәк үсәләр.* Анатомия. *Зоологик коллекцияләр регуляр рәвештә җиңләтелә торган коры урында, 18–22 °С температурада сакланырга тиеш.* Коллекцияләрне саклау юллары

РЕГУЛЯ́ТОР *и. нем.* 1) *тех.* Механизмның эшен яки хәрәкәтен автоматик рәвештә көйли, җайлый торган прибор. *Двигательне җибәргәндә, цилиндрларга ягулыкны күбрәк бирү өчен, регуляторның баеткычы хезмәт итә.* Тракторлар. *Көчәнеш регуляторы. Вакуумлы регулятор*

2) *хим.* Әчү процессын тоткарлый торган химик матдә, антиоксидант

3) *сәяси* Дәүләт системасының билгеле өлкәсендә алып барылган эшчәнлекне җайга салу һәм күзәтчелек органы

РЕГУЛЯ́ЦИЯ *и. лат. биол.* Организмның нинди дә булса яралану, пешү һ.б.ш.лар нәтиҗәсендә имгәнгән яки бөтенләй юкка чыккан урынын төзәтергә омтылышы. *Теге организмнар эшчәнлегенең координациясе һәм регуляциясе нерв һәм эндокрин системаларының эшчәнлеге нәтиҗәсендә башкарыла.* Биология

РЕГУЛЯ́ЦИЯЛӘҮ *ф.* Нормага, тәртипкә салу, көйләү. *Сөт ясалуны регуляцияләүдә --- гипофиз гармоны – пролактин әһәмиятле роль уйный.* Кызыклы физиология. *Терек организмнарның үз-үзен регуляцияләвен өйрәнә һәм бу белемнәрне техникада файдалана торган махсус юнәлеш – бионика барлыкка килде.* Гомуми биология

РЕД- *лат.* Кушма сүзләрдә «редакция» дигән мәгънәне белдерә торган беренче кисәк (мәс., *редколлегия, редсовет*)

РЕДА́КТОР *и. лат.* 1) Текстны редакцияләүче кеше. *Татарстан китап нәшриятында редактор булып эшли ---.* М.Гайнуллин. *Техник редактор. Фәнни редактор. Җаваплы редактор*

2) Нинди дә булса китап, газет, журнал һ.б.ш. ны бастырып чыгару эшенә җитәкчелек итүче, аның эшчәнлегенә юнәлеш бирүче хезмәткәр; мөхәррир. *Нурлат районы газетасының элекке редакторы Марсель Васильев, миңа ышанып бетмичәрәк, ахры, язган репортажымны башта үзенә алып кертеп күрсәтергә кушты.* Т.Нәҗмиев. *Бөтен «байлыгымны» – мәкаләм белән бергә куен дәфтәремне дә, хәтта магнитлы тасмага язылган җаваплары да редакторга кертеп бирдем.* К.Тимбикова

3) *информ.* Текстны һәм сурәтне үзгәртергә, төзәтергә мөмкинлек бирә торган компьютер программасы

РЕДА́КТОРЛЫК *и.* Редактор вазифасы, эше; мөхәррирлек. *Татарның гасыр буена җыелган редакторлык тәҗрибәсе шуны раслый: иң тупас хата да – мантыйкыймы, фактикмы ул – аваз-хәреф хатасына битарафлыктан башлана.* Ватаным Татарстан

РЕДАКТУ́РА *и. рус махс.* 1) Редакцияләү эше, мөхәррирлек процессы

2) Редакцияләнеп, басмага әзерләнгән кулъязма

РЕДАКЦИОН *с.* Редакция (*1 мәгъ.*) белән бәйле, редакцияләүгә (*1 мәгъ.*) мөнәсәбәтле. *«Галиябану» либреттосының бу соңгы варианты Әхмәт Ерикәй иптәш тарафыннан редакцион комитетның утырышында тикшерелгән һәм расланган план буенча эшләнгән.* М.Җәлил

РЕДА́КЦИЯ *и. лат.* 1) Текстны эшкәртү, төзәтү эше, редакцияләү

2) Әдәби, музыкаль һ.б.ш. әсәрнең беренче башлап язылган яки соңыннан үзгәртүләр, эшкәртүләр нәтиҗәсендә барлыкка килгән варианты; эшкәртелгән һәм басмага яраклы дип табылган текст. *Сүзлекнең беренче редакциясе*

3) Нәшриятта кулъязмаларны бастырып чыгаруга әзерләү белән шөгыльләнә торган бүлек һәм шул бүлек

урнашкан бина. *Язучының амбары, билгеле инде, аның нәшрият, театр һәм редакцияләргә тапшырган һәм алар дөньяга чыгарган әсәрләре белән билгеләнә.* Н.Исәнбәт. *Язуын редакциядә язам. Анда да әллә ни җәелеп китәрлек түгел, дүртәү утырабыз.* К.Тимбикова. *1980 елда бу бина редакция һәм типографиягә бирелә.* Т.Нәҗмиев

4) Китап, газет, журнал һ.б.ларны редакцияләү эшенә җитәкчелек итү

5) Нинди дә булса фикернең, кагыйдәнең бирелеше

РЕДА́КЦИЯЛӘҮ *ф.* 1) Текстны укып төзәтү; аны басмага әзерләү. *Була шундый әсәрләр: аларны редакцияләү бөек затларның үзләре белән очрашуга, аларның уй-тойгылары белән рухланып яшәүгә тиң.* Г.Бәширов. *[Идрис] Иң әүвәл --- чираттагы сангә ике мәкаләне редакцияләде, берничә хатка җавап язды.* А.Гыйлаҗев. *Дәүләт Советының Фән, мәгариф, мәдәният һәм милли мәсьәләләр даими комиссиясе депутатлары аларны [мөрәҗәгать проектын] тагын бер кат ныклап редакцияләделәр.* Татар милләт календаре

2) Басма хезмәтләрне, вакытлы матбугатны бастырып чыгару эшенә җитәкчелек итү

3) *сөйл.* Үз белгәненчә үзгәртү, үзенчә төзәтмәләр кертү. *Икенче әби, син бит урысча җиде сүз генә беләсең, мин менә унҗиде сүз беләм дигәндәй, тавышына масаю галәмәте чыгарып, беренче әби әйткәннәрне «редакцияләп» сөйли.* Р.Юныс

Редакцияләп алу Тиз генә, тиз арада редакцияләү

Редакцияләп бетерү Тулысынча редакцияләү; барысын да редакцияләү. *--- көн буе, үзенә урын таба алмыйча, пошынып, кайгырып йөрде. --- редакцияләп бетерәсе ашыгыч эшенә дә кулы бармады.* И.Гази

Редакцияләп бирү Кем өчендер редакцияләү, редакцияләргә ярдәм итү. *Ул минем ике китабымны җәмәгатьчелек тәртибендә редакцияләп бирде.* А.Хәсәнов

Редакцияләп килү Һәрвакыт, күптәннән, электән үк эзлекле рәвештә редакцияләү. *Хикәядә сурәтләнгәнчә, ул, совет чоры идеологиясенә таянып, күп еллар буе әдәби әсәрләрне шул рәвешле «редакцияләп» килгән.* Р.Зарипова

Редакцияләп кую Алдан редакцияләү

Редакцияләп тору Даими рәвештә, һәрвакыт редакцияләү; әле, сөйләү моментында редакцияләү белән шөгыльләнү

Редакцияләп утыру Даими рәвештә редакцияләү белән шөгыльләнү. *Миңа утыз елдан артык башкаларның әдәби әсәрләрен редакцияләп утырырга туры килде.* Х.Сарьян

Редакцияләп чыгу Башыннан ахырына кадәр, беткәнче редакцияләү. *--- либреттист киңәшмәләрдә катнашучыларның һәм рецензентларның күрсәтмәләрен һәм җитди замечаниеләрен нигездә искә алган һәм үзенең либреттосын намуслы рәвештә редакцияләп чыккан, дип әйтә алам.* М.Җәлил. *К.Гольдони пьесасын татарчага Зәйни Солтанов тәрҗемә иткән. Тәрҗемә тексты тагын бер кат редакцияләп чыгуга бик мохтаж.* Р.Батулла

Редакцияли бару Һәрберсен, булган берсен редакцияләү

Редакцияли башлау Редакцияләргә керешү

РЕДИС *и. лат.* 1) Әвернәчәчәклеләр семьялыгыннан, тиз өлгерешле, ак, алсу яки кызыл төсле, түгәрәк яисә озынчарак тамырлы яшелчә үсемлек. *– Баклажаннарны утыртыр алдыннан, әлеге урында алдагы елларда кыяр, суган, редис, кузаклы культуралар, кәбестә үссә яхшы була.* Шәһри Казан

2) Шуның алсу яки кызыл юка тышчалы, әчкелтем бүлбесе. *Әмма май ахырында инде редис өлгерде.* Ф.Зыятдинов

РЕДИ́СКА *и. рус сөйл. к.* **редис**. *Яки бакчада редискага су сибеп йөрер идем хәзер, әʔ* М.Мәһдиев. *Яңа өлгергән редиска һәм яшел суганнан салат ясаган, көндез Зариф бабай белән Мансур алып кайткан мәрсин балыгыннан уха пешергән.* С.Сабиров. *Кемнәрдер кишер орлыгы чәчә, чөгендер, редиска утырта, кемнәрдер бәрәңге өчен җир казый, кемнәрдер җиләк-җимеш үсентеләрен эшкәртә.* Шәһри Казан

РЕДКОЛЛЕ́ГИЯ *и. лат.* 1) Редакцион коллегия: китап, газет, журнал һ.б.ш.ларны редакцияләү, басмага әзерләү эшендә киңәшләшү һәм карар чыгару органы буларак белгечләр төркеме. *– Бүген кич алты сәгәттә редколлегия утырышы. Алдагы номерны чыгару турында сөйләшербез, – дидем.* Г.Нәбиуллин

2) Редакцион коллегия утырышы. *Һәрвакыттагыча, эшнең иге-чиге юк, бер сәгәттән редколлегия, ә син монда --- берәүнең кулъязмасын ничек итеп ипләбрәк кире кагарга икән, дип борсаланып утыр.* Р.Мостафин

РЕДУ́КТОР *и. лат. тех.* 1) Бер валның әйләнешен икенчесенә күчерү процессында әйләнү тизлеген үзгәртә торган тешле механизм

2) Торба буенча ага торган сыекча яки газның басымын үзгәртү яисә даимилеген саклау өчен хезмәт итә торган җайланма. *Кысылган газ редуктор аша ягулык багына керә, шуның нәтиҗәсендә бактагы басым яну камерасындагыдан зуррак була.* В.Казневский. *Редукторда һаваның басымы ун атмосферага түбәнәеп, шланг аша автоматка килә.* В.Сабуев

РЕДУ́КЦИЯ *и. лат.* 1) *махс.* Нинди дә булса катлаулы күренешнең гадигә күчүе яки күчерелүе

2) *биол.* Функциясе югалу сәбәпле, организмдагы берәр әгъзаның төзелеше гадиләшү, шул әгъзаның күләме кечерәю яки бөтенләй юкка чыгу. *Бу төркем моллюскларында өчен арка ягында кушылган ян кабырчыклы ике капкач, шулай ук баш һәм кыргычлы йоткылык редукциясе хас.* Биология

3) *лингв.* Басымсыз иҗекләрдәге сузык авазларның кыскару күренеше. *Бу морфонологик күренешнең икенче сәбәбе – [ы] һәм [е] кыска сузыкларының редукциягә омтылышында.* М.Зәкиев. *Редукция – басымсыз иҗектә килгәндә, [ы, е, о, ө] сузыкларының кыскарып килүе.* Фән һәм тел

РЕДУ́КЦИЯЛӘҮ *ф.* Редукция (*1 мәгъ.*) булдыру, редукция барлыкка китерү

РЕДУ́КЦИЯЛӘНҮ *ф.* Редукциягә (*2 мәгъ.*) дучар булу, гадиләшү, юкка

чыгу. *Икенче төркем үсемлекләрендә гаметофит ныкредукцияләнә, ул мөстәкыйль үсемлек түгел, спорофитта урнаша.* Л.Мәүлетова

РЕДУПЛИКА́ЦИЯ *и. лат. лингв.* Тамыр сүзне кабатлау юлы белән яңа сүз яки форма ясау (мәс., *кайта-кайта, яши-яши*)

РЕДУТ *и. лат. тар.* Фортификациядә: тирә-ягы вал һәм канау белән әйләндереп алынган күппочмак, турыпочмак яисә түгәрәк формасындагы әйләнә буйлап оборона тоту өчен кыр нығытмасы

РЕЕСТР *и. лат.* 1) Мал-мөлкәтне һ.б.ш.ны хисапка алу максаты белән төзелгән язма исемлек. *Бу – машинкада немец телендә басылган җиде-сигез пунктттан торган реестр: бритва, оекбаш, күлмәк, дүртенче яисә бишенче пункт булып «брифташе» – почта сумкасы дигән сүз тора.* Р.Мостафин

2) Эш кәгазьләрен теркәү кенәгәсе

3) *информ.* Операцион системаның махсус мәгълүмат базасы

РЕЖИМ *и. фр.* 1) Эш, яшәеш, тормышның рациональ бүленешләргә салынган тәртибе. *Врач гафу итсен, ял режимын бозды.* М.Максуд. *Больница режимын бозган өчен, профессор Ханзафаровны бик каты кисәтте.* Г.Әпсәләмов. *Йокы туйганчы йоклау яхшы. Режим һәм диета саклау файдалы.* Мәдәни җомга

2) Нәрсәнең дә булса барлыкка килү, булу, яшәү, эшчәнлек итү шартлары. *Бактерия үрчү өчен гажәп әйбәт шарт. Буфет эченә ультрашәмәхә нурлар үтми, температура режимы шундый кулай, берничә сәгатьтән сезнең тәлинкәләрегезне миллиардлаган бактерия явы басып китәчәк.* М.Юныс. *«Шарп» магнитофонында, тиз яздыру режимында эшләтсәң дә, дүрт кассетаны күчереп алу өчен, сиксән алты минут вакыт китәчәк иде.* Р.Мирхәйдәров. *Самолёты белән авырлык югалтуга беренче тапкыр килеп кергән очучының күзәтүләре кызыклы. Беренче секундларда аңа башы күбенә, зурая бара кебек тоела, аннары гәүдәсе каядыр билгесез якка әйләнә башлагандай була, араларны чамалау хисен югалта һәм авырлыкны югалту режимын туктатырга мәҗбүр була.* Кызыклар дөньясында

3) Нинди дә булса максатка ирешү өчен кирәк булган кагыйдәләр һәм чаралар системасы. *Туфраклардагы су режимы процессларына үләннәрнең тәэсир итүләренең монда санап үтелгән үзенчәлекләре корылыклы районнарда зур роль уйный.* Күпьеллык үләннәр

4) Дәүләт төзелеше, дәүләт белән идарә итү формасы. *Бу – тоталитар режимның ныгый барып, репрессия, эзәрлекләүләрне киңрәк җәелдереп --- җибәрү чоры, дисәк тә урынлы һәм хактыр.* Рәмзи Вәлиев. *Колониаль режим кешенең шәхси сыйфатларын әшәкелеккә көйләүче оранжерея хезмәтен үтәп килә.* М.Юныс. *Ә балалары намус ише иске режим калдыгы белән санашмый.* Х.Камалов

5) *информ.* Компьютерның эшләү ысулы, үзенчәлеге

РЕЖИМЛЫ *с.* Режим (*1, 3 мәгъ.*) белән алып барылган, режимга буйсындырылган. *Без булган каты режимлы лагерьларда тел иреге яшәде, сүз өчен эзәрлекләү дигәнне мин хәтерләмим.* А.Гыйләҗев. *Гомәрне ниндидер кырыс режимлы колониягәме, «хезмәт белән төзәтү лагере»намы хөкем итәләр.* Р.Әмирханов. *Одер һәм Рейн калкулыкларында, кайчандыр социалистик режимлы Венгриядә шул тургайлар сайравын тыңлап хозурланганым бар.* Я.Шәфиков

РЕЖИМЛЫЛЫК *и.* Режимлы булу

РЕЖИССЁР *и. фр.* Спектакль һәм кинофильмнар куюга җитәкчелек итүче; драма әсәрләрен сәхнәгә куярга әзерләүче, сәхнәләштерүче сәнгать җитәкчесе. *Җәйге каникулга кайтып балыкка төшәргә өлгермәде, комсомол оешмасы аны клубның драмтүгәрәгенә режиссёр итеп билгеләде.* Г.Бәширов. *Кызлар ролен дә егетләр башкарачак иде. Режиссёрыбыз – Илдар.* Г.Лотфи. *Режиссёр Фәрит Бикчәнтәев сәхнәләштергән әлеге спектакль шактый тәэссоратлы килеп чыккан.* Мәдәни җомга

РЕЖИССЁРЛЫК *и.* Режиссёр булу, режиссёр вазифасы, режиссёр эшчәнлеге. *Ул [Илдар] – шәһәр малае, бу эшнең ибен-җаен яхшы белә, режиссёрлык вазифасын бик җиренә җиткереп үти.* Г.Лотфи

РЕЖИССУ́РА *и. рус* 1) *к.* **режиссёрлык**. *Театр сәхнәләрендә сез артист булып эшләдегез, тынгысыз, эзләнүчән табигатегез сезне режиссура өлкәсенә алып килде.* Мәдәни җомга

2) Фильм яки спектакльнең режиссёр трактовкасы. *Чыннан да, Габдулла абый Йосыпов татар телен, театрның тарихын яхшы белә иде, әмма анда кешенең рухын ачып сала торган режиссура юк иде.* Р.Батулла

3) *җыйн.* Спектакль, фильмны куюга җитәкчелек итүче режиссёрлар. *1930 елда театрыбыз Мәскәүдә СССР халыклары театрлары Олимпиадасында катнаша. Шуның нәтиҗәсе буларак, режиссурага яңа таләпләр куела һәм, махсус югары белемле режиссёрлар әзерләү өчен, талантлы яшьләр Мәскәүгә укырга җибәрелә.* Татар театры

4) *күч.* Вакыйгалар барышына йогынты ясарлык итеп алдан уйланылган эш-хәрәкәт, әйтеләсе сүзләр, планлаштырылган вакыйгалар теземе. *Алдан уйланган режиссураның бозылуы, ялыну, ялвару сүзләренең әйтелмәве өлкән штурманның да кәефен бозган иде, күрәсең.* М.Юныс

РЕЗЕДА *и. фр. бот.* Резедачалар семьялыгыннан вак кына ак чәчәкләре башак яки чукчәчәк төркеменә берләшкән, хуш исле күпьеллык бакча гөле; мәхәббәт чәчәге. --- *читкә утыртылган резедалар көчле исләре белән юл өстендәге һаваны аңкыталар* ---. М.Әмир

РЕЗЕДА́ЧАЛАР *и. күпл. бот.* Кайбер төрләре декоратив максатларда үстерелә, кайберләреннән эфир майлары алына торган, якынча 70 төрне берләштергән үсемлекләр семьялыгы

РЕЗЕ́КЦИЯ *и. лат. мед.* Организмдагы берәр органны яки аның өлешен операция ярдәмендә кисеп алу. *Кичә ашказанына резекция ясалган авыруның хәле начарланды.* Г.Галиев

РЕЗЕРВ *и. лат.* 1) Аеруча һәм ашыгыч кирәк булу очрагы өчен алдан әзерләнгән әйбер; запас, ресурс. *Сезнең сүзегез үтә. Кондуктор өчен кыска-*

кыска торбалар сорагыз. Базада бар алар, резервта ята. К.Кәримов

2) Яңа мөмкинлекләр, көч алу чыганагы. *Организмның яшерен резервлары, авыр яраланганнан соң да, инвалид булып калмыйча, сафка басу мөмкинлеген бирә.* Кызыклар дөньясында

3) *хәрби* Яңа группировкалар төзү яки булганнарын тулыландыру максаты белән командир карамагында калдырыла торган хәрби көчләр. *Бер урында дошманның резервта яткан кавалерия бүлекләре ике полк арасына килеп кергән.* А.Шамов. *Комбриг үзенең резервын да сугышка кертте, әмма кыйтауны алып кына булмый.* Г.Әпсәләмов. *Гаҗиз булып аптыраган полк командиры соңгы резервны – штабта торган 40 кешелек комендант взводын алгы сафка китерергә әмер бирде.* Мәдәни җомга

4) *хәрби* Кайбер илләрнең армияләрендә: гаскәри хезмәт үткән һәм кирәк булганда кабат армиягә чакырылырга мөмкин булган, хәрби исемлектә торган кешеләр; запастагылар. *Моннан соң фронтовик һәм шагыйрь булып эшемне дәвам иттерермен. Хәзергә мин әле резервта. Шушы ике көндә Көнбатыш фронтка, хәрәкәттәге армиягә китәм.* М.Җәлил

РЕЗЕРВА́ЦИЯ *и. лат.* 1) Резервка калдыру, алып калу, бронь ясау. *Билетлар резервациясе*

2) Кайбер илләрдә: илдә сакланып калган төп җирле халыкның яшәү урыны буларак билгеләнгән территория. *--- минемчә, Америка индеецларының резервацияләрен барып өйрәнергә кирәк. Безнең татар авылы моңа кадәр милләтне саклап калган резервация ролен үтәде. Хәзер ул бездән китә башлады – җибәрмәскә кирәк! Аны җибәрмәү механизмнары, минемчә, әнә шул резервацияләрдә.* Р.Вәлиев

РЕЗЕРВА́ЦИЯЛӘҮ *ф.* Резервация ясау. *Кунакханәдә урын резервацияләү*

Резервацияләп кую Алдан ук резервацияләү

РЕЗЕРВИСТ *и. рус* Кайбер дәүләтләрнең армиясендә: резервтагы хәрби хезмәткәр. *--- октябрь башында Новосибирск һәм Томск өлкәләреннән 16 мең резервист ун көнлек хәрби җыеннарда катнашты.* Татарстан яшьләре

РЕЗЕРВУАР *и. лат.* Сыеклык, газ саклау өчен махсус савыт; бак. *[Карам:] Әнә шул тау итәгенә резервуар куйдырып, чишмә суын авыл өйләренә кертеп бетергәч әйтермен, ярыймы?* Э.Яһудин. *Сулау системасының тишекләре һава куыклары ябышкан җирләрдә урнашкан; яшәү өчен кирәкле кислородны [су астында] бөҗәкләр шул резервуарлардан алалар.* Кызыклы физиология. *Филләр үз хортумнарын су саклау өчен резервуар сыйфатында файдалана икән.* Мәдәни җомга

РЕЗИДЕНТ *и. лат.* 1) Илчедән бер ранг ким булган дипломатия вәкиле. *--- Нуриевны кичекмәстән СССРга кайтарып җибәрергә кушып, без шунда ук Париждагы резидентка катгый фәрман җибәрдек.* Равил Вәлиев

2) Даими рәвештә чит илдә яшәгән яисә рәсми теркәлгән һәм шул дәүләтнең кануннарына буйсынырга тиеш булган физик яки юридик зат

3) Чит дәүләттә эшли торган разведканың яшерен җитәкчесе. *[Хикәядә] Дошман як разведкасы резиденты белән Совет илендә туып үскән яшь кызның бәрелеше тасвирланган.* М.Сәхапов

РЕЗИДЕ́НЦИЯ *и. лат.* Хөкүмәт башлыгы, югары посттагы яки зур байлыкка ия булган кешеләр яшәгән урын, бина. *Алпавытның резиденцияләре революциядән соң бик хәтәр җимерелүләргә, кыргыйларча котырынып ватуларга дучар ителсәләр дә, әле һаман кирпеч стеналарын, гөмбәзле түшәмнәрен саклыйлар.* Г.Ахунов. *Ратуша, университет корпуслары, императорларның җәйге һәм кышкы резиденцияләре, дөньяда атаклы Вена операсы, яшькелт, сары, аксыл мәрмәрдән салынган, алтын йөгертелгән һәйкәлләр, чәчәккә күмелгән парклар үзенә бер илаһи атмосфера тудыра.* Т.Галиуллин. *Мондый үләнне минем Кырымдагы патша резиденциясе булган Ливадия бакчасында күргәнем бар.* М.Юныс

РЕЗИН *и. сөйл. к.* **резина**. *Каюм хәлфә --- бер башына кечкенә бакыр кыршау кидереп, аңа ашалып түгәрәкләнгән бер резин кыстырган карандаш кисәге тоттырды.* Ә.Фәйзи. *Палаталарның берсендә утырганда, резин тәгәрмәчле ак арбага салып, Сәлимованы операциягә алып китүләрен күреп, аңа күңеленнән хәерле юл теләде.* Г.Әпсәләмов

РЕЗИ́НА *и. лат.* **1.** 1) Каучукны вулканизацияләү юлы белән табыла торган сузылучан материал. *Туфракта әллә ниткән эзләр калдыра торган шинлы немец велосипеды сатып алган. Педальләре авыр, калын резинадан, аның яннары күзнең явын алырлык сары челтәрле пыяла белән бизәлгән.* М.Мәһдиев

2) *к.* **резинка** (*5 мәгъ.*). *Тәүфикъ, урта һәм имән бармагына резина тагып, аткыч ясады.* М.Юныс. *Маңгай чәчләрендә су тамчылары, чәчен яшь кызлар кебек резина белән арттан кысып куйган.* Г.Әпсәләмов

2. *с. мәгъ.* Шул материалдан эшләнгән (ясалган). *Әгәр ул аллы-гөлле зур резина туп күтәреп чыкмаган булса һәм аның белән бөтен малайларны кызыктырып уйнамаган булса, бернәрсә булмаган булыр иде.* А.Шамов. *Тирәнтирән баткан тояк эзләре, резина галош эзләре, кечкенә-кечкенә ялангач аяк эзләре җир өстен чуарлаганнар.* М.Әмир

РЕЗИ́НАЛАУ *ф. тех.* Резина сеңдерү, резина катламы белән каплау

РЕЗИ́НАЛЫ *с. к.* **резина 2.** *Аның өстендә ябык якалы кыска тужурка, аяк йөзенә үк төшеп торган озын тар чалбар, аягында тәбәнәк үкчәле, балтырыннан тотып кия торган шнурсыз резиналы ботинка иде.* М.Гали

РЕЗИ́НКА *и. рус* 1) *к.* **резина**

2) Карандаш белән язганны, сызганны ышкып бетерә торган махсус резина кисәге; бозгыч, бетергеч. *Ахири халтурадан минем фамилияне резинка белән җуеп, үзенекен язып куйды.* Г.Афзал

3) *сөйл.* Резин галош. *Аякта әүвәлге чабата урынына өр-яңа җәйге резинка булуы дәртле никрутның башын тагы да югарырак күрсәтә.* Г.Ибраһимов

4) *сөйл.* Ясалма сагыз, ясалма чәер. *Мине – тугыз яшьлек малайны да үзеннән калдырмый иде. Күксагыз дигән үсемлек чәчәләр иде сазлыклы җирләргә. Аңардан резинка ясыйлар икән,*

тамыры сузыла иде аның. Н.Гыйматдинова

5) Резин җеп: мамык яки ефәк җеп резин җепләр белән аралашкан сузылучан тасма, бау. *Әржә өстенә брезент каплады, резинкага таккан ыргакларны әйләнәгә эләктереп чыкты.* М.Юныс. *--- ул үзен нидер югалткан кебек сизде. Кесәләрен капшады: сөяк саплы, дүрт япьле пәкесе төшеп калмаган, рогаткага дигән кызыл резинка да кесәдә, нәрсәсе югалган соң малайның?..* А.Гыйләҗев

6) Сузылучан һәм җыелучан итеп бәйләү төре

7) Киемнең шулай бәйләнгән җиң очы, муены һ.б.ш. өлеше

РЕЗИ́НЛЫ *с.* Составында резин булган, резин катнаштырып эшләнгән

РЕЗОЛЮ́ТИВ *с. кит.* Төп нәтиҗәләрне, резолюцияне эченә алган, йомгак ясаган

РЕЗОЛИ́ЦИЯ *и. лат.* 1) Нинди дә булса берәр мәсьәләне киңәшмәдә тикшереп кабул ителгән карар. *Резолюцияне Шихрай тавышка куйды, һәм җыелыш аны беравыздан кабул итте.* Ш.Камал. *Ул [Татарстан өлкә комитеты сәркатибе] М.Солтангалиевкә карата кабул ителгән резолюцияне игълан итә.* Рәмзи Вәлиев

2) Рәсми эш кәгазьләре, документ, гариза һ.б.га язып кул куелган җитәкче боерыгы, карары, күрсәтмәсе. *Ул Тимерханның үтенеч кәгазенә --- резолюция яза да бүлек мөдиренә бирергә куша.* Г.Ахунов

РЕЗОНАНС *и. фр. физ., тех.* 1) Нинди дә булса тирбәнешләр системасында берәр тышкы көч тәэсире белән тирбәнешләрнең көчен арттыру күренеше. *Тирбәнү контурында резонанс булсын өчен, контурның үз тирбәнүенең ешлыгы белән аңа тыштан бирелгән көчәнеш ешлыгы бертигез булу кирәк.* Физика курсы

2) Резонатор яки бина стеналарының тавышны яңгыратучанлыгы, яңгыраш

3) *күч.* Берәр вакыйга турында халык арасында барлыкка килгән билгеле фикер, бәя. *Аның басылып чыккан һәр мәкаләсе һәм шигъри циклы, һәр китабы олы сөйләшүләргә нигез булды, резонанс алды.* Р.Вәлиев. *Сезне зур иҗтимагый резонанс уяткан мондый эшләрне санап ялыктырасым килми.* Татарстан

РЕЗОНА́ТОР *и. лат. махс.* Резонанс күренеше барлыкка китерә торган кушылык яки система. *Әлбәттә, алар [бакалар] үз балаларын бөтенләйгә йотмыйлар, ә бугаз яныңдагы, кычкырганда резонатор ролен үти торган капчыкка салып куялар.* Кызыклар дөньясында

РЕЗОНЁР *и. фр.* 1) Күп һәм озын сөйләргә, үгет-нәсыйхәт бирергә, акыл сатып өйрәтергә ярата торган кеше. *Һәрхәлдә, кешеләргә мораль укып, акыл сатып йөрүче резонёр түгел иде.* Ә.Еники

2) *әд., театр* Әдәби әсәрдә, сәхнәдә сурәтләнә торган вакыйгаларга, геройларга карата автор фикерен җиткерүче персонаж; шундый персонажлар ролен башкаручы актёрның амплуасы

РЕЗОНЁРЛЫК *и.* Резонёр булу

РЕ́ЗУС *и. нем. биол.* 1) Маймылларның макакалар семьялыгына караган бер ыруы

2) *сөйл. к.* **резус-фактор**. *Фалия, бала авыруына резус дигән нәрсә сәбәп булуы мөмкин, дип әйтеп куйды.* Х.Камалов

РЕЗУС-ФА́КТОР *и. нем. мед.* Резус маймылларының һәм кешенең каны составында була, төрле кешеләрнең каннары тәңгәл килү-килмәвен билгели торган органик матдә, антиген. *Моңа [баладагы кимчелекләргә] сәбәпче булып токсикоз, төрле имгәнүләр, канның резус-факторы, баш травмасы, нәселдән килгән авырулар һ.б. факторлар тора.* Ф.Харрасова

РЕЗЬБА *и. рус сөйл.* 1) Сыр, винт сыры. *Резьба башында – гайка. Шул гайкаларның әле берсен, әле икенчесен борып, сынган сөякне тигезлиләр икән.* Ф.Яруллин

2) Агач, сөяк кебек өслеккә уеп ясалган рәсем, сырлап ясалган бизәк. *Ул башкарган монументаль эшләр дә байтак: мозаика, гипс резьбасы, стена бизәлеше – болар Татарстанның һәм Башкорстанның урам һәм мәйданнарында --- сакланалар.* Г.Ахунов

РЕЗЬБАЛЫ *с. сөйл.* Сырлары булган. *Һәр чыбыкның башы резьбалы иде.* Ф.Яруллин

РЕЗЮМЕ *и. фр. кит.* Язылган, сөйләнгән, укылган нәрсәләрнең төп эчтәлеген чагылдырган кыскача йомгак. *--- монда кешеләр үзгәрмиләр. Кызык карт! Бер сүз белән резюме ясаганда – исәр!* А.Гыйләҗев. *Алар [миниатюрахикәяләр] кыска, әйтәсе фикер, тасвирлау стиле тыгыз, һәрбер җөмлә иң соңыннан әйтеләсе резюмега хезмәт итә.* Р.Миңнуллин

РЕИНКАРНА́ЦИЯ *и. лат.* Җанның бер тәннән икенчесенә күчеп урнашуы, яңадан гәүдәләнүе. *Хәят серләрен бәян итүче эзотерик әдәбият белән кызыксынучыларга «реинкарнация» дигән термин яхшы таныш, аны әле кабат гәүдәләнү дип тә атыйлар.* С.Шәмси

РЕЙ *и. голл. махс.* Җилкәнле судноларда мачтада туры җилкәннәрне беркетү, киерү, механик двигательле судноларда антенналар кую, сигналлар күтәрү өчен хезмәт итә торган шудырмалы аркылы борыс

РЕЙВ *и. инг.л* Заманча музыка һәм бию культурасына караган, якты ут уйнату тәэсирендә барлыкка килгән эффектларның электрон музыкага хас дәртле ритмнар белән кушылуыннан гыйбарәт юнәлеш. *Рейв белән мавыгу*

РЕЙД I *и. голл. махс.* Портта яки портка якын җирдә судноларны якорьда тоту өчен уңайлы урын. *Без палубада тын гына басып торабыз. Рейдтагы башка корабльләрдә дә шул хәл. Порт тыныч, яр буенда бернинди хәрәкәт юк.* М.Мәһдиев. *Порт каршысындагы рейдка җиткәч, пароход баруын әкренәйтә, кемнедер чакырып, басынкы тавыш белән гудок бирә.* М.Юныс. *--- көчле давыл чыгу нәтиҗәсендә, тышкы рейдта торган «Виктуар» командасы-ние белән диңгез төбенә китә.* Кызыклар дөньясында

РЕЙД II *и. инг.л* 1) *хәрби* Сугыш хәрәкәтләре алып бару ысулы: дошман тылына гаскәри көчләрнең үтеп керүе. *Ләкин сугышта, бигрәк тә дошман тылындагы рейдлар вакытында, ал, арт дигән нәрсә юк.* Г.Гыйльманов

2) *күч.* Җәмәгатьчелек, матбугат оешмалары һ.б.ш. тапшыруы буенча активистлар тарафыннан нинди дә булса объект, предприятие эшчәнлеген

тикшерү. *Бөтен хикмәт тә әнә шунда: ни эшләргә? Рейд бригадасы әгъзаларының күзләрен нәрсә белән томаларга?* М.Сәлим

РЕЙДЧЫ *и.* Рейдта II катнашучы

РЕ́ЙКА *и. рус* 1) Яссы борыс; юка, тар агач такта, планка. *Заводка өр-яңа рейкалар, опалубка такталары өзлексез килеп тора.* А.Гыйләҗев

2) Үлчәү бүлекләре булган махсус агач борыс

3) Геодезия эшләрендә ике ноктаның чагыштырмача биеклеген билгели торган бүлемле үлчәү тактасы. *Менешев һәм Харищенко теодолит, үлчәү рейкасы һәм бер көнлек азык алып, Пиратны ияртеп, төньяк юнәлешендәге профильгә кереп киттеләр.* И.Хуҗин

РЕЙС *и. нем.* Транспорт чараларының билгеле бер маршрут һәм расписание буенча үткән юлы. *Кайсы рейска кирәксә, шуңа билет юллап бирәм.* К.Тимбикова. *Үзе эшли торган комбайн белән ике рейс ясап, савымчы кызларны һәм җиңгиләрне су эченнән алып чыга.* Г.Ахунов. *Кайвакыт катер яныннан ерак рейстан кайтучы океан пароходы узып китә.* М.Юныс

РЕ́ЙСМАС *и. нем.* Слесарьлык, столярлык эшендә параллель сызыклар төшерү өчен кулланыла торган инструмент. *Столярлык мастерскоенда рейсмас дигән прибор бар. Ул борысның кырыйларын параллель итеп эшкәртү өчен кулланыла.* Геометрия

РЕ́ЙСМУС *и. нем. к.* **рейсмас**

РЕЙСФЕ́ДЕР *и. нем.* 1) Тушь яки буяу белән сызу әсбабы

2) Грифель язу әсбабының буяулы үзәген кую өчен кыскычы булган металл көпшә

РЕЙСШИ́НА *и. нем.* Параллель юллар сызу өчен, Т рәвешендәге сызым линейкасы. *Балык зурлыгын чагыштырыр нәрсә эзли, стенадагы рейсшинага туктала.* Р.Батулла

РЕ́ЙТАР *и. нем. тар.* XVI–XVII гасырларда Көнбатыш Европада һәм Россиядә башлыча утлы корал белән сугышкан көбә киемле атлы гаскәр, ялланган кавалерия солдаты

РЕ́ЙТИНГ *и. инг.* 1) Нинди дә булса затның, оешманың, группаның билгеле бер вакыт эчендәге эшчәнлегенә, программасына, сәясәтенә бирелгән бәяләрдән чыгып, саннарда күрсәтелгән авторитеты, популярлык дәрәҗәсе күрсәткече. *Шул ук рейтинг иң арзан фатирларның Смоленск, Брянск, Ульяновск, Арзамас, Чаллы һәм Курск шәһәрләрендә икәнлеген күрсәтә.* Татарстан яшьләре. *Вузларның укыту һәм тикшеренү эшләренә, аларның дөнья күләмендә казанган дәрәҗәсенә карап рейтингларын билгеләү күптәннән килә.* Мәгърифәт

2) *спорт* Спортчының классификацион исемлектәге ирешкән уңышларыннан чыгып бәяләнгән саннардагы шәхси күрсәткече. *Әзерлек, сайлау ярышларында җыйган баллар буенча билгеләнгән рейтинг көрәшченең кем белән алышачагын ачыклый.* Татарстан

3) *күч.* Кадер, дәрәҗә, абруй. *Нәфрәттән туса – туар Үч кенә. Ә Үчнең рейтингы кечкенә!* Р.Фәйзуллин

РЕЙТУЗ *и. нем.* 1) Ботларга сыланып тора торган тар чалбар (ат өстендә йөргәндә киелә). *Гусарның арттан шома түгәрәк итеп киелгән ак төстәге рейтузы каеш чыбыркы сукканнан ярылып китте.* З.Зәйнуллин

2) Балалар, хатын-кызлар кия торган бәйләнгән җылы ыштан. *Бәйрәмгали хатын-кыз рейтузыннан, чалбар үтүкләп йөри, үзе җырлый.* Д.Салихов

РЕЙХ *и. нем.* 1) Империя, дәүләт, держава (гадәттә немец илләре тур.). *СССР булмаса, Өченче рейх итеге астында калып изелгән бу дәүләт бүгенге көндә дөнья картасында бөтенләй булмаган булыр иде инде.* Шәһри Казан. *Борынгы рейх тарихы*

2) Фашист Германиясе. *Тагын биш-алты йөз талантка бронь бирүдән Рейх җимерелмәс.* Т.Әйди. *– Нишләп тә нишләп, син анда сәхнәдән Рейх режимына каршы сүзләр әйттерәсең? – дип, бик каты сорау алалар.* Р.Батулла

РЕЙХСВЕР *и. нем. тар.* Беренче Бөтендөнья сугышыннан соң 1935 елга кадәр Германия армиясе исеме

РЕЙХСКА́НЦЛЕР *и. нем. тар.* 1945 елга кадәр Германиядә хөкүмәт башлыгы

РЕЙХСТАГ *и. нем. тар.* 1) Аерым чорларда Германия, Австрия һ.б.да парламент исеме

2) Шул парламент урнашкан бина. *Рейхстаг түбәсенә байрак кадарга тиешле кешеләрнең исемнәре Берлинны камый башлау белән үк билгеле була.* А.Хәсәнов

РЕКВИЗИТ *и. лат.* 1) Театр тамашасында, кино төшерүдә җиһазлау өчен кулланылган барлык чын һәм бутафорик әйберләрнең җыелмасы. *Аның гримда, реквизит костюмнан төшкән фотолары миндә әле дә саклана.* А.Расих. *Бутафорлар ясаган әйберләр реквизитлар цехында урын алган.* Сәхнә

2) **реквизитлар** *күпл. юр.* Рәсми эш кәгазьләрендә, документларда мәҗбүри язылырга тиешле күрсәткечләр, мәгълүматлар (имза, вакыт, рәсмиләштерелгән урын һ.б.). *Оешма-предприятиеләр реквизитындагы өстәмә мәгълүматларны ачыклыйсы килгән моның.* Т.Нәҗмиев

РЕКВИЗИ́ТОР *и. рус театр* Реквизит (*1 мәгъ.*) өчен җаваплы кеше

РЕКВИЗИ́ЦИЯ *и. лат.* Гадәттән тыш чорда (мәс., сугыш вакытында) шәхси яки җәмәгать мөлкәтенең, кире кайтару яки түләү шарты белән, дәүләт хакимияте тарафыннан мәҗбүри рәвештә вакытлыча алынып торуы. *Хакимият Уфа митрополиты Андрейны (кенәз Ухтомскийны) кулга алырга һәм нинди-дер максатларда чиркәүләргә реквизиция ясарга боерык бирә.* И.Гафаров

РЕКВИЗИ́ЦИЯЛӘҮ *ф.* Реквизиция ясау

Реквизицияләп бетерү Тулысынча реквизицияләү

Реквизицияләп килү Акрынлап, аз-азлап, даими арттыра барып реквизицияләү

РЕКЛА́МА *и. лат.* 1) Сатып алучылар, тамашачылар, кулланучылар игътибарын җәлеп итү, кызыксындыру максаты белән үткәрелгән чаралар. *[Октябрь революциясенә кадәр] Нинди генә юнәлештәге журналлар чыкмаган! Хәтта реклама журналларына кадәр булган ул чакта.* Р.Мостафин. *Әсәр чыгу белән берничә дистә рецензия басылып чыга, телевидениедән реклама*

ясала ---. М.Юныс. *Реклама өчен куелган бер «мәңгелек двигатель» бервакыт миңа да зур мәшәкать тудырды.* Кызыклы физика

2) Кешеләрдә кызыксыну тудырырлык итеп эшләнгән, берәр нәрсә турында кыскача хәбәр, мәгълүмат тупланган игълан, белдерү, афиша. *Шәһәр төзеклеге, чисталыгы, ялтыравык витриналары, әллә каян кычкырып торган рекламалары белән үзенә тартып тора.* Т.Галиуллин. *Әгәр дә магнитофон яңа гына уйлап чыгарылган булса, бу шигырь, бәлки, реклама буларак ярар да иде.* Р.Вәлиев. *Рекламаларның нинди төрләрен генә күрмисең дә, ниндиләрен генә ишетмисең.* Татарстан

3) *күч.* Гомумән нәрсәнедер нык пропагандалау күренеше. *Капиталистик дөнья нәрсәсе белән ота? Реклама ясый белүе белән.* Г.Ахунов

РЕКЛА́МАЛАУ *ф.* 1) Реклама ясау, реклама чаралары үткәрү. *Сатучыларга да товарын рекламалап газапланасы юк.* Ватаным Татарстан. *Әлеге фирмалар шул рәвешле үзләрен дә рекламалыйлар.* Татарстан яшьләре

2) *күч.* Берәр нәрсәне нык пропагандалау. *Аерым бер партияне хөкүмәт партиясе ясап рекламалап, яратырга мәҗбүр итеп кенә халыкта патриотик хис уятып булмый.* Безнең гәҗит

3) *күч.* Яшермәү, ачыктан-ачык күрсәтү. *Шәфига карчык үзенең сәләтен бик үк рекламаламаса да, аны тирә-якта күпләр белә, теге яки бу хәсрәтеннән котылырга теләп мөрәҗәгать итә иде.* М.Кәбиров. *Биологик әти-әниләр һәм суррогат әниләр үзара мөнәсәбәтләрен, кем әйтмешли, рекламалап йөрмиләр.* Өмет

Рекламалап алу Тиз генә, кыска вакыт арасында рекламалау. *Без протокол тутырган арада, үз эшенең арзанракка төшүен искәртеп, фирмасын рекламалап та алды.* Сабантуй

Рекламалап йөрү Һәрвакыт, бөтен җирдә рекламалау. *Тагын бер нәрсә бар: үз эшенә чын-чынлап табынган талантлы режиссёр, артист, гомумән сәнгать кешесенең үзен, иҗатын рекламалап йөрергә вакыты да, теләге дә юк бит аның.* Ватаным Татарстан. *Равил Сабиржан әйтүенчә, алар үзләре туктаган урыннарда очрашулар уздырып, үз-үзләрен рекламалап йөрергә җыенмыйлар ---.* Татарстан яшьләре

Рекламалап тору Һәрвакыт, гел рекламалау. *Сыраны да, тәмәкене дә гел рекламалап торалар.* Татарстан яшьләре

Рекламалап утыру *сөйл. к.* **рекламалап тору**. *--- телевидение көне-төне шуны рекламалап утыра, һәм без тауга дару ашыйбыз.* Шәһри Казан

Рекламалап яту *сөйл. к.* **рекламалап тору**. *Миңа калса, телевидение детективларны рекламалап кына ята бугай.* Татарстан яшьләре

Рекламалый башлау Рекламаларга керешү. *Соңгы вакытларда стоматологлар имплант кую ысулын рекламалый башлады.* Ватаным Татарстан. *Иң кызыгы шунда: алтыга өч метрлы зур щитларда (такталарда) халыкның зур күпчелеге куллана алмый торган әйберләрне рекламалый башладылар.* Татарстан яшьләр

Рекламалый төшү Тагы да күбрәк рекламалау

РЕКЛАМА́ЦИЯ *и. лат.* Нинди дә булса товарның, хезмәтнең түбән сыйфатлы булуы сәбәпле, күргән зыянны түләүне яки кимчелекне төзәтүне таләп итеп бирелгән шикаять, дәгъва, таләп. *2012 елда гына, мәсәлән, Уфа электр транспорты предприятиеләреннән җитештерүче заводка 400 дән артык рекламация җибәрелгән.* Кызыл таң

РЕКЛА́МАЧЫ *и.* Реклама белән шөгыльләнүче, реклама оештыручы зат. *--- күп очракта рекламачы бәяләр хакындагы мәгълүматны тулаем биреп бетерми.* Ватаным Татарстан. *Ә менә маркетолог, пиарчы, рекламачы, финансчы, төзүчеләрнең якын араларда эш табуы бик шикле.* Татарстан яшьләре

РЕКОГНОСЦИРО́ВКА *и. лат.* 1) *хәрби* Сугыш хәрәкәтләре алдыннан командир һәм штаб офицерлары тарафыннан урынга разведка ясау эше. *Бригада командирларының берсенең дә лагерьдан рекогносцировкага чыкканы, лагерьдан тышта ниләр барын үз күзе белән күргәне юк.* Г.Әпсәләмов. *Бу юлы безнең һөҗүм өчен сайланган сәгать тә, артиллерия әзерлеге дә, яшерен рекогносцировка чаралары да бик уңышлы оештырылган булып чыкты.* Казан утлары

2) *геол.* Геодезия һ.б.ш. махсус эшләр башланыр алдыннан, әлеге урынны тикшереп чыгу эше. *Шул ук Биләр тирәсендә рекогносцировка үткәрәбез.* Фән һәм тел

РЕКОГНОСЦИРО́ВКАЛАУ *ф.* Рекогносцировка ясау

Рекогносцировкалап алу Тиз генә, тиз арада рекогносцировкалау

Рекогносцировкалап бетерү Тулысынча рекогносцировкалау

Рекогносцировкалап чыгу Башыннан ахырына кадәр рекогносцировкалау

РЕКОМЕНДА́ЦИЯ *и. лат.* 1) Яңа эшкә яки оешмага алынасы кешенең эшчәнлеге турында кемнең дә булса язмача яки телдән биргән уңай бәяләмәсе; характеристика, дәлаләт. *Өч партия членыннан рекомендация ал.* М.Юныс. *Анда өч СССР Язучылар союзы әгъзасының сине хуплап язган рекомендациясе булу мәҗбүри.* Р.Миңнуллин

2) *кит.* Киңәш, тәкъдим; күрсәтмә. *Татарстанда тәҗрибә авылларга нигез салына, өлкә проект оешмаларының рекомендацияләре бар, шуларга нигезләнеп, кайбер районнарда берәр катлы йортлар, коттеджлар өлгертеп киләләр.* А.Гыйләҗев. *Шенк банкка чек, обсерватория директорына рекомендация хаты язды ---.* В.Обручев

РЕКОНКИ́СТА *и. исп.* VIII–XV гасырларда испан халкының Пиреней ярымутравын басып алган гарәпләргә (маврларга) каршы милли азатлык сугышы. *Вакыйга Испаниядә реконкиста чорын – гарәпләр белән испаниялеләр арасында барган сугышларны чагылдыра.* Мәйдан. *Колумб үз экспедициясен оештырган вакытта Испаниядә реконкиста дигән хәрәкәт барган чор була.* Татар, уян!

РЕКОНСТРУКТИВ *с.* Реконструкция белән бәйле

РЕКОНСТРУ́КЦИЯ *и. нем.* 1) Нәрсәне дә булса яхшырту, камилләштерү максаты белән, тамырдан үзгәртү, яңадан кору эше. *--- иске ипподром, күп тапкырлар ремонт һәм реконструкция үткәрелүенә карамастан, заманча*

таләпләргә җавап биреп бетерми иде. Татарстан яшьләре

2) Сакланып калган өлешләре буенча һәм тасвирлау нигезендә берәр нәрсәне элекке хәленә кайтару, яңадан торгызу. *Реконструкцияне кайчан тәмамларга уйлыйсыз?* Р.Вәлиев

РЕКОНСТРУ́КЦИЯЛӘҮ I *ф.* 1) Реконструкция ясау, яңарту, яңадан кору, камилләштерү. *Совхозда иске фермаларны реконструкцияләү юлы белән дуңгыз асраучылыкны промышленность нигезенә күчерү буенча күп эш башкарылды.* Татарстанда терлекчелек

2) Реконструкция ясау, яңадан торгызу, элекке хәленә кайтару. *Тел тудырган топонимнар аша ата-бабаларыбыз моннан мең ел элек яшәгән җирләрнең табигатен, хәтта географиясен реконструкцияләп өйрәнергә була.* М.Юныс

РЕКОНСТРУ́КЦИЯЛӘҮ II *и. к.* **реконструкция**. *Саба районы авылларын электрлаштыруга һәм реконструкцияләүгә дә зур көч куйган Россиянең атказанган энергетигы Мансур Гыйләҗев --- кинәт вафат булды.* Т.Нәҗмиев. *--- яшьләр тулы кыйммәтле дәүләт теле була барган татар телен дә кызыксынып өйрәнәләр. Дөньядагы теләсә кайсы башкаланы бизи ала торган концерт залыбызны реконструкцияләү төгәлләнгәч, бу процесска яңа импульс бирәләчәк.* Мирас

Реконструкцияләп бетерү Тулысынча реконструкцияләү

Реконструкцияләп тору Әле, хәзер, сөйләү моментында реконструкцияләү. *Төзелеш башланганда ук боларның барысын да искә алган булсагыз, хәзер заводны реконструкцияләп торыр идекме?* Р.Вәлиев

Реконструкцияләп чыгу Барысын да, һәрберсен бер-бер артлы, башыннан ахырына кадәр реконструкцияләү. *Үзенең монографиясендә Марсель Бакиров төрки поэзиядә әлеге берлек-синкретизм җирлегендә барлыкка килгән иң борынгы жанрлар системасын да барлап, реконструкцияләп чыкты.* Ә.Шәрипов

РЕКОРД *и. англ.* 1) Спортта ирешелгән иң югары күрсәткеч. *1934 елда парашютчы Евдокимов сигез километр биеклектән шулай [парашютын ачмыйча] сикерде һәм парашют белән «озаклап» төшүдә дөнья рекорды казанды.* Кызыклы физика

2) Тормышта, яшәештә, хезмәттә ирешелгән иң югары нәтиҗә. *Инде ышануы авыр булган рекордларга килсәк, монда Англия крестьяны Томас Карне хакында әйтергә кирәк. Ул 207 ел яшәгән һәм унике корольне соңгы юлга озатышкан.* Кызыклар дөньясында. *Гиннессның рекордлар китабында әлегә иң зуры дип Бөекбританиядә үстерелгән 3,5 килограммлы бәрәңге санала иде.* Татарстан яшьләре

РЕКОРДИЗМ *и. рус спорт к.* **рекордчылык**

РЕКОРДИСТ *и. рус* 1) *к.* **рекордчы**

2) Рекордчылык белән мавыгып китүче спортчы

3) Уңай сыйфатлары белән рекордлы күрсәткечләргә ия булган йорт хайваны

РЕКОРДЛЫ *с.* 1) *спорт* Иң нәтиҗәле, рекорд булып торган

2) Иң югары, моңарчы күрелмәгән. *1957 елның 4 октябрендә Советлар Союзында Җирнең беренче ясалма иярчене җибәрелү белән, ракеталарның рекордлы очу биеклеге 947 км га җиткерелде.* В.Казневский. *Быел республика игенчеләре рекордлы уңыш җыеп алган.* Мәдәни җомга

РЕКОРДСМЕН *и. англ. к.* **рекордчы**. *Ераккa үтеп керү буенча кечкенә генә үрмәкүч рекордсмен булып чыга. Аны инглиз экспедициясе көньяк полюстан нибары биш йөз километр ераклыкта таба.* Кызыклы физиология

РЕКОРДЧЫ *и.* 1) *спорт* Рекорд куйган спортчы. *Яңа рекордчы, су астыннан чыгар алдыннан, йөрәгенең туктап-туктап тибә башлаганлыгын, шуңа күрә анда, планлаштырганча, 23 минут тора алмаганлыгын таныган.* Ватаным Татарстан

2) Хуҗалыкның берәр өлкәсендә хезмәт күрсәткечләре белән иң югары нәтиҗәләргә, уңышка ирешкән кеше

РЕКОРДЧЫЛЫК *и.* Рекордлар белән артык мавыгу, рекорд артыннан куу

РЕКРУТ *и. фр. тар.* 1) Чит ил армияләрендә армиягә алынган, еш кына үзе ялланып баручы кеше

2) 1705–1874 елларда Россиядә: ясак түләүче катлаулардан хәрби хезмәткә чакырылган кеше. *Иртәгесен, бөтен халык кырда вакытта, рекрутлар атка төялеп бер тапкыр урам әйләнделәр.* М.Мәһдиев. *Пётр I язган указында үзе төзегән регуляр армия рекрутларына карата таләпләрне кыска һәм ачык итеп формалаштырган.* Кызыклы психология

РЕКРУТЛЫК *и. тар.* Рекрут булу. *--- чукынганнар өчен төрле өстенлекләр билгеләнә: аларны өч елга салым түләүдән, рекрутлыктан, җинаять кылганнарны җаваплылыктан, бурычлыларны – әҗәттән азат итү турында махсус указлар чыгарыла.* Ф.Ислаев

РЕКТИФИКАТ *и. лат. махс.* Ректификация нәтиҗәсендә табылган продукт (мәс., спирт)

РЕКТИФИКА́ЦИЯ *и. лат. махс.* Катнашмаларны аеру, чистарту, сафландыру процессы. *Ректификация аппараты. Ректификация колоннасы*

РЕКТИФИКА́ЦИЯЛӘҮ *ф.* Ректификация ясау

Ректификацияләп бетерү Барысын да, тулысынча ректификацияләү

Ректификацияләп кую Алдан ректификацияләү

Ректификацияли төшү Тагы да бераз ректификацияләү

РЕ́КТОР *и. лат.* Югары уку йорты җитәкчесе. *Беркөнне аны ашыгыч рәвештә университет ректоры Бушмин янына чакыралар.* Г.Әпсәләмов. *Безне Линц шәһәрендә педагогик академия ректоры профессор Шперрер әфәнде каршы алды.* Т.Галиуллин. *Яңа геометриягә нигез салучы бөек математик Н.И.Лобачевский 20 елга якын университетның ректоры була.* Татарстан тарихыннан хикәяләр

РЕКТОРАТ *и. нем.* 1) Ректор тарафыннан җитәкләнгән, югары уку йорты белән идарә итә торган административ орган. *Приказны ректорат язган, аннан соң гыйльми советта расланган, диде.* М.Юныс. *Дипломы «кызыл» булгач, ректоратта: «Кая теләсәң, шунда җибәрәбез», – диделәр.* И.Абдуллин

2) Әлеге орган урнашкан бина

РЕ́КТОРЛЫК *и.* Ректор вазифасы, ректор эшчәнлеге. *Закировка ректорлык мәртәбәсен югалтуы, депутатлыктан мәхрүм калуы бары тик уңышларына «теш кайраучы» башбаштаклар тарафыннан китереп чыгарылган яманлык кебек тоелды.* Ф.Яхин

РЕКУЛЬТИВА́ЦИЯ *и. фр.* Кеше эшчәнлеге нәтиҗәсендә зыян килгән җирләрнең рельефын, туфрак катламын һ.б.ларны элеккеге табигый хәленә кайтару эше. *Борис Петров әйтүенчә, полигонда рекультивация эшләре алып барылмый.* Ватаным Татарстан

РЕКУЛЬТИВА́ЦИЯЛӘҮ *ф.* Рекультивация чаралары күрү. – *Бу җирләрдән ком, торф алганнан соң барлыкка килгән чокырларны төзелеш, агач-таш калдыклары белән тутырып, өстенә балчык белән ком түши. Шул рәвешле рекультивацияләү эше башкарыла, – дип аңлатырга тырышты.* Ватаным Татарстан

Рекультивацияләп бетерү Барысын да тулысынча рекультивацияләү

Рекультивацияләп кую Алдан рекультивацияләү

Рекультивацияли төшү Тагы да бераз рекультивацияләү

РЕЛАКСА́ЦИЯ *и. лат.* Физик һәм психик киренкелек беткәннән соң килә торган тынычлану, йомшару стадиясе. *Релаксация – стресслардан чыгу, психик киренкелекне йомшарту, авыр кичерешләрдән соң тынычлана алу. Аның чаралары күп.* А.Низамов

РЕЛЕ *и. фр. махс.* Электр чылбырын тоташтыра һәм өзә торган автомат әсбап. *Катодлы реле кулланып, Термен приборның сизгерлеген арттыра да аңа гади индикатор урынына --- радиоколакса тоташтыра.* Б.Галиев

РЕЛЕВАНТ *с. ингл.* 1) *лингв.* Тел берәмлекләрен аерырга сәләтле, аермасын белдерә торган. --- *фонология өчен фонемаларның мәгънә аеру – релевант үзенчәлекләре өйрәнү объекты булса, морфонологиядә фонемаларның релевант булмаган үзлекләре өйрәнелә.* М.Зәкиев

2) *информ.* Бирелгән эзләү таләбенә туры килә торган

РЕЛЕВАНТЛЫК *и.* 1) Урынлылык, әһәмиятлелек

2) *информ.* Бирелгән эзләү таләбенә алынган җавапның көтелгән нәтиҗәгә туры килүе, эзләнгән нәрсәнең алынган җавапка тәңгәл булуы

РЕЛИ́КВИЯ *и. лат.* 1) Теге яки бу дингә ышанучылар кодрәтле көчкә ия дип уйланылган табыну әйберсе; изге әйбер. *Храмнарга изге дип белдерелгән әйберләрне – реликвияләрне: Христосның чәчләрен, хәтта «тир тамчылары»н, ул кадакланган хач (тәре) кисәкләрен, аны кадаклаган кадакларны һәм шулай ук дин өчен корбан булганнарның изге мәет калдыкларын куялар.* Урта гасырлар тарихы

2) Кадерләп, төс итеп саклый торган әйбер, истәлек, ядкәр. *Яшел кара белән дә, шәмәхәсе белән дә миңа адресланган хатлары изге реликвияләр булып сакланалар.* Р.Әхмәтҗанов. *Актарына торгач, тагын бер хикмәтле әйбер табылды: бу – аталарының яшь чагында тотып йөргән кыска саплы, күн чуклы, өч япьле, һәр җәбенең очына көмеш пластинка бөкләп кидерелгән бик шәп камчысы иде. --- менә бу, ичмасам, реликвия! – диде кияве дә, сокланып. – Тик кем саклар аны?* Ә.Еники

РЕЛИКТ *и. лат. махс.* **1.** 1) Борынгы дәверләрдән сакланып калган хайван яки үсемлек организмы

2) Борынгыдан сакланып калган әйбер яки күренеш; борынгылык калдыгы. *Колониаль буйсынудагы халыкның телен кимсетү, санга сукмау, хәтта аңа мыскыллы мөнәсәбәт күрсәтү Аурупа колонизаторларында реликт рәвештә генә сакланган.* М.Юныс

2. *с. мәгъ.* Борынгыдан килгән, борынгыдан сакланган; борынгылык калдыгы булган. *Мең еллар элек реликт урманнар борынгы кешегә туң, салкын җирләрдә, кырларда, елга-күл буйларында төпләнергә ярдәм иткәннәр.* Татарстан яшьләре. *Һәм чыннан да 60 нчы еллар уртасында шундый реликт нурланыш ачылды. Реликт нурланышның булуы – безнең чыннан да киңәя баручы Метагалактикада яшәвебез кебек фундаменталь фактны раслаучы хәлиткеч дәлил дияргә ярый.* Галәм, җир, кеше

РЕЛЬЕ́Ф *и. фр.* 1) Җир өсте төзелеше; җир кабыгының төрле тигезсезлекләрдән торган гомуми күренеше (коры җир, океан һәм диңгез төпләре өслеге). *Чуерташлар шыбыр да шыбыр күчерелә́ләр, берсе үзенең терлек абзарларының планын күрсәтә, икенчесе үз басуының рельефын тасвирлый.* М.Мәһдиев. *Бу очракта буй урманнар рельеф таләбен исәпкә алып утыртылган булалар.* Татарстан

2) Яссылык өстендә калкып өскә чыгып торган кабарынкы урын, күпереп торган эз, кабарынкылык. *Җиң уемынан рельефлар төшереп, тоташ киселгән күлмәк.* Йорт эшләре

3) Яссылыкта калку итеп төшерелгән рәсем, сурәт

РЕЛЬЕ́ФЛЫ *с.* 1) Рельефлары булган; яссылык өстендә калкып, кабарып өскә чыгып торган. *Таулы илләрдә автомобиль белән барганда, җирнең рельефлы булуы күзгә бәрелеп тора, таулар һәм болыннар бер-берсеннән аерылып күренәләр.* Кызыклы физика. *Рельефлы хәрефләр*

2) *күч. кит.* Ачык; мәгънәле; тәэсир көче зур булган

РЕЛЬЕ́ФЛЫЛЫК *и.* Рельефлы булу, рельефлардан тору. --- *безнең күзебез якындагы әйберләрнең рельефлылыгына бик сизгер, ә ерактагыларына алай ук сизгер түгел.* Кызыклы физика

РЕ́ЛЬС *и. ингл.* Вагон, паровоз һ.б.ш.ның тәгәрмәчләре хәрәкәт итү өчен шпалларга ике яклап беркетелгән тар корыч борыс; тимер юл. *Хәзер рельслар, шпаллар тирәсендә су кебек ару балласт, шпаллар, шөрепләр, костыльләр яңартылганнар, вагон сикерми, төз бара.* Г.Гали. *Поезд кызуллый. Вагон тәгәрмәчләре рельс ялгауларының өстеннән тигез тавыш белән сугып үтүләрен ешлата баралар.* Ә.Еники. *Ипташ егете кечкенә баланы рельстан алып ташлаган, ә үзе өлгерә алмаган.* Р.Кәрами

РЕ́ЛЬСЛЫ *с.* Рельслар салынган; рельслардан йөри торган. *Франциядә бер рельслы тимер юл сала башлаганнар, ди.* Р.Вәлиев. *Балчык гадәттә карьерлардан ачык ысул белән, экскаватор ярдәмендә казып алына һәм керамик эшләнмәләр ясау кәсәбәсенә (предприятиесенә) рельслы, автомобиль һәм*

башка төр транспорт ярдәмендә ташыла. Төзү материаллары

РЕЛЯТИВИЗМ *и. лат. филос.* Белемне субъектив дип санап, чынбарлыкны объектив танып белү мөмкинлеген инкяр итә торган методологик принцип

РЕЛЯТИВИСТ *и. рус* Релятивизм тарафдары

РЕЛЯТИВИ́СТИК *с.* Релятивизмга караган, релятивизмга мөнәсәбәтле. *Ул гына да түгел, релятивистик физиканың бу казанышлары американ галиме Хойлның һәм шул ук Нарликарның яңа астрофизикасы белән дә исбат ителә.* Ә.Илдус. *Шуның белән бергә, классик механика кысаларында XX гасырда барлыкка килгән релятивистик идеяләргә тарткан фикерләр дә туа.* Фән һәм тел

РЕМА́РКА *и. фр. әд.* 1) Текстка карата кайбер урыннарга өстәгән яки ачыклаган билге, искәрмә яки сорау

2) Драма әсәрендә катнашучыларның төс-кыяфәтен, өс-башын, үз-үзен тотышын, кыланышларын, сөйләү рәвешен, уен барган урынны, вакытны һ.б.ш. сурәтләп биргән автор аңлатмасы. *--- авторның ремаркаларга салган уйфикерен, тәэсир көчен сәхнәдә чагылдыруы – шактый кыен эш.* Р.Батулла

РЕМА́РКЕТИНГ *и. ингл.* Базарда товарга яки хезмәткә ихтыяҗ төшкәч, аны яңадан күтәрү чаралары: базарның яңа мөмкинлекләрен өйрәнү, хәрәкәттәге базарның мөмкинлеген киңәйтү, яңа базарлар яулау өчен яңа реклама кампаниясе һ.б.ш.; кабат маркетинг

РЕМЕЙК *и. ингл.* 1) Билгеле сәнгать әсәрен үзгәртеп, шуның нигезендә яңа әсәр тудыру алымы. *--- бүген ремейк ясалган пьесаны 90 нчы еллар башында Дамир Сиражиев Тинчурин театрында зур уңыш белән сәхнәләштергән иде.* Сәхнә

2) Билгеле сәнгать әсәренең (роман, спектакль, алданрак төшерелгән фильмның) шулай үзгәртелгән яңа версиясе. *Туфан Миңнуллинның «Әлдермештән Әлмәндәр»енә ремейк ясадык.* Шәһри Казан

РЕМИЗ *и. фр.* 1) Кылыч уенында: кисәтү рәвешендә кабат ясалган кадау хәрәкәте

2) Кәрт уенында: алдан билгеләнгән взяткаларның саны җитмәү, шуның өчен штраф

РЕМИКС *и. ингл.* Берәр музыкаль әсәрнең оригиналыннан соңрак, гадәттә заманчарак стильдә яздырылган яңа версиясе. *Узган елны «Сагыш» җырына ремикс ясап, «Музыкаль десант» концертларында, төрле дискотекаларда җырлап йөрдем.* Тамаша. *Татар халык җырларына ремикс ясап, яңартып, яшьләрне җәлеп итәләр бит.* Безнең гәҗит

РЕМИЛИТАРИЗА́ЦИЯ *и. фр.* Дәүләтнең хәрби куәтен кабат торгызу, яңадан коралландыру (демилитаризациядән соң)

РЕМИЛИТАРИЗА́ЦИЯЛӘҮ *ф.* Ремилитаризация үткәрү

Ремилитаризацияләп бетерү Тулысынча ремилитаризацияләү

Ремилитаризацияләп килү Азазлап, акрынлап эзлекле рәвештә ремилитаризацияләү

РЕМОНТ *и. фр.* Зарарланган, тузган, ватылган, бөтенлеге бозылган әйберне төзекләндерү, төзәтү эше. *«Тукымалар» кибетенә ремонт ясатырга кирәк миңа.* Г.Ахунов. *[Микәй] Авылның машина һәм тракторлар паркында ремонт эшләре белән мәш килгән ирләр тирәсендә чуалырга күнекте.* Р.Мөхәммәдиев. *Иң беренче чиратта, мичләренә ремонт кирәк булды.* Т.Нәҗмиев

РЕМОНТЛА́У *ф.* Ремонт ясау, төзәтү. *Шул клубны яхшылап ремонтларга берсенең-бер кулы җитми.* Р.Төхфәтуллин. *Өен ялт иттереп ремонтлаган.* Ф.Яруллин

Ремонтлап алу Тиз генә, бераз ремонтлау

Ремонтлап бетерү Ахырына кадәр ремонтлау

Ремонтлап җибәрү Бераз, бернидәр ремонтлау; ремонтларга өлгерү. *Син бәби тапканчы, без аны бик шәп итеп ремонтлап җибәрербез.* Ф.Яруллин

Ремонтлап тору Һәрвакыт, гел ремонтлау. *Буяу өстенә буяу сылап, туктаусыз ремонтлап торган стена төсенә керә башлыйбыз.* Ф.Яруллин

Ремонтлап чыгу Башыннан ахырына кадәр ремонтлау; ремонтлау эшен төгәлләү

Ремонтлап яту Әле, хәзер ремонт белән шөгыльләнү. *Булат табындагыларга аңлатты: – МТСта тракторлар ремонтлап ятабыз, бер көнне, газета тотып, Заһир килгән.* Т.Таһиров

Ремонтлый бару Һәрберсен, булган берсен ремонтлау

Ремонтлый башлау Ремонтларга керешү

Ремонтлый төшү Тагы да бераз ремонтлау

РЕМОНТЧЫ *и.* Ремонт ясаучы. *Тимерхан бер минутка да ремонтчылар яныннан китмәде.* Г.Ахунов. *Сакчылары бик аз, ахры. Комбинезон кигән ремонтчылар гына күренгәли.* С.Таһиров

РЕНАТУРАЛИЗА́ЦИЯ *и. фр.* 1) *а.х.* Җирнең уңдырышлылыгы, җир өслегенең ландшафты бозылган вакытта аны табигый хәленә кайтару эше

2) *күч.* Нинди дә булса бер сәбәп белән гражданлык хокукын югалткан кешеләргә яңадан гражданлык хокукын торгызу

РЕНАТУРАЛИЗА́ЦИЯЛӘҮ *ф.* Ренатурализация ясау. *Эмигрантны ренатурализацияләү*

РЕНЕГАТ *и. лат. кит.* Үзенең карашларыннан баш тартып, үз идеалларына, мәсләгенә хыянәт итүче, аумакай. *Ренегатмы чыгышы ягыннан, Ортодоксмы ул, мәсәлән.* Казан утлары

РЕНЕГАТЛЫК *и. кит.* Ренегат булу. *Ул 1910 елда элеккеге остазы, идеалы К.Мотыйгый ренегатлыгын махсус гәүдәләндергән «Сибгатуллин» шигырен яза.* М.Гайнетдинов

РЕНЕССАНС *и. фр.* 1) Җәмгыять үсешендә капиталистик мөнәсәбәтләр барлыкка килеп, мәдәният, идеология алга киткән чор; яңарыш чоры. *Иҗат эше ирекле барган, башкача Ренессанс шәхесләре мондый уңышларга ирешә алмаслар иде.* М.Юныс. *Мин аннан Хейенхаген хакында белештем. Ренессанс чорының гүзәл җимеше ул Хейенхаген, диде профессор.* М.Әмирханов

2) Гомумән мәдәни яңарыш. *Шиһабетдин Мәрҗани кебек гигантлар калдырган хезмәтләрне аңлау һәм*

пропагандалый башлау дәрәҗәсенә күтәрелү бу [1905 елгы революциядән соңгы] чорның чын-чынлап татар дөньясында Ренессанс чоры барлыкка килүен күрсәтә. М.Юныс

РЕНКЛОД *и. фр.* Сливаның эре, түгәрәк, сары, татлы сорты

РЕНОВА́ЦИЯ *и. лат.* Мораль һәм физик тузу нәтиҗәсендә юкка чыга торган төп фондларны алмаштыру. *Бюджетта оештырылган реновация фонды гына авыр хәлдән чыгарга бераз ярдәм итә.* Татарстан яшьләре. *Ун ел элек судно реновация үтте һәм тагын озак вакыт эшләячәк әле.* Идел таңнары

РЕНОВА́ЦИЯЛӘҮ *ф.* Реновация үткәрү. *Реновацияләү, модернизацияләү, нефтьне эшкәртү тирәнлеген 90–95 процентка җиткерү мөмкинлеге бирүче яңа корылмалар урнаштыру буенча проектларның гомум бәясе якынча 100 миллиард сум тәшкил итә.* Кызыл таң

РЕ́НТА *и. нем.* 1) *икът.* Капитал, мөлкәт яки җирдән, махсус хезмәт куймыйча, процент белән даими алына торган керем, табыш; күчемсез мөлкәттән файдаланган өчен, аның хуҗасына түләнә торган аренда хакы. *Арендалаучы биргән рента шул салымны капларга да җитеп бетми.* Мәдәни җомга

2) *фин.* Облигацияләре булган кешеләргә даими табыш китерә торган мөддәтсез (срогы билгеләнмәгән) дәүләт заемы

РЕНТА́БЕЛЬ *с. икът.* **1.** Үз чыгымнарын үзе каплап, өстәмә файда китерә торган, табышлы; товарлыклы, хуҗалык өчен файдалы. *Бер татар мәктәбе дә ачмадык. Аннары безгә хөкүмәт, сездә укымыйлар, сез рентабель түгел, дип әйтә.* И.Сиражи

2. *рәв. мәгъ.* Үз чыгымнарын үзе капларлык итеп, файда китерерлек итеп, табыш алып. *Рентабель эшләү*

РЕНТА́БЕЛЬЛЕ *с. ялг. к.* **рентабель**

РЕНТА́БЕЛЬЛЕК *и.* Рентабль булу. *План үтәлеше, рентабельлек, үзкыйммәт, продукция җитештерү – барысы да ал да гөл.* Р.Мирхәйдәров. *2010 ел йомгаклары буенча рентабельлек, ягъни икътисади нәтиҗәлелек күрсәткече 13,8 процент тәшкил итсә, 2012 елда ул 14,7 процент булган.* Шәһри Казан

РЕ́НТАЛЫ *с.* Табыш китерә торган, табышлы, кереме булган; рентага мөнәсәбәтле, рента формасындагы, рентага нигезләнгән

РЕНТГЕН *и. нем. сөйл.* 1) *к.* **рентген нурлары**. *Тубәнге катта рентген аппараты эшли башлады, әкрен генә гөжләү ишетелә.* Г.Әпсәләмов

2) Рентгенография һәм рентгеноскопия ысулларын сөйләмдә гадиләштереп атау сүзе; шуларны ясау аппараты. *– Берәр атна хәл җый да Казанга рентгенга бар, – дип, кулымнан килгәнчә үзен дәваларга тотындым.* Г.Кутуй. *Камилнең танышы Миләүшәне шунда ук рентгенга җибәрде.* Ф.Яруллин. *МВД врачы прокурор ярдәмчесеннән травматология институтында Костяга рентген үткәрүләрен үтенде.* Р.Мирхәйдәров

3) Рентген яисә гамма-нурланыш дозасын исәпләү берәмлеге. *Кесәдәге дозиметрлар безнең нормадан икеөч мәртәбә артык рентген радиация алуыбызны күрсәтә ---.* Шәһри Казан. *А.Бугорский алган нурланыш заряды 200 мең рентген белән исәпләнә.* Татарстан яшьләре

РЕНТГЕ́Н НУРЛАРЫ *и. физ.* Үтә күренми торган әйберләр аша үтеп керергә сәләтле кыска электромагнит дулкыннарыннан гыйбарәт күзгә күренмәс нурлар. *– Синдә рак түгел, – дидем, – шулай да рентген нурларына күренәсең калган.* Г.Кутуй. *Бу яңа ачылган нурлар, рентген нурлары кебек, төрле матдәләр аша, шулай ук юка металл пластинкалар аша да үтә ала торган нурлар булып чыга.* Физика курсы. *Рентген нурлары ярдәмендә төшерелгән фотосурәттә андый умырткалык бамбук таягын хәтерләтә.* Юлдаш

РЕНТГЕНОГРА́ММА *и. нем.* Рентген нурлары ярдәмендә төшерелгән фотографик сурәт

РЕНТГЕНОГРА́ФИК *с.* Рентгенография юлы белән алынган; рентгенографиягә нигезләнгән

РЕНТГЕНОГРА́ФИЯ *и. нем.* Үтә күренми торган әйберләрнең эчке төзелешен рентген нурлары ярдәмендә рәсемгә төшерү ысулы. *Яңа туган баланың умыртказлары аз сөякләнгәнгә, рентгенографиядә биеклеге буенча кимерчәк дискка тиң озынча түгәрәк күләгәләр булып күренә.* Фән һәм тел

РЕНТГЕНО́ЛОГ *и. рус* Рентгенология һәм рентгенотерапия белгече; шул белгечлектәге табиб. *Рентгенолог китте инде, установка токтан өзелгән. Иң яхшысы: авыруны изоляторда калдырыгыз, иртән --- сәгать уннарга рентген рәсеме әзер булыр.* Р.Мирхәйдәров. *Терапевт, рентгенолог, акушер-гинеколог, лор кебек белгечләргә кергәнче, миңа, мәсәлән, 780 сум акча түләргә туры килде.* Ватаным Татарстан

РЕНТГЕНОЛО́ГИК *с.* Рентгенологиягә нигезләнгән, рентгенология юлы белән өйрәнелә торган. *13 яшьтән соң балалар умыртказлыгының рентгенологик сурәтләре олыларныкыннан аерылмый диярлек.* Фән һәм тел

РЕНТГЕНОЛО́ГИЯ *и. нем. мед.* Рентген нурларын эчке әгъзаларны тикшерү, диагноз кую, дәвалауда куллану ысулларын өйрәнә торган фән; медицинаның бер тармагы. *Ул – атаклы Казан рентгенология мәктәбен оештыручыларның берсе, аның күпьеллык җитәкчесе.* Г.Мөхәммәтшин

РЕНТГЕНОСКО́П *и. нем.* Рентгеноскопик тикшерү аппараты

РЕНТГЕНОСКО́ПИК *с.* Рентгеноскопиягә нигезләнгән; рентгеноскопия юлы белән алынган, өйрәнелгән. *Тагын да хирургка сурәтне 3D, 2D һәм рентгеноскопик форматта бирә ала.* Яңарыш

РЕНТГЕНОСКОПИ́Я *и. рус* Нәрсәнең дә булса эчке төзелешен, аны рентген нурлары белән яктыртып, махсус экранда күләгәсен тикшерү, өйрәнү методы

РЕНТГЕНОТЕРАПИ́Я *и. нем.-лат.* Рентген нурлары ярдәмендә дәвалау теориясе һәм гамәли тармагы. *Медицинаның рентгенотерапия өлкәсендә дә, төрле авыруларны дәвалау өчен, рентген нурларыннан еш файдаланалар.* Физика курсы

РЕОРГАНИЗА́ЦИЯ *и. фр.* 1) Нәрсәнең дә булса төзелешен, эшчәнлеген үзгәртү; үзгәртеп кору, үзгәртеп

оештыру, үзгәртеп төзү эше. *Алдагы елларда реорганизация башка мәктәпләргә дә кагылачак*. Ватаным Татарстан

2) *махс*. Юридик зат буларак оешманың бер төрдән икенче төрле юридик затка күчеше, хокук мөнәсәбәтләрендә барлыкка килгән үзгәрешләр. *Әйтик, Казандагы элекке «Элекон» юридик зат булудан туктап, реорганизация үтеп (бу шулай ук аның филиалы «Электросоединитель»гә дә кагыла), акцияләрен аерым физик затларга бирә*. Безнең гәҗит

РЕОРГАНИЗА́ЦИЯЛӘҮ *ф.* Нәрсәнең дә булса төзелешен, эшчәнлеген үзгәртеп кору, үзгәртеп оештыру

РЕОСТАТ *и. нем. махс.* Электр чылбырында токның көчен яки көчәнешен тигезләү, үзгәртү аппараты. *Нинди дә булса гальваник элемент чылбырына бер реостат тоташтырыйк һәм тәҗрибәдә чылбырның тышкы һәм эчке өлешләрендәге көчәнешләрнең суммасын белик.* Физика курсы

РЕПАРАЦИОН *с.* Репарациягә бәйләнешле, репарациягә нигезләнгән

РЕПАРА́ЦИЯ *и. лат. махс.* Җиңелгән илнең гаебе белән башланган сугыш китергән зыянны каплау өчен, җиңүче илгә түләнә торган акча яки әйбер. *Вольф, сез җиңелдегез, оккупациягә бирелдегез, тезләндегез, алтмыш алты ел буена репарация түлисез*. А.Толстой

РЕПАТРИАНТ *и. лат.* Репатриация буенча чит илдән туган иленә кайткан кеше. *Чит ил тормышын тамаша кылган, аның уңай вә кире якларын үзләштергән, үлчәү тәлинкәләренең кайсысы аска тартканын күреп белгән репатриантларны төрмәгә тыкты.* А.Гыйләҗев. *Димәк, анда репатриант әрмәннәр Якын Көнчыгыштан китереп саткан энҗеләр дә бар...* Р.Мирхәйдәров

РЕПАТРИА́ЦИЯ *и. нем.* Сугыш аркасында чит илгә барып эләккән хәрби әсирләрнең, эмигрантларның, гражданлык хокуклары алып, кире туган илләренә кайтуы. *Казахстанның Нурлы көш (Нурлы күченү) дип аталган, чит илләрдә көн күргән башка этник казахларны үз илләренә кире кайтару – репатриация программасы бар.* Татар, уян!

РЕПАТРИА́ЦИЯЛӘҮ *ф.* Эмигрантларны, әсирләрне туган илләренә кайтару

РЕПЕЛЛЕНТ *и. лат.* Корткыч яки кан суыручы бөҗәкләрне куркыту өчен кулланыла торган исле матдә. *Помидор (томат) яфракларыннан һәм чәчәкләреннән алынган томатин гликоалкалоиды исә репеллент буларак кайбер корткыч бөҗәкләргә каршы кулланыла.* Агулы үсемлекләр. *Урамга чыккан арада, тешләүчеләрдән саклану өчен, репеллент-салфеткалар ярдәмгә килер*. Кәеф ничек?

РЕПЕР *и. гр.* Җир өсте тигезлеген үлчәүдә чагыштырма өчен алына торган нокта. *Әмма репер юк дигән сылтау белән эш башламыйлар икән.* Т.Нәҗмиев

РЕПЕРТУАР *и. фр.* 1) Театр, эстрада, циркта башкарылган әсәрләр җыелмасы; аерым бер артист башкарган барлык рольләр, әдәби, музыкаль әсәрләр. *Репертуарлары да чуар, һәрхәлдә, Гәүһәр булса, кайбер номерларны рәхәтләнеп төшереп калдырыр иде.* Г.Әпсәләмов. *Өлкә комитеты совет зыялыларын идея-политик яктан тәрбияләү эшен оештырмаган, --- сәнгать оешмалары репертуарына җитәрлек контроль ясамаган булып чыга.* Ф.Галимуллин. *--- аның белән очрашулардан соң безнең укучыларыбыз, аның җырларын концертларда башкарып, үзләренең репертуарларын баеталар иде.* Л.Моратова

2) *күч.* Кемгә яки нәрсәгә дә булса хас кыланмышлар, вакыйгалар һ.б.ш. *Әмма бер үк репертуар туйдыра. Нишләп шуны аңламый бу ирләр?!* Казан утлары

РЕПЕТИ́ТОР *и. лат.* 1) Берәр кешегә нинди дә булса фәнне үзләштерергә ярдәм итү өчен, өстәмә дәрес бирүче, дәрес өйрәтүче хосусый укытучы. *Улым, университетка әзерләнү өчен, репетиторга йөри башлады.* А.Хәсәнов. *Ә авыл җирендә репетитор яллау мөмкинлеге юк, бар өмет – укытучыларда*. Татарстан яшьләре. *Роман хәзер бик тырышып инглиз телен өйрәнә, аңа репетитор да булыша*. Сабантуй

2) Актёрлар белән аерым-аерым яки төркемләп репетицияләр үткәрә торган тәҗрибәле белгеч. *1985 елдан ул ансамбльдә --- репетитор булып эшли.* З.Гыйльметдинова. *Мин башта театрда репетитор булып эшләдем*. Шәһри Казан

РЕПЕТИ́ТОРЛЫК *и.* Репетитор вазифасы, репетитор эше. *«Кырлай шәкерте» югалып калмый: бай балаларына дәресләр бирә, репетиторлык, язусызу белән шөгыльләнә ---*. М.Ихсанов. *Шәһәр укытучылары зур гына акчаларга репетиторлык белән шөгыльләнгәндә, авылныкылар иртәле-кичле укучыларына бушлай консультация бирергә йөгерә*. Ватаным Татарстан

РЕПЕТИ́ЦИЯ *и. лат.* Спектакль, концерт, тамашалар өчен билгеләнгән драматик һәм музыкаль әсәрләрне һ.б.ш.ны сәхнәгә кую өчен әзерләү, алдан башкарып карау. *Авылның яшьләр түгәрәге белән ячейкасы берләшеп, гаеткә каршы музыка-әдәбият кичәсе куймакчылар да, бүген шуңа репетиция ясап чыгып киләләр икән.* Г.Ибраһимов. *Репетицияләр таңга кадәр сузыла, артистлар уеннарын режиссёрга ошата алмыйча, манма тиргә баталар.* Г.Бәширов. *Кәҗә өенең бер бүлмәсендә бик яшерен рәвештә репетицияләр ясалды.* Г.Лотфи

РЕПЛАНТА́ЦИЯ *и. лат. мед.* Төрле травмалар, бәхетсезлек очраклары нәтиҗәсендә кешенең өздергән әгъзасын, зарарланган тән тукымасын яки алдан алдырылган тешен ялгау, күчереп утырту, торгызу белән бәйле медицинадагы яңа юнәлеш

РЕ́ПЛИКА *и. фр.* 1) Кемнеңдер сүзләренә каршы әйтелгән җавап сүзе, искәрмә. *Г.Тукай соңгы елларда язган әсәрләрендә --- И.Гаспринскийны 22 мәртәбә, ул чыгара торган «Тәрҗеман» газетасын 40 мәртәбә телгә ала, махсус мәкаләләр, репликалар яза.* Казан утлары. *Шул юлларны укыгач, газетага реплика язасым килде*. Татарстан яшьләре

2) Сөйләүченең сүзен бүлеп, каршы әйтелгән искәрмә, кыстырылган сүз. *Суд утырышчыларыннан берсе шулай дип реплика кыстырып, тигез генә сөйли башлаган Әсфанны буташтырды.* Ф.Хөсни

3) *юр.* Сүз барышында белдерелгән каршы якның дәгъвасы, ризасызлыгы

4) *сәнг.* Үткәндә булган әйберне, сурәтне, оригиналны яңача кабатлап эшләнгән вариант, интерпретация. *Дөньякүләм шедеврларның кабатламасын (алар реплика дип йөртелә) эшләргә булдык.* Р.Вәлиев

РЕПЛИКАР *и. инг.л.* Элек популяр булган автомобиль моделен тыштан төгәл кабатлаган, ә эчке җиһазлары заманча булган копия, реплика (*4 мәгъ.*)

РЕПОРТАЖ *и. инг.л.* 1) Массакүләм чараларда агымдагы вакыйгалар турындагы чыгыш, язма; шундый язма жанры. *Икенче көнне эш бүлмәмдә, әйткәнемчә, репортаж өчен милли бәйрәмебез ярышларын, уеннарын, бәйгеләрен игә китерә алмыйча чиләнеп беттем.* Т.Нәҗмиев

2) Көндәлек вакыйгалар хакында мәгълүмат туплау эше, репортёрлык. *Репортаж сүз боткасыннан түгел, эш кайнаган, вакыйгалар куерган, мәсьәләләр чишелгән кайнар участтан языла.* К.Тимбикова

РЕПОРТЁР *и. инг.л.* Репортаж әзерләүче (язучы), репортаж тапшыручы кеше. *Репортёрлар интервью алган кешеләр арасында Данирова да бар иде.* Р.Мирхәйдәров. *Репортёр кешеләр арасында сораштыру үткәреп йөри.* Татарстан яшьләре

РЕПОРТЁРЛЫК *и.* Репортёр булу, репортёр вазифасы

РЕПРЕССИВ *с.* Репрессия белән бәйле, җәзалау чарасы булган, бастыру, мәҗбүр итү ысуллары кулланган. *Сугыштан соң Советлар Берлегендә Сталин диктатурасы, репрессив ысуллар куллану, сәяси эзәрлекләүләр янә көчәеп китә.* Х.Миңнегулов. *Безнең Диния нәзарәтләрен кайберәүләр репрессив орган итәргә тырыша.* Безнең гәҗит

РЕПРЕССИВЛЫК *и.* Репрессив булу

РЕПРЕ́ССИЯ *и. лат.* Дәүләт органнары тарафыннан үткәрелгән җәза, кысу, бастыру чаралары, җәзалау эше. *Бу газеталар һәм журналлар һәммәсе диярлек 1937–1938 еллардагы репрессияләр чорында һәм соңрак сугыш башлану сылтавы белән ябылалар.* Р.Мостафин. *Ул [мәгърифәтче Мөхәммәттаип Яхин], Сабага килеп, --- имамлык итеп, репрессия елларында Архангельск өлкәсенә сөргенгә җибәрелеп, шунда юкка чыгарыла.* Т.Нәҗмиев. *Революциядән соң исә тикшеренүләр туктатыла, ә галим [Б.Розинг] репрессиягә эләгә.* Кызыклар дөньясында

РЕПРЕ́ССИЯЛӘҮ *ф. төш. юн.* Репрессиягә дучар ителү. *Безгә тарихыбызның гаепсезгә репрессияләнгән миллионлаган совет кешеләренең исемнәре язылган караңгы сәхифәләренә дә --- үз мөнәсәбәтебезне булдырырга кирәк.* Т.Миңнуллин

РЕПРЕ́ССИЯЛӘҮ *ф.* Репрессия куллану, җәзалау, кысу. *Җавапка тартылган зыялылар белән урамда очраклы рәвештә очрашып сөйләшү дә кулга алыну, репрессияләү белән тәмамлана.* Р.Вәлиев

Репрессияли башлау Репрессияләргә тотыну. *Руханиларны, дин әһелләрен Сталин режимы күпләп репрессияли башлагач, Тулбаев Мөхәммәдгариф, Уральскидагы пединститутта гади каравылчы гына булып эшләсә дә, Көнбатыш Казахстан өлкәсе буенча НКВД идарәсе тарафыннан кулга алына.* Т.Кәримов

Репрессияләп килү Озак вакытлар дәвамында репрессияләү

РЕПРИВАТИЗА́ЦИЯ *и. лат.* Кайчандыр национализацияләнгән милекне элекке яки хәзерге хуҗасына шәхси милек итеп кире кайтару эше

РЕПРИ́ЗА *и. фр.* 1) Музыкаль әсәрнең нинди дә булса бүлеген төгәл яки берникадәр үзгәртеп (мәс., соната формасында) кабатлау алымы

2) Музыкаль кисәкнең кабатлануын белдерә торган билге

3) Циркта, эстрадада телдән сөйләнгән, яки пантомима рәвешендә уйналган көлкеле кыска чыгыш. *Татар театрының кече күләмле драматургиясе – нинди бай өлкә! Бер пәрдәлекләр, репризалар, интермедияләр, мәзәкләр, эстрада өчен нотыклар бетәсеме?* Р.Батулла

4) Атның бер-бер артлы кабатлаган бер үк төрле аллюр хәрәкәте

5) Чиратлашып кабатлана торган трюклар сериясе

РЕПРИНТ *и. инг.л.* **1.** 1) Оригиналның төгәл күчермәсен алу юлы белән (китапны) яңадан бастыру ысулы. *--- аларны репринт юлы белән яңадан күбәйтеп чыгару ихтыяҗы туды.* М.Зәкиев

2) Шул ысул белән кабат бастырылган китап

2. *с. мәгъ.* Шундый ысул белән басылган. *--- «Татар сарыфы» Токиода басыла. Хезмәт Корея мөселман дини вә милли идарәсе тарафыннан басыла һәм 1913 елгы икенче басманың репринт күчермәсе булып тора.* Б.Хәкимов

РЕПРОГРА́ФИЯ *и. лат.* Нинди дә булса документның күчереп язудан башка төрле ысуллар (фотога алу, микрофильм ясау, ксерография һ.б.) ярдәмендә алынган төгәл күчермәсе

РЕПРОДУ́КТОР *и. лат. радио* Тавыш көчәйткеч аппарат. *[Әби] --- урыннан торучы булмагач, стенадагы репродукторны борып ача.* Р.Вәлиев. *Башкаларның өзлексез гүелдәүгә әйләнгән тавышлары да, репродуктордан ишетелеп тора торган белдерүләр дә, ишек-тәрәзәләрдән агылып керә торган гөрелтеләр дә тынып калды кебек.* К.Тимбикова. *Рубкага беркетелгән репродуктордан елга өстенә дәртле җыр агыла.* М.Юныс

РЕПРОДУ́КЦИЯ *и. фр. махс.* 1) Фотография, клише яки полиграфия ярдәмендә сурәтнең (рәсем, картина, сызым, басылган текст һ.б.ның) күчермәсен алу, аны күбәйтү

2) Шул юл белән алынган сурәтнең үзе. *--- горизонтта табигый булмаган пейзаж җәелгән! Бу – Тицианның «Гөнаһларыннан ваз кичүче Мария Магдалина» дигән атаклы эшеннән алынган репродукция иде.* М.Хәсәнов

РЕПРОДУ́КЦИЯЛӘҮ *ф.* Репродукция ясау

РЕПС *и. фр.* **1.** Бик вак сырлы тыгыз тукыма

2. *с. мәгъ.* Шул тукымадан тегелгән

РЕПТИ́ЛИЯ *и. лат. зоол.* Сөйрәлүчеләр классына караган умырткалы хайваннарның гомуми исеме (кәлтә, елан, крокодил һ.б.лар). *Җир эволюциясенең мәгълүм һәм бик ерак бер дәверендә планетабызга тышкы кыяфәтләре*

белән репутацияләрне хәтерләткән цивилизация вәкилләренең үтеп керүе фактлары да билгеле. С.Шәмси. *Диңгез ташбакалары иң тиз йөзүче репутацияләрдән санала.* Кызыклар дөньясында. *Репутацияләрнең җылы тоючы парлы органнары күзләреннән бераз түбәнрәк, ә кайчакта аскы иреннәренә урнашкан.* Кызыклы физиология

РЕПУТА́ЦИЯ *и. фр.* Берәр кеше яки нәрсә турында гомуми фикер; аның сыйфатлары, өстенлекләре яки кимчелекләре турында күзаллау. *Сез генә ул эш бетүгә кыякларга торасыз, бездә алай түгел, безгә ышаныч, репутация яшәүдән дә кадерлерәк.* Р.Мирхәйдәров. *Бу мәлгунь [спирт] битеңне кызарта, репутацияне каралта, гомереңне кыскарта, вакытлы дусларыңны күбәйтә, чын дусларыңны азайта.* М.Юныс

РЕПУТА́ЦИЯЛЕ *с.* Нинди дә булса репутациягә ия, кайсы да булса ягы белән игътибар үзәгендә торган

РЕ́СЛЕР *и. инг. спорт* Реслинг белән шөгыльләнүче спортчы

РЕ́СЛИНГ *и. инг. спорт* Рингта (*1 мәгъ.*) бара торган ирекле көрәш һәм дзюдо алымнарын кулланган профессиональ көрәшнең бер төре. *Гавайда, әле европалылар килгәнче үк, бокс, реслинг, йөгерү кебек спорт төрләре киң таралган була.* Сөембикә

РЕСПИРА́ТОР *и. лат.* Сулыш әгъзаларын тузан һәм газлардан саклау өчен махсус җайланма – фильтрлы маска яки ярыммаска. *[Хәйруллин:] Цех һавасындагы зарарлы газларны кимертергә, эшчеләргә респираторлар кигезергә...* М.Маликова

РЕСПИРАТО́Р *с.* Сулыш юллары белән бәйле. *Респиратор авырулар*

РЕСПИРА́ЦИЯЛЕ *с. лингв.* Сулыш юллары ярдәмендә ясала торган. *Респирацияле авазлар*

РЕСПОНДЕНТ *и. инг.* Анкета сорауларына җавап бирүче яки интервью бирүче кеше. *Сораштыруда катнашкан 1200 респондент ярдәмендә белгечләр аерылуга китергән сәбәпләрнең өчтән бере матди кыенлыкларга бәйле булуын ачыклаганнар.* Ватаным Татарстан

РЕСПУ́БЛИКА *и. лат.* 1) Хакимиятнең югары органнарын билгеле срокка сайлап куюга яки парламентлар тарафыннан формалаштыруга нигезләнгән дәүләт идарәсе формасы; идарә итү формасы шундый булган ил; җөмһүрият

2) Россия Федерациясе (элегрәк – СССР) составындагы милли-территориаль өлкә. *Мин, беренче мөмкинлек булу белән, бу турыда республика прокурорына хәбәр иттем.* Һ.Такташ. *Татарстан Республикасының Матбугат, телетапшырулар һәм массакүләм коммуникация чаралары эшләре министрлыгы, Журналистлар берлеге, Республика ветераннар советы Бөек Ватан сугышында җиңүнең 55 еллыгына багышланган конкурс игълан иттеләр.* Татарстан

РЕСПУ́БЛИКАЧЫ *и.* 1) Республика төзелешен яклаучы; республика тарафдары. *Унбер африкалы һәм Голландия судносы матросларының бер өлеше республикачыларга кушыла.* Кызыклар дөньясында

2) Республикачылар партиясе әгъзасы

РЕССОР *и. фр.* Тигезсез юлдан барганда сикертүләрне киметү өчен, транспортның күчәре белән кузовы арасына куела торган сыгылмалы җайланма

РЕССОРЛЫ *с.* Рессор куелган, рессоры булган. *Ярый әле, тарантаслары рессорлы, югыйсә рессорсыз тарантас таш юлда бик яман сикертә ул...* Ә.Еники

РЕСТАВРА́ТОР *и. фр. сәнг.* 1) Борынгы һәйкәлләр, истәлекләр, сәнгать әйберләрен реставрацияләүче белгеч. *Татар малае Мөхәммәтша Зариф улы Кәримов союз күләмендәге реставраторларның, консервация осталарының берсе булып үсә.* М.Әмир. *Шәһәрнең мөмкинлекләре зур, Ташлыярны яңадан туган кебек итәргә була! Рәссамнарны, реставраторларны чакырырга, үзебезнең авыл осталарын дәшәргә дә эшкә тотынырга.* Р.Вәлиев

2) Реставрация (*2 мәгъ.*) тарафдары

РЕСТАВРА́ТОРЛЫК *и.* 1) *сәнг.* Реставрацияләү (*1 мәгъ.*) эше. *Исәнбәт җыйналма текст төзүнең «сәнгать реставраторлыгы булу ягыннан беркадәр ижади эш итеп тә каралырга тиеш» икәнлеген искәртә, үзенең чыганактан файдаланып тәнкыйди текст төзегәнен исбатлый.* Казан утлары

2) Реставратор (*2 мәгъ.*) булу

РЕСТАВРАЦИОН *с.* Реставрация белән бәйле, реставрация эшенә караган. *Реставрацион эшләрнең барышы*

РЕСТАВРА́ЦИЯ *и. фр.* 1) Искергән, тузган, бозылган сәнгать әсәрләрен, борынгы һәйкәлләрне һ.б.ш.ны элекке хәленә кайтару, яңадан торгызу эше. *Ремонт, реставрация ясаганда һәм яңаны төзегәндә, конструкцияләрнең тоташлыгын тәэмин итәргә тиешле төзү эшләренең төрле вариантлары очрарга мөмкин.* Төзү материаллары. *1890 елның мартында җирле рәссам Ф.Т.Травкин профессор Н.А.Осокин күзәтүендә бу каретага бердәнбер реставрация ясый.* Мирас. *Әлеге реставрация «Казанның тарихи үзәген саклау һәм үстерү» дип аталган максатчан федераль программа кысаларында үткәрелә.* Татарстан яшьләре

2) Моңа кадәр яшәгән, бәреп төшерелгән сәяси стройны (төзелешне) яңадан торгызу, кире кайтару эше һәм шуның яклы карашлар системасы

РЕСТАВРА́ЦИЯЛӘҮ *ф. төш. юн.* Реставрация кичерү. *Кремльнең башка урыннары да якынча шундый ук тәртиптә – борынгы архитектура һәйкәлләрен саклап калырлык һәм аларны бүгенге шәһәр ихтыяҗлары өчен нәтиҗәле кулланырлык итеп реставрацияләндә.* Фән һәм тел. *Әгәр дә элекке мәдрәсә бинасы музей итеп реставрацияләнсә, шушыларны минем [М.Мәһдиев] исемнән тапшырырсыз әле.* Татарстан яшьләре

Реставрацияләнә башлау Реставрация эшләренә керешү

Реставрацияләнеп бетү Тулысынча, ахырга кадәр реставрацияләнү. *Экскурсовод урыс хатыны урам буйлап әле реставрацияләнеп бетәргә дә өлгермәгән биналар белән таныштыра.* Безнең гәҗит

РЕСТАВРА́ЦИЯЛӘҮ *ф.* 1) Реставрация ясау. *Өч миллион китапны рәтләп урнаштырып, реставрацияләп, төпләп, саклап тәртиптә тотар өчен һәм килгән укучыларны утыртыр өчен, әлеге бинадан алты мәртәбә зуррак*

мәйдан кирәк. Р.Вәлиев. *Казан Кремле мәдәни мирасны саклау, аны өйрәнүгә комплекслы якын килү, саклап калу һәм реставрацияләү өлкәсендә Россия дәүләт мәдәни сәясәтенең бер ачык мисалы булып тора.* Мирас

2) Элекке, бәреп төшерелгән сәяси стройны яңадан торгызу, кире кайтару. *Россиядә империяне реставрацияләү юлыннан китәргә вәсвәсә салулар көчле булды.* Мирас

Реставрацияләп бетерү Тулысынча, ахырга кадәр реставрацияләү. – *Ай ярым дигәндә самолётны тулысынча реставрацияләп бетердек, һәм ул үз тәгәрмәчләрендә шушы урынга килеп басты, – ди Рөстәм Саттаров*. Кызыл тан

Реставрацияләп кую Тулысынча реставрацияләнгән хәлгә китерү; алдан реставрацияләү. *Әйтергә кирәк, кыска гына вакыт эчендә Рөстәм һәм аның командасындагы егетләр ярым җимерек самолётны күз явын алырлык итеп реставрацияләп куйдылар*. Кызыл тан

Реставрацияләп тору һәрвакыт, һәрдаим реставрацияләү. *Ватанны яклап башын салганнар истәлегенә куелган монументлар һәм һәйкәлләрне саклап, реставрацияләп тору*. Ватаным Татарстан

Реставрацияли башлау Реставрацияләргә керешү. *Петербурглылар Казанда XIX гасыр архитектурасының уникаль һәйкәле фасадларын реставрацияли башладылар.* Мәдәни җомга

РЕСТАВРА́ЦИЯЧЕ *и. сәяси к.* **реставратор** (*2 мәгъ.*)

РЕСТА́ЙЛИНГ *и. ингл.* Стильне яңарту, стильне үзгәртү

РЕСТИТУ́ЦИЯ *и. лат. юр.* 1) Тартып алынган шәхси милекне элекке хуҗасына кайтарып бирү турындагы закон. *Балтыйк илләрендә реституция турындагы канун нигезендә таланып алынган милек асыл хуҗаларына кайтарылды.* Р.Зарипов

2) Гражданлык хокукында: төзелгән шартнамәне законсыз дип таныган очракта, шул шартнамә нигезендә алынган барлык әйберләрне дә кире кайтару. *Реституция исә аңа хуҗалык корылмаларын, җирне арендага биреп, акча эшләргә мөмкинлек тудырачак*. Ватаным Татарстан

3) Бер дәүләтнең сугыш вакытында икенче дәүләт тарафыннан законсыз талап алынган милкен кире кайтару

4) *биол.* Зарарланган организмның яки аерым әгъза һәм тукымаларның тернәкләнүе, төзәлүе

РЕ́СТЛИНГ *и. ингл. к.* **реслинг**

РЕСТОРАН *и. фр.* Матур бизәлгән һәм махсус җиһазландырылган, җанлы музыка, җыр-бию программалары да булган, өстәл янында хезмәт күрсәтелә торган кыйммәтле ашханә. *Ресторанда күп йөреп Бетердем мин малымны.* Ш.Мөхәммәдев. *Шәһәрдә, әле теге чакларда, ресторанда катык-каймак таптырып, официантларның теңкәсенә тия иде.* М.Хуҗин. *Ресторанның идәннәре ак мәрмәрдән, диварлары акка буялган, аларның өске ягы күбесенчә көзгеләнгән иде.* Т.Әйди

РЕСТРУКТУРИЗА́ЦИЯ *и. фр.* 1) Төзелешендәге үзгәрешләр, яңача үзгәртеп корулар; реорганизация. *Эштән бушатылу куркынычы янаган кешеләрне һәм инвестицион программаларга ярашлы производствога реструктуризация һәм модернизация үткәргән, алдынгы технологияләр кулланучы предприятиеләр хезмәткәрләрен һөнәри юнәлештә алдан укытуга программада зур игътибар бирелә*. Кызыл тан

2) *икът.* Кредит күләмендәге чикләүләр, кредит түләү, бурыч кайтару шартларындагы, срокларындагы үзгәрешләр

РЕСТРУКТУРИЗА́ЦИЯЛӘҮ *ф. төш. юн.* 1) Нәрсәнең дә булса структурасы үзгәртелү, яңача үзгәртеп корылу. *Урта Пошалым мәктәбе, реструктуризацияләнгәч, база мәктәбенә әвереләчәк.* Ватаным Татарстан

2) *икът.* Кредит күләме чикләнү, кредит түләү сроклары үзгәртелү

РЕСТРУКТУРИЗА́ЦИЯЛӘҮ *ф.* Реструктуризация үткәрү

РЕСУРС *и. фр.* Нәрсәнең дә булса тупланган чыганагы; запасы; байлык. *Республика ресурсыннан ара-тирә фураж да биреп куйгалыйлар.* Г.Ахунов. *Илгә сугыш куркынычы янамаганда, нигә шулкадәр акча, ресурслар түгеп, чамасыз гаскәр тотарга?* А.Гыйләҗев

РЕТЕЙЛ *и. ингл.* Икътисадта җитештерү, сәүдә яки хезмәт күрсәтү базарының ваклап сатуга бәйле аерым бер секторы; гомумән, ваклап сату

РЕТЕ́ЙЛЕР *и. ингл.* Ваклап сатучы

РЕТИ́НА *и. лат. анат.* Күзнең яктылык сизә торган эчке челтәр катлавы

РЕТИНИТ *и. лат. мед.* Ретинаның ялкынсынуыннан гыйбарәт авыру. *--- кайбер кешеләрдә кератоконъюктивит, ретинит, катаракта, глаукома кебек күз авырулары килеп чыгу электромагнит нурланышның тискәре йогынтысыннан түгел, бәлки көн дәвамында мониторга текәлеп, зур игътибар белән киереңке хәлдә эшләгәнлектән була*. Безнең гәҗит

РЕТО́РТА *и. лат. махс.* Сыекчаны куу, төрле катнашмаларны җылытып таркату өчен кулланыла торган озын һәм кәкре муенлы груша сыман лаборатория савыты

РЕТРАНСЛЯ́ТОР *и. рус* Ретрансляция ясый торган җайланма, элемтәара көчәйткеч пункт. *--- ел саен дөньяда 50 миллион кош һәлак була икән, һәм бу сан елдан-ел арта. Үтерүчеләр исә – кесә телефоннары сигналын кабул итүче вышкалар – ретрансляторлар.* Мәдәни җомга

РЕТРАНСЛЯЦИОН *с. махс.* Ретрансляциягә бәйләнешле

РЕТРАНСЛЯ́ЦИЯ *и. лат. махс.* Радио-телепрограммаларны, радиосигналларны көчәйткеч элемтәара пункт аша кабул итү һәм алга таба тапшыру. *Иярченнәр радио һәм телевидение өчен зур мөмкинлекләр ачалар, чөнки аларны континентара радио һәм телетапшырулар өчен ретрансляция станцияләре итеп файдаланырга була.* В.Казневский. *«Яңа гасыр» каналы җитәкчеләре лицензияне үзгәртү, яисә ретрансляцияне саклап калу өчен чара күрә алмады*. Татарстан яшьләре

РЕТРАНСЛЯ́ЦИЯЛӘҮ *ф. махс.* Ретрансляция ясау. *Узган елда «Азатлык» радиосы тапшыруларын «Яңа гасыр» радио каналы аша ретрансляцияләү туктаган иде*. Безнең гәҗит

РЕ́ТРО *и. лат.* **1.** XX йөзнең 70 нче елларында Көнбатыш сәнгатендә, мәдәниятендә модадагы стиль: үткәндәге,

борынгы барлык әйберләр. *[Республика рок-музыка стилендә] Иң төп юлны мин «ретро» дигән хәрәкәттә күрәм. Бу – үз тамырларыңа, үз милләтеңнең үткәненә мөрәҗәгать итү дигән сүз.* Идел

2. *с. мәгъ.* Шул стильгә караган. *Соңгы елда синең репертуарда инде онытыла башлаган ретро җырлар барлыкка килде.* Татарстан яшьләре

РЕТРОГРАД *и. фр. кит.* **1.** Прогресс дошманы, реакционер

2. *с. мәгъ.* Прогресска каршы булган, реакцион караштагы

РЕТРОСПЕКТИВ *с.* Үткән тарихны күзәтүгә багышланган. *Автор әлеге каләмдәшләренең тәҗрибәсен үстерә, баета барып, өлкән яшьтәге Заһидә ханымны яшь Заһидә туташ белән очраштыра. Ретроспектив алым ярдәмендә үткәннең аерым чорларына, вакыйгакүренешләренә алып керә, шул мохиттә безне дә яшәтә.* Ә.Закирҗанов

РЕТРОСПЕ́КЦИЯ *и. лат. кит.* Ретроспектив характердагы күзәтү алымы; үткәнне күзәтү эше. *«Торналар төшкән җирдә», «Бәхилләшү» әсәрләрендә үткәндәге тормыш аерым кешеләр өчен бүгенгедән әһәмиятлерәк яссылыкка куела, --- вакыт ягыннан тәртипле оешканлык, ретроспекция алымы үткәндәге психологик вакытка алып китә.* Г.Гайнуллина

РЕ́ТУШЬ *и. фр.* Фото тасмага, гравюрага һ.б.ш.га төшерелгән рәсемнәрне буяп яки цифрлы ысул белән эшкәртү, кимчелекләрен төзәтү, матурлау эше. *Матур булсын өчен рәсемгә ретушь ясыйлар.* Ш.Галиев. *Язулар һәм тамгаларның сакланышы бик начар, аларны бары ретушь ысулы белән генә беркадәр ачарга мөмкин.* М.Әхмәтҗанов

РЕ́ТУШЬЛАУ *ф.* 1) Ретушь ясау, ретушь ысулы белән төзәтү

2) *күч.* Чынбарлыктагы кимчелекләрне күрсәтмәскә тырышу, чынбарлыкны матурлап күрсәтү

Ретушьлап җибәрү Бераз, бернигадәр ретушьлау

Ретушьлап кую Алдан ретушьлау, ретушь ясап әзер хәлгә китерү

Ретушьлап чыгу Һәрберсен, берәмберәм барысын да ретушьлау

РЕ́ТУШЬЧЫ *и.* Ретушь ясау остасы, ретушь белгече

РЕУТИЛИЗА́ЦИЯ *и. лат.* Бер хуҗалык тармагының калдыклары икенче хуҗалык тармагында чимал буларак кулланылуы

РЕФА́КЦИЯ *и. фр. икът.* 1) Товарның сыйфаты үзгәрү, югалу, алдан билгеләнгән нормативларга туры килмәү сәбәпле, сәүдә килешүләре вакытында аның бәясенә яки авырлыгына ясалган ташлама

2) Товарның авырлыгы зур булганда, махсус килешү нигезендә йөк озатучыга түләү өчен тарифка ясалган ташлама

РЕФЕРАТ *и. лат.* Китап, мәкалә, гыйльми хезмәтнең һ.б.ш.ның язып яки сөйләп биргән кыскача эчтәлеге; шул характерда язылган доклад. *Калэм сабын кимереп, азапланып язган хезмәтең өчен ут йотып йөрисе бар, азактан – әлеге рефератның үрнәк-өлге итеп студентлар күргәзмәсенә куелуын күргәч, шыпырт кына, тыйнак кына сөенәселәре бар.* Г.Ахунов. *Музей директорының тырышлыгы, үҗәтлеге белән 6 китап нәшер ителгән, соңгы өч елда гына да музей материаллары буенча алтмышлап реферат язылган, дүрт диплом эше якланган.* Татарстан яшьләре

РЕФЕРАТИВ *с.* Эчтәлекне реферат рәвешендә биргән, реферат характерындагы, кыска. *Чыгыш реферативхарактерда булды*

РЕФЕРЕ́НДУМ *и. лат.* Берәр мөһим дәүләт мәсьәләсен хәл итү максаты белән үткәрелгән гомумхалык тикшерүе; бөтен халык фикерен ачыклау өчен уздырылган тавышка кую. *Мондый сәясәтне 1992 елгы референдум вакытында халык яклады, һәм ул Татарстан Конституциясендә беркетеп куелды.* М.Шәймиев. *Бөтен халык референдумыннан соң, Швейцария алдагы биш елда илгә геннары модификацияләнгән ризыкларны кертүне тыя торган карар кабул иткән.* Мәдәни җомга. *Әмма депутатларның күпчелеге, бу принципиаль мәсьәлә түгел дип, референдум үткәрүне хупламый.* Мәгърифәт

РЕФЕРЕНТ *и. лат.* 1) Реферат төзүче яки укучы кеше

2) Россия дәүләт хезмәте системасында «Белгечләр» категориясенең иң югары группасына караган эш вазифасы. *Россия Президентының референты*

3) Аерым мәсьәләләр буенча махсус консультацияләр биреп торучы, җитәкчегә докладлар язып бирүче хезмәткәр. *Үзенә референт итеп, Мәскәүдән Казанга кайтарткан чибәр гөрҗи хатынын алды.* А.Гыйләҗев

РЕФЕРЕ́НЦИЯ *и. лат.* 1) *фин.* Фирманың яки аерым шәхеснең кредит түләү мөмкинлеге турындагы белешмә

2) *лингв.* Чынбарлыкта булган нәрсәне сүз, фраза белән белдерү

РЕ́ФЕРИ́ *и. инг.* Спорт уены вакытында уеннның барышын күзәтеп торучы судьяның халыкара традицион атамасы. *Уенчы стандартка туры килмәгән зурлыктагы кәшәкә кулланса, аңа штраф салына. Еш кына рефери (баш казый) кәшәкәне каршы як командасы таләбе буенча үлчи.* Чемпион булу серләре: хоккей

РЕ́ФЕРИЛЫК *и.* Рефери вазифасы

РЕФИНАНСИ́РОВАНИЕ *и. инг.* 1) Бер икътисади тармакны, алынган доход исәбеннән, кабат яки өстәмә финанслау. *13 июльдән Үзәк банк тагын ярты процентка рефинансирование ставкасын төшергән.* Кәеф ничек?

2) Хөкүмәт тарафыннан түләү срогы җиткән облигацияләрне срогын озаккарак күчереп яңартып чыгару

РЕФЛЕКС *и. лат.* 1) *физиол.* Организмның тышкы тәэсирләргә нерв системасы аша җавабы. *Балыкта шартлы рефлекс тудыру өчен җайсызрак җир бу...* А.Тимергалин. *Һәр яңа тынычсызлагыч шул ук вакытта ориентлашу рефлексы китереп чыгара, бу исә организмга теләсә нинди көтелмәгән хәлгә әзер торырга ярдәм итә.* Кызыклы физиология. *Шартлы һәм шартсыз рефлекслар аркасында хайваннар әйләнә-тирәлеккә бик яхшы җайлашалар.* Дарвинизм нигезләре // Берәр сәбәп аркасында ихтыярсыз ясалган хәрәкәт

2) *күч. кит.* Нәрсәнең дә булса нәтиҗәсе, чагылышы; берәр күренеш тарафыннан барлыкка китерелгән икенчел күренеш. *Дини бәхәсләр милли*

ризасызлыклар барлыкка китерү рефлексына әверелде

3) *күч. сәнг.* Нинди дә булса төсле әйбернең икенче өлеккә төшкән күләгәсенең чагылыш төсмере. *Өйнең ак стенасындагы яшел яфраклар рефлексы*

РЕФЛЕ́КСИЯ *и. лат. кит.* Үзеңнең эчке кичерешләреңне тикшерү, үзүзеңдә казыну. *Рефлексия – кешенең эчке психик эшчәнлеге, ул кешегә үзенең халәт һәм гамәлләрен аңларга, үзенең рухи дөньясына төшенергә ярдәм итә.* А.Низамов

РЕФЛЕКСОДИАГНО́СТИКА *и. лат.-гр.* Рефлексотерапия өчен кеше тәнендәге сизгер нокталарны билгеләү эше

РЕФЛЕКСО́ЛОГ *и. лат.-гр. психол.* Рефлексология (*3 мәгъ.*) белгече

РЕФЛЕКСОЛО́ГИЯ *и. лат.-гр.* 1) *психол.* Психологиядә 1900–1930 елларда үсеш алган, Россиядә В.М.Бехтерев тарафыннан нигезләнгән, кешенең психик эшчәнлеген аның рефлекслары җыелмасы буларак караган юнәлеш

2) Рефлексларны өйрәнә торган фән

3) *мед.* Медицинаның кеше тәнендәге биологик актив (мәс., кул, аяк табанындагы) нокталарга тәэсир итеп (массаж ясап, басып һ.б.) дәвалау белән шөгыльләнә торган бүлеге

РЕФЛЕКСОТЕРАПИ́Я *и. лат.-гр.* Кеше тәненең тирегә якынрак торган нерв очларына яки биологик актив нокталарга тәэсир итеп дәвалау методы. *Анда докладлар белән РГМУның реювенология курслары мөдире, Нью-Йорк академиясе академигы, профессор М.И. Ундрицов, Казан ГИДУВының неврология һәм рефлексотерапия кафедрасы мөдире Г.И. Иванычев --- һәм башка күренекле галимнәр чыгыш ясар дип көтелә*. Ватаным Татарстан

РЕФЛЕКТИВ *с.* 1) Рефлекслар белән бәйле. *Организмның рефлектив эшчәнлеге*

2) Рефлекс рәвешендәге, акыл һәм ихтыярга бәйле булмаган, машиналь. *Рефлектив реакция*

РЕФЛЕКТО́МЕТР *и. лат.-гр.* Яктылык кайтарылу коэффициентын үлчәү әсбабы

РЕФЛЕ́КТОР *и. лат.* 1) Яктылык һәм җылылык нурларын чагылдырып кайтара торган батынкы көзгеле өслектән гыйбарәт әсбап, көнкүреш җиһазы. *--- ни кызганыч, күктә очып янмаган, суда батмаган Салих ага ятакта, җылытқыч рефлектордан одеялына ут кабып, ис һәм ялкыннан буылып үлде.* Р.Фәйзуллин

2) Антеннага якын итеп урнаштырыла, радиодулкыннарның юнәлешле таралышын тәэмин итә торган җиһаз

3) *махс*. Батынкы көзгеле телескопның бер төре

РЕФЛЕКТО́Р *с.* 1) Рефлекс белән бәйле булган; тышкы тәэсиргә реакция белдергән. *--- психик процессларның үзенчәлекләре --- тулысы белән тәрбиягә һәм укыту-өйрәтүгә бәйле, ягъни ахыр чиктә шартлы рефлектор бәйләнешләрнең катлаулы системаларының тулы бер иерархияләре барлыкка килүгә бәйле икән.* Кызыклы физиология. *Кул һәм аяк табаннары – рефлектор зона*. Кәеф ничек?

2) Ихтыярдан башка, үзеннән-үзе башкарылган. *Рефлектор хәрәкәт*

РЕФЛЕКТОРЛЫК *и.* Хәрәкәтнең аңга бәйсез рәвештә, үзеннән-үзе, рефлектор эшләнүе

РЕФЛЯ́ЦИЯ *и. ингл. икът.* Элек кыйммәтен югалткан бәянең яңадан үсеп, үз хәленә кайтуы, бәя торгызылу. *Рефляция күзәтелү*

РЕФО́РМА *и. лат.* 1) Нәрсәне дә булса үзгәртү, үзгәртеп кору, яңадан төзү. *Дарвин ясаган реформа Ньютонның механика өлкәсендә ясаган реформасына охшый ---.* Дарвинизм һәм дин

2) Яшәп килгән стройның нигезләрен үзгәртмичә, аңа кайбер сәяси үзгәрешләр кертү

РЕФО́РМАЛАУ *ф.* Реформа үткәрү, реформа ясау, үзгәртеп кору. *Аларның «тәрәккыйпәрвәрлеге» борынгы дини мәдрәсәләрне реформалау, милләтне европалаштыру, яңача укуны яклаудан ерак китмәде.* М.Җәлил. *Гыйнвар уртасында Дмитрий Медведев Дәүләт Думасына сәяси системаны реформалый торган берничә закон проектын кертте.* Татарстан

Реформалап тору Еш, әледән-әле реформалау. *Алга барган саен, яңадан-яңа проблемалар туып тора, һәм, аларны хәл итү өчен, системаны яңартып, үзгәртеп, реформалап тору кирәк.* Ватаным Татарстан

РЕФО́РМАЛАШТЫРУ *ф. ялг. к.* **реформалау**

РЕФОРМА́ТОР *и. фр.* Реформа үткәрүче, реформа ясаучы. *Ләкин нәкъ рәтләнеп җитте дигәндә генә тагын Ленин яки Ельцин кебек бер акыллы баш реформатор табылыр да яңабаштан үзгәртеп кора башлар, илне янә киregә өстерәр*. И.Хуҗин. *Реформатор иң сабыр, тыйнак, гади, керсез юл белән революция ясады да куйды*. Казан утлары. *XIX гасыр ахыры – XX йөз башы татар әдәби телендә угыз компонентының активлашуына бу чорда нигезендә күренекле мәгърифәтче һәм реформатор И.Гаспринскийның уртак төрки әдәби тел концепциясе яткан гомумтөркичелек идеяләренең татарлар арасына үтеп керуе дә сәбәпче була*. Фән һәм тел

РЕФОРМА́ТОРЛЫК *и.* 1) Реформалар ярдәмендә үзгәртеп кору эше. *Нәтиҗәдә яңа иҗтимагый-фикри хәрәкәтләр кузгала, төрле яктан уянулар, яңару-җәдитләнүләр, реформаторлыклар башлана.* Татар театры. *Шулай итеп, җәдитчеләрнең гаилә тормышларындагы бу үзенчәлек реформаторлык хәрәкәтенең Ауропа культурасын үзләштерүдән генә гыйбарәт булмаганын дәлилли.* Шәһри Казан

2) Реформа яклы карашлар, үзгәрешләрне хуплаган агым. *Шәех Кәмалетдин әл-Әфгани (1839–1897) – гарәп дөньясында реформаторлык хәрәкәтенә нигез салучы, мәшһүр әфган галиме, сәясәт эшлеклесе.* Гасырлар авазы. *Аларга исә соңгы елларда икенче бер «авыру» йокты: ул «реформаторлык» дип атала*. Татарстан яшьләре

3) Берәүнең реформатор буларак эшчәнлеге. *Гали хәзрәт Ш.Мәрҗани һәм башка прогрессив карашлы кешеләрнең реформаторлык эшчәнлеген яклаган, үзе дә яңалыкка, прогресска омтылган*. Г.Мөхәммәтшин

РЕФОРМАЦИОН *с. тар.* Реформациягә бәйләнешле

РЕФОРМА́ЦИЯ *и. лат.* 1) *тар.* XVI йөздә Көнбатыш Европада католик динен Библиягә яраклаштырып үзгәртү, папа хакимлеген чикләүгә юнәлтелгән иҗтимагый-сәяси хәрәкәт, дини үзгәртеп корулар. *Кешеләрнең рухи тормышын үзгәртү – реформация – христиан динендә яңа тармакның – протестант диненең барлыкка килүенә китерә.* К.Гыйззәтов

2) Гомумән дингә мөнәсәбәт, дини карашлардагы үзгәрешләр. *Сәүдәсәнәгать капиталы тупрагында туган идеология эчендә дини реформация хәрәкәте бар. Бу Мәрҗанидән алып хәзергәчә сузыла.* Г.Ибраһимов

РЕФО́РМАЧЫЛЫК *и. к.* **реформизм**. *Үзенең «эчке дошманы» – кадимчелеккә каршы көрәштә ныгый төшкәч, кадимчелеккә каршы көрәшендә ул [эре һәм урта буржуа хәрәкәте] бишенче елга хәтле дәверендә мөмкин булган чаклы искечеләр белән конфликттан качу, аларны яңартырга тырышу һәм үзенә көч җыю юлын тоткан булса, хәзер, шул ук реформачылык нигезен саклаган хәлендә, аларга каршы кискенрәк тәнкыйть коралларын да куллана башлаган иде.* Г.Нигъмәти

РЕФОРМИЗМ *и. фр.* Революцион көрәшне инкяр итеп, җәмгыятьтә сыйныфларның үзара хезмәттәшлеге нигезендә социаль үзгәрешләр үткәрүгә ирешүне максат итеп куйган сәяси агым, хәрәкәт

РЕФОРМИСТ *и. рус* Реформизм тарафдары

РЕФОРМИ́СТИК *с.* Реформизмга бәйләнешле

РЕФРАКТО́МЕТР *и. лат.-гр.* Төрле җисемнәрдә, мохитләрдә нурлар сыну күрсәткечен үлчәү приборы. *Оптик либрация белән берәртән обсерватория хезмәткәрләре белән рефрактометр янында физик либрация дә бар.* Фән һәм тел

РЕФРА́КТОР *и. лат.* 1) Күк җисемнәрен линзалар ярдәмендә күзәтә торган телескоп. *Республика башлыгы астрономия тарихы музеенда булды, КФУда галәм технологияләрен үстерү экспозициясен һәм рефрактор телескобын карады.* Мәдәни җомга

2) *иск.* Яктылыкны көчәйтә торган зурайткыч пыяла // Шундый пыяла куелган лампа

РЕФРАКЦИОН *с. физ., астр.* Рефракциягә бәйләнешле

РЕФРА́КЦИЯ *и. лат.* Ике төрле мохит (мәс., һава белән су) чигендә нурлар сыну күренеше. *М.Бертло фәнгә «молекуляр рефракция» төшенчәсен кертә, матдәнең яктылык сындыру үзлеге белән аның составы арасындагы бәйлелекне өйрәнә.* Фән һәм тел. *Лазер белән операция ясау ул – бары косметик чара, ягъни, күзнең рефракция мөмкинлекләрен бетерү, дигән сүз.* Әлмәт таңнары

РЕФРА́КЦИЯЛӘҮ *ф. махс.* Рефракциягә дучар булу

РЕФРЕН *и. фр.* 1) *муз.* Бөтен әсәр дәвамында берничә тапкыр үзгәрешсез кабатлана торган төп тема яки аерым бер музыкаль материал. *Чакыруялвару сүзләре, гадәттә, рефрен булып, текстның буеннан-буена бара һәм еш кына аны тәмамлап та куя.* М.Бакиров

2) *шигъ.* Билгеле бер тәртип белән кабатлана торган юл яки кушымта. *Такмаклар һәр уен өчен даими булып торалар һәм уенга уен төсе бирүче, аны оештыручы, үстерүче төп композицион чара – рефрен хезмәтен үтиләр.* К.Миңнуллин. *Г.Зәйнашеваның кайбер җырларында референнар эчтәлекләре белән лирик эндәшләр булып торалар.* Д.Нигъмәтҗанова

РЕФРИЖЕРА́ТОР *и. лат.* 1) Зур суыткыч җайланманың сыекчаны парга әйләндереп түбән температура барлыкка китерә торган өлеше һәм шул җайланма үзе

2) Тиз бозыла торган азык-төлек (туңдырма, торт һ.б.) яки билгеле температура режимы таләп ителгән әйберләрне (дарулар, чәчәкләр һ.б.) күчерү өчен, шундый суыткыч белән җиһазландырылган транспорт чарасы, йөк ташу машинасы. *--- үткән-сүткән кешеләргә тузан бөркеп, Чыгытай урамыннан җирле минераль су төягән көмеш сыман рефрижераторлар чабыша ---.* Р.Мирхәйдәров // Суыткычы булган вагон яки судно

РЕФРИЖЕРА́ТОРЛЫ *с.* Рефрижераторы булган. *Рефрижераторлы судно*

РЕЦЕНЗЕНТ *и. рус* Рецензия язучы, рецензия авторы; бәя бирүче. *Рецензентның бер киңәшен дә кабул итмәде ул [Варин]. Бит кырыйларына карандаш белән язылган искәрмә, күрсәтмәләрне бетергеч белән --- чистарткалады.* М.Хәсәнов

РЕЦЕНЗЕНТЛЫК *и.* Рецензент булу

РЕЦЕ́НЗИЯ *и. лат.* Фәнни хезмәткә, әдәби әсәр, спектакль, кинофильм һ.б.ш.ларга язма рәвештә бирелгән бәяләмә. *Әсәр чыгу белән, берничә дистә рецензия басылып чыга, телевидениедән реклама ясала ---.* М.Юныс. *Дарвин китабына бик тискәре рецензияләр башка матбугат органнарында да басылып чыга.* Дарвинизм һәм дин

РЕЦЕ́НЗИЯЛӘҮ *ф.* Фәнни, әдәби яки берәр төрле сәнгать әсәренә рецензия язу, бәя бирү. *ВАК --- Ә.Борһановның диссертациясен, рецензияләү өчен, ул тәнкыйтьләгән галимнәргә тапшыра!* Рәмзи Вәлиев. *Чыннан да, Ж.Вәлиди Г.Тукайның төп китапларын үзе исән чагында ук рецензияли.* Татар әдипләре

Рецензияләп бару һәр очракны системалы рәвештә рецензияләү

РЕЦЕПТ *и. лат.* 1) Даруның составы, аны ничек куллану турында табиб язып биргән рәсми кәгазь. *Авыруларны бик җентекләп, озаклап карадым. Үземчә диагнозлар куйдым, рецептлар яздым.* Н.Фәттах

2) Берәр төрле ашамлык әзерләү ысулы турындагы мәгълүмат. *Конкурска тәкъдим ителгән тәм-томнарның моңарчы булган рецептка туры килүкилмәве яки яңа рецепт буенча пешерелүе, бизәлеше, тәме, башкалардан аерылып торуы исәпкә алыначак.* Кәеф ничек?

3) Нәрсәнең дә булса төзелеше, состав өлешләре, аны әзерләү буенча китерелгән күрсәтмәләр җыелмасы. *--- үз-үзенә сорау бирә: «Нигә соң бу асфальт ике елга да чыдамый? Нәрсә кирәк? Әллә кулланылган чуерташы, әллә битумы начар? Рецепт төзи белә́безме?»* З.Дәүләтов

4) *күч.* Тормышта килеп чыгарга мөмкин булган төрле очракларда, эш-вакыйгаларда үзеңне ничек тоту турындагы киңәшләр, әзер кулланмалар. *---күп кенә төшенчәләр әледән-әле үзгәрә тора, кичәге исәбең бүгенгә әле тартып-сузып яраса да, иртәгә инде, әлбәттә, ярамый, рецепт белән яшәү мөмкин түгел, һич юк*. К.Миңлебаев

РЕЦЕ́ПТОР *и. лат.* Тере организмда нерв җепселләренең очындагы тышкы тирәлеккә, ярсытуга үтә сизгер үсенте җыелмасы. *Бал кортларының һава температурасын һәм углерод диоксиды концентрациясен кабул итү рецепторлары да бар.* Р.Сафиуллин. *Күзәнәк мембранасының төрле рецептор үзлегенә ия булган өлешләре температурага һәм фотопериодикага бәйле биоритмнарны көйли, дип карыйлар.* Р.Гыйльметдинова. *--- бу вакытта [су астында] канда кислород микъдарының җитешмәве турында хәбәр итүче рецептор гына эшли ---.* Кызыклы физиология

РЕЦЕПТУ́РА *и. нем.* 1) *фарм.* Фармакологиянең рецептларны дөрес язу кагыйдәләрен өйрәтү тармагы

2) *фарм.* Даруларның һәм дару катнашмаларының составлары һәм аларны әзерләү ысуллары җыелмасы. *Республиканың барлык медицина учреждениеләрендә рецептура бланкының электрон үзгәртүләре программасы кертелгән*. Фән һәм тел

3) Нәрсәнең дә булса составы һәм аны әзерләү ысуллары турында мәгълүмат. *Иптәш Кузнецов, табигатьтә иң матур төсләр комбинациясен чагылдыра торган яңа рецептура ачтым. Менә формуласы!* Т.Шакирова

РЕЦЕ́ПЦИЯ *и. лат.* 1) Рецепторлар ярдәмендә ярсыткычларны кабул итү, тану һәм ярсыткычлардан алынган энергияне нерв сигналларына әверелдерү. *Бал кортларының һава температурасын һәм углерод диоксиды концентрациясен кабул итү рецепторлары да бар. Хәбәр һәм аны кабул итү, ягъни рецепция затлар арасында тиешле бәйләнеш каналы барлыкка китерә.* Р.Сафиуллин. *--- үзара барган «диалог»та әдәби мәгълүматны тапшыручы һәм кабул итүченең статусдәрәҗәләре бертигез. Бу урында рецепция күренеше кызыклы үзгәреш кичерә, ягъни тәэсир итүче аны кабул итүченең әдәби карашларын үзгәртә.* Ә.Закиржанов. *Кайбер хайваннарның җылылык рецепциясе үсеп, азык эзләүдә әһәмиятле җайланмага әверелгән.* Кызыклы физиология

2) *кит.* Башка илдә яки башка тарихи чорда барлыкка килгән социаль һәм мәдәни формаларны нинди дә булса җәмгыятьнең кабул итүе һәм үзенә яраклаштыруы

РЕЦИДИВ *и. фр. кит.* 1) *мед.* Тулысынча терелеп беткән кебек тоелганнан соң авыруның яңарып кабатлануы; өзлегү. *--- түзә алмыйча, морфий уколы кадау ихтималы бар иде ---. Эзлеклелек югалса, яман хәл, рецидив килеп чыга. Ул инде өченче төнен морфийсыз үткәрә*. Х.Камалов

2) *күч.* Нинди дә булса, гадәттә тискәре күренешнең кабатланышы

РЕЦИДИВИСТ *и. фр. юр.* Берничә тапкыр җинаять эшләгән кеше. *Монда зур галим дә, язучы да, дәүләт эшлеклесе һәм кеше талаучы, үтерүче рецидивист та бер категория кешесенә – «гражданин» яисә «иптәш пассажир»га әверелә, гап-гади кеше булып кала*. Ә.Гадел. *Аннары яңадан рәшәткә артына. Дүртенче кат. «Үтә куркыныч рецидивист» исеме!..* М.Насыйбуллин. *Өч тапкыр төрмәдә утырып чыккан. --- юристлар теле белән әйткәндә, рецидивист бит инде ул*. Т.Миңнуллин

РЕЧИТАТИВ *и. ит. муз.* Табигый сөйләмгә хас ритмны һәм интонацияләрне җырда бирүдән гыйбарәт вокал формасы. *[Әлфия ханым] Хис белән җырлый ул... Ул ярым сөйләм, ярым җыр белән сәхнәгә чыга. Речитатив белән алдыра.* Р.Батулла. *Әйтенүләрдә логик басым шигырь юлының соңгы сүзенә төшә, һәм ул сузыбрак әйтелә. Бу – әсәрне речитатив рәвешендә башкаруга китерә.* Р.Ягъфәров

РЕ́ЭВАКУАЦИОН *с.* Реэвакуациягә бәйләнешле

РЕ́ЭВАКУА́ЦИЯ *и. лат.* Куркыныч узганнан соң, эвакуацияләнгән урыннарына кире кайтару эше

РЕЭВАКУА́ЦИЯЛӘНҮ *ф.* Эвакуацияләнгән урыннарына кире кайтарылу

РЕЭВАКУА́ЦИЯЛӘҮ *ф.* Эвакуацияләнгән урыннарына кире кайтару

РЕ́ЭКСПОРТ *и. лат. махс.* Бер илгә читтән, башка илдән кертелгән товарны кире чыгару яки өченче бер илгә сату. *Турыдан-туры реэкспорт*

РЕЭМИГРАНТ *и. рус* Эмиграциядән туган иленә кире кайткан кеше

РЕЭМИГРА́ЦИЯ *и. лат.* Эмиграциядә булган кешеләрнең туган илләренә кире кайту процессы

РЕЭМИГРА́ЦИЯЛӘҮ *ф.* Эмиграциядән туган илгә кире кайту

РЕ́Й *и. голл. махс. к.* **рей**

РИАЛ *и. гар.* Согуд Гарәбстаны, Иран, Катар кебек гарәп телле илләрдә төп акча берәмлеге. *Бер бай, аена ике йөз риал түлим дип, хезмәтче яллый икән*. Әкият. *Садаканы болай өләшеп йөрүче дә күп: кайсы күмәч тоттыра, кайсы тәсбих тарата, риал өләшеп йөрүчеләр дә байтак*. Мәдәни җомга

РИБА *и. гар.* Процент алу күренеше. *Нәкәс мулла исә байтак заманнардан бирле «К» авылында имам булып, хәйлә вә хәрам кәсепләр, ришвәт вә риба тарикы илә мал казанып, хәзерге вакытта авылның башка имамнары белән чагыштырганда шактый бай тормышта яшәгән.* З.Бигиев

РИБАХУР *и. гар. к.* **рибачы**

РИБАЧЫ *и.* Процент алучы. *Ул үтә ярдәмчел: әвене янганнарга зур процент белән акча биреп тора, рибачы әҗәтен түләүне ашыктырмый, процентын гына арттыра.* А.Гыйләҗев

РИБАЧЫЛЫК *и.* Рибачы булу; рибачы эшчәнлеге. *Журналистлар --- ислам банкы, рибачылык турында да сорадылар.* Татарстан яшьләре

РИБО́ЗА *и. лат.* Барлык тере организмнарның күзәнәкләрендә рибонуклеин кислотасы составында булган, суда яхшы эри торган татлы төссез кристалл; моносахарид

РИБОНУКЛЕ́ИН КИСЛОТАСЫ *и. биол.* Күзәнәкләрдәге аксымны синтезлауда катнаша, генетик информацияне тапшыруда мөһим роль уйный торган, үзендә рибоза булган нуклеин; һәрбер тере организмда булган макро-

молекула. *Ул [биохимик], теория буенча, информация мидә РНК, ягъни рибонуклеин кислотасы молекулаларында яисә ниндидер башка макромолекулаларда кодлаша, дип уйланыла.* Кызыклы физиология

РИВАЯ *и. гар. иск. к.* **риваять**. *[Татар халык мәкальләре] --- мәсәл, хикмәт элементларын асрап килүләре белән, күпчелеге --- ривая калыбында төзелгәннәр.* Н.Исәнбәт

РИВАЯТЬ *и. гар.* Эпик характердагы, реаль тарихи шәхескә, вакыйгага яки урынга багышланган фольклор жанры. *--- эволюциянең югарыгы баскычларында да инь-ян багланышлары гармониясен саклау кирәклеге Нух пәйгамбәр риваятендә иңдерелгән.* Р.Сафин. *Себер татарларының риваятьләре бу юлбасарның үлемен бөтенләй башкача – чын тарихка якынрак рухта сурәтлиләр.* Ф.Урманче. *Утызынчы елларда халык әкият-риваятеннән, бәетеннән өлге, оеткы алып, фаҗигале яисә җырлы-биюле әсәрләр иҗат ителә.* Т.Галиуллин

РИВАЯТЬЧЕ *и.* Риваять сөйләүче. *Чөнки минем атам да, бабам да риваятьчеләр булган.* Р.Батулла

РИГАЯ *и. гар. иск.* 1) Кайгырту, карау, мәрхәмәт, игътибар. *Безнең шәкерткә булган ригаябезне сизеп, ул [юл остасы] да тегенең сырхаулыгына вә начар эшләвенә күз очтан гына карап үтә иде.* Ш.Камал

2) Олылау, ихтирам, хөрмәт. *Аның [Зиннәтнең] соргылт күзләрендә һәм шактый озынча ябык битендә аны тыңлаучыга да, ул телгә алган бүтән кешеләргә дә яхшы теләк һәм ригая яктысы балкып тора иде.* Г.Бәширов. *Бер сүз әйтмичә, йөзенә ригая елмаюы чыгарып тора башлаган.* Х.Камалов

РИГАЯ́ ИТҮ *ф.* 1) Игътибар итү, әһәмият бирү. *Баланың җан бирүе беленгәч, Шәфигулла агай тавышсыз гына җылап җибәрде дә, моңлы күз яшьле тавыш белән, көен бик ригая итмичә генә, «Күмү маршы» җырларга тотынды.* Ф.Әмирхан

2) Ихтирам итү, хөрмәт күрсәтү, яхшы мөгамәләдә булу. *Без совет законнарын ригая итәбез. Әмма җәберләү турында, Алла шаһит, Локман, яла ягу бу...* Т.Гыйззәт. *Карт алаша буразнаны бозмый – карт кеше тәртип кагыйдәгә ригая итүчән була, теләсә ничек башсызланмый, дигән мәгънәләрдә әйтелә.* Н.Исәнбәт

РИГАЯ́ КЫЛУ *ф. к.* **ригая итү**. *--- әүвәл сәлам бирмәде, бу кадәр халыкны баса-баса кичте, картларга хөрмәт итмәде, картлардан югары чыгып утырды – олыларымызны ригая кылмады, – диделәр.* К.Насыйри. *Ислам дине кешеләр арасында хаклар билгеләп, шуларны ригая кылырга боерган булса, һәртөрле хайваннар, кошкортлар һәм җанварларның хакларын да җиренә китерүне лязем итә.* Р.Фәхреддин

РИГАЯЛЕ *с.* **1.** Кайгыртучан, игътибарлы. *--- хөкем ителүче кешенең йөкле булуын искә алып, суд Гөлчирә Габбасовага карата ригаяле булырга тырышты ---.* Ф.Хөсни

2. *рәв. мәгъ.* Игътибар итеп, игътибар күрсәтеп. *Лектор аның [Ирекнең] сүзләренә ригаяле елмаеп кына куйды һәм, әңгәмәнең беткәнен белгертеп, портфеленә тотынды.* Х.Камалов

РИГА́ЯТӘН *рәв. гар. иск. к.* **ригаяле 2.**

РИГАЯТЬ *и. гар. к.* **ригая**

РИГОРИЗМ *и. лат. кит.* 1) Нинди дә булса принципларны яки берәр төрле карашны үткәрүдә чамадан тыш таләпчәнлек

2) Әхлак кагыйдәләрен үтәүдә, тәртиптә, дини таләпләрне саклауда чамадан тыш таләпчәнлек

РИГОРИСТ *и. рус кит.* Ригоризм тарафдары

РИДА *и. гар.* Ир-ат хаҗиларның ихрамда вакытта гәүдәләренең өске өлешен бөркәү япмасы. *Гәүдәнең өске өлешен каплап торганы рида дип, аскы өлешен каплап торганы изар дип аталган.* Кызыл таң

РИДВАН *и.* 1) *диал.* Көлтә, салам, печән һ.б.ш. ташыганда кулланыла торган зур арба. *Көлтәне, үгез җигеп, ридван белән әвенгә ташый идек.* Ватаным Татарстан

2) *иск.* Ерак юлга чыкканда кулланыла торган зур карета. *Кинәт шул арада безнең өй каршына пар ат җиккән ридван килеп туктады.* Н.Дәүли

РИДИКЮЛЬ *и. фр.* Хатын-кызлар йөртә торган кечкенә сумка. *Хатын-кыз кулында – хуҗалык сумкасы, ридикюль, целлофан капчык, азык-төлек ятьмәсе.* М.Юныс. *Тәгъзимә Яббаровна ак миниатюр ридикюлен ачып, шыртлатып япты.* Г.Ахунов. *Кыз, ридикюленнән ачкыч алып, ишекне ачты, иркен генә квартирага үттеләр.* Ф.Садриев

РИЕ́ЛТОР *и. ингл.* Күчемсез мөлкәтне сату-алуда арадашчы. *Фатирны риелторлар саткан*. Идел

РИ́ЗА *и. гр.* Баштан киеп кую өчен кисеме булган, күкрәкне һәм арканы каплап торган христиан рухание киеме; шулай ук Мәскәү патшаларының көмеш белән бизәлгән зиннәтле киеме

РИЗА́ *хәб. сүз гар.* 1) Канәгать, канәгать булу. *Байлыгына кызыгып ризалыгын бирде дип уйлама. Мин ипи белән бәрәңге ашап яшәсәм дә риза.* Ф.Яруллин. *Мин аткан укның, мин төзәгән йөрәккә тимичә, бумеранг булып үземә кайтуына һич кенә дә риза түгел.* Т.Миңнуллин

2) Нәрсә дә булса эшләргә, башкарырга ризалык бирү, карышмау, күнү; әзер тору. *--- гомерем буена битем белән җир ертырга, чәчем белән ишегалдыгызны себерергә риза. Тик безне аерып мыскыл итмәгез.* Т.Гыйззәт. *– Була. Риза, – диде Сәгыйть, үз-үзенә ышанган ныклавыш белән.* Н.Фәттах

РИЗА́ БУЛУ *ф.* 1) Нәрсәнедер эшләргә күнү, каршы килмәү; ризалыгын белдерү. *Фәридә үзе таныды, шуңа риза булып, имзасын куйды.* Т.Галиуллин. *Мин сиңа беркайчан да бер генә авыр сүз дә әйтмәм, тик минем белән йөрергә риза гына бул!* В.Нуруллин

2) Булганына канәгать булу, артыгын таләп итмәү

РИЗА́ ИТҮ *ф. к.* **ризалату**. *Мәет янында утыруыбыз үзебез өчен булгач, йорт хуҗасының: «Бу кешеләрне ничек итеп риза итик икән», – дип борчылып йөрүе урынсыз.* Ислам

РИЗАЛАНДЫРУ *ф. сир. к.* **ризалату**. *Бәлки, ничек тә ризаландырып булыр әле!* Г.Исхакый

РИЗАЛАТУ *ф.* 1) Үтенеп, сорап, нәрсәне дә булса эшләргә күндерү. *– Габделлатыйф хан Мәскәү зинданында бит әле, олуг кенәз Василий ризалашыр микән? – дип шиген белдерде Шаһ-Хөсәен. – Аны ризалату синең җилкәгә төшәчәк инде, Сәед.* М.Әмирханов. *Яучы такмаклары кыз ягына егет ягының ният-тәкъдимен үзенчәлекле һәм тәэсирле итеп җиткерүгә, сүз «кодрәте» һәм кинаяле тел белән ризалату һәм килешүгә хезмәт иткәннәр.* М.Бакиров. *Аннары инде, Румия больницадан чыккач, аны бәхилләтү, эшне күпертмәскә ризалату кыен булмаячак. Беренче җил-давылны гына хәвефхәтәрсез уздырырга иде.* М.Маликова

2) Кем белән булса да алыш-бирәш мәсьәләсендә бурычлы булып калмау, эшләгән эше өчен канәгать итү, бәхилләтү, алачак-бирәчәкләр калдырмау. *Ул төнне, әтине ничек ризалату, акчаны ничек күбрәк табу турында уйланып, беренче әтәчләргә хәтле йоклый алмый яттым.* Г.Бәширов

3) Нинди дә булса эшкә кемнеңдер ризалыгын алу, рөхсәтенә, килешүенә ирешү. *Алар бу сөйләшүдә бер-берсенә вәгъдә бирергә тиешләр, иртәгә яучы җибәрү, әти-әнине ризалату, өйләнешү турында, юлга киртә булган Исмәгыйль турында сөйләшергә тиешләр.* М.Җәлил. *--- әнисен ризалату өчен, никадәр вакыт кирәк булды бит. Әгәр бүген укырга алсалар, бүтән көннәрдә атларны да көтүдән иртәрәк алып кайта башлар[га кирәк булачак].* В.Нуруллин

Ризалата бару һәр очрак саен ризалату; һәрберсен ризалату

Ризалатып бетерү Тулысынча ризалату; барысын да ризалату. *Бөтенесен ризалатып бетерәләр, мин ризалашмыйм.* Ватаным Татарстан

Ризалатып карау Ризалатырга омтылу. *Ул чагында... төгәл нишләргә икәнен белмәсәм дә, икенче, өченче, унынчы тапкыр ризалатып карау иде планда.* Х.Ширмән

РИЗАЛАШУ *ф.* 1) Бер-береңне аңлап, уртак фикергә килү, килешү. *– Кыскасы, Вера Павловна, операцияне мөселманча дога белән үткәрүгә сез ничек карыйсыз? – Ри-и-за-а... Вераның шулай бик тиз ризалашуы көтелмәгәнчәрәк килеп чыкты, аптырабрак калдым димме.* М.Әмирханов. *Шулай да Нурия белән ризалашу авыр иде аңа [Гөлзиләгә]. Ни өчен? Монда ул ачык кына җавап бирә алмады.* М.Кәбиров

2) Сатулашып, әйбернең бәясе турында килешү

3) Ярәшү, өйләндерү яки кызын бирү турында сөйләшеп кую, килешү. *Шуннан кыз белән дә ризалашып, туй ясарга уйлыйлар.* Әкият. *--- ефәк чуктай кызым кемгә дә ярарлык. Әйдә, хәерлегә була күрсен. Яшьли сөешеп кавышканга ни җитә дип кенә ризалашу, ярәшү иде.* М.Хәсәнов

Ризалаша бару Акрынлап-акрынлап фикерен үзгәртә барып ризалашу

Ризалашып бетү Тәмам, тулысынча ризалашу. *Әгәр дә мин, өздереп, җыр менә шушы инде ул, дисәм, минем белән килешеп, ризалашып бетмәүчеләр дә аз булмас иде.* Г.Ибушев

Ризалашып кую Алдан ризалашу; көтмәгәндә ризалашу. *Мин дә шул принциптан чыгып, ярар, шулай булсын, дип ризалашып куям.* Ватаным Татарстан

РИЗАЛЫК *и.* 1) Риза булу, күнү. *Сабый бала нә кылырга белми, анасы теләге белән ризалыгын белдереп, вакбак баш какты.* М.Хәбибуллин. *Казан хөкүмәте һәм аксөякләр ризалыгы белән ул [Сафагәрәй] хан итеп игълан ителә.* Д.Сабирова. *--- ташландык хәлдәге чишмәне бик кызгана һәм тирәягын кулыннан килгәнчә җыештыра. Су анасының ризалыгын алу өчен, букчасындагы икмәк кисәгенең яртысын да чишмәгә сала.* Татарстан чишмәләре

2) Рөхсәт. *Аннан [Чукай сәүдәгәрдән] ризалык алгач, Каратун --- Нугай юлы һәм Чулман аръягындагы мөселманнарны чукындырырга куша.* Р.Батулла. *Урта мәктәпне алтын медальгә тәмамлагач, картайган ата-анасы ризалык бирмәсә дә, Мәскәүгә, корыч институтына укырга керә.* Ш.Янбаев

РИЗАЛЫКСЫЗ *рәв.* Рөхсәт сорамыйча, рөхсәттән башка; үзара килешмичә. *Октябрь инкыйлабына кадәр Идел һәм Урал буе татарларында өйләнешү-кияүгә чыгуның өч төре формалашкан булган: 1) кыз ризалыгы белән яки ризалыксыз, аны урлап өйләнешү; 2) кызның булачак кияве йортына үзе китүе («ябышып» яки «качып чыгу»); 3) алдан килешеп («ярәшеп – яучылап») өйләнү.* Р.Фәйзуллина

РИЗАСЫЗ *с.* **1.** 1) Риза булмаган, канәгатьсез, килешмәгән. *Ризасыз кешеләрне җыеп, Зәйтүнә түти яңадан мулла абзыйга барса да, эш хәл ителгән иде инде.* Р.Батулла

2) Ризасызлыкны белдергән. *Ул урынныннан бик ризасыз кыяфәт белән кузгалды да чыгып китте.* Х.Камалов

2. *рәв. мәгъ.* 1) Риза булмыйча, канәгать булмыйча. *Ләйлә, үзенең кыяфәтеннән ризасыз калып, эченнән генә, «Үтте дә китте яшьлегем» җырын шыңшый башлады.* Ф.Яруллин

2) Ризасызлык белдереп, теләмичә. *Аның тавышы ризасыз, хәтта кырыс яңгырады.* М.Маликова. *Ризасыз гына буйсынды әмергә Каменский.* С.Шәрипов

РИЗАСЫЗЛЫК *и.* Канәгатьсезлек; канәгать, риза булмау. *Фаягөлнең бу сөйләшүдән ризасызлыгы чыраена бәреп чыкты: бите, әлерәк кенә алсуга кабынган бит алмалары сулды, агарып китте.* Г.Ахунов. *Бригадир әледән-әле ризасызлык белдерде, бертуктаусыз ашыктырып, кызулап йөрде.* Н.Фәттах. *Остазыбыз юри тынып калды. Ул безнең шаулашуны, ризасызлыкны көтә иде.* Р.Батулла

РИЗЫК *и. гар.* 1) Ашарга яраклы теләсә нинди азык. *Аллаһы боерса, шул наратлык безне коткарыр. Урманда малларга ризык җитәрлек. Эш коралларын алырбыз.* С.Зыялы. *Төн йокысын йокламаса йокламый, әмма ризыгын эшкәртү әмәлен белә авыл кешесе...* Г.Галиева

2) Пешереп әзерләнгән, куллану өчен әзер булган ашамлык; нигъмәт, икмәк (*5 мәгъ.*). *Кулыннан килмәгәне юк. Ризыкны телеңне йотарлык итеп пешерә.* Г.Ибраһимов. *Әтисе дә, әнисе дә күз яше белән юл хәстәрен күрәләр, ризык әзерлиләр иде.* М.Мәһдиев

3) *күч.* Яшәү, көн күрү чарасы, яшәү чыганагы, икмәк (*6 мәгъ.*); хезмәт хакы. *Азган татар сезнең ише*

козгыннарга иң татлы ризык инде ул, атакай. Т.Миңнуллин. --- *артистлар дөньякүләм таныла, исемнәр, бүләкләр ала. Алар турында язып, менә сезнең кебек күпме язучы-журналист халкы ризык җыя.* М.Галиев

◊ **Ризыгы чәчелү** Туган иленнән читкә чыгып китүенең сәбәбен тәкъдир кушуы белән ризыгының төрле җирләргә таралуына бәйләүдән туган тәгъбир. **Ризык бару** Ашый алу, ризык үтү. *Ата-ана менә ничә көн инде үзләре ачлар. Хәер, аларга ризык бармас та иде, чөнки күз алларында һаман төпчекләре Рәисә, аның тилмереп үлүе тора*. Ф.Бәйрәмова. **Ризык бетү** 1) Кая да булса китеп бару сәбәпле калдырган урынына кире кайту мөмкинлеге калмау; 2) Үлеме җитү. **Ризык йөртү** *к.* **ризык тарту**. *«Сибелә чәчәк» җырын көйли-көйли Сибелгәнбез ерак-еракка. Мөһаҗирлек мәллә канга сенгән, Ризык мәллә шулай йөретә?!* Ә.Рәшит. **Ризык киселү** *к.* **ризык бетү**. **Ризык талымлау** Аш-суны сайлаучан булу, артык талымчанга әйләнү, нәзберекләнү. *Якуб картның яшьләрнекенә бирешмәслек дип уйлаган таза ашказаны, соңгы көннәрдә, яңа төрле аш сорапмы, өстәлдәге ризыкны талымлый башлады*. Р.Сибат. **Ризыктан калдырмау** Булган, әзерләгән ризыгы белән һәрвакыт уртаклашу. --- *барган әти-әнисен, ягъни биатасы белән бианасын ташлап бетерми иде. Таба ашы пешерәме, гает көннәре буламы, я башка бәйрәмме – тәмле ризыктан калдырмый иде аларны*. Ф.Сафин. **Ризыктан олы түгелсең** Аш-чәй вакытында килеп кергән кеше табынга утырудан баш тартканда әйтелә. **Ризыктан өстен булу** Табынга чакыруны игътибарсыз калдыру, чакырулы мәҗлескә бармый калу. *Ризыктан өстен булу ярый торган эш түгел ул, балам. Рәнҗешен кая куярсың?* Ә.Баян. **Ризык тарту** Каядыр чит җиргә китүне тәкъдир белән бәйләү, кешене ашыйсы ризыгы йөртә, дигән ышанудан туган тәгъбир. – *Кеше үзе китми ул, аны ризык тарта, ризык! – ди торган иде.* Г.Ибраһимов. *Кошлар очып җитмәс җиргә, Җилләр исеп җитмәс җиргә, Ризык тарта, диеп, ул барыр*. Г.Афзал. **Ризык читкә язган** Туган иленнән читтә яшәвенең сәбәбен тәкъдир кушуы белән бәйләүдән туган тәгъбир. *Ризык читкә язып кына китермәгән булса ярый инде, гомерендә бер мәртәбә авылыннан чыкмаган кеше алты мең чакрымга кил, имеш.* Г.Исхакый. *Ризык читкә язса язсын, туфрак читкә язмасын!* Н.Исәнбәт

РИЗЫКЛАНДЫРУ *ф.* Ризык бирү, ризык белән тәэмин итү; ашату-эчертү, туендыру. *Яу, яу, яңгыр, яу, яңгыр! Син безне ризыкландыр ---*. Такмак. *Йосыф белән Мәрьям дә, бил турайтып ял итәсе урында, үзләрен генә түгел, туган-үскән җирләрен мәңгегә ташлап киткән балаларын да ризыкландырырга мәҗбүр ителеп, ызан белән түтәлдән баш калкытмыйча интегәләр иде*. А.Гыйләҗев. --- *юлдашлары аны ике мәртәбә ризыкландырдылар*. А.Хәлим

Ризыкландырып килү Элек-электән, күптәннән бирле даими ризыкландыру

Ризыкландырып тору Даими, һәрвакыт ризыкландыру. *Газзәбану белән Зөлкамал көн саен чиратлашып килеп ризыкландырып тордылар*. Г.Галиева. --- *Җир-ана планета авыл хуҗалыгы ресурсларының бик аз өлешен генә файдаланган кешелекне элеккечә үк ризыкландырып тора*. Мәдәни җомга

РИЗЫКЛАНУ *ф.* Ашау-эчү, азыклану, туклану, туену. *Минем, дигән була, кеше хакы ашап ризыкланыр хәлем юк.* Ш.Камал. *Кайда нәрсә туры килә, шуның белән ризыкланып, көндез кырларда, чокыр-чакырларда посып ята-ята, төнлә-төнлә генә үзебезнең якларга кайтып җиттем*. В.Нуруллин

Ризыкланып алу Бераз тамак ялгау, тиз генә ризыклану

Ризыкланып йөрү Билгеле бер вакыт аралыгында ризыклану, шактый вакыт ризыклану. *Әйдә, бездә ризыкланып йөрегез хәзергә*. З.Зәйнуллин

Ризыкланып калу Ризыкланырга өлгерү

Ризыкланып тору Һәрвакыт, гел ризыклану; хәзерге моментта ризыклану. *Мондый кызу эш вакытында чәйне дә көненә бер генә тапкыр эчәләр, бер кадак арыш икмәге белән генә ризыкланып торалар*. М.Галәү

Ризыкланып утыру *к.* **ризыкланып тору**. *Тәмле ашарга яратучы кияү Рамазан алдына асрау Гайнинең, ул аш сораган саен, чемодан чыгарып куюы, Рамазанның чемодан ачып ризыкланып утыруы шәхсән минем тәэсиргә комачаулык итмәде*. Л.Минаева

РИКОШЕТ *и. фр.* Очып килгән берәр әйбернең (мәс., ташның), нинди дә булса өслеккә бәрелеп, юнәлешен үзгәртеп очуы. *Пуляларның күбесе читкә очалар, өч-дүрте генә капкачка тиеп рикошет ясап үтте*. И.Хуҗин

РИКША *и. яп.* 1) Кеше утыртып йөртү, йөк ташу өчен, кеше тартып йөртә торган ике көпчәкле кечкенә арба; велосипедлы коляска

2) Шундый арбаны тартып йөртүче кеше үзе

РИМЛЫ *и.* 1) Борынгы Рим империясе гражданы. *Римлылар, бигрәк тә ир-атлар, христианнарга каршы баш күтәрәләр*. М.Хәбибуллин. *Гөлчәчәкне роза дип йөртү борынгы римлылардан калган, диләр*. Безнең йорт

2) Италиянең Рим шәһәрендә яшәүче кеше

РИНГ *и. ингл.* 1) *спорт* Бокс һәм башка кайбер көрәш төрләре өчен канат белән уратып алынган мәйданчык. *Боксны калдырып, әкренләп сәяси «авырлык» җыя башлады бугай дип уйларга да өлгермәдек, Кличконың киләсе елның язында тагын рингка чыгачагы мәгълүм булды*. Шәһри Казан. *Ул инде рингта унөч очрашу үткәрде һәм унөчендә дә җиңү яулады*. Татарстан яшьләре

2) Күргәзмәдә нәселле этләрне күрсәтү мәйданчыгы

3) Тимераякта шуу өчен ясалма боз түшәлгән өслеге булган бина

4) Роликлы тимераякта йөгерү өчен асфальтланган мәйдан

РИНГТОН *и. ингл.* Кесә телефоннарында сигнал урынына кулланыла торган аерым җырдан, көйдән өзек. *«Иң яхшы рингтон» номинациясендә Ләйсән Гыймаева һәм Булат Бәйрәмовның «Җанашым» җыры җиңү яулады.* Кәеф ничек?

РИНИТ *и. гр. мед.* Борынның лайлалы тышчасы ялкынсыну авыруы. *Күзәтүләрдән билгеле булганча, төп төркемгә караган балалар тын алу юллары – ринит, фарингит, бронхит, ларингит кебек чирләр белән ешрак авырыйлар*. Фән һәм тел

РИНОЛО́ГИЯ *и. гр. мед.* Медицинада борын авыруларын өйрәнә торган бүлек. *Кәлимуллиннарның олы улы Харис Балтачта алдынгы механизатор булып лаеклы ялга чыга, Зиннурлары – Татарстанның атказанган табибы, РФ ринология җәмгыяте әгъзасы, республикабызның көньяк-көнчыгыш регионында танылган отоларинголог, дәрәҗәле шәхес*. Безнең гәҗит

РИНОПЛА́СТИК *с. мед.* Ринопластика белән бәйләнгән

РИНОПЛА́СТИКА *и. гр. мед.* Пластик хирургия методы белән борынның формасын үзгәртү, зарарланган булса, элекке хәленә кайтару операциясе

РИНОСКОП *и. гр. мед.* Борын, тамак куышлыгын карау өчен кулланыла торган медицина көзгесе

РИНОСКОПИ́Я *и. гр. мед.* Борын, тамак куышлыгын риноскоп ярдәмендә тикшерү методы

РИПЕС *и. лат. бот.* Крыжовникчалар семьялыгыннан вак сары чәчәкле, кара, көрән яки сары җимешле, кайбер якларда табигый киртә булып кулланыла торган куак үсемлек; юләр карлыган; *русчасы:* **репис**

РИСАЛӘ *и. гар. иск. кит.* Мәкалә, кечкенә китап, брошюра. *Бу рисалә Ибне Фадлан сәяхәтнамәсенең үзе түгел, бәлки Якут Хәмәви тарафыннан Болгар бүлегендә сәяхәтнамәдән күчергән беркадәр җөмләләр генәдер*. М.Хәбибуллин

РИСВАЙ *рәв. фар.* Мәсхәрә, хурлык. *Балаңны ташлау ил каршында оят, рисвай саналсын*. М.Маликова

◊ **Рисвай галәм булу** Адәм мәсхәрәсенә, дөнья хурлыгына калу, кеше каршында оятлы булу. *Кыйналганнан бигрәк, рисвай галәм булудан кан басымы күтәрелгән тәмуг мәчесе укшый-укшый ятты да акча косарга тотынды*. З.Мәхмүди. **Рисвай галәм итү** Хурлыкка калдыру, мәсхәрә итү. **Рисвай кылыну** Хурлыкка калдырылу. *[Колшәриф хәзрәтләре] «Хаклык өстен чыгар, җаһилләр-наданнар рисвай кылыныр һәм хөкем ителер», – дип, изге сүзләрне мәҗлестә янә бер тапкыр кабатлады*. М.Хәбибуллин

РИСВА́Й БУЛУ *ф.* Хурлыкка калу, яман аты чыгу. *Хатыныгызның, суд юлларында йөреп, мир алдында рисвай буласы килми*. М.Маликова. *Бөтен авылга рисвай булдык бит, кызым*. Г.Гыйльманов

РИСВАЙЛЫК *и.* Мәсхәрәле, хурлыклы хәл. *Моны туйдан элек хәбәр итәргә кирәк иде, бу – рисвайлык миңа!* М.Акъегет. *Ул рисвайлыкка бу кыз сәбәп булмый, ата-анасы була ич*. Г.Исхакый

◊ **Рисвайлыкка төшү** *к.* **рисвай галәм булу**

РИСТАН *и. рус гади с.* 1) «Арестант» сүзеннән фонетик үзләшеп кабул ителгән, шул ук мәгънәне белдерә торган сүз. *Сибгат ага Хәким, ярым шаяртып: «Ач торырга күнеккән ристан, каторжан», – дип әйтә торган иде*. Р.Мостафин. *Урамда малайлар мине ристан малае дип тотып кыйнагач, өйгә кайтып җылый идем*. М.Маликова. *Утыз сигезенче елны моны да ристан иткәннәр икән*. С.Шәрипов

2) Ачулану, ризасызлык белдерү сүзе. *Чаялыгы белән даны таралган Ситдыйк Мөнәвәрәсе: «Нигә минем хезмәт көннәремне урлап калдың, аксак ристан!» – дип, хисапчы Сабирның якасына ябышты*. А.Расих. *Гөлсем башта аптырап калды, аннан соң ачусыз гына кычкырырга тотынды: – Нишләвең бу, ристан?* Н.Фәттах

РИТМ *и. гр.* 1) Нинди дә булса элементларның тигез үлчәү белән чиратлашып килүе. *Таш урамнар аша эчкәрәк керсәң, кечкенә генә бер электр станцасы йөрәк тибешедәй тигез ритм белән бертуктамый эшләп тора*. А.Алиш. *Татар поэзиясенең егерменче елларда язылган үрнәкләрендә, кайбер юлларның кыскартылган яки озынайтылган булуына карамастан, һәркайсының нигезендә билгеле бер ритм бар*. Х.Туфан. *Ишетәм: тышта шыбырдап яңгыр ява, тигез ритм белән шаулап ява*. М.Мәһдиев

2) Нәрсәнең дә булса билгеле бер эзлеклелектә барышы. *Нәкышнең геометрик рәсеме интерьерның туры почмаклы архитектура формалары белән, аларның ритмы белән ярашып килә*. Г.Вәлиева

РИ́ТМИК *с. к.* **ритмлы**. *Әмма Тукай шигырененең иң гүзәл ягы --- ритмик музыкальлек югала. Юкса, Тукай шигырьләренең барысы да саз аккомпанементына көйләнгән*. Н.Хисамов. *Такташ шигырьнең ритмик төзелешен бетерергә димәсә дә, аны сөйләүгә җайлаштыру, стиль ягыннан яңарту турында гына сүз йөртсә дә, футуристлар, имажинистлар моны башкача аңладылар: алар, гомумән ритмик төзелеш бетәргә тиеш, дип чыктылар*. Х.Госман

РИ́ТМИКА *и. гр.* 1) Ритмның системасы һәм характеры. *Әлеге шәкли эзләнүләр чынлыкта шигъри бизәкләрне, алымнарны үстерүгә, чагыштыру, рифма, ритмика, авазлар яңгырашы байлыгын арттыруга мәгълүм өлеш кертә*. Т.Галиуллин. *Аның сабый күңеленә, аңына җыр-шигырьнең мәгънәсеннән бигрәк моңы, көе, ритмикасы барып ирешә*. Р.Миңнуллин

2) Ритм турында тәгълимат (мәс., музыкада, биюдә, шигырьдә һ.б.)

3) Аерым бер ритм белән башкарылган хәрәкәтләр

РИ́ТМЛАШТЫРУ *ф.* Нәрсәне дә булса ритмга салу, ритмлы итү

Ритмлаштыра бару Эзлекле рәвештә ритмлаштыру

Ритмлаштыра килү Электән үк ритмлаштыру белән шөгыльләнү

Ритмлаштыра төшү Тагын да ритмлырак итү

Ритмлаштырып тору Һәрвакыт, гел ритмлаштыру

Ритмлаштырып чыгу Башыннан ахырына кадәр ритмлаштыру

РИ́ТМЛЫ *с.* Ритмга салынган, ритмлашкан тигез үлчәүле, билгеле бер ритмга көйләнгән. *Без әйләнә-тирәбездәге төрле ритмлы үзгәрешләрне күзәтәбез: яз, җәй, көз, кыш, --- тән температурасы үзгәрү һ.б.* Р.Гыйльметдинова. *Такт күмәк көчкә бердәмлек биргән, эшне оештыруга*

булышкан, күпмедер җиңеллек китергән. Хезмәтнең һәр төренә кулай ритмлы җыры булган. Ф.Хатипов

РИ́ТМЛЫЛЫК *и.* Ритмга салынган булу, ритмлы булу. *--- шигырь юлын йөгерек итүдә бер юл эчендә үк ритмлылык тудыру да уңышлы кулланыла, җырның яңгырашын, аһәңен бизи.* К.Миңнуллин

РИТМОПЛА́СТИКА *и. гр.* Гәүдәнең дөрес, гармоник, матур хәрәкәтләнү өчен физик күнегүләр системасы. *«Нур» студиясендә укыту өч юнәлештә алып барылачак: актёрлык осталыгы нигезләре, ритмопластика һәм музыкаль тәрбия.* Безнең гәҗит

РИ́ТМСЫЗ *с.* **1.** Ритмга салынмаган, билгеле бер ритмга көйләнмәгән. *Ритмсыз музыка булмаган кебек, шигырьне дә аннан башка күз алдына китерү кыен.* Татар әдәбияты

2. *рәв. мәгъ.* Ритмга салмыйча, билгеле бер ритмга нигезләнмичә. *Әгәр чит кеше аның күкрәгенә колын куйса, һичшиксез, йөрәкнең ватык молотилка шикелле тигезсез, ритмсыз эшләгәнен сизәр иде.* М.Мәһдиев

РИ́ТМСЫЗЛЫК *и.* Ритмсыз булу, ритмга салынмаган булу

РИ́ТОР *и. гр. тар.* 1) Борынгы Грециядә, Римда: ораторлык сәнгатенә өйрәтүче, риторика укытучысы

2) Иске Россиядә: руханилар семинариясенең риторика классында укучы

РИТО́РИК *с.* 1) Риторика кагыйдәләренә буйсынган, риторикага нигезләнгән

2) Сурәтләүдә күтәренкелек, эмоциональлек белән аерылып торган. *--- поэманың байтак кына йомшак яклары да күренә. Акланмаган озынлык күзгә бәрелә, тасвирчылык, риторик купшылык үзен сиздерә.* Р.Фәйзуллин. *--- автор укучыны текстның башлам өлешеннән үк әзерләргә керешә. Анда ул шәкертләр адресына риторик характердагы гомуми сораулар юллый.* В.Гарифуллин. *Гамил Афзалның «Чәчәкләр бирегез» шигырендә аерым кешегә игътибарлы булуны, кеше кадерен ул исән чакта белдерүгә теләкне чагылдырган бик матур риторик өндәү мисаллары бар.* Фән һәм тел

3) Сөйләүченең шартлы адресатка мөрәҗәгать итүеннән гыйбарәт, җавап таләп ителмәгән, сорау, өндәү формасындагы. *--- табигать күренешләрен эзлекле рәвештә, эзмә-эз тасвирый алым белән күз алдына бастырган шигырьләргә тартым, җавап таләп ителми торган риторик эндәш («Күрәмсез, дустларым, көз килде...») белән башланып киткән тезмә күңелдә авыр, басынкы хисләр уята.* Т.Галиуллин. *Сөйләмнең аһәңен, эмоциональ тонын баетып килүче риторик сорау җөмләләр мәкальләрне формалаштыруда гаять уңышлы файдаланыла.* Г.Нәбиуллина. *Сөйләмнең эмоциональ яңгырашын баету өчен кулланыла торган алымнар риторик фигуралар була. Бу төркем фигураларның рәтенә риторик мөрәҗәгатьләр, риторик эндәшләр һәм өндәүләр керә.* Н.Гәрәева

РИТО́РИКА *и. гр.* 1) Сүзгә осталык, ораторлык сәнгате һәм аның теориясе. *Башта чичәннең турыдан-туры шәкертләре санала алырлык, үзләре дә рухы-күңеле белән аның фикердәше, теләктәше булган, үзләре дә татар риторикасының элгәрләре саналган шәхесләребезнең фикерләренә мөрәҗәгать итик.* И.Низамов

2) Төзек, матур сөйләмгә, ораторлык сәнгатенә өйрәтү буенча филологик дисциплина. *Гарәп телен һәм әдәбиятын, логика һәм рифорикаңы (сүз сәнгате), гарәп һәм башка халыкларның хәрби сәнгатен өйрәнә.* Ш.Рәфыйков

3) *күч.* Тышкы яктан эмоциональ яңгырашлы булып та, эчтәлексез, буш сөйләм. *М.Крыймов, Ә.Түрәй, Г.Теләш, А.Әсгат, И.Йосфи кебек шагыйрьләр мирасында шигъри дәртне – риторика, гомумиләштерүне – буш сафсата, лиризмны коры хәбәр алыштырган мисаллар тулып ята.* Т.Галиуллин. *Шундыйларга, мәсәлән, «Ак сөяккә», --- «Мәҗүсиләр» кебек шигырьләрне кертергә мөмкин. Алар күтәрелгән темалары белән кызыклы гына. Әмма дә ләкин образсыз юллар, гади риторикадан уза алмау аркасында, бөтен куәткә яңгырый алмыйлар.* Р.Миңнуллин. *Кай урында Фәниярның уйлану-фикер йөртүләре публицистик риторикага әйләнеп китә. Алгы планга язучы калкып чыга.* С.Хәкимова

РИТУА́Л *и. лат.* 1) *дини* Нинди дә булса дини йоланы үтәү тәртибе. *Йола-җыр текстлары исә нәкъ менә борынгыларның хуҗалык эшчәнлегенә һәм көнкүрешенә бәйләнешле әлеге йола, ритуаллар җирлегендә барлыкка килгәннәр.* М.Бакиров

2) Гореф-гадәт буенча килә торган яки берәр нәрсәне башкаруда кабул ителгән тәртип-кагыйдәләр; церемониал. *Андый ябык дини оешмага керү процедурасы – инициация – каты тикшерү һәм куркыныч ритуаллар аркылы башкарылган.* Р.Сафин

3) *сөйл.* Гадәт, тәртип. *Һәркөн йокларга алдыннан урамда йөреп керүне ул ритуал дәрәҗәсенә җиткерде*

РИТУАЛЛАШУ *ф.* Ритуалга әйләнү, ритуал булып урнашу

РИТУА́ЛЬ *с.* Дини йола буенча үткәрелә торган; дини йолага бәйләнеше булган. *Йола, ритуаль уен һәм бию җырлары турында сөйләгәндә, без барыннан да элек әнә шул, бик борынгыдан килгән мифологик карашларга нигезләнергә тиешбез.* Ф.Урманче. *Таш гасырында кыя-ташларга төшерелгән ритуаль рәсемнәрне галимнәр хәзерге иң оста, иң атаклы рәссамнарның рәсеменә караган кебек кызыксынып карыйлар.* Р.Әхмәтьянов

РИ́Ф I *и. нем.* 1) Суднолар йөрү өчен куркыныч тудырган, су асты яки су өстенә дә чыгып торырга мөмкин булган кыя. *Күк төсендәге зәңгәрсу балыкчыклар – попугай балыклар – мәрҗән рифы тирәсендә туенып йөриләр.* Н.Плавильщиков

2) *күч. кит.* Нинди дә булса беренче карашка сизелмәгән куркыныч, кинәт килеп чыгарга мөмкин булган каршылык

РИ́Ф II *и. голл.* Җилкәннең кырыйлары буйлап сузылган тишекләр яки элмәкләр (көчле җил вакытында шул элмәкләргә киертелгән арканны тарттырып, җилкәнне җыерып, мәйданын кимәтү өчен кулланыла)

РИ́ФМА *и. гр.* Шигырь юлларында соңгы өлешләрнең охшаш яңгырашы, аваздаш кабатлаулар; кафия. *Хәсән*

Туфанны ал син. Анда, ичмасам, рифма дисәң дә рифма! Иярүчеләре дә шундук табылды. Газиз Әхмәтов шундый рифмалар белән яза. Ф.Хөсни. *Әлеге строфа дүртенче һәм алтынчы иҗекләрдән соң килә торган кече цезуралы ун да тугыз үлчәве белән язылган, һәм анда ритм, рифма, паузалар гармоник рәвештә бербөтен итеп үрелгән.* И.Ногман

РИ́ФМАДАШ *с.* Аваздаш, бердәй яңгырашлы. --- *татар теленең сүз составы рифмадаш сүзләргә шулкадәр бай ки, әйтерсең рифмалашыр өчен генә барлыкка килгәннәр.* Х.Туфан. *Шагыйрь, илһамы ташып торганда, иң әүвәлге караламаларына әле тулысынча шигырь булып ук оешып бетмәгән беренче фикерләрен һәм шул фикерләрне йөртүче рифмадаш сүзләрне теркәгән.* Н.Юзиев

РИ́ФМАЛАНЫШ *и. әд.* Рифмаларның чиратлашу тәртибе, рифмалану характеры

РИ́ФМАЛАУ *ф. к.* **рифмалаштыру**. *Туксан яшьне үтеп үлгән әнисе дә – иҗади күңелле кеше, аның һәр сөйләмендә ниндидер халык мәкале, әйтеме була, үзе дә сизмәстән рифмалап та сөйләп җибәрә.* Кызыл таң

РИ́ФМАЛАШТЫРУ *ф.* Рифмага салу, бер-берсенә ятышлы сүз куеп рифма ясау; шигырь юлларындагы ахыргы сүзләрне рифмалы итеп китерү. *Кадыйров иптәш шигыренең бер куплетында «ясадык – ясадык» сүзләрен рифмалаштыра.* А.Алиш. *Җөмләләрне гади итеп кенә түгел, ничектер илһамланып, дүрт юлга бүлеп, рифмалаштырып язарга маташуымны күргән ул.* Р.Корбан. *Рух үзе сүзләрне рифмалаштыра, ритмга сала, фәлсәфәсен, строфикасын, башкасын таба, ягъни чын шигырьне яза.* Казан утлары

Рифмалаштыра бару Һәрберсен, булган берсен бер-бер артлы рифмалаштыру

Рифмалаштыра башлау Рифмалаштырырга тотыну

Рифмалаштыра төшү Тагы да әйбәтрәк рифмалаштыру

Рифмалаштырып бетерү Ахырга хәтле, тулысынча рифмалаштыру

Рифмалаштырып җибәрү Бераз, берникадәр рифмалаштыру

Рифмалаштырып карау Рифмалаштырырга тырышу

Рифмалаштырып кую Алдан рифмалаштыру; рифмалаштырылган хәлгә китерү. *Дәрес вакытында, укытучының кисәтүләрен колагына элеп тә бирмичә, иптәш кызы белән записка язышканда, очраклы рәвештә генә ике юлны рифмалаштырып куймасынмы!* Шәһри Казан

Рифмалаштырып тору 1) Бертуктаусыз рифмалаштыру

2) Әле, хәзерге вакытта, сөйләп торганда рифмалаштыру

Рифмалаштырып чыгу Башыннан ахырына кадәр, тулысынча рифмалаштыру

РИ́ФМАЛАШУ *ф.* Яңгырашлары аваздаш булып, рифма барлыкка китерү. *Белмим, «тораллар» белән «егалар» сүзләре никадәр уңышлы рифмалаша торгандыр?* Р.Батулла. *Строфада һәр дүрт юл рифмалаша, соңгы бишенче юллар үзара рифмалаша, хәтта бер үк сүз белән рифмалашырга мөмкин.* Ф.Тарханова

Рифмалаша төшү Күбрәк, әйбәтрәк рифмалашу

Рифмалашып бару Һәрберсе, булган берсе рифмалашу. *Ленар Шәехнең бу шигырендә фигыльләр һәрдаим башка сүз төркемнәре белән рифмалашып барса, ул бик ясалма килеп чыгар иде.* Идел

Рифмалашып бетү Барысы да рифмалашу

Рифмалашып тору Бик нык рифмалашкан булу. *«Әлдермеш»тә «Мамадыш» – «Париж» белән рифмалашып тора.* Фән һәм тел

РИ́ФМАЛЫ *с.* Рифмага салынган, рифмалардан торган. *Өч-дүрт яки биш яшьләрдә бала рифмалы сөйләмне ярата.* Х.Курбатов. *«Таң вакыты» шигыренең жанры автор тарафыннан «рифмалы нәсер» дип билгеләнә.* Әдәбият. *Аның үткәне, хәзергесе, киләчәге турында уйлары, хис-кичерешләре төз рифмалы юлларга әверелә.* Шәһри Казан

РИ́ФМАЧЫЛЫК *и. сөйл.* Эчтәлеккә игътибар итмичә, бары рифмаларның ярашуын гына максат итеп куйган, художество ягыннан йомшак шигырьләр язу шөгыле

РИХЛӘТ *и. гар. иск.* 1) Күчеш, күченеп китү

2) Үлем, фани дөньядан бакый дөньяга күчү. *Аллаһ аңа рәхимлерәк була: репрессияләрнең дулап кызган чагында гына Ризаэтдин бине Фәхреддин хәзрәтләре 1936 елда 77 яшендә дәрел фанәдин дәрел бәкага рихләт итә.* Р.Батулла. *Бар җиһанны бер итеп йөргән, гәүдәсе белән генә түгел, сүз әйтүеннән дә бүтәннәрне сытып китәрлек мондый мәһабәт затның шушы рәвешле рихләт кылачагын һичкем башына китермәгән иде.* Ф.Яхин

РИШВӘТ *и. гар.* Билгеле бер максатка ирешү өчен (гадәттә, законсыз эш эшләтү ниятe белән), урындагы кешене сатып алырга теләп бирелә торган акча яки кыйммәтле әйбер. *Ришвәт алу – нечкә нәрсә, прокурор аны җинаятьләр кодексы һәм хокук белеменә караганда да яхшырак белә иде.* Р.Мирхәйдәров. *Ришвәтне ничек төртү турында уйларга да өлгерми, түрәләр үзләре мөрәҗәгать итә: «Нәрсәң бар? Нәрсә алып килдең?».* Ә.Дусайлы. *«Күчтәнәч» күлдан-күлга күчү белән алыш-бирешне ясалачагын алдан ук белеп торган оперлар килеп кереп, урындагы кеше тарафыннан ришвәт алу очрагын документлаштырып куя.* Безнең гәҗит

РИШВӘТЧЕ *и.* Ришвәт алучы һәм бирүче кеше. *Исерек, ришвәтче Мүкән Кантун турындагы бу озын бәет беткәч, мәҗлес тынып кала.* Р.Батулла. *Мәсәлән, урам себерүче ришвәтче дә, коррупционер да була алмый бит.* Безнең гәҗит

РИШВӘТЧЕЛЕК *и.* 1) Ришвәт алучанлык, ришвәт алу гадәте. *Ирексезләү, сату-алу, ришвәтчелек белән дөнья тулган.* Р.Батулла. *Түрәләр ришвәтчелек белән көрәшүнең тагын бер ысулын уйлап тапкан.* Ватаным Татарстан

2) Ришвәтче булу. *Әйтик, ришвәтчелеккә каршы нинди дә булса комитет оештырыла икән, аның башына, гадәттә, иң хәтәр ришвәтче куела.* Татарстан яшьләре. *Ришвәтчелеккә каршы республика комиссиясе*

Татарстанның Арча, Кукмара, Лениногорск, Кайбыч районнарына чыгып, андагы хәлне тикшергән. М.Закирова

РИШЕЛЬЕ *и. фр.* Бизәкнең кырыйларын элмәкле җөй белән эшләп, бизәк сызыклары челтәрләп тоташтырылган һәм арада буш калган тукымасы кисеп алынган ажурлы чигү (киемнәрендә шундый чигү булган кардинал А.Ришелье исеменнән). *Ирекле чигүгә тамбур, ришелье, тыгыз итеп ак җептән чигү керә.* Йорт эшләре

РИШТӘ *и. зоол. диал. к.* **жеп суалчан**

РИЯ *и. гар.* Кешегә күрсәтү өчен генә эшләнгән, ихластан башкарылмаган эш, гамәл, икейөзлелек, ясалмалылык. *Ният, күңел гамәле булганлыгы өчен анда рия булырга мөмкин түгел.* Р.Фәхреддин. *Ягъни кияүгә чыгу өчен, ислам динен кабул итү мәҗбүри булганга гына бу дингә күчмиме ул? Риядан гына, диюем.* Г.Бәширов

◊ **Рия сату** Хәйләләү, чын хәлне яшерү, кыланган булу. *Ыспай сүзле Иннокентий, клиентны кулдан ычкындырудан куркып, рия сата башлады.* З.Мәхмүди

РИЯЛАНУ *ф.* Кешегә күрсәтү өчен генә эшләү, ясалма кылану, икейөзлеләнү, монафикълану, ялагайлану. *Рияның иң зарарлы төре – дин исеме белән риялану.* Р.Фәхреддин. *Андый бәндәнең гомумкешелек кыйммәтләрен дәгъва итүе, рияланып, шәхес хокукын даулап йөрүе мәгънәсезлек кенә түгел, хәтта зарарлы да.* Мәдәни җомга

Риялана бару Торган саен күбрәк риялану

Риялана башлау Рияланырга тотыну

Рияланып тору Әле, хәзерге вакытта, сөйләү моментында риялану. *Шахмат тактасы зурлыгында гына бер хөкүмәт министры булуга карамастан, ул рус эмигрантлары алдында рияланып тормаган, тоткан да: «Мин моннан соң русча сөйләшмим», – дип приказ чыгарган.* Г.Гобәй

РИЯЛЫ *с.* **1.** Икейөзле, ясалма, монафикъ, ялагай. *Ошбу илле яшьләрендә улган Хикмәт хажи авылларда дәгел, шәһәрләрдә тиңе аз улган байларның бере улдыгы хәлдә чиксез надан, риялы, тәкәббер бер зат иде.* Р.Фәхреддин. *Хәсән мулла надан муллаларны, риялы суфыйларны, ялганчы ишаннарны сөйми.* З.Һади

2. *и. мәгъ.* Икейөзле, монафикъ, ялагай, эчкерле кеше. *Риялыдан рәхим көтмә.* Әйтем

РИЯЛЫЛЫК *и.* Икейөзлелек, ясалмалык; монафикълык, ялагайлык. *Риялылык, икейөзлелек, ялган эченә башаяк чумып-батып маташкан кебек без.* Ф.Яхин. *Чөнки эшкә тиешле игътибар юк икән, камилләшүгә стимул югала, яхшы һәм күренекле, --- эчкерсезлек һәм риялылык арасындагы чикләр эреп юкка чыга башлый.* Сәхнә

РИЯСЫЗ *с.* Эчкерсез, турылыклы, ихласлыкка нигезләнгән, саф; чын. *Әле бу чакта сүз кирәкми, хисләр әле вакланмаган, иң риясыз уйлар бары тик бер генә затка төбәлгән чак...* А.Гыйләҗев. *Язам дисең икән, халык тормышына риясыз күз белән кара, аны өйрән, хыял канатларына күтәр, бәгыреңне телгәләгән уй-тойгыларыңны ак кәгазь битләрен көйдерерлек итеп яз да яз.* Ф.Садриев

РИЯСЫЗЛЫК *и.* Эчкерсез, керсез күңелле, саф булу. *Әмма сүз кибәгеннән арындырып, гамәлләренә, кыланмышларына карасаң, аларның риясызлыгына ышану мөмкин түгел.* Р.Зәйдулла

РИЯЧЫ *и. сир.* Икейөзле кеше, берәр нәрсә эшләгән булып кыланучы кеше

РОБАГЫЙ *и. фар. әд.* Шәрык поэзиясендә афористик эчтәлекле дүртьюллыклардан гыйбарәт лирик жанр. *Аның [Н.Арслановның] «Робагыйлар», «Афоризмнар» кебек шигъри бәйләмнәренә кергән фәлсәфи-лирик характердагы дүрт, икеюллыклары тарихи шәхесләр, ил-ватан, яшәү, үлем, мәңгелек, туган табигать турында җитди уйлануларны, сөземтә-күзәтүләрне эченә ала.* Т.Галиуллин. *Аның [Т.Миңнуллинның] робагыйларыннан Әлмәндәр карт мут елмаеп карап тора: хатын-кызга сокланып, эчкерсез шаяртып, --- Ходайга рәхмәтле булып...* М.Галиев. *Әллә нәрсә булды аңа: колагында робагый яңгырый, алдында – Укытучының галәм карасыдай кара күзләре...* Х.Ширмән

РОБДЖА́МПИНГ *и. ингл.* Эластик бау – тарзанка белән бәйләнеп, зур биеклектән сикерүдән гыйбарәт экстремаль күңел ачу төре

РО́БОТ *и. чех* 1) Катлаулы яки сәламәтлек өчен зыянлы эшләр башкаруда кешене алмаштыру өчен хезмәт иткән автомат механизм. *Шул [завод] ишекне атлап керүгә, алар кеше булудан туктыйлар, бина эчендәге станокларның, машиналарның бер өлешенә – роботларга әйләнәләр.* Ә.Дусайлы. *Дүрт аягы, сыгылмалы умыртказлыгы, хәрәкәтләнә торган башы белән робот иң җитез ерткыч – гепардка охшатып ясалган.* Мәдәни җомга

2) *күч.* Уйламыйча, механик рәвештә генә эш-хәрәкәт башкаручы. *Мин, робот шикелле, моннан бер ай элек ятлап куйган сүзләремне әйтә башлавымны сизми дә калдым.* Ә.Дусайлы

РО́БОТЛАШТЫРУ *ф.* Җитештерү процессларын автоматлаштыру, җитештерү процессларында роботларны куллануга күчү. *Җир шарын тоташтан роботлаштыру дәвере башланды.* Ватаным Татарстан

Роботлаштыра башлау Роботлаштырырга тотыну

Роботлаштырып бетерү Тулысынча роботлаштыру

РОГА́ТКА *и. рус* Ике япьле агач кисәгенең яки чыбыкның очларына резинка бәйләп ясалган уенчык, аткыч. *Соңыннан күпме эзләсәләр дә, рогатканың табылмавын, бары тик көзен --- бер сабакка уралган --- резинка чыкканын искәртеп узыйк.* А.Гыйләҗев. *Алар рогатка атышып уйныйлар икән: тимерчыбыкны кыска гына итеп кискәлиләр, уртага бөгәләр һәм резинка тарттырып атып җибәрәләр.* З.Мурсиев

РОД *и. рус лингв.* Кайбер телләрдә исемнәрнең иркәк һәм теше (мөзәккәр, мөәннәс) затларга яки әйберләргә мөнәсәбәтен белдерә торган грамматик категория; грамматик җенес. *Әгәр бер әйбер хакында «она, эта» дип әйтергә ярасә, ул әйбер женский род, ягъни хатын токым була.* Г.Тукай

РО́ДИЙ *и. лат. хим.* Югары химик тотрыклылыкка ия, табигатьтә бик сирәк очрый торган химик элемент,

соры көмеш төстәге затлы каты металл. *Профессор В.К.Половняк лабораториясендә палладий, агалтын, родий элементлары кергән комплексны органик кушылмаларны синтезлау һәм тикшерү үткәрелә* ---. Фән һәм тел

РО́ЖА *и. пол. мед.* Тире яки лайлалы катлауларның ялкынсынуыннан гыйбарәт йогышлы авыру

РО́ЗА *и. нем. бот.* 1) Гөлчәчәклеләр семьялыгыннан гадәттә төрле төстәге хуш исле катмарлы эре чәчәк ата торган, сабаклары чәнечкеле декоратив куак үсемлек һәм шул үсемлекнең чәчәге. *Төн буе төшендә ниндидер бик матур бакчада роза чәчәкләре утыртып йөрде.* Д.Булатова. *Мисал өчен, өч хризантема ботагы, ике роза, болар янына тагын 2–3 яшел ботак та куеп, шуны матурлап төрсәләр һәм ялтыравык лента белән бәйләсәләр, 900 сумлык букет сезгә елмаеп тора дигән сүз.* Татарстан яшьләре

2) *диал. кулин.* Майда йөздереп пешерелгән катлы җәймә; катлама

РОЗА́РИЙ *и. нем. к.* **розариум**. *Өлгереп җиткән алма исе бөтен паркка җәелгән, --- кыргый матур агачлар һәм куаклардан, --- розарий һәм кура җиләклеге ягыннан тәнеңне иркәләрлек, җаныңны дулкынландырырлык ис-аромат аңкый иде.* Р.Мирхәйдәров. *Москвадагы Үзәк ботаника бакчасының розариендә төрле-төрле формадагы һәм төрле төстәге розалардан бик зур коллекция җыелган.* Н.Верзилин

РОЗА́РИУМ *и. лат.* Розалар үстерелә торган питомник; розалар үсә торган урын, чәчәклек

РОЗАЧАЛАР *и. күпл. бот.* Роза, кура җиләге, алмагач, шәфталу, слива, чия, җир җиләге һ.б. керә торган агач, куак һәм үлән үсемлекләр семьялыгы; гөлчәчәклеләр. *Розачалар төрле үсемлек бергәлекләрендә очрый*. Минем йорт

РОЗЕ́ТКА *и. фр.* 1) Чәй янында варенье, бал салу өчен кечкенә тәлинкә

2) Кайбер үсемлекләрдә (мәс., бака яфрагы һ.б.) төрле якка нурлар сыман таралып китеп җиргә яткан яфрак төркеме. *Яфраксыман лишайниклар тәңкә, розетка яки, гадәттә, теленмәле эре җәймә рәвешендә үсә*. Биология. *Аяк астында йомырка сыман яфраклар розеткасы*. Робинзон эзләре

3) *архит.* Стена яки түшәмгә ябыштырыла торган, бер ноктадан төрле якка таралып киткән яфрак яисә чәчәк, таҗ яфракчыклары рәвешендәге бизәк

4) *махс.* Төрле яктырткыч, җылыткыч ише электр җиһазларын тоткa тоташтыру җайланмасы. *Профессор стенадагы розеткадан папиросына ут алдырды.* М.Мәһдиев. *Көнкүрештә очсызлы розетка һәм озайткычлардан, кабызгычлардан файдаланырга ярамый: алар янгын чыгу куркынычын арттыра*. Ватаным Татарстан

РОЗМАРИН *и. лат. к.* **бәбрия**. *Ак чыршы, эвкалипт, розмарин майларын ингаляция, массаж, тәнне ышку, борынга тамызу өчен файдаланырга була*. Сабантуй. *Лимон, грейпфрут, розмарин (бәбрия) исләре күңелгә ятышлы.* Мәдәни җомга

РОК *и. инг.л.* Экспрессив катлаулы ритм, гади көй хас булган музыкаль агым. *Моннан ун еллар элек яшьләр арасында джаз, рок, авыр рок, битлз кебек сүзләр бик киң таралган иде*. Р.Батулла. *Рок, субкультура буларак, инде алтмыш елга якын яшәп килә, һәм киләчәктә дә яшәргә хаклы икәнен ул күптән исбатлады*. Ватаным Татарстан

РОК- *ингл.* Кушма сүзләрдә «рок» мәгънәсендәге беренче кисәк (мәс., *рок-ансамбль, рок-опера*)

РОКА́РИЙ *и. инг.л.* Төрле зурлыктагы, төрле формадагы ташлардан һәм үсемлекләрдән торган бакча композициясе. *Дөрес ясалган рокарий тәрбияне аз таләп итә*

РОКГА *и. гар.* 1) Язма, язуы булган кәгазь кисәге

2) Гарәп язуының каллиграфик төре

РО́КЕР *и. инг.л.* 1) Башкаларга охшамаган, стандарт булмаган үз-үзләрен тотышлары белән җәмгыятькә каршы чыга торган яшьләр төркеменең бер вәкиле. *Караклар дөньясы белән связьлары зур, ди. Үзенә элекке дусларыннан, яңа рокерлардан яңа группировка корган. Имансызлар, явызлар.* Т.Галиуллин. *Мотоцикллары эчтәрәк, куаклыкта. Бүген дә төнлә егетләр рокерлар ярышына кушылмакчы*. С.Шәрипов

2) Рок стилендәге музыка белән мавыгучы яки профессиональ шөгыльләнүче кеше

РОКИРО́ВКА *и. фр.* 1) Шахмат уенында: уен барышында бер үк вакытта король һәм ладья белән йөреш ясап, ладьяны король янына китерү, корольне аның икенче ягына сикертеп кую. *Икеләнгән пешкаларның кыйммәте берәрләп торган пешкаларныкына караганда түбән, рокировка ясагач, корольнең кыйммәте аңа кадәргедән артык була*. Уйлаучы машиналар

2) *күч.* Урыннарын алмаштыру. *Әлегә янкилар Мисырда уңышлы рокировка ясый алдылар: Мөбарәкне аның иярченнәре белән алыштырып торуга ирештеләр*. Татарстан яшьләре. *Бер нәрсә бәхәссез: Рөстәм Миңнеханов кадрлар белән эш иткәндә «рокировка», ягъни урын алмаштыру чарасын бик сирәк куллана.* Безнең гәҗит

РОК-МУ́ЗЫКА *и. рус* Гадәттә электрон уен кораллары һәм вокалист тарафыннан башкарыла торган кызу ритмлы эксцентрик эстрада музыкасы. *«Дөньяяратылу» халыкара җанлы музыка фестиваленең икенчесе быел 27 июньдә узачак һәм, танылган йолдызлар белән бергә, башкалага күпсанлы рок-музыка сөючеләрне дә җәлеп итәчәк*. Ватаным Татарстан

РОК-Н-РОЛЛ *и. инг.л.* Кызу эксцентрик темпта башкарыла торган импровизацияле парлы бию. --- *парк ябылыр алдыннан, борынгы парк өстендә рокн-ролл авазлары тетри, сәхнәдә һәм бию мәйданчыгында нәрсәләр булганлыгын белү өчен, барысын да үз күзләрең белән күрергә кирәк*. Р.Мирхәйдәров

РОКОКО *и. фр.* XVIII гасыр башларында Франциядә барлыкка килгән архитектура һәм бизәү сәнгатендәге катлаулы, купшы стиль. *Еш кына ул плиталәргә XVIII гасырларда Көнбатыш Аурупа архитектурасы һәм сәнгатенә хас барокко, рококо стильләренә охшатып, тарихи бизәкләр төшерә*. Безнең гәҗит

РОКФОР *и. фр. махс.* Өсте алынмаган сыер, сарык яки кәҗә сөтеннән әзерләнгән, махсус күгәртү гөмбәчекләре булган әчкелтем сыр сорты; шул

сорттагы сыр. *Тәннең төсе озак сакланмасын өчен, бәрәңге, шпинат, бавыр, рокфор сыры ашарга кирәк*. Кәеф ничек?

РО́ЛИК *и. нем. тех.* 1) Кечкенә тәгәрмәч. *Рояльгә роликлар кую*

2) *махс.* Электр, телеграф чыбыкларын беркетү өчен, кәтүк формасындагы фарфор изолятор

3) *тех.* Механизмның кечкенә цилиндр яки кәтүк формасындагы әйләнә торган кисәге

4) Кыска метражлы телевизион яки кино тасмасы. *Гади генә сценарий буенча төшерелгән ролик берничә көн эчендә әзер була*. Шәһри Казан. *Әлеге репортаж берничә көн дәвамында Интернетта иң популяр ролик булып торган.* Татарстан яшьләре

5) *сөйл.* Хәрәкәт итү өчен, табанына кечкенә тәгәрмәчләр беркетелгән аяк киеме; роликлы тимераяк. *Ә менә бейсбол, софтбол, каратэ, сквош һәм ролик спортына әлегә зур ярышларда урын табылмады*. Ватаным Татарстан

РО́ЛИКЛЫ *с.* 1) Роликлар беркетелгән, роликлар өстенә куелган. *214 гектар мәйдан биләүче бу кырда роликлы велосипедларда һәм скейтбордта да җилдерергә мөмкин.* Татарстан яшьләре. *Ә бер елны мин роликлы тимераякларга заказ биргәч, әни киметкә үземне алып барып, бергә сайлап алдык*. Кәеф ничек?

2) Роликлардан торган; роликлар ярдәмендә эшли торган. *Роликлы подшипник*

РОЛЬ *и. фр.* 1) Сәхнәдә, кинофильмда артист (актёр) гәүдәләндергән драматик образ. *Бу роль мине иҗади яктан шундый үстерде, халык та йөрде бит, мәгънәсе барып җитте тамашачыга.* Ю.Сафиуллин. *Роль уңышсыз чыга. Яңадан күнегүләр, репетицияләр башлана. Тагын уңышсызлык! Ләкин артист, сәнгатьне чын-чынлап яратса, чигенми.* Р.Батулла. *Фуат Халитовның тагын бер уңай ягы шунда ки, ул, кулына роль алгач, текст белән генә канәгатьләнми, эзләнә, шуның нәтиҗәсендә образның характерын ачуга ирешә.* Шәһри Казан

2) Спектакль барышында артист тарафыннан башкарыла торган текст. *Син бит каядыр тамада булып сарыф иткән вакытыңны роль өйрәнүгә багышлый алыр идең?* Идел

3) Нинди дә булса эш, шөгыль; вазифа. *Гафури, шул рәвешчә, «үле» сүзләрне – җөмләдә бернинди роль уйнамаган сүзләрне чыгарып ташлый.* Н.Юзиев. *Әгәр мәчет шушындый роль үти икән, димәк, дәгъвәтнең нәтиҗәсе бу, ягъни халык белән эшләү җимеш китергән.* Безнең гәҗит

4) Кемнең яки нәрсәнең дә булса әһәмияте, эшкә яки вакыйгага катнашу яисә йогынты ясау дәрәҗәсе, керткән өлеше, хезмәте, тоткан урыны. *Мәгърифәт, гомумән тәрбия турында сөйләгәндә, халкыбыз тарихында төп рухи роль уйнаган китап – Галиҗәнап Китап турында аерым әйтеп китү кирәк.* Р.Фәйзуллин

◊ **Рольгә керү** 1) Үзе башкарачак рольне, образны аңлау һәм үзен шул герой дип хис итә алу. *Шулай ук, яшь кенә булсалар да, артистлар, рольгә кереп, хис белән, күңелләргә үтәрлек итеп уйныйлар.* Ватаным Татарстан; 2) Үз вазифасын үзләштерү, үз хәленә төшенү. *Әмма әнә шул хәер сорашучыларның күбесе профессиональ дәрәҗәсендә рольгә керә: авыру, гарип булып «уйный», бу аларның кәсебе икән бит!* Сөембикә. **Роль уйнау** 1) Йогынты ясау, тәэсир итү. *Миссионерлар, бигрәк тә Казан миссионерлары, Россиядә сәяси роль уйнарга һәм рус хөкүмәтен мөселман халыкларына каршы агрессив сәясәт юлына кертергә тырышалар.* С.Максуди; 2) Әһәмияткә ия булу. *Милли традицияләргә корылган гаилә милләт бөтенлеген саклауда, камил шәхес тәрбияләүдә алыштыргысыз роль уйный.* Фән һәм тел. *Бөтен заманча медианы күз уңында тотсак, һичшиксез, Интернет сәяси яңалыкларны җиткерү буенча хәлиткеч роль уйный*. Кызыл таң; 3) Сәбәпче, этәргеч көч булу. *Әйтик, музыканың авыруларны тернәкләндерүдә зур роль уйнаганын, төсләрнең дә теге яки бу авыруны дәваларга булышканлыгын беләбез.* Шәһри Казан; 4) Берәр нәрсә функциясен үтәү, бурычын, вазифасын, хезмәтен башкару. *Әлеге очрашу турында фикерләрне укыгач, үзебезнең татарда, республикабызда «иҗат интеллигенциясе» дип атарлык зыялылар даирәсе Татарстанның сәяси-иҗтимагый тормышында нинди роль уйный, алар хакимият белән ачыктан-ачык бәхәскә керерлекме, безнекеләрнең гражданлык кыюлыклары ни дәрәҗәдә, дигән сорау да туа.* Ватаным Татарстан

РОЛЬГАНГ *и. нем. тех.* Сәнәгатьтә авыр йөкләрне күчерү өчен файдаланыла торган җайланма, роликлы транспортёр

РОМ *и. инг.* Шикәр камышының ачыган согыннан яки патокасыннан әзерләнгән көчле исерткеч эчемлек. *Тәкәнәев аңа, ром салып, кружкасын суздыы*. Х.Камалов. *Ниндиен телисез – ак аракы, коньяк, виски, ром?* З.Хәким

РОМАН I *и. фр. әд.* 1) Гадәттә проза белән языла торган катлаулы сюжетлы зур әдәби әсәр. *Роман халыкка, киләчәккә ышаныч рухы белән сугарылган.* Х.Миңнегулов. *Егерменче еллар азагында Кави Нәҗми, зурдан тотынып, вакытлыча исеме «Гарнизон» булган тарихи роман яза башлый*. З.Зәйнуллин. *Фоат Садриевның «Таң җиле» әсәре басылып чыккач та, вакытлы матбугатта роман хакында шактый гына фикерләр күренде.* Р.Рахман

2) *сөйл.* Ир белән хатын һәм егет белән кыз арасындагы мәхәббәт, сөешү бәйләнешләре. *Кайчандыр уйнап кына башланган роман шулай итеп никахлашуга килеп җиткән иде.* Р.Мирхәйдәров. *Әйе, чүт-чүт кенә уйгыр театрының режиссёры белән роман булмый калды*. Театр

РОМАН II *с. лат.* 1) Латин теле нигезендә барлыкка килгән тугандаш испан, португал, француз, итальян, румын, молдован һ.б. телләрне һәм шул халыкларны берләштергән, шуларга мөнәсәбәтле. *Роман төркеменә керә торган халыклар --- Көньяк-Көнбатыш Европада яшиләр*. Дөнья кисәкләре географиясе

2) Борынгы Рим культурасы нигезендә туган, шул культурага тыгыз бәйләнеше булган. *Төрмәгә охшаулы авыр, салмак, караңгы роман чиркәүләре готика чиркәүләренә алмаша барганнар.* Г.Гали. *Роман стиле*

РОМАНИСТ I *и. рус әд.* Романнар иҗат итүче әдип. *Азәрбайҗан халык язучысы, Азәрбайҗан Язучылар союзы правлениесенең беренче секретаре Мәһди Хөсәен болай дип яза: «Зур татар прозаигы, романист Г.Ибраһимовның әсәрләре республикабыздагы киң катлау укучылар арасында зур уңыш казанды».* Ә.Нәҗипова-Зиннәтуллина. *Г.Ибраһимов – кыска хикәяләр остасы да, атаклы романист та.* Фән һәм тел

РОМАНИСТ II *и. фр.* 1) Роман телләре һәм әдәбияты белгече

2) *махс.* Рим хокукы белгече

РОМАНИ́СТИКА I *и. рус* Роман халыклары культурасын, телен һәм әдәбиятын өйрәнә торган фән; роман филологиясе. *Роман телләрен, аларның килеп чыгышын, үсешен, классификациясен һәм башка аспектларын өйрәнә торган фәнне романистика дип атыйлар (ул – лингвистиканың бер өлеше).* Ф.Сафиуллина

РОМАНИ́СТИКА II *и. рус* Әдәбият жанры буларак романнар; романнарның һәммәсе. *Л. Цырлинның тарихи романистиканы художникның субъектив иҗади дөньясы принцибы белән классификацияләве әдәбият белемендә тәнкыйтькә очрады.* Ә.Нәҗипова-Зиннәтуллина

РОМАНС *и. фр.* 1) Тавыш һәм инструмент өчен язылган, җырдан катлаулырак, лирик характердагы музыкаль әсәр. *--- минем шушы шигъри юлларым күренекле татар композиторы Рөстәм Яхин музыкасы белән кушылу бәхетенә иреште. Һәм нәтиҗәдә дөньяга «Мин яратам Сезне» дигән яңа романс туды.* Л.Шагыйрьҗан. *Рөстәм Яхин – 300 дән артык җыр һәм романс авторы.* Шәһри Казан

2) Гадәттә музыкага салына торган зур булмаган лирик шигырь

РОМАНТИЗМ *и. фр.* 1) XIX йөзнең башында әдәбиятта һәм сәнгатьтә классицизмга каршы барлыкка килгән, идеаллаштырылган хисләр, идеаль геройлар сурәтләү белән мавыккан әдәби юнәлеш. *Ибраһимовны, 1910–1912 нче еллар иҗаты белән бәйле рәвештә, галимнәр бертавыштан диярлек, асылда, романтизм вәкиле, дип игълан иттеләр.* Ф.Яхин. *Әдәбиятның халыкчанлыгы, тормыш белән бәйләнеш алымнары турында уйланыйкмы, реализм, натурализм, романтизм, символизм кебек иҗат юнәлешләре турында фикер туплыйкмы, күбесенә Г.Ибраһимов мирасыннан җавап булмаса да, мөнәсәбәт табарбыз.* Ә.Дусайлы

2) Әдәбият һәм сәнгатьтә кешенең бөеклеген ачык образларда күрсәтергә омтылган һәм оптимизм белән сугарылган художество методы. *Кешене иҗтимагый тирәлектән бәйсез итеп сурәтләү, образны гадәттән тыш зурайтып, калкытып һәм үткенәйтеп бирү дә – романтизм билгеләре.* И.Нуруллин. *Ул иң гади, әйтик, лап-лап басып йөргән чын җир кешесен дә бераз һавалырак итеп, җирдән күтәребрәк бирә, китапчарак әйтсәк, үзе дә сизмәстән, образларын романтизм белән сугара.* Р.Батулла

3) *кит.* Романтиклык, чынбарлыкны идеаллаштыру, хыялга (тойгыга, хискә) бирелүчәнлек

РОМА́НТИК I *и. лат.* 1) Романтизм тарафдары. *Менә француз язучысы һәм фәлсәфәчесе Роже Гароди «Ярларсыз реализм» китабының «Сен-Жон Перс» бүлегендә романтик шагыйрьләр иҗатының фәлсәфи асылы турында болай дип яза ---.* И.Вәлиулла

2) Романтикага, хыялга бирелүчән кеше. *Тормыш миңа романтик булырга түгел, реалист булырга куша.* Х.Туфан. *Поэзиягә җилле-давыллы, дәртле романтик буларак бәреп кергән --- Илдар Юзеев халыкны нәкъ шуның киресенә үгетләү юлына баса...* Т.Галиуллин. *Алсуланган «Әлмәт төннәре»ннән, «Ак куаклар күләгәсе»ннән Туфан җаныңдагы романтик Янаржан Искәндәрне көненә берничә шигырь-җыр тудырып дәрәҗәдә үзенә табындырган, --- һәр сулышын илһам чыганагы итеп бәяләгән Тәнәкә...* Сөембикә

РОМА́НТИК II *с.* 1) Романтизм (*1, 2 мәгъ.*) рухындагы. *Бурнашның «Таһир – Зөһрә», «Хөсәен мирза»лары шикелле романтик әсәрләре аша татар драматургиясе бу өлүбкә тугрылык сакларга тырыша ---.* А.Әхмәдуллин. *Тормыш, яшәеш хакында сүз алып барганда, традицион романтик прозадагы шикелле үк, автор яктылык һәм караңгылык, яхшылык һәм явызлык антитезаларына якыная.* М.Кәбиров

2) Романтикага (*2 мәгъ.*) бәйләнешле. *Синең белән очрашуның иң матур, иң романтик яклары гына күз алдына килә.* Н.Нәҗми. *Бер яшь егет Авангард урамында яшәүче сөеклесенә романтик сюрприз ясарга уйлый һәм аның өченче каттагы фатирына тәрәзәдән керергә карар итә.* Безнең гәҗит. *Елыгыз романтик очрашуларга, рәхәт мизгелләргә бай булачак.* Кәеф ничек?

3) Хыялланучан, романтикага, хистойгыга бирелүчән, нечкә күңелле. *Илназны Татар радиосы «Иң романтик җырчы» номинациясендә бүләкләде.* Татарстан яшьләре

РОМА́НТИКА *и. фр.* 1) *к.* **романтизм**. *Тормыш һәм тарихтагы реаль вакыйгалар анда әкияткә хас нечкә романтика белән сугарылганнар.* М.Җәлил. *Без бит төньякка сезнең кебек «озын берлек» эзләп килмәдек, безне бу якларга романтика әйдәде.* И.Хуҗин

2) Эмоциональлек, күңел күтәренкелеге тудыра торган, кешене алга әйдәүче хисләр, фикерләр. *Чөнки яшьлектә барысы да матур, җиңел, барысы да романтика томанына төренгән, хыял канатларында уйнаклый торган була.* Р.Мирхәйдәров

РОМА́НТИКЛАШТЫРУ *ф.* Кемне яки нәрсәне дә булса романтик II (*2 мәгъ.*) буяуларда, идеаллаштырылган рәвештә күзаллау, сурәтләү, тасвирлау

Романтиклаштыра бару Торган саен ныграк романтиклаштыру

Романтиклаштырып килү Электән, күптәннән системалы романтиклаштыру

РОМА́НТИКЛЫК *и.* Романтика (*2 мәгъ.*), романтизм (*3 мәгъ.*) белән сугарылган булу. *Минемчә, геология – әле хәзер дә романтиклык саклап калынган һөнәрләрнең берсе.* Ватаным Татарстан

РОМАНЧЫ *и. к.* **романист**. *Күк каһарманы, әдәбият каһарманы, шагыйрь, романчы, драматург Салих Батталның тормышы – үзе бер роман ул!* Р.Батулла

РОМА́ШКА *и. рус бот.* Оешмачәчәклеләр семьялыгыннан каурыйсыман

телгәләнгән яфраклы, уртасы сары, тажлары ак төстәге үлән үсемлек; бабүнә чәчәк; ак чәчәк. *Кәрешкә, мәтрүшкә, кәккүк чәчәкләре, --- ромашкалар, зәңгәр кыңгыраулар белән чуарланган, әле чабылып өлгермәгән болынның хуш исле һавасына туйганчы иркәләндек.* М.Әмир. *Бәкәлләрен иркәләгән сусыл үләннәргә, ак башларын моңсу тибрәндергән ромашка һәм әнисләргә исе дә китмәде, уенда урманга барып җитү генә иде.* Р.Мөхәммәдиев. *Менә ул, кызның яшенчә, 17 бөртек ромашка санап алды да, гөлләмәне култык астына кыстырып, чыгу ягына кузгалды.* Г.Гыйльманов

РОМБ *и. фр.* 1) Кырлары үзара тигез, почмаклары туры булмаган геометрик фигура; параллелограмм. *Ромб параллелограмм булганлыктан, ул параллелограммның барлык үзлекләренә ия була*. Геометрия

2) *тар.* 1919–1943 елларда, погоннар кергәнгә кадәр Совет Армиясендә югары команда составын аеру өчен кулланылган билге. *Шинеленең петлицаларында икешәр ромб.* И.Салахов

РО́МБИК I *и. рус* 1) Кечкенә ромб. *Ундүрт телле, күрегенең алгы ягына ак буяу белән ромбик төшерелгән гармун әле дә бар ул*. А.Хәлим

2) *к.* **ромб** (*2 мәгъ.*). *Армия аркылы уздырасы иде бу егетләрне. Ромбик таксалар да, нидер җитеп бетми бит шул мәктәпне узмаганнарга*. М.Мәһдиев. *Якасына ромбик тагып, взвод командиры итеп чыгаралар.* Р.Батулла

3) Ромб формасындагы берәр билге, значок һ.б.ш. *Зәңгәр тышлы катыргы төрле кулларда йөреп уңды, рюмка төпләрендә йөзеп, кулдан-кулга күчепкүченеп йөргән яшел ромбик эзсез югалды*. Х.Ибраһим

РО́МБИК II *с.* Ромб формасындагы, кечкенә ромб рәвешендәге, кыек дүрткел рәвешендәге

РОМЛЫ *с.* Ром салынган, ром кушылган. *Димәк, аныңча, татлы шәраб, ромлы кәнфит, салкын сырадан башланган тормыш наркологик диспансер белән тәмамлана.* Безнең гәҗит

РО́МБСЫМАН *с.* Ромбка охшаган, ромб рәвешендәге, ромбны хәтерләтә торган. *[Цементитның] атомнары ромбсыман рәшәткәдә тыгызлап урнашкан була.* Төзү материаллары

РО́НДО *и. ит. муз.* Төп темасы берничә тапкыр рефренда кабатлана торган музыкаль әсәр

РОНДО́ I *и. фр. әд.* Кабатлана торган ике рифма белән тоташкан сигез юллы шигырь формасы (унөч һәм унбиш юллы катлаулы формалары да булган). *Хәзерге вакытта рондо иске формага ияреп язу өчен генә кулланылырга мөмкин*. Н.Гыйззәтуллин

РОНДО́ II *и. фр.* 1) Махсус түгәрәкләндерелгән язма, шулай ук басма шрифт

2) Шундый шрифт белән язу өчен яссы очлы каләм

РОССИ́ЯЛЕ *и.* Россиядә яшәүче кеше. *Саклык чарасы итеп, инде бүген 2 миллион россиялегә прививка ясалган.* А.Әпсәләмова. *Кайбер мәгълүматлар буенча, бүген 68 процент россияле үз балаларының чит илдә укуын тели икән*. Шәһри Казан

РОССИЯН *и. рус к.* **россияле**. *Безне милләтсез итәргә, «совет халкы» итәргә тырыштылар. Боларның әле берсе дә онытылмаган. Хәзер инде көчләп, хәйләләп, милләтсез «россиян» итмәкчеләр*. Р.Миңнуллин

РО́СТБИФ *и. инг. махс.* 1) Сыер итеннән түгәрәк бер кисәк рәвешендә кыздырып әзерләнгән ашамлык, куырма. *Миңа бер порция суп китер, тавыктан булсын, икенчегә бер порция ростбиф китер.* Г.Камал

2) Сыер түшкәсенең шундый ашамлык әзерләү өчен китә торган сырт өлеше

РОСТОВЩИК *и. рус* Процент белән бурычка акча биреп торып, шуннан табыш алып яшәүче кеше; рибачы. *Беренче тапкыр ломбард Франциядә Людовик X (1461–1483) вакытында Төньяк Италиянең Ломбардия өлкәсеннән чыккан ростовщиклар (кешеләргә бурычка акча биреп торып, зур табыш алучылар) тарафыннан төзелә ---*. Г.Исхакый. *Джайнитларның дине игенчелек белән шөгыльләнергә комачау итә, дөресрәге, кушмый. Чөнки җир сөрү вакытында күпмедер бөҗәк, кортлар тапталып, сытылып үләләр бит. Әнә шуңа күрә джайнитлар – сәүдәгәрләр, ростовщиклар.* М.Мәһдиев

РОСТОВЩИКЛЫК *и.* Ростовщик шөгыле; риба. *Риба, ягъни ростовщиклык яһүдләргә Муса галәйһиссәлам һәм Гайсә галәйһиссәламнәр алып килгән шәригатьләрдә дә катгый тыела.* Б.Хаков

РО́ТА *и. нем. хәрби* Батальон составына керә торган гаскәри берәмлек. *Ротаның арткы рәтендәге кызылармеец Зариф --- салмак кына атлап бара.* Ә.Еники. *Рота һәм взвод командирларының, солдатлар кебек үк, сугышта кырылганнарын беләм*. Н.Нәҗми. *Характеристикага рота командиры лейтенант Михеев кул куйган.* Р.Мостафин

РОТАПРИНТ *и. инг. махс.* Эш кәгазьләре, документлар, реферат, бюллетень һ.б.ш. кебекләрне аз тиражда бастыру машинасы

РОТА́ТОР *и. лат. тех.* Сызым, кулъязма һәм рәсемнәрне бастырып күбәйтү аппараты

РОТАЦИЗМ *и. гр. махс.* 1) *лингв.* Нинди дә булса авазның [р] авазына тарихи күчеше. *Шуңа өстәп, алар болгар төркеме дип, борынгы болгар һәм хәзерге чуваш телләрен китерәләр һәм аларда ротацизм һәм ламбдаизм күренеше булуны күрсәтәләр*. Фән һәм тел

2) Сакаулыкның бер төре буларак «р» авазын дөрес әйтмәү күренеше; сөйләмдәге дефект

РОТАЦИОН *с.* Ротация принцибында эшли торган. *Ротацион машина*

РОТА́ЦИЯ *и. лат.* 1) Әйләнеш, үз күчәре тирәли әйләнү

2) Берәр структураның элементларын эзлекле, даими рәвештә алмаштырып тору. *Өстәвенә биредә кадрларны һөнәри үстерү өчен, горизонталь ротация ысулы актив кулланыла*. Шәһри Казан

3) *а.х.* Чәчү әйләнеше циклында авыл хуҗалыгы культураларының бер әйләнеш ясавы. *Дүрт басулы чәчү әйләнешендә ротация дүрт елга, алты басулы чәчү әйләнешендә алты елга сузыла*. А.Фаткуллин

4) *махс.* Ротацион машина

РО́ТМИСТР *и. нем. хәрби тар.* 1917 елга кадәр Россиядә атлы

гаскәрдә һәм башка кайбер илләрнең армияләрендә капитан дәрәҗәсенә туры килә торган офицер дәрәҗәсе һәм шул дәрәҗәдәге кеше. *КГЖУ начальнигы ротмистр Кирсанов биргән мәгълүматлар буенча, 1911 елда И.Терегулов Уфа губернасы земство идарәсенең рөхсәт ителмәгән съездында катнашкан.* Р.Әмирхан

РОТО́НДА I *и. лат. махс.* Гадәттә гөмбәз белән капланган, колонналар белән әйләндереп алынган түгәрәк яки ярымтүгәрәк кечкенә бина, павильон яки зал

РОТО́НДА II *и. лат. иск.* Җиңсез җылы хатын-кыз өс киеме

РО́ТОР *и. лат.* Турбина, электр двигателе, нефть бораулау машиналары һ.б.ш.ның әйләнә торган өлеше. *Вышка артыннан ук, лебёдка, ротор, трослар һәм культбудка урнаштырылган тимер чаналарын өстерәп, өч-дүрт трактор да баржага керде.* М.Хәсәнов

РО́ТОРЛЫ *с.* Роторы булган, ротор белән эшли торган. *Күп урыннарда роторлы сиптергечләр куллану да максатка ярашлы.* Ватаным Татарстан

РОЯЛИЗМ *и. фр. тар.* Король хакимлеге яклы булу, король властена турылыклы булу

РОЯЛИСТ *и. фр. тар.* Роялизм тарафдары, король хакимлеген яклаучы кеше

РОЯЛИ́СТИК *с. тар.* Роялизмга мөнәсәбәтле, роялизм рухындагы. *Роялистик карашлар*

РО́ЯЛТИ *и. ингл.* Хосусый байлыкларны, авторлык хокукын, патентларны һ.б.ш.ларны кулланган өчен күчерелә торган компенсация. *Шул сумма һәм ун процент роялти (һәр данәдән килгән процент).* М.Кәбиров

РОЯЛЬ *и. фр.* Металл кыллары горизонталь урнашкан, клавишлы зур музыка коралы; фортепианоның бер төре. *Хәят Борһан абзыйдан рояль алдыртырга тырышып караса да, булдыра алмагач, өч-дүрт көн атасына караңгы чырай күрсәтеп йөрде дә ташлады.* Ф.Әмирхан. *Безгә килеп керү белән, ул һәрвакыт, рояль янына утырып, Чайковскийның «Сентиментальный вальс»ын уйный иде.* Р.Батулла

РӨКҮГЪ *и. гар.* 1) Алга таба иелү хәрәкәте, бил бөгү. *Хөкемдарны сәламләү рөкүгы*

2) *дини* Намазда кулларны тезгә куеп бил бөгеп тору позасы. *Ул җеназа намазы башка намаз кебек түгел, рөкүгъ, сәҗдә юк, аягүрә дүрт тәкбир белән тәмам була.* К.Насыйри. *[Хәдичә түти], --- бөтенләй онытылып, рөкүгъ урынына сәҗдәгә китеп бара.* Г.Бәширов. *--- башкалардан качып кына намаз укый торган урынына сыгылып төште, кыйбласына борылды, бер сәҗдәгә китеп, бер рөкүгъта торып, ләгънәтен кире кайтара башлады.* А.Хәлим

РӨКҮ́ГЪ ИТҮ *ф.* Бил бөгү. *Көчем җыйдым да алдыңда рөкүгъ иттем.* М.Гафури

РӨКҮ́ГЪ КЫЛУ *ф. к.* **рөкүгъ итү**. *Туфрагына сәҗдә кыйлганчы, Тукайның үзенә рөкүгъ кылсаң да, зур файда иткән булыр идең.* Г.Халит

РӨХСӘТ *и. гар.* **1.** 1) Бер кеше тарафыннан икенче бер кешегә берәр төрле эшне эшләргә бирелгән ризалык. *Тамак туйгач, әнинең рөхсәте илә урамга чыктым.* Г.Тукай

2) Ризалыкны раслый торган документ. *Рәсми һәм хөкүмәт рөхсәте белән ачыла торган бу җәмгыятьләрдәге эшләр рәсми дәфтәрләргә теркәп барыла.* Р.Фәхреддин

2. *хәб. сүз мәгъ.* Ризалыкны, уңай җавапны белдерә. *Шулай булгач, үзегезгә тагы бер сорау бирергә рөхсәтме?* Р.Мөхәммәдиев

◊ **Рөхсәт бирү** *к.* **рөхсәт итү**. **Рөхсәт итегез** 1) Берәр нәрсә эшләргә рөхсәт, ризалык сорау. *Инде әлеге мәкаләдән өземтә китерергә рөхсәт итегез...* Р.Зарипов; 2) Нәрсәнең дә булса башлануын тәкәллеф белән белдергәндә кулланыла. *[Зөлфия:] «Якты юл» партия оешмасының җыелышын ачарга рөхсәт итегез.* Р.Ишморат. **Рөхсәт итү** Нәрсәгә дә булса ризалык бирү. *Әйдәгез, әйдә, сезгә генә читән аша керергә дә рөхсәт итәм.* М.Әмир

РӨХСӘ́Т КӘГАЗЕ *и.* Язма рәвештә бирелгән рөхсәт, берәр нәрсә эшләргә, кая булса да керергә язма рәвештә бирелгән документ, рәсми таныклык; лицензия. *Зәкинең дә рөхсәт кәгазе юк икән. Ул кемгә эләкте шуңа ияреп керә алса гына актара икән төрек-татар тарихын.* Р.Мөхәммәдиев

РӨХСӘТЛЕ *с.* Рәсми рөхсәте булган, рәсми рөхсәт алган. *Краснодар ягында Русиядәге беренче рөхсәтле казино ачылды.* Безнең гәҗит

РӨХСӘТНАМӘ *и. гар.-фар. к.* **рөхсәт кәгазе**. *Язма чыганакларда кондыз яшәгән урман сулыкларында аларны аулау өчен махсус рөхсәтнамә бирелгәнлеге турында язылган.* Р.Фәхретдинов. *Шулай да Рәсәй дәүләт мәгарифенең бер өлеше булган Татарстан дәүләт мәгарифенең республика чикләрендә рәсми статуска ия рөхсәтнамә бирү хокукы бар.* И.Әмирхан. *Узган ел күпфатирлы торак төзелешенә – 185, шәхси торак төзелешенә 120 рөхсәтнамә бирелгән.* Шәһри Казан

РӨХСӘТСЕЗ *с.* **1.** Рөхсәт алмыйча эшләнгән; рөхсәт ителмәгән. *Боларның рөхсәтсез чакта күпләп җәнлек кырганнарын фаш итәргә алынган.* Р.Батулла

2. *рәв. мәгъ.* Рөхсәт бирелмичә, рөхсәт булмыйча, үзара килешмичә, рөхсәттән башка, рөхсәт алмыйча. *Ләкин гармун кадәр гармунның өй түрендәге сандыктан рөхсәтсез алынуын да, аның яндырылуын да яшереп калып булмый.* Н.Әхмәдиев. *Егет белән кыз сөйләшәләр, ә шушы вакытта күңелләре, ихтыярларыннан рөхсәтсез генә, бер-берсенә нур сигналлары тапшыралар бугай.* Х.Камалов. *Нишләп безнең өйгә рөхсәтсез кердегез?* Ф.Яруллин

РӨШДИ *и. гар. к.* **рөшдия**. *Рөшдинең эчтәлеген түбәндәге предметлар хасил итәргә тиеш була: Коръән, хифыз, фикъһе (юриспруденция), гакаид (иман), тарихе ислам (ислам тарихы), шифаһи мәгълүмат, лисане гарәби (гарәп теле), тарихе милли (милли тарих), хисап, җәгърафия, гыйльме әшья (физика, табигать белеме) ---.* Р.Әмирхан

РӨШДИЯ *и. гар.* **1.** *тар.* Революциягә кадәр: башлангычтан югары (урта) мәктәп

2. *с. мәгъ.* 1) Балалыктан чыккан, җитлегү чорына кергән

2) Югары, өлкән; урта. *Мәдрәсәдә рөшди сыйныфлар, ягъни анда төрле авыллардан килгән зур шәкертләр*

ятып укыйлар. Ә.Еники. *Башлангыч мәктәпне яңа нигездә тәртипкә китереп, Галимҗан хәзрәт әкренлек белән рөшти (урта) сыйныфны ислах итә, 1899 елда яңартылган рөшдия бүлеген ача.* Ә.Хуҗиәхмәтов

РУБЕРО́ИД *и. лат.-гр. махс.* **1.** Махсус состав сеңдерелгән, изоляция һәм түбә ябу өчен кулланыла торган материал. *Дымны үткәрмәү өчен, шлак өстенә цемент эремәсе салына, аңа, битум белән сылап, өч кат рубероид җәелә.* Яшелчә һәм җиләк-җимешне саклау, эшкәртү

2. *с. мәгъ.* Шундый материал белән капланган. *Рубероид түбә*

РУБИ́ДИЙ *и. лат. хим.* Көмешсыман төстәге йомшак металл, химик элемент

РУБИ́ЛЬНИК *и. рус тех.* Электр тогын тоташтыра яки өзә торган җайланма. *Башта әле ул, ут та кабызмыйча, подвал тынлыгына колак сала. Шактый тыңланып торганнан соң гына, рубильникны куша, директор кабинетына уза.* Ә.Дусайлы

РУБИН *и. лат. махс.* **1.** Корундның кызыл төстәге төре, асылташ; кызыл якут, ләгыль. *1325 рубин һәм турмалин, 559 фирүзә, 16 энҗе, 28 сапфир һәм 36 башка асылташлар белән бизәлгән, кыйммәтле металлардан эшләнгән бу тәхетне финанс якган, тарихи якган – аеруча, бәяләп тә бетереп булмый хәтта.* Ватаным Татарстан

2. *с. мәгъ.* 1) Шул асылташтан гыйбарәт, шуннан ясалган. *Ир кеше хатынына рубин кашлы балдак бүләк итәргә тиеш.* Туйлар

2) Шул асылташ төсендәге, кызыл. *Бәллүр чәркәләргә рубин төсендәге шәраблар, опал төсендәге коньяклар коелды.* Шәһри Казан

РУ́БКА *и. голл.* 1) Кораблнең өске палубасында идарә итү постлары урнашкан корылма. *Мин менгәндә, капитан рубка өстәлендә радиограмма язып азаплана иде.* М.Юныс

2) Нинди дә булса махсус эш өчен билгеләнгән бүлмә. *Радио рубкасы*

РУБЛЬ *и. рус* Хәерге Россиядә 100 тиенгә тигез төп акча берәмлеге. *Тагын да игътибар беләнрәк караса, кыялар дигәнең соры гранит та, таш та түгел, ә акча төргәкләре икән иҫ: долларлар, евролар, рубльләр.* Н.Көбәш. *Хәлләрнең начарлануы рубльнең бәясе төшүе һәм инфляциянең артуына да бәйле.* Безнең гәҗит

РУ́БРИКА *и. лат.* Газет, журналларда гомуми темага караган мәкаләләрнең башы, исеме. *Әле тагын журналда күптәннән инде укучылар яратып өлгергән «Нәниләргә укыгыз» исемле рубрика яшәп килә.* Р.Миңнуллин

РУДА *и. слав.* Составында металл яисә аларның кушылмалары булган тау токымы, табигый минерал, чимал; мәгъдән. *[Борынгылар] Күлләрдән руда чыгарганнар, ә руданы эретеп, тимер уклар ясаганнар.* М.Хәбибуллин. *Бай урманнар, игенчелек өчен уңдырышлы туфрак, --- бакыр рудасы, --- кыйммәтле җәнлек тиреләре һәм балык – боларның барысы да дәүләтнең зур тизлек белән икътисади үсешенә ярдәм иткән.* Т.Кәримов

РУДАЛЫ *с.* 1) Руда чыга торган. *Рудалы урыннар*

2) Составында руда булган. *Әржә рудалы балчык белән тутырылган, троснының түбәндәге очына аркылы тәртә куеп, берничә кеше тарта.* Х.Камалов. *Көньяк һәм Көнчыгыш Африкада рудалы казылмалар тирәндә түгел, чөнки анда борынгы кристаллик токымнар җир өстенә якын гына ята.* Материклар һәм океаннар географиясе

РУДИМЕНТ *и. лат.* 1) *биол.* Организмның эволюцион үсеше процессында үзенең әһәмиятен югалтып, үсми калган, калдык әгъза (мәс., кешенең сукыр эчәк үсентесе, койрык сөяге һ.б.ш.)

2) *күч.* Борынгы күренеш, искелек калдыгы. *Никахлашу – Россиядә әһәмиятен югалткан бер йола – рудимент кына булуны күрсәтмиме бу?* Шәһри Казан

РУДИМЕНТАР *с.* Рудимент булган, җитлекмәгән хәлдәге; калдык. *Рудиментар органнар кешенең хайваннардан килеп чыгуын исбат итүче иң мөһим дәлил булып тора.* Биология. *Рудиментар сөякләр дә сынгалый.* Ватаным Татарстан

РУДНИК *и. рус* Файдалы казылмалар чыгару өчен, җир асты корылмалары системасы; шул эшләрне оештыра һәм башкара торган тау сәнәгате идарәсе; мәгъдән учагы. *Каралып беткән сәламә шахтёрлар рудник тирәсендә дәрья кебек дулкынлана, кайный иделәр.* Ш.Камал

РУЗА *и. фар. дини иск.* Ураза. *Руза, намаз кыйла күргел, гомрең үтәр, Кыямәт көн намаз соралыр, кодрәт берлә.* М.Колый. *Чөнки бу кеше укымыш улып, белер иде ки, кәсеп вә эш шәригать буенча намаз вә руза тоту кеби фарыз вә гыйбадәттер.* М.Акъегет

РУЗНАМӘ *и. фар. иск.* 1) Газета, көндәлек матбугат. *Кайсыбер рузнамәләрдә Сафагәрәй ханның Сөенбикәгә өйләнүе Казаннан нугай йортына качып баруыннан соң булганлыгы язылса да, бу сүз ялгандыр.* һ.Атласи

2) Көндәлек дәфтәр, календарь

РУЛЕТ *и. фр. махс.* 1) Хайван яки балыкның йомшак итеннән төреп, ыслап әзерләнгән ашамлык. *Итне 6–7 миллиметр калынлыктагы телемнәргә бүлеп, һәркайсын агач чүкеч белән суккалап йомшарталар, тоз һәм борыч сибәләр, буена 2–3 караҗимеш тезеп, рулет итеп төрәләр, тешказыгычлар белән беркетәләр, тоз, борыч сибәләр.* Мәдәни җомга

2) Тартылган иттән эченә нәрсә дә булса салып, озынча түгәрәк формада пешерелгән ашамлык

3) Эченә варенье, павидло һ.б. нәрсәләр салып пешерелгән татлы камыр ризыгы. *Октябрь бәйрәменә дип дүртәр йөз грамм рулет бирделәр.* М.Мәһдиев

РУЛЕ́ТКА *и. фр.* 1) Берәр нәрсәне үлчәү өчен, өстендә сантиметрларга бүленеше булган тасмадан гыйбарәт, түгәрәккә урала торган озынлык үлчәү әсбабы

2) Саннар сугылган чокырлары булган әйләнмәле түгәрәктән һәм шуның тирәли тәгәрәгән шардан гыйбарәт комарлы уен җайланмасы һәм шул уенның үзе. *Хәзер, рулетканы һәр әйләндереп җибәрү алдыннан, яшел өстәл өсте төрле төстәге фишкалар белән тула башлады.* Р.Мирхәйдәров

РУЛОН *и. фр. махс.* Түгәрәкләп уралган төргәк. *Уземнең исәпләүләр белән генә әйтә алам: бер сыерың кышны тук чыксын өчен, ким дигәндә җиде төргәк салам, ун рулон печән, бер тонна фураж кирәк.* Кызыл таң

РУЛЬ *и. голл.* Корабль, самолёт, автомобиль һ.б.ш. транспорт чаралары белән идарә итү җайланмасы. *Кызлар машинага печән төягәнче бераз йөреп килим, руль артында оешкан аяклар язылсын дип, Ярмөхәммәт арыш басуына таба китте.* Р.Батулла. *Фаил, сикерергә әзерләнгән мәче сыман, җилкәләрен дугайландырып, ике кулы белән рульгә чытырдатып ябышты ---.* Р.Вәлиев

РУМ *и. гар. иск.* Грек, византияле. *Рум сатучысы гына түгел, бүтәннәр дә хан катына буш кул белән генә килмәгәннәр иде, билгеле.* Н.Фәттах

РУМЕЙ *и. гр.* Азак буе грекларының ике этник төркеменнән берсе: православие динен тоткан, төрки телдә сөйләшкән урумнардан аермалы буларак, грек теленең бер диалектында аралашкан халык һәм шул халыкның бер вәкиле

РУМИ *с. гар. иск.* Грекныкы, рум иленеке. *Календарь күрсәткечләре һиҗри һәм руми еллар белән янәшә күрсәтелеп бирелә ---.* М.Әхмәтҗанов

РУМЫН *и. лат.* Телләре роман төркеменә караган, Румыниядә күпчелекне тәшкил иткән халык һәм шул халыкның бер кешесе. *Капчык эчендә торып калган 300 меңнән артык немец, румын, итальян, испан, фин сугышчыларының саннарының күплеге безнең командование өчен дә көтелмәгән яңалык булды.* З.Зәйнуллин

РУМЫ́НИЯЛЕ *и.* Румыниядә туып үскән яки шунда яши торган кеше

РУМЫ́НЧА *рәв.* **1.** 1) Румын телендә. *Румынча сөйләшү*

2) Румыннарга хас булганча. *Туйны румынча үткәрү*

2. *с. мәгъ.* 1) Румыннарга хас булган. *Румынча бәрәңге гуляшы.* Ватаным Татарстан

2) Румын телендә булган, румын телендә язылган. *Монда да авылларның татарча исемнәре әкренләп румынча исемнәр белән алмаштырыла, аларның тарихи татарча исемнәре тик әдәби әсәрләрдә һәм халык хәтерендә генә сакланып кала.* Казан утлары

3. *и. мәгъ.* Румын теле. *Румынчаны җиңел генә өйрәнү*

РУ́НА *и. фин* Балтыйк буе фин халыкларында эпик җыр жанры

РУНДУК *и. төрки диңг.* Елга һәм диңгез судноларында әйбер саклар өчен кулланыла торган сандык, тартма. *Капитанның рундугын ачтым. Әйтерсең тентү, погром узган.* М.Юныс

РУ́НИК *с.* Руннарга караган, руннарга бәйләнешле. *Герман руник язмасының Орхон-Енисей руник язмасыннан барлыкка килүе --- турында --- күп меңләгән ышанычлы чыганаклардан алынган мәгълүматлар бар бу китапта.* М.Юныс

РУННАР *и. фин күпл.* Борынгы төрки кабиләләрдә һәм скандинавиялеләрдә кулланылган иң борынгы язу, әлифба. *Арами алфавитыннан борынгы фарсы, борынгы еврей, гарәп, уйгур, грузин язулары, төрки руннары һ.б. үсеп чыга.* Х.Курбатов

РУНО *и. гр. махс.* Сарыкның кыркып алынган тоташ йоны; сарык өсте. *Бер сарыктан йон кыркып алу ун килограммга җитмәсә дә, кайберләреннән уннан артык килограмм затлы руно кыркып алынган еллар булды.* Татар әдипләре

РУ́ПИЯ *и. санскр.* 1) XV гасырдан алып Һиндстанда басылган көмеш акча. *Шулчак биш көлчә иясе: – Миңа бу акчадан биш рупия тиеш, ә синең өч көлчәңә – өч рупия, – дип, үз өлешен даулый башлаган.* Әкият

2) Һиндстан, Индонезия һәм кайбер башка илләрдә акча берәмлеге. *Соңгы рупия акчаларны кибетче алдына китереп селеккәч, сатучы сингал егете, елмаеп, чәйнең иң яхшы сортларыннан тагын берничә пачканы алдыма куйды.* М.Мәһдиев

РУ́ПОР *и. голл.* 1) Конус формасындагы тавыш көчәйткеч труба. *Болар эшкә мавыгып сизми калдылармы, әллә инспектор шайтан кебек су астыннан килеп чыктымы, кинәт күзне камаштырырлык фара яктыртты, һәм котны алып рупор аша әйтелгән сүзләр яңырады: «Балык бармы, егетләр?!»* З.Мурсиев

2) *күч. кит.* Кемнең дә булса фикерләрен, карашларын таратучы, үткәрүче кеше яки басма. *Ә Фәнҗүмә апасын рупор буларак файдалану кулай: ачуыңны китергән нәрсәне аның аша әйттерәсең дә, үзең гөнаһсыз бер җан иясе кыяфәте ясап утырасың.* Н.Көбәш

РУС *и.* Телләре көнчыгыш славян төркеменә караган, күбесе православие динендәге, Россиядә күпчелекне тәшкил иткән һәм шулай ук БДБ илләрендә дә яшәгән халык һәм шул халыкның бер кешесе. *Тукай заманыннан башлап, без гарәп-фарсы сүзләреннән баш тарта башлаганбыз, аларның урынын, нигездә, рус сүзләре алган.* Р.Вәлиев. *Ул башкорт, татар, рус, чуваш, удмурт, мари, мордва, украин халыкларының җыр-биюләре белән үрелеп барды.* Өмет

РУСИЗМ *и. рус* 1) Рус теленнән алынган сүз яки тәгъбир

2) Рус халкы башка халыклардан өстен, дип раслаган караш. *Илне бер телдә сөйләшү генә саклап кала алмаячак, көчләп тагылган русизм һәм шовинизм арасында тугланган халыкны иезуитлар бик тиз юлдан яздырачаклар.* М.Хәбибуллин. *Милләттәшләр белән татар халкының киләчәге турында фикер алышканда, мин сигез төрле концептуаль юнәлеш сизәм: глобализм, русизм, татарчылык, татарстанлык, төркичелек, төрки-славянлык, исламизм, этник сепаратизм.* Р.Вәлиев

РУСИСТ *и. рус* Русистика белгече. *Мин грузин алдында татарларның дөньяга җитәрлек дәрәҗәдә күп күренекле шәхесләр биргәнен: урыс телен өйрәнү буенча күренекле галим-русист, беренчеләрдән булып «Игорь полкы турында хикәят»не өйрәнә башлаган Хәйрулла Мәхмүдов турында да әйтмәдем.* Р.Батулла

РУСИ́СТИКА *и. рус* Рус телен, культурасын өйрәнә торган фәннәр җыелмасы. *Тарихи яктан гына аңлатып була торган традицион чиратлашулардан аеру өчен, позицион чиратлашуларны русистикада авазларның үзгәрешләре дип билгелиләр.* М.Зәкиев

РУСИФИКА́ТОР *и. рус* 1) Рус телен, гореф-гадәтләрен, мәдәниятен (гадәттә көчләп) кертүче

2) *информ.* Рус телен кулланганда кирәк булган компьютер программасы

РУСИФИКА́ТОРЛЫК *и.* Русификатор карашлары, позициясе

РУСИФИКА́ЦИЯ *и. рус сәяси* Рус булмаган халыкларны руска әйләндерү, руслаштыру сәясәте

РУСИ́ЯЛЕ *и. к.* **россияле**. *Гасырлар буена төп һәм изге ризык булып саналып килгән ипине русиялеләрнең 19 проценты – һәр унынчы гаилә – авыз тутырып ашый алмый икән.* Татарстан яшьләре

РУСИЯҺ *и. фар. иск.* Йөз каралыгы, кара йөз. *Иң бөек максат безем: хөр мәмләкәт – хөр Русия! Тиз генә кузгалмыйбыз без, и груһе русияһ!* Г.Тукай

РУСЛАШТЫРУ *ф. сәяси* Рус булмаган халыкларны көчләп руска әйләндерергә тырышу, үз милли теле һәм мәдәнияте урынына рус телен һәм гореф-гадәтләрен үткәрү, рус итү. *Берәүгә дә сер түгел, рус теле аралашу чарасы гына түгел, ә үзгә милләтләрне үз-үзләре булып калудан яздыру, руслаштыру коралы буларак та кулланыла.* Р.Зарипов

Руслаштыра бару Торган саен ныграк руслаштыру. *Әле болай да Интернет дигәне балаларны руслаштыра бара*. Мәдәни җомга

Руслаштырып бетерү Тәмам, тулысынча руслаштыру. *Аның исемен, динен, чын тарихын алыштыруны, руслаштырып бетерүне максат итеп куя*. Татарстан тарихыннан хикәяләр

РУСЛАШУ *ф.* Үз милли телен һәм мәдәниятен онытып, рус теленнән һәм гореф-гадәтләреннән файдалану, тел һәм гореф-гадәт буенча руска әйләнү, рус булып китү. *Мәскәү экспансиясе нәтиҗәсендә, Олы Урда татарларының бер өлеше көньякка (бик күбе Госман империясенә) күченә, ә күченми калганнары, казак сословиесенә күчеп, Мәскәүгә хезмәт итә башлый, аннан әкренләп руслаша, православие кабул итә.* Татарстан тарихыннан хикәяләр

Руслаша бару Торган саен ныграк руслашу. *Казандагы татарлар ничек руслаша барса, Төркиядәге татарларга да төрекләшү шул дәрәҗәдә яный, дип уйлыйм*. Безнең гәҗит

Руслаша башлау Руслашу билгеләре күренү. *XVII гасырда да әле, бигрәк тә гасырның беренче яртысында, казаклар, бигрәк тә Дон казаклары, күпчелек татарлар, православие кабул итеп, руслаша башлаган татарлар булганнар*. Безнең гәҗит

Руслаша төшү Бераз руслашу. *Мин үзем, ихтимал, руслаша төшкәнмен*. Ватаным Татарстан

Руслашып бетү Тәмам, бөтенләй руслашу. *Менә аларга күз салсак, монда инде исемнәр аша милләтнең фәҗигасе дә күренә, чөнки агач формасында үстерелгән шәҗәрәдә кайбер ботаклар, ябалдашлар гел руслашып беткән дә булгалый*. Татар әдипләре

Руслашып китү Билгеле бер вакыттан, вакыйгадан соң руслашу. *Бу – төньяк өлкәләрдә гомер-гомердән төрки-татарлар яшәгәнлеген, соңыннан тарихи сәбәпләр аркасында аларның руслашып китүен аңлата*. Безнең гәҗит

РУССОЧЫ *и.* Руссочылык тарафдары яки аны дәвам иттерүче

РУССОЧЫЛЫК *и. тар.* XVIII гасырда яшәгән француз галиме Жан-Жак Руссоның иҗтимагый һәм педагогик тәгълиматына нигезләнгән карашлар системасы

РУ́СЧА *рәв.* **1.** 1) Рус телендә. *Теле русча ачылган бала татарчаны ана теле итеп кабул итә аламы?* Безнең гәҗит

2) Русларга хас булганча. *Ә Казан әлегә русча уйлый, русча фикер йөртә, русча яза, русча сөйләшә.* Р.Вәлиев

2. *с. мәгъ.* Рус телендә булган, рус телендә язылган. *Шуннан Габдулла әфәнде җаны теләгән кадәр русча китапларны алып укый иде.* Г.Камал

3. *и. мәгъ.* Рус теле. *Рус авылы булгач, маржа кызлары да бик чибәр, тик безнең русча чамалы, шуңа күрә танышырга ояла идек.* Өмет. *Русчаны тиз өйрәнү*

РУ́СЧАЛАШТЫРУ *ф. сөйл.* 1) Башка телдә сөйләшкәндә, рус акценты белән, бозып сөйләшү

2) Рус теленә тәрҗемә итү

РУ́ТА *и. лат. бот.* Рутачалар семьялыгыннан, көньякта үсә һәм яфрагыннан эфир мае алына торган, сары чәчәкле, агулы куак үсемлек; сәдәф уты

РУ́ТАЧАЛАР *и. бот.* Ике орлык өлешле, каурыйсыман яфраклы, җимешләре эфир майларына бай булган үсемлекләр семьялыгы атамасы (лимон, әфлисун, мандарин, грейпфрут һ.б.); сәдәфутычалар

РУТЕ́НИЙ *и. лат. хим.* Платина группасына керә торган химик матдә: сорырак көмешсыман төстәге җиңел металл (ювелир әйберләр һәм электр лампочкаларының кылын эшләүгә китә)

РУТИ́НА *и. фр. кит*. 1) Искелек, торгынлык, катып калганлык

2) Механик рәвештә эшләнә торган көндәлек эшләр

3) Эштә, яшәештә эчпошыргыч бертөрлелек

РУТИНЁР *и. фр. кит*. Искелекне яклаучы, иске шаблон буенча эш итүче, иске тәртипләргә ябышып ятучы кеше

РУТИНЁРЛЫК *и.* Рутинага бирелгәнлек

РУХ *и. гар.* 1) Аң, фикерләү, психик сәләт. *Балаларда иң беренче рух тәрбияләүче, фикер уятучы – әдәбият дәресләре.* Татар әдипләре. *Милли аң, милли рух бетеп бара...* Татарстан яшьләре

2) Психик халәт, кешенең, коллективның мораль көче, дәрт. *Менә кайчан кешегә рух кабилияте үз серлелеге белән ярдәм итә, аны тыелгысыз көчкә ия яшьлек буранарыннан саклап кала!* Ф.Яхин. *Ә менә авырып китсә, таягын алып, мин барыбер йөриячәкмен, дип атлап китүе – монысы инде көчле рух билгесе*. Ватаным Татарстан

3) Кешенең эчке, психик дөньясы, кәеф; күңел, йөрәк. – *Бар кешегә дә Кәрим Тинчуринга бирелгән кебек какшамас көчле рух бирелми, күрәсең, – ди Заһидә ханым.* Р.Батулла

4) Материалистик философиядә һәм психологиядә: югары төзелешле материянең аерым бер махсус үзенчәлеге буларак фикерләү сәләте, аң. *Хәер, коммунистик философиягә нигез ташы булган «материя беренчел, рух икенчел», «яшәеш аңны билгели» кебек карашлар да, ахыр чиктә коммунистик рух түгел, ә малга хирыслык җиңәчәген тәгаенли ләбаса?* Р.Зарипов

5) Идеалистик философиядә: дөньяның беренче башлангычы, сәбәбе. *Идеализмның төп карашы бер нәрсәгә кайтып кала: имеш, дөньяның, безнең чолганышыбызның асылы – идея, рух, аң.* М.Абдрахманов

6) Дөньяга караш, мәсләк. *1905 ел революциясе либераль рәк фасылда калыпланган укучы яшьләр хәрәкәтенә яңа рух өрә.* Р.Әмирхан

7) Дәрт, омтылыш, илһам. *Ул татар прозасына киң сулыш бирде, рух һәм дәрт кертте, аны романтик пафос белән сугарды.* Фән һәм тел

8) Дини ышанулар буенча: кешедә материаль булмаган, үлемсез илаһи башлангыч; җан. *Әрвах вә рух – улгән кешеләрнең җаннары*. Г.Тукай. *Әй, нинди рух булсын, ак күлмәкле хатын иде лә ул...* Г. Гыйльманов

9) Дингә, мифологиягә, мистикага ышанучылар өчен: табигатьтән өстен, җисемсез зат (фәрештә, җен-пәри). *Илаһи рухлар эше бу [кеше уйларын укый белү], алар эшенә тыгылырга ярамаганны беләсең бит...* Г.Гыйльманов. *Татарларда Бичура төнге тискәре рух буларак «дан алган».* Ф.Урманче

10) Берәр нәрсәнең төп эчтәлеге, асылы, характерлы үзенчәлеге, юнәлеше. *Ләкин болар Һ.Такташның чын революцион рух һәм тирән социалистик эчтәлек белән сугарылган иҗатындагы төп юнәлеш өчен характерлы түгел.* М.Җәлил. *Кайберләре туган телдә аралаша алмаса да, милли рух – татарлык исән икән, шөкер.* Ватаным Татарстан

11) Кемнең дә булса үз-үзен тотышын, фикерләү юнәлешен билгели торган нигез, башлангыч. *Чыңгыз ханның гаскәрләрендә хөкем сөргән искиткеч катгый тәртип, хәрби җитезлек һәм сугышчан рух җиңүгә китерә.* Р.Фәхретдинов

◊ **Рух бирү** *к.* **рух күтәрү**. *Әлмәндәр – һәрберебезгә оптимистик рух биреп торучы образ*. Ватаным Татарстан. **Рух кертү** *к.* **рух күтәрү**. **Рух күтәрелү** Күңел күтәрелү, дәртләнү, рухлану. *Партизан көрәшләрендә даны чыккан Урал көрәшчеләре булып, аларның исемнәрен ишетү белән рух тагын да күтәрелде*. Ш.Усманов. **Рух күтәрү** Дәртләндерү, рухландыру. *Шул сәбәпле фронттагы сугышчыларның рухын күтәрү, аларны җиңүгә рухландыру өчен, алгы сызыкка җибәрергә Татарстанда 15 концерт бригадасы төзелде.* Р.Батулла. *Хәзер Сабан туеның эчтәлеге үзгәрде: Җыен татарның милли мәдәниятен саклау гына түгел, аның рухын күтәрүче чара да булып тора.* Безнең гәҗит. **Рух өрү** *к.* **рух күтәрү**. **Рух суыну** *к.* **рух төшү**. **Рух сүнү** *к.* **рух төшү**. *Бетсә дә көч-дәрманым, Рух, дәртләр әле сүнмәгән*. Б.Рәхмәт. **Рух сыну** *к.* **рух төшү**. --- *Әхмәтнең әтисе Рәшит Ярулла, абыйлары Габделбари белән Зәкәрия һәм җизнәсе Һади Атласи халык дошманнары буларак гаепләнә. 1938 елда Төркиягә аларның, кеше түзә алмаслык җәзалардан рухлары сынган хәлдә, атып үтерелүе һәм, ниһаять, арыган йөрәкләренең тынганы хакындагы хәбәр килеп ирешә*. Мәдәни җомга. **Рух төшү** Күңеле төшү, төшенкелеккә бирелү. *Күңелсез хәлләр, өметсезлек, рухлары төшкән, Сабантуй уздырырга да хәлләре калмаган.* М.Миначев

РУХАН *рәв. гар. иск.* Рухи яктан. *Мин дә рухан үтерелергә, мәңгегә шул гадәт-йола зинданында калырга хөкем ителгән булсам да, үземнең муллалык тормышымны әллә нинди идеаллар берлә бутыйм, чолгыйм; мулла булып, мәгънәлерәк, тулырак иттереп торуга төшенәм, планнар корам!* Г.Исхакый

РУХАНИ *и. гар.* **1.** Дин башлыгы. *Хак, хакимиятнең дилбегәсен үз кулына алырга омтылган императорга каршы чыгучы руханилар да табыла, әйтик, рухани Нестор: «Аллах адәм баласыннан туа алмый», – дип, соборда үз сүзен әйтә.* М.Хәбибуллин

2. *с. мәгъ. иск. к.* **рухи** (*2 мәгъ.*). *Минемчә, сиңа аны җисмани һәм рухани тарафларыннан тәрбия итәргә кирәк.* Г.Тукай. *Ничек кенә булмасын, дин ул рухани өлкә генә түгел, ул мәдәни, фәнни берәмлекләрне генә түгел, хәтта гадәти күзаллауларны да үз эченә ала, әхлакый нормаларны төзи.* Р.Фәхреддин

РУХАНИЛЫК *и.* Рухани (*1 мәгъ.*) вазифасы. *Узган гасырның 70 нче еллар уртасыннан башлап 2009 елга хәтле патриарх Кирилл төрле шәһәрләрдә төрле дәрәҗәдә руханилык итә.* Шәһри Казан

РУХИ *с. гар.* 1) Рух (*1, 2 мәгъ.*) белән бәйләнешле; *киресе:* **матди**. *Киләчәктә олы шәхесләребезне эзләп табып, бергә җыеп, халкыбызның рухи казанышларына куша алсак, милләтебезнең гомере тагын да ышанычлырак булыр иде.* Р.Вәлиев

2) Кешенең эчке дөньясы, рухы (*3 мәгъ.*) белән бәйләнешле. *Күмәк көч белән башкарылган эштән барыбыз да рухи канәгатьлек алдык.* Кызыл тан

◊ **Рухи азык** Җан азыгы, аң-белем, шәхесне тәрбияли торган күренеш. *Алар рәхәтләнеп ял итәләр, биюләр, чын мәгънәсендә үзләренә рухи азык ала беләләр.* Ватаным Татарстан

РУХИЛЫК *и.* Җанның рухи, әхлакый һәм интеллектуаль мәнфәгатьләренең матдилектән югары торуына нигезләнгән сыйфаты; камиллеккә омтылыш. *Рухилык белән милләтләр, диннәр арасындагы мөнәсәбәтләр проблемасы да нык бәйләнгән*. Татарстан яшьләре

РУХИЯТ *и. гар.* 1) Рухи дөнья, кешенең эчке дөньясы. *Ул [Рухия] инде үзенең сәер халәтенә, яңа рухиятенә (кара, исеменә рас килеп тора тагын!) күнегә башлаган иде инде.* Г.Гыйльманов

2) Рухлар дөньясы. *[Хәлим] Шулай үлем белән яшәү, җир белән күк, хәят белән рухият арасында күпме барыр иде икән, әйтүе кыен, әмма бервакыт аның ярымтере гәүдәсе ниндидер караңгы, тирән яр-чокыр буена килеп чыкты.* Г.Гыйльманов

РУХЛАНДЫРГЫЧ *с.* Рухландыра торган. *Кыскасы, «Горурланабыз, хезмәтләрегезне бәялибез!» дигән рухландыргыч сүзләрне яшьләр һәр чыгыш ясаучы авызыннан ишетте*. Ватаным Татарстан

РУХЛАНДЫРУ *ф.* Илһам, дәрт бирү, илһамландыру, дәртләндерү, көч кузгату, уяту. *Кешеләрне яратуы, аларның гозерләренә игътибарлы булуы, заман сулышын тоеп, зур максатларга омтылып эшли, башкаларны да шуңа рухландыра белүе белән район халкының тирән ихтирамын яулады.* Г.Мөхәммәтшин. *Ул моны ничек аткарып чыгасын, монда ничек яшисен дә анык кына*

белми, --- әмма йөрәгенең яшерен бер почмагында үзенең көченә ышаныч, киләчәгенә өмет яралып, аны әйди, рухландыра, алга омтылдыра иде. Г.Мирһади

Рухландыра бару Торган саен ныграк рухландыру

Рухландыра башлау Рухландырырга тотыну. *– Давай, туган, күрсәт үзеңне, шушындый көчне күрсәтми йөриләрмени? – дип, Фазылны көрәшкә рухландыра башлады*. Ф.Яхин

Рухландыра төшү Тагы да рухландыру

Рухландырып алу Кыска вакытка рухландыру

Рухландырып җибәрү Рухлануга этәргеч бирү. *Чыннан да, Туфан Миңнуллинның бу идеясе бик күп укучыларны канатландырып, рухландырып җибәрде, фольклорга, җырмоңнарыбызга игътибарлырак булырга чакырды.* Р.Миңнуллин

Рухландырып йөрү Һәрвакыт, бөтен җирдә, бөтен очракта, барысын да рухландыру. *Директорыбызның һәр эштә башлап, безне рухландырып йөрүе көч өсти үзебезгә*. Безнең гәҗит

Рухландырып карау Рухландырырга омтылу. *Теге яки бу гамәлгә рухландырып караса да, егетләр башлап тотынырга ашкынмадылар*. Ф.Яхин

Рухландырып килү Электән, күптәннән даими рәвештә рухландыру. *Татар халкының атаклы гармунчысы Оркыя Ибраһимова да озак еллар буе үзенең моңнары белән халкыбызны рухландырып килгән*. Ватаным Татарстан

Рухландырып кую Алдан ук рухландыру. *Әлки хакимиятендә аппарат җитәкчесе булып эшләүче Әнвәр Вәлиев «Шомырт бәйрәме»нә инде авылны көйләгән, кешеләрне рухландырып куйган була*. Ватаным Татарстан

Рухландырып тору Һәрвакыт, бертуктаусыз рухландыру. *Аларны ул рухи-иҗади дәрте белән генә түгел, шәхси үрнәге белән дә зур эшләргә рухландырып торды булса кирәк...* Р.Низамиев. *[Тимер:] Исрафил хәзрәт, син дә минем белән яуга барырсың, син мине рухландырып торырсың!* Р.Батулла

РУХЛАНУ *ф.* 1) Дәртләнү, жанлану, күңел күтәрелү. *Түрә кызы, бертөрле рух вә илһам белән рухланып, хәзерге Ашказар көен җырлап җибәрә*. Г.Тукай. *Каракаш Янбулатка рухланып нидер сөйли һәм Тугзак ариясенең соңында ул тирмәдән баланы алып чыга.* М.Җәлил

2) Жанлану, рух, жан керү, хәрәкәткә килү. *Иртәгә мөселманнар шул олы, изге бәйрәм шатлыгы белән рухланып, уртак сөенечне бүлешү, бергәләп бәйрәм намазы уку өчен мәчетләргә җыелачаклар.* Татарстан яшьләре

Рухлана бару Торган саен ныграк рухлану

Рухлана төшү Тагы да рухлану. *Әлфия апа торып басты да, күлларын канаттай җилпеп, рухлана төшеп, чатнатып җавап бирде.* Сәхнә

Рухланып йөрү Билгеле бер вакыт дәвамында рухланган халәт кичерү. *Мәхәббәттән исереп, илһамланып, йөрәк кылларын чирттергән ниндидер аһәңнәрдән рухланып йөргән вакытларга тиле яшьлек ярты гомерен бирә*. Шәһри Казан

Рухланып китү Тагын да рухлану. *Мин Мөбинәнең шундый матур озатуыннан соң тагы да рухланып киттем.* М.Җәлил

Рухланып кую Кинәт кенә рухлану

Рухланып тору Һәрвакыт, бертуктаусыз рухлану

РУХЛЫ *с.* 1) Билгеле рухтагы. *Ләкин иҗади рухлы кеше тормыш кырыслыгына бирелми, үз максатына ирешә торган була ул.* М.Кәбиров. *Ә.Баянов – партиябезнең XX съезды алып килгән демократик рухлы чорда яза башлаган шагыйрь.* Р.Миңнуллин

2) Күтәренке рухтагы, жанлы, дәртле, шат күңелле

РУХЛЫЛЫК *и.* Югары хисләр, омтылышлар белән сугарылганлык, рухлы булу. *Менә шушы гадилек, югары рухлылык, нәфислек, кеше күңеленең тирән моңы ята бу җырда*. Р.Вәлиев

РУХСЫЗ *с.* **1.** 1) Дәртсез, кәефсез, күңелсез, төшенке күңелле. *Ул бөтенләй үзгәргән, бик ябык, хәлсез, рухсыз, өмидсезлеге йөзенә чыккан.* Г.Ибраһимов. *Ә инде, киресенчә, Ризаэтдин Фәхреддин әйткәнчә: «Әдип вә галимнәре булмаган кавем бәхетсез, мәшһүр кемсәләрен онытkан халык көчсез, әдәбияты булмаган халык рухсыз».* Кызыл таң

2) *күч.* Тормыш әсәре булмаган, жансыз. *Яралы йөрәккә шигырь белән генә яшәү уты өстәп була, рухсыз чор тудырган рухи суык күшектергән җаннарны шигырь белән генә җылытырга мөмкин.* Кызыл таң

2. *рәв. мәгъ*. Дәртсез, күңелсез хәлдә, салкын рәвештә. *Бу хәлдән соң Рөстәм төшенкелеккә бирелә, күңелсез йөри, дәртсез, рухсыз булып кала.* И.Нуруллин

РУХСЫЗЛАНУ *ф.* Рухи яктан үзгәрү, күңелсезләнү, төшенкеләнү. *Көннәр кызу, явымнар юк, халык рухсызлана, борчыла*. Идел

Рухсызлана башлау Рухсызлануга табан үзгәрү

Рухсызланып китү Кинәт, бераз, берникадәр рухсызлану. *Гражданнар сугышының беренче айларында каһарманча сугышкан, армый-талмый эшләгән егет соңгы вакытларда нәрсәгәдер рухсызланып киткән иде*. Ш.Усманов. *– Җәмәгать, – диде Сафин, – шыпыртлап сөйләшүләрне куеп торыйк, мәҗлес рухсызланып китте*. Ш.Камал

Рухсызланып тору Әле, хәзерге вакытта, сөйләү моментында рухсызлану

РУХСЫЗЛЫК *и.* Рухсыз булу. *Манкортлык, рухсызлык, әле өстәвенә психик һәм физик сызлану китерүче наркоманлык афәтеннән ничек котылып була?* Татарстан яшьләре

РУ́ЧКА *и. рус* Язу коралы, каләм. *Тәрәзә төбенә озатылган блокнот белән ручка кабат кызның җылы кулына килеп керде.* Ф.Бәллүр

РЫСКАЛ *и. гар.* Бәхет. *Изге ният – ярты рыскал*. Мәкаль. *Батырлыгың белән алалмыйсың, Ходай үзе рыскал бирмәсә.* Җыр

РЫ́ЦАРЬ *и. нем.* 1) *тар.* Феодаль Европада хәрби-дворян сословиесе вәкиле

2) Шул сословиегә караган, атының да, үзенең дә саклану кораллары тимердән булган, авыр коралланган атлы гаскәр; алпар. *[Париж музеенда] Рыцарьлар рухы аңкый*. Г.Гали. *Колумб Кешелек хәтеренә тәвәккәл диңгезче, материклар ачучы булып кереп калса, Дон Кихот гаделлек каһарманы, бала күңелле рыцарь булып уелып калган.* Р.Фәйзуллин

3) Европада Урта гасырларда барлыкка килгән, Бөекбритониядә хәзергә кадәр бирелә торган шәрәфле титул. *Элтон Джон – бөтен дөньяга танылган җырчы, Англия королевасы аны рыцарь дәрәҗәсе белән бүләкләде.* Безнең гәҗит

4) *күч. кит.* Кемне яки нәрсәне дә булса фидакяр рәвештә яклаучы, аның намусын саклаучы, аның өчен үзен аямаучы кеше; югары фидакяр вөжданлы кеше. *Повестьның үзәгендә торган геройга, аның өчен нинди генә яхшылыклар эшләмәсен, ире Хәйдәр үтә гади һәм гадәти, бернәрсәсе белән дә гаҗәпләндермәстәй кеше булып күренә, ә автобус тукталышында очраклы рәвештә очрашкан ир исә чын рыцарь булып тоела.* М.Кәбиров

РЫ́ЦАРЬЛАРЧА *рәв.* Олы күңеллелек күрсәтеп, чын күңелдән, файда яки рәхмәт көтмичә, рыцарьлар кебек. *Зөлфәтебез дә аларга рыцарьларча игътибарлы иде.* Идел

РЫ́ЦАРЬЛЫК *и.* 1) *тар.* Рыцарь дәрәҗәсе; рыцарь хезмәте

2) Рыцарьлар тормышы, яшәү рәвеше. *Әдипнең «Хыянәт» романын укучылар беләдер, ул үзенең көтелмәгән вакыйгалары, геройлар тотышындагы егетлек белән, француз әдәбиятында заманында бик популяр булган рыцарьлык романнарын хәтерләтә.* Р.Рахман

3) *күч.* Олы җанлылык, интеллигентлык; фидакярлек, чын күңелдән бирелгәнлек. *– Неужели аз гына да рыцарьлык хисе юк синдә? – дигәч, шуның өстенә тагын Фәләхкә ялварулы итеп карап та торгач, каршы килергә урын калмады...* В.Нуруллин. *Үз-үзеңне яхшы, матур тоту Аурупада рыцарьлык заманнарында чәчәк ата.* Татарстан яшьләре. *Ә рыцарьлык чын ир-ат булуны аңлата.* Безнең гәҗит

РЫЧАГ *и. нем. физ.* 1) Таяну ноктасы тирәсендә әйләнә торган балкадан гыйбарәт, азрак көч куеп авыр йөк күтәрү өчен хезмәт итә торган иң гади җайланма. *Ташларны күтәрү һәм горизонталь күчерү өчен дә рычаг хезмәт иткән.* Фән һәм тел. *Ул [кулдагы ике башлы] мускулның түбәнге башы рычаг хезмәтен үтәүче беләк сөягенең таяну ноктасы янына беркетелгән, ә йөк шул рычагның икенче башына тәэсир итә.* Кызыклы физика

2) Берәр механизм белән идарә итү өчен билгеләнгән тотка; кулча. *Дөберт! Арслангали, сискәнеп, күзләрен ачты, кулыннан тормоз рычагы ычкынган икән!* Г.Ахунов. *Бер үк бассейнда яшәүче ике дельфинны ике фигураның берсен күрсәткәндә – сул рычагка, ә икенчесен күрсәткәндә, уң рычагка басарга өйрәткәннәр.* Кызыклы физиология

РЫЧАГЛЫ *с.* Рычагка көйләнгән, рычагы булган. *Мәсәлән, шәраб һәм май җитештергәндә рычаглы, кысып кертү принцибына нигезләнгән чөйле, ә соңыннан бормалы прессларкулланыла.* Фән һәм тел. *Рычаглы тормоз. Рычаглы конструкция*

РЭ́КЕТ *и. ингл.* Куркытып, янап, көч кулланып тартып алудан, талаудан гыйбарәт җинаять. *Бөтен дөнья урлашканда, яшьләребезнең яртысы рэкет белән шөгыльләнгәндә, үз гомерендә бер генә көн дә эшләп карамаган бот буе малайлар, кыска итәкле кызлар «мерседес»ларда чыжылдап узып киткәндә: «Гадел бул, балам!» – дидең ни дә, димәдең ни.* Р.Миңнуллин. *Кооперация тудырган һәм зур акчалар тәмен татыган, хакимиятнең көчсезлеген аңлаган рэкет дигән афәтне инде туктатырмын димә.* Р.Мирхәйдәров

РЭКЕТИР Рэкет белән шөгыльләнүче, куркытып талаучы. *Алтын табучылар артеле тирәсендә Госман кебегрәк кешеләрнең, хәзергечә әйтсәк, рэкетирларның бөтерелүе «Скорцени»ны гаҗәпләндермәде.* Р.Мирхәйдәров

РЭ́КЕТЧЫ *и. к.* **рэкетир**. *Хәзер генә ул ярым пышылдап рэкетчы дип сөйләгән булалар, чынлыкта рэкет әллә ни гомерләрдән бирле бар, бары тик чит илдән кергән яңгыравыклы исеме генә юк иде.* Р.Мирхәйдәров

РЭП *и. ингл.* 1) Музыкада ритмлылык һәм үзенчәлекле речитатив манерасында башкару рәвеше белән аерылып торган стиль; шул стильдәге музыка. *Татар халкының халыкчан җырчысы да, рэп җырлаучысы да, операсы да булырга тиеш.* Кәеф ничек?

2) Үзенчәлекле манерада, гадәттә музыка белән башкарыла торган һәм шушы стильгә туры килә торган рифмалы текст. *Бер төркем мәктәп укучыларының «Руслан һәм Людмила» поэмасын рэп стилендә укуын сәерсенеп тыңлаучылар да, кызыксынучылар да булды.* Ватаным Татарстан

РЭ́ПЕР *и. ингл.* Рэп стилендәге музыка башкаручы, шундый музыка белән мавыгучы кеше. *Илназ исә әле яңа гына рэпер Шәкүр белән яздырган дуэтын безгә тыңлатты.* Кәеф ничек?

РЮКЗАК *и. нем.* Аркага асу өчен махсус тасмалары яки каешлары булган, берничә кесәле юл капчыгы. *Кабинетына иләмсез зур рюкзак асып килеп кергән кешене таный алмый торды ул башта.* Р.Мөхәммәдиев. *Тикмәгә генә бу шәһәргә Җир шарының төрле почмакларыннан аркаларына рюкзак аскан студентлар ябырылмыйдыр.* М. Юныс

РЮ́МКА *и. нем.* Гадәттә исерткеч эчемлек салып эчә торган кечкенә савыт. *Бер үк кашык белән уылдык, маринад алдылар, төрле закускаларга үрелделәр, шул үк вакытта рюмка тотарга да онытмадылар.* М.Галәү. *Бер-ике рюмка җибәргәч, Арслангали сораштыруны көтеп тормады, үзе сөйли башлады.* Д.Каюмова

РЯ́ПУШКА *и. рус зоол.* Сөләйман балыклар семьялыгыннан Балтыйк һәм Төньяк диңгезләре бассейнында яши торган вак балык төре

РЯДОВОЙ *с. рус хәрби* **1.** Командирлар составында булмаган, гади. *Мин сукканнан милиция өлкән лейтенанты Сәлим абый артында өлеп торган рядовой милиционерлар арасына кереп тәгәри.* З.Зәйнуллин

2. *и. мәгъ.* Кече хәрби звание; шул званиедәге солдат. *Мин сугышның беренче көннәреннән үк Кызыл Армия сафына алындым. Артиллериядә рядовой булып хезмәт иттем, кыска вакытлы урта политсостав курсларын үттем.* М.Җәлил

РЯ́СА *и. гр. дини* Христиан руханиларының билләп тегелгән киң җиңле озын өске киеме. *Феодорның юешләнеп беткән ряса чабулары аякларына урала, ул сукмакны көч-хәл абайлап, пычрак җирдә абына-сөртенә бара.* Кызыклы физиология

ЭЧТӘЛЕК

Сүз башы 3
Сүзлектән файдаланучылар өчен белешмә 4
Шартлы кыскартылмалар 10
Татар алфавиты 12
Сүзлек 13

Справочное издание

ТОЛКОВЫЙ СЛОВАРЬ ТАТАРСКОГО ЯЗЫКА

(на татарском языке)

Том IV
(Л – Р)

Редактор *Н.К. Нотфуллина*
Корректоры: *Н.К. Нотфуллина, Р.К. Сагдиева*
Компьютерная вёрстка *Н.Т. Абдуллиной*

Формат 84×108 $^{1}/_{16}$. Бумага офсетная. Гарнитура Times New Roman.
Печать офсетная. Усл. печ. л. 79,8. Уч.-изд. л. 93,2
Тираж 1000 экз. Заказ

Оригинал-макет подготовлен
в Институте языка, литературы и искусства им. Г. Ибрагимова АН РТ
420111, Казань, ул. К. Маркса, 12

Издательство Академии наук Республики Татарстан
420111, Казань, ул. Баумана, 20